# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ЗУР ДИАЛЕКТОЛОГИК СҮЗЛЕГЕ

АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
ИМЕНИ Г.ИБРАГИМОВА

# БОЛЬШОЙ ДИАЛЕКТОЛОГИЧЕСКИЙ СЛОВАРЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

Около 40000 единиц

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2009

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г.ИБРАһИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ һӘМ
СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ЗУР ДИАЛЕКТОЛОГИК СҮЗЛЕГЕ

Якынча 40000 берәмлек

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2009

УДК 811.512.145.28(038)
ББК 81.2Тат-67я2
Т23

Китап 2004–2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын үтәү максатында нәшер ителә.

Редколлегия:
М.З.Зәкиев, К.М.Миңнуллин, Ф.Р.Шәйхиева

Төзүчеләре:
Ф.С.Баязитова (А, Ә, Ж, З, Ө, С, Ш, Э)
Д.Б.Рамазанова (Г, Ғ, К, Қ, Х, Һ, Ц, Ч)
З.Р.Садыйкова (Д, И, Л, О, Р, Т, У, Ү, Ы)
Т.Х.Хәйретдинова (Б, В, Җ, Й, М, Н, П, Ф)

Рецензентлары:
И.Б.Бәширова, Ф.С.Сафиуллина

Җаваплы мөхәррирләре:
Д.Б.Рамазанова, Т.Х.Хәйретдинова

Нәшрият мөхәррирләре:
Р.Н.Шакирова, В.Р.Камалиева, Р.В.Сабиржанов

Т23 Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С.Баязитова, Д.Б.Рамазанова, З.Р.Садыйкова, Т.Х.Хәйретдинова. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2009. – 839 б.
ISBN 978-5-298-01788-6

Сүзлек татар теленең барлык диалектлары буенча тупланган якынча 40000 берәмлекне үз эченә ала. Сүзләрнең мәгънәләре татарча аңлатыла, рус теленә тәрҗемә ителә һәм бай иллюстратив материал белән раслана.

Китап тел галимнәренә, укытучылар һәм студентларга тәкъдим ителә. Хезмәт шулай ук башка өлкәдә эшләүче галимнәр һәм, гомумән, татар мәдәнияте, тарихы, сәнгате белән якыннан кызыксынучы киң даирә укучылар өчен дә файдалы булыр.

УДК 811.512.145.28(038)
ББК 81.2Тат-67я2
ISBN 978-5-298-01788-6

© Татарстан китап нәшрияты, 2009
© Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2009

## СҮЗ БАШЫ

Билгеле булганча, телне урын-ара яссылыкта өйрәнүнең зур әһәмияте бар. Галимнәр, телне нигезле өйрәнү өчен, башта аның җирле сөйләшләрен өйрәнергә, турыдан-туры тыңлап-күзәтеп язып алырга кирәк, диләр, бары шуннан соң гына әлеге телне фәнни тикшереп була дип саныйлар. Урыннарга барып җирле сөйләшләрне өйрәнү, визуаль күзәтү һәм язып алу эше, нигездә, диалектологлар тарафыннан башкарыла.

Татар диалектологиясе, фән буларак формалашканчы, шактый озын тарихи юл үткән. Бу турыда махсус мәкаләләр бар*. Татар тел белемендә диалектология тармагының фән буларак барлыкка килүе XIX гасыр галиме А.Бессонов исеме белән бәйле. Н.Катанов, Г.Әхмәров, С.Малов, 20–30 нчы елларда Ж.Вәлиди, 40–50 нче елларда Л.Җәләй, 50–80 нче елларда Л.Мәхмүтова кебек танылган галимнәрнең эшчәнлеге татар диалектологиясенең фән буларак үсешендә әһәмиятле роль уйнадылар.

Бүгенге көндә җирле сөйләшләрне өйрәнү белән бергә әлегә кадәр тупланган материалларны гомумиләштерү эше дә алып барыла. Ике китаптан торган «Татар халык сөйләшләре» (Казан: Мәгариф, 2008) дигән монументаль хезмәттә барлык татар сөйләшләренең җыелма тасвиры (свод) бирелде, татар теленең зур байлыгы тупланды. Ул татар халкының рухи мирасын, мәдәниятен өйрәнүчеләр өчен бай чыганак буларак та зур әһәмияткә ия.

Телебезнең җирле сөйләшләре буенча сүзлекләр төзелүнең бай һәм кызыклы тарихы булуын күрсәтеп үтүне дә урынлы дип саныйбыз. Билгеле булганча, татар телен фәнни өйрәнү XVII гасырда башлана. Җирле сөйләшләрне тикшерү тарихы да, нигездә, шушы чорга карый дип санарга мөмкин, чөнки беренче татар сүзлекләре аерым сөйләшләргә нигезләнеп төзелгән. Шундыйлардан 1785 елда төзелгән С.Хәлфин сүзлеге урта диалектның Казан тирәсе сөйләшләрен чагылдыра, Дамаскин сүзлеге (1785) – Урта Иделдәге фин-угыр телләре һәм татар теленең мишәр диалекты буенча материалларны эченә алган күптелле сүзлек. И.Гиганов сүзлеге (1804) себер диалектларының сүз байлыгын үз эченә ала. Н.Остроумов (1876, 1892), А.Воскресенский (1894) сүзлекләре керәшен татарлары сөйләшләре лексикасына нигезләнеп төзелгән. Алар телебезнең билгеле бер чорга хас җанлы телен чагылдыралар, шул чорның тормыш-көнкүреше турында бай мәгълүмат бирәләр. Шуңа күрә бу сүзлекләр татар телен, татар мәдәниятен тарихи яктан тикшерү өчен гаять әһәмиятле чыганак булып торалар.

Татар теленең диалекталь лексикасы башка галимнәрнең хезмәтләрендә дә берникадәр чагылыш тапкан. Мәсәлән, Л.Будагов, В.Радлов, Н.Катанов, Г.Әхмәров һ.б. мәкаләләрендә шактый бай материал теркәлгән.

Узган гасырның 40 нчы еллар азагы – 50 нче еллар башында татар диалектларын экспедицияләр оештыру юлы белән өйрәнү активлаша, аерым сөйләшләрнең фонетик һәм грамматик үзенчәлекләрен яктырткан хезмәтләр языла. Бу эш барышында лексик материаллар да туплана һәм, аларны эшкәртеп, диалектологик сүзлекләр (1948, 1953, 1958) төзелә.

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында махсус диалектологлар төркеме оешкач, сөйләшләрне диалектологик атлас төзү максаты белән өйрәнү башлана. Экспедицияләр барышында махсус төзелгән программа (1959) нигезендә бай лексик материал да туплана, һәм 1969 елда «Татар теленең диалектологик сүзлеге» дөнья күрә. Төзүчеләре: Л.Мәхмүтова, Н.Борһанова, Г.Якупова һәм З.Садыйкова. Җаваплы мөхәррире – Л.Мәхмүтова. Бу сүзлек Л.Мәхмүтова тарафыннан төзелгән оригиналь принциплар нигезендә татарча-русча сүзлек итеп эшләнгән. Авторлар, диалекталь лексиканы тулырак чагылдыру йөзеннән, яңа материаллар белән берләштән, әлегә кадәр чыгарылган сүзлекләрдән дә, бигрәк тә 1958 елгы сүзлектән файдаланалар. Татар әдәби теленең формалашуында һәм үсешендә төп роль уйнаган ике зур диалектның (урта һәм мишәр диалектларының) лексик байлыгын эченә алган бу сүзлек татар һәм рус лексикографиясенең традицияләренә таянып, аларны тагын да үстереп төзелә. Аңа кергән сүзләрнең (1400 сүз һәм сүз тезмәләрен эченә алган) билгеле бер өлеше, язучылар тарафыннан әдәби әсәрләрдә кулланылып, әдәби телгә һәм шуннан татар теленең 3 томлык аңлатмалы сүзлегенә дә (1977–1981) кереп китте. Шулай итеп, 1969 елда чыккан диалектологик сүзлек татар әдәби теленең сүзлек фондын баетуда әһәмиятле роль уйнады.

Сүзлектә татарча-латинча-русча үсемлек атамалары (төзүчесе – Н.Борһанова), татар диалектлары буенча кыскача белешмә (авторлары: Л.Мәхмүтова, Н.Борһанова), библиография һәм схематик карта (төзүчесе – Н.Борһанова) бирелә. Ул татар тел белемендә генә түгел, гомумән тюркология фәнендә дә югары бәя ала, әлегә хезмәткә карата күпсанлы рецензияләр басылып чыга.

Сүзлек өчен материаллар туплауда төзүчеләрдән тыш шул чор диалектология группасы хезмәткәрләре Ф.Әхмәтова (Баязитова), Р.Мингулова, Ф.Юсупов, аспирантлар Л.Арсланов, Д.Рама-

---

* Махмутова Л.Т. Краткий обзор истории изучения среднего и мишарского диалектов татарского языка // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 7. Казань, 1989. С. 5–24; Рамазанова Д.Б. О достижениях и задачах татарской диалектологии // Научный Татарстан. 2000. № 3. С. 78–83; Рамазанова Д.Б. Татар диалектологиясе: казанышлар һәм бурычлар // Фәнни Татарстан. 2000. №3. 65–70 б.; Рамазанова Д.Б. Татарская диалектная лексикография и диалектная лексикология на рубеже III тысячелетия // Актуальные вопросы татарского языкознания. Казань, 2002. С. 101–106; Рамазанова Д.Б. Татар диалектларын өйрәнү тарихыннан // Татар халык сөйләшләре. 2 китапта. 1 кит. / Баязитова Ф.С., Рамазанова Д.Б., ХәйретдиноваТ.Х. һ.б. Казан : Мәгариф, 2008. 11–18 б.

занова катнашалар. Болардан кала И.Абдуллин, Г.Вафин, Н.Зимасов, Р.Муллин, М.Мөхәммәдиев, Г.Тавлин, Ф.Фасеев, Р.Якупов та төрле вакытта язып алынган материалларын тапшыралар. Шул рәвешле диалектологик сүзлекне баетуга үзләреннән шактый өлеш кертәләр һәм фәндә билгеле дәрәҗәдә эз калдыралар.

Диалектологик атлас төзү өчен материаллар туплау дәвам итә. 60–80 нче елларда, Идел буе төбәкләрендә таралган сөйләшләр белән беррәттән татар теленең Урал алды, Урал арты һәм Көньяк Урал тирәләрендә формалашкан сөйләшләрен өйрәнү буенча да зур эш башкарыла, шактый бай диалекталь лексика туплана. Нәтиҗәдә 1993 елда «Татар теленең диалектологик сүзлеге»нең Ф.Баязитова, Д.Рамазанова, З.Садыйкова һәм Т.Хәйретдинова тарафыннан төзелгән икенче китабы дөнья күрә. Бу китап та Л.Мәхмүтова җитәкчелегендә һәм аның тарафыннан 1969 елгы беренче китап өчен эшләнгән принциплар нигезендә төзелә. Редколлегия әгъзалары М.Зәкиев, Д.Рамазанова (җаваплы мөхәррир), Т.Хәйретдиновалар була.

Анда нигездә Татарстаннан читтә таралган, беренче китап чыкканда әле өйрәнелмәгән яки өйрәнү стадиясендәге (мәсәлән, бу турыда 1969 елда дөнья күргән беренче китап ахырында бирелгән схематик картаны кәрәгә мөмкин) урынчылыклар һәм сөйләшләр буенча лексик материал чагылыш таба: урта диалектның минзәлә сөйләше, бәләбәй урынчылыгы, мишәр диалектының стәрлетамак сөйләше, хәзерге Башкортстанның төньяк-көнчыгыш (урта диалектның златоуст сөйләше) һәм үзәк (урта диалектның тепекәй, турбаслы сөйләшләре) районнарында таралган татар сөйләшләре, бастан сөйләше тирәсендәге (күршә сөйләше), Ульяновск өлкәсе Барыш районындагы (калда сөйләше), Карсун тирә-юнендәге татар авыллары сөйләшләре татар диалектлары системасында шартлы рәвештә мөстәкыйль берәмлекләр итеп карала. Атлас төзү барышында Татарстанга, Башкортстанга, Чувашстанга, Мари Эл һәм Удмуртиягә, Пермь, Ульяновск, Түбән Новгород, Оренбург өлкәләренә оештырылган контроль экспедицияләр вакытында да шактый лексик материал туплана. Болардан тыш 1983–1985 елларда, диалектологик сүзлекнең икенче китабын төзүне күздә тотып, диалектологлар тарафыннан махсус лексикологик экспедицияләр оештырыла. Татар диалектологлары тарафыннан диалекталь лексиканың тематик төркемнәрен гомумиләштереп тикшерү өчен уздырылган экспедицияләр дә икенче сүзлеккә материалларны тулыландырырга булышлык итә.

Диалектологик сүзлекнең икенче китабы да, беренчесе кебек үк, татар теленең төп ике (урта һәм мишәр) диалектына караган лексиканы үз эченә ала. Ул башлыча яңа материал нигезендә төзелә. Әмма анда беренче китапка кергән сүзләр дә очрый, тик алар башка территориядән язып алынган булган һәм яңа мәгънәләр белдергән. Сүзлектә төзүче-авторларның материалларыннан тыш Н.Борһанова, Р.Әмирханов, М.Әхмәтҗанов, Р.Әхмәтьянов, Л.Җамалетдинов, Ф.Гарипова һәм башка галимнәр тарафыннан диалектологлар карамагына тапшырылган материаллар да файдаланыла.

Икенче китапта да татар диалектлары буенча кыскача очерклар (Д.Рамазанова) һәм татар теленең урта һәм мишәр диалектларына караган библиография (Л.Мәхмүтова) бирелә. Очеркларда татар диалектларына хас үзенчәлекләрнең нигездә беренче китапка кермәгәннәрен генә күрсәтү максаты куела, диалектология фәненең формалашуы, лингвистик география ысулының мөмкинлекләре һәм әһәмияте билгеләнә, Урал тирәсе сөйләшләренең формалашу тарихы бирелә. Бу китапның да татар әдәби телен баетуда роле зур була, фәнгә яңа материаллар, татар теле, аның сөйләшләре формалашу тарихы буенча яңа мәгълүматлар кертелә.

Соңгы егерме елда илебездә барган үзгәрешләр, тарихка, туган телгә игътибарның көчәюе диалектология фәненә мөрәҗәгать итүләрне арттырды. Дөнья күләмендә барган глобализация процессы да җирле сөйләшләрнең роленә яңача караш барлыкка китерде. Туган телне саклауның аеруча әһәмиятле алшартларыннан берсе җирле сөйләшләрне саклау икәнлеге барыбыз өчен дә мөһим мәсьәлә булып тора. Телебез һәм халкыбызны, аның күркәм традицияләрен, тарихын, җир-су атамаларын, мәдәниятебезне саклап калу мәнфәгатеннән рухи мирасыбызны, шул исәптән диалект-сөйләшләребезне өр-яңадан барлау зарурияте җирле сөйләшләрне өйрәнү-тикшерү аспектларын киңәйтте, татар теленең яңа зур диалектологик сүзлеген төзү ихтыяҗын тудырды.

Әлеге сүзлек татар тел белеме һәм мәдәният өлкәсендә эшләүче галимнәргә, массакүләм белгечләргә кирәклеген күздә тотып төзелде. Алда нәшер ителгән диалектологик сүзлекләрдә татар теленең Көнбатыш Себер һәм Әстерхан регионнарында таралган сөйләшләре буенча материаллар чагылмаган иде. Диалектологлар исә төрле төбәкләргә экспедицияләр уздыру барышында өстәмә диалекталь сүзләр дә туплады. Кыскасы, зур диалектологик сүзлек төзү көн тәртибенә килеп басты һәм бүгенге көндә без укучыларыбызга әлеге сүзлекне тәкъдим итәбез.

Бу сүзлек тә диалектология фәнендә танылган һәм камил булып саналган Л.Мәхмүтова принципларына нигезләнеп төзелде. Ул якынча 40000 сүз һәм сүзтезмәне үз эченә ала. Анда барлык татар диалектларының лексик байлыгы чагылыш таба. 1969, 1993 елларда дөнья күргән һәм Д.Тумашева тарафыннан себер диалектлары буенча чыгарылган (1992) сүзлекләрдән тыш әлеге хезмәттә диалектологларның хәзергә хәтле даими уздырылып килә торган экспедицияләр барышында тупланган материаллары да бирелә. Сүзлек ахырында татар диалектологиясе буенча зур библиография китерелә (төзүчеләре: Т.Х.Хәйретдинова, Р.С.Барсукова).

*Дария Рамазанова*

# ДИАЛЕКТОЛОГИК СҮЗЛЕК ТӨЗҮНЕҢ ТӨП ПРИНЦИПЛАРЫ

Диалектизмнарны билгеләүнең критерийлары, диалектологик сүзлек төзүнең төп принциплары Л.Мәхмүтова хезмәтләрендә эшләнгән. Зур диалектологик сүзлекне төзегәндә дә, алда әйтеп үткәнебезчә, шул ук принципларга таяндык.

## ДИАЛЕКТАЛЬ ЛЕКСИКАНЫҢ ТИПЛАРЫ

Диалектологик сүзлеккә кертелгән сүзләрне биш төркемгә бүлеп карарга мөмкин.

1. Әдәби телгә хас булмаган сүзләр, ягъни саф диалектизмнар. Мәсәлән: *азымтык, алсузма, арый, айау, әрлүс, баганчак, баткылчык, бексәм, дегәч, деңгезләү, җәйләү, иртчак, қабызлык, қаса, қулбашлы, қушқалақ, кәбәц, паца, пәтер, тылдақ, үрцән, цала, мешә, озан, песийут, рәшмән, тәлпәк, чабырма, эшкину* һ.б.

2. Әдәби телдәге сүзләр белән аваздаш, ләкин сөйләштә бөтенләй икенче мәгънәдә кулланыла торган сүзләр. Мәсәлән: *думбра* – төклетура; *матур* – әйбәт, яхшы; хуш исле; *песнәк* – сукыр лампа; *қабырга II* – шәл читендәге ачык күзләр рәте; *қурқыныч* – карачкы; *чардак* – чардуган; *киндер* – кычыткан; *алаша* – тәбәнәк; *сакал* – ияк һ.б.

3. Әдәби тел белән чагыштырганда сөйләшләрдә киңрәк мәгънәдә кулланыла торган сүзләр. Мондый очракларда сүзләрнең диалекталь мәгънәләре яки мәгънә төсмерләре генә исәпкә алына. Мәсәлән, *айаз, бәлеш, қатлама, зур, қалақ, қойо, қолга, сашым, таза, әлбә, чишмә* кебек сүзләрнең әдәби телдә билгеле булган мәгънәләре белән диалектологик сүзлектә теркәлгән мәгънәләрен чагыштырып карагыз.

4. Контексттан тыш әдәби мәгънәне белдереп тә, сөйләшләрдә әдәби тел өчен хас булмаган тезмәләрдә кулланыла торган сүзләр. Мәсәлән, *чәчү* сүзе әдәби телдә арыш, бодай һ.б. бөртекле ашлыкларга карата кулланылса, тархан, минзәлә, мәләкәс, карсун, стәрлетамак сөйләшләрендә исә бәрәңге, кәбестә кебек яшелчәләргә карата да әйтелә. Яки әдәби телдәге *кояш* сүзе, себер диалектларында *як* сүзе белән килеп, көнчыгыш мәгънәсен дә белдерә.

5. Әдәби сүзләрнең фонетик вариантлары, кагыйдә буларак, сүзлектә бирелми. Ләкин сөйләштә яшәп килгән ике-өч фонетик закончалык бер сүздә чагылса яки теге йә бу фонетик күренеш сөйләштә аерым сүзләрдә генә күзәтелсә, диалектологик сүзлеккә мондый сүзләр дә кертелде. Мәсәлән: *буwам* – буа, *буйак* – буяу, *бышқы* – пычкы, *зәрзә* – сәрдә, *ирешә* – рәшә, *паца* – бажа, *куца* – хуҗа, *йенце* – энҗе, *әрйен* – әйрән, *сичак* – чәчәк һ.б.

## СҮЗЛЕК МӘКАЛӘСЕНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ

1. Баш сүзләр алфавит тәртибендә бирелә.

2. Сүз тезмәсе составына кергән сүзләрнең берсе хәзерге көндә аңлашылмый торган булса, мондый сүз баш сүз итеп кертелә һәм, бу сүздән соң ике нокта куелып, сүз тезмәсе бирелә.

Мәсәлән:

**ДҮППӘНӘ: дүппәнә шикелле** *лш.* ...

**ҚАРАН II: қаран қалу 1.** *злт.* ...

**НУБЫЙА: нубыйа йем** *төм.* ...

3. Сүз тезмәсе составына кергән сүзләрнең берсе диалекталь сүз булса, сүз тезмәсе шул сүз статьясыннан соң кызыл юлдан бирелә.

Мәсәлән:

**СӘЙЕЛ 1.** *себ.* аяз ...

**сәйел йаңгыр** *себ.* кояшлы яңгыр ...

Бер үк сүзгә караган берничә сүз тезмәсе булган очракта алар алфавит тәртибендә бирелә.

**КАСНИК** [*рус.* косник] **1.** *хвл., кузн., лмб.* ...

**бакалы касник** *тмн.* ...

**куш касник** *хвл.* ...

**челтәрле касник** *кузн.* ...

4. Сүз тезмәсе составына кергән сүзләрнең һәр икесе әдәби булып та, сүз тезмәсе үзенең мәгънәсе ягыннан диалекталь булса, доминант сүзнең хәрефләре ара калдырып языла һәм баш сүз итеп бирелә, русча тәрҗемәсе дә күрсәтелә. Әгәр бу сүз әдәби сүзнең фонетик варианты булса, аның әдәби әйтелеше дә күрсәтелә.

Мәсәлән:

**қ а р** *урт.д., себ.* кар (снег):

**йепкәц қар** *туб.-ирт.д.* йепшек кар ...

**йowан қар, йуwан қар** *төм.* эре кар, ябалак кар ...

**ч ә й I** (чай):

**бәбәй чәйе** *лмб.*, **бәби чәйе** *трх.* бала туу уңае белән уздырыла торган мәҗлес ...

**буш чәй** *дәб.* коры чәй, тәмләткечләр салмаган чәй ...

**қара чәй** *эстр.* такта чәй...

5. Урта яки себер диалектларында һәм мишәр диалектында сүз яки сүз тезмәсе, бер үк мәгънәдә йөртелеп тә, [*г*] – [*ғ*], [*к*] – [*қ*] яки [*в*] – [*w*] авазларының әйтелеше белән генә аерылсалар, мондый сүз яки сүз тезмәләре бер статья эчендә бирелә.

Мәсәлән:

**ЧАҒАЛА** *эстр.*, **ЧАГАЛА** *влгг.* к.: **ақсырдақ**.

**ЧЫДАҚЛЫ** *минз.*, **ЧЫДАКЛЫ** *стрл.* чыдам ...

И с к ә р м ә: мондый сүзләр яки сүз тезмәләре, бер яки берничә мәгънәсе белән бер-берсеннән аерылып торсалар, аерым статья итеп бирелә.

Мәсәлән:

**ЦУЛАК** *срг., тмн.* к.: **чулак** ...

**ЦУЛАҚ** *тбл.* 1. аңлаешсыз ... 2. к.: **чулак**.

6. Башка очракларда диалекталь сүзләрнең фонетик вариантлары үз урыннарында алфавит тәртибендә бирелә. Мәсәлән, **РӘШМӘН** һәм **ЭРӘШМӘН** сүзләре алфавит тәртибендә үз урыннарында китерелә.

7. Мөмкин булган очракларда алынма сүзләрнең чыганагы баш сүздән соң сүзнең таралышын күрсәтә торган билгеләмәләргә кадәр квадрат җәяләр эчендә бирелә: [*рус.*], [*морд.*], [*гар.*] һ.б. Сүзнең ике-өч фонетик варианты өтер аша бер статья эчендә бирелсә, аның чыганагы соңгы вариантыннан соң урнаштырыла.

Мәсәлән:

**КӘЗӘМБИР** *перм.*, **КӘЗӘМИР** [*рус.* кашемир] *злт.* кашемир.

**КУЛАС** *срг.*, **КУЛАСА** [*рус.* колесо] *мам.* к.: **кул′аса 2**.

Көнбатыш телләрдән кергән сүзләр янында [*рус.*] билгесе куела, чөнки алар татар теленә рус теле аркылы кергән. Рус сүзләренең чыганак формасы да күрсәтелә.

Төрки телләрдән кергән сүзләрнең чыганагы күрсәтелми. Кайчандыр төрки телләрдән (шул исәптән татар теленнән) рус теленә кереп тә яңадан татар теленә кайткан сүзләрнең чыганагы шулай ук күрсәтелми. Мәсәлән: *чулка, бирук, бура* һ.б.

8. Аңлатманың русча тәрҗемәсе күпчелек очракта кыскартып бирелә; фигыльләр шартлы рәвештә йә совершенный, йә несовершенный видта гына тәрҗемә ителә.

Мәсәлән:

**МОҚЧОНУ** *к.т.* төпченү (копаться, докапываться, интересоваться деталями).

**ЦАЙБАЛУ** *том.д.* чайкалу, селкенү (качаться).

9. Абсолют синонимнар бер-берсенә җибәрелә.

Мәсәлән:

**ГЕНБАҺАР** *мәл.* к.: **айбагар**.

**ЧАГАК** *чст.-крш.* к.: **с′аваскан**.

Сүзләрнең мәгънәләре яки мәгънә төсмерләре якын булса, русча тәрҗемәдән соң *чаг.*: дип куела.

Мәсәлән:

**БЕЛЕКСЕЗ** ... 2. мәгънәсез, мәнсез (бестолковый); чаг.: **дундук I** ...

**ЧАГУ II** 1. *мам., минз.* калку җир, калкулык (холм, возвышенная местность); чаг.: **қаш I, 1** ...

10. Омонимнар аерым статьяларда рим цифрлары белән билгеләп бирелә.

Мәсәлән:

**КАРАГАЙ I** *байк., стрл.* к.: **қарағай** ...

**КАРАГАЙ II** *мәл.* к.: **қаралчық** ...

**ЦАПМА I** *эчк.* к.: **артча**.

**ЦАПМА II** *саз.я.* ит чабу бүкәне...

11. Баш сүзләрнең һәм сүз тезмәләренең аерым мәгънәләре гарәп цифрлары белән билгеләнә.

12. Сүзнең мәгънәләрен ачыклау өчен, төрле сөйләшләрдән язып алынган мисаллар китерелә. Җөмләләрнең төгәл, аңлаешлы булырга тиешлеген күз алдында тотып, төзүчеләр тарафыннан кайбер мисалларга җәяләр эчендә аерым сүзләр өстәлә.

13. Теге яки бу сүз, сүз тезмәсе төрле диалект, сөйләшләрдә бер үк мәгънәдә (яки мәгънәләрдә) кулланылса, аның таралышын күрсәтә торган билгеләмәләр (кыскартмалар), кагыйдә буларак, баш сүздән соң куела.

14. Сүз төрле сөйләшләрдә төрле мәгънәләрдә кулланылса, мондый билгеләмәләр мәгънәгә бирелгән аңлатма алдыннан куела.

Мәсәлән:

**КАРЫЛӘК** 1. *мәл., клд.* к.: **қарағат**; 2. *клд.* кара җиләк (черника).

15. Сүз яки сүз тезмәсе һәм мисаллар бер генә сөйләштән язып алынган булсалар, мисаллардан соң сөйләш исеме күрсәтелми.

Мәсәлән:

**БАЛАК** *стрл.* к.: **балдақ**. Ызын балаклы ыйык кимәгәч, ыштан балагы күренә шул. Итек балагымда пәке.

16. Китерелгән мисаллар төрле-төрле сөйләшләрдән язып алынган булсалар, сөйләшне күрсәтә торган билгеләмә һәр мисалдан соң куела. Билгеләмә алдыннан сызык куела.

Мәсәлән: **БАЛАЙАК I** 1. *кузн., лмб., карс., срг.* бал тәпәне, бал савыты (кадушка, посуда для хранения мёда). Балайак-балайак бал алганда чөчәмиде, кодагый? Кызың алып киткәндә, йыламинде, кодагый? (*хал.җыр.*) – *кузн.* Агацныкы була балайак. – *лмб.* Туй ничег уза, wат туй шулай уза, бал балайаклап. – *карс.* Кийәү кызга акца биргән, бал бер балайак, пелүш тун. – *срг.* ...

17. Басылып чыккан диалектологик сүзлекләрдәге аңлатмалар аерым очракларда яңа редакциядә бирелә.

Мәсәлән, «Диалектологик сүзлек»нең 2 нче кисәгендә (1953) «башбаш» сүзе «бастырыкны алдан әләктерә торган бау» дип бирелергә тиеш.

18. Аңлатмада этнографик элементларны белдергән сүзләр курсив белән бирелә. Аларның мәгънәсен сүзлектән табарга мөмкин.

19. Хәзергә кадәр әдәби телгә кереп урнашмаган, ягъни диалекталь булып калган сүзләр, әдәби тел сүзлекләрендә бирелүләренә карамастан, бу сүзлеккә дә кертелделәр.

Мәсәлән:

**САҚ III** *том.д.*, **САК III** *миш.д.* юка пальто (тонкое пальто).

**ТУПЫЙ I** [рус.] 1. *мам., блт.* тирәсенә мех тотылган түгәрәк, сай бүрек (женская шапка с меховой оторочкой)...

20. Сүзләрнең дөрес әйтелешен чагылдыру максаты белән сүзлектә кайбер транскрипцион билгеләр кулланылды. Алар түбәндәгеләр:

[′] – тартык авазның нечкә әйтелешен күрсәтә торган билге; хәрефнең уң ягына өскә куела;

[w] – ирен-ирен тартык аваз билгесе;

[d] – әдәби телдәге [*з*] авазын алмаштырып килә торган интерденталь [*з*] билгесе;

[қ],[ғ] – кече тел (увуляр) тартыклары;

[ʾ] – фарингаль тартык;

[¯] – сузык авазның озынлык билгесе;

*я, ю, е* хәрефләре урынына сүзлектә *йа, йә, йу, йү, йы, йе* билгеләре алынды.

## ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР

а) *урт.д.* – урта диалект
*әстр.* – әстерхан сөйләше (Волгоград һәм Әстерхан өлкәләре)
*баст.* – бастан сөйләше (Рязань өлкәсе)
*бәр.* – бәрәңге сөйләше (Мари Эл)
*бгрс.* – богырыслан сөйләше (Оренбург өлкәсе)
*блт.* – балтач сөйләше (Татарстан: Казан арты)
*бөре.* – бөре сөйләше (Башкортстан)
*глз.* – нократ сөйләшенең глазов урынчылыгы (Удмуртия)
*дөб.* – дөбъяз сөйләше (Татарстан: Казан арты)
*злт.* – златоуст сөйләше (Башкортстан)
*каз.ар.* – казан арты сөйләшләре төркеме (Татарстан: Казан арты)
*каз.ар.-крш.* – казан арты керәшеннәре сөйләше (Татарстан)
*кас.* – касыйм сөйләше (Рязань өлкәсе)
*кмшл.* – камышлы сөйләше (Самара өлкәсе)
*кргл.* – каргалы сөйләше (Оренбург өлкәсе)
*крш.* – керәшен сөйләшләре
*к.т.* – кама тамагы сөйләше (Татарстан: Тау ягы)
*к.-уф.* – красноуфим сөйләше (Свердловск өлкәсе)
*лш.* – лаеш сөйләше (Татарстан: Казан арты)
*мам.* – мамадыш сөйләше (Татарстан: Казан арты)
*минз.* – минзәлә сөйләше (Татарстан һәм Башкортстан)
*нгб.-крш.* – нагайбәк керәшеннәре сөйләше (Чиләбе өлкәсе)
*нокр.* – нократ сөйләше (Киров өлкәсе һәм Удмуртия)
*нрл.* – норлат сөйләше (Татарстан: Тау ягы һәм Чувашстан)
*перм.* – пермь сөйләше (Пермь өлкәсе)
*т.кам.-крш.* – түбән кама керәшеннәре сөйләше (Татарстан)
*тпк.* – тепекәй сөйләше (Башкортстан)
*трбс.* – турбаслы сөйләше (Башкортстан)
*трх.* – тархан сөйләше (Татарстан: Тау ягы)
*т.я.* – тау ягы сөйләшләре төркеме (Татарстан: Тау ягы)
*учл.* – учалы сөйләше (Башкортстан)
*эчк.* – эчкен сөйләше (Курган өлкәсе)

ә) *миш.д.* – мишәр диалекты
*әҗе.* – Әҗе авылы сөйләше (Рязань өлкәсе)
*байк.* – байкыбаш (мишкә) сөйләше (Башкортстан)
*влгг.* – волгоград сөйләше (Волгоград һәм Әстерхан өлкәләре)
*карс.* – Карсун авылы сөйләше (Ульяновск өлкәсе)
*клд.* – Калда авылы сөйләше (Ульяновск өлкәсе)
*кузн.* – кузнецк сөйләше (Пенза өлкәсе)
*күрш.* – күршә сөйләше (Тамбов өлкәсе)
*лмб.* – ләмбрә сөйләше (Мордовиянең Ләмбрә һәм Рузаевка районнары)
*мәл.* – мәләкәс сөйләше (Ульяновск һәм Самара өлкәләре)
*м.-кар.* – мордва-каратай сөйләше (Татарстан)
*срг.* – сергач сөйләше (Нижний Новгород өлкәсе)
*стрл.* – стәрлетамак сөйләше (Башкортстан)
*тмн.* – темников сөйләше (Мордовия)
*т.я.-крш.* – тау ягы керәшеннәре сөйләше (Татарстан)
*хвл.* – хвалын сөйләше (Ульяновск өлкәсе)
*чпр.* – чүпрәле сөйләше (Татарстанның Чүпрәле, өлешчә Буа районнары һәм Чувашстан)
*чст.* – чистай сөйләше (Татарстан һәм Самара өлкәсе)
*чст.-крш.* – чистай керәшеннәре сөйләше (Татарстан)
*шрл.* – шарлык сөйләше

б) *себ.* – себер диалектлары
*туб.-ирт.д.* – тубыл-иртыш диалекты (Төмән һәм Омск өлкәләре)
*саз.я.* – саз ягы сөйләше (Төмән өлкәсе)
*тара.* – тара сөйләше (Омск өлкәсе)
*тбл.* – тобол сөйләше (Төмән өлкәсе)
*твр.* – тевриз сөйләше (Омск өлкәсе, өлешчә Төмән өлкәсенең Вагай районы)
*төм.* – төмән сөйләше (Төмән өлкәсе)

в) *брб.д.* – бараба диалекты (Новосибирск өлкәсе)

г) *том.д.* – том диалекты (Томск, Кемерово, Новосибирск өлкәләре)
*клм.* – калмак сөйләше (Кемерово, Новосибирск өлкәләре)
*яүшт.* – яүштә-чат сөйләше (Томск өлкәсе)

д) *гар.* – гарәп теле
*коми.* – коми теле
*мари.* – мари теле
*монг.* – монгол теле
*морд.* – мордва теле
*рус.* – рус теле
*угор.* – фин-угор телләре
*удм.* – удмурт теле
*фарс.* – фарсы теле
*чув.* – чуваш теле

е) к.: – кара
чаг.: – чагыштыр

# ОСНОВНЫЕ ПРИНЦИПЫ СОСТАВЛЕНИЯ ДИАЛЕКТОЛОГИЧЕСКОГО СЛОВАРЯ

Критерии определения диалектизмов, принципы составления диалектологических словарей разработаны Л.Махмутовой. При составлении данного словаря использованы эти же принципы.

## ТИПЫ ДИАЛЕКТНОЙ ЛЕКСИКИ

Слова, включённые в диалектологический словарь, можно разделить на пять групп:

1. Слова, отсутствующие в литературном языке, т.е. собственно диалектные слова.
2. Слова, созвучные с литературными, но имеющие иные значения.
3. Слова, имеющие более широкое значение, чем их аналоги в литературном языке.
4. Контекстуальные диалектные слова.
5. Фонетические варианты слов – в случаях, если в одном слове нашло отражение несколько фонетических законов или то или иное фонетическое изменение слова не является закономерным для данного говора.

## О СТРУКТУРЕ СЛОВАРНОЙ СТАТЬИ

1. Заглавные слова даются в алфавитном порядке.
2. Если слово самостоятельно не употребляется или в настоящее время потеряло своё привычное лексическое значение, то после него ставится двоеточие, а затем приводится словосочетание, фразеологический оборот и т.д.
3. Если диалектное слово употребляется в составе какого-либо словосочетания, то последнее даётся после статьи на это слово; словосочетания и обороты даются в алфавитном порядке.
4. Если слова, образующие диалектное словосочетание, – литературные, то доминантное слово даётся вразрядку и с переводом на русский язык. Если же оно представляет собой фонетический вариант литературного слова, то перед переводом помещается и его литературный вариант.
5. В случае, если слово встречается в говорах диалектов в одинаковых значениях и различается лишь по употреблению звуков [*г*]–[*ғ*], [*к*]–[*қ*], [*в*] – [*w*], то такие слова даются в одной статье.

Примечание: если такие слова отличаются друг от друга по одному или нескольким значениям, то они даются в разных статьях.

6. Во всех других случаях фонетические варианты слов помещаются в алфавитном порядке.
7. После заимствованных слов в квадратных скобках до определения места распространения даётся указание на язык-источник. Слова, заимствованные из западных языков, обозначаются как [*рус.*], т.к. они пришли в татарский язык через русский. Исключение составляют слова из других тюркских языков и слова тюркского происхождения, которые некогда были заимствованы русским языком и снова вернулись в татарский.
8. Переводы толкований значений слов даются сокращённо; глаголы условно переводятся только в совершенном или несовершенном виде.
9. При наличии абсолютных синонимов снабжается толкованием только один из них, остальные отсылаются к нему.

Если слова близки по своему значению или оттенку значения, то после перевода толкования ставится помета чаг.: (сравни) и приводится слово, со значением которого сближается данное слово или его отдельное значение.

10. Омонимы обозначаются римскими цифрами.
11. Отдельные значения заглавных слов и словосочетаний обозначаются арабскими цифрами.
12. После каждого значения слова приводится иллюстративный материал с пометой, указывающей на говор, из которого взят данный пример.
13. Если слово или словосочетание употребляется в одном и том же значении в нескольких говорах, пометы, обозначающие их, ставятся после заглавного слова.
14. Если в разных говорах употребляются разные значения слов, то пометы с указанием говоров ставятся перед толкованием значения слова.
15. Если слово или словосочетание и приведённый пример зафиксированы только в одном говоре, после примера помета не ставится.
16. Если иллюстративный материал приводится из разных говоров, после каждого примера даётся соответствующая помета с указанием на говор, из которого взят пример. Перед указанием говора ставится тире.
17. Толкования слов, имеющиеся в изданных словарях, в необходимых случаях уточнены, т.е. даны в новой редакции.
18. Диалектные слова, обозначающие этнографические элементы и употреблённые при толковании значения другого слова, даны курсивом. Их значения можно найти в словаре.
19. Слова, помещённые в словарях литературного языка, однако не вошедшие в литературный язык, также приводятся в данном словаре.
20. С целью более точной передачи произношения слов в словаре применяются некоторые транскрипционные знаки. Они следующие:

[ʹ] – знак палатализации согласных, ставится справа сверху;
[w] – губно-губной щелевой звонкий согласный;
[d] – интердентальный звонкий согласный;
[қ], [ғ] – увулярные смычные согласные;
[ʾ] – фарингальный согласный;
[¯] – знак долготы гласного.

Буквы *я, ю, е* в словаре передаются сочетаниями: *йа, йә, йу, йү, йы, йе*.

## УСЛОВНЫЕ СОКРАЩЕНИЯ

а) *урт.д.* – средний диалект
*әстр.* – астраханский говор (Волгоградская и Астраханская области)
*баст.* – бастанский говор (Рязанская область)
*бәр.* – параньгинский говор (Марий Эл)
*бгрс.* – бугурусланский говор (Оренбургская область)
*блт.* – балтасинский говор (Татарстан: Заказанье)
*бөре.* – бирский говор (Башкортостан)
*глз.* – глазовский подговор нукратовского говора (Удмуртия)
*дөб.* – дубъязский говор (Татарстан: Заказанье)
*злт.* – златоустовский говор (Башкортостан)
*каз.ар.* – группа говоров Заказанья (Татарстан)
*каз.ар.-крш.* – говор заказанских крещёных татар (Татарстан)
*кас.* – касимовский говор (Рязанская область)
*кмшл.* – камышлинский говор (Самарская область)
*кргл.* – каргалинский говор (Оренбургская область)
*крш.* – говоры крещёных татар
*к.т.* – камско-устьинский говор (Нагорная сторона Татарстана)
*к.-уф.* – красноуфимский говор (Свердловская область)
*лш.* – лаишевский говор (Татарстан: Заказанье)
*мам.* – мамадышский говор (Татарстан: Заказанье)
*минз.* – мензелинский говор (Татарстан и Башкортостан)
*нгб.-крш.* – говор нагайбаковских крещёных татар (Челябинская область)
*нокр.* – нукратовский говор (Кировская область, Удмуртия)
*нрл.* – нурлатский говор (Нагорная сторона Татарстана и Чувашия)
*перм.* – пермский говор (Пермская область)
*т.кам-крш.* – нижнекамско-кряшенский говор (Татарстан)
*тпк.* – тепекеевский говор (Башкортостан)
*трбс.* – турбаслинский говор (Башкортостан)
*трх.* – тарханский говор (Нагорная сторона Татарстана)
*т.я.* – группа говоров Нагорной стороны Татарстана
*учл.* – учалинский говор (Башкортостан)
*эчк.* – ичкинский говор (Курганская область)

б) *миш.д.* – мишарский диалект
*әҗе.* – говор села Әҗе (Азево, Рязанская область)
*байк.* – байкибашевский говор (Башкортостан)
*влгг.* – волгоградский говор (Волгоградская и Астраханская области)
*карс.* – карсунский говор (Ульяновская область)
*клд.* – калдинский говор (Ульяновская область)
*кузн.* – кузнецкий говор (Пензенская область)
*күрш.* – куршинский говор (Тамбовская область)
*лмб.* – лямбирский говор (Мордовия)
*мәл.* – мелекесский говор (Ульяновская и Самарская области)
*м.-кар.* – говор мордвы-каратаев (Татарстан)
*срг.* – сергачевский говор (Нижегородская область)
*стрл.* – стерлитамакский говор (Башкортостан)
*тмн.* – темниковский говор (Мордовия)
*т.я.-крш.* – подберезинский говор (Татарстан: Нагорная сторона)
*хвл.* – хвалынский говор (Ульяновская область)
*чпр.* – дрожжановский говор (Дрожжановский, частично Буинский районы Татарстана и Чувашия)
*чст.* – чистопольский говор (Татарстан и Самарская область)
*чст.-крш.* – чистопольско-кряшенский говор (Татарстан)
*шрл.* – шарлыкский говор (Оренбургская область)

в) *себ.* – сибирские диалекты
*туб.-иртд.* – тоболо-иртышский диалект (Тюменская и Омская области)
*сазя.* – заболотный говор (Тюменская область)
*тара.* – тарский говор (Омская область)
*тбл.* – тобольский говор (Тюменская область)
*твр.* – тевризский говор (Омская область, часть Вагайского района Тюменской области)
*төм.* – тюменский говор (Тюменская область)

г) *брб.д.* – барабинский диалект (Новосибирская область)

д) *том.д.* – томский диалект (Томская, Кемеровская области)
*клм.* – калмакский говор (Кемеровская область)
*яүшт.* – эуштинско-чатский говор (Томская область)

е) *гар.* – арабский
*коми.* – коми язык
*мари.* – марийский
*монг.* – монгольский
*морд.* – мордовский
*рус.* – русский
*угор.* – финно-угорский
*удм.* – удмуртский
*фарс.* – персидский
*чув.* – чувашский

ж) к.: – смотри
чаг.: – сравни

*Л.Махмутова, Д.Рамазанова*

## АЛФАВИТ*

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| А а | Ж ж | Л л | Р р | Һ h |
| Ә ә | Җ җ | М м | С с | Ц ц |
| Б б | З з, d | Н н | Т т | Ч ч |
| В в, W w | И и | Ң ң | У у | Ш ш |
| Г г | Й й | О о | Ү ү | Ы ы |
| Ғ ғ | К к | Ө ө | Ф ф | Э э |
| Д д | Қ қ | П п | Х х | |

* Гамәлдәге алфавитка татар диалектологиясендә кабул ителгән транскрипцион хәреф-билгеләр дә өстәлде.

# А

**АБА** *себ.* к.: **абыстай 1.** Күчереп киләләр кинчәкне кейәү йаққа абалары, йеңгәләре, туган-қардашлары. – *төм.* Инәмнең абалары кийәләр иде қалфақ, бездән олулар киде. – *том.д.*

**АБА(Й) 1.** *минз., нокр., т.кам.-крш., кргл.* абый (старший брат и форма обращения к нему). Моносо минем абам була. – *минз.* Бертуған абасында тордо улым. Безнең аба күпне күргән, сүләргә дә җарата. – *т.кам.-крш.* Абай персидәтел былып торды. – *кргл.*; **2.** *карс., кргл.* к.: **абыстай 1.** Тоздүбәгә бардығызмы, абай? – *кргл.* Абам сиксәндә микән, җитмеш тугызда микән. – *карс.* **3.** *кргл.* хатын, карчык (жена, старушка). Шул бабайның абасы килде. Бичарақай, теге бабай үлмәде, бу абай үлде; **4.** *әстр.* әни, ана (мать). Абамның тастарын сақлап тотам.

**зур абай** *кргл.* әтисе яки әнисенең апасы (старшая сестра отца или матери).

**икөн аба, қарт аба** *әстр.* әби (бабушка). Мамай баланың атасын мақтый, абасын мақтый, икөн абасын мақтый.

**қарт абам** *әстр.* әнисенең апасына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре матери). Қарт абам ди минем сеңлемнең қызы мине. Әйесеннән зур инде мин, әйесенең тәтәсе.

**кендек абасы** *әстр.* кендек әби (повитуха). «Кендек абасын белергә тийеш бала үскәндә, чарылдап җиргә төшкәндә, кендегеңне кискәндә», – диде.

**кичү аба** *том.д., брб.д.* кече кыз туган, бертуган апаларның кечесе (самая младшая из старших сестёр).

**олу аба** *том.д., брб.д.* олы кыз туган (старшая сестра).

**улан абай** *перм.* аналык (матка). Улан абай урныкмаса, бик шәб awырта эч улан тапқач.

**АБАҒА** *эчк.* ябага (слинявшая шерсть). Хайwанның абағасы қойола.

**АБАҒАЙ** *перм., к.-уф.* кызу, кабаланучан, уйламыйча эшләүчән (горячий, суетливый, неосторожный). Безнең малай бертөрле қызу, абағай бик, шуңа қурқам. – *перм.*

**АБАҒЫРУ** *брб.д., том.д.* акыру (орать).

**АБАЖУР** [*рус.* обжора] *злт.* к.: **алйот 2.**

**АБА-ҖАБА** *чст.-крш.* эленке-салынкы (вяло). Аба-җаба кеше бит салына да тешә.

**АБА-ЙЕСНӘ** *брб.д.* апа-жизни (сестра и зять). Қызны озатып китәде абасы-йеснәсе, пес белә ғалдыг инде тойларны.

**АБАЙРАУ** *тбл.* ис китү, гажәпләнү (удивляться). Ник абайрап қалтың?

**АБАҚАЙ** *т.я.-крш.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы.** Әпрәмне Ырым (*ав. ис.*) абакай ди.

**АБАЛАҚ** *себ.* ябалак (сова).

**АБАЛАНУ 1.** *трх.* үрмәләп менү (вскарабкаться). Печәннеккә менеп китәм абаланып; **2.** *каз. ар.-крш.* сөртенү (спотыкаться, оступаться). Мин абаланып җәрийем.

**АБАЛАП: абалап йату** *минз., стрл.* күп булу, аунап яту (быть много, довольно много, валяться некоторое время). Элек менә куйан абалап җатадырыйы. – *стрл.*

**АБАЛАУ I** *лш., кмшл., злт., чст.-крш.* көчле өрү, ярсып өрү (лаять сильно, разъярённо). Эт абалый нәрсәгәдер. Басу қапқасын чыққанда, Этләр қалды абалап (*хал. җыр.*). – *лш.* Эт абалап эрә. Абалап йабышмале. – *кмшл.* Капкаларны ачып кергән чакта, Кара кечекәйе абалый (*хал. җыр.*). – *чст.-крш.*

**АБАЛАУ II** *себ.* лыгырдау (болтать, говорить вздор).

**АБАЛЫ-КҮКӘЛЕ** *том.д.* апалы-сеңелле (старшая и младшая сестра). Мин аны бик йақшы беләм, абалы-күкәле икебез дә беләбез аны.

**АБАМ, АБАУ** *себ.* бертуган апасына эндәшү формалары (формы обращения к родной старшей сестре).

**АБАУЛАНУ** *хвл.* кабалану, ашыгу (суетливо спешить, торопиться). Керүwенә абауланып сүли башлады. Абауланып ашама, пешәрсең. Ни абауланасың, сүлә рәтләп. Бак, абауланган вит!

**АБАУЛАУ** *лмб.* **1.** абайлау, сизенү (насторожиться, догадаться, подозревать); **2.** шикләнү, шүрләү (усомниться, испугаться). Кылупка киткәч абауладым ырышмасыннар дип.

**АБАҺИМ** *кмшл.* к.: **алйот 2.** Абаһим, бетен бawырсақны ашап бетергән.

**АБАҺИМНАНУ** *кмшл.* к.: **абжурлану.** Абаһимнанма инде, диләр.

**АБДЫРАВЫК, АБДЫРАWЫК** *кузн., срг., хвл.* ашыгыч (спешный, срочный; спешно, срочно). Эшебез бик абдырawык тегел. – *кузн.* Минем эшем бик абдырawык. – *срг.*

**АБДЫРАТУ** *лмб., хвл.* ашыктыру (торопить). Катны абдыратты күмәргә. – *лмб.*

**АБДЫРАУ** *миш.д., м.-кар.* **1.** ашыгу (торопиться); чаг.: **абаулану.** Абдырамас идегез. – *кузн.* Абдырап кемдер килә, чәчәдем. Эшкә дә пузналанам, шаңа абдыряйм, дийр. Кайа абдыраган, ыланнары йылыймыни. – *лмб.*; **2.** *срг.* сәер, гажәп (странный, удивительный). Бик абдырау эш.

**АБДЫР-КОБДЫР** *клд.* ашык-пошык (торопливо, наспех, кое-как). Анан абдыр-кобдыр кийенәсең, эшкә китәсең.

**АБЖУР** [*рус.* обжора] *т.я., кмшл., срг., хвл., чпр.,*

*м.-кар.* к.: **алйот 2**; чаг.: **җык; йот**. Абжур да инде бу үрдәкләр, күпме салсаң, шул бетә. – *к.т.* Нигә туксан тугыз пилмән генә алдың? – Йөзне ашарга әллә мин абжурмы? – *чпр.* Әй, чистый абжур булган инде. – *м.-кар.*

**АБЖУРЛАНУ** [*рус.* обжора + *афф.* -лану] *хвл.* чамадан тыш күп ашау (обжорничать). Абжурланып ашап эчен авырттырган.

**АБҖАНАҒА** [*гар.*+*тат.*] *т.я.* к.: **абызморза**. Ирнең агасын, биаганы, абҗанаға дий идек. – *к.т.*

**АБҖИҢГИ** [*гар.*+*тат.*] *т.я.* иң олы абыйсының хатынына эндәшү сүзе (форма обращения к жене самого старшего брата).

**АБЗАГАЙ** [*гар.*+*тат.*] *лмб.* к.: **абз'икай**.

**АБЗА(Й)** *кргл.* әтисе яки әнисенең абыйсы (старший брат отца или матери).

**АБЗАЙ-ЗӘҢКӘЙ** *срг.* абый-җиңги (старший брат и его жена). Абзай-зәңкәй белән сүләшә идек.

**АБЗАР 1.** *т.я.* каралтыда терлекләр ябар өчен бүрәнәдән мүкләп эшләнгән җылы урын (тёплое помещение для скота, сделанное из брёвен). Абзар буралы була, җылы була, қышын гына абзарга җабабыз. – *к.т.*; **2.** *кргл.* кышлыкка саманнан эшләнгән җылы урын (тёплое помещение для скота, сделанное из саманных кирпичей); **3.** *каз.ар., минз., кмшл.* терлекләр ябар өчен тактадан яки читәннән үреп ясалган, ябык һәм кыш өчен салкын урын (закрытое, холодное помещение для скота, сделанное из досок или плетени). Абзар мүкле түгел кәнүшнәй кебек,бәрәннәрне җылабзарга чыгартты. – *минз.*; **4.** *кас.* к.: **йорт 1**; **5.** *минз., трбс., стрл.* каралтылар (надворные постройки).

**абзар алды** *минз.* хуҗалыкта терлек ябу өчен киртә яки читән белән тотып алынган, өсте ачык яки ябык урын (открытый или закрытый загон для скота во дворе; карда).

**абзар керү** *минз.* көзен терлекләрне көтүгә кумый башлау, көтүләрне туктату, терлекне йорта карый башлау (о переходе на стойловое содержание скота). Менә абзар керүгә бозаулар инде (сыерыбыз).

**АБЗАР** *минз.* к.: **абзар 5**.

**АБЗӘБИ** *т.я.* авылда өлкән, укымышлы саналган карчыкларга эндәшү сүзе (форма обращения к наиболее уважаемым пожилым женщинам на селе). Абзәби шулай сүли торганийе безгә. – *к.т.*

**АБЗӘНИ** *т.я., тмн.* **1.** к.: **абзәби**; **2.** *т.я.* элек киленнәр каенаналарына шулай эндәшкәннәр (в старину невесты так обращались к свекрови); **3.** *т.я.* әтисе яки әнисенең апасына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре отца или матери); **4.** *тмн., лмб.* каенатасының апасы яки сеңлесенә эндәшү сүзе (форма обращения к старшей или младшей сестре свёкра). Кан'атасының чистрасы буладыр абзәни. Менә абзәнинең камзулын кийәм әле дә. – *тмн.*

**АБЗ'И** *карс., мәл., стрл.* абый (старший брат и форма обращения к нему).

**абзалим абз'и, абз'и майым, күркле абз'и, матур абз'и, хүрмә абз'и, чибәр абз'и** *карс.* бертуган абыйларга эндәшү сүзләре (формы обращения к родным старшим братьям).

**келәү абзилары** *кузн.* кыр келәвендә башлык булып йөри торган картлар (старики, главари полевого моления). Келәү абзилары була, алар эшти пешерә кыр келәвендә.

**АБЗ'ИКАЙ** *лмб.* элек: килен кеше каенесенә шулай эндәшкән (в старину: форма обращения невестки к младшему брату своего мужа).

**АБЗЫЙ 1.** *нрл.* әтисе яки әнисенең бертуган ир туганнары (родные братья отца или матери и форма обращения к ним); **2.** *хвл., кмшл.* к.: **аба(й) 1**. Сәлә абзый киләдер. Нәҗиб абзыйлар әлдә китмиләрме? Минем әтинең абзыйы. – *хвл.*

**алма абзый, дәү абзый** *нрл.* әтисе яки әнисенең ир туганнарына эндәшү сүзе (формы обращения к братьям отца или матери).

**бер ген(ә) абзый** *мәл.* элек: килен кеше, каенесе бер генә булса, аңа шулай эндәшкән (в старину: форма обращения невесты к младшему брату мужа, если он был единственным).

**зур абзый** *минз.* к.: **абз'и: абзалим абз'и**.

**кечкенә абзый, матур абзый** *нрл.* к.: **алма абзый**.

**мулла абзый** *минз.* к.: **абз'и: абзалим абз'и**.

**тәти абзый, туганый абзый** *нрл.* к.: **алма абзый**.

**шәкерт абзый** *минз.* к.: **абз'и: абзалим абз'и**.

**АБДЫЙ** *минз.* к.: **аба(й) 1**.

**дур абдый, мулла абдый, шәкерт абдый** *минз.* к.: **абз'и: абзалим абз'и**.

**АБЗЫҢКАЙ** *хвл.* яшь киленнең өлкән килендәшенә эндәшү формасы (форма обращения младшей невесты к старшей сношеннице).

**АБИ** *глз.* әби (бабушка).

**ай аби** *глз.* им-том иткәндә телгә алына торган мифологик персонаж (мифологический персонаж, упоминаемый во время заговоров, знахарского лечения).

**белүче аби** *глз.* имче әби (знахарь). Муча пичтә чүмечтә кургашын кыздырып та суга түгилир белүче абиләр.

**кийаш аби** *глз.* к.: **ай аби**.

**АБИТКА** [*рус.* объедки] *хвл., мәл.* к.: **қуwықлық**.

**АБКАЙ** *күрш.* әбекәй (бабуся, бабуленька). Олаңгыналарым абкай-абкай кыцкыралар.

**АБЛ'УГА** [*рус.* оглобля] *тмн., кузн., хвл.* к.: **арыш I**. Арбаның абл'угалары сынган. – *тмн.*

**АБРА** *яүшт.* арба (телега).

**АБРАУ** *нгб.-крш.* коткару; саклау (спасти, выручить; хранить). Алла абрады инде.

**АБРИК: абригы ачылу** *хвл.* гадәттән тыш активлык күрсәтү (слишком активничать).

**АБСЫН 1.** *перм., кас.* килендәшләр (сношенницы, жёны двух или трёх братьев). **Гөлби минем абсыным була.** Абсыннарыгыз тату торамы дип сорыйлар ыйы элек. – *перм.* Ике абсын, икебез дә Эрәшидә атлы. – *кас.*; **2.** *перм.* көндәш (соперница). Бер кешегә ике қатын барса, алар абсын була; **3.** *әстр.* олы килен (старшая сноха). Абсыны – олы килен, кечесе килен була.

**АБСЫНЛЫ-КИЛЕНЛЕ** *әстр.* ике килен-килендәш (жёны двух братьев). Абсынлы-киленле булса татуым дип әйтәде бер-беренә.

**АБУ I** *том.д.* апа (тётя). Ғайшә абу, тегеп бир әле Ходай өчен йаңы көйнәк, бәйрәмгә бик кирәк.

**АБУ II** [*гар.*] *туб.-ирт.д.* гафу (прощение).

**абу қылу** *туб.-ирт.д.* гафу итү (извинять, прощать). Йә, йегет, инте мине абу қыл! Мин сине рәнҗеттем.

**АБУҒАР** *тбл.* ярым үлек хәлдә (полумёртвый).

**АБУРКА** [*рус.* оборка] *миш.д.* к.: **балан II: балан итәк**. Абурканы бишәргә чәке йасыйлар. Итәгочка биш абурка тоталар иде. Эстенә эч эрәт абуркалар салалар иде, тастымалны тегеләй бөкләп, арттан бәләп куйалар иде, кәркешләр белән бәләп чабата кийәләр иде. – *хвл.* Абуркалы күлмәк. – *срг.* Сатин шәл бәлиләр иде элек, аста тастар кала иде – абуркалы тастар, ука белән чигелгән, ычы арттан сәленеп йөри. – *кузн.* Мин чымычкы эчен лаукага бардым, йәш килен абуркалы күлмәк кигән, арт чабуына бастым да, абуркасы сүтелде. – *лмб.*

**АБУРМА** [*рус.*] *карс.* к.: **балан II: балан итәк**. Абурмалы күлмәкләр, сүрәлеп йөри иде берәр абурмасы.

**АБУРТКА** [*рус.*] *әстр.* к.: **балан II: балан итәк**. Күлмәкнең итәгендә абуртка.

**АБЧУК** [*рус.*] *чст.* солыча (овсюг).

**АБЫЗ** [*гар.*] **1.** *карс., тмн.* апа (старшая сестра). Бар, абыз чакыра, диген. – *карс.*; **2.** *тмн., карс.* әтисе яки әнисенең апасына һәм сеңлесенә эндәшү сүзе (форма обращения детей к старшим или младшим сёстрам отца или матери); **3.** *тмн., кузн., карс., лмб.* өлкән хатын-кызга хөрмәтләп эндәшү сүзе (форма почтительного обращения к пожилой женщине); **4.** *тмн.* олырак яшьтәге укыган ир кеше (пожилой грамотный человек). Әтекайым шолай ат'кан иде, Мин кызымны бирем абызга (*бәет.*); **5.** *глз.* им-томчы (знахарь). Менәwәрә абыз ул, төрле зәхмәттән уналта. Абызга барабыз күз тисә, олан йыласа.

**абыd бабай** *минз.* әтисе яки әнисенең олы ир туганына эндәшү сүзе (форма обращения к самому старшему брату отца или матери).

**абыз бикәм** *нокр.* иренең апасына олылап эндәшү сүзе (почтительное обращение невестки к старшей сестре мужа). Абыз бикәм белән киңәш иттем туйда.

**абыз йеңкай** *хвл.*, **абыз йиңги** *нокр.*, **абыз йиңкай** *тмн.* абыйсының хатынына эндәшү сүзе (форма обращения к жене своего брата).

**абыз тәтәй** *срг.* әнисенең апасы (старшая сестра матери).

**абыз тутай** *нокр., срг.* бертуган апасына олылап эндәшү сүзе (форма почтительного обращения к старшей сестре).

**абыз түтеш** *кузн.* әнисенең апасы яки сеңлесенә эндәшү сүзе (форма обращения к старшей или младшей сестре матери).

**абыd түткәй** *минз.* апасына яки өлкән кыз туганына хөрмәтләп эндәшү сүзе (форма уважительного обращения к старшей сестре или родственнице).

**ал'ым абыз, йәүһәр абыз** *лмб., хвл.* яшь киленнең каенсеңелләренә эндәшү сүзе (формы обращения невестки к младшим сёстрам мужа).

**йәш килен абыз** *хвл., чпр.* күршеләре яки туганнарының яшь киленгә хөрмәтләп эндәшү сүзе (почтительное обращение к невестке соседей или родственников). Йәш килен абыз, тозлы капыстан бик тәмле булган. Йәш килен абыз эшне белеп эшли. – *чпр.*

**күркле абыз** *лмб., хвл.* к.: **ал'ым абыз**.

**уналтучы абыз** *глз.* к.: **абыз 5**. Уналтучы абыз булгалады элек, хәзер дә бар уналтучы абыз.

**АБЫЗАГАЙ** [*гар.+тат.*] *лмб.* к.: **абз'икай**.

**АБЫЗАПА** *чст.* **1.** к.: **абзәни 3**; **2.** иренең апасына эндәшү сүзе (форма обращения невестки к старшей сестре мужа).

**АБЫЗАСТАЙ** *мәл., чст.* каенсеңелләренә эндәшү сүзе (форма обращения невестки к младшим золовкам).

**АБЫЗӘБЕКӘЙ** *бөре.* әтисенең җиңгәсенә балалары шулай эндәшә (форма обращения к жене старшего брата отца).

**АБЫЗӘБИ 1.** *бөре.* әтисенең апасына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре отца); **2.** *перм.* өлкән хатын-кызга хөрмәтләп эндәшү сүзе (форма обращения к пожилым женщинам). Зираттан қайтып бара абызәби.

**АБЫЗӘНИ 1.** *перм.* кендек әби (бабка-повитуха); **2.** *тмн.* иренең апасына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре мужа). Кийәүдән ыстарши булса, абызәни әтә.

**АБЫЗБАБАЙ** *т.я., минз., бөре.* әтисе яки әнисенең иң өлкән абыйсына эндәшү сүзе (форма обращения к самому старшему брату отца и матери).

**АБЫЗБИКӘ, АБЫЗБИКӘМ** *нокр.* к.: **абызапа 2**.

**АБЫЗБИКӘЧӘЙ** *нокр.* к.: **абызастай**.

**АБЫЗДӘДӘЙ 1.** *тмн.* к.: **абызбабай**; **2.** *хвл.* хатынының бертуган абыйсына эндәшү сүзе (форма обращения к старшему брату жены).

**АБЫЗҖИҢГИ** *т.я., чст., перм., нокр.*, **АБЫЗҖЫҢКА** *тмн.* иң олы абыйсының хатынына эндәшү сүзе (форма обращения к жене самого старшего брата).

**АБЫЗҖЫҢКАЙ** *кузн.* к.: **абыз 3**.

**АБЫЗЗ'ЫҢКАЙ** *кузн.* әтисе яки әнисенең иң олы абыйсының хатынына эндәшү сүзе (форма обращения к жене самого старшего брата отца или матери).

**АБЫЗЙЕҢГӘЙ** *нокр.* к.: **абҗиңги**.

**АБЫЗЙЕҢГИ** *тмн.*, **АБЫЗЙИҢӘ** *кузн.* к.: **абызз'ыңкай**.

**АБЫЗЛАЧЫН** *тмн.* каенсеңлесенә яки иренең туганнан туган кыз кардәшенә эндәшү сүзе (форма обращения к младшей сестре или двоюродной сестре мужа).

**АБЫЗМОРЗА** *тмн.* иренең абыйсына эндәшү сүзе (форма обращения невестки к старшему брату мужа).

**АБЫЗТӘТӘЙ** *тмн.* к.: **абызәни 2**.

**АБЫЗТҮТЕШ** *кузн.* к.: **абзәни 3**. Абызтүтешем бар иде, анарга сүли иде әнийем. Әнийемнең игәче ул, абызтүтеш әтәбез.

**АБЫЗТҮТИ** *тмн.* **1.** к.: **абыз 1, 2**; **2.** к.: **абзәни 3**. Абызтүти, ашарга кил, диләр пләмәнчаның оланнары.

**АБЫЗЫМ** *тмн.* к.: **абызәни 2**.

**АБЫЗЫН** *том.д.* иренең сеңлесе (младшая сестра мужа).

**а б ы й** (брат):

**туганым абый, тумачи абый** *трх.* әтисенең абыйсына эндәшү сүзләре (формы обращения к старшему брату отца).

**АБЫКА** *лмб.* әби, әтисенең әнисенә эндәшү сүзе (бабушка, форма обращения к матери отца).

**АБЫРАТ** [*рус.* обратно] *глз.* сепараттан чыккан сөт (обрат). Абыратны кайванга эчертәбез, корт йасыйбыз.

**АБЫН-ТӨБӨН** *кузн.* абына-сөртенә (спотыкаясь).

**АБЫРУ** *бәр.* куу, куалау (гнать, гонять). Сарык абырганда, җыгылып кулын сындырган.

**АБЫСТА** [*гар.+тат.*] *т.я., нокр., кмшл.* апа (старшая сестра). Абыстаңа сәләм әйт. Абысталы-сеңелле бер җортка төшкәннәр. – *к.т.* Бар, абыстаңны чакыр, җаучы килде, сөлге бирәм, ди әнийем. – *нокр.*

**айак себергец** *чст.* аяк сөрткеч тастымал (полотенце для вытирания ног). Кан′атага айак себергец, намазлык бирәләр.

**айақ сынау** *нгб.-крш.* пасха көнне беренче кергән кешенең аягы җиңел булырмы дип сынау (обычай гадания в день пасхи: кто первый зайдёт в дом, лёгкая ли у него нога). Иртә белән торасын да, беренче кергән кешене мендәргә утырта да черләтә, күкәй, камфит бирә, ул айақ сынау була, җәннек-җәрәшкә, тawық-чебешләр, маллар ишәйсенгә.

**айак такта** *м.-кар.* чабата табанына беркетелгән агач табан (деревянная подошва, дощечка, прикреплённая к лаптям). Айак такта куйган чабатлар кидек су үтмәс эчен.

**айақ тарту** *туб.-ирт.д.* көзән җыеру (сводить ноги судорогой).

**айақ тарыту** *сазл.* аяк басмау (не ступить ногой). Айағыңны тарытма өйгә.

**айак тебе** *мәл.* к.: **айагасты**. Йөри-йөри айак тепләрем калмады.

**айақ туны** *себ.* ыштан (штаны). Марлыдан айақ туны тегәбез, кәфеннек марлыдан була. – *төм.*

**айақ тупсасы** *каз.ар.-крш.* к.: **ашық II, 2**.

**айақ цандыры** *эчк.* к.: **чәлтер**. Айақ цандыры сынған әттәмнең.

**айақ цицү** *том.д.* аяк чишенү (разуться).

**айак чәпәге** *чст.* к.: **айақ бите**.

**йул айағына** *бөре., к.т.*, **китәр айакка** *тмн.* киткәндә, юлга чыкканда (перед дорогой). Китәр айакка цәй эцәр идең. – *тмн.*

**тирес айақ** *әстр.* җен-пәрине шулай әйтәләр (так говорят о нечистых силах: о джиннах, бесах и т.д.). «Шайтан алып китәр, тирес айақ», – дип, безне қурқыта булғаннар балаларны. «Әнә, тирес айақ килеп йатыр», – дисә, қурқып қачалар иде.

**АЙАҚ III** *перм.* үсемлек сабагы (стебель растений). Әрем ақ айақлы, қандала печәне – қызыл.

**айаққа үсү** *перм.* к.: **азу 2**. Айаққа ғына үсте дә үсте, мәсә қылына баса, чәчәк атмады (гөл).

**АЙАҚ IV** *минз., перм.* киги, тәгәрмәч теше (спицы колеса). Күпчәк қайындан, аныға тишек уйып, айақ қағалар. – *перм.*

**АЙАҚ V** *бөре.* берничә иңнән тегелгән әйбернең бер иңе (одна из полос материи, из которых состоит тканевая вещь). Чаршау суғадырыйық туғызар айақ итеп.

**АЙАҚ VI** *минз.*, **АЙАК** *стрл.* карават яки өстәл кырыена тотылган чигүле йә челтәрле кашага яки эскәтер (скатерть, вышитый или кружевной подзор у кровати или стола).

**АЙАҚ VII** *бәр., нокр.* ит түшкәсенең дүрттән бер өлеше (четверть туши мяса). Иңгелек йартыға бүләләр, аннары айақлап бүләләр, дүрт айақ бер қuwыш була. – *бәр.* Бер айақ ат алдым, қазылық йасадым. – *нокр.*

**АЙАҚ VIII** *лш.* сабан көлтәсеннән куела торган чүмәлә (копна, которая ставится из снопов яровых хлебов).

**АЙАКЛАЙ** *глз.* түшкәнең дүрттән бер өлеше бөтен көе (четверть туши в неразрезанном виде). Айаклай аласызмы итне?

**АЙАҚЛАНУ I** *туб.-ирт.д.* аякка басу, сәламәтләнү (встать на ноги, поправляться).

**АЙАҚЛАНУ II** *перм.* сабакка утыру, сабаклану (выпустить стебель, выйти в трубку). Алары үлмәде, шы көwө айақлана инде (гөл турында).

**АЙАКЛАНУ** *клд.* гайрәтләнү, усаллану (разозлиться, ободриться, расхрабриться). Анасы алнында әтә вет, анамны сев, әле анасы айаклана инде.

**АЙАҠЛАУ** *минз.*, **АЙАКЛАУ** *стрл.* мичкә ягу өчен тизәктән сугылган кирпечләрне өчәрләп өеп кую (способ сушки кизяка, приготовленного для топки). Әле генә айакладык кизәкне. – *стрл.*

**АЙАҠЛЫ** *перм.* тәпи йөри башлаган бала турында (о ребёнке, начавшем ходить). Ызур қыз, айақлы инде у чақта.

**айақлы болыт** *туб.-ирт.д.* тиз генә явып үтеп китә торган болыт (быстро проходящая дождевая туча).

**АЙА'-САЙА'ЛЫ** *кас.* ярлы-ябага, ярлы халык (беднота, раньше богачи так называли бедных людей).

**АЙАКСУ** *стрл.* хәрәкәтчән – бала турында (любящий ходить, живой, подвижный – о ребёнке). Бик айаксу булды бу бала.

**АЙАҠТАН** *нокр.* к.: **айағочта**. Аларның (балаларның) ул ғәдәт инде: айақтан ашап йерү.

**АЙАҠТУН** *себ.* ыштан (штаны). Қышын қалын айақтун кигәннәр. – *төм.* Айақтунны пау мән кигән, пиштән чалып үрәләр. – *тбл.*

**АЙАҠЦУ** *брб.д.* к.: **сарғыч: айақ сарғычы.**

**АЙАҠЦЫ** *төм.* кунак сыйлаучы (человек, ухаживающий за гостями).

**АЙАКЧА** *мәл., кузн.* кошларның аякларына салынган тамга, билге (метка, тавро на ногах птиц). Тавыкларга айакча тегәргә кирәк. – *мәл.* Ьавадыйн очкан ике асыл кош, Берсе айакчалый, берсе буш (*хал. жыр.*). – *кузн.*

**АЙАҠЧЫ** *минз., бгрс., себ., әстр.*, **АЙАКЧЫ** *стрл.* мәҗлес уздырганда аш-су әзерләргә булышучы (женщина, помогающая хозяйке готовить обед для приглашённых гостей). Ике айакчысы бар иде. – *бгрс.* Ничә кешегә әйтәде айағ өстендә йөрмәгә, айақчыларға. – *әстр.* Ирләр чыккачтын айакчы дип күрше-тирәләрне, туйда йөргән кешеләрне чакырып ашата торганнар ыйы. – *стрл.* Айақчы тип әйтәтеләр, патнус тотаты йеңгәләр, патнусга бawырсағы пулаты, кампит-пәлән, йемеш, йөсем. Айақчы булып кемнәр оста йырлағалы, кемнәр оста кеше көрмәт иткәле, алар йөргән. Кеше сыйлағалы йөргәннәр. – *брб.д.*

**АЙАЛ** *туб.-ирт.д.* эскерт яки түбәдәге саламны кысып тора торган, парлап беркетелгән бастырыклар (перемотка: попарно связанные сверху жерди, прижимающие солому на скирдах или кровле).

**АЙАЛАУ** *каз.ар., бгрс., кргл., нгб.-крш.* кәҗә мамыгын аяда тарау (расчёсывать козий пух специальным гребнем). Мамық айалап утырам. – *нгб.-крш.* Мамық айаласым бар. – *мам.*

**АЙАНМАУ** *перм.* көчне кызганмау, аямау (не щадить себя). Фирмыда awыр эш тип кермиләр ийе, мин айанмадым, эшләдем.

**АЙАНУ** *перм.* кызгану, жәлләү (жалеть). Ақчаны айанып қына тота ул.

**АЙАП** [*гар.*] **1.** *эчк.* күп, бик күп (много, очень много). Анда жиләк айап!; **2.** *саз.я.* гаҗәп (удивительно, удивительный). Айап кән тимесен анта цейә, ицкем йыймасын!

**АЙАПМА** *саз.я.* бик (очень). Айапма ыспай, айапма солу.

**АЙАРА** *нокр.* иске ай бетеп яңа ай туганчы булган ара (отрезок времени, проходящий после четвёртой четверти луны до нарождения молодого месяца). Айара кен ай булмай.

**АЙАСЛАУ** *брб.д.* аязу (проясняться – о погоде).

**АЙАТ** *әстр.* ишек төбе (прихожая).

**АЙАУ** *туб.-ирт.д.* **1.** кызгану (жалеть). Әрғайсы үс паласын айайты. – *тбл.* Бы йигиткә бирәтегәннән айамағын, ни сураса, бир. – *тара.* **2.** кызганыч (жалко, жалкий). Утын айау түгел, мин мунцатан ойалам. – *тбл.*

**АЙАУЛЫ I** *эчк.* к.: **айап I.** Айаулы жыйдығызмы жиләк?

**АЙАУЛЫ II** *эчк.* **1.** авырткан, авырта торган (больной). Айаулы жиренә тидегезме әллә?; **2.** *тмн., нгб.-крш., бгрс., карс.* к.: **ардақлы**. Әбигә ынык бик айаулы була. – *тмн.* Берәүнең бер айаулы ғына баласы диләр. – *нгб.-крш.* Айаулы күзгә чүп төшә (*әйтем*). – *бгрс.* Кыш көнендә сыwык була, утын бит инде айаулы. – *каре.*

**АЙАУЛЫ-АРДАҚЛЫ** *стрл.* к.: **атаулы 1.**

**АЙАУСЫЗ 1.** *т.я.* оятсыз (бесстыжий, циничный). Айаусыз кеше ул, қатын-қызлар жанында әллә ниләр сүли. Аузында жыйын айаусыз сүз. – *к.т.*; **2.** *злт.* бик, искитәрлек, чамасыз (очень, чересчур, слишком). Ул малайым уңған минем айаусыз.

**АЙБАҒАР** *блт., каз.ар.-крш., т.кам.-крш., нгб.-крш., брб.д.*, **АЙБАГАР** *миш.д.* көнбагыш (подсолнечник). Айбағар утыртқан ыйым, ашап беттеләр қарчық-қорчықлар. – *нгб.-крш.* Айбағар чәчәләр ийе. – *каз.ар.-крш.* Айбагар бармы лаукада? – *срг.* Айбагар цүпләрең белә идәнне цүпләмә. – *чет.* Йоморка сыттым, айбагар майы салдым (камырга). – *кузн.* Апа, айбагар ашыйсыңмы? Айбагарлар чәчәк ата инде. – *мәл.*

**АЙБАҒЫР** *каз. ар.-крш., нгб.-крш.*, **АЙБАГЫР** *мәл.* к.: **айбағар**. Айбагыр майымы бу? Айбағыр утырттық. – *каз. ар.-крш.* Бүген калхуз айбағырын ташыйлар. – *нгб.-крш.*

**АЙБАҒЫШ** *каз.ар.-крш.* к.: **айбағар**. Найди тәтәдән айбағыш сора. Айбағыш майы.

**АЙБАЛТА** *нокр., туб.-ирт.д.* ит чапкыч, кечкенә балта (тяпка). Айбалта белән чабалар иде итне, утын балтасы белән дә. – *нокр.*

**АЙБАР I** *мәл., чст.* к.: **айбағар**. Айбар утадылар. – *мәл.*

**АЙБАР II** *әстр.* матур (красивый, привлекательный). Айбар булып күренде йаулығың.

**АЙБАРЛАНУ** *тмн.* озак маташу, акрын кыймылдау (копошиться, возиться, медлить, мешкаться). Бик озак айбарланма, йулдашларың китәдер.

**АЙБАТАҚ** *саз.я.* иркә (избалованный, изнеженный).

**АЙБАҺАР** *мәл.* к.: **айбағар**.

**АЙБЫНУ** *брб.д.* юану (утешаться).

**АЙБЫНЫШУ** *туб.-ирт.д.* курку, шүрләү (бояться, трусить). Айбынышып кәпләшмәйтеләр. – *тара.*

**АЙБЫТУ** *брб.д.* юату (утешать).

**АЙВАН** [*гар.*] *күрш.* хайван (животное, скотина). Айваным акыллы, белә ул Шарик.

**АЙҒАЛАШУ** *брб.д.* бәйләнешү, тарткалашу (связываться с кем-либо, ссориться). Син ул кәрәкмәгән кеше менән айғалашып йөрмә.

**АЙҒАЛУ** *туб.-ирт.д.* маташу (возиться, копошиться). Айғалам та йөрәйем тawықлар пелән. – *тара.*

**АЙҒАШ** *туб.-ирт.д.* болганчык – су турында (мутный – о воде).

**АЙҒАШТЫРУ** *туб.-ирт.д.* охшату (уподоблять). Исемне айғаштырып қуйабыс: Шамил, Камил, Наил. – *тара.*

**АЙҒОЛАҚ** *саз.я.* саңак калканы (жаберная крышка).

**АЙГЫ** *т.я.-крш.* айлык (месячный). Әле бит минеке биш айгы бала бар.

**а й г ы р** (жеребец):

**айгыр җеретү** *м.-кар.* нардуган көннәрендә ат булып киенеп чыгу (нарядиться лошадью в дни святок). Айгыр булалар, җеретәләр айгырны. Зур корманы сәнәккә тыгалар, ул колаклы була, ат була беҗек. Айгырлы әйтелә.

**айгыр үләне** *кузн.* к.: **баллыкай**.

**АЙҒЫРАҚ** *брб.д.* **1.** яшь айгыр (молодой жеребец); **2.** колынчак (жеребёнок).

**АЙГЫРЛЫ** *м.-кар.* к.: **айгыр: айгыр җеретү**.

**АЙҒЫРЦАҚ** *себ.* к.: **айгырак. 1,2.**

**АЙДАР** *әстр.* **1.** малайларның баш түбәсендә алмыйча калдырылган чәче (чуб, пучок волос, оставленный на макушке – у мальчиков); **2.** этәч кикриге (петушиный гребешок, гребень).

**АЙДАУ** *брб.д., тбл.* куу, куып җибәрү, куып алып китү (гнать, прогнать, угнать). Йирән Чичән бу үгесне хатынына айдап килде. – *тбл.*

**АЙДАШ** *минз., стрл.* бер үк айда туган кешеләргә карата (о людях, родившихся в одном и том же месяце). Фәнүр белән айдашлар алар. – *стрл.*

**АЙДУР** [*рус.* одёр] *трх.*, **АЙД'УР** *чст.* к.: **ад'ур 2.**

**АЙДЫН** *тбл.* тышкы як, тышкы кыяфәт, төс (наружность, внешний вид, цвет).

**АЙЙАБАБА** *хвл.* бик каты гаҗәпләнгәндә әйтелә торган сүз (слово, которое употребляется при сильном удивлении). Айябаба, тамаша, кәбәм!

**АЙҚА** [*удм.?*] *нокр., глз.*, **АЙКА** *глз.* әти-әни йорты, туып үскән йорт (родительский дом). Туй беткәч, бераздан кыз айкасына кечатнаға бара кейәwe йағыннан қызлар ийәртеп. Анда тәбәгый алып бара, бәлеш белән қайта. – *нокр.* Минем айка йыртым бар ич әле. Әнийемнең айкалары йугарырак торалар ыйы бездән. – *глз.*

**айқасына бару** *нокр.* туйдан соң яшь киленнең үз әти-әнисе йортына килүе. Атна кич (пәнҗешәмбе) көннәренең берсендә яшь килен, кияве ягыннан берничә кызны иярtеп, үзенең туган йортына кунакка килә (гостевание, приход невесты в гости в свой родной дом). Айқасына қунаққа бара кийәү белән қыз. Қода узғачын, қыз белән кийәүне қунаққа чақыралар. Ат белән барғанда, кийәү аттан төшә қапқаға йитмәстән алда. Атны туқтаталар ылча башында. Қыз үзе генә ойалып керә. Арттан кийәү керә: «Рөхсәт бармы мыңа кермәгә». Кийәү инде рөхсәт сорап қына керә қапқадан.

**АЙҚАЛАНУ** *перм.* буталу, чуалу, тик тормау (вертеться, сидеть неспокойно). Айқаланма, айқалыб утырма.

**АЙҚАЛАУ** *перм.* болгату, бутау (мешать, размешивать); чаг.: **атлау**. Қаймақны айқалыйбыз йазғанда.

**АЙҚАЛУ** *туб.-ирт.д.* к.: **айғалу**.

**АЙҚАСАН** *саз.я.* зур казан (большой котёл).

**АЙҚАУ** *брб.д.* атыну (качаться на качелях).

**АЙЛА** *себ.* хәйлә (хитрость). Айламан үлтергәле булды. – *твр.*

**АЙЛАҒАН** *саз.я.* айлар буена сузылган (длящийся месяцами). Айлаған қунақ пулмақма?

**АЙЛАҚ** *әстр.* бик, бигрәк тә (особенно, очень). Wақ турғай айлақ күп.

**АЙЛАНА** *тбл.* тирәли, әйләнә-тирәдә (вокруг, около).

**АЙЛАНТЫРУ** *себ.* әйләндерү (вращать, превращать, перевернуть наизнанку).

**АЙЛАНУ** *себ.* әйләнү (кружиться, вертеться, обходить вокруг чего-либо). Пашым айланып китте.

**АЙЛАПҚЫЧ** *минз., кргл., кмшл., т.кам.-крш.* к.: **алҗапма**. Мин бит әле килен булмаған айлапқыч кийәргә. – *кмшл.* Айлапқычы айлы-айлы, Сөйләгән сүзе җайлы (*хал. җыр.*). – *т.кам.-крш.*

**АЙЛАУ I** *төм.* айну (отрезветь).

**АЙЛАУ II** *твр.*, **АЙЛАҢ** *төм.* әйләнеч (обходной).

**АЙЛУ, АЙЛЫ** *төм.* к.: **awыр II**.

**АЙЛЫ'** *кас.* айлык хезмәт хакы (месячная зарплата). Зур айлы' аласынмы?

**АЙЛЫҚЧЫДА** *мам.* даими эштә (на постоянной работе). Әни, айлыкчыда күпме эшләгәнне беләсеңме? Үзем дуңгыз қарыйм, айлыкчыда бит инде.

**АЙМАҒЫСЫ** *к.-уф.* к.: **берче 4**. Сарыкларны, қош-қортларны аймағысын тоқонға кертеп йаптым. Ул бала-чағаның аймагысы ике көн эшләгәнне мин берүзем бер көндә эшләп ташлыйм.

**АЙМАҚ 1.** *мам., минз., к.-уф.*, **АЙМАК** *чст.* төбәк (определённый район, участок). Ул аймақтағы awыллар аймағы белән шул җыйынға керә инде. – *мам.*; Awылда алты аймақ. – *к.-уф.*; **2.** *минз.* к.: **курмыйш**. Менә бу аймакта мин генә бит (картлардан); **3.** *перм., злт., к.-уф.* төркем; күп, ишле, мәс., гаилә (много людей; большая, напр., семья). Без аймағыйе дә суң, хәзер икәү генә. Без аймақ булдық, туғыз ыланнар ийе без. – *перм.* Аймақ кеше булғас, эш тиз бетәр. – *к.-уф.*; **4.** *злт., брб.д.* нәсел (род). Awылда аймақлар күп безнең. Мулла аймақлары күп безнең. Мулла аймақлары айырым күмелгән. – *злт.* Йитегез йите аймақка таралған. – *брб.д.*

**АЙМАҚЛАП** *перм., к.-уф.* **1.** бергә-бергә, берг-

әләшеп, күмәкләшеп (совместно, вместе, сообща, коллективно). Җитенне тиз генә аймакlап эшләп алыйк әле, төшлеккә бетерербез. Аймакlап җылга буйга барып утырыйк, кызлар, әйдәгез. – *перм.;* Аймакlап әзерләнәбез туйга. – *к.-уф.*; **2.** к.: **аймак 3.** Аймакlап чебеч карадым.

**АЙМАКЛАУ** *брб.д.* учлап алу, уч белән алу (брать горстями).

**АЙМАКЛАШЫП** *перм., к.-уф.* к.: **аймакlап 1.** Аймакlашып килеп керделәр дә идәнемне таптап чыгып киттеләр. – *к.-уф.*

**АЙМАЛУ I** *тбл.* тотып алыну (быть схваченным).

**АЙМАЛУ II: аймалу балта** *брб.д.* кечкенә балта (маленький топорик).

**АЙМАМ** *саз.я.* уч (горсть). Пер аймам аш алтым.

**АЙМАН** [*гар.*]: **айман белән** *каз.ар.-крш., к.т.* иминлек белән, исәнлек белән (с благополучием). Ай күрдем айман белән, Аузым тулы иман белән, Айга – айлык, мәңа – саулык (яңа туган айны күргәч картлар әйтә торган сүз). – *каз.ар.-крш.*

**айман көйөннән** *т.кам.-крш.* акрынлыктан, сүлпәнлектән (от медлительности, вялости, нерасторопности). Айман көйөннән тәм тапкан кешедән нидий өмет бусын дий.

**АЙМАНЫШУ** *тбл.* көрәшү, бер-берсенә ябышу (бороться, схватиться).

**АЙМАТ** [*рус.* омёт] *чст.-крш.* к.: **күбә III, 1.** Ике аймат печән калды былында.

**АЙМАТУ** *тбл.* тоттыру (заставить схватить, дать себя схватить).

**АЙМАУ I** *саз.я.* учлап алу, уч белән алу (брать горстями).

**АЙМАУ II** *тбл.* **1.** тотып алу, әләктереп алу (схватить); **2.** тоткa (ручка, рукоятка).

**АЙМАХ** *саз.я.* токым (потомство, племя).

**АЙМУТ** [*рус.* омёт] *чст., срг., мәл., чпр., шрл.* печән яки салам эскерте (скирда, клад сена или соломы). Элгәре урак көлтәсен җыйганны кибәнгә куйалар иде, хазер кибән йуг ул, саламны, печәнне аймутка куйалар. – *чст.*

**АЙМЫЛ: аймыл булу** *лш.* каушау (растеряться). Аймыл булып киттем, берәү кинәт кычкырган ыйы да.

**АЙМЫЛЫШ 1.** *бөре.* аркылы-торкылы (крестнакрест). Күкрәкчәнең баулары аймылыш була; **2.** *срг., чпр.* буталчык, таный алмаслык (неразборчивый, запутанный). Аймылыш йазган хатны, укып та булмый. – *срг.*; **3.** *срг., лмб., шрл.* ялгыш, хаталык белән (по ошибке, неправильно, случайно). Аймылыш кына чәчкән теге малай мыны. – *лмб.* Аймылышмы куйылган? – *срг.* Сүзен аймылыш сүли, шолай да бирми, ул кире була. – *шрл.*

**АЙНА** [*фарс.*] *әстр.* көзге (зеркало).

**АЙНАНАЙ** *бгрс., кргл.* к.: **апайым 2.** Миңә чәй кирәкми, айнанай.

**АЙНӘК** [*фарс.*] **1.** *төм.* күзлек (очки). Кәлимә йеңкәгә йасып йебәрепте, миңа та айнәк йебәрсен тип, йебәрепте; **2.** *том.д.* к.: **айна.**

**АЙНЕ** [*фарс.*] *әстр.* әйе (да – утвердительная частица). Син кишә килдең, айне?

**АЙНИКАР'АМ** *кузн.* кызны кияү йортына озатканда җырлана торган җырлар (песни, которые исполняются при проводах невесты в дом жениха). Бөтен awыл йогора кыз алырга килгән йиргә, айникар'ам ишетергә. Йегетләр кабак төбендә айникар'ам йырлап тыралар инде: Айникар'ам бу җиһанда Син тудыңмы анадин. Син тумагансың анадин, Җан иңгәндер hawадин (*хал. җыр.*).

**АЙНУ I** *саз.я.* уйдан кире кайту (передумать, раздумать). Өй алутан айнытым.

**кире айну** *кргл.* кире уйлау (передумать). Ул барасы булган да Аримбурга, аннан кире айныган.

**АЙНУ II** *себ.* әчү (становиться кислым – о вине).

**АЙНЫК** *әстр.* яшен (молния).

**АЙНЫПТЫ: күзен айныпты** *әстр.* берәр кеше ерак юлдан кайту уңае белән уздырылган мәҗлескә килгән кешеләр тарафыннан әйтелә торган сүз (слово, которое произносят гости, пришедшие на угощение, организуемое в честь возвратившегося из дальней дороги, из армии и т.д.). «И, тәтәм, күзен айныпты», – диделәр.

**АЙНЫШУ** *саз.я.* к.: **айну I.**

**АЙOWБАБАW** *кас.* к.: **каткантун.**

**АЙРА** *минз.* башка төрле, икенче төрле, үзенә бертөрле, аерым (иной, другой). Аның (ниндидер үсемлекнең) йапрагы айра була.

**айра түтәрәм** *т.я.* төрле урыннардагы җир участогы (земельные участки земли на разных местах). Элек җирне җарымбиш, түтәрәмнәр белән үлчиләр ийе; икe түтәрәм бер җарымбиш була, җарымбишнең түтәрәмнәре төрле урында булса, айра түтәрәм диләр ийе. – *трх.*

**АЙРАWЫК I** *мам.* куермаган, изелмәгән, һәрнәрсәсе аерылып тора торган – аш турында (несгустившийся, неразварившийся – о супе). Ашым айрawык кына, дерә әйбәт булган.

**АЙРАWЫК II** *мам.* сирәк, вакыт-вакыт (изредка, временами). Айрawык кына китерә кәзер, җыш китерми кеше баланы.

**АЙРАWЫК III** *минз.* **1.** к.: **арлак.** Суганнардан айрawык тегеләрнеке бакча; **2.** озынрак (подлиннее). Ирләр моннан айрawык итеп озон тун кийәләр.

**АЙРАWЫК IV: айрawык печән** *минз.* бекмания.

**АЙРАН 1.** *перм.* к.: **әйрән.** Сауган сөттән айран ойотам; **2.** *брб.д., к.-уф.* май әйрәне (сыворотка, оставшаяся после пахтанья масла). Сөтнең қаймағын май итеп пешәбес. Әмде аныкы майын алдык, айранын эчәсең. Үсең қолдан йасаган май айраны. – *брб.д.* Айранны қайнатып, айран эчерә тоган бала туган қатынга. – *к.-уф.*

**айран май** *к.-уф.* к.: **май I: ас'лан май.** Айран майны қайнатабыз мичкә қуйып, май туртасы чыга.

**айран сыу** *к.-уф.* май әйрәне (пахтанье). Айран сыу дип, қаймақ сыу дип әйтәләр.

**май суккан айран** *глз.* к.: **айран сыу.** Бәбәй анасына май суккан айран эчертәләр.

**АЙРАХ** *саз.я.* елганың икенче ягы (противо-

положный берег реки). Айрахларга пер қалац, песхә мең қалац.

**АЙРЫ: сәнәк айры** *перм.* озын саплы, өч яньле агач сәнәк (деревянные вилы с тремя развилинами). Сәнәк айрылары белән үwәләр печинне.

**АЙРЫҒОЙРЫҚ** *туб.-ирт.д.* к.: **айрықойрық**.

**АЙРЫЙАҚ** *брб.д.* черви (в картах).

**АЙРЫҚ** *себ.* **1.** аерылган (разведённый); **2.** аерым (раздельный).

**АЙРЫҚ: айрық йул** *себ.* юл чаты, урам чаты (распутье, перекрёсток)

**АЙРЫҚОЙРЫҚ** *перм.* карлыгач (ласточка). Йawын булыр, ахры, айрықойрықлар түбән генә очалар.

**АЙРЫМ-COWРЫМ** *хвл.* **1.** аерым-аерым, аерылышып (порознь, по одному; врозь). Айрым-cowрым ашарга килеп йөрүләре бик уңайсыз минем өчен; **2.** урык-сурык (урывками). Айрым-cowрым ашап-эчеп ауруга саптырыр.

**АЙСА** *мам., каз.ар.-крш., минз., нгб.-крш., хвл.* алайса, алай булса (если так, в таком случае). Мә, җегет, син эч айса. Айса җоқоны қалдырганың бүген. – *каз.ар.-крш.* Айса сез қайтқандарақ қуйарбыз чәй. – *мам.* Айса китәм инде мин. – *минз.*

**АЙСАМ** *мам.* к.: **айса**. Өйдәдер айсам. Айсам боз син моно, йазма.

**АЙТАҚ: айтақ цана** *тбл.* кечкенә чана (маленькие сани).

**АЙТЫШ** *тбл.* сүз, сөйләм (речь, изречение).

**АЙТЫШУ** *тбл.* **1.** сөйләшү, әңгәмә кору (разговаривать, беседовать); **2.** әйтешү (ссориться, пререкаться).

**айу I** (медведь):

**айу арбасы** *т.кам.-крш.* авыр сөякле, тупас хәрәкәтле кеше турында (о тяжёлом на подъём, неповоротливом человеке); чаг.: **балбан**. Айу арбасының қайчан билгеләнгән багытқа килеп җиткәне бар сун?

**айу әппәс** *дөб.* алпан-тилпән, ава-түнә, аю кебек – кешенең йөрүе турында (ходить вперевалку, вразвалку – о ходьбе человека).

**айу баба җили'и** *кас.* артыш җиләге (ягода можжевельника).

**айу баланы** *хвл.* к.: **гөләф**.

**айу баласы** *каз.ар., минз., себ.* яшь баланы коендырганда әйтелә торган сүзләр (слова, которые произносятся во время купания маленького ребёнка). Айу баласы, бүре баласы, бүреккә саласы. – *блт.* Айу баласы, бүре баласы, бүреккә саласы, йалан төлкесе. – *минз.* Баланы йомшақ йапырақ белән сыпыра инәлек қортқайақ мунчада, баланы йуwaты: «Минем балам түгел, айу баласы, бүре баласы, мунса ташы, бүрәнә башы, бүре теше». – *төм.*

**айу башы** *чст.* к.: **баллықай**.

**айу булу** *т.кам.-крш.* нардуганда аю булып киенү (наряжаться как медведь в дни святок). Тунны әйләндереп кийеп айу булалар.

**айу бырыны** *стрл.* к.: **ғөләф**. Айу бырыны даруга да җарый, диләр, әптиккә җийалар аны.

**айу қамыры 1.** *злт.* к.: **камыр: камыр йемеш**; **2.** *чпр., байк., стрл.* к.: **гөләф**. Айу камыры бакчада бар. – *чпр.*

**айу қапчығы** *себ.* ана аю (медведица).

**айу көпшәсе** *бөре.* к.: **айу табаны 2**.

**айу күзле** *нрл.* к.: **қаплама-қамыш**.

**айу күсле** *себ.* баланы күз тигәннән имләгәндә әйтелә торган ырым сүзе (заклинательные слова, которые произносятся во время заговаривания от сглаза). Өстендәге кейемнәрен салғысып имнәйләр: «Айу күсле булсын, күкерт күсле булсын, күк күсле булсын, йәшел күсле булсын, күк булып күкрәсен, йәшен булып йәшнәсен». – *тбл.*

**айу табаны 1.** *мам.* сукыр кычыткан (пустырник); **2.** *мам., каз.ар.-крш.* испәрәк (живокость высокая).

**айу чикмәне** *т.я.-крш.* Яңа ел, нардуган көннәре (святки, святочные дни). Айу чикмәнен кетеп тырабыз ыйы кийенеп чыгабыз дип.

**айу чикмәненә чыгу** *т.я.-крш.* раштуа бәйрәме көннәрендә була торган уеннарда катнашу (участвовать в играх во время рождественских праздников, в святочных увеселениях). Җыйылып керәләр җегермешәр җегет, кыз, алар кермәгис ачынып тырабыз ый, алар бийеп чыгалар ыйы, әллә ниләр кийенеп чыгабыз ыйы, матур чапле кийенәбез ийе, айу чикмәненә чыгу була.

**айу шоморыт** *перм.* бүре җиләге (волчьи ягоды). Үкмәшеб-үкмәшеб үсә йафрақ түздә, баллы була, нийә ашамаға йарамыйдыр ул айу шоморытны.

**инә айу** *себ.* к.: **айу қапчығы**.

**йер айу** *нокр.* каты таракан, коңгыз (земляной таракан, жук). Йер айу җирдә була.

**АЙУ II** *себ.* әйтү (говорить). Артық сүс аймас идем. – *том.д.*

**АЙУБАШ** *кузн.* туку станы детале, сугылган киндерне урап куя торган агач (деталь ткацкого станка). Киндерне выт кирәк чолгарга. Ул айубаш була. Айубашында боргоч тайагы була. Тайак тыгасың, киндер катып тора.

**АЙУКАМЫР** *кузн., мәл., лмб., чст., хвл.* к.: **гөләф**.

**айукамыр гөле** *кузн., хвл.* роза – бүлмә гөле (роза – комнатный цветок).

**айукамыр талы** *лмб.* к.: **гөләф**.

**АЙУҚУЗҒАЛАҚ** *перм.* ат кузгалагы (щавель конский).

**АЙУЛЫЙ** *стрл.* аю кебек (подобно медведю). Бу айулый бии.

**АЙУТАБАН** *перм.* к.: **айақ II: ағас айақ**.

**АЙУЧЫ** *лмб.* аю ияләндереп, аны авылдан авылга йөреп биетеп, шуның белән көн күрүче кеше (человек, приручивший медведя, занимающийся этим для развлечения людей). Раштывада йергәндә Ләтуш айучы булды, мин айу булдым. Тирес тунымны йабындым, йөземне карага буйадым. Ыланшаклар куркынып качтылар.

**айучы йыры** *лмб.* аю биетүче җыры (песни человека, приручившего медведя). Айучы йырын йырлакладым пләмәнчам эвендә. Айучылар, бүречеләр, бармак ычтан бийүчеләр, Алтawылдан алтмыш хатын, Абыстайны тыйучылар. Айучы буламын ышта, Сатин эшләпәдән тыш та, Көтәчәк булсагыз мине, Килермен киләсе кышка (*хал. җыр.*).

**АЙФАРЛАНУ** *к.т.* матурлану (прихораши-

ваться); чаг.: **куқыртлану**. Байадан бирле көзге қаршында айфарлана инде.

**АЙХАЙ: айхайында да йук** *чпр.* исендә дә юк, уенда да юк (и не думает, и в мыслях нет).

**АЙЦЫҚ 1.** к.: **айчыҡ 2; 2.** *себ.д. тбл.* к.: **аилбаш**.

**АЙЧЫҚ 1.** *минз.* уртасына асылташ куеп, читләрен көмештән челтәрләп эшләнгән бизәнү әйбере, гадәттә ул парлы була һәм яка яки камзул чабуларын каптырып куяр өчен хезмәт итә (парное кружевное украшение из серебра с драгоценным камнем посередине, используемое обычно как застёжка ворота платья или полов камзола); **2.** *себ.* ярым ай (полумесяц). Айчыҡ қуйалар қабер өстенә.

**АЙЧЫК** *стрл.* к.: **айчыҡ 1**.

**АЙШИК** [*гар.*] *миш.д.* гыйшык, мәхәббәт (любовь).

**айшик тотышу** *миш.д.* гыйшык тотышу, яратышу (любить друг друга, влюбиться). Кыз белән малый айшик тотышалар. – *срг.*

**АЙШИКЛЫК** [*гар.* + *афф.* -лык] *карс.* к.: **айшик**. Билләреннән кысып сүүырып үпсәң, Айшиклыкка дәwа шул икән (*хал. җыр.*).

**АЙШЫҚ** *себ.*, **АЙШЫК** [*гар.*] *кузн., хвл.* к.: **айшик**. Айшык йыры. – *хвл.* Қапқадин қарадым сәне, Айшыҡ уты йандыра мәне (*хал. җыр.*). – *тара.*

**айшык булу** [*гар.* + булу] *кузн., хвл.* к.: **айшыклану 1**. Маймыл шул кызга айшык булган (*әкият.*). – *хвл.*

**АЙШЫКЛАНУ** [*гар.* + *афф.* -лану] *кузн., карс.* **1.** гашыйк булу (влюбиться, полюбить кого, что-либо). Айшыкланган кыз белән җегетнең вит терле сүзе була. – *карс.*; **2.** к.: **адалану 1, 2**. Айшыкланган выт шул көтүгә. – *карс.*

**АЙШЫКЛЫК** [*гар.* + *афф.* -лык] *хвл.* к.: **айшик**. Айшыклык йырын йырлый идек, шоно кызлар тыңный иде.

**АЙЫБСА** *перм.* к.: **айса**.

**АЙЫҚ** *том.д., твр.* ачык (ясно, ясный). Алыстағыны айыҡ күрмән, кешене таныман, йәш кәнәйеп китте ғуй. – *яүшт.*

**АЙЫҚЛАП** *туб.-ирт.д.* яхшылап (как следует, хорошенько). Айыҡлап қарап пагайын. – *тбл.*

**АЙЫЛ I** *төм.* түшлек (подбрюшник).

**АЙЫЛ II** *том.д.* авыл (деревня). Ике айыл бергә ийылып йаңғыр теләделәр қуй суйып. Халық күп булды, айылыбыз бик матур иде. – *яүшт.*

**АЙЫЛБАШ** *туб.-ирт.д.* к.: **аилбаш**.

**АЙЫЛБЫЛҒАЧ** *перм.* алай булгач (тогда, в таком случае).

**АЙЫЛДАУ I** *м.-кар.* ахылдау (ахать, охать). Айылдап җерим, билем awырта.

**АЙЫЛДАУ II: айылдап чыгу** *яүшт.* гает көнне, өйдән өйгә кереп, авыл буйлап йөреп чыгу (зайти во все дома деревни, поздравляя с религиозным праздником). Қорбан бәйрәме көнне без, бала-чаға, айылдап чыгабыз, өй боронча йөрибез. Бу гайет көн була, айылдап чыгып күкәй, камфит алып қайтабыз.

**АЙЫЛЛАУ** *себ.* ызманы кысыбрак бәйләү (подтянуть подпругу).

**АЙЫЛУ** *саз.я.* **1.** айну (отрезветь); **2.** сәламәтләнү (выздоравливать).

**АЙЫНДА: айында бул** *әстр.* берәр кеше ерак юлдан кайту уңае белән уздырылган мәҗлескә килгән кешеләргә өй хуҗасы тарафыннан әйтелә торган сүз (слово, с которым хозяин дома обращается к гостям, пришедшим на угощение, которое организуется в честь возвратившегося из дальней дороги). «Айында бул», – дип әйтеп керәде, баласы қайтып күренде, ғуй.

**АЙЫНУ** *глз.* айну, аңга килү (придти в сознание). Серен тиде, айындым сәйәт эчтә.

**АЙЫНЫТТЫ: күзен айынытты** *әстр.* к.: **айныпты: күзен айныпты**. «Күзен айынытты», – дип әйтеп керәделәр. Ул әйтәде: «Айында бул», – дип.

**АЙЫП** [*гар.*] *себ.* гаеп (вина).

**айыба гүрмәң** *себ.* гаеп итмәгез (не обессудьте).

**АЙЫПЛАУ** [*гар.* айып + *афф.* -лау] *себ.* гаепләү (обвинять).

**АЙЫПЛУ** [*гар.* айып + *афф.* -лу] *брб.д.* **1.** гаепле (виноватый, виновный); **2.** җинаятьчел (преступный).

**АЙЫПЛЫ** [*гар.* айып + *афф.* -лы] *брб.д.* бозык, әшәке, гарип (порочный, увечный).

**АЙЫР I** *твр.* елгадан кереп киткән су (речной рукав). Қапқанны су ағып тора торған айырға қорабыс.

**АЙЫР II 1.** *әстр.* сәнәк (вилы). Айырың бар ғуй; **2.** *кузн.* япь (развилка, развилина у вил и т.п.). Синәкнең бер айыры сынган.

**АЙЫРА** *нокр.* бигрәк тә (тем более, тем паче). Аштан сыңра айыра эчәсе килергә тийеш.

**АЙЫРМАС** *әстр.* к.: **ахирәт: ахирәт тус**. Үмерлеккә айырмас булып йәшәдек, серләр уртақ булды.

**АЙЫРУ 1.** *нокр., глз., перм., т.я.-крш., карс.* бүлеп бирү, бүлү, өләшү (разделить, делить, дать). Аш айырдым, ашама булмай, теш сызлай, ди. – *нокр.* Кешегә айырдым. Сандыгыбыз айырмаган. – *карс.*; **2.** *срг.* тешләү, талау (кусать, кусаться). Ничә кешене айырды бу коцок.

**АЙЫРЧА** *блт.* к.: **қайчыгойроқ**. Айырчалар күбәйеп киткән баз өстендә, җүwеш булғач.

**АЙЫРШУ** *саз.я.* аерылышу (разводиться). Йәшәгең килмәгәц айыршайых.

**АЙЫРЫ** *минз.* **1.** аерым (отдельно, особо, самостоятельно). Алар айыры тордолар. Беднең қодабыd ул, бed үdебedгә айыры, үл үdенә айыры, әнә теге өйдә тора ул. Икәү җырладылар, берсе айыры җырлады; **2.** к.: **айра**. Көрән мондый буламыни, көрән айыры була.

**АЙЫРЫҢҚЫ** *минз., перм.*, **АЙЫРЫҢҚЫ** *стрл.* к.: **айра**. Нәрсә айырыңқысыз? – *минз.* Монда Қазанны қарағанда сүләшү күб айырыңқы. – *перм.* Һәрнәстәнең айырыңқысы була, туганнар. – *стрл.*

**АЙЫРЫТ** *тара.* хәйләкәр (хитрый). Ул йақның халғы айырыт.

**АЙЫРЫТЛАНУ** *тара.* хәйләкәрләнү (хитрить).

**АЙЫРЫШ** *перм.* күч, яшь ил (отделившийся рой). Быйыл қортларға килешмәде, айырыш булмады. Айырышны йаңы умартаға йаптым.

**АЙЫШ** *трбс.* эчке мәгънә (смысл, суть). Сүзе-

нең айышына төшөнмим. Ул сүз айышын белми, ахры. Айышына туры китереп әйт.

**АҚ I** *лш., нокр., минз., себ., әстр., яүшт.*, **АК** *стрл.* сөт һәм сөт ашамлыклары (молочные продукты). Җәй айларында аққа туйындык, сыйырларға көтүлектә ашау иркен. – *лш.* Күршең сөткә керә. Үсенең сыйырының сөте бар. Хет йарты ыстакан булса да бирергә йарамый, тиләр. «Ақ өстенә ақ була» ти, йарамый. – *яүшт.* Ит шорпасын ақ қатып эчкәннәр. – *әстр.* Қайбаннарны гидта (абзарда) тотабыз ақ эчен. – *нокр.*

**сөт ақлары** *әстр.* егет ягыннан қыз өенә китерелгән әйберләр (свадебные подарки жениха). Икенче атнага килгәндә тийешле җимешләрен, сөт ақларын алып киләләр тийешле затлары белән.

**сыйыр ағы** *лш., минз.*, **сыйыр агы** *стрл.* к.: **ақ I**. Шул сыйыр ағы белән тордоғ инде ачлық җылларда. – *лш.*

**АҚ II** *урт.д.*, **АК** *миш.д.* туганлык мөнәсәбәтен белдерә торган сүзләр алдында килеп, олылап, хөрмәтләп әйтүне белдерә (слово, употребляемое с терминами родства для обозначения уважительного, почтительного обращения).

**ақ әби** *т.кам.-крш.* әтисенең өлкән кыз туганына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей родственнице отца). Ақ әби дип әйтәбез Гөрпинә әбине, ул безгә оло көнгә киләсе әле, күрерсез ақ әбийебезне.

**ақ бабықай** *минз.* әтисенең абыйсына эндәшү сүзе (форма обращения к старшему брату отца). Ақ бабықай булып, аның тawышы белән эндәште йорт анасы.

**ақ бала** *әстр.* **1.** иренең энесе һәм аңа эндәшү сүзе (форма обращения к младшему брату мужа); **2.** балага иркәләп эндәшү сүзе (ласковое обращение к ребёнку).

**ақ бийем** *т.кам.-крш., нгб.-крш.* иренең апасына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре мужа). Иремнең тутасы мыйа ақ бийем тийешле. – *нгб.-крш.*

**ақ бикәм** *әстр.* әнисенең сеңлесенә эндәшү сүзе (слово обращения к сестре матери). Ақ бикәм әнийемдең қыз туғаны була.

**ақ дәдәй** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* әтисе яки әнисенең иң өлкән ир туганына эндәшү сүзе (форма обращения к самому старшему брату отца или матери). Ақ дәдәй қунаққа киләсейе, Албайда торawыл.

**ак йегет** *срг.* иренең кече энесенә эндәшү сүзе (форма обращения к младшему брату мужа). Ак йегет дидем кеце энесенә.

**ақ қыз** *т.кам.-крш.* иренең сеңлесенә эндәшү сүзе (форма обращения к младшей сестре мужа). «Ақ қыз, күлмәк печеп тегә беләңме?» – димен.

**ақ мулла** *әстр.* кияүнең энесенә эндәшү сүзе (форма обращения к младшему брату мужа).

**ақ пала** *әстр.* к.: **ак бала**.

**ақ печкә** *каз.ар.-крш.* иренең кече сеңлесе һәм аңа иркәләп эндәшү сүзе (форма ласкового обращения к младшей сестре мужа). Ақ печкә белән кичкуйынға чығабыз питырауда тәңкәләр тағып.

**ақ тай** *перм.* әтисенең апасы (старшая сестра отца). Қызлар көл иләп қуйганнар түбәгә (Яңа ел кичне). Безнеке ақ тай иләп қуйған. Читек белән бассалар – байга барасың, чабата белән басса – йарлыға. И ақ тай сықтый, имеш, чабата белән басқаннар көлгә, йарлыға барам тип. Абыйы җурамалый қарап торған да чабата белән басып қуйған иләгән көлгә.

**ақ тәтә** *каз.ар.-крш.* к.: **ақ түти**.

**ақ тутам** *әстр.* әнисенең апасына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре матери). Ақ тутам килен чәйенә чақырма килгән мине.

**ақ түтәй** *әстр.* әтисенең сеңлесенә эндәшү сүзе (форма обращения к младшей сестре отца).

**ақ түти** *каз.ар.-крш.* иренең апасына олылап эндәшү сүзе (форма почтительного обращения к старшей сестре мужа). Ақ түти, гөсләдә уйнап қына утыр, син эшләмә.

**АҚ III 1.** *каз.ар., бгрс., кргл., крш.*, **АК** *чст.-крш.* кызны бирергә килешкәннән соң, кыз ягыннан бирелә торган вәгъдә бүләкләре, гадәттә сөлге яки ашъяулык биргәннәр (подарок со стороны невесты стороне жениха после сговора в знак согласия; дарили обычно белое полотенце или белую скатерть). Аққа ашаулық, бистәрләр бирә қыз; аққа қаршы җегет җағы ақча бирә. Мәтрүнә Ибанга үзе ақ биргән, үзе җаратмыйым дип җылап утыра. – *каз.ар.-крш.*; **2.** *әстр.* хәер итеп бирелгән тукыма (ткань, которую вешают или дарят как подаяние).

**ақ алыштыру** *крш.* вәгъдә бүләкләре бирешү (обмениваться подарками во время помолвки). Ақ алыштыру диләр, җегетнең бер әйберсен қыж җағына, қызның бер әйберсен җегет җағына бирәләр. – *каз.ар.-крш.*

**ақ алышу** *т.кам.-крш.* к.: **ақ алыштыру**. Қыз килешкәндә ақ алышалар ыйы. Алып баралар ыйы пары белән ипей, кийәүгә җанчық чигүле, анарға чикләwек тутыралар ыйы.

**ақ апқайту** *каз.ар.-крш.* қыз ягыннан вәгъдә бүләкләре алып кайту (после помолвки принести подарки со стороны невесты). Әwәл қыж җағыннан ақ апқайталар: аққа бистәрләр, ашаулық бирә қыз, аққа қаршы җегет ақча бирә. Ақ апқайтқаннан сун қыз wәғдәсендә тормаса йә икенче кешегә китеп барса, аның ақ итеп биргән әйберләре белән бозом итеп була, дип сөйләгәннәр. – *каз.ар.-крш.*

**ақ җибәрү** *әстр.* әүлия каберенә элү өчен ак төстәге тукыма җибәрү (дарить, отослать белую скатерть на могилу святых). Ақ җибәрү диләр, әүлийә қаберенә элеп қуйалар.

**аққа салу** *каз.ар.-крш.* ярәшкәч қыз ягыннан егет ягына ак сөлге, ак ашъяулык бүләк итү йоласы (обычай дарить в знак согласия белое полотенце или белую скатерть родственникам жениха со стороны невесты после сговора).

**акны котлау** *чст.-крш.* туй кунакларының килен котлап бүләк бирүләре (поздравления свадебных гостей невесте с преподношением подарков). Туй кунаклары йәш килен суккан сөлгене карап сокланалар, кулдан-кулга йөретеп карыйлар, мактыйлар. «Акны котлыйбыз, йәш килен бәхетле булсын, тигез гомер итсеннәр», – дигән

сүзләрне әйтеп, үзләре алып килгән бүләкләрне подноска куйалар.

**ак өләшү** *әстр.* үлгән кешене бер елдан соң искә алу мәҗлесендә бүләк өләшү (раздача подарков на годовщине смерти). Килгән халыққа барысына да ак өләшәләр, ак җаулык, мийешенә акча төйнәп.

**ак чыгару** *чст.-крш.* туй мәҗлесендә кызның үзе чигеп яки тукып әзерләгән, «ак» итеп биргән сөлгесен яки ашъяулыгын халык алдына чыгарып күрсәтү (вынос подарка невесты – обычно это бывает вышитое полотенце или скатерть – гостям на свадьбе). Туйда миңа әйтә, ак чыгаргын, ди. Мин инде патнуска салдым да чиккән бистәрне: «Агы килә, агы килә, Аг артыннан тагы килә, Алтмыш агасы, җитмеш җиңгәсе, Тулмаганын тутырыгыз, җитмәгәнен җиткерегез, Шалтыратып салыгыз, йалтыратып алыгыз», – дип чыгардым.

**ак элү** *әстр.* изгеләр, әүлиялар каберенә ак төстәге тукыма элеп кую (повесить белую ткань на могилу святого). Әүлийә каберенә ақны элеп куйам.

**ак I V** *урт.д., себ.*, **ак** *миш.д.* ак (белый):

**ак бит** *мәл.* өстенә манный, тары һ.б. боткасы ягып пешерелгән кабартма (лепёшки, испечённые с тонким слоем каши сверху).

**ак йаудым** *саз.я.* к.: **йаңғыр: церетмә йаңғыр**.

**ак мәтрүшкә** *мам.*, **ак мәтрүшкә** *чст., лмб.* меңьяфрак, ярмабаш (тысячелистник).

**ак салу** *әҗе.* күзгә ак төшү (появляться – о бельме на глазу). Ак салган аныкы бер күзенә.

**ак таумашқа** *себ.* ак гөмбә (белый гриб).

**ак тирә** *чст.-крш.* агулы үлән (ядовитая трава).

**ак тирәк** *себ.* кырда бала бишеген элеп кую өчен җайланган өч япьле агач (приспособление, сделанное для подвешивания детской люльки на поле). Цәңгелцәкне аппаратлар талаға. Ақ тирәк тип элеп куйғаннар өч йәпле ағачқа. Үсең урақ урасың, эшләйсең. Талаға паланы алып парса, чебен ашамасқа қороп қуйасың, цәңгелцәккә саласың, шунда ырғап йоқлатасың. Ақ тирәк тип әйткәннәр. «Ақ тирәгеңне қалдырма, анда қуйғалы кәрәк цәңгелцәкне. Пала талата әйбәт йоқлай». – *тбл.*

**көс ағы** *себ.* күз агы (белок глаза).

**АҚ V** [*гар.*] *себ.* хак (правда, истина, право). Әкә-иничилек ақы үчүн. – *твр.*

**АҚА** *себ.* абый (брат). Ақаныңқы бичәләре йеңкәлекләр була туйда, алар сыйлайты қунақларны.

**АҚАЙ I** *кргл.* **1.** к.: **аба(й) 1**; **2.** үзеннән олы ир кешегә эндәшү сүзе (форма обращения к старшему мужчине). Идрис ақай бәйетне башлаучы иде.

**АҚАЙ II** *перм.* к.: **алақай**.

**АКАЙ** *мәл.* кылый күзле (косоглазый). Акай Сирай малайы кат'кан.

**АҚАЙАШКА** *глз.* к.: **акашка**. Ақайашкага кукай буйап оланнарга бирабыз, кырга чачу чачкан йирга алып барабыз.

**АҚАЙ-ЧУҚАЙ** *мам.* к.: **алақай**.

**АКАШКА** *глз.* язгы чәчү алдыннан үткәрелә торган бәйрәм (праздник, проводимый перед весенним севом). Кар астыннан ук йасарлар ыйы акашканы, чачмастан ыл'ык чакта. Акашка йасаганнар абилар.

**акашка әйтү** *глз. акашка*ны бәйрәм итү (праздновать *акашку*). Акашка әйтәләр, чакырышып йөрәләр, буйап йомырка пышыралар йаман айбат итеп.

**АҚБАБАЙ** *әстр.* этисенең өлкән ир туганы (старший брат отца). Ақбабай бабам қаладан қайтты.

**АҚБАЛА** *әстр.* к.: **ақ II: ақ бала**. Ақбала, ақбала, Ақ бозауны бақ, бала. Ақ бозауны бақмасаң, Сиңа қаймақ йуқ, бала. Бу ақбала қайдикән, Қызлар белән туйдикән (*хал. җыр.*).

**АҚБАШ** *мам., блт., дөб.* әнис (анис). Ақбаш – ашый торған үлән ул. – *блт.*

**АҚБИ** *әстр.* кияү ягыннан өлкән қыз туганына киленнең эндәшү сүзе (форма обращения невесты к старшей родственнице мужа). Ақби тәтәм, Қоръән ашына кил.

**АҚБИЗ** *т.кам.-крш.* к.: **бур II**. Ақбизгә бизәгән ийем моржаны.

**АҚДАРУ** *хвл.* **1.** аудару (свалить, повалить). Бур'а белә акдара манарасын; **2.** кою – яңгыр турында (лить как из ведра). Йауды йаңгыр, чиләкләп ақдарды.

**АКИЛУ** *әстр.* алып килү (принести, привезти).

**қачырып акилу** *әстр.* кызны урлап алу (взять девушку в жёны путём умыкания). Қачырып акилсә қызны, барған җирен йаратмаса, бик қаты кәйенә қыз анасы.

**АҚҚА** *твр.* к.: **ақа**.

**АҚҚАЙ** *эчк.* к.: **аба(й) 1**.

**АҚҚАЦЫ** *туб.-ирт.д.* үрдәкнең бер төре (белогоголь).

**АҚҚУ** *әстр.* аккош (лебедь).

**АҚЛАН** *бөре., минз., кмшл., бгрс., перм., трбс., злт.*, **АКЛАН** *байк.* к.: **айаз 1**. Урман ақланында җиләк җыйдым. – *бөре.* Мәндәй ақланы дип йөртәләр. – *минз.* Ақлан печәне йақшы чабарға. Наратлы ақланындағы җиләклекне чапқаннар, әй җиләге күп булайе дә. – *кмшл.* Ақланның печәне күп була. – *кргл.* Бабайлар килеп утырғанда ақлан җир булған, тирә-йақ ачықлық булған. – *бгрс.* Ақланнар йуқ шул инде, фис сөрәләр. – *злт.*

**АКЛАУ** *хвл.* агарту (белить). Менә мин алачык акладым, йаз эчен выта йакшы.

**АҚЛАШУ** *мам., минз., каз.ар.-крш., кмшл., нгб.-крш., перм., кргл.*, **АКЛАШУ** *срг., стрл., чст.* ярәшү, кызны яучылаган егеткә бирергә риза булу (сосватать, просватать невесту). Башта җаучы йөри, эти-әнисе риза булса, ақлашалар аннан. Ақлашқанда инде бүләкләр алышалар, туй турында, җегет җағы нинди әйберләр бирәсе турында сөйләшәләр. Ақлашқачтын туйға әзерләнә башлыйлар. – *мам.* Алар қыd ақлашып қайтқаннар. – *минз.* Элек ақлашалар, ике җақ та килешәләр, күлмәкләр бирәләр. – *нгб.-крш.* Ақлашқанда кемгә қуша, шул килә инде йаучы булып. Йегеткә сөлге, айақ сөрткеч, қулжаулық бирә инде қыз ақлашқанда. – *каз.ар.-крш.* Иң беренче ақлашу була торганыйы. Қыз йанчыққа тутырып читлә-

wек бирә торған ыйы, бер чәй бистәре бирә торған ыйы. Имеш, бу инде ышанмаҡлыҡҡа була. – *т.кам.-крш.* Аҡлашҡанда әйтәләр: «Сез инде ҡаты тормағыз, Без килдек сәбәп белән, Сез тормағыз сәнәк белән», – ди. Күлмәген йә бистәр бирәләр ҡызныҡын. – *нгб.-крш.* Аклашкач, ике йак та килешкәч, баш чагалаган инде, диләр. – *срг.* Кызны ырлашмыйлар бездә, аклашалар. – *чст.*

**аҡлашу бүләге** *минз.* к.: **ак I**. Аҡлашу бүләгенә айаҡ сөрткече, намадлыҡ биреп жибәрәләр, ике жаҡ та әйбер биреш жасағаннар аҡлашу бүләге дип.

**АКЛЕС** [*удм.*] *глз.* алжыта, туйдыра торган (надоедливый, назойливый). Аклес малай, йетте, сикермә.

**АҠЛЫҠ I** *каз.ар.* кыз ягыннан егет ягына вәгъдә бүләге итеп бирелә торган әйбер (подарок со стороны невесты стороне жениха в знак согласия на брак). Сөлге суғам, сөлге суғам, Сөлге суғам аҡлыққа, Қызыл башлы сөлгеләрем йазсын бәхет-шатлыққа (*хал. жыр.*). – *мам.*

**бәхет аклыгы** *хвл.* теләк теләгәндә әйтелә торган сүз (слово, которое произносится во время благопожелания). Мин малайның әнисе белән күрешәм. Әнисе тора да: «Бала гынам, бала гынам, бәхет аклыклары бирсен үзеңә, шатлыклар», – ди, үбә үземе, утыра.

**сөт аҡлығы** *әстр.* егет ягыннан кыз өенә бирелә торган әйберләр – кием-салым, ашамлык һ.б. (вещи – одежда, продукты и т.д., привозимые со стороны жениха в дом невесты). Сөт аҡлығына кийем бирәде, камфитлар табаҡ-табаҡ, ул табаҡларның өстенә йаулыҡ салады.

**АҠЛЫҠ II** *әстр.* кеше үлеп бер елын үткәргәндә өләшенә торган бүләк (подарок, который преподносят гостям во время проведения годовщины покойного). Йылын уқытҡачтын аҡлыҡ бирәләр. «Ахтығы шул булсын, артық үлем булмасын», – дип теләйләр. Аҡлыҡны жылында да, қырҡында да алып бара.

**аҡлық бирү** *әстр.* бер ел үткәннән соң, кайгылы халәттән чығу билгесе итеп мәжлестә бүләк өләшү (выйти из траурного состояния, раздать подарки в день поминовения). Йыл Коранында бөтен awыл халқы килә, аҡлық бирәләр үлгән кешенең хазәйкәсенә.

**аҡлық йаулығы** *әстр.* искә алу мәжлесендә кайгылы халәттән чығу билгесе итеп аклык яулыгы бәйләтү (повязать белый платок в знак выхода из траура в день поминовения). Йыл Кораны көнне Коранга хәтле иртә белән йаулығын чишеп аҡлық йаулығы бәйләтәләр халық жыйылғанчы.

**аҡлыққа чығу** *әстр.* кайгыру халәтеннән чығу (выйти из состояния траура). Бер йылын уқытҡачтын ул инде ақлыққа чыға, ақлық биргәчтен. Йөри башлый туйларға. «Ақлыққа чыққаның хәйерле булсын», – дип бирәделәр. Килгән халыққа барысына да ақ өләшәләр, ақ йаулық, мийешенә ақча төйнәп.

**АҠМА** *тбл.* чишмә, кизләү (источник).

**йулдус ақмасы** *тбл.* төшә торган йолдыз (падающая звезда).

**ақма қаста** *перм.* к.: **ақмалы**.

**АКМА** *чст.* ага торган, агым (проточный – о воде). Акма йылгада керләр йыва идек без кыз чакта кышның кенендә йалан кул.

**АҠМАҠ** *туб.-ирт.д., брб.д.* ахмак (глупый).

**АҠМАЛЫ** *т.я.* ага торган – шеш яки яра турында (незаживающий, гноеточивый – о ране или опухоли).

**АҠМАН-ТУҠМАН** *нгб.-крш.* март урталарында була торган көчле бураннар (последние зимние бураны в середине марта).

**АҠМУЛЛАМ** *әстр.* иренең абыйсына эндәшү сүзе (форма обращения к старшему брату мужа). Ақмуллам өйдә, қазан асып аш пешерәм.

**АҠОРТ** *туб.-ирт.д.* балык ашый торган корт (метляк).

**ақорт йамғыр** *туб.-ирт.д.* беренче язгы яңгыр (первый весенний дождь). Қар бетмәс wақытта йawаты ақорт йамғыр. – *тбл.*

**АҠПАЛЫҠ** *себ.* корбан балык (лещ). Аулағашқа ақпалық китерәтеләр йегетләр. – *төм.*

**АҠРАЙУ** *саз.я.* жикеренү (кричать, орать на кого-нибудь, повышать голос). Ақрайма миңа!

**АҠРАП** [*гар.*] *тбл.* октябрь; Чаян йолдызлыгы (созвездие Скорпиона).

**АҠСАННАУ** *яушт., төм.* аксаклау (хромать). Ақсаннап килгәнне күрәләр дә утырталар. – *яушт.*

**АҠСАҒАС** *перм.* тез асты (место сгиба в колене).

**АКСЫЛТЫ** *м.-кар.* аксыл (беловатый). Дарйа акайның өйе әнә шыл булыр, аксылты.

**АҠСЫМАЛ** *тбл.* аксыл (беловатый).

**АҠСЫРДАҠ** *злт.* акчарлак (чайка). Ақсырдақ қысқырса, йаңғыр йawa.

**АКСЫРДАК** *хвл., срг.* аксыргак (чемерица белая).

**АҠТАЙ 1.** *перм.* иң өлкән кыз туганы (самая старшая сестра). Ақтайы зурырағы була инде аның; **2.** *к.-уф.* әтисенең апасы (старшая сестра отца). Безнеке ақтай көл иләп қуйған түбәгә (күрәзәлек итү өчен).

**АКТАКАЙ** *тмн.* әти яки әнисенең энесенең хатынына эндәшү сүзе (форма обращения к жене младшего брата отца или матери). Кече дәдәйнең катынына актакай әтәбез.

**АҠТАМЫР** *чст.* акмыек (белоус).

**АҠТАНАСТЫ** *дөб.* өйалды асты (помещение под полом сеней, подполье). Ақтанастына кереп сала безнең бер таwық.

**АҠТАРУ 1.** *кмшл.* к.: **агдару**. Бер машина утын китереп ақтарды; **2.** *перм.* сүтү (разобрать). Бер көн йатқач үлеп, ақтарып кердек ишекне.

**АКТАРУ 1.** *чст., хвл., стрл.* к.: **агдару**. Ылауны шында актар. – *чст.* Кабак эстеңә китереп актара вет (печәнне). – *хвл.* Арбага төйәп китереп актарабыз куча йасап. – *стрл.*; **2.** *чст.* бушату, салу (пересыпать, переливать). Чәйне банкыга актарам. Суны чәпчәккә актар. Иләкнекен чиләккә, табанықын сawытка актару (*мәкаль*). – *чст.*

**АҠТАРЫЛУ** *саз.я.* аву, егылу, әйләнеп төшү (опрокинуться, упасть). Пәтрәсе пелән ақтарылып китте.

**АҠТАРЫП: ақтарып алу** *минз.*, **АКТАРЫП: актарып алу** *стрл.* к.: **гөреп: гөреп алу**. Хәзер

ни актарып иген алалар эшләгән өчен, актарып акчасын алалар. – *стрл.*

**АҠТАШ** *минз.* акбур (мел). Берәд ақташ бир әле.

**АКТАШ** *лмб.* **1.** сөяктән ясалган ялтыравыксыз ак төймә (белая пуговица, сделанная из кости); **2.** таблеткалы дару (лекарство в таблетках). Шаннан (врач) бирде миңа шандый-шандый акташлар.

**акташ бизмәне** *чпр.* юк-бар сөйләп йөрүче (болтун; человек, говорящий чушь, вздор); чаг.: **йарбока**.

**кара акташ** *лмб.* ялтыравыксыз кара төймә (простая чёрная пуговица).

**АКТИРӘК** *мәл.* ак тополь (серебристый тополь).

**АҠТӘТӘЙ** *блт., минз.* к.: **чәчәк I: айлы чәчәк**.

**АКУКАЙ: кимакыл акукай** *хвл.* юләр, тинтәк (слабоумный, придурковатый).

**АКУЛЦА** [*рус.* околица] *чст., срг.* басу капкасы, авыл башларында тотылган капкалы киртә (околица). Акулцаның теге йагында йаңгыр телиләр балалар, кас'ы wакытта йәт тә бирә Хыдай Тәлә йаңгырны. – *чст.*

**АКУЛЧА** [*рус.* околица] **1.** *чст., срг., мәл., трбс., стрл., клд.* к.: **акулца**. Акулча белән awылны әләндереп алганнар. – *чст.* Акулча сакчысы. – *срг.* Элгәре безнең авыл акулча белән әләндергән иде. – *мәл.*; **2.** *трбс., клд., лмб., стрл.* авыл янындагы буш җир (округа деревни). Машиналары акулчада ғына тора чиғаннарның. – *трбс.* Акулча булган бу урам. – *стрл.* Акулчага тешердем казларны, выс'ы китмичен йаталар иде. – *лмб.* Акулча йанда буладыр кыр келәве. – *клд.*

**а к ц а** *чст.* акча (деньги):

**шылдыр акца** *чст.* вак акча (монета). Бал циләген кан'ата шылдыр акцалар салып аца.

**АҠЦАЙТУ** *сазл.* акайту (вытаращивать, пялить глаза).

**а к ч а** (деньги):

**акча салу** *лмб.* егет ягыннан кыз ягына тарту акчасы тапшыру йоласы (обряд передачи родителям невесты соответствующей суммы денег для проведения свадьбы).

**акча сүләү** *лмб.* акча бирергә килешү (договориться о деньгах). Бирнә кыздан инде, йегет йагы калын әтә, акча сүли.

**акча туйы** *хвл.* тарту акчасын, ягъни кыз өчен егет ягыннан бирелә торган акчаны тапшырганда үткәрелә торган мәҗлес (пир, устраивающийся в доме родителей невесты, во время которого передавалась им соответствующая сумма денег для проведения свадьбы).

**акча чәчү** *мам., минз., әстр.* туйда уңыш, муллык теләп акча чәчү йоласы (свадебный обычай). Кыз приданы килеп йатқанда, йегет қардәшләре он чәчәделәр, акча чәчәделәр: «Ашлы-сулы булсын». – *әстр.*

**қалым акча, қалын акчасы** *әстр.* кыз өчен егет ягыннан бирелгән акча, тарту (деньги, преподнесённые стороной жениха дому невесты). Тийешле қалым акчаны, дөгене бирәләр. Қалын акчасын да, кийемнәрен, шәлен, йаулыгын салалар кийәү биттән.

**кырт акчасы** *лмб.* кызның бирнәләрен котлап салынган акча (деньги, преподнесённые невесте, поздравления её в честь приготовленного приданого). Кыз йагы китерә инде кызның бирнәләрен кыртлаган акчаны. Шал кырт акчасын китергәннән сун туй була.

**манит акча** *әстр.* тәңкә акча (монета). Бер агасыннан ике йөз манит акча, шулай акча салалар.

**сөт акчасы** *әстр.* кыз өчен егет ягыннан бирелә торган акча (деньги, преподнесённые со стороны жениха за невесту). Сөт акчасы диләр, қыз анасы сорый, йегет анасы ыриза була.

**тарту акчасы** *к.-уф.* кызны ярәшкәч, егет ягыннан кыз өенә бирелә торган акча (деньги, преподнесённые женихом в дом невесты после сватовства). Тарту акчасына қызға әрбир алып җыйалар.

**АҠЧИ** *трх., кргл.* к.: **ағале**. Нинди матур малай, ақчи. Афтабуз үткән икән, ақчи, тегеннән менеп китте.

**АҠЧИЧИ** *каз.ар.-крш.* **1.** к.: **чәчәк I: айлы чәчәк**; **2.** к.: **ак IV: ақ мәтрүшкә**.

**АҠЧЫЙ** *трх., кргл., к.т.* к.: **акчи**. Ақчый, қорт төшкән аңарға. Берсе, ақчый, байа килгән. Ақчи, минем қатын кисәге қат'ып килә. – *трх.*

**АҠШАҒАС** *перм.* к.: **ақсағас**.

**АҠШАЙУ** *туб.-ирт.д.* акаю – күзләр турында (вытаращить, пялить глаза).

**АКШАМ** [*гар.*]: **эченче акшамы** *тмн.* үлгәннән соң өче, өчесе (поминки на третий день после смерти, тризна). Эченче акшамына дыwа кылдырасын.

**АҠЫЙҚ 1.** *эчк.* ахак (агат, сердолик). Ақыйқлар салдым – батмады, Мәрзен-мәнүwәр салдым – қалыкмады (*хал. җыр.*); **2.** *себ.* кыйммәтле таш (драгоценный камень).

**АКЫК** *стрл., тмн.*, **АКЫКАЙ** *чст.-крш.* к.: **ақыйқ 1**. Тезә калчулар белән беркетелгән акыклар, акык арасында – көмөшләр. – *стрл.* Акыкайлар салдым – акмады, Ак мамыклар салдым – батмады (*хал. җыр.*). – *чст.-крш.*

**а қ ы л** (ум, рассудок):

**ақыл чыгу 1.** *бәр.* ис китү, акыл китү (удивляться, поражаться). Закирә үлде дигәч, ақыл чыкты; **2.** *мам., бәр.* якын итү, якын күрү, өтәләнү (считать близким, своим; проявлять неравнодушие). Мине күрсә, ақылы чыгып тора инде. – *бәр.*

**а к ы л** (ум,рассудок):

**акыл цыгу, акылдан китү, акылдан тайу** *глз.* акылдан язу (сойти с ума, помешаться).

**АКЫЛИ** [*морд.*] **1.** *м.-кар.* каенанасының сеңелләре киленгә шулай эндәшәләр (так обращаются к невестке младшие сёстры свекрови); **2.** *чст.* үзеннән яшьрәкләргә иркәләп, яратып эндәшү сүзе (ласковое обращение к лицам моложе себя); чаг.: **апайым 2**.

**АҠЫЛТАНА** *туб.-ирт.д.* акыллы, зирәк (умный, мудрый).

**АКЫЛ'Т'ЫЛАТУ** [*удм.*] *глз.* к.: **йалқыту**. Тәтәне акыл'т'ылатып бетердем шай.

**АКЫЛЫЧКЫЛАУ** [*удм.*] *глз.* к.: **йалкыту**. Алай йаман бүреләр акылычкылагач, бөтен awыл җыйылып, бүре kүwабыз дип җиңгелеләр белән корга чыккан.

**АКЫР: акыр гына** *тмн., лмб.* акрын гына, ашыкмыйча гына (потихоньку, медленно). Килә акыр гына. Акыр гына кан'асын, баса теш кирасинканы. – *тмн.*

**АҚЫРТ** *туб.-ирт.д.* балык ашый торган корт (метляк).

**а к ы р у** (кричать громко, во весь голос):

**җир ақыру** *лш., к.т.* бик каты акыру, бик каты кычкырып елау (сильно орать, сильно реветь). Җир ақырып йылый. – *лш.*

**АКЫРЧЫК** *хвл.* кычкыручан (крикливый). Бозауны ызбага керткәндә сүләшмә, акырчык булыр бозау, дәшми керт, сүләп кертмә.

**АКЫ-ТОКЫ** *срг.* әкәм-төкәм (улитка). Акытокы Фатима, ач awызыңны, йым күзеңне, цыгар ике мегезеңне (*такмак*).

**АКЫШ-МАКЫШ** *чпр.* **1.** рәтле-рәтсез, ялгыш-йолгыш (беспорядочно, ошибочно). Акыш-макыш сүли; **2.** аңгы-миңге (бестолковый, непонятливый). Авырудан соң акыш-макыш булып калды.

**АКЫШ-МЫКЫШ** *мәл.* к.: **акыш-макыш 2.** Әле үзем дә акыш-мыкыш булып тырам.

**АЛ I 1.** *минз.* алдынгылык, беренчелек (первенство). Ансы әйбәт чаба торган ийе, алны бирмәде бер дә (ат турында); **2.** *м.-кар.* яхшы, әйбәт (хороший, прекрасный). Әллүбәллү иткәндә, Ал бишектә йатканда... (*хал. җыр.*). Ал йокы; **3.** *перм.* түр (передний угол избы). Килегез, алдан утырың.

**АЛ II** *стрл.* ярый (ладно, пусть). Ал, балакайым, әле инде мин китәм.

**АЛ III** *тара.* көч (сила, мощь). Әгәрки алың килмәсә, үзеңне хараб итәрсең.

**АЛ IV: ал тел** *злт.* тасма тел (льстивый, сладкоязычный). Ул үзенең ал теле белән ышандырды.

**АЛА I 1.** *нокр., глз., кмшл., минз., тпк., стрл.* ...-дән, ... тиңентен (вровень с ..., до, по); чаг.: **тигелтен**. Тез ала суда басып торганнар. – *глз.* Тездән ала суда ничек су керәсең. Сүwы тирән түгел, билдән ала бардыр. – *кмшл.* Билдән ала күмделәр, ди. – *стрл.* Шушыннан ала айак шеште. – *тпк.*; **2.** *нокр., глз.* кадәр, чаклы (столько, сколько); чаг.: **тике**. Торган ала тормам инде, Күз алдыгыз йакътырсын (*хал. җыр.*). – *нокр.*; **3.** *минз., стрл.* моннан, моннан алып (отсюда, с этого места). Моннан ала барып эшләмәс. – *минз.*

**а л а II** (пегий, пятнистый):

**ала туба** *перм.* **1.** кыр күгәрчене (полевой голубь); **2.** урман күгәрчене (лесной голубь, горлица). Ала туба ағачқа қуна ул.

**АЛА III** *брб.д.* бизәк (узор). Олу ала йасап аламышлар суқтық.

**АЛАБАЙ** *дөб.* к.: **чәчәк I: айлы чәчәк**.

**АЛАБАТА** *лш., дөб., бәр.* алабута (лебеда). Алабата күмәче әче була. – *лш.*

**энҗе алабатасы** *лш.* ак алабута (белая лебеда). Энҗе алабатасы була, ақ була йафрақлары, орлоғы җалтыр-җалтыр итеп тора.

**АЛАБОТА** *мам., бөре.* **1.** к.: **алабата**; **2.** песи тарысы (амарант, ширица).

**алабота әреме** *мам.* к.: **нәркәмәс: кара нәркәмәс**.

**АЛАБЫҒА** *сазл.* к.: **албыға**.

**АЛАБЫТА** *эчк.*, **АЛАБЫТАН** *туб.-ирт.д.* к.: **алабата**.

**АЛАҒАЙЫМҒА** *минз.*, **АЛАГАЙЫМГА** *стрл.* чамадан тыш, гаять, артык (слишком, чересчур). Алағайымға күтәргән. Алағайымға ақыра. – *минз.*

**АЛАҒАЙЫП** *каз.ар.* к.: **алағайымға**. Алағайып сары май сипкән бәлешенә, awызда эреп китә. – *блт.* Аны сибәм дигәч тә алағайып сипмисең инде (тавыкларга җим). – *мам.*

**АЛАҒАРҒА** *төм.* козгын (ворон).

**АЛАЙ I** *перм.* ал (алый, розовый). Алай күлмәк тиз уңа қый. Пыйала ышкаф эчләреннән Алай чәчәкләр алам (*хал. җыр.*).

**АЛАЙ II** *нокр., твр., тара.* шулай (так, такой). Кечкенәдән инде алай ул. Алай ул: кем эшләмәй, ул ашамай, диләр ич. – *нокр.* Қырлар алай йатат. – *твр.*

**АЛАЙЛЫ** *минз.* андый (такой). Беддә алайлы қартлы-қортқалы кешеләр генә җуқ шул.

**АЛАЙСУ** *перм.* алсу (розоватый). Чичкә атып җийғаннар бақча гөлләре: қайсы сары, қайсы алайсу, көрәннәре дә бар.

**АЛАЙУ** *туб.-ирт.д.* куркып тирә-якка карану – күзләр турында (пугливо озираться – о глазах).

**АЛАЙУК** *хвл.* бик аз (очень мало). Чәчем бик майлы булган, алайук кына салган идем каймагын да выт!

**АЛАЙУККА** *хвл., кузн., мәл., чпр.* **1.** арзан, очсыз, бушка диярлек (дёшево, недорого, почти даром). Алайукка саткан. Жикитың алайукка кала. – *хвл.* – Бәйәме анда соң бу? – Алайукка! – *кузн.* Алайукка кин'а күрсәттеләр. – *чпр.*; **2.** бушка, эшләмичә (даром, не работая). Ул бит алайукка алмый акчаны. – *хвл.* Эш көнен бит алайукка бирмиләр. – *мәл.*

**АЛАЙУҚТА** *т.я.* башка вакытта, башка чакта (другой раз, иной раз). Алайуқта син үзең дә барадыр ыйың бит, нигә хәзер бармыйсың? – *к.т.*

**АЛАҚ** [*гар.*] *минз.*, **АЛ'АК** *стрл.* к.: **айаусыз 2**. Күб инде, ал'ак күп. – *стрл.*

**АЛАҚАЙ** *дөб., каз.ар.-крш.* сүзендә һәм хәрәкәтендә чама белмәгән, тыйнаксыз, әрсез кеше турында (о нескромном, не знающем предела в своих словах и поступках человеке). Алақай кеше ул, аның сүзенең рәте йуқ. – *каз.ар.-крш.* Һи, алақай, күзенә-башына берни күренми. – *дөб.*

**АЛАҚАЙҒАН** *мам.* к.: **алақай**.

**АЛАҚАЙЛАНУ** *дөб., каз.ар.-крш.* тирә-як белән санашмыйча үзенекен эшләү; әрсезләнү, тыйнаксызлану (не считаясь с окружающими, делать своё; проявлять беззастенчивость, нескромность). Қайа керәсең алақайланып? – *дөб.* Алақайланып монда нигә килеп кердең әле син? – *каз.ар.-крш.*

**АЛАҚАН** *туб.-ирт.д., брб.д.* уч, уч төбе (ладонь, горсть).

**АЛАҠАНЛАУ** *тбл.* уч төбе белән сугу (ударить ладонью).

**АЛАҠАННАУ** *злт.* **1.** күзе-башы әйләнү, тирәяк белән санашмыйча үзенекен эшләү (не считаясь с окружающими, делать своё; быть крайне увлечённым). Ул wақытта тәмам алақаннаған, җайға килә торған булмаған; **2.** әрсезләнү, тыйнаксызлану (проявлять беззастенчивость, нескромность). Нәрсә монда алақаннап килеп кердең әле? Тансыларға чыгып алақаннап йөрми иде, уқый да уқый иде.

**АЛАҠ-ЙОЛАҠ** *тпк.* ара-тирә, урыны-урыны белән (изредка, местами). Қайда қар эрегән алақ-йолақ, шунда серек бәрәңге сыға.

**АЛ′АКМА** *чст.* к.: **алҗапма**. Ал′акмалар йawып кызлар пецән цабарга киттеләр.

**АЛАЛАНУ** *мам.* карның урыны-урыны белән эрүе (таять отдельными местами – о снеге). Анда қар алаланса, ташу аға.

**АЛ′АМ** [*гар.*] *хвл.* галәм, кешелек (человечество, мир). Ал′ам бага безгә.

**АЛАМА 1.** *глз., перм., минз., нокр., кмшл.* к.: **който**. Бик нық қартайсаң да биг алама була бит: қәдерсез буласың. – *перм.* Безнеке аламарақ булды туфрақ. – *минз.*; **2.** *перм.* чүп, чүп-чар (сор, мусор). Күзгә алама керде, алмаға кәрәг инде. Қызым, идәнеңнең аламасын учаққа ор. Бу алама қайан чыға қый, көн дә себереп.

**пычқы алама** *перм.* к.: **йарма I: ағач йармасы**. Пычқ(ы) алама белән ышқыған да ышқыған қулын.

**АЛАМАҒА** *том.д.* алабуга (окунь).

**АЛАМАЛАНУ** *минз., кргл., злт.* начарлану (стать плохим). Мийә қыdың аламаланды тип керделәр, бардық, бәбекәйем, танымады мине. – *минз.* Күзләр аламаланды хәзер. – *кргл.*

**АЛАМАЛЫҚ 1.** *минз.* кыенлык, авыр хәл (трудности). Ул wахытта эре терлек буйынча аламалықтан қотолабыз; **2.** *трбс., том.д.* начарлык (скверность). Аламалық бит бу, кызым. – *трбс.* Аламалық бумады элек айылда. – *яушт.*

**АЛАМАЧЫ** *минз.* чүпрәкче (тряпичник). Аламачылардан сәйлән алып қалфақ чигәдерийем.

**АЛАМА-ШАЛАМА 1.** *каз.ар., т.я., минз.* алама-сәләмә, иске-москы (лохмотья, хлам, старьё); **2.** *кргл.* әшәке (плохой). Алама-шалама малайлар йуқ awылыбызда.

**АЛАМ-САЛАМ 1.** *минз.* к.: **алама-шалама 1**. Алам-салам, җыртық-мыртық кийемнәр; **2.** *трбс., кргл., стрл.* тузга язмаган, юк-бар, начар (вздор, ерунда, пустяк; плохой). Андый алам-салам сүзне силәшмәскә тийеш. – *стрл.*

**АЛАМУҒА** *том.д.* к.: **аламаға**.

**АЛАМЫШ** *себ.* кулдан сугылган палас (домотканый палас, ковёр). Қуйның йонын үреп, аны суғып аламыш булган. Аламыш йуллы-йуллы була, инне ингә тегәләр. Аламышны түргә йәйеп қуйалар. Миндә ул аламыш әле дә бар. – *брб.д.*

**буй аламыш** *брб.д.* юллы палас (полосатый палас, коврик).

**кәртемәч аламыш** *брб.д.* шакмаклы палас (палас, коврик в клетку).

**олу ала аламыш** *брб.д.* эре-эре бизәкле палас, келәм (палас, коврик с крупными узорами). Бәйрәмдә йәйә торган аламышны олу ала аламыш тип әйтәтләр.

**түр аламышы** *брб.д.* сәкегә җәеп куела торган палас, келәм (палас или коврик, который настилают на сплошные нары в избе). И матур-матур аламышлар түргә йәйеп қуйғаннар. Түр аламышы. Моноқо йонын өч йыл үрдем.

**АЛ′АНДЕРУ** *срг.* чукындыру (крестить, заставить принять христианскую веру). Иван Грозный күп татарларны ал′андергән.

**АЛАН-ЙАЛАН** *себ.* арлы-бирле (туда-сюда).

**АЛАҢҒЫР** *кмшл.* бик зур, кирәгеннән артык зур – киемдәге тишек, ертык турында (очень большой, чересчур большой, огромный – о дыре, порванном месте одежды, обуви). Йа Алла, алаңғырмыни айырылған күлмәгең.

**алаңғыр тишеге** *блт.* кирәгеннән артык зур тишек, уем (чересчур большое отверстие, дыра). Зур-зур тәрәзәләр алаңғыр тишеге кебек.

**алаңғыр хатле** *чст.*, **алаңғыр хәтле** *кмшл.* к.: **алаңғыр тишеге**. Алаңғыр хәтле тишек ыйығында. – *кмшл.*

**АЛАҢНАДЗЫЛ** *брб.д.* кыюсыз, икеләнүчән (нерешительный).

**АЛАҢНАУ** *брб.д.* ахмак, кыюсыз, икеләнүчән булу (быть глупым, рассеянным, нерешительным).

**АЛАП I 1.** *дөб., тбл.* юкәдән үрелгән бер, өч, биш яки алты пот сыйышлы ашлык савыты (большой короб или корзина из лубка для зерна). Алапны биш потлы, алты пот керешле итеп эшлиләр, өч потлы, бер потлы итеп тә эшлиләр. – *дөб.*; **2.** *хвл., чпр.* кабыктан ясалган зур савыт, эрҗә; гадәттә 1×1 м зурлыгында була һәм көл җыю яки кибәк ташу өчен кулланыла (лубочный короб, ящик обычно размером 1×1 м для сбора золы или мякины); **3.** *м.-кар.* туздан ясалган тәмәке савыты (табакерка из бересты); **4.** *мам.* каз оясы (корзина из ивовых прутьев, где гусыня высиживает яйца). Нечкә талдан үрәләр, каз утырта торган алап була; **5.** *блт.* тарантасның чыбықтан үрелгән эрҗәсе (плетёный короб тарантаса). Сиртмә җиңел арба, алабы ғына йуқ, алабы булса – тарантас була; **6.** *минз., стрл.* чыбыктан үреп балчык белән ясаган савыт, ашлык йөртү өчен кулланыла (плетёный короб, замазанный глиной и служащий для мерки или перетаскивания зерна); чаг.: **мирке**; **7.** *каз.ар.-крш.* зур такта ящик (большой деревянный ящик).

**АЛАП II 1.** *т.я.* мифик образ: зур гәүдәле, көчле батыр (мифический образ: великан). Алап чабатасын қаққан, дий, безнең йақтағы таулар шуннан қалған, дий. – *к.т.*; **2.** *т.я.* к.: **алапа**; **3.** *т.я., кмшл., хвл., чпр., чст.* бик зур, бик киң (очень большой, очень широкий). Алап хәтле күлмәк кигән. – *хвл.* Синең алаб айақларыңа бу батинкылар җарар инде. – *к.т.* Алап хәдәр калуш кигән. – *кмшл.*

**алап awыз** *т.я., кмшл., к.-уф., хвл., злт.* **1.** зур авызлы (человек с чересчур большим ртом); **2.** күп сөйләүче (любящий много говорить, болтун); чаг.: **акташ: акташ бизмәне**. Алап awыз, шуны тәки әйткән бит үзенә. – *кмшл.*

**АЛАПА** *минз.* зур, таза гәүдәле, озын буйлы кеше (человек огромного роста, здоровенный).

**алапа күтәрү** *минз.* шау-шу, гауга күтәрү (поднять шум, крик). Син монда алапа күтәреп йөрмә.

**АЛАПАЙ** *тбл.* игътибарсыз (невнимательный).

**АЛ'АПКЫЩ** *чст.* к.: **алҗапма**. Ал'апкыщ күлмәкнең алны керләнмәстән йахшы була.

**АЛАПЛАП** *чст.* күпләп, бик күп итеп (очень много). Үзләре теләгәнчә алаплап, үзләре теләмәгәнчә калаклап та йук.

**АЛ'АПМА** *чст.* к.: **алҗапма**. Ал'апма дибез без. Бала итәк оцына тәңкә акца теккәннәр. Цигешле ал'апма, түшешен цигәләр кызлар.

**АЛАПЧАҚ** *тбл.* кечкенә әрҗә, кап (коробочка).

**АЛАРТУ** *тбл.* кызарту (делать красным).

**АЛАС: алас сикерү** *тара.* туй вакытында атны ут аша сикертү. Шул чакта «алас, алас, әр бәләтән қалас» дигән сүзләр әйтелгән (устаревший свадебный обычай проводить коня через огонь. Обряд сопровождался волшебными словами «алас, алас». Алас – восклицательное слово шамана).

**АЛАТА** *минз., стрл.* к.: **ала I, 1**. Шуннан алата сыр ийе ойокның кунычлары. – *минз.* Казаннан алата килдегезме? – *стрл.*

**АЛАТТЫҒЫ** *трбс.* к.: **ала I, 1**. Баштан алаттыгы йурган йабынып йаттым, күз күрмәсен тип, қурқам мин үзем дә, йәшеннән қурқам.

**АЛАТУБА** *перм.* к.: **алатыwа**.

**АЛАТЫ** *трбс.* к.: **ала I, 1**. Моннан алаты айағың күренмәсен, моннан алаты беләгең күренмәсен.

**АЛАТЫWА** *минз., бөре.* урман күгәрчене (горлинка, горлица).

**АЛАЦА** *туб.-ирт.д.* алача (пёстрая, полосатая материя из Средней Азии).

**АЛАЧАБЫР** *перм.* ала, чуар (пёстрый). Алачабыр үрдәк иткә тәмле була.

**АЛА-ЧАЛА** *минз.* аз-маз, бераз (немножко, понемногу); чаг.: **азар-азар, безрик, цала-цола**. Ала-чала ғына белә.

**АЛАЧЫҚ 1.** *каз.ар., бәр.* мунча алды, мунча алды корылмасы (предбанник). Мунча эшләтте, алачыгына сәке йасаған киң итеп, ләүкәсе дә, сәкесе дә буйаулы. Миннән алда чыгып китте (мунчадан), тышқы йақтан алачықның ишеген бикләгән. Чиләкне алачыққа қуйдым. – *дәб.*; **2.** *минз., трбс.* ишегалдындагы махсус аерым каралты, җәйге кухня: җәен аш-су пешерелә, кышын яшь мал тоталар (отдельная постройка во дворе: летом используется как кухня, для приготовления пищи, летняя кухня, а зимой в ней живёт молодняк).

**нәүрәп алачыгы** *к.т.* кар базы өстендәге корылма (сооружение над погребом).

**таwық алачыгы** *бәр.* тавык абзары (курятник). Таwық алачыгында үрдәкләр бар әле.

**АЛАЧЫК 1.** *хвл.* к.: **алачық 2**. Безнең алачыкның тетене чыга. Вата алачыкта пешерәбез. Алачыкта кышын терлек тотканнар, йазын аш пешергәннәр. Кабык алачыгым, туз чиләгем, үз үгенәм булсыйде (*әйтем*). Бу безнең алачыгыбыз, кышын тормыйбыз; **2.** *глз.* тәрәзәсез, түшәмсез һәм җир идәнле агач корылма; элек ул җәйге кухня булып та хезмәт иткән һәм кар базы да шуның астында булган (небольшое деревянное сооружение с земляным полом, без окон и потолка; в летнее время оно служило кухней, под ним находился также и погреб для хранения продуктов). Алачык пырусты бер йорт, ычтинасы да йабу гына, тәрәзәсе дә йук, идәне дә, төшәм дә йук; ул алачыкта сөт кайнаткалаганнар, зур казаннар булган элеп куйганда, алачык эчендә кар базы да булган.

**АЛАША I** *миш.д., м.-кар.* ат (лошадь, конь). Алаша йигә беләсеңме? – *тмн.* Алаша баскан айагына, севәгенә тәкле кайырыб алган. – *лмб.* Бездә алашалар сирәк инде, машина гына. – *хвл.* Туй инде бик зур була бездә: унбишәр алаша очтан очка йөри. Тенәгесе көн алашада уздыгызмы сез? – *кузн.* Алашаның йалын үрә (абзар иясе), ак күбеккә төшә алаша да. – *срг.* Алаша шундайы, шунда кәнүшнәдәдер ул. – *т.кам.-крш.* Чукынгынчы ак алаша келәве булыптыр икән. – *м.-кар.*

**алаша йибәрү** *срг.* ат чабышы (бега, скачки).

**алаша кузгалдагы** *тмн., кузн.*, **алаша кузгылдагы** *лмб.*, **алаша купиры** *күрш.* к.: **айуқузгалақ**.

**алаша тотучы** *лмб.* ат тотучы (кучер). Туйда инде шалай бер алаша тотучы була иде кыз кибиткада барганда.

**тубал алашасы** *срг.* кодаларның күчтәнәч ашсулары куелган тубалны китерүче ат (повозка с гостинцами сватов в составе свадебного кортежа). Тубал алашасы кыз утырган вәдәк артыннан килә. Вәдәк ничек әйләнеп керә туй ызбасына, тубал алашасы да алай керә.

**АЛАША II** *туб.-ирт.д., брб.д.* к.: **ашақ I**. Аттан йуғары, көцөктән алаша (*табыш.*).

**алаша йер** *тара.* түбән җир, уйсулык (низкое место, низина).

**АЛАШАРУ** *тбл.* тәбәнәкләнү (сделаться низким).

**АЛАШИТӘК** *твр.* бала итәк (оборка).

**АЛӘМ** [*гар.*] *лмб., хвл., кузн.* кешеләр, халык (публика, народ). Аләм арасында маскарага калма. Аләм арасында килештерәләр кийәү мән кызны. – *лмб.* Авылда инде вис аләмең кубар иде. – *кузн.*

**АЛӘСӘ** *минз.* к.: **айса**.

**АЛБА** *әстр.* әлбә (сладкая мучная каша). Үлене күмгәндә пешерәде албаны. Үлене күмеп килгәндә алба пешереп ашатады. Қабер қазырға киткәннән суң бороңғыда алба пешерә булганнар.

**АЛБАҢНАУ** *туб.-ирт.д.* алпан-тилпән килү (переваливаться – о походке).

**АЛБАРДАҒА** *злт.* бер дә юкка (зря).

**АЛБАРТЫ** *саз.я.* авыр сөякле (тяжёлый, неуклюжий).

**АЛБАСТАҚ** *тбл.*, **АЛБАШТАҚ** *себ.* бушка, юкка, бушлай (тщетно, попусту, даром).

**АЛБИДРӘ** *чст.* гөлбадран (дикая рябина, пижма).

**АЛБОЙ** *клд.* ал (розовый).

**АЛБОРОН** *төм.* к.: **гөләф**.

**АЛБУЙ I 1.** *хвл.* күлмәк итәгенә ике-өч рәт салына торган тар тасма (узкая лента, нашиваемая на низ женского платья). Кара сатин күлмәкнең итәгенә албуй тыткач матур була; **2.** *әстр.* тасма (лента). Төкәндә (кибеттә) саталар албуй.

**АЛБУЙ II: албуй саты** *срг.* **1.** сирень; **2.** к.: **гөләф**.

**албуй чәчәкле гөл** *лмб.* бохар кынасы (бальзамин).

**АЛБУТ** *чст., хвл., чпр.* алпавыт (помещик). Бийек тау башында салкын чишмә, Агып төшә албутның садына. Уңлы да гына суңлы кашым тарта, Ахры, сүгән йар гына сагына (*бор. җыр.*). – *хвл.*

**албут кебек** *чст.* к.: **ажгырыйн**. Албут кебек ир әшләминче тик йөри.

**АЛБЫҒА** *төм.* алабуга (окунь).

**АЛБЫРАП: албырап тору** *минз.* эшләр-эшләмәс тору (стоять, не приступая к работе).

**АЛБЫРҒАУ** *себ.* эч пошудан нәрсә булса да эшләү (заниматься чем-либо от скуки).

**АЛБЫРУ** *туб.-ирт.д.* алсулану, кызару (порозоветь, покраснеть). Битең албырап китте. – *төм.*

**АЛБЫТ** *карс.* к.: **албут**. Албытлар җигәләр пар алаша, Башлары күренә дуга аша (*хал. җыр.*).

**АЛWА** *әстр.* к.: **алба**. Ураза бәйрәмендә мамайлар алwа пешерәләр, саwаплы диләр.

**алға I** *себ.* алка (серьги):

**ай алға** *туб.-ирт.д.* ай рәвешендәге алка (дугообразные серьги).

**алға ғату** *себ.* алка кию (носить серьги).

**АЛҒА II** *перм.* алдан, алданрак, элегрәк (впредь, раньше). Бийән (миннән) алға килгәннәр алар. Мин сездән алға килдем қый.

**алға таба** *перм.* кредитка (в кредит). Әле сездә кийем-салым да бирәләр түгелме алға таба?

**АЛҒАЗЫ** [*ғар.*] к.: **алйот 2**. Алғазыға әйләнгәндер, ашый да ашый.

**АЛҒАЙ-САЛҒАЙ** *кас.* эленке-салынкы, ничек җитте шулай (небрежно, неаккуратно, кое-как). Алғай-салғай эшлип 'уй'ан.

**АЛҒАПЫС** *каз.ар.-крш.* к.: **алҗапма**. Қайсы берсе берәр алғапыс күкәй җыйып китә торганнар ыйы. Алғапысы айлы-айлы, Сөйләгән сүзе җайлы (*хал. җыр.*).

**АЛҒАСАҚ** *туб.-ирт.д.* борчылучан (беспокойный).

**АЛҒАСАУ 1.** *саз.я.* сагыну (скучать). Күкрәнтегә алғасатым; **2.** *себ.* нәрсәгә дә булса тартылу (стремиться, влечься к чему-нибудь).

**АЛҒАСУ** *к.т.*, **АЛГАСУ** *хвл.* омтылу, атлыгу (рваться, стремиться к чему-либо). Бер чыкса, алгасып тыра, чыгасы кели. – *хвл.* Сыйыр көтүгә алғасыған, чыгып китәргә генә қарый. – *к.т.*

**АЛҒАСЫНУ** *т.я.* к.: **адалану 1, 2**. Бик уйынға алғасынған бу малай, өйгә қайтып керүне белми, ашауны белми. Алғасынды бит чистый шуңа барырга. – *к.т.*

**АЛҒАУ** *брб.д.* фатиха бирү (благословить).

**АЛҒАЦАҚ** *тбл., тара.* тынычсыз, борчылучан (беспокойный).

**АЛГЫ** *күрш.* элек, элегрәк (раньше). Алгы инештән эцә идек, хазер кул гыналарымны, айакларымны зывам инештә.

**АЛҒЫ** *себ.* бурыч (долг).

**АЛҒЫНУ** *саз.я.* үз өстенә алу (принять на свой счёт). Башқа гешегә эйткәнне үсенә алғынаты.

**АЛҒЫР 1.** *әстр.* җитез (проворный). Шундый алғыр, тиз йөри торған кешене чақырып акилә; **2.** *себ.* алырга яратучы, ришвәтче (хищный, алчный).

**АЛҒЫРЛАНУ** *себ.* комсызлану (жадничать).

**АЛҒЫРЫ** *туб.-ирт.д.* элек, алда (перед чем-нибудь). Ун көн алғыры пулдым.

**АЛҒЫСАҚЛАНУ** *злт.* к.: **алғасу**. Нәрсәнедер сизеп, алғысақланып торды.

**АЛҒЫСЛАНУ** *эчк.* к.: **иреғү 1**. Алғысланып киткәнсеңдер илне уйлап.

**АЛҒЫСУ** *минз.* к.: **адалану 2**. Қара әле бу балаларны, йарышқа барырға алғысып торалар.

**АЛҒЫШ** *брб.д.* фатиха (благословение).

**АЛҒЫШЛУ** *брб.д.* бәхетле, имин (благословенный).

**АЛҒЫШУ** *брб.д.* тартылу, көч сынашу (состязаться в силе).

**АЛДАWЫЧ** *лш., мам.* к.: **баткылчык**. Алдаwыч йасап қуйғаннар, чабатама су үтте. – *мам.*

**АЛДАҒЫ** *туб.-ирт.д.* элекке, үткән (прошедший). Алдағы йылның үләне.

**АЛДАҚ I** *дөб.* очлап, ягъни бер-бер артлы җиккәндә алга җигелә торган ат (первая, передняя лошадь в упряжке гуськом). Алдаққа йақшырақ җөри торған атны җигегез, төпкә җиңгел була.

**АЛДАҚ II** *минз., тпк., нокр., бгрс.*, **АЛДАК** *шрл., стрл.* ялган (обман, ложь). Бер дә алдақ сүз түгел. – *минз.* Алдақ сөйләйсеңдер әле. – *тпк.* Сүзем алдаққа чыга. – *нокр.* Алдақ булды мамыгым, йебеткәннәр дә әз калды. – *шрл.*

**алдақ белән** *бгрс.* алдашып, ялганлап (обманывая, обманным путём). Балалары алдақ белән кереп эйтәләр, миңа тиде, дип.

**АЛДАЛАҚ** *нокр., глз.*, **АЛДАЛАК** *срг., чпр.* алдакчы, ялганчы (обманщик, лгун). Алдалақ ул бабач. – *нокр.* Алдый ул, алдалакка ат'алар. – *срг.*

**АЛДАН-АЛА** *дөб.* алдан ук, күптән (заранее, давно). Алдан-ала җыйа килдек апилка.

**АЛДАНЧЫҚ** *перм.* к.: **алдақ II**. Wақ чақта, тупсаға утырма, үсмәссең, дигән булалар, алданчық қына да ул!

**АЛДАҢҒЫ** *лш.* алдагы (передний, находящийся впереди). Ғыйныwардан алдаңғы айда...

**АЛДАПҚЫҢ, АЛДАПҚЫЧ** *минз., себ., нокр.* к.: **алҗапма**. Алдапқыц йаптыралар алдына киленнеке, йеңкәлеге йаптыра. Хәсер инте күлмәкләр, алдапқычлар, ойоқлар. Нинтәй туғаны бар, аңа пиргәле. – *төм.* Алдапқычны алға мандым, Алсу булмаған икән (*хал. җыр.*). – *нокр.*

**АЛДАР** *тбл., брб.д.* алдакчы (обманщик, лгун).

**АЛДАСТЫМАЛ** *нокр.* мәҗлестә кунаклар алдына ябу өчен әзерләнгән озын тастымал (длинная салфетка для гостей). Алдастымалны ақ киндердән суғар ыйық.

**АЛДАУКА** *срг.* к.: **меле**.

**АЛДАШ** *карс.* к.: **алдақ II**. Син йаңгал, алдаш сүлисең.

**АЛДЫМ-САЛДЫМ** *төм.* туйда кияү ягыннан китерелә торган ашамлыклар, кием-салымнар һ.б. (вещи: продукты, одежда и др., привезённые в дни свадьбы из дома жениха в дом невесты). Суратып килсә, кийәү алдым-салымын бирәте, үсләре йарашып бирәтеләр.

**АЛДЫН: алдын көн** *әстр.* өченче көн (позавчера, третьего дня). Алдын көн килгәй иде.

**АЛДЫР 1.** *перм.* к.: **дустыған 1.** Мунча чыққас, шушы алдыр белән дүртне-бишне әчәм; **2.** *т.кам.-крш., т.я.-крш.* сыра бүлә торган зур чүмеч (большой деревянный ковш для разлива домашнего пива). Кыз сырасында бер алдыр сыраны ике җегеткә бүлеп сала. – *т.я.-крш.*

**АЛДЫРА** *перм.* ...-дән алып (от, с). Күпердән алдыра җәйәүләтеп килделәр.

**АЛДЫРҒЫШ** *перм.* тапкыр (находчивый). Бик алдырғыш булдым, суқтырмадым, ул уйнады, мин бийедем.

**АЛДЫРЫШУ** *минз., стрл.* сугышу, көрәшү (драться, бороться). Кичә бәк каты алдырышканнар. – *стрл.*

**АЛ'ЕМ** [*гар.*] *лмб., хвл.* укыган, галим (образованный, грамотный). Безнең Кырби ал'емырак сездән. – *хвл.*

**ал'ем морза** *тмн.* к.: **җанағай: абыз җанағай.**

**АЛҖАБУ** *перм.* к.: **алҗапма.** Зәәр итеб эшләгәндә генә алҗабу кәрәк була.

**алҗапқыч** *урт.д.* алъяпкыч (фартук, передник):

**тәлинкә күкрәкле алҗапқыч** *блт.* к.: **алйапқыч: кимәле алйапқыч.** Тәлинкә күкрәкле алҗапқычның қысасы була алдан да, арттан да.

**АЛҖАПМА** *т.я., чпр., хвл., минз.* алъяпкыч (передник, фартук). Алҗапма җабыйм әле, хет аллар пычранмас. – *к.т.* Алҗапмага алма җийа, әбиткә пешереп ашатырга ыланнарга. – *чпр.* Йиртүк тороп алҗапмасын йапкан киленнәр. – *хвл.* Алҗапмалары матур итеп чигелгән, җилкә башлары, итәкләре бәбәй итәкле буладырыйы. – *минз.*

**АЛҖЫҒАН** *каз.ар.-крш.* к.: **нажағай.** Алҗыған уйный.

**АЛҖЫРАУ** *тмн.* алҗу, тилмерү, зарыгып бетү (утомиться, томиться); чаг.: **бәлтерәү.** Алҗырадым сине көтеп.

**АЛЗЫН** *саз.я.* к.: **алсын 1.**

**АЛИМБУР** *тмн.* к.: **алабата.**

**алйапкыц, алйапқыч** (фартук):

**ышлапырлы алйапқыц** *чст.* күкрәк турысы бала итәкләп тегелгән алъяпкыч (фартук с воланами на груди). Ышлапырлы алйапкыц кийә идек, келинкурны карага манып, анарга тәңкәле акцаны аралаш итеп тезә идек.

**алйапқыч** *перм.; трх.* алъяпкыч (фартук):

**әкәр алйапқыч** *перм.* билсез, туры алъяпкыч (прямой, фартук без талии). Әкәр алйапқыч билле булмый у, туры була.

**кимәле алйапқыч** *трх.* баштан киелә торган алъяпкыч (фартук, который надевается через голову). Қанатлап теккән кимәле алйапқыч бар иде.

**АЛЙАПМА 1.** *чст., мәл., чпр., туб.-урт.д.* к.: **алҗапма.** Алйапма кискән күгә йатале, таки йүләтә алмыйым. Канатлы алйапма йапкан. – *чст.* Алйапмасы ал мәллә, Алмалары бар мәллә. Сандугач кебек сар'идыр, Awызында кош бар мәллә? (*хал. җыр.*) – *мәл.*; **2.** *минз.* к.: **алсузма.** Алйапма озон сөлге, аны төрледән шақмақлап сугалар. Алйапма буладырыйы бөтен табынға әйләндереп салышлы.

**АЛЙОТ** *злт.* **1.** к.: **қатымыш; 2.** комагай, туймас тамак (обжора).

**алқа** *урт.д.* алка (серьги):

**қалас алқа** *дөб.* зур түгәрәк алка (большие круглые серьги).

**АЛКА** [*гар.*] *лмб., кузн., карс.* ачыга изгән бодай камырыннан клиндер формасында ясап, майда пешерелә торган ашамлык, уртасы тишек кабартма (мучное изделие домашнего приготовления: пончик с дыркой посередине); чаг.: **йезәңге.** Әтә, алар алка ашатырлар, мин питырас ашатыр идем. Алканы келәңгеч майында пешерәләр, уртасы тишек. – *лмб.*

**АЛҚОРҒЫЧ** *әстр.* к.: **алҗапма.** Алқорғычын қайа бәрдең?

**АЛҚЫМ** *дөб.*, **АЛКЫМ** *хвл.* тамак, бугаз (горло). Әле алқымымнан килеп тора, эчтек. – *дөб.* Алкымыннан килгенче ашады. – *хвл.*

**алқымыннан алғыры** *баст.* орышу, каргау сүзе (зложелание). Алқымыннан алғыры, сыйыр қайтып җиткән, cawарға кирәк.

**АЛҚЫН 1.** *дөб.* к.: **алқым.** Алқынынннан килгәнче ашады; **2.** *трбс.* аяк киеменең тамагы (подъём обуви). Алқыны тар итекнең, кийеп булғыдай түгел.

**Алла** (бог):

**алла чәчәге** *к.-уф.* чәчәк авыруы (оспа). Алла чәчәге чықты минең энекәйемә.

**АЛМА I** *тмн., лмб., чст., чпр., срг., стрл., күрш., т.я.-крш., блт., глз.* бәрәңге (картофель). Алманы ничек пешерим: суйыпмы, мундирдамы? – *тмн.* Алмалар чәчмәгән иде. Алмалар чәчәк җибәрә башлады. Алма сабагын тапаган сыйыр. – *лмб.* Алма утакладым. – *чпр.* Алгы кырда выт алмалар, кырда берцәк бирәйдәр бакца. – *күрш.* Алма салдым ашка. – *стрл.* Алма җырабыз. – *блт.*

**алма боткасы** *чст.* бәрәңге боламыгы (картофельное пюре).

**алма җыру** *блт.* к.: **йару I, 1.** Алма җырырға иртәрәк шул әле.

**алма көрниге** *лмб.* бәрәңге бәлеше (картофельный пирог).

**алма кыймагы** *чст.* к.: **табикмәк: бәрәңге табикмәге.**

**алма сызу** *т.я.-крш.*, **алма узу** *тмн.* к.: **йару I, 1.** Алма сызып алмалы каҗер, алма сызгис киләбез әнде. – *т.я.-крш.* Алма утап бетердем, инде узарга гына кирәк. – *тмн.*

**алма цыгару** *чпр.* бәрәңге алу (копать картошку, убирать картошку). Алма цыгарырга кирәк, кырга барам.

**алма эчле пирук** *күрш.* к.: **алма көрниге.**

**кывырган алма** *күрш.* кыздырган бәрәңге (жареная картошка). Әбекам, кывырган алма бармы?

**алма II** (яблоко):

**алма бавыры** *м.-кар.* алма компоты (яблочный компот). Алма бавыры диләр бездә кампутны.

**алма геле** *чст.* иске ромашка (ромашка пахучая).

**алма иске чәчәк** *мам.* к.: **алма геле**.

**алма йаран** *мам.* яран гөле (герань).

**алма печәне** *бәр., блт.*, **алма печин** *перм.* к.: **алма геле**.

**алма сабағы** *бәр.* иркәләү сүзе (ласкательное слово). Менә энем қайта, алма сабағы кебек.

**алма тирәк** *әстр.* алмагач (яблоня). Алма тирәк утыртыпсыз, Төбе чайырлы булсын (*хал. җыр.*).

**алма үләне** *бөре., лмб., дөб.* к.: **алма геле**.

**сад алма** *тмн.*, **саз алмасы** *шрл.* алма (яблоко). Туйга эстәлгә сад алма, изум белән бәлешләр куйалар. – *тмн.* Апаларың икенче килгәндә саз алмасы алып киләләр. – *шрл.*

**АЛМА III** *минз., тпк., стрл.* к.: **әкәлә 2**.

**туйыра алмасы** *лш.* имән яфрагында була торган ал төстәге төерчек: аның эчендә бөҗәк йомыркасыннан чыккан корт була («орешек», галл(ы) на листьях дуба).

**АЛМА IV** *нокр.* к.: **абыстай 1**. Биби алма, кер әле безги. Разийә алма, бабайның айагын сындырыпсин ич.

**алма апа** *каз.ар., глз.* өлкән кыз туганына эндәшү формасы (форма обращения к старшей родственнице).

**АЛМАЗӘЙ** *чст.* к.: **аба(й) 1**.

**АЛМАЙ 1.** *срг.* к.: **абыстай 1**. Алмай, эни йәште, безгә кер. Ике алмайым, бер сеңлем бар. Хатималмай, баг әле, дзиңәкәйме килә?; **2.** *хвл.* яраткан апага эндәшү формасы (форма обращения к любимой старшей сестре). Фатыйма алмай ашата. Барсам алмайларга барам.

**АЛМАКАЙ 1.** *чст.* к.: **алмай 2**. Алмакай, алмакай, алмагызга сыйыр кергән; **2.** *мәл.* к.: **абыстай 1**. Минем алмакам йыракта тырган. Безнең үзебезнең нәселдә алмакай диб әйтү күберәк.

**АЛМАЛАУ** *каз.ар.-крш.* киндерне төрле төстәге мамык яки йон җепләреннән түгәрәк яисә ромб сыман бизәкләр ясап сугу (выткать на полотне круглые или ромбовидные узоры из разноцветных хлопчатобумажных или шерстяных ниток). Аққа алмалаған алҗапқысым бар. Шаршауларға қадәр алмаладым мин.

**АЛМАЛЫ** *каз.ар.-крш., миш.д.* түгәрәк яки ромб сыман әре бизәкле киндердән тегелгән (сшитый из холста с круглыми или ромбовидными большими узорами). Алмалы алҗапқычым әле дә бар сондоқ төбендә. – *каз.ар.-крш.* Бирнәгә алмалы сөлгеләр алып килә килен булдац кеше. – *срг.*

**АЛМАЛЫК** *чст., срг., тмн.* бәрәңге бакчасы (картофельный огород). Алмалыкта йыгылды да, тел-awыз салды да, үлде дә. – *тмн.* Алмалыкларга йаwа йаңгыр, йаңгыр намазы укыгач. – *тмн.*

**АЛМАПА** *т.я., каз.ар., чст.* үзе белән бертуган яки әнисе белән бертуган апасына эндәшү сүзе (форма обращения к родной старшей сестре или сестре матери); чаг.: **абыстай 1; абыз 1**.

**АЛМАПТЫЙ** *чпр.* туганнан туган апа һәм аңа эндәшү сүзе (двоюродная сестра старше себя и форма обращения к ней). Алмаптыйга цәй йасап бирергә, эцкем кели, дир. Миңа алмаптый бал каптырды үгә кергәцен дә. – *чпр.*

**АЛМАСАР: алмасар булу 1.** *каз.ар.* алдану, ышанып, алданып калу (обмануться в надеждах, пронадеяться). Алмасар булып қалмаса җарый Палый миңа қарап. – *каз.ар.-крш.* Аңа қарап алмасар булып қалдым. – *дөб.*; **2.** *дөб.* гафил булу, абайламый калу (проглядеть, недоглядеть, оплошать). Айағыңа калуш алсаң, алмасар булма, начары туры килмәсен.

**алмасар итү** *каз.ар.* алдау, вәгъдәне үтәмичә алдап калдыру (обмануть, не сдержать своё обещание). Мин алам дип алмасар итте безне, алганы да җук. – *дөб.*

**АЛМА-ТИЛМӘ** *т.я., мәл., нгб.-крш., перм., стрл., чст., чпр., лмб., срг.*, **АЛМА-ТИЛМИ** *кас.* алмаштилмәш (чередуясь, поочередно, попеременно). Алма-тилми 'ил'өз. – *кас.* Алма-тилмә күз қашым тарта, хәйерлегә булсын. – *к.т.* Сикерешеп тырдылар алма-тилмә, ди. – *мәл.* Алма-тилмә көтү көтәбез. – *нгб.-крш.* Алма-тилмә итеп бәйләп ағачны читән йасыйбыз ий. – *перм.* Ике квашн'а белән алма-тилмә әпәй салдым. – *стрл.* Алма-тилмә эшлибез. – *чст.* Алма-тилмә эшлиләр иде Майнур апа белән синең әнең. – *чпр.* Алма-тилмә утырып йөриләр алашаларга. – *лмб.* Сөлгеләрем бар алма-тилмә тотарга. – *срг.*

**АЛМАША** *перм., минз.* килделе-киттеле, иләсмиләс, акылга җиңел, юләр (легкомысленный, глуповатый, склонный к бреду); чаг.: **акыш-макыш 2**. Бу қыз бигрәк алмаша инде. Алмаша кеше әйткәндәй, қызымны озурлап қына үстердек. Ил күрмий итек салма, ди әти, минем күк алмаша кешийе бик. – *перм.* Алмаша ти бит ул, хәдер чирләй. – *минз.*

**АЛМАШАЛАНУ** *к.-уф.* иләсләнү, юләр сату (дурить, делать глупости). Йөрсен инде шунда алмашаланып, башында мийе булмағач.

**АЛМАШУ 1.** *каз.ар.-крш.* ияләнү, күнегү (свыкнуться, привыкнуть). Бер көйгә алмаштың име, икенчене табарға җүн җук; **2.** *блт., нгб.-крш.* әверелү, әйләнү (превратиться во что-либо). Күземдән йәш аға да аға, awыруға алмашмаса йарар иде. – *блт.* Керәшен җирендә торғач керәшенгә алмашалар инде. – *нгб.-крш.*

**АЛМОРОН** *кргл.* к.: **гөләф**. Алморон хәзер чық төшкәндә пешә инде. Безнең туғайлықта инде алморон.

**АЛНЙАПМА** *мәл.* к.: **алҗапма**. Алнйапма йүләгән кызым.

**АЛНЫ 1.** *лмб., тмн., срг.* ал, алды (перед, пред). Алныга утыр (арбага). – *лмб.* Алны ачык күлмәк кигән. – *срг.* Алныгыз арты, артыгыз бире (әйтем – «китүең яхшы» дигән мәгънәдә). – *тмн.*; **2.** *чст., хвл., чпр.* алгы (передний). Алны йакта ирләр утыра. – *чст.* Алны басуда алма сабы йолыктык беген. – *чпр.*

**АЛНЫЗБА** *лмб., мәл.* к.: **гуринча 1**. Алнызбага әлә йеслеген килен килгәч тә, кан'н'а битен себерә. – *лмб.*

**АЛПАWЫТ** *перм.* к.: **ажғырыйн**. Алпawыт күwек дастуйын ир, тәрәзәдән сыйардай түгел. Алпawыт тип зур кешене әйтәләр шай қый.

**АЛПАWЫТТАЙ** *т.я.-крш.* мәһабәт, килешле гәүдәле (статный, рослый – о человеке). Алпаwыттай дад'уwым, ди, дад'усына җырлый.

**АЛПАҒЫТ** *тбл.* к.: **албут**.

**АЛПАМА** *эстр.* зур кисәкле басылган камыр (большой кусок готового теста). Бишбармаққа алпамадан өзеп җоқалақ қамыр сала.

**АЛПАМЫШ** *минз.* к.: **алап II, 1.**

**алпамыш йоқосо** *минз.* каты йокы (крепкий сон).

**АЛПУТ** *мам., лш., нрл.* к.: **албут**. Алпут бар ыйы бездә, алпут урманы бу. – *лш.*

**алпут җиләге** *лш.* к.: **гөләф**. Алпут җиләгеннән қақ йасамыйлар, чәйгә генә җыйалар.

**АЛСАҚ** *злт.* к.: **алчақ**. Шундый алсақ кеше бит ул.

**АЛСЕПРӘК** *к.-уф.* к.: **алҗапма**. Алсепрәгең матур икән.

**билле алсепрәк** *к.-уф.* билле алъяпкыч (приталенный фартук).

**қайылған алсепрәк** *к.-уф.* чигешле алъяпкыч (вышитый фартук).

**сәйләп алсепрәк** *к.-уф.* сәйләп белән чигеп бизәлгән алъяпкыч (фартук, вышитый бисером). Алсепрәгең сәйләндер, Сәйләп йағын әйләндер (*хал. җыр.*).

**АЛСУЗМА** *дөб., каз.ар.-крш.* табында кунаклар алдына җәю өчен бирелә торган озын сөлге (длинное полотенце, которое подают гостям за столом). Алсузмам бар минем алга җәйә торған, киселмәгән. – *дөб.* Киндер итеп суғасың, әзерлисең инде, нәстә кирәг инде, ашаулығын, бит сөртә торған сөлгеләрен, алсузмаларын мына кеше килгәченнән алға салырға инде. – *каз.ар.-крш.*

**АЛСҮПРӘК** *к.-уф.* к.: **алҗапма**.

**АЛСЫН 1.** *т.я., чст., мәл., хвл.* чапканнан соң икенче кат үскән үлән, курпы (отава). Қай йылны алсынын чаwып та шақтый печән була. – *к.т.* Икенче кат өлгермий инде ул, ул алсын өлгереп җитми. – *хвл.*; **2.** *лш.* үскән игеннең төбеннән чыккан яшь тармагы, үрентесе (молодая поросль, поднявшаяся у корней созревших хлебов).

**АЛТ** *себ.* **1.** ал, алды (перед, передняя часть); **2.** *брб.д., тара.* ас (низ). Йабынты алтында. Мин сиңа инде айақ алтында қол булайын. – *тара*; **3.** *яушт.* тау алты (подножье горы).

**алт йақ** *төм.*, **алт өй** *төм., саз.я.* кече як (кухонная часть дома, кухня).

**алт тойық** *тара.* алда нәрсә булачагын белмәүче (не ведающий о том, что будет).

**АЛТАWЫЗ** *дөб., к.-уф.* к.: **алап I: алап аwыз 2.** Алтаwыз ул минем шикелле. – *дөб.* Минем ише алтаwызны сөйләштерәң әле син. – *к.-уф.*

**АЛТАҒАЧ** *т.я.*, **АЛТАГАЧ** *чст.*, **АЛТАЙАҚ** *каз.ар., бөре., перм.* тегермәндә ташны әйләндерә торган орчыкның кырык чәйгә тоташкан югары башы (шестерня – часть мельницы).

**АЛТАМ** *брб.д.* адым (шаг).

**АЛТАМНАУ** *брб.д.* алдау (обманывать).

**АЛТАНУ** *брб.д.* атка атлану (садиться верхом).

**АЛТАНЦЫК** *туб.-ирт.д.* юаныч (утешение, забава).

**АЛТАР** *тбл., брб.д.* к.: **алдар**.

**АЛТАУ** *брб.д.* атлау (шагать).

**АЛТАШҚЫР** *тбл.* алдакчы (врун).

**АЛТАШТЫРУ** *туб.-ирт.д.* юату – баланы (забавлять, утешать).

**АЛТЙАПҚЫЦ** *төм., тара.* к.: **алҗапма**.

**АЛТҚАРЫ** *тбл.* алда (впереди).

**АЛТМЫЖЫНДЗЫ** *брб.д.* алтмышынчы (шестидесятый).

**АЛТТА** *себ.* алда (впереди). Қайсы бригата алтта параты? – *брб.д.*

**АЛТЫН** *тбл.* алда, алдан, элек (впереди, перед, раньше).

**АЛТЫН-БАЛТЫН** *мам.* к.: **атын**.

**АЛТЫНЦЫҚ** *төм.* үзеннән кечерәкләргә иркәләп эндәшү сүзе (форма ласкового обращения к человеку младше себя).

**АЛТЫ-ТҮКЫЗ** *срг.* алты-биш, акылга җиңел (полоумный, слабоумный).

**а л у** (брать, взять):

**қан алу** *себ.* күзгә кан саву (налиться кровью – о глазах).

**қызлар алу** *перм.* өйләнү (жениться).

**пнча алу** *себ.* к.: **қызлар алу**.

**тын алу** *себ.* ял итү (отдыхать).

**цыгарып алу** *чст.* к.: **қызлар алу**. Йегете цыгарып та алма келәгән, цыкмаган кыз.

**чәчәк алу** *каз.ар.-крш.* төрле дару үләннәре һәм чәчәкләр җыю (сбор различных лечебных трав и цветов). Чәчәк алабыз питырау көнне, қырық ызаннан қырық төрле чәчәк алырға әйтә торғаннар ыйы қартлар.

**АЛУТКА** [*рус.* лодка] *карс.* көймә (лодка). Агиделкай дашыкач без нишләрбез, Алуткагу утырып кичәрбез (*хал. җыр.*).

**АЛҮКӘ: алүкә йон** *саз.я.* үрдәкнең кыл йоны (щетина утки).

**АЛЦАЙТУ** *себ.* киңәйтү (расширять).

**АЛЦАҚ 1.** *тбл.* юктан шикләнүче (мнительный). Алцақ кеше, нимә әйтсәң дә, үсенә алгынып китәте; **2.** *туб.-ирт.д.* уенчыл, шаян (игривый, шутник).

**АЛЦАҢНАУ** *тара.* эшсез селкенеп йөрү (слоняться без дела). Алцаңнама, йәнне көйтөрөп.

**АЛЦУ** *туб.-ирт.д.* хәтерсезләнү, акылсызлану – картлыктан (отупеть, обеспамятеть – от старости). Мин алцыған қарт қуй мин. – *төм.*

**АЛЦЫҚ** *себ.* акылын югалткан (лишившийся ума).

**АЛЧАҚ** *каз.ар., бәр., глз., минз., т.я., кмшл., нгб.-крш.* ачык йөзле, якты чырайлы, ягымлы (приветливый, радушный, любезный). Әйбәт алай, бик алчақ киленнәре. – *минз.* Бик алчақ ул, сүләшергә йарата. – *глз.* Йөзе белән туйдырып тыра инде, шундый алчақ. – *дөб.* Без үзебез дә алчағырақ кешеләр инде. – *нгб.-крш.*

**АЛЧАҚЛАНУ** *т.кам.-крш.* күңеллеләнү, күңел ачу (повеселеть, веселиться, развлекаться). Җыручы кеше гел җырлый, жоқлыйсы кимей, бөтен кеше шуңа қарап алчақланып утыра инде.

**АЛЧАКЛЫК** *чст.* ачык йөзлелек, ягымлылык (приветливость, любезность). Алчаклыгы бар инде Хәтимәнең.

**АЛЧЕПРӘК** *каз.ар.*, **АЛЧЕПРИК** *перм.* к.:

**алҗапма**. Алчеприк бәйлиләр дә бawын сәлендерәләр; Шундый ғына нимәләр дә Башны ғәрләндерәләр (*хал. җыр.*). Мәшкәне алчеприккә җыйдым қый. – *перм.* Алчепрәк тектем берсеннән. – *каз.ар.-крш.*

**АЛЧҮПРӘК** *нокр., нгб.-крш.* к.: **алҗапма**. Мича йағучыға мичада салып қалдыралар йә алчүпрәклек, йә чулқа, йә ақча салып қалдыралар. – *нокр.* Алчүпрәгеңне бәйлә. – *нгб.-крш.* Бәчүкә түтинең алчүпрәген күрсәттем боларға. Сандықта кейем күп: күлмәкләр, ыштаннар, бөйстәрләр, алчүпрәкләр, җаулықлар. – *каз.ар.-крш.*

**АЛЫЙ I** *перм., нрл.* алай (так). Мин сийа алый тип әйтмәдем дә. – *перм.*

**АЛЫЙ II** *бөре., минз.* йөзьяшәр (алоэ древовидное, столетник).

**АЛЫЙРНИК** [алыр + *рус. афф.* -ник] *срг.* к.: **алымсақ**. Алыйрник алырга ярата, бирергә сүми.

**АЛЫҚМАС: алықмас үләи** *туб.-ирт.д.* каз үләне (гусиная лапка – растение).

**АЛЫМ** *т.я.-крш.* сөйләшә белү, эш итә белү (приём, способ, подход, тактика); чаг.: **тасыл**. Аның бит алымы да җук, сүз куша белми.

**АЛЫМСАҚ** *тбл.* алырга яратучы, ришвәтче (любящий брать взятку, алчный).

**АЛЫМ-САЛЫМ** *тара.* бирнә (приданое).

**АЛЫН 1.** *срг., чст., мәл.* к.: **алны 1**. Алында ылан утырткан. Алын, кабакка кереп, арт кабактан цыкты. – *срг.* Йәшләр алынга таба, без артка таба. – *чст.* Бу сәгат алында диләр, ахыры. – *мәл.* Кеше капцыгы артында, үз капцыгың алында *(мәкаль)*. – *срг.*; **2.** *стрл., чпр.* алда, алдан, элек (раньше); чаг.: **алгы**. Миннән алын абзый кайткан ыйы. Алланурдан алын барып җиттем. – *стрл.*; **3.** *чст.* кыр эшләре эшләгәндә бер кеше алып бара торган җир участогы, кишәрлек, ал (участок земли или полоса, выделенная для работы в один приём). Барып алын алып куйдым. Барып утадык бер алын. Өч алыннан ике ridwan чүп китердем.

**алын арба** *мәл., чст.* арба алды, арбаның тәгәрмәчләре һәм тәртәләре белән бергә алгы күчәре (передок телеги).

**алын баскан** *хвл., чпр.* чиккән изүле (вышитый перед – у платья). Изүгә алын басканнар, анарга петен тәңкә кадилар. – *чпр.* Алын баскан күлмәкне йәш килен дә кийә, кан'н'а да кийә. – *хвл.*

**алын йапма** *чст., мәл.* к.: **алҗапма**.

**алын хут** *чпр.* к.: **алын арба**.

**алынга китү** *чпр.* алга китү (идти вперёд, спешить – в часах). Сәгат алынга киткән иде.

**алынлы күлмәк** *чпр.* күкрәк турысында икенче төрле тукымалардан изү эшләп тегелгән күлмәк (платье, грудь которого украшена круглым узором из другой материи); чаг.: **изү**.

**АЛЫНДАРЫ** *бәр.* к.: **андары**. Бер бишлек ақча бир алындары.

**АЛЫНҖАПМА** *чпр.*, **АЛЫНЙАПҚЫЦ** *тара., брб.д.*, **АЛЫНЙАПМА** *мәл., чпр.* к.: **алҗапма**. Алынҗапмам билләрдә, Җилфердәми җилләрдә. Сандугачлар да сайрамый Сез булмаган җирләрдә (*хал. җыр.*). – *чпр.* Алынйапмам йапкан.

**АЛЫННАН** *чпр.* алдан, алдан ук (заранее). Алыннан йасап куйган иде аны, пилмәнне, туйга.

**АЛЫНЧА** *хвл., кузн.* тәңкәләр тезеп яки ука тотып ясалган изү; элек аны хатын-кызлар түшкә күлмәк өстеннән кигәннәр (старинный женский нагрудник, украшенный монетами или расшитый позументом, надевался поверх платья). Алынчаны катыннар бәли иде. – *кузн.* Алынчасы вак көмешле. Шоның киңнеге, шоның буйлыгы чук була, өч рәт манит: илле тийеннек, йегермешәр тийеннәрне тезәләр. – *хвл.*

**алынча басу** *хвл.* укалы изү тегү (изготовить, шить нагрудник, изу). Кызлар теннәр буйы чиккәннәр, алынчалар басканнар, бер сондок тутырганнар.

**АЛЫНЫЗБА** *карс.* к.: **гуринча 1**.

**АЛЫП: төн алып** *бәр.* төн буе (всю ночь). Төн алып утырабыз дисезмә, бүгеммә?

**АЛЫПЛЫҚ** *тара.* батырлык (храбрость, подвиг). Алыплық истән китте.

**АЛЫС I** *хвл.* к.: **алсын 1**.

**АЛЫС II** *эчк., кргл., бгрс., злт., себ., әстр.* ерак (далеко). Безгә қала бик алыс, илле чақрым. Аның хатыны алыстан. Күренгәннең алыслығы йуқ, күтәргәннең awырлығы йуқ *(мәкаль)*. – *эчк.* Менә ушыннан алыс түгел инде. – *кргл.* Алыс қына йердән күренә икән. – *злт.* Күп қызларны озаттым алысларға. – *әстр.* Алыстан килгәнсез икән. – *тара.*

**АЛЫССЫНУ** *себ.* ераксыну (считать далёким). Алыссынмайбыс, йөреп ултырабыс.

**АЛЫСТАҒЫ** *әстр.* ерактагы (дальний). Алыстағы кешене чақырып көтеп торадылар кеше үлгәндә.

**АЛЫСЫН** *м.-кар.* к.: **алсын 1, 2**.

**АЛЫШ I** *туб.-ирт.д.* бәрелеш (схватка).

**АЛЫШ II** *тара., твр., брб.д.* дус; ирләр бер-берсенә шулай әйтәләр (друг; употребляется в обращении мужчин друг к другу). Йөр, алыш, урманға! сунарлап китәк. – *твр.*

**АЛЫШ-ТИЛЕШ 1.** *мам.* к.: **алма-тилмә**. Алыш-тилеш өчәү эшли. Алар икәү-өчәү алыштилеш эшли алачақ; **2.** *минз.* алыш-биреш итү, алыштыру (совершать куплю-продажу, обмен чего-либо). Алыш-тилеш иттереп булса да берәрсенә бирергәйе (бозауны).

**АЛЫШУ** *брб.д., тара.* көрәшү, бер-берсенә ябышу (бороться, схватиться). Атышамысын, алышамысын, тиде.

**АЛЫШУ II** *брб.д.* алышу (менять).

**АМАЙДА'Ы-МАМАЙДА'Ы** *кас.* к.: **ғазимдәге**. Амайда'ы-мамайда'ыны эзлип 'ил'ин.

**АМАҚ 1.** *лш., трх.* агач кайрысында була торган каты гөмбә (гриб из семейства трутовиковых на стволах деревьев); **2.** *лш.* агач кайрысында була торган ерык (прорезь или выемка на коре деревьев).

**АМАҚЛЫ** *лш.* ерыклы (имеющий прорезь, с прорезью, с выемкой). Амақлы ағач.

**АМАЛАНУ** *минз.* тузу, сәләмәләнү (износиться, истрепаться). Күлмәге амаланып беткән.

**АМАМ** *чст., хвл.* к.: **апайым 2**. Амам, кил әле. Барып кайт әле, амам. – *чст.* Син, амам, истурийәне укы. – *хвл.*

**АМАН I** [*фарс.*] *баст.* гүя, әйтерсең (лә) (как, как будто, словно). Айаҡларын сузып чолғый идек шул биләүеч белән баланы, аман палка тора иде олан, айаҡлары қыңғыр булмый.

**АМАН II** [*гар.*] *тмн., әстр.* имин, исән (цел, невредим). Аман кат'ып йетегез. Дөнйалыҡта аман өчен, ахирәттә иман өчен булсын. – *әстр.*

**АМАН-АМАН** [*гар.*] *төм.* һаман, һаман саен (всё время, постоянно). Аман-аман миңә әйтәсең дә торасың.

**АМАНАТ** [*гар.*] *срг., туб.-ирт.д.* кеше аркылы җибәрелгән күчтәнәч, бүләк (гостинец или подарок, переданный через кого-либо). Малайымнан аманат килде. Рашидалар белән аманат йебәрде кызым Мәскәүдән. Аманатыңны бак, сиңа йаулык. – *срг.* Миннән аманат, Қазанға сәләм. – *төм.*

**АМАН-ИСӘН** [*гар.* + -исән] *әстр.* исән-сау (живздоров). Балам аман-исән қайтҡан.

**АМАННАШУ** [*гар.* + *афф.* -нашу] *әстр.* исәнләшү (поздороваться). Бу йаҡның қодалары қул алышып, аманнашып чығалар, күрешеп.

**АМАННЫҚ** *перм.*, **АМАННЫК** [*гар.* + *афф.*-ныҡ] *мәл.* иминлек, тынычлык (благополучие, мир). Илгә аманнық бирсен! – *перм.* Сүлә әле, тутай, без дә тыңлик, телеңме жәл, без дә аманнык белән йәшик. – *мәл.*

**АМАНСЫЗМЫ** [*гар.* + *афф.* -сызмы] *әстр.* исәнмесез (здравствуйте). «Амансызмы?» – дип керәде йаучы.

**АМӘН** [*фарс.*] *карс.* к.: **аман 1**. Айагымны бастым, амән тартыб алдылар уземне, йыгылдым.

**АМИТ** *лш., чст., мәл.*, **АМЙУТ** [*рус.* омёт] *тмн., чст.* к.: **аймут**. Амйутларга куйдык саламны. – *тмн.* Башта пецәнне йыгалар, аннан пакусларны зыйып амйутка ийәләр. – *чст.*

**АММА** *нокр.* к.: **абыстай 1**. Амма қайтты Кирыфтан. Амма, сүләшмә алай, үзебезчә сүләш.

**АМНА** *тбл.* һөҗүм (нападение).

**амна қылу** *тара.* һөҗүм итү (нападать). Йулбарс аңа амна қылды.

**АМРА'** *кас.* к.: **йанйолымны**. Ахмәт би' амра' малый.

**АМРУТ** *тбл.* груша.

**АМУТ** [*рус.* омёт] *шрл.* к.: **аймут**.

**АМЫКУЙ** *нокр.* иң яраткан апасына иркәләп эндәшү сүзе (форма ласкового обращения к самой любимой старшей сестре). Амыкуй диләр бик йаратқан абыстасын.

**АМЫЛ: амыл булу** *минз.* аймыл булу, аймылыш булу, аймылышу (разойтись в пути, разминуться).

**АМЫШҚА** *брб.д.* карт (старик, дед).

**АН** *туб.-ирт.д.* әйе, шулай – раслау мәгънәсендә (да, так – в значении утверждения). – Алар синең мән киттеләрмә? – Ан, минең мән.

**ана** (мать):

**җир анасы** *лш.* җир тараканы, каты таракан (жук).

**йер анасы** *хвл.* мифологик образ: җир анасы (мифологический образ – мать земли). Баш, эч, йөрәк awыртканда тозло су әләндереп түгәләр дә: «Йер анасы – йерән сакал, соу анасы – суган сакал, тоткан булсагыз, йебәрегез, шул бәндәгә саулык бирегез», – диләр.

**йорт анасы** *тмн., лмб., кузн., срг.* абзар иясе (домовой). Йорт анасы сүмәгән тыwарны марит итә, ул аны йадаулата, ә йесли кас'ын йарата, ад булса йалын үрә ыста итеп кенә, ә сүмәгәнен йалын былгаштырып ишкәли, аны сутәлмисең. – *тмн.* Йорт анасын чакыра, мин, ди, үңгә тешкә барам, ди, миннән калма, ди, чакыра, чыга да йортка кычкыра, йәшәләр үзләре мынан. – *лмб.*

**кызамык анасы** *глз.* кызамык иясе – мифологик персонаж (мифологический персонаж – хозяйка, дух болезни корь). Кызамык анасын ботка пешереп йобаталар.

**соу анасы** *хвл.* су анасы (водяная). Йер анасы – йерән сакал, соу анасы – суган сакал.

**теш анасы** *тмн., кас.* балага теш чыкканын беренче күргән хатын-кыз (женщина, которая первой заметила прорезание зуба у ребёнка). Теш анасымы, үз тудыкайымы цәцен үрә инде кызның. – *тмн.* Бал аша'ан 'энне бит бер'енче' 'аплайлар җәш 'илен'и, теш анасы була 'ознын, шул бер'енче' 'аплай би' cawап дип. – *кас.*

**урман анасы** *нокр.* урман иясе (лесовик, леший). Урман анасы була, алар бик зурлар, күкрәкләре бик озын, ылан имезә, йергән wакытта йилкә аша қуйа күкрәген. Кешегә тигәнен белмимен, атамның атасы сүли иде, үзем күргәнем йуқ.

**чәчәк анасы** *глз.* к.: **кызамык анасы**. Чәчәк анасын йобаталар, ботка пешереп балаларны чакырып ашаталар.

**АН'А** *т.я., каз.ар.-крш., чст., злт.* әнә (указательное местоимение: вон). Ан'а, иң түбән башта, үзәндә без чабабыз. – *каз.ар.-крш.* Ан'а мендәрләрне ал, кирәксә йастыкны алып йат. Ал ан'а теге кагызны. – *чст.* Ан'а килә афтамабил, Төйәгәннәр ташкүмер (*хал. җыр.*). Ан'а ғына аларның өйләре, җырақ түгел бездән. – *к.т.*

**АНАБАШ** *күрш.* олы яшьтәге хатын-кызларның баш киеме, чалма сыман итеп бәйләнгән яулык (головной убор пожилых женщин в виде чалмообразно завязанного платка). Анабаштан, читек-чарыктан йөрде минем анам, үлде тугзан эч йәшендә.

**анабаш бәләү** *күрш.* олы яшьтәге хатын-кызларның башына чалма сыман итеп ак яулык бәйләү (способ повязывания платка у пожилых женщин). Анабаш бәләделәр олы йәштәгеләр, урамга анабаш бәләп кенә чыктылар.

**АНАГЫНАҚ** *чст.* к.: **ан'а**. Анагынак чигеп утырмый ул.

**АНАЙ** *хвл., кузн., карс., срг., чпр.* **1.** әни (мать, мама). Балам ыризыксыз булсын дип, Тугандамы, анай, каргадың (*бор. җыр.*). – *срг.*; **2.** кереш сүз функциясендә (в функции вводного слова). Чабата калды, анай, аман кийә идек. – *кузн.*; **3.** *карс., срг.*

гаҗәпләнү ымлыгы (междометие выражающее удивление). Куйлар да икешәрне асырый иде безнең, анай. – *карс.*

**анай кәбәм** *срг.* әни кешегә яратып, ягымлы итеп эндәшү сүзе (ласковое обращение к матери). Анай кәбәм цакырды цәйгә.

**АНАКАЙ 1.** *стрл.* к.: **анай 1**. Инәй димиләр иде элек, анакай дийә иде; **2.** *карс.* каенанага эндәшү формасы (форма обращения к свекрови); **3.** *хвл.* нәкъ анасы төсле (похож точь-в-точь на мать). Анакай инде, анакай кызы.

**анақай баласы** *злт.* к.: **анакай 3**.

**АН'АКАМ** *мәл.* к.: **анай 2**. Безнең алмагачлар, ан'акам, вит инде кырык йыл.

**АНАЛТЛАУ** [*удм.*] *глз.* калдыру, югалту (оставить, потерять). Атларның арбаларын аналтлап кайтты әтей.

**АНАМЫЗ** *әстр.* дини мәҗлестә дога багышлаганда әйтелә (употребляется при молитвословиях). Анамыз Мәрйәм, анамыз Фатыйма, анамыз Әминә, анамыз Хawa рухына багышладым.

**АНАН I** *саз.я.* әйе шул, шулай булмый ни (да, конечно, а как же). Сеснең awылға кино киләме? – Анан!

**АНАН II** *брб.д.* к.: **андары**.

**анан ары** *брб.д.* к.: **андары**.

**АНАННИ** *брб.д.* к.: **анан I**.

**АНАР** *перм.* аннары (затем, потом, далее); чаг.: **азақ**.

**анар суң, анар таба** *перм.* аннан соң (затем, после этого). Элек әбигә булыштык, анар суң үзебезнекен башладык. Алдан күрше абзый китте, анар таба хатыны йөгерде.

**АНАТА** *карс.* әти-әни (мать и отец, родители).

**АНА-ТУМА** *нокр.* анадан тума, шыр ялангач (голый, в чём мать родила). Ана-тума қалдырды.

**АНАТЫРА** *блт., т.кам.-крш., м.-кар.* к.: **ан'а**. Анатыра күтәрде. – *блт.* Анатыра өстәлдәге чуйынны әйтәм мин сийа. – *т.кам.-крш.* Анатыра бу настойашший ак күлмәк. Анатыра тыз кашыкта, күрмиләр. – *м.-кар.*

**АНАУ** *т.я., лш., минз., кргл., трбс., злт., стрл., тпк., төм.* әнә шул, әнә теге (вон тот). Анау күлмәкне алып бир әле. Анау җегетне күргәнем бар кебек. – *к.т.* Анау қойога барсағыз ғына инде. – *лш.*

**АНГУР** *лмб.* бәйләгән шәл (вязаный платок, шаль).

**йеп ангур** *лмб.* җептән бәйләгән шәл (вязаный бумажный платок).

**йын ангур** *лмб.* йон шәл, йон җебеннән бәйләгән шәл (вязаный шерстяной платок).

**пыхавуй ангур** *лмб.* мамык шәл (пуховый платок).

**АНДА** *карс.* шунда (там). Син кайа, мин анда.

**анда сынгра** *глз.* к.: **андары**. Пәке дә ала иде ул кийеү, ислемай, анда сынгра кезгеләр.

**АНДАҚ** *брб.д.* андый (такой, такая, такое).

**АНДАЛАНУ** *т.я.-крш.* алдану (ошибаться, обмануться). Андаланып төшкән бозга басам дип, суга агып китте.

**АНДАП** *трбс.* сагалап, күзәтеп (подкарауливая, ожидая, подстрекая). Андап қына торған да элəктереп алған тawықны. – *трбс.*

**АНДАРАҚТАН** *каз.ар.-крш.*, **АНДАРАКТАН** *глз.*, **АНДАРАҚТЫН** *т.кам.-крш.* к.: **андары**. Андарақтан, җиңгей, әперәнне алҗапқычқа чигүчигү итеп қуйарыйық. – *каз.ар.-крш.* Мине Начтый түтей тиргидерийе, әтей җанында ғына җәри дә аны җақлый андарақтын, дидерийе. – *т.кам.-крш.*

**АНДАРЫ** *блт., бәр., каз.ар.-крш.* аннан ары, аннан соң (потом, затем). Андары киштәләп китәсең, кибүwе җитсә, шәбелләп китәбез сәнәк белә бер күтәрерлек, бер күтәрерлек итеп. – *бәр.* Қыйаматлық баш бәйләтә, андары қыз төп нигезгә қайта. – *каз.ар.-крш.*

**АНДАРЫҒЫСЫН** *бәр., блт., каз.ар.-крш.*, **АНДАРЫҒЫСЫННАН** *бәр.* к.: **андары**. Туй бетә, андарығысын кийәүне алмаға китәләр. Көч җиткәндә балаларны қоро тотам, андарығысыннан көч җитмәс дим. Андарығысыннан бер энем бар awылда. Андарығысыннан сuwырмаға җәрдәг инде, балам. – *бәр.* Бер малайым әрмийәдә, андарығысын берсе өйдә. – *блт.*

**АНДАУ** *минз.* к.: **аңдау**. Алыстағы дошманнан андап йөргән (торган) дус йақшы (*мәкаль*).

**АНДРАҒЫСЫННАН** *бәр.* к.: **андары**. Монда башта ширмешләр торған, андрағысыннан татарлар килгәлләр.

**АНДУ** *бөре., минз.* к.: **аңдау**. Почмақта андыбрақ тор әле шуларны, килеп чықмаслармы. – *бөре.*

**АНДЫ'** *кас.* к.: **қарнық**. Анды' тиризи.

**АНДЫП** *стрл.* сагалап, күзәтеп (подкарауливая, ожидая, подстрекая). Тышка чыккан кешене андып тора, керергә (песи). – *стрл.*

**АНДЫРА** *бәр.* к.: **андары**. Андыра ақтықтан ыриза булды инде.

**АН'И** *миш.д.* әни (мама).

**ан'и кәбәм** *кузн.* к.: **анай: анай кәбәм**. «Ан'и кәбәм, бир бахиллегең имезгән ак сөтеңә», – дип йырлаган қыз.

**АН'ИЙ** *глз.* **1.** к.: **анай 1**. Безнең ан'ий әйткәлий иде алай дип; **2.** к.: **абыстай 2**.

**АНИКАМ** *тмн.* әнигә иркәләп эндәшү формасы (форма ласкового обращения к матери). Аникам, ызбага кереп чәй эчеп утыр.

**АНҚУРА** *эчк.* к.: **бақча**. Сыйыр анқураға чыгып бәрәңгене бозмасын.

**аннан** (оттуда):

**аннан кире** *бөре., минз., бгрс.* к.: **андары**. Печәнне башта күбәгә җыйабыз, аннан кире чүмәлә қуйабыз. – *бөре.*

**аннан сыңга** *лмб.* к.: **андары**. Эшләдем, аннан сыңга бер йыл укыдым. Элек балтат' итә, аннан сыңга эшен башлый.

**аннан сыңра** *нокр.* к.: **андары**. Анда қунақ булып башта чәй эчәләр, аннан сыңра аш, аннан бәлеш, аннан сыңра ит белән йералма ашыйлар да қайтып китәләр.

**АННАРТЫ** *мам.*, **АННАРЫҒЫН** *каз.ар.-крш.*, **АННАРЫҒЫСЫН** *блт.* к.: **андары**. Башын алалар ыйы дағын аннарығын җитенне җәйәләр ийе җиргә, болай тезеп-тезеп китәләр ийе җуқарақ итеп. Аннарығын аны талқыйлар ыйы, талқыйлар ыйы дагын җерлейләр ийе. – *каз.ар.-крш.*

Җитмәс борон сослонға куйалар, аннарығысын чүмәләгә (ашлыкны). – *блт.*

**АН′Н′У** *т.я.-крш.* к.: **анай 1**. Элек тары чәчәбез ий, тарыны түшә-түшә арып бетә тырган ыйы ан′н′улар.

**АНСЫҢРА** *нокр.* к.: **андары**.

**АНТУХ** *саз.я.* шунда ук (сразу, тотчас). Ааң турынта кәп цыхтыма, антух қысарынат.

**АНТ-ШИРТ** *төм.* ант (клятва, обет).

**АН′У** *кузн., тмн.* к.: **агару**. Бу (күлмәк) шылай ан′ыдымы инде. – *кузн.*

**АНЦА I** *срг.* аныңча (по его желанию, по его мнению). Анца булмаса, идәнгә йатадыр да акырадыр малайы.

**АНЦА II** *тбл., брб.д.* к.: **анцақ**.

**бир анца** *тбл., брб.д.* бераз (немного).

**АНЦАҚ** *туб.-ирт.д.* ул чаклы, ул хәтле (столько). Анцақлықны белмәйте лә.

**АНЦЫ** *тбл.* аучы (охотник).

**АНЧА** *минз.* к.: **алчақ**. Биг анча түгел, ахыры, бу киленкәй, мийа шулай тойолды.

**АНЧАК** *т.я.-крш.* ул чак, ул вакытта (тогда). Анчак мин кечкенә идем.

**АНЫЙ** *нрл., чст.* к.: **ан′а**. Аный шал урамда торабыз без. – *нрл.*

**АНЫҚ** *т.я., блт., дөб., лш., нокр., глз.*, **АНЫК** *тмн., лмб., кузн.* әзер (готовый). Аныҡ өй булса, күчереп салырыйық. – *лш.* Йералмаң аныҡмы? – *нокр.* Сиңа нәрсә өйдә кешең булғач, қайтсаң аныҡ. – *к.т.* Әни, сөтең аныкмы? – *тмн.* Эштийең аныкмы, кызым? – *лмб.* Йесли аныҡ ликсийәгез булса. – *кузн.*

**АНЫҚЛАНУ** *блт., нокр.*, **АНЫКЛАНУ** *карс.* әзерләнү, әзер булу (готовиться, быть готовым). Бер амбары да аныҡланмаған, шул килеш торалар. – *блт.* Мин барма(ға) да аныҡланасы ич печән чапма. – *нокр.* Бернәрсә аныкланмаган иде. Сыйыр самарга аныкланып тор. – *карс.*

**АНЫҚЛАУ** *каз.ар., нокр., әстр., себ.*, **АНЫКЛАУ** *кузн., лмб., хвл., карс., күрш.* әзерләү, әзерләп кую (готовить, приготовить). Аныҡладыңмы аппарасы нәстәләрне? Җаздан уҡ аныҡладылар. – *лш.* Киткенчә сиңа май аныҡлыйсы ич әле. Ашау йаҡны да беттегесен аныҡлаған. Печән аныҡла, салам аныҡла. – *нокр.* Сезгә манный бутарга савыт аныклыйм. Кыз аныклый падарка кийәүгә. – *кузн.* Пәсук аныкласын әтте. Түндәкләр аныклый иде үгә китерергә. – *лмб.* Йармаркага акча аныклыйбыз. – *хвл.* Утын китерергә барабыз, дүрт йул аныкладык. – *карс.* Аныклый йегет нивистаның кийемен. – *күрш.* Килә торған қунақ бар, аныҡланабыз. – *әстр.* Аныҡлап пиргәнне ашайтылар. – *тбл.*

**АНЫҢДА** *перм., эчк.* анда, аңарда (у него, у неё). Аныңда миңке китап бар. – *эчк.* Аныңда да бар гәйеп. – *перм.*

**АНЫШУ** *нгб.-крш.* к.: **аңгару 1**. Шуны да анышмасқа син. Син мине аныштыңмы?

**АНЫҢЦӨН, АНЫҢЧӨН** *туб.-ирт.д.* шуның өчен (поэтому). Алар эштә булыр, мин аныңцөн аларға әйттермәдем. – *төм.*

**АҢ I 1.** *саз.я.* поши (лось); **2.** *тбл., тара., төм.* болан (олень); **3.** *себ.* хайван (зверь); **4.** *тбл.* җәнлек (дичь, всякое животное, на которое охотятся).

**аң гүн** *тбл.* поши тиресеннән эшләнгән күн (кожа, выделанная из шкуры лося).

**аң сыйыр** *тара.* ана болан (самка оленя).

**АҢ II** *төм.* ау (охота).

**аңқа пару** *төм.* ауга бару, сунарга чыгу (идти на охоту).

**АҢАНЧЫ** *дөб.* аңа кадәр (до этого, до того времени). Аңанчы қайтыр әле Сәләх.

**АҢҒАЙ I** *перм.* к.: **аруга II, 4**. Күбәләк күwек қызым белә кийәwем аңғай очоп қайталар Пиремнән.

**АҢҒАЙ II** *том.д.* аңкау (нёбо).

**АҢҒАЙЫНА** *перм.* шунда ук (сразу, тотчас же, с ходу). Килеп керде дә аңғайына җылый башлады, сиңке малайың үлгән, ти, үлдем дә киттем. Аңғайына йығылып киттем.

**АҢҒАН** *тбл.* агачлык (дубрава).

**АҢҒАРЛАУ** *эчк.* к.: **аңғару 1**. Минем қыз сезне аңғарлар иде.

**АҢҒАРМАҒА** *кмшл.* өйрәнергә (научиться). Былар да терле теллəр аңгармаға чыққаннар.

**АҢҒАРТУ** *перм., нгб.-крш.* аңлату (объяснить, толковать). Теләсә ничек аңғарт. Әйттеләр қый аңгартып. – *перм.*

**АҢҒАРУ** *трх., злт., бгрс., перм., нгб.-крш., әстр., эчк., себ.*, **АҢГАРУ** *миш.д.* **1.** аңлау, төшенү (понять). Сүзләрен ишеттем, аңғармадым. – *трх.* Мин урыччаны аңғармыйм. – *нгб.-крш.* Син аңғармадың қый, алай тимиләр қый. – *перм.* – Тиха гына тыр, аңгардыңмы? Син аңгара алмыйсын аны. Аңгармадым, ни сүләдең? – *лмб.* Аңгардыңмы, ни әйттем? – *срг.* Утыр, тыңна, аңгар. Нинди тел аңгарасыз. – *кузн.* Качан ат′алар, телен аңгармыйбыз. – *шрл.* Без сүлибез, аңгармый. Аңгарганга ишарәт, аңгармаганга бишәр әт (*әйтем*). – *хвл.*; **2.** *лмб., хвл.* аеру, белү, тану (определить, знать; узнать). Гөлҗиһан аңгармый да бер атналык йымырканы, ун көннекне генә аңгара. – *лмб.* Каты гына, төсен аңгара алмыйм. – *хвл.*

**АҢҒАШУ** *нгб.-крш.* к.: **аңғару 1**. Нәрсә әйткәнен аңғашмадым.

**АҢГИНЦА, АҢГИНЧА** *чст.* к.: **аңанчы**. Аңгинца киц була инде. Сәгат бердә китәм. Мин кат′ам аңгинча.

**АҢҒЫЙ** *минз.* аңгыра (глупый). И аңғый, шуны да аңламыйсың!

**АҢГЫЙНЧЫ, АҢГЫНЧА** *чст.* к.: **аңгинца**. Аңгынча бер йыл силсәwиттә эшләдем. Аңгыйнчы инде ыланнар сагынып тырырлар.

**АҢҒЫРУ** *тбл.* кычкыру – ишәк турында (кричать – об осле).

**АҢҒЫРЫҚ** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш., лш.* ерактан ишетелә торган тонык тавыш, аваз; шау (глухой шум, голос издалека; гул). Җырақтан аңгырық килә. – *т.кам.-крш.* Аңғырық килә, монда кеше бардыр. Қорт аңғырығы. – *каз.ар.-крш.* Урманнан чыққанда ғына кеше аңгырыгы ишетә. – *лш.*

**АҢҒЫШУ** *минз., т.я., т.кам.-крш., каз.ар.-крш.* к.: **аңғару 1**. Мин аңғышмыйынчы қалдым, керде дәген бақчадан қыйарны өзеп алды. – *каз.ар.-крш.*

Мирdайанның нәмә тигәнен аңғышмай қалдым. – *минз.* Менә монсон аңғыша төшәсеңме? Аңғышмый қалдым. – *к.т.* Аңғыша башлады инде бу қәлдә. – *т.кам.-крш.*

**АҢДАУ** *минз., эчк.* сагалау, саклап-күзәтеп тору (наблюдать, следить, подстерегать). Бабаң сыйыр қайтқанны аңдап утыра. – *эчк.*

**АҢДУ** *минз., эчк.* к.: **аңдау**. Аңдыбрақ тор әле шуны, килеп чыкмасмы. – *минз.*

**АҢДЫП** *бөре., злт.* к.: **андап**. Элекке сәғәтләр йуг ийе, әтәч қычқырғанны аңдып утырадырыйық. – *бөре.* Ақса бирүләре бар, аңдып торорға кирәк. – *злт.*

**АҢҚАЙУ** *минз.* аңғыраю (глупеть, стать непонятливым). Аңқайып торма инде.

**АҢКАЙУ** *миш.д.* **1.** акаю (вытаращить, выкатить – глаза). Аңкайган выт′ бу. – *мәл.*; **2.** к.: **бозолу**.

**АҢКАЙЫП** *срг.* азапланып (испытывая муки, тяготы). Аңкайып киләсең әни йанына, дийр, рахмәт сиңа, дийр.

**АҢҚАЛА** *трх.*, **АҢКАЛА** *чст.* самогон.

**АҢҚАУ** *бгрс., әстр.*, **АҢКАУ** *тмн.* аңсыз, надан (глупый, тупой, невежда); чаг.: **моқый**. Аңқау бит инде әwәлге халық, башы эшләмәгән бәрәңге чәчәргә. – *бгрс.*

**АҢКАУЛЫК** *мәл.* аңғыралык, наданлык (глупость, неграмотность). Аңкаулык инде бу, карағыда аранга чыгып сарык тотканнар раштуwада.

**АҢҚУ** *перм.* к.: **аңқылу 1.** Аңқып йөрибез теләсә қайа, су йуқ, эссе дә булды, жар да булды. Қаз үлә қый тамағы аңқып.

**АҢҚЫ** *перм.* аныкы (его, её). Аңқы бер малайы эшкә чыкмый йата.

**АҢКЫ-ЗИҢКЕ** *чпр.* к.: **алты-тукыз**. Фахри аңкы-зиңке кеше ул, сүләшеп утыра күрмә аның йанында.

**АҢҚЫЛУ 1.** *перм., к.-уф.* бик нык эчәсе килү, сусау; сусаудан әлсерәү (сильно хотеть пить, чувствовать сильную жажду; изнемогать от жажды). Йаланда тамақ қорый, су йуқ, эчең туйғанчы, аңқылырсыз. Су булмагач, тамақ қорый да, аңқыласың. Қазлар килгән, аңқылғаннар бупча; **2.** *к.-уф.* бик нык сагыну (сильно скучать, тосковать); чаг.: **иреғу I**. Шулқадәр аңқылып көттек, ә син хәбәр дә бирмисең.

**АҢҚЫ-МИҢКЕ** *злт.* миңгерәүләнеп (оглушившись). Фәли бабай йығылған йеренән аңқы-миңке торып китте.

**АҢҚЫ-ТИҢКЕ** *саз.я.* тиле-миле, аңгы-миңге (полоумный, придурковатый). Пер аңқы-тиңке нимәсе шанта.

**АҢҚЫТ** *мам.* ахмак, аңгыра (глупый, тупой, бестолковый). Ул аңқыттан эш чыкмас.

**АҢЛАУ** *тбл.* ауга бару (идти на охоту).

**АҢНАШУ** *бгрс.* к.: **аңғару**. Мин әзерәк аңнашам да, ишетмим.

**АҢНЫҚ** *төм.* балык аулау әйберләре (снасть для ловли рыбы). Палыкны аңныгы булганнар тота.

**АҢТУ** *перм.* к.: **аңдау**. Кемне аңтып торасың?

**АҢТЫУ** *саз.я.* **1.** балык тоту (ловить рыбу). Пер ай пулаты аңтымай йататханнарына; **2.** ауга чыгу, аулау, сунарлау (охотиться). Қырғошлар аңтынатған.

**АҢЦЫ 1.** *тбл., төм.* аучы (охотник); **2.** *тбл.* балыкчы (рыбак).

**АҢШАБИ** *дөб.* аңгыра (глупый, бестолковый); чаг.: **ат′акыш 1.**

**АҢЫ: аңы сөрә** *саз.я.* шуңа күрә (поэтому, ввиду этого). Йакшы эшләйте, аңы сөрә бушатып, тораға йебәрептеләр.

**АҢЫРМА** *себ.* ачык авыз (зевака).

**АҢЫРУ I 1.** *туб.-ирт.д.* ис китү (удивляться); **2.** як-якка карану (глазеть по сторонам). Аңырмай ғына бар урамнан. – *төм.*

**АҢЫРУ II** *клм.* аңлау (понимать). Кежене аңырмый бит.

**АҢЫШ** *тбл.* аңлау (понятие, понимать).

**АҢЫШЛЫ** *минз., стрл., чст., т.кам.-крш., туб.-ирт.д.* аңлаешлы (понятный). Әкерен кешенең эше дә аңышлы була. – *минз.* Қәзер аңышлы инде, ырадийу бик зур белем бирә аңышқан кешегә. – *т.кам.-крш.*

**АҢЫШЛЫҚ** *тбл.* зирәклек (понятливость).

**АҢЫШУ** *чпр., хвл., срг., чст., каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* к.: **аңғару**. Кизләү диләр, чишмә сүзен дә аңышалар. – *чпр.* Мин аңышып йатам. – *хвл.* Татарча аңыша башлады. – *срг.* Сөйләшә башлағач аңышырсыз әле. – *каз.ар.-крш.*

**АПА I 1.** *бөре., минз., перм., хвл.* үзеннән яшь, ләкин укымышлы хатын-кызларга эндәшү формасы (форма обращения к образованной женщине моложе себя); **2.** *мам.* к.: **аба(й) 1.** Абзыйның малайы әйтә, апа, син гәзле җирдә дә эшләмәдең бит, ди. Элек апа диләр ийе, хәзер абый инде, хатын-қызны тәтәй диләр.

**ағ апа** *минз.*, **апа әни** *кас.*, **мулла апа** *минз.* әнисенең олы кыз туганына эндәшү сүзләре (формы обращения к старшим сёстрам матери).

**сандугач апа, сылуым апа** *мәл.* кызларга егетләрнең иркәләп эндәшү сүзе (ласковое обращение парней к девушкам). Йегетләр кысти йырларга: «Сандугач апалар, йырлагыз әле»,– диләр. Безнең awыл борма-борма, Бормалы, борылмалы. Кунак кызы, сылуым апа, Качынып утырмале (*хал. җыр.*).

**туған тимеш апа** *том.д.* туган тиешле апа (тётя, которая приходится роднёй). Туган тимеш апа тора урам аша. – *яүшт.*

**АПА II 1.** *әстр.* әни (мама). Балаларыбыз киләде апа дийеп, кийәүләр, киленнәр киләде. Апам үлде, қайғырып утырдым. Апам, ыриза бул, мине ашаттың, уқыттың, килгәндә қаршы алдың; **2.** *себ.* укымышлы хатын-кыз (образованная, уважаемая, грамотная женщина).

**АПАЙ I 1.** *каз. ар., кмшл., хвл., кргл.* к.: **абыстай 1.** Апайың қайа, қызым? Әллә қайда жөрмәгез, хәзер көтүләр қайтыр. Апай уқый, мин әле уқымыйм. – *дөб.* Әллә теге Ташкиннан қайтқан апайларымы? Апайы инжинир булып эшли. – *кргл.*; **2.** *каз.ар., кмшл.* үзеннән олы хатын-кызга эндәшү формасы (форма обращения к любой женщине старше себя); чаг.: **абыз 2, абыстай 2**; **3.** *хвл.* к.: **абызапа 2**; **4.** *минз., бөре., перм., кргл., бгрс.* к.: **апайым 2**. Утырың, апайлар, чәйгә. – *перм.*

Апайларыңны қарап тор, шайарып уйнап, өмәчеләргә матап йөрмәсеннәр. – *минз.*; **5.** *каз. ар.-крш.* акыллы, белемле (умный, знающий). Ақыллы булғанға апай диләр.

**апай қортқа** *төм.* им-томчы (знахарь). Апай қортқа бар бу урамда.

**АПАЙ II: апай итү** *кузн.* әп итү – балалар телендә (целовать – в детской речи). Кырчагың бик күрекле, бир мин апай итим.

**АПАЙЫМ** (*-ң, -ы*) *минз., бөре., шрл.* **1.** эне яки сеңел һәм аларга эндәшү сүзе (младшие брат или сестра и форма обращения к ним). Апайларым Шакир белән Нәсимәне миңа қарарга туры килде инәй эшкә киткәч. – *минз.*; **2.** үзеннән яшьрәкләргә иркәләп эндәшү сүзе (ласковое обращение к лицам младше себя). Әй, апайым, йырлаган чаклар бар иде. – *шрл.* Апайым, син мәктәпкә йөрисеңме? – *минз.*

**АП-АҚ** *тара.* бик нык – көчәйткеч кисәкчә (очень – усилительная частица). Кицен эштән килсәләр, түшәк шикелле түшәләтеләр, арып қуйатылар ап-ақ.

**АПАҚ 1.** *каз.ар., глз.* к.: **абыстай 1, 2.** Қазанга барсаң, апақларға сәләм әйт. Апақны күрмәгәнгә ни ғымыр. Мәгри апақ, сийа қунақлар бар. – *дөб.* Ғәззәапақ идәме? – *глз.*; **2.** *перм.* әнисенең сеңлесенә эндәшү сүзе (форма обращения к младшей сестре матери). Сиксәмбердә тиме апақ. Апақ – әнинең сеңеле инде.

**АПАК** *байк.* к.: **апайым 1.**

**АПАҚА** *төм.* бертуган иң зур апа (самая старшая родная сестра).

**АПАҚАЙ** *злт.* к.: **апайым 2.** Аннан йырақ былыр, апақай. Гөлсөм, әз генә су бир әле, апақай.

**АПАКӘ** *саз.я.* апа, үзеннән олы чит хатын (тётя, старшая по возрасту женщина).

**АПАЛНЫЙ** [*рус.* опальный] *кмшл., хвл.* артык, кирәкмәс (лишний, ненужный). Апалный балабыз йуғале. – *кмшл.*

**АПАРА** [*рус.* опара] **1.** *хвл., мәл., кмшл., каз.ар.* сыек камыр башы (жидкая закваска для теста). Тәпән тебендәге апараны нишләтергә? – *кмшл.*; **2.** *бәр., каз.ар.-крш., блт.* сыек былчырак (жидкая грязь); чаг.: **батқақ.** Апаралы былчырақ безнең урамыбыз. – *бәр.* Апара җырып бардым җаз көне. – *каз.ар.-крш.*

**апара басу** *хвл.* камыр басу (месить тесто). Киленнәрнең берсенә апара басу булса, берсенә мунча йагу булган, эченчесенә сирлар булган саварга. – *хвл.*

**апара циләге** *чст.* камыр башы куя торган кечерәк савыт, камыр чүлмәге (небольшая посуда для опары, опарник).

**апара чиләк 1.** *кузн.* к.: **балайак I, 2.**; **2.** *чст.* к.: **апара циләге.**

**АПАРАЛАНУ** [*рус.+афф.* -лану] *блт.* былчыраклану, былчыракка әверелү (превратиться в жидкую грязь). Җаңгыр җауғач апараланған җир.

**АП-АРУ I** *нокр., глз.* чип-чиста (очень чисто). Бешкән бу, ап-ару қала (сөяге). – *нокр.*

**АП-АРУ II 1.** *срг.* к.: **аруга II, 4.** Ап-ару йазыб утыра бу. Ашагым келәми, ап-ару эцкем кели; **2.** *срг.* к.: **ару II, 5.** Ап-ару шәкәр белән генә тора да. Күтәреп көлтә бирергә ыстрашны иде wүз башына, ап-ару кисеркә була иде; **3.** *срг.* бөтенесе, барлыгы, нибарысы (всего, в сложности). Ап-ару кырык сутый усатым; **4.** *срг., мәл.* к.: **ару II, 1.** Бywa кытыла алмады, усатларымны ап-ару су алды. Ап-ару йерәгемне бетерделәр. Олан ап-ару бизгән, килми дийр. – *срг.* И дөрестән дә ыланым ап-ару айакка басты. – *мәл.*; **5.** *срг.* к.: **ару I, 11.** Куралар сынган, йауса, ап-ару йawa; **6.** *бәр.* бернәрсәсез (без ничего). Болар башқа чықтылар, ап-ару ғына чықтылар да төштөләр бернәрсә алмыйчы.

**АП-АРУГА** *срг.* шактый озак (довольно долго). Оло кызын бактым ап-аруга.

**АПАЙЕМ** *чпр.* к.: **апайым 2.** Ынытылгандыр инде, хатерем йук, апайем.

**АПАЧ** *перм.* к.: **асыл 2.** Апач апалар килгән. Апач итеп кийенгән.

**АПҚАҚЛАУ** *туб.-ирт.д.* сазда бата-чума йөрү (ходить по болоту).

**АППА I** *мәл., хвл.* к.: **абыстай 1, 2.** Аппалар симйасыннан бик сагынып, бик күп сәләм. Гасимә аппа, минем өчен күп борчылдың инде, бик зур рәхмәт. – *мәл.* Ана тегесе аппам. Аппа, бу кадәрле бәрәңге чәчмә, ди, кирәкми, ди. – *хвл.*

**АППА II** *саз.я.* эх! (и! ну!) Аппа, балалар, оцасыс ғуй!

**АППАЙ** *бәр., дөб., каз.ар.-крш., блт.* к.: **абыстай 1, 2.** Төнәген аппайға тақта төймәгә бардым. Ғәрифәппай, нихәл? – *бәр.* Аппай да шулай әйтер ийе, гөслә генә уйнаб утыр син, дийер ийе, җерләмә, дийер ийе. – *каз.ар.-крш.* Аппай, чәчеңне әче су белән җywасыңмы? – *блт.*

**АППАҚ** *дөб.*, **АППАК** *кузн.* **1.** к.: **абыстай 1, 2.** Исәнләшеп кит аппақ белән. – *дөб.*; **2.** *глз.* к.: **абыстакам.** Кәмлә аппак диләр мине.

**туған аппақ** *дөб.* абыйсының хатынына эндәшү формасы (форма обращения к жене старшего брата).

**АППАРУ I** *хвл., кузн.* к.: **ап-ару I.** Аппару итеп идәннәрен йywып чыгарган, прәме мә сиңа. Сабынны суда йуган идем, аппару булды. Аппару күлмәк кигезеп чыгарган идем үзеңе, нишләттең, кәфер кыз, итәкләрен? – *хвл.*

**АППАРУ II** *хвл., кузн., мәл., чпр.* к.: **ару II, 1.** Аппару гар'ыпны бетерде. Аппару эч. – *кузн.* Шәкәр аппару беткән икән? – *мәл.*

**АППАРУГА** *кузн.* к.: **ару II, 2.** Аппаруга сукрайа инде, үлем хал'га төшә инде. Калпаклар әле бетте аппаруга.

**АППЫЙ** *мам.* к.: **аба(й) 1.** Ғәптелғәзиз аппый белә бер җылда киттек без. Аппый әйтте, қарап тот, диде.

**АППА** *бөре.* казларга ашату өчен икмәккә он сибеп әзерләнгән болгатма (корм для гусей, приготовленный из хлеба и муки); чаг.: **былгама 2.**

**АПСА** *саз.я.* комагай, туймас күз (обжора, ненасытный).

**АПСАЙУ** *тбл.* комагай булу (быть прожорливым).

**АПСАҚ** *том.д.* усак (осина).

**АПСАЛАНУ** *тбл.* артыгын ашау (есть через меру).

**АПСЕН** *кас.* к.: **абсын.**

**АПСЫ** *саз.я.* к.: **апса**.

**АПТАҢ-ТИПТӘҢ** *тара.* **1.** әрле-бирле (тудасюда, взад-вперёд); **2.** алпан-тилпән (вразвалку).

**АПТИ** *әстр.* апа (старшая сестра).

**АПТРАҚ 1.** *тбл.* ашыгыч (поспешный); **2.** *себ.* ашыгучан (торопливый).

**АПТЫЙ 1.** *т.я., чст., чпр.* к.: **абыстай 2.** Сәраптый миннән күп қарт түгел ул, миңа алтмыш биш булса, аңа җикмештер. – *к.т.*Ниг аптыйлар сүләшмиләр? – *чст.*; **2.** *трх.* к.: **абыстакам**.

**АПТЫҢ-ТИПТЕҢ** *туб.-ирт.д.* к.: **аптаң-типтәң 2**.

**АПТЫРАУ 1.** *срг., себ.* к.: **абдырау 1**. Аптырап китәсез, аптырамас идегез. Көйләгем аптыраганта йыртылып китте; **2.** *тара.* ару, талчыгу, хәлдән таю (устать, обессилеть). Қысым аптыраган килеш йоқлаты.

**АПТЫРАШ** *твр., том.д.* ашыгыч (поспешный). Сес аптыраш икән. – *твр.*

**АПХАНА** *саз.я., тбл.* бәдрәф (уборная).

**АПЫЙ 1.** *лш.* абый (старший брат). Апый қайтты, апый артыннан эти бүләкләр җибәрде. Сабир апый утыра шунда; **2.** *мам.* к.: **аба(й) 1**. Күлмәгеңне ки, улым, өйдә қунақ апый бар. Апыйың белән қаз көтүwенә барырсың, улым. Апыйсы солдатқа киткенче өйләнгән ийе.

**АПЫЛДАУ** *хвл.* тыпырдау (стучать; топать ногами). Йыкыдан тырды да, апылдап барды да.

**АПЫРТУ** *дөб.* арттырып, күпертеп сөйләү (слишком преувеличивать).

**АПЫЧ** *глз.* к.: **аба(й) 1**. Апыч, кара пычай (песи) анда. Ашама пешермәле, апычың да кайтыр.

**АРА I** *әстр.* пычқы (пила).

**АРА II** *мам., каз.ар.-крш., нгб.-крш., нрл., тмн., чст.* вакыт (время). Керергә арам да җуқ, көйем дә җуқ. Иртәгесен керергә ара булмады. Әле барасы да килмий, барыға ара да җуқ. Чәй эчеп торырға ара җуқ. – *мам.* Идән җуwарға да арам җуқ. Күкәйгә төшерем дигән ийем, арам җуқ. Килеп утырырға арам булмады. – *каз.ар.-крш.* Сагынырга ара йук. – *чст.* Зәйнәпнең арасы йук йазарга (хатны). – *тмн.* Барырға ара йуқ. – *нгб.-крш.*

**ара йерү** *срг.* кодалау, яучылап йөрү (сватать).

**ара йерүче** *мәл.* ике кеше арасында йомыш йөртүче, арадашчы (посредник, сводник). Ара йерүчесе кеннәде дә, үзе йерергә тытынды.

**ара қыз** *перм.* егет кызны качырып алганда арадашлык итүче һәм шаһит ролендә катнашучы хатын-кыз (женщина, играющая роль посредницы или свидетельницы невесты при её выходе замуж убегом); чаг.: **араччык**. Минең ара қызым йуқ, мин әйтәм, мин риза түгел.

**ара өзү** *срг.* кыз ярәшкәндә соңгы вәгъдә сүзен бирү (дать последнее обещание во время сватовства невесты). Биргәне ара өзә, ара өзгәндә сөлге бирәләр.

**араға бер** *бәр.* әллә нигә бер (изредка). Араға бер бәлеш пешерәм.

**арада булу** *глз.* мәхрүм булу, читтә калу (оказаться в стороне от чего-либо). Бала қарап уқудан арада булдым мин.

**АРАБА 1.** *нокр., глз., т.я.-крш.* арба (телега). Араба чүләрен йасап бирде. – *глз.* Анда бер араба алды бар. – *нокр.* Бер араба утын апкайтты. – *т.я.-крш.*; **2.** *глз.* к.: **йәпләшкә**.

**АРАҚ I** *себ., әстр.* аракы (водка). Айағуйын төне белән, арақ йуқ. – *төм.* Без кинчәк булып йөргәндә арақка awыз тигән йуқ. – *әстр.*

**кәнче арақ** *себ.* көмешкә (самогон). Кәнче арақ арышныкы қыwәтле була.

**АРАҚ II** *себ.* ара, чак – алмашлыклар белән кулланыла (место, время – употребляется с местоимениями). Йәслә шул арақта ғына. – *клм.* Ул арақта теге қарт керә. – *төм.*

**АР'АК** *срг.* к.: **йуwач**. Кайа булдың син, мин сиңа қыцкыра йердем? – Ар'акта булдым.

**АРАКӨН** *м.-кар.* к.: **атнарас** (көн).

**АРАҚЫДЗЫ** *брб.д.* эчкече (пьяница).

**АРАҚЫЛАУ** *брб.д.* аракы эчү (пить водку).

**АРАЛАНУ 1.** *дөб.* таралу – болыт турында (рассеяться, разойтись – о тучах). Былытлар араланып беттинде алар. **2.** *стрл.* аерылу (отделяться). Элек катышкан ийек без ул авылга, шуннан соң араландылар.

**АРАЛАУ** *т.я.* **1.** сирәкләү (разрежать). Чәчкән кишер бик куйы тишелгән, быраз аралап чықтым. – *к.т.*; **2.** коткару, арындыру, котылырга ярдәм итү (освободить, избавить, помочь избавиться). Төштем awыр қайгыларға, Дусларым, аралағыз (*хал. җыр.*). – *к.т.*

**АРАЛЫ** *туб.-ирт.д.* сирәк (редкий; на расстоянии друг от друга).

**АРАЛЫҚ, АРАЛЫК 1.** *перм., к.-уф., минз., эчк., хвл., әстр.* тыкрык (переулок). Шу сес килгән аралықта торалар. – *перм.* Менә шул аралықтан үттең исә, қала қапқа. – *минз.* Сыйыр аралықта йөрәй қый. – *эчк.* Аралықтан ғына бар, анда йул қорорақ. – *к.-уф.*; **2.** *перм., т.я., дөб., блт., мам., чст., хвл.* к.: **бүлмәч 1**; **3.** *эчк.* вакыт (время); чаг.: **ара**. Шул аралықта йегеттән түшәк-мендәрләр килә.

**АРАМ** [*гар.*] *брб.д.* хәрәм (запретный, запрещённый религией).

**АРАН I 1.** *байк., чпр., карс., стрл., срг., мәл., хвл., кузн., эчк.* к.: **абзар 1**. Азбарда тора сыйыр, сарык, бик сыwык былса, аранда. – *байк.* Терлекләрне зыйдым, аранны чистарттым. – *чпр.* Аран диләр инде вак маллар йабар өчен. – *стрл.* Аранны нүwек кыстырып эшлиләр, йылы була. – *срг.* Моның эчендә ван'а аран, кышын йабабыз терлекләрне, йазын жар була, йазын йапмыйлар. – *хвл.* Безнеке кан'ушн'абыз йук, майым, аран гына. Дуңгыз аранына итеп әләндерәләр үзен (свинка белән авырган кешене). – *кузн.* Аран бу, келәтләр кирәкми хазер. – *мәл.*; **2.** *лмб., чст., тмн., стрл. тара.* к.: **абзар 3**. Азбар аранга караганда эчтәрәк, тынычрак, анда буран бурамый. – *лмб.*; **3.** *стрл.* к.: **чиннек I, 1**; **4.** *төм.* өй алды (сени).

**аран ийәсе** *чпр.* абзар иясе (домовой, живущий в помещении для скота). Атның йалын цыбалтып бетерә аран ийәсе, кинап, тирләтеп бетерә.

**ат аран** *төм.*, **ат араны** *чпр.* ат абзары (конюшня). Ат аранына кертеп ашатырга сирны. – *чпр.*

**өй аран** *төм.* к.: **ишегалды**.

**сыйыр аран** *том.д.* җылы абзар (хлев).

**АРАН II** *т.я.* көчкә, көч-хәл белән (еле, насилу). Сулуwы қаба, аран гына китте. Аран күтәреп чыктым. Қапиз бабай да қартайған инде, аран җөри. – *к.т.*

**АР'АН** *тмн.* әйрән, катык (айран). Ар'ан белән ашадылар бекмәне, тәмле булды.

**АРАН-АРАН, АРАН-БӘЛӘ** *т.я.* көчкә-көчкә, көч-хәл белән (еле-еле, чуть-чуть, насилу). Җазгы пычрақта су җырып аран-бәлә килеп җиткәннәр. – *к.т.* Бәрәнкене аран-аран утыртып петерделәр. – *т.я.-крш.*

**АРАНДАҒЫ-ҚАРАНДАҒЫ** *лш.* к.: **амайда'ы-мамайда'ы**. Арандағы-карандағы нәрсәләрне сөйли.

**АРАН-НАЧИЛА** [*рус.* насилу] *т.я.* к.: **аран-аран**. Шундый қаты җапқан қапқачын, аран-начила ачтық. Шундый қаты буран ыйы, аран-начила қайтып җиттек. – *к.т.*

**АРАН-ТАБАН** *мам.* к.: **аран-аран**. Аран-табан чықтылар суны.

**АРАПА** [*гар.*] *глз.* гарәфә, бәйрәм алды (канун мусульманского праздника). Арапа кен мунча йагалар.

**АРАПТАЙ** *кас.* карабодай (гречиха). Араптай бут'асы 'уйалар.

**АРАС** *саз.я.* дус түгел (находящийся в ссоре). **арас булу** *саз.я.* к.: **араслашу**.

**АРАСЛАШУ, АРАСЫШУ** *саз.я.* ара бозылу (ссориться, быть не в ладах).

**АРАТА 1.** *мәл., чпр., т.я.* өрлек, идән такталарын түшәү өчен куела торган аркылы агач (перекладина, переруб, на который настилается пол); **2.** *мам.* баскыч басмасы, баскычның басып менәр өчен куелган аркылы агачы (ступенька, перекладина на лестнице). Өй түбәсенә менеп булмый, басқычның аратасы сынған.

**арата ағачы** *лш., минз.* мәетне күтәреп бара торган җайланма, җеназа агачы (носилки, на которых несут покойника).

**АРА-ТУРА** *лш., мам., трх., т.кам.-крш., глз.* **1.** ара-тирә, сирәк кенә (изредка, иногда, временами). Ара-тура гына ипи ашатабыз бозауга. – *лш.* Ара-тура килгәли. – *т.кам.-крш.* Ара-тура киләләр Ижаудан. – *глз.*; **2.** ара-тирә, сирәк-мирәк, урыны-урыны белән (местами, кое-где). Карабодай чәчкәннәр, ара-тура тишелгән, тары тыгылып үскән. – *лш.*

**АРАЦАН-ҚОРАЦАН** *брб.д.* төрле эчемлекләр (разные напитки). Арацан-қорацан пижирде.

**АРАЦЫ** *туб.-ирт.д.* арадашчы (посредник).

**АРАЧЧЫК** *хвл., кузн.* ике кеше арасында йомыш йөртүче, арадаш (посредник; сводник). Йегет белән кыз арасында хат йөретүче була араччык. – *хвл.*

**АРАЧЫ** *мәл.* егет белән кыз арасында хәбәр йөртүче (посредник, посредница между парнем и девушкой). Арачы була, йегет белән кыз арасында хәбәр йөртә, хат йөртә. Арачы йөрде-йөрде дә үзе барып куйды йегеткә, дип сүлиләр.

**АРАША** *эстр.* сугышкан кешеләрне аралаучы, туктатучы (человек, разнимающий людей при драке, ссоре). Арашаңны җиргә суғармын, атыңны урлармын.

**АРАШЧЫК** *хвл., кузн.* к.: **араччык**. Анарга арашчык – анасы йөргән башкода. – *кузн.*

**а р б а** (телега):

**алын арба** *байк.* баланы тартып йөртә торган ике тәгәрмәчле кечкенә арба, кул арбасы (двухколёсная детская коляска). Алын арбага куйып баламны алып барсам, барып җитәрменме дим.

**арба арышы** *себ.* арба тәртәсе (оглобля). Сәңгелцәкне арба арышына элеп қуйа қырда. – *төм.*

**арба астығы** *тара.* арбаның алгы күчәре өстенә утыртылган кәкре агач (деревянная часть над передней осью телеги).

**арба боты** *т.я., бөре.* арбаның астында буйга куелган агачлар (дроги).

**арба қолағы** *тара.* чәкүшкә (чека, стержень).

**арба мендәре** *блт.* арба күкрәге (подушка – толстый брус на передней и задней оси телеги).

**арба сузмасы** *дөб.* к.: **арба боты**.

**арба тәгәрчәге** *к.-уф.* арба тәгәрмәче (колесо телеги).

**бәләкәй арба** *минз., мам.* бәби арбасы (детская коляска). Бәләкәй арбаны матур итеп йасады. Қабықтан йасаган бәләкәй арбаға салып тартып йөрү ийе. – *минз.*

**далгуша арба** *к.-уф.*, **дулгиш арба** [*рус.* долгуши] *перм.* к.: **карандас**. Җәй булса, далгуша арбалар белән туй була.

**җәшнек арбасы** *минз.*, **йәшнег арба** *мам.* кырыйлары ящик формасында ясалган такта арба (телега, сделанная из досок). Җәшнек арбасына төйәлеп, ураққа киткәннәр. – *минз.* Дугалары бүгеп йасаган, йуқа ғына такта телеп түшәгән бу йәшнег арба. – *мам.*

**қаты арба 1.** *к.-уф.* бүрәнә ташый торган озын арба (длинная телега для перевозки брёвен); **2.** *перм.* гади арба (простая телега).

**кашawай арба** *к.-уф.* кошёвка. Кашawай арбада килен белән кийәү килә.

**кечү арба** *том.д.* к.: **йәпләшкә**. Бәләкәй малай утынға бара кечү арба бән. Қоро-сары утыннарны җыйган кечү арбаға.

**қузалаг арба** *эстр.* дүрт тәгәрмәчле арба (телега с четырьмя колесами).

**қутуг арба** *саз.я.* к.: **қаты арба 1.**

**қуш арба** *тбл.* арба – дүрт тәгәрмәчле арба (телега).

**кырантас арба** *минз.* к.: **крандас**.

**пәләг арба** *твр.* җиңел арба (бричка).

**ресур арба** *эстр.* кошёвка. Ресур арбаға утырып кийәүләр килә.

**сандык арбасы** *т.кам.-крш.* туйда кызның сандыгы куелган арба (свадебная повозка с сундуком невесты). Сандык арбасына салып алып киләләр, ат тотучыга бирнә бирәләр сандык арбасын алып килгән өчен.

**тәртә арба** *перм.* к.: **ад'ур 2.**

**түшәг арбасы** *чст.* килен төшергәндә аның түшәк-ястыкларын салып килә торган арба (повозка, на которой везут постельные принадлежности невесты). Түшәг арбасы да була, алдагы атта кийәү белән кыз утыра, икенче атта әрчи кызлары.

**уқалла арбасы** *каз.ар.-крш.* к.: **йәпләшкә**.

**урман арбасы** *трх.* к.: **ад'ур 2.**

**үреш арба** *туб.-ирт.д.* к.: **куш арба**.

**чатра арба** *нгб.-крш.*, **чыбык арба** *чст.*, **чытыр арба** *минз.* к.: **эридуwан**. Чыбык арбага печән тийәргә җайлы. – *чст.*

**чәнчег арба** *перм.* к.: **карандас**.

**чәңгелчәк арба** *себ.* тирес арбасы – ике тәгәрмәчле (тачка).

**чытыр арба** *минз.* тирән эчле арба (телега с глубоким дном). Чытыр арба белән көлтә ташыдык.

**шайтан арбасы** 1. *чст.* көлтә ташый торган арба (телега, на которой возят снопы); 2. *кмшл.* тирес ташый торган арба (телега для навоза). Лапастан алырсын шайтан арбасын.

**АРБАЗ** *злт., трбс.* абзар (хлев). Арбаз башын йабасы бар, тақта ғына йетәрлек түгел. – *злт.* Арбазға җабайдек малларны. – *трбс.*

**йалан арбаз** *злт., трбс.* к.: **абзар: абзар алды**. Йалан арбазға җабалар малларны кәртәләп. – *трбс.*

**АРБАЙАҚ** *перм.* киги (спицы).

**АРБАЙ-ТАРБАЙ** *бгрс.* тәртипсез, теләсә ничек, аркылы-торкылы (беспорядочно, как попало). Синең монаwы арбай-тарбай кискәнең (кәгазьне).

**АРБАКТЫ** *стрл.* юньсез, тәртипсез (беспорядочный, безалаберный). Ачуwы килгән әдәмгә, алама нәстәгә, усал булган әдәмгә арбакты диләр. Теләсә ничегерәк йөргән кешене, әй арбакты, диләр.

**АРБАУ** *брб.д.* к.: **арбыу**.

**АРБАУЧЫ** *брб.д.* сихерләүче (колдун).

**АРБАЧА** *перм.* туку станогында көре тагыла торган аркылы таяклар (палочки на ткацком станке, к которым прикрепляются ничанки – служат блоком при их передвижении).

**АРБУWЫН** *туб.-ирт.д., брб.д.* к.: **кормош**. Арбуын цәйнәсә шешемәйт. – *тбл.*

**АРБУУН** *брб.* к.: **кормош**.

**АРБЫУ** *саз.я.* сихерләү (заколдовать). Йылан арбыйт тиләр.

**АРWУЫН** *саз.я.* төклетура (шмель).

**АРҒА** 1. *себ.* арка (спина); 2. арт (задняя часть). Чуал арғазына кирде. – *твр.*

**АРҒАЛЫ** *тара.* тырыш (старательный).

**АРҒАЛЫҚ I** *себ.* матча (матица). Арғалықны үтмәйенцә генә сүләшкәннәр сауцылар. – *төм.* Қасқақны арғалыққа қыстырып қуйаты. – *тбл.* Өй күтәргәндә, арғалық башына айәтләр йасап қуйалар. – *тара.*

**АРҒАЛЫҚ II** *себ.* игелек теләү (пожелание добра). Аналықлар йыйдырдым, арғалықлар әйттердем.

**АРҒАЛЫХ** *саз.я.* к.: **арғалық I**. Арғалыхқа йоwан пүрәнә салсаң әйwәт.

**АРҒАН** *тара.* аркан (толстая верёвка, канат, верёвка из конского волоса).

**арған ату** *тара.* арканлау (арканить, заарканить).

**АРГАН** [*рус.* варган] *срг.* бәйләгән әйбердәге резинка формасындагы сыр, бизәк (резиночный узор на вязаных вещах). Наскиныңмыни арганы, эризанкасы.

**арганны цолка** *срг.* фабрикада резинка формасында бәйләнгән оек (фабричные чулки, вязанные в резинку).

**АРҒАСЫС** *тара.* ялкау (ленивый). Үсе бер аргасыс, иренцәк қатын пулған.

**АРҒОРЫ** *брб.д* к.: **арғыры**.

**АРҒОШ** *каз.ар.-крш.* туйда иң олы, дәрәҗәле кеше, баш кода (распорядитель на свадьбе: обычно им является дядя или родной брат невесты, а со стороны жениха – его дружка). Туйда оло урын аргошнықы, кергән кеше аның белән күрешә башта, пирwый ыстаканны да бирәләр аңа, аргоштан башқа җыр да башламыйлар.

**АРҒУН** *тара.* к.: **арбуын**.

**АРҒЫЛАР** *туб.-ирт.д.* тегеләр (те).

**АРҒЫМЛЫ: арғымлы җир (урын)** *минз.* ардыра торган таулы җир (утомляющая при ходьбе холмистая местность).

**АРҒЫРЫ** *брб.д.* аркылы-торкылы (крест-накрест).

**АРҒЫШ** *перм.* туйга бара торган парлы кунаклар (супружеские пары, приглашённые на свадьбу; когда свадьбу играют в доме невесты, таковыми обычно являются родители и родственники жениха, и наоборот, когда свадьбу играют в доме жениха – родственники невесты). Арғышлар, өндәүлеләр бергә баралар ирмәг итеп.

**АРГЫШ** *чст.-крш.* туй башлыгы (глава свадьбы). Безнең әниләр аргыш ыйы, аргыш дигәнем туй башлыгы ыйы, аргышка җырлыйлар.

**аргыш келчәсе** *чст.-крш.* туйның соңгы көнендә табынга чыгарыла торган көлчә яки икмәк (хлебцы, которые выносят гостям в последний день свадьбы, якобы испечённые *аргыш*ом). Сары сандугачның баласы Сайрый-сайрый җирләргә төшәме, Безгә генә китәр багытлар җитә, Аргыш келчәләрегез пешәме? (*хал. җыр.*)

**АРДА'** *кас.*, **АРДАК** *лмб., тмн., кузн., мәл., карс.* кадер, хөрмәт (почёт, честь, уважение). Син бит үwендә ардаклы, мында ардакың йук. – *лмб.* Йугинде әткәй-әнкәй ардагы. Аналы-аталы, ардакта үскән. Ардагы пушчырак булыр иде ат'ам. Ардакта үскән башымны йалчым белән йырлыйлар (*бор. бәет.*). – *кузн.* Кыз балакай дигән гар'ып бала, йәшли бетә аның ардагы, сылывым ардагы (*бор. җыр*). – *тмн.* Арда'та үстем. – *кас.* Ардак кынам, наз гынам, калды әни түрендә (*хал. җыр.*). – *карс.*

**АРДАҚЛАНУ** 1. *лш.* арыну, котылу (избавиться, отделаться). Үзеңнекеләрдән ардақланғач моносы бик тәмне була бит ул (баланың баласы турында). Үземнекеләрдән ардақландым бит инде, алар үсебеткән, бу бала җаңа җимеш; 2. *лмб., т.я.-крш.* иркәләнү, таяну, аркалану (нежиться; рассчитывать, надеяться на кого-либо). Кемгә ардакланып тырасың? Тайаныр җире бар, ардаклана. – *т.я.-крш.*; 3. *лмб.* чистарыну (стать чистым). Ардакланырсыз, иртәгә мынча йагабыз.

**АРДАҚЛАУ I** *каз.ар.-крш.*, **АРДАКЛАУ** *мәл., кузн., хвл., чст., күрш.* кадерләү, иркәләү (заботиться, заботливо относиться к кому-либо, нежить, ласкать). Ардақлап қына тотқаннар қызны. –

*каз.ар.-крш.* Ыланын ардаклап үстерә. Кызны үстерәсең ардаклап та, алар унзиде йәшеннән китәләр синең йаныңнан. – *чст.* Ардаклап кына үстерәм баламны. – *кузн.* Ардаклыйм, нишлим соң, жәлләр выт. Ардакламаска, әбиләре булам. – *хвл.* Кызым, кийәвемне кунакка цакырдым, ардакладым. Кунак ардакладым. – *күрш.* Ардаклап үстердем кызымы, ардаклы балам ул минем. – *чпр.*

**АРДАҚЛАУ II 1.** *мам., каз.ар.-крш., т.кам.-крш., т.я.* чистарту, арындыру, чүптән аеру (очистить, расчистить, выбирать, сортировать). Унике қазның эчен-башын бер көндә ардақладым. Мәче ардақласын, қуй сөйәгенә өстәл астына. Түбән өйдәге бәрәңгеләр үри бит әле, мынчалаланып беткән, аны ардақлап қуйасы бар беркөнне. Бәрәңгеләр ардақладым, иресен ирегә, wағын wаққа. – *мам.* Түбән өйдә бәрәңгебез үрә, ардақласаң да қәзер үсеп чыға. Үзен-үзе ардақламаган кешене жаратмыйм да. – *каз.ар.-крш.* Ардақлап чығардық, ди торғаныйы безнең эни чүп-чарны чыгарып ташлаганнан соң. – *т.кам.-крш.*; **2.** *к.т.* юну, юнып чистарту – агачны ботакларыннан (очистить дерево от веток); чаг.: **бунау 2**. Суқмақ буйындағы қайынны жығып, ботақларыннан ардақладым.

**АРДАҚЛЫ** *каз.ар.-крш., эчк., перм., злт.*, **АРДА'ЛЫ** *кас.* кадерле, якын (дорогой, любимый, близкий). Чәч тей очларында көмеш тәңкә, Тағып қына чықсаң салмақлы. Қыз дей чақларында шунысы рәқәт, Башқайларың була ардақлы (*хал. жыр.*). – *каз.ар.-крш.* Менә минем улым ардақлы инде берәү генә былғас. – *злт.* Арда'лы 'уна'ыбыз син. – *кас.*

**АРДАКЛЫ** *миш.д.* **1.** к.: **ардақлы**. Үзеңнеке лан усал булса да ардаклы, күрекле. – *кузн.* Ардаклыйдем, хурмәтлейдем, Әткай-әнкай түрендә (*бор. жыр.*). – *хвл.* Сабаклы түмә салмаклы, Сабаксыз түмә салмаксыз. Аталы бала ардаклы, Атасыз бала ардаксыз (*әйтем*). – *чст.* Без бердәнбер ардаклы малай үстердек. – *мәл.*; **2.** *стрл.* к.: **атаулы**; **3.** *стрл.* начар даны чыккан кеше (человек с дурной славой). Әйбәт түгел инде ул ардаклы кеше булгач.

**АРДАКСЫЗ** *кузн., лмб., тмн., чст.* кадерсез (неуважаемый; не имеющий уважения, ценности, заботливого отношения к себе). Бер генә ардаклы, бер генә булмаса – ардаксыз. – *кузн.* Ардаксызның аркасы туза, йеңгәсезнең йиңе туза (*әйтем*). – *тмн.*

**АРДАНА** *срг.* әрдәнә (штабеля дров, поленница).

**ардана бул** *срг.* орышу, каргау сүзе (ругательное слово, проклятие).

**АРДЗУУЛ** *брб.д.* к.: **битйаулық**.

**АРЖАҚ** *минз.*, **АРЖАК** *чст.-крш.* Казан арты күздә тотыла (имеется в виду Заказанье). Элгәре аржактан кемешчеләр киләдерийе, беләзекләр, балдак-беләзекләр кийалар ыйы. – *чст.-крш.*

**АРИХ** [*рус.* орех] *әстр.* чикләвек. Қатланчыққа арих салыпты.

**АРЙАҚ** *глз., нокр.* өйнең икенче ягы, икенче бүлмә (другая половина избы). Арйақтан китер чашка. Арйақтамы әчәбез чәй? – *глз.*

**АРЙАН** *әже.* әйрән (айран).

**а р к а** (спина):

**арқа жылысы** *трх.* к.: **арқа йылы 1**. Арқа жылысы гына кигән, урамнан күрдем, ничек туңмый.

**арка йылы** *чпр.* **1.** көрти, сырган камзул, сырган жиңсез кием (стёганая безрукавка, душегрейка). Әтәң урамга минем арка йылымны кийеп цыккан, ахыры; **2.** бәйләгән жиңсез кием (вязаная безрукавка). Арка йылылары үзем бәләклим.

**арқа йылысы** *нрл.*, **арка йылысы** *байк.* к.: **арка йылы 1**. Шул халат өсөндә арқа йылысы кигән. – *нрл.*

**арқа қочтору** *т.я., мам.*, **арқа қочу** *блт.*, **арқа қычу** *кргл.* аркага күтәрү (посадить на спину). Арқа қочтороп қына жөртте. – *к.т.* Биш баланы арқа қочоп үстердем. – *блт.* Эч чақрым йерне уһылдап, арқа қычып қайтасың. – *кргл.*

**арқа сабағы** *перм.*, **арқа севәге** *миш.д.*, **арқа сийәге** *кмшл.* умыртка, умырткалык (позвоночник). Шәп қаты қайғының арқа сабағына зыйаны күп. – *перм.* Мына ушы тештән арқа сийәгем awырта. – *кмшл.*

**арқа үзәге** *минз.* к.: **арқа чоқоро**.

**арқа чабыш** *минз.* уен исеме (название игры). Кич утырғанда арқа чабыш уйный торғаннар ыйы жәшләр.

**арқа чоқоро** *мам.* арка сөяге (спинной хребет).

**АРҚАҚ** *тбл.*, **АРҚОУ** *брб.д.* аркау жебе (уток). Арқақ йип.

**АРҚАЛАП** *әстр.* аркага асып (повесив на спину). Арқалап алып қайттым кизәкне.

**АРҚАЛЛЫҚ** *дөб.* к.: **арқанлық**.

**АРҚАЛЫҚ I** *эчк.* к.: **арата 1**. Идән арқалығы.

**АРҚАЛЫҚ II** *перм.* к.: **артча**. Арқалыққа өчәр рәт ваграк тәңкә тезелә, очона өчәр бөтен тағыла.

**АРҚАЛЫҚ III** *әстр.* өстән киелә торган жилән (верхняя одежда – джилян). Арқалықның итәге киң, жиңе киң, уқалы була, төймәләре көмеш була. Арқалықның биллəре бөрелеп тора, парчалардан тегелгән. Бар да махмал, бар да уқалы, бар да уқа ман теккән. Арқалықтан күлмәге чығып торған.

**астарлықлы арқалық** *әстр.* инеч салып тегелгән жилән (джилян с подкладкой). Йулақ-йулақ йефәктән астарлықлы арқалық кийәтеләр.

**қызлар арқалығы** *әстр.* ефәк тукымадан билле итеп тегелгән жилән (шёлковый приталенный джилян). Қызлар арқалықсыз йөремәде, қызлар арқалығы затлы ылбадан, бөрелеп тора.

**махмал арқалық** *әстр.* бәрхеттән тегелгән жилән (джилян, сшитый из бархата). Махмал арқалық байларда булды.

**чал арқалық** *әстр.* йон тукымадан тегелгән жилән (джилян, сшитый из шерстяной ткани). Чал арқалық жылы булаты, әүләдә йөргәндә кийәм чал арқалықны.

**ылба арқалық** *әстр.* ефәк жилән (шёлковый джилян). Монади гөлле-гөлле ылба арқалық бар.

**АРҚАН** *нокр.*, **АРКАН** *глз.* киндерә (оборки). Чабатаға арҡан кертәбез, чормап-чормап мендерәбез. – *нокр.*

**АРҚАНДЫРУ** *минз.* к.: **ирәгештерү**. Арҡандыра хәзер.

**АРҚАНЛЫҚ** *дөб.* аркалык (чересседельник). Тау менгәндә атыннын арҡанлыгын төшер.

**АРКАСУГЫШ** *чст.* балалар уенының бер төре (детская игра). Малайлар аркасугыш ун′ап йаталар.

**АРКАУЛЫК** *хвл., мәл.* к.: **арҡанлық**. Бу алаша аркаулыгын күтәргәнне йаратмый. – *хвл.* Алашаның аркаулыгын бересен бушатаештем. – *мәл.*

**АРҚЫЛАҒАЧ** *к.т.* өй эчендә әйберләр элү өчен мич тирәли куела торган колга (шест, устроенный у печки для развешивания салфеток, белья и т.д.). Тастымалыңны почмақтагы арҡылағачҡа эл, кибеп торор.

**АРҚЫЛУ** *мам.* к.: **артылу**. Теләсә нишләсеннәр, минем үз қайғым түбәмнән арҡылған.

**АРҚЫЛЧАҚ** *дөб.* арата (поперечина, перекладина).

**АРҚЫЛЫ-ТИРКЕЛЕ** *том.д.* аркылы-торкылы (крест-накрест).

**АРҚЫРАЙУ** *перм., к.-уф.* киреләнү, тискәреләнү (упрямиться). Мин карт, уқый алмыйм дип, арҡырайып бармадым. – *перм.*

**АРҚЫРЫ** *перм., к.-уф.* **1.** к.: **аткыры 1**. Арҡыры агачны буй бормый (*мәкаль* – ялкау кеше турында әйтелә). – *перм.* Йулға арҡыры йата. – *к.-уф.*; **2.** кире, тискәре (упрямый). Арҡыры бу, сүз тыңнамый қый. – *перм.* Бер йомыш қушып тыңлатып булмый, бик арҡыры бу малай. – *к.-уф.*

**АРЛАҚ** *нгб.-крш.*, **АРЛАК** *срг., хвл., кузн.* арырак (дальше, подальше). Моннан арлақ барсаң, ышкул булыр. – *нгб.-крш.* Арлак барсаң, күрерсең йулны. – *срг.* Син арлак бар әле. – *хвл.*

**АРЛАН** *тпк.* ата эт яки песи (самец – у кошек или собак).

**АРЛАУ I** *глз.* к.: **ардақлау II, 1**. Зийарәткә күп ағач үскән, арлау кирәк, чиләм үссен.

**АРЛАУ II** *туб.-ирт.д.* билгеләү (определить, размечать).

**АРЛЫ 1.** *каз.ар.-крш.* к.: **ары 4**. Тағы килер әле төштән арлы. Шуннан арлы қурқам (йәшеннән). Аны күмгәннән арлы тағы ике кийәүгә барды; **2.** *каз.ар.-крш., эчк.* к.: **ала 1, 2**. Тездән арлы қызыл балчыққа батып менгән. Моннан арлы ғына бер сәке кисәге йошторо бирген әле. – *каз.ар.-крш.* Аның қулы шуннан арлы йуқ. – *эчк.*

**АРЛЫҚ 1.** *каз.ар., т.кам.-крш.* к.: **ала 1**. Билдән арлық судан чықтық. – *мам.* Қәзер озон кийәләр менә шушыннан арлық, озон итеп тек, дей, мин әйтәм, моннан арлық текмибез, матур тегел алай теккәчтен, дим. – *т.кам.-крш*; **2.** *каз.ар.-крш.* к.: **арлак**. Читәннән арлық қына безен бақча; **3.** *мам., каз.ар.-крш.* ... ук, бирле, алып (с, от). Иртәдән арлық башым awырта. – *каз.ар.-крш.* Сез қайдан арлық килдегез соң инде? – *мам.*

**АРЛЫҚЫЙ** *т.кам.-крш.* к.: **ала 1**. Түшлек булыр ыйы менә тушыннан арлықый, түштән арлықый тәңкә.

**АРМА** *туб.-ирт.д.* койма баганасы (заборный столб).

**АРМАҢ! АРМАЙ ЭШЛӘҢ!** *себ.* эшегез уң булсын (работайте не уставая).

**АРМАСТАН** *әстр.* картаймыйча, яшь көенчә (не состарившись). Армастан үлеп киткән кешегә бик тақмақлап йылыйлар.

**АРМЫТ** *әстр.* груша.

**армыт тирәк** *әстр.* груша агачы (грушевое дерево). Армыт тирәк күп утыртыпсыз.

**АРНАП** *әстр.* багышлап (посвящая). Үлгән кешегә арнап чик бирәсен, қормандай итеп.

**АРНАУ** *туб.-ирт.д., брб.д.* билгеләү (предназначать).

**АРПА 1.** *т.я., лш., дөб.* терлекләрдә була торган авыз эче бетчәләү чире (воспаление полости рта – у животных). Сыйырға арпа булған, бернәстә ашамый, селәгәйе аға да тора. – *к.т.*; **2.** *каз.ар.* күзнең өске кабагына чыга торган бетчә (ячмень на верхнем веке глаз); чаг.: **эт II: эт терсәге 2**.

**арпа тапый** *перм.* к.: **чүпләмле**.

**арпа теле** *т.кам.-крш.* арпа имләгәндә әйтелә торган сүзләр (заговорные слова, наговор от ячменя).

**арпа тышлау** *перм.* махсус төйгечтә яки тегермәндә арпа орлыгының тышчасын, кабыгын салдыру (обдирка ячменя ручным способом или на специальной мельнице); чаг.: **қақтыру**.

**АРПАЛАУ** *минз., стрл.* арпа имләү (знахарский метод лечения от ячменя). Арпалый идек тә, бетә иде. – *минз.*

**АРПАЧА** *кузн., тмн.* күзгә чыга торган арпа (ячмень на глазу).

**АРС** *тара.* үтенеч, теләк (просьба, желание).

**АРСАР** *тбл.* **1.** исәр, юләр (глупый, дураковатый, бестолковый); **2.** кыргый (дикий).

**АРСАУ** *туб.-ирт.д.* ошау (нравиться).

**АРСУ** *саз.я.* **1.** исәрләнү, юләрләнү (дурачиться, становиться дураком, глупеть); **2.** гашыйк булу (влюбляться). Камил Нурийәгә арсып китепте.

**АРСУЛ** *брб.д.* яулык (платок). Мойнында торға арсул пар иде.

**АРСЫЙ** *злт.* кызны кияү йортына озата баручы парлы кунаклар, гадәттә туганнары яки якын кардәшләре (родственники или близкие невесты, сопровождающие её в дом жениха). Элгәре ике арсый килә торған ыйы.

**арсый ашау** *злт.* туйның икенче көнендә үткәрелә торган кызлар мәҗлесе (девичий пир на другой день свадьбы). Туйның икенче көнне арсый ашау була. Аны шул қыз йиңгәләре үзләре йыйылышып қунақ булышалар бер өйдә, қызның арсыйын ашыйбыз, диләр.

**АРСЫТУ** *саз.я.* **1.** котырту (подстрекать, подбивать, дурачить). Суға төшкәле арсытаты; **2.** юату (занимать, развлекать). Паланы арсыт.

**АРТ I 1.** *кас.* ас (низ, под). 'азан артын җа'ып җибәр'ен. Үрди' артына җиде җомор'а 'уйдым, и бәрси ди чы'ты; **2.** *мәл.* соң (после). Йыкладык мунча арты бик йакшы итеп.

**АРТ II** *каз.ар., т.я., мәл.* бәрәңге бакчасы (картофельный участок). Артлар қап-кара, сувык булғач, бәрәңге тишелми. Әйткән ийем, атны артқа

туwар дип. – *лш.* Кемнең арты җитми, өстәп сытый бирәләр. Арттан кердем ийе бәрәңге утап. – *трх.* Артыбыз йакшы, шынарга күрә китмибез мыннан. – *мәл.*

**АРТ III** *карс.* чәчкап (женское украшение для волос). Бик йакшы субагач китердем, запун кырдым, арт тактым.

**АРТ VI: арт итү** *нгб.-крш.* к.: **асрану 3.** Без пинсийә белән генә арт итәбез.

**арт тәңкә** *карс.* к.: **арт III.**

**АРТА** *к.-уф.* к.: **азак.** Арта әйтә бу Сәлимгә. Анда барғас, арта безгә кил!

**арталар қалгыры** *нокр.* артта калгыры, беткере! (зложелание: да пусть останется позади!). Арталар қалғыры Мазар тawы, йес тағалы туратым меналмай; Арталар қалғырының йырақ йулы, Йебәргән сәләм хатым йеталмай (*бор. жыр.*).

**АРТАБА 1.** *перм., к.-уф.* к.: **анар: анар суң.** Килешмәде, артаба чәчмәс булдық. – *перм.* Башта үзегез килегез, артаба без барырбыз. – *к.-уф.*; **2.** *крғл.* анда таба (в том направлении). Артабарақ барсаң, алар. Артаба бар taw.

**АРТАБАН** *перм., трбс.* к.: **андары.** Мунча чоланда торғаннар, артабан Әлфит өйгә кереп киткән. Артабан мине эзләп алдылар. – *перм.* Бер сүз дә әйтмичә, артабан китеп барды. – *трбс.*

**АРТБАКЦА** *чст.*, **АРТБАҚЧА** *каз.ар., кмшл.* каралты тирәсендәге җир участогы (приусадебный участок земли). Әни артбақцада бәрәңге үwә. – *чст.* Артбақчаны җармадығызмы әле? – *дөб.* Артбақча дәү түгел безнең. – *лш.* Артбақчадан гына қарап кер бүлмәне. – *кмшл.*

**АРТҖАУЛЫ'** *кас.* шәльяулык (большой платок). Артҗаулы'лар бар иде, чәчә'ле, йа'шы, йәш 'иленне'е фурмасында.

**АРТИЛ** *лмб.* күп, ишле (много, многочисленно). Артил малай арасында бер генә кыз булып үстем үскәндә.

**артил йөрү** *т.кам.-крш.* к.: **әртил җерү.** Көзен маллар суйғачын артил йөрибез өйдән өйгә кереп.

**артил чыгу** *лмб.* күп булу, күп чыгу (много выделяться – о молоке). Артил чыга йазын бозаулаган сийрның сөте.

**а р т қ а** (назад, взад):

**артқа қуймау** *мам.* кире какмау, баш тартмау (не отказываться, не отвергать). Булса, артқа қуймыйлар керәшеннәрең ат итен дә.

**АРТКАВЫ** *кузн.* к.: **арқақ.** Шул чәке буйына гына, әлдә арткавына да кирәк.

**АРТҚАРЫ** *перм., сазя.* ерактагы, аргы (дальний). Артқары җалан. – *перм.* Артқары, иген йақтағы өйләрне сыу алмаған. – *сазя.*

**АРТҚЫЛЫ** *каз.ар.*, **АРТКЫЛЫ** *тмн.* к.: **аткыры 1.** Урам артқылы ғына алар. – *блт.*

**артқылы кеше** *каз.ар.* дошман (враг).

**АРТКЫЛЫЙ** *мәл.* к.: **аткыры 1.**

**АРТКЫРЛЫ** *мәл.* аркасында (из-за). Шул йазу арткырлы эслитестewийе барды да.

**АРТҚЫРЛЫ 1.** *злт.* иң (ширина). Сүбәген артқырлысына эрлиләр; **2.** *злт., крғл.* к.: **аткыры 1.** Кеше артқырлы ғына сүләгән сүз. – *крғл.*

**АРТКЫРЫ** *срг.* к.: **аткыры 1.** Түшәкне арткыры сал.

**АРТКЫРЫ-ТОРТКЫРЫ** *срг.* аркылы-торкылы (крест-накрест, вдоль и поперёк). Китапларын арткыры-торткыры ташлаган.

**АРТЛАТА** *мәл., шрл.* бакча артыннан (сзади). Киткәннәр, ди, артлата урамнардан.

**АРТЛАУ** *бгрс., крғл.* артта калу (отставать). Андый wақытларда балаларның уқулары артлый. – *бгрс.*

**АРТЛАЦ: артлац пулу** *сазя.* аймылыш булу (разминуться). Пес аның пелән артлац пулыппыс.

**АРТЛАШ: сүзгә артлаш төшү** *себ.* сүзне бүлдерү (перебивать речь).

**АРТЛЫ-АЛАННЫ** *мәл.* аллы-артлы (один за другим). Эц цашкы эцтем артлы-аланны.

**АРТМАҚ 1.** *злт.*, **АРТМАК** *т.я.-крш.* күннән яки киндердән тегелгән букча, сумка (кожаная или холщовая сумка). Йеңгәләре қодагыйга китерәләр күстәнәс төйәп, артмақ диләр аны, йеңгәләр артмақ апара. – *злт.* Элек Паскада сабан туйы бара иде, артмак күтәреп җөриләр иде җымырка җыйып. – *т.я.-крш.*; **2.** *тбл.* йөк (вьюк).

**АРТСАЛМА** *том.д.* җиңсез камзул (безрукавка, камзол). Артсалманы қатыннар да, ирләр дә кийә. Мамайларның артсалмаға тәңкәләр тезгән була иде. Балаға артсалма тектеләр. – *яүшт.*

**АРТТӘҢКӘ** *чпр.* чәч тәңкәсе (накосная монета). Цәцләрен шылай тылым итеп үргән дә арттәңкә үргән киленнәр.

**АРТТЫРУ** *нокр.* өстәү, өстәп салу (добавлять). Арттырыйммы аш?

**АРТУ I 1.** *сазя.* хайванга йөкне аркылы асу, төяү (нагрузить, навьючить). Атқа арыт пы қапцықларны; **2.** *брб.д., тбл.* таякка катлап-катлап кием элү (вешать бельё, платье на перекладину, одно поверх другого).

**АРТУ II** *туб.-ирт.д.* киртә (преграда).

**АРТЧА** *хвл.* хатын-кызларның бизәнү әйбере: өстенә өч-дүрт рәт тәңкәләр тезелгән һәм чәч толымнары өстенә куела торган ике тар тукыма кисәге, тасма (женское украшение: две тесёмки или узкие куски материи, украшенные 3–4 рядами монет и прикрепляемые поверх кос во всю их длину). Артчаны сала йәш килен йәш килен йылында. Артчага чулпылар тагалар. Иңсә төпләренә куйа булганнар да... Вота шонда элеп була артча.

**АРТЧЫ** *минз.* к.: **арсый.** Қыңғыраулар белә китердек, өчәр артчы китердек, дөбөрдәтеп туй йасадық.

**АРТЧЫЛЫЙ** *карс.* к.: **арсый.** Элке йәрәштеләр, аннан сың вет пар алаша, тырантас анда, артчылыйлар утыра.

**АРТЫ** *перм.* чүп, соңгылык – хайваннарда (послед – у животных); чаг.: **йатқылық 3.**

**АРТЫЗБА** *лмб., кузн., хвл.* куш өйнең кара ягы, аш-су пешерә торган ягы (чёрная половина избы; вторая половина избы, служащая кухней). Әлдә этәм, ди, сезнең артызбагыз ышыкта, анда тора торгансыздыр. – *кузн.* Барыгыз, артызбага чыгып сүләнегез. – *хвл.*

**АРТЫҚЛАУ** *тбл., брб.д.* **1.** яхшырту (улучшать); **2.** процент түләү (платить проценты).

**АРТЫҚСЫНУ** *тбл.* берәр нәрсәне икенче

әйбердән артыграк күрү (считать что-нибудь выше, лучше другого).

**АРТЫЛУ I** *перм., к.-уф., нгб.-крш., каз.ар.-крш.* ташу, тулып ташу (переливаться, литься через край). Ул сыра артылып китәйе ыстаканнан.

**АРТЫЛУ II 1.** *саз.я.* тау, койма һ.б. нәрсә аркылы чыгу, үтү (перелезать через гору, забор или др. преграду). Ницек цыктың қойматаң? – Артылып; **2.** *тара.* атлану, ябышып утыру (садиться верхом, прижавшись).

**АРТЫМСЫЗ** *тмн.* үрчемсез, артмый торган, алга китми торган – эш турында (не увеличивающийся, медленно продвигающийся вперёд – о работе). Либәдә артымсыз утарга.

**АРТЫН: аннан артын** *минз.* к.: **андары.** Қурқа буғай аннан артын, икебедне дә утыртмады кәбинәгә.

**йәш килен артын килү, кыз артын килү** *кузн.* килен алырга килү (приехать за невестой). Кыз артын киләләр алашларда, калакуллар таккан.

**АРТЫП: артып алу** *тара.* чистартып алу (почистить).

**АРТЫЧЫ** *глз.* к.: **арсый.**

**артыш I** (можжевельник):

**артыш җим** *перм.* к.: **айу I: айу баба җили'и.**

**АРТЫШ II** *тбл., брб.д.* артыгы, артып калганы (остаток, излишек).

**АРТЫШУ** *тбл., брб.д.* **1.** артыгын калдыру (оставить излишек); **2.** калу (остаться).

**АРУ I 1.** *хвл., кузн., т. я., глз., нокр., кмшл.* чиста, пакь (чистый, негрязный, непоганый). Алар ару-пак торалар. – *хвл.* Ару су. – *кузн.* Әт, мәче сәмытын ихәтле җусаң да арусыз була инде, ару булмый. Ару су wул, эчәргә җарый. – *к.т.* Фәззә апақ ару тыра. – *нокр.* Ару сәмытқа аудар. – *кмшл.*; **2.** *хвл., срг., глз., нокр.* чиста, ак (чистый, негрязный). Өс-башын ару-ак йөртә анасы, ни тагын кирәк. Йугачтан ару гына була. Күлмәкнең алнысы арурак кала вит. Ару эшләрмен. – *хвл.* Ару йумыйлар идәнне. – *глз.* Қулым ару дегел, қоромны. Кийемне дә ару йөрмә йарата. – *нокр.* Йөзен ару йумаган. – *срг.*; **3.** *хвл., тмн., шрл.* чиста, саф – су турында (чистый, прозрачный, немутный – о воде). Бездә ару су. – *хвл.* Иртә мынан инеш ару була. – *тмн.* Шындый чиста, ару сулар ага. Ару су ага инде мына, аруның арувы. – *шрл.*; **4.** *чст., хвл., чпр., кузн., тмн.* чиста, саф, ачык (чисто, ясно, чётко – о речи); чаг.: **айаз 5.** Хазергесе кебек ару сүләмәгән, чобалта төшеп сүләгән. – *хвл.* Син ару бик сүлисең. Бәк ару сүли Мәрус'а. – *кузн.* Вата йөрдегез каа, анда каты сүлиләр, бездә арулар. – *тмн.* Бик ару, сүләгәннәрен аңгарып була. – *чпр.*; **5.** *хвл., срг., шрл.* матур, чибәр (красивый, симпатичный). Төскә ару гына кызлары. Ул миннән ару, йәмне. – *хвл.*; **6.** *лмб., кузн.* гаепсез (честный, невиновный). Алашаны ырлауда ару кешене айыплыйлар. – *лмб.*; **7.** *нокр., бәр.* саф, катнашмасыз (без примеси, чистый). Ару эспирт. – *нокр.* Саламын алам да, ару ашлық қала. – *бәр.*; **8.** *каз.ар.-крш., мам., дөб., стрл.* яхшы, әйбәт (хороший; хорошо). Тамағыңа қапсаң, җегәр дә керер, терелергә дә ару булыр. Һәркем үзен ару җаққа сайлап қуйа, чақ җақта кеше җук. Сөт ару, сөт эчәм. Әрмийәдән қайтты ару гына бер җегет, димним үзенә. – *мам.* Синең бу күлмәгең йәшеленә қарағанда арурақ. Ару йоқладығызмы? – *минз.* Төшкән җирем дә ару ийе. Барыр әле, җырларға бармый, тамышы ару бит. – *каз.ар.-крш.* Ару кешене йаратам мин. – *бәр.* Игзаминығыз беттеме, ару бирдегезме? – *перм.* Ит ару түгел, тозлыдыр. – *кргл.* Ару түгел ашамый утыру. – *бгрс.* Wахытында арувын да күрдек, начарын да, хәзер ару инде барыбыз да. – *трбс.* Бу малайлар ару эш күрсәткәннәр. – *злт.* Алар ару сүзләр сөйләшеп утыралар, қартлар сүзләре. – *нгб.-крш.* Шул Хафиз кәмит уйный, ару гына уйный инде ул. – *стрл.*; **9.** *урт.д.* исән-сау, таза (здоровый, небольной). Нихәл, бабай, арумы? – *мам.* Ару ғына йөреп қайттыңмы? – *минз.*; **10.** *мам., каз.ар.-крш., минз., кмшл.* яхшы, әйбәт, симез (хороший, жирный). Ару әтәчләр әләккән сиңа, симедләр. – *минз.* Ите ару үзенең, майы да чыққан. – *кмшл.*; **11.** *каз.ар., минз., бәр., срг., стрл.* куәтле, көчле, ныk; шактый, байтак (сильно, крепко; значительно). Су күп тә, арурақ җауса, чишмә җулы бетә. – *мам.* Арурақ чап. – *минз.* Без мунчада ару гына исердек. – *срг.* Ару, үзенә ошаған малайы. – *бәр.* Балтырғанны ару ғына җыйып қайтқансыд. – *минз.* Ару кыйммәт булгандыр. – *стрл.*; **12.** *каз.ар.-крш.* кыйбат (дорого). Морҗа аруға төшә, чығару өчен генә бирәсең ниқәтле; **13.** *каз.ар., бәр.* сабан ашлыгы оны (мука из яровых культур). Аруға өзелмибез без бер дә, узған йыл бодай күп алганыйық. – *блт.*

**ару азық** *кмшл.* ак он, бодай оны (белая мука, пшеничная мука); чаг.: **ару I, 13.** Хәзер ару азық күб инде, қалач қына ашыйбыз.

**ару җоморқа** *т.я.*, **ару йоморка** *чст., хвл.* чебешсез, яралгысыз йомырка (яйцо без зародыша). Йегерме йомырка белә цебеш утырткан идем, икесе ару булган, унсигез цебеш цыкты. – *чст.* Бер утырды – ару иде йоморкалары. – *хвл.* Бер атна утырғач қарыйбыз да ару җоморқаларын алабыз қазның. – *к.т.* Умбиш йоморқа салған, умбише дә ару буган. – *трх.*

**ару он** *каз.ар., т.я., кмшл., нгб.-крш.* к.: **ару I, 13.** Күб итеп ару он әзерләдек. Ару он күп булғач, қабартма, қоймақны гел пешерәбез. – *к.т.* Ару оннары кибеттә дә өзелми. – *мам.*

**ару үлем** *хвл.* яхшы үлем, ягъни хәвефсез, фаҗигале түгел (хорошая смерть, т.е. смерть, не связанная с трагическим случаем). Ару үлем, ак кифен (*әйтем*).

**АРУ II 1.** *срг., глз.* бөтенләй (весь, совсем, вовсе). Сез арумы мында килгәнегез йук? Ару сүләмәскә мужыт. Кыйларның бурасы ару зимерелеп төште. – *срг.*; **2.** *срг., глз.* бөтенләйгә (навсегда, насовсем). Зәкийә арумы килгән, китәргәме? – *срг.* Синең укысы беткәндәме инде ару, аңа да синеке хәтлүк бетерәсезме? – *глз.*; **3.** *срг.* бөтенесен дә, барысын да, тулысы белән (всё, целиком, полностью); чаг.: **берче 3.** Итегезне арумы асыйм?; **4.** *хвл., нокр.* гел, шау (весь, сплошь). Ару чәчәк эчендә утыра. Бакчалары ару чәчәк. – *хвл.* Ару ақ чәчкә ата, андайға ниwиста гел әйткәннәр. – *нокр.*; **5.** *хвл., срг., глз., нокр.* гел, фәкать, шыр, ... гына

(совершенно, совсем, весь; лишь, лишь только, исключительно). Артында ару сабын қалған (чәчнең). – *нокр.* Ару тоз булган ашың. Сөте ару су гына, бер тәме йук. Ару май гына ите. Кесәлең бик чөчө, ару бал гына. Үләре ару тузан. – *хвл.* Ару бишкә укий. – *срг.*

**ару ач** *хвл., кузн.* к.: **зықма II**; чаг.: **берче 1.** Хайwан ару ач бит, нәстә дә бирергә иде. – *хвл.* Ару ач тора. – *кузн.* Камыры ару йоморка. Катыгы ару каймак кына. – *хвл.* Ару бишкә укий. – *срг.*

**ару йукка** *хвл.* **1.** бөтенләй юкка, юк өчен, сәбәпсез (зря, совершенно зря, без причины). Ару йукка бәләнә; **2.** к.: **алайукка 1.** Ару йукка саттым сыйрны.

**ару су булу** *хвл.* манма су булу (промокнуть насквозь). Шондый жар, ару су булдым.

**ару тир булу** *хвл.* шабыр тир булу (сильно вспотеть, быть мокрым от пота). Бөтен тәне ару тир булган.

**АРУWЫМ-САРУWЫМ** *хвл.* малайлар су коенганда соңгы тапкыр чуму алдыннан әйтелә торган сүз (слово, произносимое купающимися мальчиками перед последним нырянием). Арuwым-сарuwым, бер чумuwым-чыгuwым.

**АРУГА I** *хвл.*, **АРУҒА** *каз.ар., т.я., кмшл., кргл.* чистага, кешлеккә – кеше арасына чыкканда гына кия торган кием турында (для надевания в нерабочее время – о выходной, нерабочей одежде). Күлмәгемнең моносон аруға кийәм. – *мам.* Аруға кийә торған кийем. – *к.т.* Ансы аруға калсын инде (күлмәк). – *кмшл.* Қызлар аруға ғына бәйлиләр пауτинканы. – *кргл.*

**АРУГА II 1.** *хвл., срг., карс., кузн.* к.: **ару II, 1.** Выргытканнар аруга. – *хвл.* Сөтөн түкте дә мачы баласы, аруга ач калды, нәстә тагы бирим инде. – *кузн.* Көлкө инде аруга. Аруга йук ыйыткым. Бездә кандала аруга йуктыр. – *срг.* Утырдым да ыныттым аруга. – *карс.*; **2.** *срг., карс.* к.: **ару II, 2.** Аруга килгән инде Фәридә awылга. – *срг.* Малый үwендә кыз кертәләр, аннан аруга алалар инде кызны бөтенләй әйбере белә (кияү йортына); **3.** *срг.* к.: **ару II, 3.** Усатыңны аругамы күмдең? **4.** *срг., хвл., кузн.* гел, һәрвакыт (всегда, постоянно, всё время). Нидер йазасыз аруга гына. Аруга awылда тырабыз. – *кузн.*

**аруга алып китү, аруга китерү** *срг.* кызны кияү йортына бөтенләйгә алып китү (окончательные проводы невесты в дом жениха). Кызның радителләре әзерләгән була кызга сондок, урын-йир, йастыгыдыр, адийалыдыр. Билгеләнгән бер көнне кызны әйберләре белән алып киләләр малайның йортына бөтенләйгә. Озата баруцы кодалар утыра. Кийәү белән кыз аткамы, машинагамы утыра. Алып китәләр аруга. Кыз озата баручылар була инде. Кийәү йортына төшкәц тә, аруга китергәнце, өстенбашын тишенми әле кыз, аруга китергәнце кыз үзенеке өйөнә кайтып йөри әле кунарга. Пастил бит анда калган була. Аруга төшергәц, кыз ана йагы цакырмыйцы бармый, барыга дерес тегел.

**АРУЛАНУ** *каз.ар., бөре., кргл., кмшл., злт.* яхшыру, әйбәтләнү, рәтләнү (улучшиться, хорошеть, поправляться). Чөгендерләр йаңғырдан соң аруланды. – *бөре.* Тормышы аруланды хәзер қызымның. – *мам.* Заманнар хәзер аруланды, ни ашасаң – ул бар, ни кисәң – ул бар. – *кргл.* Хәзер аруландым инде, личинийәгә йөредем. – *злт.*

**АРУЛАТУ** *хвл., мәл., чпр., м.-кар.* печтерү (кастрировать). Арулаткан булса, тәкәнеке дә йакшы була, шолай да тешенеке йакшырак (ите). – *хвл.* Арулаткан тәкә. – *м.-кар.*

**АРУЛАУ I** *тбл.* мактау, хуплау (хвалить, одобрять).

**АРУЛАУ II 1.** *чст., мәл., хвл., кузн.* юу, чистарту, тазарту, чайкау (мыть, чистить, полоскать). Йаңыдан казанны арулап, кукай сытып, йаңыдан эремчекне салып казанга, кайнатасың. – *чст.* Аннан китереп керне ару су белән арулыйлар. – *кузн.*; **2.** *перм.* мәетне юу (омывать покойника). Әле арулама итәләр, сәгәт пирwайларға күмәләр; **3.** *бәр.* орлыкны кибәгеннән аеру (очистить зерно от мякины). Бездән йырақ түгел тегермән барыйы, арулый да чыгара тарыны.

**АРУЛЫҒЫМ-ЧИРКӘНЧЕГЕМ** *каз.ар.* к.: **арuwым-сарuwым**. Арулыгым-чиркәнчегем, тазалыгым-байлыгым. – *блт.*

**АРУМСЫЗ** *нгб.-крш.* исәнмесез (форма приветствия при встрече). Арумсыз, Кәтүк түти!

**АРУМЫ** *урт.д., каз.ар., крш., минз.* исәнме, саумы (форма приветствия при встрече). Нихәл, бабай, арумы? – *мам.* Апанас дәдәй, арумы? Арумысыз, Даржа түтәй? – *каз.ар.-крш.*

**АРУСЫЗ** *т.я., чпр., чст., мәл.* чиста түгел, пычрак, пакь түгел (нечистый, поганый). Арусыз әйбирләр йук бездә. – *мәл.*

**АРУСЫЗЛАУ** *т. я.* пычрату (сделать поганым, нечистым). Қойға мәче төшкән, суны арусызлаған инде. Арусызлама чәй сuwымны теләсә нинди саwыт тыгып. – *к.т.*

**АРУСЫНМАУ** *бгрс., каз.ар.* яхшысынмау (считать неудобным, неприличным). Ил′дар арусынмый әйтергә. – *бгрс.* Әйтмәдем мин сезгә ул сүзне, арусынмадым. – *мам.*

**АРУ-ТАРУ** *т.я., каз.ар.* к.: **ару I, 13.** Ул җылны иген бик уңды, ару-тару күп пулды. – *к.т.* Йаз көне ару-тару бетеп киткән wакыт, сезне бик сыйлап пулмад(ы) инде. – *дөб.*

**АРУЦАН** *күрш.* чиста, пөхтә (чистый, аккуратный). Мин аруцан, алар беләләр мине.

**АРУЧА** *бәр.* к.: **ару I, 2.** Бик аруча йы ул йаман.

**АРЦАЛАНУ** *байк.* арыну, котылу (избавиться, освобождаться); чаг.: **ардаклану.** Дошманнардан арцаланып башланып киткән безнең тормыш.

**АРЦИ** *чпр.* к.: **арсый**. Арци туйда кыз артыннан килә, тугыз-ун ылау арци була.

**арци йоласы** *чст.* килен төшкәндә аны озатып килгән кызларны хөрмәтләү, қунаққа алу (свадебное застолье в честь девушек, сопровождающих невесту). Арци йоласы бит инде, күршедә кунаклар йидылар, күп кенә кызлар килделәр.

**арци кыз** *чст.* яшь киленне кияү өенә озатып баручы кыз (девушка, сопровождающая невесту в дом жениха). Тыгырыкны менгәндә кошовка awa йазды, мин бырылып карадым, арци кызым аумады микән дип.

**арци төшү** *чст.* егет ягына килен төшү, туй килү (переезд невесты в дом жениха с сопровождающими). Алтышар ат белән арци төшкән, пawыска белән арци төшкән.

**арци уздыру** *чст.* туй уздыру (провести свадьбу). Бер әби арци уздыруны сүли иде.

**АРЦУ** *срг.* әрчү (чистить, очищать).

**каз эцен арцу** *срг.* каз йолку (выщипывание зарезанных гусей). Каз эцен арцырга барабыз, диләр иде.

**АРЦУWЫЛ** *брб.д.* яулык (платок).

**АРЧА** *минз., трбс., кргл., стрл.* **1.** к.: **арсый**. Килен төшергәндә кыз җағыннан киләләр арчалар, йә ике пар, йә бер пар. – *минз.*; **2.** к.: **кодача**. Артыннан арчасы да бар. – *стрл.* Кызның үзенең арча кызы диләр, йанында инде иптәш кызы була. Кыз үзе йалгыз ғына булмый, аны кийендерәләр. Шул арча кызлары озата барганда бергә утырып баралар. – *трбс.*

**АРЧАЛАУ** *перм.* **1.** аеру, аралау (разнимать, разъединить). Ике кеше суғышқанда берсе кереп арчалый; **2.** аеру, (иреннән) аертып алу, (хатынын) аертып бару (разлучать, отбить чужую жену или чужого мужа); **3.** к.: **аралау 2**. И Ходайым, үзең арчала. Awырлыклардан арчала.

**АРЧАЛАУЧЫ** *перм.* аралаучы, берәр төрле кыенлыктан котылырга ярдәм итүче, ярдәмче (заступник, защитник). Тегесе малайым минем бөтен думымны қырды, мине беркем арчалаучы булмады.

**АРЧИ 1.** *хвл., кузн., чст., мәл., чпр., кмшл.* кызны кияү йортына озата баручы кызлар яки хатыннар (девушки или женщины, сопровождающие невесту в дом жениха). Кызны озаталар арчи катыннар. – *кузн.* Ике арчи бара инде: йакын кардәше була, йакын күршесе була. – *хвл.* Арчи булып дус кызың, туганың бара. – *чст.* Арчига бардым әле. – *чпр.* Арчи қызлар. – *кмшл.*; **2.** *бөре., минз., кмшл.* кызны кияү йортына озата баручы парлы кунаклар: гадәттә кияүгә баручы кызның абыйлары белән җиңгәләре һәм апалары белән җизнәләре (супружеские пары, сопровождающие невесту в дом жениха: обычно братья с жёнами и сёстры с мужьями).

**арчи алучылар** *кузн.* кияү ягында яшь киленне озата баручыларны кунакка чакыручылар (родные и близкие, которые приглашают в гости женщин, сопровождающих невесту в дом жениха). Йегет йагыннан киләләр арчи алырга. Анда әз генә, бер кырук кына утыралар. Арчи алучылар йырлап утыралар.

**арчи багарга чыгу** *кузн.* туй килгәнне күрергә чыгу (выйти встречать свадебный обоз с сопровождающими невесту). Арчи багарга чыгабыз дип көтеп торалар. Бөтен awыл арчи багарга чыга.

**арчи йыры, арчи кеве** *кузн.* яшь киленне кияү өенә озата килүче кызларның җыры (песни девушек, сопровождающих невесту в дом жениха). Аның үзенең асуби кеве бар, арчи кеве.

**арчи кийеме** *кузн.* яшь киленне озата килүче кызларның киеме (одежда девушек, сопровождающих невесту в дом жениха). Арчи кийеме үзенә бер затлы инде, килешле ак пәртүк, бидәрле күлмәк.

**АРЧИЛАП: арчилап төшү** *минз.* туйда озатучылар белән зурлап килен булып төшү (привоз невесты в дом жениха вместе с сопровождающими). Безгә арчилап төшүләр бик әләкмәде. Элек байырақ қызлар арчилап төшәләр ийе.

**АРЧУ 1.** *лмб., хвл.* к.: **ачу I, 1**. Лампыларны арчыйм. – *лмб.* Красин савытын көл белән арчыдым. – *хвл.*; **2.** *хвл., кузн., мәл., перм.* чистарту (чистить, вычистить, прочистить); чаг.: **ардақлау II, 1**. Су арчыды тебен. – *хвл.* Азбарларны гына арчыйм да. – *мәл.* Йертә торган чыпчык тешен казый, соң торган күзен арчый (*әйтем*). – *кузн.*; **3.** *чпр., т.я.-крш.* утау, йолку (дёргать, рвать). Кантут сабы арчыдык. – *чпр.*; **4.** *перм.* җыештыру, юу (убирать, прибирать, мыть). Ызба арчу. Пәрдә арчыйлар.

**АРЧУWЫЛ** *брб.д.* яулык (платок). Йәш кинчәкне арчуwыл бөргәп кертәделәр кейәү өйенә, йецкә йебәк арчуwыл булаты. Шәлләр, камзуллар, арчуwыллар булған сыйға кийә торған.

**АРЧЫЙ 1.** *чст., мәл., чпр., хвл.* к.: **арчи 1**; **2.** *бөре., минз., кмшл., кргл., бгрс.* к.: **арчи 2**.

**арчый атнасы** *минз., кмшл.* килен төшерү атнасы (неделя, в течение которой совершается обряд проводов невесты в дом жениха).

**АРЧЫЛЫЙ: арчылый бару (килү)** *кргл., хвл., кузн., карс.* киленне кияү йортына озатучы булып бару яки килү (ехать в качестве сопровождающих невесту в дом жениха). Қызны утыртып алып китәләр, арчылый баралар өч пар. – *кргл.* Элеке йәрәштеләр, аннан сын вет пар алаша, арчылыйлар. – *карс.*

**арчылый килүче** *хвл., кузн.* к.: **арчи 1**. Арчылый килүчеләр куйкасына килен әйберләрен куйалар. – *хвл.*

**АРЧЫНУ 1.** *карс., м.-кар.* чистарыну, юыну (чиститься, мыться). Мунчада сабыннанган, арынган, арчынган. – *карс.* Арчына бит әле ул. – *м.-кар.*; **2.** *хвл.* җыештырыну (убираться). Үдә генә бераз арчындык; **3.** *перм.* ашлык җилгәрү (веять зерно). Ысклат алдында қызлар арчыналар.

**АРЫ I 1.** *лмб., тмн., кузн., хвл., чст., карс.* анда (там). Бутыма ары апаңа. Мин эч йыл калада тырдым, ары завудда эшләдем. – *лмб.* Мин барганым йуг ары. – *карс.*; **2.** *лмб., карс., тмн., кузн., хвл., чст., срг.* анда, шунда, шул җиргә (туда). Чыгам ары үзем. – *тмн.* Татар катыннары каа эшли, без ары барыбыз. Ары йөрегә йырак, бире инде көн дә баралар. – *кузн.* Кайа кеше күп, ары барам, бик кеше сewәм. – *карс.*; **3.** *тмн., лмб., кузн., хвл., чст.* анда, тегендә (туда, на то место). Мында чебен дә күп, арымы чыгып йатасың? – *кузн.* Арымы киттең? – *чст.*; **4.** *каз.ар., эчк.* соң (после); чаг.: **арт 2**. Сездән ары эчәрбез әле. Иртәнге салқыннан ары җабып қуйам бозауны. Әле чәй эчкәннән ары сиптем тawыкларға. – *мам.* Питраудан ары ғына пешә җиләк. Төштән ары көтүгә чыгам. – *каз.ар.-крш.* Өйләдән ары китсәк тә қайтабыз. Бераздан ары җабарсыз әле боларны. – *дөб.*; **5.** *каз.ар.* югары, ашып, үтеп (выше, сверх). Сыртыннан ары су җырып чыққан сарық. – *мам.*

**ары җүн** *м.-кар.* к.: **йуwач**. Иделнең ары җүнендә.

**ары таба** *тмн.* к.: **ары 1**. Ары таба тузан йук.

**АРЫ II** *брб.д.* бал корты (пчела).

**АРЫ-БИРЕ** *каз.ар., злт., минз., стрл.* алай-болай (в случае чего). Ары-бире қайтасың килсә, Фәрит абыйыңа әйт. – *блт.* Ары-бире тышта булсам, тизерәк өйгә керәм. – *минз.*

**АРЫЙ** *стрл.* мәртәбә (раз). Аш җыйарга кирәк ике-өч арый.

**АРЫ-ЙАГЫ: ары-йагы бар** *мәл.* бик яхшы, бик әйбәт (очень хороший, замечательный). Бу инде олом, ары-йагы бар.

**АРЫҚ** *тбл., тара.* ябык, ябыккан (худой, исхудалый, тощий).

**АРЫҚ-УРЫҚ** *тмн.* к.: **айрым-cowрым 2**. Арык-урык йөрергә йаратмыйм.

**АРЫМА** *перм.* кыстап сыйлаганда әйтелә (выражение, употребляемое при угощении). Йә, Фелүрә, арыма, ашап бетер.

**АРЫНДЫРУ** *т.я.* **ачу I, 2**. Қул тастымаллары қайнатып җумасаң, арындырып булмый. – *к.т.*

**АРЫТУ I 1.** *хвл., срг., мәл.* к.: **ачу I, 1**. Чәйнеген арыттыңмы? – *хвл.* Писук белән йу идәнне, писук белән тизрәк арытасың. – *срг.* Ике аранны да арытып чыгардым. – *мәл.*; **2.** *хвл., кузн.* к.: **арчу 2**. Бөтен үләрен арытып тырам. Коромнар арытырга, вата моннан арчырга. – *хвл.*

**АРЫТУ II** *саз.я.* **1.** атны хәлдән тайдыру (загнать, заездить – о лошади). Атны арытып қуйтым; **2.** арыту, ябыктыру (истощать, ослаблять, утомлять).

**АРЫУ** *каз.ар.-крш.* к.: **ару 1**. Бер тычқан күсе ойасына бик тәҗелләп кереп әйткән: син, күрше, арыу хәбәрне ишеттеңме әле? (*әкият.*)

**АРЫУМЫ** *каз.ар.-крш., нгб.-крш.* к.: **арумсыз**. – Бәчүкә түтей, арыумы? – Арыу, биг арыу. – *каз. ар.-крш.*

**АРЫШ I** *әстр., себ.* арба тәртәсе (оглобля).

**арыш ағач** *туб.-ирт.д.* к.: **арыш I**.

**арыш II** (рожь):

**арыш гөл** *бөре.* кашгарый гөле (астра).

**арыш инә** *төм.* к.: **аташлық**.

**арыш йуwа** *твр.* кырыкмыш суган, орлыктан үскән яшел суган (лук-сеянец).

**арыш чәчәге** *т.я., кас.*, **арыш чәчәкайы** *лмб.* күкбаш, күкчәчәк (василёк посевной).

**АРЫШПАУ** *туб.-ирт.д.* камыт бавы, төргәк (завёртка на оглобле, гуж).

**АСА** *нокр.* бизәк (узор). Сабантуйға суққан селгеләр сала, аса тутырып суға, атның башына әлә.

**АСАБА** [*гар.*] **1.** *минз., стрл., лмб.* озын буйлы, таза гәүдәле (высокий, крепкого телосложения); чаг.: **алпawыт**. Әнә асабадий быратың, туганың йаныңда. – *лмб.*; **2.** *минз., каз.ар., стрл.* ир бала; гомумән балалар (сын-наследник; вообще – дети). Бердәнбер асабам үлде. – *минз.* Асаба алдық, картайған көндә үзебезгә бала булыр қарарга дип. – *дөб.*; **3.** *минз.* к.: **бер: бер йаңыс**; **4.** *чст.* авылның иң өлкән, мөхтәрәм кешесе (самый старший, уважаемый мужчина на селе). Awылның асабасы мин инде; **5.** *минз., стрл.* хәрби хезмәткә яраклы (годный для военной службы).

**АСАБАДИЙ** *кузн.* бер генә, кадерле (единственный, дорогой). Асабадий быратым, дәдәм, дәдәм катны үдә тыралар.

**АСА-ГӨСӘ** *саз.я.* бердәнбер (единственный). Пер аса-гөсә айбатақ паласы бар, шаңа ней ғылырын пелмәйте.

**АСАКА** [*рус.*] *тмн.* күрән, саз кыягы (осока).

**АСАЛАҒАН, АСАЛЫ** *нокр.* ясалып суккан, бизәкләгән (сотканный закладным способом, украшенный узорами). Асалаған селгеләр булғалады, андайны элгәләде килен. Асалы селге, уртасы ақ йептән, башлары озон, матур.

**АСАН I** *каз.ар.* ансат (лёгкий, удобный). Асан үлем телә, диб әйтергә, ди. – *дөб.*

**АСАН II** [*гар.*] *төм.* азан. Мулла асан әйтәде, өйгә кереп хатем укыйды.

**АСАУ 1.** *нгб.-крш., әстр.* җигәргә өйрәтелмәгән (необъезженный – о лошади). Асау ат күwек җәрисең сүз тыңламый. – *нгб.-крш.* Аты асау, атларны тибә. Қандай асау булсын! – *әстр.*; **2.** *туб.-ирт.д.* к.: **азау I, 2**. Аннан Қушкүлтән (*ав. ис.*) алты, ул хатын асау ите, мине цабатыйте.

**АСҒЫРУ I** *туб.-ирт.д., брб.д.* аздыру, юлдан яздыру (сбить с пути, развращать, испортить). Мынау исерекпаш асғырып китте әшгәрә баламны.

**АСҒЫРУ II** *туб.-ирт.д.* ис китәрү (удивлять, ошеломлять).

**АСҚАҚ I** *минз.* мал суйгач тунау һәм эчен төшерү өчен асып куярга әзерләнгән агач җайланма (деревянное приспособление для обработки зарезанного животного).

**асқақта қалдыру** *мам.* к.: **күтәртү**.

**асқақта калу** *мам.* күтәрәмгә калу (дойти до полного истощения, изнеможения). Начар хуҗаның сыйырлары асқақта қала.

**АСҚАҚ II** *к.-уф.* к.: **ақсағас**. Уң айағымның асқағына шеш чыққан, йөри алмыйм.

**АСКАК 1.** *стрл.* к.: **асқақ I**. Инәй чыкса, безнең сыйыр аскакта; **2.** *хвл., кузн., мәл.* дар агачы (виселица). Кыз ат'а: кирпеч, ди, сездә, ди; иртәгә, ди, аскакка астырам (*әкият.*). – *кузн.* Аның өчен вет сине аскакка асалар. – *стрл.*

**АСҚАҚЛАУ** *злт.* озак вакыт ач торудан бетеренү, ябыгу (изголодаться, истощиться). Асқақлаған дип кешегә дә, хайwанға да әйтәбез. Йапқаннар да, хайwаннар асқақлағаннар. Асқақлаған кешегә кисәк күп ашатырға йарамый.

**АСҚАР** *туб.-ирт.д.* көз көне бәкедән балык тоту җайланмасы (приспособление для осеннего лова рыбы). Асқар цағыт шикелле йертән қасылат. – *тбл.*

**АСКАРКАЛЫК** *чст., чпр.* бавыргалык, түшлек (подбрюшник).

**АСҚЫ** *туб.-ирт.д.* к.: **асқылық**. Агач цәнцеп асқы қуйаты, қасан эләте.

**АСҚЫЛЫҚ** *злт., к.-уф.* кырда ашарга пешергәндә чәйнек, казан асу өчен ут өстенә куелган аркылы агач (поперечная перекладина, на которую вешают посуду над костром). Асқылықны текәрәк қада, ут қабарлық булмасын. – *к.-уф.*

**АСҚЫНЙАҚ** *тбл.* аз гына (немножко).

**АСҚЫРҒЫЧ** *том.д.* урманда яшәүче (мифологик) зат, ул кешеләрне адаштыра (мифологическое существо, лесовик). Асқырғыч кешеләрне адаштыра, қычқыра урманда.

**АСЛАҒАН** *брб.д.* к.: **астыған**.

**АСЛАМ** *тбл., брб.д.* табыш, төшем (выгода, прибыль, процент).

**АСЛАМНАУ** *брб.д.* файда итү (иметь прибыль, барыш).

**АСЛАМЦЫ** *тбл.* бурычка акча биреп торучы (ростовщик).

**АСЛАН** [*гар.*] *кузн.* асла, һич тә, бер дә (нисколько, ничуть). Минем йокым аслан келәми.

**АСЛАТА** *срг.* астыртын, яшерен (скрытно, исподтишка, тайком). Аслата сынап торган мине.

**АСЛАУ** *брб.д.* азаю (уменьшаться).

**АСЛИК** *карс.* ачлык (голод).

**АСЛЫҒАН** *брб.д.* к.: **курл'ак**.

**АСМАН** *туб.-ирт.д.* күк йөзе (небо).

**АС'МУХА** [*рус.*] *кузн.* үлчәү берәмлеге, әчмуха (термин измерения – восьмушка). Ике ас'муха чәй, бер пар чәйен куйа.

**АСПА** *тара.* лапас (навес, лабаз).

**АСРАНТЫ** *тара.* тәрбиягә алынган (взятый на воспитание).

**АСРАНУ 1.** *саз.я.* бала үстерү, бала тәрбияләү (растить, воспитывать ребёнка). Асранамысың? – Анан!; **2.** *төм.* к.: **асрау 2**; **3.** *кузн.* яшәү, көн итү (жить, существовать). Анарга да асранырга кирәк вет.

**АСРАУ 1.** *каз.ар., нгб.-крш.* әйберне озак вакыт бер хәлдә тоту (держать предмет долго в одном состоянии). Ишекне төбенә чаклы әчек асрадым инде, чыгып бетми бу ис. Өйегезне сувык асрамагыз, ди улым, утын табылыр, дий. Бер минут асрамасқа, хәзер бал'нисқа илтәргә, диде бырач. Морҗаны бер дә әчек асрарлық түгел җәй көне (яшеннән куркыныч). – *блт.* Бакча асраган кешеләр бар. – *нгб.-крш.*; **2.** *бөре., байк., перм., к.-уф., минз., тпк.* табу, тудыру (родить). Минем белән бергә асраган қызын нифтәнек алып китте. Унбер бала асрадым, бишесе генә үсте. – *к.-уф.* Олан асрамадым да бит. – *тпк.*

**АСТАЙ** *каз.ар., чст., мәл.* апа (сестра, тётя). Тәгәрмәннектән астай да килде. Майтабастайны күрдем, эшкә бара иде. – *чст.*

**абыз астай** *чст., мәл.*, **иркә астай** *чст., мәл.*, **йылтыр күз астай** *чст., мәл.*, **матур астай** *чст.*, **сүгәнем астай** *чст., мәл.*, **туганым астай** *чст.* к.: **абызастай**.

**остабикә астай** *чст.* абыстай, дини укымышлы хатын-кыз (женщина, которая исполняет религиозные обряды; знаток обрядов). Остабикә астай турады мәзелестә казларымны.

**АСТАҚАЙ** *мам.* к.: **астай**. Әйдә, Сәйдә астақайым, уз, утыр.

**АСТАНА** [*фарс.*] *себ.* изгеләр каберлеге (могильник святых). Астана сиратның эцентә. Күрше awыллар хәйер биреп торалар астанаға. Йакшылар күмелгән анта. Әргем садақа салды йакшыларның рухына дип. Йакшылар йататы астаната. Йосып Шәйехләр, Қәсән-Кәсәйеннәр күмелгән. Астаната өц қыс тиделәр әүлийалар: Сабира, Сәрбийамал, Сариба әүлийа қыслар тиделәр аларны. Алар итәкләре белән йир ташып түбә қылганнар, өчтүбә тип атаганнар. Астананың сарайы бар, анда мал суйатылар. – *төм.*

**астана қатым** *туб.-ирт.д., брб.д.* изгеләр рухына багышлап корбан чалып, догалар укып үткәрелә торган мәҗлес (религиозное угощение с жертвоприношениями в честь святых). Астана қатым үткәреп торатылар. Кем тawық, кем қуй, кем қас апкерәте астанаға. Аны суйып, қатым уқытып торатылар. Астаналы awылта йәшәгән мин. – *тбл.*

**АСТАНКИГЕЦ** *срг.* эчке күлмәк (нижняя рубашка). Йефәк астанкигецләр китергән Мәскәүдән.

**АСТАР 1.** *каз.ар., кмшл.* олтан, ас (подошва, подмётка). Итек астарына җеп җегерлим. – *блт.*; **2.** *байк., бөре.* әдеп (подшивка подола). Итәк астары. – *бөре.*; **3.** *дөб.* түбәнең аскы катына куела торган такталар (нижний ряд досок крыши).

**астар тыш** *саз.я.* сүрү (нижняя наволочка подушки, перины). Астар тыш қалын малтан.

**АСТӨЙ** *минз.* аскы өй (нижний этаж). Астөйдә торабыз қышын.

**АСТЫ** *каз.ар., саз.я.* аскы (нижний). Асты ниргәне күммәдек. – *блт.* Асты өйтә үсепес торапыс, өсте өйөпескә кеше цыгарғалы уйлыйбыс. – *саз.я.*

**АСТЫҒАН** *туб.-ирт.д.* к.: **курл'ак**. Қарағай йақта астыған пулатыған.

**АСТЫЛЫ-ӨСТӨЛЕ** *каз.ар.* аслы-өсле (двухэтажный). Астылы-өстөле җорт безнеке. – *мам.* Қаралты-қуралары бик шәб ийе, астылы-өстеле өй. – *дөб.*

**АСТЫР** *т.я., чпр., кргл., м.-кар.* түбән җир, иңкү җир (низменность, низина). Астырда утырған булғач. – *к.т.* Астырдан барам. – *м.-кар.* Астырдан булса да бирәләр (печән). – *чпр.* Мына wы астырда ғынайы ул мәчет урыны. – *кргл.*

**астыр җир** *т.я.* к.: **астыр**. Безнең бакча астыр җирдә булғач, йазғы су төшә. – *к.т.*

**АСТЫРҒАҚ** *саз.я.* тел асты (нижняя часть полости рта).

**АСУ I** *т.я., трбс., кмшл., минз., тмн., лмб., срг., себ.* пешерергә салу, пешәргә кую, пешерә башлау – аш турында (заварить, начинать варить, поставить вариться – о пище). Аш асу. Ит асу. – *срг.* Көтү килә, каршы чык, мин ашарга асам. Сүндермә учакны, хәзер ашарға асам. – *тмн.* Мин ашарға астым бит, қайа ашығасыз? – *минз.* Эшти асу. – *лмб.* Қазан асмыйбыз микән әле? – *трх.* Берәр тәрилкә аш ашарбыз, аш асқаныйым. – *кмшл.* Шурба да асып куйам пичкә, йакшы азык та. – *кузн.* Картуп асцы. – *төм.* Палых асыф йеwәртем. – *саз.я.*

**АСУ II** *кас., т.я.-крш.* файда, игелек (польза, добро). Йакшы балалар үстерсәң, асу күрәсең. Ай ишегем, ишеғем, Ишек ачар кешидем; Асрай белгән кешегә Асу итәр кешидем (*бор. җыр.*). – *т.я.-крш.* Ишек төбем ақ балчық, Басма, әнекәйем, тайарсың. Асу итми балаң китә, Шунда, әнекәйем, айарсың (*хал. җыр.*). – *кас.*

**АСУ III** *том.д.* адашу (заблудиться).

**АСЫЙ 1.** *туб.-ирт.д.* бер яшьлек, былтыргы (годовалый, прошлогодний). Асый утын. Асый бысауғыс пар иде; **2.** *тара., твр.* иске, искергән, бозылган (старый, негодный, испорченный). Асый су нейгәте?

**АСЫЙҚЛАНУ** *злт.* нык ачулану (сильно разозлиться); чаг.: **ачыг: жан ачығысы белә 2.** Теше чыкмый тора иде, бырач асыйқланып бер тартты. Асыйқланып қысқырды.

**АСЫЙСЫРАУ** *тара.* искерү (портиться, становиться старым). Ашаң, қыслар, картуп асыйсырамасын.

**АСЫЛ** [*гар.*] **1.** *тя., каз.ар., кмшл., чпр., мәл., кргл., бгрс.* шәп, яхшы, әйбәт (хороший); чаг.: **ару I, 9.** Асыл кешейе, әрәмнәр булды. – *к.т.* Җидене петерсә дә, асыл гырамыта кирәк. – *чпр.* Әй асыл да инде читсысы. – *кмшл.* «Асыл безнең ил» дигән җыруны беләсеңме? – *каз.ар.-крш.*; **2.** *чпр., мәл., тмн., кргл., бгрс., кмшл.* матур, чибәр (красивый; красиво); чаг.: **ару I, 5.** Бик асыл баласы бар иде кызымның, йәшен бәреп үтерде. – *мәл.* Асыл сайрар идем, кош булсам; Рахат йәшәр идем, кыз булсам (*бор. җыр.*). – *тмн.*

**АСЫЛМА** *злт.* тәрәзә капкачы (оконные ставни).

**АСЫЛЫМ** *чпр., кмшл.* к.: **апайым 2.** Асылымнан хат килде әле, бик шатландым. – *кмшл.*

**АСЫЛЫҢҚЫ** *минз.* салынып торган, салынкы (отвисший, обвислый). «Нишләп моноң қорсағы асылыңқы?» – дигән.

**АСЫМЦЫЛАУ** *эчк.* дуамаллану, кирәкмәгәнне эшләү (сумасбродничать, делать глупости, дурачиться). Үзенең қәдерен белмәй, асымцылап йөрәй.

**АСЫРАНУ** *клд.* тәрбияләнү (воспитываться). Анам алты бала белән кала, фабрикта да эшли, без асыранабыз шылай.

**АСЫРАУ 1.** *минз., трбс., злт., байк., стрл., бөре., перм.* к.: **асрау 2.** Туғыз бәбәй асырады қызым, берәүсе Төмәндә тора. – *трбс.* Ул баланы балнистa асырады да алып қайттық. – *злт.* Унике бала асырадым. – *байк.* Дүрт йыл бала асырамай йөрдем, бишенчедә генә булды. – *бөре.* Ике баланы эштән қайтқач қына асырадым. Ул қатын бала асыраған. – *перм.*; **2.** *стрл.* балалау – песи турында (котиться, окотиться). Песи бәләкәй ийе, быйыл гына бала асырады.

**АСЫРУ** *брб.д.* төчкертү (заставить чихать).

**АСЫРЫЛЫП: асырылып тору** *перм.* җимеше күплектән сыгылып тору (согнуться от изобилия плодов – о дереве). Қайсы йылны асырылып тора wы миләш. Қарағат, шомарт күп булса, ылыс кебег асырылып тора, диләр.

**ат I** (лошадь):

**ат әйдәүче** *әстр.* к.: **атбаш.** Кийәүнең ағасы туйда ат әйдәүче була. Бер көймәгә ат әйдәүче, қыз белән җегет утыра. Анда башқа кеше сыймый. Ат әйдәүчегә йақшы зат бирмәгә тийеш, мата (тукыма) бирәләр, нийәтлиләр.

**ат байы** *глз.* ат хуҗасы (хозяин лошади). Ат байына сөлге салалар бүләк итеп.

**ат булу** *т.кам.-крш.* нардуганда йөргәндә ат булып киенү (наряжаться лошадкой в дни святок). Атлар булып киләләр, тәрәзәгә килеп шапшап бәрәләр. Ике кешене дүрт айаклатып куйалар, аларга өстән бөркәп куйалар бөркәүләр.

**ат йәмшик** *глз.* к.: **ат әйдәүче.** Ат йәмшикләргә дә бүләк бирилир сабан туйда.

**ат қолағы** *трх., тпк.*, **ат колагы** *стрл.*, **ат кузгалдагы** *хвл., кузн.*, **ат кузгылдагы** *кузн.*, **ат қучқылақ** *нокр., глз.* к.: **айүқузғалақ.** Қайтқан wақытта ат қолағы ашай-ашай қайттық. – *тпк.*

**ат нәзере** *чст.* ат башы пешереп теләк мәҗлесе ясау (моление с жертвоприношением лошади). Кас'ы кешенеке ат нәзере була, ди. Атның башын пешереп мәзелес йасилар.

**ат теләге** *чст.* к.: **ат нәзере.** Кешегә цир килә, ат теләге йасилар. Ат башын пешереп, башыннан әләндереп сүwәген йиргә күмәләр, ат теләге була.

**ат тойағы 1.** *минз., бәр.*, **ат тойагы** *стрл.* к.: **катлама 1.** Ат тойағы пешерәләр, қамырны түгәрәк итеп җәйәләр дә орлоқны җәйәләр, қатлам-қатлам була. – *бәр.*; **2.** *минз.* к.: **катлама 3.**

**ат үләме** *срг.* к.: **зибәләй: зибәләй үләм.**

**ат цана** *сазя.* зур чана (большие сани).

**ат эсле** *стрл.* җайдак (всадник, наездник). Эрәзе сиңа ат эслегә бүре килә. Бер ат эсле килә.

**базықту ат** *том.д.* яхшы йөри торган ат (ходкая лошадь).

**йөгерәк ат** *трх.* чабыш аты, җитез ат (скакун, скаковая лошадь). Озон тороқлы йөгерәк ат ийе.

**қазақ ат** *трх.* алаша (мерин).

**қуйан ат** *к.-уф.* бүләк уенчык (подарочная игрушка). Қуйан ат бирәм, ди, сөннәткә утыртқанда, бабай алай әйтә.

**паш ат** *төм.* кияү ягыннан туйга бирелә торган зур яхшы ат (лошадь, которую дарили со стороны жениха на свадьбу). Паш атқа пирделәр йуwан ат. Паш атны сақлай ителәр. Паш ат, суғым, ике ат алтылар кейәүдән. Туй – кейәү өстендә.

**чығын ат** *төм.* чыгымчы ат (норовистый конь).

**ат II** (имя):

**ат атау** *әстр.* исем кушу (нарекать именем). Мулла балаға ат атый.

**ат ат'теру** *срг.* килен төшкәч кияүнең туганнарына эндәшү өчен ягымлы сүзләр билгеләп кую йоласы (свадебный обряд, согласно которому невеста должна придумать различные ласковые слова для обращения к родным своего мужа). Минем биш кан'игәцем бар иде,ештем, кан'игәцләрем йийылдылар, ат ат'терәләр миннән. Бер-икесе ат'терде.

**ат этешү** *кузн.* дус кызларның бер-берсенә төрле матур, ягымлы исемнәр бирешүе, мәс., сандугач, ахирәт, алма, роза һ.б. (обычай девушек-подружек называть друг друга не по имени, а какими-либо другими словами, напр., соловушка, яблочко, подружка, роза и т.д.).

**ат эттерү** *миш.д.* к.: **ат ат'терү.** Минем биш канигәцем бар иде, ат эттерәләр миннән. Малайның кыз туганнарымы бар, ир туганнарымы бар, олы апаларымы бар, апасының туганымы бар, аларга ат эттерәләр. – *срг.*

**ат бишек** *әстр.* балага исем куштырганда кул-

ланыла торган бишек (колыбель, используемая при наречении ребёнка именем). Баланы ат бишеккә салып мамайдан такмақ әйттерәләр.

**ат қойу** *себ.* к.: **ат атау**.

**ат кыцкырту** *чст.*, **ат кычкырту** хвл., **ат қычқырту** *әстр.*, **ат кычкыру** *лмб.*, **ат салдыру, ат салу** *нокр.* исем куштыру (дать имя, нарекать именем). Ат кыцкыртырга кирәк әле. – *чст.* Бер ай тула ул балага да, ат кычкыртабыз. – *хвл.* Мулланы чақырып ат қычқыртып алабыз. – *әстр.* Берәр атнадан суң инде ат кычкырыга җийынасың, анда инде бабайлар йәшәсең, ат кычкыра инде берсе, уки, азан кычкыра. – *лмб.* Мәләкәйгә саласын баласын, ат саласын, салаwат әйтәсен. Қолағына қычқырасы әч тапқыр атын. Баланы туғач зақ тотасы дегел, әби алыштыра аны, ат саласы тизерәк, өч кендән артық тотасы дегел. – *нокр.*

**йакшы ат әтү** *миш.д.* ир ягының туганнарына матур, ягымлы эндәшү сүзләре белән мөрәҗәгать итү (обращение к родственникам мужа с ласковыми именами). Кан′игәчләргә үз атлары мынан ат′миләр киленнәр, йакшы ат ат′аләр. – *срг.*

**кендек аты** *әстр.* балага тугач та бирелә торган вакытлыча исем (имя, которое дают ребёнку сразу после рождения; временное имя). Кендек аты қушалар бала туғач та, бала атсыз тормасын.

**урам аты** *хвл., тмн.* к.: **атағат**. Урам аты белән ат′саң, бар да белә аны. – *хвл.* Урам атлары манах буладыр. – *тмн.*

**а т а** I (отец):

**ата бала** *тбл.* әтисе исеме кушылган ир бала (мальчик, названный именем отца).

**боронды қ ата** *к.-уф.* туйда киленгә икенче «әти» итеп куелган кеше (посажёный отец). Боронды қ ата қуйу боронғылардан қалған.

**җизни ата** *әстр.* әтисенең олы кыз туганының иренә эндәшү сүзе (форма обращения к мужу старшей родственницы – сестры отца). Җизни атаға сыйлық қуйдым, қуй суйдым.

**йир атасы** *хвл.* җир атасы (отец земли – мифологический персонаж). Йир атасы, йир анасы дип әтеп тозлы су түгәбез әч awыртқанда.

**кендек ата** *әстр.* балага исем кушканда билгеләп куелган кеше (человек, назначенный отцом во время наречения именем). Атқушарда кендек ата дип йөри.

**Рәхимкул ата** *мәл.* сулар, диңгезләр хуҗасы (хозяин, владыка воды, морей – мифологический персонаж). Йаңгыр теләгәндә, суларны, диңгезләрне тотучы Рәхимкул атага укилар.

**үкел ата** *том.д.* туйда кыз ягыннан да, егет ягыннан да икенче ата итеп билгеләнеп куелган кеше (посажёный отец). Малай йақтан абыйсы бар – ул аталық була тоған, үкел ата дигәннәр.

**АТА II: ата йawын** *себ.*, каршы, текә яңгыр (встречный, отвесный дождь).

**а т а - а н а** (отец и мать):

**ата-ана йоласы** *кузн.* к.: **awызландыру: бабай awызландыру**. Бала бал′ничадан килгәч, балмай каптыралар. «Ата-ана йоласы, бәхетле бул»,– дип.

**ата-ана хагы** *тмн.* кияү ягыннан кызның әти-әнисенә бирелә торган акчалар (деньги, передаваемые со стороны жениха родителям невесты). Башкыда китереп бирде ата-ана хагын.

**АТА-ӘНКӘ** *чст.* ата-ана (родители). Ата-әнкә бик сагына инде балага.

**АТАБАШ 1.** *хвл., чст., минз.* әти кеше, йортта хуҗа кеше (глава семьи, отец). Атабашыбыз кайтмаган әле. – *чст.*; **2.** *т.я.* ата хайван – бигрәк тә кош-кортка карата әйтелә (самец у птиц). Бер атабаш, ик(е) әңкәбаш қазым ғына бар. – *к.т.*

**АТАWА, АТАWЫ** [*рус.* отава] *карс., кузн., тмн., чст., перм., к.-уф.* к.: **алсын 1**. Атаwалар тагын куйы булып үсә. – *тмн.* Атаwаны кемгә кирәк, шул чаба инде. – *кузн.* Атаwа чығып килә инде, малларға йахшы булыр. – *к.-уф.*

**АТАWЫЧ** *минз.* гөбе пешкәге, гөбе таягы (мешалка для пахтанья масла, пахталка). Атаwычын күрәм, дий.

**АТАҒАТ** *тбл.* кушамат (прозвище).

**АТАҒУ** *трх.* дан чыгу, ат казану (прославиться).

**АТАЙ I 1.** *хвл., чпр., срг., эчк., әстр.* әти (отец). Атайлар гына сүли иде. Безнең атай айрылганда ике душ бар иде. – *хвл.* Утырдым атайның түренә. Бусагасы алтын күренә... Ун′аган гынам, келгән генәм, Каладыр ла атай үwендә (*бор. җыр.*). – *срг.* Йома көнне атайлар йома нийазына кителәр. – *әстр.*; **2.** *хвл., кузн., мәл., срг.* кереш сүз функциясендә (в функции вводного слова). Кирәкми, атай, үземнең катыгым бар. – *хвл.* Равиләнең бишеген чыгарып куй, атай. Баг, атай, кәбәм, әләнеп чыктың алай? – *кузн.* Атай, кереб әтергә кирәк, барсыннар мунца сабынырга. – *срг.*

**АТАЙ II** *туб.-ирт.д.* атап, махсус, юри (специально, нарочно). Атай килгәнсең, йөрең, күрең. – *төм.*

**АТАЙ-АНАЙ** *әстр.* әти-әни (отец и мать). Атай-анай қыз белән саубуллашырға керә.

**АТАЙБИКӘ** *әстр.* әтисенең апасы (старшая сестра отца). Укыған доғаларымны Әминәхан атайбикәм рухына бағышлыйм.

**АТАЙЛАП: атайлап әйтү** *саз.я., тара., твр.* атап әйтү (сказать нарочно, специально).

**АТАҚ** *туб.-ирт.д.* **1.** данлы (булу), атаклы (булу) (слава, известность); **2.** яман атлы (булу) (дурная слава, клевета); **3.** *минз.* к.: **атағат**. Атақлары ничек; **4.** *минз., саз.я.* к.: **анай 3**.

**АТАК I** *стрл.* к.: **анай 3**. Атак, чалгының сабы йук.

**АТАК II** *хвл.* **1.** яман ат, начар исем, начар дан (дурная слава). Синең атагың дөнйага таралган инде, усаллыгыңы дөнйа белә. Атагың чыкса, хур булырсың; **2.** яхшы исем, абруй (авторитет, хорошая слава). Кыз бала атагын сакларга тийеш.

**АТАКАЙ** *карс.* каенатага эндәшү сүзе (форма обращения к свёкру).

**АТАҚЛАУ** *тбл.* **1.** атау (называть). Аларны керәшен тип атақлап қуйған; **2.** үртәү, үчекләү (дразнить).

**АТАҚЛАШУ 1.** *саз.я.* үртәшү (дразниться); **2.** *тбл.* сүгенү (ругаться бранными словами). Атақлашып орышаты.

**АТАҚЛЫ** *минз.*, **АТАКЛЫ** *стрл.* аерым, махсус билгеләнеп куелган (специальный, особо наз-

наченный). Үзебезнең атаклы урманыбыз бар ийе. – *минз.*

**АТ'АКЫШ** 1. *мәл.* аңгыра, булдыксыз (бездарный, глупый, бестолковый). Әй, ат'акыш, шыны да аңнамыйсынмы? Әй, ат'акыш, кеше кынлы итеп ат та йигә белмисен; **2.** *м.-кар.* Яңа ел көннәрендә төрлечә киенеп өйдән өйгә кереп йөрүче (участник святочных игр, который, нарядившись в маску, ходит из дома в дом). Ат'акышлар җери'ләр иде, айгыр ат'акышлар була иде.

**АТАЛА** *тбл.* майда кыздырылган он (жаренная в масле мука).

**АТАЛАWЫЧ** *нгб.-крш., минз., стрл.* к.: **атаwыч.** Гөбедә йадған элеке кеше, болай тотоп туғылый торғаны – аталаwыч. – *минз.*

**АТАЛАМЛЫ** *туб.-ирт.д.* тиз йөрешле, адымлы (ходкий).

**АТАЛАП** *т.я., мәл.* к.: **атына 2.** Үзенә (малайга) аталап күлмәк текмәгәч, ник җыламасын ул. – *трх.*

**АТАЛАТУ** *тмн.* акайту, күзне зур итеп ачу (таращить глаза). Аталатма күзләреңне, Барча халайыклар куркадыр (*хал. җыр.*).

**АТАЛАУ** *сазл.* текәлеп карау (смотреть пристально). Аш пешергәнтә аталап торалар, ашым уңмайты.

**АТАЛМЫШ** *минз.* к.: **атаулы 1.** Аталмыш гармунчы булған ул Камилә тутаң.

**АТАЛЫК** *том.д.* туйда икенче ата итеп куелган кеше (посажёный отец). Аталыклар бар иде, хәзер дә бар ул аталыклар. Йакынын қуйа аталық итеп. Аталық ул күптән түгел генә өйләнгән йәш кеше була.

**АТАМ I** *тара.* эндәш сүз (форма обращения). Асийә, цық, палам, кил, атам.

**АТАМ II** *әстр.* әүлияларны телгә алганда әйтелә (говорится о святых). Шупаш атам диделәр, менә қулың сынады, айағың сынады, ул сынганнарға йардәм итәде.

**АТАМЫЗ** *әстр.* дини мәҗлесләрдә дога багышлаганда әйтелә (употребляется при молитвословиях). Әдәм атамыз рухына багышладым.

**АТАН** *төм., тбл.* комач (кумач).

**атан қысыл** *төм.* кып-кызыл, ачык кызыл (ярко-красный).

**АТАРАН** *тара., тбл.* ат абзары (конюшня).

**АТАРЫНУ** *сазл.* пыр туздырып йөрү (разбушеваться). Нимәгә атарынасың?

**АТАТ** [*гар.*] *себ.* гадәт (обычай).

**АТАТУТ** *чпр., мәл., шрл.* к.: **ат'акыш 1.** Теге ататут ийәртеп киткән баланы урманга. – *шрл.* Бу ататуттан рәт чыкмас инде. – *чпр.*

**АТАУ I** *тмн., лмб., хвл., кузн.* үлгән кешене искә алып аш уздыру йоласы (поминки). Атауга барсаң, буш бармыйсың, йә йеслек, йә йаулык, йә канфит итәсең. Атау мәҗлесендә ашны өстәмәскә, туйамы-туймимы. Ничек өстәл тезелгән, шулай ашыйлар атауда. Атауда тийеш ботка пешерегә, эшти ашата атауда. – *кузн.* Күрше үлгән ыланының атавын үткәрде. – *хвл.* Былтыр ылым үлде, атавын уздырам. – *лмб.*

**атау ашау** *хвл.* атау йоласын үткәргәндә әзерләнгән ашны ашау (есть пищу, приготовленную для проведения поминок). Картларга никтер атау ашарга йарамый: башым авырта вата.

**атау ашы** *хвл.* үлгән кешене искә алу мәҗлесе (поминки). Атау ашы диләр, эче, җидесе, кырыгы дип тә әйтәләр, хатем укилар.

**йыллык атау** *лмб.* үлгән кешенең бер еллыгын искә алу мәҗлесе (поминки-годовщина, религиозное угощение в честь умершего). Йыллык атаулары булды, тawык суйып кан чыгаралар.

**АТАУ II 1.** *т.кам.-крш., каз.ар.* к.: **қаш I, 1.** Атауға уйынға мендек. – *т.кам.-крш.* Бийек буғанға, безен очно атау диләр. – *каз.ар.-крш.* Атау хәтле тирес. – *дөб.*; **2.** *лш.* калку җирдәге куаклык (кустарник на холме). Атауға утынга бардық.

**АТАУ III** *мам.* авылның елга белән аерылып торган урамы (одна часть или улица деревни, разделённая речкой). Теге йақта, атауда куwақлықлар булған, чикләwек қuwақлығы.

**АТАУ IV** *төм.* үзәнлек (долина, лощина, балка).

**АТАУ V** [*рус.*] *кас., кргл., срг., карс.* к.: **алсын 1.** Атауны чапмайлар безди. – *кас.* Атау булыр әле, ди, курмысыз қалдым дип суқыранса. – *кргл.* Ул wакыт икенче атау чабу булмас. – *срг.*

**АТАУЛЫ 1.** *т.я., минз., лш., кмшл., стрл.* атаклы, күренекле, билгеле (знаменитый, известный). Безнекеләр атаулы кешеләр булганнар. – *лш.* Ул бик атаулы кешейе безнең бу тирә-җүндә. – *к.т.* Җегете атаулы. – *минз.*; **2.** *глз., чпр.* аерым, махсус билгеләп куелган (специальный, особо назначенный). Атаулы мулла йук, кем теләсә, шул укый. – *глз.*

**атаулы қунақ** *дөб.* махсус яки атап чакырылган хөрмәтле кунак (специально приглашённый, уважаемый гость).

**АТАШЛАНУ** *т.я., каз.ар.* к.: **адалану 1, 2.**

**АТ'АШЛАП: ат'ашлап әйткәндә** *т.я.-крш.* үзенә эндәшкәндә, мөрәҗәгать иткәндә (при обращении лично). Ат'ашлап әйткәндә Ан'уш диләр.

**АТАШЛЫҚ** *перм.* арыш анасы (спорынья).

**АТӘҢКӘ** *т.я.* к.: **ата-әнкә.** Атәңкә күңле – балада, баланықы – далада (*мәкаль*). – *к.т.*

**АТБАҚЧЫ** *нокр.*, **АТБАКЧЫ** *глз.* туйда кияү ягыннан килеп атны саклап, карап торучы егет (парень из свиты жениха, который караулит лошадей). Кийәүгә пар ат йигәләр дә пар селге әләләр атларга, қапқа тептә туқтый. Кийәүне қаршы алма чығалар. Атбақчы атлар йанында торма тийеш була, күми йанында тора. Чәй эчмә дә кергезмиләр атбақчыны. Атбақчыға зур селге бирәләр. Қайнананың энесе була ул атбақчы йә кийәүнең қәрдәш-қәбиләсеннән була. – *нокр.* Атбакчыга бирнәгә селге алма йебәрдем. – *глз.*

**АТБАШ** *нокр.* туйда ат тотучы (кучер на свадьбе). Қыз селге сала атбашқа дип. «Ай, йақшы селге салған ис атбашқа»,– диләр.

**АТЕЛУ** *кузн.* нәзер әйтү (дать обет). Йаңгыр булмагач, ателәләр, әби-чәби, карт-кортлар киләләр алтawылдан да.

**АТИКАМ** *тмн.* әтисенә иркәләп эндәшү (лас-

ковое обращение к отцу). Атикам әтеп йылый кыз туйда.

**АТИЛ** [*гар.*] *тара.* юмарт (щедрый).

**АТИНӘ** *себ.* әти-әни (родители).

**АТҠАҚ** *яүшт.* саңак яфрагы (жабры).

**АТҠАРУ 1.** *перм.* берәүнең йомышын үтәп җибәрү, озату (выполнить, удовлетворить чьюнибудь просьбу, выпроводить). Мин бу абыйны атқарыйм әле, аннары сүләшербез. Атқардыг әле аларны (печәнчеләрне). – *перм.*; **2.** *перм., минз., кргл.* озату, җибәрү, тарату (отправить, раздать – о вещах, скотине и т.п.). Сыйыр бар ийе, бодау бар ийе, тавыҡ-чебеш дисеңме – қайсын қайа, қайсын қайа атқарып бетердинде, үде қарый алмағач. – *минз.* Менә шуларны атқарып бетәргә (кунакларны). – *кргл.*; **3.** *перм.* җибәрү, олактыру (выпроводить, отправить). Мин моно атқарам теге дөнйаға, дип әйтә, ди; **4.** *минз.* җиренә җиткермичә эшләү, эштәр-өштер китерү (делать коекак, поверхностно). Атқарып парабыс тиген, атқарып қына, җиренә җиткермәгәч; **5.** *әстр.* уздыру (проводить). Туй атқарып қайтабыз.

**АТҠАРЫ** *перм.* **1.** к.: **арлаҡ.** Үкәртәдә башқа төш беткәнмени, атқарырақ итеп сал саламны; **2.** югары (вверх, наверх). Тауға мендең исә, атқары менәсең инде.

**атқары чуҡ** *перм.* югары урам, югары оч (верхняя улица, т.е. верхний конец деревни).

**АТКИЛАНУ** *хвл.* к.: **азаманнашу: азаманнашып уйнау.**

**АТКИ-МАТКИ** *мәл.* уендагы санамыш (считалка во время игры). Атки-матки, чаву датки? Печәнме кирәк, саламмы? Миңа саламы да йарый.

**АТҠУРА** *тбл.* ат абзары (конюшня). Атқурата тораты, атлар кән (күп) пулаты пестә.

**АТҠУШАР** *әстр.* к.: **атқушар мәҗлес.** Атқушарда туған-тохомнан йақшы бүләкләр киләде балаға.

**атқушар мәҗлес** *әстр.* исем кушу мәҗлесе (угощение в честь наречения именем). Атқушар мәҗлес җыйады, ашын пешерәде, бал белән чәй эчерәде.

**атқушар туй** *әстр.* к.: **атқушар мәҗлес.** Атқушар туйға қуй суйады, қунақ чақырады, awыл қартларын чақырады.

**АТҠЫ** *минз.* к.: **айуқузғалақ.**

**АТҠЫЙ** *минз.* ат кузгалагының орлыгы (семена конского щавеля). Ат қузғалағы була да, атқый үсә инде сыdырмалы.

**АТКЫЙ-МАТКЫЙ** *чпр.* туплы уены (игра в мяч).

**АТҠЫЙУ** *тбл.* атларны су эчертә торган бәке (прорубь, из которой лошади пьют воду). Ағытта атқыйу қыйалар атларга.

**АТҠЫР** *тара., брб.д.* яхшы атучы (хороший стрелок).

**АТКЫРЫ 1.** *кузн., хвл., мәл., чпр., срг., клд.* аркылы (поперечный, поперёк, через). Аткыры агач, башы аткыры тоткан була. Аткырыга йаталар иде. – *хвл.* Фуфайкыңны курага аткыры куй. – *чпр.* Аткыры ул урам. – *мәл.* Кабак төбендә, аткыры казыклар каккан йирдә, кийәү йегетләре айникарәм йырлап торалар иде. – *кузн.* Аткыры казыклар каккан җир эстенә. – *клд.*; **2.** иң, киңлек (ширина). Минең йортның аткырысы тикле сарай. – *кузн.*

**АТКЫРЫЙ** *тмн., карс., мәл.* к.: **аткыры 1.** Кабакны аткырый ағач белән терәдем. – *мәл.* Аткырый түши, йурган да чыкмый. Лар аткырыйгамы. – *хвл.*

**АТКЫРЫЙ-ТОТКЫРЫЙ** *тмн.* к.: **арткыры-торткыры.** Аткырый да йат, тоткырый да йат.

**АТҠЫУ 1.** *сазл.* умырып чеметү (ущипнуть, сильно зажать). Пеләгемне атқыты; **2.** *себ.* әләктереп алу (захватить, хватать); **3.** *тбл.* көчләп алу, қысып тоту (захватить силой, сжимать, крепко держать).

**АТҠЫЦ** *туб.-ирт.д.* ачқыч (ключ). Йусағын ацарға атқыцы йоқ. – *тара.*

**АТЛАWЫЧ** *мәл.* к.: **атawыч.** Атлawычым йук, каймаклата ук бетерәләр.

**АТЛАҒАНКӨН, АТЛАҢҒАҢКӨН** *перм.* к.: **бушкен.**

**АТЛАМ** *тбл.* адым, баскыч (шаг, ступень).

**АТЛАМА** *туб.-ирт.д.* беркеткеч (скоба).

**АТЛАНМА** *минз.* **1.** ияр (седло); **2.** ике казыкны бер-берсенә беркетә торган аркылы агач (перекладина, соединяющая два кола); чаг.: **арата 3.**

**АТЛАП** *хвл., кузн., лмб., м.-кар.* к.: **атына 1.** Сыйрга атлап, пичтә киптердем арышны. Ул атлап шулай эшләгән дә. Казанны атлап йырлаталар. – *лмб.* Атлап бара идек йылга буйларына. Сезне атлапмы йебәрделәр. – *кузн.*

**АТЛАП-ЧУРЛАП** *шрл.* ниятләп, төбәп (намеренно, запланированно). Атлап-чурлап килгәнсең, бурычымны бирепе куйыйм.

**АТЛАУ** *срг., тмн.* изү, туглау (месить, замесить, смешать). Ачылый була, чүпрәгә, сөткә атлыйсың, шәкәр дә саласың. – *тмн.* Күптермәне кул белән басмыйсың, атлыйсың гына. Кuwашн'а атлап куйдым. Йоморканы атлап сөт белән, шурбага саласын. – *срг.*

**АТЛАШ** *туб.-ирт.д.* йөреш (походка).

**АТЛУ** *тбл.* исемле (имеющий имя). Йаңбай атлу.

**АТЛЫҚ 1.** *каз.ар., минз.* к.: **айуқузғалақ.** Атлық җыйып қайттым тawықларға. – *мам.* Атлықны эч киткәнгә эчәләр. – *дөб.*; **2.** *минз.* к.: **атқый.** Бусы үзенә айыры: ат қузғалағының атлығы инде.

**АТЛЫҚЛЫ** *тмн.* к.: **атаулы 1.** Казан калпагы иде, Казан вит атлыклы. Атлыклы ахутник булган ул.

**АТЛЫ-ЦАПЛЫ** *срг.* к.: **атаулы 1.** Атлы-цаплы кешиде эти.

**АТМА: атма ат** *себ.* нәкъ (именно).

**атна** (неделя):

**бәрмәнчек атнасы** *т.кам.-крш.* бәрмәнчек көненнән алып Пасхага кадәр булган бер атна (вербная неделя, т.е. дни от вербного воскресенья до Пасхи).

**май атнасы** *т.кам.-крш.* Масленица бәйрәме атнасы (неделя праздника Масленицы). Май атнасында атна буйы май чапқаннар җырлашып.

**уйын атнасы** *чст.-крш.* җәйге түгәрәк уеннар

чоры (время летних хороводов). Уйын атнасы Паскыдан алып башлана, көн сайын уйынга чыгабыз кийенешеп.

**АТНАКЕН** *чпр.* җомга (пятница).

**АТНАКИЧ 1.** *каз.ар., миш.д., кмшл.* к.: **кечатна**. Атнакичме бүген? – *блт.* Кимә итек, ки читек; Бүген атнакич итеп (*хал. җыр.*). – *чст.* Атнакичкә, ди, туй йасарбыз, ди. – *кузн.* Керләрне атнакич йуwарбыз инде. – *кмшл.*; **2.** *чст.-крш.* к.: **атнарас** (көн).

**атнакич өлеше** *кузн.* к.: **атнакич тевене.**

**атнакич өлеше илтү** *кузн.* кызны ярәшкәннән соң һәр пәнҗешәмбе көн саен егет өеннән кызга күчтәнәчләр илтү (привозить гостинцы из дома жениха в дом невесты каждый четверг после их обручения). Йәрәшкәннән соң атнакич инде күмәчләр китерәләр, атнакич өлеше илтү була.

**атнакич питрачы** *лмб., кузн.* кызны ярәшкәннән соң туйга кадәр егет өеннән кызга һәр пәнҗешәмбе көн саен китерелә торган күмәчләр (хлебцы, преподносимые в каждый четверг сосватанной невесте из дома жениха). Атнакич питырачын ыруыннан-тамырыннан бер малай китерә тевен мынан. – *лмб.*

**атнакич тевене** *кузн.* кызны ярәшкәннән соң һәр пәнҗешәмбе көн саен егет өеннән китерелгән күчтәнәчләр (гостинцы, привозимые каждый четверг из дома жениха в дом невесты после их обручения). Туйың тиз булмаса, тагы атнакичтә китерә ул тевен, атнакич тевене дип ателә дә ул.

**АТНАКӨН 1.** *кузн., мәл., чст., срг., байк., м.-кар., т.я., кмшл.* җомга (пятница). Атнакөнгә каршы, кечатнакөн, җуwам идән-сәкеләрне һәрwакыт. – *к.т.*; **2.** *крш.* к.: **урсатна** (көн). Атнакөндә убший җал бит. – *каз.ар.-крш.* Атнакөн эшкә бармыйбыз. – *нгб.-крш.*

**АТНАРАС** (көн) *миш.д.* шимбә (суббота).

**АТНАРТЫ** (көн) **1.** *блт., байк.* к.: **атнарас** (көн); **2.** *каз.ар.-крш.* к.: **башкен.**

**АТ'Н'У** *м.-кар.* ачу (киснуть, прокиснуть). Эшти ат'н'ыганмы?

**АТО'** *кас.* чүлмәктә май яза торган дүрт япьле таянчык (палочка с четырьмя развилинами, предназначенная для сбивания масла в горшке); чаг.: **атawыч**.

**АТОУ** *себ.* к.: **ату III**. Айағында галушлы атоу. – *төм.*

**АТРАСМАН** *туб.-ирт.д.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрағы.**

**АТРУС** [*рус.* отросток] **1.** *хвл., чст., срг., мәл., стрл., злт., кмшл.* үсемлекнең яфрак төбеннән яки тамырыннан үсеп чыккан яшь ботагы, үрентесе (отросток). Былтыр утырткан алмагачым ике атрус йебәргән. – *мәл.* Ансы бит атруслар. Атрусқа киткәннәр (гөлләр). – *кмшл.*; **2.** *чст.* к.: **алсын 1.**

**АТСЫЗ I** *мәл., чпр., чст.* томау (насморк). Бырынымнан атсыз алды. – *чст.*

**АТСЫЗ II** *лмб.* к.: **ислекәй 1.** Әтә күрмә, атсыз йуктыр высе.

**АТТАШ** *брб.д.* адаш (тёзка).

**АТТӘЙ** *чст.* к.: **абыстай 1, 2.** Аттәй, тырдыгызмы?

**АТ'Т'У** *т.я.-крш.* әти (отец, папа). Безнн ат'т'у катка итек сырлама киләләр ийе.

**АТТЫРМА** *к.-уф.* ат тырмасы (борона). Агачтан эшләнгән аттырма булды.

**а т у I** (стрелять):

**йәшен ату** *минз., злт., стрл., т.я., перм., кмшл., хвл., кузн., чст.* яшен сугу (ударить – о молнии). Бер қатынны йәшен атып үтерде. – *к.т.* Ызбасын йәшен атты. – *минз.* Анасын йәшен атты. – *злт.* Ике азбарны, ди, атты, бер мунчаны. – *кузн.* Быйыл бездә бер ызбаны йәшен атты. – *чст.*

**АТУ II** [*рус.* а то] **1.** *т.я., каз.ар., кмшл., хвл., кузн., чпр., мәл., чст.* к.: **айса**. Ату барып кил. – *мәл.* Үзең килмәсәң, ату атаң килсен. – *чпр.* Ату мин үзем генә барам ашка. – *чст.* Ату мин китәм, йыласаң. – *кмшл.*; **2.** *кмшл.* йә, яисә (или, или же, либо). Сиртмә имәннән була ату миләштән; **3.** *трбс., клд.* югыйсә (а то). Хазер ашыйлар паңгыны, элке ату ашамыйлар иде. – *клд.*

**ату да** *чст.* бик; бигрәк, тагын да (очень, ещё более). Әле мына кыластан кыласка күчкәндә ату да awыр була.

**ату исә** *т.я., перм., мәл., стрл.* к.: **айса**. Ату исә үзем генә киттем клупқа. – *к.т.* Күп салыймmы, ату исә мыннан бирәм сиңа. – *стрл.*

**АТУ III** *эчк., лмб., кузн., себ., әстр.* читек (ичиги); чаг.: **бәбес**. Қунаққа барғанда итек кимим мин, ату белән калуш кийеп барам. – *эчк.* Айакларым минем атулы, Башкынайым минем сатулы (*хал. җыр.*). – *лмб.* Қортқайақлар ату кийәтеген. – *себ.*

**айулы ату** *төм.* каюлы читек (вышитые ичиги).

**мачтақ табанлы ату** *әстр.* тәбәнәк үкчәле читек (ичиги на низком каблуке). Мачтақ табанлы ату киделәр қортқалар.

**шығырдақлы ату** *төм.* шыгырдавыклы читек (скрипучие ичиги). Шығырдақлы ату була тоғон ыйы, басқан сайын шығыр-шығыр итеп тораты.

**АТ'УЛЫ** *срг.* к.: **атаулы 1**. Бик ат'улы иде абзий.

**АТХУЦ** *саз.я.* ачкыч (ключ).

**АТЦАНА** *тара.* үрәчәсез чана (сани без разводов).

**АТЧАЛМАН** *әстр.* (тушканчик).

**АТ-ЧАП** *кузн.* к.: **атағат**. Ат-чап та диләр, кушамат та атәләр.

**АТЫҒУ** *себ.* дан казану (становиться славным, прославиться).

**АТЫҚА** *төм.* эти (папа).

**АТ'ЫЛУ** *хвл., кузн.* гаебен тану, гаебен әйтеп бирү (признать свою вину). Өчесе дә вет ат'ылмый, күрдек выт. Тегеләр тагын ат'ылмыйлар. – *кузн.*

**АТЫЛЫП-АТЫЛЫП** *лмб.* өзелеп-өзелеп, өзек-өзек (отрывками, отрывочно). Абидка тәке дә атылып-атылып сүләде (радио).

**АТЫН** *каз.ар.* таган (верёвочные качели). Атын атына. – *мам.*

**АТЫНА 1.** *миш.д., т.я.* к.: **атай II**. Атына цыгып та ынытып керәм. – *срг.* Мин атына сине йәшергә килдем бит. – *чст.* Тенә челтәр энәсенә

атына бардым. Бездә әвәл була тырган иде атына җырчылар. – *лмб.* Кеше атына чыккан Казаннан, җырла инде. – *трх.*; **2.** *хвл., срг., т.я.* үзенә, үзенә атап (лично такому-то лицу). Урным атыма. – *хвл.* Атыма бир. – *срг.* Шуфирны бүләклиләр, атына фылак эленеп тора. – *трх.*; **3.** *тмн., срг., лмб., кузн., хвл., чпр.* аерым (отдельно, особо, самостоятельно). Инде ничек туй килә, әвәл инде ирләр атына бара, катыннар икенче көнне бара. – *тмн.* Йегетләр атына, кызлар атына (җыела). Ул кызым атына тыра бездән. Атына кумнытта ыланнар. – *кузн.* Синең эшең атынамы? Йазмаларыбыз да безнең атына. Айша ризыккы атына, Фатима ризыккы атына (*мәкаль*). – *лмб.*; **4.** *чст., лмб., срг., кузн., хвл.* к.: **айра**. Бу атына бер төрле үләмме. – *чст.* Бу гел атына исле була. Цулпы атына, целдерт атына. – *срг.* Пугр′ап атына ул. – *кузн.*; **5.** *каз.ар.* өчен, хакына (ради). Алар атына кунакълар да җыйдым. – *мам.*

**АТЫНҒЫЧ** *бөре.* к.: **атын**. Атынғыч эшләп пирдек (балага).

**АТЫНЧАК** *кузн.* к.: **атташ**. Әти атынчагы кеше килде.

**АТЫНЧЫҚ** *блт.* к.: **атын**. Абый атынчык атына.

**АТЫРУС** [*рус.* отросток] *минз., стрл.* **1.** к.: **қуwақ 3**; **2.** к.: **алсын 1**. Атырусы үскән инде аның, бер генә чабалар бездә. – *стрл.*

**АТЫШ** *саз.я., тбл.* атасының исеме кушылган ир бала (мальчик, названный именем отца).

**АТЫШҚА** *саз.я.* ата (отец).

**а у** (сеть, невод):

**ау тәстымал** *саз.я.* кул сөртү өчен эленгән иске ятьмә (старые сети, приспособленные для вытирания рук).

**ау тегү** *саз.я.* ау кую (ставить сети).

**АУДЫРУ** *тбл.* аудару (склонить набок, перевернуть, сваливать).

**АУКАЙ** [*морд.*] *м.-кар.* к.: **җырағәби**. Кызымы балалары маңа аукай ди.

**АУҚАМ** *злт.* к.: **аумақ II**. Эсем пошоп азак, ауқамда йылыйм.

**АУҚАН** *перм.* к.: **аумақ II**.

**АУКАТЛЫ** [*гар.*] *чпр., мәл., кузн.* **1.** бай, хәлле, барлыклы (богатый, состоятельный); **2.** көчле, хәлле (сильный, крепкий). Аукатлы түгелдер дә, йөри. – *чпр.*

**АУҚӘТЛЕ** [*гар.*] *минз.* бай, хәлле, барлыклы (богатый, состоятельный). Бик ауқәтле генә торган кеше булган.

**АУҚЫН** *лш.* к.: **аумақ II**. Ауқын җирдә торалар.

**АУЛ** *тбл., тара.* авыл (деревня).

**АУЛАҒАШ** *нокр.*, **АУЛАГАШ** *шрл., глз.* аулак өй (дом в деревне, где временно отсутствуют старшие, т.е. родители, или только отец, и куда собирается молодёжь на посиделки). Әнийем-әтийем кетте, ди, аулагашка барыбыз. – *нокр.* Аулагашта тене буйы утырабыз әнде, сүләшәбез, кем наски, кем челтәр бәйләшә, кем чигешә. – *глз.*

**АУЛАГИ** *глз.* к.: **аулагаш**. Ка ки аулаги булса керә идек, аулагиларда мына уйнар идек.

**АУЛАҚ** *т.я., каз.ар., трбс.* к.: **аулагаш**. Без аулакны аппаручы өч кенә кыз ыйык. – *нрл.*

**аулак сүз** *каз.ар.* яшерен сүз, сер (тайное слово, секрет). Минем сиңа аулак сүзем бар ыйы. – *мам.* Аулак сүзләр сөйләшмәгез, мин ишетеп җатам. – *лш.*

**аулак утырма** *глз.* к.: **аулак**. Йалгызлы хатыннарның өйенә аулак утырма баргаладык.

**туй аулагы** *чпр.* туй алдыннан кыз өендә үткәрелә торган яшьләр мәҗлесе (предсвадебная вечеринка молодёжи в доме невесты). Тыпырдадылар гына тенката, йегетләр, кызлар бер бийеп кат′алар инде кеңел ацып туй аулагында.

**АУЛАҚСУ** *тбл.* аулак булып калу (быть опустошенным, быть безлюдным).

**АУЛАҚСЫРАУ** *тбл.* ялгыз, кешесез яшәү, кешеләрдән читләшү (жить одиноким, уединяться).

**АУЛАКЧЫ** *т.я.-крш.* аулак өйдә утыручы, өй саклаучы (человек, который один был в доме; который смотрел за домом). Кунактан кайталар да: «Аулакчылар, тау сига», – диләр.

**АУЛАНУ 1.** *хвл.* аву, ишелү (свалиться, обрушиться). Арба хазыр аулана дип торам; **2.** *кузн., мәл.* аунау (валяться). Ат ауланды. Алашаны тывардым да, ауланырга тотонды.

**АУЛАНЦАҚ** *тара.* аумакай (беспринципный, шаткий, колеблющийся).

**АУЛЦЫҒАЦ** *тбл.* кечкенә авыл (деревня).

**АУМАҚ I 1.** *каз.ар.* к.: **аймақ 1**. Керәшеннәр аумагы-аумагы белә бездә. – *мам.* Бер атна бер аумак җыйыны. – *блт.*; **2.** *каз.ар., т.кам.-крш.* к.: **курмыйш**. Алар түбән аумакта торалар. – *т.кам.-крш.*; **3.** *минз.* к.: **аймақ 3**. Урамның йугары йагында бер аумак халык.

**АУМАҚ II** *т.кам.-крш.* аулак, тыныч урын (укромное, уединённое место). Аумактарак әйтермен әле.

**АУНАҚЛАУ** *туб.-ирт.д.* чайкалу, селкенү (качаться, покачиваться).

**АУНАНДЫРЫП** *глз.* күп итеп (в большом количестве). Аунандырып чебен дарувы серттем, папа кергән ийе.

**АУНАТУ 1.** *нокр., глз.* басу, итек басу (валять – о валенках). Кош коно кэз итек аунатып кигәләделәр. Аунаткан кэз итек. – *глз.*; **2.** *перм.* тәгәрәтү (катать). Мичтә аунатып өтөкләдем ийе кәртүкне.

**АУНАУ** *перм.* **1.** тәгәрәү (катиться). Күләсә аунап пара. Таудан аунап төшеп киткән аты белән; **2.** әйләнү (вращаться, вертеться). Аунап қына тора шуннан (шүре турында).

**АУРАҚ** [*гар.*] *себ.* өрәк (привидение). Йеңгәм үлде, аурагы керде. Йоқлап йатам. Төн. Мич түбәтә миски утыра. Мискине түрт мәртәбә чиртте. Аурак йөрите. – *тара.* Аурак үләр алтытан йөрите. – *тбл.*

**АУРАҚЧАН** *төм.* авыручан (болезненный). Аурақчан кешеләрне чапчаққа төрле печәннәр салып, мәтерүшкәләр салып, ташларны қыздырып салалар да шул суға утырталар икән.

**АУРАХ** [*гар.*] *саз.я.* к.: **ауран**.

**АУРТҚЫ** *брб.д.* яңак (щека).

**АУРТЛАУ** *брб.д.* авызга күп итеп алу (наполнить рот).

**АУРЦЫҚ, АУРЧЫҚ** *брб.д.* орчык (веретено).

**АУРЫҚАЙ** *брб.д.* к.: **аурақчан**.

**АУСАҚ** *себ.* усак (осина). Аусақ ағачтан була кywашна. Аусақ агачын қапқа башына йә ишек башына бәйләп қуйа, йен-зәхмәт кермәстән. – *төм.* Көймә аусақтан қасылып йасалат. – *тбл.*

**аусақ пете** *тара.* к.: **бет: йүгә бете**.

**АУСАНУ** *туб.-ирт.д.* телгә алу (упоминать, вспоминать). Қайтқац мине аусанырсыс.

**АУСЛАНУ** *төм.* **1.** авызга алу (взять в рот); **2.** сөйләү (говорить).

**АУСЫН I** *карс., кузн.* к.: **алсын 1**. Аусын бездә калмыйдыр да инде, тывар-кара йөри печән чапкач. – *кузн.*

**АУСЫН II** *минз., стрл.* ниндидер авыру (какая-то болезнь).

**АУХАТ** [*гар.*] *чпр.* көч (сила). Шоннан аухаты бетте.

**АУХАТЛЫ** [*гар.* + *афф.* -лы] **1.** *чпр., срг., кузн.* к.: **аукатлы 1**; **2.** *хвл., кузн.* к.: **атаулы 1**. Унсигез йәшәрлек йегет кырк биш йәшлек кызга үләнде, аухатлы кыз иде. – *кузн.*; **3.** *карс., кузн.* гайрәтле (мужественный, отважный, удалой). Биг аухатлы ир булган ул. Мәҗелес халқы бага инде, бу кыз биг аухатлы булган икән дип сүлиләр. – *кузн.*

**АУШЫНУ** *мәл.* авышу, йогынтыга бирелү (склоняться, поддаться влиянию). Телебез аушынган мишәр йагына.

**АФХАНА** *сазл.* к.: **апхана**.

**АХАЛ: ахалга төшү** *злт.* хәлдән таю, ару, алҗу (выбиться из сил, утомиться). Барып йиткәнсе ахалға төштем.

**а х и р ә т** [*гар.*] (загробный мир):

**ахирәт бәйете** *чст.-крш.* мәет янында төн саклап утырганда әйтелә торган бәет (похоронные песни). Ахирәт бәйетен җырлап утырды маржа урсанай.

**ахирәт булу** *кузн.* к.: **ахирәтлек: ахирәтлек қушылу**. Ахирәт булабыз дип этәбез: «үмерлеккә-тамырлыкка сердәш, ташламаска үмерлеккә».

**ахирәт ғоселе** *минз.* мәет юганда соңгы кат коендыру (последнее, окончательное омовение покойника). Илаһи нийәт қылдым ахирәт госеле қойындырмаға.

**ахирәт йаулығы** *әстр.* мәет кәфеннәгәндә башына урап куела торган яулык (платок для повязывания головы покойника).

**ахирәт күләге** *әстр.* кәфеннек эченнән мәеткә кидертелә торган күлмәк (нижняя рубашка для покойника).

**ахирәт қыз** *т.кам.-крш.* туйда кәләшне озатып йөрүче дус кызы (подруга невесты, сопровождающая её на свадьбе). Ахирәт қызым озатты кәбенгә. Кәбеннән қайтқачын, ахирәт қызым, тагын биш-алты қыз утырдылар почмакта.

**ахирәт тус** *себ.* үзара бүләк бирешеп дуслашкан ахирәт дусты (друг в загробной жизни). Туслашасын пүләк биреп: «Менә, тустым, ахирәтем өчөн, йаулығым да, күлмәгем дә сиңа». Ахирәт тустым бар awылда. – *төм.*

**ахирәт ыштаны** *әстр.* мәеткә билдән түбән урап куела торган урама (повязка для обматывания нижней части туловища покойника).

**АХИРӘТЛЕК: ахирәтлек қушылу** *әстр.* ахирәтлек дус булу (стать загробными друзьями). Бер көн затлы ашлар пешереп, әти-әниләренә бүләкләр бирешеп қушылышалар, ахирәтлек қушылдық диләр.

**АХНАУ** *хвл.* уфтану (охать, ахать). Ахнап утыра бу кыз.

**АХТАРУ** *күрш., баст., себ.* к.: **агдару**. Утын ахтардым абзарда. Цебешләргә ахтардым алманы. – *күрш.* Өстөмә соу ахтарты. Утын қолақ ахтарылған ийән. – *сазл.*

**АХТЫКЛЫК** *хвл.* гомерендә соңгы тапкыр булган эш, хәл, вакыйга һ.б. турында (о событии или поступке, случившемся в последний раз в жизни человека). Ахтыклыгың тегелдер, тагы килерсен. Ахтыклыгына ашаган икән бу! Ахтыклыгын итенгән икән, бичара.

**АХУТА** [*рус.* охота] *хвл., чст., лмб., кузн., мәл., кмшл., мам.* теләк, теләү (желание, хотение); чаг.: **келәү**. Ахутаң булса, бар. – *хвл.* Ахутасы булса, карасын инде. Минем чәйгә ахутам зур. – *чст.* Ахутагыз булса, килегез укытырга. – *кузн.* Ахутаң булса, аша. – *кмшл.* Қарамыйм, ахутам йуқ. – *мам.*

**ахутаны калдыру** *лмб.* биздерү, сүрелдерү, күңелне кайтару, туйдыру (отбить охоту, желание). Эштән ахутамны калдырдылар.

**АХУТАЛАНУ** [*рус.* охота + *афф.* -лану] *хвл., мәл.* теләк туу (возникнуть – о желании). Иртәгә базарга барырга ахуталандым әле. – *мәл.*

**а х ш а м** [*гар.*] (молитва):

**ахшам гөле** *минз.*, **ахшам сафа** *тмн.* к.: **гөл I: төн гөле**.

**АХШАМСУ** *глз.* таң суы, им-том өчен таң вакытында алып кайтылган су (вода, принесённая на заре для знахарского лечения). Ахшамсу дип өч чишмәдән йә йеде чишмәдән су китерә.

**АХЫЙ** *эчк.* аптырап калганда, гажәплэнгәндә әйтелә торган сүз (возглас при растерянности, изумлении и т.д.). Ахый, қалай анда менгән! Ул китап йазған қый. – Ахый!

**АХЫҚ** *нокр.* какы (свербига восточная). Ахық ул арыш басуда күп була.

**АХЫР′АТ** [*гар.*] *кузн.* ахирәт, дус (закадычная, задушевная подруга). Алар ахыр′атлар. Мәтәм, вет кас′ы ахыр′аты, шонон игәче. – *кузн.*

**АХЫРҒАР** *тбл.* соңрак, ниһаять, ахырда (позже, наконец).

**Аһ** *тпк., чст.* рәнҗү, күз яше, каргыш (обида, огорчение, слёзы, проклятие). Ғәйеплэнде ул, минем аһым төште. – *тпк.* Суган эшләгән акцабызны алып калды, аның аһы кемгә тешәр. – *чст.*

**АЦАЙИП** [*гар.*] *тбл.* гажәеп (удивительный).

**АЦАҚ 1.** *сазл.* билге – уенда (метка – в игре). Ацақ билгеләрем ша төпкәцә; **2.** *төм.* сызык (линия).

**АЦАМАЙ** *себ.* беркеткеч, тоташтырма (перемычка).

**ацамай итү** *төм.* утын кисү өчен кузла кую (ставить козлы для распилки дров).

**АЦАМАЙЛАУ** *төм.* к.: **ацамай: ацамай итү**.

**АЦҒЫЛТЫМ** *сазл.* әчкелтем (кисловатый).

**АЦҚУЦ** *брб.д.* ачкыч (ключ).

**АЦЛАУ** *тбл.* ач булу (быть голодным).

**АЦУ I** *себ.* ачыгу, карын ачу (проголодаться). Ул ацқан булыр, перәй нимә эцентер.

**ацу II** *себ.* ачу (гнев, злоба, ярость):

**ацу күрмәң** *тбл.* ачуланмагыз (не сердитесь, не гневайтесь).

**АЦУ III** *тбл., төм.* **1.** әчү (скиснуть); **2.** кымырҗу (зудеть).

**АЦУ-ҒЫЦУ** *саз.я.* ачу-фәлән (злоба). Ацу-ғыцу йуқ.

**АЦУЛАҢҚЫР** *тбл.* ачучан (сердитый, гневливый, злющий).

**АЦЦЫ** *төм., тбл.*, **АЦЫ** *себ.* әче (кислый).

**ацы сөт** *төм.* әчегән сөт (скисшее молоко).

**ацы таш** *тбл., төм.* ачуташ (квасцы).

**ацы цийә** *тара.* мүк җиләге (клюква).

**АЦЫҒ** *себ.* к.: **аццы.**

**АЦЫҒАЙ** *тбл.* оеган сөт (простокваша).

**АЦЫҚЛЫҚ** *туб.-ирт.д.* ачык урын (открытое место).

**АЦЫҚСЫРАУ 1.** *тбл.* ачтан үлү (умереть голодной смертью); **2.** *тбл.* к.: **ацу I.**

**АЦЫЛИ** *клд., тмн.* к.: **ачылый.**

**ацыли камыр** *клд.* чүпрә белән ачытылган камыр (тесто на дрожжах). Бәлешләр ацыли камырдан, алгы выт шунди зурларны пешерәйдек.

**АЦЫЛМА** *эчк., төм., твр.* к.: **ачылма.** Бала ацылманы watмасын. – *эчк.* Ацылмамны ацып қуйатым. – *төм.*

**ацылма тирәс** *саз.я.* капкачлы тәрәзә (окно со ставнями). Әр ғайсы пүлмәә ацылма тирәс кәрәх.

**АЦЫЛУ** *срг.* к.: **ачылу.** Керләр йуганда ацыла (куллар).

**АЦЫНУ** *тбл.* ачыну, үкенү (сожалеть, быть печальным, горевать).

**АЦЫРҒАНУ** *саз.я.* ачыну, әрнү (чувствовать боль, страдать). Әшгәрә ацырғанып қыцқырған ите бақ, йылан цағыпты.

**АЦЫТҚЫ** *туб.-ирт.д.* әче камыр (кислое тесто).

**АЦЫТКЫ** *чпр.* к.: **қурйын.** Ацыткы кала цапцак эцендә, кыwашна куймаа кирәк була.

**АЦЫТМА** *саз.я.* чүпрәле, әче камыр (дрожжевое тесто).

**ацытма пawырсах** *саз.я.* әче камырдан пешерелгән бавырсак (баурсак из кислого теста).

**АЦЫТХЫ** *саз.я.* к.: **қурйын.**

**ацытхы пawырсах** *саз.я.* кабартма (пончик). Ацытхы пawырсах трошайлы оннан пешереләт.

**АЧАГЫНДА** *т.я.-крш.*, **АЧАҚТА** *перм.* ул чакта (тогда, в то время). Ачақта мә акчаға эшләдек, җәз җегерме сум беле чықтым пинсийәгә. Аслы-өслө ачақта йәсле. – *перм.*

**АЧАЛАҚ-ҖОМАЛАҚ** *к.т.* ача-йома, бер ачып, бер йомып (то открывая, то закрывая – о глазах). Күземне ачалақ-жомалақ жатам.

**АЧАМА** *минз.* к.: **қачылық.** Қыйғачлап қуйалар да ачама йасыйлар.

**АЧАМАЙ 1.** *перм., к.-уф.* к.: **қачылық.** Күршеләр йортны бик қызу тоттылар: инде ачамайын да утыртып өлгергәннәр. – *к.-уф.*; **2.** *минз., чст., кмшл.* бер-берсенә кыек, кыйгач, почмакка почмак (крест-накрест, наискосок, наискось). Ачамай торалар алар Корбан әзиләр белән. – *чст.* Анда йәнәшә ул бергадирларға, ачамай ғына. – *кмшл.*; **3.** *кмшл.* кылый, чалыш (косой – о глазе).

**АЧАР** *эстр.* ачкыч (ключ). Кабинетқа кердек – ачар йуқ.

**АЧАРБАҚ** *т.кам.-крш., каз.ар.-крш., бәр.*, **АЧАРВАК** [ач + *гар.*] *кузн.* к.: **алйот 2.**

**АЧАРЛАУ** *брб.д.* китап битләрен йөгертеп карап чыгу (перелистать).

**АЧАУЛЫК** *глз.* к.: **ашаулык.** Кызыл ачаулык, киҗеле ачаулык булгалады.

**АЧИСТ** *м.-кар.* к.: **алйот 2.** Ачист кеше ол. Ачист упкын ди, туйалмаса.

**АЧИСТЛАНУ** *м.-кар.* комсызлану (жадничать). Ни ачистланасын?

**АЧИЧТ** *м.-кар.* к.: **алйот 2.**

**АЧЙАУЛЫҚ** *минз.* к.: **ашаулық.** Сигred ачйаулығым бар әле минем шул катуклардан суққан.

**түр ачйаулығы** *минз.* кашага (бордюр вдоль матицы и стен под потолком). Түр ачйаулығын матчага, ишек өсләренә әлә килен.

**АЧҚАҚЛАУ** *минз.*, **АЧКАКЛАУ** *стрл.* бик нык ачыгу, ачка интегү (сильно голодать, изголодаться); чаг.: **аскаклау.** Күркә ачкаклап бетә икән, үрдәк балалары суда йөри икән. – *стрл.*

**АЧКАМЫР** *лмб., кузн.* камыр башы, ачыткы (квашня, закваска для ржаного или пшеничного хлеба).

**АЧКЫЛДЫМ** *кузн.* әчкелтем (кисловатый).

**АЧҚЫЧБАУ** *трх.* к.: **путемар.** Ачқычбауны қыйықлап кийәләр ийе.

**АЧЛАУ** *трх., т.я.-крш., хвл.* май язу (пахтать масло, сбивать). Май ачлый торған гөбө була. – *трх.* Әйрән чиләгенә салып ачлаган энде майны. – *т.я.-крш.* Каймак җийалар да ачлыйлар. – *хвл.*

**АЧМАЛЫ** *минз.* ачылмалы, ачыла торган (открывающийся). Ике ачмалы фәрдә.

**АЧМИННЕК** [*рус.* осьминник] *кмшл., мәл.* борынгы җир үлчәү берәмлеге: $^1/_3$ дисәтинә (старинная единица измерения земли, равная примерно $^1/_3$ десятины). Ул ачминнек дигән йеребез былай: хәзергечә әйткәндә қырық сутый. – *кмшл.*

**АЧУ I 1.** *т.я., хвл., чст., чст.-крш., мәл.* берәр нәрсәне ялтырап торырлык итеп чистарту (чистить до блеска). Самуwар ачарга әче қатық әйбәт була. Самуwар ачтым, пичләр ақшарладым, бәйрәм җитә бит. – *к.т.* Қатық алып қайтырмын дигән идем самawыр ачырга. – *чст.* Йарты йыл бар инде самawырны ачканым йук. – *мәл.*; **2.** *кузн., хвл., лмб.* әйберне (чәчне, тукыманы һ.б.) бик чиста итеп юу (промыть, выстирать очень чисто, до блеска – о волосах, материи и т.п.). Качтуныңны начила ачтык, нәнәй, шандый карайган. – *лмб.*

**ачу II** (злоба, гнев):

**ачуға алу** *глз., нокр.* к.: **азарлау.** Аз йаза хатны дип ачуга алма. – *глз.*

**ачу III** (открывать):

**бәке ачу** *мәл.* бәке ую, тишү (прорубить прорубь).

**сут ачу** *нрл.* судка бирү (отдать под суд). Ул сут ачып қырығ-илле сум түләгәнче, син ач сутны, диделәр.

**ызба пиче ачу** *лмб.* борынгы йола: яңа йортка мич чыгарганнан соң, нинди дә булса хайван ча-

лып, өйгә картларны җыеп мәҗлес ясау (старинный обряд: проведение угощения после кладки печи). Ызбаны куйып бетергәннән сун пич куйгач, мачы чагасын кертеп йибәрәләр, кучат чалалар, кан чыгаралар, кан чыгарганнан сун, ызба пиче ачарга дип, картларны җийалар шал итне нәзер итеп ашарга.

**АЧУ IV** *перм.* картаю, эштән чыгу (состариться, стать дряхлым – о человеке).

**ачып беткән** *перм.* к.: **ачыган.** Әхми абый белә микән (авыл тарихын)? – Белә ди ул ачып беткән нимә!

**АЧУК** [*рус.* очко] *хвл.* очко.

**ачук куйу** *мәл.* арттырып җибәрү, кем икәнлегеңне күрсәтү (перехватить через край, показать себя с какой-либо стороны).

**АЧЫ I** *кмшл.* к.: **ачылык 2.** Киндер ачыда үсә.

**АЧЫ II** *хвл.* әйдә, әйдәле (давай, давай-ка). Ачы, йырла, әнекам.

**АЧЫ III** *перм.* агу (яд). Атасы-инәсенә көйөп ачы эчеп үлде.

**АЧЫ IV** *срг.* бик, кирәгеннән артык (очень, чересчур).

**ачы жар** *срг.* бик эссе, бик кызу – мәс., көн турында (очень жаркий – напр., день). Ачы жарда кийәләр иде бит сыкна цулка.

**а ч ы V** (кислый):

**ачы кузгылдак** *кузн.* к.: **ачыкый.**

**ачы кымызлык** *перм.* к.: **ахык.**

**ачы тирәйак** *лмб.* эфьюн (опиум, опий).

**АЧЫ: җан ачыгы(сы) белә** *бәр.* **1.** җан ачысы белән (с горечью, негодованием в минуту предсмертного отчаяния). Җан ачыгысы белә тотқандыр қулын; **2.** җан ачуы белән (с сильным гневом, негодованием). Җан ачыгым белә қуwып чыгардым, монда айақ басасы булма дип.

**АЧЫГAWЫЗ** *минз.* вак бәлеш (мелкие бэлиши).

**АЧЫГАВЫЗ, АЧЫГAWЫЗ 1.** *кузн., карс., мәл., чст.* ит, эремчек, повидло һ.б. әйберләр белән пешерелә торган пәрәмәч (перемяч; ватрушка). Картуг ачыгawызлары пешерәсен; **2.** *стрл.* к.: **қарақаш.**

**АЧЫҒАН** *перм.* бик нык картайган, картаеп эштән чыккан – кеше турында (очень старый, дряхлый – о человеке). Инде ачыған кешегә, балақайым, нәстә дисәң дә күнегез инде. Башқа әбиләр монда хәтерсезләр, ачығаннар күбесе.

**АЧЫГУ** *т.я.-крш.* алып чыгу (вынести, вывести). Ачыгалмайлар кызны ызбадан, начила ачыктылар.

**АЧЫЙҒАНЫП** *блт.* өзгәләнеп, ачыргаланып, чын йөрәктән (терзаясь, с болью в душе, изнывая). Ачыйғанып әйткәннең рәнҗүwе төшкәндер.

**АЧЫҚАЙ** *себ.* яшен (молния). И болот чықты, ачықайлар йалтырый, көн күкри. – *брб.д*

**АЧЫҚЫЙ** *нрл.* кузгалак, эче кузгалак (щавель кислый).

**АЧЫЛАУ** *т.я., бгрс.* к.: **ачлау.** Ағач гөбәдә ачылыйлар инде майны. – *трх.* Ачылый, ачылый, көннең озоно ачылый, май төшми. – *бгрс.*

**АЧЫЛМА** *перм.* ике якка ачыла торган тәрәзә (двухстворчатое окно). Монда быйыл берсе рамканы алабыз да ачылма йасыйбыз.

**АЧЫЛУ** *т.я., чст., хвл.* югач ялтырап калу, ялтитү (заблестеть, засверкать). Керләрең күгәргән генә, қызым, бер дә ачылмаған. – *к.т.* Гүмердә ачылмаган керләр. – *чст.* Ком белән ышкыгач, баг әле, бу паднус ничек ачылды. – *хвл.*

**АЧЫЛЫЙ** *тмн.* ачы камырдан, ачыга пешерелгән (испечённый из дрожжевого теста, вкислую). Камырны ачытасын, кисәсен, куйасын кабартырга, май эченә саласын, ачылый катлама була.

**АЧЫЛЫҚ** *минз.* **1.** баткаклык, сазлык, сазламык җир – гадәттә елга буйларында (болото; болотистое, топкое место – обычно вдоль рек, после ухода разлившейся воды). Хәсән ачылықтан қыр үрдәге атып алып қайтты; **2.** *минз., кмшл.* уңдырышсыз, тозлы, аксыл туфрак (неплодородная, солончаковая почва). Үткән йылны бәрәңге җирдә булмады, ачылықта булды. – *минз.*

**АЧЫРҒАЛАНУ** *т.я., минз.* өзгәләнү, авыртудан яки ачудан һ.б. үзен-үзе белештермичә бәргәләшү (выражать отчаяние; биться, метаться от боли или злобы). Малайы ачыргаланып җылый, берәр җире awыртадыр. – *к.т.* Дөбәйдә қыдына ачыргаланып қычқыра. – *минз.*

**АЧЫТҚЫ** *блт.* к.: **болгама 2.**

**АЧЫТКЫ** *чст., мәл., хвл., кузн.* чүпрә (дрожжи). Ачыткы бир әле, Сабира, бүген камыр куйам. – *хвл.* Зур апа, әзрәк ачыткыгыз йукмы? – *чст.*

**АЧЫТКЫЛЫЙ** *карс.* к.: **ачылый.** Нәстә генә йук, алкамы йук, кылакмы йук, ачыткылыймы йук, чечеткелийме йук, кабартмамы йук – бетенесе бар.

**АЧЫТУ** *глз.* авырту, әрнү (болеть). Ычым ачыта, йалгыз тормага усал.

**АШ I 1.** *себ.* ашлык (хлебные злаки, хлеба). Пес аш цацапыс; **2.** *себ., эчк.* иген (хлеба – в поле; жито). Ашлар өлгөрөп киләте. – *тбл.* «Ашларыбыз уңсын»,– тип, йомортқа цацатлар аш цацқанта. – *төм.* Быйыл аш уңар. Алар бик күп алдылар аш. Аш өлгереп килә басуларда. – *эчк.*

**аш айыртатыгын машина** *төм.* сортировка машинасы (сортировка).

**аш иләк** *төм.* җилгәргеч (веялка).

**аш қамышлау** *учл.* к.: **нажағай.**

**аш керчеге** *брб.д.* ипи валчыгы (хлебная крошка).

**аш қыра** *туб.-ирт.д.* игенлек, иген басуы (пашня, хлебное поле).

**аш суққыц** *себ.* чабагач (молотило, цеп).

**аш цацғыц** *төм.* чәчкеч (сеялка).

**АШ II 1.** *миш.д.* камыр ашлары (мучные изделия); **2.** *каз.ар.* төп кодаларның туй күчтәнәчләре (свадебные гостинцы главных сватов: родителей жениха или родителей невесты). Иртәгесен мине әпкитәләр, мин дә барам аш белән. – *лш.* Төп қода әпкиләдер ийе ашны. – *мам.*; **3.** *себ.* токмач (лапша).

**арчи ашы** *кузн.* яшь килен ягыннан килгән кызларның күчтәнәчләре (свадебные гостинцы девушек, сопровождающих невесту). Арчилар баралар кажныйы патнус белән, аш алып, арчи ашы дип сүлиләр.

**аш айыручы** *глз.* мәҗлестә аш бүлүче (чело-

век, который разливает суп, разделяет еду во время угощения). Ул аш айыручы ике кеше, эч кеше була инде. Салып йибәрә инде итен кусоклап, буткасын да салып йибәрә. Ул бабачлар йанына ару катыннарны куйалар кизүләмәгә, йумага, ашына су китереп салмага.

**аш арбасы** *минз., стрл.* кызны кияү йортына озатканда күчтәнәчләр куеп бара торган арба (тележка с угощениями, которая сопровождает невесту в дом жениха). Аш арбасы туй артыннан бара. – *стрл.* Аш арбасы белән киләләр җегет җағыннан. Аш арбасында күчтәнәче, бawырсагы куйган була. – *минз.*

**аш ашлау** *глз.* ашка сала торган токмач яки чумар (заправки для супа: лапша или клёцки). Аш ашлауларны күкәйгә баскан, йумал камырны.

**аш бирү** *нгб.-крш.* үлгәннәр хөрмәтенә корбан чалу, мәҗлес үткәрү (обряд жертвоприношения; провести поминальную трапезу). Аш бирү болай була инде. Михайлов көнне, көҗминкә көнне бирәләр. Атыйлар сыйыр, башын җыwалар. Менә йәш сыйырны атап суйам затыма-зәweремә дип. Ишегалдына зур қазан қуйалар. Йарты йақны кисеп салалар қазанға, аш биргәндә малның сул йагын кисеп салалар. Аш пешкәчен бер малайны ат атландырып чыгаралар ашқа чақырырга. Өч йылга чақлы аш бирелә.

**аш бойорту** *әстр.* туйга егет ягыннан ашамлыклар китертү турында килешү (договориться о преподнесении продуктов на свадьбу со стороны жениха). Қыз йағы аш бойортады кийәүгә: қуй бойортады, пахлawa бойортады, алма бойортады, қыз йағы бойортады.

**аш бүлеме** *мам.* к.: **багырча**. Элек аш бүлемнәре ағач ийе.

**аш бүлүче** *чпр.* камыр ашларын кисеп өләшүче (человек, который режет и раздаёт за столом угощение). Аны, cawымны, аш бүлүче бүлә. Йанында ак селге тыра кулын сертергә, артта кымганы тыра кулын йуарга.

**аш итү** *бәр., каз.ар.* кунак җыеп аш мәҗлесе уздыру (провести званый обед, ужин; приглашать в гости). Дүрт көрпәне җәйеп аш итә торган ыйық идәндә. – *бәр.* Орқыйа аппайлар аш итәләр икән бүген, әнисе чақырды кичкә. – *блт.*

**аш йақ** *нокр.* к.: **бүлмәч 2**. Аш йақта қайнатам бар, сүләшмә йарамый.

**аш йасап бару** *чст.* туйга күчтәнәч ашамлыклар пешереп алып бару (идти на свадьбу с гостинцами). Цит awылга барса да, үз awылына барса да, туйга аш йасап баралар. Әҗәр аш белән баралар иде, шылай аш йасап баралар иде туйга. Үзенең йакын туганнары аш йасап баралар. Кайсыбер туйларга дүртәр, бишәр аш килә. Менә әле генә төштеләр биш аш белән.

**аш йасау 1.** *минз., стрл.* туйга алып бару өчен күчтәнәч әзерләү (приготовить угощения для свадьбы). Йақшы күмәч сала, пар қазы була, аш йасап йибәрә. – *минз.*; **2.** *себ.* токмач басу (месить лапшу). Қазан йағына себерәктән килеп алганнар. Инәсе аш йасарга қушқан киленең. Ул қамырны басқан, йәйәргә кирәк.

**аш йәймә** *мәл.* ашъяулык (скатерть). Кийәү бәлешен, йакшы аш йәймәгә тереп, кийәүгә бирә, аннары кийәү алып китә.

**аш йеретү** *себ.* туйда кара-каршы ашамлыклар бирешү (обмениваться угощениями на свадьбе). Бәлеш салатлар көрәс қушып, палан бәлеш, цийә бәлеш. Ике йә түрт бәлеш пешереп апкилә те. Аны ике йақлап апкилә те, аш йеретү булаты. Қыс йаққа апкилә те, аннан сун кийәүгә апкилә тләр. Туй да қыс йақта пулган әвәл.

**аш йес** *себ.* аш исе (запах еды).

**аш йес чығару** *себ.* үлгән кешеләрне искә алып, нинди дә булса камыр ашы пешерү (испечь что-нибудь мучное для поминания умерших); чаг.: **таба: таба исе чығару.** Қатымда иң беренче аш йес чығару, пәтер пешерәме.

**аш йийу** *себ.* ашау, туклану (кушать, питаться). Бу йакта көнлекчеләр аш йийып йатады, инәм бала тywып йатады теге йақта. – *тбл.*

**аш йулы** *хвл.* к.: **үмәч**.

**аш қайтару 1.** *минз.* кыз өеннән егет ягына күчтәнәчләр белән бару (идти с гостинцами на свадьбу со стороны невесты). Җегетнең атасы-инәсе алып килә туйга күdикмәк, әпәй, чәкчәк, пар қалач. Шуннан аны, җегет җағыныкыңнан бер бөртек тә кәм итмичә, қыd анасы қайтара торган ыйы туй қайтқанда, аш қайтара торган ыйы. – *минз.*; **2.** *перм., әстр.* к.: **қайтару II**. Йәгез, аш қайтарыйқ әйдә! – *перм.* Туй беткәч аш қайтаралар, теләк бирәләр. – *әстр.*

**аш қутару** *әстр.* к.: **аш төшерү**. Қазаннан чараға қутарып алган килен ашны, қамыш урып китергәннәр әтиләр, қазанда аш пешерәбез.

**аш қушлау** *туб.-урт.д.* акча салышып кичә ясау (устроить вечер в складчину).

**аш күләүче** *чст.* аш пешерүче (человек, готовящий еду; повар). Ул тырпычаны аш күләүче йасый иде. Ул аш күләүче бәлешләрне бер көн алдан пешереп куйа иде.

**аш күрсәту** *нгб.-крш.* көз көне сугымнар суйгач, мәҗлес ясап кунак чакыру (провести званый обед осенью, когда режут скотину). Аш күрсәтәбез мал суйғачын, чақырасын үзенең хәрендәшырywын. Алар суйғач, алар аш күрсәтә, сине чақыра.

**аш ошлап** *себ.* ашамлык әйберсе тотып (держа в руках какую-нибудь еду). Гүрше-ғара хәл белгәле керсә, потқа йә қоймақ пешереп, аш ошлап керә. – *төм.* Сөлге белән аш ошлап апцық-қаннар, көлле сөлгеләр белән. – *тбл.*

**аш cawыты 1.** *каз.ар.* төп коданың күчтәнәчләре салынган сандык (сундук, куда кладут свои гостинцы главные сваты). Сондоққа тутыралар җегермеләпне, аш cawыты булып аталадыр ыйы. – *мам.* Әwәле сондоқлар, аш cawытлары чыгып китә қапқадан, аннан кийәү белән қыз. – *лш.*; **2.** *кузн.* ашказаны (желудок). Синең аш савытың эшләми.

**аш сайлау** *хвл., срг.* авырга узганда аш талымлау (привередничать, быть разборчивой в еде при беременности). Ник былай аш сайлыйсың, әллә кырсакка уздыңмы? – *хвл.* Аш сайлаганда өрәткәннәр тозсыз ашарга. – *срг.*

**аш сондок** *кузн.* к.: **аш cawыты 1**. Туй ашлары туй алдында килә, аш сондокта, ике катын

китерә. Оликмәк куйган, уннымы, уникеме катлама, йезәңге китерә бер сондок.

**аш сөрәп килү** *әстр.* үлгән кешенең бер елын искә алу мәҗлесенә ашамлыклар һәм акча белән килү (прийти на годовщину умершего с едой и деньгами). Йыл Коранына инде үлегә аш сөрәп килү диләр, берәү дөгесе белән чәйен китерә, берәү куй бирә, берәү акчалата бирә.

**аш тайарлау** *себ., кмшл., минз.* аш әзерләү (приготовить еду). Аш тайарлайтар, цөцбәрә бөгә торганнар қасан ашқа. Төмән-төрле аш тайарлап, пawырсақ, ит-аш тайарлап утырышатылар. – *тбл.*

**аш тақта** *себ.* куна тактасы (кухонная доска).

**аш тарту** *әстр.* туй вакытында һәр ике якның бер-берсенә туй күчтәнәчләре бирешүе (взаимное угощение в дни свадьбы). Йегет анасына – қыздың анасы, қыздың анасына йегет анасы аш тарта. Патнус белән тастархан эстенә қуйадлар, менә қодағыйға тартқан аш дип. Җәмәгәтләр бар да қарый йақшы аш дип. Қартларға қуйның башы, җанбаш салына, қалақбаш салына, муйын сөйәге йарамый, сеңерле сөйәк йарамый. Сыйлы сөйәк салмаға кирәк. – *әстр.*

**аш тәргәү** *себ.* аш әзерләү (приготовить еду). Өстәл тутырып аш тәргәп утызатық тойда, майға бешергән бawырсақ, мендәү сәмез итләр табақта. Мин күп тойда болдым ғой. Ит, шурба, қалач пешерәде, өстәл тутырып аш тәргәп утызатық. – *брб.д.*

**аш төшерү** *т.кам.-крш., минз.* аш бушату (вычерпать суп из котла). Ағач табаққа ашны төшереп, сәкегә қуйдым. – *т.кам.-крш.* Ашны төшер әле. – *минз.*

**аш түгү** *әстр.* ашамлык салу (положить, разливать еду). Табаға аш түгәләр бездә. Бер таба пахлawa, бер таба нуғай бәлеше, лақсалбасы, бадамгеле була.

**аш уздыру** *мам.* к.: **аш итү.** Аш уздырғанда табақлықта бер бала күренмәс ийе элек.

**аш цүмец** *туб.-ирт.д.* к.: **багырча.**

**аш чанасы** *бөре., перм., трбс., минз., хвл., мәл.* кызны кияү йортына озатканда ашлар куеп бара торган чана (повозка с угощениями, которая сопровождает невесту в дом жениха). «Таудан әкерен генә мен, аш чанасының җөге awыр»,– диләр. – *минз.*

**аш чаңнawы** *себ.* к.: **багырча.**

**аш чыланы** *чст.* к.: **бүлмәч 2.**

**аш шулпа** *глз., себ.* аш (суп). Аш шулпа пешерәсем әле. – *глз.* Йылу ут йемен аш шулпага салып ашаган, ашап туйғысыс булган. – *төм.* Аш шулпа пешерәсем әле. – *глз.*

**аш эцү** *себ.*, **аш эчү** *бәр., каз.ар., минз., нокр., перм., кргл., бгрс., шрл., стрл., себ.* аш ашау (есть – суп). Ашны қалақ белән эчәсезме, қашық белән ме? – *мам.* Әйдә, бабай, аш эчәргә кер! – *дөб.* Ашны булдырыйқ, эчеп китәрсез. – *каз.ар.-крш.* Бу ашны эчеп қарыйсызмы? – *перм.* Чәй йук, аш эчегез. – *стрл.* Ашны мин көнгә өч тапқыр эчәм. – *кргл.* Икесе бер cawыттан аш эчәләр. – *бгрс.* Аш эчкегез келәмиме? – *шрл.* Сездә элек аш эчәләр, без чәй эчәбез. – *нокр.* Ашны эцеп пөттөк. – *себ.*

**бәбәй аш** *глз.*, **бәбәй ашы** *каз.ар.* к.: **май аш.** Бәбәй ашка чакырабыз исем салганда ук. – *глз.* Бәбәй туғач, үзенең җақыннары, күршеләре бәбәй ашы илтәләр, бәлеш, қайсы тawық тутырып илтә. – *блт.*

**бәйрәм аш** *әстр.* туйга пешерелә торган камыр ашлары (мучные изделия, приготовленные для свадьбы). Туйға бәйрәм ашлар пешә қыз биттә дә, йегет биттә дә. Аш тарта бәйрәм ашлар пешереп.

**бөтөн аш** *нрл.* искә алу мәҗлесенә китерелә торган ашамлыклар. Ул өч төрле әйбердән торырга тиеш: юка, ипи, тавык (еда, угощение, преподнесённое на поминках; состоит из трёх компонентов: хлеб, тонкие лепёшки, курица). Бөтөн аш китерәм дип алдан уқ пешеренә башлый.

**буш аш** *минз., байк., стрл.* к.: **cywанаш.** Хазер буш аш бармени, ә итле аш озак пешә. – *байк.* Ит йук, буш аш кына пешергәнийем әле. – *стрл.*

**җәйге аш** *том.д.* кычыткан ашы (суп из крапивы). Җәйге ашны күп ашадық, чалқайдан пешерәбез җәйге ашны. Күкәй, қаймақ салып пешергәннәр борынғы халық.

**ипи чумар аш** *глз.* ипи камырыннан чумар ясап борчак белән пешерелгән аш (суп с клёцками из хлебного теста). Ипи пешерә дә, камыры кала. Аны әwәли, кискәли чепчеги кебек, чумар ди, ипи чумар аш ди.

**исем ашы** *минз.* балага исем кушуга багышланган мәҗлес (угощение, устраиваемое в честь наречения ребёнка именем). Исем ашына ит алып килгәннәр.

**йаңгыр ашы** *чст.* яңгыр теләп кырда пешерелгән аш яки ботка (обряд вызывания дождя с угощением). Йаңгыр ашын йаздан пешермәсәләр, йаңгыр йаумый. Беркөнне дүрт җирдә пешерәләр безнең awылда: су башына пешерәләр, Байтирмән сазына, Чурай йылгасына, Мулла бабай чишмәсенә. Әрбер өйдән йомырка бирәләр, он, тawык. Сарыкны чалалар, балалар тирә-йакка утыралар. Һәр бала кашыгын, cawытын алып килә. Йомырка тәбийәсеннән һәр балага өлеш чыгаралар. Ашап бетергәч сөйәкләрне читкә ыргытырга йарамый.

**йәрек аш** *брб.д.* авырлы хатынның үзенчә теләгән ашы (еда, которую хочет беременная женщина). Минең қарт әнинең йәрек ашы пөхмә (пилмән) булған.

**йыл ашы** *урт.д., себ.* **1.** кеше үлгәннән соң бер ел үткәч уздырыла торган искә алу мәҗлесе; **2.** үлгән кеше рухына багышлап ел саен уздырыла торган дини мәҗлес (религиозное угощение, годовщина в честь умершего). Йыл ашын йыл да сайын үткәреп тораты. Бер йылга бер искә алғалы кәрәк. – *төм.*

**қаз ашы** *каз.ар., минз., байк.* каз өмәсе (помочь при ощипывании зарезанных гусей; в конце работы устраиваются угощение и игры). Қазы булса, қаз ашы булайде, қазы булмаса да аш җыйа инде қайсы берсе үзе йөргәч. Қаз ашында көлчә дә пешерәләр. – *мам.* Қаз өмәсе көнне кич белән қаз ашына җыйалар. Бөтен қазны салып, қаз шулпасына аш пешерәләр. Қызларға чәй эчертеп

аладырыйық қаз жуып қайтқачын. Кичкелеккә фәлән сәғәткә дип ашқа чақырадырыйық. Ул үзенчә бер оло бәйрәм буладырыйы қаз өмәсе. – *минз.*

**қазан ашлары** *әстр.* казанда майда пешерелгән бөккәннәр (пирожки, испечённые в котле в масле).

**қақсы аш** *перм.* эчәккә тутырылган иттән – *каксы*дан пешерелгән аш (суп из колбасы домашнего холодного копчения). Ат эчәгене киптерәләр, чи күwенә киптерәләр, җебетәләр, тозлаған кисәк ит тутырасың, чығарып қуйалар тышқа, кисепкисеп *қақсы* аш пешерәләр.

**қамыр аш** *әстр.* токмач (лапша). Йомырқа сытасың, қамыр йазасың, қулдан кисәсең дә саласың. Итеңе саласың қуй суйсаң күп итеп. Қызыл балығың саласың, балығың булса.

**қара аш** *каз.ар.* үпкә-бавырлар белән пешергән аш (суп, приготовленный с ливером). Бүген қара аш қына пешердем, үпкә-бawырларым торадырыйы. – *блт.*

**қару ашы** *каз.ар.* туйдан кайтканда каршы биреп җибәрелә торган күчтәнәчләр (свадебные гостинцы). Күмәч, җәүликмәк, қару ашы биреп җибәрәләр инде қайтқанда, берқавым итеңе биреп җибәрәләр ийе, ул қару ашы була. Қару ашы ашарға җақыннарыңны, туған-тумачаларыңны чақырасың инде. – *мам.*

**қасан аш** *себ.* казанга салып пешерелгән шулпалы аш (суп, сваренный в котле). Аш тайарлайтар, цөцбәрә бөгә торғаннар қасан ашқа. – *төм.*

**каткан аш** *клд.* к.: **буш аш**.

**қатым** [*гар.*] **аш** *төм.* үлгән кешене искә алу мәҗлесе, хатем аш (поминальное угощение). Үлекне искә алып, өцесенә бер аш, йетесенә бер аш, қырығына, йөсенә, йылына аш үткәрәсең. Қатым аш үткәрә. Қатым ашқа қысқа онаш кискәннәр. Қатым ашын өстәп салу йарамыйты.

**кәрике аш** *нокр.* солы оны камырыннан шакмаклап ясалган өй токмачы (домашняя лапша квадратной формы). Йаратам мин кәрике ашны.

**кейәү аш** *себ.* кияү һәм кияү егетләре өчен әзерләнгән ашамлыклар, сый-хөрмәт (еда, угощение, приготовленные в честь жениха и его свиты).

**кереш ашы** *лш.* озак вакыт яңгыр яумый торса, өй саен йөреп, йомырка, ярма һ.б. җыеп су буенда пешерелгән ботка; ашаганнан соң су сибешәләр (один из старинных обрядов моления о дожде).

**кийәү аш** *миш.д., перм.*, **кийәү ашы** *миш.д.* **1.** *перм.* к.: **кейәү аш 1**; Йәш килен өчен бара кийәү йегетләр, ике арба киләләр. Кан′иш халкы, ырулары бара, аларга кийәү аш куйалар. Кийәү ашка кийәү йегетләре акча сала. – *кузн.* Кийәү ашына тип қызлар җыйыла, кийәү шунда пудыра, исле сабын, җаулық тарата. Без кийәү ашқа бардық кийәү керткән чағында. – *перм.* **2.** кияүгә, кияү егетләренә пешергән камыр ашлары (специально приготовленные мучные изделия для жениха и дружков). Кийәү ашын катлама камырыннан кисәләр. Кызлар йасый кийәү ашы, чигелдәк, ун-унбиш тәрилкә тезеп куйа эстәлгә. – *кузн.*

**кийәүгә аш тарту** *әстр.* кияүгә сый әзерләү, хөрмәтләү (угощение жениха). Қыз бит кийәү сыйлағанда кийәү сыйға аш тарта торған ыйы. Қыз бит аш тартады кийәүгә. Ике чит кийәүгә, ике дусына, кийәүнең ағасына тартадылар аш. Җиде табақ аш тартыла.

**қода ашы** *тпк.* **1.** туйга кияү ягыннан килгән кодаларның күчтәнәчләре (гостинцы-яства, привезённые родителями жениха на свадьбу). Йедесигед саналы туй булыр ыйы, adақысында қода ашы була; **2.** туйда кунакларны кодалар алып килгән күчтәнәчләр белән сыйлау мәҗлесе (свадебное угощение). Тәү көнне никах була, икенче көнне қода ашы була.

**қорман ашы** *каз.ар.-крш.* яңгыр теләп, чишмә буенда корбан чалып пешерелгән ботка (жертвенная каша для вызывания дождя). Қорман ашы дий торғаннар ыйы, тишмә буйындайы. Безнең оло тишмә бар монда, биг оло тишмә. Ана шу тишмә буйына бөтен awыл җыйыла тоған ыйы, қорман ашына барабыз дип.

**коры аш** *срг.* камыр ашлары (мучные изделия). Бер купы аш-шурба, коры ашлар куйа зиде кицендә. – *срг.*

**қуйын ашы** *себ.* күчтәнәч (гостинцы). Мине бер бабай туйдызаты, ул алып килеп қуйаты, менә қуйын ашларым. – *брб.д.*

**кунак ашы** *т.кам.-крш.* май белән бал, онны болгатып пешерелә торган хәлвә, аны кеше үлгән көнне пешерәләр дә килгән халыкка авыз иттерәләр, табутка да куялар (халва, которую готовят в день проводов покойного). Бал белән он, майны болгатып пешерә дә кунак ашы дип кеше сайын шуны каптырып чыга. Йөз кеше булса, йөз кешегә дә каптыра. Кунаг ашы диләр аны. Бер ак җаулыкка төйнәп, бәләкәй генә итеп үленең гырубына да куйалар аны, кунак ашын. Тегендә баргач үлеләрне сыйлый ул. Кунак ашы дип бал белән онны бутап кайнатып пешерәләр, бер төйенчеккә төйөннилəр дә шуны куйып җибәрәләр гыруп қырыйына.

**күпкән аш** *брб.д.* ачы камыр (дрожжевое тесто). Күпкән аштан бешергәле төрлү ашлар. Урама, күпмә бawырсақ бешерәде күпкән аштан.

**күц аш, күцен аш, күчен аш** *себ.* кияү өенә килен төшкәндә алып килә торган ашамлыклар (свадебное угощение, привезённое со стороны невесты). Күц килгән цакта күц аш киләйте. Алар та пүләк алып килә кийәү йаққа. Ашны килгәц ацалар, ацкан кешегә пер йаулық, аны пер йақын туғаны аца. Күцен аш тиделәр күцкә барғац. Пашта ирәннәр утыраты. Күчен аш тиделәр. Қоталарны, туған-қәрендәшне сыйлайтылар. Пулышқалы керәтеләр. – *төм.*

**қызлар ашы** *минз.*, **кызлар ашы** *чст., чст.-крш., минз.* көз көне уздырыла торган кызлар мәҗлесе (осенний праздник угощения девушек). Қунақ қызы килгәч, ашқа җыйғаннар қызларны, йорт сайын қызлар ашына чақырғаннар, килгән қунақ қызларын ашқа җөрөткәннәр. – *минз.*

**қызырағ ашы** *том.д.* туй ашы (свадебное угощение). Қызырағ ашы диләр, туй ашы була, пачутта булған қызырағ ашы.

**май аш** *глз.* бәби туу хөрмәтенә уздырыла торган чәй мәҗлесе (угощение в честь рождения ребёнка). Май ашка килегез дип чакырабыз нәселйәwерне. Әйбер китерәләр, бәбәй кийем.

**май ашлары** *кузн.* майда пешкән камыр ашамлыклары (мучные изделия, жаренные в масле). Атауда куй суйалар, май ашлары пешерәләр.

**озын аш** *том.д.* озын токмач (лапша длинной формы). Озын ашны бик йаратмаймын. – *клм.*

**оло аш** *т.кам.-крш.* кешенең үлгәненә бер ел тулгач үткәрелә торган искә алу мәҗлесе (поминки, которые справляют через год). Зиратқа барып чақырабыз, әйдә, синең бүген оло ашың, қайт, диб әйтеп.

**он т'апен'а аш** [*удм.*] *глз.* к.: **буш аш**. Он т'апен'а аш бер тәбеч ашадым да чыкладым.

**өнтәү ашы** *тпк.* туй вакытында килен ягыннан килгән кодаларның күчтәнәчләре (гостинцы, привезённые на свадьбу родственниками со стороны невесты).

**табаклы аш** *кузн.* хәергә бирү өчен пешерелә торган коймак (блины, испечённые для подаяния). Бала имә дә коса, аңарга кирәк табаклы аш пешерегә, кимак пешерегә. Йә, биш кимаклык кына атла инде камырны, тегиле булмасын, бабайга ашаталар шул кимакны, бабай ашый инде. Табаклы аш шул була!

**тотқан аш** *брб.д.* төче камыр (пресное тесто). Тотқан аштан пешергән бәлешне, аны бөргәндә йомшақ булса, йәйелеп китәде.

**тубал ашы** *срг.* тубалга салып туйга алып барыла торган камыр ашлары (мучные блюда, угощения, которые везут в лукошке на свадьбу). Тубал ашын келәткә кертәләр дә кийәү белән кызга икәү генә ашарга кушалар, кешегә ашатмаска. Ашап бетерегә тийеш аны йегет белән кыз. Ашап бетерә алмаса, сирга каптыралар, йарый диләр тywарга. Тубал ашларын кисәкләп-кисәкләп кенә кешеләргә дә турап куйалар. «Тубал ашы кап, бәхетле булырсың, үмерле булырсың», – диләр.

**туй аш, туй ашлары** *кас., әстр.* туй өчен пешерелә торган камыр ашлары (мучные изделия, приготовленные для свадьбы). Туй ашлары зурларны пешери тор'ан бул'аннар. 'азаннар бул'ан, майда пешери тор'ан бул'аннар.– *кас.*

**түгем ашы** *т.кам.-крш.* үлгән кешене искә алу мәҗлесенә пешерелгән ашамлыклар (еда, приготовленная для поминок). Җыл тулган көнне оло ашын үткәрәләр. Кайда үлгән, шунда урын көйлисең, шунда табак куйып, түгем ашларын саласың, коймагын, тәбикмәген, балыгын саласың.

**утбасар аш** *әстр.* туйда егет ягыннан китерелә торган ашамлыклар (еда, угощение, привезённые из дома жениха в дом невесты). Утбасар аш килә: ит, дөге, чәй, шикәр, җимешләр.

**үри аш** *нокр.* өйрә (суп из крупы). Үри аш бешерә арпа йармадан, соло йармадан.

**чәй ашы** *кас.* камыр ашлары: бәлеш, кабартма h.б. (мучные блюда: пироги и др.). Эстил җаптылар, чәй йанында чәй ашлары була, күдрә, билеш.

**чырыш богол' аш** [*удм.*] *глз.* ипи чумары (клёцки из хлебного теста). Ипи пешерә дә, камыры кала, аны борчак белән чумар итеп пешерә, чырыш богол' аш була.

**шақмақ аш** *том.д.* шакмаклы токмач (лапша квадратной формы). Туй ашқа шақмақ аш уңай. – *яшт.*

**АШ III** *туб.-ирт.д.* эрен (гной). Цыйган аш йыйаты, анан тишеләте – *төм.*

**АША I 1.** *хвл.* к.: **ашалай 1**. Ашасыннан узып кереп китте; **2.** *чст.* ...дан соң, үткәч (после, спустя); чаг.: **ары 4; арт 2**. Awылныкы кат'ып сүләде мында ун йыл аша; **3.** *тмн., мәл., шрл.* артык, бик (чрезмерно, чрезмерный; очень, излишне). Аша кызыл тиз ан'ый, зәңгәресе йакшырак *(мәкаль)*. – *тмн.* Аша матурны эзли-эзли, Чак матурдан да калма (*хал. җыр.*). – *мәл.* Бездә аша йәмсез кеше бер дә йук. – *шрл.*; **4.** *перм.* к.: **арлақ**. Урал тау Кизелдән дә аша wы.

**аша пила** *туб.-ирт.д.* аркылы пычкы (поперечная пила).

**АША II** *төм.* **1.** бик күп, күбрәк (очень много, более); **2.** аша (послелог – через).

**аша барса** *перм., кмшл., мәл., срг.* **1.** күп булса, һич югында (самое большее, не более). Бу күлмәкне, аша барса, бер-икөч қабат кигәнемдер. – *перм.* Аша барса, бер сагат йөрерләр. – *мәл.* Аны (плащны) аша барса кыскартырсың гына. – *срг.*; **2.** *кмшл.* һәрхәлдә (во всяком случае). Аша барса, үзенә файдасы булыр.

**аша йату** *кузн.* озак пешеп изрәү – аш, ашамлык турында (перевариться, слишком развариться – о пище).

**аша йебәрү** *срг.* ташыту (литься через край); чаг.: **артылу**. Аша йебәрдем циләкне.

**аша китү** *чпр., срг.* артып китү, артыкка китү, күп булу (быть излишним, чрезмерным; много). Аша киткән инде. Аша китсә, майын ал буткаңны. – *срг.*

**АШАҒА, АШАҒЫ** *себ.* **1.** чит, ят (чужой, посторонний, незнакомый). Ашагawылга кейәүгә цыкты. – *төм.*; **2.** чит, ят җирләр (чужие края). Ашағыта та йөрөп килте. – *тара.*

**АШАЙАК** *чпр.* аш савыты (маленькая чаша, блюдце для супа). Шыгыр-шыгыр арба, шыгырданга барма, шыгырданга барсаң, бер ашайак салма *(әйтем)*.

**АША-ҚОША** *перм.* к.: **арбай-тарбай**. Қылтам (авылы) аша-қоша утырып җыйылган.

**АШАҚ** *т.я.*, **АШАК I** *м.-кар.* тәбәнәк, түбән (низкий, невысокий; низко). Бу өстәл безнең бигрәк ашақ. Баш астың ашақ булса, тағын бер күпчек сал. – *к.т.* Ашак агач. Тегесе бийек, икенчесе ашаграк булды. Үләннән ашак, судан тонык (*мәкаль* – тыйнак кеше турында). – *м.-кар.*

**АШАК II: ашак кеше** *т.я.-крш.* к.: **ашаулы**. Күп ашак кеше түгел мин, безрик капкаласам була.

**АШАЛАЙ** *тмн.*, **АШАЛЫЙ** *лмб., кузн., стрл., мәл.* **1.** аша, аркылы (через, поперёк); чаг.: **аткыры 1**. Урам ашалай чыкканда, Айны гына болыт каплады; Минем дә йан гына тартмады, Әтекай кәбәм шылай каплады (*бор. җыр.*). – *тмн.* Ашалый йатты. Ашалый йатма әтәм. Безнең кырлар ни зур кырлар, Ашалый уза кыргыйлар (*хал. җыр.*). – *кузн.* Кеше ашалый гына ишеттем. –

*стрл.* Су ашалый чыкмагыз, айаккыз йебенер. – *мәл.*; 2. аркылы, үтәли (через, сквозь). Сетка ашалый уздыр сөтне. – *лмб.*

**ашалый кисү** *чст.* әйләндереп, түгәрәкләп кисү – ипи турында (резать круглым ломтиком – о хлебе). Мин ашалый кисәм, әләндереп әпәйне.

**АШАМА** *глз., нокр., кас.* азык, ашамлык (еда, пища, провизия, продукт). Ашамалары шунда иде. – *кас.* Эчүчеләргә бик тәмле ашама (балык). – *глз.* Оланнар-кызлар чакырып йергәләгәннәр бийем-бийатаны: «Әйдәгез, ашама йетте»,– дип. Ашамалар әзерли, кызыл ашаулык кертеп җәйә килен. Килен, кулын җиңенән чыгармайчы ғына, ашама салады. – *нокр.*

**АШАМАК** 1. *срг., мәл., хвл.* к.: **ашама**. Ашамак исенә йыйыла инде бу чебен. – *мәл.* Кырга куйган ашамагымны ашадым да йаттым. Туй итәргә ашамаклар китергән. – *срг.* Бабай ашарга бир әле, ди, карт ашамак бирә. – *хвл.*; 2. *срг.* к.: **аш I, 1**. Илле пыт ашамак бирдем.

**АШАМАКЛЫК** *т.я.-крш., чпр.* к.: **ашама**. Күп ашамаклык алып чыктым йулга. – *т.я.-крш.* Апкайтырлык ашамаклыклары бар. Ашамаклыгы бетсә дә, кийемнәре калсын иде. – *чпр.*

**АШАМТЫҚ** *каз.ар.-крш., нгб.-крш.* к.: **ашама**. Ашамтыкны келгә күмәйең. – *каз.ар.-крш.* Өй сатып алынған нардуғанда, уйныйбыз, җырлыйбыз, чәй эчәбез, ашамтық ашыйбыз. – *нгб.-крш.*

**АШАМ-ЭЧЕМ** *минз., стрл., трбс.* к.: **ашама**. Ашам-эчем алып киләләр туйға сындыққа салып. Чәкчәк, қаз, ашам-эчем, қоймақ. – *трбс.*

**АШАНДЫ** *нгб.-крш.* к.: **ашама**. Ул әйберең әллә ашанды инде?

**АШАНТЫРУ** *туб.-ирт.д.* ашату (кормить). Ник қунақларны ашантырмайсың? – *твр.*

**АШАНУ** *төм., тбл.* ашау, ашап тую (кушать, есть, наесться). Пес ашанған. – *тбл.*

**АШАТА** *саз.я.* аша (через).

**йыл ашата** *саз.я.* ел аша (через год).

**көн ашата** *саз.я.* көн аша (через день). Көн ашата суғарғалы хәрәх.

**АШАУ I** *минз., глз.* аш, ашарга (еда; есть); чаг.: **ашамак**. Қырга ашау пешереп илттем урақчыларға. Балаларға ашау пешерәм мәктәптә. Эткә ашау бирергә кирәк. – *минз.* Эстәлгә ашау – пирипич, бутка китерәләр, гөлаш йералма белән, ит белән чабып инде. – *глз.*

**ағ ашау** *нокр.* ак оннан пешерелгән камыр ашлары (мучные изделия). Чепчеги, қабарчы, қоймак – ағ ашау инде туй эстәлдә.

**ашау йасау** *глз.* ашарга пешерү (готовить еду, суп, обед). Ашау йасамага айтканмы икән? Ашаумы йасайсин?

**ашаудан қалдырыну** *перм.* ашау-эчүдән калу, ашаудан язу (перестать есть-пить, потерять аппетит). Ашаудан қалдырынам инде, айақны соноп үләргә генә қала.

**сагынып ашау** *т.я.-крш.* үлгән кешене искә алып ашау (поминки). Өч көненә кимак пешереп сагынып ашилар, үлгән мәндәләргә туклык булсын, диләр.

**тартып ашау** *лмб.* чөмереп, тавыш чыгарып ашау (есть с шумом). Салма ызын булгач, тартып ашарга туры килә, йерәк майым, ызын итмә.

**шөпөреп ашау** *к.т.* к.: **тартып ашау**. Сарпатсыз, шөпөреп ашыйсың.

**АШАУ II** *эчк.* эчү (пить). Ул күлнең сыwын ашарға йарамый.

**АШАУ III** *перм.* артык (более); чаг.: **аша 3**. Ситнырдан ашау ийе аның дуңғызы. Җөздән ашаудыр әле.

**АШАУЛЫ** *мам.* ашамчак (любящий поесть). Ашаулы түгел ул Кәшиф. Мин бик ашаулыйым.

**АШАУЛЫҚ** *бәр., каз.ар., минз., кмшл., т.кам.-крш.*, **АШАУЛЫК** *чст.* ашъяулык (скатерть). Өстәлгә ашаулыкны җәйегез. – *бәр.* Ашаулыкны җәй, бүлмә өстеннән ал да. – *каз.ар.-крш.* Бистәрләрне элгәләб бетергәч, ашаулык алалар; тоталар да ашаулыкның ике йағыннан, өстәлегез қыйық, диләр. – *т.кам.-крш.* Чәй эчеб бетергәч, ашаулыкны пычмакка кертеп куй. – *чст.*

**бүлмә ашаулыгы** *чст.* өйдә стенага элү өчен чигеп ясалган җәймә (скатерть, вышитая для развешивания на стену). Бүлмә ашаулыгы дип аны да цигеп эләләр ийе.

**йул ашаулық** *нокр.* кечкенә ашъяулык (маленькая скатерть). Йул ашаулықлар илткәләде киленнәр икмиклир түнәп илтмәгә. Киже белән шақмақлап суққанда була йул ашаулық.

**салфиткә ашаулык** *чст.* әйбер төрү өчен әзерләнгән ашъяулык (скатерть, изготовленная для завёртывания вещей). Бawырсакны зур салфиткә ашаулыкка төрәләр.

**АШ-АШЧЫ** *әстр.* 1. аш пешерүче (повар); 2. туй өстәле өчен җаваплы кеше (повар; главный, ответственный человек за свадебный стол). Аш-ашчы аш әзерли, аш-суны барлый, сыйлық төзи. Аш-ашчы ашны пешерәде, пылауны пешерәде, чәйне қайнатып торады. Ащ-ашчы бөтен мәҗлесне қулда тота.

**АШҖӘЙМӘ** *мәл., кузн.* к.: **ашаулық**. Ызба кийендерегә чүпләп суккан селгеләр, кендә йертергә ике ашҗәймә китергән. Артызбага йәйә ашҗәймәләр, халк күрә. – *мәл.* Бу ашҗәймә киленемнеке. – *кузн.*

**АШИ** *глз.* к.: **бүлмәч 2**. Ашидә көтүчегә аш пешә.

**АШИК I** [*гар.*] *лмб., тмн., срг.* к.: **айшык**. Уг аттым, уйга теште, Ул уйдан кышлар ычты; Теләмәсәң дә аламын, Ашигым сиңа теште (*хал. җыр.*). – *лмб.*

**ашик булу** [*гар.* + булу] *тмн., хвл.* 1. к.: **айшыклану 1**; 2. к.: **адалану 2**. Ашик булган килергә монда, монда килеп үлергә. – *тмн.*

**ашик тоту** *тмн.* к.: **айшыклану 1**. Ашик тоткан туташларнын Йөзләре сары була; Алла үзе йардәм бирсен Ашик тотучыларга (*хал. җыр.*).

**АШИК II** *стрл.* к.: **ашық II, 1**.

**АШИКЛЫК** [*гар.* + *афф.*-лык] *срг.* к.: **айшык**. Ашиклыкка ашик әй димәгез, Ашиклыкка күңел бирмәгез; Ашиклыкка күңел әй бирсәгез, Ак йөзем саргайа димәгез (*хал. җыр.*).

**АШЙАБУ** *перм.* к.: **ашаулық**.

**АШЙАҚ** *нокр.* к.: **бүлмәч 2**. Бийем белән сүләшә, бабам кышылар белән сүләшмәде, ашйақта ашады киленнәр.

**АШЙАПМА** *нрл.* к.: **ашаулық**. Ашйапма җәйеп ашарға утырдылар.

**АШЙАУЛЫҚ** *перм.* савыт-саба, ипи өстенә яба торган җәймә (салфетка, которой покрывают посуду и продукты).

**табын ашйаулыгы** *минз.* к.: **ашаулық**. Табын ашйаулыгын сәкегә җәйеп, сәкедә ашыйдырыйык.

**түр ашйаулыгы** *минз.* к.: **ашаулық: бүлмә ашаулыгы**. Түр ашйаулыгын чигеп әзерлидерийек. Өйне бизиләр, түр ашйаулыгы әләләр матурлап.

**АШЙӘЙМӘ** *мәл., чст.* к.: **ашаулық**.

**АШҚАҚ 1.** *минз.* к.: **ашық II, 1; 2.** *эчк.* к.: **чәлтер: чәлтер севәге; 3.** *брб.д.* үкчә (пятка).

**ашқақ тарамыч** *брб.д.* үкчә сеңере (жила пятки).

**АШҚАЛАҚ** *к.-уф.* аш кашыгы (ложка для супа). Ашқалақлар ағастан булды.

**АШҚАРА** [*фарс.*] *тбл.* ачык, таныш, билгеле (ясный, знакомый, известный).

**АШҚАРАЛАУ** [*фарс.* + *афф.* -лау] *тбл.* ачылу, күренү (открываться, показаться).

**АШКӘБӘН** *к.-уф.* ашлык кибәне (стог хлеба). Ашкәбән қуйарға өмә булды.

**АШҚЫНУ** *перм.* **1.** бик күп булу, уңу (быть много, уродиться – о плодах). Ашқынған быйыл өмөҗе; **2.** бик шәп, бик яхшы (очень хороший, чересчур хороший). Тағы җорт бетерделәр, ашқынган җортлары; **3.** к.: **адалану 4.** Безнең Ғарифулла мәктәптә бик ашқына дип сөйлилләр; **4.** әллә кем булу, тәкәбберләнү (возгордиться, зазнаться); чаг.: **белтәйү**. Бер тишеккә ике башны тыкты да ашқынды ул қәзер (үзе бригадир, сеңлесе счетовод булган кеше турында әйтә).

**АШКЫНУ** *срг.* ярракка һәм сабакка үсү (сильно развиться в стеблях); чаг.: **азу 2.** Картубың ашкынган, Фатима алма, ницек күмерсең? Картуп саламы ашкына, керерлек тегел.

**АШЛАУ I 1.** *кргл., туб.-ирт.д., брб.д.* җилпуч (лоток для муки, для просеивания зерна). Тактадан йасаган мөйөшле ашлау була. – *кргл.* Солоны киле мән төйөп, кибәген қойаты, ашлаута кибәген оцораты. – *брб.д.* Ашлаута он тиде, пер қулыңны онға тык, пер қулыңны майға тык. Он ошлайым ашлаутан, онны пулсын қулларым. – *тбл.*; **2.** *минз., стрл.* зур агач табак (большая деревянная чаша). Ашлауны уртага утыртасың да кашык белән кем өлгөрөшкә ашыйсың. – *стрл.*; **3.** *эчк., эстр.* к.: **тигәнә 1**. Ашлау кирәк кер йугалы. – *эчк.*; Әссәләмәгаләйкем дигәндә, ашлау җамап җатырмын. – *эстр.*

**кер ашлау** *төм.* к.: **тигәнә 1.**

**тәрәс ашлау** *туб.-ирт.д.* тәрәзә капкачы (оконные ставни).

**АШЛАУ II** *глз.* пешерергә куйган ашка токмач, макарон, умач һ.б. салу (положить в суп лапшу, макароны, клёцки и т.п.). Ашны ашладым әле генә.

**ашлау йылга** *туб.-ирт.д.* тиз күтәрелеп, тиз ташып китә торган елга (река, которая быстро выходит из берегов).

**җеп ашлау** *минз.* эрләнгән җепләрне онлы суга салып кайнату (кипятить пряжу в мучной воде).

**АШЛАУ III** *себ.* такталарны бер-беренә китереп кадаклау (сколачивать доски в закрой).

**АШЛЫ** *мам., нгб.-крш.* юынтык (помойный). Ашлы су чиләгенә сал сувыңны. – *мам.*

**АШЛЫҚ** *себ.* арпа (ячмень). Ашлық монта үсмәйте, көйөп қуйаты. – *брб.д.*

**ашлық бастыру** *нгб.-крш.* к.: **чүпләшү**. Ашлыкны қул белән бастырдық әлек.

**ашлық қысуы** *туб.-ирт.д.* ашлык үсеп чыгу (прорастание зерновых). Қәсер ашлық қысқынчы йаңгыр керек бейт. – *тбл.*

**ашлық он** *себ.* арпа оны (мука из ячменя). Питай оннан, ашлық оннан да була нан.

**ашлық печин** *перм.* к.: **чәчәк I: арыш чәчәге**.

**җыл ашлық** *к.-уф.* к.: **җазлы'лар**. Җыл ашлық уңды быйыл. – *к.-уф.*

**йылы ашлық** *перм.* к.: **җазлы'лар**. Сабан туйы йыл(ы) ашлық чәчмәс борон булайе элек. Быйыл чәчәбез, быйыл урабыз, шуның өчен йыл(ы) ашлық тибез. – *перм.*

**кор ашлык** *глз.* иген, ашлык (хлеба, зерно). Кор ашлык та йакшы булсын, корбан чалгаладык.

**очлы күз ашлық** *себ.* к.: **ашлық**. Ашлықны төйнәйсең, очлы күз ашлықны, питай түгел, арыш түгел. Аны икмәген пешерәтләр, тирсәкне аның белән имнәйтеләр. – *тара.*

**АШМАНЦЫ** *эчк.*, **АШМАЦЫ** *туб.-ирт.д.* к.: **казанчы**. Ашманцы булып йөрәйме инәйең туйларда? – *эчк.* Ашмацы бармак йаласа да туйар. – *тбл.*

**АШСОСҚАҚ** *том.д.* к.: **бағырча**. Ашсосқак белән ашны соса. – *клм.*

**АШТАБАҚ** *нокр.* зур табак (большое блюдце для супа). Туйда алдан чәй эчәләр ашамалар белән. Ағач аштабақта аш, аш артыннан бәлеш.

**АШТАҚА** [*фарс.*] *брб.д.* аждаһа (дракон).

**АШУ I** *нокр., глз.* к.: **ашама**. Менә бит кискән ашулар бар. – *глз.*

**АШУ II** *к.-уф., эстр., себ.* артык (больше, выше); чаг.: **ары 5**. Йөздән ашу кеше килгән. – *к.-уф.* Бу awылға ике йөз ашу бар. – *эстр.* Пайтақ кеше йыйылған, йөстән ашу пулыр. – *төм.*

**ашып чыгу** *хвл.* к.: **артылу**. Су бучкадан ашып чыкты.

**хәттән ашқан** *т.я., перм.* артып киткән, чиктән ашкан (чрезмерный, перешедший всякие границы).

**АШЫҒЫНУ** *тбл.* шаяру (шутить).

**АШЫЙБАРСА** *бөре.* к.: **аша II: аша барса**. Ашыйбарса, бу эш бер көннек.

**АШЫҚ I** [*гар.*] *тбл.* гашыйк (влюблённый).

**ашығы төшү** *тбл.* гашыйк булу (влюбиться).

**АШЫҚ II 1.** *минз.*, кул һәм аяк бармакларындагы буын сөякләре, кузналар (козоны, суставные кости пальцев рук и ног). Ашығы тайған. – *минз.* Ашықлар бар бармак сайын. – *тпк.*; **2.** *туб.-ирт.д.* тубык (щиколотка); **3.** *туб.-ирт.д.* ашык (кости для игры).

**ашық буйақ** *эстр.* үлән исеме, дару үләне (лекарственная трава). Ашық буйақ, менә шуны йувып сәрен җирдә киптерәм, шуны эчәм йүткергәнгә. Йаңгыр йаугач чыға ашық буйақ, тамыры да йуқ.

**АШЫҚ 1.** *стрл.* к.: **ашық II, 1; 2.** *карс., мәл., срг., стрл., лмб., хвл.* к.: **ашық II, 3**. Беткелгесе бер урында тыралар иске зийарәттә, берсеннән йез

ашык чыкты. – *мәл.* Ашык белән бишташ ун'и идек. – *карс.*

**ашык севәге** *хвл., лмб.*, **ашык сөйәге, шайтан ашыгы** *стрл.*, **шайтан ашыгы** *бөре., трбс., минз., злт.* к.: **ашық II, 2.** Ашык севәгемне бәрдем. – *лмб.*

**АШЫҚСЫРАУ** *себ.* гашыйк булу (влюбиться).

**АШЫҚЦАН** *себ.* ашыгучан, ашыгыч (торопливый, поспешный).

**АШЫМАЛ** *әстр.* әчегән сөткә яки катыкка салып пешерелгән дөге (рис, сваренный в кислом молоке, катыке). Ашымал айран белән пешергән дөге була, азаматлар ашый.

**АШЫРУ** *брб.д.* узып китү (обогнать).

**АШЫРША** *төм.* кабартма (пончики).

**АШЫРЫЛУ** *мам.* рәтләнү, тазару – авыру турында (поправиться, выздороветь после болезни); чаг.: **йан: йан тарту 2.** Бозаулары аурый дигән ийе, инде хәзер ашырылган.

**АШЫТ, АШЫТПАШ** *туб.-ирт.д.* басма (мостик, мостки, помост).

## Ә

**ӘБ** [*фарс.*]: **әб орган итү** *к.т.* бик тиз ашап бетерү (очень быстро, моментально съесть еду). Әб орган иттеләр ашны, ачыккан булганнар икән.

**ӘБӘ I** *мәл.* к.: **маман 1.** Әбә малайым бар, башы эшләп бетерми, үзенә алып эш эшли белми; **2.** *дөб.* телсез (немой). Әбә ул, әбә, телсез.

**ӘБӘ II** *себ.* апа (старшая сестра). Кейәүнеңке әбәсе сөт қаптыра кинцәккә дә, кейәүгә дә. – *төм.*

**әбә телле** *дөб.* усал телле, сүзчән (языкастый, острый на язык). Бик әбә телле килене, бер дә жawап таба торған түгел.

**ӘБӘГӘ** *туб.-ирт.д.* апа (старшая сестра матери).

**ӘБӘГӘЛҮ-СИҢИЛЛҮ** *себ.* апалы-сеңелле (старшие и младшие сёстры). Әбәгәлү-сиңиллү йир талашыр, суғышыр-ай. – *брб.д.*

**ӘБӘЙ** *карс.* к.: **картинә(й) 1.**

**ӘБӘК** *урт.д., туб.-ирт.д.* куышып уйнаганда әйтелә торган сүз (слово, произносимое во время игры в салки).

**әбәк печин** *перм.* сукыр кычыткан (пустырник).

**ӘБӘЛӘЙ** *крғл.* йоннан бәйләнгән чүәк (тапочки, связанные из шерстяной нитки). И балакайым, әбәләйне саққа да кийәдер ийек.

**ӘБӘЛӘК 1.** *перм., бөре.* сүз күтәрмәүчән, тиз үпкәләүчән (обидчивый, недотрога); чаг.: **пыртық.** Бик әбәләк бала ул. – *бөре.*; **2.** *злт., минз., тпк., трбс., стрл.* к.: **чәүчәләк.** Қартаймыйым да мин, бирешмим дә, сезнең кебек әбәләк түгелмен. – *злт.* Ирләр әбәләк була бит ул қатыннарға қарағанда, әз генә чирләсә дә. – *минз.*

**ӘБӘЛӘНҮ** *каз.ар.-крш.* чуалу (путаться, запутаться). Жебең әбәләнгән.

**ә б ә т** (обед):

**әбәт чиләге** *мам., минз.* басуга, кырга су яки катык алып йөрү өчен ясалган савыт (посуда для ношения воды или кислого молока на поле). Әбәт чиләге белән су илтәдерийек қырға. Қатық салырға да әйбәт, қапқачы да була әбәт чиләгенең. – *минз.*

**көтү әбәте ашату** *нрл.* чираттан көтүче ашату (кормить пастуха по очереди). Кичә көтү әбәте ашатқан ыйым әле.

**ӘБӘТӘ: әбәтә булу** *туб.-ирт.д.* һәлак булу (погибнуть).

**ӘБӘҮ** *туб.-ирт.д.* апага эндәшкәндә әйтелә (форма обращения к тёте, сестре).

**ӘБӘШӘТЛЕ** [*рус.* обещать+*афф. -ле*] *мәл.* вәгъдәле (верный своему обещанию).

**әбәшәтле булу** *хвл.* **1.** вәгъдәле булу (сдержать своё слово); **2.** вәгъдә кую (давать обещание, обещать).

**ӘБДӘН** *мәл.* бер дә, һич тә, бөтенләй (совсем, вовсе, никогда, нисколько); чаг.: **мәңге 2.** Әбдән була торган эш түгел.

**ӘБЕГӘРЛӘНҮ** *трх.* к.: **былашу.** Терлек килсә, шулар белән әбегәрләнәм, шулар белән қыйт булам.

**ӘБЕЗӘНКӘ** *перм.* к.: **тумачи 3.**

**ӘБЕКУЙ** *нокр.* әбигә иркәләп эндәшү сүзе (ласковое обращение к бабушке). Әбекуй, сине йаз итеп жыру йазам.

**ӘБЕЛ-ҚАБЫЛ** *дөб.* к.: **әпен-талау.** Әбел-қабыл килеп чығып китте.

**ӘБЕН** *к.-уф., себ.* әвен (овин). Әбенгә китәләр ийе жыйылып қызлар-йегетләр, уйын уйнаған булалар мәсә қынып. – *к.-уф.* Йетенне әбенгә киптерегә қуйабыс, мунца шикелле эселе. – *төм.*

**ӘБЕНДЕ** *лш.* вак-төяк куаклар (мелкие кусты, редкий кустарник); чаг.: **бүләк II; киләклек.** Жиләк әбенде булған жирдә була ул.

**ӘБЕРКӘ** [*рус.* оборка] *минз.* к.: **балан II: балан итәк.**

**ӘБЕР-ЧЕБЕР** *мам.* вак-төяк, ыбыр-чыбыр – бала-чага турында (маленький, мелюзга – о детях). Бала-чаға да әбер-чебер.

**ӘБЕС** *срг.* к.: **тәтә 2.** Безнең әбес тә бар.

**ӘБЕСТӘТӘЙ** *баст.* каенсеңелгә эндәшү сүзе (форма обращения к золовке).

**ӘБЕСТӘТӘ'** *кас.* к.: **абыстай 1.**

**ӘБЕСТҮТИЙ** *кас.* к.: **абзәни 3.**

**ӘБЕСЧИЧИ'** *кас.* әнинең әнисе ягыннан кыз туганнарына эндәшү сүзе (форма обращения к сёстрам бабушки по матери).

**ӘБЕТӘ** *туб.-ирт.д.* апа (тётя).

**ӘБЕТИ 1.** *чпр., трх., чст.* к.: **абыстай 2.** Санийә әбети суга китте. – *чпр.*; **2.** *чст., срг.* к.: **абыстай 1.** Әллә безнең әбети мында йукмы? – *чст.*

**ӘБЗӘ(Й)** *чпр., мәл., чст., хвл.* к.: **аба(й) 1.** Әбзәй, качан үгә кат'абыз? Әбзәй тырахтырда эшли эц йыл инде. Мының әбзәсе белә әкийәт. – *чст.* Безнең әбзәй дә Әндижанда. Әбзәй зурларны укытты, запхуз. – *мәл.*

**ӘБЗӘНИ** *к.т.* **1.** к.: **абзәби.** Хәбибҗамал абытый әби булып жөрдө, шуңа awылдағы бөтен жәшрәкләр әбзәни диләр; **2.** к.: **абзәни 2.**

**ӘБЗӘНКИЙ** *к.т.* к.: **абзәни 2.**

**ӘБЗӘТКИЙ** *к.т.* элек киленнең каенатасына эндәшү сүзе (старинная форма обращения невестки к свёкру).

**ӘБЗӘНКӘ 1.** *к.т.* к.: **абзәни 3**; **2.** *к.т., дөб.* к.: **абызәби 2.**

**ӘБЗИ** *чст., кас.* к.: **аба(й) 1.** Әбзи булгач йеткән инде. Мынчаны әбзиләргә йактыңмы? – *чст.*

**ӘБИ I 1.** *злт., минз., стрл., байк.* әтисе яки әнисенең олы кыз туганы һәм аңа эндәшү формасы (старшая сестра отца или матери и форма обращения к ней); **2.** *злт., тпк., стрл.* әтисе яки әнисеннән олы хатын-кызга эндәшү формасы (форма обращения к женщине, которая старше отца или матери говорящего); **3.** *перм.* олы яшьтәге ирнең үз хатынына эндәшү сүзе (форма обращения мужчины старшего возраста к своей жене); **4.** *бөре., каз.ар., кмшл.* киявү кешенең хатынының әнисенә эндәшү формасы (форма обращения жениха к матери жены); **5.** *кргл.* хатын, карчык (жена, старушка). Тәүге әбийем үлде дә, бер сигез-туғыз йыл гына әле өйләнгәнемә. Шул бабайны әбисе мунча ғына кертми, шунысы йәбер.

**awыл әбийе** *дөб.* к.: **кендекәй.** Awыл әбийе йуг инде хәзер, бүлнискә баралар қатыннар.

**awыру әбиләре** *глз.* авыру хуҗасы – мифологик персонаж (мифологический персонаж – хозяйка, дух болезни). Awыру әбиләре үпкәләмәсен дип өшкергәләделәр.

**азбар әби** *нокр.* йорт анасы (домовая). Хайwанларға бәйләнә азбар әби, аптырата, мучит итә. Тәкәнең мөгезен салалар азбар әбийенә.

**ай әби** *глз.* к.: **аби: ай аби.** Ай әбиләр дип әйтәбез имнәләгәндә.

**ақ әби** *т.кам.-крш.* к.: **әби 1.** Ақ әбине қунаққа дәштем, сезгә җырлар әле ул элекке җырларны. Ақ әби күчтинәч бирең җибәрде безгә.

**алыс әби** *чпр.* к.: **җырағәби.** Алыс әбийең кайда?

**әбиләр көне** *хвл.* к.: **чуwақ: қортқалар чуwағы.**

**әнеки әби** *крш.* туйда «икенче әни» итеп куелган хатын-кызга киленнең балалары шулай эндәшә (обращение детей к посажёной матери своей мамы). Әнеки әбийем әле дә мине қызым дип әйтә.

**бала түрәтүче әби** *кузн.* к.: **кендекәй.** Бала түрәтүче бер әби була, элек бит бал'ничалар булмаган, әбине бала түрәтергә йәшәләр.

**бәбәй әбисе** *чпр., чст.* к.: **кендекәй.** Бәбәй әбисе була үдә ылан тапса, awылда бер-ике генә кеше иде бәбәй әбисе. – *чпр.* Бик күп кешегә бәбәй әбисе булган үземнең әни, атаулы бәбәй әбисе булган. Бәбәй әбийенә атап дога кылалар, хайер биргәндә дә искә алалар. – *чст.*

**белүче әби** *глз.* им-томчы, өшкерүче (знахарь). Белүче әбиләр булгалады, өшкергәләделәр.

**гүлмич әби** *глз.* өй иясе (домовой). Гүлмичкә кертеп саласы гүлмич әбине.

**җәш әби** *т.я., каз.ар.-крш.* **1.** к.: **абзәни 3**; **2.** әтисе яки әнисенең җиңгәсенә эндәшү сүзе (форма обращения к жене старшего брата отца или матери); чаг.: **абызәби.**

**җите әби** *к.-уф.* корбан суйгач хәер биреләсе әбиләр, аларның саны җидедән ким булмаска тиеш (бабушки, которым раздают подаяние после жертвоприношения; обычно их должно быть не менее семи). Қорбанның күтәргәндә җите әбигә хәйер таратабыз.

**җырақ әби** *крш., бөре., минз.* к.: **җырағәби.**

**зур әби** *минз., стрл.* әтисе яки әнисенең апасына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре отца или матери).

**имче әби** *к.-уф.* к.: **белүче әби.** Минем қулым түгел, Ағыйделдән ағып килгән имче әбинең қулы.

**инәкә әби** *әстр.* к.: **кендекәй.** Инәкә әби булды awылда, электә мамайлар арасында белгән кешеләр булған, алар йөргән бала туwайақ җирдә.

**йәш әби 1.** *байк., т.я.* к.: **абзәни 3**; **2.** *тмн.* бабасының әнесенең хатыны (жена младшего брата дедушки).

**йорт әби** *глз.* к.: **азбар әби.** Йорт әбине китермә кушалар йаңы өйгә. Йаңы йортка баручылар пумала белән алып баралар йорт әбине.

**йырағ әби** *бгрс.* к.: **җырағәби.**

**қараучы әби** *әстр.*, **караучы әби** *глз.* к.: **белүче әби.** Қараучы әбиләр булды, алар им-том итте. – *әстр.* Караучы әбигә баргаладык олан аураса. – *глз.*

**кентекче әби** *тбл.* к.: **кендекәй.** Туwар wахыт йитсә, кентекче әбине чақыралар.

**кор әби** *глз.* кыр анасы – мифологик персонаж (хозяйка полей – мифологический персонаж). Кор әби йулдан адаштыра.

**қот қойусы әби** *к.-уф.* куркып авырган кешене имләүче әби (бабушка-знахарка, лечащая от испуга). Қотым, кил, қотым, кил, дип сақыра қот қойусы әби.

**кызамык әби** *глз.* к.: **ана: кызамык анасы.**

**мича әби** *глз.* мунча хуҗасы – мифологик персонаж (домовой, который, по представлениям, живёт в бане). Мича әби куркыта, мича ишеген ача да йаба.

**ой әбийе** *нокр.* йорт иясе (домовой). Өй әбийегезне қалдырып китегез, ди. Йә, безнең белән бармa, менә хузәйкәгез, дип әйтирсиз, ди, гул'бечкә кертеп қалдырығыз, ди.

**өшкерүче әби** *урт.д.* к.: **имче әби.** Өшкерүче әбинең қулында тайағы бар ыйы. Шул тайағы белән сызып, уқып керәдер ийе өшкерүче әби. – *блт.*

**су әбийе** *нокр.* су иясе (водяная). Су әбийе суда йәши, су әбийе тарта кешене қойонма кергәч. Су әбийе тартқан, диләр суға батқач.

**таң сuwы алучы әби** *урт.д., миш.д.* к.: **белүче әби.** Таң атқан wақытта бидрә белән су алып қайтқан таң сuwы алучы әби. – *минз.*

**түти әби** *кас.* к.: **кендекәй.** Түти әбине ча'ыра, ул 'арай бала ту'анда. Түти әби 'арай тор'ан бул'ан, анай җанына сала тор'ан бул'ан баланы.

**узыр әби** *перм.* әбисе яки бабасының олы кыз туганы (старшая сестра бабушки или дедушки).

**уналтучы әби** *глз.* к.: **белүче әби.** Уналтучы әбиләр булгалады.

**үз әби 1.** *мам.* үзләре белән бергә торган әнисе яки әтисенең әнисе (мать матери или отца, которая живёт вместе с детьми). Үз әбисенә дә, миңа да бүләк итте қызымның улы. Йаннарында тор-

ғач, үз әбисе диләр атасының әнисен; **2.** *чст.* әтисенең әнисе (бабушка со стороны отца, мать отца).

**чәчәк әбисе** *глз.* к.: **ана: чәчәк анасы**. Чәчәк әбисе үпкәләшкән, күзенә ак төшкән.

**шарпу ташлаучы әби** *әстр.* к.: **белүче әби**. Шарпу ташлаучы әби бер кешегә бер зат та сүләмичә өйөнә қайта.

**ӘБИ II** *м.-кар.* к.: **ногый**.

**әби уйын** *м.-кар.* таш уены (детская игра в камушки).

**әби серкәсе 1.** *минз., кргл.* к.: **чәчәк I: җитен чәчәк**; **2.** к.: **печин I: ақча печин 1**.

**әби чәче** *минз., эчк.* к.: **җибәләй**.

**ӘБИ-БАБАЙ: әби-бабай борчагы** *мәл.* к.: **бырцак: бырцак үләне**.

**ӘБИ-ХӨБИ** *перм.* әбиләр, карчык-корчык (бабушки, старушки). Әби-хөбиләрне дә азырақ печин җийарға чақырың.

**ӘБКАЙ** *карс.* к.: **әби 1**.

**ӘБРӘКМӘН** *туб.-ирт.д.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы**.

**ӘБТӘЙ** *чст., мәл.* к.: **абыстай 1**. Берише халык элгәректән әбтәй ди шул алмакай дигәнгә. – *чст.* Әле әбтәйгә дә сүлим. – *мәл.*

**ӘWАРА** [*фарс.*]: **әwара булу** *кргл.* ияръ (следовать за кем-то, подражать кому-либо). Иптәшләренә әwара булып эчмәсен, инәй, замичайт ит, ди.

**ӘWӘ I** *брб.д.* hава (воздух).

**ӘWӘ II, ӘWӘY** *саз.я.* эти-әнисенең сеңелләренә эндәшү формасы (форма обращения к младшим сёстрам родителей).

**ӘWӘЛТЕННӘН** [*гар.*+ *афф.*-теннән] *каз.ар.*, **ӘWӘРТЕННӘН** *минз.* элек-электән (издавна, издревле, с давних пор). Бу инде әwәлтеннән қалған сүз. – *мам.* Без аны әwәртеннән үк җир тараqаны дип йөртәбез. – *минз.*

**ӘWӘРӘ** *туб.-ирт.д.* мохтаҗлыкта, кайгыда булучы (находящийся в нужде, в горе).

**ӘWӘРӘ: әwәрә булып йөрү** *әстр.* маташып йөрү (возиться, копошиться). Моңа әйтәләр: «Мамам, син быйыл варинйә қайнатам дип әwәрә булып йөрмә, үзебез қайнатырбыз», – ди.

**ӘWӘРӘМӘЧ: әwәрәмәч килү** *минз.* к.: **чәркемә: чәркемә килү**. Алар әwәрәмәч килеп беткәннәр.

**ӘWӘС** *брб.д.* куян тоту коралы (древнее орудие для ловли зайцев).

**ӘWЕН** [*рус.* овин] *эчк.* к.: **бақча**. Кәзә әwенгә керде.

**әwен бабай** *кас.* к.: **рәшмән**.

**әwен башлы** *кузн.* тузгак башлы хатын-кызга карата әйтелә (говорится о лохматой женщине).

**әwен ипийе** *баст.* көз көне игеннәр өлгергәч пешереп хәергә бирелә торган ипи (хлеб, который пекут для подаяния осенью). Әwен ипийе пешереп кертә күршегә.

**әwен йақ** *эчк.* каралтылар арты, бәрәңге бакчасы ягы (задворье); чаг.: **артбақча**.

**әwен 'а'ма'а** *кас.* к.: **чүпләшү**.

**әwенне җил қағу** *нгб.-крш.* суыктан бик нык туңу мәгънәсендә (сильно мёрзнуть).

**әwен өй** *глз.* ашлык киптерү өе (дом для сушки снопов). Әwен өйдә әwен пичне йагып көлтө киптердек.

**әwен суғу** *дөб.* к.: **чүпләшү**. Әwен суғудайым бүген.

**ӘWЕРСЕНУ** *минз., стрл.* к.: **алгасу**. Қайтырға әwерсенеп торғач шулай инде. – *минз.*

**ӘWЕСЛЕК, ӘWЕСНЕК 1.** *трх., дөб., стрл.* к.: **бастырма**. Печәнне әwеслек йасый да өйөп қуйа шунда, ишеп төшерә дә ашата бирә. – *минз.*; **2.** *каз.ар.* өсте ябык ындыр табагы (закрытый ток, ток с навесом). Әwеснектә ашлық суқтыра. – *блт.*

**әwеслек асты** *трх.* к.: **пайыт 1**. Қазлар қызуда әwеслек астында торалар.

**тез әwеслек** *чст.* к.: **пайыт: лапас пайыт**.

**туры әwеслек 1.** *трх.* к.: **турамселек**. Қаралды жәнына туры әwеслек йасыйбыз ачықлыққа, шуның өстенә печән үwәбез; **2.** *чпр.* к.: **пайыт: лапас пайыт**.

**ӘWЕТУ** *себ.* к.: **бәwетү**. Парцы, кецегәң сықтайты, кецкенә әwетеп тор. – *брб.д.* Сәлтепне әwетеп утырғалы та йарамаймын. – *тбл.*

**ӘWИ** *әстр.* сюжетлы жыр (песня с сюжетом). Сөннәт туйда әwи әйтәделәр кимперләр.

**ӘВИ-ШӘВИ** *кас.* к.: **әбер-чебер**. Әви-шәви halы'.

**ӘWКӘ, ӘWКӘМ** *саз.я.* сыерларга иркәләп эндәшү формасы (форма ласкового обращения к коровам).

**ӘWУР** *туб.-ирт.д.* халык төркеме, көтү, күплек (толпа, стадо, множество). Йулда бир әwур қысларға учураған.

**ӘWУРЛӘУ** *туб.-ирт.д.* олылау, ихтирам итү (почитать).

**ӘWУС** *туб.-ирт.д.* авыз (рот).

**берәр әwүс сүз** *твр.* берничә сүз (несколько слов). Берәр әwүс сүзүм бар, аны айтып бирәйин.

**ӘГӘЛӘ** *хвл.* к.: **агале**.

**ӘГӘРДЕМ ДӘ, ӘГӘРЧӘН ДӘ** *мәл.* әгәр дә (если).

**ӘГИС** *брб.д.* игез, игезәк (близнецы, двойня).

**ӘДАВА** *клд.* к.: **ад'ава**. Элгәре әдава йабына иделәр. Урындыкка шыл әдаваны йawып куйалар.

**әдәм** (человек):

**әдәм сынсыз** *дөб.* гадәттән тыш (чрезмерно, чересчур); чаг.: **қотсыз**. Әдәм сынсыз жуwан. Әдәм сынсыз усал. Әдәм сынсыз бақчалары.

**әдәм тәгәнәсе** *минз.* адәм көлкесе (позор, посмешище). Учақларға көл тулған, ий әдәм тәгәнәсе, бернәрсәнең рәте қалмаған.

**ӘДЗӘЛ** *брб.д.* әҗәл (смертный час, смерть, кончина).

**ӘДЗЕНУ** *брб.д.* ачыну, кайгырту (печалиться, заботиться, сердиться).

**ӘДЗИГЛӘНУ** *брб.д.* ачулану (сердиться).

**ӘДЗИРГЕ** *брб.д.* матурлык өчен ияр киезе өстенә жәелә торган көрпә (подстилка под седло поверх потника, служащая для украшения).

**ӘДИЛ** *туб.-ирт.д.* Идел (река Волга).

**ӘДИП** *брб.д., туб.-ирт.д.* әдеп (опушка, обшивка).

**әдрәс** (бухарская полушёлковая ткань):

**әдрәс гөл** *минз.* к.: **бакә II: бакә гөле.**

**әдрәс палас** *кмшл.* төрле төстәге йон җебеннән шакмаклы итеп тукылган палас (ковёр, вытканный из разноцветной шерстяной нити).

**әдрәсләп: әдрәсләп суғу** *минз.* төрле җепләр катыштырып, бизәкләп сугу (ткать разноцветными нитками). Әдрәсләп суққан палас, төрле җептән йасап.

**ӘЖАҒА** *злт.* к.: **нажағай.** Әжаға awғыс тирәләрендә была инде.

**ӘЖЕГӘЙ** *эчк.* к.: **әжекәй.** Әжегәй шәйләдем күп итеп.

**ӘЖЕКӘЙ** *к.-уф., злт.* к.: **тура I, 1.** Әремеккә сөт қойдом да әжекәй қайнаттым. Қайнатқанда шәкәр салаң, сары төс кергәс, май салаң да қуйаң. Әжекәй була, пыйалаға салаң да утыртаң. Шундый йомошақ, әйбәт була, қып-қызыл була wы, ыспай булып қайный. – *к.-уф.* Шәңгәне әжекәйдән дә пешерәбез. Әжекәй әремчектән қайнатыла, сuwы қорғансыға хәтле қайнатам. – *злт.*

**ӘЖИК** *брб.д.* ишек (дверь).

**ӘЖӘҒА** *каз.ар., перм.*, **ӘЖӘҒӘЙ** *минз.*, **ӘЖӘҒЫ** *каз.ар.* к.: **нажағай.** Әжәга уйный, арышны җиткезергә ут уйный, арышны чабақлый әжәға уты. – *перм.* Икмәк җиткерә торған әжәға ғына ул, йәшен түгел. Самай арыш җиткән wахытта әжәгы уйный. – *мам.*

**ӘЖӘЙ** *мәл.* к.: **аба(й).**

**ӘЖӘМЕ** *перм.* к.: **пестелчек 2.** Кийәү әжәмерәк булды.

**ӘЖӘТЛЕК** *перм.* әжәтханә (уборная, туалет). Әжәтлеккә барған булып йөрөң, тидем.

**ӘЖБАҒЫР** *лш.* артык үткен (слишком бойкий, проворный); чаг.: **дәллә I; ләтчә II.** Шундый әжбағыр қыз ул.

**ӘЖЕГӘН I** *чст.* к.: **нажағай.**

**ӘЖЕГӘН II** *м.-кар.* йөгән (уздечка).

**ӘЖЕКӘЙ** *перм., к.-уф., трбс.* к.: **тура I, 1.** Сифараттан чыққан сөтне қайната қазанға салып, сапсары булганчы қайната, әжекәй диләр ансын. – *трбс.*

**ӘҖЕМНӘР** *к.т.* берәр кеше турында киная белән әйтү сүзе (иносказательная форма, когда речь идёт о ком-либо). Башы тишек монда утырған әҗемнәрнең дә, күп сүләмә.

**ӘҖҖАӇЫ** *мам.* к.: **нажағай.** Әҗҗаһы уйный, арыш җитәргәдер.

**ӘҖИ** [*морд.*] *м.-кар.* к.: **нәнә I, 2.** Әҗи, урамга чыгыйм әле.

**әҗи бергенәсе** *к.т.* к.: **әзи II: әзи бергенәсе.**

**ӘЗӘЙ** *чст., хвл., чпр., мәл.* **1.** к.: **абай 1.** Кызым, әзәйең йәшә сине. – *мәл.*; **2.** үзеннән олы ир кешегә эндәшү сүзе (обращение к любому мужчине старше себя). Әптеләкәй әзәй дә кат′мады сугыштан. – *чпр.*

**ӘЗӘР I** [*фарс.*]: **әзәр телле** *бөре.* усал телле, зәһәр телле (острый на язык). Бик әзәр телле қыз ул.

**ӘЗӘР II** *карс.* к.: **азар-азар.** Әзәр ашый, часта ашый.

**ӘЗӘРЛӘҮ** *эчк.* к.: **гедәтү.**

**ӘЗӘТ** [*гар.*] *эчк.* әҗәт, бурыч (долг). Әзәт алғанда үпкә йуқ (*әйтем*).

**ӘЗӘҮ** *чст.* әз (мало). Без бит мында әзәү тегел.

**ӘЗГӘЙ** *эчк.* к.: **тура I, 1.**

**ӘDГӘРӘЙ** *тпк.* вак тәңкә (мелкая монета). Монта қәситәсе бар ийе, әdгәрәй тәңкә тегәbed шуңа. Маңқайсаға да әdгәрәй тәңкәсе тақтық.

**ӘЗГӘРИ** *т.я., чст.* к.: **әdгәрәй.** Безнең бу тауда җир суқалағанда әзгәри тәңкәләре чыға. – *нрл.* Әзгәри тәңкәләр диләр, wак тәңкәләр чыга кукшин белән. – *чст.*

**ӘЗД′АКЫ** *чпр., хвл.* к.: **аз′д′акы.**

**ӘЗЕ** *чст.-крш., каз.ар.-крш.* изге (святой). Җиде әзегә бутка пешереп келәү итәбез. Әзе зираты. – *чст.-крш.* Безнең монда әwәл қала булған, әзе дигән урын бар, изгеләр урны. Анда ғәзизләр күмелгән булған, җақшы җаннар, әзе дип шуңа әйткәннәр. – *каз.ар.-крш.*

**ӘЗЕРИК** *мәл.* к.: **безрәк.**

**ӘЗИ I** *чст.* **1.** к.: **аба(й) 1.** Кайсының әтисе ала, кайсының әзисе ала газит; **2.** туганнан туган абыйсына яки гомумән үзеннән олы кардәш ир кешегә эндәшү сүзе (форма обращения к двоюродному брату или старшему родственнику вообще); **3.** үзеннән олы чит ир кешегә аның исеменә өстәп әйтелә торган сүз (при обращении к мужчине старшего по возрасту прибавляется к его имени). Хасән әзи белә тыргандыр awылның тарихын.

**ӘЗИ II: әзи бергенәсе** *к.т.* иркә, үзенә күп игътибар таләп итүче кешегә карата әйтелә (человек, требующий к себе много внимания; капризный). Син ниндий әзи бергенәсе соң ул хәтле, бар да сиңа булырға?!

**ӘЗИ-ҖИҢГӘСЕ, ӘЗИ-ЙЕҢГӘСЕ** *чст.* абыйҗиңгәсе (брат с женой). Эченче ашта әрчи кызлары, әзи-җиңгәсе була.

**ӘЗИЛ** *әстр.* элек (раньше). Әзил қызлар махмал арқалықлар кийеп йөрделәр.

**ӘЗИЛДӘ** *әстр.* элек (раньше). Әзилдә урам буйы придан йөртү бар иде. Әзилдә туйда җыйын ағасы бар иде. Бишекнең төбе тишек булады әзилдә.

**ӘЗИЛЕ-ЙЕҢГӘЛЕ** *чст.* абыйлы-җиңгәле (брат с женой). Әзиле-йеңгәле парлап туйга килделәр.

**ӘЗКИМ** *шрл.* к.: **азмача.** Әзким бирд(е) инде.

**ӘЗЛӘҮ** *чст., мәл.* к.: **кимнәү.** Ул мине әзли. Симийәсе бик әзли дип сүләделәр. – *чст.* Шындый матур кешене дә әзләгәч инде. – *мәл.*

**ӘЗМӘWЕР: әзмәwер кебек** *т.я., лш., чст.* к.: **алапа.** Әзмәwер кебек малайы эшләми җата. Әзмәwер кебек буйларың белән ничек уйнап йөрисең? – *к.т.* Әзмәwер кебек қызы бар. – *каз.ар.-крш.* Әзмәwер кебек бу, бер эшне дә қалдырмый ындыр табағында. – *минз.*

**ӘЗРИК** *мәл.* к.: **безрәк.** Катык әче була, каймак әзрик салырга. Үзебезнеке әзрик калган иде дә, үрә төшкән инде ул (суган).

**ӘЗҮ** *брб.д.* эссе (жаркий).

**ӘЗҮЛӘҮ** *брб.д.* кайнар булу (быть горячим – о больных частях тела).

**ӘЙ 1.** *хвл.* элек килен балалары булганчы иренә шулай эндәшкән (в старину: форма обращения жены к мужу до рождения первого ребёнка). Әй, дим, кер әле үгә; **2.** *дөб., кмшл.* хатын кешенең үз

иренә эндәшү формасы (форма обращения жены к мужу).

**ӘЙӘМӘЦЕ** *төм.* мифологик персонаж (мифологический персонаж). Әйәмәце төшепте пуран көнне, лаңғыр-лоңғыр йөреп йатыр. Әйәмәце күтәреп китәр, ти тоғаннар ыйы.

**ӘЙӘРЛӘНҮ** [*гар.* + *афф.* -лән ү] *себ.* җаен, әмәлен табу (ухитриться).

**ӘЙБЕР I** *мам.* сүз (слово). Киленгә әйбер әйтмиләр алар.

**ә й б е р II** (вещь):

**әйбер җыйу** *урт.д.* сабан туена бүләк җыю (сбор подарков для сабантуя). Әрбер өйдә туқтап, әйбер җыйып йөриләр сабантуй дип. – *дөб.*

**әйбер әлү** *минз.* к.: **тезү III: ызба тезү.** Әйбер әлү диләр. Килен әйберен әлеп бетерәләр дә, ачаулығын җәйеп, балдыр, майдыр қуйалар, доға қылалар оло кешеләр.

**киҗеле әйбер** *к.-уф.* кулдан тукылган әйбер (домотканые вещи). Кейәү китергән йепләрдән киҗеле әйберләр суғып утырған ул.

**сандык әйбере** *урт.д.* кыз бирнәсе (приданое невесты). Кейәү кеше ақса түләп ала сандық әйберен. – *лш.*

**теген әйбере** *к.-уф.* кулдан эшләгән әйберләр (вещи, сшитые вручную). Теген әйберләре була сандықта.

**терлек әйбере** *к.-уф.* кызның кулдан әзерләнгән бирнәсе (приданое невесты). Хәленнән килгән кеше йәш wақытта терлек әйбере әзерли: намазлығын, тастымалын, өстәл йабуwын.

**ӘЙБЕР-СӘЙБЕР** *мам., каз.ар.-крш.* әйберләр (вещи). Әйбер-сәйберләр, қагыла күрмә берүк. – *мам.* Әйбер-сәйбер дә апқайтқаннар. – *каз.ар.-крш.*

**ӘЙГЕНӘКӘЙЕМ** *шрл.* дус хатын-кызларның бер-берсенә эндәшү сүзе (форма обращения друг к другу женщин-подружек).

**ӘЙГЕНӘМ** *минз.* дус кызларның бер-берсенә эндәшү сүзе (форма обращения подружек друг к другу).

**ӘЙДӘКЛӘҮ** *мам.* әйдәләү (звать, уговаривать). Мине дә әйдәклиләр иптәш қызларым.

**ӘЙДӘЧ** *перм.* әйләнеч (обходной, непрямой, окольный). Аннан әйдәч, моннан туры. Мин алый йөрмәс ийем, сез әйдәч йөргәнсез.

**ӘЙДЕП: әйдеп йөрү** *әстр.* төз басып, матур йөрү (ходить красиво). Әйдеп йөри торған кеше бу.

**әйдеп кеше** *әстр.* матур, зифа буйлы кеше (красивый, стройный человек). Әйдеп кешегә сәләм бирдем.

**ӘЙЕМ** *әстр.* әнием (мама моя). Әйем әйтә иде, булмаса да табып бир қуншыңа, йуқ дип әйтсәң, син йуқ булып қаласың, бар дип әйтсәң, бар булып қаласың.

**әйемнең әйесе** *әстр.* к.: **қартинә(й) 2.**

**әйемнең тәтәсе** *әстр.* әнисенең апасы (старшая сестра матери). Әйемнең тәтәсе қунаққа килде.

**бахчы әйем** *әстр.* имче карчыкка эндәшү сүзе (слово обращения к знахарке). Бахчы әйем, мине ошоқлап китте.

**дин әйем** *әстр.* дини йолаларны өйрәтүче (религиозный наставник). Дин әйемә килдем, никах мәҗлесен ничек йасыйм, ниләр пешерим дип.

**дус әйем** *әстр.* әнисенең дустына эндәшү сүзе (форма обращения к подруге матери). Дус әйем мине шулай им итте.

**зур әйем** *әстр.* абыйсының хатынына эндәшү сүзе (форма обращения к жене старшего брата). Зур әйем дип әйтәм қахамның хатынына.

**ӘЙЕТ I** [*гар.*] *себ., миш.д.* гает – дини бәйрәм (религиозный праздник). Туйны әйеткә туры китерәтләр, шулай кәпләшкәннәр. – *төм.*

**ӘЙЕТ II** *кас.* к.: **әйхәт.**

**ӘЙКӘЙЕМ** *кргл., тпк.* к.: **әйгенәкәйем.** Мә әле, әйкәйем, ал. – *тпк.*

**ӘЙКӘЛ** *том.д.* к.: **путемар.** Балага әчтән әйкәл кигезә, аның эчендә доғалық була, аны арқылыға кийәләр.

**ӘЙКӘР** *туб.-урт.д.* көбә күлмәк, кабырчык (панцирь).

**ӘЙКҮЛ** *том.д.* к.: **путемар.** Әйкүлгә wақ қына энҗе тезгән. Әйкүл эченә доғалар салып қуйған әбиләр.

**ә й л ә н ә** (окружность):

**әйләнәсе тулу** *глз.* бала тудырырга вакыт җитү (быть на последней стадии беременности). Киленнең әйләнәсе тулганда, өйдә генә утыра.

**түшәк әйләнә** *глз.* түшәк тышы (наволочка). Түшәк әйләнәсе булгалады козның.

**урын әйләнә** *глз.* урын-җир әйберләре (постельные принадлежности). Козныкы урын әйләнәләрен бирепе йибәрәсе була.

**ӘЙЛӘНӘ-ҖҮН** *дөб.* к.: **зәмәт.** Круглый әйләнә-җүнемне үзем қақтым, үзем рәтләдем.

**ӘЙЛӘНДЕРМӘ I** *минз.* к.: **каршага.** Өй әйләндермәләре қора. Әйләндермә җуғыйы бит ул, мин аны мөржә йәмсез булғанға ғына қуйдым.

**ӘЙЛӘНДЕРМӘ II** *стрл.* к.: **беләзек II.**

**ӘЙЛӘНМӘ I** *м.-кар.* к.: **қазан.**

**ӘЙЛӘНМӘ II: табын әйләнмәсе** *к.т.* к.: **алсузма.** Табын әйләнмәләрен киленнәр әлек суғып китерделәр, шақмақлап суққаннары булды.

**ӘЙЛӘН-ТУЛҒАН: әйлән-тулған килеп** *минз.* әйләнеп-тулганып (заметавшись, суетясь). Әйләнтулған килеп көчкә-начылый машинаға менеп утырдық.

**ӘЙЛӘШТЕРҮ** *тмн.* килештерү, җайлаштыру, туры китерү (согласовать; подобрать нужные слова). Үзең әйләштереп йаз шында.

**ӘЙЛӘҮ** *лш.* куу (гнать). Көтүне ул әйләй, ул көтү әйләгәндә, мин чәй қайнатам.

**ӘЙЛЕ** *әстр.* бозым (порча). Әйле йасап китепсең ди маға.

**әйле чишү** *әстр.* бозомны бетерү (снять порчу). Әйле йасап суға ташласа, аны чишә алмый, ди, муллалар. Болай әйлене чишәләр.

**ӘЙМӘ'** *кас.* **1.** к.: **аймак 1.** А' әймә', 'ара әймә'. А' әймә''ә ин бай салалар – Җаубаш, Шырин, Бийем-Сала, Татарбай, 'олчо', Барамы' 'ир'ин; **2.** к.: **курмыйш.** Ышкул безнең әймә'ти.

**ӘЙНӘ** *сазл.* әтисенең туганнан туган абыйсының хатыны (жена двоюродных братьев отца).

**ӘЙНӘК** *туб.-урт.д.* **1.** к.: **айнәк; 2.** тәрәзә (окно).

**әйнәк қату** *туб.-урт.д.* күзлек кию (надеть очки).

**ӘЙНӘКӘ 1.** *туб.-ирт.д.* җиңги, әти-әнисенең абыйсының хатыны (жена дяди – старшего брата отца или матери); **2.** *саз.я.* к.: **әйнә**.

**ӘЙНӘНӘ** *кас.* каенана (свекровь). Әйнәнә башына җимеш сиби 'илен'и.

**ӘЙНҮ: күзегез әйнегән, ӘЙНЕПТЕ: күзегез әйнепте** *әстр.* кеше ерак юлдан кайткач, аның гаиләсенә әйтелә торган сүз (слово, которое произносят, поздравляя семью, у которой кто-то возвратился из дальней дороги). «Күзегез әйнепте», – диде. «Күзегез әйнегән», – диде, кем кереп бара менә ишектән. «Аллаға шөкер, малайыгыз әрмийәдән кайтқан, күзегез әйнегән». Күзегез әйнегән, диде, баласы йырақ йулдан йә тотқыннан қайтса.

**ӘЙРӘН** *перм., лш.* катык (квашеное молоко, катык). Әйрән сүwы ғына йасап эчтем. – *лш.*

**әйрән май** *к.-уф.* к.: **май I: ас'лан май.** Сауган сөтнең қаймағыннан әйрән май төште.

**әйрән сапсақ** *к.-уф.* гөбе (кадушка для ручной маслобойки). Элмә ағастан була әйрән сапсақ. Әйрән сапсаққа салып туқыдық сөтнең өстен алып, әйрән май төшә.

**әйрән сыу** *к.-уф.* май әйрәне (пахта). Әйрән майдан қалған сыуны әйрән сыу дип әстеләр әпәйләп, қаймақ әйрән дип.

**әйрән чиләге** *т.я.-крш.* к.: **батман.**

**қаймақ әйрән** *к.-уф.* к.: **әйрән сыу.** Әйрән майдан қалған сыуны қаймақ әйрән дип әйтәбез. Әпәйләп ашыйбыз.

**май суққан әйрән** *нокр.* к.: **әйрән сыу.** Майашта бәбәй анасына май суққан әйрән эчертәләр.

**ӘЙРЕ** *брб.д.* елга (река). Әйретә йонышып китте.

**ӘЙТӘ** *к.т.* әйе бит, әйе (да, так).

**ӘЙТӘWЕР** *нгб.-крш., кргл.* кереш сүз функциясендә (в функции вводного слова). Әй, теңкәгә тимәле, җараппый, әйтәwер. – *нгб.-крш.* Бер урысчаны белмичә керде, уқыды, әйтәwер. – *кргл.*

**ӘЙТЕМ** *перм.* к.: **сәwем.** Бер басмада ничә әйтем була, Санийа апа? Бер басмада алтмыш әйтем дүртәр бөртекләп.

**ӘЙТЕШ 1.** *каз.ар.-крш.* кушымта (припев). Бу җырның әйтеше ничек суң? Бусы җырның әйтеше генә бит. Қодалар көйөнең әйтеше бумый; **2.** *туб.-ирт.д.* сөйләм (речь).

**ӘЙТЕШЛЕ** *т.кам.-крш.* әйтик – кереш сүз (скажем – вводное слово). Җегет җағына, әйтешле, ақча да салғаннар, қызға җилән дә тектереп биргә қушқаннар.

**ӘЙТМӘ** *нгб.-крш.* к.: **әйтеш.** Бу – җырның әйтмәсе генә.

**ӘЙТМӘКЧЕ** *нгб.-крш.* әйткәндәй (как говорят). Кәтүг әйтмәкче, эшләмәгән кешене ашатмыйлар.

**ӘЙТТЕРҮ** *мам., минз., әстр.* қыз ярәшү (сосватать невесту).

**әйттерелгән қыз** *әстр.* ярәшелгән қыз (сосватанная девушка). Мин сигез ай тордым әйттерелгән қыз булып. Әйттерелгән қызларга бәйрәм бүләге җибәрәләр.

**әйттереп килү** *әстр.* қыз ярәшергә килү (прийти сосватать). Йаучы килде әйттереп, дип әйтә торғаннар ыйы.

**әйттереп қуйу** *әстр.* қыз ярәшеп кую (сосватать, обручить). «Мин балама қыз әйттереп қуйдым, менә бу қыз әнисенең биреп җибәргән билгесе», – дип, түргә җаулық элеп қуйа торган булған.

**җәмәғәт әйттерү** *мам., минз.* к.: **әйттерү.**

**ӘЙТҮ** *нокр.* қыз сорау (сватать невесту). Бийатай әйтеп қайтқач кәбен салдылар.

**ӘЙТҮЛЕ** *каз.ар., минз., стрл.* к.: **атаулы 1.** Тәңкәле қыз дип әйтүле идем. – *мам.* Бәк зур бырач бар ийе әйтүле. – *минз.* Ишәй бабай да биг әйтүле булган. – *стрл.*

**ӘЙТЦӘ** *брб.д.* алайса (если так, раз так). Чәй эчмим. Сөт эц әйтцә.

**ӘЙХӘТ** [*гар.*] *тмн.* әкият (сказка). Әйхәт сүлим, тыннагыз.

**ӘЙШУН** *тмн.* к.: **шәл: күбек шәл.** Әйшуным бар, иртәгә шуны йабармын, кәртечкәгә сугарсын.

**ӘҚ** *әстр.* катык (кислое молоко).

**ӘҚАЙ: әқай заманындағы** *кргл.* к.: **ғазимдәге.** Әқай заманындағы ул кина.

**ӘКӘ** *себ.* абый (брат).

**ӘКӘ-АБА** *том.д.* абый-апа (брат с сестрой).

**ӘКӘҮ** *себ.* **1.** к.: **әкә; 2.** абыйга эндәшкәндә әйтелә (звательный падеж к слову «әкә»). Шакир әкәү қайтып йата. – *клм.*

**ӘКӘДИ** [*рус.* оказия] *минз., стрл.* к.: **ғыйллә 1.** Әй, аларның әкәди, сүләсәң гөмөргә бетәрлек түгел. – *минз.*

**ӘКӘЙ I** *срг.* яшь киленнәр кия торган тәңкәле баш киеме (головной убор молодухи, украшенный монетами). Киленнәр цәц цыбалмасынга әкәй кигәннәр тәңкәләр тезгән, тәңкәле бетүләр кигәннәр, сабаклатқан тәңкәләр.

**ӘКӘЙ II** *эчк.* к.: **аба(й) 1.** Лоқман әкәй белән балық әләктергәле барабыз.

**Ә'ӘЙ** *блт.* к.: **кәкәч II.**

**ӘКӘ-ЙЕҢГӘ** *том.д.*, **ӘКӘ-ЙЕҢКӘ** *тбл.* абыйжиңги (брат и его жена). Қыс йақтан әкәсе-абасы, малай йақтан әкәсе-йеңгәсе барып ишекне ачайлар, чәй қуйалар. – *яүшт.*

**ӘКӘЛӘ 1.** *каз.ар., хвл., күзн., карс., шрл.* имән чикләвеге (жёлудь). Имән әкәләсен дуңгыз өчен җыйалар. – *дөб.* Нийә, вет имәннән әкәлә. – *карс.*; **2.** *каз.ар., перм., хвл.* кайбер агачларда була торган күркә (шишка некоторых деревьев). Зирек әкәләсе. Нарат әкәләсе. Чыршы әкәләсе. – *блт.* Чырш(ы) әкәле җыйыб алайыг ий дә қайнатайыгый (буяу ясаганда). – *перм.* Бер тубал нарат әкәләсе җыйып кат'кан. – *хвл.*; **3.** *мам.* сырга – каенда (серёжка – у берёзы); чаг.: **песи.** Йәшрәк wақытта балалар ашыйлар да қайын әкәләсен. Қайын әкәләсе ашарға бардық.

**ӘКӘЛЕ 1.** *т.я., лш.* к.: **әкәлә 1.** Әкәле тәмсез лә ул, чикләwек кебек ашап пулмый анны. – *к.т.* Без имән әкәлесе дибез инде, бүтән җирдә көләләр алай дисәң. – *трх.*; **2.** *дөб., бәр.* к.: **әкәлә 2.** Ит белән зирек әкәлесен ашат, бозawыннын эч китүwе хәзер туқтар. – *дөб.*

**ӘКӘЛИ** *каз.ар., м.кар.* к.: **әкәлә 1.** Әкәли имәннеке бик тәмсез, бик әче. – *лш.* Әкәлийен дә утыртты қ, кәлшәсен дә пасаткыда. – *каз.ар.-крш.* Әкәли җыйалмадым быйыл. Туйыра әкәлийен дуңызга ашатабыз. – *м.-кар.*

**ӘҖӘЛЛӘ, ӘҖӘЛЛӘЙ, ӘҖӘЛЛЕ, ӘҖӘЛЛЕМ** *себ.* ичмасам (хоть, хоть бы). Әҗәлле ҡәwәр салмайт. – *клм.* Әҗәллә әрсәнне пулса ийе. – *саз.я.*

**ӘКӘМӘЙ** *чпр.* **1.** әкәмәт, гажәп, искиткеч (удивительно, странно). Әкәмәй кызыклы кеше бу Әхмәт; **2.** кереш сүз: әкәмәт (в значении вводного слова: чудак). Кеше затлы кийенгән ләса, әкәмәй. Әкәмәй, нә эшләргә инде, йаңлыш булган бит, әкәмәй.

**әкәмәт** (чудо; чудной, потешный, странный): **әкәмәт җөрү** *каз.ар.-крш.* к.: **айу I: айу чикмәненә чыгу.** Әкәмәт җөреп ҡайтҡачын, тыңга чығып китәдерийек қышқы көндә.

**ӘКӘР 1.** *перм., к.-уф.* ата эт яки мәче (самец – у кошек и собак). Әкәр эт җақшырақ була, әкәр ҡочоқ алмага кәрәк ҡарау өчен. – *перм.* Әкәр песи. – *к.-уф.*; **2.** *к.-уф.* кыргый ата хайван (самец у диких зверей). Әкәр айу тотҡан Әхмәт.

**ӘКӘРЛЕК** *мам.* к.: **текерлек.**

**ӘКӘРТСӘ** *каз.ар.* к.: **қузақ: қузақ ағачы.**

**ӘКӘТ** [*рус.* акация] *дөб.* к.: **қузақ: қузақ ағачы.** Сызғыра торған әкәт бар бит.

**Ә'ӘЧ** *т.я., лш.* к.: **кәкәч II.** Ә'әч ул, қызым, қапма. – *к.т.*

**ӘКЕРТ: әкерт кенә** *кузн., срг., мәл.* к.: **акыр: акыр гына.** Бармаклары әкерт кенә селкенә. – *кузн.* Әкерт кенә үтте пуйыз. – *срг.* Әкерт кенә әзерләнәсеңме? – *мәл.*

**ӘКИЙӘТЧЕ** *перм.* к.: **маскарцы.** Әкийәтче ул қарт. Әкийәтче ий ул да, қайчан уйлап ала сүзен.

**ӘККӘ** *саз.я.* абый (дядя, старший брат).

**ӘККӘҮ** *саз.я.* абыйга эндәшү формасы (форма обращения к старшему брату).

**ӘКМӘ** *перм.* к.: **мәрәтә.**

**ӘКҮ** *кргл.* к.: **дусай.** Әкүнең улы матурный лисапит белән чығып китте.

**ӘКҮЛЧӘ** *чст.* к.: **акулча.** Кругум әкүлчәсе тоткан иде, әпәйгә чыкмастан.

**ӘКЦӘЛҮ** *брб.д.* ярсытылу (быть потрясённым).

**ӘКЦӘҮ** *брб.д.* тетрәтү, ярсыту, ачуландыру (потрясать, возбуждать, возмущать).

**ӘЛ** [*гар.*] *чст.-крш., тбл.* хәл (сила, мощь, бодрость). Китәм генә, ди-ди, китәм, ди-ди, Китәрдегез минем әлемне. Белсәң иде, балам, хал'емне, Җарып бирер идем җанымны (*хал. җыр.*). – *чст.-крш.* Сес ней әлле? – *тбл.*

**ӘЛАЛМАШ: әлалмаш йасап** *т.я.-крш.* бер-берсенә үзара булышып (взаимно помогая друг другу). Ызбаларны әлалмаш йасап салабыз, ул сина килә, мин ана барам.

**ӘЛ'АПКЫЧ** *стрл.* к.: **алҗапма.** Киндер әл'апкыч китердем бит үзеңә, келәттә эшләгәндә кийеп йөрдең.

**ӘЛӘ: әлә нинди** *перм.* к.: **айаусыз 2.** Төтен әлә нинди. Озан күкәй әлә нинди сипкелле.

**ӘЛӘБИС** *туб.-ирт.д.* авыртучан (болезненный).

**ӘЛӘК** [*гар.*] *туб.-ирт.д.* **1.** бик күп (очень много); **2.** бик (очень). Күлмәгең әләк матур.

**ӘЛӘКӘТ** [*гар.*] *әстр.* ләхет (боковое углубление в могиле).

**әләкәт чығару** *әстр.* ләхет алу (делать боковое углубление в могиле). Дүрт кеше қазыса, бишенчесе әләкәт чығара. Белгән кеше кирәк әләкәт чығарырға.

**ӘЛӘМ** [*гар.*] *нрл.* к.: **қурқылық.** Чөгөндерне қарға алмасын өчен, әләм қуйабыз. Силус базы йанында әләм кебек басып тормағыз.

**ӘЛӘМӘТ 1.** *брб.д.* газап (мучение); **2.** *туб.-ирт.д.* бәхетсезлек (несчастье).

**ӘЛӘМ-ӘТРӘК 1.** *т.я.* билгесез, чит кеше (кто-то, неизвестный, чужой человек). Әллә кем, әләм-әтрәк ич ул миңа. Әллә кем, әләм-әтрәкләр дә килгән ийе анда. – *к.т.*; **2.** *лш.* дәрәҗәсез кеше, ярлы-ябага (неавторитетный человек, бедный); чаг.: **айа'-сайа'лы.** Әләмәтрәкләрне кертмиләр ийе өйгә.

**ӘЛӘНГӘЧ** [*угор.*] *мәл.* өсте капкачлы кечерәк кисмәк (небольшая кадка с крышкой).

**ӘЛӘП 1.** *клд., мәл.* к.: **тике.** Тойга әләп. – *мәл.*; **2.** *кузн., хвл., клд.* шуннан алып, башлап (начиная с ..., с тех пор). Тездән әләп кәркеш бәләгән. Моннан әләп кийәсен. – *хвл.* Шуннан әләп мин тыл тордым. – *клд.*

**ӘЛӘСАҢ** *минз.* к.: **айса.** Әләсаң чалгы алып бар.

**ӘЛӘСӘ** *байк., минз., карс., чпр.*, **ӘЛӘСӘЙ** *м.-кар.*, **ӘЛӘСӘК** *мәл.* к.: **айса.** Аты булгаң әләсә, безнекеләргә утырып киткәндер. – *байк.* Чуны белергә кирәгә, әләсәй. – *м.-кар.* Әләсәк алай йарамый. – *мәл.*

**ӘЛӘС-ПӘЛӘС** *карс.* к.: **аңкы-миңке.** Әләс-пәләс үгә керәм, теге биртелгән эт кебек.

**ӘЛӘХЛӘҮ** *саз.я.* һәлак итү (погубить).

**ӘЛӘҢ** *брб.д.* кармак (удочка).

**ӘЛӘҢЛӘҮ** *брб.д.* кармак белән балык тоту (удить).

**ӘЛӘШӘ** *дөб.* яшьләр уены (гулянье, игры молодёжи). Ашыт җыйынында қала тауға әләшәгә чыгалар ыйы җәшләр.

**ӘЛӘҮКӘ** [*рус.* лавка] *блт.* к.: **пул.**

**ӘЛБӘ 1.** *минз.* манный боткасы (манная каша). Инәй әлбә пешергән; **2.** *злт.* абстракт мәгънәдә кулланыла, дөньяда юк ашамлык мәгънәсендә әйтелә (употребляется в абстрактном смысле, т.е. еда, которой нет, не существует).

**ӘЛБӘНДЕРЕК** *лш.* к.: **атын.**

**ӘЛБӘТӘ** *т.я.* ярыйсы, канәгатьләнерлек (ничего, удовлетворительно). Хәле бик начар иде, хәзер әлбәтә инде. – *трх.* Әни әзрәк әлбәтә булды инде, қаwым-қаwым ғына саташа. – *нрл.*

**ӘЛБИДӘ** *срг.* к.: **алабата.**

**ӘЛWӘН: әлwән қағы** *мам., кмшл.* әлүн кагы (сухая алычовая пастила); чаг.: **кагыт.** Қазаннан әлwән қағы апқайттым. – *кмшл.*

**ӘЛДӘ 1.** *тмн., кузн., хвл., чст., срг.* әле (ещё, пока, пока ещё, всё ещё). Бу әлдә йәш. – *тмн.* Әлдә арбага утырмаган, китәргә йыйына. – *кузн.* Әлдә кәпәчләр бар иде. – *хвл.* Әлдә барып йетмәгәндер әле. – *чст.* Әлдә йәйәү бары(р)га кирәк анда. – *срг.*; **2.** *мәл.* һаман да (всё ещё). Машинасы йук әлдә. Төнә бардым, бөген килдем, әлдә шылай торалар (*әкият.*); **3.** *кузн., хвл., чст.* әле ярый, ярый ла (хорошо ещё). Килдең әлдә, килмәсәң, бик каты әләгә иде үзеңә миннән. Әйттең әлдә, ату бушка барган була идем. – *хвл.*;

**4.** *кузн., чст.* хәзер, хәзер дә, әле дә (теперь, сейчас, и сейчас). Путмарлар йугинде әлдә. – *кузн.* Ашка йерерсең кызларың тырса, әлдә чебиләре белән кат'ып керсә (ни эшләрсен?); **5.** *минз., стрл., трбс.* ярый әле (хорошо ещё, ладно ещё). Кисәң көләрләр ийе, әлдә булмаган. – *стрл.*

**ӘЛДЗИ** *брб.д.* илче (посланник).

**ӘЛЕ** *карс.* әллә (разве). Әле килдең? Әле сездә кыдачалый бару йук?

**ӘЛЕWӘ** *тбл., крш.* әлбә (сладкая мучная каша).

**ӘЛЕГӘЧТӘН** *т.я.* хәзердән үк, вакытыннан элек (раньше времени). Әлегәчтән қайа барасыз әле, жиләкләр пешмәгән ич. – *к.т.*

**ӘЛЕ'-МӘТРЕ': әле'-мәтре' булу** *кас.* әллә нишләп бетү (о всяких неприятностях, случившихся с кем-либо). Әле'-мәтре' булып петтe', 'ермисез ди без'и.

**ӘЛЕКӘЙ** *бгрс.* аумакай (поддающийся чужому влиянию). Әлекәй кешегә ғомбағыш диләр.

**ӘЛЕНЙАПМА** *мәл.* к.: **алжапма**.

**ӘЛЕП** *бөре.* к.: **астар 2**.

**ӘЛЕСӘ** *чст.* к.: **айса**. Әдә киттек әлесә.

**ӘЛЕШ: әлеш итү** *кузн.* йоклау – балалар телендә (спать – в детской речи). Йат, кәбәм, йат, әлеш ит: әлеш-бәлеш!

**ӘЛЕШ-БӘЛЕШ** *кузн.* әлли-бәлли (баю-баюшки). Әлеш-бәлеш, кандалага салма, ылым (кызым) – алтын алма.

**ӘЛЖЕРӘУ** *перм.* к.: **пожу**. Гөлөң әлжерәгән, су салмағансыңдыр.

**ӘЛИ'** *кас.* к.: **йәләк**.

**әли' салма'а** *кас.* к.: **ошақлау**. Әли' салма'а би' жарата.

**ӘЛИСӘ** *т.я., злт., минз.*, **ӘЛИСӘК** *т.я., мәл., чпр., шрл.*, **ӘЛИСӘН** *каз.ар.* к.: **айса**. Әлисә син үзең барырсың суға. – *к.т.* Әлисә тышқа чығарып қуйам мин аны. – *злт.* Әлисәк үзең кил. – *мәл.* Әлисәк быраз кетеп тыр, бабаң кат'ып йетәр. – *шрл.*

**ӘЛКӘЙ** *перм.* к.: **сәлей**.

**ӘЛҚЫМ** *туб.-ирт.д.* бугаз, тамак (горло).

**ӘЛЛӘ I** *брб.д., туб.-ирт.д.* риза булмау ымлыгы (а! – восклицание неодобрения).

**ӘЛЛӘ II: әллә мәкәй** *минз., трбс., стрл.* әллә нәрсә (что-то). Әллә мәкәй онытып бетердем. Әллә мәкәй жырласы килә дә, жыр чыкмый. – *минз.*

**ӘЛЛӘЙТАН** *саз.я.* әллә каян (откуда-то).

**ӘЛМӘНДЕРЕК** *каз.ар., т.я.* к.: **атын**. Әлмәндерек уйныйбыз лапаста, бау асып бирерләр ийе, шуңа тақта қуйар ыйык та. – *блт.*

**ӘЛМӘРХҮМ** [*гар.*] *әстр.* үлгән кешенең кабер ташына языла торган сүз (слово, которое пишут на надмогильной плите). Әлмәрхүм, фәләнчә йылны туған, фәләнчә йылны үлгән.

**ӘЛМЕРӘП** *минз., тпк.* йомшак; изрәгән, тотанаксыз (мягкий, размягчённый). Ат қолағы пешкәч әлмерәп тора ул. – *минз.*

**ӘЛМОРОН** *стрл.* к.: **гөләф**. Ул тәбәшәк үсә, әлморон диләр аны, эче жонно була.

**ӘЛПӘ** *эчк.* балык тәңкәсе (рыбья чешуя). Әлпәсез була ул балык.

**ӘЛПЕ** *кмшл.* энҗе, сәйлән (жемчуг, бусина, бисер).

**ӘЛСӘ** *минз., злт., перм., чст.*, **ӘЛСӘК** *кмшл.* к.: **айса**. Әлсә көтеп тор, мин дә барам. – *злт.* Әлсә сийән (синнән) сүз булды? – *перм.* Әлсәк, Нурмөхәммәтләр қайтқаннар икән. – *кмшл.* Сапсим бетте әлсә. – *чст.*

**ӘЛСӘН** *злт.* к.: **айса**. Әлсән ул безнеңчә сүләшмәй. Әлсән калхузға мине сүләшмә.

**ӘЛТӘН** *туб.-ирт.д.* еш (часто).

**ӘЛТӘНЛӘҮ** *туб.-ирт.д.* ешайту (учащать, делать часто).

**ӘЛҮН** *каз.ар.* әлүчә (алыча).

**әлүн қағы** *каз.ар.* к.: **әлwән: әлwән қағы**. Әлүн қағы салып чәй әчәм. Әлүн қағы, балан қағы Тәмле була чәйләргә. Дошманнарға житә қалды Без дусларны чәйнәргә (*хал. жыр.*). – *блт.*

**ӘЛЦЕ: әлце салу** *срг.* баш киемен кырын салып кию (надеть набекрень – шапку, тюбетейку и т.д.). Бишни күлмәк бишни лә, Камзулында биш түмә. Түбәтәйен әлце салып, Бәнем жәнкәй нишли лә? (*хал. жыр.*) – *срг.*

**ӘЛЧЕ** *мәл.*, **ӘЛЧИ** *трх.* к.: **қуқыр**. Әлче ди кийәwе. – *мәл.* Әлчи ийе бик қартлары, қуштан. – *трх.*

**әлче салу** *чпр.* к.: **әлце: әлце салу**. Башыңдагы кәләпүшең Нинди байның бүләге, Әлче сал да чык урамға, Йансын дошман йөрәге (*хал. жыр.*). – *чпр.*

**ӘЛЧУҚАЙ** *әстр.* ашый торган үлән тамыры (съедобный корень растения). Әлчуқай ул – қара тамыр, аны жуwып киптереп, икалап-икалап төйеп ашадық.

**ӘЛЧҮПРӘК** *нокр.* к.: **алжапма**. Әлчүпрәк йап алдына.

**ӘМӘЙЛЕ** *бөре.*, **ӘМӘЙЛЕК 1.** *минз., перм., к.-уф., злт., кргл.* к.: **путемар**. Әмәйлек без тақмадық, қортқаларда гына булыр. – *минз.* Әмәйлек тақмыйлар инде хәзер. – *к.-уф.* Әмәйлек кийә торғаннар ыйы элгәре, без кимәдек. – *злт.* Байларның қызлары мыннан уратып, мойыныннан тағалар ыйы, қаптырмалап қуйа, аны әмәйлек ди торғаннар ыйы. – *кргл.*; **2.** *тпк.* к.: **қәситә 2**.

**ӘМӘКӘЙ I** *перм.* к.: **ат'акыш 1**.

**ӘМӘКӘЙ II** *нгб.-крш.* ни, нәрсә (что). Ни әмәкәй сорасаң да, белә.

**ӘМӘЛ I** [*фарс.* хәмәл] **1.** *туб.-ирт.д.* язгы бәйрәм (весенний праздник); **2.** *брб.д.* жителек (ловкость).

**әмәл гөлцә** *төм. әмәл* бәйрәменә пешерелә торган вак күмәч (хлебцы, испечённые к празднику *әмәл*).

**әмәл тукац** *төм.* к.: **әмәл ғөлцә**. Әмәл тукац тип тукацлар қылып цацабыс.

**ӘМӘЛ II** [*гар.*] **1.** *тпк.* бозык (колдовство, порча). Әбиләргә күрсәт тисәк, әмәл диләр awыруны; **2.** *перм.* йәри торган сукмак өстенә казып һәм өсте күренмәслек итеп каплап куелган чокыр (замаскированная яма на тропинке). Әмәлгә баттым. Әмәленә қар йауғыры, теге тағы йаза.

**әмәлен белү** *т.кам.-крш.* жаен, тәртибен белү (знать порядок, содержание обряда или чего-либо). Аның көне бар йаңғыр ботқасы пешерүнең, әмәлен белергә кирәк.

**әмәленә қаршы** *минз., стрл.* бәхетенә каршы, бәхетсезлегенә каршы (к счастью, к несчастью).

Бу сикереп торган да чыккан, әмәленә каршы, урамнан теге җегет үтеп бара икән. – *минз.*

**ӘМӘЛӘТ** [*гар.*] *тмн.* орышу сүзе (ругательное слово). Әмәләт, сүләмә йукны.

**ӘМӘЛДӘШ** *брб.д.* иптәш (товарищ).

**ӘМӘЛ-ҖӨМӘЛ** [*гар.*] *бәр.* к.: **аран II**. Әмәл-җөмәл генә эшләп бетердем бу эшне.

**ӘМӘЛЧЕ** *т.кам.-крш.* йола үтәүче (человек, знающий обряды, их исполнитель). Әмәлчеләр бетеп китте хәзер.

**әчемнек ачу** *тара., твр.* бөркәнчек ачу (обряд открывания покрывала у невесты). Әчемнекне кейәүнәгәр ачаты шабала ман. Әчемнекне ача та иң әwәле инәсе мән атасы инәте, қәйен-қәйнәсе, киленчәкне күргәле. – *тара.*

**ӘЧЕТКЕ 1.** *баст.* ачыткы (закваска); **2.** *дөб.* к.: **былгама 2.** Әчетке бар қазларға. Бар, тawықларға әчетке болғатып бир әле, қызым, көрпәсе дә шунда, бәрәңгесе дә.

**ӘЧИ** *мәл.* к.: **йенгәчәй.** Тенә мин әчиләргә бардым. Бу – минем әчи.

**ӘЧИКМӘК** *чст.* к.: **әпәй.** Әчикмәк диләр арыш икмәген, быдайныкын быдай җымшагы диләр – ыразнисы бар анда.

**ӘЧКЕЛТЛЕ-ТӨЧКӨЛТЛЕ** *мам.* әчкелтем-төчкелтем (кисло-сладкий). Әчкелтле-төчкөлтле була бу алма.

**ӘЧКИ** *нрл.* кырда иртәнге аш белән төшке аш яки төшке аш белән кичке аш арасындагы ашау (еда на поле между завтраком и обедом или между обедом и ужином). Әйдә, әчки ашап җибәрик. Қыйарыңны аппарасыңмы әчкигә? Бер-ике сәгәт эшләгәчтен, әчкигә утыралар.

**ӘЧЛЕК** *нгб.-крш.* к.: **ачылық 2.** Әчлек җирдә ашлық уңмый.

**ӘЧМИН** *кмшл.*, **ӘЧМИННЕК** [*рус.* осьминник] *минз.* к.: **ачминнек.**

**ӘЧТИК** *к.т.* к.: **безрәк.** Әчтик кенә қамыр башы биреп тор әле, Сабираптий.

**ә ч ү I** *блт., дөб.* ачу (открывать):

**ишек қырыйы әчү** *блт.* к.: **қылтайту 1.** Ишек қырыйы әчкән ийем әле төтөн булғач.

**ӘЧҮ II** *баст.* куас (квас). Әчүне күп пешерәбез, ике чиләк туп-тулы. Атауға әчү пешердек.

**ӘШӘ** *туб.-ирт.д.* кармак җебен урап куя торган шүре (челнок для наматывания лески).

**ӘШӘК I** *т.я.* к.: **ашақ**. Бу урындык бик әшәк, өстәлгә буй җитмий, утырсаң. – *к.т.*

**ӘШӘК II** *злт.* к.: **патлуфкы**. Қабырғасында әшәге бар. Әшәккә йақсаң, эссе була. Әшәгенә йаға, пелиткәсенә қомған белән сыw утырта.

**ӘШБӘ** *перм.* к.: **әшпә 1**.

**ӘШЕМ** *туб.-ирт.д.* иптәшем, юлдашым (товарищ мой, спутник мой).

**ӘШЕРБАҚ** *туб.-ирт.д.* ялагай (подхалим).

**ӘШКӘРӘ I** *минз.* ачыктан-ачык, белә торып (сознательно, открыто). Әшкәрә қылған гөнаһларыбызны, җәшереп қылған гөнаһларыбызны җарлықа дип сорыймын.

**ӘШКӘРӘ II** [*фарс.*] **1.** *перм., глз.* кызык, көлке (забава, посмешище); **2.** *минз.* яшерен (тайно, скрытно). Әшкәрә генә эшләп қуйдым эшне; **3.** *себ.* к.: **әләк 2**. Әшкәрә қаты айыпланыр ите.

**әшкәрә булу** *перм.* кызык булу, хур булу (стать посмешищем; опозориться). Бар кийемен жәлләп кими йөрийе, йуғалтқан, ди, әшкәрә булған икән! Ай әшкәрә булды қый йығылып, бийеп башладийе.

**әшкәрә итү** *перм.* кызык итү, хур итү (сделать посмешищем, опозорить). Алихан хатынын туқмады – әшкәрә иткән!

**әшкәрәдән тыш китү** *дөб.* к.: **аша II: аша китү**.

**ӘШМӘЛӘҮ** *т.кам.-крш.* к.: **қоршу 1**. Чыбық-чабықтан ғына әшмәләгән бу шалашны.

**ӘШПӘ** *перм.* **1.** буш, сирәк – бәйләгән әйбер, челтәр h.б. турында (редкий – о вязаной вещи, кружеве и т.п.). Әшпә генә бәйләп қуйған, диләр, буш бәйләдең исә (оекны); **2.** юка – тукыма турында (тонкий – о материи). Әшпә тиләр бик йоқа ғына булғанны. Әшпә қытат чыдамсыз була; **3.** к.: **пестелчек 2**. Әшпә Ниғамәтһан бар ийе (бездә).

**ӘШТАҒЫ** *төм.*, **ӘШТӘҒӘ** [*фарс.*] *саз.я.* аждаһа (дракон).

**ӘШТӘНЧЕК** *хвл.* к.: **қанчық 2**.

**ӘШТҮ** *кузн.* **1.** таптау, басу (растоптать, мять). Кар әштү; **2.** кыйнау (бить, отлупить). Кәзә бакцага кергән иде, бик нык әштеп цыгардым.

**ӘШХАРӘ** [*фарс.*]: **әшхарәдән тыш китү** *дөб.* к.: **аша II: аша китү**. Әшхарәдән тыш киткән җегерме биш сум биргәч.

**ӘШХӘРӘ** [*фарс.*] *саз.я.* к.: **әләк 2**. Әшхәрә көцөм пөттө.

# Б

**БАА** *төм.*, **БААС** [*фарс.*] *төр., тбл., төм.* бәя, бәһа (цена). Қөйбат баас белән йаллыйты. Көләмнеке кәнтәй йөсе пар, Песнең қулта йөсөк пар, Шәәр бааслы баасы пар. – *төм.*

**БАБА 1.** *лмб., кас., каз.ар.-крш., төм.* ир, карт (муж, старик); чаг.: **абышқа**. Бабам бар, эҗ балам бар. – *лмб.* Былтыр бабам үлде, шундан сыр'-ауландым. – *кас.*; **2.** *төм.* к.: **бабай I, 3**; **3.** *яүшт.* к.: **бабай I, 2**.

**бабага җыйылу** *лмб.* иргә чыгу (выйти замуж). Бабага җыйылдым, аннан ике ыл, ике кыз булды; ике балам мән йәнәдән бабага җыйылдым, аннан ике ылым бар.

**бабаға утырту** *т.я.* сөннәткә утырту (совершить обряд обрезания).

**йеснә баба** *тбл.* к.: **бабай I: җизни бабай**.

**БАБАЙ I 1.** *бөре., злт.* хатынының әтисе (тесть); **2.** *т.я., бөре., кмшл.* хатынының әтисенә эндәшү сүзе (форма обращения к тестю); **3.** *т.я., бөре., злт., минз., тпк., кмшл., перм., стрл.* әтисе яки әнисенең абыйсы һәм аңа эндәшү сүзе (старший брат отца или матери и форма обращения к нему); чаг.: **абызбабай**; **4.** *эчк., т.кам.-крш.* әтисенең абыйсы (старший брат отца); чаг.: **абызбабай**; **5.** *м.-кар.* әтисенең әнисе (бабушка с отцовской стороны). Бабай инде тәтәйнең әнкәсе була, Дарйа бабай; **6.** *перм., кргл., бгрс.* к.: **баба 1**. Мин, бабайым киткәч, бала-чаға белән генә йасадым ызбаны. – *перм.*; **7.** *перм., злт., минз., тпк., стрл.* әтисе яки әнисеннән олырак чит кеше (мужчина старше отца или матери).

**әткий бабай** *каз.ар.-крш.* әти-әнисенең туенда *қыяматлық* булган ир кешегә эндәшү формасы (форма обращения к посажёному отцу отца); чаг.: **бабай I: йәш бабай 3**.

**бабай башы** *блт., мам., яүшт.* к.: **тузғақбаш**.

**бабай булып җерү** *чст.-крш.* нардуганда маскарад ясап киенеп йөрү (ходить ряженым в святках); чаг.: **айу: айу чикмәне**. Нардуганнар шулай була инде wыл, ий бырынчы җеридер ийег инде, бабай булып җериләр. Нардуганда, эй, бабайлар, бабайлар, безгә керми калмагыз, диләр. Кайсы – күремче, кайсы – бабай, кайсы җәш килен булып кийенә.

**бабай әләге** *кузн.* к.: **гөләф**.

**дәү бабай** *т.кам.-крш.* к.: **бабай I, 3**.

**җәш бабай 1.** *каз.ар.-крш.* әтисенең абыйсы, әнесе (старший или младший брат отца); **2.** *т.кам.-крш.* әтисенең иң олы абыйсы (самый старший брат отца).

**җизни бабай** *к.т.* әнисенең апасының ире (муж старшей сестры матери).

**җырақ бабай** *бөре., минз., крш., бгрс.* әнисенең әтисе (дед с материнской стороны). Кызларымның балалары күп, безгә килеп тыралар, җырак бабай дип киләләр. – *чст.-крш.* Аның җырақ бабасы белән минем бабам бертуған. – *каз.ар.-крш.* Җырақ бабай awырған. – *нгб.-крш.*

**зур бабай** *минз., стрл.* әтисе яки әнисенең апасының иренә эндәшү формасы (форма обращения к мужу старшей сестры отца или матери).

**йәж бабай** *кузн.* к.: **бабай I 1, 3, 4**.

**йәш бабай 1.** *байк.* к.: **бабай I 1, 3, 4**; **2.** *трх.* к.: **бабай I, 1**; **3.** *чст.-крш.* яшь киленнең балалары әниләренең *қыяматлық* әтисенә эндәшү формасы (форма обращения к посажёному отцу родителей); **4.** *тмн.* бабасының әнесе (младший брат дедушки); **5.** *к.т.* әнисенең абыйсы (брат матери, дядя); **6.** *к.т.* әтисенең апасының ире (муж старшей сестры отца); **7.** *к.т.* иренең абыйсы (старший брат мужа).

**теш бабай** *лмб.* балага теш чыкканны беренче күргән ир кеше (мужчина, увидевший первый зуб ребёнка).

**үз бабай** *мам., чст.-крш., т.кам.-крш.* әтисенең әтисе (дед со стороны отца).

**БАБАЙ II** *кргл., глз.* к.: **баба 1.** Бик мактаулы агарутник иде бу әбинең бабайы. Инде икенче бабайга барды да куйды. – *кргл.* Икәү ташыдык бабай белә. – *глз.*

**БАБАЙ III** *нокр.* бәби, бәбәй (грудной ребёнок, младенец). Бабайы белән азапланам, анасы болонға китте. Бабайы бар киленнең. Бик йаман awырдан китергәләдем бабайлар. Бабай сүбәт йасадык.

**БАБАЙКА** *бәр.*, **БАБАЙКЫ** *дөб.* к.: **тузғакбаш.**

**БАБАЙЛАТУ** *глз.* сөннәткә утырту (подвергать обрезанию). Хәзер инде бездә бер дә бабайлатмыйлар.

**БАБАЙЧЫ: бабайчы бағыты** *каз.ар.-крш.* нардуган вакыты (святки).

**БАБАКА** *глз.* к.: **өшөмкә.** Бабака йийышты-ра идек.

**б а б а к а й** (форма ласкового обращения к дедушке):

**йәш бабакай** *карс.* әнисенең абыйсы (старший брат матери). Бу инде аналарының дәдәсе, йәш бабакай була.

**БАБАЛАШ** *перм.* мәче башлы ябалак (филин).

**БАБАСЫР: бабасыр үләне** *минз.* к.: **албидрә.**

**БАБАУ** *төм.* әнисенең әтисе (дедушка со стороны матери).

**цәци бабау** *төм.* **1.** к.: **бабай I, 3.** Инәсенең әкәсе дә цәци бабау була; **2.** иң олы абыйга эндәшү сүзе (форма обращения к самому старшему брату).

**БАБАЦЫ** *чпр.* к.: **бабачы I, 1.** Бабацы килсә, ыланшак каца дир.

**БАБАЧ 1.** *нокр.* бабай, карт (дедушка, старик). Ул бабач минем бай белән бер йылның; **2.** *нокр., глз.* к.: **бабача.** Йыклап китепмен ич, бабач киткәнне сизмәпмен. Ул минем бабач инде. – *нокр.*; **3.** *глз.* әтисенең абыйсы, әнесе яки әнеләреннән иң зурысы (старший или младший брат, самый старший из младших братьев); **4.** *нокр.* әнисенең әнесе (младший брат матери). Миңә бабач була әнинең әнесе.

**БАБАЧА** *нокр., глз.* әтисеннән олырак ир кеше (мужчина старше отца). Сәйфеттин бабача киттемени силсәwиттән, кирәг ийе қағаз алмаға. – *глз.* Алма кергәннәр иде Ғиззәт бабачалар. – *нокр.*

**БАБАЧЫ I 1.** *т.я., блт.* сөннәткә утыртучы, сөннәтче (тот, кто совершает обряд обрезания); **2.** *т.я.* хәйләкәр (хитрый человек, хитрец).

**БАБАЧЫ II: бабачы бағыты** *каз.ар.-крш.* к.: **бабайчы: бабайчы бағыты.**

**БАБУЛ** [*рус.* бобыль] *срг.* җирсез яки җире аз булган кеше (бобыль безземельный или малоземельный).

**БАБЫЙ** *т.я.-крш., нрл.* бабай (дедушка). Бабыйны ташлап китте. – *т.я.-крш.* Әти, бабый балта остасы булғаннар. Без ике бабыйны ғына белә-без. – *нрл.*

**БАБЫКАЙ** *карс.* **1.** к.: **бабый; 2.** к.: **бабай I, 1.**

**БАWЫР: баwыр ағачы** *дөб., минз., нрл., трх.* аюбаш (пришва – часть ткацкого станка).

**БАВЫРИН** *әстр.* өрлек (перекладина).

**БАWЫРСАҚ** *нрл., төм.*, **БАWЫРСАК** *мәл.* **1.** чәкчәк (чакчак – национальное мучное блюдо). Туйға қаз алып баралар иде, баwырсақ йасап, патнусқа бал қатыралар эйе. – *нрл.*; **2.** *перм.* кош теле (хворост – национальное мучное блюдо); **3.** *әстр.* ачыга яки төчегә пешерелгән, ромбик формасында киселгән һәм майда кыздырылган камыр ашы (мучное блюдо из пресного или кислого теста, разрезанное в форме ромбика и жаренное в масле).

**баллы баwырсақ** *перм., минз.* к.: **баwырсақ 1.**

**wақ баwырсақ** *перм.* к.: **баwырсақ 1.**

**йомар баwырсақ** *брб.д.* майда пешкән кабартма (пончик).

**қалач баwырсақ** *төр.* к.: **йомар баwырсақ.** Қалач баwырсақ майға пешерәбез. Қалач баwырсақ ачыға да, төчегә дә пешерәбез. Қалач баwырсақлар алып баралар.

**қапқа баwырсағы** *минз.*, **капка баwырсагы** *стрл.* килен төшкәндә капка төбенә чәчү өчен яулыкка төреп алып килә торган бавырсак (баурсак, завёрнутый в платок и предназначенный для рассыпания у ворот жениха перед невестой). Қапқа баwырсақларын чәчеп йеппәрә дә йаулығын кесәсенә тыга. – *минз.* Капка баwырсаклары чәчелеп бетә, йаулыгы җыртылып бетә. – *стрл.*

**кийәү баwырсақ** *төм.* кияү ягыннан кыз ягына алып барыла торган бавырсак (баурсак, привозимый со стороны жениха). Никәгә кийәү баwырсақлар алып парабыс, ыwақ пawырсақлар, туқацлар кәстрүлләр белән аппарабыс.

**самсы баwырсақ** *төм.*, **санса баwырсақ** *тара.* чикләвек кебек вак бавырсак (мелкий, в форме орешков, баурсак).

**БАҒАЛМА** *каз.ар.* к.: **бағалма 1.** Алманы бағалмасы диләр ийе. – *блт.*

**БАҒАЛМА 1.** *чст., чпр., тмн., т.я.-крш.* алма (яблоко). Багалмасы бармы икән? – *чст.* Садawай алмага багалма дибез. – *чпр.* Трофимовның багалмасын сындырып бетерәләр. – *т.я.-крш.*; **2.** *т.я.-крш.* алмагач (яблоня).

**БАҒАН 1.** *эчк.* казык (кол). Бағаннан кәртә тотқан кеше йуқ бездә; **2.** *том.д.* багана (столб); **3.** *тбл.* тирмәнең киезләрен күтәреп терәтеп куя торган колга (шест, которым поднимают и подпирают кошмы в кибитке).

**БАҒАНА I** *мам., лш.* оек кунычының башындагы уңлап-суллап бәйләнгән өлеше, сыр (часть паголенка чулка, связанная в резинку).

**бағана үкчә** *трх.* оекбаш үкчәсен бәйләү ысулы: уң яктан бер күзәнәкне буш алып, икенчесен бәйләп бару, сул яктан бөтен күзәнәкне дә бәйләү (способ вязания пятки носка: узор, полученный столбиками).

**қуш бағана** *лш.* ике бармак арасына чыккан шеш (нарыв, болячка между двумя пальцами). Аны қуш багана төбеннән алынған балчық белән дәвалыйлар, имеш.

**ойоқ бағанасы** *мам.* к.: **бағана I.** Ойоқ баға-

насын берне сулга, икене уңга бәйләсәң, матур була.

**тоз бағана булып қату** *каз.ар.-крш.* ис китү, шаккату (удивляться, поражаться).

**БАҒАНА II** *каз.ар.-крш.* куплет. Җегерме дүрт баганалы бәйет җadганнар ыйы.

**БАҒАНЧАҚ** *дөб.* койка (холодец). Бағанчаҡны ат, сыйыр айаҡларыннаң пешерәләр.

**БАҒАРА** *кргл.* шыртлака (ёрш).

**БАҒУ** *нокр., перм., кргл., бәр., тара., брб.д.* **1.** карау (смотреть). Фәрwиза тәтәйгә чыгып багайтым. Ҡойаш баққан көнне әйбәт кибә. – *перм.* Белмим инде кемгә барып бағарға. – *бәр.*; **2.** тәрбияләү, асрау (смотреть за кем-либо, ухаживать). Улан бағу. Сыйыр бар, сыйыр багабыз. – *перм.* Ҡуй бақтым. Ҡартинәсе қас пағыб утырған. – *брб.* Иңгал берсен бағып бирдем. – *бәр.* Күрше-күләнбик бағалар. – *нокр.* Мин бала бағам, өйне ташлап китәлмим. – *дөб.*; **3.** *перм.* чит кеше баласын тәрбияләп үстерү (воспитывать чужого ребёнка). Бер балабыз бар, бағып үскергән балабыз ғына; **4.** *кргл.* көтү (пасти). Үзләре өчен cawалар бийәне, үзләре бағалар. Ул бабай wақытында сыйыр бақҡан, сарық баққан.

**баш бағу бәйрәме** *дөб.* искечә Яңа ел көнне төнлә бәкедән суга карап күрәзәлек итү йоласы (обычай, гадание у проруби в новогоднюю ночь по старому стилю). Баш бағу бәйрәмендә айның бик йақты wақытында төнгө сәғәт уникедә бәкедән қараганнар.

**дөнйа бағу** *кргл.* дөнья көтү (жить, существовать). Дөнйа бағалмастай булғач, улына китте инде.

**БАҒУ 1.** *миш.д., т.я.-крш.* к.: **бағу 1.** Ачып бактым, баксам – план, багам-багам дийәм, танымам. Ылан багып тора. – *миш.д.* Быйыл тагын утыртып бактым инде. Җәмәгәтләр үдә булмады, багалмадым. – *м.-кар*; **2.** *миш.д.* к.: **бағу 2.** Ылан багуы – йылан агуы (*әйтем*). Каста малайын бага. – *миш.д.*

**бағу бағу** *миш.д.* күрәзәлек итү (ворожить, гадать).

**БАҒУЦЫ** *тмн.* караучы, тәрбияләүче, күз-колак булып торучы (тот, кто присматривает за кем-нибудь, чем-либо). Бер багуцы да булмаган, нукасы урманга китеп барган.

**БАҒУЧЫ** *бәр.* к.: **багуцы.** Аны бағучы кеше йуқ.

**БАҒУЧЫ-КҮРҮЧЕ** *күзн.* к.: **багуцы.** Багучы-күрүче йук.

**БАҒЦАР** *тбл.* к.: **пақцар.**

**БАҒЦАРҒА** *тбл.* к.: **пәкчергәй.**

**БАҒЫ** *мам.* йөк төялгән арбаны күтәртә торган агач (подпорка, с помощью которой приподнимают нагруженную телегу).

**БАҒЫЛТЫРЫҚЛАУ** *брб.д.* бау кую (надеть верёвку). Кисәсең, тишекләр тишәсең, бағылтырыҡлайсың.

**БАҒЫМ: бағым бағу** *эчк., нгб.-крш.* к.: **багу: багу багу.**

**БАҒЫМСЫ** *злт.* к.: **белемче.** Бағымсыға барма, башыңа бәлә алма (*мәкаль*).

**БАҒЫНДЫРУ** *тбл.* баш идерү, буйсындыру (заставить поклониться, сделать покорным, покорить, подчинить себе).

**БАҒЫНУ** *кргл.* карану (осматриваться, оглядываться). Чишмә йаққа бағынып тырам.

**БАГЫНУ I** *срг.* караштыргалау, эзләштергәләү (посмотреть, поискать). Багын, монда ышкап йанында йук микән (кайчы)?

**БАГЫНУ II** *м.-кар.* чукыну (креститься, молиться).

**БАҒЫНЧАҚ** *дөб.* к.: **баганчақ.**

**БАҒЫР** [*гар.*] *туб.-ирт.д.* мәрхүм (покойный). Атам бағыр.

**БАҒЫРЦЫҚ** *төм.* к.: **бахыр.** Тын күрәцәк күрепте, бағырцық.

**БАГЫРЧА** *лмб.* аш чүмече (половник). Багырчамны сындырдым, аш сысарга хаз'ыр ни дә йуктыр.

**БАҒЫТ I** [*гар.*] *каз.ар.-крш.* вакыт (время). Шулай үләрсең дә китәрсең инде, оторо бағыт җиткән. Бер бағытта тора өйрәнгәс, без бик иртә торабыз.

**БАҒЫТ II** [*гар.*] *нгб.-крш.* бәхет (счастье). Минем йәштән үк бағытым булмады.

**БАҒЫШ-КҮРЕШ: бағыш-күреш итү** *бәр.*, **БАГЫШ-КҮРЕШ: багыш-күреш итү** *күзн.* күз-колак булып, булышып тору (присматривать за кем-либо, чем-либо). Бағыш-күреш итсә күршеләре, бик йақшы да. – *бәр.* Багыш-күреш итәрсен инде. – *күзн.*

**БАГЫШЛЫ** *чпр.* охшаш (похожий, сходный). Менә чушыңа багышлы иде.

**БАҒЫШУ** *нокр.* к.: **багу 1.** Бағышасыңмы урамны?

**БАДАЙКА** [*рус.* бадейка] *мәл.* чиләк (бадья, ведро). Бер бадайка карту бирең чыгардым үзенә.

**БАДАЙЫМ** [*рус.* водоём] *нрл.* сулык, бассейн (водоём). Ул бадайымнарны без чоқодоқ. Бадайымда алты қой бар, ди.

**БАДАМЛЕ** [*фарс.*] *әстр.* өйдә пешерелгән прәннек (пряник домашнего приготовления).

**БАДИЙА** [*рус.* бадья] **1.** *чст.* кое чиләге (бадья, колодезное ведро). Әрәмәдә теге бадийа белән ала торган су бар; **2.** *нгб.-крш.* агач чиләк (деревянное ведро). Бадийалар була йы элек; **3.** *нгб.-крш.* зур чиләк (деревянное ведро, конное ведро). Бадийа белән су китерәбез.

**бадийа чиләк** *нгб.-крш.* к.: **бадийа 3.** Бадийа чиләк су китерергә awыр була.

**БАДИЙАН 1.** *мам., бәр.* кечкенә агач табак (маленькая деревянная чаша). Монда алып килеп салган әле бер бадийанны, мин аш салырға әзлим дә әзлим. Бәрәңгене бадийанға салып қына җywарсын. – *мам.* Қабықларын бадийанга сыпырып төшер. – *бәр.*; **2.** *минз.* тәлинкә (тарелка); **3.** *минз.* бал яки май сала торган капкачлы савыт (специальная посуда с крышечкой для мёда и масла).

**бадийан айақ** *бәр.* к.: **бадийан 1.**

**бадийан кywагы** *чст.* к.: **албуй II: албуй саты.**

**бадийан үләнминз.** к.: **алма I: алма геле.**

**бадийан чәчәк** *дөб., мам., блт.* бадьян чәчәк (сивец луговой).

**БАД'ЙА** [*рус.* бадья] *чст.* к.: **бадийа 1.**

**бад'йалы кыйы** *лмб.* сиртмәле кое (колодец с журавлём).

**БАД'ЙАН I 1.** *минз., т.кам-крш., дөб.* кечкенә савыт (небольшая посуда). Таш бад'йанға салып бир сөтнө. – *минз.* Эчәрләр идем бал булса, Бад'йа-

ны бақырдан булса (*хал. жыр.*). – *т.кам.-крш.*; 2. *мәл.* касәдән зуррак савыт (деревянная чаша); чаг.: **бадийан 1**. Бер бад′йан катык ашадым.

**БАД′ЙАН II**: **бад′йан бөрү** *мам.* к.: **кәрәз: кәрәз бөрү**. Бад′йан бөреп күлмәк тектем.

**БАДЫЙА** [*рус.* бадья] *эчк.* к.: **бадийа 3**.

**БАДЫЙАН** *дөб.* к.: **бадийан 1**.

**БАДЫРАМАУ** *байк.* үсмәү, үсеп китә алмау (не приживаться, не укореняться). Айу табаннарын утыртмадым, ул бездә бадырамый.

**БАЖАҚ** *тара.* ук очлыгы (наконечник стрелы).

**БАЖҚАҚЛЫ** *әстр.* каптырма (застёжка).

**БАЖҒАРКА** *кузн.* к.: **баштакта**. Башчыма бажарканы бирче.

**БАЗ** *к.-уф.* к.: **гелбәч**.

**баз йандыру** *минз.* махсус чокырларда нарат, каен кебек агачларны яндырып, сумала, дегет һ.б. кудыру (гонка дёгтя, вара и пр. из сосны, берёзы и др. в специальных ямах).

**баз йандыручы** *минз.* сумала, дегет, вәр һ.б. кудыручы (тот, кто гнал дёготь, вар и пр.).

**баз текмәләү** *чст.* базны бурау, стеналарын агач белән ныгыту (сделать сруб для погреба, укрепить его стенки деревянным срубом).

**җәйәүле bad** *минз.* подвал шикелле эшләнгән кар базы (погреб типа подвала, землянки).

**қыр bady** *тпк.* бәрәңге базы (картофельная яма). Пер ынтыр пәрәңкесе керә җada қыр bадына.

**суқыр баз** *минз.* к.: **қыр bady**.

**сөт базы** *чст.*, **өй базы** *мам., т.кам.-крш.* к.: **гелбәч**. Ике песи баласы үстерәләр алар, гел өй базында тоталар. – *т.кам.-крш.*

**БАЗ′А** *миш.д.* баҗа (свояк).

**БАЗАР** *бәр.* якшәмбе көн, базар көн (воскресенье). Базар сайын мунча йағадырыйық.

**базар алды** *минз.* шимбә (суббота). Кийәүләп җәри қайсысы, атна кич килә икән, базар алды қайтып китә шунда, элек шундый хәлләр булған, сыйырын сатып, бурасын сатып кийәү сыйлаған.

**базар кен** *карс., чст.* к.: **базар**.

**БАЗАРЛАУ** *перм.* базарга бару, базарда кибетләргә кереп әйбер алып йөрү (ходить на базар, делать покупки). Ақча алалар да базарлыйлар, ди, шунда, Чирнушкада.

**БАЗАТУ** *злт.* 1. интектерү (мучать). Тул′ке мине күзем генә базатты; 2. ялыктыру, туйдыру (надоедать). Гел қарабодай ботқа базата бит ул.

**БАЗАУ** *злт.* курку (не решаться, не рисковать). Шуннан азақ барасым килмәде пысрақтан базап. Әнкәй базап тора сыкмасқа.

**БАЗДУШ** [*рус.* воздушный] *нгб.-крш., злт., минз., стрл.* саман, саман кирпеч (саманный кирпич).

**БАЗДУШНЫЙ** [*рус.* воздушный]: **баздушный өй** *нгб.-крш.* саман өй, балчыкка салам катнаштырып ясалган кирпечләрдән салынган өй (дом из самана); чаг.: **ваздунай**.

**БАЗИ** *м.-кар.* к.: **баз′а**.

**БАЗЛАВЫК** *хвл., чпр.* сикәлтә, юлдагы чокырчакырлар (ухабы, рытвины, колдобины). Базлавыкта чанадан төшәм дә калам. – *чпр.* Базлавыктан барасын, тигездән бар. – *хвл.*

**БАЗЛАУ** *злт.* әрнү, әрнеп авырту (ныть). Табан астым базлап тора.

**БАDЛАУ** *тпк.* базга салу (опускать в яму или погреб). Ике bad bадлайым, пәрәңке уңа бик. Перүdем алтым, перүdем bадладым пәрәңкене.

**БАЗНАЙТ′: базнайт′ итү** *злт., трбс.* батырчылык итү, батырчылык кылу (решаться, осмеливаться). Шулхәдәрле базнайт′ итеп суға төшәргә көз көне. Базнайт′ итеп әйтмәдем. – *злт.*

**БАЗЫҒЫ** *том.д.* йөреше (походка).

**БАЗЫЙАН** *мам.* к.: **бадийан 1**. Бер базыйан аш та эчми.

**БАЗЫҚ** *т.я.-крш.* юан – бау, җеп, эчәк һ.б. турында (толстый – о верёвке, нитке, кишке и т.п.). Базык эрләгән, йуwанырак.

**базык эчәге** *т.я.-крш.* юан эчәге (толстая кишка). Базык эчәге awырта.

**БАЗЫҚ** *том.д.* бикле (запертый – о двери).

**БАЗЫҚТУ: базықту ат** *том.д.* тиз йөри торган ат (ходкая лошадь).

**БАЗЫНУ 1**. *лмб.* басымчак итү, әрсезләнү, әрсезлек күрсәтү, артык кыюланып китү (проявлять бесцеремонность, беззастенчивость). Базынсалар, биздererлеге калмый бу ыланнарны; 2. *чст.* ышану, ышаныч күрсәтү (доверять).

**БАЙ I 1**. *нокр., глз., лш.* хуҗа (хозяин). Тее йәшел йабулы ийнең байы йаман бай ыйы. Бу итнең байы кем? – *глз.* Өйдәме байлар? – *лш.* Кем бай қатын була, мә, чәй йасама утыр (диләр). – *нокр.*; 2. *нокр., глз., кргл.* к.: **абышқа 1**. Байым эшли, үзем йуқ. Минем бай белән ул бертуған. – *глз.* Минем байым кисез. – *нокр.* Монда қайтқач балаларым үлде, байым үлде. – *кргл.*; 3. *глз.* идарә итүче, җитәкче (руководитель). Колхоз бай. Ышкол бай. Awыл бай.

**БАЙ II** [*рус.* пай] 1. *т.я., лш., кмшл., мәл., чст.* өлеш (доля, пай). Минем байға тийергә тиеш. – *трх.* Күршеләрең байын да салгансың ашқа тозны. Менә алар байы тәрилкәдә инде. Мин ике чиләк таш җыйып қуйдым инде үз байымы. – *лш.* Анарға ике бай салырга тийешле. – *кмшл.* Мин үз бай печәнемне чаптым инде. – *мәл.*; 2. *минз., стрл.* көтү чиратын исәпләү өчен билгеләнгән берәмлек (единица измерения для определения очерёдности пастьбы стада). Бер сыйыр бер бай, дүрт сарық бер бай, башына өч тәңкә, менә безнең бай җарым, бер сыйыр да ике сарық. – *минз.* Көтүчегә бездә бай башыннан микән? – *стрл.*

**ата байы** *т.я.* атадан калган мирас (наследство, доставшееся от отца). Бу йорт миңа ата байы булып тидийе. – *нрл.*

**байын бирү** *нрл., трх.* кирәген бирү (наказывать, взгреть). Бирә байын малайның. – *трх.*

**БАЙ III** *блт.* бау (верёвка). Чиләк суға төшсә, ырғақлы байға бәйләп алалар.

**БАЙАНАҚ** *лш., каз.ар.-крш., нгб.-крш.* бая, баягынак (недавно, давеча). Байанақ қына чыгып китте. – *лш.* Байанақ исәпләп қуйдым. – *каз.-ар.-крш.* Байанақ қайнамый йы самawыр. – *нгб.-крш.*

**б а й а р** [*рус.* бояр]:

**байар ағачы** *мам.*, **байар куwагы** *чст.* к.: **қузақ: қузақ ағачы**.

**байар мәләше** *чст.* к.: **байбай**.

**байар шелеге (шөләге)** *кргл., бгрс.* к.: **кузак: кузак ағачы.**

**БАЙБАЙ** *дөб.* карга миләше (бузина). Байбай қортларға, бөжәкләргә хут бирми ул.

**байбай ағачы 1.** *дөб., блт., байк.* к.: **байбай.** Бу байбай ағачы самаwыр ағарта торған. – *блт.*; **2.** *бөрг.* к.: **кузак: кузак ағачы.**

**БАЙБАҚ** *том.д.* оек (чулки).

**БАЙҚАУ** *кргл.* к.: **бағу 1.** Байқап маташмадым инде. Шул җирдә буразна булғанмы, байқамый қилгәнме?

**БАЙЛАН 1.** *тбл.* карагай (лиственница); **2.** *твр.* ақ чыршы (пихта).

**БАЙМАК** *срг.* к.: **dywадак 2.** Баймак мин, кемем дә йуктыр.

**БАЙМАҚ** *брб.д.* башмак (башмаки, домашние туфли).

**БАЙНАҚ** *бәр., каз.ар., минз., перм., т.кам.-крш.* к.: **байанақ.** Байнақ килгән ийе. – *бәр.* Байнақ үләнсалган идем. Байнақ син миңа ақчаны артық биргәнең. – *мам.* Байнақ қына үзебездә чәй эчтек. – *блт.* Байнағрақ уйанған идем дә. – *т.кам.-крш.* Байнақ әле Кәшифә барында да керде. – *минз.*

**БАЙРАК** *м.-кар.* тау, таулы җир (холм, гора, гористая местность); чаг.: **қаш.** Байрак ул безне урман үзе, анда гура безне. Мирзаның йире бире байрак йанында, потом Сукей артында йылга буйында иде.

**БАЙСА'ТАЙ** *кас.* озын буйлы, таза гәүдәле хатын турында әйтелә (говорится о женщине крупного телосложения); чаг.: **алапа.**

**БАЙТАҚ** *төм., тара.* **1.** киң, киң җәелгән, иркен (обширный, широко раскинутый, просторный); **2.** күп, күпсанлы (много, многочисленный).

**БАЙТКА** [*рус.* батька] *к.т.*, **БАЙТКӘ** *трбс.* якын итеп эндәшү формасы (форма ласкательного обращения). Эй, байтка, этийең өйдәме? – *к.т.*

**БАЙЦЫЛЫҚ** *тара.* муллык (богатство, достаток). Қәсер байцылық қый, ашағаның алтыңта, ашамаганың артыңта.

**БАЙЫҒУ** *перм., минз., к.-уф., злт.*, **БАЙЫГУ** *стрл.* баю, муллыкта яшәү (богатеть, разбогатеть, жить в достатке). Аңқы туғаннары хәзер байықтылар. Қыз байықты инде, бағ, ызба бетерделәр. Элгәре байлар безнең арқада байыққаннар. – *перм.* Хәзер бик байықты инде халық. – *минз.* Азақ байығып киттеләр. Халықны байықтырырға тырыша. – *злт.*

**БАЙЫҚЛАНУ: күңел байықлану** *мам.* канәгатьләнү (удовлетворяться, получать удовлетворение). Күңелем байықланды инде бу хәлдән соң. Аның шулай йөргәнен күргәч, күңелем байықланды инде.

**БАЙЫҚЛАУ** *каз.ар.-крш.* саклап тору, берәр нәрсәгә багышлап тоту (специально беречь, бережно хранить для чего-либо). Алған оном бар ыйы, шуңа байықлабрақ барған ыйым.

**БАЙЫРАК** *м.-кар.* к. **байрак.** Күгән байыракта үсә.

**БАКА I** *тмн.* чулпы (женское накосное украшение). Бырын катыннар чәчләренә зур челтәрле бакалар бәлиләр иде.

**манитлы бака** *тмн.* тәңкәле чулпы (женское украшение).

**таж бака** *кузн.* көмеш кысага асылташ утыртып һәм аңа көмеш тәңкәләр саплап беркетелгән медальон сыман бизәнү әйбере (женское украшение из драгоценного камня в серебряной оправе, украшенной по окружности тремя серебряными монетами; надевалось оно наподобие медальона на шею). Таж баканы бун'га тагалар иде мәрҗән урынына.

**б а к а II** (лягушка):

**бака йафрагы 1.** *стрл.* к.: **бақа йафрағы; 2.** *мәл.* к.: **бақа: бақа ғөле.**

**бака кыргасы** *срг.* к.: **қаршуwа.**

**бака түшәге** *мәл.* бака ефәге (нитчатка, лягушачий шёлк).

**бака үләне (үләме)** *чст., тмн.* к.: **бақа: бақа қабығы.**

**качылы бака** *чст.* кысла (рак).

**б а қ а** *урт.д.* бака (лягушка):

**бақа ғөле** *т.я., каз.ар.* карабодай гөле, бегония (бегония).

**бақа йафрағы** *бөре., минз., злт.* үги ана яфрагы (мать-и-мачеха).

**бақа йефәге** *минз.* бака тәңкәсе (ряска трёхдольная).

**бақа қабығы** *эчк.* бака яфрагының барлык төрчәләре (подорожник).

**бақа қазаны** *т.я.* к.: **қаршуwа.**

**бақа тәңкәсе** *каз.ар.* к.: **бақа қабығы.**

**бақа үләне 1.** *мам.* к.: **бақа қабығы.** Бақа үләнен, қайнар суга пешереп, шешкә йабалар; **2.** *трх.* к.: **бақа йафрағы.**

**БАКАБАЛЫК** *мәл., хвл.* чукмарбаш (головастик).

**БАКАWАЙ (?): бакawай эшәл** *бәр.* йон белән киже мамык катыш бәйләнгән шәл (шаль, связанная из шерстяной и хлопчатобумажной пряжи).

**БАКАВЫЗ** [*рус.* пакгауз] *чпр.* иген сала торган зур ишекле амбар (амбар с большими воротами для хранения зерна).

**БАҚАҚАЙ** *минз.* к.: **қаршуwа.** Бөтен җар буйларын бақақай қаплаған.

**БАККЫНАСЫ** *мәл.* гаҗәпләнүне белдереп әйтелә торган сүз (слово, выражающее удивление).

**БАҚМАЧЫ: бақмачы булу** *перм.* кеше кулына калу, кеше күзенә калу, кеше ярдәменә бик мохтаж булу (нуждаться в посторонней помощи, напр., из-за плохого состояния здоровья). Таза булмадисә, чирле булдисә, ул бақмачы була сийә. Билеңне өзеп ташларсын, безгә бақмачы булырсын.

**БАҚРА: бақра гөлө 1.** *минз., бөре., байк.* бакра гөле (петунья); **2.** *т.кам.-крш.* үрмәле гөл (вьюнок).

**БАҚРАҖ** *тбл.* чуен, чүлмәк (чугун, чугунок).

**БАҚРАЧ 1.** *минз.* бакыр табак (медный таз); **2.** *минз., т.я., мам., лш., нгб.-крш., т.кам.-крш., кргл.* к.: **багырча.** Бер қоштабаққа ике генә бақрач китә. Ике бақрач белән туйасың инде итлаш булса. – *мам.* Бер бақрач аш сал. – *нгб.-крш.* Қашық булмаса, бақрач қуйасың. – *кргл.*

**БАКРАЧ** *чст., стрл.* к.: **багырча.**

**БАКСАҢ** *миш.д.*, **БА'САН** *кас.* бәлки (может быть, возможно). Ба'сан, җыламас. Ба'сан, 'илеп чы'ар. – *кас.*

**БАКЦА** *чст., срг.* к.: **алмалык**.

**цаwыл бакца** *байк.* к.: **бакча: ағач бакча**. Цаwыл бакцага саwытларга җыйганмын кура йеләкне, карагатны.

**БАҚЦАР** *төм.* к.: **пақцар**. Бақцарға ир балалары булғац ойа йасыйлар.

**БАҚЦАРҒА** *төм.* к.: **пақцарға**.

**БАКЦЫ** *срг.* к.: **бақчи**.

**БАҚЧА** *каз.ар., т.я.* к.: **алмалык**. Бақчам бик әйбәт минем, үзән. – *мам.*

**ағач бақча** *мам.* өй янындагы җимеш бакчасы (фруктовый сад). Ағач бақчаның эрәшәткәсе җимерелде, таwықлар керә.

**бақча алу** *мам.* бәрәңге алу (копать картофель). Бақча алыр wахыт та җитте.

**бақча күмү** *мам.* бәрәңге утырту (сажать картофель). Бақча күмгән wахытта қайтты.

**бақча сорат** *перм.* карачкы (пугало в огороде).

**җимеш бақча** *перм.* яшелчә бакчасы (огород).

**БАҚЧА 1.** *чст., кузн.* к.: **алмалык**; **2.** *мәл.* кабер өстенә тотылган киртә, рәшәткә, чардуган (решётка, изгородь – на могиле).

**БАҚЧИ** *мам., трх., перм., кмшл.*, **БАКЧИ** *чст., чпр., мәл.* к.: **агале**. Мин, бакчи, кас'ын алам? – *мәл.* Монда бер француз йаулыгым бар әле, бакчи. – *чст.* Шаһитлар бар бит, бақчи, монда йазып утыралар. – *трх.* Бақчи, балаларым нихәтле печән җыйдылар! – *мам.* Бақчи, бу кем микән димим дә. Өсләрең, бақчи, тудан ғына. – *минз.*

**БАКЧЫ** *кузн., хвл.*, **БА'ЧЫ** *кас.*, **БАҚЧЫЙ** *кмшл.* к.: **бақчи**. Бакчы, эшләп килә вет. – *хвл.*

**БАҚЫЙ** *перм.* абына-сөртенә йөрүче кеше (человек, который ходит спотыкаясь).

**БАҚЫЛ** *тбл.* к.: **қатымыш**.

**б а к ы р** (медь):

**бақыр йылан** *минз.* кәлтә еланы (ящерица).

**бақыр тәтәй** *перм.* бакра (куколь).

**БАҚЫРҒАЧ** *бөре.* к.: **қаршуwа**. Таныптан (*елг. ис.*) бақырғачлар җыйып қайтқан.

**БАҚЫРТМА** *перм.* сыбызгы (свисток). Әйдә, қырықтартмачылар килгән, бақыртма алып пирәм, ди.

**бақыртма печин** *перм.* к.: **печин I: ғүзәлдәшле печин**.

**БАКЫТ** [*ғар.*] *чпр.* к.: **бағыт I**. Бакытың булса, кицкә сүләшеп утырырга кил.

**б а л** (мёд):

**ақ бал** *бәр.* ачы балның бер төре (один из алкогольных сортов медового напитка домашнего приготовления).

**бал ағызу** *минз., перм.* кәрәзне изеп, балын агызып алу (отделение мёда от сот путём выдавливания и сливания его в другую посуду).

**бал ашама'а** *кас.* элек кызны кияүгә биргәндә туйга кадәр үтәлә торган йолаларның берсе: катлама ашау мәҗлесен үткәргәннән соң, ярәшкән кызның иптәш кызларын бал ашау мәҗлесенә җыеп, бал белән сыйлау (один из старинных свадебных обрядов).

**бал ашау** *хвл.* туйдан соң үтәлә торган йолаларның берсе (один из старинных свадебных обрядов). Ике йакта да туй ун'ийлар. (Аннан соң) катыннар бал ашарга киләләр.

**бал башлау** *трбс.* туй йоласы: кыз ягында туй мәҗлесе вакытында кызның абыйсы өстәлгә бал куя һәм, бүләк биреп, мактау сүзе белән каба, башка кунаклар да бал кабып бүләк бирәләр (один из старинных свадебных обрядов, согласно которому родственники невесты и приглашённые на свадьбу гости преподносят подарки).

**бал җау** *т.я.* яфрак балы (падевый мёд).

**бал қалач** *перм.* сушки. Бер кила бал қалач алдым.

**бал қарау** *перм.* умартадан бал алу, бал суырту (взятие мёда из улья, выкачивание мёда). Әле қарамаға башладығызмы бал?

**бал кисү** *тмн., перм.*, **бал 'исew** *кас.* к.: **бал қарау**. Бүген калхузда бал кисәләр. – *тмн.* Бал кисә, чәй эчмәгә чақырмый, өч бидрә бал кисте берүзенә. – *перм.*

**бал китерү** *трх.* кызны килешкәч, егет ягыннан кыз ягына бал, чәй, акча китерү йоласы (передача родителями жениха соотвествующего количества мёда, чая, денег родителям невесты после сговора).

**бал қойу** *перм., злт.* к.: **баллау II**.

**бал қуу** *кмшл.* к.: **бал қарау**. Йаңы ғына қуган йәш бал.

**бал күкән** *әстр.* умарта корты (пчела).

**бал менү** *минз., бөре.* к.: **бал қарау**.

**бал пышу** *минз.* бал агызып алу өчен кәрәзне изү (мять соты для извлечения оттуда мёда и сливания его в другую посуду); чаг.: **бал ағызу**.

**бал сыгу** *минз.* к.: **бал қарау**.

**бал туйы** *хвл.* к.: **бал ашау**. Аннан нәстә белән бара бал туйына.

**балы кисү** *перм.* эчеп җитү, өлгерү (о завершении процесса брожения). Балның ачып туқтағач, шикәре беткәч, балы кискән була.

**БАЛА I 1.** *хвл., мәл., кузн., глз., нокр.* к.: **бәкәй 1**. Аранга чыгара идек куй балаларын. – *хвл.* Куйның эченнән баласы чыккан, бываз килеш суйганнар. – *мәл.*; **2.** *каз.ар., эчк., перм., глз., нокр., хвл.* бәбкә (гусёнок, утёнок). Қаз бала. – *эчк.* Қаз балаларны суға қу. – *глз.* Каз, үрдәк балаларым күб быйыл. – *хвл.*; **3.** *перм.* кечкенә (маленький). Хәнәфи бала қазан алдыйы икене, шуныңда җудым баланы. Бала чана.

**бала баса торған** *перм.* утыра торган – тавык турында (наседка). Бала баса торған чебешем төшкән, аны көтәп тора ашарга.

**бала җылға** *перм.* к.: **бала йылға**. Суны бала җылғадан ғына барып ал, қызым.

**бала йылға** *перм.* кечкенә елга, чишмәдән агып чыккан су (речка, маленькая речушка; ручеёк, вытекающий из родника). Бала йылғаға-фәләнгә салмыйлар мунчаланы.

**бала қорт** *бөре.* аерым умартага сосып урнаштырылган күч, яшь күч (рой, помещённый в отдельный улей; молодая семья пчёл).

**бала матча** *чст.* түшәм такталарын ике яктан тотып тору өчен куелган аркылы агачларның берсе (одна из планок, прибиваемых поперёк потолочных досок у стыка их со стеной).

**бала пич** *т.я.* зур мич янына чыгарылган плитә (плита, приделанная к русской печи).

**бала шәл** *трх., к.-уф., чст.* шәльяулык (платок небольших размеров, нередко набивной или вышитый по углам).

**чебеч бала, чипи бала** *перм.* чебеш (цыплёнок). Бар әле, чебеч баланы қуwып чығар әле, балам. Қычқыра торғаны әтәч чебеч бала була, икү-өчөү мыса әтәчләре.

**БАЛА II** *себ.* малай (мальчик). Ике татар ғызы, пер татар баласы гилә. – *брб.д.*

**бала жиңеләйтү** *перм.* бала тудырганда ярдәм итү, кендек әбисе булу (быть повитухой, повивальной бабкой).

**бала йатқы** *төм.* к.: **йатқылық 3.**

**бала пүкән** *мам.* к.: **йатқылық 3.**

**берибәч бала** *брб.д.* кечкенә бала (дитя, ребёнок).

**йорт башы бала** *байк.* эти-әнисе йортына хуҗа булып калырга тиешле бала, гадәттә кече малай, варис (тот из детей, кто наследует хозяйство, дом родителей; наследник). Йорт башы балаң үлгәч ни, ини ушын йуйган.

**қул баласы** *минз.*, **кул баласы** *стрл.* яшь бала (младенец). Монау йакта ана урманыбыз бар, шунда эшлибез, кул баласы бар. – *стрл.*

**қыз бала** *перм.* к.: **балдыз 2.** Қыз балалар бармы, ул балалары бармы – аларға бишбармақ бирә килен.

**ул бала** *перм.* к.: **жанаға(й).** Жиңгә кешесе ул бала белә қыз балаға бүләк алып килә. Ул балаларым бар ий, қызлар алдылар артаба.

**БАЛА III** *брб.д.* к.: **келисап.**

**БАЛА IV** *перм.* к.: **була.** Сийа бала мин көннәр буйы өйдә утырам түгелмени?

**БАЛА-БАҚРА** *твр.*, **БАЛА-БУТА** *каз.ар.-крш.* бала-чага (дети, ребята). Бала-бақралары awылта. – *твр.* Үләсен белми бала-бута, төшәләр дә чумыналар. Бала-буталары күп ул сеңнемнең. – *каз.ар.-крш.*

**балawыз** (воск, вощина, соты):

**балawыз қабарту** *бөре.* ясалма кәрәзнең күзәнәкләрен тирәнәйтеп бал салырлык итү (надстраивать соты). Қортлар, балawызны қабартып, бал жыйғач, кәрәз дибез инде.

**балawыз жawы** *т.я.* к.: **мәл′хам.**

**БАЛАГАН** [*рус.*] **1.** *перм., минз.* шалаш. Қарawылчының балаганы йылғаның қырында уқ. – *перм.*; **2.** *злт.* яланда вакытлыча яшәү өчен оештырылган вагон, кыр вагоны (полевой вагон, вагончик). Көтүселәр балаганда куна. Балаган қордылар урман эчендә; **3.** *трх.* утын сарае (сарай для дров, дровяник).

**БАЛАЙАК I 1.** *кузн., лмб., карс., срг.* бал тәпәне, бал савыты (кадушка, посуда для хранения мёда). Балайак-балайак бал алганда чөчөмиде, кодагый? Кызың алып киткәндә йыламинде, кодагый (*хал. жыр.*). – *кузн.* Агацныкы була балайак. – *лмб.* Туй ничег уза, wат туй шулай уза, бал балайаклап. – *карс.* Кийәү кызга акца биргән, бал бер балайак, пелуш тун. – *срг.*; **2.** *чст., мәл., срг.* к.: **ләнгәч.** Әпәй изә торганга без балайак дибез инде. – *чст.* Әлдә балайагым йумаган апара куйарга. – *срг.* Бер балайак камыр куйдым. – *мәл.*

**БАЛАЙАК II** *кузн.* туй алдыннан үткәрелә торган мәҗлес (один из свадебных обрядов: званый обед перед свадьбой).

**БАЛАК** *стрл.* к.: **балдақ.** Ызын балаклы ыйык кимәгәч, ыштан балагы күренә шул. Итек балагымда пәке.

**БАЛАКА** *миш.д.* сука башы (рукоятка сохи).

**БАЛАҚАЗАН** *перм., к.-уф.* котелок. Йылға буйында йағып, балақазан тутырып бәрәңге пешердем, чәй қайнаттым. – *к.-уф.*

**БАЛАКЛАНДЫРУ** *т.я.-крш.* төчетү, төчетеп салат ясау (сделать, приготовить солод). Бич жагып, (арышны) калын салып, тагын балаклandыра, аннан жука салып киптерә. Кибеп житкәннән соң, тирмәнгә акитеп ын жасап и су кан′атып, былгатып куйа шал ынны, у төпкә китеп утыра. Эстен кабырлап куйа пар чыкмастан.

**БАЛАКЛАУ** *т.я.-крш.* шикәр салу, баллы итү (делать сладким, подсластить). Әдә, балаклап жибәр чәйне.

**БАЛАЛАНУ** *тбл.* **1.** бала табу (родить детей); **2.** балалар үрчетү (завести детей).

**БАЛАЛАУ** *хвл., кузн., чст., перм., нокр., том.д.* к.: **бәкәйләү.** Элгәре сарык эчне балаласа, хәйерлегә тегел дип әтәләр иде, хаз′ыр уйлаш та йук. – *чст.* Мәдәкийәнеке балалаған ийе сарық, қысып үтергән берсен. – *перм.* Сарығым балалады, кәзә балалай. – *нокр.* Қуй балалапты, перәwе қуцқар, перәwе қысцығац. – *том.д.*

**БАЛАЛМА** *лмб., чст.* к.: **бағалма 1.** Балалма садлары да бармы? – *лмб.*

**БАЛАМ** *бәр., т.я.* иркәләп эндәшү сүзе (одна из форм ласкового обращения). Апай, балам-апакай. Әни, балам-әнкәй. Ипи, балам-ипикәй. Аш, балам-ашқай. – *бәр.* Абыстай, балам, нигә бер дә килеп утырмыйсың? – *к.т.*

**балан I** (калина):

**балан қатығы** *трх.* баланга шикәр комы һәм салат оны салып мичтә пешерелгән ашамлык (блюдо, приготовленное из калины с песком и солодом).

**БАЛАН II** [*рус.* волан]: **балан итәк** *лмб., нгб.-крш.* хатын-кызлар күлмәгенең очына тотыла торган киңрәк бала итәк (сравнительно широкая оборка, пришиваемая к низу женского платья). Балан итәкле күлмәк тегә иде әни. – *лмб.* Балан итәкле күлмәк кидек элек. – *нгб.-крш.*

**балан тайақ** *перм.*, **балан үрдәк, балан чәчәк,** *срг.* к.: **бармак: балан бармақ.**

**БАЛАНЧИ** *том.д.* карабүрек (снегирь).

**БАЛ′АС** [*рус.* балясы] *м.-кар.* култыкса (перила). Күперне бал′аслары нинди матур иде.

**БАЛАТ I** *тбл.* пулат (ташпулат), сарай (палаты, дворец). Бардылар, бир йәй бүткәнцә бардылар, бир таш балат күрделәр.

**БАЛАТ II** [*рус.* полати] *төм.* к.: **иргәнәк 1.** Балат пашта йатабыс кәпләшеп.

**БАЛАТПАШ** [*рус.* + *тат.*] *төм.* к.: **иргәнәк 1.**

**БАЛБАН** *хвл., мәл., чст.* юан, симез, еш кына авыр хәрәкәтле кеше яки хайван турында әйтелә (говорится о тяжёлом на подъём, слишком полном человеке или слишком упитанном животном). Ыланы балбан шикелле таза иде выт, ни булган, кәбәм, үзенә? Кызы тазарган, әмән балбан булган бит. – *хвл.*

**БАЛБАҚСЫ** *твр.*, **БАЛҒУРТ** *тбл.* к.: **мурта 2.**

**БАЛДАҚ** *минз., мам.* куныч, балтыр (паголенок). Ақтанышта озын қунычлы ойоқны балдақлы ойоқ диләр. Балдақлы калуша була торған ийе. Итекнең балдақлары монда қәдәр. – *минз.*

**БАЛДАК 1.** *хвл., мәл., карс., кузн., шрл., стрл.* к.: **балдақ.** Чолка балдагы йыртылган. Итекләренең балдаклары киңрәк булган. – *хвл.* Итек балдагы тузган. – *мәл.* Ул выт шылай чике балдаклы читекләр миндә бар иде. – *кузн.* Ыйыкларның балдаклары кыска, төшеп күренеп тораларр. Иртән итек кигән идем, балдакларын сызганган идем. – *шрл.* Ызын балдаклы ыйыкны салдым да бозауны тышаулап калдырдым. Балдагын кисеп алалар да икенче пиманы төплиләр. – *стрл.*; **2.** *клд.* чалбар балагы (штанина). Ирләрнең брука балдагыннан күлмәк тегеп кигезә идек (балаларга).

**БАЛДЫ** *брб.д.* к.: **балдыз: қыз балдыз.**

**БАЛДЫЗ 1.** *минз., перм.* хатынының сеңлесе яки энесе (младшая сестра или младший брат жены). Сил′па персидәтеле Ахметов Сәит минеке балдыз була, сәләм әйтте йезнән дийерсең. – *перм.*; **2.** *эчк.* иренең сеңлесе (младшая сестра мужа). Балдызым Йаңawылда (*ав. ис.*) тора.

**балдызға алу** *глз.* ящь хатын итеп алу, икенче хатынга өйләнү (вторично жениться, взять вторую жену). Ул кызны балдызга алгалады wул.

**балдызга бару** *глз.* икенче хатын булып бару (стать второй женой).

**ир балдыз** *бөре., злт.* хатынының энесе (младший брат жены); чаг.: **балдыз 1.** Балдызы белән ир балдызын ийәртеп китеб утырған. Анда балдыз бар Мөнир исемне. – *злт.*

**қыз балдыз** *бөре.* балдыз, хатынының сеңлесе (младшая сестра жены).

**БАЛДЫКАЙ** *хвл.* туйда җырлана торган шаян җыр, такмаклар (шутливые песни, частушки, которые поются на свадьбе). Балдыкайны катыннар йырлый. Балдыкайны пич такта сугып йырлыйлар: «Бара идем йул белән, балдыкай, Очырады гурынча, балдыкай, Гурынчада кодача, балдыкай, Пешерәдер йывача, балдыкай».

**БАЛДЫР** *әстр.* метис.

**БАЛДЫРГАН** *карс.* к.: **бәбәк III.**

**балдырған бәбәк** *каз.ар.-крш.* ящь балтырган сабагының йомры башы (круглая головка молодого стебля борщевика).

**БАЛИҚ** *перм.* менә сиңа кирәк булса! (вот тебе на!). – Нийә килдең? – Менә сиңа балиқ, киләсе килгәнгә килдем!

**БАЛКА** [*рус.*] *тмн.* к.: **матка.**

**БАЛЛАҚ** *трбс.* шикәр тәме кергән (слащавый). Бәрәңге тунған, баллақ.

**БАЛЛАУ I** *мәл., срг., чпр.* к.: **бәкәйләү.** Әле төнә генә сарык баллады. – *мәл.* Кәзә, сарык баллады. – *чпр.* Кәзәм дүртне баллады. – *срг.*

**БАЛЛАУ II** *лш.* бал кую, бал ясау (готовить напиток из мёда). Ике чиләк кенә баллаған булганыйық. Җыйынға баллыйлар инде әммекәй җортта. Баллаған балны эчеп бетерә бара.

**баллы** (сладкий):

**баллы җау** *минз.* к.: **башмақ II: башмақ тәтәй.**

**баллы қywәт 1.** *бәр., дөб.* к.: **баллықай; 2.** *мам.* күзлут (пикульник красивый, жабрей); **3.** *блт., минз.* к.: **башмақ II: башмақ тәтәй.**

**баллы күбән** *әстр.* к.: **бал: бал күкән.**

**баллы cawыр** *мам.* к.: **баллы қywәт 2.**

**баллы тәтәй** *блт.* к.: **башмақ II: башмақ тәтәй.**

**баллы үлән, баллы чәчәк** *кргл., бгрс.* к.: **баллықай.**

**БАЛЛЫҚАЙ** *минз.* тукранбашның барлык төрләре (все виды клевера).

**БАЛ′НИК** [*рус.* валенок] *чст.* йон оекбашлар (шерстяные носки); чаг.: **чолкабаш.** Нугыма бал′ник бәлим.

**БАЛСУРҒЫЧ** *глз.*, **БАЛТУТАЙ** *нокр.* к.: **баллықай.**

**балта** (топор):

**балта дәдәсе** *м.-кар.* балта түтәсе (обух топора).

**балта үткере** *м.-кар.* балта йөзе (лезвие топора).

**балта әшләү** *блт.* балта эше эшләү (плотничать). Мин инде қырық җыл балта эшлим.

**тарақ балта** *перм.* аркылы балта, бура бурый торган киң балта (пазник, топор, которым рубят срубы).

**БАЛТАҚАН** *перм.* бер сүзне кат-кат сөйләүче турында әйтелә (говорится о человеке, любящем много раз повторять одно и то же).

**БАЛТӘТӘЙ** *минз.* к.: **баллы: баллы қywәт 2.**

**БАЛТУДЫҚ** *дөб.* бер йортта яшәүче килендәшләрнең бер-берсенә эндәшү сүзе (форма обращения жён двух братьев, живущих под одной крышей); чаг.: **абыстумачи.**

**БАЛТҮТИ** *каз.ар.-крш.* туган тиешле үзеңнән олы хатын-кызга эндәшү сүзе (форма обращения к старшей родственнице).

**БАЛТЫР** *хвл., кузн., мәл.* балтыр ите (икры ног). Кочок балтыраннан капкан. Су балтырына хат′ле үткән. – *мәл.*

**балтыр севәге** *кузн.* балтыр (голень).

**балтыр чүперәге** *лш.*, **балтыр чүпрәге** *чст.*, **балтыр чүпрәк** *каз.ар.-крш.* к.: **сарғыч: айақ сарғычы.** Балтыр чүпрәкләре йасыйлар ақ киндергә эшләп. Бистәр биргәннәр, балтыр чүпрәк биргәннәр җегеткә ағ алышқанда.

**БАЛТЫРАТУ** *т.я.* балакларны, оекларны салындырып йөрү (ходить со спущенными чулками или не засученными штанинами). Шушы җүwештә балақларың балтыратып қайа барасың, әби? Ана, Вәсимә тәтә килә, балақларын балтыратқан. – *нрл.*

**БАЛУАН** [*фарс.*] *тара.*, **БАЛҮАН** *том.д.* пәхлеван (богатырь). Бу бала күцлү, бик балуан булды. – *тара.*

**БАЛ′УК** [*рус.* валёк] *срг.* бәләк, кер бәләге (валёк для белья).

**БАЛУН** [*рус.* валун] *бәр.* коеның чылбыр урала торган үзәге, кое валы (колодезный вал, валик). Балунның қулы бәрмәсен. Қойоның балуны да, қой үзе дә тузған инде.

**БАЛЩАРҒА** *тбл.* к.: **пақцарғы.**

**БАЛЦЫ** *срг.* умартачы (пчеловод). Балцыга кердегез.

**БАЛЧАҒЫWАН** *твр.* к.: **мурта 2.**

**БАЛЧӘЧӘК** *чст.* к.: **башмак II: башмак тәтәй.**

**БАЛЫЙ** *нокр.* кызтәкә, хонса, ике җенесле (гермафродит).

**б а л ы к** (рыба):

**ак балык** *минз.* кырпы балыгы (белуга).

**арыш балыгы** *чпр.* эт балыгы (вьюн). Арыш балыгы ул – ашамый торган тәңкәсез вак балык.

**әситер** [*рус.*] **балык** *лш.* мәрсин (осётр). Мишәдә әситер дигән балык бар.

**бакыр балыгы** *тпк.* бәрде (хариус). Бакыр балыгының тәңкәсе булмай.

**балык бағу** *эчк.* к.: **балыклашу.** Майан (*күл ис.*) күлдә багалар балык.

**балык бағуцы** *эчк.* балык тотучы, балыкчы (рыбак). Балык бағуцы кеше күп бу awылда.

**балык чирақлау** *перм.* сөңге белән балык тоту (ловить рыбу при помощи копья). Төннә балык чирақларға йөрибез, салдау белән чәнчеп.

**боқортый балык** *кргл.* ташбаш (пескарь; бычок).

**зәңгелә балык** *дөб.* шыртлака, ертыш (ёрш). Зәңгелә балык лайлалы була, сырты чәнечкеле була.

**керәшен балыгы** *мам.* еланбалыкка охшаган тәңкәсез шома балык (один из видов угря). Бирсут йылгасында бәртәс, ташбаш, керәшен балыгы бар. Керәшен балыгын қайберәүләр ашый.

**қылыс балык** *злт.* кәлчәк (чехонь).

**күтәмә балык** *трх., чст.* к.: **боқортый балык.**

**майма балык** *стрл.* к.: **арыш балыгы.**

**мыжық балык** *каз.ар.-крш.* к.: **арыш балыгы.**

**сыла балык** *бөре.* судак балыгы (судак).

**тақта балык** *глз.* корбан балыгы (лещ).

**үрләү балык** *т.кам.-крш.* маймыч (малёк, малявка).

**БАЛЫҚЛАШУ** *нокр., глз.* балык тоту (ловить рыбу). Балықлашма барам. – *нокр.* Әтийе беле берги йерилир балықлашырга. – *глз.*

**БАНИ** [*гар.*] *брб.д.* фани (бренный мир, суета). Дөнйа бани, сөрмә аный, қуwып тоталмыйсың аны.

**БАНҚЫ** [*рус.* банка] *дөб.* чүлмәк (горшок). Әй, гөл банкысы бар бит.

**банкы чүлмәк** *дөб.* к.: **банкы.** Зур банкы чүлмәктә йасый җорт сырасы.

**БАПЛАНУ** [*гар.*+*афф.*-лану] *кргл.* иркәләнү (нежиться). Бер көнгә барганда бапланып тормыйсың инде.

**БАПЛЫ** [*гар.* + *афф.*-лы] *кргл.* уңган, булган (способный, умелый). Аш-суға шулхәтле баплы, Гал'а кебек беркем дә аш-су хәзерли алмый, ди.

**б а р** (есть):

**бар булыгыз** *срг.* исән булыгыз, сау булыгыз (будьте здоровы, до свидания). Бар булыгыз, майларым.

**бар күге** *т.кам.-крш.* бар булганы (то, что есть). Хәзер бит туганнар бар да читтә, килгәч ачык чырай кирәк, бар күген ашатып-эчертеп җибәрәсең.

**БАРАБИКӘ** [*рус.*] *том.д.* чыпчык (воробей).

**БАРАҚ** *тара.* шул вакытта, шул җирдә (в то время, на том месте).

**БАР'АМ** [*фарс.*] **1.** *миш.д.* бәйрәм (праздник); **2.** *срг.* аш, мәҗлес (поминки). Кицә бар'ам иде, илле бер кицәсенә укыдылар.

**бар'ам кылу** *срг.* бәйрәм итү (праздновать). Уңыш бар'амы кылдык укт'абрда.

**йымырка бар'аме** *срг.* пасха. Йымырка бар'амендә шының тәке малайлар ызбага керәләр дә әтәләр (иде): «Кыдый, кыдый ак таwык, Майа сала карт таwык, Әби-бабай үдәме? Бер йомырка бирәле. Тимерцегә барамын, тимер тукмак аламын, сугып башын йарамын!» Шылай кытнагац, малайга йымырка бирәләр.

**кызыл йымыртка бар'аме** *м.-кар.* к.: **йымырка бар'аме.**

**БАРАНАҚ** *том.д.* к.: **бәкәй I.**

**БАРАТА** *төм.* бу арада (на днях, в эти дни).

**БАРГАЗ** [*удм.*]: **баргаз каз** *глз.* к.: **дуwадақ 1.**

**БАРҒЫЛДАҚ** *том.д.* кара карга (грач).

**БАРИГА** [*рус.* варега] *чст., чпр., срг.* к.: **били.** Баригам кайа китте сын, шында гына куйган идем? – *чст.* Барига бәләп китердем ыланыма. – *чпр.* Барига белән ки, кулын туңса. – *срг.*

**БАРИНА** *әстр.* к.: **қамыраш II.**

**БАРИТКА** [*рус.* баретки] *срг., лмб.* туфли, ботинка (туфли, ботинки). Бариткаларым айагымны баса, кай шул турымны. – *срг.*

**БАРҚЫЛДАҚ 1.** *перм.* миләш чыпчыгы (дрозд). Барқылдақ миләшне ашый. Барқылдақ чыпчықтан зур, төннә килеп ашый паланны көтүләре белә; **2.** *перм.* к.: **пақцар; 3.** *перм.* к.: **бистурғай.** Барқылдақ басуда утыра wы қычқырып, чыпчық кеwек у, ашлығ арада була; **4.** *тпк.* үрдәкнең бер төре (один из видов утки). Барқылдақ үрдәге булғылаган ул.

**БАРҚЫЛДЫҚ** *перм.* к.: **пақцар.** Барқылдықлар килгән, күрдегезме?

**БАРЛАҚ** *трх.* яткын җир (залежная земля).

**БАРЛЫ-КӨРЛӨ** *блт., мам., лш., каз.ар.-крш., трбс.* к.: **аукатлы 1.** Барлы-көрлө кеше туйны бик җақшы итәр ийе. – *блт.* Барлы-көрлө кешеләр алар ғүмер-ғүмергә. – *каз.ар.-крш.* Әтәйләр барлы-көрләләр иде. – *трбс.*

**б а р м а қ** (палец):

**балан бармақ** *перм.*, **балан ийәк бармақ** *каз.ар., бәр., минз.*, имән бармак (указательный палец).

**бәбли бәпчек бармақ** *бәр.*, **бәләкәй бәпеч бармақ** *минз.*, **буби бармақ** *тара.*, **гөлгә чеби бармақ** *минз.* атсыз бармак (безымянный палец).

**гөлчәчәк бармақ** *бәр.* чәнчә бармак (мизинец).

**исемсез бармақ** *нокр.* к.: **бәбли бәпчек бармақ.**

**қайын бармақ** *дөб.*, **қарақ бармақ** *нгб.-крш.* к.: **балан бармақ.** Малайның қарақ бармағы шешкән. – *нгб.-крш.*

**кецкенә бәбәй бармақ** *тара.*, **кечкенә бармақ** *нокр.*, **күн күкеч бармақ** *минз., стрл.* к.: **гөлчәчәк бармақ.**

**күрсәткец бармақ** *тара.*, **күстинеч бармақ** *нокр.* к.: **балан бармақ.**

**сәнә бармақ** *злт.* к.: **гөлчәчәк бармақ.**

**сөйән бармақ** *минз.* к.: **бәбли бәпчек.**

**суқ бармақ** *тара.* к.: **урта тийәк бармақ.**

**тыкылыйк бармак** *перм.* к.: **гөлчәчәк бармак.**
**уйын кубыз бармак** *перм.* к.: **бәбли бәпчек.**
**урта тийәк бармак** *каз.ар., бәр., минз.*, **урта тирәк бармак** *перм.* урта бармак (средний палец).
**цыцалак бармак** *тара.* к.: **гөлчәчәк бармак.**
**чәнәкәй бармак** *бгрс., кргл.*, **чәнәчә бармак** *т.кам.-крш.*, **чәнки бармак** *мам.*, **чәнтекәй бармак** *нгб.-крш.*, **чәнти бармак** *блт.*, **чәнчәй бармак** *брб.д.*, **чәнчәкәй бармак** *минз.*, **чәнчекәй бармак** *брб.д.*, **чәнчи бармак** *бөре.*, **чәнки бармак** *лш.*, **чеңелте бармак** *нокр.*, **чинәчә бармак** *трх.*, **чиңги бармак** *трх.*, **чыгылыйк бармак, чыгыныйк бармак** *перм.* к.: **гөлчәчәк бармак.** Чәнчәй бармаққа йөзек шигелле чалып бәйлиләр йенне.

**б а р м а к I** (палец):
**балан ийәк бармак** стрл., **балан үрдәк бармак** *т.я.-крш.* к.: **бармак: балан бармак.**
**бәләкәй бәпеч бармак, гөлгә чеби бармак** *стрл.* к.: **бармак: бәбли бәпчек бармак.**
**кәт'еки бармак** *т.я.-крш.*, **күн күкеч бармак** *стрл.* к.: **бармак: гөлчәчәк бармак.**
**олы бармак** *глз.* баш бармак (большой палец).
**сөйән бармак** *стрл.* к.: **бармак: бәбли бәпчек бармак.**
**сыңарчак бармак** *лмб., кузн.* к.: **бармак: гөлчәчәк бармак.**
**урта тийәк бармак** *стрл.*, **урта тирәк бармак** *лмб., т.я.-крш.* к.: **бармак: урта тийәк бармак.**
**цәцә бармак** *чпр., срг.*, **чәчи бармак** *хвл.*, **чигә бармак, чиңгә бармак** *чст.* к.: **бармак: гөлчәчәк бармак.**
**чөмөмәки бармак** *т.я.-крш.* к.: **бармак: бәбли бәпчек бармак.**

**БАРМАК II** *кузн.* киги (спица у колеса).

**БАРМАК III** *чпр.* бавырсакның бер төре: йомыркага гына басылган төче камырны озынча формада кисеп майда пешерелә һәм шикәр комы белән катырыла (один из видов национального мучного блюда). Бармак пешерәм оланнарга, йулга да булыр. Он уңышлыгын бармак белдертә.

**БАРМАҚЦА** *тбл.* перчатка.

**БАРМАУ: йаратып бармау** *байк.* яратып бетермәү, яратып җиткермәү (недолюбливать). Кийәүне йаратып бармыйм, awылдагы йегете бигерәк акыллы иде.

**БАРМЫЙ** *перм.* тормый (не станет). Җywaш, кеше белән тиргәшеп бармый.

**БАРНАҚ** *мам.*, **БАРНАК** *т.я.-крш.* бармак (палец). Айак барнагым бака awызы қәдәр булып йарылган. – *мам.*

**БАРНАСКА** *т.я.-крш.* уймак (напёрсток). Алай әткистән белмиләр, барнаска диләр.

**БАРНАУ** *минз., стрл.* **1.** акча санау берәмлеге (денежная единица измерения). Безнең инәй сүлидерийе бороңголар ақчаны бер барнау, ике барнау дип саный торган булганнар дип. – *минз.*; **2.** өч тиенлек акча (трёхкопеечная монета). Барнау диләр ийе өч тиенне.

**БАРСЫБЫЗ** *глз.* барыбыз (все). Барсыбызны да алып барыгыз инде.

**БАРТАННАУ** *злт.* үпкәләп үч итү, үч итеп эшләү (сделать назло). Инәй мине суга йебәрми, әллә бартаннап үзе китерә. Үпкәләгән кеше дәшми, бу бартаннап тырт-мырт итеп йөри, сәнсеп.

**БАРТАННАШУ** *злт.* к.: **бартаннау.** Қызына бер эйткән, ике эйткән, шуннан үзе бартаннашып киткән.

**БАРУ 1.** *тмн., хвл.* кайту (возвращаться). Кызым авылга барам ат'кән. – *тмн.*; **2.** *нокр.* китү (уехать, уйти). Берсе уқытучы уқырга барды, әле қайтмады. – Апаң ийдәме? – Бализинга барды; **3.** *тмн.* үсү, үрчү (расти, размножаться – о животных и растениях). Тывар бара хаз'ыр калхузда. Быйыл гөлләрем бармый; **4.** *тмн., хвл.* килешү, килү (быть, идти к лицу, быть хорошо). Безнең сүләү сезгә бармый высе. – *тмн.* Бу күлмәген сиңа бармый. Кызыл төс бармый, карасы бара. – *хвл.*

**БАРУК 1.** *чст.* к.: **тура I, 1**; **2.** *т.кам.-крш.* к.: **эремек.** Төчө пирәмәч пешерәсен барук белән, үзең дә ашыйсың, келәү итеп сыйырга да, бозауга да қаптырасың.

**БАРУСИ** *м.-кар.* к.: **багышлы.** Баз'ины братыма килгән дип торам, шул кешегә баруси.

**БАРЦА** *тбл.* бөтенесе, барысы (все, всё); чаг.: **барсыбыз.**

**БАРЫМТАЛЫ** *к.т., мәл.* таза, тулы (полный, расположивший). Балам бик барымталы иде, қызамық белән awырғачтан җадаулады. – *к.т.*

**БАС I** *нрл.* гармун бакасы (басовая клавиша гармони).

**БАС II** *твр., төм., тбл.* к.: **баа.** Песнең қулта йөсәк пар, шәәр баслы басы бар. – *твр.*

**БАС III** *том.д.* к.: **гелбәч.**

**БАСА I** *каз.ар.* к.: **бас I.** Баса белəм басасын. Басасына басып уйный белми ул. – *лш.*

**БАСА II** *перм., злт.* **1.** ләбаса, соң (частица же, ведь). Күпме wақыт қайттың ти баса? Ничә китте ди баса? – *перм.* Қыз қайа китте баса? Қайа қуйған баса, қыwызны тапмыйм. – *злт.*; **2.** к.: **мыса.** Без иртәгесен чықтыг ийе баса базарга? – *перм.* Тозлы кәбестәне әле қайсы көнне баса түктем? – *злт.*

**б а с а III** (посконь):
**ақ баса** *тпк.* к.: **мошко I: кара мошко.**
**қара баса** *тпк.* к.: **мошко I, 1.** Қара басаны суга сала торган ыйық, ақ басаны йәйә торган ыйық.

**БАСҚА** [*рус.*] *брб.д.* пасха. Басқа төшә, көскө утыта, йеп менә сыу и қараб отыра көскөтән төннә, көскөтән көрөнә.

**БАСКАЛАУ 1.** *хвл.* к.: **басу I, 2**; **2.** *хвл.* таптау, пычрату (пачкать, грязнить); **3.** *мәл.* таптау (топтать). Баскаламагыз картуфларны.

**БАСҚЫЛАУ** *м.-кар.* уу, юу (стирать). Кер баскылау.

**БАСҚЫНЧАҚ: басқынчаг итү** *нокр., мам.* басымчак итү (не считаться, пренебрегать, не уважать, унижать). Басқынчаг итеп йөрәсез мине дийә. – *нокр.*

**БАСҚЫРЫҚ** *брб.д.* к.: **болдор.**
**б а с к ы ч** (ступенька, лестница):
**басқыч тәлинкәсе** *блт.* к.: **басмача 1.**

**БАСЛЫҒУ I** *трбс.* авыраю – тән, гәүдә турын-

да (тяжелеть, отяжелеть – о теле, туловище). Тәнем көннән-көн баслыга.

**БАСЛЫҚ** *перм.* печәнлеккә менә торган яки базга, идән астына төшә торган баскыч (лестница, стремянка). Баслық араға кереп қалырсың, башың белән килеп қазалырсың да.

**БАСМА I 1.** *срг., тмн., тя.-крш., чст.-крш., перм.* ситсы (ситец). Басмамы күлмәгең, ыштапелме? Басма йаулык бәләдем. – *срг.* Күлмәк кисәргә басманы эзләдем сандыктан. – *тя.-крш.* Басма беркәw. – *тмн.* Бирмәгә мә? Басма бирәләр ий, кизел күлмәк салалар ий. – *перм.*; **2.** *карс., лмб., кузн.* баш яулыгы (ситцевый головной платок). Басма бәлә башыңа. Басмасын төшереп бәли күзенә. – *лмб.* Басманы шулай тыта идең, ирләр булса. – *карс.*

**басма tawap** *чст.-крш., каз.ар.-крш.* к.: **басма I, 1.**

**кызыл басма** *лмб.* француз яулык (большой красный ситцевый платок с белыми узорами).

**БАСМА II** *нрл., трбс.* к.: **баслық.** Басма қуйабыз да моржа сыларга менәбез. Шул басмадан шүшиләгә менәбез. – *нрл.*

**басма башы** *трбс.* к.: **күтәрмә I: күтәрмә башы.** Әтәй басма башында утыра, waба чире тиде.

**басма төбе** *нрл.* к.: **болдор.**

**БАСМАҚ I** *т.кам.-крш., к.-уф.* к.: **басмача 2.** Басмақтан чықтығызмы? – *т.кам.-крш.*

**БАСМАҚ II** *том.д.* **1.** түшәмә (настил); **2.** тозак (ловушка).

**БАСМАЛАУ** *тбл.* тукымага бизәк (басма) төшерү (набить набойку на ткань).

**БАСМАЧА 1.** *блт., бгрс., кргл.* басма, баскыч тактасы (ступенька лестницы). Қазлар басмачаны буйап киттеләр. – *блт.* Басмачаларны йуwa башлаған иде, йаңғыр йауды. – *бгрс.* Бийек бит аларның басмачасы. – *кргл.*; **2.** *мам., чст.* су аркылы салынган басма (мостик через речку); **3.** *минз.* мунча ләүкәсенә басып менә торган басма, баскыч (приступок в бане, на который встают, чтобы подняться на полок).

**БАСМИ** *карс.* к.: **басмача 2.** Аламасы шул басмидан чыга икән.

**БАСМЫШ** *әстр.* к.: **баслық.**

**БАСНА: басна сыйу** *тара.* таныш яки кардәш кешегә барырга кыюлык җитү (осмелиться пойти к знакомым или родственникам); чаг.: **базнайт′: базнайт′ итү.** Баснаң сыйса, парып пақ әнеләреңә.

**БАСТАРТҚЫЧ** *әстр.* хатын-кыз җилкәсен каплап тора торган бөркәнчек (лёгкое покрывало, которое прикрывает спину женщины).

**БАСТАҢҒЫР** *чст., әстр.* яшьләр кичәсе (молодёжный вечер).

**БАСТРУҚ** [*рус.* острог] *боре., төм.* төрмә (тюрьма).

**БАСТУ** *том.д.* к.: **базық.**

**БАСТУРҒАЙ** *кмшл.* бүдәнә, бытбылдык (перепёлка). Бастурғай дигән қош бар. Бастурғай дигән қош бар бездә, күбә астыннан чыға.

**БАСТЫРҒЫЧ** *нрл.* чалгыны сапка саплаганда бастырып куя торган чөй (клин, служащий для крепления косы на черенок, окосье, косовище). Бастыргычны тотар өчен ике алқа була. Бастырғыч чалғы чөмәген бастырып қуйа.

**БАСТЫРМА** *чст.* лапас астына нечкә агачлар, такталар тезеп печән кую өчен ясалган урын, печәнлек (сушилка для сена под навесом). Бөген бастырмада печән өстендә йокладым.

**БАСТЫРУ I 1.** *әчк., нгб.-крш.* куу (прогонять). Қad баласы бастырып йөрөй малайың. Утыр, кәзәләрне бастырып керәйем. – *әчк.* Алар берберсен бастыралар. Tawық бастырып йөрдем (бақчадан). – *нгб.-крш.*; **2.** *минз., перм., стрл.* куып бару, артыннан куу (гнать, гнаться). Тайақ белә бастырып йөрдә қыйнарга дип. – *минз.* Урамда бастырып туқмыйлар икә. – *перм.*

**БАСТЫРУ II: төрмәгә бастыру** *нрл.* төрмәгә яптыру (заключить, упечь в тюрьму). Мин сине төрмәгә бастырам, ди.

**БАСТЫРЫК** *чст.* к.: **бастырма.**

**БАСТЫРЫҚ I** [*рус.* острог] *кмшл.* к.: **баструқ.** Сигез йыл бастырықта йатқан.

**БАСТЫРЫҚ II** *тбл.* туннының тышы (верх шубы).

**БАСТЫРЫҚЛЫ** *тбл.* тышлаган тун (крытая, обшитая шуба).

**БАСУ I 1.** *хвл., чст., мәл., трх., м.-кар.* көрәк белән җир казу (копать, рыть землю лопатой). Бақчаны бер кат басып чыктым, грәпләләргә дә түтәлләр йасарга гына эше калды. – *хвл.* Бер көндә бастым да чәчтем дә бәрәңгене. – *м.-кар.* Бәрәңге өчен бақча басабыз. Җир басып қарбызлар, қawыннар үстерә идек, чирәм басып. – *трх.*; **2.** *лмб., нокр.* таптау (топтать, мять). Анда шымырт йуктыр, картушны гына басасыз. – *лмб.* Сыйырлар йералманы басқаннар. – *нокр.*; **3.** *миш.д.* таптау (давить, задавить кого-либо). Килнесен тырактыр басты. Матасикыл безне басмый инде, йырак. – *клд.*

**БАСУ II** *чст.* сукаланмый калган җир (невспаханное поле).

**басу түре** *дөб., мам.* ерак басу (отъезжее поле). Басу түрләреннән күтәреп қайтадырыйық печәнне. – *мам.*

**қаты басу** *дөб.* тақыр басу (паровое поле). Элек қаты басуда көтү йөрткәннәр, суқаламыйлар аны.

**БАСУ III: басып алып китү** *бәр.* урлап китү (похитить, похищение). Уйыннан басып алып киттеләр тушы қызымны, Ақтүбәдән қайтқаллар да гызны басыб алып киткәлләр.

**БАСУ IV: йаңгыр басу** *мәл., карс.* яңгыр ява башлау (начаться – о дожде). Йаңгыр баскынча күтәреп тә бетерделәр (печәнне). – *мәл.* Йаңгыр кайа басты үзегезне? – *карс.*

**БАСУ V: балық басу** *кмшл.* балык тоту, сөзү (ловить рыбу). Су қуйырық, балық басалар йәтмә белән.

**БАСУ VI** *перм.* чигү (вышивать). Сөрәнчеләргә бирмәгә тастымал басып қуйдым ийе. Кийеүгә басқан чолғау әзерләгәннәр қызлар.

**БАСЫЛУ 1.** *злт.* к.: **баслыгу I.** Бүген басылам да басылам, сез килергә икән; **2.** *трх.* картаеп, кечерәеп калу (стать меньше ростом в преклонном возрасте). Басылып беткәч үлде инде ул қарчық; **3.** *лмб.* сөйләми (әйтми) башлау, телдән

төшеп калу (выпасть из употребления). Җизни басылды инде, җизнәкәй атәләр. Әле инде басылды җизни әтуләр.

**БАСЫМ I** *тмн.* 1. басынкы, бастырынкы (тихий, спокойный, скромный). Бик басым кыз; 2. утыра торган – тавык һ.б. төрле кошлар турында (сидящая на яйцах – о птице-наседке). Басым каз кебек утыра, беркайа бармый.

**БАСЫМ II** *минз., кмшл., стрл.* иген бастыру (молотьба). Басымга бара торган ийек төнгә, көндез ура торган ийек тә. – *стрл.*

**басым өстендә** *минз., стрл.* ашлык сукканда (во время молотьбы хлебов). Синтәбердә басым бастырганда басым өстендә бик эссе була торган ийе. – *стрл.*

**БАСЫМ III** *тбл.* һөҗүм (приступ).

**БАСЫМЛАП: басымлап йаwy** *минз.* томалап, озак яву (говорится, когда небо обволакивают тучи и в течение продолжительного времени идёт дождь или снег). Бүген қар басымлап йаwарға кереште.

**БАСЫМЛАУ** *тбл.* һөҗүм итү, һөҗүм итеп алу (нападать, взять приступом).

**БАСЫРНЫҒУ** *тара., тбл.* к.: **паслыгу 2.**

**БАТА** [*рус.* вот] *срг.* к.: **вота.** Бата кас'ы безнең ызба.

**БАТ'АЛ** *кузн.* байтал (кобыла).

**бат'ал колагы** *кузн.* иске туй йолаларыннан берсе: егет йортына туй килеп кергәч, бер малайны атка атландыралар; кыз аңа яулык бүләк итә (один из старинных свадебных обрядов).

**БАТИ** *чст., мәл.* к.: **агале.** Хәзер инде, бати, лапас та шифер. – *мәл.*

**БАТИЛ** *брб.д.* к.: **йабайы.**

**БАТИН** [*рус.* ботинок] *мәл.* туфли.

**БАТИНКА** [*рус.* ботинок] *лмб.* элек хатын-кызларның аяк киеме – киез ката (старинная женская обувь – валяные башмаки).

**БАТИҢКА** [*рус.* ботинок] *трх.* к.: **галуш 1.** Элгәре сарық асыраган кеше дә батиңка кийә иде, итек йуғ ыйы.

**кийез батиңка** *трх.* к.: **галуш 1.** Һәр йылны батиңка бастырып җибәрәбез, кийез батиңка.

**БАТҚАҚ** *эчк., перм.* балчык, пычрак (глина, грязь). Өйгә батқақ апкерәсең. – *эчк.* Ыштаны гел батқақ, йамаулысын ғына булса да бир инде, ди, ойала. – *перм.*

**БАТКЫЛЫК** *чст.* баткаклык, сазлык (болотистая местность, болото, трясина). Монда баткылык бит.

**БАТКЫЛЧЫК** *хвл.* яз көне карны казып өстенә кар, салам, җәй көне балчык сибеп эшләгән кечкенә алдау чокыры (маленькая яма, ловушка, западня, устраиваемая для потехи над кем-нибудь).

**БАТКЫЩ** *тара.* баскыч (лестница).

**БАТКЫЧ** *чст.* к.: **болдор.** Баткычлары сапсары итеп йуwылган.

**БАТ'КӘ** [*рус.* батька] *бөре.* к.: **кәбәм 2.** Әй бат'кә, тәмне дә соң! Күз белә ата гына бит, бат'кә!

**БАТ'КӘКӘЙ** [*рус.* батька + *афф.* -кәй] *бөре.* кереш сүз функциясендә (в функции вводного слова). Уқыйлар, бат'кәкәй, уқымышлылар.

**БАТМАҚ** *т.кам.-крш.* к.: **йубалғы 1**; чаг.: **салақ.** Дөнйада була инде уңмаган кешеләр, бездә андыйға батмақ диләр қартлар.

**БАТМАН I** 1. *кузн., хвл., чст.* ун кадак авырлыгындагы үлчәү берәмлеге (единица веса, равная десяти фунтам); 2. *кузн., хвл., чст., т.я.* бер батман сыешлы савыт (посуда, вмещающая сыпучие вещества весом в один батман).

**батман баш** *т.я.* зур баш (большеголовый; человек с большой головой).

**биш батман** *кмшл.*, **илле батман – Идел суы** *т.я.* ашның суын күп итеп салып пешергәндә шулай әйтәләр (так говорят об очень жидком супе).

**БАТМАН II** *тпк., стрл.* гөбе (пахталка, кадушка для ручной маслобойки). Батманта бешеп, сықарқанны ақ май тиләр. – *тпк.*

**БАТМАШ** *эчк.* к.: **болдор.** Бабаң батмашта утыра.

**БАТУ** *брб.д.* сыю (быть в пору).

**БАТУН** [*рус.* бутон] *эчк.* 1. төнбоек (водяная лилия, кувшинка). Батуннар матур итеп ақ цәцкә ата; 2. к.: **бәбәк II.** Суганның батунын ғына эз.

**БАТЧИ** *чст., мәл.* к.: **агале.** Безнең Сафийәнең, батчи, җиде кыз. – *чст.*

**БАТША** *тара.* патша (царь).

**БАТЫҚ** *минз.* батынкы (впалый, углублённый). Батық көзгөдән қарагач көлөштек.

**БАТЫЛ** *тара.* начар, эшәке (худой, гадкий).

**БАТЫР I** 1. *чпр., срг.* яхшы, нык, матур (хороший, крепкий, красивый). Бик батыр тигилдир инде мәйданы. Ызбаны бик батыр салдык та, симйалар Ул'анда. Батыр пыцак белән китереп цаптым дир. – *чпр.* Ишетәм мин ишетүен, батыр ишетәм. – *срг.*; 2. *мәл.* теләп, яхшы (с желанием, хорошо). Безгә бик үк батыр килми ул кеше. Укырга бик батыр безнең балалар.

**БАТЫР II** *бәр.* бака яфрагы чәчәгенең сабагы (цветоножка подорожника). Батыр уйныйлар суғып, башын өзөп, беренекенә берен.

**батыр үләм** *чст.*, **батыр үлән** *бәр., минз.* к.: **бақа: бақа қабығы.**

**БАТЫРАҚ** *кмшл.*, **БАТЫРАК** *чст.* чирек (четвертушка). Бер батырак аракыга бер кыйлы тыз апкайтам. – *чст.*

**БАТЫРДАУ** *төм.* 1. шакылдау, шакылдату (стучать); 2. пырылдап очып йөрү (порхать).

**БАТЫРМА: матча батырмасы** *трх.* матча батырып куела торган бүрәнәләр (бревно сруба с углублением для кладки матицы). Матча батырмаларын алыштырдық быйыл.

**БАТЫРУ** *нгб.-крш.* пычрату (пачкать). Өстеңне батырма.

**б а у I** (верёвка):

**ачқыч бау** *нокр.* к.: **путемар.**

**бау тоту** *яүшт.* ишек бавы тоту йоласы (обычай при переезде невесты в дом жениха держать ручку двери и не пускать невесту, пока она не одарит их подарками). Анда бау тоталар, керетмиләр киленне, тегесе үзенә тарта, монысы үзенә тарта.

**ир бawы** *лш.* чишелмәслек итеп чияли бәйләнгән бау (мёртвый узел).

**кылак бавы** *чпр.* чабатада: киндерә үткәрү өчен тишек (отверстие в лаптях, в которое вдевают оборки, ушник лаптя).

**эзәр бавы** *чст.* билбау (пояс, кушак). Йегетнең эзәр бавын тишә кыз.

**БАУ II** *байк., кузн., злт.* басма, киндер җепне үлчәү берәмлеге (единица измерения пряжи). Төннәр буйы эрлисең, җиде бау эрләсәң, бер киләп була. – *кузн.* Йепне эрләп бауга тутырасың, сәвемдә дүрт йеп була. – *злт.* Бау алтмыш сәвем була. Көн дә бер бау йеб эрлим. – *байк.*

**БАУ III** *влгг.* җимеш бакчасы (фруктовый сад). Бауга һәркем су агызгалы кели.

**баw алмасы** *срг., мәл.* к.: **бағалма 1.**

**БАУҚАЛАЧ** *перм.* клиндер (крендель).

**БАУЛАУ 1.** *перм., минз., стрл.* бауга тезү (нанизать на верёвку, нанизать лук на верёвку). Суган бауладым бүген. – *стрл.* Суганны баулыйбыз, паланны бүкәннибез. – *перм.*; **2.** *брб.д.*к.: **пайлау.**

**БАУР** *твр.* бавыр (печень).

**БАУРЫШ** *әстр.* аркылы агач (перекладина).

**БАУСЛАУ** *тара.* бугазлау (колоть, резать – скот). Буғусуна қылыцны салған бауслағалы.

**БАУ-ЧӘҮ** *перм.* бау (верёвка). Монан бау-чәү әпкитәсең.

**БАХАТАЙ** [*рус.* выходной] *чст.* эш беткәч була торган күңел ачу, ял итү (отдых, развлечения после окончания работы). Бахатай була эш беткәч.

**БАХИЛ** [*рус.* бахилы] **1.** *минз.* сырып эшләнгән кунычлы итек (стёганые сапоги). Бахил өстеннән эржиңкә кисәң, шәп была; **2.** *минз., стрл.* озын кунычлы аяк киеме (обувь с длинным голенищем). Бахил дигән ике ризиңке белән эшлибез, менә шушыннан су. – *минз.*

**БАХИЛА** [*рус.* бахилы] **1.** *чст.* брезенттан тегелгән аяк киеме (обувь, сшитая из брезента). Зур бахилалар айакта, табаны йук, турыга теккән; **2.** *мәл.* зур, симез – аяк турында (большая, полная – о ноге). Синең бахила айагыңа нәстә сыйсын; **3.** *кмшл.* таза, симез – кеше турында әйтелә (полный, крепкий – о человеке); чаг.: **балбан.** Йа Алла, бахиламыни!

**БАХИЛО** [*рус.* бахилы] *клд.* к.: **бахила 1.** Аны әле былай гына тегел, бахилосы да булган. Зур бахило кийә, анан чәркәсенә бәләп куйа.

**БАХМИТ** *кмшл.* к.: **бахила 3.** Маһинур апайның Рәйсәсе бахмит кебек.

**БАХТА** [*фарс.*] *әчк.* мамык (хлопок). Бахтадан күбелгән йурган диләр.

**БАХУЛ** *чпр., срг.* менә шул, шушы (вот этот). Бахул Әхмәдуламы мәдәктә тартып бара идем. Бахул йахшы йулдан йөре. – *чпр.* Бахул, анай, үлсәм шуларны сүләрсез. – *срг.*

**БАХЫЛАЙ** *чпр.* менә шулай (вот так). Бахылай мендәргә салып цыгарабыз ыланны ат кушканда.

**БАХЫНДА** *чпр.* **1.** менә шунда (вот здесь). Мин бахында үлмә келим; **2.** әнә шунда (вон там). Бахында аран йанында бар утын.

**БАХЫНДЫЙ** *срг.* менә шундый (вот эдакий). Бахындый малайы бар.

**БАХЫР** *кргл., бгрс., әчк., злт., тпк.* мескен, бичара (бедный, бедняжка). Ул йығылып қалған, бахыр. – *әчк.* Кинәт кенә шул бахыр үлеп қуйды. – *злт.* Күзеннән йәш тәгәрәп төшә бахырның. – *тпк.*

**БАХЫРҚАЙ** *минз., злт., трбс.*, **БАХЫРКАЙ** *стрл.* к.: **бахыр.** Бахырқай, үлде инде ул. – *минз.* Әпекәй генә пешереп тордо бахырқай. – *злт.* Киленне, бахырқайны нык тоталар ыйы. – *трбс.*

**БАХЫРНИСА** [*гар.*] *перм.* бака (лягушка).

**БАЦА** *тбл., тара.*, **БАЦАЙ** *том.д.* к.: **баз'а.**

**БАЦҚЫЦ** *том.д.* к.: **болдор.**

**БАЦМАШ** *әчк.* к.: **болдор.**

**БАЧИ** *чст., мәл., т.я.-крш.* к.: **агале.** Чирмешән, бачи, бакчаның башында ук тора. – *мәл.* Элек, бачи, сука белән эшләгәннәр. – *т.я.-крш.*

**БАЧТА, БАЧ(Ы)** *срг.*, **БАЧЧЫ** *хвл.*, **БАЧЫШ** *чст.* баш асты (изголовье). Бачтамы карсак? Бачтанмы алыйк айак ыцыгызга куйарга? Бачым каты. Бачыма йастык куймаган. – *срг.* Бар да утырта баччына (зиратта агач). – *хвл.*

**БАШ I.** *лмб., кузн., хвл., кмшл.* түбә (крыша). Башы кызыл үдә тора. Башы йабылмаган клупның. – *лмб.* Үwенең башын йәшелгә буйаткан. – *хвл.*

**өй башы** *трбс.* к.: **қатнар.** Өй башындадыр тулайоқ белән чабата, тийатыр уйнарға алалар.

**БАШ II** *нокр.* кешеләр саны турында сүз барганда кулланыла (единица счёта – когда речь идёт о людях). Әке башмени аныңқысы салдатта малайлары? Дүрт баш балам бар. Әке баш ылан бар минем.

**баш аву** *мәл.* баш әйләнү (кружиться – о голове). Дүрт йыл башым ауды.

**баш арты** *минз.* икенче тапкыр (второй раз). Баш арты килдеме икән?

**баш бала** (кыз, ул) *перм., минз., кргл., бгрс., кмшл., нгб.-крш.* беренче бала (первенец). Төпчегем дә син, баш балам да син. Мин үзем баш бала булдым. – *минз.* Баш баласы қыз ыйы, ул үлде. – *кргл.* Баш қызы да җидедә генә әле. – *кмшл.* Баш балам ул минем. – *нгб.-крш.*

**баш йату** *срг.* үлү, үлеп калу (умирать). Сикез йыл салдатта йерепсен, башын йатмаган әтәм.

**баш қадағы** *перм.* стенага озатканда җепне беренче башлап бәйләп куйган кадак (первый гвоздь, к которому привязывается начало нити при снования). Баш қадағына җепнең очон бәйлисең дә җүгертә башлыйсың.

**баш косу** *хвл., срг.* баш кысу (колоситься, выколоситься, выбросить метёлку). Арышлар баш коса башлаган. – *хвл.*

**баш ору** *злт.* к.: **башыру.** Сине баш орған. Баш орошсақ былыр ыйы.

**баш өтү** *минз., стрл.* к.: **бикәц: бикәцкә керү.** Баш өтәләр бүген, диләр, кызны йабалар да. – *стрл.*

**баш салу** *нгб.-крш.* баш ию, буйсыну (подчиняться). Әле генә баш салып торам, баш салмыйм мин аңа.

**баш сәңү** *тара.* к.: **баш аву.**

**баш тақтасы** *тпк.* баш астына, мендәр астына куела торган кыеклап эшләнгән такта (наклонная доска, предназначенная для того, чтобы ставить под голову, под подушку, на изголовье).

**баш тану** *тара.* юл алды чәе (чаепитие перед дорогой).

**баш тоту** *кузн., хвл., срг.* баш авыруы (мигрень).

**баш чагалау** *минз.* 1. бер-ике см киңлектә гади ысул белән тукып, киндер сугуны башлап кую (приготовиться к началу работы на ткацком станке); 2. *каз.ар.* киндер сугу станында сугылган киндернең чугын кисеп алу (отрезать бахрому на конце самотканого полотна); 3. *минз.* ике якның ата-анасы кызны килешеп кую (сговор о сватании невесты между родителями жениха и невесты заранее).

**баш чагалау** *стрл.* к.: **баш чағалау 1, 3.** Кыз белән йегет белмәсә дә, ата-инәсе баш чагалап куйганнар. Аклашкач, ике йак килешкәч, баш чагалаган инде, диләр.

**баш чаптыру** *дөб.* баш саптыру (обсоюзить, пришить головку к обуви). Менә итегемә баш чаптырып алдым.

**баш чирәбе** *хвл., мәл.* баш сөяге (череп).

**баш чүперәге** *лш.* к.: **айак II: айак башы.**

**баш эстенә йазган таш** *клд.* язулы кабер ташы (надгробный камень).

**башы белән** *бөре., байк., кузн., чпр., кмшл., перм.* к.: **башала 1.** Алар башы белән үзләренчә сүләшмиләр, кеше керсә. Без башы белән дә белмәдек. – *бөре.* Башы белән алуцы булмады бәрәңгене. Мин үдә пешергәнем йук башы белән дә. Башы белән йоклый алмый, төнө белән йөреп цыкты. Бөгөн күренмий башы белән дә. – *байк.* Ысдат иткән савсимга башы белән. – *кузн.* Башы белән йуғалды. Башы белән қайтмады. – *кмшл.* Анда чawынның йуқ башы белән. – *перм.*

**мәтник баш** *чст.* җиңел уйлаучы кеше, төптән фикер йөртә белмәүче (легкомысленный, недолго думающий).

**БАШАЙ** *злт., трбс.* йон оекбаш (шерстяные носки). Мин аңа башай бәйләп биргән ийем ике пар. Башай, озон қунычлы ойоқ та бирәләр кийәүләргә. – *злт.* Қәбер awызы ачқан кешегә җә башай, җә эрзинкә, җә җахшы тастымал бирә. – *трбс.*

**б а ш а қ** (колос):

**башақ қысу** *глз.* к.: **баш: баш косу.** Башақ қысқач, бозайларны боз суқты.

**БАШАҚЛАУ I** *минз.* саламга кайнар суда изелгән бәрәңгене катнаштырып яки он сибеп терлеккә бирү (дать скотине месиво из соломы с картофелем или мукой). Башақлыйм да көтүгә дә апчыгып керәм бodауларны.

**БАШАҚЛАУ II** *тбл.* ук очлыгын киертү (насаживать наконечник на стрелу).

**БАШАҚЧА** *глз.* туй чыгымнары өчен егет ягыннан кызның әти-әнисенә бирелә торган акча (деньги, даваемые родителям невесты со стороны жениха на свадебные расходы). Башақча ул мәһәр булмый, мәһәр қақ ул ниқах wақтында ғына була, айырылғанда түлиләр. Башақча этисенә қарыжға була.

**БАШ-АҚЫЛ** *глз.* к.: **ис III.** Баш-ақылым беткән инде минем.

**БАШАЛА** *дөб., нокр., кмшл., кргл., бгрс., мәл.* 1. бөтенләй (совсем). Хәлем китеп тора башала. Башала төшкәс кенә күрә қайнана киленне, тоташ төшкәс кенә. – *дөб.*; 2. бөтенләйгә (навсегда, насовсем). Шәмсенур үзе башала китте. Без башала китәбез. – *кмшл.* Башала бетте микән инде? – *мәл.*

**БАШАЛТАЙ** *минз., стрл.* к.: **башай.**

**БАШАН: ақылға башанрақ** *минз.* акылга җиңелрәк (глуповатый); чаг.: **ақыш-мақыш 2.**

**БАШАНТАЙ** *минз., тпк., стрл.* к.: **башай.** Йон эрләргә кирәк, башантай бәйләйбеd. Хәdер мал қараған башантайны да салып керәбеd. – *тпк.* Әнисе башантай йебәргәндер. – *стрл.*

**БАШАРТЛАУ** *твр.* оештыру (организовать и провести).

**БАШБАТА** *нокр.* кабер өстенә куелган таш яки агач казык (намогильный камень, кол на могиле); чаг.: **башқазық.** Таш башбата. Ағач башбата. Теге қабернең башбатасы түнгән. Башбатасына да йазған ич. Йазулы башбаталар бар.

**БАШБАУ** *мам., бөре.* бастырыкны алгы яктан элəктерə торган бау (верёвка, с помощью которой закрепляют спереди бастрык, гнёт).

**БАШ-БАШ** *нокр.* бәрә-бәрә – сарыкларны чакыру ымлыгы (возглас, которым скликают овец).

**БАШҚА** *глз.* к.: **айыры 1.** Мин ул чақта башқа торайым.

**БАШҚАЗЫҚ** *срг., кузн.* кабер өстенә куела торган казык (кол на могиле).

**БАШҚАЛАНУ** *минз.* башка чыгу, аерым яши башлау (отделиться). Алар җәйен башқаландылар.

**БАШҚАЛАУ** *тбл.* үзгәртү, аеру (изменять, различать).

**БАШКАЛЫЙЦА** *срг.* башкача, бүтәнчә, яңадан (больше, в другой раз, снова). Башкалыйца иргә бармадым.

**БАШҚАРУ** *әстр.* үзгәрү (измениться, стать другим). Йәшләр телне башқартты. Хәзер башқарды тел.

**БАШКАЧАЛЫЙ** *чст.* башкача (по-иному, по-другому). Башкачалый йуг инде. Ату безнең башкачалый хут йук.

**БАШКЕН** *миш.д., трх.* дүшәмбе (понедельник). Сез башкендә бездә булырсызмәле? – *мәл.* Киләсе атналарны эшкә чыгаргайе дә, башкен чыгарга булган инде. – *чст.* Башкеннеме сың килделәр, бушкенгә китмә келиләр. – *срг.*

**БАШКИГЕЦ** *срг.* яулык астыннан киелә торган ситсы калфак (колпачок, чепчик из простой материи, надеваемый под платок); чаг.: **сылawыц.** Башкигец астан кийә торган булганнар, йаулык астыннан.

**БАШКИЦ** *чпр.* якшәмбе кич (воскресенье вечером). Башкиц базар кен киц була ул, башкен алды.

**БАШКИЧ I** *чст., чпр.* якшәмбе (воскресенье). Башкич, атнакичне үлеләр йөри торган көн диләр. – *чст.*

**БАШКИЧ II** *кузн.* исән балалар саулыгына уздырыла торган Коръән ашы (званый обед или ужин, устраиваемый за здоровье детей и сопровождающийся чтением молитвы). Кызымның башкиче иде, башкич уздырдым, укытабыз кийәүнең, кызның саулыгына.

**БАШҚОДА** *перм., злт.*, **БАШКОДА 1.** *миш.д.* яучы, димче (сват, сваха). Кызыбызга башкода килде. Лэт'укка башкода булып барган идем. Элек бит башкода белән алалар иде кызны. Башкода бара, саулыклаша, чәй йанында сүз башлый: кызыңа башкода булып килдек, ди. – *хвл.*; **2.** *т.я.* егет белән кызның аталары (отцы жениха и невесты).

**БАШКӨН** *миш.д., трх., перм., әстр.* к.: **башкен**. Йулға башкөн чыксаң, йахшы инде. – *трх.*

**БАШКӨЛЛӨ** [*тат.+гар.*] *злт.* бөтенләй (совершенно, совсем). Башкөллө йуғалды.

**БАШ-КҮЗ: баш-күз итү** *хвл.* хуҗалыкта күзколак булу, күзәтү (следить за хозяйством, вести хозяйство); чаг.: **багыш: багыш-күреш итү**. Апасы баш-күз итте: үтотто, терлек тотто, сыйыр асрап килде.

**БАШКЫДА** *шрл.* к.: **башҡода 1. Йебәрә йегет башкыданы.** Башкыдага ыриза былмыйсың тык, йәшләр бәхты киселә ат'асың. – *шрл.*

**БАШКЫДАЛЫЙ** *карс., тмн., лмб.* яучы булып (в качестве свата). Башкыдалый да бармадым. – *карс.* Әни, ад'а, башкыдалый килделәр, кайт тизерәк. – *лмб.* Мин башкыдалый килдем, әтә. – *тмн.*

**БАШЛАГА** [*рус.* обшлаг] *хвл.* җиң кайтармасы (обшлаг). Башлагалары сидрәп беткән. Күлмәгемнең йиңнәрен башлагасыз гына йаса.

**БАШЛАП** *байк.* беренче тапкыр (впервые, первый раз). Башлап күрәсеңме, әллә кайцан алган ыйык?

**БАШЛАПҠЫ** *төм.* беренче (первый, ранний). Башлапқы пала. Әнийем йәшләй үлгән, мин башлапқы баласы булған.

**БАШЛАПҠЫДА** *төм.* башта (вначале).

**БАШЛАТУ** *нгб.-крш.* кабызу, кую (разжечь, поставить). Самоварны башлатып җибәрим.

**БАШЛАШ** *байк.* чиктәш, эргәдәш (смежный, соприкасающийся концом). Бер зимнәнкәгә башлаш ийе. Башлаш булса, йастыклаш дип тә әйтәләр.

**БАШЛЫК** *чст.* йорт башы карчык (старуха – хозяйка дома, глава семьи, рода).

**БАШЛЫҠ I 1.** *тара., твр., брб.д.* к.: **пашлық 1**. Заһирә башлық. Қарт башлықлар көн. – *брб.д.* Башлық тың қарт қортқайақ ул пашлық. – *твр.*; **2.** *брб.д.* олы яшьтәге хатын-кыз (женщина преклонного возраста).

**БАШЛЫҠ II** *брб.д.* **1.** абруй (авторитет); **2.** түрә (начальник).

**БАШМАҠ I 1.** *минз., бөре., перм., брб.д.*, **БАШМАК** *чст., мәл.* бер яшьлек тана (годовалая тёлка). Башмак тана. – *чст.* Хәзер башмақлар алмаға қушалар. – *перм.*; **2.** *минз., бөре.* ике-өч яшьлек тана (двух-трёхгодовалая тёлка, нетель).

**б а ш м а қ II** (башмак, туфля):

**башмақ тәтәй** *мам.*, **башмак үләме** *чст.*, **башмақ чәчәге** *мам., дөб.* баллы чәчәк (льнянка).

**җөн башмақ** *т.кам.-крш.* к.: **галуш 1.** Җөн башмақ бик эрәқәт бит өйдә кийәргә.

**кийез башмақ** *каз.ар.-крш.* к.: **галуш 1.**

**күтәрмәле башмақ** *т.я.*, **күтәртмәле башмақ** *кмшл.* табаны калын агачтан ясалган юкә яки күн өсле аяк киеме (обувь из лыка или кожи на толстой деревянной подошве).

**БАШТАҠ 1.** *перм., к.-уф.* шаян, шук, тәртипсез; башбаштак (озорной, шаловливый, самовольный). Баштақ, қорамыш балалар бақча җимешне таптап бетергәннәр. Баштақ, үләр хәл йуқ, ул зыйан салмый йөрмәс, уйнамый утырмас. Бигерәк баштақсың, Нәфисә алай түгел. Биг үк җаматай сыйырыбыз, баштақ, чоланға килеп керә, кәҗинкәгә дә кереп китә, ишеге ачық булса. – *перм.*; **2.** *твр.* к.: **паштақ 2.**

**БАШТАҠЛАНУ** *перм., к.-уф.* тәртипсезләнү, шаяру, башбаштаклану (озорничать, своевольничать, самовольничать); чаг.: **адалану 4.** Баштақлана башласа, әйтербез әле. – *перм.*

**БАШТАҠТА** *күзн.* сәкенең мендәр кую өчен күтәренке итеп ясалган башы (приподнятый конец нар, изголовье).

**БАШТАРҒЫЧ** *әстр.* башка бәйли торган урама (узкая материя для повязывания на голову); чаг.: **баштастар**.

**БАШТАСТАР** *лмб.* башка бәйли торган сөлге сыман тукыма, *тастар* (узкая, как полотенце, материя для повязывания на голову, *тастар*). Баштастар бирәләр башкыдага, пухлы чуклар баскан.

**б а ш т ү б ә н** ( вниз головой):

**баштүбән китү** *күзн., хвл.* к.: **мәтәкләү**.

**БАШУWАРЛЫК** *глз.* баш юа торган ачы катык яки катык суы (кислое молоко или айран из кислого молока для мытья головы). Башуwарлык белән йуwабыз чәчне.

**БАШУҒЫЧ** *каз.ар., т.я., глз.* к.: **башуwарлык**. Башуғыч бик күп, барығызға да җитәр. – *лш.* Башуғыч йуқ, май сукканнықы йакшитмәй. – *глз.*

**БАШУҠ 1.** *блт., минз.*, **БАШУК** *стрл.* к.: **башала 1.** Хәзер башуқ йуқ җыйын. Мынсысы бәрәңге җаратмый да аның башуқ. Башуқ матурланған. Башуқ матур түгел синең йазу. Мин башуқ белмим бу әйберләрнең нәстә икәнен. Мәдинә башуқ қайтқан. – *блт.* Мин башуқ риза түгел, сабыйны, мәтәм, ничек бирәмсең. – *минз.*; **2.** *перм.* тулысы белән, тулысынча (полностью). Әлеге хатны алып пир әле, аның әдерисе башуқ буғай.

**БАШУМАК** *хвл., мәл., чст., чпр., срг.* к.: **башуwарлык**. Башумак та бар, кызларның үзләренә атап (мунча) йагарга иде. – *чст.* Башумак белән йуwасыңмы башыңны? – *срг.*

**БАШЧЫ** *хвл., күзн., мәл.* **1.** к.: **бачыш**. Башчың түбән булса, тагын бер йастык сал. Чыгарчыгар йастык башчыңа. Әйберләрен башчына салып йаткан иде. Бура йасап куйа эспичкадан башчына: кем элке килә, шул кийәү була. – *хвл.* Башчың карсак төгелме? – *мәл.*; **2.** баштүбән (головой вниз). Мин кергәндә, башчына баскан иде. – *хвл.*

**БАШШИКӘР** *әстр.* очлы формалы итеп койдырылган шикәр (сахар, отлитый в остроконечной форме). Башшикәр қойдырдылар туйға.

**БАШЫМАК** *хвл.* к.: **башуwарлык**.

**БАШЫРУ** *злт.* әләкләү (доносить, ябедничать). Улын килеп башырған.

**БӘБӘ** *м.-кар.* бер гаиләдә адаш хатыннардан

берсен атый торган сүз (так называют одну из двух женщин-тёзок в семье).

**б ә б ә й** *клд.* бәби (грудной ребёнок, младенец): **бәбәй ашы** *каз.ар., кмшл.* бала тугач якын кешеләр тарафыннан китерелә торган аш, гадәттә бәлеш (пирог, приносимый близкими и родными после рождения ребёнка).

**бәбәй майы 1.** *хвл.* к.: **бәби: бәби майы 1.** Бәбәй майына җыйа идек; **2.** *мәл.* бала тугач, кунак чакырып, май ашату йоласы (обычай, согласно которому в честь новорождённого приглашают гостей и угощают их маслом); чаг.: **бишек: бишек туйы.** Кунмады инде, бәбәй майындайы тенә; **3.** *дәб.* яңа туган баланы юындырганнан соң килгән кунакка куела торган май; бу майны ашагач, гадәттә акча куялар (масло, которым угощают гостей, пришедших после купания новорождённого, они же оставляют деньги, попробовав это масло.). Қарт, бәбәй майына акча саласы булыр, акчаңны тыгып бар; **4.** *клд., яушт.* к.: **ботка: бәби боткасы.** Ынугымның бәбәй майына катлама пешергән ийем вата. – *клд.* Бәбәй майына сөлгөчәк йә акча. – *яушт.*

**бәбәй үстерү** *минз., стрл., шрл.* бәби котлау (поздравлять с новорождённым: обычно близкие и родные приносят подарок и что-нибудь съедобное). Берәү бәбәй үстерегә килгән ийе, җиләктән йасаган ләвәш. – *стрл.*

**бәбәй чәйе** *хвл.* элек бала тудырган хатынны мунча керткәннән соң, туганнарын, күрше-тирәләрен чәйгә чакыру йоласы (старинный обычай, связанный с рождением ребёнка). Мунчадан соң чәй эчерәләр ыру-кардашны – ул бәбәй чәйе була.

**кецкенә бәбәй** *тара.* к.: **бармак I: сыңарчак бармак.**

**БӘБӘЙТӘК** *минз., бөре.* бала итәк (волан, оборки); чаг.: **балан: балан итәк.** Чаршауны бәбәйтәкләп тегәбез, кискәндә бәбәйтәклек қалдыр дибез дә. – *минз.*

**БӘБӘК I** *миш.д., кмшл.* күз – кимсетеп, ачуланып, ирония белән әйткәндә (глаз – с оттенком иронии или пренебрежения). Таҗ белән бәбәккә бәрер ул. Кийәү бәбәгенә атарга сылы цыгаралар. Бәбәк алдында сине эзләп тыра герәбәнкә. – *срг.* Кем риза, сыраганның сугып бәбәкләрен тишегез. – *лмб.* Ват, кара бәбәк! – *кузн.* Бәбәкләреңе йалтыратма! Алаша бәбәге тике. – *хвл.* Ни бәбәкләреңне аттың миңа? – *мәл.* Бәбәкләре wиз төпкә төшеп утырган. Кил әле, бәбәгең кайа? – *чпр.* Бәбәгеңе ақайтып тырма. – *кмшл.*

**бәбәк тону** *срг.* күзе тону (темнеть, потемнеть от злости). Бәбәкләреме сың тоңган.

**бәбәкләрне катырып утыру** *лмб.* ис китеп, күзләрне зур итеп ачып утыру (пялить глаза). Бәбәкләрне катырып утырган инде бу тастарларга.

**терәнә бәбәк** *хвл.* күзләрне зур итеп ачып бер ноктага текәлеп торучан кешегә карата әйтәләр (говориться о человеке, который часто уставляется широко открытыми глазами в одну точку).

**БӘБӘК II** *лш.* суганның орлык бирә торган көпшәсе, сабагы (стрелка лука). Бар, бәбәк белән сыйла қызларны.

**БӘБӘК III** *минз.* балтырган (борщевик). Бәбәк ашы пешердем.

**БӘБӘКЛӘНҮ** *трх.* тернәкләнү (поправиться, оправиться). Бәрәңгеләрем шулай бәбәкләнеп киттеләр.

**БӘБӘМ** *кргл.* **1.** к.: **бәбекәчем.** Бездә бәрәңге уңмады, бәбәм; **2.** к.: **апайым 1.** Әнә бәбәмнең қулын йудыр.

**БӘБӘНӘК I** *минз.* к.: **бәбәк II.** Бер қарыш булғач, бәбәнәк чыгара.

**БӘБӘНӘК II** *трх.* кул (рука). Чәчәм белән җир себердем, бәбәнәгем белән җир қазыдым. Бәбәнәк көчө белән орчоқ әрләдек, суғу суқтық.

**БӘБӘЧЛӘНҮ** *срг.* төче телләнү (льстить).

**БӘБЕКӘ** *трх.* бәбкә, кайчы (стропило). Бәбекәләр утырталар.

**БӘБЕКӘЧЕМ** *трх.* бәбкәм, балакаем (дитя моё, голубчик мой). Таһир ишек төбендә тора, бәбекәчем.

**БӘБЕР** *т.я.* вак буын(нар) (мелкие суставы конечностей). Сарықның да, сыйырның да һәр айагында икешәр бәбер, икешәр қузна була, атнықында бер бәбер, бер қузнасы була.

**БӘБЕРКӘ** *каз.ар.-крш.* к.: **бармақ: бәбли бәпчек бармақ.**

**БӘБЕС** *срг.* читек (ичиги).

**БӘБЕТИ** *каз.ар.-крш.* к.: **бәбер.** Бармағымның бәбетийе чықты.

**БӘБЕЦ** *срг.* к.: **бәбес.** Бәбецләр цигелгән була. Бакцы, нинди матур бәбец кигән бу қыз.

**БӘБЕЧ** *трх., клд., карс.* к.: **бәбес.** Бәбеч тә кийәләр ийе үкчәсез, намазға кийәләр. – *трх.* Казакидан, бәбечтән. – *клд.*

**бәбеч башмак** *карс.* читек-кәвеш (ичиги).

**бәбеч геләнешчәсе** *карс.* читек кунычы (голенище ичигов).

**бәбеч чепрәкләре** *карс.* к.: **сарғыч.**

**БӘБИ I** *каз.ар., бәр.* к.: **бала I, 2.** Умбиш бәбийе бар иде үрдәкнең, умбиштән бишкә қалдылар. – *бәр.* Қанаты айырылған бәбийем бар ыйы, шул қайтмады. Бер бәби чығып китте қапқа астыннан, үрдәге бу йақта қалды. Бер қаз бәбийе саташып кергән, безнен кардада җәри. Су буйы тулы үрдәк бәбийе, қаз бәбийе. – *дәб.*

**б ә б и II** (младенец):

**бәби майы** *чпр.* **1.** балага исем қушу мәҗлесе (пир в честь нарекания имени ребёнку); **2.** яңа туган балага беренче тапқыр каптырыла торган май (масло, которое впервые дают новорождённому).

**бәби чәйе** *нрл.* к.: **ботка: бәби боткасы.** Бәби чәйенә аппарасың қоймақ.

**БӘБИШ** *дәб.* к.: **бала I, 2.** Бу қазның бәбишләре күп икән.

**БӘБҚАЙАҚ** *мам.* көлтә өеменең бер төре (способ сложения снопов для сушки). Ун бәбқайақлық урдық шул арада.

**БӘБКӘС** *дәб.* үскән, каз төсе кергән бәбкә (подросший гусёнок).

**БӘБЧЕК** *блт.* агач төбеннән чыккан үсенте (мелкая поросль, поднявшаяся из корней у ствола дерева); чаг.: **туйыра 3.**

**БӘWЕЛМӘЛЕ: бәwелмәле күпер** *злт.* асыл-

малы күпер (висячий мост). Бәwелмәле күпер урынына зур күпер салганнар.

**БӘWЕЛСӘК** *злт.* сикәлтәле, чокыр-чакырлы (ухабистый, неровный). Алама йуллары, гел бәwелсәк.

**БӘWЕЛҮ** *эчк., злт.* тирбәлү, селкенү (колебаться, качаться). Йер бәwелеп тора. – *эчк.* Менә шулай қулы бәwелеп, селкенеп тора. Без бәләкәй сақта да бәwелеп торған сазлықлар бар ыйы. Қайын ағас былғас бәwелми дә инде. – *злт.*

**БӘWЕТҮ** *тпк., тара., твр., эчк.* тирбәтү (качать). Пишеккә сал да бәwет. Сәңгелдәге йуқ пишекне бәwетергә. – *тпк.* Балаңны бәwетеп кенә утырыйм әле. – *тара.* Бәwет нәнәңне. – *твр.* Бала бәwетәм. – *эчк.*

**БӘГАЛМА 1.** *мәл.* к.: **бағалма 1.** Ай, бәгырем, бәгалмам, Калса хатерен табалмам (*хал. жыр.*).

**БӘГӘ** [*фарс.*] *нокр.* бәя (цена). Бәгәсен күтәреп тора.

**БӘГӘЙҮ** *м.-кар.* колакка каты булу, начар ишетә башлау (стать тугим на ухо, плохо слышать). Ишетмим, кылаклар да бәгәйде.

**БӘГЕЛЧӘ** *лш.* бөгәлжә (деревянное кольцо).

**б ә г ы р ь** (печень; сердце, душа):

**бәгыр күү** *чст.* бик эчәсе килү (очень сильно хотеть пить).

**бәгыр тийенчеге** *кмшл.* иркәләп, сөеп әйтелә (ласкательное обращение).

**БӘДӘМ** [*гар.*] **1.** *мәл.* бәдән, гәүдә (туловище, тело). Кешенең йөз картаймаса да, бәдәме картайа бит; **2.** *трх.* буй (рост). Үземнең бәдәмем кечкенә генә йе.

**БӘДӘНИЦ** [*рус.* вязаница] *чпр.* җитен бәйләме (пучок льна). Бер бәдәниц пәзи түдем.

**БӘДЕКӘЙ** *эчк.* к.: **кечкеник.** Бәдекәй бала йылап утыра.

**БӘДЕЛ** *эстр.* йөз, кыяфәт, физиономия (лицо, вид, физиономия). Күрмисеңмени бәделен, утырған.

**БӘДЕР** *яушт.* күмәч – төче (лепёшка – пресная); чаг.: **бәтер.** Бәдер ашадық церек картупқанықы. Бәдерне оннан да бешерәбез.

**БӘДРИГА** *хвл.* җәймә (то, что постлано, подстилка). Бәдригага утыр инде.

**БӘЖИ** [*угор.*] *перм.*, **БӘЖ'И** *злт.* к.: **мошко I, 1.** Бәжине суға батырасын да мунчаға күтәреп талқыйсын, җебен бешерәсен. Ағыйделнең арйагында Самawыр агарталар, Бәжи күлмәк сугалар да Қулбашын қабарталар (*хал. жыр.*). – *перм.* Һәрбер кеше элке үзләре сәсә йе бәж'ине. – *злт.*

**БӘD** *тпк.* кара көрән (тёмно-коричневый).

**БӘЗ-БӘЗ** *чпр.* к.: **баш-баш.**

**БӘЗӘР** *чст.-крш.* бизәк (узор, рисунок ткани). Үзеннән чыккан бәзәр ийе күлмәгем.

**БӘЙ I** *мам., т.кам.-крш.* к.: **бәйләмеч.** Утырмаға бәйемне алып килергә онотқаным, тик утырдым. – *мам.* Бәйли торған бәйем беттәле, кичкә башқа эш әзерләмәдем. – *т.кам.-крш.*

**БӘЙ II** *лш.* бау, бәйләвеч (верёвка). Бәй белә бәйләп қуйды қапқынны.

**бәй салу** *лш.* бәйләү (вязать, связывать). Бишеккә арқылы-торқоло бәй салып, фирмедә эшләдем.

**БӘЙӘ** [*фарс.*] *миш.д.* кыйммәт, кыйбат (дорого, дорогой по цене). Сездә май бәйәме? – *лмб.* Бәйәгәме алган? Атергә дә тегел инде, бик бәйә булды. – *срг.* Базар көне әрберләр бәйә тегел. – *чст.*

**БӘЙӘРҮ** *миш.д.* бәясе күтәрелү, кыйбатлану (подорожать, стать дороже). Мында бит әле киләкилә бәйәрә. – *чст.*

**БӘЙГЕ 1.** *минз., бөре., блт.* сабан туенда уеннар үткәрелә торган мәйдан (площадь, где во время сабантуя устраиваются различные игры); **2.** *бәр., блт., злт.* сабан туенда җиңүчеләргә бирү өчен җыела торган бүләк (подарки, собираемые для сабантуя). Бер күлмәк бәйгегә чығарғаныйым, аны кылупқа алдылар. – *блт.* Иртәгә сабан туйы дигән көнне бәйге йыйдылар. Тастымал биргәннәр бәйгегә. – *злт.*; **3.** *крғл.* чабыш аты (скакун, скаковая лошадь). Оло мал алып қырга чығып, шунда суйып, бәйгеләр чаптыралар ыйы; **4.** *блт.* сабан туе уеннары: көрәш, ат чабышы һ.б. (игры, проводимые на сабантуе: борьба, конные скачки и др.).

**БӘЙГЕЛӘҮ** *крғл.* ат чабыштыру (провести скачки). Йегерме икенче йылларда awылның йыллыгын бәйгеләп уздырдылар.

**БӘЙГҮЧ** *т.кам.-крш.* бәйләвеч (завязка, то, чем завязывают). Қызым бәйгүчле, ди, чигәчәсен.

**БӘЙДӘН** [*рус.*] *кас.* к.: **бадийа 1.** Диривнада 'ойодан cow алалар бәйдән белин, барса'ыз 'үрерсез: бер бәйдәне төши, берсе мени.

**БӘЙЕЛКЕ, БӘЙКЕ** [*рус.* веялка] *трх.* к.: **жиллек.** Бәйелке белән дә сүwырдық. Бәйке белән дә сүwыртабыз.

**БӘЙЕТ** *тбл.* җыр (песня). Әүвәлге саманта бәйетләргә цицән булғаннар.

**БӘЙЛӘМ** *бөре., минз., трбс., стрл.* бәйләнгән – оек, носки (вязаный – чулки, носки и т.п.). Бәйләм ойоқ эчендә айақ өши. – *трбс.*

**бәйләм күлмәк** *минз.* трикотаж күлмәк (трикотажное платье). Балалар бәйләм күлмәкләре бармы?

**БӘЙЛӘМӘ** *перм.* к.: **бәйләмеч.** Мә, у чақта бәйләмәң тороп қалған ийе.

**БӘЙЛӘМЕЧ** *перм.* бәйли торган әйбер, бәйләү эше (вязанье, вязаная вещь). Бәйләмечләрне ор идәнгә, бәйләп беткән қый.

**БӘЙЛӘН** *тара.* к.: **пайлан.**

**б ә й л ә ү** (вязать, связывать):

**қайын башын бәйләү** *каз.ар.-крш.* яфрак бәйрәме алдыннан каен ботакларына ситсылар бәйләү, тастымаллар элү йоласы (перед праздником Троицын день повязывают на ветки берёзы куски ситца и вешают полотенца). Урманға қайын башын бәйләргә барабыз, диләр ийе, болай баш артқылы күкәй чөйөләр ийе қайынға.

**тартмалы бәйләү** *трбс.* чияли бәйләү (связывать глухим, мёртвым узлом).

**чалмалы бәйләү** *трбс.* элмәкләп бәйләү (завязать петлёй).

**БӘЙЛИ** *чст.* к.: **били.**

**БӘЙЛИС** *төм.* бәйле, бәйләнгән (привязанный).

**БӘЙМӘТ** *перм.* алабуга балығы (окунь). Бәймәт вақ қызыл балық. Бәймәт ашауға тәмне.

**БӘЙНӘ'** *кас.* к.: **байанақ.**

**б ә й р ә м** (праздник):

**бәйрәм җыйу** *нгб.-крш.* кунак җыю, мәҗлес җыю (приглашать гостей). Бәйрәм җыйғансыз икән.

**җаңгыр бәйрәме** *баст.* яңгыр теләп корбан чалу (один из старинных обрядов: моление дождю); чаг.: **ботқа: қарға ботқасы; чүк I: чүк итү.** Җаңгыр бәйрәмендә зират җанында қуй суйабыз.

**БӘЙСӘКӘ** *стрл.* төбәнәк буйлы (низкорослый). Йәше булып, гәүдәгә бәләкәй булса, бәйсәкә була.

**БӘЙТӘ** [*фарс.*] *тара.* пәйда булу (внезапное появление, возникновение).

**БӘЙШӘМБЕ** [*фарс.*] *брб.д.* к.: **пәйшәмбе.**

**БӘК I** *кузн., м.-кар.* к.: **әләк 2.** Йаңыр бәк озак болмады. Шында бер Пәтрәй атлы кеше бәк җуwан чыркы йанындагы аланга барып чыккан, диләр. – *м.-кар.*

**БӘК II** *м.-кар.* нык (крепкий). Кайын ул бәк нәстә, кайын ул сынмый.

**БӘКӘЙ I** *каз.ар., минз., кргл.* бәрән (ягнёнок, козлёнок). Бәкәйемә үләм салмаған әле. Ике бәкәйе йүгереп җөри. Сарық бәкәйләренә тамга салам. – *блт.* Урамда сарық бәкәйләре күренми әле. Бәкәйе имә, кәҗәне cawасы бар тизрәк. – *минз.* Бәкәйнеке wақ қына пирсук. – *кргл.*

**БӘКӘЙ II 1.** *әчк., злт.* бәкәл (путовая кость); **2.** *к.-уф.* к.: **ашық II, 2.** Йаңғыр йауды, бәкәйгә җитә cywы.

**БӘКӘЙЛӘҮ** *блт., минз.* бәрәнләү (ягниться, объягниться). Сарық бәкәйләде. – *блт.* Кәҗә өчнө бәкәйләде. – *минз.*

**БӘКӘЛ 1.** *чст., чпр., стрл., бөре., минз., тпк.* кеше аягының балтыр белән тубык арасы, нечкә җире (часть ноги человека чуть повыше щиколотки). Бәкәлдән айагым awырта. – *чст.* Айаклары бәкәл тик эзелә. – *мәл.* Хазер син әтмәсәң дә күмәкне бәкәлдән кийәләр. – *чпр.* Айақның бәкәле awарты. – *тпк.*; **2.** *лш.* к.: **ашық II, 2.** Кешегә бәхетне баш түбәсеннән биргән, безгә бәкәл сөйәгеннән дә бирмәгән икән, абый; **3.** *каз.ар.* аеры тояклыларда: тоякның бер өлеше (у двукопытных: одна часть копыта). Сарықларның ике бәкәл арасы awырта.

**бәкәл сөйәге** *стрл.* к.: **ашық II, 2.**

**БӘКӘЛӘ** *минз.* к.: **бәйсәкә.**

**БӘКӘЧ** *минз., мам., каз.ар.-крш.* к.: **бәкәй I.** Бәкәчләрне апчыгып китмәсеннәр. – *каз.ар.-крш.* Сарығымның бәкәче айрылып қалған. – *мам.*

**БӘКБӘТ** *каз. ар.* явыз, усал кешегә карата ачуланып әйтелә (бранное слово в значении «злодей»).

**БӘКИ** *каз.ар.* к.: **бәкәй I.** Сарығым ике бәки китерде.

**БӘКМӘ I** *әчк.* к.: **бала I, 2.** Қаз үрдәкләренең бәкмәләре урамда йерәйләр, қый!

**БӘКМӘ II** *төм.* к.: **ашық II, 2.**

**БӘ'ЧЕ, БӘ'ЧИ** *кас.* к.: **бақчи.** Бә'че, 'ем 'или?

**БӘҚЫТУ** *брб.д.* бәхетле (счастливый). Бәқыту бала пулдың.

**БӘЛӘ I** *перм.* яшь, яңа туган (новорождённый – о ягнёнке). Бәлә бәрән тиресе бүрек тә ыспай күренә.

**БӘЛӘ II** *перм.* к.: **була.** Усатбаға бәлә генә чықтыг инде без аңа. Суға бәлә дә килгәннәр инде, шишмә дә шишмә безнең, тегеннән чыға, моннан.

**БӘЛӘ-БӘЛӘ** *перм.* к.: **бди-бди.** Сарығым қулыман қотолып қуйды да, бәлә-бәлә, дип торам.

**БӘЛӘWEЧ** *мәл.* к.: **бәйләмеч.** Эч пышканда бәләweч тытам.

**БӘЛӘЙ** *т.я.-крш.* к.: **били.**

**БӘЛӘК I 1.** *минз.* к.: **ашық II, 2.** Чабатаны кийәдер ийек тә, киндерәсен айақ бәләгеннән җуғары бәйләп қуйадыр ийек. Айагын awыртгырды әле ул дағын, бәләктән тайды. Бәләк сөйәге диләр, шақай сөйәге бит инде малда ғына була; **2.** *лш.* к.: **ашық II, 3.** Бәләк белән бәреп җыға, җыққан икән, қузнаны үзенә ала.

**БӘЛӘК II** [*рус.*] *минз.* мичтә озынча формада пешерелгән икмәк (хлеб продолговатой формы, испечённый в печи).

**БӘЛӘКӘЙ I 1.** *минз., бөре., каз.ар.* к.: **кечкеник.** Бәләкәй генә бер қыз килгән. Бәләкәй қызчық минем шушы инде. – *бөре.*; **2.** *каз.ар., минз., кргл., бгрс., тпк., стрл.* к.: **безрәк.** Бәләкәй генә ал, қызым. Син бәләкәй генә сабыр ит әле монда, йәме? Бәләкәй генә ашасам, тамағым кибә минем. – *мам.* Чық бәләкәй қойашқа. Минем ғумердә бәләкәй туры килде әйбәт тормош. – *кргл.* Қатықны тонғас бәләкәй тоз қушып бастырып қуйасың таш белә. Ыслаганда бәләкәй қатық қушып басалар қортно. – *тпк.*; **3.** *бөре., минз.* к.: **әләк 2.** чаг.: **бида, каты.** Бәләкәй оло икән бу. – *бөре.* Дур булдисә, бәләкәй оло диләр беддә. – *минз.*

**бәләкәй қалақ** *мам.* к.: **қалақ 2.**

**БӘЛӘКӘЙ II** *глз., нокр., минз.* к.: **йастық I.** Бәләкәй алып бирәм сиңа. Бер урында бер бәләкәй белән генә йықлаббыз. – *нокр.*

**БӘЛӘКӘЙ III** *минз., тпк., стрл.* к.: **бәйсәкә.** Бабай озон, мин бәләкәй, ниткән тигезлек ди ул. – *минз.* Минем бабай бәләкәй генә бит. – *тпк.* Алтмыш биш килагырамны капчыкларны күтәрә бәләкәй генә нәстә. – *стрл.*

**БӘЛӘКӘЧ** *минз., стрл.* к.: **бәйсәкә.**

**БӘЛӘҮ** *миш.д.* бәйләү (вязать).

**ике очлап бәләү** *м.-кар.* ике төрле җеп белән бизәкләр ясап бәйләү (вязать разноцветными нитками, делая узоры).

**БӘЛӘЧЕ** [*гар.*] *блт., мам.* көйсез, борчулы (капризный, беспокойный). Бигерәк бәләче бу бала, теге йарамый, бу йарамый. – *блт.* Бәләче, чебен тимәс чер итәр. – *мам.*

**БӘЛӘЧЛЕК** *чст.-крш.* к.: **мәләнчек.** Бусы бәләчлек, бәләчлек димен мин, аны сүткән ийе, җасап бетермәгән әле.

**БӘЛҖӘЛӘҮ** *перм.* сынганны бәйләп кую (связать, перевязать переломанное место). Сыңған айақны қабық қуйып бәлҗәлиләр.

**БӘЛЕКӘЙ, БӘЛЕКИЙ** *тпк.* к.: **бәйсәкә.**

**БӘЛЕШ** *тмн.* табага салып пешерелгән күмәч (лепёшка, испечённая на сковороде).

**алдақчы бәлеш** *минз.* табага ит, бәрәңге, май салып, өстенә камыр ябып пешерелә торган ашамлык (пирог с мясом и картофелем с «крышкой» из теста). Тиз була дип, алдақчы бәлеш кенә пешереб алдым.

**бәлеш бармағы** *мам., бәр.* бәлешнең сырланган, бөреп куелган өлеше (защеплённая часть бәлиша между его крышкой и нижней частью). Бәлеш бармағын кем кисә, кисегез әле. – *мам.* Бәлеш бармағын шакмакълап кисеп куйарлар ыйы да, шуны эче белән бергә ашар ыйык. – *бәр.*

**бәлеш тәтәй** *мам.* к.: **тупыйбаш 2.**

**бәлеш эрнәwe** *бәр.* к.: **бәлеш бармағы.**

**кийәү бәлеше 1.** *мәл.* кияүгә атап пешерелгән камыр ашамлыклары (угощение, преимущественно пироги, специально приготовленное в честь жениха); **2.** *чст.* бавырсак (баурсаки – национальное блюдо).

**таба бәлеше** *тмн.* ит-бәрәңге яки ит-ярма белән капкачсыз итеп пешерелгән бәлеш; табынга шулпа салып бирелә (пирог с мясом и картофелем или крупой, без «крышки»; перед подачей на стол пирог заливают бульоном).

**төпсез бәлеш** *минз.* к.: **алдакчы бәлеш.**

**чирәб бәлеше** *хвл.* чүлмәккә эретмәгән карын маен җәеп, тары яки бодай ярмасы салалар һәм өстенә камыр каплыйлар; пешкәч аны тәлинкәгә яки коштабакка бушатып ашыйлар (пирог, приготовляемый следующим образом: горшок изнутри выстилается сальником, затем наполняется пшённой или пшеничной крупой и закрывается куском теста).

**чәчә бәлеш** *тмн.* җиләк-җимештән пешерелгән бәлеш (сладкий пирог).

**БӘЛИ I** *чст.* к.: **били.** Кулына ак бәли кигән иде.

**БӘЛИ II 1.** *карс.* бәлки (возможно, может быть). Бәли, булыр, кем белә; **2.** *тара.* әйе (да).

**БӘЛИКӘЛИ** *твр.* аз гына (немного, немножко). Бәликәли йийғаның иләк.

**БӘЛЛҮДӘ** [*рус.* блюдо] *минз.* к.: **җәйләү.** Бәллүдәләрне алып кил.

**БӘЛМӘН** *тбл.* к.: **шөшпәрә.**

**БӘЛСӘМ** [*рус.*] *трх.* к.: **бәлсән.**

**киндер бәлсәме** *трх.* киндер орлыгыннан ясалган сыекча, медицинада эч, күкрәк авыруларыннан файдаланылган (сок, жидкость, сделанная из семян конопли). Өстәлләрдә пар бутилка, Берсе киндер бәлсәме (*хал. җыр.*).

**БӘЛСӘН** [*рус.*] *бәр.* бальзам.

**орлоқ бәлсәне** *бәр.* к.: **бәлсәм: киндер бәлсәме.**

**БӘЛТАРАФ** [*гар.*]: **бәлтараф итү** *трх.* исраф итү (расточить, транжирить, тратить что-либо). Бәлтараф итеп бетерер байлығын.

**БӘЛТӘКӘ** *перм.* **1.** тун теккәндә калган тире кисентеләре (обрезки, оставшиеся после шитья шубы). Тун тишелсә инде, тире бәлтәкә белән йамыйлар; **2.** тире (кожа). Чеметә бәлтәкәсен; **3.** тире (шкура). Бозау бәлтәкәсе. Бәлтәкәне қаршыға текмиләр инде, уңайға тегәләр.

**БӘЛТӘКӘР** *перм.* май бизе (сальная железа). Қайсы май ти, қайсы бәлтәкәр ти, эт ашамый.

**БӘЛТЕК** *байк.* к.: **кечкеник.** Бәлтек кенә ызба бар.

**БӘЛТЕРӘҮ** *бөре.* интегү, аптырау (мучиться, маяться, томиться). Бәлтерәп йөрмә. Йул табалмый бәлтерәп беттем.

**БӘЛҮДӘ** [*рус.* блюдо] *минз.* к.: **җәйләү.**

**БӘЛҮНКӘ** [*рус.* валенок] *дөб.* к.: **галуш 1.**

**БӘЛҮҢКӘ** [*рус.* валенок] **1.** *дөб.* к.: **галуш 1**; **2.** *лш.* йоннан энә белән бәйләнгән тапочка (тапочки, связанные спицами, крючком). Бәлүңкәне кр'учук белән бәйлибез.

**БӘЛҮҢКИ** [*рус.* валенок] *дөб.* к.: **галуш 1.**

**БӘЛХҮТ** [*гар.*] *мам.* бәрхет (один из видов бархата). Плүш түгел, бәлхүт, читләре уқалы, изүләре ачық булыр ыйы кәмзүлнең. Бәлхүт ул бик матур, озон җонно түгел ул, ыспай эшләнгән, шома, мондай бәрхет кебек түгел. Йәшмә бәлхүт йәшел була.

**БӘЛЦЕК** *лмб.* балчык (глина). Бәлцек алган йер тау буйы.

**БӘЛЧӘ** *дөб.* **1.** тәлгәш (кисть, гроздь); **2.** җимеш сабагы (плодоножка).

**БӘЛЧӘН** *дөб.* к.: **бәлчә 1.** Балан бәлчәне. Бәлчәннәре бик матур.

**БӘЛЧЕК** *лмб., кузн., хвл.*, **БӘЛЧИК** *мәл.* Бәлчектән кыйалар бездә ызбаларны. – *лмб.*

**БӘНКЕ** *т.я.-крш.*, **БӘҢГЕ** *срг.* өянке (ветла). Бәнке агачларына каргалар ойалаган. Бәңге бездә ышкул азбарында бар.

**БӘПӘ** *тара.* кечкенә бала (маленький ребёнок). Мин бәпә булыпмын.

**БӘПКӘ I 1.** *каз.ар.* көлтә киптерү ысулы: тугыз көлтәне башлары белән эчкә таба салып, аларның өстенә тагын берсен утыртып кую (способ укладки снопов для сушки). Бәпкәгә утыртабыз арыш көлтәсен, ун көлтәдән берсен сындырып өстенә қуйасын. – *лш.*; **2.** *перм.* җитен көлтәсен өю ысулы (способ укладки снопов льна для сушки). Җитенне җәйәсең, җиткәс бәпкәгә утытасың.

**БӘПКӘ II** *перм.* яшь үсенте (молодой отросток). Пиканның чықты инде хәзер бәпкәләре, қурайга утыра. Нимәгә бәпкәсен генә җыймыйсың, қартын да җыйасың. Ужы килеп чыға башлаган бәпкәсе картупныкы.

**БӘПЧЕК 1.** *мам.* к.: **бәбәк III**; **2.** *блт.* к.: **бәпкә II**; **3.** *бәр.* агачның яки солының яшь үсентесе (молодой отросток у овса, деревьев). Быйыл бәпчекләр йуғ ич, озон соло. Йаман қысқа wахытлары булды, ураққа керми, шул бәпчек була, соло бәпчеге. Ағачның бәпчекләре үскән, үстерсәң, ағач була.

**бәпчек күшәсе** *мам., дөб.*, **бәпшек күшә** *блт.* к.: **бәбәк III.**

**БӘР** *нокр.* әйдә! (давай!). Бәр, чәй эчәйек.

**БӘРӘБИШКӘ** [*рус.*] *том.д.* чыпчык (воробей).

**БӘРӘЙ** *перм.* к.: **алма I.** Бәрәй өтөп ашаб җатадыр ийек.

**БӘРӘК** *тпк.* ис китүне белдерә торган ымлык (междометие, выражающее удивление). Бәрәк, син шулай җалқау булырға итәсеңмени?

**БӘРӘКӘЙ** *злт., эчк.* к.: **бәкәй I.** Бызауқайны кертәбез мал өйөнә, бәрәкәйләрне кертәбез исәйгенсә. Бер сарыгым, ике бәрәкәйем бар. Кәзә бәрәкәйе белән қайтмады. – *злт.* Кәзәмнең бер бәрәкәйе бар. – *эчк.*

**БӘРӘМӘС** *тпк.* к.: **пирипич.** Қамырга эремекне күкәй салып басып йағасың, бәрәмәс була.

**БӘРӘМӘЧ: бәрәмәч килү** *минз.* сугышып, ыз-

гышып бетү (передраться, разнести в пух и прах).

**БӘРӘМЕТ** [*рус.*] *каз.ар.* җәен балыгын тота торган зур кармак (большой крючок для ловли сома). Су арқылы салынған йуwан җепкә қысқа ғына бау белән бәйләнә ул бәрәмет.

**БӘР'ӘМНӘҮ** *карс.* бәйрәм итү (праздновать). Утыз бәр'әмен бәр'әмниләр булган.

**БӘРӘН** *трх., минз., стрл.* к.: **бикәч II**. Берсе тәкә, берсе бәрән. – *стрл.* Бәрән, бәрәннәмәйче қалса, шешәк була. – *минз.* Бәрәнен қалдырам, тәкәсен сатам. – *трх.*

**бәрән қабы тун** *минз.* яшь бәрән тиресеннән тегелгән тун (шуба, сшитая из шкурок новорождённых ягнят).

**бәрән минеге** *чпр.* кышын яшь бәрәннәргә ашату өчен бәйләп киптерелгән яфраклы ботаклар (молодые побеги, приготовленные к зиме для ягнят).

**бәрәңге** (картофель):

**бәрәңге башы** *м.-кар.* бәрәңге күзе (глазок, зачаточная почка у картофеля).

**бәрәңге күшәсе** *блт.* к.: **йон: йонно бәрәңге**.

**бәрәңге тапау** *чст.* к.: **кәтмәкләү**. Бәрәңге башта тапибыз, аннары төбен үwәбез.

**бәрәңге чыгару** *минз.* бәрәңге алу (копать картофель). Бәрәңге чыгарабыз көз көне.

**бәрәңге эзү** *мәл.* к.: **бәрәңге чыгару**. Бәрәңге эзү wақытында awырый иде инде.

**бәрәңге ындыры** *мәл.* к.: **алмалык**.

**күдергән бәрәңге** *трх.* кабыклы бәрәңге (картошка в мундире). Күдергән бәрәңге пешерәм җарып-җарып, тоз салып. Син үзең әйттең бит күдергән бәрәңге пешер, дип.

**БӘРӘҢГЕЛӘК** *трх.* к.: **алмалык**. Билчәннәр чәчәк ата башлаган бәрәңгелектә.

**БӘРӘС** *тпк.* к.: **бәкәй I**. Дүрт сарыққа ике бәрәс бар.

**БӘРӘСЛӘҮ** *тпк., стрл.* к.: **бәкәйләү**. Сарық бәрәсләгән дә, бәрәсләре туңқан та, ди. – *тпк.* Алачыкны мал өйө дибез, бәрәсләгән сарык тора. – *стрл.*

**БӘРӘХӘТ** [*гар.*]: **бәрәхәт килә** *м.-кар.* туйга күчтәнәч белән килүчеләрне каршы алганда әйтелә торган сүз (слово, которое произносится при встрече участников свадьбы, пришедших с гостинцами). Бәрәхәт килә, бәрәхәт килә, дип, cawым китергәндә әйтеп торалар.

**БӘРӘЧ I** *кргл., стрл.* к.: **бәкәй I**. Ансы элек кухнайы, хәзер бәрәчләр йабабыз. – *кргл.* Үткән йылгы бәрәч бу йылга калдисә, шешәк тиләр. – *стрл.*

**БӘРӘЧ II** *минз., кмшл.* гаҗәпләнү, ис китү, шатлану кебек тойгыларны белдерә торган ымлык (междометие, выражающее удивление, радость и пр.). Бәрәч! шуны да белми икән бу! – *минз.*

**БӘРӘЧЛӘҮ** *минз., стрл.* к.: **бәкәйләү**.

**БӘРӘШ-БӘРӘШ** *т.я.* к.: **баш-баш**.

**БӘРӘШКӘ** [*рус.*] **I** *кас.* клиндер (баранки, сушки). Кибеттә бәрәшкәләр бар.

**БӘРӘШКӘ II: соңго бәрәшкә** *минз.* соңгы бөртек, калдык (последняя крупинка, остаток). Соңго бәрәшкә ақчаларымны җыйып карандаш алдым. Соңго бәрәшкә он белән қоймақ пешердем әле.

**БӘРДӘ** [*гар.*] *тбл.* пәрдә (занавес). Тәрәсә бәрдә.

**БӘРЕ** *тара.* к.: **беткелгесе**. Бәре халық.

**БӘРЕЛҮ** *кмшл.* йомыш төшү, кирәге чыгу (иметь к кому-либо дело, нуждаться в чьей-либо помощи). Кереп бәрелермен дә дим.

**БӘРЕП** *т.я.-крш.* каты (сильно). Бу бала чирләй бәреп.

**БӘРИЛӘ** *төм.* штакетниктан киртә (забор из штакетника).

**БӘРЙӘМ, БӘРЙЕМ** *нокр.* к.: **бар'ам**. Гашурә бәрйемдә садақа бирә. Бәрйәм ашы – қара-қаршы (*мәкаль*).

**БӘРКӘЙ** *том.д.* к.: **куй**.

**БӘРЛЕГҮ** *перм.* бәрелү (удариться, стукнуться, столкнуться). Суқыр тәкә күwег ул килеп бәрлегә сийә. (Сукыр булгач) барып бәрлегәсен бер-бер нәмәгә, йә ишеккә, йәйсә эчтинәгә.

**БӘРМӘНЧЕК 1.** *каз.ар.-крш.* к.: **ботка: йаңгор боткасы**; **2.** *нгб.-крш.* русларда дини бәйрәм (вербное воскресенье).

**бәрмәнчек сугу** *т.кам.-крш.* христиан бәйрәмендә яшьләр уеннары (игры молодёжи в день вербного воскресенья). Бәрмәнчекне сугалар ыйы төнлә җәшләр салам чыбыркы белән, бәрмәнчек сугуга пуп қаршы йы.

**БӘРМӘЧЛЕКИ** *каз.ар.-крш.* сырга – талда (серёжка – у ивы); чаг.: **песи**.

**БӘРМӘЧТЕКИ: бәрмәчтеки атнасы** *каз.ар.-крш.* бәрмәнчек көненнән алып пасхага кадәр булган бер атна вакыт (вербная неделя). Оло бәйрәмдән бер атна алдан бәрмәчтеки атнасы дип әйтәләр ийе инде.

**БӘРОШ-БӘРОШ** *м.-кар.* к.: **баш-баш**.

**БӘРЧӘ 1.** *дөб.* солы яки тары башагы (колос овса или проса); чаг.: **бәлчә**. Быйыл солы бик уңған, бәрчәсен көчкә күтәреп тора; **2.** *бәр.* солы башагы (овсяной колос). Тарының бәрчәсе булмый, бер генә баш бит ул, соло бәрчәле була, йақ-йаққа таралған; **3.** *бәр.* к.: **бәпкә II**. Бәрчә чыгарған диләр ағач төбендә үскән йафраққа; **4.** *дөб.* сабак (гроздь, кисть). Бер-ике бәрчә шоморт бир әле? Чийә дә бәрчәле була, икеле, өчлө бит. Бөрлөгән дә бәрчәле.

**БӘРЧӘКЛӘҮ** *минз.* вату, челпәрәмә китерү; челпәрәмә итү (разбить вдребезги). Лампычкыны бәрчәкләп бетерде.

**БӘРЧӘЛӘҮ** *дөб.* к.: **мәндерәтү**.

**БӘРҮ** *кузн., хвл., мәл., карс., чст., срг., чпр.* **1.** к.: **быргыту**. Цыгарын бәр азбарга бу цупләрне. – *срг.* Боз бәрдем шонда арага. – *кузн.* Себереп бәргәсендер нawызын. Ырыштыwада кабаг аша (кызлар) чабата бәрәләр (иде), шул бит өстөнә бәрелсә, кайгылы кешегә бәрәләр, өскө йакка бәрелсә – шатлыклыга. – *хвл.* Мә шында бәр инде. – *чпр.* Сындырып бәрми ул кешене. – *срг.*; **2.** к.: **выргыту 2**. Кукы төсле ыланнарын бәреп китте. – *чст.* Катнын бәргән Али. Жалкикән сүгән кешеңне бәрергә. – *срг.* Ире бәргән, ди үзе. – *хвл.* Ничек үне бәреп киткең кели, кеше йук. Ә бусы дайарка тырды жиде йыл, бәрде ватаккынасы. – *чпр.*

**бәреп қуйу** *перм.* ташлап китү, ташлап калды-

ру (бросить, оставить без присмотра). Матай белән килгәннәр дә күрше awылға бәреп куйганнар.

**БӘС-БӘС** *чпр.* к.: **баш-баш**.

**БӘСӘ 1.** *тбл.* к.: **баса II**; **2.** *тара.* к.: **мыса**. Кәртүшкәне казый бәсә?

**БӘСТӘ** *тбл.* ахры, булса кирәк (вероятно, по-видимому, наверное). Бәстә бер йарым метр туңган йер.

**БӘСТҮК** [*рус.* пастух] *төм.* көтү (стадо). Куйлар килеб утыраты бәстүктән. Сыйыр бәстүктән үсе гиләте.

**БӘТЕР I** *эчк.* к.: **күзикмәк I, 1.**

**БӘТЕР II** *лш.* тимерчыбыктан үрелгән сәкә (вид рыболовной снасти: верша, морда, сплетённая из металлических прутьев). Күлгә куйыла бәтер, ике канатлы, түгәрәк фурмыда була.

**БӘТИ** *дөб., мам.* к.: **бәкәй I**. Дүрт бәти, ике сарык асырап чыктык. Сәке астында бәтиләр тора. – *дөб.* Бәтиләргә хәсилтә бәйләргә кирәк, күз тийәр йә. – *мам.*

**БӘТИЛӘҮ** *дөб.* к.: **бәкәйләү**. Сарык бәтиләде дә, көтүгә чыгармадыг әле.

**БӘТКЕ** [*рус.* батька] *бөре.* к.: **анай 2**. Бәтке, килеп тә җиттең?! Бәтке, ник алай әйттең?

**БӘТ'ЕС** *кас.* баскыч (лестница); чаг.: **баслык**.

**БӘТРӘ** [*рус.* ведро] *тбл.* к.: **бид(е)рә**. Пер бәтрә бәрәнке.

**БӘТРӘК 1.** *чпр.* чая, кыю (отчаянный, смелый). Бу бик бәтрәк ийе безнең; **2.** *т.я., м.-кар.* бәйләнчек, сугышырга яратучан, сугыш чукмары (назойливый, драчливый, задира); чаг.: **җилбаш**. Хәйруш awылда иң бәтрәк иде йәш чағында. – *к.т.* Менә кем кешегә бәйләнеп йата, бәтрәк диләр. – *м.-кар.*

**БӘТРӘКЛӘНҮ** *м.-кар.* бәйләнү, җикеренү; сугышырга әзер тору (приставать, привязываться; быть готовым к драке). Бәтрәкләнеп килеп куна.

**БӘТЧӘ** *дөб.* к.: **бәлчә 1**. Карлыган, миләш бәтчәсе.

**БӘТЧӘЛӘП** *дөб.* тәлгәше белән, сабагы белән (гроздьями; с ножками). Мин җиләкне бәтчәләп җыйдым.

**БӘҮРИЛГӘН** *тара.* кара бөрлегән (ежевика).

**БӘҮТҮ** *тбл.* ялагайлану (льстить).

**БӘХЕРНИСА** [*гар.*] *перм.* бака (лягушка). Сүwык тотса, бәхерниса күрсәтәләр курыксын өчен.

**БӘХЕТ: бәхет чәчәге** *дөб.* бу үсемлекнең чәчәккә бөреләнгән ботагын, өзеп, стенага яки түшәмгә кыстырып куялар. Бөреләр ачылса, бу йортка да бәхет ачыла, имеш (золотая розга).

**БӘЦКӘЙ** *срг.* к.: **баш-баш**.

**БӘЧ** [*рус.* весь] *трх.* к.: **ару II, 1**; чаг.: **башуқ**. Печәнне сушилаға үдек, бәч күгән. Кызлар бәли, қулы бәч қан.

**БӘЧӘ** *глз.* якын туган хатын-кыз (близкая родственница). Йакын туганың бәчә була.

**БӘЧИ-БӘЧИ** *м.-кар.* к.: **баш-баш**.

**БӘЧМӘЧӘ** *минз.* салма (клёцки). Менә bedдә бәчмәчәне шушылай иттереп пешерәләр инде, төче камырны басасың биг әйбәтләп, әзерәк җоморка саласың, қунада әүкәлисең дә үч төбендә бөтөреледереп төшөреп бетерәсең.

**БӘЧТЕК** [*рус.* пустяк] *минз.* к.: **безрәк**. Бәчтек кенә боролган була ул.

**БӘШӘКӘ** *төм.* к.: **куй**. Бәшәкә бирәтләр. Бәшәкә гарасалар, үсенә булаты.

**БГОР** [*угор.*] *нокр.* йомгак (клубок).

**БДИ-БДИ** *чпр.* к.: **баш-баш**.

**БЕВЕРЛЕ, БЕWЕРЛЕ** *кузн., хвл.* к.: **бөwерле**. Эч беверле була бырынгы бишмәт. Бewерле тун. – *хвл.*

**БЕГӘЛҖӘ** *т.я.-крш.* к.: **бөгәрҗә**. Менә бусы бишек бегәлҗәсе.

**БЕГӘЧӘ** *м.-кар., т.я.-крш.* бүген төнлә, бүген кич (сегодня ночью или вечером). Бегәчә булас инде тансы. – *м.-кар.* Мин бегәчә җал, карawылга бармим. – *т.я.-крш.*

**БЕГЕЛҮ** *хвл.* бөгәрләнү (согнуться, изогнуться). Карават читенә айакларын җыйып бегелеп йаткан.

**БЕДЕР'И** *кас.* токмачның кабырчык формасындагы төре (один из видов лапши в форме ракушки; ракушка).

**БЕДЕРЛӘНҮ** *чпр.* таралу, ярмалану (становиться крупчатым, рассыпчатым). Сыгым майы йакшы, кан′атсаң, бедерләнеп тора.

**БЕДИ** *чст.* к.: **бәкәй I**.

**БЕДРА** [*рус.* ведро] *срг., нокр.* к.: **бид(е)рә**. Кызым, бедраларыңны алып суга барчы. – *срг.*

**БЕДРӘ** *тмн.* бөре (почка у растений). Кара урманнарның, әй, кукысы Ашидыр агачның бедрәсен (*бор. җыр.*).

**БЕҖЕК, БЕҖИК** *м.-кар.* к.: **безек**. Беҗек агач.

**БЕҖМИН** *перм.* бизмән (безмен). Җәнне беҗминдә генә үлчәмәгә кирәк.

**БЕҖҮ** *м.-кар.* к.: **безнәү**. Төн ката беҗеде. Ә хәзер беҗи белсен түлке: «Ай, кызи, йахшы беҗисен!» – ди.

**БЕЗ** *тмн.* кылчык (ость). Безләр керә иде дәнгә арышныкы.

**БЕЗӘРИК** *т.я.* к.: **безрәк**. Шул безәрик утын апқайтқанға да ачулана. Безәрик шәүлә күрәм. – *к.т.*

**БЕЗБЕЛДЕК** *бөре.* чокыр һәм яр читләрендә оялый торган, умарта кортына охшаш сары төстәге вак корт (насекомое, очень напоминающее пчелу и устраивающее свои гнёзда по краям оврагов).

**БЕЗДӘННӘҮ** *злт.* киләп сару, эшсез йөрү (болтаться без дела). Бездәннәп йөрмә.

**БЕЗДӘРӘК** *трх.* к.: **безрәк**.

**БЕЗЕК** *м.-кар.* биек (высокий).

**БЕЗЕЛДӘWЕК** *т.я., мам., мәл.* **1.** такылдык, күп сөйләргә яратучан (болтун, любитель поговорить); **2.** күп зарланучан кеше (тот, кто часто жалуется; нытик). Безелдәwек кеше эчне пошыра ул. – *к.т.*

**БЕЗНӘҮ** *м.-кар.* бию (плясать, танцевать). Җырлый, безни бергә, ире, катыны бергә.

**БЕЗРӘК** *нрл.*, **БЕЗРИК** *т.я., лш., чпр.* аз, аз гына, бераз, берникадәр (немного). Безрик көтеп торыгыз әле. – *к.т.* Безрик кенә бирделәр. – *лш.* Безрик арыш оны сибә. – *т.я.-крш.* Безрик мишәрлекләре бар, йомшаграк кына сүләшәләр. – *чпр.* Дару белән безрәк қапқаладым ыйы мин. Майны

үлчәп қуйайы да үги ана безрик кенә безгә бирер ийе. – *нрл.*

**БЕЙЕРЛЕ** *баст., кас.* к.: **бөwерле.**

**бейерле бишмәт** *баст.* билдән бөргән фалдалы бишмәт (бишмет, сосборённый в талию, с фалдами, и расклешённый книзу). Бишмәт әбиләрнең өч бейерле, мамык беле сырыған, выратниксыз, җиңне.

**бейерле тун** *кас.* билле тун (шуба, сшитая с фалдами в талию и расклешённая книзу). Бейерле туннар да бул'ан, туры туннар да бул'ан.

**БЕКЕРӘЙТҮ** *мәл.* төшерү – күңелне, рухны (портить, испортить – настроение). Мин алдыртмаска иткән ийем дә, кайенем әтә, баланың кеңелен бекерәйтеп, ти.

**БЕККӘН: казан беккән** *м.-кар.* пилмән (крупные пельмени).

**БЕКМӘ 1.** *тмн., т.я.-крш., срг.* к.: **бирук.** Ид бекмәсе пешерәм. – *тмн.* Алма бекмәсе, чегендер бекмәсе. – *т.я.-крш.* Бекмә табага икәү керә, зурлак та була. – *срг.*; **2.** *срг., тмн.* к.: **шөшпәрә.**

**киндераш бекмәсе** *тмн., срг.* киндераш пилмәне (пельмени из толчёной конопли). Киндераш бекмәсе пешерәбез, киндерашны түwәбез, йарма салабыз, безерик, камырны иткә, йомыркага басасын да пешерәсен суда пилмин кебек. – *срг.* Киндераш бекмәсен дә пешерәләр, липушкасын да. – *тмн.*

**БЕКСӘМ** *мәл.* кыса, күлмәкнең өске өлеше (верхняя часть платья). Күлмәкнең бексәме кыскарак булды.

**БЕКШЕНҮ** *чпр.* күз тию, күзсенү (подвергнуться сглазу, сглазить).

**БЕЛӘЗЕК I 1.** *чст.* божра (кольцо); **2.** *бөре.* арба күкрәген ныгыту өчен бер-берсенә янәшә куела торган божралар (металлические крепления на подушке телеги); **3.** *мам.* к.: **башлага.**

**җиң беләзек** *бөре.* к.: **башлага.**

**җылан беләзек** *мам.* беләкне берничә тапкыр уратып ала торган пластмасс беләзек (пластмассовый браслет в несколько рядов). Җылан беләзек кидем, салганда да сыммыйдыр ыйы, җылан шикеллерәк торадыр ыйы.

**ишмәле беләзек** *трх.* ишмә беләзек (кручёный, свитый браслет).

**йазулы беләзек** *әстр.* бизәкле беләзек (узорчатый браслет).

**шарлы беләзек** *трх.* кигәч борып, әләктереп куя торган беләзек (браслет с застёжками в виде шариков).

**БЕЛӘЗЕК II** *стрл.* урама (кушанье в виде раскатанных и свёрнутых в трубку кусков сдобного теста, жаренных в масле).

**БЕЛӘЗЕКЛЕК** *кузн.* беләк сөяге (запястье).

**б е л ә к I** (рука от кисти до локтя):

**беләк кыстыру** *мәл., хвл., кмшл.* җиң сызгану (засучить рукава). Беләкләреңне кыстырып, хаз'ыр ук тотын эшкә! – *хвл.* Беләкләреңне кыстырып камыр басарсың. – *кмшл.*

**БЕЛӘК II** *перм., минз., стрл.* к.: **бүләк II, 2.** Жүкәле беләк, чаганлы беләк, көпшәле беләк. – *минз.*

**БЕЛӘК III** *кргл.* бер тапкыр кулга урап эрләрлек күләмдә кәҗә мамыгы (козий пух в количестве, достаточном для обматывания в одну руку для разового прядения; локоток). Манганнан соң, бер беләклек алып беләккә урыйлар эрләр өчен, ул беләк була.

**БЕЛӘКСӘ I 1.** *к.т.* сарык йоныннан яки кәҗә мамыгыннан бәйләп, җылылык өчен кышын беләккә кия торган җиңсә сыман әйбер (связанное из овечьей шерсти или козьего пуха и надеваемое зимой для тепла подобие нарукавника); **2.** *перм.* к.: **башлага.** Беләксәсен дә қара, шушының җуwаннығы беләк була димени.

**БЕЛӘКСӘ II** *минз., стрл.* беләзек (кисть руки).

**БЕЛӘКЧӘ 1.** *хвл., кузн., мәл., минз.* җиңсә (нарукавник). Урак урганда, чәнчемәсенгә беләкчә кийәбез. Укучылар терсәк катмастан кийәләр беләкчә, алынйапма кийәләр; **2.** *твр.* җиңдәге манжет (манжет на рукаве). Беләкчәләп әwәл йеңнәрен теккәннәр күбесе, тар гына, пер сәдәп қуйа.

**БЕЛӘМ** *әстр.* күрәсең, мөгаен (видимо, вероятно). Ул қалған, беләм.

**БЕЛӘНҮ** *перм.* шытып чыгу, шыту (всходить, взойти). Картуплары беләнгән. Беләнгәч, тырматалар ий ағач тырма былы. Қабақ күп беләнгәнме сезнең?

**БЕЛӘСТӘ** *чпр.* к.: **белдектә.** Без беләстә күпер генә бар иде.

**б е л ә ү** (оселок):

**беләү җара** *т.я.* озак төзәлми торган яра (незаживающая рана). Бармағыма шырпы кереп, беләү җара булды. Шешкән бармагыңны бәйләп җөр, беләү җара булмасын. – *к.т.* Қулымны әз генә кискән ийем, бәйләми җөрдем дә, беләү җарасы булды, ахыры, төзәлми дә төзәлми. – *нрл.*

**БЕЛГӘН** *перм.* **1.** к.: **әләк 2.** Малай баштақ түгелме? У-у, белгән!; **2.** к.: **айап 1.** Белгән була су монда, бик шәп булды үткән йыл да ташу, болоннар җап-җақты сыу була, кәмә белән йөриләр фирмегә. Буганда, белгән була ул җиләк.

**БЕЛГЕНҮ** *чпр.* беленү (выявиться, проявиться). Машина белән таштан китсә дә белгенми бит.

**БЕЛГЕЧ** *каз.ар.-крш.* к.: **белемче 1.** Ул әби белгеч әби булған.

**БЕЛДӘ** *перм.* билге, тамга (знак, помета, засечка).

**БЕЛДӘЛӘҮ** *перм.* к.: **билдәләү.** Бидерәдәге онны белдәләп қуйған, мәйтәм, бу белдә қуйған қый.

**БЕЛДӘЛЕ** *перм., стрл.* к.: **билдәле.** Сабан туйы дигәч, белдәлинде, сабан беткәч. – *перм.*

**БЕЛДЕКЛЕК: белдеклек сату** *мәл.* белдекләнү (претендовать на знания, на осведомлённость). Һаман белдеклек сата.

**БЕЛДЕКТӘ** *глз.* белгәндә (на чьей-нибудь памяти). Мин белдектә йуғ инде ул, бабамнар силий иде.

**БЕЛДИ-СӘЛДИ** *чпр.* берәм-сәрәм, сирәк-мирәк (изредка). Белди-сәлди генә карцыклар тупи кийәләр башларына.

**БЕЛЕКИЙ** *перм., к.-уф.* к.: **кечкеник.** Белекий генә әбийе. – *перм.*

**БЕЛЕКЛЕ** *минз., баст.* белемле (знающий). Ул

белекле кеше. – *минз.* Ай матур иде, ай белекле иде. – *баст.*

**БЕЛЕКСЕЗ** *каз.ар.-крш., бөре., перм., злт.* **1.** белемсез (незнающий). Белексез булған инде. – *бөре.*; **2.** мәгънәсез, мәнсез (бестолковый); чаг.: **дундук.** Шундый белексез кеше ул. – *каз.ар.-крш.* Малай кеше белексез була икән. – *злт.* Ул әби бигрәк белексез икән, бер сум бирсә нимә була. – *перм.*

**БЕЛЕКЧЕ** *каз.ар.* к.: **белемче 1.** Белекче қарчық әйткәндәй, йә йawар, йә йуқ.

**БЕЛЕМ I** *нокр.* белен (блин).

**белемгә бару** *нокр.* туй йолаларыннан берсе: киленне кияү йортына төшергәннән соң, кияүне, кияү егетен һәм егет ягыннан туйда катнашучыларны кыз ягына кунакка чакыралар. Сый ахырында табынга белен бирәләр. Белен өстенә кияү акча сала (один из старинных свадебных обрядов).

**кийәү белем** *глз.* кияү коймагы (блины для жениха). Кийәү белем ашаталар кийәүгә, қызга.

**БЕЛЕМ II** *глз.* к.: **кикрук.**

**БЕЛЕМЧЕ 1.** *трбс.* күрәзәче (предсказатель, гадалка). Син белемчегә барып қарале; **2.** *т.кам.-крш.* им-том итүче, им-томчы (ворожея, предсказатель; человек, занимающийся знахарством). Қурқыталар икән шом тотқан кешене, бар бит ул белемчеләр.

**БЕЛЕП: белеп түгел** *минз.* бик күп, бихисап (очень много, без счёта, неисчислимо). Қода-қодағыйларға бүләк белеп түгел, бер лафка әйберсе.

**белеп тә түгел** *минз., стрл.* к.: **белеп түгел.** Ул чийә инде белеп тә түгел. – *минз.*

**БЕЛЕПНЕКЕ** *мәл.* белеп, белгән көе (зная что-либо). Белепнеке төгәл вет.

**БЕЛЕШМӘҮ** *каз.ар.-крш.* ақылдан язу (лишиться ума, помешаться). Чуқындырған урсайым белешмидер ийе инде ул чағында.

**БЕЛМЕР: белмер булу** *тара.* белмәгәнгә салыну (прикидываться незнающим). Белмер булып систергән үсен.

**БЕЛТӘЙҮ** *перм.* әреләну, масаю (зазнаться, возгордиться, заважничать); чаг.: **киберләну.** Санийә уғата белтәйгән.

**БЕМӘ** *нокр.,глз.* өмә (помочь; коллективная помощь). Чүпләшмә бемәсенә бардым. Утын бемә йасадым. – *нокр.* Казны суйганчы суга алып барып койондырабыз чиста булсын дип, каз бемә йасыйбыз. – *глз.*

**БЕМИ** *глз.* к.: **бемә.** Элек каз бемигә сигез, тугыз өйгә бара, каз йуwарга чишмәләргә төшәрләр иде.

**б е р** (один):

**бер awыз булып** *әстр.* бер сүздә булып (договорившись, единогласно).

**бер азғынтай** *әстр.* бераз (немного). Бер азғынтай дим алам.

**бер ат җул** *мам.* бер йөк, бер олау (один воз). Бер ат җул утын җитә безгә қышқа.

**берәр җартын** *к.т.* берәр җирдән, каян да булса (откуда-нибудь).

**бер бармак иннеге** *хвл., кас.* бер бармак киңлеге, бер илле (шириной в один палец).

**бер басма җеп** *мам.* киләптәге йөз егерме бөртек җеп, ягъни утыз савым (сто двадцать ниток в мотушке).

**бер бәйләм** *мам.* талкыган сүснең егерме учка яки кырык *җәнчем*гә тигез булган күләме (количество пакли, равное двадцати горстям).

**бер-бер** *перм.* бер дә, бөтенләй, һич тә (совсем). Мәрхәбә, мийә ақча қуйсыннар, ыңгырашып тормасыннар бер-бер.

**бер-бер кор′оклы** *кузн.* бер-бер артлы (друг за другом). Өчесе дә бер-бер кор′оклы килде.

**бер-берәү** *перм.* кайбер (некоторый, иной). Бер-берәү иләмтеге күп қала дибез, бер-берәү он өресе күп қала дибез.

**бер буйдан** *трх., мәл., чст.* һаман, бертуктаусыз, өзлексез (постоянно, беспрестанно, беспрерывно). Бер буйдан китапқа қарамыйча икешәр сәгәт сүли инде. Бер буйдан awылда йәшәүче. – *трх.* Әти, нигә бер буйдан әләнеп карыйсың, дигән. – *мәл.*

**бер буйли** *чпр.*, **бер буйлый** *трх., мәл., чст., кузн.* **1.** к.: **бер буйли.** Без бер буйли сүләүчеләр. – *чпр.* Чәй кибеттә бер буйлый булып тормый әлекечә. Бер буйлый сөйләп тора. – *трх.* Бу хатле бер буйлый сүләп торысың икән. Бер буйлый нушфы әчәм. – *мәл.*; **2.** *трх.* рәттән (подряд). Хәзер бер буйлый мунча; **3.** *кузн.* бер буйдан, бер тоташ (беспрерывно). Шолай бер буйлый йырлап торган.

**бер буйынча** *клд.* к.: **бер буйдан.** Бер буйынча кийеп булмый ш′олк күлмәкне.

**бер генә гүс** *тбл.* бердәнбер (единственный). Бер генә гүс қызлары бар иде.

**бер дә санда** *нокр.* сирәк, әллә нигә бер (редко, изредка, один раз за большой отрезок времени). Бер дә санда алган читча күлмәгең була иде.

**бер җартын** *лш., каз.ар.-крш., к.т.* беркаян, бер җирдән (ниоткуда). Бер җартын да подмог килми. – *лш.*

**бер җары** *блт.* к.: **бер йары.** Бер җары урнашса шунда.

**бер җарым биш** *т.я.* к.: **йарымбиш.**

**бер җәнчем** *мам.* талкыр өчен алынган җитен яки киндернең бер тоташлы, ягъни берьюлы эшкәртелә торган күләме (горсть льна или конопли, обрабатываемого в один приём).

**бер җәшет** *каз.ар.* к.: **бер йыллык.** Икебез дә бер җәшет. Аның малайы белән безнеке бер җәшет. – *лш.* Қарчык та минем белән бер җәшет ийе. – *дөб.*

**бер җир** *мам.* буе 200 м, иңе 400 м булган җир үлчәү берәмлеге (единица измерения поля, длина которого равна 200 м, ширина 400 м). Бер җир буйга ике йөз митыр, иңе дүрт йөз митыр була, бер кешегә тийә. Бу басудан бер җир тийә, теге басудан бер җир тийә тар ғына.

**бер җома** [*гар.*] *тмн., хвл.* бер атна (неделя).

**бер җөмә** *кас.* к.: **бер җома.**

**бер зат та** *кузн.* беркем дә (никто). Бер зат та орышмады.

**бер иле** *хвл., мәл., кас.* к.: **бер бармак иннеге.** Чиләгем бер иле тулмады. – *мәл.*

**бер йаңыс** *клд.* бердәнбер (один, единственный). Бер йаңыс камунист идем awылда.

**бер йары** *блт.* берәр җиргә, кая булса да (куданибудь).

**бер йарымбиш** *т.я.* к.: **йарымбиш**.

**бер йәшет** *каз.ар.* к.: **бер йыллык**. Минем картым белән бер йәшет. – *мам.* Минем дә кызым бар ийе, синен белән бер йәшет. Икесе дә бер йәшет алар. – *дөб.*

**бер йыллык** *клд.* яшьтәш; бер яшьлек, бер яшьтәге (одного года, одногодок, ровесник). Бабай белән бер йыллыклар алар.

**бер қawым** *блт., дөб., бөре.* бер өлеш, бераз (некоторая часть, немного); чаг.: **безрәк**. Бер қawымын кешегә саттық, бер қawымын үзебез урдық. – *блт.* Бер қawым баралар да туқтыйлар хайваннар. – *дөб.* Арышлар да чапқаннар ийе бер қawым. – *бөре.*

**бер кәрәм** *кузн.* к.: **бертына**. Бер кәрәм барам.

**бер қуласты** *т.я. йарымбиш*нең бер чирегенә тигез җир (участок земли, равный четверти *йарымбиш*).

**бер макка** *срг.* к.: **берыңгай 1**. Әйдә, бер макка мыны итеп ташлыйк.

**бер нимә қылу** *тбл., тара.* бер нәрсә эшләү (что-нибудь делать).

**бер саба' җеп** *кас.* бер саплам җеп (нитка в один конец).

**бер сабан суғу** *нрл.* чабагач белән дүрт кеше сугу (вчетвером молотить цепом). Дүрт кеше тәпәч белән суққанны бер сабан суға, ди торғаннар ийе.

**бер сawым җеп** *каз.ар., кмшл.* киләптәге дүрт бөртек җеп (четверо ниток в мотушке).

**бер саплам йер** *тмн.* бер карыш, аз гына (один вершок, немного). Бер саплам гына йер калган кат'ырга.

**бер сарық өсте** *т.я., кмшл.* бер сарыктан кыркып алынган йон (шерсть, полученная с одной овцы). Бер генә сарық өстем қалды эрләргә. – *к.т.*

**бер сафқа қалу** *т.я.* к.: **берыңгай: берыңгай булу**. Малайым киткәч бик сағынған ийем, инде бер сафқа қалдым. – *к.т.*

**бер сыйра** *яушт.* ә дигәнче (мгновенно, не успеешь сказать а). Бер сыйра тойоб ийам.

**бер табан** *каз.ар.* ярты аршынга тигез үлчәү берәмлеге (пол-аршина, величина, равная ступне ноги). Бер табан җир сөрмәделәр.

**бер талай 1**. *мәл., хвл., кузн., кргл., әстр.* бернекадәр вакыт; әллә никадәр вакыт (некоторое время; значительный отрезок времени). Бер талайдан соң үзе кат'ып керде. Бер талай көттем үзен. Бер талайдан соң сүнде. Дүрт бырат тордолар (бергә) бер талай. Бу да бер талай бал'ничада йөрде. – *хвл.* Бабайдан бер талай йазарсың. – *әстр.* Султаннарда сүләп утырдык бер талай аның мынан. Ыланнарым котолды бер талайга. – *кузн.*; **2**. *нгб.-крш., кргл.* беркадәр, бераз (некоторое количество, расстояние и т.д.); чаг.: **безрик**. Бер талай җир бардым да туқтадым. Татар да күп, урыс та күп бер талай. Шуннан килеп бер талай йөрсәң, тағын искә төшә. – *кргл.*

**бер талайға** *баст.* к.: **бер талай 1**. Ул инде бер талайға җарый.

**бер терит** *минз., стрл.* бер төркем, бер өлеш, бераз (одна часть, одна треть). Бер терите Р'азаннан, ди, бер терите Иделдән, ди (килгән халық турында). – *стрл.*

**бер толом** *дөб.* к.: **бер җәнчем**.

**бер тур(ы), бер турылы** *минз.* бер чор, бер вакыт (в одно время, в один отрезок времени). Бер турны азаландылар бит. Әгерҗе белән бер турымени безнең сабантуй? Әнә шул бер турылы килгәннәр инде алар.

**бер тылым** *лш.* к.: **бер җәнчем**.

**бер тын** *минз., стрл.* бераз, бераз вакыт (немного, немного времени). Бар, алайса, тагы бер тын йөрөп қайтығыd. Кич утырабыd бер тын сүләшеп. – *минз.*

**бер тытам** *кмшл.* бер дә, һич тә, бер адымга да (совсем, ни на шаг). Арттан бер тытам қалмый бит.

**бер уңғайли** *чст.-крш.* берөзлексез (беспрерывно). Мона мин дә дүрт җыл бер уңғайли бардым шул чишмәгә, халем җиңелерәккә китте.

**бер шәйдән** *бөре.* к.: **берыңгай 1**.

**бер шәп торғач** *перм.* бераздан, бераз вакыттан соң (некоторое время спустя). Ашаб алырбыз әле бер шәп торгач, пичкә балық қуйдым ий.

**бер шәптә** *бөре., перм.* тиз арада, тиз вакыт эчендә (очень быстро, моментально, в короткий промежуток времени). Бер шәптә қарап чыгыйм әле. – *бөре.* Ат белән бер шәптә килеп җиттек. Бер шәптә икешәр бидраны җыйып қайталар ийе. Хәзер бер шәптә барасың да Шутчийға бер шәптә қайтып та төшәсең. – *перм.*

**бер шәптән** *перм., злт.* к.: **бер шәп торғач**. Чығарым әле бер шәптән, тегеннән очтан табатын килсеннәр әле. – *перм.* Бер шәптәнерәк килерсез. – *злт.*

**бер эрәт** *перм.* бер чама, бертөрлерәк (примерно одинаковый). Үткән җыл қыйбат булмады: йазын да бер эрәт, көзен дә бер эрәт.

**БЕРАНЧА, БЕРАНЧАК** *лмб.* к.: **безрәк**. Беранча ачкамыр бирген. Кабак башында дранча, Эстәл эстендә суланча, Бик гыразалап сырамагыз, Срук бирегез беранча (*бор. җыр.*). Беранчак калдырган идем, дувыл-дувыл пешердем.

**БЕРӘГӘЙ** *себ.* менә дигән итеп (превосходно).

**БЕРӘЙ** *злт., тпк., трбс., стрл., туб.-ирт.д.* берәр (некий, некоторый, какой-то). Берәй кеше килсә, мине инәйләргә китте диб әйтер. – *злт.* Берәй шабала аш салың. – *тбл.*

**БЕРӘЙСЕ** *злт., тпк., стрл.* берәрсе (кто-нибудь).

**БЕРӘЛКӘ** [*рус.* прялка] *брб.д., твр.* орчык (веретено). Ашлар шайлап, берәлкә менан йүң өйөреп помич итә деген. – *брб.д.* Берәлкә мән эрли идек. – *твр.*

**БЕРӘМЕК-БЕРӘМЕК** *т.я.-крш.* шакмаклы (в клетку, клетчатый).

**берәмек җаулыгы** *т.я.-крш.* шакмаклы яулык (клетчатый платок).

**БЕРӘМЕКЛӘП** *лш.* берәмләп, аралап (перебирая). Җиләкне берәмекләп сайлаб ашый.

**БЕРӘМНӘТӘ** *лмб.* берәмләп (тщательно). Берәмнәтә җийам куңызларны, тагын тулганнар.

**БЕРӘМ-САЛАМ** *тмн.* берәм-сәрәм (поодиночке). Берәм-салам йыйылганнар Сыркыдыга (*ав. ис.*).

**БЕРӘН-СЫРАН** *тмн.* к.: **берәм-салам**. Берәнсыран керәләр.

**БЕРӘРЛЕ** *перм.* берәр, берәрдән (по одному). Икебез дә берәрле генә торабыз. Бер көн шомортқа китиг әле, берәрле бидерә әпкилсәк җитәр ийе қорторға. Берәрле сумнан да утыз сум бирсен ийе ул бала қарасы килмәгәч.

**БЕРГӘЛӘНҮ 1.** *т.я.-крш.* туңу, туңып оешу, бөрешү (замёрзнуть, закоченеть). Бөтен барнак башлары бергәләнеп киткән. Ражтываның айында Бергәләнә бәкесе, Сикереп-сикереп тибәр идем, Селкенәдер сәкесе (*хал. жыр.*). **2.** *нокр.* к.: **бергәләшү**. Сырауну ире белән бергәләнделәр.

**БЕРГӘЛӘШҮ** *минз.* берғә тормыш кору, өйләнешү (пожениться). Биағам үземә әйтте дә бергәләшәйек дийеп...

**БЕРДЕКЛЕ** *срг.* турылыклы (прямой, честный).

**БЕРЕМЕКЛӘП** *чпр.* берәмтекләп (перебирая). Беремекләп карап аши ашны.

**БЕР(Е)НӘ** *перм.*, **БЕРЕНЧӘ** *хвл.* борынча (по). Ү бер(е)нә йөримсез. – *перм.* Ү беренчә кергән диме? – *хвл.*

**БЕРЗАМАТ** *лмб., кузн., бгрс., әстр.* к.: **заман 1**. Сыw пичтә кан′арлана берзамат. Берзаматка гына кер әле безгә. – *лмб.* Выт ачык калмасын берзаматка. – *кузн.* Берзамат ишекте дә қорып бир. – *әстр.*

**БЕРИШЕ** *трх.* кайберсе (некоторые). Беришендә шартламка йаулык ийе.

**БЕРЙУЛЫ** *бөре.* к.: **башала**. Хәзер ололар йуқ берйулы. Күзләр күрми башлады берйулы.

**БЕРҚАWЫМ** *каз.ар., т.я., т.кам.-крш., чст.* берникадәр вакыт, бераз вакыт (некоторое время, немного времени); чаг.: **безрәк**. Салқын булды бит әнә берқаwым. – *мам.* Ут алғач, берқаwым торған ыйық, өйгә килеп керде кийәwе. – *т.кам.-крш.* Беркаwымнан афицианкы кайтып керә. – *чст.*

**БЕРКАСАК** *лмб.* к.: **безрәк**. Беркасак каршы бара тим бабайга.

**БЕРКӘW** *тмн.* бөркәнчек (покрывало). Туйда әwәл, безнең заманда, басма беркәw йабынганнар.

**БЕРКӘЛҮ** *шрл.* үсү – үлән турында (приживаться, прорастать – о траве). Менә шул тауга үлән беркәлми.

**БЕРКЕМСӘ** *нокр., перм.* кем дә булса, берәр кеше, берәү (кто-нибудь, некто). Қурыққаннар шай, әйтмәгәннәр беркемсәгә дә. Беркемсәдән дә мал алмаған. – *нокр.* Беркемсә бар монда. Беркемсәне чақыралар. – *перм.*

**БЕР'ИНЧЕ'** *кас.* туй килер алдыннан ярәшкән кызның хатын-кыз кардәшләреннән берсе яки иң якын дус кызы тарафыннан бүләк ителгән күлмәклек яки шәл белән күлмәклек (подарок невесте от её родственницы или подруги).

**БЕР'ИСИ'** *кас.* к.: **безрәк**. Бер'иси' үтми' бир-е'ен.

**БЕРЛЕ** *баст.* ялгыз (одинокий). Ул инде берле хатын.

**БЕРЛЕ-ИКЕЛЕ** *срг.* берән-сәрән (изредка). Берле-икеле генә, бездән Казанга йеруце йук.

**БЕРЛЕКЛӘШҮ** *перм.* берләшү (объединяться). Берлекләшеп, сүз қуйышып килделәр.

**БЕРЛЕКСЕЗ: берлексез итү** *т.я.* юк итү (уничтожить, свести на нет). Башына суғып берлексез итәрмен. – *к.т.*

**берлексез қалу** *каз.ар.-крш.* берсе дә калмау (остаться без единого, потерять всё). Дүрт малайдан берлексез қалдым.

**БЕРЛӘНТИН** [*рус.* бриллиантин] *злт.* ялтыравыклы ефәк кушылган тукыма (шерстяная ткань с атласным лоском). Мәскәүдән, мин туғас, әткәй йегерме митр берләнтин алып қайтқан.

**БЕРЛӘП** *чст.-крш.* берәмтекләп (считать по одному; подсчёт по одному). Бөтенесенең исемнәрен дә берләп әйтер ул.

**БЕРЛӘТӘ: берләтә бер** *каз.ар., перм.* к.: **берләч**. Берләтә бер қызым бар, аның да туйын итмәгәч. Берләтә бер малай ыйы, үлде, әйткәннәр бит: «Бер малай – җуқ малай, ике малай – бер малай». Берләтә бер қызы бар ыйы, баладан үлде. – *дөб.* Берләтә бер қызның бәқыте булмады. – *перм.*

**БЕРЛӘЧ** *минз., кмшл.* бер генә, бердәнбер (один единственный). Аларның берләч кенә малайлары булған. – *минз.* Безгә берләч кенә булғанға кийендерәбез. – *кмшл.*

**БЕРМӘКӘЙ** *минз.* әт әчәге(се) (вьюнок).

**БЕРМӘКЛӘП 1.** *трх., минз., стрл., шрл.* к.: **бермекләп**. Қул белән бермәкләп утарға инде. – *трх.* Син бермәкләп сөйли тор қызларға. – *минз.* Бермәкләп-бермәкләп йазасыз. – *стрл.*; **2.** *минз., стрл.* берәмләп, берәм-берәм (по одному, в одиночку). Без тау башына бермәкләп мендек. – *минз.*

**БЕРМЕКЛӘП** *кмшл.* җентекләп, җиренә җиткереп (тщательно, детально разбирать, довести до конца); чаг.: **беремекләп**. Шул (врач) күзне бермекләп қарый, монон да кебек әйбәт кеше булырмы. Машина йөртергә бермекләп өрәтеб алып чықты қызны.

**БЕРМЕКЛЕ 1.** *трх.* яхшы, сыйфатлы (качественный). Әwәл әйберләр бермекле иде бит; **2.** *чпр.* берәгәйле (достойный). Бер булса да бермекле.

**БЕРОҢҒАЙ** *бөре., минз.* к.: **берыңғай 1**.

**БЕРОС′ТАН** *кас.* берочтан (из одинакового материала; одинаково). Безди вит падругалар берос′тан 'ейенилир.

**БЕРОЧ** *мәл.* к.: **берочтан 2**.

**БЕРОЧТАН 1.** *мам., шрл., минз.* бертоташтан, берәттән (подряд). Бақчаны берочтан утап бетерәбез инде. – *мам.* Ике сәғәт берочтан без сезнең белән сочинение йазабыз. – *минз.*; **2.** *мәл.* бертөрле, бертөсле (одинаково, однообразно). Икесе дә берочтан кийенгәннәр.

**БЕРРӘТ** *к.т., кмшл., хвл.* бервакыт (однажды, один раз). Беррәт без, Қазанға барғач, аны күргән идек. – *к.т.*

**БЕРСАНА** *кргл.* к.: **безрәк**. Берсана таллар күренә.

**БЕРСӘК** *миш.д., т.я.-крш.*, **БЕРСИК** *хвл., мәл.* к.: **безрәк**. Берсик йәшереп торабыз да, алай да карыйлар инде. Алай берсәк рәтлерәктер әле. Ашале берсәк. Әбзи кат′т(ы) ул, берсәк бар. Кас′ы берсәк йахшы булыр икән. – *мәл.* Берсәк йактылык бәрелә, таң атканны да тойам. Берсәк сораклагыз, ул белә. Тырактыр белә тартып китерелә иде берсәк. Берсәк хыт′ син кендез йыкла,

ату йадауланып китәрсен, йыкламыйнчы башыңа күтәрелер. Аларга берсәк кенә кыйаш бага. – *хвл.* Йал итегез берсәк. – *чст.* Берсәк утырыйк, сүләшийек инде кызың белән. Берсәк айбагар салып цыгарга идең. Берсәк арулап цыгарсак, йахшы була. – *чпр.*

**БЕРСЫПРА** *брб.д.* к.: **пертөрөк**.

**БЕРТАЙАН** *брб.д.* к.: **перпайтақ**.

**БЕРТЕКӘ** *әстр.* бернәрсә, берни (ничего, нисколько). Бертекә эшләмәгән халық алып тора.

**БЕРТЕШ**: **бертеш булу** *нокр.* к.: **чүмкеләнү**. Бычақ бертеш булған.

**БЕРТУМА** *мәл., хвл., лмб., кузн., баст.* бертуган (единоутробный). Ул выт аның бертума апасы. – *мәл.* Санийә – иремнең бертума агасының кызы. Ул синең бертума быратыңмы? – *хвл.* Бертума апам бар, ир балаларны да тытып булмый. – *баст.*

**бертума(лар)ның ыланнары** *хвл.* к.: **тудыка(й) 1**.

**БЕРТУРАЛАР** *кас.* яшьтәшләр (одногодки); чаг.: **йәшет**.

**БЕРТЫМ-БЕРТЫМ** *минз.* бераз-бераз (понемногу, немного). Кызлар да булышалар бертым-бертым.

**БЕРТЫН** *мам., перм., нгб.-крш., т.кам.-крш.* к.: **безрәк**. Бертын эшлик тә йал итәрбез. – *мам.* Бертын җөри дә тағы қайта. Бертын ғына утырайық. – *нгб.-крш.* Бертын әле ул урманда қасып йөреде тотолғансы. – *перм.* Малайы утырды безнең белән бертын ашаб-эчеп. – *т.кам.-крш.*

**БЕРТЫНА** *мәл., чпр.* бер тапкыр, бервакыт (один раз, однажды); чаг.: **берраәт**.

**БЕРТЫНАП** *мәл., хвл., срг., чпр.* к.: **бертына**. Бертынап барып кат'кан идем.

**БЕРХӘТЛЕДӘН** *блт., т.я.* бераздан, берникадәр вакыттан соң (некоторое время спустя). Берхәтледән килерсең, әлегә қайтып тор, қызым. – *блт.*

**БЕРХЫЙЛЫ** [*фарс.*] *әстр.* бик күп (очень много). Берхыйлы wақыт узды.

**БЕРЦӘК** *срг., чст., чпр., мәл., клд.* к.: **безрәк**. Берцәк ашакла. – *срг.* Берцәк кенә туктап тыр, йәме. – *чст.* Бәрәңгемне берцәк алып бирсәләр җарар иде. Берцәк йегетләр бийеп ала, берцәк – кызлар. Тенә берцәк казыдык бәрәңге. – *чпр.* Берцәк эшти бешергән ийем, ашагыз. – *клд.*

**БЕРЧӘ 1**. *лмб.* к.: **берче I, 4**. Ыстулларны берчә чыгарган; **2**. *перм.* бертигез, бер формада (одинаково). Барысы да берчә укыйлар, берчә.

**БЕРЧӘЙ**: **берчәй печин** *нокр.* к.: **йылыwыт**. Берчәй печин белән wеник бәйләдем бер кийем.

**БЕРЧӘК 1**. *лмб.* к.: **бертына**; **2**. *мәл., баст.* к.: **безрәк**. Аңгартам берчәк, элгәре берчәк белә идем. Тунны қайлар берчәк берештерә тешләләр иде. – *баст.*; **3**. *лмб.* әгәр дә, гәрчә (если). Берчәк тытсам, талга бәләп йарам (кәҗәне).

**БЕРЧЕ I** *лмб., тмн., кузн., хвл., мәл., карс., әстр.* **1**. һәрвакыт (всегда, постоянно). Кулында китабы, берче укый гына. Бире килде берче. – *кузн.* Берче башым awыртып тора. Берче шылай кычкырына. Нәсле бар, берче кунак йөри. Боларга берче куйалар, бик севәләр. – *хвл.*; **2**. рәттән, тулысынча (сплошь). Бу урын берче урман булган: зиреклек, тегендә булган кайыннык, кайынсарлык; **3**. бөтенләй (совсем). Кулым арыды берче. – *кузн.* Гармунны берче wаткан. – *мәл.* Гыбалары кипкән берче. – *карс.*; **4**. барын, барысын (всё). Берче ашап бетер. – *чст.* Берче биреп бетердем. – *кузн.*; **5**. барлык, барча, барысы, бөтенесе (всё, все). Берчиен йаптыңмы чебешләрнең? Минем чәчемә берчесе сокланалар. Берчегез дә килегез бире. – *тмн.* Безнең awылда берчесе йетмеш азбар бар. Берчесен бер кучага куй. Әбигә берчесе килә. Узганбарган да эчте, берчесе эчте. Берчегез дәме бер awылда? Берче кешегә икешәр ызба бездә. – *лмб.* Сыразу сукырайганга күрә, хезмәттән калганга күрә берчесен оноттом. Берчесенең ыланнары берәр ызба була. Алай киткән инде берчесе. Бергә торасың берчесе менән? – *кузн.* Ул чакта выт кийәү сүли берчесен. Берчебезгә итек. Берчесеннән сәл'ам. – *хвл.*; **6**. бик, нык (очень, сильно). Йәш катын назлы, берче эшләтә ирне. – *мәл.*

**БЕРЧЕ II** *карс.* йә ... йә (или ... или). Берче бәлчег әрчибез, берче җийынабыз.

**БЕРЧЕГӘ** *хвл.* к.: **башала 2**. Берчегәме килә монда?

**БЕРЧЕСЕ 1**. *шрл.* к.: **берче I, 5**. Берчесе акча эшли, акча җитми; **2**. *әстр.* к.: **берче I, 4**. Уның берчесе қалпақ.

**БЕРЧИ I 1**. *мәл.* к.: **берче I, 3**. Берчи шылай; **2**. *хвл.* к.: **берче I, 1**.

**БЕРЧИ II**: **берчи печин** *нокр.* к.: **йылыwыт**.

**БЕРЧИГӘ** *мәл.* к.: **аруга II, 1**. Карамалның чабатасын кийеп кердем күршегә, Күршедән әләнеп кергинче, төбе төште берчигә (*хал. җыр.*).

**БЕРЧИ'** *кас.* борчак (горох).

**БЕРЧИСЕН** *мәл.* бөтенесен, барысын, барын (всё, целиком, полностью). Себереп ал берчисен.

**БЕРШИКЕЛЛЕ** *чст.* бер килеш, бер көенчә (так себе, средне). Тырабыз инде бершикелле.

**БЕРЫҢГАЙ** *минз., т.я., тпк.*, **БЕРЫҢГАЙ** *стрл.* **1**. берьюлы, бер тотынган көе (заодно). Арышны инде аны берыңгай урып алабыз, тик өлгерсен генә. – *минз.* Танawы канаган да танawы канаган, берыңгай канаган да канаган. – *стрл.*; **2**. *т.я.* юл уңаенда, бер уңайдан (заодно, по пути). Безнең awылға килгәнсең, ник берыңгай безгә кермәдең? – *нрл.*

**берыңгай булу** *лш.* тыныч лану (успокоиться). Бозау белән барып килсә, берыңгай булабыз, қалаға барып җөрергә қалмый аннары.

**БЕРЫЧТАН** *мәл.* к.: **бероч**. Йакыннары беткелесе cawым кене йасый, берычтан бергә йасыйлар.

**БЕС** *тара., твр., брб.д.* пычак йөзе (лезвие ножа).

**БЕСЕП** *тпк.* биштәрләп (надевая котомку через плечо). Тоқно арқаға бесеп бардық.

**БЕСЛҮ** *твр.* үткен (острый). Пычақның ике йағы да беслү.

**БЕСНӘК** *злт.* к.: **пысқыш**. Лампаның торбасы былмаса, беснәк была.

**БЕСТӘННӘҮ** *злт.* к.: **бездәннәү**. Апа бестәннәй, йезнә сүз әйтмәй.

**БЕСЧӘ** *твр.* безнеңчә (по-нашему). Бесчә шулай.

**б е т** (вошь):

**бет серкәсе** *дөб.* к.: **чәчәк I: җитен чәчәк.**

**йер бете** *злт.* сырлан (липучка).

**йүгә бет** *себ.*, **йүкә бете** *төм.*, **қайын бет** *том.д.*, **шоморт бет** *нокр.* урман бете, талпан (клещ). Йүгә бет. Шоморт бет керә тәнгә. Шоморт бет чыршыда күп була.

**БЕТӘ** [*рус.* будто] *карс.* **1.** к.: **бетәмен.** Айша күлдә йөзәдер, Бетә мәрҗән тезәдер (*хал. җыр.*); **2.** бугай, булса кирәк (кажется, будто). Без дә бетә үзегезне инде бик ачык чырай ман каршы алдык, бик кадерләдег инде.

**БЕТӘГӘ** *нокр.* бүтәкә (желудок у птицы). Бетәгәсе ансы, ашайсынмы?

**БЕТӘЙТҮ** *нокр.* бетерү, тәмамлау (закончить, завершить). Сәгәт җидедә бетәйтәбез эшне. Аш китерәләр, бәлеш китерәләр, аннан сыңра ит қуйалар, кампут белә бетәйтәләр.

**БЕТӘМЕН** [*рус.* будто + *фарс.* әмән] *кузн.* әйтерсең, гүяки (как будто). Берлеләрне (бер балалыларны) бетәмен кан′касын аксата да куйа.

**БЕТӘҮ I** *әстр.* буу, ябу (запрудить, закрывать, перекрывать). Валны бетәгәннәр, хәзер индеге су йуқ.

**БЕТӘҮ II: бетәү йара** *мәл., злт.* к.: **беләү: беләү җара.**

**БЕТӘШҮ** *т.я.* к.: **бетенкерәү.** Қыш буйы awырып чыгып бөтеннәй бетәштем. Салқын тийереп бетәшеп йатарсың әле менә сақланмасаң. – *к.т.*

**БЕТЕГ** *лмб., тмн.* хат, язу (письмо, записка). Бетег йаздым. Пасылкасына бетег тә куйган, шыны укып бир әле. – *лмб.*

**БЕТЕК** *чст.* бөти (амулет, талисман). Күзекмәс эчен бетек тагалар.

**БЕТЕКИ 1.** *блт., перм., к.-уф.* к.: **кечкеник.** Қызы да бар, қызы дәү түгел, бетеки генә. – *блт.* Җылғаның теге йағында бетеки генә қул йасалған. Бетеки awыл бар қый килгән җирегездә. – *перм.*; **2.** *перм., к.-уф.* к.: **безрәк.** Келәт алдығызны шықлаң аны бетеки. Айаққа басып торасың, табаға бетеки саласың да рақыны. – *перм.* Қайа, бетеки генә әпәй сындырып бир әле. – *к.-уф.*

**БЕТЕН** *чст.* сау, таза (здоровый). Балаларыбыз бик бетеннәр, берсе дә awырмый.

**бетен итү** *глз.* **1.** тутыру (наполнять). Бу сawытларны су белән бетен итәсе була; **2.** бетерү, тәмамлау (завершить, закончить). Күлмәгеңне тегеп бетен итим.

**БЕТЕНКЕРӘҮ** *блт., нгб.-крш.* бетерешү, бетеренү, хәлсезләнү, бирешү (ослабнуть, одряхлеть, стать хилым). Бу җылларда қақшап, бетенкерәп китте әле безнең қарт. – *блт.*

**БЕТЕҢКЕРӘМӘҮ** *минз.* бетеп җитмәү (не совсем завершиться, закончиться). Ат сарайы бетмәгән әл(е), иптәшләр, бетеңкерәмәгән.

**БЕТЕП 1.** *чст., кмшл., бәр.* к.: **башала 1.** Бетен тешебез таш, бетеп таш. Камышлы бит бетеп сазлык булган. – *чст.* Элгәре бетеп киндер ийе. – *кмшл.*; **2.** *перм., байк.* к.: **башала 2.** Бетеп қайтабыз, тиләр ийе, имеш тә, қунаққа ғына килгән шикелле. – *перм.* Бетеп қайтып китәм, берсенә дә бармыйм. Мин бетеп ардым. – *байк.*

**БЕТЕРӘ** *эчк.* **1.** к.: **берче I, 5.** Ул аларны бетерә белә; **2.** к.: **башала 2.** Бетерә торып қалдым бы awылда.

**БЕТЕРГИ** *трх.* бигуди. Бетергийеңне биреп торчы!

**БЕТЕРЕБЕ** *чст., мәл.* к.: **берче I, 2.** Ул йылга буйлары бетеребе урман иде. – *чст.* Бетеребе арыш. Бетеребен алып кат′тык печәннән. – *мәл.*

**БЕТЕРЕКСЕЗ: әйтеп бетерексез** *бәр.* әйтеп бетергесез (не передать словами). Йаман да аш тәмне булған шикелле, әйтеп бетерексез.

**БЕТЕРЕП** *байк.* бөтенләй, нәкъ (в точности, весь). Бетереп ул.

**БЕТЕРКӘ** *кмшл.* купшы, көяз, матур (щеголеватый, красивый). Урған келтә матур булган шикелле, бетеркә ул.

**БЕТЕРҮ 1.** *минз.* кичерү, үткәрү (завершить, закончить, участвовать до конца). Ике суғым бетердем; **2.** *мам., блт., минз.* салу (построить). Қышқа җорт бетереп керделәр. – *мам.* Әле генә өй бетердек бит. Энем қайтуwына җорт бетә. – *минз.*

**БЕТИ I** *блт.* **1.** к.: **безрәк.** Бети генә сал тозны ашқа; **2.** к.: **кечкеник 1.** Без монда килгәндә бети-бети ағачлар ийе.

**БЕТИ II** *дөб.* к.: **путемар.**

**БЕТКЕЛ** *чст., мәл.* бөтен, барлык (всё, весь, полностью). Беткел өстен буйап бетергән. Беткел йаңы әйбер матур була. Беткел мендәрләрне тышка цыгарамсың әллә? – *чст.* Шылай беткел awыл җыйыла иде. – *мәл.*

**БЕТКЕЛГЕСЕ** *кмшл.* барысы, бөтенесе (всё). Монда бит беткелгесе шындый.

**БЕТКЕЛЕ: беткеле түгел** *минз., стрл.* бетәрлек түгел, беткесез (нескончаемый, неисчерпаемый); чаг.: **белеп: белеп түгел.** Анда җиләк беткеле түгел ийе. – *минз.*

**БЕТКЕЛ(Л)ЕСЕ** *мәл.* к.: **беткелгесе.** Безнең awыл халкы беткеллесе клупка йөри. Беткелесе аны йаклыйлар. Беткелесе китте, укыйлар. Беткелесен үзем эшлим. Беткелегезне сырады. Беткелесе клупка китеп беттеләр, үдә берәү дә йук.

**БЕТКЕР** *чст.* к.: **беткел.** Алдан бара бу беткер эшне эшләп.

**БЕТКЕРЕМ: беткерем түгел** *минз., стрл.* к.: **беткеле: беткеле түгел.**

**БЕТМЕР** *трбс.* тере, үткен (живой, бойкий, шустрый). Улым бик бетмер ийе, үзем кебек.

**БЕТТӘМӘН** [*рус.* будто + *фарс.* әмән] *мәл., злт.* к.: **бетәмен.** Беттәмән, ут чыккан, үле авазга кычкыра. – *мәл.*

**БЕТТЕГЕ** *нокр., глз.* к.: **беткел.** Минеңке беттеге оланнар читтә. Беттегез үлеп бетәрсез. Беттеге нәстәне белепсин син. Беттеге нәстәм ару. Син беттегенә өйрәнгән инде. – *нокр.* Беттеге ашлықны ташийлар ат белә. – *глз.*

**БЕТТЕГЕСЕ** *нокр., глз.* к.: **беткелгесе.** Беттегесе эшкә чыгып киттеләр. – *нокр.*

**БЕТҮ I 1.** *блт., дөб., бәр., каз.ар.-крш., т.кам.-крш., трх., нокр., лмб., хвл., чст., м.-кар.* үлү (умереть). Оло абый сугышта бетте. Бетәргә җыйынған иде инде ул, сөт эчеп кеше булды. – *блт.* Бабагыз ачлық җылны бетте. Ике улым бар ыйы, икесе дә

суғышта бетте. – *дөб.* Башта әби-бабай бетте, туғаннарым бетеп, андары ирем үлде. – *бәр.* Балаларым сугышта беттеләр. Икесе сугышта бетте, берсе идә бетте, әч ыл үстереп берсез калдым. – *глз.* Кийәве суғышта беттемени? – *нокр.* Эти тормый, беткән. – *трх.* Сугышта бетте, суғыш қаты булған. – *каз.ар.-крш.* Сугышта беттеләр инде. – *т.кам.-крш.* Йулдашым вайнада бетте. – *лмб.* Минем братым кездә бетте. – *м.-кар.* Сугышта бетте малайым, хаты да, хәбәре дә булмады. – *чст.* «Бет! Жаның чыксын!» Күп тормас инде, бетәр. – *хвл.*; **2.** *хвл., чпр., м.-кар.* к.: **бетенкерәү**. Теге Дун'а апаң беткән инде, жылтын-кылтын арап йөри. – *м.-кар.*; **3.** *перм., эчк., нгб.-крш.* к.: **бетәйтү**. Алып беткәннәр. – *перм.* Ашап беттек ашны. Сигезне бетеп, туғызға күцте қызым. – *эчк.* Эшләп беттек инде. Эшне бетеп қайттық. – *нгб.-крш.*

**бетәсе төгөл** *стрл.*, **бетәсе түгел** *минз.* к.: **белеп: белеп түгел**. Жиләк бетәсе түгел. – *минз.* Тирә-йакта бетәсе төгөл сатыб алган жирләр. – *стрл.*

**мич бетү** *перм.* янып бетү (прогореть – о дровах в печи). Бетмәгән, йанған мичтә пешерәсеңме аны?

**мунча бетү** *перм., хвл.* әзер булу – мунча турында ( быть готовой для мытья – о бане). Мунча бетте, инәргә йарый. – *перм.*

**пич бетү** *хвл.* к.: **мич бетү**.

**суға бетү** *нокр., глз.* суға батып үлү (утонуть). Су кермә, кереп суға бетәр, Алла сақласын. – *нокр.* Хийалый абый суга бетә ич дигән. – *глз.*

**БЕТҮ II** *тмн., кузн., лмб.* к.: **касидә**. Чылбырлыкай чапуг, буй бетү. Буй гына үстердем, элмәдем (*бор. жыр.*). – *тмн.* Әтекайның түрендә йефәк бетү тышладым. Әткай, кәбәм, авырсынма, Ахтык кышны кышладым (*бор. жыр.*). – *кузн.*

**БЕЦҮ** *тбл.* к.: **печү**.

**БЕЧӘ** *перм.* к.: **бичә**.

**БЕЧЕКИ** *перм.* к.: **кечкеник 1**. Бечеки малайыбыз бар.

**БЕЧТЕК: бечтек сарык** *глз.* печкән тәкә (кастрированный баран).

**БЕЧҮ** *тмн., әстр.* к.: **печү 1**. Кемгә күлмәк бечәсен? – *тмн.*

**БЕШЕ** *перм.* тыгыз – бәйләнгән әйбер турында (тугой – о вязаных вещах). Озон чөлкә фирмыда торғанда бәйләдем ийе, wата беше булды.

**БЕШЕМ: бешем булу** *глз.* пешеп житү (свариться). Әнкәй, ашың бешем булгач, балаларың жыйылыр. Айырырсын да, мин булмагач, Күз йәшләрең кыйылыр (*хал. жыр.*).

**БЕШЕРҮ** *перм.* кайнату – сөт турында (кипятить – о молоке). Бешереп ойотасың да, айран була анысы.

**темир бешерү** *глз.* тимер эретү (плавить железо, металл). Темир бешерү дә кирәк.

**бешкән** *тмн., перм.* пешкән (варёный):

**бешкән каймак** *тмн.* к.: **пешеқаймақ 1**. Бешкән каймакның майы тәмне була.

**бешкән сөт** *перм.* кайнаган сөт (топлёное молоко). Бешкән сөт эчең.

**БЕШТЕРӘ** *дөб.* чабатада киндерә үткәрү өчен тишек (отверстие в лаптях, в которое вдевают оборки, ушник лаптя).

**БЕШҮ 1.** *тпк.* к.: **ачлау**. Патманта бешеп сыгарған майны эретәләр дә, сары май була; **2.** *төм., тбл.* пешү (поспевать, созревать).

**БИАҒА(Й)** *минз., бөре., перм., нокр., каз.ар.-крш., нгб.-крш., т.кам.-крш.* каенага (старший брат мужа). Биагасы мин аның. Биага – бөтен ир, жанаға – жарты ир. – *бөре.* И, биағай монда икән ул. – *каз.ар.-крш.* Биағай қайтып керде қырдан. – *нгб.-крш.*

**БИАНА(Й)** *минз., бөре., кргл., бгрс., т.кам.-крш., нгб.-крш.* каенана, иренең әнисе (свекровь). Минем қыз биана белән биатага күренергә тийеш инде. – *кргл.*

**БИАТА(Й)** *минз., бөре., кргл., бгрс., т.кам.-крш., нгб.-крш., кмшл.* каената, иренең әтисе (свёкор). Кийәунең атасы киленнең биатасы була. – *кмшл.* Биатам суғышқа китеп биш йыл торған. – *кргл.* Минем биатай урақка бик шәб ийе. – *т.кам.-крш.* Синең тәтәү қатыныңға биатай була. – *нгб.-крш.*

**БИБӘМ** *әстр.* әнекәш яки сеңелкәш (младший брат или сестра).

**БИБЕКӘ** *к.т., лш.* к.: **бала I, 2**. Қаз бибекәләрем унау чықты. – *к.т.* Бибекәләрне жәwып керим. – *лш.*

**БИБЕС, БИБЕШ** *дөб.* к.: **бала I, 2**. Сигез бибес чығарған ыйы қазым, икесе үсеп беткәс үлде. Минем бер жылны да бер бибешем дә, бер чебешем дә үлгәне жуғ ыйы.

**БИБЕШ-БИБЕШ** *дөб.* бәбкә чакыру ымлыгы (возглас, которым подзывают гусят, утят).

**БИБИ I** *каз.ар., минз., шрл., чст.* к.: **бала I, 2**. Утызар, қырығар үрдәк бибийе генә була, жигерме бибийебез бар ике ойаға. – *лш.* Сигез бибийе бар бер қазымның. – *дөб.*

**БИБИ II** *баст., кас.* бәби (грудной ребёнок, младенец). Биби мунчасы жагалар.

**биби башына** *әжә.* бәбигә (грудному ребёнку, младенцу). Туганырак кардәшләре биби башына, ланга китерәләр.

**биби зийыны, биби майы** *әжә.*, **биби чәйе** *баст.* бәби туе (родины). Биби тугац, май ашаталар, биби зийыны була. Биби чәйе әле дә жийалар, қатын бераз ис тартқач.

**БИБИШКА** *кузн.* күлмәк кокеткасы (кокетка у платья).

**БИГӘ** *төм.* хатынының апасы (старшая сестра жены)

**мулла бигә** *тбл.* иренең иң өлкән апасы (самая старшая сестра мужа). Ул миңа мулла бигә тийеш, иң оллосы.

**БИГӘНӘК** *срг.* к.: **азымтық**.

**БИГӘТ** *әстр.* түтәлләр арасындагы канау (канавка между грядками, запруда между грядками).

**БИГЕТҮ 1.** *перм.* бикләү (закрыть, запереть). Анан ишеге барый, бигеттек; **2.** *әстр.* төймәләү, каптыру; ябу, ныгыту (застёгивать; закрывать, укреплять). Кил, ыштаныңны бигетийем.

**БИГЛАЙ** [*рус.* беглый] *чпр., минз.* качкын (беглый).

**БИГЫЛЫЙ** *лмб., хвл.*, **БИҒЫЛЫЙ** [*рус.* беглый]

*кмшл.* к.: **биглай**. Җамали, кызны бигылыйлар орлаган бармы? Шал йырны әт син. – *лмб.*

**БИДА** [*рус.* беда] *перм., злт.* к.: **әләк 2**. Бакчада бида шәп қорт. – *перм.* Ашадым бида әйбәт итеп. – *злт.*

**БИДӘР** *дөб.* бизәк (украшение). Қар(а) алтын, сар(ы) алтыннан бидәр төшереп йасалған була бидәрле беләзек.

**БИДӘРЛӘҮ** *кузн.* бизәү, бизәкләү (украшать).

**БИДӘРЛЕ** *кузн., әҗе., дөб.* бизәкле (с украшениями). Бидәрле кешемир. Бидәрле сондок өстендә Бизәнермесен йиңыкай? Усал кан′сеңле киткәч, кинәнермесен, йиңыкай (*бор. жыр.*)? – *кузн.* Бидәрле беләзекләр кидек без. – *дөб.*

**БИД(Ы)РА** [*рус.* ведро] *чпр., стрл., т.я.-крш., нокр., злт.* к.: **бид(е)рә**. Ал бидра, гөл бидра, Суларны болгандыра, Бергә чакта берни түгел, Айырылгач, сагындыра (*хал. жыр.*). Бер бидыра җылы сөт сawып алдым. – *чпр.* Бидыраларга су качат′ итеп куй әле. – *стрл.* Су ташыганнар ағач бидра белән, қайсының йапқычы да була. Эстесен әнийебез ағач бидраға бушата иде. – *нокр.* Бидырасы биш тийен. – *злт.*

**БИД(Е)РӘ** [*рус.* ведро] *минз., бөре., перм., кргл., бгрс., кмшл., злт., тпк., трбс., стрл., шрл.* чиләк (ведро). Аның бидрәсе бездә. Бидрә чумарлық йуқ. – *бөре.* Wақ бидрәләр алып килә, быйаулы. Қодоққа бидерәсен илтеп тыққан икән. – *перм.* Безнең бидрәләр бик қарайган икән, ағартырғайы. – *кмшл.* Ике бидерә қарлыган җыйыб алып қайттым. – *кргл.* Хатыннар берәр бидерә йыйалар. – *злт.* Бидерәләр, көйәнтәләр белән төшөрде кәртечкәгә. – *трбс.* Бидерәләр тегендәме? – *шрл.*

**ашлы бидрә** *перм.* ашлы су чиләге, лакан (лохань). Ашлы бидрә әлеге бидрәдән йуwантығырақ, қолау қуйылган.

**БИДРӘТҮ: дөнҗаны бидрәтү** *нгб.-крш.* дөнья гизү (обойти весь мир). Дөнҗаны бидрәтәсез инде, балалар.

**БИҖӘК** *м.-кар.* к.: **безек**.

**БИҖҮ** *м.-кар.* к.: **безнәү**.

**БИЗ I** *тмн.* бот төбенә чыккан шеш (опухоль, шишка у бедра).

**дуңгыз бизе** *кузн.* колак арты бизе шешү (свинка – болезнь). Элекке вахытта бер малай дуңгызлар көтә иде, вис үзен дуңгыз бизе басты.

**БИЗ II** *перм.* салкын, туң (холод). Җәйгә төшкәч җылытмый торд(ы) исә, моноң қар бизләре бар шай, шуңа җылытмый тибез.

**БИЗӘК I** *срг.* к.: **бизәнек**. Бизәкләре бар иде берцәк.

**бизәк II** (узор):

**урын бизәкле** *каз.ар.-крш.* чуптарлы (с узорным тканьём, с узорной вышивкой). Өститәкле күлмәкләр булган, ал төстәгесе урын бизәкле ийе, үзеннән чыққан бизәк.

**БИЗӘКӘЙ** *перм.* әйбергә төшергән бизәк (узор на чём-либо); чаг.: **бидәр**. Мына иләсәне сырлап бәйләгәнне бизәкәй тиләр.

**БИЗӘКӘЙЛӘҮ** *перм.* бизәү (украшать, наносить узор); чаг.: **бидәрләү**. Шул тастымал башны бизәкәйләп суғасыз қый.

**БИЗӘНЕК** *лмб., клд.* бизәнү әйберләре (предметы косметики). Эстәл эстендә бизәнек, Бизәнешегез, җиңгиләр; Убыр гына китә, урыны кала, Кинәнешегез, җиңгиләр (*бор. жыр.*). – *лмб.* Төрле бизәнекләр бар иде. – *клд.*

**БИЗӘРЛӘҮ** *т.я.-крш.* бизәнү (краситься, наряжаться).

**БИЗӘРЛЕ 1.** *глз.* бизәкле (узорчатый, с узорами). Тегермән артында түгәрәк күл ич. Бизәрле йаулыкларымны мин йудым, Бизәрле дә йаулык, ай ди, сандугачым, Синең өчен ич аналардан мин тудым (*бор. жыр.*); **2.** *чст.* чуптарлы ( с узорным тканьём).

**БИЗӘҮ I 1.** *мам., тбл.* к.: **сырлау 1**. Былтыр үde бидәде бер банкы белән; **2.** *мам., каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* агарту (белить). Морҗаларымы бизәсе бар, таш сuwым бар. – *мам.* Таш сuwы җасап морҗалар бизәде. – *каз.ар.-крш.* Морҗа бизиләр, әлек ақ балчық чыгарып бизидер ийек. Қортлар булмасқа амбар бизибез. – *т.кам.-крш.*; **3.** *тбл.* бизәү, обойлау (красить, украшать, оклеивать обоями).

**БИЗӘҮ II** *чпр., т.я.-крш.* к.: **бизәнек**. Кесәсеннән бизәwе тешеп калган. – *чпр.*

**БИЗӘҮ III** *злт.* кысыр (яловая, нестельная). Қайсы тана сыйыр йылына сығып та бозауламый, бизәүгә әйләнгән была.

**БИЗГЕЛДӘҮ** *к.-уф.* к.: **wақсу II, 1**. Тагын бизгелдәргә тотонды инде, нәрсә җитмидер бу кешегә.

**бизгәк** (лихорадка):

**бизгәк чәчәге** *минз.* к.: **сырхawат**.

**БИЗДЕРҮ** *брб.д.* туйдыру (надоедать). Төне буйы алар шуны йырлап мине биздерәләр.

**БИДЕР** *минз.* урман межасы (просека). Ул урмандагы бидерләрне бөтенесен белә.

**БИЗЛӘҮ** *перм.* суыту (похолодать). Көн бизләп ките(е) әле, бизе бар икән, диләр, йаз көннәрне була инде бигерәк.

**БИЗМӘҮ** *мәл.* баш тартмау, кире какмау (не отказаться). Биргәненнән бизмә син, ал гына.

**БИЗНИК** *әстр.* карга борыны (чёрный паслён).

**БИЗРӘҮ 1.** *т.я., злт.* читләшү (надоесть, отвыкнуть). Аңарға да шул, миңа да шул, тегеннән бизрим. Тәмәке тартуны ташладым, күңелем бизрәде үзеннән. – *т.я.* Бизрәп киткән мыннан. Нинди ақыллы сыйыр көтүдән бизрәде. – *злт.*; **2.** *злт.* к.: **базау**. Тышқа чығарга бизрәп торам.

**БИЗЫЛАУ** *глз.* к.: **бизрәү 1**. Әллә ни сеттән бизыладым.

**БИЙАГА(Й)** *каз.ар., трх., нокр., бгрс., нгб.-крш.*, **БИЙАҒЫЙ** *нрл.* к.: **биаға(й)**. Бийағай тийешле кешем бар. – *бгрс.*

**БИЙАЛА** [*фарс.*] *тпк.* тәрәзә (окно). Бийалаңы ашаулық белә қороп қуйа торған ыйық, фәрдә йуқ бит ул сақта.

**БИЙАНА(Й)** *каз.ар., нгб.-крш., кргл., шрл.* к.: **биана(й)**. Минем бийанай култыг астына кыстырып йөрий баланы. – *шрл.*

**БИЙАНАМ** *т.я.-крш.* иренең әнисенә эндәшү формасы (форма обращения к свекрови).

**БИЙАТА(Й)** *каз.ар., нгб.-крш., нокр., кргл., шрл.*, **БИЙАТЫЙ** *т.я.-крш.* к.: **биата(й)**. Бийемем дә, бийатам да бар ыйы. – *мам.* Бийатай килеп тә

җиткән. – *нгб.-крш.* Бийата сүли иде, ад'а сәнәгеңне ал, дип. – *шрл.*

**печкә бийата(й)** *каз.ар.-крш.* каенатага хөрмәтләп эндәшү формасы (форма почтительного обращения к свёкру). Әwәле бийатайны печкә бийатай дигәннәр.

**БИЙАУ** *минз., стрл.* сөртү (мазать, намазывать маслом, вареньем). Ипигә wәринҗә бийап биргән. – *минз.*

**БИЙАУСА** *эчк.* камка (божья коровка).

**БИЙӘ I** *каз.ар.* к.: **бума I**. Бийә бийәгәннәр бездә, бийә булгач, бетми су. – *дөб.*

**б и й ә II** (кобыла):

**бийә сөтө** *злт.* бадьян (бадьян китайский). Бийә сөтә сары сискә ата.

**БИЙӘЛӘҮ** *каз.ар., дөб.* буу (прудить, запрудить). Үткән җыл бийәләп йөргәннәр ийе Зәйне. – *дөб.*

**БИЙӘЛИ** *трх., тара.* к.: **били**.

**бер энә бийәли** *трх.* ыргаклы энә белән бәйләнгән бияләй (варежки, связанные крючком). Бер энә бийәлийен бер энә белән генә бәйлиләр, ире итеп.

**бишбармақ бийәли** *төм.* перчатка.

**тархан бийәли** *трх.* к.: **бер энә бийәли**. Бер энә бийәлийен тархан бийәли диләр, айырылып тора.

**тыш бийәләй, тыш бийәли** *каз.ар., мам., бәр., т.я.* брезент бияләй (брезентовые рукавицы). Тыш бийәләй белән тотоп җыйа қычытқанны. – *бәр.* Шалийәдән теккән тыш бийәләй рәхәт инде, җил үткәзми. – *мам.*

**тышмақ бийәли** *төм.* к.: **тыш бийәләй**. Тышмақ бийәли бийәли өстенә кийә торған. Миңа тышмақ бийәли кийеп барырға кирәк булған икән.

**БИЙӘЛҮ** *каз.ар.* килеп тыгылу, өелү (скопиться в одном месте). Тегермән җанына килеп бийәлгән. – *дөб.*

**БИЙӘНҮ** *перм.* ышану (верить). Көчеңә бийәнмә, байлығыңа қуанма (*мәкаль*).

**БИЙӘТ** *стрл.* хәситәнең тәңкәләр тезелә торган тукымасы, җирлеге (подоснова нагрудного украшения – перевязи, на которую нанизываются монеты и прочие).

**БИЙӘҮ I** *каз.ар., тара.* к.: **бийәләү**. Кичә без бийәгән бийә йаман да шәп булды. – *дөб.* Улышны бийәп алғаннар. – *тара.*

**БИЙӘҮ II** *бөре.* буяу (краска).

**БИЙЕК** *брб.д.* озын (длинный, высокий). Бийек кеше. Бийек буйлы, эре.

**БИЙЕМ I** *каз.ар., минз., кмшл., бгрс., кргл., нгб.-крш., т.кам.-крш., нокр., стрл., шрл.* к.: **биана(й)**. Хәзер бийемнәр усал түгел инде. – *блт.* Бийеменә, биатасына күлмәк тегеп алып килә қыз. – *мам.* Әй, Аллақайым, мин бийемнән дә ишеткәнем йуқ ул сүзләрне. – *кмшл.* Бийеме килене белән тора инде. – *т.кам.-крш.* Қаз балаларны қулың белән үтерепсең, қарамапсың, ди бийеменә. – *нокр.* Бийеме кенәген генә үлде. Бийемем бида усал ыйы. – *нгб.-крш.* Бал'ниска барса, бийемендә кала инде баласы. – *стрл.*

**бийем анам** *т.кам.-крш.* к.: **биана(й)**. Бийем анам минем. Ул' йәнә карчык була.

**ак бийем** *т.кам.-крш.* иренең апасы (старшая сестра мужа).

**БИЙЕМ II: бийем бийү** *әстр.* бию (плясать). Қызлар бийем бийеп утыра.

**БИЙЕН** *нокр.* биек, югары (высокий). Бийенгә утыр.

**БИЙЕННЕК** *нокр.* биек җир, биеклек (высокое место, возвышенность, пригорок); чаг.: **қаш**. Әwәле awыл бийеннектә утырған.

**БИЙЕРЕК** *әстр.* биек (высокий). Бусағасы бийерек.

**БИЙЕРЛЕ** *дөб.* к.: **бөwерле**. Биш бийерле бишмәт.

**БИЙЕТКЕ** *дөб.* бәлешнең бөрелгән җире, кыры (защеплённые края бәлиша, пирога). Бийеткесен кисеб аласың түгәрәкләп, өлешләп чығасың да инде бийеткеләрен тәрилкәгә таратасың.

**БИЙЛЫҚСЫЗ 1**. *мам., нрл.* тотрыксыз – гәүдә турында (неустойчивость – о туловище). Әти бийлықсыз ийе. Awыр эшләгәннән була бийлықсыз. – *мам.* Җатса утыра алмый, утырса җата алмый, бийлықсыз инде. – *нрл.*; **2**. *каз.ар.* боелыгын тота алмый торган (страдающий недержанием мочи). Бийеме бийлықсыз булып җатты. – *мам.*

**БИЙӨСТӨР** *каз.ар.-крш.* к.: **битйаулық**. Борчақ чүпләме бийөстөр.

**БИЙЫНА** *перм.* к.: **бер: бер буйдан**. Уқырға кермәде, эшләде генә бийына.

**БИКӘ 1**. *минз., бөре.* к.: **бичә**; **2**. *т.я.-крш.* хатыныңың әнисе (тёща); **3**. *нокр.* иренең апасы (старшая сестра мужа). Бикәмнәремә бардым қунаққа. – *нокр.*; **4**. *яүшт.* иренең қыз туганы (родственница со стороны мужа). Бикә була идем, ул абамнықы ире; **5**. *яүшт.* хатыныңың апасы (старшая сестра мужа).

**бикә җыйыны** *минз.* искечә июнь башларында уздырыла торган җыен (джиен, празднество, устраиваемое в начале июня по старому стилю).

**БИКӘМ** *нокр.* иренең апасына эндәшү формасы (форма обращения к старшей сестре мужа). Туқтале, бикәмнәрем белән киңәш итим, ди.

**БИКӘР** [*фарс.*] *дөб., бгрс., кргл.* юкка (зря). Бикәр әйттем мин аңа. Бикәр җырлап күрсәтмәдең шуларға. – *дөб.* Минем қызыма барығыз дип әйтмәдем бикәр. – *бгрс.*

**БИКӘРГӘ** *мам.* к.: **бикәр**. Бикәргә йөрдем, булмады.

**БИКӘЦ** *чпр.* бикәч (молодая жена).

**бикәцкә керү** *чпр.* қыз куенына керү (провести первую брачную ночь). Туйдан соң бикәцкә керә кийәү.

**б и к ә ч I** (молодая жена):

**бикәчләп йерү** *чст.* кияүләп йөрү (ходить или ездить к невесте, пользуясь правами супруга). Әwәле күп йөргәннәр бикәчләп, йаз кене булса, атка атланып килә калакуллар белән, пар атлар белән.

**йәш бикәч** *тара.* иренең апасы (старшая сестра мужа). Қәйнегәч, йәш бикәч, «Тун табалмадым» диде, «Ник соңа қалдың?» дигәч.

**БИКӘЧ II** *каз.ар.* саулык, теше бәрән (ягнёнок–самка).

**бикәч бозау** *лш.* тана бозау (тёлка).

**БИКӘЧӘЙ** *глз., нокр.* к.: **балдыз 2.** Бикәчәй йарма (ө)чен барды қалаға. – *глз.* Минем бикәчәйем булмады. – *нокр.*

**БИКӘЧӘ(М)** *глз.* к.: **балдыз 2.** Бикәчәмне былтыр кийәүгә бирдек.

**БИКӘЧЕМ** *нокр., глз.* к.: **балдыз 2.**

**БИККЕЧ** *чст.-крш.* бик, ишек биге (дверной запор). Ишекнең биккече бар.

**БИКИЙЕМ** *нокр.* к.: **бикәм.**

**БИ'ИС** *кас.* к.: **бикәч II.**

**б и к л ә н ү** (закрываться):

**тамыр бикләнү** *мам.* тамырлану, тамыр җибәрү (пускать корни, укорениться). Чийәне быйыл ғына күчердем, тамыры бикләнмәгәнме, чийәсе аз.

**БИКЛӘҮ I** *тбл.* ябу (закрывать, запереть). Awылларда мәктәпләрне бикләйтләр.

**төп бикләү** *каз.ар., мам.* к.: **бикләнү: тамыр бикләнү.** Миләш туйырасы утыртқан ыйым, төп бикләб алсын әле, аннары күчеремен. Гөлне күчердем, төп бикләсен әле.

**БИКЛӘҮ II** *глз.* буу (прудить). Суны бикли иделәр, су тирмәне йасыйлар.

**хатны бикләү** *минз., стрл.* конвертны ябыштыру (заклеить конверт). Хатын бикләгән инде, бар, чыгар да салып кер. – *стрл.*

**БИКТӘРЛӘНҮ** *т.я.-крш.* бикләнү, беркая бармау (запираться, уединяться). Менә шунда биктәрләнеп йатабыз, беркайа бармайбыз.

**БИКЦӘРГӘ** *төм.* к.: **пакцарғы.**

**б и л** (пояс):

**бил бәйләү** *твр.* багышлау (посвятить, связать себя с кем-либо, чем-либо). Аурылыққа биллəрен бәйләделəр.

**бил бөрмәләре** *тара.* бөрмәле бил – күлмәктә (поясничная оборка – на платье).

**бил йугалу** *кузн.* радикулит.

**бил күтәрмә** *әстр.* аркалык (чересседельник).

**билен кыскан** *әҗе.* билле итеп (приталенный). Билен кыскан да тегәләр иде, пыр'амуйлар да.

**БИЛАЛА** *тбл.* кыргый ерткыч кош (тилгән) (хищная птица типа коршуна). Awаларға оцқан билаланың Қанат оцқайларын йил ала (*хал. җыр.*).

**БИЛӘКЛЕК** *тбл.* беләзек (браслет).

**БИЛӘМ I 1.** *блт., бәр.* кеше өенә барып утыру, кешегә чыгу, күңел ачу (развлечение). Килеп утыр, биләм булыр. – *бәр.*; **2.** *блт.* кеше арасына чыгу, уенга чыгу (гулянье, прогулка, вечерние игры). «Кичке биләмгә чықтыңмыни? Қайа барасың?» – «Биләмгә».

**БИЛӘМ II: биләмне булсын** *тмн., срг.* озак вакытлар файдасын, рәхәтен күр(егез) (долго владей(те), пользуйтесь чем-либо). Ызбагыз биләмне булсын!

**БИЛӘМ III: биләм энәсе** *байк.* бишәнә, оек бәйли торган энәләр (спицы для вязанья).

**БИЛӘМЛӘҮ** *блт.* килү, килеп утыру (прийти к кому-либо, чтобы посидеть, поразвлечься). Қайтқан wахытта биләмләп қунып китегез.

**БИЛӘНКЕ** [*рус.* белянка] *перм., эчк.* ак гөмбә (белый гриб).

**БИЛӘҢКӘ** [*рус.* белянка ] *злт.* к.: **биләнке.** Гөрөж'лә, биләңкә тозлаған ыйым күб итеп.

**БИЛӘҢҮ** *кргл.* тоткарлану (задерживаться, застревать). Минем өчен генә биләнеп тормасын.

**БИЛӘҮ I 1.** *том.д.* к.: **асрау 2.** Хәзер малай күп биләмәйләр. Қалғаннарын бал'ниста биләгән баланы; **2.** *твр.* биләү (пелёнка).

**бала биләп тору** *т.кам.-крш.* бала үстерү (растить детей, воспитывать детей). Сатый атлы кеше балалар биләп тора.

**бала биләү** *трх., минз., карс., чпр., тмн.* к.: **асрау 2.** Унике бала биләдем, алтысы исән. – *трх.* Буйдақ қына, берүзе йөри, бала биләмәде. – *минз.* Эҗ бала кан'ам биләде үзе мин килгәч әл дә. – *карс.* Ылы быратым ол, кыз биләсен, кече быратым кыз да күрмәсен. – *тмн.*

**БИЛӘҮ II** *срг.* бәхетле булу (быть счастливым). Бары да бар, биләргә генә йазсын.

**бәхет биләп тору** *тмн.* бәхетле булу (быть счастливым). Эрәшедәм йакшы бәхет биләп торсон, ире белән картайсын.

**бәхет биләү** *срг.* бәхетле булу, яхшы тормыш итү (быть счастливым, жить хорошо). Ул да бәхет били алмады.

**дәүләт биләп тору** *тмн.* муллыкта, байлыкта яшәү (жить в достатке, богатстве). Дәүләт биләп торсыннар ыланнарым.

**денйа биләү** *клд.* дөнья көтү (жить, существовать, проживать). Элеге денйаны били белмиләр.

**БИЛӘҮ III** *баст.* кулда буйсындырып тоту (держать в руках, подчинять, усмирять). Элеге киленнәрне биләмәссең.

**БИЛӘҮ IV** *әстр.* бию (пляска, танец; плясать). Билитен туқсан төрле көйе бар.

**БИЛГЕ I** *стрл., шрл.* вәгъдә бүләге (подарок со стороны невесты родственникам жениха после сговора, дарили обычно полотенце и т.п.). Билге биреп җибәрә инәсе-атасы, тасмал, кулҗаулык. – *стрл.*

**билге мәзлесе** *шрл.* егет һәм кыз ягы җыелып туй үткәрү турында сөйләшү, киңәшү, бүләкләр бирешү мәҗлесе (обед, проводимый родственниками жениха и невесты, где назначают день свадьбы и обмениваются подарками в знак согласия). Агайэнеңне энде дәшәсең, билге мәзлесе была энде, үзең дә бүләк бирәсең, мамык пирчатка инде парны.

**қул билгесе** *бәр.* к.: **билгә I.** Җаучыға қул билгесе итеп бирде сөлге.

**БИЛГЕ II: билге башына менү** *тпк.* багана башына менү (взобраться на столб). Сабантуйда билге башына менү була.

**БИЛДӘ** *перм., минз., кргл., злт.* к.: **белдә.**

**БИЛДӘЛӘҮ** *злт., байк.* билгеләү (делать пометку, отмечать). Онны билдәләп куйган. – *байк.*

**БИЛДӘЛЕ** *минз., кргл., злт., тпк., стрл., байк.* к.: **белдәле.** Килү белән, билдәле, быларның эшләре сауда (итү). – *кргл.* Фирме эше билдәле инде. – *злт.* Арбаның алды қайдан тәгәрәсә, арты шуннан тәгәри, ул билдәле була. – *тпк.*

**БИЛДӘМӘ I** *чст.* билбау (пояс). Аклы ситсы күлмәгемнең Билдәмәләре җитми (*хал. җыр.*).

**БИЛДӘМӘ II** *әстр.* к.: **баурыш.**

**БИЛДӘМЧӘ** *бгрс., кргл.* җиңсез сырма (стёга-

ная безрукавка). Билдәмчәне алып кимәдеңмени? – *бгрс.*

**БИЛДӘНЛЕ** *кузн.* билле (с талией). Билдәнле пәртүк.

**БИЛДӘҮ I 1.** *нрл., бөре.* бил (талия). Әнә тотып тора бит матур билдәүле қыз. – *нрл.*; **2.** *нрл.* к.: **билдәмә I**. Кара аның билдәwe бар ыйы, Нурийә, теге өйдә.

**БИЛДӘҮ II** *тбл.* билге (знак).

**БИЛДӘҮ III** *әстр.* арата, аркылы агач (поперечная балка, прибиваемая между столбами забора); чаг.: **баурыш**.

**БИЛДӘҮЛӘҮ** *тбл.* билгеләү (обозначать, назначать).

**БИЛЕШ** *кас.* бәлеш (пирог). 'ип'ин алмадан да билеш пешерилир.

**БИЛИ** *кас.* бияләй (варежки).

**билина** *нокр.* (белена):

**билина ырлық** *нокр.* к.: **тилвәрән**.

**БИЛИФУР** [*рус.* велюр] *бәр.* үзеннән бизәк чыгарып тукылган тукыма (тонкая ткань с узорным тканьём). Минем билифурым бар ыйы, үз чәчәге үзенә төшкән ийе, қақ төсле йе минеке, йуқа, қалын түгел.

**БИЛЛӘМӘ** *трх.* **1.** аел (подпруга); **2.** аркалык (чересседельник, поперечник).

**БИЛЛЕК** *срг.* к.: **билдәмә I**. – Фатима алма, биллеккә қалмадымыни? – Цәпе-цепеләре дә қалмады.

**БИЛМАУ** *әстр.* к.: **билдәмә I**.

**БИЛСӘ** *төм.* бирнә, кызның ата-анасы биргән әйберләре (приданое со стороны невесты). Билсәгә герә инә-ата пиргән әйберләр, пилсә нәрсәләребесне қатерләп йөрөтең тим, пилсә йастықлар, пилсә йурған, түшәмәләр биргән.

**БИЛСӨЙӘК** *төм.* умыртқалык (позвоночник).

**БИЛТАРАФ** [*гар.*]: **билтараф булу** *лш.* ике арада калып бернәрсә дә булдыра алмау, кыен хәлдә калу (оказаться в затруднительном положении). Үзең дә билтараф буласың ике бала белән қалып. Монда қайната да билтараф була бит инде, ул қалага китсә.

**БИЛТӘ** *м.-кар.* ябага (шерсть–линька); чаг.: **абаға**. Сарыкны кыркырга җарамый әле, билтәсе калыкмаган.

**БИЛТӘК 1.** *хвл., чпр.* биртәк, сакау (картавый, косноязычный); чаг.: **мақау 1**. Теле билтәк аның, әллә ницегрәк сүли. – *чпр.*; **2.** *мам., т.я.* теле тотлыгучан (заика).

**билтәк сүлей** *кас.* сакау сөйләшү (говорить шепелявя, картаво).

**БИЛТӘКЛӘНҮ** *каз.ар.* көрмәкләнү (заплетаться, потерять способность говорить). Телем билтәкләнеп, сүземне әйтә алмый тордом – *лш.*

**БИЛТӘЛӘНҮ** *каз.ар., бәр.* киезләнү, киезләнеп чуалу (сваляться, спутаться – о волосах, шерсти). Чәчем билтәләнгән, тарап булмый. – *мам.* Билтәләнгән җирен кисеп ал җепнең. – *лш.* Чәчем йаман да тиз билтәләнә минем. – *бәр.*

**БИЛТЕР** *дөб.* алкын (подъём ноги, обуви). Айағымның билтере бийек.

**БИЛТЕРӘП: билтерәп килү** *трх.* җилтерәп килү (стремительно идти). Билтерәп килеп җитте персидәтел.

**БИЛТЕРЛЕ** *чст.* чылбырлы (имеющий цепь). Кыз-катынның эчендә бишекле-билтерле бала йатар, ди (*әйтем*).

**БИЛЧӘЙҮ** *блт., чст.* к.: **билчәү**. Сафаның, йыгылып, кулы билчәйгән иде. – *чст.*

**БИЛЧӘҮ** *тмн.* каерылу, буын чыгу (вывихнуться). Севәге билчәде айагымның.

**БИМӘ** *нокр., глз.* к.: **бемә**. Қаз бимә йасама кәлмә насыйп итсен. – *нокр.*

**БИНЕК** [*рус.* веник] *чст., срг.* к.: **йапрак**.

**БИНИС I** [*рус.* венец] *т.я., чпр.* к.: **винеч**. Түбәңге бинисен алыштырасы бар. – *нрл.*

**БИНИС II** [*рус.* венец] *каз.ар.-крш.* таж (корона, венец). Пуп кәбен қыйа, бинисләр кигерә кәбен қыйғанда.

**БИННЕК** [*рус.* веник] *нокр.* к.: **йапрак**. Ишегал, мича, қәйwан биннек хәстәрләй.

**БИҢЗӘТ** *тбл.* матур (красивый).

**БИПКӘ** *т.я.* к.: **бала I, 2**. Қаз бипкәләрен йахшы қара, улым, тилгән алмасын. – *к.т.*

**БИРӘЗӘ** *әстр.* бөркәнчек (головное покрывало). Көндезге туйға баралар киленнәр бирәзәләрен йабынып.

**БИРӘЙӘК** *әстр.* бирәчәк (долг, задолженность).

**БИРӘН** *трх.* дус-ишкә, иптәш кешегә якын итеп әйтелә торган сүз (слово, которое употребляется при обращении к близкому другу, товарищу). Бирән, җоқлағыз инде. Бу йулға гына тыңла инде, бирәнем, сүземне. Ризық бик тәмне, аша, бирәнем.

**БИРӘЦӘ** *тара.* сырма, бишмәт (стёганое пальто).

**БИРӘШКИ** *тбл.* сумса (пирожок). Бирәшки бешерәтеген эченә кәртешкә тығып.

**БИРГӘН** *перм.* төшкән – төс турында (о смешении цветов, окраски). Чобар түнийләр бар ийе, аққа қызыл биргән.

**БИРГЕ** *кузн.* задатка (задаток). Без ике йәш матур сәвешәбез, Ниләр бирийем, җанийем, биргегә (*хал. җыр.*)?

**БИРЕ I** *кас.* биредә (здесь).

**БИРЕ II** *себ.* **1.** бу (этот); **2.** якын (близко).

**БИРЕ III** *себ.* биз, май һәм иттәге биз (железа, жировая железа).

**БИРЕНӘ** *т.кам.-крш.* кыз ягыннан егет ягына бирелә торган бүләк (подарок со стороны невесты жениху и его родным).

**биренә җабу** *т.кам.-крш.* бирнә бирү (раздача подарков родителям жениха со стороны невесты). Малай җағы биренә җапмый бит инде, қыж җағы ғына җабадырыйы биренә.

**БИРЕНЧӘК** *т.я., к.т.* тиз бирешүчән, ник каршы тора алмаучан (быстро поддающийся чему-либо). Мин үзем авыруга бик тиз бирешүчән. – *к.т.*

**БИРЕТЕ** *кас.* к.: **бире I**.

**БИРЕТЫН** *м.-кар.* бирле (послелог с, со). Иртән биретын ашыйбыз.

**БИРЕЧЛӘНҮ** *мам.* **1.** бирчәю (заскорузнуть, загрубеть, стать мозолистым). Қулларым биречләнеп бетт(е) инде көрәк тотоп; **2.** бик нык кату, катып бетү (затвердеть). Биречләнә ул берәр көннән қойаш пешергән җирдә. Биречләнеп беткән бәрәңге җире, көрәк тә керми.

**БИРЕШТӘ** [*гар.*] *твр.* фәрештә (ангел).

**БИРКӘСЕНДӘ** *т.я.-крш.* аркасында, сәбәпле (благодаря, из-за). Тырышып эшләвем биркәсендә бүләкләндем.

**БИРКӘЧ** *әстр.* зур агач табак (большое деревянное блюдо).

**БИРНӘ** 1. *нокр., глз., т.я.-крш.* гомумән бүләк (подарок вообще). Ул тәтәсенә Мәскәүдән гел бирнә йебәреп тора. – *глз.* Туйда қаз башладым, бирнә бирде. – *т.я.-крш.*; 2. *кузн., хвл., чст., мәл., каз.ар.-крш., перм., кмшл.* туйда кыз тарафыннан кияүнең әти-әнисенә, кияү тарафыннан кызның әти-әнисенә бирелә торган кара-каршы бүләк (подарок, преподносимый стороной невесты родителям жениха и, наоборот, со стороны жениха – родителям невесты). Бирнәне йактан йакка бирәдер туй булганда: малай йагыннан да, кыз йагыннан да. – *чст.* Йегет анасы бирсә дә – бирнә, кыз анасы бирсә дә – бирнә. Кушкулмәкләр ике йакка да бирәләр бирнәгә. – *кузн.* Бирнә булғач, бир сийә да бир мийә була. – *перм.*; 3. *мам., нокр., т.кам.-крш., т.я.-крш., лмб., хвл., кузн., чпр.* туйда кыз тарафыннан кияүнең әти-әнисенә бирелә торган бүләк (подарок, преподносимый невестой родителям жениха). Туйда кийәүгә киткән кеше бирнә җаба. – *т.кам.-крш.* Качан моннан түшәкне итәсен, кыз инде бирнә бирә. Йахшы гына халлесе бирнә дә күп бирә. Адийал да куйдым, пал′тә дә куйдым бирнәгә. Бездә хаз′ыр бирнә биреп тырмыйлар. Тенә сун бирнә багарга бардылар – йеслекләр. Җыма кенне бирнә сал′арга бардылар. – *кузн.* Әзерли инде бирнәләр: күкрәкләр, тастымаллар чигәләр иде. Бирнәләрен йаратмилар, Кодагий башын каший...(*бор. җыр.*). – *хвл.* Шал килен дигәне бирнә бирә, итәк җапмамы, ниме – *т.я.-крш.*; 4. *блт.* кыз артыннан бара торган терлек, калым (приданое невесты). Кийем-салымнан башқа бирнәгә сыйыр, бозау, сарық, қошқорт кебек җанлы маллар да бирелгән. Бирнәсе булмаса, ниргәсе дә булмый (*әйтем*); 5. *эчк.* кыз ярәшкәндә кызның әнисе тарафыннан башкодага бирелә торган бүләк (подарок, преподносимый матерью невесты свату во время сватания). Минем инәй бирнә итеп д′аулық бирде; 6. *чст., кузн.* бала тудыргач яки баланы сөннәткә утырткач бирелә торган бүләк (подарок, преподносимый в связи с рождением ребёнка или проведением обряда обрезания). Ылан тугац, бирнә итеп биж митыр ыштапел күлмәклек алып бирде. – *чст.*; 7. *мам., дөб.* сабан туе өчен җыела торган бүләкләр (подарки, собираемые для преподношения победителям на сабантуе). Урамнарда бирнә җыйып йөри торғаннар ыйы. – *мам.* Урамда бирнә җыйалар сабан туйында көрәшкән өчен бирергә. – *дөб.*

**бирнә кыртлау** *лмб.* кыз бирнәсенә каршы акча салу йоласы (обычай давать деньги в ответ на подарок, полученный от невесты).

**бирнә-ниргә** *блт.* туй бүләкләре (свадебные подарки). Бирнә-ниргәләрне мул итеп бирәләр ийе.

**бирнәне ниргәләп бирү** *блт.* туй бүләкләрен мул итеп бирү, күп итеп бирү (давать помногу свадебные подарки).

**бирнә сону** *минз.* бүләкләрне подноска салып туйда күрсәтү, җитү-җитмәвен тикшерү (старинный обычай показывать свадебные подарки, разложив их на подносе).

**бирнә сорау** *чст.-крш.* туйда бүләк сорау йоласы (один из старинных свадебных обрядов). Каз тураганда, бирнә сорап җырлый: «Мин пычаклар кайрый алмим, Әти чалгы да кайрый. Каз канатларына берләр кыш кунган, Бирнә булмас микән, дип сайрый».

**бишек бирнәсе** *нокр.* яшь киленнең беренче баласы тугач, балага, кода белән кодагыйга киленнең әнисе һ.б. туганнары тарафыннан китерелгән бүләкләр (подарки, преподносимые родителям жениха и новорождённому матерью и другими родственниками невесты после рождения её первенца).

**БИРНИ** *кас.* к.: **бирнә**.

**БИРТӘК** *каз.ар.-крш.* сакау (косноязычный, картавый). Биртәк кеше бу.

**БИРТЕК** 1. *срг., мәл.* биртелгән, гарип (искалеченный, калека). Оланнарым бер дә биртекләр, кыңырлар булмады; 2. *минз.* төшенке, кимсенүчән, китек күңелле (подавленный, угнетённый). Минем күңел биртек бит инде, малайым җук, қартым җук. Қартайгач күңел тегеләй дә биртек була; 3. *срг.* иске, тузган (ветхий, старый). Бер биртек клуп бар бит тетелеп беткән; 4. *тбл.* имгәнгән (повреждённый).

**БИРТЕКЛӘНҮ** *минз.* төшенкелеккә бирелү (поддаваться угнетённому настроению, грустить). Кешегә җәри-җәри биртекләнеп бетте инде.

**БИРТЕКЛЕК** *мәл.* гариплек (инвалидность, уродство). Биртеклегең бар, сиңа терелергә трутна булыр, ди.

**БИРТЕЛҮ** 1. *трх., чпр.* к.: **йадаулану**. Әйләнеп кат′кан сайын бирмәсәң, бәбекәләр биртелә; 2. *кузн., хвл., мәл.* ару-талу яки авыр эш аркасында авыруга сабышу, имгәнү (калечиться, получить увечье, болезнь из-за тяжёлой работы, усталости и проч.). Биртелеп беттем су койа-койа, йаңгыр йук. – *кузн.*

**БИРТЕН** *мам., лш., чст.-крш.* бирле, буена (с, на протяжении ... лет). Җитмеш җылдан биртен алған әйберләр тормый. Ун җылдан биртен көтү көтә. Шуннан биртен кергәне җук. Ничә җылдан биртен тора инде. – *мам.* Кичәдән биртен шушында печәндә қундым. – *лш.* Инде мин белгәннән биртен шылай Әлүк бабай карчыгы. – *чст.-крш.*

**БИРТҮ** 1. *хвл., мәл., чпр.* имгәтү (калечить, увечить, ушибить). Әй каты кыйнаганнар да үзен, биртеп ташлаганнар. – *чпр.* Биртеп ташлады бу грипп. –*мәл.*; 2. *срг.* бирешү (сдаваться из-за тяжёлой работы, усталости). Биртә инде картайгац, үмер буйы эшләгәц.

**БИРУК** *тпк.* сумса (пирожок). Муйыл биругы пешергән итем. Эремек биругы тәмне була, қаймақ саласың, күкәй сытасың.

**БИРҮ** 1. *чст.* салым (налог). Ул вакыт бирү салмаганнар; 2. *тмн.* ришвәт (взятка). Бирү бирергә дә кешесен табып булмый, безнең халдән дә килми.

**БИРЧӘЙҮ** *хвл., тмн.* к.: **билчәү**.

**БИС** [*рус.*] *м.-кар.* к.: **пич I.**

**бис такта** *м.-кар.* к.: **пиц I: пиц тактасы.**

**БИСӘ** *злт.* к.: **бичә.** Бу минең бисә була. Бисәләр эшкә баралар.

**БИСЕРӘЙҮ 1.** *лш., дәб.* бер эшсез киенеп-ясанып йөрү (разодеться и ходить без всякого дела); **2.** *к.т.* күкрәген киереп, биленә таянып басып тору (стоять «руки-в-боки», с выпяченной вперёд грудью). Кеше эшләгәндә берүзең бисерәйеп торма.

**БИСИДА** [*рус.* беседа] *карс., кузн.* мәҗлес (званый обед). Бисидамнын күрке килгән, кыдагилар утырган (*хал. җыр.*). – *карс.*

**БИСКӘ** [*рус.* бочка] *т.я.-крш.* мичкә (бочка).

**БИСТАРКА** *чпр., злт.*, **БИСТАРКЫ** [*рус.*] *чст.-крш.* иген салып ташу өчен арбага куеп йөртелә торган зур тирән әрҗә (большой глубокий ящик для перевозки зерна, прикреплённый на телегу). Бистарканы иген акмый торган итеп агачтан йасыйлар. – *чпр.* Бистаркыга күпме нәстә керә, шуны үзе күтәрә, үзе аудара. – *чст.-крш.*

**БИСТӘР 1.** *крш.* к.: **битйаулык.** Бачи, чиккән бистәргә сөрт кулыңны. – *чст.-крш.* Әwәле кызлар әнә шундый кызыл башлы сөлгеләр, бистәрләр, тастымаллар хәзерли ийе. Кыз җиңгәсе, сандыкны ачып, тастымал, бистәр әлә башлый. «Бистәр, тастымал әләргә чөй җуғ икән», – дип, кийәү җегетеннән акча сорый. Иртә белән торып чығywына Чөйдәге бистәрләрең ак булсын. Төнгө йоқоларың татлы булсын, Таң йоқоларың сақ булсын (*хал. җыр.*). Қайнар су барында тегенең бистәрен сығып ал. Тушы пурмыға бистәрләр бар минем. – *каз.ар.-крш.* Битне бистәрләргә сөртәбез. – *нгб.-крш.* Бистәрләрне кругум әләләр. – *т.кам.-крш.*; **2.** *минз., нгб.-крш.* чиккән башлы озын сөлге (длинное вышитое полотенце).

**чәй бистәре** *т.кам.-крш.* тастымал (салфетка, маленькое полотенце). Иң беренче ақлашу була торған ыйы, қыз йанчыққа тутырып читләwек бирә торған ыйы, бер чәй бистәре бирә торған ыйы.

**БИСТЕРГӘК** *брб.д.* биздерүчән (надоедливый, скучный).

**БИСТУРҒАЙ** *кмшл.* тургай (жаворонок).

**БИТ I** *карс.* к.: **айазлық.** Урман битләрен арба басмаган, Үгә кат'ырга Алла йазмаган (*бәет.*). Улсы йөгерә йери урман битендә.

**БИТ II** *әстр.* к.: **бите.** Безеке ары биткә чыққан. Ол'а биткә бармаға кирәк.

**БИТ III** (лицо):

**бәлеш бите** *нрл.* бәлеш капкачы (верхняя часть, крышка бәлиша).

**бит алмасы** *кузн., хвл., глз., кмшл.* бит уртасы (щека). Бит алмалары йанып тора. – *хвл.* Атасы, сугышқа киткәндә, бит алмасын тешләп қалдырды, исендә тытсын дип. – *глз.*

**бит җаулығы** *мам., лш., минз.* к.: **битйаулық.** Бит җаулығы бир апаңа сөртенергә. Бит җаулығы алдымы мунчаға? – *мам.*

**бит йаулығы** *мам., минз., кмшл.*, **бит йаулыгы** *стрл.* к.: **битйаулық.** Йywынсағыз, менә бит йаулығы да. – *мам.* Битне бит йаулыгы белән себерәләр инде. – *стрл.*

**бит киселү** *чст.* оялу (стыдиться).

**бит очы** *нгб.-крш.* к.: **бит алмасы.**

**бит себергеч, бит себеркесе** *шрл.* к.: **битйаулық.** Элеп куй бит себеркесен.

**битен күрендерү** *лмб.* егет ягыннан кардәш хатын-кызларның кыз яныңа килеп танышу йоласы: башта булачак каенана, аннан каенигәч, кодачалар килеп, киленнең бөркәнчеген ачып карыйлар һәм үбәләр, соңыннан бүләк бирәләр (один из свадебных обрядов: знакомство родственниц жениха с невестой); чаг.: **кыз: кыз күрү.**

**битеннән басып керү** *хвл.* тыйнаксыз рәвештә керү, басып керү (вторгнуться). Нишлим инде, битеннән басып кергәч.

**камыр бите** *карс.* камыр өсте (поверхность теста).

**мендәр бите** *т.я.-крш.* к.: **кап 2.** Мендәр битләре дә суккан булган.

**БИТ IV** [*рус.* вид] *тара.* күренеш (вид). Открытка йебәргән, Қасан Кремленең бите, бик қадерле итеп сақлыйм.

**БИТ V** *әстр.* як (сторона).

**йегет бит** *әстр.* к.: **йага I, 4.**

**қыз бит** *әстр.* к.: **йага I, 4.**

**түр бит** *әстр.* к.: **йага I, 5.**

**БИТАШАР** *әстр.* кыз күрсәтү йоласы (смотрины).

**БИТӘ** [*рус.* ведь-а] *к.т.* әйеме (частица ли). Син кичә қайттын битә?

**БИТӘР** *себ.* караганда да, чагыштырганда да (даже по сравнению).

**БИТЕ** *эчк.* яны, буе (рядом, вдоль чего-либо); чаг.: **йага I, 3.** Салawай битенә барабыз пецәнгә. Сыw битендә утырдыңмы?

**БИТҖАУЛЫҚ** *мам., лш., каз.ар.-крш.* к.: **битйаулық.** Битҗаулықлар да киндер. – *мам.* Бит сөртә торғаны битҗаулық була, қызыл башлысын сөлгө дибез. – *лш.* Сезен битҗаулыққа сөртеп өлгергәннәр буғай. – *каз.ар.-крш.*

**БИТЙАУЛЫҒОҢ** *төм.* сөлге башы (конец полотенца). Битйаулығоңлар үсем пәйләгән.

**БИТЙАУЛЫҚ** *кмшл., эчк., бгрс., крғл., тара., твр.*, **БИТЙАУЛЫК** *шрл.* сөлге (полотенце). Ана шунда битйаулық та қуйдым битегезне сертергә. – *кмшл.* – Битйаулық китергән кийәwенә. Сабын ал, битйаулығ ал. – *эчк.* Битйаулықлар фис эзерләй. – *тара.*

**БИТКҮРЕМ** *әстр.* киленнең битен ачу хөрмәтенә үткәрелә торган мәҗлес (угощение в честь открывания лица невесты перед народом). Җегет җақ қалыққа биткүрем күрсәтәде, җақын туғаннарын чақырады, битләрен җаулық белән бәйләп, тез бөгеп сәләм бирәде килен.

**биткүрем туй** *әстр.* к.: **биткүрем.** Биткүрем туй булады.

**БИТЛӘҮ** *к.т., кмшл.* күңелдән ятлау, күңелгә бикләү (выучить наизусть). Бер бит шигырне хәзер битләдем. – *кмшл.*

**БИТСЕБЕР** *м.-кар.* к.: **битйаулық.** Җәш килен җибәрә битсебер.

**БИТСЕБЕРГЕЧ** *чст., карс., стрл., шрл.* к.: **битйаулық.** Урта тәрәз төбендә бер тәрәзә уйыгыз. Битсебергеч өсләренә бер шәл йаулык куйыгыз (*хал. җыр.*). – *чст.* Бирнәне без бирдек бик йакшы, йакшы эстакер, чәчәкле шәлләр, битсе-

бергечләр куйдым. – *карс.* Битсебергеч бар сандыкта. – *стрл.* Битсебергечне чийгә эләсен. – *шрл.*

**БИТСЕЗ** *хвл., кмшл.* оятсыз, намуссыз (бессовестный, бесстыдный). Ойатың йуқ икән синең, битсез. – *кмшл.*

**БИТСӨЙӘК** *перм.* к.: **йәйәк II**.

**БИТСӨРТӨҢГЕЧ** *чст.* к.: **битйаулық**. Кайнана булмакчы кешегә инде йакшыдан күлмәк бирәләр, кайнатасына да күлмәк, битсөртөңгечләре инде.

**БИТҮ** *твр.* туу, барлыкка килү (рождаться, появляться). Әүвәл башлап ни битти? Күн битти дә, ай битти.

**БИТЫРАЧ** *м.-кар.* к.: **питрач I, 1**. Битырач була кечкенә.

**БИЦӘ** *эчк., тбл.* к.: **бичә**. Хәлимнең бицәсе килә. – *эчк.*

**БИЦӘЛ** *яүшт.* к.: **пицәл**. Бицәл булса, қорсағы зур була, айақлар нәзек була, рахит инде ул.

**БИЦӘМӘЦЕЛӘР** *том.д.* бурлаклар (бурлаки).

**БИЦИН** *төм.* явыз рух (злой дух).

**БИЧ I** [*рус.* весь] *перм., минз., бөре., лш.* бөтенләй, тулысынча (весь, полностью, целиком); чаг.: **башала 1**. Җилкә-баш бич муйыннан алып awырта. – *перм.* Бич алып бетергән. Бич беткән теге қайын төбе, бернәстә қалмаған. – *бөре.* Берсен генә алыйм дисең, бич җолқонып чыға. – *лш.*

**БИЧ II** [*рус.* печь] *минз., бөре., м.-кар.* к.: **пич I**. Ағач көрәге белән бичкә салабыз. Аларның бичләре бар. – *бөре.*

**бич такта** *м.-кар.* к.: **мич: мич ал тақта**. Бич каплый торган такта бич такта була.

**БИЧӘ** *перм., минз., бөре., трбс., тара., твр., төм. стрл.* хатын (жена). Аның бичәсе ача торған ийе. Бичәсе йаланға китте ийе, бичәсе бәбиләгән. – *перм.* Бичәсе белән килгән иде. – *минз.* Бу Әбүзәр бичәсе. – *трбс.* Ирле-бичәле чыгып киттек. – *стрл.* Аның бичәсе кийәүгә барып қуйды. – *тара.* Пала тыумаған (тапмаган) бичәләрне бала тудырдым сылап. – *твр.*

**БИЧӘЛЕ-АБЫШҚАЛЫ** *перм.* ирле-хатынлы (муж с женой). Алар бичәле-абышқалы икәү барғаннар.

**БИЧӘШ: бичәш бағанасы** *минз.* сәндерә баганасы (столб, поддерживающий полати).

**БИЧЕКИ** *глз.* кардәш хатын-кыз (родственница).

**БИЧЕН** *себ.* убырлы карчык, җен (ведьма).

**БИЧИ** [*удм.*] *нокр.* туган тиешле ир кеше (родственник). Йәсәwи безнен бичи малай.

**БИЧИР** [*рус.*] *төм.* кичә (вечер). Бичирта утыратығаннар, аны-моны уйнайтығаннар.

**БИЧҮ** *твр.* к.: **пычу I**.

**БИШӘМ** *т.я.* биш көлтәдән торган өем (способ сложения снопов по пять штук).

**БИШӘРЛӘҮ** *шрл.* тизәк кирпечләрен киптерү өчен бишәрләп өю (способ сложения кирпичей из кизяка для сушки).

**БИШБАРМАК** *чпр., срг.* к.: **бишбармақ 2**.

**БИШБАРМАҚ 1.** *перм.* кул чугы (кисть руки); **2.** *перм., к.-уф.* перчатка. Қайын кешегә бирәләр бишбармақ, қызларга – алжапқыч. – *перм.*

**БИШБАРНАҚ** *блт.* юл үләне (цикорий).

**б и ш е к** (колыбель):

**бишек баласы** *каз.ар.-крш.* бишектәге бала, яшь бала (грудной ребёнок). Бишек балабыз бар, берқайа да баралмыйм.

**бишек киштә** *глз.* бишек сиртмәсе (шест, на который подвешивается люлька). Бишек киштә түшәмгә кулчу салып әләләр.

**бишек кыргыч** *лмб.* бишек чыбылдыгы (занавес для люльки). Бишек кыргыч астыннан күзләрен ал'андыра олан.

**бишек туйы** *кузн., әҗе.* бәби туе (пир в честь рождения ребёнка, родины); чаг.: **бутка**.

**бишек чәчәге** *мам.* бала тәненә чыга торган вак бетчә (потница, сыпь). Бишек чәчәге дә чықты.

**БИШЕК-БИЛЕК: бишек-билеге белән** *карс.* бишеге-ние (с колыбелью и проч.). Бишеге-билеге белән, анай, ызатканнар кызымны.

**БИШИЛЕ** *злт.*, **БИШИЛЛЕ** *каз.ар., минз.* биш бармак калынлыгы (толщиной в пять пальцев). Бишилле генә бәйлисем бар. – *лш.*

**БИШИН** *твр.* төштән соң (по полудни, после 12 часов).

**БИШИНӘЙЫК** *мәл.* сарык йоныннан бәйләнгән озын кунычлы оек (шерстяные чулки ручной вязки). Тулайык булмаса, бишинәйык белән кийәсен чабатаны.

**БИШКӘ** *тбл.* чәшке (норка). Пашынта бишкә тақйалар.

**БИШЛЕК** *карс.* бишле (отлично, оценка пять). Бик йакшы укыды, аның бишлекләр генә.

**БИШМАСТЫ** *лш.* к.: **пибаш**.

**БИШМАШЫ** *каз.ар.* к.: **пибаш**. Бишмашы қырыйына басып менә торған утырғыч бу. – *лш.*

**БИШМӘТ 1.** *дөб., кмшл., хвл.* сырган пальто; картлар телендә гомумән пальто (стёганое пальто; в речи старшего поколения вообще пальто); **2.** *срг.* камзул (камзол). Зинсез бишмәтем әлдә бар, өц сынлы итеп теккән; **3.** *перм.* костюм; **4.** *срг.* пиджак.

**сынлы бишмәт** *срг.* билле бишмәт (приталенное пальто, расклешённое к низу).

**БИШНӘ** *срг.* бишинә (спицы для вязанья); чаг.: **биләм III: биләм энәсе**.

**бишнә цылка** *срг.* к.: **бишинәйык**.

**БИШНӘЙОК** *чст.* к.: **бишинәйык**.

**БИШНӘК** *минз., мам.* тегермәнгә су җибәрү өчен ачыла һәм ябыла торган итеп ясалган улак (погонный ларь, коуз на водяной мельнице, откуда вода течёт на колесо). Тегермән бәйәсенең бишнәге була, оло су килдемә, бишнәген ачып җибәрәләр, ачмасаң, китә бөйә. – *лш.* Бишнәккә қабат сала торған суын. – *мам.*

**БИШНИ** *лш., каз.ар.-крш.* шакмаклап сугылган киндер (домотканое полотно в клеточку). Ситсы кимәдег ич әwәл, бишни кидек. Бишни шақмақлы була. – *лш.* Бишни күлмәкне икене қараны, икене ақны җә дүртне ақны, дүртне қараны атып суғаң инде. Бишни күлмәк кидек, алача ыштан кидек әле без. – *каз.ар.-крш.*

**сарылы бишни** *чст.-крш.* вак кына итеп сары, кызыл җепләрне аралаштырып сугылган киндер (домотканое полотно, клетки которого смешиваются с жёлтыми, красными нитями).

**БИШТЕРӘ** *дөб.* к.: **бештерә**.

**БЛИ-БЛИ** *глз.* к.: **баш-баш**.

**БО** *төм.* бу (это, этот, эта). Илленце йылта бо awылға беренче машина килгән.

**БОАЙ** *бөре.* бугай (кажется, как будто).

**БОБАТ** [*рус.* боб] *глз.* җитеннең маен алгач калган калдыклары (жмых).

**БОҒА** *эстр.* үгез (бык).

**БӨҒАҖӘ** *минз.* арбаның арт һәм ал карамалары (вязки, схватки телеги, саней).

**БӨҒАҚ** *брб.д.* к.: **буғаз**.

**БӨҒАЧЛАУ** *бөре.* **1.** суелган терлекне арт аякларыннан агачка элэктереп асып кую (вешать тушу мяса с помощью куска дерева на задние ноги); **2.** сүз көрәштерүдә, бәхәсләшүдә җиңеп чыгу (взять верх, победить в споре). Син аның белән сүз көрәштерсәң, ул сине боғачлап ташлый.

**БОҒО, БОГО** *глз.* бау, тотка (дужка у ведра, котла). Қазанның чиләкнең шикелле богосы булған.

**БӨҒӨҒЫ** *том.д.* к.: **БУҒАЗ**.

**БОҒОЗЛАУ** *нгб.-крш.* бугаз (горло). Бүре атның боғозлawына җабышқан. Боғозлawына сыwық тигән.

**боғозлау башы** *нгб.-крш.* бугаз төене (кадык).

**БОГОЛ 1.** *кузн., хвл., мәл.* көлтә кибәне (стог из снопов). Кышын боголыннан сүтә, арышны көлтәләтүк кертә булған. – *хвл.*; **2.** *чпр.* эскерт (скирда).

**боғол итәге** *дөб.* печән кибәненең түбән әйләнәсе (нижняя часть стога сена). Боғол итәген чичталап д'ийыгыз, эшебездән кеше көлмәсен.

**боғол үзәге** *дөб.* шеш, кибән шеше (стожар). Боғол үзәген йақшылап беркетегез, терәүләү нық булсын, боғол селкенеп утырырлық булмасын.

**БОҒОРЛОҚ** *дөб.* атларны һ.б. тоту өчен өч метр озынлыгындагы агачның башына элмәк куеп ясалган җайланма (арканный шест для поимки лошадей); чаг.: **буғалақ**. Мәкәләй батырны боғорлоқ белән тотқаннар.

**БӨГРӘП** [*рус.* погреб] *себ.* к.: **нәүрәп**.

**БОҒЫЛ** *баст., эстр.* кибән (стог). Қураламаған боғыл. – *баст.*

**б о д а й** (пшеница):

**кышлау бодай** *байк.* көзге бодай (озимая пшеница); чаг.: **'езле'лир**.

**БОЖО** *глз.* к.: **бабайчы: бабайчы багыты**. Божо кетәбез инде пирбый йамбар ай.

**БОЖОУ** [*удм.*] *злт.* к.: **пожу**. Бәрәңгеләр божоды.

**БОЖУ** [*угор.*] *перм.* к.: **пожу**. Гөлләр божоганнар, су сибәсе бар.

**БОҖАЛ** *минз.* вакыт, срок (срок). Балаға ашарға алганга божалыбыз тулгач, умбиш көн эшләдек.

**божалға бару** *перм.* егет белән кыз үзләре генә килешеп өйләнешкәннән соң, егет ягыннан кыз ягына туй һ.б. турында киңәшергә бару (идти советоваться о свадьбе с родственниками девушки, вышедшей замуж убегом). Божалға барабыз тип баралар қызн(ы) алгач. Өч көн булгач кителәр божалга дип.

**БӨЗ I** *нрл.* бүз (пепельный, беловатый серый цвет).

**б о з** (лёд) **II**:

**боз тоту 1.** *перм.* боз кату, боз туктау (ледостав). Идел бозы тотқач қына арйаққа чығып йөри башлыйлар; **2.** *злт.* боз кату (замерзать, превращаться в лёд).

**б о з а у** (телёнок):

**бикәч бозау** *лш.* тана бозау (тёлка).

**бозау колагы** *байк.* к.: **бақа: бақа гөлө**.

**теше бозау** *чпр.* к.: **бикәч бозау**. Сыйырымның теше бозawы бар.

**БОЗҒАҚ** *мам., т.кам.-крш.*, **БОЗГАК** *чст.-крш.* бозлавык (гололедица). Чишмә сuwына барырға tawы гел бозғақ булды көзөн-көзли. Җулны артқылы чығышлы түгел, бозгақ. – *т.кам.-крш.*

**БОЗОҚ** *т.я.*, **БӨЗӨК** *хвл.* сихер, бозу (порча, колдовство).

**БОЗОЛУ** *перм.* аң югалту (потерять сознание). Дawлинйәсе зур, хатын бозолған, бала тудырмага кәрәк.

**БОЗОМ** *бөре., трбс.* к.: **бозоқ**. Әллә бозом эшенә әләктеңме? – *бөре.* Бозомға очораған бу кеше. – *трбс.*

**БӨЗӨРОҚ** [*рус.* пузырь] *төм.* к.: **мөрҗә 3**. Лампа бөзөрого.

**БӨЗУ 1.** *мәл., тмн., чпр.* вату (разбить). Стаканны кан'ар су агызып боздым. Тәрәзәне бозма! – *тмн.*; **2.** *хвл., т.я.* язуны бетерү (стереть написанное).

**БӨЗУ** *тара.* вату, сындыру (ломать, разбивать).

**БОЗЫЛУ I** *тмн., мәл., чпр.* ватылу, җимерелү (разбиться). Стаканым кулымнан төшеп бозылды. – *чпр.*

**БОЗЫЛУ II** *баст.* эпилепсияле булу (иметь болезнь эпилепсии). Кечкенә чағында қурқудан бозылып қалды.

**БӨЙ** *твр.* буй, гәүдә (тело, туловище).

**бөй бирмәү** *тара.* буйсынмау (не покоряться, не уступать). Бу хатын бөйын бу байға бирмәде.

**БОЙА'А** *кас.* к.: **биаға(й)**.

**БОЙКЫЗ** *клд., срг.* к.: **буйкыз**. Икесе дә бойкызлар иде. – *клд.*

**БОЙЛОҚ: Алла бойлоғо** *каз.ар.-крш.* Алла кушуы (повеление Всевышнего). Алла бойлого белән ике тапқыр искә алырға.

**БОЙМА** [*угор.*] *тара.* к.: **пима 1**.

**қысқа қуыслы бойма** *тара.* к.: **ғалуш 1**.

**БОЙОРТУ** *эстр.* заказ бирү (заказать). Туғантохомнар бойорталар үземә.

**БОЙТЛАУ** [*рус.* +*афф.* -лау] *минз.* юл кую, яклау (допускать, позволить что-либо делать; защищать недостойные дела). Ул үз баласын бойтлады да бойтлады.

**БӨЙЫН** *тара.* муен (шея).

**БӨҚ** *том.д.* болын (луг).

**БОКАЙ** *мәл.* бүкәй (бука). Әләлә, бокай килә.

**БОҚОРАТУ** *кргл.* туздыру (поднять пыль). Тузанын боқоратма.

**БОЛА** *перм.* к.: **була**. Шушы суға бола төннә торам да. Җиргә бола килгәннәрдер инде.

**БОЛАҒАЙ** *каз.ар.-крш., минз.*, **БОЛАГАЙ** *стрл.* к.: **салак**. Бер болағай ғына қатын шунда. – *каз.ар.-крш.* Анда болағайга җулықтығыз? – *минз.* Борынгы кеше бигерәк болагай җөри, теге тийә, бу тийә дип тормый.

**БОЛАЙ: моннан болай** *каз.ар.* к.: **ары 3.** Моннан болай қайтмам дигән ийе, қайтмый бит гупчи. – *мам.*

**БОЛАМА 1.** *блт., каз.ар.-крш., т.я., перм.* буталчык, буталган (путаный, запутанный). Бездә алма да диләр, бәрәңге дә диләр – болама инде. – *блт.*; **2.** *минз., стрл.* буталчык, болганчык – чор, дәвер (путаное, смутное – время). Болама wакыт, абзаңны да шушы урынга сыйдыр, диде. – *стрл.*; **3.** *каз.ар.-крш.* аралаш (смешанный). Керәшене, татары болама инде хәзер.; **4.** *каз.ар.-крш., бөре.* бергә (вместе). Идәнне ул да йywa, мин дә йywam, без бит болама тапайбыз. – *бөре.*; **5.** *каз.ар.-крш.* рәтсез, юньсез, тәртипсез (непутёвый). Әлек-әлектән болама кеше, қартайғач бөтенләй рәтсезләнде.

**болама итү** *минз.* **1.** аралаштыру, бутап бетерү (перепутать); **2.** пычрату (испачкать); чаг.: **баскалау.** Идәнне болама иткәнсең.

**БОЛАМЫҚ** *чпр., хвл.* к.: **болама 1.**

**БОЛАМЫҚ** *т.кам.-крш.* җәй көне үткәрелә торган дини бәйрәм (религиозный праздник, проводимый летом). Боламықта инде бөтен урам кыруглый әйләнәдер ийек. Мин казыр онытам, қайсы айда килә сун әле ул боламық?

**болан** (олень):

**болан сийыры 1.** *минз.* болан (олень); **2.** *трх.* к.: **мошый.**

**БОЛАҢҒЫР** *перм.* **1.** тоник (мутный, непроницаемый свет). Бу күзлек болаңғыр. Тирәзә тирләп китә – болаңғыр була, үткәрә күренми; **2.** төмсә (мрачный, хмурый). Көн болаңғыр диләр болотлы да, томанны да көнне; **3.** к.: **қуйырық 3.** Йылға да, ташып китт(е) исә, болаңғыр була.

**БОЛҒАҚ** *минз.*, **БОЛГАК** *стрл.* к.: **болама 2.** Суғыш чыгып китте, ана шунда бик болғақ булып китте.

**БОЛГАКЛАУ** *м.-кар.* җиңелчә генә чайкау (коекак полоскать). Җылга җакын безгә, чыгып болгаклыйбыз да, чиста була.

**БОЛГАМА** *мәл., кузн.* **1.** саламга кайнар суда изелгән бәрәңге катнаштырып яки он, көрпә сибеп әзерләнгән терлек азыгы, башак (месиво скотине из соломы с кортофелем или мукой); **2.** кошкорт өчен ясалган измә (месиво для домашних птиц). Тawыкларга дийеп пешергән болгамамны мачы ашаган. – *мәл.*

**БОЛҒАУ 1.** *минз.* к.: **болгама 2**; **2.** *перм.* к.: **қуйырық 3.** Балықны саң белән тоталар йазғыда, су болғау wакытта.

**БОЛГАУ I 1.** *хвл., карс.* к.: **болгама 1**; **2.** *стрл.* к.: **болгама 2**; **3.** *тмн., кузн.* комачаулау (мешать). Утыр, утыр, син миңа болғамыйсың. – *тмн.*

**БОЛГАУ II 1.** *мәл.* болгату (замесить корм для скота). Бозауга башак болгап бирдем; **2.** *м.-кар.* изү (месить – о тесте). Камырны сеткә болгыйбыз.

**БОЛҒУ** *перм.* к.: **қуйырық 3.** Бүген йылғаның суы бигрәк болгу инде, уланнар йылғаны болғатып, қызыл батқағын чығарғаннар.

**БОЛДОР** *хвл., байк., мәл., стрл., злт., трбс.* өй алды баскычы (крыльцо). Болдордан менгәндә сөрлектем. – *мәл.* Тайанцык сарык тотторалар болдор төбенә төшүгә. – *байк.* Бер қарт бабай болдорда утыра икән. – *злт.*

**БОЛДОР-БОЛДОР** *хвл., мәл.* баскыч-баскыч, киртләч-киртләч (уступами). Крыл′чалары бик бийек, болдор-болдор менәргә кирәк.

**БОЛДЫР** *срг., чпр.* к.: **болдор.** Фелүрәнең туфлиен болдыр астыннан алдым.

**БОЛДЫР-БОЛДЫР, БОЛДЫРЛЫ** *м.-кар.* к.: **болдор-болдор.**

**БОЛДЫРУ** *әстр.* шадраландыру (рябить – о воде). Су болдырый.

**БОЛОТЛЫ** *срг.* караңгы чырайлы (хмурый, неприветливый); чаг.: **борнай.** Болотлы кеше иде, үмер эченә бер келми.

**БОЛЦАУ I** *тбл.* оештыру (устроить).

**БОЛЦАУ II** *төм.* билгеләнгән вакыт (срок); чаг.: **божал.**

**БОН** *срг.* к.: **бун′.**

**БОР** [*рус.* вор] *төм.* к.: **бур.**

**БОРА** *төм.* монда (сюда, здесь). Кил бораға, паланы қарап тор, мин ут төртеп әйәйек перәй йергә.

**БОРАЙЛАП-БОРАЙЛАП** *кмшл.* борма-борма (закручивая изгибами, спиралью). Чабата киндерәсен бит борайлап-борайлап ишеп, матур булсын дип йасыйлар.

**БОРАК** [*рус.* бурак] *срг.* тоз савыты (солонка).

**БОРАЛУ** *әстр.* бәйләнү – тел турында (заплетаться, запутываться – о языке). Телем хәзер боралып китә.

**БОРАМ** [*рус.* паром] *минз., стрл.* паром.

**БОРАМАҚЛАУ** *бәр.* әрәм итү, сарыф итү (тратить больше, чем надо, или без надобности). Өстәлгә қуйган майны тәмам борамақлап бетергәннәр.

**БОРҒЫЧА** *перм.* аюбаш (пришва).

**БОРДЫРУ** *т.кам.-крш.* кою (лить, заливать). Дәүрәк тәңкәдән бордырган беләзегем бар ыйы, балдақны да үзең бодыра торған ыйың.

**БОРЛАУ** *тара.* игеннең артык өлгереп, кибеп коелуы (осыпание зерновых от перезревания и высыхания).

**БОРЛОҒУ 1.** *лш., каз.ар.-крш.* борчылу, хәсрәтләнү (беспокоиться, волноваться). Йуққа борлоғасыз. Нигә борлоғасыз, җанашым? – *лш.* Оло җулларға чыққан чақта, Майлы бусын арбаң дегете; Қызығыз өчен борлоқмагыз, Ким-хур булырлық түгел җегете (*хал. җыр.*). – *каз.ар.-крш.*; **2.** *минз.* боегу, күңелсезләнү (грустить, унывать). Барасы килгән җиренә җибәрдем аман да қыдымы, борлоқмасын дидем.

**БОРЛОГУ** *стрл.* к.: **борлоғу 2.** Эчең поша кайчакта, йамансылаб утырасың борлогоп. Борлоктор, Ходай, борлоктор. Борлогасы йылымдыр (*хал. җыр.*). Ул да борлокто бер баласы да калмагач.

**БОРЛОҚТЫРУ** *каз.ар.-крш.* борчу (беспокоить, волновать). Мине борлоқтырасы килми.

**БОРНАҒЫ: борнағы көн** *әстр.* өченче көн (позавчера). Савинкаға борнағы көн бардым.

**БОРНАЙ 1.** *мам.* һавалы, тәкәббер (высокомерный, гордый). Бик борнай кеше ийе ул, бер кеше белән ачылып китеп сөйләшмәс, бер кешене дә йақын итмәс ийе; **2.** *блт.* сөйләшмәүчән, караңгы чырайлы, төксе, төмсә (мрачный, нахмуренный). Бик борнай кешеләр шул.

**БОРНАЙЛАНУ 1**. *лш.* тәкәбберләнү, әреләнү (важничать, гордиться, кичиться). Борнайланыб утыручы булса, читен булыр ийе; **2**. *дөб.* талымчанлык күрсәтү, талымчан булу, нәзберекләнү (быть разборчивым в пище). Борнайланып утырыр инде ул.

**БОРНАТУ** *хвл.* к.: **борнау 2**.

**БОРНАУ 1**. *кузн., хвл., дөб., тбл.* шыту, шытып чыгу (прорасти). Картуплар борнамый никтер. – *кузн.* Бодайлар борнаганнар. – *к.т.* Сололар борнаганнар инде. Қабақ орлоқлары борнаганнар инде. – *дөб.*; **2**. *хвл., к.т.* борынлау (выклёвываться – о цыплёнке).

**БОРНО** *кузн.* борын (нос). Борно төбән күрми, борно өстән!

**БОРОЛОШ** *перм.* к.: **арқылы 2**. Боролош кеше безнең Әхмәтҗан әтәч, бер дә оңғайга сүләми.

**б о р о н I** (нос):

**қаты борон** *минз.* дуңгыз (свинья).

**кийермә борон** *трх.* почык борын (курносый нос). Бер кийермә боронны киленнәре бар.

**очло борон** *стрл.* к.: **қаты борон**.

**БОРОНА** *кмшл.* к.: **беренә**. И борона йөри.

**БОРОНДЫҚ I** *минз.*, **БОРОНДЫК** *хвл., чпр., чст.* йөгәннең борон өстенә туры килә торган өлеше (часть уздечки).

**БОРОНДЫҚ II: борондық әни** *к.-уф.* к.: **борондық инәй**.

**борондық әти** *злт.* егетнең әти-әниләре тарафыннан киленгә туй вакытында әти итеп билгеләнгән якын туганы (посажёный отец).

**борондық инәй** *злт.* егетнең әти-әниләре тарафыннан киленгә туй вакытында әни итеп билгеләнгән якын туганы (посажёная мать). Борондық инәй қызны қунаққа сақыра, қыз аңа тастымал апара.

**БОРОНЧОҚ 1**. *минз.* гөлҗимеш җимешенең очындагы борыны (бородка ягод шиповника); **2**. *мам.* башакның очында өлгереп җитми калган бөртек урыны, кибәге (пустое гнёздышко зерна на верхушке колоса). Әдерәк борончоқлары була инде ул сытқан солоның.

**БОРОНЧОҚ** *стрл.* к.: **борончоқ 1**.

**БОРОҢҒАЙ** *т.кам.-крш.* һаман (постоянно, всегда); чаг.: **берче 1**. Бороңғай бер сүзне сүли инде ул.

**БОРОС** [*рус.* брус] **1**. *каз.ар., перм., минз., бөре., злт., т.кам.-крш., нгб.-крш.* к.: **кас'ак I**. Тәрәзә боросы. Ишек боросы. Бөтен өй аққа буйалыб бетте, бүген тәрәзә борослары буйадым. – *т.кам.-крш.* Өйләрнең тәрәдә боросларын қуйалар инде. – *минз.* Бүген тәрәзә боросы буйадым. – *нгб.-крш.* Тәрәзә қуйған, борос утыртқан. – *перм.*; **2**. *глз.* матча (матица). Пирчәткәсен боросқа күтәреп салды. Буйындан буйына сәке борос кебек сузган, ишек тепте килен йоклый; **3**. *бәр.* су белән агызыла торган бүрәнә, сал (плот, плотовой лес). Борос җибәрәләр ийе зур суға. Бүрәнәне суға төшерәләр дә, шул ағып китә, шул инде борос, озон-озон бүрәнә, йомры көйөнчә ағызалар.

**кийәү борос** *глз.* к.: **матча 1**. Бураганны күтәрәләр, күтәргәч, кийәү борос салалар бурап салған йорт өстенә берне.

**БОРОТ** [*рус.* пруд] *перм.* к.: **бума 1**.

**БОРСАЛАНУ** *минз.* борчылу, тынычсызлану, үз-үзеңне кая куярга белмәү (не находить себе места, сильно беспокоиться). Җоқламый икән, борсалана икән ирем. «Теге бала борсалана, – ди, – хәзер».

**БОРСАЛАУ** *бгрс.* борчу, аптырату (беспокоить, тревожить, донимать). Үзләре матур йырлый, мине генә йырла дип борсалыйлар.

**БОРТАК** *мәл.* сак тотучы, йорт тота белүче, уңган (экономный). Безнең әни бик бортак кеше иде, шуңа без йук үсмәдек.

**БОРТАҚ: бортақ сүз** *злт.* тупас сүз (грубое, тупое слово). Ул бисә бортағырақ сүзле шул.

**БОРТЫН** *трх.* борын, ...-га кадәр (до). Тумас бортын қартайғаннар.

**БОРУ I** *дөб.* елганың борылышы (излучина реки). Әнә бер боруда сарықлар ақты ич.

**БОРУ II** *нрл., злт.* сыгу (выжимать, отжимать). Бар, борып ки күлмәгеңне. Кем керләре, бора да алмаған. – *нрл.* Керләреңне қатырақ борып эл, тизерәк кибәр. – *злт.*

**бороб алу** *нрл.* сыгып алу (выжимать, отжимать). Тирләп пешкән, күлмәкләрен бороб алырлык ти.

**БОРУ III** *перм.* ишү (свить, свивать). Бау борабыз ийе мынчаладан.

**б о р у IV** (крутить):

**қойо бору** *минз., стрл.* бораулап кое эшләү (бурить колодец). Өстә қойо бордолар, бороп төшөргән қойо. – *минз.*

**БОРЧАҚ** *перм.* к.: **қузақ: қузақ ағачы**. Қапқаның берсе җағында борчақ, берсе җақта сирин.

**балта борчак** *минз.* өч кырлы эре борчак (чина).

**борчақ чүпләме** *каз.ар.-крш.* кәрәз сыман сырлы чүпләм (вафельный узор). Борчақ чүпләме бөйөстөр.

**вак борчак** *срг.* ясмык (чечевица).

**БОРЧА'ЛО'** *кас.* к.: **қузақ: қузақ ағачы**.

**БОРЧОЛУ** *каз.ар.-крш., лш.* таушалу (мяться, изнашиваться). Чәй пакитым бер дә борчолмаган дисәм, икенчесен башлағанмын икән. – *лш.* Бу инде борчолоб бетте, кигәләдем инде. – *каз.ар.-крш.*

**БОРЧЫ** *тара.* бурыч (долг, обязанность, заём).

**БОРЫЛМА: сүз борылмалары** *м.-кар.* әйләнмәләр (обороты речи, словесные выражения). Этра Монастырскида (*ав. ис.*) Сүкине (*ав. ис.*) аңламыйлар, үңгә төрле сүз борылмалары.

**б о р ы н I** (нос):

**борын танawы** *дөб.* борын (нос). Борын танawын җимерелмәсен, қарап йөр.

**борын тарту** *перм.* к.: **борнау 1**.

**БОРЫН II** *кузн.* элек, әүвәл (раньше). Борынарда кийәү манит сала иде.

**БОРЫЧМАН** *чст.* борыч төя торган савыт (посуда, в которой толкут перец). Борычман wатылды бит.

**БОС** *нрл.* к.: **боз I**. Бос шақмақлы җылан була, чаға, усал, awызын ача, сызғыра.

**б о т** (бедро):

**бот айырчасы** *каз.ар.-крш.*, **бот башы** *к.т.* бот

төбе (основание бедра). Бот айырчасыннан жырып қайттым қарны.

**йуwан бот** *бөре.* бот, аякның тездән югары өлеше (бедро).

**БОТА I: чалма бота** *перм.* к.: **билдәмә I.**

**БОТА II** *әстр.* дөя колыны (верблюжонок).

**бота қан** *әстр.* колынлы бия (кобыла с жеребёнком).

**БОТА I** *тара.* **1.** пута (пояс); **2.** шәл (шаль).

**БОТА II** *твр.* к.: **бота II.**

**БОТАЛАWЫЧ** *кргл., бгрс.* к.: **болама 1.** Аларныкы боталawыч телләре. – *кргл.*

**БОТАЛАУ** *перм.* көянтәне бизәкләп буяуның бер ысулы (один из способов украшения коромысел).

**БОТАУ I** *дөб.* ботак (ветвь, ветка).

**БОТАУ II** *дөб.* к.: **ардакълау II, 2.** Картайгач, ботакларын ботадык, йәш үрендесе генә калды.

**ботқа** (каша):

**бәби боткасы** *т.я.-крш.* бәби туе (пир в честь рождения ребёнка).

**йаңгор боткасы** *кузн., хвл.*, **қарға ботқасы** *бәр., бөре.* озак вакыт яңгыр яумый торса, бала-чага өй саен йомырка, он, ярма җыя да су буенда ботка пешереп ашыйлар. Соңыннан су сибешәләр (один из старинных обрядов моления о дожде). Карга ботқасы йасылар: қайсыбыз күкәй, қайсыбыз җарма, сөт бирәбез. Йар қаршында ботқа пешерәбез, аннан ашыйбыз, су сибеше була торган ыйы. Қарға ботқасы йасамасақ та, йаңгыр йawып қына тора. – *бәр.*

**нигез ботқасы** *каз.ар., бәр.* өйнең нигезен коргач пешерелә торган ботка (каша, которая варится при закладывании основания дома). Нигез қорғач, нигез ботқасы пешереб ашыйлар, қайсы Қор'ән уқыта. – *лш.*

**сабан ботқасы** *блт.* к.: **йаңгор боткасы.** Жаңгыр булмаганда сабан ботқасы жасый торганнар ыйы: сөт, жарма, күкәй жыйып, су буйына төшеп пешереп ашыйлар, аннан су сибешәләр.

**БОТЛАУ** *минз., стрл.* к.: **бойтлау.** Менә шулай итеп ботлагачтын булмый ул. – *стрл.*

**БОТЛОҚ** *бөре.* мич янында вак-төяк кую өчен ясалган куыш (печурка, ямка в зеркале печи). Ботлоққа қомган қуйабыз қышқыда.

**БОТОҒУСЫ** *перм.* к.: **беткелгесе.** Ботоғусы да килеп життеләр эшкә.

**БОТОҚА** *перм.* **1.** к.: **батқақ; 2.** к.: **қуйырық 3.** Ботоқа су белән йуганнармы, йаматай иткәннәр күлмәк(не).

**БОТУҚ** *перм.* к.: **берче I, 4, 5.** Әйберләрен ботуқ алып киткәннәр. Баганалар ботуқ ауганнар, торгызып жыйарга кирәг ийе.

**БОТЫЙ** *каз.ар.-крш.* ботка (каша). Ботый пешерәм дигән идем.

**БОХАПТАН** *перм.* **1.** киң жиңле, тезгә кадәр озынлыктагы камзул (камзол с достаточно широким рукавом, в длину почти до колен); **2.** костюм, озын пальто (костюм, длинное пальто); чаг.: **бишмәт 1, 3.**

**БОХАР: бохар миләше** *дөб.* к.: **байбай.**

**БОХОЙЛА, БОХОЛ** [*рус.*] *злт.* таза, юан, симез кеше (толстый, тучный человек).

**бөхойла кебек кийену** *злт.* калын итеп, катлы-катлы итеп киену (одеваться толсто); чаг.: **урина: урина кебек.** Син бохойла кебек кийенгәнсең.

**БОХОЛДАТУ** *злт.* симертү, тазарту (откармливать, дать ожиреть). Шамилыфны быйыл бохолдатасыз икән қымыз эчереп димен.

**БОШЫҒУ** *тбл.* күңелсезләнү, пошыну (грустить, унывать, беспокоиться).

**БӨWЕРЛЕ** *хвл.* бөрмәле, билдән бөргән; фалдалы (сосборённый, со сборками; с фалдами). Ак пылатна күлмәккә кызыл кештәк куйалар иде, аннан бөwерле камзул кийә идек. Мукшы халкы бөwерле иттереп тегәләр иде, безнеке киң итеп. Өч бөwерле камзул.

**БӨГӘ** *мам.* к.: **бума 1.** Тегермән бар чағында бөгә бар ыйы. Миндә иске-мосқылар бөгә бөгәрлек.

**БӨГӘЖӘ 1.** *трх.* к.: **бөгәлжә I, 4; 2.** *минз., тпк.* к.: **бөгәлжә I, 1, 2; 3.** *минз.* асылмалы лампа утырта торган тимер асма (подвесное устройство для висячей лампы); **4.** *минз.* ныклык өчен арба кабыгы астына бөгеп куела торган аркылы агач (перекладина, согнутая и устроенная под настилом телеги для прочности).

**БӨГӘЛЖӘ I 1.** *минз., т.кам.-крш.* агачны бөгеп ясалган божра (деревянное кольцо); **2.** *трх., т.кам.-крш., мам.* чалгының сабына аркылы бөгеп куелган тотка (поперечная рукоятка косы). Бөгәлжәсе була сапқа, йомошақ ағачны бөккәннәр дә қуйганнар. – *мам.*; **3.** *минз.* к.: **бөгелжә; 4.** *минз.* колак алкасы, йозак h.б. дугасы (дужка серьги, замка и пр.). Қолақ алқасының бөгәлжәсе. Йозақ бөгәлжәсе; **5.** *минз., стрл.* бишекнең агач сиртмәгә элү өчен җайланган ярым божра формалы тоткасы, дугасы (дужка у люльки); **6.** *трх.* камыштан үрелгән ике ярым божраларны аркылы-торкылы куеп, марля белән тарттырып ясалган балык тоту җайланмасы, сөкә (верша, морда, рыболовная снасть, дно которой сделано из двух прутьев – полукругов, обтянутых марлей).

**бөгәлжә алқа** *дөб.* к.: **алқа: қалас алқа.** Қашсыз, нисез бөгәлжә алқа була.

**БӨГӘЛЖӘ II** *перм.* бөгәлчән (слепень).

**БӨГӘН** *блт.* к.: **қамыраш II.**

**БӨГӘР** *минз., тпк., стрл.* тез (колено). Бөгәр астына йетеп тора чәче. – *тпк.* Бөгәрдән өстә тора итәге. – *стрл.*

**БӨГӘРӘП** [*рус.* погреб] *тпк., стрл.* к.: **нәүрәп.** Ана тегендә бөгәрәп. – *стрл.*

**БӨГӘРЖӘ 1.** *каз.ар.* к.: **бөгәлжә I, 5.** Бишек бөгәржәсеннән ычкынып төшкән дә бала қапланып қалган; **2.** *блт.* чулпының тәңкәләр тагыла торган алкасы, божрасы (дужка накосника, на которую подвешиваются монеты). Бөгәржәгә тагыла тәңкәләр, чулпы аталган.

**бөгәржә қул** *дөб.* к.: **бөгәлжә I, 2.**

**БӨГӘЧӘ I 1.** *т.я., лш., перм., срг.* бүген (сегодня). Кичә хәтерең қалган иде, Бөгәчә көн кем тапқан (*хал. жыр.*)? Туган көне дип бөгәчә жыйа да йәшләрне. – *т.я.* Менә шушыны күчереп собранийәгә қуйасыйым бөгәчә. – *лш.* Бездә кину бөла бөгәчә. – *срг.* Пример, бөгәчә ниқах уқытабыз

инде, әйтеп қайтара шул кичәне килергә дип куйын керергә. – *перм.*; **2.** *м.-кар., перм.* к.: **бегәчә.** Киләсе ничек булыр, бөгәчә аз йокладым. Мин бөгәчә эшләрем, бөгәчә кабыстырым (йандырырмын). – *м.-кар.*

**БӨГӘЧӘ II** *блт.* к.: **бөгәлҗә I, 2.**

**БӨГЕЛ** *стрл.* к.: **бөгөл 2.**

**БӨГЕЛЕП** *срг.* иелеп (нагибаясь, наклоняясь). Кинады, кинады да арыды, мин бөгелеп тырам.

**БӨГЕЛҖӘ** *минз.* ыргак (крюк, крючок); чаг.: **бөгәрҗә.** Қойыдан чиләк алырға бөгелҗәгезне бирегез әле.

**БӨГЕЛМӘ** *каз.ар.* бөгелә торган, бөгелүчән (гибкий, эластичный). Йаз көне тал чыбыгы бик бөгелмә була.

**БӨГӨЛ** *минз., стрл.* **1.** тез асты (место сгиба в колене); **2.** урам борылышы (поворот). Гайнулла абый әнә шунда бөгөлдә генә тора. – *стрл.*

**БӨГӨЛӨП** *хвл.* бөгәрләнеп (свернувшись, съёжившись). Ишек төбенә бөгөләп йаткан.

**БӨГӨЛӨШ** *тара.* к.: **бөгөл 2.** Бөгөләштүк йыгылып қалты.

**БӨГӨМ** *минз.* бөгеш (сгиб – в одежде). Сүтеп җибәр әнә шул төшөн, бөгөм өстөн, кереш тыгарға да җайлы булыр.

**БӨГӨШ I** *минз., трбс., стрл.* к.: **кукыл′.** Бер пичне бушка уздырмыйм, җә пәрәмәч салам, җә кыстыбый, җә бөгөш. – *стрл.* Йуwa бөгөшләре пешерә торган идек. – *трбс.*

**БӨГӨШ II** *трх.* алъяпкычның өске өлешен һәм итәген тоташтыра торган путасы (пояс, соединяющий верхнюю и нижнюю части фартука).

**БӨГӨШҮ** *нокр.* бөгелү, иелү (нагибаться). Бөгөшәсем кәлмий ич қартайғач.

**БӨДӘҖӘ** *минз.* к.: **бөгәҗә 4.**

**БӨДӘРЛӘНҮ** *трх.* бөгәрләнү (мяться, измяться). Бөдәрләнеп беткән күлмәк.

**БӨДӘҮ 1.** *лш., нгб.-крш.* бирү (давать); **2.** *лш., дөб.* йодрык белән тарту (неожиданно ударить тычком). Ну, Разийа апа үтеп киткәндә дә бөдәп китә ул. Бөдәп кенә ала, күрми да қаласын. – *лш.* Қул суғыш уйнаганда китереп бөдиләр тегенең қулына. – *дөб.*

**БӨДЕ** *срг.* дөге (рис). Лаукага килгән, перәндек алды, бөде йармасы алды. Бөде үрәсе.

**БӨДЕР** *тмн.* к.: **бедрә.** Таллар инде бөдерләнгән, алмагачның бөдереннән чәчәк чыгып килә.

**БӨДЕРЛӘНҮ** *тмн.* бөреләнү (набирать почки – о растениях).

**БӨДРӘ** *эстр.* к.: **бедрә.**

**БӨДРӘЛӘНҮ** *мәл.* к.: **бөдерләнү.** Алмагач чәчәккә генә бөдрәләнгән иде әле. – *мәл.*

**БӨДӨР** *чпр.* к.: **бедрә.** Кайын бөдөресе бик әйбәт.

**БӨДӨР-БӨДӨР** *тмн.* бөрмә-бөрмә (сборчатый, со складками). Ә йиң очлары бөдөр-бөдөр тора, абуркалар.

**БӨЖҮ** [*угор.*] *эчк.* к.: **пожу.** Суған бөжеп беткән.

**б ө ж ә к** (насекомое):

**утлы бөҗәк** *блт.* төнлә караңгыда ут кебек ялтырап күренә торган бөҗәк (светлячок).

**БӨЙӘ I** *лш., блт., мам.* к.: **бума 1.** Қойонырға була, бөйә бар, җырақ түгел. Бу суға җыл сайын бөйә бөйиләр. – *блт.* Бөйәгә қазлар төшөрдем әле. – *мам.*

**БӨЙӘ II** *блт.* бия (кобыла). Ғәйеп бөйәдә дә бар, тәртәдә дә бар (*әйтем*).

**БӨЙӘЛГӘН** *дөб.* буылган (запруженный). Бөйәлгән тирән су, шунда төшкән. Бөйәлгән суда ике қыз батты.

**БӨЙӘН** *кргл.* к.: **тутыртма II, 2.** Элек бик пешерәйек бөйәнне, хәзер пешергән йуғ әле.

**БӨЙӘНӘ** *эчк.* к.: **бөйрәк.** Бөйәнәмә сыwык тигән.

**БӨЙӘНҮ** *перм.* ышану, таяну (верить, быть уверенным). Үзеңә үзең бөйәнмәгәч, эшне башламыйлар. Үзеңә үзең бөйәнмәгәс, азырақ қурыққас, йулға чыкмыйсың да аны.

**БӨЙӘТ I 1.** *минз., стрл.* к.: **тутыртма II, 2; 2.** *злт.* к.: **қазы.** Бөйәт ашаган-ашаган да сусағас қар ашаган.

**БӨЙӘТ II** *блт.* ике бүрәнә арасына мүк урынына салына торган мунчала катыш салам бау (соломенная верёвка, обвёрнутая мочалкой для кладки в паз сруба). Аның хәзер бөйәтләре дә йанган, бүрәнәнең ырмawына салына мунчала белән. Өй салган кешегә хатын-қызлар бөйәт үргә киләләр.

**БӨЙӘҮ I** *блт., мам., лш.* к.: **бийәләү.** Безгә бик ару булды әле инешне бөйәгәч. – *блт.* Бөйә бөйәделәр, бездә су бар. – *мам.* Бөйә бөйәү. – *лш.*

**БӨЙӘҮ II** *мам.* к.: **бума 1.** Бөйәү җырақ түгел, әнә күренеп тора. Бөйәүдәге суны алып менеп сал инде.

**БӨЙӘҮ III** *тара.* тоткарлау, комачаулау (мешать). Йәшрәк булсам, китер итем суғышқа, йәшем бөйәп қалты.

**БӨЙЕНДЕ** *дөб.* яз көне җыелып торган кар суы (лужа талой воды).

**БӨЙЕРТАШ** *перм.* чуерташ (крупная галька).

**БӨЙРӘК** *дөб., т.я., эстр.* бөер (почка – у человека, животных). Симез дип артық симез түгел, но бөйрәкләре майға күмелгән иде сарыгының. Бөйрәге икән май эчендә, әле симез булган. Май эчендәге бөйрәк кебек (кадерле). – *т.я.* Сарыкның бөйрәге әләккән сезгә. – *дөб.* Қуйдан чыққан бөйрәктәй. – *эстр.*

**БӨЙСТӘР** *т.кам.-крш.* к.: **битйаулық.** Өйләрне бизәгән чақта чаршау қуйабыз, тәре бөйстәре қуйабыз, бөтенесен шулай қастәрләп әләбез.

**БӨЙСТӨР** *каз.ар.-крш.* к.: **битйаулық.**

**БӨЙӨНДЕ** *блт., дөб.*, **БӨЙӨНТЕ** *дөб.* яз көне җыелып торган кар суы (лужа талой воды). Элек йаз көннәрендә бөйөнтегә атлар төшеп үлә торган ыйы. – *дөб.*

**БӨЙӨРЛЕ** *баст.* бөрмәле билле, фалдалы (приталенный, расклешённый книзу). Тун мех эчле, тышлаган да була, бөйөрле дә була.

**БӨЙӨРӨК** *эстр.* к.: **бөйрәк.** Қуйдан чыққан бөйөрөктәй.

**БӨК** *яүшт.* кыр, басу (поле). Урта бөктә бәрәңге утыртқаннар.

**БӨКӘ** *минз., перм.* к.: **кукыл′.** Шулай кәбестә бөкә пешермәгә йөрим. – *перм.*

**БӨКӘЙ** *перм., мәл.* к.: **боҡай**. Ҡылама, мич артында бөкәй утыра; алып китәр, диләр. – *перм.*

**БӨКӘЙҮ** *яүшт.* иелү, бөкрәю, бөгелү (наклоняться, нагибаться). Билләрем awырта, бөкәйә алмыйм. Йирдән бөкәйеб алсам, йөрәкне ҡыса.

**БӨКӘН: көпчәк бөкәне** *трх.* тәгәрмәч бүкәне (ступица).

**БӨКӘЧ** *трбс.* к.: **бөкөч**.

**БӨКӘЧ-БӨКӘЧ** *лш.* к.: **баш-баш**.

**БӨКЕРЕ** *дөб.* ат тәненә йомырка сала торган бөжәк, кигәвен (овод). Бөкере чыққан, атларны шаҡтый азапларлар инде.

**б ө к к ә н** (пирожок, кулебяка):

**ҡазан бөккәне** *каз.ар.-крш.* к.: **шөшпәрә**. Өстәл күтәреп тормаслыҡ итеп апкиләләр ҡаз, ҡазан бөккәнен туйда.

**мирза бөккән** *дөб.* эченә корт, ҙимеш салып пешерелгән бәлеш (пирог с начинкой из засушенного красного творога и фруктов). Мирза бөккән эченә ҡорт салып, йемеш салып йасала, аның да бийеткесләре була.

**БӨКЛӘЗЕН** *төм.* бүсер (грыжа).

**б ө к л ә н ү** (загибаться, загнуться):

**бөкләнеп китү** *минз., стрл.* сыгылып төшү, иелеп төшү, бөгелү (прогибаться, поникнуть, согнуться в три дуги). Туйыра белә салдым, бөкләнеп китте. – *минз.*

**БӨКМӘ 1.** *срг., тмн., хвл., глз.* к.: **шөшпәрә**; **2.** *срг., минз., перм., т.кам.-крш.* к.: **кукыл′**. Элеке көн мин бөкмә ҙасап ҙийдым эректән. Эре бөкмә йасыйлар, имеш. – *перм.* Элеке бөкмә дигәннәр, ҡәзер бөккән инде. – *т.кам.-крш.*

**бөкмә ҡашыҡ** *перм.* сөзгеч (шумовка). Бөкмә ҡашыҡ белән созалар бәрәңгене.

**казан бөкмәсе** *срг.* к.: **шөшпәрә**. Туйда казан бөкмәсе пешерәләр.

**БӨКӨ** *мам.* өчпочмакның кечкенә генә капкачы (маленькая крышечка треугольника). Бөкөнө йасыйсың дағын пешкәч (шуннан) ҡайнар шулпа саласың.

**бөкө шалҡаны** *тпк.* шалкан, зур шалкан (репа).

**БӨКӨРИ** *бгрс.* к.: **кукыл′**.

**БӨКӨС′** *тпк.* к.: **көмөрө**. Бөкөс′ ҡыды бар.

**БӨКӨЧ** *минз., стрл.* к.: **бәйсәкә**; чаг.: **бохойла**. Бөкөч тә диб әйтәләр, бик бәләкәй булса. – *минз.* Корсак ҙywан булса, бөкөч диләр. – *стрл.*

**БӨКРӘННӘЙҮ** *брб.д.* бөкреләнү (сгорбиться).

**БӨКРЕ** *чст., кмшл.*, **БӨКРИ** *минз.* к.: **кукыл′**. Ашый-ашый барам, апай, алдым бөкре. Эчәк бөкресе сызыҡ ҡушып тәмне була. Ҡыдағый килсә, пешерегез шул иттән бөкре. – *кмшл.*

**БӨКТӘР** *т.я., кмшл.* төенчек (узел, узелок). Бөктәрен күтәреп утырмаға китте ҡызым. – *т.я.*

**БӨКЧӘЙҮ, БӨКЧӘННӘҮ** *минз., стрл.* бөкрәю (сгорбиться, сутулиться).

**БӨКШӘЙЕП 1.** *лш.* күшегеп, салкыннан бөрешеп (согнувшись, сжавшись от холода). Бөкшәйеп утырған шунда су төбенә. Балаң утырыр ийе бөкшәйеп син эштән ҡайтҡан чаҡта. Сywыҡҡа туңып бөкшәйеп утырам; **2.** *стрл.* бөгелү, сыну (гнуться, ломаться). Суған бөкшәйеп төшә.

**БӨКШӘНҮ** *хвл.* бөрешү (съёживаться, морщиться); чаг.: **бөкшәтү**. Нәстә болай бөкшәндең, сыwыҡ тидеме әллә?

**БӨЛГӘН** *перм.* к.: **айап 1.** Мендәрләр монда да күп, мич башында да бөлгән.

**БӨЛДӨРКӘ** *минз.* кулга кияр өчен себерке сабына беркетелгән элмәк (петля на кнутовище кнута).

**БӨЛДӨРМӘ** *байк.* к.: **бөлдөркә**.

**БӨЛӨК** *перм.* харап, эшләр харап (дела плохи, дела в плачевном состоянии). Аннан суң эш бөлөк, мондый калхузны күрсәтсәләр.

**БӨЛҮ** *перм.* пычрак, тәртипсез булу (быть грязным, неубранным). Безнең өй бөлгән, ҙудырасы бар, ҙийыштырасы бар. Өйләре бөлгәнме, пычрақмы? Безнең өй бөлгән, бөтен әрбир тышта, рәтләмәгән. Айаҡ бөлә.

**БӨР-БӨР** *минз., стрл.* к.: **баш-баш**.

**БӨРЕ** *тара.* ботак (ветка); чаг.: **саңаҡ**.

**БӨРЕЛМӘЛЕ** *тбл.* бөрмәле (сборчатый, со сборками). Бөрелмәле күлмәк.

**БӨРКӘНЧЕК 1.** *лш.* зур яулык (большого размера платок, которым покрывают лицо). Таза әле, ике тапҡыр өздөреп килеп китте, бөркәнчекләр йабынып; **2.** *әстр.* баш яулыгы (платок для покрытия головы).

**ҡуш бөркәнчек** *лш.* ике яулыкны кушып тегеп ясалған япма (покрывало из спаренных платков). Ҡуш бөркәнчекләр бөркәнеп килен төшәдер ийе.

**БӨРКӘҢГЕЧ** *бөре.* к.: **бөркәнчек 1.** Бөркәңгеч йаулыҡ белән битне күрсәтмәгәннәр, француз йаулыҡ.

**БӨРКӘҮ I** *мәл.* бөркү (душный). Пайыт астында да бөркәү, ат тирләгән.

**БӨРКӘҮ II** *лш.* лапас (навес).

**БӨРКӘҮ III 1.** *нгб.-крш., каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* япма (простыня, покрывало). Түшәген ҙәйеп, базар бөркәwен сала астына. – *нгб.-крш.* Элек үзебез суға торған ийек бөркәwен, шаршawын. – *т.кам.-крш.*; **2.** *т.кам.-крш.* чаршау (полог, занавес). Уникe аршыннан ыйы бөркәwe; **3.** *т.кам.-крш.* бөркәнчек (покрывало, которым покрывалась невеста при венчании). Ҡыйаматлыққа кертеп баш бәйләп, бөркәү бөркәп, кәбен ҡойдырып ҡайталар.

**баш бөркәwe** *т.кам.-крш.* к.: **бөркәү III, 3.** Ҙәш килен ҙилән кигән, аннары баш бөркәwe бөркәп ҡуйғаннар, кеҙеле, ҡызыл буладыр ыйы.

**тәрәзә бөркәwe** *нгб.-крш.* к.: **ҡорғоч 1.** Тәрәзә бөркәwен тарт. Тәрәзә бөркәwләрен әлдек.

**түшәк бөркәwe** *т.кам.-крш.* к.: **бөркәү III, 1.**

**БӨРКӘҮ IV** *твр.* төрү, биләү (завёртывать, закутывать). Баланы бөрким.

**БӨРКЕТҮ** *каз.ар.-крш.* өркетү, куркыту (пугать).

**БӨРКҮ** *перм.* чәчү (сеять). Шалҡан бөркү. Мәк бөрөктем ийе ыспайыға.

**БӨРЛӘ** *глз.* ирен, авыз (губа). Бөрлә читләре буйаған булса, керетмә kywартирға, ҡупшы булса. Бөрләләремне йыртҡанчы сywыра идем башлы шикәрне.

**БӨРЛӘНТИН** [*рус.* бриллиантин] *тпк., т.я.-крш.* мамык тукыманың бер төре, ситсы (один из видов хлопчатобумажной ткани, ситец); чаг.: **бөрләнтин**. Бөрләнтин тиләр ийе әwәле, пертөрлө сырлырақ ситсы. – *тпк.*

**БӨРЛӨГӘН I** *блт.* тырнак төбенә чыга торган

үлекле шеш (гнойный нарыв около ногтя). Тырнақ қырыйына бөрлөгән чыга, бөрлөгән чыққан, бөрлөгән имним диләр.

**БӨРЛӨГӘН II** *тара., твр.* кара бөрлегән (ежевика).

**дәңгәр бөрлөгән** *минз.* к.: **бөрлөгән II.**

**қара бөрлөгән** *бәр.* кара җиләк (черника).

**чыпчық бөрлөгәне** *минз.*, **чыпчык бөрлөгәне** *стрл.* к.: **байбай.**

**БӨРМӘ I** *кузн., лмб., твр., тара.* к.: **балан II: балан итәк.** Итәгендә бөрмәсе бар. – *твр.* Көйләкнеңке пилен пөрмә гылып печеп пирәделәр. – *тара.*

**БӨРМӘ II** *срг.* бәйләм (связка). Бер бөрмә нәркәмәс китердем.

**БӨРМӘ III** *дөб.* к.: **бәлеш: бәлеш бармагы.** Қайнатам әйтә, килен, бөрмәсе ундүрт кенә була, ди, шайарта.

**БӨРМӘ IV** *брб.д.* сыер тиресеннән тегелгән аяк киеме (обувь, сшитая из кожи коровы); чаг.: **қыйндырақ.**

**БӨРМӘКӘЙ I** *минз., стрл.* к.: **арган.** Минем әни гел сырлыйдыр ийе ойоқны, бөрмәкәй урынарын. – *минз.*

**БӨРМӘКӘЙ II** *минз., стрл.* эт эчәге (вьюнок полевой).

**БӨРМӘШКӘ** *төм.* бәби итәк (волан).

**БӨРМӘШКӘЛӘҮ** *төм.* бала итәк кую (пришивать волан). Ақтан тегәтләр иңбашларын бөрмәшкәләп тегә, сәленеп тораты.

**БӨРӨ** *бөре.* к.: **әкәлә 2.** Чыршы бөрәсе.

**БӨРӨМ** *минз., стрл.* бөрмә (складка, сборка). Элек күлмәкнең бөрөме йугарырак була бит. – *стрл.*

**БӨРӨШ** *дөб.* кое бозы чаба торган корал (инструмент для сколачивания льда).

**БӨРТЕК I** *баст., әҗе.* иген, ашлык (хлеб, хлеба). Бөртек алып баралар иде, саталар иде. – *баст.* Бөртекнең барын чәчәләр иде. – *әҗе.*

**БӨРТЕК II** *срг.* бик кечкенә (очень маленький); чаг.: **бетеки 1.** Бөртек малайлар да (тәмәке) тарта.

**БӨРТЕК-СЫРТЫҚ** *блт.* к.: **берәм-салам.**

**БӨРТӨК** *бөре., злт., тпк.* бер киләп озынлыгындагы җеп (моток пряжи). Бөртөк киләб агачы озонлыгында була, митыр йарым микән. Бер сawымда дүрт бөртөк була. – *бөре.* Суққан wахытта өс бөртөктән саныйбыd, киләпкә салғанда дүрт бөртөктән саныйбыd. – *тпк.*

**БӨРУ 1.** *тара.* оекны очлау, бетерү – оек бәйләгәндә (заканчивать чулок – при вязании). Йышымны бөрәм; **2.** *брб.д.* бәйләү, төреп бәйләү (завязывать, завёртывать, обвёртывать). Йаулыққа бөрөп қуйған, бөрөнчөктә йата китапмы, тywалыкмы.

**БӨРҮЛӘҮ** *тара.* ишек астарлау (обшивать дверь). Ишеккә тиреләр бәрәбес, бөрүлибес.

**БӨРЧӨКЛӘҮ** *трх.* к.: **бөрчү 1.** Киртәдә бәрәңге бөрчөклим.

**БӨРЧҮ 1.** *т.я., лш., минз., стрл.* бәрәңге борынын сындырып чистарту (очистить картофель от ростков). Кибеткә чықтым ыйы да, машина кешесе әйтте йе дә, бәрәңге кирәк, дип, бөрчемәгән әле. – *к.т.* Бәрәңге дә бөрчөмәйенче чығып китте, шау чабып җөри. – *минз.*; **2.** *т.я., лш., дөб.* чистарту, арчу – җиләк-җимешне (очистить – о ягодах). Җиләк бөрчеп утырам. Бөрчегәч, бер чиләк булды җыйған шомырты. Җиләкне чәйеңә бөрчеп сал. – *нрл.* Бөрчеп тутыра, ди, ул (тиен) чикләwекне. – *лш.* Шомыртны бөрчөп бетердеңме? – *дөб.*

**БӨСТӘР** *лш.* к.: **битйаулық.** Минем бөстәргә дә кереп сөрткәннәр.

**БӨТӘ 1.** *минз., нгб.-крш.* к.: **беткел.** Шул бер қойо бөтә, хәзер буwалар бар бугай инде. Берәү генә үлде буғай, бөтә исән чықтылар қышны. – *перм.* Бөтә мәндә сыйыр эзли. – *нгб.-крш.*; **2.** *минз., стрл.* к.: **беткелгесе.** Бөтә эчереп китәм. – *минз.*

**БӨТӘЙЕШҮ** *тбл.* к.: **бөтәшү II.**

**БӨТӘНЧӘЛИ** *т.кам.-крш.* бүтәнчә, башкача (иначе, по-другому). Бөтәнчәли әйтә алмим инде.

**БӨТӘСЕ** *злт.* к.: **беткелгесе.** Кийенешкәннәр дә бөтәсе дә қунаққа ғына йөриләр, ди.

**БӨТӘШҮ I** *перм.* к.: **бетенкерәү.** Залақай бик бөтәшкән, барып хәлен белмәгә кирәк.

**БӨТӘШҮ II** *тбл.* бөтенәю, төзәлү (исцеляться, поправляться). Йаралары бөтәшмәгән.

**БӨТӘҮ** *минз.* **1.** тоташтыру (соединить); **2.** бөтен яктан җитешле (обеспеченный всем, совершенный).

**бөтәү йату** *минз.* бикләнеп, бер дә чыкмый яту (сидеть запершись дома).

**БӨТЕН** *т.я.* тәңкә, бер сумлык көмеш акча (рубль, целковый, монета, достоинством в один рубль).

**бөтен тәңкә** *стрл.* тар тукыма кисәгенә бер сумлык көмеш тәңкәләр тезеп ясалган, муенга киелә торган бизәнү әйбере (старинное женское украшение из монет, нашитых на узкую материю, надевавшееся на шею).

**БӨТЕРКӘ** *кмшл.*, **БӨТЕРКЕ** *блт., т.я.* бөдрә (кудрявый). Кечтеки малайның безнең чәче бөтерке. – *блт.*

**БӨТИ I** *блт.* к.: **бөтү I, 2.** Бөтидән сырып пирдем бер җурган. Теге җақтагы җурган да бер җағы бөти, бер җагы сатин.

**БӨТИ II** *лш., к.т., тара.* к.: **путемар.** Бөти кийәләр ийе, аңарға челтәрле қашлы әйберләр, бөтөн тәңкәләр, илле тийеннекләр, ун тийеннекләр тезеп, шуны қыйқач кийеп қунаққа баралар ийе. – *к.т.* Алда бөтиләр – тәңкәле, артта чәчтәңкә буладыр ыйы қызларда. – *лш.* Бөти киң була, шау тәнкә була ул, қыйышлап полай кийәте, қатынқысыңққы шайы күп пулып элке. – *тара.*

**БӨТИ III 1.** *каз.ар.-крш.* бала итәк (оборка, пришиваемая к низу женского платья). Күлмәкләрне итәгенә бөтиләр салып китәрләр ийе; **2.** *минз., стрл.* итәктәге кештәк (ластовица на подоле).

**бөти салу** *каз.ар.-крш.* бала итәк салу (пришивать оборки).

**БӨТИ IV** *блт.* к.: кечкеник. Бөти wахытта тотсалар, дәwаласалар, алай азмас ийе ул.

**БӨТИЛЕ** *блт.* к.: **бөтүле.** Бөтиле җурган.

**БӨТИЛӘП** *каз.ар.-крш.* бала итәклән (с оборкой). Күлмәкләрне бөтиләп, итәгенә бөтиләр салып тегеп кийәрләр ийе.

**БӨТКЕЛГЕСЕ** *мәл.* к.: **беткелгесе**. Бөткелгесе дә таза тормышта йәшиләр.

**БӨТКӨЛ** *злт., мәл., кргл.* к.: **беткелгесе**; чаг.: **башала, башук**. Хәзер бөткөле эштә машиналарның. – *кргл.* Бөткөл сүзе шул былды. – *злт.* Үwенә керсәң, бөткөл нәрсәсе бар. – *мәл.*

**БӨТКӨЛГЕСЕ** *кргл.* к.: **беткелгесе**. Бөткөлгесенә дә сибимме, қыйарларға ғына сибимме?

**БӨТЛӨК** *перм.* к.: **беткел**. Бөтлөк қызлар мәңа қарый. Мәшкә бөтлөк җирдә бардырмы wы?

**БӨТӨК** *перм.* к.: **ат'акыш 1**. Мин үзем тужы бөтөк булдым, бернәмә дә белмәдем.

**БӨТӨРӘ 1**. *тбл., төм.* бөтенләй (полностью); чаг.: **беткел**. Тарихларны бөтөрә беләме? – *тбл.* Инте бөтөрә йонцотом. – *төм.*; **2**. *төм.* к.: **беткелгесе**. Ғартымнықы гөйләкләре торат ите, өләштек пөтөрә.

**БӨТӨРЧӨК** *мам.* май яза торган кечкенә таяк (маленькая мутовка для маслобойки). Табақта йазған майнықы ғына бөтөрчөк була, гөбө тайағы зур була.

**БӨТҮ I 1**. *кузн., хвл., лмб., бөре., минз., злт., перм., тара.* к.: **бетек**. Баш сызлағаңға бөтү тағадыр ыйық. Өчпочмақлысы бөтү була, аны чәч төбенә үрәсең. – *бөре.* Ике бөтүне түшәг астына куйган. – *лмб.* Бөтү өчпочмақлы, бийек элеп қуйалар, доғалар йазып тығып, бала йыламасын өчөн. – *тара.*; **2**. *бөре.* өчпочмаклы тукыма кисәкләреннән җыелган корама юрган тышлыгы, япма (лоскутное покрывало, верх одеяла).

**БӨТҮ II** *срг.* к.: **буйынса 1**. Бөтүwенне каладанмы алдың? Нәймә бөтү элми, часы элми.

**БӨТҮ III** *әчк.* зур бәлеш, ләкин ит бәлеше түгел (большой пирог, но не с мясом). Йеләк бөтүwен йаратамсын, улым?

**БӨТҮ IV: мич бөтү** *перм.* мичнең янып бетүе (истопиться – о печи). Мичкә йаққан, мич бөтә.

**БӨТҮК** *перм.* к.: **беткелгесе**. Дүрт балам бар ыйы, бөтүк үлеп беттеләр.

**БӨТҮЛЕ** *бөре.* корамадан җыелган, корамалы (лоскутный). Бөтүле йурған.

**БӨХИЛ** *дөб.* к.: **мыжым**.

**БРАЗДАЛАУ** [*рус.* борозда + *афф.* -лау] *кузн.* бәрәңге төбенә өю (окучивать картофель). Алманы браздалыйбыз, йәш утны т'апкалыйбыз, бийегәйгәч, кул белән (утыйбыз).

**БРАМАТЛАУ** *лш.* аз-маз сөйләшә белү; берәр нәрсәне эшли белү, маташтыру (на каком-либо языке кое-как разговаривать; немного уметь что-либо делать). Татарча браматлый берсе.

**БРАМАТЛЫҚ** *минз.* эшләмичә ялкауланып йөрү, ялкаулык (леность, лень). Браматлық йахшы нәрсә түгел.

**БРАН** [*рус.* пароm] *нгб.-крш.* к.: **борам**. Ағыйделне чыққан ыйық без бран белән.

**БРАТ** [*рус.*] *хвл., кузн., м.-кар.* **1**. ир кардәш, ир туган (брат вообще); **2**. эне (младший брат). Братлары кунакка килгән. – *хвл.* Мине братым кәзер бетте, элгәре укыды урыс'с'а. Минем картымы атасын браты иде ул. – *м.-кар.*

**БРӘЗГӘ** [*рус.* брюзга] *блт.* **1**. җирәнүчән (брезгливый). Мин бик брәзгә бит; **2**. вакчыл (мелочной, мелочный). Эчкән кеше брәзгәле була бит ул.

**БРӘЗГӘЛӘҮ** [*рус.* брюзга + *афф.* -лӛү] *мам.* көйсезләнү, тынычсызлану (капризничать). Йоқосы килә, шуңа брәзгәли.

**б у** (этот, эта, та, это):

**бу әсәрен** *тара.* бу арада (сейчас, в эти дни, на днях). Бу әсәрен хат йуқ пулып китте.

**БРОМ, БРОН, БРУМ** [*рус.* пароm] *блт.* к.: **борам**. Элек Изелне брум белән чығайық.

**БУБАЙКА** *төм.* к.: **сырмыш**. Эштә бубайка гейеп йөрөйтләр.

**БУБЧА** [*рус.* вовсе] *перм.* гомумән (вообще). Җавып-җавып җыйды қый, бупча су беле қапланды безнең чуқ (урам).

**БУБЫЙ I** *нокр.* җитен түбе (выжимки из льняных семян). Шишара күмәч бешердек ипи йуқта бубыйдан.

**БУБЫЙ II: бубый тырмақ** *тара.* атсыз бармак (безымянный палец).

**БУW: кул бувы** *чст.-крш.* беләзек (браслет). Алтышар мыскаллы йы беләзекләребез, уникешәр тәңкәле йе кул бувларыбыз.

**б у w а** *срг., хвл.* буа (пруд):

**бувa җатувы** *минз., стрл.* к.: **типкен**. Бувa җатувы килә.

**бувa тыту** *срг.* к.: **бийәләү**. Инештә бувa тыттылар.

**БУWАЗЛАНУ** *срг.* буынга утыру, буынтыкланy (появление суставов, сегментация – у растений). Арыш бувазланган.

**БУWАК** *миш.д.* иртәнге ак томан (утренний туман). Тастымал тактым куакка, Иртә тудым бувакта; Бирдең, атай, йыракка, Килә алмамын кунакка (*хал. жыр.*).

**БУWАҚ I** *тбл.* ияк асты (подбородок).

**БУWАҚ II** *тбл., брб.д.* бер уч, урак урганда кулга алына торган бәйләм (горсть; пучок стеблей, который хватают рукой при жатве).

**БУWАКЛАНУ** *срг.* тирләү, ак күбеккә бату (вспотеть – о лошади). Цаптыра килеп бувакланган алашаның эце.

**БУWАЛА** *тара.* к.: **буғалақ**.

**БУWАЛМА** *чпр.* к.: **багалма 1**. Бувалма лаукага килгән. Цөцө бувалма, ацы тегел.

**БУWАМ 1**. *перм., злт.* к.: **бума I**. Безнең awылда йеде-сигез бувам. – *злт.* Мычала бувам ғына бар бездә. Бувамда балчық үwелгән дә, өстенә үлән чыққан. Бувамны бувалар да суға төшәләр; **2**. *перм.* балык тоту өчен бер урынын ачык калдырып, суда чыбыктан киртә тоту (запруда – для ловли рыбы). Бувам йасыйлар ылыстан бәйләп, шунда.

**БУWАНАҚ** *т.кам.-крш.* куян аулау өчен тимерчыбыктан ясалган элмәк сыман тозак, капкын (капкан для ловли зайцев). Урманға барып, қуйаннарға буанақ салып қайттым әле.

**БУWАУ** *минз., стрл., чпр., хвл.* к.: **бийәләү**. Зур булып җәелгән ийе бувагачтын. – *минз.* Иделне бувадык. Суны бувaганнар. – *хвл.* Терлекләргә була бувaган инде йылганы. – *стрл.*

**БУWЫЛУ** *срг.* асылыну (повеситься, удавиться). Бу быратым бувылып үлде.

**б у w ы н I** (сустав; узел – у растений):

**бувын қылу** *дөб.* к.: **буазлану**.

**БУWЫН II** *брб.д.* к.: **ашық II, 2.**

**буwынға төшү** *минз.* ач торганнан соң берьюлы күп ашагач буыннарның хәлсезләнеп калуы (ослабление суставов после приёма пищи враз на голодный желудок). Кинәт кенә ашасаң, буwынға төшәр дидек.

**буwынсыз булып көлү** *перм., стрл.* көлә-көлә эч кату (надорвать живот от смеха). Буwынсыз булып китә инде көләп қыз. – *перм.* Тегеләр буwынсыз булдылар көлеп. – *стрл.*

**БУWЫННАУ** *мәл., чст.* еккан агачны өлешләргә кискәләү (распиливать срубленное дерево на части). Кисәсең урталай, менә шул буwыннау. – *мәл.*

**БУWЫРТУ** *трх., злт.* бик нык таләп итү, таптыру (требовать, спросить, зажав в угол). Кем йанына кергән дип буwыртқан. – *трх.* Йә шул буwыртасың, ақса кирәк икән. – *злт.*

**БУҒА** *дөб., том.д.* к.: **боға**. Буға кебек йегет. – *дөб.*

**БУГАWАЙ** [*рус.* пуховый] *твр.* мамык шәл (пуховая шаль). Бугawай шәл алтым.

**БУҒАЗ** *дөб.* базед авыруы, зоб (зоб). Элек аның бугаз булган, йәш чағында йасау (операция) булмаган инде.

**БУҒАЗЛАУ** *мам.* ерткыч хайванның терлекләрне бугазын чәйнәп үтерүе (убить, перегрызя горло). Сарыкларын рәттән буғазлап чыққан бүре.

**БУГАЗЛАУ** *карс.* сую (резать, зарезать). Казлар йыл да тытабыз, былтыр сигезне бугазладык.

**БУҒАЙ** *нгб.-крш.* печелмәгән үгез (некастрированный бык). Малайым мийа буғай биреп жибәрде.

**БУҒАЛАҚ** *минз.*, **БУГАЛАК** *стрл.* кыргый атларны тота торган элмәкле аркан (аркан с петлёй, предназначенный для ловли диких лошадей).

**БУҒАН** *эчк.* үрдәкнең бер төре (чернь – одна из разновидностей утки).

**БУҒАНА** *тара.* хәйләкәр (хитрый).

**БУҒАРДАҚ** *лш.* терлек муенына сала торган элмәкле бау (верёвка с петлёй, ошейником); чаг.: **муйынчык**.

**БУҒАУ** *тбл.* богау (колодка, окова).

**БУГРИП** [*рус.* погреб] *минз., төм.* к.: **нәүрәп**. Бугрип бар ыйы, бугрипкә төшөреп қуйа. – *төм.*

**БУҒУ** *тара.* бугаз (горло). Буғусуна қылысын салған.

**БУҒЫРТАҚ** *тара.* бугаз (горло). Бугыртақлары қыйшайып цықты қасларның, туйдылар.

**БУДЫМСАҚ** *әстр.* жир грушасы (топинамбур, земляная груша).

**БУД(Ы)РА** [*рус.* бурда] *дөб., лш., мам.* **1.** бәрәңге пешергән суның куесы, пешкәндә изелгән бәрәңге (часть картошки, разварившаяся и осевшая на дно посуды). Бәрәңгенең будрасы ич, маллар эчә аны. – *дөб.* Бәрәңге будырасын чыгарып бир эткә, ипи сал да. – *лш.*; **2.** юынтык суның куесы (осадок в помойной воде); **3.** кайнаган суның төбенә утырган юшкын, утырым (осадок воды, осевший на дно посуды). Графинада қайнаған суның будырасы ғына. – *лш.*; **4.** ачыган балның төбенә утырган куесы (осадок браги).

**БУДЫРАЛАНУ** *блт., дөб., лш.* болганчыклану, болганып куеру (стать мутным, мутнеть). Чишмәнең суы будыраланган, бала-чага болғатқандыр. – *блт.*

**БУДЫРАЛЫ** *блт., дөб., мам.* болганчык, куе (мутный); чаг.: **қуйырық 3.** Будыралы су. – *блт.* Суға он да сал әз генә, будыралырақ булсын. – *мам.*

**БУДЫРҒЫЧ** *мам.* к.: **будырма**.

**БУДЫРМА** *каз.ар.* оек төшмәсен өчен аякны будырып куя торган сузылмалы резин тасма (круглые резинки для чулок). Ойоқ будырмасы инде бу.

**БУЖАЛ** *байк.* к.: **божал**. Буҗал куйалар, wакыт куйалар.

**БУЖАН** *каз.ар.-крш.* коңгыз (жук). Бужан оча.

**БУЗ** *нрл.* к.: **боз I**. Безнең этинең буз ийе бүреге.

**БУЗА 1.** *тмн., м.-кар.* өй сырасы (домашнее пиво). Иртәсе көнне кийәү ырулары килә, йәш килен буза йөртә. – *тмн.*; **2.** *эчк.* к.: **керчемә**; **3.** *нокр.* куас (квас); **4.** *тбл.* ясмыктан ясалган эчемлек (питьё из ячменя).

**БУЗАН I** *чст.* к.: **байбай**.

**БУЗАН II** *трбс.* к.: **бусан 1**.

**БУЗАРА** *перм.* ләтчә (ласка).

**БУЗАРУ 1.** *блт., кргл., бгрс.* аксыл төскә керү (побелеть, белеть). Бузара башлагач, жыйнарбыз памидурны. – *блт.* Бер жиләге қалмаган сабағында, қойолып беткән, бузарғаннары ғына қалған. – *кргл.*; **2.** *т.я., перм.* комсу төскә керү (приобрести сероватый оттенок). Йуған керләрем бер дә ағармаған, тик бузарган ғына. – *к.т.*

**БУЗАРЫНУ** *дөб., лш.* ачудан кызарынып бүртенү (надуться, раскраснеться от злобы). Дәшми, сөйләшми, бузарынып утыра. – *лш.*

**БУЗҒУ** *тбл.* бетерү, туздыру (уничтожение).

**БУЗҒУЛАУ** *тбл.* бозылу (испортиться).

**БУЗИНА** [*рус.*] *кузн.* к.: **байбай**.

**БУЗЛАУ** *әстр.* елау (плакать, оплакивать). Қыз чығып киткәндә, анайлары бузлап қалады.

**БУЙ** *хвл., мәл., стрл., глз., минз., т.кам.-крш., тара.* к.: **бексәм**. Кыска буйлы күлмәк. Күлмәгемнең буйы озынрак булган. – *хвл.* Күлмәкнең буйы кыска. – *мәл.* Элек кыска буйлы иде, буйлы күлмәк тегәләр иде, бөрмәле. – *стрл.* Күлмәкне буйлы итеп тә тегилир. Буй гына ул, күлмәк түгел. – *глз.* Мин берне тектем итәкле алжапқыч, итәк белән буй арасы чигүле йе. Челтәр берсе итәктә, берсе буйда йы. – *т.кам.-крш.*

**буй тору** *бгрс.* жаена тору (делать в лад комулибо). Wәжеттин йезнәсенә буй тора ул, түтәсе хақына.

**БУЙАК I** *хвл., клд., шрл.*, **БУЙАҚ** *әстр.* буяу (краска). Сары буйак йетәме? Идән астында бер банкы буйак бар иде, шыны чыгар әле. Кас'акларын буйагыбыз кели ак буйакка. – *хвл.* Куполлары әмән алтын төсле, буйаклары йалтырап тора. – *клд.* Үләре дә буйақсыз. – *әстр.*

**БУЙАК II** *кузн.* ...дан бирле (с); чаг.: **биртен**. Берничә айдан буйак күргәнем йук Сәйфулланы.

**БУЙАКЧЫ** *лмб.* буяучы (тот, кто красит).

Аппак диләр, бик мактыйлар Буйакчының буйавын (*хал. җыр.*).

**БУЙАУ I** *нрл.* кара (чернила). Ручканың буйавы җук бит.

**БУЙАУ II** *перм.* ягу (мазать). Эпине майга буйап бирсәң, ашый. Қаймақны буйадылар да урталый бүлеп бирделәр, қыз белән җегет бер-берсенә май шикелле тора дип.

**БУЙ-БУЙДАҚ** *минз.* 1. к.: **бер: бер буйдан.** Су буй-буйдақтан ага да аға; 2. буш кул белән (с пустыми руками). Килеп чықтым әле үзеңе сағынып буй-буйдақ қына; 3. бушка, юкка (впустую, вхолостую, зря). Буй-буйдақ бардым, әллә ничә бардым.

**БУЙ-БУЙДАҚҚА** *минз.* к.: **буй-буйдақ 3.**

**БУЙҒАТ** *твр.* к.: **awыр II.**

**БУЙДАҒАҚ** *минз.* к.: **бер: бер буйдан.** Буйдагақ шулай булды инде ул кеше. Буйдағақ шулай килә тормош.

**БУЙДАҚ I** 1. *блт., каз.ар.-крш.* җәяүле (пеший, пешеход). Рашкиға (*ав.ис.*) буйдақ қына бардым; 2. *кргл., бгрс.* ялчы (наёмник, наёмный).

**БУЙДАҚ II** 1. *трх., минз., кргл., тпк.* ялгыз, бала-чагасыз ир яки хатын кыз (одинокий мужчина или женщина, не имеющие детей); 2. *трх., минз., стрл.* бала тапмаган хатын-кыз (женщина, не рожавшая детей); 3. *твр.* тол хатын (вдова); 4. *нгб.-крш.* к.: **башмақ I, 1.** Танақай бозаулама-са, җәйгә чықдисә буйдақ диләр.

**буйдақ башы** *минз.* к. **буйдақ I, 1.**

**БУЙДАҚ III** *перм.* к.: **үзбуйдақ.** (Буйдақ ул) – үзе белдегенәрәк йөрүче кешене әйтәләр, тыйуға килми андый кеше, үз буйлыларына эшләгән булып йөриләр, тәртипсезрәк кеше; кеше сүзен сүз итми, үз сүзен генә сүз итеп йөри ул.

**БУЙДАҚ IV** *минз.* даими, һәрвакыт була торган (постоянно); чаг.: **айлыкчыда.** Буйдақ эшкә кергән. Сыйыр савучыларның буйдақ эшләп торған эш бит инде.

**БУЙДАК I** 1. *карс., стрл., әҗе.* к.: **буйдақ I, 1**; 2. *стрл.* к.: **буйдақ II, 2.**

**БУЙДАК II** *стрл.* к.: **үзбуйдақ.**

**БУЙДАҚЛЫҚ** *кргл., бгрс.* ялчылык (быть наёмником, наёмным рабочим). Бабасы да, үзе дә буйдақлықта җөргәннәр. – *кргл.*

**БУЙДАҚ-ТАЙЛАҚ** *нрл.* эшлексез, эш яратмаган кеше, ялкау (бездельник, ленивый, лентяй).

**БУЙДЫМАР** *каз.ар.-крш.* к.: **путемар.** Буйдымар киделәр кичкуйынға чыққанда. Буйдымарны элек кигәннәр, қәзер җук.

**БУЙКА** [*рус.* бойкий] 1. *лш.* иркә, назлы, узындырылган (избалованный). Буйка үсте инде ул, эшләмичә; 2. *м.-кар.* кыю, үткен (бойкий). Буйка катыннар айгырга да тезенәтләр.

**БУЙКЫЗ** *миш.д.* җиткән кыз (девушка на выданье). Берсе буйкыз инде, улыбызныкы кыз. – *лмб.*

**БУЙЛАМА** *перм.* к.: **басмача 2.** Буйлама да бар аржаққа чыға торған.

**БУЙЛАТА** *лмб.* 1. к.: **сартын.** Синең буйлата аны кын'адым этә. Атасы буйлата багам. Минем эшем буйлата килде. Минем этием буйлата инде; 2. буенча (по). Сүләве буйлата белдем.

**БУЙЛАУ I** 1. *бөре., минз., перм.* ат тотучыга буйсынмыйча, атның юлдан читкә чыгып, башын иеп чабып китүе турында (понести, мчаться, не слушаясь управления – о лошадях). Атым буйлады. – *бөре.* Буйлаган атқа лутчы күп тағалар (сөлге). Аты буйлағанға ачуы килмәсә. – *минз.* Тегеләй, җиңел сүwәкле ат ул, буйламады да. – *перм.*; 2. *тбл.* әлдереп алып китү – ат турында (понести). Мине ат буйлап алып китте; 3. *перм.* утның учактан чыгып икенче бернәрсәгә үрләве, кабуы турында (о пламени, которое, растянувшись из костра, охватывает какие-либо вещи). Йоқлап киткәнем дә, учағым буйлап җатқан; 4. *минз.* к.: **адаландыру.** Қыd җегетне буйлаб алды.

**БУЙЛАУ II** *перм.* һаман бер гадәтне куу, дәвам иттерү (продолжать, входить в привычку, становиться привычным). Буйлады да буйлады шы көwә. Буйлый тип ақча бирмәгә қурқам. Шуңа буйлаган инде, бер ашамағач ашамасқа.

**БУЙЛЫ I** *дөб., блт., тара., брб.д.* к.: **awыр II.** Буйлы хатыннарға минем эшкә әйткәнем җук. – *дөб.* Буйлы киленем. – *тара.*

**БУЙЛЫ II** *мәл.* к.: **бер: бер буйдан.**

**тем буйлы** *м.-кар.* к.: **алып: төн алып.** Тем буйлы йокламыйлар.

**БУЙЛЫЙ** 1. *чст., мәл.* бертоташтан, бертуктаусыз, өзлексез (постоянно, беспрестанно). Буйлый йата торган ғына булмаса йарар ийе. Бер дә салмый ки, буйлый ки. – *мәл.*; 2. *трх.* к.: **бер: бер буйдан.** Буйлый ничә киламитыр җәйәү бардың?

**БУЙМА I** [угор.] *тбл.* к.: **пима 1.** Буйма басқаннар.

**БУЙМА II** *тбл., тара.* басым, бума (давление, удушье).

**БУЙМАБУЙ** *минз., стрл.* к.: **бер: бер буйдан.** Буймабуй җаңгыр. – *стрл.*

**БУЙТАЙАҚ** *твр.* карчыганың бер төре (один из видов ястреба). Буйтайақтай қуш бөлып булутны үргә сүрмәсәм.

**БУЙЫ: буйы белән** *перм.* к.: **буйлый.** Буйы белән көн дә шунда ничек йөрмәгә кәрәк?

**БУЙЫЛ** *глз.* к.: **быйыл.**

**БУЙЫН** *перм.* к.: **бун'.**

**буйын сону** *тара.* буйсыну (покоряться, повиноваться). Буйын сонмаған әле.

**буйын тәңкә** *перм.* к.: **гылбу 1.**

**буйыңа сеңдер** *брб.д.* тәнеңә сеңдер, аш булсын (на здоровье – пожелание во время еды).

**БУЙЫНА** *перм.* к.: **бер: бер буйдан.** Буйына ыскотник булдым қышын.

**БУЙЫНСА** *перм.* 1. к.: **гылбу 1.** Ал буйынса, гөл буйынса, Безнең буйында булса (*хал. җыр.*); 2. к.: **путемар.** Буйынсаларны әбиләр кийәләр ий.

**БУЙЫНЧАК** *мәл.* муенчак (ошейник).

**БУКА** [*рус.* бок] *срг.* 1. к.: **йамбыз.** Букам awырта; 2. к.: **йага I, 1.** Буртawай машина букасы.

**БУҚМА** *тбл.* ит бөккәне (пирог с мясом).

**БУКЫН** [*рус.* буханка] *м.-кар.* бер кирпеч – ипи турында (буханка). Икешәр букын бирәләр икмәк.

**БУЛ I** *перм., брб.д.* бу (это, эта, этот). Бул чақта пашлыры палниста. – *брб.д.*

**БУЛ II** *тара.* тәгәрмәч бүкәне (втулка у колеса).

**БУЛА** *хвл., чпр., т.я., яүшт.* аркасында, сәбәпле, өчен (ради, из-за, по причине); чаг.: **сартын**. Ыланына була ват ул килә йөзлеп-йөзлеп. – *хвл.* Сиңа була тордым. – *чпр.* Күптән китә ийем, сиңа була тордым. – *т.я.* Қайнинәсенә килә бақцаларына була. – *яүшт.*

**БУЛАТА** [*рус.* болото] *т.я.* пычрак (грязный). Бәрәңгеләре булата көйә қайта. – *трх.*

**БУЛАФКЫ** [*рус.* булавка] *каз.ар.-крш.* булавка кебек каптырыла торган бизәнү әйбере, брошка (женское украшение типа брошки). Үзе булафкы кебек қаптырыла, башында чылбыры бар.

**БУЛАШУ** *перм.* тырышу (стараться). Артаба булаштым, булаштым, берсе дә үрәнмәделәр. Чығарға булаша йы, чығармыйлар әле.

**БУЛҒАН** *тара.* **1.** җитлеккән, өлгергән (созревший); **2.** булдыклы, уңган (дельный, ловкий).

**БУЛҒЫЛЫ** *трбс.* булырдай, булырлык (возможный, осуществимый). Булғылы булса, бар диләр, булғылы булмаса, йуқ диләр.

**БУЛГЫСЫЗ** *лмб., хвл.* булдыксыз (бестолковый, неприспособленный); чаг.: **ат'акыш**. Бек булгысыз катын ул. – *лмб.* Алар симйалары белән булгысыз. – *хвл.*

**БУЛҒЫЛТАУ** *тбл.* селкенү (качаться, колебаться).

**БУЛГЫЧ** *кузн.* к.: **булдач**.

**БУЛДАКЧЫ** *чст., шрл.* к.: **булдач**. Кийәү булдакчы кешебез армийәгә китте. Әллә кийәү булдакчысы алып калдыргандыр? Шул кайнана булдакчысы бәрәңгене сызып кына калдыра йы. – *чст.* Бер килен булдакчысы йәш килен йанында йөри. – *шрл.*

**БУЛДАЦ(Ы)** *чпр.* к.: **булдач**. Әби булдацы әтә, себерке китердегезме, дир. Кайене булдац килде дә, нәстә белән барасыз, дир. Килен, булдацны апкерегез, дир. Әби булдацы әтеп тыра.

**БУЛДАЧ** *кузн., хвл., чст., чпр., шрл., трх.* тиеш(ле), булган (тот, кто приходится кем кому, приходяшийся кем кому). Ул бит безнең җиңги булдач кешебез. Кийәү булдач кешесе шуфирлыкка китмә кели, дий. Кайнана булдачлары да килгән булган. Бусы инде әти булдачларыдыр. Кийәү булдачың әллә качан үләнгән, тырмаган сине көтеп. Кайна булдач ни атлы? – *чст.* Кайна булдач алып килә оногын. Кода булдач, кодагый булдач, йә үзе бара каниш эвенүк. – *хвл.* Кийәүнең апа булдачларында чәй эчтем ийе. – *чпр.* Тегесе қайнана булдач. – *трх.*

**БУЛДАЧЫ** *т.я., мәл.* к.: **булдач**. Минем сеңел булдачы кеше савит министрыфқа бирә. – *трх.* Машина белән кат'кан кыда булдачыбыз. – *мәл.*

**БУЛДЫРУ** *мам.* талкырлык хәлгә җиткерү (довести до готовности, чтобы мять – обычно о стебле льна). Җитенне суға салып булдырасың, алалар да киптерәләр аннан ары.

**БУЛДЫРЫҚЛЫ** *трбс.* булдыклы (способный, дельный). Булдырықлы йегет.

**БУЛЖАЛ** *стрл.* к.: **божал**. Киткән кыздан китмәгән кызның булжалы кыска.

**БУЛ'И** *чст.* к.: **буйлый 1**. Бул'и кыр капка саклыйм.

**БУЛИWEC** *кас.* биләүсә (длинный и узкий свивальник, которым обвивают ребёнка поверх пелёнок).

**БУЛМАЧА** *лш.*, **БУЛМАЧЫ** *каз.ар.-крш.* к.: **булгысыз**. Булмачарақ қатыннарны ачулана икән, алты ғына көлтә урған, дип. – *лш.* Булмачы кеше. – *каз.ар.-крш.*

**БУЛУ I** *тмн., лмб., хвл.* җитү, җитәрлек булу (быть достаточным). Икмәк шыл буламы, тағы ашыйсызмы? – *тмн.* Сүләдем, булды инде. Эчкеләре келәсә, бар да булыр иде. – *лмб.* Булыр инде, күп сүләмә. – *хвл.*

**буламы утырып** *минз.* узып баручы кешенең урамда утырып торучылар белән исәнләшеп, әңгәшеп китү сүзе (форма приветствия проходящего к сидящим на улице знакомым).

**БУЛУ II** *лш., каз.ар.-крш., трх., минз.* җитен яки киндер сабагының талкырлык булып җитешүе (становиться готовым, чтобы мять – обычно о стебле льна или конопли); чаг.: **булдыру**. Басаны җиргә җәйәдер ийең дә ул буладыр ыйы, йаңғырда йатқач. – *лш.*

**БУЛЦАУ** *тбл.* срок билгеләү (назначить срок). Туй булцатық титләр, сырогын билгеләдек титләр.

**БУЛЧАУ** *тбл., тара.* чамалау (предполагать, расчитывать).

**БУЛЫҒУ 1**. *т.я.*, **БУЛЫГУ** *чст.* буылу, тончыгу (задохнуться). Awызыма-борыныма су кереп, булыға җаздым. – *к.т.* Пугрәпкә тешсәң, булыгасың, тының бетә. – *чст.*; **2**. *дөб.* тар күңеллелек күрсәтү, ярдәмчел булмау (быть завистливым, жадным, нетерпимым). Кеше кергәч тә булықмаған безнең әни, кечкенә өй булса да.

**БУЛЫҚТЫРУ** *т.я.* тончыктыру (душить, заставить задохнуться). Җилгә қаршы барып булмый, булықтыра.

**БУЛЫШ I 1**. *чст.* булышлык, ярдәм (помощь, содействие). Әле сөйенсеннәр, үзебез булыш сорамадык; **2**. *каз.ар.-крш.* ярдәм, өмә (помочь, помощь, подмога). Қул была эшләр ийе элекке, бөтөн җәшләр булышқа килер ийе.

**БУЛЫШ II** *кргл.* к.: **аулагаш**. Булышлар йасыйлар иде, қызлар, йегетләр җыйылып уйнаған була.

**булыш җырлары** *чст.-крш.* **1**. аулак өйдә җырлана торган җырлар (песни, которые поют на посиделках); **2**. туй җырлары (свадебные песни). Булыш җырлары кара-каршы җырлана, кызны алып киткәндә.

**БУЛЫШЛЫ** *чст.-крш.* зурлап, җиренә җиткереп барлык туганнар катнашында үткәрелгән туй (свадьба, проведённая с участием всех родственников, с почестями). Пирбый, кызны килешкәч, булышлы җасарга келиләр, ул бик зур туй була инде.

**БУЛЫШЛЫЙ: булышлый бару** *тмн.* кыз өендә туй буласы көнне авыл ирләренең, берәр икмәк кыстырып, егет өенә буза эчәргә бару гадәте (один из свадебных обычаев: мужчины-односельчане в день свадьбы, проводимой в доме родителей невесты, идут с караваем хлеба в дом родителей жениха пить домашнее пиво – бузу).

**БУМА I** *лмб., кузн., хвл., чст., шрл., стрл., кас.,*

*злт., эчк.* буа (пруд). Буманы күргәнең йукмы? Ан'а урталыкта, терлекләр төшә анда. Зур бума будылар. – *хвл.* Казлар бумага китте. Бума тытсаң да, су тытылмый. Агын су безнеке, бума бywабыз. – *кузн.* Бума йасыйлар йылгада. – *лмб.* Анда элек бума буылган иде. Кичә, бөген бума бywалар. Әле бума тытмаган. Кайа су керергә урман буйындагы бумагамы бардыгыз? – *чст.* Көн туса, бума өсте туп-тулы каз-үрдәк була. Бумага су кыйынырга киттеләр. Бул'дозир бума бywарга китте. – *шрл.* Шәб йаңгыр йауды да буманы йебәрде. – *стрл.* Бума тоталар. – *кас.* Бума бywалар. – *злт.*

**БУМА II** *т.я.* к.: **будырма**. Бумаларым бумаған, ойоғом төшә.

**БУМА III** *бгрс., кргл.* мамык шәлнең читен уртасыннан һәм читнең телләреннән аерып торган күзләр рәте (ряд открытых петель на краю пухового платка, разделяющий кайму от середины и гребешка).

**БУМА IV** *срг.* эпилепсия. Быратының бума шикелле цире бар.

**БУМАГА** [*рус.* бумага] *м.-кар.* киҗе (хлопчатобумажная нитка).

**БУН'** *миш.д.* муен (шея). Бун'нарына такканнар мәрҗәннәр. – *хвл.* Бун'нары да бегелми. – *лмб.* Бун'га асылына. – *мәл.* Бун'ына атландырма, дир. – *срг.* Сары атым, сары буйы, Йиз камыты бун'ында. – *влгг.*

**БУНАҚ-БУНАҚ** *кргл., бгрс.* буын-буын (сегментами, как бы перетянутое чем-то). Бунақ-бунақ киселеп тора ботлары (баланың), хәзер дә дастуй. – *кргл.*

**БУНАУ 1.** *лш., перм., эчк.* үсеп утырган агачның кайрысын төшерү, урыны-урыны белән тунау (снять кору с дерева, ободрать местами). Ағачны бунап қоротқаннар. – *перм.* Ағацны бунап төшердем. – *эчк.*; **2.** *хвл.* еккан агачның ботакларын чабып, аны аерым өлешләргә кискәләү (очищать срубленное дерево от веток, сучков и распиливать его на части); **3.** *кмшл., хвл.* агач кәүсәсен ботакларыннан арындыру (очищать ствол дерева от сучьев). Буныйлар, пычкы белән кисәләр, болар алып торалар. Имәнне бунамый торогыз, пыткларын бик калын. – *хвл.*

**БУН'СА** *чст.* к.: **муйынча 1.**

**БУНТ** [*рус.* бунт] *блт.* печән кибәне (стог сена). Ике көн салған чүмәләләр қызмаса, бунтта низашту қызмый.

**БУПЧА** [*рус.* вообще] *перм.*, **БУПЧИ** *минз., перм., бәр.* к.: **башала 1.** Бупча рәхәт күрмәдем. – *перм.* Бупчи лампы булмаған, чыра белә җеп җерләгәлләр. – *бәр.*

**БУР I** [*рус.* вор] *каз.ар., т.я., минз., бөре., кргл., бгрс., кмшл., эчк., нгб.-крш., шрл.* карак (вор). Бур үзенә кирәген ала, ут барсын да қырып себерә. – *мам.* Қарақныкын бур урлый (*әйтем*). – *кмшл.* Бурдан кала, уттан калмый. – *шрл.*

**БУР II** *каз.ар., нгб.-крш., тбл.* акбур (мел).

**БУР III: бур булу** *тпк.* симерү, юанаю (жиреть, полнеть, тучнеть); чаг.: **бохолдату**. Симереп, бур булып китте шул, күтәрергә дә awыр.

***бура I*** (сруб):

**бала бура** *чст.* нигез баганалары арасына эшләнгән бура (сруб, сделанный между фундаментными стойками). Бала бура бурадылар ызбаны күтәрер эчен, ату ызбабыз тәбәнәк була иде.

**қара бура** *трх., нрл.*, **кара бура** *мәл.* **1.** к.: **бала бура**. Қара бура салалар ике тумран арасына, пирwый шулай сала башлыйлар нигезне. – *трх.* Думбылар арасына ағачтан қара бура ике рәт имәннән тезелә. – *нрл.* Кездән үк кара бураны туфрак белән каплаган идем, алай да идәннәр салкын булды. – *мәл.*; **2.** *минз.* идән асты базына эшләнгән бура (подпольный сруб). Диңгеd белән қара бура арасына балчық төйөлә сuwық кермәскә.

**БУРА II** *перм.* чардуган (решётка на могиле). Минең ызба озонныгыйы бурасы зийәрәттә.

**бура тайақ** *т.я.* юан таяк (толстая палка). Бура тайақ белән қыйнаған атны. – *к.т.*

**БУРА III** *әстр.* дөя (верблюд).

**БУР'А** [*рус.*] *тмн., лмб.* давыл, өермәле җил (буря, ураган). Бик бур'а иде, сарайларны кайырмадымы? Бур'а бурый, бур'а бурый, Ак келәтләрне сылыйдыр (*хал. җыр.*). – *тмн.* Булса иде бур'а, чил awыл йандра иде. – *лмб.*

**БУРАБЗАР** *дөб., блт., минз., стрл.* к.: **абзар 1.** Бүген бурабзарның тәрәзәсеннән җил өрә. – *дөб.* Былтыр көз бурабзар эшләттеләр. – *блт.* Безнең ана бурабзар инде, йылы, түшәме бар. – *минз.*

**БУРАЗДА** [*рус.* борозда] *кузн.* ызан (межа); чаг.: **буразна**.

**БУРАЗНА** [*рус.* борозда] *трх.* ике җир арасы, чик (межа, граница между участками, полями). Буразна ике җирнең арасы, син дә чәчмисең, мин дә чәчмим, суқа белән суқаланған инде ул.

**БУРАҚ** *тара.* ат (лошадь).

**БУРАК** [*рус.* бурак] *м.-кар.* туз чиләк (берестяное ведро, бурак). Бурак кайын тузыннан йасаганнар. Бурак безгә катле булган.

**БУРАМА** *тпк.* бура (сруб).

**БУРАМЫҚ** *том.д.* тоныk (мутный).

**БУРАН I** [*рус.* паром] *мам.* к.: **борам**.

**б у р а н II** (буран):

**абыстай бураны** *минз.*, **қарға бураны** *т.я.*, **карга бураны** *хвл.* яз көне кара каргалар килер вакытта була торган соңгы бураннар (бураны перед прилётом грачей).

**буран бурау** *тмн.* буран уйнау (разыграться – о буране).

**БУРАНА** *тбл.* бүрәнә (бревно).

**БУРАН-ҚЫЗАН** *нрл., дөб., мам.* кар бураны, кышкы давыл (буран, пурга, метель). Бу буран-қызанда қайа барасың? – *нрл.* Буран-қызан чыққанчы қайтып қалырға кирәк. – *дөб.*

**БУРАУ** *эчк.* тутыру (набить, наполнить). Пинҗәгенә бураган пыйазны. Әчәккә утын бурадым.

**БУРӘМӘЧ** *трбс.* к.: **пирипич**.

**БУРҒУЦ** *тара.* бер якка кереп китә торган юл (боковая дорога).

**БУРҖА** *тара.* манара (минарет, башня). Мәҗитнең бурҗасы.

**БУРКИ** [*рус.* бурка] *перм., минз.* мамыктан сырылган аяк киеме (обувь типа чулок, стёганная из ваты). Буркины калуш белән кийәсең,

машина белән сырасың, озоно да була, қысқасы да, мамык белән эшлиләр аны.

**БУРЛАҚ** *минз.*, **БУРЛАК** *чст.* к.: **барлақ**.

**бурлакка бару (чыгу)** *мәл.* чит авылларга, күрше байларга ялчылыкка йөрү (батрачить на стороне, у соседних помещиков). Бурлакка да бара идек паннар кырына. Без бурлакка чыгып күп йереп үстек.

**бурлакка китү** *лмб.* читкә эшкә китү (уезжать на заработки, отхожий промысел). Бурлакка китәләр иде ирләр, йылга бер генә киләләр иде.

**БУРЛАНУ** [*рус.* вор + *афф.* -лану] *лш.* хәйләләү (хитрить).

**БУРЛАУ** *каз.ар., бөре., бгрс., нгб.-крш., тбл.* акбурлау, агарту (белить мелом). Морҗаларны бурладым кенәген. – *каз.ар.* Мөрҗәләрен бурлай әле ул. – *бөре.* Аның өйөн үзем салдым, бурладым. – *бгрс.*

**БУРЛЫ: бурлы йелткә** *төм.* кара үрдәкнең бер төре (голубая чернь – порода уток).

**БУРЛЫҚ** [*рус.* вор + *афф.* -лык] *лш.* караклык (воровство).

**БУРН'А** [*рус.* воронка] *глз.* буранка (воронка); чаг.: **мөшкә**. Бурн'асына түгәләр, чийылканын ашлыкны.

**БУРСУ** *төм., тара.* күгәрү, бозылу, чери башлау (преть, гнить).

**БУРТАҚ** *тбл.* исраф итүчәнлек (расточительность).

**БУРУНЧУҚ** *тара.* кечкенә таулык, калкулык (маленький холмик).

**БУРУЦ** *тбл.* борыч (перец).

**БУРЦАҚ I** *том.д.* боз (град).

**БУРЦАҚ II** *твр.* бавырсак (национальное мучное блюдо, баурсак). Бурцаклар бешерә идек.

**урама бурцак** *твр.* урама (национальное мучное блюдо, хворост трубкообразной формы). Урама бурцаклар бешерә идек.

**БУРЫ** *глз.* каен җиләге (земляника).

**БУРЫЛ** *твр.* к.: **пурыл**.

**БУРЫМ** *том.д.* төтен, корым (дым, копоть).

**БУРЫЧ** *минз., чст., хвл.* түләм, салым (обложение, налог). Бурыч бик шәп түләдем мин. – *минз.* Бер миңа гына бурыч салмаганнар анда. – *чст.* Бурыч та күп түли идек ул wакытта. – *хвл.*

**БУС** *нрл.* к.: **боз I**. Бурундук үзе бус, пуласасы бар.

**БУСА** *төм.* к.: **ачкамыр**.

**БУСАГА I 1.** *чст.* ишек төбе (преддверие, место перед дверью); **2.** *эстр.* к.: **болдор**.

**бусага күте** *нрл.* к.: **болдор**. Чыгыб утырыр ыйык бусага күтенә, басмаға.

**буса'а бастыру** *кас.* к.: **тышау: тышау кисү 1.** Җәреми, буса'а бастырадыр ыйы', алашаны тышаулыйлар, шулай тышаулыйлар и буса'а бастырасын, 'исисин урталы'тан.

**БУСАГА II** *лмб.* яшь киленнең беренче кергәндә бирә торган бүләге (подарок невесты, даримый родителям жениха, когда она впервые перешагивает их порог). Ике чын кизе ыштан хәзерли кайынанага да, бусагага да. Элке кизе ыштанны бусага арткыры куй, анан үзең атлап кер.

**бусага бирү** *карс.* яшь киленнең каениш бусагасын беренче атлап кергәндә бүләк бирү йоласы (один из свадебных обрядов, связанный с приходом невесты в дом жениха: когда она впервые перешагивает их порог, дарит им подарки).

**бусага рәде** *клд.* к.: **бусага II**.

**бусага салу** *хвл., срг., кузн., клд.* к.: **бусага бирү**. Килен бусага сала – йеслек бирә кан'атасына, күкрәк – кан'анасына. Ник килмәдең, әллә бусаган салмаганмы? Килен бусага китерә. – *хвл.* Килгәндә үк бусагага сала бер йеслек. – *клд.* Бусага керә, йөслөкме, йаулыкмы кан'анага бусага салып керә. – *кузн.*

**бусага тешү** *карс.* яшь киленнең кияү йортына беренче керүе (приход невесты в дом жениха, когда она впервые перешагивает их порог). Ә бикәҗ бирә бусага тешкәч күлмәк кан'ына, кан'анасына.

**БУСАЛАНУ** *минз., стрл., әҗе.* үз-үзенә урын тапмый борчылу, бусану (не находить себе места, сильно беспокоиться). Төннең буйы бусаланып чыкты. – *стрл.* Бала йыкламый, бусалана, күз йарамаган әтәләр. – *әҗе.*

**БУСАН 1.** *лш., мам.* божан (шершень). Төкләтура бусан түгел ул. Бусан чаға да үтерә диләр. Бусан сары була, умарта қорто төслә була, урманда ойа йасый, бүрек төслө. Шөпшә кечкенә генә, тупыйқ қына, матур ул, бусан озонча була. – *лш.* Бусан чақса, шештермичә қалмый, кийемеңә сыймыйсың. Баланның булса, җақын барма, бусан була. – *мам.*; **2.** *т.кам.-крш., дөб.* к.: **дөңгориш**. Урманда бусан атасы күргән идек. – *т.кам.-крш.* Бусан чақты, шундый зур ул. – *дөб.*

**БУСАНУ 1.** *т.я., лш., кргл., бгрс.* эсселәнү, эсселәп тирләү (вспотеть от жары, от духоты). Әллә нишләп бусанып киттем. – *к.т.* Йокы кермәди бит, бусанам, әле тегелә барам, әле болай барам. – *кргл.*; **2.** *кргл.* ачу кабару, ачу килү (злиться, гневаться). Бусанып йөри, тawыш қутара инде диләр, үзалдына тулышып, ағywы қабарып йөрәсә.

**БУСАРУ 1.** *трх.* кызара, пешә башлау (начать краснеть, зреть, поспевать). Бусармый да, йәшләтә җыйалар эт боронон; **2.** *тара.* өлгерә башлау – иген турында (начинать созревать – о хлебах). Аш бусарынты, тистән пешер инте.

**БУСАУ** *твр.* борчу, аптырату (беспокоить). Ник мине бусайсың?

**БУСКИТ** *тара.* авылның басу киртәсе (околица).

**БУСҚЫН** [*рус.* бочка]: **бусқын кебек** *злт.* к.: **бохойла**. Үзе бусқын кебек, бернәрсә ашамый. Үзе таза, бусқын кебек симез. Бәләкәй сақта бусқын кебек таза булғаммын.

**БУСТЫР'АЙ** *кас.* к.: **бистургай**.

**БУСТЫРЫК 1.** *кузн.* бөрмәле, билле, җиңсез, бик матур каптырмалы бәрхет камзул (бархатный камзол, сосборённый в талии, без рукавов, с красивой застёжкой). Көндәлек бустырыгым – кызыл гырнитур, Кешлек бустырык – йәшел гырнитур (*бор. җыр.*); **2.** *лмб.* кыска җиңле камзул (камзол с короткими рукавами). Бустырык кигән, тастар сарган әбиләр.

**БУСУ** *тбл.* тию, бозу (тронуть, испортить).

**БУТА** *чст.-крш.* к.: **билдәмә 1**. Бута бәләмичә җөрергә җарамый, ди.

**БУТА-БОЛАМА** *к.т.* **1.** к.: **болама 1; 2.** аннан-моннан, өстән-өстән, ничек җитте алай (как-нибудь, так-сяк, плохо делать что-либо). Бута-болама ғына хәзер идән дә җуwып алды, суға да китте.

**БУТАЛА** [*рус.* ботало] *перм.* ат кыңгыравы, атны көтүгә җибәргәндә тагыла торган кыңгырау (колокольчик на шее коня); чаг.: **қутаз, бутыл**.

**БУТАЛАК** [*рус.* потолок] *карс.* к.: **түбә 1**.

**БУТАЛАУ** *перм.* к.: **боталау**.

**БУТАЛУ** *срг.* буялу, бераз пычрану (загрязниться, пачкаться). Сиргацка барганда үңгә тилагрика кирәк, диләр, бу, диләр, буталган.

**БУТА-МУНЧАЛА** *к.т.* к.: **болама 1**. Шапшак, аш-суның да рәте йуқ, бута-мунчала шунда.

**БУТАНУ** *мәл.* кизәнү (замахиваться на кого-либо). Бутанып-бутанып ыршынып торалар иде.

**БУТАУ I 1.** *тмн.* болгату (мутить). Көндез казкош бутыйлар инешне, иртә мынан ару була; **2.** *мәл.* актару (ворошить). Китапны бутамыйбыз инде; **3.** *лмб.* к.: **болгау I, 3**. Бутама ары апаңа.

**бутау мунчаласы йасау** *кмшл.* астын өскә китерү, бутап бетерү (перевернуть вверх дном, нарушить порядок).

**БУТАУ II** *кмшл.* к.: **болгама 2**.

**БУТИНКА** *каз.ар.-крш.* ясмык яки борчак онынан пешерелә торган таба күмәче (пресные лепёшки из чечевичной или гороховой муки).

**БУТКА** *кузн.* бала туена ботка пешереп кунак чакыру гадәте (обычай отмечать рождение ребёнка приглашением гостей на кашу); чаг.: **бишек: бишек туйы**.

**пашул** [*рус.* пошёл] **буткасы** *чпр.* к.: **кайтыраш**. Кунакны озатканда пашул буткасы пешерәләр маскар итеп.

**БУТ′МАР** *лмб., кузн.* к.: **путемар**. Бут′мар йилкәдән алдыра. – *лмб.*

**БУТТА** [*рус.* будто] *миндз.* к.: **бетә 2**. Қызлар уйыннан қайтқач инде, урамда кеше беткәч, айағыңнан итегеңне саласың да инде итег ырғытасың қойма арқылы, бутта итегеңнең башы қайсы йаққа қарап төшсә, шул җаққа китәсең.

**БУТУМАР** *т.кам.-крш.* к.: **путемар**.

**БУТУРҒАҚ** *тара.* бөтенләй ярылмасын өчен уратып ныгытылган агач (расщепившееся дерево, скреплённое для того, чтобы оно не развалилось).

**БУТУРЛАУ** *тара.* ярылган агачны уратып ныгыту (обматывать, скреплять расщепившееся дерево).

**БУТЫЙ: нигез бутыйы** *блт.* к.: **ботқа: нигез ботқасы**.

**БУТЫК** *шрл.* к.: **қуйырық 3**. Су бутык түгелме? Йылга бутык булмаса, анда чәйкибез керләрне. Бик бутыкмы бума? Бутык су китергән.

**БУТЫЛ** [*рус.* ботало] *кргл.* терлек муенына тагыла торган зур кыңгырау (ботало, глухая погремушка из железного или медного листа, привязываемая к шее пасущихся коров).

**БУТЫШУ** *кргл.* кушылу, буталып бетү (смешаться, перемешиваться). Татарлар белән башкыртлар бутышып беттеләр инде хәзер.

**БУУ I** *тбл.* бәйләү (завязывать). Көлтә бугалы йөритегән итек.

**БУУ II: буу авыруы** *к.т.* скарлатина. Малайларның тамақ шешсә, буу awыруы дип өшкөрәләр ийе.

**БУФАЙҚА** *яүшт.* йон кофта (джемпер).

**БУХМЫЙЧ: бухмыйч кебек** *хвл.* таза, симез бала турында (полный, крепкий – о ребёнке); чаг.: **бохойла**. Бухмыйч кебек таза.

**БУЧА** [*рус.* вовсе] *перм.* к.: **башала 1**. Ақлар қайсылый килгәнен буча белмим инде.

**БУЧАҚ** *перм.* к.: **гылбу 1**. Кибетчедә күрмәдегезме аппақ бучақ?

**БУШ** *чст.* к.: **дуwадақ 1**.

**буш awыз** *лмб., тара.* ач (голодный). Алла, йерәк майларым, буш awыз белән китәсезме? – *лмб.* Қара әле, буш awыз ғына чыгып киттеләр. – *тара.*

**буш пәрәмәч** *кузн.* кабартма (лепёшка, пышка).

**буш тору** *т.я.-крш.* тик тору (стоять или сидеть ничего не делая).

**буш төш** *т.я.* эч, корсак (живот). Буш төшемнән қату ала. – *к.т.*

**уқудан буш қалдыру** *миндз.* укытмыйча, белемсез калдыру (оставить неучем, без образования). Болар мине уқудан буш қалдыралар, ди.

**БУШАҚ I 1.** *тпк.* көпшәк (рыхлый). Қар бушақ булған да, алмағасны тысқан кимергән; **2.** *трбс.* буш (нетуго, нетугой). Бушақ бәйләгәнсең бawыңны.

**БУШАҚ II** *тара.*, **БУШАК** *стрл.* буш, иркен (пустой, свободный). Бушагырак җиренә икенче чәнчемне салырсың. – *стрл.*

**БУШАҚЧА** *перм.* акча ғына (только деньги). Бушақчаға эшләми, тагын башқасы кирәк.

**БУШАН I 1.** *блт.* буш (пустой, неплотный). Болай бушан түгел (мендәр); **2.** *трх.* буш (свободный). Бушан кеше ул Рәфиқ; **3.** *трх.* коры көлсу туфрак турында әйтелә (говорится о сухой, подзолистой почве).

**БУШАН II** *тбл.* **1.** көчсез (слабый); **2.** буш, ныгытмаган (слабо, слабоприкреплённый).

**БУШАНУ** *төм.* чыгу, китү (выходить, выйти). Атпускыға бушанған, бесәнгә киткән.

**БУШАТАН** *перм.* зур калын без (большое, толстое шило). Бушатан кирәк тонине йамарға.

**БУШАТУ I** *мам., миндз., т.кам.-крш.* сосу (перелить, переложить). Аш бушатканда айак астында йөрмәгез әле, җә пешәрсез. – *мам.* Ашны қаданнан бушаттым. – *миндз.* Ашны табаққа бушатыймммы? – *т.кам.-крш.*

**БУШАТУ II** *төм., брб.д., твр.* җибәрү, китәргә рөхсәт итү, азат итү (отпустить, разрешить уйти, освободить). Ул бесейне күрше awылға кергәч бушатқаннар. – *төм.* Пушатмасаң, тападылар, аның өчен өченче йыл бушатмастық. – *твр.* Бабайың маладис, Себергә бушатыб утыра. – *брб.д.*

**БУШӘК** *әстр.* камыш көлтәсе (сноп из камыша).

**БУШ-БУЙДАҚ 1.** *дөб., лш., миндз.* буйдак,

өйләнмәгән (холостяк, одинокий). Синең әле буш-буйдак чагың, рәхәтләнеп җөр. – *дөб.* Бер дә кешесе булмаса буш-буйдаг инде ул. – *минз.*; **2.** *минз.* баласыз хатын (бездетная женщина); чаг.: **буйдак II, 2; 3.** *каз.ар.* әйбересез-йөксез җәяүле (пеший без груза, без вещей, с пустыми руками); чаг.: **буйдак I, 1.** Буш-буйдак қына барып қайттым Балтачқа. – *блт.* Әйдәле, буш-буйдак әле, барып җитәр. – *каз.ар.-крш.* Буш-буйдак қайтқан бернәрсәсез. – *дөб.*; **4.** *каз.ар.* бала-чагасыз яки балага узмаган хатын (бездетная или небеременная женщина). Буш-буйдак хатын, күтәрсә-төшерсә дә була. – *мам.* Буш-буйдак чақта эшләп қал. – *дөб.*

**БУШКЕН** *миш.д.*, **БУШКӨН** *миш.д., блт., әстр.* сишәмбе (вторник).

**БУШЛАМА** *бәр.* мөшмәлә (мушмула, ирга). Бушламаны чыпчықлар ашап бетерә.

**БУШЛЫҚ** *төм.* к.: **пушлық.**

**БУШМАЛА** *бәр.* к.: **бушлама.** Бушмала диләр, қарлыған түгел ул, қара булса да.

**БУШЫМ** *перм., к.-уф.* ат аягы тиресеннән эшләнгән аяк киеменең – *қонҗырыйқ*ның – киндердән тегелгән куныч өлеше (верхняя часть обуви, называемой *қонҗырыйқ*, сшитая из грубого полотна).

**БУШЫМНАУ** *перм., к.-уф. конҗырыйққа бушым* кую (обшить верхнюю часть *қонҗырыйқ* грубым полотном). Конҗырыйқны тегеп пирәләр ийе ирләр бушымнап. Элек буча элеккеләр чабатаны бушымныйлар икә айақ қатмас дип, т'үни җуқ чақта. – *перм.*

**БҮБЕРИК** [*рус.* бобрик] *мам.* киез ката қырына тотылган мех, тире (меховая оторочка на войлочных ботах, галошах). Қызлар элек калуш кийә торғаннар ыйы қырыйына бүберик тотып. Бүбериге тиредән була, калушы җоннан инде.

**БҮWӘ** *перм., минз.* к.: **бума 1.** Қышлау (*елг. ис.*) бүwәсе бар. Қышлауны бүwеп қуйғаннар. – *перм.*

**БҮWӘТ I** *минз.* баткан кешене коткарганда кулланыла торган җайланма (деревянное приспособление, применяемое при спасении утопающего). Қарамадан бүwәт йасайық та бүwәт белән тартып чығарайық, ди икән.

**БҮWӘТ II: бүwәт қолағалқа** *трх.* к.: **алқа: қалас алқа.** Минем бүwәт қолағалқам бар иде, түгәрәк.

**БҮWЕР** *перм.* бавыр (печень).

**БҮWЕРТАШ** *перм.* к.: **бөйерташ.** Бүwерташ салабыз мунчаға қыздырыр өчен.

**БҮГӘ** *мам., минз.* к.: **бума I.** Җылда бүгә бүгеп қуйалар ыйы, быйыл қуймадылар. – *мам.*

**БҮГӘРЧӘ** *мам.* к.: **бөгәлҗә I, 1.** Бүгәрчә тота торған җире чалғының. Кендеккә үлчәп қуйасың бүгәрчәне.

**БҮГӘТ** *әстр.* к.: **бума I.**

**БҮГРӘП** *әчк., перм.*, **БҮГРИП** [*рус.* погреб] *төм.* к.: **нәүрәп.**

**БҮДӘНӘ: бүдәнә йафрагы** *лмб.* к.: **йар I: йар йафрагы.**

**БҮДҮРӘ** *твр.* к.: **беткелгесе.**

**БҮЖИК** *твр.* бишек (колыбель).

**БҮЗ I 1.** *трх.* ак ситсы (белый ситец). Ғомеребез көз кебек, Чәчебез ақ бүз кебек (*хал. җыр.*); **2.** *блт., злт., карс.* бәз (бязь, бязевый). Бүзнең митрын туқсан тингә алдым. – *блт.* Алты митыр бүз алдым. – *злт.*

**бетле бүз** *дөб., лш.* төерчекле бәз (бязь с комочками). Бетле бүз шома түгел, төйөрчекле була. – *лш.*

**БҮЗ II** *тбл.* ак төс (белый цвет).

**БҮЗТУРҒАЙ** *әстр.* чыпчык (воробей).

**БҮЗЛӘҮ** *кузн.* җеп агарту (отбеливать пряжу).

**БҮЙИР** *брб.д.* к.: **пойдир.**

**БҮКӘЙБАШ** *тпк.* к.: **тузғақбаш.** Бүкәйбаш бар, бақса туп тулы.

**БҮКӘЙЛӘҮ** *блт., кргл., тпк.* мүкәләү (ходить на четвереньках). Бүкәйләп кермәслек итеп эшләнгән. – *блт.* Бүкәйләп йатып су керәбез. – *кргл.* Ыdаннан бүкәйләп китәдер ийе. – *тпк.*

**БҮКӘН I** [удм.] **1.** *мам., бөре., минз., перм., к.-уф., бәр.* артсыз урындык (табурет). Бүкән йасап китергән. – *мам.* Мин бүкәнгә утырып чәй эчтем. – *бөре.* Бүкән ал, утыр. – *перм.* Абыйыңа бүкән китер, басып тора қый. – *к.-уф.*; **2.** *трх., эчк., злт., м.-кар.* урындык (сиденье вообще, стул, табурет). Бүкәннәрегезне алып чығығыз. – *трх.* Лафкадан бүкәннәр алдық. – *эчк.* Менә монда бүкәнгә утырың. – *злт.* Бүкән астында эскәмийә, Ай дигәнем микәнем, Тимер артлы бүкәнем (*хал. җыр.*). – *м.-кар.*

**бүкән кийезе** *бәр.* урындык киезе, көрпә (подстилка для стула). Бүкән кийезе салыйқ, туқта.

**БҮКӘН II** *перм.* балан, миләш тәлгәшләреннән озын итеп ясалган үрем (длинная связка калины или рябины). Биш бүкән бүкәннәдег инде паланны.

**БҮКӘН III: бала бүкәне** *мам., минз.* аналык (матка). Сул йаққа төшеп утырған бала бүкәнең, ди. – *минз.* Эче төшкән дә, бала бүкәне дөрөс утырмаған икән. – *мам.*

**БҮКӘННӘҮ** *перм., минз., стрл.* җимешне тәлгәше белән кертә барып үремгә тезү – гадәттә балан, миләш тәлгәшләре (связывать, сплетать в связку кисти плодов – обычно калины, рябины). Бүкәннәгәс awыр була, йуғарыга бәйләп қуйасың, қыш қына ашыйсың. Паланны, мелишне бүкәннисең, суганны баулыйсың. – *перм.* Балан бүкәннән утыра. – *стрл.*

**БҮКӘТӘ** *минз.* к.: **бетәгә.**

**БҮККӘЛ: бүккәлле аш** *дөб.* эремчек пилмәне (варе-ники). Қарчық, әллә бүген бүккәлле аш пешерергәме?

**БҮККӘН** *дөб.* к.: **кукыл′.**

**БҮКЛӘТЕП: бүкләтеп тегү** *перм.* бөрмә салып тегү (шить со складкой). Бул эре бүкләтеп теккән қый.

**БҮКМӘ** *перм.* к.: **кукыл′.**

**эрек бүкмә** *перм.* к.: **бүккәл: бүккәлле аш.**

**БҮКСӘ** *трх., чст., мәл., перм.* к.: **бексәм.** Күлмәк бүксәсе күтәрелеп тыра. – *мәл.* Күлмәкнен бүксәсе қысқа булған. – *перм.*

**БҮКСӘЛӘНҮ** *мам.* сабакка утыру, көпшәгә утыру (выбросить стебель).

**БҮКТӘР I** *нрл., к.т., каз.ар., кмшл.* к.: **бөктәр.** Мин малайларға бүктәр-бүктәр җибәрәдер

ийем. – *нрл.* Бер бүктәр ашамлық алып килде. – *кмшл.*

**БҮКТӘР II** *тбл.* кар өеме (сугроб).

**БҮКҮН** *том.д.* к.: **цебен**.

**БҮЛӘ** *том.д.* урт (десна).

**БҮЛӘК I 1.** *әҗе.* к.: **келчә 2**; **2.** *дөб.* күчтәнәч итеп алып барыла торган камыр ашлары (мучные изделия, приносимые в качестве гостинца). Бездә туйга паштит, бүләк аппаралар, бүләк – ашамлық, төш, хәзер аны чәкчәк диләр инде.

**бүләк җабу** *нгб.-крш.* бүләк бирү (одаривать, преподносить подарок). Мийа китереп бүләк җаптылар туй бағытта.

**тел бүләге** *әстр.* кызның ризалыгыннан соң егет ягыннан китерелә торган тәм-томнар (сладости, приносимые невесте со стороны жениха после сговора). Конфет, шикәр инде тел бүләге була.

**БҮЛӘК II 1.** *минз., кмшл., стрл.* к.: **беләк I**; **2.** *минз., стрл., байк.* кечкенә вак куаклык (мелкий кустарник); **3.** *тара.* агачлык (небольшой лес, роща; заросли деревьев). Бүләктәге қарағатқа да баш булған.

**БҮЛӘК III** *кргл., әстр.* аерым (отдельно). Бәпкәләр бүләк йөриләр, бүләк менәләр. – *кргл.* Бүләк-бүләк утырғаннар. – *әстр.*

**БҮЛӘК-САЛАҚ** *блт.* бүләкләр (подарки).

**БҮЛӘҮ** *әстр.* биләү (пелёнка). Аң бүләүләргә биләгән.

**БҮЛБЕ** [*рус.* бульба] *бөре., кмшл., байк., стрл.* к.: **алма 1**. Бүлбе уңмады быйыл. – *бөре.* Калхуз бақчасыннан бүлбене мичкәгә тутырып алып киләбез. – *кмшл.* Быйыл бүлбе булмый инде, йаңгыр йук. Бүлбе пәрәмәче бик тәмле. – *стрл.*

**БҮЛГЕ** [*рус.* бульба] *бөре., байк.* к.: **алма I**. Қорсағығыз ачқандыр, бүлге ашап тороң. – *бөре.*

**БҮЛДӘМӘ** *чст.* к.: **билдәмә I**.

**БҮЛДҮРЦҮН** *тбл.* бүдәнә, бытбылдык (перепёл, перепёлка).

**БҮЛЕК** *байк.* бүлемне (разделённый на части). Такта цәй бар ул цакта, сигезгә бүлек.

**БҮЛЕМ 1.** *каз.ар.-крш., кргл.* бүлмә (комната). Өч бүлемнесе тийә, тийә дип тора. – *каз.ар.-крш.* Зур өй йе безнең, мынawында бүлем иде. Әби белән әниебезгә бер бүлем җитә инде. – *кргл.*; **2.** *нрл., к.т., мәл.* бүлмә тактасы, урта стена (перегородка). Мине бүлем арқылы қарыйлар. Ул бүлем урынында ғына инде. – *нрл.* Бүлем тақталарын аққа буйағаннар. – *к.т.*; **3.** *к.т.* к.: **бүлкә 2**; **4.** *к.т.* тәрәзә күзе, тәрәзә өлгесе (звено у окна).

**бүлем қойу** *трх.* бүлмә бүлү (сделать перегородку). Монда бүлем қойған була иде.

**БҮЛЕМТЕК** *минз.* бүленгән (разделённый). Беднең бу awыл бүлған икегә бүлемтек.

**БҮЛКӘ 1.** *кргл., минз., стрл.* бүлем (отдел, отделение). Шушы кибет ике бүлкәле йе. – *кргл.* Сарай бүлкәгә бүленгән инде; **2.** *кргл., минз., стрл.* тәрәзә өлгесе (звено окна). Бәләкәй wақ бүлкәле йе тәрәзә. – *кргл.* Тәрәзәләрнең бер бүлкәсе wатыграқ булған. – *минз.*; **3.** *чст., кмшл., кргл.* к.: **бүлем 1**. Шылай итеп өч бүлкә. – *чст.* Эчен кереп қарасагыз ыйы (өйнең), бүлкә-бүлкә; **4.** *байк.* өлеш, бүлек (часть). Безнең awыл өц бүлкәдән тора.

**БҮЛКӘЛЕ-БҮЛКӘЛЕ** *минз., стрл.* билле-билле – кузак турында (местами перетянутый – о стручке). Көртләк бугы дидер идек (арахисны), бүлкәле-бүлкәле була торган ийе. – *стрл.*

**БҮЛМӘ I 1.** *чпр., әстр.* кухня; чаг.: **почмак**; **2.** *мам., минз., кргл., тпк.* к.: **кәзәнкә 2**. Бүлмә ишеген җawып җөрөгез. – *мам.* Безнең бүлмә йуғ, әнә келәт. – *минз.* Элек бит чыланның уртасында бүлмә была торған ыйы. – *кргл.* Итне тозладық та бүлмәгә қуйдық. – *тпк.*; **3.** *минз., стрл.* кыз белән егетне беренче көндә кундыру өчен махсус билгеләнгән өй, келәт (дом, предназначенный для новобрачных); **4.** *т.я.* бура (закром, сусек).

**БҮЛМӘ II** *тбл., төм.* к.: **бүлем 1, 2**.

**БҮЛМӘЛӘҮ** *тбл.* **1.** койма белән әйләндереп алу (окружить забором); **2.** бүлү; бүлеп кую (перегородить, отделить).

**БҮЛМӘЧ 1.** *каз.ар.-крш., мам., блт., нокр.* к.: **кәберкә**. Бүлмәчкә дә шаршау қордом. – *каз.ар.-крш.* Бу – бүлмәч, җөрелмәле булғаны аралық була. – *блт.* Безнең бүлмәч йуқ бит, Нәҗми абыйларның бүлмәчле пич аралығыннан йөрисе. Бүлмәчтә кисәү ағачлары тора; **2.** *стрл.* өйнең мич алды ягы, почмак (уголок дома, находящийся перед шестком и заменяющий собственно кухню).

**БҮЛМЕ** [*рус.* бульба] *кмшл.* к.: **алма 1**. Бүлме дә алып чықты. Чәчкән бүлмегез күпме сың? Бүлме җирен су басты. Йаңы бүлмегезне ашыйсызмы әле сез?

**БҮЛМИ** *глз.* к.: **бүлкә 1**. Бу азбарыбыз бүлми дә бүлми.

**БҮЛНӘК** *нрл., каз.ар.* к.: **бай II, 1**.

**БҮЛТЕК-БҮЛТЕК** *трх.* бүлем-бүлем, киртләч-киртләч (утёсистый); чаг.: **кирткәс 2**. Таулар бүлтек-бүлтек тора.

**БҮЛТЕРЕК** *минз., тпк., стрл.* к.: **бәйсәкә**. Бәләкәй кешене көдге бүлтерек тиләр беддә. – *минз.* Кешене дә, үсмәсә, бүлтерек диләр. – *тпк.*

**БҮЛТЕРЕКЛӘҮ 1.** *минз., стрл.* көзен бәрәнләү (объягниться осенью). Кәҗәбез йаз бәрәннәде, көз бүлтерекләде; **2.** *бөре., минз.* җәен бәрәнләү (объягниться летом). Безнең сарық бүлтерекләде. – *бөре.*

**БҮМИЧ** *минз.* к.: **бүлмәч 2**.

**БҮРӘК I** *чст., кмшл.* к.: **бөйрәк**.

**БҮРӘК II** *әстр.* **1.** к.: **шөшпәрә**; **2.** сумса (пирожки).

**БҮРӘМӘЧ** *трбс., стрл.* к.: **пирипич**. Бәрәңгенең бүрәмәчен пешерәләр. – *трбс.*

**БҮРӘН 1.** *төм.* яткан су, иске үзән, елга култыгы (старица; речной рукав); **2.** *төм.* уйсу җиргә җыелган су, күл (стоячая вода, озеро); **3.** *төм., тбл.* кечкенә күл (озерцо, заводь). Бүрәннәр бар, бүрәннәр пай, палығы кән. Йалбақ бүрән, Түңәрәк бүрән, Ақ сулы бүрән. Бүрәннән ташып сыу сибә тоғайтық. Бүрәннән эцәбес.

**бүрәнә I** (бревно):

**бүрәнә кисү** *байк.* урман кисү (рубить лес). Бүрәнә кисү бар ыйы әлек.

**йалған бүрәнә** *перм.* өйнең дүрт почмагына утыртылган бүкәннәр арасына тыгылган бүрәнә (бревно между колодой, используемое вместо фундамента). Йалған бүрәнә қыстыралар, чередисә, йаңыны қыстыралар.

**кийәү бүрәнә** *глз.* к.: **матка 1.**

**май бүрәнә** *к.-уф.* к.: **матка 1.**

**БҮРӘНӘ II** *перм.* озынлык үлчәү берәмлеге (единица измерения длины). Ничә бүрәнә саласың, өч бүрәнә, дүрт бүрәнә саласың, унбишәр аршин булawы, озон була.

**БҮРӘТӘҮ** *кмшл.* к.: **бетәгә.** Бүрәтәwе пешкәндер инде, ашый тор.

**БҮРӘЧИҢКӘ** [*рус.* поросёнок]: **дуңгыз бүрәчиңкәсе** *к.т.* дуңгыз баласы – балаларны орышканда әйтелә (поросёнок – употребляется, когда ругают детей). Нәрсә чиныйсың, дуңгыз бүрәчиңкәсе?

**БҮРГӘҮ** *тара.* к.: **пөргәү.**

**б ү р е** (волк):

**бүре борочо** *мам., перм.* җимешләрен тамак шешен дәвалау өчен файдаланалар (купина неопалимая).

**бүре бөрәсә** *мам.* карга җиләге (воронец колосистый).

**бүре җиләге 1.** *мам.* к.: **бүре бөрәсә; 2.** *минз.* к.: **бүре шоморто.**

**бүре җүкәсе** *перм.* бүре җиләге (волчье лыко, волчьи ягоды).

**бүре йүкәсе** *минз., стрл.* колмак кебек уралып үсә торган чәнечкеле үлән (колючая сорная трава, игольчатка, волчец).

**бүре күз** *лмб.* эре иләк, борчак иләге (грохот). Сирәк иләктән үтмәгәне бүре күздән үткәрә (димче).

**бүре тарагы** *карс.* абага (папоротник).

**бүре уты** *дөб.* бүре уы (крапивница). Бүре уты чыкса, кызыл әйбер белән бүре кебек улап ywacын.

**бүре шоморто** *мам.* эт шомырты (крушина ольховидная).

**бүре эләге 1.** *тмн.* к.: **байбай; 2.** *лмб.* эт шомырты (крушина слабительная; жестер).

**б ү р е к** (шапка):

**иманны бүрек** *минз., стрл.* мескен бүрек (шапка без ушек).

**имансыз бүрек** *лмб.* кубань бүреге (кубанка).

**қазан бүрек** *перм.* к.: **имансыз бүрек.**

**кәпә бүрек** *блт.* хатын-кызлар кия торган тәбәнәк бүрек (круглая женская шапка без ушек).

**климка бүр(е)к** *лмб.* к.: **иманны бүрек.**

**күкәй бүрек** *дөб.* к.: **иманны бүрек.** Күкәй бүрек қаракүлдән дә булған, бәти тиреләреннән дә тегәләр ийе қысқа җолло.

**қырма бүрек** *перм.*, **қырпы бүрек** *злт.* кырпулы бүрек (шапка с меховой оторочкой).

**миски бүрек, мискин бүрек** *лш.* к.: **иманны бүрек.**

**тирәле бүрек** *чст.* к.: **қырма бүрек.** Үләнгәч, Қазанға барып, тирәле бүрек алып қайткан идем.

**тырпыса бүрек** *тпк.* к.: **иманны бүрек.** Пашынта моның тырпыса бүрек, қама бүрек түгел.

**чәчәк бүрек** *минз.* к.: **имансыз бүрек.**

**чүлмәк бүрек** *м.-кар.* к.: **қырма бүрек.**

**ызынчык бүрек** *лмб.* озынча, очлы бүрек (гололька).

**БҮРКӘ** *каз.ар.* к.: **бурки.**

**БҮРКЕ** *миш.д.* бүрек (шапка). Бүркесе йаңа выт әлдә. – *хвл.* Бүркен салып куйадыр болдырга. – *карс.*

**бәбүр** [*рус.* бобёр] **бүрке** *срг.* к.: **бүрек: қырма бүрек.** Бәбүр бүрке диләр иде бик тар мех тотылган түгәрәк бүркегә.

**тәwәккәл бүрке** *срг.* к.: **бүрек: иманны бүрек.**

**БҮРЛӘНКӘ** [*рус.* воронка] *блт.* бүрәнкә (воронка). Бүрләнкә белән салыйм дим кирасинны.

**БҮРТКЕН** *эстр.* к.: **бедрә.** Қорттай бүрткеннәре бар.

**БҮРТМӘЛЕ: бүртмәле сөлгө** *дөб.* шадра сөлге (вафельное полотенце). Бүртмәле сөлгө белән төшөрәләр қәбергә.

**БҮРТМӘЧ** *мам.* кабарынкы (выпуклый). Бүртмәч булганга қалын күренә.

**БҮРТМӘЧЛӘНҮ** *мам.* кабарынкылану (делаться выпуклым). Шул (күзне) бәйләми алганға бүртмәчләнеп қала бит инде ул.

**БҮРТМӘЧЛЕ-БҮРТМӘЧЛЕ** *мам.* к.: **бүртмәч.** Бүртмәчле-бүртмәчле була сөлгө башлары күтәреп суққач.

**БҮСӘ** *т.я., мәл.* бүксә (зоб – у птиц). Қазлар солы ашап тәмам туйғаннар, бүсәләре җирдән өстерәлә. – *т.я.* Таwык бүсәсенә тутырган. – *мәл.*

**БҮСКӘ I 1.** *трх.* туп (мяч). Бүскә уйныйдырыйық сикертеп-сикертеп; **2.** *мәл., т.я.* тәгәрәтеп уйный торган пыяла шар, уенчык (стеклянный шарик, игрушка); **3.** *мәл.* кискә (толстый обрубок бревна, кряж, на котором рубят дрова).

**БҮСКӘ II** *минз., стрл.* к.: **бетәгә.**

**БҮСМӘН** *мам.* авыр гәүдәле, ялкау кеше (тяжёлый на подъём, ленивый человек); чаг.: **азымтыҗ.**

**БҮСТЕР** *каз.ар.-крш.* к.: **дүстер.** Менә монда җаңа бар ыйы, бүстере генә қалган инде. Бүстере дә қалмағанмы қәситәнең?

**БҮСҮ** *мам.* турсайту – авыз турында (дуться, надуть губы, обижаться). Сез awызыгызны бүскәндә, без дә awызыбызны бүсеп утырырға тийешме?

**БҮТӘГӘ I** *нокр., злт., трбс., төм., миш.д.* к.: **бетәгә.** Таwықның бүтәгәсен йаратам. – *злт.*

**БҮТӘГӘ II 1.** *кмшл., кргл.* кылган төбендә үсә торган үлән (трава, растущая у корней ковыля). Бүтәгәләр күтәрелә йәм-йәшел булып, кез йаңғырлар булса. – *кргл.*; **2.** *нгб.-крш.* башка үләннәр төбендә үсә торган вак үлән (мелкая травка, растущая у корней других трав). Шелекәй буйлары вак бүтәгә.

**БҮТӘКӘ I** *кргл., бгрс.* к.: **актамыр.**

**бүтәкә үлән** *минз.* к.: **актамыр.**

**БҮТӘКӘ II** *трбс.* көзге бәрән (козлёнок, ягнёнок осеннего окота).

**БҮТӘКЛӘНҮ** *тара.* шытып чыгу, үрү – орлык турында (прорасти, пускать ростки – о семенах).

**БҮТӘНЧӘ** *перм.* бик, бигрәк (особенно). Аларның ата қазлары бүтәнчә дә усал инде. Бүтәнчә уйын-көлкегә қызықтым. Бүтәнчә алам, ди, уқытам, ди шу кеше.

**БҮТӘНЧӘЛИ(Й)** *т.я., лш.* к.: **бөтәнчәли**; чаг.: **айра.** Бүтәнчәли кирәк, алай кирәкми. – *к.т.* Бүтәнчәлий йуқ. – *лш.*

**БҮТЕГЕ** *нокр.* к.: **бетәгә.** Бүтегесе ансы, ашыйсынмы?

**БҮТИ** *нрл.* к.: **бәкәй I.** Кәҗә бүтисе бик шайан була.

**БҮТИ-БҮТИ** *нрл.* к.: **баш-баш.**

**БҮТКЕН** *әстр.* дөя баласы (верблюжонок).

**БҮТРӘ** *тбл.* к.: **пөтөрә**.

**БҮТҮ 1.** *твр.* үсү, өлгерү (расти, поспевать); **2.** *тара.* ясалу (быть сделанным).

**БҮҮ** *минз.* к.: **бийәләү**. Бүwәләр аны ағачлар, саламнар белә, бүгәч, куласага ағып төшеп, тегермәнне әйләндерә.

**БҮЧӘ** [*рус.* вовсе] *перм.* к.: **башала 1**. Хәзер бүчә қартлар жуқ.

**БЫВАҚ** *кузн.* бәс (иней, изморозь). Агачка бывак кунган.

**БЫWАҚ** *тара.* бау (верёвка). Чарық быwақ қап-қара була. Қара быwақны йетен йебеннән йасайлар.

**БЫWЫЛУ** *яүшт.* к.: **бүwылу**. Таза, бийек малай иде, быwылыб үлде.

**БЫWЫМ: быwым қыwыу** *злт.* вак балыкларны тоту өчен банка эченә ясалган җайланма (способ ловли мелкой рыбы банкой, внутри которой приделана воронка из тюля). Быwым қыуғанда, банкы эсенә әпәй салып, ағым йүнәлешенә қаршы қуйалар.

**б ы w ы н** *тпк.* буын (сустав):

**быwын керү** *тпк.* хәл керү, терелеп китү (набираться сил, выздоравливать, поправляться). Сары белән awырдым да, быwын кереп китмәй.

**быwын петү** *тпк.* хәл булмау, хәлсезләнү (терять силы, слабеть). Йүнәлдем инде, йөрөйөм хәдер, шулай да пыwыным йуқ. Минем қайғы белән быwыным петкән.

**БЫWЫРТУ** *злт.* к.: **бүwырту**. Қайтқач, Зәйтүнәдән быwыртам. Мийәрдән быwыртыр ыйы дип қурқам. Алып китсә, миннән быwырталар бит инде.

**БЫГАУ** *клд.* к.: **бума I**.

**БЫГАУЛАУ** *клд.* к.: **бийәләү**. Суны быгаулыйлар су көп болсын, йиылып тырсын эчен.

**БЫҒРАҚ** *төм.* к.: **қуйырық**.

**БЫГЫЛ** *сргн.* к.: **богол 1**. Ындыр артларында ай ак тана, Быгдай быгылларын акдара (*хал. жыр.*).

**БЫҒЫЛДАЙ** *том.д.* бугаз төене (адамово яблоко).

**БЫҒЫМ** *эчк.* к.: **айап 1**. Анда йеләк быгым.

**БЫҒЫН** *яүшт., твр.* к.: **пыгын**.

**БЫЖАН-БЫЖАН** *т.кам.-крш.* шыпырт кына (тихонечко, незаметно). Быжан-быжан ғына чық та қайтып кит урманнан.

**БЫЖБЫЖАҚ** *т.я.* **1.** уен исеме: берничә кеше түгәрәккә утыра да, уртада торган «көтүчегә» күрсәтмичә, тез асларында камчы яшереп йөртәләр. «Көтүче» күрмәгәндә генә аңа камчы белән сугалар һәм аны яңадан тез астыннан жибәрәләр (название игры); **2.** бөтергеч (волчок).

**БЫЖУ I** [*угор.*] *трх., минз.* к.: **пожу**. Быжыганмы торма. – *трх.* Бәрәңгең быжыган, тәмне түгел. – *минз.*

**БЫЖУ II** [*угор.*] *глз.* бакча кырыйларында үскән чирәм (трава, выросшая по краям сада). Быжуларны баскаламасын инде сукалаганда.

**БЫЖЫЙ** *блт.* ачы бал (брага).

**БЫЖЫҚ I** *минз.* к.: **който**. Быжык ғалуш.

**БЫЖЫҚ II** *әстр.* күп сөйләүче (болтун). Бер быжык зат үзе.

**БЫЖҖЫҚ** *минз.* йомшак, тотрыксыз (слабый, непрочный). Быжык та инде бу, бөгелеп тора.

**БЫЖҖЫҚЛАНУ** *минз.* бәйләнеп, күп тапкырлар әйтеп аптыратып бетерү, теңкәгә тиеп бетү (приставать с чем-либо, надоесть своими приставаниями, требованиями). Быжыкландылар гел мендергәнче, аннары кирәкмәс булды (күкәй).

**БЫЗАКШИН, БЫЗАКЫШИН** *тмн.* өй сырасы салып тота торган кувшин (кувшин для домашнего пива). Бызакшиннар белән өстәл йанында йөриләр.

**БЫЗАУБАШ** *хвл.* урман коңгызының бер төре (один из видов лесного жука).

**БЫЗҒЫ** *минз.* тынгысыз, борчучан (беспокойный, неспокойный). Қайбер қарчық бызгы була бит ул.

**БЫЗНАУ, БЫЗНЫУ** *хвл.* елау, сыкрау (плакать, ныть). Үзен бәләнәсен вет, аннан соң бызныма, йәме.

**БЫЗУ** *тмн., лмб., мәл., чст., клд., карс.* к.: **бозу 1**. Тарилканы бызалар (туйда конфет сипкәч). – *тмн.* Ыстаканнарны быза күрмә. – *чст.* И тәрәзәне вич бызам. – *карс.*

**бәлеш бызу** *т.я.-крш.* турау, кисү (резать, разрезать). Анчак бодай бәлеше затлы инде, анарга акча куйа бәлеш бызган эчен.

**БЫЗЫЛУ** *лмб.* к.: **бозылу I**. Ыр'умка төшеп бызылды.

**БЫЙАЗ** [*фарс.*] *тара.* к.: **пыйаз**. Быйаз салып ит бәлеше булаты.

**БЫЙАҚ** *минз., бөре.* бу як (эта сторона). Быйақта тора ул. – *бөре.* Быйақны типтәр дип йөртәләр. – *минз.*

**БЫЙАУ** *бөре., каз.ар., кмшл.* к.: **буйак I**. Ақ быйау кирәк ийе әле безгә дә. – *бөре.* Чәчләрне быйағач, матур инде. Быйау белән быйап қарайта. – *мам.*

**БЫЙМА** [*угор.*] *тпк., төм., твр.* к.: **пима 1**.

**галуш быйма** *тпк.*, **қысқа қуныцлы быйма** *төм.* к.: **галуш 1**.

**БЫЙМАБЫЙ** *минз., стрл.* к.: **бер: бер буйдан**. Быймабый жаңгыр булгач, нәрсәшләргә рәт жук. – *стрл.*

**БЫЙЫГУ** *чпр.* ою – аяк һәм кул турында (неметь – о конечностях). Кулым быйыга башлады.

**БЫЙЫЛ** *глз., нокр., карс.* хәзер, хәзерге моментта (сейчас, в данный момент). Сәгәт унике булғандыр инде быйыл? Мин күп эчтем инде чәйне быйыл. Тәрәзәне ачсағыз да йарар инде быйыл, бик йаман ис булды, башығызға ис тийәр йә. – *нокр.*

**БЫЙЫЛГЫ** *карс.* хәзерге (нынешний, настоящий).

**БЫЙЫМ: ак быйым** *чст.-крш.* иренең апасына эндәшү формасы (форма обращения к старшей сестре мужа).

**БЫЙЫР** *нокр.* к.: **бөйрәк**.

**БЫЙЫРА** *глз., нокр.* җилен (вымя). Кәзәләренең быйыралары бызылган. – *глз.* Сыйырларның б(ы)йыраларын йумага ару су дий. – *нокр.*

**БЫЙЫРЫ** *чпр.* к.: **бөйрәк**. Быйырыга тигәндер инде, быйырыга тимәсә, алай булмас иде awыру.

**БЫКБЫК** *лмб.* өч литрлы, чирекле шешә (трёхлитровая бутылка). Ыланнарыма берәр быкбык сет.

**БЫКЫ** *чст.* к.: **билтәк 1**.

**БЫКЫРТ** *клд.* баш бармак белән урта бармак арасына тигез үлчәү берәмлеге, сөям (старинная мера длины, равная расстоянию между большим и указательным пальцами; пядь).

**БЫЛА I** *кмшл.* аркасында, сәбәпле, өчен (ради, из-за, по причине). Аңча түләргә была бармады ул анда.

**БЫЛА II** *тпк.* белән (с). Киләләр машина была.

**БЫЛАҒАЙ I** *лш.* урманлы, печәнле урын (лесистая, травянистая местность). Үзебез былагайда ыйык, крачинкы қабынган.

**БЫЛАҒАЙ II** *дөб.* кыланчык, шамакай, уенкөлке яратучан (шутник, любитель подурачиться).

**БЫЛАҒАЙЛАНУ** *минз., дөб.* кылану, шамакайлану, шаяру, юләр сату (дурачиться). Килә дә гел минем белән былагайлана бала. – *минз.*

**БЫЛАЗАУ** *т.кам.-крш.* к.: **азымтық**. Былазау булмасаң, син әзерәк ашыгыр идең. Былазау қузғалғанчы, эшлекле эшләп ара (*мәкаль*).

**БЫЛАЙ: моннан былай** *мам., кмшл.* к.: **ары 3**. Менә моннан былай йәшелчәләр чыгар әле (яңгырдан соң). – *мам.* Мыннан былай алай эшләмә. – *кмшл.*

**БЫЛАЙАҚ** *тара.* чуар аяклы – ат турында (пестроногий – о лошади).

**БЫЛАМА** *минз., дөб.* к.: **болама 1**. Awыл көтүе белән фирмы көтүе былама былып беттеләр. – *минз.* Туйда ире-қатыны бергә былама утыра. – *дөб.*

**БЫЛАН** *тпк.* к.: **была II**.

**БЫЛАПКА** [*рус.* булавка] *кас.* брошка (брошь). Безнен атабыз йа'та иде, йезе'ен, былапкасын алыштырып китерә иде.

**БЫЛАУКА** [*рус.* булавка] **1.** *срг., чст., тмн.* булавка. Бир былаука. – *тмн.* Кайдадыр былаука да бар иде бит. Ылаука арасында биж былаука, Алып када, җаный, йаулыкка. – *срг.*; **2.** *срг., баст., әҗе.* к.: **былапка**. Кемештән былаукалар эләләр иде. – *срг.*

**БЫЛАФКА** [*рус.* булавка] **1.** *кас.* к.: **былапка**; **2.** *хвл.* к.: **былаука 1**. Төмәсе төшкәч, былафка белән генә эләктергән.

**БЫЛАФКИ** [*рус.* булавки] *хвл.*, **БЫЛАФКЫ** *кмшл.* к.: **былаука 1**.

**БЫЛАШ** *злт.* ызгыш-талаш (раздор, делёж, возня, давка, толчея). Тәрилкәсе белән май сыгаралар, ул былаш анда. Бәрәңге утыртмайлар, базарда былаш.

**БЫЛАШУ 1.** *злт.* эткәләшү, төрткәләшү, тарткалашу (толкаться, брать на расхват). Олосы да, бәләкәйе дә былашып тырып алып бетерәләр инде майны; **2.** *перм., тпк., трбс.* маташу (возиться, провозиться). Тарма белән былашмадылар, орлоғона бәлә генә чәчтеләр. – *перм.* Олы-қары былашты эшләп. – *трбс.* Хәдер аның былан былашыб утырмайлар. – *тпк.*

**БЫЛГАМА 1.** *хвл., клд.* к.: **болгама 1**. Сыйырларына үдә былгама ашаталар иде. – *клд.*; **2.** *хвл.* к.: **болгама 2**.

**БЫЛГАУ 1.** *тмн., лмб.* к.: **болгау I, 3**. Китегез, мында былгамагыз апайыгызга! Гуренчәдә кем дә былгами, бар, анда укы. – *лмб.* Кем сиңа былгый мәллә? – *тмн.*; **2.** *м.-кар.* болгату, туглау, изү (мешать, размешивать). Былгыйсын анан сын.

**БЫЛДЫР** *лмб., хвл., тмн., мәл., чст., срг., карс., чпр., шрл., м.-кар., перм., дөб., трбс.* к.: **болдор**. Чирку былдырларын менгән чакта, Уң да гына айакларым тайадыр (*бәет*). – *лмб.* Былдырга чыгып утырган. Былдырдан йырак китеп йума айагыны. – *чст.* Былдырга менеп кыцкырды куцат. Пуйыз былдырыннан йыгылып төштем. – *срг.* Былдырга җитте, тытынды чинәргә. – *карс.* Былдырга йаткан мачи. – *чпр.* Былдырдан төшкәндә йыгылдым. – *шрл.* Мин мында булам, былдырда утырам. – *мәл.* Былдыр басмалары. – *м.-кар.* Былдыр өстендә утырып торам. – *трбс.*

**БЫЛК: былк итеп тору** *байк.* ялт итеп тору (блестеть, сверкать). Ул былк итеп торадыр ыйы да суң үзем белән бергә картайган бишмәт.

**БЫЛҚЫЛДАҒАН** *минз.* симез битле, тулы йөзле (полнолицый). Былқылдаған битле.

**БЫЛҚЫН** *каз.ар., минз., т.я.-крш., т.кам.-крш.* к.: **балбан**. Былқын шикелле сарықлар ийе. – *мам.* Ай симез бу – былқын күк. – *т.я.-крш.* Былқын шикелле ул қыз, симез. – *дөб.* Былқын инде, симергән дуңгыз шикелле. – *т.кам.-крш.*

**БЫЛТОҚ** *нокр.* каз куыгы (гусиный пузырь).

**БЫЛЦЫРАУ** *тбл.* көчсезләнү, хәлсезләнү (быть ослабленным).

**БЫЛЧЫРАҚ** *каз.ар., трх.* пычрак (грязный, нечистый). Машинасы былчыраққа батқан. – *трх.*

**БЫЛЫМ** *глз.* болын (луг). Ар Паржаны чыккач, былым кере.

**БЫРАВЫК** *тмн.* көлтәләрне җилләтеп алу өчен теземгә куюның бер ысулы (способ сушки снопов).

**БЫРАК** [*рус.*] *кузн.* тирән чокыр (овраг). Пыртның теге йагы бырак та бич йанды.

**БЫРАМ** [*рус.* паром] *минз., стрл.* к.: **борам**. Бырам судан чыгара машиналарны, кешеләрне. – *минз.*

**Б(Ы)РАМАТ** *чст.-крш., мәл.* юлдан язган кеше (человек, сбившийся с пути).

**б(ы)раматлыкта йөрү** *злт.*, **б(ы)раматта йөрү** *чст.-крш., шрл.* к.: **илдәтнә: илдәтнәдә йөрү**. Мин бираматта йөргәнем йук, каам белим, сүләсәләр дә, ишеткәнем йук. – *чст.-крш.* Бик озак бираматта йерисең, мин көтөб арыдым. – *шрл.*

**БЫРАМАТЛАУ** *лш.* к.: **браматлау**. Фәләмәт бираматлый башлаган гармунны.

**БЫРАМАТЧЫ** *кмшл.* биләмче (праздношатающийся, любящий ходить без дела из дома в дом).

**БЫРАН** *твр.* бик (очень). Пес әле быран йабык төгәл.

**БЫРАТ** [*рус.* брат] **1.** *тмн., хвл., кузн., мәл., шрл., карс., стрл., чст.-крш., трх., минз., бгрс., кргл.* к.: **брат 1**. Ире үлгәч, быратына килгән. Без мының быратын үләндердек. – *тмн.* Бу ызба быратларымныкы. – *хвл.* Минем быратның балалары тутай диләр мине. – *чст.-крш.* Дүрт быраттан берүзем калдым. – *стрл.* Былар эч бырат ыйы, ике бираты кергән мыңа. – *бгрс.*; **2.** *лмб., мәл., карс., стрл., трх.* к.: **брат 2**. Берсе ага, берсе бырат иде. – *лмб.* Быратларым йук иде, гел эч агай иде. – *карс.* Мин китәргә йөрим Окт'абрыскига эшкә, бырат-

лар шунда эшли. – *стрл.*; **3.** *стрл.* ике туган балалары (двоюродные). Наил абзый белән безнең Риф быратлар алар, аның инәсе белән Рифның әтәсе бертуган; **4.** *трх.* ир туган, ир кардәш (родственник).

**БЫРҒУ** *эчк.* к.: **быргыту**. Утыннарны кәртә аша бырғыдым.

**БЫРҒЫТУ** *бәр., дөб., эчк., злт.* ыргыту, ташлау (выкинуть, выбросить). Қазларға тушының ғына хәтле ағач бырғытқан ыйым, берсенә әләкте. – *бәр.* Мин килен булып қураға керүгә, айағыма мендәр бырғыттылар. – *эчк.* Бырғытмале, қарыйқ нинди таш ул. Тубын бырғый әле шуның. Безгә нәрсәгә ул, бырғыт үзенә, улым, қурчағын. – *дөб.* Аны бырғытасы ғына бар. – *злт.*

**БЫРЗЫЙ** [*рус.* борзая] *чст.* бурзай, ау эте (борзая собака).

**БЫРҚЫЛДАУ** *трх.* пычрану, пычракка бату (загрязниться, вымазаться); чаг.: **буталу**. Йулдан бырқылдап қайтып керде.

**БЫРЛЫГУ** *шрл.* борчылу, күңелсезләнү (беспокоиться, волноваться, печалиться). Бырлыкмас идек без болай, Бырлыктырды бер Ходай (*бор. җыр.*).

**БЫРМИ-БЫРМИ** *мәл.* к.: **баш-баш**.

**БЫРНАЙ** *шрл.* аш талымлаучан (привередливый, разборчивый – в еде).

**БЫРНУ** *кузн.* к.: **борнау 1**.

**БЫРСАЛАНУ** *кмшл.* к.: **борсалану**. Төн буйы бырсаланып чықтым.

**БЫРТАҚ** *кмшл., эчк.* әдәпсез (невоспитанный, плохой; невоспитанно, плохо). Минем кийәүләр быртақ сүләшмәйләр. – *эчк.*

**БЫР′УКА** [*рус.*] *тмн.* чалбар (брюки). Кас′ына быр′ука кирәк, кас′ына күлмәк кирәк.

**б ы р ц а к** *срг.* борчак (горох):

**бырцак үләне** *срг.* песи борчагы (просвирняк приземистый).

**wак бырцак** *срг.* к.: **йасмақ**.

**йәшмик бырцак** *срг.* к.: **йасмақ**.

**б ы р ч а к** *миш.д.* борчак (горох):

**дуңгыз бырчагы** *карс.* к.: **бырцак: бырцак үләне**.

**БЫРЫ** [*удм.*] *глз.* җир җиләге (клубника).

**БЫРЫҚТЫРУ** *әстр.* бутау (путать, запутывать). Ул бырықтырып сүли.

**б ы р ы н I** *нокр.* борын (нос):

**бырын буйына уйлау** *кмшл.* үзалдына яки үз төшенә уйлану (думать про себя, обдумывать что-либо). Шуннан чығып бырын буйына уйлап қарарсын.

**бырын йебәрү** *нокр.* к.: **борнау 1**. Бырын йебәргән бу гөлем.

**бырынын сындыру** *лмб.* киледә төю (толочь в ступе). Быдайнын бырынын сындырам киледә.

**йәмшек бырын** *кмшл.* яньчек борын (курносый).

**БЫРЫН II** *карс.* к.: **алғы**. Бырын бар иде күзләүләр, казыйлар иде. Бырыннарны мунчаклар тага булганнар.

**БЫРЫС** [*рус.* брус] *нокр.* к.: **матка I**.

**б ы т а қ** *кмшл.* ботак (ветвь, ветка):

**қырыған бытақ** *кмшл.* к.: **қырыбытақ**. Чыбан дисәң, чыға, ди, қырыған бытақ дисәң, қырый, диләр.

**БЫТАҚЛЫ** *тмн.* муенсаның бер төре: озынча мәрҗәннәре аркылы-торкылы тезелгән була (один из видов бус). Мун′га кызыл мәрҗәннән әләләр иде, бытаклылар була иде.

**БЫТБУЛ** [*рус.* подпол] *т.я.-крш.* к.: **гелбәч**. Бытбулдан алма алып пешерә.

**БЫТБЫЛДАП** *каз.ар.-крш.* йомшак булып (становясь мягким). Бытбылдап пешә шомырт, менәтерә сөйәге дә булмый.

**БЫТБЫЛДАУ** *кмшл.* бытылдау, юкка-барга борчылып, сөйләнеп тору (много лишнего говорить; попусту выражать беспокойство).

**б ы т к а** *миш.д.* ботка (каша):

**җаңгыр быткасы** *т.я.-крш.* к.: **ботқа: йаңгор боткасы**. Дawай, җаңгыр җаумый, җаңгыр быткасы пешерик әле, диләр. Май әнде, җарма җиган, сет, зур казан аскан әнде, шунда бытка пешергән.

**сүс быткасы, чүк быткасы** *чст.-крш.* к.: **чүк: чүк итү**. Сүс быткасы диләр аны, шунда бөтен бала-чага тешәдер ийе, ул бытканы ашап бетерәләр ийе дә, җәшләр су сибешәләр. Чүк быткасына бетен awыл җыйылган элеке, бытка пешереп су сибешкән.

**БЫТЛЫҚТЫРУ** *дөб.* табылмаслык итеп җыеп, яшереп кую (спрятать так, чтобы было трудно найти). Қайа бытлықтырдың инде кизитекне, хис табар хәл йуқ.

**БЫТН′ЫК** *хвл.* бөтнек (мята).

**БЫТХАНА** *әстр.* чебен-черки (мошкара).

**БЫТЫБЫЙ** *дөб.* к.: **ләпелдек**. Бытыбый Сәгедәт күп сөйләшә.

**БЫТЫРАЗ** *м.-кар.* к.: **питырас 2**. Бытыраз була, табикмәк була.

**БЫТЫРӘТҮ** *тара.* сибеп җибәрү (посыпать).

**БЫТЫРҒАҚ** *тбл.* кытыршы (шероховатый).

**БЫУУ: көлтә быуу** *төм.* көлтә бәйләү (завязывать, затягивать снопы жгутом).

**БЫХАР** *чст.* көрән төс (коричневатый цвет).

**БЫЦАК** *тмн.* к.: **бычак**.

**БЫЦҚАҚ** *тбл.* хайванның бот тиресе (кожа с бедренной части любого животного); чаг.: **поцқақ**.

**быцқақ тун** *тбл.* хайванның бот тиресеннән тегелгән тун (шуба, сшитая из кожи с бедренной части животного). Быцқақ туннарға тыш қуйганнар, қаты мал булған үспәкләрнеке сынны, қатысы тун тышы булған. Быцқақ тунны кецерәк-кецерәк кисәкләртән, тейеннекеннән қылганнар.

**БЫЧАК** *тмн.* пычак (нож). Кирпечкә ышкылыйым да, кар′ала бычак.

**БЫЧАН** *тмн.* печән (сено). Аз′уг абыз, бычангамы барасыз?

**БЫЧКЫЧ** *глз.* шыртлака (ёрш). Бычкычның кадаугычлары була.

**БЫЧЫК** *м.-кар.* к.: **почык**.

**БЫШАМ** *тбл.* көлтә өеме, сослан (снопы, составленные в небольшие кучки, суслон).

**БЫШҚЫ** *том.д.* пычкы (пила).

**БЫШЛАУ** *тара.* выжлау (свистеть). Йел бышлап тырады, қатты буран.

**БЭРТЕК** *срг.* аксак (хромой).

**БЭРТЕЛГӘН** *срг.* имгәнгән (увечный).

**БЭРТЕЛҮ** *срг.* имгәнү (калечиться, искалечиться). Бэртелмә, тагын багарга булыр.

# В

**WAFAШ** *брб.д.* токмач (лапша). Полар wafaш та ашағысы килә, wafaш та пешерәм.

**WAFЫШEШ** *нокр.* тмин.

**WAЖҖAГA** *стрл.* к.: **нажағай**. Waжага уйный, ашлык пешәдер.

**WAЖҖMA** [*рус.* пазьма] *бөре.* бураның бер бүрәнәсен икенчесенә кую өчен уелган ырмавык (паз в бревне).

**WAЖҖЫГAЙ** *стрл.* к.: **нажағай**. Waжыгай уйный жиләк пешкәндә.

**ВАЗДУНАЙ** [*рус.*] *чст.* җәен әйберләр куеп тору өчен саман кирпечтән яки таштан төзелгән корылма (специальная постройка из саманного кирпича или камня, служащая для хранения летом одежды и др. вещей).

**ВАЗДУШ** [*рус.* воздушный] **1.** *минз., стрл.* к.: **баздуш**; **2.** *кмшл., шрл.* к.: **ваздунай**.

**ваздуш өй** *минз.* саман кирпечтән эшләнгән өй (дом из саманного кирпича); чаг.: **ваздунай**. Менә этинең төп йорты ваздуш өй. Әwәл читәннән дә саладырыйык, ваздуштан да саладырыйык.

**WAЗИЛКА** [*рус.*] *хвл.* салам тарттыргыч җайланма (волокуша для соломы).

**WAЙ** *тбл., төм.* гаҗәпләнү, кызгану, курку ымлыгы (междометие, служащее для выражения удивления, жалости, страха). Wай, туңып қалған қуй қуллары. – *тбл.*

**ВАЙАР** *кас.* Ока елгасының аргы ягы (противоположный берег реки Оки).

**ВАК** *тмн., лмб., кузн., хвл.*, **WAҚ** *төм.* валчык (крошка). Көнозын авызыма вак капмадым. – *тмн.* Икмәк wағыңны итәнгә ташлама. – *төм.*; **2.** *брб.д.* тигәнәк (репей).

**wақ қабартма** *мам.* к.: **май I: май күмәче 2**.

**wақ сату** *перм.* вак-төяк сату (продажа мелких товаров). Қазанныкылар wақ сату белән җөрәп сатқаннар қый тәңкәне.

**wақ сатучы** *мам., перм.* кырыктартмачы (коробейник). Wақ сатучы сатып җөридер ийе беләзекләр, җөзөкләр. – *мам.* Wақ сатучы татар булған, tawap сатқан. – *перм.*

**wақ сүләү** *байк.* к.: **wақсу II, 1**. Wақ сүли торган кеше инде ул, мөжгө.

**wақ тал** *перм.* к.: **тал: сары тал**.

**wақ чақта** *перм.* кечкенә вакытта, бала чакта (в детстве, когда был маленьким). Элек жау төшәләр ийе без wақ чақта.

**wақ шырлан** *лш.* сырлан (липучка).

**пыцкы wагы** *чпр.* пычкы чүбе (опилки). Пыцкы wагы сибәм йеләк арасына.

**WAҚЛAP** *тбл.* бала-чагалар, кечкенә балалар (маленькие дети). Wақлар үртәйделәр қосоқбашны, тәмле була инде. Сурғуттағы қыснықы wақлары килгән, кицәге қаймақны ашамайлар.

**WAҚCAP** *к.т.* вак, ваграк (мелкий, некрупный). Wақсар булды бәрәңгебез быйыл.

**WAҚCУ I 1.** *перм.* вакчыл (мелочный, любящий разбираться в деталях). Гөлсемнең әнкәйе бигрәк wақсу қарчық инде; **2.** *перм., минз., злт.* көйсез (капризный). Бигрәк wақсу баласы да, җанын қойа торған. – *минз.* Wақсу булдым да кечкенә чақта. – *перм.*

**WAҚCУ II 1.** *перм., к.-уф., злт.* вакчыллану (проявлять мелочность, мелочиться). Wақсып йөрмәле, йәме, исәнгерәп. – *перм.*; **2.** *минз., злт.* көйсезләнү (капризничать). Кит әле, wақсыма. Нәмәк кирәк тип қуйасың балалар wақсынған чағында. – *минз.* Баласы wақсый нийәдер. – *злт.*

**WAҚCЫЛ** *трх.* к.: **wақсар**. Житен йаңғыры wақсыл була инде.

**WAҚЧAH** *каз.ар.-крш.* к.: **wақсу I, 1**. Wақчан кеше түгел.

**WAЛ** [*рус.* вал] *мәл.* к.: **қыра III**.

**вал суғу** *әстр.* туфрак өю, вал төзү (засыпать, строить вал). Вал суғып иген игәде.

**WAЛЛAУ** [*рус.* вал+*афф.*-лау] *карс.* к.: **киштәләү**.

**ВАЛ′НИК** *кузн., карс., әстр.*, **ВАЛ′НИ′** *кас.* [*рус.* валенок] к.: **пима 1**. Вал′ник бастырдым. – *кузн.* Байа йаңғыр йawa, ул вал′никтан. – *карс.*

**ВАЛ′Н′ЫКА** [*рус.* валенок] *тмн.* к.: **пима 1**. Айагыбыздагы вал′н′ыкабызны салабыз да выргытабыз. Пич башына чүгән дә вал′н′ыкаларыбызны.

**ВАЛУ** *тмн.* ватылу, җимерелү (разбиться, испортиться). Машинасы валган.

**WAЛУ 1.** *минз.* эш эшләп ватылу (устать, утомиться, чувствовать себя совсем разбитым). Шул чақта (сугыш вакытында) wалып қалдық без; **2.** *перм.* чәрдәкләнү (размозжиться, раздробиться). Сөйәге wалып башына кергән.

**ВАЛУН** [*рус.*]: **үз валунына** *хвл.* үз дигәненә, үзенчә, үз җаена (по-своему, на свой лад).

**WAЛЦAҚ, WAЛЦAҢ** *тбл.* вак (мелкий, размельчённый).

**ВАЛЫХ** [*рус.* валух] *хвл.* печкән сарык тәкәсе (валух).

**ВАН′А** *хвл., чпр.*, **ВАНА** [*рус.* вона] *карс., мәл., чст., шрл.* әнә (вон). Ван′а кас′ын алып кил. – *хвл.* Кантура вана теге аның. – *шрл.*

**WAНА** [*рус.* вон] *кмшл., мәл.* к.: **ван′а**. Wана шунда торалар. Wана арба йасыйм. – *кмшл.* Wана wында туксан биш йәшлек карт бар. – *мәл.*

**ВАНАГЫНАК** [*рус.* вон + *афф.*-гынак] *миш.д.* к.: **ван′а**.

**ВАНАКАЙ** [*рус.* вон + *афф.*-кай] *карс.* к.: **ван′а**.

**ВАНЕ** [*рус.* вон] *кузн., стрл.* к.: **ван′а**. Теп урынбыз ване пычмакта. Ване, ване болотка керепкитте. Ване бырагың нихадәре димен. – *стрл.*

**WAН′E** [*рус.* вон] *стрл.* к.: **ван′а**.

**WAНИХАЙ** *тара.* чуалыш (путаница).

**ВАНЫ** [*рус.* вон] *стрл.* к.: **ван′а**.

**ВАР** [*рус.* вар] *лмб.* кайнап торган су (кипяток). Вар ман йугын май чиләген.

**WAР** *саз.я.* хәйләкәр (хитрый; хитрец).

**ВАРГАН** [*рус.* варган] *карс.* гармун.

**ВАРИГА, ВАРИК** [*рус.* варега] *тмн., лмб., кузн., хвл., срг., мәл., чпр.* к.: **били**. Ак варига, ак чылка кигән. – *тмн.* Варига үтәли кискән бармакла-

рын. – *лмб.* Варига бәлисеңме, пәрцәткәме? – *чпр.* Йон бирерсен варикларына. – *срг.*

**ВАРКЫЛДАУ, ВАРКЫНАУ** *хвл.* бакылдау (крякать – об утке). Үрдәк варкылдый. Үрдәкләре төнката варкынадылар.

**WАРЛАНУ** *саз.я.* хәйләкәрләнү (хитрить, стать хитрым).

**ВАРСУ** [вар + *тат.* -су] *м.-кар.* к.: **вар**. Варсуны кырчыгага саласың.

**ВАРУЧА** [*рус.* воротца] *кас.* терлек (сыер h.б.) кертә торган капка (ворота в скотный двор).

**ВАС'ЫЫ** [*рус.* вовсе] *шрл.* бик (очень). Ут-күздән сакланырга вас'ы әрәхат'.

**ВАТА** [*рус.* вот] *кузн., хвл., чст., чпр., мәл., карс.* менә (вот). Вата боларын ашагыз, йомшак кына. – *мәл.*

**WАТА** [*рус.* вот] *каз.ар., минз., перм.* к.: **бүтәнчә**. Касинканың бәйәсе wата очсыз. Әйе, кийенгәч wата матур төшми ул. Силусқа тоз сипсәң, wата малға да файдалы була ул. Баллы булгач, wата тәмне була. Көтмәгән қунақ wата қадерле була ул. – *дөб.* Wата жырақ монда сиңа. Wата иркеннәп күзләшә торған ийек. Кийәуле булгач, wата әйбәт. – *минз.* Wата дөрес инде Мәликәнеке. Wата қызғаныч инде, гөдрәйе. – *перм.*

**wата да** *дөб.* к.: **бүтәнчә**.Wата да тазарта ди ул әрем.

**ВАТАГЫНАК** [*рус.* вон + *афф.*-гынак] *мәл., срг., чст.* менә, менә ич (вот). Ватагынак бу кыз кад'а утыра. – *мәл.*

**ВАТАКАЙ** [*рус.* вот так + *афф.* -кай] *карс.* к.: **вата**.

**ВАТАККЫНА** [*рус.* вот так + *тат.* кына], **WАТАККЫНАСЫ** [*рус.* вот так + *тат.* кынасы] *карс.* к.: **вата**.

**WАТАЛҒЫ** *трбс.* чиләкнең тышкы ягын шомарта торган үткен инструмент (железный инструмент, предназначенный для шлифовки ведра).

**WАТҚЫЧ** *лш.* шикәр кайчысы (щипцы для сахара).

**WАТУ** *минз., стрл.* кыйнау (бить). Дабай ызначит моно wаталар кендек белә. – *минз.*

**ВАТЫ, WАТЫ** [*рус.* вот] *стрл.* к.: **вата**. Wаты бабай белә бертуган тутай бар иде бит. Ана wаты кайынныk булган, шул хатле матур булган. Ваты вет Газизгә бер врач ат'кән. Әле ваты бу малайны да ачуландым.

**WАТЫҚ: итмәк wатыгы** *тбл.* к.: **вак**.

**ВАТЫКАЙ** [*рус.* вот + *афф.* -кай] *стрл.* к.: **вата**. Әби, ватыкай пәке.

**WАТЫЛУ** *злт.* кыйналу (быть битым, избитым). Без генә нисә тапқыр wатылып қайттық.

**WАФИЛА** [*рус.* вафля] *минз., стрл.* формалы табада пешерелгән печенье (печенье, испечённое в специальной сковороде).

**WАФЫР** *тбл.* к.: **порам**.

**WАЦАҚ** *брб.д.* к.: **ағыс I**.

**wәғәдә** *урт.д.* вәгъдә (обещание):

**wәғәдә бүләге** *каз.ар.* к.: **билге II**.

**wәғәдә қылу** *брб.д.* вәгъдә итү (обещать).

**ВӘДӘК** [*фарс.*] *лмб., кузн., карс.*, **WӘДӘК** *карс., әстр.* к.: **мәдәк 3**. Вәдәкләр мынан итәләр кызны. – *лмб.* Элгәре шыл кыршау бегеп вәдәк йасаганнар, кешегә күргәзминчә, хаз'ыр вәдәге төбендә бийеп ала (кыз). – *кузн.* Бырыннарда вәдәг инде, вәдәк эчендә утыртыб алып киләләр кызны. Wәдәктә килмәдек, без килдек аламада. – *карс.*

**WӘЗДУШ** [*рус.* воздушный] *минз., стрл.* **1.** к.: **баздуш; 2.** саман кирпечтән салынган абзар (помещение, хлев из самана). Бер-ике көн өйдә кундырабыз да wәздушка чыгарабыз. – *стрл.*

**ВӘЗЕРКӘ** *хвл.* нәзек сыйраклы, ябык – хатын-кызга карата яратмыйча әйтелә (пренебрежительно говорят о женщине с тонкими ногами).

**WӘЗҮК** [*рус.* возок] *баст.* к.: **мәдәк 3**. Элгәре җәш киленне wәзүкка утырталар.

**ВӘЙКЕ** [*рус.* веялка] *чст.* к.: **җиллек I, 1**. Без элгәре вәйке әләндердек. Вәйке селкенмәстән бүрәнә куйа идек.

**ГӨРСӨМӘН** *яушт.* ишкәк (весло). Кимә ишеләсең гөрсөмәннәр белән.

**ГӨРТ: гөрт төшү** *лш.* кинәт каты кайгыга төшү, борчуга төшү (вдруг стать печальным, горестным).

**ГӨРШӘК** [*рус.*] *баст.* чүлмәк (горшок).

**ГӨС** *брб.д.* **1.** бөртек, тамчы (крупинка, крошка); **2.** бөртек (зерно, зёрнышко). Пер гөс қарағат йоқ.

**ГРӘЗНӘ** [*рус.* грядка, борозда?] *мәл.* к.: **герәдә**. Грәзнәләп чәчтек суганны да.

**ГРӘПЛӘ** [*рус.* грабли] *мәл., хвл., тмн.* тырма, кул тырмасы (грабли).

**грәпләле чалгы** *чст.* тырмалы чалгы (коса с граблями).

**ГРӘПЛӘЛӘҮ** [*рус.* грабли + *афф.* -ләү] *хвл.* тырмалау, тырмалап җыю (сгребать граблями). Печәнне грәпләләп бетердек.

**ГРӘПЛИЧӘ** [*рус.* грабловище] *кузн.* чалгы тырмасы (грабли на косе, грабли). Чалу чабабыз грәпличә белән, соло, виканы, борчак.

**ГРУЗҖА** [*рус.* груздь] *м.-кар.* к.: **гөрөздә**. Грузҗаны жарит итеп ашыйлар.

**ГРУПКА** [*рус.* грубка] *баст., срг.* плитә (плитка). Зур пич групка белән бергә. – *баст.* Әле пич йакмыйбыз, групка гына. – *срг.*

**групка пис** *кас.* икмәк пешерә торган өлеше һәм мич башы булмаган, әмма казанлы, плитәле мич (печь с плитой и очагом с котлом, но без лежанки и пода). Зур пислир йу' awылда, групкалар салдылар.

**групка пич** *срг.* к.: **групка**. Групка пич йаныптора, йылы.

**ГРҮНКӘ** [*рус.* горенка] *кас.* к.: **гуринча 1.** 'озлар грүнкәсе бул'ан.

**ГРЫЛА** [*рус.*] *мәл.* бугаз (горло).

**ГУБА** [*рус.*] *клм.* к.: **гоба**. Губаңа памада сөртеп чык.

**ГУWA** [*фарс.* гуаһ] *перм.* танык, шаһит (свидетель). Гуwалары булмаган да сут ачмаганнар әле. Күрүче булмагас, гуwа булмагас.

**ГУЗ'** [*рус.* гвоздь] *кузн., хвл., мәл.* кадак (гвоздь). Гуз'ларны сывырып-сывырып куйган идем, каадыр? Гуз'лар коргочларга кечерәк кирәк, былар выт зурлар. – *кузн.* Гуз'лармы кирәк? – *мәл.*

**ГУЗНА** [*рус.* козон] **1.** *минз., чст., мәл., чпр.* к.: **ашык II, 2**. Айагын мыннан кискәннәр, гузнадан. – *мәл.* Айак шешти, гузнасы да билгеле төгәл, буwыны да. – *чпр.*; **2.** *чст.* **ашык II, 3**; чаг.: **бәбер**. Малайлар гузна унилар идәндә.

**ГУЗНИКА** [*рус.* козонок] *перм.* к.: **ашык II, 3**; чаг.: **бәбер**. Малайлар беле гузника уйнап утыра.

**ГУЛ'АШ** *глз.* ит белән пешергән бәрәңге (картошка с мясом).

**ГУЛБӘЧ, ГҮЛМӘЧ** [*рус.* голбец] *т.кам.-крш.* к.: **кәберкә**.

**ГУЛИ** *тмн.* к.: **гелән**. Эч быша бүген гули. Базарга гули йөри, мин аны беләм. Минем картычкага авызым гули зур төшә.

**ГУМЕР: гумер барына** *мәл.* гомер буена (всю жизнь). Бергаҗир булды гумер барына.

**ГУМЕРЛӘНҮ** [*гар.* + *афф.* -ләнү] *чст.* гомер итү, тормыш итү (жить, проживать). Киң эчлийе, йакшы гумерләндек тә.

**ГУНАУ 1.** *мәл., хвл.* гөрләү (ворковать – о голубях). Күгәрченнәр гуныйдыр йаз башында. – *мәл.*; **2.** *хвл., лмб., мәл.* шаулау, улау (гудеть). Ыстулбалар гуныйберчегә, шындый җил. – *хвл.*; **3.** *лмб.* гүләү, гөрелдәү (гудеть, греметь). Минеке дә маторы гуний.

**ГУН'АУ 1.** *тмн., лмб., кузн., хвл., мәл.* к.: **гунау 1**. Голекай гун'идыр. – *тмн.* Бик гун'аулары йахшы. Күгәрчен гун'ый. – *кузн.* Күктә күк күгәрчен гун'ый. – *хвл.* Күгәрчен нидән гун'ыйдыр? Баласы бар да, сөте йук (*бор. жыр.*). – *лмб.*; **2.** *мәл., хвл.* к.: **гунау 2**. Тилигырам баганалары гун'ый, һава алышыныр, ахыры. – *мәл.*

**ГУНЙЫЛАТУ** [*удм.*] *глз.* күңелгә тию, үтләтү, биздерү – азык турында (надоесть, опротиветь – о пище). Тәбәгыйны эсселәй ашама, тапсаң йаман йакшы, калса гунйылата.

**ГУҢГИ** *м.-кар.* коңгыз (жук); чаг.: **гуңгыйк**. Навыс гуңгийе. Су гуңгийе.

**ГУПЧИ** *каз.ар., минз., трх., нрл., лмб.*, **ГУПЧИМ** *мам., каз.ар.-крш., т.кам.-крш.*, **ГУПЧЫ** [*рус.* вообще] *т.кам.-крш., минз.* бөтенләй (совсем). Борчакълы ашны гупчи ашамый ул. Балны гупчи эчми ул. Кенәген алган күмәч, ашамады гупчи. Гупчи сөт тәме килмий. Гупчи инде алай дип әйтмәдем. – *мам.* Гупчи уйламағанда җырлап җөрисен ул. – *блт.* Суганнарыңны йылкып бетерәләр инде гупчы анда. Аңа ун җыллар бардыр инде гупчим. – *т.кам.-крш.* Гупчы сине алай сөйләмәдем. – *минз.*

**ГУР'А** [*рус.*] *лмб., карс.* хәсрәт (горе). Гур'а күрегә чыкмагансыз, җибәргәннәрдер. Ас'л'ик йылны үги бала эстенә бардым, бик гур'алар күрдек. – *карс.* Әбийеңнен башыннан терле гур'а узган. – *лмб.*

**ГУРAWAT** [*рус.*]: **гурawат итү** *карс.* кайгыру (горевать).

**ГУР'АЛАНУ** [*рус.* горе + *афф.* -лану] *лмб.* к.: **хыйтлану**. Икәү гур'аланабыз кызым мынан.

**ГУРБА** [*рус.* горб]: **гурба чыгу** *нрл.* бөкре чыгу (сгорбиться, ссутулиться от непосильной тяжёлой работы). Сезгә эшләп гурбам чыккан.

**ГУРБАЙУ** [*рус.* горбиться] *перм.* бөкрәю, иелү (горбиться, нагибаться). Менә урак белән гурбайыб урасын ий.

**ГУРБУН** [*рус.* горбун] **1.** *нрл., мәл., чст.* к.: **көмөрө**. Аның бер гурбун қызына ышанып йөри бу җүләр. – *нрл.*; **2.** *мәл., чст.* к.: **уwа**. Аркасында гурбуны да бар. – *мәл.*

**ГУРБУН' I** [*рус.* гармонь] *мәл., чст.* гармун.

**ГУРБУН' II** [*рус.* горбун] *нокр.* к.: **уwа**. Апам сирле иде, арқасына гурбун' чыққанда иде.

**ГУРБУШ** [*рус.* горбуш] *перм.* к.: **көмөрө**. Тумыштан бәлекий буйлы, гурбуш ийе.

**ГУРЕНЧА** *лмб.*, **ГУРИНЦА** [*рус.* горница] *чпр.*

к.: **гуринча 1**. Гуренчага без чистый утын гына йагабыз. – *лмб.*

**ГУРИНЧА** [*рус.* горница] **1**. *лмб., кузн., хвл., срг., тмн., карс.* ак өй, кунак өе (горница; чистая половина избы). Йөгереп кереп гуринчага Лимун кистем йартылап (*бор. җыр.*). – *тмн.* Гуринча, кемнеке ызбасы бай, зур гуринча инде. – *хвл.* Әби гуринчада куна. – *кузн.*; **2**. *чст., чпр.* такта яки калай түбәле зур, биек һәм яңа өй (новый высокий дом с дощатой или жестяной кровлей). Нинди йакшы гуринча салды Хажи әзи. Аларның гуринчалары да бар бит Казанда. – *чст.* Гуринчасы бийеккә карама, үрәсе сийык (*мәкаль*). – *чпр.*; **3**. *лмб.* яхшы йорт (добротный, хороший дом). Этекай, йыртың тез тегел, Гуринча куйар төш тегел (*бор. җыр.*).

**ГУРЛА** [*рус.* горло] *миш.д., каз.ар.-крш.* к.: **грыла**. Ашарға булмас ийе, гурлалар әчетәдер ийе. – *каз.ар.-крш.* Гурласына сувык тигән, йүткерә. Апирацийә ийдә генә җасадылар, мына шыннан гурланы тиште. – *чст.* Җырла, җырла, киң гурла, Җырламасаң ни була (*хал. җыр.*). – *чпр.* Йаздан бирле ашыйм, ди, гурламнан тешми, ди. – *мәл.* Гурласы калын аның. Гурланңы киңәйтебрәк тор. – *шрл.* Зеңи цәй йасап керә, цәй гурладан тешми минем. – *чст.*

**ГУРЛ′АПА** *срг., мәл.*, **ГУРЛАФА** *стрл.*, **ГУРЛӘЙ** [?] *срг.* к.: **гөрләпә**. Гурл′апаның кабыгын сийырыб ашый идек. – *срг.* Гурлафалар җыйа идек утаганда, утырып ашый идек. Бу гурләй тегел микән, димен, йук, сары цәцәк булды.

**кычык гурл′апасы** *срг.* эт какысы (сурепка, сурепица). Кычык гурл′апасының тышы йынны, ашамыйлар, каты сабаклы.

**ГУРНИЧА** [*рус.* горница] **1**. *кузн., карс.* к.: **гуринча 1**. Йогырып кердем гурничага, Буйга йиткән кызым йук... (*хал. җыр.*). – *кузн.* Ак та гурничага керерсен дә, Вал′нигынны салып йерерсен (*бор. җыр.*). – *карс.*; **2**. *төм.* өйнең алгы өлеше (передняя часть дома).

**ГУРТ I** [*рус.*] *мам., дөб., лш., чст., хвл., мәл.* шәһәр (город). Гуртларда бийек-бийек думнарда йәшиләр. Гурт җирендә йуктыр шул алар (үләннәр). – *мам.* Кызым гурттан қайтты да, урманға киткәлләр ийе. – *дөб.* Бер wахытны китә ул гурттан гуртка. – *чст.* Әле тагы выт кире гуртка киткесе кели. – *хвл.*

**ГУРТ II** [*рус.*] **1**. *минз., мәл., чст., стрл.* көтү, мал көтүе (гурт). Берүзенә гурт чыгара торган байыбыз бар ийе. – *минз.* Анарда гурты белә сарыклар җери иде. – *стрл.* Элеке гурт кувалар иде, киң ийе ул йул. – *мәл.*; **2**. *мәл.* кош-корт көтүе, кош-корт төркеме (куча, множество, группа – о птицах). Тавыклары гурт выт, кәбәм, багам.

**гурт җийучы** *минз., стрл.* көтүе белән мал сатып алучы (покупающий скот гуртом).

**ГУРЫНЧА** [*рус.* горница] **1**. *мәл., тмн.* к.: **гуринча 1**. Урны гурынча кебек. – *мәл.*; **2**. *күрш.* өйалды (сени). Гурынчамда эрли утырам.

**ГУР′ЫНЧА** [*рус.* горница] *хвл., карс.* к.: **гуринча 1**. Эти эвендә, гур′ынчаларда, Кен дә йередем читек-кәвештән (*бор. җыр.*). – *хвл.*

**ГУРЫТ** [*рус.* город] *мам., злт.* к.: **гурт I**. Гурытта үскән бала қайан белсен қақыны. – *мам.* Менә шуннан қырық киламитыр гурыт бар. – *злт.*

**ГУС′** [*рус.* гвоздь] *хвл.* к.: **гуз′**.

**ГУСНИС** *мәл.*, **ГУСНИЦ** *срг.*, **ГУСНИЧ** [*рус.* гостинец] *мәл., хвл., кузн.* к.: **келчә 2**. Гуснис ашарга бардым. – *мәл.* Терле йактан гусниц килә. – *срг.* Менә, дигән, әнийемнән гуснич китердем. Гуснича китерәдер күрше кызы. – *хвл.* Гуснич китергән кем. – *мәл.*

**ГУС′УК** [*рус.*] *хвл.* терлекнең эчке органнары барысы бергә, эче-башы (внутренние органы животного: лёгкие, печень, почки и сердце). Малның гус′угы ул, үпкәсе дә, бавыры да, йөрәге дә керә. Гус′укны пешер әле, кывыр, йерәге, бавыры, үпкәсе бер кучада гус′ук була.

**ГУЧНИЧ** [*рус.* гостинец] *глз.* к.: **келчә 2**. Гучнич китергән кеше бу.

**ГҮБӘН** *минз.* юан, калын – кеше турында (толстый – о человеке); чаг.: **балбан**.

**ГҮWӘНДӘ** *нрл.* көянтә (коромысло).

**ГҮЛБӘЧ** *глз., нокр.*, **ГҮЛБИЧ** *перм., кузн.*, **ГҮЛМӘЧ** *глз.*, **ГҮЛМИЧ** [*рус.* голбец] *т.кам.-крш., глз., перм.* к.: **гелбәч**. Гүлбәчтәмени майыгыз? Күлмәкләрен гүлмичкә салып, балта белән чабып йандырды.

**ГҮМБЕК** *перм.* к.: **гөмбек**. Гүмбеккәрәк утыткан да, жыгылып төшә йазган (баласы).

**ГҮҢКӘЙҮ** *трх.* бүкән булып утыру, күзле бүкән булып утыру (сидеть болваном, сидеть как чурбан с глазами). Мин тиг утырган, гүңкәйеп утырған кешене йаратмыйм.

**ГҮПЧӘЙ** [*рус.* вообще] *минз.*, **ГҮПЧЕЛИ** [*рус.* вовсе + *афф.* -ли] *мам.*, **ГҮПЧИ** *каз.ар., минз.*, **ГҮПЧИМ** [*рус.* вообще] *минз.* к.: **гупчи**. Гүпчели дә охшамаған син анаңа. Гүпчи әйтмәгән икән ул. Гүпчи белмидерийем, кичә генә күрдем әле. – *мам.* Гүпчи беткән айағы. – *блт.* Гүпчи дәшмиләр дә мийа. – *дөб.* Син эшләмәгәнсең гүпчи. Гүпчим бөкөрәймәс ийе ул. Гүпчәй истә дә җуқ. – *минз.*

**гүр** (могила):

**гүрләр өсте** *м.-кар.* каберлек, зират (кладбище).

**ГҮРБӘЧ** [*рус.* голбец] *чст., каз.ар.-крш.* к.: **кәберкә**. Гүрбәчкә кердем дә җылар-җыламас торам. – *каз.ар.-крш.*

**ГҮРЕНКӘ** [*рус.* горенка] *кас.*, **ГҮРЕНЧӘ** [*рус.* горница] *баст.* к.: **гуринча 1**.

**ГҮРЕСТАН** [*фарс.*] *каз.ар.-крш.* к.: **гүр: гүрләр өсте**. Түбән Сын зираты диләр ийе, гүрестаннары билгелейе, шунда күмгәннәр татар буганда.

**ГҮРИНЧӘ** [*рус.* горница] *баст.* к.: **гуринча 1**.

**ГҮРЛӘНҮ** [*фарс.* + *афф.* -ләнҮ] *каз.ар., перм.* җәфа чигү, җәфалану (мучиться); чаг.: **алҗырау, бәлтерәү**. Гүрләнделәр-гүрләнделәр, апменә алмадылар (йөкне таудан). – *блт.* Элек гүрләндек инде суғулар белән. – *каз.ар.-крш.* Эшләп гүрлән-гүрлән дә тағын алар белән утыр монда. – *перм.*

**ГҮРЛӘҮ** [*фарс.* + *афф.* -ләү] *нокр., глз.* җирләү (хоронить). Апайымны гүрләмәгә йердем калаға. – *глз.*

**ГҮРМӘКЦӘ** *срг.* 1. к.: **рәшмән**. Гүрмәкцә ыйалаган. Гүрмәкцә төште, хабар килер; 2. пәрәвез (паутина). Цылбыр-цылбыр ызайадыр Көзге көнне гүрмәкцә (*хал. җыр.*).

**ГҮРНӘЧӘ** 1. *мәл., т.кам.-крш.* к.: **гуринча 1**; 2. *минз., т.кам.-крш., чст.* к.: **гуринча 2**. Гүрнәчә җиткерәләр бит. – *т.кам.-крш.* Синең гүрнәчәне дә карап чыгыйк әле. – *чст.*

**ГҮРНИСӘ** *эчк.*, **ГҮРНИЧӘ** [*рус.* горница] *тмн.* к.: **гуринча 1**.

**ГҮРШИ'** [*рус.*] *кас.* чүлмәк (горшок).

**ГҮС** *себ.* к.: **гөс 1**. Алтынны сумныкларым пар ите, пер гүс калган. – *брб.д.*

**ГҮСБӘТ** *нрл.* зур гәүдәле ялкау кеше (лоботряс, дородный, рослый, но ленивый человек).

**ГҮЧТӘНӘЧ** *мәл., т.кам.-крш.*, **ГҮЧТИНӘЧ** [*рус.* гостинец] *т.кам.-крш.* к.: **келчә 2**. Әзерәк гүчтинәч тә алып килгән тегеләргә. Ий, шулкадәр гүчтәнәчләр безгә куйганың син. Гүчтәнәч чәйем бар әле, шуны эчсәм, тереләм. – *т.кам.-крш.*

**ГЫБА** [*рус.*] *лмб., кузн., клд., карс.* к.: **гоба**. Гыбалары кипкән берче. – *карс.* Гыбаларын да тийермәделәр. Гыбаларым чабырткан. – *лмб.*

**ГЫЙБРӘТЛЕ** [*гар.* + *афф.* -ле]: **гыйбрәтле булу** *т.кам.-крш.* к.: **габратлы: габратлы булу**. Гыйбрәтле булган инде элеке кеше, ойала торган, инсафлы.

**ГЫWЫЗ** [*рус.* гвоздь] *кузн.* к.: **гуз'**. Бу ишеккә озын гыwыз кирәк.

**ГЫДЫРЛЫ** *срг.* кытыршы (шероховатый). Гыдырлы була кырык карта.

**ГЫЖ** *нгб.-крш.* бик күп, мыжлаган, бөтенләй (очень много, сплошь); чаг.: **айап**. Бу этәсем гыж бала йон.

**ГЫЖНЫЛУ** *мәл.* сулу кабу (задыхаться). Чабыша-чабыша бик каты гыжнылды. Бераз гыжнылды да инде.

**ГЫЙЛЛӘ** [*гар.*] *стрл.* к.: **ғыйллә 1**. Тегеләрнең гыйлләсен тагы сүлим инде, аларны сүләп бетәрлек түгел.

**ҒЫЙМАЛАУ** [*гар.* + *афф.* -лау] *әстр.* мактану (воображать, хвастаться). Менә, ғыймаладыңмы?

**ГЫЛАКУЛ** [*рус.* колокол] *карс.* кыңгырау (колокольчик). Беләсен иске wахытта нинди хал' иде, гылакуллар белән инде туй.

**ГЫЛБУ** *т.я.-крш.* 1. муенса (бусы); 2. мәрҗән, энҗе бөртеге (бисер, жемчуг). Гылбуларын йепкә тезеп муйынга элгән.

**ГЫЛДЫМ: гылдымга бару** *кузн.* кая баруын белдерергә теләмәгәндә әйтелә торган сүз (выражение, употребляемое в случае, если человек не желает говорить о том, куда он идёт). – Кайа барасын? – Гылдымга!

**ГЫЛДЫР** *лмб., тмн.* к.: **болдор**. Гылдыры бийек, менәлмәм; Кас'агы кыйык, керәлмәм; Минем бил генәм бик нәзек, Кан'ишка хезмәт бирәлмәм (*бор. җыр.*). Гылдыр аста. – *лмб.* Гылдырда сүләп тыра булганнар, аны күргәннәр. – *тмн.*

**ГЫЛДЫРЛЫ** *мәл.* к.: **гыдырлы**.

**ГЫЛИДУР** [*рус.*] *лмб.* коридор.

**ГЫЛЫШКУМ** [*рус.* голышом, голышком] *лмб.* к.: **галиш 1**. Гылышкум чыгалар урамга, балалар аза.

**ГЫМБАГЫШ** *шрл.* к.: **айбагар**.

**ГЫРАБЛ'А** [*рус.*] *тмн.* к.: **г(е)рәплә**. Былай гырабл'а белән йыйарга печәнне.

**ГЫРАДА** [*рус.*] *клм.* к.: **герәдә**. Бер гырада пийас, бер гырада кәбестә.

**ГЫРАЗАЛАУ** [*рус.* угроза + *афф.* -лау] *т.я., кмшл., чст.* бик нык янау, куркыту, каты кисәтү (угрожать, *жёстко предупредить*). Шырпыга қағылма дип, бик нык гыразаладым инде үзен (баланы). – *к.т.* Шулхәтле гыразалама инде. – *кмшл.* Ат бар, симинә бар күwенчә чәчми калсак, ди, эти шылай гыразалады. – *чст.*

**ГЫРАМУШКА** [*рус.* погремушка] *баст.* шалтыравык (погремушка). Гырамушкалар китердем, бир әле үзенә.

**ГЫРАН I** [*рус.* грань] *трх., чст.* 1. ара (расстояние). Әҗмәр белә Йамбакты (*ав. ис.*) гыраны җегерме чакырым булыр. – *трх.*; 2. к.: **герән**. Былынның бер кырыйы гыранга чыга. Чабыш атларының гыраны ан'а шонда. – *чст.*

**ГЫРАН II** [*рус.*] *бәр.* кран. Су барма гыранда?

**ГЫРАТ** [*рус.* гряда] *төм.* к.: **герәдә**. Пер гыратта пөтөнөсе укыруп, пер пийас, пер сәртәк йук.

**ГЫРБУН** [*рус.* горбун] *нрл.* к.: **гарбун 1**. Арқасында әпийе бар диләр гырбун кешене.

**ГЫРБЫУ** *тбл.* кырпу (опушка, выпушка, оторочка). Аның гырбыwы төлкөтәнмә, қаматанма?

**ГЫРДА** [*рус.* груда] *чпр., чст., клд., кмшл.* к.: **горда**. Иртәгә син гырда wатырсың. – *клд.* Гырданы куптарып-куптарып карагыз сез. – *чпр.* Ул йакта йул гырдалы. Сәнәскәгә утырып, гырдалардан дыңгыр-дыңгыр төшәсең. – *чст.*

**парн'а гырдасы** *чпр.* к.: **бәйсәкә**.

**ГЫРЖЫWА** [*рус.*] *твр.* челтәр (кружева).

**ГЫРЖЫWАЛЫ** [*рус.* + *афф.* -лы] *лш.* челтәрле (с кружевами). Гыржыwалы алҗапқычларым бар, дүрт балайтәк тотқан.

**ГЫРЖЫЛАУ** *мәл.* каты итеп, авырттырып ышку (сильно тереть – при мытье). Мынчада арканы йаңы мачалка белән гыржыладылар.

**ГЫРИБА** [*рус.* гриб] *карс.* гөмбәнең бер төре (вид гриба). Урманда күрмиләр дә мине, мин йерим гырибалар эчендә.

**ГЫРИЖ** [*рус.*] *лмб.* бүсер – хатын-кызларда (грыжа – у женщин). Гыриж катыннарда була, кила – ирләрдә.

**ГЫРИЛЧА** [*рус.* крыльцо] *карс.* коридор.

**ГЫРИП** [*рус.* гриб] *нокр.* к.: **гиби: сақ гиби**.

**ГЫРИС** [*рус.* грыжа] *кузн.* бүсер (грыжа).

**ГЫРЛА** [*рус.*] *лмб., кузн., лш.* к.: **грыла**. Су гырласыннан икән, батып китә йазган. – *лш.* Гырланны капла, сывык тимәсен. – *кузн.*

**ГЫРЛАФА** [?] *минз.* к.: **гөрләпә**.

**ГЫРУДА** [*рус.* груда] *минз.* ун-унөч көлтәдән куела торган чүмәлә: унысы утыртып, өчесе шулар өстенә ябып куела (форма сложения снопов в кучу, копна из десяти-тринадцати снопов).

**ГЫРЫЖ** [*рус.*] *әстр.* бүсер (грыжа). Гырыжлы бала.

# F

**FAWAҚ** *тара.* яфрак (лист).

**йамғырча ғawaқ** *тбл.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы.**

**татлы ғawaқ** *тара.* к.: **йара II: йара йапрақ.**

**ҒАЗИМДӘГЕ** [*гар.* + *афф.* -дәге] *каз.ар.-крш.* әллә кайчангы, борынгы, күптәнге (давнопрошедший, очень давний, древний). Ай, ғазимдәге ич бу камзул.

**ҒАЗНИЧ** [*рус.* козелец] *чст.* к.: **ирен I: ирен бозгыч.**

**ҒАЙАУ** *төм.* текәү (вперить, устремлять – взгляд). Күсеңне йиргә ғайап торасың.

**ҒАЙБЕРӘННӘР, ҒАЙБИРӘННӘР** [*гар.* + ирән] *мам., лш.* мифик җан ияләре (мифические существа). Ғайберәннәр җомга көннәрдә җәриләр, ди, чиста қапқа төбө була, керәләр, ди, чиста булмаса, кермиләр, ғайберәннәр безгә күренмиләр алар. – *лш.* Ғайбирәннәр ир кешеләр алар, безнеңчә, Аллаһы Тәғәлә қушқан аларны. Ғайбирәннәр бар, өч җөз алтмыш кеше диләр, алар кеше, фирештә түгел. – *мам.*

**ҒАЙШӘБИКӘ** [*гар.* + *тат.*] *блт.* к.: **бийауса.** Ғайшәбикә, кийәwең килә, қач, тимер қапқаңны ач.

**ҒАЛА-ҒАЛА** *төм., тбл.* каз чакыру ымлыгы (междометие, употребляемое при подзывании гусей).

**ҒАЛАЧ** *клм.* бәрәңге пәрәмәче (ватрушка с картошкой). Картопкалы ғалач пыжыра тоғаннарты.

**ҒАЛҒАЛАҚ** *тбл.* к.: **бала I, 2.**

**ҒАЛТАҚ** *перм.* гаҗәпләну сүзе (слово, выражающее удивление). Ғалтақ, шуны йазалмадың! Үләм, ғалтағым, төннә икмәк пешерә.

**ҒАПУЛЕК** [*гар.* + *афф.* -лек] *брб.д.* гафу (прощение, извинение). Ғапулек сура.

**ҒАПШЫРМА** *төм.* чия һ.б. җиләк-җимештән пешерелгән зур сумса (пирог полукруглой формы из ягод). Чийә пиругы бу, чийә ғапшырма.

**ҒАРАЗАЛАУ** [*гар.* + *афф.* -лау] *к.т.* ялыну, ялвару (упрашивать, просить, умолять). Шырпы беткән, йалынып, ғаразалап сорадым сатучыдан.

**ҒАСАБА** [*гар.*] *минз.* ир бала, варис (наследник).

**ҒАТ** [*рус.* гать] *трх.* күтәртелгән юл (насыпь). Алар ғаттан әйләнеп төшкәннәр, ауғаннар.

**ҒАТАРЫ** [*гар.*] *төм.* хәтле (с – предлог). Ошо ғатары соло ғойалар (салалар) кесәмә.

**ҒАТМА** *себ.* җеп ката торган орчык (большое веретено для ссучивания нити). Ғатма белән цыйратацыс, түбә тақтада түңгәрцәк пула, шаннан төшөрәпес тә. – *тбл.* Туқта, мин сиңа ғатманы та гүрсәтәйен, орцоқно та гүрсәтәйен. – *төм.*

**ҒАТУ** *төм.* тагу (надевать, надеть – бусы). Пы йаулыққа ғата тыған (торган) мунцақ та бар ғуй.

**'АУ'АЛАМА'А** *кас.* к.: **абдырау.** 'ау'аламайсынмы?

**ҒӘЗБЕ** [*гар.*]: **ғәзбе қабару** *кргл.*, **ғәзбе килү** *бгрс.*, **ҒӘDБЕ** [*гар.*]: **ғәdбе қабару** *тпк.* ачу килү (сердиться, рассердиться, разозлиться). Аңа ғәзбесе қабарып китә. Минем аңа ғәзбе қабарып тора әле. Ғәзбем килде, ди, бик ғәрләнгән инде. Ғәdбесе қабарып киткән тә, пирмәйем тигән.

**ҒӘЙЕП** [*гар.*]: **ғәйеп булу** *трх.* (читкә китеп) юғалу, юкка чыгу (пропасть, исчезнуть). Балаларын қалдырып қайа ғына ғәйеп булды икән дим.

**ғәйеп қунақ** *т.я., каз.ар.* көтелмәгән, чакырмыйча килгән кунак (гости, пришедшие неожиданно, без приглашения). Сез ғәйеп қунақлар. – *трх.* Ғәйеп қунақлар икәнсез алайса, чәй эчеп алыгыз, қунақ булыгыз. – *мам.* Ғәйеп қунақ килсә, соңғы әпәйеңе дә чыгарасы. – *к.т.*

**ҒӘЙЕПЛӘНҮ** [*гар.* + *афф.* -лән ү] *тпк.* кулга алыну (быть арестованным). Ғәйеплән де ул, минем аһым төштө.

**ҒӘЙЕТЛӘҮ** *тбл., твр.* Гает бәйрәме итү (праздновать праздник Гаит). Элке ғәйетләгән әйбәтләп. – *твр.* Әле генә ғәйетләтеләр қуй (бит). – *тбл.*

**ҒӘЙШӘБАНУ** [*гар.*] *блт.* к.: **бийауса.** Ғәйшәбану, ғәйшәбану, кийәwең килә, алтын қапқаңны ач та қач.

**ҒӘЛӘМӘТ** [*гар.*]: **ғәләмәт итү** *тпк.* тәртипсезләнү, тәртип бозу, тупас шаяру (нарушать порядок, проявлять невоспитанность, дебоширить). Гармун уйнап ұтсә, ғәләмәт итеп йөрсә, хөкемгә сақыралар ийе.

**ҒӘРРӘ** [*гар.*]: **ғәррә туйу** *злт.* бик нык тую (наесться, пресытиться). Қырық биш тийенгә ғәррә туйдым.

**ғәррә былып ашау** *злт.* туйганчы ашау (есть досыта, наесться до отвала). Өйдә ғәррә былып ашап килсәм дә, шулхәтле тәмне былды ул өспосмақ.

**ҒӘТ** [*фарс.*] *минз.* усал, явыз, күрә алмаучан (вредный, злой). Килендәшләрем генә ғәт булдылар.

**ҒӘТИФӘ** [*гар.*]: **ғәтифә җим** *перм.* к.: **бырцак: бырцак үләне.**

**ҒОҒОРА** *нокр.* кошларның тын юлы (дыхательный путь у птиц).

**ҒОЗЕР I** [*гар.*] *кргл., бгрс.* кимчелек, авыру (изъян, болезнь). Айағында әзрәк ғозере бар. – *кргл.*

**ҒОЗЕР II** [*гар.*] *дөб., бәр.* рәхәт, иғелек (добро, благо, польза), чаг.: **асу II.** Апайыбыз биг әйбәт, балаларының ғына ғозерен күрмәде. – *дөб.*

**ҒОЙОН** *клм.* әйе, әйтмә дә инде (да, не говори, действительно так).

**ҒОЙОУ 1.** *тара., тбл.* кою (налить, наливать). Цай ғойоу. Ғойайым цай тағын; **2.** *тбл.* салу, тутыру (сыпать, насыпать). Кесәгә соло ғойоу.

**ҒОЙРОҚ: қара ғойроқ** *туб.-урт.д.* ас (ғорностай).

**ҒОЛБАҒЫШ** *дөб.* к.: **айбағар.** Ғолбағышны хәзер силусқа ғына салалар.

**ҒОЛДОРДЫҚ** *злт.* к.: **ғоғора.** Суйган үрдәкнең ғолдордығын тартып алып песәйгә бирдем.

**ҒОМБАҒАР** *трх.*, **ҒОМБАҒАШ** *минз.*, **ҒОМБАҒЫШ** *кргл., бгрс.*, **ҒОМБАҚТЫ** *каз.ар.-крш., трх.*, **ҒОМБАһАР** *трх.* к.: **айбағар.** Ғомбаһар бирим малайға. – *трх.* Кичә улым қырдан қайтты, тары

шушылай, ди, ғомбағыш әдәм буйы, ди. – *бгрс.* Ғомбақты майы сатты. – *каз.ар-крш.*

**ғомбағаш башағы** *минз.* көнбагышның тәлинкә сыман түгәрәк башы (головка подсолнуха).

**ҒОМЕРЗАЙА** [*гар.* + *тат.*] *эчк.* умырзая (подснежник). Йалан ғына йердә, сәхрәләрдә Ғомерзайа сәскәсе үсә (*хал. җыр.*).

**ҒОНАҒА** [*гар.*] *клм.* гөнаһ (грех). Ғонаға аласың, йаңлыш угысаң Көрәнне.

**ҒОРДА** [*рус.* груда] *каз.ар.-крш., кмшл., злт.* оешып каткан балчык, кантар (глыба, ком). Ғорда-ғорда қалган бақча. – *кмшл.* Җир өстө гел ғорда йы, шуны watып утырттық бәрәңгене. – *каз.ар.-крш.* Ғордалы йердән алып барма инде. Бәрәңге бақчасы ғордалы, тырматywы awыр. – *злт.*

**ҒОРЙАН** [*гар.*] *к.т.* к.: **ғорйан**.

**ғорйан булу** *дөб.* аптырау, тилмерү (нуждаться, бедствовать, мучиться). Ғорйан булдым сөт белән чәй эчәргә. Папкыға да ғорйан булып йәшибез завыскылат awыргач.

**ҒОСОҚ** *себ.* эрбет чикләвеге (кедровый орех).

**ғосоқ циртү** *себ.* эрбет чикләвеге ашау (грызть орехи). Циртәмсең ғосоқ, пирәйенмә. – *тбл.*

**йомро ғосоқ** *төм.* әчтерхан чикләвеге (грецкий орех).

**кийәү ғосоқ** *туб.-ирт.д.* кияү тарафыннан махсус янчыкта күчтәнәчкә алып киленә торған эрбет чикләвеге (кедровые орехи, специально привезённые женихом для угощения только что переселившейся невесты).

**қытай ғосоқ** *төм.* җир чикләвеге (арахис). Кийәү ғилепте (килгән), қалтасынта қытай ғосоқ аппақ, уртасынта пил өсөклө.

**самар ғосоқ** *төм.* к.: **йомро ғосоқ**.

**ҒОТТА** [*рус.* годе, годи...]: **ғоттадан чығу** *минз.* чыгырдан чыгу (выбиться из колеи, выйти из терпения). Былтыр алты шуфир булды, кийәү қайтқан ийе қыз белә, готтадан чықтық.

**ҒӨДӨРЛЕ** [*гар.* + *афф.* -ле] *минз.* кимчелек (изъян). Аның бер күзе ғөдөрле, ақ төшкән буғай.

**ҒӨЗӨР** [*гар.*] *дөб., бәр.* к.: **ғозер II**. Ул үз эшенең ғөзөрен җибәрә. – *бәр.*

**ҒӨЛЛӘ** [*гар.*] *төм.* кәфен (саван). Гөлләләр кисәте кеше үлгәц.

**ғөмөр** *урт.д.* гомер (жизнь, время от рождения до смерти):

**ғөмөр бақыйына** *минз.*, **ғөмөр барына** *минз., трх.* гомер буенча, гомергә (на всю жизнь, всю жизнь). Ғөмөр барына бергә эшләп килдек. – *трх.*

**ҒӨМӨРЗАЙА** *эчк.* умырзая (подснежник, прострел раскрытый).

**ҒУЙ** *себ.* к.: **қый I**. Қырық пиштә соуғыш пөттө ғуй. – *брб.д.*

**ҒУҢҒЫЙҚ** *к.т.* тирес коңгызы (навозный жук). Ғуңғыйқ тирес астыннан чыға, қара төсе, қойашта җәшел булып күренә.

**ҒУПЧИ** [*рус.* вообще] *кмшл.* к.: **гупчи**. Ғупчи күрмәдем, күргәнем йуқ.

**ҒУРА** *туб.-ирт.д.* абзар (хлев). Ғураға йаңа гергән мал күwек. – *тара.* Мал ғуралар йасапты. – *тбл.*

**сыйыр ғура** *туб.-ирт.д.* сыер абзары (коровник).

**ҒУЦ** *туб.-ирт.д.* куныч (голенище). Царық қысқа ғуцлы пулған. – *тбл.*

**ҒУЧЛЫҚ** [*гар.* +*афф.* -лык] *трх.* комсызлык (жадность, алчность).

**ҒЫWЫНТЫ** *төм.* куылган, килмешәк (отверженный). Йақ-йаққа ғыwынты былып йөрөтөм, ағацны йыртып, сағыс агыстық, анан турыф кискәле партым.

**ҒЫЗЕР** [*гар.*] *дөб.* к.: **ғозер II**. Әйберенең ғызерен күрмәдем.

**ҒЫЙ** *төм., төр.* к.: **қый I**.

**ҒЫЙА** *брб.д.* ғына, кына (только – в ограничительном или усилительном значении). Тәрәсә төбентә таш йатар, аны ғыйа ал.

**ҒЫЙЛЛӘ** [*гар.*] **1.** *минз., тпк.* мажара, хәл (приключение, происшествие, случай). Күп ғыйлләләр булды инде анда, пелиндә. – *минз.* Күрмәгән ғыйллә қалмады. – *тпк.*; **2.** *минз.* хикмәт, сер (секрет, тайна, загвоздка). Төшә дә китә ул, қай җирендә ғыйлләсе, белмәйем.

**ҒЫЙЛЫ: пер ғыйлы** *төм.* бертөрле, бертигез (одинаковый, одинакового размера). Йецкә талны бер ғыйлыны алып қайттым.

**ҒЫЙЛЫҚТА: пер ғыйлықта** *төм.* бертиғез, бер зурлыкта (равный, одинаковый по размеру). Игесе бер ғыйлықта булсын.

**ҒЫЙНАWА** [*рус.* гнев]: **ғыйнаwa қуу** *блт.* үпкә саклау, ачу саклау озак вакыт үпкәләп йөрү (таить обиду, злобу).

**ҒЫЙРА: ғыйрасы килү** *туб.-ирт.д.* ялкауланy (лениться). Ғыйралары киләте, эшләмәйтләр. – *төр.*

**ҒЫЙРАЛЫҚ** *төм.* ялкаулык (леность, лень). Ғыйралықларыннан сыйырны бөтөргәннәр.

**ҒЫЙШЫҚ** *төм.* кыек (кривой, косой). Ирләр гөйләгә ғыйшық йағалы, төймәләр тесеп.

**ҒЫЙЫНЦЫЛЫҚ** *тара., төр., төм.* авыр, яшәве кыен булган (трудный, тяжёлый – период, время). Ул ғыйынцылық wақыт. – *тара.*

**ҒЫЙЫШ** *тара.* килешми торган, урынсыз (неуместный, не к месту). Пер ғыйыш сүс әйтсә, орошматым та, қауғалашматым та.

**ҒЫЛБАҒЫШ** *дөб.* к.: **айбағар**.

**ҒЫЛУ** *тбл.* **1.** итү (делать, сделать, составить). Сап-сары көлцән (көлчә), олло ғылмапты; **2.** ясау (делать). Туй ғылып пирделәр, қорт-қайақларны цағырып, қатемнәр угытып, ашлар үткәсеп.

**ҒЫРҒАРА: ғырғара килү** *злт.* талашу (скандалить). Үзара ғырғара килеп йәшәсәләр дә, кешегә күрсәтмиләр.

**ҒЫРҒЫРА: ғырғыраға килү** *тпк.* **1.** хәлдән таю, бик нык ару (сильно устать, выбиться из сил). Уф, ғырғыраға килтем қadлар қywып, noday әдләп; **2.** җәфалану, иза чигү (мучиться, выбиваться из сил). Ғарип ата белә мин сине ғырғыраға килеп үстердем.

**ҒЫРҚЫЛДЫҚ** *лш.* ғырлый торган (храпун). Бабай бик ғырқылдық дип, тышта йоқлаған була.

# Д

**ДАБРА** [*рус.* тавро] *перм.* атка һәм башка йорт хайваннарына салына торган тамга (тавро); чаг.: **белдә**.

**ДАБЫРСУ: кеңел дабырсу** *мәл.* к.: **давырсу: кеңел давырсу**. Сине кетә-кетә кеңелем дабырсып бетте.

**ДАWАДАҚ** *эчк.* к.: **дуwадак 1**.

**ДАWАЙЛЫҚ: башын дawайлыққа салу** *бәре.* юләр булып кылану (прикидываться дурачком). Дөнҗа көтә алмаган, башын дawайлыққа салган. Исәр түгел ул, башын дawайлыққа салып җөрөй инде.

**ДАWАЛ** *минз.* зыян (вред, урон, ущерб). Башына чир төшсә, малыңа дawал тийәр (*әйтем*).

**ДАВЫРСУ: кеңел давырсу** *мәл.*, **ДАWЫРСУ: күңел дawырсу** *к.т.* хәвефләнү, тынычсызлану (тревожиться, беспокоиться). Кеңел давырсып тыра, нәстә булыр инде.

**ДАWЫРСЫНУ** *трх.* **1.** күңел күтәрелү, дәртләнү (подбодриться, воодушевиться). Кеше килгәч, әйтәм, дawырсынып китәм; **2.** ашкыну (стремиться, жаждать); чаг.: **адалану 2**.

**ДАҒАН 1.** *каз.ар.-крш., трбс.* таган (качели). Оло бәйрәмдә даған аса торғаннар ыйы өч-дүрт төшкә биг эшәб итеп, анда бөтөн awыл халкы җыйыла торған ыйы – җәше-қарты. – *каз.ар.-крш.*; **2.** *лш., к.т., кмшл., чст.-крш.* таган (верёвочные качели). Даған атыну. – *кмшл.* Башы әйләнгәнче даған атынған. Өй тирәсендә уйнасыннар дип, даған асып бирдем үзләренә. – *к.т.* Алты даганнарның ағачы, Жиденчесе аның түбәсе (*хал. җыр.*). – *чст.-крш.*; **3.** *минз.* шеш, кибән шеше (стожар). Даған утырта торган ыйық, аннан тайау қуйасың. Тайау дағанны тотып тора, астан җилләп торырға, печән җиргә тийеп торып бозылмасқа да йахшы була.

**ДАҒАНА** *кргл.*, **ДАҒАНЫЙ** *лш.* к.: **даған 2**. Дағана атынабызмы? Дағаный атындығызмы?

**ДАҒЫ** *әстр.* -че – кисәкчә (частица – же). Шул йырларды йырла дағы.

**ДАҒЫРДАУ** *әстр.* сөйләшү (раговаривать).

**ДАДЫ** *нрл.* азык, җим (питание); чаг.: **зим I, 2**. Жуқ, чимәнкенең тамыры җирнең дадын ала.

**ДАЙА I** *минз.* сиртмә, бишек тирбәтү өчен куелган озын агач (длинная жердь, на которую подвешивается колыбель).

**ДАЙА II** *тбл.* әни, туйдыручы (кормилица).

**ДАЙАНУ** *әстр.* түзү, чыдау (терпеть, выдерживать). Шкула йана, маллар йана, тawышына дайанып булмый.

**ДАЙАР** [*фарс.*] *нгб.-крш.* әзер (готовый). Инде болар килергә самawыр шаулап утыра, май табақлары дайар була.

**ДАЙАРЛАУ** *нгб.-крш.* әзерләү, әзерләп кую (готовить, приготовить). Син килә дип дайарлап қуйдым.

**ДАЙДУК** *тмн.* к.: **йастык I**.

**ДАЙНА: дайна чабу** *кмшл.* бик күп йөрү (много ходить, гулять).

**ДАЙЧЫ** [*рус.*] *лш.* дача. Дайчы алдырмады атасы, менә шушы өй сезгә, диде.

**ДАЙЫМ-ДАЙЫМ** [*гар.*] *кузн., срг., дөб.* һаман, һаман саен, һәрвакыт (всегда, постоянно); чаг.: **берче 1**. Тәрәзә төбем исле гөл, Ислөнәмен исенә; Дайым-дайым, сәйәт сайын Син төшәсен исемә (*хал. җыр.*). Дайым-дайым ат′ инде. – *срг.* Дайым-дайым минут сайын, сине көтәм, бәғырем. – *дөб.*

**ДАЛА** *кргл., чст.* кыр (поле). Қарлыған далада да күп, өйдә дә бар. Иртәгә көн матур булса, далаға чығарсыз. – *кргл.* Далага китте бригадир. – *чст.*

**ДАЛГУШ** [*рус.*] *кас.* элек байлар җигә торган алты-җиде кеше сыярлык йомшак утыргычлы озын арба. Бу арбаның аяк куярга да җайланмасы була; утырып баручылар бер-берсенә аркаларын куеп утыра торган булалар (повозка на длинном ходу, долгуша).

**ДАЛМАЧ** *минз.* тылмач (переводчик).

**ДАН** *эчк.* әйбәт, яхшы (хорошо); чаг.: **аван**.

**ДАНДУРАЙ** *хвл.* балалыгы чыгып бетмәгән кешегә карата әйтелә (легкомысленный, ребячливый); чаг.: **дилдарай**.

**ДАНЛАП** [дан + *афф.*-лап] *эчк.* яхшылап, әйбәтләп (хорошенько). Йоқлап алдығызмы данлап?

**ДАҢГЫЛ: даңгыл эстип** *тмн.* кола ялан (пустынная голая степь). Йир булмаган, йарлы булганнар, килгәннәр бире, даңгыл эстипкә утырганнар.

**ДАҢГЫРТ** *хвл.* дөңгерт (бац – междометие).

**ДАРАЙ** [*фарс.*] 1. *каз.ар.-крш., әстр.* ефәк (шёлковый). Жаулық бүләг иткән жегете, қызыл дарай жаулық. – *каз.ар.-крш.* Әстерханда қышладым, Дарай туннар тышладым (*хал. жыр.*).

**ДАРАЙЛАНЫП** [*фарс.* + *афф.* -ланып]: **дарайланып шешү** *лш.* тулышып, кызарып шешү (сильно распухать). Сыйырның имийе дарайланып шешкән.

**ДАРАЙЛАР** [*фарс.*] *кузн.* асыл чүпрәкләр (кусочки красивой материи).

**ДАРАНА: дарана кебек шишү** *злт.* к.: **дарайланып: дарайланып шешү**. Айағы дарана кебек шишкән.

**ДАРБАЙУ** *перм.* тырпаю (взъерошиться, топорщиться). Үскән печине дарбайышып тора да шартламаныкы, ийәреп килә.

**ДАРБЫҚ** *перм.* **1.** як-якка җәелгән, таралып үскән агач (раскидистое дерево); **2.** аягын ике якка җәеп, килешсез кыяфәт белән йөруче кеше (человек, который ходит неуклюже, широко раставив ноги); чаг.: **чапрыш 1**.

**ДАР-ДОР** *хвл.* дуамал (сумасброд, безумец). Аларның ул малайлары бер дар-дор инде.

**ДАРҚАС** [*фарс.*] *нокр.* зинһар (пожалуйста). Дарқас уқ утыр әле, Нәфис, дарқас уқ утыр.

**ДАРҚАСЛАУ** *т.кам.-крш.*, **ДАРКАСЛАУ** [*фарс.* + *афф.* -лау] *лмб.* зинһарлау, үтенү (настоятельно просить, умолять). Дарқасламасаң да әйтер-

мен, әзерәк көт. Дарҡаслый-дарҡаслый аптыратып бетерде. – *т.кам.-крш.* Ул инде даркаслады, ал, ди. – *лмб.*

**ДАРМАН** [*фарс.*] **1.** *кузн.* чара, юл (способ, метод). Бу эшнең дарманын таптым, эшләнә инде; **2.** *кузн., лмб.* дару (лекарство). Аптиктан дарман алдым. Дарманың килеште. Бу үләннән дарман йасыйлар. – *кузн.* Әнкама дарман йыйам, үлмәсен. – *лмб.*

**ДАРМАНА** *чст.* к.: **албидрә**.

**дармана үләне** *дөб.* к.: **албидрә**.

**ДАРМАНГА** [*рус.* даром +*афф.* -га] *кузн.* бушка, тик торганда (зря, напрасно, впустую).

**ДАРС: дарс итеп** *тмн.* көтмәгәндә (неожиданно). Дарс итеп килеп керде кийәвем.

**ДАРХАСЛАП** [*фарс.* + *афф.* – лап] *срг.* хөрмәтләп, зурлап (торжественно, с почестями). Анда инде килделәр безне дә дархаслап йәшергә.

**ДАРЫ I** *минз.*, бөре. тары (просо). **Йалҡау Ниса басуда, Үзе башын ҡашуда; Чүпсез үсә дары, Утамай да йарай (*такмак*). – *бөре*.** Быйыл бездә дары бик уңды. Кичә дары ботҡасы пешердек. – *минз.*

**дары йарма** *к.-уф.* тары йармасы (пшено). Дары йарма бирәм сипейләргә.

**ДАРЫ II** *срг.* к.: **дарман 2**. Дарымы эцеп багасын әллә? Барын дарыларын китерә, банкалар сала.

**ДАРЫ III** *т.кам.-крш.* христианнарда изге су (святая вода у христиан). Дары эчертергә чиркәүгә алып баралар ыйы.

**ДАРЫЛУ 1.** *хвл.* усалланып ыргылу, һөжүм итү (набрасываться злобно); **2.** *мәл.* омтылу, талпыну (порываться, пытаться). Шоны ничә тынап этергә дарылдым, ну этмәдем; **3.** *мәл.* сузылу, тартылу (тянуться). Кабактан кергәч үк миңа дарылды.

**ДАСМАЛ** [*фарс.*] *глз.* тастымал (салфетка, маленькое полотенце). Чынайак дасмал, кул дасмал, айак дасмал була.

**ДАСТАН** [*фарс*] *трх.* мөнәҗәт (мунаджат). Кеше атына чыҡҡан Ҡазандан, бер дастан әйтеп ҡибәр?

**ДАСТАР** [*фарс.*]: **дастар баш дыту** *глз.* мәет юганда өстендә ҡәймә тотып тору (при омовении покойника держать над ним покрывало). Дастар баш дыттым.

**ДАСТАРХАН** [*фарс.*] *әстр.* ашъяулык (скатерть). Кийезне түшәде, мендәрне салды, безгә дастархан ҡәйде, ҡодағыйлар утырдыҡ.

**ДАСТУЙ** [*рус.* достоин] **1.** *кмшл., чет., бгрс., кргл.* зур гәүдәле, озын буйлы кеше (рослый, здоровый человек); таг.: **алапа**. Усман безнең бик дастуй, бар эшкә дә кулы йата. – *чст.* Дастуй ғына қыз иде, кечерәйеп ҡалған. И, дастуй булып китте, бичарақай. – *бгрс.*; **2.** *кргл.* таза, сәләмәт (здоровый). Йөрәк дастуй, шуның бедән генә йөреп ҡайттыҡ.

**ДАСТУЙЫН** [*рус.* достоин] *блт., мам., минз., нгб.-крш., злт., трбс., бгрс., кргл., шрл.* к.: **дастуй 1**. Мин дастуйын түгел. – *блт.* Улым бида дастуйын минем. – *нгб.-крш.* Барыбыз да дастуйын, жиде килен бер кыруклық. – *кргл.* Атасы шикеле дастуйын. – *злт.* Дастуйын улы бар. – *мам.*

**ДАСТУК** *мам.*, **ДАСТУП** [*рус.* заступ] *нокр.* к.: **қырғыч 1**.

**ДАСТЫЙН** [*рус.* достоин] *минз., бөре.* к.: **дастуй 1**. Ансы буйга дастыйн. – *минз.*

**ДАСТЫМАЛ** [*фарс.*] *глз., нокр.* тастымал (салфетка) для рук.

**ал дастымал** *глз.* к.: **алсузма**.

**ДАУ: дау күтәрү** *срг.* тавыш чыгару (поднимать шум, скандалить). Дау күтәрмә инде, олым, дим.

**ДАУЛАТЫП: даулатып атлар жигү** *перм.* яхшы атлар жигү (запрягать лихих коней). Даулатып атлар жигәләр, қырын-қырын сикереп кенә килә инде атлар.

**ДАУМАК** *күрш.* уен-көлке (веселье, развлечение). Эрлим, тугим, даумак, уникегә тәке утырайдек.

**ДАХАТ** [*гар.*] *кузн., хвл., срг., тмн., минз.* тәкать, түземлек, чыдамлык (терпение). Тату, йакын идек, үлде бит ыл, йылап дахатым бетте. – *хвл.* Дахатым бетте. – *тмн.* Дахатыңы бетерә. Дахатым калмады, арыдым, кыр артыннан йәйәү кат′тым, бакчы. – *кузн.* Эшкә тотонсалар, дахатлары бетә. Дахатым беткенчәк чабадыр идем. – *хвл.*

**дахаттан калу** *лмб.* хәлдән таю, нык ару (сильно устать). Утадым да высы дахаттан калдым.

**ДАХАТ-ДАРМАН** [*гар.*] *хвл.* к.: **дахат**.

**ДАһАТ** [*гар.*] *мам., кузн.* к.: **дахат**. Даһаты бетеп арыды көне буйы, әле туйдым анай, ди. – *кузн.*

**ДӘWАД** [*фарс.*] *стрл.* к.: **путемар**.

**ДӘWӘ** *трх., әстр., кргл., чст.* дөя (верблюд). Биш дәwәләре бар, өч йәшәрлек дәwә. – *трх.* Дәwә жоно салады мендәргә. – *әстр.* Дәwә ите ашыйсызмы? – *кргл.*

**ДӘWӘЙҮ 1.** *каз.ар.-крш., мам., трбс.* зураю, эреләнү (увеличиваться в размере). Лискуз жылдан-жыл дәwәйә. – *каз.ар.-крш.* Кишерегез дәwәйгән. – *мам.*; **2.** *дөб.* эреләнү, тәкәбберләнү (загордиться). Дәwәйеп киттеңмә хәзер?

**ДӘWӘНИ 1.** *каз.ар.* к.: **абызз′ыңкай**; **2.** *т.я.* этисенең беренче хатынына яшь хатын балалары шулай эндәшә (форма обращения детей от второго брака к первой жене отца); **3.** *злт., кргл.* к.: **абыз 2**; **4.** *злт., кргл., т.кам.-крш.* әнисенең абыйсының хатынына эндәшү сүзе (форма обращения к жене старшего брата матери). Дәwәни, Wалирий абый бер кыз апкилә йата, ди. – *кргл.*

**ДӘWӘТ I** [*фарс.*] **1.** *минз., бөре., бгрс., кмшл., стрл., шрл.* к.: **путемар**. Қунаққа барғанда қалфақ кийәдерийек, дәwәт кийәрийек. – *минз.* Дәwәт бизәнү әйбере булган. – *шрл.* Бер дә белмисеңмени, әбекәңнең күлмәгенә дәwәттән алганнарны тезгәннәр ийе. – *кмшл.* Дәwәт қыйғачлап кийелә, дәwәтнең асты ситса, өстенә тәңкә тезәләр ийе. – *бөре.* Дәwәт диләр ийе, кыйыш кийәләр ийе бөтен тәңкә иң тәү, анан иллелек. – *стрл.* Дәwәт бизәнү әйбере булган. – *шрл.*; **2.** *т.кам.-крш., чст.-крш.* тар гына материя кисәгенә мәржән һәм бөтен тәңкәләр тезеп ясалган, муенга арттан кысып бәйләп куела торган бизәнү әйбере (старинное женское украшение из монет и бус, нашитых на узкую материю, плотно надевавшееся на шею); таг.: **йақа**.

**ДӘWӘТ II** [*гар.*] *хвл.*, **ДӘВӘТ** *тмн.* фарфордан ясалган кара савыты (фарфоровая чернильница).

**ДӘWӘТИ 1.** *каз.ар., т.кам.-крш.* к.: **бабай I, 4; 2.** *злт., кргл.* к.: **бабай I, 1; 3.** *злт., кргл.* әнисенең апасының иренә эндәшү сүзе (форма обращения к мужу старшей сестры матери).

**ДӘWӘТ-ТАМАҚСА** *т.кам.-крш.* хәситә белән *тамакса*дан торган комплексы бизәнү әйбере (женское нагрудное украшение, состоящее из комплекса *дәwәт* и *тамакса*). Дәwәт-тамакса буладыр ийе иңнән тора торган. Дәwәт-тамакса диләр ийе муйында җакшы, өстендә тамакса тәңкәдән йә бер рәт, җә ике рәт, асқарақ түштә дәwәте, шунда чикле төшөп тора.

**дәwер I** *урт.д.* дәвер (эпоха, период):

**дәwер сөрү** *бәр.* мәетне югач, ике мулланың кара-каршы утырып җеназа укуы (отпевать, читать за упокойную). Йуғач дәwер сөрүләр буған. Дәwер сөрөп бетергәч, сәдәқа бирәләр.

**ДӘWЕР II** *т.кам.-крш.* **1.** к.: **асыл 2.** Күлмәге дәwер икән; **2.** к.: **ирмәк 2.** Дәwерме кылупта? Дәwер, бик дәwер.

**ДӘWЕРӘЙТҮ** *каз.ар.-крш.* зурайту (увеличивать). Мин аны дәwерәйттем.

**ДӘWЕРЛЕ** [*гар.* + *афф.* -ле] *бгрс.* к.: **ауқатлы 2.** Синең самый дәwерле чағың иде.

**ДӘWЕРЛЕК** [*гар.* + *афф.* -лек] *чст.-крш.* вакытлы күренеш (временное явление). Мендем генә моржа җабарга,Ештем генә мәржән җийарга. Мәржән җийулары дәwерлек, Кыз бала булулары гомерлек (*хал. җыр.*).

**ДӘWЕСЕРҮ** *дөб.* кунакка йөрешү (ходить в гости друг к другу); чаг.: **қунақлау, қунақлашу.** Игелләрне чәчәсен, чәчеп бетергәчтен дәwесерәләр. Дәwесерә, килеште тегеләргә.

**ДӘWЕШ** *мам.* итле бәрәңгене табага салып, өстенә юка итеп җәелгән камыр каплап пешерелгән ашамлык (блюдо, состоящее из картофеля и мяса покрытого тонким слоем теста). Дәwеш – итле бәлеш, тик асқы қамыры йуқ.

**ДӘWЕШЛӘМӘ** *мам.* к.: **дәwеш.** Дәwешләмә пешереб ашатырыйым, бүген китмәсәң.

**ДӘГӘНӘК** *перм.* **1.** энә, чәнечке – үсемлекләрдә (иглы, шипы – у растений). Ақ чыршының дәгәнәге йуқ, қара чыршы дәгәнәкле була; **2.** шайтан таягы (чертополох); **3.** к.: **гөләф.**

**ДӘГЕЛ** [*рус.* дягиль] *чпр., стрл.* шома көпшә (дягиль). Дәгел тамырларын ашыйлар; дәгелне болайлата да ашыйлар, дәгел ақ цәцәг ата. – *чпр.*

**дәгел көпшәсе** *минз.* к.: **дәгел.**

**ДӘДӘ 1.** *каз.ар.-крш., чст.-крш.* к.: **аба(й) 1.** Дәдәсе кайтса да, шоноң белә гөр килә. – *чст.-крш.*; **2.** *кузн.* бабасының бертуган абыйсы яки әнесе (брат деда). Дәдәләрең килделәр, ди, сиңа ни булса да китергәндер (*әкият.*). Минен дәдә бик ыста йырлый иде.

**адаш дәдәм** *тмн.* адашларга балалары шулай эндәшәләр (форма обращения детей к тёзке своего отца).

**ақ дәдә** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* әтисе яки әнисенең иң өлкән абыйсына эндәшү сүзе (форма обращения к самому старшему брату отца или матери).

**ДӘДӘЙ 1.** *мам., крш., срг., карс., кузн., хвл., тмн., шрл., стрл.*, к.: **аба(й) 1.** Дәдәсе өйләнде. – *мам.* Минем дәдәй көн сайын шебеш саный. Минем дәдәй белән дә җәдәшкәнем бар. Җәмәлкә дәдәмнен үги малайы. Минем дәдәйнен кыз(ы) ул. – *т.кам.–крш.* Дәдәйне үләндердек. – *срг.* Син, брат, дәдәңне өрәтмә инде. – *хвл.* Дәдәй безгә бик йардәмнәште инде. – *шрл.*; **2.** *т.кам.-крш., карс., стрл., шрл.* әтисе яки әнисенең ир туганы һәм аңа эндәшү формасы (брат отца или матери и форма обращения к нему). Безнең дәдәй бар ыйы түтеш белән, ул күп белә иде. – *стрл.*

**ақ дәдәй** *каз.ар.-крш.*, **ак дәдәй** *чст.-крш.* к.: **дәдә: ак дәдә.** Ак дәдәй қунаққа киләсейе, Албайда тора wыл. – *каз.ар.-крш.* Ак дәдәй җөзәк салдырган, анарга җыру чыккан. – *чст.-крш.*

**җырақ дәдәй** *крш.* әнисенең абыйсы һәм әнесенә яки әнисе ягыннан туган тиешле үзеңнән олы ир кешегә эндәшү формасы (форма обращения к братьям матери или старшим родственникам со стороны матери); чаг.: **бабай: йәж бабай.** Җырақ дәдәгез көлеб утыра сездән. – *т.кам.-крш.* Такмаков Темәфи минем җырақ дәдәм ул. – *чст.-крш.*

**ДӘДӘКАЙ** *стрл.* әтисе яки әнисенең абыйсы (старший брат отца или матери).

**ДӘЙ** *каз.ар.-крш.* абый (дядя, обращение к мужчине, старшему по возрасту; присоединяется к собственным именам). Закир дәй, саумы?

**ДӘЙӘК** *чст.* к.: **йәйәк I.** Ац кына дәйәкле, йабык кына ул. Дәйәккә салыб йеббәрде бу, кылаклар ишетмәде бер атна.

**ДӘЙЕМ** [*гар.*] *лш.* к.: **бер: бер буйдан.** Дәйем мәшәкәтә бар бит бәрәңгенең, утырталар, йаралар.

**ДӘЛӘХАТНЫЙ** [*рус.* деликатный] *срг.* күркәм холыклы, аралашучан, сөйкемле (благонравный, симпатичный, общительный). Ирем дәләхатный кеше иде, йараталар иде, туйларда йөрде.

**ДӘЛИЛ** [*гар.*] *дөб.* ихлас, әвәс (искренний, чистосердечный, охочий). Әминә бик дәлил сөйләшергә.

**ДӘЛЛӘ** [*гар.*] *кргл.* **1.** үткен, чая (смелый, бойкий, отчаянный). Бабай ул дәллә кеше; **2.** усал, явыз (злой); чаг.: **матур 2.** Әләкли шул дәллә хатын. Инәсе бер дәллә хатын инде.

**ДӘМ** [*гар.*] **1.** *перм.* ризык (пища, пропитание). Бер җыл ун көн дәм қапмый җаттым; **2.** *бгрс.* тәм (вкус). Дәме җуқ.

**ДӘМӘК** [*гар.*] **1.** *т.кам.-крш., нгб.-крш., каз.ар.-крш.* кызык, мәзәк (забава, шутка). Туйларда да дәмәкләр буладырыйы. Безнең Ибан бәк дәмәк шөйләшә. Үзе дәмәк кешенең дәмәк булмаған сүзләреннән дә көләләр. – *т.кам.-крш.* Алар бик дәмәк халық. – *нгб.-крш.*; **2.** *мам., каз.ар.-крш.* оста, сәләтле (умелый, способный). Ул эшкә дә бик дәмәк булды. – *мам.* Дәмәгрәк кешеләр биилләр. Безнең персидәтел аның ишегә бик дәмәк, төзөргә җарата чишмәләрне, күперләрне. Шундый эшкә дәмәк. – *каз.ар.-крш*; **3.** *мам., каз.ар.-крш., нгб.-крш.* сүзгә оста (красноречивый). Әле үлеп киткән

бабай бик дәмәг ийе сүзгә. – *мам.* Син қодаға бар, ул сүзгә бик дәмәк. – *нгб.-крш.*

**ДӘМӘН I** *әстр.* к.: **дәwә**

**ДӘМӘН II: дәмән инә** *әстр.* к.: **инә II: чирмеш инәсе.**

**ДӘМБӘС** *дөб.* к.: **болотлы.** Дәмбәс тә инде шушы Хәлимә, кешегә арты белән генә тора. Дәмбәс, бер сүз дә әйтми, қайнанам шунда утыра.

**ДӘМЛӘУ** *дөб.* горчица, керән h.б. суга изеп, томалап тоту, ачыту (приготовление горчицы, хрена и т.д.); чаг.: **зимнәу I.** Изәм дә быраз дәмләп алам берәр сәрәт горчитсаны.

**ДӘМСЕНУ 1.** *т.я.* сизү, тою (чувствовать, ощущать); чаг.: **абаулау 1.** Син килгәнне дәмсенми қалдым; **2.** *трх.* рәнжү, күңелгә авыр алу (принимать близко к сердцу). Дәмсендем мин аңардан, аның әйткән сүзеннән.

**ДӘН** *нгб.-крш.* тән (тело). Дәннәрем awырта инде, эшләп арыдым.

**ДӘНДЕРЕК** *әстр.* юла (волчок).

**ДӘНСЕМӘУ** *к.т.* к.: **дәмсенү 1.** Дәнсеми қалдым кеше кергәнен. Ул дәнсемәде син хәйләләргәнне.

**ДӘҢГӘЛ** *чпр.* утыргычлы кечкенә чана, гадәттә, шомартылган киң такта өстенә кечкенә эскәмия беркетеп ясалган була (небольшие салазки с сидением).

**ДӘҢГЕЗЛӘУ** *хвл.* бер аякта сикереп йөрү, титаклау (скакать на одной ноге); чаг.: **деңгезләү.**

**ДӘҢГЕЗЛЕК** *шрл.* сикәлтә юлдагы чокыр-чакырлар (ухабы, рытвина, колдобины).

**ДӘҢГӘЛ: дәңгел эстеп** [*рус.*] *срг.* к.: **даңгыл: даңгыл эстип.** Дәңгел эстепләрне цапкан цакта Исердем лә үләп исенә, Исермәдем үләннәр исенә, Жан сүгәнем теште исемә (*хал. җыр.*).

**ДӘҢЕЗЛӘУ** *бөре.* к.: **дәңгезләү.**

**дәңезләп килү** *срг.* сикерә-сикерә, сикергәләп (вприпрыжку). Кара орман ортасында Куйан килә дәңезләп; Ак йаулыкка конфит бәләп, Мин килермен сине эзләп (*хал. җыр.*).

**ДӘРӘ** [*рус.* заря]: **дәрә итү** *мам.* борынгы йола: яз көне сабан туе алдыннан ярма, май h.б. алып чыгып су буенда ут ягып, ботка пешереп ашау (старинный обряд: весной перед праздником сабантуй собирать народ, выносить крупу, масло и т.д. и при костре варить и есть кашу). Сабан туйы булыр алдыннан, дәрә кычкырып: «Дәр, дәр, дәрәгә, иртә торсаң боткаға, берсекөнгә сабанға», – дип қычқыралар ийе тау қырына барып, ботқа пешергән җирдә, ут йаққан җирдә қычқыралар.

**ДӘРБЕШ** [*фарс.*] *клд.* гарип (калека, инвалид, урод). Бар да дәрбеш, кас'ы аксак, кас'ы ишетми.

**ДӘРБЕШӘЙҮ** [*фарс.* + *афф.* -әйү] *клд.* гарипләнү (становиться уродливым, искалечиться). Алаша картайа йә дәрбешәйә, суйасың. Кас'ыбыз сугышта дәрбешәйеп калды.

**ДӘРҖИН** *перм.* к.: **қақлawыч.**

**ДӘРМАН** [*фарс.*] *кузн., лмб.* к.: **дарман 2.** Дәрман бирдеме суң? – *кузн.* Балничага барырга кирәк, дәрман бирер. Биргән дәрманыңа ырахмәт, кызым. – *лмб.*

**ДӘРМАНА** [*гар.*] *блт.* к.: **албидрә.**

**ДӘРМӘН** [*гар.*] *әстр.* к.: **дарман 2.**

**ДӘРМӘНӘ: дәрмәнә үләне** *блт.* к.: **албидрә.**

**ДӘРМЕШЛЕК** [*фарс.*+ *афф.* -лек] *перм.* ярлылык (бедность, убожество, нужда). Қоролый себеренсәң, барга-йуққа сызғырынсаң, дәрмешлек килә, ишектән башлап элгәре таба себеренсәң, кәрте-фәлән уйнасалар да.

**ДӘРТ** [*фарс.*] **1.** *чст., кузн., мәл., хвл.* кайгы, хәсрәт, борчу (горе, печаль; забота). Бырцылма йук дәрт эцен. Картайгастан бер эш эшләwе дәрт. Җыллары гына тыныч булсын инде, бар дәрт шул. Дәрт бетми инде hаман. – *чст.* Дәртләре дә шул гына. – *кузн.* Шоноң дәртеннән вет инде касталанды. – *хвл.* **2.** ваем (забота). Аның кебек дәртсез булсаң гына, бегенгә бар, иртәгә эчен кайгырмый. – *чст.* Дәрт йук әле. – *мәл.*

**ДӘРТЛӘНДЕРҮ** [*фарс.*+*афф.* -ләндерү] *т.я.-крш.* ачуландыру (злить, разозлить, сердить, рассердить). Дәртләндермәгез, ашагыз мин пешергән ашны.

**ДӘРТЛӘНҮ** [*фарс.* + *афф.* -ләнү] **1.** *чст.* к.: **борлыгу 1.** Йукка дәртләнмә, бар да рәтләнер. Малайым каста, шынарга дәртләнәм. Мына кицә бу wакытта дәртләнеп тора идем, ницек саламга барып кат'им дип. Аны дәртләнеп дийеп кеше белән сүләшми тырмас инде. Дәртләнә дә җылый икән; **2.** *т.я.-крш., чпр., чст.* җәфалану, интегү, мәшәкатьләнү (мучиться, маяться). Тешем сызлады, төне буйы дәртләнеп беттем. Берсе күрми күзлекнең, дәртләнеп җерим. Быйыл ызба белән дәртләнделәр сеңелемнең кызлары. – *т.я.-крш.*

**ДӘРТЛӘУ** [*фарс.*] *тмн.* шаярту (подшучивать, заигрывать). Който төшкә бирсәләр, аны дәртлиләр кызны, қыңгырайталар, йырлаклилар.

**ДӘРТЛЕ** [*фарс.*+ *афф.* -ле] **1.** *чст.* тыныч, ваемсыз (спокойный, беззаботный). Дәртле йыкы шулай була инд(е) ул йәш wахытта; **2.** *чпр.* кайгылы, борчулы (опечаленный, безотрадный). Кайгылы, хәсрәтле кешене без дәртле кеше дибез.

**ДӘРҮ** [*фарс.*] *әстр.* к.: **дарман 2.**

**ДӘТЙАЛ** [*гар.*] *злт.* дәҗҗәл, явыз (злой, свирепый, лютый). Дәтйалның да дәтйалы, ди, ул хатын.

**ДӘҮ 1.** *мам., лш.* к.: **айап 1.** Су дәү кимеде. Суның дәү файдасы тими безгә. Дәү эшләгәндә дә awырта ул (ашказаны). Өйартында дәү җөрсәләр, чыгыб әрлим (яшьләрне). – *лш.*; **2.** *каз.ар.-крш.* к.: **ару I, 11.** Жанғыр дәү җауды, қурқыч. Син дәү болыт килгәнне беләңме, аңныйңмы?

**дәү әти** *т.кам. -крш., кргл.* әтисе яки әнисенең абыйсы (старший брат отца или матери). Дәү әти тора әле, әти белә бертуған, абыйсы ул, дәү әтинең қатыны дәү әни була. – *лш.* Дәү әти, кереп, бабайның ийәрен базға йәшереп қуйған, ди. – *кргл.*

**дәү бawырлы** *мам.* тәкәббер (высокомерный). Дәү бawырлы кеше ул, зур булып йөри, безнең ише кешегә ачық түгел.

**дәү дәдәй** *т.кам.-крш.* **1.** абыйларның өлкәнрәге (старший из братьев); **2.** әтисенең иң олы абыйсы (старший брат отца).

**ДӘҮҒӘТ** [*фарс.*] *кмшл., бгрс.* к.: **путемар.**

**ДӘҮЛЕК** *т.кам.-крш.* зурлыгында (величиной с ..., размером с...). Алма йодрық дәүлек кенә була ул. Өстәл дәүлек таш ийе.

**ДӘҮМӘЛЕК** *минз.* зурлык (величина, размер). Торбыча бидерә дәүмәлек инде бийеклеге.

**ДӘҮМӘТ** [*гар.*] *минз.* әҗер, савап (вознаграждение за добрые дела, довольства). Иманҡайлар белән китсәм, миңа шул дәүмәтләр йитте.

**ДӘҮР** *тмн.* тиз, кызу (быстро). Дәүр сөйлисең.

**ДӘҮРӘҮ** *лш.* зураю, үсү (стать большим, взрослым). Дәүрәгәч барысы да ҡарый, нәни чаҡта әнисе генә ҡарар, име аппаҡ.

**ДӘШ** *м.-кар.* яшь (молодой). Дәш катын әйткән, кызың маңа кирәкми, дип, адаштыр дигән (*әкият.*).

**Д'ӘШЕЛ** *м.-кар.* к.: **нажагай**. Агачны д'әшел атты. Д'әшел ун'ый дибез. Вот пример жаңыр йук, бертуктамый д'әшел уный, аздага, дибез.

**д'әшел д'әйәсе, д'әшел җәймәсе** *м.-кар.* к.: **дуга: күк дугасы**. Д'әшел җәймәсе дибез.

**д'әшел д'әй(ү)** *м.-кар.* салават күпере чыгу (появление радуги).

**ДӘШМӘКИ** *лш.* эндәшми торган кеше (молчаливый человек). Равийә минем дәшмәки.

**ДӘШМЕШ** *лш.* аз сүзле, күп сөйләшми торган (молчаливый, немногословный). Кече абый дәшмеш булған.

**ДӘШҮ 1.** *злт., трбс.* к.: **йәшү 1**. Сүләш, дәш, дибез тегеңә. – *злт.* Дәшәсе килми. – *трбс.*; **2.** *стрл.* к.: **йәшү 2**. Йорт хуҡасы табын җыйа, awылдагы туганнарын дәшә, дусларын.

**ДЕБЕТ I 1.** *кргл., себ.* кәҗә мамыгы (козий пух); **2.** *перм.* каз мамыгы (гусиный пух); **3.** *мам.* сырлап итекләр чигә торган җеп (нитки для вышивания национальных сапожек).

**дебет чүпләү** *кргл.* кәҗә мамыгын кылдан һәм чүпләрдән чистарту (очистка козьего пуха от волосков и примесей). Шәл бәйләү дебет чүпләүдән башланған.

**тараған дебет, тарақ дебет** *кргл.* урындагы кәҗәләрдән тарап алынган кыскарак, куе һәм йомшак җепселле мамык (козий пух с более коротким, густым и мягким волокном, счёсанным с местных коз).

**ДЕБЕТ II 1.** *чпр., мәл., чст.* к.: **ҡолаҡай**. Дебет карт ул, кылагы ишетми. – *мәл.* Аның карты дебет. Дүрт йәшлек була ул, дебет, ишетми. – *чст.*; **2.** *минз.* к.: **ат'акыш 1**.

**ДЕБЕТЛӘНҮ** *минз.* аңгы-миңгеләнү, иләсмиләсләнү, аңгыралану (оглупеть, стать ненормальным). Дебетләнеп йөри, ни булғандыр үзенә.

**ДЕБРӘН 1.** *чст.* к.: **ҡолаҡай; 2.** *чпр.* к.: **гөбән: гөбән корсак 1**. И дебрән корсак!

**ДЕБРӘННӘНҮ** *чст.* саңгыраулану, чукракланы (глохнуть, оглохнуть, потерять слух). Ике кылагы да дебрәннәнеп кат'ты.

**ДЕВА** [*гар.*] *хвл.* к.: **дива 1**.

**ДЕВЕШ** *кузн.* к.: **тевеш 2**. Ак куйанның баласы, сырты кара, девеши ак (*хал. жыр.*).

**ДЕГӘ-ДЕГӘ** *минз.*, **ДЕГЕШКИ-ДЕГЕШКИ** *трх.* к.: **гал'-гал'-гал'**.

**ҖЕТЕ** *мам.* **1.** ачык (яркий). Сары чәчәкләр җыйа (бала), күзгә җете күренәдерме сары; **2.** җитез, хәрәкәтчел (бойкий, ловкий, быстрый). Бик җете нәрсәләр алар, үрдәк бәпкәләре.

**ҖЕТЕРҮ 1.** *к.т.* бетерү (выбить из сил, измучить); чаг.: **гедәтү**. Шушы бала ғына җетерде үземне, әле болай бирешми ийем; **2.** *к.т., лш.* к.: **үчерү**. Үзе дә бетте, нәселен дә җетерделәр. – *к.т.* Йола җетерү. – *лш.*

**ҖЕТИМ** *нрл.* ятим (сирота). Бу анасыннан йәшлий ҡалған, бу җетим.

**ҖЕТМӘ: җетмә суҡыр** *дөб.* к: **дөмә-дөм**. Икесе тиң җетмә суҡыр ҡалдылар.

**ҖЕФЕЛТ: җефелт итеп** *минз., стрл.* ялт итеп (чисто, блестяще). Җефелт итеп кенә калыр тәрликәсе. – *стрл.*

**ҖИБӘЛӘЙ** *байк.* кылган (ковыль).

**ҖИБӘРҮ** *карс.* к.: **җебәрү**. Бер кен килә ирем, ике кен килә, җибәрәм инде үзем дә. И, бырат, әтәм, җибәрмим, әтә, җибәр, сыңға үзеңә кыйты булыр.

**ҖИБУТА** *минз.* җигү кирәк-яраклары (сбруя). Мин калхузда җибута җүнәтәм.

**ҖИГӘРЛЕ** *перм.* **1.** к.: **йегәрле**; **2.** к.: **җете 2**.

**ҖИГЕ: җиге-җиге белән** *кргл., бгрс.* җентекләп (детально). Фәттах ҡарт аны җиге-җиге белән аңлатыр иде. – *кргл.*

**ҖИГЕМ** *кузн.* җигүле хайван (запряжённый; годный к упряжке). Җигем аты бар. Җигем дә бирде: ат бирде, аннан тәвә бирде.

**ҖИГЕРЛӘҮ** *бөре.* к.: **йегерләү**.

**ҖИ'ИН** *кас.* йөгән (узда, уздечка). А' тимиле җи'ин.

**ҖИДӨҒЫШ** *минз.* әйберне кирәгеннән артык җыючы (скопидом; человек, копящий вещи больше необходимого); чаг.: **мыжым**.

**ҖИЙӘК I** *лмб.* к.: **йәйәк I.**

**ҖИЙӘК II** *минз.* к.: **албуй I, 2.** Җийәк – тасма инде төрлесеннән. Бер бәбәйтәк салып, шушылай ике илле җийәк тоталар ийе.

**ҖИЙЕҮ** *лш.* бозылу, бозыла башлау (гнить, повреждаться, испортиться). Монда күмгәндә тәннәре җийегән ийе.

**ҖИЙНАЛЫШ** *бөре., минз., стрл.* җыелыш (собрание).

**ҖИЙНАҮ** *минз., стрл.* **1.** к.: **тезү III: эстәл тезү.** Ишегалдына өстәл җийнап мәҗлес йасаб алды. – *минз.*; **2.** җыештыру (убирать, прибрать). Өйне җийнаған матур итеп. – *минз.*; **3.** җыю (собирать). Тырма белән җийныйбыз да китәбез. Фәйрүзә, ничә кила җийнадың? – *стрл.*

**ҖИЙУ I 1.** *кузн., хвл.* эренләү (нагнаиваться). Унбиш төштән тәнем җийды. – *кузн.* Йаланайак, кадала да айагың җийа. – *хвл.*; **2.** *лмб.* шешү (пухнуть, опухать, распухать). Ун бармагы җийды, эшләмәде. Кылагым җийа, сүwык үткәннән этәләр.

**ҖИЙУ II** *каз.ар.-крш., бөре., трх., әстр.* ашау (есть, съесть, кушать). Уртак малны эт җимас (*әйтем*). – *каз. ар.-крш.* Итеңне мачы җийып китәр әле. – *трх.* Кода бастың (башның) йартысын җийды. Безнең атлар бик охота солы җийған wакытта. – *әстр.*

**ҖИЙУ III** *перм.* икенче бер фигыль белән бергә килгәндә, эшнең, хәрәкәтнең күплеген, тәмамлануын белдерә (в сочетании с другим глаголом обозначает завершённость действия). Барыбызны да өстән җөреп җийа. Бу чебенне үтереп җийам, Рәйсә, тагы қунып җийалар. Күгәрепкүгәреп төшөп җийған ийе арқа. Күрше awылында қарбыз килеп җийылған икән. Әтекәй, төшөп җийа (бала турында). Бабай күп сүләшеп җийа әле.

**ҖИЙҮ** *блт.* к.: **җийу II.** Дөнйа ризығы җиймәгәнгә өч көн.

**ҖИЙЫЛУ** *лмб.* өйләнү, гаилә кору (жениться, создать семью). Ылларым бар, икесе җийылмаган.

**ҖИЙЫН I** *т.я.-крш., кузн.* к.: **курмыйш.** Минем кебек эшләүче җийынында да берсе дә йук. Шул awылда үскән, теге җийында булган. – *т.я.-крш.*

**ҖИЙЫН II** *баст.* мәҗлес, аш мәҗлесе (поминальное угощение, поминки). Берәү үлә, җийын эшләйләр, җитесе, қырық кене. Керегез балдар, бығарда җийын.

**җийын эчү** *м.-кар.* бергә берләшеп әле берсендә, әле икенчесендә кунак булу (собравшись артелью, вместе гостить то у одних, то у других по очереди).

**ҖИК** *перм.* җек, ярык (щель). Без қойма қырыннан, җиктән қарап торайық.

**ҖИКӘН** *әстр.* камыштан үрелгән чыпта (рогожа из камыша).

**ҖИКӘТЛӘҮ** *т.кам.-крш.* җитәкләү (водить, вести за руку, под руку). Аннан су җулы күрсәтергә апчыгып китәләр инде ике қыз җикәтләп.

**ҖИКЛӘНҮ** *перм.* ярылу, ярыклар барлыкка килү (трескаться, растрескаться). Җикләнгән бит сезнеке дә түшәмегез.

**ҖИКСЕ** *перм.* кешене аптыратучан (надоедливый). Җиксе кеше.

**ҖИКСЕНҮ** *минз., кргл., бгрс., стрл.* авырсыну, теләмәү (считать для себя затруднительным, не хотеть). Алар җиксенмиләр дә кешедән, қунақ қайтасы бар. – *кргл.* Ике йыл эшләргә җиксенә, awылда каласы килми. – *стрл.*

**ҖИКСҮ** *перм.* берәр нәрсә белән аптырату, қыенсындыру (надоесть, затруднять чем-либо).

**ҖИКШӘМБЕ** *баст.* якшәмбе (воскресенье).

**җикшәмбе арты** *баст.* дүшәмбе (понедельник).

**җ и л I** (ветер):

**җил қубызы** *бәр.* к.: **йақлы.**

**җил қыйық** *байк.* қыеклап япкан өй түбәсе (двускатная крыша).

**җил тору** *хвл.*, **җил тыру** *лмб.* җил чыгу, җил күтәрелү (подняться – о ветре).

**җилгә тоту** *блт.* җилгәрү, суыру (веять – о зерне). Бодайларны җилгә тотып бетердеңме, әүди?

**тискәре җил** *минз.* каршы җил (встречный ветер).

**ҖИЛ II** *трх.* сугыла торган буй җеп аерылып торсын өчен, аның арасына көредән соң куела торган таякчык (деталь ткацкого станка в виде тоненькой палочки, вставляемая между нитками).

**ҖИЛ III** *перм.* көч, хәл (сила, мощь). Ботның җиле йуқ, йөрдәм исә, awырта.

**ҖИЛ IV: қул җиле** *лш.* кул ялы (плата за труды). Қул җиле бирә инде ул түбәне җабышсаң.

**ҖИЛӘЗ** *мам.* к.: **йарау.** Өйөбез бик җиләз ийе моңончы, пичкә йақтық (шуңа эссе).

**ҖИЛӘЗЛӘНҮ** *мам.* к.: **йараулану I.** Өй җиләзләнде әзрәк, җуwып чығарғач.

**ҖИЛӘК** *чст.-крш.* җимеш: йөзем, өрек, каражимеш h.б. (фрукты: изюм, урюк, чернослив и др.).

**җиләк сawыты, җиләк чичкә** *перм.* к.: **чәчәк I: бүрәнкә чәчәк.**

**йалан җиләге** *минз., стрл.* җир җиләге (клубника).

**камар җиләге** *шрл.* к.: **гөләф.** Чәнечкеле ал чәчәк ата камар җиләге. Камар җиләгенең суын да кан'атыб эчтем.

**ҖИЛӘМӘ** *дөб.* талгын, салкынча яки җылымса – су турында (чуть тёплый, прохладный – о воде).

**ҖИЛӘН** *минз.* болындагы калкулыклар, калку җирләр (холмики, бугры на лугу). Қайынлы җилән. Малайлар, чийәле җиләнгә барабыdмы?

**ҖИЛӘНКЕ-ҖИЛӘНКЕ** [*рус.* делянка] *каз.ар.-крш.* к.: **уйат-уйат.** Җиләнкесе-җиләнкесе белән ул җиләк.

**ҖИЛӘТҮ** *бөре.* к.: **базату 2.** Көн дә бәлеш, көн дә бәлеш, җиләтте инде.

**ҖИЛӘНЧЕ** *чст.-крш.* юртак (рысак). Җиләнче атларның җиллесен Җилдереп карагач белерсен (*хал. җыр.*).

**ҖИЛӘҮ I** *бөре., минз., перм.* тую, бизәү, күңел кайту (надоесть); чаг.: **җепкерү.** Көн дә пылау, көн дә пылау, җиләдем инде мин аннан. Җиләдем инде бу кешедән. – *бөре.* Җиләп беткәнгә киткән ул. Җиләдем инде йалғыс. Мин ашамай-

мын гүпчә дә, җиләдем. – *минз.* Ана шу пажар wакытта җиләп китте бигерәк, чыгам ди инде. – *перм.*

**ҖИЛӘҮ II** *каз.ар.-крш.* йөгерү (бежать). Җиләдем лә, ай җиләдем Асыл кийеккәйләрнен артыннан (*хал. җыр.*).

**ҖИЛБАШ** *перм.* кызу, гайрәтле, ләкин булдыксыз, эшен җиренә җиткермәүчән (горячий, вспыльчивый и неорганизованный).

**ҖИЛБЕДӘК** *минз.* к.: **фиренҗе**. Бер қара шәлҗаулық бәйләдем, бик күб ийе җилбедәге. Өстенә (күлмәк итәгенең) сәйләнне җилбедәклене тотадыр ийек әле.

**ҖИЛГӘРӘЙ** *эчк.* к.: **тума II**. Аңа җилгәрәй қушарға кирәк дигәннәр.

**ҖИЛДӘН-ҚУЗДАН: җилдән-қуздан табу** *перм.* к.: **дус: дустан табу**. Җилдән-қуздан табып қуйдийе қартайған көнөндә.

**ҖИЛДЕРБАЙ** *кмшл.* **1.** к.: **җилбаш**. Йери бит җилдербай кебек; **2.** җиңел сөякле (лёгкий на подъём).

**ҖИЛДЕРҮ 1.** *мам.* к.: **җил I: җилгә тоту**. Кичә җилдереп, тутырып қуйған ыйым арышны; **2.** *минз., кмшл., стрл.* пешекләү (обваривать в кипятке). Эчәк тә җилдермәгән әле. – *кмшл.* Эчәге җилдерү. Малның эч қарнын җилдерәләр дә төйәләр, шуны ачыга кыстырып пичтә пешерәләр. Тawыкны җилдереп йолыку. – *стрл.* Эчәгене җилдерү дә йуғ ыйы элгәре. – *минз.*; **3.** *минз.* кояшта җилләтеп, киптереп алу (проветрить, просушить на солнце).

**ҖИЛЕМ I** *мам., блт.* җилен (вымя). Җилемнәрен җуwып сawалар. Җилемендәге сөтөн дә сawып бетермәгәндер, сыйырын бик тиз чығарды. – *мам.* Майлап сawмасаң, сыйырларның җилемнәре бозолоп бетә. – *блт.*

**җилем итү** *каз.ар.-крш.* җилен тутыру (вымнеть). Сыйырлар бозаулағанчы бер-ике ай җилем итсәләр, бозаулағач, сөтләре күп була. Сыйырны җилем иткәндә инде әзерәк җал итерергә кирәк.

**ҖИЛЕМ II** *крғл., бгрс.* саман кирпеч сугу яки өй салу өчен балчыкка салам кушып ясалган измә (смесь глины с соломой, которая идёт на изготовление саманного кирпича, а также на обмазывание домов). Җилемегез аз бит, җитәрме?

**ҖИЛЕНЧЕК** *әстр.* балтыр ите (икры ног).

**ҖИЛЕП-ҖАЛЫП** *минз., стрл.* к.: **дывыл-дывыл**. Берәүсе капчык күтәргән, җилеп-җалып бушата. – *стрл.*

**ҖИЛЕШ** *бәр., каз.ар.-крш.* к.: **җил III**. Сабан туйында айақларның җилешен сыныйлар. – *бәр.* Қәзер үк айақларның җилеше җуқ. – *каз.ар.-крш.*

**ҖИЛҖАҚ** *т.я.*, **ҖИЛЙАҚ** *лш.* мактаганны яратучы кеше, юкка барга үсенеп китүче кеше (человек, который радуется всякой похвале, разным пустякам).

**ҖИЛКӘ** *лш.* арка (спина). Гөлфирә, минем җилкәне җуwарға килерсең.

**ҖИЛКӘWEЧ** *перм.* к.: **йулпуч**.

**ҖИЛКӘЛЕК** *каз.ар.-крш.* керәшеннәрдә: чигә турысына тәңкәләр тезгән хатын-кыз баш киеме (у кряшен: женский головной убор из монет). Аудый җилкәлеген биреп җибәрсен әле, җә үзе килсен. Җилкәлеге түбән төшеп тора, матур булмаған. Сүрәкә бәйләп, җилкәлек кийеп йөрделәр.

**ҖИЛКУWАР** *чст.* җил уңаена (по направлению ветра, по ветру). Без дә йандык, безгә җилкуwар иде.

**ҖИЛЛӘТКӘН: җилләткән каз** *глз.* каклаган каз (вяленый гусь). Җилләткән каз йаратам мин, тызлап ылеп җилләтәм.

**ҖИЛЛЕК I 1.** *перм., минз., бөре.* җилгәргеч (веялка). Элек җиллек булмаған, улаққа салып торған – (ә) ике кеше әйләндерә. – *перм.* Җиллек белән җилләтеп амбарға саладыр ыйық. Җиллек белән җилләтәбез, қул әйләндереп. – *бөре.*; **2.** *трбс.* кар тота торган киртә (щит, предназначенный для снегозадержания). Қар өй буйын басмасқа җиллек утыртабыз.

**ҖИЛЛЕК II** *мам.* җәй көне өйне, өй асларын җилләтү өчен өй нигезендә калдырыла торган төннек (отверстие, оставляемое в фундаменте дома с целью вентиляции его). Җиллекләрне дә сылап қуйдым әле, өй җылынсын дип.

**ҖИЛПЕЧ** *минз.*, **ҖИЛПУWЫЗ** *кас.* к.: **йулпуч**.

**ҖИЛСӘРҮ** *трх.* җилсенү (слегка припухнуть, вспухнуть). Бите җилсәреп киткән.

**ҖИЛҮ I** *хвл., мәл.* җикеренү, җикеренеп килү (сердито, иногда замахиваясь на кого-либо; кричать). Әлдә минең өстөмә җиләсен! – *хвл.* Җилеп килә. – *мәл.*

**ҖИЛҮ II** *перм.* китәрү, кыру – чәч, сакал-мыек турында (сбрить – о бороде, волосах). Бабай, чәчеңне җилим. Ирләр башларын җилиләр, сақалларын.

**ҖИЛХУЗ** *минз., стрл.* **1.** җиңел холыклы, кызу кеше, дуамал (неуравновешанный, горячий, сумасбродный); **2.** җен (бес, чёрт). Айатлар йазып җилхуз килмәскә қуйалар. – *минз.* Awырлы хатыннарның awырын алган җилхуз, диләр ийе. – *стрл.*

**ҖИМ I** *перм.* төш, орлык (семя, ядро семени); чаг.: **зим 2**. Бу қомбағышның җиме йуқтыр инде, қыру тиеп китте. Мә, қомбағыш аша, җиме йуқ соң утыртқас. Қыйар җиме. Қабақ җиме.

**ҖИМ II** *мам., минз.* к.: **былгама 2**. Гел җим белән генә тотоп булмый, бөртекле ашлық та сибәргә кирәк. – *мам.* Җегерме дүрт тawық асыйбыз, аның җиме ачыб утыра чиннегендә. Қады-үрдәге – аларға җимнәр ташыб үтә гөмөр. – *минз.*

**ҖИМӘН** *перм.* күп (много); чаг.: **йаман I**. Болында җимән төрле чичкәләр үсә. У апаңда җимән төрле анда (җепләр).

**ҖИМЕШ** *каз. ар.-крш., м.-кар.* яшелчә (овощ). Җимешләргә сыw сибә. – *каз.ар.-крш.* Җимешләр үскерәм, кыйам аларны. – *м.-кар.*

**бақча җимеш** *перм.* к.: **җимеш**. Син ыскул сал бақча җимешкә суны, җawын су, җawын су қый.

**йөзөм җимеше** *трх.*, **сawаплы җимеш** *лш., мам.* к.: **гөләф**. Чәнечкеле қуақлы йөзөм җимеше генә инде. – *трх.* Сawаплы җимеш безнең бақчада да бар ыйы, ашыйдырыйық. – *мам.*

**саз җимеше** *перм.* мүк җиләге (клюква). Сандугачлар сайрый саз җирдә, Саз җимешләр бар җирдә (*хал. җыр.*).

**сары җимеш** *кас.* к.: **таракан җимеше**. 'иленне 'аршы алалар, 'әйнәнә чы'а җимеш бели, үпми' бели, сары җимеш, 'ара җимеш.

**тарақан җимеше** *дөб., блт.* төшсез йөзем (сорт изюма без косточек). Күчтәнәчкә тарақан җимеше тыққаллар. – *дөб.*

**ҖИМ-ҖИМ** *нокр.* җилт-җилт, тиз-тиз (быстро-быстро, легкой походкой). Әллә қаа баралар бу қатыннар җим-җим.

**ҖИМТЕК** *перм.* к.: **былгама 2**. Чебечләргә җимтек бирдеңме?

**ҖИНАҒАСЫ** *әстр.* к.: **аргыш**. Җинағасы туйнын хәзәине, ул кийәүнең йақын туғаны, ағасы.

**ҖИНАКАЙ** *лмб.* җизнәкәй (форма обращения к мужу сестры). Җинакай, ад'а урманга.

**ҖИНАУ** *хвл.* җыйнаулашып, барсы бергә (все вместе). Җинау килделәр.

**ҖИНЧЕК** *перм.* **1.** к.: **айақ II: айақ бите; 2.** к.: **чәлтер: чәлтер севәге**.

**ҖИҢӘЛИ** *клд.* к.: **арсый**. Җиңәлиләр килә инде ирле-хатынны. Җиңәлиләр китә кат'ып, туй бетә.

**ҖИҢӘРЛЕ** *мам.* батыр, гайрәтле, егәрле (сильный).

**ҖИҢӘЧИ** *чст.* к.: **йеңгәчәй**.

**ҖИҢГӘ** *бөре., минз., стрл.* к.: **арсый**. Хәллерәге икешәр җиңгә белән бара. – *минз.* Җиңгә булып баралар, бертуган тутасы булса, кийәwе белән бара, агасы булса, парлап бара. – *стрл.*

**қыз җиңгәсе** *бөре.* к.: **арсый**.

**ҖИҢГӘЛӘҮ** *әстр.* килен битен ачып күрендерү (открывать лицо невесты). Җиңгәнең битен ачабыз, җиңгәли.

**ҖИҢГӘЛИ** *клд.* к.: **арсый**.

**ҖИҢГӘЧӘЙ** *байк., минз.* **1.** к.: **йеңгәчәй; 2.** олырак хатын-кызларга эндәшү сүзе (форма обращения к пожилым женщинам); чаг.: **җиңги; олгонакай**.

**ҖИҢГӘЧИ** *трх., чст.*, **ҖИҢГЕЙ** *т.кам.-крш.* к.: **йеңгәчәй**. Мин әйтәм, барыйым әле, җиңгәчинең хален беләм. – *чст.*

**жырақ җиңгей** *т.кам.-крш.* әнисенең абыйсының яки энесенең хатыны һәм аңа эндәшү формасы (жена старшего или младшего брата матери и форма обращения к ней). Жырақ җиңгей, мин қалдырып төшәм баланы.

**ҖИҢГЕЛЕ** *глз., нокр.* қыңгырау (колокольчик, колокол). Кулларыбызга җиңгеле тытып, чылтыр селкетеп керәбез ишекләрдән. Атлар белән, җиңгелеләр белән киләләр иде, атның дугасына бәйлиләр иде. – *глз.* Дуға җиңгеле. – *нокр.*

**ҖИҢГИ** *т.я.* икенче авылда туып үсеп, бу авылга килен булып төшкән, үзеннән олы хатын-кызга эндәшү сүзе (форма обращения к женщине старше по возрасту, происходящей из другого села); чаг.: **абыз 2**.

**жырақ җиңги** *т.кам.-крш.* к.: **җиңгей: жырақ җиңгей**; чаг.: **нәнә I, 4**.

**ҖИҢДЕРЕНҮ** *перм.* к.: **йөгенү II**. Чирләп йөри-йөри дә кисәк қаты awырып китә, җиңдеренеп.

**ҖИҢЕЛ-ҖИЛПЕ** *кузн.* акылга җиңел (придурковатый, недалёкий).

**ҖИҢЕЛСУ** *минз.* к.: **җиңел-җилпе**. Шулай үде җиңелсурақ кешинде, ақылға башанырақ.

**ҖИҢЕСЕЗ** *каз.ар.-крш.* тиктормас, теләсә кая барып тыгылучан; юньсез (непоседа, беспутный). Қара, ашқа менеп төшкән бит, җиңесез (мәче турында).

**ҖИҢИ** *чст., хвл.* к.: **йеңгәчәй**.

**жырақ җиңи** *каз.ар.-крш.*, **д'ырак җиңи** *чст.-крш.* әнисе белән бертуган абыйсының хатыны (жена старшего брата матери); чаг.: **нәнә I, 4**. Энемнең қатынының балалары жырақ җиңи диләр. – *каз.ар.-крш.*

**ж и р** (земля, место):

**ж и р а қ ы р у** *мам.* акырып елау (плакать навзрыд, рыдать).

**жир ачу** *минз.* иген чәчү өчен урман кисеп жир әзерләү (расчистка земли от леса и подготовка её под посевные культуры).

**жир бәрәңге** *минз., стрл.* к.: **қуйан: қуйан тобоғы**. Жир бәрәңге ашадық, қуйан тәпийе дә диләр аны. – *минз.*

**жир-жәйә** *трх.* бөтен жирдә, бар жирдә дә (везде, всюду). Жир-жәйә жаугандыр ул, җиңги.

**жир җиләге** *перм., минз., стрл.* **1.** каен җиләге (земляника). Шартлама былған җылны была, йыл да булмый, теге жир җиләге дә йыл да булмый. – *перм.*; **2.** *минз., стрл.* к.: **бөрлөгән II**.

**жир кендек** *перм.* **1.** к.: **кузанак**. Жир кендек үзе күберелеп чығып тора, самаwыр кебек қайнап тора, үзе ақмый. Жир кендеккә йазгы, көзге сулар қушылмый. (Чишмәнең) жир кендекләре монда; **2.** к.: **баткылык**. Батар өстәнә батасың, батар өстәнә батасың, чығып булмый, әнә шуғысын жир кендек тибез, селкенеп торawы.

**жир килешмәү** *т.я.* климатка яраша алмау (не мочь оклиматизироваться). Урта Азийәдә миңа жир килешмәде, гел awырдым. – *нрл.*

**жирдән йаву** *чст.* көчле жил белән ява торган яңгыр (дождь при сильном ветре).

**жирен-гүрен қуймау** *перм.* бик каты сүгү, дөньядагын калдырмау (не разбираясь в выражениях, сильно браниться).

**жир саруты** *чст.-крш.* (ежа сборная).

**жир үләме** *чст.* к.: **үләм: каз үләме 1**.

**жир чеметкән** *минз.* к.: **бәйсәкә**.

**иске жир** *нгб.-крш.* ата-бабаларның туган иле, туган ягы (прежняя родина, родина предков).

**тайыз жир** *к.т.* үсемлекләр үсми торган жир, такыр жир (местность, лишённая растительности).

**тақыр жир** *бөре.* такыр басу (паровое поле).

**ташланқы жир** *минз.* ташландык басу (залежь).

**түбәрә жир** *м.-кар.* к.: **қаш I, 1**. Түбәрә жирдә су жыйылып йата алмый.

**ҖИРАЛМА** *кас., бөре., чст., әҗе.* к.: **алма I**. Жиралманы да утыртып петер'индер halы'. – *кас.* Сук быйына китсәгез, жиралмасын йегерме төрле йаздырырлар. – *чст.*

**ҖИРӘКӘҮЛЕ: жирәкәүле булу** *дөб.* ялагайланып яхшы атлы булу (угождать, угодничать); чаг.: **жалақлану**.

**ҖИРӘНЧӘ** *т.я.-крш.* жирән (рыжий). Жырак-

тан җакын күренәдер Җирәнчә атның кашкасы (*хал. җыр.*).

**ҖИРДА** [*рус.* жердь] *чст.* к.: **кура I, 1.**

**ҖИРЕК** *мам., бөре., перм., лмб.* к.: **йерек I.** Җирек қайрыларына манып суға идек җепләрне. – *мам.*

**җирек кура, җирек печин, җирек үләне** *перм.* к.: **қырлыған 1.**

**ҖИРЕКБАШ: җирекбаш печән** *бөре.* к.: **қырлыған 1.**

**ҖИРЕН** *хвл.* к.: **йирне.** Җирене тагын чабыртқан.

**ҖИР-ҖИРГӘ** *әстр.* төрле якка (в разные стороны). Алар җир-җиргә киттеләр.

**ҖИРЛӘНҮ** *чст.* к.: **йерләшү 1.** Камышлыда җирләнеп калганнар шул.

**ҖИРЛӘҮ** *т.кам.-крш.* күмү, базга салу (зарыть, засыпать в яму). Биш олау бәрәңгене җирләп қайттық, малай.

**ҖИРЛЕ: әйтәм җирле** *каз.ар., кмшл.*, **әтәм җирле** *хвл.* җирле (то-то! вот почему!).

**ҖИРСҮ** *т.кам.-крш.* к.: **алғасу.** Қызарып қойаш чыққан чақта, Шунда пешә диләр җир җиләк; Әллә китәр багытлар җитә микән, Нигә җирсәй микән бу йөрәк (*хал. җыр.*).

**ҖИСЕРЛӘНҮ** *каз.ар.-крш.* азаплану, тырышу (мучаться, делать что-либо с трудом); чаг.: **җанталашу.** Җисерләнеп бозау үстердем, алығыз, мин әйтәм, маңа karawat.

**ҖИТЕК I** *каз.ар.* үткен, җитез (проворный, умелый, ловкий); чаг.: **матур 1.** Алар исәпкә җитек.

**ҖИТЕК II 1.** *минз., стрл., тпк.* к.: **тоқон I, 5.** Бездә бит райун җире түгел, бер җитек awыл. – *минз.* Беднең бер җитектә утырған awыл булды бу. – *тпк.*; **2.** *минз., стрл.* олы юлдан читтәрәк, кеше аз йөри торган юл (дорога, находящаяся вдали от большака). Бу бик җитек йул, кеше йөрми, машина әз йөри. – *минз.* Барганыбыз да җук, җитек җул булгач. – *стрл.*

**ҖИТЕЛДЕРҮ** *чпр.* өлгертү (довести до созревания). Арышны җителдерә. Игенне җителдерә.

**ҖИТЕМ** *кас., нгб.-крш., кргл., бгрс.* к.: **җетим.** Җитем бала қарап үстерәм. Җитем бала асрасан, awызын-боронын қан булыр. Җитем бозау асрасан, awызын-боронын май булыр (*мәкаль*). – *нгб.-крш.* Ике җитем бала үстердем. Без үзебез җитем үстек, күп қыйынлық күрдек.– *кргл.*

**ҖИТЕМ-ҖИБЕР** *кргл., бгрс.* ятим, тәрбиячесе булмаган (сирота, одинокий). Җитем-җибер кешеләрдә генә йук қойо, йорт сайын бар. – *кргл.*

**ҖИТЕМ-ҖИЛПЕ** *нгб.-крш.* ярлы-ятим (сирота, одинокий). Бер җитем-җилпе әби бармы, бабай бармы, шуңа бирә.

**ҖИТЕНЧӘ** *м.-кар.* бура (сусек).

**ҖИТЕШҮ** *перм., стрл.* к.: **әйләнә: әйләнәсе тулу.** Күнәк беле Асаға (*ав. ис.*) киттем җитешкән күгә. – *перм.* Мин оло қорсақлы бит инде, җитешкәммен. – *стрл.*

**ҖИТКЕЛЕКЛЕ** *блт., мам.* җитәрлек (достаточный; достаточно). Сал җиткелекле итеп, ди. Җиткелекле булмады. – *блт.* Барысы да җиткелекле булсын дип тырышасың бит. – *мам.*

**ҖИТҮ** *хвл.* өлгерү, пешү (поспеть, созреть). Җитмәгән алма ашап эчеңне бозарсын.

**ҖИФЫРТ-МИФЫРТ** *минз.* кыланчык, көяз, фырт (щеголеватый, франтоватый). Бу кеше җифырт-мифырт икән.

**ҖИЧЕ** *дөб.* к.: **кейемче.** Җичегә барған ыйым, күлмәгемне текмәгән.

**ҖОБАЛҒЫ** *минз.* к.: **йубалғы 1.** Бу қәдәр җобалғы булырсың икән.

**ҖОБАНУ** *бөре., минз.* акрын кыймылдау, маташу (быть медлительным, нерасторопным). Күршеләрдә бигрәк одақ җобандың. – *минз.*

**ҖОБАТУ** *перм., трбс.* к.: **йобату.** Җобатып чығып китте. – *трбс.*

**ҖОWAP'Ы** *кас.* югары (вверх).

**ҖОҒАНАҚЛЫ** *блт.* к.: **йоғачан 1.** Җоғанақлы чир.

**ҖОҒАШ** *т.я.* к.: **бағышлы.** Чуwаш теле безнекенә җоғаш бит. – *к.т.*

**ҖОҒО** *трх.* к.: **ырмат: ырмат заты да.** Ачса, әфлисунның да, алманың да җоғо җук, ди.

**ҖОҒОМ** *нрл.* үзенә тартып, җәлеп итеп торучанлык, сөйкемлелек (привлекательность). Кешедә бер җоғом була бит, аның белән сүләшәсе дә килә.

**ҖОҒОНОШЛЫ** *мам.* колакка ятышлы, ягымлы (приятный на слух). Минем сүзләрем җоғоношлы булдымы?

**ҖОҒОРО(СЫ) 1.** *т.я.* бер бөртеге (дә), бер әйбере (дә), бернәрсәсе (дә), аз гына (да) (абсолютно ничеғо). Дөнҗада җоғоро да җук аның. Онноң җоғоросы да қалмаған чапчақта. – *к.т.*; **2.** *нгб.-крш.* эзе (дә) (и следа). Упыймның җоғоры да йук артыннан чықсам.

**ҖОГОРТАК** *стрл.* **1.** җиңел сөякле, тиз йөри торган (расторопный, поворотливый, лёгкий на подъём – о человеке). Җогортак кеше булса, барыб эпкилә; **2.** чит ирләр белән йөрүче хатын (гуляющая). Күрәсең, килен җогортак булган, кайна белән күп тормаганнар, айрылышканнар.

**ҖОГОРЫП: җоғорып китү** *стрл.* к.: **ир II: ир артыннан китү.** Кайсы болай җогорып китә иде.

**ҖОҚ I** *т.я.-крш.* к.: **нәсел-асаб.** Симон бабай җоғы инде без.

**ҖОҚ II** *мам., нгб.-крш.* барлык, байлык (состояние, богатство). Бай кешенең җоғо бер дә бетми аның. – *мам.* Бар ғына җоғомны, бар тапқанымны аңар бирәм. – *нгб.-крш.*

**ҖОҚА I** *минз., кргл.* к.: **күзикмәк I, 1.** Туйға ағай-әнеләр җыйналып аш-су пешерәләр ийе, иллешәр пар җоқа пешерәләр. – *кргл.*

**җоқа җәймә** *трбс.* к.: **йәймә I, 2.** Җоқа ғына итеп җәйәләр җоқа җәймәне.

**ҖОҚА II** *минз.* к.: **йабык.** Җоқа кешеләр шул тал қайрысы төшөреп көн итте.

**ҖОҚАЛАҚ** *әстр.* юка (тонкий). Җоқалақ патыр.

**ҖОҚАМЫШ** *перм.* к.: **күзикмәк I, 1.**

**ҖОҚЛО** *мам.* к.: **аукатлы 1.** Җоқло кешеләр алар безнең қодалар.

**ҖОҚЛОШ** *перм.* йокы чүлмәге, йокы капчыгы, йокларга яратучан (соня, любитель поспать). Мәгә җоқлыйсың ул қәдәр, җоқлош.

**ҖОЛДОРУ** *лш.* шудырып төшереп җибәрү (спустить); чаг.: **җылдыру**. Икмәкне су белән генә җолдордым.

**ҖОЛУ** *срг.* хак түләү, сатып алу (оплачивать, купить). Кийәү кимәкны җола, акча куйа.

**ҖОМА** [*гар.*] *тмн., хвл., чпр., кас.* атна (неделя). Ике җомага килде отпуска. – *тмн.* Бер җома кунакта тороп кат'ты. – *хвл.* Җомасында и'е мәртиби базар була. – *кас.*

**ҖОМАҠ I** *перм., т.кам.-крш.* к.: **йомак I, 1.** Мин җомак әйтәм, син җawап тап. – *т.кам.-крш.*

**ҖОМАҠ II** [*гар.*] *каз.ар.-крш.* к.: **очтомак.** Җомакълы булсын инде, безнең әни җарманы җарып утырадыр ыйы. Кәзер җомак, җомакта йәшибез.

**ҖОМА'** *кас.* к.: **йомак I, 1.**

**ҖОМАРЛАҠ: май җомарлагы** *минз.* к.: **җомарлаклы: җомарлаклы май.** Май җомарлагы кебек җасап, тәрлинкә белән базларга төшәреп куйабыз.

**ҖОМАРЛАКЛЫ: җомарлаклы май** *стрл.* бер йомарлам май (кусковое масло, комок масла).

**ҖОМАРЛАМА'А** *кас.* төрү (завернуть). Ыланны җомарладым.

**ҖОМАХ** *дөб.* к.: **йомак I, 1.**

**ҖОМҒАЧАЙ** *нгб.-крш.* йомгак (клубок). Җомгачайым тәгәри китте.

**ҖОМОЛЫП: җомолып йату** *трх.* күмелеп яту (утопать, тонуть в постели). Түшәгең бар, җомолып кына җатсаң ни була монда утырганча.

**ҖОМОР** *трх.* чынаяк чокыры, чынаяк өсте (чашка). Чәшкасы белән генә он, бер җомор сөт саладыр ыйык.

**җ о м о р җ а** *урт.д.* йомырка (яйцо):

**йара җоморҗа** *т.я., бөре.* к.: **йоморка: йел йоморка.** Tawык йара җоморҗа салган, ашау җитми, ахры. – *бөре.*

**орлоҡ җоморҗасы** *к.т.* к.: **күкәй I: орлоҡ күкәй.**

**җоморҗа бәйрәме** *блт.* Пасха – христианнарның дини бәйрәме (Пасха – религиозный праздник у христиан).

**җомор'а 'ойма'ы** *кас.* йомырка тәбәсе – йомырканы сытып, ләкин тугламыйча ясалган төре (глазунья); чаг.: **йәсничә.**

**ҖОМОРЛАҠ** *трх.* к.: **җомарлаклы: җомарлаклы май.** Элке гөбәне ачлыйдыр ыйык, алтышар җоморлак май буладыр ийе.

**ҖОМОРЛАНУ** *нрл.* к.: **йомарлану II.** Ансысы чәчәккә җоморланган.

**ҖОМОРО I** *трх.* к.: **җомор.** Awызы монау җоморо хәдәре.

**ҖОМОРО II** *минз.* ярмаган агач, артык юан булмаган бүрәнә (не распиленные тонкие брёвна). Җомородан tedдек сайгагына, түшәменә.

**ҖОМОРТҠА** *минз., бөре., әстр.* к.: **җоморҗа.**

**ҖОМОРЫЙ** *трх.* к.: **пөтәүләтә.** Җоморый да пешерегез бәрәңгене.

**ҖОМРО I** *бөре., минз.* к.: **җомор.** Җомроны буйадым, эч.

**тустаган җомросы** *бөре.* к.: **җомор.**

**ҖОМРО II** *минз.* башлы – суган турында (имеющий головку – о луке, репчатый). Җомро суганыбыз да күп.

**җомро акча** *минз.* Читләре тигез булмаган борынгы акча (древняя монета, края которой неровные). Җомро акчалар күп булган анда.

**ҖОМШАК** *чст.-крш.* к.: **йомшак.** Җомшак пешердем, чәй эчәргә утыргын.

**ҖОН: җилкә җоно** *к. т.* к.: **йөннөк.** Җыгылган да җилкә җоно өзелгән дий.

**ҖОНДОЗ** *мам., каз.ар.-крш., нгб.-крш.* йолдыз (звезда). Монда өч җондозмо, дүрт җондозмо? – *каз.ар.-крш.*

**җондозлы кәштәпи** *мам.* к.: **кәртәши.** Элек бай хатыннары җондозлы кәштәпи кийәләр иде.

**җ о н н о** *урт.д.* йонлы (волосатый):

**җонно көпшә 1.** *мам., каз.ар.-крш.* к.: **йонно: йонно бәрәңге; 2.** *мам.* к.: **бәпчек.**

**җонно күшә** *дөб.* к.: **йонно: йонно бәрәңге.** Җонно күшәнен бәрәңгесен ашыйлар.

**ҖОННОҠАЙ** *минз.* к.: **йонно: йонно бәрәңге.**

**ҖОНТАУ** *нгб.-крш.* тартып алу, талап алу (ограбить).

**ҖОРМАСЛАУ** *дөб.*, **ҖОРМАЧЛАУ** *дөб., лш.* тигезле-тигезсез итеп эшләү (кисү, чабу, кимерү h.б.), тигезсез-тигезсез әз калдыру, урыны-урыны белән калдырып эшләү, урыны-урыны белән каеп эшләү h.б. (оставить неровные следы, неровно сделать что-либо, вырвать местами и т.д.). Кейә күбәләге итегемне дуғайлап-дуғайлап җормачлап кисеп бетергән. Печәнне чабам дип җормачлап бетергәннәр. Песи тоқмачны җормачлаған. – *лш.*

**ҖОРНАТ** *т.кам.-крш.* к.: **ырмат: ырмат заты да.** Бакчадагы үләннең җорнаты да җук.

**җ о р т** *урт.д.* йорт (дом, здание, жилище):

**җорт эче** *стрл.* к.: **йорт 1.** Җорт эчендә койолар булды, чыгып кына алырга.

**ҖОРТ-ИЛ** *минз.* йорт-җир (имущество, кров). Җорт-илләре дә дүртпочмакълы ғына, салам түбәле өй.

**ҖОТҚОЛ** *мам.* к.: **мыҗым.** Җотқол кешеләр алар.

**ҖОТОҒУ 1.** *т.я.* к.: **қолқону 2.** Ай, шулхәдәре қаты җотоқтым, кемдер киләдер ачығып; **2.** *каз.ар., минз.* бик нык ачыгу, карын ачу, нык ашыйсы килү (проголодаться, испытывать сильный голод). Җотоғып қайта, нәрсә бар ашарга, дип. – *дөб.* Маллар көтүдән җотоғып қайталар, ашарга әйбер йук болонда. – *мам.* Җотоғуың җитсә, ашарсың. – *минз.*

**ҖОТОМЧЫҚ** *т.кам.-крш.* тамак авыруының бер төре (один из видов болезни гортани). Җотомчык була, тамақ төбө awыртса, әни, бар, урамга чыгып тауны, ташны, hawаны җотам дип җотон дип чыгара торган ийе.

**ҖОХОЛ** *дөб.* к.: **йыбытқы 1.**

**ҖӨБЕН** *минз.* к.: **пестелчек 2.**

**ҖӨГӨНДЕРҮ** *кргл., бгрс.* бөлдерү (заставить сделать большие расходы, разорить). Мынawы хәтле ике йақны да җөгөндереп нәрсәгә инде туй? – *кргл.*

**ҖӨГӨНҮ I** *минз.* к.: **йөгенү II.** Кешедә ашый алмагач, алайса, син кешегә қунаққа баргач, җөгөнеп қайтасың? Бу ат ач торган, ахыры, бик җөгөнгән.

**ҖӨГӨНҮ II** *трбс.* к.: **абалану 2.** Җөгөнә айак та, җығылам да китәм.

**ҖӨГӨРТМӘ I 1.** *т.я.-крш.* к.: **йөгөртмә II.** Арба җөгөртмәсе астында калдым, айагым шуннан awырта; **2.** *перм.* арбаның алгы тәгәрмәчләре (передние колёса телеги, передок).

**ҖӨГӨРТМӘ II** *нрл.* к.: **қулазақ 1.** Җөгөртмәнең үзенә тәртәсе, үзенә күчәре бар, бүрәнә ташығанда қулланалар.

**ҖӨГӨРТҮ** *перм.* озату, җеп озату (сновать, сновать пряжу). Қыш буйы ирлибез, әлек эстинә буйлатып җөгөртәсең буй йасап.

**ҖӨГӨРЧЕК** *т.кам.-крш.* к.: **пестелчек 2.** Ибанның қызы җөгөрчек тә булды инде, уқытып та қарады – чыкмады, чикратар да булды – чыкмады.

**җөдәү** *каз.ар.* йөдәү (уставать, изнуряться): **җөдәүгә чыққан** *блт.* бик нык ябыккан (очень худой, сильно похудевший); чаг.: **йөгенү II.**

**ҖӨДӘҮЛЕ: җөдәүле булу** *кргл.* бөлү, ярлылану (разоряться, обеднеть, обнищать); чаг.: **гидай: гидай қалу.** Тегеннән бик җөдәүле булып қайттык.

**ҖӨДӘШҮ** *перм.* к.: **гедәү.** Мин инде алты көн чаптым, җөдәштем.

**җөз** *урт.д.* йөз (лицо): **җөз итү** *каз.ар.* кунак итү, күңелләрен табу (угостить; угождать). Умбер бала қайта, аларны җөз итәргә кирәк. – *лш.* Қунақларны, қодаларны ничек җөз итәрбез дип қайғырам. – *мам.*

**җөз күтәрү** *нгб.-крш.* к.: **йөз II: йөзе килү 2.**

**сувық җөз** *нрл.* караңгы чырай (угрюмое, хмурое лицо). Ирләрегез қаршына сувық җөз белән чықмагыз, ди торған ийе қайнанам.

**ҖӨDLӨK: җөdlөкле туу** *минз.* йөзлек белән туу (родиться в рубашке). Мөхәппәтле бала диләр җөdlөкле туганны.

**җөзөм** *урт.д.* йөзем (изюм): **җөзөм җиләге 1.** *нрл.* к.: **гөләф.** Җуwa (җыены) җөзөм җиләге чәчәк атқан чақта була; **2.** *каз.ар.-крш.* йөзем (изюм). Пирәмәчне әлеке җөзем җиләгеннән пешерә торғаннар ыйы менә шулай түгәрәкләп табаға.

**җөй** (шов): **җөй тегү** *блт.* тегү (шить, портняжить). Әни җөй тегеп утырыр ыйы.

**җөй энәсе** *минз.* тегү энәсе (иголка швейная). Җөй энәсе төрлө-төрлө була.

**ҖӨЙҮ** *минз.* к.: **йүләү I.**

**ҖӨК I: җөгөнгә керү** *блт.* хәлен аңлау, хәленә керешү (сочувствовать). Синен җөгөнгә керәдер ийе ул, әрәтләп сөйләшсәң.

**ҖӨК II: җилкә җөге** *дөб.* к.: **йөннөк.** Бер хатынның җилкә җөгө өзөлгән.

**ҖӨЛӘЙҮ** *перм.* к.: **җылайту.** Җөләйде дә төшөрде ди шы көwенә, сары май сөрткән ийе.

**ҖӨЛҮ** *перм.* к.: **җилү II.**

**ҖӨМӘН** *перм.* күп (много; разнообразный). Уйыннар күб ий лә, җөмән төрлө уйыннар уйнап табан аслары сызлый ийе. Җөмән төрлө күләк кийеп җыйа.

**ҖӨМБӘШ** *төм.* юаш (смирный, тихий, кроткий). Җөмбәш инде, часта түгел, җуwaш.

**ҖӨММИ: җөмми түгеп йылау** *стрл.* күз яшь белән нык елау (горько плакать, плакать со слезами). Җинаулашып җөмми түгеп йылыйлар.

**ҖӨМНӘП** *минз.* к.: **җийу II.** Җөмнәп тә бетергән бу малай.

**ҖӨПЛӘП** *т.кам.-крш.* җентекләп (тщательно, подробно, детально). Җөпләп сорап торасың.

**ҖӨПМӘ: җөпмә суқыр** *бәр.* к.: **дөмә-дөм.** Җөпмә суқыр булып утыра. Ике күзе җөпмә суқыр булды.

**ҖӨППӘ** [*гар.*] *перм.* казаки, кәзәки (казакин, поддёвка). Әтинең җөппәсе, эче көрән сатин ий, кесәләре бар ий. Әтинең җөппәсен сүткеләде халат тегәм дип. Җөппәләр мулла бабайларныкы, җиләннәр маса, әбиләрнең дә була.

**ҖӨРӘКСЕНҮ** *блт.* борчылу, кайгыру (беспокоиться). Ул җөрәксенеп өйдә җата инде, мескен.

**ҖӨРГӘК** *перм.* к.: **иске.**

**ҖӨРДӘК** *каз.ар.-крш.* кыска (короткий). Күлмәген җөрдәк буган.

**ҖӨРЛӘҢКИ** *т.кам.-крш.* к.: **пақцар.** Җөрләңкиләр килгәнче тизерәк җерлә, диләр ийе, песнәктән зурырақ бер қош, җерләмәсәң телчәңки, җерләмәсәң телчәңки, диб әйтә ул, диләр ийе.

**ҖӨРМӘҮ** *мам.* типчү, күкләү (метать, сметать). Тегүчеләр дә җөрмәп чыгалар ире-ире итеп, wақwақ итеп чәнчеп чыгасың.

**ҖӨРӨМТӘЛЕ** *минз., стрл.* **1.** йөри торган (гуляющий). Шул кигә азды да җөрөмтәле қызны алды. – *минз.*; **2.** к.: **сайақ I, 2.** Бозау йөрөми, бик җөрөмтәле тегел. – *стрл.*

**ҖӨСӨНБАШ** *перм.* к.: **йосомбаш.**

**ҖУБАЛҒЫ** *минз., мам., дөб., к.т.* к.: **йубалғы 1.** Җәш wақытта да бик җубалғы ғына қатын ыйы Мәптуха. – *мам.* Җубалгы хатын ул, өс-башын қарамый. – *дөб.*

**ҖУWАЛТУ** *лш.* югалту (терять, потерять). Без аны җуwалттық ул җазуны.

**ҖУWАНУ** *к.т.* к.: **җобану.** Озақ җуwанма, тиз генә эшләб ал.

**ҖУWАЧА 1.** *нгб.-крш.* к.: **йуwача 2; 2.** *минз., стрл.* к.: **йомшак.** Элек бит ике төрле салалар ийе, арыш әпәйе, бодай җуwачасы. – *стрл.*

**ҖУW'ЫРЛАНМА'А** *кас.* якынлашу (приближаться, сближаться). 'еше белин җуw'ырланма'а белми ул.

**ҖУҒАЙСӘМ** *блт.* югыйсә (а то, не то). Без җуғайсәм икәw генә торабыз.

**ҖУГАЙУ** *м.-кар.* к.: **җуйалу.** Кайчы безне җугайды.

**ҖУҒАЛТЫНУ** *перм.* югалту; талану (потерять; быть ограбленным). Пирwый барған җылны җуғалтындық. Шунда-шунда баргансыз, әйберегез җуғалтынгансыз, ди шу маржа.

**ҖУҒЫЧ** *бөре.* к.: **йуғыч 2.** Бу апайыма җуғыч бирим дигән ийем.

**ҖУДАЦЫ** *баст.* мәет юучы (тот, кто моет покойника). Җидесендә җудацыларны чақыралар, наски, майка бирәләр.

**ҖУЙАЛУ** *дөб.* югалу (пропадать). Берсе җуйалса, берсе бар. Синдә җуйалмый ул, ала қаргадан аласын булсын дий. Әллә қайа җуйалган мәллә?

**ҖУЙҒЫЧ** *минз.*, **ҖУЙМА** *бөре.* бетергеч, резинка (ученическая резинка).

**ҖУЙМА'А** *кас.* югалту (потерять). Җуйма тул'кы чебешләрне.

**ҖУЙЫЛУ** *блт.* к.: **җуйалу**. Персидәтелнең сәләмәтлеге җуйылды инде.

**ҖУЙЫҢҚЫРАУ** *нгб.-крш.* югала төшү (немного теряться, исчезать). Безнең таwышқа җуйыңқырый синең таwыш.

**ҖУҚА I** *дөб., блт., лш., каз.ар.-крш., к.т., чст.-крш.* к.: **күзикмәк I, 1**. Җуқаны җөпсә итеп куйалар, бер пар, бер пар итеп. – *лш.* Унике җуқа пешердем, иртәгә қунаққа барабыз. – *дөб.* Җуқа, қабартма пешердем дә кийәүләрне ашқа алдым. – *к.т.*

**ҖУҚА II 1.** *блт.* к.: **йабык**. Атасыз үстек, чын җуқа чағыбызда әти булмады; **2.** *блт., минз.* к.: **йадау**. Электән үк җуқа кешийе. – *минз.*

**ҖУКА** *м.-кар.* к.: **җәймә I, 2**. Жука пешерәләр, камырны нәзек кенә итәсең, каймакка изәбез дә, болғайбыз да онда аунатабыз, табада пешерәбез.

**ҖУҚАЙОҚ** *дөб.* базар оегы (простые чулки, чулки из простых ниток).

**ҖУҚ-ҖЕТЕК** *нгб.-крш.* ярлы, хәерче (бедный). Без җуқ-җетекләрне эзләп килгән кешеләр, диләр.

**ҖУҚСЫЛ** *лш.* ярлы (бедный, бедняк). Җуқсыл wақыт ич ул wақытта.

**җ у л I** *урт.д.* юл (дорога, тропинка):

**итек җулы** *перм.* итек эзе (след от сапогов). Тегенеңә көләм, итек җулыңы кәртечкегә төшөреб алдылар тип.

**ҖУЛ II** *блт.* к.: **арый**. Бер җул утын апқайтмады. Биш җул печән китерделәр. Умбер җул утын китте қышын.

**ҖУЛАП** [*рус.* жёлоб] *чст., кас.* к.: **йалғаш**. Безнең әтинең атлары, Җулап тебе кимерә (*хал. җыр.*). – *чст.*

**ҖУЛЛАУ** *минз.* эзләү (искать). Мин қайтырға чыққанда, тегеләр киләләр ийе мине җуллап.

**ҖУЛЛЫҚ** *каз.ар., перм.* юлда каршыга беренче булып кемнең очравына карап юлның уңу яки уңмавын билгеләү гадәте (поверье: повезёт или не повезёт, что якобы зависит от первого встречного). Аның җуллыгы начар, очраса җул уңмый. – *лш.* Җуллығың йақшикән. – *перм.*

**җуллықлы кеше** *перм.* кая да булса барган чакта, каршыга беренче булып очраган кешене юлның уңуына юрау (первый встретившийся на пути человек, приносящий везение, удачи). Санийәттай тәрәзәсеннән булса да қарап қалсын әле, ти, мин шундый җуллықлы.

**ҖУЛПЫЧ** *мам.* к.: **йулпуч**.

**ҖУМА** *трх.* куштан (льстивый человек). Бик җума ғына килен.

**ҖУМАЛАУ-ҖҮКӘЛӘҮ** *дөб.* к.: **йумакайлау**. Җумалап-җүкәләп апкитте баланы.

**ҖУҢҒЫ** *к.т.* к.: **йунгы**. Балта эшендә булғач, җуңғылары да қайта.

**җуңғы балтасы** *к.т.* агач юну өчен хезмәт итә торган балта (топор для обтёсывания дерева).

**ҖУРАМА** *каз.ар.-крш.*, **ҖУРАМАЛАЙ** *дөб.*, **ҖУРАМАЛИ, ҖУРАМАЛЫЙ** *каз.ар., нгб.-крш.*, **ҖУРАМАН, ҖУРАМЫЙ** *каз.ар.-крш.*, **ҖУРАП** *м.-кар.* к.: **йурамал**. Җурама пешермәдең, ди. – *каз.ар.-крш.* Мыскыл итеп утыра, җурамали әйтә ул. – *блт.* Җурамалый, миңа дигәч атын апқайтмады, ди. – *мам.* Җурамалый җазып җибәрдеңме? Җураман кердем сурәткә төшәргә дип. Җураман сораб утыра инде. Җурамый әйткәннәр – *каз. ар.-крш.* Җурап ат'кан иде, леп итеп утырды. – *м.-кар.* Җурамалый чүперәк алып килгән ийем өстәл сөртергә. – *нгб.-крш.*

**ҖУРНА** [*рус.* зерно] *мам., к.т., минз., срг.* к.: **зурна**. Журна ашаса, таwықлар җоморқаны тиз сала башлый. – *к.т.* Бүген бодай суқтырдық, журнасы күп төште. – *минз.* Монда тотоналар бәрегә журна белән инде. – *срг.*

**ҖУРТАҚ** *т.кам.-крш.* буйсынмас (непокорный, непослушный, своенравный). Безнең әней журтағырақ булған, ирен бик саннап бетермәгән.

**ҖУРЫҚЛАУ** *трх.* к.: **җаңғырлау**. Тама-тама шулай җурықлар инде.

**ҖУРЫМАЛ** *чст.-крш.* к.: **йурамал**. Минем чигәчәнең тәңкәләре калай гына, җурымал гына җасаган нәстәләр.

**ҖУСАН** *әстр.* к.: **нәркәмәс**. Җул буйында җусаным.

**ҖУСЫГЫНА** *м.-кар.* к.: **йага I, 1**. Ү җусыгына килгәне дә йук (песинең).

**ҖУСЫҚ** *дөб.* юнәлеш, як, юл (направление). Алар шул җусық белән җөргән инде.

**ҖУУ** *нрл.* агарту (белить).

**пич җуу** *нрл.* мич агарту (белить печь). Пичне ақ балчық белән җуwып төшөрәбез.

**ҖҮWЕШМӘН** *нрл.* кыргаяк (сороконожка). Җүwешмән чи ызбада була. Җүwешмән ул, җүwештә җарала торған ни ул.

**ҖҮГЕРТҮ** *перм.* к.: **җөгөртү**. Җаңгыш җүгертканәнем, чыбытыб алып җийасы бар. Ничәле қылычқа җүгертәсең, шулай саныйсың.

**ҖҮГЕШ** *мам.* юеш (сырой, влажный; сырость). Җүгештә ашамыйлар маллар.

**ҖҮК** *баст.* як (сторона). Она дывур җүгендә. Ике йерне теккән, бу җүктә, бу җүктә, уртадан керәсең, чыбылдық була.

**ҖҮКӘ** *перм.* к.: **йүкә**. Җүкәне баш өстөндә өзгөлийләр. Паланны җүкә беле бәйлибез дә қыстырып қуйабыз.

**җомшақ җүкә** *к.т.* к.: **йүкә**; чаг.: **чырымта 1**. Җүкә салдық җебетергә, эрәхәтләнербез җомшақ җүкәгә. Берәр мунчалалық йомшақ җүкән җүкмы, идән җүwарға мунчалам җүк.

**җүкә очо** *мам.* чабатаны ясар өчен әзерләнгән юкә тасмасы (лыко для плетения лаптя). Чабатаны қайтаралар, қайтарған җүкәне беткәнче қанатлыйлар, җүкә очо белән тезә торған ыйық нық булсын өчөн. Чабатаны қайтарғанда бер тезәләр, җүкә очо белән айырым җаңадан тезәләр нық булсын өчен.

**ҖҮЛӘТҮ** *чст.* тектерү (шить, сшить). Быйыл чикмән җүләттем, қыска дийеп әйтмәгез (*бәет.*).

**ҖҮЛӘҮ** *трх., трбс., т.я.-крш., м.-кар., карс., чпр.* к.: **йүләү I**. Алйапмалар җүлибез, җиңсәләр җүлибез урақ урырга. – *трх.* Қапны җүлиләр кәкере әнә белән. – *трбс.* Күлмәк җүләмим хәзер, күздән

кәй мин. – *т.я.-крш.* Башына челтәр җулиләр иде. – *карс.* Бетен awылга җуләп җата иде. – *чпр.*

**ҖУЛӘҮЧЕ** *чст.* к.: **кеймечe**. И, әйбәт җуләүче бар бездә.

**ҖУЛЕ** *м.-кар.* буй җәйләренә кызылдан яки карадан тасма кертеп теккән борынгы хатын-кыз күлмәге (старинное женское платье, на продольные швы которого накладывалась тесьма из красного или чёрного материала). Җуле булган безгә тәре (хәтле). Җуле ак була, кара җеп белән тегәләр иде итәген дә.

**ҖҮН I 1.** *трх., чст.-крш.* к.: **отсыз**. Анысы қыйбатлы, безнең җүн ийе. Икмәк җүн булған. – *трх.* Җүн ситсы кайткан. – *чст.-крш.*; **2.** *мам., каз.ар.-крш.* хәл, мөмкинлек (возможность, состояние). Дарулар алырға җүн булмады (егерме беренче елны). – *мам.*

**җүн җитмәү** *каз.ар.-крш.* акыл җитмәү, уйлап җиткермәү (ума не хватать, не додуматься). Қаты җуқ малайның, райун Теләчедә буганда барып эзләтергә җүн җитмәде.

**ҖҮН II** *нрл., мам.* **1.** як (сторона, направление). Түбәнең өске җүнен моржа дибез. Қай җақта ул Саба, Қазан җүндә түгелме? – *нрл.* Чыпчық ирганың өстәге җүндәгеләрен ашый, астағы җүндәгеләрен җыйдылар буғай. – *мам.*; **2.** к.: **бүлкә 1**. Ике җүнне кәнүшни булса, бер җүнендә ат тора, бер җүнендә – сийр. – *нрл.*

**ҖҮНӘЙҮ I** *минз., стрл.* к.: **җүнәлү 1**. Әпиратсәдән суң җүнәйә алмады. – *стрл.*

**ҖҮНӘЙҮ II** *төм.* очсызлану, арзанаю (дешеветь, подешеветь). Итекләр җүнәйде дә утын күп кирәк, итек басмый башладым.

**ҖҮНӘЛҮ** *минз., стрл.* **1.** терелү (поправиться после болезни); чаг.: **йан: йан тарту 2.** Саратуфта өч ай йатып, җүнәлеп, кайтарырга йазу бирделәр. – *стрл.*; **2.** к.: **йүнәйү II**. Телләре дә җүнәлде. – *минз.*

**ҖҮНӘҮ** *перм.* к.: **җүнәлү 1**. Аның чире җүнәгәнме, җәриме инде?

**ҖҮННӘТЛӘП** *нгб.-крш.* юньләп, рәтләп (толком, порядочно, путно). Ашны да җүннәтләп ашамыйбыз.

**ҖҮНТЕРӘҮ 1.** *трх.* аптырау, интегү (мучиться); чаг.: **хыйтлану**. Шундый җүнтерәйделәр инде ачлықтан; **2.** *бөре.* к.: **җазау 1**. Лотый қарт җүнтерәгән инде.

**җүнтерәп бетү** *дөб.* к.: **җазау 1**. Җүнтерәп беткән бу қарт.

**ҖҮНЧЕЛ** *перм.* эшлекле (деятельный, работящий).

**ҖҮП-ҖҮН** *бгрс.* к.: **кандawый**. Ул wахытта мин дә җүп-җүн идем.

**ҖҮПСЕНМӘҮ** *мам.* теләмәү (не хотеть). Бернә ашамый, күкәйне дә җүпсенми.

**ҖҮР** *перм.* юан агач тумраннарыннан иләк кысасы әзерләгәндә кулланыла торган махсус пычак (специальный нож, применяемый при изготовлении обечайки сита, решета).

**ҖҮР'ИН** *кас.* к.: **җеборған**. Җүр'иннир сырый идем, йәш ча'та.

**ҖҮРЛИМИ'И** *кас.* к.: **йүләү I**.

**ҖҮРМӘ** *т.я.* камчы (плеть, плётка). Менә шунда без шайарғанда тотып аладыр ыйы да җүрмә белән тетәдер ийе безне. Җәргәнгә җүрмә ләгә инде ул. – *трх.*

**ҖҮРМӘ-ҖҮРМӘ** *трх.* калын, юан, бүртеп-бүртеп (толстый). Атқа суқсаң, җүрмә-җүрмә эз қала.

**ҖҮРМӘЛӘНҮ** *трх.* юан, калын, нык булу (быть толстым, густым, твёрдым). Җүрмәләнеп үсми, ашлық қысыр қала.

**ҖҮРМӘҮ 1.** *трбс.* к.: **җөрмәү**. Күлмәкне кискәннән соң, үзләре җүрмәп бирәләр магазинда; **2.** *әстр.* тупчу (штопать).

**ҖҮТ** *т.кам.-крш.* к.: **дәшмәки**. Бу қәдәрле җүт булыр икән, каршы килеп тә эндәшмәде.

**ҖҮТ'ЕРЕ'** *кас.* ютәл, йөткерү (кашель).

**ҖЫБЫРҒАН** *минз.* к.: **җеборған**. Җастыг алып килә, җыбырғанын да алып килә қыd килгәндә.

**ҖЫБЫТҚЫ** *мам., минз.* к.: **йыбытқы 1**. Әйдәсәнә, җыбытқы, чығасың да булмады инде. – *мам.* Тегеләй үdem дә җыбытқы. – *минз.*

**ҖЫВА** *м.-кар.* юа (дикий лук). Җыва ашадык, кузгалак ашадык.

**ҖЫWЫ'** *кас.* якын (близкий; близко). Урман без'и би' җыwы'.

**ҖЫҒЫЛСЫНУ** *лш.* к.: **йыгылу**. Арышлар бик қуйы, шуның өчендер инде җығылсынганнар.

**ҖЫҒЫТУ** *перм.* егу (свалить). Хәзер пычқы белән, аннан сун «Доружба» белән җығыталар.

**ҖЫЙМА** *минз.* к.: **кереш 1**. Җыйма да бир инде.

**ҖЫЙНАЛЫШ** *бөре., минз., стрл.* к.: **җийналыш**. Җыйналышта бирделәр бик зурлап мидал. – *минз.* Җыйналышка барам. – *стрл.*

**ҖЫЙУ** *лмб., хвл.* к.: **җийү I, 1**. Бармакка җыйа. – *лмб.*

**ҖЫЙЫН I 1.** *блт., дөб.* авылның бер төбәгендә яшәгән ыру, нәсел (род, люди одного рода, живущие в одном конце, районе села). Борбаш awылында Бикмақнықылар, Шибайнықылар, Ашмақнықылар, Үтәмешнекеләр дигән җыйыннар бар; зийарәттә җыйынны җыйынға күмәләр дә. – *блт.* Аларның (Курсавиларның) җыйыны зиратның уртасында. – *дөб.*; **2.** *перм., трх.* к.: **курмыйш**; **3.** *каз.ар., бәр., трх., перм.* элек: бер төркем awылларда үткәрелә торган бәйрәм; гадәттә ул, сабан эшләре тәмамлангач ук башланып, атна саен төркемнән төркемгә күчкән һәм дүрт-алты атна буена дәвам иткән. Кайбер очракта җыен вакытларында ярминкәләр дә оештырыла торган булган (в старину: ежегодные сельские празднества, устраивавшиеся группой сёл после окончания весенних посевных работ; эти празднества, переходя через каждую неделю из одной группы сёл в другую, продолжались примерно четыре-шесть недель. Иногда в это время организовывались и ярмарки); чаг.: **игерче**; **4.** *каз. ар., бәр., минз., перм.* сабан туе (сабантуй); **5.** *нгб.-крш* мәҗлес, кунаклар табыны (званый обед, пир). Җыйын җыйабыз, малай қайтқач. Җыйын көйөн җырлыйық; **6.** *әстр.* туй (свадьба). Җыйынға җыйадыр ыйы.

**же'ет җыйыны** *кас.* егет ягында туйга кадәр

үткәрелә торган мәҗлес (предсвадебное угощение на стороне жениха). 'оз йа'та бал ашау була, 'ийеү жа'та же'ет жыйыны була.

**жыйын ағасы** *әстр.* к.: **арғыш**. Жыйын ағасы ақча санайды.

**ЖЫЙЫН II** *мам., лш., хвл.* бөтен, барлык (весь). Жыйын кешегә дә житәр. – *мам.* Жыйынысы бергә килгән. – *лш.*

**ЖЫЙЫНТЫҚ** *перм.* алдан жыелып килгән запас (ранее накопленный запас). Ақча түктек тә түктек быйыл, бар жыйынтыкны бетердек.

**ЖЫЙЫП: шәл жыйып** *мам.* шәл оештырып, шәл бәйләп (вязать шаль, оформить шаль). Кәкәм, миңа қуйан мамығыннан шәл жыйып бир әле, ди.

**ЖБЫЫРЫҚ** *нгб.-крш.* к.: **йырчык**. Ул әбинең бите жыйырык кына.

**ЖЫЙЫШУ** *мам.* к.: **аулагаш**; чаг.: **урнаш 1**. Жыйышулар бар ыйы элек, берәү әзерәк май алып килә, берәү күкәй, йарма алып киләләр дә ботқа пешереп ашыйбыз, йегетләр дә килә, кермәгәннәре тышта, тәрәзә артында жырлап йөри.

**ЖЫҚ** [*гар.*]: **жық булу** *т.я.* никадәр ашаса да туймау, туймас тамакка әверелү (проявить обжорство, стать обжорой). Жық булған бу мәчегә, ни ашатсаң да туймый. Чистый жығы булды бу мәченең, ашатам-ашатам, туймый.

**ЖЫҚАҚ** *баст.* юка (тонкий).

**ЖЫҚАМЫШ** *перм.* к.: **йықамыш 1**.

**ЖЫҚЛАНУ** *блт.* к.: **хыйтлану**. Ник жықланасын, дим моңар.

**ЖЫҚЫҚЛАУ** *перм.* к.: **кикнату**. Кем сағынды икән инде, жықықлый.

**жыл** *каз.ар.* ел (год):

**дуңғыз жылы** *каз.ар.-крш.* к.: **жылқы жылы**. Қай жылны жылы була, дуңғыз жылы, диләр.

**жылқы жылы** *дөб., мам.* кышы жылы, явымлы килгән ел (год с тёплой зимой).

**қуйан жылы** *дөб.*, **сыйыр жылы** *мам.* кышы салкын, явымсыз килгән ел (год с холодной зимой).

**тычқан жылы** *мам.* иген уңа торган ел (урожайный год).

**ЖЫЛА** *минз., тпк., стрл.* к.: **йыла**. Тугымы жыладан була. – *стрл.*

**ЖЫЛАWЫҚ** *баст.* кәчеркә, кәчтеркә – яңа туган бала аркасында (щетинка – на спине у младенцев).

**ЖЫЛАWЫК** *әҗе.* елак (плакса, рёва).

**ЖЫЛАЙТУ** *перм.* кубару, сыпыру, сыпырып төшерү (смахнуть). Қулға батқақ тисә дә, жылайтып төшөрәләр.

**ЖЫЛАЙУ I** *перм.* кубып төшү, суелып төшү (слезть – о коже; грязи).

**ЖЫЛАЙУ II** *нгб.-крш.* жылыну (согреться, стать тёплым). Сыw жылайғаммы?

**ЖЫЛАҚ: жылақ тығылу** *минз.*, **ЖЫЛАК: жылак тыгылу** *стрл.* к.: **карыну: йәшенә карыну**. Жылакларым тыгылып, жылардай булып торам. – *стрл.*

**жылан** *урт.д.* елан (змея):

**жылан күз** *бөре.* к.: **күгәрчен: күгәрчен чәчәге**.

**жылан теле** *каз.ар.-крш.* кыяк, күрән (осока острая).

**ЖЫЛАНКҮЗ** *перм.* бармакка чыга торган шеш (нагноение на пальце); чаг.: **қарақ: жылан қарағы**. Бармаққа жыланкүз чықты.

**ЖЫЛАТУ** *м.-кар.* кыз елату йоласында махсус кешенең такмаклап елавы (один из старинных обрядов: причитание специальной плакальщицы во время проводов невесты). Мин үзем дә күп кешене жылаттым.

**әтекәм жылату** *т.я.-крш.* к.: **йаслату**. Элекчә әтекәмнәр жылаткан, тастарлар сарындырган.

**жылау** *кас.* елау (плакать):

**әҗел итеп жылау** *кас.* к.: **йаслату**.

**ЖЫЛАШЛЫҚ** *перм.* к.: **каташлык**. Жылашлыклар белән чыққас утыйбыз.

**жылға** *перм.* елга (река):

**қоро жылға** *перм.* к.: **йар I, 1**.

**ЖЫЛҒЫ: жылғы чыбығы** *минз.* сары тал (карағана кустарниковая, чилига); чаг.: **тысқан сыбығы, шелек**. Ишегалдын жылғы чыбығы белән себерәләр.

**ЖЫЛҒЫР I 1.** *перм.* шома (гладкий, скользкий). Сабын қушалар аңа жылгыр булырға. Балық та жылгыр була; **2.** *мам., блт., лш.* киндер орлыгыннан пешерелгән пилмән (пельмени с толчёным конопляным зерном); чаг.: **тупы**. Киндер орлыгыннан жылғырлар пешерә ийек. Қазанға салып қайнатқанда, сүктән эремчек кебек нәрсә йасала, аны иләктән сөзәләр дә пилмәннәр йасап, иләк асты сuwында пешерәләр; шул инде жылғыр була. Жылғырны киндер майына манып ашыйлар. – *блт.* Жылгырлар шикелле балалары, бер дә тик тормыйлар. – *мам.* Жылғыр – дөнйада тәмне нәстә инде ул. Жылғырны қызлар жыйылып та пешерә торган ийек. – *лш.*

**жылғыр беккәне** *блт.*, **жылғыр тәкәсе** *мам.* к.: **жылғыр I, 2**. Жылгыр беккәне пешерә торган ыйық, орлоқны төйәсең, қайнаталар, ул эри, эремчек шикелле йомшақ қына була, шуны сөзеп беккән йасыйлар, тышы тоқмач қамыры кебек, суда пешерәсең, орлоқ майы белән майлап ашыйсың. – *блт.* Тәмне ул жылғыр тәкәсе, киндер орлогын төйөп чыгасың, сыйықлап қайнатасың, қуйыра ул, қамыр эченә тыгасың, эремчек тәкәсе күк пешерәбез. – *мам.*

**ЖЫЛҒЫР II: жылғыр қара** *перм.* кап-кара – гадәттә ат, эт, песигә карата әйтелә (чёрный-пречёрный – обычно употребляется по отношению к лошади, собаке, кошке). Этләре жылгыр қара булган. Ат та жылгыр қара була инде.

**ЖЫЛДАМ** *к.т.* к.: **йанйолымны**. Бик жылдам кеше.

**ЖЫЛДАН** *лш.* елдам – ат турында (резвый, с хорошим ходом – о лошади). Жылдан ат.

**ЖЫЛДЫРМА** *трх.* к.: **нажағай**.

**ЖЫЛДЫРУ 1.** *к.т.* ыргыту, тондыру (отбросить, отшвырнуть); чаг.: **выргыту 1**. Ташны читкәрәк жылдыр; **2.** *перм.* үткәрү (пропускать). Пабитласын ашаң әле, итмәк жылдырмаға әйбәт у; **3.** *перм.* шудыру, чәлдерү (стянуть, стащить, украсть). Нимә жылдырдың? Ылыс он үзенә дә жылдыра.

**ЖЫЛДЫРЫМ 1.** *т.я., лш.* яшен (молния).

Җылдырым уйнап қаты җаңғыр җawды. Җылдырым уйный башласа, бисмилла әйтеп, қултық төпләрен сыпырыгыз. – *нрл.*; **2.** *перм., к.т., стрл.* к.: **нажағай**. Җылдырым йылдырып китә шулый ул, болот булмаса да була. – *перм.* Кичә җылдырымнар уйнады, йәшен булды. – *к.т.*

**ҖЫЛҚЫ** *мам., кргл.* к.: **йылқы 2**. Җылқы суйдық әле, диләр, симертеп суйғач. – *мам.* Уналты йыл көтү көттем, җылқы, әби cawa, мин көтәм. Киртәдән күлгә җиткәнче җылқысы, үгезе, башмағы. – *кргл.*

**җылқы ите** *лш.* ат, каз, үрдәк ите кебек мае туңмый торган итләр (мясо, сало которого не застывает на холоде: конина, гусятина, утятина и т.п.).

**җылқы малы** *минз.* к.: **алаша**. Шул қайынның арасында җылқы маллары шыкланып йаталар.

**ҖЫЛҚЫЛДЫҚ** *бөре.* к.: **алабата 2**.

**ҖЫЛЛАТУ: җыллатып йөрү** *бөре., минз.* элек: хатынны каениш йортына туйлап алып кайткан чы, аның янына бер ел буена кияүнең килеп йөрү гадәте (в старину: обычай, согласно которому жених в течение года ездит в дом невесты и только после этого устраивают свадьбу и он переводит её в свой или отцовский дом).

**ҖЫЛТЫМБЫЙ** *трх.* к.: **пысқыш**. Җылтымбый белән җәймә чигәләр ийе. Шишаға кәрәчин салалар ыйы да мамық тығып җандыралар, шул җылтымбый була инде.

**ҖЫЛТЫР** *к.т., нрл.* к.: **чыр 1**. Ите арық булғач, аш өстендә бер җылтыры да җуқ. – *к. т.* Җылтыры күп чыкмый аның, ну ашы бик тәмне була бозау итенең. – *нрл.*

**ҖЫЛУ I** *т.кам.-крш., трх.* су ашагач чокырланып кергән урын; култык (место, размытое водой; залив). Барадыр идем җул белән, Атым кереп китте җылуға (*хал. җыр.*). – *т.кам.-крш.* Зийәдән кергән зур җылу бар. – *трх.*

**ҖЫЛУ II** *перм.* **1.** агып төшү (стекать). Су җылып төшә торган олакләр қуйдым; **2.** таудан шуу (кататься с горы). Тул'кы wыл қабыргасы белән җылып китә, айағы қыска өчөн.

**ҖЫЛЫ I** *минз.* к.: **йонйылымны**. Җылы кеше.

**ҖЫЛЫ II** *нрл.* бары (всего лишь, только). Җылы милитсийә генә, бер кеше йуқ.

**ҖЫЛЫМЫҚ** *лш., к.т.* җылымса (тепловатый, чуть тёплый). Җылымық қына су. – *к.т.*

**ҖЫЛЫМЧЫ** *минз.* җылым белән балык тотучы, балыкчы (рыбак, ловящий рыбу с помощью невода).

**ҖЫЛЫСА** *т.кам.-крш.* к.: **җылымық**. Қазанда бардыр шунда җылыса су.

**ҖЫЛЫШУ** *перм.* к.: **җылу II, 2**.

**ҖЫМА** [*гар.*] **1.** *лмб., карс.* к.: **җома**. Ике җыма тырдым Мәскәүдә. – *лмб.* Бер җыма тулды буш кендә. – *карс.*; **2.** *баст.* к.: **йома 2**.

**җыма арасы** *баст.* шимбә (суббота).

**ҖЫМАК I** [*гар.*] *чпр.* оҗмах (рай). Кеңелең йахшы, әллә җымакка кермә келисен?

**ҖЫМАК II** *күрш.* к.: **әхийәт**. Җымак сүләшә утыр.

**ҖЫМЫРТКА** *м.-кар.* йомырка (яйцо).

**ҖЫНҖЫР** [*фарс.*] *блт., кас., нокр., кузн.* чылбыр (цепь). Җынҗыр белә бәйләсәләр дә тормыйм. – *блт.* Итебезне җынҗырға бәйләдек. – *нокр.*

**ҖЫҢҒЫР** *перм.* к.: **қулса**. Қаптырма җыңғырлы у, сәлдерәп тора торған.

**ҖЫҢҚАЙ** *тмн., хвл.* к.: **йеңгәчәй**.

**ҖЫПҚЫ 1.** *трх.* к.: **астыр**. Әнә күренеп тора җыпқы буйы. Бер җыпқы бар, шунда күчкәннәр алар; **2.** *минз., перм.* ерганак (рытвина, овражек). Берәр йер – болоннар йәйсә тау буйлары җырылып киттисә, җыпқы була. Җыпқы буйдан җырып, су кертәселәр килдисә, йылға сыwын бuwалар да қуйалар. – *перм.*

**ҖЫПЫРТУ 1.** *минз.* к.: **атқару 4**. Җыпыртып қына киттем. Рәтләб эшләмәде, җыпыртты ғына; **2.** *минз., кмшл.* кызу йөрү; кызу-кызу атлап китеп бару (очень быстро ходить; уйти быстрыми шагами). Җәш кеше тид җәри, җыпырта ғына. – *минз.*; **3.** *т.я.* бик тиз ашап бетерү (быстро съесть). Бер табақ ашны җыпырттылар ғына.

**җ ы р** (песня):

**шурба җырлары** *тмн.* табын җырлары (застольные песни).

**ҖЫРАҒАЙ** *крш.* әнисенең абыйсы яки әнесе һәм аңа эндәшү формасы (дядя со стороны матери и форма обращения к нему). Ибан җырағай килде.

**ҖЫРАҒӘБИ** *бөре., минз., крш.* әнисенең әнисе (бабушка с материнской стороны). Җырағәбине белмим мин, әни җәш чағында уқ ұлгән ул. – *каз.ар.-крш.* Болар менә йәсләдән керәләр җырағәбигә. – *т.кам.-крш.* Җырағәбийем қунаққа килгән ийе. – *нгб.-крш.*

**ҖЫРАҚАЙ** *минз., нгб.-крш.* к.: **җырағәби**. Җырақайны күргән җуқ күптән. – *нгб.-крш.*

**ҖЫРАҚҚЫ** *перм.* ераклыкы, ерактагы (издалека; из дальних краёв). Җырақкы алар, чәй әчермә кәрәк.

**ҖЫРМАҚ** *т.я.* **1.** ерганак (овражек, промоина, рытвина); **2.** яңгыр яки кар сулары агар өчен ясалган ермак (канава, сделанная для дождевой или снеговой воды). Җырмақ җыру.

**ҖЫРНАЙ** *дөб.* к.: **балык: арыш балыгы**. Җырнайны татарлар ашамый, хәйләкәр балығ ул. Җырнай тәңкәсез, қарасу балық, ғәдәттә аны ашамыйлар, эткә, мәчегә бирәләр.

**ҖЫРТ** *чст.-крш.* к.: **йорт 1**. Бер җыртка җийылып бергә җеридер ийек, атка утырып барадыр ыйык печән җыйарга.

**җырт бабай** *баст.* йорт иясе (домовой). Қайыннам ұлгәч, мин бик җылый идем, җырт бабай тайағы белән суғып җерде.

**ҖЫРТҚЫЧ** *лш.* җеназа күтәреп баручыларга бирелә торган тастымаллар яки ярты метр чамасындагы тукыма кисәкләре (салфетки или куски материи размером в 0,5 м, которые раздаются тем, кто нёс покойника); чаг.: **йыртыш**.

**ҖЫРТЛАНУ** *перм.* ертылу (рваться, разорваться). Җыртланып атылып бетә ул китаплар.

**ҖЫРТУ** *перм.* к.: **йырту 1**. Чәчеңе җыртам, шайарсаң, пукач итсәң.

**ҖЫРТЫШ 1.** *лш.* к.: **җыртқыч**; **2.** *к.т.* мәет өстендә ертылып таратыла торган ситсы (ситец,

который рвут на части над покойником и раздают присутствующим); чаг.: **жыртқыч**. Дөнйалықта кешенең битен жыртқан гөнаһларын жарлықасын дип жырталар жыртышны.

**ЖЫРТЫШУ** *перм.* к.: **йасқышу 2**. Тегесе килеп жыртыша торған ийе.

**ЖЫРУ I** *каз.ар.* к.: **йару I, 1**. Бәрәңгебез жырмаған әле, менә бүген жырасы булғаннар ыйы. – *лш.* Бәрәңге жырырға иртәгә ике тырактыр чыға. – *дөб.* Бәрәңгене жырғач, бик қоторып үсте. – *мам.*

**ЖЫРУ II** *т.я.-крш.* кисү (резать). Качы белән жырам келийүңкене.

**ЖЫРУ III** *крш., дөб., эчк., кргл.* к.: **йыру II**. Бар жыруны мин жырладым. Жук жыруны таптырма (*хал. жыр.*). – *т.я.-крш.* Қәдер игенче жырулар китте. – *каз.ар.-крш.* Бер йылны илле-алтмыш жыру йазып киткәннәр ийе. Шул кигән жақлардан отоп кигән жыруларны жырлыйлар. – *чст.-крш.* Жырулар күб инде бездә. – *нгб.-крш.* Жырулар да жазасызмы сез? Аңа жыру жырладым. – *дөб.* Шул Сафыйаны тапсағыз, ул бик матур жырулар әйтер иде. – *эчк.*

**ЖЫРУЦЫ** *эчк.*, **ЖЫРУЧЫ** *каз.ар.-крш.* жырчы (певец). Бүтән жыручы жук, чибәр жиңги генә жырлый бу көйне. – *каз.ар.-крш.*

**ЖЫРЫЛУ** *мам.* арыну (избавляться, освободиться от чего-либо). Бәйеттән жырылдық шулайтеп, қотолдоқ хәзер.

**ЖЫРЫНДЫ** *перм.*, **ЖЫРЫНЖЫ'** *кас.* к.: **жыпқы 2**. Аның жырындылы жире күп жук қый.

**ЖЫРЫУ** *нгб.-крш.* к.: **йыру II**. Сезнең жырыу күңелгә ошақлы.

**ЖЫТЫГЫШУ** *чст.-крш.* к.: **жотоғу 2**. Таwыклар жытыгышып жериләр, беркайа үлән жук.

**ЖЫҢУТ** *хвл.* к.: **қатымыш**.

**ЖЫШҚЫ** *перм.* к.: **йышқы II**.

**ЖЫШҚЫННЫҚ** *минз.* урманның куе жире, чытырман куелык (лесная чаща). Жышқынныққа балан жыйып жөрим.

**ЖЫШЛАУ** *минз.* к.: **йимбеллəү**. Сайгақ жышлый башлаған ыйык.

**ЖЫШУ** *перм.* к.: **йышу 1, 2**.

**ЖЫШЫНУ** *минз.* ышкыну (тереться). Жышынма, үзеңә жоғар чире.

# З

**ЗАВАЛ'** *карс.*, **ЗАВАЛ, ЗАВАЛ'НА** *срг., кузн.*, **ЗАWАЛ'НӘ** [*рус.* завалинка] *перм.* кышка каршы өйнең тышкы ягына туфрак яки саламнан өелә торган нигез (завалинка). Завал'ын күмгәннәр, кем навуз белән, кем тупырак сала. – *карс.* Завал куйалар ызба эшләгәндә. – *кузн.* Завал'наны пычкы wагыннан куйалар. – *срг.* Бездә заwал'нәне күммиләр, эстинә черемәсен дип. – *перм.*

**ЗАВИТКАЛАНУ** [*рус.* завидки + *афф.* -лану] *кузн.* көнләшү, көнләү (завидовать, ревновать). Братлары завиткалана да, давай, ди, үтерийек (*әкият.*).

**ЗАWОҚЛЫ** [*гар.* + *афф.* -лы] *кузн.* кызыклы, күңелле (интересный, развлекательный). Кызны йылаталар инде туй көнне. Заwоклырак алардагы туй безнекенә караганда.

**ЗАВЫ'** [*гар.*] *кас.* күңел ачу (увеселение, развлечение). Бер завы'ны 'алдырмай идем: вичерны, туйны.

**ЗАWЫТ** [*рус.* забота]: **заwыт итү** *т.кам.-крш.* мәшәкать ясау (создавать хлопоты, причинять беспокойство). Қайтасыз да, туганайлар, китәсез, Атқайларға заwыт итәсез. Атқайларға заwыт итмисез, Безгә жамансы итәсез (*хал. жыр.*).

**ЗАГУН** [*рус.* загон] *чст., баст.* көтү йөри торган жирләр, көтүлек (пастбище). Сарыкларны загунга кывала. – *чст.* Зур-зур қырлар, киң загуннар, Урақ қынам қалды урырсыз (*хал. жыр.*). – *баст.*

**ЗАДАН** [*рус.*] *байк.* умартага куела торган иске рамнар, магазин (верхние рамы в улье, магазин).

**ЗАДАТКА** [*рус.* задаток] *кузн., чпр., срг.* туй алдыннан қыз өенә егет ягыннан китерелә торган акча һәм ашамлыклар (деньги и продукты, привезённые из дома жениха в дом невесты перед свадьбой). Задатка илткәндә, башкыда, кан'ана бара. Элеке бал илткәннәр, акча. – *кузн.*

**зур задатка** *срг.* туй алдыннан қыз ягына егет ягыннан бирелә торган бүләкләр һәм акча (подарки и деньги, преподнесённые женихом в дом невесты перед свадьбой). Зур задатка китергәндә йәшиккә төйиләр зимешләр, перәннек, цигелдәк, айбагыр, цитләвек. Цигелдәкләр алу зур задатка була.

**кеце задатка** *срг.* туй алдыннан кияү ягыннан китерелгән акча (деньги, преподнесённые перед свадьбой в дом невесты со стороны жениха). Кеце задаткада кийәү йагыннан акца китерәләр, тәмтомнар килә. Кийәүнең атасын каршы алып хүрмәтлиләр.

**ЗАДУР** [*рус.* задор] **1.** *чпр.* к.: **бәтрәк 1**; **2.** *дөб.* усал, бәйләнчек (злой, придирчивый); чаг.: **бәтрәк 2**.

**ЗАЗУР** [*рус.* задор] *каз.ар.* к.: **бәтрәк 1**. Бик зазур йегетләр китте анда. – *дөб.*

**ЗАЗУРЛЫ** [*рус.* задор + *афф.* -лы] *блт.* к.: **бәтрәк 1**. Зазурлы булдым мин, үзем кечкенә генә булсам да.

**ЗАЗЫК** *тмн.* язык (грех). Тырмыш awыр булса да, зазыкны белделәр, руз'а тыттылар.

**ЗАИБ, ЗАИП** [*гар.*] *чст.-крш., нгб.-крш.* зәгыйфь (калека). Заиб булган берсе чебинең. – *чст.-крш.* Заиб бу бала, айакайы, қулыкайы эшләми. Ул баласы заип туды. – *нгб.-крш.*

**ЗАЙМАН** [*рус.* заем] *мәл.* заем.

**займаны уйнау** *мәл.* нәрсәне дә булса вату, жимерү, соңыннан түләргә кирәк булу (что-нибудь разбить, уничтожить, а потом заплатить).

**ЗАЙЫП-ҒӘРЕП** [*гар.*] *кас.* зәгыйфь (увечный, калека). Алты балам, берсе дә зайып-гәреп тө'өл.

**ЗАЙЫФ** [*гар.*] *мәл.* к.: **заиб**.

**ЗАКАЛ** [*рус.*] *хвл.* пешмәгән, чи, уңмаган –

икмәк турында (некачественный, не до конца испечённый – о хлебе). Курың койты булса, закал була, чеп-чи икмәгең, пешмәгән була.

**ЗАКУСКА** [*рус.* закуска] *кузн.* кыз йортында кияү ягыннан килгән күчтәнәчләр белән үткәрелә торган мәҗлес (предсвадебное угощение в доме невесты с гостинцами со стороны жениха). Закусканы йегетнең кардәше итә бара, закускаларында читлавык, канфитлар була, закуска тишүче була. Закуска тишүче тишә дә бер канфитны үзе йартысын каба, йартысын йиңгәсенә дә каптыра. Ул инде берлек белән тору дигән сүз, паднустагы закускаларны кызлар алнысына куйалар.

**DAЛ** [*гар.*]: **dal булу** *минз.* зар булу, зарыгу (томиться в ожидании). Инәләрегез dal булып көтеп тора торғандыр.

**ЗАЛ'АК** [*рус.* залежь] *хвл.* к.: **барлақ**.

**ЗАЛАПҚА** [*рус.* за лавку] *эчк.* шкаф алды (место перед шкафом). Қатығын залапқада утыра.

**ЗАЛАТНИКЛАП** [*рус.* золотник + *афф.* -лап] *срг.* мыскаллап (золотниками). Awыру шул потлап килә, залатниклап китә.

**ЗАЛӘҚ** [*рус.* залежь]: **заләк йир** *лмб.* к.: **барлақ**. Эт капыстасы заләк йирдә үсә.

**ЗАМАЙ** *минз., стрл.* бераздан, бераз торгач (через некоторое время). Йарай, замай булыр, ди. – *минз.*

**ЗАМАН 1.** *м.-кар., чпр., клд., кузн., нокр., глз., перм.* бик тиз, тиз генә, тиз арада (быстро, за короткий промежуток времени); чаг.: **зәһәр 2**. Пулемёттан заман бүреләрне үтерергә була. – *м.-кар.* Алар заман гына кермәсләр әнде. – *чпр.* Йатып заман гына йокога киттем. – *клд.* Ыздруг болотласа, йангор заман килә. – *кузн.* Заман гына йөреп қайтайым су өчен. Туқталмыйча заман барса, хәзер барып йетә. – *нокр.* Хәзер алтыдан гына йасыйлар чүмәләне, заман қоросын дип. Заман киләләр, бүгенме-иртәме дип торалар. Өйдә тороң, қайтыр заман. – *перм.*; **2.** *нокр.* аз гына вакыт, билгеле бер вакыт (немного времени, определённое время). Заман да бәрмей, уйанып китә теге кечтеки малай.

**ЗАМАНДА** *нокр.* к.: **заман 1**. Мин заманда гына чыгып килим әле школга.

**ЗАМАТ 1.** *дөб., кмшл., нрл., каз.ар.-крш., кас., миш.д.* к.: **заман 1**. Кас'ы кеше замат кына эшли вит. Халык йыналып пожар замат сүндерделәр. – *мәл.* Чепийәгә замат қына алып пардылар да. Үзем замат та эшләп ташлыйм. – *блт.* Замат қына әләгешеп киттеләр әле. Заматта кисеп бетерделәр. – *кмшл.* Энем, мин замат кына бер йергә барып килийем әле. Замат эшләп ыргыта ул. – *чст.* Замат та менәсең, замат та төшәсең арыдан. – *дөб.* Шәкәрне шонон чике дә қапмыйм, қосқом кели замат. Утырығыз шолай, мин замат калхуз йортона гына менеп төшәм. – *нрл.* Минем быллтыр замат арада үсеп җиттеләр бәпкәләрем. – *каз.ар.-крш.* Замат тишелеп чы'а, 'ишир, су'ан. – *кас.*; **2.** *лмб., кузн.* к.: **заман 2**.

**ЗАМИР** [*гар.*]: **замирын қайтару** *бөре.* үч алу (отомстить). Быйыл замирын қайтара, үткән йыл сыw басты, быйыл сыw йуқ.

**замирын сығару** *злт.* к.: **замир: замирын қайтару**. Мин әйтәм, элек йөргәннең замирын сығарабыз.

**ЗАН** *том.д.* гадәт, йола (обычай). Андый зан бездә йуғ ыйы. Элеке заннар бетте хәзер, йәшләр аны белми. Киленгә йастығын-түшәген анасы биреп җибәрә, бездә зан менә шул.

**ЗАНЫЙ** *крш.* җаный (милый, милочка, душенька). Урманнарға барсаң, син иртә бар, Урман күкеләрен уйатып, заный. Ай, заный, wай, заный. – *т.кам.-крш.*

**ЗАПУН I** [*рус.* запон] *злт., бгрс., карс., чпр., т.я.-крш., мәл., лмб., кузн., хвл., срг., м.-кар., т.я., перм., кргл.* к.: **алйапма**. Запунын йуғыс иткән, йердән тапты. – *злт.* Запунны килен булып төшкәндә тегеп алып төшә идек. – *бгрс.* Запун биримме билегезгә. – *карс.* Айагым сынгач, запунымны салдырдылар да чырмап куйдылар. – *чпр.* Запун әнде без чиккән. – *т.я.-крш.* Запун буган йаңыны, запунын кытла. – *лмб.* Запун корабыз ат'абыз. – *кузн.* Запуннар йәш киленнәр кийә ул. – *хвл.* Мин запуннар да йүләклим. Нәк биленә запун кырмадын? – *срг.* Запун ирләрнеке була киндердән, тубықтан уза өс қараймасқа. Камилә, запуныңны бир әле. – *перм.*

**бумагалы запун** *м.-кар.* к.: **алйапма**.

**қайулы запун** *к.-уф.* чигүле алъяпкыч (вышитый фартук). Қайулы запуннар әзерләп қуйалар қызлар кейәүгә барырға.

**киндер запун** *к.-уф.* кулдан сугылган тукымадан тегелгән алъяпкыч (фартук из домотканой материи). Запун киделәр ирләр, қалын киндердән запун киделәр, түбәтәй киделәр.

**запун будыру** *срг., лмб.* туй мәҗлесендә кунаклар алдында яшь киленгә алъяпкыч бәйләтү. Аны, гадәттә, каенана булган кешедән бәйләттерәләр. Шул вакытта килен кешедән барлык кунаклар алдында «әни» сүзен әйттерәләр (свадебный обряд). Йәш киленгә запун будыра кан'әни. Кунаклар сорыйлар киленнән: «Кем запун будырды?» – «Әни». Өц мәртәбә сорыйлар. Кас'ы сабын, кас'ы йаулык, кас'ы акца бирә киленгә кыртлап. – *срг.*

**запун кору** *миш.д., крш.* алъяпкыч бәйләү (надеть фартук). Кызыгыз иртүк торыр, Ап-ак запунын корор, Әнисендә ничек торса, Бездә дә шулай торор. – *хвл.*

**запун кыртлау** *лмб.* яшь киленгә алъяпкыч бәйләткәннән соң, аны котлап бүләкләр бирү (свадебный обряд). Туйда яшь киленгә запун бәлиләр дә запун кыртлыйбыз дип бүләкләр, акча йийалар. Акча йийганнан сың, шал запунга салалар кесәсенә. Акчасы да, запуны да йәш киленгә була.

**ЗАПУН II** [*рус.* запон] *тмн.* к.: **элгец**.

**ЗАПУНКА** [*рус.* запонка] *к.т., мам.*, **DAПУНКА** *минз.* к.: **элгец**. Күлмәгеңне тегеп бетердем, төймә тагып, запунка йасыйсы гына қалды. – *к.т.* Ақлы ситсы күлмәгемнең Dапункасын кем уйған (*хал. җыр.*)? – *минз.*

**ЗАПЫН** [*рус.* запон] *перм.* к.: **алйапма**.

**ЗАР'А** [*рус.*] *срг., т. я.-крш.* таң (заря).

**зар'а йарылу** *срг.*, **зар'а җарылу** *т.я.-крш.* таң ату (рассветать). Зар'а җарылғач та торған идем. – *т.я.-крш.*

**кицке зар'а** *срг.* кичке шәфәкъ (вечерняя заря).

**ЗАРАН** [*гар.*] *лмб.* зыян (вред, ущерб). Су анасы заран итәргә мужыт кешегә, кемдер сүли иде.

**З'АРАШУ** *күрш.* к.: **ақлашу**. Икенче көнендә килдәр мине з'арашма. Әнийемә-әтийемә килдәр. Тутам маға этәдер де з'арашма килдәр дип. И з'араштар ды, бирдәр де үземне.

**ЗАРИЙӘ** *лмб.* «Наза» уеныңың бер төре (вид молодёжной игры с песнями). Зарийәдән ун'илар, уртага тешә бер малай ман кыз, уртадагы берне сыурыб ала, үзе урнысына керә.

**ЗАРҚУ** [*фарс.* + *афф.* -ку] *каз.ар.-крш.* зарыгу (томиться, истомиться в ожидании).

**ЗАРЛАНДЫРУ** [*фарс.* + *афф.* -ландыру] *перм.* к.: **йончу I, 2**. Тәбрисне зарландырып йөртте, бармый.

**ЗАРЛАНУ** [*фарс.* + *афф.* -лану] *перм.* рәнжү, каргау (проклинать). Үзе дә бала күрмәсен дип эт зарланғандыр әле балаларын чапқач.

**ЗАРНИК** [*рус.* озорник] *клд.* к.: **дилдawай**. Гафа абзый зарник иде.

**ЗАСЛУН** [*рус.* заслонка] *кас., баст.* мич капкачы (заслонка). Эче awыртса баланың, заслун белән баса идек. – *кас.*

**ЗАСТУЙЫН** [*рус.* достойный] *минз.* таза кеше (здоровый человек). Бик күп застуйыннар үлеп китте awылда.

**ЗАСТУК** [*рус.* заступ] *каз.ар.* к.: **қырғыч 1**. Застук белән өйгәнийек. – *мам.* Застук белән дә күтәрәсең инде киртмәне җуқ кеше. – *дөб.*

**ЗАСТУН** [*рус.* заслонка] *кас.* к.: **заслун**.

**ЗАТ** [*гар.*] **1.** *лмб., кузн., хвл., карс., крғл.* әйбер, нәрсә (вещь, предмет). Затларын алып китмәдеме? – *лмб.* Ул бара сукаларга кырга, сукалаганда сукасы әләгә бер затка да, бага башлый (*әкият*). Кыз бер генә булган, бер зат та эшләми булган. Икенче заттан куйсаң – әдеп була. Мин вет, Эркийә булмаса, бер зат та тапмыйм. – *кузн.* Бу затларыгызны чоланга куйсагыз да йарый иде. Китә, бөтен затларын җийа. Мин кормыйм решительный бер зат. – *хвл.* Бай баласының заты күп була иде. – *крғл.*; **2.** *лмб., срг.* сүз (слово). Бер зат этәм, ад'а. – *лмб.*; **3.** *хвл.* нәмәрсә – кеше турында көлеп (иронически: личность). Шул затлар аталарыннан китмәстән, монда тыгрыкта үләр салдылар.

**awыру зат** *әстр.* авыру (болезнь). Awыру зат, сырхау китсен дигән сүз бу.

**ашайақ заты** *әстр.* ашау әйберсе, ашамлык (еда, продукты). Ашайақ затыбыз күп.

**зат итү** *әстр.* нәрсә дә булса эшләү (что-то делать). Килеп сыйыр cawa, зат итә. Ни зат итәсең?

**йаман зат** *әстр.* җен-пәри (нечистая сила). «Бәхетле булсын, йаман затлар ийәреп килмәсен» дип, киленне ут белән ышықлап кертәде.

**қызның заты** *әстр.* кыз бирнәсе (приданое невесты). Қызның затын төзиде, сандығын, йастығын, кашмасын, кийезләрен, күрпә-мендәрләрен.

**ни зат** *әстр.* нинди әйбер (какая вещь). Ни зат бирәйәк, ни зат алайақ, ни зат бирмәгә тийеш, хәле тартамы, йегет бит белән сөйләшәделәр.

**ЗАТ-ЗӘWЕРЕ** *крш.* нәсел-нәсәбе (родня). Қызын илтеп қуйа бер зат-зәweренә.

**ЗАТ-ЗӨРИЙӘТ** [*гар.*] *перм.* к.: **нәсел-асаб**. Шуңқы заты-зөрийәте бу халық.

**DАТИЛЫК** [*рус.* затылок]: **dатилық тору** *минз.*, **затилык тору** *стрл.* чират тору (стоять в очереди). Без китапларны dатилық тороб алады-рыйық. – *минз.* Аңарга затилык торалар әле. – *стрл.*

**ЗАТСЫЗ** [*гар.* + *афф.* -сыз] *бәр., минз., трх., каз. ар., чст.* юньсез, тәртипсез, килешсез (непорядочный, невоспитанный; непорядочно, невоспитанно). Затсыз қыланма, балам, Әхмәдиләрнең Бибинуры бигрәк затсыз нәрсә инде. – *трх.* Затсыз баш булған инде. – *дөб.* Бигрәк затсыз инде балалары. – *бәр.*

**ЗАТСЫЗЛАНУ** *бәр.* ямьсез кылану, тәртипсезлек күрсәтү (вести себя невоспитанно, некрасиво). Затсызланып утырма, җәме, уқучы кеше син, шыпырт қына тор.

**ЗАУҚЫМ** [*гар.* + *афф.* -м] *дөб.* теләк (желание). Бик барасы килеп җөридерийе, барып зауқымын басып қайтты.

**ЗӘӘР** [*фарс.*] *перм., бөре.* к.: **дибә**. Зәәр дә матур күлмәк тектергән инде. – *перм.* Зәәр таза кешеләр бар. – *бөре.*

**ЗӘБӘЛ** [*рус.* завал] *бгрс.* саман кирпечтән өеп ясалган эскәмия (скамья, сложенная из саманных кирпичей). Әйдә, зәбәлгә утырабыз.

**ЗӘВЫКЛЫ** [*гар.*] *тмн.* к.: **sawоклы**. Бик ул зәвыклы кеш(е) иде.

**ЗӘҒИФ-ЗӘНКӘР** *мам.* авыру, көчсез, зәгыйфь (слабый, больной, хилый). Зәғиф-зәнкәр балалар күбәйә awылда.

**ЗӘДӘС** *дөб.* ядәч (дужка). Без аның белән зәдәс айырғанийек, мин аны алдадым.

**ЗӘЙӘК** *срг., чст., чпр.* яңак (щека). Зәйәккә бирде берне. – *срг.* Аның зәйәккә элеккән берсәк кенә. – *чпр.* Шылай ике зәйәгемне тытып маңгайымнан үпте. – *срг.*

**ЗӘЙМӘ** *эчк.* җәймә (тонкая лепёшка).

**ЗӘЛӘМӘ 1.** *миш.д.* к.: **алама-шалама**. Зәләмә күлмәк кийеп урамга чыккан. – *хвл.*; **2.** *кузн., хвл.* тузган, начар, иске (обветшалый, плохой, старый). Вына зәләмә чиләккә ташла. Элек зәләмә генә awыл иде, йарлы гына. – *кузн.*

**ЗӘЛКӘ** [*удм.*] *нокр., глз.* сыерчык (скворец). Кара зәлкәләр килгән диләр йаз йеткәч. – *глз.* Бийек тауларның башында Қара ла зәлкәләрнең ойасы (*хал. җыр.*). – *нокр.*

**кара зәлкә** *глз.* к.: **пақцар**. Кара зәлкә килә бала чыгармага, көз көне китә.

**ЗӘЛПӘК** *чпр., срг.* яссы (плоский).

**ЗӘМӘТ** *миш.д., баст.* койма (забор). Әле инде зәмәт аша сүләмә, ызбада сүләгәй идең. Терлектән саклыйсын – выт, крипит ит йакшы чакта зәмәтеңне. Зәмәт йарыкларыннан, кабак йарыкларыннан бага идек. – *хвл.* Зәмәтне кайырып кергәннәр. – *тмн.* Барыбер йаңгыр басты аны, зәмәт буйына куй. Кан'атамның башмагын зәмәт аша ташладым. – *чст.* Акбашлар йагындагы зәмәтне бирми анарга. – *чпр.* Зәмәт башына утырып йазыб утырасың. – *шрл.* Зәмәтләрне қуйдық, қабағ әле қуймаған. – *баст.*

**ЗӘМЛӘҮ** *бгрс.* к.: **зимнәү I**.

**ЗӘҢГӘРБАШ** *чст.* к.: **чәнчәwек.**

**ЗӘҢГӘРТ** *перм.* таш ыргыту өчен баудан ясалган җайланма (верёвочное приспособление для бросания камней).

**ЗӘҢГЕЛӘ** *бәр., каз.ар.* буыннар авыруы (болезнь суставов, ревматизм). Минем айак-кулларымда зәңгелә awырywы бар. – *бәр.* Зәңгеләгә быйылгы караҗимешне ашарга кирәк. Йаңа йыл җиткәнче караҗимеш ашап калыйм әле, зәңгеләмә файдасы тимәс микән. – *лш.* Сарык айагында да зәңгелә була. Айакларның начарланywы зәңгелә хикмәте, сywык тийүдән калды. – *дөб.*

**зәңгелә җимеше** *блт.* караҗимеш (чернослив).

**зәңгелә качыру** *каз.ар.*, **дәңгелә качыру** *минз.* яз көне ашарга яраклы үләннәр үскәч, беренче мәртәбә ашап карау, ырым сүзләре әйтү (заговор, когда говорят при первом употреблении съедобных трав весной). Элек зәңгелә качырабыз дип кычытқан ашы пешерәләр ийе. – *мам.* Беренче җywa, икенче күдғалак, ачы кақы, кымыдлык, шуларны беренче кабасың да: дәңгелә кач, дәңгелә кач, Идел кич, иске корсак, йаңа аш, дип, ihaha дип кешнәп куйасың ат булып. Болар дәңгелә качыру була инде, эчендәге чүп-чар чирләреңне себерә дә ыргыта инде. – *минз.*

**зәңгелә маймыч** *минз.* вак, ашарга ярамый торган балык (мелкая, несъедобная рыба).

**ЗӘҢКИ** [*фарс.*] *т.я., каз.ар., злт.* карақгы чырайлы, усал хатын-кыз (неприветливая, злая женщина). Алар бик сөйләшмиләр, зәңки ул җиңги. – *блт.*

**ЗӘҢКИЛӘНҮ** *дөб.* усаллану (становиться злым). И шушы Фатыйма апа зәңкиләнеп күз астыннан карап йөри.

**ЗӘПӘСИЙӘ** [*рус.* запястье] *кузн.* к.: **башлага.**

**ЗӘР** *кузн., мәл., т.я., каз.ар.* билгә буа торган киң билбау (кушак). Кийәү зәр бәләгән. – *кузн.* Йегетләр зәр бәйләп йөриләр ийе элек. – *мам.* Бишмәт өстеннән кызыл зәр буганнар. – *к.т.*

**ЗӘРӘ I** [*рус.* заря] *миш.д.* к.: **зар'а.** Алай карамыйнчы да йандыра, зәрә вактында гына килде дә йатты урныга. Таң ата микән, таң микән, Таңда зәрәләре бар микән (*хал. җыр.*)? Таңда зәрәләре сызылып килә. – *кузн.* Әле хет әч кич кунса да, зәрә белә китә. – *мәл.* Зәрәдән тырдым. – *хвл.*

**зәрә бәбәгеннән** *мәл.* иртә таңнан, иртүк (ни свет ни заря, очень рано). Кайа киттең болай зәрә бәбәгеннән?

**зәрә беленү** *чпр.* таң беленү (рассветать). Куцатлар кыцкыра, зәрә беленә.

**зәрә ботқасы** *мам.* к.: **дәрә: дәрә итү.** Җарма җыйалар, итләр, майлар, ботқа пешерәләр, зәрә ботқасы.

**зәрә йарылу** *миш.д.* к.: **зар'а: зар'а йарылу.** Зәрә йарылу белән йулга чыктык. – *хвл.* Без мунчага килгәндә, зәрә йарыла иде инде. Зәрә йарылу белә көтүне kywa башлыйлар инде. – *чст.*

**зәрә йасау** *кргл.* чәчүгә чыгар алдыннан йомырка җыю гадәте (обычай собирать яйца перед выходом на посев). Иң әwәле балалар зәрә йасыйлар, қапчык белән күкәй җыйалар, шул зәрәдә балаларга ашлар пешереп ашаталар.

**зәрә қычқыру** *мам.* сабан туена ике көн кала балаларның тауга менеп, утлар ягып, сабанга чыгарга вакыт җиткәнлеген белдереп кычкырып йөрү йоласы (старинный обычай, проводимый детьми перед посевом); чаг.: **дәрә: дәрә итү.** Сабан туйына ике көн қала зәрә қычқыралар ыйы балалар, тауга менеп, утлар җағып. Зәр-зәр-зәрәгә, иртә тор да сабанға, дип.

**зәрә тамагыннан** *срг.* к.: **зәрә бәбәгеннән.** Килә зәрә тамагыннан.

**кен зәрәсе** *шрл.* көн яктысы (дневной свет). Кен зәрәсе беткәч, йәстү була.

**төн зәрә** *срг.* иртүк, таң белән (спозаранку, очень рано). Төн зәрә торамын, атка атланып китәмен.

**ЗӘРӘ II: зәрә очу** *дөб.* кот очу (сильно испугаться). Қаршыма килеп чыққач, зәрәм очты инде.

**ЗӘРӘПИ** [*рус.* зверобой] *т.я.-крш.* сары мәтрүшкә (зверобой). Зәрәпи җыйып алып кайттык. Миңа да бирегез әле шул зәрәпине. Зәрәпи кайнатып эчтем әле, салкын тиган иде.

**ЗӘРӘТ** [*гар.*] *миш.д.* к.: **гүр: гүрләр өсте.** Чывашларның зәрәтләре өстенә урнашкан.

**ЗӘРӘТӘ** *перм.* сәрдә (сныть обыкновенная).

**ЗӘРӘТЛЕК** [*гар.* + *афф.* -лек] *тмн., лмб.* к.: **гүр: гүрләр өсте.** Зәрәтлектә чалдылар ике сирны, бик зур казаннарда пешерделәр. – *лмб.*

**ЗӘР-БӘЗӘР: зәр-бәзәр китерү** *тмн.* пыран-заран китерү, туздыру (разнести в пух и прах).

**ЗӘРДӘ** *к.т., чст.* к.: **зәрәтә.**

**ЗӘРДӘК** *нрл.* к.: **зәрәтә.** Зәрдәк урманда үсә, пешерәйдек бигәйбәтләп, җоморқа қыздырасың да бергә пешерәсең аш.

**ЗӘРЗӘ** [*фарс.*] *злт., стрл.* к.: **зәрәтә.** Балтырганга окшаклы, зәрзә үләне диләр ийе. – *стрл.*

**ЗӘРЛӘҮ** *хвл.* эзәрлекләү, яшерен сагалап йөрү (преследовать, тайно следить за кем-либо); чаг.: **андау.** Каракны зәрләп йөриләр.

**ЗӘРРӘ: зәррә очу** *дөб.* к.: **зәрә II: зәрә очу.** Қурқып, зәррәләре очоп тора инде тегеләрнең.

**ЗӘҮМӘТ** [*гар.*] *перм.* к.: **дәүмәт.** Алмагыз йегетләр қалган хатын, Зәүмәтләре булмас қыз кебек (*хал. җыр.*).

**DӘХӘР** [*фарс.*] *минз.* к.: **бәләкәй 1, 2.** Дәхәр әйбәт кеше бу.

**ЗӘХМӘДИ** [*гар.*] *нрл.* явыз, әшәке (злой, плохой). Әбәү, зәхмәди дә инде.

**з ә х м ә т** [*гар.*]:

**зәхмәт теле** *к.-уф.* пәри-җен кагылудан имләү (знахарское лечение от злых духов). Зәхмәт теле дип су саласың, җиде төрле әйбер саласың, күмер, көл, қазак, чәч h.б.

**ЗӘҺӘН** *әстр.* ефәк (шёлк). Ак зәһәннән әләм әлеп қуйдым әүлийә өйөнә. Ак зәһәннән куржива теккән.

**ЗӘҺӘР** *бөре., перм., злт., стрл.*, **DӘҺӘР** [*фарс.*] *минз.* **1.** бик шәп, бик әйбәт (очень хороший, замечательный). Қунак җанына қунак зәһәр әйбәт. Бик зәһәр миллек. Әй зәһәр дә инде бу қыз, бер килмәгән җире йуқ. – *бөре.* Аның бичәсе зәһәр дә инде, шул Қазан җақныкы. – *перм.* Ашау бик дәһәр ийе. – *минз.* Бик зәһәр күлмәк алган. – *злт.* Ите зәһәр симез булган сарыкның. Зәһәр

көчле кеше. – *минз.*; **2.** *бөре.* бик тиз, җитез (очень быстро, прытко). Әй зәһәр дә чаба инде бу ат.

**ЗБУТ** [*рус.* свод] *т.я., чпр.* мичнең төтен юлы (дымоход).

**ЗЕБЕТ** [*удм.*] *нокр.* **1.** тыйнак, тотнаклы (скромный, сдержанный). Зебет қыз дегел; **2.** булдыклы, сәләтле (деловитый, способный); *чаг.*: **бортак**. Бик йырт йаққа зебет икән ич, эшкә зебет икән ул.

**ЗЕБЕТЛЕК** [*удм.* + *афф.* -лек] *нокр.* тыйнаклык (скромность). Зебетлеге йу', үзен тота белмәй.

**ЗЕЛЕФ** *лмб., мәл.* зелпе (жимолость). Зелеф кывагы.

**ЗЕЛПЕ** *каз.ар., т.я., кмшл.*, **ДЕЛПЕ** *минз.* **1.** марҗа алкасы (бересклет бородавчатый); **2.** бересклет европейский.

**ЗЕМӘЛӘҢУ** *лш.* к.: **абдырау 1**. Китәрләр дип қурқып земәләнәм генә, қурқам ашқа кертми қалырбыз дип.

**ЗЕН** *срг.* к.: **йөннек**. Йыгылып зенеңне эзмә.

**зен қалқу** *перм.* җен ачуы килү, җене чыгу (разозлиться, прийти в сильное негодование, вспылить). Мөхәммәт бичәне қыра, имеш, зене қалыққан қыз киткәс.

**зен қалыққан wахыт** *перм.* җеннәр йөри торган вакыт (время, когда будто бы ходят черти, бесы). Икенде белән ахшам арада зен қалыққан wахыт була.

**з е н и** (җиңги):

**зени тутыка** *чст.* җиңги, яшь киленгә эндәшү сүзе (форма обращения к молодухе). Миңа зени тутыка кулйаулык бирде дип сүләделәр кинәнеп.

**ЗЕҢӘКӘЙ** *срг.* к.: **йеңгәчәй**.

**ЗЕҢГЕРӘҮ** *стрл.* калтырау (дрожать). Илаһым, идәннәр зеңгери, җугал диб, илаһым кычкыра.

**ЗЕҢИ** *срг.* **1.** к.: **йеңгәчәй**; **2.** туй вакытында кыз янында йөрүче хатын-кыз, кыз җиңгәсе (женщина, которая ухаживает за невестой во время свадьбы). Зеңи кыз йагында мунца йага, зеңигә бер митыр запунныk бирә килен.

**ЗЕР 1.** *к.т.* керле, кап-кара (грязный, чумазый). Бер кийеп бардың, ақ җақа зер була; **2.** *клд.* к.: **былчырақ**. Зер йийыла-йийыла да калынайып чукракка әйләнә.

**ЗЕРӘКЛӘНЕШҮ** *тмн.* ачуланышу (ругаться). Зерәкләнешсәләр, сүләшмиләр.

**ЗЕРӘКЛӘҢУ** *күрш.* ачулану, усаллану (ругать, злиться, бранить). Кан'анасы зерәкләнә кызымның.

**ЗЕРНӘЛЕ: зернәле алабута** *лмб.* к.: **алабата 2**.

**ЗЕРНӘҮ** *тмн.* **1.** дерелдәү, калтырану (дрожать). Тешем тешкә бәрелә, зерним. Ни шылай зернисең?; **2.** дер селкенү (трястись, дрожать). Айу үкерә, бөтен йер зерни.

**ЗЕРНИЙӘТЕ** *шрл.* к.: **җоғоро(сы) 1**. Миндә Казанның зернийәте дә йук.

**ЗЕШ** *кмшл.* к.: **дәллә 2**. Әй, аның кебек зеш булмас.

**ЗИБӘЛӘЙ: зибәләй үлән** *байк.* йонча (мятлик).

**ЗИЙАҚ** *лш.* уяу, үткен (удалой). Абыйым бик зийақ булды.

**ДИЙАН-ДАЙРӘТ** [*гар.*] *мам.* зыян-зарәт, зарар (вред, ущерб, потеря). Әле моңончо дийандайрәт күргәнем йук.

**ЗИЙАНДАШ** *перм., тмн.* зыяндаш (эпилепсия). Зийандаш ателә, өшкерәләр, әле инде укуллар. – *тмн.*

**зийандаш қағылу** *перм.* үз чире тию, үз чире авыруы тию (заболеть эпилепсией).

**зийандаш тоту** *тмн.* зәхмәт кагылу (подвергаться заболеваниям). Зийандаш тота, агардан дуwа бар.

**ЗИЙАФ** [*гар.*] *чст.* бизәк (узор).

**дулкынны зийаф** *чст.* дулкынлы бизәк (волнистый узор). Бикәцкә килгәнце йибәргәннәр букцаны. Мына дулкынны зийаф белән циккән, бу әнинең букцасы.

**ЗИЙӘК I** *чпр., срг.* к.: **йәйәк I**. Зийәгенә апиратсийә йасаганнар. – *чпр.* Зийәккә бирә ату. – *срг.*

**ЗИЙӘК II** *каз.ар., нрл.* хатын-кызлар киеменә тотыла торган тасма (тесьма, нашиваемая на женскую одежду); *чаг.*: **албуй**. Ураққа төшкәндә ақ тулайоқ белән чабата кийенәдер ийек, ал зийәкле җиңсәләр, зийәкләре дуғай-дуғай салынған була. – *лш.* Зийәк тоталар ийе, зийәкле күлмәк кигән дип атақлы булған инде. – *нрл.*

**ЗИЙӘК III** *дөб.* киндер сабагы (стебель конопли). Туқмақлап орлығын алғач, ишегалдында җәйәсең зийәген, ул ағарып сүс була.

**ЗИЛЕМ** *шрл.* уен, күңел ачу (игра, веселье). Кылупта булдыгызмы, зилем карамадыгызмы?

**ЗИЛЕН** [*рус.* зелень] **1.** *кузн.* к.: **алсын 1**; **2.** *мәл.* яшелчә (овощ). Берсәк зилен ашарга кирәк.

**ЗИМ I 1.** *кузн., лмб., хвл.* туклыклылык, бәрәкәт (питательность, калорийность). Ак әпәйдә бер дә зим йук, карада зим күп. Арыш әпәйе зимне була. – *хвл.* Сыйырлар салам аший – зиме йок саламның. Әле (язын) вит курмыларның зиме йук. – *кузн.*; **2.** *кузн., хвл., карс., мәл.* уңдырышлылык (плодородность). Тупрақның зиме бетмәгән әле. – *хвл.* Зименә күрә җимеше йук. – *карс.*; **3.** *кузн., тмн., мәл.* азык, җим (корм, пища, еда, питание). Агачның зиме беткән дә корыган. – *кузн.* Ишектән кердем, зим сиптем Утыра торган казыма. Тагы берәр йыл торса идем, Шәт, калмас идем башыңа (*хал. җыр.*). – *тмн.* Балалы каргадан зим артмый (*әйтем*). – *мәл.*; **4.** *блт., т.кам.-крш., лмб., бөре.* баллылык, татлы тәм (сладость). Ире шақмақлы шикәр зимнерәк, аның тәме озон. Ипиле кәрәзне сыктым, тәмне зим генә. – *блт.* Җиләк пешеп тә җитмәгән, зим генә. – *т.кам.-крш.* Қырт бу чәчәкләрдән зим ала. – *нгб.-крш.* Зиме петкән, wаринйа қайнатасың шикәр өстәп. – *бөре.*; **5.** *кузн., хвл.* сүл, сок, сыекча (сок, жидкость). Игеннәр йахшы төгел, камка зимен суырадыр. – *хвл.*

**зим итү** *к.-уф.* азык итү, ашамлык итү (считать за еду, за корм). Бер генә арпаны зим итәнме инде аны.

**зим цәцәк** *срг.* алабай (пупавка красильная).

**ЗИМ II** *лмб.* күбек (пена). Эскә зимнәре күтәрелгән иде кывасының.

**ДИМ** *минз.* к.: **дим 1**.

**dим тибү** *минз.* көз көне боз катар алдыннан елгада карлы боз агу (появление шуги на реке). Иделдә dим тибә.

**ЗИМАЛЫ: зималы күл бавы** *бөре.* тәңкәләр белән бизәп ясалган беләзек (браслет, украшенный монетами).

**ЗИМБЕЛ** [*гар.*] *әстр.* камыштан үрелгән сумка (сумка, плетённая из камыша или тростника). Зимбелләр бәйлиләр чакыннан. Чакыннан бәйләгән затны сумка димиләр, зимбел дип сөйлиләр. Уникелек зимбел, йегерме дүртлек зимбел булды.

**ЗИМЕС, ЗИМЕСЛЕК** *әстр.* кияү ягыннан кыз өенә туй алдыннан китерелгән тәм-томнар, чикләвекләр (сладости, орехи, принесённые в дом невесты со стороны жениха). Йегетнең күчтәнәче зимес дип әйтелә. Ун кила, уникә кила зимес киләде йегет биттән.

**DИМНӘНКӘ** [*рус.* землянка] *минз.* к.: **азбар: йер азбар**. Dимнәнкәгә төшәргә бачкычы бар, бәрән белән сарык тота.

**ЗИМНӘҮ I** *перм., трбс., злт., байк., к.-уф., стрл.*, **DИМНӘҮ** *минз.* бал ачып туктагач, шикәр өстәп баллап кую (услащать брагу). Балым әчерәк булган, зимнәп җибәрдем әле, шикәр қомо салып. Балны зимнәп җибәрдем, тәмне булсын дип. – *каз.ар.-крш.* Ацыган балны, ширбәте бетсә, зимнәп куйасың. – *байк.* Зимнәп куйдым әле балымны, ачырмы, йукмы? – *стрл.* Шәкәре бетеп китсә, нык асып китмәскә тагы шәкәр өстиләр, зимниләр. – *к.-уф.*

**ЗИМНӘҮ II** *перм.* ямау салу (наложить заплату). Күлмәгең туза, йамыйсың, зимнәп куйдык тисең.

**ЗИМНЕ** *кузн., хвл., карс.* **1.** туклыклы (питательно). Ит кебек, май кебек нәрсә ашасаң, зимнерәк була. Зимне аш; **2.** уңдырышлы (плодородный). Зимне йер бу.

**ЗӢН** [*гар.*] *срг., чпр.* зиһен, хәтер (память). Инде ыныттым да – зӣнем йук. Зӣненнән айырмасын диген. – *срг.*

**ЗИҢӘКӘЙ** *срг.* к.: **йеңгәчәй**. Ишегалнына йаттым, зиңәкәй түшәген бирде.

**ЗИҢГӘЧИ** *чст.* к.: **йеңгәчәй**. Зиңгәчинең хален белəм.

**ЗИҢИ** *чст.* к.: **йеңгәчәй**. Барам әле, зиңине сагындым.

**ЗИҢКЕТҮ** *минз., бөре., стрл., чпр.* алҗыту, интектерү (мучить, изнурять; надоедать). Мине айак awыртқан көйе зиңкетеп бетерделәр инде сыйырлар. – *минз.* Теш сызлап зиңкетә, капланғыры. – *бөре.* Зиңкетмә ыланны, йыкласын. – *чпр.*

**ЗИҢКҮ** *бөре.* алҗу, арып бетү (утомиться, обессилеть). Қыш көне чаңгы белән барып зиңкеп бетә идек.

**ЗИПКЕ** [*рус.* зыбка]: **зипке бирү** *трх.* тирбәтү (качать). Бала инде йоқлаған, зипке бирмәсәң дә җарый.

**ЗИПУН** [*рус.* запон] *злт.* ирләр алъяпкычы (мужской фартук, запон).

**DИРАТ** *минз.* кабер (могила). Әтәйнең dираты қайда дип сораучылар да бар.

**зират** (кладбище):

**зират бәйрәме** *әстр.* үлгән кешеләр рухына багышлап җәй көне уздырыла торган бәйрәм (праздник, который проводится летом в честь умерших). Зират бәйрәменә арба-арба халық килә, аш пешә дә теләк телиләр, теләк йасый булғаннар.

**зират теләк** *әстр.* к.: **зират бәйрәме**. Зират теләккә йыл да барабыз, ару, затлы кийенеп барабыз.

**ЗИТЕМ** *тмн.* ятим (сирота). Бер ызба тулы зитемнәр калдык.

**ЗОҢҚАРЛАУ** *нокр.* к.: **мөһөрләү**. Әйдә, бик зоңқарлап торма, йарар (күлмәкне үтүкләгәндә).

**ЗӨЗӨК** *каз.ар.-крш.* йөзек (перстень).

**зөзөк салу** *каз.ар.-крш.* нардуганда күрәзәлек итеп йөзек салу (святочное гадание). Зөзөк салғанда төрле җырулар чыға, шулар гел туры килә.

**ЗӨҢГӨ** *перм.* **1.** бал кортының угы; елан угы (жало пчелы или змеи); чаг.: **чага II**. Зөңгесе белән чәнчи wы қорт. Зөңгөсе була, шерпе күwек мәсе қадалып қала тәңгә. Йыланның аузыннан зөңгөсен алып қуйынға тыгалар, имеш; **2.** очлы башлы тимер (остроконечный железный предмет, напр., лом). Зөңгөсе бар сажин йарым озонлығы, шуның белә төртә; **3.** *трбс.* сөңге, сай җирдә балык тоту коралы (орудие в виде копья, используемое для ловли крупных рыб, оказавшихся в мелководье).

**ЗУБАНА** [*рус.* зобня] *дөб.* бәрән ашату өчен юкәдән үреп ясалган кап (короб из липовой коры для кормления ягнят); чаг.: **алап I, 2**.

**ЗУБНА** [*рус.* зобня] *чпр.* кибәк ташый торган савыт (посудина, в которой носят мякину).

**ЗУWЫК** *тмн.* якын (близко). Лаукага зuwык ук торадыр үйләре.

**ЗУДАЦЫ** *күрш.* юучы (тот, который моет). Зудацыларны тегәндисен инде, бирәсен күләкләр и акца.

**ЗУҚЫМ** *т.я.-крш.* к.: **заман 1**. Бер чиләк суны койашка утыртсаң, зукым җылына. Йәле, кызым, сабагыңны зукым гына укып күрсәт әле.

**ЗУМАНА** [*рус.* зобня] *лш.* к.: **зубана**. Зуманаға салып ашатабыз қышын.

**ЗУМНАУ** *перм.* борыслыкны үлчәп дүрткырлап ясап кую (приготовить четырёхгранный брус). Ишегебез қыстау булды, баш төртөлә, бер қарыш кисеп ташлады зумнаған нәмәне, рубучийыбыз баштақ булды.

**DУНТИК** [*рус.* зонтик] *минз.* к.: **картус**.

**ЗУПЫТ** [*удм.*]: **зупыт итү** *глз.* бөрештерү (подвергаться действию какого-либо вяжущего вещества). Awызны зупыт эти ачы алма, шомырт ашагачын алай була.

**ЗУР 1.** *лмб., срг., мәл., клд., шрл.* көчле, каты, нык (сильный, сильно). Йыгыра чыктым, эт бик зур әрә. – *лмб.* Нинди зур йаңгырлар йауды. – *срг.* Мин зур эчкем келәгәндә генә эчәмен чәйне. Зур исерек тә түгел. – *шрл.* Әз-әзләп йawып алды да, зур йук шул. Бик зур йаумаган, ахыры. – *мәл.* Сызарга иде вата картуфны, зур йаңгыр әле вет. – *клд.*; **2.** *срг.* озын (длинный). Цәцем бик тә зур иде минең йәш бахытта; **3.** *каз.ар., кмшл.* озак (долго). Әллә ни зур йәшәгән кеше булмады. –

*каз.ар.* Читтә зур йермәде инде ул. – *кмшл.*; **4.** *мәл., шрл., срг.* күп (много). Хазер йәшләр дә зур йук. – *мәл.* Зур сүләргә йарамый. – *шрл.* Безнең заманда зур калмады борынгы кийемнәр. – *срг.*

**зур бawырлы булу** *лш.* к.: **борнайлану**. Бик зур бawырлы булдым инде мин, тегесе дә йарамады, моносо да йарамады.

**зур итү** *т.кам.-крш.* зурлау (величать). Бик зур итмәсәгез дә, қур итмәгез, Ким-қур булырлық түгел җегете (*туй җыр.*).

**зур йаз килү** *стрл.* язгы ташу башлану (начало весеннего половодья).

**ЗУРАГАЙ** *лмб.* к.: **абызбабай**.

**ЗУРАЙУ** *чст.* мактану (хвалиться). Такта чулпым да бар иде, хастәм дә дип зурайа иде кан′анам.

**ЗУРАТ 1.** *глз.* печән кибәне (стог сена); **2.** *бгрс.* тизәк кирпечләр өеме (куча кирпичей из кизяка, сложенная в виде трапеции). Безнеке зуратта энде, эш бетте.

**ЗУРАТА** *кузн.* к.: **абызбабай**.

**ЗУРЛАНУ** *глз.* әреләнү, масаю (важничать, зазнаваться). Зурланган күк була димен, керәмен.

**ЗУРЛАНЧЫК** *лмб.* к.: **кибер**.

**ЗУРЛЫҚЫЙ** *каз.ар.-крш.* зурлыгында (величиной с ...). Тушыны зурлықый балық. Тушыны зурлықый булыр ыйы бөккән, қазан бөккәне.

**ЗУРН′А** [*рус.*] *трх., карс.* ашлык бөртеге, ашлык (зерно, хлеб в зерне). Көрәк белән сuwыра торған ыйық, кибәген алып китә, зурн′асы қала. – *трх.*

**ЗУРНӘ** *кргл.* к.: **қартинә(й) 1**. Ул зурнәсен йарата шул.

**ЗУРНӘЙ 1.** *стрл.* к.: **абызтүти 2**; **2.** *бөре.* к.: **картинәй**. Зурнәй тиргәй.

**DУРНӘКӘЙ** *минз.* әти яки әнисенең олы ир туганының хатыны (жена старшего брата отца или матери). Әни, dурнәкәй чақыра.

**DУРНЫЙ** *минз.* әби, әтисенең әнисе (бабушка с отцовской стороны).

**ЗУРУТ** *глз., нокр.* к.: **зурат 1**.

**З′ҮГЕННӘН** *күрш.* к.: **йағалап**. Килә вит зират з′үгеннән трапинка буйынцы.

**ЗЫБЫН** [*рус.*] *миш. д., глз., баст.* чикмән (зипун). Йаңа зыбын кийеп килгән. – *чпр.* Зыбынга чормаганнар да күмәләр. – *кузн.* Зыбын кийеп, билең бuwып, Кайа киттең әле син (*хал. җыр.*)? Зыбын бит сыкнаныкы сырсыз була тылып кебек. – *срг.* Ширестән суғылған зыбынны салқын wақытта кийәләр иде. Кетү кеткән, эстендә зыбын ғына икән. – *баст.*

**кара зыбын** *хвл.* кара бәхет, бәхетсезлек (несчастье).

**ЗЫВЫТ** [*рус.* свод] *хвл., мәл.* к.: **збут**.

**ЗЫҒЫТ** *әстр.* хәйләкәр (хитрый). Зыгыт кеше икән син.

**з ы й а н д а ш** (эпилепсия):

**зыйандаш сугылу** *перм.*, **зыйандаш тоту** *мәл.* к.: **зийандаш: зийандаш қагылу**. Тыумыштан уқ зыйандаш суғылды да припадкаға әйләнде. – *перм.* Ак тирәкләргә тешереп әләләр иде зыйандаш тыткан баланың күлмәкләрен. – *мәл.*

**ЗЫЙАН-ЗАРАТ** [*гар.*] *стрл.* зыян-зарар (собир.: вред, ущерб, убыток). Зыйан-заратым йуг алай.

**ЗЫЙБ** [*рус.* зыбь]: **зыйб белән** *мәл.* әкренләп, иплəп (медленно, постепенно).

**ЗЫЙФА-ЗИРӘК** [*гар.*] *кмшл.* ямьсез һәм тәкәббер кешегә карата көлеп әйтелә торған сүз (говорится о высокомерном человеке с некрасивой внешностью – ирон.).

**ЗЫЙЧ** *хвл.* калай (жестяной). Зыйчтан йасалған пич.

**ЗЫҚ: зық зәмәнә булу** *бәр.* зык кубу (шуметь, галдеть).

**ЗЫҚ: зык салкын** *мәл.* бик салкын, көчле салкын (сильный мороз). Аннан зык салкыннарга калырсың.

**ЗЫҚМА I** *каз.ар., т.я.*, **ЗЫКМА** *чпр.* **1.** бөтенләй, тәмам (совсем, совершенно); чаг.: **башала 1**. Зықма қаста булдым үзем дә қаста җанында. – *мам.* Көне буйы җаңғыр җауғач, хайwаннар бүген зықма ач. – *к.т.*; **2.** *мам.* төбенә кадәр (настежь). Ишекне зықма ачып қуйдым.

**ЗЫҚМА II** *блт.* бик ач (очень голодный). Әни, зықма ыйы бу малай, бер тәрилкә аш ашады.

**ЗЫҚЫ I** *перм.* к.: **мәте 2**.

**ЗЫҚЫ II: зықы салқын** *каз.ар.* к.: **зык: зык салкын**.

**ЗЫҚЫ III: зықыға тийү** *нгб.-крш.* теңкәгә тию (докучать, надоедать); чаг.: **дын: дынын бетерү**. Зықыма тидең инде, бала.

**ЗЫКЫ I: зыкыны чыгару** *шрл.*, **зыкысын чыгару** *мәл.* хәлдән тайдыру (довести до изнеможения); чаг.: **чиләнү**. Элгәре азапландык, зыкыларыбызны чыгардык.

**ЗЫКЫ II: зыкы салкын** *мәл., чст., чпр.* к.: **зык: зык салкын**.

**ЗЫҚЫЛДЫҚ: зықылдығы чығу** *дөб.* бик нык ару, җәфа чигү, хәлдән таю (сильно уставать, маяться); чаг.: **алҗырау; гүрләнү**. Эшли-эшли аның зықылдығы чыққан инде.

**ЗЫҚЫМ I** *блт.* йогынты, тәэсир (влияние). Җүнсез малайларның зықымы тигән сиңа.

**ЗЫҚЫМ II** *трх.*, **ЗЫКЫМ** *чст.* к.: **зықма I, 1**. Биш ылан белән зыкым ач калган идем. – *чст.*

**ЗЫМ** *тмн.* йон (шерсть). Куй зымын эрлиләр иде, басалар иде.

**З′ЫМА** [*гар.*] *күрш.* к.: **җома**. Бер эц з′ыма тырсайдегез.

**ЗЫҢҒУ** *перм.* ныгу (крепнуть). Зыңғып үсә бит ул бәпкәләр, бодай ашаса.

**ЗЫҢҒЫТЫП** *перм.* нык итеп (крепко). Ашаң зыңгытып, чебеч ашау ашау буламени. Бас зыңғытып.

**ЗЫҢҚАР** *бгрс., кргл.* авыру (болезнь). Менә шуның зыңқары белән очалмыйлар икән алар қазлар. Мында қайтқач эшләп йөрөде дә, зыңқары булғандыр инде. – *кргл.*

**ЗЫҢҚАРЛАНУ** *каз.ар.-крш.* к.: **гүрләнү**. Зыңқарланмый бала үсми инде.

**ЗЫҢҚАРЛАУ** *бгрс., кргл.* к.: **awырықсыну**. Электән зыңқарлаған, ахырсы, ул, нинди дә булса рәнжүwе булғандыр. – *бгрс.*

**ЗЫҢҚАРЛЕК** *дөб.* к.: **аламалық**.

**ЗЫҢҚАРУ** *чст.* к.: **гүрләнү**.

**ЗЫПЫН** [*гар.*] *чст., каз.ар., әстр.* к.: **зыбын**. Зыпыныңны салсаңчы. – *лш.* Зыпын тегәмез, қулынан теккән узыр салып. Озон зыпын кигән кинчәкләр. – *әстр.*

**ЗЫР I** *м.-кар.* **1.** сыр, бизәк (узор). Ызбага җасаган зырларны каратлар; **2.** к.: **буйак I**. Ничти зырлары? Чит-чит итә, читәнгә куна, әләмән кырлы, алтын зырлы (*табыш.: әтәч*).

**ЗЫР II: зыр кыругум** *каз.ар., бәр., чст.-крш.* тирә-яклап, һәр яктан (кругом). Зыр кыругум ашлыкны тезеп менәсең көлтәне. – *дөб.* Кисмәкнең төбен зыр кыругум бармак тирәлеге алып чыгалар. Зыр кыругум салып барып. – *бәр.* Зыр кыругум киртә тоткан. – *чст.-крш.*

**ЗЫРЛЫ** *трбс.* сырлы (ребристый, узорчатый). Қарындыкның зырлы тиресен қуптарып алып тәрәзәгә қуйған. Аның қырлары зырлап эшләгән булған.

**ЗЫРТ** *күрш.* йорт, өй (дом).

**зыртлыкка алу** *күрш.* йортка кертү (пустить примака). Зыртлыкка алдым ир, үлде, зангыз калдым.

**ЗЫРУК** [*рус.* вдруг] *кузн.* кинәт, көтмәгәндә (вдруг, неожиданно). Кычкырып йебәргән зырук.

**ЗЫРХЫWAT: зырхыwat сире** *к.-уф.* тәнгә чыккан шеш (нарыв, опухоль на теле). Зырхыwat сире булса, тәне шешә қызыл булып, боты шешә. Зырхыwat сире булса, қызыл чеперәк белән урап қуйарға кәрәк.

**ЗЫРЫҚ: зырық кебек** *перм.* к.: **ажғырыйн**. Зырық кебек қызы бар. Малайы бар зырық кебек, таза, гыйфрит кебек кеше.

**ЗЫТ** *дөб.* сер бирмәс кеше (человек, который умеет хранить тайну, секреты). Анықын белмәссең, ул бик зыт кеше.

**ЗЫХЫТ** [*гар.*] *кас.* к.: **дахат**. Зыхытым чы'ты.

# И

**ИБАЗ: ибазға бирү** *кргл.* кирәген бирү (наказывать, взгреть, задать по заслугам). Тирги торған ыйы безне ибазыбызға биреп, нық усал ыйы үгәй инәй. Қайтқач ибазына бирә ире, мәҗлестә үзе йырла диб әйтә дә!

**ИБӘ** [*гар.*] *злт.* вәгъдә бүләге (подарок невесты родственникам жениха после сговора; дарили обычно полотенце и т.п.). Туйына ибә биреп қайтара торғаннар ыйы килешеп.

**ибә итү** *төм.* гафу итү (простить). Ибә иттем. Мәйет қулы белән оцлап қалса, бар гөнаһларны ибә иттем тейсең, анан пушатайты.

**ИБӘК** *брб.д.* ефәк (шёлк).

**ИБӘРЛӘНҮ** *тара.* ваклану (крошиться).

**ИБӘЦ** *тара., төм.* бераз, аз гына (чуток, немножко). Бер ибәц атласам, арып қуйам.

**ИБӘЦЕ** *том. д.* к.: **тумрам**.

**ИБӘЦЛӘП: ибәцләп кисү** *тбл.* ваклап кисү (нарезать мелкими кусочками).

**ИБЕНӘ** *туб.-ирт.д.* к.: **башкөллө**.

**ИБИРҮ** *брб.д.* әйләндерү (вращать).

**ИГАР** *минз.* к.: **игәр I, 1**.

**ИГӘН I** *себ.* икән (оказывается).

**ИГӘН II** *төм.* камышның бер төре, җикән (разновидность камыша, рогоз).

**ИҒӘНӘ** [*гар.*] *минз.* муллага бирелә торган хәер (милостыня, пожертвование, которое даётся мулле).

**ИГӘР I** *минз. брб.д.* **1.** ау эте (охотничья собака); **2.** ялкау – кешегә карата әйтелә (лентяй – о человеке).

**ИГӘР II** *саз.я.* иде – кисәкчә (бы – частица). Оссон көмөрлө wулсыннар игәр. Игәр ахца пирф йеwәрсәр ит. – *саз.я.*

**ИГӘРГЕСЕЗ** *трх.* җыеп бетергесез, күп – уңыш турында (очень много, богато – об урожае). Быйыл игәргесез булды инде ул бәрәңге.

**ИГӘРЕШҮ 1.** *эчк.* шаяру, тик тормау (шалить, озорничать); **2.** *тара.* тотыну, тию (держать, задевать); **3.** *тара.* киреләнү, карышу (упрямиться, перечить).

**ИГӘРҮ 1.** *эчк.* ияртү (следовать за кем-либо). Безгә игәреп бара күрмәсең; **2.** *төм.* җыеп бетерү (убрать всё). Пецәннектә игәрә алмаслық бецән.

**ИГӘРЧЕ 1.** *хвл.* әче камырдан пешерелгән вак-вак түгәрәк ипиләр (мелкие хлебцы); чаг.: **питрас**. Игәчемнең үwенә баргыйнчы бер игәрчелек он тартырмын (*әйтем*); **2.** *к.т.* вак ипи, хәергә бирер өчен кечкенә итеп әвәләнә торган ипи (маленький круглый хлебец для подаяния).

**ИГӘТ** *стрл.* кызга ата-анасы ягыннан кияү йортына алып барырга бирелә торган мал (подарок-живность, даримый родителями невесты при вступлении её в брак).

**игәү** (подпилок, напильник):

**игәү қойрық** *тбл.* су күсесе (ондатра).

**ИГӘЦ** *тмн., чпр.* бертуган апа, үзеңнән олы кыз туган (старшая сестра). Минем игәцемнең кан'анасы Касим кызы иде. – *тмн.* Игәцебез мулла катыны булып торды. Кан'атасының игәце бар, сеңлесе бар. – *чпр.*

**ИГӘЧ 1.** *тмн., лмб., кузн., хвл., чпр., әстр.* к.: **игәц**. Игәчләрем, сеңелләрем Мәскәүдә тыра. – *тмн.* Берсе сеңлем, берсе игәчем. Игәчем бар, сеңлем бар. – *лмб.* Игәчле-сеңелле икебезгә дә бирнә бирде. Игәчле-сеңелле иде үзләре. Игәче бар, анда плəманчалары. – *кузн.* Анасы сукыр, бер игәче бар. Игәчем кызы бу плəмәнчəм. Игәч инде, үзеңнең тума апаңа ат'алар. – *хвл.* Игәчләрем күрше awылда гына торалар. – *чпр.* Игәчем Волгоратта тора. – *әстр.*; **2.** *карс., кузн., хвл., тмн.* бертуган апа яки сеңел (родная сестра). Канигәчләрем, кан кыйгычларым, Үз игәчләрем, сыр белгечләрем (*бор. җыр.*). – *кузн.* Пристина кан'агага да, кан'атага да; игәчләренә дә күлмәкләр. Тее игәчләремнеке чәчләре кап-кара. – *кузн.* Без аның белән игәчләр. Игәчем дә анда булган, Казан каласында. – *хвл.* Шул игәчем үлде. – *карс.*; **3.** *карс.* туганнан туган кызлар (двоюродные сёстры); чаг.: **алмаптый**. Бер анадан туганнары үлеп бетте инде, игәчләре генә калды; **4.** *лмб.* бертуган (единоутробные). Без дүрт игәчләр: ике ыл, ике кыз; **5.** *әстр.* бертуганның кызы (племянница).

**игәч бәрәннәр** *к.т.* икесе бер вакытта бер ананнан туган бәрәннәр (ягнята-двойни). Безнең бу сарык җыл сайын игәчне китерә.

**ИГӘШТЕРҮ** *эчк.* к.: **ирәгештерү**. Мине игәштермә!

**ИГЕЛҮ** *тбл., төм.* сибелү, чәчелү (сыпаться, осыпаться). Утырттым кайын төбенә, игеләр мигән сары йапрагы. – *төм.*

**ИГЕН 1.** *перм.* басу, кыр (хлебное поле). Арыш, бодай, арпа, гәрәчүхә – һәммәсе безнең игендә үсәләр; **2.** *төм.* төп йорттан читтә булган бакча (огород, расположенный вне основной усадьбы); **3.** *әстр.* яшелчә (овощ). Иген пешкәнен көтәсеңме?

**иген игәү** *минз., стрл.*, **иген итү** *перм.* иген игү (заниматься хлебопашеством). Игенне йакшы игәдек. – *стрл.* Игенчелек әз ителәдер ийе безнең монда, җир кысык. – *перм.*

**ИГЕНЧЕ** *чст., к.т.* икенче (второй). Игенче ире тужы Сарманныкы. – *чст.*

**ИГЕРЧЕ** [*рус.* игрище] *тмн.* элек: бер төркем авылларда ел саен җәй айларында төрле уеннар белән үткәрелә торган бәйрәм; шунда ярминкә дә оештырылган (в старину: ежегодные сельские увеселения, празднества, устраивающиеся в летние месяцы группой сёл; в это время проводились и ярмарки); чаг.: **җыйын 3.**

**ИГЕТҮ** *төм.* ваклау (крошить). Икмәкне игетмә.

**ИГИН** *брб.д.* к.: **инсә**.

**ИГИННӘНҮ** *брб.д.* җилкәгә алу (взять на плечо).

**ИГНӘ** *брб.д.* энә (игла). Игнәнең көзү.

**ИГҮ I** *дөб., бәр.* кыру (тереть, натереть). Ул awырудан қайтқач та бәрәңге игеп аша, ди. – *бәр.* Бәрәңгене игәйек қалай иккестән. Чөгөндерне игеп иккеч арқылы. – *дөб.*

**ИГҮ II** *тбл.* **1.** сөрү (пахать, возделывать, культивировать); **2.** агач утырту (посадить дерево, рассадить посредством корней).

**ИГЫРЧА** [*рус.* игрище] *тмн.* к.: **игерче.** Әwәл заманда бездә игырча була иде, игырчанын көнөндә базары була. Тewи, Карай awыллары игерчегә бергә керделәр; Дашка, Митрал awыллары үзләре чакырдылар аларны игерчегә.

**ИДЕРЕШҮ** *перм.* бик нык кычкырышу (ссориться, кричать друг на друга). Бетекиләре ачыктылар ий, идерешәләр дә идерешәләр.

**ИДЗИК** *брб.д.* читек (мягкие сапожки).

**ИЖӘН** *тбл.* өн (нора животных).

**ИЖЕГАЛНЫ** *брб.д.* к.: **йорт 1.**

**ИҖЕКЛӘҮ** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш. нгб.-крш., чст.-крш.* үчекләү, үртәү (дразнить, поддразнивать); чаг.: **ирештерү**. Мине иҗекләб утыра. – *чст.-крш.* Иҗекләп сөйләштереб алып китәләр. – *каз.ар.-крш.* Мине иҗекләп көлеп утыра бит. – *нгб.-крш.*

**ИҖЕҮ** *брб.д.* көймәдә йөрү (плыть на лодке).

**ИҖТИҺАТЛЫ** [*гар.* + *афф.* -лы] *бөре.* хәстәрле (запасливый, заботливый). Прастуй булсам да, иҗтиһатлымын, иҗтиһатсыз кешеләр бар ул.

**ИЗ** [*фарс.*] *қарс.* һич(ни). Йыладым, йыладым, из йук файда, Йәштән сүгән йарем, син кайда (*хал. җыр.*)?

**ИЗӘН** *брб.д.* исән (здоровый, невредимый).

**ИЗӘННӘҮ, ИЗӘННӘШҮ** *брб.д.* исәнләшү (здороваться, кланяться друг другу).

**ИЗӘНҮ** *брб.д.* истә тоту, аңлау (помнить, понимать).

**ИЗӘҢГӘ** *төм.* киләсе елда (в будущем году).

**ИЗӘҢГҮ** *брб.д.* өзәңге (стремя).

**ИЗӘТЛӘТҮ** *тара.* яхшырту (сделать лучше, улучшить).

**ИЗӘТЛӘҮ** *тара.* өстен чыгу (превосходить).

**ИЗӘТСЕНҮ** *дөб.* яхшысынмау, уңайсызлану (считать неудобным, стесняться). Аларға керергә изәтсенеп җерим.

**ИЗӘТҮ** *брб.д.* к.: **ислими'и**.

**ИЗӘҮ 1.** *минз., злт.* селтәү, болгау – кул турында (махать рукой). Үзем пал'та әзләдем-әзләдем дә қул изәдем инде. – *минз.*; **2.** *брб.д.* к.: **исләү 2.**

**ИЗЕНҮ** *мәл.* күнегү, өйрәнеп җитү (привыкнуть, приучиться).

**ИЗЕПИ** *дөб.* йомшак күңелле, җебегән (мягкосердечный, слабый). Кеше қылағанға қылап тора, қарале бу изепине.

**ИЗЕРӘК** *тбл., брб.д.* исерек (пьяный). Козы Көрпәц ицте, изерек. – *тбл.*

**ИЗИН** *клм.* исән (здорово). Изин торасыспа?

**и з ү I** (нагрудное женское украшение):

**изүле күлмәк** *к.т., нрл., стрл.* күкрәк турысына түгәрәкләп тәңкәләр тезеп, тасмалар тотып бизәп тегелгән күлмәк (платье, на груди которого полукругом пришиты монеты, ленты и другие украшения). Изүле күлмәге әнинең әле дә бар ийе. – *к.т.*

**сакмай изү** *стрл.*, **сапма изү** *к.т., трх.*, **сапма изүwe** *нрл., трх.*, **сатма изү** *трх.* уртага тәңкәләр тезеп, кырыена ука тотып ясалган күкрәккә киелә торган хатын-кыз бизәнү әйбере, изү (старинное женское нагрудное украшение с нашитыми монетами или расшитое позументом; надевалось оно поверх платья). Сапма изүwe була, уқалар белән зур, күкерәк кебек әйләндереп-әйләндереп. – *нрл.* Сапма изү линтеләр белән, уқалар белән сырлап-сырлап тегеләр ийе, қырыйында да, уртасында да бөрәп-бөрәп йасаған кечнә итәкле кебек муйындан бәйләп қуйалар ыйы. – *к.т.* Сатма изү муйынға изүгә кийелә, қаплап қуйыла, уқадан була, атлас киңлеге тотып чыққан була, қунаққа барғанда җахшы кийем өстеннән кийелә. – *трх.*

**ИЗҮ II** *том.,д., брб.д.* эссе (горячий).

**ИЗҮ III** *себ.* үзе (сам, сама).

**ИЗҮЧӘ 1.** *минз., стрл., мәл., чст.* к.: **изү I: сакмай изү**. Тасмалардан гына йасалган изүчә буладырыйы, уқа тоталар ийе аңарға. – *минз.* Изүчәне инде бәләмиләр, ату исә карайа. – *стрл.* Әнәйләр изүчә кийә иде. Апай әле безнең сапмаларны, изүчәләрне йазма кели. – *чст.*; **2.** *мәл.* к.: **алынча**.

**изүчәле күлмәк** *минз.* к.: **изү I: изүле күлмәк**.

**ИDҮЧӘ 1.** *минз.* к.: **путемар**; **2.** к.: **изү I: сакмай изү**. Idүчәне әбиләр кийә инде, уқадан йасалған.

**и й I** *глз.* өй (дом):

**ий әбей** *глз.* өй иясе (домовой). Ий әбей мишаламый кешеләргә.

**тетен ий** *глз.* морҗасыз, кара өй, карадан ягыла торган өй (курная изба). Элек wахытта безнең awылда тетен ий булған, тетен чыкмага қайадыр тишек булган.

**ИЙ II** *тбл.* 1. йомшаклык (мягкость). Тиренең ийе килгән, әйбәт иләнгән; 2. җай (толк).

**ийен бирү** *тбл.* к.: **ибаз: ибазға бирү**. Өйгә қайтыб ал, ийеңне бирәрем.

**ИЙАЛУ** *глз.* к.: **кан′: кан′ тоту**. Бер бийағам бар, әл дә ийалам мин. Элек ийалдыралар иде ич, йәшерен йөрисен.

**ИЙӘ I** *кмшл.* чир, рак авыруы (раковая болезнь). Садыршәйетне йуқка ғына ийә ашамады аны.

**ИЙӘ II: қора ийә** *брб.д.* абзар иясе (разновидность домового, якобы живущего в хлеву).

**утар ийәсе** *т.кам.-крш.* к.: **ий I: ий әбей**.

**ИЙӘЛӘУ** *трх.* үзеңнеке итү, үзләштерү, хуҗа булу (присваивать). Синең җаулыкмы, ийәләмисеңме?

**ИЙӘЛЕ** *брб.д.* җенле (бесноватый). Ийәле ул рошша, тырактырислар анда қонорчақ чыға тип әйтәләр.

**ийәле булу** *тара.* тыныч, имин булу – өй турында (быть спокойным, быть в благополучии – о доме). Өйөгес ийәле булсын, үсегескә йәшәгәле булсын.

**ИЙӘЛЕ-БАШЛЫ: ийәле-башлы булу** *перм.* башлы-күзле булу (обзавестись семьей); чаг.: **диңгез: диңгез қормаған**. Ийәле-башлы булғаннар алар. Ийәле-башлы булу кирәк.

**ИЙӘЛҮ** *минз.* к.: **өйәләү 1**. Моның ғына хәтле бийеклеге, сыйыр шуңа ийәлеб үлгән.

**ИЙӘН I** *брб.д.* буш (пустой, полый).

**ИЙӘН II** *тара.* икән (оказывается).

**ИЙӘННӘНҮ** *брб.д.* бушау (опустеть).

**ИЙӘРЧӘН** *минз., стрл.* к.: **ийәрчен 4**. Үгәй кыз ул, ийәрчән килгән кыз ийе. – *стрл.*

**ИЙӘРЧЕ** *к.т.* 1. к.: **ипи: кywас төбе ипи**. Қywас чиләге қырған қамырның быразын қуас қамырына қалдырдым да қалғанын ийәрче итеп тықтым; 2. к.: **гердә I, 1**. Ипи салғанда мин аңа гел ийәрче әwәлим.

**ИЙӘРЧЕК 1.** *мам.* төп кодага ияреп туйга, кыз йортына бернинди бүләксез баручы (человек, который идёт с главным сватом на свадьбу в дом невесты, но в отличие от него, безо всякого подарка). Ийәрчек анысы әрәм тамақ була, бушқа ашап қына қайта ул, аппармый бернәрсә дә; 2. *минз.* к.: **арсый**. Ийәрчек диләр ийе, қодалар ийәртеп киләләр, аннан қыз китәдер ийе җиңгә белә.

**ИЙӘРЧЕН 1.** *лш., минз., крғл., стрл.* к.: **ийәрчек 1**. Қодалар ийәрчен дип ике малай ийәртәдер ийе, ирле-хатынлы парлап баралар. – *лш.*; 2. *минз.* к.: **арсый**. Сәғыйдәне былтыр әпкиттеләр әле ийәрченнәр белән. Әл дә шул фурмыда қызлар ийәрчен белән бара бит; 3. *стрл., минз.* төп кодага ияреп туйга килгән ялгыз кеше (одинокий человек, пришедший на свадьбу вместе с главным сватом). Бер ийәрчен малайын алып килгән ул, бер пичкә балы. – *стрл.* Бер ийәрчен белән бараcың никахқа. Ийәрчен булып иң йақын туғанын алып бара. – *минз.*; 4. *трх.* инәсе иргә чыкканда ияреп килгән бала (ребёнок, пришедший за матерью, пасынок, падчерица); 5. *перм.* уен уйнаганда оешкан команда членнары (члены команды при игре). Ике атаман була, шуның ийәрченнәре була.

**ИЙӘТЛӘУ** [*фарс.* + *афф.* -ләү] *тмн.* к.: **ислими'и**. Иртәгә йакшыраг ийәтләрсен, бүген йырлама инде.

**ИЙЕКЛЕ** *бәр.* үткен, җитез (проворный, умелый, ловкий). Эшкә бик ийекле кеше ул безнең қода.

**ИЙЕКМӘУ** *блт., дөб.* ияләнмәү (не привыкать, не свыкаться). Балаларға да ийекмәгән ул үги әни. – *блт.* Сезнең җанда қалырға бер дә ийекми, қарале Рәисне. Ул боларға бер дә ийекмәде. – *дөб.*

**ИЙЕН: ийен бирү** *т.кам.-крш.* кирәген бирү (проучить); чаг.: **ибаз: ибазға бирү**. Қайтқач ийеңне бирермен әле.

**ИЙЕҢКЕ** *каз. ар.-крш.* ягымлы (приветливый, ласковый). Қара урманнарның урталарын. Қайын киртә белән тотарбыз; Балақайығыз ийеңке булса, Үзегездән иркә тотарбыз (*хал. җыр.*).

**ИЙЕРҮ** *тбл.* эрләү (прясть, напрясть). Йон ийерә теген стан пар гуй.

**ИЙМАҒА** *нокр.* җыярга (собирать). Печин иймаға барды. Без чабып қалдырғанны ийма(ға) бардық, йаңғыр ирек бирмәде.

**ИЙРӘК** *эстр.* үрдәк (утка).

**ИЙРҮ** *төм.* к.: **ийерү**. Кинтерне қалын итеп ийрәпес кинтер ағацга салып. Йеб ийрә тыған урцоқны күргәнмә син?

**ИЙҮ 1.** *каз.ар.-крш.* бөгү, бөгеп ясау, мәс., тәгәрмәчне (гнуть, делать, напр., колесо). Элмәдән тәгәрмәч ийәләр; 2. *саз.я.* ашау (есть, кушать).

**ИЙҮ-ЭЦҮ** *саз.я.* ашау-эчү (питание).

**ИЙЫЛУ** *нокр.* җыелу (собираться). Ийылабыз уланнар белә.

**ИЙЫШТЫРУ** *нокр.* җыештыру (убирать). Ийыштырам эстәлне. Карачинны бик йырақ ийыштырған ич.

**ИК** *твр.* җәй, ярык (шов, щель, рубец). чаг.: **жик**.

**ИКАЛАУ** *эстр.* юкалау (делать тонким). Камырны икалап җәйә.

**ИКАРА** *перм.* тыкрык (переулок). Менә монда икара. Монда икара бар, мәгешлектә, шушы икарадан төшеп китәсен дә аннан болай ыскылат қарышында алты мәгөшле үгә керәсен.

**ИКАРАТА** *тбл.* юкса (не то). Ныграқ урынға утырайын, икарата йыгыларым.

**ИКӘ I** *перм.* икән (оказывается). Лафкыга кәрәчин килгән икә.

**ИКӘ II** *брб.д., тара.* ике (два). Қушнуң икә баласы йыланны йип қойды. – *брб.д.*

**и к е** (два):

**ике абалу, ике апалу** *брб.д.* апалы-сеңелле (старшая сестра с младшей). Усган йыл ике апалу апиратсы йасаттық. Ике абалу чәй эчеп алмапты.

**ике йақ** *перм.* ике басулы чәчү әйләнеше (двупольный севооборот, двуполье). Өч-дүрт диктар җир бар ый ике йаққа.

**ИКЕ-БЕР 1.** *лмб., әстр.* кайвакыт, сирәк-мирәк (иногда, изредка). Ике-бер килә сатуга пыластинкалар. – *лмб.* Ике-бер күрдем радн'аларымны awылға килеп. Әнийем алып китә иде мине ике-бер. – *әстр.*; **2.** *әҗе., кузн.* бер-ике (один-два). Ике-бер кеше бодай цәцмә баралар. – *әҗе.* Ике-берне эчәсең, минутта сыwына. – *кузн.*

**ИКЕЗҮ** *том.д.* икесе (двое; оба). Икезү бер йәштү.

**ИКЕҚОЙРОҚ** *злт.* к.: **қайчығойрық.**

**ИКЕЛӘНҮ** *тпк.* аз гына саташу, акылына зәгыйфълек килү (бредить, помешаться, стать придурковатым). Ned аны пелмәйbed пит инте икелән тип, ned парған сайын ул арырақ китә.

**ИКЕЛӘНЧЕК** *бәр.* икеләнүчән (нерешительный).

**ИКЕЛЕ** *тпк.* акылына зәгыйфълек килә башлаган (слегка тронутый, придурковатый). Икеле ул, икеле хатын.

**ИКЕНЧЕЛӘЙ** *перм.*, **ИКЕНЧЕЛӘП** *хвл.* икенче тапкыр, икенче мәртәбә (второй раз). Бозауны икенчеләй эзләп таптым. – *перм.* Тазарак, икенчеләп бабайга бирмәскә иде. Икенчеләп сорама. – *хвл.*

**ИКЕТӘН: икетән тыуған** *себ.* к.: **тудыка(й) 1.** Минеңке әтийем мән икетән тыуған алар.

**ИКИ** *брб.д.* ике (два).

**ИКИЛӘНҮ** *брб.д.* икеләтә арту (удвоиться).

**ИКИЛЕКЛӘНҮ** *брб.д.* икеләнү (сомневаться).

**ИККЕС** *дөб.* кыргыч (скребок, тёрка). Бәрәңгеләр, кишерләр игәсең, йомырҡа игәсең иккес белән.

**ИКМАWЫТ** (икмәк + ут) *перм.* к.: **зәрәтә.**

**ИКМӘГУТЫРЛЫҒЫ** *мам.* к.: **зәрәтә.**

**ИКМӘК** *минз., злт.* иген (хлеба). Күп чәчтек бит икмәкләрне. – *минз.*

**әче икмәк** *каз.ар.-крш.* арыш ипие (ржаной хлеб). Ашны әче икмәк белән ашыйм әле.

**икмәг ачыту** *перм.* икмәк изү, баш ясау (заквасить тесто). Икмәг ачытам әле сол он қатыш арыш ондан.

**икмәк йабу** *тмн., шрл.* пешерү – ипи, бәлеш һ.б. камыр ашлары турында (делать, печь – о хлебе, пирогах и др. мучных изделиях). Икмәк йабам иртәгә үзем дә. Әле йаңа оннан икмәк йапкан идем. – *тмн.*

**икмәк қатыру** *перм.* икмәк камырын басу (месить тесто).

**икмәк күтәрү** *минз.* ашлык киптерү, мәс., мунчада (сушить хлеб, напр., в бане).

**икмәк чапчақ** *перм.* к.: **ләнгәц.**

**эчле икмәк** *перм.* ипи камырыннан эченә повидло, балан һ.б. кыстырып пешерелгән камыр ашы, икмәк (мучное блюдо типа хлеба, приготовленное из хлебного теста с начинкой из повидла, калины и т.д.). Чәчәләндергән паланнан эчле икмәк йасасаң була.

**ИКӨН** *әстр.* өлкән (старший). Икөн ағаларым бар.

**ИКРАЛЫ** [*рус.* икра + *афф.* -лы] *мәл.* ярмалы (рассыпчатый). Безнең икралы да алма.

**ИҚТЫМАТ** *каз.ар.-крш.* җиренә җиткереп, яхшы итеп (как следует, хорошо). Иқтымат итеп суққаннар сөлгәне.

**ИКҮНА** [*рус.* икона]: **икуна казыгы** *мәл.* тәре агачы – ачулану сүзе (крестовый кол – ругательное слово).

**ИКШЕМ** *төм.* к.: **алты-тукыз.** Икшемгә сут йуқ. Икшем тә, шим тә шал уқ.

**ИКШҮ** *тара.* очынып китү, чытлыклану, кылану (ломаться, кривляться). Икшеп китте, телен цығарып қуйыпты.

**ИКЫЛДАУ** *хвл.* к.: **кикнату.** Иртүк икылдадым, кемдер мине сүләдеме.

**ИЛ 1.** *мам., блт., тя., минз., бгрс., злт., нгб.-крш., тмн., кузн., хвл., карс., шрл., мәл., әстр.* авыл (деревня). Җаңғыл иле дибез, Борнаг иле дибез – алар инде бер тирәдә. – *блт.* Теге қызың ил җирендә үскәндер, эшкә оста. – *мам.* Ашаң, ил әпийе тансық була ул. – *минз.* Утыз җиде йыл витиринарный филшер булыб эшләдем шушы илдә. – *бгрс.* Илгә барып қайттық. Қартымны илемә алып қайтып күмдем. Илдә дөнйа көтсөн балалар. – *злт.* Анда ил җуқ инде. – *әстр.* Үзгә илгә бирделәр қызларын. Әтмә, әни кәбәм бер ил дийеп, әстемә багып йыларсын. – *тмн.* Бу илдә туwып үскән идем инде мин. – *хвл.* Илебез шындый йакшы, беркемнең бернәрсәсенә тийеш йук. Йаз көне шәһәргә караганда ил йирендә әйбәтрәк тырырга. – *мәл.* Мәскәүдә хәзер кеше күб инде, илдә кеше әз. – *шрл.* Безнең илгә килгәннәр. – *карс.*; **2.** *миш.д.* туган як (родная сторона, родные края); **3.** *кас., перм.* чит җир, чит авыл (чужая сторона, чужая деревня). Әле илдән килгән хатыннар бар, монда да бии, кәртә қырда да бии. Ил қунақлар киләме, Шуртамбашлар ғынамы дип қарап қалдым. Илләрдә мондый қашаға мазар йуқ ти. 'ем awыл'а бара,'ем ил'и 'ити. – *кас.*; **4.** *мам.* як, юнәлеш (сторона, направление). Сез үзегез қайсы илнеке?

**ил келәве** *лмб.* яңгыр теләү йоласы: озак вакыт яңгыр яумый торса, өй саен йөреп, йомырка, ярма һ.б.ш. җыялар да, су буенда берәр карчыктан ботка пешертәләр; шуннан соң су сибешәләр, кемне дә булса тотып суга ташлыйлар (один из старинных обрядов моления дождя).

**ИЛ-АЛ'АМ** [*тат.* + *гар.*] *хвл.* бик күп кеше, бик күп халык (много народу, большое число людей). Ил-ал'амны җидылар да кунак җийалар.

**ИЛӘ** *брб.д.* аннары, аннан соң (после, потом).

**ИЛӘБАЙА** *тара.* еш кына (частенько).

**и л ә к I** (сито):

**йөзле иләк** *бәр.* вак иләк (сито с мелкой сеткой).

**қул иләк** *минз., кмшл.* к.: **бүре: бүре күз.** Қул иләге белә иләп тегермәнгә ашлық тутырабыз. Қул иләк – ол(ы) иләк ул, асып қуйылған була. – *минз.*

**соло оно иләге, чыпта иләк** *бәр.* эре иләк (редкое сито).

**и л ә к II** (решка):

**иләк төшү** *т.кам.-крш.* уңышсызлыкка очрау, уңышсызлыкка дучар булу (потерпеть неудачу). Аңа бу йулы иләк төштәле. Бер иләк төшә башласа, төшә бит ул.

**ИЛӘК III 1.** *нокр., глз., твр., тбл.* җиләк (ягода). Иләк йыйдым. Эх, қайын иләкнең исе! – *нокр.* Иләккә баралар йаңыдан. – *глз.*; **2.** *твр.* каен җиләге (земляника).

**ИЛӘК IV** *төм., тбл.* к.: **илек 1.**

**ИЛӘМ** *каз.ар.-крш., т.я.-крш., нрл., трх., чст.* ямь, матурлык (красота, прелесть). Безнен өйләргә иләмнәр керде, Қодалар кигәч қунаққа (*хал. җыр.*). – *каз.ар.-крш.* Шылдыр-шылдыр беләзек, Кул иләме китерә ул; Буйга җиткән кыз чыккис, Уйын иләмен китерә ул (*хал. җыр.*). – *т.я.-крш.* Малай булмагач, иләм йуқ. – *трх.* Қартайгач, кешенең иләме қалмый. – *нрл.*

**ИЛӘМЛЕ 1.** *трх., т.я.-крш., м.-кар., крғл., әстр.* матур, ямьле, күңелле (красиво, приятно, радостно). Ишектән керүләре, Иләмле келүләре (*хал. җыр.*). – *т.я.-крш.* Қызлар булғач, үдә иләмле. Табын иләмле булыр, син утыргач. – *трх.* Ул әтәчнең җөргәне бер иләмле бит әле. – *крғл.* Сары үзәнкәй буйы бик иләмле. – *әстр.*; **2.** *трх.* сөйкемле, күңелгә ятышлы (приятный, симпатичный). Иләмле генә қарт килеп чыкты. Ул бик матур, иләмле кеше.

**ИЛӘМЛЕК** *т.я., крғл.* матурлык (красота, прелесть). Пыйала күз қуйарсың иләмлег өчен, дигәннәр. – *крғл.*

**ИЛӘМНЕ** *т.я.* к.: **иләмле 1.** Иләмне йе заманасына күрә. – *нрл.*

**ИЛӘМНЕК** *т.я.* к.: **иләмлек.** Иләмнек инде бер, үзем апқайтып утырттым ул ағачны. – *трх.*

**ИЛӘМСЕЗ** *дөб., т.я.* әшәке, начар (нехороший, плохой); чаг.: **йаматай.** Нәчәлникләр беләләр безне, бер иләмсез, қыйты сүз әйтмиләр. – *дөб.*

**ИЛӘНДЕК** *тмн.* к.: **әре.**

**ИЛӘНҮ** *твр.* җәфалану (мучиться).

**ИЛӘПӘН** *кмшл.* аркылыга җәелгән, симез – кеше турында (рыхлый, раздобревший – о человеке). Таралып йери тырғанға иләпән диләр инде.

**ИЛӘСӘ** *перм.* к.: **били.** Қулына кимәгә иләсәсе йуғыйы, айағына кимәгә кийестеге йугыйы. Сездә дә иләсә бәйләп кийәләрме?

**ИЛӘТҮ** *дөб.* он ак булсын өчен бодай, арыш кебек бөртеклеләрнең кабығын салдырту (обдирать – о зерне). Әле генә бер ситнер бодай иләтте. Бодай иләтергә итәм, иләтү ташы анда йахшы.

**ИЛӘҮ I** *тара.* эш итү (заниматься чем-либо, обрабатывать). Олло қысым иләйде тебетне.

**ИЛӘҮ II** *әстр.* басу – камыр турында (замесить – о тесте). Сары суга иләгән кал′акай (күмәч).

**ИЛӘҮ III: қырмысқа иләwе** *крғл.* қырмыска оясы (муравейник). Аның иләwе бар шунда фундамитта, йаңгыр йawарға булса, чығалар қырмысқалар, қанатланалар.

**җиләк иләwе** *крғл.* җиләклек (ягодник). Эх, малай, җиләк иләwенә очрадық.

**ИЛӘҮЛӘҮ** *каз.ар.-крш.* илерү, үзен-үзе белештерми елау (плакать навзрыд). Иләүли инде, иләүли, җылый бу, бармыйм, ди.

**ИЛӘШТЕРҮ** *т.я., злт.* ияләштерү (одомашнивать, приручать). Сезне иләштерсәң дә йарамый икән. – *трх.* Иләштермә безгә ул малайны. – *злт.*

**ИЛӘШҮ** *минз., т.я., бөре., кмшл., злт., хвл., кузн., лмб.* ияләшү (привыкать, свыкаться); чаг.: **ийегү.** Аларның қулға иләшкән күгәрченнәре бар. Иләштегезме инде безнең awылга? – Иләшминче. – *кузн.* Йылыга йылан иләшә (*әйтем*). – *лмб.* Сиңә иләшеп петкән инде, йаныңнан да китми. – *злт.*

**ИЛГӘК** *яүшт.* иләк (сито). Илгәк белә илиләр.

**ИЛДӘТНӘ** *злт.* биләмче, биләмдә йөрергә яратучы (праздношатающийся). Илдәтнә, қайда йөрдең шул қәдәр?

**илдәтнәдә йөрү** *злт.* өйдән өйгә йөрү, биләмдә йөрү (праздно шататься по домам). Илдәтнәдә йөреп бернәстә эшләмәдем.

**ИЛДЕРҮ** *срг., перм.* к.: **иләүләү.** Илдерә генә ылан. – *срг.* Мәә илдерәсең ни? Уланнар илдереб утырырлар төннә. – *перм.*

**ИЛЕ** *кас.* илле, бармак киңлеге (шириной в палец). Қылыс сырты 'еби' ит өстенди майы бер иле.

**чына' иле** *кас.* чәнчә бармак киңлеге (шириной в мизинец). Чына' иле 'адәр майы бар, түбән сорт.

**җывын иле** *кас.* баш бармак калынлыгы (шириной в указательный палец).

**ИЛЕГҮ** *минз., тбл.* ияләнү (привыкнуть, освоиться). Өч-дүрт көнсез илекмәй, илексә, сағыз була (бала турында). Әби белә үскән бала инәгә гел илекми икән ул. – *минз.* Инте миңә илегеп киткән ите. – *тбл.*

**ИЛЕҚ** *тбл., төм.* **1.** кыр кәҗәсе (дикая коза); **2.** *брб.д.* боланның бер төре (косуля).

**ИЛЕКМӘС** *чст.* кеше белән тиз аралашмый торган, йомык кеше (необщительный, замкнутый человек).

**ИЛЕКМӘҮ** *бөре., минз.* ияләнмәү. Чебешләр илекмәй ди таwыққа. – *бөре.* Әнкәй, мин монда да илекмим, диде дә читкә китте. – *минз.*

**ИЛЕМ** *бгрс., эчк., төм., тбл.* ягымлы, ачык йөзле (общительный, обаятельный, приветливый); чаг.: **алсақ.** Қыз бала илемрәк була инде. – *бгрс.* Безнең Тузау халықлары бик илем. – *эчк.*

**ИЛЕРҮ** *минз., тара.* саташу (бредить).

**ИЛҖИН** [*рус.*] *т.кам.-крш., чст.-крш., минз.* Ильин көн (Ильин день). Җәй үтеп китте менә, илҗин җиткәчен андары кешенең битен дә кыйаш ашамый, дидер ийе безнең әни. – *т.кам.-крш.*

**ИЛИМ-ПИЛИМ** *дөб.* акылга җиңелрәк кеше (слабоумный, придурковатый человек); чаг.: **ад′ур 3.**

**ИЛ-КҮРШЕ** *блт.* күрше-күләи (соседи). Үз көчөм белән генә йәшәмим, ил-күршем биг әйбәт.

**ИЛЛА** [*гар.*] *злт.* берүк, зинһар (пожалуйста, ради бога). Илла ғәйепләмәң, балалар. Балтаны йуғатма илла, қара.

**ИЛЛӘ** *т.кам.-крш.* бик тә (очень). Иллә дә тәмне була ул қатық.

**ИЛЛЕК** *бәр.* кергәндә-чыкканда алына торган итеп киртәләрдән эшләнгән капка (сделанные из поперечно установленных съёмных жердей ворота).

**ИЛТӘН** *твр.* йомшак җил, җиләс (небольшой ветерок, прохлада).

**ИЛТӘҮ I.** *крғл.* илтү (нести, относить; везти, отвозить). Икенче қызын да стансаға илтәделәр.

**ИЛТӘҮ II** *тбл.* җилгәрү (веять). Элек самантa қул мән илтәйтегәннәр ите, қәсер машина илтәйте.

**ИЛТИМАСЛЫ** [*гар.*] *стрл.* ихтирамлы, түбән-челекле (почтительный, вежливый). Кешегә илтимаслы кеше ийе.

**ИЛТКӘ** *брб.д.* җилкә (затылок).

**ИЛТҮ** *нокр.* алып китү (унести). Карға илтер дип курҗам каз бибиләрне.

**ИЛ-УМА** *дөб.* к.: **қом-қырыс**. Ил-ума суғышып йаталар.

**ИЛ-УМАЧ: ил-умач килеп** *дөб.* шау-гөр килеп (дружно). Алар белә моңғарчы ил-умач килеб алдым. Ил-умач килеб уйныйлар (балалар).

**ИЛҮ I: илүдә җөрү** *к.т.* к.: **илдәтнә: илдәтнәдә йөрү**.

**ИЛҮ II** *брб.д.* к.: **иле**.

**ИЛЧЕ** *перм.* димче (сват, сваха). Җегет белән қыз берен-берсе күрмәгән әле, илче йөри.

**ИМ** *карс.* к.: **дарман 2**. Эх, мунчалары, имнәр серттек мунчада.

**им булу** *перм.* шифа булу, сәламәтлеккә файдасы тию (быть полезным для здоровья). Менә бу суны эчеп қара, им булыр.

**и м а н** (вера в бога, верование):

**иманга ойу** *хвл.* дөньясын оныту (забыть всё на свете).

**ИМАРАТ** *тбл.* ихата, йорт-җир (усадьба).

**ИМАШТЫРУ** *бгрс., кргл.* оештыру (собрать, организовать). Колхуз да халыкны имаштырды бергә. – *бргс.*

**ИМӘК I** *трх.* элек: җан башына бүлгәннән соң калган калдык-постык җир (в старину: клочок земли, оставшийся после раздела подушного надела).

**ИМӘК II 1.** *брб.д., тара.* чиләк бавы (ведёрная дужка, перевесло); **2.** *тбл.* чалгы тоткасы (рукоятка косы).

**ИМӘЛӘМӘ** *минз., стрл.* өеп, өеп тутырылган (наполненный верхом). Коштабак тулган иде, имәләмә булган иде. – *стрл.*

**ИМӘН** *том.д.* тирәк (тополь).

**бала имән** *каз.ар., стрл.* яшь имән (молодой дуб).

**имән алмалану** *стрл.* имәндә чикләвек барлыкка килү (появление желудей у дуба).

**имән алмасы** *минз., тпк., стрл.*, **имән бөресе** *минз.*, **имән күкәйе** *минз., злт., стрл.* имән чикләвеге (жёлудь). Имән алмасы сата кеwек. – *тпк.* Имәннең күкәйе була, шуннан үстерәләр аны. – *минз.*

**ИМӘНГЕЧ 1.** *т.кам.-крш., перм., минз., стрл.* шаккатарлык, искитәрлек (удивительный, поразительный). Хәдерге сарыклар имәнгеч бит алар, күтәреп җөртергә аларны. – *минз.*; **2.** *лш., минз.* куркыныч (страшно; страшный). Алай да имәнгеч үзең генә булсаң. – *лш.* Имәнгеч ул сүдләрне сүләргә. – *минз.*

**ИМӘНДЕРҮ** *брб.д.* оялту (стыдить).

**ИМӘНЕЧ 1.** *перм., минз.* бик (очень); чаг.: **дуwамал 2**. Быйыл болында җиләк имәнеч тә күп инде. – *перм.*; **2.** *перм.* бик оста, бик яхшы (хороший, умелый, искусный). Гармунчы қый у имәнеч; **3.** *бөре.* бик күп, бихисап (очень много, без счёту, неисчислимо). Имәнеч былды кеше сабранйада.

**ИМӘННЕК** *каз.ар.-крш.* иминлек (благополучие, целостность, сохранность). Су имәннеге, җир имәннеге диләр инде, труйсынға чәре җолқорга җарамый инде.

**ИМӘНСӘР** *бәр.* имәнлек (дубняк, дубрава). Имән күб үскән җирне имәнсәр диләр.

**ИМӘНСӘРЛЕК** *бәр.* к.: **имәнсәр**. Анда имәнсәрлек бар.

**ИМӘҢ 1.** *брб.д., тара.* тартыну, оялу (стесняться). Ашағыс, имәнмәгес. – *тара.*; **2.** *том.д.* курку (бояться, страх).

**ИМӘҢГЕЧ** *т.кам.-крш.* **1.** к.: **имәнгеч 2**. Қарарға имәңгеч җыланны; **2.** к.: **имәнгеч 1**.

**ИМӘС** *тара., твр., әстр.* түгел (не – отрицательная частица). Казах имәсбез. Алыс имәс Казахстан. – *әстр.* Ул көйләк порыңкы, хәсерге имәс. Бес монди имәс едик. – *твр.*

**ИМГӘК 1.** *нокр., том.д.* җәфа, авырлык (мука, страдание, забота). Ақлы ла читча күлмәгемнең Күтәреп бегәмен йеңнәрен, Арталар Қалгырның (*тау ис.*) дынйасында Күбикән күрәсе имгәгем (*хал. җыр.*). – *нокр.*; **2.** *тпк.* балага узгач аш талымлау (привередничанье забеременевшей). Киленнең имгәге белән бидгәге бергә булды.

**ИМГӘКЛӘҮ** *твр., тбл., брб.д.* мүкәләү, дүрт аяклап йөрү (ходить на четвереньках, ползать). Бозоғодан имгәкләп йөрәдегән. Өсөм алар белән имгәкләп уйнап йөрим. – *брб.д.* Пала имгәкләй пашлаты. – *твр.*

**ИМГЕЧ** *т.я.-крш.* **1.** имезлек (жевка для грудных детей, завёрнутая в тряпку). Марлыга салган имгечне, шал терәпке сүwырып йаткан, сирәк киндер салган да; **2.** резин имезлек (резиновая соска). Мүгез тап, анарга йаса имгеч, дигән (*әкият.*).

**ИМЕ: име күрешү** *тара.* башка бәла төшү (испытывать горе).

**ИМЕЗЕК** *срг., хвл.* к.: **имгеч 1**. Каа да булса циткә китсәң, имезек тыга писүк белән әпәйдән, тамак тугайтырга тегел, аwызы буш тегел. – *срг.*

**ИМЕЛДӘҮ** *перм.* йомшау – пешү турында (мягко свариться). Пучинкә шалқанны салып томалыйсың, ул имелдәп кенә пешә.

**ИМЕН** *тбл.* карагай (лиственница).

**ИМЕШ** *тара.* җимеш (фрукт). Пер бәц булыпты имеш, цийә булыпты.

**ИМЕШ-МӘМЕШ** *дөб.* имеш-мимеш (будто бы, как будто бы, якобы).

**ИМЕШТЕРЕМ** *хвл.* к.: **имеш-мәмеш**. Имештерем, ул килеп киткән инде.

**ИМ-ҖОМ** *перм.* к.: **им-йом**. Элек им-жом итеп қыйышқаннар.

**ИМИНҖӘ** [*рус.*] *мам.* хосусый милек (имущество, собственность).

**иминҗә җыйу** *мам.* элек: налог түли алмаган кешеләрнең ястык, самовар, казан h.б. шундый хуҗалык әйберләрен җыю (в старину: сбор имущества у людей, которые не смогли заплатить налог). Дүрт тәңкә налук бар, түли алмыйбыз, иминҗә җыйарға чыгалар, җастыкмы, самаwырмы.

**ИМ-ЙОМ** *перм.*, им-том (заговор, заклинание).

**ИМКӘМНӘП** *злт.* иркенләп, җайлап, ашыкмыйча (чувствуя себя свободно, не торопясь). Имкәмнәп тотоналар бездә, ашыкмыйлар. Имкәм-

нәп кенә тапасам была. Аны имкәмнәб утырып йазарға кирәк.

**ИМНӘҮ 1.** *мам., каз.ар.-крш.* дәвалау, дарулау (лечить). Сарықлары чирләгәнме, имнәргә төшкән бырач. – *мам.*; **2.** *тмн.* дару сибү, агулау, мәс., зарарлы бөҗәкләрне (применять ядовитые вещества, напр., против вредных насекомых). Кандала каба, имнәргә кирәк.

**ИМНЕГ** *брб.д.* тискәре, чыгымчы (неприрученный, упрямый – о лошади).

**ИМ-ОМ** *нокр.* к.: **им-йом**. Име-омо бу булсын.

**ИМРӘҮ 1.** *хвл.* йокымсырау, аз гына йоклап алу, черем итү (вздремнуть). Ат айак эстеннән имрәп ала; **2.** *хвл., мәл.* йотлыгып тыңлап тору, тәэсиренә бирелү (внимательно слушать). Имрәп тыңнадылар, музыка бик йахшы иде. – *хвл.*

**ИМТЕК** *перм.* к.: **имгеч 1.**

**ИМҮ** *тмн., хвл., клд., тара.* суыру (сосать – конфеты и т.д.). Шәкәр иммә сүли, тешең awыртыр. – *тмн.* Мында канфит, үзегезгә имә тырганны бирийем. – *клд.* Кәнфитне имеп-имеп эц цайны. – *тара.*

**ИМЦӘГИНӘ** *тбл.* анасы киткәндә баланы вакытлыча имезеп торган хатын (женщина, временно кормящая ребёнка в отсутствие матери). Инәм тораға киткәндә, мин Алимә апакәне имепмен, ул миңә имцәгинә булаты.

**ИМЦӘХ** *саз.я.* имчәк (сосок).

**имцәх инйә, цөцө инйә** *саз.я.* яңа туган баланы иң беренче имезүче хатын (женщина, первой кормящая новорождённого ребёнка).

**ИМЧӘГАСТАЙ** *трх.* яшь, яңа туган колын (жеребёнок). Ул бийәнең имчәгастайы үлгән ийе.

**ИМШЕГӘН** *мам.* талгын (нормальной теплоты – о воде). Имшегән, әйбәт су, җуwын шунда.

**ИН I** *кузн., хвл., брб.д., тбл.* иң (ширина). Бумази тар инне. – *кузн.*

**ИН II** *лмб.* алача, киндер, тукыма (полотно, материя). Бәдриҗәмал иннәр тугыйдыр, Ак атасы йиргә күк ата; Йәшлек халләрен үзем беләм, Йәш күңлемне үзем йыватам (*бор. җыр.*).

**ИНА 1.** *лмб., кузн., хвл., кас.* к.: **айса**. Китерийем ина, чәйнектә бар. Ина сымавар куйам, эчкең келәсә. Иртә торгач бирегез ина шул күмерне дә, китийем тиз генә, дигән. – *кузн.* Кулыннан тотар идегез дә ина кергезер идегез. Барыйым ина, анайы китте суга. – *лмб.*; **2.** *хвл.* хәзер (теперь). Ина ансы риза түгел.

**ИНАБАТ** *минз.* вөждан, намус (совесть).

**ИНАБАТЛЫ** *дөб., минз.* тыйнак, намуслы (скромный, совестливый). Хәдер, қыдым, җәүнә бит, инабат җуқ қайбер кешедә. – *минз.* Берәр инабатлы ғына қыз алып бирегез дә, мында ғына тырсын инде. – *дөб.*

**ИНАҚ** *глз.* чиста (опрятно, нарядно). Инақ йергән чақта ақны кийәсин.

**ИНАҚЛЫҚҚА** *глз.* кешелеккә (на выход – об одежде). Инақлыққа кийәсен инде, буйын башқа, итәген башқа иттереп теккәләделәр күлмикне.

**ИНАЛ** *бәр.* башта (сначала). Инал берсен бағып бирдем өч йәшенә хәтле.

**ИНАСА** *лмб., кузн., хвл., кас.* к.: **айса**. Барып чыгарга кирәк инаса. – *кузн.*

**ИНАСАҚ** *тмн., кузн., лмб., чст., шрл.* к.: **айса**. Инасак, варинйы менән чәй эчәрбез. – *тмн.* Барырга булгач, инасак, ад′а, киттек. Тукта, эткәләрсен инасак. – *кузн.* Әдәгез, инасак барып киләбез. – *лмб.* Син бармыйсың икән инасак, мин барыйм. – *чст.* Барыбыз инде инасак. – *шрл.*

**ИНАСЫ** *хвл.* к.: **айса**. Сымавырны, инасы, чыра гына салыйым да чәй эчийек. Инасы әтсә идең.

**ИНАТҮ** *твр.* җыю (собирать, собрать, убирать). Чәчеңне инат.

**ИНӘ I** *перм., минз., нгб.-крш., байк., себ.* ана, әни (мать, мама). Ата-инә қулларында Бала тормый гөмергә (*хал. җыр.*). Инәсендә утырды биг озақ. – *перм.* Пер инәдән туғабыс. – *брб.д.* Инәсе йәш шул аның. Үзенең инәсе кебек, әтәсе кебек карады инде. – *байк.* Инәм йәшләй үлеп қалған. – *тбл.*

**зур инә** *минз., кргл.* к.: **қартинә(й) 1.** Зур инәсе килгәндә апкилгән. – *минз.* Зур инәңнең кеше чақырғанда җәйә торған әйберләре бит бу. – *кргл.*

**оло инә** *т.кам.-крш.* баланы чукындыручы хатын-кыз (крёстная мать). Мине оло инә ди, денгә керткәч.

**үгәй инә** *себ.* үги әни (мачеха). Үгәй инәман үстек. – *тара.*

**чебеш инәсе** *бөре.* чебеш анасы (клуша, наседка). Чебеш инәсен бәйләп қуйдым әле, бақчаға керә.

**и н ә II** (игла, иголка):

**әкәй инәсе** *бәр.* к.: **чирмеш инәсе**.

**чирмеш инәсе** *мам.* камыт әнәсе (толстая шорная сапожная игла). Чирмеш инәсе белә дебет дигәнне тығасың да, wақ-wақ чәнчеп, җөрмәп чығасың, қызыл-чуwар итек була.

**ИНӘЙ** *бөре., минз., перм., кмшл., эчк., бгрс., нгб.-крш., злт., трбс., шрл., байк., стрл.* әни (мать, мама). Инәй қайттымы? – *минз.* Инәй, дөнйаны көтмә, қайтыб алам көзгә, ди. – *бгрс.* Инәй бер инде аларның, ата башқа. – *перм.* Инәйем белән бертуған сеннекәшем ул минем. – *нгб.-крш.* Безнең инәй басқысын санап та өлгөргән. – *злт.* Қайнем инәйне барыб алған. – *трбс.*

**зур инәй 1.** *кмшл.* к.: **картинәй 1.** Зур инәй белән бертуған Минсафа апай телдән қалған; **2.** *бгрс.* әтисенең яки әнисенең апасына әндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре отца или матери). Зур инәй, йырла, син йырларга шәп; **3.** *стрл.* әтисенең иң олы абыйсының хатынына әндәшү сүзе (форма обращения к жене самого старшего брата отца).

**узыр инәй** *перм.* к.: **тәтә 2.**

**ИНӘК I** *тбл.* сыер (корова).

**ИНӘК II** *брб.д.* ияк (подбородок).

**ИНӘКӘ** *төм., тбл.* к.: **инәкәү**.

**ИНӘКӘЙ** *минз., кмшл., бгрс., шрл., стрл.* әни (мать, мама). Инәкәй базарга апкиткәндер бидрәне. – *бгрс.* Инәкәй, пешереб ашат үзенә, тиб әйтә, ди. – *минз.* Инәкәйгә теш куйдырам дип ләпиләпи кертте. – *шрл.* Инәкәй үлде безнең. – *кмшл.*

**зур инәкәй, дур инәкәй** *минз.* к.: **инәй 3.** Зур малайның хатыны кече малайның балаларына зур инәкәй була бит.

**ИНӘКӘМ** *төр.* әнинең апасына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре матери).

**ИНӘКӘҮ** *себ.* әнием – эндәшү формасы (мама – форма обращения).

**ИНӘКӘШ 1.** *тара.* җаныкаем – иркәләү сүзе (душенька – ласковое обращение). Талата йөргән, инәкәш. Үссен инәкәшләр, ти, қасларға су сала та; **2.** *тбл.* ана (мать); **3.** *тбл.* әнисенең исеме кушылган бала (ребёнок, носящий имя матери). Инәкәш қайсының инәсе булты микән, әтәсенеңмә, инәсенеңмә?

**ИНӘЛЕК** *төр.*, **ИНӘЛЕХ** *саз.я.* к.: **кендекәй**. Инәлек мин, умбер баланы тыудыртқан мин, кендеген кискән. – *төр.*

**инәлек мамай** *төм.* к.: **кендекәй**. Инәлек мамай сөйрәб алған шу баланы.

**ИНӘЛҮ** *мам., минз., злт., тпк., т.я., кузн., хвл., мәл., чст., чпр., т.я.-крш., шрл.* ялыну, ялвару (упрашивать, умолять). Иртән уйансам да, Аллаға инәләм. – *мам.* Элек бит хатны да инәлеп кенә йаздырғаннар. – *минз.* Инәлеп сорадым инде. – *злт.* Күпме генә инәлеп йөрсәң дә, бирмим. – *хвл.* Әй инәлтәләр дә инде болар. Безгә хазер бит мына шуңа, мастирга инәлергә кирәк. – *чст.* Инәлеп тә әтәм, йизни, сиңа, Безнең тудыкайны какмагыз (*бор. җыр.*). – *кузн.* Җаңгыр булмаса, Аллага инәлгәннәр. – *т.я.-крш.* Инәлүен Рафикага да инәлдем дә. – *чпр.* Бу утырды да җылый, инәлә. – *к.т.*

**ИНӘНҮ** *блт.* имәнү, сискәнү (испугавшись вздрогнуть). Мин үзем дә аттан инәнеп киттем.

**ИНӘҮ I 1.** *к.т., каз.ар., хвл.* хайванга һәм кошкортларга икенче кеше хайваннары белән буталмасын өчен тамга салу (сделать метку, наложить тамгу домашним животным). Бәрәннәремнең қолақларын тишеп инәдем. – *к.т.* Үрдәк бибекәләремне барсын да инәдем кешеләрнеке белән җалгышмасын дип. – *лш.* Куй чагаларымны беген инәдем. – *хвл.*

**ИНӘҮ II 1.** *себ.* к.: **инәкәү**; **2.** брб.*д.* каенанага эндәшү сүзе (форма обращения к свекрови).

**ИНӘҮ III** *тбл.* асу, тагу (повесить, навесить). Көйәнтә инәп су инкәле китте.

**ИНӘХ** *саз.я.* ана поши яки болан (лосиха, оленуха).

**ИНӘЧ 1.** *перм.* булачак тавык, тавык буласы чеби (цыплёнок – курочка, не петушок). Инәч чебеч балам бар ыйы. Ике чебеч бала бар: бер әтәч тә бер инәч; **2.** *минз., перм.* к.: **бикәч II**.

**ИНӘЧКӘ** *перм.* к: **бикәч II**.

**ИНӘ III** *тбл.* анасының исеме кушылган кыз баланы шулай атыйлар (так называют девочку, наречённую именем матери).

**ИНГИЗҮ** *тара.* кертү (заставить зайти, впускать).

**ИНГИР** *төм.* азрак, бик үк яхшы түгел (немного, не очень хорошо).

**ИНГИСҮ** *тара.* к.: **ингизү**. Ирен ингисеп патшаның урнына ултысты.

**ИНДАУТКА** [*рус.*] *тара.* күркә һәм үрдәктән яралган гибрид кош-корт (гибридная птица, появившаяся от индюка и утки; индоутка).

**ИНДӘЛЕК** *төр.* к.: **кендекәй**.

**ИНДӘМӘ** *төр.* к.: **петәй 2**. Минем индәмәләремә сөт төште.

**ИНДЕГЕ** *кргл., әстр.* инде (уж, уже, же). Ул индеге йарағандай хезмәт. – *әстр.*

**ИНДЕК 1.** *нрл.* колга, юан булмаган озын агач (жердь, шест). Бастырық күк индек қуйған ике қапқаға; **2.** *злт.* берсе өстенә берсе куелган, кергәндә-чыкканда алына торган киртәләрдән эшләнгән басу капкасы (ворота, сделанные для пешеходов из снимаемых жердей); чаг.: **индек 1**. Анда хәзер қапқа микән, индек микән? Малларны индеккә алып баралармы?

**ИНДЕРҮ I** *карс.* терелтү (оживлять). Безнең бабаларны индерсә идең, инанмаслар да иде.

**ИНДЕРҮ II** *бәр., лш.* сугу, кундыру (ударить, стукнуть). Алдым да қысқач белән индереп шишка йасап чығардым тегеңә. – *бәр.*

**ИНЕК** *яушт.* к.: **индек 2**.

**ИНЕЛИК** *брб.д.* әнә кадагыч (игольник).

**ИНЕШ** *тбл.* керү урыны, ишек (вход, дверь).

**койаш инеше** *хвл., кузн.* **1.** кояш баешы (закат солнца); **2.** кояш баеган як, көнбатыш (запад, западная сторона). Йәш wакытта булдым Ригада, койаш инешендә. – *кузн.*

**ИНЗӘЛЕК** *тара., брб.д.* камытның эчке ягы (внутренняя часть хомута).

**ИНЗИЛӘҮ** *брб.д.* бирнә бирү (дать приданое).

**ИНИЙ** *байк.* к.: **инә 1**. Иний көлеп тора. Иний килсә дә, сүләми торма, сүлән, димен.

**ИНЙӘ** *саз.я.* к.: **инә I**.

**ИНЙӘҮ** *саз.я.* к.: **инәкәү**.

**ИНКЕЛ** *дөб.* к.: **астыр**. Йаз көне инкел урыннарға су җыйылып қала.

**ИНКЕШ** *блт., мам.* к.: **астыр**. Аңа бер инкеш чығасы булған. – *блт.* Түбән оч иңкешерәк. – *мам.*

**ИННӘ** *төм.* к.: **инә 1**.

**ИННӘҮ I** *тмн.* үлчәү (мерить, измерять). Сикереп кенә төштем бакчага, Агләнекәй киндер иннәдем (*хал. җыр.*).

**ИННӘҮ II** *саз.я.* к.: **инәкәү**.

**ИННЕК I** *блт., мам., каз.ар.-крш., бөре.* к.: **индек 2**. Бақча башындағы иннекне җаптыңма? Иннек төбеннән була ташу сүwы, бер дә гәләмәт. Иннекне ачып ташыйлар печәнне. – *блт.* Сезнең дә лә безнең аралар, и Безнең араларда иннек бар, Безнең ди болай утырwыбыз, ай, Җөзлек кенә түгел лә, меңлек бар (*хал. җыр*). – *каз.ар.-крш.*

**ИННЕК II** *мәл.* к.: **иле**. Бер бармак иннеге кисеп алганнар.

**ИНПАШ** *тара.* к.: **инсә**. Инпашым сыслайты.

**ИНСӘ** *нгб.-крш.* иңбаш (плечо). Инсәгә салып китәсен чалғыны.

**ИНТЕГҮ** *карс.* үкереп елау (рыдать, плакать навзрыд).

**ИНТЕК: интек тыру** *срг.* к.: **моқтану**. Цәйгә интек тырмыйм мин.

**ИНҮ 1.** *брб.д., тара.* керү (заходить). Саучы ингән соң әрекмәгез тиде, йоқ, әрекмәйбез титек, инең, инең. – *брб.д.* Рабиға циңнәгә тә интегесмә? – *тара.*; **2.** *срг.* әйләнү, әверелү (превратиться). Ат гөнаһсыз, тай wакытта кара тywа да алты төрле йонга инә.

**койаш инү** *кузн., хвл., мәл.*, **қойаш инү** *т.я.* кояш баю (заходить, закатиться – о солнце); чаг.: **йату 1**. Қойаш күптән инде ич. – *т.я.* Койаш ингенче дигән. – *хвл.*

**күлмәк инү** *перм.* күлмәк кию (одевать платье). Күлмәгем қайда икән, күлмәк инмәгә кирәк.

**мунча инү** *перм., к.-уф.* мунча керү (мыться в бане). Бер атна җарым мунча ингәнем җуқ. Фәрит, мунча инәмсең? – *перм.* Мунча инәргә исәбегез бармы? Мунча инәргә кил, бик қызу итеп йақтым, сүwы да күп. – *к.-уф.*

**төш инү** *кас.*, **төшкә инү** *лмб., кузн., срг., хвл., тмн., стрл.* төшкә керү (присниться, сниться). Төш инә үземә. Тawық төшенә тары инә. – *стрл.* Кызы шайтанга ышыйдыр, кендез инә тешенә. – *срг.* Әле инде төшеңә дә инми. – *тмн.* Нәнәй төшкинде тенәген. Нәнәй төшемә инде, бик кинәндем, дийр. – *лмб.* Кичен йатып бер дөш күрдем, Бабакай инде дөшемә (*бәет.*). – *кузн.* Ыланнарым төшемә инсә, кинәнәм инде. Болар төшкә инмәгән нәрсәләр, әнисеме, әтисеме әтеп калдырган. Аклы ситсы күлмәгемнең Итәге бөгеш икән, Сагынганда төшкә инми Дигән сүз дөрес икән (*хал. җыр.*). – *срг.* Бөгөн төшемә ингәнсең, имеш, икәү кайадыр барабыз. – *хвл.*

**ИНЦЕ I** *тбл.* балык агы, балык сөте (молоки).

**ИНЦЕ II** *эчк.* элек: килен булып төшкәндә кызга егет ягыннан бирелә торган аяклы мал (в старину: скот, передававшийся невесте со стороны жениха). Сыйырдан бер баш, қуйдан бер баш тоттыралар киленне қотлап, аны килен инцесе диләр.

**ИНЦЕЛӘҮ** *эчк., төм.* элек: киленгә егет ягыннан бирелә торган аяклы малны тапшыру (в старину: вручение невестке родителями жениха дарственного скота). Инцеләп қуйа алтан уқ, сөйләшеп қуйа. – *эчк.*

**ИНЦИ** *тбл.* к.: **терлек 1.**

**ИНЦИЛӘҮ** *тбл.* үзләштерү, үзенеке итү (присвоить).

**ИНЧЕ** *дөб.* к.: **терлек 1**. Қызның үзенә бер сандық бирәләр, ул инче була инде.

**ИНЧЕГҮ** *брб.д.* тыныч лану, күнегү (успокаиваться, привыкнуть). Ул инчекте.

**ИНЧҮ** *брб.д.* тыныч (спокойно); чаг.: **қоморок 2.** Инчүрәк урын йуқма, мынта шаулашатылар.

**ИҢ I** *лш.* терлек колагын кисеп салган билге, тамга (клеймо, метка, сделанная на ушах животных или на птице). Иңе бармы сарығыгызның?

**ИҢ II** *срг.* к.: **инсә**. Балалар әтиләренең кыр сумкаларын иңнәренә асып мәктәпкә йөгерделәр.

**ИҢӘК** *перм.* **1.** к.: **қамақаш**; **2.** *перм.* теш урты (десна). Бер дә ашый алмыйсың? – Ашадым қый иңәк белә; **3.** *твр., брбд.* к.: **инәк II**.

**ИҢӘЛҮ** *мәл., карс., лмб., кузн., хвл., әстр.* к.: **инәлү**. Әнкәсе дә, җиңәсе дә иңәләләр, бирмә, дип. – *мәл.* Кызлар качалар иде, җегетләрдән иңәлдереп кенә ширма ачалар иде. – *карс.* Иңәлә идем йырла дип. – *лмб.* Мин аны Мәкбүләгә иңәләм. Иңәләләр иде, иңәләләр иде, ачмый идек, кәбәм, тәрәзәне. Иңәлеп йәри. – *кузн.* Кешегә иңәлеп йәреми идем, үзем кисә идем, чигә идем. Күпме генә иңәлсәм дә, сүземне тыңнамады. – *хвл.* Иңәлеп тормады бу. – *әстр.*

**ИҢӘРӘ** *төм., тара.* киресенчә (наоборот, напротив).

**ИҢӘҮ** *мам., лш.* к.: **инәү I**. Иңә син аларны, чебешләрне. – *мам.*

**ИҢӘЧ** *тмн.* к.: **игәц**.

**ИҢӘЧӘЙ** *минз., стрл.* к.: **йеңгәчәй.**

**ИҢӘЧИ** *мәл.* әнисенең яки әтисенең ир туганнарының хатыны (жена дяди по отцу или матери).

**ИҢӘЧ-СЕҢЕЛЛӘР** *тмн.* апалы-сеңелле кызлар (родные сёстры); чаг.: **игәч 2.**

**ИҢГӘ** *твр.* к.: **йеңгәчәй.**

**ИҢГӘЙТҮ** *брб.д., твр.* к.: **иңкәйтү.**

**ИҢГӘЙҮ** *брб.д.* бөкрәю (горбиться). Иңгәй!

**ИҢГӘК** *тара.* бөкрәйгән (согнутый).

**ИҢГӘКЛӘҮ** *төм., тбл.* к.: **имгәкләү.**

**ИҢГЕСҮ** *тара.* төшерү, кертү (спустить, занести). Йорты литр сөт тә иңгесмәйте.

**ИҢГЕШ** *злт., тпк., стрл.* төклетура (шмель). Иңгеш йергә керә, тысқан қазыған йергә дә ойа йасый. – *злт.*

**ИҢГҮ** *бәр.* яньчелү (вдавливаться, мяться). Қой чиләген тимерлиләр оролып-бәрелеп иңгеп бетмәсен өчен.

**ИҢДЕРҮ: эч иңдерү** *мам.* эч төшерү (заболеть опущением живота). Эчне иңдердем awыр күтәреп, дүртенче йыл бил awыртып бөкөрәйә башлағанға.

**ИҢЕЛЕК** *клд.* иннек (румяна, косметическая краска). Кершән бизәнгәнне дә белгезми, иңелек бар иде.

**ИҢЕЛЧӘК** *нокр., глз.* ыңгырчак (седёлка).

**ИҢЕЛЧЕ** *минз., к.т., нокр., глз.* к.: **иңенче**. Иңелче туған улым үлде. – *к.т.* Ул инде иңелче йаққа китә башлаған ыйы. – *нокр.* Ту'та, иңелчесен бирим (пычакның). Әнәй алмаға килер дип иңелче ийгә китерделәр. – *глз.*

**иңгелче туган** *глз.* к.: **тудыка(й) 1.** Без иңелче туған.

**ИҢЕНЧЕ** *каз.ар.-крш.* икенче, башка, бүтән (второй, другой, иной). Ул иңенче җирләрдә йөргән. Иңенче тағы аптөштек. Йетәр, иңенчене йырла, дий.

**ИҢЕР I** *твр.* эңгер-меңгер (сумерки). Иңер төшөп китте.

**иңер аралық** *тбл.* к.: **иңер I.**

**ИҢЕР II** *тбл.* изү (ворот, разрез рубашки).

**ИҢЕРЕ** *тбл.* к.: **иңәрә**. Қуйтырғалы уйлаган итем, иңере сықтайты.

**ИҢЕЧ** *мам., перм., бөре., трх., кргл.* инеч (подкладка). Иңеч қуйғаннар тирләсә-нитсә дип. Бу иңеч тузса, икенче иңеч қуйғаннар. – *мам.* Күлмәгемә иңеч қуйдырдым. – *бөре.* Күкрәкчә иңечле иде, шунда өч кесәсе бар иде. Эченә иңеч қатлап қуйа. – *кргл.*

**ИҢЕШ** *лш., каз.ар.-крш.* инеш (речка). Иңешнеке җарамый ашқа (су). – *лш.* Иңештән китерәләр суны. – *каз.ар.-крш.*

**ИҢИЛЗӘҮ** *брб.д.* к.: **иңкәйтү.**

**ИҢКӘ** *твр.* к.: йеңгәчәй.

**ИҢКӘЙТҮ** *брб.д.* ию, бөкрәйтү (согнуть).

**ИҢКӘЙҮ 1.** *т.кам.-крш., тбл., тара., әстр.* иелү, аска карау (наклоняться, нагибаться, смотреть вниз). Иңкәйеп күтәреп қайт урамнан печәнне. – *т.кам.-крш.* Ишектән иңкәйеп керәте, пийек пуйлы. – *тбл.* Иңкәйсәм, билем талаты, итән йуганца утырып йал иткәле гәрәк пулаты. – *тара.*; **2.** *брб.д.* сөялеп тору (прислоняться).

**ИҢКӘК** *брб.д.* иелгән (согнутый).

**ИҢКӘКЛӘП** *төм.* к.: **үрмәклән**. Иңкәкләп цығып китте.

**ИҢКӘЛ** *хвл.* ит һәм бәрәңге белән пешерелгән токмач ашына токмач камырыннан киң-киң итеп кисеп салынган камыр кисәкләре (крупно нарезанные куски раскатанного теста, которые кладут в суп-лапшу с мясом и картофелем).

**ИҢКӘЛҮ** *перм.* **1.** интегү, җәфалану (мучиться); чаг.: **бәлтерәү**. Бик шәп иңкәлдем бу йулда дей, йәйсә аты ара, арбасы awa, йулы йаматай була; **2.** к.: **инәлү**. Бу хатта Ғатаулланы иңкәләп өйенә қайтырга қуша.

**ИҢКЕЛ** *мам.* к.: **астыр**. Шушы иңкелдә қарлығаң күп була.

**ИҢКЕЛ-ТИҢКЕЛ: иңкел-тиңкел қалдыру** *нокр.* алдау, вәгъдәне үтәми алдап калдыру (обмануть, не сдержать своего обещания). Мине иңкел-тиңкел қалдырмағыз чықмайынча қунмаға.

**ИҢКЕРТ: иңкерт wақыт** *тбл., төм.* к.: **энер 1.**

**ИҢКЕ-ТИҢКЕ** *мам., лш.* аңгы-миңге (отупевший, ненормальный). Иңке-тиңке җөри башлаған инде, қартайган Хәлим абзый да. – *мам.* Иңке-тиңке җөрдө алты җыл бизгәк тотоп. – *лш.*

**ИҢКЕШ** *мам.* к.: **астыр**. Ул иңкешерәк, қойашқа арқанрақ, қыш көнө қар күб утыручан була ул йақта (Атау үзәгендә), шунда қар алаланса, ташу ага инде.

**ИҢЛӘЙҮ** *төм.* читкә китү (уклоняться, отклоняться). Уқлары иңләйеп параты. Қарт бақырты: палалар, түмәнрәк атың.

**ИҢЛЕК 1.** *дөб., бгрс.* к.: **индек 2.** Иңлекне әчеп, миңа кертә торғаннардыр (печән). – *дөб.*; **2.** *дөб.* киртә (ограда из жердей).

**ИҢНӘЛЕК** *брб.д.* әнә карагы (стрекоза, кузнечик).

**ИҢНӘҮ** *чст.* кочаклап күтәрү, күтәреп алу (схватив поднять, удержать в объятьях, обхватить). Ий Хыдайым, мәйтәм, мин сине иңни алмыйм бит инде (кешегә карата).

**ИҢНЕК** *перм.* к.: **иңлек 2.**

**ИҢОТЫРЫ** *тбл.* тагын да күбрәк, артыграк (ещё больше, всё более). Мин орышсам, ул иңотыры әйтәте.

**ИҢӨСТӨ** *т.кам.-крш.* җилкә өсте (предплечье). Моннан иңөстөм сызлады.

**ИҢСӘ 1.** *миш.д., м.-кар., әстр.* баш арты, баш чүмече (затылок). Иңсәсе белән йыгылган. – *хвл.* Иңсә чогыры. – *м.-кар.*; **2.** *т.я.* ике кулбаш арасы (межплечье); **3.** *нгб.-крш., чст.-крш.* к.: **инсә**. Иңсәм сызлый. – *нгб.-крш.*

**иңсә бәләгеч** *кузн.* чәч толымын муенга әләктереп куя торган бау, тасма (лента для прикрепления косы к шее). Иңсә бәләгеч иңсәдән шуwытмасын (толымны).

**ИҢСӘЛӘҮ** *мәл.* к.: **ибаз: ибазга бирү**. Иңсәләрмен әле аның чөн.

**ИҢҮ I** *т. я., чст., мәл.* йогу, уңу – тукыманың буявы турында (линять, пачкать – о краске материи). Вилвитка иңмәде, кулга иңде. – *чст.* Бер күлмәгенә иңгән дә. – *мәл.*

**төшкә иңү** *срг.* к.: **инү: төш инү**.

**ИҢҮ II 1.** *тмн.* к.: **инү: койаш инү**. Таң йарылганнан кийаш иңгенчегә; **2.** *бәр.* к.: **иңгү**. Чиләк иңгән.

**ИҢҮ III: соу иңү** *саз.я.* су китерү (приносить воду). Көн қунғансын, соу иңкәле йарамайт.

**ИҢЫЛЧАҚ** *нокр.* к.: **иңелчәк**.

**ИПЕКӘЙ** *минз., злт.* иген, ашлық (хлеба). Ипекәйләрне бирсен җир күкрәкләренә. – *минз.*

**ИПИ** *минз., перм.* икмәк (хлеб). Ипине күп чәчә торған ийе. Ипи чәчеп тордог инде без искедән үк. Ипи хәтәр булды бездә. Йаз чыққач та таптата башлыйбыз шушы ипине, көз җиткәнчегә хәтле. – *минз.* Анда ипи уңайы да суң, йаңы йер. – *перм.*

**бер бүwын ипи** *трбс.* бер буханка ипи (буханка хлеба).

**ипи чылату** *нгб.-крш.* к.: **икмәк: икмәг ачыту**. Бүген менә ипи чылатам.

**кywас төбе ипи** *дөб.* савытны кырып җыйган камырдан әвәләнгән кечкенә ипи (маленький хлебец из остатков теста, выскребков квашни); чаг.: **гердә**. Kywac төбе ипине ашамыйлар, сийырға бирербез.

**қул ипийе** *минз.* өйдә пешерелгән ипи (хлеб, испечённый дома). Бу қул ипийе, үзең эшләп өйдә пешергән.

**таба ипийе** *бәр.* ачыга изгән арыш яки бодай камырыннан кул белән юкарак итеп җәеп, ут каршында табада пешереп алган азык (лепёшки из кислого теста).

**чөгендерле ипи** *нокр.* ипи камыры эченә чөгендер тыгып пешерелгән камыр ашы (мучное блюдо, приготовленное из хлебного теста с начинкой из свёклы). Чөгендерле ипи – қара ипи эченә чөгендер тыгып мин дә пешерепмен тоз салып, тоз салмаа йарамай икән.

**ИПЛЕ** *кргл.* акыллы, мәгънәле – сүз турында (умный, содержательный – о словах). Борынғыларны надан диләр, қалай ипле сүзләр әйткәннәр.

**ИПЛЕ-ЙӘПЛЕ** *яүшт.* хәлле (состоятельный, зажиточный). Ипле- йәпле кешедә тора ул қазылар.

**ИП-САП: ип-саб итү** *злт.* баш-күз алу, мәшәкатьләрдән арыну (передохнуть, освободиться от забот). Быраз ип-саб иткәс китәрмен инде. Быраз wахыт үткәс, ип-саб иткәс, тастымалларны кәштәгә, қашағаға әләләр. – *злт.*

**ИП-САУ: ип-сау алу** *байк.* к.: **ип-сап: ип-саб итү**. Ип-сау алгацтын, әйберләр элгәннән суң, су йулы башлаталар.

**ИПСЕС** *тара.* **1.** искитәрлек, бик (изумительно, очень). Ашың ипсез татлы булыпты. Башта сөт, аннан ацы цай қойабыс, ипсес ацы цай. Ипсес йаман ийән теш сысласа; **2.** исәпсез-хисапсыз, күп (необычно много). Ипсес кән цебен ите. Ипсез инте, ташлаң.

**ИПСЕСЛӘНҮ** *төм.* уңайсызлану (смущаться, чувствовать неловкость).

**ИПТӘ** *дөб.* әйеме (так ведь, правда). Қазанға барабыз әле без, иптә, улым?

**ИПТЕГЕ** *перм.* бәрабәренә, каршысына (соответственно чему-либо, вместо чего-либо). Мин сийә шалған бирәм, син мийә аның иптеге борчақ бир.

**ИР I** *твр.* җир (земля). Тиү пулаты ир астыта.

**и р II** (мужчина, муж):

**ир артыннан китү** *кузн., лмб.*, **ир артыннан чыгу** *карс.* кияүгә качып чыгу, ябышып чыгу (выходить замуж убегом). Ир артыннан китте кызы. Йәрәшер кийәве калды, ир артыннан китте. Аның ике кызы да кыдалап китмәде, ир артыннан кителәр. – *лмб.* Уналты йәшеннән үк ир артыннан чыгарган булган аны. Чыксын, абыстай майым, ир артыннан дийр. – *карс.* Тевенен тотып ир артыннан чыга да китә. – *кузн.*

**ИР-АТАУ** *лш.* ир-ат (мужчина). Ир-атау қайан да таба утынны. Ир-атау кеше қоро-сары ғына ашамый. Ир-атаудан қалғач, сүзең дә үтми, қәдерсез дә буласың. Ир-атауларны тәрбийәләwe awыр.

**ИРӘ** *минз.* к.: **ири**.

**ИРӘБӘ 1.** *каз.ар.* зур, әре сөякле, зур гәүдәле, таза (ширококостный); чаг.: **алапа**. Бик ирәбә бу малай, башуқ җиде йәшлек кебек тә түгел. – *мам.* Ул үзе ирәбә кеше, awыр бит қарт сөйәкне күтәреп җөрүwe. – *каз.ар.-крш.* Шундый ирәбә балалар ыйы алар. – *дөб.*; **2.** *нгб-крш.* к.: **йадау**. Ирәбә генә бозауны җөз тәңкәгә алған.

**ИРӘБЕ** *каз.ар.* **1.** әре, зур (крупный, большой). Бәк ирәбе боз җауды, туйыраны җарып чәрдәкләп бетергән. – *каз.ар.-крш.* Ай ирәбе туған. Ирәберәк ийе чебиләре. – *дөб.*; **2.** к.: **ирәбә 1**. Әтисе кебек ирәбе буласы бу малай. – *мам.* Сеңнесе апасыннан ирәберәк. – *лш.*

**ИРӘГЕШТЕРҮ** *хвл.* ирештерү, үртәү, үчекләү, котырту (дразнить, поддразнивать, подтрунивать). Син ыланны ирәгештерәсең?

**ИРӘГЕШҮ** *хвл.* к.: **иргәләшү**. Йитәр инде, ирәгешеп утырмагыз.

**ИРӘЙҮ 1.** *лш.* үсеп китү, эреләнеп, зураеп китү (вырасти, стать больше, крупнее). Ике җыл эчендә сыйырлар ирәйделәр; **2.** *бөре.* масаю (зазнаваться, гордиться); **3.** *минз., злт., стрл.* узыну, кылану, кылтаю (кривляться, представляться). Кит, ирәйеб утырма. – *минз.* Чү, чү, ирәймә. – *стрл.* Син шунда ирәйеп, бийау сатып йөргәнсең, дерә ирәйеп китәсез. – *минз.*

**ИРӘК** *к.т., лмб., срг.* ерак (далеко, далёкий). Туғаннарыбыз ирәктәрәк әле безнең. Балам, ирәк китмә, җомышқа кирәк булуың бар. Ирәктәге қойаш җылы була (*әйтем*). – *к.т.* Этләрне ирәгрәк бәләгез, әт син аларга. Ирәктән күренә урман. Урман артын ирәктән күрә, бырын астын ирәк булмаса да күрми (*мәкаль*). Алмагачның алмасы ирәк тешми (*әйтем*). – *лмб.* Усалның ирәге йахшы (*әйтем*). – *срг.*

**ИРӘМСҮ** *тбл.* һаваланып, масаеп, тәкәбберләнеп (важно, гордо, высокомерно). Утырған алар йанта ирәмсеп.

**ИРӘН** *себ.* ир (мужчина). Ирәннәр пецән эшенә әсерләнеп йаталар. Ирәннәрнең көйләге қыйыш йағалы булған. – *тбл.*

**ИРӘНЕЧ** *чпр., мәл.* җирәнгеч (отвратительный, противный).

**ИРӘНҮ** *тмн., лмб., хвл., срг., чпр., карс., твр.* җирәнү (брезгать, испытывать отвращение). Килен алдым, кинәндем, салмасыннан ирәндем (*тақмақ*). – *тмн.* Мин ирәнәм чи сет әчәргә. – *лмб.* Ирәнәм мин дуңгыздан. – *срг.* Ирәнмәгез, минең awырuwым йуқ. – *твр.*

**ИРӘСӘК** *тбл., тара.* үсмер, үсеп җиткән (подросток, подросший). Ирәсәк кеше. Ирәсәк тай.

**ИРӘҮ** *тара.* сүтү (распарывать).

**ИРӘҮЛӘҮ** *дөб.* к.: **иләүләү**. Кирпеч ычтина артқылы ишетелә, менә ирәүлиләр инде.

**ИРӘШӘ** *каз.ар.-крш.* рәшә (марево, мгла). Ирәшә җуқ үзе җуғын, ул игеннәрне саргайта.

**ИРWАСТА** *сазл.* әкрен генә, җай гына (потихоньку, спокойно). Ирwаста эшләwe.

**ИРГӘБАЙ** *әстр.* себерке (метла).

**ИРГӘЙҮ** *тара., төм.* алдан сизеп тору (предчувствовать).

**ИРГӘК** *тара., төм.* ата хайван (самец – у животных). Айғыр ат иргәк. – *төм.*

**иргәк ат** *твр.* айгыр (жеребец).

**ИРГӘЛӘШТЕРҮ: сүd иргәләштерү** *минз.* к.: **иргәләшү**.

**ИРГӘЛӘШҮ** *дөб., минз., нгб.-крш.* сүз көрәштерү, бәхәсләшү (спорить). Син эшлә дә мин эшлә дип иргәләшмәдек инде без, әйбәт йәшәдек. – *дөб.* Иргәләшеп утырдық малайымнарда. Алар иргәләшеп китәрләр. – *т.кам.-крш.* Сүd иргәләшү. – *минз.*

**ИРГӘНӘК** *тара.* **1.** сәндерә (полати). Иргәнәкнең өстендә палалар йоқлый, аста посау торған. Иргәнәк өйдә, астында посау тора тығын, өстә паллар йоқлый тығын; **2.** *твр.* өй эчендә яшь бозау, бәрәннәрне саклый торган урын (место в доме, отведённое для новорождённых животных).

**иргәнәк қапқа** *тара.* җил капка (лёгкие, одностворчатые ворота, сколоченные из жердей).

**иргәнәк посау** *тара.* алты айга җитмәгән яшь бозау (телёнок в возрасте до шести месяцев). Өйдә торғанны иргәнәк посау тиләрте.

**ИРГӘҮ** *тбл.* к.: **ийерү**.

**ИРГЕН-ТАРҒЫН** *төм.* иркенләп (вволю, почувствовав свободу). Ирген-тарғын кәпләштек ике туғанымқы паласы белән.

**ИРДАWАЙ 1.** *дөб., злт., трх., мәл., чпр.* ирдәүкә, үзен ирләр кебек тотучы хатын-кыз (женщина с мужскими манерами). Ирдawай оло қызлары, тәмәке тарта. – *трх.*; **2.** *байк.* бик үткен хатын-кыз (очень бойкая женщина, бой-баба). Сез дә ирдawайсыз, заданйада йөрөрлек булгаң.

**ИРДАУКА** *тмн.* к.: **ирдawай 2**. Әбекәй безнеке ирдаукарак булган, ирләр ман эшләгән.

**ИРЕГҮ I 1.** *т.кам.-крш., кргл., төм.* зарыгу, тансыклау (томиться, истомиться, заждаться, соскучиться). Иртән килеп ирекмә, көндез килеп көнөкмә (*мәкаль*). – *т.кам.-крш.* Аның белән уйнаучы йуқ, шуңа иреген тора. – *кргл.* Әшкәрә эшкә иретәте. – *төм.*; **2.** *миш.д., нокр., төм.* сагыну (скучать, соскучиться о ком-либо, тосковать). Ирекқәндә багарсың. Әнисе бик иретә үзен. – *лмб.*

Бик иректем, әмән ике-әч ай гына киткәненә. Иректек инде үзенә. Зөфәр генә ирексә инде. Ирегәм дип йаза кызым. Без, мишәрләр, сагынуны ирегү дип ат'абыз. Ирегәсең дә багасың. – *кузн.*; **3.** *тбл.* туйдыру, биздерү (надоесть). Эше ирегеп, йерне ғасыпты. **4.** *тбл.* берәр төрле аш кабасы килү, берәр нәрсә ашыйсы килү (испытывать потребность в какой-нибудь пище). Пәлмәнкә иректем.

**ИРЕГҮ II** *нокр., мам.* ялкаулану, иренү (лениться). Эшкә ирекми ул, бик тирақ. Тирақ қыз булдым, эшкә ирекмәдем. – *нокр.* Эшкә ирекмим мин бер дәген. Тәрәдәдән тороп қарарға да иректем. Мин пешерергә ирекмим, булса. Ирекмәгән җан. – *мам.*

**ирек** (свобода):

**ирек ачылу** *лмб.* күңел ачылу (подниматься настроению). Киләм дә гурыттан, иркем ачыла, гурыт вуздыхы тегел инде.

**ирек итмәү** *бәр.* ирек бирмәү, комачаулау (не давать возможности сделать что-либо, мешать). Қызым awырта, ирек итми эшләргә.

**ИРЕКЛӘП 1.** *перм.* үз ирке белән, ирекле рәвештә (добровольно, непринуждённо). Көчләп түгел, ирекләп; **2.** *т.я.-крш.* к.: **имкәмнәп**. Мин ирекләп эчәрмен чәйне.

**ИРЕКЛӘҮ** *чст.* кыстау (уговаривать, упрашивать); чаг.: **ирсезләү**.

**ИРЕКТЕРҮ 1.** *хвл., срг., чпр.* сагындыру (заставить скучать, тосковать). Бик иректерде инде кат'мица. – *срг.*; **2.** *тара.* эч поштыру (возбуждать скуку).

**ИРЕКҮ 1.** *минз., стрл.* к.: **ирегү II**. Ирекмәй беднең әтәй сүләргә. – *минз.* Күмәч салырга ирекәм. – *стрл.*; **2.** *хвл.* к.: **ирегү I, 2**. Каа ылым, алла ылымны иректем.

**ИРЕМ I** *перм., төм., твр.* су төбендә барлыкка килгән чокыр, чоңгыл (углубление на дне реки или озера, омут). Аның (Сарс елгасының) зур чумғыллары, иремнәре бар, элек биг үлгән анда кеше төшеп. – *перм.*

**ИРЕМ II** *тбл.* бәйләм (связка, пучок). Пер ирем йөнем пар ите.

**ирен I** (губа):

**дөйә ирен** *бөре.* китек ирен (заячья губа).

**ирен бозгыч** *м.-кар.*, **ирен йаргыч** *трх., бөре., минз., кмшл.*, **ирен йаргыц** *байк.*, **ирен җарғыч** *каз.ар.-крш., лш., к.т., трх., бөре.* кәҗә сакалы (дикий пастернак, пастернак луговой). Ирен йарғычлар ашап, иреннәр җарылып бетәйде. – *трх.*

**ИРЕН II** *перм.* тукта (стой, подожди). Хәбибә апа, ирен, кирәкмәс.

**ИРЕНГЕЧ** *перм.* к.: **азымтык**.

**ИРЕНҮ I** *себ.* к.: **ирү II, I**.

**ИРЕНҮ II** *нгб.-крш., минз., стрл.* ялыгу, ару, тую (утомиться, устать, надоесть). Иренә ул көм буйы өйдә утырып. Нәнәwем кешедән иренә. Телбистә, әле генә сөйләшми; сөйләшә ул, иренеп бетәм. Иренеп беттем инде арчына-арчына. – *нгб.-крш.* Мин бик иренәм аның мәшәкәтеннән. Синең йаныңда тора-тора да иренеп беттем инде. – *минз.*

**ИРЕҮЛӘТҮ** *твр.* көчәйтү (усилить). Бераз радионы иреүләт, Ринат.

**ИРЕЧЛЕ** *каз.ар.-крш.* бала тапмый торган хатын (женщина, которая не может рожать детей).

**ИРЕШ** *тбл.* буй җеп – тукымада (нить – основа в ткани).

**ИРЕШӘ** *т.кам.-крш.* рәшә (марево). Иртә лә ирешә, кич тә ирешә, Безнең басуларны ла ай нишләтә (*хал. җыр.*).

**ИРЕШЕНҮ** *перм.* шаярту (подшучивать). Матчаны салмыйбыз тип ирешенәләр алар, май чығармадың исә.

**ИРЕШТЕРҮ** *злт., бгрс., кргл., стрл.* үчекләү, үртәү, котырту (дразнить, злить). Малайлар ирештерәләр. Ирештерәм инде, ситтән килгән кеше былса. – *злт.* Ирештереп тиргәдем инде. – *стрл.*

**ИРЕШҮ 1.** *кргл., тпк.* ачуланышу, сүзгә килү (браниться, вздорить, поругаться с кем-либо). Бабай белән ирешеп алам. – *кргл.* Хәдер киттек пит инте ирешеп. Қайсысы ирешеп йөрөй, эрәхәткә сықтық тимиләр. – *тпк.*; **2.** *мәл.* дучар булу, төшү, әләгү (подвергнуться, попасть, напр., в тяжёлое положение). Бик awыр хәлгә ирешкән бу.

**ИРҖДАЙ** *нгб.-крш.* к.: **ирдawай 1**.

**ИРИ** *кас.* өйрә (суп из крупы).

**ИРИЖ** *кас.* шалкан (репа).

**ИРИК** *тбл.* **1.** черек, әче, бозык (гнилой, кислый, испорченный); **2.** тире иләү өчен солыдан ясалган ачыткы (овсяная закваска для выделки кожи).

**ИРКАСТАЙ** *чст.* каенсеңелгә эндәшү сүзе (форма обращения к младшей золовке).

**ИРКӘК 1.** *чст., әстр.* ир (мужчина). Иркәк кеше килми җаучы булып. Иркәк булса, утырмый кузовка. Иркәкләр киләте. – *әстр.*; **2.** *лмб.* ата эт (кобель); **3.** *карс., тара.* ата эт яки песи (самец – у кошек или собак).

**иркәк мешәк** *тара.* ата песи (кот).

**инә мешәк** *тара.* ана песи (кошка).

**ИРКӘМ** *минз., кргл., злт., тпк., стрл.* эне яки сеңел һәм аларга эндәшү сүзе (младший брат и сестра и форма обращения к ним). Пинсийә җитә, күлмәк иркәләрем биреп тора. Вилүс дигән иркәм бар, бәләкәй әле. Үзең белән иркәңне дә алып бар. – *минз.* Иркәләре көлеп қарап тора, ә бу йылап тора. – *кргл.* Бер иркәсе Уфада. Иркәм, ишекне йабың әле. – *злт.*

**қыз иркәсе** *злт.* сеңлесе (сестрёнка). Бер қыз иркәсе Уфада.

**ИРКӘНҮ 1.** *т.я.-крш.* к.: **иренү II**. Мин җөрәгә иркәнмим. Эштән иркәнмәгән бер дә; **2.** *тмн.* к.: **ирегү I, 2**. Чебелдеккәйем чып-чывар, Чебен генә кунса, кем кывар; Туган илемне иркәнеп йылаганда, Йыламачы дийеп кем тыйар (*бор. җыр.*); **3.** *т.я.-крш.* тансыклау, теләү (сильно хотеть, сильно желать). Бу иркәнмәй дә иде энде.

**ИРКӘТӘЙ** *тара.* көйсез (капризный, избалованный).

**ИРКӘҮ** *тара.* иркәләү (нежить, изнежить). Көндез йөргәнендә иркәләмә балаңны, йоқлағанында ғына сөй.

**ИРКӘЦЕ** *әчк.* иркә (изнеженный, неженка). Ул йаман иркәце бала.

**ИРКӘШКӘ** *төм.* к.: **иркәце**. Иркәшкә пулаты, эш пелмәйте.

**ИРКЕН** *минз.* боярларда крепостнойлыкта булмаган – авыл турында (вольные, независимые от помещиков – о деревнях). Иркен арурақ булғандыр инде. Йуқ, керәстийән дүгел, иркен.

**ИРКЕНЧЕЛ** *трх.* иркенчелек (достаток). Андағы иркенчелгә қызықмаслық түгел.

**ИРКЕЧ** *перм.* күңелсез, ямансу (скучно, грустно, невесело). Бүтәнне тағы шундый қызлар йебәресез, иркеч қала мийә.

**ИРКЕЧӘҮ, ИРКЕЧЛӘҮ** *перм.* күңелсезләнү, ямансулау (скучать, стать грустным, тосковать). Иркечлибез, эчләребез боша.

**ИРКҮ** *мам.* к.: **иреғү II**. Базға төшерергә иркеп әчетәм сөтне.

**ИРЛӘН** *төм., тбл., төр.* әрлән (хомяк).

**ИРЛӘҮ** *перм.* к.: **ийерү**. Ирләгәс, җепне кәләпкә саласың.

**ИРЛЕК** *тбл.* өйнең беренче ниргәсе (первый венец сруба).

**ИРМӘК 1.** *перм., злт., себ.* кызык, күңеллелек (забава, интерес). Без бақчага утыртабыз инде ирмәг өчен. Ирмәккә эшләп қуйғаннар. – *тара.*; **2.** *перм., злт., к.-уф., эчк., тбл.* кызыклы, күңелле (интересный; интересно); чаг.: **зawоклы, сыкланыч**. Йефәк қалфақлар кийеп, бигерәк ирмәк була торған ийе. Ирмәк булды. Монда ирмәгерәк йерләр йуқ микән тип қарыйм да. – *перм.* Бу китабың ирмәкме? – *эчк.* Ул бигрәк ирмәк сүләшә. Ай ирмәк тә булды инде Нәҗибәнең туйында. – *к.-уф.* Ирмәк йерләрен сүләп йебәр. Йәш бала бигрәк ирмәк была инде ул. – *злт.* Песне тыңлағалы ирмәк булыр. Ирмәк сүс кәпләйте. – *тбл.*; **3.** *себ.* кичә (вечер). Пүген клупта ирмәк пулат иген.

**ирмәк қылу** *тбл., тара.* к.: **ирмәкләшү**. Ирмәк қылып утырамыз. – *тара.*

**ИРМӘКЛӘШЕП** *перм., к.-уф., сазл., төм., тара.* күңелле итеп (весело). Ирмәкләшеп кеше белә эчмәгәч, ул нинди эчүдер инде ул. – *перм.* Әйдә, бер җыйылып ирмәкләшеп алыйқ әле. – *к.-уф.* Нәнәң ирмәкләшеб утыра қәпләшеп. – *тара.* Ирмәкләшеф утырawыс. – *сазл.* Кицләрен ирмәкләшеп утыратығайтық, аны-моны кәпләйтегәйтек. – *төм.*

**ИРМӘКЛӘШҮ** *тара., тбл.* вакытны күңелле уздыру, күңел ачу (приятно проводить время). Бермәлне ирмәкләшәсең, қайтсағыз себерәкләрцә сүләшәсез инде. – *тара.* Пер берең мән ирмәкләшәсең. – *тбл.*

**ИРМӘКЛЕК** *лш.* **1.** ирлек, егетлек,; батырлык (мужественность; поступок, достойный мужчины). Алай эшләү ирмәклек түгел; **2.** ирләр арасында күп эшләгән хатын-кызга карата кимсетеп әйтелә (говорится принебрежительно о женщине, много работавшей среди мужчин); чаг.: **ирдawай**.

**ИРМӘКЦЕ** *тбл.* тамашачы (зритель, тот, кто смотрит). Үрдәныктан ирмәкцеләр килеп тулган, Халайыққа тар булаты Сапра урам (*чәч туе җыр.*).

**ИРМӘН** *тбл.* к.: **нәркәмәс**.

**ИРМӘХ** *сазл.* **1.** к.: **ирмәк 2**. Ирмәх кеше ийентең; **2.** к.: **ирмәк 1**. Ирмәх кәпләф вақыт уздырабыз. Ирмәх кәпләшәт.

**ИРМЕШӘК** *тбл.* ата песи (кот).

**ИРМИРӘЙ** *кмшл.* **1.** к.: **ирдawай 1**. Кит, ирмирәй, шулхәдәр қылынмасаң; **2.** артык шук, шаян – бала-чагага карата әйтелә (говорится о чересчур шаловливых, озорных детях).

**ИРНӘWЕННӘН** *нгб.-крш.* мөлдерәмә (доверху, до краёв). Ирнәwеннән тулған чиләк.

**ИРСӘК 1.** *дөб., тара.* азгын, бозык (распутный, безнравственный). Ирсәг ис ул Сәлих, кеше қатыны артыннан чаба. – *дөб.*; **2.** *злт.* кыланчык (кокетливый, жеманный). Ирсәк была алмый балалар, йәшләргә қарата әйтелә ирсәк дип.

**ИРСЕЗ-КУШСЫЗ** *тмн.* ялгыз, ирсез (одинокая, не имеющая мужа). Ирсез-кушсыз бер катын кешегә тормыш алып баруы кыйын. Ирсез-кушсыз бик кыйын.

**ИРСЕЗЛӘҮ** *срг.* ирексезләү (неволить, вынуждать, заставлять). Ирсезләп кецкә цыгардык. Кызларын ирсезләп бирделәр.

**ИРСЕМӘК** *төм., тбл.* **1.** к.: **ирдawай 1**. Ирсемәкләнеп йөрөйте қуй; **2.** уңган (способный, дельный).

**ИРСЕТҮ** *злт., байк.* узындыру, җаена гына тору, кәпрәйтү (потакать, баловать). Хөкөмәт қарсықларға пинсийә биреп ирсетте дә, қартлар қарсықсыз йөрөй. – *злт.*

**ИРСҮ 1.** *эчк.* көйсезләнү (капризничать). Ирсемә әле, балам; **2.** *тбл.* ачу килү, үпкәләү, хәтер калу (злиться, обижаться). Шал кийәүгә ирсийем; **3.** *тбл.* мактану (хвалиться). Ирсеб утырма.

**и р т ә** (утро):

**иртә ары, иртә соң** *тмн.* к.: **ирти: ирти артында**. Иртә арыга китәсез дә...

**иртә өстән** *тмн.* к.: **иртә эстән**. Иртә өстән мунчадан сың кийә үзгә күлмәкләр.

**иртә соң** *тмн.*, **иртә узгач** *срг.* к.: **ирти: ирти артында**. Иртә узгач китәбез, әтәләр.

**иртә чагында** *нрл.* к.: **иртәгәч**. Иртә чағында жywынам.

**иртә эстән** *мәл.* иртәнге якта, иртәнге сәгатьтә (с утра, в утренние часы). Беген иртә эстән дә йаумады әле, умберләрдә башлады. – *мәл.*

**и р т ә г ә** (завтра):

**иртәгә соңа** *минз., стрл.*, **иртәгә соңға** *злт., бгрс., кргл.*, **иртәгә суңа** *минз., перм., стрл.* к.: **ирти: ирти артында**. Иртәгәме, иртәгә соңамы? – *минз.* Персидәтел иртәгә соңға қайтырга тийеш. – *злт.* Иртәгә соңға печәнгә. – *бгрс.* Барам, иртәгә суңа көтү көтәргә. – *стрл.*

**ИРТӘГӘДӘН: иртәгәдән ары** *мәл.*, **иртәгәдән соң** *хвл., мәл., чпр.*, **иртәдән арыга** *чст., мәл.* к: **ирти: ирти артында**. Иртәгә кер йywам, иртәдән арыга зиләккә барам. – *мәл.* Иртәдән арыга китәрсен. – *чст.*

**ИРТӘГӘЧ** *минз., т.я., чпр.* иртән, иртә белән (утром). Иртәгәч, көтү қуганчы үк уйандым ийе. Иртәгәч китәбез. – *минз.* Иртәгәч тә қарап тордым. – *трх.* Бүген иртәгәч пичкә җаққанда искә төшеп, күземә җәш килде. Иртәгәч күреп қалдым. – *к.т.* Иртәгәч кабызам шул. – *чпр.*

**ИРТӘГЕЛЕК** *төм., тбл.* к.: **иртәгәч**.

**ИРТӘДӘ** *эстр.* элек (раньше). Иртәдә үзенең тирмәне булды.

**ИРТӘДӘН: иртәдән арыга** *чст., мәл.*, **иртәдән**

**соңға** *злт.* к.: **ирти: ирти артында**. Қызлары иртәдән соңға килергә тийеш. – *злт.*

**ИРТӘК** *әстр.* әкият (сказка).

**ИРТӘЛЕ** *кузн.* к.: **иртәгәч**. Ничек иртәле белән пешеремен. – *кузн.*

**ИРТӘН** *әстр.* к.: **иртәсте 1**. Улан-холлга иртән китәшәк булам.

**иртән йуқ** *әстр.* к.: **ирти: ирти артында**. Иртән йуқ барарбыз.

**ИРТӘНГЕЛЕК** *минз., шрл.*, **ИРТӘҢГЕЛЕК** *кмшл.* иртәнге аш (завтрак). Әле мин иртәнгелекне дә ашамаған. – *минз.* Иртәнгелекне ашадым да чегендергә киттем. – *шрл.*

**ИРТӘНЕ** *минз., стрл.* к.: **иртәгәч**. Лимма иртәне ышкулга китте. – *стрл.*

**ИРТӘНСАҚ, ИРТӘНСӘК** *злт., тпк.* к.: **иртәгәч**. Тасны иртәнсақ түгә дә қуйа, түгә дә қуйа. – *злт.* Кичтән жуwабыз да иртәнсақ кийәбез. – *тпк.*

**ИРТӘНЧӘКЛЕК** *шрл.* к.: **иртәнгелек**.

**ИРТӘСТЕ 1**. *срг.* иртәгә (завтра). Иртәсте буладыр бар′ам; **2**. *срг., кузн.* к.: **иртәгәч**. Иртәсте йатканнар дийер, өчәү торалар. – *кузн.* Иртәсте кеше булмаган, бар да эштә булган. – *срг.*

**ИРТӘСТЕН, ИРТӘСТӨН** *лмб., кузн., хвл.* к.: **иртәгәч**. Иртәстен йыварга кирәк керне, кендез казлар куйырта суны. Иртәстен киләдер кызым каладан. – *лмб.*

**ИРТӘЦАҚ** *төм.* к.: **иртәгәч**. Иртәцағ озаттылар.

**ИРТӘЧАҚ** *нрл.*, **ИРТӘЧАК** *м.-кар.* к.: **иртәгәч**. Иртәчақ булды ул пужар, таң атқан ыйы. – *нрл.* Иртәчак малай белән утырдым. – *м.-кар.*

**ИРТӘЧӘ** *трх.* к.: **иртәгәч**. Ул иртәчә бирер.

**ИРТӘЧӘК 1**. *мам.* к.: **иртәгәч**. Байа иртәчәк бардым. – *минз.*; **2**. *чст.-крш.* йокыдан бик иртә торучы (тот, кто очень рано просыпается). Безнең күршедәге катын шулай иртәчәк ийе.

**ИРТЕСТӘН** *тмн., кузн., хвл.* к.: **иртәгәч**. Кичен куймадым инде, иртестән куйарбыз чәй. – *тмн.* Иртестән бер нәүмәт кабып булмый. – *кузн.*

**ИРТИ** *кас.* иртә (утро).

**ирти арты** *кас.* берсекөн (послезавтра).

**ирти артында** *кас.* берсекөнгә (послезавтра). Са'а 'әйчән 'ала'а барма'а? Танда'а да була, ирти артында да.

**ИРТЧАҚ, ИРТЧӘК** *нрл.* к.: **иртәгәч**. Иртчақ киләлмәсә, кич килер. Булмаса, иртәгә иртчәк китәрмен.

**ИРТЫWАН: иртыwан салу** *твр.* буа буу (ставить запруду, запрудить).

**ИР УРТА: ир урта ир** *дөб.* урта яшьләрдәге ир (мужчина средних лет). Ир урта ир қырықларда, қырық йәш, илледә дә ир урта әле, кемгә ничек бит.

**ИРҮ I** *лмб.* эрү – май турында (растопиться – о масле). Сары май кебек иредем. Иреде бу кыз.

**ИРҮ II 1**. *эчк.* әкрен (тихий, тихо). Тawышы ирү ишетелә; **2**. *төм., тбл.* сүлпән, әкрен (медленно, вяло). Планны тултыру ирү парат; **3**. *тбл.* ялкаулык, ялкау (леность; лениво).

**ИРҮЛӘНҮ** *тбл.* әкренәю, тыну (становиться тихим, притихнуть).

**ИРҮЛӘҮ** *тбл.* ялкаулану (лениться).

**ИРХӘХ** *саз.я.* иркәк (самец).

**ирхәх эт** *саз.я.* ата эт (кобель).

**ИРШҮ** *перм.* к.: **ирәгештерү**. Аннары балалар Габдулланы иршемей башлыйлар. Аны иршемә син, нийә иршисең?

**ИС I** [*фарс.*] *кас., карс.* һич (отнюдь, нисколько).

**ИС II** *кас.* ислемай (духи).

**ИС III 1**. *минз., перм., кас., кргл., злт., чпр., тбл.* хәтер, зиһен (память, рассудок). Үденең исе жуқ. Исе булмағач, хәдер самawур қуйып чәй эчерәсең, хәдер тағы самawур қуй, ди. – *минз.* Ис житкән әле кертеб утыртырға. Иссез булып әчә башласа ғына, аныңа эш кәрәкми. – *перм.* Аның исе зирәк. Әле шатланам, тазамын әле, исем дә йақшы. – *злт.* Сөйләргә кән исем йуқ. – *тбл.*; **2**. *перм.* көч, хәл (сила, мощь). Айақларда ис йуқ, қузғалмый бупча.

**ис айлану** *брб.д.* һушка килү (прийти в себя; очнуться).

**ис асғыру** *тара.* ис китәрү (удивлять, ошеломлять). Әлеге ғарт кәпләсә, исләрен асғырыр ите.

**ис асу 1**. *тбл.* иссез булу, һуштан язу (потерять память, лишиться чувств). Исем асып китәте; **2**. *тара.* ис китү (удивляться).

**ис (-ем, -ең, -е) килү** *тбл.* к.: **ис айлану**. Қыслар арата утырам, пер исем килсә.

**ис китү** *перм., злт.* аптырау, аптырап бетү (измучиться). Бабайы қышқы сuwықларда эзләб исе китә. – *перм.*

**иссез қалу** *кргл.* к.: **ис асу 1**. Чықсалар, эти иссез қалган.

**иссес китү** *тбл., төм* к.: **ис асу 1**.

**истән төшү** *минз.* истән чыгу, оныту (забыть). Исемнән төште инде, хәдер теләсә қайа йәри үde.

**ИСАЛА** *нгб.-крш.* аңгыра, ахмак, юләр (глупый, придурковатый; дурак). Бигрәк исала инде бәләкәй малайлары.

**ИСӘ** *дөб., минз., к.-уф.* икән, булыр икән (может, может быть). Минем бүрегем қайадыр исә? – *дөб.* Ул кемгә килде исә. – *к.-уф.* Кемнән чықтымы исә, күрмәйенче калдым. – *минз.*

**ИСӘБЕ** [*гар.+афф.* -е] *минз., стрл.* чамасы (приблизительно, около). Берәр жыл исәбе тордо да китте. – *минз.*

**ИСӘWӘН** *кргл.* ахмак, аңгыра, акылсыз (глупый, бестолковый, неумный); чаг.: **дундук**. Борынгы кешеләр исәwәнрәк чақта чегәннәр абзардан тawықларын алып чығып киткәннәр.

**ИСӘЙҮ** *мам., минз., срг.* үсеп, ныгып китү, көч керү (подрасти, окрепнуть). Көзгә хәтле хәзер исәйеп қалалар алар (яшь бозаулар). – *мам.* Малай да исәймәгән ийе әле. – *минз.* Оланнар исәйә башлагач. – *срг.*

**ИСӘКӘЙ** *мам.* каз өмәләре вакытында егетләр һәм кызларның төрлечә киенеп, уйнап-биеп йөрүләре (веселья, устраиваемые молодёжью в дни коллективной помощи по ощипыванию резаных гусей). Қаз йолқығанда исәкәйләр йасыйбыз, қызыг ул, чықмаған кеше қалмый қарарға.

**ИСӘН-АМАН** *тмн.* к.: **исән-имән**. Исән-аманмы?

**ИСӘНГӘ** *твр.* киләсе елга (на будущий год, в

следующем году). Исәнгә илле йыл тула йәшәгәнебезгә. Исәнгә тағы бер йыл ғына уқый да уқытырға қайта. Исәнгә машина алам диб әйтте.

**ИСӘИГЕРӘҮ 1.** *минз., перм.* к.: **ис III: ис асу 1**; **2.** *минз., нгб.-крш., перм., шрл.* аңгыралану, баш әйләнү, баш кату (стать бестолковым, отупеть); чаг.: **бәлтерәү**. Эзли-эзли исәңгерәп беттем. – *нгб.-крш.* Йыкламаган тен буйына, кунакларны кирәк кararга, вич исәнгерәгән. – *шрл.*

**ИСӘН-ИМӘН** *минз.* исән, исән-сау (здоровый, целый, невредимый; жив-здоров). Исән-имән җәрәп қайтсын инде.

**ИСӘНКЕРӘҮ** *дөб.* к.: **исәнгерәү 2.**

**ИСӘНТӘ 1.** *тара.* исән булсак, киләчәктә (если будем здоровы, в будущем). Исәнтә күрерпес. – *тара.*; **2.** *саз.я., тбл.* к.: **исәнгә**. Исәнтә мынта күцф килмәкцеләр. – *саз.я.* Палам сабақка исәнтә керәте. – *тбл.*

**ИСӘНТӘӘ, ИСӘНТӘГӘ** *саз.я.*, **ИСӘҢГӘ** *твр.* к.: **исәнгә**. Қысым унны пәтә исәңгә.

**ИСӘҢГЕРӘЙҮ** *перм.*, **ИСӘҢГЕРӘҮ** *бөре., минз., злт., дөб., к.-уф.* к.: **исәнгерәү 2**. Шулай исәңгерийем, сандыг ачқычымны ничә рәт жуғатам көнгә. Исәңгерәп беттем инде бу балаларның шау-шуwына. Үзегез дә исәңгерәп бетәмсез (язаяза). – *к.-уф.*

**ИСӘҢГЕРӘТҮ** *перм., к.-уф.* к.: **исеңерәтү**. Хәлем бетте бигерәк, мине исәңгерәтмә. – *перм.* Исәңгерәтмә әле, болай да башым әйләнгән. – *к.-уф.*

**ИСӘҢКЕРӘҮ** *төм., тбл.* **1.** к.: **исәнгерәү 2.** Исәңкерәп китермен, қайта йатуwымны белмәйем; **2.** к.: **ис III: ис айлану**. Исәңкерәсәм, аранта йәрәп йатам игән.

**ИСӘҢРӘҮ** *перм.* к.: **исәнгерәү 2.**

**ИСӘП I** [*гар.*] *мам., минз., кмшл., чпр., чст.-крш.* кайгы-хәсрәт, сагыш, уй (печаль, тоска, дума). Исәбем буламы, сөйенечем буламы – шушы җиремә қату чыға. Исәп белә кеше үлми, чир белә үлә. Башыма күпме исәпләр, исәпләгән исәбем китапқа да сыймас. – *мам.* Чәчне исәп ағарта инде ул, исәпне күп уйладым. Чир йуқ сиңәрдә, тип әйтте врач, исәптән генә шулай булғансың, ти. – *минз.* Исәп күп булд(ы) инде безнең ғумердә. – *кмшл.* Ул исәпле Питер, минем бернәстә исәбем йук. – *чст.-крш.*

**исәп керү** *дөб.* уйлау, уй-фикер килү (думать, приходить – о мысли). Теге әйберне алмасқа исәп керде әле.

**ИСӘП II** *бәр.* күп (много). Бер тәлинкә аш дәү кешегә исәпмени ул.

**сәғәт исәбе** *перм.* бер сәгатькә якын, бер сәгать чамасы (около часа, почти в течение часа). У тартышып йата торған ий сәғәт исәбе.

**ИСӘП III** *т.кам.-крш.* киңәш (совет). Минем әни дөрәс ийе, жақшыйы, бөтен кеше киләдер ийе исәпкә.

**ИСӘПЛӘҮ** [*гар.+афф.* -ләү] *мам., кмшл.* уйлану; хәсрәтләну, кайгыру (думать о ком-либо, о чём-либо; горевать, печалиться). Уйанам да қызымны исәпләп йатам, йоқламыйм. – *мам.* Исәпләп, уйлап қарыйм да исем китә үземә. – *кмшл.*

**ИСӘР 1.** *перм., минз., к.-уф., тара.* аңгыра, ахмак, юләр (глупый, придурковатый; дурак); чаг.: **ат′акыш**. Үзең әчсең, шунда исәрләр белә исәр буласың. Көчөктә (*ав. ис.*) бер исәр хатын җырлады. Әбисе дә исәр сыман ийе. Wат исәр баш, уқымый қалдым. Исәр кеше әйткәндәй, озурлап қына үскердем үзем. – *перм.* Ул әзрәк исәр дә булған. – *к.-уф.* Пелмәйен, исәр бултық мийән. – *тара.*; **2.** *минз.* бик, искиткеч (очень); чаг.: **дибә**. Исәр бай булған.

**ИСӘРЛӘНҮ** *минз., перм., к.-уф.* юләрләну, акылдан язу (сойти с ума). Әнисе, исәрләнде, дип сүли торған ийе. Ишеттегезме, Хәйри исәрләнгән. – *перм.* Исәрләндеңме әллә, бер дә йуққа кешегә бәйләнәсең. – *к.-уф.*

**ИСӘРСҮ** *твр* к.: **исәрләну**. Йөрсөн ул исәрсеп.

**ИСӘҮ** *яүшт.* к.: **ислими′и**. Алланы биг исәүче йуқ. Хәзер исәттерә, йәш wахытта уйламыйсын.

**ИСЕ-ДЫХЫ** [*тат.* + *рус.*] *лмб.* исе-җиле, хәбәре (весточка, известие). Исе-дыхы да йук.

**ИСЕ-ҚОҢҒЫСЫ** *перм.* исе-фәләне (и следа).

**и с е м** (имя, название):

**исем атау** *стрл.* кушамат тагу, исем бирү (дать прозвище). Алар бит бер-берсенә исем атый.

**исем салдыру** *нокр., глз.* исем куштыру (дать имя, нарекать именем).

**кушам исем** *глз., стрл.* кушамат (прозвище). Урам аты кушам исем булмасын ул. – *глз.* Кушам исемнәре аларныкы Карсаг иде, шундый төлке булган. – *стрл.*

**ИСЕМБАШ** *перм.* к.: **йосомбаш.**

**ИСЕМНЕ** *минз., перм., стрл.* к.: **атаулы 1.**

**ИСЕН** *перм.* к.: **тором II**. Бодай булайы, исенне булайы, ул очмый җилгә, эпейең қара була.

**ИСЕҢЕРӘТҮ** *к.-уф.* аптырату (надоедать, донимать). Мине көн буйы исеңерәтеп утырды.

**ИСЕ-ОСО** *тара.* к.: **ис III, 1.** Аның әле исе-осо төрс.

**ИСЕРҮ** *срг.* аңгыралану, миңгерәүләну, хәлдән таю (глупеть; стать бестолковым). Сүли-сүли исергәннәр биш-алты сәәт буйына сүләшә-сүләшә. Йаза-йаза исереп беткәнсездер инде.

**ИСЕҮ** *тара.* авыз кырые (край рта).

**ИСИ′** *кас.* к.: **кәнтә**. Чили′лирне cow′a бар′анда иси′и асалар.

**ИСКАЛЕК** *глз.* истәлек (память; вещь, подаренная на память). Искалеккә калсын.

**ИСҚА-САНҒА: исқа-санга қату** *тбл., төм.* к.: **исләү 1.** Исқа-санға ғатмайым, ә ул мине көсәтеп тора ийен. – *тбл.*

**ИСКӘРӘСТӘ** *т.я.-крш.* белгәндә (на чьей-нибудь памяти). Мин искәрәстә awыл җәзгә җитеп үскән иде. Мин искәрәстә ит′аулар, ин′аулар урысчарак иде.

**ИСКӘРҮ** *т.я.-крш.* к.: **исләү 2.** Йахшы искәрәм барыбер.

**ИСКӘҮ I** *тбл.* к.: **ислими′и**. Пелмәйем мин аны, онытым инте, искәмәйем.

**ИСКӘҮ II 1.** *мам., нгб.-крш., бөре., минз., кмшл., злт., к.-уф., трбс., миш.д., брб.д.* иснәү, сулау (нюхать, обнюхивать, дышать). Мәтрүшкә иским. Песи итне искәде дәген китте, ашамады әле. – *мам.* Искәпләр қарый қашықны. – *нгб.-крш.* Искәргә була инде. – *минз.* Искәп қарале, бу чәчкә

нинди хуш исле. – *кмшл.* Һawa искәб утырабыз. Искәп қара, исле ул. – *злт.* Исен искәле, диләр. – *трбс.* Искәче, бар бит бу гөлнең исе. – *лмб.* Күпме иским, течкертми. – *тмн.* Бабай чәчәкне алып бирә. Искәп бага (*әкият.*). – *кузн.*; **2.** *т.я.* к.: **исләү 1.** Син аның ни эшләгәнен искә әле.

**ИСКӘҮ III** *тбл.* тарту, өзү, йолку (тянуть, рвать, теребить).

**ИСКЕ** *кузн., хвл., злт., кмшл.* яшь баланы төрү өчен чүпрәкләр (детские пелёнки). Ыланы тугач, өр-йаңы искеләр йасап бирдем үзенә. – *хвл.*

**бала искесе** *чст.* к.: **иске.** Искерсә, бала искесенә тотоп аларны, күлмәк итәген дә, фырансуз йаулыгын да.

**ИСКЕ-БЫСКЫ** *глз.* иске-москы, искергән (изношенный). Иске-быскы чабаталар кийеп...

**ИСКӨР** *төм.* к.: **қолақай.**

**ИС'ӘҮ** *кас.* к.: **искәү II, 1.**

**ИСЛӘМӘСТӘН** *минз.* к.: **кискәнәттән.** Исләмәстән генә килеп чыға да қарап җәри утны мант'ур.

**ИСЛӘҮ 1.** *нгб.-крш., кргл., шрл.* искәрү (заметить, обратить внимание, приметить). Лар'укның ачықлығын исләмәдем. – *нгб.-крш.* Кат'канмы, йукмы, аны исләгән дә йук. – *шрл.*; **2.** *трбс.* аңлау, төшенү (соображать, понять). Исләб алдым тиз генә; **3.** *кас., тбл.* к.: **ислими'и.** Эчен пош'анда уйнаб алырсын исләб, диде. – *кас.* Шушы гөлне исләйем. – *тбл.*

**ИСЛЕ I 1.** *тбл., том.д., минз.* зиһенле, зирәк, акыллы (сообразительный, понятливый). Балалары бик исле шул; **2.** *миш.д., эчк.* хәтерле (имеющий хорошую память). Йарый әле араларында ислерәк апа бар. – *кузн.* Мәликә әптәй бик исле ул. – *эчк.*

**ике исле** *дөб.* к.: **исәр 1.** Шул ике исле белә җәрмәсән, қыз тапмам дип қурықтымманы.

**ИСЛЕ II** *минз., стрл.* зуррак (побольше). Себеркедән чак қына исле ағачлар. – *минз.*

**ИСЛЕКӘЙ 1.** *перм.* кандала (клоп). Ислекәйне бетерә торған дару җибәрең әле безгә; **2.** *бөре* түндербаш (болиголов).

**ИСЛЕМАЙ** *лмб.* к.: **алма И: алма геле.**

**ИСЛЕРӘХ** *саз.я.* зуррак (побольше). Миң паламнан ислерәх.

**ИСЛИМИ'И** *кас.* искә төшерү; хәтерләү (вспоминать; припомнить).

**ИСЛҮЛӘН 1.** *к.т., дөб., каз.ар.-крш.* к.: **алма I: алма гөле**; **2.** *дөб.* к.: **печән: қандала печәне.**

**ИСМАС: исмас пулу** *твр., төм.* к.: **ис III: асу 2.**

**ИСПҮШКӘ** [*рус.* избушка] *тара.* кечкенә өй (домик, избушка).

**ИССЕҮ** *тара.* эсселәнү, кайнарлану (стать горячим). Су иссете.

**ИСТӘ-ҚОСТА** *т.я.* истә, хәтердә (в памяти, пока не забыто). Истә-қоста чақта биреп қуйыйм, җә онотормын. Истә-қоста да җуғ ыйы бөтеннәй қайтыр дип, қайтты килде. – *к.т.*

**ИСТӘ-ОСТА** *дөб.* к.: **истә-қоста.** Истә-оста җуқта қайа килеп кердең?

**ИСТӘРГӘН: истәргәнгә чығу** *т.кам.-крш.* нардуган вакытында төрле уеннар уйнау (обычай проведения различных игр во время праздника нардуган). Нардуган унике көнгә сузыла, без аны истәргәнгә чыгабыз дип шүләшәбез инде.

**ИСТӘҮ 1.** *кузн.* теләү (хотеть, желать). Бу алаша су исти, бир үзенә су. Бегенгесе көнне исти дыстигат' итәргә; **2.** *тара., тбл.* эзләү (искать). Мешәк палларын истәйте. – *тара.*

**ИСТОСТА** *тбл.* к.: **истә-қоста.** Истоста булмаған қунақлар килепте.

**ИСТҮ** *том.д.* исле (угарный).

**ИСҮ I** *яүшт., төм.* эссе (горячий). Исү шурпа кирәк.

**ИСҮ II** *тара., брб.д.* авызның ике як кырые, чите (края губ). Майны исүеннән серләтеп эйәте. – *брд.д.*

**ИСҮ III** *тара.* пычрату (пачкать). Айағың былцырақ, итәнне исмә.

**ит I** (мясо):

**зим ит** *перм.* сум ит, йомшақ ит, итнең сөяксез җире (мясо без костей, мякоть). Зим итләр була: балтыр ите. Әллә нимә майлы булмый инде ул зим ите. Зим ит – сүәксез, майсыз ит.

**ит гептәсе** *әстр.* фрикадельки.

**ит шешләү** *тара.* тозлап киптерелгән итне утта кыздыру (жарить на костре вяленое мясо).

**озын ит** *срг.* к.: **зим ит.** Озын ит, цәни алмиймын.

**ИТ II** *нокр., глз.* к.: **кочок.** Йәш кенә ит баласы нәқәс, йаман, талап үтерә йазды. Итне машина басты, йаман йыладым. – *нокр.* Чебешләрем бер дә бақмадым ич, әллә ит ташып бетерде. – *глз.*

**ИТ III: ит қоштыру** *тара.* к.: **ит қысу.**

**ит қысу** *тбл.* ачулану, ачу килү (сердиться, злиться). Итемне ғыстырма!

**ИТ IV: ит тамақ** *тбл.* аш юлы, үңәч (желудочный тракт, пищевод).

**ИТ-АЖ** *хвл.*, **ИТ-АШ** *т.кам.-крш.* ит белән пешерелгән ризыклар (мясные блюда). Башта итаж чыга башлый, аннан салма чыга, бутка чыга, бодай буткасы йә сал'ник, аннан чәй ашлары. – *хвл.* Ит-аш та алып бардық, калбаса, ит алып бардық, өстәлне көйләдек әйберләр белән. – *т.кам.-крш.*

**ИТАШ** *тбл.* итле аш (мясной суп). Иташ эцкәле йаратмайты.

**ИТАШАР: иташар көн** *чст.-крш.* христианнарның ураза беткән көннәре (последний день поста у христиан). Иташар көн ураза беткән көн була.

**ИТ-АШЫ: ит-ашы пөткән** *брб.д.* ябыккан, кибеп беткән (исхудал, высох).

**ИТӘК I 1.** *мам., т.я., минз., злт., т.кам.-крш., мәл.* юбка. Беднең магадинға итәкләр күп қайтқан ийе. – *минз.* Итәген кийеп туздырдым, куфтысы бар әле. – *злт.* Қарендәш-ыруға күлмәген, итәген җибәреп тора. – *т.кам.-крш.* Ақ куфта, қара итәк йәш қызларға бик килешә ул. – *к. т.*; **2.** *бәр., т.кам.-крш., к.т., лмб., мәл., кузн., хвл., твр., әстр.* бала итәк (волан, оборка). Өчәр итәк тотоп кийә торған ийек. Итәк тотқан күлмәге бар ийе әнинең. – *бәр.* Итәкле алҗапқычлары бар ийе әнинең. – *к.т.* Күлмәгенә итәк тоткан. – *кузн.* Анай, күлмәк ызын, икешәр итәкләләр, йерәк майым, сездә дәме шылай? – *лмб.* Итәк салып күлмәккә, хет монда сал. – *твр.*; **3.** *перм.* алъяпкычның

җилкә өсте турысына салган бала итәк (оборка на плечевой части женского фартука). Шушы төшкә итәк салалар, шуны қанат та диләр; 4. *тбл.* чабу (пола одежды).

**әкәй итәге** *бөре.* киң бала итәк (широкая оборка). Әкәй итәге ийе, бер генә қатлы балайтәк булса.

**балан итәк** *лмб.* к.: **итәк I, 2.** Балан итәкле күлмәк тегә иде әни.

**итәк җақма** *т.кам.-крш.* к.: **алҗапма.** Итәк җақмасы пычрақ та инде шул қатынның.

**итәк эсте** *мәл.* к.: **итәк I, 2.** Минем күлмәгемдә итәг эсте иде җидешәр.

**итәккә утырту, итәккә утыру** *бөре.* кияү куенга керәсе көнне чыбылдык эчендә урын-җир өстенә бер бала яки урынның дүрт почмагында дүрт бала утыртып тору гадәте (свадебный обычай: на занавешанную постель новобрачных перед приходом жениха сажать детей); чаг.: **каталату: урын каталату.** Итәккә дә утырғам бар, кийәү көмеш бирә дүрт мөгөштә.

**итәкле күлмәк** *к.т., хвл., брб.д., твр.* бала итәкле күлмәк (платье с оборками). Элеке итәкле инде күлмәкләр, қайсысы таққан итәкле, инечле, көштәкле түгәрәк җақа. – *к.т.* Күңләк кәң кенә, өч итәкле, төрт итәкле. – *брб.д.*

**карават итәге** *минз., стрл.* карават яки өстәл кырыена тотылган чигүле йә челтәрле кашага, япма яки эскәтер (скатерть, вышитый или кружевной подзор).

**кәбестә итәк** *дөб.* күлмәкнең итәгеннән биленә кадәр салынган берничә киң бала итәк (широкие оборки, пришитые снизу до пояса платья). Кәбестә итәк билгә хәтле менә йазайы. Кәбестә итәк дәүдәү итәк була торган ыйы.

**нәни итәк** *к.т.* к.: **итәк I, 2.** Икешәр нәни итәкле күлмәкләр буладыр ийе.

**оло итәк** *т.кам.-крш.* к.: **әкәй итәге.** Оло итәкне чеметеп-чеметеп тоталар, қайсы чеметмичә дә тота.

**стена итәге** *минз., стрл.* кашага (бордюр, занавеска вдоль стены).

**таққан итәк** *дөб., минз., т.я.* кызлар күлмәгенең итәк очына бөреп тотыла торган киң итәк (широкая оборка, пришитая к подолу женского платья). Қайсысы таққан итәкле, инечле, кештәкле, түгәрәк җақа. – *к.т.*

**төз итәк** *каз.ар.-крш.* турыга кисеп тегелгән юбка (прямая юбка).

**чаршау итәге** *мам.* чаршау өстенә бөреп тотылган тар кашага (узкий сборчатый бордюр над пологом).

**ИТӘК II** *дөб., бөре.* тирә, төбәк (определённый участок). Ул итәктә җөргәнем җук. – *дөб.* Ул итәккә барғаным йук. – *бөре.* Шул итәктә ите өйөпес. – *тбл.*

**күл итәге** *твр.* күл яны (место у озера).

**түбән итәк** *дөб.* тау итәгенең аскы өлеше (подошва горы).

**ИТӘКЛӘҮ 1.** *злт., твр., саз.я.* җитәкләү (водить за руку). Уллары бар тума суқыр, авчарка итәкләп йөртә. – *злт.* Төшкәч, йастыққа бастыралар, кийәү итәкләп киленчәкне ишеккә китерә. – *твр.*; **2.** *брб. д.* итәккә алу (взять в подол).

**ИТӘЛГҮ** *тбл.* кошның бер төре (мышелов).

**ИТӘНЦИ** *тара.* идән юучы, хезмәтче хатын-кыз (женщина, которая моет пол; служанка).

**ИТӘХ I** *саз.я.* к.: **итәк II.** Машина сеснең итәхестә посолты.

**ИТӘХ II** *саз.я.* хәтле, кадәр (до; величиной с...).

**ИТӘХЛЕ, ИТӘХЛЕК, ИТӘХЛЕМ** *саз.я.* к.: **итәх II.** Айу итәхлем йowан.

**ИТЕ** *тбл.* җиде (семь).

**ите йәшәр** *тбл.* к.: **дөңгөриш.** Ите йәшәр цағып китте йыслығымны (борынымны).

**ИТЕК 1.** *лмб., хвл., кмшл.* к.: **пима 1; 2.** *мәл.* озын кунычлы резин итекләр (высокие резиновые боты). Итегемне кийеп киткән иде, кайгыртып тыра тыргандар инде бәлчек дип.

**атоу итек** *тара.* читек (ичиги).

**итек сугу** *бәр., каз.ар.* итек басу (валять валенки).

**тыш итек** *бәр.* күн итек (кожаные сапоги). Очормадан тыш итек кийеп төшөп килә, ди ул.

**чобар итек** *трх.* чигүле киез итек (вышитые валенки).

**ИТЕКӘ** *тбл., том. д.* к.: **ywa.**

**ИТЕК-ЧӘРЕК** *чст.-крш.* һәртөрле күн аяк киемнәре (всякая кожаная обувь). Бу инде этинең борынгы кийе, итек-чәрек теккән чакта җырлар ыйы.

**ИТЕМ** *твр., тбл.* ятим, үксез (сирота).

**ИТЕМЦӘК** *тбл.* к.: **итем.**

**ИТЕН** *тбл.* җитен орлыгы (льняное семя).

**ИТЕНГӘЛӘҮ** *чст., мәл.* дип әйткән булу, дигән булу, кыланып әйткән булу (притворно говорить; говорить, что будто ...). Куркып тырам әле, итенгәли. Хамит абый тилифун аша ызwанит итеп йөрде, кат'асыңмы итенгәли! – *чст.* Зәйнәп тә, тиливизыр алам итенгәләде дә, эстемә кеше ташыма, дидем. Йазар, кирәк булса, итенгәли. – *мәл.*

**ИТЕНЕШ** *миш.д., т.я.* кыланыш (выходка; поступок; манера вести себя). Итенеше үзеннән зур. – *хвл.*

**ИТЕНҮ** *миш.д., трх.* **1.** кылану (вести себя некрасиво, ломаться, кривляться, жеманиться и т.д.); чаг.: **йақлану.** Итенмә болай, ойатсыз. Әллә ниләр итенмә, башкалардан бер дә артыклығың йук, майым. Итен бераз йахшырак. – *кузн.* Начар итенми иде бер дә: кычкырып көлмәс, кычкырып сүләмәс. – *мәл.* Үз башына итенә. Былай итенү килешми инде. Йукка итенмәгез. – *хвл.* Ринат, йахш(ы) итен. – *срг.*; **2.** маташу (возиться, заниматься). Җоморқаларны айырған итендек ийе. – *трх.*

**ИТЛӘК** *тбл.* итләч (мясистый).

**ИТЛЕК I** *мам., перм.* сугымга симертелгән терлек, сугымлык (убойное животное). Қышқа бит безнең итлегебез йук, мал-тywар сатучы барда алып қалыйқ. Быйыл қаз, үрдәкләр дә булмагач, итлекләр дә күп түгел, ике әweннек арышы булса, берсен сата да итлек алыр ийе безнең әти. Көз көне итлеккә бирдек сыйырны. – *мам.*

**ИТЛЕК II** *эчк., себ.*, **ИТЛЕХ** *саз.я.* келәт, амбар (место хранения зерна, клеть, амбар). Итлехтә он, қаныт, қыш гөне ит, палых сахлайwc. – *саз.я.* Ашны қапцыққа қойып итлеккә аппаратылар. – *брб.д.*

**ИТМӘК** *төм.*, **ИТМӘХ** *сазл.* к.: **үпмәк.**

**итмәк кисмә** *төм.* к.: **ләнгәц.**

**итмәх пала** *сазл.* кечкенә ипи (хлебец, маленький хлеб).

**итмәх салу** *сазл.* к.: **йабу I, 1.** Итмәх салған көннә әлсерәп төшөлләт.

**тора итмәх** *сазл.* кибеттә сатыла торган ипи (хлеб, который продаётся в магазине).

**ИТУЖЫК** [*рус.*] *мәл.* шулай да, алай да (всё-же, всё-таки).

**ИТҮ I** *м.-кар.* салу, пешерү – ипи, бәлеш турында (печь – о хлебе, пирогах). Икмәк итәргә он илим.

**ИТҮ II 1.** *кузн., хвл., злт.* к.: **илтәү I.** Вана балничага итеп кистерә идем. Алашада иттем инде утыртып. – *кузн.* Бар, итеп куй әле апаң сандыгына. Иттем дә бер чиләк суга салдым. – *хвл.* Әтәңә ашарға итәңме? – *злт.*; **2.** *тбл.* җитү (достигать). Түргә иткән күргә итәр (*әйтем*).

**ИТҮ III** *блт., дөб., бөре., минз., злт., байк.* теләү, берәр нәрсә эшләмәкче булу (желать, хотеть, намереваться сделать что-либо). Чыгарға итә инде бу қаз. – *блт.* Мин аның өйенә керәсе итмәдем. – *дөб.* Йаңы муйса төзөргә итә. – *злт.*

**ИТЧЕК** *нокр.* эт эчәге (вьюнок полевой).

**ИТЫРА** *м.-кар.* менә, шушы (вот, эта); чаг.: **менәтерә.** Итыра безне ышкул.

**ИХӘҮ: ихәү worон** *сазл.* игәү борын – урдәк төре (грохаль). Пороно оцло, оссон, эцхә қарайт, пуйыны сары.

**ИЦ** *брб.д., тбл.* эч (внутренняя часть).

**ИЦӘ** *тбл.* иҗек (слог).

**ИЦӘМӘ** [*фарс.* + *тат*] *төм., тбл.* к.: **ицмә.** Алай гөләтегән булсаң, ицәмә тә қәпләмәм.

**ИЦӘТҮ** *төм.* ашыйсы килү (хотеть есть).

**ИЦWЕР, ИЦWЕРӘҮ** *сазл.* һичкем, беркем дә (никто). Ицwерәүләре күренмәте.

**ИЦЕГҮ** *тбл.* тәрбияләнү, иркәләнү (быть кормимым вместе с кем-либо, приласкаться).

**ИЦЕК** *тбл.* эчке күлмәк (нижнее платье).

**ИЦҚАЛАЙ** *сазл.* һичничек, берничек тә (никак). Ицқалай пармай.

**ИЦКӘ I** *тбл., брб.д.* нечкә (тонкий).

**ИЦКӘ II** *брб.д.* к.: **ичке.**

**ИЦКЕ** *себ.* к.: **ичке.** Арық болпты суйған нимәләре, ицкеләре. – *тара.*

**ицке вала** *тбл.*, **ицке пала** *төм.* кәҗә бәрәне (козлёнок).

**қыр ицкесе** *тара.* к.: **қоралай.**

**ИЦКЕЛӘҮ** *тара.* бәрәннәү (ягниться – о козе). Ицке ицкеләйте.

**ИЦКЕРЕК 1.** *тбл.* очкылык (икота); **2.** *тара., тбл.* кикерү (отрыжка).

**ицкерек ошлау** *тбл.* к.: **кикнату.**

**ИЦКЕРЕКЛӘҮ** *тара* к.: **кикнату.**

**ИЦКЕРҮ** *тбл., тара.* кикерү (отрыгивать).

**ИЦМӘ** [*фарс.* + *тат.*] *сазл., төм.* берни дә, һичнәрсә (ничто, ничего). Ицмәм йух. – *сазл.* Ицмә күрмәгән, айақ-қулы сау. – *төм.*

**ИЦМӘК** *тбл.* күн бияләй (кожаные рукавицы).

**ИЦНИМӘ** *себ.* к.: **ицмә.**

**ИЦӨК** *төм.* балык тотканда елганы буып кую өчен суга утыртылган сал (котец, котцы; плетневой перебой через речку для удерживания и ловли зашедшей туда рыбы).

**ИЦУҚ** *тбл.* ичмаса (хоть бы, по крайней мере). Ицуқ палам йуқ.

**ИЦҮ** *брб.д., тбл.* ашау, эчү (кушать, пить).

**ИЦХАЙТА, ИЦХАЛАЙ** *сазл.* беркая, һичкая (никуда). Ицхалай пушатмайм сине.

**ИЦЦУХ, ИЦЦҮХ** *сазл.* ичмасам (хотя бы, хоть). Көннәр иццух ысwайланса ит.

**ИЧАҚ** *перм.* к.: **иртәгәч.** Икмәг ачыттым, ичақ бешерем инде.

**ИЧЕГЕП** *каз.ар.-крш.* эченә кереп, кызыксынып (проникновенно, увлечённо). Әл дә барам қылупқа, ичеген-ичеген қарыйым тийәтер кисә, ражиуны да ичеген тыңлап торам, қызықлар күп қәзер дә.

**ИЧКЕ** *кузн., әстр., тара.* кәҗә (коза). Кызым, ичкеләрне китер әле. – *кузн.* Ичке сикерергә тора, ди. – *әстр.* Бездә ичке тотмыйлар, Қара күлдән алып қайттылар пых ичкийе. – *тара.*

**ИШ I** *т.кам.-крш.* к.: **абышқа 1.** Әй минем жаным ишем, сийа бик күп сәләмнәребезне бөтен жамақатларыбыздан да озатып қалам.

**ИШ II** *нокр.* еш (часто, частенько, нередко). Қартымны иш күрәм төштә.

**ИШАЛДЫ** *мам., каз.ар.-крш., кас., нокр., глз.* к.: **йорт 1.** Ишалдын, басқыч төпләрне дә себерештем инде. – *нокр.* Туй ишалдына кергәч, туйға қаршы өйдән май, жуқа, жуwача, әчемнекләр белән чыгалар. – *каз.ар.-крш.* Иртә торды, ишалды себере(р)гә тотынды. – *мам.*

**ИШАНҮ** *нокр., глз., перм.* к.: **ишәнү.** Азбар хуҗасына мин биг ишанып та бетмим. Ишанмаған идем лишак барға, инде ишандым, дий. Ишанмасаң ишанмассың. Мин ишанмадым. – *нокр.*

**ИШАҢҒЫЧЛЫ** *глз.* ышанычлы (надёжный). Сән ишаңғычлы дәп килгән.

**ИШАРАТЛАУ** *блт., мам.* кул хәрәкәтләре белән сөйләшү (говорить жестами). Ул татарча белми, мин урысча, икебез ишаратлый-ишаратлый сөйләшәбез. – *блт.* Аңнамасын дип, миңа ишаратлап қына әйтте. – *мам.*

**ИШ-АШ: иш-аш булу** *мам.* игелекле, файдалы булу (быть полезным, благотворным). Ул қайтып та иш-аш була алмый инде.

**ИШӘЛӘҮ** *карс.* әвәләү (скатывать, обвалять). Камырны болай ишәлисең дә...

**ИШӘНҮ** *перм., тбл., төм.* ышану (верить, надеяться).

**ИШӘТ** [*гар.*] *тбл.* шаять, ахрысы (вероятно, возможно).

**ИШБАҒӘТСЕЗ** *т.кам.-крш.* ямьсез, кыяфәтсез (некрасивый, неприятный); чаг.: **қошбәтсез.** Кирый Апанаслары бу жаңа өйләренең түбәсен әй ишбағәтсез дә жапқаннар инде.

**ИШГЕҒАЛАҚ** *тара.* ишкәк (весло). Палам, ишгеғалақны апкилце, балыққа төшәм.

**ИШЕҒАЛ** *эчк.*, **ИШЕГАЛ** *байк., хвл., стрл., шрл.* к.: **ишегалды.** Ишеғалны себермәгән мин. – *эчк.*

Ишегалга кертмә кычыкны. – *хвл.* Бидраны мунча ишегалга куй. – *стрл.* Ишегалларымны ышкып алмаммы дигән идем. – *шрл.*

**ишегал төп** *байк.* баскыч төбе (место у входа в сени). Ишегал төптән бер дә китмиләр бу казлар.

**ИШЕГАЛДЫ** *минз., тпк., трбс., миш.д.*, **ИШЕГАЛНЫ(СЫ)** *миш.д.* өйалды (сени). Йаңа өй, ишегалдыннан менгәндә, арқа пешә иде әwәле. Ишегалдын йуwыб алдым. – *трбс.* Ишегалдындамы йатасың, Әббәз? Монда түwәрән, ишегалды тулы. Ишегалны салкын булыр. – *срг.* Берсен ишегалына куйарсын су чыгып-чыгып алырга. Ишегалының башына менгән. Безнең бабай дүрт угыллы ызба куйганда, ишегалнысы читән иде. – *кузн.* Крыша тузган, шынарга ишегалына йаңгыр үтә. – *мәл.* Wахит ишегалына утын кертә. – *чст.*

**ИШЕГАН, ИШЕГАНБАШ** *твр.* к.: **болдор.**

**ИШЕК** *тбл* к.: **йорт 1.**

**ишек алды** *миш.д.* к.: **ишегалды.** Идәне зур, ишек алдына йатсыннар. – *хвл.* Ишек алдын да йу, ызбаны йугац. – *срг.*

**ишек борыс** *перм.* ишек яңагы (косяк).

**ишек қаш** *тбл.* ишек башы (верхний косяк дверей, притолока).

**ишек өс(те)** *тмн., чпр.* ишек төбе (преддверие, место перед дверью). Ишек өстә торма, уз түргә. – *тмн.*

**ишек тупса** *том.д., тбл.* к.: **тупса 1.** Кеше ашы ишек тупсатан цыққанта йатып қалаты (*әйтем*). – *төм.*

**ишек цыганақта** *тбл.* ишек артында (за дверью).

**ишек элдергеч** *перм.* ишек элгече (запор, защёлка, засов – у двери).

**ишек эс** *лмб.* к.: **ишек ос(те).**

**ИШЕЛМӘЛЕ** *бәр.* ишетелә торган (слышимый, слышный). Бу йақтан теге йаққа ишелмәле булған бырғы таwышы.

**ИШЕЛҮ** *блт., дөб., трх., нрл., бгрс., трбс., глз., том.д.* ишетелү (слышаться, послышаться). Қурыққанға қуш ишелә (*әйтем*). Ғаптулла таwышы ишелә тегендә. – *блт.* Өйалдына чыгып кер әле, таwышы ишелмиме? Бер таwыш ишелә. – *дөб.* Бетен таwыш ишелә. – *глз.* Иренә ишелә ул таwыш. – *трх.* Awылға ишелеп торайы. – *трбс.*

**ИШЕМ** *тбл., төм., тара.* үрем, толым (коса).

**ИШЕМНӘҮ** *тпк.* артыграк ачыган камырны он һәм су өстәп яңартып басу (заново замесить прокисшее тесто, добавляя воду и муку).

**ИШЕНДЕРҮ** *хвл.* болгату, чуалту (спутать, запутать).

**ИШЕНҮ** *тбл., тара., брб.д.* көймәдә йөрү (кататься на лодке).

**ИШЕРЕЛҮ** *бөре., злт.* җимерелү, ишелү (развалиться, рухнуть). Күтәрмә ишерелеп киткән. – *бөре.* Өйгән утын әрдәнәсе фис ишерелеп төште. – *злт.*

**ИШЕРЕМ 1.** *т.я.* саламны кайнар су белән парлап, өстенә он яки көрпә, тоз сибеп әзерләнгән терлек азыгы (месиво для скота). Сыйырға ишерем болғатып бирдем. – *к.т.*; **2.** *лш.* ашлыкны җилгәргәндә аерылган кибәк, әрбә (отходы при отвеивании зерна, мякина). Ишерем өйеп қуйасын, қышын хайwаннарға бирдем. Әwендә өйләр ишеремен.

**ИШЕРҮ 1.** *злт.* ишү (валить, разваливать). Кисә салған кибәнне йел ишергән; **2.** *мам.* ашлык җилгәргәндә сугылган ашлык өстенә төшкән башакларны һәм очыкларны себереп тору (во время молотьбы: очищать зерно метлой от мякины).

**ИШКӘНДЕ** *тара.* кычыткан авыруы (крапивница).

**ИШКЕ I** *әстр.* к.: **ичке.**

**ИШКЕ II** *тбл., төм., тара.*, **ИШКЕК** *төм.* к.: **ишгегалақ.**

**ИШКЕН** *брб.д.* атның юыртуы (рысь лошади).

**ИШКЕННӘҮ** *брб.д.* юырту (идти рысью).

**ИШКЕНЧЕ** *брб.д.* юртак (рысак).

**ИШ-ҚУШ** *перм.* туган-тумача, агай-эне, кодакодагый, гомумән якын кешеләр (родня, близкие, сватья и т.д.). Қайда иш-қуш бар, шунда китеп беттеләр. Аның қәзер беркеме йуқ, ише-қушы да йуқ.

**ИШЛӘНҮ** *перм.* өйләнү (жениться). Қазанда ишләнеп қайтты, Ырымбурда торалар.

**ИШЛӘҮ** *минз., тпк., стрл.* басу (замесить, месить тесто); чаг.: **ишемнәү.** Иртән ишләйсең дә пичтә пешерәсең. Бодай оно белән изеп, дары оно белән ишләйдер ийек, таба қалыннық була ул тәбә. – *минз.*

**ИШЛЕК** *перм.* чәчүргеч (лента, вплетаемая в косы). Әле чәчне ишлексез генә иштем ий, мужыт, муча булыр дип.

**ИШЛЕ-ҚУШЛЫ** *каз.ар.-крш.* парлы, икәү (на пару, вдвоём). Ишле-қушлы булып чыгасыз икән (клубка).

**ИШМӘ 1.** *перм.* катылган җеп (сучёная нитка). Син орчог алғансың ике ишмә ишәргә; **2.** *брб.д.* к.: **ишпә.** Түгәрәкләйсәң дә қушасың, ишмә әйтәделәр; **3.** *тара.* читән (плетень).

**ИШМЕШ: ишмеш буйынца** *срг.*, **ишмеш буйынча** *хвл.* ишетеп, ишетү буйынча (понаслышке). Ишмеш буйынца сүләдем. – *срг.*

**ИШПӘ** *әстр.* өйдә хәзерләнгән кренделләр (сушки домашнего приготовления).

**ИШҮ I** *миш.д.* ишетү (слышать, услышать). Ишмим, кычкырып ат'. Әй эшләдем, эшләдем, Билемнән фартыкымны тишмәдем; Билгенәмнән фартыкны тишмәсәм дә, Йахшы сүзегезне ишмәдем (*хал. җыр.*). – *тмн.* Ишмәдем, ни этте. – *лмб.* Ишмәдем сүккәнен, ишмәдем awыр сүз әткәнен иремнең. Wәт әле колаклар тонды, сүләгәнне ишмим. Аны ишкәнем йук. – *срг.* Нәрсә әтәсең, ишмим. – *чст.*

**ИШҮ II 1.** *перм., эчк., злт., себ.* чәч үрү (заплести косу). Мин болый ишмәгә белмим шул. Чәчне ишеп тормыйм мунча инәсе булғач. – *перм.* Цәцеңне ишеп йөр. – *эчк.* Сәсне ишәләр ийе дә осона тәңкә тагалар ыйы. – *злт.*; **2.** *перм.* җеп кату (сучить, скручивать – о нитках). Мәстәгә ишеп җыйасын суң бу қәтле.

**үлбән ишү** *себ.* буш үрү (заплетать слабо).

**цыйрақ ишү** *себ.* тыгыз үрү (заплетать туго).

**ИШҮ III 1.** *перм., брб.д.* чәч толымы (коса).

Аның (чәче) ишүдә дә тормый қый қаты өчен. – *перм.* Қыс вақтында перәү генә ишү болпты, икегә айырып ишкән йоқ. – *брб.д.*; **2.** *брб.д., төм.* к.: **ишем**. Ике ишү, пер ишү пулаты. – *төм.*

**ИШХАН** *твр.* өйалды баскычы – өйнең буеннан-буена эшләнә (крыльцо – делается на всю длину дома).

**ИШХЕХ** *саз.я.* **1.** ишкәк (весло), **2.** балык йөзгече (плавник).

**ИШШАН** [*фарс.*] *перм.* бик (очень). Ызбағызны йуғач, ишшан әйбәт булып, йақтырып киткән, бигрәк ысланған иде.

**ИШ-ЫРУ** *перм.* к.: **нәсел-асаб**. Иш-ыруларын алалар ый арғыш итеп.

# Й

**ЙА I** *чст., мәл.* ә (междометие а). Ник сугышасың, йа? – *мәл.*

**ЙА II** *тбл.* җәя (лук).

**йа бөгү** *тбл.* җәягә бөгү (сгибать в лук).

**ЙААҚ I** *яүшт.* к.: **йәйәк I**.

**ЙААҚ II** *брб.д.* к.: **йәйәк II**. Ишек йаағы.

**ЙАБ** *брб.д.* калкулык (возвышенность, холм).

**ЙАБА** *төм.* к.: **йапма II**. Йабаға ташыйтлар ынтырға, эскерткә салатлар.

**ЙАБАЙ I** *брб.д.* оча сөяге (тазовая кость).

**ЙАБАЙ II** *төм.* к.: **йабан**.

**ЙАБАЙЫ** *тара.* коелып калган орлыктан үскән иген (растения, выросшие из оставшихся зёрен).

**ЙАБАҚАЙ** *том.д.* үткен сүзле, тапкыр (остроумный).

**ЙАБАЛАЙ** *хвл.* гаҗәпләнү, аптырауны белдергән ярдәмче сүз (вспомогательное слово, обозначающее удивление, недоумение). Эшен йәпйахшы белә йабалай.

**йабалак I** (сова):

**қара йабалақ** *нокр.* соры ябалак (неясыть бородатая).

**қуйан йабалақ** *перм.* ак ябалак (белая сова).

**өкө йабалақ** *перм.*, **чупай йабалақ** *трбс.* колаклы ябалак (ушастая сова).

**ЙАБАЛАҚ II** *перм.* к.: **керфек I, 2**.

**ЙАБАН** *тбл., төм.* чүл, ялан, дала (степь, пустыня, равнина); чаг.: **йапан**. Йабанда үскән йалғыз наратта личит′са итәргә кирәк тигән. – *төм.*

**ЙАБАСТЫ** *брб. д.* тау үзәне, тау итәге (подножье горы, долина).

**ЙАБДАШ** *лмб.*, **ЙАБДӘШ** *кузн.* оста, булдыклы, булган; зирәк, сәләтле (умелый, способный; бойкий); чаг.: **матур 1**. Бик йабдаш сүләргә. – *лмб.* Үзе укырга йабдаш булды ул. Безнең халык – йабдәш халык. – *кузн.*

**ЙАБЗАҚ** *брб.д.* к.: **ашақ**.

**ЙАБУ I 1.** *тмн., лмб., кузн., хвл., карс., шрл., әстр.* салу, пешерү – ипи, бәлеш, пирог һ.б. турында (печь – о хлебе, пирогах и т.п.). Каравайга йапкан икмәк тәмне була. – *тмн.* Тенәген генә йаптым әле әпәй. – *лмб.* Калач йапкан уңган катын. Әпәй йаба идек уникe поттан, ике поттан әләкшә йаба идек. Бәлешләр йаптым, йомшак йаптым. Әпәй йаба торган савыт. – *кузн.* Кас′ы йабып китерә йомшак, кас′ы күмәч китерә. Берче әпәй йаба, мунча йага. Ул вакытта лаукаларда калач йаба иделәр. – *хвл.* Үзем йапкан әпәйне ашбыз. Кунакларны белдем, питрас йаптым. Чәршәмбе кен йапкан әпәй. – *карс.* Ун йыл күмәч йаптым калхузда. Кышын күп була кеше, күмәчен йабарга кирәк. – *шрл.* Апара иттем, әпәй йаптым, бәлешләр йаптым. – *әстр.*; **2.** *кузн.* ясау (делать). Әпкаң әллә акча йабамы?

**аш йабу** *карс.* к.: **йабу I, 1**. Камыр ман маташам, аж йабам.

**ЙАБУ II 1.** *перм.* ашъяулык, тастымал, юрган һ.б.ш. әйберләр (скатерть, одеяло и проч.); чаг.: **йапма 1, 2**; **2.** *чпр., трх.* чыпта (рогожа). Йүкәдән йабу суғалар иде. – *трх.*; **3.** *трх.* ишек тышлыгы (обшивка двери); **4.** *перм.* к.: **йапма I, 5**; **5.** *нокр., глз.* к.: **баш 1**. Азбар йабу. Ике генә қучақлы өйләр ийе, йабулары арыш салам белән йапқан ийе. Тее йәшел йабулы инең байы йаман бай иде. Қалай йабулы ий. – *нокр.* Ағач йабуны черетә. – *глз.*

**ЙАБУ III** *хвл., дөб., к.-уф.* сылтау, аудару – кеше гаебен (сваливать вину). Үзе айыбын миңа йаба выт. – *хвл.* Мин бернәрсә белмим, кеше ғәйебен миңа йапмағыз. – *к.-уф.*

**йала йабу** *тара.* яла ягу (клеветать, оклеветать).

**ЙАБУ IV 1.** *тбл.* к.: **йапкыч**; **2.** *том.д.* түшәү (навес).

**ЙАБУЛАУ** *трх.* тышлау (обшивать). Ишекне дә йабуладым.

**ЙАБЫҒУ 1.** *нокр., глз.* к.: **ирегү I, 1**. Ақ Иделнең буйларында Үсә диләр пар қайын; Ул қайынға басып қара, Миндән йабыққан сайын (*хал. жыр.*). Йабыгам сездин дигән, бик шәп хат йазған. Бу чығып китсә, йабығам инде. Үзең дә киттең, ай қалдырдың, Йабыгып утларында йансын дип. Бу йыруларымны ай ытып қал, Миндин йабыққан чақта йырларсин. Сәғәте ай тик, айы йыл тик. Шулхәдәрле синдин йабықтым (*хал. жыр.*). – *нокр.*; **2.** *брб.д.* йөдәү, туеп бетү; эч пошу (иметь отвращение, скучать); **3.** *брб.д.* ярлылану (беднеть).

**ЙАБЫҒЫЧ** *нокр., глз.* күңелсез, ямансу (скучно, грустно, невесело). Бездә сезгә йабыгыч түгелме? – *нокр.* Йабығычмы тыйыла бездә? Йаман йабыгыч йер ул. – *глз.*

**ЙАБЫЗ** *яүшт.* к.: **бәйсәкә**. Йабыз, Фирүзә абамнан йабыз иде йеснәм. Йабыз ғына булса да, бик эшмәкәр.

**ЙАБЫК** *карс., срг.* ярлы (бедный). Картаймышлы калгач йабыгырак тырасың. – *карс.* Безнең awыл бик йабык иде, бездә җир кысык булган. – *срг.*

**ЙАБЫҚ 1.** *перм.* к.: **йабык**. Бик йабық қалды шул ирендән, йә бақчасы йуқ, йорты лыстыр, маллары йуқ, бик начар қалды, аймақ бала белә; **2.** *брб.д.* мескен (бедняга). Теге йабық килә, ти, әтием, әтием, ти.

**ЙАБЫҚТЫРУ** *брб.д.* **1.** йөдәтү (докучать, быть

назойливым); **2.** ярлыландыру (сделать бедным); **3.** ябыктыру (сделать тощим, заморить).

**ЙАБЫМ** *лмб.* мичтә пешерелгән камыр ашлары (мучные изделия, включая хлебы, испечённые в печи или поставленные в печь).

**ЙАБЫНҒЫЧ** *нокр., глз.* ябынып йоклый торган әйбер (то, чем покрываются во время сна; одеяло, простыня и т.п.). Бәләкәй сал да йабынғыч сал астына. – *глз.*

**ЙАБЫНДЗЫҚ** *брб.д.* бит челтәре (вуаль).

**ЙАБЫНТЫ** *брб.д.* к.: **җеборган.**

**ЙАБЫНЦЫҚ** *тбл.* ябынча (накидка). Йабынцыклар тегәтләр ыспай итеп, цигеп-цигеп ыспай йепләр белән көл төшөреп куйатлар түгәрәкне. Йабынцык йаға сынны булаты, түлке қалын булаты.

**йабынцықлап тегү** *төм.* бөрмәләп тегү (шить с оборками). Йабынцықлап теккәннәр, бөрмәкләпбөрмәкләп.

**йабынцықлы көйләк** *төм.* бала итәкле күлмәк (платье с воланом, оборками). Йабынцықлы көйләкләр тегеп бирәләр, қуштаннар қуйып.

**ЙАБЫРЛЫГУ** *тмн.* ябырылу (налетать, идти, двигаться целой ватагой). Марта кортлары йабырлыга сиңа.

**ЙАБЫС** *том.д.* к.: **ашақ.**

**ЙАБЫШ** *срг.* каты – йокы турында (крепко – о сне). Бик йакшы йабыш йыклыйсыз.

**ЙАБЫШҚАҚ I** *мам.* **1.** к.: **җабышқақ.** Урманда йабышқақ тешләгән ийе йаңағымны, әл дә қызарып тора; **2.** к.: **йәшенцәк.** Көнә буйы судан чыкмый да, башы тулы йабышқағ инде.

**ЙАБЫШҚАҚ II** *дөб.* эт тигәнәге (череда трёхраздельная).

**ЙАБЫШҚАН** *тара.* к.: **қамыраш II.** Йабышқан веналарны киңәйтә dawлинйәдән. Йабышқан тигәнәкле була.

**ЙАБЫШТЫРУ** *хвл.* йоктыру – авыруны (заразиться болезнью). Қайан йабыштырдың тагы бу авыруны?

**ЙАБЫШУ 1.** *срг., тмн., лмб., хвл.* йогу – авыру турында (пристать – о заразной болезни). Грипп йабышкан үзенә. – *хвл.* Йок, йабыша ул wитрәнка. – *срг.*

**ЙАБЫШУ II** *мам., нокр., глз., т.кам.-крш., чст.* башлау, тотыну, керешү; башлану (начинать; начинаться). Кич белән йабыша уйыннар. – *мам.* Йуwышма йабышқан, сuwы аз ғына. Аш қуйа йабышырмын, сәгәт унда. Кожил дигән awылдан йабышып батқақлық. – *глз.* Чебиләр чыкма йабышқаннар, биш данә чыққан инде. Суқалама йабышқан инде (бакчаны). Кич биштә йабышабыз эшкә. Йаңгыр йаума йабышты. Гөлләрем чәчәк атма йабышқаннар. – *нокр.* Хәdер генә йабыштылар әле утарга. Қойо қазырға йабышқаннар ийе. – *т.кам.-крш.* Сез бигрәк иртә йабышқаннар әле йокларга. – *чст.*

**ут йабышу** *глз.* ут кабу (загореться, быть охваченным огнём). Машиналарга ут йабышты.

**ЙАWА** *төм.* к.: **йапма II.**

**ЙАВАШ-ЙАВАШ** *лш.* әкрен генә, сиздермичә генә (незаметно, тихонечко, тихонько). Йаваш-йаваш қына йазарға кирәк аны.

**ЙАWРАХ** *саз.я.* к.: **йапрақ.** Қышхыға егерме биш-утыз йawрах йасайwс.

**ЙАWРЫН 1.** *перм., эчк., к.-уф., злт., тмн., тбл.* иңбаш, қулбашы (плечо). Йawрынымнан йарата. – *эчк.* Йawрыныңда үлән китерә идең бер капчык. – *тмн.*; **2.** *карс., брб.д.* җилкә (затылок, спина, плечо). Awырттымы йawрының? – *карс.*; **3.** *брб.д., тбл., тара.* калак сөяге (лопатка).

**ЙАWРЫНБАШ** *к.-уф., тбл.* к.: **йawрын 1.**

**ЙАWРЫНҚАЛАҚ** *тбл., том.д.* к.: **йawрын 3.**

**ЙАWЫЗ I** *брб.д.* к.: **бәйсәкә.** Малайым йawыз, мине қырау суққан, үсә алмадым, тите.

**йawыс санау** *брб.д.* түбәнчелекле тоту (быть снисходительным). Үсеңне йawыс санарға кәрәк.

**ЙАWЫЗ II** *брб.д.* к.: **астыр.** Йewештереб алырлық пар бецән йawыз йерләрдә.

**ЙАWЫҚ** *брб.д., твр.* **1.** якын (близкий, близко). Ышкулға йawық тип көчкән; **2.** туган (родственник). Инәйгә йawық, өлнәсе (энисенең апасы) қуй. Мине йawығым ол, қәртинәләребез пертуған, уғымышлу. – *брб.д.*

**ЙАWЫН 1.** *перм., злт.* яңгыр (дождь); **2.** *брб.д.* явымлы көн (ненастье, дождливая погода).

**айас йawын** *төм.* кыска вакытлы яңгыр (кратковременный дождь). Айас йawын ас йawаты.

**ЙАWЫР** [*гар.*] *глз.* к.: **йәwер 1.** Безне нуқрат йawыр диләр.

**ЙАВЫРНА, ЙАВЫРНЫ 1.** *тмн., мәл., эчк.* к.: **йawрын 1.** Йавырныма менеп басты да киштәдән китап алды. – *мәл.*; **2.** *кузн.* к.: **йawрын 3.** Алла, йawырныларым, әмән кеше утырган; **3.** *тмн.* иңбашы – киемнең (плечо – одежды). Йавырналары бик төшкән куфтасының.

**йавырна башы** *лмб., чст., чпр.* к.: **йawрын 1.** Йавырна башында тырнак эзләре калган иде. – *чпр.* Лапаткаларым awырта, йawырна башларым сызлый. – *чст.*

**ЙАWЫС** *брб.д.* к.: **ашақ.** Йawыс қой у, тәрәсәләр кечү. Өйләң (үлән) йawыс, сайақ (сирәк), көп чабасың, өйләңе аз.

**ЙАWЫСБЫ** *төм.* изгеләр кабере (могила святых). Йawысбы астаналы, йахшылар йатқан йер, хәсер цитән қуйганнар.

**түшәк йапма** *байк.* к.: **йапма I, 1.**

**ЙАПМА II** *минз., перм., злт., стрл.* түбәле ындыр яки ындыр табагы (крытый ток или гумно). Йапма буладыр ийе бик зур, малатилка белән ашлық суға торган ийек. – *перм.* Йапма ашлық өйә торған урын, башы йабыла, шунда қыш буйы әwен суғаң. – *злт.* Байыракларның йапмасы була. – *стрл.*

**ЙАПМА III 1.** *твр.* к.: **йапқыц II.** Йапма салып көйләкләрне тегеп қуйа тыған итек. Ул йапманы итәккә салалар, түгәрәккә; **2.** *твр.* инеч (подкладка); **3.** *төм., твр., тара.* изү капламасы (планка на разрезе рубахи). Қыйыш йага ирләрнеңке, қыйыш йапмасы була, аңа сәтәб утысалар. – *тара.*

**ЙАПМА IV** *себ.* к.: **йамаучық.**

**ЙАПМАЛЫ** *төм.* к.: **йақма.** Көмөш ақца алтын йапмалы.

**ЙАПМАЛЫҚ** *тбл.* к.: **йамаучық.** Иң төбөн уйыб алайын, йапмалық та пецеб йейәйен.

**ЙАПМАЧ** *твр.* **1.** к.: **йапқыц II; 2.** к.: **йапма III, 3.**

**ЙАПМЫШ** *кузн.* к.: **йақмыш 1.** Йегерме биш йапмыш ашаган да, жалуткасы авырткан.

**йапмыш(лар) йабу** *кузн.* таба ашлары пешерү – пәрәмәч, бәлеш h.б.ш. турында (печь пироги и проч. мучные блюда). Шаны ашарга чыгардыңмы, йапмыш йапмадыңмыни? – ди.

**ЙАПРАҚ** *перм., төм., тбл., тара.*, **ЙАПРАК** *байк.* каен себеркесе, мунча себеркесе (веник, берёзовый веник). Йапрак бәйләргә минцаласы йуг әле, кайын йапрагын бәйләп төшәм димен. – *байк.* Йапрақ пелән цабыну гәрәк. – *тара.*

**йапрак йебәрү** *хвл.* яфрак яру (распускать листья).

**ЙАПСАҚ: йапсақ оцлау** *тбл.* к.: **зийандаш: зийандаш қағылу.** Йапсақ оцлаған, аннан үлеп киткән.

**ЙАПСУҚ** *брб.д.* тансык аш (пища, которую редко едят).

**ЙАПТАҚ 1.** *тара., брб.д.* чана үрәчәләре (разводы саней); **2.** *брб.д.* к.: **йәйтақ I, 2.**

**ЙАПТЫНКЫ** *чст.* к.: **астыр.**

**ЙАПТЫРУ** *кузн.* салдыру, пешертү – таба ашлары турында (заставлять ставить тесто, печь хлебы, пироги и т.п.); чаг.: **йабу I, 1.** Ипийен дә кешедән йаптыра иде, камыр ашларын да.

**ЙАПШАР** *т.я.-крш.* ягымлы, яхшы (ласковый, приятный). Йапшар сүз бөтен нәстәдән йахшы.

**ЙАПЫРТМА** *перм.* к.: **йапма III, 3.**

**ЙАПЫРУ** *әстр.* комсызланып ашау (есть с жадностью, пожирать).

**ЙАР I 1.** *кузн., хвл., мәл., чст.* чокыр (овраг). Ул йакларда йарлар күп, йөрүwе awыр булыр. Йаман сыйыр йарда бозаулый (*әйтем*). – *хвл.* Кәжәләре йарга төшкән. – *мәл.*; **2.** *тбл.* текә яр (крутой берег, крутизна).

**йар йафрағы** *бөре., тпк.*, **йар йафрақ** *перм.*, **йар йафрак** *байк.* үги ана яфрагы (мать-и-мачеха). Йар йафрағы бәйләп қара син. Әле дә йар йафрақлары үсеп сыға ашлық арасынта, дым бар. – *тпк.*

**йар қошқацағы** *том.д.* яр карлыгачы (стриж).

**ЙАР II** *лш.* яры (плёнка). Йар басқан ыйы минем күземне.

**ЙАР III: йар итү** *төм.* атын чыгару, таныту, тарату (ознакомить, признавать, показать). Пөтөн татарға йар итәсез. Пөтөн илгә йар итеп йасып йөрисес.

**ЙАРА I** *тбл., твр.* урталай, икегә бүлеп (пополам). Йара алайық та йара бүләйек. Йара йыртып ташлаты. – *тбл.* Пер кисәгебес пулса, йараға бүлеп ашыйбыс. – *твр.*

**моннан йара** *тара.* моннан алып (отсюда, отсель). Цейәгә барсаң, моннан йара суланып қайтасың.

**питән йара** *твр.* билдән генә, бил уртасыннан гына (от пояса, с середины пояса). Алйапқычы питән йара.

**йара II** *себ.* яра (рана):
**йара йапрақ** *төм.*, **йара йафрағы** *мам.*, **йара үләне** *перм.*, *кргл.*, *бгрс.* бака яфрагы (подорожник).

**ЙАРААЦЫЛМА** *сазя.*, *төм.*, *тбл.* капкачлы тәрәзә (оконные ставни).

**ЙАРАК** *кузн.* корал (орудие).

**ЙАРАҚЛАУ** *төм.* әзерләү (готовить, приготовить). Сал (зал) йарақладылар, киленепеснеңке қырық йәш.

**ЙАРАҚСЫЗ** *бәр.* көчле, каты (очень сильный); чаг.: **йаман**. Йарақсыз җил иде төнәген.

**ЙАРАМСАҚ** *тара.* куштан, ялагай (подхалим, льстец).

**ЙАРАН I** *твр.* к.: **ирән**.

**ЙАРАН II** *төм.* к.: **ишегалды**.

**ЙАРАТУ** *кмшл.* туры китерү (подобрать что-либо к чему-либо). Тәрәзә йаратып булмый әле, Бәдретдин абзыйларныңы да йарамады.

**ЙАРАТМАҚСАН: йаратмақсан булу** *тара.*, *брб.д.* яратмаган булу (притвориться, что не любишь).

**ЙАРАУ** *трх.*, *мәл.* салкынча (прохладный). Әле йарый беген көне йараурақ. Мындый йарау кенне кеше кебек алар да керми торғандыр. – *трх.* Күләгә йирдә дә йарау түгел, көн кызу булгач. – *мәл.*

**ЙАРАУЛАНУ I** *трх.*, *мәл.* салкынча булып китү, һаваның эсселеге кимү (стать прохладным).

**ЙАРАУЛАНУ II** *шрл.* дәртләнү, күңел күтәрелү (повыситься – о настроении, подбодриться). Таки теге йарауланып киттеме?

**ЙАРАУЛАТУ** *трх.* салкынча булып китү, һаваның эсселеге кимү (становиться прохладно). Көн йараулатып җибәрде.

**ЙАРАУЛЫ** *трх.* эшләргә яраклы, ярый торган, сәламәт (трудоспособный, здоровый, работоспособный). Камиссийадан чықты, йараулы, эшли.

**ЙАРАУСЫС** *тара.* ярамаслык (невозможный). Пылтыр йараусыс цебен ите, ул балам қалын кейемнәр кейеп йөрөте.

**ЙАРАЦЫЛМА 1.** *тбл.*, *том.д.* икегә, ике якка ачыла торган (открывающийся на две стороны). Кеймеңке алты йарацылма пулса, йәктә тиләр. Тирәсәсе йарацылма. – *тбл.*; **2.** *тбл.* к.: **ачылма**.

**ЙАРАШТЫРУ** *хвл.*, *мәл.* к.: **йарату**. Йозакка аскыч йараштырып ачкан. – *хвл.*

**ЙАРАШУ I** *лш.*, *тмн.*, *төм.* ярәшү (просватать, сговариваться). Йарашылган кызга подругалары киләләр. – *лмб.* Туй башлана йарашудан. – *тмн.* Қысның йарашуы булған. Қыс йаққа бара йарашу, йегет алып пара, қысны сатыб алу була. Йарашуны билгеләйләр. – *төм.*

**ЙАРАШУ II** *себ.* **1.** им булу, дару булу (быть целебным); **2.** татулашу, килешү (помириться, прийти к согласию). Инте йарашуны әцкәннәр. – *төм.*

**ЙАРАШЫҚ** *тбл.* яраклы, яраулы (пригодный, пристойный); чаг.: **йараулы**.

**ЙАРАШЫҚСЫС** *тбл.* яраусыз (непристойный, чрезмерный).

**ЙАРБОКА** *чст.* күп сөйләүче, юк-барны сөйләүче (болтун, болтливый человек).

**ЙАРҒА** [*рус.*] *тбл.* пүлән (полено).

**ЙАРҒАҚ I** *төм.*, *тара.*, *сазя.* к.: **бийәли: тыш бийәләй**. Йаргақның эценнән мийәләй кийәтеләр. – *төм.* Йарғақ пийәләй өстеннән, тирдән теккәннәр, цөбрәктән дә. – *тара.*

**ЙАРҒАҚ II** *тбл.* сертотмас (болтливый, не держащий тайны). Йарғақ, аны йарлап та йебәрә қуйыпты.

**ЙАРГАК** *стрл.* какча, чандыр (сухощавый, худощавый); чаг.: **йазау**. Минем шикелле йаргак кына, йабык кына бер хатын.

**ЙАРҒАЛАС** *нокр.* к.: **дуwадақ 1**. Йарғалас қаз йерәй.

**ЙАРҒАНАҚ** *төм.* чокыр, ерым, ерынты (овраг).

**ЙАРҒУ** *брб.д.* карар, хөкем (решение, судебный приговор).

**ЙАРҒУЗАҚ** *брб.д.* дәгъвалашып йөрергә яратучы кеше (сутяга).

**ЙАРҒУЛАУ** *брб.д.* хөкем итү, хөкем чыгару (судить, выносить решение).

**ЙАРҒЫНЛАУ** *брб.д.*, **ЙАРҒЫРАУ** *тбл.*, *тара.*, *брб.д.* ялтырау, җемелдәү, ялкылдау (блестеть, сверкать). Йарғырап тормасын күгерттә тип көс көнө йаwып қойгамын. – *тара.*

**ЙАРҒЫЧ** *т.кам.-крш.* к.: **қолташ**. Қул белән йару инде, ручной тегермән йаргыч диләр, әйләндереп торалар қул белән.

**ЙАРГЫЧ** *тмн.* к.: **айбағар**.

**ЙАРҒЫЧЛАУ** *кмшл.* яру (обдирать семена). Қул тегермәне белән быдайны йарғычлыйсың.

**ЙАРДАМЦЫЛАУ** *тбл.* ярдәм итү (помогать).

**ЙАРИЛӘ** *кузн.* язгы бәйрәм (весенний праздник). Азбар сайын аш пешә йариләдә.

**ЙАРЙАРЛЫЙҚ** *твр.* к.: **бабалаш**.

**ЙАРКА I** [*рус.* ярка] **1.** *тмн.*, *мәл.*, *стрл.*, *шрл.* к.: **бикәч II**. Куйымнын ике чагасы бар, берсе кучкар, берсе йарка. – *тмн.* Сарык икене чагалаган: берсе йарка, берсе тәкә. – *шрл.*; **2.** *лмб.*, *кузн.*, *хвл.*, *мәл.*, *чст.*, *срг.*, *шрл.*, *минз.* гадәттә бәрәнләмәгән бер яшьлек сарык яки кәҗә (годовалая овца или коза, обычно неягнившаяся). Безнеке дә ике йарка чагаламады выт. – *кузн.* Чага йылның икенче йылына йарка була. – *хвл.* Кечкенә чакта бәрән дибез, шуны кышлыкка калдырсаң, ул инде йарка була да, кәҗә йаркасы, сарык йаркасы дибез. – *чст.* Гумер булса, бер-ике йарка алсак. – *шрл.*

**ЙАРКА II** *чпр.*, **ЙАРҚА** *трх.*, *дөб.*, *перм.* ярган агач, ярган утын агачы (расколотое полено). Туйыра йарқаларыннан нәүрәп йасыйм, ди. – *трх.* Йарқасы озон була, бусы тумыран. – *дөб.*

**ЙАР'А** *кас.* ярлыка, кичер (прости).

**ЙАРҚАНАТ** *мәл.* к.: **дөмә: дөмә қараңғы**.

**ЙАРҚЫН** *брб.д.* ялтырау, җемелдәү, яктылык, нур (блеск, свет, луч).

**ЙАРҚЫРАУ** *брб.д.* балку, балкып китү (сверкать, блестеть). Йалтырап чыққан қойаш кебек йарқырар микән Том буйы.

**ЙАРЛАWЫҚ** *минз.*, **ЙАРЛАWЫК** *стрл.* яр буе, чокырлы җир (побережье, овражистая мест-

ность); чаг.: **йар**. Бака йафрагы киңчел йафраклы, йарлаwыкта була. – *стрл.*

**ЙАРЛАУ I** *тара.* **1.** су астындагы чокырлар, тирән җир (подводные ямы, глубокое место). Анта йарлау, су цуммаң; **2.** к.: **вәке.**

**ЙАРЛАУ II** *тбл.* серне сөйләп ташлау (разболтать тайну).

**ЙАРЛЫ** *тбл.* мескен – парлы сүзләрдә кулланыла (несчастный, бедняга – употребляется в парных словах). Әткәң йарлы шигелле кәп пелмәйсен.

**ЙАРЛЫҒУ** *бөре.* ярлылану (беднеть, нищать, обнищать). Болар бик йарлыққаннар җир аз булгач.

**ЙАРЛЫК 1.** *срг.* белдерү кәгазе (извещение). Акца йарлыгы килде; **2.** *чст.* квитанция. Тирмән тарту өчен йарлык алырга барам.

**ЙАРМА I** *тбл.* ярма, арпа ярмасы (крупа, ячменная крупа).

**ағач йармасы** *т.я.* пычкы чүбе (опилки).

**сары йарма** *кузн., хвл.* тары ярмасы (пшено). Сары йарма буткасы. – *кузн.* Сары йармадан да салалар. – *хвл.*

**такта йармасы** *чст.* к.: **ағач йармасы.** Түбә такталары эстенә башта кез кене кипкән йафрак, аның эстенә такта йармасы салалар.

**чичкә йарма** *перм.* вак арпа ярмасы (мелкая ячменная крупа).

**эре йарма** *перм.* эре арпа ярмасы (крупная ячменная крупа).

**ЙАРМА II: йарма картуф** *хвл.* уртага ярып пешерелгән бәрәңге (картофель, сваренный в разрезанном пополам виде).

**ЙАРМАБАШ** *тара.* к.: **айуқузғалақ.**

**ЙАРМАҚ** *твр.* кисәк, бармак – чүпрә турында (кусок – о дрожжах). Тороша алам пер йармақ.

**ЙАРМАШ** *тбл.* ярма ашы (суп с крупой).

**ЙАРМУНКА** [*рус.*] *хвл.* ярминкә (ярмарка).

**ЙАРПАЙУ** *хвл., кузн., мәл., срг., шрл.* к.: **йалпайу I, 1, 2.** Алар йарпайды, без картайдык. – *срг.* Шуннан бирле йарпайа алмимен. – *шрл.* Йаңгыр йава, йер дымайа, Йәш үләннәр йарпайа (*хал. җыр.*). – *кузн.* Йахшы төштә кеше йарпайа, който төштә картайа (*мәкаль*). – *хвл.*

**ЙАРПАЙЫП** *мәл.* рәхәтләнеп, яратып, җәелеп (с удовольствием). Перине атлар йарпайып ашилар.

**ЙАРПАЛАНУ** *кузн.* ярылу, яргалану (потрескаться). Ирнеләрем йарпаланган.

**ЙАРПАЧ 1.** *минз., стрл.* к.: **борнай.** Йарпачырақ алар үзләре дә, үзен генә өстен қуйа. – *минз.* Кылтайып сүләгән кеше йарпач инде. – *стрл.*; **2.** *минз.* мактанчык (хвастун). Әй йарпач та инде.

**ЙАРСЫТУ** *нокр., чпр.* к.: **ирәгештерү.** Итне йарсытмасаң, тими ул. Йарсытып қына әйтәм. – *нокр.*

**ЙАРТАН** *сазл.* к.: **вәке.** Йартан цәнцү. Йартан тишү.

**ЙАРТЫ I** *мам.* к.: **җарты.**

**йарты II** ярты (половина):

**йарты йақ** *минз.*, **йарты йак** *стрл.* читтә (на стороне). Икмәгең йарты йақ булганға әйтәмен. – *минз.*

**йарты сөйләшү** *тара.* сакау, авыр сөйләшү (картавить, шепелявить, запинаться). Инәсе тә йартырақ сөйләшә, атасы та йартырақ сөйләшә.

**ЙАРТЫҚ** *брб.д.* ватык, ярык (разбитый, треснутый). Йартық қасан.

**ЙАРТЫЛЫШУ** *минз., стрл.* яртыга җитү (дойти до половины). Бу wахытта бодай да йартылыша торған ийе. – *минз.* Йартылышкач, йартысы беткән дигән хисапка тора. – *стрл.*

**ЙАРТЫШЛАЙ** *трх.* яртышар, ярты (наполовину, пополам; половина). Йартышлай булған элгәре безнең awыл: йартышлай татар, йартышлай урыс.

**ЙАРУ I** *лш., кузн., хвл., чст., мәл.* **1.** сука белән бәрәңге төбенә әю (окучивать картофель с помощью сохи). Сука менән йарып узар картукны. – *кузн.* Актыкта сука белән йарасын. – *хвл.* Сафхуз бәрәңгесен тырактыр белән йардык. – *чст.* Бәрәңге йарырға wақыт җитте. – *лш.*; **2.** *лш., мәл.* к.: **қайырту; 3.** *хвл.* ашау – *мәс.*, көнбагыш орлыгын (грызть семечки). Орлок йарма, идәнне чүплисең.

**пычқы йару** *мам., минз.* бүрәнәне буйга яру (распилить вдоль). Элек қул белә йару бар ийе бит, пычқы йардық хөкөмәткә. – *минз.* Әле пычқы йаралар, бушамыйлар, тақта кирәк. – *мам.*

**ЙАРУ II** *мәл.* күп сөйләү (говорить много; любить поговорить).

**ЙАРУ III** *тбл.* яктыру (светить). Қойаш йарыйт.

**тирес йарыйт** *тбл.* төньяк балкышы (полярное сияние).

**ЙАРУ IV** *тара.* вату (разбить). Тирәсемне йарып китмәсеннәр.

**йомырқа йару** *тара., брб.д.* йомырка сыту, вату (давить, раздавить). Йомырқа йарғаннар сөткә.

**ЙАРУҚАНАТ** *брб.д.* ярканат (летучая мышь).

**ЙАРЦА** *тбл.* ярка (плаха, толстое бревно).

**ЙАРЦЫ** *брб.д.* **1.** к.: **йарка II; 2.** к.: **йунгы; 3.** такта (доска).

**ЙАРЫ I** *перм.* брезенттан тегелгән бияләй (брезентовые рукавицы); чаг.: **бийәли: тыш бийәли.**

**ЙАР(Ы) II** *минз., трх., кмшл., чст., м.-кар.* җир, урын, як (место). Нишләп икебез икә йары йатыйқ? – *минз.* Безнең awыл мында терле йардан җыйылган. Мин белгәндә икә йары мәктәп дип йертелә торған икә и бар ийе. – *кмшл.* Биш йары күчем бар. – *трх.* Мында терле йардан килгән халыклар булган. – *чст.* Йортыбыз ишелде дә үзгәне алдык иде без, икенче йары. – *м.-кар.*

**бер йары** *чст., м.-кар., минз., кргл., бгрс., кмшл.* беркая (никуда). Бер йары да китмим. – *чст.* Бер йары килми безнең тел, чурт кайан алынган. – *м.-кар.* Бер йары баралмыйм. – *кргл.* Барма, бер йары барма. – *бгрс.*

**берәр йары** *чст., кргл., бгрс.* кая да булса, берәр җиргә (куда-нибудь). Берәр йары барасызмы әллә? – *чст.* Урнаштығызмы берәр йары? – *кргл.*

**кич йары** *перм.* кичкә таба (к вечеру). Кич йары барым әле, кич йары. Кич йары чыққаннар алар, адашқаннар.

**ЙАРЫ III: йары май** *минз., стрл.* **1.** эретмәгән май (сало животное до топления); **2.** кайнаган сөтнең өстендәге каймагы (плёнка, образованная на молоке после кипячения).

**ЙАРЫҒАЙУ** *саз.я.* яктыру (светать, рассветать). Мин уйанғанта көн йарығайған ит.

**ЙАРЫҚ 1.** *тбл.* якты, яктылык (светлый; свет; светло). Киц сигездә дә йарық пула ғуй; **2.** *төм., тбл.* ут (свет). Ыстансалар қап-қараңғы, йарықлары йуқ. – *төм.* Йарық пелән палларныңқы ыштан тобоғон йамаб утырганнар. – *тбл.*

**ЙАРЫҚ-ЙАРЫҚ: йарық-йарық итү** *тара.* ялтйолт итү, яшен яшьнәү (сверкать – о молнии). Йарық-йарық итеп қалады, йамқыры та болмайды.

**ЙАРЫҚЛЫҚ** *тбл.* яктылык (свет).

**ЙАРЫҚЛЫҒЫМ** *төм.* күз нурым – иркәләү сүзе (светик мой – ласкательное слово). Йарықлығым, порцақ пирце миңа.

**ЙАРЫМ 1.** *себ.* ярты (половина). Урысныңқы қәрепнең аңқаралмайым йарымын; **2.** *төм., твр.* кайбер (некоторые).

**йарым ай** *төм.* ярты ай (пол месяца). Йарым ай йаттым.

**йарым кеше** *төм., твр.* кайберәүләр, кайбер кеше (некоторые). Йарым кеше қартнәй ти, йарым кеше анауқай ти. Йарым кеше пуш пәйләте наскины. – *төм.* Йарым кешенең қәйнәсе була. – *твр.*

**ЙАРЫМАР** *себ.* яртышар (пополам).

**ЙАРЫМБИШ** *срг., т.я.* элекке вакытта җир үлчәү берәмлеге: дисәтинәнең өчтән бер өлеше (старинная единица измерения земли, равная трети десятины). Йарымбиш кецкенәсен түтәрәм дип йөртәләр (җирнең). – *срг.* Ике түтәрәм җир бер йарымбиш була. – *т.я.*

**ЙАРЫМТЫҚ** *перм.* шүрәле (шурале, леший, лесной дух).

**ЙАРЫМЦЫБЫК** *срг.* элеккеге җир үлчәү берәмлеге: бер дисәтинәнең дүрттән бер өлешенә тигез (старинная единица измерения земли, равная четверти десятины).

**ЙАРЫНДЫ** *брб.д.* ярык (щель).

**ЙАРЫСҚЫ** *брб.д.* к.: **йаруқанат.**

**ЙАРЫТҚУЦ** *брб.д.* яктырткыч – балык тотканда; нур, факел (освещение – при ловле рыбы; луч, факел).

**ЙАРЫТМАЛАУ** *тбл.* яктыртып, нур белән балык тоту (лучом ловить рыбу).

**ЙАРЫТУ** *тара.* яктырту (освещать).

**ЙАРЫХ** *саз.я.* к.: **йарық.** Өйгә йарых төшмәйт. Йарых төшәр-төшмәс тороф х'итү.

**ЙАРЫШ** *перм.* к.: **йадау.** Йарыш қына, чандыр буйлы.

**ЙАС I** *блт.* к.: **гелбәч.** Йасларына бәрәңгеләр салғаннар.

**ЙАС II** *тбл.* матәм (траур). **Йас цағы игән.**

**ЙАСА** *тбл.* көч-хәл белән (кое-как). **Йаса тейде.**

**ЙАСА-ПОСА** *төм.* к.: **цала-бала.**

**ЙАСАУ I 1.** *нокр.* эшләү (работать, делать). Ни йасайсың инде? Ни йасап озақ тордың клупта? Ни йасап йаталар, тенә үк қайтасы ич дий (болыннан); **2.** *перм., хвл.* төзү (строить). Мин, бабайым киткәч, бала-чага белән генә йасадым ызбаны. – *хвл.* Башқа чықты, өй йасап бирдек без. – *перм.*

**ЙАСАУ II** *твр.* ... дип уйлау (принять за когонибудь). Мин сине Көлчәчәк йасатым, песнең пер қысыпыс пар тората эшләйте, мин ул тип йатармын.

**ЙАСАУЛАҒАН** *перм.* корылган – мылтык турында (заряженный – о ружье). Тимә, тимә, қорылған, дисәләр дә, тигән дә атқан да йебәргән, йасаулаған икәнен аңламый.

**ЙАСҚАНЫП** *минз.* җиң сызганып, ашкынып, гайрәтләнеп (с большой охотой, готовностью). Мин эшкә чығарға бик йасқанып йатам.

**ЙАСҚУ** *минз.*, **ЙАСКУ** *стрл.* ачыктан-ачык янау (грозить, угрожать). Халык бик усаллана башлады, моно йаскыйлар күб ыстатйа куйдың дип, шуннан ары чыкты. – *стрл.*

**йасқып йөрү** *минз.*, **йаскып йөрү** *стрл.* үч тоту, үчегү (таить злобу, таить зло). Йасқып йөри мийә. – *минз.* Ана ул кешегә йаскыган да, иренә төшкән. – *стрл.*

**ЙАСҚЫЛЫҚ, ЙАСҚЫСЫН** *себ.*, **ЙАСҚЫТА** *тара., том. д., брб. д.* к.: **йазғылықта.** Йасқылық палыкны пос өстөтән ошлатылар.

**ЙАСҚЫШУ 1.** *злт.* бәхәсләшү (спорить). Гел йасқыша, сабантуйға алып қайтасы килә. Йасқыша, икенсе рост кийәм, ди; **2.** әрләшү (ссориться, ругаться). Үзе әйтергә тийеш, йасқышып түгел. Йасқышып бақсасын сорыйлар. Бөгән үк алып кит дип йасқышты, алып китми булмый инде.

**ЙАСЛАWЫК** *шрл.* елак (плакса, нытик).

**ЙАСЛАП** *мәл.* сулкылдап (всхлипывая). Йаслап йылый выт, чугынган.

**ЙАСЛАТУ** *лмб.* элек: җырлатып елатудан гыйбарәт булган кыз елату йоласы (в старину: один из старинных свадебных обрядов – плач невесты, состоявший в том, что невеста перед тем, как совершится обряд бракосочетания, пела песни о своей несчастной доле и плакала; иногда вместе с ней пели и подруги или же приглашались специальные плакальщицы). Кызны никаһ укыганчы йаслаталар (иде). Бездә кыз йаслаталар иде, минем үземне дә йаслатып бирделәр. Сүми барган кешене йаслатканда хийәмәт була инде.

**ЙАСЛАУ 1.** *брб.д.* язны үткәрү (провести весну); **2.** *тбл.* кайгылы вакыт үткәрү (быть в трауре).

**ЙАСМА: йасма таш** *тпк.* яссы таш (плоский камень).

**ЙАСМАҚ** *дөб.*, **ЙАСМИК** *карс.* ясмык (чечевица).

**й а с м ы к** ясмак (чечевица):

**йасмық печән, йасмық үләне 1.** *лш.* к.: **печин: ақча печин 1; 2.** *мам.* к.: **үлән: борма үлән.**

**ЙАСПАШ** *тбл.* яз башы (начало весны, ранняя весна). Йаспаш пиргәннәр пулсийте миңә унике тегем ау.

**ЙАССУ: қул йассуwы** *каз.ар.* уч төбе киңлегенә тигез үлчәү берәмлеге (старинная единица измерения, равная ширине ладони). Бер қул йассуwы киңлегендә булса, җитә. – *мам.*

**ЙАССЫ 1.** *нокр., глз., блт.* киң, иңле (широкий). Куйкасы да йаман йассы миңа, бер кешелек кенә куйка кирәк. Зур ич ансы, әйбәт, йассы (өстәл). – *глз.* Йассы матур йәтмә бәйлисең. – *блт.*; **2.** *глз.* юан (толстый, полный). Андай йассы хатын!

**ЙАССЫЛЫҚ** *нокр., глз.* иң, киңлек (ширина). Бу читчаның йассылығы шәп икән. – *нокр.* Бармак йассылыгы ит тә тек күлмәкне. – *глз.*

**ЙАСТАНЛАУ** *трбс.* ялагайлану (лебезить перед кем-либо). Өй беренә кереп йастанлап йөри.

**ЙАСТАНУ** *брб.д.* баш астына салу – мендәр урынына (положить под голову – вместо подушки). Алтын ийәр йастанды.

**ЙАСТАУ I** *трбс.* яхшы карашта, мөнәсәбәттә булу (быть в хорошем отношении).

**ЙАСТАУ II** *брб.д.* к.: **йастану**. Ийәрен йастады.

**ЙАСТАУЛЫ: йастаулы қыз** *трбс.* ягымлы (любезный, приветливый).

**ЙАСТУ: қул йастуwы** *каз.ар.-крш.* к.: **йассу: қул йассуы**. Бу төшләрдә қул йастуwы уқа булған сүрәкәнең. – *каз.ар.-крш.*

**ЙАСТУП** [*рус.* заступ] *трх.* к.: **қырғыч 1**. Йаступ белән җир бастық.

**ЙАСТЫ** *блт.* к.: **гелбәч**. Йастында бәрәңге үреб бетә.

**ЙАСТЫҒАЦ** *тбл.* колак мендәре, кечкенә мендәр (маленькая подушка, подушечка).

**ЙАСТЫҚ I** *эчк., себ.*, **ЙАСТЫК** *миш.д.* мендәр (подушка). Минең йастыклар бишәр килу мамыктан йасалган. – *срг.* Бездә вит йастык-түшәкне дә йегет алып килә. – *тмн.* Йастыкларым күп минем. – *хвл.*

**йастық қыбы** *брб.д.*, **йастық тыш** *себ.*, **йастых тыш** *саз.я.* мендәр тышы (наволочка). Йастық тышларын да йуу гәрәк. – *төм.*

**йастыққа бастыру** *төм.* мендәргә бастыру (при переезде невесты в дом жениха она спускается с повозки на подушку). Йастыққа бастыратлар, өстәнә бawырсақлар қойатлар, питай қойатлар.

**йастықтан үтү** *брб.д.* килен төшкәндә мендәргә басу, мендәрдән төшкәч, аягын юарга һәм ул суны баскыч астына түгәргә, ягъни шулай итеп ул егет йортына чистарынып аяк басарга тиеш була (после того, как невеста спускается с повозки на подушку, она должна мыть ноги, а воду вылить под крыльцо, только затем должна войти в дом жениха). Йастыктан үткәч, айақларын йыwып пасқарақ астына сыwын түгәләр, қәсер алар да пәттә.

**нәнә йастық** *төм.* к.: **йастыгац**. Нәнә йастық әсерләп қуйғайным.

**осон йастық** *тара.* ике кешелек мендәр (удлинённая подушка на два человека).

**пала йастық** к.: **йастығац**.

**паш йастық, пуйын йастық** *тбл., тара.* к.: **йастық I**.

**пүксә йастық** *тара.* бер кешелек мендәр (подушка на одного человека).

**ЙАСТЫҚ II** *перм.* к.: **арба: арба мендәре**.

**ЙАСТЫКЛАШ** *байк.* аркылы; берсе буй белән, икенчесе аркылы тору (поперечная грань чего-либо; торец). Бер зимнәнкегә йастыклаш йәшәдек.

**ЙАСТЫКЛЫК** *м.-кар.* к.: **арба: арба мендәре**.

**ЙАСТЫҚХАНӘ** *нокр.* сәке; урын җыя торган җир, ятак (нары; место где стелят постель, где спят).

**ЙАСТЫН** *тара.* к.: **қазантөп**. Йастын пулған оло кешеләрнең ыштаны.

**ЙАСТЫРАУ** *твр.* төбәү (целиться, прицеливаться, прицелиться). Қапқа тирәсентә қалық мылтық йастырадылар йуғары қарап.

**ЙАСУ** *тара.* баш төзәту (опохмелиться). Ақцалып пашын йасты.

**ЙАСЫҚ** *тара.* к.: **қона**.

**ЙАТ** [*фарс.*] *тбл.* хәтер, хатирә (память, воспоминание).

**йатқа килу** *нокр.* к.: **ислими'и**. Тағы нинди жырулар бар әле, ич тә йатқа килмәй ич!

**ЙАТАҒ: йатағ ай** *твр.* яңа туган айның иң сөзәк торышы (наиболее наклонное положение луны в период новолуния). Қайсы wақыт йатақта булаты ай.

**ЙАТАҒАН** *тара.* өйдән чыкмый ятучы (домосед, лежебока). Йатаған цыкса, йау булыр (*мәкаль*).

**ЙАТАҚ I** *кргл.* киезләнүчән – кәҗә мамыгы турында (непушистый, свалявшийся – о шерсти).

**ЙАТАҚ II** [*рус.* едок]**: йатақ башына** *төм.* җан башына (на едока). Йатақ пашына пүлеп пирәте қуй пецәннекне.

**ЙАТАҚАЙ** *кргл.* к.: **йатақ I**. Йатақай булды бу дебет, шалны йүwешлә дисәң, қата да қуйа.

**ЙАТАП** [*рус.* этап] *каз. ар., злт.* туктау урыны – этап белән, тоткыннарны конвой белән озатканда (место остановки, когда под конвоем провожали арестованных по этапу). Йатапта апқайтқанда қачқаннар. – *блт.* Ул wахытта Қыйғы йатап қына былған. – *злт.*

**ЙАТАУ** *тбл., твр.* **1.** к.: **йадау**; **2.** к.: **йадауланy**.

**ЙАТҚЫ** *тбл.* төтен юлының чормадагы өлеше (часть дымохода, находящаяся между потолком и крышей); чаг.: **дуңғыз**. Өйнең түбәсенә цыкқац, порас палцықта параты, аннары йугары түбәгә цыгып китәте, урамға, аны монта йатқы титләр.

**ЙАТҚЫЛЫҚ 1.** *минз.* агым су җыелып торган җир (место, где нет течения, тихая заводь); **2.** *дөб., блт.* туплавык, көтү ята торган урын (лежбище, место, где отдыхает стадо, обычно у водопоя). Йатқылықта хуҗалық көтүе йал итә. Йатқылықта қалганнар дип торам көтүне. – *блт.*; **3.** *перм.* соңгылык, бала урыны (послед). Бала асрагач йатқылығы төшмәде исә, чыпчыг орлоғын қайнатып эчерәсең. Олан туды, йатқылық төшмәде әле, қайным килеп керде шулай.

**ЙАТЛАНУ** *төм.* к.: **йатсырау**.

**ЙАТЛЫ** *тбл.* хәтерле (памятливый).

**ЙАТСЫРАУ** *тара.* ятсыну (стесняться, чуждаться). Йатсырап кәпләшмәй утыра.

**ЙАТУ I** *минз.* чоңгыл (омут, водоворот, пучина). Элек йатулар күб ийе.

**ЙАТУ II 1.** *хвл.* бату, баю (заходить – о небесных светилах); **2.** *лмб.* бетү, онытылу (выйти из употребления, забываться). Әле инде алар йаттылар: уха-чәчәкләр, тайкалар, пирталар. Кыз йаслатулар йатты инде. Ул муды йатты хазер.

**ЙАТУ III** *брб.д.* барлыкка килү, урнашу (возникновение; обоснование). Өц йөз йыл артық бар awыл йатқанға.

**ЙАТХЫСУ** *саз.я.* яткыру (уложить, положить). Палларны йохлатхалы йатхыстым.

**ЙАТЫП** *бөре., тпк., байк.* торып, яшәп уку, эшләү һ.б. (находясь, пребывая, живя какое-то время на месте учебы или работы). Йатып уқучылар бар ыйы мәдрәсәдә. – *бөре.* Dawышны уқымагансыддыр, йатыб уқығансыддыр. – *тпк.* Йатып кисәләр (урманны), кыш цыгалар. – *байк.*

**йатып қалу** *төм.* торып калу (остаться, оставаться). Ул йәштә йатып қалты уwақ-wақ қына паллар белән.

**ЙАТЫРҒАУ** *перм.* к.: **йатсырау.** Йатырғый, қул биргән була инәсенә. Сезне йатырғый әле ул.

**ЙАУ I** *чст., мәл.* к.: **ай II.**

**й а у II** яу (война):

**йау йарағы** *брб.д., тбл.* сугыш коралы (боевое оружие).

**ЙАУҒАН** *тбл., тара., брб.д.*, **ЙАУҒАНАШ** *эчк.* к.: **сywанаш.** Йауған пешереңце. – *тбл.* Йауған аш, ите йуқ. – *тара.*

**ЙАУЗАУ** *тара.* түбәнәю, төшү, тәбәнәкләнү (опускаться, сделаться низким).

**ЙАУЛЫК** *карс.* кулъяулык (носовой платок). Бырынгылар әтәләр ийе йаулык.

**борон йаулығы** *твр., каз.ар.* к.: **йаулык.**

**йаулық йабу** *перм.* иске туй йолаларыннан берсе: килен каениш өенә беренче тапқыр кергәч, каенана аның башына күренү бүләге итеп яулык яба торган булган (один из старинных свадебных обычаев, заключающийся в том, что при входе невестки в дом впервые свекровь покрывала её голову дарственным платком). Әнә мийа йаулық йапты арта килене итеп.

**йаулық тарту** *перм.* элек: йөз яшерү (в старину: обычай закрывать лицо в присутствии мужчин). Үзе йаулық тартып йөргән, қайнағасына бара үзе бичә өстенә.

**кесийә йаулық** *дөб.* кисея материалыннан булган яулык (платок из кисейного материала). Өстән бәйләнгән йаулық бар, кесийә йаулық.

**никах йаулық** *тара.* киленгә каенананың бүләге (подарок свекрови невесте). Никах йаулық, тарақ бирә қәйнәсе қысға, никах қойган көнне бирәтеләр, башына кигезәләр.

**пырансыс йаулық** *тара.* зур кызыл чәчәкле яулык, француз яулыгы (платок с большими красными цветами; французский платок). Қысыл пырансыс йаулық.

**тешле йаулық** *тбл.* төрек яулыгы (турецкий платок).

**тирәли йаулык** *мәл.*, **читле йаулық** *кмшл.* кырыйларына төрле төстәге бизәкләр төшерелгән яулык (набивной платок).

**чыбар йаулық** *т.я.-крш.* тастар өстеннән бөркәнелә торган махсус яулык (специальный платок, который накрывается поверх национального головного убора – тастара).

**шартланка** [*рус.* шотландка] **йаулық** *трх.* шакмаклы яулык (клетчатый платок; шотландка). Шартланка йаулық йаба ийек.

**ЙАУРҒАН** *брб.д.* к.: **жеборган.**

**ЙАУРЫЛУ** *твр.* хәлсезләну, көчсезләну (ослабевать, обессиливать).

**ЙАФАН 1.** *кузн., хвл., бөре.* к.: **йапан.** Чыктым йафаннарга йерергә, Күземә күренде, ай, кара (*хал. җыр.*). – *кузн.* Утын йафанда тора, қоймаға терәп қуйыла. – *бөре.*; **2.** *чст.* к.: **йага I, 1.** Йафан җирдән килгән халықмы?; **3.** *кузн., хвл.* киң әйбергә карата әйтелә (так говорится о чём-нибудь слишком широком); чаг.: **айап II, 3.** Йафандай күлмәк кигән. – *хвл.*

**ЙАФРАҚ 1.** *перм., к.-уф., злт.* к.: **йапрақ.** Мин теге мунча керә торган йафраққа қушып бәйләдем ий черки печинне. Сез мунчаны йафрақ белә инәмсез? – *перм.* Қайын йафрағы белән сабындық. Мынса керергә йафрақ сындырабыз. Йафрақны да әлдем, йаңгыр йауды. – *злт.*; **2.** *к.-уф.* к.: **бәрән: бәрән минеге.**

**абдрахман йафрагы** *мәл., клд.*, **гапдрахман йафрак** *глз.* әрекмән яфрагы (лопух).

**алтын йафрак** *чст.* к.: **бака: бака гөле.**

**ана үгей йафрақ** *нокр.* к.: **йар I: йар йафрағы.**

**бәти йафрағы** *бәр.* к.: **бәрән: бәрән минеге.** Бәти йафрағы йасыйсын йүкәдән.

**қарлығач йафрагы** *дөб., блт.* к.: **йара II: йара йапрақ.**

**кочан йафрак** *глз.* к.: **абдрахман йафрагы.**

**суган йафрағы** *глз.* суган кыягы (перо лука).

**үгәй инә йафрагы** *кргл., бгрс., минз.* к.: **йар I: йар йафрағы.**

**ЙАФСАРЛЫ: йафсарлы көйлək** *сазя.* бөрмәле күлмәк (платье со множеством оборок).

**ЙАХШЫ: йахшы бөтөңнәр** *брб.д.* к.: **йақшымысыс.**

**йахшы килдеңгә килү (керү** һ.б.) *төм.* исәнсау кайтуы белән котлап килү (прийти поздравить с благополучным возвращением). Йахшы килдеңгә керәбез әле.

**ЙАХШЫЛАР** *тбл.* изгеләр (святые). Астана тип йахшылар йатқан урынға әйтәтеләр.

**ЙАХШЫЛАРМЫСЫС** *тбл.* к.: **йақшымысыс.**

**ЙАХШЫМ** *хвл.* к.: **майым.** Бар әле, йахшым, ишекне йап.

**ЙАХШЫМАҢ** *тбл.* к.: **йақшымысыс.**

**ЙАҺИЛ** [*гар.*] *тпк.* к.: **дәтйал.** Бәк йаһил бу.

**ЙАШТАКАЙ** *чст.* ялагай (подхалим).

**ЙӘ** *твр.* әйе (да). Тәүрескә паратың, йәме? – Йә, паратым.

**ЙӘАЛЛА** *кмшл.* бик, искиткеч (очень, удивительно). Ул эчте йәалла. Шуннан байып киткән йәалла.

**ЙӘБӘЛӘ** *мәл., чст., чпр., кмшл.* рәт, юнь (толк, порядок). Ул кешедән йәбәлә чыкмас. Сүзенең бер дә йәбәләсе йук. – *мәл.* Бу кешенең йәбәләсе йук. – *чст.* Күзләрендә йәбәлә йуқ, биглый кебек. – *кмшл.*

**ЙӘБӘЛӘҮ** [*рус.* ябеда + *афф. -лӛу*] *чст.* к.: **йәләкләү.** Кан′анасы эстән гел йәбәләп тора.

**ЙӘБДӘШ I** *мәл., кузн.* к.: **йабдаш.** Алар укуга бик йәбдәшләр. – *мәл.*

**ЙӘБДӘШ II** *тара.* ачык, ягымлы (приветливый). Кешегә йәбдәш халық алар.

**ЙӘБЕГӘР** *төм.* кеше-кара йөрми торган, аулак (безлюдный, укромный). Йәбегәр урын булған, айу йатқан шунта.

**ЙӘБЕЛЕК** [*рус.* яблоко] *эчк.* к.: **алма II.** Йәбелек ашарлық булған инде.

**ЙӘБЕРДӘШҮ** *перм.* тынычсызлану, борчылу

(вести себя беспокойно). Дөм ач йаталар мескеннәр, йәбердәшеп йаталар. Ач булғач шалтырыйлар, тибешәләр, йәбердәшү була.

**ЙӘБЕШЕНЦӘК** *төм.*, **ЙӘБЕШКЕЧ** *брб.д.* к.: **тегәнәк I**.

**ЙӘБЕШМӘ** *кузн.* әче камырдан пешерелгән вак күмәч (мелкие домашние булочки); чаг.: **игәрче, питрач 1**.

**ЙӘБЕШҮ I** *перм.* к.: **йабышу II**. Без үскәч, шушындыйны кийергә йәбештек.

**ЙӘБЕШҮ II** *себ.* ябышу (прилипать).

**йәбешеп чыгу** *минз.* ябышып чыгу (выходить замуж убегом). Безнең wахытта туйлап түгел инде, йарлы wахыт, элгәре йәбешеп чығу диләр иде бит инде, кич белән сүләшеп, җегет өйөнә қайту иде инде.

**ЙӘWӘН** *брб.д.* к.: **йуwан.**

**ЙӘWЕН** *брб.д.* явым-төшем (осадки).

**ЙӘWЕР I** [*гар.*] *нокр., кмшл.* нәсел, токым (род, племя); чаг.: **нәсел-асаб**. Алар йәwерләре белән усаллар. Йәwерен бар да урнаштырды ич, үкенеч йуқ. – *нокр.* Йәwерләре белән килгәннәр. – *кмшл.*

**ЙӘWЕР II** [*гар.*] *кмшл.* кяфер (неверный).

**ЙӘWЕР-ЙӘПТЕ** *нокр.* к.: **нәсел-асаб**. Йәwер-йәпте беттегесе була туйда.

**ЙӘWЕРЛЕ** [*гар.*+*афф.* -ле] *минз.* таза гәүдәле, озын буйлы (высокий, полный – о человеке).

**ЙӘВЕРНӘ** *кузн.* к.: **йаwрын 1**. Йәвернәмә тике кулым эшеште.

**ЙӘWЕР-ТАМЫР 1.** *глз.* к.: **нәсел-асаб**. Йакйактан йәwер-тамырлары килгән; **2.** *нокр.* туган-тумача (родня). Йәwер-тамырына бирә бүләкне.

**ЙӘВЕТ** [*рус.* явить]: **йәвет итү** *кузн., хвл., мәл.* берәр кеше өстеннән хәбәр бирү, барып әйтү; әләкләү, фаш итү (донести на кого-либо, доносить); чаг.: **башыру**. Баргы идең, йәвет итке идең. – *кузн.* Сизә дә райунга барып йәвет итә. – *мәл.*

**ЙӘWИТ** [*рус.* явить]: **йәwит итү** *чст., кмшл.* фаш итү, сөйләү; хәбәрен тарату (разболтать, распространить слухи). Бетен awылга йәwит итеп йери инде. – *чст.* Сез түгел бит ул, бетен ден′йаға йәwит итәргә. – *кмшл.*

**ЙӘWКӘ** [*рус.* явка]: **йәwкәгә чыгару** *хвл., кузн.* к.: **йәwит: йәwит итү**. Әле генә тегел, күптән севештек, Әле генә чыгардылар йәwкәгә (*хал. җыр.*). – *кузн.*

**ЙӘWЛӘҮ** *лмб.*, **ЙӘВЛӘҮ** [*рус.* явно + *афф.* -ләү] *әстр.* к.: **йәвет: йәвет итү**. Эчлекле кеше булса, күптән йәwләгән булыр иде аның бу хален. Мин үзем йәwләмәдем. – *лмб.*

**ЙӘWНӘ** [*рус.*] *бгрс.* ачыктан-ачык (явный, откровенный; явно, откровенно). Элгәре йәшертен йөрөгән, аннары йәwнә йөри башлаған.

**йәwнәгә чыгару** *хвл.* к.: **йәwит: йәwит итү**. Анарга сереңне сүләмә, йәwнәгә чыгарыр.

**йәwнәгә чыгу** *хвл.* ачылу, билгеле булу, фаш ителү (обнаружиться, стать известным, явным). Усаллыгы йәwнәгә чыккан.

**ЙӘWНӘДӘН** [*рус.* явно + *афф.* -дән] *лмб.* ачыктан-ачык (открыто).

**ЙӘWНӘМӘҮ** [*рус.* явно + *афф.* -мәү] *лмб.* белдермәү, фаш итмәү (не разглашать, не распространять). Атасы баласын йәwнәми инде.

**ЙӘҒӘЗ** [*гар.*] *бөре.* к.: **қийәғәз**.

**ЙӘГИРМӘ** *брб.д.* к.: **йерме**.

**ЙӘГИРҮ** *тбл.* җиктерү (велеть запрягать).

**ЙӘД** [*фарс.*] *миш.д.* к.: **ис III**. Йәдендә дә йук. – *лмб.* Сүләгәнем йәдендәме? – *тмн.* Баг йәдемнән китәләр вет. Йәд йук миндә. Бик йәдемдә иде. Йәдемдә йуктыр. Әл дә мин йәдемдә, әниләр чапуклар белән чылтыр-чылтыр. – *кузн.*

**йәдгә килү, йәдгә тешү** *миш.д.* к.: **йат: йатқа килү**. Бер (йыр) йәдемә килгән иде, ыныттым. – *кузн.* Таныйм да вет, йәдемә тешми кем икәнеге. – *лмб.*

**йәддән китү** *миш.д.* истән чыгу, хәтердән чыгу, онытылу (стереться из памяти, забыться).

**ЙӘДИ** *брб.д.* к.: **йетте**.

**ЙӘДИК** *брб.д.* җитез, тырыш, акыллы (проворный, прилежный, разумный).

**ЙӘДЛӘҮ** [*фарс.* + *афф.* -ләү] *кузн., хвл., тмн., шрл., әстр.* к.: **ислими'и**. Минем йәдем йуг инде, балалар, йәдләмим. – *шрл.* Син ул йылны йәдлисенме? – *кузн.* Качыларны каадыр куйдым, йәдләмим дә. Мин йәдлим, фартык кырып, чәчкә манитлар бәләп. – *тмн.* Йәдли алмыйм, йәшләр йәдләр инде. – *әстр.*

**ЙӘЖӘҢ** *брб.д.* **1.** дымлы (влажный); **2.** чи, пешмәгән (сырой, недоваренный).

**ЙӘЖӘҮ** *брб.д.* гомернең бер елын яшәү (прожить год жизни).

**ЙӘЖЕМБЕК** *клм.* к.: **йәшенцәк**.

**ЙӘЖЕН** *брб.д.* к.: **йылдырым 2**.

**ЙӘЖЕНБӘК** *яүшт.* к.: **йәшенцәк**.

**й ә й** *миш.д.* җәй (лето):

**йәй башы** *сргз.* яз, яз көне (весна). Йәй башында алдык без бр′уканы, априлда. Йәй башы сuwында агарталар киндерне.

**ЙӘЙӘК I** *кузн., хвл., сргз., шрл., клд.* яңак (щека). Илгизәрнең йәйәгенә сукты. – *клд.*

**йәйәк севәге** *кузн., хвл.* яңак сөяге (скула).

**ЙӘЙӘК II** *клд.* яңак, тәрәзә һәм ишек яңагы (косяк, брус дверной и оконной рамы). Ишек йәйәге.

**ЙӘЙӘКЛӘҮ** *сргз.* яңаклау (давать пощёчину). Малайны кинаган, куллары белән йәйәкләгән.

**ЙӘЙБӘК** *тбл.* к.: **йалбақ 1**.

**йәйбәк табақ** *тбл.* тәлинкә, сай табак (тарелка, неглубокая чашка).

**ЙӘЙВӘХ** *саз.я.* тирән булмаган савыт-саба (неглубокая посуда ). Йәйвәх тавахта аш тис сowыйт.

**йәйвәх тавах** *саз.я.* к.: **йәйбәк: йәйбәк табақ**.

**ЙӘЙГЕЛЕК** *төм.*, **ЙӘЙГЕСЕН** *себ.*, **ЙӘЙГЕТӘ** *твр.* җәй көне, җәен (летом). Пер йәйгелек суғыш ацылып, суғышқа китте тә парты йәнекәгенәм. – *төм.* Қырғапқа барғайнем йәйгетә. – *твр.*

**ЙӘЙҒОР** *төм.*, **ЙӘЙҒЫРТ** *тбл.* к.: **дуга: күк дугасы**. Йәйғор күрә тә йарым әйтә, мин күген алам, тите, йарымы – сарысын.

**ЙӘЙЕЛГӘН** *тара.* җыелган (собранный).

**ЙӘЙЕЛМӘ** *брб.д.* бала итәк (оборка, волан). Йәйелмә тип итәк қуйганнар, итәг өстенә йәнә итәк қуйганнар.

**ЙӘЙЕЛМӘЛӘҮ** *брб.д.* бөрү, бала итәк салу (де-

лать оборки, волан). Итәген йәйелмәләп, камсулға нуғалар салып тегәде. Йәйелмәләп күлмәк тегәде, йыурып-йыурып теккән.

**ЙӘЙЕЛТЕРЕП** *брб.д.* яулыкны татарча бәйләү (завязывать платок по-татарски). Ходағый апақ йаулық йәйелтереп пәйләй.

**ЙӘЙЕН** *эчк.* ындыр табагы (ток – с.-х.).

**ЙӘЙИ** *тбл.* еш, куе (частый, густой).

**ЙӘЙИН** *брб.д.* к.: **йәйгелек**.

**ЙӘЙИРҮ** *тбл.* куерту (сгущать).

**ЙӘЙКӘР** *чст.* сөйкемлелеге, ягымлылыгы белән үзен яраттыра торган (симпатичный).

**ЙӘЙКӘРЛӘНҮ** *том.д.* к.: **йалағайу**.

**ЙӘЙЛӘWEC** *тпк.* җәй көне яки көзгә таба туган бәрән (ягнёнок второго окота, летний приплод). Йәйләwec пәрән суйдым, песән тырнарға киттеләр. Йәйләwескәй пәрәсе бар, көтүгә қумай сарығын.

**ЙӘЙЛӘТҮ** *төм., тара.* җәен мал симертү (откормить скот летом).

**ЙӘЙЛӘҮГЕС′** *тпк.* к.: **йәйләwec**. Алтмыш биш йәйләүгес′ пәрәс′ булды, минең қулда мал үргеде.

**ЙӘЙЛЕК I** *тара.* к.: **иске**.

**ЙӘЙЛЕК II 1.** *тбл.* болдыр – өйнең буеннан буена әшләнә (крыльцо – делается на всю длину дома); **2.** *төм.* баскыч (лестница).

**эцке йәйлек** *төм.* к.: **ишегалды**.

**ЙӘЙЛЕК III** *твр.* к.: **нәүрәп**.

**ЙӘЙЛЕКПАШ** *туб.-иртд.* баскыч алды (крыльцо дома).

**ЙӘЙМӘ I 1.** *злт., тмн., клд., чст., срг., брб.д.* к.: **күзикмәк I, 1**. Сөсө йәймә бик тәмне була, йоқақ қына итеп пешерәм. Элгәре туйға да пешергәннәр йәймәне. – *злт.* Эченче ахшамына йәймә бешерәләр, йәймә эстенә үз′ум куйалар. – *тмн.* Йәймәне әпәй булмаганда тиз генә пешереп алалар, цәй йанына куйарга. – *срг.* Ywәләйсең, өрөләп, йәйелеп бетә, өстәлнең көркәме тип әйтәбес йәймәне. – *брб.д.*; **2.** *тпк.* қыстыбый тышы (тонко раскатанное тесто пшеничной муки для кыстыбый).

**ЙӘЙМӘ II** *эчк.* к.: **йәйен**.

**ЙӘЙМӘ III** *саз.я.* **1.** к.: **ашаулық**. Түрт қырлы көллө өстәл йәймә алтых; **2.** җәймә (простыня).

**итән йәймә** *саз.я.* тар келәм (дорожка, коврик).

**тиван йәймә** *саз.я.* диван җәймәсе (накидка для дивана).

**ЙӘЙНАМАС** *тара.* к.: **намазҗәй**.

**ЙӘЙПӘК** *тмн.* юка, яссы (тонкий, плоский). Чечебича йәйпәк булайды.

**ЙӘЙТАҚ I 1.** *төм.* кечкенә чана (маленькие сани); **2.** *тбл.* утын ташый торган чана (дровни). Пестә пецәнне йәйтақ цанаға төйәп ташыйтылар.

**ЙӘЙТАҚ II** *төм., тбл.* сөзәк (пологий).

**йәйтақ атлану** *тбл., брб.д.* яр салмыйча атка атлану (сесть верхом без седла).

**ЙӘЙҮ I** *тара.* җыю (собирать).

**йәйеп қуйу** *тара.* җыеп кую (собирать).

**ЙӘЙҮ II** *төм.* ташу вакыты (половодье).

**ЙӘЙЦЕ** *тбл.* начар һава торышын тудыручы (человек, создающий плохую атмосферу).

**ЙӘКӘ** *төм.; тбл.* аерым (отдельно; отдельный).

**йәкә цығу** *төм., тбл.* башка чыгу (отделиться). Инте өйләнтегес, инте йәкә цыгу кәрәк. – *төм.*

**ЙӘКТӘ 1.** *төм., тбл.* костюм (пиджак); **2.** *твр., тбл., төм.* камзул (камзол). Көмеш йәктәсе бар ийе инәмнеңке. Көмөш йәктә порного пархыт әwәле, қәзер белүш ти идек. – *твр.* Порон самантa йәктә тиб әйтәте, йеңсес, осон, тубықтан, қайбере тубыққа йетмәйде. Минеңке көмөш йәктәм пар ийе, йиңсес. – *тбл.*; **3.** *тбл.* камзул тибында тегелгән озын кием (длинная одежда типа камзола). Йәктә пелүштән, мақмал инте, йеңе осон пулады, матирийадан та тегәтегәннәр; **4.** *тбл.* бәйләнгән кофта (трикотажная кофта).

**суқма йәктә** *төм.* укалы камзул (камзол с золотым позументом).

**ЙӘКТӨЦ** *тбл.* астар (подкладка).

**ЙӘЛӘК** *чст.* әләк (ябеда).

**ЙӘЛӘКЛӘҮ** *чст.* әләкләү (ябедничать). Йәләкләгәнем дә йук инде, йахшы тырсыннар дим.

**ЙӘЛӘЛӘК** *брб.д.* себер көзәне (колонок). Йәләләк матур ул.

**ЙӘЛӘЛИ** *брб.д.* туй җыры (свадебная песня).

**ЙӘЛЕП-ЙӨЛӨП** *минз., стрл.* к.: **дывыл-дывыл**. Йәлеп-йөләп итеп тора айаклары. – *стрл.*

**ЙӘЛП** *минз., тпк., стрл.* к.: **җәлп**. Йәлп итеп қайта да килә сағынғас. – *тпк.* Йәлп итә дә йүгереп килә. – *стрл.*

**ЙӘЛПӘЛӘНҮ** *бөре.* яньчелү; чатнау (вдавиться; треснуть).

**ЙӘЛПЕЛТӘТЕП** *тпк.* җәһәт, җәһәт кенә (живо, проворно, быстренько). Бик йәлпелтәтеп қамыр басасың, нәстәкәй бешерәсең?

**ЙӘЛПЕЛТӘҮ** *тпк.* җилфердәү (развеваться, колыхаться). Кер йәлпелтәп кибә.

**ЙӘЛТӘГӘ** *тбл.* флюгер.

**ЙӘЛТЕР** *эчк.* к.: **чәлтер**. Йәлтеренә балта тигән утын цапқанда.

**ЙӘЛҮ** [*рус.* жаловаться]: **йәлү итү** *мәл.* к.: **йәләкләү**. Туваруг ашаган эчен дә йәлү итә иренә.

**ЙӘЛЧҮ** *глз.* үрчү (размножаться, размножиться). Алар Кәстем нәсел ди, Кәстемнән йәлчегәннәр.

**ЙӘМ** *нокр.* матур (красиво). Йаман йәм йырлайсың ич.

**ЙӘМӘҒӘТ** [*гар.*]: **йәмәғәт әйттерү** *минз.* кыз килешеп кую, ярәшү (просватывать). Қайтсам, мина йәмәғәт әйттергәннәр.

**ЙӘМЕ** *твр., тара.* әйе бит, әйеме? (да ведь, не так ли?). Салих абышқаның улы пар ите, йәме, ул оста ите кәпкә. – *твр.* Нурийә, атам бишенце йылның, йәме?

**ЙӘМЕ-ҖӘЙӘМЕ** *кас.* яме, матурлыгы (красота). Би' матур иде бу, бә'чи әле йәме-җәйәме' ит-'ин.

**ЙӘМЕС** *тара., саз.я.* ямьсез (некрасивый; некрасиво).

**ЙӘМИЙӘТ** [*гар.*] *клд.* халык (народ). Сугыш йылында awырлык күрде йәмийәт.

**ЙӘМИШ: қат йәмиш** *брб.д.* к.: **йемеш 2, 3**.

**ЙӘМ-ЙӘШ** *эчк.* яңь-яшь (совсем молодой). Бу қыз бик йәм-йәш икән.

**ЙӘМКӘ** *минз., тпк., стрл., шрл.*, **ЙӘМКИ** *минз.* к.: **җәмкә**. Кунакка барганда алйапкычым белән йәмкәмне калдырмый идем. – *шрл.*

**ЙӘМЛЕ** 1. *глз., мам.* к.: **sawoклы**. Бу кину йәмле микән, апа, син карадыңмы? – *глз.*; 2. *срг.* матур, чибәр (красивый; красиво); чаг.: **йәм**. Йәмле кыз.

**ЙӘМНЕ** 1. *кргл.* к.: **йәм**. Мин йәмнерәк йаза идем; 2. *срг., чпр., нокр., кргл.* к.: **йәмле** 2. Бик йәмне бу катны. Теге Сәдәтнең ире йәмникән. Йәмнерәк күрә дә сүwә. Син йәмне йазасың да. – *срг.* Атаң Инсафтан йәмнерәк йазадыр әле. – *чпр.* Сабантуй йәмне уздымы? – *нокр.* Бу йәмне иде, қара чәчле, күк күзле. – *кргл.*

**ЙӘМРЕК-ЙӨМРӨК** *брб.д.* җимерек, хәрабә (развалины, руины; разрушенный).

**ЙӘМСЕЗ** *блт., чет.* 1. бик, искиткеч (очень, слишком). Йәмсез йарата баланы. Йәмсез салқын. – *блт.*; 2. бик яхшы (очень хорошо, очень хороший). Әнекийнең энесенең улы йәмсез гармунчыйы инде ул. – *блт.* Йәмсез белә ул тарихны. – *чст.*

**ЙӘМТЕ** *брб.д.* йә инде (ладно уж).

**ЙӘМҮ** *тбл.* елмаю (улыбаться).

**ЙӘН** *перм., твр., саз.я.* җан (душа).

**йән киселү** *перм.* 1. үзәк өзелү, яну, көю (болеть душой, переживать); чаг.: **йезелү: йерәк йезелү**. Хәнифәм дип гөмөрем буйына йәнем киселеп бетте; 2. җәфалану, азап чигү (измучиться); чаг.: **гүрләнү**. Өтөлдем инде, йәнем киселеп бетте шулар белән.

**йән көйү** *твр., саз.я.* ачу килү, ачулану, үпкәләү (злиться, ругаться, обижаться). Ағам йәне гөйөп киткән. – *твр.* Йәне көйхән ийән, аның өцөн минең белән кәпләшмәйт. – *саз.я.*

**йән сақлawыцы** *саз.я.* өрәк (привидение, призрак).

**ЙӘНӘГӘ** *мәл.* к.: **йәренгә**. Без йәнәгә тагын кайтачакбыз.

**ЙӘНӘГЕ: йәнәге йыл** *тбл.* к.: **йәренгә**.

**ЙӘНӘМӘСЕ** *блт.*, **ЙӘНӘПӘСЕ** *минз.*, **ЙӘНӘСӘК** *чст.* янәсе (дескать, будто бы, якобы). Бишектән балаларны ачып қарап йөри, йәнәпәсе, бала монда түгелме? Бүген кырга барган идем, йәнәсәк, эшли алмаммы дип.

**ЙӘНӘҮР** *брб.д.* шаяртып эндәшү (шутливое обращение). Ә, йәнәүр!

**ЙӘНӘШ** *злт.* янында, янәшәсендә (рядом; по соседству). Монда йәнәштә генә Оло Қызылбай awылы бар. Йәнәшендә энесе утыра.

**ЙӘНӘШӘ** *минз., стрл.* рәттән (подряд). Өч көн йәнәшә йаттым. – *минз.* Базар буладыр ийы монда безнең ике көн йәнәшә. – *стрл.*

**ЙӘНЕКӘМ** *төм.* җаныкаем (душенька моя).

**ЙӘНЕМ-КҮЗЕМ** *тбл., тара., брб.д.* иркәләү сүзләре (ласкательные слова).

**ЙӘНЕҢНӘН** *тбл.* к.: **йәнекәм**. Йенче пелән ай мәрүәрне, Теселмәсәң, йәнеңнән, тесмәген. Исәнлә булсам, мин қайтырмын, Миннән өмөтөңнө өсмәген (*хал. җыр.*).

**йәнеңнән китәйен** *төм.* к.: **йөрәк: йөрәгеңнән китәйен**.

**ЙӘНЕСЛӘП: йәнесләп қуйу** *твр.* кеше әйберенә хуҗа булу (присвоить).

**ЙӘНЕЧҮ** *тмн.* таптау, таптатып үтерү (задавить). Машина йәнечте тудыкамны.

**ЙӘНЕШИШӘ** *тбл.* тагын (ещё). Йәнешишә техникумға уғу ғылыпты, awыл мәктәпне тә бөтөрмәгән.

**ЙӘНКЕ: йәнке агач** *перм.* к.: **сәрwи: сәрwи ағачы**.

**ЙӘННӘНҮ** *брб.д.* җанлану (оживиться).

**ЙӘННЕК** *стрл., шрл., яүшт.* хайван (животное). Дүрт сыйыр йәннеге бар. – *стрл.* Ит өчөн сыйыр йәннеге асырыйбыз. – *шрл.*

**ЙӘНТӘМ** [*гар.*] *тбл.* җәһәннәм (ад).

**йәнтәм киццен** *тбл.* җәһәннәмгә китсен (чтоб ему провалиться сквозь землю).

**ЙӘНЦЕК** *байк.* янчык (кисет, мешочек).

**ЙӘНЦҮ** *тара.* изү (мять, давить). Картуп йәнцейтегән туқмақ пулатыған.

**ЙӘНЧЕЛҮ** *нокр.* 1. к.: **йырчыклану**. Қартайу булсын иде дә, мына бит йәнчелмәсен иде, ә?; 2. к.: **йомарлану**. Алай йәнчелепмин халатларым.

**ЙӘНЧҮ** *брб.д.* к.: **йәнечү**. Йулда машина йәнчеп китте.

**ЙӘҢӘ** *брб.д.* к.: **йеңгәчәй**.

**ЙӘҢГЕ** *минз., кргл., стрл.* өяңке (ива). Менә йәңге, шуларға қарғалар күп киләләр, шуның белән қарғалы қушқаннар. – *кргл.*

**ЙӘҢКЕ** *м.-кар.* талның бер төре (ветла).

**ЙӘҢКЕЛМӘ** *тбл.* к.: **қалым** 2.

**ЙӘП** 1. *трх.* үсеп утырган агачның ботагы (ветвь растущего дерева). Ике йәпле тал ийе; 2. *мәл.* чәч толымы (коса). Бер йәпкә берсен, бер йәпкә берсен тага идем чулпыны.

**ЙӘПЕЛТӘК** *төм.* җиңел, җиңел сөякле (лёгкий; лёгок на подъём). Қодаца белән қота бала қушылыплар, мин қушқан, йәпелтәг итем қуй.

**ЙӘПЛӘШКӘ** *трх., чст.* ике тәгәрмәчле кечкенә кул арбасы (таратайка, двухколёсная ручная тележка).

**ЙӘПЛӘШҮ** *чст.* гәпләшү, сөйләшү (беседовать, разговаривать). Әз генә йәпләшеб алдыг әле.

**ЙӘПМӘЛЕ** *минз., стрл.* япьле (развилистый, с развилками, ветвистый). Өч йәпмәле тимерне шәмдек диләр. – *минз.*

**ЙӘПТӘШ** 1. *минз., мәл.* к.: **йабдаш**; 2. *трх., бгрс.* оста, зирәк, сәләтле (ловкий, умелый, способный, сноровистый). Ул бабай бик әйбәт, сүзгә дә йәптәш. – *бгрс.* Киленем зерә йәптәш инде. – *трх.*; 3. *минз., стрл.* к.: **лачақ** 1. Кийеме үзенә йәптәш. – *минз.*

**ЙӘПТЕРТӘК** *төм.* бала итәк (волан). Элек ни йәптертәк тибес пес қат-қат.

**ЙӘПШЕНҮ** *брб.д.* ябышу (прилипнуть).

**ЙӘПШЕРҮ** *брб.д.* ябыштыру (приклеить).

**ЙӘР I** *миш.д., хвл.* ияр (седло).

**йәр баскычы** *кузн.* өзәңге (стремя).

**ЙӘР II** *брб.д.* к.: **ир I**.

**ЙӘРӘКӘ** *минз.* зур көймә (большая лодка).

**ЙӘРЗӘК** *брб.д.* туган илне сагынучы (скучающий по родине).

**ЙӘРЗӘЛӘНҮ** *брб.д.* к.: **йерсәү**.

**ЙӘРЕГҮ** *брб.д.* берәр төрле аш ашыйсы килү яки берәр аштан бизү – авырлы хатыннарда (испытывать потребность или, напротив, отвращение к какой-нибудь пище – у беременных женщин).

**ЙӘРЕН** *яүшт.* киләчәк (будущий).

**ЙӘРЕНГӘ** *кузн., хвл., мәл., чст., чпр., бөре., эчк., кмшл., к.т., нокр.* киләсе елга (на будущий год, в будущем году). Йәренгә барып алсак кына, быйылга булмады инде. Сезгә әле йәренгә генә укырга. – *мәл.* Сез йәренгә киләсезме безнең awылга? Безнең малай йәренгә укырга керә. – *чст.* Йәренгә тағы килегез. – *эчк.* Йәренгә икенче улыбызны да йебәрәбез инде уқырға. – *кмшл.* Улым әрмийәдән йәренгә қайта. – *бөре.*

**ЙӘРЕНГӘГӘ** *кузн., хвл., мәл.* к.: **йәренгә**. Йәренгәгә килгәндә алып килерсең. – *кузн.*

**ЙӘРЕҢӘ** *кргл., бгрс.*, **ЙӘРЕҢГӘ** *лмб., чпр., шрл., кргл., бгрс., перм., эчк.*, **ЙӘРЕҢГӘГӘ** *лмб.* к.: **йәренгә**. Йәреңгә элгерер клуп. Йәреңгә кем бар, кем йук. – *лмб.* Петер әле, йәреңгә калмас. – *чпр.* Йарар, йәреңгә шулай итәрсең син. – *шрл.* Йәреңгә тағын өч балам уқый менә. – *перм.* Йәреңгә тағын килегез. – *эчк.* Йәреңә йақын була ышкул, ишег алдында. – *кргл.*

**ЙӘРИКЛӘҮ** *брб.д.* к.: **йәрегү**.

**ЙӘРИНГӘ** *нгб.-крш.* к.: **йәренгә**.

**ЙӘРКӘ I** [*рус.* ярка] *стрл.* к.: **бикәч II**.

**ЙӘРКӘ II** *кргл., бгрс.* к.: **йарпач 2**. Бар йәркә кешеләр. – *кргл.*

**ЙӘРКӘЛӘНҮ** *кргл.* к.: **ирәйү 3**. Бар, бар, йәркәләнмә.

**ЙӘРЛӘҮ** *кузн., хвл.* иярләү (оседлать). Кийенә, атны йәрли, атланып каршы чыга, ир кийемнәрен кийенгән (*әкият.*). – *кузн.*

**ЙӘРТЕЙӘН, ЙӘРТЕЙӘНЛЕ** *тбл.* зәгыйфь (калека, инвалид; неполноценный). Энем бар ите, йәртейән ите. Тол қатын йәртейәнле.

**ЙӘРТИП: йәртип йату** *брб.д.* жиргә яту ( прикладываться к земле). Йәкәү қуғын келә йатқанны йәртип йатып тыңнайтыған полаты.

**ЙӘРЦИК** *эчк.* к.: **йәшнек**. Он-ашны йәрциккә салдым.

**ЙӘРЧӘ** [*рус.* яровая] *минз., стрл.* язгы арыш (яровая рожь). Анда шул бәрәңге, аннан ары табан йәрчә чәчәләр. – *минз.* Йәрчәнең тәме шул арыш икмәге сыман. – *стрл.*

**ЙӘСӘЙ** [*рус.* язь] *төм.* бәртәс, опты (язь).

**ЙӘСЛӘ** [*рус.* ясли] **1.** *карс.* камыштан яки талдан үрелгән атынгыч (качалка, сплетённая из камыша или из ивовых прутьев); **2.** *чпр.* бала караваты (детская кровать). Йәсләдә азмыйлар, йокла.

**ЙӘСНИЧӘ** [*рус.* яичница] *кузн., хвл., карс., лмб., мәл.* йомырка тәбәсе – йомырканы туглап ясаган төре (яичница). Кунакларга биш йомыркадан йәсничә сыттым. – *хвл.* Икән йәсничә сыттыра. – *кузн.* Йомырканы круглай бешеримме, йәсничә йасыймmы? – *лмб.*

**ЙӘСТЕРҮ** *брб.д.* язылу (разминаться, размяться, разгибаться, разогнуться). Пакуста қона йатқыза тоған, айақлар да йәстерми.

**ЙӘТ I** [*гар.*] *миш.д., минз., блт., кргл., бгрс.* җәһәт, тиз (быстро); чаг.: **заман 1**. Бу йәт туза тырган нәстәдер инде. Машина йәт итә сезне. Йәт кат'ырсың син аннан. – *чст.* Беднең Әлфәт қайтты да йәтрәк чығып китте. – *минз.* Йәтрәк қапчықларыңны әзерләп қуй, тегермәнгә барырбыз. – *блт.* Әйдә тегендә қәдәр төшик йәтрәк. – *кргл.*

**ЙӘТ II** [*фарс.*] *миш.д.* к.: **ис III**.

**йәткә белү** *төм., тара.* хәтердән белү (знать на память, наизусть).

**йәттән чыгу** *миш.д.* к.: **йәд: йәддән китү**. Карале, әле йәтемнән чыкты. – *шрл.*

**ЙӘТӘЛ I** *төм.* теләп, ихлас күңелдән яратып (желая, от всей души любя). Моно йәтәл алты ул пала, күңел итеп.

**ЙӘТӘЛ II** *туб.-ирт.д.* тырыш (старательный).

**ЙӘТӘС** *саз.я.* ядәч (дужка – у птиц).

**ЙӘТЕРӘК** [*гар.* + *афф.* -рәк] *минз., блт., кргл., тпк., стрл.* к.: **җәтерәк**. Йаталар, йәтерәк саумасаң. – *минз.* Алдындағын эс тә шыл йәтерәк. – *тпк.* Йәтерәк барыйқ, соңа қалырбыз. – *блт.*

**ЙӘТЕШ 1.** *срг., шрл., стрл., минз., бгрс., кргл., тпк.* уңай, уңайлы, җайлы (удобно; удобный). Барганда машина очрады, бик йәтеш булды. – *срг.* Сүләнергә йәтеш булып калды. – *шрл.*; **2.** *минз., стрл.* к.: **ару I, 11**. Йыраклыгы йәтеш кенә бар әле. – *стрл.*

**ЙӘТЕШ-ТӨГӘЛ** *төм.* исән-сау (живой-здоровый, жив-здоров). Аллам йулын ацсын, йәтеш-төгәл йөрөсеннәр.

**ЙӘТИМ: йәтим цицәк** *төм.* к.: **гөмөрзайа**.

**ЙӘТИМ-ҖИЛПЕ** *минз.*, **ЙӘТИМ-ЙЕБЕР** *стрл.*, **ЙӘТИМ-ЙЕЛПЕ** *минз., стрл.*, **ЙӘТИМ-ӨТӨМ** *яушт.* ятимнәр (сироты). Йәтим-җилпегә бик бирмәйләр. Элек йәтим-йебердә ут булмаган. – *стрл.* Элек бит инде булған йәтим-йелпе. – *минз.* Итен йәтим-өтөмнәргә бирәсен. – *яушт.*

**ЙӘТИМСЕРӘҮ** *твр.* ятимсенү, үзеңне ятим сизү (испытывать чувство сиротства). Инә китсә, йәтимсерәйте пала.

**ЙӘТИШ** *минз., стрл.* к.: **йәтеш 1**. Қайда йәтишерәк урны бар, әнә шунда қапқан салып суқтыралар аны. – *минз.* Үзенә йәтиш кенә табасы була. – *стрл.*

**ЙӘТКӘ** [*фарс.* + *афф.* -кә] *тбл.* бушка, юкка (впустую, понапрасну). Йәткә йөреп қайттым.

**ЙӘТКӘҖ** [*фарс.* + *афф.* -кәҗ] *тбл.* хәтерле (обладающий хорошей памятью). Антайға әтийем йәткәҗ кеше ийе.

**ЙӘТЛӘҮ** [*гар.* + *афф.* -ләү] **1.** *тбл., саз.я.* җайлау, тырышу (приспособить, наладить, стараться). Йәтләп килеп утыраты. – *тбл.* Йахшы уқыгалы йәтлә. – *саз.я.*; **2.** *тбл.* хәтерләү, искә төшерү (вспоминать, восстановить в памяти, прийти на память). Йәтләп бетерә алмыйм.

**ЙӘТЛЕ** [*фарс.* + *афф.* -ле] *лмб., кузн., хвл., клд., тмн.* к.: **исле I**. Бу ынытмый инде, йәтле бит. – *лмб.* Сез йәтлеләр, мин онотамын. – *хвл.* Икәү сүләрбез, беребез ынытса, беребез сүләр, ул йәтлерәк миннән. – *клд.* Ул йәтле, йәте йакшы. – *тмн.*

**ЙЫПЦЫҚ** *тара.* көлгән булып кыланучы (притворно смеющийся).

**ЙЫПЫЙ** *тбл.* чүәк (чувяки). Йоннан йыпый бәйләп киттем.

**ЙЫПЫЛЫҚ** *брб.д.* к.: **пысқыш**.

**йыр** *миш.д.* җыр (песня):

**йыр күтәрү** *хвл.* җырлый башлау (запеть песню). Кичен аны әрлиләр, чолка бәлиләр, эче пошкан кеше йыр күтәрә, йегет керү йуг иде, үзара гына.

**йырга кушу** *кузн.* берәр кеше турында җыр чыгару (сложить песню о ком-нибудь).

**ЙЫРА** *әстр.* инеш, елгачык (речушка). Сайға қойа йыралар.

**ЙЫРАҚҚЫ** *перм.* к.: **җырақкы**. Үзегез йыракқымы сез?

**ЙЫРАУ** *тбл.* җырлаучы, җырга оста (поющий, умеющий хорошо петь). Әшгәрә йырау қыс, ди.

**ЙЫРАУЦЫ** *тбл.* җырчы (певец).

**ЙЫРГАК** *карс.* ыргак (крюк, крючок).

**ЙЫРҒАНАҚ** *тбл., тара.* кечкенә елга, канау (маленькая речка, канава).

**ЙЫРМАҚ** *тбл.* к.: **йырымцак**.

**ЙЫРМАЦ** *тара.* чалбар изүе (ширинка).

**ЙЫРМАЧ** *кузн.* ертык (дыра; рваный, дырявый). Йыртык йырмачтан көлә (*әйтем*). Минем энем бар – йырмачлар йамыйм.

**ЙЫРТ** *тмн., лмб., кузн., чст., шрл., карс., мәл.* **1.** к.: **йорт 1**. Машина белән утын китерделәр, йыртка бушаттылар. Безнең йыртта кар күп. – *чст.* Йырты йук, ызба гына. Теге катынга йыртка чыгып эрәтте. – *карс.*; **2.** к.: **паз′ма**. Йырт үлчиләр үземә шул җирдән. Бер йыртта өч ызба идек, артил тырдык. – *кузн.*

**йырт алны** *стрл.* к.: **йорт 1**.

**йырт анасы** *хвл.* йорт иясе (домовой). Йырт анасы атның йалларын үргән, диләр, ат тирләгән була, йырт анасы атны йаратмый, диләр.

**йырт қору** *кмшл.* к.: **койу I, 2**. Алар персидәтелгә йырт қоралар.

**ЙЫРТАГАЙ** *лмб.* элек: килен кешенең каенесенә эндәшү сүзе (в старину: форма обращения невестки к младшему брату мужа).

**ЙЫРТЛАШ** *блт.* к.: **йорша**.

**ЙЫРТУ 1.** *перм.* йолку, өзү (рвать, оторвать). Чәч йырту; **2.** *глз.* кубару (отодрать, содрать). Йүкәсен китерәсин, йыртасин, аркан ишеп чабата йасайсин.

**мичала йырту** *глз.* мунчала төшерү (драть лыко). Пыртка йүкә салганнар мичала йыртмага.

**ЙЫРТЫНУ** *кргл.* к.: **қыйышу 1**. Җәй булды исә, урманда йыртына, күгәнен, җиләген йыйа.

**ЙЫРТЫШ I 1.** *хвл.* мәетне кабергә төшергәндә, читкәрәк китеп, кычкырышып-кычкырышып яңа тукыма кисәген ерткалау йоласы (старинный обычай с шумом-криками быстро отходить от могилы и на ходу рвать кусок материи на части в момент погребения покойника). Йыртышка бирдек ыштапыл′ны. Йыртыш алыб баралар; **2.** *срг.* элек: мәетне кабергә төшергәндә кырыннан гына ертып ярлырак бер кешегә бирелә торган дүрт метр тукыма (в старину: четырёхметровый кусок материи, который слегка надрывался при погребении покойника и отдавался какому-нибудь бедному человеку); чаг.: **җыртыш 2**; **3.** *злт.* метрлы тукыма кисәге, гадәттә аннан алъяпкыч, күкрәкчә тегеп килен төшкән вакытта бала-чагага, өлкәннәргә тараталар (метровые куски ткани, из которых шьют фартуки, нагрудники для раздачи молодёжи, детворе, пожилым женщинам). Қыз китәр сақта йыртыш дип ситса китерәләр, аңардан алйапқыс йасыйлар, күкерәк йасыйлар, мендәр тышлары тегәләр иптәшләре йыйылып; **4.** *тара.* кисәкле-кисәкле ситсалар (кусочки ситца). Йыртышқа тр′әпке йебәртем, гатаwый платочеклар йебәрдем, аны йыртып уголочыгына акца бәйләйләр хәл хәтәре инде.

**ЙЫРТЫШ II** *перм.* к.: **йорша**.

**ЙЫРТЫШУ I 1.** *перм.* талашу (ссориться, ругаться). Бигрәк усалсың, йуққа-барға йыртышып йөрисең; **2.** *тбл.* каты тешләү (больно кусать). Күгәwен йыртышаты.

**ЙЫРТЫШУ II** *тбл.* тырышу (стараться). Өй салсам тип йыртышып йататы.

**ЙЫРТЫШЫП-ЙЫРМАШЛАП** *тбл.* тырышып-тырмашып (очень старательно). Йыртышып-йырмашлап цақ цықтым өй түбәгә.

**ЙЫРУ I** *кузн., карс.* к.: **йару I, 1**. (Бәрәңгене) сука белән дә йыралар. Карту йыралар. – *кузн.* Кырда инде бәрәңгене йырабыз. Аннан сука белән йырырга. – *карс.*

**ЙЫРУ II** *нокр., глз.* җыр (песня). Алар анда йыру әйтмә тыңнашып торалар.– *нокр.*

**ЙЫРЧЫК** *кузн.* җыерчык (морщина).

**ЙЫРЧЫКЛАНУ** *кузн.* җыерчыклану (покрыться морщинами).

**ЙЫРЫҚ** *тара., брб.д.* сынган яки төшкән теш урыны (щербина; место молочного или выпавшего зуба).

**ЙЫРЫМЦАҚ** *тбл.* ерганак (водомоина, протока).

**ЙЫРЫН I** *тмн.* к.: **вәл.** Пых йырын.

**ЙЫРЫН II** *кргл., бгрс., тпк.* ерганак, ермак, ерынты (промоина, рытвина, канава, овражек). Сипаратлар төшөп қалған йырынға. – *кргл.* Мостафа дигән кеше печән чапқан йырын. – *бгрс.* Шушында бер йырың гына төшә. – *тпк.*

**ЙЫРЫНУ 1.** *кргл., бгрс.* мәхрүм булу (лишиться кого-либо). Шул сыйырдан йырынмасақ инде! – *кргл.*; **2.** *төм.* бетү, калмау, арыну (лишиться чего-либо, потерять). Андый әйберләрдән йырындығ әле. Сыйырыбыз бозауламаған, йырынып торабыз әле.

**ЙЫС** *эчк., себ.* ис (запах). Самаwырның йысы цыққан. Йебердәк гөлнең йысы тәмле. – *эчк.* Йыс цығаты. – *тбл.* Йысы әйбәт эт борноныңқы. – *брб.д.*

**йыс тарту** *тбл.* к.: **йыслау.** Айу йыс тартқан.

**йыс цығу** *тбл.* ис тию (угореть). Пашыма йыс цықты.

**ЙЫСЛАУ** *себ.* иснәү (нюхать); чаг.: **искәү.** Йыслап пақ пы итне, йысланмапма? Ул тәмән йыслаты. – *тара.* Тәрүләр чыққанчы аны йыслап, чәйен эчеп. – *брб.д.*

**ЙЫСЛЫ** *төм., тбл.* исле (пахучий, имеющий запах).

**йыслы гөл** *төм.* исле гөл (тимьян).

**йыслы палыйн** [*рус.* полынь] *тара.* к.: **нәркәмәс.**

**йыслы үләи** *төм.* ак чәчәк, ромашка.

**ЙЫСЛЫҚ** *тбл.* к.: **танау 1.** Йыслығымны итейәшәр цағыпты.

**ЙЫСУ** *тара.*, **ЙЫСЫҒУ** *тбл.* исләнү (иметь запах, пахнуть, протухнуть). Йыслы йысықмайты.

**ЙЫТЫНУ** *хвл.* комсызланып ашау яки эчү (жадно, взахлёб есть или пить).

**йыш I** *урт.д.* еш (часто):

**йыш ағац** *твр.* чыршы (ель).

**йыш ийә** *тбл.* урман иясе, пәри (леший).

**йыштан йыш** *минз., стрл.* бик еш, әледән әле (то и дело, часто). Бал'ниста йыштан йыш йатам инде. – *стрл.*

**ЙЫШ II** *саз.я.* бәйләнчек, бәйләнүчән (навязчивый, придирчивый, назойливый).

**ЙЫШАТУ** *лмб.* бушайту, зурайту (растянуть, сделать больше). Йаңы эрзинкәләремне йышаттың инде.

**ЙЫШҒЫ** *тбл.* к.: **йыш II.** Ну қәйер йышгы гуй ша!

**ЙЫШҚЫ I** *тпк.* к.: **йунгы.** Ут йаққаннар йышқыға.

**ЙЫШҚЫ II** *перм., себ.* ышкы (скобель, струг).

**ЙЫШҚЫЛАНУ** *тбл., тара.* кеше барында юкбарны сөйләп тыкшынып йөрү (вмешиваться в чужие дела).

**ЙЫШКЫНУ 1.** *мәл.* к.: **йылышу 1.** Йышкын берсәк; **2.** *хвл.* к.: **йылышу 3.**

**ЙЫШҚЫРҒЫЦ** *төм., тбл., саз.я.* к.: **қустартқыч.** Кисәүне пес йышқыргыц тибес. – *төм.*

**ЙЫШЛАНУ** *саз.я.* **1.** тию, тиеп китү (коснуться, дотрагиваться, трогать); **2.** бәйләнү (придираться).

**ЙЫШТЫРУ 1.** *кузн.* җыю (собирать). Ликсандр йыштыра памушникларын. Ул падиша үзенен вәзирләрен йыштыра, бер төрле монда засидан'йе йасыймы инде (*әкият.*). Ыланнарын йыштырган, эвенә кереп утырган. Бу малларны да йыштырадыр да и су белән китә; **2.** *кузн.* җыю, булдыру (устроить жизнь). Үзенә тормош тамы йыштырды?; **3.** *кузн.* җыю, яшерү (подобрать, спрятать). Ыштаныңны чолкаларыңа йыштыру; **4.** *хвл.* җыю, җыештыру (убрать, прибрать). Үләрен әйбәтләп йыштырып куйганнар.

**ЙЫШУ I 1.** *перм., тпк.* к.: **йимбелләү.** Бармақларын өздөргән тақта йышқан җирдә. Пытылукларны да йышып түшисең. – *перм.* Мин йунам, йышам, пабай сызып пирә. – *тпк.*; **2.** *перм.* тырнау (царапать). Қара инде, песи йыша.

**ЙЫШУ II** *себ.* **1.** сөртү (вытирать). Өстәлне йышып алың; **2.** сөртү, ягу (мазать, помазать). Табага май йыштыңма? Пәтернеңке өстөнә қаймақ йышатылар. – *төм.* Путра йышқаннар, қашларны та йышқаннар. – *тбл.*; **3.** ышку (тереть). Қом мән табақларны йышабыс. – *төм.*; **4.** ышкылау (строгать). Йышқы белән тақта йышатылар. – *төм.*; **5.** *төм.* кыру – аякны (натирать ногу). Туфли айағымны йышқан; **6.** *саз.я.* кабатлап әйтү (повторять). Ницәнцехә йышам, қолағына алмайты.

**ЙЫШХЫ** *саз.я.* к.: **йышқы II.** Йышхы плән йышу.

**ЙЫШХЫЦ** *саз.я.* к.: **йуғыч 2.**

**ЙЫШЫЛУ** *перм.* **1.** ышкылану (быть строганным); **2.** тырналу, сыдырылу (поцарапаться). Айақлары йышылган.

**ЙЫШЫМ** *тбл., твр., тара., төм., брб.д., саз.я.* оек (чулки). Йышым пәйләмәдем, Рәқыйә апа йышым киде. – *төм.* Йоннан бәйләнгән йышым кигәннәр. Йоқа йышым магасиннықы була. Йышым кимәсәң, талата ницек йөрисең. Йоқа йышым ман кейәделәр атуны, магасынның пылады. Пиш инә мән байлаган йышым пы. – *тара.* Йышымны өреп, наски үрәделәр, энде балалар гөрбәсен. Пер капырун йышым сусылып йата. – *брб.д.* Кейгәле йышым-пәлән йох, айах өшөф-өшөф исе қалмайт. – *саз.я.*

**йеп йышым, йоқа йышым** *брб.д.* базар оегы (чулки простые, базарные, фабричные).

**йөн йышым** *брб.д., саз.я.* к.: **бишинәйык.**

**йышым энә** *төм.* бишинә (вязальные спицы).

**ЙЫШЫНУ** *тмн.* к.: **йылышу 1.** Йышыныгыз өстәлгә, ашибыз ни барын.

**ЙЭР** *нокр.* к.: **баба 1.** Мона йәр кешем, атасы йуқ иде, анасы бар иде. Қызым маслозаводта, йәр кешесе дә анда эшли.

# К

**КАБАК I** 1. *миш.д.* капка (ворота). Кабакны йап, йаwып цык. – *срг.* Кыдалар килде кабакка, кыз терәлде кабага (*мәкаль*). – *лмб.* Бак, кабакны ач, куйлар килә. Арт кабакны йил кайырган. – *тмн.* Сорап тормады ул, кабакны ачты да чыгып китте. – *хвл.*; 2. *лмб., хвл.* йорт, өй, хуҗалык (дом); чаг.: **азбар** 3. Тенә каршы кабак йанды. Каршы кабакта гына тыра ул. – *лмб.*

**ач кабак кычкыру** *кузн.* килен төшкәндә егет йортының капкасын ачтыру (кричать, чтобы открыли ворота дома жениха при переезде невесты). Ач кабак, акча сип, дип кычкыралар, аннан туйны кергезергә тотоналар.

**кабак эс(те)** *миш.д.* капка төбе (место у ворот). Машина кабак эстенә килеп туктады. – *хвл.* Кабак эстә утырыр идегез. – *лмб.* Кабак өскенәйем таш түшәгән иде, Судлар йери-йери баз булды (*бор. бәет.*). – *тмн.*

**кабаг эстенә чыгу** *карс., кузн.* капка төбенә чыгып утыру (выходить вечером на посиделки у ворот). Йазны йегетләр килмиләр, йазны (кызлар) кабаг эстенә чыгалар.

**кура кабак** *миш.д.* к.: **қапқа: кәртә қапқа**.

**такта кабак** *лмб.* к.: **қапқа: қалай қапқа**.

**КАБАК II** *стрл.* үр (возвышенность).

**КАБАК-КУРА** *чст.* капкалар, каралтылар (ворота и надворные постройки). Кабак-кура кийа.

**КАБАЛАУ I** *чпр.* к.: **қабалау**.

**КАБАЛАУ II** *чст.-крш.* өрү (лаять). Капкалардан кергән чакта, Кара кечекәйең кабалый, Кыдагый, канатым, чыгып кара, Күп килмәдек микән кыдалый (*туй җыр.*).

**КАБАРТА** *срг.* кабарчык (волдырь на коже).

**КАБАРТУ** *т.я.-крш.* кабартма (лепёшка, пончик, пышка). Кабарту ачыдан пешерәләр. Таба белән пич алдында пешергән кабартуны пичкә тыккан.

**КАБАРУ** *стрл.* к.: **қабару**. Кабармаган сөтне эчмим мин.

**КАБАТЕП** *клд., мәл.* каба (прялка). Кабатеп белә эрлиләр иде йынны, әл инде кабатепләр аз, кучаркага бәли дә тарта.

**КАБАШЛАНУ** *мәл.* капшану (шарить, ощупывать). Йурый кабашланып хатынга килә.

**КАБАШЛАУ** *чст., чпр., т.я.-крш.* к.: **қабалау**. Ник кабашлап җөрисез сез? – *т.я.-крш.* Караңгы иде, кима буйлап кабашлап йөргәч кенә кече ишекләрен таптым да йортларына кердем. – *чст.*

**КАБЕШ** *тмн.* к.: **кәбәм** 1. Эни кабеш кынам, әллә син каргадың, Баш кынам йугала нахакка. Эни кабеш кынам ак мамык йерлидер (*бор. бәет.*).

**КАБУ I** *тмн., лмб., кузн.* 1. к.: **қабу** 2; чаг.: **айыру** 2. Кытырган эт капкан. – *лмб.* Вана кочок чебешегезне кабар. – *кузн.*; 2. ашау – кандала турында (кусать – о клопах). Кандала йок, әллә булып та безне капмыйлар. – *тмн.*; 3. чуку, тешләү – кошлар турында (клевать – о птицах); 4. *тмн., лмб., кузн.* к.: **қадау II**. Мурта капты башымны; 5. *тмн.* к.: **каклау**. Кечерткән үрти, каба.

**КАБУ II: эш кабу** *мәл.* эш уңу (удаваться, удаться, получиться, везти, повести). Эше капмаган.

**КАБЫ** [*рус.* как бы] *злт.* ...а күрмәсен(нәр), ... магайы (как бы не ...). Син кабы әйтеп куйма.

**КАБЫМНЫК** *стрл.* к.: **қабас**. Бер кабымнык эризык калмаган. Бер кабымныкны да калдырып киткән кешеләр бар бит.

**КАБЫНУ** *глз.* төпләнү, тамыр җибәрү (начинать расти, напр., после пересадки – о растениях). Гелем кабынды. Әллә кабына, әллә йук бу гел дип утырткан идем, кабынды, чачагы бик мотор (матур).

**КАБЫР** [*гар.*] *кас.* кабер (могила).

**КАБЫРГА I** *мәл.* ян, кырый (край, боковая сторона чего-либо).

**КАБЫРГА II** *шрл.* к.: **қабырға II**.

**КАБЫРГА III: кабыргалы кул** *чпр.* к.: **қабырға III: қабырғалы қул**. Туйга сawым аппарганнар, анда кабыргалы кул, бал, бөккәннәр була.

**КАБЫРЛАУ** *т.я.-крш.* 1. туплау, бер урынга җыю (собирать в кучу). Бywa җанында кабырлап җаталар сыйрларны; 2. ябу, томалау (закрыть, закутать). Эстен кабырлап куйа пар чыкмастан.

**КАБЫШЛЫК** *чст.* кабымлык, бер кабымлык (кус, один кус хлеба и т.д.). Бер-ике генә кабышлык кына, йоласына гына пешерәләр.

**КAWЫЗ** 1. *мәл., стрл., карс.* к.: **бишнәк**. Агиделкайлардан чыккан чакта, Атым тайладыла кawызга (*хал. җыр.*). – *карс.* Тирмәннең kawызын ачканнар да, бywада су кимегән. – *мәл.*; 2. *срг.* чишмә улагы (жёлоб, желобок родника). Анда kawыз куйылган, цәй сywы ага.

**KAWЫК** *тмн.* 1. куык – лампа өчен (пузырь – для лампы); 2. челтәр яки ефәк шәлләрдә кабарып-кабарып торган бизәкләр (выпуклые рисунки ажурных платков). Ак, kawыклы-kawыклы шәлләрем бар иде, зур. Kawыклы, озын чәчәкле, ак шәлләр булган.

**КАВЫМ** *м.-кар.* кабак (тыква). Татар кабак ди, безнечә кавым.

**KAWЫМ-КАБИЛӘ** *лмб., карс.*, **KAWЫМ-ЫРУ** *карс.* к.: **нәсел-асаб**. Kawым-кабилә, ыру-тамырың бардыр. – *лмб.* Борыңгылар бит kawым-ыруны тикшерәләр. – *карс.*

**KAWЫРСЫН** *байк.* пластмасса. Kawырсын күбәтә.

**КАГАЙУ I** *мәл., лмб., тмн., срг.* алҗу, тилмерү, зарыгып бетү (утомиться, томиться). Син килгәнне көтә-көтә кагайырмын да. – *тмн.*

**кагайып тыру, кагайып утыру** *мәл.* хәрәкәтсезлектән катып калу (закоченеть от обездвиживания). Тик тыргынча кагайып, барып кат′.

**КАГАЙУ II** 1. *миш.д.* каклану (вялиться, сушиться). Кагайган ит. – *тмн.*; 2. *мәл., лмб., тмн., срг.* к.: **кәкшү**. Көлтәләрне кагайырга утыртып куй. – *срг.*

**КАГАУ** *миш.д.* тилгән (коршун). Кагау кен дә бер цебешне ырлый. – *чст.* Үрдәк балаларын ницә? – Зидәүләр! Кагау алырлык тегел әлдә. – *срг.* Чебешен кагау алса, калган тавык кытаклый. – *хвл.*

**КАГУ I 1.** *хвл., кузн.* селкетү, селкетүдән хәлсезләнү, күңел болгану (укачивать, быть в плохом состоянии от качки на санях, поезде и машине). Ызак кат′тык, какты, йаман булды үземә. – *хвл.*; **2.** *мәл.* чаңгының, чана табанының эздән, юлдан читкә тайпылуы, салулавы (раскатываться, съезжать на ухабах – о санях и лыжах). Таудан төшкәндә лыжыны кага.

**КАГУ II 1.** *карс., кузн., срг., тмн., лмб., мәл., шрл.* болгатып пешерү, болгатып торып кайнату (варить перемешивая – о каше, толокне; кипятить – о молоке). Боламык кына, атә, кагабыз. – *тмн.* Йә, манный кагасызмы? Сөткә манный каксаң да йакшы вет. – *карс.* Сөт кагабыз. – *срг.* Боламык какпык тиз генә. – *шрл.*; **2.** *карс., срг., стрл.* изү, туглау (месить, замесить, смешать). Торгас ук какпым киймагымны, килдем дә пешердем. – *карс.* Камыр кагабыз. Кимагымны какпым энде. – *срг.* Борчак күптермәсе, ныгытып каксаң, әй тәмне булып китә. – *стрл.*; **3.** *кузн., хвл., чст.* исерткеч эчемлек эчү (выпить вино, водку). Какмыйынчы йырларгыйдең. – *кузн.* Әз гени каккан, йатып тора. – *чст.*

**КАГУ III 1.** *глз., стрл.* ашлык сугу – чабагач белән (молотить цепом). Ике йаклап дүртәр кеше кага иде чиплар мынан, чолбанмый инде. – *глз.*; **2.** *стрл.* су чыгару өчен җиргә труба төшерү (вбить трубу в землю для выкачивания воды). Йортларында гына какпылар, сувы баг инде йакшы. Өчдүрт митырга какса да су чыга.

**КАГУРЦЫН** *чпр.* каурый, кавырсын (птичье перо). Каз йылыкканда кагурцыннарын атына зыйалар иде, аннары алардан таба майлый торган канат йасыйлар.

**КАГЫЗ** [*гар.*] *кузн., чст.* к.: **қийәгәз**. Ак кагызга йаза йырларын, көңелдән бикли. – *чст.* Зур кагыз икән. – *кузн.*

**КАГЫЛМАЛЫ** *чпр.* салулы – юл турында (ухабистый – о дороге). Салам алып кат′канда, кагылмалы йулда цана ал′анып капланды, йарый әле бастырык белән бәләгән идек, ылау тузмады.

**КАГЫЛУ** *кузн.* салулау – чана турында (раскатываться – о санях).

**КАГЫРСЫН** *срг.* к.: **кагурцын**. Элек кагырсын белән йазганнар.

**КАГЫТ** *тмн., чпр., хвл., мәл., чст., стрл., чст.-крш., срг., шрл.* как (сухая тонкая пастила домашнего приготовления). Кагыт саламысыз чәйегезгә. – *тмн.* Кагытны эләктән дә, карлыганнан да кыйалар. Карлыган кагыты белән чәй эчтек. – *чст.* Алма кагыты җәйдем. – *хвл.* Мәләшнең кагытын койабыз. – *стрл.* Кагыт салыб эч. – *чст.-крш.* Алма кагытлары җәйгән идем. – *мәл.* Кагыт белән ме эцәсен цәйне? – *срг.* Качан гына ашадыг әле балан кагытын. – *шрл.*

**кагыт киптерү** *хвл.* как кою (приготовлять пастилу). Бик күп алма кагыты киптердем.

**КАДАГЫЧЛЫ** *кузн.* к.: **қазаwычлы**. Кадагычлы үлән.

**КАДАК** *күрш.* камыл, печән чапкач калган каты сабак төпләре (стерня, – у злаковых и у трав). Насуклар сага бирем, кадаклар бардыр пецән зима.

**КАДАЛУ 1.** *хвл.* шырпы керү (занозить). Кулыма кадалган; **2.** *лмб.* ашаганда яки эчкәндә чәчәү (поперхнуться во время еды или питья).

**КАДАУ I 1.** *лмб.* кагу (вбить, вбивать). Такта китерергә дә ике түндәк кадарга җиргә, идән була; **2.** *клд.* тагу (пришить). Темә кададым. Акча кадаган хасидә элләр иде мун′нарына.

**КАДАУ II** *т.я.-крш.* элгеч (вешалка). Вана, жинпырын кадауда, шаннан алып кит.

**КАДИМИДАН** [*гар.+афф.* -дан] *чст.* борынгыдан (издревле, издавна). Кадимидан бирле кодакодагыйлык булган.

**КАДУЛА** [*рус.* колода] *срг., мәл., чст.* терлекләргә эчертү, болгатып ашату өчен бүрәнәдән чокып ясалган улак (колода для скотины). Кадулага су салыгыз, атлар су эчсеннәр. – *чст.*

**КАДУШКА** [*рус.*] *кузн.* к.: **ләнгәц**; чаг.: **балайак I, 2**. Кадушкасы белән камыр булган пиз башта.

**КАЖУК** [*рус.* кожух] *лмб.* мич куышы (печурка, углубление в печи, где сушат, греют что-нибудь); чаг.: **қучқар 2**.

**КАҖАКАНА** [*гар.+ фарс.*] *глз.* бәдрәф (уборная). Ана сат турда безнеке каҗакана.

**КАҖГЫЛДЫЙ** *лмб.* к.: **ахың**.

**КАҖЕР** [*гар.*] *чст.-крш.* хәзер (сейчас). Кил, Үгәпи, утыр, җырлыйбыз каҗер.

**КАҖУМКА** [*гар.*] *тмн.* **1.** к.: **бүлмәч 2**. Килен энде каҗумкада гына ашаган, кан′ы-кан′атасы йанында утырмый; **2.** к.: **кәберкә**.

**КАҖУННАЙ** [*рус.* казённый] *трбс.* зур урман (большой лес). Каҗуннай қырыннан қайтып киләм, тей.

**каз I** (гусь):

**каз быpны** *кузн.*, **каз быpнысы** *тмн.* к.: **гөләф**.

**казлар эсте** *карс.* каз ашы (вечеринка, устроенная вечером после коллективного выщипывания гусей). Асыл гына иттереп артымнан йери, казлар эстенә барабыз, вичуркаларга барабыз.

**каз тәпийе** *чст.* к.: **қазыйақ 1**.

**КАЗ II 1.** *стрл.* тары көлтәсеннән куелган чүмәлә (копна из снопов проса). Тары көлтәсен казга куйалар ыйы; **2.** *кузн.* дүрт көлтәдән куела торган өем (форма временного сложения снопов); чаг.: **быравык**.

**каз башы** *срг.* егерме биш-илле көлтәдән куела торган өем (копна из двадцати пяти-пятидесяти снопов).

**каз ойасы** *срг., чст., кузн.* дүрт көлтәдән куела торган өем (копна из четырёх снопов). Кипсенгә, кагайырга каз ойасына куйабыз. – *срг.*

**КАЗАЙАК** *карс., мәл.* йонлы бәрәңге (бутень клубненосный).

**КАЗАК I** *кузн.* к.: **бәпкә I, 1**; Көлтәләрне бәлиләр, казаклар куйалар, арыш келтәсен дә казакка куйалар, тугызны утырталар да берсен каплыйлар.

**КАЗАК II 1.** *стрл.* к.: **қазақ I, 1**; **2.** *срг.* печтерелгән айгыр, алаша (мерин).

**КАЗАН 1.** *кузн.* чиләк (ведро); **2.** *хвл.* су төбендә барлыкка килгән чокыр, чоңгыл (омут, пучина).

**казан асты куйу** *лмб.* пешерергә салу, пешәргә кую, пешерә башлау – аш турында (заварить,

начинать варить, поставить вариться – о пище, о еде).

**КАЗАН-АЙАК** *кузн.* **1.** казан тирәсе (место около котла; котёл и связанные с ним посуда, пища и др.); **2.** аш-су (продукты питания, пища). Казан-айак кулыбызда, килен хезмәте – оҗмах нәүбәте.

**КАЗАНКА** [*гар.* + *рус. суфф.* -ка] *эчк.* к.: **кәзәнкә 2.**

**КАЗГАНУ** *тмн., лмб.* **1.** тырышу, тырышып эшләү (стараться, усердно трудиться, вложить чересчур много сил). Илле йыл казгандым. – *тмн.* Картларча казгана башлады. Казгандың инде, укыдың? – *лмб.*; **2.** максатка ирешү (добиться, достичь цели). Ул заф(лык)ны үзенә казганды. – *тмн.*

**КАЗГЫЛДИЧ** *клд.*, **КАЗГЫЛДЫЙ** [*рус.* козелец] *лмб.* к.: **ахыҡ.** Казгылдичның сабагын суйасың да ашыйсың, зур булып үсә, урман буйларындарак, сазамлыкларда үсә, сары чәчәкле, кызынчыкрак үсә. – *клд.* Казгылдый чабырта гыбаларны.– *лмб.*

**КАЗЛӘПӘ** [*тат.* + *рус.*] *кузн.* казаяк, каз үләне (гусиная лапка). Казләпә аший идек, сазда үсә, сазымлыкта, каз үләне дип тә әтелә анарга.

**КАЗЛИЙАК** *срг.* к.: **аҡбаш.**

**КАЗЛИЦ, КАЗЛИЧ** [*рус.* козелец] *срг.* к.: **ирен I: ирен бозгыч.** Ура да ура арыдым, Казличлы йерләргә тарыдым (*хал. җыр.*).

**КАЗНА I** [*гар.*] *тмн.* к.: **бүлмәч 2.** Казнада гына эчәрбез чәйне. Пукмар казнада тыра.

**КАЗНА II** [*гар.*] *срг.* элек: җир өчен түләтелә торган салым (в старину: налог на землю). Йәй башы казна, кече казна, ике мәртәбә түлиләр иде. Йиргә казна күп килеп, халык түли алмаса, шул көйө кала иде.

**КАЗНАК** [*гар.*] *байк., стрл.* к.: **қазнақ 1.**

**КАЗНИЧ** [*рус.* козелец] *стрл., шрл.* к.: **ирен I: ирен бозгыч.** Казнич ашаганмы, ирнесе әләшәгән. – *стрл.*

**КАЗ'ОМКА** [*гар.* + *рус. суфф.* -ка] *тмн., күрш.* к.: **бүлмәч 2.** Каз'омкада соса иде ашарга кан'нам. – *тмн.*

**КАЗУ** *лмб., тмн.* чоку (долбить). Агачтан казыган шawасы әлдә дә тора. – *лмб.* Тигәнә, казылган бу. Ыстуйкаларга кийарлар тозлаганнар, имәннән казыйлар иде. – *тмн.*

**КАЗ'УМКА** *күрш.*, **КАЗ'УН'КА** [*гар.* + *рус. суфф.* -ка] *тмн.* к.: **бүлмәч 2.** Каз'умкада утырадыр килен.

**КАЗЫ 1.** *тмн., срг., хвл., лмб.* к.: **қазы; 2.** *шрл.* атның сыртындагы мае (жир на спинной части лошади). Сугымыгызның казысы кул йасуwы хәтле әнде, суйырга wакыт.

**КАЗЫЙАК** *срг.* к.: **казайак.**

**КАЗЫР** [*гар.*] *т.кам.-крш., чст.-крш.* к.: **қаҗер.** Казыр чыгам. – *чст.-крш.*

**КАЙА 1.** *миш.д.* кайда (где); **2.** *мәл., чст.* кайчак, кайвакыт (иногда, временами). Кайа бик йакшы сүләшә, кайа мине дә танымый. – *мәл.*

**КАЙАГЫ** *стрл.* кайдагы (откуда). Бу кызларым кайагы кызлар?

**КАЙА-КАЙА** *тмн., срг., чст., мәл.* **1.** кайчак, кайвакыт (иногда, временами). Кайа-кайа мин дә биргәләрмен. – *мәл.* Кайа-кайа без дә чабарбыз (печән). – *тмн.* Кайа-кайа эшләкли, сирәк-мирәк кенә. – *чст.*; **2.** кайбер урында, урыны-урыны белән (кое-где, местами). Эләк кайа-кайа бар, кайа-кайа йук. – *срг.*

**КАЙАНКИ** *глз.* к.: **қайки 1.** Кайанки барангы аласикән?

**КАЙАУ** *стрл.* бал кортының угы (жало пчелы). Йуwынса да кайawы калган, кайawын алмаганлыктан шешенгән ул.

**КАЙГАНАК** *чст.* сөткә изеп кыздырылган йомырка (яичница на молоке).

**КАЙГЫРТУ** *мәл.* борчылу, кайгыру (беспокоиться). Кат'а тырган сәгатендә кат'маса, кайгырта башлыйм. Бызау ашый, кайгыртма.

**КАЙДИ** *срг.* кайдагы, нинди (какой, который). – Мин Казаннан килдем. – Кайди Казаннан?

**КАЙКЕН** *м.-кар., шрл.* шушы арада, шушы көннәрдә (на днях, намедни). Кайкен кетүгә чыккан идем. – *шрл.* Кайкен бардым: берсе карап тора маңа (төлке). – *м.-кар.*

**КАЙКЕННЕ** *кмшл.* беркөн (на днях, недавно). Кайкенне Найләгә күрсәттем.

**КАЙКӨН** *хвл., кузн.* к.: **кайкен.** Кайкөн килә әпәй, йайлы була. – *кузн.*

**КАЙКӨННЕ** *кузн., мәл.* к.: **кайкенне.** Әл дә кайкөнне генә барган идем. – *мәл.* Кайкөнне дә бирдем, бөгөн дә бирсәм. – *кузн.*

**КАЙМА** *кузн.* шәл чите (кромка шали, которая связывается отдельно и пришивается). Шәлне кас'ысы каймасы белән бергә бәли.

**к а й м а к** (сметана):

**каймаг атлагыч** *клд., хвл.* к.: **атawыч.** Каймаг атлагыч була, эчендә тәрмән канаты кебек нәстәсе була. – *клд.* Агачтан каймаг атлагыч йасыйлар иде. – *хвл.*

**кызган каймак** *карс.*, **пешкән каймак** *срг.* мичтә кайнатылган сөт каймагы (сметана, снятая с топлёного молока). Кызган каймак бирдем кунакларына.

**чечели каймак** *кузн.* чи, кайнамаган сөттән алынган каймак (сметана, снятая с сырого молока).

**КАЙНА** *чст., стрл.* к.: **биана(й).** Бишектәге бишкә төрләнә, кайнам бар чакта сәке ийе. – *стрл.* Кайна күwен дә күләргә кирәк, ир күwен дә күләргә кирәк. – *чст.*

**КАЙНАГАЦ** *әҗе.*, **КАЙНАГАЧ** *м.-кар.* каенигәч (старшая сестра мужа или жены).

**КАЙНАРЛАНУ** *т.кам.-крш.* к.: **йерәкләнү.** Бабай, бабай, кайнарланма, йурый гына әйттем, ди.

**к а й н а у** (кипеть):

**кайнау кертү** *срг.* кайнатып чыгару (дать закипеть). Кайнау кертеп куйган булсам иде, пешкән булыр иде.

**КАЙНАШТЫРУ** *чст.* маташтыру, эшләгән булу, эшләү, итү (делать, заниматься, возиться, пытаться). Радиwаны шылай кайнаштыра идем дә сүли иде. Сез ашадыгыз, без дә кайнаштырыйк микән.

**КАЙНӘ** *стрл.* к.: **бийана(й).** Кайнәсе киленгә май салмый, ди.

**КАЙНЫ** *т.я.-крш.* **1.** к.: **биата(й); 2.** хатының этисе (отец жены). Җегет кайныларына үгез апарып бирә.

**КАЙСАК** [*рус.*] *мәл.* к.: **йәйәк II.** Тәрәз кайсагына агачларым йитми.

**к а й с ы** (который):

**кайсы көнне** *стрл.* к.: **кайкенне.** Кайсы көнне мине чакканнар ийе кортлар, йегерме булгандыр.

**КАЙСЫ-КАЙСЫ** *карс.* кайбер (иной, некоторый, кое-какой). Хазер кайсы-кайсы нәчәлләрне шул кешеләргә ышатам.

**КАЙСЫЛАЙ** *стрл.* к.: **қайсылай.** Кайсылай әтергә дә белмим.

**КАЙТА** [*удм.?*] *нокр., глз.* утын агачы (полено).

**КАЙТАРМА: кийәү кайтармасы** *чст.-крш.* к.: **қайтарма: кийәү қайтармасы.** Қызны бирәләр дә кийәү кайтармасына кызны җәшәләр.

**КАЙТЫШ** *тмн.* кечерәк (меньше по размеру, росту). Алма буйга синнән бераз гына кайтыш булыр.

**КАЙЧАН** *стрл.* кайвакыт (иногда). Әтәләр кайчан. Шомыртка баралар кайчан.

**КАЙЧУРА** *хвл.*, **КАЙЧУРЫ** *кузн.* кайчан, кай арада (когда, когда только). Кайчура килдең? – *хвл.* Кайчуры шартлап тутырган дөнйаны. – *кузн.*

**КАЙШКӘ** *срг.* кая, кайсы урынга (куда, на какое место). Кесәмдә иде, аны кайшкәдер алып куйдым.

**КАЙШТӘ** *срг.* к.: **каштә.**

**КАЙЫЗ** *кузн., лмб.* карама (вяз). Кайыз агачы. – *кузн.* Кайыз да кистек, тал да, утынга йарыйлар вет. – *лмб.*

**КАЙЫНСАР** *чст.* каенлык (березняк). Кайынсарда җиләк күп була.

**КАЙЫРМА** *шрл.* нечкәрәк төз агач (кол, прямая жердь). Кайырма китереп урманнан рам йасарга.

**КАЙЫРТКЫҢ** *срг.* бәрәңгенең төбен кузгатып, әйләндереп чыга торган сука (вид сохи для копания картофеля; картофелекопалка). Бәрәңге кырына иң беренче башлап кайырткыҗ цыга.

**КАЙЫРТУ** *срг.* махсус сука белән бәрәңгене казу, төбен әйләндерү (копать, выкопать картофель при помощи специальной сохи). Кайырткыҗ бәрәңгене кайырта, аның артыннан кешеләр бәрәңгене цуплиләр.

**КАЙЫРУ 1.** *срг., кузн.* казу (копать). Йир кайыра идек, тучны усат кайырганда килде. – *срг.* Йирне кайырабыз көрәк белән. – *кузн.*; **2.** *срг., карс.* тырнау, җәрәхәтләү (поранить, царапать). Жуwылгы алган да, аның ычында дир шыплар, битен кайырган. – *карс.* Икайагымны да кайырыпмын awышынып йереп. – *срг.*

**күлмәк кайыру** *карс.* кыйнау (бить). Мунчага итеп күлмәкләрен кайыралар икән аталары.

**КАЙЫРЫЛУ** *срг.* тырналу, җыртылу, җәрәхәтләнү (пораниться, поцарапаться). Ләпәм кайырылды, шыпмы булган.

**КАЙЫС** *кузн., лмб.* к.: **кайыз.** Кайыснын җирекнекенә пахуж йапрагы. – *лмб.*

**КАЙЫШ** *тмн., м.-кар.* к.: **қайыш I, 1.** Кайыш бийәли. – *м.-кар.* Кәвешме, батинкамы, бийек табанны да, кайышныкы да. – *тмн.*

**кайыш айак** *срг.* нечкә, кәкре, гарип аяк (тонкая и кривая нога). Ике кайыш айак йегетләр була (*әкият.*).

**к а к** (пастила):

**как теше** *чпр.* к.: **чепчәги.** Сawымга как теше итә.

**КАКАЙ** [*рус.* кака] *мәл.* начар (плохо). Ун сум какай мәллә?

**КАКАЙУ** *хвл.* боегу (приуныть, сгрустнуть). Ни какайдың?

**какайып утыру** *хвл.* боегып, интегеп утыру (мучиться, томиться, торчать); чаг.: **қағайу: қағайып утыру.** Йарты сәгат′ ишек төбендә какайып утырдым.

**КАКАЛ** [*чув.* кăвакал] *нрл.* к.: **куwакал.**

**КАКАШ** *срг.* эремчек пәрәмәче (ватрушка с творогом, шаньга). Табага камырны җәйеп, өстенә тварук йагып пешергән какаш була.

**КАКЛАНУ** *шрл.* ябыгу (худеть). Апай, бик каклангансың син, ди.

**КАКЛАУ** *мәл.* чагу – кычыткан турында (жалить – о крапиве). Кечеткән каклый.

**КАКМАЙ: какмай итү** *мәл.* чүрәкәй уены вакытында кыекбашны җиргә төшермичә чүрәкәй таягы белән сикертеп тору (постоянно подбрасывая наверх, не дать чижику упасть на землю). Чижыкны гына какмай итәләр.

**КАКРА** [*морд.*] *тмн.* к.: **ишегалды.** Какрада тора сулар. Какрадагы утынны керт.

**КАКУЛ** [*рус.* хохол] *карс., срг., чпр., хвл.* **1.** бүрек – кошларда (хохолок – у птиц). Какуллы тавык. – *хвл.* Казынын какуле бар. – *карс.* Агиделкәйләрдән агып килә Галанский казның какулы (*хал. җыр.*). – *срг.*; **2.** чук (кисть на шапке, на конской сбруе). Шапканын какулы йезелеп тешкән. – *хвл.* Ай-һай, астымдагы туры да атым, Йал арткыры салган какулы (*бор. бәет.*). – *срг.*

**КАКУЛ′ЛЕ** [*рус.+афф.* -ле] *мәл.* бүрекле (хохлатый). Какул′ле tawык.

**КАКУРТКЫЙ** [*рус.* кокурка] *хвл.* әче камырдан пешерелгән вак-вак түгәрәк ипиләр (мелкие хлебцы из дрожжевого теста).

**КАКУШКА** [*рус.* кокошник] *нокр.* калфак урынына киелә торган кечкенә түбәтәй, такыя (женский головной убор: маленькая тюбетейка, надеваемая на макушку вместо калфака).

**КАКШАУ** *глз.* к.: **йадаулану.** Нигә былай какшадың, дим. Анда бик тазайы, какшаган, быркысы гына калган. Эсседә ашамыйлар алар, какшыйлар (сыерлар).

**к а к ы** (свербига):

**татар какысы** *стрл.* к.: **ахық.**

**урыс какысы** *стрл.* урман какысы (свербига лесная).

**КАЛАWЫС 1.** *төм., тбл., твр., саз.я., тара.* махсус бөрмәле-баулы кечкенә капчык, сумка (специально изготовленный мешочек из холста с нарядными тесёмками, с кисточками на конце). Калawыс булган көйәс ийе, қунаққа баргында пәтер салыптылар. – *төм.*; **2.** *саз.я.* полиэтилен капчык, сумка (полиэтиленовый пакет, сумка).

**КАЛ′АГА** [*удм.*] *глз.* гәрәнкә (брюква). Кал′агаларга су түктем. Кал′аганы кош буйынча хайwан ашар.

**КАЛАЙМАГА** [*рус.* колымага] *кмшл.* печән яки салам ташый торган читән ящиклы арба (телега с плетёным ящиком для возки сена или соломы).

**КАЛАК I 1.** *чпр.* агач көрәк (деревянная лопата). Бахилда аран йанында бар калак, калак белән цыгарыга алманы; **2.** *хвл.* юка агач соскыч (тонкий деревянный совок).

**агач калак** *хвл.* к.: **калак I, 2.** Агач калак он ала торган cawук кебек, нечкә була ул.

**КАЛАК II** *мәл., срг.* кузак (стручок). Борчак калагы ашарга цыккыз, кызлар. – *срг.*

**КАЛ′АКАЙ** *әстр.* күмәч (булочка). Сөтнең сары суын салып ачытады кал′акайны.

**КАЛАКЛАЙ: калаклай ашау** *т.я.-крш.* чилепешле итеп пешереп, калак белән ашау – йомырка турында (есть яйцо всмятку). Калаклай ашисынмы җымырканы?

**КАЛАКЛАНУ** *мәл., срг.* кузаклану (образовывать стручки, стручиться). Борчак калаклана башлаган инде. – *срг.*

**КАЛАКУЛ** *чст., әстр.*, **КАЛАКУН** [*рус.* колокол] *мәл.* к.: **җиңгеле.** Арци была килдем, калакуллар белә дугада. – *чст.* Дәрескә калакун булдымәле? – *мәл.*

**КАЛАМА** [*рус.* колымага] *чст., минз.* ашлык ташый торган әрҗәле арба (телега с ящиком для возки зерна). Қапчығыңның борчағы аға, калама төбеннән аға. – *минз.*

**КАЛАМАШКА** [*рус.* колымажка] *чст., чпр.* арба (телега).

**КАЛАНКА** [*рус.*] *брб.д.* бала итәк (волан). Көйләккә каланкалар, ләнтәләр сала тыганнар.

**КАЛАНУК** [*рус.* колонок – зверёк из рода хорьков] *злт.* агач башында була һәм шуннан кешегә һөҗүм итә торган песи төсле җәнлек; селәүсен? (рысь?).

**КАЛАҢҚУЛ** [*рус.*] *карс.* к.: **җиңгеле.**

**КАЛАПУШ** [*фарс.* + *фарс.*] *стрл.* к.: **кәпәч 1.** Калапушың урыймы, Баш түбәңә йарыймы (*хал. җыр.*).

**КАЛАТ** *м.-кар.* җилән (азям).

**пустау калат** *т.я.-крш.* к.: **тулак: тулак чапан.**

**КАЛАЧ 1.** *стрл.* ачыга изгән бодай камырыннан, сигезлегә охшатып, табада пешерелә торган азык (крендель в виде восьмёрки из кислого теста); **2.** *брб.д.* ипи камырыннан уртасын тишекле итеп пешерелгән камыр ашы (один из видов мучного изделия: лепёшка из хлебного теста с дыркой в середине).

**КАЛАЧИК** *тара.* бублик, клиндер (бублик).

**КАЛӘМ** [*гар.*] *шрл.* карандаш. Каләмен бәләп куйган.

**КАЛӘМФЕР** [*гар.*] *т.кам.-крш., мәл.* к.: **кәләмпер.** Каләмферләр, ике төрле канфит. – *мәл.*

**КАЛБАСА** *каз.ар.-крш.* к.: **тутыртма II, 2.** Без калбаса тутырабыз, мәсәрупкыдан ит үткәрәбез, суган, борыч салабыз, йарма бүрттерәбез, эчәгенең, бер башын бәйләп, бер башыннан тутырабыз.

**КАЛГУ** *әҗе.* черем итеп алу (дремать). Берцәк затам да калгыймын.

**КАЛГЫ** *миш.д.* талкыш (костра, кострика). Калгысын селкә пәзинен. – *чпр.* Әлэнне, талкыгац, түwәләр, калгылар кыйыла. Әлән калгысы. Киндераш калгысы. – *срг.* Тарагач калгылар тешәдер. – *лмб.* Ишегалдым калгылы, Су сиб, җанийем, дымайсын (*хал. җыр.*). – *кузн.*

**КАЛГЫНУ** *лмб.* селкенү, селкенеп тору – өстәл һ.б. турында (шататься, качаться – о столе и т.д.). Эстәл калгына, әйбер кыстыр.

**КАЛГЫШ** *карс.* к.: **калгы.** Талкийлар, калгышы кыйыла.

**КАЛДА** *карс.* к.: **абзар: абзар алды.**

**КАЛДАЗ** *лмб.* к.: **абзар 3.**

**КАЛДЫ** *мәл., чст., тмн., чпр.* к.: **абзар: абзар алды.** Калдыны азбар алдына куралардан гына йасыйлар аны.– *чст.* Калдыларында тездән бата, герәз.– *тмн.* Әwәле заманда сыйырны калдыда cawалар иде. – *чпр.*

**КАЛДЫЗ** *тмн., кузн.* к.: **абзар 3.**

**КАЛҖА: җомортка калҗасы** *м.-кар.* к.: **кайганақ.** Җомортка калҗасы сөт белән бичкә куйабыз.

**КАЛИЙАНДЫР** [*рус.* кориандр] *бәр.* к.: **бушлама.** Бушлама дип тә, калийандыр дип тә әйтәләр.

**КАЛИНКА** [*рус.*] *стрл.* буын (поколение, колено). Икенче калинкага киткән.

**КАЛКУ 1.** *лмб., хвл., тмн., карс.* күтәрелү, кабару – камыр турында (подниматься, всходить – о тесте). Ачылыйга басам, суң калка, бәк йакшы була. – *тмн.* Куйдым тенә чүпрәгә, атладым, шул арада инде ул калка. – *карс.* Кывашнәң калкамы? – *лмб.* Камырың калкмыйча, пичеңе кабызма. – *хвл.*; **2.** *клд.* чыгу – шеш турында (опухать). Шул тешемә шишка калкты, шының бийеклеге. Кылаг артына шишка калка мының.

**КАЛКЫ** *чпр.* к.: **калгы.**

**КАЛКЫТУ** *лмб.* селкетү (трясти, шатать, шевелить). Калкытма эстәлне.

**к а л о ш** (галоши):

**калош пыйма, калош пыймасы** *брб.д.* к.: **галуш 1.** Сыwыг полса, калош пыймасы кийәмен.

**КАЛМАК** *стрл.* тулы – кеше турында (полный – о человеке). Симез генә, калмак кына, йәш кенә.

**к а л п а к** (калфак):

**баскан калпак** *байк.* укадан чәчәк төшерелгән калфак (калфак, вышитый канителью). Баскан калпаклар кийәбез ий.

**кукиш калпак** *срг.* кечкенә калфак (калфак маленьких размеров). Кыз тешерәләр арганнар белә, кыз кукиш калфак кигән, шарыплар бәләгән, пар алашада, алннарында кучыр.

**кырук калпак** *срг.* түгәрәк формада эшләнгән калфак (калфак круглой формы).

**чәчәкле калпак** *күрш.* чачаклы калфак (калфак с бахромой).

**КАЛТА I** *каз.ар.-крш.* к.: **қалта II, 1.** Калта дилер, менә күлмәкнең итегене тагы бөрөп куйалар.

**КАЛТА II** *влгг.* янчык, портмоне (кошелёк, портмоне). Калтадан кара акчаларны.

**КАЛУ** *чпр.* туктау, басылу, тыну (перестать, стихать); чаг.: **тилыгу 1.** Зил калмаганмы?

**КАЛУДА** [*рус.* колода] *лмб., кузн., хвл., мәл., чст., клд., баст.* **1.** к.: **кадула.** Калуданы элке калын бөрәнәне казып, ышкылыйлар иде, әлинде пылawай такта. – *клд.* Калуда – сыйырга,

алашага болгарга. – *хвл.* Бу калудада терлек ашатабыз. – *мәл.* Туwарны жаратмаса, калудага җыга иде җорт ийәсе. – *лмб.*; **2.** утлык (ясли, кормушка для скота).

**КАЛ'УС, КАЛ'УСА** [*рус.* колесо] *кузн., хвл., карс., мәл.* к.: **йөгәртмә II.** Кал'услар ваны кигезмәгән, аның чәкушкасы йуг, ахыр'ы. – *карс.* Дөнйа – кал'уса, әләнә дә бер баса. – *мәл.* Бу көннәрдә кал'усаларын шиннатты. Кал'усаның йанына ызайып йата идек, хәзер инде җиңел – трактырлар. – *хвл.* Кал'усага йасый бер тыккыч. – *кузн.*

**кал'уса печән** *нокр.* к.: **бырцак: бырцак үләне.**

**КАЛУТКА** [*рус.* колодка] *чст., кузн., мәл.* калып (колодка). Итек калуткасы. – *чст.*

**болдорлы калутка** *срг.* элек: табаны калын агачтан ясалган юкә яки күн өсле аяк киеме (в старину: у деревенской бедноты обувь из лыка или кожи на толстой деревянной подошве). Болдорлы калуткадан су менми.

**КАЛУШ 1.** *мам., минз., кмшл., глз., нрл., брб.д.* к.: **галуш 1.** Җоннан калуш баса торганнар ыйы. – *мам.* Итекнең балтырын кисеб алалар да калуш булып қала. – *нрл.*; **2.** *мәл., хвл.* калош (галоши). Лакама тике калушлар кигән. – *мәл.*; **3.** *нрл., минз., хвл.* күн ботинка (кожаные ботинки, туфли). Күннән калуш теккәннәр, күн калуш қысқа қунычлы. – *нрл.*

**атулы калуш** *әстр.* читек-кәвеш (ичиги с кавушами).

**балтырлы калуш** *нрл., дөб.* кунычлы ботинка (глубокие ботинки).

**җөн калуш, кийез калушы** *глз.* к.: **галуш 1.**

**күн калуш** *трх., хвл.* к.: **калуш 3.**

**сай калуш** *хвл.* туфли.

**суқма калуш** *перм.* юкә башмак, чабата башмак (башмак, сплетённый из лыка). Суқма калуш җүкәдән йасыйсың, қунычлы калуш кебек була, бawы йуқ.

**эрҗин калуш** *трх.* к.: **калуш 2.**

**КАЛУША 1.** *клд., кузн., твр.* к.: **калуш 2.** Тәрән калушалар килгән (кибеткә). – *клд.*; **2.** *минз., стрл.* к.: **галуш 1.** Калуша кийәсеңме, сuwық бит. – *минз.*; **3.** *минз., кузн., стрл.* к.: **калуш 3.** Кайышныкы була иде калуша, асты падуша. – *кузн.*

**йон калушасы** *срг.*, **пима калуша** *клм.*, **пыйма калушасы** *баст., твр.*, **төпли калуша** *баст., кас.* к.: **галуш 1.** Төпли калуша җиңгел, уңғайлы. – *баст.*

**КАЛУШИТЕК** *минз.*, **КАЛУШЧА** *карс.* к.: **галуш 1.** Калушитек бийыл алдым әле, җылы кийеп йөрөргә, қунычын қайтарып қуйған. Калушчаны бастырабыз үдә кийәргә.

**КАЛФАК 1.** *т.я.-крш.* балалар башлыгы (сшитый чепчик); **2.** *клд.* суганның орлыкланган башы (семенной бутон на стрелке лука). Суган бар да башлы, калфаклы; **3.** *чпр.* к.: **тәлпәк 3**; **4.** *чст.* лампа конфоркасы (конфорка лампы).

**КАЛЧА I** *м.-кар.* акча янчыгы, калта (мошна, кошелёк); чаг.: **қалта 4.**

**КАЛЧА II** *брб.д.*, **КАЛЧУ** [*рус.* кольцо] *стрл., шрл.* божра (кольцо). Тезә дийләр, калчулар белә беркетелгән акыклар, акык арасында көмешләр. – *стрл.* Бишек калчуга элгән. – *шрл.*

**КАЛ'ЫБ** [*гар.*] *мәл.* күңел, йөрәк (душа, сердце). Кал'ыбында булмагач йук инде ул.

**КАЛЫЙМАШКА** [*рус.* калымажка] *чпр., мәл.* туфрак ташый торган ике тәгәрмәчле арба (двухколесная тележка для возки земли); чаг.: **калама, каламашка.**

**КАЛЫМ** *карс.* к.: **калын I, 1.**

**калым кисү** *карс.* калымны тулысынча хәл итү (окончательно договориться о калыме). Самый эшне бетереп калымны кискәндә генә дҗиңәсе бер китерә дә шуның биклек выргыта да хатлар.

**КАЛЫН I 1.** *кузн., хвл., чст.* элек: егет ягыннан кызга бирелгән кием-салым һәм әйберләр (в старину: вещевая часть выкупа, передававшегося невесте со стороны жениха); **2.** *тмн., карс.* туй расходлары өчен егет ягыннан кызның атаанасына бирелә торган акча (деньги, даваемые родственникам невесты со стороны жениха на свадебные расходы). Бер баруда әтисе ыриза булмады, икенче мәртәбә бардылар, өҗ йөз тәңкә калын алдылар, бирнә бирде, бездән каршы бүләк бирделәр. – *тмн.*

**калын кагызы** *кузн.* элек: кызга егет ягыннан бирелә торган әйберләрнең исемлеге язылган кәгазь (в старину: список, содержащий перечень вещей, передаваемых невесте со стороны жениха). Кызның атасы сырый ни кирәкне – калынга яздыра; калын кагызы йазалар.

**калын сүләү** *карс.* туй чыгымнары өчен бирелә торган акчаны килешү (договориться о сумме денег, даваемых родственникам невесты со стороны жениха на свадебные расходы). Кыргар манит калын сүлиләр иде, шыны тутыра иде.

**КАЛЫН II 1.** *чст., кузн., мәл., әҗе.* юан (толстый). Бүрәнәсе калын икән. Калын багана торган. – *мәл.* Калын тайак. Калын бүрәнә. – *кузн.* Шул сүзләрне сүләтергә калын апа килгән иде бер. – *чст.* Ылы бик калын. – *әҗе.*; **2.** *стрл.* бай (богатый). Бик калыннар ийе, дүрт сийыр.

**КАЛЫНАЙУ** *срг., әҗе.* юанаю (толстеть). Калынайдым нәктер, халем йукка, күрәсең. – *срг.* Калынайды ылы, нәзек кенәйде. – *әҗе.*

**КАМАКҮЗ** *клд.* урт (десна).

**КАМАКЫШ** *миш.д.* **1.** к.: **қамақаш.** Камакышым суйылган. – *хвл.*; **2.** мич көймәсе (свод печи). Пичнең камакышы түбән булган. – *хвл.* Камакышыннан кирпеч төште. – *әҗе.*; **3.** *м.-кар.* урт теш, азау теш (коренной зуб).

**КАМАУ 1.** *кузн., хвл., тмн., лмб., әҗе.* хөрмәтләү, олылау, кадер-хөрмәт күрсәтү (уважать, оказывать почтение, окружать заботой). Анатаны да камыйлар иде бырынны. – *лмб.* Кан'насын бер дә камамый вит. Бегенгә чике бик камап тыра ыланнарым. – *кузн.* Кан'атамны шылай камадым. – *тмн.* Олларым да камыйлар. Ир камаганны ил камый, ир какканны ил кага (*әйтем*). – *хвл.*; **2.** *лмб., хвл.* яклау, кайгырту (заступаться, заботиться). Авылны каматты, әле инде үзен каматалмый. – *хвл.* Камар агасы йук, куркар хуҗасы йук (*әйтем*). – *лмб.*; **3.** *тмн., кузн.* тыю, буйсындыру (подчинять; подавлять, усмирять). Азсаң, атаң тиз камар. – *тмн.*; **4.** *кузн.* буйсыну (подчиняться). Бу дириктырга беркем дә камамый.

**КАМАУЛЫ** *лмб., кузн.* хөрмәтле, хөрмәткә лаек, кадерле (уважаемый, почтенный); чаг.: **ардаклы**. Камаулы атакай каршында, Ничек мыңлы кевем башлыйым (*бор. җыр.*)? – *лмб.* Балаларым да камады, үзем дә камаулыга камадылар. – *кузн.*

**КАМАҺУWA** [*гар.*]: **камаһywa итеп** *дөб.* әзер итеп, эшен бетереп (приготовив, сделав готовым к употреблению). Печәнне киптереп, камаһywa итеп сарайга тутырып куйдык.

**эшне камаһywалау** *дөб.* эшне җиренә җиткереп эшләп бетерү (завершить работу полностью, выполнить, довести до конца работу). Кунакларкилгәнче өйдәге эшне камаһywалап куйдым.

**КАМАШ** *әҗе.* теш ите (десна).

**КАМБАЛАУ** [*рус.* канва + *афф.* -лау] *тпк.* канва белән чигү (вышивать на канве). Камбалап шәл бәйләдем, кара йоннан камбалап.

**КАМБАЛЫ** [*рус.* канва + *афф.* -лы] *тпк.* канва белән чигелгән (вышитый на канве). Камбалы алйапкыс, түшен кайыйлар, итәген кайыйлар.

**КАМБУРКА** [*рус.*] *төм.* конфорка (конфорка самовара). Кус сала тыгын камбуркасы йугалган самаwарныкы.

**камва** *тмн.* канва:

**камва тегү** *тмн.* к.: **камбалау**. Чигү дә чигәм, камва да тегәм, белмәгән эшем йуг иде.

**КАМЗУЛЛЫ** [*рус.* камзол + *афф.* -лы] *минз.* алды да, арты да ябык – алъяпкыч турында (с закрытым передом и спинкой – о переднике). Камзуллы алжапкыч ийе күбесенчә. Кийәүгә чыккач та бардаwай сатин апкайтып кигерде миңа, камзуллы алжапкыч.

**КАМИЛ** [*гар.*] *тбл., саз.я.* тәмам (совершенно). Камил теңкәмә тейтең. – *саз.я.*

**КАМИС** *срг.* (кызлар?) күлмәгенең бер төре (один из видов (женского?) платья). Бер терле камис, бер терле сирвәлә кийәләр иде.

**КАМКА** *кузн.* колорадо коңгызы (колорадский жук).

**камка бабай** *мәл.* к.: **бийауса**. Камка бабай, туныңны сал, зыбыныңны ки.

**КАМКА-ТУТАЙ** *лмб.*, **КАМКА-ТУТКА** *тмн., чпр.* к.: **бийауса**. Камка-тутай, оч-оч. – *лмб.* Камка-тутка, оч-оч, анаң салма пешерә, атаң ашап бетерә (*такмак*). – *тмн.*

**КАМПАСИ** [*рус.* монпансье] *бәр.* түгәрәк карамель конфет (круглая карамель). Кампаси белән чәй эчегез.

**КАМСА** [*рус.* хамса] *карс.* килька кебек вак балык (хамса). Пыл килу камса ашады. Джәмийәт вет калбасасын, камсасын, пиругын ашый да вет, эске кели.

**КАМСУЛ** [*рус.* камзол] *төм., тара.* костюм (костюм). Кысымныңкы паласыныңкы камсулы калты миңә, кәсер кәчтүн тиб әйтәтләр. – *төм.* Эцке тунны беләсеңмә, камсул ул уң. – *тара.*

**иңсес камсул** *төр.* жилет.

**КАМФУР** *бәр.*, **КАМФУРКА** *әҗе.*, **КАМФУРКЫ** [*рус.*] *хвл.* к.: **камбурка**. Камфуры бар, чәйнекне утыртасың. Сымавар башында камфуркакүршәлмабыз дип курка. (*хал. җыр.*).

**КАМЧАУ I** *т.я.-крш.* шеш (опухоль). Камчау дигән нәстә минем кызга булды, пешә ди ул, бер карчык имнәгән ийе камчау белән, китте.

**камчау булу** *чпр.* тәнгә кычыттыра торган бетчәләр чыгу (появление на теле свербящих прыщиков). Камчау булган петәй башына, кечемсери.

**КАМЧАУ II** *т.я.-крш.* көтүче сумкасы – үлән исеме (пастушья сумка – трава). Камчауның чәчәге бик йук, өч читле нәстәсе бар.

**камчы** (кнут, плеть, плётка):

**кийәү камчысы** *стрл.* к.: **йара II: йара йапрак**.

**КАМЫКАШ** *стрл.* к.: **қамақаш**.

**КАМЫЛ′** [*гар.*] *кузн., хвл.* өлкән, олы (пожилой, старший). Камыл′ инде, алтмышларда булыр. Берсе миннән дә камыл′рак. Кызым камыл′рак булса да йарар иде вет, ату әл дә йәш, унсигез генә тулды. – *кузн.* Ул борынгы кеше, бездән камыл′ырак. – *хвл.*

**КАМЫЛ′АЙУ** [*гар.* + *афф.* -айу] *кузн., хвл.* олыгаю, өлкәнәю (стать пожилым, постареть). Монда кәләше йәш кала, ул килгинчек камыл′айа. – *хвл.*

**камыр** (тесто):

**камыр җимеше** *стрл.* **1.** к.: **гөләф**; **2.** к.: **қамыраш II**.

**камыр итү** *карс.*, **камыр чылату** *глз.* камыр изү (замесить тесто, ставить тесто). Кuwашнага камыр итәбез. Угыз сөтөнә камыр чылатып тәбәгый ашамага чакыра.

**камыш** (камыш):

**камыш үлән** *лмб.* күрән, саз кыягы (осока).

**КАМЫШАЙАК** *байк.* **1.** кечкенә агач савыт (миска, маленькая деревянная чаша); **2.** к.: **дустыган 2**.

**кан I** *срг.* хан (хан):

**кан сугышы** *срг.* Рус дәүләтенең Казан ханлыгы белән сугышы (война между Русским государством и Казанским ханством).

**кан II** (кровь):

**кан йебәрү** *лмб.* берәр төрле йола уңае белән корбан чалу (обычай резать скот, колоть жертвенное животное при исполнении какого-либо обряда). Йаңа ызбага кергәндә иң алдан мачы чагасын йебәрәләр, кан йебәрәләр, таwык чалалар.

**кан йылы булу** *кузн.* теш итләре канау (кровоточение дёсен).

**кан кабару** *глз.* ачу килү (рассердиться, разозлиться). Каным кабара, тартыб алам тилебизырны.

**кан кайнау** *чст.-крш.* үзәк өзелү, бик теләү (сильно хотеть, убиваться). Сан′кам инде кан кайный, әни, алып кайтыйг инде шул сыйырны, ди.

**кан тоту** *т.я.-крш.* терлек суйганда аның канын бер савытка агызып алу (собрать в какую-либо посуду кровь во время убоя скота). Бездә терлек канын тоталар. Мыйыннан ышкыганда кан тоталар, марле куйалар да йон төшмәстән.

**КАН′** *карс., тмн., лмб., кузн., срг.* к.: **биата(й)**. Минең кан′ым йуг иде. – *карс.* Кан′ым бар, кан′анам бар. – *срг.* Кан′ым бар, кан′ам үлде. – *лмб.*

**кан′ тоту** *кузн.* тел яшерү йоласы (обычай, согласно которому запрещается невесте разговаривать с отцом и старшими братьями мужа).

**КАН′А** *карс.* к.: **бийана(й)**.

**кан′а теле** *чст.* каты билчән (бодяк полевой).

**КАН′АГА** *миш.д.* к.: **биаға(й)**.

**карт кан′ага** *кузн.* каенанаңың абыйсы (старший брат свекрови).

**КАН′АГАЛАУ** *кузн.* к.: **кан′: кан′ тоту**.

**КАНАПИЛ′** [*рус.* конопля] *кас.* киндер (конопля). Канапил′дан бау эшлийләр.

**КАН′АР 1.** *карс., кузн.* кайнар ризык, аш h.б. (горячая пища, горячее). Кан′ар ашимысыз? Хазер кан′ар пешерәм. – *карс.* Сийр башына ун сум, кичен кетүчегә кан′ар пешереб ашатабыз. – *кузн.*; **2.** *срг.* кызу, тиз кабынучан, ачулы, тиз ачынучан (сердитый, горячий). Ул бик кан′ар кеше иде.

**КАН′АРЛАНУ** *мәл.* к.: **йөрәкләну**. Мәнге кан′арланмый ул Рузы.

**КАН′АРЛАТУ** *клд.* җылыту (разогреть). Кан′арлатам, бик сывыттың инде чәйеңне.

**канат I** (крыло):

**йил канатлары** *күрш.* **1.** казның култык астындагы каурыйлары (подмышечные перья – у гуся). Йил канатларын йолкыб алып выргытасын; **2.** алъяпкыч иңбашындагы бала итәк (оборки передника на хлястике).

**КАНАТ II** *мәл.* як – урам турында (сторона – об улице). Ул урам бер генә канат.

**сүрәкә канаты** *чст.-крш.* сүрәкәнең арттагы бер өлеше (часть головного убора кряшенок).

**КАНАТ III** *стрл.* кызны кияү йортына озата баручы кызлар, хатыннар яки парлы кешеләр (супружеские пары, девушки или женщины, сопровождающие невесту в дом жениха).

**КАН′АТ** *чст., чст.-крш.* **1.** иркәләп, яратып эндәшү сүзе (форма ласкательного обращения). Син эчәсеңме, кан′ат, чәй? Сез үзегез кас′ы йакныкы, кан′ат? – *чст.*; **2.** к.: **абызастай**. Иремнең сеңлесенә акыллым кан′ат диб эттем, йараттым. – *чст.* Кан′атым, җылы су сал әле. – *чст.-крш.*

**акыллым кан′ат** *чст.* к.: **абызастай**. Иренең сеңелләренә кас′ына кана′ат тисең, бик сүгәненә акыллым кан′ат әтәсен.

**КАН′АТА** *миш.д.* к.: **бийата(й)**.

**кан′ата тоту** *хвл.* к.: **кан′: кан′ тоту**.

**КАН′АТАЛАУ** *кузн.* к.: **кан′: кан′ тоту**.

**КАН′АТКӘ** *чст.* к.: **кан′ат 1**. Йәшрәк кызлар булса кан′аткә диб әйтәләр.

**КАНАТЛЫ** *тмн., срг.* бала итәкле (с воланами). Фартыклар терле-терле, канатлы, артлы-алынлы. – *тмн.* Алнына петү шикелле кызыл тасма тыткан, канатлы була фартык. – *срг.*

**КАН′АТУ** *клд.* болгату, тавыш чыгару, җәнҗал чыгару (поднимать шум, скандалить, бузить, мутить). Кан′аткым келәми, кирәкми миңа. Шул кан′насы бетен тырмышларын кан′атучы. Денйаны кан′ата.

**КАНАТЫМ** *кузн.* к.: **кан′ат 1**. Быйыл, канатым, дөрт алмагачыбызны криса ашаган.

**КАН′АУ** *хвл., кузн., чст.* маташу, эшләү (делать что-либо, заниматься, возиться с чем-либо, иметь дело); чаг.: **қыйышу**. Габбас бәрәңге киптерү sawытында кан′и йде. Белмим ул эшне, кан′аганым йук. Сез нәрсә кан′ап йөрисез? – *чст.*

**КАН′АШУ** *чпр.* к.: **қайнашу**. Йарар инде, Гелисә, кан′ашма.

**КАНӘЙ** *чст.* кара әле, әй (смотри-ка, надо же). Канәй дип сүлиләр ийе, хазердә дә әйтәләр. Канәй, мин белмәдем выт.

**КАН′ӘНИ** *карс.* чит кешеләр белән сөйләшкәндә килен каенанаңы шулай атый (так называет сноха свою свекровь в разговоре о ней).

**КАН′ӘТИ** *карс.* чит кешеләр белән сөйләшкәндә килен каенатаны шулай атый (так называет сноха своего свёкра в разговоре о нём).

**КАНДАWЫЙ** [*рус.*] *трх.* таза, сәламәт (здоровый). Сезнең кандawый чагыгыз, йәш чагыгыз, ашый торган чагыгыз.

**КАНДАЛИЧ** *каз.ар.-крш.* к.: **бийауса**.

**КАНДЕРКОШ** [?] *мәл.* кызыл кирпеч (кирпич красный).

**КАНДИ** *чпр.* кечкенә эмаль табак (маленькое эмалированное блюдо). Кандиларны алдыңмы?

**КАНДИЙ** *чпр.* нинди (какой). Кандий гына кызыл карама Безнен урманнарда аланда (*хал. җыр.*).

**КАНДИКА** *срг.* к.: **канди**.

**КАНДИЛ′** [*гар.*] *чст.* асылмалы лампаның металлдан ясалган рамы, каркасы (рама или каркас подвесной лампы). Ылампы өстендә кыwык, асып куйа торганы кандил′, аның өстендә эшл′апасы була, пузыре аумасын эцен. Ызбада кандил′лы лампылар йуг иде.

**КАНДЫРКОШ** [?] *срг.* йолкынган кош (выщипанная птица). Кан′иш эwе – кандыркош, Ана эwе – тутый кыш (*бәет.*). Кандыркош галиш инде, йылкынган кош.

**КАН′Е** *срг.* кая әле (ну-ка). Кан′е, эцегез берцәк.

**КАНDУЛ** [*рус.*камзол] *минз.* камзул (камзол). Күлмәкләр, бишмәтләр, кандул бәрхеттән китерә кийәү.

**КАН′ИШ 1.** *карс.* к.: **биана(й)**. Шунда (театрда) мин кан′иш булыб ун′адым; **2.** *стрл.* хатыныңың туганнары (родственники жены). Казанда минем кан′иш бар, хатынның тутасының малайы; **3.** *срг.* хатынга иренең бергә тора торган туганнары (родня мужа). Анарга йаман кан′иш әләкте. Каты кан′иш иде, эре, кырыс иде. Мин килеп төшкән идем кан′ишемә унберенце кешегә.

**КАН′ИШЛАТУ** *кузн.* каенанаңы, каенатаны хөрмәт иттерү, аларга буйсындыру (заставить уважать и подчиняться родне мужа). Кан′ишлаталар иде, кан′ана-кан′ата камау була иде, әле исләре китә!

**КАН′ИШЛАУ** *кузн.* к.: **кан′: кан′ тоту**.

**КАНКА** [*рус.*] *күрш.* күркә (индюк). Алаша да тытабыз, сир, куй, үрдәк, канка.

**КАН′-КАА** *тмн.* каядыр (куда-то). Хаз′ыр чыкты кан′-каадыр.

**КАН′-КААН** *кузн.* к.: **кан′-кайан**. Берлеләрне бетәмән, кан′-каан аксата (ялгыша) да куйа (укучы турында).

**КАН′-КАЙА** *тмн., кузн., хвл., мәл.* әллә кая, еракка (вон откуда, вон куда; издалека). Кан′-кайа килгән. Үзләре кан′-кайа чабалар.

**КАН′-КАЙАН** *тмн., кузн., хвл., мәл.* каяндыр, әллә кайдан (откуда-то, невесть откуда).

**КАН′-КАР′Ы** *тмн.* каян ук, ерактан (вон откуда, издалека). Кан′-кар′ы килгәннәр.

**КАН′-КАЧАН** *тмн., кузн., хвл., мәл.* әллә кай-

чан, күптән, кайвакытта (давно, с давних пор, давным-давно). Кан′-качан инде ул эшли. – *тмн.* Китевенә кан′-качан. – *хвл.*

**КАНКӨН** *т.я.-крш., м.-кар.* к.: **қаңкөн**.

**КАН′НА, КАН′Н′А** *миш. д.* к.: **биана(й)**. Килен казан аса, бер кашык тыс сала; аның артыннан кан′на барып сала ашка бер кашык тызны. – *чст.* Кан′насы калды дүрт ылан белән. – *кузн.* Казанда да кан′наларын йаратмыйлармы шылай? – *мәл.* Кан′-кан′н′ага бирә падаркалар. – *карс.*

**кан′н′а күрү** *хвл.* яшь киленнең каенана белән беренче күрешүе (первая встреча невестки со свекровью).

**КАН′-НӘСТӘ** *срг., кузн., хвл.* әллә нәрсә, әллә ни, нәрсәдер, нидер (что-то, неизвестно что). Кан′-нәстә булса булган, килмәгән. – *срг.* Кан′-нәстә атте шында. – *хвл.*

**КАН′-НИ 1.** *тмн., кузн., лмб., хвл.* күп, әллә ничаклы, әллә никадәр (много, невесть сколько). Бак, кан′-ни йаздың. Кан′-ни бездә бу үләп. – *тмн.* Бер кабарга кан′-ни бирерсең. – *лмб.* Йеределәр кан′-ни халык. Үз арадан да табабыз, кан′-ни кирәкми. – *кузн.*; **2.** *тмн., кузн., хвл., мәл.* нәрсәдер, нидер, әллә ни (что-то, неизвестно что). Кан′-ни этермен ни дә. – *мәл.* Кан′-ни, ахр′ы, жармыдыр суккан үзен. – *хвл.* Кан′-ни салкын бәрде. – *кузн.*; **3.** *лмб.* әгәр ...са (вдруг, а если). Кычкырып сүләмәгез, кан′-ни уйаныр.

**КАН′-НИГӘ** *лмб.* нигә, бернигә (ни во что). Кан′-нигә дә алмыйлар әткәнне ыланшаклар.

**КАН′-НИНДИ 1.** *мәл.* кара нинди, әллә нинди (смотри какой, вон он какой). Кан′-нинди кеше! Кан′-нинди үзләре; **2.** *кузн., хвл.* әллә нинди, нинди генә (хоть какой, какой бы ни был). Кан′-нинди канфит булса да кирәкми. – *кузн.*

**КАН′-НИХАТ** *мәл.* шактый, хәтсез (довольно, значительно, изрядно). Карту кан′-нихат чыкты.

**КАН′-НИЧЕК** *кузн., хвл., мәл.* әллә ничек, ничектер (как-то). Кан′-ничек йазылган. – *мәл.* Ничек кенә эткәннәр, кан′-ничек. – *кузн.*

**КАН′-НИШЛИ** *кузн., хвл., мәл.* әллә ни эшли, нәрсәдер эшли (что-то делает). Авырттыра, бора, кан′-нишли. – *хвл.*

**КАННЫ** *чст.* к.: **генибалы**. Канны халык.

**КАНПУРКА** [*рус.*] *тара.* к.: **камбурка**.

**КАНТУЛ** [*рус.* камзол] *тпк.* **1.** к.: **кесәбикә**; **2.** к.: **арка: арка йылы 1, 2**.

**КАНТУТ** [*рус.* картофель] *чпр.* к.: **алма I**. Иске кантутның тәме кацты. Кантутларыгыз бик йакшы үсеп бара.

**КАНУПКА** *тпк.* такта астына сыер тизәге катыштырып боз катырып тау шуу өчен ясалган җайланма (деревянное приспособление для катания с горы, низ которого покрыт льдом, смешанным с коровяком); чаг.: **кулата**.

**КАН′УШНА** *карс., мәл.*, **КАН′УШН′А** *тмн., кузн.*, **КАН′УШНАЙ** *мәл., злт., трбс., минз.*, **КАН′УШН′И** *чст.*, **КАН′УШНЫЙ** [*рус.* конюшня] *мәл., злт., трбс.* к.: **абзар 1**. Кан′ушн′а йылы буладыр. – *тмн.* Иртә дә генә тырып сылы салдым Кан′ушн′ада йапкан атларга (*хал. жыр.*). – *кузн.* Бер сарыгым бәрәннәде. – Кайа соң бәрәннәрең? – Кан′ушн′ида. – *чст.* Бай кан′ушнасында күг айгырым Зиш шылбырын кабыб уйныйдыр (*бор. жыр.*). – *карс.*

**КАНЧАУ: канчау булу** *мәл.* кул яки аякның нык шешүе (сильное распухание ноги или руки); чаг.: **камчау: камчау булу**. Канчау булган бу.

**КАН′ЧЕ** *карс.* кая эле, кая, бир, бир эле (дайка, ну-ка, ну-ка дай). Кан′че, сыwы йукмы шурпаңның. Дарийа, кан′че, берне йасыйм үзеңә.

**КАН′ЧЫ** *миш.д.* к.: **кан′че**. Кан′чы, тукта пычаккызны кар′ыйым. Кан′чы аннан чиләкне китер. – *лмб.*

**КАН′Ы I** *карс.* к.: **биана(й)**. Кан′га, кан′ыга куш күлмәк.

**КАН′Ы II, КАНЫ** *миш.д.*, **′АНЫ** *кас.* **1.** бир, кая, бир, бир эле (дай-ка, ну-ка дай, ну-ка). Кан′ы йеслекләр. – *карс.* Каны миңа йөслек, каны миңа носкилар. – *влгг.* Апай, каны казык башына чиләгеңе. – *хвл.* Каны эле сawытыңны. – *чпр.* Каны, икәү бүлик. – *срг.* Каныгыз миңа китапны. – *кузн.*; **2.** әйдә, әйдәле (айда, давай – в значении приглашения, предложения что-либо сделать). Кан′ы, мунча йагыйм. Цәй эцик, каны. Каны, ашны сысыйк та ашыйк. Каны-каны эц инде. Каныгыз, цәй эцегез. – *срг.* Каны бире йаныма. Кан′ы, аш кап. – *кузн.* Шаның белән эц эле, каны. – *чпр.* Эле дә китмибез, утырыгыз, утыр, каны. – *хвл.*

**КАН′ЫЛАР** *карс.* карагыз эле (смотрите-ка). Кан′ылар, йыгылдым.

**КАН′ЫМ** *крш.* хатынының атасына эндәшү формасы (форма обращения к отцу жены).

**КАҢГЫЛ** *стрл.* к.: **қаңғыл 1**.

**КАПАТ** [*рус.*] *кузн.* к.: **балан II: балан итәк**. Әле капатлы тегел күлмәкләр. Куш капатлы күлмәкләр дә була иде. Йефәк күлмәгем уникe капат... (*хал. жыр.*).

**КАПИК** [*рус.* капелька] *мәл.* тамчы да, бер бөртек тә (нисколько). Башым бер капик та awыртмый. Чиләктә бер капик та су калмаган.

**КАПКА** *стрл.* к.: **қапқа**. Шуннан кырык өч капка йандык.

**урысча капка** *стрл.* к.: **қапқа: түбәле қапқа**.

**арата капка** *стрл.* к.: **қапқа: арата қапқа**.

**КАПКАК** *әҗ.* капкач (крышка). Самаварнын капкагын тапмим.

**күз капкагы** *лмб.* күз кабагы (веко). Күз капкагын мурта капты.

**КАПКЫЧ** *мәл., хвл., чст.* чәй эчә торган әйберләр: шикәр-конфет һ.б. (сладости к чаю: сахар, конфеты и проч.). Лаукага барамын, капкычым бет–кән. – *мәл.* Капкычлар бар бит, алыгыз. – *хвл.*

**КАПЛАМ** *байк.* каплавыч, күлмәк изүенең өстә кала торган ягына каплап тегелә торган тар планка (планка разреза платья, рубашки).

**КАПЛАМА** *стрл.* к.: **қотчоқ**.

**КАПЛАМЫШ** *чст.* изү (прорез рубашки, платья). Капламышының түмәсе дә йук.

**КАПЛАНУ** *карс.* йөзне каплау (покрываться, покрыть лицо). Үгә кергәндә бусаганы атлыйсын капланып. Кыз инде йылый чыга капланып.

**КАПЛЫ** [*рус.* капли]: **каплы камфит** *злт.* к.: **мәтлекәп**. Каплы камфитны әткәй шәһәрдән апкайта торган ыйы.

**КАПНА** [*рус.* копна] *карс.* комбайн сугып төшереп киткән салам өеме (куча соломы, выброшенная из копнителя комбайна). Капналар тезелеп утырып каладыр камбай артыннан.

**КАПТАЛ** *әҗе.* плюш жакет (бархатный жакет). Кунакка барганда каптал кийә иканнар, зебәк wәлләр.

**КАПТ'ОЖКЫ** [*рус.*] *хвл.* к.: **пысқыш**.

**КАПТЫРМА 1.** *әҗе.* элек: уртасында кашы булган, челтәрләп эшләнгән көмеш бизәнү әйбере, астында эләктергечләре була, шуның белән камзулны бер генә җирдән эләктереп куйганнар (в старину: серебряная, с камнями застёжка на полах камзола). Каптырмалар әтәләр иде кашлы, быхрамалар тыткан зиңсез камзул, каптырмалы иде; **2.** *хвл.* к.: **элгец**. Темәләрен кададым, каптырмаларын үзең йасарсын.

**КАПТЫРТМА** *тмн.* каптырма (крючок, застёжка). Каптыртмасы йуг икән бу камзулның.

**КАПУ** *лмб.* капкач – тәрәзәгә карата (оконная ставня). Тәрәзәмнең капусына Моңлы кош килеп кунган (*хал. җыр.*).

**КАПУТ 1.** *срг., мәл.* күлмәкнең кыска итеп кисеп тегелгән өске өлеше (кокетка – деталь платья); чаг.: **бибишка**. Аклы ситсы күлмәгемне, Капутка кистермәдем (*хал. җыр.*). – *мәл.*; **2.** *трх., дөб.* күлмәкнең изүенә һәм җиңнәренә бөреп тотыла торган бала итәк (волан на груди и рукавах женского платья); чаг.: **балан II: балан итәк**. Капутлап теккәннәр күлмәкне җиңенә, изүенә. – *дөб.* Күлмәкне капутлап тегә идек. – *трх.*

**капут күлмәк** *срг.* бала итәкле күлмәк (платье с воланами). Әвәле инде капут күлмәк, бил тиңетен бөргән иде.

**КАПУТЛАУ** *трх.* бала итәк салу (пришивать оборки). Айлапкыч-күлмәкне капутлап тегә идек.

**КАПЫ** *лмб.* к.: **кабак I, 1**. Эстәл эсләрендә каты бал, Кап дисәгез дә капмамын, Капыдан чыгып киткәндә, Кат′ дисәгез дә кат′мамын (*хал. җыр.*).

**КАПЫСТА** [*рус.*] *хвл., тмн., карс.* к.: **қawыста**.

**КАПЫШТЫРУ** *чст.* кабызу (зажечь). Кандил′ны капыштыр.

**кар** (снег):

**кар җыйу** *глз.* к.: **қар: қар салу**. Кар йаман җыйа бездә, өй бийеклек, таразага хадар йаба кар җыйып.

**КАР′А I** *чпр.* кайры (кора). Кар′а суйдырдылар агацына була.

**КАР′А II** *срг.* борынгы озынлык үлчәү берәмлеге (старинная мера длины).

**кар′ага салып** *срг.* карышлап (измеряя пядями).

**КАР′А III** *карс.* кара (чёрный).

**кар′ага саз** *карс.* каралы-сарылы – ат төсе турында (чёрный с жёлтыми подпалинами – о масти лошади). Кар′ага саз атыңны син җигәрсен, Сакускай урамын җиләрсен (*хал. җыр.*).

**КАРА I** *карс.* ярлы (бедный). Бирмәмен кызым, Йырты бик кара (*хал. җыр.*).

**кара II** (чёрный, тёмный):

**кара зер** *мәл.* песи тарысы (амарант).

**кара кечеркән** *тмн., лмб.* сукыр кычыткан (пустырник).

**кара кура** *чст.*, **кара малина** *кузн., лмб.* кара бөрлегән (ежевика).

**кара тутлы** *т.я.-крш.* к.: **карлыгаччобар 2**. Чып-чыбар, кара тутлы кыз.

**кара элбәда** *тмн.* к.: **кара зер**.

**томрый кара** *хвл.* чем-кара, кап-кара (чёрный-пречёрный).

**КАРААН, КАРААТ** *срг.* кара карлыган (чёрная смородина).

**КАРAWАЙ** [*рус.*] *лмб.* ачытып изгән коймак камырыннан балчык савытка салып пешерелә торган камыр ашы (мучное блюдо из кислого теста в виде хлеба, испечённое в глубокой глиняной чаше). Пешерәләр чирәпинкәгә салып кеймак камырын, аны турилар да май мынан ашийлар, май кийып-кийып, ул була karawай.

**karawай қалас** *тпк.* калач (калач). Karawай қаласны хәдер ақ әпәй дипед инте.

**karawай күмәч** *лш.* зур, түгәрәк ак икмәк, калач (калач). Karawай күмәч гөбөрдәп гөбөк шикелле торадыр ыйы, зур бөтән буладыр ыйы.

**k a r a w a t** (кровать):

**тезмәле karawat** *кузн.* җыелмалы карават (сборная кровать).

**КАРAWЫЛ: tawык karawылы** *срг.* к.: **карак: tawык карагы**. Күземә tawык karawылы булды.

**КАРАГАЙ I** *байк., стрл.* к.: **қарагай 1**. Терке 80-90 йылдан карагай була. – *байк.*

**КАРАГАЙ II** *мәл.* к.: **қаралчык**. Ван′а бер карагай күренә, шул килми микән.

**КАРАГАТ** *срг., байк.*, **КАРАГЫТ** *мәл.* **1.** к.: **қарағат**. Моның карагаты йакшы карагат. – *срг.*; **2.** *мәл.* эт җиләге (паслён). Без кечкенә чакта җийылышып карагыт ашый идек.

**КАРАК: tawык карагы** *чст.* тавык күзе (куриная слепота). Ит ашамасаң, tawык карагы була, ди.

**КАР′АК 1.** *миш.д.* кайрак (точило); **2.** *хвл.* күкрәк шеше, күкрәк ялкынсынуы (грудница).

**КАРА-КАТЫШ** *мәл.* к.: **қатыш-қара**. Саламны парлап он белән кара-катыш бирәләр.

**КАРАЛАТУ** *тмн.* каралту (марать, пачкать). Чәчне сылawычныкы корогона тыруба эченә йебәрә, каралатмасын күлмәкне дип.

**КАРАЛКА** [*рус.* королёк] *брб.д.* кечкенә кабартма (маленькие булочки). Каралка тип тә әйтәте, әчү сет белән йомортқа йарасың, су та саласың, тәмнү генә пешәде ул.

**КАРАМА-КАРШЫЛЫК** *мәл.* капма-каршылык (противоположность, противоречие). Халыклар арасында карама-каршылык кечле булган.

**КАРАМҖЫЛ** *клд.* кара-кучкыл (тёмный, чёрный). Үзе карамҗыл-кызыл иде.

**КАРАМЫК** *м.-кар.* караңгыланып, каралып, томалап – hава торышы турында (пасмурный – о погоде). Карамык тора, болытлый – значит йаңгыр китә.

**КАРАН: каран калгыры** *мәл.* каргау сүзе (выражение проклятия); чаг.: **қаран II: қаран қалу**.

**КАРАНДАС** *злт.*, **КАРАНТАС** [*рус.* тарантас] *каз.ар.-крш., бәр., нокр.* к.: **крандас**. Карандаста йәнәш утырып килгән. Син минем карантасны җикмә. – *бәр.* Карантас та, арба да бар. – *нокр.*

**КАРАНЧКА** *м.-кар.* карачкы (пугало). Каран-

чка йасыйлар, канатлар куйа, селкенә дә куркыта ул.

**карацгы** (тёмный; темно; темнота):

**караңгы базар** *тмн.* яшьләр уены: так булган кыз яки егет бер-бер артлы тезелеп баскан парларның сыңарын алып, уртадан, куллар астыннан чыгалар (один из видов молодёжной игры). Караңгы базар ун′илар, кара-каршы тытынышып, астан чыгарып.

**караңгы кагу** *чст.* караңгылану, караңгы төшү (стемнеть, смеркаться). Караңгы какты ат җиккенче.

**КАРАСИЛ** [*рус.*] *перм.* карусель (карусель). Җәрминкә була йы, атлар чаптырып, карасиллар была йы үрелә (әйләнә) торган.

**КАРАТАЙКА** *хвл.* 1. көрти, сырган җиңсез кием (стёганая безрукавка, душегрейка); 2. бәйләгән җиңсез кием (вязаная безрукавка). Каратайкамны кийәмен, йылы булып тыра.

**КАРАТАТАР** *т.я.-крш., чпр.* карабалык (линь).

**карау** (смотреть, глядеть):

**tawык карawы** *мәл.* к.: **карак: tawык карагы**. Tawык карawы булганда кыйаш иңә башлагач, кеше бернәрсә дә күрми башлый, кендез күзе тынып йери, ул кешегә bawыр ашаталар.

**карга** (ворона):

**ак билле карга** *лмб.*, **йамаулы карга** *тмн., лмб.*, **сарый карга** *тмн.* ала карга (ворона).

**карга теле** *лмб.* к.: **қатый**. Карга телен йомыркага гына басасын. Кийәү ман чакырырмын карга теле ашарга. Карга теле диләр, (камырны) җәйәсен дә кисәсен, кыйкча кисәләр аны.

**КАРГАУ-СӨРГӘУ** *стрл.* каргау, рәнҗү (проклинать, обидеться). Тегеләр каргап-сөргәп, җылашып киткәннәр.

**КАРДЕ, КАРДЫ** *блт., мам., дөб., минз., злт., кргл., чст.* җәен кырда терлекләр ябар өчен киртә белән әйләндереп алынган урын (изгородь в поле для скота). Ашагач, сауғач, сыйырларны кардегә йабалар. – *мам.* Җәй көне җәйләүләрдә карды була. – *блт.* Бер карды бар көтү җawып қуйа торган. – *дөб.* Нийә эстә кардыда алмыйлар сарық йөнөн. – *злт.* Җәйен сийырларны awылга апкат′мибез, кырда кардыга гына йабабыз. – *чст.*

**КАРЕ I, КАР′Е** *тмн., срг., мәл., кузн., шрл., влгг.* 1. кая, кай җиргә (куда). Атаң каре китте? Каре барала ике оланы булгач. Кар′ега итәсен куйларны? – *тмн.* Каре барасыз? – *кузн.* Каре абдырыйсың? – *срг.* Мин каре ды зерми идем. – *мәл.* Кар′е китәсен син? – *влгг.*; 2. к.: **кайа** 1. Без каре йатырбыз?

**КАРЕ II** *срг., хвл.* борынгы үлчәү берәмлеге: терсәктән алып бармак очларына кадәр булган аралык (старинная мера длины, равная длине руки от локтя до кончика пальцев); чаг.: **қара I,1**. Каре белән үлчиләр иде әwәл киндерне. Бер каре йеп. – *хвл.* Бер каре буйы, имеш, алай да итенә. – *срг.*

**КАРИ** *глз.* карт (старик). Әүлийә кәбер турыда зират кылмага киләләр карилар.

**КАРИЛЫКТА** *чст.* картлыкта (в старости). И сезнең карилыкта матур җаулыклар чыкты бит.

**КАРИТА** [*рус.* корыто] *хвл., әҗ.* 1. к.: **йулпуч**. Кечерәк карита, әпәй карита дибез. – *хвл.* Пикарнинеке зур карита вет. – *әҗ.*; 2. агачтан чокып эшләнгән мал тагарагы (выдолбленное корыто для скотины); 3. *злт.* тимер тагарак (корыто). Керне каритада йywабыз. Сыйырларның каритасы тузды.

**КАРЛАУ I** *чст.* к.: **тигәнә 1**.

**КАРЛАУ II** *чст., чпр.* к.: **қарлау 1**. Төрән тактасын карлау белән тазарттым. – *чст.*

**КАРЛЫГАЧЧОБАР, КАРЛ′ЫГАЧЧОБАР** 1. *кузн., клд.* сипкел (веснушки). Карлыгаччобар бетми. Бит алмалар ару иде, мун′ында бар иде карлыгаччобар; 2. *клд.* сипкелле (веснушчатый).

**КАРЛЫГАЧЧЫБАР** *хвл.* к.: **карлыгаччобар 2**.

**КАРЛЫГУ** *мәл.* сакаулану – кошлар турында (изменить пение – о птицах). Кукылар сыңга таба карлыга башлый.

**КАРМАЖИН** [*фарс.*] *чст.* яхшы, затлы тукыма (ткань хорошего качества). Байларда кармажиннан, туры йакадан казаки булды.

**КАРМАН′ЙА, КАРМАТ′ЙА** *сазл.* гармун (гармонь). Карман′йа ошлай weләwc.

**КАРМАУ** *глз.* тырнау, тырнап канату (царапать до крови); чаг.: **йышу I, 2**. Печән кулымны кармады.

**КАРМАШУ** *глз.* тырышу, тырмашу (стараться, прилагать усилия); чаг.: **қазғану**. Аман узы чынрак (үзе өченрәк) тырыша, кармаша.

**КАРСАГАЙУ** *чпр.* тәбәнәкләнү (стать низким, опускаться). Ызбасы да карсагайа бара йылдан-йыл.

**КАРСАК** *миш.д.* 1. тәбәнәк, түбән (низкий, невысокий; низко). Карсаг эстәл. Карсак кына сawытта үсә. – *чст.* Синең башың (баш астың) карсак булган, ахыры. – *мәл.*; 2. тәбәнәк, кыска (низкий, короткий). Арышлар карсак быйыл, башлары да кечкенә. – *лмб.* Башы быдайның йакшы, ну карсак. – *чст.* Карсагы киндераш. – *тмн.*

**КАРТА I** [*рус.* карта?] *кмшл.* җир үлчәү берәмлеге: иңе-буе 100 әр сажень булган (мера измерения земли: 100x100 саженей).

**КАРТА II** [*рус.* карта] *лмб.* карта, домино, шашка кебек уен әйберләре (игральные карты, домино, шашки и т.п.).

**КАРТА III** *лмб.* төймә, сәдәф (пуговица). Алнысына зур ак карта кадаган.

**КАРТАЙМЫШ** *кузн., хвл., тмн.* к.: **қарыйлық**. Картаймышыбызга безгә дә йеңеллек инде. – *кузн.*

**КАРТАНАЙ** 1. *срг., лмб.* әтисенең иң олы абыйсының хатынына эндәшү сүзе (форма обращения к жене самого старшего брата отца). Минем ылы килендәшем балаларыма картанай була. – *лмб.*; 2. *хвл.* әтисенең беренче хатынына яшь хатын балаларының эндәшү сүзе (форма обращения детей от второго брака к первой жене отца).

**КАРТАПКА** [*рус.*] *брб.д.* к.: **алма I**.

**КАРТАТАЙ** 1. *срг., стрл., шрл.* к.: **қартатай 1**. Аларның картатайлары безнең картатайлар белән дуслар. – *шрл.* Аликай, Үтәй дигән кешеләр килгән, картатайлар әйтеп калдырган. – *стрл.*; 2. *срг.* әтисе яки әнисенең иң өлкән абыйсына эндәшү сүзе (форма обращения к самому старшему брату отца и матери); 3. *хвл.* әнисенең элекке ире (первый, предыдущий муж матери).

**КАРТАУ** [*рус.*] *срг.* к.: **алма I**. Картау алдык, арыдык энде бик.

**КАРТӘНИ 1.** *срг., шрл.* к.: **қартинә(й) 1**. Картәни, адә безгә. – *срг.*; **2.** *срг.* әби; әнисенең яки әтисенең әнисенә эндәшү сүзе (бабушка, форма обращения к матери отца или матери); **3.** *тмн.* әтисенең абыйсының хатыны (жена старшего брата отца). Минем атам да аның ире быратлар, ул миңа картәни; **4.** *хвл., әҗе.* әтисенең олы хатынына кече хатын балаларының эндәшү сүзе (форма обращения детей к первой жене отца).

**КАРТӘНӘЙ** *шрл.* әтисе яки әнисенең апасына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре отца или матери). Картәнәй йанына утыртырга иде быларны.

**КАРТӘТИ 1.** *тмн.* бабасының атасы (отец дедушки, прадед); **2.** *срг.* к.: **қартатай 1**; **3.** *хвл.* к.: **қартатай 3**.

**КАРТӘТӘЙ** *байк., стрл.* к.: **қартатай 1**.

**КАРТИНӘЙ, КАРТНӘЙ** *стрл., байк., шрл.* к.: **қартинә(й) 1**. Әллә, картинәй, йылап калдың инде. – *байк.* Картинәйләр Пинза йагыннан килгәннәр тувып кына. – *стрл.*

**КАРТОК** *карс.*, **КАРТОПКА** *том.д.*, **КАРТОПКЫ** [*рус.*] *клм.* к.: **алма I**. Карток чәчәбез, үстерәбез. – *карс.* Картопка утызырга кирәк. – *клм.*

**КАРТТАЙ** *шрл.* **1.** к.: **қартатай 1**; **2.** к.: **картатай 2**.

**КАРТТӘ(Й)** *байк.* к.: **қартатай 1**. Карттәйләр сүлиләр ийе инде. Карттәңә утыргыц китереп бир, улым.

**КАРТУ** [*рус.* картофель] *кузн., хвл., срг., мәл.* к.: **алма I**. Йабышыгыз картуга, ату карту сувына. – *хвл.* Әнекай китте карту казырга. Йангор йаугач, карту була инде. – *кузн.*

**карту измәсе** *хвл.* бәрәңге боткасы (картофельное пюре).

**КАРТУБИСГЕ** *тбл., саз.я.* төйгеч, тукмак (пестик, колотушка).

**КАРТ′УК** *хвл., кузн.*, **КАРТУК** [*рус.* картофель] *кузн., лмб., мәл., карс., әстр., злт.* к.: **алма I**. Карт′укны да савитский влас алдыннан гына белдек. – *хвл.* Картукларны икәwе генә йыралар. – *лмб.* Хаз′ыр картук чәчтеләр артта. – *кузн.* Җымры картуг үзегезгә пешердем. – *карс.* Утынына, песәненә, картугына берүзе. – *злт.* Картук бурый. – *әстр.*

**картук тилли** *әстр.* юка итеп туралган һәм онга болгатып кыздырылган бәрәңге азыгы (блюдо из рубленого картофеля, смешанного с мукой и обжаренного на сковороде).

**картук эсте** *кузн.* бәрәңге алу вакыты (время уборки урожая картофеля). Картук эсте иде, эш күп иде.

**КАРТУКЛЫК** [*рус.* картофель + *афф.* -лык] *кузн.* бәрәңге бакчасы (огород, картофельный огород).

**КАРТУП** [*рус.* картофель] *әстр., хвл., срг., кузн., туб.-ирт. д.* к.: **алма I**. Ипи белән картубын сала. – *әстр.* Бармы картуп анда? Картупны утап бетердем. – *срг.* Картуп утысган, аш цацган. – *төм.* Пеләкләрем йанышты, картуп күмтем. – *твр.*

**картуп туру** *перм.* әрчү – бәрәңгене (чистить кожуру – о картошке.).

**картуп шәңкә** *туб.-ирт.д.* бәрәңге пәрәмәче (шаньга с картошкой).

**КАРТУПКА** [*рус.* картофель + *афф.* -ка] *тбл.* к.: **алма I**.

**картупка баш** *тбл.* аңгыра (тупой).

**КАРТУС** [*рус.* картуз] *дөб.* өй кыегында карниз өстенә ясала торган сөзәк түбә (навес над карнизом переднего фасада дома). Картусны артык текә итсән, кипкесен басып кигән кеше шикелле була өй.

**КАРТУФ** [*рус.* картофель] *эчк., хвл., мәл., карс., кузн.* к.: **алма I**. Бер мишүк картуф бирдем. – *хвл.*

**йарма картуф** *мәл.* урталай ярып пешерелгән бәрәңге (картофель, сваренный в разрезанном пополам виде).

**КАРТУШ** *тмн., лмб., срг., карс.*, **КАРТУШКА** [*рус.* картошка] *тмн., төм., тбл., твр.* к.: **алма I**. Кывырган картуш. Картушны басма (таптама)! – *лмб.* Картушны турап, су кан′ап чыккач, салырсың. – *срг.* Картуш, кызым, салмаган идеңме? Картушка да алма, сад алмасы да алма. – *тмн.* Картушканың цүбен қыртым, төплөтем. – *төм.* Картушка ашамағынчы, қорсақ туймас. – *твр.*

**КАРТЫЙ** *байк.* к.: **қартинә(й) 1**. Картый, ураза бөгән беттеме? Картый, койаш бетте бит инде, аша инде, диләр балалар.

**КАРТЫЧКА** *кргл.* карточка (фотография):

**картычка алыну** *кргл.* рәсемгә төшү, карточкага төшү (сфотографироваться). Туйда йөргән қызлар җыйған ақчага Аримбурға барып картычка алыналар ыйы.

**КАРУ I** *чст.* җавап (ответ). Йегет йагына ницек бирелә, кызга да шылай, каруга кару инде.

**кару кайтару** *мәл.* үч кайтару (вымещать, мстить).

**КАРУ II: күз карувы** *хвл.* к.: **қару II: күз қарувы**. Күз карувым да бетте.

**КАР′УК** [*рус.* хорёк] *мәл.* сасы көзән (хорёк).

**КАРУЛЫ** *срг.* эчкерле, усал (злопамятный, таящий злобу). Алимә ул карулы төгел.

**КАР′УМНА** [*рус.* хоромы] *мәл.* кирпечтән яки таштан эшләнгән җимерек ташландык бина калдыгы, хәрабә (развалины, остатки каменного или кирпичного здания). Күршеләрнең ыланнары кар′умнада шак-шаки ун′илар.

**КАРФАНКА** [*рус.*] *блт.* к.: **камбурка**. Карфанкасын қуй самавырның.

**КАРЧАГА** [*рус.* корчага] **1.** *лмб., клд.* зур чүлмәк, сыра чүлмәге (большой глиняный горшок, пивная корчага). Чирәп карчагасы иде, сыралар куйалар иде пичтә чечетеп. – *клд.* Карчага кывасын йарата иделәр. – *лмб.*; **2.** *клд.* бөтен юан бүрәнәне чокып эшләнгән тагарак (жёлоб, выдолбленный из цельного бревна). Агач карчага иде, чирәп карчага да иде.

**КАРЧЫГАН** *м.-кар.* карчыга (ястреб).

**КАРЧЫК** *лмб.* **1.** картлар, карт кешеләр (старик и старушка, старые люди); **2.** карт ир кеше (старик). Нәнәйеңә бер карчык табам әле.

**КАРШАГА** *мәл.* кашага (бордюр, занавеска вдоль стены).

**КАРШУ: каршу булу** *тмн.* күз тию (подвергнуться сглазу). Каршу була, ылан йылый, өшкөрәсең

каршудан, кем булса килә, севәме-ниме, шуннан була каршу, ылан йылый башлый.

**КАРШЫ I** *карс.* кире (несговорчивый, упрямый).

**каршы кирәмәт** *чст.* кире, үзсүзле, тыңлаусыз (непослушный, упрямый); чаг.: **аркыры 2**. Тыңнамый тырган кешегә каршы кирәмәт тиләр.

**КАРШЫ II** *чст.* карата, күрә (соответственно чему-либо, по). Акцага каршы гына алып тыр хазергә.

**КАРШЫДА** *кузн.* вакытта, чакта (в то время). Ул эшләр булмады безнең каршыда.

**КАРШЫЗБА** *хвл.* к.: **карызба**.

**КАР'Ы** *клд.* кайда (где). Берсе вон кар'ы тыра.

**КАРЫЗБА** *кузн., чст.* өйнең аш-су пешерә торган ягы (часть дома, где готовится пища; кухня). Без мында карызбада гына ашибыз. – *кузн.*

**КАРЫЙ I** *стрл.* к.: **қарый III**. Моңа карый бийегрәк ул кеше.

**КАРЫЙ II: карый күрү** *мәл.* йөз чөерү, дошман күрү (отворачиваться, ненавидеть). Үлесен дә карамадылар, карый күрделәр awыл кешеләре.

**КАРЫЛӘК 1.** *мәл., клд.* к.: **қараға**т; **2.** *клд.* караҗиләк (черника).

**КАРЫЛУ** *глз.* к.: **қарылу 1**; чаг.: **карыну**.

**КАРЫМСА** *чст.* бавыргалык, түшлек (подбрюшник). Атның карымсасы асылынып тыра, күтәреп бәлә.

**карын** (желудок; утроба):

**карын чаршawы** *тмн.* терлекнең ашказаны янындагы май ярысы (жировая плёнка около желудка животных). Карын чаршawы була, симез булса.

**кырк карын** *тмн.* кырыккарта – күшәүче хайваннарда (рубец – у жвачных животных). Кырк карын була куйныкы, сийрныкы.

**КАРЫНДАС** [*рус.* тарантас] *каз.ар.-крш., минз., бөре., байк.* к.: **крандас**. Туйларга җөрдәләр, җәй буса, карындас була, жа'шы җасты'лар салып, парлап утырып. – *каз.ар.-крш.* Җәй булса, кийәү карындаска утырып килә. – *байк.*

**КАРЫНДАШ** *глз.* кардәш (родственник). Карындашлары кэлгән.

**КАРЫНДЫК** *срг.* пыяла, тәрәзә пыяласы (оконное стекло). Карындык куйу. «Карындык куйам, карындык куйам!» – дип кыцкырып йөриләр иде.

**карындык куйучы** *срг.* к.: **карындыкчы**.

**КАРЫНДЫКЧЫ** *хвл.* тәрәзә куючы, пыялачы (стекольщик).

**КАРЫНУ: йәшенә карыну** *чпр.* яшенә тыгылу (подавиться слезами); чаг.: **қарылу**. Йәшенә карынып кереп киткән йырламыйцы.

**КАРЫШ** *тмн.* каршы, каршы як (напротив, против). Сипарат карыш кабакта.

**карыш чолан** *тмн.* өйалдында он-тоз, ашамлык әйберләре куяр өчен ясалган бүлмә (чулан в сенях). Вын'ы карыш чоланда катык, ышкаптамы каймак.

**КАРЫШЫН: карышын булу** *м.-кар.* күз тию (подвергнуться сглазу, заболеть от сглаза). Кеше караклагач, малайлар җылый выт, карышын була инде.

**КАС'** *мәл.* кайсы (который). Кас' тешең әрни?

**КАСА** [*фарс.*] *мам., бәр.* шикәр савыты (сахарница). Бер каса тутырып қуйам, бер шикәрне қалдырмый бу балалар. – *мам.*

**КАС'АК I** [*рус.* косяк] *миш.д.* тәрәзә һәм ишек яңагы (брус дверной и оконной рамы; косяк). Ирем тәрәз кас'агы йуwынып йата. – *чст.* Кас'акларны сырладыгызмы? – *срг.* Тәрәс кас'акларын ак краскага буйадык. – *хвл.* Кас'акларын матур итеп буйап куйган. – *шрл.* Тәрәз кас'аклары да, ишек кас'аклары да әзер, диде. – *стрл.*

**КАС'АК II 1.** *тмн., лмб., срг.* кисәк (кусок). Бер кас'ак ипәй бир, ашак келәдем. – *тмн.* Бер кас'ак әпәй. – *лмб.* Кас'ак-кас'ак күк цәпе. – *срг.*; **2.** *карс.* кисәк – аз-маз әйбер турында (кусочек – о малом количестве). Ын кас'агысы ман бутыйсың, кышын шулай ашатасын сыйырны. Бер кәҗәм генә, шыннан сет кас'агысын кабам; **3.** *лмб.* бераз, бераз вакыт (немного, немного времени). Утыр бер кас'ак. – *лмб.*

**КАС'АКЛАП** *кузн.* күп итеп, төргәге белән (помногу, тюками). Кас'аклап китерә иде байлар басманы.

**КАС'АКЛЫ** *лмб., срг.* корамадан җыелган, корамалы (лоскутный). Кас'аклы адийал. – *срг.* Кас'аклы йасыйсын, чуклар йийасын да. Ике урны, икесенә дә кас'аклы йәйгән. – *лмб.*

**КАСАЛКА, КАСАЛКЫ** [*рус.* качалка – зыбка, колыбель, люлька] *злт.* к.: **крандас**. Касалкаға ат йегүле. Абзый утырып килгән ийе касалкыга.

**КАСАР** *т.кам.-крш.* к.: **қылчақ**. Касар балық касар пычаққа ошаган.

**КАСАРКА** [*рус.* косарь – тот, кто косит сено; косилка – машина для косьбы] *минз., стрл.* печән чабу машинасы (косилка).

**КАСӘ** [*афф.*] *бәр.* варенье, шикәр һ.б. сала торган савытлар (сахарница, конфетница и др.). Касәдә шикәрмә, баринйама тора. Разыйа, минем касәмне китер, карлыган waринйасын йаратмыйм мин.

**КАСИ** [*фарс.*] *әстр.* касә (чаша, пиала). Каси белән қымыз бирә.

**КАСИДА** [*гар.*] **1.** *лмб., әҗе.* к.: **касид**ә. Касида зәнцек була бархыттан. – *әҗе.*; **2.** *кузн., карс., клд.* к.: **путемар**. Касида акца зийа тырган капцык, шунда тагып йөриләр иде, тагалар уты (менә) бун'га, бири кийәләр дә, зери занцыкта акца. – *әҗе.* Касидада анда акчасы йерегән. Касида диләр, кара ни эсенә акча тезә дә, шал тешен, кун'ена йибәрә, йанчык шикелле бар иды, астында ука мынан чигәләр иде. – *лмб.*

**КАСИДӘ** [*гар.*] *тмн., лмб., хвл., кузн., карс., клд., әҗе.* хәситәгә тагыла торган кесә, янчык (небольшой бархатный карманчик, украшенный монетами или расшитый позументом и пришиваемый к *путемар* с правой стороны). Касидә – йасаган йәнчек көбәк, йантыгына куйа. – *хвл.*

**КАСИТА** [*гар.*] *т.я.-крш.* к.: **путемар**.

**КАСМАК** *срг., чпр., мәл., м.-кар.* шапшак, җыйнаксыз (неряшливый, неаккуратный, неопрятный). Бу хатле касмак булырсың икән. Касмаг ишеп чыгардым (идән юып чыгаргач). – *мәл.* Йакшы тегел, касмак. – *м.-кар.*

**КАСМАКЛАНУ** *м.-кар., чпр., срг.* керләнү, пыч-

рану, каралу (загрязниться, выпачкаться, замазаться). Касмакланып килер идем картушка барсам, йаңгыр йауды бит. – *срг.* Ул үзе касмакланган. – *м.-кар.*

**КАСНАК** *срг.* яшерен, качып (тайком, скрытно). Каснак кына килә (кияү) кыз катна.

**КАСНИК** [*рус.* косник] 1. *хвл., кузн., лмб.* чулпы (женское накосное украшение). Касник булган байларда, суга иделәр көмештән. Ике үремгә берәр касник була иде. – *хвл.* Манмага манган була касник. – *лмб.*; 2. *минз.* очына тәңкә тагылган чәчүргеч тасма (тесьма с монетами на конце, которая вплетается в косы); чаг.: **чәчтасма**.

**бакалы касник** *тмн.* чулпының бер төре (одна из форм накосника).

**куш касник** *хвл.* ике буынлы чулпы (накосник состоящий из двух звеньев).

**челтәрле касник** *кузн.* челтәрле көмеш чулпы (накосник, состоящий из серебряной ажурной бляхи). Чапукның беренче акыгына тәңкәләр тагылса, ул челтәрле касник була.

**КАСТ** [*гар.*]: **кастын күрү** *мәл.* хәстәрен күрү, алдан чарасын күрү (заблаговременно заботиться, предпринять что-либо). Кастын күрсәң, хут нинди эшне дә булдырасың аны.

**КАСТА** [*фарс.*] 1. *чст.-крш., клд.* авыру (болезнь). Ай-хай, печәннәрне их чабыwы, Чабыwыннан awыр җыйыwы, Әҗәл кастасыннан awыр икән Артларыннан җылап калыwы (*хал. жыр.*). – *чст.-крш.*; 2. *карс., мәл., әҗе.* чирле (болезненный). Хазер кастасын вата. – *карс.* Анабыз каста иде дә, зәтим калдык. Каста, выс'е кулга калган иде ире. – *әҗе.*

**каста йату** *чпр., клд.* чирләп яту (лежать в постели – болеть). Эч ай каста йатты. – *чпр.* Карт каста йата, сүләми. Каста йатмыйчы үлийем инде димен. – *клд.*

**КАСТАЛАНУ** [*фарс.* + *афф.* -лану] *мәл., карс., чст.* чирләү, авыру, авырып китү (болеть, заболеть). Әни касталанма кели. Касталанып йерде дә тенә терелде инде. – *мәл.* Касталандыңмыни? – *карс.* Бала касталанмадымы суң? – *чст.*

**КАСУЙЛАП** [*рус.*косо + *афф.* -лап] *кргл., бгрс., шрл.* турыдан түгел, әйләнеп, кыеклап (криво). Касуйлап-касуйлап кына бардым. – *шрл.*

**КАС'УК** [*рус.* косяк]: **кас'ук бүресе** *мәл.* озак һәм каты итеп үкереп елаган бала (ребёнок, который плачет долго и с рёвом, ревёт).

**КАС'Ы-КАС'Ы** *карс.* кайбер (некоторый, иной). Хазер кас'ы-кас'ы нәчәлләрне шул кешеләргә ошатам.

**КАТА I: әмерхан ката** *стрл.* к.: **қата I: әмерхан қата**.

**КАТА II: йаз ката** *миш.д.* җәй буе (всё лето, в течение всего лета). Йаз ката бездә булды, кышка гына китте. – *лмб.* Йаз ката, кыш ката шул хал'дә. – *мәл.*

**йәй ката** *чст., чст.-крш.* к.: **йаз ката**. Йәй ката шуны түли иде. – *чст.-крш.* Ал, мәтәм, сиңа йәй катага йетә ул. – *чст.*

**кич ката** *мәл.* кич буе (в течение всего вечера). Кич ката утыралар, чыгарсыз.

**көз ката** *миш.д.* көз буе (в течение всей осени). Быйыл кез ката йаңгыр йауды. – *мәл.*

**кыш ката** *миш.д.* кыш буе (всю зиму, в течение всей зимы). Кыш ката миндә тырды оланы. – *срг.* Бер машина шабырдатып китерә дә (утыны), кыш катага була. – *хвл.* Кыш ката салам йага идек пичкә. – *кузн.* Кыш ката бездә тырды нәнәй. – *лмб.* Кыш ката утын йагабыз. – *мәл.*

**төн ката** *миш.д.* төн буе, төнозын (всю ночь). Төн ката йыкламадым. Кенызын да йыклый, тен ката да йыклый. – *лмб.* Үгә кермәгән тен ката. – *срг.* Тен ката йүтәлләп чыктым. – *мәл.* Күземне дә йыммый теннәр ката бишек тирбәтеп утырам шылай. – *чст.* Әле ван'а төн ката да йөри. – *хвл.* Йын ката Шакур катны тен ката. – *чпр.*

**КАТАЙ** [*рус.* катать] *к.т.* к.: **бал'ук**. Биг әйбәт кер катайым бар ыйы, җарылды.

**КАТАЙЛАУ** [*рус.* катать + *афф.* -лау] *к.т.* к.: **қырлау I**. Сырлы бәләк белән кер катайлыйдыр ыйык. Эскәтер, тастымал кебекләрне хәзер дә катайлыйм мин.

**КАТАЙСА** [*рус.* кататься]: **катайса җөрү** *каз. ар.-крш.* Масленица бәйрәмендә атка утырып йөреп күңел ачу (веселиться, развлекаться во время Масленицы, катаясь на лошадях). Майда катайса җөри тоган ыйың ат белән җәшләр, кызлар, менә минем әтий дә апчыга катайса, тее кешенең дә атасы апчыга, awылны әйләнәдерийек җырлашып.

**КАТАЙТЛАУ** [*рус.* катать + *афф.* -лау] *лш.* к.: **қырлау I**. Сырлы wәләк белә катайтли.

**КАТАКЛАУ** [*рус.* катать + *афф.* -лау] *лмб.* тәгәрәтү (катать). Йана башлау мән, катаклый-катаклый сандыгымны чыгардык.

**КАТАЛАК** [*рус.* каталка] *срг.* к.: **бал'ук**.

**КАТАЛАНУ** [*рус.* катать + *афф.* -лану] *влгг.* аунау (валяться). Үзем каталанганымны аңгарам.

**КАТАЛАТУ** [*рус.* катать + *афф.* -лату] *миш.д., кас., баст.* аунату, тәгәрәтү (катать, валять, навалять). Бер синәклек каталата барасын (печәнне). – *кузн.* Каталатып пешерә идек (бәрәңгене). – *хвл.* Каталатырбыз (мичкәне). – *срг.* Җомор'а каталаталар. – *кас.* Каталатып кисәсең дә чәйгә салып ашыйсың (бавырсакны). – *чпр.*

**урын каталату** *баст.* кияү белән кәләш беренче кич кунасы урында бала аунату йоласы (обычай, согласно которому на постели новобрачных катали детей). Урын каталаталар, бер малай каталый.

**КАТАЛАУ** 1. [*рус.* катать + *афф.* -лау] *мәл.* к.: **қырлау I**. Әбинең каталата тырган нәстәсе бар ыйы, күлмәкне шымартырга; 2. *миш.д., баст.* аунау, тәгәрәү (катиться, валяться). Аннан каталый-каталый сиңа менде. Каталап китәр дә төшәр. – *срг.* Калын йылан выж-выж йөрәми, выт шолай каталый. – *кузн.* Мында идән буйлап каталап йери ул. – *чпр.* Туп эстәл астына каталады. – *хвл.*

**КАТАҢГЫ** *т.я.-крш.* чандыр, кипкән, ябык (худощавый, сухопарый).

**КАТАРДА** [*гар.*] *шрл.* чамасы, бер чама – яшь турында (примерно одинаково – о возрасте; одной меры).

**КАТАРЫННАН** *влгг.* к.: **қатарыннан.**

**КАТАТ′** [*рус.* катать] *трх.* к.: **бал′ук.** Катат′ була торган ыйы кер катат′ итә торған, сырлысырлы була.

**КАТАШЛЫК** *мәл., чпр., срг., клд., чст.* сабан ашлыклары (яровые). Каташлыкны йаз башында чәчәләр, тары әтийек, сылы, бырчак. – *клд.* Каташлык чәчтек тә туй йасадык эш беткәч. – *чст.* Хазерге көндә дә картлар, каташлык чәчү беткәч, анда йөриләр. – *срг.*

**КАТ′ЕМ** [*гар.*] *карс.* дога; Коръән (молитва; Коран). Катемнәр укып җиргә күмегез (*бәет.*).

**КАТИК** *кузн.* йомырка тәгәрәтеп уйнау (детская игра: катанье яиц). Йаз башында кар беткәндәрәк катик дийә идек, йомыркалар йийа идек, уний идек.

**КАТ-КАСЫ** *мәл.* кап-каты, бик каты (твёрдый-претвёрдый, очень твёрдый). Кәҗәнең җилене әлдә һаман кат-касы.

**КАТКЫ** [*рус.* катка – перевозка чего-нибудь на тачках] *минз.* чана артына озын бүрәнәләрне ташу өчен тагыла торган җайланма (устройство, приделанное к саням для перевозки брёвен). Каткы, чана артына арқан белән тағып, бүрәнәне шуңа салалар ыйы.

**КАТЛАЖИ** *стрл.* овал формада, алгы яктан чигелгән, кәләпүш төсле, бәрхеттән, хатын-кыз баш киеме (женский головной убор из бархата, напоминающий тюбетейку, но с овальным дном и вышитый спереди).

**КАТЛАМА 1.** *тмн., кузн., чпр., срг., шрл., хвл., стрл.* камырдан пешерелә торган кунак ашы: берничә кашык каймак яки сөт һәм йомыркага гына басылган ак он камырын юка гына итеп җәяләр дә тар тасмалар итеп кисәләр; киселгән тасмаларны трубка сыман итеп төреп кайнап торган майга салып пешерәләр (национальное праздничное блюдо: хворост трубкообразной формы). Катламаны чырнап салалар казанга. Катламаны куйасын тужы парнуй сеткә генә, йәйәсен дә шылай чырнап йебәрәсен. Кытыр-кытыр катламаны Ашармысын, кодагый? Бер кызыңы алып киткәч, Йылармысын, кодагый (*хал. җыр.*)? – *кузн.* Ачытминча чечелидән бешерәсен, ул инде кетеркетер итә. – *тмн.* Катламаны кыз анасы да, йегет анасы да пешерә, икесен дә йегет белән кыз ашап бетерергә тийеш. Катламаны туйга зур итеп йасыйлар. – *срг.* Катлама пешерәбез, җәймә җәеп кисәбез хот′ үзен, хот′ уклауга чорга, майда казанда пешерәбез. Катлама кыйкча кебек җәйәбез, җәймәне кисәсен, аны киң итеп бөгә барасың, чырмыйсын да казанга салып барасын майга. – *хвл.*; **2.** *лмб.* йомыркага басып, юка итеп җәеп майда пешерелә торган төче камыр ашы, юка (национальное мучное изделие). Катлама чечеләтә була, ачылата тегел; **3.** *стрл.* к.: **қатлама 1**; **4.** *карс., стрл.* яхшы онны йомыркага гына туглап, ачыга, таба зурлыгында итеп пешерелә торган камыр ашы (лепёшка из кислого теста, жаренная в масле). Май, сөт, кукай салалар, пешкәч, кисеп ашыйлар катламаны. – *стрл.*; **5.** *срг., карс., әҗе.* ачыга изгән бодай камырыннан майда яки табада пешерелгән булка, кабартма (булочка из кислого теста). Үземнекеләр килсә, ацылый куйам да майда пешерәм катлама. – *әҗе.* Катлама диләр кунак килгәндә, Айыт бар′амнәрендә генә ашыйлар, йомшак быдай ыннан була. – *срг.*; **6.** *стрл.* гөбәдия (губадия); **7.** *срг.* коймак (оладьи).

**ачылый катлама 1.** *әҗе.* ачы камырны җәеп, ромб рәвешендә кисеп пешерелгән кабартма (ромбовидная булочка из кислого теста); **2.** *тмн., карс.* ачыга изгән бодай камырыннан клиндер формасында ясап майда пешерелә торган азык, уртасы тишек кабартма (мучное изделие в форме кренделя из кислого теста, жаренное в масле). Ачылый, чөчөлий катлама бешерәбез туйга. – *тмн.*

**катлама йасау** *хвл., кузн.* туй алдыннан катлама пешерү өчен кызлар җыю йоласы (один из моментов свадебного обряда: сбор девушек для приготовления *катламы*). Катлама йасаганда туйга чике кызлар җийыла. – *хвл.*

**катлама келәве** *тмн.* туйның икенче көнендә егет өенә кодачаларны һәм кардәш-ыру кызларны чакырып сыйлау мәҗлесе (угощение девушек – родственниц невесты и жениха, устраиваемое в доме родителей жениха на второй день свадьбы).

**к$^{у}$ош катлама** *срг.* ярәшкән кызга егет ягыннан җибәрелә торган ике кечкенә ипи (два небольших хлебца, присланные сосватанной девушке со стороны жениха). Кызны сүлиләр, мәәр сүлиләр, к$^{у}$ош катлама итәсең кызга.

**таба катламасы** *хвл.* к.: **қабартма.** Көн дә кыwашна салам, әпәй куйасын да кыwашнага, айырып аласын да камырны, пешерәсен таба катламасы.

**шырпылы катлама 1.** *мәл.* юка гына җәелгән камырга май яки повидло ягып ясалган рулетны турап табада пешерелә торган камыр ашы (мелко нарезанный рулет с начинкой из повидла и т.д.); **2.** *чпр.* к.: **катлама 1.** Камырны катлы-катлы итеп төрәләр, таралып китмәсен өчен шырпылар кадап куйалар, шырпылы катлама диләр; **3.** *чст.* туйга пешерелә торган азык: йомыркага һәм каймакка гына басылган ак он камырын юка гына итеп җәяләр, аны берничә кисәккә кисеп, һәр кисәкне аерым-аерым майда кыздырып алалар һәм берсе өстенә берсен катлы-катлы итеп төрәләр; катлама төргәге таралып китмәсен өчен, каен агачыннан ясалган шырпылар кадыйлар (свадебное блюдо: кусочки тонко раскатанного сдобного теста жарят в масле и свёртывают их по несколько штук в трубку; чтобы оно не развалилось, закалывают тоненькими берёзовыми палочками).

**КАТЛАУ** *т.я.-крш.* күлмәк күкрәгендәге тартар складлар (узкие складки на груди платья).

**КАТЛЫ-КАТЛЫ** *лмб.* кат-кат, кабат-кабат (несколько раз, снова и снова). Катлы-катлы йывабыз.

**КАТМАШУ** *м.-кар.* әйләнү (кружиться). Карачы икмәкләреңе шунда, башым катмаша.

**КАТНАШУ** *м.-кар.* саташу, акылы чыга башлау (путаться, сбиваться с толку, помешаться). Карт катнаша әзерәк.

**КАТТАЧИ** *нрл., дөб.*, **КАТТАШИ** *трх., к.т.* к.: **катлажи.** Каттачи йаулық өстеннән кийелә дә, чапан бөркәнә. – *дөб.* Каттачи кийәләр, маңгайында

әзерәк энҗеле. – *нрл.* Катташины байлар кийәләр ийе, уқа белән чиккән. – *трх.* Катташи йаулық астыннан, йәшерәкләр қалпақ кийәдер ийе. – *к.т.*

**КАТУ I, КАТ′У** [*рус.* катать] *глз.* басу – киез итекләр турында (валять – о валенках). Кийез итеген дә кат′а, биг эшләй.

**КАТУ II** *стрл.* к.: **қату I**. Кату катып ашарга йаратмыйм мин.

**кату кату** *байк.* к.: **қату I: қату қату**. Кату катып эчәм ашка гел.

**катулы аш** *стрл.* к.: **қату I: қатулы аш**. Катулы аш күңелне ачып йебәргән күк була.

**к а т у III** (твердеть):

**колак кату** *стрл.* к.: **қолақ II: қолақ қату**. Колаклар катты, ишетелми.

**КАТУ IV** *м.-кар.* туңу (зябнуть). Бик йылы тыта итегем, ито катам.

**КАТУК I** [*рус.* каток] **1.** *трх., мәл.* кәтүк (катушка, шпулька). Катукка йарақлыйы әрләгән җитен җебем. – *трх.*; **2.** *трх.* к.: **бал′ук**; **3.** *клд., кузн.* к.: **уклawык**. Йәймә йәйә катук мынан. – *кузн.*; **4.** *кузн.* бавырсак, чәкчәк һ.б.ш. кисәр өчен озынча итеп әвәләгән камыр кисәге (скатанные, свалянные продолговатые куски теста для нарезания баурсака, чак-чака и др.). Чигелдәк пешергәндә катат′ итә идең дә катукка, катуклый-быз да, кискәли бара түгәрәк итеп, май эчендә, хот′ пич каршында пешерә.

**КАТУК II** *әстр.* к.: **абзар 1**.

**КАТУЛАУ** *стрл.* к.: **қату I: қату қату**. Кат′кач катулап аш ашадым. Шурпаны катулаб эчәбез.

**КАТУТ 1.** *мәл.* сырлан (липучка). Ыйыкка катут йабышты. Вайна йылында катут ашап тырдык; **2.** *хвл.* шиңмәс үлән (бессмертник).

**КАТЦА** *чст., чпр.* чабагач күбәге (рукоять цепа).

**КАТЫ I 1.** *байк., мәл., срг.* ник, күп, көчле (сильно, много). Каты йаңгыр арттан килә. – *мәл.* Каты аргац йоклап булмый диләр. – *срг.*; **2.** *байк.* күп (много). Анда бигрәк каты ашыйлар; **3.** *срг.* шәп, әйбәт, яхшы (хорошо); чаг.: **ару I, 10**. Бер ликтыр сүләде каты; **4.** *байк.* бик (очень). Каты тәмне була шишара.

**КАТЫ II** *чпр.* к.: **қаты I: қаты басу**. Ул басуда катыга калган цирәмнек бар.

**каты кура** *м.-кар.* һиндыба, буын чәчәк (цикорий).

**КАТЫ III** *срг.* к.: **қатымыш**.

**каты карун** *мәл.* бик саран (очень жадный; скряга, скаред).

**каты көн** *влгг.* якшәмбе (воскресенье). Каты көнгә автобус тагын була.

**к а т ы н** *м.-кар.* хатын (жена; женщина):

**буйка катын** *м.-кар.* үз буйлы, теләсә нәрсә эшли торган хатын (женщина своевольная, не всегда придерживающаяся общепринятых норм поведения). Салдатка тезенәтләр иде, берәү тезенгән, бер буйка катын кийенгән айуга, әллә нигә.

**КАТЫН-КОТОН** *мәл.* хатын-кыз – кимсетеп, түбәнсетеп әйтү (женщины – говорится при пренебреж. отношении).

**КАТЫП-КАТЫП** *әҗе.* эче катып (смеяться до упаду). Пәйшәмбә күрдем мин аны, келә катып-катып.

**КАТЫРГАН** *чст.* к.: **қамыраш II**.

**КАТЫРТУ** *мәл.* **1.** әлдертү (быстро ехать, быстро бежать). Катырта гына; **2.** туңдыру (морозить, подмораживать). Тышта катырткан; **3.** ныгыту, кысу (затянуть, укрепить). Гужны катыртырга кирәк, бушаган.

**КАТЫШ-КАТЫШ** *срг.* аралаш (смешанный). Катыш-катыш кадаган тәңкәләрне, эрене дә, wакны да.

**КАТЫШУ I** *стрл.* **1.** кушылу (впадать, втекать). Иделнең катышкан йерен күргәнең бармы?; **2.** берләшү (объединяться). Элек катышкан ийек без Әлшәйгә (*ав. ис.*), шуннан соң араландылар; **3.** өйләнешү, кушылу (пожениться, сойтись).

**КАТЫШУ II** *тмн., лмб.* тию, кагылу (трогать). Катышма, апаң йыкласын. – *лмб.* Катышма эт белән, кабар үзеңне. – *тмн.*

**КАУДАН 1.** *чст.* к.: **қау II**; **2.** *хвл., мәл.* к.: **абаға**. Алаша кауданын кыйа. – *мәл.* Каудан койу. Сыйыр кауданын койа башлаган. – *хвл.*

**КАУДЫРЛАНУ** *мәл.* кабалану, ашыгу (суетиться, спешить).

**КАУЛАТУ** *т.я.-крш.* к.: **каулау 1**. Тастар сарынып кетү каулата.

**КАУЛАУ 1.** *чпр.* куу, куалау (гнать, выгонять). Ашасыннар инде, каулама; **2.** *байк.* китерү, алып килү, алып кайту, мәс., машинаны һ.б. (пригнать, напр., машину и проч.). Камбайын каулаган ийем бер йылны, йул нацар, йаwын, бер атна кайттым.

**КАУША** [*рус.* ковш] **1.** *трх., хвл.* мөшкә (лоток мельничный). Тирмәннәрдә кауша әлдә дә бар. – *трх.* Каушага сала бара, тегендә ыны тешә бара. – *хвл.*; **2.** *трх.* триердагы улак (лоток триера). Каушаға салалар бөртөк, ул суртларға айыра.

**КАУШАУ** *чпр.* кабалану, ашыгу (суетливо спешить, торопиться). Туктале, каушап сүләмә.

**КАХПА** [*гар.*] *хвл., кузн.* бозык, тотнаксыз хатын (развратница, безнравственная женщина); чаг.: **азман II**. Кахна син, дип хурлады. – *хлв.*

**КАХПАЛАНУ** [*гар.* + *афф.* -лану] *кузн.* бозыклык итү (развратничать).

**КАЦУ** *байк.* тел яшерү йоласы (обычай, запрещающий невесте разговаривать с отцом и старшими братьями мужа). Элекке киленнәр кацып, кушйаулыклар йабынып йөргәннәр, ансы бездән элекерәг инде, йөзне күрсәтмице кушйаулык йабынып, мына шулай бөркәнеп кенә йөргәннәр.

**КАЧ** *т. я.-крш.* кит (уходи); чаг.: **кытылу 3**. Кач әле, азаплап бетермә.

**КАЧАК** [*рус.* косяк] *чст., мәл., шрл.* к.: **кас′ак I**. Ызба салыштым ике кен, качаклар утыртыштым. – *чст.* Тәрәзә качагын буйыйбыз. – *мәл.*

**КАЧАН 1.** *лмб.* кайчагында, кайчак (иногда, иной раз). Качан сигэәншәр тийен була йымырка; **2.** *срг.* ... икән, ... булса, алайса (тогда, если так, в таком случае); чаг.: **айса**. Ишекне йабыйым качан, сезгә салкын. Мин киттем качан, сау буласыз; **3.** *тмн.* ...да, вакытта (когда, во время). Кышын сугымнар качан чалына, казылар йасыйлар.

**КАЧАН-КАЧАН** *лмб., тмн., мәл.* кайчагында, кайчак (иногда, временами, иной раз). Качан-качан сезгә дә йарый выт сүләмәскә. – *мәл.* Тыңный

качан-качан, качан чыгынный (бала турында). – *лмб.* Быраз укыкла качан-качан да. – *тмн.*

**КАЧАШ** *кузн.* бәрәңге яки эремчек пәрәмәче, шәңгә (шаньга, шанежка); чаг.: **кәкери**. Качаш аласың ди вәлисең, баскалыйсын йә итме куйасын, карту измәме куйасын, бөгәсен, awызы ачык кала. Тываруктан качашлар йасыйлар карту катыш.

**КАЧКАЛАК** *стрл.* к.: **қачқалақ 2.**

**КАЧКЫН** *чст.* йөгерек – ат турында (скакун – о лошади). Качкын ат. Атың качкын булсын, йөрәгең йалкын булсын (*әйтем*).

**КАЧМАНАР** *чст.-крш.* христианнарның ел башында була торган дини бәйрәме (один из праздников православных христиан; крещение). Качманар кене сыwык буса җаратканнар.

**качманар су** *чст.-крш.* к.: **қач: қач маңған су**. Килнем качманар су алып кайтып бирде, Питернең мәниннигенә қатле тыттым шуны.

**КАЧМЫК** *т.кам.-крш.* к.: **қачмық**.

**КАЧЫ I: качыга салу** *срг.* көлтәләрне өю алымы (способ складывания снопов в копны).

**КАЧЫ II** *чпр.* Америка өрәңгесенең орлыклары (зёрна американского клёна).

**качы кywагы** *чпр.* Америка өрәңгесе (американский клён). Качы кywагы ул качылар чыгара.

**КАЧЫНЫП** *лмб.* тел яшереп (не разговаривая со свёкром и старшими братьями мужа). Бырын вит качынып йери идек.

**КАЧЫРЫНЫП** *кузн., клд.* яшеренеп (прячась). *Кайадыр качырынып тәмәке тарталар. – клд.*

**качырынып чыгу** *кузн.* ябышып чыгу (выходить замуж убегом). Мин качырынып чыктым.

**КАШ** *м.-кар., хвл., срг.* к.: **қаш I, 1**. Алар каштарак (торалар). – *хвл.* Без кайтканда, чушы каштa тыра иде. Кашны менәсен и тешәсен. – *м.-кар.* Теге каштарак торалар алар. – *срг.*

**пиң кашы** *чпр.* к.: **қашаға I, 1**.

**КАШАГА 1.** *стрл.* к.: **қашаға I, 1**. Монсы шырпы кашагасы. Кашагада тора минем котыйчык; **2.** *мәл.* тәрәзә пәрдәсе (оконная занавеска, шторы). Тәрәзә кашагасы каралган; **3.** *срг.* күкрәкчә (нижний нагрудник).

**КАШАК** *т.я.-крш.* к.: **коргоч**. Тәрәзә кашакларына буйы белә кадап чыгалар чәчәкләр.

**КАШБАУ** *т.кам.-крш., тмн., чст.*, **КАШБУ** *т.я.-крш.* хатын-кызлар кия торган борынгы баш киеме, тәңкәләр тезгән түгәрәк бүрек (женский головной убор: холщовая шапочка, обшитая снаружи серебряными монетами). Балык тәңкәсе кewек тачкылтап җалтырап тора кашбау тәңкәсе. – *т. кам.-крш.* Кашбауга маржа тәңкәсе тезгәннәр йалтырawыклы, уртасы тишекле сәйләннән, wак түмәләрдән бизәк йасап теккәннәр, ун тийен тәңкәләр тезгәннәр, wак түмәләрне салындырып йасаганнар. – *чст.*

**КАШКА: кашка күрү** *чпр.* дошман күрү (считать врагом, ненавидеть, возненавидеть). Күп барып йөрсәләр, начал'никлар кашка күрә башлый.

**КАШКИ** [*фарс.*] *тбл.* ичмаса (хотя бы, хоть бы, пусть бы). Кашки ул килеп китсә ите бүген.

**КАШ-КЫМЫР** *срг.* чырай, төс, йөз (вид, лицо); чаг.: **қон**. Кашын-кымырын киган.

**КАШЛЕНӘ** *кузн.* брошка (брошка).

**КАШЛ'ИК** *тмн., кузн.* кашык, пычак кебек әйберләр кую өчен юкәдән яки чыбыктан үреп ясалган кечкенә әрҗә, тартма (плетённая из лыка или прутьев корзиночка, коробка для хранения ложек, ножей и т.п.). Тал'никсардан үргән кашл'ик тыра күркле генә. – *кузн.* Абзикайым кашл'ик тугидыр, Кашык куйарга кашл'икка (*бор. җыр.*). – *тмн.*

**КАШЛЫК 1.** *лмб.* стенага, гадәттә, казан турысында, кашыклар кыстырып кую өчен кадакланган нәзек агач (планка, прибитая к стене для хранения ложек); **2.** *хвл.* к.: **кашл'ик**; **3.** *чпр.* стенага кашыклар кыстырып кую өчен кадакланган каеш (ремень, прибитый к стене для хранения ложек).

**КАШМА** *тмн., лмб., мәл., хвл., чст., әстр.* сарык йоныннан басылган киез (кошма, войлок). Кан'ым кан'анамны шул кашмага чолгап энде күмдек, түргә йәйдек кас'ын. – *тмн.* Кизләүне кашма белә тымалап киткәннәр. – *чст.* Киленнен кашмаларын илтәләр. – *мәл.* Кашманы астыбызга җәйәргә басалар. Кашмага, вал'ник балдагына ышкыйлар. Кашма мәчеттә намазлык урнына йери. – *хвл.* Қызның кашмасы да булады. – *әстр.*

**КАШНА** *стрл.*, **КАШНЕ** [*рус.* квашня] *нокр., глз.* к.: **ләнгәц**. Ике кашна белән алма-тилмә әпәй салам. Бер кашнедин ипи ашарлар дигән. – *нокр.*

**кашне кертик** *нокр.* күәсне кырып җыйган камырдан әвәләгән кечкенә ипи (маленький хлебец из остатков теста, выскребков квашни); чаг.: **гердә 1, игәрче**.

**КАШНИК** *клм.* беләзек (манжет). Киногы (күлмәге) бәленнән бөрмә йасап, киң қысқа йең, кашниклы.

**КАШПАУ** *лмб., карс.*, **КАШПУ** *т.я.-крш.* к.: **кашбау**. Кашпау кийәләр, кыругум манитлар тезгән, шуны тайка кебек кийәләр, кашпау выч'ы тайка. Башында тайка шикелле кашпау, сылawыч, аннан кашпау, анын эстенә тастар, шалайча. – *лмб.*

**КАШТАН 1.** *кмшл., кузн., чст.* куштан (подхалим, льстец). Ул awылның каштаны иде. – *кмшл.* Атай безнеке сырхав иде, анай безнеке каштанрак. – *кузн.*; **2.** *мәл.* тәкәббер, масаючан (высокомерный, надменный).

**КАШТАНАЙУ, КАШТАННАНУ** *мәл.* тәкәбберләнү, масаю (гордиться, зазнаваться, кичиться). Йериләр шонда каштанайып.

**КАШТӘ** *срг.* кай төштә, кайда, кайсы урында (где, на каком месте). Казан йагыннан ул килен, каштәндер. Ул кешең сың каштә?

**бер каштә дә** *срг.* беркайда да (нигде). Бер каштә дә йук андый камбайын.

**к а ш ы к** (ложка):

**аш кашыгы** *чст.* к.: **қашық: қуштан қашық**.

**калай кашык** *карс.* тимер кашык (металлическая ложка). Калай кашык чыңгылдый, йаратмийым.

**кашык кагу** *әҗе.* Яңа ел кичендәге юрауларның берсе: кыз кашык кага башлагач, кайсы якта эт өрә башлый, имеш, шул якка кияүгә китә (одно

из новогодних гаданий: начинают бить ложкой и откуда донесётся собачий лай, будто-бы в ту сторону девушка и выйдет замуж). Кашык какканым бар, кашык кагасын, коцок кайан өрә кашык какканда, шунда кийәүгә барасын.

**татар кашык** *глз.* агач кашык (деревянная ложка). Татар кашык была ашимсың?

**урыс кашык** *глз.* к.: **калай кашык**.

**КАШЫН** [*рус.* кошёлка, кошель?] *перм.* ашлык ташый торган зур күн кап (большой кожаный куль для перевозки зерна).

**КӘБӘГЕНӘМ** *хвл., мәл.* к.: **кәбәм 1**. Багам, кәбәгенәм. – *мәл.* Их, кәбәгенәм! Йаңгышкан. – *хвл.*

**КӘБӘЙ** *срг.* к.: **кәбәм 2**. Уйаулы-йыкылы тырган цакта, Анай кәбәй килде каршыма (*бор. бәет.*). Мине анай кәбәй сагынамы икән?

**КӘБӘК I** *стрл.* к.: **ислекәй 1**. Стинада кәбәк йукмы?

**кызыл кәбәк** *стрл.* к.: **ислекәй 1**. Кызыл кәбәк күрендисә, минем картым тытмый аны, хазер бетерә.

**КӘБӘК II** *төм.* кое бурасы (сруб колодца).

**КӘБӘК III** *брб.д.* к.: **күбек I**.

**КӘБӘМ** *тмн., лмб., кузн., хвл., мәл., влгг.* **1.** иркәләп, яратып эндәшү сүзе (форма ласкательного обращения). Кәбәм, әтийем, барма. Кәбәм, ник соң алай итенәсең? Бар инде, кәбәм. – *мәл.* Бак атай, кәбәм, әпәй менән аша шурбасын. – *влгг.* Кий, кәбәм, кий башыңа. – *лмб.* Кызы, кәбәм, үзе тәкле! Әти, кәбәм, эчмә, дим. Нишли аласын, кәбәм, чүп тә итә алмыйсын. Анагыз кайа, кәбәм? – *кузн.* Кәбәм әтекайның әвендә, ничек бу күләрне сузайым (*бор. жыр.*)? – *тмн.*; **2.** кереш сүз функциясендә (в функции вводного слова). Кулларым туңды, кәбәм, бигрәк сывыткан. – *хвл.* Йук, кәбәм, минекеләр андый төгел. – *мәл.*; **3.** *мәл., хвл.* гаҗәпләнү сүзе (междометие, служащее для выражения удивления). Багам, кәбәм, нинди йакшы. Кәбәм, багале, нинди зур булган. Алла кәбәм анакай, ак алаша кара тай. – *мәл.*; **4.** *мәл.* ачулануны белдерә торган сүз (междометие, употребляемое при сильном возмущении, раздражении). Кит, кәбәм, инде мыйымны кан′атма.

**кәбән** *минз., бөре., перм., глз., злт., стрл., себ.* кибән (стог):

**қақчыр кәбән** *перм.* җил йөрергә ике яктан тишек калдырып куелган кибән (стог хлеба, в котором с двух сторон оставлены отверстия для вентиляции). Қақчыр кәбән җоморо була, ике җақтан тишек қуйабыз, ул җawында да бурсымый.

**кәбән басу** *глз.*, **кәбән ташлау** *туб.-ирт.д.* кибән кую (метать стог, ставить стог). Кәбәнен дә баса, йетенен дә йәйә. – *глз.* Алар кәбән ташлайтылар. – *төм.*

**КӘБӘРӘ, КӘБӘРЕ** *срг.* бавырсак, чәкчәк, төш, салма һ.б. шундыйларны кисәр өчен озынча итеп әвәләнгән камыр кисәге (кусок скатанного теста в форме тонкой колбасы). Кәбәрә эзеп салырбыз, цумар булыр.

**КӘБӘРКӘ 1.** *дөб., бөре., байк., стрл.* к.: **кәберкә**. Кәбәркә нәрсә сун ул, әнекий, дип сорадым килгәч. – *дөб.* Бәрәңгене йуwып тутыралар ыйы кәбәркәгә. – *стрл.* Теге хатын кәбәркәгә кереп ухыwат белән көрәшкән, ди. – *бөре.*; **2.** *стрл.* к.: **кәзәнкә 2**.

**КӘБӘРКЕ** *бөре., байк.* к.: **кәберкә**.

**КӘБӘРТКӘ 1.** *бәр., дөб., минз., трбс.* к.: **кәберкә**. Тегеннән җәри торган булмаса, кәбәрткә була. – *дөб.* Кәбәрткәгә қуйған чыра ағачын. – *бәр.* Кәбәрткәдә қачып торған. – *минз.*; **2.** *кргл.* мич белән стена арасына ясалган сәке (нары, расположенные в пространстве между печью и стеной). Кәбәрткә өстендә балалар, астында бәрәчләр тора.

**КӘБӘРТКЕ** *минз., стрл., тпк., трбс.*, **КӘБӘРТМӘ** *дөб.* к.: **кәберкә**. Кәбәрткедә утын, табагач, кисәү агачы тора инде. – *стрл.* Сарық пәрәсләре кәбәрткедә була, қысқырыша башлый. – *тпк.*

**КӘБӘЦ** *себ.* **1.** к.: **кәпәч 1**. Кәбәц ирләр кигән. – *твр.* Кәбәц кейептеләр, кипкәне йаратмағаннар әwәл. – *тбл.* Кәбәцне йөгөрөп йөргән қыслар та қатыпты, палларға та кәбәц кейдереп, турап (киндер) булса да. – *төм.*; **2.** *туб.-ирт.д.* к.: **маңгайча**. Кәбәцләр пулты қуй, пы йерләрентә йенце. Кәбәцләрне қыйыш қына төшөрөп, үсе суплық қына, осон пулаты, салып қуйсаң. – *төм.* Пы кәбәц қарцықларныкы. Уғалы кәбәц кейгәннәр, шәпкә шунтай, алтта цимәйле. – *тбл.*; **3.** *тбл., төм., тара.* түбәтәй рәвешле юка, зур бавырсак (мучное изделие в форме тюбетейки, жаренное в масле, из такого же теста, из которого готовят татарское национальное блюдо – чак-чак).

**кәбәц пawырсақ** *туб.-ирт.д.* к.: **кәбәц 3**. Кәбәц пawырсақ пулган, аны ницек тартып қылғаннар. – *тара.* Кәбәц пawырсақ та була, қамырны басасың, өстәлгә салып wақлайсың, түгәрәкләйсең, эцен уйыб аласың, тартып йуқартасың, майда пешерәсең кәбәц пawырсақны. – *тбл.*

**КӘБӘЧ** *твр., брб.д.* к.: **кәпәч 1**.

**кәбәч пawырсақ** *твр.* к.: **кәбәц 3**.

**КӘБЕКӘЙ** *кмшл.* к.: **кипен: чәй кипене**. Кәбекәйләр, шикәр ашар эчен утырасыз, ийегезгә қайтқач эчәрсез (балаларга карата).

**КӘБЕЛЛЕ** [*фарс.* + *афф.* -ле] *бәр.* к.: **кәбенле**.

**КӘБЕН I** [*фарс.*] **1.** *нокр., глз., перм., к.-уф., бәр., блт.* никах (бракосочетание по мусульманскому обычаю). Қызға кәбен уқығанда тигезле кеше, дыға уқып, қызның чәчесен үрә. – *нокр.* Унсигезне тутырмый кәбен уқымадылар. – *перм.* Кәбен уқыйлар, аннан туй була. – *к.-уф.*; **2.** *крш.* чиркәүдә христиан дине кагыйдәләре буенча башкарылган никахлашу (бракосочетание, венчание в церкви по христианским канонам).

**кәбен алжапқычы** *крш.* никах укыганда киелә торган алъяпкыч (передник, надеваемый при исполнении обряда бракосочетания по мусульманскому обряду).

**кәбен балдагы** *крш.* туй балдагы (обручальное кольцо).

**кәбен қойдыру** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* к.: **кәбен қойу**. Әwәле қыз белә кийәүне кәбен қойдырырға алып баралар, андары җегет өйөнә қайталар.

**кәбен қойу** *крш.* чиркәүдә егет белән кызны никахландыру (венчать, обвенчать в церкви). Иртәгә туй дигән көннө кәбен қойу була, чиркауға бара-

лар. Кәбен қойарға китәләр киҗеле бөркәүләрен бөркәнеп, чиркаудан туйга қайталар. – *т. кам.-крш.* Кәбен қоймаға чиркәүгә баралар ыйы җегет белән қыз. – *каз.ар.-крш.*

**кәбен күлмәге** *крш.* туй күлмәге (подвенечное платье). Кәбен күлмәкләрен, алҗапқычларын алтмыш тәңкәгә биргән дә җибәргән. – *т.кам.-крш.*

**кәбен қыйдыру** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш.*, **кәбен қыйу** *крш.* к.: **кәбен қойу**. Кәбен қыйдырғач, қызны өйөнә апқайта. Кәбен қыйылған җаулығ ич бу минем. – *каз.ар.-крш.*

**кәбен салу** *нокр., глз.* никах уку (совершать обряд бракосочетания). Кичә кәбен салдылар, туйға бардық. – *нокр.*

**кәбен туй** *перм.* никах мәҗлесе (угощение после бракосочетания). Инәләренә кәбен туйға бардық.

**КӘБЕН II** [*гар.*] *туб.-урт.д.* кәфен (саван).

**КӘБЕНЛЕ** [*фарс.* + *афф.* -ле] *бәр.* никахлы (законный). Мин бит синең кәбенле хатының, дим.

**КӘБЕРКӘ** *бөре., байк.*, **КӘБЕРТКӘ** *минз., бөре.* мич белән стена арасында калдырылган урын (запечек, пространство между печью и стеной). Кәберткә мич башына әйбер куйарға керергә кирәк. – *минз.* Безнең кәберкә йуқ. Эзләгән, кәберткәләрне қарап бетергән. – *бөре.*

**КӘБЕЦ** *брб.д.* туфли.

**КӘБЕШ(ЕМ)** *тмн., кузн., хвл., мәл.* к.: **кәбәм 1**. Йә инде, кәбеш, тыңна. – *мәл.* Әлдә, диләр, кәбешем, ике ай эшкә йарамый. Туктагыз, кәбешем, өсне алыштырыйм. – *хвл.* Дүрт йылда дүрт (бала), кәбешләрем, әле дә бересе үлде. – *кузн.*

**'ӘБИМ** *кас.* к.: **кәбәм 4**. 'ит, 'әбим, мондай бала.

**КӘБИН** *перм.* кибән (стог). Ана у кешеләр булса, икене кәбин артық салайық.

**КӘБРӘ** [*гар.*] *тара.* кабер (могила).

**КӘWӘК** *тбл.* пыяла муенса (стеклянные бусы).

**КӘВӘР** *срг.* нечкә итеп сузган камыр, әнәчә (тесто, протянутое в виде верёвки). Кәвәр ишәсең камырдан берцәк шылай.

**КӘWӘРӘУ** *чпр., чст.* әвәләү (валять, повалять, скатывать). Сеткә, каймакка чече камыр басасың, аны кәwәрәтәсең дә бармак белән этәреп җибәрәсең. – *чст.* Муни шылай кәwәрисен. – *чпр.*

**КӘWӘРТӘК** *брб.д.* сызык (шкварки).

**КӘВӘРУ** *чпр.* к.: **кәwәрәү**. Салманы кәвәрә, аны кисеп казанга салган.

**КӘWӘХ** *саз.я.* к.: **қаудан 5**.

**КӘWӘХЛӘУ** *саз. я.* кавыклау (появление перхоти).

**КӘWӘЦ** *тбл., твр., саз.я.*, **КӘВӘЦ** *саз.я.* к.: **кәпәч 1**.

**КӘWЕК** *себ.* к.: **коко**.

**кәwек қыйғыру** *брб.д.*, **кәwек үгерү** *тара.*, **кәwек цағыру, кәwек цақыру** *себ.* күке кычкыру (куковать). Кәwек қыйғырса, әйтәсең, кәwег ана, песнең йәшебесне сана, чәчкән ашлар баш чығарса, теле тотлыға аныңқы. – *брб.д.* Цақыралай кәwек, цақыра (*хал. җыр.*). – *тбл.* Аш баш қысып, қылцықланып йатады, тамағына қылцық утырғац, кәwек үгермәйде. – *тара.*

**кәwек цәцәк** *төм.* умырзая (подснежник). Кәwек цәцәк иң перенце цыға.

**кәwек цәцәкәй, кәwек цицәкәй** *тара.* аю көпшәсе, аю табаны, кәккүк итек (борец высокий). Кәwек цәцәкәй ашаған иреннәр қап-қара була, йот (йод) эцкән кебек, кәwек қыцқырғац үсә башлый ул үләм. Кәwек цицәкәй цәцәк атады, киткән инте кәwек, аш паш қысып, тамағына қылцық утырады.

**КӘWЕРТӘК I** *брб.д.* бугаз (горло).

**КӘWЕРТӘК II, КӘWЕРТЕК** *брб.д.* к.: **кәwәртәк**.

**кәwеш** *урт.д.* кәвеш (кавуши – национальные мягкие кожаные башмачки):

**әмерхән кәwеш** *мам., дөб.* ялтырап торган галош (блестящие галоши). Әмерхан кәwеш кийәдер ийек, йалтырап тора торған ыйы. – *дөб.* Шартшорт итеп торадырыйы байларның әмерхән кәwешләре. – *мам.*

**кәгәwен** *перм.* кигәвен (овод):

**ат кәгәwен** *перм.* кигәвен (овод).

**кәҗә кәгәwен** *перм.* бөгәлчән (слепень).

**КӘГӘWЕЦ** *брб.д.* шөлди (кулик). Кәгәwец – қыйгыра тығын қош.

**КӘГӘЙ** *брб.д.* к.: **бармак II**.

**КӘГӘҮ** *брб.д.* янау (угрожать).

**КӘГЕЛ** *брб.д.* атның маңгай чәче (волосы на лбу лошади, чёлка).

**КӘГЕЛДЕРЕК** *брб.д.* сулыш алу бугазы (дыхательное горло).

**КӘГЕРҮ** *брб.д.* кикерү (отрыгивать).

**КӘГРӘНЗӘН** *брб.д.* караңгы чырайлы (угрюмый).

**КӘГРӘНҮ** *брб.д.* мыгырдау (ворчать).

**КӘДИК** *брб.д.* тешсез (беззубый).

**КӘДИЛ** [?]: **ишек кәдиле** *әстр.* ишек бавы – кияү кергәндә сорала (вознаграждение жениха при входе к невесте).

**КӘДИЛҮ** *брб.д.* теш коелу (выпадать – о зубах).

**КӘЖ'ИНКӘ, КӘЖ'ИҢКӘ** [*гар.*] *злт.* к.: **кәзәнкә 2**. Кәжиңкәдә итләр бозолмасын.

**КӘҖӘ I** *минз.* кечкенә бөккән (пирожок).

**КӘҖӘ II** *мәл.* к.: **кәзә I**.

**кәҗә III** (коза):

**кәҗә бәрәне** *трх.* кәҗә бәрәненең саулык булганы (ягнёнок-самка козы). Кәҗә бәрәнен сатам, тәкәсен қалдырам.

**кәҗә җебе** *каз.ар.-крш.* мамык җепнең бер төре (вид хлопчатобумажной пряжи). Әwәле җеп булған төрле-төрле, кәҗә җебе дип җөрткәннәр, мамық сыман, җуwан ул.

**кәҗә күшә** *перм.* к.: **ирен I: ирен бозгыч**.

**кәҗә майы** *бәр.* беләк мускулы (двуглавая мышца). Кәҗә майы сызлый инде алайса синен. Кәҗә майына укул салдырған ыйым, шеште.

**кәҗә майы чыгару** *мам., дөб., бәр.* беләк мускулын сугып кабарту (резким ударом вызвать вздутие двуглавой мышцы). Беләгемә суғып кәҗә майы чығарды. – *мам.*

**кәҗә сакалы 1.** *стрл.* к.: **гөләф**. Кәҗә сакалын бик файдалы диләр, эчәргә кушалар ашказанына. Кәҗә сакалы төрле йакта төрлечә бит ул, аның эче тулы төш; **2.** *т.я., каз.ар., минз.* к.: **ирен I: ирен бозгыч**. Иренне боза торғаны кәҗә сақалы анын. – *дөб.* Кәҗә сақалының тамырын, көп-

шәсен йәш wақытта ашыйлар, бик тәмне ул, cywы иренгә тисә, иренне чабырта. – *к. т.* Кәҗә сақалын җыйып килгәндә, қуллар бозолоп бетәдер ийе. – *минз.*

**кәҗә чүлмәге** *дөб.* бик кечкенә чүлмәк (очень маленький горшочек). Кәҗә чүлмәгенә бәрәңге игеп (кырып) салып қуйа.

**КӘҖӘЙИН** [*гар.*] *каз.ар.-крш.* хуҗа (хозяин). Җәшми-тынмый кермиләр, қywып чыгара кәҗәйин, кемнән сорап кердең дип.

**КӘҖӘК** *нрл., чст., мәл.* к.: **кәзеки**. Кәҗәк йага башладык, нawуздан утын йасый идек. – *мәл.* Бездә урман йырак, шынын белә кәҗәк йагабыз. – *чст.*

**КӘҖӘЛЛЕК** [*гар.*+*афф.*-лек] *дөб.* к.: **кәзәнкә 2**. Кәҗәллеккә кереп чүгәр ийем арғач.

**КӘҖӘНКӘ** [*гар.*] **1.** *т.я., минз., чст.* к.: **кәзәнкә 2**. Кәҗәнкәдән алып бир қатық. – *минз.* Кәҗәнкәгә кереп йатып торам әле. Мә, шул майны кәҗәнкәгә чыгарып қуй әле. – *трх.* Аның үз катыгын да кәҗәнкәгә куйдым иде. – *чст.*; **2.** *минз., чст.* к.: **кәберкә**. Комганы кәҗәнкәдә тора. – *чст.*

**КӘҖӘНЛЕК** [*гар.* + *афф.* -лек] *дөб.*, **КӘҖӘҢКӘ** *нрл.*, **КӘҖӘҢКЕ** [*гар.*] *кргл., бгрс., минз., стрл., шрл.* к.: **кәзәнкә 2**. Кәҗәнлеккә кереп жатқан. Ырадийо утыра кәҗәңкәдә, wатық. Ишегалдының кәҗәңкесе бар. – *стрл.* Кәҗәңкегә кемнең нәрсәсе бар, шуны қуйа инде: он, тоз, ашамлық. – *бгрс.*

**КӘҖЕ I** *стрл.* тәбәнәк (низко; низкий). Никтер кәҗе бу агач, үсмәгән. Бәләкәй, кәҗе булды, үсмәде Шамил.

**КӘҖЕ II** *миш.д.* торф кирпече (торфяной кирпич). Таш кисеп, кәҗе кисеп төзәдек каралдыны. – *хвл.*

**КӘҖИ** *мәл.* кәҗә куу ымлыгы (возглас, при помощи которого отгоняют коз).

**КӘҖ-КӘҖ-КӘҖ** *нрл.* кәҗә чакыру ымлыгы (возглас, которым скликают коз).

**КӘҖҮ** *минз.* кимү, азаю (уменьшаться, убавиться). Суйадырыйық та, кәҗеде әле сарық.

**КӘҖҮНКӘ** [*гар.*] *бөре., перм.* к.: **кәзәнкә 2**. Итне китереп қуйган мешиге белән кәжүнкә түбәгә. – *перм.*

**КӘҖҮНКЕ** [*гар.*] *чст.* кечкенә капка, ян капка (боковая калитка).

**КӘЗ** *мам., блт., брб.д.* кәс (дёрн). Чирәм үскәнне суқалыйсың икән, кәз була. – *мам.* Кән кешнең үбашы кәз белә йабылған. Элке торғаннар йәрдә, кәздән өй салғаннар. – *брб.д.*

**КӘЗӘ I** *нгб.-крш.* утын кискәндә яки такта ярганда бүрәнә кую өчен җайланма, кузла (козлы для распилки дров или досок).

**кәзә II** кәҗә (коза):

**кәзә сакалы** *стрл.* к.: **гөләф**. Без кәзә сакалы дийүчәнбез, гөлҗимеш тә диләр.

**кәзә тел** *кузн.* гөлбадран (дикая рябина, пижма).

**пух кәзә** *злт.* мамык кәҗәсе (коза, дающая пух). Хәзер пух кәзәләрне күб асрамыйлар.

**kәdә** *тпк.* кәҗә (коза):

**кәdә сағалы** *тпк.* ут чәчәк, сары умырзая (адонис).

**КӘЗӘК** *мәл.* к.: **кәзеки**. Кәзәк йасыйлар иде йагарга, хазер утын күп, кас'ы брикит ала.

**КӘЗӘКӘЙ** *нокр.* к.: **ирен I: ирен бозғыч**.

**КӘЗӘЛЕ** *стрл.* холыксыз (несдержанный, неуравновешенный).

**КӘЗӘЛЕК** *стрл.* үпкә, әр, шелтә (упрёк, обида, укор). Бала-чагада безгә кәзәлек калмасын димен.

**КӘЗӘЛЛЕК** [*гар.*] *дөб.* к.: **кәберкә**. Күмер сосқочы кәзәллектә тора. Кәзәллеккә кереп ки (күлмәкне).

**КӘЗӘЛТКҮ** *брб.д.* к.: **кисеркә I**.

**КӘЗӘМБИР** *перм.*, **КӘЗӘМИР** [*рус.* кашемир] *злт.* кашемир. Кәзәмир ди торғаннар ыйы әлгәре, шундый йаулығым бар ыйы. – *злт.*

**КӘЗӘНКӘ** [*гар.*] **1.** *дөб.* к.: **ишегалды**. Утыларны кәзәнқәгә қуйып тор, мичкә йаққанда алырым. Киз итекләрен кәзәнкәдә; **2.** *т. я., лш., эчк., минз., мәл., чст., срг., стрл., тара.* өйалдында бүленгән урын, бүлмә (чулан в сенях). Кәзәнкәдә ишектән кергәч тә сандық бар. – *минз.* Майны кәзәнкәгә куйып тор. – *стрл.* Ын кәзәнкәдә. – *чст.* Кәзәнкәдә аның кырачинкасы, чәй куйарсың, үзләре эчәрләр. – *лш.* Кәзәнкәгә керттем әйбереңне. – *эчк.*

**КӘЗӘНЛЕК** [*гар.* + *афф.* -лек] *блт.* к.: **бүлмәч 2**.

**КӘЗӘҢКӘ** [*гар.*] *т. я., дөб., минз., стрл., кргл.* к.: **кәзәнкә 2**. Сыйыр кәзәңкәгә кергәли ул. – *стрл.* Кәзәңкә ишеген йап, тawықлар кермәсен. – *минз.* Кәзәңкәдән әйбер алайым, йығылдым. – *дөб.* Онно кәзәңкәгә чығарып қуйдым. Кәзәңкәне ачық қалдырғансың да, тawықлар тулып онно чәчкәннәр. – *к.т.*

**кәзәңкә тақта** *глз.* бүлмә тактасы, урта стена (перегородка).

**КӘЗӘР** *твр.* юләр (сумасшедший).

**КӘЗӘРҮ** *твр.* тилерү, юләрләнү (сходить с ума).

**КӘDӘТЕЛ** *тпк.* блузка изүенә тагылган волан, бала итәк – гадәттә ул спираль формасында кисеп ясала (спиралеобразно выкроенный волан на груди блузки). Ақ куфты тектерәбеd, кәдә телле итеп тороп.

**КӘЗЕ** *клм.* к.: **ичке**.

**КӘЗЕКИ** *чст.* кизәк, тирестән сугылган кирпеч (кизяк в виде кирпичей). Кәзеки сугабыз нawыздан йагу чен.

**КӘЗЙӘНКӘ** [*гар.*] *клм.* к.: **кәзәнкә 2**.

**КӘЗЛӘП** *бәр.* буразна рәте белән, буразна саен (по каждой борозде, по бороздам). Утыртылған бәрәңгене кәзләп-кәзләп қарыйлар. Кәзләп қарый башлаған ыйым, таптым.

**КӘЗҮҢКӘ** *байк.*, **КӘЗҮҢКЕ** [*гар.*] *яушт.* к.: **кәзәнкә 2**.

**КӘЙ 1.** *каз.ар.* кечкенә, ябык, чандыр (маленький, худой, хилый, тощий). Безнең бу қызыбыз нишәптер бик кәй. – *дөб.* Беренче бала кәй була. – *лш.*; **2.** *брб.д.* физик кимчелек (физический недостаток). Аусы кәйлү. Күсендә кәйе пар шәгеллү, начар қарайты; **3.** *каз.ар., нрл., т.я.-крш., төм.* яман, начар, әйбәт түгел (плохо; дрянной). Мона шул жағы кәй, су жырақ. Мин кәй жирдән килмәгән, сондоқ тулы ийе суққан әйбер. Бәрәңге бик кәй бит, әкрен тишелә. Кәй жаққаннан жүwешләнә ул ызба. – *нрл.* Туган гына Аудаким, кил

утыр минн җанга, минн кәйем синн җанга сагыз булып җабышмас. – *т.я.-крш.* Җиләкләр җылдагыча түгел, кәй быйыл. – *дөб.* Кәй алар, кәй. Әркем үсенекен кәй итеп сөйлисе килми. – *төм.*; **4.** *нрл.* ярлы, начар (бедный, отсталый, плохой). Өчлө лампы йы әwәле, кәй ийек инде, кәй ийе тормош.

**кәй цыбык** *тбл., сазя.* тал чыбыгы – читәнне бәйләп куя торган (ивовый прут – для перевязывания плетня). Кәй цыбык йыккалы барам төсгә. – *тбл.*

**кәйгә әйләнү** *нрл.* к.: **кәйү 1**. Күршебез кәйгә әйләнде, бозолдо.

**КӘЙӘ I** *мам., минз.* к.: **койты**. Тормышы кәйә булган. Быйыл кәйәрәк, кортлар бик җәрийәлмәй. – *минз.*

**кәйә күрү** *бәр.* чит күрү, үз итмәү (чураться, чуждаться). Үз әниләре үлгәнгә кәйә күрделәр моно.

**кәйәгә қалу** *мам.* к.: **йончу I, 1**. Бу алма ағачын җил сындырды да, әнә шулай кәйәгә қалды ул.

**КӘЙӘ II** *тбл.* к.: **ичке**. Кәйәләрен пәстеккә йебәрмәйтләр, керәтәгә керәтләр.

**КӘЙӘЛӘНҮ** *кмшл., чст.* к.: **кәйү 1**. Мин қайтуға әтиләрнең тормышлары кәйәләнгән иде. – *кмшл.*

**КӘЙӘСӘҮ** *минз.* к.: **кимегү**.

**'ӘЙ'ӘНӘ'** *кас.* к.: **йәсничә**.

**КӘЙГЕНӘ 1.** *себ.* өчаякта киптерелгән ит турап, йомырка сытып, суган турап, борыч сибеп әзерләнгән ашамлык (еда, приготовленная путём тушения в треноге вяленого мяса с яйцом и заправленная луком, перцем и т.д.). Кәйгенә себерәк ашы, кәйгенәне пешерәләр қоротқан иттән, йомырқалы була, оцайақта бешерәтеләр. – *тбл.*; **2.** *тара.* киптерелгән иттән яисә казыдан пешергән аш (суп из домашней колбасы или вяленого мяса). Қоротқан итне турап салаты шулпаға, картуп турап салаты, йомырганы да туғып салаты та кәйгенә булаты. Кәйгенә пешерәбес қороған иттән йә казыдан, картук, йомырқа, бийас салабыс; **3.** *тара., тбл., төм.* каклаган иттән кыздырма (жаркое из вяленого мяса); **4.** *тбл.* к.: **йәсничә**.

**КӘЙЕГҮ** *т.я., каз.ар., кргл.* **1.** начарлану, ябыгу (стать плохим, стать хилым; похудеть). Киткенче йереттем бызауны үләнгә, мин киткәч кәйеккән. – *кргл.* Бу йылларда бик кәйекте абыйың. – *к.т.* Чирләде дә кәйегеп китте. – *лш.*; **2.** зәгыйфьләнү – үсемлекләр турында (стать хилым – о растениях). Тушлай кәйегеп кенә утыра инде ул гөл. – *дөб.* Қоролоқтан соң уҗымнар да кәйекте. – *к.т.*; **3.** *злт.* тую, күңел булу, бизү (насытиться, пресытиться, опротиветь). Күрдем инде, туйдым, мин әйтәм, кәйектем. Күкәйдән кәйектем, күп ашаған ыйым.

**КӘЙЕКСҮ** *кргл.* бирешү, хәлсезләнү (слабеть, обессилеть, сдаться). Чирдән соң кәйекседе, бик шәп кенә қатын ыйы.

**КӘЙЕКТЕРҮ** *каз.ар., т.я.* к.: **койтырту**. Тегесен талап кәйектерделәр бибинен. – *дөб.* Кәйектереп бетерәсез мәче баласын, теләсә ничек әwәләп, қурқытып. – *мам.*

**КӘЙЕМӘҮ** *кргл.* борчылмау (не беспокоиться, не горевать). Әйткән сүзләренә син кәйемә дә, дим.

**КӘЙЕН** *тара., тбл.* **1.** соң – бәйлек (после – послелог). Төштән кәйен уқыйты. – *тара.*; **2.** соң (поздно). Кәйен килгәннәрнеңке иге ғыс қалыпты. – *тбл.*

**кәйен ағу** *төм., тара.* чигенү, артка китү (отступить, отойти назад).

**кәйен тарту** *тара.* артка тарту (тянуть назад). Кәйен тартцы алмағацны.

**КӘЙЕНҮ** *әстр.* **1.** борчылу, кайгыру (тревожиться, горевать). Бик қаты кәйенә қыз анасы; **2.** кызгану (жалеть). Кәйенеп йөри, йазық.

**КӘЙЕРӘК** *нрл.* начаррак (хуже). Имәннең кәйерәге инде үзебезгә була торған ыйы.

**КӘЙИМ** *брб.д.* кием (одежда).

**КӘЙЛӘ** [*гар.*] *мәл.* хәйлә (хитрость). Кәйләң булмаса, Алла ни памужыт.

**КӘЙЛӘНҮ** *нрл., глз.* начарлану (ухудшаться). Кәйләндек инде қәзер, қартайдық. Кәйләнмәсен дип, куфтыны чумаданға салып қуйдым. – *нрл.* Монау өйне утытқачын, кәйләнде күршем. – *глз.*

**КӘЙЛЕ** *злт.* к.: **кәй 3**. Нисек ашыйң да кәйле қый, телне бөрөштерә.

**КӘЙЛЕК** *т.я., т.я.-крш.* начарлык (скверность). Саулығы кәйлек белән ташлар инде (эшне). – *т.я.-крш.* Малны табам, күп бетерәм, Әллә үзем кәйлектән (*хал. җыр.*). – *к.т.*

**КӘЙМӘ** *тбл.* к.: **цәмпәр 2**. Кәймәләр салып тегәтләр көйләкләрне, қысыл, күк.

**КӘЙМӘ-КӘЙМӘ** *кргл., бгрс., шрл.* бормаланып, борма-борма (изгибаясь, извилисто). Димне генә қара, кәймә-кәймә аға. – *бгрс.*

**КӘЙНӘ** *стрл.* к.: **биана(й)**. Мин күпне күрдем кәйнәдән.

**'ӘЙНӘ'** *кас.* к.: **йәсничә**.

**КӘЙНӘЛЕ** *брб.д.* бармый торган, алга барасы урынга артка бара торган, үтә чыгымчы – ат турында (ленивый, вялый, – о лошади). Кәйнәле ике үшән ат.

**КӘЙРӘ** *брб.д.*, **КӘЙРИ** *твр.* кире (обратно). Ташны алып кәйри чығарып тау башына салып қойды.

**КӘЙСЕТҮ** *дөб.* к.: **кимнәү**. Бик кәйсетеп сөйләшә ул. Кәйсетмә кешене.

**КӘЙТӘН** *лш., крш., перм., чст.* укадан ишелгән бау, шнур (гайтан, тонкий шнурок из позумента). Итәккә кәйтән тыту бар ийе. – *чст.* Әйтәмен дә, дустым, әй әйтәмен, Укалардин чалдым кәйтәнем (*хал. җыр.*). – *лш.*; **2.** *нгб.* ботинка бавы, шнур (шнурки для ботинок).

**КӘЙШӘҮ** *төм.* кәкрәю (сгорбиться, согнуться). Минең шигелле кәйшәйеп пөткән қортқалар.

**КӘЙҮ 1.** *нрл., трх.* начарлану (ухудшаться). Йыллар ғына кәйеп китте быйыл, қыздыра. – *трх.*; **2.** *кргл.* боегу, күңелсезләнү (унывать, становиться невесёлым, считать себя униженным). Барыб утырасың қунаққа, кәйеб утырасың инде ғәрләнеп.

**КӘЙҮК** *сазя.* каек – тактадан эшләнгән зур көймә (каюк).

**КӘКӘЙ I** *т.я.-крш.* к.: **кәки**. Җәй көнө кәкәй күп булмый базарда. Дуңгыз кәкәйе тураган энде анда.

**КӘКӘЙ II** *мам.* к.: **бәбәк II**. Суганнарым кәкәй чыгара башлаган.

**КӘКӘЙ III** *перм.* к.: **кәбәм 2**. Хәтирә бигрәк менчел инде, бераз аурап йатқан идем, қурқып кермәде қәкәй.

**КӘКӘЙ IV** *хвл.* к.: **кәкәч II**. Бәр авызыңнан, кәкәй ул.

**КӘКӘЙЕМ** *перм.* 1. к.: **кәбәм 2**. Тапмыйым инде, кәкәйем; 2. к.: **кәбәм 3**. Апач үскән ңенә wы, кәкәйем.

**КӘКӘМ** *лш., мам.* к.: **кәбәм 1**. Кәкәм, син минем идәнне себереп алырсың. – *мам.* Кәкәм, миңа қуйан мамығыннан шәл җыйып бир әле, ди. – *лш.*

**КӘКӘРӘЙ** *брб.д.* әтәч койрыгындагы озын канатлар (самые длинные перья на хвосте у петуха).

**КӘКӘЧ I** *чст., чпр.* к.: **пәрәпәч 1**.

**КӘКӘЧ II** *лш., к.т.* шакшы, әшәке – балалар телендә (грязный – в детской речи). Кәкәч ул, қызым, қапма. Ана, күлмәгең кәкәч булган. – *к.т.*

**КӘКӘШ 1.** *чст., срг., мәл., чпр.* к.: **пирипич**. Тыwарук йасап кәкәшләр пешерәсен. Кәкәш ацы камырдан, аны сары май белән майласаң, бигрәк тәмне була. – *чпр.* Аша берәрне кәкәш. – *срг.* Эремчек кәкәше пешерәбез. – *чст.*; **2.** *чст.* к.: **пәрәпәч 1**. Йулыңа ит кәкәше пешермен инде; **3.** *чст., срг., мәл.* к.: **дурочмақ**. Картук кәкәше ашый алмадым, үкенечем калды. – *срг.* Кара тегене, тары кәкәше кебек изрәп тыра. – *мәл.*

**кәкәш борын** *мәл.* яньчек борын (приплюснутый нос).

**КӘКЕЛДӘҮ** *мам.* какылдау (гоготать). Син қаз булып кәкелдәдең дә қалдың.

**КӘКЕРЕ I** *минз., злт., стрл.* к.: **кукыл′**. Кабар урныгыз булмаса да, җылы бәрәңге кәкересе ашагыз әле. – *стрл.* Эремчектән wақ қына кәкере пешерәдер ийек. – *минз.*

**қазан кәкересе** *злт.* казанда пешерелгән эремчек бөккәне (пирожок из творога, сваренный в бульоне).

**КӘКЕРЕ II** *бөре.* арба карамасы (вязки телеги).

**КӘКЕРЕЧ** *перм.* кәкре (кривой). Қарчығым эшкә җарамый, хәзер кәкереч инде.

**КӘКЕРЕШКӘ** *минз.* к.: **қустартқыч**; чаг.: **кисағач**. Кәкерешкәгә киндерәсе ләгеп барып төшкән дә, и Ходайым, җеннәр тотто бит дип, торорға қурқып җата икән.

**КӘКЕРИ** *минз., крғл., бгрс., стрл., шрл.* к.: **кукыл′**. Кәкери пешердем, җаңғыр җawулық белә эшкә бармадық та. – *минз.* Қызым, кәкери ашағыз. – *крғл.*

**КӘКЕРМӘЦ** *твр.* тимер мич торбасы (труба железной печки). Мицнең кәкермәцен төзәтмәпте.

**КӘКЕШ 1.** *срг., чст., чпр., шрл.* к.: **пирипич**; **2.** *срг.* к.: **кукыл′**.

**КӘКИ** *трх., нрл., т. я.-крш.* ит (мясо). Кәки пешереп җәрим. Кәки пешердем ийе. – *нрл.* Кәки ашыйсызмы? – *т. я.-крш.*

**сөйәксез кәки** *трх.* бәрәңге – шаярту (картофель – шуточн.). Утырыгыз, сөйәксез кәки белән сыйлыйбыз.

**КӘКИЙ** *нрл.* 1. яңа суйган ит (свежее мясо). Кәкий дип суйган wахытта ғына әйтәләр; 2. к.: **кәки**. Элгәре кәкий диб әйтә торғаннар ийе итне.

**кәкий йасау** *нрл.* ит әзерләү (готовить мясо, запастись мясом). Кәкий йасадыг әле.

**КӘКИР** *тбл.* к.: **қустартқыч**.

**КӘКИТ: кәкит шәл** *кас.* озын чуклы ефәк шәл (шёлковый платок с длинной бахромой). Кәкит шәл була, чәчә'ләре би' озон, жиби'.

**КӘКМӘК** *нрл.* к.: **кәтмәк I**. Бәрәңгене көрәк белән утыртабыз, кәкмәк белән күмәбез.

**КӘКМӘЛӘҮ** *брб.д.* сакаулану (стать косноязычным).

**КӘКМӘШӘ** *дөб.* кәшәкә (клюшка). Кәкмәшә суғып уйный торған малай булған инде ул.

**кәкмәшә уйнау** *дөб.* к.: **кусака: кусака суғу**. Малайлар белән кәкмәшә уйнап йөри.

**КӘКРӘБӘ I** [*фарс.*] *төм., тбл.* муенса (ожерелье, бусы). Кәкрәбәм ике ите минең, қатқым киләде, тип әйтқәц, қысыма пиртем. – *төм.*

**КӘКРӘБӘ II** *тбл.* к.: **кикрук**.

**КӘКРҮШКӘ** *трх.* самовар торбасы (труба самовара).

**КӘКСӘҮ** *перм.* к.: **күксәү 2**. Кәксәү йүткереб йөргән кеше була, бер туқтамый.

**КӘКТӘ 1.** *төм., тбл., саз.я., тара.* бәйләнгән оекбаш (вязаные носки); **2.** *твр.* эт тиресеннән теғелгән оекбаш (носки из собачьей шкуры).

**КӘКТӘР** *төм., тбл.* к.: **голекай**.

**кәкүк** (кукушка):

**кәкүг итек** *перм.* аю көпшәсе, аю табаны (борец высокий).

**кәкүг уты** *стрл.* үлән исеме (название травы).

**кәкүк читек** *перм.* к.: **кәкүг итек**.

**КӘКЦӘЛЕК** *төм.* артталык, артта калганлык (отсталость). Кәкцәлеге белән аңнамай қалған.

**КӘКЦЕК** *төм.* кәкре, кыек – очлы башы күтәрелеп торган аяк киеме турында (кривой – о загнутом кверху носке туфель). Кәкцек пашлы түплә.

**КӘКЧЕК** *туб.-ирт.д.* йөргәндә гәүдәсен артык туры тота торган кеше (человек, который при ходьбе держится слишком прямо).

**КӘКШЕТҮ** *т.я.* кипшетү (дать подсохнуть, подсыхать). Жилдә йафрақны әз генә кәкшетеп аласың. – *трх.* Айаг астын кәкшеткән, хәзер була җөрөргә. Пичкә қуйып кәкшетеп алдым қабақ орлоғон, бик тәмне булды ашарға. – *к.т.*

**КӘКШҮ** *т.я., чпр.* кибү, кипшенү (подсыхать, подсохнуть). Берәр көн җаумаса, җул хәзер кәкши ул. Чеп-чи утын, җаргалап қуйсаң, ичмаса, җилдә бираз кәкшер ийе. – *к.т.*

**КӘЛӘБӘ** *бгрс.* к.: **қатлық**. Кәләбә ул – дебет белән қушыла торған җеп.

**КӘЛӘБӘЦ** [*фарс.*] *тбл.* 1. к.: **кәпәч 1**; 2. хатын-кыз баш киеме (женская шапочка).

**КӘЛӘГӘ** [*фин-угыр.*] *төм.* гәрәнкә (брюква).

**кәләгә қawағы** *тбл.* шалкан яфрагы (ботва, листья репы, брюквы).

**КӘЛӘК, КӘЛӘКӘ** [*рус.* калека] *брб.д.* гарип (увечный, калека). Аннан да кәләкләр бар. Пы йанбаш аның кәләкә иде wайнадан.

**КӘЛӘМПЕР** *стрл.*, **КӘЛӘМФЕР** [*гар.*] *карс., мәл.* канәфер (гвоздика).

**КӘЛӘПҮШ** [*фарс.*] *дөб.* бәлеш капкачы (крыш-

ка, верхняя часть, макушка бәлиша). Иң элек кәләпүшен кисеб алалар да бәлешнең, бийүчегә бирәләр.

**КӘЛӘСӘ** [*рус.* колесо] *брб.д., клм.* к.: **йөгәртмә II**. Кәләсәләр йасый торғаннар иде арбаларға. – *клм.*

**КӘЛӘШ** *себ.* сөяркә (любовница).

**кәләш әйттерү** *тпк.* өйләндерү (женить). Ике улына кәләш әйттерде, ул беләдер инде тawар китеруләрне.

**КӘЛГӘ** *кас.* синька.

**КӘЛДӘ** [*гар.*] *перм.* к.: **кәллә I, 1**. Кәлдә сийә үзеңә ошағаң бу қызың. Кәлдә анасы инде, ике бер тамчы су.

**кәлдә мечик** *перм.* к.: **чечерекле**.

**КӘЛДИН-КӘЛДИН** *минз.* акрын-акрын, көйгә генә (тихо, медленно, на свой лад); чаг.: **акыр: акыр гына**. Кәлдин-кәлдин генә қайтып килә.

**кәлен** *глз.* килен (сноха, невестка):

**бәчә кәлен** *глз.* киленнәрнең зуррагы (старшая из снох).

**КӘЛЕП-КӨЛӨП** *тпк.* к.: **кәлп-кәлп**. Тайақ тайанған, кәлеп-көлөп, кәлеп-көлөп килә.

**КӘЛҖӘМӘ** *бөре.* к.: **өшемкә**.

**КӘЛҖЕМӘ I 1.** *т.я., чст., чпр., мәл.* к.: **кукыл′**. Кәлҗемә йасаған йеләктән. Кәлҗемә йасыйбыз эремчектән. – *чпр.* Эчәк кәлҗемәсе, кабак кәлҗемәсе пешәрәбез. – *мәл.* Мына кәлҗемә ашағыз. Көз көне мин бик пешерәм қабақ кәлҗемәсен дә, кәбестәнекен дә. – *к.т.*; **2.** *минз., бөре., байк.* черегән бәрәңге күмәче (лепёшки из гнилой картошки). Кәлҗемә чергән бәрәңгедән пешерәсең, чергән бәрәңгене әрчеп төйәсең. – *бөре.* Бәрәңге кәлҗемәләре пешердек, йаз чергән бәрәңге җийып. – *минз.* Цергән бәрәңге кәлҗемәсе ашаб үсте ике малай. – *байк.*

**казан кәлҗемәсе** *чпр.* к.: **кәкере I: қазан кәкересе**. Казан кәлҗемәсе салып бир әле, Шәфика аптый.

**қазан кәлҗемәсе** *к.т.* киндер орлыгы яки киндер орлыгы белән эремчекне кушып пешерелгән пилмән (вареники из конопляного семени либо из толчёной конопли, смешанной с творогом). Қазан кәлҗемәсе ди-ди, киндер орлоғон эремчек белән бергә қамыр эченә тыгып пешерәсең. Эремчегенә быраз гына орлоқ та қушып қазан кәлҗемәсе пешердем, бик тәмне булды.

**КӘЛҖЕМӘ II** *минз.* к.: **пәрдәй**. Кәлҗемәләр җыйып, фәқыйрлек белә гөмөр иттеләр ул чағында.

**КӘЛЗЕМӘ** *байк.* к.: **кәлҗемә I, 2**.

**КӘЛИ I** *тара.* к.: **бала I, 2**.

**КӘЛИ II** *перм.* тигезсез җир, түмгәкле җир (неровная, кочковатая местность).

**КӘЛИГӘ I** [*удм.*] *перм., бөре., төм.* к.: **кал′ага**. Кәлигә бешердем ийе, балалар аны сүми қәзер. – *перм.* Кәлигә уҗым қалмадымы? – *төм.*

**КӘЛИГӘ II: кәлигә түтәл** *минз.* озынча түтәл (грядка продолговатой формы).

**КӘЛИНКӘ** [*рус.* калитка] *нгб.-крш.* бакча ишеге (калитка, ведущая в огород). Кәлинкә ишеген жап, бозау кермәсен.

**КӘЛИҢКӘ** *нрл.* **1.** к.: **кәлиткә I**. Кәлиңкә генә инде бу, кечкенә; **2.** келә (запор, щеколда). Кәлиңкәне шықылдатасың, хуҗа чыға.

**КӘЛИТӘ** [*рус.* корыто] *каз.ар.-крш.* к.: **тигәнә 1**. Кәлитәгә су салығыз кер жуwарға.

**КӘЛИТКӘ I** [*рус.* калитка] *трх.* өйалдыннан ишегалдына яки ишегалдыннан бакчага чыга торган кечкенә капка (калитка, ведущая во двор или в огород).

**КӘЛИТКӘ II** [*рус.* клеть] *минз.* к.: **кәзәнкә 2**. Кәлиткәдә тора шунда wағы-төйәге.

**КӘЛКӘ** *нрл.* к.: **кисеркә 1**.

**КӘЛКЕТМӘ** *перм.* к.: **қалатқы**.

**кәлкетмә қойроқ** *перм.* к.: **кәмәцә 1**.

**КӘЛКЕТУ** *перм.* бер югары, бер түбән төшереп тору, астан өскә йөртү (качать сверху вниз). Қойорығын кәлкетеп тора ул қош.

**КӘЛКҮН 1.** *минз., стрл.* к.: **атын**. Бар, әзерәк кәлкүн атынып килегез; **2.** *перм.* к.: **қалатқы**.

**КӘЛЛӘ I** [*гар.*] *перм.* **1.** гел, нәкъ (точно, точь-в-точь); чаг: **бетереп**. Минеке дә қәләм кәллә синеке қәләмең кебек; **2.** к.: **башала 1**. Анда кәллә балчық әле.

**КӘЛЛӘ II** [*гар.*] *дөб., нрл.* к.: **кәпәч 1**. Элек ирләр кәллә кийәләр ийе, җегетләрдә қара хәтфә кәллә йе. – *нрл.* Синең бу кәлләң бик матур икән. Әwәле кәллә эшлиләр ийе, читек тегәләр ийе қызлар. Башларына кәллә кигәлләр. – *дөб.*

**КӘЛМӘШТЕРУ** *мәл.* к.: **қоршу 1**. Мунча кисәге кәлмәштердем әле.

**КӘЛПӘК 1.** *чст., мәл., трх.* к.: **кәпәч 1**. Кәлпәген кигән бабаң, кәлпәкләре матур, иләмле. Ани бер кәлпәк сатам, қалпақ урынына кийәрсен. – *трх.* Кәлпәгенне ки, карт, кызу сукмасын башыңа. – *мәл.* Бу, мәйтәм, шәб икән кәлпәк. – *чст.*; **2.** *к.т.* к.: **калфак 3**. Кәлпәге қайа самуwарның, исе бар, бастырырға кирәк; **3.** *кргл.* йон эшләпә (войлочная шляпа). Мынawы кәлпәкне ничек итеп кийеп бара инде. Башқа кәлпәк кийәләр җөннән әwәләп.

**кәлпәктә булу** *к.т.* салмыш булу (быть слегка навеселе). Бераз кәлпәктә бар, чыгыйм әле, йазалар да йазалар монда.

**КӘЛПЕК** *минз.* к.: **ашақ**.

**КӘЛП-КӘЛП** *тпк.* алпан-тилпән (вперевалку, вразвалку). Ике тубық бөгөлә, кәлп-кәлп итеп қала.

**КӘЛСӘ** [*рус.*] *клм.* к.: **калча II**.

**КӘЛТӘЙТУ** *трх.* калкыту – башны (поднять – голову). Башын кәлтәйтә дә қарый тегеләрне.

**КӘЛТЕР** *перм.* к.: **горда**.

**КӘЛТЕРӘК** *тбл.* ипсез (неловкий, неприспособленный).

**КӘЛТЕРӘУ** *тара., тбл.* калтырану, калтырау (дрожать, трястись). Қартайғансын кәлтерәп йөрийем өйтә. – *тара.*

**КӘЛ′УС** [*рус.* колесо] *карс.* к.: **йөгәртмә II**. Ылым, арбаның кәл′услары алыштырмаганмы, йахшыларымы?

**КӘЛЦӘ** *яүшт.* к.: **кисеркә 1**. Кәлцә йылан қойроғон өскалтыра (өзеп калдыра).

**КӘЛЦӘК** *тбл.* кәлчәк (чехонь).

**КӘЛШӘ 1.** *мам.* яшелчә үрентесе (рассада овощей). Бу памидурның кәлшәләрен Теләчәдән (*ав.*

*ис.*) апкайтып утырттым. Қыйар, памидур, қабақ кәлшәсе апкайттым сафхуздан, утыртасы булыр. Кәлшә була бит инде ул бәрәңге, тишелеп чыққачыннан; **2.** *нрл., каз.ар., шрл., мәл.* урып-җыю вакытында коелган ашлыктан үсеп чыккан иген үсентеләре (молодые всходы хлебов на убранном поле из осыпавшихся во время уборки зёрен). Арыш қойолоп кәлшә киткән. – *каз.ар.-крш.* Ашлыққа урғачтын кәлшә үсә, көзән маллар йөртәргә әйбәт була. – *мам.*; **3.** *минз., чст., чпр., т. кам.-крш.* коелган орлыктан яки камыл төбеннән үсеп чыккан солы (новые всходы овса после уборки урожая). Йаңгырларга китсә, сылыны ургач кәлшә үсә. – *чст.* Сылыны чапқач, кәлшә китә, аны чабып аласың. – *т.кам.-крш.*; **4.** *блт., бәр., дөб., минз., мәл.* к.: **алсын 1.** Кәлшәне чапмыйлар, чабып булмый икенче қатын. – *бәр.* Көз көне кәлшә печәнне чабабыз. – *блт.* Қар җауғанчы кәлшә чawып алсаң, шақтый курмы була. – *дөб.*; **5.** *дөб.* коры елларны соң тишелеп өлгереп җитми калган ашлык, буш башаклы иген (поздние, недозревшие всходы хлебов); **6.** *кузн.* яз башында кар астыннан ук үсеп чыккан яшь үлән (зелёная травка, поднявшаяся ранней весной прямо из-под снега); **7.** *лш.* кыяк печән (осока).

**КӘЛШҮ** *каз.ар.-крш.* к.: **кәкшү.** Кәлшегән печән.

**КӘЛҮСӘ** [*рус.* колесо] *кас.* к.: **йөгөртмә II.**

**КӘЛҮТӘР** *перм.* к.: **ғорда.**

**КӘЛҮШ** *к.т., бгрс.* к.: **галуш 1.**

**қаты кәлүш** *минз.*, **каты кәлүш** *стрл.* туфли рәвешле күн аяк киеме (кустарные кожаные туфли). Қызга шәл чәчақлы йә йақшы читсамы, сатинмы күлмәк, қаты кәлүш бирәләр ийе күн итек қунычыннан теккән, сай батинкы кебек була.

**кәлүш итек** *минз.*, **кийез кәлүш** *минз., стрл.* к.: **галуш 1.**

**күн кәлүш** *мам.* ботинка (ботинки). Күн кәлүш була торған ийе, аның артына туз қуйа торған ийек тә шығыр-шагыр бара торған ийе ул.

**сай кәлүш** *минз., стрл.* к.: **галуш 1.**

**КӘЛҮШӘ 1.** *тпк.* ботинка рәвешле күн аяк киеме (кожаная обувь типа ботинок). Кәлүшә кийә торған ийек, күннән тегә торганнар ийе; **2.** *минз.* к.: **галуш 1.** Кәлүшәне қартлар-қарчықлар кийә.

**КӘМ** [*гар.*] *тара.* чара (мера, средство). Ул әшкәрә осақ аурты, пер кәмен гүрү гәрәк ите.

**КӘМӘГӘЧ** *брб.д.* **1.** мичнең казан утырта торған өлеше (часть печи, в которую вделывается котёл); **2.** тандыр.

**КӘМӘК** [*рус.*] *тбл.* к.: **йалман 1.**

**КӘМӘЛ I** *брб.д.* к.: **кәбин.**

**КӘМӘЛ II** [*гар.*]: **кәмәле килү** *т.кам.-крш.* рәвеше килү, якынча ошау (стать приблизительно схожим по форме, принять сходную форму). Кәмәле килгән бит.

**кәмәленә китерү** *лш., т.кам.-крш.* килешен, рәвешен китерү, якынча охшаш итү (сделать похожим, уподобить). Кәмәленә китерә бит. – *т. кам-крш.* Кәмәленә китерсәң, йарый инде. – *лш.*

**КӘМӘХ** [*рус.*]: **кәмәх цыцхан** *сазл.* к.: **йалман 1.**

**КӘМӘЦӘ 1.** *тбл.* су чыпчыгы, чәперчек (трясогузка); **2.** *төм., тбл.* карлыгач (ласточка); **3.** *төм.* яр карлыгачы (стриж). Кәмәцә бозга ултырып килә, агацларға ултырып, шуның өцөн ул кәмәцә.

**КӘМӘШЕ** *т.я.* кисәге: үзе бәйләнгән сүзнең – исемнең мәгънәсенә кимсетү төсмере бирә торган сүз (слово, придающее имени оттенок пренебрежения; досл. кусок). Силсәwиттә эшләгән кеше нәчәлник кәмәше инде ул. – *нрл.* Қарт белән қарчыққа бер сыйыр кәмәше булса җиткән. – *к.т.*

**КӘМЕР** *мам.* киндер агарту өчен кулланыла торган порошок (порошок-отбеливатель для холста). Киндер туқмап, кәмерләргә манчып аласың да чирәмгә җәйәсең, киндер ағарта торған ул. Элек кәмер белә ағартқаннар, ақ парашук ул.

**КӘМИР: кәмир шәл** *лмб.* челтәрле, кабарынкы бизәкле, озын чуклы ефәк шәл (ажурный шёлковый платок с длинными кистями). Кәмир шәл ул күбек кебек өрелгән шәлләр була.

**КӘМИТ** [*рус.* комедия] *нрл., трх.* карусель (карусель на ярмарках). Өчәр кәмит килә торған ийе йәрминкәгә. – *нрл.* Кәмит булған Қыйат (*ав. ис.*) йармуңкасында. – *трх.*

**КӘМНӘҮ** *мәл.* кимсетү (унижать, унизить). Бик кеше кәмнәгән шул ул, мин укыган дип.

**КӘМҮК** *брб.д.* кимек, сөякнең йомшак җире (мягкие части костей).

**КӘМҮКЛӘШҮ** *брб.д.* йомшару, көпшәкләнү – сөяк, агач турында (делаться мягким, дряблым – о костях или дереве).

**КӘМШӘЙТҮ** *тбл.* бозу, кыегайту, турсайту – авыз турында (искривить, надуть рот). Кәмшәйтеп awызыңны, утырма сықтагалы.

**КӘМШӘЙҮ 1.** *минз., перм., кмшл.* ямышәю, яныч елү, кыйшаю (вдавливаться, скоситься, загибаться). Чәйгүннең бороно кәмшәйгән. – *минз.* Эшләпәңнең чите кәмшәйгән. – *кмшл.*; **2.** *тбл., сазл., брб.д.* кыйшаю – авыз турында (скривиться – о рте). Кәмшәймә! Сықтағың киләмә гәрәк? – *тбл.*

**КӘМШЕК 1.** *злт.* киң, җәенке – борын турында (приплюснутый – о носе). Кәмшек танаулы; **2.** *злт., шрл., тбл.* ямышәйгән, кыегайган (кривой, вдавленный, скосившийся). Awызы кәмшек, башы тақыр, қызлар күзли икән. – *злт.* Мынау кәмшек awыс ник сықтайты таға? – *тбл.*; **3.** *шрл.* ямышек (сплющенный, вдавленный). Кәмшек-кәмшек awызлы әбиләребез ошады, ахыры, үзегезгә.

**кәмшек танау** *злт.* почык борын (курносый).

**КӘМШЕТҮ** *трх.* кипшетү (дать подсохнуть, сохнуть). Тары җармасын җуwалар, кәмшетәләр, киптерәләр инде.

**КӘН** *себ.* күп (много). Сас цийәне кән йыйатылар пестә. – *сазл.* Кән кешеләрне уғытқан. Палаларығыс кәммә? Кән кеше утырмау гәрәк. – *төм.* Тыуганнарыбыс та гән. Өйләнмәйен йөргәннәр кән түгел. Икетән туған ағасы йетмешне ашты, кән йәшәте. – *тбл.* Кән йәптертәкле гөйләкләр пулып. – *твр.* Цийәне кән йыйат ите. Кән йәшкә йетеп қуйдым, перқайда киткәнем йуқ, монта тыуғаным, монта үскәнем. – *тара.* Өс-вашха алынғалы кәрәх ит кәнрәх. – *сазл.*

**КӘНӘ** *сазл.* йә әле, яле (ну-ка). Кәнә, кит.

**КӘНӘЙТҮ** *себ.* күбәйтү (умножить, увеличить). Иртәгесен кәнәйтеб ийәм қамырны. – *твр.*

**КӘНӘПИ** [*фарс.*] *нокр.* урындык, артлы утыргыч (стул).

**КӘНӘПИЛ** [*фарс.*] *тара.* к.: **кунапил.**

**КӘНӘТИЛ** [*рус.* канитель] *перм.* кием-салымга тотар өчен, алтын яки көмеш укадан үрелгән уралма, канитель (серебряная или мишурная витушка для золотошвейных работ, канитель). Башындағы түбәтәйең Кәнәтилме, уқамы (*хал. җыр.*). Уқамы, кәнәтилме шунда қалпағы.

**КӘНӘШ** *чст., чпр., мәл.* к.: **қолқай.** Кәнәш үсә-үсә тайга әләнә. Ат кыннады, кәнәше бар. – *мәл.* Кәнәшләргә азык салырга кирәк. – *чпр.*

**КӘНӘШ-КӘНӘШ** *тмн., трх.* колын чакыру ымлыгы (возглас, которым скликают жеребёнка).

**КӘНДЕ** [*гар.*] *байк.* нәкъ (точно, словно, будто, чисто). Әле целлә шул, кәнде шындый цак. Кәнде арыш цагында ызбабыз йанды. Кәнде сугыш wакытында тугансыз. Кәнде петчән өстө туры килде.

**КӘНДИ I** [*фарс.*] **1.** *т.я., лш., дөб., кмшл., чст., мәл., т.кам.-крш., минз., кргл., стрл.* артык зур булмаган агач яки металл табак, зуррак агач яки металл савыт (небольшая чаша, большая миска). Кәнди белән қарабодай ботқасы пешергән. Бер кәнди қатық бирсәң ийе. Тәрилкә урынына шушы кәндиләрне җөртәм мин аш ашарға. – *к.т.* Миңа шушы кәндигә генә салып бир. – *кмшл.* Бәрәңгене кәндигә генә салдым. – *чст.* Салқын су алып эчтем бер кәнди. – *минз.* Ағач кәнди тотоп килә, шуңа он салып алып китә. – *кргл.* Қурқулық қойғанда, қургашын эретеп баш түбәсенә кәнди қойганнар. Бер кәнди бәрәңге алып чықты. – *к.т.* Кәндиләргә салып ашаш булмаған әwәле. – *кргл.*; **2.** *к.т., чст.* һәртөрле кечерәк табак, савыт (миска из любого материала); чаг.: **бадйан 1.** Үзеңә зуррақ кәндигә сал, малайға кечкенә ағач кәндигә сал бутқаны. – *к.т.*

**КӘНДИ II** [*фарс.*] *мам.* болында чебен-черкидән саклану өчен марлядан корыла торган чатыр (палатка из марли, временно устроенная во время сенокоса для защиты от комаров).

**КӘНДИК** *брб.д.* кендек (пупок).

**КӘНДИТЕР** [*рус.* кондитер] *блт.* камырны җәеп, майлап, песок сибеп, борып-борып пешерелгән кабартма (слоёная пышка, булочка-слойка). Чәйгә кәндитер пешерәләр бороп-бороп.

**КӘНДУЛ** *тпк.* камзул (камзол). Кәндулым матур ийе tydмac борон.

**КӘНСӘ** [*рус.*] **1.** *лш., блт., каз.ар.-крш., минз., бөре.* канцелярия, колхоз канцеляриясе (канцелярия). Кәнсәгә бер барганым җук. – *лш.* Безне кәнсәгә чақырттылар. – *блт.* Анда кәнсә салдылар. – *бөре.*; **2.** *блт., бөре.* колхоз идарәсе (правление колхоза). Кәнсә йук бездә. – *блт.* Колхуз кәнсәсе дә шунда. – *бөре.*

**КӘНТӘ I** *стрл.* көянтә (коромысло). Кәнтә кебег итеп бөгәлҗәсен куйалар бишекнең.

**КӘНТӘ II** *тара., сазл.* күптән (давно). Кәнтә бер гилгәйте. – *тара.* Кәнтә булған хәл. – *сазл.*

**КӘНТӘЙ 1.** *минз., кмшл., нгб.-крш., тпк.* к.: **қанчық 1**; **2.** *перм.* эшлексез, тик йөрүче (бездельник).

**кәнтәй йыланы** *минз., бөре., кмшл.* к.: **кисеркә 1.** Қурықма, кәнтәй йыланы бит ул. – *бөре.*

**КӘНТӘРЛЕ** [*рус.* кантар + *афф.* -ле] *бәр., бөре.* кәсле, кантарлы (с глыбой, комом – о земле). Аларга икенче мәртәбә сөрәсе бар ийе, бақчалары кәнтәрле. – *бөре.* Бақча кәнтәрле быйыл. – *бәр.*

**КӘНТУЛ** *тпк.* к.: **кәндул.** Бы кәнтулымны қыdым аппирде.

**КӘНҮШНӘЙ** [*рус.* конюшня] *минз., перм., злт., чст.*, **КӘНҮШНИ** *нрл.* к.: **абзар 1.** Сыйыр қыш көнө кәнүшнәйдә тора. – *минз.* Кәнүшнәйнең мөгөшөндә бер күкәй бар. – *злт.* Безнең кәнүшнәй эссе, мөкләп күтәргәс. – *перм.* Җәйен лапаста тора, қышын кәнүшнәйдә (терлекләр). – *минз.* Хәзер кәнүшнигә чығардық бәрәңгене. – *нрл.*

**кәнфит** [*рус.* конфета] *әстр.* конфета:

**кәнфит сындыру** *әстр.* кызны бирергә риза булу, кызны килешү (сговориться, просватать). Кызны бирмәгә ыриза булсалар, кәнфит сындыралар.

**КӘНЧЕК** *трбс.* сөңге сыман корал (орудие в виде копья, используемое для ловли крупных рыб, оказавшихся в мелководных местах реки).

**КӘНЧӘЙ** *к.-уф.* к.: **қанчық 1.** Кәнчәй эт. Кәнчәй песи.

**КӘҢГЕЛ** *брб.д.* яхшы күңелле, ачык (добродушный, откровенный, любезный).

**КӘҢГЕЛДЕ** *т.кам.-крш.* текә тау (крутая гора). Кәңгелдедә қышы буйына қар булмый.

**КӘҢКӘЙҮ** *мам.* к.: **йалпайу II.** Кәңкәйгәнме бер йаққа өйөбөз?

**КӘҢКӘЙТҮ** *кргл.* кыйшайту, қыңгырайту (наклонить голову набок, скосить, скривить). Илһамийа қайда дисәң, башын кәңкәйтеп тора.

**КӘҢКЕРӘЙҮ** *лмб.* к.: **қуқырау.** Кәңкерәйеп малай белән утыра йәш килен, ыйалмый да.

**КӘҢКЕРЛЕ** *лмб.* һавалы, тәкәббер (гордый). Быраз кәңкерлерәг иде катны. Итенешле кешегә кәңкерле ат′алар, чораганда йәшми путле.

**КӘҢЛЕК** *брб.д.* к.: **кәңгел.**

**КӘҢШЕРЕК 1.** *туб.-ирт.д.* йоткылык өсте (носоглотка); **2.** *тбл., сазл.* к.: **қамақаш.**

**КӘП I** [*фарс.*] **1.** *себ.* сүз (слово). Йал иткән мәлгә парсағыс, кәп эшетәрсес. – *тара.* Пес кәпләгәнтә урлап та қуйтың пер гәпне. – *төм.*; **2.** *себ.* әңгәмә, сөйләшү (разговор, беседа). Кәбегесне пүлийем. – *төм.*; **3.** *тара., брб.д.* сүз, сөйләм, әйтем, мәкаль (слово, речь, поговорка, пословица). Порнағылар кәбе. – *тара.*

**кәп қапщық** *туб.-ирт.д.* тел бистәсе, күп сөйләшүчән (любящий много говорить, болтун).

**кәп кәпләү** *туб.-ирт.д.* сөйләшү (разговаривать).

**кәп килешентә** *тбл., сазл.* җае чыкканда, сүз уңаенда (к слову, при случае). Кәп килешентә әйтеп қуйайын, сес үсегес Қасанныңма? – *тбл.*

**КӘП II** *том.д.* к.: **голекай.**

**КӘПӘЙҮ** *мам.*, **КӘПӘРУ** *каз.ар.-крш.* к.: **киберләнү.** Қыз булып җиткәч кәпәргән инде ул.

**КӘПӘЦ 1.** *срг., чст., чпр., әҗе., күрш., себ.* к.: **кәпәч 1.** Кәпәцне өстәл артында кийәләр. Башка кәпәц кийә идек. – *срг.* Әнә килә әтәц, башында

кызыл кәпәц (*такмак*). – *чпр.*; **2.** *әҗе., себ.* кечкенә бала башлыгы (чепчик младенца). Баланын петүwен ту бун′ына, ту кәпәценә тагалар иде. – *әҗе.*; **3.** *срг., яүшт.* к.: **тәлпәк 3.** Хыт башына кәпәц тә куймағансыс. – *яүшт.*

**КӘПӘЧ 1.** *тмн., лмб., кузн., хвл., мәл., карс., баст., әстр., т.я., бәр., нгб.-крш., брб.д., том.д.* кәләпүш, түбәтәй (тюбетейка). Кәпәч кийәләрме хазер Казанда? – *лмб.* Бүген бик жар, кәпәч ки. Кара бархатны икене кәпәчне китерә. – *кузн.* Шул бабай бер кәпәч таж белән ызба салган, ди, айгыр алган, ди (*әкият.*). – *хвл.* Туйда инде ирләр кәпәчләрдән генә утыралар. – *карс.* Кәпәче йергә теште. – *мәл.* Кәпәчне Казанда баса торганнардыр, бархыт кәпәч. Казан кәпәчләре чибәрләр, көпме торалар. – *тмн.*; **2.** *дөб., бәр., стрл.* элек хатын-кызлар кигән укалы һәм әнҗеләр белән чигелгән бәрхет түбәтәй (бархатная тюбетейка, украшенная жемчугом и позументом, которую в старину женщины носили поверх платка); чаг.: **кәртәши.** Кәпәчне бик кидек без. Қыч чағымдагы кәпәчемне әл дә сақлыйм. – *дөб.*; **3.** *кузн.* киез эшләпә (войлочная шляпа для полевых работ). Кәпәҗ йасый иде, ышл′апа, кас′ы үзе йасый иде, кул′ар тоталар иде, йыннан; **4.** *трх.* фуражка.

**кәпәч бүрек** *лш.* к.: **кәпәч 2.** Әwәле кәпәч бүрег ийе җаулық өстеннән, хәзер шәпкә бәйләнгән қара җоннан, җә әкәй җаулық.

**КӘПЕР** *әчк.* кечкенә соскыч (маленький совок).

**КӘПЕРӘН** [*гар.*] *туб.-ирт.д.* сүрү (наперник).

**КӘПЕРЕНҮ** *кмшл.* тәкәбберләнү (возгордиться, задрать нос). Қандала дисәң, үрчи, имеш, кәперенеп-кәперенеп, кибәк дисәң, кибә, ди.

**′ӘПЕСТИ** [*рус.*] *кас.* к.: **капыста.**

**КӘПИЛ** [*гар.*] *брб. д.* җаваплылыкны үз өстенә алучы (поручитель).

**КӘПИЛЛЕК** [*гар.* + *афф.* -лек] *брб.д.* җаваплылыкны үз өстенә алу (поручительство).

**КӘПКЕР I** *себ.* сүзчән, күп сөйләүче, сөйләшергә ярата торган (разговорчивый, любящий поговорить). Ул кәпкер, күп пеләде. – *тара.*

**КӘПКЕР II** [*фарс.*] **1.** *баст., себ.* тишекле чүмеч, сөзгеч (шумовка, дуршлаг). Кәпкерне қулланалар пawырсақ пешерсәң. – *тара.*; **2.** *тара.* к.: **күмериләк.**

**КӘПКЕР III** *тбл.* үлгән кешене искә алу ашына махсус так итеп пешерелә һәм кунакларга өләшеп чыгыла торган вак-вак камыр ашы (маленькие пончики, специально и в нечётном числе испечённые на поминки; их раздавали присутствующим). Қырықпер күс кәпкер пешерәте, оллоларқа пешерәте, өләйте килгәннәргә.

**КӘПКИР** *әҗе.* к.: **кәпкер II, 1.**

**КӘПЛӘНҮ I** *брб.д.* киенү, бизәнү (наряжаться, краситься).

**КӘПЛӘНҮ II** *брб.д.* эләгеп калу (зацепиться); чаг.: **кипләшү.**

**КӘПЛӘНҮ III** *тбл.* **1.** төштә саташып сөйләшү (говорить во сне, бредить); **2.** сиздереп сөйләү (говорить намёками).

**КӘПЛӘНҮ IV** *трх.* каплану (покрыться, быть покрытым). Әйберләре кәпләнеп қуйылған булған.

**КӘПЛӘҮ I** *себ.* **1.** сөйләшү (говорить). Пес кәпләйекмә? – *төм.* Алар осақ кәпләтеләр, соң қына китте. – *тбл.*; **2.** сөйләү (рассказывать). Порноғоларны кән кәпләйте ул пашлық. – *тара.*

**КӘПЛӘҮ II** *брб.д.* эләктерү, тотып алу (поймать, ловить, удержать). Сыйыр мөгезенә кәпләп чығарға әйберсе йоқ.

**КӘПЛӘҮ III** *брб.д.* купшы (наряженный, щеголеватый).

**КӘПЛӘШҮ** *себ.* к.: **йәпләшү.** Әбәү, шаның пелән кәпләшеп пақ, тите. – *төм.* Кәпләште, үпкәләгән. – *твр.* Осақ кәпләшеп утыратығайнтық. Осақ кәпләшмәгән паланы баш түбәсеннән икмәкне йары сынтыра тыған. – *тбл.* Кәпләшмәгән паланыңқы түбәсентә йылы икмәк сынтқаннар. – *сазл.*

**КӘПРӘН** [*гар.*] *төм.* к.: **кәперән.**

**КӘПТӘР I** *туб.-ирт.д.* к.: **голекай.** Кәптәрләр пала цыгарып қуйғаннар. – *төм.*

**КӘПТӘР II** *тара.* к.: **кәпцән.** Ул кәптәр қуй, кән пеләте, әйтер.

**КӘПТӘШИ** *каз.ар.-крш.* к.: **кәртәши.**

**КӘПЦӘН** *себ.*, **КӘПЦЕ** *тара.* сүзчән (разговорчивый). Райқаннан кәпцән кеше йуқ ите. – *тбл.*

**КӘПЦЕК** *срг.* капчык (мешок). Шәкәрне кертеп куйа кәпцеге белә.

**КӘПЦЕЛ** *туб.-ирт.д.* к.: **кәпцән.** Кәпцел қортқа ул, парың, парың. – *төм.* Кәпцел қуй исе (үзе). – *тбл.*

**КӘПЧӘЛЛӘ** *тара.* кадак суыра торган корал, кадак суыргыч (гвоздодёр).

**КӘР** [*фарс.*] *дөб.* көч, егәр, куәт (сила, мощь). Чәйнекләрне гел wатып торам, қулларымның кәре йуқ. Қулның кәре җуқ, әйбер төшә дә китә.

**кәр итү** *кузн.* тәэсир итү, йогынты ясау (оказать влияние, влиять). Духтырның сүзләре Нәсригә кәр итте: ул эчүне высыга ташлады.

**КӘРӘ I** [*гар.*] *влгг.* к.: **арый.** Бер кәрә әйтә, икенче кәрә әйтә.

**КӘРӘ II** [*гар.*] *срг., хвл.* киенгән, ясанган (ряженый). Кәрәләр булып йериләр иде. – *срг.* Кәрәләргә пешерәләр бawырсакны, йана йылда йөриләр вата. – *хвл.*

**кәрә йерү** *срг.* элек: раштуа бәйрәме көннәрендә була торган, төрлечә киенеп башкарыла торган уеннар (в старину: игры с переодеваниями во время рождественских праздников у крещёных татар, святочные увеселения).

**КӘРӘБӘ** [*фарс.*] *карс., лмб., хвл., чст., перм., тпк.* гәрәбә (янтарь). Кәрәбә таккан бунна, кәрәбә бәләгән. – *лмб.* Аргы йактан килдем, ди. Бунымда кәрәбәләр, ди (*хал. җыр.*). – *хвл.*

**КӘРӘЗ** *к.т., м.-кар.* көнбагыш башында орлык урнашкан күзәнәкләр (ячейки, гнёздышки семян на шляпке подсолнуха). Комбакты кәрәзе. - *м.-кар.*

**кәрәз бөрү** *к.т.* тукыманы кәрәз күзәнәкләре рәвешендә бөрү (делать на ткани сотообразные сборы). Элегрәк күлмәк теккәндә билен кәрәз бөрә торған ыйық.

**кәрәз мөрүwе** *трх.* өс киемендә кәрәз формасында бөреп ясалган складка (сотообразные сборы, складки на одежде). Алйапмаларны кәрәз мөрүwе белән мөрөп тегәләр ийе. Кәрәз мөрүwе белән мөргәндә җепләрне чаташтырып тарталар.

**КӘРӘЗЛӘНҮ** *дөб.* башлы-күзле булу, гаилә корып җибәрү (обзавестись семьёй). Кәрәзләнсәләр, хәзер китеп тә баралар йәшләр, өйдә қалмыйлар.

**КӘРӘЗЛЕ** *т.кам.-крш.* борчак-борчак бизәк суккан – ак киндер турында (белый холст, сотканный браным способом, в результате чего образовались узоры типа горошин). Күтәреп суққан кәрәзле ашаулық шушы инде, кәрәзле киндер бит ул.

**КӘРӘКӘ** *дөб.* табан балык (карп).

**КӘРӘКСЕТҮ** *төм., тбл.* кирәксенү (чувствовать необходимость, нуждаться). Начар ите ире, кәрәксетмәте.

**КӘРӘЛКӘ** [*рус.* корольки] *төм., тбл.* чәкчәк камырыннан, уртасы тишекле итеп пешерелгән камыр ашы (баурсак с дырқой посередине).

**КӘРӘМ** *әстр.* к.: **арый**. Йаучы ике кәрәм киләде.

**КӘРӘМӘ** [*фарс.*] к.: **кәрәбә**.

**КӘРӘМӘТ** *тара.* кирәмәт (кереметь, идол).

**КӘРӘМӘТЛЕ** *тара.* тылсымлы (волшебный). Бир кәрәмәтле йүзүгү бар иде... уң қулына қатты, қарцыга булып уцуп китте.

**КӘРӘНГЕ** *минз.* к.: **кал′ага**.

**КӘРӘНДӘС, КӘРӘНТӘС** [*рус.* тарантас] *бәр., минз.* к.: **крандас**. Кәрәндәс йасап қуйалар чыбықтан. Кәрәндәскә салдылар да киттек, чыбықлы үрелгән йәшнекле була бит әле. Йахшы кәрәнтәс белән алып китәләр қызны. – *бәр.*

**КӘРӘПИН** *перм.* әрекмән (лопух).

**КӘРГЕ** *брб.д.* к.: **қырғыч 1**.

**КӘРГЕЦ** *брб.д.* киергеч (деревянный прибор для растягивания шкур).

**КӘРЕ** *м.-кар.* кире (обратный, назад; отрицательный; строптивый, упрямый).

**КӘРЕЛЕ-ТУРЫЛЫ** *м.кар.* к.: **кәрле-турлы**.

**КӘРЕЛҮ** *брб.д.* киерелү (потягиваться, растягиваться).

**КӘРЕН** *лмб.* карын (желудок).

**кәрен ачылу** *лмб.* карын ачу (проголодаться, захотеть есть).

**КӘРЕНДӘС** [*рус.* тарантас] *бөре., минз.* к.: **крандас**. Кәрендәс җигеп бирә булған. – *бөре.*

**КӘРЕНДӘШ** *глз.* туган, туган-тумача (родня). Кәрендәшләргә кердем, йакын-йақташларға.

**КӘРЕС** [*рус.* гарус] **1.** *байк.* төрле төстәге юан чигү җепләре, гәрес (гарус). Кәресләр, кәшәмирләр саталар ийе. Цуптарлап сугалар ыйы кәрес белән.; **2.** *себ.* кашемир. Йақшы кәрес йаулық пы. – *тара.* Сор шәл пулаты ите, кәрес эшәл. – *тбл.*

**кәрес шәл** *тара.* **1.** бизәкле кәшемир шәл (кашемировый платок с крупными цветами); **2.** зур, калын, юан чуклы шәл (большой толстый платок с толстыми кистями). Сипкә (калынга) кәрес шәл пиреп, минең сип шәлем тип кәпләйделәр, сор, йыллы, қалын цацақлы.

**КӘРЕШ** *себ.* чөгә (стерлядь). Кәрешне йәшләй туңырып ашайбыс. – *тбл.*

**кәреш үләне** **1.** *тбл.* каз үләне (гусиная лапка – растение); **2.** *тбл.* кара әрем (чернобыльник).

**КӘРЕШКӘ** *минз., стрл.* тычкан борчагы (мышиный горошек).

**кәрешкә үләне** *кмшл.* к.: **кәрешкә**.

**КӘРҖИН** [*рус.* корзина] *тпк.* тарантас арбаның чыбыктан үрелгән әрҗәсе (плетёный короб тарантаса).

**КӘРИ I** [*гар.*]: **кәри килү** *т.я., каз.ар., чпр., м.-кар.* **1.** туры килү, очрау (встречаться, попадаться). Базарға барсаң, пилтә кәри килмәсме? Ничек булыр бит, уңғанға уңмаған да кәри килә (кияү белән кыз турында). – *к.т.* Аптабус кәри килсә, сәғәт дүрткә қайтып җитәр ул. – *лш.* Тырмышыгызда бупчи кәри килә тырган кеше тегел ул. – *чпр.*; **2.** туры килү, охшау (соответствовать, совпадать, быть схожим). Чувашларның күп кенә сүзләре безнеке белән кәри килә. – *к.т.* Безне белә бергә бер мишәр служит итте, касы сүзләр кәри килә. Безне телебез кайсы татарга да кәри килә, кайсы сүзләре мишәрләргә пахуж. – *м.-кар.*

**кәри китерү** *т.я.* туры китерү, очрату (встретить, застать). Өйөнә ике барсам да, кәри китерә алмадым. – *к.т.*

**кәри II** [*гар.*]: **кәри күрү** *карс.* дошман күрү (ненавидеть, считать врагом). Шулчаклы үзегезгә изгелекләр иттем, һаман кәри күрәсез мине.

**КӘРИЙӘ** [*рус.*] *злт.* агач кайрысы (кора дерева). Бүтән кәрийәләр алынмый, тал кәрийәсе, имән кәрийәсе китә.

**КӘРИКӘ** [*удм.*] **1.** *глз.* к.: **кесәллек**. Кәрикә ын; **2.** *нокр.* солы онынан пешерелгән чумар (клёцки из овсяной муки); чаг.: **чумар: кул чумары**. Сылы кәрикә пешергәләйләр ийе.

**КӘРИЛӘП** [*гар.+афф.*-ләп] *дөб.* к.: **кирәмәйләп**. Қарале бу баланы, кәриләп суға бит.

**КӘРИТӘ** [*рус.*] *яүшт.* тагарак (корыто).

**итмәк кәритәсе** *яүшт.* к.: **йулпуч**. Итмәк кәритәсе була иде, итмәк баса торган.

**КӘРИҺ** [*гар.*]: **кәриһ 'үрми'и** *кас.* к.: **кәри II: кәри күрү**. Ни', гәреп, кәриһ 'үри тор'андыр, бер усаллы'ым йу'?

**КӘРКЕШ** [*морд.*] *миш.д., злт.* **1.** бау (верёвка). Тачкыларыгызга кәркеш алдыгызмы? Йүкәдән ишеп булса да хыт кәркеш кебекләр веникларны бәләкләр иден. – *тмн.* Билегезгә кәркеш бәйләп эшләгез. – *злт.*; **2.** киндерә, чабата бавы (оборки лаптей). Кийеп сығарга кәркешсез сабата была торган ийе. – *злт.* Кәркеше белән чорнаганнар чабатаны. – *карс.* Чабатаны чишеп алдым да кәркешеннән тотоп бәрдем. – *стрл.* Цабатамның кәркеше эзелде, цәцүргец белән бәләп кат′тым. – *чпр.* Тездән әләп кәркеш бәләгән. – *хвл.* Кәркешне пәзидән, монцалалардан өрәләр иде. – *срг.* Без пәзи кәркеш цырнап, цабата кийеб үстек, хазер, баци, барысынын да айагында итек, эрзинкә, туфле. – *чст.* Кәркеш бушаган бара торгач, утырып бәләргә иткән идем. – *мәл.*

**КӘРЛЕ-ТУРЛЫ** *м.-кар.* кирле-морлы (противоречиво, бестолково). Кәрле-турлы сүләшә.

**'ӘРЛЕ'ӘС** *кас.* к.: **айырықойрық**.

**КӘРМӘК I** *тмн.* булавка.

**КӘРМӘК II** *брб.д.* каерының аскы сусыл катламы (нижний сочный слой коры). Кәрмәкне болый пычақ белән қырасын, ап-ақ әйбер, чөчөк тиб әйтте, йазғыда гына буладығын, чөчөкләй йийа тегәбез (җыябыз) инте.

**КӘРМЕЦ** *туб.-ирт.д., брб.д.* кирпеч (кирпич).

**кәрмец цай** *брб.д.* такта чәй (плиточный чай).

**КӘРМЕЧ** *твр., брб.д.* к.: **кәрмец**. Йөз кәрмечкә ун кәрмеч үсемә полты. – *брб.д.*

**КӘРНӘЙ** *туб.-ирт.д., брб.д.* ас (горностай).

**КӘРПӘЙҮ** *саз.я.* кәпрәю (важничать). Йәнгитүмнәр (*ав. ис.*) кәрпәйеп паратылар.

**КӘРСӘҮ** *брб.д.* акыллы (умный).

**КӘРСЕШҮ** *злт.* ныкәчү, артыкәчү (прокиснуть). Мискәгә қыйар тозлап қуйғаннар, кәрсешеп утыра.

**КӘРСИНКӘ** [*рус.*] *брб.д.* керосинка (керосинка). Пес кечү чақта кәрсинкә тә йоқ ите.

**КӘРСҮ 1.** *перм.* эчемлекнең озак торудан айнып, өстенә ак бөрчекләр чыгып бозылуы, серкәләнүе турында (выдыхнуться, испортиться – о напитке). Бал кәрси. Аның кәрсегән балын (эчәмме соң!); **2.** *бөре., злт.* күксү (горкнуть, плесневеть). Ныкачыгач кәрсей. – *бөре.* Әпәйнең кәрсегәнен беләсең бит инде. – *злт.*

**КӘРТӘ 1.** *трбс., минз.* к.: **йорт 1.** Безнең кәртәдәге утынны да кереп пыч әле. – *трбс.* Мал кәртәгә керде. Кийәүләрнең кәртәсенә барып та керде сыйыр. Бәйкәгә үлән қалмады, көйдө кәртәм. Урамга чықма, кәртәдә генә уйна. – *минз.*; **2.** *кргл.* к.: **абзар: абзар алды**.

**кәртә абзар** *стрл.* к.: **абзар: абзар алды**.

**кәртә алды** *минз.* ишегалды (двор).

**КӘРТӘЛӘП** *перм.* шакмаклап – киндер сугу турында (в клетку, клетками – о тканье холста). Кәртәләп җә буйлап суғабыз ий киндерне.

**КӘРТӘШИ** *блт.* элек: олырак яшьтәге хатынкызларның яулык өстеннән кия торган бәрхет баш киеме; такыя: гадәттә аның алгы ягы энҗе яки мәрҗән белән чигелгән була (старинный женский головной убор, вышитый спереди бисером и надеваемый поверх платка); чаг.: **кашпау**. Кәртәши кийеп, шәл бөркәнгәч баш туңмый торған ыйы.

**КӘРТЕКӘ** [*рус.*] *туб.-ирт.д.* к.: **алма I**.

**КӘРТЕМӘЧ** *брб.д.* шакмак (клетки – о ткани, паласе и т.п.). Алалап соққан аламыш, кәртемәчләре бар, перәwе пой аламыш.

**КӘРТЕПКӘ** [*рус.* картошка] *тбл.* к.: **алма I**. Кәртепкәне өйөп китте ысбайы итеп.

**КӘРТЕРҮ** *брб.д.* бурату (дать срубить). Геше таып ағацын кәртереп қойдық өйнең.

**КӘРТЕШКӘ** [*рус.* картошка] *тбл.* к.: **алма I**. Иң пөрөңге утысқан кәртешкәне бес.

**КӘРТЛӘКӘ** *блт.* кечкенә буйлы кеше, кәрлә (карлик). Кечкенә буйлы кешегә бездә кәртләкә диләр.

**КӘРТЛӘКИ: кәртләки қалақ** *блт.* чүрәкә уйнаганда агач шарны яки таякчыкны кагып җибәрә торган саплы калак (деревянная дощечка, которой бьют по чижику во время игры «в чижики»).

**кәртләки қалақ уйнау** *блт.* чүрәкәй уйнау (играть «в чижики»).

**КӘРТМӘ** *твр., брб.д.* **1.** өй бурасы, бура (сруб). Өйөбеснеңке кәртмә генә отыраты. – *брб.*д.; **2.** бурап эшләнгән чардуган (срубленная ограда вокруг могилы). Кәртмә қуйасын агачтан, сираты йуйылмасын. Мийең инәмнеңке кәртмәне бабай кәртте. – *твр.*; **3.** *кргл.* терлек ябу өчен киртә яки читән белән тотып алынып өсте ачык булган урын (открытый загон для скота во дворе, карда).

**кәртмә қура** *твр.* бура абзар (срубленный хлев).

**КӘРТҮ** *твр., брб.д.* бурау (рубить, срубить). Йаңа мунча кәрткән қартым, инәмсес? – *твр.* Үләрне ағачтан кәртәтеләр. – *брб.д.*

**КӘРТҮК** [рус. картофель] *злт., төм.* к.: **алма I**. Кәртүк тәмне была асығып қайткан кешегә. Мин аларға бер бидерә кертүк пешереп бирәм. – *злт.* Кәртүккә бартым тораға. – *төм.*

**кәртүк аграты** *төм.* бәрәңге бакчасы (картофельный огород). Кәртүг агратында сыйыр йөри.

**КӘРТҮКӘ** *тбл.*, **КӘРТҮП** *туб.-ирт.д.*, **КӘРТҮПКӘ** [*рус.*] *тбл.*, **КӘРТҮШКӘ** [*рус.* картошка] *себ.*, **КӘРТФХӘ** [*рус.*] *саз.я.* к.: **алма I**. Көцөм пөткәнцә эшләнәм, кәртүптән цүп сыwырам. – *тара.* Кәртүпкәнең көце йуқ аның, қорсақны тутыраты, йөрәкне кисәте. Кәртүпкә сумсасын малып ашасаң, тәмне була. Бәрәңгене кәртүшкә диләр себерәкләр. – *төм.* Кәртүшкә утадылар, көмтеләр. – *брб.д.*

**кәртфхә қутару** *саз.я.* бәрәңге алу (убирать картофель).

**КӘРҮ I** *брб.д.* киерү (растягивать, напяливать).

**КӘРҮ II** *брб.д.* җеп үлчәү берәмлеге: киләп (моток).

**кәрүгә урау** *брб.д.* к.: **кәрүләү**. Йепне кәрүгә урыйсың.

**КӘРҮЛӘҮ** *брб.д.* киләп сару (сновать). Бу ыстинадан икенче ыстинага йөргезеп кәрүлисең. Кәрүләп буйыйтаннар (буйылар) йонны.

**КӘРФӘНКӘ** [*рус.* камфорка] *мам.* к.: **камбурка**. Кәрфәнкәгә утырт чәйнегеңне, чәйе пешсен.

**КӘРЦӘК** *тбл.* чын, тугры (истинный, верный).

**КӘРЧӘК** [*рус.* корчага] *твр.* к.: **кырчыға**. Бу унбиш ақчаға бир кәрчәк сүт ал.

**КӘРЧӘМӘ** *чпр.* эче бал (мёд, медовая брага).

**КӘРЧӘННЕК** *блт.* чәйханә (чайная, чайхана). Кәрчәннектә сыйланып утырғаннар дус-ишләре белән. Кәрчәннеккә кереп чәй эчеп чыққан инде, кәрчәннек Әхмәтҗан диләр ийе бер кешене.

**КӘРЧЕМӘ** *трх.*, **'ӘРЧЕМИ** *кас.* к.: **кәрчәмә**.

**КӘРЧХӘ** [*рус.* карточка] *саз.я.* фоторәсем (фотокарточка).

**КӘРШӘК** *тара.* **1.** кыйшык (кривой). Кәршәк борын; **2.** үҗәт, кире (упрямый). Ул кәршәк кеше, әйткән сүскә күнмәйте.

**КӘРШӘН I** *брб.д.* **1.** к.: **йулпуч**; **2.** тагарак (корыто).

**КӘРШӘН II** *брб.д.* ялкаулыктан белмәмешкә салынучы (притворяющийся незнающим из-за лени).

**КӘС I 1.** *туб. ирт.д., брб.д.* юләр, тиле (сумасшедший). Кәс игәнтен. – *тбл.* Сес кәсләрне қыwып (ияреп) ник килтем. – *твр.*; **2.** *чст., тбл., тара.* аңгыра, аңсыз (бестолковый). Әлә мин кәсмә алғамы пирергә. – *тбл.*

**КӘС II** *минз.* торф кирпече (торфяной кирпич).

**КӘСӘКӘ: кәсәкә суғу** *эчк.* к.: **кусака: кусака суғу**.

**КӘСӘЛКӘ** [*рус.* качалка] *злт.* к.: **крандас**.

Қыңғыраулар тағалар, тастымаллар тағалар, қызны кәсәлкәгә утырталар.

**КӘСӘНКӘ I** *мам.* к.: **ғорда**. Тапталса, бақча кәсәнкәле була инде ул.

**КӘСӘНКӘ II** [*гар.*] *туб.-ирт.д., том.д.* к.: **кәзәнкә 2**.

**КӘСӘНКЕ** *блт.* к.: **ғорда**. Бигрәк кәсәнкеле икән бақчағыз.

**КӘСӘҢКӘ I** *блт., мам.* к.: **қушаңқы**. Чикләwек кәсәңкәсе. – *блт.* Чикләwекне кәсәңкәсе белә генә сатқаннар. – *мам.*

**КӘСӘҢКӘ II** *дөб., мам.* к.: **ғорда**. Кәсәңкә wул бақча гел, быйыл ғына суқалаған. – *дөб.* Болай-болай кәсәңкәләр арасына тығып қуйып та үсә икән бәрәңге. Тапталғанга күрәме, быйыл бик кәсәңкәле бақчабыз. – *мам.*

**КӘСӘҢКӘ III** [*гар.*] *туб.-ирт.д.* к.: **кәзәнкә 2**. Кәсәңкәтә қаныт, йарма, он сахлайwс. – *саз.я.*

**КӘСӘРТКӘ** *кргл., злт.*, **КӘСӘРТКЕ** *перм., бөре., стрл., к.-уф.* к.: **кисеркә I**. Кәсәрткеләр печин ҳыйғанда бик күп очрыйлар. – *к.-уф.* Кәсәртке дә күргәнем бар урманда. – *стрл.*

**КӘСӘРУ** *тбл.* тилерү, юләрләнү (сходить с ума, потерять разум). Исереб ийсә кәсәреп китә қуй, кәс қуй ул.

**КӘСӘТУ** *тбл.* әйтү, кушу (наказать, приказать).

**КӘСЕЛ** [*гар.*]: **кәсел кеше** *бгрс.* авыру, чирле кеше (больной человек).

**КӘСЕРКӘ** *лш., минз., лш.* к.: **ҳылаwық**. Кәсеркәләрен чығарып, үстереп әпкитте малайын. Бала бик ҳылый, кәсеркәле диләр, имчәк сөте белән уғач қап-қара булып чыға, уғач төшә. – *лш.* Кәсеркә йылақ балада була ул, уратып-уратып уwып сөт белә чығарасыз аны, ими сөтө белән уwауwа, бөртөк-бөртөк кер булып чыға. – *минз.*

**КӘСЕРУ** *тара.* акылсызлану (глупеть, стать тупым, бестолковым). Кәсереп петкән, аңғырайып.

**КӘСЕҮ** *тара.* к.: **киндер II: киндер урны**.

**КӘС-КӘС-КӘС** *мәл.* к.: **коч-коч-коч**.

**КӘСКЕ** [*рус.*] *перм.* бозда шуар өчен кабыктан тагарак шикелле ясалган ҳайланма (приспособление для катания по льду, сделанное в форме ванны из коры, лубка). Бала чанаға салып алып барам кәскене. Кәске була торған ийе, гел карита кебек қабықтан.

**КӘСЛӘНЧҮК** *брб.д.* к.: **кисеркә I**.

**КӘСЛӘҢКӘ** *дөб.* оешып каткан балчык, балчык оешы (ком, комья земли). Шалғаллар чәчкәченнән кәсләңкә қалдырмас өчөн чалу белән чалдыралар, тырмаласаң, асқа кереп қала орлоқ.

**КӘСТӘНКӘ** *блт.* к.: **ғорда**.

**КӘСТРҮНКӘ** [*рус.*] *дөб.* өч аяклы таба (сковорода-тренога). Өс айақлы кәстрүнкә булайде, шунда пешерәләр ийе әлбәне.

**КӘТӘ I** *тбл.* күз кабагы (веко).

**КӘТӘ II** *эстр.* камыштан, сылап ясалган зур кышқы өй (большая зимняя камышовая мазанка).

**КӘТӘ III** [*гар.*] *төм.* хак (цена). Кейәү керәте, кейәү баладан кәтәсен сурайтлар, йыслы сабынма, көмешмә, анансың йеңкәлекләр цығып китәте, кейәү белән кинцәк қалаты. Килен сантықны апкергән кешегә кәтә биргәннәр.

**КӘТӘЙ** *брб. д.* ярлы (бедный).

**КӘТӘК** *тбл., брб.д.* кетәк (курятник).

**КӘТӘЛӘҮ** *мәл.* мәтәлү (кувыркнуться). Кәтәләп тешсә, үлә.

**КӘТӘНӘ 1.** *минз., т.кам.-крш., стрл.* к.: **бәйсәкә**. Бик бәләкәй кешеләргә кәтәнә дип әйтәләр бездә. – *стрл.* Үзе кәтәнә генә, үзе зурайып йөргән була бит. – *дөб.*; **2.** *к.т.* кечкенә – бала турында (маленький – о детях). Әле бу кәтәнә дә тороп җиткәнмени.

**КӘТӘНӘК** *дөб.* к.: **бәйсәкә**. Кәтәнәк кенә бер ир уртасы ир килеп керә.

**КӘТӘП** [*гар.*] *м.-кар.* китап (книга). Кәтәпкә дә кергестмиләр (диалекталь сүзләрне).

**КӘТӘР** *тбл.* төркем; күч, ил (толпа; рой).

**КӘТӘРМӘЧ** *дөб.* солы онынан төчегә майда әвәләп пешерелгән төче күмәч (хрустящая лепёшка, испечённая из овсяной муки). Солоны киптереп, өрдөреп кәтәрмәч пешерер ийек, йуқа ғына, түгәрәк кенә. Орлоқ майын кәтәрмәчкә дә салып пешерәләр.

**КӘТӘРҮ** *лш.* китәрү (сбрить, сбривать).

**чәч кәтәрү** *лш.* әлек: чәчне пәке белән кырып алу (в старину: сбрить волосы безопасной бритвой). Чәч кәтәрү өчен пычақны шундый қайрақ белән қайрағаннар.

**КӘТЕ** [*гар.*] *эстр.* к.: **кәтә II**.

**КӘТЕК** *нрл.* китек, киртләч, тешле-тешле (с зарубками, с зазубринкой, с зубцами). Зур-зур кәтек йафрақлы, айу табаны дибез. Өрәңге җапырағы да кәтекле-кәтекле.

**КӘТЕР 1.** *трх.* онга бәрәңге крахмалы кушып пешерелгән камыр ашы (мучное блюдо – лепёшка, испечённая из муки и картофельного крахмала); **2.** *к.т.* черек бәрәңге күмәче (лепёшка из крахмала сгнившей за зиму картошки).

**КӘТЕРӘWЕК** *брб.д.* к.: **йилбердәк**. Кәтерәwек кечү-кечү, йалтырақ өсө.

**КӘТЕРӘWЕКЛЕ** *брб.д.* ялтыравыклы (блестящий, с блёстками). Кәтерәwекле шәл.

**КӘТЕРКӘ** *минз., стрл.* к.: **кәтермәч 1**. Мич төбө кәтеркәсе. – *минз.* Таба кәтеркәсе. – *стрл.*

**КӘТЕРКИ** *минз.* балтырган кушып пешерелгән төче күмәч (лепёшка, испечённая из смешанной с борщевиком муки).

**КӘТЕРМӘС** *злт.* **1.** сохари (сухари). Әпәйне киптереп кәтермәс йасап йебәрдем. Кәтермәс кимереб утыра; **2.** мич төбенә салып пешерелгән төче күмәч (пресная лепёшка, испечённая на поду печи). Кәтермәс пис төбенә көлгә салып қатырып пешерелә, нинди оннан – белмим.

**КӘТЕРМӘЧ 1.** *бәр.* төче камырны юка ғына итеп җәеп, уалып тора торган итеп пешерелгән күмәч (хрустящая тонкая лепёшка из пресного теста). Кәтермәч пешерәләр ийе, уwалып тора; **2.** *чст.* к.: **бауқалач**. Синең кәтермәч пешергәнеңне дә көтмим, китәм.

**төчө кәтермәч** *бәр.* к.: **кәтермәч 1**. Төчө оннан тачқып пешерәләр, төчө кәтермәч була.

**КӘТИПӘ** [*гар.*] *т.кам.-крш.* хәтфә, бәрхет (бархат, плюш). Кәтипә камзул.

**КӘТКӘ** [*рус.*] *тбл., саз.я.* кисмәк (кадушка). Кәткәгә сыу қой. – *тбл.*

**КӘТМӘ** *тбл.* к.: **ашық II, 2**.

**КӘТМӘК I** *нрл., трбс.* китмән (кетмень, мотыга). Кәтмәк белән тырнап чыгабыз суганны.– *трбс.* Бакчаның чүбен кәтмәк белән кәтмәклибез. – *нрл.*

**КӘТМӘК II** *трх.* шакмак, агач шакмагы (чурка). Самаwыр кәтмәге. Кәтмәкне самуwырга җәгабыз.

**КӘТМӘКЛӘҮ** *нрл., трбс.* китмәнләү (мотыжить, обработать кетменем, мотыгой). Безрәк кәтмәкләдег әле бакчаны. – *нрл.* Бакча кәтмәклим. – *трбс.*

**КӘТМӘЛЛӘҮ** *бәр.* к.: **кәтмәннәү**. Тимер көрәк белә кәтмәлләwе awыр, суқа белә суқаладылар андары. Бәрәңгене кәтмәллибез, утыртабыз қул белән.

**КӘТМӘННӘҮ** *минз.* казу (копать, вскапывать, рыть). Төнө белә йоқламыйым, төннә кәтмәнним бакчамны. Кич җитәр-җитмәс көйгә бәрәңге кәтмәннисең.

**КӘТМӘР** *перм.* шаян, уенчак кеше (шутник, озорник). Ай кәтмәрләр, наруш сөйрәп чыгарып қуйганнар.

**КӘТМӘШЕ** *дөб.* к.: **кәшә**. Боз өстендә кәтмәше белән уйный идек.

**КӘТТӘ** *кас.* сөйгән егет (возлюбленный); чаг.: **цилбәй**. Ас'у'ны кәттәсе белин 'үрдем.

**КӘТТӘҖҢИ** *дөб.*, **КӘТТӘЧИ, КӘТТӘШИ** *дөб., блт.* к.: **кәртәши**. Менә тушыңға энҗе туқыйлар инде, кәттәҗине биг әйбәт числықлы җаулықлар белән генә кийәләр. Энҗеле кәттәчиләр була торған ыйы. Кәттәши бәрхеттән, энҗе тезеп; тәңкәле кәттәши дә була торған ыйы. – *дөб.* Энҗеле кәттәши кийәр ийек, түгәрәк бүрек кебек була ул. – *блт.*

**КӘТҮ** *нрл.* **1.** чикләвек вату (щёлкать, грызть орехи). Чики бирим, кәтерсең, без чүкеш белә дә кәтәбез. Чикине кәтеп-кәтеп ашап җата; **2.** утын яру (колоть дрова). Утын кәтеп керт, мичкә йағам.

**КӘТҮЛ** [*рус.*] *брб.д.* кечкенә чиләк (маленькое ведёрко). Кәтүл йуқ пес кечү чақта. Темән төрле кәтүл ите. Йеләккә кәтүл менән барадыған.

**КӘТҮМӘ** *злт.* кечкенә буйлы, йомры гәүдәле – әбиләр турында (округлая и маленького роста – относительно женщин преклонного возраста).

**КӘТЦӘ** *тбл., тара.* аңгыра, аңсыз (бестолковый). Ул әшкәрә кәтцә, уқыса да бернимә аңламайты. – *тбл.*

**КӘҮБАШ** *брб.д.* аю көпшәсе, аю табаны (борец высокий). Кәүбаш, чичәге татлы бопты.

**КӘҮГАНА** *брб.д.* к.: **коко**.

**кәүгана чақыру** *брб.д.* к.: **кәwек: кәwек цағыру**. Кәүгана чақырады йәшебезне санап.

**КӘҮК** *туб.-ирт.д.* к.: **коко**.

**КӘҮМӘН: кәүмән чичәк** *твр.* умырзая чәчәге (подснежник).

**КӘҮРӘК** *твр., тара.* уалып тора торган (рассыпчатый). Пәлеш тышына май салғалы кәрәк, кәүрәк пула, көрөч (дөге) салғаннар. – *тара.* Кәүрәк, awыста эреб утыра. – *твр.*

**КӘҮСӘ 1.** *минз.* түшкә (туша мясная). Анда туйда кәүсәсе белән йөрөй итләр. Кәүсәсе белән сарықны алып киләләр пешереп; **2.** *нгб.-крш.* гәүдә (тело, стан). Ул кәүсәсен күтәрә алмый. Кәүсәсен сузып, урам буйлап йөри.

**КӘҮХ** *саз.я.* к.: **коко**.

**КӘҮЦ** *брб.д.* галош (галоши).

**КӘҮШӘ** [*рус.* ковш] *нрл., трх., лш., дөб.* мөшкә (мельничный лоток). Тегермән гел ағачтан, ике ташы бар, ташның кәүшәсе бар ашлық салырга. – *дөб.* Қанат ташны әйләндрә тибеш итеп, ашлықны кәүшәгә салалар. – *нрл.*

**КӘҮШӘНҮ** *туб.-ирт.д.*, **КӘҮШӘҮ** *саз.я.* күшәү (жевать). Ат кәүшәнә тә тораты. – *төм.*

**КӘФИЙӘТ** [*гар.*]: **кәфийәтләп кийү** *дөб.* саклап, бозмыйча, тиешле тәрбия белән кию (носить бережно, осторожно, с учётом особенностей одежды). Әгәр ул дубл'онқаңны кәфийәтләп, сылапсыйлап кисәң, әйбәт сақланачақ.

**КӘХЧЕЛТӘХ** *саз.я.* кетердәп тора торган (хрустящий). Пawырсахлар кәхчелтәх пулғанны йаратам.

**КӘЦӘ** *тбл.* к.: **ичке**. Кәцә ит симес пулаты, ашқа та тәмнү.

**КӘЦЕЛ** *тбл.* каклаган балык (вяленая рыба). Эцен алып цыбықта киптерсә, кәцел типес.

**КӘЦЕРГӘ** [*рус.*] *тара.* к.: **қустартқыч**.

**КӘЦИНӘ** *брб.д.* кичен (вечером).

**КӘЧӘ** *себ.* к.: **ичке**. Кәчәләрепес кәнәйеп китте, шал пәйләгәле гәрәк. – *тбл.*

**КӘЧӘК I** [*рус.* косяк] *дөб., минз., кмшл., т.кам.-крш., кргл., бгрс., шрл.* к.: **кас'ак I**. Кәчәкне нараттан эшлиләр. – *минз.* Әле кәчәкләр йунып қайттық шунда. – *кмшл.* Тәрәзә кәчәкләрен әле буйамаған ыйық. – *кргл.*

**КӘЧӘК II** [*рус.* косяк] *минз.* төркем, өер (группа, толпа, стая); чаг.: **аймак 3**. Тегеннән бер кәчәк халық килә, афтawыдқа киләләрдер инде алар да. Кантырул' эшкә кәчәге белән өчле булган.

**КӘЧӘРКӘ** *каз.ар.-крш.* к.: **җылawық**. Чүпрә белән дә, имчәк сөтен салып та ywасың, эткә, мәчегә тимәгез, балаң кәчәркәле була, диләр әбиләр.

**КӘЧӘШ** *клд.* пәрәмәч (ватрушка).

**КӘЧ-КӘЧ-КӘЧ** *к.т.* к.: **коч-коч-коч**.

**КӘЧКИ** *к.т.* кыргый пастернак (дикий пастернак).

**кәчки сақалы** *к.т., нрл.* к.: **кәчки**. Кәчки сақалын иренгә тийермичә ашыйсың, қутырлый awыз. – *нрл.*

**КӘЧТҮР** [*рус.*] *минз.* чөй (костыль). Агач кәчтүр, тимер кәчтүр була бит.

**КӘШӘ** *т.я., минз., чпр.* кәшәкә (клюшка). Кәшә уйнағанда кәшә әләккән башына. – *к.т.*

**кәшә тайағы** *т.я., каз.ар.* к.: **кәшә**. Кәшә тайағы сорап алдыртты инде. – *мам.*

**КӘШӘWӘЛӘНҮ** [*гар.*] *дөб.* сыпалану (ласкаться). И кәшәwәләнә беләйе инде безнең эти йәш хатынына.

**КӘШӘЛӘНҮ** *перм.* к.: **қаушақлану 2**. Картуп шәп қайҗағанға, қулларым кәшәләнде.

**КӘШӘЛӘҮ I** *блт., мам.* песинең әйберне тәпие белән этеп-этеп баруы (двигать ножкой что-нибудь – о кошке). Мәче аны айағы белән кәшәли ийе, уйный ийе. – *блт.* Песи тычқанны үтергән дә кәшәләп-кәшәләп карawат астына әпкерде балаларын уйнатырға. – *мам.*

**КӘШӘЛӘҮ II 1.** *кргл., бгрс., шрл.* к.: **қаушақла-**

**ну 2**. Битләре кәшәләп беткән; **2**. *к.-уф.* чебиләү (покрываться цыпками). Пычрақта йаланайақ йөрөп, айағы кәшәләп беткән.

**КӘШӘМИР** *тбл.* зур калын шәл (большой, толстый платок). Эцемән йебәк йаулық пәйләйем, кәшәмир суры, йawаны булады.

**КӘШӘН** [*рус.* кожан] *тара.* Кәшән кигәннәр йаңғыр йауса.

**КӘШӘНӘ I** *минз., стрл.* к.: **қушаңқы**.

**КӘШӘНӘ II 1.** *трбс.* чардуган (ограда вокруг могилы). Кәшәнәсез қуймыйлар хәзер кешене, йә ағачтан, йә тимердән йасыйлар; **2.** *минз., стрл.* изге зират, иске каберлек (древнее кладбище, священное место). Бездә кәшәнәләр бар. – *минз.*

**КӘШӘҢКӘ** *бөре., кмшл., бгрс.* к.: **кушаңқы**. Бер кәшәңкә читләwек таптым. – *бөре.* Кәшәңкәсе белән ғенә тутырдық чикләwекне. – *кмшл.*

**КӘШӘҢКЕ** *минз.* кызармаган, пешмәгән – жиләк-жимеш турында (недозревшие – о ягодах). Қура жиләк кәшәңке генә бит әле ул.

**КӘШӘҮ** [*рус.*] *дөб.* артлы чана (кошёвка).

**кәшәү чана** *дөб.* к.: **кәшәү**.

**КӘШБӘЙҮ** *перм.*к.: **кәшмәйү**. Бидрәнең кәшбәйгән йерләрен төзәттем әле.

**КӘШЕК** *әстр.* әт (собака). Безләр кәшек асырамаймыс.

**КӘШКӘ** [*фарс.*] *тара.* к.: **кашки**. Кәшкә бер гүс йамқыр йауса ийән.

**КӘШКӘЛӘНЧЕК** *нрл.* к.: **айбағар**. Кәшкәләнчек геләп қойашқа борола бит ул.

**КӘШЛӘКӘ** *мам.* чикләвек жыйганда агачны ию өчен кулланыла торган ыргаклы таяк (палка с крючком, либо с загнутым концом, применяемая при сборе лесного ореха).

**КӘШМӘЙТҮ** *перм.* кыегайту (кривить рот). Чәй эчеб утыра awызын кәшмәйтеп.

**КӘШМӘЙҮ** *перм.* к.: **кәшбәйү**. Табақлар бәргеләнеп, қаққыланып кәшмәйгән, кәшмәк булғаннар. Кәшмәйгеләп жийылған чалғылары.

**КӘШМӘР** *брб.д.* к.: **ирлән**.

**КӘШНӘЙ** [*рус.*] *саз.я.* һәр, һәрбер (каждый). Кәшнәй кеше алай кәпләй wашласа.

**КӘШТӘ** *злт.* киштә, шүрлек (полка).

**бишек кәштә** *глз.* бишек әлә торган агач колга (деревянный шест, с помощью которого подвешивают люльку к потолку). Бишек кәштә түшәмдә, кулчу салып кәштә әләләр.

**КӘШТӘК** *перм.* к.: **йапыртма**. Кәштәкле күлмәк, кәштәкле алчеприкләрдәген булган.

**КӘШТӘПИ** *мам.* к.: **кәртәши**. Жондозло кәштәпи кийәр ийек.

**КӘШТЕРДӘҮ** *минз.* әкрен генә йөрү – олы кеше турында (ходить потихоньку, ковылять – о старом человеке). Әби кәштердәп йөрөй әле.

**КВАШН'А** [*рус.* квашня] *хвл., әжә., тмн.* к.: **ләнгәц**. Бер кырдан квашн'ага ын салып икмәк басалар. – *тмн.* Элке агачныкы квашн'алар бар иде. – *хвл.*

**КЕБАР'АНЕ** *лмб., карс.* гөбе әйрәне, май әйрәне (сыворотка, получаемая при пахтании масла). Кебар'ане эчәмесез? – *лмб.* Эчмәсәң, кебар'ане камырга кушарга да йарый вет. – *карс.*

**КЕБЕ** *чпр., баст., м.-кар., карс., мәл., дөб.* к.: **батман II**. Кебе бар иде элгәре, кебели идек майны шынарда. – *чпр.* Кебе белән атлағанда май сywы тәмне буладыр ыйы. – *дөб.* Алда май йасий торган кебе бар иде, кебегә саласың да кебелисен, тайагы бар иде, майы була ачланмай. – *м.-кар.* Кебе ул, агачтан қазыған. – *баст.*

**кебе ағацы** *чпр.* к.: **атawыч**. Кебе агацы диләр бездә, нәнак. Кебе агацы белән ар'аннары сыгылып цыга, майы тәмне була.

**кебе майы** *чпр.* гөбедә язылган май (сливочное масло, полученное путем пахтанья в пахталке). Кебегә салып кебели майны, кебе майы тәмнерәк.

**КЕБЕЛӘҮ** *м.кар.,чпр.,карс.* к.: **ачлау**. Кебе белән кебели идек лаңгырт-лаңгырт. Каймактан май кебели. – *чпр.* Майга кебелисен, чи майлата сатыла иде. – *карс.* Кебедә кебелисен тайак белән, ачланмай була. – *м.-кар.*

**КӘБӘҪ** *том.д.* к.: **кәпәч 1**.

**КЕВӘ** *тмн.*, **КЕWӘ** [*гар.*] *тбл.* к.: **гywа**. Мин кевә идем. Ол кewә полпты кейәүнеңке йақтан.

**КЕВӘНДӘ** *миш.д.*, **КЕWӘНДӘ** *карс.* к.: **кәнтә**. Кевәндәне алып куйса, уңган килен була. – *хвл.*

**КЕWӘР** [*рус.* ковёр]: **кewәр үwерү** *твр.* ковёр төрү (заворачивать ковёр). Кewәр үwерәләр, перәү бийеп тора, перәү уйнап тора, шапканы селкеп тора кewәр үwереп, әркем ақца ташлап торалар.

**КЕДЕРӘЙҮ** *шрл.* гайрәтләнү (расхрабриться). Анасы баргач, бу да кедерәйә.

**КЕҖЕКЛӘҮ** *к.-уф.* ирештерү, үртәү, үчекләү, котырту (дразнить, поддразнивать, подтрунивать). Кеҗекләмә әле шул баланы, башқа эшең йуқ мәллә?

**КЕҖҮЛӘҮ** *нокр.* аш-су пешерү (готовить еду). Қатыны чықмаған сабантуға, кеҗүләй ди, илле йәш ич хуҗасына.

**КЕЗЛӘҮ** *лмб.* к.: **кизләү**. Безнең каршыда кезләү, киләдер кезләүгә суга.

**'ЕЗЛЕ'ЛИР** *кас.* уҗымнар, көзен чәчелгән ашлыклар (озимые).

**КЕЙӘ** *брб. д.* кенә, генә (только).

**к е й ә ү** *нокр., перм., себ.* кияү (жених):

**кейәү бала** *туб.-ирт. д.* кияү (жених). Негә уғыганта кейәү бала, киленцәк пергә булаты. – *төм.* Қосоқ цийертәделәр, аны гейәү бала алып параты та цымылтықта цийертеп ултырдылар. – *тбл.*

**кейәү интерү** *төм.* кияү кертү, кияүне кыз янына алып килү (оставить жениха и невесту первый раз вместе). Кейәү интерәтләр тыуғаннары, урамта йырлап тороб аппаратлар, қыс цымылтықның эцентә ултыраты.

**кейәү сақчы** *нокр.* кияү егете (дружка, шафер). Эртәгә таңда туй дийәсе кенне қыз йаққа кейәү килә, ул үзе генә келмәй, кейәү сақчы белән килә, ул бер дә кейәүдән айырылмый инде.

**КЕЙГЕЛЕК** *төм.* к.: **кейенцек**. Пер қабатқа пар кейгелегем.

**КЕЙЕК** *туб.-ирт.д.* к.: **моши**. Кейекләр аулап йөргәннәр. – *төм.* Кейек атқан. – *тбл.*

**КЕЙЕКЧЕ** *каз.ар.-крш.* аучы (охотник). Кейекчеләр бар бит ул әр awылда да.

**к е й е м** *себ.* кием (одежда):

**сип кейем** *төм., тбл.* ярәшелгән кызга кияү

ягыннан китерелә торган кием-салым (предметы одежды, преподносимые сговорённой девушке со стороны жениха). Эриса булса кейем сурайты, сип кейем тип, оценнан пашына кейем. – *төм.* Кәртнәмнеңке сип кеймнәрен мин беләм, сип йәктәләрен, суқмалы йәктә, уғалы. – *тбл.*

**КЕЙЕМ-КИЦӘ** *тара.* к.: **кейенцек**. Кейем-кицәләр әсерләйде, көйләк, шәл, йаулық.

**КЕЙЕМЧЕ** *каз.ар.-крш.* тегүче, кием тегүче (портной, швея). Кейемчеләр кейем кисәдер, Қала микән аның почқағы (*хал. җыр.*).

**КЕЙЕНЦЕК** *срг.* кием-салым (одежда, одеяние). Кейенцекләр кетәмен, әби атте бирергә.

**КЕЙЕХ** *сазл.* к.: **моши**. Кейех атқалы китеп қалған әтийем, тисме қайтыр.

**кейех кихәwен** *сазл.* бөгәлчән, сукыр кигәвен (слепень, овод конский).

**КЕЙИК** *брб.д.* **1.** болан (олень); **2.** җәнлек (дичь).

**КЕЙЛЕ** *тара.* ашлык төю өчен зур агач тукмак (большой деревянный пест для толчения зерна).

**КЕЙТӘН** *брб.д.* киндер (холст). Кейтән күңнәк, кейтән ыштан теккәбес, кейгәбес.

**'ЕЙҰW** *кас.* к.: **кейәү**. 'ейүwне йаратма'аннар, имеш.

**'ейүw пыстасы** *кас.* туйдан соң кызны кияү йортына озату йоласы (обряд проводов невесты в дом жениха после свадьбы); чаг.: **арчылый: арчылый бару**.

**КЕЛ** [*удм.*] *нокр.* к.: **қаудан 5**.

**КЕЛӘ** *т. я.-крш.* үкчә (каблук). Батинка келәсе.

**КЕЛӘWЕЗЛӘНҮ** [*рус.* кляуза + *афф.* -лән ү] **1.** *лш., дөб.* көйсезләнү (капризничать). И келәwезләнә инде бу бала. – *дөб.* Нәрсә келәwезләнәсең инде. – *лш.*; **2.** *дөб., каз.ар.-крш.* зарлану (жаловаться). Келәwезләнмә, Начтый. – *каз.ар.-крш.* Бер җире әз генә awыртса, awырыйм, ди, келәwезләнә. – *дөб.*

**КЕЛӘЙ I** *минз., стрл.* келә (затвор, щеколда, задвижка). Сандыкның келәйен сүwырыб алганнар. – *стрл.*

**КЕЛӘЙ II** [*рус.*]: **келәй ашаулык** *чпр.* клеёнка (клеёнка). Келәй ашаулык булмаган элеке.

**'ЕЛӘЙЛӘНЕШ** *кас.* к.: **айбағар**.

**КЕЛӘЙНӘ** [*рус.*]: **келәйнә бәйләү** *каз.ар.-крш.* өчпочмаклап бөкләнгән яулыкны ияк асты турысыннан инә яки булавка белән элэктереп кую (форма повязывания платка: сложенный в треугольной форме платок под булавку). Җепәк җаулыкны, җон җаулыкны келәйнә итеп бәйләп инде, болай борчоп бәйләмисең. Дарай җаулыкны келәйнә бәйлә.

**КЕЛӘЛӘЙ** *кузн.*, **КЕЛӘЛӘНГЕЧ** *тмн., кузн.* к.: **айбағар**. Келәләнгеч майы. – *тмн.* Келәләй чәчәләрмедер сездә дә, сүwык йак төгелме анда. – *кузн.*

**КЕЛӘМ** *туб.-ирт.д.* тар озын келәм (дорожка). Келәмнәрем кән, үсем суққан. – *тбл.*

**балас келәм** *төм.* төрле җепләр, иске чүпрәкләрне телеп суккан тар келәм (дорожка домашней работы). Балас келәмнең бер тәңкә пер қолацы.

**йулақ келәм** *туб.-ирт.д.* юллы-юллы итеп сугылган келәм (дорожка с рисунком в полоску); чаг.: **чаптырма**. Йулақ келәм киң кенә, йеп пелә суққан йөннән, көйәс ите. – *төм.*

**қалақ келәм** *туб.-ирт.д.* станда түгел, яссы агач калак ярдәмендә суккан келәм (узкая дорожка, сотканная не на стане, а с помощью неширокой планки). Қалақ келәм төңгәлләп суққан қалақ пелән, цуқлы, гөйәз. – *тбл.*

**КЕЛӘН** *туб.-ирт.д., брб.д.* к.: **гелән**. Келән йамқур йаwаты. – *твр.* Алар келән икәwе эшләптеләр. – *төм.*

**КЕЛӘНГЕЧ** *лмб., кузн., карс.*, **КЕЛӘНДЕРГЕЧ** *кузн.* к.: **айбағар**. Келәнгеч майы. – *кузн.* Келәнгеч чәчтеңме син, Латук абыстай? Келәнгеч майын майга куйасыңмы? – *лмб.* Картук куwырырга келәнгеч майы йакшы. – *карс.*

**КЕЛӘНДИР** [*рус.*] *чст.* келиндер (крендель).

**КЕЛӘНҮ** *лш., тя., шрл.* теләнү (попрошайничать, клянчить). Чел генә малай килеп келәнеп йөри иде. – *трх.* Малай килеш келәнеп йөри иде. – *лш.*

**КЕЛӘНЧЕ** *миш. д., т. я., кмшл.* теләнче, хәерче (нищий). Хәзер келәнчеләр бер дә җук. – *к.т.*

**КЕЛӘҢ 1.** *туб.-ирт.д., брб.д.* к.: **гелән**. Келәң рәсинкә кийәм. – *төм.* Пер цыксаң, келәң цыгасың. – *тбл.* Аларныңқы палалары келәң өлгәннәр. – *брб.д.* Келәң кеше эшли эшемне. – *твр.*; **2.** *брб.д., яүшт.* бөтенләй (совсем). Келәң сәермә, йакшы болмыйты. – *брб.д.*; **3.** *брб.д.* барысы, барлык (всё, все).

**КЕЛӘҢГЕЗ** *тмн.* к.: **айбағар**.

**КЕЛӘП** [*рус.* кляп] *срг.* к.: **келәй I**.

**КЕЛӘТ** *дөб.* к.: **кәзәнкә 2**.

**баз келәт** *глз.* кар базы өстендәге каралты, ул җәй көне келәт яки кухня ролен үтәгән (постройка над погребом, выполняющая летом роль кухни либо клети). Алачык диләр ийе баз өстенә йасаганны, аны баз келәт тә дигәннәр инде.

**келәт алды** *мам., чст.* ындыр табагы (ток). Бүген келәт алдына барасы, бодай сүwырырга. – *мам.*

**КЕЛӘТҮ** *срг., әҗе.* кыз сорату, яучы җибәрү (сватать девушку). Башкода йибәрү диләр Казан халкы, бездә келәтәләр диләр. – *срг.* Ул аны келәткән иде хатыны үлгәч, ул инде бармады. – *әҗе.*

**КЕЛӘҮ 1.** *тмн.* теләк (пожелание). Нинди келәү келим, абыз, сиңа?; **2.** *миш.д.* теләү (хотеть, желать). Зим машинасы белә баш әлән, кысасыны келәтә. – *чст.* Кулымдагы йөзегемнең Исеме Гайникәмәл; Айырыга келәгәчтән, Табалар икән әмәл (*хал. җыр.*). – *мәл.*; **3.** *каз.ар.-крш., т. кам.-крш., м.-кар.* гыйбадәт (моление, молебен). Урыс атнасы көнне чиркәүгә келәүгә барайык. – *т.кам.-крш.* Ийүн җегерем алтысында үңгә awылдан да киләтләр анда келәүгә. – *м.-кар.*; **4.** *хвл.* к.: **ботка: йаңгор боткасы**.

**ак алаша келәwе** *м.-кар.* ак ат суеп үткәрелә торган борынгы йола (древний языческий обряд, связанный с жертвоприношением белой лошади). Чугынгынчы ак алаша келәве булыптыр икән: ак алаша суйатлар икән; ак алашаны тотатлар икән дә башына ак йаулык бәйлитләр икән; ак алаша башы пешкенчә кызлар уный икән; севәкләрен җиргә күмеп китәтләр икән.

**балык келәве** *м.-кар.* балыкның күп булуын теләп үткәрелгән йола (обряд моления о рыбе).

Балык келәве итәләр ийе карчыклар бу йүндә йылна бер кен.

**җорт келәү** *м.-кар.* хатын-кызлар тарафыннан йорт-нигезгә багышлап үткәрелә торган борынгы мәҗүси йола мәҗлесе (языческий обряд: моление, совершаемое женщинами-хозяйками в честь дома).

**зур келәү** *хвл.* к.: **ботка: йангор боткасы**. Көтүләрне сөрми калдырып, ололар катнашы белән үткәрәләр зур келәүне.

**келәү айы** *т.я.-крш.* борынгы җирле календарь буенча елның алтынчы ае (по древнему местному календарю – шестой месяц года). Келәү айы көз башында була.

**келәү итү** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш., м.-кар.* гыйбадәт кылу (молиться). Элек келәү итәләр ийе басуға чыгып. – *каз.ар.-крш.* Чыршаланда (*ав. ис.*) чырш(ы) агачына келәү итеп торганнар. Тезләнеп, ике җиңен тытып, баш орып келәү итәтләр иде. – *м.-кар.*

**келәү пешерү 1.** *хвл.* яңгыр теләү йоласын үткәргәндә аш пешерү (приготовление обеда при проведении обряда моления о дожде); **2.** *мәл.* к.: **ботка: йоңгор боткасы**.

**кыр келәве** *т.я.-крш.* к.: **ботка: йангор боткасы**.

**кырыс келәү** *трх.* бик саран кеше (очень скупой человек); чаг.: **мыжым**. Йаман да кырыс келәү ул.

**нәзер келәү** *тмн.* нәзер ашы (угощение, устраиваемое во имя исполнения данного обета). Бу сырхаудан котылсам, кызлар йийармын ди, нәзер келәү була анысы.

**тавык келәве** *лмб., м.-кар.* к.: **ботка: йангор боткасы**. Тавык келәwендә йә тавык, йә куй чалалар иде. – *лмб.* Элек тawык келәве итәтләр иде карчыклар бу йүндә. Тавык келәwе урны бар иде, сукалап бетерттеләр. – *м.-кар.*

**үлдүкләр келәү** *м.-кар.* һәр елны көзен, 25 октябрьләрдә, кардәш-ырулары җыелып, үлгән кешеләрне искә алу йоласы (обряд моления об умерших в определённое время года – осенью).

**КЕЛӘҮЧӘН** *каз.ар.-крш.* дин тотучан, гыйбадәт кылучан (религиозный, молящийся). Аның әнийе келәүчән булган.

**КЕЛӘҮЧЕ** *м.-кар.* теләүче, гыйбадәт кылучы (молельщик, молящийся). Аның гүре мында, безне авылда күмгәннәр, келәүче кеше булган бик.

**КЕЛӘҮЧЕЛЕК** *м.-кар.* келәү итә торган җир (место моления). Келәүчелеккә җиткенче озат.

**КЕЛӘШ** [*рус.*] *глз., мәл.* к.: **бет: йүгә бете**.

**КЕЛБАҒЫШ** *клм.* к.: **айбагар**.

**КЕЛЕКӘЙ, КЕЛЕН** *стрл.* к.: **қолқай**.

**КЕЛЕНДЕРИК** [*рус.*] *дөб., лш., блт.* клиндер (крендель). Балаларга келендерик алып қайт.– *дөб.* Кибеттә келендерик бар ди, балаларны җибәрдем. – *блт.*

**КЕЛЕННӘҮ** *стрл.* к.: **коннау**.

**КЕЛИДОК** *брб.д.* лапас (навес, лабаз, сарай). Келидокта бабай пәрәңге турый йата.

**КЕЛИНД(Е)РИК** *т.я.*, **КЛИНДИР** *хвл.*, **КЕЛИНҖИР** [*рус.*] *м.-кар.* клиндер (крендель, сушки). Әни, келиндерик саталар икән.–*трх.* Келиндерикләр, перәннекләр апқайтқан қаладан күб итеп. – *к.т.* Келинҗир дәмнәре бит бу, дидер идек.

**КЕЛИНЧӘК** *брб.д.* килен (невестка). Бөлмақ қайны кәлинчәгинә дөнйада йөқ көлмәк тигип алып кәлгәле қөшаты.

**КЕЛИСАП** *каз.ар.-крш.* киле сабы (пест). Дүрт кеше төйәр ийек алмашлап келисап белән, сүсне салыр ыйық та.

**'ЭЛИТМИ'И** *кас.* яучыларга, димләргә (сватать, сосватать). Беен 'элитми'и баралар.

**КЕЛИФ** [*рус.* хлев] *мәл.* әйберләр куярга яраклы һәртөрле каралты (различные надворные постройки, куда складывают дрова и другие вещи). Бусы утын келифе, бусы пуграп келифе. Келифтә кирәкмәгән әрбир тора, буш кисмәкме, утынмы. Келифтә йәшшиктә лампычкы бар.

**КЕЛКЕНЕЧЛЕ** *чст.-крш.* көлкеле (смешной, забавный, смехотворный). Кызны иң элек кийаматлыкка алып кайталар, аңарга келкенечле җырлар җырлилар.

**КЕЛЛӘНҮ** [*удм.* + *афф.* -лән(ү] *нокр.* кавыкланy (появиться перхоти). Башым келләнгән.

**КЕЛЛЕ** [*гар.*] *чст.* **1.** бөтенләй, нәкъ (в точности, весь). Үзем тесле келле; **2.** барысы, бөтенесе (все). Бу әйберләрнен келлесе йари.

**КЕЛПӘҮ** *нгб.-крш.*, **КЕЛПҮ** *лш.* к.: **көлпү**. Өйләре келпәп тора. Бөтөн абзар келпегән.

**КЕЛТЕРӘҮ** *мам., лш.* к.: **голдордау**. Сездә дә шулай келтерәдеме йәшен, астай? – *мам.* Күк келтери башлағач, бик қурыққан ыйым. – *лш.*

**КЕЛЧӘ 1.** *чст., кмшл., чст.-крш.* бодай кабартмасы (пышка, небольшая лепёшка из пшеничного теста на дрожжах); **2.** *т.я.-крш.* күчтәнәч (гостинец). Чыгытны мазар эстенә алып киткәннәр дә кайткастан элэшеп биргәннәр, имеш, инде келчә бирепә җибәрде шаннан.

**калын келчә** *чст.-крш.* көлчә (лепёшки из кислого теста). Кунак килгәндә туйга калын келчә пешерәләр ийе, калын келчәне урталый җаралар ыйы да эстәлгә тезеп чыгалар ыйы.

**КЕЛӘМ** *нокр., глз.* к.: **мошко I, 1**.

**КЕМ 1.** *карс.* беркем (никто). Чүп тә йук, кем дә белми; **2.** *нокр., глз.* нинди (какой, что за). Кем кеше сын анда тыра?; **3.** *нокр., глз.* нәрсә, ни (что, что-либо). Кемнәр булса биспакуйыт итмәделәрме, йакшы йыкладыгызмы? – *глз.*

**әллә кем булмау** *мам., минз.* шәп булмау, яхшы булмау, уртача гына булу (не очень хорошо, так себе, средне). Тормошлары әллә кем булмаган аларның, апайым. – *минз.* Бәрәңгесе әллә кем түгел, ашарга җитсә җарар инде. – *мам.*

**кем дә** *карс.* беркем (никто). Кем дә белмәгән аның әләккә киткәнен.

**кем кеше** *тбл.* кайбер кеше, кайсы берсе, кайберләре (некоторые). Кем кеше аны түwәрәк қылып пешерәде цақцақны. Көбә сөтнә кем кеше қайwанына эцерә, кем кеше қамыр қыла.

**КЕМӘЙ** *минз.* к.: **дусай I**. Кемәйләр булыб үстек, күрше генә тордоқ. Қайынсеңнем биг әйбәт ийе, аның белә бик кемәй булыб үскән ийек.

**КЕМӘЙЕМ** *минз.* бергә туып үскән якын дуска, ахирәт дуска эндәшү сүзе (форма обращения

к задушевной, интимной подруге). Бергә тувып, бергә үскән иптәшең, шуны кемәйем дисең.

**КЕМГЕЛДЕК** *злт.* кем беренче, кем элек – балалар уенында (кто первый – из детской игры). – Кемгелдек? – Мингелдек.

**КЕМЕЛ** *клм.* к.: **кәбин**.

**КЕМЕЛДЕК** *лмб.* кем башта, кем беренче? (кто первый?). Выргыта кийәү бер пачка акчаны кемелдеккә.

**КЕМЕР** *лмб.* күмер (уголь).

**кемер алгыч** *лмб.* к.: **җәмкә**. Кемер алгыч йуктыр?

**КЕМЕСЕ** *нокр., глз.* **1.** кайсы, кем (кто). Кемесе ул керде? – *нокр.* Бер кемесе дә йуқтыр ич. – *глз.*; **2.** беркем (никто, никого). Бардым исә, идә кемесе дә қалмый. – *нокр.*

**КЕМКЕЙ, КЕМКИ** *нокр., глз.* **1.** к.: **кемесе 1**. Кемкей буласин? – *нокр*; **2.** к.: **койы-кем**. Кемки малайлар Күкшедән дә (*ав. ис.*) барганнар Йүкәмингә. – *глз.*; **3.** кем дә булса, берәү, берәр кеше (кто-нибудь, кто-то). Кемки сырамадымы мине? Кемки дә йымырка йукмы? – *глз.* Йымырқа кемкейдән аласы иде. – *нокр.*

**КЕМСӘ** *т.кам.-крш.* кеше (человек). Кем бусын – кемсә! Кемсә тавышлы җабалақ.

**КЕМСӘН** *тбл., сазл.* алтынлы бизәк (позолота). Кемсәнле цене табағымны ваттым. – *тбл.*

**КЕН I** *срг.* кояш (солнце). Айга гына баксам айамын, Кенгә генә баксам күүәмен (*бор. җыр.*).

**кен алу** *мәл.*, **кен ашау** *тмн.* кояш ашау, кояш алу (выгореть, выцвести под действием солнечных лучей). Бусын, ватагына кен ала. – *мәл.* Кен ашады, аркам йана, үләм. – *тмн.*

**кен II** *нокр., глз., дөб., кмшл., миш.д.* көн (день): **буш кен** *кузн.* сишәмбе (вторник).

**кен куйу** *тмн.* туй көнен билгеләү (назначить день свадьбы). Кызны йарашалар, йарашкач кен куйалар, касы кенгә туй булыр энде.

**кен эстенә** *кмшл., м.-кар., шрл., брб.д., том.д.*, **кеннең эстендә** *шрл.* бер көндә, бер көн эчендә (за день). Кен эстенә ката'да. – *м.-кар.* Мин кен эстенә генә барып қайттым. – *кмшл.* Баулыга барабызмы кен эстенә генә, минем анда бар кардәшләр. – *шрл.* Тосқа партық иде диңгестән, кен эстенә қайтып киттек. – *брб.д.* Беген үзем барымын сиңа кеннең эстендә. – *шрл.*

**кече қыда кене** *нокр.* туйның өченче көнендә егет һәм кыз якларында үткәрелә торган мәҗлес (угощение в домах жениха и невесты на третий день свадьбы).

**ылы қыда кене** *нокр.* туйның икенче көнендә кыз яклары егет ягына бүләкләр белән туйга бару көне (второй день свадьбы, когда родные невесты приходят в дом жениха с подарками). Экенче көнне үләдән сыңра қыз йақлары ыл йаққа ылы қыда кене үткәрмә баралар, қыз анасы чепчеги кетерә, бирнәләр кетерә.

**КЕНАЛМАШ** *нокр.* көнаралаш, ике көнгә бер (через день). Мин кеналмаштан кел ала тырған идем, кеналмаштан қалғаладым.

**КЕНӘ I** [*фарс.*] *т.я.* кинә, үпкә (обида, злоба). Миңа ниндидер кенәсе бар. – *к.т.*

**кенә қуу** *т.я., кмшл., злт.* үпкә саклау, ачу саклап йөрү (таить злобу, обиду). Атналар буйы сүләшми йөри кенә қувып. – *злт.* Бер сүз әйтсәң, бик озақ кенә қува. – *к.т.*

**КЕНӘ II** *т.я.-крш., нрл.* к.: **кенәген**. Кенә шикәр алдыңмы? – *т.я.-крш.* Кенә кич шул кечкенә машина ғына килде. – *нрл.*

**КЕНӘГӘ** [*рус.* книга] **1.** *крш., м.-кар.* китап (книга). Боларны инде нигә, кенәгәгә җазамсың? – *м.-кар.*; **2.** *м.-кар.* кырыккарта – күшәүче хайваннарда (рубец – у жвачных животных). Сыйрда кенәгәсе була.

**КЕНӘГЕ** *мам.* кичәге (вчерашний). Кенәгесен дә ашамадылар әле, тавыкларға салдым (ашны).

**КЕНӘГЕН** *мам., лш., крш., чст.*, **КЕНӘГЕНӘК** *лш., каз.ар.-крш.* кичә, кичәгенәк (вчера, вчерашний день). Кенәген мәче җувына дагын, қунақ килер дим. Кенәген көтү чыкмады, җаңғыр булғач. Кенәген кич тағын җауды. – *мам.* Кенәген генә Қазанға китте. Сез кенәгенәк килгән булғансыз икән. – *каз.ар.-крш.* Кенәген ашағанны онота торған кеше. – *т. кам.-крш.* Кенәген килгән ийе хаты, уқәле. – *т.кам., -крш.* Кенәген бик каты җил булды. – *чст.* Сыйыр кенәген үзе қайтты. – *нгб.-крш.* Кенәгенәк кенә қайтты Қазаннан. – *лш.*

**кенәз** *кас.* князь:

**кенәз берчи'и** *кас.* к.: **қарлыған**.

**КЕНӘЛӘШ** *карс.* к.: **айбағар**. Кенәләш майы әлдә дә бар wит.

**КЕНӘЛЕ** [*фарс.* +*афф.* -ле] *минз.* мәкерле, хәйләле (хитрый, коварный, лукавый). Ул үзе болай кенәле кеше түгел.

**КЕНӘЛҮ** *брб.д.* үч алучан (мстительный).

**КЕНӘНҮ** *нрл.* к.: **келәнү**. Малайларым кенәнергә дә чыкмадылар, тырыш булдым.

**КЕНӘҢГЕ** *лш., мам.* кичәге (вчерашний). Кенәңге эшме әле бу. – *лш.* Кенәңге аш. – *мам.*

**КЕНӘШ-КЕНӘШ** *кузн., чст., мәл.* к.: **кәнәш-кәнәш**. Кенәш-кенәш атеп-атеп чакырабыз алашнықы тайын. – *мәл.*

**КЕНДЕК** *перм.* чалгының сабына аркылы бөгеп куелган тотка (поперечная рукоятка косы).

**өмөҗе кендек** *перм.* кура җиләгенең эчендәге тотынып торган җире, үзәге (торчок, стержень малины). Кендекләре белә сувырылып чыға өмөҗе, пешмәдисә. Аппақ була өмөҗе кендек.

**КЕНДЕКӘЙ** *бөре., минз.*, **КЕНДЕКЧЕ** *брб.д.* әби, кендек әби (повивальная бабка, повитуха). Мин өсөм тә кендекчемен, сикез кендек кәскән мән. – *брб.д.* Бөтөн кендекәйләр қарагатқа китеп беткән, миңә кендекәйләр тапмайлар икән, инәй бәбәйләп утыра икән. – *бөре.*

**КЕНДЕРИК** *лш., каз.ар., крш.* к.: **келәндир**. Кендерик ди торғаннар ийе бed бала wахытта, хәзер шүшки диләр. – *лш.*

**КЕНЕ** *лмб.* көнчелек (ревность). Дышман кенесеннән сүлидер.

**КЕНЕЗЕН** *мәл., чст., кузн.* к.: **көнсәтә**. Беген ашарга да кат'ып булмады кенезен. – *чст.*

**КЕНЕЛӘҮ** *лмб., карс.* көнләшү, көнләү (ревновать). Кенеләгән, багам күзне, теге миңа бага. – *карс.* Бырынгылар бит кенеләмиләр иде. Бәбәйдән кенеләде бу.

**КЕНЗӘЛӘ** [*рус.* кудель] *чст.* йон кабасы, та-

раксыз каба (прялка без гребня; палка, приспособленная для прядения шерсти).

**КЕННӘТҮ** *срг.* көн буе тоту (оставить на один день, держать один день). Кеннәтәләр ул сетне, эссе (өсте) утыра.

**КЕННҮ** *т.кам.-крш.* югач, бизәгәч, өйнең яктырып, балкып китүе турында (стать светлым, чистым после уборки – о комнате); чаг.: **көлпү**. И, бөтен өйөгез кеннеп киткән. Бийекәй тауларны менгән чакта, Атыбызны бөркөт өркетте; Безнең киленебезнең әйберләре Бөтен өйөбезне кеннетте (*бор. җыр.*).

**КЕНСӘТӘ** *тмн., срг., мәл., чст., карс.* к.: **көнсәтә**. Беген йаңгыр булгач, терлек-тywар кенсәтә азбарда. Кенсәтә кырда йерисен, арыпсын, дийр. – *срг.* Кенсәтә улсын сүлисен, бусын сүлисен. Кенсәтә йөрисең кешедә. – *тмн.* Кенсәтә йазу эстендә былар. – *мәл.* Кенсәтә мында инде, әбисеннән бер дә айырылмый. – *чст.*

**КЕНТЕК** *тбл.* күз – бәрәңге турында (глазок – у картошки).

**кентег ата** *брб.д.* кендек әбисенең ире (муж повитухи по отношению к тому, кого повитуха принимала). Кентег атамның қойлары көп полған.

**КЕНТЕКЧЕ** *брб.д.* к.: **кендекәй**.

**к е н т е х** *саз.я.* кендек (пуповина):

**кентех ин′йә** *саз.я.* к.: **кендекәй**.

**КЕНЦӘН** *мәл.*, **КЕНЧӘН** *чст.* көнче (ревнивый). Ире әзрәк кенцәнрәк тә. – *мәл.*

**КЕҢГЕРӘҮ** *т.я.-крш.* алҗу, тилмерү, зарыгып бетү (утомиться, томиться). Аның кайтасын кеңгерәп кеттек.

**к е ң е л** *миш.д.* күңел (дух, настроение):

**кеңел алу 1.** *чст.* күңел булу (довольствоваться). Беркawым кеңел ала, беркawым кеңел калдыра (*әйтем*); **2.** *тмн.* күңел теләү (хотеть, желать); чаг.: **келәү 2**. Кеңелең алса, аша йералманы.

**кеңел калу** *срг.* к.: **кеңел алу 1**. Бер ашадың, кеңел кала (балны). Кеңел калгынца ашарлар.

**кеңел эштерү** *лмб.* күңел болгану, косасы килү (тошнить, мутить).

**кеңелгә килү** *срг.*, **кеңелгә тулу** *лмб., хвл.* ошау (нравиться, быть по душе). Мунца кеңлегезгә килдеме? Бер дә кеңелләренә килер кеше йук. – *срг.* Безнең авыл кеңленә тулдымы? Синең кеңленә ничек тулыр, минекенә тулды, дийр (аш турында). – *лмб.*

**КЕПТӘР** *саз.я.* к.: **голекай**.

**КЕПЧЕК** *чст., мәл.* мендәр (подушка). Пар кепчек бирдем. – *мәл.* Мени бысын башыңа беклә, анары кепчек куйарсын. – *чст.*

**к е п ш ә** *миш.д.* көпшә (трубчатый стебель, ствол растения):

**гаснич кепшәсе** *карс.* к.: **ирен I: ирен бозгыч**.

**КЕПШӘК** *карс.* арыш онын нечкә иләктән иләп, әчегә пешерелгән кечкенәрәк икмәк (маленькие ржаные хлебцы, испечённые из кислого теста, из ржаной муки, просеянной через мелкое сито).

**к е р I** (грязь на теле и белье):

**керлеген алу** *злт.* киндерне язгы кар суында тукмап агарту (отбеливание холста, бить в талой воде). Киндерен ағарта торған ыйық, аны керлеген алам дип сыwық сыwға сәпиң.

**керле он** *кргл.* кара он, арыш оны (ржаная мука). Ағ он былсын, керле он былмасын.

**КЕР II** *эчк.* үч, ачу (месть, злоба). Миндә нинди керең бар алай дип әйтергә.

**КЕРӘ** *төм., тара., твр., брб.д.* пычкы (пила).

**керә табы** *брб.д.*, **керә чүбе** *твр.* пычкы чүбе (опилка).

**қул керә 1.** *төм.* аркылы пычкы (поперечная пила); **2.** *тбл.* кул пычкысы (ножовка).

**КЕРӘК** [рус. кряк] *перм.* себер үрдәгенең бер төре (один из видов сибирских уток).

**КЕРӘ-КИЧҮ** *нрл.* кичү (переправа, брод у реки). Дәwеш белән Черкен (*ав. ис.*) арасында быйыл күпер салганнар, керә-кичүдән генә йөриләр ийе.

**КЕРӘНТЕ** *перм.* к.: **көрәнте**. Әны қый, су түгә торған йақны керәнте дибез без.

**КЕРӘСЛӘ** [*рус.* кресло] *себ.* чана үрәчәсе (розвальни).

**КЕРӘТ** *тбл.*, **КЕРӘТӘ** *тара., твр.*, **КЕРӘТЕ** [*рус.*] *тара.* яшелчә бакчасы (огород). Керәтә тулған аш: пийас, сәртәк, пубый (фасоль). Керәтетә нимә ул, сыйырма?

**картуп керәтә** *тара.* бәрәңге бакчасы (картофельный огород). Картуп керәтәгә цыққан.

**КЕРӘЧ I** [*фарс.*] **1.** *лш.* акбур яки ак балчык суы (раствор мела, белой глины или извести). Ақ ташны төйәләр дә қайнар суға салып, идә сипарат сөтөнә изәләр – шул керәч була, аның белән пич, моржа ағарталар; **2.** *минз.* ак балчыктан ясалган чынаяк (чашка из белой глины); **3.** *минз.* ниндидер тау токымы (одна из горных пород). Керәч арасыннан чыға торғандыр, керәч ул сапсары, бик қаты таш.

**КЕРӘЧ II** *минз.* җәнлек тиресен тарттырып киптерү өчен хезмәт итә торган агач киерге (деревянное приспособление для натягивания шкуры, снятой с убитого зверя).

**КЕРӘЧ III** *минз.* к.: **керәүшә**.

**КЕРӘЧЛӘНҮ** [*фарс.* + *афф.* -лән] *мам.* ташның янып вакларуы (превращение камня в известь вследствие обжига). Керәчләңгән таш була, муча ташының асты, шуннан таш сuwы чыгарадырыйық.

**КЕРӘЧҮГӘ** [*рус.* гречиха] *тара.* карабодай (гречиха).

**КЕРӘҮ** *крш.* тырмалап җыю (сгрести, сгребать – сено). Грабля белән керибез пецәнне.

**КЕРӘҮШӘ** *дөб.* керәшә (касатка, береговая ласточка). Керәүшә дигән қош ойасын бик сылап йасый бит.

**керәүшә ойасы кебек** *дөб.* бернинди тишексез, ярыксыз (плотный, без щелей и отверстий – о постройках). Аның әбрәкәйен күрсәгез, керәүшә ойасы кебек, бер тишеге йуқ.

**КЕРБЕ** [*рус.* гриб] *тбл.* к.: **паңгы**. Кербе тә кән пестә, опийанкалар.

**КЕРГЕ, КЕРГЕСЕ** *тпк.* к.: **кире 3**. Шуннан керге әпәйне тығып қуйалар. Шуннан кергесе фирмедә эшләдем.

**КЕРДӘШ, КЕРДЕШ** *стрл.* авылга соңыннан килеп утырып кушылып киткән (кеше) (пришелец со стороны). Кердеш булып кына килгәннәр түгелме соң Султанофлар.

**КЕРЕНДЕРҮ** *бөре.* тиргәү, әрләү (ругать). Батырны җыйылышта иллә керендерделәр суң.

**КЕРЕС** *перм.* кәрәз (соты). Кересле бал алдым ийе. Қысасыннан кисеб алсаң, кересле бал була.

**КЕРЕЧ** [*удм.?*] *нокр., глз.* кер (грязь). Кереч кергән тырнақ арасына. – *нокр.*

**КЕРЕШ** 1. *мам., минз.* будырмалы резин тасма, будыргыч (подвязка, круглые резинки для чулок). Минем керешем қайа, ойоқ төшә. Керешле була бит инде тасма, күлмәк җиңенә тағам. – *минз.* Керешемне йугалттым да, хәзер ойоғом төшә. – *мам.*; 2. *мам., перм.* йон тетү өчен җайланма (приспособление для битья шерсти); 3. *мам., брб. д.* җәя җебе (тетива, потяг шерстобита); 4. *том., тара.* ишелгән тегәрҗеп (суровая сучёная нить).

**бер кереш уқ ату** *брб.д.* бер мәртәбә ук ату (выстрелить один раз из лука).

**кереш ашы** *дөб.* к.: **ботка: йаңғор боткасы.** Кереш ашы дип су сибешләр йасыйлар ийе, ботқа пешереп, урамда кем күренсә су сибеп... Җаңгыр җаумаса, кереш ашы пешерәләр кешедән җарма, май җыйып.

**керешлү тел** *брб.д.* тел кереше кыска булган (язык с короткой уздечкой). Керешлү теле пола паланыңқы, сөйләшми.

**КЕРЕШТЕРҮ** *т.кам.-крш.* бер үк вакытта берничә эшне башкару, барысын берьюлы эшләү (в одно и то же время выполнять несколько дел, совмещать). Син икән йазуны да керештерәсең, чигүне дә алып барасың.

**КЕРЕШҮ** *кргл.* пешерү өчен нәрсә дә булса алып, аулак өйгә җыелу (сбор в доме, где отсутствуют старшие и устраивается вечеринка, куда приходят, взяв что-либо с собой для приготовления угощения). Әwәле керешәдер ийек, кемнең нәрсәсе бар, шуны алып килеп, нәрсә пешерәсе килсә, шуны пешерә.

**КЕРЛӘНЕШҮ** *срг.* бозылышу, әрләшеп ямьсезләнү (портить дружеские отношения). Алар бер дә ачуланышмаганнар, керләнешмәгәннәр.

**КЕРЛӘҢ** *том.д.* тәлгәш (кисть, гроздь). Қолмақ керләңе.

**КЕРЛӘҮ** *перм.* каралту (грязнить, загрязнить). Көн дә берне күлмәк керләп орғам була.

**КЕРЛЕ** *тбл.* йогышлы (заразный). Ул цир керле булып цықты.

**КЕРЛЕКЛЕ** *мам.* кер күтәрми торган (маркий). Эче дә керлекле булды (бишмәтнең).

**КЕРЛИСА** *злт.*, **КЕРЛИЧ** [*рус.*] *твр.* к.: **болдор.** Керлисасы йуғ аның, башы да асық, күтәрмәсе дә йуқ. – *злт.* Ачылмадан кергәннәр дә басып чықтылар, без – керличтә.

**КЕРЛИЧӘ** [*рус.* крыльцо] *твр.* к.: **ишегалды.**

**керличә алды** *твр.* к.: **болдор.**

**КЕРНӘ** *сазя.* рахит (рахит).

**КЕРНӘЛӘҮ** *сазя.* тоз белән им-том итү ( заговаривать солью, знахарским способом).

**КЕРӨК** *клм.* кирәк (нужный, нужно, надо). – Кәртүшкә керөкмө? – Керөк, кән керөк.

**к е р п ә** [*рус.* крупа] *кмшл.* көрпә (отруби):

**манный керпә** *кмшл.* манный ярмасы (манная крупа). Манный керпә йуғ икән кибеттә, ул тиз пешә.

**КЕРПӘК** [*рус.* крупа + *афф.* -к] *нокр.* к.: **эре.**

**КЕРПЕ** *мам.* кырпу (опушка, оторочка). Керпе бүрек булган.

**КЕРПЕК** 1. *хвл.* хатын-кызлар күлмәгенең итәк очына бөреп тотыла торган киң итәк (широкая оборка, пришитая к подолу женского платья); 2. *глз.* керфек төбенә өстәмә чыккан керфек (ресница, появляющаяся у ресницы и мешающая зрению). Керпек чыға қаты, үзенә башқа, awырта.

**КЕРСН′АН′У** [*рус.* крёстный + *тат.*] *т.я.- крш.* к.: **урсәти**

**КЕРСН′АТ′У** [*рус.* крёстный + *тат.*] *т.я. -крш.* к.: **урсәти**

**КЕРТ** *әстр.* йозаклы ишек (дверь с замком).

**КЕРТӘҮ** *тбл.* ышку (тереть). Керне кертәп йыума, тусгә (доска) белән йыу.

**к е р т ү** (вводить):

**кертеп сугу** *нокр.* асалап сугу (ткать закладным способом).

**КЕРТҮК** *срг.* чабагач сабының башында тәпәч әйләнеп торырлык итеп тоташтырыр өчен эшләнгән урын (место на конце рукоятки цепа для прикрепления било цепа; оно делается таким образом, чтобы било цепа могло вертеться). Чип палканы әйләтергә кушайтып кертүк эшлиләр иде.

**КЕРҮ I** *хвл.* йогу, уңу – тукыманың буявы турында (линять, пачкать – о краске материи). Керә торганнарыңы вата ыстул өстенә куй, аклариңны шawага куй. Йупқыңнан кермиме?

**КЕРҮ II** 1. *перм.* йөрү, бару, барып җитү (ходить, добираться). Ташкингә ничә көн керә хат?; 2. *клд., стрл.* югары менү, күтәрелү (подниматься). Агач башына кердем. – *клд.* Самал′от күккә кергән бийеккә. Пич башына да керәләр бездә. – *стрл.*; 3. *перм.* кыз куенына керү (провести первую брачную ночь). Кийәү керә, кунақлап җөрөй.

**КЕРҮ III** *минз.* к.: **керешү**; чаг.: **тәпәрләнү** 2. Йазғысы керми, көзгө йоннан басабыз итекне.

**КЕРҮ IV** *себ.* кыйнау (бить). Йахшы иттереп кереп алайым мин сине, кәрәгеңне пирәйем. – *тбл.*

**КЕРФЕК I** 1. *лш.* тар бала итәк (узкий волан на подоле, на рукавах платья). Керфекле күлмәк. Аңа керфекләр тотабыз әле, гыржывалар, күлмәккә; 2. *минз., стрл.* җиләкнең сабак кырындагы вак яфракчыклары, касә яфрагы (чашелистик). Қоро йылны җиләге wақ була, керфеге озон була. – *минз.* Йаңгыр йаумаган йылны җиләк керфеккә үсә. – *стрл.*;

**КЕРФЕК II** *бәр.* 1. мәчет манарасының чыгып азан кычқыра торган урыны (место, балкон у минарета, где муэдзин призывает к молитве). Элек мәчетнең манарасы өч керфекле иде: 2. *дөб.* к.: **картус.**

**КЕРЦӘК** *себ.* эчкерсез (искренний).

**КЕРЦӘН** *сазя.* тиз пычрана торган (маркий, быстро марающийся). Керцән көләх (күлмәк).

**КЕРЦЕК** *туб.-ирт.д.* ылыс (хвоя). Урманнықы (чыршыныкы) керцекләре қойылмайты. – *төм.*

**КЕРЦЕЛ** *туб.-ирт.д.* к.: **керцән.**

**КЕРЦЕХ** *сазя.* к.: **керцек.**

**урман керцех** *сазя.* чыршы ылысы (хвоя ели).

**КЕРЧЕК I** *перм.* билгеләнгән урын – уен вакы-

тында (определённое, очерченное место – во время игры). Син керчегеңә барып җиткәнчи, сийә ормага тийешләр. Чапқы топ уйнағанда керчек була.

**КЕРЧЕК II** *твр.* **1.** к.: **керцек**; **2.** кара чыршы (ель).

**КЕРЧЕМӘ** *чпр.* ачы бал (медовая брага).

**к е р ш ә н** (крем для лица):

**бөтөркәле кершән** *бәр.* төймәле кершән (крем для лица в тюбиках). Бөтөркәле кершән диб әйтерләр ийе, кийәү бүләгенә бирерләр ийе.

**КЕРШӘНӘ** [*рус.* крещение] *м.-кар.* к.: **қачманар**. Шул кен алаша йасыйлар иде камырдан, паминат′ итәләр иде; кершәнә чабатлар ат җигеп тейәлешеп, җырлашып йөритләр иде.

**к е с ә** (карман):

**кесә йаулық** *туб.-ирт.д.* кулъяулык (носовой платок). Йесле сабынма, көмөшмә, йеслемай шишәмә уцлатып қуйа кесә йаулық белән урап. – *төм.*

**КЕСӘБИКӘ I** [*рус.* қацавейка] **1.** *дөб., блт., мам., каз.ар.-крш., к.т., бәр., минз.* кызлар яки яшь киленнәр кия торган кыска җиңле камзул (короткий камзол без рукавов – для молодых женщин и девушек). Кесәбикә пелүштән тегелә, җиңсез була. – *мам.* Қуш бөркәнчек бөркәнеп, кесәбикә кийеп килен төшәдер ийе. – *лш.* Уқалы кесәбикәләрне қызлар кийәләр ийе. – *блт.* Кесәбикәне бәрхеттән тегәләр. – *бәр.* Кесәбикә диләр ийе тағын, анысы қысқарақ, теесе камзул, плүштән, кырүгум уқа, озон. – *к.т.*; **2.** *лш., бәр.* терсәктән җиңле итеп тегелә торган хатын-кызлар камзулы (женский камзол с укороченными рукавами). Кесәбикәнең қайсысының қысқа җиңе була, қама тотоп төшөрәләр ийе итәг очона. – *бәр.*

**КЕСӘБИКӘ II** *нрл.* кесәгә тутырып алып кайткан ашлык (зерно, приносимое домой в карманах). Кесәбикә алып қайтсаң да әләгәсең; кесәбикә – кесәгә тутырып алып қайтқан орлоқ була.

**КЕСӘЛ** *т.я., каз.ар., срг.* солы көрпәсен изеп, берәр көн ачыталар да, беркадәр җылы су өстәп, аны иләк аша саркыталар һәм казанга салып болгата-болгата куерганчы кайнаталар, суынгач, сөт белән ашыйлар (пища, приготовляемая из овсяных отрубей; овсяный кисель). Қайнар кесәлне сөт белән ашарға тәмне. – *к.т.* Кесәлне киндер орлоғо сүге белән дә ашыйлар. – *лш.* Кесәл пешердем, тансық аш бит, ашарға керегез. – *мам.*

**солы кесәле** *т.я., каз.ар.* к.: **кесәл**. Солы кесәле ашқазанына әйбәт, пешерергә иренмәсәң шунда. – *мам.* Солы кесәле була, аны бәк сирәк пешерәбез. – *нрл.*

**КЕСӘЛЛЕК** *мам.* солы (овёс). Кесәллек йармасыннан ботқа пешердем.

**кесәллек он** *минз.* **1.** солы яки арпа оны (овсяная или ячменная мука). Кесәллег оннан ипи пешердем; **2.** солы оны (овсяная мука). Кесәллег ононнан тәмне була wул умач.

**КЕСӘНҮ** *минз.* эзләнү, өмет итеп көтеп йөрү (рыться, обшарить, искать, надеяться). Эшләргә иренә, ә ашарға кесәнеп кенә йёри.

**КЕСЕРКӘН** *тмн.*, **КЕСЕРТКӘН** *срг., злт.* кычыткан (крапива двудомная).

**КЕСИ** *туб.-ирт.д.* киездән, мехтан тегелгән аяк киеме (кисы, бурки). Пойма ғуныцтан кеси тегәтеләр. – *төм.* Қыш көнө кийәсең, табаннан теккән, менә гилен күрсәтеп бақсын кесийен. – *тбл.*

**КЕСИЙӘ I** *т.я.-крш.* кесә (карман).

**КЕСИЙӘ II** [*чув.*] *т.я.-крш.* к.: **майқарақ**.

**КЕСИЙЕ: кесийе гел** *нокр.* к.: **гөл I: ылыс гөле**.

**КЕСИЙЕН** [*рус.* казеин] *твр.* пластмасс савыт (пластмассовая чаша).

**'ЕС'А'А** *кас.* элек килен кеше каенесенә шулай эндәшкән (форма обращения к младшему брату мужа). 'ес'а'ам орыштан 'айтма'ан.

**КЕСКӘ-ЗУРГА** *лмб.* көчкә-көчкә, көч-хәл белән (насилу, еле-еле). Кескә-зурга акса бирәм.

**КЕСКӘК** *нокр.* кыскыч (щипцы, клещи).

**КЕСКЕ** *перм.* каргаборын (плоскогубцы). Тойақ кисә торған кескесе бар.

**КЕСМӘН** *минз., әстр.* ишкәк (весло).

**кесмән суғу** *минз.* ишкәк ишү, ишү (грести). Кесмән суға-суға қулым қабарды.

**КЕСТЕНҮ 1.** *лмб., кузн., хвл., мәл.* пошкыру – ат турында (фыркать – о лошади). Йылкы тау менгәндә кестенә. Әтийемнең сивай аты Йулга чыкса, кестенә (*бор. җыр.*). – *лмб.*; **2.** *мәл., хвл.* көрсенү, кайгыдан авыр сулау (вздыхать, тяжело вздыхать от горя). Awыр хәсрәт wакытында адәм кестенә дә, «Илахи хайерлегә булсын» дип куйасын. – *мәл.*

**КЕТӘК** *брб.д.* өйдә тавыклар өчен ясалган урын (место в доме для кур). Кетәктән цығарып қойып. Кетәк тибес, элек тawықлар, қорослар үдә иде, айырып йасап қуйған урын пулаты.

**КЕТӘЛ′УК** [*рус.*] *мәл.* котелок (котелок).

**КЕТЕКИ** *бәр., мам., блт., дөб.* **1.** к.: **бетеки 1**. Қазанға кетеки чақта ғына барғаным бар. – *бәр.* Иң кетекийе бу була. И кетекиләре була аның су буйында (бака казанының). – *блт.* Кетеки генә миңа да сындырып бир әле. – *мам.*; **2.** к.: **безрәк**. Кетеки генә май бирим, ипи белән ашап тороғыз. – *дөб.*

**КЕТЕР: кетер ақ** *блт.* бик ак, ап-ак (белый-пребелый, очень белый). Буйала, булмый кетер ақ җөрөп.

**КЕТЕРӘWЕК** *твр.* вак тәңкәләр – киемгә бизәү өчен тегәләр (мелкие монетки, блёстки – пришиваются на одежду в качестве украшения). Сарawыч уға ман тегелгән, пашқа пәйләгәннәр, кетерәwекләр таққаннар.

**КЕТЕРМӘWЕК** *минз.* каткак (мёрзлая земля). Көн сайын бер кийем чабата, көз көнө кетермәwек була, тиз туза.

**КЕТЕРМӘК** *эчк.* бугаз (горло).

**КЕТЕР-МЕТЕР** *нгб.-крш.* к.: **чәлпәк 1**. Кетерметерне пычак белән кисеп пешерәләр, қыр-қырлары сырлы була.

**КЕТЕРТ** *м.-кар.* чирак – җеп турында (туго скрученный – о нитке). Кетерт була каты булгач, крута эрләгәч.

**КЕТЕРЧӘ** *т.кам.-крш.* к.: **җылawық**. И кетерчә буған диләр ийе, кетерчә җыуғач, ана сөтен сawып җомошатқач бетә дип сөйлиләр.

**КЕТИ** *тпк.* к.: **кочок**. Кетиләргә сөйәк белән бәрсәң, шыңшымайлар, ди.

**КЕТМЕР** *минз.* к.: **кечкеник**.

**КЕТНЕК, КЕТНИК** [*рус.* кутник] *нокр.* к.: **лаука 2**. Кетник йанындағы чапчаққа тутырмапсин ич су.

**КЕТТӘ** *чст.* кәттә, яхшы, дәрәҗәле, күренекле (важный, знатный, видный); чаг.: **атаулы 1.** Ул кеттәрәк кеше бит инде. Ул заманының кеттә кешесе булган.

**к е т ү** *срг., чст.* көтү (стадо):

**кетү серү** *чст., срг.* к.: **көтү II: көтү сөрү.** Кетү сергәч йатмаган идем әле. – *чст.*

**КЕЦЕ** *әҗ., себ.* к.: **бәйсәкә.** Минем мән йәшле ул, үсе пер кеце кенә кеше. – *тбл.* Кем зур, кем кецерәк. – *әҗ.*

**КЕЦЕ-ГЕЦЕМНӘН** *төм.* кече яшьтән үк (с детства, с малых лет). Мин кеце-гецемнән кергән кешене цай эцермәйен цығармаган мин.

**КЕЦЕГӘ** *туб.-ирт.д.* үзеңнән кече бертуганнарың, эне яки сеңел (младшие родные – брат или сестра). Йөгөр, кецегәм, Шәйәкпәр әкәң машинәгә ултысам тите. – *тбл.* Икке кецегәм пар ите. – *тара.* Атамнан-инәмнән қалтым, кецегәләремне асырадым. – *төм.*

**ир кецегә** *туб.-ирт.д.* эне (младший брат). **Ир** кецегәмне асратым, өйләнтертем. – *төм.*

**КЕЦЕГӘЦ** *туб.-ирт.д.* к.: **кецегә.** Бертуган кецегәцем соуғышта үлеп қалты. – *төм.*

**КЕЦЕЙОМА** [*мат.* + *гар.*] *эчк.* к.: **кечатна.**

**КЕЦЕК** *чпр., себ.* к.: **кечкеник.** Бер кецек кенә ызбасы бар. – *чпр.*

**КЕЦЕЛӘЙ** *сазл.* к.: **кечүләй.** Аар кецеләй йәтимә пулф халтылар.

**КЕЦЕРГӘН** *брб.д.* к.: **кесеркән.** Кецергән пайдалу тейте, тәре ийән қанға та, пашқа та.

**КЕЦЕРКӘН** *срг., чст.*, **КЕЦЕРТКӘН** *тмн., мәл., чпр.* к.: **кесеркән.** Майым, кецерткәнме цакты. – *тмн.* Кецерткән дә ашадык. – *мәл.* Кецерткән шикелле тиз үрци бу гел. – *чпр.* Кецеркән кецертмәсен. – *чст.*

**КЕЦЕРТҮ** *срг., чст.* к.: **каклау.** Кецерткән кецертә. – *срг.* Сатка цыкма, айагыңны кецерткән кецертер. – *чст.*

**КЕЦЕРҮ** *төм., тара., брб.д.* кечерәю (уменьшаться). Қысылғаш (*ав. ис.*) кецереп параты. – *төм.*

**КЕЦЕХӘ, КЕЦЕХӘС** *сазл.*, **КЕЦКӘ** *твр.* к.: кецегә. Кецехәсләрем кән мийең. – *сазл.* Анта минеке кецкәм тора, тоумас (бала тапмый), паллары йоуқ. – *твр.*

**ҚЕЦКЕН** *тара.* к.: **кечкеник.** Галушың кецкен ғуй, йуқмы аннан йыwанырақ.

**КЕЦКЕНӘ** *тбл.* аз гына (немного). Маңа инте кецкенә тыңгылық пирген.

**КЕЦКЕНТӘЙ** *себ.* к.: **кечкеник.** Менә монтай кецкентәй пала уқцығацы пелән атқан. – *төм.* Ул бақыт кецкентәй итем. – *тара.*

**КЕЦКИЙ** *эчк.* яшьрәк (моложе). Кийәwем бер йәшкә кецкий қызымнан.

**КЕЦУСАК** *чпр.* к.: **кечучақ 1.**

**КЕЦҮ** *тмн., байк., срг., чпр.* кычыту (чесаться, зудеть). Кецеде айакларым, йаргаланды. – *тмн.* Цәцне тотып булмый, кеци башлый. – *байк.* Өске ирен кеци, мацым битен йуwа, кунак килергә булган. – *срг.* Иренем кеци, синең белә сүләшергә булган икән. – *чпр.*

**КЕЦХӘ** *сазл.* к.: **кецегә.** Кецхәм пуйыл уғалы бараты.

**к е ч** *миш. д.* көч (сила):

**кеч бирү** *клд.* көчәңке килү – бала тапканда (потуги – при родах).

**кече кечкә йитмәү** *мәл.* берни дә эшли алмау, чарасыз булу, теләсә дә теләмәсә дә, (волей-неволей). Кече кечкә йитми, йылый-йылый сикез йәшлек малай урманга китә.

**КЕЧАНАМ** *тмн.* абыйсының хатынына эндәшү сүзе (форма обращения к жене дяди). Дәдә катына бездә ат'а кечанам.

**КЕЧАТНА** *мәл., м.-кар., т.я., мам., каз.ар-крш., нокр., глз., чст., карс., нгб.-крш., дөб.* пәнҗешәмбе (четверг). Кечатна киләбез, диделәр wәгдә билгесе алырға. – *мам.* Кечатна киткән ийе, бүген қайтыр микән. – *трх.* Кечатнамы килепсез? – *карс.*

**кечатнага бару** *нокр.* яшь киленнең туып үскән йортына бер ел буена кунакка барып йөрүе турында (посещение невестой родительского дома в течение первого года замужества). Бер йылға қадәр кечатнага барғанда, қыз-келен бәлеш белән қайта.

**КЕЧӘТНӘ** *тмн., нрл., перм.* к.: **кечатна.** Кечәтнә кен – йакшы кен, килербез йөзег алырга, әтиләр. – *тмн.*

**КЕЧӘҮҒАЧ** *минз.*, **КЕЧӘҮГАЧ** *стрл.* к.: **қустартқыч.**

**к е ч е** (маленький):

**кече җақ** *мам., минз., дөб.* к.: **бүлмәч 2.** Кече җаққа да шаршау қорам. Кече җаққа бүлмәчтән керәсе. – *минз.* Кече җақта ғына ашарбыз ашны. – *мам.*

**'э ч е** *кас.* кече (маленький):

**'эче фи'элле** *кас.* кечелекле (почтительный, выражающий почтение).

**КЕЧЕЙАҚ** *мам., трх.* к.: **бүлмәч 2.**

**КЕЧЕК** *чст.* к.: **кочок.** Тими ул, тими ул кечек.

**КЕЧЕКЛӘҮ** *перм.* үчекләү (дразнить). Кечекләп қайтарды, матур қызны үзебез алабыз тип.

**КЕЧЕКЛЕК** *трх.* хурлык (позор, срам, стыд). Қыз йабышып чықса, ата-әнкәне кечерәйтү, кечеклек була инде.

**КЕЧЕРКӘН** *тмн., хвл., кузн., мәл., чст.*, **КЕЧЕРКИН** *перм.* к.: **кесеркән.** Кечеркән чага вет, тотма. – *кузн.* Кечеркин арада йата чебечләр, жар қый. – *перм.*

**КЕЧЕРТКӘН** *лмб., мәл., т.кам.-крш., чст.* к.: **кесеркән.**

**кечерткән йыланы** *бөре.* кәлтә (ящерица).

**кечерткән қылмағы** *т.кам.-крш.*, **кечерткән кылмагы** *чст.*, **кечерткән чәчкәсе** *бөре.* кычыткан ефәге (повилика).

**КЕЧЕРТКИН** *перм.* к.: **кесеркән.** Кечерткин үкәләгән баланың артына, сықтап беткән.

**ата кечерткин** *перм.* вак яфраклы кычыткан (вид крапивы с мелкими листьями). Ата кечерткин бар, wақ йапрақлысы.

**қара кечерткин** *перм.* сукыр кычыткан (глухая крапива, пустырник).

**КЕЧЕРТҮ 1.** *мәл., кузн.* к.: **каклау.** Кечерткән кечертте, үтерде генә. Айагымны кечерткәнгә кечерттем. – *мәл.*; **2.** *мәл., кузн., лмб.* бәйләнү, төрттереп әйтү, чәнчү, чәнчеп кую (подкалывать,

подколоть, съязвить, подковырнуть). Һаман шоно кечертә, иманың йук. – *мәл.* Син, дигән, кечертмә, так сүлидер кечертеп. – *кузн.*

**КЕЧЕТКӘН** *трх., төм.* к.: **кесеркән.** Кечеткәннәрне чабып алдым. Кечеткән қулны кечеттерә ул. Кечеткән тәнеңә ләксә күпертә. – *трх.* Кечеткәнне ашадылар ашқа турап. – *төм.*

**кечеткән қолағы** *бөре.*, **кечеткән қомалағы** *минз.* к.: **кечерткән: кечерткән қылмағы.**

**КЕЧЕТТЕРҮ** *трх.*, **КЕЧЕТҮ** *кргл., бгрс., шрл.* к.: **каклау.** Қарлыған жыйам дип йөри торғач, кечеткән кечетеп бетерде үземне. – *кргл.*

**КЕЧКӘ** *твр.* к.: **кецегә.** Кечкәләрем, әппәләрем бар иде, пер кечкәм әрмийәдә қалды.

**КЕЧКӘЙ** *влгг.* к.: **кечкеник.** Кечкәй балыклар бар иде.

**КЕЧКЕНӘЙАҚ** *перм.* к.: **бүлмәч 2.** Апа зурырақ мийән, кечкенәйақта он илəб утыра.

**КЕЧКЕНЕ** *клм.* к.: **кечкеник.** Кечкене балалар да бөккә (болынга) китеп.

**КЕЧКЕНИК** *нрл., срг.* кечкенә (маленький). Awыл зур иде, тукыз йөз азбар иде, мәдрәсә кечкеник кенә иде. – *срг.*

**КЕЧКЕНТӘЙ** *әстр.* **1.** к.: **кечкеник.** Без кечкентәй булдық; **2.** кече, башлап белешүче (младший – по положению; начинающая сватовство – о свахе). Пирwуй кечкентәй йаучы килә.

**КЕЧКЕНТ'УК** *мәл.* кечкенә генә – иркәләп әйтү (малюсенький – ласковое обращение).

**КЕЧКЕНТҮК** *тбл.* бик кечкенә (очень маленький). Кечкентүк кенә өйләре.

**КЕЧКИ** *клд.* к.: **кечкеник.** Кечки куңгыз күрдем.

**КЕЧКИ-КЕЧКИ** *клд.* кечкенә-кечкенә (мелкие, маленькие). Кечки-кечки генә йасап майда пешерәбез ачылый.

**КЕЧКӨНТӨЙ** *әстр.* дүрт көн дәвам иткән туй (свадьба, которая длится четыре дня).

**КЕЧМӘН** *әстр.* к.: **кесмән.**

**КЕЧНӘ** *к.т.* к.: **кечкеник.** Кечнә генә өйә, кечнә генә тәрәзе, берүзе яши шулый, балалары да булмаған.

**КЕЧНӘЙТӘК** *к.т.* бала итәк (волан на подоле платья). Кечнәйтәкле күлмәгем бар ийе, Чабырға (*жыен ис.*) кийеп чыққан ийем.

**КЕЧНЕЙАҚ** *минз.* к.: **бүлмәч 2.** Кечнейақтан тыңнап торғаннар алар, болары сизмәгәннәр.

**КЕЧНИК** *нрл.*, **'ЕЧРИ'** *кас.*, **КЕЧР'УК** *клд.* к.: **кечкеник.** Кечник кенә кәнүшнийе бар. – *нрл.* 'ечри' тай. – *кас.* Кечр'ук кызыңны алып кил үзебезгә. – *клд.*

**КЕЧТӘН** *кузн.* көчләп (силой, силом); чаг.: **awаннап.** Күлмәген кечтән тарттырып йырттырган.

**КЕЧТЕГӘН** *т.я.-крш.* к.: **кесеркән.** Кечтегәнне дә ашаганнар теге ачлык чакта.

**wак кечтегән** *т.я.-крш.* к.: **қычытқан: кәрлә қычытқан.**

**кечтеғән чыпчығы** *т.я.-крш.* юк-бар сүзне күп сөйли торған кеше (болтушка, болтливая – о человеке). Бер кечтегән чыпчығы кызы бар аның, күп сүли торған.

**КЕЧТЕК** *бәр.* аз гына, бераз, берникадәр (немного).

**КЕЧТЕКИ** *мам., дөб., каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* к.: **кечкеник.** Кечтеки генә awыл. – *мам.* Жәй көнө су бик кечтеки була. Кечтеки генә урыйм әле, дип чыққан ыйым. – *каз.ар.-крш.* Жанағай диләр бездә кийәwеңнән кечтекирәк булса. – *т.кам.-крш.* Абзар кебек нәстәкәйләр кечтеки генә йе. – *дөб.*

**КЕЧТИ 1.** *мам., лш., блт., каз.ар.-крш., нокр.* к.: **кечкеник.** Кечти пычақ қайа микән? Кечти жаулық жабыйм әле. Дүрт көпчәкле кечти арбаға утырып жөриләр. – *мам.* Минем кечти қыз йуқмы мында? – *нокр.* Кечти тәлинкә қайда? Бер кечти самawыр аласы булыр әле. Моржа уртадарақ безнең, өй кечти түгел микән. Килен қайсын дәү жиңги, қайсысын кечти жиңги ди. – *каз.ар.-крш.* Без кечтирәк чақта жаулықны да суғып бәйләрләр ийе. Кечти-кечти тәңкә қуйарлар ийе, қашлы белəзекләр дə булыр ийе. – *лш.*; **2.** *каз. ар.-крш.* кыска (короткий). Озон ыйы чәчем, қәзер генә кечти қалды.

**КЕЧТИЙӘ 1.** *трх.* песнәк (синица); **2.** *к.т.* к.: **кечкеник.** Ә-ә, кечтийә қыз, әле тороп та житкән.

**КЕЧТИК 1.** *мам.* бик аз (совсем мало, немножечко). Кечтик кенә сал әле. Кечтик кенә он бирәләр ийе көм буйы эшләгәнгә; **2.** *глз.* к.: **кечкеник.** Кечтик қызым каз тутукларны куwа микән? Кечтик кенә ийендә дә сыйган; **3.** глз. кече (младший). Самай кечтийе белән тыра.

**КЕЧТИНӘ** *каз.ар.-крш.* бәби туе (угощение, приготовленное в честь новорождённого). Кечтинәдә қалық күп зыйыла, бүләкләр китерәләр.

**КЕЧТУН** [*удм.*] *каз. ар.-крш.* үлгәннәрне искә алу мәжлесе (поминки). Кенәген кечтунга барған ыйық, шунда сөйләде ул аны.

**КЕЧУРДЫК** *срг.* к.: **бүлмәч 2.** Кечурдык эчендә була бер тәрәз.

**КЕЧУЧАҚ 1.** *мам., дөб., блт., бөре.* учак, казан асты (очаг). Кечучақтагы ут сүнеп китмәсен, утын тыгыгыз, мин хәзер керәм. – *дөб.* Кечучаққа йағып жибәр, аш сал. Кечучақның көлен аласы бар. – *мам.*; **2.** *мам., блт.* кече моржа, учакка яккан утның төтен юлы (дымоход очага). Кечучақ эчекме, тарт үзен. – *блт.* Кечучақ ачық қалған да өй тартылып киткән. – *мам.*

**КЕЧҮ I** *лмб., хвл., мәл., перм.* к.: **кецү.** Башымны тарыйм, башым кечей. Учым кечи, нәнәй, акча алырбыз. – *лмб.* Уч эчем кечи, акча керер, ахыры. Кечемәгәнне кашыма инде. – *мәл.* Аркам кечи. – *хвл.*

**КЕЧҮ II 1.** *т.я.-крш., брб.д., том.д.* кечкенә, кечерәк (маленький, меньше). Миннән ничә йәш кечү. – *т. я.-крш.*; **2.** *брб.д.* к.: **кечкеник.** Тәрәсләр кечү, үwем йылу. – *брб.д.*

**КЕЧҮЛӘЙ** *брб.д.* кечкенәдән (с малых лет). Ол кечүләй эшләгән.

**к е ш** (соболь):

**кеш йеләк, кеш күс** *тбл.* кара бөрлегән (ежевика).

**кеш мал 1.** *тбл., брб.д.* каманың бер төре (вид выдры). Асыл кеш мал туннар бабайлар кийә. – *тбл.*; **2.** *тбл., төм.* к.: **кеш.** Сунарлый бы, кеш мал та тотқаны бар. – *төм.*

**кеш малы** *тбл.* к.: **кеш.**

**кешән** (путы для треножения лошадей):

**кешән тай** *хвл.* яшь тай, имә торган тай (жеребёнок-сосун); чаг.: **қоломчақ**.

**кеше** (человек):

**кеше қузғалағы** *блт., мам.* кузгалак, әче кузгалак (щавель кислый). Безнең бакчада кеше қузғалағы да, ат қузғалағы да, чыпчык қузғалағы да үсә. – *мам.*

**КЕШЕМ** *нокр., глз.* ирем (мой муж). Кешем йегәрле булды, үләр қуйды, ак мунча да қуйды. – *нокр.* Кешем суғышта үлде. – *глз.*

**ир кешем, йәр кешем** *нокр., глз.* к.: **кешем**. Ир кешем тора иде липутат булып. Мона йәр кешем урманға китте. – *нокр.*

**КЕШКЕ** *дөб.* к.: **көшкө**.

**КЕШКЕЛӘНҮ** *дөб., мам., шрл.* к.: **көшкөләнү 1**. Кешкелә́нәсең генә ирле кеше. – *шрл.*

**КЕШМӘР** *брб.д.* су күсесе (водяная крыса).

**КЕШМЕРИК** *перм.* җиләк җыю өчен каен тузыннан бүрәнкә рәвешле ясалган савыт (воронкообразное берестяное лукошко для ягод).

**КЕШНҮК-КЕШНҮК** *чст.* к.: **кәнәш-кәнәш**. Кешнүк-кешнүк дисәң, килә ул, курыкмый кешедән.

**КЕШТӘК** *тмн.* кыек – күлмәк итәге турында (клин на подоле платья). Әле бит тур(ы) ук, алты клин тегә идек, кештәк әтәләр.

**КИ 1.** *нокр., глз.* ...са, әгәр (если). Китап ки бар, йиңел уқыма. – *глз.* Йил булмаса ки, бик йылы ий. Син тее йаққа барсаң ки, анда нәқәс күп иләк. – *нокр.*; **2.** *нокр., глз.* ...дыр, бугай (кажется, возможно, вероятно, наверно). Қаа китсен йанйаулық, қучақ асқа төште ки. – *глз.* Килен идә йуқмы? – Қаа чықты исә ки. – *нокр.*; **3.** *эчк.* ич, бит (ведь, же). Синә йөз мәртәбә әйттем ки.

**алай ич ки** *нокр., глз.* алайса, алай булса (если так, в таком случае). Алай ич ки безгә кел. – *нокр.*

**ни ки** *нокр., глз.* **1.** нигә (зачем, почему). Ни ки чығып киттең? – *нокр.*; **2.** ниндидер (какой-то). Ни ки печән, айтма булдырмайым. – *глз.*; **3.** ни дә булса, нәрсә дә булса (что-нибудь, что-то). Ни ки йазма таптығыз, шәт? – *глз.* Күптер әле ни киләр сорама. – *нокр.*

**ничә ки** *нокр., глз.* ничәдер (сколько-то). Ничә ки, уналты тийенме? – *глз.*

**КИБАР′АНЫ** *карс.* к.: **кебар′ане**. Кибар′анын үги баласына бирми икән, кочокка сала икән.

**КИБӘК** *срг.* саламга кайнар суда изелгән бәрәңге катнаштырып яки он, көрпә сибеп әзерләнгән терлек азығы, башак (месиво скотине из соломы с картофелем или мукой). Кибәк бирә идек, кадулага салам, су салып ал′андереп, өсөнә он сибәләр иде аның, кибәг ателә.

**кибәк печән** *мам.* себерке үләне (клоповник, венечник).

**кибән** (стог):

**кибән айағы** *трх.* көлтә суга торган урын (место на поле, где молотят хлеб). Кибән айағында қүwәтле су торадырыйы.

**кибән айағына суғу** *бәр.* игенне әвендә киптереп тормыйча сугу (молоть хлеб, не высушив в овине). Кибән айагына суғу бар ийе муклака утыртырлар ийе дә.

**кибән баш цығару** *тара.* кибән очлау (завершать стог, заканчивать укладку стога).

**кибән ташлау** *туб.-ирт. д.*, **кибән ыргыту** *яүшт.*, **кибән ултысыу** *төм.* кибән кую (метать стог, ставить стог). Ниде ултыстыгыс пуйыл кибән. – *төм.* Озон-озон сәнәкләр була кибән ырғыта тырған. – *яүшт.* Қанча кибән ташладығыс? – *тара.* Кибән ташлағалы кешләр кәрәк полар. – *тбл.*

**КИБӘЦ** *брб.д, том.д.*, **КИБӘЧ** *яүшт.* к.: **кәпәц 1**.

**КИБЕГҮ** *тара., брб.д.* күнегү, гадәтләнү (привыкнуть). Төс ташуға айағың кибектемә. – *тара.*

**КИБЕЗҮ** *т.я.-крш.* киптерү (сушить, высушивать). Судан чыккистан кибезәбез сүсне, кибезгәсен талкис була, талкыгис түwәбез.

**КИБЕН I** [*гар.*] *тбл.* кәфен (саван).

**КИБЕН II** [*фарс.*] *тмн.* к.: **кәбен 1**. Качан киләләр кибенгә, никах укырга, шунда китерәләр бирнә.

**КИБЕНЛЕ** [*фарс.* + *афф.* -ле] *срг.* никахлы (женатый). Ике кибенле кеше булмасын.

**КИБЕР** [*гар.*] *кузн., хвл.* тәкәббер, hавалы (высокомерный, горделивый). Үзе нигә дә килмәгән, кибер тагы. – *хвл.*

**КИБЕРЛӘНҮ** [*гар.* + *афф.* -лән] *кузн., хвл.* тәкәбберләнү (возгордиться, высокомерничать); чаг.: **белтәйү**. Ү йаныннан киберләнеп узып китә, керми. Биргән әйберенә алмый, киберләнә, кәбәм. – *хвл.*

**КИБЕРЛЕК** [*гар.* + *афф.* -лек] *кузн., хвл.* тәкәбберлек, hавалылык (высокомерие).

**КИБИ: киби чабу** *к.т.* ат чабышы (скачки на лошадях во время сабантуя).

**кибигә чығу** *дөб.* сабан туе көнне өй саен йомырка җыярга чыгу (сбор яиц в день сабантуя). Ат менеп чыгалар ыйы кибигә йәшләр.

**КИБИЛӘР** *к.т.* сабан туе алдыннан бер көн элек әйбер җыеп йөрүчеләр (сборщики подарков для сабантуя накануне этого праздника). Кибиләр буладыр ыйы, җаулық җийалар ийе, малайлар чаwып җөриләр ийе. Киби-киби җоморқа, Иләк белә җыwача; Мадийан белән сырача, Чығарығыз җоморқа, дип.

**КИБИТ** *к.т.* кибет (магазин). Кибитта сату сата қызы.

**КИБИТКА** *лмб.* дүрт почмагына таяклар утыртып, чаршау корылган тарантас (свадебная кибитка или повозка); чаг.: **кимә**.

**пич кибиткасы** *лмб.* к.: **қамақаш**.

**КИБИЧЛӘР** *блт.* сабан чәчүенә чыгар алдыннан атка атланып йорт саен йомырка җыеп йөрүче яшүсмерләр (подростки, участвующие в обряде сбора яиц накануне начала весеннего сева); чаг.: **кибиләр**. Киби, киби, биш күкәй дип, күкәй җыйып йөриләр ийе кибичләр.

**кибла** [*гар.*] *срг.* кыйбла (кыбла, юг):

**кибла йиле дә тигермәү** *срг.* җил-яңгыр тидермәү (оберегать, пылинки сдувать). Аwызкулы белән кош тоткан балам, бәхетсез бит, кибла йиле дә тигермицә карадым.

**КИБЛӘЙЕМ** *перм.* кимендә, аз дигәндә (по меньшей мере). Районға кибләйем утыз киламитыр булыр.

**КИБРӘН** [*гар.*] *том.д., тбл., тара.* к.: **кәперән.**

**к и б ү** (сохнуть, высыхать):

**келтерәп кибү** *каз.ар.*, **шөкөрдәп кибү** *к.т.* бик нык кибү – утын, печән һ.б. турында (сильно высохнуть, пересохнуть – о дровах и т.д.). Утыннарың келтерәп кипкән, әни. – *лш.* Бу песәлләр келтерәп кипкәлләр. – *дөб.* Келтерәп кипкән печәннәрне йаңғыр килеп җиткәнче кертик. – *мам.* Мә, кизитекләрең шөкөрдәп кипкәннәр, җылы көйө кийеп қуй. – *к.т.*

**КИБЫН** [*фарс.*] *күрш., карс.* к.: **кәбен 1.** Кибын укыттык. – *күрш.* Мәһәреңне тутырминча кибын бирмиләр иде. – *карс.*

**кибын күлмәге** *карс.* никахлашу күлмәге (свадебное платье, одеваемое во время бракосочетания). Кибын күлмәге кигезәләр акны.

**КИБЫНЛЫ** *тмн.* к.: **кибенле.**

**к и w ә н** *саз.я.* кибән (стог):

**киwән ташлау, киwән ултысыу** *саз.я.* к.: **кибән: кибән ташлау.** Киwәнне ун-унбиш моғолтан ташлайwс. Нице киwән ултыстығыс, йамқырға цақ. Киwән ултысқалы та алыс.

**к и г ә w е н** (овод):

**ат кигәwен** *тара.* бөгәлчән, сукыр кигәвен (слепень).

**КИГӘНҮ** *тбл., саз.я.* үч тоту, үч саклау (сердиться, затаить зло на кого-нибудь.). Кигәнеп йәшәмәйте, йақшы йәшәйте. – *тбл.*

**КИГӘҮ** *тбл.* янау (угрожать).

**КИГЕЗИТЕК** *карс.* к.: **пима 1.**

**КИГЕРМӘК** *төм.* каен кабығының туз астындагы катлавы (слой берёзовой коры, расположенный под берестой).

**КИГЕРТӘК** *туб.-ирт.д., брб.д.*, **КИГЕРТӘХ** *саз. я.* бугаз (горло). Кигертәгеңне сығарым. – *тбл.* Пала йеткесеп, эшләп, кигертәгемнән пултым. – *төм.* Тамағымның кигертәге аурып киткән. – *твр.*

**КИГЕЦЛЕ** *срг.* баштан киеп, билдән төймәләп куела торган алъяпкыч (передник, надеваемый через голову). Запун ателә, баулы тегел, кигецле, ул wахытта кигецле атәләр иде.

**КИГЕЧ: астан кигеч** *срг.* эчке күлмәк (сорочка, комбинация).

**КИГЕЧЛЕ** *трх.* алдан да, арттан да ябык һәм канатлы – алъяпкыч турында (покрывающий и спину, и грудь – о переднике). Кигечле алҗапма җүләдем.

**КИГИ** *лш.* тырнак (ноготь). Баланың кигисе җиткән.

**КИДӘН** [*фарс.*] *брб.д.* киндер (холст). Кидән йүңнән төгөл, лүннән.

**КИДӘРИ** *брб.д.* к.: **йага I, 6.**

**КИҖЕ 1.** *т.кам.-крш.* кызыл (красный). Базардан киҗе буйау алдым; **2.** *каз.ар., т.я.* кызыл төстәге мамык җебе (красная хлопчатобумажная пряжа). Киҗеләп суққан киндер. Киҗеләп суққан ашаулықларым әл дә тора. – *мам.* Қызыл башлы сөлгеләр суғарға киҗе ала торғаныйық. – *к.т.*

**КИҖЕК** *лмб.* к.: **кәҗәк.** Киҗек сугабыздыр бу ыстанда.

**КИҖЕ-КӨРЧИН** *мам.* кызыл яки шуңа якын төстәге җеп (красная или близкая к ней по цвету пряжа). Киҗе-көрчин алып суға торған ийек.

**КИҖЕТЕК** *мәл.* к.: **пима 1.** Киҗетегемнең төбенә салдырдым.

**КИЗӘГӘ** *брб.д.* баскыч (лестница).

**КИЗӘК I** *карс.* кизү (повальная болезнь). Айаклар аwырды, кизәк булган.

**КИЗӘК II** *брб.д.* кинәт, көтмәгәндә (вдруг, неожиданно). Кизәк әйткәле йарамайты өүләмнә.

**КИЗӘКИ** *мәл.* к.: **кәзеки.** Кизәки суктык кенсәтә.

**КИЗӘНКӘ** [*гар.*] *әстр.* к.: **кәзәнкә 2.**

**КИЗӘҢКЕ** [*гар.*] *стрл.* **1.** к.: **бүлмәч 2.** Кизәңкедән ашларын китерә; **2.** к.: **кәзәнкә 2.** Кизәңкедә утыра бер самаwырым.

**КИЗӘРҮ 1.** *лмб., кузн., хвл.* кибү, кибеп кату – камыр, ипи турында (засохнуть – о тесте, хлебе). Камырның өстә кизәргән иде. – *хвл.* Әпәйне күп кисмә, ашалмый, кизәрә генә. – *лмб.*; **2.** *кузн., лмб.* кибеп яргалану – җир турында (засохнуть, растрескаться – о земле). Йир кизәргән берче, йарылып беткән. – *кузн.*

**КИЗӘТКЕ** *брб.д.* к.: **кисеркә.** Кизәтке көргән дә қорыққан.

**КИЗӘҮ** *трх., лш.* киледә төю (толочь в ступе). Йарма кизәп чығыйм әле. – *трх.* Киледә тары кизәп эштән чығадырыйық. – *лш.*

**КИЗДЕК** *мәл.* к.: **пима 1.** Киздегемне тартып салдырдылар.

**КИЗЕ** *кузн., срг.* киҗе (хлопчатобумажная пряжа).

**КИЗИТЕК** *т.кам.-крш.* к.: **пима 1.** Кизитегенең асты тишелгән булған.

**кәлүш кизитек** *т.кам.-крш.* к.: **галуш 1.**

**КИЗҚАТА** *нгб.-крш.* к.: **пима 1.**

**КИЗЛӘҮ 1.** *нрл., трх., мәл., чпр., карс., т.я.-крш.* чишмә (родник, источник, ключ). Шалый кизләү чығып тора түгәрәк. – *нрл.* Тау астында кизләү бар, башта анда өч кизләү бар иде. Кизләү генә булған элгәре анда бурасыз. – *трх.* Йар буйында бар бер кизләү, кизләү сuwына китә гewәндә бели. – *т. я.-крш.*; **2.** *нрл., трх.* чишмәдән ағып килә торган елгачык (маленькая речка, вытекающая из родника). Аланбашыннан кизләү буйынча ағып бара икән җомочқалар. – *нрл.* Кизләү чогорында атасы бар диләр андатраның. – *трх.*; **3.** *к.т.* чишмә суының җәелгән җире (залив от родника). Аққатыр кизләwе, чишмәсе дә булған аның, шишмә кизләүгә чыға, чығып җәелгән җире кизләү була.

**КИЗЛӘҮЛЕК** *кмшл.* сазлыклы (болотный). Түбән Норлатта бар ийе кизләүлек.

**КИЗҮ 1.** *хвл.* чират (очередь). Киленнәр кизү белән эшләгәннәр; **2.** *минз.* көтү чиратын исәпләү өчен билгеләнгән берәмлек (единица измерения для определения очерёдности пастьбы стада). Ике сарық бер кизү, бер сыйыр бер кизү була.

**ил кизүwе** *мәл., минз.* бер үк вакытта күп кешеләр авырый торган авырулар – грипп һ.б. (эпидемия – грипп и проч.). Ил кизүwе дә қаба, қайсы wахыт озақ йатам. – *минз.* Ил кизүwе булгандыр сиңа. – *мәл.*

**кизү бүлмә** *глз.* к.: **бүлмәч 2.** Монда булган кизү бүлмә, кәҗәңкә такта белән бүленгән.

**КИЗҮЛӘП** *трх., чст.* чиратлап, чиратлашып (по очереди). Мәдрәсәнең пичен кизүләп өйдән салам алып килеп үзебез йаға идек. – *трх.* Идәнен кизүләп йуwа идек. – *чст.*

**КИЗҮЛӘҮ** *нокр., глз.* аш-су пешерү, йорт эчендәге эшләрне башкару (готовить пищу, выполнять домашнюю работу). Кизүләмәчен идә кешесе дә йуқ. Әллә тыңнатасы (концертны), әллә чығып кизүләсе? – *глз.* Ашамалар бешерә, саумар қуйа, әзән себерә – ул кизүли була. Эч кен кизүләдем туйда. – *нокр.*

**КИЗҮЛЕК** *глз.* көндәлек, эшкә кия торган – кием турында (рабочая, повседневная – об одежде). Кизүлек кийем.

**КИЗҮЧЕ** *нокр.* өй эшләрен эшләүче (выполняющий домашние работы, рабочий). Кизүче йуқ, давай, қыз ал, дигәннәр әтиләр.

**КИИК** *брб.д.* киек (дичь).

**КИИП** *тбл.* кием (одежда). Бир қысның ақ қуш киибен йигит алып қайтты үйгә.

**КИИРТМӘЦ** *яүшт.* җыерчык (морщина). Пер кииртмәцең йоқто пидеңтә.

**КИИС** *твр.* киез (войлок, кошма). Бичәләре киистән әү (өй) қылды.

**КИЙ** *срг.* кое (колодец). Кий казытканнар йыртларында.

**цүлекмәле кий, цүлекмәле кийы** *срг.* сиртмәле кое (колодец с журавлем).

**КИЙАМАТЛЫК** *чст.-крш.* к.: **қыйаматлық**. Алпан да тилпән җерегә Айу балаларына ла килешә, Айаклар тибеп бийергә Кийаматлыкларга килешә (*туй җыр.*).

**кийаш** *миш.д.* кояш (солнце):

**кийаш иңеше йак** *чпр.* көнбатыш (запад). Ул җакта кийаш иңеше инде безнең, кийаш иңеше җакта артмый ызбалар, үрцеми.

**КИЙӘ** *т.я., лмб., кузн.* берәр нәрсәнең яки берәр кешенең кадерен белмәүчелек, ризасызлык нәтиҗәсендә җәзасын күрү, бәлагә төшү (наказание, несчастье как результат недовольства, неуважительного, непочтительного отношения к кому-либо или чему-либо). Ипи, тозно қәдерсезләргә җарамый, қызым, кийәсе төшмәсен. Әйберне қәдерсез итсәң, кийәсен күрәсең, ди. Җәш чағында ирен бик қәдерсез итте, саннамады, қартайғач үзе дә күрә инде кийәсен. – *к.т.* Кийә сүләдем, кийә итендем, Чабата кидем чүплектән генә. Кийә сүзләрем килде каршыма, Чабата кидем чүплектән генә (*бор. җыр.*). – *лмб.*

**КИЙӘВЕН** *лмб.* к.: **күгәwен**.

**КИЙӘЛӘНҮ** *т.я.* кылану, кадерен белмәү, канәгатьсез булу (быть недовольным тем, что есть; хулить то, что есть). Кийәләнмә шулхәдәр, әллә ни күрерсең. – *к. т.*

**КИЙӘЛЕ** *минз.* зыянлы, борчу яки бәла китерүче (вредный, вредоносный). Кийәле кеше булып чықтың әле син.

**КИЙӘЛЕК** *т.я., каз.ар., каз.ар.-крш., кмшл., бгрс.* к.: **кийә**. Бала-чағадан кийәлек күрә ди бит, баланы итеп ырғытқан да. – *каз.ар.-крш.* Барны йуқ, дип әйтүwебезнең кийәлеге җитте. Инде мыңардан да китсәң, кийәлеген күрерсең дигәннәр. – *бгрс.* Кийәлек җитте аңа: ирне саннамады, ирсез қалды. – *к.т.* Бала кийәлеге бирде аңа Ходай: баласыз қалды. – *дөб.* Әллә ни сөйләп кийәлек китереп утырма. – *блт.* Малның қәдерен белмәсәң, кийәлеген күрәсең: йуқлыққа қалырсың. – *лш.*

**КИЙӘНӘКЛЕ** *глз.* тигәнәкле (репейный, терновый). Гаптрахман йафрақ кийәнәкле булып үсә.

**к и й ә ү** (жених, муж):

**кийәү бала** *туб.-ирт.д.* кияү (жених). Кийәү баланы йастыққа сикертәде. – *төм.*

**кийәү бәлмән** *тбл.* кияү қыз куенына керер алдыннан егет ягында уздырыла торган мәҗлес (застолье в доме жениха перед первой брачной ночью). Кийәү бәлмән титләр, кийәү кермәстән алтта кийәү цайы эцертәләр, кийәү бәлмән тип, ул үсенеңке йақыннарынта булаты гуй.

**кийәү белем** *нокр.* к.: **киймак: кийәү киймагы**.

**кийәү булгыц** *срг.* кияү буласы кеше (будущий жених). Кийәү булгыцым белән кабаг аша гына сүләшә идем.

**кийәү бүләгенә җөрү** *бәр.* яшь кияү килгән йортка керү; гадәттә кияү бүләк бирә торган булган (посещение, особенно детьми, дома, где гостит молодой жених; обычно посетителям давали гостинцы). Андары кийәү бүләгенә җөрөр ийек, эрпет чикләwеге, қуйан буғы, перәллекләр бирерләр ийе.

**кийәү җийу** *лмб.* кияүгә чығу (выйти замуж). Кызымның йулдашы вайнадан қайтмады, йаңыдан кийәү җийды.

**кийәү җулдашлары** *әстр., м.-кар.* к.: **кийәү сақчы**. Җегет җийа үзенә кийәү җулдашлары. – *м.-кар.*

**кийәү итеге** *дөб.* аеруча яхшы хромнан, бик нык ялтырап тора торган йомшак күн итек (особенно мягкие и блестящие хромовые сапоги; обычно в таких сапогах красовался жених, молодой зять).

**кийәү қайтармасы** *каз.ар.-крш.*, **кийәү қайтармасы** *чст.-крш.* қыз ягында үткәрелә торган туй мәҗлесе: керәшеннәрдә гадәт буенча туй башта егет ягында була; аннан соң билгеләнгән көнне егет ягы қыз ягына каршы туйга бара (ответный пир на стороне девушки, устраиваемый после свадьбы, проведённой на стороне жениха – у кряшен). Җегет җағы қыз җағына қаршы туйга баруны кийәү қайтармасы диләр. – *каз.ар.-крш.* Әле генә кызларын биргәннәр ийе бит, кийәү қайтармасына кызларын җәшкәннәр, шунда киткәннәр. – *чст.-крш.*

**кийәү қамчысы** 1. *перм.* ишек бавын тотучыларга кияү эчерә торган эчемлек (напиток, которым угощает жених родственников невесты при первом своём посещении дома невесты); 2. *лш., минз., каз.ар.-крш.* бака яфрагы (подорожник); 3. *кргл., бгрс.* бүлбеле кияү камчысы, кияү камчысы (зопник клубненосный).

**кийәү қатламасы** *нрл.* зөфаф кичәсенә яшь кияү белән яшь киленгә атап махсус пешерелгән ике кечкенә икмәк (пара маленьких хлебцов, специально испечённых для жениха и невесты в день их первого свидания). Кийәү қатламасы кийәү кергән көннө үзенә берне дә киленгә берне бирәләр атап.

**кийәү қотлоғо** *туб.-ирт.д.* яңа төшкән киленне мәҗлестә күрендергәч, аны котлап җыелган

акча; киленгә тапшырыла (деньги и подарки, даримые тогда, когда происходит обряд открывания лица только что переселившейся в дом жениха невесты; собранное вручается невесте).

**кийәү күлмәге** *нрл.*, **кийәү күлмик** *нокр.* кияүгә кыз бүләк иткән күлмәк (махсус тегелгән һәм чигелгән) (специально сшитая и вышитая рубаха, даримая жениху невестой ). Әни оста булған бик, кийәү күлмәге теккән сәдәфләп, чигеп, җитен сүсеннән генә эшләнә ул, җалтырап тора. – *нрл.* Кийәүгә кийәү күлмик бирәләр қыз йақ. – *нокр.*

**кийәү күрендерү** *срг.* кияүнең беренче мәртәбә кызның туганнары белән очрашуы; бу мәҗлестә кияү кызга чәкчәк бүләк итә (званый обед на стороне девушки, где происходит встреча жениха с родственниками девушки; при этом жених дарит девушке чакчак). Кийәү күрендерү була иде, нәсел-нәсәбе бар да килә, кыз цигелдәг ала кийәүдән, аннан кийәүне күрендерәләр, падарка бирәләр барысы да, күмәцли барганда кийәүне күрендерәләр.

**кийәү сақчы** *нокр.* кияү егете (дружка, шафер). Кийәү сақчы кисә чәкчәкләрне.

**кийәү сый** *әстр.* қыз ягындагы туй (свадебное застолье на стороне девушки).

**кийәү табагы** *әстр.* никахка китерелә торган күчтәнәч тәм-томнар (сладости-гостинцы, преподносимые к столу при обряде бракосочетания).

**кийәү табақ** *том.д.* қыз ягында кияү хөрмәтенә оештырылган мәҗлес (угощение, организованное в честь жениха и его родственников, которые в ответ на угощение кладут деньги и др., передаваемые потом невестке). Кийәү табаққа барасың икән, нәрсәгә осталығың бар, шуны пешереб аппарасың, кийәү йақларны сыйлайсың, кийәү йақлары ақца салалар, ул киленкә була.

**кийәү тевене** *лмб.* элекке туй йоласы: егет ягыннан қыз ягына күмәч белән килүче кодачалар артыннан қызга тапшыру өчен җибәрелә торган төен – егет бүләге (старинный свадебный обряд: узелок с подарками жениха, посылаемый им невесте через своих родственниц).

**кийәү урыны** *лш., каз.ар.-крш.* кияү белән қызга зөфаф киченде җәелгән урын (специально приготовленная постель для молодых в первую брачную ночь). Кийәү урыннары җәйәдерийең, кийәү аңар да ақча бирә. – *лш.*

**кийәү чәйе** *лш.* кияү беренче тапқыр қыз янына килгәндә уздырыла торган зур булмаган мәҗлес (небольшое застолье, организованное при первом приходе жениха в дом девушки).

**кийәү чиреге** *дөб.* қыз куенына керергә килгән кияүнең күчтәнәч әчемлеге (напиток, привезённый женихом в первую брачную ночь родственникам невесты). Кийәү килгәч, берсе шешә бирә кийәүгә, кийәү шешәгә ақча тыгып җибәрә, хәзер бер литырлық ақча тыға, менә шуны кийәү чиреге диләр.

**кийәүгә бару** *лмб.*, *яүшт.*, **кийәүгә җыйылу** *лмб.*, **кийәүгә керү** *м.-кар.*, **кийәүгә чыгу** *лмб.* йортка керү (стать примаком). Бик кеңел калды ылыма: кийәүгә барды. – *лмб.* Кийәүгә барды игенче бичәгә. – *яүшт.* Солдаттан килде дә күреш катынга кийәүгә җыйылды ылым, бик кеңелем калды үзенә. Хатынына да бармый, кийәүгә дә керми, йери шул кийе.

**КИЙӘҮНӘӘР, КИЙӘҮНӘГӘР** *перм.* туйда мәҗлесне алып баручы, җырга һәм уен-көлке сүзләргә оста кеше (тамада, ведущий на свадьбе); чаг.: **арғош, кейәү: кейәү сақчы**. Кийәүнәгәр була җырға оста кеше, табынны ача, һәр ризыкны башлый, һәрберсенә җыр җырлый.

**КИЙӘШӘННӘ** *әҗе.* к.: **айбағар**. Партугына канфитлар, кийәшәннә куйып авылга цыга.

**КИЙЕЗ 1.** *тя., каз.ар.* аска җәяр өчен мамык белән сырылган сырма, көрпә (матрас). Мамық алдым, сырасы ғына бар кийезне. – *дөб.* Қорама җасап, балаларга җәйеп җатырға кийезләр сырдым. – *к.т.* Бар, астыңа кийез апчығып сал. – *лш.*; **2.** *минз.* йон җептән сугып баскан – шәл һ.б. турында (о шерстяном платке и т.п., сотканном и свалянном в домашних условиях). Кийез шәл бәйләдек, йонно эрләп, суғып шәлләр бәйлиләр ийе.

**ас кийезе** *бәр.* аска салып ята торган киез яки көрпә (войлочный или стёганый матрас). Ас кийезе киндердән булды, өс җурғаны киндердән булды ул wахытларда.

**КИЙЕЗДЕК** *бөре.*, **КИЙЕЗҚАТА** *перм., минз.* к.: **пима 1**.

**КИЙЕЗМӘКЛӘНУ** *тмн.* киезләнү, киезләнеп чуалу – чәч, йон турында (сваляться, спутаться – о волосах, шерсти). Чәчем кийезмәкләнгән, тарый да алмыйм.

**КИЙЕК I 1.** *перм., тбл., брб.д.* к.: **моши**; **2.** *перм., төм.* болан (олень). Безнең йаланда кийек була қый, көз көнө йуқ була. – *перм.*; **3.** *нрл.* тычкан (мышь). Кийек тотмый әле мачы.

**кыр кийеге** *кргл.* к.: **моши**. Қыр кийеге булғалый безнең йақта.

**олы кийек** *нокр.* к.: **йалман 1**.

**урман кийеге** *кргл.* к.: **кийек I, 2**. Урман кийеге мөгезсез болан ул.

**КИЙЕК II** *минз., стрл.* чәчмичә, үзлегеннән, кыргый рәвештә үсеп чыккан – арыш, бәрәңге, киндер һ.б. (взошедший сам по себе, дикий – о растениях); чаг.: **азау 2**. Ачлық йылның икенчесендә кийек арышлар чықты, аны урып суқтық та әле. – *минз.*

**кийек тарма** *стрл.* к.: **мошко I: кыргый мошко**. Кийек тарма тармаклы була, киндерашы wаграк була. – *стрл.*

**КИЙЕМ I** *т.я., мам., нокр., хвл., т.я.-крш.* пар (пара чего-либо). Ике кийем чиләк. Биш кийем себерке бәйләдем. – *к.т.* Ике кийем башмагым, Ничек кийеп туздырырмын?.. (*бор. җыр.*). – *т. я.-крш.* Ничә кийем биннек алып қайттық. – *нокр.*

**к и й е м II** (одежда):

**бөтөн кийем** *минз.* қыз ягыннан егет ата-анасына бүләк ителә торган кием (баш киеме, өс киеме, аяк киеме) комплексы (комплекс одежды, преподносимый родителям жениха со стороны девушки). Қыз йагы мамық шәлләр, фырансуз күлмәк, читек-галуш әбиләргә-бабайларға, бөтен кийем дигәннәр. Әйтик, бабайға түбәкәй, күлмәк, камзул, ыштан, читек-калуш, шушы бөтөн кийем

була, әбигә фырансуз йаулық, йефәк шәл озон чәчақлы, затлы күлмәк, читек-кәwеш була, байлығына қарап бирешкәннәр. Бawырсақ белән бергә бөтен кийем дә килә.

**КИЙЕМ-ТОТОМ** *т.я., кузн., хвл.*, **КИЙЕМ-ТЫТЫМ** *карс., чпр., мәл., кузн., хвл.* к.: **кейенцек**. Бик күп кийем-тотом да, сөлгө, әскәтерләре дә киленнең. Кийем-тотом да күб апқайтқан. – *к.т.* Үзенең куйы-штыларын, кийем-тытымнарын алып киткән. – *карс.* Ашаргабыз, эцәргәбез бар, кийем-тытымыбыз бар. – *чпр.*

**КИЙЕМЧЕ** *нгб.-крш.* к.: **кейемче**. Бөрмәле чикмән тектерә торған ийек, үзебез басар ийек, кийемнәр таба торған ийек тектерергә. Минем тәтәү кийемче буған.

**КИЙЕН** *минз., стрл., мәл., брб.д.* к.: **кире 3**. Бардым Менәwәрләргә сездән кийен. – *минз.* Аннан кийен алып кердем дә... – *стрл.* Шоннан кийен эвенә кереп китте. – *мәл.* Миннән кийен иге қатын алды. – *брб.д.*

**КИЙЕНДЕКЛЕ** *влгг.* яхшы киенгән (хорошо одетый). Кийендекле кеше утырды, йахшы галстуклы.

**КИЙЕНМӘ** *баст.* к.: **кейенцек**. Аларда элгәреге кийенмәләр бардыр.

**КИЙЕНЧЕК** *минз., стрл.* төп киемнән тыш матурлану, бизәнү өчен булган әйберләр, күпшы киемнәр (предметы украшения и наряды сверх основной одежды). Ир әйбәт булса, хатын кийенчекле була. – *стрл.*

**КИЙЕНЧЕКЛӘР** *хвл.* яхшы, матур киемнәр (наряды, нарядная одежда). Аның кийенчекләре күп. Катынына кийенчекләр алып кайткан, диләр. Корчагына кийенчекләр тегә.

**КИЙЕНЧЕКЛЕ** *хвл.* **1.** кием-салымы яхшы, матур һәм күп булган, кием-салымлы (имеющий много нарядной одежды). Йәш киленнәр кийенчекле була; **2.** матур итеп киенгән (нарядный, нарядно одетый). Кийенчекле-кийенчекле кызлар үтеп китә. Бик кийенчекле генә бер кыз килгән иде.

**КИЙЕРГЕ** *тара.* агач кайрысы (древесная кора).

**КИЙЕРЕМ** *минз.* киң итеп – ачык ишек турында (широко – об открытой двери). Ике тирәдә кийерем ачық.

**КИЙЕРТЛӘҮ** *себ.* к.: **кийертү**. Кийертләп өй салаты. – *тара.*

**КИЙЕРТЛЕ** *т.кам.-крш.* кайтармалы (отложной). Ирләргә тегәдер ийек туры җаңа, кийертле җаңа әле чыкты.

**КИЙЕРТМӘ** *туб.-ирт.д.* бура (сруб). Кийертмәсе бар, өц-түрт әрәт.

**КИЙЕРТҮ** *твр., тбл.* к.: **киртмәләү**. Өй гийертү.

**кийес** *себ.* киез (войлок, кошма):

**кийес калуш** *туб.-ирт.д.* к.: **галуш 1**.

**КИЙЕТ 1.** *әстр.* кияү ягындагы хатын-кыз туганнарга бүләк – яулык, тастымал, ислемай һ.б. (подарки – платок, полотенце, духи и др., преподносимые родственницам жениха со стороны девушки). Кийет әзерлиләр туйға; **2.** *әчк.* егет ягыннан кызга бирелә торган кием-салым (одежда, преподносимая невесте со стороны родственников жениха); **3.** *әстр.* бүләк (подарок). Әммесенә дә кийетләр бирәләр.

**КИЙЕТЛӘҮ** *әстр.* бүләкләү (одарить, преподнести подарки). Кийәү йағында барын кийетләгән. Қоры чығармый, кийетләп чығара.

**КИЙЕШ** *каз.ар.-крш.* килеш (в виде). Чи кийеш ашый.

**КИЙЛӘК** *тара.* к.: **көйләк**.

**йабынцақлы кийләк** *тара.* итәгенә генә түгел, якасына да бала итәк тотылган күлмәк (платье с оборками не только на подоле, но и на воротнике и т.д.). Пөрмәләренә қыйулар салып тисма мән, йабынцақлы кийләк полған, иге-өцкәцәйен тә қылатылар, намас уғыса йабырылып тораты. Йабынцақлы кийләкнең йағасынта да йабынцақ булыпты.

**киймак** *миш.д.* коймак (оладьи):

**алма киймагы** *әҗе.* майда пешерелгән кабартма (пончик, жаренный в масле). Кызларны цагыралар шул алма киймагы белән (сыйларга).

**йымырка киймагы** *срг.* сөткә куырылган йомырка (омлет). Йымырка киймагын сет белән пешерәләр.

**кашык киймагы** *срг.* катыкка изелгән арпа оны коймагы, табага кашык белән салына (оладьи, тесто для которых замешивается на катыке и из ячневой муки и кладётся на сковороду ложкой). Кашык киймагын пешерәләр, катыкка арпа ынныннан пешерәләр. Катыкка арпынынннан атлийлар, салалар аш серкәсе, җылыга куйалар, күперә ул, кашык белән табага салалар, таба майланган була, кан′арлата ашыйлар, майга манып мытырдатып ашыйлар.

**кийәү киймагы** *срг.* кыз белән кияү хөрмәтенә түгәрәк һәм матур итеп пешерелгән вак төче коймак (красивые и небольшие оладьи из пресного теста, специально приготовленные для дочери и зятя). Кийәүләр киймагы белен кебек цецегә йасыйлар бик түгәрәк, матур итеп йасыйлар, кийәү белән кызны йәшкәндә киймак куйалар, уртасына май куйалар, манып ашыйлар. Кийәү белән кызга вак киймак куйалар үwеп, чогор белән май куйалар, кияү белән кыз киймакка акца куйып цыга.

**цеце киймак** *срг.* к.: **кийәү киймагы**.

**КИЙНОК** *клм.* к.: **көйләк**. Әр кийногы қән қуй.

**КИЙРӘ** [*рус.* гиря] *тбл.* үлчәү (весы).

**КИЙУ** *тмн., м.-кар.* су сибү (поливать). Агарут кийарга цыгам. – *тмн.* Кийарны гына кийарым, үзгәсе тырыр. Җимешләр бар, шуларны кийгалаклим. – *м.-кар.*

**КИЙҮК** *глз.* кебек (как, вроде). Син кийүк мин дә.

**КИЙЫНЧЫ** *карс.* кыйный торган (бьющий, имеющий привычку бить, колотить). Аның ире кийынчы була.

**КИК: кик тоту** *тбл.* үч тоту, үч саклау (затаить злобу на кого-нибудь).

**КИКА** *лмб.* чәч толымы (коса). Чәч эргән ике кикадан.

**КИКӘРИ** *дөб.* к.: **күкәри**. Суғыш wақытында кикәри җыйдық.

**КИКЕЛДӘҮ** *перм.* көлү, кеткелдәү, хихылдау (смеяться, хихикать).

**КИКЕРИК** *бгрс., кргл., злт.* тел – шәл читендә (зубчики по краям каймы пухового платка). Сыйырны сауганчы бер кикерик булса да бәйлим. – *бгрс.* Шәл қалын, кикерикләре әре былды. – *злт.*

**КИКЕРТӘК** *тбл.* к.: **кигертәк**. Кикертәк өсөләп параты, өн цықмайты.

**КИККАЗ** *лмб., хвл.* киек каз, кыр казы (дикий гусь).

**кикказга тезү** *лмб.* көлтәләрне җилләтеп алу өчен аркылы-торкылы салып бару (складывание снопов для сушки).

**КИКЛАНУ** *т.я.-крш.* кылану (кокетничать). Кикланалар инде җәш катын-кыз.

**КИКНАТУ** *тмн.* очкылык тоту (икать).

**КИКРИК I 1.** *минз.* к.: **кикерик**. Шәлләр бәйлидер ийем кикрик-кикрик җасап; **2.** *т.кам.-крш.* алъяпкыч күкрәгенең өске читендәге телләр, киртекләр (зубчики на верхней кромке нагрудной части передника).

**шәл кикриге** *злт.* к.: **кикерик**. Кикериген шәлнең бәйләп петереп барам.

**КИКРИК II** *к.т.* кикерек (отрыжка).

**кикриккә килү** *к.т.* к.: **кикрик II**. Майлы әйбер ашарга җарамый, гел кикриккә килеп тора.

**КИКРИКЛӘҮ** *минз., т.кам.-крш.* тел, киртек ясау (делать, вязать зубчики). Кикрикләгәч бәк матур буладыр ыйы шәл. – *минз.* Кикрикләнгән борыңғы алҗапқычы тора әле әнинең. – *т.кам.-крш.*

**КИКРУК** *кузн.* кикрик (гребешок – у птиц). Бак, бак, чәченә бак: әмән кучат кикругы.

**КИКЧА** *эстр.* өчпочмаклап киселгән һәм майда пешерелгән камыр ашы (тонкий хворост треугольной формы).

**КИКЫЛДАУ** *лмб., мәл., клд.* к.: **кикнату**. Тагы ашагым кели башлый, кикылдарга тытынам. Ик ай йаттым болнисада кикылдап кына. – *клд.* Анан сың ылан кикылдый иде, бусагага бәйләп куйалар ийе, чырмап шалай йаткызалар иде дә соко эт уздыралар әпәйгә алдаб-алдаб ике йакта ике кеше, эч мәртәбә уздыралар и кикылдawы бетә иде. – *лмб.*

**КИЛ..., КИЛ** [*морд.*] *м.-кар.* теләсә ничек (нинди, кем, ни); кем (нәрсә, ничек, нинди) булса да (хоть, или, хоть как, хоть кто, хоть что). **Кил сетләп пешер, кил итләп пешер ашны.**

**КИЛА** [*рус.* кила] *хвл., карс.* бүсер (грыжа). Иренен киласы бар, кила катны әтәбез анарга. – *карс.*

**КИЛАУСА** [*рус.*] *стрл.* к.: **йөгөртмә II**.

**КИЛӘЙ** *минз.* к.: **кийеш**. Түгәрәк киләй бирәләр ийе. Җылы киләй эч чәйеңе.

**КИЛӘК: умарта киләге** *лш., чст.* урманда умарталык өчен бүлеп алынган урын (пасека, место для пасеки). Чумар умарта киләге дигән җир бар, туқсан баш умартасы булган бабайның. – *лш.* Умарта киләгенә барган йулда зират бар. – *чст.*

**КИЛӘКЛЕК** *чст.* куаклык, вак агачлык (кустарник, полесье); чаг.: **бүләк II**. Берлегән киләклектә күп була.

**КИЛӘНДЕРҮ** *мам., блт.* шатландыру, рәхәтләндерү (дать повод или возможность радоваться, наслаждаться). Киләндердег инде кешене. – *блт.* Эшләп кемне киләндергәнең бар, җил қуwып җөрисең. – *мам.*

**КИЛӘНҮ** *нрл., мам., трх.* кинәнү, рәхәтләнү (наслаждаться, блаженствовать). Киләндем әле килен йуқ чақта. – *трх.* Укул қадаса, киләнеп җоқлыйм дий. Киләнеп ашыйлар сыйырлар кукурузны. – *мам.* Эшләмәгән эш қалмаған, киләндергән төш қалмаған. – *нрл.*

**КИЛӘҢ** *брб.д.* бөтенләй, тулысынча (совсем).

**КИЛӘП 1.** *нгб.-крш.* борынгы озынлык үлчәү берәмлеге: ике якка сузылган кулларның озынлыгына тигез (старинная мера длины, равная расстоянию между концами вытянутых в стороны рук); чаг.: **қара I**. Бистәр бер киләп булыр инде; **2.** *кузн.* киндер җебен үлчәү берәмлеге (единица измерения холщовой нити).

**киләп салу** *кузн.* киләп сару (сновать). Ни киләп салып йөрисен, эшең булмаса, мин сиңа эш табыйым.

**КИЛӘПЛЕК** *каз.ар.-крш.* куаклыклар арасындагы ачык урын (открытая местность среди кустарников); чаг.: **айаз 1**. Киләплекләрне чаба торғаныйым, көлтәлийем дә печәнне, апқатайым.

**КИЛБӘТ** *перм.* мичнең моржасын балчыктан ясаганда эченә куела торган калып, форма (деревянная колодка, форма, оставляемая внутри печи при сложении трубы глинобитной печи). Килбәт қуйабыз ағачтан (моржаны балчыктан төеп чыгарганда).

**КИЛГА** *чст.* **1.** колга, юан булмаган озын агач (жердь, шест); **2.** киртә (ограда из жердей).

**КИЛГЕН** *баст., лмб., кузн., карс., себ.*, **КИЛГЕНЧЕ** *перм.* читтән килгән кеше (неместный человек). Ул килген вит, мындагы тегел. – *карс.* Безнеке чебеш тә йуқ, без килгеннәр вет. – *лмб.* Килгеннәр бире күб иде. – *баст.* Бу килген тужы. Бу эшләпалылар килгеннәр вет. – *кузн.* Алар килгенче қый.

**КИЛЕК** *туб.-ирт.д.* к.: **көйләк**.

**әҫ килек** *туб.-ирт.д.* эчке күлмәк (комбинация, нательная рубаха).

**КИЛЕМ I** *тмн.* төшем, файда (доход, польза). Кайсылары машинада эшләде, аларга килем бар.

**КИЛЕМ II** [*удм.*] *глз.* к.: **мошко I, 1**. Мин белдектә килем чәчкәләмәделәр. Килем орлоған гриҗа булғанда қайнатып эчертәләр.

**КИЛЕМ III: сүз килем(ен)нән** *баст.* мәсәлән (например).

**килен** (сноха, невестка):

**йәш килен мамыгы** *кузн.* туйның икенче көнендә үткәрелә торган хатыннар мәҗлесе; бу мәҗлескә килгәндә, гадәттә, төрле-төрле ашамлыклар алып киләләр (званый обед, устраиваемый для женщин на второй день свадьбы; приглашённые обычно приносят с собой пироги и др. гостинцы).

**килен катыгы** *стрл.* килен төшкән җирдә җыелган бала-чаганы катык белән буяу гадәте (обычай, согласно которому детвору, собравшуюся у ворот жениха встречать невестку, мажут катыком). Килен төшкәндә бала-чаганы катык белән буйыйлар.

**килен керетү** *т.кам.-крш.* чиркәүдә никахлашкач, киленнең кияү йортына кайтуы (приезд невесты в дом жениха после бракосочетания в церкви). Җегет өйөнә туйда килен кертәләр, кызның ике иптәше була җанында.

**килен күренеше** *дөб.* егет өенә төшү белән, килен тарафыннан каенанага бирелә торган бүләк (подарок свекрови, преподносимый невестой сразу после переезда в дом жениха). Җаулыкмы, күлмәкме килен, төшүгә, қайнанага бирә, килен күренеше шул була.

**килен сөйә бару** *эчк.* к.: **кыз: кыз күрү**.

**килен цайы** *брб.д.* килен күчеп килүгә була торган мәҗлес (чаепитие, устраиваемое сразу после переезда невесты в дом жениха). Киленне алып килгәннән соң, килен цайы эцерәләр, пөтөн күршеләр, тойда болған, тойда болмоғон, пөтөнөсе ақца сала, пүләкләнеп паралар.

**килендәш** (сношенница):

**икабыс килентәш** *тара., тбл.* килен-киленд әшләр, ике килендәш (две сношенницы). Килентәш пулғайныҡ аташым Нәписә ман, икабыс килентәш пөлтыҡ. – *тара.*

**КИЛЕН-ҖӨРӘМӘТ** *перм.*, **КИЛЕН-КИРТЕК** *минз.* килен турында түбәнсетеп әйтү (уничижительное выражение о снохе). Килен-җөрәмәт бар, бер килеп тә қарамый. Килен-киртекләр дә йырақтан килгән.

**КИЛЕШҮ I** *мәл., чпр., чст.* уңу, булу (уродиться, дать хороший урожай); чаг.: **ашқыну 1**. Быйыл бәрәңгем дә килешкән иде. – *мәл.* Бик килешә иде бу җирдә тары. – *чст.*

**КИЛЕШҮ II 1.** *нокр., глз., перм.* ошау (нравиться). Килешәме атым? Умырзайа (җыры) миңа килешә. – *нокр.* Ашаң қоймагын, килешмимени? Килешеп булмый кешегә. – *перм.*; **2.** *блт.* охшау (быть похожим, походить). Нәкъ мәйеткә килешә икән (төсе, чырае).

**КИЛЕШҮ III** *трх.* кыз ябышып чыкканда, никах укыту, мәҗлес уздыру кебек йолаларны башкарырга риза булу (согласиться исполнить обряды бракосочетания при уходе девушки убегом). Җәш бабаң җаңға Хисамеддин бабаң барды килешергә, ул килешмәде, килешми хәлләре җуқ дип, җизни килеште аннары.

**КИЛИМ** [удм.] *глз.* **1.** к.: **мошко I, 1; 2.** к.: **киндераш 2**. Килимне ашайлар.

**КИЛКЕННИ** *чст.* **1.** беркөнне, бервакыт (однажды, в одно время). Килкенни салган идек бәрәңгене, сywы да килкенни булды; **2.** көн буе (целый день). Тәненнән бөтен килкенни су агып тырды анын.

**КИЛӨК** *туб.-ирт.д.* к.: **көйләк**.

**ир(ән) килөк** *туб.-ирт.д.* ирләр күлмәге (мужская рубаха).

**эц килөк** *туб.-ирт.д.* эчке күлмәк (нижнее, нательное платье, комбинация).

**КИЛ'ОКАЙ** стрл. к.: **қолқай**.

**КИЛСАП** *мам., шрл.* к.: **келисап**. Киндерашны килегә салып, килсап белән тейәсең. – *шрл.* Житенне талқыдыҡ, дүртәр килалы килсап белән төйәйек сусне. – *мам.*

**КИЛТӘ** [*рус.*] *т.я.* филтә (фитиль). Ылампы килтәсе. Ычқырға бишле килтә қуйарға да җарый. – *к.т.*

**КИЛҮ** *миш.д., перм.* кайту (приезжать, возвращаться, вернуться). Ире ороштан килде. Куйларыгыз килдеме? – *кузн.* Тенә килдем каладан. Килен әле генә килде эштән. – *лмб.* Кетү килә. – *тмн.* Нәк килми атаң үгә? – *срг.* Көзнөчтәге малай суғыштан ранни булып килде. Мин унтуғызынчы йылны киттем ийе, килдем йегерме икенче йылны. – *перм.*

**келкегә килү** *клд.* көлкегә калу (стать посмешищем, оказаться в смешном положении). Качан да келкегә килмәде, тафиклы иде шындый.

**КИЛҮЛЕ** *срг.* килбәтле, килешле (благообразный, красивый). Килүле кийенә. Бик матур иде, бик килүле иде килен.

**арты килүле булсын!** *к.т.* яңа әйберне котлап яки саткан һәм биргән әйбергә карата әйтелә торган тәгъбир (выражение доброго пожелания).

**КИЛ'ЫКАЙ** *стрл.* к.: **қолқай**. Бер дә кил'ыкай да китерми ул, шуны ту бийә диләр.

**КИЛЭМ** [удм.] *нокр., глз.* к.: **мошко I, 1**. Гриҗа булғанда килэм ырлық қайнатып эчертәләр. – *нокр.*

**ким** (неполный, недостаточный; меньший):

**бер ким...** *срг., кузн.* бергә ким... (без одного столько-то; своеобразный способ ведения счёта). Нәнәйем дә үлде бер ким алтмышта. – *срг.* Ике ким тугызанда Абдырахман бабай. – *кузн.*

**... минут ким** *срг., тмн. ...* минутсыз (без стольких-то минут столько-то; своеобразный способ счёта времени). Хәзер йегерме минут ким умбер. – *срг.* Ун минут ким сикез. – *тмн.*

**КИМАК 1.** *миш.д.* коймак (оладьи, маленькие блины); **2.** *срг.* кабартма (булочка). Бусы кимагы, кимак пешердем, сез кабартма атасез. Кимакны бәрәмнәрдә генә ашийлар.

**алма кимагы** *срг.* вак коймак (мелкие блины). Йегетләр алма кимагы белән селтиләр қызларга.

**йымырка кимагы** *чпр.* к.: **йәсничә**. Йымырка кимагы гына пешереп ашаттым.

**кимак кашыгы** *чст.* зур агач кашык, кечкенә агач чүмеч (большая деревянная ложка, маленький деревянный ковшик).

**цәй кимагы** *срг.* төче коймак (оладья).

**КИМАКЫЛ: кимакыл акукай** *мәл.* юләр, тинтәк (дурак, глупый, ненормальный).

**КИМӘ** *кмшл.* көймә, өсте бөркәүле арба (кибитка). Бик байлар ғына кимәгә утырып йөргән.

**кимә җибәрү** *дөб., мам.* яз көне боз өстенә ут ягып җибәрү (сделать костёр на льдине во время ледохода). Йаз көнө ташу аға башласа, җыйылалар ийе йәшләр, салам көлтәсенә ут төртәләр дә ағызып җибәрәләр, шуны кимә җибәрдек, диләр. – *мам.*

**КИМӘГӘ** *яүшт.* мичнең казан утырта торган өлеше (часть печи, в которую вделывается котёл).

**КИМӘЛ** *том.д.* к.: **кәбин**.

**КИМӘЛЕ: кимәле ал'апқыч** *глз.* баштан киелә торган алъяпкыч (передник с закрытой горловиной, через которую надевается). Кимәле ал'апқычны баштан кийеп мондан тумилип саласин.

**КИМӘЛЕ-КИМӘЛЕ** *злт.* вакыт-вакыт, кайча-

гында (иногда, временами); чаг.: **ким-ким**. Кимәле-кимәле сызлай айак.

**КИМӘЛЕК** *бәр.* хатын-кыз мәетен зиратка күтәреп илткәндә, аның өстенә чатырсыман корыла торган чаршау, тукыма (материя, покрывало для покрытия устройства в виде шатра над телом покойницы). Өстән кимәлек йабалар. Кимәлегемне дә тектереп куйдым, кифеллегемне дә кистереп куйдым.

**КИМӘЛЛЕ** *эчк.* к.: **дихай 1**. Кимәлле башым awырта.

**ҚИМӘЦӘ** *тбл., төм.*, **КИМӘЦЕ** *туб.-урт.д.* к.: **кәмәцә 1**.

**КИМӘЧӘ** *стрл.* чәчкапның башка кигәч бәйләп куя торган бавы (тесьма, завязка, при помощи которой *чәчкап* привязывается, прикрепляется к голове). Чәчкапны кимәчә белә генә кийәсең, йаулыг астында кала.

**КИМЕГҮ** *срг.* кимсенү (считать себя униженным). Йаным кимегә, тәнем кимегә. Кимегеп йәши.

**КИМЕК 1.** *перм.* сөякнең җелек аралашкан йомшак өлеше (губчатое костное вещество); **2.** *каз. ар.* кимерчәк (хрящ). Кимегеңне сындырдың мәллә. – *лш.* Тешләрем бар чакта кимекне рәхәтләнеп чәйнәп-чәйнәп ашыйдыр ыйым. – *мам.*

**КИМЕКЛЕ** *лш.* кимчелекле (с недостатком, дефектный). Әллә нигә кимекле бу шикәр, эремий awызда.

**КИМЕЛЧӘК** *хвл.* к.: **кимек 2**. Мин кимелчәкле ит йаратайым, инде тешем йук.

**КИМЕСЛЕ** *лмб.* ким, кимсетелгән (униженный). Халык арасында андан кимесле кеше йук.

**КИМЕТҮ** *нокр.* к.: **кимнәү**. Мине киметеп силәй.

**КИМЕШЕК** *әстр.* хатын-кыз баш киеме (женский головной убор).

**КИМ-КИМ** *стрл.* кайчагында, торып-торып (иногда, временами). Ким-ким сызлана, борчымый алай. Ис awадыр ийе ким-ким. Ашкаданым чирли ким-ким.

**КИМНӘҮ** *чст., блт.* кимсетү, санлашмау (пренебрегать, унижать). Ул мине йыл буйы кимнәде инде. – *чст.* Кимнәп әйтмим мин сине. – *блт.*

**КИМПЕР** *әстр., туб.-урт.д., брб.д., яүшт.* к.: **қортқа**. Кимпере булу кирәк, мин аны эстәмәдем. – *твр.* Кимпертән көлгәннәр полыр. – *брб.д.*

**КИМСӘ** *твр.* кем булса да (кто-нибудь). Кимсә сөйләр, пеләрсләр.

**иц кимсәнә** *тбл.*, **ичбер кимсә** *твр.* hичкем (никто). Ишегалдында утырмаң ичбер кимсә.

**КИМТИК** *тбл.* кимчелек (изъян).

**КИН** *әстр.* килен (невестка, сноха). Кин дүртбиш күрпә бирә мамыктан йасаған.

**КИНАШУ** *тмн.* сугышу (драться). Малыйлар килгән кинашырга.

**КИНӘ** [*фарс.*] *брб.д.* үчлелек, эчкерлелек (мстительность, злопамятность).

**КИНӘК** *том.д.* к.: **көйләк**.

**КИНӘКТӘН** *тара.* кинәттән (вдруг). Кинәктән сүс табып пулмайты.

**КИНӘЛЕК** *мам.* к.: **кийәлек**. Чәчмә писүкне идәнгә, кинәлеген күрерсең. Қыйағазны турый да турый, кинәлеген күрер әле. Анасын рәнҗетте ул, шуның кинәлеген күрә хәзер.

**КИНӘЛҮ** *кргл., шрл.* к.: **киләнү**. Апа кинәлде инде көләп, ди. – *кргл.*

**КИНӘН** *тара.* киң, иркен (широкий, свободный). Ул өй қуғыслай торайте, ул өйнә улым йүкте, урын кинән пулып қалты.

**КИНДӘШ** *тмн., кас.* килендәш (снохи, невестки родных братьев). Кан'сеңелем, киндәшем илтеләр болничага. – *тмн.*

**КИНДЕР I** *брб.д.* к.: **кесеркән**. Киндер қулға сийәте.

**к и н д е р II** (холст):

**ак киндер** *т.кам.-крш.* к.: **шома киндер**.

**киндер сийәге** *дөб.*, **киндер сөйәге** *мам.* к.: **калгы**.

**киндер урны** *мам., бөре., тмн.* киндер станы (ручной ткацкий станок).

**күтәреп суққан киндер** *т.кам.-крш.* ак чүпләмле киндер (ажурный холст, сотканный браным способом).

**мунча киндере** *бәр.* мунча өйалдындагы утыргычка җәелә торган җәймә (простыня или кусок материи, которым покрывается лавочка, сиденье в предбаннике). Мунча киндерем икәү ийе, ике йағына да җәйәдер ийем. Мунча киндере әзерләгән буласың, сөлгөсөн, тастымалын.

**шома киндер** *перм.* гади генә, бизәксез дә, буяусыз да сугылган киндер (холст обыкновенный, который не имеет ни узоров, ни разноцветных сочетаний). Әле анда шома киндер генә түгел қый, кәртәләп тә суғам ий.

**КИНДЕРАШ 1.** *миш.д., клм.*, **'ИНДЕРАШ** *кас.* к.: **мошко I, 1**. Йулның уң йагында киндераш йере. Киндераш орлого. – *чст.* Киндерашны йылка идек, тепкә бәлибез, аннан йәйәләр йаңгырга. – *кузн.* Киндераш, дары борон чәчәләр иде. – *клм.* 'индераш үстерийек әwәл. – *кас.*; **2.** *хвл., мәл., карс., шрл., чпр., трх.* киндер орлыгы (семена конопли). Аның киндерашы бар башында, орлого, ул майлы. – *хвл.* Киндерашын кәбестә кәлҗемәсенә қушадырыйық. – *трх.* Киндерашны хәлле кешеләр генә чәчкән инде. – *шрл.*

**киндераш куркынычы** *мәл.* карачкы (чучело, пугало). Бу кийемеңне кигәч, перәме киндераш куркынычы тесле буласың.

**киндераш майы** *карс., чпр.* киндер майы (конопляное масло). Киндераш майы бик тәмле ул. – *чпр.* Киндераш майы. – *карс.*

**киндераш орлыгы** *карс.* к.: **киндераш 2**.

**кысыр киндераш** *стрл.* к.: **мошко I: кара мошко**.

**цыпцык киндерашы** *байк.* кыргый киндер (дикая конопля). Цыпцык киндерашы киндераш инде бетеп, орлогы wак була, сары.

**КИНДЕРӘ 1.** *глз.* к.: **мошко I, 1**; чаг.: **айақ II**. Көпшәсе мындый озын булғаны киндерә була; **2.** *перм.* чабата кырыена куеп калдырыла торган бөтергән юкә (одинарное, кручёное лыко, вставляемое по краям лаптей, обушник или кайма). Ишкәч, бау була, бороп қына қуйғач, киндерә, дибез.

**КИНДЕРӘЛЕК** *минз.* аякның чабата киндерәсе урала торган өлеше (та часть ноги, где завязываются оборки лаптей). Киндерәлек тирәләре қапқара тузан икән.

**КИНДЕРҮ** *лмб.* бизәү (украшать, убирать). Ызбаны киндерәм.

**КИНЖӘ** *тпк.*, **КИНҖӘ** *перм., влгг.* к.: **қалдық 2**. Кинжә энем бар Зөфәр исемне. – *тпк.* Кинҗәсе бар иде, Фәриха иде. – *влгг.* Кинҗә бала. Кинҗә малайым да уқырға керде. – *перм.*

**КИНЗӘ** *эчк.* **1.** к.: **берләч**; **2.** к.: **қалдық 2.**

**кинзә тай** *шрл.* к.: **қалдық 2.**

**КИНЙӘ** *злт.* к.: **қалдық 2**. Кинйә үстем. Кинйә қызыбызның улы.

**КИНКӘ** *себ.* сай күн аяк киеме (неглубокая кожаная обувь).

**кинтер** *себ.* киндер (конопля):

**кинтер им** *тбл.* к.: **киндераш 2**. Итен (җитен) им, солло, кинтер им цацатыннар ите.

**КИНТЕРАҒАЦ** *туб.-иртд.* каба (прялка). Кинтерағацқа бәйләп өйөрәбес, пуйайбыс йонно. – *төм.* Кинтерағацқа бәйләп өйөрәпес. – *тбл.*

**КИНЦӘ** *тбл.* **1.** кече (младший). Кинцә кейәү; **2.** к.: **қалдық 2.**

**КИНЦӘК** *туб.-иртд.* килен, яшь килен (невестка, молодая невестка). Кинцәкне апкилгәндә йастыққа бастыра тығаннар. – *тбл.* Өйләнтергәнтек атасы исән цақта, цыкиткән кинцәге. – *тара.*

**КИНЦӘТАЙЫМ** *тара.* бердәнбер балага йә төпчек балага карата иркәләп, яратып кулланыла торган сүз (форма ласкательного обращения к единственному ребёнку или ребёнку-последышу). Қарынтөбәм алысқа китеп қалты, кинцәтайым. Йә пер гүскә кинцәтайым тийән.

**КИНЦӘТӘЙ** *тара.* **1.** к.: **қалдық 2**; **2.** бердәнбер бала (единственный ребёнок). Кинцәтәй пер генә пала йә соңқо пала.

**КИНЧӘБИГӘ** *тбл.* ирнең иң кече апасы (самая младшая из старших сестёр мужа). Иренең-ке әбәсе, кинчәбигә тийеш, кечесе.

**КИНЧӘК** *әстр.* килен, яшь килен (невестка, молодая невестка).

**КИНЧӘКЛӘҮ** *әстр.* яшь киленнең туйга килгән кунакларны сәламләве (приветствование молодой невесткой гостей, собравшихся на свадьбу).

**КИНЧӘЛЕК** *дөб.* к.: **басу II: қаты басу**; чаг.: **барлақ**. Кинчәлектә була әрем.

**КИҢ** *кргл.* к.: **алчақ**. Үҗәркә халқы киң халығ инде.

**киң бәйелле** [*гар.* + *афф.* -ле] *себ.* киң күңелле, мәрхәмәтле (добрый, великодушный, милосердный).

**КИҢӘҮ** *мәл., срг.* к.: **киләнү**. Awыл халкы киңәнә. – *мәл.* Кицен аранга керә, линтасын бәләп калдыра да иртән бага, йәш куцқарга бәләсә киңәнә, йәш кийәүгә бара. – *срг.*

**эче киңәнү** *мәл.* бик нык шатлану (обрадоваться, сильно радоваться). Эче киңәнә инде аның ишетсә.

**КИҢӘШ** *тара.* туй алдыннан уздырыла торган хатын-кыз мәҗлесе (званый обед женщин перед свадьбой). Киңәш перенцесе, анан туй, туйтан сун күц күцерү, анан түрген булады.

**киңәш салмасы** *тпк.* яучы килеп киткәч, кыз ягы туганнары җыелышкан мәҗлес (угощение, совет родственников невесты после того, как побывал у них сват). Киңәш салмасына йийабыd тип утырып ағайнысы киңәшләшкәннәр йаусы килеп қайтқас.

**КИҢӘШҮ-УҢАШУ** *кузн.* киңәш-табыш итү (советоваться, совещаться). Киңәштег-уңаштык та, кыз буйлы-сынлы, өсле-башлы, аналы-аталы, зур абыйым барды да эшне бетреп тә куйды.

**КИҢГӘ** *злт.* к.: **қалдық 2**. Бу безнең киңгә қызыбыз инде. Киңгәсенә алты тула.

**КИҢГЕРЦӘК** *тбл.* к.: **келисап**. Кинтерен малатит белән суққаннар, талғығаннар, киле буған, киңгерцәк пелән төйәсең.

**КИҢКӘ** *тара.* **1.** хатын-кыз аяк киеменең бер төре (разновидность женской обуви). Киңкә пийек үкцәле пулатаған, аны Эрбеттән апкиләтәгән, галуша йуғ ите, итекнең қуныцын кисеб алған шигелле пулатаған; **2.** к.: **кинкә**. Киңкә булған күннән теккән, үкцә тә қуйа тығаннар, галуш кебек. Қысыма киңкә тегеп пирәйен, қәсер булса туфли тиб әйтеп қуйатығын.

**КИҢЧЕЛ** *стрл.* киңрәк (пошире). Уң йактан сулга чалыш итеп хәситә кийәләр, бу тирәсе киңчел була.

**КИП I** [*рус.* кипа] *минз.* печәннән яки саламнан шакмак рәвешендә прессланган тюк (прессованный тюк соломы или сена). Печәнне эшләйләр кип белән. Моннан салам кипләп җибәрәләр бит.

**КИП II** *влгг., яүшт.* рәвеш, форма (форма, образ). Татар календаре шул кипта йазыла. – *влгг.* Қатыны матур иде, үлгәц тә кибе бозылмады. Кибе әйбәт, тик эцәй. Әтинең төсөн дә, кибен дә белмим. – *яүшт.*

**кибе бетү** *тара.* кыяфәте, килеш-килбәте бетү (потерять внешний вид). Цалбарның кибе беткән игән, қәнә үтекләп пирәйен.

**КИПЕН: чәй кипене** *каз.ар.-крш.* чәй эчәргә яратучы (любитель чаевничать, пить чай). Чәй кипеннәре без синең белә.

**КИПЕННЕК** [*гар.* + *афф.* -нек] *т.кам.-крш.* кәфенлек (саванный материал).

**КИПЕНСЕЗ** [*гар.* + *афф.* -сез] *т.я.* к.: **консоз**. Кипенсез, кеше хурлый бит. – *к.т.*

**КИПКЕР** [*фарс.*] *әстр.* к.: **кәпкер II, 1**. Кипкер белән сөзә.

**КИПЛӘНҮ 1.** *брб.д.* әләгү, бикләнү (попасться, оказаться запертым); **2.** *перм.* кысылу, кысылып калу (застревать, увязаться в щели). Қумақлар ойа тишегенә барып кипләнеп, керәлми үлеп йаталар дару сипкәч.

**КИПЛӘҮ** *брб.д.* бикләү (запирать).

**КИПРӘН** [*гар.*] *мәл., хвл., тбл.* к.: **кәперән**. Йастықларыма йаңы кипрәннәр тектем. – *тбл.*

**КИПРҮ** *твр.* күпер (мост). Йаңа кипрүне күргәнсес пулыр, йылғабыс сур ғуй.

**КИРАЛКАН** *мәл.* чалкан (лицом вверх, на спине). Суда киралкан йатып йездем.

**КИРАРҚАН** *т.я.*, **КИРАРКАН** *мәл., чст.* к.: **киралкан**. Айағым тайып кирарқан килеп төштөм. – *к.т.* Ылау башыннан ычкынып китеп, гыр-

далар эстенә кираркан тешкән дә биле каймыккан. Кираркан йаткан. – *мәл.*

**КИРӘМӘЙЛӘНҮ** *минз.* киреләнү (упрямиться); чаг.: **арқырайу**. Әй, кирәмәйләнеп йөрмәле.

**КИРӘМӘЙЛӘП** *минз.* киерелеп, кизәнеп (размахнувшись). Утын йарғанда кирәмәйләп суғасың. Кирәмәйләп суқты.

**КИРӘМӘТ 1.** *тара.* могҗиза (чудо); **2.** *бгрс.* кире (упрямый, своенравный).

**кирәмәте қатыру, кирәмәте килү** *каз.ар.* к.: **кирәмәйләнү**. Кирәмәте килсә, жүнгә китерә алмыйсың аны. – *блт.* Ни кирәмәте килгән тағы? – *дөб.*

**кирәмәте китү** *дөб.* киреләнми башлау, киреләнүдән туктау (перестать упрямиться, упираться).

**кирәмәтенә бару** *дөб.* к.: **кирәмәйләнү**. Үзенең кирәмәтенә бара, син әйткәнне тыңнамый.

**кирәмәт эсте** *чст.-крш.* зират (кладбище). Кирәмәт эстенә менәләр түгемдә.

**КИРБӘЙҮ** *тбл.* үзеңне зурга кую, тәкәбберләнү (важничать, возгордиться). Кирбәйеп утырғаннар.

**КИРГЕ** *тпк., төм.* к.: **кире 3**. Аннан кирге Миңлебану бар ийе. Шуннан кирге сабан сөрәләр. – *тпк.* Миннән кирге сеңел тыуды. – *төм.*

**КИРГИ** *к.т.* киерге (пяльцы).

**КИРЕ 1.** *чст.* кыен, читен, авыр (трудно, труднее, хуже). Былай йазу эштән киредер бу, ә?; **2.** *чст., хвл., кузн., т.кам.-крш.* яңадан, тагын (снова, ещё). Әле кызлар кире тугый башладылар киндер. Уннарда-унберләрдә кире кил сawарга. – *кузн.* Никадәр күрсәң дә, кире сағындыра икән. – *т.кам-крш.*; **3.** *бөре., минз., кргл., бгрс., эчк., злт., тпк., шрл., стрл.* соң – бәйлек (после – послелог). Моннан кире йыллар тыныч булсын. – *стрл.* Киндер булғаннан кире мучага күтәреп киптерәсең. – *минз.* Мыннан кире сыйыр асырап булмас. Мыннан кире тәрбийәңнән ташлама. – *злт.* Талқыйсың, шуннан кире сүсне эрләйсең. Суғыштан кире дөнйалар эрәхәт. – *тпк.* Мыннан кире жәй көнө айыртып қуйарға симинаны. – *кргл.* Йарты төннән кире қайтты эштән. – *эчк.*

**кире йақ** *әстр.* төньяк (север).

**кире йағадан** *минз.* к.: **йангылай**. Кире йағадан мучаға күтәреп киптерәсең.

**кире қанатлы** *каз.ар.-крш.* көмеш тәңкәнең бер төре (вид монеты). Муйын жақасыннан уң жағыннан бөтөн тәңкәсе кисеп бирде, кире қанатлы тәңкә йе.

**кире қушай** *лш.* кире, киребеткән – балаларга карата (упрямый – по отношению к детям).

**КИРЕЛӘҮ** *бгрс.* артка калу – укуда (отставать – в учебе). Шул қыз артыннан йөрөп уқуwын киреләде.

**КИРЕМУР** *кузн.* к.: **кирәмәт 2**.

**КИРЕСУҢГА 1.** *чст.-крш.* кире ягы белән (обратной стороной). Алдылар да киресуңга куйдылар; **2.** *срг., чпр., мәл.* к.: **киралкан**. Киресуңга салдык, теле дә сүләми. Киресуңга йат та, куй калган цәйне күзеңә (арпаны дәвалау). – *срг.* Киресуңга йату. – *мәл.*; **3.** *мәл.* киргә, тискәре якка ( в обратную сторону); чаг.: **тирес 4**. Киресуңга таба сукалыйсың.

**КИРЕТҮ** *тбл.* к.: **киртмәләү**.

**КИРЖАК, КИРЖӘК** [*рус.* кержак] *перм.* кеше белән аралашмаучан, йомык характерлы, кире кеше (необщительный, замкнутый, нелюдимый, упрямый); чаг.: **арқыры 2**. Бездә дә берәү моқый бар, бергә эшлибез үзебез, утырып ашамый бергә, шундый киржак.

**КИРЖЫН** *шрл.* к.: **кирәмәт 2**. И киржынсың да.

**КИРИШ** *твр.* жәя жебе, кереш (тетива). Қылдан йичкә тартылған йау кириши шул булыр.

**КИРКӘН** *әстр.* к.: **кәтмәк I**.

**КИРЛЕ-КИТӘРЛЕ** *хвл., кузн.* килделе-киттеле (нелепый, несуразный, неуравновешенный, сумасбродный).

**КИРЛЕ** *тпк.* бирле, алып (с, со). Иделдән кирле йәйәү килдек.

**КИРЛЕМАР** *чст.* к.: **кирле-китәрле**.

**КИРЛЕМУР** *мәл.* к.: **кирәмәт 2**.

**КИРМӘН** *т.я.-крш.* шәһәр (город). Айаз кендә жаңгыр жауса, Урик жылый дийегез, Кирмән жактан жил килсә, Урикны ырышалар дийегез (*бәет.*).

**КИРМӘК** *тбл., тара., саз.я.* каен кабыгының туз астындагы катламы (нижний слой берёзовой коры).

**КИРМӘХ** *саз.я.* кайры, кабык (кора – о дереве).

**КИРМЕЦ** *туб.-ирт.д.* кирпеч (кирпич).

**КИРСЕНҮ** *глз.* кимсенү (считать себя хуже других). Аның сүзенә кирсенеп утырма.

**КИРСУМҒА** *трх.* к.: **киралкан**. Кирсумға йатып эш бетми ул.

**КИРТ** *перм.* мич сыры (выступ на печи). Моржа кирте.

**КИРТӘ I 1.** *чст., каз.ар.-крш.* колга, юан булмаган озын агач (жердь, шест). Ызын арба белә киртә ташыйбыз. – *чст.* Тезмә киртәсен аптөштөм ике буйын. – *каз.ар.-крш.*; **2.** *чст.* өйдә әйберләр элү өчен куелган агач, колга (перекладина в избе). Пыцмакта киртәгә таккан сарфитны да, тастымалны да; **3.** *к.т., трх., мәл.* к.: **абзар 3**. Сарыкларға киртәгә генә сал ашарға, сыйырны абзарға кертеп ишерем болгатып бир. Сарыкларны қышлый абзарда тотсаң, жоннары әйбәт булмый, шуңа киртәдә қундырабыз, сарық туңмый ул. – *к.т.*; **4.** *трх.* бурамаған һәртөрле абзар (любой вид хлева, кроме срубного). Киртәләрем бик тузган. Киртәгә чығам да, Аллаға шөкөр, дим. Киртәсе эт алачығы хәтле генә; **5.** *минз., мәл., бгрс., шрл.* к.: **абзар: абзар алды**. Ике сыйыр киртәдә. – *шрл.* Киртәгә чығардыңмы сарыкны? – *бгрс.* Калхуз киртә йасаган Иш буйына сыйырларға. – *минз.*; **6.** *төм.* абзар (хлев).

**ачық киртә** *трх.* к.: **абзар: абзар алды**.

**йылы киртә** *чпр.* к.: **абзар 1**. Йылы киртәгә кертә бозауны.

**киртәгә тағу** *минз.* гаепле кешене киртәгә бәйләп куеп жәза бирү, суктыру (наказание виновного: высекают, привязав к изгороди). Тегеләрне тышта киртәгә тағалар икән. Хәдер киләләр моно да киртәгә тағарға, элек бит ул киртәгә таққаннар да қыйнағаннар ғәйебе булса.

**тышқы киртә** *трх.* к.: **абзар: абзар алды**.

**эчке киртә** *трх.* к.: **киртә 4.**

**КИРТӘ II** *чст.-крш.* рәт, рәт-рәт, кат (ряд, строй, рядами). Ничә киртә, киртә-киртә тезелешеп уйнап җеридер ийек.

**КИРТӘБАШ** *к.т.* башка чыгучы гаиләгә ата йортыннан бирелә торган терлек – гадәттә ул сарык булган (скотина – обычно овца, отдаваемая родителями, когда молодая семья переезжает в собственный дом). Киртәбаш сарыгымның нәселе бу, җыл сайын икешәрне китерә.

**киртәбаш сарык** *трх.* абзардагы иң зур сарык (самая большая овца в хлеве). Суйдым да киттем базарга киртәбаш сарыгымны.

**КИРТӘЛӘҮ** *дөб.* чабылган печән юлларын, кипкәч, ике яктан тырма белән өеп чыгу, җыеп бер юл ясау (огребать в длинный ряд скошенное и высохшее сено, делать валки). Печәнне башта киртәлиләр, аннары сун шәбеннилләр. Чапкан печәнне берүзем киртәләдем, берүзем шәбелләдем.

**КИРТЕК 1.** *перм., тара.* к.: **кикерик.** Киртекләре барыбер пухowай эшәл кебек. – *перм.*; **2.** *кузн.* киштә (полка).

**КИРТКӘС** *тпк.* **1.** өркәч (горб у животных); **2.** тау сыртындагы күтәрелеп-күтәрелеп торган очлар (возвышенности на хребте горы). Алатауның өс киртәсе бар; **3.** агачтан эшләнгән әйбернең киртләчләре, телләре (зарубки на краях деревянных предметов); **4.** к.: **кикерик.** Шәлнең киртәсе нисәдер, пелмәйем.

**КИРТКӘСЛӘҮ** *тпк.* киртләчләү (делать зазубры, зазубривать). Киртәсләп эшләгән гәрнезен.

**КИРТЛӘЧ** *к.т., т.я.-крш., перм., бөре.* к.: **басмача 1.** Өйалды киртләче. – *к.т.* Киртләчен кырып та тырмадым, кереп киттем. – *т.я.-крш.* Күтәрмәнеңке бер киртләче сындыйы. – *перм.*

**КИРТЛӘҮ** *минз.* кисәтү (предупреждать); чаг.: **гыразалау.** Алдан киртләп куйма, булмаган сүдеңе.

**КИРТЛЕ: киртле җаҡа** *т.кам.-крш.* кайтарма яка (английский воротник). Қазер генә чыкты асылынып торган киртле җаҡа, очло. Шәл җаҡа, қайберсе шулай киртле җаҡа буладыр ыйы.

**КИРТМӘ I** *каз.ар.-крш.* **1.** баш, камыр башы (закваска для теста). Менә ипигә изәсең дә инде, ипинең қамырын, башын киртмә диб алып қуйалар; **2.** кечкенә ипи (маленький хлебец из выскребков квашни). Бер бәләкәй генә киртмә тыққан ыйым пичкә, алыйым эле. Ипи башыннан киртмә салалар, кечкенә ипи, биргән кеше хәйергә бирә. Киртмә элеке әйтә торганнар ыйы, ипи башыннан алып табаға салып пешерәләр.

**КИРТМӘ II** *әстр.* груша. Киртмәләр дә бар иде, бағалма да.

**КИРТМӘ III 1.** *туб.-ирт.д.* бура (сруб); **2.** *твр., тбл.* буралап эшләнгән чардуган (бревенчатая ограда на могиле); **3.** *клм.* киртек (зарубка). Бер йәшлегә – бер киртмә, ике йәшлегә ике киртмә кисәләр (тайларның ялын), табунда күпмә тай барын белер өчен.

**КИРТМӘЛӘҮ** *тбл., брб.д.* бура бурау, бура кую (рубить сруб, ставить сруб).

**КИРТМӘН** *лш.* к.: **кәтмәк I.**

**КИРТҮ** *туб.-ирт.д.* к.: **киртмәләү.** Ағацны киртәтеләр палта белән. – *тбл.*

**КИРҮҢҚА** *сазл.* киргә, киргә таба (обратно, в обратном направлении). Кеше алтқа атласа, ул кируңқа парат.

**КИРҮ** *әстр.* төньяк (северная сторона света). Җил кирүдән булса, салқын була.

**кирүгә килү 1.** *минз., стрл.* уңышсыз булу, уңмау (не получаться, не удаваться). Эй, кирүгә килде дә инде. – *стрл.*; **2.** *бгрс.* кыенга килү, авыр булу (испытать затруднение, оказаться в тяжёлом положении). Атларга бик кирүгә килә дип, Иске Тиресне (*ав. ис.*) дә утыртқаннар йам итеп.

**КИРЦЕГӘ** *тбл.* к.: **кирәмәт 2.** Қыйын миңа аның ман, кирцегә.

**КИРШӘН** [*рус.*] **1.** *нрл.* юкә агачын уеп ясалган тагарак (желоб из цельного липового дерева). Киршән була торган ийе, җүкәдән йунып йасаған, тигәнә фурмасында. Киршән белән сыра була торган ийе; **2.** *брб.д.* тоткалы тагарак, ялгаш (корыто, корытце). Ики қулақлу киршәнгә иден қазаннан цыгарды.

**КИС** [*рус.* кисть] *трбс.* мунчала пумала (помело из мочала).

**КИСАҒАҪ** *тбл.* өрлек, матча (балка, перекладина).

**КИСАҒАЧ** *минз., кмшл.* к.: **қустартқыч.** Кисағач белән утыртырмын бик ачуwымны китерсән. – *кмшл.*

**КИСАЙ** [*рус.* киса] *кас., кргл.* эт баласы – балалар телендә (щенок – в детской речи). Кисай ойасы. – *кас.*

**КИСАП** *минз., злт., лмб., карс., стрл.* к.: **келисап.** Биж атнадан сун черидер дә кап-кара була мошко, талкибез, талкыгач, кызлар йийып тewә идек кисап мынан киледә. – *лмб.* Мышкы чәчәләр, шуны талкийлар, анан тewәбез шулай кисап белән. – *карс.*

**КИСАУҒАЧ** *минз.* к.: **қустартқыч.** Кисауғач менеп уйный, ат итеп.

**КИСӘ 1.** *себ.* аркылы (поперёк). Кисә йөгәрәп чыгу. – *төм.* Кисә килсә пала порола алмайты (туганда). – *тбл.* Кисәгә тақта қаққан. – *төм.*; **2.** *төм.* капкага аркылы салынган бик (поперечный запор на воротах). Қапқаға кисә салып қуйабыс ацылмасқа; **3.** *том.д.* аркылы агач – коймада, рәшәткәдә h.б. (перекладина – на заборах и т.п.). Рәшәткәнең кисәсенә қаққан.

**кисә тумрау** *тбл.* урталай чабу, чабып өзү (перерубить).

**КИСӘБАШ** *тбл.* чабылган җирнең киңлеге (ширина скошенного места, скошенной полосы).

**КИСӘҒАЧ** *минз.* к.: **қустартқыч.**

**КИСӘК I** *мәл., чст.* хәл, егәр (сила, мощь). Куркуwымнан кисәгем калмады. – *чст.* Кисәге дә йук мескеннең. – *мәл.*

**КИСӘК II 1.** *перм.* к.: **курмыйш.** Қайа барма итәмсен? Мин теге кисәккә барып киләм әле. Гөлсапалар теге кисәктә қый у; **2.** *влгг.* аерым, кайбер (некоторый, отдельный). Даже бозы булган кисәк җирләрдә; **3.** *әстр.* сирәк-мирәк, кайчакта (иногда, изредка). Балық сатадын төгел микән, кисәк килеп сатадын иде.

**бер кисәк 1.** *твр.* бер дә, бер бөртек тә (ни разу, нисколько). Өйгә бер кисәк кайту йуқ, көнтөс қырата, төннә аш ташыйбыс; **2.** *төм.* аз гына да, бер секунд та (нисколько, ни секунды). Бер кисәк wахытым пулмады.

**кисәге белән** *минз.* тоташ, тоташтан, бөтенләе белән (подряд, сплошь, целиком); чаг.: **ару II, 1.** Бу булған урман ғына кисәге белән. Бу awыл кисәге белән йанды.

**кисәк җир** *минз.* елганың текә ярлы, тирән урыны (глубокое с крутыми берегами место реки).

**КИСӘККӘ** *лш.* кинәт, көтмәгәндә (неожиданно, ни с того, ни с сего); чаг.: **кискәнәттән.** Үзебеднеке дә кисәккә генә үлде бер бәпкә.

**КИСӘК-ПОСҚАҚ** *төм.* кисәк-косак, вак кисәкләр – тире, тукыма һ.б. турында (лоскутки – о шкуре, тканях и т.п.). Кисәк-посқақтан қул белән тегепмен йөрмәп-йөрмәп. Миңә йорон бирең, қалған кисәк-посқақларны.

**КИСӘЛӘЙ** *тбл.* аркылы (поперёк).

**КИСӘЛЕК** *тбл., саз.я.* киңлек, иң (ширина). Кисәлеге күлнеңке утыз биш-кырык киламитыр.

**КИСӘРКӘ** *минз., тмн., лмб., чст., шрл., стрл.*, **КИСӘРТКЕ** *туб.-ирт.д.*, **КИСӘРТХЕ** *саз.я.* к.: **кисеркә I.** Кисәркәнең қойроғы киселеп қала бит тотсаң. – *минз.* И йыланнар, кисәркәләр чыга. – *шрл.* Кисәрткетән қурғатыған пулған өцөн аларны қулға алмыйм. – *төм.* Кисәртхе цағу. – *саз.я.*

**КИСӘТҮ** *тара.* үпкәләү (обижаться).

**КИСӘҮ** *лш., нрл., брб.д.* к.: **қустартқыч.** Мич тарта башлар ийе кисәү белән, бәк булышадыр ийе. – *лш.* Учақ бутарға кисәүне әзлим, табалмыйм. – *нрл.*

**КИСӘҮЛӘҮ** *тпк.* бик нык борчылу, нишләргә дә белми өзгәләнү (метаться, не зная что делать, сильно беспокоиться). Аңа хафаланасың бит, кисәүләйем, қайғырам.

**КИСӘФӘТ** [*гар.*] *брб.д.* зыян (вред, ущерб). Кисәфәт тawып айақ-қолсыс қалмайын тип қороқтым.

**КИСЕНДЕК** *мәл.* кисенте (вырубка, делянка).

**КИСЕНДЕЛЕ** *лш., к.т.* казылмалы, сикәлтәле (ухабистый); чаг.: **базлawык.** Кисенделе була, урман җулы шикелле булмый. – *лш.* Безен бу арада җул алай кисенделе түгел. – *к. т.*

**КИСЕННӘШҮ** *лш.* к.: **йасқышу 1.** Йуқ, ти ул, кисеннәшә.

**КИСЕНТЕ** *блт.* күкрәккә чыккан шеш (опухоль в молочных железах). Минем имигә дә кисенте булды.

**КИСЕНТЕЛЕ** *мам.* к.: **кисенделе.** Бу йул бик кисентеле икән.

**КИСЕНТЕЛЕК** *трх., бөре.*, **КИСЕҢКЕ, КИСЕҢКЕЛЕК** *перм.* кисенте, киселгән урман урыны (вырубка, место вырубленного леса). Менә әле кисентелектә бик шәб ул қура җиләк. – *бөре.* Өмөжә кисеңке йердә эштән чыққан була.

**КИСЕРАН: кисераны белән** *мам.* зур кисәге белән (большим, огромным куском). Кисераны белән ипи тотоб ашый. Шулхәтле кисераны белән тотмасаң ул ипине.

**КИСЕРӘ** *твр.* кешенең өрәге, әрвахы (призрак, привидение).

**КИСЕРӘН: кисерән күк** *минз.* таза, зур гәүдәле, әзмәвердәй (здоровый, крупный – о человеке). Кисерән күк малай үлеп китте, сигез йәшкә чыққан.

**КИСЕРКӘ I** *срг., чпр., кузн., хвл., мәл.* кәлтә елаңы (ящерица). Быйыл кисеркә йылы да, ахры. Зиде йыллық кисеркә цакса, анын име дә табылмый, ди. – *срг.*

**КИСЕРКӘ II** *чст., трх.* кискә (толстый обрубок бревна, кряж, на котором рубят дрова).

**КИСЕШҮ** *мам., дөб.* к.: **йасқышу 1**; чаг.: **қылйара: қылйара төшү.** Тучны белмәгәч, ник кисешәсең. Кисешепме-кисешә бу буразна сиңа керә дип. – *мам.* Кисешә инде шулқәдәр, менә урталай кискән инде. – *дөб.*

**КИСИ** *туб.-ирт.д.* к.: **кеси.** Оло әбәмнеңке қысы киси йебәрепте.

**'ИСИ'ЛИР** *кас.* вак кабартмалар (пончики). Җәйеп сун (соңыннан) эшләдем 'иси'лир, туй ашы да диләр.

**КИСКӘ 1.** *перм.* төп, агач төбе (пень). Кискәләрне ыргып қына чаба, ди; **2.** *дөб.* су сеңгән авыр агач (обрубок, кряж, впитавший в себя воду). Су кискәсе; **3.** *мәл.* кузгатырга авыр әйбер, кузгатып булмый торган әйбер (вещь, которую невозможно сдвинуть с места). Китәрләр әле, килгән йулларына кискә йатмаған. Анын шикелле кискә; **4.** *мәл.* кузла, дүртаяк (козлы).

**утын кискәсе 1.** *бөре.* к.: **кискә 4.** Әнә утын кискәсе бар утын кисәргә; **2.** *злт.* эшкә авыр кузгала торган кеше (человек, тяжёлый на подъём).

**КИСКӘК** *хвл.* к.: **кисеркә II.** Аскакка тотоп асармын, кискәккә куйып кисәрмен (*әкият.*).

**КИСКӘЛЕК** *т.я.-крш.* агач киселгән урын (место, где много пней). Җиде җатның капкасы, Капкас тебендә бакчасы, Бакчасында кискәлек, Кискәлектә җыланнык, Кергәндә дә чашкырыр, Чыкканда да чашкырыр.

**КИСКӘЛӘҢҮ** *лмб.* кискән кебек итеп сызлану (ныть, как будто разрезают на куски). Жар бәрә, башны аудара, бетен тешем кискәләнә.

**КИСКӘН: кискән үлән** *лмб.* к.: **мөртлөк.**

**КИСКӘНӘТТӘН** *трх.* кинәт, көтмәгәндә, кисәк (вдруг, неожиданно). Кискәнәттән әйткәннәр дә ире үлгәнен, шуннан чирләде, йоқлый алмады.

**КИСКӘРЕ 1.** *лш., мам.,т. кам.-крш.* к.: **кирәмәт 2.** Бик кискәре кеше. – *мам.*; **2.** к.: **кискәржақ.** Ойоғоңы кискәре кигәнең бит. – *мам.*

**КИСКӘРЖАҚ** *лш., т.кам.-крш.* тискәре як, сул як (обратная сторона, изнанка). Кискәржағын кигән. – *лш.* Күлмәгенең кискәржағын кигән дә чығып бара. – *т.кам.-крш.* Кискәржағын кисәң, бүләк була ди торған ийе әби. – *мам.*

**КИСКЕЛЕККӘ** *злт.* кичкә (на вечер, вечерком, под вечер). Кискелеккә алтыға бар.

**КИСКЕР I** *эчк.* к.: **кирәмәт 2.** Кискер кеше.

**КИСКЕР II** *туб.-ирт.д.* үткен (острый). Пы пила кискер игән.

**КИСКЕС: кискес йалқау** *злт.* үтә ялкау, бик ялкау (лентяй, лодырь). Бернәрсә эшләми бу қыз, кискес йалқау инде. И, кискес йалқау, утынны hаман йармаған.

**КИС-КЫС** [*рус.* кис-кис] *хвл., мәл., чст.* көчек, эт баласы (щенок).

**КИСКӘЛӘҮ** *глз.* яру – мәет турында (вскрывать, вскрыть – труп). Кискәләмәги қалага алып бардылар.

**КИСМӘ I** *туб.-арт.д.* мичкә (бочка). Ағац кисмәгә тослап, онлап тутыралар шкураны, йоно қойола. – *төм.*

**КИСМӘ II 1.** *тбл.* чәй токмачы, кош теле (хворост – вид национального мучного кушанья). Кисмә булгац, кисеп-кисеп қыйып цыққан пула қуй; **2.** *әстр.* токмач һәм туралган иттән торган ризык (кушанье, состоящее из нарезанной лапши и мяса).

**КИСРАН: кисраны белән** *мам.* к.: **кисеран: кисераны белән.** Кисраны белән тот та аша, нәрсәгә кисеп торасың инде аны.

**КИСРӘ** *тбл.* к.: **кисерә.** Кисрәсен күрәсен кешенеке, үсен танытмайты, кеше үсенеке қарынташ-туганнарына танытмай йөрәйте.

**КИСРӘНҮ** *т.я.-крш.* селкенү, тетрәнү, калтырау (дрожать, трястись, шататься). Син сүләгәндә кече тел кисрәнеп тора бит. Лып-лып басмагыз, җир кисрәнә дийерләр.

**КИСТАН** [*рус.* кистень]: **кистан хәдәр** *к.т.* зур, бик зур (очень большой, большой). Кистан хәдәр тоқмач басқан.

**КИСТӘН** *чст., бөре.* күсәк (дубина). Кистән белән биргән җәш ағайга арттан. – *бөре.* Сыңар кул кистәне, бер кул кистәне дә, ике кул кистәне дә була. – *чст.*

**КИСТЕК** *мәл., кмшл., чст.* к.: **пима 1.** Кызыл кистекләр була иде, бизәк салып йасыйлар иде. – *мәл.* Матур бу кистек, матур, қулда баскан кебек күwәз: әле быйыл астына салмыйча кийәсең. – *чст.*

**калуш кистек** *чст.* к.: **галуш 1.**

**КИСТЕКЛЕ** *лмб.* чуклы (с кистью). Сылawычлар, кашпаулар йугала башлагач, шапка кийә башладылар кистеклене, чәчәкләре дә бар.

**КИСТЕНҮ** *лмб.* сөртенү (спотыкаться). Әтиемнен сибай аты Баскан сайын кистенә (*хал. җыр.*).

**КИСТРАН: кистраны белән** *лш.* к.: **кисеран: кисераны белән;** чаг.: **кучтур: кучтуры белән.** Кистраны белән күтәреп чыққан ипине.

**КИСТЫК** *лмб.* чук (кисть). Бы тешендә мәржәннәрдән, читендә кистыклары.

**КИСТЫКЛЫ** *лмб.* к.: **кистекле.** Кистыклы кашпау.

**КИСУТ** *бәр.* мариларның келәү итә торган урыннары (место жертвоприношений и моленья у марийцев). Йөри торғач мари кисутына килеп чыққамбыз, кисут – мариларның тәйикмәк йандыра торған җирләре.

**КИСҮ I 1.** *лмб., чпр., т.я.-крш.* чалу, сую (зарезать, заколоть). Кез кен ун каз кистек. – *лмб.* Кискән үгезне Йалчикка (*ав. ис.*) аппардылар. – *чпр.* Карт үгезне кистеләр. – *т.я.-крш.*; **2.** *перм.* к.: **кискәләү.** Бул′нистә йатты ике көн киселми. Безнең әнә шундый үлгән кешеләрне Қарайделгә итеп кисәләр; **3.** *тбл.* операция ясау (оперировать). Өцөнцәгә киселтем бүлнистә.

**бал кисү** *төм.* бал суыру (качать мёд). Утыцар килаграм кәрәз белән кисә иде бал. Алар бөгән бал кисәләр.

**бирнә кисү** *бәр.* туйда кода-кодагыйларга бирелергә тиешле күлмәклекләрне кисеп әзерләү (приготовление отрезов материй, предназначенных для дарения родителям невесты или жениха во время свадьбы).

**КИСҮ II** *миш.д.* тулгак (предродовые схватки). Кисү башланды, акырамын. – *срг.* Кисү кисте эц сәгәт буйына, аннан таптым ыланны. – *чпр.*

**кисү алу** *кузн.*, **кисү кисү** *чпр.*, **кисү тоту, кисү тыту** *хвл., чст.* тулгак тоту, тулгаклау (испытывать предродовые схватки). Кисү тыта башладымы үзен? – *чст.* Кисү кисте кен буйына, биг awыр таптым ыланны.

**теңкәне кисү** *перм.* теңкәне корыту (донимать, замучить, надоедать). Аларныңқы қортлары бигрәк җаматай, теңкәләрне кисеп бетә.

**КИСХЕР** *саз.я.* к.: **кирәмәт 2.**

**к и т а п** (книга):

**китап ачу** *мам.* к.: **китап қарау.** Китап ачучы қатын бар анда, туры килә диләр. – *мам.*

**китап әйтү** *нокр.* уку (читать). Китаб әйтәләр, Асыл җиңги китаб әйтә.

**китап қарау** *твр.* багу, фал ачу (гадать – по книге). Арибә башлық китап қарағалы оста ите.

**КИТАПЧА** *минз.* букча (сумка, ранец). Китапларыңны китапчаға салып қуй.

**КИТӘК** *туб.-арт.д.* кетәклек (насест, курятник).

**КИТӘН** [*гар.*] **1.** *дөб., бөре.* нечкә җептән сугылган ак полотно (полотно белого цвета, из тонкой пряжи). Тамбурларым төшми китәннәргә, Бәгыремә дигән сөлгөгә (*хал. җыр.*). – *дөб.* Ақ китән күк була инде ул киндер, агартқач. – *бөре.*; **2.** *бөре.* бик нык агартылган киндер тукыма (отбеленный тонкий холст). Чистый матур ақны китән диләр, аппақ киндергә әйтәләр; **3.** *т.я., хвл., себ.* киндер (холст). Кецерәк мәлне китәннән кейгән көйлөкне. – *төм.* Элке китән суғу ийе. – *твр.* Китәнне үзем суқтым, киндер дип китәнне әйтәләр. – *тара.* Пецәнне дә эшләген, қуйға да өлгөрген, китәнен дә кейген. – *тбл.* Китәннән тегеп көйләкләрне. Пестә китән суқмайдылар, урыстан сатыб алайдылар. – *тара*; **4.** *төм., тара., твр., том.д.* җитен киндер (льняной холст). Китән турапның тың йецкәсе, йитеннән. – *төм.* Тураптан қаплар әсерләгәннәр, халық үсләре эшләб алғаннар, китәннән көйләк теккәннәр. – *тара.* Күбесе китәнне кигән, эрләр чалбарын да, киногын (күлмәген) да. – *твр.*

**ақ китән** *баст.* к.: **китән 1.** Ақ китән күләклек мага қайыннам биргән иде, йебәк тә тегел, пырастуй да тегел. – *баст.*

**ак китән** *хвл.* к.: **китән 2.**

**китән йәктә** *тбл.* астарсыз киндер костюм (холщовый костюм без подкладки). Китән йәктәне мин кейгән, эце булмайды.

**КИТӘРҮ** *кузн., хвл.* үткәрү, уздыру – вакыт турында (провести – о времени). Вахытны китәрү. Йукка вахытыңы китәреп йөрмә. – *хвл.*

**КИТЕКЛЕ-КИТЕКЛЕ** *трх.* киртләч-киртләч (с зарубками, имеющий зубцы). Китекле-китекле йафрақлы була балтырған.

**КИТЕП: китеп тешү** *т.я.-крш.* аңын югалту,

һуштан язу (потерять сознание). Теге кызы китеп тешә, әни үлде дигәстән.

**КИТЕРМӘ** *брб.д.* тәрәзә башы (верхняя часть оконной коробки).

**КИТЕРҮ** *миш.д., нокр., глз.* **1.** алып килү, алып кайту (привести, принести). Әле безне китерде, китерде дә радийол җибәрделәр, тытындылар тансawайт итәргә. Каладан чәй китердем. – *лмб.* Кичә бардым, бер чиләк йеләк китердем. – *чст.* Апалар Мәскәүдән күп кийем китергәннәр. – *глз.* Патифун инә китер миңа қаладан. – *нокр*; **2.** алып чыгу, алып тору (принести, брать). Без күршедән китерәбез үтүк. – *глз.*

**эшен китерү** *чст.* җайлау, җайга салу (наладить, уладить). Әни баргач, аның эшен китереп кайтыр инде.

**КИТЕШЛЕ** *төм.* сыешлы (вмещающий, ёмкостью в ...). Әwәл саманта сур сыw кисмәкләр булыпты, өң пәтрә китешле кисмәкләр булған, аларға ит тослағаннар.

**КИТЛАНУ** [*фарс.* + *афф.* -лан] *т.я.-крш.* маташу (возиться, трудиться). Сибәләнчек бер үләм бар, тушы үләнне сыу тебенә ташлыйлар, таки җаңгыр җawa иде, картлар шулай китланган энде.

**КИТМӘЛЛӘҮ** *дөб.* көрәк белән җир казу (копать, рыть землю лопатой). Шуғыш wахытында җирләр китмәлләдек, бақчаны әйткән дә йуқ, басуны китмәлләдек. Тимер көрәк белән бақчаны китмәлләгән кебек китмәлләп чәчтек.

**КИТМӘН** I *перм.* аркылы балта (топор с поперечным лезвием).

**КИТМӘН** II: **китмән ипи** *дөб.* ипи камырынан пешерелгән көлчә яки аның дүрттән бере (лепёшка из хлебного теста или одна четвёртая часть этой лепёшки).

**КИТМӘННӘҮ** *мам.* к.: **китмәлләү**. Йартысын суқалаттық, йартысын үзебез китмәннәдек.

**КИТРА I** *туб.-ирт.д.* кедр.

**КИТРА II** [рус.]: **китра быйма** *төм., тара.* фетр итек (фетровые валенки).

**КИТРАЙ** [*рус.*] *саз.я.* хәйләкәр (хитрый).

**КИТРӘ** *тбл.* кедр.

**КИТҮ I 1.** *крш., трх.* кияүгә чыгу (выходить замуж). Син киткәнме, ирең бармы? – *трх.* Җегерем биштә қалдым ике бала белән, китмәдем, җаңгыз җәшәдем. – *каз.ар.-крш.*; **2.** *лмб.* башка чыгу (отделиться от родителей и жить самостоятельно). Киткән ылым ман килнем килде кунакка. Элке киткән чакны йезлек тагып калдыралар, чаршawым да калды, канишем төбәмнән үпте, бар, кит, бәхетле бул, диде.

**китеп килү** *т.я.-крш.* барып килү (сходить, съездить). Китеп кил бер сагынып.

**чыгып китү** *нрл.* ябышып чыгу (выходить замуж убегом). Бу тағы чыгып қына киткән берәүгә.

**КИТҮ II** *т.я., чст., хвл., мәл.* төпләнү, тамыр җибәрү – үсемлекләр турында (пускать корни, укореняться, начать расти, – о растениях). Таллар утырткан идем, китмәделәр. – *мәл.* Алмагачларыгыз киттеләрме? – *чст.* Бу гөлнө күчереб утыртқан ыйым, нишләптер китмәде, қордо. – *к.т.*

**кифен** [*гар.*] *баст.* кәфен (саван):

**кифен сыру** *баст.* кәфен тегү (шить саван). Кифен сырма кеше йуқ, бардым кифен сырмаға.

**КИФЛӘНУ** [*гар.* + *афф.* -лән] *шрл.* кинәнү, рәхәтләнү (довольствоваться, блаженствовать, наслаждаться). Туй да туй, кифләнделәр. Ад'а, кифләнсен, шондой күлмәкләр кигезергә кирәк.

**КИФРӘН** [*гар.*] *тмн.* к.: **кәперән**.

**КИФРӘННЕК** [*гар.* + *афф.* -нек] *тмн.* сүрүлек (материал для нижней наволочки подушки). Кифрәннек бирең тор әле, абыз. Түшәккә кифрәннек кирәк булыр.

**КИЦӘ I** *тара.* аша (через). Урман кицә китте.

**КИЦӘ II** *төм.* к.: **кицәү**. Мин кицә утызған қawынны, көлө тә йуқ қуй.

**алтаңқы кицә, қицәге көн** *тара.* өченче көн (позавчера). Алтаңқы кицә килделәр.

**КИЦӘWЕН** *брб.д.* кичен (вечером).

**КИЦӘҮ** *туб.-ирт.д.* соң (поздно). Иртәнрәк пар, кицәүрәк қайт. – *тбл.* **Кицәwерәк** партым. Кицәwерәк торабыс қыш көнө. Кицәү тораты йоқотан. – *тара.* Ул кицәүрәх ашады. – *саз.я.* Кицәү қайтқан эштән. Алар қицәү килмәкләр. – *төм.*

**КИЦӘҮЛӘҮ** *тара.* кичкә авышу (вечереть). Көн кицәүләйте.

**КИЦКЕЛЕК** *төм.*, **КИЦКЕТӘ** *тара., брб.д.* кичен (вечером). Йалғыс кицкетә шом пулаты.

**КИЦМӘ** *чпр.* кичү (переправа, брод у реки).

**КИЦҮ** *тара.* кичерү, гафу итү (прощать).

**КИЦХӘ** *саз.я.* к.: **кецегә**. Кицхәләре бийен уйнамайты, уғығалы йарата.

**КИЦХӘМ, КИЦХӘҮ** *саз.я.* эне яки сеңелгә эндәшү сүзләре (формы обращения к младшему брату или сестре). Кицхәм, пиреч миңа берсен, йақшысын.

**КИЧАРА** *лмб.* кич белә, кичен (вечером). Кичара сөзәләр бузаны.

**КИЧАТНА** *блт., чст.-крш.* к.: **кечатна**. Тройчында бит инде кичатна кенне симек була, кайын башын бәйләргә барабыз. – *чст.-крш.*

**КИЧӘ 1.** *карс.* кич, кичен, кич белән (вечер, вечером). Кичәгә килермен; **2.** *лмб.* үлене искә алу көне (день поминок). Инде кичәсе, кырык кичәсе, илле ике кичәсе була. Беген йиде кичәсе бер әбинеке.

**КИЧӘWӘЧ** *брб.д.* к.: **кеце**.

**КИЧӘWЕН** *брб.д.* кичә (вчера). Кичәwен килде. Көр әле, кичәwен салаwат көпере чықты.

**КИЧӘГӘ** *мәл.* к.: **кичә 1**. Кичәгә килермен мин, хәзер китим әле.

**КИЧӘТНӘ** *перм.* к.: **кечатна**. Кичәтнә көн җийылабыз да пумич итәбез ий, кем бәйләнә, кем орчоқ әрли.

**КИЧӘҮН** *брб.д.* к.: **кичәwен**.

**КИЧӘЧӘК** *брб.д.* к.: **кеце**.

**КИЧЕНҮ** *кузн.* үлү (умереть).

**КИЧЕҢКЕДӘ** *трх.* кичкә таба (к вечеру). Кичеңкедә монардан сорыйлар.

**КИЧЕРҮ** *м.-кар.* күчерү (переводить, перевести). Йалабугадан Лайишкә кичерделәр.

**кичке** (вечерний):

**кичке қорон** *к.т., трх.*, **кичке күлем** *дөб.* кичкә таба, кичкырын (к вечеру). Игенче көннө кичке

қорон йанында тороп сорадым. – *трх.* Кичке күлем чығарбыз әле печәнгә. – *дөб.*

**КИЧКЕДӘ** *перм.* кичен, кич белән (вечером). Иртән унда чығабыз, кичкедә сәгәт дүрттә Пиремдә булабыз.

**КИЧКЕЛЕК** *мам., минз., кмшл.* кичке аш (ужин). Кичкелекне ашарға безгә кил. – *минз.* Кичкелеккә нәстә әзерләрбез икән? – *кмшл.* Кичкелекне пичкә куйдым да асат булды. – *мам.*

**КИЧКЕНЕ** *минз., стрл.*, **КИЧКЕСЕН** *перм., минз.* к.: **кичкедә.** Кичкесен қайталар. Кичкене йөрөргә йаратмыйм. – *минз.* Кичәгенәк кичкене мин аны күрдем. – *стрл.* Кичкесен мин бөтен җирне бикләдем. – *перм.*

**КИЧҚОРО** *каз.ар.-крш.*, **КИЧКОРОН** *мәл.* к.: **кичке: кичке қорон.** Кичқороға ғына қайтыр ул.

**КИЧЛӘҮ** *перм.* куну (ночевать, переночевать). Кемдә кичләдегез? Кичләп қайтың, иртән китәрсез.

**КИЧЛЕК** *т.кам.-крш.* к.: **кичкедә.** Кичлегендә рәқәт бергә утырywы.

**КИЧҮ I** 1. *минз., перм.* зур елгаларда мал әчәргә төшә торган сай урын (водопой у больших рек); 2. *лмб.* елга яки күл кырыенда басып су алыр һәм керләр чайкар өчен салынган кечкенә басма (мостки на берегу реки или озера); чаг.: **басмача 2.**

**КИЧҮ II** *т.я.-крш., т.кам.-крш., трх.* уздыру – билгеле бер вакытны (провести, пережить – время). Узган йыл да шулай утынсыз қыш кичтек. Йоқламыйча төннәрен утырып кичәйек. – *трх.* Кыш кичәме ул анда, Уралда. – *т.я.-крш.* Җырлый-җырлый төннәр кичәләр ийе. – *т.кам.-крш.*

**КИЧҮ III** *брб.д.* кече, кечкенә (младший, маленький).

**КИШ I** *тбл.* кеш (соболь).

**КИШ II** *эстр.* к.: **кицәү.**

**КИШӘ** *лш., дөб.* туку өчен әзерләнгән буй җебе үрмәсе (нитки – основа, сплетённая по принципу вязания крючком).

**КИШӘЛӘҮ** *каз.ар.* буй җепне буталмасын өчен үреп кую (сплести по принципу вязания крючком цепь из ниток, чтобы она не запутывалась – в ткацком деле). Чөйләргә озатасың да кишәлисең җепне. Җеп кенә кишәләп бир әле дип әнине апчыга торған ийе. – *блт.* Кишәлиләр ийе җепне сугарға, суққанда кишәне берне-берне җибәрәләр. – *мам.*

**КИШӘНКЕ** *дөб.* кыр эшләре эшләгәндә бер кеше алып бара торган җир участогы, кишәрлек, ал (участок земли или полоса, выделенная для работы в один приём). Бер кишәнке җир қалды (урасы).

**КИШӘҢГЕ** *каз.ар.-крш.* кәс (дёрн). Җирне кишәңге қаплаған. Кишәңгеләрне wақлап-wақлап чықтым, қаты җир ийе.

**КИШӘРЛЕКЛӘП** *трбс.* төркем-төркем булып (группами, отрядами). Без менә шулай тезеләбез дә китәбез кишәрлекләп.

**КИШӘҮ I** *дөб., мам.* к.: **кишәләү.** Буй җепне үреп кишәп барабыз. – *мам.*

**кишәп қуйу** *дөб.* к.: **кишәләү.**

**КИШӘҮ II** *дөб.*, **'ИШЕW: 'ишew алу** *кас.* к.: **көйшәү.** Алаша 'ишew алмай, сыйыр 'ына ала. – *кас.*

**КИШКӘ** [*фарс.*] *тбл.* к.: **кашки.**

**КИШКИН** *брб.д.* к.: **арыш I.**

**КИШЛАУ** *т.я.-крш.* кимерү (грызть, глодать). Сарыклар чийәне кишлап бетерделәр, шаның белән чирләгән. Кәкәйен бирмә, сүwәген бир: кишларга җаратам. Кунакка сүwәк кишлаттык.

**КИШЛӘП: кишләп суғу** *перм.* асалап сугу (ткать закладным способом). Кишләп сугу монсо ақ булса, монсо қызыл, берне арқау җеп аталар да төрлө-төрлө җеп салып баралар. Тутай кишләп җаулықларға шайы суға йы.

**КИШЛЕ: кишле тастымал** *перм.* башы асалау юлы белән бизәкләп сугылган сөлге (полотенце, концы которого сотканы украшенными, выделанными закладным способом узорами).

**КИШТӘ I** 1. *лш., мам., бәр.* кипкән печәнне җыеп ясаган тезем (валок – при уборке сена). Чабып киткәч әйләндереп киптерәсен дә ике йақтан җыйып китерәсең, шул киштә була. – *бәр.*; 2. *кргл.* күбә (ворох сена на один подъём).

**киштәгә җыйу** *каз.ар.-крш.* кипкән печәнне тезмәгә җыю (сделать валки после того, как сено высохло). Киштәгә генә җыйалар әле печәнне.

**печән киштәсе** *мам.* к.: **киштә I, 1.** Тирләгән көйө печән киштәсенә йатып йоқлаған.

**КИШТӘ II** 1. *глз.* юан булмаган озын агач, колга (жердь, шест); 2. *нокр.* бишек элә торган сиртмә агачы, колга (шест, на котором подвешена детская люлька); 3. *глз.* маяк (веха, ветки). Йул буйлап киштәләр утыртылган.

**КИШТӘК** *байк.* кештәк (подмышник, ластовица). Киштәк куймыйцы тексәң, тиз килеп цыга йыртылып. Киндер күлмәкләрне киштәк куйып тегәләр ийе. Өстөмдәге күлмәгемнең Тар булды киштәкләре (*хал. җыр.*). Ыштан төбөндә дә киштәк була.

**КИШТӘЛӘҮ** *блт., мам., лш., минз.* к.: **киртәләү.** Киштәләп чығасың печәнне кипкәч, ике җулны бер итеп. – *мам.* Печән кибә, кипкәч киштәлибез, пакусқа салып-салып. Печәнне ике йақтан җыйып қысып барасың киштәләп, буйы белән китә торған ыйық киштәләп. – *лш.*

**КИШТӘРЛӘҮ** *дөб.* читән яки койма белән әйләндереп алу, уратып алу (оградить, окружить изгородью). Бақча әйләнәсен киштәрләп бетердем инде, қазлар кереп йәшелчәне ашамаслар.

**КЛАКУН** [*рус.* колокол] *трх.* к.: **җиңгеле.** Дуғасына клакун тағалар.

**КЛАП** [*рус.* кляп] *дөб.* ишек элгече (щеколда).

**КЛАСҚЫШ** *төм.* к.: **битйаулық.**

**КЛАТ** [*рус.* клад] *трх., чпр.* эскерт (скирд, скирда). Печәнне клатқа қуйабыз. Без клат қуйучылар идек. – *трх.* Салам клатлары озонча була. Шушы awылда дүрт клат, биш клат печән була иде. – *чпр.*

**КЛӘБИК** *яүшт.* кетәклек (курятник).

**КЛИНДИР** *хвл.*, **КЛИНҖИР** [*рус.*] *м.-кар.* к.: **келәндир.** Клинҗир пешерәтләр иде, калач пешерәтләр, кәзер калач та ашийсы килми. – *м.-кар.*

**КЛӨКӘ** [*рус.*] *туб.-ирт.д.* к.: **қустартқыч.**

**КОБАГАЙ** *стрл.* к.: **қобағай.** Көрән кобагай

шәшке, йәшел кобагай шәшкеләр wатылды, өч тач булды.

**КОБОТЫЙ** *мәл.* юан – кеше турында (толстый – о человеке). Мәстураның ирен күргәнем йук иде, бик коботый икән, насилык йөри.

**КОБОШКА** [*рус.* кубышка] *мәл.* мәк башы (головка мака). Макы кобошкасын кан'атып эчкән.

**КОWАШН'А** [*рус.* квашня] *хвл.* 1. к.: **ләнгәц**; 2. бер күәс чиләге ипи камыры, ипи пешерергә әчеткән камыр (квашня готового теста из муки). Шонда кowашн'а басамын.

**КОДА** *лмб.* туй (свадьба).

**зур кода итү** *глз.* к.: **күренеш: әwәлге күренеш.** Без wакытта кәбен салалар ыйы картларны җыйып, зур кода итү диләр, зур туйы була инде анын.

**кода куу** *чст.-крш.* туйдагы шаян йолаларның берсе: мәҗлесне алып баручы кеше ипи калагына көлчә бәйләп кодаларны куа (шутливый обычай во время свадьбы, согласно которому кто-то из главных хозяев прогонял приезжего главного свата). Аргыш келчәне әпәй калагына бәйли дә «кеш-кеш» дип кодаларны куwа.

**кода ун'ау** *лмб.* кыз алу-бирү барышында кода-кодагыйларның үзара бер-берсен кунакка чакырышуы (во время сватовства приглашение сватов друг друга в гости). Кода ун'илар иде буза мынан.

**пәри кодасы** *лмб.* пәри туе (воздушный вихрь, смерч).

**КОДАЛЫЙ** *чст.-крш.* кода итеп, кода булып (в качестве сватов). Туй үткәннән соң, кодалый чакыралар. Мин кодалый барганда кайнар пируг алып бардым. Туй үткәчен кара-каршы кодалый җөрөшәбез без.

**КОДРА** *нокр.* к.: **көдрәч.** Чәчем йаман кодра, вынучка да миңа барган, чәче кодра.

**КОЖАН** *м.-кар.* кар бураны, кышкы давыл (буран, пурга, метель). Җилләде, кожан китәр әле. Кожан себерә. Күз ачкысыз кожан. Җәйәүле кожан.

**КОZАWЫЗ** *нокр.* наратбаш (хвощ полевой). Кozawызның йәш сабагын йаз көннәре йыйып ашайлар.

**КОЗГО** [*удм.*?] *глз.* к.: **кикрук.** Таwык козгосо ничек кызарган.

**к о й м а к** (блины, оладьи):

**КҮКӘЙЧӘН** *кмшл.* күкәйне күп салучан (яйценоский). Бәрәңге генә ашатсаң, тawық күкәйчән булмый, әзерәк үлән дә салалар.

**КҮКӘЛЕ: абалы-күкәле** *яүшт.* апалы-сеңелле (сёстры, старшая сестра с младшей сестрой). Арғы кибеттә абалы-күкәле сатышалар.

**КҮКӘМ** *том.д.* к.: **күкәцәгем.**

**КҮКӘМӘЙ** *тара.* к.: **коко.**

**КҮКӘРИ, КҮКӘРИН** *дөб.* к.: **өшемкә.** Суғыш wақытында күкәрине дә җыйып ашадық. Әйдә күкәрингә барабыз, дип китә торған ийек басуға. Бәрәңге басуларында җир чыкса, күкәрин җыйарға чығып китәбез, ашқа умач итеп салабыз күкәрин ононнан. Күкәрин, арттан әллә кем қуwа, ничег итеп күтәрим (*такмак*).

**КҮКӘЦӘГЕМ** *том.д.* үзеннән кече яшьтәге туганыңа яки чит кешегә яратып эндәшү сүзе (форма ласкового обращения к младшим родственникам или любому человеку младше себя). Ай, күкәцәгем, қацан килеп қалдың? – *яүшт.*

**КҮКБУМА** *әстр.* бума ютәл (коклюш).

**к ү к е** (кукушка):

**күке башы** *трх.* күкебаш (медуница). Чәнечке формасы үзе урманда да үсә, чалуда да.

**ышна күкесе** *трх.* миңгерәү, ачык авыз (бестолковый, разиня).

**КҮКЕГЕР** *тбл., төм.* к.: **қотан 1.**

**КҮКЕЛ** *нокр.* к.: **кукыл'.** Кәбестә күкеле бешердем.

**күкел тыту** *нокр.* к.: **кукыл': кукыл' тыту.** Күкелләр тытабыз.

**КҮКЕЛДЕГЕМ** *блт.* к.: **кукыл'дык: йерәгемнен кукыл'дыгы.**

**КҮКЕЛЕ** *нокр.* к.: **кукыл'.**

**КҮКЕМӘ** *тбл., төм.* к.: **қотан 1.**

**КҮКЕН** *кргл., бгрс.* вак елга балыгы (мелкая речная рыбёшка). Сақмарда төрле балық бар: алабуға, қызылқанат, қушбаш, шүкә, күкен, жирих. – *кргл.*

**КҮКЕР: күкер күкрәү** *злт.* к.: **гөлдөртәү.**

**КҮКЕРӘКЛӘҮ** *трх.* печән кибәненең кеше биеклеге хәтле өлешен өю (метать стог до уровня человеческого роста). Күкерәкләгәнче қул белән бирәсең, аннан кибәнгә бер кеше менеп таптап тигезләп үwә. Күкерәкләгәндә өчәү-өчәү бергә қадап чүмәләне алып тондора.

**КҮКЕРИ** *лш.* к.: **өшемкә.** Күкери күмәче пешерәдер ийек йаз көнө.

**КҮКЕРТ: күкерт күкерәү** *твр., тбл.* к.: **гөлдөртәү**. Икенче йыл биг иртә күкерт күкери, ағач йапрақ йармыйча, боз өстенә күкерт күкери, бал булмый. – *твр.* Күкерттән алтта нацағай була-ды. – *тбл.*

**күкертле йаwым** *төм.* яшенле яңгыр ( гроза, грозовой дождь).

**КҮКЕС** *твр.* күкрәк читлеге (грудная клетка). Җаныңны бир, мытлыкны күкесеңә ур.

**КҮКЕТҮ** *туб.-ирт.д.* үсендерү (дать возгордиться). Әбекәй тип күкетеп куйадылар, бәстә (кайвакыт) пуләкләп куйадылар. – *тара.*

**КҮКЕШ** *туб.-ирт.д.* мактанчык, борын күтәрүчән (важничающий от небольшой похвалы, хвастунишка).

**КҮКЙҮТӘЛ** *әстр.* к.: **күкбума**.

**КҮКЛӘҮ I 1.** *тбл.* искедән сырылган кечкенә генә киез – бала өчен (подстилка для ребёнка, сшитая из лоскутьев); **2.** *тбл.* к.: **күбү I, 1**. Қәсер бақта пулса та, матрас күкләтеп куйған; **3.** *төм.* к.: **күбү I, 3**; **4.** *брб.д.* к.: **күбү I, 2**.

**КҮКЛӘҮ II** *тбл., сазл.* сыерның яшь үләндә йөрүе (пастись на молодой траве – о корове). Сыйыр күкләгәнтә сөтне кән пирәте.

**КҮКМАЛ** [*тат.* + *коми.*] *перм.* күк җиләк (голубика).

**КҮКМҮНЦАҚ** *тбл.* зәңгәр төстәге мәрҗән бөртеге (бисеринка, крупинка голубого цвета). Күк мунцақ тегеп куйатыған булганнар баланықы гәбәҗенә күк күсле гешедән қурқып.

**КҮКНАР** [*тат.* + *фарс.*] *себ.* мәк (мак). Күкнарны үскермәйтеләр қәсер. – *твр.*

**КҮКРӘК I 1.** *т.я., каз.ар., кузн., хвл., чпр., лмб., чст., злт.* хатын-кызлар киеменең бер өлеше: күлмәк астыннан күкрәккә киеп калдырыла торган чигүле тукыма, күкрәкчә (вышитый нагрудник, надеваемый женщинами под платьем). Күкрәкне изүләр күренмәскә кийәләр. – *блт.* Күкрәк кирәк түгелме, сезгә бирер идем. – *мам.* Күкрәгем дә бар. – *злт.* Күкрәк кидем картайгынчы. – *лмб.* Күкрәкне астан кигәннәр, изү турысын чиккәннәр. – *хвл.* Килен булып төшөп, қайнанасына бер күкрәк тә бирмәгән. – *к.т.*; **2.** *срг.* изү (нагрудное украшение: *изу*). Күкрәк әләләр иде көмеш түмәле, пелүш белән түгәрәкләтеп теккән.

**күкрәк алйапқыч** *глз.*, **күкрәк йапқыч** *глз., нокр.* к.: **күкрәк I, 2**. Күкрәк йапқыч әниләр кийә иде. – *глз.*

**күк(е)рәк кеше** *перм.* к.: **кибер**.

**күкрәк чире** *чст.* туберкулез. Бырайның үрәсе күкрәк чире эчен бик йакшы ди.

**КҮКРӘК II** *брб.д.* к.: **гөлдөртәү**.

**КҮКРӘКЛӘҮ** *төм.* күкрәк кую (шить с нагрудной частью – о переднике). Күкрәкләгән алйапқычым тораты қуй.

**КҮКРӘКЦӘ** *тара.* к.: **күкрәк I, 1**.

**КҮК(Е)РӘКЧӘ 1.** *нокр., мам., төм.* төрле төстәге ука, бәрхет яки тасмалар белән бизәп эшләнгән изү, күлмәк өстеннән киелә (нагрудник, украшенный разноцветной тесьмой, бархатом, позументом; *изу*). Күкерәкчә эшләнгән була анысы төрле-төрле тасмадан, уқадан була. Абыстайлар ашқа йөргәндә күкерәкчә кигәннәр. Элек уқаланган күкерәкчә йе, сары бәрхет, шәмәхә бәрхет, зәңгәре, алы. – *мам.*; **2.** *к.т., минз., хвл.* к.: **күкрәк I, 1**. Күкрәкчәне эчтән кийәләр хатыннар, бала имедгәндәме, ниме. – *минз.* Күкрәкчә ул, алға эчтән кийеп қуйалар, гөмөр буйынарға кийеп җөрдөм, аны кимәсең, безгә гөнаһ бит ул. – *к.т.*; **3.** *минз., тмн.* алъяпкычның яки күлмәкнең билдән югары өлеше, күкрәге (верхняя нагрудная часть передника или платья с отрезной талией). Фартык киндер күккә манган, каралана ату, күкрәкчә менән үк, алнылы. – *тмн.* Күкрәкчәле алжапқычлар матур була, чигешләп тә теғәләр, бәбитәк тә салалар. Күкрәкчәсенә алжапқычның ышлапыр да салалар. Бәләкәй алжапқыч бу, элеке күкрәкчәле алйапқыч ийе гел, балайтәк тә тегәләр ийе. Күкрәкчәле алжапқыч, биленнән буwышлы, анан чықты артлы алжапқыч. – *минз.*; **4.** *влгг.* түш кесә (нагрудный карман). Ана күкрәкчәдә ват акча.

**КҮКРӘКЧЕ** *брб.д.* к.: **күкрәкчә 1**. Муйынчы белән күкрәкчене бергә эшләгәннәр.

**КҮКСӘ** *тбл.* күкрәк читлеге (грудная клетка).

**КҮКСӘНДЕРҮ** *тбл., сазл., твр.* йөткертү (вызывать кашель).

**КҮКСӘРҮ** *нокр., глз.* күгәрү (ржаветь). Қайа барсақ та сыйарбыз, Күксәргән қалай түгел (*хал. җыр.*). – *глз.*

**КҮКСӘҮ 1.** *минз., каз.ар., т.кам.-крш.* чахотка, астма, коклюш h.б. ютәл чирләре (болезни с приступами кашля: чахотка, астма, коклюш и т.д.); чаг.: **йүтәл: күк йүтәл**. Күксәү чиреннән генә үлде инде, бақыр. – *т.кам.-крш.* Бу балаға күксәү булған икән, бертуқтаусыз йүткерә. – *дөб.*; **2.** *дөб., мам., туб.-ирт.д.* йөткерүче, йүтәл авырулы (чахоточный; тот, кто страдает болезнью, сопровождающейся кашлем). И ул күксәүгә қалған тагын анда қәдәр җәйәү барырға! – *дөб.* Теге күксәү килә, қачыйм әле, җөткерә башласа дип қурқам. – *мам.* Күксәү пулыб аураты осақ. – *тбл.*

**КҮКСӘҮЛӘНҮ** *т.кам.-крш.* йөткерү чире белән авырый башлау (подхватить болезнь, сопровождающуюся кашлем). Уқый-уқый күксәүләнеп бетте инде.

**КҮКСЕ** *брб.д.* уртасында кашы булмаган чулпы (накосник без камня, без глазка). Цулпыныңқы уртасынта болай цулпы күс, күссес полса, күксе диб әйтедегеннәр.

**КҮКСЕЛ** *т.я.* күгәргән (заплесневелый, прелый). Бу бодай күгәргән булған икән, ононнан күксел тәм килә. – *к.т.*

**КҮКСЕМӘК** *том.д.* эчтән киелә торган җиңсез мех тун (меховая душегрейка).

**КҮКТӘТӘЙ** *минз., блт.* күкбаш (василёк).

**КҮКТӘҮ** *төм.* к.: **кәрсү 2**. Көлйемеш күктите мейецтә цөцөтмәсең, күктите тә цайы тәмсес цығаты.

**КҮКҮ** *тбл.* аз гына мактаудан эреләнеп китү (возгордиться от небольшой похвалы).

**КҮКҮК** *перм.* к.: **коко**. Күкүк белән Зәйнәп булған, аларны аналары қарғаған.

**КҮКҮРТ I** *брб.д.* к.: **гөлдөртәү**.

**КҮКҮРТ II** *том.д.* күкерт (горячая сера).

**КҮКФИРАС** *тбл.* купорос (купорос).

**КҮКЧЕЛ** *хвл.* күгелҗем (синеватый, голубоватый).

**КҮКЧИН** *перм.* шәмәхә төс (фиолетовый цвет). Л'упин күкчин чичкә атты. Бер сабакта күкчинне атты, бер сабакта сарыны атты.

**КҮКШӘЙҮ** *мам.* күшегү, начарлану (продрогнуть, зябнуть, мёрзнуть). Йаңгырда калып, бәпкә күкшәйгән.

**КҮКШЕЛ** [*рус.* кувшин] *мам.* к.: **кукшил**. Күкшелгә салдым каймакны.

**КҮКШЕН** *төм.* искергән, тузган – кием турында (изношенный, поношенный – об одежде).

**КҮЛ I** [*рус.*] *твр.* казык (кол). Мин үлсәм, табытымны такта қойың, башымға бир дәстә күл чәнчеп қойың.

**КҮЛ II** *тбл., тара., брб.д.* көл (зола).

**КҮЛӘ** [*рус.* куль] *эчк., тбл.* чыпта капчык (мешок, вытканный из мочала; куль). Ун күлә бәрәңге булды. – *эчк.* Күлә суққан пес, йүгәне әпкилеп қуйатылар. – *тбл.*

**КҮЛӘWӘТ** *минз.* сазлы күл өстендә ачык урын (окно в болоте или на болотистом озере). Кичә Шәйәхмәт күләwәтеннән бер чүрәкәй (атып) алдым.

**КҮЛӘWЕК 1.** *минз.* вак күлләр (мелкие озёрца); **2.** *эчк.* күл яки акмый торган су (озеро, водоём); чаг.: **йатңылық 1**; **3.** *к.т.* су җыелып торган сазлырак җир (болотистое место, где скапливается вода); чаг.: **йепсәк**.

**КҮЛӘГӘТКӘ** *злт.* к.: **күгәлә**. Мин аның күләгәткәсен дә күрәсем килми.

**КҮЛӘГӘЦ** *брб.д.* көй (мелодия).

**КҮЛӘЙТКЕ** *тбл.* к.: **күгәлә**.

**КҮЛӘК I** *кргл., бгрс., шрл., эчк., күрш., әстр., брб.д.* к.: **көйләк**. Ак күләк кигән, мага каршы килә. – *күрш.* Иркәкләргә иркәк күләге бирә. – *әстр.* Әнийемнең күләге ул. Кийү күләк китергән. Ақ күләк, қара тижурка, Килешә нәзек билләргә (*хал. җыр.*). – *эчк.* Барыбыз күләкчән йатабыз. – *кргл.* Қызның күләген чығарып элгән. – *әстр.*

**эт күләге** *әстр.* к.: **күлмәк: көчөк күлмәге**.

**КҮЛӘК II** [*рус.* кулёк] *тбл.* кап (мешок, пакет, куль). Избиске мәгәзингә киләте күләк белән.

**КҮЛӘКӘЙ** *перм.* к.: **көйләк**.

**КҮЛӘМӘ** *том.д.* тозак (капкан).

**КҮЛӘНКӘ I** *кузн.* к.: **күләткә 1**. Утырыгыз күләнкәгә.

**КҮЛӘНКӘ II** *тбл.* йөзек (кольцо).

**КҮЛӘНҮ I** *перм.* ашап-эчеп алу, тамак ялгау (заправиться, поесть). Эштән қайттың қый, күләнеп ал, аш сywына бит.

**КҮЛӘНҮ II** *срг.* кайгыру (горевать). Урамда күләнеп йөргәндә икенце бер салдат оңорый, атә, нәк күләнәсең (*әкият.*)?

**КҮЛӘНҮ III** *тара.* күмелү (скрыться из вида). Сywы тирән игән, башымнан күләнеп китте.

**КҮЛӘҢКӘ** *влгг.*, **КҮЛӘҢКЕ** *кргл., шрл., брб.д.* к.: **күләткә 1**. Күләңкәдә йаталар, эшләгесе килми. – *влгг.* Апкереп күләңкегә салғаннар. Эсседә тағы шуңа сарайға керә сыйыр күләңкегә. – *кргл.* Күренми, кәртечкәгә күләңкедә төшкән. – *шрл.*

**КҮЛӘСӘ** [*рус.* колесо] *перм., тбл., твр., тара.* к.: **йөгөртмә II**. Бейек йар икән, артқы күләсәләр төшөп китте кампайыннықы. – *твр.* Арбаның күләсәсе қырылды. – *перм.*

**КҮЛӘТКӘ 1.** *дөб., бәр., крш., перм., себ.* күләгә, күләгәле җир (тень, сень, тенистое место). Күләткәдә утыра. Күләткәгә керегез хәзер, қызу булмас. Чебешләргә күләткә кирәк дип чапмыйбыз әремне. – *каз.ар.-крш.* Койашта черки йук, күләткәдә чыдарлык тегел. – *чст.-крш.*; **2.** *бәр., дөб., минз., крш., к.т., кргл., бгрс., шрл., хвл.* к.: **күгәлә**. Күләткәңне генә күрәмен, күрмим шул. – *минз.* Тәрәзә төбенә күкшин күләткәсе төшкән. – *т. кам.-крш.* Үз күләткәсеннән үзе қурқа. Аның хәзер күләткәсен дә күрмисең. – *бгрс.*; **3.** *т.я.-крш.* сурәт, рәсем (рисунок, картинка). Болар укымалылар, күләткәле тегелме (китап)? Та да бер күләткә бар иде, күрмәчә калдым.

**КҮЛӘТКӘЛӘҮ** *дөб.* күләгәләү, күләгә төшерү (заслонять, затенять); чаг.: **коршылау**. Күләткәләмә, улым, кит әле аннан.

**КҮЛӘТКЕ** *туб.-ирт.д.* к.: **күгәлә**.

**КҮЛӘТХӘ** *саз.я.* к.: **күләткә 1**.

**КҮЛӘҮ I 1.** *тара., брб.д.* сөйләү (говорить). Йә, ирмәк күләп утыра. – *брб.д.*; **2.** *туб.-ирт.д.* шаулау, кычкырышу (шуметь, кричать). Әй, палалар, күләшмәгес. – *тара.*; **3.** *тбл., брб.д.* акыру, ырылдау – хайваннар турында (громко кричать, рычать – о зверях); **4.** *тбл.* җырлау, көйләү (петь, напевать). Бу қыс туруп күләде, таушының сыпайысына хайран қалды.

**КҮЛӘҮ II** *к.т.* к.: **йепсәк**. Күләү җир бар ыйы, шуннан чапқаннар.

**КҮЛӘЧКЕ** *твр., тара.* к.: **күгәлә**. Күләчкегә қарыйлар ийе әтәч қычқырса. Күләчке абитка йеткәндә қысқа була, кичкә озынайа бара. –*твр.* Сәғәт йуқ, күләчкегә қараб апқайтқаннар көтүне дә. Күләчкегә қарыйлар, абитқа йеткәнтә күләчке бер митер. – *тара.*

**КҮЛБАҒЫШ** *том.д.* к.: **айбагар**.

**КҮЛБИ** [*рус.* гольфы] *твр.* гольф кебек бәйләнгән, бизәкләп бәйләнгән оек (шерстяные чулки, связанные как гольфы). Күлби тубықтан төбән, көлләп пәйлиделәр.

**КҮЛБИЦ** [*рус.*] *төм.* к.: **гелбәч**. Күлбицкә тә салған картупны, пүкрәпкә тә салғабыс.

**КҮЛБУҒА** *саз.я.* к.: **көлбуқа**.

**КҮЛБҮРӘҮ** *брб.д.* сулкылдау (всхлипывать). Күлбүрәмә күн инә, булут килсә, батарсың.

**КҮЛЕК** *кргл., влгг.* эш аты, җигү аты (лошадь для упряжки). Бер күлек җиксәләр, өч-дүрт хатын утырып бара. Иренә күлек булса, барам базарга. Күлекле кешеләр йыракка да бара. – *влгг.*

**КҮЛЕМ 1.** *минз., бөре., перм., кргл., бгрс., шрл., злт.* төшке аш (обед). Әле күлемгә туқтадыгызмы? – *злт.* Күлемгә қайту. – *минз.* Күлемгә қайткәнда чабатаны суға батырып қуйар ыйық. – *бгрс.*; **2.** *бөре.* басуда эшләгәндә, көн эсселәтә башлагач, ашап-эчеп, ял итеп алырга туктаган вакыт (перерыв в первой половине дня во время полевых работ).

**бер күлем** *минз., бөре., перм.* бераз, берникадәр вакыт (немного, некоторое время). Төшкелеккә

туқтағанчы бер күлем эшлик әле. Бер күлем сөрдек инде. – *перм.*

**иртәгәчке күлем** *т.я., мәл.* к.: **иртәнге күлем 1.**

**иртәнге күлем** *минз., перм.* **1.** иртәнге як (дообеденное время); **2.** иртәдән төшкә чаклы булган эш вакыты (часть рабочего врмени до обеда); **3.** к.: **күлем 2**; **4.** *мам.* иртәнге аш (завтрак). Иртәнге күлемне ашағач, әзрәк җатып тордом, башым awыртты. – *мам.*

**кичке күлем** *перм., минз., каз.ар.-крш., каз.ар., т. кам.-крш., трх.* кичке як (послеобеденное время). Кичке күлемдә, қойаш сүрелгәч апменәбез инде печәнне. – *мам.* Кичке күлемдә сулыйым бақчаны. – *т.кам.-крш.* Кичке күлемгә керәбез инде. – *трх.* Кичке күлем муча җағарбыз тағы. – *каз.ар.-крш.*

**КҮЛЗҮ** *брб.д.* мәзәкче, шаяртучан (шутник, шутливый).

**КҮЛИ I** *каз.ар.-крш.* к.: **көйләк. Җ**ариймы шушы күлине кисәм сүрәткә төшкәндә?

**КҮЛИ II** *срг.* к.: **кийеш.** Шол күли генә цәцәбез.

**КҮЛИ III** [*рус.* куль] *минз.* сумка, капчык (сумка, маленький мешочек). Менә синә күли, эчендәге әйберләрен ал да бар лафкага.

**'ҮЛИ'** *кас.* к.: **көйләк.**

**'уш 'үли'** *кас.* к.: **күлмәк: куш күлмәк.**

**КҮЛЛӘ** [*гар.*]: **күллә тун** *твр.* хәллә тун (тёплое, стёганое одеяние).

**КҮЛЛӘWEK** *кргл., бгрс., шрл.* уйсулык, үзәнлек (низина); чаг.: **йату.** Менә бу борыннан күлләwектән китәбез. – *кргл.* Менә шушы күлләwектән барығыз, малайлар, күлләwектән чабығыз. – *бгрс.*

**КҮЛЛҮК** *тбл.* көл селтесе (щёлок).

**күлмәк** (платье, мужская рубашка):

**абуркалы күлмәк** *срг.* бала итәкле күлмәк (платье с оборкой). Өстә абуркалы күлмәк, асында ак абурка.

**алынлы күлмәк** *чпр.* күкрәк турысында икенче төрле тукымадан йә ефәктән изү эшләп тегелгән күлмәк (платье, грудь которого украшена круглым узором из другой материи, шёлка, кружев и т.д.); чаг.: **изү.**

**алынны күлмәк** *срг.* күкрәк турысына икенче төстәге, гадәттә кызыл, тукыма куеп тегелгән киндер күлмәк (женское холщовое платье с красной нашивкой на нагрудной части).

**астагы күлмәк** *т.я.-крш.*, **асты күлмәк** *глз.* эчке күлмәк (сорочка – женская). Асты күлмәк тә йерткәләдек ситседән.

**бийақ күлмәк** *мам.* буяган җитен җебеннән тегелгән күлмәк (платье из крашеного холста). Киндер күлмәк, киндер ыштан, буйауға буйап күбесе, бийақ күлмәк диделәр инде, күк бийауға манып.

**борчақ күлмәк** *т.кам.-крш.* борчак чүпләм белән сугылган (гадәттә ак һәм кызыл) киндердән теккән күлмәк (платье из холста, сотканного из пряжи двух цветов – обычно белого и красного – в мелкую клеточку).

**бөкөли күлмәк** [*рус.* букле] *т.кам.-крш.* йон тукымадан тегелгән күлмәк (шерстяное платье). Бөкөли күлмәк тегәрләр ийе уқалар тотоп.

**буй күлмәк** *т.кам.-крш.* юл-юл итеп суккан киндердән теккән күлмәк (платье из холста, сотканного в полоску). Буй күлмәкләр суқтым.

**гәүдәле күлмәк** *чст.* кысалы күлмәк (платье с отрезной талией).

**җарканат күлмәк** *чст.-крш.* җиңе тоташ кисеп тегелгән күлмәк (платье с цельнокроенными рукавами). Кештәкле күлмәк култыг асты җыртылмас өчен, менә сез җарканат күлмәкләр кийәсез бит, шуның төсле.

**җүле күлмәк** *м.-кар.*, **зүле күлмәк** *срг.* к.: **йүле күлмәк. Ж**үле күлмәкләр ак булган, ызын җиңе, кара җеп белән тегәтләр аны. Терле цәпедән зүләгәннәр зүле күлмәкне, элке булган ул, әзүләрен кызылмы, йәшелме анда тегеп цыкканнар.

**изүле күлмәк** *чст.* **1.** изүе һәм күкрәге ефәк тасмалар, ука һәм тәңкәләр белән бизәлгән күлмәк (платье, грудь которого отделана полукругом шёлковыми лентами, позументом и монетами и т.д.). Әнинең изүле күлмәге бар ийе; **2.** күкрәк турысына изү беркетелгән күлмәк (платье, на грудь которого прикреплено нагрудное украшение *изу*, полукруглой формы, отделанное шёлком, позументом, камнями и т.д.).

**ике итәкле күлмәк, ике қатлы күлмәк** *нрл.* бил турысына бала итәк яки ике рәт киң бала итәк тотылган күлмәк (женское платье с широкой оборкой у талии в один или два ряда).

**итәкле күлмәк** *трх.* бала итәкле күлмәк (платье с узкими оборками в конце подола). Мин белгәндә бар ийе әле итәкле күлмәкләр.

**йәүдәле күлмәк** *чст.* к.: **гәүдәле күлмәк.**

**йон күлмәк** *срг.* йоннан бәйләнгән кофта (шерстяная вязаная кофта).

**йүле күлмәк** *тмн., срг.* буй җәйләренә кызыл комач кыстырып теккән борынгы күлмәк (платье, сшитое из фабричной ткани или холста, на продольные швы которого накладывалась тесьма из красного материала, кумача). Элке булган ул йүле күлмәкләр, түтешем ат'а иде алай. – *тмн.*

**кәбенгә кергән күлмәк** *крш.* **1.** чиркәүдә никахлашкан чакта киелгән, милли итеп тегелгән күлмәк (национальное платье, в котором девушка была обвенчана в церкви). Кәбенгә кергән күлмәген әни миңа бозоп текте. – *т.кам.-крш.*; **2.** хәзерге туй күлмәге (современное свадебное платье). Бу кече қызымның кәбенгә кергән күлмәге, ақ күлмәк. – *каз.ар.-крш.*

**кәбестә күлмәк** *перм.* берничә кат киң бала итәк тотылган күлмәк (женское платье с широкими оборками в несколько рядов). Бездән олорақлар шул кәбестә күлмәкне киделәр.

**кендек күлмәге** *срг.* яңа туган балага кидерелә торган күлмәк (распашонка). Бәбәй анасына бал кертәләр иде, цәпе китерәләр иде, бәбәй цәйенә йәшә идек, кендек күлмәк китерәләр, тугац кийә торган.

**керәшен күлмәге** *т.кам.-крш.* керәшенчә тегелгән күлмәк: билен вак-вак склад белән киң итеп, итәк очын астарлап, эшләгәндә комачауламасын өчен ике яктан эчтән бау куеп тегелә һ.б. (платье, сшитое по-кряшенски: мелкими-мелкими складками на талии, с широким подолом, ниж-

ний край которого оторочен с внутренней стороны; с тесёмками внутри подола с двух сторон, чтобы, связав их, можно было убрать подол во время работы и т.д.). Керәшен күлмәген чеметеп-чеметеп тегәләр ийе, итәген астарлап, итәг очон, тиз тузмасқа.

**қода күлмәк** *твр.* кодалар бүләк иткән күлмәк (платье или рубашка, подаренные сватом). Туй булғач, көчө йеткән кеше қода күлмәк кидергәндер.

**көчәк күлмәге** *дөб., блт.* балага кырык көне тулганчы кидерә торган күлмәк (рубашонка младенца, надеваемая до того, пока ему не исполнится сорок дней).

**крайкалы күлмәк** *кузн.* тукыманың буйдан-буйга кисеп алынган кырыеннан бала итәк тотып тегелгән күлмәк (женское платье, оборки которого сделаны из краёв материи). Крайкасы йыртыб алынадыр да күгерчен шикелле тотола.

**куриклы күлмәк** *чст.* итәген тукыманы кыекка ярып кисеп тегелгән, киң һәм озын итәкле күлмәк (длинное широкое платье, подол которого выкроен вкосую, по диагонали ткани). Куриклы күлмәк була иде, итәген кыйыклап йарып тектеләр.

**куш күлмәк** *кузн.* килен тарафыннан каената һәм каенанага бирелә торган пар күлмәк (платье и рубашка из одинакового материала, преподносимые невестой родителям жениха). Куш күлмәкләр ике йакка да бирәләр.

**қушталлы күлмәк** *дөб.* берничә рәт тар бала итәк тотылган күлмәк (женское платье с узкими оборками в несколько рядов). Қушталлы күлмәк безнең шикелле қарчықларда ғына инде ул.

**қуштанны күлмәк** *блт.* к.: **итәкле күлмәк**. Қуштанны күлмәкләр, кесәбикәләр кийә торғаннар ыйы.

**күлмәк буйы** *хвл.*, **күлмәк бүксәсе** *мәл.*, **күлмәк қысасы** *каз.ар.* к.: **буй**. Жар булғач тирлисең дә, бүксәсе генә туза күлмәкнең. – *мәл.* Итәген айырым, қысасын айырым тектең мәллә? – *мам.*

**күлмәк кайыру** *карс.* кыйнау (бить). Мунчага итеп күлмәкләрен кайыра икән аталары.

**күлмәк элеге** *перм.* к.: **элгеҗ**.

**күлмәк эстинасы** *к.т.* к.: **буй**. Күлмәкнең эстинасы озонрақ булған, билдән түбән тора.

**өскитәкле күлмәк** *перм.* бил турысына бер яки ике рәт киң бала итәк тотылган күлмәк (женское платье с широкой оборкой у талии в один или два ряда).

**пуйаслы күлмәк** *чст.* биленә киң планка куеп тегелгән күлмәк (платье с широкой планкой на талии).

**сырлаған күлмәк** *т.кам.-крш.* итәгенә кәйтән яисә тасма тоткан күлмәк (платье, на подол которого пришита тесьма или гайтановые шнурки).

**тамақсалы күлмәк** *минз.* якасы чигүле һәм тәңкәләр тезгән күлмәк (платье, воротник которого вышит, украшен монетами наподобие женского нашейного украшения *тамакса*). Тамақсалы күлмәкләр, тәңкәле, чиккән буладыр ийе. Тамақсалы күлмәкләр кийеп уйныйлар әртисләр.

**тәңкәле күлмәк** *чст.* **1.** тәңкә-тәңкә бизәк төшереп суккан киндердән тегелгән күлмәк (платье, сшитое из холста, на котором на равномерном расстоянии вытканы небольшие круглые узоры из нитки другого цвета); **2.** итәгенә тәңкәләр тегелгән күлмәк (платье, на подол которого нашиты монеты).

**төн күлмәк** *тмн.* йокы күлмәге (ночная рубашка).

**урыс күлмәк** *м.-кар.* турыга тоташтан тегелгән ак күлмәк (белое платье прямого, сплошного покроя). Чыба астыннан урыс күлмәк кийәләр, тотошлый күлмәк булган, ак.

**чабулап йасалған күлмәк** *т.кам.-крш.* клёш итәкле күлмәк (платье-клёш).

**КҮЛМӘК-КҮНЧЕК** *т.я., дөб., перм., кузн.* күлмәкләр, җиңел кием-салым (лёгкая одежда: платья, бельё и т.п.); чаг.: **кийем-тотом, кийенчекләр**. Күлмәк-күнчекләре күб аның. – *к.т.* Күлмәк-күнчек тә қалмады – барсын бирдем. – *дөб.* Күлмәк-күнчек ала. – *кузн.*

**КҮЛМИК** *нокр., глз.* к.: **көйләк**.

**асалы күлмик** *глз., нокр.* асалап суккан киндердән тегелгән күлмәк (платье, сшитое из холста, сотканного закладным способом). Асалы күлмигем ай ди асалы, Сондоқларға салмай суға салдым ич (*хал. җыр.*). – *нокр.* Чын асалы күлмигем бар. – *глз.*

**КҮЛ-ПАРА: күл-пара қылу** *тара.* чәлпәрәмә китерү (разбить вдребезги).

**КҮЛТӘМ** *тара., брб.д.* елгадагы ике борылыш арасы (расстояние по реке между двумя её поворотами).

**КҮЛТКҮНЗҮЛҮ** *брб.д.* көлкеле (смешной).

**КҮЛ-ТОЗАН: күл-тозан қылу** *тара.* көлен күккә очыру (разнести в пух и прах, превратить в пыль).

**КҮЛҮК I** *мам.* күрек – тимерчелектә (мех – кузнечный). Өрдөрә торғаны күлүк була. Күлүк басам, күлүк басам ди торған ийе әни бишек тирбәткәндә. Күлүкне дә бау белә басып торалар, тегеннән тора өрдөреп утны.

**КҮЛҮК II** [*рус.* кулёк] *дөб.* к.: **йабу II, 2**. Күлүк суғадыр ыйық монда, wакытында күлүк суғылды, салам жағылды.

**КҮЛҮК III** *твр.* атаклы, данлыклы (славный, знаменитый). Ә, әкәм, синдән алып бармы игән? Синдән күлүк бармы игән?

**КҮЛҖӘР** *тбл.* чиләк каймасы (ободок). Су пәтрә күлҗәреннән.

**КҮЛЧӘ** [*рус.* кольцо] *перм., тара., брб.д.* к.: **қулса**. Күлчә була сәли ағачқа, пытылукқа бороп кертәләр. – *перм.*

**КҮМӘ 1.** *трх.* кул арбасы (двухколёсная телега, тележка). Бөтөн әйберен төйәде, балаларны күмәнең бер қырыйына утыртты. Ат булмаса, күмә белән алып барабыз. Икешәр қапчық әт борно жыйып қайта идек күмәгә салып; **2.** *байк.* көймәле арба (крытая повозка, кибитка). Күмә мулла-мәзиндә генә була, киленнәр күмәләп киләләр; **3.** *трх., чпр., чст.* яшь баланы тартып йөртә торган арба (двухколёсная детская коляска).

**күмә артчылар** *нокр.* кызны егет йортына озат-

канда, икенче ат белән аның әйберләрен алып баручылар (сопровождающие повозку с вещами невесты во время провода её в дом жениха). Күмә артчылар эченче атта кызның әрҗә, таз, әйберләрен алып баралар.

**КҮМӘГӘЙҮ** *тпк.* ишәю, зураю, арту – мәс., гаилә (увеличиться, прибавиться, размножиться – напр., семья). Симийә күмәгәйде, дурайды.

**КҮМӘК I 1.** *эчк., перм., злт., тпк.* ишле, күп – мәс., гаилә (много, многочисленно – напр., семья). Күмәк симийә булды, ике көйлә тары йитмәй торған ийе. – *тпк.* Сөйләп бетердем қый, әл дә күмәк булды. – *эчк.* Күмәк үстек без қызлар. – *перм.*; **2.** *әстр.* өмә (коллективная помощь).

**күмәк итү** *әстр.* булышу (помогать). Пылауга мәркү йуналар йегетләр, күмәк итәләр.

**КҮМӘК II** *туб.-ирт.д.* к.: **ирләи**.

**КҮМӘКЛӘҮ** *тбл.* күчкә салу, өю (класть в кучу).

**КҮМӘКЛӘШҮ 1.** *тбл.* бергә җыелу (столпиться, собраться); **2.** *әстр.* берләшү (объединиться, собраться).

**КҮМӘКЧЕ** *әстр.* булышучы (помогающий). Ит турамаға кил, дип күмәкчеләрне чақыра. Күмәкчеләр күп була туйда.

**КҮМӘРТӘ** *трх., минз.* бергәләп, җыелышып, күмәкләшеп (вместе, совместно, вкупе, сообща). Зур җирне күмәртә чәчәләр ийе. – *трх.*

**күмәртәсе белән** *трх., минз.* күп булып, бер төркем булып (кучей, гурьбой). Без монда күмәртәбез белән җыйылғанбыз. – *минз.* Алар күмәртәсе белән килсәләр дип күп пешердем ашны. – *трх.*

**КҮМӘРТӘБЕЗ** *минз.* барыбыз, бөтенебез (все из нас, все мы). Күмәртәбезнең қызықсынуwын җәлеп иткән бу қыз.

**КҮМӘРТӘК** *төм.* төргәк (пачка). Ақцаны күмәртәге пелән алатылар.

**КҮМӘРТӘМ** *нрл.* күп итеп, күпләп (помногу, оптом). Күмәртәм алып қайта туқмачны да, писүкне дә.

**КҮМӘС I** *злт.* **1.** кабартма, әчегә пешкән булка (булка, булочка из кислого теста); **2.** төче күмәч (маленькая лепёшка из пресного теста).

**КҮМӘС II** *к.-уф.* к.: **келчә 2.** Малайым Мәскәүдән безгә күмәс йебәргән: кәнфитләр... .

**к ү м ә ц** *срг.* күмәч (лепёшка):

**зур күмәц** *срг.* **1.** кызны килешкәч, кыз ягында егет яклары катнашы белән уздырыла торган мәҗлес (званый обед на стороне невесты после просватания, где участвуют и родственники жениха). Зур күмәцкә күп кеше килә; **2.** килешкәч, кыз ягында уздырылган мәҗлескә егет яклары махсус пешереп алып килә торган зур ак ипи (специально испечённый большой белый хлеб, который везут на званый обед, проводимый на стороне девушки после просватанья). Зур күмәцләр белән уникешәр алаша килә йегет йактан.

**кецкенә күмәц** *срг.* кыз килешкәндә уздырыла торган чәй, кечкенә мәҗлес (небольшое угощение во время сватанья девушки). Кецкенә күмәц баштук була. Кецкенә күмәцкә берцәк кеше килә.

**күмәцли килү** *срг.* кызны кияүгә биргәндә, кызны килешкәч уздырыла торган йола: егет туганнарының кыз ягына чәйгә килүе (приехать на званый обед, состоящийся после просватания девушки); чаг.: **зур күмәц**. Кызны килешәләр, зур задатка китерәләр, аннан кызга күмәцли киләләр, нәсел-нәсәбе бар да килә.

**таба күмәце** *срг.* ипи камырыннан өстенә бодай онынnан тугланган сыеграк камырны ягып пешерелгән таба ашы; хәзер аңа бәрәңге дә ягалар (мучное блюдо из кислого теста, типа ватрушки). Арыш камырына, быдай камыры йасый беленгә атлаган кебек атлыйсың, шуны йагып таба күмәце пешерә идек. Картуш йаккан таба күмәце була.

**КҮМӘЧ I 1.** *мәл., м.-кар., т.кам.-крш., хвл., карс., күзн., брб.д., клм.* к.: **күмәс I, 2.** Әни, күмәч, пич баштына чүмәш. – *мәл.*; Қырқысына қырық күмәч пешерәсен. – *т.кам.-крш.* Күмәч чүпрәсез ул. – *м.-кар.*; **2.** *глз.* к.: **секере**. Бер күмәч ипи биреп тор әле әҗәткә. Дүрт-биш күмәч ипи менгезгән; **3.** *туб.-ирт.д.* к.: **күмәс I, 1**; **4.** *к.т., м.-кар.* черек бәрәңге күмәче (лепёшка из крахмала гнилой картошки). Крахмалга җөрдек җаз, тунибыз вич тә күмәч пешерәбез – *м.-кар.*; **5.** *т.я., каз. ар., брб.д., том.д.* бодай ипие (пшеничный хлеб); **6.** *к.т.* **калач**.

**базар күмәче** *минз.* к.: **қалач: қалач әпекәй**.

**киген күмәче** *хвл.* элек: егет белән кызга беренче кичне ашатыла торган тозсыз күмәч (в старину: лепёшки, приготовленные без соли специально для жениха и невесты в день бракосочетания).

**күкәй күмәче** *минз., стрл.* төче күмәч (лепёшка из пресного теста, замешанного на яйце). Йулга күкәй күмәче пешердем, тиз искерми ул. – *минз.*

**күмәч ипи** *глз.* зур, түгәрәк ак икмәк (большой пшеничный хлеб круглой формы). Сигез күмәч ипи сыйа иде пичкә.

**күмәч чиләге** *минз., стрл.* к.: **ләнгәц**. Күмәч чиләгеме кертеп қуймағамын. – *минз.* Күмәч чиләгенә салып тотам әпәйне. – *стрл.*

**май күмәче** *блт., минз., стрл.* к.: **күмәс I, 2.**

**орлоқ күмәче** *мам., лш., минз., т.кам.-крш.* киндер орлыгы қушып, төчегә пешерелгән вак камыр ашы (небольшая пресная лепёшка с конопляными семенами). Киндердән күмәч пешергәннәр, киндер орлоғын төйөп, орлоқ күмәче дип пешергәннәр. – *т.кам.-крш.* Көз җитсә, орлоқ күмәче пешерәдер ийе әни, тәмне була ул, кетертәп тора. – *мам.*

**өй күмәче** *к.т.* өйдә пешерелгән бодай икмәге (пшеничный хлеб, испечённый в домашних условиях). Зур түгәрәк өй күмәчен турап өйдә.

**пуwузник күмәче, пуwыҗник күмәче** *м.-кар.* яшь килен егет капкасыннан керү белән ат башында утыручы кияү егете тарафыннан чөеп җибәрелә торган бөтен, түгәрәк икмәк, шундагы халык ул икмәкне кабып калырга тырыша (ритуальный хлеб, сбрасываемый дружкой-кучером наверх при въезде невесты во двор жениха; каждый старается отведать этот хлеб). Пуwыҗник

күмәчен капкадан керә дә каралдыда выргытып җибәрә, бүлеп ашийлар, кайсында дәмне була, кайсы дәмне булмый, бер генә күмәч йасилар, кайсы кабартып йасий, кайсы былай.

**таба күмәч** *хвл.* көлчә (лепёшка из хлебного теста).

**татлы күмәч** *срг.*, **төчө күмәч** *каз.ар., минз., крш.* к.: **күмәс I, 2**. Борчактан да төче күмәч пешерделәр әле бирwагыт. – *т.кам.-крш.* Төчө күмәчләр салдым әле, җулга да алырым дидем. – *мам.*

**чүрәк күмәч** *мам., минз.* йомыркага гына басып пешергән төче күмәч (лепёшка из пресного теста, замешанного лишь на яйце); чаг.: **күмәч: күкәй күмәче**. Йулга чүрәк күмәчләр пешердем, туклыклы да булыр. – *мам.*

**КҮМӘЧ II** *перм., к.-уф.* к.: **келчә 2**. Күмәч кәнфитләр, кызым алып килгән ийе. – *перм.* Мийә күмәч җибәрдеме? – *к.-уф.*

**КҮМӘЧЧЕ** *к.т., минз.* калач пешереп сату итүче (тот, кто занимается печением и продажей калачей). Безнең эти күмәччеләр булганнар. – *к.т.* Әлмәттә (*ав. ис.*) атаклы күмәччеләр булган безнең бабай. – *минз.*

**КҮМБАЛЫК** *тбл.* этләч, эт балыгы (вьюн). Күмбалык нацар балык, палыкның уwылтырын ашайты.

**КҮМБӘ** *тбл.* үргән җылым (плетёный невод).

**КҮМГӘЧ** *твр.* мичнең казан утырта торган өлеше (часть печи, в которую вделывается котёл).

**күмгәч асты** *твр.* учак (очаг).

**КҮМЕЛТЕРЕК** *твр.* сбруйның ат күкрәгенә салына торган өлеше (нагрудник – часть верховой сбруи). Күмелтерек салган күрәң ат.

**күмер** (уголь):

**күмер алгыч** *тмн.*, **күмер кайчысы** *яүшт.* к.: **җәмки**.

**күмер чүмече** *нгб.-крш.* к.: **күмериләк**.

**урыс күмере** *дөб.* махсус рәвештә агач яндырып алынган күмер (уголь, полученный путём специального сжигания). Урыс күмере қаты була, тимерче өчөн дә йарый, җиргә күмеп, қапқач белән қаплап йандырыла, торбадан эскипидәре чыга, дегете айырым йулга чыга, күмере дә була қаты.

**үле күмер** *хвл., мәл., чпр., кмшл., дөб., злт.* сүнгән күмер (затухшие, потушенные, холодные угли). Үле күмер сал самыварга. – *мәл.*

**КҮМЕРАЛГЫЦ** *тмн.* к.: **җәмки**.

**КҮМЗӘН** *тбл.* алтынлы бизәк (позолота).

**КҮМИЙӘ** *тбл.* к.: **қомпалық**.

**КҮМЕРИЛӘК** *злт.* күмер соскычы (совок для угля).

**КҮМКӘ I** *карс.* зәңгәр, куе зәңгәр – күзләр турында (синий – о глазах). Тәмни телләри, татли сүзләри, Сөрмәли керфек, күмкә күзләри (*бәет.*).

**КҮМКӘ II** [*рус.* комок] *мам.* к.: **ғорда**. Күмкә-күмкә балчык астында бәрәңге йата чыгалмыйча.

**КҮМПӘЧ** *эстр.* көлчә (лепёшка). Күмпәч дип әйтеләде, көлчә пешерәде мичтә.

**КҮМРӘҮ** *том.д.* к.: **көпрү**.

**КҮМСҮ 1.** *брб.д.* начар ис килү (плохо пахнуть); **2.** *перм.* к.: **қомшу**. Ботқа күмси қый шәп йақсаң.

**КҮМҮ 1.** *нокр.* к.: **йару I, 1**. Ат белән күмәләр йералманы; **2.** *төм.* утырту – бәрәңге турында (сажать – о картофеле). Әwәле йерне көрәкләйпес, сунан күмәбес картупны, цубен утайбыс та өйчөкләйпес.

**КҮН I 1.** *перм.* тире (кожа, наружный покров тела). Күн дә сүwәк кенә қалған бу қыз. Сәлдерәп тора җықа күннәре (пешкән тән турында); **2.** *перм., туб.-ирт.д.* тире (шкура, необработанная шкура). Ат күне, сыйыр күне, қуй күне булаты, пәтәрәсен тә алатылар. – *тара.* Қайwанның күнен ацытатлар кисмәктә салатлар салып (тире иләгәндә). – *төм.*; **3.** *туб.-ирт.д.* эшкәртелгән тире (выделанная шкура). Күн тақйа булаты, эт тиртән тә, мешәк тиртән тә. – *тбл.*

**күн салу** *туб.-ирт.д.* тире иләү (выделывать шкуру). Күнне көлләйтеләр, тутлайтылар талны салып, йонын цығарыб алып көлгә салып қысартып килеп ыwасың, йомшартатылар, күн салу эшкәрә азаплы. – *тбл.*

**күн II** (орёл, сторона монеты с гербом):

**күн төшү** *т.кам.-крш.* уңышлы булу (быть удачным, успешным). Аның әр нәстәсе күн төшә инде.

**КҮН III** *брб.д.* көн; кояш (день; солнце).

**пала күни** *брб.д.* балачак (детство).

**КҮН IV: күн қыс** *себ.* хезмәтче кыз (девушка-служанка).

**КҮНӘ: күнә су** *себ.* терекөмеш (ртуть).

**күнә сүwы 1.** *т.я., дөб., чпр.* к.: **күнә: күнә су**. Күнә сүwы шул терекөмөш ич инде. – *к.т.* Күнә сүwы ул куркыныч бит. – *чпр.*; **2.** *дөб.* к.: **чарыс 3**. Батырмас та күнә сүwыйы улым.

**КҮНӘК I 1.** *перм., к.-уф., тпк., стрл., брб.д.* тырыс (коробок или ведро из бересты); чаг.: **қарнаса**. Күнәк белән җыйып алып килә икән (җиләкне). Суға төшкәндә қарағат җийыб алдым күнәк белә. – *перм.* Бер күнәк шартлама йыйдым. – *к.-уф.*; **2.** *тпк., стрл.* агачтан чокып эшләнгән ачык авызлы, цилиндр формалы, чиләктән зуррак савыт, гадәттә төрле сөт ашамлыклары саклар өчен яки ипи күәсе итеп файдаланыла (посуда, выдолбленная из цельного дерева, используемая как квашня, мерка для зерна или для хранения различных молочных продуктов); чаг.: **қушма**. Күнәк белә исәпләйләр ийе ашлыкны. – *тпк.*

**КҮНӘК II** *яүшт.* к.: **көйләк**. Порноғо күнәк пы, сәнбә (синме) сақладың?

**КҮНӘЛӘҮ** *брб.д.* көнләү (ревновать). Агаң килеп саңа күнәләп аттан түшмәй китте.

**КҮНӘРГӘШҮ** *төм.* бер-береңнән көнләшү (завидовать друг другу).

**КҮНӘЧӘК** *эстр.* к.: **абзар 3**.

**КҮНЕМЛЕ** *тбл.* **1.** күндәм (послушный, покорный). Әкәсе күнемле геше, йарар, тигән; **2.** түземле (терпеливый).

**КҮНДЕРҮ 1.** *хвл., мәл., лмб.* үтәү, башкару (выполнять). Шул эшне дә күндереп кат'саң инде, аннан ары ни дә кирәкми. – *мәл.* Ике үнең хезмәтен күндерә. – *лмб.*; **2.** *лмб.* төзәтү (вылечивать, исцелять). Чыбык геле чыбанга йарый, күндерә чыбанны диләр; **3.** *лмб.* баш төзәтү (опохмелиться). Иртә тырып баш күндерергә чакыра-

лар. Баш күндердек тә анан йәш киленне барыб алырга кирәк.

**КҮНЕЧ** 1. *нокр.* куныч (голенище). Итек күнеч. Ыйық күнеч; 2. *карс.* куныч, күн итек кунычы (голенище кирзового сапога).

**КҮНЕШҮ** *себ.* күнү (соглашаться).

**КҮНИК** [*рус.* конюх] *бәр.* ат караучы (конюх). Пинсийәгә чыққанчыға хәдәре күник булыб эшләдем.

**КҮНЛҮК** *тбл.* чиркәүдә төтәтү өчен кулланыла торган хуш исле сумала (ладан). Күнлүк төтәтәмен.

**КҮННӘ** *брб.д.* беркөн, бервакыт (однажды).

**КҮНПАТЫШ** *брб.д.* көнбатыш (запад).

**КҮНТӘМ** *саз.я.* борын (мыс).

**КҮНҮ** 1. *брб.д.* кызгану, кайгырту (жалеть, заботиться о ком-либо); 2. *брб.д.* көнләү, көнләшү (быть завистливым, завидовать); 3. *срг.* ияләнү (привыкать). Мин килдем, күнәлмимен бер дә. Азбарлары кийык керәлмәм, Былдырлары бийек менәлмәм. Үзләре дә усал, телләре ачы, Мин ул ызбаларга күнәлмәм (*кыз елату җыр.*).

**КҮНҮГҮ** *тбл.* тыныч кына көтү (спокойно ожидать).

**КҮНҮЛӘҮ** *брб.д.* 1. к.: **күнәләү**; 2. көнләшү (проявлять зависть, завидовать).

**КҮНЦҮЛЕК** *тара.* көнлек (дневной, достаточный на день). Мыннан йити күнцүлек йир булыр.

**КҮНЦЫҒЫШ** *брб.д.* көнчыгыш (восток).

**КҮНЧЕ** *твр.* к.: **қап I, 2**. Йити күнчеләп аш бирдем, йитимләрне тойдырдым.

**КҮНЧЕК** 1. *т.я.* к.: **вырт**. Күнчекләрем қутырлаған, awызымны ача да алмыйм. – *к.т.*; 2. *мам., бәр., тмн., лмб.., байк.* изү аермасының килеп туктаган чиге, изү очы (конец прореза рубашки). Күзгә арпа чықса, күнчек белә имниләр. – *мам.* Арпаны күнчек белән имниләр әбиләр. – *байк.*; 3. *каз.ар., минз., кргл., бгрс., шрл.* күлмәк изүе (прорез рубашки); чаг.: **йапыртма**. Күзгә арпа чықса, күлмәк күнчеге белән имниләр, күзгә төртәп-төртәп: «Ни булған?» – «Арпа булған!» дип, ун мәртәбә әйтәләр. – *минз.* Құрғашынны эретәләр дә күнчектән төшөрәләр: нидән құрықса, шул сүрәт төшә. – *лш.* Қойаш чыққанчы күнчек белән имниләр арпаны. – *дөб.*; 4. *хвл., кузн.* куен, кесә (пазуха, карман). – Күктә-күктә ниләр бар? – Күл буйында кызлар бар; – Күнчегендә ниләр бар? – Йыпар белән шәкәр бар (*уен такмагы*). – *хвл.*

**КҮҢГЕЛДИ** *лмб.* к.: **бырцак: бырцак үләне**.

**КҮҢГЕРМӘҮ** *т.я.-крш.* яшәмәү, үлә бару – балалар турында (не жить, умирать – о детях). Оланшак күңгермәй иде аныкы.

**күңел** (душа, сердце, внутренний мир, чувство человека):

**күңел сарсылу** *дөб.* к.: **сарсылу**.

**күңел тарығу** *туб.-ирт.д.* эч пошу, ямансулау (грустить).

**күңел чығу** *лш.* гайрәт чигү (охладеть, пропасть – об интересе). Бер килгәннәр ийе әртисләр, күңелебез чыгып қалды, жүнле әйбер апкилмәгәннәр ийе.

**күңелгә йағу** *твр.* күңелгә яту (приходиться по душе). Сүсе күңлемә йаққанға күс чигемне салғанмын.

**күңелгә керү** *төм.* шикләнү (подозревать, заподозрить). Кеше суйған итне ашамыйм, әллә ни күңелемә керәте.

**күңелдә йатмау** *перм.* истә калмау, хәтердә сакланмау (не запоминаться, забываться). Минем қолақ берсе ишек, берсе тишек, күңелемдә йатмый, онотам.

**КҮҢЕЛЦӘК** 1. *туб.-ирт.д.* олы күңелле (великодушный); 2. *тбл.* йомшак – кеше турында (добрый – о человеке).

**КҮҢЕЛЧӘК** *мам.* күңелле, шаян (весёлый, жизнерадостный, озорной, шутливый). Үзләре шундый күңелчәк инде.

**КҮҢЕЛЧҮ** *твр.* күңел булу (остаться довольным, удовлетворённым). Күңелем күңелчеми қала, бирим әле, дидем.

**КҮҢЛӘК, КҮҢНӘК** *брб.д.* к.: **көйләк**.

**КҮҢСҮ** *перм., тбл.* көю (пригореть). Фу, күңсегән, қазаннан жаматай ис килә.

**КҮҢЦҮК** *брб.д.* кәнизәк (рабыня). Инә қайа пағып әйтти: Күңцүгүн пугдай қауртып йи.

**КҮПЕР** *перм.* өсте бөркәүле ишегалдында тактадан түшәлгән идән (дощатый пол закрытого двора). Күперне нийә сепермәдең, пычрақ қына.

**сират күпере** *срг., кузн., мәл.* к.: **дуга: күк дугасы**.

**КҮПЕРӘП** [*рус.* погреб] *тбл.* к.: **нәүрәп**.

**КҮПЕРМӘ** *тара.* төче күмәч (сдоба из пресного теста).

**КҮПЕРТЕП-КҮПЕРТЕП** *минз.* ак чүпләм ясап, чуптарлап (делая холст узорчатым – путём браного тканья). Күпертеп-күпертеп чүпләп суғалар оста кеше. Бит жаулыкларын да күпертеп-күпертеп суғалар ийе.

**КҮПЕРТМӘ** 1. *т.я., чпр.* куе итеп тугланган төче камырдан, табага салып, узган мичтә пешерелә торган азык (большая лепёшка из пресного теста). Ақ бодай онон сөткә, жоморқаға ғына туғыладым да зур табаға күпертмә итеп салып тықтым пичкә. – *к.т.*; 2. *т.я., минз., тпк.* борчак, ясмык, карабодай онынан пешерелгән калын коймак (тонкая лепёшка из гороховой, просяной, гречишной или чечевичной муки). Борчақ күпертмәсе, жасмық күпертмәсе қайнар көйө ашарға ғына тәмне була ул. – *к.т.*; 3. *тмн., кузн., хвл.* к.: **түː түкоймагы 2**. Төчөтеп күпертмә пешерәләр түононнан. – *хвл.*

**КҮПКӘ** 1. *саз.я.* сыер абзары (коровник, хлев); 2. *брб.д.* к.: **абзар 1**. Әтисе сандықны күпкәгә күмгән. – *брб.д.*

**КҮПКӘК** 1. *чст.-крш.* зур корсаклы, юан (толстопузый). Күпкәк ич ул, кайа жүгерсен; 2. *тбл.* эч күбү авыруы (болезнь вздутия живота). Күпкәк пулаты, онно пасасың, шалый сөтнө йышып күкрәг awысына қуйасын, аннары ул йарашаты, йомшақ пулады.

**тимер күпкәк** *тбл.* рахит (рахит). Тимер күпкәк пулаты, төс қуйанныкы пашын қоротасын та паланыңқы үсәген төрткәләп қарайтылар, урап йатқысатылар.

**КҮПКӘКЛӘҮ** *твр.* эч күбү (вздуться – о животе).

**КҮПКӘН** *твр.* рахит, зур корсаклы (рахит, вздувшийся живот).

**КҮПКЕН** *тбл.* көчле дулкын (большие волны).

**КҮП-КҮҢГӘК** *т.я.*, **КҮП-КҮҢКӘХ** *сазл.* күмкүк (совершенно синий). Иреннәре күп-күңгәк булган. Күп-күңгәк булгансың бит, чык судан. – *к.т.* Күп-күңкәх awыс-иреннәре. – *сазл.*

**КҮПЛӘК** *твр., тара.* сай җир (мелководье).

**КҮПЛӘҮ** *мәл.* нәрсәне дә булса күпләп, зур итеп эшләү (делать что-то помногу, в большом объёме). Варинийыны күпләмә, бавырыңа йарамас.

**КҮПМӘ I** *чст.* эч авыруының бер төре: эч күбү (одна из болезней живота, сопровождающаяся вздутием). Күпмә булган баласына, бала тын ала алмый торган була. Игезәк бала тапкан кеше табан (үкчә) белән баскаклый, бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, аннан киргә саный, өч мәртәбә санап тибә дә шифасы шунда була.

**КҮПМӘ II** *эчк.* к.: **кийез**. Күпмә йәйәм сезгә.

**КҮПРӘК** [*рус.* погреб] *туб.-ирт.д.* к.: **нәүрәп**. Күпрәктә сөтләр тораты. – *тбл.*

**КҮПРЕ** *тбл., брб.д.* к.: **көпрү**.

**КҮПСҮ** *минз.* **1.** артык ачу – сөт азыклары турында (прокиснуть, перекиснуть – о молочных продуктах); чаг.: **көҗәләү 3**; **2.** к.: **қабыгу 2**. Бурадағы ашлық күпсегән; **3.** *злт.* ачып күперү (бродить, прокиснув вспениться). Өстен асып қуйдың исә, күпсеп сыга.

**күптән** (давно):

**күптән йуқ** *блт., нокр.*, **күптән йук** *хвл., кузн.* күптән түгел (недавно). Күптән йуқ қалаға йөрәдек, кәбен күлмик алдық. – *нокр.* Күптән йук кына килделәр. – *хвл.*

**КҮПТЕРМӘ 1.** *срг., хвл., минз., стрл., чпр., тпк.* к.: **күпертмә 2**. Күптермә салабыз бырцак ынынан алма былан ашарга. – *чпр.*; **2.** *срг., хвл.*, к.: **күпертмә 1**. Күптермәне кул белән басмисың, кашык белән атлыйсың гына. – *срг.*; **3.** *тбл.* кабартма (булочка из дрожжевого теста).

**борчақ күптермәсе** *минз.*, **борчак күптермәсе** *стрл.* к.: **күпертмә 2**. Борчак күптермәсе ныгытып каксаң, әй тәмне булып пешә. – *стрл.*

**карабодай күптермәсе** *срг.* к.: **күпертмә 2**. Карабодай күптермәләре пешерәләр иде.

**күкәй күптермәсе** *стрл.* йомыркага аз гына он салып пешерелгән калын белен (толстый блин, испечённый из яйца, смешанного с мукой в небольшом количестве).

**КҮПТЕРМӘЛӘП** *байк.* кабартып (выпукло, делая выпуклым). Поцмакларына кабартып-кабартып күптермәләп чигелгән ийе шәлем.

**КҮПЦӘК I** *чпр., чст.* к.: **йастык I**. Мын′и баш астыңа күпцек сал. – *чпр.*

**КҮПЦӘК II** *тбл.* к.: **эремек**.

**КҮПЦҮ I 1.** *тбл.* калку (всплывать). Ағац сута күпцеп цығаты; **2.** *тбл.* йоклау (спать). Төшгәцә күпцейте; **3.** *төм.* шыңшу (хныкать). Күпцеп утырма.

**КҮПЦҮ II** *сазл.* к.: **күпсү 1**. Аш күпцит, халатилниккә утыс.

**КҮПЧӘК** *стрл.* к.: **йөгөртмә II**.

**КҮПЧЕК 1.** *т.я., каз.ар., минз., кмшл., крғл., бгрс., шрл., чст., мәл.* к.: **йастык I**. Быйыл қазлар күп суйғач, аңа да зур-зур ике күпчек җасадым. – *к.т.* Олорақ кешеләр күпчек ди мендәрне. – *лш.* Теге күпчекне син ал җоқларға. – *каз.ар.-крш.* Бу бәләкәй күпчекне салыйқ әле. – *мам.* Ана, ал бу күпчекне, йатып тор диб әйтмәде. Karawat әйберләре, күпчекләре – бөтөнөсе җандинде. – *минз.* Ике мамық күпчеген ала да китә. – *бгрс.* Баш астына күпчек салып йат. – *мәл.*; **2.** *т.кам.-крш.* мамыктан гына ясалган мендәр (подушка, набитая лишь пухом). Күпчек қad мамығыннан ғына була, аны бик қәдерле қунаққа ғына саласың.

**күпчек камфит** *мам.* дүртпочмаклы конфет (конфеты-подушечки).

**күпчек сатулашу** *каз.ар.-крш.* яшь кияү белән кәләшкә беренче тапкыр җәелгән урын өстендәге кыз яки малайга кияүнең акча бирү йоласы (обычай, согласно которому жених одаривает монетами девочку или мальчика, специально посаженных на постель новобрачных). Ишек төбендә күпчекләрне сатулашырлар ийе, түшәкне кийәү сатыб ала бытта.

**КҮПЧЕТҮ** *минз., стрл.* күпертү – тән тиресе турында (делать пузыри – о коже, теле). Қырлы қурай иренне күпчетә. – *минз.*

**КҮПЧҮ** *мам.* к.: **күпсү 1**. Әче су әчегән генә түгел, күпчегән. Әчеп, күпчеп җата бу қатық.

**КҮПШӘК I** *тмн.* бодай онынан пешергән ак ипи, бодай күмәче (калач, белый пшеничный хлеб). Күпшәкне кицен куйасың, иртүк тороп басасың.

**КҮПШӘК II** *минз.* җыйнаксыз, булдыксыз (неряха, растяпа). Күпшәгрәк кешенең ашы да тәмне була.

**КҮПШЕНҮ** *чпр.* күбенү (пучить, дуться). Әwәле күпшенгән кешене кашмага салып каталатканнар.

**КҮР** *брб.д.* к.: **кирәмәт 2**.

**КҮРӘ** *мам.* караганда (по сравнению). Безнекеңәр күрә әз чықты моноң, ике орчоқ қына чықты.

**күрә қарау 1.** *мам., бөре.* күзләре ачык булып та күрмәү, сукыр булу (не видеть открытыми глазами, быть слепым); **2.** *дөб.* кыек күрү, күз карасының бер чите белән күрү (видеть только краем глаза, видеть криво); **3.** *мам., бөре.* игътибарсыз булу (быть невнимательным). Һи, күрә қарау, үзе шунда қарап тора, үзе күрми. Күрә қарау булдың мәллә, пычағың шунда қаршыда тора бит! – *мам.*

**КҮРӘЗӘ** *каз.ар.-крш.* күрәзәче (ворожея, гадалка, предсказательница).

**күрәзә қарау** *каз.ар.-крш.* багу (гадать, ворожить). Күрәзә қарыйлар, күрәзә қарағаның жүкмени?

**күрәзәце** *себ.* күрәзәче (ворожея, гадалка, предсказательница):

**күрәзәце абышқацық, күрәзәче абышқачық** *твр.* к.: **күрәзә**.

**КҮРӘ-ҚАРА** *к.-уф.* начар күрүче, ерактан күрмәүче, күрәкараучы (близорукий). Бер ағай өч хатынға өйләнгән дий, өчөсенең дә күзләре начар күргән, агай бу хәлгә бик ачынып, шундый бәйет чыгарған: Күрә-қара, күрә-қара, Күрә-қарадан бәхет, Тагын моносы күрә-қара, Күрә-қарадан бәхет (*такмак*).

**КҮРӘЛЕ** *яушт.* кара әле (смотри-ка).

**КҮРӘМӘ: күрәмә күрү** *перм.* к.: **күрмешләнү.** Никулай wахытларда күрдек без күрәмәне, чырақ җағып, берәүсе күмер сындырып тора.

**КҮРӘМӘТ: күрәмәтне күрү** *перм.* к.: **күрем: күрем күрү.** Күрдег инде күрәмәтне суғыш wақытта, Ходай күрсәтмәсен. Әни бигрәк шәп күрде күрәмәтне, awыр заманнар булды.

**КҮРӘН I** *кргл., бгрс.* юл яфраклы күрән (вейник тростниковидный).

**КҮРӘН II** абзар (хлев). Күрән тибес қайwан тығатқан йерне.

**КҮРӘҢ I** *твр.* көрән (бурый). Күрәң ат. Бил сауру күрәңне менгәнем.

**КҮРӘҢ II** *туб.-ирт.д.* саз печәне, саз кыягы, күрән (сено, скошенное на болоте; шумиха; сено, состоящее в основном из осоки).

**КҮРӘТӘ 1.** *мәл., чст.* күрә (смотря, по). Заманасына күрәтә. – *мәл.*; **2.** *минз.* күреп, карап (по ..., смотря на ...). Ул беддән күрәтә малай китереп барды, мин қыd тапмадым. – *минз.*; **3.** *нокр.* юри, күрәләтә (нарочно, заведомо). Күрәтә қайтмый тырабыз, диләр.

**КҮРӘҮ** *брб.д.* нечкәрү, юкару – печәннең кибүе турында (стать тонким – о подсохшем сене). Пецән күрәгән, қыртаута кипкән.

**КҮРӘЧӘК: күрәчәк күрү** *тмн.* к.: **күрмешләнү.** Күп күрәчәк күрдем.

**КҮРWИЦӘТКӘ** *сазһ.* к.: **көрпәсәткә.**

**КҮРГЕН** *твр.* яшь киленне күрергә бару (смотрины невесты). Килен цит awылтан пулса, күрген киләте.

**КҮРЕК I** *тбл., сазһ.* балыкны тере килеш саклау яки үрчетү өчен күлдән яки елгадан бүлеп алынган яки махсус казылган урын (садок). Tywанның үцегеннән палыкны сосатылар та күреккә салатылар, тоннаға қәтәр. Күрек түрт поцмақлы цалтан эшләнә, көскөсен палыкны шанта туңтыратылар, қыш алатылар.

**күрек палық тоту** *тбл., сазһ.* күрек белән балык тоту (садковый лов рыбы).

**КҮРЕК II** *перм.* төтен өрдергеч (дымарь). Күрек бал қортларын қywарға төтен биреп тора.

**күрек өй** *тбл.* тимерчелек (кузница).

**күрек цөй** *туб.-ирт.д.* арба кендеге (шкворень).

**КҮРЕКЛЕ** *лмб., хвл., срг., тмн.*, **'үре'ле** *кас.* к.: **күркле.** Күрекле awыз гына атәләр иде үземә. – *тмн.* Малайы да күрекле, икесе пар килгән. – *лмб.* Йандукада (*ав. ис.*) бик күрекле кызлар. – *хвл.*

**күрекле агай** *лмб.*, **күрекле морза** *тмн.* к.: **абзикай.**

**КҮРЕМ: күрем күрсәтү** *тмн., лмб., кузн., хвл.* җәфалау, газаплау, авырлык күрсәтү (мучить, терзать, заставить страдать). Күпме күрем күрсәтте каниш үземә. – *лмб.* Киленгә күрсәткән күрем! – *кузн.* Атасына бик күп күрем күрсәтте. – *тмн.*

**күрем күрү** *тмн., кузн., хвл., карс., мәл.* җәфа чигү, интегү, авырлыклар күрү (мучиться, переносить тяготы). Күргән күремнәреңне ынытмыйсын вет. – *карс.* Олы үлгәннән соң, килен кулына калыw, ну күремен күрде инде, факыр. – *мәл.* Кан'ишка барган, күрем күргән. – *кузн.* Бик вет күремнәр күрдек инде. – *хвл.* Мин кан'иштән күп күрем күрдем. – *тмн.*

**эт күреме** *лмб.* авырлык, нужа (трудности, нужда); чаг.: **аламалық; дәрт 1.** Эт күреме күрде.

**КҮРЕМЛЕК** *тара.* **1.** егет ягыннан кыз ягына туй ясау өчен бирелә торган ашамлык әйберләр (продукты, преподносимые стороной жениха родителям невесты для свадебного застолья). Күремлекне қысның атинәсе сурайды қый, пер қаб он, қуй, поронғорақта булғанты ул. Күремлек сурый қысның әтиләре кийәүдән, он буламы, қуй буламы инде, кешенең хәленә қарап; **2.** киленгә бирелә торган туй бүләге (свадебный подарок, преподносимый невесте); **3.** кияү өендә, кызны күргәч, бирелгән бүләк (подарок невесте, даримый после того, когда увидели её в доме жениха). Қыс пашта цымылтықта утырған, әцемлек питендә, бер пала ике орцоқ ман әцемлекне күтәреп ацаты, күремлек пиреп күрешәсен; **4.** *әстр.* килен килгәч, беренче күрешкәндә кызга кияү туганнары тарафыннан бирелә торган бүләкләр (подарки, преподносимые невестке со стороны жениха после переезда её в дом жениха). Килен кигәчен, күремлек сорыйлар, килен килде, **күреңез**, күремлеген биреңез.

**КҮРЕМНЕК 1.** *тара.* к.: **күремлек 3.** Иге цыбық ман ацатылар киленцәкнеке әцемлеген, күремнек пирәсең күргәц; **2.** *кузн., тмн.* кияү тарафыннан кыз туганнарына бирелә торган бүләк (подарок жениха родственникам невесты). Кийәүнең күремнеге кан'иш халкына күлмәк, шәл. – *тмн.*

**күремнек бүләк** *кузн., тмн.* кияүнең кызга беренче мәртәбә күрешкәч биргән бүләге (подарок жениха невесте при первом свидании). Күремнек бүләк. – *тмн.*

**КҮРЕМЦЕ 1.** *тара.* им-том итүче (знахарь). Күремце әпләйте, тереләсең; **2.** *тбл.* к.: **күрәзә.** Күремцегә қаратқаным.

**КҮРЕМЧЕ** *каз.ар.-крш.* күрәзәче, багучы (ворожея, гадалка, предсказательница). Бер күремче килгән ийе.

**КҮРЕМЧЕЛӘР** *глз.* карап торучылар (присутствующие, наблюдатели). Җиңгилеләр белән җырлатып җөрәйләр, беләбез инде қыз урлағаннар, қарарға чығабыз, күремчеләр була инды қыз йақтан да, йегет йақтан да.

**КҮРЕНГЕР** *тбл.* күренә торган, күренүчән (часто предстающий перед глазами, виднеющийся). Қурықсаң, йылан күренгер пулаты.

**КҮРЕНДЕРҮ** *лмб., м.-кар.* элек: туй мәҗлесендә кунаклар алдында яшь киленнең битенә ябылган бөркәнчеген ачу (в старину: снять у невесты головное покрывало перед собравшимися гостями во время свадебного пиршества). Халыг инде килә, эстәл кыругына килеп басалар кыз ман йегет шанда инде, кызнын инде фәрдәсен бер бала ала, анарга кыз йаулык бирә, ул инде күрендерү була. – *лмб.* Кайнанасы күрендерә, бүләк бирә йәш киленгә. – *м.-кар.*

**кийәү күрендерү** *срг.* яраշкәннән соң, кыз ягында егетләр һәм кызлар җыеп мәҗлес уздыру (провести молодёжную вечеринку у невесты после сговора).

**КҮРЕНЕШ 1.** *дөб.* яшь киленгә аның белән беренче күрешкәндә бирелә торган бүләк (подарок, даримый кем-либо невесте при первой встрече). Күренешкә нәрсә алып керим икән йәш киленгә; **2.** *злт.* кияү белән кәләшнең беренче күрешкәндә бер-берсенә бирә торган бүләкләре (подарки, даримые женихом и невестой при первой встрече). Кийәү кеше дә тәүге барған сакта күренеш бирә кызга, кыз да бирә. Қайсан күрешәләр, шунда бирәләр күренешне.

**әwәлге күренеш** *перм.* кыз килешкәч, егет әтиәниләренең кыз әти-әниләрен беренче мәртәбә кунакка чакыруы (первое приглашение в гости родителей невесты в дом жениха после сватанья). Әwәлге күренешкә дә чақырдылар безне.

**күренеш йасау** *перм.* качып чыккан кыз һәм аның кияве беренче тапкыр кызның ата-анасы йортына кунакка баруы (первое посещение женихом и невестой её родительского дома после выхода девушки замуж убегом). Әwәле барғас, бер атнарас торабыз да әнигә күренеш йасыйбыз.

**күренеш қунақлары** *перм.* беренче тапкыр күренешкә килгән кунаклар (гости, присутствующие в угощении, устроенном в честь первого приглашения родителей невесты после сговора). Малайның әниләре чақырыб ала қызнықы әниләрен туйға хәтле, күренеш қунақлары чақырыб алдым ый ти. Алар күренеш қунақларын чақырмағаннар ий мени.

**күренешкә бару** *перм.* к.: **күренеш йасау**. Шу сыйыр ақчаға күренешкә бүләкләр аппарды күренешкә барғанда. Кийәү күренешкә буш қул белә бармый инде.

**КҮРЕЦ** *срг.*, **КҮРЕЧ** *трх., карс.* корыч агач (ясень). Йағарға күреч ботақлары жыйып апқайттым. – *трх.*

**КҮРЕШ I** *тмн., кузн., чст., срг.* күрше (сосед). Күреш кабакта бар сипарат. Йаназа күреш. Әнкайыма әтә күрешләр, Тегел кызыңнын урнысы (*бор. жыр.*). – *тмн.* Күрешеңнән сырарлар. – *кузн.* Күрешкә йүләдем бу күлмәкне. Үмер бит ул күз белән каш арасында дий, безнең күрештә берәү пиз башында йатып үлде. Син дә керәсең, мин дә керәм күрешкә, диген. – *срг.*

**КҮРЕШ II: күреш күрү** *блт.* к.: **күрмешләнү**. Күрдек без күрешне. Күрсәттем күрешен.

**КҮРЕШЕ-АРЫШЫ** *төм., чст., чпр.*, **КҮРЕШ-КАРА** *срг.*, **КҮРЕШ-КЕВӘН** *тмн., мәл.*, **КҮРЕШ-КОРОШ** *кузн.*, **КҮРЕШ-КҮЛӘГӘЙ** *срг.*, **КҮРЕШ-КҮРӘ** *тмн.* күрше-күлән (соседи). Күреш-каралар белән бара. Күреш-кевәннәрне чакыралар туйга. – *тмн.* Күреш-күрәләрдән сырармын катык. Кыш көнә кич утырырга жәрим мин күреше-арышыга. – *чст.* Күреше-арышы, туганнар китерә күлмәк. – *чпр.* Күреше-арышы сураштырған. – *төм.*

**к ү р е ш ү** (видаться, видеться; свидание, встреча):

**күрешү қунағы** *перм.* к.: **күренеш: әwәлге күренеш.** Күрешү қунаққа малай йағы чақыра, қода қайчан була, қайчанға чақырабыз тип килешәләр.

**күрешүгә бирү** *төм.* килен төшергәндә каената тиешле кешенең киленгә терлек бүләк итүе (дарение свёкром невесте живности при её переезде в дом мужа). Киленцәккә күрешүгә бирәте қайината танама, сыйырма, пы сиңә күрешүгә тип.

**КҮРЕШТЕРҮ** *тбл.* яңа гына төшкән киленнең егет ягы туганнары белән күрешеп чыгуы, һәрберсе акча сала бара (обряд, согласно которому только что перешедшая невестка за руку здоровается с родственниками мужа, которые одаривают её деньгами или подарками). Аннан киленне күрештергәле цыгаратылар, пөтөн кеше белән күрешеп цыға, аңа ақца бирәтләр.

**КҮРИШ** *твр.* к.: **күреш I**. Үсләренең күришләрентә булған.

**КҮРКӘ I** [*рус.*] *м.-кар.* к.: **багырча**. Күркә белән эс.

**күркә борын** *чст.* нәдербаш (чистец забытый).

**КҮРКӘ II: күркә пуран** *тара., төм.* язгы буран (весенний буран).

**КҮРКӘЙТҮ** *тмн., кузн., карс.* матурлау, матур итү, күркәмләтү, ямьләндерү (делать красивым, украшать). Бу залларны кем күркәйткән, Зур камуд белән кезге (*хал. жыр.*). – *тмн.* Шалай частарак килсәйдегез, awылыбызны күркәйтер идегез. – *карс.* Безнең артны ни күркәйткән? – Агып барған су йулы (*хал. жыр.*). – *кузн.*

**КҮРКӘМ** *кузн., хвл., әстр.* матур – әйберләр турында (красивый – о вещах); чаг.: **йәмле 2**. Тастар өстеннән тастымал бәлиләр иде, бик йахшы күркәм кара шәлләр бәлиләр иде. – *кузн.*

**КҮРКЕ** *кргл., бгрс.* истәлек (память о ком-либо). Бу кийемнәрем балаларымның күркесе. – *бгрс.*

**КҮРКЕМЛЕ** *т.кам.-крш.* күңелле, ямьле; чаг.: **заwоклы**. Тормошым бик күркемле.

**КҮРКЛЕ** *миш.д.*, **'ҮР'ЛЕ** *кас.* сөйкемле, матур, чибәр (красивый, обаятельный). Ақ кримка бүрклесе, Шул арада күрклесе (*хал. жыр.*). – *карс.* Мин күркле тегел. – *срг.* Бик йәш вакытта күркле иде. – *хвл.* Ул 'оз би' 'ур'ле. – *кас.*

**КҮРЛӨК** [*гар.*] *брб.д.* әшәке, яраксыз (гадкий, негодный).

**КҮРМӘҮ** *тбл.* төенләп бәйләү (завязать узлом, связать в узел).

**КҮРМЕШ 1.** *срг.* җәфа, газап, интегү (мучение, мука, страдание). Салам белән күрмеш иде әwәле; **2.** *чст.* күрәчәк, язмыш (судьба, участь, рок); чаг.: **йазу II**. Күрмеш бит үзең белән. Карчыгы алдан йыгыра бара, күрмеше тартамы сың?

**күрмеш күрү** *срг.* к.: **күрмешләнү**. Күрмеш күреп килделәр йаңгырда. Күрмешне күп күрдем, кызым. Әwәлдә йәш киленнәр күпме күрмеш күрә иде.

**КҮРМЕШЛӘНҮ** *срг.* җәфа чигү, интегү, авырлыклар күрү (мучиться, переносить тяготы); чаг.: **бәлтерәү, гедәү**. Ирдән китмәстән күрмешләнеп тыра инде. Кыш буйына күрмешләнде инде, бичара.

**КҮРПӘ 1.** *тара.* көдрә йонлы бәрән тиресе (кудрявая шкура барашка); **2.** *әстр.* көрпә (матрас).

**КҮРСӘТКЕЦ** *тара.* к.: **бармақ I: балан бармақ.**

**к ү р с ә т ү** (показывать, указывать):

**чәчкә күрсәтү** *минз.* чәчәк ату (расцвести). Булмастый булса, чәчкә күрсәтми торган ийе.

**КҮРТИШЕК** [*гар.* + *тат.*] *туб.-ирт.д.* кабер (могила).

**КҮРҮ I** *минз., трх., клм.* к.: **бағу 1.** Йәле, улым, күрим. – *минз.* Ул Кийерчегә (*болын ис.*) печән күрергә киттейе. – *трх.* Сәғәтне қәсер күрәм. Күргән бололор да кесәгә салып қойолор. – *клм.*; **2.** *яүшт., клм.* к.: **бағу 2.** Йыл буйы күрдем инәңне. – *яүшт.*

**йөз күрмәгән** *лмб.* таныш булмаган (незнакомый). Йөз күрмәгән кеше.

**КҮРҮ II** *глз.* к.: **асрау 2.** Туғызны күрдем, бишесе исән. – *глз.*

**бала күрү** *глз., туб.-ирт.д.*, **пала күрү** *туб.-ирт.д.* к.: **асрау 2.** Икегә дә барды, бала күрмәде. – *глз.* Пала күрмәдем мин. – *тара.* Пы кинцәкәмем, пиш пала күртем. – *төм.*

**КҮРҮЦ** [*фарс.*] *тбл.* к.: **гөрөц.** Қәсер күрүц мән бешрәтләр пәличне.

**КҮРХӘСҮ** *саз.я.* күрсәтү (показать). Күрхәсеф алайын.

**КҮРЦЕН** *төм.* йөк – хайван өстендәге (вьюки).

**КҮРЧӘГӘ** [*рус.* корчага] *каз.ар.-крш.* к.: **кырчыга.** Арыш саламын үрдергән арыш оно белән манчыйлар да, балтушка шикелле йасап, күрчәгә белән пичкә тығалар. Пичкә тығабыз күрчәгәләр белән сосланы, иртә белә алабыз да ағызабыз. Бер күрчәгә балық тозладым.

**КҮРШӘК** [*рус.*] *брб.д.* чүлмәк (горшок).

**КҮРШЕ-ҚҰНАҚ** *туб.-ирт.д.*, **КҮРШЕ-КҮБӘ** *дөб., бәр.*, **КҮРШЕ-КҮРПЕ** *блт.* к.: **күреше-арышы.** Күрше-қунақ пан сүләшеб утырабыс. – *тара.* Туйға барам, Аллах Тәғалә көн пирсә, күрше-қунақ тун пирсә. – *тбл.* Тырактыр белән үтәргә бирмәделәр күрше-күбәләр. Киткәненә күрше-күбәсенең исе китте. – *дөб.* Күрше-күбәгә керми тормыйсың ич. – *бәр.* Күрше-күрпеләр бик күрергә сусап торалар. – *блт.*

**КҮРШЕ-ТИҢӘРӘК** *туб.-ирт.д.* якын-тирә, күрше-тирә (окружение, соседи). Күрше-тиңәрәктәге awылларда бар. – *твр.*

**КҮС I 1.** *себ.* күз (глаз); **2.** *тбл.* җылу (полынья); **3.** *туб.-ирт.д.* сазда ачык су (водное место среди болота).

**күс айтын** *туб.-ирт.д.* **1.** туганнарыннан берәү ерак юлдан кайтканда, гаиләсен котлап әйтелгән сүзләр (слова, которые произносятся при поздравлении семьи с возвращением издалека кого-нибудь из её членов); **2.** котлау – шул ерактан кайткан туганны (приветствие в той же ситуации). Улы әрмийәтән килепте, күс айтынға герү гәрәк. – *төм.*

**күс бетү** *туб.-ирт.д.* к.: **күс йуwалу.** Шәмшинеңке күс бетте пәғыремнеңке.

**күс йару** *саз.я., тбл.* к.: **асрау 2.** Аның күсе йарған. – *тбл.*

**күс йуwалу** *брб.д.* сукыраю (ослепнуть). Күс йуwалты, үсем чаып йөрәр итем.

**күс кешесе** *твр.* к.: **күс пәбәйцек.**

**күс күрмәwец** *төм.* күз бәйләш (игра в жмурки).

**күс пәбәйцек** *тара.* күз карасы (зрачок).

**күс петү** *туб.-ирт.д.* к.: **күс йуwалу.**

**күс серәйү** *саз.я.*, **күс тармайу** *тара.* күз акаю (вытаращиться – о глазах). Теге гиләте, пайы, гүсе тармайып, қарап тораты.

**күс таш, күс ташы** *туб.-ирт.д., брб.д.* к.: **күс пәбәйцек.** Күс ташы ғап-қара нәрәситәнең. – *төм.* Күс таш цыққыныңцы көргән мән. – *брб.д.*

**күс ташым цыққынцы** *тбл.* күзем чыкканчы (пока не вылупились глаза). Күс ташым цыққынцы эшләп утырып қуйтым.

**күс төшү** *яүшт.* күз тию (подвергнуться сглазу).

**күс чергәй, күс черки** *твр.* к.: **йомоқ.**

**күстән үлү** *брб.д.* күз тиеп үлү (умереть от сглаза).

**соло күсле** *твр.* төссез күзле (с бесцветными глазами). Йәмсес, пәтер чырай, соло күсле.

**уң күсне салу** *твр.* кайгырту (заботиться). Пер уң күсен салып йөрте, қыйналтырматы.

**КҮС II** *себ.* **1.** бөртек (крошка, крупинка). Пирце бер гүс цейә. – *саз.я.*; **2.** данә (штука). Перәр күс, икешәр күс палық пирәте, онно шабала белән пүләткәнтек. – *тбл.* Ике гүс туқац ашайым. – *төм.* Циләккә икешәр күс кирмец салатылар. – *тара.* Пер генә күс таwығым күкәй салматы. – *брб.д.*; **3.** баш – терлек санын алганда (голова – при счёте животных). Атам тонйа тотқан, ун күсләп ат асыраған. – *тбл.*

**бер күс** *себ.* к.: **пер гүс.** (Монда) мең паш мал, анда да анча уқ, бер күс қалмады қәзер. – *тара.*

**wақ күсле** *тара.* вак (мелкий). Wақ күсле йаңғыр әкрен генә йаwаты, қаwақ церетмә йаңғыр.

**күсле ботай** *твр.* бөртекле бодай (пшеница в зерне).

**пер гүс, пер күс** *туб.-ирт.д., том.д.* **1.** берәү генә, бердәнбер (один единственный, единственный). Көлчирә тә пескә пер күс кенә. – *төм.* Пер гүс сарығыбыс бар ыйы. – *тбл.*; **2.** бер бөртек тә, бер генә дә (ни единого, ни одного). Пер гыратта (түтәлдә) бер күс кишер йуқ. – *төм.*

**КҮС III** *себ.* каш (глаз, камень – на ювелирных украшениях). Күсле алға. – *тбл.* Күсле пеләлек тә була. – *төм.* Цылбыныңқы урта йерентә қып-қысыл сур күсе бар. – *тара.* Күсле алғалар қатқалы йаратам. – *твр.*

**КҮС IV** *твр.* к.: **күз IV.** Перәй нимәне инәмнең күсе итеп йөртәсең.

**КҮСАЙТЫН: күсайтынға килү** *тара.* ерактан кайткан берәүне котларга, аның белән күрешү мәҗлесенә килү (прийти поздравить того, кто вернулся из долгосрочного пребывания в дальних краях). Күсайтынга килтем, сөйөнцесен бирә тә цай эцерә, ул тыцерә, мин тәцерәм.

**КҮСӘ** *себ.* **1.** су кайната торган чуен яки тимер чәйнек (чугунный или железный чайник удлинённой формы для кипячения воды). Цайны күсәгә қайнаттым. Монтай күсә, йес, эце аппақ, цай қайнатыб эцкәле. – *тара.*; **2.** к.: **гал′ник.**

**КҮСӘБӘ: күсәбәсе белән** *дөб., блт.*, **КҮСӘК: күсәге белән** *к.т.* к.: **кистран: кистраны белән.** Нигә күсәбәсе белән күтәрдең (итне), хәзер аш була бит? – *дөб.* Баласына күсәге белән икмәк күтәрткән, сындырып қына бирсә җарамағанмы?

**КҮСӘЛМӘГӘ, КҮСӘМӘЛГӘ** *перм.* **1.** юкка, бушка (попусту, зря, напрасно). Күсәлмәгә барып қайттым. Күсәлмәгә ачуланма тип әйтәм; **2.** бер дә юктан, сәбәпсез (без всякой причины); чаг.: **дихай 1.** Күсәмәлгә генә айырылыштылар да мине ғәйепле итеп қалдырдылар.

**КҮСӘМӘН: күсәмәне белән** *мам.* к.: **кистран: кистраны белән.** Күсәмәне белән тотқан ипийен, күтәрелеп қарамый да, ашawын ғына белә.

**КҮСӘНӘК** *тара., брб.д.* өйалдының яки сарайның кечкенә тәрәзәчеге (маленькое оконце в сенях или сарае).

**күсәнәк қапқа** *туб.-ирт.д.* җил капка (лёгкие, одностворчатые ворота, сколоченные из жердей).

**КҮСӘУ I** *лмб., кузн.* к.: **йосомбаш.** Чәй әзер, бер күсәве генә бар. – *лмб.* Әби сукрайсын өчен күсәү төтенән чыгара да чыгара (*мәзәк.*). –*кузн.*

**КҮСӘУ II** *туб.-ирт.д.* төзәү, төбәү (целиться, прицелиться). Мылтыкны күсәп атып йебәртем ғуй. – *тара.*

**КҮСӘ-ЦӘЙНЕК** *тара.* савыт-саба, чәй кайнатып әчү кирәк-яраклары (посуда, принадлежности для чаепития). Әwәлге түрәләр син урмәген, мин йурғанын талап, күсә-цәйнекне алып цығып.

**КҮСЕРЕП** *тпк.* күп итеп, күче белән, уч тутырып (много, кучей, полной горстью). Эшләгән кешегә күсереп ақсасын бирә.

**'ҮСИW** *кас.* к.: **йосомбаш.**

**КҮСКӘ** *брб.д.* көзге (зеркало).

**КҮСКӘЛӘК** *тара.* к.: **күсмамай.** Күскәләкнең күсе йуқ, күсе пулса, үсе йуқ.

**КҮСЛӘЙ** *туб.-ирт.д.* к.: **күслəтə.** Күслəй йеләк салтым мин күркәнең (чумечнең) эценә шикәр белән болғап. – *тара.*

**КҮСЛӘНҮ 1.** *тара.* күз тию (подвергнуться сглазу); **2.** *төм.* күз ачылу (открываться – о глазах).

**КҮСЛӘТӘ** *туб.-ирт.д.* бөртекле килеш (в виде зерна, зерном). Ашны күслəтə пирəте. – *твр.*

**КҮСМАМАЙ** *яүшт.* күз бәйләш уены (игра в жмурки).

**КҮСМӘҮЦИЛӘҮ** *тбл.* **1.** белдермичә генә карап тору (подглядывать, подсматривать незаметно). Күсмәүциләп алып китәр үсеңне; **2.** шамакайлану; шамакайлык (паясничать; шутовство).

**КҮССЕС** *туб.-ирт.д.* **1.** к.: **қашақ 2.** Күссес қортқайақ; **2.** к.: **йомоқ.** Осағ эшләгәле булмай төстә, күссес цәйнәйте. – *тбл.*

**күссес цергәй** *туб.-ирт.д.*, **күссес цебен** *тбл., саз.я.* к.: **йомоқ.**

**күссес цыцқан** *саз.я.* к.: **әндәк.**

**КҮССҮWЫ** *т.я.* күз яше (слеза). Күссүwың ағызып утырма жүғ өчен. – *к.т.*

**КҮСТӘНӘЧ** [*рус.*] *хвл., мәл.* к.: **келчә 2.** Күстәнәчләре бик тәмне булды, бүләкләре бик матур. – *хвл.*

**КҮСТӘҮ** *том.д.* текәлеп карау (смотреть пристально).

**КҮСҮ I** *мәл.* к.: **кисү II.**

**КҮСҮ II** *мәл.* тоту – әйтемдә (взять, держать – в поговорке). Кеше кулы белән ут күсә.

**КҮТӘРӘМ 1.** *мам.* күтәреп ташый торган йөк, авыр әйбер (тяжёлая ноша). Суғыш wахытында ғел җилкәдә ташыдық инде, күтәрәмнәр күтәргәнгәдер инде, күз күрмий; **2.** *каз.ар.-крш., минз., тпк., кргл.* к.: **чәбен.** Қул тырмасы белән күтәрәм җыйалар. – *минз.* Күтәрәм ике сәнәклек буламы? – *тпк.* Пакусны ике йақтан күтәрә икән, аны күтәрәм, диләр, күтәрәм җыйып қайттық, диләр. – *кргл.*; **3.** *тбл.* үз гәүдәсен күтәрә алмый торган, утырган урыныннан күзгала алмый торган (тяжёлый на подъём).

**күтәрәм булу** *перм.* күтәрәмгә калу – ат турында (дойти до полного истощения – о лошадях). Атлар күтәрәм булып беттеләр.

**КҮТӘРӘМНӘҮ** *тпк.* күбәләү, печәнне бер күтәрелек өемнәргә өеп чыгу (сложить сено мелкими ворохами на один подъём). Тауда песән күтәрәмниләр.

**КҮТӘРӘМЧЕЛӘР** *кргл.* элек: Казан ягыннан вак товарлар алып килүчеләр (в старину: коробейники – люди, привозившие из Казани мелкие товары на спине). Элек Қазаннан күтәрәмчеләр киләләр ийе, қапчық күтәреп киләләр ийе.

**КҮТӘРГӘК** *тара.* сазлыктагы тирбәлеп торган урын (трясина в болоте).

**КҮТӘРЕЛҮ I** *тпк.* күшегү (озябнуть, продрогнуть). Таwық күтәрелеп беткән сыwда.

**КҮТӘРЕЛҮ II** *лмб.* төшү, чыгу – сипкел турында (появляться – о веснушках). Кыкычыбар йаз башын күтәрелә, мындый чыбар күтәрелми.

**пажар күтәрелү** *клд.* янгын чыгу (вспыхнуть пожар). Калныда (*ав. ис.*) пажар күтәрелде.

**КҮТӘРЕЛҮ III** *брб.д.* кабару – камыр турында (подняться – о тесте). Қамырымты күтәрелепме.

**КҮТӘРЕҢКЕ 1.** *минз.* һавалы, тәкәббер (высокомерный, горделивый). Үзен әллә кемгә қуйып, күтәреңке йөргән кешене йаратмыйлар; **2.** *стрл.* бай, барлыклы (богатый, имущий). Бик күтәреңке кеше булмаган элег-электән; **3.** *бөре.* югары (наверху, вверху). Шуңардан күтәреңке генә пансионат бар.

**КҮТӘРЛӘНҮ** *перм.* күтәренү (поднять, захватить много вещей). Қараб алдым, и күтәрләнгәннәр, икесе киләләр.

**КҮТӘРМӘ I** *минз., бөре., перм., байк., к.-уф., дөб., злт., тпк., трбс.* к.: **болдор.** Күтәрмәдән сығарып ташлыйбыз да ишекне элəбез дə қуйабыз. – *злт.* Күтәрмәдән айақны алып булмай. – *трбс.* Күтәрмәдән менгәндə бидрәдəге сүwымны түктем. – *бөре.* Күтәрмастын қара, булса пешеребез (йомырканы). – *минз.* Шунда күтәрмаста кичкə чақлы җата wыл (эт). – *перм.* Йаңғыр килə, күтәрмəгə айақ кийемнəрен апқуйасы бар. – *дөб.*

**күтәрмә башы, күтәрмә өстө** *минз.* тышкы өйалды, баскыч башы (верхняя, более просторная ступенька крыльца). Җыраг эби бозауға бәрәңге турый торғандыр күтәрмə башында. Өйалдында ут бар, күтәрмə башында ут йуғ икән.

**КҮТӘРМӘ II 1.** *нокр., глз., эчк.* к.: **келə.** Күтәрмəлейе қайулы читегем. – *глз.* Итек күтәрмəсе төшəп қалған. – *эчк.* Читекнең күтәрмəлесен дə, күтәрмəсезен дə алып қайттым. – *нокр.*

**өзөклө күтәрмə, өдөклө күтәрмə** *минз.* чабатада: тоташ булмаган күтәрмə (несплошная подставка, прикрепляемая к лаптям). Чабатаға күтәрмə қағып чығадыр ыйық су үтмəскə, өдөклө күтәрмə дə буладыр ыйы.

**КҮТӘРМӘ III 1.** *срг.* к.: **бастырма.** Пайыт астындагы күтәрмəдə пецән бар; **2.** *срг., чпр.* к.: **пайыт: лапас пайыт.**

**күтәрмә башы** *срг.* к.: **бастырма**. Бер күтәрмә башы пеҙән китерделәр.

**КҮТӘРМӘ IV** *нгб.-крш.* күтәрелеп ачыла торган тәрәҙә (поднимающаяся форточка, фрамуга). Күтәрмәләрне ачып ҡибәр.

**күтәрмә сату** *дөб.* кырыктартмачы булып йөрөү, вак-төяк сату (быть коробейником, продавать мелочь). Күтәрмә сату белә йөриләр ийе, тегәрҙәпләр, буйаулар, инәләр сатып.

**КҮТӘРМӘЛӘҮ** *тара.* салпы якка салам кыстыру (подольститься, подъехать). Син күтәрмәләп суғылып паҡсы.

**КҮТӘРМӘЛЕ** *т.кам.-крш.* чүпләмле (сотканный браным способом). Күтәрмәле ашаулығым ҙанды.

**КҮТӘРМИС** *трх.* грамотасызлыкны бетерөү (ликбез) вакытында халыкны укырга өйрәтүче (человек, занимающийся ликвидацией безграмотности). Күтәрмисләр булып йөрөдем наданнарның белемен күтәрөү буйынса.

**КҮТӘРТМӘ I** *перм.* к.: **болдор**. Безнең күтәртмәнең ҙиде киртләче бар.

**КҮТӘРТМӘ II** *т.я., кмшл., мәл.* күтәрмә (деревянная подставка, прикрепляемая к лаптям).

**КҮТӘРТҮ** *лмб.* күтәрәмгә калдыру, ябыктыру (сильно ослабить, довести до полного истощения). Кышын атларны күтәртте.

**КҮТӘРҮ I 1.** *баст., каз.ар.-крш., мәл.* өю – бәрәңге төбен (окучивать – картошку). Алаша белән сызып булмас, ҡулда күтәрәләр. – *баст.* Бәрәңгене мутык белән күтәрәбез. Ҡул белән дә күтәрәбез, суҡа белән дә сызалар. – *каз.ар.-крш.* Минем Әримам кулга да тигерми бакчаны, матикли да, күтәрә дә. – *мәл.*

**КҮТӘРҮ II** *күзн.* уздыру, үткәрөү, бәйрәм итү (праздновать, отмечать). Айытны күтәрөү.

**КҮТӘРҮ III** *лмб.* тағу, кору (занавешивать, подвешивать). Әләнде челтәр күтәрмиләр вычы.

**күтәрү IV** (поднять, поднимать):

**күтәреп суғу** *мам.* үзеннән бизәк чығарып сугу (способ браного тканья, при котором получаются ажурные узоры). Күтәреп суғасы булса, тақта күтәреп тордо тәтә. Бүртмәчле-бүртмәчле була сөлгө башлары күтәреп суҡҡач. Киҙеле башлы чүпләмне булса, аҡ сөлгө күтәреп суҡҡан була.

**КҮТӘС** *сазл.* **1.** к.: **күтәрәм 3**; **2.** иренчәк, ялкау (ленивый).

**КҮТЕН** *трх.* киребеткән, елак (упрямый, плакса).

**КҮТЕНКӘ** [*рус.* котомка] *перм.* к.: **кытумка**. Илле биш чақырымны ҡайтып ҡара әле күтенкә сүрәп, артта күтенкә, алда күтенкә.

**КҮТЕР 1.** *минз., эчк.* өсте үлән белән капланып сазлыкка әверелгән күл, тирбәлеп тора торган сазлык (трясина); чаг.: **баткылык**. Күтергә кермәң, батуҙың бар. – *эчк.*; **2.** *эчк.* күл уртасындағы камыш төпләрендә барлыкка килгән тумгәклек (кочки в озере, образованные вокруг стебля камыша). Салҡын көннө балыҡлар күтер астына керәләр; **3.** *төм.* саз үләненең бер төре (разновидность болотной травы); **4.** *кргл.* саз (болото, топь). Чишмә суларыннан күтер тәме килә диләр.

**КҮТЕРЛЕК** *минз., стрл.* сазламык, сазлык, баткаклык (болото, трясина, топь). Атлар керәлми, күтерлек. – *минз.*

**КҮТЕЧ** *перм.* к.: **қатымыш**.

**КҮТИК** *мам.* кош-корт койрығында урнашкан май чығара торган бизнең башындағы мамык (пух на головке железы, находящейся под хвостом птиц и выделяющей жир). Ҡаз күтиген манып тегеп ҡуйалар, матур сәдәпләр ҡуйалар бала башлығына.

**'ҮТИРЕН'Е** *кас.* к.: **кибер**.

**'ҮТИРМИ** *кас.* к.: **пайыт 2.**

**КҮТКӘРЕ** *тара.* кире, кирегә (обратно). Инде алар күткәре ҡайттылар икәү.

**КҮТҮ: балық күтү** *брб.д.* балык тоту (ловить рыбу). Тармакүлнең пу йагынта параба кешеләр балық күтүп йатадығын.

**КҮТҮМКӘ** [*рус.* котомка] *блт.* к.: **кытумка**. Тартҡан арбағыз йуҡ, күтәргән күтүмкәгез йуҡ.

**КҮТҮРМӘЛӘҮ** *тара.* чаптырганда атларны куу, әйдәү, куу (побуждать, подгонять лошадей при беге).

**КҮТЧӘ** *тбл.* к.: **аңқыт**.

**КҮФХӘ** *сазл.* к.: **абзар 1.**

**КҮХ** *сазл.* **1.** үлән (трава, травка); **2.** чирәмлек, алан, кечкенә болын (лужайка).

**КҮХӘЛ** *сазл.* ата үрдәк (селезень). Күхәлнеңке йоно сарғылтым, пашы йәшел.

**КҮХЕРТ** *сазл.* **1.** яшен (молния); **2.** к.: **гөлдөртәү**.

**күхерт ут** *сазл.* к.: **күхерт 1.**

**КҮҢ I** *туб.-ирт.д.* **1.** күчмә (кочевой). Күҙ ҡалыҡлар; **2.** туйдан соң кызны һәм аның бирнәсен кияү йортына күчерү өчен ҡыелган арбалар (свадебный поезд – ряд повозок, нагруженных имуществом невесты при переселении её в дом жениха). Күҙ көткәле ҡалық йыйылаты. – *төм.* Пы йақта ҡәсер инте күҙ көтәтләр, ҡалық йыйылады. – *тбл.*

**күҙ кейәүгә герү** *тара.* йортка керү (стать примаком).

**күҙ кийәү** *тара.* йортка кергән кеше (примак). Күҙ кийәү тиләр ҡатын йаққа барса.

**күҙ күҙерү** *туб.-ирт.д.* килен төшерү (переезд невесты в дом жениха). Игепес тә йитем пулыб үскәпес, туй йасатық, күҙ күҙертек, тату-татлы йәшәтек. – *төм.* Күҙ күҙергәнтә киленҙәк әҙемлек мән утырған. – *тара.* Күҙ күҙерү туйға баруҙылар, әкәләре-йеңкәләре, атинәсе бергә, сандықларны төйәп паруҙы бер геше, йеснәсеме, пәлицесе (бәлеше) итнеңке, әртникләр, ҡалаҙ-туғаҙлар, туй бағырсағы, күҙ күҙерү тителәр. – *тбл.*

**ҠҮҢ II** *брб.д., тара.* көчле (сильный). Бик күҙ батыр иде. – *брб.д.*

**КҮҢӘ 1.** *себ.* арпа ярмасы (ячневая крупа); **2.** *тара.* итсез, кысыр ашамлык (постное кушанье).

**КҮҢКЕЗ** *тмн.* басма (мостик из двух-трёх досок через речку). Су анасы да була, кийаш иңгәҙ выт су аша күҙәргә күҙкез куйган, шунда утыргаҙ күрәләр иде бырынгылар.

**КҮҢКЕР** *төм.* шөлди (кулик).

**КҮҢ-КҮҢ** *төм.* к.: **бийауса**. Күҙ-күҙ тың сур та булаты, күҙ-күҙ, күҙеп кит, әнийеңне алып кит, мине дә алып кит, бары йергә йеткер, тип тақмаҡлаған, оҙоп китәте.

**КҮЦЛЕ** *тбл.* көшелле, көшелдәге (в куче, ворох – о намолоченном хлебе). Күцле аш.

**КҮЦМӘКҮЦ** *төм.* к.: **бийауса**.

**КҮЦҮ** *туб.-ирт.д.* килен булып төшү (переезд невесты). Кыс пала күцкән цакта баш өстән акца цацкәннәр.

**күцеп пару** *тбл.* к.: **күцү**. Тормошка цыктылар әбәләрем, күцеп партылар.

**КҮЧ I** *твр.* **1.** к.: **күц I, 2**. Күчләр килеп төшкәндә мылтык белән атышалар. Күч булмастан никах йасыйлар да шул көннө күч белән алып китәләр; **2.** килен утырган арба (повозка во главе свадебного поезда, где располагается невеста). Күч алдына утырып килә бер кыз, аңа бүләк бирәләр.

**күч алырға бару** *твр.* кыз алырга бару (ехать за невесткой). Уникe чана килделәр күч кыwып, монан бардык дүрт чана, күч алырға бардык.

**күч куу, күч кыwу** *твр.* киленне озата бару (сопровождать невесту). Күченеп әпкиттеләр, унсигез арба күч кыwалар.

**КҮЧ II 1.** *мам., каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* ташу, яңгыр яки язгы кар суы ташкыны (сильный поток после дождя или оттаяния снега). Урманда җауган дий, күчләр аққан. – *каз.ар.-крш.* Сызадан күч төшсә, тигермән бөйәсен алып китәр быйыл. – *т.кам.-крш.* Әби әйтәдер ийе, җаз көннө күч шәп төшсә, иген дә шәп була, дип. Менә бу қаршы таудан қайсы йылны шундый қаты булып төшәдер ийе күч, шаулап торадыр ыйы. – *мам.*; **2.** *дөб.* боз (лёд). Күч китә башлағач, бер ташу қарап менәргә кирәк. Зур суларда күч китә башлады.

**КҮЧӘ I** *твр.* тезген (повод – у узды).

**күчә II** [*рус.* куча]:

**күчә белә** *мам.* өйгән килеш, өеме белән (кучой, скирдой или стогом). Хәзер бик әйбәт, күчә белә қайтарып қуйалар печәнне.

**күчәсе белән** *перм.* төркем булып, бөтенесе (все вместе, скопом, кучей). Тарақаннары күчәсе белән чыққан да киткән ызбалары йанар йылны.

**күчә булып** *перм.* көтүе белән, укмашып, җыелып (все вместе, скопом). Күчә булып килеп керделәр ийе кичкедә, кинага барабыз тип.

**КҮЧӘ III 1.** *хвл.* киледә төелгән бодайдан мичтә пешерелгән ботка (каша, сваренная в печи из толчёной пшеницы). Күчәне Гумәр абзыйым йарата иде, бодайны тевәләр киледә кабыгы арчылганчы, кибәргә куйалар аны, уртасы гына кала аның, аннан бер ыстаканмы, ике ыстаканмы сала да пичкә тыга да куйа, куча үзе генә йарамый, шурба салалар симйәсенә карата; **2.** *тара.* арпа ярмасы (перловка).

**күчә пешерү** *кузн.* төрле әйбер салып пешерү (сварить пищу, в составе которой не менее семи компонентов). Әшүрә бар′амында күчә пешерәбез, җиде терлене салабыз, су, тызын да салабыз, йарма, итен дә, борчак.

**күчә үрә** *тара.* арпа ярмасы белән пешерелгән аш (перловый суп).

**КҮЧӘ-КҮЧӘ** [*рус.* куча] *перм.* төркем-төркем (группами). Күчә-күчә булып әрберсе бер чук булып утырганнар.

**КҮЧӘР** *чпр.* к.: **йәпләшкә**. Күчәр белән җәй буйы үлән ташыдык.

**КҮЧӘРӘ** *себ.* эре арпа ярмасы белән пешергән аш (суп, приготовленный из перловой крупы).

**КҮЧӘРГӘ** *твр.*, **КҮЧӘРКӘ** [*рус.* кочерга] *твр., тара.* к.: **қустартқыч**. Өй ийәсен күчертем, пичнеке күчәркәләрен, пумаланы алып, әйдәң, мин киттем, қалмаң миннән тип, атланып мондача килеп, кереп, сөйәп қуйдым. – *твр.*

**КҮЧЕП** *лмб.* аша, аркылы (через). Алар бездән йырак йук, ү күчеп тыралар.

**КҮЧЕРГЕ** *нгб.-крш.* үрнәк, күчергеч (образец).

**КҮЧЕРГЕЧ** *т.кам.-крш.* үрнәк, рәсемне күчереп алу өчен үрнәк (образец, эталон для срисовывания). Элкеге мәләнчек, сүрәкә диләр ийе, казер күчергечкә дә җуқ бит алар.

**'ҮЧЕР'И** [*рус.* кочерга] *кас.* к.: **қустартқыч**. 'үчер'и белән тарт!

**к ү ч е р ү** (перенести, перевезти):

**күчереб алу** *перм., твр.* к.: **'ейүw: 'ейүw пыстасы**. Пар атлар, қыңгыраулар тагып алып килдем инде күчереб алганда (хатынын). – *перм.*

**'ҮЧИН: 'үчин җапра'ы** *кас.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы**.

**КҮЧКЕЗ** *кузн.*, **КҮЧМӘ I** *карс.* к.: **күцкез**. Күчкез эстеннән ике кура иде.

**КҮЧМӘ II** *нрл., т.я.-крш.* шаулама, тавышланма, тик тор! (не шуми). Күчмә, кызым, күчмә син! – *нрл.* Күчмә, каҗыр, чулка бирермен. – *т. я.-крш.*

**КҮЧМӘНЛЕ** *твр.* күчмә (кочевой).

**КҮЧТӘНӘЧ** [*рус.* гостинец] *каз.ар.-крш., дөб., т.я., кмшл., кргл.* бүләк (подарок). Шушы шалны күчтәнәч итеп бирде. – *кргл.* Күчтәнәчкә бирелгән җир булған. Күчтәнәч күлмәк бу. – *кмшл.* Күчтәнәч итеп бик матур күлмәклек апкилгән. – *к.т.*

**күчтәнәч чанасы** *минз.* туйга барганда күчтәнәчләр (чәкчәк, каз h.б.) төялгән чана (отдельные сани, где везут гостинцы сватов, едущих на свадьбу). Күчтәнәч чанасы арттан килә.

**КҮЧТӘНӘЧЛӘҮ** [*рус.* гостинец + *афф.* -ләү] *каз.ар.-крш.* бүләкләү (дарить, награждать). Башта тана бирепкүчтәнәчлибез, диделәр, аннары дуңгыз баласы бирделәр күчтәнәчләп.

**КҮЧТӘРКӘ** [*рус.* костёрка] *дөб., блт.* **1.** өч аяклы чуен савыт, тирән таба (глубокая сковородка на трёх ножках). Күчтәркәгә салып қына тәбә пешереп бирим. – *блт.*; **2.** өчаяк (таган). Күчтәркә қуйалар да өрә-өрә пешерәләр. – *дөб.*

**КҮЧТЕЛ** [*рус.* костыль] *перм.* прәшкә (пряжка ремня). Салдат қайышы зур күчтелле була қый.

**КҮЧТИ** [*рус.* гостинец] *минз., кргл., стрл.* к.: **келчә 2**. Бездәге ақ күмәчне күчтигә диб әпкитәләр ийе. – *минз.* Күчти-мазар апқайтқаннармы? Танауларын ышқый бу қыз, күчти ашыйсы килгәндер. – *кргл.* Күчтиләп эчәй эчәрбез. – *стрл.*

**КҮЧТИНӘЧ** [*рус.* гостинец] *каз.ар.-крш.* к.: **күчтәнәч**. Бу күчтинәч күлмәклек.

**КҮЧҮ I** *кузн., лмб., карс.* елга яки диңгез чыгу, кичү (перейти через речку или море). Башым әләнә дийә, суны да күчә алмый. Үмер тегел күпер, тиз генә күчеп булмый. Күперне күчеп Рәхимә әби тырадыр, аныкы ызба шанда. – *лмб.* Ул этте шылай безгә инде, диңгезне күч, тап безгә бал. Киттем, суны күчтем, и алар сукмагыннан киләм. – *карс.*

**КҮЧҮ II** *твр.* килен булып төшү (бару) (переехать в дом жениха). Ә мин хадук белән кенә күчтем, қодағыйлар йәйәү килде пер awылтан пулгац. Мин үсем тә сантық пелә күчтем. Хадук белән күчтем, қыңғыраулар тағып, атлар йигеп.

**дөньядан күчү** *минз.* үлү (умереть, уйти из этого мира). Кендег әбисен алып кердем, дөнйадан күчә, диде, қарады да.

**КҮШ** [*фарс.*] *том.д.* к.: **кәки**.

**КҮШӘ** *мам., блт.* көпшә, үсемлек сабагы (ствол растения, дудка, трубчатый стебель). Бәпчек күшәсен йаратам, бер қочақ жыйыб апмендем әле. – *мам.* Қақының күшәсен ашыйсың. – *блт.*

**бәрәңгеле күшә, жонно күшә** *мам.*, **йонлач күшә** *блт.* к.: **қуйан: қуйан тобоғы**. Бәрәңгеле күшә дә сабагы йоннорақ була, төбөндә бәрәңгесе була, әрчеб ашыйсың. Кәүсәсе йонно була йонно күшәнең, йафрағы wағрақ була, әрчеб ашыйлар.

**күшәле қычытқан** *блт.* сукыр кычыткан (пустырник).

**шома күшә** *мам.* шома көпшә (дягиль). Шома күшә урманда күбрәк үсә.

**КҮШӘГӘ 1.** *лмб.* япма, япкыч (покрывало). Күшәгәләрне чананың артына каплыйлар кыз төшкәндә, йаз булса – кибеткага. Кибетка ман йәш киленнәрне алалар иде, күшәгәләр әләләр иде терле чуктан йасаганны, бәйет атәләр иде; **2.** *нокр.* жыеп куелган түшәк-ястык, урын-жир өстенә яба торган жәймә (покрывало, накидка для постельных принадлежностей); **3.** *кргл., бгрс., яүшт., клм.* чаршау (полог, занавеска). Килен булып төшкәндә утыз аршиннан күшәгәм иде. – *бгрс.* Күшәгәләрем дә керле, идәннәрем дә керле. – *яүшт.* Карawатқа күшәгә тартқаннар тыйықлап (шыплап); **4.** *клм.* пәрдә (занавеска).

**киҗеле күшәгә** *лмб.* к.: **күшәгә 1**. Киҗеле күшәгә кыдагида бар.

**күшәгә башы** *злт.* элек: егетнең әти-әнисенә кыз тарафыннан туйда бирелә торган бүләк (в старину: подарок невестки родителям жениха, даримый во время свадьбы). Күшәгә башына күлмәк.

**тәрәс күшәгәсе** *клм.* к.: **күшәгә 4**.

**КҮШӘЛӘТҮ** *бөре.* к.: **қаушақлату**. Адикалун битне күшәләтә.

**КҮШӘЛӘҮ** *т.я.* к.: **кишәләү**. Озатқач, жепне күшәлисең дә ыстанға саласың. – *к.т.*

**КҮШӘМ** *карс.* кибән башы (горбушка хлеба). Чәршәмкен йапқан әпәйнен күшәмен сүкиләр дә ... (арпа имнәгәндә).

**к ү ш ә ү** (жевать – о животных):

**күшәү чыгару** *кузн.* күши башлау (начать жевать – о животных). Бер ай күшәү чыгармады (сыер авырып).

**КҮШИЛ** [*рус.* кошель] **1.** *т.я.* юкәдән үргән капкачлы сумка (сумка, плетённая из лыка); чаг.: **кашлик**. Күшилгә салып қуй бу қадақларны, кирәк булғанда эзлисең аннары. – *к.т.*; **2.** *дөб.* баудан челтәрләп үрелгән кап (мешочек, плетённый из верёвки; плетёнка); чаг.: **этмә I, 2**; **3.** *глз.* кәрзин (корзинка, плетёнка из прутьев); чаг.: **мөргә**. Гөмбәне бидрәләп, күшилләп килтерәләр.

**КҮШЛЕГҮ** *тбл.* жәелү (растекаться, разливаться, расползаться). Путқаның майы күшлегеп йататы.

**КҮШМӘ** *тбл.* корама жәймә (простыня из лоскутков).

**КҮШМӘК** *әчк.* агачта кайры белән үзагач арасында була торган кызгылт төстәге катлам (красный слой между корой и древесиной); чаг.: **қыртыш 8**. Күшмәге кирәкмәй, тузын ал (агачның).

**КҮШТЕРҮ** *перм.* жиңелчә туңдыру, чирату (слегка подморозить).

**КЫБИТКА** [*рус.* кибитка] *лмб., карс.* к.: **күмә 2**. Кызны алып китәләр йегет әвенә кыбитка ман. – *карс.* Кыбиткага күмәчләр бәлиләр, кайа кыз утыра, шанда күмәж бәләп қуйалар ыштубы аш-су ман барсын. – *лмб.*

**КЫБЫЛА** [*гар.*] *т.кам.-крш.* кыйбла (кыбла, направление на Каабу, куда обращаются мусульмане во время молитвы). Кыбыладан исә бүген жил.

**КЫВ** *тмн.* бәлеш капкачы (крышка, макушка бәлиша). Бәлешнең кывын ачалар да шурбасын салалар.

**КЫВАК** *лмб., кузн., хвл., мәл.* кавык (перхоть). Башы тулы кывак. – *мәл.* Кываклар кечетә башны. – *лмб.* Кыз булып – башы тулы кывак, шоно бетерми, Ходайым! – *хвл.*

**КЫВАС 1.** *лмб.* куас (квас); **2.** *хвл., әҗе.* к.: **күрчәмә**. Кывасны онны цецетеп йасыйлар, дружжа зибәрәләр. – *әҗе.* Кывас булган, борын аны ачыта колмак белән, бражка иде, ачый бирә. Ул wахытта кываслар йасап кына иде туй, аракы йук. – *хвл.*

**кызыл кывас** *лмб.* өй сырасы (домашнее пиво).

**КЫВАШН'А** [рус. квашня] *хвл.* к.: **ләнгәц**. Төнката кывашн'а куйды, йокы бирмәде, сәәт дүрттә сафсимга торды.

**КЫWАШН'А** [*рус.* квашня] **1.** *срг., клд., хвл., әҗе., лмб.* к.: **ләнгәц**. Кыwашн'а була иде арыш әпәйенә. – *кузн.* Агачтан йасыйлар кыwашн'а, әпәй қуйа торган кыwашн'а. – *әҗе.* Кыwашн'а басмийлар, үкмәк пешермиләр. – *хвл.*; **2.** *лмб.* бодай камыры ачыта торган кечкенә агач кисмәк (маленькая деревянная кадушка для квашения теста из пшеничной муки); чаг.: **қушма 1**.

**кыwашн'а пәрәмәче** *клд.* арыш оны камырыннан пешерелгән кабартма (ржаные пышки из кислого теста). Пәрәмәч пешерәләр иде, нәнәйләр кыwашн'аныкын.

**кыwашн'а салмасы** *клд.* ипи чумары (клёцки).

**КЫWАШНА** [*рус.* квашня] *стрл.* Кыwашна йуган суны малларга сал.

**кыwашна булу** *брб.д.* эч күбү – балалар турында (вздуться – о животе детей). Эче күбеп китсә баланыңқы, нә болған, кыwашна болған, нә болпты, кыwашна бопты, тәп пашыға кийертеп, кийертеп алалар кыwашнаны.

**КЫВЫРМА** *мәл.* кыздырган ит (жареное мясо).

**КЫWЫРТУ** *тмн.* кыздыру (жарить).

**КЫВЫШ** *тмн.* мичтә самовар трубасын тоташтыру өчен калдырган тишек, самовар төннеге (отверстие дымохода для самоварной трубы).

**КЫДА** *лмб., срг.* туй (свадьба). Вакытында йеретәләр иде кыдаларга пешерергә дә, әл инде сила калмады, пешерәм үземә генә. Кем кыдага бара,

үзенә алаша йигә. Элке бит дүртәр, бишәр кен ала идек кыдага. – *лмб.* Без кышны Казанга бардык кыдага. – *срг.*

**кыда катын** *м.-кар.* кызны чиркәүгә никахка, аннан егет өенә кияү егете белән бергә озата баручы хатын-кыз, гадәттә, кияүнең чукындырган әнисе була (женщина, обычно крёстная мать жениха, сопровождающая вместе с шафером, дружкой невесту в церковь под венец и оттуда в дом жениха).

**кыда ун'ау** *лмб.* **1.** туй ясау (сыграть свадьбу, справить свадьбу). Кыда ун'илар иде буза мынан. Икенче атнада кыда ун'аганнар; **2.** пәри туе (смерч). Йил чыга қуwатлы, пирләр ун'и, кыдалары була каты уйында, кыда ун'и ат'алар.

**КЫДАЛАУ** *чст.-крш.* кызны килешкәч, булачак кодаларны кунакка чакыру (обычай приглашать в гости будущих сватьёв после сговора между родителями жениха и невесты). Башта кызның әтиләре кыдалый, аларга ашлар белә баралар, казлар белә; аннан сың йегетнең әтиләре кыдалый, шылай ук эч-дүрт парлы кунак ашлар, казлар белә бара.

**КЫДАЧАЛАР** *м.-кар.* к.: **қодачалар.** Җәш киленне ызатканда кыз йулдашлары бара, кыдачалар диләр инде.

**КЫДАЧАЛЫЙ** *карс.* киленне кияү йортына озатучы булып (в качестве сопровождающей невесты в дом жениха). Барган идем кыдачалый, шунда күлмәк салдылар. Әле сездә кыдачалый бару йук?

**КЫД'УМКЫ** [*рус.* котомка] *глз.* тубал (лукошко, кузов, кузовок, плетёная котома). Йүкә кабыктан йасаган була кыд'умкы, аны суга салып йасаган була, муйныларына элеп чәчеп йерде.

**КЫДЫРАУ** *срг.* к.: **көдрәч.** Кыдырау цәц.

**КЫДЫРЛАНУ** *кузн.* к.: **кытырлану II.**

**КЫДЫРУ** *влгг.* ял итү, кунак булып йөрү (отдыхать, ходить по гостям). Сезгә кыдырып килде.

**КЫЖМЫРАН** *тмн.* тырыш, эшчән (старательный, усердный, трудолюбивый). Үмерлек кыжмыран, йермеше дә тырышныкы Адиләнеке.

**КЫЖМЫРДАУ** *стрл.* кыштырдау, кыштыр-кыштыр килү (шуршать, шелестеть, зашуршать). Уннан суң учак тирәсе кыжмырдый башлый. Кортмыни, кыжмырдап йөри.

**КЫЖАН** *м.-кар.* к.: **буран-қызан.** Кыҗан китте.

**КЫЖҖАННАРЫ** *чст.-крш.* ярәшелгән кызның туйда катнаша торган дус яки туган тиешле кызлары (подруги или близкие невесты, которые участвуют на свадьбе). Кыҗҗаннарысы җырлап тыра инде туйда.

**кыз** (девушка, девочка):

**кечкенә кыз** *т.я.-крш.* **1.** к.: **печкәчи; 2.** к.: **абызастай.**

**кыз алу** *чпр.* **қыз I: қыз алу.**

**кыз балы** *чст.* туй уңае белән егет йортында әзерләнә торган эчемлек (мёд, напиток, приготовленный в доме жениха для свадьбы).

**кыз бәйете** *кузн.*, **кыз кеве** *лмб.*, **кыз кичә** *кузн.* борынгы кыз елату җыры (старинная песня-плач, исполняемая невестой и её подругами перед началом свадьбы). Кыз кичә кенне ыру-кардәшләрен, йиңәләрен, дусларын йыйалар. Әни, тенә этепсен бер йыр, ул – кыз кичәме?

**кыз җаны кызлар** *чст.-крш.* кызны әзерләргә булышып, җырлап, аны озатып йөрүче кызлар (девушки, подруги невесты, исполняющие около неё песни и сопровождающие её в дом жениха). Кыз бөркәнчег астында җата, кыз җаны кызлар җырлыйлар инде.

**кыз йабу** *стрл.* к.: **қыз I: қыз йабу.** Бер атнадан йабалар, әле ул кыз ун'ап йөри.

**кыз йаслату** *тмн.* к.: **йаслату.**

**кыз йулдашлары** *м.-кар.* **1.** кызны егет йортына озата баручы кызлар (девушки, сопровождающие невесту в дом жениха). Кыз йулдашлары икеме-өчме кеше була; **2.** килен төшәсе йортны киендерүчеләр, бизәүчеләр (девушки, которые приходят в дом жениха раньше невестки и развешивают её вещи, украшают дом).

**кыз келәтү** *әҗе.*, *күрш.* кыз сорау, яучы җибәрү (сватать, посылать сватов). Йакшы кийәүләр келәттеләр кызымны. – *күрш.* Ыргуда (*ав. ис.*) түрткыз келәтәләр. – *әҗе.*

**кыз кичә әтү** *кузн.* к.: **йаслату.**

**кыз күрү** *лмб.* кияүгә туган тиешле хатын-кызларның беренче тапкыр яшь килен белән танышу йоласы (обряд знакомства родственниц жениха с невестой); чаг.: **бит III: битен күрендерү.** Кыз күргәндә башта кайнана, аннан кыдачалар киленнең битен ачып карап үбәләр, бүләк куйалар.

**кыз тирәсе** *лмб.*, *стрл.* кыз бирнәсенә булган әйберләр (приданое невесты). Кыз тирәсен әзерлиләр хазер көп. – *стрл.* Кыз тирәсен берчесен китергән Мескүдән. – *лмб.*

**кызлар бәйрәме көйе, кызлар эчкесе кейе** *чст.-крш.* керәшеннәрдә: бер генә көн була торган яшьләр бәйрәме (у кряшен: молодёжное гулянье в течение одного дня, когда девушки собираются то у одной, то у другой, угощаются и поют протяжную мелодичную песню). Җәш кызлар җыйылышып кунакка җериләр, май айында бер генә көн була ул, кызлар эчкесе кейен сузып җырлыйлар.

**сары кыз, чибәр кыз** *т.я.-крш.* иренең сеңлесе, каенсеңел (младшая сестра мужа, золовка).

**КЫЗАЙ** *мәл.* **1.** иптәш кыз (подруга). Кызайың белән кунакка килегез; **2.** иптәш кызга эндәшү сүзе (форма обращения к подруге).

**КЫЗ'АК** *мәл.* хатынша (обабившийся мужчина, мужчина, выполняющий женские работы).

**кызамык** (корь):

**кызамык боткасы** *чст.* кызамык белән авыручы баланы имләү өчен пешерелгән ботка (ритуальная каша, которая варится для лечения знахарским способом больного корью ребёнка). Кызамык боткасы пешерәсен бодай ярмасыннан, бер әбигә бирәсен, ул аши да укып дога кыла.

**кызамык чыгару** *чст.-крш.* кызамык белән авыру (болеть корью). Мин каникулга кайтып кызамык чыгардым.

**КЫЗ'АН** *м.-кар.* к.: **буран-қызан.** Кыз'ан себерә, нәчәр.

**КЫЗАНКЫ** *мәл.* к.: **қырмызы**. Кызым кызанкы awырywы белән үлде.

**КЫЗАРКЫ** *мәл.*, **КЫЗАРТКЫ** *байк., стрл.* йәзлек (горячие угли в передней части пода печи во время печения хлеба). Пичнең кызаркысын тарттым, әпәйгә кызу була. – *мәл.* Кызарткы да куйганым йук, әпәйнең өстә килсен өцөн. – *байк.* Нийә соң кызарткы куйасың. – *стрл.*

**КЫЗАУ** *әҗе.* юкәдән үрелгән кечкенә кәрзин (маленькая корзина, сплетённая из лыка). Кызаугa куйа идек кашыкларны.

**цәцү кызawы** *әҗе.* тубал (лукошко для сеяния семян). Цәцү кызawы була зүкәдән тугыган.

**КЫЗГАНУ** *хвл.* көнләшү, көнчелеге туу, күпсенү (завидовать). Үзенеке булмагач, минекен кызгана. Йахшы тырмышны кызгана, күрә алмый.

**КЫЗГАНЧЫ 1.** *мәл.* к.: **қатымыш**. Кит, кызганчы, шул чике эшләп тә акчасын бирмәде.; **2.** *хвл., чпр., мәл.* көнчел, кешедән күпсенүчән, кешедән кызганучан (завистливый; завистник). Кызганчыныкын кызыл мачы ашаган (*әйтем*). – *мәл.* Кызганчыныкын кызыл кычык ашый (*әйтем*). – *хвл.*

**кызганчы мачы** *мәл.* к.: **кызганчы 2**.

**КЫЗДЫРУ** *байк.* к.: **қыздыру 1**. Иртә белә кыздырып бирәм аңа калган ашны.

**КЫЗТӘКӘ** *чст.* к.: **ирдawай 1**.

**КЫЗУ** *стрл., чпр.* к.: **қызу I**. Шул калакулга кызадыр ийем. – *стрл.* Аның шәл йаулыгына кызма син. – *чпр.*

**КЫЗЫКЛАНУ** *әҗе., кузн.* кызыксыну (интересоваться). Цегән баласы телемне бәләде, кызыкландым. – *әҗе.* Бу сың быларны нигә йазасың, кызыкланасызмы? – *кузн.*

**кызыл** (красный):

**кызыл алабута** *тмн.* песи тарысы (амарант, ширица).

**кызыл канат** *лмб.*, **кызыл тунны** *кузн.* к.: **ислекәй 1**. Кызылканатлар мине ашамилар, кызылканатлар йуктыр миндә.

**кызыл төп** *тмн.* бальзамин «не тронь меня».

**КЫЗЫНУ** *клд.* к.: **қызу I**. Чәчәкләр дә йиганнар да кызынган шыларга.

**КЫЙАМАТЛЫК** *т.я.-крш.* **1.** ахирәт дус (задушевная подруга); **2.** куелган ата яки куелган ана (посажёная мать или посажёный отец).

**кыйаматлык әнʹу** *т.я.-крш.* билгеләп куелган ана (посажёная мать).

**кыйаматлык әтʹу** *т.я.-крш.* билгеләп куелган ата (посажёный отец).

**КЫЙАРАК** *срг., лмб.* култык астында барлыкка килә торган каты биз (железа или уплотнение, возникающее в подмышках). Кыйарак чыкса, култыг астына йәш кыйарны йарып куйалар. – *лмб.*

**КЫЙАУ** *кузн.* чыбыктан үреп ясалган чишмә бурасы (сруб источника, сделанный из прутьев). Кыйау тешердең (чишмәгә), әйбәт булды, терлекмазар тыгылырлык тегел.

**КЫЙГАЛАМАУ** *глз.* базмау, кыймау (не осмелиться, не сметь). Кыйгаламадым атыкий алдында йормага.

**КЫЙГЫЛ: кыйгыл йалан** *стрл.* к.: **қыйғыл: қыйғыл йалан**. Безнең бит кыйгыл йалан монда.

**КЫЙГЫРЫШ** *лмб.* бәхет кошы (птица счастья). Аның кыйгырышы бардыр (бай кеше турында).

**КЫЙДЫРУ** *лмб.* к.: **куйу 1**.

**ызба кыйдыру** *лмб.* к.: **койу I: ызба койу**. Биж йыл ызба кыйдыра алмый.

**КЫЙКА** *стрл.* к.: **қыйқа**. Кыйка тәмәртә ашны.

**КЫЙЛЫ** [*рус.* кило] *стрл.* кило, килограмм (кило, килограмм). Кыйлысы белән апкилгән чәйен.

**кыймак** *стрл.* коймак (оладьи, маленькие блины):

**алма кыймак** *стрл.* чокырлы-чокырлы итеп эшләнгән махсус табада пешерелгән коймак (блины, испечённые на специальной сковороде с углублениями).

**КЫЙНДЫРАШ** *стрл.* к.: **киндераш 2**. Кыйндыраш чәчәләр wак кына бөртөкле, шунардан пәҗи үсә.

**кыйндыраш майы** *стрл.* киндер мае (конопляное масло).

**КЫЙРАЛУ** *стрл.* кырылу (быть убитым). Бу сугышта бик күп кыйралды халык.

**КЫЙРАТУ** *стрл.* к.: **қутару 1**. Өч мәчетне кыйратып ышкул иттем.

**КЫЙСАП** *стрл.* к.: **келисап**.

**КЫЙТЫ** *карс., тмн., лмб., шрл.* к.: **който**. Кыйты сүз әтмә. Халем кыйты, ыланнар. Үлем кыйтысын ирәми (җирәнми), йакшысын җәлләми (*әйтем*). – *лмб.*

**КЫЙТЫЛАНУ** *тмн., лмб.* к.: **койтылану**. Әлдә кыйтыландым инде, кәбәм, бик. – *тмн.*

**КЫЙТЫРУ** *карс.* начарлану (ухудшиться, испортиться). Кийәүгә чыккас′ кайан кыйтырыб элгерәләр икән бу кызлар.

**КЫЙУ I** *чст., мәл.* ефәк тасма (шёлковая тесьма, лента). Бер митыр кыйу бир. Кыйу тыткан, ахры. – *мәл.* Бар кыйуларыңны алып кер әле, үрербез (чәчеңне). – *чст.*

**КЫЙУ II 1.** *клд., м.-кар., карс., срг., чст., шрл.* су сибү (поливать). Капыста утырттым, кыйдым. Йаран геле, wакыт йук, кыйгалыймын качан-качан. – *кузн.* Илле чиләк кыйа идек кыйарларга, ниләргә. – *карс.* Кыйарны гына кыйам. Җимешләр бар, шуларны кыйгалаклим. – *м.-кар.* Капыста кыйарга цыгам әлдә. – *срг.* Сатларны кыйасынмы? – *чст.*; **2.** *шрл.* агызу (наливать – чай). Миңа да кый әле чәй әз генә.

**су кыйу** *стрл.* к.: **кыйу II, 1**. Кызлары бакчада су кыйа.

**кыйу III** *миш.д.* кою (отлить, изготовлять литьём):

**фунтамит кыйу** *мәл.* бетоннан нигез, фундамент салу (заложить бетонный фундамент). Фунтамитны хазер таштан кыйалар, элгәре агачтан кара бура куйалар иде.

**КЫЙШАМЧЫК** *стрл.* к.: **қыйшамчық**. Дилара кыйшамчык тагы килгәнмени Мәдинә апаның башын әйләндерергә.

**КЫЙШЫККА** *карс.* кыйгачлап (косо, вкось). Лапша җәймәсен шылай-шылай кискәлисен кыйшыкка.

**КЫЙЫ** *карс.* к.: **кизләү 1**. Бик матур иттереп кыйылар чыга.

**кыйы башы** *карс.* к.: **кизләү 1.** Ничәмә-ничәмә буралар йасап куйган кыйы башына.

**КЫЙЫК I** *чст., тмн., мәл.* кыргый – киек хайван яки кош-корт (дикие животные). Кыйыг үрдәк, кыйык казлар Кондорча буйына киләләр ийе. – *мәл.* Кыйык үрдәк, кыйык каз атадыр. – *тмн.*

**су кыйыгы** *карс.* су хайваны, су киеге (водяное животное). Суның кыйыкларын атыр идем, Су буйында тезелгән чакта (*хал. җыр.*).

**КЫЙЫК II 1.** *әҗе.* ачыга, кыек формада пешерелгән камыр ашы (ромбовидное мучное блюдо из кислого теста). Кыйык әтәбез, ачылый пешерәбез, кыйыкка кисәбез дә; **2.** *кузн., лмб.* өчпочмаклы итеп ясалган яулык (косынка). Бәлә башыңа бу кыйыкны. – *лмб.*

**КЫЙЫКЛЫ** *мәл., чст.* к.: **бөтүле**. Кыйыклы йурган. – *мәл.*

**КЫЙЫКСУ** *шрл.* кыйгач (наискосок). Менә бу кыйыксу гына үземнең төп йорт.

**КЫЙЫКЧА 1.** *тмн., лмб.* ачы яки төче камырдан ромб яисә өчпочмак формасында ясалып пешерелә торган кабартма (пышки из кислого или пресного теста, имеющие форму ромба или треугольника). Дурашым йуктыр кыйыкча куйарга. – *лмб.*; **2.** *хвл., кузн., мәл.* юка гына итеп җәйгән камырны вак-вак кыек кисәкләргә кискәләп майда пешерелгән ашамлык (мучное блюдо: хворост треугольной формы, жаренный в масле). Камырны ун йомырка сыта, сөт сала да бик йакшы гына үзләтеп җәйә; аннан ары вак-вак кискәләп майда пешерә – шыл инде кыйыкча була. – *хвл.*

**КЫЙЫКЧЫ** *т.я.-крш.* к.: **аңцы**.

**КЫЙЫЛУ** *лмб., стрл., чст.-крш.* төшү – оек, ыштан турында (сползти – о штанах, чулках). Тегенен ыштаны кыйыла, ахыры. – *стрл.* Чылкаң шылай кыйылыпмы йерде? – *лмб.* Ыйыгым кыйыла, күтәрәм дә күтәрәм. – *чст.-крш.* Ыштанын кыйа иде дә утыра иде йергә, йылы килсә, чәчәбез, ди.

**КЫЙЫЛЧЫК** *чст.* к.: **қағылма**.

**КЫЙЫМНЫК** *глз.* кыюлык (смелость, решимость). Кыйымнык әйбәт түгел бездә.

**КЫЙЫНЦЫ** *срғл.* усал, кыерсытучы (злой, обидчик). Алар бик кыйынцылар, цыдый алмам дийр.

**КЫЙЫШУ** *байк.* к.: **қыйышу 1.** Истурийа йазып кыйышкан ийе бер карт.

**КЫКЫ** *лмб., карс.* к.: **коко**.

**КЫКЫЧЫБАР** *лмб.* сипкелле (веснушчатый).

**КЫЛ** *срг., лмб.* чиләкнең, казанның тоткасы, бавы (дужка котла); чаг.: **боғо**. Кылсыз казан, кыллы казан булган. Казаннын кылы, циләкнен бawы әтәбез. – *срг.* Чиләкнең кылы чыккан. – *лмб.*

**КЫЛА** *чст.-крш.* ырмау, уем (выем, выемка, паз). Ачсам, кыласыннан су идән асты, умарталарыбыз йөзәп җөри.

**КЫЛАГАРКА** *чст.* к.: **сырға I, 1**. Бик матур кылагарка кигән.

**КЫЛАК I** *мәл., чст.* чабатаның киндерә үткәрә торган тишеге (отверстие в лаптях, в которое вдевают оборки, ушник лаптя). Чабатаның кылагы йезелеп чыкты да насук белә кат′тым. – *чст.*

**КЫЛАК II** *карс.* к.: **қатый**.

**КЫЛАК III** *хвл.* тарының беренче чыккан яфрагы (первые листья проса). Тарыны кылактан, баланы йәштән багарга икән.

**кылак IV** *миш.д.* колак (ухо):

**кылакка сыймау** *кузн.* яратмау, ошатмау (не нравиться, не воспринимать). Шундый сүз сүләмә, анын кылагына сыймый андый.

**КЫЛАКБАУ** *тмн.* к.: **бау III: кылак бawы**. Цабатага кылакбау куйалар, айакцу белән кийенәләр.

**КЫЛАКЛЫ** *срг.* к.: **корак**. Безнен кылаклы гына ул катын, әwәлгене бик белмий.

**КЫЛАКУЛ** *срг.*, **К(Ы)ЛАКУН** [*рус.* колокол] *трх.* к.: **җиңгеле**. Кызны алып барганда, бөтен алашалар бергә бара, цеңгелдәп килә кылакул. – *срг.* Дугасына клакун тагалар. Кылакун кебек чәчәк ата. – *трх.*

**КЫЛАКЧА** *лмб.* к.: **сырға I, 1**. Уң кылагымда кылакча, Ай, уртасында биш тийен (*бор. җыр.*).

**КЫЛАП** *брб.д.* к.: **келәй I**. Кылап төшкән, бawыма өсөк.

**КЫЛАС′** *м.-кар.* озынлык үлчәү берәмлеге (мера длины); чаг.: **киләп II**. Ун кылас′ җир булыр.

**КЫЛАТ** [*рус.* клад] **1.** *мәл., трх., лш.* к.: **клат**. Аграматный үгәнгә печәнне кылат диләр. – *мәл.* Элке матур ийе Зewә, зур-зур кылатлар буладыр ыйы. – *трх.*; **2.** *мәл., чпр., лш.* көлтә кибәне (стог из снопов). Келтәләрдән зур кылат йасыйбыз. – *мәл.* Насилка белән келтә ташыдык кылатларга. – *чпр.* Зур-зур кылатлар булған арыш келтәсеннән, кирәк чақта ғына суғыб алған. – *лш.*; **3.** *кузн.* озынча итеп өеп катырылган чәкчәк (*чәкчәк* в виде трапеции).

**КЫЛАУСА** [*рус.* колесо] *стрл.* к.: **йөгөртмә II**.

**КЫЛАЧ** *мәл., чст.* озынлык үлчәү берәмлеге (мера длины). Ун кылач диләр инде, йарты гиктар. – *мәл.*

**КЫЛӘТКУМ** [*рус.* клетками] *мәл.* шакмаклы (в клетку).

**КЫЛБУ** *т.я.-крш.* к.: **ғылбу 1**. Мәржән кылбу әле җук шал, элек бар иде ул.

**КЫЛГАН** *байк.* күрән, кыяк (осока). Кылган алып кайткан түбә йабарга саздан.

**КЫЛДАВАЙ** [*рус.* кладовая] *лмб., мәл., кузн., хвл.* урамга, өй каршына таштан яки саман кирпечтән салынган келәт (кладовая из камня или саманного кирпича, построенная на улице напротив дома).

**К(Ы)ЛИДУР** [*рус.*] *чст.* коридор (коридор). Кылидурыбыз кецерәк шул, бетен әрбер шында.

**КЫЛ′ИДЫК** [*рус.* коли так?] *шрл.* «беттек, харап булдык» мәгънәсендәге ымлык сүз (крышка – междометие). Беттек, кыл′идык икән, кайталмыйбыз, тырамвай йук.

**КЫЛ′ИКАЙ** *стрл.* к.: **қолқай**. Ат җигеп әләнәләр иде машинаны, кыл′икайлары җөри иде шылайга.

**КЫЛИМА** [*рус.* колымага] *чст.* ашлык ташый торган әрҗәле арба (телега с ящиком для возки зерна).

**КЫЛИМАГА** [*рус.* колымага] *мәл., чст.* утын,

көлтә, салам h.б. ташый торган арба (телега, предназначенная для перевозки дров, снопов, соломы и т.д.).

**КЫЛИШ** [*рус.* клещ] *мәл.* к.: **келәш**.

**КЫЛКЫНУ** *чпр.* атлыгу, бик теләп тору (рваться, стремиться к чему-либо). Кылкынып тыралар кызлар, малайлар кылупка барабыз дип.

**КЫЛМА I** [*рус.* комната] *тмн.* фатир (квартира). Кылма йаңгыз гына ничек торсын.

**КЫЛМА II** *хвл.* нәкъ, кыл (точно, ровно, точь-в-точь). Кылма уртага бүлеп бирдем үзенә. Кылма уртасы менә шонда инде.

**КЫЛМА-КЫЛ** *кузн.* тип-тигез, төп-төгәл (ровно, точь-в-точь). Кылма-кыл чыкты, йөз грамга – йөз.

**КЫЛОWУСКА** [*рус.* кола – повозка на колёсах, телега-возка] *бөре.* бизәкләп эшләнгән җиңел арба (нарядная повозка). Җыйында ат чабу булмай, зур круг ул әйләнәләр, анда гел кәрәндәс кенә булмай, кылowуска, дуwалкасына хәтле була.

**КЫЛТ** *чпр., т.я.-крш.* к.: **безрәк**. Кылт кына үңгәреше бар энде аларның сүләшүwендә. – *т.я.-крш.*

**КЫЛ'Т** *мәл.* ременьнең очын кертеп куя торган шудырмасы (шлёвка, кожаная гайка на два ремня).

**КЫЛТАЙУ** *шрл.* к.: **баштақлану**. Үзең корыраг ат' әле, кылтайалар безгә балалар.

**КЫЛТЫК, КЫЛ'ТЫК 1.** *мәл.* юк-бар сәбәп, сылтау (отговорка, предлог, повод). Килгесе келәми, бер кылтык таба; **2.** *хвл.* кимчелек, гаеп (недостаток, изъян). Бер кыл'тык табар әле; **3.** *мәл.* юк кына кимчелек, гаеп (незначительный изъян, недостаток). Бер кылтык килеп чыктымы – беттең.

**КЫЛУ** *мәл.* рәхәтләну, иркенләну (блаженствовать, почувствовать себя на воле). Бер кылдык алар киткәч.

**КЫЛ'УК** [*рус.* клюка] *мәл.* 20 см чамасы озынлыктагы уен таягы (небольшая (20 см) клюка для игры в шары).

**КЫЛУН** *эчк.* к.: **әweслек**.

**КЫЛ'ЫДЫК** *шрл.* к.: **кыл'идык**. Такси тизрәк барыр дип уйлаган идек, кыл'ыдык, такси да йук, ут та йук.

**КЫЛ'ЫКАЙ, КЫЛ'ЫМ** *стрл.* к.: **колкай**.

**КЫЛ'ЫМЛАУ** *карс.*, **КЫЛ'ЫМНАУ** *стрл., карс.* к.: **коннау**.

**КЫЛЫМЧАК** *глз.* к.: **қолқай**. Абзардагы кылымчаклар Ат булалар, йари, Буйга йеткән кызларыбыз Йат булалар, йари (*хал. җыр.*).

**КЫМАЧ** *карс.* ситсы (ситец). Ике митыр кымач алдым, Анын кызына запунга (*бәет.*).

**кымаҗ башы** *лмб.* сөлге башы (конец полотенца). Кас'ы инде кымаҗ башы чикте, кас'ы йерли, кас'ы чылка бәли, кас'ыбыз пирчәткә.

**КЫМБАГАР, КЫМБАГЫШ** *чст.* к.: **айбагар**.

**КЫМКИ** *глз.* к.: **кемки 2**. Кымки ишегалдыннан керде.

**КЫМКЫРСАК** *лмб.* атсыз бармак – балалар телендә (безымянный палец – в детской речи); чаг.: **бармак: уйын кубыз (бармак)**.

**КЫМЛАУ** *тмн., күрш.* к.: **коннау**. Алаша кымли этәбез. – *күрш.* Алашаң кымласын, кет. – *тмн.*

**КЫМЛЫ: кымлы башак** *лмб.* к.: **кымкырсак**.

**КЫМНАК** *т.я.-крш.* к.: **қомалак**.

**КЫМНАКСАР** *т.я.-крш.* колмаклык (место, где много хмеля). Кымнаксарда кетү йери, Ала сирлар катышмый, Без уйынга чыккистан, Куштан кызлар катышмый (*хал. җыр.*).

**КЫМПАЙ, КЫМПАС** [*рус.* монпасье] *мәл.* конфет (конфета). Кымпай бирең йобатырбыз.

**КЫМРЫСКА** *кузн.* к.: **қымрысқа**. Кымрыска йөри башласа, тоталмыйсын үзен.

**КЫМЫЗ** *чст.* к.: **айуқузғалақ**.

**КЫМЫЗЛЫК 1.** *стрл.* к.: **ахық**; **2.** *байк.* урман какысы (свербига лесная). Ак цицкә аткан, анысы кымызлык була.

**КЫМЫЛ'ДАУ** *хвл., мәл.* к.: **қымшану**. Зур эш алгинца шонда кымыл'даша кеше дир. – *мәл.*

**КЫМЫРЫСКА** *тмн., лмб., срг.*, **КЫМЫРЫЦКА** *чпр.* к.: **қымрысқа**. Балга кымырыска йыйылган. – *тмн.* Безнен үдә кымырыска бар шыл. – *срг.* Кымырыцка ызбада да бар ыйы җәй көне, кайа киткәндер. – *чпр.*

**КЫН I** *м.-кар.* к.: **қушаққы**. Чикләwек кыны.

**КЫН II** *карс.* чырай, төс (вид – у человека). Вис сыпатларын, кыннарын ала куркытып.

**КЫН III** *чст.* к.: **қолқай**.

**КЫН IV** *глз.* көн (день).

**кын алмаш** *глз.* көнаралаш (через день). Кын алмаш сала каз кукайны.

**КЫНА: кынасы су күтәрми** *мәл.* серкәсе су күтәрми (его пыльца не терпит воды, т.е. очень обидчивый).

**КЫН'ДЫК** *кузн., мәл.* кендек (пупок, пуп). Шул әбкай аныкы кын'дыгын кисүче. – *кузн.*

**КЫН-КЫТ: кын-кыт ычу** *лмб.* кот очу, бик нык курку (сильно испугаться). Кыны-кыты ычкан (яшен яшьнәгәндә).

**КЫННАУ** *мәл., чст.* к.: **коннау**. Ат кыннады, кәнәше бар. – *мәл.* Ат кыннаган, тайы балык кебек цаwып йөри. – *чст.*

**КЫННЫ** *мәл.* төсле, шикелле (как, подобно). Ул кеше кынны йиймый, кеше хатле икене йийа.

**КЫНСЫЗ** *чст., мәл.* к.: **қонарсыз**. Шылай бәләмә инде, бигрәк кынсыз була. – *чст.* Карчыклар кынсыз була, битләре җыйырчыклы. – *мәл.*

**КЫҢГЫР 1.** *әҗе.* кәкре (кривой). Кыңгыр айаклы уланы; **2.** *карс.* бөккән (пирожок). Картуф кыңгыры. Эремчек кыңгыры.

**КЫҢГЫРАЙТУ** *мәл.* каршы төшү, киресен сөйләү (возражать, выступать против). Кыңгырайтма инде.

**КЫҢГЫР-МЫҢГЫР** *кузн.* кәкре-бөкре (корявый, кривой); чаг.: **кәкереч**.

**КЫҢЫР** *срг.* кырын, кыек – карау турында (косой – о взгляде). Кеше белән сүләшкәнне йаратмый, кыңыр багып тора.

**КЫҢЫРАТ** *срг.* к.: **атагат**. Андый кыңыратлар сездә дә күптер.

**КЫПАК** *чпр.* кырпак (пороша). Кыпак кына, йымшак кына кар йаwып тыра.

**КЫПЫРСУ** *кузн.* кыбырсыклану, кыбырсу (егозить, быть неугомонным).

**КЫР I 1.** *шрл., стрл.* тирә (окрестность, ок-

руга). Бу кырда бернәрсә булмаган инде; **2.** к.: **йага I, 6**. Кырга китеп укып кат′ты.

**бер кыр** *тмн.* к.: **қыр II: бер қыр**. Бер кырдан квашн′ага ын салып икмәк басалар.

**к ы р II** (поле):

**кыр арты** *мәл., срг.* ерак басу, иген басуының ерак башы (дальнее поле, дальний конец хлебного поля). Кыр артыннан җәйәү килдек, галиш айак, галиш кул, кулымны туңдырган иде. – *срг.*

**кыр атасы** *м.-кар., срг.* мифик образ: кыр хуҗасы, игеннәрне җыеп алганда аңа багышлап башаклар һәм ипи сынығы калдырганнар (мифический образ: хозяин поля, которому после завершения уборочных работ в знак благодарности оставляли колосья и кусок хлеба).

**кыр капкасы** *чст.-крш.* к.: **акулца**. Кыр капкасын чыккынчы җырлап китте.

**кыр кишере** *лмб.* төтәч (дымянка лекарственная).

**кыр кучкары** *лмб.* туфракта яши торган, чаянга охшаган мөгезле бөҗәк (насекомое, имеющее внешнее сходство со скорпионом).

**кыр кынасы** *чст.* кыңгырау чәчәге (колокольчики).

**кыр пизеле** *тмн.* к.: **албидрә**.

**кыр сакалы** *м.-кар.* җирне бетергәндә урмыйча борып калдырыла торган башаклар (колосья, оставляемые на конце поля несжатыми).

**кыр сыйыр** *глз.* к.: **моши**. Кыр сыйырларны урынтын гына аталар.

**кыр укырга чыгу** *чст.-крш.* яңгыр теләп, кырга укырга чыгу (один из старинных способов моления о дожде). Бер йылны кыр укырга чыкканнар да йаңгыр койып та йебәрде, бетенесе йүweш булып кайтканнар ийе.

**кыр чәчәлийе** *лмб.* ярут (ярутка полевая).

**кыр эт** *глз.* янут (енот).

**КЫРА** *т.я.-крш.* к.: **корык**. Быйыл кыра күп анда.

**КЫРAWАЙ** [*рус.* каравай] *стрл.* тары онынан пешерелгән зур күмәч (большая лепёшка из просяной муки).

**КЫРAWЫЗ** *карс.* ашамыйча (не ев, не кушая). Кырawыз китәргә йакшы тегел.

**КЫРАГАЙ** *мәл.* кыргый (дикий). Бу хатле кырагай кешене күргәнем йук иде.

**КЫРАЖ 1.** *тмн.* юка бәлеш (пирог). Кыраж бешерәләр иде эченә сад алмасы куйып; **2.** *чпр.* табада пешерелгән төрле камыр ашлары (различные мучные изделия, испечённые в печи, на сковороде). Кыраж йарата бу малай.

**КЫРАЙ** [*рус.* край] *чпр., клд., мәл.* түгәрәк икмәкнең кибән башы яки кыерчыгы (краюха хлеба). Ачык чырай, каткан кырай. – *чпр.* Каткан кырай, ачык чырай, айып итмәгез инде. – *клд.* Кырай асты кырчынга. – *мәл.*

**КЫРАК, КЫРАКЛЫ** *карс.* кордаш (сверстник). Армийәгә чике булганбыз ват сезнең кыраклы чакта.

**КЫРАМЫЙСЛА** [*рус.* коромысло] *мәл.* көянтәле үлчәү (весы коромыслом).

**кырамыйсла бака** *тмн.* ике аерлы чулпы (накосник, состоящий из двух параллельных блях с монетами, соединённых на одном орнаментированном кусочке металла). Аннан булайды корокка бака ике айырылы, дүрт манит, кырамыйсла бака әлдә әтеле иды.

**КЫРАНГЫШ** *чст.* к.: **дыраңғыш**.

**кырангышка әләнү** *чст.* бик нык ябыгу (очень сильно похудеть); чаг.: **йадауланy**.

**КЫРАНДАС** *минз., стрл., тпк.*, **КЫРАНТАС** [*рус.*] *трбс., тпк.* к.: **крандас**. Арба йасыйлар, кырандас үрәләр, чыпта сугучылар күб ийе, тимерчеләр бар ыйы. Хаҗиның кырандасы бар ыйы. Тәкәләр суйып кырандас белән килен төшөрәләр җәй уртасында. – *минз.* Кырандас белән сабан туйына баралар, ридwан белән көлтә ташыйлар. – *стрл.* Улы утырган бит кырантасқа. – *трбс.* Килен булып төштөк кырантас белә, төрлө урамтан әйләндереп апкилә, күпереп торган ике ментәр. – *тпк.*

**КЫРАНТИЛ** [*рус.* крендель] *тпк.* к.: **келендерик**. Аң қалас алып қайта, кырантил алып қайта бадардан.

**КЫРАТ** [*рус.* гряда] *төм.* к.: **герәдә**. Песнең цәцинәү бахыр кырат йасай тыгын ите.

**к ы р а х** [*рус.* крах]:

**кырахын китерү** *стрл.* пыр туздыру (разнести в пух и прах). Крахын китереп ташлаган. Кырахын китерә шул мескеннәрне әтә.

**КЫРАХМАЛ** [*рус.* крахмал] *тпк.* к.: **өшемкә**. Ул аслық wахытта кырахмал бик әйбәт булты, аппаг аның күмәсе. Кырахмалына була қадыйбыд да қадыйбыд бақсаны.

**КЫРАЧИК** [*рус.* крайчик] *мәл., чст.* к.: **кырай**. Бер кырачик әпәйең булмаса да... – *мәл.*

**КЫРАШ: кыраш ашату** *мәл.* мәҗлес алдынан кунакларга икмәк ашату (угощение хлебом гостей перед званым обедом).

**к ы р б а н** *миш.д.* корбан (жертва, жертвенный):

**туй кырбаны** *тмн.* элек: туйдан соң корбан чалып уздырылган аш (в старину: угощение с жертвоприношением в доме жениха, устроенное после свадьбы). Хал′ белүчеләр киткәч, туй кырбаны уздыралар иде куй чалып.

**КЫРГАЙАК** *карс., кузн.* к.: **рәшмән**. Вун′и баг әле, кыргайак, мында пәнәwез сузган ул. – *карс.*

**КЫРГАК** *тмн., кузн.* к.: **қорғақ II**. Кыргаклар китте, жар кywыра. – *тмн.*

**КЫРГЫЙ** *мәл., чст., чст.-крш.* карчыга (ястреб). Кырларга чыктым, кыргый аттым, Элгерә микән сабан ашлыгы (*бор. җыр.*). – *чст.-крш.*

**КЫРГЫЩ** *срг.* к.: **қырғыч 1**. Без әтәбез кыргыщ дип, Маклаукада заступ диләр.

**КЫРГЫЧ I** *карс., кузн., лмб.* тәрәзә пәрдәсе (оконная занавеска, шторы). Тәрәзә кыргычын кырыйк. – *кузн.* Челтәр кыргыч, бу кыргычлар китергән. – *лмб.*

**КЫРГЫЧ II** *хвл., мәл., влгг., шрл.* к.: **қырғыч 1**. Кыргычларга саплар куйасы иде. – *мәл.* Кыргычымны алып бир. – *влгг.* Кыргыч сабы сынган. Бер кешегә бер кыргыч җитә инде (көрәргә). – *шрл.*

**КЫРЖЫН** *чст., мәл.* к.: **қатымыш**; чаг.: **мыжым**. Кыржын кеше булыр да икән. – *чст.*

**КЫР′И** *карс.* к.: **йага I, 6**. Берсе тыра кыр′и, икесе дә кыр′ида тыралар алар.

**КЫРИЛСА** *чпр.*, **КЫРИЛЧА** [*рус.* крыльцо] *мәл.* к.: **болдор**. Ышкып кына чыгарды әле кырилсаны, сарыкларны керткән. Ишегалны гына иде, улым кырилча чыгарды. Кырилчаларын да буйыйм.

**КЫРИМКА** [*рус.* крымка] *карс., клд.* к.: **кримка**. Шәр′укның башында кыримка бүрк, Алмагачка кунган кыш кебек (*хал. җыр.*). – *карс.*

**КЫРИСАЛДЫ** [*рус.* крыльцо + *тат.* алды] *к.т.* к.: **болдор**. Кырисалдына килгән дә чакырып чыгарган.

**КЫРКА** *мәл., карс., лмб., чст., шрл., клд., т.я.-крш.* күркә (индюк). Йаптыңмы кыркаларны? – *мәл.* Кырка кызылны севәдер вет. – *карс.* Шал тирәдә үк бар ул кырка. – *лмб.* Кырка канаты. – *чст.* Кыркаларың бакча ашалый чыкты. – *шрл.*

**кырка зиләк** *чст.* кызармаган, пешмәгән – җиләк-җимеш турында (недозревшие – о ягодах). Зиләккә барган иде, кырка зиләк кенә китергән.

**КЫРКАБАК** *мәл.*, **КЫРКАПКА** *чст.* к.: **акулца**.

**КЫРКАТ** *карс.* к.: **карын: кырк карын**. Думбыра йасый булганнар куй эчәгеннән, куйның кыркатыннан.

**КЫРКИЧ** *срг.* баланың тууына кырык көн булган көн (сороковой день младенца, который принято было отмечать как праздник). Бар′ам булды аларда, кызының кыркиче иде.

**КЫРКУЛЫК: кыркулык койу** *чст.* к.: **кырыклык II: кырыклык коюу**. Кыркулык койдыртадыр ыйы, кургашны эретә дә утта, суга сала, нәрсәдән курыкса, шуның сурәте чыгадыр ыйы.

**КЫРКУСЫЗ-ЭРКУСЕЗ** *лмб.* курыкмый торган, курыкмаучан (бесстрашный, не знающий страха). Кыркусыз-эркусез үстермә дим.

**КЫРКЫЛДАУ** *срг.* к.: **кырыклау I**. Бер тавыгым кыркылдаган иде, унбер чебеш чыгарды.

**КЫР-КЫР: кыр-кыр кырылдау** *әҗе.* гырылдау (храпеть). Кыр-кыр кырылдый улан, сувык тисә.

**КЫРЛАЙЧЫ** *стрл.* к.: **кырлайчы**. Абыстай миңарга бер алып биргән иде кырлайчыдан көмөш беләзек, әл дә тора.

**КЫРЛАУ** *байк.* читләтеп әйтү (сказать намёком). Кырласа, бер бүләгем бар. Алай кырлап төшмәде үзе.

**КЫРЛИЧ** *тмн.*, **КЫРЛЫЙЧ** [*рус.* крыльцо] *клд.* к.: **болдор**. Эт кырличка менгән. Кырлыйчлар элке йер белән тигез, әле вет энде нинди бийек.

**КЫРМА I** *лмб., чст.* к.: **коргоч**. Тәрәс кырмасы кырсам, карангы була. Әнәй, кырмаларны ал әле тәрәзәдән. – *чст.* Кырмаларны кыр, кызым. – *лмб.*

**КЫРМА II** *кузн.* трахома (трахома).

**КЫРМА III: кырма бәрәңге** *мәл.* кабыгы белән пешерелгән бәрәңге (картошка в мундире). Бу заман кийеме, бу ашау йуг иде, күпме байларда да арыш әпәйе, кырма бәрәңге иде.

**КЫРМАWЫК** *срг., чпр., чст., мәл.*, **КЫРМАВЫК** *срг., хвл.* к.: **кырмawык**. Тити тавык кырмавык, пич астында йырлавык (*такмак*). – *хвл.* Кырма wыклары була рахман йафырагының. Кырмawыкландым бакчада, ыйыгым нәстә булды, бак. – *чпр.* Адәм басарлык тегел, кецеркән дә кырмawык. – *чст.* Сакалын кырмавыкка буйап йебәргәннәр. – *мәл.*

**КЫРМАWЫСКА** [*рус.* кормовозка] *шрл.* к.: **арба: чытыр арба**.

**КЫРМАWЫЧ** *чст.* к.: **абчук**.

**КЫРМАҖИН** *крш.*, **КЫРМАЗИН** [*рус.* кармазин] *каз.ар.-крш.* кармазин. Кырмаҗиннар алдым ай җиләнгә, Көмөш кенә кирәк җөйләргә (*хал. җыр.*). – *каз.ар.-крш.*

**КЫРМАЛАУ** *тмн., хвл., кузн., лмб., чст., м.-кар., мәл., шрл.* к.: **қырмawық**. Йөнө бич кырмалау, бер дә карамаган икән сарыкларын. – *стрл.* Күрмичә кырмалау арасына барып кергәнмен. – *шрл.*

**дуңгыз кырмалавы** *хвл.* эре сырлан (чернокорень лекарственный).

**кырмалау йапрагы** *кузн., лмб.*, **кырмалау җапрагы** *м.-кар.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы**.

**КЫРМАН** *лмб.* корбан (жертва).

**кырман асты** *лмб.* корбан чала, яңгыр тели торган урын (место жертвоприношений, моления о дожде). Кырман астында кырманнар чалалар иде.

**нәзер кырман** *лмб.* әйткән нәзерне үтәү өчен уздырылган Коръән ашы (званый обед с чтением Корана по поводу выполнения данного обета). Нәзер кырман атәләр, нәзер атәдер дә суйа куймы, ниме, чыгара нәзер итен, чәй алнына тагы ни дә булса куйа, җире җире мән, җире җимеше мән.

**КЫРМЫЖ** *чпр.* к.: **кормош**.

**КЫРМЫКЧА** *мәл.*, **КЫРМЫЧКА** *хвл., мәл.* к.: **кымрысқа**. Путалактан кырмыкча теште.

**КЫРМЫШ: кырмыш кырты** *срг.* к.: **кормош**. Цага да ул кырмыш кырты.

**КЫРТ I** *чст.* к.: **тура I, 1**. Кырт куй кунакларга.

**КЫРТ II: кырт акчасы** *лмб.* элек: кыз тарафыннан кияүнең ата-анасына бирелә торган бүләкне котлап салган акча (в старину: деньги, преподнесённые гостями родителям жениха при осмотре подарков невесты).

**КЫРТ III: кырт итеп** *чст.* бик пөхтә һәм матур итеп (аккуратно, красиво, шикарно); чаг.: **қып: қып итеп тору**. Бәбәй ашы китергән иде, кырт итеп кийенгән.

**кырт IV** *миш.д.* корт (червь, гусеница):

**кызыл кырт** *клд.* к.: **селәү II, 1**.

**КЫРТКА** *шрл.* к.: **қортқа**. Кырткалар чакырган идек ашка.

**КЫРТЛАУ** *лмб., карс., чпр.* котлау (поздравлять, поздравить). Ызба кыртлаттык. – *карс.* Ызба пиче ачканда пирwый хатем укыталар, ызба кыртлый китерәләр. Бирнәне кыртлыйлар, кырт акчасы әтәләр. – *лмб.* Ызба кыртлап палас аппарган ыйым. – *чпр.*

**запун кыртлау** *лмб.* туйда яшь киленгә алъяпкыч яптырып, кесәсенә акча салу йоласы (обычай, согласно которому невестке завязывают передник и кладут в карман деньги). Туйда запун кыртлилар, запун бәлиләр дә йәш киленгә акча җиганнан сың, шал запунга салалар, акчасы да, әйбере дә йәш киленгә була.

**КЫРТМЫШ** *чпр., чст., мәл.* к.: **қырқыма**. Кыртмыш тайны йигәргә әрәтәләрме? – *мәл.*

**КЫРТЫЙШ** [*рус.* коротыш] *мәл.* йорт бурасының тәрәзә яннарындагы кыска бүрәнәләре (короткие брёвна сруба, находящиеся около оконных и дверных проёмов).

**КЫРТЫШ 1.** *чпр.* к.: **қыртыш I, 1**. Кер, симез сарыкта да кыртыш майы була; **2.** *байк.* каты үлән үскән калкулыклы (неровный, холмистый, бугристый). Лабагрейка белән җар өсләрен, кыртыш җирләрен цаба.

**КЫРУ 1.** *мәл., чст., чпр.* әрчү (чистить кожуру). Бәрәңге кырам да ике күршегә кереп чыгам. – *чст.* Давай, үзем дә кырышам алма, диләр. – *чпр.*; **2.** *чст.-крш.* бәрәңгене беренче кат китмәнләү (мотыжить картофель первый раз). Бәрәңгене дә кырыша алмады Марус. – *чст.-крш.*

**эҗ кыру** *байк.* эч пошу (грустить). Белмәгәҗ, эҗ кыра бит инде.

**К(Ы)РУК** [*рус.* круг] **1.** *миш.д., т.я.* түгәрәк (круг). Кырукны зурайтыгыз. – *чст.*; **2.** *миш.д.* тирәюнь (окрестность); чаг.: **мәрә 2**. Казан кыругы ничек, уражай ничек? – *хвл.*; **3.** *кузн., карс., мәл.* тирә, ян (вокруг, около). Күрше йегете йезе кара, Кыругымда әләнәдер (*бәет.*). Ыланнарым кыругыма җийылдылар. – *карс.* Малайлары кайадыр шул кырукта гына йөри торгандыр. – *мәл.* Эштән генә кат'сын инде, кыругына җыйылалар. – *шрл.* Йогырамы йерийем кырукларында. – *кузн.*; **4.** *кузн., срг., мәл.* тирә, кырый (край). Йугатыпсын шыл, кыругы циккән йаулык иде. – *срг.*; **5.** *чпр., мәл.* киртә, койма (ограда). Вайналы йылны кыругы бетте, вайнадан сың гына мыни кырук әләндергәннәр иде. – *чпр.*

**иләк кыругы** *карс., мәл.* иләк кысасы (обечайка сита).

**йыл кыругы** *мәл., чст., срг., кузн.* ел, ел әйләнәсе (год, продолжительность года). Йыл кыругы ызын бит. – *мәл.*

**кыруг уйнау** *к.т.*, **кыруг ун'ау** *тмн., кузн.* әйлән-бәйлән уйнау (водить хоровод).

**түр кыругы** *стрл.* өйнең эчендә стена буйлап элеп чыккан кашага (занавеска вдоль стены под потолком).

**К(Ы)РУКЛАУ** [*рус.* круг + *афф.* -лау] **1.** *карс.* шинләү – тәгәрмәч турында (обтягивать шиной – о колесе); **2.** *стрл., мәл., хвл., чст., шрл.* к.: **кыршу**. Өй белән рәттән кырукланган бакчалар бар да керә инде усатбыга. – *стрл.* Кабакны үзе йасады, йортны үзе круклады. – *хвл.* Аларның таш белән кырукланган. Син кыруклап карлыган утыртсаң, ди, нихатле файда. – *шрл.*

**КЫРУП** [*рус.* короб] *злт.* тал чыбыгыннан арба яки чана зурлыгында итеп үреп эшләнгән әрҗә (плетёный короб, корзина на телеге или на санях). Бу партфил кырупқа охшаган.

**КЫРУС** [*рус.* крест] **1.** *т.я.-крш.* тәре, хач (крест). Кызны алып баралар да чиркәүгә кырус кигезәләр; **2.** *мәл.* җиңелчә тиргәү сүзе (слово, употребляемое при лёгкой брани).

**КЫРУТА** [*рус.* круто] **1.** *миш.д., т. я.* текә (крутой). Агидел буйының йары да кырута, Йарыладыр кыйаж жарына (*хал. җыр.*). – *карс.* Кырута тау. – *к.т.* Агиделкайларның йары крута, Дотынып менәргә далы йук (*хал. җыр.*). – *кузн.* Баргач та анда таганнар бар, крута йар. – *м.кар.* Бүwадан китиг әле, бу йак крутарак. – *чст.* Кырута тау анда. – *шрл.* Атакай йыртың крута, Атлар тарталмый тыруйка (*хал.җыр*).– *лмб.*; **2.** *миш.д., т.я., кмшл., минз.* к.: **кискәнәттән**. Ыланпының филтәсен кырута чыгарма. Барганда кырута суккач, аwып китәргә дә мөмкин. – *чст.* Мына бит ничек, кырута гына этеп булмый. – *мәл.* Кырута дәшмә, қурқытырсың. – *к.т.* Куп-крута йыгылды да үлде. – *мәл.*; **3.** *мәл.* кызу, шәп (быстро). Тауны бик кырута менмәгез; **4.** *хвл., мәл., чст.* к.: **йерәкле**. Бик крута мин, ул сабыр. – *хвл.*

**КЫРУТУК** [*рус.* круто + *тат.* ук] *мәл.* к.: **кискәнәттән**. Үзең дә кырутук кермә, кызым, кычыклары бар.

**КЫРЧАК** *чпр.* к.: **корчак**. Кырчак алдырды алты тәңкә биреп, кырчагы кайа әле.

**КЫРЧАМА** *т.я.-крш.* к.: **кәрчәмә**. Кырчама йасай, су сала, писук сала, ачыйдыр чүпрә салгач, балы булган балдан йасаган.

**КЫРЧУ 1.** *т.я.-крш.* кырку (стричь). Үзем күрешкә сарык җыны кырчырга киттем; **2.** *мәл.* кыру, кырып бетерү (бить, громить, истреблять). Ул шахмыттан барысын да кырчи.

**КЫРЧЫГА** [*рус.* корчага] *тмн.* балчыктан эшләнгән, тар авызлы зур чүлмәк (большой глиняный горшок с узким горлышком). Мин дә белән кырчыганы, бер пыт сыйа булган үзенә, тар гына авызлары, бәлчектән эшләнгән.

**КЫРЧЫН** *стрл.* к.: **қырчын**. Кырчын китерт-терә дә йортка тараттыра.

**кырчын белен** *хвл.* төелгән киндер орлыгыннан пешерелгән белен (блины из толчёной конопли). Киндерашны тewәләр дә белен пешерәләр, шоно кырчын белен диләр.

**КЫРШАУ I** *чпр.* к.: **к(ы)рук 1**. Кыршау йасыйлар, зыйылалар, унилар.

**КЫРШАУ II** *м.-кар.* чорнау, урау (мотать, намотать). Күп кыршады бу җепне.

**КЫРШИН** [*рус.* кувшин] *лмб.* к.: **кукшил**. Кыршиннар чил, йәш килен, кыршиннарны бушатырга кирәк.

**КЫРШУ** *шрл.* читән яки койма белән әйләндереп алу, уратып алу (огородить, окружить изгородью). Әле кыршыдылар һәйкәлне.

**КЫРШЫwА** [*рус.*] *яүшт.* челтәр (кружево). Оцқа кыршыwа тегәдеген.

**КЫРШЫЛАУ** *срг.* к.: **қачушлау**. Алаша кыршылыйбыз.

**КЫРШЫЛУ 1.** *мәл.* такта белән бүлү, каплау (разгораживать, отделить дощатой переборкой). Цылан диләр, ишегалдында кыршылыб алынган булса; **2.** *кузн.* түбәсе ябылган булу (быть покрытым крышей). Сарайда ишекләре йук, тик кыршылган гына такта менән.

**КЫРЫ** *кузн., клд.* к.: **гелән**. Кыры мактап кына йөримен. Эч йакшы гына канарлий, кыры йазып кына тырасың. Кыры нужа белән үстек, самый кыйты wакытларда. – *клд.* Кыры йылый. – *кузн.*

**кыры йаңгыз** *карс., срг.* япа-ялгыз, берүзе (совсем одинокий). Урманда кыры йаңгыз йередем

быйылга тәкле. – *карс.* Кыры йаңгыз гына тора. – *срг.*

**КЫРЫБЫТАК** *чст.* к.: **қырыбытақ**. Чыбан дигән нәрсәне кырыбытак та диләр.

**КЫРЫЙК** *лмб.* к.: **курик 1**. Этнең кырыйгын киссән, куй булмас (*әйтем*).

**КЫРЫЙЛЧА** [*рус.* крыльцо] *чст., чпр.* к.: **болдор**.

**КЫРЫЙМЫСКА** *лмб.* к.: **қымрысқа**.

**КЫРЫЙСА** [*рус.* крыльцо] *к.т.* к.: **болдор**. Кырыйса тақтасы чүмәлеп киткән дә барып төшкән: айағын қаймықтырған. Кырыйса алды ишеген җawып җөр.

**КЫРЫК I** *чст.* чыбык (прут). Кулыңа кырык ал да куркыт шул казларны.

**кырык II** (сорок):

**кырык кице** *срг.* кырыгы (сороковой день от рождения). Бар'ам бит, кызның кырык кице иде.

**КЫР'ЫК** *кузн.* к.: **курик 1**. Кыр'ыклы йындыз.

**КЫРЫКМА** *чст.* к.: **қырқыма**.

**КЫРЫМЗАУ** *м.-кар.* к.: **бийауса**.

**КЫРЫМЧЫК** *чпр.* сөт к.: **кырындык 1**. Сетнең кырымчыгын кыра да awызына каба.

**КЫРЫ-МЫРЫ** *кузн.* к.: **қыры-қары**.

**КЫРЫНДАС** [*рус.* тарантас] *минз.* тарантас (тарантас). Иркәм, бер кырындаслы ат килә.

**КЫРЫНДЫК 1.** *мәл.* сөт кайнатканда, ботка пешергәндә төбенә утырган касмак (остаток, поскрёбки, прикипевшие на дне котла во время варки каши или кипячения молока). Казаннан кырындыкны кырып торма инде, су гына салып куй; **2.** *тмн., әҗ., шрл.* күәсне кырып җыйган камырдан пешерелгән ипи (хлебец, испечённый из выскребков квашни). Кырындык булгач, күwәс тебе икмәге була энде. – *шрл.* Кырындыкны эткә бирәсен, садака бирәсен дөнйалыгы өчен. – *тмн.*

**кырындык үкмәк** *әҗ.* к.: **кырындык 2**. Камыры кала да кырындык үкмәк пешерә.

**КЫСА I** *чст.* к.: **буй**. Күлмәк теккән идем дә, кысасы тарырак булган.

**КЫСА II** *глз.* к.: **кәлшә 1**.

**КЫСАУГАЧ** *стрл.* к.: **қустартқыч**. Кысаугачның сабы кыскарак, кузга кулым пешә.

**КЫСИМА** [*мат.* + *гар.*] *тпк.* пәнҗешәмбе (четверг). Кысима көннә умбиш көн йаңқыр йawа башлағанқа.

**КЫСКИ** [*рус.* тиски] *перм.* тимерлектә кулланыла торган озын саплы кыскыч (щипцы с длинной ручкой, употребляемые в кузнице; большие клещи). Кыски белә алабыз тимерне куздан, озон саплы булawы.

**КЫСКИК** *күрш.* кыска (короткий). Кыскикларны зырларым зырларны.

**КЫС'КЫРЫ** *карс.* к.: **кичке: кичке қорон**. Без бире мычадан чыгабыз кыс'кыры.

**КЫСМА** *стрл.* к.: **қысма I, 2.**

**кысма кысу** *стрл.* к.: **қысма I: қысма қысу**. Абзарга кысма кыса торган ийек йә саламнан, йә камыштан.

**КЫСТАНЫЧ** *тмн., карс.* авыр, кысынкы, ярлы – тормыш турында (стеснённый деньгами, бедно, тяжело – о жизни). Ис, ат'а, нишләрлек тә йук, ат'а, анда да бик кыстаныч. – *карс.* Ул йылларны кыстаныч иде. – *тмн.*

**КЫСТАНЫЧЛЫК** *карс.* кысынкылык, авырлык, кыенлык (нехватки, недостаток, тяготы). Шал әз бала ман калдым, бик кыстанычлык күрдем.

**КЫСТАУ** *хвл.* к.: **абдыравык**. Әшем бик кыстау иде.

**КЫСТИНКА** [*рус.* костяная, костяник] *срг.* чулпы (накосник). Цәцне цәпе белән үреп, шуның оцына кыстинка тагыла, өц цылбыр, оцларында тәңкәләр. Кыстинка шулай кашның кыругында өц цылбыр, цылбыр оцларында бер тәңкәлек, ике букасында ике тиннек.

**КЫСТЫМБЫЙ** *чст., м.-кар.* к.: **йақмыш I**. Без кыстымбый пешерәбез. – *чст.* Кыстымбый ул җука эченә каплап куйасын бәрәңгедән, тары боткасыннан да, суганын жарит итеп саласын. – *м.-кар.*

**КЫСТЫРГАН** *чст.* к.: **йақмыш 1**.

**КЫСТЫРМА** *срг.* бөккән (пирожок). Кыстырма аша, эрис белән эцәк салып пешердем. Кыстырма эшләйләр, ацы камыр эшләйләр, эченә ит куйалар, картушка була. Кыстырма закрытый инде, пируг кебек, борчак, ит, бырыц, тос салып, суган салып ике цитен бергә йасийлар. Карабодай онныннан кыстырма тәмне булайде. Кыстырма икмәк камырыннан, сочный булайде.

**КЫСТЫРТКЫЦ** *срг.* кер кыстыргыч (прищепка для белья).

**КЫСТЫРЫМБЫЙ** *чпр.* к.: **йақмыш 1**. Кыстырымбый җәймәсе кебек йока.

**КЫСТЫРЫП** *чст.-крш.* нечкә генә тасма кертеп калдырып тегү – күлмәк бизәге турында (вшивая узкую полоску ленты – об отделке платья). Кыз чагындагы кыстырып теккән күлмәгем бар.

**КЫСЫЛУ** *хвл.* тартыну, уңайсызлану (стесняться, смущаться, чувствовать себя неловко). Кысылып тора. Ашагыз, кысылып тормагыз, аша, быратым, тартынма.

**КЫСЫҢКЫ** *лмб.* тар (узкий, тесный). Бу күлмәгең үзеңә кысыңкы.

**КЫСЫРЛАУ** *лмб.* кыстау, мәҗбүр итү (принуждать, вынуждать). Әле хазер эшкә бик кысырламилар оланнарны.

**кытат** (парча, китайский шёлк):

**кытат кебек 1.** *шрл.* ачык – кызыл яки яшел төскә карата (яркий – о красном и зелёном цветах). Йезләре кытат кебег инде. Йаз кене ул йәмйәшел, кытат кебек була кары ачылган җирләр; **2.** *стрл.* ямь-яшел, хәтфә кебек (зелёный-презелёный, как зелёный бархат).

**КЫТ'КАЙ** *мәл.* кәжә яки сарык бәрәненә иркәләп эндәшү сүзе (форма ласкательного обращения к ягнятам).

**КЫТКАРУ** *чст.* к.: **коткару 3**. Бишмәтеңнең түмәләрен кыткарыб йибәр.

**КЫТ'-КЫТ'-КЫТ'** *мәл.* кәжә яки сарык бәрәнен чакыру ымлыгы (возглас, которым скликают ягнят).

**КЫТНАВАЛ** [*рус.*] *мәл.* котлован.

**КЫТНАУ** *мәл., күрш.* к.: **қырықлау I**. Кытнап цыкты тавык. – *күрш.*

**КЫТЧЫК** *мәл.* к.: **коцок**. Кытчыклары бар дип йазгандыр кабагына.

**КЫТЫЙЧЫК** *чст.* к.: **қотчоқ**. Кытыйчыкка сары май саласын, анан ары кып-кызыл алма батырасын, чийә батырасын анда.

**КЫТЫЛУ** 1. *лмб.* бушау (освободиться). Беген дә кытыла алмадым Хатирәгә барырга; 2. *тмн., срг., мәл., чпр.* ычкыну – төймә турында (отстегнуться). Түмәләрең кытылган бит. – *чпр.* Күлмәк үзеwем кытылды. – *тмн.*; 3. *чст., мәл.* китү, ычкыну (уйти, убраться). Бар, бар кытыл мыннан. – *чст.* Бызау кытылган, буйынчакка куйарга кирәк. – *тмн.*; 4. *срг., мәл.* сүтелү, күзе китү (распороться – о петле). Йебе кытылмасын эцен цәпе сал бегешенә. – *срг.* Шырпым сынды, күзләр кытыла бара (бияләй бәйләгәндә). – *мәл.*

**КЫТЫР** *чст.* к.: **қуқырт**.

**КЫТЫРЛАНУ I** *чст., мәл.* к.: **қуқыртлану**. Қара ничек кытырлана йегетең. – *мәл.*

**КЫТЫРЛАНУ II** *кузн., мәл.* тигезсезләнү, кытыршылану (становиться неровным, шероховатым).

**КЫТЫРЛЫ** *мәл.* кытыршы (неровный, шероховатый).

**КЫТЫРМАС** *срг.* кимек (хрящ).

**КЫТЫРМАЧ** 1. *мәл., хвл., стрл.* к.: **қытырмач** 1. Кытырмач йыйыла бит, кытырмачны түwәм дә килегә салып, канарлый бәрәңгегә йабып куйам; 2. *стрл.* к.: **қытырмач 2**.

**КЫТ'ЫШ** *мәл.* кәжә яки сарык бәтиен куу ымлыгы (употребляется при отгоне ягнят). Кыт'ыш, тегең үчкере.

**КЫХ: кых кирәк** *мәл.* бик кирәк (до зарезу, позарес нужно). Бер ун сум акча кых кирәк иде.

**КЫЦУ** *срг., чст.* к.: **кецү**. Йылыта, ахре, уң колагым кыций. – *срг.*

**КЫЦЫК** *әҗе.* к.: **коцок**. Бала кыцыктан куркына, бишектәгенеке биштегә терләнә, ту күз тийә, ту нәрсә.

**КЫЧАУГАЧ** *стрл.* к.: **қустартқыч**.

**КЫЧКЫРЧЫК** *хвл.* кычкырып сөйләшә торган (разговаривающий громко). Мин кычкырчык, апаның шындыйдан да көңөлө кала аныкы.

**кычкырып** (крича; громко):

**кычкырып бару** *стрл.* җикеренү, дорфа итеп кычкыру (орать, грубо крикнуть). Инәңә кычкырып бармыйлар алай.

**КЫЧУ** *стрл.* к.: **қецү**. Танawым кычый да танawым кычый.

**КЫЧУ-КЫЧУ** *чпр.* к.: **бди-бди-бди**. Кычукычу, сарыкларым ката.

**КЫЧЫК** *миш.д.* к.: **кочок**. Бүреме алды кычыгымны? – *тмн.*

**кычык шымырты** *мәл., чст.* эт шомырты (крушина ольховидная).

**КЫЧЫРУ** *глз.* кычкыру (кричать). Абзарга кургитка керәләр дә кычыралар сарыклар.

**кыш I** (зима):

**кыш кына** *тмн.* бохар кынасы (бальзамин).

**кыш өсөннән** *срг.* кышын (зимой). Кыш өсөннән туwар карыйбыз.

**кыш II** *миш.д.* кош (птица):

**кыш теле** *срг.* к.: **катлама 1**. Кыш теле пешерәләр уклауга урап, берничә кабат ураган, тиз генә майга салып пешерәләр, розы кебек итеп тә пешерәләр.

**КЫШИН** [*рус.* кувшин] *лмб.* к.: **кукшил**. Мунча йагучыларга кийәү акча сала, анда кышин куйалар, кышин астына кийәү акча куйа.

**КЫШЛАУ** *чст.* кышлаган, кыш чыккан (перезимовавший). Әммебездә кышлау да бар, тана да бар.

**кышлау кына** *байк.* к.: **кыш I: кыш кына**.

**КЫШЛЫЙ** *чст.* к.: **ката II: кыш ката**. Кышлый мунчасын керде.

**КЫШЛЫКТА** *срг., чпр.* к.: **қышқылық**. Кышлыкта да, җәйлектә дә бер wахыт тырам мин. – *чпр.*

**КЫШТАБАК** *мәл.* кечкенә эмаль табак (маленькая эмалированная чаша).

# Қ

**ҚААҚ** *яүшт.* яфрак (лист). Ағац қаағы.

**қаба** *урт.д.* каба (пряслице):

**җәй қабасы** *нгб.-крш.* кул белән теккәндә (тегелә торган) тукыманы эләктереп кую өчен ясалган җайланма (приспособление для прикрепления ткани при ручном шитье).

**ҚАБАҒАН** *тбл., тара.* тешләшә-талый торган – эт турында (кусающаяся – о собаке).

**ҚАБАҚ I** *крш., брб.д.*, **'АБА'** *кас.* к.: **кабак I, 1**. Зур 'ына 'аба'.

**күк қабағы** *т.кам.-крш.* күк капусы (миф: открытие ворот счастья). Күк қабақайлары ай ачылса, Күк эчләрен шунда күрербез (*хал. җыр.*).

**ҚАБАҚ II** *перм.* 1. каеры (кора). Аусақ йәшел қабақлы була. Элмә қабағы; 2. кабык (кожура; скорлупа). Кәртүк қабағы. Күкәй қабағы.

**қабақ III** *урт.д.* кабак (веко):

**тау қабағы** *кргл., бгрс.* тау бите (склон горы). Әрем дигәннән, анау тау қабағында күб ийе әwәл.

**ҚАБАҚ IV** *дөб.* җыен (джиен: родовой праздник нескольких сёл, устраиваемый после весенних работ). Қабақларға әзерләнәләр ийе әниләр, өрөк сулары қайнаталар ийе. Қабақ Мажарда (*ав. ис.*) арыш урағы алдыннан була йы.

**ҚАБАҚ V** *тбл.* үлән; яфрак (трава; лист).

**үлгән қабақ** *тбл.* саргайган үлән (пожелтевшая трава).

**ҚАБАҚ VI** *каз.ар.-крш.* аракы (водка). Бырашкы қуйдылар, қабағ алып қайттылар лапкыдан.

**ҚАБАЛАН** *нгб.-крш., тпк.* 1. тиз, ашыгыч (срочно, спешно). Минем эшем бик қабалан. – *нгб.-крш.* Қабалан булмаса, көтәп тор. Әле қабалан булды, қунақ итә алмадым. – *тпк.*; 2. *тпк.* ашыгып, тиз-тиз (торопясь, торопливо, наскоро). Иртәнсәк қабалан бутқа пешерәм. Хат йадайым тиб утырайым қабалан.

**ҚАБАЛАН-ҚАБАЛАН** *нгб.-крш.* ашыга-ашы-

га, тиз-тиз (поспешно, торопливо); чаг.: **қаба-тота**. Қабалан-қабалан чығып китте.

**ҚАБАЛАНУ I** *трбс., тпк.* к.: **абдырау 1**. Мин барып қайтқанчы тороп торогыз, қабаланмыйсызмы? – *трбс.* Қабаланма, көтөп тор. – *тпк.*

**ҚАБАЛАНУ II** *нрл.* к.: **қабалау**.

**ҚАБАЛАНЧЫҚ** *минз.* ашыгучан, кабаланучан (суетливый, торопливый). Бригадирыбыз қабаланчық иде.

**ҚАБАЛАНЫП-ҚАРСАЛАНЫП** *тпк.* каушый-каушый, кабаланып (суетясь, спеша, с волнением). Қабаланып-қарсаланып эшләдек, кем йиңә тип.

**ҚАБАЛАП** *к.т.* капшанып (ощупывая, обшаривая). Қабалап җөрим инде, күзләрем күрми.

**ҚАБАЛАУ** *нрл., к.т.,* капшау, кармалау (щупать, ощупывать). Мин суқыр, қабалый-қабалый бардым шунда. Төнлә қырда җөргән җулны қабалап. – *нрл.* Кесәмне қабалап қарый, симәңке җуқ микән дип. – *к.т.*

**ҚАБАМ** *перм.* к.: **қабас**. Бер қабам ырзық.

**ҚАБАРЛАШУ** [*гар.* + *афф.* -лашу] *тбл.* авылдан авылга кунакка йөрү (ездить в гости из одной деревни в другую).

**ҚАБАРМА** *брб.д.* **1.** к.: **кабарту**; **2.** к.: **келчә: калын келчә**.

**ҚАБАРТМА** *лш., минз., нокр.* көлчә, ачыга изгән арыш яки бодай камырыннан кул белән юкарак итеп җәеп ут каршында табада пешереп алган азык (лепёшки из кислого теста). Әпәй салдым, қабартма пешердем мич алдында йуқа ғына итеп. – *минз.*

**бәрәңге қабартмасы** *нрл., трх.* ипи камырыннан пешерелгән бәрәңге пәрәмәче (картофельная ватрушка из хлебного теста). Бәрәңге қабартмасы пешердегезме, ә без җақмыш ашап төштөк. – *нрл.*

**ипи қабартмасы** *мам.* к.: **қабартма**. Ипи җитмәсә, җә ипи қабартмасы ғына пешереб алам пич қаршында.

**қазан қабартмасы** *лш.* казанда майда пешерелгән кабартма (булочка из кислого теста, жаренная в масле). Қабартма – мич қаршында, қазан қабартмасын майда қазанда пешерәләр.

**ҚАБАРТУ: йөрәк қабарту** *минз.* йөрәк бозу, кәеф бозу (портить настроение). Сөт сорап, бакал тотоп йөрмәйем йөрәк қабартып.

**ҚАБАРУ** *минз.* кайнап чыгу, кайнау (закипеть, кипеть). Пешерер ийе тары ботқаны, қабарта да томалый да қуйа. Қабармаған сөт эчәсезме?

**ҚАБАРЧА, ҚАБАРЧЫ** *нокр., глз.* к.: **чәлпәк 3**. Қабарчысын ашағыз. Туйларга қабарчы пешерәләр.

**ҚАБАС, ҚАБАСЛЫҚ** *нрл.* кабым, бер кабарлык (кус). Бер қабас эпи бирүче булмас. Фөмөргә тату була ахириләр, бер қабаслық ыризықтан қалмаган кеше була. Начар кешедән бер қабаслық ыризық қала, ди.

**ҚАБАТ I 1.** *эчк.* к.: **йага I, 1**. Уң йақ қабатына қуйа торғаныйы йозақны; **2.** *эчк., туб.-урт.д.* к.: **қыр II, 1**. Wагун қабатына бардық. – *эчк.* Өй қабатта. – *тбл.* Сийарәт қабатынта йәм-йәшел чыршы үсә. Қыс ман йегет қабатынта нүгәр (кияү егете) булады. Қабатымта утыраты. – *твр.*; **3.** *туб.-урт.д.* янәшә (рядом). Икәү қабат утыратылар, мулла сурайды, эриса булып алдыңма? – *твр.*; **4.** *твр., тбл.* кырый, чит (кромка, край). Матур қаптырмалар, қашлы, қабатларында тәңкәләре булады. – *тбл.*; **5.** *саз.я., тбл.* чит (сторона). Эшләнгәнне қабаттан қарап йөрү килешмәйте. – *тбл.* Аны қабатқа йебәрең. – *саз.я.*

**ҚАБАТ II** *төм.* к.: **арый**. Ике қабат цағырып килтем, килмәйте.

**қабат ат** *төм.* пар ат (пара лошадей).

**ҚАБА-ТОТА** *т.я.* ашыгып, кабаланып (торопливо, суетливо); чаг.: **абаулану**. Қаба-тота сүләде, берни аннамадым. – *к.т.*

**ҚАБАЧ** *брб.д.* сынык, калган ипи кисәге (кусок, ломоть). Динә, синең қабачың төгөлмә?

**ҚАБЕР** [*гар.*] *туб.-урт.д.* кафер (гяур, неверный).

**ҚАБЕРСТАН** [*гар.+фарс.*] *әстр.* зират (кладбище). Қаберстанда Коран уқый ул.

**ҚАБУ 1.** *блт., мам.* нык үткен коралның кисәсе әйбергә тиз ябышуы, әләгүе (схватывать, прихватывать тонким острием – о режущих инструментах). Бу пәке бик үткен қайралган, чәчкә қаба. – *блт.* Балтасы бармаққа қаба, шулхәтле үткен. Урақны тешәсе бар, қапса урырға җиңел. – *мам.*; **2.** *лш., төм., твр.* талау, тешләү – әт турында (кусать, укусить – о собаке); чаг.: **айыру 2**. Теге қаба торған этегез исән ийе әле. – *лш.* Аннан қурықмаң, ул ицкемне қапмайты. – *төм.*; **3.** *тбл.* әләктерү, кул белән алу (брать руками).

**ҚАБУЛА** *нрл.* кузла (козлы).

**ҚАБЫҒУ 1.** *минз.* муртаю, черү (преть, дрябнуть, тлеть). Қабыққан тawар булмасын; **2.** *минз., перм., кргл.* күгәрү (заплесневеть). Қабыққан печән. Ул йәшел нәстә (печән) үзеннән-үзе қабыға. – *перм.* Қабыққан бозайның оно начар була. – *минз.*

**ҚАБЫЗЛАНУ** *дөб.* авырту – эч турында (болеть – о животе). Ашыйсым килми, эчем қабызланып тора әле.

**ҚАБЫЗЛЫҚ** *лш., дөб., блт., перм.* ут кабызгыч чыра, йомычка яки башка әйбер (щепки, лучина или что-нибудь другое для разжигания огня). Қабызлығ алды да пичкә ут әпкилә көрәк белә. – *перм.*

**ҚАБЫҚ** *глз.* **1.** тыш – пирог, бәлеш турында (корка у пирога). Бәлеш қабығын кискеләделәр; **2.** мендәр тышы (наволочка). Ақ қабықлар бирдем йастыққа; **3.** *тара., твр.* балык тәңкәсе (чешуя). Албоға қаты қабықлы, урыслар укун тейме? – *твр.*

**қар қабығы** *бөре.* кар өстендә барлыкка килә торган юка ғына боз катлавы (твёрдая корка на снегу после короткой оттепели; наст).

**ҚАБЫЛ-ҚОБОЛ, ҚАБЫЛ-ТИБЕЛ** *к.т.* алпантилпән (вперевалку, качаясь, шатаясь). Үз өйөмдә қабыл-қобол җөрим.

**ҚАБЫМ** *брб.д.* йотым (глоток). Пер қабым да арақы йотмайдыған.

**ҚАБЫННЫҚ** *минз.* к.: **қабас**. Қабыннығын урталай бүлеп қаба.

**ҚАБЫНУ** *нгб.-крш.* кайгыру, яну-көю (горевать, печалиться); чаг.: **дәртләнү 1**. Қабынып үләм сезнең җанда.

**ҚАБЫРҒА I** *минз., нгб.-крш., кргл., глз., перм.* **1.** берәр нәрсәнең чите, яны, буе (рядом, вдоль чего-либо). Беренче нифтне awыл қабырғасында тапқаннар. – *минз.* Қабырғамнан киләйе ата қаз,

чымытыб алды. – *нокр.*; **2.** кырый, ян, як, чит (край, боковая сторона чего-либо). Қабырғадан қарағанда бигрәк тә охшаган сиңа. – *кргл.* Ләгүшиннең (*ав.ис.*) қабырғасында ғына ул awыл. – *нгб.-крш.* Таш җулның қабырғасы ғына безнең җорт. Қазанның үзенекеме, қабырғасындағымы? – *перм.*

**қабырғаға қуйу** *перм.* читтә калдыру, икенче планга кую (оставить в стороне, отвести на задний план). Ә без, киресенчә, төп эшне қабырғаға қуйабыз.

**тәрәзә қабырға, тәрәзә қабырғасы** *перм.* тәрәзә яңагы (косяк). Тәрәзә қабырғада бар қый бер энә.

**ҚАБЫРҒА II** *бгрс., кргл.* мамык шәл читендәге ачык күзләр рәте (ряд открытых петель на краю каймы пухового платка).

**қабырға III** *урт.д.* кабырға (ребро):

**қабырғалы қул** *кмшл.* ит түшкәсенең кабыргалы ал боты (одна четвёртая, передняя с рёбрами часть туши мяса). Пешермиче қаз әпкилә туйға, қазы булмаса, қабырғалы қул әпкилә.

**ҚАБЫРЗАҚ** *брб.д.* нечкә, тар (тонкий, узкий).

**ҚАБЫРТМА** *брб.д.* каптырма (старинная ажурная застёжка с камнем). Қабыртмалу камсолым бар.

**ҚАБЫЧАҚ** *брб.д.* янчык, кечкенә капчык (мешочек, кисет). Қабычаққа салып түрәп қуйадым (акчаны).

**ҚАБЫШҚАҚ** *тбл.* к.: **қабаган**. Салимчаналарның этләре бәйләгән, қабышқақ.

**ҚАБЫШТЫРУ I** *брб.д.* типчү (наметать). Тегәм, йелкәмнән төшмәй, әле қалат қабыштырып қуйдым.

**ҚАБЫШТЫРУ II** *брб.д.* к.: **лампы: лампы эрү**. Ут қабыштырырга серәңке йуқ.

**ҚАБЫШУ** *тбл.* талашу (ругаться, ссориться). Моннан пы йаққа аның пелән ицбер қабышмас итем.

**ҚАWAҚ 1.** *себ.* яфрак (лист). Қайын қawағы сап-сарық. – *брб.д.* Йеләк қawағы көп. – *төм.д.*; **2.** *брб.д.* к.: **йапрақ**. Қawақ мынан чабынайынма?

**ат қawақ** *себ.*, **ацы қawақ** *тбл.*, **йаңқырца қawақ** *тбл.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы**.

**қawақ пәйләү** *тбл.* себерке бәйләү (готовить веники). Қawақ пәйләйте төстә мунцаға.

**қawақ церетмә йамқыр** *тбл.*, **қawақ цертмә йаңқыр** *тара.*, **қawақ черетмә йамқыр** *твр.* вак, сибәләп ява торган яңгыр (моросящий дождь). Қawақ цертмә йаңқыр осақ йawаты, әкрен кенә. – *тара.* Төнә белә йawат, қawақ черетмә йамқыр, өсө соуқ. – *твр.*

**қарлиғач қawақ** *тара.* к.: **бырцак: бырцак үләне**.

**қарынташ қawақ** *тара.*, **қас қawақ** *твр.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы**. Қас қawақлары кән монта, қас қawақны баш төбәгә қуйамын.

**май қawақ** *тбл.* к.: **йара II: йара йапрақ**.

**татар қawақ** *тара.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы**. Татар қawақ, йапырағы йалбық.

**татлы қawақ** *себ.* к.: **йара II: йара йапрақ**.

**төп қawақ** *тбл.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы**.

**урыс қawақ** *твр.* **1.** к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы**. Урыс қawақны сыслағанға қуйалар; **2.** к.: **айуқузғалақ**.

**цуцқа қawақ** *тара.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы**.

**ҚAWAЛ** *әстр.* кыллы чиртмә уен коралы (щипковый струнный музыкальный инструмент).

**ҚAWAЛЧЫ** *әстр. қawалда* уйнаучы (играющий на *қawале*). Мин үзем қawалчы.

**ҚAWAH** *сазя.* кабан дуңгызы (кабан).

**қawан цуцха** *сазя.* к.: **қawан**.

**ҚAWAT** *сазя.* к.: **қыр II, 1.** Мииң қawатта тор, алыс хитмә.

**ҚAWЫЗ** *каз.ар.-крш., кмшл.* к.: **бишнәк**. Awызы – иске тегермән қawызы (*әйтем*). – *кмшл.*

**ҚAWЫМ I: бер қawым** *каз.ар., минз., бөре., кргл., бгрс.* **1.** бераз вакыт, ара (некоторое время); чаг.: **безрәк**. Бер қawым тордо да қартлар җортона итеп қуйдылар. Чәйне бер қawымнан үзем қуйып эчәм. – *блт.* Бер қawым йатып тырган ыйым, йоқоға киткәнем. Бер қawым сөйләшеп торыйғ әле. – *мам.* Бер қawым бик қызу булды, аннан салқынайтты. – *кргл.*; **2.** бер өлеш, бераз (некоторая часть, немного). Бер қawымын кешегә саттық, бер қawымын үзебез урдық. – *блт.* Арышлар да чапқаннар ийе бер қawым. – *бөре.* Бер қawым торасызмы әле? – *дөб.*

**ҚAWЫМ II** *минз., перм., нгб.-крш.* к.: **қawын 1.** Қawымнарға су сибәргә кирәк, dyp-dyp булып үсәләр алар. – *минз.*

**ҚAWЫМ-ҚAWЫМ** *нрл.* вакыты-вакыты белән (временами). Әни қawым-қawым саташа әле.

**ҚAWЫН 1.** *каз.ар.-крш., минз., эчк., чст.-крш.* кабак (тыква). Қawын бөгөше пешердем. – *минз.* Қawын үстерғәлиләр. – *нгб.-крш.*; **2.** *туб.-ирт.д.* кыяр (огурец). Тослаган қawын қуйатылар. – *тара.* Қawыннар көл күрсәтмәйен утыраты, көн сыwық. – *тбл.*

**йөнлө қawын** *төм.* к.: **ден II**.

**қawын қабағы** *перм.* к.: **қawын 1**. Қawын қабағы итле була, җиме wақ була.

**тын** [*рус.* дыня] **қawын** *тара.*, **шәр қawын** *төм.* к.: **ден II**. Тын қawын та үсәте пестә.

**ҚAWЫПЛЫ** [*гар.+ афф.* -лы] *туб.-ирт.д.* куркынычлы, хәвефле (страшный, опасный). Йелтә қawыплы, Қунтан – оллы күл.

**ҚAWЫПСЫУ** [*гар.+афф.* -сыу] *тара.* курку, хәвефләнү (бояться, опасаться).

**ҚAWЫР** *бәр., лш.*, **ҚAWЫРҒЫЙ** *нрл.* каурый, кawырсын (птичье перо). Элек без қawыр белән йазар ыйық. – *бәр.* Қаз қawры. – *лш.* Қawырғый җыйып қайттым мендәргә. – *нрл.*

**ҚAWЫРМАЧ** *брб.д., туб.-ирт.д.* куырмач (жареное зерно – как еда).

**ҚAWЫРСЫН 1.** *төм., тара.* камыл (стерня, жнивьё). Компайн йаққа парсағыс, йенцеккесне қawырсын қырар. – *тара*; **2.** *злт., әстр.* пластмасса. Wатылганға күрә хөкөмәт белеп қawырсын пасудалар сығара инде. – *злт.* Қawырсын нәлбәкте ала қуй. Қawырсын табақлар чыкты хәзер. – *әстр.*

**ҚAWЫРУ** *твр., тара.* куыру – орлыкны (жарить – зерно). Аш ипийе йитми, ачлық, тарма йемен қawырып ашайбыс.

**ҚАWЫСТА** [*рус.* капуста] *туб.-ирт. д.* кәбестә (капуста). Қawыста та тослайым. – *төм.*

**ҚАҒА** *брб.д.* козгын (ворон).

**ҚАҒАЙУ 1.** *блт., лш.* гәүдәнең бер позада хәрәкәтсез озак булуы (долго сидеть или стоять в какой-либо позе без движения). Нәрсә қағайыб утырасың аны көтөп? – *лш.* Қузгалмый басып торасың қағайып афтawыз көтөп. – *блт.*; **2.** *дөб.* кату, калҗаю (затвердеть, рассохнуться). Инде личит итеп булмый, былар қағайган инде, диләр (кул); **3.** *тбл.* кату (затвердеть); **4.** *дөб.* к.: **алҗырау**.

**қағайып тору** *каз.ар.* хәрәкәтсезлектән катып, интегеп басып тору (стоять закостеневшись без движения). Қузғалмый басып қағайып тора, мине көтөп. – *блт.*

**қағайып утыру 1.** *каз.ар., т.я.* берәр эш өстендә бик озак интегеп утыру (сидеть долго, напряжённо над какой-либо работой, корпеть). Нәрсә қағайып утырасың аны көтөп. – *лш.* Қағайып утырадырыйық суғу дип, орчоқ дип. – *к.т*; **2.** *кмшл.* к.: **алҗырау**. Қағайып утыра, мескен, берүзе.

**ҚАҒАЛАҚ** *том.д.* саз үләне (резун – болотная травка).

**ҚАҒАЛУ** *тбл.* җәфалану, интегү (маяться).

**ҚАҒАН** *яүшт.* агачлык, кечкенә урман (местность, заросшая деревьями; небольшой лес, роща). Қаған дип зур түгел генә бүләкне әйтәләр.

**ҚАҒАНАҚ** *том.д., тбл.* бала урыны, карын (плацента). Қағанағы алттан йыртылып китсә, awыр пулаты тапқалы. – *тбл.* Қағанақ йарылып китепте, асрай алмай зақ йатты, сыу китәде дә. – *том.*

**ҚАҒАР** *туб.-ирт.д.* кыргый үрдәкнең бер төре (один из видов диких уток).

**ҚАҒАУ** *минз., брб.д.* тилгән (коршун). Қағау йуқмы, чебешләрне қара. – *минз.* Қагау тиләр тилгәнне, бәпкәләрне ала. – *брб.д.*

**ҚАҒУ I** *минз.* су чыгару өчен җиргә труба төшерү (вбить трубу в землю для выкачивания воды).

**ҚАҒУ II 1.** *төм., тара., брб.д.* селкү (трясти). Өц-түрт пар саламны қағаты; **2.** *глз.* болгау (махать). Қул қағу; **3.** *т.я* селкетү, селкетүдән хәлсезләнү, күңел болгану (укачивать, быть в плохом состоянии от качки на санях, поезде или машине). Чана қагу. Машина қағу. Берәр җиргә барсам қышын, чана қағудан көне буйы игә киламыйм. – *к.т.*; **4.** *тара., төм., брб.д.* селкү (трясти); **5.** *брб.д.* төртү (толкать).

**йаулық қағу** *глз.* кичке яшьләр уены (вечерние молодёжные танцы у реки, у подножия горы). Тау бар ич, анда йаулық қағабыз дип паралап-паралап тешкәләдек.

**ҚАҒУ III** *төм.* **1.** чуку (клевать); **2.** читләтү, ят күрү, кимсетү (считать чужим, унижать).

**қырый қағу** *лш.* кагу, чит күрү, ят итү (обижать, отвергать, считать чужим). Сандықның ачқычын әни миңа бирде, шуңа күрә ул апабыз мине қырый қақты.

**ҚАҒУ IV** *брб.д.* суғу (ударять). Бажына қағалар да, бажы йарыла да. Берсенә қағасың та йүгерәсең, тота алмаза, ул қаға (уен вакытында).

**қақ та йүгер** *брб.д.* әбәкле – уен исеме (салки). Қақ та йүгер уйнадық тау башта.

**ҚАҒУ V: ...дан қағу** *каз.ар.-крш.* (нинди дә булса) төскә буяу (покрасить). Безнең маманың туны қарадан қаққан ыйы.

**ҚАҒЫЙ: қағый чана** *твр.* утын ташый торган чана (дровни).

**ҚАҒЫЛМА** *т.я.* салу (раскат на зимней дороге). Ул җулда атқа бик awыр, қағылмалар күп. – *к.т.*

**ҚАҒЫЛУ I** *т.я.* к.: **кағылу**. Бер зур ғына қағылмада чана қағылып та китте, тәртә шартлап та сынды. – *к.т.*

**ҚАҒЫЛУ II** *лш., каз.ар.-крш.* керү, сугылу, кереп чыгу (зайти, заехать). Иртүк киткән ийем, қағыла-қағыла киләм, кич булды инде, соңа қалып беттем. – *лш.*

**ҚАҒЫЛЦУ** *тбл.* бизү (отвыкать).

**ҚАҒЫРАН** *туб.-ирт.д.* **1.** кышкы аяз һава (ясная погода зимой); **2.** озак торган аяз көннәр (продолжительная ясная погода).

**ҚАҒЫРТХЫ** *саз.я.* какырык (мокрота).

**ҚАҒЫТ** *злт., минз., бгрс.* как (сухая тонкая пастила домашнего приготовления). Бу қазан қағытымы? Мынса сыққас қағыт белә тәмне была сәй. – *злт.* Былтыр алған қағытым әле дә тора. – *бгрс.*

**'АДАWЫ'** *кас.* **1.** к.: **қырмawық**; **2.** чәнечке, әнә – үсемлекләрдә (иглы, шипы – у растений)

**қадақ** *урт.д.* кадак (гвоздь):

**суңғы қадақ** *перм.* җеп озатырга каккан чөйләрнең соңгысы (последний колышек при наматывании нитки для тканья). Чүте җомарлағанда иң суңғы қадақтан башлыйсың, җилегә җитә йазғанчи чүтелисең.

**ҚАДАҚЛЫ: қадақлы сандал** *дөб.* сай, өстән эләктермәле сай туфли (неглубокие сандалии, прикрепляемые сверху ремешками).

**ҚАДАЛЦЫҚ** *тбл.* чәнечке (колючка, шип). Эткүтнең (билчән) қадалцықлары бар.

**ҚАДАМА** *минз.* брошка. Аның бик матур қадамасы бар. Мәрҗән муйында, колагында алқасы, күкрәгендә қадама – бар да берочтан.

**ҚАДАННАУ** *брб.д.* гел бер үк нәрсәне эшләү (часто делать одно и то же).

**ҚАДАР** *брб.д., том.д.* к.: **қатар I**. Песнең қадары ғыйа болса да кән пеләде. – *брб.д.*

**ҚАДАР-ҚАДАР** *брб.д.* кабат-кабат (часто-часто, неоднократно).

**ҚАДАУ I** *брб.д.* **1.** кадак (гвоздь); **2.** шырпы (заноза).

**ҚАДАУ II** *трх.* чагу – бал корты турында (жалить – о пчеле). Тәнендә җәри, қадамый мартасы.

**ҚАДАУҒЫЧЛЫ** *глз.* к.: **қазawычлы**. Үзе қадауғычлы, үзе матур була шаған агачы.

**ҚАЖАН** *том.д.* абзар (хлев).

**ҚАЖЫҚ** *брб.д.* зур кашык (большая кухонная ложка).

**ҚАҖАУ** *перм., к.-уф.* к.: **йуну 2**. Бәрәңге салды қажап, җомролата. Кәртүкне қажамый салалар ийе (ашка). – *перм.* Бәрәңге қажап қуй, қызым, қайтқач үзем турап салырмын. – *к.-уф.*

**ҚАЗ I** *минз.* тары көлтәсеннән куела торган чүмәлә (копна из снопов проса).

**қаз айағы** *кргл.* унбиш-егерме көлтәдән өелгән көлтә чүмәләсе (копна из пятнадцати-двадцати

снопов). Көлтәне қаз айағына куйадыр ыйық, аннан зуратқа куйалар.

**қаз II** *урт.д.* каз (гусь):

**йаз қаз** *нокр.* кыр казы (дикий гусь). Йаз қаслар килделәр, сабан ашлық йахшы булыр, диләр.

**қаз айағы печән** *бөре., перм.* абаганың бер төре (один из видов папоротника).

**қаз ашы** *мам.* каз өмәсе булган көнне уздырыла торган кичке мәҗлес (званый обед вечером того дня, когда произошло выщипывание гусей). Қазы булса, қаз ашы булайде, қазы булмаса да, аш җыйа инде үзе йөргәч. Қаз ашында көлчә пешерәләр.

**қаз бала** *тбл.* к.: **бала I, 2.**

**қаз билчәне** *дөб.* яшелчә билчәне (осот огородный).

**қаз қабартмасы** *мам.* каз өмәсе көнне каз йолкучылар казны юып кайтуга ачы камырны кул белән юкарак итеп җәеп табада пешерелә торган камыр ашы, көлчә (большие лепёшки из кислого теста, испечённые после завершения выщипывания гусей). Қаз жywып қайтқач, қаз майын эретеп, манчып-манчып ашыйсың қаз қабартмасын.

**қаз қоймағы** *мам.* каз өмәсе көнне каз йолкучылар казны юып кайтуга пешерелә торган коймак (оладьи, испечённые после завершения выщипывания гусей). Қазны йywып қайту белән қаз қоймағы ашарға утырасың, қаз майына манып ашыйлар аны.

**қаз көлчәсе** *мам.* к.: **қаз қабартмасы.** Қаз ашында көлчә пешерәләр қаз көлчәсе дип, қаз майы белә ашатасың инде қаз суйған көннә.

**қаз қузғалағы** *минз.* чыпчык кузгалагы (щавель, малый щавель).

**қаз муйыны бору** *мам.* юрау: каз муенын кем тиз өзеп ала, шул, имеш, тиздән кияүгә чыга (гадание: кто быстрее оторвёт шею у выщипанного гуся, та скорее выйдет замуж). Ике қаз суйдық, эй муйын борған булабыз, миңа тартышырға да туры килде дә шул, барыбер ике тәтәмне қалдырып китеп бардым.

**қаз оты** *брб. д.* 1. кыяк үләне, күрән (осока); 2. билчән (осот).

**қаз тәпийе** *минз.*, к.: **қазыйақ I.**

**қаз теше йасау** *кмшл.* бөреп тегү ысулы (вид сборки при шитье). Қаз теше йасап береп-береп теккән күлмәгем бар ийе.

**қаз үләме** *т.кам.-крш.* к.: **қаз билчәне.**

**қаз үләте** *т.я., кмшл.* 1. зәһәр казаяк (лютик едкий); 2. агулы казаяк (лютик ядовитый).

**қаз чәй** *мам.* сөтле билчән (осот полевой). Қаз чәйләр җийа торған ийек арыш арасыннан, қаз чәйне өзсәң, сөтө чыға аппақ.

**қаз чәйе** *кргл., бгрс.* к.: **қаз билчәне.**

**қаз читәне** *минз.* чыбыктан үргән каз оясы (корзина для гусыни, чтобы высиживать гусят).

**қунаша алмаған қаз** *нрл.* аталана алмаган, дуадак (гусыня, не выведшая гусят, не совокупляющаяся).

**қad** *минз.* каз (гусь):

**қad йулы** *минз.* ике көлтәне аркылы-торкылы куя барып ясалган өемнәр рәте (ряд копён, состоящих из двух поперечно сложенных снопов). Қad йулына салып қуйабыd кибәргә киндер суға торганың, орлоқныкын да көлтәгә бәйләп қуйабыз.

**ҚАЗА I** *тара.* 1. язмыш (судьба, предначертание); 2. әҗәл (смертный час). Бир гүнләрдә байның қазасы йитеп үлде.

**ҚАЗА II** *тбл.* казларны куу ымлыгы (междометие, употребляющееся при отгоне гусей).

**ҚАЗАWЫЧЛЫ** *нокр.* чәнечкеле (колючий, с шипами). Кыржауник алай қазawычлы була ич.

**ҚАЗАЙАҚ I** *бгрс., кргл.* 1. к.: **қаз I: қаз айағы;** 2. *трх.* к.: **қad: қad йулы.** Қазайаққа қуйалар биштән жегермегә қәдәр иген қуйы төштә, сирәк төштә биш-биш кенә, иген әз чыққан төштә.

**ҚАЗАЙАҚ II** *бөре., перм., төм.* абаганың бер төре (один из видов папоротника). Қазайақ қаты үләп, цәцәген күргәнем йуқ. – *төм.*

**қазайағы печин** *перм., бөре.* к.: **қазайақ II.**

**ҚАЗАҚ I** *минз.* 1. ялгыз – ир кеше турында (одинокий – о мужчине). Мин үdем қазақ жегеткә бардым шул, өй эчендә бер генә малай, малы йуқ; 2. *минз.* буйдак, өйләнмәгән егет (холостой); 3. *перм.* буйдак, ялгыз ир яки хатын (холостяк, одинокий мужчина или одинокая женщина). Қазақ жегеткә бардым ийе, үзе генә йе; 4. *нгб.-крш.* солдат. Қазаққа алыну.

**қазақ қода** *бәр.* ялгыз, өйләнмәгән кода (холостой, неженатый брат невесты или жениха).

**ҚАЗАҚ II** *тбл.* өтөрге (долото).

**ҚАЗАН** *т.я.* су төбендә барлыкка килгән чокыр, чоңгыл (углубление на дне реки или озера; омут). Ул җирдә Зөйәнең қазаннары күп ти, су қойонорға керәләр дә батып үләләр. – *к.т.*

**ашау қазаны** *минз.* к.: **аш II: аш савыты 2.** Ашау қазаны шулай зур микән? – ди.

**қазан асу** *трх.* ашарга әзерләү, пешерергә салу (варить кушать, поставить вариться). Жәйәү барып эшлә, қайтқач қазан ас.

**қазан бөккәне** *каз.ар.-крш.* пилмән (пельмени). Аш белән киләләр жегет жағында да, қыз жағында да, өстәл күтәреп тормаслық итеп апкиләләр қаз, қазан бөккәне.

**қазан өй** *әстр.* кечкенә камыш йорт, кухня сыйфатында кулланыла (отдельная, камышовая маленькая постройка, используемая как кухня).

**қара қазан** *әстр.* зур казан (большой котёл).

**ҚАЗАН-АЙАҚ** *әстр.* казан һәм савыт-сабалар (котёл и прочая посуда). Қазан-айақ йywаты килен.

**қазан-айақ йаны** *әстр.* к.: **бүлмәч 2.**

**ҚАЗАНБАШ** *туб.-урт.д.* туйда аш-суга жаваплы кеше (человек, ответственный за угощение и приготовление свадебного стола). Қазанбаш итә тоганнар ите йәш пулса та, туйта ғына була қазанбаш, пүләк пирәтләр айырым, гөйләклек мал бирәтләр.

**ҚАЗАНЛЫҚ** *әстр.* тышта эшләнгән учак (очаг, находящийся во дворе).

**ҚАЗАННАУ** *брб.д.* казанда пешерү (готовить еду в котле).

**ҚАЗАННЫҚ** *злт., трбс.* к.: **бүлмәч 2.** Қазанныкта пешеренән инде. – *злт.* Қазанның жағына кереп китәр ийе қарчығы. – *трбс.*

**ҚАDАННЫҚ** *тпк.* 1. к.: **бүлмәч 2.** Қadаннық-

тағы пөтөн әйберне сорап сықтың, қашығыдыр, йәмкәседер қалмады; **2.** казан һәм аның янындағы стена, учак һ.б. (котёл и всё то, что находится в непосредственной близости к нему). Элек пит қаданныққа салып, қаданныққа йағып бешердек. Қаданныҡ қыда бит одаҡ су йылытҡас, пүрәнәгә ут үрләп...

**ҚАЗАНТӨП** *төм.* элек: киң төп – ыштан турында (в старину: штаны с широким шагом). Мамам пар ите, әтийемнең әнисе, гел ыштаннарны қазантөп итеп тегә теген ийе.

**ҚАЗАНЧЫ** *твр.* аш пешерүче, пешекче (повар, повариха).

**ҚАЗАРТҚЫ, ҚАЗАТҚЫ** *брб.д.* давыл, өермә (буря).

**ҚАЗҒАЛАНУ** *кргл.* тырышу, тырышып эшләү (стараться, усердно трудиться, вложить чересчур много сил). Ғымер буйы шунда қазғаланды инде.

**ҚАЗҒАНУ** *себ.* кайгырту (заботиться, забота).

**ҚАЗЛАУ** *минз.* каты – җир турында (твёрдый – о земле, почве). Қазлау җир.

**'АЗНА** [*гар.*] *кас.* өсәк, бура (закром, сусек). 'азнаның бер җа'ына борча' сибилир, бер җа'ына соло сибилир.

**ҚАЗНАҚ 1.** *минз.* мич казнасы (основание, фундамент печи, опечек); **2.** *злт.* сәке астын каплап тора торган такталар (доски по краю нар).

**ҚАЗНАСТЫ** *каз.ар.-крш.* к.: **қазнақ 1.**

**ҚАЗНАУ** *перм.* **1.** к.: **қазнақ 1**; **2.** к.: **қазнақ 2.** Сике қазнау; **3.** к.: **диңгез 1, 2.**

**'АЗО** *кас.* к.: **қазы.**

**ҚАЗТАМАҚ** *блт.* тамак асты бизләре шеше (зоб). Қаztамақ чыққан, муйын да бора алмый.

**ҚАЗЧӘЙ** *блт.* к.: **қаз II: қаз билчәне.**

**ҚАЗЫ** *кргл., нокр., глз., себ.* өйдә ат итеннән әзерләнгән казылык (домашняя колбаса из конины). Қазы тутырасин ат иттин, ашап та туймайсин. – *нокр.*

**қазы эчәк** *яүшт.* казылык ясарга яраклы эчәк (часть кишков, пригодная для приготовления домашней колбасы).

**ҚАЗЫЙАҚ I** *дөб.* казаяк, каз үләне (гусиная лапка). Қазыйақ эс син, эсен awыртқанда.

**ҚАЗЫЙАҚ II** *минз.* к.: **ақсырдақ.** Қазыйақ tawышы җөрәгемә җарамый.

**ҚАDЫЙАҚ** *минз.* ун көлтәдән куела торган өем (копна из десяти снопов). Қadыйақта ун көлтә була, аннан dуратқа салайық.

**ҚАЗЫҚ: тимер ғазык** *төм.* так каравыл уены (горелки – игра).

**ҚАDЫЛЫҚ** *тпк.* атның майлы юан эчәгесен әйләндереп эченә май тутырып әзерләнгән ашамлык (домашняя колбаса из конского сала).

**қабырға қadылығы** *тпк.* казылык (брюшина с салом).

**тутырған қadылық** *тпк.* тутырма (домашняя колбаса с мясом и крупой).

**ҚАИМЛАУ** *тбл.* бору, әйләндерү (повернуть, вертеть).

**ҚАИП** [*гар.*]: **қаип булу** *тбл.* юкка чыгу, югалу (исчезать, исчезнуть).

**ҚАЙ I: қай арада** *каз.ар.-крш.* кайвакыт (иногда). Хәзер дә ул чирләр қай арада була.

**ҚАЙ II** *туб.-ирт.д.* **1.** беренче кар, җәй азагында яки көз башында кар яву (снегопад в конце лета или начале осени). Утынны бөтөрмән, көсге қайларға кәрәгер. – *саз.я.*; **2.** май аеның урталарында кар яву (выпадение снега в середине мая); **3.** язгы явым-төшемле, карлы, җилле һава (весеннее ненастье, снегопад, ветер). Пақцарның (сыерчыкның) қайы пулаты йасқылық; **4.** берәр кеше үлгәннән соң яуган беренче кар яки яңгыр (первый снег или дождь, выпавший после чьей-нибудь смерти).

**ҚАЙА** *каз.ар., т.я.* кайда (где). Сез қайа эшлисез? – *мам.* Қайа тора чиләк. – *к.т.*

**ҚАЙАҚ** *туб.-ирт.д.* юан агачны чукып эшләгән көймә (лодка-долблёнка). Қайақ ман китерәте пецәнне алыстан. – *төм.*

**қайақ кәмә** *туб.-ирт.д.* к.: **қайақ.** Қайақ кәмәләр кән полоп қуй элек. – *тбл.*

**ҚАЙАКИ** *глз.* к.: **қайки 2.** Қайаки минем чиләгем бар иде.

**ҚАЙАМА** *яүшт.* к.: **қайақ.**

**ҚАЙАС** *туб.-ирт.д.* тырыс (коробок из бересты). Палықны қайасқа тултыратылар, йәнцелмәсен өцен. – *төм.* Тустан қайас йасайбыслар, арқаға йөкләп тороп йөрибесләр. – *тара.* Қайас арқага асып йөри торған, цийә йыйалар. Қайаста цийә иселмәйте. – *твр.* Қайасқа қарағат тәргәле (җыярга). – *төм.*

**ҚАЙАТА** *төм.* к.: **биата(й).** Иремнеңке әтийе қайатама туқсан пийыл.

**ҚАЙАУ** *минз., тпк.* ук – бал корты турында (жало). Қайawы қалғач, қорто үлә бит. – *минз.* Қайawын тыгып қалдыра да үde үлә. – *тпк.*

**ҚАЙБАТ** *саз.я., тбл.* балык тоту өчен кармаклы ау (перемёт: рыбная снасть с крючками, которую натягивают на колья).

**ҚАЙҒАНЗЫ** *брб.д.* могҗиза (чудо).

**ҚАЙҒАНУ** *брб.д.* **1.** гаҗәпләну (удивляться); **2.** көнләү, көнләшү (проявлять зависть, завидовать).

**ҚАЙҒАТУ** *брб.д.* гаҗәпләндерү (удивлять).

**ҚАЙҒЫНАҚ** *баст.* сөттә туглап пешергән йомырка, омлет (омлет). Сөт қайный да җоморқаны дүртне болғыйсын, қайғынақ була.

**ҚАЙЕБИРӘННӘР** [*гар.* + *тат.*] *тбл.* к.: **ғайберәннәр.** Қайебирәннәр тә йататы Қыскүлтә.

**ҚАЙЖУ** *перм.* к.: **йуну 2.** Қайжыйбыз, аппағ итеп қайжыйбыз да қазанға салып пешерәбез (бәрәңгене).

**ҚАЙИНӘ** *төм.* к.: **биана(й).** Қайинәм, мәрқүм, йырауцы ийе, «Ашқасар»ны йаратат ите.

**ҚАЙКЕН** *кмшл.*, **ҚАЙКЕННЕ 1.** *нокр., глз., кмшл.* к.: **қайкөн.** Мин қайкенне сезгә барып, ишек ачып қарасам, дәү қыз тора. – *кмшл.* Қайкенне йылап утырамин, кийәwем қайтты. – *глз.*; **2.** *глз.* кайвакыт, кайбер көнне (иногда). Қайкенне сийләб утырамын, исемә төшә дә.

**ҚАЙКИ** *нокр., глз.* **1.** каяндыр, каян да булса (где-нибудь, откуда-нибудь). Утын аласы булыр инде қайки, утын бетте. – *нокр.*; **2.** кая да булса, бер җиргә (куда-нибудь, куда-то). Қайки барасинмы? Қайки киткән булыр чебиләр. – *нокр.* Қайки китте ич бу. – *глз.*; **3.** кайда, кайда икән (где, где

же?). Нәwәл апа қайки? – *глз.*; **4.** кайдадыр (где-то). Қайки қаты йаңғыр булды шай. – *нокр.*

**ҚАЙКӨН** *т.я.*, **ҚАЙКӨННӨ** *нрл.* беркөнне, шушы арада (на днях, намедни). Қуwас эчеп тә мин қайкөннө үлә йаздым. – *нрл.* Қайкөн генә қайтты бит әле қалаға. – *к.т.*

**ҚАЙЛАР** *баст.* кайсылары, кайберәүләр (некоторые). Қайлар искечә уқый беләләр.

**ҚАЙЛАУ** *тбл.* **1.** мыгырдау (ворчать); **2.** авыз эченнән генә көйләү (напевать про себя песню); **3.** сүзсез көйләү (петь без слов).

**ҚАЙЛӘЛҮ** [*гар.* + *афф.* -лү] *брб.д.* хәйләкәр (хитрый).

**ҚАЙМА: пинзә қайма** *баст.* шәлнең читен һәм уртасын беркеткән урындагы ак челтәр (белое кружево на стыке середины и каймы пухового платка). Қайма белән уртасы арасына ақ чичәкләр эшлиләр иде кр′учок белән, пинзә қайма әтәләр.

**қаймақ** *урт.д.* каймак (сметана):

**қаймақ әйрән** *перм., к.-уф.* к.: **кебар′ане**. Қаймақ әйрән қала, майны туқыб алғач. – *перм.*

**қаймақ басу** *минз.* к.: **ачлау**. Қаймағын басабыз да ақмай чыға.

**қаймақ майы** *мам.* миҷтә кайнатылган сөт каймагыннан язган май (сливочное масло из сметаны, снятой с топлёного в печи молока). Қаймақ майы тәмне дә була ул.

**қаймақ сuwы** *эчк.* к.: кебар′ане. Қаймақ суны сыйырға эчер. – *к.-уф.*

**ҚАЙМБИКӘ** *злт.*, **ҚАЙМИКӘ** *перм., злт., эчк.* иренең апасы (старшая сестра мужа).

**ҚАЙМЫСЫРТТА** *саз.я.* әллә кайда, җәһәннәм артында, җиде кат җир астында (у чёрта на куличках).

**ҚАЙНА** *минз., туб.-урт.д., брб.д., том.д.* к.: **биана(й)**. Қайнам бар әле суқыр. – *минз.* Оуникe йыл утырты қайнам қашақ (сукыр) пулып. – *тбл.*

**ҚАЙНАДА** *том.д.* к.: **биата(й)**. Қайнадасы йөздән ашу йәшәгән минең инәмнеңке.

**ҚАЙНАНА 1.** *урт.д., себ.* к.: **биана(й)**. Тәлил тә тартыб утырадым қайнана абыс тип. – *брб.д.*; **2.** *тара., брб.д.* к.: **қаймбикә**. Кийәүнең апасын да қайнана дитләр. – *твр.*

**қайнана теле** *трх.* кактус.

**ҚАЙНАРИ, ҚАЙНАРЫЙ** *әстр.* к.: **пәрәпәч**. Ике өйгә қайнари пешерә.

**ҚАЙНАУ** *перм.* эрү – металл турында (плавиться – о металле). Электән утта қайнатып җәбештерәсең ий тимерне, афтагиннар йуқ.

**қайнау керү** *нрл.* кайнап чыгу (закипеть). Бәрәңгегә қайнау керде.

**сағызы қайнау** *перм.* сагызлану – ылыслы агачлар турында (пропитаться смолой – о хвойных деревьях). Сағызы қайнағач, мечикле булғач, суны үткәрми ағач. Сағызы қайнамый.

**ҚАЙНӘ** *перм., к.-уф., эчк., себ.*, **ҚАЙНЕ** *перм.* к.: **биана(й)**. Қайнәм қызларында йәши. – *перм.* Қайнәсенә керәте барuwышлай. – *тара.* Қотағый-быс цәйләп киләте, қысымныңқы қайнәсе. – *тбл.* Қайнәсенең пинсийәсе кән төгәл булыр. – *брб.д.* Қайнәсен қуйарға барты, оутыз икке гырадус соуқта. – *яүшт.*

**ҚАЙНЕМ** *эчк.* к.: **биата(й)**.

**қайнем қортқайақ** *төм.* каенанам (свекровушка моя).

**ҚАЙНИКӘ** *перм.* к.: **қаймбикә**. Қайникәсе беле бергә бардыларый базарға, иренеке апасы беле қый.

**ҚАЙНИНӘ** *том.д.* каенана (свекровь; тёща). Қайнадасы да, қайнинәсе дә бергә йәшәйтеләр. – *клм.* Қайнинәсе бар қызымның. – *яүшт.*

**ҚАЙНЫ(М) 1.** *перм., злт., эчк., тпк., себ.* к.: **биата(й)**. Қайныға, бийанага бирнә саласың. – *перм.* Қайны булған кешегә аппақтан намадлық суғабыd. Қайным мәрхүм килә торған ийе йаусы булып. – *злт.* Киленне қайны былған кешенең йортына китерәләр хәдер. – *тпк.* Қайныбыз бүген базарға китте. – *к.-уф.* Қайным белән сөйләшмәдем. – *эчк.* Қайнысы, қәйнәсе үлеп киткән. – *төм.* Қайнымалар та аурыб үлеп китте. Қайнына әткә тибес пес. – *тбл.* Пы қайным үскергән пийас. – *твр.* Қайнысы соуғышта өлеп. – *брб.д.*; **2.** *брб.д.* каенатасының абыйсы (старший брат свёкра). Пы қайнымның малайы, пабайның абзыйының. Қайны, үгә кер, қонақ пар. – *брб.д.*

**ҚАЙНЫ-ҚАЙНӘ** *минз., тпк., эчк., себ.* каената белән каенана (свёкор со свекровью). Қайны-қайнәләргә көйләк китергән, мәңа та йалтырақлы шәл пирте. – *тара.*

**ҚАЙРА** *туб.-урт.д., брб.д.* **1.** кире, киргә (обратно). Ақчаны қайра алғалы сәйәблинйә биртем. – *төм.* Арғалық (матча) төшкән, балчығы төшкән-төшкән дә арғалық қайра күтәрелеп урнына утырған. – *твр.* Парабадан қайра қайтып, үсем тапқан мал төгәл, мин тапқан жәл төгәл қой (бит). Үсенең awылына қайра қайтып киткән пичәсе. – *брб. д.*; **2.** кире (упрямый). Иңсәтә уйдық пар анта, қайра кешенеңке цоңқор пула дийән. – *тбл.*

**ҚАЙРАДАН** *брб.д.* к.: **киредән**. Қайрадан йәй булып, иген чачып тороп киткән.

**ҚАЙРАҚ I** *каз.ар.-крш., каз.ар., минз.* бот төбенә чыга торган биз (железа или уплотнение, появляющееся в промежности). Қайрақ та була бот төбендә, қайсы кеше имнәтә дә аны. – *каз.ар.-крш.* Бот төбенә қайрақ чыққан, атлый да алмый икән әле. – *мам.*

**ҚАЙРАҚ II: қайрақ төшү** *дөб.* кайрак булу — ипи турында (образоваться закалу – о хлебе). Берәр илле қайрақ төшкән ипиләр була ул, өстө әйбәт кенә була үзенең.

**ҚАЙРА-ҚАЙРА** *брб. д.* кабат-кабат (часто-часто, несколько раз). Қайра-қайра уғыпмын шу китапны.

**ҚАЙРАҚЛАНУ** *мам.* кабармыйча пешкәнгә күрә тыгыз, каты булып тору – ипи турында (непропекаться, оставаться твёрдым и плотным – о хлебе). Қайрақланған ипи, қамырым уңмады.

**ҚАЙРАН** [*гар.*] *төм., тара.* яхшы, гаҗәп (хороший, изумительный). Әрпересен йасайты та қуйаты, қайран нимә. – *тара.*

**ҚАЙРУ** *брб.д.* кайту (вернуться, возвратиться).

**ҚАЙРЫШЛАУ** *тара.* иренү, ялкаулану (лениться).

**ҚАЙСАҚЛАНУ** *тара.* бүртү, күбенү (разбухать, набухать).

**ҚАЙСЫЛАЙ** *минз., тпк., трбс.*, **ҚАЙСЫЛЫЙ**

*перм.* ничек (как, каким образом). Элекке йортлар фәкыйр булган, қайсылай булса да. – *минз.* Сүләшергә кирәк, қайсылай булса да. – *трбс.* Қайсылый кич булганны да белмисең урманда. Әле сез қайсылый килеп кердегез. – *перм.*

**ҚАЙТА** *сазл.* 1. кая (куда). Қайта warасың?; 2. кайда (где). Қайта тораты?

**ҚАЙТАДАН** *әстр.* яңадан, тагын (снова, ещё раз). Қайтадан боган (моңа) барды.

**ҚАЙТАРА** 1. *бәр., тбл., тара.* яңадан, кабат, икенче мәртәбә (ещё раз, снова, повторно, вторично). Қайтара күрсәтмәсен ул хәлләрне. – *бәр.*; 2. *перм.* к.: **арый**; чаг.: **пайма**. Ничә қайтара төштем, йуқ та йуқ. Бер қайтара да ачқыч йөрөтмәде ул шылтыратып. Быйыл җәй буйына бер қайтара да бал белән чәй эчмәдек; 3. *тбл., тара.* кире, киргә (обратно). Бары да килгән ишеккә қайтара инеп чыгып киттеләр. – *тара.*

**иң қайтара** *төм.* киресенчә (наоборот).

**қайтара алу** *тбл., тара.* киргә алу, яңадан алу (брать обратно, брать снова).

**қайтара кирә** *бәр.* к.: **қайтара** 1. Қайтара кирә генә күрсәтмәсен. Бу сугышлар қайтара кирә генә була күрмәсен.

**қайтара тарту** *тбл., тара.* яңадан үлчәү (перевешивать).

**ҚАЙТАРМА** *крш.* каршы, җавап итеп (в ответ на ..., в качестве ответа, ответная). Қайтарма чақыра. Қыз йағында қайтарма дип туй була. Туй беренче җегет җағында, аннан, қайтарма дип, қыз җағында була.

**бер қайтармада** *минз.* тагын, яңадан, икенче тапкыр (в другой раз, во второй раз, ещё раз). Салатығызны тыгып қуйығыз, бер қайтармада алыб ашарсыз.

**қийәү қайтармасы** *крш.* қыз ягында үткәрелә торган туй мәҗлесе: керәшеннәрдә, гадәт буенча, туй башта егет ягында була; аннан соң билгеләнгән көнне егет ягы кияү қайтармасына бара (ответный пир, устраиваемый на стороне невесты после свадьбы, которая обычно проводится у крящен на стороне жениха). Туй беткәннән арлы шушы килен җағы кийәү қайтармасына җыйа. – *крш.* Қызны бирәләр дә кийәү қайтармасына қызны җәшәләр. – *т.кам.-крш.*

**қайтарма сөрү** *тара.* туңга сөрү (вспашка на зябь).

**қайтарма туй** *минз.* каршы туй: туй қыз ягында булган очракта, берәр атнадан егет ягында да уздырыла торган туй мәҗлесе (ответный пир на стороне жениха в том случае, если свадьбу сыграли на стороне невесты). Қайтарма туй йегет йағында була, берәр атна үткәч, қайчан җитешәсең, шунда қайтарма туй үткәрә, қода-қодағый, күршеләр, туган-тумачалар килә, туйға килмәгән кешеләр килә.

**ҚАЙТАРМЫШ: қайтармыш туй** *тпк.* егет ягында килен төшкәч була торган мәҗлес (ответный пир на стороне жениха, устраиваемый обычно после переезда невесты). Йоқа бешереп апкилә торғаннар ыйы қайтармыш туйға килгәндә, қайтармыш туй йегет йағында була.

**ҚАЙТАРУ I** *т.кам.-крш.* к.: **быргыту**. Хатын тотмый: ала да қайтара, ала да қайтара.

**ҚАЙТАРУ II** *т.я.* аштан соң дога кылу (читать молитву после еды). Җәгез, қайтарыйқ, табын зарығып тормасын.

**ҚАЙТАРУ III** *глз.* каршы әйтү, әрепләшү (возражать, браниться). Әнием әйтер иди, балаларым, қайтармагыз, әйткәнең кемеш булса да, әйтмәгәнең алтын.

**ҚАЙТЛЫҚМА** *төм.* сикәлтә (ухаб). Қайтлықмата төшөп қалыпты сумкалары.

**ҚАЙТУ** 1. *перм., эчк.* китү (уходить, уехать). Қунаққа килеп қайттылар ийе элекке йылны. Бишбармағым қалғаный дип, Килеп қайтсаң ни була (*хал. җыр.*). – *перм.*; 2. *себ.* үлү (умереть). Ике тута қыслар ыйық, пербес қайттинте. Тутам паладан қайтты. – *брб.д.* Инте эриса, иртә-бөгөн қайтсам та. – *тбл.*

**қайтып китү, қайтыш булу** *брб.д.* к.: **қайту** 2. Минең иге қысым сабый wахытларынта оло awырутан қайтып киттеләр. Пабай қайтыш полған.

**ҚАЙТЫМ-КИТЕМ** *мам.* килем-китем (гости, посетители). Қайтым-китемнәр булса җайлы була, турап тозлап қуйам да.

**ҚАЙТЫҢҚЫ** 1. *блт.* яшьрәк (моложе). Сездән әз генә қайтыңқыйым ирем үлгәндә; 2. *т.я., мам.* кечерәк (меньше по размеру, росту). Минем қыз буйға синекеннән әз генә қайтыңқы булыр. – *к.т.*; 3. *т.кам.-крш.* к.: **йадау**. Сарықлар быйыл үткән җылдағыға қарағанда қайтыңқы, көр түгел. Метрий дәдәйнең малларын туйдыр-туйдырма, барыбер қайтыңқы инде.

**ҚАЙТЫРАШ** *тпк.* туй кунаклары қайтып китәсе көнне пешерелә торган аш; аеруча дөге боткасы пешерелә торган булган (угощение, устраиваемое для гостей, участвующих на свадьбе, перед их отъездом). Қайтырашқа дөгө пешергәннәр дә, қайсы шунта өйнең тышыннан төрткәннәр.

**ҚАЙУ I** 1. *злт., тпк.* чигү (вышивать). Мендәр қабының қайулыларын салдырып алган ийем. Йең осын қайып йебәрәйек. Қайылған эскәтерләр, қайылған намазлықлар. – *злт.* Қулйаулық қайый торганнар ийе, қайулы тастымалым әл дә-дә бар, күрсәтәйемме. – *тпк.*; 2. *кас.* тегү (шить). Су'ыр ул, а' 'үлми 'ни 'ара җеп белин 'айы'ан; 3. *трх., нрл.* бер генә төстәге җеп белән чигү (вышивать ниткой лишь одного цвета). Аны инә белән қайыб эшләргә кирәк, бер төсле җептән генә қайа чәчәкләп; 4. *минз.* машинада тегү (шить на машинке). Башта үзе типчидер ийе, тегүче қайып бирәдер ийе.

**қайу қайу** *тпк.* чигү чигү (вышивать вышивку). Қайу қайыдым мин шау, тастымал чүпләдем, қайу қайыдым.

**ҚАЙУ II** *брб.д.* күк йөзен болыт каплау (покрываться облаками).

**ҚАЙЦЫ** *тбл.* йөгән прәшкәсе (пряжка узды).

**ҚАЙЦЫҒОЙРЫҚ** *төм.* к.: **қайчығойроқ**. Қайцығойрык қолаққа да керә.

**ҚАЙЦЫЛАУ** *тбл.* кайчы белән кисү (отрезать ножницами, стричь).

**қайчан** *урт.д.* кайчан (когда):

**қайчан ара** *перм.* кай ара, кай арада, бик тиз (когда, как быстро); чаг.: **кайчура**. Бырач қыз,

мәйтәм, қайчан ара килеп җиткән, әле өмөҗөдә қалдыйы.

**ҚАЙЧЫ** *әстр.* дамба, вал. Атасы ман қайчы йасап торады.

**ҚАЙЧЫҒОЙРОҚ** *төм.* аерыкойрык (двухвостка).

**ҚАЙШАЙУ** *тара., брб.д.* кыйшаю, чалшаю (скривиться, скоситься).

**ҚАЙШАЛАНУ** *кргл.* кайшалу, каймыгу (вывихнуться). Аның айагы қайшалана да қуйа, айағы awырта әле аның.

**ҚАЙЫЗЛАУ** *мам., минз.* к.: **йуну 2.** Қалын итеп қайызлый бәрәңесен, бәрәкәтсез итеп. – *мам.* Әнә бит бәрәңге қайызлыйлар. – *минз.*

**ҚАЙЫМ: қайымға алу** *минз.* гаепкә алу (осуждать). Қайымга аласыз минем сүземне, дидем.

**ҚАЙЫМЦЫЛ** *туб.-ирт.д.* гаепчән, мыскыллаучан (любитель осуждать, ехидничать). Қайымцыл пулматылар алар, пала-бақра кән пулты, эшләтеләр тә эшләтеләр. – *төм.*

**ҚАЙЫН I** *перм., себ.* **1.** к.: **бийата(й).** Қәйнә белән қайынға берәр күлмәг аппарасың. Килен қайынға сөртү элгән. – *перм.* Қайыным қарт күлгә киткән. – *тбл.* Қайыны күлхә кейтеп қалыпты палхқа. – *сазл.* Қайыны белән қайнәсе тә мөнтәү өйтә торадылар. – *брб.д.* Қайыны малай баға, килене уғуға киткән. – *яушт.*; **2.** хатынының атасы (тесть, отец жены). Пер гейәү қайынына қунаққа килгәйн ийән. – *тбл.*; **3.** *брб.д.* иренең абыйсы (старший брат мужа). Қайтса, килен сыйыр cawып йөрәй, қайның ман йеңкән қайа тип сорай.

**қайын awышха** *сазл.* каенатам, карт (свёкор мой, старик). Қайын awышхасы аурап китеп, балнисаға апкитепләр.

**қайын ағам** *тара.* **1.** хатынының абыйсына эндәшү, сүзе (форма обращения к старшему брату жены); **2.** иренең агасына эндәшү сүзе (форма обращения к старшему брату мужа).

**қайын күкәм** *яушт.* хатынының энесенә иркәләп-олылап эндәшү сүзе (форма ласкательного и почтительного обращения к младшему брату жены). Қайын күкәм, өйгә кер әле.

**қайын II** *себ.* каен (берёза):

**қайын бәбәнәге** *минз.* **1.** сөялле кабар агачы, маржа алкасы (бересклет бородавчатый); **2.** кабар агачы (бересклет европейский).

**қайын киргә** *тбл.* агач кайрысы (древесная кора).

**ҚАЙЫНӘЙНӘ** *тара.* **1.** к.: **биана(й); 2.** әби, хатынының әнисе (тёща). Йорттағы малайымның қайынәйнәсе бар.

**ҚАЙЫНБИГӘ** *себ.* каенигәч, иренең яисә хатынының апасы (старшая сестра мужа или жены).

**ҚАЙЫНБИКӘ 1.** *баст.* каенананың қыз туганы (старшая сестра или родственница свекрови); **2.** *туб.-ирт.д.* каенигәч (старшая сестра жены; старшая сестра мужа).

**ҚАЙЫН-ҚӘЙНӘ** *тпк., себ.* к.: **қайны-қайнә.** Қайын-қәйнә «булар инте» тимәгенце соу ташыйсын. – *тбл.* Қайын-қәйнәсенә күренмәйце йөргән. – *тара.*

**ҚАЙЫННА** *баст.*, **ҚАЙЫННАЙ** *дөб.* к.: **биана(й).** Қайыннам белән утыз биж йыл тордым. Қайыннам чибәр хатын иде, уңған иде. – *баст.* Қайыннай, иртәгә безгә қунаққа менәрсең.

**ҚАЙЫНПИГӘ 1.** *себ.* хатынының яисә иренең апасы (старшая сестра мужа или жены). Ирнең әптәсе, қайынпигә пулған кеше, атны йекте. – *тбл.*; **2.** *брб.д.* хатынының анасы (тёща).

**ҚАЙЫНПИКӘ** *туб.-ирт.д.* к.: **қайынбикә 2.** Қайынпикә қәйнә кебек пулаты қуй. – *тара.*

**ҚАЙЫНТАЙ** *дөб.* каенатага эндәшү сүзе (форма обращения к свёкру). Қайнатасы бик йахшы кеше булған аның, тегесе дә «қайынтай» дип кенә торған.

**ҚАЙЫП** [*гар.*] *тара.* гаеп (вина).

**ҚАЙЫР** [*гар.*] *саз. я.* бик, искиткеч (очень, изумительный). Қайыр ирмәх. Қайыр аларны күрхем киләт ғуй.

**ҚАЙЫРМА I** *трбс.* утыртма читән (частокол).

**ҚАЙЫРМА II** *брб.д.* ачылмалы тәрәзә (открывающееся окно, створчатое окно). Қайырмалары йабық, циргәй кән.

**ҚАЙЫРЫЛМА I** *төр.* кайтарма – яка турында (отложной – о воротнике). Қайырылма йаға та бар, утысма йағалы көйләкләр ирәннәрнеке болған.

**ҚАЙЫРЫЛМА II** *брб.д.* киереп, төбенә хәтле (широко, настежь). Тирәсләр қайырылма ачық тиге йақта, чергәй толуқ.

**ҚАЙЫРЫЛЫП** *мам., лш., каз.ар.-крш.* куе, биек, калын булып – печән, иген h.б. турында (быть густым, частым и высоким – о сене, хлебах и т.п.). Қайырылып та үскән печәне, қайларға таратып киптерерсез. – *мам.* Қайырылып беткән җир, җылғалы җир, чабам тирләп-пешеп. – *лш.* Қайырылып үскән быйыл игеннәр. – *каз.ар.-крш.*

**ҚАЙЫСТА** *брб.д.* кайда, кая (где, куда). Қайыста киттең?

**ҚАЙЫШ I 1.** *кас., баст.* күн (кожа – выделанная). Қайыш итек, кәweш қайыштан, читек белен җымаға барғанда кийәләр. – *баст.*; **2.** *туб.-ирт.д.* кара елан, зәһәр елан (гадюка); **3.** *туб.-ирт.д.* елан (змея). Қайыш күп, башын цыгарып қуйа, қурқам. – *тбл.* Қайыш шу қәтәр йәмсес йөсәйте. – *төм.*

**ҚАЙЫШ II** *каз.ар.-крш.* **1.** бил тасмасы, бил планкасы, биллек – алъяпкыч турында (пояс – у передника). Алҗапқычымны төзәтәм әле, бил қайышы киң булған; **2.** атлама (плечевой хлястик передника). Җилкәдән атлатып қайыш була, қайышқа *қанат*лар (кара) тегәбез бөрөп-бөрөп. Элекке қайыш алҗапқычлар ийе, билдән дә қайыш булыр ийе, җилкәдән дә.

**қайыш суғышмақ** *төр.* яшьләр уеныңың бер төре (вид молодёжной игры). Қайыш суғышмақ уйнай тыған итек.

**'АЙЫШ** *кас.* к.: **қайыш I, 1.**

**ҚАЙЫШАЙАҚ** *т.я.* әрсез (пронырливый).

**ҚАЙЫШУ** *төм., тбл.* бөгелү, бөгәрләнү (сгибаться, съёживаться). Ирәннәр пелән эшләгәле мин түгел, йегетләр қайышып цыгатылар. – *төм.* Йылан тисәң, йылып китәте, қайыш тисәң, қайышып китәте (*әйтем*). – *тбл.*

**ҚАҚ I** *дөб.* повидло. Алма қағы қайнаттым, паштитқа да җарый ул, ипигә җағып чәй дә эчәсең.

**қақ бәлеш** *перм.* **1.** к.: **гөлбәдийә; 2.** к.: **чеп-**

**чәги**. Өндәүлесе дә туйға шулай уқ қақ бәлешләр белән бара.

**қақ төсле** *бәр.* чия төсендә (коричневый). Минем күлмәк қақ төсле йе.

**ҚАҚ II** *перм., злт., минз., тпк., туб.-ирт. д.* **1.** ялангач, үлән үсми торған (голый, лишённый растительности). Қақ тау башы. Қақ җир. – *перм.* Бу қақ тау былған, этиләр әйтүwенә қарағанда. – *злт.*; **2.** коры, буш, ялангач урын (голое место). Қаққа утырма, монда утыр. Бәй, қаққа утырдың, мондарақ кил. – *минз.* Әй, қаққа утырдың, қыдым. – *тпк.* Қақ итәнкә сусылып йатты. – *тбл.* Полай та сапсим қақ, ицнимә йуқ. – *саз. я.*; **3.** *туб.-ирт. д.* төче – камыр турында (пресный – о тесте). Қақ қалац. Қамыр қаққа та басылаты, ацытқыға та. – *тара.* Қақ туғац қыладылар туртадан. – *тбл.*; **4.** *әстр.* тозлак, тозлы туфрак (солончак); **5.** *әстр.* тоз (соль); **6.** *саз.я., тбл., төм.* коры, киптергән (сухой, сушёный). Қақ утын. – *саз. я.*; **7.** *себ.*каты, тигез – юл турында (ровная и стоптанная, твёрдая – о дороге). Қақ йул. – *төм.*

**қақ йарау** *төм.* к.: **йарғақ**. Кийеw бала қақ йарау ғына, ыспайы.

**қақ палық 1.** *тбл.* кояшта киптергән балык (рыба, вяленная под солнцем); **2.** *тбл., саз.я.* каклаган балык (вяленая рыба).

**қақ сана** *тпк.* шәрә чана, коры, әйбер салынмаган чана (голые, непокрытые сани). Туңыбеттем, қыш өстөндә қақ саналарда йөрөп.

**қақ сүwәк** *перм.* к.: **чәлтер: чәлтер севәге**. Қақ сүwәкне нимә тиделәр баса сездә.

**қақ цай** *тбл.* чәй генә, тәм салмыйча (чай без сладостей). Қақ цай эцмәң, waринйа белен эцең.

**қахқа wасылған он** *саз.я.* төче камыр (пресное тесто). Пирашки, пәрәмецләрне қахқа wасылған оннан пешерәwс.

**ҚАҚ III** *брб.д.* акмый торган су (стоячая вода, лужа, пруд).

**ҚАҚ IV** *тбл.* юшкын (накипь, осадок).

**ҚАҚ V** [*гар.*] *себ.* хак (истинный, правильный). Қақ сүс. – *тбл.*

**ҚАҚ VI** *тбл.* нәкъ (точь-в-точь). Йара атып қуйты нишананы қақ уртасына.

**ҚАҚАЙ: қақай басу** *бгрс.* аякта басып тору — бәләкәй бала турында (стоять на ножках – о ребёнке). Қақай басадыр ыйы, хәзер басмый әле.

**ҚАҚАЙТУ** *дөб.* тилмертү, интектерү (изнурять, томить, мучить). Әчкә қақайттылар көтүне алып чыкмыйчы.

**ҚАҚАЙУ 1.** *перм.* к.: **кизәрү**. Икмәге қақайган киленнеке, бодай икмәк тиз қақайа; **2.** *эчк.* к.: **йадаулану**. Сыйырыгыз нәмә қақайып киткән?

**қақайып утыру 1.** *перм.* башны күтәреп, тураеп, селкенми-бөгелми утыру (сидеть прямо, не сгибаясь). Алар утыралар қақайып; **2.** *лш.* к.: **қағайу: қағайып утыру 1.** Қақайып утырганбыз инде орчоқ тип, суғу дип.

**ҚАҚАЧ** *глз.* к.: **жаматай**. Ике кешеләр бар иде элек, қақачырақ кешеләр иде.

**ҚАҚАШУ** *перм.* керләну, каралу — кием турында (загрязниться – об одежде). Йуwыб алырым, йылы күлмәге дә қақашкан.

**ҚАҚЛАWЫЧ** *т.я.* каты билчән (бодяк полевой).

**ҚАҚЛАНДЫРУ** *твр.* ягу (мазать, намазывать). Майны қақландырып аша.

**ҚАҚЛАНУ I** *тбл.* юшкын утыру (образоваться накипи). Чәйген қақланган.

**ҚАҚЛАНУ II 1.** *туб.-ирт.д.* ябышу (приклеиться). Пер уголта кағас қақланып тораты. – *тбл.* Наски кийәлмән, кисәм қақланаты (шешкән). Сағыс қақланаты. Әчәге әчәккә қақланып қуйған. – *твр.*; **2.** *твр.* ябышу (уцепиться, ухватиться). Бер арқанға қақланты.

**ҚАҚЛАУ I** *твр.* ялгау, ябыштыру (приклеивать, соединять). Йиғет ақ сүкмән киде, күтенә wар қақлады. Пернең торосына (дөресенә) уннын йалғанын қақлыйр.

**ҚАҚЛАУ II 1.** *т.я., лш.* чагу — кычыткан турында (жалить – о крапиве). Қычытқанға утыра күрмә, қақлый. Қычытқан түгел ул, қақламый ул, қурықма. – *трх.* Қулымны қычытқан қақлады. – *к.т.* Жаланайағын қақласын быраз дигән ийем бу қычытқаннар. – *лш.*; **2.** *нрл., к.т.* чәнчү, чәнчеп кычыттыру — йон кием турында (кусать, колоть – о шерстяных вещах). Сарық җононнан бәйләнгән ойоқно җалан тәңгә кийалмыйм, қақлый. – *к.т.* Бу жимперны кийеп булмый, қақлый, сатам инде. Маңа қақламый торғанын ал дидем, йомшағын жимперне. – *нрл.*

**ҚАҚЛЫҒУ 1.** *перм.* к.: **қағылу I**. Қақлығып төшеп киткән чанасы җөг утыны белән; **2.** *тбл.* сугылу, тәгәрәп китеп бәрелү (удариться).

**ҚАҚЛЫҚМА 1.** *перм.* салу (раскат, ухаб); **2.** *перм., тбл.* к.: **базлавык**. Қақлықмата йығылып китте.

**ҚАҚМА** *нрл.* ғармонь теле (клавиша гармони). Басның да қақмасы бар, телнең дә қақмасы бар, чығып торғаны. Қақмалары тыштағысы, әчтәгесе түгел, қул белә басып тора торғаны.

**ҚАҚМАҚ I** *яүшт.* капкач (крыша). Қақмақ пирәйенмә қаплағалы.

**ҚАҚМАҚ II** *тбл., саз.я.* керле, пычрак (грязный). Көйләгем қақмақ, ойалам.

**ҚАҚМАЛАНУ** *төм.* капшану (щупать, шарить в карманах).

**ҚАҚМАЦ** *брб.д.* каеры (кора). Ағац қақмацын соғып қурт йийып йүргүн.

**ҚАҚМАЧ** *перм.* к.: **йаргак**; чаг.: **йадау**. Қақмач битле.

**ҚАҚ-СУҚ: қақ-суқ итү** *нрл.* кыерсыту, җәберләү (обижать, притеснять). Бергадирларыбыз әйбәт булды, бер қақ-суқ итмәделәр. Үғи ана балаларын қақ-суғ итә.

**ҚАҚСЫ** *перм.* **1.** к.: **қазы**. Ат итен қақсыга тығабыз, ул бозолмый бергwахытта да; **2.** киптерелгән ит (сушёное, вяленое мясо).

**ҚАҚТУ** *яүшт.* таплы (запятнанный). Көйләгә қақту.

**ҚАҚТЫ 1.** *туб.-ирт.д., яүшт.* сыерчык оясы (скворечник). Паллар қақты қылып қуйыпты. – *тара;* **2.** *төм.* умарта оясы (улей). Қақты сатып алыпты, цағwыны йуқ.

**ҚАҚТЫРУ** *блт.* он ак булсын өчен, бодай, арыш кебек бөртеклеләрнең кабыгын салдырту (обдирать – о зерне). Бодайны қақтырып тарттырдым, оном бик ақ булды.

**ҚАҚУЛ** *тбл., тара.* атның маңгаена төшкән ялы (чёлка у лошади).

**ҚАҚЦЫРЛАУ** *тбл.* **1.** кутырны куптарып алу (сколупнуть коросту, болячку); **2.** агачның кабыгын кубарып алу (ободрать кору с дерева).

**ҚАҚЧЫР** *перм.* **1.** ботаксыз агач (дерево без ветвей); **2.** печән өяр өчен ботакларын төптән бераз калдырып конус формасында боталган агач (дерево, обрубленные ветви которого образуют конусообразную форму, оно используется при метании стога в качестве тагана). Анда қақчыр дүртәү қадалған печән өүмәгә. Қақчыр ботақлы ағач; **3.** ябык кеше турында ирония белән әйтелә (иронически – о худощавом человеке).

**ҚАҚША** *брб.д.* озын буйлы (высокого роста, высокий).

**ҚАҚШАҚ** *төм., тбл., брб.д., том.д.* какшаган, йончыған (расшатанный, измотанный). Инте бөтерә қақшақ, қақшақ қалған. – *төм.*

**ҚАҚШАЛУ** *туб.-ирт.д., брб.д.* **1.** авыру, саусызлану (болеть, ослабеть, хиреть). Йаңа ғына қақшалыб алтым. – *брб.д.*; **2.** *тара.* борчылу, ватылу – кеше турында (чувствовать себя разбитым, утомляться, уставать). Йул батқақ, ипсез, қақшалып килдек. Күп йыйғанбыс гөрөстәне, қақшалғанбыс. Йул батқаг игән, қақшалып килтек; **3.** *тара.* борчылу (беспокоиться). Қақшалманң, қақшалманң, үсем таып пирәм.

**ҚАҚШАТУ** *тара.* борчу (беспокоить). Цац үстерәпес үсепес, пет қақшататы, тип сөйләй.

**ҚАҚШАУ** *блт., каз.ар.-крш.* **1.** к.: **awырықсыну** 1. Сыйырыбыз қақшау әле, көтүгә җибәрмәдем, канауларға сақларға апчықтым. – *блт.* Әллә җилгә апчығып күп җөрткәнгә, қақшап тора әле Җүрик, тәрәз-ишек җиле дә тийә ул балаларға. Бу җылларда қақшап тороп, бетенкерәп китте бабаң. – *каз.ар.-крш.*; **2.** *глз.* к.: **каста 2**. Қақшау қалды awыртып йөргәнгә күрә. Йәш исә йәш, қарт исә қарт, қақшау исә қақшау, йақшырақларын суғышқа йебергеледелер.

**ҚАҚШАХ** *саз.я.* к.: **қақшақ**.

**ҚАҚШЫҚ: қақшық қалу** *төм.* какшау, бетеренү, эшкә ярамаслык булу (хиреть, расшатываться). Қақшық қалған, эшкә йарамай қалған аурап.

**ҚАҚЫ I: қазан қақы** *глз.* касмак (поскрёбки). Қазан қақын қырып ашасаң, туйында буран була.

**қақы II** *урт.д., себ.* какы (свербиға).

**әче қақы** *лш., каз.ар.-крш.*, **қазан қақы** *нокр., глз.* к.: **ахық**. Әче қақыны җаратам мин, әче қақылар ашасам, күңелләрем ачылып китәсыман. – *лш.*

**ҚАҚЫ III** *төм.* как (пастила). Қақыны қасаннар йасай қарағаттан.

**ҚАҚЫЙ: қақый цана** *твр.* сөзәк (полоғий).

**ҚАҚЫҚ** [*гар.*] *каз. ар.-крш.* к.: **ақыйқ**. Қәситәгә қақық тағалар, тәнкә тезәләр ийе, астары җепәк булайы.

**ҚАЛ I** [*гар.*] *себ.* миң (родинка, родимое пятно). Тыуганта қалысы полпты аныңқы, Қалпигә айтыпты исемен тә. – *твр.*

**ҚАЛ II** *тара.* аңгыра, аңсыз (бестолковый, непонятливый).

**қала** *брб.д.* ныгытма (крепость, укрепление): **қала алу** *дөб.* бик зур авырлык яки бик зур шатлык күрү. Менә қала алды инде, тамам үзәгенә үтте. Әй, Хәтимә қала алды инде хәзер, балалары кыwартир алды.

**қала гөлө** *бәр.* яран гөле (герань). Қала гөлө бу. Балчығы әйбәт булса, қала гөлө чәчәк ата.

**қырмысқа қаласы** *глз.* кырмыска оясы (муравейник). Қырмысқа қаласына илтеп йатқырыр идем бу йаwызны.

**ҚАЛАWЫС** *саз.я.* полиэтилен пакет; букча (полиэтиленовый пакет).

**ҚАЛАЙ 1.** *кргл., бгрс., эчк., злт., тпк., әстр., себ.* к.: **қайсылай**. Атларыбыз сыуға төшәр йә қалай итәр. – *злт.* Күбәне қалай қуйасың, пер арбаға петмәгәннәре дә була. Awылның исемен қалай тип әйтә алам ни. – *тпк.* Қалай булды ул? Қалай барып йеттең син? – *эчк.* Қалай белгән, алай теккән. – *брб.д.* Баласыз қалай торайым дип ташлап китте. – *әстр.*; **2.** *эчк., кргл., бгрс.* нинди (какой). Қалай ипле сүзләр. – *кргл.*; **3.** *себ.* кая (куда). Мә! Қалай барасың? – *тбл.* Қосқын ул песнең йәйен тә монта, қышын та, иц қалай китмәйте. – *брб.д.*; **4.** *себ.* кайда (где). – Қалай йәшәйте? – Иц қалай. – *твр.*

**ҚАЛАЙТЕП** *тпк.* ничек итеп (каким образом). Әтәй даманың қалайтеп сөйләйем микән.

**ҚАЛАЙТҚЫ** *тбл.* калкавыч (поплавок).

**ҚАЛАҚ 1.** *мам., лш., минз., злт., эчк.* металл аш кашыгы (металлическая столовая ложка). Қалақ биримме, қашық белән ашыйсыңмы? Қалақ белән эчалмыйм мин ашны, аузым пешә. – *мам.* Ағач қашықлар бетте инде, қалақ белән ашыйбыз. – *лш.* Қалақ шалтырап төштә дә, қыдым әйтә, дәwәни, қунақлар килә, самawырыңны қуй, ди. – *минз.*; **2.** *лш., каз.ар.-крш., кмшл., төм.* бал кашыгы (чайная ложка). Қалақ белән генә алырға балны, қашық тықсаң, тиз бетә. – *лш.*; **3.** *нрл.* яныавыч, чалгы калагы (брусок). Қалақны җуғалтқан да чawып бетермиче қайтқан алған урынын; **4.** *лш., дөб.* тартып ачыла һәм этеп ябыла торган шакмаклы яссы юшкә (плоская, четырёхугольная вьюшка). Қалақны ачмағансың, өйнө төтөн белә тутырғансың. – *лш.* Қалақны эшермәдем, бигрәк эссе бит. Су ақты қалақтан, бик қаты җаңғыр җаудис әле, ышқыштырып қына қуйған ийем морҗаны. – *дөб.*; **5.** *тбл.* агач кашык (деревянная ложка); **6.** *төм.* ипи көрәге (деревянная лопатка для сажания увалянного хлеба на подпечье).

**җануч қалағы** *дөб.*, **йанғыч қалағы** *бәр.* к.: **қалақ 3**.

**қалақ бийәләй** *минз.* гадәттәге биялә (обычная рукавица).

**қалақ келәм** *төм., тбл.* станда түгел, бәлки, тар агач тактачык ярдәмендә кулдан сугылган тар озын келәм (узкая длинная дорожка, сотканная не на стане, а с помощью деревянной дощечки). Қалақ келәмне тураб урынта төгөл, қалақ пелән генә суғасың. – *төм.*

**қалақ күтәреп суғу** *минз.* асалап сугу (ткать закладным способом). Қалақ күтәреп суққаны чәчкәле суғу була. Абыстай суққанда мин қалақ күтәреп торадырыйым.

**қалақ салма** *перм.* к.: **чумар: қашық чумар**.

**чебен қалағы** *нрл.* чебен үтергеч, шапалак (мухобойка). Монсо чебен қалағы чебен үтерергә.

**ҚАЛАҚЛАНУ** *минз.* кузаклану (выпускать стручки, стручиться). Борчақ қалақланган.

**ҚАЛАҚПАШ** *төм.*к.: **алты-тукыз.**

**ҚАЛАҢНАТУ** *брб.д.* тирбәтү (качать, укачивать).

**ҚАЛАҢНАУ** *брб.д.* селкенү, атыну – атынгычта (двигаться туда и сюда, качаться – на качелях).

**ҚАЛАС I** *злт.* ачыга, уртасы тишек итеп пешерелә торган вак икмәк (мучное изделие домашнего приготовления).

**ҚАЛАС II: қалас күрү, қалас пулу** *тбл.* хөрмәтләү, хөрмәт күрсәтү (оказывать почёт, почитать). Кешегә қалас пулты. Кергән итем, қалас пулты.

**ҚАЛАТҚЫ** *туб.-арт.д., том.д.* калкавыч (поплавок).

**ҚАЛАУС** *твр.* **1.** күн капчык (кожаный мешок). Қалаусқа алтынны тултырып ала...; **2.** биштәр (котомка).

**ҚАЛАЦ 1.** *себ.* күмәч, ак икмәк (булка, белый хлеб). Қалац салаты. – *төм.* Қысым қалацлар китерепте. – *тбл.*; **2.** *төм., тара., сазя.* к.: **қалач 2**; **3.** *төм., тара., тбл.* уртасы тишекле кабартма (булочка с дыркой в середине). Тишекләп салғанны қалац тиләр пестә. – *төм.*; **4.** *тара., тбл.* кабартма (булочка). Қалацны қалған қамыртан бешерәтләр, ацы булаты. – *тбл.*

**қалац шәйгә** *себ.* к.: **ләнгәц.**

**ҚАЛАЧ 1.** *минз.* ачыга изгән бодай камырыннан сигезлегә охшатып табада пешерелә торған камыр ашы (мучное изделие домашнего приготовления); **2.** *перм.* клиндер (крендель); **3.** *бәр., минз.* озынча формадагы кечкенәрәк ак күмәч (небольшой белый хлеб продолговатой формы). Қалачны бөккән сыман пешерерләр ийе. – *бәр.*; **4.** *әстр., брб.д.* ипи, икмәк (хлеб). Қалач салам. – *әстр.* Қалачны қысыбыс пешерәде. – *брб.д.*

**арыш қалачы** *брб.д.* арыш ипие (ржаной хлеб). Пер арыш қалачы алып килгән иде.

**қалач алқа** *дөб.* йомры түгәрәк алка (серьга полукругом дутая; лунница). Қалач алқа була, тақта қалач алқа була, ике төрле ис ул.

**қалач әпекәй** *бөре.* калач. Қалач әпекәй салдыралар туйға.

**қалач име, қалач көлә** *твр.* к.: **бырцак: бырцак үләне.**

**қалач сырға** *твр., тара.* к.: **қалач алқа.** Инәкәйнең қалач сырға бар иде, нәбәрәсенә бирепте. – *твр.*

**саплы қалач** *лш.* **1.** бодай онынан клиндер сыман пешерелгән камыр ашы (мучное изделие из пшеничной муки в форме кренделя). Қазанға барғач саплы қалач апқайталар ийе, әwәле бит бороп-бороп пешергәннәр, саплар қуйып; **2.** *нгб.-крш.* уртасы тишек калач (калач в форме замка с дужкой). Лафкыдан саплы қалач алдым; **3.** үчекләү сүзе (дразнилка). Атаң саплы қалач апқайта дип үртәп сөйлиләр ийе.

**тақта қалач алқа** *дөб.* яссы, түгәрәк алка (пластинчатая серёжка полукругом).

**ҚАЛӘМБЕР** [*гар.*] *себ.* канәфер (гвоздика).

**қаләмбер йысы** *тбл.* хуш ис (приятный запах). Шал нимәне сиптергәц, қаләмбер йысы цығаты.

**қаләмбер қawақ** *тбл.* к.: **қаләмбер.**

**ҚАЛӘМПЕР** [*гар.*] *брб.д.* к.: **қаләмбер.**

**ҚАЛӘҮЛЕ** *әстр.* игелекле, яхшылык эшли торган (добрый, благодетельный). Халыққа қаләүле.

**ҚАЛБАЙТУ** *брб.д.* торгызу, тырпайту (навострить уши). Қолақларны қалбайтып қуйалар.

**ҚАЛБАҚ 1.** *себ.* калфак (национальное украшение, калфак). Қалбақ тийен сүсләрне тә ишетепсен, күрепсен. Пәтқийә палтызымныңқы қалбақ пулған. – *тбл.* Қыйыш қалбақлу. – *төм.* Қыйыш қалбақ кигән, маңнайында йенчеләр булған. – *брб.д.*; **2.** *тбл.* самовар капкачы (крышка самовара).

**ҚАЛБАҚЛАУ** *брб.д.* киң бала итәк салу – алъяпкыч жилкәсенә (шить широкий сборчатый волан на плечи передника). Алтйапқычлар төрлүчә, қалбақлап та тегәте, сәлентереп, ышкулнай фурмалар да бар қой.

**ҚАЛБАҢНАУ** *брб.д.* селкенү, әрле-бирле йөрү (двигаться туда-сюда, слоняться, колебаться).

**ҚАЛБЫР** *әстр.* **1.** иләк (решето); **2.** к.: **кәпкер II, 1.** Дөгене қалбырға бушата.

**ҚАЛҒАН** *яүшт.* к.: **қалдық 1.** Менә уттый йана, диде, қалған сүзе шул булды.

**ҚАЛҒУ I** *брб.д.* чумып калкып чыгу (вынырнуть из воды, всплыть).

**ҚАЛҒУ II** *тбл.* йокымсырау (дремать).

**ҚАЛҒЫТУ** *брб.д.* калкыту (заставить вынырнуть, достать из воды).

**ҚАЛҒЫШ: қалғыш булып китү** *тбл.* рәхәтләнеп китү (испытать удовольствие).

**ҚАЛДАУ** *кргл.* калку, тигезсез (возвышенный, неровный); чаг.: **қаш.** Тигез жирдә түгел, қалдау жирдә.

**қалдау үлән** *мам.* к.: **қау II.**

**ҚАЛДЫҚ** *лш., каз.ар.-крш., т.кам.-крш., перм.* **1.** соңгы, ахыргы, актык (последний). Иң қалдығы Мехәммәт исеме була. – *лш.* Қалдығыңы бирәсен шундый кешегә. – *минз.* Қалдық барuwың булдымы қалаға? – *каз.ар.-крш.* Илле бере самый awыр көнә, ди, қалдық йазықлары бетә, ди. Қалдық қисәкне алғанда, күрше, миңа қалдыр әле, ди. – *т.кам.-крш.*; **2.** төпчек, иң кечкенә бала (последыш). Қалдық бала. – *каз.ар.-крш.* Қалдық қызыбызны бирмибез, жегерем бишкә чақ қарыйбыз әле, дигәннәр. – *перм.*

**'АЛДЫ'** *кас.*, **ҚАЛДЫҚҚЫ** *перм.* к.: **қалдық 1.** Бу жортта 'алды' 'өннирен уздыра. Ызначит бездә қалдыққы кичегезне қунасыз.

**ҚАЛЖА 1.** *к.т.* угызлы сөттән ясалган эремчек (творог из молозива). Сыйыр бозаулағач, берике көн қалжа йасыйм, малайлар әрәхәтләнә ашап. Уғызлы сөттән қалжа пешерәләр ийе; **2.** *каз.-ар.-крш.* сөткә туглап кыздырылган йомырка (омлет). Қалжа ашап жибәрсәң, қәл кереп китә ди торған ийе оло жиңгей; **3.** *әстр.* бөккән (небольшой пирог, бәккән). Кәбестә қалжа.

**жоморқа қалжасы** *к.т.*, **күкәй қалжасы** *каз.ар.-крш.* к.: **қалжа 2.** Күкәй қалжасы пешерәләр бездә сөткә туғылап.

**уғыз қалжасы** *к.т.* к.: **қалжа 1.**

**ҚАЛЖАУ** *бөре.* к.: **йуну 2.** Бәрәңге қалжау.

**ҚАЛҚАУ** *лш.* буш консерв савыты (пустая консервная банка).

**ҚАЛҚУ I 1.** *перм.* күтәрелү, чыгу, таралу – бөҗәкләр турында (появиться, возникнуть – о насекомых); чаг.: **қужу 2.** Пырутларын жырғач, җәмсез озонборон қалыққандыр инде анда хәзер; **2.** *т. я., кргл.* күтәрелү, куба башлау – язгы сарык йоны яки кәҗә мамыгы турында (подняться, отделяться – об овечьей шерсти перед весенней линькой). Сарык жоннарын да аласы бар, қалыққан инде. – *к.т.*; **3.** *перм.* к.: **йерәкләну.** Әле мин дә қалқып китсәм, бабай әйтмеш, чыдый қалың.

**ҚАЛҚУ II** *тбл.* йөзү (плыть). Соута қалкып йөрөйте, нимәте ол тип күргәсә ийән.

**қалқып китү** *тбл.* йөзеп китү (поплыть).

**қалқып чығу** *тбл.* йөзеп чыгу (выплыть, переплыть).

**ҚАЛҚЫН** *төм.* к.: **қалатқы.** Палық көткәле бараты, қалқынын қарайты.

**ҚАЛҚЫТУ** *перм.* күтәрү (открывать, вскидывать). Күзне қалқытып қарый алмыйм.

**ҚАЛЛАП 1.** *себ.* мәзәкче (шутник, балагур). Қалықта барта қаллап, ацға үлмәйте (*әйтем*). – *тбл.* Қаллап кеше ул, йумырлы. – *тара*; **2.** *тбл.* кыланчык, чытлык (кокетливый).

**ҚАЛЛАПЛАНУ** *туб.-ирт.д.* чытлыклану, шаяру (шутить, кокетничать, балагурить). Қуй, қаллапланмачы.

**ҚАЛ'ПАЙУ** *перм.* калжаю, калтаю (коробиться, покоробиться). Қал'пайған йереннән йыртам да йәбештереп қуйам (обойны).

**ҚАЛПАҚ 1.** *бөре.* хатын-кызлар кигән тәңкәле борынгы баш киеме (старинный женский головной убор, украшенный монетами). Бийек қалпаққа ике рәт тәңкә тезәсең, алтынга манып тезәдер ийек; **2.** *трх., нрл., нокр.* бәйләгән башлык (вязаная шапка). Сарық жононнан үзем дә қалпақ бәйләдем, иремә себитер. – *трх.*; **3.** *нокр.* бәйләгән бала башлыгы (детская вязаная шапочка). Қалпақ бар баланынқы, йонныкы байлағанда иде; **4.** *т.кам.-крш.* самовар томалагычы, самовар түбәтәе (заглушка самовара). Түбәсенә қалпақ қуймаған самawырының, сuwы да ағыб утыра; **5.** *т.кам.-крш.* яшь бала башлыгы (детский чепчик). Қалпақны да wақ-төйәк ситчадан тегеп қуйдым, үзем эшлим мин. Балалар қалпағына ақ қортбашлар тағадыр ыйық күз тимәскә.

**йотроқ қалпақ** *төм.* к.: **чүкәтә қалпақ.** Энчеле қалпақлар, кецке қалпақлар, сур қапцыклы қалпақлар та булган, йотроқ қалпақлар та, шанысы кецке генә, төйрәп кенә қуйатыган.

**қаты қалпақ** *минз.* аскы өлеше каты булып, утырып тора торган калфак (калфак, нижняя часть которого сделана жесткой). Безнең инәйнең қаты қалпаг ыйы, жем-жем итеп торадыр ийе.

**қуйан қалпақ** *перм.* куян мамыгыннан бәйләгән башлык (шапка, вязанная из заячьего пуха).

**тебетий қалпақ** *перм.* түбәтәй формасындагы, алгы ягы чигелгән хатын-кыз баш киеме (женский головной убор из бархата в форме тюбетейки, вышитый спереди). Тебетий қалпақ, энжедән жасыйлар.

**чүкәтә қалпақ** *минз.* ак энҗе тезелгән кечкенә түгәрәк калфак (женский головной убор – калфак небольшого размера, расшитый бисером).

**ҚАЛПАҚ-ЧАЧАҚ** *каз.ар.-крш.* кызларның борынгы баш киеме: чигүле, чуклы зур калфак; башка кигәч, чуклы түбәсе аркага салындырып куела (старинный девичий головной убор у крещёных татарок).

**ҚАЛТА I 1.** *эчк.* чигешле кечкенә капчык (вышитый мешочек); чаг.: **артмак.** Туйда қалта цыгаралар (төрле күчтәнәчләр салган); **2.** *әстр., себ.* букча, кечкенә капчык (мешочек, сумка). Сөннәткә утысадылар, қалта қуйадылар та ақца салатлар. – *тбл.* Муйнында қалта. – *әстр.*; **3.** *брб.д.* кесә (карман); **4.** *туб.-ирт. д.* янчык (кисет); **5.** *төм.* мәет юганда кия торган ситсы бияләй (ситцевые рукавицы, надеваемые при омовении покойника). Йыуган цақта қулға кийәтләр, пиш қалта кирәк.

**қалта йөрөтү** *төм., тбл.* ярәшелгән кызга егет ягында махсус капчыкка бүләкләр жыю (обычай, согласно которому на стороне жениха проводился сбор подарков сговорённой девушке в специальный мешочек). Қалта йөрөтәтләр күцмәстән алта йегет йақта, әркем, тыуғаны, биреп цыгатлар, қосоқ, йемеш (конфет), көмөшләрне өстенә тегәтләр, қалтаның өстенә. Пы қалта йөрөтү туй алтан, қалта қыс йаққа бараты ғуй, ир йақтан йөрөтөп-йөрөтөп қыс йаққа аппарадылар.

**қалта тоқсай** *эчк.* пешкән икмәк салып куя торган кечкенә капчык (мешочек для испечённого хлеба).

**ҚАЛТА II 1.** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* киң бала итәк (широкая оборка). Қалта диләр, менә күлмәкнең итәгенә тағы бөрөп қуйалар. – *каз. ар.-крш.* Қалтаны итәкнең очона тоталар инде, қатқат була. Элеке безнең керәшен қатыны баш бәйли, чигәчә кийәләр, қалталы күлмәкләр. Элеккеге күлмәккә уникешәр арышын кирәк булған, алача күлмәктән дә awырырақ әле аның қалтасы. – *т.кам.-крш.*; **2.** *т.кам.-крш.* чаршау кашагасы (бордюр занавеса).

**чаршау қалтасы** *т.кам.-крш.* к.: **қалта II, 2.**

**ҚАЛТАҚАЙ** *бөре.,перм.* **1.** киң ау чаңгысы (широкие охотничьи лыжи). Қалтақай киң була, лыжи тар була. Қалтақайға почқақны қақтың исә, чаңғы була. – *перм.*; **2.** гади, ягъни астына мех тотмаган чаңгы (простые лыжи, без меховой подшивки); **3.** *перм.* к.: **қақчыр 3.**

**ҚАЛТАЦЫҚ** *төм.*, **ҚАЛТАЦЫХ** *саз.я.* янчык (маленький мешочек); чаг.: **калта I, 2; касидә.** Тuwалыкны пер төрле қалтацыққа тыгасың, қултыг астыға әлтереп қуйасың пawы белән.

**ҚАЛТАШ, ҚАЛТАШИХА** *төр.* казан (котёл).

**ҚАЛТРАҚ** *төм.* калтыраучы, калтырый торган (дрожащий).

**ҚАЛТУН** [*рус.*] *тбл.* к.: **қачқыч.**

**ҚАЛТЫРМА** *тбл.* басма (мостик, мостки, помост).

**ҚАЛФАҚ** *нокр., перм.* к.: **қалпақ 2, 3.** Шушы қалфақны үзем бәйләдем күрше хатынның баласына. – *перм.* Қалфақ қызларға да, бәләкәй сабыйларға да. – *нокр.*

**дутийлы қалфақ** *баст.* өрдерелгән юка пыяла

мәрҗәннәр белән бизәлгән калфак (калфак, вышитый бисером из дутика). Энҗеле қалфақ, дутийлы қалфақ була.

**көрәкле қалфақ** *перм.* энҗеле калфак — чәчкә каптыргач, түбәсе көрәк рәвешендә тора (женский головной убор – калфак большого размера, широкий, расшитый бисером).

**ҚАЛЧАЙУ** *блт., мам.* туңу, күшегү (зябнуть, продрогнуть); чаг.: **бөкшәйеп 1.** Көн йаwымны булғачыннан, печәнчеләр чалашта йаталар инде қалчайып. – *блт.* Суықта қалчайып йөрмәгез, ийдә утырығыз дидем мин сезгә. – *мам.*

**ҚАЛЧАҚ** [*гар.* + *афф.* -чақ] *твр.* к.: **қал I.** Қалчағы бар балачыққыңқы.

**ҚАЛЫ** [*гар.*] **I** *себ.* миң, кызыл миң (красноватое родимое пятно). Пәсе (кайбер) балата қалысы булаты, шал уқ исемне қуйасын, Қалбай, Қалбигә, Қалы. Питентә қалысы бар. – *тбл.* Қалысы булган, Қалчамал тиб ататылар, йасуларынта Зипа ул. – *төм.* Пыларныңқы қалысы маңлайынта ите аның, қалы тиб әйтеп торғаннан соң пөткән. – *твр.* Қалысы wөтсөн өцөн, қырыхынацы син Қалы тиф йөрөтәтләр. – *сазл.*

**ҚАЛЫ II** *твр.* кайда (где). Ақ Күбәк қалы? Ақ Күбәк әудә йоқ.

**ҚАЛЫҒУ** *бәр.* **1.** калку, өскә чыгу (всплыть, подняться на поверхность воды). Боз суда қалыға ич; **2.** үсү (расти). Балаларыбыз қалығалар инде, шуңа сөйөнөб бетә алмыйбыз.

**ҚАЛЫЙМА** *твр.* надан (невежественный, невежда).

**ҚАЛЫЙУ** *тбл., тара., сазл.* **1.** әйбернең яссы ягы белән кыеклап очып төшүе (падать плоской стороной, парить в воздухе). Центабағын (чынаяк тәлинкәсен) ташлаб эйгән ите, ул ғалыйып китеп, қотоққа төшөп китте. – *сазл.*; **2.** эреләнеп, борын күтәреп йөрү, кылану (возгордиться, гордиться, задирать нос). Қалыйып усып китте, исәнләшмәте тә. – *тбл.* Қалыйып йөргән нәстәкәйне, бицәсен, күрте тә йабышты. – *тара.*; **3.** *тара.* hушы китү, аңгыралану (обеспамятеть, отупеть); **4.** күз эленеп алу (вздремнуть).

**ҚАЛЫЙЫП: қалыйып йаwу** *тбл.* ишелеп яву – кар турында (идти обильно – о снеге). Қалыйып қарлар йаусайкән, Ат тубықларыннан булсайкән; Буласы эшләр булсайкән, Дошман күңелләре сынсайкән (*хал. җыр.*).

**қалыйып йоқлау** *тбл.* тәгәрәп йоқлау (крепко спать, спать без задних ног). Уғып-уғып өшкөрте, қалыйып йоқлап қуйыптым.

**ҚАЛЫЙЫП-КӨНӘЙЕП** *тбл.* зураеп, үсеп, яхшырып (увеличиваясь, расти, улучшаясь). Қалыйып-көнәйеп утыраты қантала тейсәң, сасық тейсәң пөтөб утыраты.

**ҚАЛЫҚ** *эчк.* к.: **қалдық 1.** Хәлимә әби ницәнце йыл қайтты қалық wахытны.

**ҚАЛЫМ 1.** *тбл.,төм.* кечкенә күл, җыелып торган су (небольшое озеро, небольшой водоём со стоячей водой). Пы гөл (күл) төгөл, қалым қуй, күлцегәц кенә. – *төм.*; **2.** *тбл.* тирбәлеп торган саз, баткаклык (трясина). Монта пассаң, алтта күпереп утыраты – шал қалым пулаты.

**ҚАЛЫМБАШ** *минз.* к.: **тайансық 1.** Қалым-башқа бирелгән сарығым беренче җылда уқ өчне бәрәннәде.

**ҚАЛЫН I 1.** *каз.ар., бәр., т.я., минз.* элек: кыз кияүгә киткәндә егет ягыннан китерелә торган әйберләр (в старину: одежда и вещи, преподносимые невесте со стороны жениха). Қалынға түгел, бер җыл торғач алдық бу шәлне. Қызны бирсә килешәләр инде, қалын салалар. Бабаң қалынға салды тушы сандықны, бусысы қалын шәле. Қалынға эшәл салғаннар, қалынға нәстә салған дип сорыйлар. – *бәр.* Қалынны туйға әпкиләләр. – *минз.*; **2.** *т.кам.-крш., минз., тбл.* кыз өчен егет ягыннан бирелә торган әйберләрнең акча өлеше, тарту (денежная часть выкупа за невесту). Қалын, суғым пирәт, поцқақ тун, қама қыйулы, мақмал тышлы. – *тбл.* Қалын диләр ите, әдрәг ақча да килешәләр қыз өчен, чәй-шикәр белән бергә ул қалын. – *минз.* Қалынына ақча, қалын ақчасы бирәләр, мал бирә җегет атасы, җола бит. – *т.кам.-крш.*

**қалын қортлау** *блт., мам.* элекке туй йоласы: егет ягыннан кызга бирелгән әйбер сандыгын ачканда бүләк салу (старинный обряд преподношения подарков участниками свадьбы при открытии сундука с вещами, предназначенными для невесты со стороны жениха). Қалын қортлап фыранцуз йаулық салдылар, ақча салғаннар ыйы, бер ал читле җаулығын сыразы башыма бәйләдем. – *мам.*

**ҚАЛЫН II 1.** *бәр., минз.* бай (богатый). Бик қалын безнең awыл элек-электән. – *бәр.* Қалын-қалын кешеләр йәшәгән Өфө қаласында, дип сөйлидер ийе бабай. – *минз.*; **2.** *кргл.* бай, мул (обильный, богатый). Дөнйа қалын булган, этийем сөйли иде; **3.** *баст., перм., злт.* юан (толстый). Қалын бүрәнә. Белөк қалынлығы балықлар бар. – *злт.* Қалын-қалын кр′ажларны ташыдық. – *перм.* Теғесе – быратым, бағ инде, қалын ғына үзе. – *баст.*; **4.** *злт., тпк.* күп, ишле (много, многочисленный). Симийәсе қалын ыйы. – *злт.* Безнең нәселебез қалын. – *тпк.*; **5.** *минз., перм.* зур (большой). Соң Қазан қалын бит ул. – *минз.* Қалын awыл. – *перм.*

**қалын қойроқ** *злт.* к.: **айуқүзғалақ.**

**'АЛЫН** *кас.* к.: **қалын I, 1.**

**'алын бүли'е** *кас.* к.: **қалын I, 1.**

**'алын туй** *кас.* элекке туй йоласы: зур туйга бер атна кала калымга сөйләшкән әйберләрне тапшыру өчен җыела торган мәҗлес (старинный свадебный обычай: застолье в доме невесты за неделю до начала свадьбы, на котором передаются деньги и подарки со стороны жениха).

**ҚАЛЫНАЙУ** *минз.* к.: **байығу.** Хәзер awыллар қалынайды.

**ҚАЛЫНЛЫҚ** *минз.* к.: **қалын I, 1.** Қызға қалынлық сорайлар.

**ҚАЛЫНЧА** *лш.* калынрак (немного потолще). Җәймәләр суқты инде әни сүсләрне эрләп, қалынча була йы палас кебек.

**ҚАЛЫҢНАУ** *брб.д.* егет яғыннан кыз яғына акча түләү (платить денежную часть выкупа за невесту).

**ҚАЛЫҢНЫҒ** *брб.д.* акча түләнә торган кыз, кәләш (девушка, невеста, за которую уплачивается выкуп).

**ҚАЛЫП I** *брб.д.* туз (береста).

**қалып II** *урт.д.* калып (колодка; форма, образец, модель):

**кийем қалыбы** *блт.* киенергә яратучы кеше (человек, который любит одеваться, имеет много одежды). Кийем қалыбы булыр инде, күлмәк тә күлмәк кирәк.

**ҚАЛЫРЫП: қалырып алу** *тара.* к.: **қалыйу 4.**

**ҚАЛЫШТЫРУ** *эчк.* к.: **қоршу 1.** Агацтан қалыштырып йасалған.

**қама** *урт.д.* кама (опушка, кайма):

**жөн қама** *минз.* мех кама (опушка из меха). Жөн қама тоталар ийе мескен бүреккә.

**ҚАМАЙУ** *брб.д.* алдан әйтү (предсказать).

**ҚАМАҚ** [*рус.*] *туб.-урт.д.* к.: **йалман 1.** Қамақ аулайты бы мешәгем. – *тбл.*

**ҚАМАҚАШ** *злт.*, **ҚАМАҚЫШ** *кмшл.* аңкау (твёрдое нёбо). Қамақашлары сереп сиңкә белән awырып үлде. Былай да қамақашым әпәйгә изелеп петкән, тешем былмағас. – *злт.* Қамақышым awырта. – *кмшл.*

**ҚАМАЛАҚ: қамалақ үләне** *бөре.* шылдыравык (погремок).

**ҚАМАЛАУ I: қамалап алу** *минз.* к.: **атқару 4.** Ишегалдын қамалаб алдым.

**өкө қарчыға** *перм*. ябалакның бер төре (сова ушастая). Өкө қарчыға бар, башы боролып җәри, чебешне алып китә.

**таwық қарчығасы** *лш*. к.: **озан қарчыға(сы)**.

**чичқанчы қарчыға** *перм*. торымтай (пустельга). Чичқанчы қарчыға тычқаннарны қурқытып, қанатын селкеп тора, анан төшөб ала.

**ҚАРШҚЫР** *брб.д.* бүре (волк).

**ҚАРШUWА** *бөре.*, **ҚАРШUҒА** *бөре., перм*. бака кабырчыгы (ракушка, раковина). Қаршuwа эчендә бақа була. – *бөре*. Қаршуғалар алып қайтқан Кафказдан йәт итәр өчөн. – *перм*.

**ҚАРШЫ I** *эчк.* карата, күрә (соответственно чему-либо, по...). Хәленә қаршы эш бирәләр.

**қаршы II** *тара*. каршы (противоположный, вопреки, против):

**қаршы тел әйтү** *тара*. к.: **қаршылашу 1**. Қаршы тел әйтәде, тафиқсыс пала булды.

**қаршы туй** *каз.ар.-крш*. кыз ягында үткәрелә торган туй мәҗлесе: керәшеннәрдә гадәт буенча туй башта егет ягында була, аннан соң билгеләнгән көнне егет ягы кыз ягына каршы туйга бара (у кряшен: ответный пир на стороне девушки).

**ҚАРШЫWА** *перм*. к.: **қаршuwа**.

**ҚАРШЫЛАШУ 1.** *тбл*. тыңламау, каршы сүз әйтү (не слушаться, перечить). Пес қаршылашмаған. Кәсер қаршылашатылар қәйнәгә; **2.** *төм*. киреләнү, бәхәсләшү, каршы килү (противоречить, спорить). Қаршылашма аларга тим.

**ҚАРЫ I** *брб.д.* иңбаш, кулбаш, җилкә (верхняя часть руки, плечо).

**ҚАРЫ II** *твр*. карт (старик; старый).

**оллы ғары** *тбл*. олы яшьтәге (пожилой).

**ҚАРЫЖ** [*гар.*] *глз*. чыгым, тоту (расход). Башақча қызның әтийенә қарыжға була.

**ҚАРЫЙ I** *т.я., каз.ар., нокр., минз*. к.: **қарыйлық**.

**қарый ғумер, қарый ғымер** *т.я., каз.ар., нокр., бәр.*, **қарый көн** *каз.ар., каз.ар.-крш., тпк*. к.: **қарыйлық**. Қарый ғумердә без дә күрдек әрәхәтне. – *к.т.* Қарый ғымергә қадәр исән тыр. – *нокр*. Қарый ғумеребезгә рәхәт тормыш қалған. – *бәр*. Қарый көнемдә мин бу хәлне күрмәс идем. Қарый көнемдә хурлыққа төшмим тағы, зурлыққа менәм дип тырыштым. – *дөб*. Инде қарый көндә ташламасыннар. – *лш*. Қарый көндә рәхәт йәшәйбед. – *тпк*. Қарый көнөңдә йәрдәмче булыр дип өмөт итәсең инде. – *блт*.

**ҚАРЫЙ II** *әстр.* к.: **абзар 3**.

**ҚАРЫЙ III** *каз.ар., минз*. караганда (чем, в сравнении с ...). Килен дастуйын бит малайыма қарый. – *дөб*. Бөтөн җиләккә қарый тәмне бикту-

рийә. Бөтен җиләккә қарый алдан өлгөрә қайын җиләге. – *лш.* Беднекенә қарый дурырақ аларның бақчалары. Ул миңа қарый да йәшрәк бит әле. – *минз.*

**ҚАРЫЙӘСЕ** *саз.я.* күз карасы (зрачок).

**ҚАРЫЙЛЫҚ** *мам., минз, трх., трбс.*, **ҚАРЫЙМЫШ** *дөб.* картлык (старость, преклонный возраст). Қарыйлық начар. Дөнйаның рәхәте килде инде қарыйлық көндә. – *трх.* Минем қарыйлыққа бик җиңел туры килде. – *трбс.* Қарыйлығында шундый тәрбийәсе булғач йақшинде. – *мам.* Қарыйлығым көчлө шул. Хәзер генә, қарыйлықта ғына, сәламәтлек бетт(е) әле. – *минз.* Шуңа күрә дә қарыймышында рәхәт күргән. – *дөб.*

**ҚАРЫҚ** *тбл.* к.: **қатымыш.**

**ҚАРЫЛУ 1.** *нокр., глз.* чәчәү (поперхнуться); чаг.: **карыну.** Кем ни килә шай, қарылдым. – *нокр.*; **2.** *перм.* косу (вырвать, блевать). Тамақ төпкә төрттөм дә қарылып җибәрдем; **3.** *блт.* тончыгу (задыхаться, захлебнуться). Төтөнгә қарылып ике баласы үлгән; **4.** *каз.ар.-крш., баст.* карлыгу (охрипнуть). Awызым да қарылды. – *каз.-ар.-крш.* Таwышым йуқ миндә, тамағым қарылған. – *баст.*

**қарғышыңа қарыл** *дөб.* каргаган кешегә җавап сүзе (ответное слово проклятию). Қарғышыңа қарыл, йәме.

**ҚАРЫМШАҚ** *тара.* төпчек ир бала (последний ребёнок, обычно мальчик). Ундүрт пала гүреп, пы баласы қарымшақ.

**қарын** *урт.д., себ.* карын (желудок; утроба, чрево):

**қалың қарын** *тбл.* түбәтәй карта (сетка; отдел желудка – у жвачных).

**қарын төп** *тара.* к.: **қалдық 2.**

**қарын цац(ы)** *тбл.* баланың тугандагы беренче чәче (первые волосы новорождённого младенца). Тыуғандағы перенце цац қарын цац тителәр пестә аны. Қарын цацын китәреп йебәртем қысымның, ул хақсыс китәргәле йарамайты. Паласының қарын цацы китәрелмәгән, аталмаған тите.

**ол қарын** *тбл.* ашказаны (желудок).

**ҚАРЫНДАШ-УРУҒ** *твр.* туган-тумача (родня, родственники). Қарындаш-уруғым йыйдырдым.

**ҚАРЫННАУ** *брб.д.* бүләк итү (подарить).

**ҚАРЫНТАШ: қарынташ қawақ** *тара.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрағы.**

**ҚАРЫНТӨП** *тара.* к.: **қалдық 2.** Қарынтөбөм китеп қалты, аларға қайғырыб утырам. Қарын төп малайым тораты бире.

**ҚАРЫС** *төм.* йон шәл (шерстяная шаль). Қарыс тибес, ширыст'аный, осон цацақлы шәл.

**ҚАРЫШ I** *лш.* каршы, каршы як (против, напротив). Қарышта қойо бар – сuwы қаты, терлеккә генә тотабыз.

**қарыш уйыны** *минз.* язгы чәчү эшләре беткәч, җыеннар башланганчы, тирә-як авыл кешеләре арасында берәр атна кара-каршы кунакка йөрешү, күңел ачу йоласы (обычай после окончания весенних работ приезжать друг к другу в гости из разных деревень; обычно это продолжается в течение недели). Қарыш уйыны диләр инде, бәрәңге утыртқач, қунаққа йөрешү инде берәр атна: Тирсәдән, Биктаудан, бигрәк тә Әгерҗе белән Бәйке (*ав. ис.*) инде.

**ҚАРЫШ II: қарыш шәл** *төм.* к.: **қарыс.** Қарыш шәл түгел микән, йылтыртақлар йуқ цақта алғайтым, әле йеретәмен.

**ҚАРЫШЛАWЫҚ** *тпк.* к.: **қарышлама.** Қарышлawық кewек була йефәк қорто.

**ҚАРЫШЛАМА** *перм.* күбәләк корты (гусеница, личинка бабочки).

**ҚАРЫШМАЦЫ** *төм.* карышучы, бәхәсләшергә яратучы (спорщик).

**ҚАРЫШТЫРУ** *перм.* к.: **йезән: йезән тарту.** Хәбибҗамалның айақ-қулын қарыштыра торған чире башлаган.

**ҚАРЫШУ 1.** *төм.* нык итеп тотыну, ябышу (крепко ухватиться, крепко держаться). Қарышма миңә, қарыш ботаққа; **2.** *тбл., саз.я.* ябышу, катып калу (замкнуться, соединиться). Йаңақларым қарышып қалты, аца алмайым; **3.** *т.я.* хәрәкәтләнү сәләтен югалту – кул, аяк, авыз турында (потерять способность двигаться, сокращаться – о конечностях и мускулах рта). Кеше күп көннәр ашамый, эчми торса, awызы қарыша, су да җоталмый башлый, ди. – *к.т.*

**ҚАРЫШЫМ** *туб.-урт.д.* көйсез, кире, мыжык, үзсүзле (капризный).

**ҚАС** [?] *твр.* дошман (враг).

**ҚАСА** *дөб.* ак ситсы (ситец, коленкор). Ақ қаса алдым да фәрдә тектем.

**ҚАСАЙАҚ** *төм.* к.: **қазыйақ I.**

**ҚАСАЛАЙ, ҚАСАЛЫЙ** *саз.я.* кыргый үрдәкнең бер төре (вид дикой утки).

**ҚАСАН I** *тбл.* кечкенә пластмасса чиләк (маленькое пластмассовое ведро). Пәтрә сур булады, пы ғасан.

**қасан аш** *тара.* шулпа, кайнар аш (бульон, суп).

**қасан бешерү** *брб.д.* ашарга пешерү, кайнар ризык пешерү (готовить горячее). Монча йақтырып, қасан бешереп қонақ итеп, күгәл nowаслапты.

**қасан өс** *тара.* к.: **пибаш.** Цицинәм қасан өстә йоқлап йатады.

**ҚАСАН II** *себ.* Казан – шәһәр (Казань – город).

**қасан итек** *себ.* читек (ичиги). Қасан итекләр китерепте, мин тә инәйгә алғы киләте. – *тбл.*

**ҚАСАНБАШ** *төм., тбл.* к.: **қасанпаш.**

**ҚАСАНЛЫҚ** *себ.*, **ҚАСАНЛЫХ** *саз.я.* учақ, казан асты (очаг). Қасанлыққа ут йақ. – *төм.* Қасанлыхта соу эссетәwс, аш қылғанда аш пешерәwс. – *саз.я.*

**ҚАСАННЫҚ** *себ.* к.: **бүлмәч 2.** Порнағы өйләртә қасанның пулмаған, цуwал булған.

**ҚАСАНПАШ** *туб.-урт.д.* туйда иң баш пешекче, төп пешекче (главный повар на свадьбе).

**ҚАСАНТӨП** *төм.* к.: **қазантөп.** Йеңсез камсул, қасантөп ыштан, кештәкле күлмәкләр кийәтите.

**ҚАСАПЦЫ** *тара.* итче (мясник).

**ҚАСАРТҚЫ** *тара., брб.д.* к.: **қазартқы.**

**ҚАСҒАҚ: қасғақ цайы** *тбл., саз.я.* берәрсен ерак юлга озатқач эчелә торган чәй (чай, который пьют после проводов кого-нибудь в дальнюю дорогу). Палам тораға китте, қасғақ цайын эцгәле гер. – *тбл.*

**ҚАСИБ** [*гар.*] *нгб.-крш.* к.: **асу II**. Баланның касибен күр!

**ҚАСИТА** [*гар.*] *нокр., глз.* к.: **путемар**. Қаситаны картыраг әбиләр кийалар иде. – *глз.*

**ҚАСҚАЛАҚ** *тпк.* куркак, кача-поса йөрүче (боязливый; человек, который делает что-либо украдкой, скрытно). Қурқып йөри бу, қасқалақ пабай бу, әперәтсийәгә тигән бырачы.

**ҚАСҚАУЛАҚ 1.** *туб.-ирт.д.* к.: **қырмawық; 2.** *тара.* билчән (осот). Қасқаулақныңқы башы ақ цәцкә ата.

**ҚАСҚАУЛЫҚ** *тбл.* к.: **бабай I: бабай башы**.

**ҚАСҚЫ** *тпк.* качып йөрүче, качкын (беглый; беглец, бродяга). Қасқылар йөргән бу тау арасында.

**ҚАСЛАНУ** [*гар.* + *афф.* -лану] *брб.д.* дошманлык хисе туу (настроиться враждебно). Пир йида күн йадалады, үлтүрмөккө қасланды.

**ҚАСЛЫҚ** [*гар.* + *афф.* -лық] *нгб.-крш., тара.* зарар, начарлык (вред, зло). Қаслық қылыйм дисә, қыла инде. – *нгб.-крш.*

**ҚАСЛЫҚЛЫ** [*гар.* + *афф.* -лық + -лы] *нгб.-крш.* зарарлы, начар (вредный, плохой). Сайысқаннан да қаслықлы ни бар: миләшне ашый.

**ҚАСМАБАУ** *тбл.* ризык төре (вид кушанья). Инәмалар қасмабау пешерә тығаннар ийе.

**ҚАСМАҚ I 1.** *мам., перм., злт.* аерткан сөтне кайнатканда өстенә утыра торган яры (плёнка, появляющаяся при кипячении снятого молока). Қасмағын ашамый, песәйгә бирә, сөтөн эчә; **2.** *баст., әстр.* итле аш өстенә чыккан күбек (пенка на мясном супе). Итнең қасмағы. Ашның қасмагын жыйганмы? – *баст.*; **3.** *глз.* су өстендәге әлпә (плёнка, образовавшаяся на воде). Қыйсында сuwы қасмақлырақ, улағыннан ал, қайа агып тора.

**ҚАСМАҚ II** *тбл., тара., брб.д., том.д.* балык тәңкәсе (рыбья чешуя). Палыңныңқы башта қасмағын қырасын. – *тара.*

**ҚАСМАҚЛАНУ** *перм.* аерткан сөтне кайнатканда яры барлыкка килү (образование пенки при кипячении снятого молока). Озақ қайнатқач қасмақланып та киткән мыса.

**ҚАСМАЛАУ** *себ.* шадралау (делать рябым).

**ҚАСМАХ** *сазя.* к.: **қасмақ II**.

**ҚАСНАЛУ** *брб.д.* бераз сыну, чатнау (надламываться).

**ҚАСТ** [*гар.*] *тара.* максат (цель). Үлсәм әрманым йоқ, ләкин үлтерсәм икән тип қастым бар, тиде.

**қастын күрү** *т.я.* к.: **хаст: хастын күрү**.

**ҚАСТА** *урт.д., брб.д., тбл.*, **'АСТА** [*фарс.*] *кас.* авыру, хаста (болезнь; тяжелобольной).

**бала қастасы** *глз.* өянәк (припадок).

**'астасы 'убу** *кас.* ачуланып кычкыра башлау, жәнләнү, чире кубу (о человеке, имеющем привычку кричать, бесноваться).

**қуйан қастасы** *мам.* вак терлекләрдә була торган авыру (болезнь мелкого скота). Мәсрүрәнең сарыгына қуйан қастасы булған, ахры, дүрт айагын дүрт жаққа ташлап жата. Қуйан қастасы булганда қуйан тәпийе белән имниләр ийе.

**сuwық қаста** *нокр., глз.* к.: **шом I**.

**эссе қаста** *нокр., глз.* **1.** тиф авыруы (тиф); **2.** югары температура белән баш авырту (головная боль, сопровождающаяся высокой температурой). Башына эссе қаста йабышқан, йата. – *глз.*

**'АСТАСЫНА** [*фарс.*] *кас.* тиргәү, орышу сүзе (ругательное слово). Ни'и инди 'астасына бу 'илеп жөри?

**ҚАСТӘР** [*гар.*] *тара.,брб.д.* чара, хәзерлек (мера, средство, подготовка).

**ҚАСТЫРУ** *брб.д.* казыту (дать копать, заставить копать).

**ҚАСУ** *сазя.* казу (копать). Йырақ түгел тип қассалар, тағын цықмайт сыw.

**ҚАСУТ** *брб.д.* к.: **қазыйақ I**.

**ҚАСЫ** *себ.* к.: **қазы**. Қасыны қылаты ницек? Қасан қалқы ницек эшли, алай уқ қылабыс пес тә. – *тара.*

**ҚАСЫЛАЙ** *кргл., бгрс.* к.: **қайсылай**. Менә бит безнең апа қасылай йырлый. – *бгрс.* Әнә бит су қасылай ғына килә. – *кргл.*

**ҚАСЫЛЫҚ** *себ.* к.: **қазы**. Қайwанның эцәгенә туплап-туплап қасылық йасайтлар. – *тара.* Ат иттән қасылық тутыратылар. – *твр.*

**ҚАСЫР** [*гар.*] *себ.* хәзер (ныне, теперь).

**ҚАСЫРҒА** *нокр., глз.* кәчеркә — яңа туган балаларда (щетинка – у младенцев). Қасырғаны бал белә, ын белә чыгаралар, бесәйне айақ белә типкәләгән эчен була, диләр. – *глз.*

**ҚАСЫРҒЫ** *блт.* к.: **кода: пәри кодасы**.

**ҚАТ I** *блт., каз.ар.-крш., нрл., минз., кргл.* ян (около, близ, при, у). Ғаффар абый қатына аның белән татыуланышыр өчөн үзенең кешеләрен жибәргән. – *каз.ар.-крш.* Ишек қатына чыгарып қуйганнар үлә дип. – *минз.* Мында да кердем қызым қатына. Бу чебиләрне инәләре қатына йабарғайы. – *кргл.*

**ҚАТ II** *перм.* ниргә, рәт – өйнең стенасы турында (венец, один ряд сруба). Унсигез қат безнең ызба. Кругум берәрне салып чықтың исә бер қат була.

**ҚАТ III** *твр.* шеш (опухоль). Үләрендә тамағына қулач чақлу қат чыққан.

**ҚАТА I 1.** *тпк.* галош рәвешендәге күн аяк киеме (кожаная обувь, форма которой напоминает калошу). Қатаны күннән эшләйләр, әрҗинкә күбек; **2.** *эчк.* туфляга охшатып тегелгән күн аяк киеме, күн башмаклар (кожаные башмаки); чаг.: **чакчур**. Элек қызлар қата кийә торғаныйы; **3.** *т.кам.-крш.* ботинка (ботинки). Әнинең ботинкалары бар ийе, әwәле аны қата дип сөйләшәләр ийе әниләр.

**әмерхән қата** *минз.* ботинка төре (род ботинок).

**жөн қата** *т.кам.-крш.* күн табанлы, өстен жептән үреп эшләгән кыска куныčлы аяк киеме (обувь с коротким голенищем и кожаной подошвой, верх которой сплетён из шерстяных ниток). Айагында жөн қата, матур-матур жептән жасыйлар ыйы, табаны күнне, өстө дә әзерәк күн, қуныčы қысқа, төрлө жептән эшләнгән тышы, матур булған қатасы, дип сөйли торғаннар ийе.

**кийез қата** *мам., кргл., бгрс.* к.: **галуш 1**.

**ҚАТА II: қыш қата** *нокр., глз.* к.: **ката II: кыш ката**.

**төн қата** *нокр., глз.* к.: **ката II: төн ката**. Қайтқачын да эшләй ул, төн қата да эшләй ул. – *глз.*

**ҚАТАҒЫ** *том.д.* кодагый (сватья).

**ҚАТАЙТ** [*рус. катать*] *трх.* к.: **бал′ук**.

**ҚАТАЙТЛАУ** [*рус.* катать + *афф.* -лау] *трх.* сырлы бәләк белән кер тәгәрәтү, шомарту (гладить, катать бельё). Керне қатайт белән қатайтлый ийек.

**ҚАТАЛМА: қаталма awыру** *саз.я.* үпкәгә салкын тиеп авыру (бронхит).

**ҚАТАҢҒЫ** *себ.* чандыр (сухощавый).

**ҚАТАР 1.** *брб.д.* к.: **арый**. Өц қатар қыйғыр (кычкыр). Пер қатар ырғырап күрмәде пабайым. Пер қатар йағатық, сыwық полса иге қатар; **2.** *клм.* кире (обратно). Қатар китәргә йөри идем.

**ҚАТАРДА** [*гар.* + *афф.* -да] *кргл.* тирәдә (в окрестности, здесь и т.п.). Анawы қатарда китеп бара, магазинға бара йатсам. Менә бу қатарда өч awыл.

**ҚАТАР-ҚАТАР** *яүшт.* кабат-кабат, һаман, каткат (многократно, неоднократно, много раз, постоянно). Пилмән, қатар-қатар килмән (*әйтем*).

**ҚАТАРЛЫ** *кргл.* бер-бер артлы, билгеле бер тәртип белән (последовательно, по порядку). Элек қатарлы-қатарлы иде бит туй, ул қодалар чақыру, кеше чақырып мәһәр күрсәтүләр...

**ҚАТАРЫ** *кргл.* **1.** чамасы, бер чама – яшь турында (одной меры, примерно, одинаковый – о возрасте). Безнең бабай қатары инде; **2.** яны (около, возле, вблизи). Абзар қатарына эл. Ғәлиәскәр кухна башлады безнең кухна қатарына.

**бер қатары** *кргл.* бер төркеме, беркадәре (одна группа, некоторое количество). Бер қатарлары қайтып киткән.

**ҚАТАРЫННАН** *әстр.* рәтеннән, чиратыннан (как другие, наряду, вместе с ...). Кеше қатарыннан мал асырайсың.

**ҚАТАУ** *тбл.* тагу (пришить). Ирәннәргә көйләккә сәтәп қатаған.

**ҚАТЕМ** [*гар.*] *себ.* Коръән укыту мәҗлесе, үлене искә алып Коръән укыту (званый обед, где читают Коран или отрывки из него в честь умершего). Пилбөрмә көйләкнеңке киң пулган, қатемгә барса йабырылып торсон. – *тара.*

**йос қатеме** *себ.* үлүенә йөз көн үткәч уздырыла торган аш (поминки, проводимые через сто дней после смерти). Моқтар ақаның йос қатеме үтте әле генә. – *яүшт.*

**йыл қатеме** *себ.* үлүенә бер ел тулу уңае белән уздырыла торган аш (поминки, проводимые по случаю годовщины смерти человека, годины). Рух чаны пер йылғача қайтам-қайтам тип йөри, йыл қатеме усса, инте үлтем, ти икән. – *твр.*

**қатем аш** *тара., тбл.*, **қатем хуча** [*гар.*] *твр.* к.: **қатем**. Кичә қатем хуча йасатық.

**ҚАТЕМ-ҚОРАН** *әстр.* к.: **қатем**.

**ҚАТҚАҚЛЫҚ** *мам.* кантарланып каткан җир (мёрзлая земля с глыбами, с комьями). Қатқақлықта арба тәкермәчебез wатылды.

**ҚАТҚАН** *злт.* калын, кара – урман турында (дремучий). Қатқан урман былған бу тирә.

**ҚАТҚАНАҚ** *минз.* **1.** каты, каткан (твёрдый, затвердевший). Қатқанақ балчыққа төшкән: маңғай сөйәге ywалған; **2.** туңып каткан балчык, җир (мёрзлый грунт). Бик қаты җөгөрәп қайтадыр-

йым, бик қаты қатқанағ ыйы ул җылны, бардым да төштәм, җитәкләп керттеләр.

**ҚАТҚАНТУН** *злт.* к.: **бийауса**. Қатқантун, қатқантун, кийәwең килә, қас, қас.

**ҚАТҚЫРУ** *себ.* әч катып көлү (смеяться, хохотать, ухахатываться). Қатқырғытай сүсләр килеп чыкса, қатқырыштылар қартлар. – *тбл.* Көләп, қатқырып кәпләйделәр. – *төм.*

**ҚАТҚЫРЫҚ: қатқырық йүтәл** *брб.д.* бронхит. Перәwе қатқырық йүтәлдән өлеп кәтте.

**ҚАТҚЫЧ** *мам.* җеп ката торган җайланма (приспособление для ссучивания нитки). Қабаға элеп җегерлиләр, қаталар қатқыч белә, тәгәрәтеп қата торган ике қанатлы, безнең бар ыйы ул.

**ҚАТЛАМА 1.** *мам., минз., брб.д.* юка гына итеп җәелгән камырны майлап, өстенә киндер орлыгы сибеп, аны катлы-катлы итеп төреп, кискәләп мичтә пешерелә торган азык (слойка с начинкой из конопляных семян). Қатламасы да орлоқтан була торған ийе, қат-қат бүкләп тыкмач шикелле қамырны, орлоқ җәйәләр ийе. – *мам.*; **2.** *дөб., мам.* төче камырны токмач камыры кебек итеп җәеп, аңа төйгән киндер орлогы җәеп, төреп ясалган рулетны телеп табада пешерелә торган камыр ашы (мучное изделие из нарезанного рулета, начинкой которого является толчёное конопляное семя). Қатламалар пешерәдер ийек киндер орлогоннан, тәмне була торған ийе, қамырны җәйеп орлоқ сибеп урыйсың да кискәлисең, аннары басып-басып табада мичтә пешерәсең. – *дөб.*; **3.** *трх., каз. ар.-крш., минз., тпк.* ачыга изгән бодай камырыннан пешерелгән булка, слойка (слойка, булочка из кислого теста). Мин қатламаны гел пешерәдер ийем күмәч салғанда. – *минз.* Қатлама әче қамырдан, узырлы тақтага салып кисәләр, ул сырлы була, ашаулыққа салып қуйалар, ул қабара да пешерәләр. – *каз.ар.-крш.*; **4.** *минз., тпк.* сөткә һәм күкәйгә генә басылган төче камырдан чынаяк зурлыгында әвәләп майлы табага яки мич төбенә салып пешерелә торган азык, төче күмәч (булка, булочка из пресного теста); **5.** *перм.* к.: **қабартма**. Ачы итмәк қамырдан қатлама пешереб аласың; **6.** *бәр.* төйгән киндер орлыгын ягып пешерелгән пәрәмәч (ватрушечка из толчёных семян конопли). Қатламасы пәрәмәч кебек кенә була; **7.** *дөб., брб.д., яүшт.* юка гына итеп җәелгән камырны майлап, өстенә киндер орлыгы яки мәк сибеп, аны катлы-катлы итеп төреп мичтә пешерелә торган азык (рулет, слойка с начинкой из конопляных семян или из мака). Тарма башын йийнаб алып, киптереп, төчө қамырны йәйәсең тә, төйгән йимне йәйеп, әwәләп, кискеләп мийцтә бешерәсең қатлама қылып. – *брб.д.*; **8.** *к.-уф.* к.: **питрас 1**; **9.** *тпк.* кыстыбый (кыстыбый); **10.** *тбл., твр.* сумса (пирожок). Имне төйәп, сөткә болған йоға гамырға ғуйатылар, мөйәшәсен (почмагын) пөгөп пешерәтләр. – *тбл.*; **11.** *брб.д.* төче камырдан калын итеп пешерелгән җәймә (не очень тонкая лепёшка из пресного теста). Минең пабай йаратайы қатламаны, исе (үзе) қалын, исе цөцө; **12.** *минз.* черек бәрәңге күмәче (лепёшка из сгнившей под снегом картошки). Чабатасын кийенә дә, көрәк-чиләк ала да эчерек бәрәңге эзләп китә,

қатламасын ашап эшкә бара; **13.** *минз.* песи борчагының ашый торган җимеше (съедобный плод просвирняка). Бер бала утырган песи үләне арасына, шуның қатламасын ашаб утыра. Песи қатламасы дип ашый торған ийек.

**қатлама қунағы** *минз.* **1.** күчтәнәч итеп төче күмәчтән дә яхшы әйбер алып барырлык хәле булмаган кунак (гость, который не может принести в качестве гостинца ничего, кроме пресной лепёшки); **2.** тиз генә күчтәнәчкә катлама гына алып килгән кунак (гость, который пришёл ненадолго, наспех и поэтому в гостинец принёс только лепёшку).

**қатлама печән** *перм.* ярут (ярутка полевая).

**кийәү қатламасы** *трх.* кияү белән кызга туй көнендә махсус пешерелә торган кечкенә күмәчләр (булочки, слойки, специально испечённые в день свадьбы для жениха и невесты).

**күкәй қатламасы** *минз.* сөткә һәм күкәйгә генә басылган төче камырдан, чынаяк зурлыгында әвәләп, майлы табада яки мич төбендә пешерелә торган азык (печенье домашнего приготовления); чаг.: **йуwача 3.** Күкәй қатламасын күкәйгә генә басасың да, пешә күперелеп, чынайақ зурлыгы булып.

**қырый қатламасы** *минз.* к.: **қатлама 1.**

**қырық қатлама** *блт., мам.* к.: **қатлама 2.** Қырық қатлама болай була: йуқа ғына итеп җәйгән қамырға май сөртәлә, пабидла йағыла, йә киндер орлоғо оно сибелә, аны уқлау кебек итеп төрәләр дә, wақwақ итеп кисеп табада пешерәләр. – *блт.*

**песи қатламасы 1.** *минз.* к.: **қатлама 13.** Песи қатламасы дип ашый торғаныйық, төчө генә була ул йәшел кийенә; **2.** *кргл.* к.: **бырцак: бырцак үләне.** Болар песи қатламалары, мәмийе дә була.

**тәти қатламасы** *нрл.* юка ғына итеп җәелгән камырны майлап, өстенә төелгән киндер орлыгы сибеп, дүрт яктан бөкләп табада пешерелә торган камыр ашы (четырёхугольный полуоткрытый пирожок с начинкой из конопляных семян); чаг.: **қарақаш.** Тәти қатламалары тәмне, майлы буладырыйы киндер орлогоннан.

**ҚАТЛАМЫҚ** *әстр.* юка бәлешнең бер төре; катлы бәлеш (слоёный пирог).

**ҚАТЛАНЧЫҚ** *әстр.* эченә йөзем салып пешерелә торган катлы кабартма (слоёная булочка с изюмом).

**ҚАТЛАП** *минз.* яңадан, кабат, тагын (ещё, опять). Қатлаб уқырсыз әле дигәннәр ийе.

**ҚАТЛАУ** *нрл.* складка, бөгем – киемдә (складка, сгиб – на одежде). Қатлаулы йупкы кийәләр хәзер.

**ҚАТЛАУСЫЗ** *т.кам.-крш.* эчкерсез (искренний, прямодушный, чистосердечный). Безнең кийәү қатлаусыз кеше, қайсы кеше эчле, қарун булып тора.

**ҚАТЛАШУ** *т.кам.-крш.* кушылу, катнашу (соединяться, смешаться). Сандуғачлар белән иләр қарлығач Қарурманға кергәч адашқан, Урын бирмәйенчә сез түзәлмәссез, Бәбекәйләр сезгә қатлашқан (*туй җыр.*).

**ҚАТЛЫҚ I 1.** *кргл.* мамык җеп белән кушып катыла торган киҗе мамык җеп (хлопчатобумажная нить, скручиваемая с пуховой нитью). Қатлық ике қат булса, шәл қабармый; **2.** *мам., блт., глз.* чабатаның астын икенче кат тукып чыгар өчен әзерләнгән юкә (лыко для того, чтобы делать новый слой на низ лаптей). Қатлықларын алдан җасап қуйадырыйы әзерләп, чабатасы нық буладырыйы Ғалимулла абзыйның. – *мам.* Чабатаға бер қатлық тезәләр, таза булсын дип йертәләр аны. – *глз.*

**ҚАТЛЫҚ II** *әстр.* терлек ашаганнан калган печән, печән чүбе (остаток сена, не съеденное скотом).

**ҚАТЛЫҚ III** *тбл., брб.д.* кытлык, корылык (неурожай, засуха). Йегермә перенце йылныңқы қатлығынта ул көл бойына йыйылғанбыс, йибәрегә иттеләр, палық полты, өлмәдек. – *брб.д.*

**ҚАТЛЫ-ҚАБАТ** *блт.* кат-кат, кабат-кабат (несколько раз, снова и снова). Қатлы-қабат кем барып җәри анда.

**ҚАТЛЫҚАЙ** *минз.* к.: **қатлама 1.**

**ҚАТМА** *туб.-ирт.д.* зур орчык – җеп кату өчен (большое веретено – для ссучивания пряжи). Йеб ийерә тыған урцық пы, қатма шаның зурлығы, йеп қатқалы. – *тбл.* Йепне цыйыратабыс қатма белән, қатма сур урцығ инте. – *төм.* Йеб ийерә тыған урцық пы, қатма шаның сурысы. – *твр.*

**ҚАТМАЛ, ҚАТМАЛДА(Н)** *нокр., глз.* к.: **қапылтын.** Қатмалда ғына awыртты. – *нокр.* Қатмал үлгән ул. Әнийем қатмалдан күзсез булды, қыйыдан су алғанда йылы ғына йил кәлеп бәрелде, ди. Қатмал ғына килеп сөзмәй ул, заман килми ул күрәсе имгәгең. – *глз.*

**ҚАТМАРЛЫ** *перм., злт., трбс., тпк.* катлаулы (сложный, трудный). Бу китап қатмарлы түгел ийе. Тормыш қатмарлы. – *злт.* Қатмарлы хәзер уқу. – *трбс.* Һәр дәwернең эше үденә қатмарлы. – *тпк.*

**ҚАТМАРЛЫ-ҚАТМАРЛЫ** *минз.* катлау-катлау, катлам-катлам (слоями, пластами). Балчықлары алама, шушылай қатмарлы-қатмарлы булып килеп чыға (пич чыгарганда).

**ҚАТМӘЛ** *лш.* к.: **қапылтын.** Анише таза йәшәгән кеше қатмәл үлә диләр.

**ҚАТМЫШ I 1.** *перм.* эшлексез, эшләмичә тик басып торучы кеше турында (о человеке, который ленится, не любит делать лишние движения; бездельник); чаг.: **азымтық.** Җырлыйм әле алтмышны, Төшемдә дә күргәнем йуқ Синең кебек қатмышны (*хал. җыр.*); **2.** *перм.* к.: **аңшаби.** Қатмыш, әйткәнне аңнамый, қарап тик тора; **3.** *саз. я.* к.: **қатымыш.**

**ҚАТМЫШ II 1.** *себ.* балдак (обручальное кольцо). Қысның алтын қатмышы пулаты. – *төм.* Йөсөк күсле булады, қатмышныңқы күсе булмайды. – *тара.* Пылар қатмыш, чистый алтын икәwе тә. – *твр.* Қатмыш хәллерәкләр алтыннан, хәлсесрәкләр көмөштән кигән. – *саз.я.* Қатмыш әйтеләде көсе болмаганы. – *брб.д.*; **2.** *тара., твр.* кашлы йөзек (перстень). Қатмыш күслесе дә бар, күссесе дә булады, күслесен тә қатмыш тибес. – *тара.* Палам (улым) қаттырты пы қатмышны. – *твр.*

**той қатмыш, туй қатмышы** *себ.* к.: **қатмыш II, 1.**

**ҚАТНАР** *перм.* чорма (чердак, подволока). Қатнарларда да йоқладым.

**қатнар түбә** *перм.* к.: **қатнар**. Қода қатнар түбәгә менеп киткән, баслық булған.

**ҚАТНАУ 1.** *перм., злт.* чабатаның астына кабат юкә йөртү, тагын бер кат юкә кертеп ямау (чинить, сделать новый слой на подошве лаптей). Шул бабай үзе қатнап пирә чабатаны, күтәрәлмәслег инде. – *перм.* Сабатаны үрә беләм, қатный белмим. – *злт.*; **2.** *себ.* кат-кат йөрү (ходить неоднократно, несколько раз). Өйгә қатнадым. – *саз.я.*

**ҚАТРАҢ 1.** *туб.-урт.д.* чыдам, нык (выносливый, крепкий, работоспособный). Қысым уңқан, эшкә қатрац. – *төм.* Эшкә қатрац полтым, палларны та уғыттым. – *тбл*; **2.** *саз.я.* нык кына – эшләү (хорошо, крепко – работать, трудиться). Қатрац пецән цawып йөрит; **3.** *тбл., саз.я.* житез, өлгер (проворный, ловкий, быстрый). Паласы (улы) қатты (бик) қатрац. – *саз.я.*

**ҚАТТАШИ** *дөб.* к.: **кәртәши**. Қатташине қарчықлар кигән.

**ҚАТТЫ 1.** *төм., саз.я.* каты (твёрдый). Қаттытын қатты, ний қатты (*табыш.*). – *саз. я.*; **2.** нык, таза (здоровый, сильный). Қатты йегет. – *саз.я.*; **3.** нык (крепко, сильно). Пыйыл awылны қатты сыу алу белән эшкәрә қыйын пулты. – *төм.*; **4.** к.: **әләк 2**. Палацығы қатты көчхенә. Қатты көцлө у.

**қатты гүс** *тара.* ямьсез күз, караңғы чырай (косой взгляд, недолюбливающий взгляд). Қатты гүс мән қараған түгелләр.

**ҚАТУ I** *минз., бөре., злт.* ашка ката торган катык (катык для заправки супа).

**қату қату** *минз., бөре., злт.* ашка катык кату (заправить суп катыком). Қату қатып ашайбыз. – *бөре.* Қату қатмыйсыңмы, апчығыйммы? – *минз.* Ашығызға қату қатығыз, тәмнерәк былыр. – *злт.*

**қатулы аш** *минз.* катык каткан аш (суп, заправленный катыком). Қатулы аш ашыйсызмы?

**ҚАТУ II** *перм.* туңу (зябнуть, мёрзнуть). Қатқансымақ булдым ий. Сыйрақ қата, йабығыз әле ишекне. Самай чийә чәчкә атқанда қатырып қуйа қый.

**ҚАТУ III 1.** *злт., туб.-урт.д.* киемне, аяк киемен жиңелчә генә әләктерү, аннан-моннан гына кию (набросить, накинуть, нацепить – одежду, обувь). Айағыңа калуша ғына қатып барып кил. – *злт.* Пашыма цөбөр генә қаттым та йүгертем. – *твр.* Айағыңа пойма қатып цық. – *тбл.*; **2.** *туб.-урт.д.* тагу – алка h.б. турында (надеть – о серьгах и др.). Қататы ғолағына алга, мәтис сырға да ғататлар, алтын алға та. – *төм.* Мунцақ қатмайым ицпер wақыт. – *тбл.* Сырға қату. Алтыннан, йуwан алға қаттым. – *тара.*; **3.** *туб.-урт.д.* кию – кием турында (одевать, надеть на себя). Песнекенцә сапун қаттым. – *тбл.*; **4.** *тбл., тара., саз.я.* атны жигү (надевать на лошадь сбрую). Мийәт қату. Йөгән қату. Тилбегә қату.

**ҚАТУ IV: ачу қату** *т. я.* ачу тоту (питать злобу). Ул заманда йегетләр ачу қатмыйлар ийе. – *к.т.*

**йақты чырай қату** *минз.* якты чырай күрсәтү (встретить приветливо, быть приветливым). Бергә торсаң килен белән, йақты чырай да қатмас ыйы.

**tawыш қату** *тара., тбл.* сүз кушу, эндәшү (подать голос). Син аңа tawыш қаттыңма? – *тбл.*

**ҚАТУ V** *тбл.* бүсер (грыжа). Қатуwым қатып қалты.

**қату уйнау** *әстр.* сөял чыгу (появиться мозоли).

**қ а т у VI** *брб.д.* кату (замереть, остолбенеть, оцепенеть):

**қата қалу** *перм.* шаккату, катып калу (оцепенеть, остолбенеть, крайне удивиться). Тормошоңа қарасаң, қата қалырсың, эрәхәткә чыдый алмый қырылып жатасың. Қата қалдым ишеткәс. Қата қалып тыңнап тора.

**қолақ қату** *минз., трбс.* начар ишетә башлау, колакка каты булып китү (стать тугим на ухо, плохо слышать). Бер қарчықның қолағы қатты йәшеннән қурқышыннанмы. – *минз.*

**тура қату** *каз.ар.-крш.* ис китү (удивиться, изумиться). Матур жырлады – тура қаттым.

**ҚАТУ VII** *брб.д.* кадак (гвоздь).

**ҚАТУ VIII** *брб.д., тара., төм.* каты (твёрдый, жёсткий). Қату себерәк булур. – *төм.* Йәребес қату. – *брб.д.*

**ҚАТУЛАУ** *минз.* к.: **қату I**: **қату қату**. Әйдәгез қатулыйқ. Зерә тәмне генә аш, қатулап йебәр.

**ҚАТХЫРУ** *саз.я.* к.: **қатқыру**. Кән қатхырман, сыхтарсс.

**ҚАТЦА** *төм.* аңгыра – кеше турында (тупой – о человеке).

**қ а т ы I** *урт.д.* каты (твёрдый):

**қаты басу** *дөб.* такыр басу (паровое поле). Элек қаты басуда көтү йөрткәннәр, суқаламыйлар аны.

**қаты җәннек** *нрл.* к.: **қаты қопшаңғы**.

**қаты қанат** *перм.* ертыш, шыртлака (ёрш).

**қаты кәлүш** *минз.* ботинкага охшатып тегелгән күн аяк киеме, күн ботинка (кожаные ботинки); чаг.: **қата I, 1, 2**.

**қаты қопшаңғы** *нрл.* каты таракан, коңгызның бер төре (один из видов жука). Қаты җәннек диләр, қопшаңғы була ул, қаты қопшаңғы.

**қаты қура** *нрл.* буын үләне (цикорий). Қаты қураны да файдалы диләр, бийек, зәңгәр чәчәкле, йафрақлары йуқ аның.

**қаты пар** *дөб.* к.: **қаты басу**.

**қаты суқа** *лш.* такыр басуны сукалау (паровая пахота). Мамалай жийыныннан соң қаты суқаға төшәләр ийе, парлыйлар ийе жирне көзгә чикле.

**қаты сырт** *бөре.* к.: **қаты қанат**.

**қаты үлән** *нрл.* к.: **қаты қура**. Қаты үлән зәңгәр чәчәк ата, йафрақлары йуқ аның, үзе қаты.

**күзе қаты булу** *мам.* күрмәү (не видеть, быть слепым). Әбинең күзе қаты, күз күрмәүдән дә awыр чир йуқ.

**ҚАТЫ II 1.** *бөре., себ.* к.: **әләк 2**. Қаты иртә тормыйбыз, эшкә барасы йуқ. – *бөре.* Қаты ысwайы көйләк. – *саз.я.*; **2.** *каз.ар., т.я.* нык, күп, көчле (сильно, много). Хезмәт итәйек әwәле бик қаты. Эшли идек бик қаты – *трх.*; **3.** кызу (быстро). Бик қаты жөри аның машинасы. – *мам.*

**ҚАТЫБА** [*гар.*] *твр.* хәтфә (бархат). Қатыбаны қурласам, тон торғадан кийәрмен.

**ҚАТЫҒУ 1.** *злт.* үләннәрнең өлгереп житеп,

катып китүе (высыхание, затвердение травы после созревания). Үлән қатыққан, йәш wахытта ғына сабарға әйбәт; **2.** *тбл., сазя., брб.д.* үсү, буйга җитү (расти, вырасти, достичь совершеннолетия). Ол қыс қатықты, олғайып қуйыпты. Монта килен булып төшкән, мине тувырған, әткәм минеңе асыраған, қатықтырған, хәткә йеткесеп, сур қыс қылып мине. – *тбл.* Мин йетим пулф қатыхқан. – *сазя.*; **3.** *сазя., брб.д.* симерү (поправляться, тучнеть). Қуйлар арық, қатықса суйар итек. – *брб.д.*

**ҚАТЫЙ** *бгрс.* кош теле (национальное мучное изделие: ромбовидный хворост).

**ҚАТЫҚ** *лш.* сөзмә (процеженный, отжатый катык).

**балан қатығы** *к.т., кргл.* баланнан, он яки салат измәсе белән болгатып, мичтә томалап пешерелә торган азык (пища, приготовленная из калины). Пешерә белеп пешерсәң, балан қатығы бик тәмне була ул: әчкелтем-төчкелтем. – *к.т.* Без балан қатығы да пешерәбез, тәмле була ул. – *кргл.*

**йәш қатық** *туб.-ирт.д.* к.: **ацығай**. Йаңы сауған сөтең эреп қуйа ацып қайсыда, йәш қатық булаты. – *тбл.*

**салат қатығы** *дөб.* к.: **балан қатығы**. Утырығыз, салат қатығы ашыйбыз.

**сөзмә қатық** *глз.*, **сөсмә қатық** *төм.* к. **қатық**.

**төчө қатық** *бәр.* к.: **ацығай**. Төчө қатығым бар, туғлап қоймақ пешермен иртәгә.

**ҚАТЫҚЛАНУ** *дөб.* сыеклану – кыярның эче турында (сделаться жидким, разжижаться – об огурце). Қыйарнын қатықланып қына йата эче сувық булғач, сыйықланып бетә эче. Қатықланып беткәндер инде қыйарлар.

**ҚАТЫҚЛАШ** *к.т.* катык каткан аш (суп, заправленный катыком).

**ҚАТЫҚТЫРУ** *төм., төр., сазя.* үстерү (растить, воспитывать). Пала-пағырны қатықтырып йатам. – *төм.* Йарым кешенең қайны-қәйнәсе була, баллар қатықтыралар. – *төр.*

**ҚАТЫЛЧАҚ** *төр., брб.д.* хайванның ашказаны (желудок жвачных животных).

**ҚАТЫЛЫҚ** *перм.* к.: **қаты I: қаты басу**. Қатылықта үсеп җийа қый ул (какы турында).

**ҚАТЫЛЫШУ** *тбл.* катышу (вмешиваться). Син аларның эшенә қатылышма.

**ҚАТЫМ** [*гар.*] *себ.* Коръән, дога (молитва по умершему). Қатым уғыту та йуғ ите. – *тара.* Қатым уғыттылар үлгәнтә. – *төм.*

**қатым аш** *себ.* **1.** мәет чыккан йортка читтән пешереп китерелә торган ашамлык (кушанье, которое приносят в дом после выноса тела покойника). Туйға шайланып йатасыс, ти, йәнекәң Қәмпәрең тиңкес аша цыққанта, тиңкескә йығылып үлте, Сескә қатым ашны йебәртеләр, тите. – *төм.*; **2.** к.: **қатем**. Пестә йөсөнә тә қатым аш үткәрә. – *тбл.*

**ҚАТЫМЫШ** *злт.* саран (жадный). Қатымыш Фатыйма.

**қатын** *урт.д., себ.* хатын; хатын-кыз (жена; женщина):

**буш қатын** *брб.д.* ялгыз, гаиләсез хатын (одинокая женщина).

**җәш қатын** *мам.* икенче хатын (вторая, следующая, жена). Җәш қатын булып килде қатыны үлгән кешегә.

**тоуған қатын** *брб.д.* бала тапкан хатын (рожавшая женщина; роженица).

**ҚАТЫН-УРТА** *дөб.* урта яшьләрдәге хатын-кыз турында (о женщине средних лет). Қатын-урта ғына қатын ийе, кодрәләткән чәчен.

**ҚАТЫНШАҚ** *минз., бөре.* хатынша (обабившийся мужчина). Гел қатыншақ инде, бигрәк тә wақчыл. – *бөре.*

**ҚАТҒЫР** *төм.* качыр (лошак, мул).

**ҚАТЫР** [*гар.*] *тара.* хәтер (память). Йиғитнең қатырына (хәтеренә) бу айат килде.

**ҚАТЫРАҢ** *сазя., тбл.* **1.** нык, таза (крепкий, здоровый). Қатырац қыс итең. – *тбл.*; **2.** каты (твёрдый). – Картуп пештемә? – Йуқ әле, қатырац. – *сазя.*

**ҚАТЫРҒАН** *нрл.* каты сабаклы, ак чәчәк ата торган куак (золотарник). Қатырған себерке белә себерәсең чирәмне.

**ҚАТЫРҚА** *минз., злт.*, **ҚАТЫРМА** *глз.* катыргы (картон). Қатырма тыш. Бу китапның қатырмасы матур икән. Қатырқа тышлы түгел китабы, чыдамый.

**ҚАТЫРМАҚ** *төм.* сохари (сухари).

**ҚАТЫРУ I** *перм.* к.: **ишләү**. Қоймаққа алып қалдым да қамырны әпәйгә қатырдым.

**ҚАТЫРУ II** *төр.* куып хәлдән тайдыру – ат турында (загнать – о лошади). Қара аргамақ қатырзаң, атны қайдан менәрзең?

**ҚАТЫХУ** *сазя.* **1.** үсү, зураю (расти, вырасти); **2.** сәламәтләнү, аякка басу – авыру кеше турында (выздороветь, встать на ноги – о больном человеке). Инәсе қаты аурап, қатыхқан инте.

**ҚАТЫШ-ҚАРА** *мам.* аралаш (смешанный). Бәрәңгене көрпә белән қатыш-қара китереп бирәм инде чебиләргә.

**ҚАТЫШЛЫ** *т.кам.-крш.* катнаш (смешанный); чаг.: **қатыш-қара**. Чиркәс awылы урыс белән қатышлы. Алма белән шомырт қатышлы кампут.

**ҚАТЫШУ** *минз.* **1.** кушылу (впадать, втекать). Қайрақлы йылғасы Эстәрлегә қатыша; **2.** берләшү (объединяться); **3.** өйләнешү, кушылу (пожениться). Әзерәк сүләшеп йөргәннәр дә, монда килгәч қатыштылар.

**ҚАУ I** *тбл., сазя.* **1.** ку гөмбәсе, агач гөмбәсе (гриб, растущий на дереве); **2.** *тбл., сазя., брб.д.* киптерелгән агач гөмбәсеннән ясалган сүс (трут). Серәңкә пулмаган әүwәл, қау булған, таш булған, қорыч тимер белән ут алғаннар.

**ҚАУ II** *злт., эчк., туб.-ирт.д.* чабылмый калып кар астында қыш чыккан һәм кипкән үлән (прошлогодняя трава, высохшая на корню). Қаулы йертә пецән цабу йаман. – *төм.*

**ҚАУҒА I** *дөб.* арттыручан, күпертүчән – нинди дә булса вакыйғаны (любитель преувеличивать). Awылда кеше бик қауға бит, кескенәне дә зур дип сөйли.

**ҚАУҒА II** *эстр.* к.: **бид(е)рә**.

**ҚАУҒАЛ** *тара.* к.: **қауғалы**. Цийәгә қаугалға цықтық.

**ҚАУҒАЛАНУ** *дөб.* ашығу, кабалану (торопиться, суетиться); чаг.: **абдырау 1**.

**ҚАУҒАЛАУ** *дөб.* арттыру, күпертү (преувеличивать).

**ҚАУҒАЛЫ** *тара.* әрәмәлек, агачлык (роща, лесок); чаг.: **беләк**. Йиләк пөтөпте, қауғалыта цупләнтек бербәц-бербәц.

**ҚАУДАН 1.** *лш., блт., трх., минз., перм., к.-уф., нгб.-крш., тбл.* к.: **қау II**. Қар киткәч тә сарыкларны чығарабыз қауданға. – *лш.* Малларны апчыкмыйлар көтүгә, қаудан ашап жөрөрләр ийе. – *перм.* Қаудан печән чабарға қомачаулый. – *нгб.-крш.* Балалар қауданға ут төртөп, пажар чығара йазғаннар. – *к.-уф.*; **2.** *каз.ар.-крш.* вакытында алынмыйча, егылып калган житен (оставшаяся не выдёрганной посконь). Киндерне жолоққанда қаудан жыйадырыйык, йығылып қалған баса; **3.** *перм., брб.д.* к.: **абаға**; **4.** *перм., злт.* елан кабыгы (линовище, кожица змеи). Йыланның қауданы төшөп қала икән. – *перм.*; **5.** *яүшт.* кавык (перхоть).

**қоро қаудан** *блт.* к.: **қау II**.

**ҚАУДАР** *дөб.* к.: **қау II**. Жаңға үлән чыққанчы қаудар да ашыйлар. Қаудар чыққач та қар астыннан, сыйырларны болынға қуwабыз.

**ҚАУДЫР-ҚАУДЫР** *т.я.* к.: **қабалан-қабалан**. Қаудыр-қаудыр ашады да чығып жөгөрде. Қаудыр-қаудыр сөйләмә, берни аңнамыйм. – *к.т.* Қаудыр-қаудыр қайа бара Салих бабай, чикигә мәллә? – *нрл.*

**ҚАУЗАН** *мам., минз.* к.: **қау II**. Йаз чыққач, маллар қаузан ашап та туқ булалар. – *мам.* Ишегалдым қаузан-қаузан, Қаузан башлары ауған (*хал. жыр.*). – *минз.*

**ҚАУЛАҚ I 1.** *себ.* к.: **қау II**; **2.** *туб.-ирт.д.* билчән (осот). Қаулақ қақлай тыған пулаты, қаулақ цығаты қыраларта. – *төм.* Қаулақтан да бал алалар, картуп чәчәгеннән дә. – *твр.* Қаулағ утаған қырны та үлцәгән мин. – *тара.* Әwәл қул пийен өскән қаулақны та. – *саз.я.* Қаулақлар цығаты питайларға қыраларта, қулны цәнецәте, бийәлине кийеп утайсын. – *тбл.*; **3.** *брб.д.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы**. Сор-сор қаулақ парма сеснең йақта?; **4.** *себ.* иске-москы (ветошь, старьё).

**қас қаулақ** *тара.* билчән (осот). Қас қаулақ цәнецкәкле, алып ташлайсын.

**қаулақ қабыгы** *брб.д.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы**.

**сөт қаулақ** *туб.-ирт.д.* **1.** к.: **қаз II: қаз билчәне**. Сөт қаулақны өскәц, сөт цыгаты. – *төм.*; **2.** сөтлөгән (молочай).

**ҚАУЛАНУ: тел қаулану** *баст.* тотлыгу (заикаться).

**ҚАУЛАУ 1.** *блт., мам., нрл., кмшл.* к.: **абыру**. Бәкәйне қаула әле. Чыбық белән қаула қазларны. Артыннан қаулыймmы? Қаула, энем. – *блт.* Малларны қаула әле, игенгә йақынайдылар. Қазлар қаулап китеп барадырыйы ул байағынақ. – *мам.* Сарықларны қауләле. – *кмшл.*; **2.** *мам.* куу, чабу, берәр эш белән мәшгуль булу (гнаться, бегать, быть занятым чем-либо). Үлән, жафрақ артыннан қаулый әле ул бу арада.

**ҚАУМ** [*гар.*] *твр.* кавем (племя, род). Ул қаумдан сақлану кәрәк иде.

**ҚАУРАЙ** *твр.* курай (курай – национальный музыкальный инструмент).

**ҚАУРУ** *брб.д.* куыру (жарить). Тарманыңқы йемен қаурып йийәсең.

**ҚАУРЫЙ** *төм.* к.: **дегәч**. Қаурый йасайтыған таба йышқалы.

**ҚАУТАН** *туб.-ирт.д.*, **ҚАУТАҢ** *тбл., саз.я.* к.: **қаудан 5**.

**ҚАУШАҚЛАНУ 1.** *т.я., мам.* к.: **кубагайлану**. Ычтинасы қаушақланған ағартқаннан суң уқ. – *мам.*; **2.** *к.т.* яргалану, яргаланып кубып тору – тире турында (шелушиться – о коже); чаг.: **йарпалану**. Битләр, қуллар қаушақланып бетте.

**ҚАУШАҚЛАТУ** *к.т.* тирене, тәнне яргалату (образовать шелуху на поверхности кожи, шелушить). Бу сабын битне қаушақлата.

**ҚАУШАТУ** *т.я.* к.: **абдырату**. Бик артық қаушатмағыз, өлгөрөрбез әле, wахыт бар ич. – *трх.*

**ҚАУШАУ** *төм., брб.д.* ватылу, таркалу (раздробиться, разломаться, разложиться).

**ҚАФ I** *саз.я.* к.: **қап I**. Пер қаф серәңкә пиреп торцы.

**ҚАФ II** *саз.я.* к.: **қап II**. Қаф уртасыннан кистем.

**қаф йаралай** *саз.я.* нәкъ уртасыннан, нәкъ урталай (точь-в-точь, пополам). Қаф йаралай пиртем қуй тырашасын та, итмәген тә.

**ҚАФХАН** *саз.я.* капкын (капкан). Қафхан уцтым (куйдым, утырттым) қумаққа.

**ҚАФХАХ** *саз.я.* капкач (крышка). Пи бәтрәнеңке қафхағы йоқ, қафхах фирәйенмә?

**ҚАФХАХЛАУ** *саз.я.* ябу – капкач белән (закрыть – крышкой). Қафхахлаф қуй, церғәй булмасын.

**ҚАФХЫРЛАУ** *саз.я.* эт тешләгәч им-том итү (заговаривать при лечении от укуса собаки).

**ҚАХА(Й)** *әстр.* абый (старший брат). Қахай Қазанда тора.

**ҚАХА-ЖИҢГӘ** *әстр.* абый-жиңгә (старший брат с женой). Қахасы-жиңгәсе үстергән, кийәүгә биргән.

**ҚАХАМ** *әстр.* абыем, абыйга эндәшү сүзе (форма обращения к старшему брату).

**ҚАХСУ** *саз.я.* сасу (тухнуть, протухать, провонять). Палых қахсыған. Итен қахсытат.

**ҚАХЧЫХ** *саз.я.* к.: **йадау**. Палацықларыwс қахчых ит соуғыш wақытта.

**ҚАХШАТУ** *саз.я.* вату (ломать). Уйынцыхларны қахшатмаң.

**ҚАХШАХ** *саз.я.* тарау-торау яткан әйберләр; тәртипсезлек (разбросанные вещи; беспорядок). Өйтә қахшахта атлар йер йух.

**ҚАЦ!** *төм., тбл.* кит (уходи). Қац ул пуйтан! – *төм.* Қац пуратан, ицмә эшләйәлмәйен. – *тбл.*

**ҚАЦАН** *себ.* кайчан (когда). Қацан килтенесләр? – *тара.* Той қацанты? – *тбл.*

**ҚАЦАР** *яүшт., брб.д.* яңак сөяге (скула). Қацарын пәреп цығарыпты. – *брб.д.*

**ҚАЦАУ I** *туб.-ирт.д.* к.: **қачау**.

**ҚАЦАУ II** *туб.-ирт.д.* юну (тесать, обтёсывать).

**ҚАЦҚЫ** *эчк.* к.: **қасқы**.

**ҚАЦЫ** *саз.я.* үрдәкнең бер төре (большой крохаль – порода уток).

**ҚАЦЫРУ** *тбл.* куу, куып җибәрү (прогнать, обратить в бегство).

**ҚАЦЫРЫНТЫРУ** *тбл.* каплату, йөгертү (случать).

**ҚАЦЫТУ** *тбл.* к.: **қақлау II, 1.** Қацыттыма қыцытқан?

**ҚАЧ** [*гар.*] *крш., нокр., глз.* тәре (крест). Керәшен зиратында қач куйылған була. Бездан қач чабып алалар да бәке җанына утырталар. Безнең керәшеннәр үләләр инде шул қачқа бағынып. – *каз.ар.-крш.* Муйнысына қач асқан. Қачлы урыс башбаталар бар зийаратта. – *нокр.* Анасы бәқыйлләп зата, башына ипи қуйып, бақыйл, ди. – *т.кам.-крш.*

**қач қылу** *крш.* чукыну (креститься). Қодағый ипей, май, тоз, арақы тотып чыға, майны үптеләр бөтөн кешене қач қылып, ыризықлы, бақытле булсыннар, дип, килен беренче кергәндә бөркәнчек белә кергәндә. – *т.кам.-крш.* Миңа бабай өйрәткән ийе, йақ-йағыңа қач қыл дип, мин қач қылдым да шул кеше айақ астында ут булып чәчелде. – *каз.ар.-крш.*

**қач маңған көн** *крш.* к.: **қачманар**. Чиркаудан қач маңған көн су апқайттық, изге су була ул безнең. – *каз.ар.-крш.*

**қач маңған су** *каз.ар.-крш. қачманар* көнне чиркәудән алып кайткан су (вода, принесённая из церкви в день крещения, в которую погрузили крест и освятили). Күз күтәрми қайбер бала, қач маңған су белән ишек бауларын, тәрәз ырамнарын қойондырып битенә өрсәң, тәннәрен манасың, малға күз тисә дә шулай.

**қач мандыру, қач ману** *крш.* тәрене суга ману (погружать крест в воду, освятить воду). Зур итеп бәке чабалар қач мандырырға. – *каз.ар.-крш.*

**ҚАЧАҒАН** *тбл.* качучан ат (лошадь, стремящаяся убежать).

**ҚАЧАН** *брб.д.* кайвакыт (иногда). Қачан чеwәләрем қоноққо қәләде.

**ҚАЧАР** *кргл.* бер яшьлек тана (годовалая тёлка). Қачарын калхузға ыздawайт иткән. Без қачар суйсақ та суғым суйабыз дибез.

**ҚАЧАУ** *эчк.* өтерге (стамеска).

**ҚАЧҚАЛАҚ 1.** *бгрс.* качыш уены (игра в прятки); **2.** *минз.* к.: **қасқы.**

**ҚАЧ-ҚАЧАН** *төм.* кайчан да булса (когда-нибудь). Қарт, эстинадан цай қайнатырлар қач-қачан та, тигән. Қач-қачан да бу awыл белән камандалық итәрмен.

**ҚАЧ-ҚОЧ** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* к.: **аймылыш 1.** Утынны қач-қоч өйдем. Утынны қач-қоч салып җандыралар. – *каз.ар.-крш.* Қач-қоч китереп қуйарға (киндерәне) тишеге була чабатаның. – *т.кам.-крш.*

**ҚАЧҚЫ** *бөре., перм., трбс., туб.-ирт.д., брб.д.* к.: **қасқы 2.** Қачқы булмасын, дим. – *трбс.* Аның бәләкәй улы қачқы кебек. – *бөре.* Әwәлдә қачқылар да булған ул урманда. – *перм.*

**ҚАЧҚЫЛЫҚ** *перм.* качкынлык (бегство, дезертирство). Шул қачқылықта йөрдө күп йыл.

**ҚАЧҚЫЧ, ҚАЧҚЫЧЛЫ** *мам.* качышлы уены (игра в прятки). Ғайникамалттинең лапасында қачқыч уйнадық. Аларның ишегалдында қачқычлы уйнawы рәхәт, қачарға урын күп.

**ҚАЧМАНАР** [*гар.* + *тат.*] *каз.ар.-крш.* христианнарның ел башында була торган дини бәйрәмнәре (один из праздников православных христиан; крещение). Қачманарда қунаққа бардық Қазанға, чиркауда булдық, изге су, қач маңған су апқайттық.

**қачманар су** *каз.ар.-крш.* к.: **қач: қач маңған су.** Қачманар суны даруга да тоталар.

**ҚАЧМЫҚ** *т.кам.-крш.* керәшен хатын-кызларының тастарга охшаш баш киеме (старинный головной платок у кряшенок продолговатой формы, напоминающий тастар). Қачмық сәленеп тора арқада, бәк матур булалар ыйы қызлар элгәре.

**қачу** *урт.д.* качу (прятаться):

**қачып жөрү** *лш.* борынғы гадәт буенча, яшь киленнең иренең өлкән ир туганнары белән сөйләшмәве, йөзен күрсәтмәве, тел яшерү (старинный обычай, согласно которому молодая невестка не показывала своё лицо старшим родственникам мужа, свёкру и не разговаривала с ними). Мин дә өч жаулық бетердем әле қачып жөрөп.

**ҚАЧУШ** *дөб.* ат кыргычы (скребница, щётка для чистки лошадей). Қачуш белән қырып-қырып жуwa икән атын.

**ҚАЧУШЛАУ** *дөб.* атны кыргычлау (чистить коня скребницей).

**ҚАЧЧУ** *саз.я.* туңу (замерзать). Қулы қаччхан. Салқынта қаччыф қалтым.

**ҚАЧЫ** *т.я., перм.* к.: **қанчы.** Қачы, пычақ белән уйнамый балалар, жарамый уйнарға. – *к.т.*

**ҚАЧЫЛЫҚ** *т.я.* бәпкә, кайчы (стропило).

**ҚАЧЫРУ** *т.кам.-крш.* өйләнешкән чакта егетнең кызны берәр якын кешесенә алып кайтуы, бу кеше аннан соң *қыйаматлық* була (жених приводит будущую жену в дом близкого для него человека, чаще родственника, который в дальнейшем становится посажёным). Қызны қачыру була, берәр жақын туганына алып қайта қызны, қыйаматлық диб атала, килең кеше әтки, әңки диб атый аларны.

**ҚАШ I 1.** *нрл., мам., лш., минз., бөре., перм., себ.* кашлак, калкулык (холм, пригорок, возвышенность). Бу қашларда урман булған. Теге қашта кисмәк йасый торған йуwан ағачлар үскән. Жабага қашы дигән урын бар. – *нрл.* Шушы көйөп беткән қашта жөрөп қайа сөт бирсен инде бу сыйырлар. – *мам.* Көтүне туплап тоталар қашта. – *лш.* Әмәнде қаш. Бик йәмне жирдә йе миңке ызба, қаш жирдә. – *перм.* Алар қыйра пулған, қаш пашқа цыққаннар та йатқаннар. – *төм.* Қаш йер пулған, анта хайwаннар йөрөгән. – *тара.* Пейек қаш пар. – *тбл.* Йырақ төгөл қаш полған, анта қацқылар булған. – *яүшт.*; **2.** *төм., тбл.* яр (берег). Қашта қарлығач ойалары бар ит, пуйыл күрмәгәнем. – *төм.*

**қаш башы** *т.я.* тау түбәсе, тау башы, калкулык өсте (вершина холма, возвышенность). Қаш башына мендек жиләк жыйарға. – *к.т.*

**қаш йылу** *саз.я.* тау шуу (кататься с горки). Йаңа йылта қаш йылғалы цығawс.

**қаш өстө** *лш., мам.*, **қаш паш** *себ.* к.: **қаш башы.** Әтисе қаш өстөндә ат белән эшли. – *лш.* Пес тә қаш пашта уйнатық. – *тбл.*

**мөржә қаш** *перм.* к.: **қашаға I, 1.** Мөржә қаш қайсыныкы озур була.

**су қашы** *тбл.* елгадан су алып менә торган урын (место на берегу реки, откуда таскают воду). Сыу қашыбыс йаман текә, шанан апцыққынца айақлар тойоқ аурый.

**тау қаш** *перм.*, **тау қашы** *лш., трх.* тау бите (склон горы, косогор). Мәдрәсә тау қашында, тақта чоланы йарға асылынып торғандай тора йы. – *трх.* Тау қашта ғына хәттин ашқан жир жиләк тә, шартлама да. Безнең awыл Қырылowода (*ав. ис.*) тау қашта булған, қайыннары әле дә булса бар. – *перм.*

**ҚАШ II** *туб.-ирт.д.* баш (верх, верхняя часть).

**ишек қаш** *тбл.* ишек башы (притолока).

**тирәс қаш** *тбл.* тәрәзә башы (верхняя часть оконной коробки). Тирәс қашқа қоратыған пәртә пулаты.

**ҚАШ III** *туб.-ирт.д.* кашага (занавеска, бордюр). Мейец қашлар тегәте қыс. – *төм.* Ишек қаш, тәрәс қаш йарымы алаты, йарымы цымылтық әләте. – *тбл.*

**қаш IV** *себ.* каш (бровь):

**минең қашымда** *тара.* янымда (около меня). Иц булмаса, шәм йағып йарытып (яктыртып) минең қашымда тора.

**ҚАШ V** *твр., тара.* **1.** жиң беләзеге (манжета рукавов). Олло гешләрңке йеңнәре тоуры ғына булған, қашлары булмаган. – *тара.*; **2.** ыштан бөрмәсе (сборки штанов). Ыштаннар оссон, палақлар тубыққа хәтле, қаш титләр, бау тыға тығын. – *тара.*

**ыштан қаш** *тара., твр.* к.: **қаш V, 2.** Ыштан қашларына әрисинкә шигелле ыштан бawы тығалар.

**ҚАША** *әстр.* койма (забор). Қамыш қаша.

**ҚАШАҒА I 1.** *минз., бөре., злт.* мич сыры (выступ на печи); **2.** *перм.* урындык арты (спинка стула). Сөйәлеб утыра торған бүкәннең қашағасына басты; **3.** *злт.* стенага, гадәттә казан тирәсендә, кашыклар кыстырып кую өчен кадакланган нәзек агач яки башка төрле жайланма (планка или какое-либо другое приспособление для хранения ложек, прибитое на стену); **4.** *тара., твр.* к.: **қазнақ 1**; **5.** *саз.я.* сәке йөзлеге (брус – деревянный упор у переднего края нар); **6.** *төм.* пәрдә, чыбылдык (штора, занавеска); **7.** *тбл.* кием әлү өчен стенадан стенага тоташтырылган колга (поперечный шест для одежды, протянутый от стены к стене).

**ишек қашаға** *тара.* к.: **қаш II: ишек қаш.**

**өй қашаға** *тара.* өй нигезе, эргә (фундамент).

**тәрәзә қашағасы** *мам.* тәрәзәгә элгән челтәр пәрдә (кружевные оконные занавеси). Тәрәзә қашағасы йәмсез, қаралған төсле булып тора, икенчене әләм.

**ҚАШАҒА II** *клм.* к.: **қаш II: тирәс қаш.**

**ҚАШАЙАҚ** *каз.ар.-крш., перм.* кашык-аяк, савыт-саба (кухонная посуда). Қашайақны киленнәре жуды, бәк уңған күренә. – *каз.ар.-крш.* Шапа торғанға қазаннары ашлы күгә була, қашайағы шул күгә утыра. – *перм.*

**ҚАШАЙУ** *себ.* акаю, усал карау (таращить глаза, зло смотреть). Қашақ күс, күсеңне қашайтма.

**ҚАШАҚ 1.** *туб.-ирт.д.* бер күзе сукыр кеше (одноглазый, кривой); **2.** *тбл., твр.* сукыр (слепой); **3.** *твр.* к.: **пысқыш.**

**қашақ лампы** *твр.* к.: **пысқыш.**

**қашақ пулу** *тбл.* ак төшү (появиться – о бельме на глазу). Қунақ (чәчәк) цыққанта қысылца, цыққанта да йыwыштырмайсың, йыwыштырсаң, қашақ пулаты, ақ күс пулаты, күрмәйте.

**ҚАШАҢ** *тбл., саз.я.* үжәт, кире (упрямый). Йараппи, қашаң шал бала. – *тбл.*

**ҚАШАП** [*гар.*] *минз.* юкә башмак (лыковый башмак).

**ҚАШАРУ 1.** *нрл.* ашыгу (торопиться). Қашарма, қашарма, тороп тор; **2.** *төм.* ачулану (сердиться, ругать, разбушеваться). Қашарып-қашарып паққан итем, йуқ, пулматы. Пицәсенә ғашарып сыуға батыб үлте; **3.** *тбл., саз.я.* киреләнү, карышу (упрямиться, упорствовать).

**ҚАШАУ** *әстр.* без (шило).

**ҚАШҚА** *брб.д.* **1.** пеләш башлы (лысый); **2.** пеләш (лысина).

**ҚАШҚАЙТЫП** *перм.* башны югары чөеп, тәкәббер кыяфәт белән (с высоко поднятой головой, горделиво). Чыбары тузбаш, озур, башын қашқайтып жөри.

**ҚАШҚАЙУ** *брб.д.* **1.** чәч агару (седеть); **2.** чәч коелу (лысеть).

**ҚАШҚАЙЫП** *перм.* башны югары күтәреп, тәкәбберләнеп (гордо, с гордым видом). Қашқайып йөри ул, мин кем дийеп, кешене күрми.

**ҚАШҚАЛАҚ 1.** *брб.д.* гагара; **2.** *себ.* кыргый үрдәкләрнең бер төре (один из видов диких уток).

**ҚАШҚАЛЫ** *брб.д.* к.: **қашқа 1.**

**ҚАШҚАРА: қашқара йышу** *туб.-ирт.д.* каш буяу (красить брови и ресницы). Әwәл саманта да ғыслар қашқара йышыплар, путра йышыплар. – *тбл.*

**ҚАШҚЫЛДАҚ** *әстр.* кыргый үрдәкнең бер төре (лысуха).

**ҚАШЛАҚ** *тара.* өлгереп житмәгән, пешеп житмәгән, яшел – жиләк турында (недозрелый, неспелый, зелёный – о ягодах). Нәнең цийәгә гитте, астыған (кура жиләге) қашлақ.

**ҚАШЛАМ** *клм.* калкулык, курган (возвышенность, курган). Қашламта қазыдылар (археологлар), бу тың бороңғо айыл.

**ҚАШЛЫҚ** *трх.* кашлак, калку урын (подъём, косогор).

**ҚАШМАҚ** *әстр.* качышлы уены (игра в прятки). Тәтәсе қаша икән, қашмақ уйный икән.

**ҚАШМАУ** *тпк.* бөтен чәчне, колакны каплап тора торган, алгы кырыена тоташ бөтен тәңкәләр тезелгән, башка жиренә бер рәт мәржән, бер рәт тәңкә тезелгән хатын-кыз баш киеме (старинный головной убор женщины: холщовая шапочка, покрывающая волосы, уши, шею, обшитая снаружи серебряными монетами и бисером).

**ҚАШПАШ** *төм.* ярбаш, яр буендагы калкулык (возвышенность у реки, высокий берег реки). Пүреләр қашпашта йаталар ите, йылғата тәwермән болған.

**ҚАШТАҚ** *клм.* к.: **қашлақ.** Йиләк әле қаштақ, қызармаған.

**ҚАШУWA** *перм.* к.: **қаршуwa**.

**ҚАШУЧЛАУ** *дөб.* к.: **қачушлау**.

**ҚАШЫЙАҚ** *мам.* к.: **қашайақ**. Қашыйақлар жуwасым бар, көтү дә қайтты. Қашыйақларны жуған суwыңны мал чиләгенә сал.

**ҚАШЫҚ 1.** *перм.* к.: **багырча.** Қашық белән аш созалар; **2.** *тпк.* агач тамырын юнып ясаган аш чүмече (половник, состроганный из корня дерева). Todло сыwны ағас қашықлар белән қайната торган ыйық, суwы бетә дә todo қала. Қашығ ул тамырдан эшләнгән балауник, бednең күршедә бар әле ул тамырдан эшләнгән ағас қашық; **3.** *мам.* суканың бакчаны әйләндерә торган тимере, калагы (отвал сохи). Суқаның тимере дә бар ийе, қашығы да бар ийе балчығын қайтарып сала торған.

**қашық ату** *тбл., твр., тара.* килен төшкәндә багана башына бәйләп куелган кашыкка мылтыктан атып тидерү ярышы (соревнование перед приездом невесты: попасть ружьём в ложку, привязанную к макушке высокого столба). Қашық аталар киленне китергәч тә, қашықны оссон цырғыйға бәйләгәннәр дә утыртып қуйғаннар. – *тбл.*

**қашық атышу** *твр.* к.: **қашық ату**. Күч килертән алтта ыстулбаға қашық қуйалар да қашық атышалар мылтық белән, кем тийә, аңа бүләк бирешәләр.

**қорт қашығы** *мам., трх.* сарган кортны җыя торган кашык (специальная ложка для сбора пчелиного роя).

**куштан қашық** *дөб.* аш бүлә торган зур агач кашык; татар кашыгы (большая деревянная ложка).

**пелмин қашық** *перм.* камыштан үрелгән чүмеч, пилмән сосу өчен кулланыла (плетёный дуршлаг для вычерпывания пельменей). Пелмин қашық қайда ни, пелмин сосарга.

**су қашығы** *перм.* к.: **дустыған 1**.

**татар қашығы** *лш.* кечкенә агач чүмеч (деревянный ковш небольшого размера).

**үрә қашық** *перм.* к.: **багырча**.

**ҚАШЫҚБАШ** *минз.* к.: **бакабалык**. Җылы суда қашықбашлар лепердәшә.

**ҚАШЫҚЛЫҚ** *блт., тпк.* к.: **қашаға I, 3**. Қашықларны жу да қашықлыкка қыстыр. – *к.т.* Қашық қашықлықта, пычақ қыстырмада минем. – *блт.* Қашықлықта қалақ бармы, аппир әле! – *тпк.*

**қашықлық үлән** *эчк.* абаганың бер төре (папоротник).

**ҚӘWӘРЕС** [*гар.* + *афф.* -ес<-сез] *саз.я.* ул-бусыз, әйбәт кенә, тыныч кына (благополучно, спокойно, хорошо). Қәwәрес уғып йөрит. Қәwәрес йәшәйтләр.

**ҚӘДӘ** *төм.*, **ҚӘДЕ** [*гар.*] *әстр.* хезмәт өчен, нинди дә булса эш яки йомыш өчен түләнә торган акча (деньги, даваемые за какую-либо услугу); чаг.: **кәтә**. Кийәү йулдашы ике җиңгәгә қәде биреп кереп китә торганыйы. – *әстр.* Мунца йақкан кешегә аның қәдәсе дип әйтәтләр, ақца салатлар. – *төм.*

**ҚӘДЕРСЕЗ** [*гар.* + *афф.* -сез] *перм.* бик, бик шәп (очень, очень сильно). Барғақныкы (*ав. ис.*) уңған инде қәдерсез дә бодайы.

**ҚӘДИМГЕ** [*гар.* + *афф.* -ге] *кргл.* хәйран, шактый (довольно, изрядно, достаточно). Бәрәңге тәмне икән қәдимге. Йылға буйларына қәдимге чығып қалды быдай.

**ҚӘДИМДӘГЕ** [*гар.* + *афф.* -дәге] *т.кам.-крш.* к.: **ғазимдәге**. Қәдимдәге дәфтәр бу.

**ҚӘЙЕМБИКӘ** *әстр., тпк.* **1.** к.: **қаймбикә**; **2.** иргә хатынының апасы (старшая сестра жены для мужа).

**ҚӘЙЕМБИКӘМ** *әстр.* иренең апасына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре мужа).

**ҚӘЙЕН** *перм.* к.: **биата(й)**. Қәйене усал да, қәйнәсе алай түгел.

**ҚӘЙЕНАҒА** *әстр.* каенага (старший брат жены для мужа, мужа для жены).

**ҚӘЙЕНӘ** *төм.* к.: **биана(й)**. Минең паламның (улымның) қәйенәсе гешене сақлайты.

**ҚӘЙЕНБИКӘ** *төм., тара., твр.* хатынга иренең апасы, иргә хатынының апасы (старшая сестра мужа для жены, жены для мужа). Қәйенбикә тийеш инте ул, Мәкүмә апа тийеп йөри итем. – *твр.*

**ҚӘЙЕНПИГӘ** *тара.* к.: **қаймбикә**.

**’ӘЙЕНСЕЛЕН** *кас.* к.: **қәйнесеңне**.

**ҚӘЙМИКӘ** *злт.* к.: **қаймбикә**. Қәймикә былғаннары сарығ әйтә киленгә.

**ҚӘЙМИҢКӘ** *перм.* к.: **бикәм**. Нихәл, қәймиңкә, тигән?

**ҚӘЙНӘ 1.** *злт., перм., эчк., тпк., туб.-ирт.д.* к.: **биана(й)**. Безнең қызның қәйнәсе дә алты бала өстәнә килде. Тәүге баласын тотқан қәйнәсе тора. – *злт.* Килен бәбәй китерми әле, ди қәйнәсе. – *тпк.* Килен төшкән җирдә қәйнә көтә мендәр белән. Қәйнәмнең қәйнәсен күтәреп җөртәп қарадық. – *перм.* Қәйнәм йаман усал булды. – *эчк.*; **2.** *злт., туб.-ирт.д., брб.д., том.д.* иргә – хатынының, хатынга иренең әнисе (свекровь; тёща). Қәйнәсе моның йоwаш, ағыллы геше ийән. – *төм.* Минең инәкәм сиңә қәйнә булаты тите пицәсе. Қәйнә, қуш килтең, килен, тиб әйткән, иң порноғо саманта (килен төшергәндә) ашамнық қаптырганны ишетеп қалған итем. – *тбл.* Қәйнә никах уғытқанта шәлйаулық йабады. Кийәү қәйнәсенә пүләк апкиләмә? – *твр.* Йитем үскән олы қәйнәмнең, әтәсе соғышта йугалты. Қәйнәмнеңке қысының қысы миңә балтыс. – *брб.д.*

**ҚӘЙНӘ-ҚАЙНЫ** *трбс.* каенана-каената (свекровь-свёкор). Қәйнә-қайның да бармы?

**ҚӘЙНӘМ** *тбл.* каенанага мөрәҗәгать итү сүзе (форма обращения к свекрови). Қәйнәм, мине awыл өстән алматылар, минең атинәм пар, тейтем.

**ҚӘЙНӘНӘ** *тара.* к.: **қәйнә 2**.

**ҚӘЙНӘСЕҢНЕ** *тпк.* к.: **қәйнесеңне**.

**ҚӘЙНЕ 1.** *каз.ар.-крш., минз., злт.* иренең энесе (младший брат мужа). Минең қәйнем мындағы бер уқытусыны йаратып йөрөде. – *злт.* Қәйнесенә дә, қәйнәсенә дә әйтмәгән. – *минз.*; **2.** *туб.-ирт.д.* каената (свёкор; тесть).

**ҚӘЙНЕГӘС** *злт.* к.: **қәйнигәч**. Қарсыкның апасы мийә қәйнегәс была.

**ҚӘЙНЕГӘЦ** *туб.-ирт.д.*, **ҚӘЙНЕГӘЧ** *твр., тара.* к.: **қәйембикә**. Қәйнегәц, йәш бикәц. Тун таба алмадым, тиде, Ник соңға қалтың, тигәц (*хал. жыр.*). – *тара.*

**ҚӘЙНЕ-ҚӘЙНИНӘ** *тара.* к.: **қәйнә-қайны**. Қәйнем-қәйнинәм пар ите, қайтып киттеләр сиксән йәшәргә йитеп.

**ҚӘЙНЕСЕҢНЕ** *тпк.* иренең сеңлесе (младшая сестра мужа).

**ҚӘЙНИГӘС** *злт.* к.: **каймбикә**.

**ҚӘЙНИГӘЧ** *трбс.* хатынының апасы (старшая сестра жены).

**ҚӘЙНИНӘ** *тара.* к.: **биана(й)**. Кәйнинәсе белән пергә торалмады.

**ҚӘЙТИСЕ** *әстр.* әнисе яки әтисенең олы ир туганы (старший родственник отца или матери).

**кәл** [*гар.*] *крш., себ.* хәл (положение; состояние):

**шушы қәлдә** *каз.ар.-крш.* к.: **қайкөн**. Шушы қәлдә Балтачның (*ав. ис.*) бер өйнә җәшен суққан.

**ҚӘЛӘМ** [*гар.*] **1.** *мам., злт., бөре., минз., нокр., глз., кмшл.* карандаш. Қәләмнең очо сынды. – *мам.* Қәләмне очлап бир. – *бөре.* Буйау қәләме йуқ бит, булса, матур булыр ийе. – *кмшл.* Қәләмнәрегезне алығыз, дисәң, карандашларын алалар, ручкаларын тығып. – *минз.*; **2.** *глз.* казның эре йоны, канаты (гусиное перо). Қанатын кисеб алабыз, қәләмен сызған кеше сыза, без йандырдық. Қәләм дибез, қоймақларны майлыйбыз, қанат белән эйдән себерәбез. Қәләм белән майлайбыз белемнәрне.

**ҚӘЛӘМПЕР** *тбл., саз.я.*, **ҚӘЛӘМФЕР** [*гар.*] *т. я.* канәфер (гвоздика). Теш сыслауга та йарашаты чын қәләмпер. – *т.я.*

**қәләмфер ағачы** *к.т.* к.: **албуй II: албуй саты 1**.

**ҚӘЛМӘРГӘН** *туб.-ирт.д.* акчарлак (чайка). Пер қош пар, исеме аныңқы қәлмәргән, қас сурлығында пар. Ала полыттан түмән йөрийте. Палық қайта йөрөсен, шанта пулаты қәлмәргән. – *саз.я.*

**ҚӘЛ'ПАҚ** *перм.* к.: **қалбақ 1**. Тупый кийәләр ийе, қәл'пақ та булды, көрәклесен қәл'пақ диләр ийе.

**ҚӘМЕР** [*гар.*] *саз.я.* кабер (моғила). Аңқы қәмерен күртех, йақшы торат.

**ҚӘММӘМЕР** [*фарс.?*]: **қәммәмер булып** *дөб.* интегеп, кыенлыклар күреп (испытывая трудности, перенося невзгоды); чаг.: **ғырғыра: ғырғыраға килү**. Суғыш вақытларында қәммәмер булып йөрдеғ инде силикат забутларында.

**ҚӘНӘ 1.** *мам., блт.* бит, бит инде (ведь, ведь же). Җир йөзө киң қәнә. – *блт.* Шунда ғына булдым қәнә, тапмыйм. – *мам.*; **2.** *тара., тбл., саз.я.* яле, кая (ну-ка). Қәнә, бер имәгесне ошлайын (тотыйм). – *төм.* Қәнә, көйләгеңне бағайын. – *тбл.* Қәнә, цәйгүнне қыстырайық, цай эцәйек. Қәнә, аңа йөреүце тә йуқ. – *тара.* Қәнә, килеф тор. Қәнә, цай уцыф йеwәр. Қәнә, кит йултан. – *саз.я.*

**ҚӘНӘКӘ** *тбл.* яле, кая (ну-ка). Қәнәкә, мин пағайын.

**ҚӘНБИКӘ** *төм.* к.: **қаймбикә**.

**ҚӘНИ** [*гар.*]: **қәни замандағылар** *нокр.* к.: **ғазимдәге**. Қәни замандағылар қалған аларда, йуқ нәрсә йуқ.

**ҚӘР** [*гар.*] *туб.-ирт.д.* хәрәм (запретный, несправедливый, незаслуженный, нечестно заработанный).

**ҚӘРӘЙЕШ** [*гар.*]: **қәрәйеш атлы җылан** *мам.* йокы алдыннан укый торган догадагы сүз – мифик җанвар исеме (слово, название мифического существа в составе молитвы, читаемой перед сном). Җатсам тыныч, җастығым кирпеч, қуйыным иман, динем ислам, қәрәйеш атлы җылаңға миндин сәләм, дип уқыйсың да уйанмыйчы да җоқлыйсың эрәхәтләнеп дип өйрәтәдер ийе әни мине.

**ҚӘРДӘШ** [*рус.* карандаш] *мам.* к.: **қәләм 1**. Безгә дә қәрдәш кирәк булыр йазыб утырырға сез сөйләшкәндә.

**ҚӘРЕ: қәре үртәх** *саз.я.* кара үрдәк (утка-чернец). Қәре үртәхнең йелткә йөнө қара, қорсах асты йөнө аппах wулат.

**ҚӘРЕМ** [*гар.*] *тбл.* к.: **қәреп II, 1, 2.**

**ҚӘРЕМЦӘН** [*гар.*] *туб.-ирт.д.* к.: **қәреп II, 2.**

**ҚӘРЕНДӘШ** [*рус.* карандаш] *мам., к.т.* к.: **қәләм 1**. Қәрендәшемнең очо сынды. – *к.т.*

**ҚӘРЕНДӘШ-ҚӘБИЛӘ** [*мат. + гар.*] *блт.* к.: **нәсел-асаб**. Безнең дә қәрендәш-қәбиләләр бар Малмыжда.

**ҚӘРЕП I** [*гар.*] *себ.* хәреф (буква). Аныңқы сүснең әрғайсы қәрбе йалғыш. – *төр.*

**ҚӘРЕП II** [*гар.*] **1.** *тбл., тара.* эндәшү сүзе (форма обращения). Йақшыман, қәрепләрем. Иптәш тимәйтеләр пестә, қәребем тиләр. – *тбл.*; **2.** *туб.-ирт.д.* мескен (бедняжка). Ой қәреп, аурып кейтепте. – *тара.*

**ҚӘРЕФ** [*гар.*] *саз.я.* к.: **қәреп II, 2**. Қәреф, қаты йәш ит.

**ҚӘРЕШ** *төм., тбл.* чөгә (стерлядь).

**ҚӘРТӘНИ** *минз., перм.* к.: **қартинә(й) 1, 2.**

**ҚӘРТӘТИ** *перм.* к.: **қартатай 1, 2.**

**ҚӘРТИНӘ** *брб.д.* **1.** к.: **қартинә(й) 1**; **2.** әбигә, әтисе яки әнисенең әнисенә эндәшү сүзе (форма обращения к бабушке). Қәртинә, тейте, кәртечкәгә төшәйек, тейте.

**ҚӘРТНӘ** *туб.-ирт.д., брб.д.* к.: **қартинә(й) 1**. Атабысныңқы инәсе пар ите, қәртнә. – *төм.* Миңа қәртнәм кәпләйте, тәтәмар бай булғаннар, тип. – *тбл.* Қәртнәсентә қунақ полып килтте ғуй. – *тара.* Песне әтийпесеңке инәйе – қәртнәпес өскөрдө. – *брб.д.*

**олу ғәртнә, тәү ғәртнә** *брб.д.* әбисенең әнисе (прабабушка). Олу ғәртнәләре тә терү, йышым пәйләйде әле. Килнебес Қассанның, қысыбысныңқы әнтә тәү ғәртнәсе бар.

**ҚӘРЫҖ** [*гар.*] *перм.* к.: **харыч**. Қарыж бетте. Қарыжыбыз булмады, битный булдық.

**ҚӘСИЛӘ** [*гар.*] *каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* к.: **путемар**. Қәсиләләр бawың көмөш синең, Саласыларың килмәс муйныңнан (*бор. жыр.*). Базарларға барып тәңкә алдым, Қәсиләгә түгел, түшлеккә; Қызығыз өчөн қурықмағыз, Қызыгызны тотарбыз, қодағый, кешлеккә (*туй жыр.*). – *каз.ар.-крш.* Қәсилә булған, дәwәт өстеннән арқылы була, қул җассурақ, арты буш, алды тәңкә, җылықжылықлары буладырыйы. – *т.кам.-крш.*

**ҚӘСИТӘ** [*гар.*] **1.** *минз.* к.: **путемар**; **2.** *глз.* тукыма кисәгенә тәңкәләр тезеп, бала алъяпкычы рәвешендә ясалган, муенга бау белән бәйләп күкрәккә киелә торган бизәнү әйбере, изүчә (старинное женское нагрудное украшение из монет, нашитых на материю). Қәситә алйапқыч күкрәге кебек, мун'ыға кийәләр иде. Қәситә менә бу фурмада, ал'апқыч күкрәге кебек, муйынға асып қу-

йалар иде, түлке қарчықлар ғына йөртә иде аны; **3.** *нрл.* таңкәләр яисә матур әйберләр тегеп ясалган һәм күз тимәсен өчен балалар күкрәгенә кыйгач киелә торган тасма (неширокая полоска ткани от сглаза, ушитая монетами или яркими и красивыми предметами и надеваемая на грудь ребёнка наискосок). Күз тимәсен дип, әлке малайларға тағалар ийе қәситәне; **4.** *нрл.* бишеккә мендәр астына куела торган догалык (письменные молитвы, которые кладутся под подушку в колыбель в качестве оберега от злых сил). Йазучы бабай бар, қәситәне йаздыртыб алып, малайның астына қуйған шул қәситәне.

**ҚӘСТӘР** [*гар.*] *каз.ар.-крш., нгб.-крш.* **1.** тәрбия, сый-хөрмәт; тәрбияле (уход, угощение; ухоженный). Бездә сийа қәстәр җитәр микән? – *нгб.-крш.*; **2.** к.: **хәсийәтле**. Тегендә ашарға бик қәстәр без. – *каз.ар.-крш.*

**ҚӘСТӘРЛӘҮ** [*гар.* + *афф.* -ләү] **1.** *каз.ар.-крш.* к.: **ардақлау 1**. Җаратмасаң җаратма, җаратсаң қәстәрлә (*әйтем*). Миңа қайа булса да җарар, қунақларны қәстәрләргә кирәк. Синең бу қәстәрләгәнне ничек түләрмен икән, дий; **2.** *нгб.-крш.* яхшылап, җиренә җиткереп эшләү (делать как следует, хорошо). Итне қәстәрләп тозламасаң, бозола.

**ҚӘТ** [*гар.*]: **қәткә йетү** *туб.-ирт.д.* балигъ булу, буйга җитү (достичь совершеннолетия). Қыс үсәте, қәткә йетәте. – *тбл.*

**ҚӘТWӘЛ, ҚӘТEWӘЛЕ** [*гар.*] *тара.* нәкъ шулай (точно так). Эшләгәне килеп цыққа, қәтewәле, тей.

**ҚӘТИП** [*гар.*] *тбл.* гадәт (привычка).

**ҚӘТИФӘ** [*гар.*] *каз.ар., бөре.* хәтфә (плюш, бархат). Қәтифә булайы қалфақ. – *дөб.* Қәтифә күлмәкләр кийеп җөргәннәр әwәл, хәзер дә кийәбез. – *мам.*

**қәтифә гөл** *лш., бөре.*, **қәтифә гөлө** *перм.* миңле гөл (бегония).

**ҚӘТЛЕМ** [*гар.* + *афф.* -лем] *туб.-ирт.д.*, **ҚӘТЛЕХ** [*гар.* + *афф.* -лек] *саз.я.* к.: **тике**. Тораға қәтлем йәйәү барайық. – *тбл.* Күлхә қәтлем игепес хенә йөрәбес. Awылтан күлхә қәтлех йул. – *саз.я.*

**ҚӘТМӘЛ 1.** *каз.ар.* бик тиз, бик тиз арада (вмиг, очень быстро, в сию минуту); чаг.: **дерен**. Қәтмәл генә җөгөрөп төштем мәйеткә чығышлый. – *дөб.* Қәтмәл кеше булған булса, үлмәгән булыр ыйы, қәтмәл генә алмаганнар шул. Қәтмәл күргәндә генә нәстә сөйләшәсең? – *лш.*; **2.** *мам., лш.* к.: **қапылтын**. Қәтмәл генә кирәк була, кешедә була (әйбер). – *лш.* Қәтмәл генә кирәк булса, қул астында ғына булса рәхәт була. – *мам.*

**ҚӘТТӘ** *тара.* к.: **қартатай 1**.

**ҚӘҢ** [*гар.*]: **қәң йаулых** *төм.* чалма (чалма, тюрбан).

**ҚӘЧТӘҮ** [*гар.* + *афф.* -тәү] *саз.я.* хаж (хадж, паломничество в Мекку). Пер саманны waласы weләң атасы қәчтәүхә китәтләр ийән.

**ҚИЙӘҒӘЗ** [*гар.*] *лш., к.т.* кәгазь (бумага). И, туқта, қийәгәз бирим әле. – *лш.*

**ҚИКӘЙӘ** [*гар.*] *төм.* шигырь (стихотворение).

**қима** *дөб.* койма (забор):

**йатма қима** *дөб.* такталары горизонталь кадаклап эшләнгән койма (забор, доски которого прибиты горизонтально).

**текмә қима** *дөб.* такталары вертикаль кадаклап эшләнгән койма (забор, доски которого прибиты вертикально). Хәзер йатма қиманы эшләмиләр, күбрәк текмә қима.

**ҚОАН: қоан нацағай, ҚОАҢ: қоаң нацағай** *тбл.* к.: **нажағай**. Қоаң нацағайның йамқыры пулмайты.

**ҚОБА 1.** *трх.* кара-кучкыл чия – төс турында (тёмно-коричневый). Қоба сыйыр; **2.** *тбл.* аксыл сары (светло-жёлтый – о животных). Қола қоба ат.

**қоба тал** *трх.* кызыл тал (краснотал).

**ҚОБАҒАЙ** *минз.* бизәксез, бертөсле (гладкий).

**ҚОБАҒУ** *тара.* гайбәтләргә ышанып, ярсып сөйләү (говорить страстно, основываясь на слухах).

**ҚОБЫЙ** *саз.я.* купшылык (щегольство, франтовство). Синең қобыйың артқан.

**ҚОБЫЙЛЫ** *төм.* купшы, көяз (щегольской, нарядный).

**ҚOWA** *саз.я.* к.: **қоба 2**.

**ҚOWAH 1.** *туб.-ирт.д.* эсселек, кызулык (зной); **2.** *тара.* к.: **нажағай**. Айаслық пулса, йалбақ қowan пула, йәшен тә пулмай, күкерт тә пулмай.

**қowan йәшен** *туб.-ирт.д.*, **қowan нацағай** *тара.* к.: **нажағай**. Нацағай йарғырап торуны қowan йәшен тейләр пестә. – *тбл.* Қowan йәшен йәшнәп тора, йаңғыр йаумай, қowan нацағай була. – *төм.* Қowan нацағай йаңғыр та пулмайты, қуғырт та пулмайты, йаңқыр ацылуға булар, тиләр аны. – *тара.*

**ҚOWЫЛ** *саз.я.* түмгәклек, кайчандыр сазламык булган урын (высохшее болото с кочками). Қуйлар қowылта йөрийтеләр.

**'OWЫТ** [*күк+ут*] *кас.* к.: **кугыт**.

**ҚOWЫХ** *саз.я.* куык (пузырь). Палых қowых.

**ҚOWЫШ** *саз.я.* кечкенә өй (маленький домик).

**ҚОҒУ** *том.д.* көю (пригореть).

**ҚОҒУС** *том.д.* арка (спина).

**ҚОДА 1.** *нокр., глз.* никахлашудан соң уздырылган мәҗлес (застолье после бракосочетания). Қодаға қартларны чақыралар, танышу була, никах туйы қода була. – *глз.*; **2.** *твр.* яучы (сват). Қода булып әбиләр килде, әби белән бабай ийе.

**кечкенә қода** *глз.* никах мәҗлесеннән соң (ул гадәттә қыз ягында була) егет ягында уздырыла торган кечкенә мәҗлес (небольшое застолье, проводимое на стороне жениха после совершения у девушки обряда бракосочетания).

**қода ашы** *тпк.* **1.** туйга кодалар алып килә торган күчтәнәчләр (гостинцы, привозимые сватами на свадьбу). Йете-сигед саналы туй булыр ийе, адақысынта қода ашы була; **2.** туйда кунакларны кодалар алып килгән күчтәнәчләр белән сыйлау мәҗлесе (отдельное угощение на свадьбе, во время которого угощают гостей гостинцами сватов). Тәү көннө никах була, икенсе көннө қода ашы була.

**қода башчы** *әстр.* туйда башкода, төп кода (главный сват, глава свадьбы – обычно отец же-

ниха или невесты). Қода башчыға зур табақ әкиләт, қоданың алдына табақты салат.

**қода бәлеше** *лш.* туй мәҗлесенең азагында чыгарыла торган бәлеш (пироги, подаваемые в конце свадебного пира). Қода бәлеше чыққастын, мәҗелес тарала башлый.

**қодаға чығу** *перм.* **1.** туй ясау; туйга бару (сыграть свадьбу; участвовать на свадьбе). Мөхәрәм қызы кийәүгә қачқан, исән булсақ, қодага чыгабыз икән; **2.** қыз ябышып чыккач, егет әнисенең қыз әнисенә бүләк белән күрешергә баруы (первый визит матери жениха с подарками к матери невесты, которая вышла замуж убёгом); чаг.: **божал: божалға бару**. Қыз әнисе дә бирнә әзерләп тора; бирнәсе күп булмый, қодаға чықмасалар.

**қода ипийе чығару** *каз.ар.-крш.* туй вакытында кода-кодагыйлар алып килгән күчтәнәчләрне өстәлгә чыгару (обычай, согласно которому на свадебный стол подаются гостинцы, привезённые сватами на свадьбу). Қода ипийе чыгарганчы, Аудыйға бистөр бирделәр, Миней Ычтипанына күлмәклек бирделәр.

**қода иш** *перм.* кодалар ягыннан белешләр, якыннар (близкие родителей одного из супругов по отношению к родственникам другого). Қазанда қода ишләребез бар.

**қода кертү** *перм.* туганыңа туйга килгән кодаларны кунакка алу (приглашение родственника к себе гостей, приехавших на свадьбу). Уникешәр ызба қунаққа җәрибез ий, қода кертәм ий, үтечкә алып булса да.

**қода көйләү** *каз.ар.-крш.* **1.** кыз ягында егетнең ата-аналарын, туганнарын кунак итү (угощение родителей и родственников жениха в доме невесты перед совершением обряда бракосочетания); **2.** качып кияүгә чыккан кызның әти-әнисе өенә егетнең якыннары килеп килешү ясау йоласы (обряд примирения между родителями жениха и невесты после её выхода замуж убёгом); чаг.: **божал: божалға бару**. – Қода көйләргә кемнәр бара? – дим. – Кемнәр булсын, йегетнең атасы да дәдәсе.

**қодалар күчтәнәче** *минз.* туйга егет ягыннан алып килгән ачы бал (медовый напиток, приносимый родителями жениха на свадьбу).

**қода сыйлау** **1.** *каз.ар.-крш.* туй көннәрендә туган-тумачаларның аш китерүе (обычай преподнесения родственниками гостинцев во время свадьбы). Туйда ике җақтан да була қода сыйлау, миңа килен килгәч, туганнар аш белән киләләр, қыз җақта да була, қода сыйлау шул була; **2.** *кргл., бгрс.* егет ягындагы туй мәҗлесе (свадебное угощение на стороне жениха). Қыз җагында туй була, җегет җағында қода сыйлау була, килен төшкәчтен, бер атнаданмы қода сыйлау була, қызның аталары да үзләренең туганнарын, теләгән дусишләрен алып килә. – *кргл.*

**төп қода** *мам., нгб.-крш.* туйда кияү яки киленнең әти-әниләре (родители жениха или невесты на свадьбе); чаг.: **қода башчы**. Төп қода апкилгән аш. – *мам.* Анда була төп қода парлы-парлы. – *нгб.-крш.*

**қодағый** *урт.д.* кодагый (сваха):

**қодағый әби сыйыры** *глз.* к.: **бийауса**.

**қодағый сый** *әстр.* туй алдыннан хатын-кызлар өчен көндез үткәрелә торган мәҗлес (угощение, проводимое перед свадебным застольем с участием только женщин).

**ҚОДА-ҚОДАСАЛАР, ҚОДАЛАР** *тпк.* к.: **қодалар-қодачалар**. Қода-қодасалар килә туйға. Йете-сигед саналы туй, һәрберсендә қодалар ирлехатынлы.

**ҚОДАЛАР-ҚОДАЧАЛАР** *мам., лш.* төп кодага иярең килгән туганнар (родственники, приехавшие на свадьбу с главными сватьями). Төп қода апкилгән ашқа ничә ат бара, барысы да қодалар-қодачалар була. – *лш.*

**ҚОДАЛАШУ** *перм.* туй ясау (сыграть свадьбу). Әле алар қодалашмаганнар иймени? Әңкәйләр қунаққа бардылар, қодалашып қайттылар.

**ҚОДАЛЫҚ** *әстр.* кодалар һәм якын кода-кодагыйлар катнашында уздырыла торган мәҗлес (застолье при участии главных сватов и самых близких родственников).

**ҚОДАСА, ҚОДАСАЛАР** *тпк.* к.: **қодалар-қодачалар**. Қодаса булып йөргәләдем.

**ҚОДАЧА(ЛАР)** *мам., лш., каз.ар.-крш.* кызны кияү йортына озата баручы кыз(лар) (девушка или девушки, сопровождающие невесту в дом жениха). Тырантасқа ике қодача утыра. Сондоғын ачып, килен өй кийендерә қодачалар белән. – *лш.* Қодача булып күрше қызы барған ийе. Кийәү җағыннан ничә җегет барса, қодачалар да шуның хәтле була, тақ йарамый. – *мам.*

**ҚОДАЧАЛЫЙ** *т.кам.-крш.* кодача булып (в качестве молодой свахи). Қодачалый бардым Сәвәләйдән Сәрәпәлегә (*ав. ис.*).

**ҚОДАШ** *перм.* белмәү, хәбәрдар булмау (оказавшийся не в курсе дела, незнающий). Нийә, мин қодаш, ишетмәгән. Шәрифәнең туйы булган, әллә син қодашмы?

**ҚОДОҚ** **1.** *перм., к.-уф.* к.: **вәке**. Қодоқ уйасын да шунда чайқыйсын. – *перм.*; **2.** *кргл., әстр.* кое (колодец). Бер қодоқлары йанына барып йал итеп қайтасы килә. – *кргл.* Суны қодоқтан эчкәннәр. – *әстр.*

**ҚОДОРАЙУ** *каз.ар.-крш.* кыюлану, батыраю (осмеливаться, отваживаться). Ул килә башлағач, мин дә қодорайдым.

**ҚОЖОРАЙУ** *злт.* к.: **көжөрәйү**. Ашарға керсәк тә, қожорайышып қына тора торған ыйық.

**ҚОЖҒОТУ** *нрл.* к.: **ирәгештерү**.Ниг аны (баланы) қожғоттың син?

**'ОЗ** *кас.* кыз (девочка, девушка).

**'озлар җийын** *кас.* иртәгә китәсе кыз ягында яшьләр белән уздырыла торган күңел ачу кичәсе (молодёжная вечеринка, устраиваемая за день до отъезда невесты). 'эндез бал ашау, 'ис 'озлар җийын була иде.

**'оз җинисе** *кас.* кыз җиңгәсе (близкая родственница, обычно жена старшего брата или тётя жениха, присматривающая за молодыми в первое время). 'оз җинисе алып бара 'ознын әйберләрен.

**'оз мунчасы** *кас.* иртәгә никах дигән көнне ягылган мунча (обряд топить баню накануне бракосочетания девушки).

**ҚОЗАУ, ҚОДАУ** [*рус.* кузов] *бәр.* тегермәннең

ашлық сала торган авызы, мөшкә (насыпь мельничная). Тегермәннең ашлық сала торған җире була ич, менә шунсы қоday була. Қозау қуйалар алты җиргә. Бер қозawына бер тунны керә.

**қозғон** *урт.д.* козгын (ворон, хищник):

**қозғон қузағы** *мам.* торна борчагы (сочевичник).

**ҚОЗОҚ I** *перм., к.-уф.* к.: **вәке**. Йылгага берничә қозоқ тиштек. – *перм.* Қозоқны киң итеп, су алырга җайлитеп уйган. – *к.-уф.*

**ҚОЗОҚ II** *том.д., брб.д.* к.: **қосоқ 1**. Қозоқ қойалар иде киленнеңке башынан. – *яушт.*

**ҚОЗУ** *твр.* өзеп, йолкып алу – чикләвек турында (сорвать, оторвать – орехи).

**ҚОЗЫЧАҚ** *том.д.* к.: **бикәч II**.

**ҚОЙ I 1.** *т. я., перм.* к.: **қодоқ 2**. Чиләгем қойга төште. – *к.т.* Қой су да җарый терлекләргә. – *нрл.* Аныга бидрәләп қой су қойалар икә. – *перм.*; **2.** *эчк.* к.: **вәке**. Қыш көне йылгада қой йасыйлар.

**ҚОЙ II** *брб.д., том.д.* сарык (овца). Қойлары-быс кән, ит полар. Қойны күп бақтым. – *брб.д.* Қойлары қанча? Қойларың тоудыларба, қочқорба, тешебә (тәкәме, саулыкмы)? Эжеге ачық, анта қойлар торото. – *клм.*

**қой қору** *клм.* сарык йоны алу (стричь овцу). Қайчы қой қоро тоғон.

**ҚОЙ III** *клм.* к.: **қый I**. Қоноқтордо (кунакларны) гөрбөгөн қой.

**ҚОЙ IV** *том.д.*, **'ОЙ** *кас.* к.: **hawyз**. Қойны кән салабыс қуй, пакцалар йакшы. – *яушт.*

**ҚОЙ**: **қой йелеге** *том.д.* каен җиләге (земляника).

**ҚОЙАН** *тара.* буыннарга утыра торган тоз (соли, отложившиеся в суставах). Цыганакка да утыра қойан, иңпашларга та утырады.

**ҚОЙАС** *тбл.* биштәр (котомка, заплечный мешок). Арғаға қойас йөкләп йөрибес.

**койаш** *урт.д.* кояш (солнце):

**койаш апай** *кргл.* к.: **бийауса**.

**қойаш йақ** *брб.д.* көнчыгыш (восток).

**қойаш қорт** *перм.* к.: **бийауса**.

**қойаш орлоғо** *к.т., блт., тара.* к.: **айбағар**. Қойаш орлоғо қойашқа боролып йөри. – *к.т.*

**қойаш питендә** *тпк.* кояш кызуында, кояш астында (под солнцем, под солнечным светом). Кинтерне ағартыр ийек қойаш питендә.

**ҚОЙАШЛАУ** *тара., брб.д.* аязу (проясняться – о погоде).

**ҚОЙАШЫМБАҚ** *к.-уф.* к.: **бийауса**.

**ҚОЙҒАЛАУ** *брб.д.* куыру, кыздыру (жарить).

**ҚОЙҒАШ** *брб.д.* адаш (тёзка). Қойғаш инте икәу, аташ полтық.

**ҚОЙҒОН** *тбл.* **1.** агым (течение). Қойғон уйнайты; **2.** култык, бугаз (залив, пролив).

**ҚОЙҒОРОШ** *минз.* кыланчык (кокетливый, жеманный). Шулхәдәр қойғорош инде.

**ҚОЙҒОРОШЛАНУ** *минз.* кылану (кокетничать, кривляться). Эй қойғорошланған була дибез, awыdларын бөрөп-madap итеп, қашлар сикертеп сөйләшсә.

**ҚОЙЛОҒУ** *төм.* агып төшү – елга турында (стекать – о реке, речке).

**ҚОЙЛОҚМА** *төм.* **1.** су агып төшә торган юл (сток); **2.** түбә кыегы (скат крыши).

**ҚОЙЛОШ** *перм.* к.: **қаудан 5**.

**ҚОЙМАҚ** *нокр.* ачы камырдан май эчендә пешерелгән кабартма (пышки из кислого теста, жаренные в масле); чаг.: **йуwача 1**.

**қазан қоймақ** *нокр.* к.: **қоймақ**.

**таба қоймақ** *нокр.* табада пешкән коймак (оладьи, блины).

**тәбә қоймақ** *брб.д.* кияү коймагы, беренче мунчадан соң яшь кияү белән киленгә махсус пешерелгән коймак (блины, специально испечённые для молодых к приходу их из бани после первой брачной ночи). Кийәү мән кәләшне мунца цыққаннан соң тәбә қоймақ пелен цай эчерә, кийәүгә бешерелә ул.

**ҚОЙМАЛАҚ** *әстр.* бидон (бидон для молока).

**ҚОЙМЫЛУ** *брб.д.* **1.** шат күңелле (весёлый); **2.** кәпрәйгән, эре – кеше турында (заносчивый, важничающий).

**ҚОЙМЫРУ** *брб.д.* шат күңелле булу, кеше сүзенә килешү (быть весёлым, соглашающимся, давать себя уговорить).

**ҚОЙО 1.** *злт., туб.-урт.д., том.д.* к.: **вәке**. Бозно сабабыз да қойо әшләп асабыз. Қойо уйылгаммы, сыwы бармы? – *злт.* Қойо ацабыс қышқыта. – *төм.* Бәрәнне су эчерергә қойоға төшөрә алмайбыс, бататы. – *твр.* Қышқыта қойо тишәләр. Пер йылны қойоно тишеп соу ташыған идек. – *клм.*; **2.** *минз., тпк.* к.: **кизләү 1**. Бигawай дигән қойо бар анда, сырттан ағып төшөб утыра. Керне қойода чайқыйбыз, таудан улаққа ағып төшә, өстәрәк эчәбез, астарақ чайқыйбыз. – *минз.* Қойо урғылып әйләнеп сығып йата таш астыннан. Менә унда қойоға төшәбеd суға. – *тпк.*; **3.** *перм.* кайнап чыга торган чишмә (кипучий родник, кипень). Қойо чыға тау аста. Ул қойоның сыwы чыга да таралып китә қый сазлыққа.

**җар қойосы** *минз.* елга яры астындагы артык тирән булмаган кое (неглубокий колодец, вырытый под яром, на берегу реки).

**қойо башы** *минз.* чишмә, чишмә башы (исток родника, ключ, родник). Қойо башына төштә дә шунда су эчеп менде.

**қойо тишек** *төм.* к.: **вәке**. Қышқысын бос қата қуй, қойо тишек ацабыс.

**'ОЙО'** *кас.* к.: **көйөк I**. 'ойо' 'аз.

**ҚОЙОЛОҚ** *минз.* суда бөтерелеп, кайнап ага торган урын (водоворот); чаг.: **қазан**.

**қойолу** *урт.д.* коелу (сыпаться, осыпаться, падать, пасть):

**эч қойолу** *лш.* эч төшү (опущение внутренних органов). Атта haман сикереп-сикереп йөрөп, эчләре қойолоп үлде.

**ҚОЙОН I 1.** *туб-урт.д.* өермә, көчле җил (вихрь, смерч, буря). Полот цыққан қойон шигелле. Қойон түгәрәк әйләнеп йөри, пөтөн пецәнемне фис таратып китте. – *төм.* Китеп парышта йел суққан, қойонға суғылган, оцороп алып китеп қалған, алабатанға йәбешеп қалған, утау үләнгә. – *тбл.*; **2.** *тара.* коеп яуган яңгыр (проливной дождь, ливень).

**қойон йел** *сазл.* к.: **қойон I, 1**.

**ҚОЙОН II** *клм.* к.: **вәке**. Қышқыта қойон тишәделәр. Бер йылны қойон тишеп сау ташыған идек.

**'ОЙОП-ТҮ'ЕП** *кас.* чәчми-түкми (в подробностях, не пропуская ни слова). 'ойоп-түеп сүлир ийем, белсим.

**ҚОЙОРЫҚ** *минз.* каралтылар артындагы бәрәңге бакчасының арғы башы (дальний конец огорода, расположенного за усадьбой). Йырақ түгел, қойорықта ғына йөри қадларыбыд.

**'ОЙОРЫШ** *кас.* ләтчә (ласка).

**ҚОЙРОҚ 1.** *трх., злт., трбс.* каралтылар артындагы бәрәңге бакчасы (огород, расположенный за усадьбой). Әтәйләр қойроғыннан алып қайтқан қазларны. – *трбс.* Аның қойроғы су буйына төшә. – *трх.* Анаwыл өй ташландық өй, қойроғы урманға чыққан. – *злт.*; **2.** *минз., злт.* к.: **қойорық.** Минең малай қойроқта утын кисә. – *злт.*

**бақча қойроғы** *трх.* к.: **қойорық.** Саралар бақча қойроғында тирмән булған. Безнең бақча қойроғында буwа булған, ат җөздөргәннәр.

**икке ғойроқ** *төм.* к.: **қайчығойрық.**

**сыйыр қойроқ** *твр.* к.: **айуқузғалақ.**

**ҚОЙОШҚАН** *брб.д., тбл., тара.* шлея (шлея – часть упряжи).

**ҚОЙТО** *әстр., т.я., каз.ар.-крш., перм., эчк., себ.*, **ҚОЙТЫ** *себ.* начар, әйбәт түгел (плохой, дрянной). Эшләре қойто улардың. – *әстр.* Қойто ғына әрлим шунда. – *каз.ар.-крш.* Қойто йердә дә кәртүг үстерә. – *перм.* Бийыл печән қойто, элек шал җирдән бер шүшилә тутырған. – *нрл.* Мин бик қойто йырлайым. – *эчк.* Ишекне қойто эшләп, йабылмый. – *тбл.* Қойто өйләр пөттө. – *твр.* Қойто ағац қына утысқан өй төбөнә. – *тара.* Минән тә қойто йәшәпсең ләсә. – *брб.д.* Мийецне қойты салып қуйған, йарамайты аш пешергәле. – *төм.*

**ҚОЙУ I 1.** *блт., минз.* салу, кору, төзү (строить, ставить). Хан керипос қойған. – *блт.* Хәзер қатын кеше дә қала қойа. – *минз.*; **2.** *лш., мам., минз., перм., тпк.* кую (ставить). Әwәл кибән қойалар ийе бақча йанындағы ындырға. – *мам.* Боғол қойалар. – *лш.* Күбәне чөмәләгә қойалар. – *перм.* Көлтә кибәне қойа идек үгез белә. – *тпк.*

**қойма қойу** *минз., т.я.* койма тоту, койма ясау (сделать забор, огородить забором). Нинди қоймалар қойған, әйеме?! – *минз.*

**никах қойу** *әстр.* никах уку (совершать обряд бракосочетания по мусульманским обрядам). Алар никах қойдырдылар.

**ҚОЙУ II 1.** *әстр., себ.* салу, агызу, бүлү (наливать, разливать). Қуйы қойдом чәйне, сән йаратасыңба? – *клм.*; **2.** *себ.* су сибү (поливать). Син қойма, үзем қойармын, ти, үзе аман йоқ. – *клм.*; **3.** *к.т.* пешерү (печь). Төчө қоймақ қойам мин аларға; **4.** *перм.* әчетү, кую (ставить киснуть – напиток, брагу). Бер бидрә бал қойдоқ. Теләсә қайчан қойоп эчәләр куwасны.

**аш қойу** *әстр.* аш бүлү (разливать суп). Аш қоймадық та.

**қоймақ қойу** *лш., к.т., перм.* коймак пешерү (печь блины). Кийәүгә қоймақ қойалар, мунча җағып чабындыралар. – *лш.* Қоймақ қойоп йебәрәйем иртән тороп. – *перм.*

**су қойу** *перм., себ.* су сибү (поливать). Барабыз ий, кәбестәгә су қойалар. – *перм.* Йәшелчәләргә су қойдым. – *яүшт.* Гырадаға су қойаты. – *клм.*

**тәбә қойу** *бәр.* йомырка тәбәсе пешерү (сварить яичницу). Бер күкәйдән тәбә қойам, диб әйтеп қайтып китәдер ийе.

**цай қойу** *себ.*, **чай қойу** *твр.*, **чәй қойу** *әстр., перм.* чәй ясау, чәй агызу (налить чай). Қуйы қойма чайны. – *твр.* Чәй қой қызларға, чәй қой әле син. – *перм.*

**ҚОЙУ** *брб.д.* куе (густой).

**'ОЙУ: никак 'ойу** *кас.* к.: **қойу I: никах қойу.**

**ҚОЙЦЫ** *брб.д.* сарык көтүчесе (пастух, который пасёт овец).

**ҚОЙЫҚ** *тбл.* икмәк катысы (корка хлеба).

**ҚОЙЫҚ** *тбл.* ишкәк (весло).

**ҚОЙЫЛУ** *сазл.* егылу (упасть, падать). Киртәне wақлар қойылмасқа йасағаннар.

**ҚОЙЫМЛАШУ** *твр.* кунаклашу, бер табында утыру (ходить друг к другу в гости, сидеть за одним столом). Алар ман кем қойымлашқан? Қанлар мына, биләрмән қойымлашқан мырзамын.

**ҚОЙЫН** *брб.д.* куен (пазуха, объятия).

**қойынға салу** *брб.д.* кыз куенына керү (провести первую брачную ночь). Иң элек қысны алалар, қойынға салу тителәр аны, китереп қуйалар оурынға, айырым пер йорт, анан кийәүне алып киләләр.

**ҚОЙЫН** *брб.д.* к.: **қый I.**

**ҚӨҚ** *брб.д.* көл (зола).

**ҚӨҚТЫ** *тбл.* кошлар оялый торган агач куышы (дупло, где птицы вьют гнёзда).

**ҚӨҚУЛ** *брб.д.* көлү (смех).

**ҚӨҚУЛДАУ** *брб.д.* **1.** йөткерү (кашлять); **2.** эч катып көлү (смеяться, хохотать).

**ҚОҚЫ** *туб.-ирт.д.* селәүсен (рысь).

**ҚОЛ** *клм.* кул (рука). Қолын йоwаты.

**ҚОЛАҒАЛҚА** *трх.* алка (серьги). Алтын қолагалқа қолақларында.

**ҚОЛА-ҖАЛАН** *нгб.-крш.* к.: **қолан-җалан.** Аларның ишагалды қола-җалан. Өйләре қола-җалан, бернәстә жуқ.

**ҚОЛАҖЫН** *бөре.* ике тапкыр бозаулаган сыер (корова на третьем году).

**ҚОЛА-ЙАЛАН** *минз.* урмансыз тигез җир (ровная местность без леса).

**ҚОЛАЙУ** *блт.* начарлану, бозылу (стать плохим, испортиться). Йуллар қолайған инде.

**ҚОЛАҚ I** *мам.* тел – шәлдә, кашагада, пәрдә читендә h.б. (язычки, зубчатые края – у пухового платка, занавески и т.д.). Жорт алдылар, фәрдәсен қолақлаб эшләделәр. Өлөңгене үзем теккән ийем қолақлап. Шәлнең зуры була, кечкенәсе була, аның қолағы да төрлө зурлықта була.

**қолақ II** *урт.д.* колак (ухо):

**йыраққы қолақ** *перм.* озын колак (молва, слухи). Йыраққы қолақ белән генә ишеттем ий.

**қазан қолақ** *бөре.* кәҗәсакал (козлобородник).

**қолағы йуқ** *тбл.* чукрак (глухой). Инәм қаты эшмәгәр ите, утала ите, қәйнәм саңқыр, қолағы йуғ ите.

**қолақ awыр булу** *глз.* к.: **бәгәйү.** Қолақ awыр булды минең, эшетмәй.

**қолақ артына қуйып** *минз.* колак та салмыйча (не прислушиваясь). Әйтәсең, ул синең әйткәнне қолақ артына қуйып жөри.

**қолақ асу** *баст., дөб.* колак салу (слушать, прислушиваться). Без аларға қолақ та асмыйбыз, килгән кешеләр қолақ асалар. Қолағыңа асма да. – *баст.* Сийләсәләр дә қолақ асма, тыллама да, дигән. – *дөб.*

**қолақ эңкәсе** *т.я.* эчке колак (внутреннее ухо).

**қолақ бәбәнәге** *минз.* колак ите, колак йомшагы (мочка уха). Қолақ бәбәнәге қызарған.

**қолақ қабарчы** *глз.* к.: **қатый**.

**қолақ қату** *перм.* к.: **бәгәйү**. Қолақ қатты қартайғач, ишетмибез икебез дә.

**қолақ мендәре** *минз.*, **қолақ ментәре** *тпк.* к.: **йастық I**. Ике қолақ мендәре бирдем, йастық, йурған бирдем. – *минз.* Йастыгың, қолақ ментәрең пармы, алып парып сатасың парсын та. – *тпк.*

**қолақ сағыр** *тара.* к.: **қолақай**.

**қолақ сөйөнече** *нрл., блт.*, **қолақ сөйөнчесе** *т.я., каз.ар.* ризалык билгесе (подарки, даримые родителями невесты в знак согласия выдать девушку замуж). Қолақ сөйөнчесенә жаулыкмы анда бирәләр, сүләшәләр туй буласын. – *к.т.* Йаучы белә килешәме, йуқмы, килешсә, қолақ сөйөнчесе алып килә, эшләгән чолғawын бирә, иренә йабарға алжапқыч. – *мам.* Қолақ сөйөнчесе алышқанчы чығып киттем икенчегә. – *блт.* Қолақ сөйөнече алышырға қыз әйбер бирәп жибәрә, тастымалмы шунда. – *дөб.* Қолақ сөйөнече бирәләр қызны килешкәч шулый. – *нрл.*

**қолақ сөйөнче қотлату** *лш.* ризалык билгесен котлату (поздравление с полученным согласием со стороны невесты). Қолақ сөйөнче қотлата сандығын қуйып идән уртасына.

**қолақ тәңкәсе** *бәр.* туй чығымнары өчен егет яғыннан кызның ата-анасына бирелә торган акча (деньги, даваемые родителям невесты со стороны жениха на свадебные расходы, денежная часть выкупа за невесту). Қолақ тәңкәсе күпме бирде диләр, акча ғына була, қортлап бүләк бирә бийеме.

**қолақ тиштерү** *к.т.* балалар гел үлеп торса, чираттагы баланың, кыз булса да, малай булса да, колағына алка тагу (продевать в мочку уха младенца – мальчика или девочки – серёжку для того, чтобы перестали умирать дети). Малайлар үлсә, тормаса, қолағын тиштерәләр ийе дә қолағалқа кийереп қуйалар ийе, үзе төшөп қалғанчы йөри, шуннан малайлар үлми, ир малай булса да, қыз малай булса да тиштерәләр.

**қолақ төшөрү** *минз.* колагына салу, әйтү (сказать, дать знать). Аңа қолақ төшөрсәң, керер ул.

**қолақ цөй** *брб.д.* к.: **чака 1**.

**қолақ чәйнәшү** *твр.* к.: **дустыган: дустыган эчү**. Қолақ чәйнәшү булған, белмән, қушылғаннармы, қушылмағаннармы, ишкәнем йуқ.

**қолақ чигә** *перм.* колак арты (за ухо). Қолақ чигәгә жибәрде инде, күздән утлар күренде. Қолақ чигәсе киселгән. Қолақ чигәгә утырды қызартқы.

**қолақ чийенчесе** *мам.* к.: **қолақ сөйөнече**. Қызны ыризалаштылар, қолақ чийенчесенә ике сөлгөмө, өч сөлгөмө төйнәп, ашawлық төйнәп, қыз жағыннан кийәwгә апқайтып бирделәр.

**қолақ элпәсе** *бөре.* колак пәрдәсе (барабанная перепонка). Қолақ элпәсе йарылған, әпирәтсә жасай алмайбыз, дигәннәр.

**қолаққа төшү** *тбл.* колакка чалыну (слышать у кого-то, слышать где-то). Қолаққа төшөп қала, айақ кийеменнән тә, баш кийеменнән тә бирә, бийә тә бирәт кийәү йақ.

**татар қолағы** *т.кам.-крш.* к.: **шөшпәрә**.

**ҚОЛАҚ III** *т.кам.-крш.* к.: **бештерә**. Чабатаның қолақлары өзөлөп чыққан ыйы. Ботинкалары бар ийе жырақ тутайның, қолақлы.

**ҚОЛАҚА** *тбл.* к.: **кендекәй**. Моның қолақа биршал, әүwәл қортқайақ пулған.

**ҚОЛАҚАЙ** *нокр., глз., минз., бөре., перм., тпк., злт., к.-уф., себ.*, **ҚОЛАҚБАЙ** *бөре.* чукрак (глухой). Қарчық қолақай, қолағы эшетми. – *глз.* Қолақай, ишетмәйсеңме әллә? – *злт.* Қолақай ул, қычқырып әйт. – *бөре.* Қолақай ул, аны сүләштерсәң, ызба селкенер. Ул сүләшә, хатыны ғына қолақай. – *перм.* Орошқанта қолақай тип әйтеләте. – *төм.*

**ҚОЛАҚҚА** *тбл.* колаклы бүрек (ушанка, малахай). Қолаққасын кийсен Моратның.

**ҚОЛАҚҚАЙ** *твр.* к.: **қолақай**. Минең колаг ишетмәс, қолаққай.

**ҚОЛАҚЛАУ** *мам.* тәрәзә пәрдәсенең яки *қашаг*аның читенә тел ясау (делать язычки по краям занавеса вдоль стены или у оконных занавесок). Жорт алдылар, фәрдәсен қолақлаб эшләделәр. Өлөңгене үзем теккән ийем қолақлап.

**ҚОЛАҚЛЫ** *эчк.* к.: **корак**. Ул сезнең қолақлы.

**ҚОЛАҚПАУ** *төм.* камыт бавы (гуж).

**ҚОЛАҚСА I** *нрл.* к.: **қолағалқа**.

**қолақса пүрәнәсе** *тпк.* буранның кәрниз салыр өчен почмактан башын чыгарыбрак калдырып салынган соңгы бүрәнәсе (последний ряд брёвен сруба, на выступающие концы которых строится карниз). Қолақса пүрәнәсе мөйөштән артып сығып тора, аңа кәрниз салалар.

**қоро қолақса** *каз.ар., минз., злт.* өй бурасында түшәмнән югары салына торган бүрәнә рәте (верхний ряд брёвен сруба, сделанный выше потолка). Қолақса бүрәнәсе салалар түшәм жәйеп бетергәч, қоро қолақса инде әнә шул. – *минз.* Қоро қолақса матчаларны бастырып тора. – *бәр.* Қоро қолақса йаңыны салдырдық. – *злт.*

**ҚОЛАҚСА II** *минз.* к.: **бештерә**.

**ҚОЛАҚСЫЗ** *нрл., себ.*, **ҚОЛАҚСЫС** *себ.* к.: **қолақай**. Теге қолақсыз, ишетми ул, шуңа әйтәләр. – *нрл.* Пер қолақсыз абушқа бар. – *тбл.* Пабайы қолақсыс, эшетмәйте. – *төм.*

**ҚОЛАҚЧА I** *лш.* к.: **бештерә**.

**ҚОЛАҚЧА II** *дөб.* к.: **қолақса I: қоро қолақса**.

**қоро қолақча** *бәр.* к.: **қолақса I: қоро қолақса**.

**ҚОЛАҚЧЫН 1.** *дөб.* к.: **бештерә**. Киндерәне қолақчынына тығып қуйасың да кийенәсең; **2.** *т.кам.-крш.* колак – бүректә (уши – у шапки). Тун бүрек турыға ғына, қолақчыны да йуғыйы.

**ҚОЛАҚША** *төм., тара., тбл.* **1.** колаклы бүрек (ушанка, малахай); **2.** колакчын (уши – у шапки). Тақыйаның қолақшасын төшереп кей. – *тбл.* Пес тақыйа тимәгән, пес пүрек тигән, йөннөш қуй тиретән тектерәтләр, қолақшасы булған, байлап қуйатлар. – *төм.*

**ҚОЛАҚШАЛАУ** *төм.* колак кую – бүрек теккәндә (пришивать уши – при шитье шапки). Қолақшалап теккәннәр пүрекләрне.

**ҚОЛАҚШАЛЫ** *туб.-ирт.д.* колаклы (с ушами, ушанка).

**ҚОЛАН** *тбл.* кыргый ат (дикая лошадь).

**ҚОЛАН-ҖАЛАН** *нгб.-крш.* бик зур, иркен, бупбуш (очень большой; свободный, совсем свободный); чаг.: **алаңгыр: алаңгыр хәтле**. Қоланҗалан аларның бакчалары.

**ҚОЛАНЫҚ** [*рус.* колонок – зверёк из рода хорьков] *трбс.* көзән (хорёк). Қоланық, килеп, тawықларны бywып китте.

**ҚӨЛАҢЗА** *брб.д.* начар ис (плохой запах, вонь).

**ҚОЛАТЫ** *брб.д.* **1.** к.: **қағау**. Қолаты тawық паланы алып китте; **2.** бөркет (орёл).

**ҚОЛАУ I** *перм.* чиләк тоткасы (дужка ведра); чаг.: **боғо**. Ике бидрәнең қолawын бикләп қуйасың йозак белә.

**ҚОЛАУ II 1.** *тбл.* үрелү (тянуться). Пала миңә қолайты; **2.** *тара., брб.д.* аву (падать). Әй, арбаң қолап параты, қәсер ақтарылып төшәте инте. – *тара.*

**ҚОЛАЦ 1.** *төм., тара.* сажин (сажень). Қышқысын йағатыған утыннар әсерләйтеләр йегермәутыс қолац. – *төм.*; **2.** *саз.я.* әрдәнә (поленница, швырок). Утынны қолацларға қысawс. Икке қолац утын кистех.

**қолац утын** *тара., твр.* ягарга яраклы итеп турап-ярылган утын (дрова, готовые к применению). Элек қолац утын тиләрте, пер митыр буйы. – *тара.*

**ҚОЛАЧ** *перм.* **1.** утын үлчәү берәмлеге: 2,5 м$^3$ га туры килә (единица меры дров, равная 2,5 м$^3$); **2.** утын үлчәү берәмлеге: 4 м$^3$ (единица меры дров, равная 4 м$^3$).

**бер генә қолачлы** *т.кам.-крш.* кечкенә (маленький). Безнең өйөбез бер генә қолачлы, сыймағач, жоқларға мунча жагадыр ыйық.

**ҚОЛАША 1.** *т.я., каз.ар., минз., бәр.* агачтан чокып ясалган тар һәм сай улак (узкий и неглубокий жёлоб, желобок). Сыра чүлмәкләрен қолаша өстенә тезеп қуйасың да, сосла шуннан ғына аға. – *к.т.*; **2.** *мам., минз., трх.* к.: **тәбүт 1**; **3.** *бәр.* зур он тагарагы, зур жилпуч (лоток больших размеров). Қолашасы дәү, жилпуwычы кечерәк; **4.** *кмшл.* к.: **йулпуч**. Қолашаны келәттә генә қалдыр.

**ҚОЛАШЫ** *дөб.* к.: **қолаша 1**. Чүлмәк қуйалар, мичтә қундыралар, аны қолашыға утыртып ағызалар.

**ҚОЛБАУ** *эчк.* к.: **гылбу 1**; чаг.: **буйынса**. Муйынына қолбау таққан.

**ҚОЛ'БОРАҢ** *тара.* алсу (розоватый).

**ҚОЛҒА 1.** *бөре.* кое сиртмәсе (журавль у колодца); **2.** *перм., злт.* к.: **кабатеп**. Қәйнәмнән қалған қолга. – *злт.*

**тawық қолғасы** *мам.* кунача (насест). Тишекле ташларны тawық қолғаларына алып менеп асалар тawықлар чирләмәсенгә.

**ҚОЛҒАЛАНУ** *тбл.* кыяклану – игеннәр турында (образование листьев – у злаковых).

**ҚОЛҒОР** *тбл.* балык тоту коралы (кривда – сибирский рыболовный снаряд в виде мерёжи).

**ҚОЛДОН** *брб.д.* төлке тәпие туны (шуба из лисьих лапок). Пархыт мынан тышлап, қолдон тиләр, төлкенең қулынан тегәделәр.

**ҚӨЛЙАПҚЫШ** *том.д.* к.: **айбағар**.

**ҚОЛҚА** *лш.* к.: **қылқа I**. Қолқа күлмәк.

**ҚОЛҚАЙ** *минз., перм., эчк., трбс.* колын (жеребёнок в возрасте до одного года). Қолқайға утырып килә Қазанға. – *трбс.* Атның ниндәй матур қолқайы бар! – *эчк.* Бу бийәне cawабыз, қолқайын айырдық. – *минз.*

**ҚОЛҚАЙЛАУ** *перм., к.-уф.* к.: **коннау**. Фәрхи жиккән ат қолқайлаған. – *к.-уф.*

**ҚОЛҚОНОП** *кргл.* йотлыгып – ашау турында (захлёбываясь – во время еды). Қуй итен қолқоноп-қолқоноп ашыйлар.

**ҚОЛҚОНУ 1.** *бәр.* авыздан кире килгәнче эчү (напиться, вдоволь напиться). Зур тирмыс алып барганнар ыйы, қолқондық суға; **2.** *бәр., дөб.* ашағанда яки эчкәндә чәчәү (поперхнуться во время еды или питья). Ашығып ашап қолқондым. – *дөб.*

**ҚОЛҚУ** *дөб.* тончыгу (захлебнуться). Чистый қолқой башлаган иде балаң, судан көчкә өстәрәп чыгардым.

**ҚОЛЛОҚ** *тбл.* теләк теләү (высказать доброе пожелание). Эшләйтеген кешегә «Армаң! Армай эшләң!» тителәр, шал қоллоқ пулаты.

**ҚОЛЛОҚСЫЗ** *туб.-ирт.д.* яхшылыкның кадерен белмәүче (неблагодарный).

**ҚӨЛМЕН** *том.д.* киптерелгән агач гөмбәсеннән ясалган сүс (трут).

**ҚОЛНАУ** *туб.-ирт.д., брб.д.* к.: **коннау**. Қолнаган пийәсе бар. – *брб.д.* Қолнамаған ат. – *твр.*

**ҚОЛОҚАЙ** *минз., злт., трбс.* к.: **қолқай**. Бийәләре, қолоқайлары белә шақтыйга жийыладыр әле. – *минз.* Менә быларның қолоқайы бар, бер йәштән тай була. – *трбс.* Атның қолоқайы торган да басқан. – *злт.*

**ҚОЛОМ** *каз.ар., трх.*, **ҚОЛОМЧАҚ** *каз.ар.* колын (жеребёнок до одного года). Қолом салған. – *трх.* Қоломчаққа йақын барма, йә тибәр. Атығызның қоломы адашкан, барып алығыз. – *мам.* Қолом көйө сатқан булган. – *лш.* Қоломчағы қалды да, кешнәп жибәрде атым, туқтап тик тора. – *лш.* Жаңа туғаны қоломчақ була, бер жәштән тай була. – *блт.*

**қолон** *урт.д., себ.* колын (жеребёнок):

**қолон кисәгем** *төм.* үзеннән яшьрәкләргә ярату эндәшү сүзе (форма ласкового обращения к людям младше себя). Эй, қолон кисәгем, пер босоқ сүсе пулматы.

**қолон ташлау** *тара.* к.: **қомон: қомон салу**. Пабайныңқы аты қолон ташлапты, пецәнкә бармайты.

**ҚОЛОНЦАҚ** *туб.-ирт.д.* к.: **қолқай**. Қолонцағы бар. – *тара.* Қолонцақ шийелле ырғып-ырғып параты. – *тбл.*

**ҚОЛОНЦАҒЫМ** *төм.* к.: **қолон: қолон кисәгем**. Қолонцағым, пелмәйсең минеңке төңкәлгәнне.

**ҚОЛОНЧАҚ I 1.** *мам., блт., нокр.* к.: **қолқай**. Қолончағын имезсен инде, әзрәк тороп торыйқ. – *мам.* Қолончақлы ат йеккән бер әдәм килде. – *нокр.*; **2.** *лш.* к.: **алсын 2**. Қолончақ жибәргән игенне күргәнең бармы синең?

**ҚОЛОНЧАҚ II** *лш.* туку станын корганда кылыч тулмый калса, өстәмә итеп үткәрелә торган буй жеп (нитки основы, продетые дополнительно через бёрдо и нитченку).

**ҚОЛОНЫМ** *тбл.* иркәләү сүзе (ласкательное слово).

**ҚОЛОП** *төм.* йозак (замок). Қолобыңны бикләп ал.

**ҚОЛТАШ** *брб.д.* яргыч, кул тегермәне (ручная мельница).

**ҚОЛТОН** *брб.д.* куян, бәрән һ.б. колакларыннан, юка тиреләрдән тегелгән тун (шуба, сшитая из голых мест шкур ягнёнка, зайца и т.п.). Тон өч төрлү, қолтон қуйанның қолақларыннан, кечү бәрәннәрнекеннән, йоқа булған.

**ҚОЛТОРЛО** *туб.-ирт.д.* көяз (щеголеватый).

**ҚОЛУ** *перм.* к.: **қолау I**. Бидрәнеңке қолуwы йуқ.

**ҚОЛУТ** *төр.* саз үләне (болотная трава).

**ҚОЛЩА** *тара., брб.д.* кыр суганы (полевой лук). Қолща әчү, олу. – *брб.д.* Қолща әче йердә үсәде ул. – *тара.*

**ҚОЛЩАЛАУ** *брб.д.* кабару, кабырчыклану (покрыться волдырями от ожога). Бир йанын отка қойдылар, тәрәзе пежеп қолцалады, йарылды.

**ҚОЛЧАҚ** *яүшт.* сөял (мозоль).

**ҚОЛЫМЗАҚ** *брб.д.* каракланучан, карак (вор).

**ҚОЛЫНЦАҚ** *төм., тбл., саз.я.* к.: **қолқай**.

**ҚОЛЫНЦАҒЫМ** *тбл.* к.: **қолоным**.

**ҚОЛЫП** *төм.* к.: **қолоп**. Қолып тип йосақны әйтәләр.

**ҚОМ 1.** *перм.* к.: **душқын 1**; **2.** *тбл.* җир, балчык, туфрак (земля). Цымца болады йасқысын, ул үткәс қомқа тигәле йарай, қомно қасарға йарай. Қом салып күмеп қуйабыс өйнеңке түгәрәген.

**қом төрткеч** *бгрс.* к.: **қомпалық**.

**ҚОМАҒАЙ** *т.я., блт., злт.* комсыз, нәфесле (жадный, ненасытный); чаг.: **мыжым**. Қомағайның қырық көн алдан борно қычыта, ди. – *блт.* Бездә халық қомағай түгел. – *злт.*

**ҚОМАҒАЙЛАУ** *тара.* суны болганчыкландыру, болгату (мутить, замутить – воду).

**ҚОМАЙАҚ 1.** *лш., минз., нгб.-крш.* елга ярында ком салган урын (песчаная отмель на берегу реки, песчаная коса). Қомайақта уйный бала-чаға, қазлар судан чыгарға қурқа. – *лш.* Қазақ китә, озатайық Қомайаққа җиткенче (*хал. җыр.*). – *нгб.-крш.*; **2.** *глз.* комлы (песчаный). Шушма буйлары ай қомайақ, Қадап та қалдырдым бер тайақ (*хал. җыр.*).

**ҚОМАҚ I 1.** *кргл.* к.: **қомайақ 2**. Ылғый қомақ инде бездә; **2.** *тбл., саз.я.* каты, комлы – күл, елга төбе турында (твёрдый, песчаный – о дне озера, реки). Песнең күлнеңке төбө қомақ пулатыған. – *саз.я.*

**қомақ йылым** *саз.я.* комлы төпле суларда балык тоту өчен җылым (стрежневой невод).

**ҚОМАҚ II** *бөре., перм., минз.* к.: **йалман 1**. Чебеч бала умбер бөртөк алдым ыйы, қомақ алды бишесен. – *перм.* Қомақ тишеге бардыр badda, шул қомақ тишегеннән сүwына бит. – *минз.*

**қомақ борчақ** *нокр.* тычкан борчагы (мышиный горошек).

**қомақ чычқан** *перм.* к.: **йалман 1**.

**су қомағы** *бөре.* су күсесе (водяная крыса).

**ҚОМАЛАҚ** *перм., бөре., тпк., злт.* колмак (хмель). Қомалақтан чүпрә йасыйсың, арта ачытасын қамыр. Қомалақтан йасыйлар балны. – *перм.* Қомалақ әпәйгә дә әйбәт асыту өсөн. – *злт.*

**қомалақ қыштырдау** *злт.* җиңелчә көнләшү (слегка ревновать, приревновать немножко). Нийә, қомалағың қыштырдыймы әзерәк?

**қомалақ печин** *перм.* **1.** к.: **қомалақ үләне**; **2.** эт әчәге(се) (вьюнок).

**қомалақ салу** *блт.* багу, күрәзәлек итү (гадать, ворожить).

**қомалақ үләне** *бөре.* шылдыравык – үлән исеме (погремок).

**ҚОМАР 1.** *әстр.* теләк (желание). Улардын қомары киләде; **2.** *бөре.* байлык яратучан (любящий богатство, жадный); **3.** *брб.д.* хирыс (пристрастный, охочий). Пес цәйгә қомар түгел.

**ҚОМАРЛАНУ** *минз.* комсызлану, комсызлык күрсәтү (жадничать, проявлять жадность, охоту). Синең қомарланғаның мал икән димен.

**ҚОМАЧ** *төр.* ситсы (ситец).

**ҚОМАЧАУ** *каз.ар.-крш.* җайсыз, уңайсыз, кыен (неудобно, трудно). Җуқ, тәбәнәк қомачау була (өстәл). Әни қалаға барса да қомачау була мәңа.

**қомачау килү** *төр.* мәшәкатьләнү (заниматься чем-нибудь). Картупка ман (белән) қомачау килеп пернәрсә йыштырғаным йуқ.

**ҚОМӘЛБӘ** *әстр.* к.: **халба**.

**ҚОМБАҒЫШ** *мам.*, **ҚОМБАҚ, ҚОМБАҚТЫ** *эчк.* к.: **айбағар**. Бақцаға қомбақ утыртқамбыз. Бақцасына күп итеп қомбақты утыртқан.

**ҚОМБАТЛЫ** [*гар.* + *афф.* -лы] *әстр.* кадерле (дорогой). Қомбатлы кешем син.

**ҚОМҒАН 1.** *бөре., злт., төр.* эмаль чәйнек (эмалированный чайник); чаг.: **ғал′ник**. Бер қомған сәй эсеп петтек. – *злт.*; **2.** *эчк.* зур металл чәйнек (большой металлический чайник). Қомған белән қуй цәйне, йетәрлек булсын.

**сәй қомған** *злт.* чәй чәйнеге (заварочный чайник). Берәй йердә сәй қомғаным күренмиме? Әнә сәй қомған пискә қуйгаммын.

**ҚОМҚАБАР** *әстр.* к.: **халба**.

**ҚОМҚАН 1.** *тпк.* к.: **қомған 1**. Қомқанны утырт, сәй эсеб алайық; **2.** *тбл., брб.д.* зур чәйнек (большой чайник); **3.** *туб.-ирт.д.* к.: **қамқан**.

**ҚОМ-ҚОРОЧ** *мам., т.кам.-крш.* к.: **қом-қырыс**. Башмақ үрәләр ийе, чабатаға күтәртмә җасыйлар ийе қом-қороч, бер-берсенә җийылып. – *т. кам.-крш.* Қом-қороч инде җәй җитсә, тегеннән қайта балалар, болары килә, ашарға әзерләп кенә җиткер. – *мам.*

**ҚОМКҮЗ** *кргл.* ач күзле (жадный, алчный, ненасытный).

**ҚОМ-ҚЫРЫС** *блт., лш.*, **ҚОМ-ҚЫРЫЧ** *мам., каз.ар.-крш.* ыгы-зыгы, шау-шу (суматоха, переполох, беготня, шум-гам). Қом-қырыс эш эшлидер ийек әле. – *блт.* Печән өстә, қом-қырыс әле анда. – *мам.*

**қом-қырыч килү** *мам., блт., каз.ар.-крш.* ыгы-зыгы килү, мәш килү, ду килү, нинди дә булса эш белән мавыгу (создавать суматоху, поднимать шум-гам, работать, заниматься чем-нибудь с большим увлечением). Қом-қырыч килеп суғышқаннар ике әтәч. Қом-қырыч килеп чөмәлчеки уздырдық, су сибештек. Қом-қырыч килеп бәрәңге

қазып жаталар. Қунақлар қайтқан, қом-қырыч киләләр. – *мам.* Қом-қырыч килеп сабантуйға әзерләнеп жатадырыйық, жаңғыр йawa башлады. – *блт.* Қом-қырыч килеп жөрдөк бүген сүрәткә төшөп. – *каз.ар.-крш.*

**ҚОМЛАҚ** *төм.*, **ҚОМНАҚ** *туб.-ирт.д.* к.: **қомалақ**. Усепес йасай тоған ыйық қомлақтан пуса, он аппарабыс, пуса белән ацытабыс, ацытқац пасабыс, ул күбә. – *төм.*

**ҚОМОҒУ** *минз.* чишмә авызының тыгылуы, ком белән капланyу (закупориться, засориться песком). Салқын чишмә таралды инде хәзер, монда чыға торған күзе қомоқтымы.

**ҚОМОҚ** *минз.* к.: **йалман 1**. Қапқынға моноң хәтле қомоқ төшкән, ушым китте күргәч.

**су қомоғы** *минз.* ондатра. Су қомоғы су астында ойа йасый, су буйында чебиләрне ала.

**ҚОМОН: қомон салу** *нрл.* колын салу, колын ташлау (сделать выкидыш – о кобыле).

**ҚУЦАМ** [*гар.* + *афф.* -м] *тара.* ирем (муж мой). Минем қуцам ул.

**ҚУЦАУ** [*гар.* + *афф.* -ау] *төм.* әнисе яки әтисенең энесе (младший брат отца или матери). Бер йорттан алғаннар эти белән қуцау.

**ҚУЦҚАР** *төм., тара., том.д.* кәжә тәкәсе, сарық тәкәсе (козёл, баран). Қуцқар қуйныңы пы. – *том.*

**ҚУЦЛЫ** *туб.-ирт.д.* қунычлы (с ғоленищами). Қулларынта қуцлы ай пәрцәткә, Бик партawай йөргән ир мәллә (*хал. жыр.*). – *төм.*

**ҚУЦХАР** *саз.я.* к.: **қуцқар.**

**ҚУЦЭҮРӘ** *себ.* арпа ярмасы белән пешерелгән аш (перловый суп).

**ҚУЧ** *мам.* к.: **қучқар II, 2.** Қучқа wақ-төйәк нәрсәләр тығабыз шунда, бийәләйме, наскимы.

**ҚУЧА** [*гар.*] *тара.* хуҗа (хозяин, владелец). Әске шық, Пайзи шық, Баба шық, Алем шық пулған, алар төшөп Иртыш буйына Бухарадан, берсенке аты қалған булған, ул қuwып килгән, килеп йетеп тойақларын күтәреп йатып үлепте қучасыныңқы йанына йатып.

**ҚУЧАҒЫС** [*рус.* косяк + өс] *нокр.* тәрәзә төбе (подоконник). Қучағыстан ал гелне, эшемәсен.

**ҚУЧАҚ I** [*рус.* косяк] *нокр., глз.* тәрәзә (окно); чаг.: **ачылма.** Қучақны ачып җибәрәсе, азрақ сewиж hawa керсен йаңғырдан соң. – *нокр.* Қучақлар қуйасы бар. – *глз.*

**қучақ қашаға** *нокр., глз.* тәрәзә пәрдәсе (занавес для окон). Қучақ қашаға усал, йума кирәк. – *нокр.*

**ҚУЧАҚ II** *брб.д.* ал (колени). Әйдә, қучағына утыр.

**'УЧА'** *кас.* к.: **бәкәй.**

**ҚУЧАН** *брб.д.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрағы.**

**қучан йафрағы** *нокр.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрағы.**

**ҚУЧАТ** *трх.* әтәч (петух, кочет). Шул хәдәре талый бит аный қучатың. Ике қучат асырап чықты бит.

**'УЧЕР'И** [*рус.*] *кас.* к.: **қустартқыч.**

**ҚУЧҚАР I** *әстр., твр.*, **КУЧКАР** *влгг.* тәкә (баран). Қучқарыңны миннән сорамайсыми? – *влгг.*

**ҚУЧҚАР II 1.** *каз.ар., минз., бәр.* к.: **қашаға I, 1.** Сабыннарың да қучқар өстендә, ал шуннан, төр. Шырпыны қучқарға қуй. – *минз.* Мич алды жақ қучқарда шырпы. – *дөб.* Шырпы қучқарда тора. – *лш.* Қучқардағы бийәләй дә җеп-җүwеш. – *мам.*; **2.** *дөб.* әйбер куяр өчен мич стенасында калдырыла торган урын, куышлык (углубление, ниша на передней стене печи). Әнә қучқарға ғына қуй, лампы җанына.

**қучқар башы** *дөб.* к.: **қучқар II, 2.** Қучқар башындағы лампыны суғып төшөрде.

**ҚУЧҚЫЛАҚ** *нокр., глз.* к.: **ачықый.**

**қуйан қучқылақ** *глз.* куян кузгалагы (заячий щавель).

**ҚУЧЫҚТЫРЫП: қучықтырып сийләү** *дөб.* ашығып, сүзләрнең азагын йотып сөйләү (говорить торопливо, заглатывая концы слов); чаг.: **қурт-қурт.** Пәйзи ағай әйтмешли, бигрәк қучықтырып сийлисен.

**ҚУШ I 1.** *т.кам.-крш., перм., себ.* ир яки хатын (один из супругов). Қушыңа сәлам әйт. – *т.кам.-крш.* Қушың парма? – *төм.* Қушларығыз бармы? – *перм.*; **2.** *бөре., кас.* ике бертөсле, ике бертөрле (две одинаковых вещи). Қуш йаулық. – *бөре.*; **3.** *дөб., перм.* пар (пара чего-либо). Уң қуш себерке бәйләп қайттым. – *дөб.* Умбер қуш себерке. – *перм.*; **4.** *бөре.* бер җенестән булган игез бәрәннәр (ягнята-двойни одного пола). Қуш тәкә. Қуш саулық бәрән; **5.** *трбс.* ике яулыкны кушып тегеп ясалган бөркәнчек (покрывало из спаренных платков). Минең инәй шулай қуш жабынып жөрдө.

**қуш керфек булу** *лш.* керфек төбенә эчкә икенче керфек чығу (появление на реснице другой – второй – ресницы). Әнигә қуш керфек чығадырыйы, эчкә керфек чығадырыйы да, икешәр ай күзен ачалмыйдырыйы.

**қуш өй** *минз.* арасында өйалды булған каракаршы эшләнгән ике өй (два дома-четырёхстенника, поставленных один против другого и соединённых сенями). Бабайның қуш өй былған.

**ҚУШ II 1.** *минз.* к.: **қuwыш I.** Қушқа кергән бозау, әле дә базына төшмәгән.; **2.** *блт., глз.* кечкенә балалар өчен егылып төшмәслек итеп эшләнгән утыргыч (сиденье, стул для маленьких детей). Чыбықтан үргән қушта утырып үсте балалар. – *блт.*; **3.** *тара., саз.я., брб.д.* алачык (шалаш); **4.** *тбл.* буш (пустой, полый).

**ҚУШ III** [*фарс.* хуш]: **қуш йақмау** *тара.* **1.** теләмәү, күңел тартмау (не хотеть); **2.** иренү, ялкаулану (лениться). Сawытлар йуу гәрәк ите, қуш йақмайым.

**ҚУШ IV** *твр., брб.д., том.д.* кош (птица).

**қуш қалғыту** *твр.* кош чөю – киек аулау өчен (подбрасывать птицу вверх – на охоте). Қарчығаға қуш қалғытсаң, қушын қайдан алырзың?

**'УШ** *кас.* к.: **қуш I, 2.** 'уш 'үли'.

**ҚУША** *әстр.* бергә, парлап (вместе, парой). Қуша қартайың.

**ҚУШАҒАЦ** *туб.-ирт.д.* **1.** иптәш кыз, дус хатын (подруга); **2.** иренең абыйсы яки энесе (брат мужа). Қушағацымныңқы бицәсенеңке атын онтоп киттем қуй. – *төм.*; **3.** иренең бертуганы – ир яки кыз туган (сестра или брат мужа). Қушағацым, мин әйтәм, цацың қайа? Осон ите цацы. – *тбл.*

**ҚУШАҒЫМ** *тбл.* картым, ирем (мой муж). Пы қушағымның awылы.

**ҚУШАҚ I** *тбл., твр.* кушылган кешең (иреңең).

Қушылған қушақларың ман исән пулғалы йассын. – *твр.*

**ҚУШАҚ II** *брб.д.* каеш (ремень). Солдат қушағы.

**ҚУШАМАТ** *мам.* кушымта, өстәмә, кушылган (дополнительный; то, что прибавлено). Қушамат бақчабыз тегочта.

**ҚУШАНҚЫ, ҚУШАҢҚЫ** *дөб.* **1.** к.: **кишәңге**; **2.** кишәнке (соплодие орехов). Қушаңқысы белән жыйалар чикләwекне.

**ҚУШАРАЙ** *к.-уф.* к.: **tywapa**. Быйыл бәрәңгенең қушарайлары бик күп.

**ҚУШБАШ** *перм.* кызыл канат (краснопёрка).

**ағым қушбаш** *минз.* балыкның бер төре (елец – вид семейства карповых). Агым қушбаш кәчәк белән йөриләр, беләк буйы да була.

**ҚУШҚАЛАҚ** *төм.* к.: **ачықый**. Қушқалақ ашау гәрәк. Қушқалақ әчкелтем.

**ат қушқалақ** *том.д.* к.: **айуқузғалақ**. Ат қушқалақны пешереп ашадық соуғыш цакта.

**ҚУШҚАЦАҚ** *том.д.* к.: **турғай**.

**ҚУШЛАП 1.** *перм., нгб.-крш.* икәүләп, икесе бергә, ирле-хатынлы (вдвоём, муж с женой). Қунаққа чақырды, ыштубы қушлап барыйқ дип. – *перм.*; **2.** *нгб.-крш.* бергә, парлап (совместно, в паре). Минем белән қушлап кәртечкәгә төште.

**ат қушлап** *төм.* пар ат җигеп (запрягая пару лошадей). Суларга салсаң, батмас йанған күмер, Ат қушлап қусаң, җитмәс узған ғомер (*хал. жыр.*).

**ҚУШЛЫҚ** [*фарс.* + *афф.* -лык]: **қушлық булмау** *сазл.* кәеф булмау, эч пошу (быть без настроения, скучать, хандрить). Қушлығым йох пүген.

**ҚУШМА I** *блт., мам., дөб.* бөтен агачны чокып яки вак тактадан җыеп эшләнгән агач савыт, кечкенә кисмәк, нигездә күәс хезмәтен үти (квашня, сделанная из цельного дерева и иногда из клёпок). Қушмада ипи изеп пешерәләр, ағачның эчен алып йасаган була. Безнең ике қушма: берсе бәләкәйрәк, берсе зуррақ. Қушманы wақ тақтадан да йасыйлар, ағачны чоқып та. – *мам.* Қушмаға қамыр изеп қуйдым. – *блт.*

**ҚУШМА II 1.** *минз.* өйнең дүртпочмаклы төп өлешенә кушып эшләнгән ике почмаклы алгы өлеше (прирубь). Матур ғына өй ийе, анарға қушма қуштық; **2.** *төм.* кушымта (припев). Қушмасын пеләмен, йырын онотыпмын.

**қушма исем** *дөб., сазл.* к.: **атағат**. Қушма исемнәре қурыс аларның. – *дөб.*

**ҚУШМА III** *т.я.* киндер яки җитен көлтәсе (сноп конопли или льна). Орлоқ қушмалары белән генә ышықлап қуйдым лапасны. – *к.т.*

**ҚУШМА IV: қушма ағызу** *минз.* агачны күпләп агызу (сплавить несколько плотов вместе).

**ҚУШМАҚЛЫ** *т.кам.-крш.* атап чыгарылган (именная песня). Тағын бер қушмақлы жырywым бар ийе.

**ҚУШМАН I** *нокр., глз.* ачы торма (редька). Қушманнар қырып ашадық. – *глз.*

**қушман гөл** *нокр.* нәүрүз чәчәге (примула).

**ҚУШМАН II** *т.кам.-крш.* к.: **қушма I**. Қаймақ қушманына қайын жиләге, жир жиләге жафырағын салып, бастырып чәй йасыйлар.

**ҚУШМӘК** *эчк.* к.: **күшмәк**.

**ҚУШТАЙ** *тбл.* исәнлек-саулык (здоровье).

**ҚУШТАЛЛЫ** *дөб.*, **ҚУШТАМЛЫ** *клм.* бала итәкле (с воланами, с оборками). Қушталлы күлмәкләр кигәнләр әwәле, минем үземнең әнинең дә бар ыйы. – *дөб.* Киноктор қуштамлы өстө-өстөнө тегелгән, озон йәң. – *клм.*

**ҚУШТАН I 1.** *трх., нокр., глз.* купшы, көяз – киенү турында (нарядный, умеющий красиво одеваться). Бик қуштан қатыннарда сары бау була, хәситә астында, чуқлы. Хәзер қуштан ул әби, кийәргә бар. Мәрийәм бик қуштан қатын, аңардан сорарсыз кийемнәрне. – *трх.* Кешем қуштан иде, алай да йарата иде мин теккәнне дә. – *нокр.* Қуштан булып йерелде ул азырақ. – *глз.*; **2.** *трх.* мут (шельма, плутоватый, хитрец). Мин гармунчы булдым, қуштанрақ булдым, шуңа чықты ул миңа.

**ҚУШТАН II 1.** *лш.* алача, бер буе ак, бер буе кара яки башка төстә итеп сугылган киндер (пестрядь). Қуштан ыштаннар кигәннәр. Қуштан ыштан берсе қара, берсе ак буй була; **2.** *т.я., дөб., кмшл., твр., брб.д., том.д.* бала итәк (волан, оборка). Қуштан тотарлар ийе, икитәкле күлмәк ди торғаннар ийе. Киң қуштанны күлмәкләр була. Бишәр, җидешәр қуштанны тар қуштанны күлмәкләр кидек. – *нрл.* Ике қуштанлы күлмәк кидем мин. – *дөб.* Порон тегәйе, беләмесең, йедешәр қуштан салып. – *брб.д*; **3.** *яүшт.* ыштан балагы очында – махсус чук (специальная бахрома на конце штанины у женщин). Ыштанны пес кийә тығамбыс балақту, оцонда қуштан; **4.** *брб.д.* җиң очына бөреп тотылган тар челтәр яки бала итәк (воланчики, рюши на конце рукавов). Қуштан йеңендә, итәгендә тужы қуштан; **5.** *брб.д.* чыбылдык кашагасы (бордюр полога, занавески). Чыбылдыкны қуштан белән тегәсең, өстә қуштаны бар; **6.** *кмшл.* мендәр яки җәймә читләрендәге тар бала итәк (воланчики, рюши на краях подушки и т.п.).

**қуштан итәк** *твр.* бала итәк (волан). Бөреп-пөрөп қуштан итәкле көйләк пулыпты.

**таққан қуштан** *трх.* итәк очына гына, бер генә кат тотылган киң бала итәк (одинарный широкий волан, пришитый на нижнюю кромку подола платья); чаг.: **бөти I**.

**ҚУШТАННАНУ** *трх.* купшы, көяз киенү (нарядно одеваться, уметь одеваться красиво). Шалама булсақ та, қуштаннанып йөрдөк йегетләрне соқландырырға.

**ҚУШТАННАУ** *кмшл.* бала итәк тоту (пришить воланы). Шулай қуштаннап теккән (мендәр өстенә яба торган җәймәне).

**ҚУШЫМ** *перм.* кушылган әйбер (примесь). Моноңа, бу қызыл борочқа, қушым қушып җийалар, қушымны была wы.

**ҚУШЫРУ** *тара.* кушу (соединить). Ике өстәлне қушырып утыратық.

**ҚЫБА-ЙАЛАҢАЦ** *тара.* шыр-яланғач, бер кием-салымсыз (совершенно голый, совершенно раздетый, без никакой одежды). Қыс пиргән қыбайалаңац.

**ҚЫБРЫ** *минз.* артык купшы, артык чуар (слишком яркий, слишком щегольской); чаг.: **қуқырт**. Ул хәтле қыбры кийенү нигә кирәг инде?

**ҚЫБЫРДАУ 1.** *злт.* селкенү, кыймылдау, хәрәкәтләнү (шевелиться, двигаться). Қыбырдарга қушмыйлар бит йәшен йәшнәгәндә. Қолағы қыбырдап торса ашағанда, уңған была килен; **2.** *т.я., минз., мам.* к.: **жобану**. И қыбырдый да инде эч пошороп. – *к.т.* Бигрәк қыбырдыйсың, соңа қалабыз бит. – *мам.*

**ҚЫБЫРДЫҚ** *к.т., дөб.* к.: **йыбытқы**.

**ҚЫБЫР-ҚЫБЫР** *т.я., кргл., бгрс.* акрын, сүлпән, бик акрын кыймылдап (медленно, вяло, не торопясь). Қыбыр-қыбыр көн буйына суздинде бер керне. – *к.т.*

**ҚЫБЫРСЫҚ** *т.я.* к.: **йыбытқы**. Қыбырсық әйләнгәнче, көн узып китәр. – *к.т.*

**ҚЫБЫРТАУ** *төм.* кыймылдау (шевелиться).

**ҚЫБЫРЫ** *минз.* к.: **қыбры**; чаг.: **куқырт**. Қыбыры кийенергә йараталар җәшләр, артық қыбыры инде хәдер.

**ҚЫWAҚ** *төм.* сазлы-балчыклы җирдәге әрәмәлек (кустарник около реки, на болотистом месте). Балтырған қыwақларда үсәте.

**ҚЫWALAШMA** *твр.* куышлы – уен исеме (перегонки – игра). Тау астына қыwалашма уйнарга да төшмим.

**ҚЫWALAШУ** *тбл.* шаулашу (шуметь).

**ҚЫWAN** *злт.* к.: **қywan**.

**қыwan йәшен** *төм.* к.: **нажағай**. Қыwan йәшен йаумай йәшнәйте, қоро йәшнәй, йаңқыры йуқ.

**ҚЫWAРУ 1.** *тпк.* саргаю, кору – усемлекләр турында (высыхать, пожелтеть – о растениях). Пер йағы қыwарған, алгы йагы бақсамның йәм-йәшел. Ағас қыwара, йафырағын қойоп бетә; **2.** *тбл.* агарыну, төс китү, саргаю (побледнеть, пожелтеть). Ник қыwарып қалтың, әллә awырыймысың?

**ҚЫWATLУ** [*гар.* куәт + *афф.* -лу] *яүшт.* көчле (сильный). Қыwатлу кеже.

**'ЫWЫ'** *кас.* итле ашның өстенә чыга торган күбек, аш күбеге (пена – на мясном бульоне). 'ыwы'ын алма'ан ашнын.

**ҚЫWЫЛЦАҚ** *тбл.* урман эчендәге кечкенә сазлык (небольшое болотце в лесу).

**ҚЫWЫРУ** *эчк.* куу (гонять). Балықны қыwырып тотамы? чаг.: **қуру 3**.

**ҚЫWЫШ 1.** *тбл., саз.я.* алачык (шалаш). Пес цийәтә қыwыш қылып йатабыс; **2.** *саз.я.* теш казнасы (десна).

**теш қыwышы** *тбл.* к.: **қыwыш 2**.

**ҚЫWЫШУ 1.** *төм., брб.д.* к.: **куу III**. Аман әкәсенә қыwышаты шушы пала. – *төм.*; **2.** *брб.д.* артыннан йөрү, юллау (хлопотать). Қыwышты, қыwышты, алды кywартир.

**ҚЫДА** *нокр., глз.* туй (свадьба).

**ал қыда** *глз.* кызны килешкәч, кодалар, якын туганнар белән уздырыла торган мәҗлес (застолье с участием самых близких родственников и сватов после сговора). Ал қыда теге қыдаларда да була, бу қыдада да була.

**арт қыда** *глз.* туйдан соң якын туганнар белән уздырыла торган мәҗлес (застолье после свадьбы с участием самых близких родственников). Арт қыда була туйдан сыңра. Ал қыда қыз йақта, арт қыда кийәүнең булма тийеш.

**кече қыда** *нокр.* к.: **ал қыда**. Кече қыда ике йақта да булса, сүләшәләр ничә пар, ул уқ атнада була ике йақта да, или эртә киләләр қыз йаққа, төш – йегет йаққа.

**ҚЫДРАЧ** *минз.* тиз кызучан, бәйләнчек (горячий, задира); чаг.: **бәтрәк 2**. Ул бик қыдрач нәрсә, хәзер сугышып китәргә әзер.

**ҚЫДРАЧЛАНУ** *минз.* к.: **бәтрәкләнү**.

**ҚЫДЫРАЙУ** *брб.д.* башны чыгарып карау (выглядывать).

**ҚЫДЫРЛАТУ** *кргл.* ашыктыру (торопить, подгонять). Тизерәк дип қыдырлаталар, кийендерәләр, йылаталар қызны.

**ҚЫДЫРУ I 1.** *кргл., бгрс.* дөнья күрү, гизү (разъезжать, скитаться по свету). Исәнме икән, қыдырып йөриме икән? – *бгрс.* Сез дә қыдырып қайттығызмы? – *кргл.*; **2.** *әстр., кргл.* күңел ачып йөрү, ял итеп йөрү, йөрергә чыгу (гулять).

**ҚЫДЫРУ II** *минз., злт.* тиз һәм җиренә җиткереп эшләү (работать быстро, проворно, хорошо). Алар қыдырып эшлиләр. Өй қырырға қызлар чақырдым, қыдыралар ғына. – *минз.* Разыйаның балалары бик уңганнар, қыдырып эшлиләр. – *злт.*

**ҚЫДЫС** *брб.д.* алабуга (окунь). Қыдыс қыдысны қацырып йүрә, цортан цортанны қацырып йүрә.

**ҚЫЖЫРАУ** *злт.* к.: **кыжрау**. Үзенә бер әйтәм дип қыжырап йөрим дә...

**ҚЫЖМЫЛДАУ** *перм.* кайнашу, мыж килү (кишмя кишеть). Кеше аймақ булып китә, қыжмылдап тора. Қыжмылдаган қый анда қалық.

**ҚЫЖРАУ** *каз.ар., минз.* талпыну, көчле теләк, теш кайрау (хотеть, желать, стремиться к чему-либо). Собранҗада чыгып сөйләргә бик қыжрап торган идем дә, әллә нәрсә, қыйулығым җитмәде. – *лш.* Күптәннән қыжрап йөрим инде қычытқан белән өтәләргә тотоп. – *мам.* Ғыйлмулла абзый ачуланып, қыжрап тордо торуwын, үзе бернәрсә дә эшли алмады. – *минз.* Шушы эшне эшләргә қыжрадым. – *дөб.*

**ҚЫЖҚЫЛЫ** [*удм.*] *нокр.* очкын (искра). Пажар булды йуғары awылда, қыжқылысын безгә хәдәре ычыртқалаган.

**ҚЫЖҚЫРАУ 1.** *т.я.* ачу килү, ачу кайнау (злиться, разгневаться). Байадан бирле қыжқыряйм мин сине әләктерергә, ничә әйтеп бер сүз тыңнамыйсың. – *к.т.*; **2.** *бәр.* к.: **қыжрау**. Үзебез дә қыжқырыйбыз инде йорт салмаға.

**қыз I** *урт.д.* кыз (девочка, девушка):

**қыз алу** *бәр., перм.* өйләнү (жениться, сосватать, взять девушку). Безнең эти йәштән қыз алған. – *бәр.* Малай бар, қыз алмаған. – *перм.*

**қыз арты** *трбс.* к.: **арчи 1**. Икешәр-өчәр қыз арты җибәрәбез.

**қыз бикләү** *яүшт.* к.: **қыз йабу**. Бүген қыз бикләргә өйөгезне бирерсезбә?

**қыж җанында утыру** *т.кам.-крш.* кыз китәсе көннән алдагы кичтә була торган кичә (вечеринка, устраиваемая за день до отъезда невесты). Қыж җанында үз иптәшләре, җегетнен үз иптәше, алар утыралар, қыж җанында утыру шул була.

**қыз җийыны** *каз.ар.-крш.* эшләр беткәч яшьләрнең җыелышып күңел ачуы (молодёжные увеселения вечером у кого-нибудь после завершения

полевых работ). Көз көнө қыз жыйыны дип жөридер ийек, өй сайын керәдер ийек тә, өстәл арасына утырадырыйық та, су белән жырлап утырадырыйық, урақ беткәч, бәрәңгеләр қазыгач, қыз жийынында жәшләр дә, қызлар да жөри, қатыш була торган ийе.

**қыз жыйылышы** *яүшт.* к.: **аулағаш.** Қыз жыйылышы дип әйткәннәр, картлар цыып киткәц, қыслар утыралар.

**қыз йабу** *минз.* қыз куенына керү (провести первую брачную ночь). Қыз йабу қайчан? Унжидесендә қыз йабалар, унсигезендә туй.

**қыз йәмшик** *нокр., глз.* кияү кызны алырга барғанда атны тотып баручы (кучер, который сопровождает жениха, идущего за невестой). Зур селге бирәләр қыз йәмшиккә. – *глз.*

**қыз килешү** *каз.ар.-крш.* қыз ярәшү мәҗлесе уздыру (устроить угощение во время помолвки). Мына кич қыз килештелер бездә, бийатасы, бийанасы килә, қәрендәш-ырuwын чақыралар.

**қыз күргем, қыз күрем** *кас.* қыз күрсәтү (смотрины).

**қыз озату кичәсе** *минз.* қыз китәсе көнне үткәрелә торган мәҗлес (застолье, устраиваемое по поводу проводов девушки в дом жениха). Қыз озату кичәсе қыз жағында қыз китәсе көннө була, аш-су ойоштыралар, жегетнең туғаннары қыз алырға киләләр.

**қыз сикертү** *перм.* яшь киленне кияү йортында каршы алганда үткәрелә торган йола: қыз, арбадан төшкәндә, аяк астына салынган мендәргә басмыйча, аны сикереп үтәргә һәм үзенең уңганлығын күрсәтергә тиеш булған (один из обрядов, совершаемых при встрече невесты в доме жениха). Алып парғач та қызны сикертәләр әле.

**қыз табасы** *әстр.* қыз әйберләре – урын-жир һ.б. төялгән арба (одна из свадебных повозок, где находятся приданое, постель и т.п. невесты).

**қыз утырту** *злт.* никах вакытында икенче бүлмәдә қызлар һәм егетләрнең уйнап-көлеп утырулары (увеселение парней и девушек в отдельной комнате во время религиозного обряда бракосочетания).

**қыз чәкчәге** *минз.* никах ашына әзерләнгән чәкчәк (чак-чак, приготовленный для застолья, проводимого непосредственно после обряда бракосочетания по мусульманским канонам). Никахта қыз чәкчәген қотлыйлар, хәдер қыз чәкчәге чыға, күчтәнәчләр дә чыға, ачалар теләк теләп.

**қызлар утырышы** *әстр.* к.: **аулағаш.**

**мулла қыз** *минз.* к.: **абызастай.** Қайынсеңнем бар, ул мине жиңәчәй ди, мин аны мулла қыз дим, исеме белән әйтмәгәннәр.

**озатылған қыз** *әстр.* кияүгә киткән қыз (вышедшая замуж – о девушке).

**паш қыз** *брб.д.* иң олы қыз (самая старшая дочь). Паш қызым қоноқтан қайтты (чәчәктән үлде).

**ҚЫЗ II** *нрл.* кереш сүз, әңгәмәдәшкә мөрәҗәгать сүзе (слово, употребляемое в обращении к собеседнику). Туйдан соң, қыз, үзең сыйланасың.

**қыd** *минз.* қыз (девочка, девушка):

**мулла қыd** *минз.* к.: **абызастай.**

**ҚЫЗА** *брб.д.* **1.** комсызлык, ачкүзлелек (жадность); **2.** көчле теләк (сильное желание).

**ҚЫЗАЛДЫ(СЫ), ҚЫЗАЛДЫЧЫ** *нокр.* к.: **арчи 1.** Кәбен уқып беткәч, қыда белән қыдағый қайтып кәтәләр қызны қаршалма әзерләнмәгә. Қызны қызалдылар ызата бара, беркәүле күмәгә утыртып алып баралар. Күмә арты, қызалдычыларны сыйлайлар. Аннан сыңра күмә белән ызата баралар, бер қызалды ийенә келеп йеткәч, ызата баручыларны бидра белән ысла алып чығып сыйлайлар. Икенче қызалды ийендә дә, эченче қызалды ийендә дә алай була инде.

**ҚЫЗАНА, ҚЫDАНА** *минз.* к.: **қазнақ 1.** Қыdананы дәңгәргә быйадым.

**ҚЫЗАПАЙ** *лш.* кияүгә чыкмыйча картайган хатын-кыз (старая дева).

**ҚЫЗАРТҚЫ** *перм.* к.: **бет: йүгә бете.** Бүген урманға бардым ый, қызартқы утырып қайтқан.

**ҚЫЗАУ** *трх.* тегермәндә мөшкәгә ашлык салу өчен хезмәт итә торган зур агач савыт (большая деревянная посудина для посыпания зерна в мельничный лоток).

**ҚЫЗАШ** *нокр.* кыз туганнарының туйга катнашучыларны кунакка чакыру йоласы (обычай приглашать участников свадьбы в гости к родственникам невесты). Қызашқа келүчеләр ылйақтан қызға тәнкә алып келәләр, қыз алардан қачып тора, қызны сүләштереп тәнкә бирәләр.

**ҚЫЗДЫРУ 1.** *бөре., минз., перм., злт.* жылыту, кайнарлату (согревать, разогревать). Су қыздырам да айақны йuwам. – *бөре.* Қыздырып эч (чәйне). Сuwын қыздырмыйлар қый, ухаға балығын, картубын, сuwын бержулы салалар. Идән жuwыб алырга кәрәк су қыздырып. Чәй қыздырып қына эчтем дә шомортқа киттем. – *минз.* Ашығызны қыздырып ашаң. – *злт.*; **2.** *перм.* өй жылыту (отоплять). Ызба қыздырмаға утын кәрәк; **3.** *каз.ар.-крш., лш.* куыру (жарить зерно) Қыздырып төйәдер ийек орлоқно, бал салыб ашыйдырыйық. – *лш.* Арышлар қыздырып ашап қайтадырыйық. – *каз.ар.-крш.*

**ат айағы қыздыру** *мам., блт., бәр.* сабан туеннан алдагы көнне атларны йөретү, чабышка әзерләү (тренировка лошадей-скакунов накануне сабантуя). Ат айағы қыздыру була иртәгә сабан туйы дигән көнне, бүген ат айағы қыздыралар, аннан күкәй жыйалар. – *блт.* Ат айағы қыздыралар ыйы, жоморқа буйарлар ыйы, иртәгесен мәйдан ыйы. – *бәр.* Ат айағы қыздырабыз дип чыып киткәннәр ийе, қайтқаннары йуғ әле. – *мам.*

**ҚЫЗ-ҚАТЫН** *нокр.* хатын-кыз (женщины). Қыз-қатын алай йермиләр исереп.

**ҚЫЗ-ҚЫМЫЗ** *каз.ар.-крш.*, **ҚЫЗ-МӘНИЙӘТ** *нгб.-крш.* кыз-кыркын (девушки). Қызым зуқ, қымызым зуқ, дидем дә бирдем киленгә (хәситәне). Қыз-қымыз булған жирдә уйын-көлкө булар. Қыз-мәнийәт жыйыла, кич утыра, ойоғын бәйли.

**ҚЫЗУ I** *трх., минз., бөре., тпк., злт., нгб.-крш., трбс.* кызыгу (иметь желание, соблазняться). Дөнйа малына қызма. – *трх.* Безнең қарт теге сату әпәйенә қызмай. – *минз.* Тауға қарасаң, тау бийек, тауға қызып қына булмай. – *бөре.* Қызыл-

ға күзем қызды. – *злт.* Шул суларга қызып монда утырғаннар алар. – *трбс.* Күркәнен итенә қызмағыз. – *нгб.-крш.*

**ҚЫЗУ II** *брб.д.* тырнау (царапать).

**ҚЫЗ-ХАТЫН** *блт.* к.: **қыз-қатын**. Қыз-хатын эшләп кенә алай қоралмый.

**ҚЫЗЫW** *бөре.* к.: **қызу**.

**ҚЫЗЫҚ I** *клм.* к.: **қосоқ 1**.

**ҚЫЗЫҚ II** *брб.д.* түләмә (сибирская язва).

**қызыл** *урт.д., себ.* кызыл (красный):

**қызыл ағач** *брб.д.* нарат (сосна).

**қызыл тун** *бөре.* к.: **бийауса**.

**қызыл шоморт** *бәр.* к.: **бушлама**. Қызыл шоморт ашыйсызмы, қарағыз ничек қошлар ашап бетерә, шоморты қала, сувын ғына сувыралар.

**ҚЫЗЫЛАЙАҚ** *перм.* кына, бохар кынасы (бальзамин). Қына диб ишеттем дә, шуңан бире қына инде, монда қызылайақ тип сүләшәләр аны.

**ҚЫDЫЛСА** *тпк.* к.: **кызылча I**.

**ҚЫЗЫЛЧА I** *әстр.* кызамык (корь). Қызылчаға қызылдан қызыл сөлге, қызыл тавар, қызыл йурған элеп қуйғаннар. Мин қызылча белән аурғанда, қызыл әтәчне суйып, баштан-күздән әйләндереп, қаннарын сөрттеләр.

**ҚЫЗЫЛЧА II, ҚЫЗЫЛЧЫ** *клм.* чөгендер (свёкла).

**ҚЫЗЫРТУ** *бөре.* кызыктыру, дәртләндерү, котырту (подстрекать, подбивать, подзадоривать). Тегеләр бик қызыртқаннар ыйы мине, суңыдан алар да сүрелделәр инде.

**ҚЫЗЫРУ** *мам., нокр., глз.* кыздыру, куыру (жарить). Итне қызырасың пелиткада. – *глз.*

**ҚЫЗЫШУ** *злт.* к.: **қызу I**. Мин асысына қызышып эстем әле.

**ҚЫЙ I** *перм., к.-уф., эчк., злт., тара.* ич, бит, ләбаса (ведь, же). Тотмадым қый. Парат җигеп өчәү киттек қый. Иң қәдерле түтәйемнең туйын күрмәдем қый инде мин. Базарларға бардым қый, Сары йаулық алдым қый; Чақырдым қый, килмәдең қый, Җаннарымны қыйдың қый (*хал. җыр.*). – *перм.* Үзең ашадың қый, оноттыңмыни? – *к.-уф.* Әле генә эштән қайттым қый. – *эчк.* Аш пешерәм, үземә ашарға кирәк қый. Бигерәк матур қый. – *злт.*

**ҚЫЙ II** *минз.* күп, гел, тоташ (сплошь, много, совсем, совершенно). Қый үлән борчақ. Қый чүп бақча. Ихата қый чүп.

**ҚЫЙ III 1.** *себ.* тирес (навоз); **2.** *әстр.* сарык тизәге (овечий помёт, кал).

**қый шеш** *тбл.* к.: **саник**.

**ҚЫЙ IV: қый кеше** *нгб.-крш.* буш, мактанчык, буш куык (хвастун); чаг.: **қырқымыш 3**.

**қый килү** *перм.* **1.** берәр җир авыртудан каты борчылу, өзгәләнү (не находить себе места, беспокоиться – о боли). Қый килдем мин кичә ашқазаны awыртып; **2.** к.: **қом-қырыч: қом-қырыч килү**. Риза булмый қый килделәр әтиләр. Уланнар қайтып қунаққа, қый килдек. Шулай булған, былай булған тип қый килделәр, тикшереп қарасаң, йуқ сүз булды.

**ҚЫЙА I** *злт., эчк., тпк.* кыек, кыйгач (косой, косо). Тегенең тубы қыйа китте. – *эчк.* Бүреген қыйа салган. Қыйа бәреп туры китердем. – *злт.* Қыйа кийеб, аны дәwәт ти торғаннар ийе. – *тпк.*

**ҚЫЙА II** *брб.д.* гына, кына (только – частица, имеющая ограничительное и усилительное значение). Йеләк йуқ қыйа.

**қыйақ** *урт.д.* кыяк (осока, лист злака; перо лука):

**ата қыйақ** *бәр.* суганның орлыклы кыягы (луковое перо с бутоном).

**ҚЫЙАЛАП 1.** *злт.* кыйгач итеп (вкосую). Қыйалап йасый торған ыйық әмәйлекне; **2.** *злт.* кыеклап – ыргыту турында (кидать что-либо вкось). Қыйалап йеппәрдем, пырауқаға барып төштө; **3.** *тпк.* арқылыга-буйлыга (вдоль и поперёк, как попало). Йаланға сығып тороп қыйалап ашап йөриләр кәдәләр өйөр белән.

**ҚЫЙАЛАШ** *эчк., злт.* к.: **чапырыш**. Кантур кибеткә қыйалаш тора. – *эчк.* Сәмсекамал әбигә қыйалаш қына өйләре. Ул безгә қыйалаш торайы. – *злт.*

**ҚЫЙАЛАШУ** *кргл., бгрс.* каршы әйтешү, әйткәләшү, ачуланышу (пререкаться, пререкословить, ссориться). Аларның қыйалашуwына қарап, мин телгә кереп йөриммени. Барғанда мин аның белән қыйалашып қайтам, шуңа күрә йаратмый.

**ҚЫЙАМАТЛЫҚ** [*гар.* + *афф.* -лық] *крш.* туйда һәрвакыт кыз белән кияү янында булып, аларны тәрбияләп йөрүче хатын-кыз; ул гадәттә кыз яки егетнең туган тиешле яки башка шундый якын кешесе була (женщина постоянно находящаяся на свадьбе при молодых; обычно она является и провожатой невесты, и посажёной матерью на свадьбе); чаг.: **борондық II: борондық инәй**. Қыйаматлық туйда қызны қарап йөртә, қыз белән йегет тирәсендә була. – *т.кам.-крш.* Қыйаматлық булып бардым ул кешегә. – *нгб.-крш.*

**қыйаматлық көн** *әстр.* кыз өендә үткәрелә торган никах (обряд бракосочетания по мусульманским канонам, который совершается на стороне девушки).

**қыйаматлық қызым** *т.кам.-крш. қыйаматлық*ның киленгә эндәшү сүзе (форма обращения посажёной матери к невесте). Қыйаматлық қызым, үз қызым, Чәчләреңне тарап үр, қызым. Атаң-анаң җорто қалды инде, Күзләреңне ачып күр, қызым (*туй җыр.*).

**ҚЫЙАМӘТ** [*гар.*] *тара.* искиткеч, искитәрлек (очень много, удивительно). Ицке (кәҗә) көп, қыйамәт, төбөтләре көп. Аларға қыйамәт раскут цығыр ите.

**ҚЫЙАНҚЫ** *тара.* кыргый, усал (дикий, злой).

**ҚЫЙАРАҚ** *трх., тара., твр.* к.: **қайрақ I**. Ай қайтсын, йыл қайтсын, шул кешегә қыйарақ чыққан, шул қайтсын, дип имниләр. – *трх.* Қыйарақны қайрақ белә имни иде, нәрсә уқығанын белмәйем инте, көйәнтәнеме, хамытнымы атланғансың, йарамай, тиб әйттеләр. – *твр.*

**қыйарақ үләне** *трх.* каты кыяклы үлән (жёсткая злаковая трава).

**ҚЫЙАРАН** *төм.* ике рәт читән арасына тизәк изеп тутырып ясаган абзар (хлев, стена которого сделана из кизяка, прессованного между двумя рядами частокола). Қыйаран та булған әwәле, сырғый ике рәт, уртасына қый төшөрә теген.

**қыйаш** *нокр., глз.* кояш (солнце):

**қыйаш туу** *нокр., глз.* кояш чыгу (взойти – о солнце). Қыйаш туғанда тырдым. – *нокр.*

**ҚЫЙАШБАЙМЫШ, ҚЫЙАШБАЙЫШ** *глз., нокр.* көнбатыш (запад).

**ҚЫЙАШТУМЫШ** *глз., нокр.* көнчыгыш (восток).

**ҚЫЙӘМӘТЛЕК** *каз.ар.-крш.* к.: **қыйаматлық**. Қыйәмәтлеккә туғанрақ тийешле парлы кешеләрне сайлыйлар. Урланған қызны йегет үз өйөнә апқайтмаған, жақын дус кешеләренә жә туганына апқайтып жапқан. Бу кеше кийәү белән қызга қыйәмәтлек була инде.

**ҚЫЙБЫЙ** *лш.* сабан туе вакытында төрле уеннар, ат узышлары була торған урын (место, где во время сабантуя устраиваются игры и скачки); чаг.: **мәйдан**.

**ҚЫЙҒАҚ** *туб.-ирт.д.* кыяк (лист, перо, осока).

**қыйғақ пецән** *тара., твр.*, **қыйғақ үләң** *тара., том.д.* саз печәне (сено, скошенное на болоте и состоящее в основном из осоки; шумиха). Қыйғақ үләңне цабаларма? – *тара*. Қыйғақ пецән ул шым (начар) малга, телен кисә ул.

**ҚЫЙҒАЦ I** *брб.д.* к.: **багырча**.

**ҚЫЙҒАЦ II** *тара.* к.: **қатый**. Қыйғац қыйық кисәбес. Паллы қыйғац санса қурыннан була.

**ҚЫЙҒАЧ** *твр.* ипи катысы (корка хлеба).

**ҚЫЙҒАЧА** *кргл., әстр.* к.: **қатый**.

**ҚЫЙҒУ** *тбл., твр.* гауга (ссора).

**ҚЫЙҒУЛАУ** *твр.*, **ҚЫЙҒУЛАШУ** *тбл.* кычкырышу, талашу (кричать, ссориться).

**ҚЫЙҒЫЛ I: қыйғыл йалан** *минз.* кола ялан (пустыня, голая степь).

**ҚЫЙҒЫЛ II: қыйғыл төшү** *твр.* к.: **қыйғулау**. Қарт ман қыйғыл төшөп киттек тип сеүләте.

**ҚЫЙҒЫМА** *тара., брб.д.* ипи қыерчығы, кибән башы (горбушка хлеба).

**ҚЫЙҒЫР 1.** *злт.* карчыга (ястреб). Қыйғыр қара қарғаларны йарып қына ала айағы белән. Қыйғыр бәлеки қошларны қыйа; **2.** *перм.* лачын (сокол).

**ҚЫЙҒЫРУ** *брб.д., том.д.* **1.** кычкыру (громко кричать). Ник, мәға қыйғыртырсың? Пер бала қыйғырады. – *брб.д.* Қоростар қыйғырты. Тәрәзәснән Мәймүнә тип қыйғыр. – *яүшт.*; **2.** к.: **чакыру 4**. Қоростор (этәчләр) қыйғырты. – *яүшт.*

**ҚЫЙҒЫРУШЛАНУ** *бгрс.* канатлану, очыну (воодушевляться, радоваться). Йүри шулай йөри қыйғырушланып.

**ҚЫЙҒЫЦ** *брб.д.* туз кашык (берестяная ложка).

**ҚЫЙҒЫЧ-ҚЫЙҒЫЧ** *трх.* кыек-кыек (вкривь и вкось). Туқмачын қыйғыч-қыйғыч кисәләр.

**ҚЫЙҚА I** *минз., әстр.* терлек аякларының, башының өтелгән тиресе (палёная поверхность конечностей, головы и т.д. животных). Қуйның башын китерә, қыйқасын турап өләштерә. – *әстр.* Қыйқа тәме чыққан ашқа. – *минз.*

**ҚЫЙҚА II** *баст.* толым (коса). Қажний қыйқасына бишәр була маниты, элдергәннәр унлап кемешләрне. Чулпысы бер генә қыйқага эшләгән өч манит иде.

**ҚЫЙҚАЧ** *каз.ар.-крш., лш.* к.: **чапырыш 1.** Алдан түшлекне киделәр, аны өстеннән қәсилә киделәр қыйқачлап. – *каз.ар.-крш.*

**ҚЫЙҚУЛАУ** *злт.* кычкырып шаулашу (громко кричать, шуметь). Бөтөн awылга қыйқулап сүләшә. Зөһрә апа қысқырып қыйқулаб утыра, қыз йук, дип.

**ҚЫЙЛАНУ** *туб.-ирт.д.* маташу (делать вид, представляться). Пулышқан пулып қыйлана. – *тара*.

**ҚЫЙЛАУ** *себ.* тиресләү (унавозить). Пахцаны қыйлайwc. – *саз.я.*

**ҚЫЙЛЫ** *брб.д.* шактый (изрядно, довольно много). Йиләк қыйлы бар, пер йегермә төп. Пестән қыйлы тағы бичәләр бар. Қыйлы көннәр аурапты.

**ҚЫЙМА** *брб.д.* кештәк (ластовица). Көйләккә порноғыца қыйма қуй әле мәңа.

**ҚЫЙМАҚ** *нокр.* кабартма (булочка, слойка). Туйға иң йақшысы қыймақ инде аның.

**қылақ қыймағы** *нокр.* уртасын кисеп пешерелгән түгәрәк кош теле (один из видов хвороста). Қылақ қыймағын йымырқада ғына басалар ағ ынны, майда пешерәбез, пешә майда, урта бер тешен йырасын да, фурмы була.

**май қыймақ** *нокр.* к.: **қоймақ**. Иң йахшысы май қыймақ инде аның қунақларға. Май қыймагын ашағыз, дыружжийым ғына әйбәт булмады.

**ҚЫЙМАЛЫ** *брб.д.* қыйгач (косой, наклонный).

**ҚЫЙМРАУ** *твр.* кыймылдау (шевелиться, двигаться). Аны мәргәннәр аттылар, булар қыймрамадылар.

**ҚЫЙМЫҚЛАУ** *брб.д.* хәрәкәт итү (двигаться).

**ҚЫЙМЫЛДАУ** *мам.* аз-маз селкенү, әз-мәз йөрештерү, эшләштерү (ходить или делать что-нибудь понемногу, потихоньку). Абзар тирәсендә қыймылдыйм әкренгә, болай эшкә йөргәнем йуқ.

**ҚЫЙМЫЛ-ҚАМЫЛ: қыймыл-қамыл килеп** *минз.* селкенеп, әкренләп маташып (потихонечку шевелясь). Қыймыл-қамыл килеп баланы үстереп, үрәтеп үлде қайнанасы.

**ҚЫЙНАЛУ 1.** *тара.* борчылу, азаплану (испытывать затруднения, тяготы). Йулсыс қыйналып йатқаннар; **2.** *брб.д.* жәфалану (мучиться). Баш белән бер йыл қыйналдым.

**ҚЫЙНАУ 1.** *тара.* борчу (беспокоить). Сез сурашып мине қыйнайсыс қуй; **2.** *себ.* кыйнау (бить, притеснять); **3.** *трх.* сугу, бәрү (ударять, постукивать). Қыйнап-қыйнап қарадым бүрәнәләрне.

**ҚЫЙНАШУ 1.** *злт.* суғышу (драться). Қыйнашқан кеше ул үлгәнсе қыйнаша; **2.** *глз.* талашу – кошлар турында (клевать друг друга – о птицах). Қыйнашалар қазлар.

**ҚЫЙНДЫРАҚ** *злт.* к.: **қонжорыйқ**. Атны суйалар, тубығын кисеп алалар, тиресен тайаққа қуйып қороталар, аннан тегәләр.

**ҚЫЙРА 1.** *туб.-ирт.д.* к.: **азымтық**. Кем қыйра, шул йарлы пулған, кем эшләгән, шул йақшы торған. – *төм.* Қыйра гешенең йелткәсентә цоңқоро сур. – *тбл.* Қыйра қәсерге пала-waxра. – *саз.я.*; **2.** *том.д.* хәйләкәр (хитрый).

**қыйра(-м, -ң, -сы) килү** *себ.*, **қыйра тоту** *тбл.* к.: **қыйралану 1.** Итәнне йумайым, қыйрам киләте. – *төм.* Писәнеп, пуйанып йөрим, йөрәкәм, пер тә қыйрам килмәйте. Үсемне пик қыйра тотам. – *тбл.* Қыйралары киләте, эшләмәйтләр. – *тара.*

**ҚЫЙРАҚ** *тара.* к.: **қайрақ I.** Қыйрақны қайрақ белән имнәйләр, көйәнтәне атлағансың, арбаныңкын арышны (тәртәне) атлағансың тип.

**ҚЫЙРАЛАНУ 1.** *себ.* ирену, ялкаулану (лениться). Мин қыйраландым картуп утыртырға. – *твр.* Қыйраланып тормайты ғыслары, итәнен йуwаты, cowын китерәте. – *төм.* Қыйраланмаң, қыйраланмаң, тағын пер ләт пагыңцы. – *саз.я.*; **2.** *том.д.* хәйлә кору (хитрить).

**ҚЫЙРАЛУ 1.** *эчк.* кырылу, үлеп бетү (гибнуть в большом количестве); чаг.: **бетү I, 1; 2.** *брб.д.* ватылу (ломаться). Машинасы қыйралған та йулта қалған.

**ҚЫЙРАТУ 1.** *минз., тпк.* кыру (истреблять). Уткән ел bod қыйратты бодайны. – *тпк.* Халыкны қыйратып китте ақлар. – *минз.*; **2.** *мам.* кыру – күп ашау турында юмор белән (истреблять, уплетать, съесть очень много – с мягким юмором о тех, кто любит кушать); чаг.: **абжурлану; 3.** *брб.д.* вату (ломать). Сәғәтләрен қыйратып пөткән. Тәрәснең шешәләрен қыйратты.

**ҚЫЙРАШ** *тбл.* ялкаулык (леность, лень). Қыйраш килмәсә, йон ийерәм.

**ҚЫЙСАР** [*рус.*] *трх.* к.: **кусар.**

**ҚЫЙСТӘ** [*гар.*] *төм.* берәр нәрсәнең яки берәр кешенең кадерен белмәү, риза булмау аркасында җәзасын күрү, бәлагә төшү (наказание, несчастье как результат недовольства, неуважительного, непочтительного отношения к кому или чему-либо). Әпәйне пырғап қына ташлаған, ул аның қыйстәсен күрәте. Сақлап, әйбәтләп тотмасаң, қыйстәсен күрерсең.

**ҚЫЙТЫ** *блт., трх., дөб.* к.: **қойто.** Ул wахытта тормошлар да қыйты йы инде. – *блт.* Қыйты түгел, эчеп исереп йерми. Үзебез қыйты инде без. Ирләре қыйты. Ату, қыйты булсаң, җаратмам. – *дөб.* Безнең эти қыйты булған икән, ди. – *трх.*

**ҚЫЙТЫҚ** *минз.* қыйпылчык (осколок). Беднең чабар җир тегендә бер қыйтық, монда бер қыйтық.

**ҚЫЙТЫЛЫҚ** *дөб.* әшәкелек (скверность, мерзость, пакость, низость, подлость). Үлгәч бармақлардан да сорау алалар, ди, қыйтылық эшләмәдегезме?

**ҚЫЙУ I 1.** *лш., каз.ар.-крш., брб.д.* өс киеменең яка, каплама, итәк һәм җиң очы қырыйларына тотылган мех (меховая опушка на верхней одежде). Қама қыйулы туны бар. – *каз.ар.-крш.* Тун қыйуwы – *лш.*; **2.** *төм., тбл., брб.д.* кырпу (опушка). Қама қыйулы бүрек. – *тбл.* Тақйаның қолагы йук, қыйу салып тегелгән пайларда. – *брб.д.*; **3.** *төм., тбл., брб.д.* кайма. Қөйләк йағалары қыйулы. – *төм.* Пөрмәләренә қыйулар салып тисма мән, көйләк теккәннәр. – *тара.*

**ҚЫЙУ II** *лш., каз.ар.-крш., тпк.* өс киеменең яка читенә, җиң очларына, итәк очларына әйбер тоту (оторочить, окаймлять подол, воротник или рукава одежды чем-либо). Итәкләр мона унан, итәгенә қыйадыр ийек җифәк тасма. – *каз.ар.-крш.*

**ҚЫЙУ III** *әстр.* имләү, им-том итү (лечить знахарским способом).

**ҚЫЙУ IV 1.** *тара.* кисү (резать, разрезать); **2.** *туб.-урт.д.* ую, уеп тишек ясау (вырезать); **3.** *тара.* кыекка кисеп тегү, эшләү, ясау (выкроить, выкроить вкосую). Быцқақлары булған, төймәләре йалтырақ, йагасын полай қыйулап қуйа; **4.** *твр.* кисү (резать). Сүңгү сапқа қыйарлар бал аусақның йапрағы.

**қыйық қыйу** *каз.ар.-крш.* түбәне кыеклап ясау (сделать крышу со скатом, сделать скат крыши). Қыйығын қыйған – абзар, қыйығын қыймаған, туры җапқан лапас була.

**қыйып бару** *злт.* пространствоны кисеп чыгып бару, турыга бару (идти прямо, рассекая пространство, а не по дороге). Қыйа-қыйа барсагыз, тизрәк барасыз. Урманнарны қыйып баралар, қыйалап.

**ҚЫЙУ V** *себ.* **1.** к.: **вәке; 2.** терлек эчерер өчен ясалган озынча бәке (продолговатая прорубь, прорубленная, чтобы поить скот).

**қыйу тишү** *төм.*, **қыйу цәнцү** *саз.я.* бәке ую (прорубить прорубь).

**ҚЫЙУ VI** *төм.* к.: **қойу II.** Қыйарларға су қый.

**ҚЫЙУ VII** *тбл.* юл кую, каршы килмәү (уступать). Қыйамен нимә тейсә тә.

**ҚЫЙУ VIII** *лш.* к.: **буйлау 1.**

**ҚЫЙУЛАУ 1.** *туб.-урт.д.* кайма тоту (обшивать, окантовать). Көйләк йағаңны қыйулап қуй. – *төм.*; **2.** *перм.* к.: **қыйу II.** Қыйулаган фурмысында уқалар басып қалпаққа; **3.** *перм.* каю, сыпылмасын өчен тегеп чыгу (делать строчку; прострочить, чтобы ткань не сыпалась).

**ҚЫЙУЛЫ** *каз.ар.-крш.* кайма һ.б. тотылган (окантован, оторочен). Қыйулап тектерәләр тунны, қыйулы тун диләр ансын, сары тун булыр ыйы, қыйу қыйалар ийе аңар, қыйу җалтырawықлы нәстә ул.

**қыйулы царықпаш** *төм.* бизәкләр уелган, җөйгә кайма тотылган (окаймлённый, вышитый по швам). Қыйулы царықпашымны тәтәй (бабай) алыстан китерткән игән.

**ҚЫЙ-ЧУ** *яушт.* шау-шу (шум-гам).

**ҚЫЙШАМЧЫҚ** *минз.*, **ҚЫЙШАННАҚ** *злт.* кыланчык (кривляющийся, корчащий из себя кого-либо; кривляка, кокетка). Инәсе кебек қыйшаннақ. – *злт.*

**ҚЫЙШАННАУ** *бгрс., кргл., к.-уф., злт.* мактану, кылану (хвастаться, кривляться). Әңкәйем мында дип қыйшаннаған была қый. Қыйшаннама, әйдә йырыңны әйт! – *злт.* Қыйшаннап йөрмә әле монда, азрақ кешедән ойалырға кирәк. – *к.-уф.* Кит әле, қыйшаннап торма. – *бгрс.*

**ҚЫЙШАҢ** *төм.* к.: **қыйшамчық.**

**ҚЫЙШАҢЛАУ, ҚЫЙШАҢНАУ** *туб.-урт.д.* кылану, боргалану (кривляться, вертеться). Қыйшаңнап йөрөмә миңә. – *төм.* Қыйшаңнап йөри шал қатын. – *тбл.*

**ҚЫЙШАУ** *брб.д., тбл.* кыек булу (быть или стать кривым, изогнутым).

**ҚЫЙШЫҚ** *төм.* кыек (косой, кривой). Қыйшық йагалы гөйләкләр кигәннәр ирәнләр.

**ҚЫЙЫҚ I 1.** *брб.д.* кискәләнгән (изрезанный); **2.** *тбл., твр., саз.я.* чүпрәк кисәге (лоскуток). Курцаққа қыйықтан көйләк тек. – *тбл.*; **3.** *брб.д.* итәккә теккән кыек өстәмә (клин, вставленный в подол платья); **4.** *төм.* чабу (клин). Қөйләк қыйықлары.

**қыйық җаулық** *т.я.* к.: **кыйык II, 2.** Хәзер инде җепәк қыйық җаулық қына бәйли қызлар. – *к.т.*

**қыйық (кисеп таққан) итәк** *каз.ар.-крш.* к.: **чатыр: чатыр итәк.**

**қыйық төйәү** *перм.* исерү (опьянеть). Бар да қыйық төйәгәннәр, бер дә төз кеше йуқ.

**қыйыққа җару** *т.кам.-крш., каз.ар.-крш.* тукыманы диагональ кисү, кыеклап кисү (кроить вкосую, по диагонали ткани).

**ҚЫЙЫҚ II** *төм., тара.* кырыс, усал, кыргый – ат турында (норовистый, непокладистый – о лошади); чаг.: **қыйу VIII, буйлау 1.** Әшкәрә қыйық ат, менеп пулмайты өстенә.

**қыйық қаз** *баст., брб.д.* киек каз (дикий гусь). Қыйық қаз әйтәләр қыйықлаб очқанға. – *брб.д.*

**қыйыққа қарау** *лш.* ашарга күп сорау (просить много еды – в переносном смысле). Үрдәк алмыйм, қыйыққа қарый.

**ҚЫЙЫҚЛЫ** *каз.ар.-крш.* к.: **бөтүле.** Қыйықлы алҗапқыч.

**ҚЫЙЫҚЦА I** *тбл.* кош теленең бер төре (один из видов хвороста).

**ҚЫЙЫҚЦА II** *тбл.* кештәк (ластовица).

**ҚЫЙЫҚЧА** *перм.* к.: **путемар.**

**ҚЫЙЫМ I** *мам.* кечкенә итеп кисеп алынган кисәк, телем – ипи турында (маленький кусочек – о хлебе). Бер қыйым ипи ашамадың – эшме инде бу? Ике қыйым ипи салдым, кәҗә сауғач, сөт салдым самытыңы тутырып – туйасы булмады бу мәче.

**ҚЫЙЫМ II** *төм.* сәбәп, сылтау (причина, повод). Қыйым эстәп утырма.

**ҚЫЙЫНДЫ** *перм.* кыек, түбә кыегы (скат крыши). Азбар қыйындысы. Өй қыйындысы.

**ҚЫЙЫНСЫРАУ** *перм.* кыенсыну (не осмеливаться, стесняться). Ашаң, ашаң, қыйынсыраб ашамаң.

**ҚЫЙЫНТЫ 1.** *тбл., тара.* к.: **қыйынды; 2.** *тбл.* такта белән ябылган өй түбәсе (дощатая крыша).

**ҚЫЙЫР** *твр.* казык теш (клыки).

**ҚЫЙЫРЛАУ 1.** *каз.ар., к.т.* кылчыклы игеннәрнең, бигрәк тә арпа һәм борайның башагын көшелдә яңадан сугып йомшарту, сугып кылчыктан арындыру (отбивать, отделять усики злаковых растений, напр., ячменя). Арпа қыйырлау. Арпаны ғына қыйырлыйсың, арпа қылчықлул. Хәзер арпа камбайнында ук қыйырланып чыға, бороно қалмый. – *мам.* Борайны да қыйырлағаннар. – *к.т.*; **2.** *лш.* чамалау, исәпләү, уйлау (намереваться, думать). Китәргә қыйырлый; **3.** *дөб.* чәлдерү, әләктерү (стянуть, стащить). Әзерәк аны қыйырлағаннардыр да.

**ҚЫЙЫРСЫНУ** *перм.* кыенсыну (затрудняться). Чөнки әле wақ хәрефләрне қыйырсына иде (язарга).

**ҚЫЙЫУ** *төм.* кое (колодец).

**ҚЫЙЫШ** *себ.* **1.** кәкре (кривой). Айақлары қыйышма, төсмә? – *төм.* Айағы қыйыш булмасын өцөн, туры булсын өцөн пәйләгәннәр. – *тбл.*; **2.** кыек (косой, вкосую). Қыйыш йагалы итеп тегепте ирәннәрнеңке гөйләкне. – *тбл.* Қыйыш йақа. – *твр.*

**қыйыш қалбақ** *тара.* бер якка салындырып киелә торган калфак (женский головной убор – украшение калфак, конец которого свисает набок).

**ҚЫЙЫШЛЫҚ** *тара.* ялгышлык, гаеп (ошибка, вина). Кемнең нейтәй қыйышлығы бар, аны йасыб утыраты.

**ҚЫЙЫШУ 1.** *перм., злт., бөре.* маташу, азапланy (возиться, пытаться); чаг.: **итенү 2.** Элек имҗем итеп қыйышқаннар. Ашыйм дип қыйышқан була, қара әле (бала турында). Бақча йанында қыйыша. Қыйышмаң әле минең белән, wақыт йуқ. – *бөре.* Малайы алмасқа қыйышқан была. – *злт.*; **2.** *перм.* азапланy, интегү (возиться, мучиться); чаг.: **гүрләнү.** Қыш буйы қарап қыйышты шул сыйырын; **3.** *кргл., бгрс., бөре., злт.* к.: **иргәләшү.** Иске Йақупта (*ав. ис.*) ике мулла қыйыша икән шулай. – *бгрс.* Қыйышып китәбез икебез. – *бөре.* Бер дә йуққа қыйышалар. – *злт.*; **4.** *бгрс., кргл.* оршышу, талашу (ссориться); чаг.: **қыйалашу.** Ир белән хатын иртәнчәк қыйышалар, кичтән сөйләшәләр (*әйтем*). – *бгрс.*

**ҚЫЛАЙ** *трх.* кылый – күз турында (косой – о глазах). Қылай күзле дә төгөл инде, ақ төшкән күзенә.

**ҚЫЛАҚ** *нокр., глз.* колак (ухо).

**йылы қылақ** *нокр., глз.* к.: **қолақай.** Йылы қылақ ул, қычқырып сүлә.

**қылақтан бетү** *нокр.* чукраклану (стать глухим). Апам қылақтан бетте, ишетмәс булды.

**ҚЫЛАМПИТ** *т.кам.-крш.* буяуга манылган киндернең буй-буй итеп буяу тидерми калдырылган урыны (полоски на полотне, специально оставленные неокрашенными). Киндерне манғанда буйалмасқа тийеш урнын қарындық белән бәйли ийек, ул урны буйауға манылмый, қылампит була. Алҗапқыч бауларым қылампит, Биллəремне буwып тора бит (*хал. җыр.*).

**ҚЫЛАН** *брб.д.* ат кылы (конский волос).

**ҚЫЛАНЫҚ** [*рус.*] *трбс., себ.* себер көзәне (колонок). Қыланық килеп таwықларны буwып китте.

**ҚЫЛАП** *брб.д.* элгеч (вешалка).

**ҚЫЛАУ 1.** *злт.* яры (плёнка, оболочка). Күзне қылау қаплаған. Күзне қылау қапласа, күз күрми; **2.** *әстр.* к.: **қылған.**

**ҚЫЛБАҒЫШ** *яүшт., клм.* к.: **айбағар.** Қылбағыш май кәрәк салатқа. – *яүшт.* Қылбағыш қойашқа әйләнә, аның өчөн қылбағыш әйткәннәр. – *клм.*

**ҚЫЛ-БЫҒЫР, ҚЫЛ-БЫҒЫРДЫҚ** *лш.* җыелмаган, тәртипкә китерелмәгән (сорный, неубранный); чаг.: **болама 4.** Өйөбез қыл-быгыр. Бар әйбере шунда қыл-быгырдық.

**ҚЫЛБЫР** *перм.* ташның бер төре (один из видов камня). Ул йылғаның йарында қылбыр таш. Ишегалдым қылбыр таш, басқан сайын шатлансын (*хал. җыр.*).

**ҚЫЛҒАН** *том.д.* кылчык, сөяк – балыкта (рыбья кость).

**ҚЫЛҒАНАҚ** *том.д.* **1.** кылчык – ашлыкта (ость – у злаковых растений); **2.** к.: **қылған.** Қылғанақлы палық пы.

**ҚЫЛҒАНАХ** *саз.я.* к.: **қылған.**

**ҚЫЛҒОЙРОХ** *саз.я.*, **ҚЫЛҒОЙРЫҚ** *туб.-ирт.д.* үрдәкнең бер төре (шилохвость – порода уток). Қылғойрықныңқы муйыны оссон, икке йулах усаты аппах, қойроғо оцло. – *саз.я.*

**ҚЫЛҒЫНУ I** *брб.д.* тын бетү, тончыгу (задыхаться).

**ҚЫЛҒЫНУ II** *тбл.* кылану (кривляться). Қылғынмацы!

**ҚЫЛДЫЙН** *блт.* к.: **кийек I, 3.**

**ҚЫЛДЫЙ-ПЫЛДЫЙ** *дөб.* саксыз, ничек җитте шулай (небрежно, неосторожно, как попало). Баласын әзерәк қылдый-пылдый тотса да, абыйсы, әйбәт тот, эт баласы түгел ич ул, ди торганыйы.

**ҚЫЛЙАРА: қылйара төшү** *злт.* нык бәхәсләшү, үз сүзендә каты торып бәхәсләшү (биться об заклад, держать пари). Фатыйма әбийең қылйара төшә үзебезнең тawық дип.

**ҚЫЛҚА I** *лш., дөб., т.кам.-крш., бөре., злт.* иске, сәләмә (истрёпанный, старый, обносок, лохмотья). Өстөндә қылқа, суғыштан қайтқач кийеп қайтты. – *бөре.* Қылқа булса да өйөм, тушында қайтасы килә. Қылқа чүпрәкләрең җуқмы өстәл сөртөргә. Менә бу қылқаларны да кийеп қуйам инде мин. – *лш.* Өсләрендә қылқа кийем былды суғыш петкәс тә, ну уқырға тырыш былдылар балалары. – *злт.*

**қылқаға қалу** *т.кам.-крш., лш.* к.: **амалану.** Күлмәген қылқаға қалғанчы кийә. – *т.кам.-крш.*

**ҚЫЛҚА II** *лш.* к.: **кикрук.**

**ҚЫЛҚАЛАНЫП** *лш.* кикрик кебек булып, кикрик-кикрик булып (подобно гребню, как гребешки). Менә шулай қылқаланып үсә гармун күк қәтифә гөл.

**ҚЫЛҚАЛАНУ** *т.кам.-крш.* к.: **амалану.** Арыш қапчығыбыз тегермәнгә җөри-җөри қылқаланып беттинде.

**ҚЫЛҚАСАН** *туб.-ирт.д.* **1.** тоткалы кечкенә казан (маленький котёл с ручкой). Қылқасан кечкенә, өц-пиш литерлек қасан ул, бәтрә шикелле, қолағы та, тоткасы та бар. – *тбл.*; **2.** кечкенә чиләк – кыр эшләре вакытында ашарга пешерү өчен кулланыла (маленькое ведёрко для приготовления еды на полевых сельхозработах).

**ҚЫЛҚЫНУ** *дөб., кргл., бгрс.* к.: **қолқону 2.** Бер wахытны қылқындым да, бырыс сипкәс, шуннан бирле сипкәнем йуқ. – *дөб.* Куй итен қылқынып-қылқынып ашыйлар, күрсән. – *кргл.*

**ҚЫЛЛАУ** *дөб.* к.: **коннау.** Атлар қыллый, былтыр ғына имчәк тай икәү бар ыйы.

**ҚЫЛЛЫҚ** *минз.* җеп чорный торған кайры торпыча (мотовило из лубка, на которое наматывается пряжа).

**ҚЫЛМЫШ** *мам., т.кам.-крш.* к.: **итенеш.** Қылмышларын қара әле син боларның, қосасыны китерә бит. – *мам.* Қылмышыннан үләрсең шуның. – *т.кам.-крш.*

**ҚЫЛМЫШЛАНУ** *каз.ар.-крш.* кылану (рисоваться, представляться, изображать из себя). Қылмышланып җөргәнсез инде сүрәкәләр кийеп.

**ҚЫЛНЫР** *твр.* үҗәт, кире (упрямый); чаг.: **тирес 4; кирәмәт 2.**

**ҚЫЛТ: қылт итеп қалу** *тпк.* үпкәләү, турсаю (обидеться, надуться). Бер сүd әйттисә, қылт итеп қала. Пер сүd әйтер хәл йуқ, қылт итеп қала.

**ҚЫЛТАЙТУ** *т.я.* **1.** аз гына ачып кую (приоткрыть, открыть немного). Өйгә төтен чықты, ишекне бераз қылтайтып қуйдым. Сөтөң қайнар булса, қапқачын қылтайтыбрақ җап, тиз сүwыр. – *к.т.*; **2.** янтайту (кренить, наклонять). Қашық тықма инде сөтөңә, чүлмәкнең қырыйыннан ғына қылтайтып сал. – *к.т.*

**ҚЫЛТАЙУ 1.** *т.я.* к.: **йалпайу II.** Өйләре тузған инде, бөтөннәй бер йаққа қылтайа башлаған. – *к.т.*; **2.** *т.я.* аз гына ачылып тору, тыгыз ябылмау (плотно не закрываться, быть приоткрытым – о крышке, двери, окне и т.д.). Кәчтерүл қапқачы қылтайған, әллә мәче ачқан? – *к.т.*; **3.** *перм., минз.* к.: **киберләнү; 4.** *минз.* к.: **итенү 1.** Утыр әле қылтаймый ғына. Йә, қылтайма! Қылтайып қына ырғытқач, булмады; **5.** *тбл.* к.: **қалыйу 2.**

**ҚЫЛТАЛЫҚ** *бөре.* тегермән мөшкәсенә салынган ашлыкның ташка тигез төшеп торуын булдыру өчен куелган җайланма (приспособление на мельничном лотке, регулирующее проход зерна на жернова).

**ҚЫЛТАМАҚ** *тбл.* талымлаучан, сайлануучан, нәзберек (разборчивый – в еде).

**ҚЫЛТАМЛАНУ** *перм.* к.: **киберләнү.** Уғата қылтамланма инде.

**ҚЫЛТЫҚ 1.** *т.я.* кыек, кыйшык, тигезсез (кривой, неровный, наклонный). Қылтық идән. – *к.т.*; **2.** *мам., блт.* к.: **қыйшамчық.**

**ҚЫЛТЫЛЛАНУ** *дөб.* к.: **итенү 1.** Шәһәрдә бер йыл торғаны йуқ, қылтылланып җөри.

**ҚЫЛТЫМ** *перм., минз.* к.: **кибер.**

**ҚЫЛТЫН 1.** *к.т.* к.: **қылтық 1.** Нишләп қылтын соң бу сәке?; **2.** *бәр., блт., дөб., мам.* к.: **йақлы.** И, дөнйада бер қылтын ыйы инде. – *дөб.* Қызлары бик қылтын нәстә. – *мам.*; **3.** *дөб.* мактанырлык, шәп (хорошо, замечательно, дающий право хвалиться). Әwәле туйлар да бик қылтын түгел ийе.

**ҚЫЛТЫНЛАНУ** *дөб.*, **ҚЫЛТЫННАНУ** *мам.* к.: **итенү 1.** Қылтынланып җөри, җақланып. – *дөб.* Җарар инде, қылтыннанма. – *мам.*

**ҚЫЛТЫННЫҚ** *дөб., мам.* кыланчыклык (кривляние, привычка кривляться). Әле қылтынныгы бетмәгән. – *дөб.* Бу қылтынныгың белән әллә ни эш майтара алмассың әле. – *мам.*

**ҚЫЛТЫРАУ** *злт.* борчылу, шөбһәләнү (беспокоиться, подозревать). Мине килми дип қылтырап торасызмы?

**ҚЫЛУ** *туб.-ирт.д.* **1.** итү (делать, превращать). Қамыр қылаты сөттән, майтан, йоморқатан. – *тара.* Кеце энем пер йыл қысмәт қылты. – *твр.* Эй, нүгәрләр, керең, қысым Алийә цумар қылған тите. – *төм.*; **2.** ясау, эшләү (делать, мастерить). Тейеннекеннән тә тун қылғаннар. – *тбл.*

**некә қылу** *тбл.* никах уку (совершить обряд бракосочетания).

**ҚЫЛ-УРТАҒЫШ** *блт.* кыл урталай, тип-тигез (ровно пополам, поровну); чаг.: **кылма-кыл.** Қыл-уртағыш: тегесенә дә алтмыш, моносона да алтмыш буразна.

**ҚЫЛЦЫҚТАУ** *том.д.* кытыклау (щекотать).

**ҚЫЛЧАҚ** *лш.* кәлчәк (чехонь).

**ҚЫЛЧЫҚ** *брб.д.* төк (шерстинка).

**ҚЫЛЧЫҚЛАУ** *брб.д.* үчекләү (дразнить). Кылчыкләп йата торған ийе картатам. Қылчықлап, көлдөрөп бала-бақраны көлдөрә тегән.

**ҚЫЛЧЫРУ** *твр.* ката, картая башлау – печән, үлән турында (затвердевать, начинать высыхать – о растениях).

**ҚЫЛЫ I** *тбл., саз.я.* чиләк бавы (ведёрная дужка, перевесло). Пәтрәмнең қылысы сынып цықты.

**ҚЫЛЫ II: қылы йақ** *минз.* елганың аргы ягы (противоположный берег, противоположная сторона – у реки).

**қылы урам** *минз.* елга аръягындагы урам (улица, расположенная на противоположной стороне реки).

**ҚЫЛЫЙ** *блт., мам.* кыек, тигезсез – тән төзелеше һәм кием турында (кривой, косой, неровный, асимметричный – о строении тела и об одежде); чаг.: **қылтық 1.** Минем йақа қылый тормыймы? – *блт.* Қыса йақасы да қылый, йупкы атламасын да қылый теккән. – *мам.*

**ҚЫЛЫЙҚА** *перм.* к.: **йадау.**

**қылыйқаға тийү** *перм.* жанга тию (надоедать, назойливо приставать).

**ҚЫЛЫЙШ** *перм.* к.: **қуwақ I, 2.**

**ҚЫЛЫҚ I** [*удм.*] *нокр., т.кам.-крш.* утыра торган – тавык турында (наседка). Бақчаға қылық тawық кергән, қуwалағыз әле. – *т.кам.-крш.* Қылық тawығым үлгән. – *нокр.*

**ҚЫЛЫҚ II** [*гар.*] *себ., каз.ар.* холык (нрав). Бигрәк тә начар инде аның қылығы. – *мам.* Йаман қылық, йаман пәйел пулаты. – *тбл.*

**ҚЫЛЫҚЫЛАУ** [*удм.*] *нокр.* к.: **қортлау II.** Алтысы қылықылай тawықларым.

**ҚЫЛЫНМЫШ** *кмшл.* к.: **итенеш.** Қылынмыш – қырық көнгә бер килмеш (*әйтем*).

**ҚЫЛЫНУ** *т.я., каз.ар., кмшл.* к.: **итенү 1.** Нигә дип шулай қылына икән бу қыз? – *к.т.* Қылынма әле, әйтсәң, тизрәк әйбәтләп әйт тә, барып қарарбыз. – *мам.* Қылынып сөйләшкән була. – *лш.*

**ҚЫЛЫНЧАҚЛАУ** *нокр.* к.: **коннау.**

**ҚЫЛЫП I** *тбл.* канат – балыкныкы (плавник).

**ҚЫЛЫП II** *тбл.* к.: **қылы I.**

**ҚЫЛЫР** *брб.д.* кыек (кривой, косой).

**ҚЫЛЫХ** *саз.я.* к.: **қылық II.**

**ҚЫМ** *минз.* ният (намерение). Андый қымы йуқтыр.

**ҚЫМАҚ** *нокр.* к.: **йалман 1.**

**күссез қымақ** *нокр.* к.: **әндәк.**

**ҚЫМ-ҚЫРЫЧ** *т.я., лш.* к.: **қором-қырыс.** Үземә эшем қым-қырыч чақта син жөрисең. – *к.т.* Қым-қырыч чақ шул. – *лш.*

**ҚЫМЛАУ** *тбл.* кыймылдау (шевелиться, кишеть). Қортларың қымлайма эллә, тыныц утыр.

**ҚЫМРАУ 1.** *тара., брб.д.* кыймылдау (шевелиться). Қатыны қымрамый та, кем йеңсә, мин аныңқы, ти; **2.** *твр.* кыймылдату, селкетү (пошевелить). Мин айақны қымрый та алмам.

**ҚЫМРӘШ** *саз.я.* балыкны ашый торган корт (жук-водолюб).

**ҚЫМРЫСҚА** *т.я., туб.-урт.д.* кырмыска (муравей). Қымрысқа ойалаған, ахры, идән астында: үләбез инде, шикарға қымрысқа жыйыла. – *к.т.* Қымрысқа дим мин, берише қырмысқа да дип әйтә. – *трх.*

**ҚЫМСЫНУ** *т.я.* ымсыну, теләп калу (искушаться, соблазняться, порываться); чаг.: **қым.** Қычқырырға қымсынып қалдым тәки. – *к.т.* Чақырырға да қымсындым, эш килеп чықты. – *нрл.*

**МАТИКЛАУ** [*рус.* мотыга + *афф.* -лау] *т.я., минз., тпк., чпр., чст.* к.: **кәтмәкләү.** Бәрәңге бакчаларымы матиклап чыктым. – *минз.* Бакца матиклап кердем генә әле. – *чпр.*

**МАТИС I** [*рус.* аметист] *төм., тбл.* кашлы алка (серьги с камнем). Матис сырга титләр ите, әйбәт матис нимәле ите wы.

**МАТИС II** [*рус.* матица] *чст., мәл.* сәдәп (пуговица); чаг.: **акташ 1.**

**МАТИЧ** [*рус.* мотыжить]: **матич итү** *мәл.* к.: **кәтмәкләү.** Бүген бәрәңге матич иттем әле.

**МАТКА** [*рус.* матка] **1.** *кузн., чст., карс., тмн., т.я.-крш., әстр., брб.д.* к.: **арғалық I.** Кирпеч мөржә чыгаргач, маткага awырлык төшә. Бишекне маткага тагарга йарамый. – *кузн.* Матка турысына утыра башкыда. – *тмн.* Маткага агац алган идем, шоны алып кат'асы бар. – *чст.* Матка астына куйалар бер тәңкәлек кемеш. – *карс.* Сугыштан соң маткалыклар эзлибез. – *әстр.*; **2.** *кузн.* к.: **арата 1.** Өч матка куйалар, басып йөрисең, икесе башта, угылларда. Лапас маткасы.

**МАТКАП** *әстр.* к.: **җәмкә.**

**МАТКЫ** [*рус.* матка] *клм.* к.: **арғалық I.**

**МАТҚЫУ** *тбл., твр.* йокымсырау (дремать). Пала матқып утыра.

**МАТЛАНУ** *минз., перм.* азаплану, интегү, җәфалану (стараться сделать что-либо, мучиться чем-либо); чаг.: **бәлтерәү.** Кире алырга матланған чағында ботоның итен алған. – *минз.* Ничек орчоқ эрлибез ий, киндер суғып матланабыз ий. – *перм.*

**МАТЛИК** [*рус.* маточник] **1.** *лмб., кузн.* к.: **арата 1**; **2.** *карс.* к.: **арғалық I.**

**МАТЛИЧА** [*рус.* матица] *лмб., кузн.* к.: **арғалық 1.**

**МАТРАУ** *тмн.* ою (онеметь).

**МАТРАШУ** *кузн.* бөрешү (съёжиться). Сывыкка күрә вис айак-кулларым матрашкан.

**МАТРҮНӘ** [*рус.* матерника] *лмб.* к.: **йылыwыт.** Урманга барган идем, матрүнә эзләдем.

**МАТУК I** [*рус.* моток] *злт.* к.: **катук I, 1.**

**МАТУК II** [*рус.* мотыга] *лш.* к.: **кәтмәк 1.** Матук белән бәрәңге төбөнә өйәләр.

**МАТУР I 1.** *лмб., кузн., хвл.* үткен, җитез, оста, булдыклы (бойкий, проворный, умелый); чаг.: **чирак.** Кыз матур булган: белә кийәвнең йывашлыгын, аны крупчатка он сусигына салган (*әкият.*). – *кузн.* Ну матур карчык инде, аның белмәгәне йук. Укыган кеше булган үзе, матур булган. Алимә үзе матур ул бик. – *хвл.* Мин бик матур идем эшкә, майларым. Минем бу кыз укырга матур иде. – *лмб.*; **2.** *нрл., кргл.* тәмле, хуш исле (ароматный, душистый, пахнущий). Матур исле ул ландыш. – *нрл.* Исе дә матур ул баланың. – *кргл.*; **3.** *нрл.* яхшы, әйбәт (хорошо; хороший). Матур булдыйы бәрәңге. Бездә һәрwакыт матур бит. Самый җирнең матурын кисеп бирделәр; **4.** *хвл.* усал (злой); чаг.: **зәңки.** Әмән матур кочок, чиптагы кочок.

**МАТУР II** [*рус.* мотор] *сазл.* моторлы көймә (моторная лодка). Матур пулмаса ицхайта пару йух.

**МАТУРАЙУ** *кузн., хвл.* **1.** үткенлек күрсәтү, булдыклыланып китү, остарып китү (стать бойким, умелым, проворным); чаг.: **чирақлану**; **2.** *хвл.* к.: **борнайлану.** Бик матурайма; **3.** *хвл.* усалланып китү (стать злым).

**матца** [*рус.*] *чпр.* матча (матица):

**идән матцасы** *чпр.* өрлек (балка, перекладина). Идән матцасын илттереп куйды фылантка.

**МАТЧА** [*рус.* матица] *т.я.-крш.* түшәм (потолок). Ызба җуwас диләр дә, мин әтәм, тагы матчаларны туздырмалы, дим.

**awыз матча** *т.я.-крш.* к.: **қамақаш.** Аның awыз матчасы йарык иде туганда.

**матча йаулыгы** *бгрс.* к.: **каршага.**

**матча майы 1.** *перм.* йортны бурап бетергәч, матчаны күтәргәндә, аның бер башына тагып менгерелгән һәм балта осталарын сыйлауга билгеләнгән май (когда последний венец положен и поднимают матицу, на один конец её подвешивают масло – «матичное масло», которым потом угощают плотников). Матча майы ашыйлар, бай булсын дип, сыйырсыз тормасын дип; **2.** *дөб.* матча күтәргән көнне балта осталарын сыйлау мәҗлесе (пир, устраиваемый для плотников и др. участников в день поднятия матицы); чаг.: **ботқа: нигез ботқасы.** Бүген матча майында сез, җегетләр, қарап силаныгыз.

**матча фәрдәсе** *минз., стрл.* к.: **каршага.**

**МАТЫЙК** [*рус.* мотыга] *хвл.* к.: **кәтмәк I.**

**МАТЫЙКЛАУ** [*рус.* мотыга + *афф.* -лау] *хвл.* к.: **кәтмәкләү.** Беген инде кичкә тике матыйклыйм, ди.

**МАТЫЙТ** [*рус.*]: **матыйт итү** *карс.* к.: **күтәрү 1.**

**МАТЫНДА** *минз.* к.: **сартын 3.** Нәрсә матында җыйылыш булды?

**МАУ-МАУ: мау-мау итү** *м.-кар.* сыер саву – балалар телендә (доить – в детской речи). Әйдә сыйырны мау-мау итик.

**МАХАН** *тбл.* ат ите (конина).

**МАХЛЫҚ** [*гар.*]: **сыйыр махлыгы** *тара.* сыер кисәге (подобие коровы). Сыйыр махлыгы пар.

**МАХМАЛ 1.** *сазл.* к.: **қатыба**; **2.** *әстр.* бәрхет (бархат). Махмал күлмәк.

**МАҺМАЛ** *твр.* к.: **қатыба.**

**МАЦЫ** *срг., чпр., чст.* мәче (кошка). Мацы баллаган, дүрт мацы баласы – чыбарлар. – *срг.* Мацы мур кергән пүгрәпкә. – *чпр.*

**мацы йафрагы, мацы әләге** *срг.* к.: **бырцак: бырцак үләне.**

**МАЧ: мач китерү** *каз.ар.-крш.* туры китерү (застать). Кичә агранумны мач китерә алмадық, бүген генә алдық әле.

**МАЧАЛАУ** *мам.* типчү, типчеп ямау (штопать). Ойоқларны мачаларга кирәк кич белән.

**МАЧАУ** *минз.* ямау (зашить, залатать, сделать заплату); чаг.: **зимнәү II**. Җеб белән генә мачадыңмыный?

**МАЧИНЧА I** [*рус.* Масленица] *нокр.* к.: **майлыкай: майлыкай гөрәзнәй**.

**МАЧИНЧА II** *нокр.*, **МАЧТА** [*рус.* матица] *трх.* к.: **арғалық I**.

**МАЧТАЛАУ** [*удм.*] *глз.* к.: **керәү**. Печән мачталадык.

**МАЧТУРА** *трх.* к.: **бырцак: бырцак үләне**.

**МАЧЫ I** *лмб., кузн., хвл., трх.* к.: **мацы**. Бик тагын, мачыларга ача йөримен ишек. Мачы тәрәзәдән кергән. – *кузн.*

**мачы баш(ы)** *лмб.* к.: **бабалаш**. Иртә тырып тышка чыгам, Мачы баш кунган ү башына (*хал. җыр.*).

**мачы йафрагы** *мәл., чст.* к.: **бырцак: бырцак үләне**.

**мачы курик** *хвл.* к.: **мачы тарысы**.

**мачы печи, мачы пычи бырчагы, мачы пычи җафрагы** *нрл.* к.: **бырцак: бырцак үләне**. Мачи печи бусы, түгәрәк. Мачы пычи җафрагын сал җуwып, ди. Мачы печийен ашадык бала wахытта.

**мачы пәрәпәче, мачы табаны** *блт.* к.: **бырцак: бырцак үләне**.

**мачы тарысы** *нрл.* песи тарысы (амарант, ширица).

**МАЧЫ II** *мәл.* ыргак (крюк, зацепа).

**МАШ** *трх., каз.ар.* каланча (башня, вышка наблюдения). Мин белгәндә awылда ике маш бар иде әле. – *трх.* Машқа менеп қарасаң, бөтен тирәйақ awыллары күренә. – *мам.*

**МАШАКАТ** [*гар.*] *тмн.* мәшәкать (забота, хлопоты).

**машакат уздыру** *тмн.* мәҗлес җыю, мәҗлес уздыру (устроить званый обед).

**МАШИНА** *минз., стрл.* сепарат (сепаратор).

**күмәле машина** *стрл.* **1.** өсте ябулы машина (крытая машина); **2.** «газик» («газик»).

**кытумка** [*рус.* котомка] **машина** *перм.* кечкенә фургонлы машина (маленький фургон). Кытумка машинаға ике кеше утыра, тын бетә артында йабық булғас.

**машина тегү** *минз., стрл.* тегүчелек белән шөгыльләнү (заниматься портняжничеством). Машина текте гөмөр буйы. – *минз.*

**МАШИНАЧЫ** *минз., стрл.* к.: **кеймемче**. Уллары да машиначы йы. – *минз.*

**МАШКА-МАШКА** *тара.* сарык, кәҗә куу ымлыгы (междометие, которым пользуются, когда отгоняют овец и коз).

**МАШ-МАШ** *тара.* к.: **баш-баш**.

**МАШТАҚ** *әстр.* к.: **ашақ I**.

**МАШТАЛАУ** [*удм.*] *нокр., глз.* **1.** тырмалау, тырмалап җыю (сгребать граблями). Печән машталадык. Печән машталама йердек. – *нокр.* Печән машталый тырган мажислар. – *глз.*; **2.** к.: **аткару 4**. Эзәнне машталап қына алдым. – *нокр.*

**МАШЧА** [*рус.* матица] *хвл., мәл.* к.: **арғалық I**. Машча турысында кургаш кой. – *хвл.*

**МӘ** *перм.* **1.** әйбер, нәрсә (вещь, предмет; что). Миңке малым җуқ, бер мәм дә. Магазинда нимә бар, бөтен мәне алар ала башлап; **2.** ни, ник (как, почему). Мә хәлдә йатасың тип хәл белмәгә керә wыл. Моңа чақ мә әйтмәдең?

**МӘӘР** [*гар.*] *тбл.* мәһәр (калым). Мәәр түләү гәрәх булған атинәсенә.

**МӘWӘТ** *твр.* к.: **мөйәт**.

**МӘWЕРЛӘП** *том.д., тбл.* бизәкләп (украшая, делая узоры). Гейәүгә ғыйық төшереп ойоқ пәйләгәннәр, цигеп-цигеп мәwерләп пәйләгән тыың әйбәт итеп. – *тбл.*

**МӘWЕРЛЕ** *каз.ар.-крш.* һәвәс, тырыш (склонный к чему-либо, старательный). Қәзер бәндә әшкә мәwерле.

**МӘWЕРТХЕ** *саз.я.* кечкенә опты (маленький язь).

**МӘГӘ** *перм.* нигә (зачем, почему).

**МӘҒӘЗИ** [*гар.*] *злт.* к.: **мағази**. Мәғәзигә халықтан йыйған ашлықны салалар. Мәғәзигә машина йөрөп тора.

**МӘГӘЛӘЙ** *брб.д.* к.: **мийәли**.

**МӘҒӘС** *тбл.* к.: **гелән**. Мәғәс йырлатып утырсаң та, пер тә теңкәгә тимәс ите таwышы.

**МӘДӘ** [*гар.*] *брб.д.* билге, тамга (признак, примета).

**МӘДӘГӘН** *чст., мәл.* хәлсезләнеп аяктан егылган – сарыклар турында (обессиливший – чаще об овцах).

**МӘДӘК** [*фарс.*] **1.** *хвл.* чатыр (шатёр). Чиганнар мәдәкләрен корганнар. Чиган мәдәгеннән йыгылып төшкән; **2.** *хвл.* хатын-кыз мәетен зиратка күтәреп илткәндә, аның өстенә чатыр сыман итеп корылган җайланма (устройство наподобие шатра, под которым несут покойницу на кладбище); **3.** *срг.* яшь киленне егет өенә алып килә торган өсте ябулы арба, кибитка (кибитка, крытая повозка, в которой раньше перевозили невесту в дом жениха); чаг.: **кимә**. Кийәүле барганнар мәдәктә. Ызаталар алаша белән мәдәкләр кырып; **4.** *чст., т.я.-крш.* к.: **күмә 2.**; **5.** *чпр.* к.: **йәпләшкә**. Мәдәк ике кул′асалы була. Үләмне мәдәк белән ташыйлар, урак белән урып.

**мәдәг арба** *чст.* к.: **күмә**.

**МӘДӘКЧЕ** [*фарс.* + *афф.* -че] *хвл.* чүпрәкче (тряпичник).

**МӘДӘЛӘҮ** *брб.д.* билгеләү, тамгалау (пометить).

**МӘДӘР** [*гар.*]: **мәдәр китү** *хвл.* хәлсезләнү, хәл китү (терять силы). Мәдәрем китте.

**МӘДӘТ** [*гар.*] **1.** *карс.* «Ходай үзе ярдәм итсен» мәгънәсендәге ымлык сүз (междометие в значении «да поможет Бог»). Мәдәт, анай, беләсеңме, күзләре терткән тучка инде; **2.** *тбл.* көч, хәл (сила).

**МӘДӘТЛӘНҮ** [*гар.* + *афф.* -лән ү] *лмб.* к.: **хыйтлану**. Мәдәтләнәбез, бер чиләк су кергезәм, утынны кергезәм.

**МӘДӘҮ 1.** *хвл.* егылу, авып китү (падать, сваливаться). Тик торганда мәдәде; **2.** *стрл., минз.* терлекнең сыртка егылуы – гадәттә сарыкларның (падать на спину – чаще об овцах). Без мәдәмибез, мал гына мәди. Мәдәп торалмыйча үлә дә чокырга төшә. – *стрл.* – Нишләп торалмый ул сарык? – Мәдәгән. – *минз.*

**МӘДЕХЛЕ** [*гар.* + *афф.* -ле] *трх.* кызыклы, күңелле (интересный, славный, забавный). Элек мәдехле иде инде печән җыйулар.

**МӘДЕҺЛЕ** [*гар.* + *афф.* -ле] *кас.* данлы, күренекле, мактаулы (прославленный, знаменитый). Мәдеһле ’еше.

**МӘЖ: мәж төшү** *яүшт.* мәш килү (переполошиться; копошиться). Мәж төшәләр бит уйнап. Мәж төшеп сөйлиләр.

**МӘҖӘЛ** [*гар.*] *минз.* мөмкинлек, җай, рәт (возможность). Бернәрсәгә мәҗәле калмады ул бахыркайның.

**МӘҖӘЛ: мәҗәлем җу’** *кас.* хәлем юк (нездоровится мне, слабость у меня). Бе’ен мәҗәлем җу’ра’ла.

**МӘҖЕ: мәҗе йасау** *карс.* изү, сыту (давить, задавить, раздавливать). Кан′нарын чыгарып микән мәҗе йасаганнар. Туң җир умырылып мәҗе йасаган тәтәсен.

**МӘҖЕКАЙ** *карс.* эчәк пирогы (пирог из требухи).

**МӘҖИКӘЙ** *кузн.* к.: **кукыл′**. Әни мәҗикәй пешерә.

**МӘҖҮ** [*угор.*] *төм.* к.: **пожу**. Кысылцаны та баста тоту гәрәк, мәҗеп кала ғуй.

**МӘЗӘК** [*гар.*] *чпр.* яшьләр кичәсе, аулак өйдә үткәрелә торган кичә (посиделки; вечеринка, молодёжный вечер, проводимый в отсутствии старших); чаг.: **бастаңгыр**. Күрешсә, шул мәзәктә генә күрешә. – Мәзәгегез түгәрәк булсын! – Бергә булсын!

**мәзәк утырып йөрү** *чпр.* яшьләр кичәләрендә катнашу (бывать на посиделках, вечеринках). Без анда мәзәк утырып йөри идек иптәш кызлар белән.

**МӘЙГЕ** *каз.ар.-крш.* к.: **бәйге 1**. Татар қатынқызлары мәйгегә бара алмады, безнең керәшеннәр генә қалмады.

**МӘЙДАН** [*гар.*] *мәл., чст., мам., лш., минз., нокр.* сабан туе (сабантуй). Безгә мәйданга килгән иде, шул тегелдер бит? – *мәл.* Күршаwылда мәйдан була бүген. – *мам.* Бөтен мәйданда булған әйберне бирделәр миңа. – *лш.*

**кичке мәйдан** *минз., лш.* сабан туе көнне кич белән призга уздырыла торган уеннар, җыр һәм бию ярышлары (спортивные игры, состязания, устраиваемые вечером в день сабантуя). Кичке мәйданға чыққанда ансын салдым да монсон кидем. – *лш.*

**мәйдан җыйу** *дөб.* сабан туе алдыннан бүләк җыю (сбор подарков от населения накануне сабантуя). Бүген мәйдан җыйалар. Мәйдан җыйалар қычқырып, җаулық бирсән, җаулық ала.

**МӘЙЕЛ** *тара.* ихтыяр (воля). Эценмәсән, мәйелең, қыстамайым.

**МӘЙЕР** [*гар.*] *төм.* эчкерсез, ачык (искренний, откровенный, прямодушный). Қалығыбыз беснеке мәйер, шантай килгән кешләрне қунақ итәде.

**МӘЙЕРМӘН** [*гар.*] *тбл.* миһербан (сострадание, милость, великодушие).

**МӘЙЕТСЕ** [*рус.* маяться]: **мәйетсе булу** *лш.* к.: **хыйтлану**. Алар белән мәйетсе булып утырыр хәлем йуқ.

**МӘЙЛЕ** [*фарс.*] *кргл.* шулай (так). Мәйле, мәйле, үзең беләсең.

**МӘЙЛЕС** [*гар.*] *тара.* сый, мәҗлес (званый обед, пир).

**МӘЙЛҮН** *минз.* к.: **миңгерәү**. Битенә мәйлүн булған.

**МӘЙХӘНӘ** [*гар.*]: **мәйхәнә килү** *т.я.* мәш килү, кайнашу (суетиться, возиться). Минем қаз бәпкәләрем бар бишәүләп, мәйхәнә киләсен шулар белән. Өйдә римунты бара, мәйхәнә китерделәр. Мәйхәнә киләдер ийе шул әбийең. – *нрл.*

**МӘК** *тбл.* көч, куәт (сила, мощь). Пар мәгеңә қыцқыр.

**МӘКӘ: мәкә қына** *тбл.* хаҗ кынасы (разновидность бальзамина).

**МӘКӘДЗИ** *брб.д.* алдакчы (обманщик).

**МӘКӘЙ 1.** *мам.* чикләвек бөресе (почки на ореховом кусте). Җегерме беренче җылғы ачлықта мәкәй дә ашадық; **2.** *минз.* к.: **бәбәк II**; **3.** *минз.* к.: **әкәлә 2**; **4.** *минз.* к.: **әкәлә 2**. Шыршы мәкәйенә барған кешене дә тота торган ыйы. Хәзер бар микән инде аның мәкәйе, бер дә искәргәнем җуқ, қайыннығ арқылы җөрим инде.

**МӘКӘЙЛӘҢҮ** *каз.ар.-крш.* чәчәк сабагы җибәрү – суган турында (пускать стрелу – о луке). Бу суған ник мәкәйләнә икән?

**МӘКӘЛӘҮ** *брб.д.* алдау, хәйләләү (обмануть, перехитрить).

**МӘҚӘМ** [*гар.*]: **мәқәм итү** *минз.* тамак ялгау (слегка закусить, поесть немного). Шуның белә мәқәм итеп, шуның белә тордоқ.

**МӘКӘР** *эчк.* к.: **матур I, 1**. Хәзердәге халық бик мәкәр.

**зур мәкәр** *хвл.* к.: **аз′ау**. Выт зур мәкәр.

**МӘКЕ I** *бөре., минз., тпк., трбс.* к.: **вәке**. Мәкеләр тишәләр әйбәт суға. – *трбс.*

**МӘКЕ II** [*рус.* мак] *мәл.* мәк (мак). Мәкедә йөрдек, мәке куwатлы.

**МӘКЕС** [*гар.*] *брб.д.* начар (плохой); чаг.: **нәкәс 1**. Малайлары мәкес, эчәләр.

**МӘККӘЙ** *хвл.* куырылган кукуруз (жареная кукуруза).

**МӘҚРҮМ** [*гар.*]: **мәқрүм итү** *каз.ар.-крш.* мыскыл итү, мыскыллау (насмехаться, издеваться). Мәқрүм итеп җәртмәссез минем кәртечкәне. Мәқрүм итеп ут җағып китәр.

**МӘКСӘРҮ** *мам.* бәсәрү (заиндеветь, покрыться инеем). Базның стенасы җәйен мәксәрә.

**МӘЛ** [*гар.*] **1.** *дөб., мам., кмшл., себ.* мөмкинлек, җай, рәт (возможность, удобство). Түзәргә мәл йуқ. – *кмшл.* Тырактырлар, машиналар – атлап чығарлық мәл җуқ. – *мам.* Ғәдәтләнмәгән кешенең мәле булмый. Эшкә өйрәнмәгән, мәле йуқ. – *төм.*; **2.** *себ.* вакыт (время). Пы кәртечкәне ул Қасанта уқыған мәлентә төшкән. – *төм.*

**МӘЛ′АВЫН** *хвл., кузн.*, **МӘЛ′АГАН** *тмн.*, **МӘЛӘВЕН** [*гар.*] *тмн., кузн., срг.*, **МӘЛӘWЕН** *чпр.*, **МӘЛЕГЕН** [*гар.*] *кмшл.* мәлгунь (проклятый, окаянный). Йөзең кара, мәл′авын, йук бул! – *хвл.* Айучылар-бағучылар, Алар бигрәк залимчылар, Туктамыйлар мәл′аганнар. Битемә кара йагалар (*бор. җыр.*). Кайа үзләре, мәләвеннәр? Мулла кызы мунча йага, Айучы тирәздин бага; Ни мәләвен, син багасын? Битемә кара йагасын (*бор. җыр.*). – *тмн.* И мәләwен, Алла каргаган алаша бу. – *чпр.* Шулхәдәр қаты итеп йапмаса, мәлеген. – *кмшл.*

**МӘЛӘКӘЙ 1.** *блт.* к.: **безрәк**. Мәләкәй генә

җатыб алыйм; **2.** *нокр.* к.: **йастык I.** Кызны бөркәүле күмәгә утыртып баралар. Күмәгә кызның т′аршовы әлгән була, кыз йанға эке мәләкәй куйалар.

**МӘЛӘНЧЕК** *т.кам.-крш.*, **МӘЛӘЧЛЕК** *каз.ар.-крш.* керәшен хатыннарының яулык астыннан кия торган баш киеме (головной убор крещёных татарок, надеваемый под платок); чаг.: **сылавыц.** Мәләнчегем тузды, җаңаны сырасы булыр.

**мәләш** *миш.д., т.я., төм.* миләш (рябина): **мәләш үләме** *чст.* к.: **албидрә.**

**МӘЛГЕЛТӘҮ** *тбл.* мәлҗерәү (утомляться, раскисать). Мәлгелтәп утырабыс, сәйел, эссе wакытлар.

**МӘЛГҮ** *тбл.* тирбәлү – саз турында (колыхаться – о трясине). Қалым мәлгеп йататы.

**МӘЛЕИС** *брб.д.* шат (радостный).

**МӘЛЕМЛӘҮ** *тара.* белдереп кую (предупредить).

**МӘЛКӘ** [*рус.* метёлка] *т.я.-крш.* пумала (помело). Салат салган үзе, мәлкә белән себергән.

**МӘЛЛИК** [*рус.* мельник] *минз., стрл.* к.: **милек II.**

**МӘЛМӘЙТҮ** *перм.* изү; вату (мять; ломать).

**МӘЛСЕЗ** [*гар.* + *афф.* -сез] **1.** *мәл.* к.: **латсыз 1.** Сиңа мәлсез, ахры, былай утыру; **2.** *нрл.* мәгънәсез, мәнсез, тупас (грубый, бестактный; грубо, бестактно). Бигрәк мәлсез сүләшәсез дә инде.

**МӘЛҮҚ** [*рус.* малёк] *трх.* тәңкәсез вак балыкның бер төре, гадәттә ул ун см дан артмый (вид мелкой, длиной не более десяти см бесчешуйчатой рыбы); чаг.: **майма: майма балық.**

**МӘЛ′ХАМ** *хвл.*, **МӘЛХӘМ** [*гар.*] *нокр.* ярылган урыннарга яки кечкенә яраларга сөртү өчен балавызга ак яки сары май кушып эретеп ясалган май (мазь домашнего приготовления из сливочного или топлёного масла с воском).

**МӘМӘЙ** *кргл., злт.* к.: **бырцак: бырцак үләне.** Песәй йафрағының мәмәйе була қуй. – *злт.*

**мәмәй булып** *мам.* к.: **мәмертәп.** Мәмәй генә булып пешмәгән икән әле бу қарлыган.

**МӘМӘЧ** *к.т.* агач кабыгы астындагы сыекча (сок под древесной корой).

**МӘМГЕ** *тбл.* суда яшәүче корт (водяная блоха, горбунцы).

**МӘМЕР** *тбл., саз.я.* күп, мул (много, обильно; обильный). Инәмаларта май мәмер пулатханты. – *тбл.* Пыйыл палх мәмер аңтыйтлар. – *саз.я.*

**МӘМЕРӘҮ** *минз.* артык нык пешү, үтә өлгерү (переспеть). Жиләкләрем мәмерәп беткән.

**мәмерәп пешү** *бәр.* к.: **мәмерәү.**

**МӘМЕРҖӘ** [*рус.* мурга] *кмшл., стрл.* **1.** җир убылып ясалган конус формалы чокыр (овраг конической формы, образованный в результате обвала земли). Уңдагы мәмерҗә, балакайым, мал ничек җәри торгандыр. – *стрл.*; **2.** конус формалы тирән таш чокыр (глубокий каменный овраг конической формы). Мәмерҗәгә качадырыйык, аклар килсә. – *стрл.*

**МӘМЕРТӘП** *мам.* куерып, изелеп – аш турында (сильно разварившись).

**МӘМЕРҮШКӘ** *тбл.* сумса (пирожки).

**МӘМЕРЦЕЛЕК** *саз.я.*, **МӘМЕРЧЕЛЕК** *твр.* муллык (изобилие, приволье, достаток). Ул wахытта мәмерчелек. – *твр.*

**МӘМЕШКӘК** *стрл.* к.: **гөләф.**

**МӘМКӘ** *минз.* к.: **ат′акыш 1.**

**МӘН I 1.** *тара.* рәт (толк); **2.** *твр.* мәгънә (значение, смысл). Сүснең мәнен пелмәстән кәпләнмә.

**МӘН II** *лмб., карс., тбл., тара.* к.: **ман I.** Қайа, кур′ка мән сал су. Су мән изрәтәсең, айақ мән басасын. – *лмб.* Бу каз чебешләре мән нишләргә, анай. – *карс.*

**МӘНДӘ** [*гар.*] *т.кам.-крш.* бәндә (человек). Қыр җағында диләр Гәрдәле (*ав. ис.*), Ыризық җөртә диләр мәндәне (*хал. җыр.*).

**МӘНД(Е)РӘТҮ** *хвл., чпр.* виноград, миләш, балан h.б. җимешләрне сабакларыннан аеру; көнбагыш, кукуруз, тары кебекләрнең орлыгын кул белән аерып кою (отделять рукой, напр., ягодки винограда, калины, рябины и т.п. от плодоножек, а также семена подсолнуха, зерна кукурузы, проса и проч. – соответственно от шляпки, початка, колоса и т.д.). Маланны мәндерәтеп бетердем, бер табак чыкты, мәләшне мәндерәтмәдем әле. Айбагар орлогын мәндрәтеп пичкә куй, кызым. Кукурузны мәндрәтмичә генә куй. – *хвл.* Былай бит пыжый, мәндерәтеп зыймасаң (карлыган турында). – *чпр.*

**МӘНЕ** [*гар.*] *кузн., кас.* к.: **мане.** Бу китапның мәнесен аңгарып булмый, динчә йазган. – *кузн.* Мәнесен әйтеп бир ма'а. – *кас.*

**МӘНЕЛЕ** [*гар.* + *афф.* -ле] *дөб.* төпле, мәгънәле (толковый). Биг әйбәт, мәнеле кеше партурк.

**МӘНТӘ** [*рус.*] *тбл.* ятьмә койрыгы (мотня – у невода).

**МӘНТӘШ** *төм., тара.* тиз чери торган агач (дерево, которое быстро гниёт).

**МӘНҮЦӘК** *тбл.* тәлгәш (гроздь, кисть). Қарағат мәнцәкләре. Муйыл мәнцәк сынтырып бир Сыслып таңнар атқанда (*хал. җыр.*).

**МӘНҮWӘРТ: мәнүwәрт таш** *брб.д.* мәрмәр таш (мрамор; мраморный).

**МӘҢ** *брб.д.* к.: **мим.**

**МӘҢГӘР** *т.кам.-крш.* к.: **мый.** Мәңгәр урында синең әрбәдер, әйткәнне дә аңнамыйсың.

**МӘҢГЕ I** *төм., тара.* к.: **мәмге.**

**МӘҢГЕ II** [*гар.*] *мәл., хвл.* бик күптән, бик күптәннән бирле (очень давно). Әшнәләрең мәңге көтеп торалар. – *мәл.* Мәңге китте инде. – *хвл.*

**МӘҢГЕРӘҮ** *трбс.* аңгыраю, аңгыралану (глупеть, стать бестолковым, непонятливым, тупым). Мәңгерәп тиг утырам берүзем.

**МӘҢКЕЛТЕРЕК** *тбл.* к.: **қалатқы.**

**МӘҢРӘҮ I 1.** *тбл.* к.: **маңрау 1.** Ицке мәңрәйте; **2.** *брб.д.* к.: **маңрау 2.** Қайлары геләң үтә (өйдә) мәңрәде, мәңрәгәнне эшеттем.

**МӘҢРӘҮ II** *брб.д.* миңгерәү (отупевший).

**МӘҢҮ** *тбл.* мәңге (вечный).

**МӘПЛЕКӘПЛЕ** [*рус.* мятные капли] *мам.* к.: **мәтлекәп.**

**МӘПТӘЛИН** [*рус.*] *төм.* нафталин. Көйә ғорт төшмәскә мәптәлин, йеслемай сибәтләр.

**МӘПТЕК** [*гар.*] *чст., злт.* мәктәп (школа).

**МӘР** *төм.* сыекча (сок). Қарагай мәр.

**МӘРӘ 1.** *хвл., кузн.* әйләнә (окружность). Мәрәнең уртасы буш була. – *хвл.*; **2.** *чпр.* тирә, әйләнә (место вокруг чего-либо). Хәзер мәрәләренә су сиптек, утырту зиңел; **3.** *срг.* мәйдан (площадь). Тагы да зуррак мәрә булса, йахшырак баккан булыр иде; **4.** *мам.* агачтан ясалган түгәрәк уен шакмагы (деревянная круглая чурка для игры); **5.** *хвл.* к.: **керчек I**. Мәрә булып утырыйк.

**МӘРӘК: мәрәктә җөрү** *т.кам.-крш.* туй вакытында урамда күңел ачып йөрү (развлечение, гуляние на улице во время свадьбы). Иң алдан мәрәктә җөргәндә башлап бии җәш килен, җакшы бийесә, мактыйлар инде.

**МӘРӘКӘ** *кмшл., бгрс., минз., тпк., трбс., стрл., шрл.* к.: **маскар**; чаг.: **мазак**. Шундый мәрәкәләр бар. – *кмшл.* Тел бик мәрәкә генә ул, йегерме биш киламетырда икенче төсле сүләйләр. Менә мәрәкә сүләйсен. – *минз.* Бик мәрәкә чир икән ул таш утыру бөйөргә. – *трбс.* Бөтөн кеше бик мәрәкә, алай булмый инде ул. – *бгрс.* Мәрәкә күрсәтә. Мынсы кызык та, мәрәкәрәк тә. И, мәрәкә дә инде син, Сәхип. – *шрл.*

**МӘРӘКӘЙЛӘШҮ** *твр.* сүзгә килешү, бәхәсләшү (поссориться, поспорить). Торсам, болар мәрәкәйләшкәннәр.

**МӘРӘКӘЛӘНҮ** *бгрс., кргл.* шамакайлану (дурачиться, паясничать). И, мәрәкәләнеп торма инде!

**МӘРӘКӘЛӘШҮ** *минз., стрл.* шаяртышу, үчекләшү (подшучивать, дразниться). Шуннан мәрәкәләшеп китәбез. – *стрл.*

**МӘРӘКӘН** [*рус.*] *перм.* аксыл-кызыл – бәрәңге сорты (белорозовый – скороспелый сорт картофеля продолговатой формы). – Бу ак чичкә мәрәкән кәртүк буламы? – Йуқ, руза (кызыл бәрәңге сорты) була.

**МӘРӘЛӘҮ 1.** *кмшл., нгб.-крш.* к.: **җобану**. Dawай-dawай, әйдә, мәрәләмәгез әле! – *кмшл.* Мәрәләп тора әле әбиләре. – *нгб.-крш.*; **2.** *кргл.* к.: **бүкәйләү**. Чүт мәрәләп кенә чықты; **3.** *кргл.* к.: **айбарлану**. Бик мәрәлисен, тизрәк бул.

**МӘРӘТ** *брб.д.* истәлек, төс (память). Әнийемнең күңнәге бу мәрәт итеп қалдырған, үсем теккәнем.

**МӘРӘТӘ** [ *рус.* мереда] *трх.* ятьмә (бредень). Мәрәтә әзерләп йөриләр ийе шул күршеләр.

**МӘРӘЧЛЕК** *каз.ар.-крш.* керәшен хатыннары баш киеменең маңгай турысына аркылы агач куеп ясалган һәм җилкәлекне ныгытып тоту өчен киелә торган чүпрәк калфак (часть головного убора крещёной татарки).

**МӘРӘШКӘ** [*рус.* мережка] *трх., лш.* к.: **мәрәтә**. Ничә мәрәшкә генә бетте. – *трх.*

**МӘРӘШКЕ** [*рус.* мережка] *трх.* озынборыннан, черкидән саклану өчен әзерләнгән челтәр (защитная сетка от комаров). Элгәре мәрәшке җawып йөриләр ийе дегеткә манып, төтен қуйып қына бәрәңге утыйлар ыйы; озонборон, черки күб ийе.

**МӘРWӘР** *тбл.* әнҗе (жемчуг). Мәрwәр сырғалар булған, сәленеп тора.

**МӘРДӘ** [*гар.*] *трх.* гадәт (привычка). Безнең Тарханда (*ав. ис.*) андый мәрдә йуқ.

**МӘРЕЛГӘН** *перм.* чигелгән (вышитый). Читек мәрелгән буладыр ийе хатын-қызныкы.

**МӘРҖӘМ: мәрҗәм агачы** *стрл.* к.: **байбай**.

**МӘРҖӘН** [*гар.*] **1.** *мам.* к.: **гылбу 1**. Суға барғанда, мәрҗәнем чәчелде. Энҗе-мәрҗән, қызыл мәрҗәннәр тағарлар ийе муйынға; **2.** *перм.* гәрәбә муенса (янтарные бусы); **3.** *карс.* брошка (брошь, брошка). Тирәзәкайлардан кем караган, Йагасына мәрҗән кадаган (*хал. җыр.*); **4.** *мам.* беләзек (браслет). Қулбау итеп тағарлар ийе қызыл мәрҗәнне.

**мәрҗән ағачы** *мам.* к.: **байбай**.

**МӘРҖЕМ** *минз., стрл.*, **МӘРҖЕМАНА** [*гар.* + *тат.*] *минз.* к.: **байбай**.

**МӘРЙӘМАНА 1.** *трх.* ак чәчәк ата торган бүлмә гөле, җимешеннән тәсбих ясыйлар (комнатный цветок, из ягод которого делают чётки). Мәрйәманадан дисбе тездем әле; **2.** *тпк.* к.: **байбай**.

**МӘРЙӘН** [*гар.*] *злт.* вак энҗеләрдән тезелгән муенса (бусы из мелкого жемчуга).

**МӘРКӘМӘС, МӘРКӘМӘЦ** *срг.*, **МӘРКӘМӘЧ** *лмб.* к.: **нәркәмәс**.

**МӘРКЕ** *стрл.* карама кабыгыннан балык тотар өчен ясалган чиләк кебек савыт (посудина, сделанная из вязовой коры, предназначенная для ловли рыбы).

**МӘРКӨП** [*рус.*] *клм.* к.: **сәртек**.

**МӘРТӘС** *тбл.* рәхмәт (спасибо). Сезгә күптән-күп мәртәс әйтәм.

**МӘРТЕНҮ** *брб.д.* имгәнү (калечиться, увечиться). Биле мәртенеп.

**МӘРҮ** *бөре., байк.* к.: **басу VI**. Әнә белә шулай мәриләр инде. – *бөре.* Әнә белән мәреп цәцәкләр эшләгән. Кулйаулык цитен мәриләр. Крутчук белән мәреп цыктым цитен. – *байк.*

**МӘРЦӘН** [*гар.*] *төм., тара., саз.я.* к.: **мәрйән**.

**МӘРЧЕН I** [*гар.*] *брб.д.* к.: **гылбу 1**.

**мәрчен салу** *брб.д.* муенса тагу (подвесить бусы). Мәрченнәр салғаннар төрлүwен. Мойынқа мәрчен саладыған порон.

**МӘРЧЕН II** *минз., стрл.* к.: **байбай**.

**МӘРЧЕНАЙАҚ** *твр.* аскы ягына вак-вак мәрҗәннәр салындырып эшләнгән көмеш челтәр алка, ахак кашлы (серебряная серёжка с висячими мелкими бусами, с агатом).

**МӘС** *мам.* бәс (иней, изморозь). Ағачларны қыш көне мәс бәйли. Ағачқа мәс бәйләнсә, икмәк уңа.

**МӘСӘ** *перм.* к.: **нәстә 1**. Мәсә қылнып килмәгән суң?

**МӘСӘЛӘ** [*гар.*] *т.кам.-крш., нгб.-крш.* әкият (сказка). Бабай, мәсәлә сүлә әле! – *т.кам.-крш.* Мәсәлә сөйләп көн үткәр ийе. – *нгб.-крш.*

**МӘСӘЛТЕР** *брб.д.* к.: **мawыл 1**.

**МӘСЕ** *перм.* к.: **нәстә 1**.

**МӘСИЙӘТ** [*гар.*] *т.я.-крш.* мәзәк, уен-көлке, әкият (анекдот, сказка). Мәсийәтләр ишетергә кермәлле булган икән сезгә.

**МӘСҚӘРӘ** [*гар.*] *эчк.* кызык (интересно); чаг.: **зawы'лы**. Тийатыр бик мәсқәрә булды.

**МӘСКӘҮ** [*рус.*] *минз., стрл.* бала итәк (волан, оборки).

**МӘСКӘҮЛӘП** [*рус.* + *афф.* -ләп] *минз., кргл.* бала итәк салып (пришивая оборки). Өч мәскәүләп тегә, ике мәскәүләп тегә.

**МӘСТӘ** *перм.* к.: **мә 1.**

**мәстә қыну** *перм.* нәрсә эшләү (что делать). Ана шунан awырта, мәстә қынып та бетми.

**МӘСТӘР** *тбл., тара.* сызыклы кәгазь (разлинованная бумага).

**МӘСТРИК** *тбл.* күркә – нарат, чыршы, ак чыршы, зирек турында (шишка сосновая, еловая, пихтовая, ольховая).

**МӘТ** *чст.* к.: **макау 1.** Баласы мәт икән.

**МӘТӘК** *т.я.-крш.* к.: **ашық II, 3.**

**МӘТӘКЛӘНҮ** *тмн.* к.: **билтәләнү.** Тара чәчеңне, мәтәкләнеп беткән.

**МӘТӘКЛӘҮ** *мәл., хвл.* мәтәлчек ату, мәтәлү (перекувыркнуться, полететь кубарем); чаг.: **мәтлегү.**

**МӘТӘКЛЕ** *тмн.* киезләнгән (свалявшийся; спутавшийся). Мәтәкле тегел выт, тарагансыз.

**МӘТӘЛ I** *хвл.* к.: **който.** Эшләр мәтәл, малай.

**МӘТӘЛ II** *нгб.-крш.* к.: **ара II.** Ул мәтәлдә мин булмадым.

**МӘТӘЛӘ** [*рус.* металл] *лш.* савыт (плошка, мисочка); чаг.: **митәли.** Мәтәләгә салып бир сөтнө.

**МӘТӘЛЕП-ҚАЗАЛЫП** *мам.* абынып-сөртенеп (то и дело спотыкаясь). Мәтәлеп-қазалып қайттық печәннән.

**МӘТӘЛЛӘНҮ** *дөб.* к.: **мәтәкләү.** Без мәтәлләнеп уйныйбыз.

**МӘТӘЛҮ** *мам.* аву, егылу (валиться, свалиться). Қайттым да мәтәлдем. Мәтәлеп йатқанга биш ай бар инде. Мәтәлер дип әйтмәгәннәр миңа.

**МӘТӘМ** *карс.* мин әйтәм (я говорю).

**МӘТӘТ** [*гар.*] *твр.* к.: **мәдәт 2.** Қулның мәтәте йуқ, қәл пәтте.

**МӘТӘЧ** *минз.* к.: **ашық II, 3.**

**МӘТЕ I 1.** *стрл., кргл., злт., тпк.* пычрак, сыек былчырак (жидкая грязь). Мәтегә буйалып беткән. – *кргл.*; **2.** *байк.* кызыл балчык (глина). Кызыл мәте.

**мәте балчығы** *кмшл.* к.: **мәте I, 2.** Мәте балчығыннан бишташ йасый идек, була иде кипкәч нық.

**МӘТЕ II** [*рус.* мята] *к.т.* к.: **бытнʼык.**

**МӘТЕРШИ'** [*рус.*] *кас.* к.: **йылыwыт.**

**МӘТИК** *нокр.* к.: **безрәк.** Мәтик кенә утыр әле силәшеп.

**МӘТЛЕГҮ** *каз.ар.-крш.* егылу, әйләнеп төшү, мәтәлү (упасть, свалиться; перекувыркнуться). Қодағыз шу төштә утыра, баш орған, шу төштә мәтлеккән дип килеб әйтәләр.

**МӘТЛЕКӘП** [*рус.* мятные капли] *блт.* бөтнек тәме килә торган (мятный). Кечкенә чақта без мәтлекәпне бик йаратадыр ыйық, awызға қапқач, салқынайтып жибәрәдер ийе.

**МӘТҮК** [*рус.* моток] *дөб., блт., мам.* к.: **катук I, 1.** Мәтүк жебе әйләндереп алалар. Уллы мәтүк. – *дөб.* Мәтүк жуқ челтәрне бәйләп бетерергә. Кибеттән мәтүк алдым. – *блт.*

**мәтүкле жеп** *дөб.* кәтүк жебе (катушечные нитки). Мәтүкле жеп алдым, машинаға кирәк ийе.

**МӘҮРЕТКӘ** *тбл.* опты балыгының вагы (мелкий язь). Йөзнең кецкенәсен мәүреткә тип әйтәпес.

**МӘҮТЕП: мәүтеп китү** *тбл.* оеп китү, йокыга китү, йоклап китү – бала турында (задремать, уснуть – о ребёнке).

**МӘХӘТ** [*гар.*] *минз., стрл.* мөгаен (наверно, очевидно). Мәфтухадыр, мәхәт. – *стрл.*

**МӘХӘТЛЕ** [*гар.* + *афф.* -ле] *минз.* мөгаен, ахрысы, бәлки, ихтимал (видимо, может быть, вероятно). Мәхәтле, килерләр инде тиздән қунақлар да. Мәхәтле, берәр эш булғандыр.

**МӘХРӘМӘ** *тпк.*, **МӘХРҮМКӘ** [*рус.* бахрома] *минз., стрл.* чук, чачак (бахрома). Айағында ситек-башмақ, башында мәхрәмә қалфақ. Мәхрәмә бәйләй торғаннар ыйы. – *тпк.*

**МӘҺӘР** [*гар.*] *перм.* кияү тарафыннан кызга китерелгән әйберләр (вещи, привезённые невесте со стороны жениха).

**МӘЦИКӘ** *твр., тара.* кәжә яки сарык бәтие (козлёнок или ягнёнок). Қуйныкы баласын, ицкенеке баласын мәцикә тителәр. – *тара.*

**МӘЦКӘЙ** *төм., тбл.* к.: **алйот 2.**

**мәцкәй сыйыр** *твр.* к.: **туқал.**

**мәче** (кошка):

**мәче бетийе** *чст.-крш.* к.: **бырцак: бырцак үләне.** Мәче бетийе жийыб ашыйлар бала-чагалар.

**мәче жафрағы** *трх.* к.: **алма I: алма йара(н).**

**мәче қойроғо** *мам.* **1.** к.: **песи: песи балалары; 2.** к.: **алабота 2.**

**мәче корʼыгы** *кузн.* кыяк үләненең бер төре (один из разновидностей осоки; осока ложносытевая).

**мәче табаны** *каз.ар.-крш.* к.: **алма II: алма йара(н).**

**мәче тарысы** *трх.* к.: **алабота 2.**

**мәче чыршысы** *дөб.* к.: **қарағай: қарағай үләне.**

**мәче шалқаны** *каз.ар.-крш.* к.: **бырцак: бырцак үләне.**

**мәче шыршысы** *блт.* к.: **қарағай: қарағай үләне.**

**МӘЧТӘК** [*рус.* масть] *кргл.* алаша (мерин). Мәчтәкне жигәләр.

**МӘШАЙАҚЛАР** *твр.* бала-чага (ребятишки).

**МӘШӘК** *эчк.* к.: **мацы.**

**МӘШӘКӘЛӘҮ** *кузн.* к.: **мәшәләнү.** Өскә йебәрмим ыланнарны, каа булса да мәшәкәлим үзләрен.

**МӘШӘЛӘНҮ** [*гар.* + *афф.* -лән ү] *кргл., бгрс.* маташу (возиться с кем-либо, чем-либо). Теге ат белән мәшәләнә торғач, тайларым йуқ. – *кргл.*

**МӘШЕҒҮЛЛӘНҮ** [*гар.* + *афф.* -лән ү] *мам.* шөгыльләнү, маташу (заниматься кем-либо, чем-либо, возиться с кем-либо, чем-либо); чаг.: **маталау 4.** Эштән қайтқач ук, гарбун белән мәшеғүлләнә бу малай.

**МӘШКӘ I 1.** *минз., перм., эчк., злт., к.-уф., себ.* к.: **паңгы.** Урманда мәшкә күп үсә. Қыйар белә мәшкә әпкереп пирдем. Көзгегә мәшкә жыймаға бардық. – *перм.* Мәшкә ашы пешердем. – *минз.* Бер бидрә итеп жыйғаннар ыйы мәшкә. – *эчк.* Былтыр мәшкә күп булды. – *к.-уф.* Усақ мәшкәсе. Инәй, без мәшкәгә барабыз. – *злт.* Көсен мәшкә йыйабыс, ақ мәшкә, қайын мәшкә. Мәшкәгә йөргәнем йуқ. – *төм.*; **2.** *минз.* к.: **амақ 1.** Мәшкә йунып алдым; **3.** *перм., нгб.-крш., к.-уф.* бөке (пробка). Шешәнең мәшкәсе қайда? – *перм.* Йәшелнең мәшкәсен ачып булмый. – *нгб.-крш.*; **4.** *нгб.-крш.* мактанчык кешегә карата әйтелә (говорится о хвастливом человеке). Мәшкә бит ул, йөри шунда.

**ит мәшкә** *төм.* ак гөмбә (белый гриб). Ит мәшкә йуwан, майлы була башы, аны шарит итеп ашағалы була, урман төбендә, қарағай төбендә үсә.

**қысыл мәшкә** *төм.* чебен гөмбәсе (мухомор).

**май мәшкә** *к.-уф.* к.: **майлықай: майлықай гөрәзнәй.** Май мәшкә қыздырған ыйық, барсы да ашадылар.

**мәшкә чир** *перм.* зәңгелә авыруы (цинга).

**урыс мәшкә** *к.-уф.* к.: **майлықай: майлықай гөрәзнәй.** Урыс мәшкәне йыйған кеше йуқ.

**церегәй мәшкә** *төм.* к.: **қысыл мәшкә.**

**шайтан мәшкә** *төм.* саңгырау гөмбә (дождевик).

**МӘШКӘ II** *брб.д., яүшт., том.д* к.: **бикәч II.**

**МӘШКӘ III** *брб.д.* нарат күркәсе (сосновая шишка).

**МӘШКӘЛӘНҮ 1.** *кмшл.* гөмбәләнү, каралу (покрыться ржавчиной, почернеть). Нажғағай алған, диләр, чикләwекнең эче кап-кара мәшкәләнгән була; **2.** *перм.* йомшару, бүртү (делаться мягким, набухать). Суда озақ йөрөсең дә мәшкәләнә айақ, қул да мәшкәләнә суда озақ мәтәштисең. Итектә мәшкәләнә инде эсседә айақ.

**МӘШ-МӘШ** *тара.* к.: **баш-баш.**

**МӘШТӘК** *себ.* к.: **бәйсәкә.** Мәштәк кенә бер хатын. – *тара.*

**МӘШХ′Ә: мәшх′ә май** *саз.я.* к.: **май I: ас′л′ан май.**

**МЕВЕХ** [*рус.*] *хвл.* мүк (мох).

**МЕГӘЛДӘК** *чст.* к.: **ад′ур 1.** Печәнне кылат йанына мегәлдәк белән ташибыз.

**МЕДЕРДӘҮ** *бәр.* чөкердәшеп сөйләшү (ворковать). Үз қызың белән бер медердәп сөйләшеп утырып, бер чәй эчсәң дә рәхәт булып китә.

**МЕЖӘМ** *мам.* авызыннан сүзе чыкмый торган кеше, жебегән (мямля). Безнең класста межәм генә бер қыз бар иде.

**МЕЗ** *брб.д.* чалгы йөзе (лезвие косы).

**МЕЗАН** [*гар.*] *трх.* ызан (межа). Мезан йахшы уқ билгеле.

**МЕЙӘ 1.** *брб.д., төм., саз.я.* ми (мозг); **2.** лепкә (темя). Кецкенә паланың мейәсе йомшақ пула қуй. – *тбл.*

**йоға мейә** *брб.д.* к.: **мейә 2.** Қайсы баланықы қән була, қайсы баланықы йоға мейәсе тис қатып китә.

**МЕЙЕЦ** *төм., саз.я., тбл.* мич (печь, печка).

**мейец awыс** *саз.я.* к.: **мич: мич ал тақта.**

**мейец йатхы** *саз.я.* к.: **дуңгыз II.**

**мейец қыр** *тбл.* мич сыры (карниз печи).

**мейец себертке** *тбл., саз.я., төм.* пумала (помело).

**мейец хаш** *саз.я.* мич сыры (выступ на печи для спичек).

**урыс мейец** *тбл.* рус миче (русская печь).

**МЕЙЕШ** *төм., тбл., клм.* к.: **мийеш.** Дүрт мейешкә доwалық қуйып қалдыралар. – *төм.*

**МЕЛГЕ** *тбл.* к.: **лемге.**

**МЕЛЕ** [*рус.* моль] *байк.*, **МЕЛТӘЙ** *злт.* вак балық (мелкая рыба, малёк).

**МЕЛЕЙ** *том.д.* к.: **мийәли.** Лосиный мелей тегәй.

**МЕЛЕК** *тбл.* маймыч (малёк, молодь).

**МЕЛИШ** *перм.* к.: **пизел.** Быйыл жуқ мелиш, узған жәй бар ыйы.

**мелиш печин** *перм.* к.: **албидрә.**

**МЕЛЛӘТ** [*гар.*] *дөб.* бурыч (долг). Эстеннән мелләтен бетерә алмый.

**МЕЛ′НИЧӘ** [*рус.*] *тмн.* тегермән (мельница).

**МЕЛТӘ** [*рус.*] *әстр.* пилтә (фитиль).

**МЕЛТӘЙ** *злт.* к.: **мелe.**

**МЕЛТКЕ** *тбл.* к.: **мелек.**

**МЕН** *төм., тара.* житешсезлек, кимчелек (недостаток). Мә, қарап пақ, пер менен табармигәнсең? – *төм.*

**МЕНАҮ** *нокр.* менә бу (вот этот). Менау телсез малай кәзәләр сақлый.

**МЕНӘ: менә әңкәч** *лш.* ымлык «менә сиңа» (междометие «вот тебе на»). Менә әңкәч! Бәлки, мин әнине сағынып торғамындыр.

**МЕНӘКӘ** *тбл., саз.я., яүшт.* менә (вот). Нучкасы менәкә, малайағы бар. – *яүшт.*

**МЕНӘН** *тмн., кузн.* к.: **ман 1.** Хут′ әпәй менән аша, хут′ пәрәмәчә менән аша. – *кузн.* Минем менән барасың? Эш менән килдегезме? – *тмн.*

**МЕНӘТЕРӘ** *лш., блт., хвл.*, **МЕНӘТРӘК** *к.т.* менә сиңа кирәк булса, менә ничек (вот как!). Менәтерә барнағы белән тырмады. – *блт.*

**МЕНӘШҮ** *перм.* **1.** к.: **борнайлану 2.** Минем улан аш менәшми: нимә булса, шуны ашый. Элег ул ашны менәшәйе, чирле генә йе; **2.** сайлау, тикшерү – сүз турында (быть разборчивым в словах). Ничек туры килсә, шулай йеппәрәбез, менәшеп тормыйбыз.

**МЕНДӘР 1.** *кузн.* ястык (большая продолговатая подушка). Мендәр ат′алар иде элке заманда, зур булса, аларны йасамыйлар инде; **2.** *минз.* арбаның ал күкрәге өстенә куела торган агач (часть телеги).

**қолақ мендәр 1.** *минз., перм., злт.*, **колак мендәр** *стрл.*, **қолақ мендәре** *минз.*, **қолақ ментәре** *тпк.* к.: **йастық I.** Түшәк булмаса, йастық саласың икене, қолақ мендәр саласың. – *перм.* Йастық инде ул зур была, қолақ мендәр хәтле ике-өс була. – *злт.* Ак карларга кагыб элдем Колак мендәрләремне (*хал. жыр.*). – *стрл.* Ике қолақ мендәре бирдем, йастық, йурған. – *минз.* Йастығың, қолақ ментәрең пармы, алып парып сатасың парын та. – *тпк.*; **2.** *перм.* туй вакытында чанага салып йөри торган чигүле мендәр (вышитая подушка, которая кладётся в сани во время свадебной поездки).

**мендәр бите** *нрл.* мендәр тышы (наволочка).

**мендәрле қунақ** *минз., лш.* яучы булып килгән кеше, ишектән керү белән, «мин мендәрле қунақ» дип, үзенең яучы икәнен белдерә. Өй хуҗасы аның астына мендәр салып утыртырга тиеш (сваха). Мин мендәрле қунақ тип килә жаучы. – *лш.*

**МЕНДЕРНӘ** *м.-кар.* **1.** к.: **бишнә.** Без бәйли торган эжнә дибез, ә татар мендернә ди; **2.** асылма лампыны элә торган тимерчыбык кисәге (металлический прутик для висячей лампы). Лампа мендернәсе.

**МЕНЛӘШҮ** *перм.* шикләнү, икеләнү (сомневаться, колебаться).

**МЕНЦЕНЛӘҮ** *тбл.* төпченү (допытываться, копаться, доискиваться).

**МЕНЧЕЛ** *перм.* шикләнүчән (мнительный). Биғрәк менчел кеше икәнсең, чир йоғар дип уйлый торғансыңдыр, awырғач, кереп тә қарамадың.

**МЕҢГӘШҮ** *минз., стрл.* өйдәш булу (жить в одном доме). Меңгәшмә, меңгәшсәң, эндәшмә. – *минз.*

**МЕҢГЕ** *перм.* «акча» сүзе урынына әйтелә (заменяет слово «деньги», арго). Меңгең бармы соң?

**МЕҢГЕР** *перм.* кисмәк кыршавы (кадочный обруч). Ашлы бидрәгә қолау қуйылған инде, болай чапчақның кебек меңгер қуйылған инде.

**МЕРӘWӘТСЕЗ** [*гар.*] *злт.* игелексез (неблагодарный).

**МЕРӘС 1.** *тбл., саз.я., брб.д.* мирас (наследство, имущество). Инәмнән қалған мерәс, йомор алға. – *брб.д*; **2.** *төм., брб.д., яүшт., саз.я.* истәлек (память). Мерәс итеп йасап қуйыпты ошо, улым. – *төм.* Зур қара шәлен бирде, абаңның мерәсе булыр, диде. – *яүшт.*

**МЕРГЕ 1.** *чпр.* к.: **мәргә**; **2.** *трх.* тал чыбығыннан үреп ясалған кәрзин (корзинка из ивовых прутьев). Мерге – хайwанға ашамлық ташу өчөн кәрзин ул.

**МЕРЕ** *чст.* к.: **бедрә**.

**МЕРЛӘҮ 1.** *т.кам.-крш.* акрын – тавыш турында (слабый, тихий – о голосе). Үзе дәү булса да, таwышы бик мерләү аның; **2.** *т.кам.-крш.* мыгырдау, авыз эченнән сөйләнү (бормотать). Шөйләшсән, җүнләп шөйләш, мерләп утырма; **3.** *саз.я.* сузып-сузып елау (плакать протяжно, реветь). Пөтөр таwышыңны, мерләмә.

**МЕРҮ** *т.я.* к.: **мөрү**. Җатсын шулай, мереп китә ул хәзер. – *к.т.*

**МЕСКӘ** [*рус.* миска] *әстр.* к.: **мескен**. Мескәңне алып кер.

**МЕСКЕН** [*рус.* миска] *лш.* кәстрүл формасындагы ике тоткалы балчык савыт (глиняная посуда с двумя ручками в форме кастрюли).

**МЕТӘК** *нрл.* к.: **ашык II, 3**. Әйдә, малай, метәк уйныйбызмы?

**МЕТЕРҮ** *кргл.* күп ашау, сыпыру (уплетать). Икмәкне нык ашый, метерә генә.

**МЕТЕЧ** *нрл.* кузна (альчик, бабка). Метечләр буладыр ийе, атыб-атыб уйныйдыр ыйык.

**МЕТИК 1.** *нокр., глз.* к.: **кечкеник**. Метик кенә йомырка салыптыр тавык. – *глз.* Мәләкәйләр миненкесе бик метик. – *нокр.*; **2.** *нокр.* к.: **безрәк**. Метик аңныйбыз, метик йуқ. Метик кенә беләм. Әллә метик кетәсеңме?

**МЕТЛӘК** *чст.* к.: **туқал**. Метләк сыйыр.

**МЕХЦЕ** *саз.я.* к.: **бәйсәкә**.

**МЕЧЕК: мечек сағыз** *дөб.* к.: **мечик**. Мечек сағыз булган да аққан да қатқан.

**МЕЧИК** *перм., к.-уф.* ылыслы агачларда була торган сыек сағыз, чәер (сера хвойных деревьев); чаг.: **чайыр 1**. Утын кискәндә қулым мечиккә буйалды. Мечиклесе була, ансы қара чыршы. Мечиклесен қара шыршы дибез, қулны қарайта торған, җүwеш. – *перм.*

**МЕЧТУК** *перм.* к.: **қарағай: қарағай үләне**.

**МЕШ** *тбл.* к.: **пытлыш**. Арпаға меш күрсәтәләр дә төкерәләр, арпа цыққанда йеп бәйлиләр бармаққа, ул төшкәнче йөри.

**МЕШӘ** *злт.* сазлыкта үскән яшь нарат (сосна, выросшая на болоте).

**МЕШӘК** *себ.* к.: **мацы**. Песнең мешәк бар ыйы, ул антай түгел ийе. – *том.* Үсләренең этле-мешәкле торуларын қортқайақтан күрәте. – *тбл.*

**инә мешәк** *себ.* ана мәче (кошка). Инә мешәк цыцқан тотқор булады. – *тара.*

**ир мешәк** *себ.* ата мәче (кот).

**мешәк ашы** *брб.д.* к.: **быpцак: быpцак үләне**.

**мешәк пала** *себ.* песи баласы (котёнок).

**МЕШӘККҮС** *төм.* күгәрчен күзе, зәңгәр чәчәк (незабудка).

**МЕШӘҮНИК** [*рус.* омшаник] *срг.* к.: **абзар 1**. Қызылйарда Уразыфкыдан (*ав. ис.*) бер генә киламитр – мешәүник диләр аранга.

**МЕШӘХ** *саз.я.* к.: **мешәк**.

**МЕШИ** *тбл.* чуан (фурункул).

**МЕШИК** [*фарс.*] *перм.* к.: **күлә**. Мешик тулы ашлық. Утызар-қырықар мешик суғайем мин көнөнә. Безнең мешикне гуча тимиләр зур тычқаннар.

**МЕШКӘ I** *чст.* чишмә суы агу өчен куелган улак яки торба (жёлоб или труба для стекания родниковой воды); чаг.: **қолаша 1**.

**МЕШКӘ II** *глз.* тубал (лукошко, кузов). Баланың җитезерәге мешкәдән чыга да. Мешкәне кырга баргач җиргә куйа.

**башак мешкә** *глз.* тубал (лукошко, кузов).

**МЕШКӘЧ** *дөб.* балалар авыруы – рахит (детская болезнь – рахит).

**мешкәч үләне** *дөб.* к.: **песи: песи балалары**.

**МЕШКЕ I** *хвл., тмн., лмб., шрл.* эремчек (творог). Мешке пәрәмәчәсе бешердем. Мешке бәлеше. – *тмн.* Мешке ашыйсызмы? – *лмб.* Сетне ачытыбырак куйасын кызуга, иләб-иләп сезәсен иләктән, ул була мешке. – *шрл.* Мешкедән варинник пешерәсен пилмин кебек. – *хвл.*

**МЕШКЕ II** *клм.*, **МЕШКӘ** *брб.д.* к.: **паңгы**.

**чемен мешкәзи** *брб.д.* агач гөмбәсе (древесный гриб).

**м и** (мозг):

**ми қагу** *перм.* баш авыруын имләүнең бер төре (знахарский метод лечения головной боли). Мийемне қағам әле, мийем төште.

**ми төшү** *перм.* башның бер ягы авырту (односторонняя боль головы). Мийем төште, башым awырта.

**МИГЕТӘҮ** *төм.* к.: **бетенкерәү**. Мигетәп тыwа, йылатматылар, инәкәү йанынта йата.

**МИ'ИС** *кас.* к.: **бикәч II**.

**МИДӘТ** [*гар.*] *мам., т.кам.-крш., кргл., злт.* көч, хәл (сила, мощь). Түзгән кешегә мидәт кирәк. – *мам.* Миннән – мидәт, синнән сиқәт булсын. – *т.кам.-крш.* Қарт кешедә мидәт йуқ. – *злт.* Мидәте йуқ шул бармақларның, әйбер тотмый. – *кргл.*

**МИДӘҮ** [*гар.*] *тпк.* имгәнү, көч бетү, көчсезләнү (калечиться, терять силу, обессилеть). Бик йонсу булды суғыш wахытта, шунда да мидәп қалдық.

**МИДӘҮСЕЗ** [*гар.*] *каз.ар.-крш.* хәрәкәтсез (без движений). Паралис суққан, саны мидәүсез, қуллары да қылтыр-қылтыр, теле тотлыға.

**МИЖАННАНДЫРУ** *крғл., бғрс.* к.: **дымайту**. Кипкәннән соң базға куйып мижаннандырырға кирәк, ди, себеркене. – *крғл.* Керне эләсез дә, шытырдап кибә, аны мижаннандырсаң, үтүкләргә җиңел була. – *бғрс.*

**МИЖАННАНУ** *мам.* дымлану (сыреть, делаться влажным). Печәннеккә керткәч мижаннанып китмәс микән? Чык та төшә, күгәлә дә, мижаннанып тора әле печән.

**МИЖАННЫ** *мам.* дымлы (влажный). Мижанны әле печәне, өйәп булмас.

**МИЖИН** [*рус.* межень] *кузн., хвл., чст., чпр.* җәйнең иң эссе вакыты, җәйге челлә (самая жаркая пора лета). Йә кар тийәп куйабыз, йә боз – мижингә таба. – *хвл.* Мижин йаңғыры. – *чст.*

**МИЗАН I** *эчк.* тоҗым (нити паутины, летающие осенью).

**МИЗАН II** *тбл.* сентябрь.

**МИЗАР** [*гар.*] *әстр.* к.: **мазарлық**. Өч мизар, өчесе дә ағачсыз.

**МИЗГЕЛ I** [*гар.*] **1.** *дөб.* чор; билгеле бер вакыт (определённый отрезок времени, период). Суғыш мизгелендә чабатаға сөйенәдер ийек; **2.** *нгб.-крш.* вакыт (время); чаг.: **ара II**. Бер мизгел табып безгә кил.

**МИЗГЕЛ II** [*гар.*] *мам.* гадәт (привычка). Мизгел китмәс, чир китәр, дигәннәр борынғылар (*әйтем*).

**МИЗГЕЛ III** [*гар.*] *әстр.* төшке аш, ашамлык (обед, еда). Мизгел асалар икән биш-алты кешегә.

**МИЗГЕЛЛЕ** [*гар.* + *афф.* -ле] *злт.* билгеле бер вакыт, вакыты-вакыты белән (определённый отрезок времени; временами, время от времени). Анда күкрәп йаwа, мизгелле генә.

**МИЗГЕЛСЕЗ** [*гар.* + *афф.* -сез] *к.т., мәл.* к.: **пырдымсыз 3**. Мизгелсез кеше. – *к.т.*

**МИЗИЛИН** [*рус.* мезонин] *срг.* өй кыегындагы тәрәзә (маленькое окошко на фронтоне дома). Мизилингә мәләшләр тагып куйдык.

**МИЙӘ** *эчк., к.-уф., злт.* к.: **мый**. Қырғайақ кешенең мийәсен ашый (имеш). – *к.-уф.* Awырып мийәсе бозолды. – *злт.*

**МИЙӘКӘ** *злт.* к.: **мый**. Башында аның мийәкәсе йанында раны. Мийәкә сыйықланған. Йығылып мийәкәсе сыйықланған.

**МИЙӘЛӘЙ, МИЙӘЛИ** *тара.* бияләй (варежки). Мийәләй дә пәйләп қуйғаным.

**МИЙӘНУ** *эчк.* мактану, масаю (хвалиться, хвастаться). Ул тәйен мийәнеп йөрәй.

**МИЙӘТ** *төм., тбл., сазл.* к.: **мөйәт**.

**мийәт йелткә** *төм.* камыт аслыгы (подхомутник).

**МИЙЕЗ** *кас.* мөгез (рог).

**МИЙЕР** [*гар.*] *бәр.* миһербан (милость, великодушие). Мийерләреннән йаздырмасын балаларның.

**МИЙЕС** *әстр.* к.: **мийеш**. Килен төшә, бер җиңгә килә дә ычықлый киленне җаулык мийесен йандырып, баш очыннан әйләндереп иснәтә киленгә, «ычык», «ычык» дип әйтәде.

**МИЙЕШ** *кас., минз., стрл., төм.* почмак (угол). Дүрт мийеш. Селе' мийешти 'ени тыра, ал. – *кас.* Менә моннан барып, менә болай мийештә. – *минз.* Дүрт мийешенә дүртне көмөш тәңкә кыстыра, көмеш кебек йалт итеп торсон дип. – *стрл.* Оло балам бу мийештән икенце өйдә тораты. – *төм.*

**МИҚЫЛДАУ** *мам.* нык симерү (стать жирным, полным, тучным). Миқылдаган дуңғыз чығып китте, ди.

**МИЛӘЙ** *яүшт., клм.* к.: **мийәләй**.

**тыш миләйе** *яүшт.* тыш бияләе (рукавицы).

**МИЛӘЙЕШ** *перм.* к.: **пизел**. Былтыр миләйеш тә шәб ийе инде.

**МИЛӘҮШӘ** *нрл.* умырзая (подснежник). Миләүшә була йаз айында, зәңгәр, матур исле, болый ғына сабы.

**миләүшә ағачы** *мам.* к.: **байбай**.

**МИЛӘЧ** *брб.д.* к.: **пизел**.

**м и л ә ш** (рябина):

**чыпчық миләше** *дөб.* к.: **байбай**. Чыпчық миләше ашый торған түгел ул, хатын-қызлар самаwыр ағартып йөриләр.

**МИЛЕК I** [*гар.*] **1.** *минз., бөре.* к.: **паз'ма**. Милек бәләкәй бит, йегерме биш сутыйға тутырып бирәләр. – *минз.* Китмәдисә шушы awылдан, милек бирәләр. – *бөре.*; **2.** *минз.* к.: **диңгез 3**. Минем үскән милегемә йортқа керде.

**МИЛЕК II** [*рус.*] *минз., стрл.* тегермәнче (мельник). Тегермәндә милек булып эшләде бедненең қарт. – *минз.*

**МИЛЕКЛӘҮ** *бөре.* **1.** җир арчып, ачып үз милкенә әверелдерү (присвоить, освоить землю, участок, выкорчёвывая и очищая). Қызылйарлар (*ав. ис.*) килеп утырмақчы булганнар, милекләп шул җирне; **2.** биләү (владеть, занимать). Бу безнең җир, үзебез милекләйбез. Милекләп қалған җирләрне атлысы чәчкән, атсызы сатқан.

**МИЛЕНЧА** [*рус.* мельница] *кузн.* к.: **мел'ничә**. Әләнә миленча йилләрдә, Безнең сәүгән кас'ы ла илләрдә (*хал. җыр.*).

**МИЛЕШНИК** [*рус.* мелочник] *төм.* кырыктартмачы (коробейник). Көмөшләрне милешникләр сатып йөрөйте.

**МИЛКАЧ** [*рус.* мелкий] *хвл.* кече калибрлы винтовка (малокалиберная винтовка).

**МИЛЛЕК** [*рус.* веник] **1.** *каз.ар., т.я.-крш., минз., трбс.* к.: **бәрән: бәрән минеге**. Миллек дип җыйабыз инде бәкәйләр өчен. – *минз.*; **2.** *бөре., перм., трбс., байк.* к.: **йапрақ**. Қайын миллек; **3.** *трбс.* идән себеркесе (метла, веник). Кечерткәннән миллекләр йасағыз, ти. Қайын мөрөсе җыйабыз, миллек бәйлибез, митла бәйлибез.

**МИЛЛЕКЛЕ** *минз., стрл.* һәр кешенең үзенә аерым бүленгән җир (земельный участок, разделённый каждому отдельно). Элек җир миллекле ийе. – *минз.*

**МИЛНЕК** [*рус.* веник] *мам.* к.: **бәрән: бәрән минеге**.

**МИЛЦӘ** *срг.*, **МИЛ'ЧА** *лмб., кузн., әстр.*, **МИЛЧӘ** *лмб., срг., карс.*, **МИЛ'ЫНЧА** [*рус.* мельница] *кузн.* к.: **мел'ничә**. Мил'ча планироват' иткән идек. – *лмб.* Безнең зур су да бар иде, мил'ча да бар. Бийек таукай башында, әй, җил милчә Әләндер җилләр тимичә (*бор. җыр*). – *лмб.* Милцәгә иткәндә алаша йик. Мин милчәгә барып килдем. – *срг.* Милчәләрдә, кайа җитте анда эшләп, гур'аларны

күрде инде. – *карс.* Иген тартып килде мил'чадан. – *эстр.*

**йил милчә** *лмб.* җил тегермәне (ветряная мельница). Йил милчәбезне теттеләр.

**МИМ** *тара.* миң (родинка).

**МИМИЛӘК** *нокр., глз.* сөяк эчендәге җилек (костный мозг). Мимилек бик тәмне. Баш мимилеге, сүwәк мимилеге була. – *нокр.*

**МИМЕЧ I** [*рус.* немец] *минз.* күп белә торган, булдыклы кеше (умный, знающий, деловитый). И, малайларың мимеч икән, әрәхәтләндем утларға, ди. Ут керткән ийе минем малай.

**МИМЕЧ II** [*рус.* немец] *перм.* кәрлә – кимсетеп әйтелә (карлик – уничижительно). Тупсаға утырма, үсмәссең, мимеч булырсың.

**мимеч борчак** *перм.* ногыт борчагы (боб, фасоль). Мимеч борчак утырттым ый, балалар килергә была утыттым ий, киләлмиләр артаба.

**мимеч эте** *перм.* к.: **мимеч II**.

**МИМИ** *перм.* җилен (вымя). Сыйырыбызның мимийе қаты, cawарға қыйын.

**МИНАWАТ** *каз.ар., злт.*, **МИНАВАТ** [*рус.* виноват] *бөре.* гаепле (виноватый; виноват). Мин минават. – *бөре.*

**МИНАСИЙӘ** [*рус.*] *төм.* яңгырлы һава (ненастье).

**МИНӘЙӘТ** [*рус.* менять], **МИНӘЙТЛӘР** [*рус.* менять + *афф.* -ләр] *злт.* бер товарны икенче товарга алыштырып сатып йөрүчеләр (торговцы, которые один товар меняли на другой). Минәйәттән сабын алған идем, күлмәк алған идем. Шуғыш wақытында минәйтләр килә торган ыйы, бәрәңге алыр өсөн кийемнәрдер, ниләрдер бирәләр, алыштырып китәләр.

**МИНДЕК** [*рус.* веник] *байк., стрл., злт.* к.: **бәрән: бәрән минеге**.

**МИНДӘУ 1.** *блт., минз.* к.: **awырту**. Бу ат айға йақын миндәде. – *блт.*; **2.** *нгб.-крш.* имгәнү (ушибиться, получить ушиб). Бер тawығымнын айагы миндәгән; **3.** *т.я., дөб.* миңгерәүләнү, аңгыралану (отупеть, стать бестолковым). Жығылып башымны бәргәч, бик озақ миндәп җөрдәм. – *к.т.* Урман кисәргә барғачтын, ботақ төшкән башына, әзерәк миндәп қалған. – *дөб.*

**МИНЕК** [*рус.* веник] **1.** *чст., чпр.* себерке (веник); чаг.: **йапрақ**. Кышка утыз әрем минеге әзерләдем. Алмаз урманга мунча минегенә китте. Канат тегел, минек булырга тийеш мында. – *чст.*; **2.** *лш.* к.: **бәрән: бәрән минеге**. Минек бәйләргә җибәрәләр.

**МИНЗЕНУ** *брб.д.* к.: **миңцеләү**.

**МИНҚӘЙУ** *эчк.* к.: **йадаулану**. Бозау минкәйгән.

**МИННЕК** [*рус.* веник] **1.** *минз., тпк., стрл.* к.: **йапрақ**; **2.** *чст., бәр.* к.: **минек 1**. Ишегалдын себер әле әрем миннеге белән. – *чст.*

**МИННЕКЛӘУ** *стрл.* к.: **ийәләү**. Миннекләдең бөтеннәй Салихны.

**МИНСА** *минз.* к.: **йага II, 2**.

**МИНТӘУ** *перм.* к.: **бетенкерәү**. Безнең ул wахытта (сугыш вакытында) сыйыр булды да, минтәмәделәр. Йә awырып китсең, йә чирләп китсең, минтәп қаласың чир артыннан йүнсезләнеп.

**МИНЦА** [*рус.* мовница] *байк.* мунча (баня).

**МИНЦАЛА** [*рус.* мочало] *байк.* мунчала (мочалка).

**МИНЧА** [*рус.* мовница] *глз.* к.: **минца**.

**минча төшү** *глз.* к.: **инү: мунча инү**.

**МИНЧАҚ** *перм.* к.: **гылбу 1**.

**МИНШӘК** [*рус.*] *брб.д.* пиджак. Миншәк йоқ, камсул йоқ.

**МИҢГЕР** *перм.* кисмәк коршавы, тимер коршау (железный обруч для кадушки).

**МИҢГЕРӘУ** *блт.* тимрәү (лишай). Миңгерәү җитмеш төрлө була. Миңгерәү чыга тимгел-тимгел булып, сызғач бетә.

**МИҢГЕТУ** *чст., лш.* миңгерәүләтү, миңгерәүләндерү (делать бестолковым, лишать разума, рассудка). Нигә аны миңгетеп қыйныйсыз? Миңгеткән дип әйтәләр имгәткән бәпкәне. – *лш.*

**МИҢЕЛ** *м.-кар.* к.: **қамақаш**. Миңелем пеште ашаганда.

**МИҢЛЕ: миңле гөл** *дөб.* к.: **бақа II: бақа гөле**.

**МИҢРӘУ** *бәр.* к.: **миңгерәү**.

**МИҢЦЕЛӘУ** *тара., сазя.* үзләштерү, хуҗа булу (присвоить).

**МИРА** [*рус.* мурья] *кас.* моржа (труба). Чәү'илир миралар'а ойа әшлилир. Мираларыннан тетен чы'а.

**МИРАЛЫК** [*рус.* мурья + *афф.* -лык] *тбл.* тышкы моржа (труба над крышей). Кыш уртасынта миралык сылатым.

**МИРАН** *дөб.* куян (заяц – одно из табуистических названий зайца, т.к., если дома живет молодняк, то слово «куян» не должно было произноситься). Миран диген, улым, бәтиләр бар ич.

**м и р а с** (наследство):

**мирас бала** *кргл., бгрс.* әтисе үлгәннән соң туган бала (ребёнок, родившийся после смерти отца). Мирас бала иде, үсеп җиткән, әй.

**МИРГӘ** [*фарс.*] *перм.* к.: **диңгез 2**. Миргә күмәбез.

**МИРГӘН** *тара.* к.: **мәргән**.

**МИРГӘЧЕ** [*фарс.* + *афф.* -че] *перм.* мәҗлестә бал салып өләшүче (тот, кто разливает брагу на пиру, на званом обеде); чаг.: **арғош**. Миргәче балны тарата. Миргәче бирмәгәч, эчә дә алмый ул, бирсә – эчә, бирмәсә – йуқ.

**МИРКЕ** [*рус.* мерка] *минз., стрл.* бер пот ашлык сыешлы савыт (посуда, вмещающая пуд зерна; пудовка). Йегерме мирке бодай. – *минз.*

**МИРТЕК** *тара.* **1.** зәгыйфь, биртек (немощный, увечный). Қырғапта (*ав. ис.*) әшкәрә миртек кешеләр күп игән; **2.** ватык (неисправный, сломанный, разбитый). Самуwарыгыз миртек мәллә?

**МИРТЕЛУ** *тара.* биртелү, зәгыйфьләнү (получить увечье, обессилеть).

**МИС I** [*рус.* миска] *бөре., глз., минз., стрл.* кәстрүл (кастрюля). Мискә генә сал тызын. – *глз.* Мискә салып җылытыгыd. – *минз.* Мистә аш бар, ашыйсызмы? – *стрл.*

**МИС II** [*удм.*] *нокр.* саулык – кәҗә, сарык турында (самка – о козах, овцах); чаг.: **йарка I, 1**. Сарықларның берсе – тәкә, берсе – мис.

**МИС III** [*рус.* печь] *дөб.* к.: **мейец**. Мискә йағам ич инде.

**МИСАН** *тбл.* җилсез эссе көн (безветренный жаркий день). Мисан көннәр килер әле.

**мисан очу** *тбл.* җилсез эссе көнне һавада пәрәвезләр очу (летающие в воздухе в жаркий безветренный день паутинки).

**МИСКА** *трх.*, **МИСКӘ** *перм.*, **МИСКИН** [*рус.* миска] *кмшл., дөб., злт.* к.: **мис I**. Миска да буйалмый газда. Ашны мискинға бушатып тор, табақ буш түгел. – *дөб.* Әпәй қуйа торған мискинемә су тутырып қуйганнар. – *злт.* Мискә бели китереп утырта йы. – *перм.*

**МИСНИК** [*рус.* мясник]: **мисник кеше** *перм.* к.: **бәйсәкә**. Сабир абый мисник кеше инде.

**МИТАННАП** [*гар.*] *бөре.* акрын, салмак (неторопливо, медленно, грузно); чаг.: **акыр: акыр ғына**. Митаннап қына йөри.

**МИТӘЛИ** [*рус.* металл] *дөб., лш.* төрле зурлыктағы металл савытлар (металлическая посуда различной величины). Митәли тәлинкә, митәли табақ. – *дөб.*

**МИТИЛГӘ** *твр.* чуен (чугунок).

**МИТЛА** [*рус.* метла] *миш.д., бөре., злт.* ишегалды себеркесе (метла); чаг.: **минек 1**. Йырт себерергә митла бәйлибез тысқан сыбығыннан.

**МИТЛӘП: митләп қалу** *перм.* берәр авырудан соң сәламәтлек начарланып калу (стать слабым, плохим после болезни). Марсил кечкенә чағында митләп қалды. Малны башта әйбәт қарамадың исә, митләп қала, үсми.

**МИһЕРЛЕ** [*гар.* + *афф.* -ле] *бәр.* миһербанлы, шәфкатьле (милосердный, доброжелательный, снисходительный). Бер дә миһерле түгел киленем.

**м и ц** *себ.* (печь):

**миц түбә** *тара.* к.: **пибаш**.

**МИЦАРҒА** *тара.* мич арты (место за печкой).

**МИЦӘР** *тбл.* к.: **пизел**.

**м и ч** (печь):

**мич ал тақта** *перм.* мич капкачы (заслонка).

**мич әйләнәсе** *бәр.* мич тирәли тотылган кашага (занавеска вокруг печи). Мич әйләнәсе тектем.

**мич түбә** *перм.* к.: **пибаш**. Мичнең теге ызбаның мич түбәсе жуғыйы.

**МИЧА** [*рус.* мовница] *глз., нокр.* к.: **минца**. Бик прабур, мича утыртты йапа-йалгыз. Мича йакмага буламы инде. – *глз.* Мича исән дә, йақмыйбыз. – *нокр.*

**мича төшү** *глз.* к.: **инү: мунча инү**. Йул килгәч, мича төшү әйбәт була ул.

**МИЧАЛА** [*рус.* мочало] *нокр., глз.* к.: **минцала**. Ашимдин қашығайақ мичала чықты. – *нокр.*

**МИЧАРАТҚЫ** *тара.* к.: **мицарға**. Мичаратқы булғанда, чүплек башта йоқларға бизгәк ғәрләнә, ти, мине чүплек башқа чығарып ырғыттылар тип, қәдерләргә йарамый, қәдерләсең, китми ул, мине қәдерлиләр тип.

**МИЧӘН** *минз., стрл.* ян-якка жигелү, мичәү (пристяжка, припряжка). Ике улым мичән, үзем, төпкә жигелеп, мичкә белән дегет ташыдым. – *минз.*

**МИЧИТ** [*рус.* венчать] *т.я.-крш.* никах (венчание: христианский религиозный обряд бракосочетания). Мичиткә барганнар батышка жанына.

**мичит итү** *т.я.-крш.* к.: **венеч: венеч алу**. Мичит итәләр, жәзәк awыштыралар.

**МИЧКӘ** [*рус.* миска] *минз.* к.: **мис I**. Қара мичкәгә салырым дигән ийем дә теге майны...

**МИЧТӘРЛӘҮ** *лш.* к.: **пичтәрләү: арқаға пичтәрләү**. Элек қалаға мичтәрләп жөриләр ийе.

**МИЧУРИН** [*рус.*] *стрл., том.д.* дача. Ул төшләрне мичурин итеп жасадылар. – *стрл.*

**МИШАWЫЛ** *тбл.* такта (доска).

**МИШАЛАУ** [*рус.* мешать + *афф.* -лау] **1.** *нокр.* к.: **маталау 2**. Мишалап йөрмә әле айақ арасында. Миңа мишалама, бар, кет, Қамқуй. Чапчағы мишалай ич анда, кетниккә менмә; **2.** *глз.* үтләтү (вызывать несварение желудка вследствие переедания). Пешкән бәрәңге мишалай сарыкны, чи бәрәңге мишаламай.

**МИШӘК** [*рус.* мешок] *перм., злт.* к.: **күлә**. Бер мишәк итеп бир тиң. – *перм.* Бер мишәк он китердем, ике мишәк арыш. – *злт.*

**МИШӘР: мишәр шәңкә** *тара.* к.: **қапшырма**.

**МИШИ** *тбл.* к.: **йуша 3**; чаг.: **моши**.

**МИШКӘЙӘК** *тара.*, **МИШКӘЛӘК** *тбл., твр.*, **МИШКО** *том.д.* к.: **паңгы**. Мишкәйәк ашамый торған. – *тара.* Мишкәләк йийатылар, тослап тороп ашайдылар. – *твр.* Ақ мишкәләк. – *тбл.*

**МИШУК** [*рус.* мешок] *хвл., чст., чпр., срг.* к.: **күлә**. Ташыган мишугын бар энде синең. – *чст.* Мишук белән картук китерә идем аркада. Мишугын кыстырган, кенсәтә тора ылаука йанында. – *срг.*

**МИШУРАЛАП** [*гар.*]: **мишуралап чигү** *каз.-ар.-крш.* бизәкләп чигү (вышивать с узорами). Сүрәкәләрне чиктек мишуралап, кәйтәннәр сатыладыр ыйы, мачтырлар була торған ыйы.

**МОҒА** *брб.д.* үгез (бык). Моғаларны йегеп оутын ташыдым.

**МОҒАҖИ** [*гар.*] **1.** *дөб.* кибет (магазин). Сара апа моғажиға китте; **2.** *перм.* колхоз амбары яки склады (колхозный амбар, склад); чаг.: **мағази**. Моғажида эшлиләрме? Моғажида, шүшилкәдә ут бармы?

**МОҒАЙУ 1.** *блт.* моңаю (грустить); **2.** *саз.я.* кайгыга төшү (горевать); **3.** *тара.* к.: **моғау 3**. Пыцақ моғайған.

**МОҒАМ** *төм.* **1.** бию көе (танцевальная мелодия); **2.** көй (мелодия). Уйын моғам.

**МОҒАУ 1.** *төм.* аңгыралану (тупеть); **2.** *тбл.* тупас, үтмәс (тупой). Палтаң моғау игән; **3.** *тбл.* тупаслану, үтмәсләнү (затупиться, стать тупым – о режущих инструментах). Моғап китте пила.

**МОҒОЛ 1.** *блт.* оры (нарост, шишка); **2.** *себ.* чүмәлә (копна). Йес моғол пецәнне цапқан. Сәнәк белән моғолға саласың. – *төм.* Моғолны ат тартып китерә. – *тара.* Эшләгән эшне кәпләсең, моғол булып цығар. – *тбл.* Моғол зур булмайды, ат белән тарттырып кәбәнгә қойасың. – *брб.д.* Моғол йасый-йасый да ат белә тарттырасың кибәнгә. – *яүшт.* Беренце пецәнне йыйawс, аннан моғол йасайwс. – *саз.я.*

**МОҒОЛЛАУ** *тара., төм.* чүмәлә кую (ставить копны). Пецәнне моғоллатайық. Пецән моғоллайды. – *тара.* Алар пецән ташлайтылар, пес моғоллантық. – *төм.*

**МОҒОЛЦЫҚ, МОҒОЛЧЫҚ** *төм.* к.: **күбә III, 2**. Моғолчықлар йасайпыс пер күтәрерлек.

**МОҒЫЛ** *себ.* к.: **моғол 2**.

**МОҒЫЛЛАУ** *себ.* к.: **моғоллау**.

**МОГЫР, МОГЫРИ** *мәл.* к.: **айап 1**. Бу күлдә балык могыри.

**МОЙЕЗБЕК** *әстр.* туйда киелә торган баш киеме (свадебный головной убор).

**МОЙУНДЫРЫҚ** *брб.д.* хатын-кыз эчтән кия торган күкрәкнең яка урынына тышка чыгып тора торган элементы (элемент нагрудника, надеваемого женщинами под платье, который выступает как воротник). Уйулы, моғалы мойундырығ эшләйсең, түшлеге тоташ цүпрәктән, куңнәг астан кейеп қалдыралар.

**МОЙЫРЛЫ** *тбл.* ягымлы (привлекательный).

**МОҚ 1.** *төм., тбл.* аңгыра (тупой – о человеке). Ул моқтан ней цықсын; **2.** *тбл., төм.* юаш (смирный).

**МОҚАЙ** *злт.*, **МОҚОЙ** *блт.* аз сүзле, юаш (тихий, кроткий, неразговорчивый); чаг.: **межем**. Моқой гына булса да, хатын айырды ул. – *блт.*

**МОҚСЫН** *тбл.* муксун балығы (муксун).

**МОҚТАНУ** [*гар.*] *срг., мәл., чпр.* мохтаҗлык күрү, мохтаҗ булу (терпеть нужду, нуждаться); чаг.: **абдырынкы: абдырынкы булу**. Отынга мактанмыйбыз бер дә, орман йакын болгац. – *срг.*

**МОҚТАУ** *төм.* тотлығып сөйләүче, биртәк (заика). Телтән моқтау ите ирем.

**МОҚТЫ** *кргл.* һәвәс (склонный к чему-либо, пристрастный). Бу эт тешнәргә бик моқты.

**МОҚТЫҚ** *тбл.* к.: **тылтық II, 1**.

**МОҚЧОНУ** *к.т.* төпченү (копаться, докапываться, интересоваться деталями). Тотонды инде моқчонырга. Бик моқчонма инде ул қәдәр.

**МОҚЧУ** *к.т.* төпчү (расспрашивать о чём-либо – подробно, тщательно).

**МОҚЫЙ** *тбл.* к.: **моқ 2**.

**МОКЫЙ** *чст.*, **МОҚЫТ** *т.я., мам., кргл., бгрс.* аңгыра, миңгерәү, белексез (глупый, невежда); чаг.: **ат'акыш 1**. Бигрәк мокый булганнар инде элек заман. – *чст.* Моқыт кеше ул, дуға белән печән чаба. – *к.т.* Әwәлге кеше моқыт булган ул, берни белмәгән. – *мам.*

**МОҚЫТУ** *төр.* к.: **лаңлау**. Қуй, күп моқытма.

**МОЛҒАМ** *тбл.* к.: **моңқан**.

**МОЛЛА** [*гар.*] *брб.д.* укымышлы, укыган (образованный). Wат моллите менем инәм.

**МОЛЛАТТӘЙ** [*гар.* + *тат.*] *минз., стрл.* к.: **апақ 2**.

**МОЛЛАУ** *перм.* к.: **пинәләү 1**. Аны-моны әйтсә дә үпкәләмәсен, молламасын. Кеше бер нимә әйттисә, шуны моллап торма, чирчә (сердце) тотоп йөрмә, диләр.

**МОЛ'ОКЛЫ** *глз.* к.: **ғорда**. Мол'оклы бу бакча.

**МОЛ'ЦА** [*рус.* мовница] *тара.* к.: **минца**. Мол'-цағысны йагайықмы пөгөн?

**мол'ца төшү** *тара.* к.: **инү: мунча инү**.

**МОМАНА** [*фарс.*] *т.я.* к.: **моқ 1**.

**МӨМЫ: мөмы тиғере** *яүшт.* балаларга карата әйтелә торган иркәләү сүзе (ласкательное слово по отношению к детям).

**МОНА** *т.я., мәл.* менә (вот, вот этот). Мона монда ғына йөри иде әле абый. – *т.я.*

**МОНАWЫ** *төм.* к.: **монау**. Монawы урыс бицә пескә пулышқалы килепте қуй.

**МОНАWЫНДА** *к.т.* менә монда, биредә (здесь, тут). Әйберләрегезне менә монawында қуйығыз.

**МОНАНТЫН** *глз.* моннан алып (такой величины, до этого). Монантын зур кезге.

**МОНАТОРА** *каз.ар.-крш.* к.: **менәтерә**. Монатора апкитәм, ди тәтәсе Буфканы (*кеше ис.*) да.

**МОНАУ** *т.я., лш., минз., кргл., злт., трбс., тпк., стрл., төм.* менә бу (вот этот). Монау иптәшкә әйтәм. Монау қыз бик матур җырлый икән. – *к.т.* Менә монау чаттан пудрәт балалы өй. Менә монауны шул җаққа қуй. Әней, әрче монау бәрәңгене. – *лш.*

**монау ара** *яүшт.* бу арада (определённый отрезок времени, в это время). Монау ара уттый йана.

**МОНАУДА** *лш.* к.: **монawында**. Кич белән менә монауда җатырсыз. – *лш.*

**МОНДАР** [*гар.*] *бәр.* к.: **мордар**.

**МОНТАЙЫН** *тбл.*, **МОНТАҚ** *тара.* мондый (такой). Монтақ балалар.

**МОНТАШКӘ** *тбл.* итле аштан сөзеп алына торган күбек (пена, снимаемая с мясного бульона).

**МОНЧАҚ I** *брб.д.* бу кадәр (столько).

**МОНЧАҚ II** *брб.д.* к.: **гылбу 1**. Ағыйық мончақ қыйбат, сатлы (затлы).

**МӨНЧӨ** [*рус.* мовница] *клм.* к.: **минца**. Мөнчө йаққөйдыңба?

**МОҢ I** *блт., тара.* зар, зарлану (жалоба). Киландә моң йуқ, бик әшли. – *блт.* Ицпер кешетән тә ким түгел, кейемнән тә моң түгел ите. – *тара.*

**МОҢ II** *төм., тбл.* мең (тысяча).

**МОҢАЙУ** *тмн.* к.: **моктану**. Акчага да моңаймый идек.

**МОҢАРЧЫҚ** *лш.* моңа чаклы, моңа кадәр (до сих пор). Әле моңарчық аптырамадым иткә дә.

**МОҢГИНЧА** *чст.*, **МОҢҒИНЧЫ** *мам.* к.: **моңарчық**. Моңгинча торосоң дип ул'амаган идем. – *чст.* Эчтег инде, моңғинчы эчмибезме соң! – *мам.*

**МОҢҒОЛАНУ** *мам.* куерып изелеп пешү – аш турында (сильно свариться); чаг.: **имелдәү**. Ашың қайный-қайный моңғоланып беткән инде.

**МОҢГЫЙ** *т.я.-крш.* моңаеп (грустно, жалостно). Бик моңгый җылап бара.

**МОҢҒЫЛ** *дөб.* агачта була торган кабырчык, оры (нарост на дереве); чаг.: **амақ 1**.

**МОҢҒЫЛАНУ** *минз.* к.: **моңғолану**.

**МОҢҒЫНЧЫ** *дөб.* к.: **моңарчық**. Син, малай, моңғынчы қайда йөрдең?

**МОҢҚАҚ** *төм., тбл.* күп хәсрәт күргән кеше (человек, много переживший, перестрадавший).

**МОҢҚАН** *тара.* күп, тулы, җитешле (много, полно). Пашқа нәрсә моңқан, кирбец цай ғына йақ.

**МОҢҚЫ** *тара.* тулысынча (полный). Ул маңа моңқы рисалық пирте.

**МОҢЛАУ** *перм.* кычқыру – әтәч турында (петь – о петухе). Қурас моңлайты.

**МОҢОНЧЫ** *мам.* к.: **моңарчық**. Биреп баралар ыйы әле моңончы. – *мам.*

**МӨҢРӨУ** *брб.д.* мөгрәү (мычать).

**МОҢСЫЗ** *злт.* гамьсез (беспечный, беззаботный). Бик моңсыз кеше ул.

**МОҢТАШ** *тбл.* кайгы-хәсрәтне уртаклашучы кеше (сострадательный человек).

**МОҢЫНЧЫҚ** *лш.* к.: **моңарчык**. Лимуным булды әле моңынчык.

**МОР** *әстр.* борын (нос).

**МОРА** *минз.* кыргый үскән киндер (дикая конопля); чаг.: **мошко I: кыр мошкосы**.

**МОРАЗ** [*гар.*] *әстр.* авыру (болезнь).

**МОРДАР** [*гар.*] *мам.* ачуланучан кеше (вспыльчивый, запальчивый); чаг.: **йерәкле**.

**МОРЖА** [*рус.* мурья] **1.** *каз.ар., минз., нгб.-крш., бөре.* к.: **пич**. Кыш көнө дә шул өйдә торабыз, моржалы ул. Агартқан ыйым ғына моржаны. Моржасы йуқ бу йақның, җәй көне генә торабыз. – *мам.* Моржа сүтәбез, кирбеч апқайттым. Моржасы килеште, өйөбез җылы була. – *каз.ар.-крш.* Моржа бурлау. – *нгб.-крш.* Ике моржабыдны да ул чығарды. – *минз.* Хәзер аларның моржа ғына чыгартасы бар инде. – *бгрс.*; **2.** *трх.* самавыр моржасы (самоварная труба).

**лампа моржасы** *трх.* к.: **мөржә 3**.

**моржа башы** *мам.* к.: **мира**.

**моржа башыннан** *т.кам.-крш., лш.* һәр хуҗалыктан, хуҗалык саен (с каждого хозяйства; по каждому хозяйству). Моржа башыннан бүләбез, диләр, берәр нәстә булса. – *лш.*

**моржа буйы** *блт.* к.: **қашаға I, 1**. Тос сawыты моржа буйындамы, теге җақтамы?

**моржа өстө** *каз.ар.-крш.* к.: **пибаш**. Моржа өстөндә тора ич ул (шикәр) қай көннән бирле кипмейче.

**тышқы моржа** *каз.ар.-крш.* к.: **мира**. Тышқы моржаны сүтәргә берәр ир кешегә әйтерем инде.

**МОРЗА** [*фарс.*] *төм.* иренең энесенә әндәшү формасы (форма обращения к младшему брату мужа).

**абыз морза, ал'ем морза, күркле морза** *төм.* каенеләренең олырагы (старший из младших братьев мужа).

**МОРИТ** [*рус.* морить] *бәр.* җәфа, газап (мучение, страдание). Ул қыз балаға да морит күрсәттеләр. Һай, күргән моритларны, күргән моритларны.

**морит булу, морит чигү** *бәр.* к.: **хыйтлану**. Шулхәтле морит чигеп тора.

**МОРСАЛА** *чст.* к.: **керчемә**.

**МОРТ** *тбл., тара.* мыек (усы).

**МӨРТ** *тбл.* сәлперәйгән (дряблый).

**МОРЫН** *брб.д.* борын (нос).

**МОРЫНТАУ** *брб.д.* борну, борынлау (прорасти).

**МОС** *тара.* боз (лёд). Ригә сәлифтә мос туңмайты. Умпер йәшлек палам киредән мосқа төштө.

**мос цәцгес** *твр.* к.: **сүймән**.

**МОСЛАУ** *глз.* к.: **мишалау 2**. Мослаган сарык, тawык бәрәңгесе ашаган, суйасы иде.

**МОТ** (кеже – кеше) *твр.* к.: **қаллап 2**.

**МОТ'АМАЛ** [*гар.*] *чст.* к.: **мат'амал**. Андый мот'амаллар белән минем ни эшем бар.

**МОТЛАҚ** *твр.* к.: **таин**. Сағидә мотлақ себерәк.

**МОТУ** *әстр.* оныту (забыть). Мин мотқанмын ғу.

**МОФТАЛА** [*гар.*]: **мофталаға төшү** *злт.* бәлагә очрау, юлыгу (попасть в беду).

**МОХ** *саз.я.* мокыт (бестолковый; тупица). Элех қалых мох wулған, урысца та welмәән.

**МОХАЛАУ** *злт.* к.: **алты-тукыз**. Арада мохалаwырақ бер кеше бар ыйы.

**МОХМАЛ** *твр.* бәрхет (бархат). Йәшел мохмал иде йәктәм (камзулым).

**МОХТАНУ** [*гар.*] *срг., хвл., чпр.* к.: **моктану**. Мин нигә дә мохтанмим. – *срг.* Алай малга мохтанмыйм. – *чпр.*

**МОЦКА** [*рус.* мочка] *срг.* уч, тотам (пучок конопли, кудели). Бер моцка пәзи.

**МОЦОҚ** *тара.* камыш тамыры (корень камыша).

**МОЧОР** *твр.* к.: **пизел**.

**МОШАКАТЛАНУ** [*гар.*] *срг.* мәшәкатьләнү (заботиться, хлопотать, беспокоиться). Шулар белән мошакатланып үтте вакыт.

**МОШАТЛАНУ** *себ.* ныгыту (укрепить).

**МОШИ** [*угор.*] *чст.* поши (лось).

**МОШҚА** [*рус.* мошки] *тара.* вак чебен (мошкара, мошки).

**МОШКО I** [*морд.*] *хвл., кузн., стрл.* **1.** киндер (конопля). Мошко чәчә булганнар, әле инде чәчмиләр. – *хвл.* Мошко чәчтем. Мошко орлого. – *стрл.*; **2.** киндер сүсе (конопляное волокно; пакля). Мошко киндераштан йасаклыйлар иде. – *хвл.* Талкыгач мошко була. – *стрл.*

**кара мошко** *кузн., стрл.* киндернең орлык бирми торган төре, баса (конопля, не дающая семена; посконь, дерганцы).

**кыр мошкосы** *стрл.* кыргый киндер (дикая конопля). Кыр мошкосы бар, ул чәчмичә үсә инде.

**сары мошко** *кузн., стрл.* киндернең орлык бирә торган төре (семенная конопля; матерка, матка).

**МОШКО II** [*удм.*] *глз.* **1.** туз чиләк (берестяное ведро). Мошко туздан йасалган була, күрсәтерем менә келәттә; **2.** баланы аркага асып йөрер өчен туздан ясалган бишек (берестяная люлька, в которой носили ребёнка на спине). Аркага асып йерде мошко, дүртпычмаклы ул, бала йата анда.

**МОШТОМ** *кас.* к.: **акыр: акыр гына**. Мошто м'она'илдем.

**МОШЫЙ** [*угор*] *злт.* к.: **моши**.

**МӨГӘҖИ** [*гар.*] *к.т., минз., бөре., стрл.* к.: **мағази**.

**МӨГӘЛДӘК** *чст., крғл., бгрс.* к.: **ад'ур 1**.

**МӨГӘЛҖӘ** *т.я.* к.: **бөгәржә**. Бишек мөгәлҗәсенә қарама агачы йәки чикләwек ағачы әйбәт була. – *к.т.*

**МӨГӘЛТӘК** *тбл.* к.: **мөгәтәк**.

**МӨГӘҢНӘШҮ** *брб.д.* бергәләшеп эшләү (делать совместно). Асма-көпмә мөгәңнәшип истәгән соң табатылар.

**МӨГӘРӘП** [*рус.* погреб] *тпк.* к.: **нәүрәп**. Пәрәңке күп, шытмаған көйө йата мөгәрәптә.

**МӨГӘТӘК** *тбл., төм.* кызны егет өенә күчерә торган өсте ябулы арба (крытая повозка, в которой невеста переезжает в дом жениха). Мөгәтәкләр пөгеп гилеп гысларны күцергәннәр элгәре. – *тбл.* Мөгәтәктә утызып анта киленцәк белән кийәү адийал йабатлар. Мөгәтәкне киленцәк утырған йергә генә қуйатлар, цымылтықтан йасайтлар. – *төм.*

**МӨГӘШ** *твр.* к.: **мийеш**.

**мөгөз I** *урт.д.* мөгез (рога):

**мөгөз салу** *минз.* им-томның бер төре (один из видов знахарского лечения). Мөгөз сал әле син, диләр. Мөгөзне қан чығарғанчы шул урынға қаплый, пәкесе белән чийертә қан чығарлық итеп, мөгөзен қаплый да сүwыра. Теге мөгөз эченә бозық қан тула. Мөгөзләре зурырақ, зурыраққа зурырақ, бәләкәйгә бәләкәйерәк.

**МӨГӨЗ II** *перм.* к.: **боронч0қ**. Мөгөзен сындырыб алалар.

**МӨГӨШ 1.** *бөре., перм., тя.-крш., к.-уф., эчк., злт., чст., төм.* к.: **мийеш**. Ник мөгөшкә посып утырасың? – *бөре*. Дүрт мөгөшкә дүрт бағана. – *перм.* Өстәл мөгөшенә килеп бәрелдем. – *к.-уф.* Мөгөшләре церегән. – *төм.*; **2.** урам чаты, борылыш (поворот – на улице). Урам мөгөштә миңке туған бар әле, сеңел. – *төм.*

**МӨГӨШЛЕК** *перм.* к.: **мөгөш 2**. Шунда, мөгөшлектә, икенче җорт.

**МӨГӨШ-МӘГЕШ** *перм.* к.: **мийеш**. Мескеннәр мөгөш-мәгештә утырып йырлыйбыз тип...

**МӨГРӘП** [*рус.* погреб] *тпк.* к.: **нәүрәп**.

**МӨЖГӨ** *байк.* вакчыл (мелочной, мелочный). Күп сүли, мөжгө. Эцми, башы белән мөжгө.

**МӨЖ'ГӨННӘҮ** *злт.* вакчыллану (быть мелочным, проявлять мелочность). Ул алай мөж'гөннәнеп тормай.

**МӨЖГҮ** *байк.* к.: **мөж'гөннәнү**. Сүгенмичә генә мөжги.

**МӨЖӘ** [*мар.*] *перм.* к.: **қура II**. Учаскыныкы мөжә җыйган wақытта була (сабан туйы).

**МӨЖӘП: мөжәп беткән** *бөре.* к.: **йончу**; чаг.: **дөлкөлдәгән**. Бабай да мөжәп беткән, мин дә мөжәп беткән.

**МӨЙӘ** *тбл., брб.д.* к.: **мый**. Йаса-йаса мөйәсен пөтөртөгес инте. – *тбл.*

**мөйәм йөга** *тбл., брб.д.* баш эшләмәү (голова не соображает).

**МӨЙӘТ** *төм., тбл., тара.* камыт (хомут).

**МӨЙӘТ-ШАЙ** *тара.* сбруй, дирбия (сбруя). Сеңлем, әкәңнең мөйәт-шайы гайта икән?

**МӨЙӘШ** *тбл., төм., тара., твр.* к.: **мийеш**. Түрт мөйәшкә утырып хатем уқыйлар. – *тара*. Ул мөйәштә тора. – *төм.*

**мөйәш майлау** *төм.* элек: килен бусагадан атлап керүгә, бер кыз баланың стенага май сөртү йоласы (в старину: как только невестка перешагнёт порог, одна из девушек должна помазать маслом стену).

**МӨЙӘШӘ** *тбл., төм.* к.: **мийеш**. Балта белән мөйәшәләрен киртәтеләр, ағацтан ниргә қуйыла. – *тбл.* Йецкә генә эцле үгез өйнең мөйәшәсен күтәрәте. – *төм.*

**мөйәшә майлау** *төм.* к.: **мөйәш: мөйәш майлау**.

**МӨЙӨРЛӘНҮ** [*гар.* + *афф.* -ле] *тбл.* иркәләнү (ласкаться). Әнисенә мөйөрләнеп киткән.

**МӨЙӨРЛӨ** [*гар.* + *афф.* -ле] *тбл.* миһербанлы, бәхетле (счастливый). Мөйөрле мәхәббәтләрен бирсен.

**МӨЙӨС** *тбл.* к.: **мийез**.

**МӨЙӨШ 1.** *минз., бгрс., кргл., трбс., тпк., стрл., твр., тара., төм., саз.я., әстр.* к.: **мийеш**. Монау мөйөштә генә Кифайалар. – *трбс.* Мижаның мөйөшө сайын пағана утыртырға икән. – *тпк.* Менә монау мөйөштәге карчык үлде инде. – *стрл.* Түрт мөйөшенә түрт йаулық, сөлге, тәрәт йаулық қуйып, муллалар хатем уқый. – *тара.* Мөйөшкә цатыр әләделәр, қысны утызалар. – *твр.* Өй мөйөшне қымтып цыққан, сыwых кермәсен пичф. – *саз.я.* Пер мөйөшентә мейец пулған. – *төм.*; **2.** *кргл., бгрс.* к.: **мөгөш 2**.

**мөк** *себ.* мүк (мох):

**мөк цийә** *төм.* мүк җиләге (клюква).

**мөккә утызу** *брб.д.* бураны мүкләп күтәрү (поднять сруб, используя мох). Пөләләп қойған, мөккә оутызған йоқ.

**МӨКӘЧЛӘҮ** *бөре.* к.: **бүкәйләү**. Мөкәчләнеп, тубықланып чичкәләрне җыйып йөрөй.

**МӨКЛӘШКӘ** *перм.* **1.** к.: **туқал**; **2.** бура башы (конец бревна в срубе).

**МӨКӨРӘЙҮ** *тбл.* к.: **көмөрәйү**. Аларны уқытқынцы йелткәләрең мөкөрәйер.

**МӨКӨРТӘК** *твр.* өсте ябулы арба (кибитка); чаг.: **мөгәтәк**. Бер бар ат йигәтләр, мөкөртәк тawардан қылғаннар.

**МӨКРИҖЛӘНҮ** *перм.* шешеп, бүлтәеп чыгу (распухнуть, вспухнуть – о суставах). Йанапайда (*ав. ис.*) сазда сөйәкләр мөкриҗләнде.

**МӨКСӘЙҮ** *тара.*, **МӨКЦӘНЛӘҮ** *тбл.* к.: **көмөрәйү**.

**МӨКЦӨК** *твр., тара., тбл.* **көмөрө 1**.

**МӨЛДӨРКӘ** *мәл., минз.* к.: **бөлдөркә**.

**мөлкәт** (имущество):

**мөлкәт бирү** *злт.* бөтен ихласын бирү, күңелен бирү, җанын бирү (всё отдать, отдать душу). Китап дигәндә мөлкәтен бирә.

**мөлкәтен салып** *злт.* ихлас белән, җаны-тәне белән (от всей души, с увлечением). Пөтөн мөлкәтен салып уйный шахмытны.

**МӨЛЛӘ, МӨЛТЕ** *тара.* бик, бөтенләй – көчәйткеч кисәкчә (очень, совершенно – усилительная частица). Мөллә цибәр ул гыс. Пы берәwе мөллә бала игән.

**МӨНӘЙАТ** [*гар.*] *злт.* оят (совесть, стыд). Йөзендә мөнәйат әсәре дә йуқ.

**МӨНТӘҮ** *брб.д.* мондый (такой). Мөнтәүне йебәргән ит. Төнйа мөнтәү.

**МӨҢӘЛТӘК** *төм.* к.: **мөгәтәк**.

**МӨҢГЕТҮ** *брб.д.* к.: **мөңкү 1**.

**МӨҢГӨРӘҮ** *т.я., мам.* мөгрәү (мычать).

**МӨҢКӨШ** *тара.* ташбаш (пескарь).

**МӨҢКӨШӘК** *твр., тбл.* к.: **мөңкү 2**.

**МӨҢКҮ 1.** *тбл.* атның, артын күтәреп, атланган кешене егып төшерүе (поднимать задние ноги и сбрасывать с себя седока – о коне). Ат мөңкөпте, мөңкөшәк ат игән; **2.** *твр.* чыгымлый торган ат (норовистый конь).

**МӨҢӨС** *твр.* к.: **мийез**.

**МӨҢӨШ** *твр.* к.: **мийеш**. Мөңөшләренә сыw ағады.

**МӨҢРӘК** *брб.д.* к.: **көлбуқа**. Мөңрәк пар, мүүң тип йата тығын көлдә.

**МӨР** *перм.* **1.** к.: **бәрмәчлеки**; **2.** зирек күркәсе (орешек, плод ольхи); **3.** к.: **әкәлә 3**. Қайынның да мөрө була.

**МӨРБАШ: мөрбаш печән** *перм.* зәңгәр болын чәчәге (василёк луговой).

**МӨРГӨ** *т.я.* тал чыбыгыннан үреп ясалган кәрзин, тубал һ.б. (корзина и др., сплетённые из ивовых прутьев).Талға бар, әткәй, мөргө кирәк бит. Әрбәлектән кибәкне мөргө белән ташыйлар. Қаз ойасы итеп җөртә торған бер иске мөргөм барыйы. – *к.т.*

**МӨРЕ** *чст.* к.: **бәрмәчлеки.** Талда булса мөре була, имәндә булса – әкәлә.

**МӨРҖА** [*рус.* мурья] *бөре.* к.: **пич I.**

**мөржа ағы** *бөре.* к.: **бур II.**

**мөржа башы** *бөре.* к.: **мира.**

**МӨРҖӘ** [*рус.* мурья] **1.** *хвл., кузн., байк.* к.: **мира**; **2.** *кргл., бгрс., шрл.* к.: **пич I.** Мөржә буйына қуйабызмы биредә? – *бгрс.* Мөржә чығарып беттегезме әле, улым? – *кргл.* Бик уңған катын, тегү дә тегә, мөржә дә чыгара. – *шрл.*; **3.** *хвл., чст.* лампа пыяласы (стекло для лампы). Җиделе мөржә кирәк иде; **4.** *минз.* хуҗалык (хозяйство). Мөржә ақчасы җыйалар ыйы, қырық, илле тин, бай кешенең ике-өч мөржәсе була торған ыйы.

**мөржә қаш** *перм.* к.: **қашаға I, 1.**

**мөржә табасы** *кузн.* моржа капкачы (вьюшка).

**МӨРЗӘ** [*рус.* мурья] *срг., чпр.* к.: **мира.** Бу пицнең мөрзәсе нацар тарта.

**мөрзә башы** *чпр.* чардак (чердак).

**МӨРЙӘ** [*рус.* мурья] *злт.* к.: **мира.**

**МӨРЛӘНҮ** *перм.* каенда сыргалар барлыкка килү (об образовании серёжек на берёзе); чаг.: **песиләнү.** Қартырақ қайыннар мөрләнә.

**МӨРЛИГЕН** *перм.* бөрлегән (брусника). Мөрлигенне җыйған кеше бармыни аны?

**МӨРӨ 1.** *кузн., хвл., чст., перм.* к.: **бедрә**; **2.** *перм.* к.: **йара II: йара йафрак.**

**МӨРӨК: бәрәңге мөрөк** *перм.* бәрәңге алмасы, бәрәңге сабагында була торган яшел төстәге агулы "алма" (плод на ботвах картофеля).

**җирек мөрөк** *перм.* к.: **мөр 2.**

**МӨРӨЛӘНҮ** *кузн., хвл.* бөреләнү (набирать почки – о растениях). Минеке дә төште мөрөләнгән чәчәкләре. – *кузн.*

**МӨРТЛӨК** *минз., стрл.* к.: **быт′ык.**

**МӨРҮ** *бгрс., кргл.* йоклау (спать). Мөрөр wақыты җитте бу баланың. – *кргл.*

**МӨРШИТӘ: мөршитә шәл** *тбл., төм., саз.я.* күпертмәле бизәкле, озын чуклы ефәк шәл (шёлковая ажурная шаль с длинной бахромой). Мөршитә шәлләр булған, осон цацақлы, ақ, күбеп-күбеп торған шикелле. Мөршитәнең қарасы да, ағы да була. Мөршитә шәлләр булған, күбешкән-күбешкән шәл, осон цуқлы. Мөршитә шәл әйтә тегеннәр ите сутәшләп пәйләнкән шәлләр, цитентә цимәйләп пәйләнкән шәлләр. Минем ал мөршитәм ите йәш мәлемтә. – *тбл.* Мөршитә шәлләр булыпты, цацақлы, ақ йоға ғына йебәк шәл. – *төм.*

**МӨСРӘЙҮ** [*гар.*] *минз.* к.: **мылҗырау 3.**

**МӨСРӘҮ** *т.я.* канәгатьләнү, канәгать булу (быть довольным). Тигән хәдәресенә мөсрәргә кирәк. Әйбәт чыға алай, бер төптән бер чиләк чықса да мөсрәмиләр. – *к.т.*

**МӨТӘК** *минз.* ашык янындагы сөяк (бабник, астрагал); чаг.: **мәтәк.** Сыйыр ашығы мөтәк була.

**МӨТЛӘК** *чст.* к.: **туқал.** Безнең сыйыр мөтләк.

**МӨТЛӨК 1.** *мам., к.т., стрл.* к.: **быт′ык**; **2.** *к.т.* кыр суганыннан ашка салу өчен әзерләнгән порошок (порошкообразная приправа, приготовленная из дикого лука). Қыр суғаны шәмәхә чәчәк ата, аны табада киптерәсең, төйәсең, мөтлөк була ул, ашқа саласың ашағанда.

**МӨТНӨК** *каз.ар.-крш.* к.: **быт′ык.** Мөтнөк белән бәйләсән себеркене, җақшы була.

**МӨХ** [*рус.* мох] *тмн., лмб., тбл.* мүк (мох). Мөхкә пару гәрәх. – *тбл.*

**МӨХЛӘҮ** [*рус.* мох + *афф.* -ләү] *тмн., лмб.* мүкләү (конопатить мхом).

**МӨХРЕ** *саз.я.* к.: **көмөрө.**

**МӨХЦӨ: мөхцө сөйәге** *саз.я.* койрык сөяге, койрык умырткасы (копчик).

**МӨһ** [*рус.* мох] *кузн., твр.* к.: **мөх.** Мөһ куйдык. – *кузн.*

**МӨһӘРӘП** [*рус.* погреб] *тпк.* к.: **нәүрәп.** Мөһәрәп пуралы, пашы йабулы була.

**МӨһӨРЛӘҮ** [*гар.*] *к.т., блт., лш.* бөртекләү, җентекләү (сделать что-нибудь тщательно, старательно); чаг.: **бермекләп.** Өйләрен мөһөрләп җыйыштырган. – *к.т.* Әнисе бик тырыш мөһөрләргә. – *блт.*

**МӨЦӘ** *тбл.* **1.** оча сөяге (тазовая кость); **2.** сан; буын (тело; сустав). Мөцәләрен таралсын тип итән йутырғаннар awырайақ пицәләртән. Йампашлар, мөцәләр сыслайты.

**МӨЦӘЙ** *тбл.* к.: **йәүдә 1.** Мөцәйен күлтәрә тә алмайты.

**МӨЦӨК: мөцөк адышу** *брб.д.* төз атуда ярышу (соревнование в стрельбе).

**МӨЧӘ** *т.я., лш., чпр.* к.: **йәүдә 1.** Қолақларына хәтле ут булды, қайа қуйарға белми мөчәне. Бөтөн мөчәм салынған, җаңғыр җawap, ахыры. – *к.т.* Awырыйм әле, бөтөн мөчә awыртып тора. – *нрл.* Сыйырың мөчәсе белән зурмы соң? – *чпр.* Бөтөн мөчә awырта. – *лш.*

**МӨЧКӘЧ** *к.т.* аяк буыннарында була торган авыру (суставная болезнь). Мөчкәч булса, айақны җыйырыб утыра, бер дә җөрми, өшкөрөрләр ийе.

**МӨЧТӘ-МӨЧТӘ** *нрл.* к.: **баш-баш.**

**МӨЧТӨР** *перм.* к.: **салак.**

**МӨШӘК 1.** *тара.* к.: **мацы.** Мөшәк пулмаса, цыцқан пула; **2.** *туб.-ирт.д.* әт (собака).

**МӨШӘННИК** [*рус.* омшаник] *срг.* к.: **абзар 1.** Мөшәнниккә бәрән, бозау йабабыз. Бер мөшәннигебез бар иде йылы.

**МӨШИНКӘ** [*рус.* омшаник] *кас.* к.: **абзар 1.**

**МӨШКӘ 1.** *чст.* к.: **мешкә**; **2.** *т.кам.-крш.* бункер. Камбайын мөшкәсе әй, дәү икән!

**МӨШКӘР** *тара.* гаҗәп (удивительно). Урамда мөшкәр инде.

**МӨШКӘЧ** *чст.-крш.* аяк-кул тартышу, көзән җыеру (судороги).

**МӨШКӘЧЛЕ 1.** *чст.-крш.* рахит авыруы (рахит – у детей). Кайсы берсен баланың мөшкәчле диләр, аны да карчыклар имнәгән; **2.** *дөб.* аягын тартып-тартып елый торган бала турында (о детской болезни, при которой, ребёнок плачет, дёргая ногой). Тиле торма орлоғын аягын тартып җылаған балаға ашаталар, мөшкәчле бала айа-

ғын тартып җылый, зәңгәрсуwы ир баланыкы, алсуwы кыз баланыкы дип җыйдыр ийе әни.

**МӨШКӘШ** *лш.* эч авыртуы (болезнь живота). Мөшкәш булса, балага менә болай уқып өшкөрә: «Ақ тарыны суwырдым, Кибәгеннән айырдым; Мөшкәш белән бүсерне Сабағыннан айырдым».

**МӨШКЕ** *әстр.* к.: **мешке**. Мөшке пәрәмәче пешердем.

**МӨШКӨ** *кузн., тмн., стрл.* к.: **мешке**. Шонон мөшкөсен сыгып аласын. Бер чиләк йасама мөшкө сowон. Пәрәмәчә бездә мөшкөдән дә пешерәләр. Мөшкө чиләтә ойошкан сөттән йасала. Мөшкө бәлеше, кawын бәлеше пешерә идек. – *кузн.* Ачышкан сөттән мөшкө бешерәләр. – *тмн.* Мөшкө эретийем әле. – *стрл.*

**МӨШНИК** [*рус.* мушник] *злт.* ачы яки төче камырдан эченә бәрәңге, дөге һ.б. салып пешерелә торган өчпочмак (национальное кушанье: треугольник); чаг.: **мун′ик**. Мөшникне өс мөгөшләп пешерәбез, бәрәңге, дөгө салабыз.

**МӨШТЕ: мөште өй** *клм.* җәйге кухня (летняя кухня).

**МУГАТЛЫ** [*гар.* + *афф.* -лы] *шрл.* мөгаен, шикелле (наверно, вроде, кажется). Бу квитансалар дебет шалларныкы мугатлы.

**МУҒУЛ** *брб.д.* к.: **моғол 2.**

**МУҒУЛТАУ** *брб.д.* к.: **моголлау**. Сигез муғул муғултапты.

**МУҒЫЛ** *брб.д.* к.: **моғол 2.**

**МУҒЫЛЛАУ** *брб.д.* к.: **моғоллау**. Печән муғыллайбыз, қол мынан та чаптылар ите.

**МУДЫЛАУ** [*рус.* мода + *афф.* -лау] *глз.* идән астына балчыктан нигез өю (засыпать завалинку изнутри). Асты гүлмечте инде ул, мудылыйбыз дилер, балчык үwелер, керпеч были да йасаганнар.

**МУЖГАР** [*рус.* мозжер] *чпр.* утын ярганда кулланыла торган агач чүкеч (деревянный молот, применяемый при раскалывании дров).

**МУЗИЗ′А** [*гар.*] *мәл.* могҗиза (чудо, диво). Ай, музиз′а.

**МУЗИ′ӘН** *кас.*, **МУЗИКӘН** *к.-уф.*, **МУЗЫКАН** [*рус.* музыкант] *кузн., мәл., перм.* гармун. Музи′ән уйнайыммы? – *кас.* Бер музыкан да булса, тамаша эшләтә идек бу бабаңнарны. – *кузн.* Музыканын тартып уйна, Җырлаучыга хут булсын. – *мәл.* Музикән уйнап килә урам буйлап. – *к.-уф.*

**МУЗИКӘНЧЕ** [*рус.* музыкант + *афф.* -чы] *к.-уф.* гармунчы (гармонист). Музикәнче безнең күрше йегете.

**МУЙКАЛЫ** *әстр.* ягымлы (ласковый). Шундый муйкалы кеше, аны йаратмый булмый.

**МУЙМБАҚ** *әстр.* ике рәтле муенса (бусы в два ряда).

**МУЙСА** *нгб.-крш.* к.: **йаға II, 2.**

**МУЙЦА** [*рус.* мовница] *төм.* к.: **минца**.

**муйца пикләү** *төм.* мунчаны томалау (закрывать печь в бане).

**муйца тастымал** *төм.* мунчала (мочалка).

**МУЙЫЛ** *лмб., срг., стрл., кузн., минз., злт., эчк., трбс., төм., тпк., тбл., твр., сазл.* шомырт (черёмуха). Муйыл ашап тешләрем каралды. – *лмб.* Урманга муйылга барып кайттык. – *стрл.* Муйыл, тал, җирек үсә бездә. – *минз.* Муйыл күп бездә, муйылын йыйалар. – *злт.* Муйыллы тау. – *трбс.* Муйылны сындырып бетәләр. – *эчк.* Муйылға өц қат паратылар. – *твр.*

**эт муйыл 1.** *төм.* эт шомырты (крушина). Эт муйылны ашамайсын; **2.** *брб.д.* к.: **гөләф**.

**МУЙЫЛЦА** *тбл.* к.: **минца**.

**МУЙЫМБАҚ** *әстр.* к.: **муймбақ**.

**муйын** муен (шея):

**муйын асмасы** *лш.* к.: **ғылбу 1.**

**муйын бawы** *бәр.*, **муйын бау** *мам.* к.: **ғылбу 1.** Мәрфуға апа бик таққан ул муйын бауны, хәзер дә тага. Әбиләр нинди ашқа йөрсәләр дә муйын бау тағалар, йөзөк кийәләр. – *мам.*

**муйын тәңкәсе** *минз., тпк., стрл.* к.: **йаға II, 2.** Сәсқап, муйын тәңкәсе бәйләйләр қыдлар, сумнық тәңкә тағалар. – *тпк.*

**муйын түмәсе** *бөре.* к.: **ғылбу 1.**

**МУЙЫНДЫРЫҚ** *брб.д.* муенга тага торган тәңкә, бизәнү әйбере (монисто). Муйындырық сабақлап-сабақлап манитларны тоташтырып пауға тессә пер генә рәт, илүлеге полган, тәңкәлеге полған, отыслық.

**МУЙЫНҖАҚА** *каз.ар.-крш.* тар ғына тукыма кисәгенә мәрҗән һәм бөтен тәңкәләр тезеп ясалган, муенга арттан кысып бәйләп куела торган бизәнү әйбере (старинное женское украшение из монет и бус, нашитых на узкую материю, плотно надевавшееся на шею); чаг.: **йага II, 2.** Керәшен қатыннарында муйынҗақа инде.

**МУЙЫНСА 1.** *мам., минз., бгрс., злт.* к.: **йага II, 2.** Муйынса бәйлиләр ийе, дәwәт кийәләр ийе қунаққа барғанда. – *минз.* Шау бөтөннән муйынса. – *бгрс.* Башқа уқадан басып тырып қалпақ кийә торған ыйық, муйынса была торған ыйы тәңкәләр тезгән. – *злт.*; **2.** *перм.* к.: **муйынҗақа**.

**муйынса тәңкә** *бөре.* к.: **йаға II, 2.** Муйынса тәңкә тездем әле җегермешәрледән.

**МУЙЫНЦАҚ** *тара.* к.: **ғылбу 1.** Мәрчән муйынцағы булған қәртнәмнеке. Цылбыр муйынцақ та булған. Муйынцақлар төрлө-төрлө була. Муйынцақлар пула қысыл, йәшел.

**МУЙЫНЧА 1.** *хвл., лш.* тәңкәләр яки төймәләр тезеп ясалган муенса (ожерелье из монет); чаг.: **буйынса**; **2.** *минз.* к.: **йага II, 2.**

**МУЙЫНЧАҚ 1.** *бөре.* к.: **йага II, 2.** Муйынчақ тәңкәләр кийәләр ийе қызыл бәрхеткә тезәләр дә wақ қына тәңкә; **2.** *перм.* к.: **ғылбу 1.** Бу муйынчақны киленем бирде.

**МУЙЫН-ЧУЙЫН** *дөб.* бик күп – балалар телендә (очень много – в детской речи); чаг.: **айап**. И-и, муйын-чуйын анда җиләк.

**МУЙЫНЧЫ** *брб.д.* к.: **мойундырық**.

**МУЙЫНЧЫК** *хвл.* муенчак (ошейник). Бозау муйынчыгын салган. Кычыкнын муйынчыгы йезелгән.

**МУЙЫРЫҚ** *лш.* к.: **майрық**.

**МУЙЫРЫЛЫП** *лш.* **1.** куе, озын булып – иген, үсемлек турында (бурно; густой массой – о растениях). Җәшнәп үсеп киләләр бәрәңгеләр муйырылып. Арыш муйырылып үскән, печән муйырылып үскән; **2.** сузылып-суырылып – кеше турында (становясь высоким и худым – о человеке). Муйырылып қына үсеп килә қызы да;

**3.** хәлсезләнеп, мәлҗерәп (обессилев, ослабнув). Муйырылып утырам менә изелеп, картка күрәдер инде. Муйырылып утырасың, сөйәгең җыйа алмыйсың.

**МУКАЙ** *кузн., мәл., чпр.* к.: **бокай**.

**МУКАЛАУ** *бәр.*, **МУКАННАУ** *злт.* к.: **бүкәйләү**. Мукалап җәрибез, икебезнең дә билебез awырта. – *бәр.* Муканнап йөри ийе, хәзер тәпәйләп йөри. – *злт.*

**МУКЛА** *чст.*, **МУКЛАК** *чпр.*, **МУҚЛАҚ** *блт., т.кам.-крш., перм.* к.: **туқал**. Мукла сыйырның сөте аз була. – *чст.* Безнең элекке сыйыр муқлақ ийе. – *перм.* Сыйырыбыз муқлақ ыйы. – *блт.*

**МУҚЛАҚА** *дөб., блт.* утын түмәре (полено, обрубок, чурбан). Бер муқлақа йарым утын йарырга куштым. – *дөб.*

**МУКЛАШКА** [*рус.* моклашка] *трх.* к.: **горда**. Бу җирнең муклашкалары күп икән.

**муклашка бирү** *к.т.* дөмбәсләү, кыйнау (отлупить, побить).

**муклашка әләгү** *т.кам.-крш., кмшл.* дөмбәсләнү, кыйналу (быть побитым, отлупленным).

**МУКЛАШКЫ** [*рус.* моклашка] *трх.* чукмар таяк (палица, дубина). Суғыш булған элгәре, муклашкылар белән суғышқаннар, башқа төрле қорал булмаған. Муклашкы белән алып биремен.

**МУҚСУМ** *тбл.* к.: **моқсын**.

**МУҚТАЦ** [*гар.*] *тбл.* кирәкле (необходимый).

**МУКЧА** *бөре., минз.* букча (сумка).

**МУЛ′ I** [*рус.* малёк] *м.-кар.* маймыч (малёк).

**МУЛ′ II** [*угор.*] *минз., перм.* салга бәйләмичә агызылган агач, бүрәнәләр (лес, сплавляемый не на плотах, а отдельными брёвнами). Хәзер инде сал белән түгел, мул′ ага инде. – *перм.* Мул′ белән агызу. – *минз.*

**МУЛАСНИК** *төм.*, **МУЛАСНИХ** [*рус.*] *сазя.* сөт савыты (молочница). Муласнихта сөт сахлайwс.

**МУЛАТ** [*рус.* молотило] *тбл.* к.: **чип I**. Мулат белән суққан ашны. Мулат суқтырабыз. Өц мулат, пиш мулат суқтырасың.

**МУЛАТА I** [*рус.* болото] *м.-кар.* к.: **батқақ**.

**МУЛАТА II** *тара.* к.: **чип I**. Мулата ман суққаннар, арышны қоротқаннар әwендә, әwенгә йағалар, залпым суқмыйлар, әле берсе, әле берсе. Мулата белән суққаннар, ул қайышлы булған, алмаш-тилмәш суғалар дүрт кеше.

**МУЛАТАЛЫҚ** [*рус.* болото + *афф.* -лық] *м.кар.* к.: **баткылык**.

**МУЛАТИТ** *төм., тбл.* к.: **чип I**. Мулатитлар белә суққан, мин дә суққан. Түрт мулатит лөпөлтәп кәпләшеп торғаннар суққанта. – *төм.* Қул белән суққаннар, мулатит пелән суққаннар. – *тбл.*

**МУЛАТУК** [*рус.* молоток] *тбл.*, **МУЛАТУХ** [*рус.* молоток] *сазя.* чүкеч (молоток; молот).

**МУЛИНӘ** [*гар.* + *тат.*] *төм.* абыстай, мулла хатыны (жена муллы). Мин мулинә түгел, уғымаған. Мулла қысқа өйләнепте мулинә булаты.

**МУЛИШ** *кас.* к.: **пизел**.

**МУЛЛА I** [*гар.*] **1.** *каз.ар., бәр.* комган борыныңың божрасы (кольцо на кончике носа кумгана, служащего для умывания и религиозных омовений). Мулласы булмаса, қомған мәйет йуwарға дөрес булмый. – *бәр.*; **2.** *мам.* суган көпшәсенең бутоны (бутон стрелки лука).

**МУЛЛА II** [*гар.*]: **мулла беләге 1.** *трх.* ачы камырдан җәймә ясап, эчен майлап төреп пешерелгән камыр ашы (национальное мучное изделие из кислого теста; рулет); **2.** *минз., стрл.* төче камырның өстенә киндер орлығы җәеп, урап пешерелгән камыр ашы (рулет с начинкой из конопли).

**МУЛЛА III** [*гар.*] *тбл.* к.: **молла**. Қәйнәсе бар ите, мулла ите. Уқыган кеше йомшақ тел белән сөйләсен тигем килган ите, мулларақ кешегә тип әйтү. Пестә аннан мулла кеше йуқ.

**мулла баба** *тбл.* **1.** иренең абыйсы (старший брат мужа); **2.** укыган, хөрмәтле кешене олылап атау (обращение к уважаемому, почтенному человеку).

**мулла биғә** *тбл.* иренең апасы (старшая сестра мужа).

**мулла қуца** *тбл.* к.: **мулла баба 1**.

**мулла қыз, мулла қыd** *минз.* к.: **абызастай**. Қайынсеңнем бар, ул мине җиңәчәй ди, мин аны мулла қыз дим, исеме белән әйтмәгәннәр элек.

**мулла қыс** *тара.* элек: укымышлы хатын-кыз (в старину: образованная женщина).

**мулла тусым** *тбл.* к.: **мулла баба 1**.

**МУЛЛАБИКӘ** [*гар.* + *тат.*] к.: **мулинә**.

**МУЛЛАНУ** *мәл., чст.* юкә агачы кабыгы астына су төшү (появление соков под корой липы).

**МУЛЛАТА** [*рус.* болото] *к.т.* к.: **батқақ**. Айағыңа муллата йағылған.

**МУЛЛАТАЛЫҚ** [*рус.* болото + *афф.* -лық] *к.т.* к.: **баткылык**.

**МУЛЛАТЦЫМ** [*гар.* + *фарс.* + *афф.* -ым] *тбл.* иренең энесенә эндәшү формасы (форма обращения к младшему брату мужа).

**МУЛЛӘКӘ** [*гар.* + *тат.*] *тбл.* әтисенең энесе (младший брат отца).

**МУЛЛИНӘ** [*гар.* + *тат.*] *тбл., төм., тара.* к.: **мулинә**. Ул күпне беләте, ул муллинә ите, берас саташыбрақ биргән. – *тбл.* Муллинә булмасам та уқыйм. – *төм.* Муллинә бар ите, ағац қалақ тип кәпләйте. – *тара.*

**МУЛЛИНӘЛЕК** [*гар.* + *тат.* + *афф.* -лек] *тбл.* к.: **кендекәй**.

**муллинәлек қылу** *тбл.* кендек әбисе булу (быть повивальной бабкой). Аңқы әнисе муллинәлек қылып йөрөте.

**МУЛ′ЦА** [*рус.* мовница] *төм.* к.: **минца**.

**МУЛЦАШУ** *тара.* килешү, ризалашу (согласиться, дать согласие). Әле мулцашмағаннар, сурawын суратқан. Икенцеләй туй мулцашу тиделәр.

**МУЛЫҒУ** *минз.* к.: **байығу**. Сәwит wылачы чыққач қына җиргә мулыға башладық.

**МУМАЛА** [*рус.* помело] *тбл.* к.: **мейец: мейец себертке**.

**МУМЫШ** [*рус.* немой] *шрл.* к.: **маман 1**. Карале, теге мумыш нәрсәдер әйтә бит, awызы ачылган. Теге мумышның да теле ачылған.

**МУН′** *хвл.* к.: **бун′**.

**МУНАРА** [*гар.*] *тбл.* манара (минарет).

**МУНАСЫР** *тбл.* христиан чиркәве (христианская церковь).

**МУН'ИК** [*рус.* мушник] *злт.* җиләктән, орлыктан пешерелгән өчпочмак (национальное мучное изделие: треугольник с начинкой из ягод, конопляного семени и т.д.). Мун'ик пешерәбез муйылдан.

**МУНҒАЦАЙ** *том.д.* к.: **кәмәцә 1.**

**МУН'ҖАГА** *кузн.* к.: **муйынча 1.**

**МУНҖАҚА** *каз.ар.-крш.* к.: **муйынҗакә.**

**МУНИСЛӘНГӘН** [?] *минз.* эшкә җитди караучан, эшкә бирелгән, эшчән (деловой, серьёзный, любящий своё дело).

**МУН'СА** *стрл.* к.: **йага II, 2.**

**МУН'САҚ** *тпк.* к.: **гылбу 1.** Тишекле мун'сақ йирдә йатмай.

**МУНТА** *тбл., тара.* **1.** аяк йөзе (подъём); **2.** атның муен белән ыңгырчак урыны арасы (горбинка у лошади между шеей и местом седёлки).

**МУНТАС** *злт.* к.: **дәмбәс.** Самсыкамал әби асық былмас, мунтасрақ былыр.

**МУН'ТӘҢКӘ** *стрл.* к.: **йаға II, 2.** Мун'тәцкәсе булайы, бөтен тәңкәне тишәсең дә тезәсең, бер тәңкәлек, илле тиннеге дә була.

**МУН'ТӨП** *байк.* тәңкәләр белән бизәлгән күкрәк (старинное нагрудное женское украшение из монет).

**МУНЦА** *себ.* мунча (баня).

**мунца цуму** *том.д.* к.: **инү: мунча инү.**

**МУНЦАҚ** *төм.* к.: **гылбу 1.** Мунцақ муйын түмә була. Инәкәмнең мунцақлары бу.

**мунцақ қату** *тбл.* муенса кию (носить ожерелье). Мин ицқацан мунцақ қатмаган.

**мунча** (баня):

**мунча төшү** *твр.* к.: **инү: мунча инү.** Таң атқанчы мунча йағып төшәсең.

**МУНЧАҚ 1.** *перм., нокр.* к.: **гылбу 1; 2.** *к.т., кмшл.* к.: **муйынчык.** Бозауны, гел анасын имеп торғанға, мунчаққа бәйләп қуйдық. – *к.т.*

**МУНЧАК I 1.** *лмб., кузн., м.-кар., стрл.* к.: **гылбу 1.** Чылбырга түмгәләкләр тагасың да, шул мунчак инде. – *стрл.*; **2.** *мәл., лмб., брб.д., твр.* к.: **муйынча 1.** Мунчаклар таккан бун'ысына, мунчагы күк. – *лмб.*

**МУНЧАК II** *тмн.* моның чаклы, бу чаклы, шулкадәр (столько). Бөтеннәй (ы)йатлы итте, мунчак халык алдында (*бәет.*).

**МУН'ЧАК** *карс.* к.: **муйынча 1.**

**мунчала** (мочало, мочалка):

**қашыға мунчаласы** *бөре.*, **мунчала кашык** *хвл.* савыт-саба юа торган мунчала, чүпрәк (мочалка, тряпка для мытья посуды).

**МУНЧАЛАУ** *клд.* к.: **инү: мунча инү.** Мунчаладыгызмы?

**МУҢҚЫЛТАҚ** *твр.* зур кыңгырау (колокол); чаг.: **җицгеле.**

**МУҢНУ** *брб.д.* усал, әдәпсез, әшәке (злой, неприличный, плохой).

**МУР** [*рус.* мор] *перм., хвл.* агу, агулы матдә (яд, ядовитое вещество). Ләпақларға мурға әрем печин қуйалар. – *перм.*

**МУР'А** [*рус.*] *лмб.* к.: **бур'а.** Мур'а кайырган бу талны.

**МУРА** *дөб.* к.: **маман 1.** Бездә муралар бар, алар тертеп кенә силәшәләр.

**МУРАҒАЙ** *тбл.* **1.** чыдамсыз, чарыксыз – агач турында (нестойкий – о дереве); **2.** чыдамсыз, көчсез кеше (нестойкий, нетерпеливый, невыносливый). Қәсерге балалар мурағай, түсми.

**МУРАЙУ** *трх.* муртаю, бурсу (преть, начинать преть, гнить). Сандықта да мурый инде ул чүпрәкләр.

**МУРДА** [*рус.* морда] *лш., дөб., к.т., злт.* к.: **қубыр.** Мурдағыз йуқмы? Зөфәр, мурданы қара. – *злт.*

**МУРДАР** *тбл.* усал, кабахәт, нәҗес (злой, гадкий, низкий).

**МУРИТ** [*рус.* морить]: **мурит булу** *каз.ар.* к.: **бәлтерәү.** Кәҗә артыннан чawып җәреп, мурит булып қайттым. – *дөб.* Чистый мурит булдым бәти эзләп, айақларыма хәдәр сызлый. – *лш.*

**МУРИТЛАНУ** [*рус.* морить + *афф.* -лану] *мам., лш., дөб., т.кам.-крш.* к.: **хыйтлану.** Башы белән муритлана инде, тағы җығыла торған чире дә бар. – *мам.* Бүген көнө буйы муритланып қына утырдым, рәтләп эш тә эшләмәдем. – *дөб.* Ник муритланып торасың терлег асырап?— *т.кам.-крш.*

**МУРЙА** [*рус.* мурья] *глз.* к.: **мира.** И, мурйамны ачкаммын инде.

**МУРКАЧ** *нрл.* кыр куяны (заяц-ковыльник).

**МУРТ I** *тпк.* өзелүчән, уалучан, тотрыксыз (хрупкий, ломкий). Йыланның қабыгы мурт була, тид өдәлә.

**мурт тал** *к.т.* өянке, тирәк (ракита, ива хрупкая).

**МУРТ II** *төм.* к.: **мурағай 2.** Қәсергеләр тың (бик) мурт.

**МУРТ III** *тара.* к.: **морт.**

**МУРТА** *миш.д., кас.* **1.** бал корты оясы, умарта (улей). Бер муртадан былтыр алтмыш килу бал алдык. – *кузн.* Әрәхмәт абзиларның да муртасы бар. Ван'а күршедә мурталар. Мурталарыгызны кырга алып чыкмыйсызмы? – *хвл.*; **2.** бал корты (пчела). Мурта дәваны йаратмый. – *кузн.* Муртамы чактымы икән? Мурталардан куркам, бар, керләрне керт. – *хвл.* Кызым, мурта чакмасын. Мурта чакса, кычкырыр идең әле. – *мәл.* Мурта ычып җери. – *кас.*

**мурта бызыкай** *тмн.*, **мурта қорты** *әстр.* к.: **мурта 2.**

**мурта түндәге** *кузн.*, **мурта түнди'и** *кас.* к.: **мурта 1.**

**мурта чәчәге** *лмб.* к.: **баллы: баллы қуwәт 2.**

**түндәк мурта** *чпр.* багана умарта (колодочный улей). Муртабыз цыкты да кацты түндәк муртадан.

**МУРТАЙУ** *тбл.* шиңү, сәлперәю, черү (дрябнуть, увядать, сгнивать).

**МУРТАЛЫК** *хвл., чпр.* умарталык (пасека).

**МУРТАЧЫ** *миш.д.* к.: **қортчо.**

**МУРТЫҚ** *тбл., тара.* тиз сынучан (ломкий, хрупкий).

**МУРУН** *яүшт.* к.: **морын.**

**мурун бөгы** *яүшт.* к.: **мышық I.**

**МУРЧИ** *тмн., кузн.* салма (мучное изделие, ракушки домашнего приготовления).

**мурчи борон** *хвл.* очы күтәрелеп торган борын (курносый нос).

**МУРЫМ** [*рус.*]: **мурым кыру** *хвл.* бөтен нәрсәне юк итү (уничтожать, ликвидировать всё). Бөтен

кешене мурым кыра. Барысын да мурым кыра, берсен дә күзенә күрсәтми, көн күрсәтми.

**МУРЫЦ** *тара.* бурыч (долг). Алтмыш дүрт сум мурыцым қалты.

**МУС** [*рус.*] *кас., тмн.* күпер (мост).

**МУСАПИР** [*гар.*] *брб.д.* сәяхәтче; кунак (путешественник; гость).

**МУС'КӘ** [*рус.* мячик] *трх.* кечкенә туп (мячик). Мус'кәсе тәгәрәп китте.

**МУТ** [*рус.* мот] *дөб.* дәрт, дәртле (страсть; живой, жизнерадостный, страстный). Җәш чақ – мут чақ. Бу қызга мут керә башлаған инде.

**МУТАТУ** *минз.* сугыштыру, ызгыштыру (заставить ссориться, вызвать ссору).

**МУТИК** [*рус.* мотыга] *лш.* к.: **кәтмәк 1.**

**МУТИКЛАУ** [*рус.* мотыга + *афф.* -лау] *лш.* к.: **кәтмәкләү.**

**МУТЛАНУ** [*рус.* мот + *афф.* -лану] **1.** *дөб.* дәртләну (воодушевляться, проявлять жизнерадостность). Бер мутланып қалыйғ әле; **2.** *м.-кар.* алдалау (обманывать, врать). Малай бит ул мутланмыйча сүләшә.

**МУТОР** *глз.* матур (красивый).

**МУТЫК** [*рус.* мотыга] *лш., каз.ар.-крш.* к.: **кәтмәк 1.** Шул мутык белән күтәрәбез. – *каз.ар.-крш.*

**МУТЫКЛАУ** [*рус.* мотыга + *афф.* -лау] *каз.ар.-крш., лш.* к.: **кәтмәкләү.** Мутыклыйбыз мутык белән. – *каз.ар.-крш.*

**МУЧА** [*рус.* мовница] *минз., байк., нгб.-крш.* к.: **минца.** Муча йақтым, керерсез бит? – *минз.* Мучасы кирәк. – *нгб.-крш.*

**МУШКО** [*удм.*] *глз.* к.: **мошко II, 2.** Мушко белән йәш балаларны йертәләр иде.

**МУЧАЛА** [*рус.* мочало] *бөре., минз.* к.: **минцала.**

**МУЧАУ** *срг.* йолку (рвать, вырвать). Иртәгә кат'масын гына, чәчен мучармын.

**МУЧКА** [*рус.*] *тмн.* талкы (льномялка, мялка). Тевә идең мошконы, мучка йасисың, кабада гребәлкә менән тарый идең, сун йерли идек.

**МУШНИК** *тбл.*, **МУШНИХ** [*рус.* мушник] *саз.я.* сумса; бөккән (пирожок). Мушниккә кәртешкәне wақ турайым, пийас тураб алам. Мушниккә пийас турағалы гәрәк. – *тбл.*

**МУБӘТӘК** *төм.* к.: **мөгәтәк.**

**МУWӘШӘ** *тара.* к.: **мийеш.** Үйүмнең түрт мүwәшәдә түрт йылан күрдем.

**МУWЕШ** *чст., бөре.* к.: **мийеш.** Без мүwешкә хәтле килдек. – *чст.*

**МУГӘЛӘ** *төм.* к.: **торацық.**

**МУГӘЛДӘК I** *к.т.* бишекнең сиртмәгә элеп куя торган җире (приспособление, крючок для подвешивания люльки). Ыргаққа әләргә мүгәлдәк кирәк бит.

**МУГӘЛДӘК II** *кргл.* печән ташый торган тирән арба (телега с глубоким дном для перевозки сена); чаг.: **арба: чытыр арба.** Мүгәлдәк белән төйәп қайта идек печәнне.

**МУГӘТӘК** *тбл.* к.: **мөгәтәк.**

**мүгәтәк цана** *тбл.* туйдан соң кызның әйберләрен күчерә торган артлы чана (кошёвка, на которой перевозят после свадьбы вещи невесты в дом жениха); чаг.: **мөгәтәк.**

**МУ'ӘЛДИ'** *кас.* **1.** өсте ябулы арба (кибитка, повозка); **2.** хатын-кыз мәете өстенә зиратка алып барганда корылган чатыр, чыбылдык (шатёр или полог на дужках, укрывающий носилки, на которых несут покойницу до кладбища). Тәбүт'и, 'уйалар, му'әлди' дип айтәләр.

**МУГЕШ** *перм., злт.* к.: **мийеш.** Чебечне қазлар тенәүгә менгезмәгән кебек, мүгешкә қысылыб үлгән. – *перм.*

**МУГУРДӘК** *твр.* өсте капланган артлы чана; читән арба (крытый возок, тарантас). Мүгүрдәк йигеп, ичинә бер бучка арақ салды.

**МУК: мук чәчәк** *мам.* к.: **ут II: кишер уты.**

**МУКӘЙЛӘУ** *блт., мам.* к.: **бүкәйләү.** Өйдә мүкәйләп йөри ул. – *блт.* Идәндә мүкәйләп йөри ул дүртайақлап. – *мам.*

**МУКЕРИ** [*рус.* мокрый] *лш.* к.: **җүwешмән.**

**МУКЛАБЗАР** *к.т.* к.: **абзар 1.** Элек бәрәннәрне туңа дип өйгә керткәннәр, хәдер мүклабзарда бәрәнни дә, үсә дә.

**МУКЛӘШКӘ** *перм.* к.: **гөмбек.**

**МУКЛЕ I** [*рус.* мох + *афф.* -ле] *трх., нрл., тара.* к.: **абзар 1.** Мүклене ақтарып чистартып чығарған килен. – *нрл.* Мүкледә бозаулар, бәрәннәр тора. – *трх.*

**МУКЛЕ II: мүкле күз** *трх.* яшьле күз (слезящийся глаз).

**МУКЛИЦ** *срг.* кушбаш (голавль). Мүклиц – бәртәскә охшаган балык, канатлары гына кызыл тегел.

**МУКСӘЙУ** *тбл.* бөкрәю (горбиться, сутулиться). Үзе мүксәеп қалған инде.

**МУКШУ** [*угор.*] *перм.* бозыла башлау, дымланып күгәрә башлау (начинать портиться, плесневеть); чаг.: **қабыгу 2.** Сухарины гөлбичкә төшөрмә, базға төшөр, ату мүкшеп китә.

**МУЛЕМ** [*угор.*] *перм.* к.: **мул' II.** Без теге мүлем киткән йылғаға барабыз суға. Бүрәнәләрне мүлем ағыздық.

**МУЛТӘЙУ** *мам., дөб.* күпереп, кабарып тору, бүлтәю (вздуваться, выпячиваться). Мүлтәйеп тора өстәге кесәсе. – *мам.* Тәнендә миң мүлтәйеп чыққа, ул баланың исемен алыштыралар. – *дөб.*

**МУЛЦӘ** [*рус.* мовница] *тбл.* к.: **минца.**

**МУЛЧӘР** *тара.* чама, үлчәү (мера, вес). Син аның мүлчәләрен беләсең, күпме булыр?

**МУМӘТӘК** *төм.* к.: **мөгәтәк.** Киленцәк мүмәтәктән төшкәнтә бөркәүле. Киленцәкне мүмәтәк пелә күцергәннәр.

**МУНДЕР** *том.д.* к.: **чирахман I.**

**МУНЕРӘУ** *кас.* к.: **мөңгөрәү.** Сыйыр мүнери.

**МУНСЕР** *тбл., тара.* к.: **чирахман I.** Мүнсер йawa борчақ-борчақ кебек, қыйар йафрақларын тишеп киткән. – *тара.*

**МУҢГӘЦӘЙ** *яүшт.* к.: **кәмәцә 1.**

**МУҢГУ** *брб.д.* котыру, тибү, арт аякларына басу – ат турында (взбеситься, встать на дыбы, лягаться – о лошади).

**МУҢРӘК** *брб.д.* к.: **көлбуқа.** Мүңрәк үсе кош, бык тиләр урысча.

**МУРӘУ** *м.-кар.* к.: **мөңгөрәү.**

**МУСУРӘУ** *твр.* **1.** кызганып еламсырау (причитать, вызывая жалость); **2.** кызгану (жалеть).

Син үсең мүсүрәсәң, үсең (мине) чығарып алырсың.

**МҮТИ** *злт.* юләр сыман (чудаковатый, глуповатый). Мүти Марат бар бездә, әни, сыйырың бер қычқырды да үлде, диб әйтә, ди.

**ПӨЙАУ 1.** *брб.д.* к.: **сырлау I, 1; 2.** *брб.д., сазя.* к.: **буйақ I.** Чац пөйау. – *сазя.*

**ПӨЙДЫҚ** *брб.д.* аерылып кайткан хатын (разведённая жена).

**ПОЙМА** [*угөр.*] *брб.д., төм.* к.: **пима 1.** Қайнам бағыр йаңа пойма пәрепте. – *брб.д.* Пойма ғуныцына быцағын тыққан. – *төм.*

**ПОЙТАЙ** *тбл.* к.: **питай.** Пойтайын алмай.

**ПОКМАР** [*морд.*] *тмн.* мич алды ягына савытсаба кую өчен сандык сыман итеп ясалган сәке (небольшие нары, устроенные напротив или наискосок от шестка печи, служащие одновременно кухонным столом и шкафчиком для посуды).

**ПОҚОРЛАУ** *кргл.* **1.** борчу (беспокоить). Йата да йоклый, анда да мине поқорлый; **2.** тузгу (трепаться, растрепаться).

**ПОҚРАТУ** *кргл.* тузан туздыру (поднять пыль). Тузанны поқратма.

**ПӨҚСАҚ** *брб.д.* бәйләнеш (узы).

**ПӨҚСАҚЛАУ** *брб.д.* бәйләү (связывать).

**ПОҚТА** [*фарс.*] *тара.* пөхтә, чиста (аккуратный, опрятный). Машината бы шигелле поқта булмайты.

**ПОЛ** [*фарс.*] *төм.* акча (деньги). Синә рисалығыммы, полыммы кәрәк?

**ПОЛАWЫР** *тара.* мәшәкать, комачаулау (трудность, неудобство). Полawыр қылып, ицкесен мынта қуйаты.

**ПОЛАЙЦА** *тбл.* болай (так). Полайца сүсне шәп сөйләйте.

**ПОЛАҚ** *төм.* к.: **йылыу.**

**ПОЛ'АК** *чпр., чст.* к.: **мақау 1.** Пол'ак сүләү. – *чст.*

**ПОЛҒАНУ** *төм.* пычрану, буялу (пачкаться, испачкаться). Тракторға параты та майға полғанып киләте.

**ПОЛҒАУ** *төм., тбл., сазя.* пычрату (пачкать). Пер китапны полғамайты. – *төм.* Өстөңне полғамайцы йөрей алмайсың. – *сазя.*

**ПӨЛИМ** [*рус.* полынь] *төм.* к.: **нәркәмәс.**

**ПОЛМАҚ** *твр.* к.: **мийеш.**

**ПОЛОҒУ** *брб.д.* к.: **полғану.** Анан полоғоп цыға, битләре пыцранып.

**ПОЛОҚ** *брб.д.* пычрак (грязь).

**ПОЛТЫРАУ** *перм.* к.: **абдырау 1.** Әнийең безгә полтырап кереп чықты йы.

**ПОЛУННЫ'** [*рус.* половник] *кас.* к.: **багырча.**

**ПОМИЧ** [*рус.* помочь]: **помич итү** *брб.д.* өмә ясау (устраивать помочь). Көршеләрне әйтеп, помич итеп, қаз сойып. Инәм терүwендә қаз көн полдоғон, анда помич итәдеген. Помич итеб әрләттем йөннө.

**ПӨМӨЦ** [*рус.* помочь] *брб.д.* ярдәм, урак эшләрен күршеләр ярдәме белән бетерү (помощь, окончание жатвы при помощи соседей); чаг.: **помич: помич итү.**

**ПОҢГЫЛДАТУ** *чпр.* яңгырату (издавать гром-

кий, звонкий звук). Поңгылдаталар гына пат′ифунны, туй быт!

**ПОППА** *твр.* **1.** к.: **қартатай 1**; **2.** әтисе яки әнисенең абыйсы (старший брат отца или матери); **3.** әтисе яки әнисенең апасының ире (муж старшей сестры отца или матери). Инәмнеңке оққасына поппа дийәр идем.

**ПӦППА** *твр.* к.: **қартатай 1**.

**ПОР** *тбл., төм., брб.д.* к.: **бурым**. Маңнайына пор йышып қуйадыр. – *тбл.* Маңнайға көwә сөртөп, мич алның поро ол, қара пор. – *брб.д.*

**ПОРАМ** *тбл.* мул, күп (много, обильно). Пар чагында порам, йуқ чағында алай та торам (*әйтем*).

**ПОРАНУ** *тбл.* бертуктаусыз ашап йөрү (беспрестанно что-нибудь жевать).

**ПОРАУ: порау цыбық** *тара., брб.д.* к.: **кәй: кәй цыбық**.

**ПОРҒАТА: порғата китү** *тбл.* олағу (пропасть бесследно, как в воду кануть).

**ПОРҒАУ, ПОРҒЫТУ** *төм.* ату, ташлау (бросить). Қана, ник порғайсыс йылыwытны, ул цай қуй, мин аны қорытарым.

**ПОРЗУМИТ** [*рус.*] *перм.* камзул кырыена тотыла торган укалы тасма (позумент). Әңкәйнеке камзул бар ий,·порзумитын алғаннар.

**ПОРКИ** [*рус.*] *тара.* киездән эшләнгән аяк киеме (войлочная обувь типа ботинок); чаг.: **буркы**. Порки батинка шикелле, кийестән пула.

**ПОРЛАУ** *брб.д.* агарту (белить). Мичте порладым.

**ПОРМАЦА** *тара.* урама (национальное кушанье: хворост трубкообразной формы). Төцө қамырдан пормаца пешерәбез, сансаның қамырыннан моның йомшағрақ пула. Пормаца күкәй белән генә изәсең қамырны, уртасы тишек, майда пешерелә.

**ПОРНАҒО 1.** *тбл., төм.* борынгы (древний). Порнаго мәрценне белә тегенсес, цын мәрцен. – *тбл.* Тура йылғасының порнаго исме Чемке пулған. – *төм.*; **2.** *тбл., төм., сазя.* өченче көн, өченче ел (позавчерашний день, позапрошлый год). Порнаго уғытуцы ул, ун клас пөтөргән. – *төм.*

**порнағы йыл** *тбл.* үткән ел, былтыр (в прошлом ғоду). Порнағы йыл Қасанға бардық.

**ПОРНАҒЫЦА** *төм.* борынгыча (по-старинному, по старинке).

**ПОРНАҢҚЫ** *төм.* к.: **порнаго 1**. Порнаңқы сүз кәптәшсәң, аңламайтылар ите. Порнаңқы йазуцыларны уқыту йуғ иде пит элек.

**ПОР′Н′У** [*морд.*] *кузн.* к.: **пырну**.

**ПОРОҚ** *тбл.* берүк, әмма, ләкин (только, но). Урамға цық, пороқ осақ йөрмә.

**ПОРОН I** *тара.* элек (раньше). Порон булса, қаныт тирләр ийе, қәсер шикәр.

**ПОРОН II** *сазя.* томшык (клюв).

**ПОРОНЙАУЛЫҚ** *туб.-ирт.д.*, **ПОРОНЙАУЛЫХ** *сазя.* кулъяулык (носовой платок).

**ПОРОС** [*рус.* брус]: **баш порос** *перм.* тәрәзә башы (верхний брусок окна).

**қабырға порос** *перм.* к.: **йәйәк II**.

**табақ порос** *перм.* к.: **қучағыс**.

**ПОРСАЛАНУ** *т.я.* к.: **борсалану**. Төне буйы йоқлый алмый порсаланып йаттым.

**ПОРСЫМ, ПОРСЫМ-ПОРТАҚ** *тара.* шапшак (неряшливый); чаг.: **жубалғы**.

**ПОРТ** [*рус.* пруд] *тмн.* к.: **бума 1**. Безнең ызба порт йагалый тора.

**ПОРТАҚ** *тбл.* саксыз; киемне тиз туздыручан (небрежный, неопрятный, быстро изнашивающий одежду, расточительный). Портақ кейәм кейемне мин, әшкәрә портақ.

**ПОРТСУWА** [?] *перм.* к.: **йәwер I**. Безне Солтан портсуwасы диб әйтәләр, начар портсуwа тиләр.

**ПОРУС** [*рус.* брус] *минз., бөре., перм.* к.: **йәйәк II**.

**ПОРЦАҚ** *төм., тбл.* к.: **таш**. Порцақ йаwа. – *тбл.*

**порцақ йаwын** *төм.* к.: **таш**.

**ПОРЦАУ** *твр.* үрү (прорастать). Картупкаң порцайты.

**ПОРЦУ** *тбл.* чистарту (чистить). Әнийем қосоқ порцушғалы гиләте.

**ПОРЫН I** *тара.* к.: **порон I**. Порын калхуста эшләгәнем.

**ПОРЫН II** *себ.* борын (нос).

**ПОРЫНБУҚ** *тбл.* к.: **мышық**.

**ПОРЫС** [*рус.* брус] *минз., бөре., перм.* к.: **йәйәк II**.

**ПОС I** *к.-уф.* җиз иләктән иләнгән он (сеянка). Онның посыннан ғына күмәч пешердем.

**ПОС II: пос булу** *минз.* шым булу, тынып калу (утихать, утихнуть). Җырлап киләләр җәшләр, муллабзый турысына йетсә, пос булалар ийе.

**ПӦС** *брб.д.* **1.** соры, бүз (серый, сивый); **2.** туры – ат турында (гнедой – о масти лошади).

**ПОСҚАҚ** *мам., минз.*, **ПОСКАК** *стрл.* тире калдыклары (обрезки меха). Тире посқақлары өйөп қуйғаннар. – *мам.* Тире поскакларын кыркып, эрләп, бийәләй бәйләп була. – *стрл.*

**ПОСМАҚ** *злт.* к.: **бүлмәч 2**. Посмақ тәрәзәсенә аппарып бастыра да қарамый тораң инде.

**ПОСМАҚЛЫ** *тпк.* бүлемле, яклы (...стенный). Өйләр ике посмақлы, хәдер мунсалар ике посмақлы.

**ПОСОҚ** *туб.-ирт.д.* бозык – hава торышы турында (ненастный, слякоть – о погоде).

**ПОСОЛУ** *төм., сазя.* җимерелү; ватылу (разваливаться; сломаться). Посолоп киткән өйө. – *төм.* Awылға йетмәй машина посолты. – *сазя.*

**ПОСТА: үз поста, үз постасы** *лмб., тмн.* зыяндаш (эпилепсия). Ыланнарының үз постасы иде, үлеп тә китте. – *лмб.* Үз постаны кат′аручы да бар иде. Йата, бутта үз поста. – *тмн.*

**ПӦСТУЙҒУН** *брб.д.* карчығаның бер төре (ястреб-тетеревятник). Инде қара ылауцын пӦстуйғунум пар, аны тудуп қуш күдөрбүзүң?

**ПОСУ** *чст.* үлү, үлеп бетү, юкка чығу (вымереть); чаг.: **бетү I, 1**; **үчү 1**. Фудырыфлар бар иде безнең awылда, алар да поскан инде.

**ПОСЫНЦЫ** *төм.* сихерләп бозучы (злая колдунья). Кеше посатығын йаман қортқайақ, посынцы.

**ПОТ** *бөре., кас., кузн., срг., байк.* бот (бедро).

**ПОТАҚ** *бөре., блт., злт.*, **ПОТАК** *кузн., хвл., байк.* ботак (ветка). Потақ алып қайтырға урманға киттеләр. – *блт.*

**ПОТАТАРА: потатара ғылу** *тбл.* әрәм-шәрәм

итү, туздырып бетерү (промотать, растерять). Нәрсә-гәраңны потатара ғылма.

**ПОТАУ** *тбл.* киселгән агачның ботакларын чабып алу (обрубать ветки со спиленного дерева). Ағацның потақларын палта белән потайбыс.

**ПОТЛАҚ** *төм.* елга тамагы (устье реки). Тура (*ел. ис.*) түренең потлағыннан сыу керә йасғы ташуда.

**ПОТ'МАР** *тмн.*, **ПОТМАР** [*морд.*] *кузн.* к.: **покмар.**

**ПОТСАН** [*рус.* подсанки] *каз.ар-крш.* к.: **сәләскә.** Аңа озон потсан белән төйәп қайтырлық кисә пучыны. Потсан белән тартып алып қайтты онны.

**ПОТТУФКЫ** [*рус.* подтопка] *лш.* к.: **патлуфкы.** Поттуфкыға ғына жағырбыз, су жылытасы бар.

**ПОХЫН** *мәл.* симез, үзен-үзе күтәрә алмый торган – хайван яки кешегә карата әйтелә (говорится о полном, тяжёлом на подъём человеке или тучном животном); чаг.: **балбан.**

**ПОЦҚАҚ 1.** *тбл., төм.* пошиның балтыр тиресе (кожа, содранная с голени лося); **2.** *тбл., тара.* хайванның бот тиресе (кожа с бедренной части ноги любого животного); чаг.: **почқақ.**

**поцқақ тун** *тбл., тара., төм.* тиредән тегелгән тун (шуба, сшитая из меха, из шкуры, содранной с голени любого животного). Төлгө поцқақ туным бар ите. – *тбл.* Поцқағы булған әркемнең, поцқақ тун, байырақларның төймәләре көмеш, йалтырақ, йағалары қыйулап қуйылған, эце поцқақ йон пулған. Поцқақ тун тектереп алғаннар. – *тара.*

**ПОЧҚАҚ 1.** *каз.ар.-крш.* ат, болан, поши сыйрағының тиресе (шкурка с ног лошади, оленя или лося); чаг.: **поцқақ.** Быйыл ғына теккән туннарымның Тиреләре булды почқақтан (*хал. жыр.*); **2.** *перм.* ат сыйрағының тиресе, балалар аны гадәттә шуар өчен киез итек астына тегеп куялар (шкурка с ног лошади, которой дети подшивают валенки, чтобы в них можно было кататься).

**ПОЧМАҚ** *дөб., блт., мам., лш., каз.ар.-крш., минз., нокр., т.я.* к.: **бүлмәч 2.** Бөркәнчеген бөркәнеп почмақта ашап йәшәгән инде ул килен кеше. Мич жағы почмақ була. – *дөб.* Почмақтағы идәнне себерергә ничә бардым, гел онотам. – *мам.* Безнең әби почмақта. – *лш.* Без почмақта ич, безен түргә чығып ашаған жуқ. Почмақта бер сәке жасап бир әле, Микулай. – *каз.ар.-крш.* Бар, син почмаққа кереп жат. – *нрл.* Почмақ сәкесенә утырт самуwарны, чәйне шунда эчәрбез. – *к.т.*

**алтынчы почмақ** *блт.* өйгә кушып эшләнгән кушымта (пристрой к дому). Өйнөң алтынчы почмағына ағачлар алғаннар.

**почмақ жақ** *каз.ар-крш.* к.: **бүлмәч 2.**

**ПОЧМАК 1.** *чпр.* к.: **бүлмәч 2; 2.** *лмб.* өчпочмак (национальное кушанье – треугольник). Почмаклар йабалар кунакка, ит мән картукныкы.

**ПОЧЫҚ I** *минз.* тубал, тырыс (лукошко, кузов); чаг.: **қарнаса.**

**ПОЧЫҚ II** *т.кам.-крш.* к.: **безрәк.**

**ПОЧЫК** *чпр.* **1.** ике пот сыешлы савыт (посуда вместимостью в два пуда); **2.** ике пот – авырлык үлчәү берәмлеге (тяжесть в два пуда). Ике подауканы элек почык дигәннәр.

**ПОШ** [*угор.*] *глз.* к.: **мошко I, 1.** Пош бар иде, чәчеп үстерибиз, аркан ишәләр.

**ПОШАЛАНУ** *злт.* к.: **пешәләнү.** Йоқлый алмыйса пошаланып йаттым таңға хәтле; чаг.: **борсалану.**

**ПОШАМАН** [*фарс.*]: **пошаманға қалу** *т.кам.-крш.*, **пошаманға төшү** *минз.* к.: **борсалану.** Пошамый торган кеше бер дә пошаманға қалмый әле. Мине теге бала тәки пошаманға қалдырды әле. – *т.кам.-крш.*

**ПОШКА: сары пошка** *хвл.* сары кешегә кимсетеп әйтелә торган сүз (о рыжем человеке – уничижительно).

**ПОШҚУ** *перм.*, **ПОШКУ** *хвл.* тишектән, ярыктан каты бәреп чығу – төтен яки газ турында (сильно проникать через дырку, щель – о дыме или газе).

**ПОШҚЫНУ** *брб.д.* сагыну, пошыну (скучать, беспокоиться); чаг.: **пошалану.**

**ПОШЛАҚ: сары пошлақ** *дөб.* к.: **пошка: сары пошка.** Сары пошлақ қына бер жегет шунда.

**ПОШЛЫҒА** *перм.* печән кибәненең уртасына һава йөрү өчен утыртып куела торган казык, шеш (шест, колышек, тычок для проветривания чего-либо, стога и т.п.).

**ПОШОМАН: пошоманға қалу** *т.я.*, **пошоман төшү** *мам.* к.: **борсалану.** Әнәйнең эченә пошоман төшкән, мин китә дип қурқа. – *мам.*

**ПОШОМНАУ** *перм.* аяк киеменең өске өлешенә киндер тегеп чығу: гадәттә аңа бау тығып калдыралар һәм бөреп куялар (пришивать обуви холщовый верх, оставляя внутри верёвку для завязывания). Қынжырыйқны пошомныйлар читен, бау тығылған була.

**ПОШУ** *перм.* пычак белән сыдырып жибәрү (полоснуть ножом).

**ПӨГӘЖӘ** *тпк.* к.: **бөгәлжә I, 2.**

**ПӨГӘР** *тпк.* к.: **богол 1.** Тубығым кәкерәйде, пөгәрдән тарта башлады, сөйәк сыга да китә.

**ПОГӘРӘП** *тпк.* [*рус.* погреб] к.: **нәүрәп.** Имәнне пөгәрәпкә қуйалар.

**ПӨГӨ** *брб.д.* көчле, батыр (сильный, геройский).

**ПОГОН** *брб.д.* кәкре, бөкре (кривой, горбатый).

**ПӨГӨРӘП** *стрл.*, **ПӨГРӘП** [*рус.* погреб] *стрл., тара.* к.: **нәүрәп.** Сөт-катыкларны пөгөрәпкә куйабыз.

**ПӨГРҮЗҮК** *брб.д.* кәкре (кривой).

**ПӨДОНО** *брб.д.* к.: **пытпылдык.**

**ПӨЙДИР** *брб.д.* бөер (почка).

**пөйдир түби** *брб.д.* ян (бок). Қозыкөрпәц бир йақ пөйдир түбиндә йатты, ә айақтан пасалматы.

**ПӨЙЛӘК** *брб.д.* **1.** урман (лес); **2.** к.: **бүләк II, 3.** Пөйләкләр көп пестә, қарағай полаты.

**ПӨЙУ** *брб.д.* калкып тору (возвышаться). Сусыс нәмәсис төң сәwәл пөйип йар пөйы.

**ПӨК** *брб.д.* бик (очень). Пөк пийек, сығып пулмайсың.

**ПӨКЛӘНУ 1.** *төм.* бөгелү (загибаться, согнуться). Айағым пөкләнә тип күргәстеб утырды пескә; **2.** *брб.д.* бөкрәю, сығылу (горбиться, гнуться, наклоняться). Гоурыт пойлап қапчық пөкләнеп йөрөмәсен.

**ПӨКЛӘС** *тпк.* к.: **бөгөл 2.** Ул ана анда пөкләстә генә тороп төйәгән икән кирпечне.

**ПӨКЛӘШ** *брб.д.* борылыш (поворот, изгиб); чаг.: **бөгөл 2.**

**ПӨКМӘ** *тәр.* **1.** сумса (пирожок). Пөкмәне теләсәң нидән, иттән бешерәңме, кәпестәдән бешерәңме; **2.** к.: **шөшпәрә.**

**ПӨКМӘЦ: пөкмәц цалғы** *тбл.* бөгебрәк утыртылган чалгы (коса, насаженная под более острым углом). Пөгөләпсу утыртылған цалғыны пөкмәц титеген.

**ПӨКСУ** *брб.д.* **1.** гәүдәнең аскы өлеше (нижняя часть туловища); **2.** мылтык түтәсе (приклад ружья).

**ПӨКТӘУ** *брб.д.* жыю, камау (собирать, окружать). Қуйлар чүрә йаққа қачтылар, өйсемнең пөктәүгә көчем йетмәте.

**ПӨКЛУҚ** *брб.д.* бөкрәйгән (сгорбившийся).

**ПӨЛӘ** *брб.д.* бура (сруб).

**ПӨЛӘЛӘУ** *брб.д.* буралау (рубить, срубать). Ише таып, пөләләп оутызып қойдық, игенче йылны мөккә оутызып алдық та ул уқ йылны инеп қойдық йортыбызға.

**ПӨЛИК** *брб.д.* куак (куст); чаг.: **бүләк II, пүләк II.** Пир пөлик пир ағаңқа йитәләде.

**ПӨЛМӨ** *брб.д.* **1.** к.: **ишеғалды; 2.** к.: **бацқыщ 1.**

**ПӨР I** *тбл.* тал (ива).

**ПӨР II** *тбл.* к.: **пөре 2.**

**ПӨР III: пөр исе** *брб.д.* берүзе (он один). Пөр исе генә йәшәй.

**ПӨРГӘНЦЕК** *төм.* к.: **арцуwыл.** Пестә қатыннар пөргәнцек пөргәнеп йөргәннәр.

**ПӨРГӘНЧЕК: пөргәнчек мынан туу** *брб.д.* йөзлек белән туу (родиться в сорочке). Пәүзийә тигән қысым пөргәнчек мынан тыwды.

**ПӨРГӘУ** *тбл.* каплау (закрывать). Аны шәл белән пөргәйтеләр. Киленцәк питен пөргәп цыққан, йақшы мамық шәл.

**ПӨРЕ** *тбл.* **1.** к.: **кәй: кәй цыбық; 2.** бөре (почка).

**ПӨРЛӘУ** *саз.я.* күтәрелү – тузан турында (подняться – о пыли). Кеше ашанғанцы тусан пөрләтмәце.

**ПӨРЛӨК** [*рус.* проулок] *минз.* к.: **икара.** Бу пөрлөкне қуйып, икенче пөрлөккә керегез. Моннан чыққач, икенче пөрлөктән төшөп китәсез.

**ПӨРМӘ I 1.** *тара.* к.: **балан II: балан итәк.** Пер икөц пөрмә пула. Итәге пөрмәле күперле пула, кесәсе пула; **2.** *саз.я.* оек куныч (голенище чулка).

**қасан пөрмә** *тара.* к.: **балан II: балан итәк.**

**тобоқ пөрмә** *тара.* тез турындагы бала итәк (оборка, пришиваемая к низу женского платья около коленей). Пашлықлар үс төсөннән тобоқ пөрмә қуйа тоган иге рәт.

**ПӨРМӘ II 1.** *тбл., брб.д., тара.* тире аяк киеме (поршни). Пөрмә поцқақтан тегеләт. Айақта тиртән пөрмә, ул паулы, ана шалай пәйләп-пәйләп аш цацтық үгес пелән сүрәп. Пөрмәнең қунысы қысқа. – *тбл.*; **2.** *брб.д.* чи тиредән тегелгән аяк киеме (поршни из сырой кожи). Тиртән пөрмә кәйтек.

**ПӨРМӘК** *брб.д.* к.: **пөрмә II, 2.** Пөрмәк мал айағынан, сойған тәресеннән.

**ПӨРМӘЦӘ** *тара.* **1.** иләнмәгән тиредән тегелгән аяк киеме (обувь, сшитая из необработанной шкуры). Тийердән пөрмәцә қылып кийәделәр, сыуда ләц пулып китәде, йәш тире қый. Пөрмәцә, йаңғыр булса, цеменеп китә, аннан қатып китә. Пөрмәцә кийә торғаннар, тиредән тегеб ала торғаннар аны; **2.** к.: **пөрмә II, 2.** Тирене сытырып айаққа пөрмәцә тегеп кигәннәр.

**ПӨРМӘЧЛӘУ** *тбл.* бөрмәләү (делать оборки). Пөрмәчләп тегәтләр пөрмә-пөрмә итеп.

**ПӨРМӘШКӘ 1.** *тбл., төм.* бөрмә, бала итәк (волан, сборы). Қайбере пөрмәшкәсе була гуй, элтереп қуйғалы моннан, муйыннан элгәле сапунны; **2.** *төм.* оек, носкиның резинкасы (резинка чулок, носков).

**ПӨРМӘШКӘЛЕ** *төм., тбл.* канатына бала итәк таккан (с оборками – пришитыми на плечах передника). Пөрмәшкәле алтйапқыцлар булған. – *тбл.*

**пөрмәшкәле көйләк** *төм.* бөрмәле күлмәк (платье с оборками). Киленнең пөрмәшкәле көйләге. Пер пөрмәшкәсе көйләк оцона тегелгән, пер пөрмәшкәсе өстенә тегелгән.

**ПӨРӨ** *брб.д.* бүре (волк).

**ПӨРСИНТ** [*рус.* брезент] *тбл.* брезент. Бротн'әне (аяк киеме) пөрсинттән қылғаннар.

**ПӨРТУ** *брб.д.* коба ат турында (бурый – о лошадях).

**ПӨРУ** *брб.д.* к.: **пөрө.**

**ПӨРЧӘК** *брб.д.* **1.** к.: **пөре 2; 2.** ногыт борчагы (боб).

**ПӨТӘ(СЕ)** *тбл.* к.: **пөтөрә 1.** Қайтан килтең, қайта парасың – пөтәсен сурайтылар.

**пөтә итү** *тәр., тбл.* ямау, төзәтү, рәткә китерү, бөтен итү (починить, исправить). Сал айағыңны, итегеңне пөтә итәйем. – *тәр.*

**ПӨТӘЙ** [*морд.*] *стрл.* имчәк башы (сосок). чаг.: **пети I, петәй 1, петей.**

**ПӨТӘЙУ** *саз.я.* ямалу (подвергнуться починке, быть исправленным).

**ПӨТӘҮЛӘТӘ** *злт.* бөтен көе, бөтенләй (целиком, в целом виде); чаг.: **пөтү II.** Бәрәңгене пөтәүләтә пешеримме, йарыпмы?

**ПӨТӘЦӘК** *туб.-ирт.д.* әрәм-шәрәм итүче, мал туздыручы (транжира).

**ПӨТӘШТЕРУ** *злт.* ямау (чинить). Тишек табақлар пөтәштерергә килә иде.

**ПӨТӨРӘ 1.** *саз.я.* бөтенесе, барысы (все); **2.** *тбл.* бөтенләй (полностью, целиком). Тешләрем пөтөрә беткән. Пөтөрә алып киткәннәр пернимә қалдырмай. Эшмәгәр пулған атам, көрәшкән, пөтөрә йығып қуйған.

**ПӨТӨРӘСЕ** *тбл.*, **ПӨТӨРӨСЕ** *саз.я.* к.: **пөтөрә 1.** Пөтөрәсен әйтәм, икәwе үгей, өцәwе тормошло. Қышларның пөтөрөсе тә йыйылты.

**ПӨТӨРУ** *себ.* бетерү (кончать). Кәмиле пawалар өйләрен йасап пөтөртеләр.

**ПӨТРӘ** *саз.я.* к.: **пөтөрә 1.**

**ПӨТРӨ** *саз.я.* к.: **пөтөрә 2.**

**ПӨТУ I** *бөре., чпр., байк.* к.: **бөтү I, 1.** Пөтү өцпоцмаклы була баш awыртканга. – *байк.*

**ПӨТУ II** *байк.* бөтен (целый). Пөтү бәрәңге. Нийә, ул пөтү була, ашарсыз.

**ПӨТУ III** *себ.* к.: **пөтөрү.**

**йоқы пөтү** *саз.я.* йоқы тую (выспаться).

**ПӨТҮЛЕ: пөтүле йурған** *бөре.* к.: **бөтүле.**

**ПӨЧТӨК** [*рус.* пустяк] *бөре.* к.: **безрәк.** Пөчтөк кенә тәмәке бирде.

**ПРАБУР** [*рус.* проворный] *мам., бөре., кмшл., чст.* к.: **җитек I.** Безнең Шафийә бик прабур ул эшкә, барысын дагын калдыра. – *мам.* Әтәйем прабур булган. – *бөре.* Прабур да бик, башлы малай ул. – *чст.*

**ПРАГАЛ** [*рус.* прогал] *лмб., кузн.* ике бәрәңге бакчасы арасында калган тар тыкрык (узкий переулок, проход между двумя огородами, приусадебными участками и т.д.). Прагалдан гына барырга суга. – *лмб.* Йырак тегел, прагалда пырут. – *кузн.*

**ПРАГУН** [*рус.* прогон] *срг.* к.: **табыр 2.** Прагунга барып саудым кәзәмне.

**прагун чабу** *мам.* ямщик булып йөрү (в старину – служить ямщиком). Пүләнкә (Вятские Поляны) белән ике арада прагун чапты минем қарт.

**ПРАК: прак сөт** *туб.-ирт.д.* өсте җыеп алынган сөт (снятое молоко).

**ПРАКОС** [*рус.* прокос] *төм.* печән юлы (прокос). Пракос горый, тырнавыщ белән йыйасың, сәнәк белән моғолга саласың.

**ПРАМЫШ** *шрл.* вак кигәвен (мелкий овод); чаг.: **бусан.**

**ПРАН** *тбл., сазл.* бөтенләй; нәкъ, тәмам (совсем; точь-в-точь). Палалары йыланныңқы пран кисәртке. Ир кеше пран йуқ, кел пицә. – *тбл.* Пран йоп-йован. – *сазл.*

**ПРАҢҚА** *сазл.* к.: **гелән.** Праңқа миннән ахца сурайт.

**ПРАУКА** *срг., злт., чпр.*, **ПРАУКЫ, ПРАУЛКА** [*рус.* проулок] *чпр.* к.: **икара**; чаг.: **прагал.** Праука төшә бит, шул праука йанында. – *срг.* Ул праукадан узма келиме дир. – *чпр.* Праукыга йеткәнце зата бардым. Праулка тебендә саклап тырып минем апаны ырлап кайталар.

**ПРАХА** [*рус.* пряха] *әстр.* җеп эрләгеч, җеп эрләү машинасы (прялка). Прахаң йуқмы?

**ПРӘЖӘ** *нокр.* керәшә, яр карлыгачы (береговая ласточка, касатка).

**ПРӘНИЦӘ** [*рус.*] *тара.* к.: **кабатеп.**

**ПРӘНКӘ I** [*рус.* пряник] *чпр., чст., мәл.* к.: **перәндек.** Прәнкәсен ашадылар, ахры. – *чпр.* Прәнкә бир! – *чст.*

**ПРӘНКӘ II** [*рус.* пронога] *карс.* к.: **беләзек II.**

**ПРИКАШШИК, ПРИКӘШШИК** [*рус.* приказчик] *злт.* к.: **перкәшшик.** Икесе дә прикәшшик, «Детский мир»дә эшлиләр.

**ПРИМЕ** [*рус.* пример]: **сүз примесенә** *блт.* сүз уңаена (к слову). Сүз примесенә генә әйтелә инде ул.

**ПРИНЧИТ** [*рус.* причелина] *кмшл.* к.: **налишник.**

**ПРИ-ПАРӘ** [*фарс.*]: **при-парә китерү** *нокр.* к.: **зәр-бәзәр: зәр-бәзәр китерү.** Печәй беттеге гөлләремне при-парә китергән қучақтан төшөреп.

**ПРИСАДНИК** *кузн.*, **ПРИСӘДНЕ'** [*рус.* присадник] *кас.* урам бакча (полисадник).

**ПРИСТУП** [*рус.* приступок] *злт.* мич башына менә торган басма (приступок).

**ПРИТЫК** [*рус.* впритык] *төм.* өйгә кушып эшләнгән кушымта (пристрой к дому); чаг.: **почмақ: алтынчы почмақ.** Пес притык суғып йебәрдек. Awыр саманта притык қына йы.

**ПРИЧИНЕ** [*рус.* причелина] *кмшл.* к.: **налишник.**

**ПРУБЫР** [*рус.* провор] *дөб.* к.: **җитек I.** Қыз алсаң, эшкә прубырын алырға кирәк.

**ПРУЖИНА** [*рус.*] *к.т.* **1.** к.: **будырма.** Пружинасы бушаган, ойоғым төшөп җөри; **2.** к.: **баҕана I.** Пружинасын ничек бәйлим ойоқның: киңме, тармы?

**ПРУС** [*рус.* прусак] *нрл.* к.: **пал'ак.** Ул прусслар чығар ыйы сары ғына. Элеке булайде прусслар Қазан җанында.

**ПРЫТ** [*рус.* пруд] *тмн., перм.* к.: **бума I.** Прытқа төшөп китсәң, үләсең. – *перм.*

**ПРЫЧТИ** [*рус.* прости]: **прычти кич** *т.кам.-крш.* Масленица, май чабу бәйрәменең соңгы көне (последний день Масленицы). Ул прычти кичтә уйныйдыр ыйық, бийек тау башыннан шуwадыр ыйық чәнәшкә белән.

**ПУ** *брб.д.* күгәрек (плесень).

**ПУБАЙКА** *туб.-ирт.д.* к.: **сырмыш.** Пубайка қысқа кийәтләр. – *тбл.*

**ПУБЫСКА** [*рус.* повозка] *блт.* к.: **мәдәк 3.** Пубыскалар да булған байларда. Пубыска awылда ике генә кешедә бар ыйы, қаплаулы була ул.

**ПУWАЙКА** *сазл.* к.: **сырмыш.**

**ПУWАҚ I** *тбл.* к.: **бывак.**

**ПУWАҚ II** *брб.д.* к.: **будырма.**

**ПУWАСЛАУ** *брб.д.* к.: **powаслау.**

**ПУWАЦҚЫ** *брб.д.* к.: **будырма.**

**ПУWУЗНИК, ПУWУҖНИК** [*рус.* повозник] *м.-кар.* кияү егете (шафер, дружка).

**ПУҒА** *брб.д.* к.: **поға.**

**ПУГАЙ** *чпр.* к.: **пал'ак.** Пич башларында кара пугай бетми генә. Балыгызны ацык калдырсагыз, пугайлар тулыр.

**ПУГАМЕС** [*рус.* пуговица] *минз.* к.: **пауфка.**

**ПУГАР'АП** *кузн., хвл., чст., байк.*, **ПУГАРӘП** [*рус.* погреб] *стрл.* к.: **нәүрәп.** Пугар'ап та ташныкы, кар салмадык. Пугар'ап авызын ачтык. – *кузн.* Барыгыз, пугар'аптан катык алып, әрән йасагыз. – *чст.* Пугар'ап бар, төшөреп куй майыңны. – *байк.*

**ПУГОМИС** [*рус.* пуговица] *минз.* к.: **пауфка.**

**ПУГР'АП** *стрл., чпр., карс., шрл., әстр.*, **ПУГРӘП** *тмн., мәл., срг., чпр.*, **ПУГРИП** *минз.*, **ПУ'РИП** [*рус.* погреб] *кас.* к.: **нәүрәп.** Кен дә пугр'апка тешкенчә күбрәк тартам бәрәңгене. – *стрл.* Пугрәбебез йук шул. – *срг.* Сарыгы берсе тешкән иде пугрәпкә. – *мәл.*

**ПУҒЫРТАҚ 1.** *тара.* бугаз төене (кадык). Пуре қураға кереп қуйны ашайты, қанын пуғыртақтан эцәте; **2.** *тбл.* аяк киеменең йөзе белән кунычы арасында бөгелгән урыны (сгиб обуви между подъёмом и голенищем).

**ПУ'ЭРИП** [*рус.* погреб] *кас.* к.: **нәүрәп.**

**ПУД** [*рус.* под] *лмб.* мич төбе (подпечек).

**ПУДПЫЛ** [*рус.* подпол] *күрш.* к.: **ғелбәч.** Пудпылга сала тыварға алманы, вағын салам.

**ПУДУШ** *брб.д.* буй-сын (фигура).

**ПУДУШЛУ** *брб.д.* буй-сынлы, зифа буйлы (статный, стройный).

**ПУЖУҒУ** *брб.д.* ачулану (сердиться).

**ПУЖУМ** *каз.ар.*, **ПУҖМӘ** [*рус.* пазьмо] *нрл.*, **ПУҖУМ** *мам., каз.ар.-крш., т.кам.-крш.*, **ПУҖЫМ** [*рус.* позем] *нрл., мам., минз., т.кам.-крш., каз.ар.-крш.* к.: **паз′ма**. Иң җәкшы пуҗымда урнашқаннар. Пуҗымы дуррәк булса, өй салалар. – *мам.* Әсма түтиләр күчеп килделәр дә икенче пуҗым алдылар. Буш пуҗым булғач, монда әрем үскән. – *т.кам.-крш.* Үзе киткәч, пуҗымы қалды. Бөтенесе пуҗым белән утыз биш сутый. – *минз.* Үскән пуҗымыма қайтасы килә, ди. – *каз.ар.-крш.* Бу пуҗумда қалын тормошлы кешеләр торған. – *лш.* Шул пуҗмә аның урыны, бабый урнына утырган мин монда. Хәдер йуқ инде әти пуҗумында бер кеше дә. Безнең әтәйнең пуҗумы йуғары очта, бу бабай пуҗумы. Теге очларда пуҗумнар бар ийе, анда саласы килмәде. – *мам.* Безнең бақча әйбәт, бәрәңге дә әйбәт була, пуҗумына қызығып тороплық. – *каз.ар.-крш.*

**ПУЗДА** [*рус.*] *карс., срг., хвл., кузн.* соң (поздно). Бойолгысы йылны игенне пузда чәчтеләр. – *хвл.* Танцawайт итеп бетте, пузда wакыт, иртәмән безгә китәргә. – *карс.* Без пузда бардык кырга. Ызбамы йактың, нигә пузда? – *срг.*

**пуздага калу** *карс., срг.* соңга калу (опоздать). Ит вит иртә белән генә була, пуздага калсан, аннан алып булмый. – *срг.*

**ПУЗДАЛАУ, ПУЗНАЛАУ** [*рус.* поздно + *афф.* -лау] *кузн., хвл.* кичегү, соңга калу (опоздать, запоздать).

**ПУЗИР** [*рус.* пузырь] *чпр., чст., хвл., шрл.* к.: **мөржә 3**. Пузирлар җукмы тагын? – *шрл.*

**пузирга чыгу** *кузн.* к.: **баш: баш косу**. (Игеннең) чыккан вакытында йауса, пузирга чыкканда йауса, бетте, иген була.

**ПУЗИРУК** [*рус.* пузырёк] **1.** *лмб.* к.: **мөржә 3; 2.** *хвл.* кечкенә шешә, дару сала торган шешә (пузырёк, маленькая склянка).

**ПУЗЫЙР** *срг., чпр., мәл., т.кам.-крш.*, **ПУЗЫР** [*рус.* пузырь] *чпр., карс., трх.* к.: **мөржә 3**. Пузыйрны себерегез дә эстәлгә утыртығыз, үз үwегездәге кебек булығыз. – *т.кам.-крш.* Лампы булса, пузыре була инде, пузыре булмаса, йактырак йана. – *чпр.* Чемеки лампы төтәннән утыра, пузыре да булмый. – *трх.*

**ПУЙ 1.** *төм.* кыса – күлмәкнең өске өлеше (верхняя часть платья); **2.** *тара., брб.д.* тирә (окрестность, около, возле). Тәмер йул пуйта. – *брб.д.*

**ПУЙҒАТ** *тара.* к.: **айлы**.

**ПУЙДАҚ 1.** *тпк.* к.: **буйдак II, 1**. Паласыd кеше булса, пуйдақ була; **2.** *тбл., твр.* тол хатын, тол ир (вдова, вдовец). Пуйдақ ул кийәүгә цығып айырылышқан. – *тбл.*

**ПУЙЛАУ** *төм.* кысалы итү (шить с отрезной талией). Әwәле пуйлап та теккәннәр алйапқыцны.

**ПУЙМА I** [*рус.* поймо] *т.я., м.-кар.* к.: **арый**. Урманға утыңға ике пуйма барып қайттым. – *т.я.* Бер пуйма урыйк әле. – *м.-кар.*

**бер пуйма** *трх.* бераз, берникадәр (некоторое количество, несколько). Киндер чәчәләр, аның бер пуйма басасы була.

**ПУЙМА II** [*угор.*] *саз.я., тбл.* к.: **пима 1**.

**ПУЙНАҚ** *том.* читендә киң ак полосасы булган шәл (шаль, края которой имеют широкую белую полоску). Пуйнақ шәл инәкәмнеңке йөрөйте.

**ПУЙНИЦӘ** *тбл., төм.* ике ишкәкле зур көймә (большая лодка с парными вёслами).

**ПУЙТАҚ 1.** *тбл., төм.* к.: **пуйдақ 2**. Пуйтақ иртән қалған, йалғыс қалған. – *тбл.*; **2.** *тара., тбл.* өйләнмәгән, кияүгә чыкмаган (неженатый, незамужняя); **3.** *тбл.* к.: **буйдақ II, 1**. Пуйтақ пулгац пуйы тақ тийән пулаты.

**ПУЙТОМАР** *тбл.* бөти, догалык (амулет, талисман). Пуйтомар, дуwалықлар қылып элгәннәр.

**ПУЙУ** *брб.д.* **1.** буу (душить). Тыңнаматыңыс аңа, парабаның әмти тоғымын пуйып пөтөртө, тип әйтә, ти; **2.** пута бәйләү (повязываться, завязать пояс).

**ПУЙУҒУ** *брб.д.* туңу (мёрзнуть). Ә, йиңгәм, йаман пуйуқтум.

**ПУЙЦАН, ПУЙЦЫЛ** *төм.* буйлы (высокий – о росте).

**ПУЙЫ** [*удм.*] *глз.* **1.** к.: **мөржә 3; 2.** каз куыгы (гусиный пузырь).

**ПУЙЫЗЛАП** [*рус.* пояс + *афф.* -лап] *минз., стрл.* пута куеп (с поясом, вставив пояс).

**ПУЙЫН 1.** *тбл., тара.* к.: **буң′; 2.** *төм.* хезмәтче (слуга). Аңа пуйын пулып йәшәмәкмә?

**пуйын пулу** *тбл.* буйсыну (подчиняться).

**ПУЙЫНТЫРУ** *брб.д.* к.: **пуйу 1**.

**ПУЙЫНЦАҚ** *себ.* муенчак (ошейник).

**ПУЙЫНЧЫҚ** *тара.* к.: **гылбу 1**. Мәрwәт пуйынчықлар төмән төрлө була қый.

**ПУКАС** [*рус.* покос] *тара.* к.: **цабынты 2**.

**ПУКАЧ** [?] *перм.* зарар (вред, вредительство). Шухәдәре йыл бер пукачсыз хезмәт итеп чықтым.

**пукач итү** *перм., тбл.* зарар итү (вредить). Кәкүкне инәсе қарғаған, ул әзрәк пукач итепте, әwәле қарғышлар тогры кәлпте. – *тбл.*

**ПУКЕЛ** *мәл.*, **ПУКИЛ** [*морд.*] *кмшл.* к.: **пукыл′ 1**. Шәкәр пукелен санап калдыра иде киткәндә. – *мәл.*

**ПУКМАР** [*морд.*] *м.-кар.* к.: **покмар**.

**ПУҚРАҚ** *брб.д.* к.: **былчырақ**. Қуй, пуқраққа төшмә, айағың пылцыраныр.

**ПУКРАН I** *шрл., стрл., лмб.* к.: **қашлақ**. – Әләкләр бармы? – Пукраннары бар. – *шрл.* Мин бөтенний пукраннары белән ашыйм. – *стрл.* Пешмәгән йеләк, пукран гына. – *лмб.*

**ПУКРАН II** *лмб.* укра (личинка овода под кожей животных).

**ПУҚРАП** *твр.*, **ПУКРӘП** [*рус.* погреб] *том.д., төм.* к.: **нәүрәп**. Әле та бар песнең пукрәп, майыбыс та шанта тора. – *төм.*

**ПУҚЦА** *тара.* кияү тарафыннан алып киленә торган бүләкләр (подарки, привозимые со стороны жениха). Пуқца йегет алып килә қыс қуйына кергәндә, пүләкләр була, йемешләр була.

**ПУҚЦАР** *тбл.* тормоз.

**ПУКЫЛ′** [*морд.*] **1.** *лмб., чпр.* шакмак, кисәк (кусок). Кан′ар сөт белән бер пукыл′ шәкәр аша. – *лмб.* Шәкәр пукыле алып чыг әле; **2.** *лмб.* төер, кантар (комок, глыба). Пукыл′ выргыта; **3.** *мәл.* төер, шеш (комок, шишка). Мында пукыл′ чыгып,

бекере чыгып калды инде; **4.** *лмб.* киләп (мотушка). Кыз биргәндә унар пукыл′ кизе сүләшә иде.

**ПУКЫЛ′ДАУ** *срг.* мышнау (пыхтеть). Пукыл′дый гына, шондый таза.

**ПУКЫЛ′ЛӘНҮ** [*морд.* + *афф.* -ләнү] *тмн.* төерләнү (становиться комковатым). Писук белән майны он кушып усаң, пукыл′лә нә.

**ПУЛ I** [*рус.* полок] *хвл., чст., чпр., мәл., срг.* к.: **набулат 1.** Икешәр кат менгәнем йук пулга. – *чпр.* Пулга менегез, апа. Пулына менеп чабынабыз. Пулга менгезәм, чабам мин аны, күтәреп төшерәм. – *мәл.* Пулга менеп цабындым ике сира. – *чпр.*

**мунча пул** *клд.* к.: **набулат 1.** Мунча пул астына кереп качып тора.

**ПУЛ II** [*фарс.*] *брб.д.* к.: **пол.**

**ПУЛ′А** [*рус.*] *тмн.* чабу, итәк (подол, пола). Булырсын да Пешли кийәве, без пул′агызга асылырбыз да йебәрмәбез. Чебелдеккайымны корыгыз. Пул′аларын йиргә ырыгыз (*хал. җыр.*).

**ПУЛАЗ** [*рус.*] *тмн.* чана табаны (полоз у саней).

**ПУЛ′АН I** [*рус.*] *кузн., хвл., чст., чпр.* утын агачы (полено). Бар, пул′аннар ал. – *кузн.* Бер пул′ан итәсен хал′фага. – *хвл.* Пискә берәр пул′ан ыргыт әле. Басып торма пул′ан кебек. – *чст.*

**ПУЛ′АН II** [*рус.*] *срг.* спекулянт. Ул пул′ан булган, имуществасын алганнар.

**ПУЛ′АН III: пул′ан кашка** *мәл.* маңгаенда йолдызы булган көрән төстәге ат (лошадь коричневого цвета со звёздочкой на лбу).

**ПУЛ′АНСА** [*рус.* поленница] *срг.* утын агачы, пулән (полено). Имәнне пул′ансага кисәләр, йаргалыйлар, аны пицкә бәрәләр парланырга, аннан йаралар иде.

**ПУЛАНЧА** [*рус.*] *тмн.* утын әрдәнәсе (поленница). Утын пуланчада кибеп тора.

**ПУЛАСТЫ** [*рус.* пол + *тат.* асты] *тмн., лмб., кузн.* к.: **гелбәч.** Пуласты салкын безнең, шунда куйарбыз майны. – *тмн.* Пуластка куй картукны. – *лмб.* Иске ызба пуластына салган идем картуф. Сетен бызауга эчерәбез, калганын куйабыз пуластына. Мин пуласты казытмадым, пугар′абебез бар. Пуластына күп салмыйсын, ә баздан инде йаз башты аласын (бәрәңгене). – *кузн.*

**ПУЛАТ I** [*рус.* полати] **1.** *лмб., кузн., хвл., срг., күрш., нокр.* к.: **иргәнәк 1.** Пулатка менеп йаткан йыкларга. – *лмб.* Пулат – ишек башыннан өстә. Пулатлар бар иде. – *хвл.* Пиҗбашына менәсен дә шуннан пулатка менәсен. Пулат путалактан түбән йасала. – *срг.* Пулатта йоклар ийе кыш булса. – *нокр.*; **2.** *нокр.* к.: **набулат 1.**

**ПУЛАТ II** [*фарс.*] *лмб.* к.: **ызба.** Бу пулатта кан′сеңлесе тора аныйныкы.

**ПУЛ′БА, ПУЛ′БЕ** [*рус.* бульба] *стрл.* к.: **алма I.** Ачы пычыракта ни тарыган, пул′ба казырга бара. Пул′бе пешерәм. Пул′бе күмешер ийе.

**ПУЛҒАУ** *брб.д.* кизәнү (замахиваться).

**ПУЛИСНА** [*рус.*] *м.-кар.* вәгъдә бүләге: сөлге яки ашъяулык (подарок при помоловке: полотенце или скатерть). Җәш килен хәстәрли пулисна.

**пулисна алу** *м.-кар.* вәгъдә бүләге алу (приехать за подарком при помолвке). Пулисна алырга килдек, ачуланмагыз, үмердән калган җола, диләр.

**ПУЛМАЦЫ** *тбл.* булдыксыз, уңмаган (неспособный).

**ПУЛТАУ** *брб.д.* яңакны кабарту (надувать щёки).

**ПУЛТУР** *брб.д.* былтыр (прошлый год).

**ПУЛЦАУ** *төм., тбл.* вакыт билгеләү (назначить время); чаг.: **божал.** Қысны пирәтегән көнне пулцайтылар. – *төм.*

**ПУЛЫК** *хвл., мәл., чст.*, **ПУЛЫХ** [*рус.* полог] *кузн., хвл.* к.: **плук.** Пулыкны дәйәсең икмәк салырга арбага. – *чст.* «Атны сатмый торыйык, – ди, – бар ал, – ди, – күршеңнән пулых, подаука» (*әкият.*). – *кузн.*

**ПУЛЫШ** *төм.* кияүгә ярәшелгән кызга ярдәм итү (помочь невесте после сговора). Кийәүгә йарашылғаннан соң пулыш була, бүләкләр алып керәтләр, ыскол′ко может невестаға булышатлар, тегәргә бармы анта, цәй эцеп утырғамбыс инте.

**ПУМА 1.** *тбл.* тын кысылу (одышка). Пумадан үлгән пуwылып; **2.** *тмн.* дифтерия.

**ПУМАЗУК** [*рус.* помазок] *т.я., кмшл., каз.ар.* пумала (помазок). Әткәң пумазугы белән тәрзә рамнары буйаған. – *кмшл.* Пумазук биреп тороғыз буйау буйарға. – *мам.*

**ПУМАЛКА** [*рус.*] *м.-кар.* пумала (помело). Пумалка белән себерәбез, ипине таwычтан көрәккә салабыз, икмәк көрәгенә.

**ПУМӘЛ** [*рус.* помело] *минз.* к.: **пумил.** Пумәл үскән икән, шуннан қурықтым.

**ПУМӘЛЛЕК** [*рус.* помельник] *минз.* к.: **пумиллек.** Ул дәwердә пумәллек кенә ийе алар.

**ПУМИЛ** [*рус.* помело] *перм., т.кам.-крш.* яшь ылыслы агач (молодое хвойное дерево). Пумилдән йарый сәли ағач, қарағай пумилләрен қуйасын. – *перм.* Пумил астыннан қача торған ыйық, лисник күренсә. Пумил дип кечти, қуйы, wақ чыршыларны әйтәләр. – *т.кам.-крш.*

**ПУМИЛЛЕК** [*рус.* помельник] *перм.* яшь ылыслы агачлар үскән җир (место, где растут молодые хвойные деревья: ельник, сосняк и т.д.); чаг.: **бүләк II.**

**ПУМИНКА** [*рус.* поминка]: **тыруйчын пуминкасы** *т.кам.-крш.* Тройцында үләләрне искә алу көне (поминка в Троицын день). Тыруйчын пуминкасы атнаға каршы (шимбә) көнне бөтен кеше җийыла, зиратқа бара халық, пируклар пешереп, пуминайт итәләр үләләрне шунда.

**ПУМИЧ** *перм.*, **ПУМЫЧ** *лмб., перм.* к.: **бемә.** Без тушы ызбаға чыққач, пумич иттег ийе. Балсыс пумич булмый, бал булмаса, пумичкә килмиләр. Абзый белә орчоқ пумычқа җөрибез ий. – *перм.* Аргычта була шал пумыч. Ызбалар кыйаргa пумычлар була. Әтийебез безнең эшлекле иде, пумыч җийабыз, эшләтергә кирәк, икешәр-өчәр кибән сугайык йаз башын. – *лмб.*

**ПУНАФ** [?] *шрл.* бер төргәк, кочак (свёрток, кипа, охапка). Күрдеңме прафисырны, бер пунаф акча тоткан. Бер пунаф мамык. Бер пунаф кычыткан китер дә берәр йафрак салып чәй эчәрбез.

**ПУНТУҚ** *минз.* к.: **безрәк.** Тәк тә пунтуқ қына кисеб алдым.

**ПУП** [*рус.* поп]: **пуп гөле** *каз.ар.-крш.* бояр гөле (мальва).

**ПУПАН** [*рус.* попона] **1.** *трх.* к.: **қап 3.** Ул чиккән пупанны күпчекләр анарда; **2.** *к.т.* идәнгә җәю өчен иске чүпрәкләрдән сугылган палас (дорожка, сотканная из старого тряпья). Идәнгә җәйәргә пупан суғам әле.

**ПУПМАР** [*морд.*] *м.-кар.* к.: **покмар.** Пупмар кайа кәри килә, шунда тыра.

**ПУПСА** [*рус.* вовсе] *том., тбл.* бөтенләй, бик (совсем, очень, вовсе). Көцөм пөттө пупса. – *төм.*

**ПУПУП** *кргл.* һөдһөд (удод).

**ПУР** *тбл.* к.: **бур I.**

**ПУРА** *төм., тбл.* бу ара, бу тирә (это место, здесь). Қац пуратан. – *тбл.*

**ПУРАЛЫ** *тбл.* шакмаклы (клетчатый). Пуралы көйләк.

**ПУРАМА** *тпк.* к.: **бурама.** Пыу иске пурама булған.

**ПУРАУ** *брб.д.* үрелгән тал чыбыклары бәйләме (свёрнутые связки из тальника).

**ПУРИ** [*рус.*] *кузн., хвл.* сарут (пырей).

**пури үләне** *кузн., хвл.* к.: **пури.**

**ПУРЛЫ: пурлы үртәх** *сазл.* үрдәкнең бер төре (один из видов уток). Пурлы үртәхнеңке пашы йоwан пулат.

**ПУРМАН** [*рус.* фургон] *кргл., бгрс., кмшл.* фургон. Унбиш пурман була. – *кмшл.* Үләнне кипкәч пурманға төйәп читкә чыгарабыз. – *кргл.*

**ПУРСАК** [*рус.* русак] *нокр., глз.* үр куяны (русак). Куйан пурсак кына бар, тийен. – *глз.*

**ПУРТ** [*рус.* прут] *тмн., перм.* к.: **бума 1.** Пуртта кийынырмын. – *тмн.*

**ПУРТУ** *тбл.* искерү – икмәк турында (черстветь, становиться несвежим – о хлебе, муке). Он пуртып китепте.

**ПУРУН** *брб.д.* к.: **порон I.**

**пурун пир тәмдә** *брб.д.* бервакыт (однажды).

**ПУРЧИНКЫ** [*рус.*] *каз.ар.-крш.* дуңгыз баласы (поросёнок). Пурчинкылары зур иде.

**ПУРШИН** *кргл.*, **ПУРШН'А** *хвл.*, **ПУРШЫН** [*рус.* поршни] *әстр.* чи тиредән тегелгән аяк киеме (обувь, сшитая из сыромятной кожи). Қатып қала инде ул пуршин. Пуршн'аны чи тиредән тегәбез, чабата йук.

**ПУРЫЖ** [*рус.* порог] *перм.* түбәнавыз (подуст).

**ПУРЫЙ** *мам.* к.: **миран.** Қуйан дийәргә йарамый, без пурый дибез.

**ПУРЫЛ** *твр.* бурлы ат (чалый – масть лошади).

**ПУСАЛАНУ** *тбл.* борчылу, кайгыру (беспокоиться). Палам өйтә йуқ, шаңа пусаланып утырам. Күгәwенгә пусаланаты.

**ПУСАМЫҚ** *тара.* аксыл (светлый). Мин пусамық, ул миннән қарарақ.

**ПУСАНТЫРУ** *төм.* кымыржу, кычыту (зудеть, свербеть).

**ПУСАУ** *твр.* борчу, аптырату, теңкәгә тию (беспокоить, надоедать). Мине бусап утырма.

**ПУС'ИН** *кас.* сүс (пакля); чаг.: **пачас.** Пус'ин сатып алды.

**ПУ(С)С'АЙ** [*морд.*] *м.-кар.* әнисенең әтисе, бабай (дед со стороны матери). Пусс'ай, ашарга тешмимсең? Ил'уш пус'ай әйткәндер инде.

**ПУССЫЗ** [*рус.* путь + *афф.* -сыз] *дөб., крш., бгрс.* к.: **белексез 2.** Пуссызланып утырма, теләсә нәрсә әйтеп. – *дөб.* Ул пуссыз қыз булды инде. – *кргл.*

**ПУСТА** [*рус.*] *сазл.* савыт (посуда). Пустасын қорлай пирмә, эцнә пернимә сал.

**ПУСТАУ** *яүшт.* к.: **пуғыртақ 1.**

**ПУС'ЧАЙ** [*морд.*] *м.-кар.* к.: **пу(с)с'ай.** Аукай – әнинең әнкәсе, пус'чай – әнинең атасы.

**ПУТ I** *глз.* к.: **алабота 1.** Ак пут, кара пут була.

**ПУТ II** [*рус.* под] *тмн.* к.: **пуд.**

**ПУТ III** [*рус.* путь] *әстр.* юл (дорога, путь). Белмим, йақшы путқа булсын.

**ПУТ'** [*рус.* путь] *срг., чст., минз.* рәт, җай (порядок, толк). Бу эшнең пут'ын белмибез. Пут'ка сукалый бу малай, белеп сүли. – *чст.* Бер дә пут'е йуқ. – *минз.*

**пут'ка бару** *срг.* тазару (поправляться, полнеть); чаг.: **йалпайу I, 1.** Аларның малайы пут'ка бармый.

**ПУТА** [*рус.* путы] *дөб.* **1.** түбә тактасының түбәнге башы белән кәрниз арасына кадаклана торган агач (планка, приколачиваемая между нижним концом досок крыши и карнизом); **2.** к.: **билдәмә.** Безнең awыл җегетләре қызыл пута бәйлиләр.

**ПУТАЛАК** *миш.д., әстр.*, **ПУТАЛА'** [*рус.* потолок] *кас.* к.: **түбә 1.** Путалакка текереп йата. – *лмб.* Пич салминчы путалакны лакламим, ызба йепшенә дә путалактан тешә. – *кузн.* Аркылы машча куйалар, аннан ары такта төзи – (менә сиңа) путалак. Аның (дуңгызның) астына да кирпеч кирәк, кирпеч булмаса, кабына путалакка. – *хвл.* Путалагы тишек, тупрагы азрак (*мәкаль*). – *срг.* Мунчаның бит әле путалаклары элгермәгән. – *чст.* Путалакка башлары җитәрлек өч ир килеп керде. – *шрл.* Путала'ы сары инде, монда 'озлар бар инде (*әйтем*). – *кас.*

**ПУТАФКА** [*рус.* путовка] *брб.д.* к.: **подаулық.**

**ПУТАЧИ: путачи қawақ** *твр.* к.: **бақа: бақа қабығы.**

**ПУТАШ** [*рус.* поташ] *срг.* көл (зола). Путашка күмәбез, шолай путаш картогы пешерәбез дибез.

**ПУТ'Е-КЫНЫ** [*рус.* путь + *афф.* -е + *тат.*] *лмб.* җае, рәте (порядок, толк); чаг.: **пут'.** Пут'е-кыны булырмы?

**ПУТЕМАР** *срг., хвл.* өч-дүрт рәт тәңкә тезеп ясалган, бер иңбашыннан икенче култык астына киелә торган укалы киң тасма, хәситә (женское нагрудное украшение, перевязь).

**ПУТИН** [*рус.*] *шрл.* к.: **қатлық I, 1.** Путинкыга бер тестән ыйык сүттеләр, дебет йанына путин куйабыз.

**ПУТЛӘУ** [*рус.* путь + *афф.* -ләү] *лмб., хвл.* юнәлеш бирү, юл күрсәтеп җибәрү (направить, показать путь). Син путләмәдеңме механикларны садыма? – *лмб.*

**ПУТЛУК** [*рус.* потолок] *перм.* к.: **түбә 1.**

**ПУТ'Л'Ы** [*рус.* путь + *афф.* -лы] *срг., кузн., хвл., шрл.* **1.** к.: **йусынлы 1.** Малайларым пут'л'ы гына булсын. Пут'л'ы гына булсыннар. – *срг.* Пут'л'ы

кеше булса, алай да булмас иде. – *хвл.* Пут′л′ырак кешедән сора, пут′ым йук. – *кузн.*; **2.** к.: **латлы 1.** Пут′л′ы җир тегел. – *хвл.*

**ПУТМАР** [*морд.*] **1.** *лмб., кузн., хвл.* к.: **покмар.** Путмардадыр йымырка, ал шыны. – *лмб.* Ике килен булса, берсе йата путмарда, чоланда. – *кузн.* Путмар булган, тебендә куй баласы торган, путмар өстендә йоклаганнар. – *хвл.*; **2.** *карс.* мич алды ягында бәрәңге тоту өчен ясалган сандык сыман ящик (ящик, устроенный на кухне, где шесток печи, и служащий для хранения картошки). Чыланда була путмар, ни дә булса картук куйа торган; **3.** *срг.* мич алды ягында савыт-саба өчен ясалган сәке (небольшие нары, устроенные напротив или наискосок от шестка печи, служащие кухонным столом для посуды).

**ПУТ′МАР I** *кузн., м.-кар.* к.: **путемар.** Әле йуктыр инде ул пут′мар кемдә дә. – *кузн.*

**ПУТ′МАР II** [*морд.*] **1.** *срг.* к.: **покмар.** Цоландагы пут′марда йоклыйбыз; **2.** *стрл.* кемнең дә булса гел кергәләп йөри торган җире (место постоянного посещения). Керә инде, керә, аның пут′мары монда.

**ПУТМӘР** [*морд.*] *минз., стрл.*, **ПУТНӘР** [*морд.*] *стрл.* к.: **пут′мар II, 2.** Аның путмәре монда бит, кермичә. – *стрл.*

**ПУТНУС** [*рус.* поднос] *т.я.-крш., м.-кар.* ипи калае (железный лист, противень для печки хлеба). Элек пич төбенә салган, путнуслар булмаган, бидра да булмаган. – *т.я.-крш.* Путнус бар җомросы, озынчасы. Ике путнусым бар әле. Алда табалар йуг иде, путнуслар иде. – *м.-кар.*

**ПУТПАЛ** [*рус.* подполье] *төм.* к.: **гелбәч.**

**ПУТПИЛЛӘ** [*рус.* подполье] *тара.* идән асты капкачы (крышка подполья).

**ПУТПУТАЙ** *төм.* к.: **бакә: бакә қабыгы.** Путпутай желудоктан әйбәт.

**ПУТПЫЛ** [*рус.* подполье] *кас.* к.: **гелбәч.** Путпыл′а тешми′и ′ири′ җиралма алма′а.

**ПУТСАҢКЫ** [*рус.* подсанки] *блт., дөб.* к.: **каткы.** Чананың артына путсаңкы тагалар, ике карамалы була ул. – *блт.*

**ПУТ′СЕЗ, ПУТ′СЫЗ** [*рус.* путь + *афф.* -сыз] *миш.д.* **1.** к.: **белемсез 2.** Ул пут′сезне кушсаң, очына чыгалмас бит бу эшнең. – *мәл.* Кара, кара, пут′сыз хайwан, кайа керә бит! – *чст.*; **2.** к.: **латсыз 1.** Урман йулы бик пут′сез. – *хвл.*

**ПУТТУПКЫ** [*рус.* подтопка] *дөб.* к.: **патлуфкы.**

**ПУТУWAҚ** *төм.* балык тоту коралы (орудие рыбной ловли – применяется в реках).

**ПУТУЛУК** [*рус.*] *перм.* к.: **түбә 1.** Матчаны салалар, аннары таба путулукны түшиләр. Путулукны ике қат буйаган.

**ПУТ′УМ** [*рус.* позём] *мам.* к.: **паз′ма.** Пут′ум йорт урны инде ул. Дачаны сатыб аласызмы, пут′умын ғынамы?

**ПУТФИЛЛӘ** [*рус.* подполье] *тбл.* к.: **гелбәч.** Күперәк укыратта, путфиллә – идән асты.

**ПУТ′ЫМАР I** *кузн., хвл.* к.: **путемар.** Артча йазгыга, кышка кала да аның көмешләрен кискәли дә йасый пут′ымар. – *кузн.* Кызнын пут′ымарлары-ниләре бездә калды вит. Буйкыз булгач, әлдә кидем пут′ымарны да, моно да. Йәшел сондок өсләрендә, Пут′ымар бөтүемне тышлыймын (*хал. җыр.*). – *хвл.*

**ПУТ′ЫМАР II** [*морд.*] *кузн.* к.: **покмар.** Пут′ымарга савыт-саба куйыла.

**ПУУ** *тбл.* бәйләү (завязать). Көн пуйына пецән цапқан, көлтә пуган.

**ПУУРТАҚ** *төм.* к.: **пуғыртақ 1.** Су пууртаққа йетәтеин.

**ПУФАЙКА** *тара.* к.: **сырмыш.**

**ПУФКА** [*рус.* пуговка] *злт.* к.: **пауфка.**

**ПУХЛ′АК** [*рус.* пухлый]: **пухл′ак йер** *хвл.* йомшак җир (рыхлая почва). Вата т′урка бодайны ике су арасына пухл′ак йергә чәчәбез.

**ПУЦЫ** [*рус.* путы] *срг.* бау (верёвка). Цәцпау дип тырам, пуцы икән.

**ПУЧИН** [*рус.* почин] *каз.ар.* **1.** башлангыч, беренче адым (начало, почин). Булыр, әле пучин генә бит. Пучин кипкән җафрак җәйәләр, аннан туфрак салалар (түшәмгә); **2.** чабышта алдан килгән ат, беренче булып килгән ат (лошадь, занявшая первое место на скачках).

**ПУЧИНКӘ** [*рус.* починок] *бөре., т.я., кас., байк.* икенче бер җирдән күчеп утырган кечкенә авыл (починок, выселок).

**ПУЧИҢГЕСЕНДӘ** [*рус.* починок] *дөб.* беренчесендә (на первый раз, в первый раз, прежде всего). Пучиңгесендә бер дә қурықмыйбыз.

**ПУЧУҢКА** [*рус.* печёнка] *перм.* к.: **пучиңкә II, 2.** Пучуңка шалқандан: мичне себерәсең дә шалқанны салып томалыйсың, ул имелдәп кенә пешә инде.

**ПУЧЫ** [*удм.*] *каз.ар.-крш.* тал (ива).

**пучы бәйрәме** *каз.ар.-крш.* яз башында үткәрелә торган христиан бәйрәме (вербный праздник).

**ПУШАТ** [*рус.* ушат] *бәр.* к.: **бадийа 1.**

**ПУШАТУ 1.** *себ.* җибәрү (отпускать). Қонтосларны суға пушатмақцы пулганнар. – *төм.* Сеүләшкәнтә себерәк сүсләр тә пушатабыз инте. – *тбл.*; **2.** *саз.я.* салу (опускать, положить). Пәлмәнне тоңлай қайнар cowға пушатawc. Чәйнехкә цай прас пушат.

**ПУШКӘМӘ** *дөб.* тәңкәле изү (нагрудник, украшенный монетами). Элек әниләр генә пушкәмә кийәләр ийе.

**ПУШҚУЛ** *төм.* юмарт (щедрый).

**ПУШЛЫҚ** *төм.* буш вакыт (свободное время). Awылта эш күп, пушлық йуқ.

**ПУШТАР** [*рус.* почтарь] *чпр.* хат ташучы (почтальон). Карама бар иде пуштар бабай утырткан.

**ПУШШЫ** *чст.-крш.*, **ПУШШЫЙ** [*рус.* пущий] *каз.ар.* бигрәк тә, бөтенләй (особенно, совсем). Авылда қызлар пушшы әзәйделәр. Аның апасы пушшый әйбәт. – *блт.*

**ПУЫНЦАҚЛАНУ** *тбл.* буынтыклану (сегментация, сочленение).

**ПУЫШУ** *төм.* ызгышу, кычкырышу (браниться, ругаться).

**ПУЫШЦЫЛ** *төм.* ызгышучан, бәйләнчек (сварливый).

**ПҮБӘРӘК** *злт., байк., төм.*, **ПҮБЕРӘК** *стрл.*, **ПҮБЕРӘП** [*рус.* погреб] *тбл.* к.: **нәүрәп.** Мин

палықны арцып пүбәрәккә қуйған. – *төм.* Пүбәрәктә бәрәңге. – *байк.* Пүберәк йук, сөтне саклау awыр. – *стрл.*

**ПҮГӘНТЕШ** *тбл.* сазда үсә торган чәнечкеле үлән (колючее болотное растение).

**ПҮГӘРӘП** *минз., стрл., күрш., кузн.*, **ПҮГ(Е)РӘП** [*рус.* погреб] *стрл., мәл., чст., кргл., трбс., төм.* к.: **нәүрәп**. Мин пүгәрәптән алып менермен катык ыйыткыга. – *чст.* Ачы камыр пүгрәптә. – *мәл.* Қайту белән пүгрәпкә қатыққа җөгөреп төшәм. – *кргл.* Пүгрәп ийе ул, қар салып булмады. – *трбс.* Эресен пүгәрәпкә салам алманы. – *күрш.* Пүгәрәп казыдым үзем, сөт, май тора пүгәрәптә. – *кузн.*

**ПҮЖҮК** *брб.д.* к.: **сәлей**.

**ПҮҖМӘ** [*рус.* позём] *нрл.* к.: **паз′ма**. Пүҗмә алған да җорт салган.

**ПҮЙИР** *брб.д.* к.: **нөйдир**.

**ПҮЙҮК** *брб.д.* биек, зур; бөек (высокий, большой; великий).

**ПҮК** *брб.д.* к.: **бору I**.

**ПҮКӘН** [*удм.*] *блт.*, **ПҮКЕН** *глз.* к.: **бүкән I, 1**. Утыр пүкенгә, Газза аппак. – *глз.* Пүкәннәрне апкер әле теге йақтан. – *блт.*

**артлы пүкен** *нокр.* к.: **бүкән I, 2**.

**ПҮКЕРӘП** [*рус.* погреб] *төм.* к.: **нәүрәп**.

**ПҮКИН** *глз.* к.: **бүкән I, 1**.

**ПҮКЛӘҮ** *брб.д.* к.: **бөкләү** (согнуть).

**ПҮКМӘЦ** *брб.д.* бөгелгән (согнутый).

**ПҮКТӘР** *төм.* к.: **сырау 1**.

**ПҮЛӘWӘЙ** [*рус.* полевой] *туб.-арт.д.* киндер (конопля).

**пүләwәй им** *тбл.* к.: **пүләwәй**.

**ПҮЛӘК I** *тбл.* күчтәнәч (гостинец). Цацатым тансығыңнан пүләк ашайым.

**ПҮЛӘК II** *брб.д.* к.: **нөйләк 1**.

**ПҮЛӘН** [*рус.* полено] *к.т., кмшл.* к.: **пул′ан I**.

**ПҮЛӘТӘЙ** *төм.* солыча (овсюг).

**ПҮЛБЕ** *бөре.*, **ПҮЛБӨ** [*рус.* бульба] *брб.д.* к.: **алма I**.

**ПҮЛЕСКӘТИ** [*рус.* полоскательница] *дөб.* к.: **дустыган 2**. Динә апага пүлескәти белән бал керттем.

**ПҮЛИН** [*рус.* полено] *дөб.* к.: **пул′ан I**.

**ПҮЛӨК** *брб.д.* чишмә, кое (источник, колодец).

**ПҮЛТЕРЕК** *тпк.* кечкенә – сарык бәрәне турында (маленький, малюсенький – о ягнёнке). Пүлтерек кенә, бәләкәй генә, бәләкәс кенә сарық бәрәсләре була.

**ПҮЛҮ** *брб.д.* һәлак булу, бетү (гибнуть).

**ПҮМӘЛ** [*рус.* помело] *минз.* к.: **пумил**.

**ПҮМӘЛЛӘК** [*рус.* помело + *афф.* -лек] *минз.* к.: **пумиллек**.

**ПҮПРӘК** [*рус.* погреб] *тбл.* к.: **нәүрәп**.

**ПҮР** *брб.д.* ян, кабыргадан түбән урын (бок, место ниже рёбер).

**ПҮРӘК** *тара.* сумса (пирожок). Пүрәк қарағаттан да була. Қороған йеләкне салып сәртәк пүрәк пешерәте. Пүрәк пицтә пешә ацы қурдан. Сысық пүрәк.

**ПҮРӘМӘЧ** *стрл.* к.: **пирипич**.

**ПҮРЕК** *төм.* к.: **бүрке**. Кәбәц, пүрек кийәтләр.

**ПҮРТӘҢКӘ** [*рус.* портянка] *каз.ар.-крш.* к.: **сарғыч: айақ сарғычы**. Пүртәңкәне чорнап чабата кийәләр ийе ирләр, без туланы да кидек.

**ПҮРҮ** *тбл.* боеру, хәл итү, билгеләү, тапшыру (приказывать, решать, назначать, поручать).

**ПҮРЦӘ** *брб.д.* борча (блоха).

**ПҮТӘЛӘҢҮ** *тбл.* буталану, чәбәләнү (запутаться).

**ПҮТӘНӘ** *туб.-арт.д.* к.: **пытпылдык**.

**ПҮТИ′И** *кас.* к.: **бетәгә**. Tawы′ пүти′и.

**ПҮТЛЕ** [*рус.* путь + *афф.* -ле] **1.** *злт.* к.: **йуллы**. Пүтлерәк қылан; **2.** *трх.* җайлы, ипле кеше (обходительный, ладный, толковый).

**ПҮТМӘР** [*морд.*] *минз., стрл.* к.: **пут′мар II, 2**. Аның пүтмәре шунда инде.

**ПҮТНЕЙ** [*рус.* путь + *афф.* -ней] *төм., тара.* юньле (толковый); чаг.: **пут′л′ы, пүтле 1**. Уқый да белмим пүтней. – *төм.*

**ПҮТСЕЗ** [*рус.* путь + *афф.* -сез] *чст., каз.ар.* к.: **белексез 2**. Бер малайлары пүтсез булды аларның. – *чст.*

**ПҮТСЕС** [*рус.* путь + *афф.* -сез] *тбл., саз.я.* рәтсез, юньсез (непутёвый); чаг.: **белексез 2, пуссыз**. Эшләйте, эшләйте, эшенеңке пүте булмасты, пүтсес тителәр. – *тбл.*

**ПҮТТӘ** [*рус.*] *саз.я.* кебек (будто).

**ПҮТҮ** *брб.д.* үсү, чыгу (расти, взойти, появиться). Қарныма пала пүттү.

**ПҮТҮМКӘ** [*рус.* котомка] *мам.* к.: **пиштәр**; чаг.: **печтәр**. Арқада пүтүмкә. Нийә, қапчықтан пүтүмкә йасыйлар бит, киндер қапчықтан, почмағына бәрәңге тығып бәйлибез.

**ПҮЦКӘ** [*рус.* бочка] *төм., тара.* к.: **бучка**. Пүцкәле сары май утырған. – *тара.*

**ПҮЧИН** *дөб.* к.: **пучин**.

**ПҮЧИНКӘ** *бөре., байк., т.я., кас.*, **ПҮЧИҢКӘ I** [*рус.* починок] *перм., минз.* к.: **пучинкә**. Awышқам теендә, пүчиңкәдә қалды. – *перм.* Ғәли пүчиңкәсен жаздыгызмы суң? – *минз.*

**ПҮЧИҢКӘ II** [*рус.* печёнка] **1.** *к.т.* пешкән шалкан яки чөгендер (пареная репа или свёкла). Шалқан пүчиңкәсе; **2.** *т. кам.-крш., перм.* мичкә тәгәрәтеп пешерелгән шалкан (репа, испечённая в золе). Пүчиңкә пешкән шалқан була ул. – *т.кам.-крш.* Әтисе пүчиңкә пешергән дәген ашап чирләгән. – *перм.*; **3.** *перм.* к.: **пичунка**. Пүчиңкә тәгәрәтәбез мичкә.

**ПЧУЛ′НИ′** *кас.*, **ПЧУЛ′НИК** [*рус.* пчельник] *чст.* к.: **мурталык**. Пчул′ни′ти эшлий. Йаз чыгу хутына алырга кирәк, аны чыгарып куйасын пчул′никка.

**ПЫ** *тпк., твр.* бу (этот). Пы йақта пура ишегалдым бар. – *тпк.* Пы йортта перүсе тора иде. – *твр.*

**пы берәү** *тбл., тара.* моны(сы) (этот, это, эта). Пы берәwе өстәл, теге берәwе сантал. – *тбл.*

**ПЫWАҚ I** *тбл.* к.: **бывак**.

**САЗЛАТУ** *чст.* пычрату (пачкать, запачкать). Айагыңны бу кадәр сазлатып кайа йөрөдең соң?

**САЗРАҚ** *том.д.* җир, туфрак (земля, почва). Соңғылықны бақчаның буйына сазраққа күмеп қуйалар, чеперәккә урап, қатақ салып. – *яүшт.*

**САЗЧЫ** *әстр.* гармунчы (гармонист). Борын заманда сазчы, әскерипкәче дип атлар белән awыллардан барып алалар иде, қала йақтан йалылыйлар иде. Бу киленем сазчы.

**САИРҒАУ** *себ.* рәткә салу, тәртипкә китерү (разбирать).

**САЙ I** *минз.* чабата ясау өчен телеп әзерләнгән юкә (лыко, приготовленное для плетения лаптей). Ничә сайдан үрәсең чабатаны?

**САЙ II** *туб.-ирт.д.* саен (послелог еже-; через, каждый). Сәгәт сай. Awыл сай йул бараты.

**САЙ III** *том.д.* сайлык, комлык (мель, песок).

**сай йағасы** *том.д.* яр, яр буе (берег, побережье).

**САЙА** *кузн., лмб.* бөрмәле билле, йон тукымадан тегелгән өс киеме (верхняя одежда из шерстяной ткани, сосборённая в талии). Ак сайадан, ак күлмәктән йөрдек, ак калпаклар кийә идек. Сайа диләр, пеләчә башларын күркәм итеп теккән. – *кузн.*

**САЙАҚ I** *каз.ар., бгрс.*, **САЙАК** *кузн., мәл.* **1.** к.: **илдәтнә**; **2.** йөремчәк – хайван турында (о блудливом животном). Сайақ кәжә күк бер өйендә тормый ул. – *лш.*

**САЙАҚ II** *туб.-ирт.д., том.д.* сирәк (редко). Картупны сайақ утысыпсыс. Онытылган, сирәк-сайақ қына қалган. – *төм.*

**САЙАКЛАНУ** *кузн.* к.: **илү I: илүдә җөрү.** Бу көннәрдә әле без дә сайакланып киттек.

**САЙАҚ-САНДЫРАҚ 1.** *минз.* вакытлы-вакытсыз (не вовремя, не считаясь со временем). Сайақ-сандырақ нишләп йөрисең төннә; **2.** *бгрс.* төрле яктан җыелган вак-төяк кешеләр (всякий сброд – о людях). Туйыгызда җыйын сайақ-сандырақ ыйы.

**САЙАК-САНДЫРАК** *мәл., тмн.*, **САЙА'-САНДЫРА'** *кас.* к.: **мат'амал.** Ул сайак-сандырактан нинди эш кетәсен. – *мәл.* Сайа'-сандыра' 'ешеләр вит алар, сүлишми алар белин. – *кас.*

**САЙАМАУ** *перм.* санамау (не считать). Балалары уқымағач, бернигә дә сайамый awылныкы тарихын үрәнүне. Бер кеше әйтә: бер сүзгә сайамаган була синкә әйткән сүзеңне.

**САЙБЫР** *туб.-ирт.д.* тигез юыртучан (бегущий ровной рысью).

**САЙБЫРЛАУ** *туб.-ирт.д.* тиз юырту (бежать рысью – о лошади).

**САЙБЫРЛАШУ** *туб.-ирт.д.* икәүләп атка атлану (сесть вдвоём верхом на коня). Атқа сайбырлашып менеп киттеләр.

**САЙҒАҚ I 1.** *каз.ар., минз., т.кам.-крш., нгб.-крш., злт.* идән (пол). Сайғақлары гөлт итә торган түгел аның. Wалчыкларыңы чәчкәнең, сыпырып төшер сайғак башына. – *мам.* Карawаттан төшсә, сайғақны сындыра, шундый җywан. – *дөб.* Сайғақларны сөртеп ал. – *нгб.-крш.* Сайғак диләр менә моносын, тегесе түшәм. Шушинде ул, сайғақ диләр аны, чын исеме сайғаҕ аның. – *минз.*; **2.** *т.я.* к.: **бастырма**. Қаралты түбәсен җабасы бар, сайғақтағы печәннәргә су үтә. – *к.т.*; **3.** *трх.* арата (поперечина).

**сайғақ асты** *нгб.-крш.* к.: **гелбәч**. Сайғақ астына нигә төштең?

**САЙҒАҚ II** *том.д.* кигәвен (овод).

**САЙГАК I** *чст.* к.: **бастырма**. Җәй кене мин сайгакта йыкладым. Сайгагым буш әле, үлән быйыл әз җыйдым.

**САЙГАК II** *мәл.* к.: **сайак I, 2.** Бу мачы безнең бик сайгак булды, үгә кат′ып та керми.

**САЙГАК III** *чпр.* куаклык (кустарник).

**САЙҒАҚЛАУ** *мам.* идән җәю (настилать пол).

**САЙҒАУ 1.** *трбс.* к.: **бастырма**. Сайғау башына печән өйәбез, сайғау астында утын; **2.** *тпк.* к.: **турамселек**. Сайғауның башы турыға була, өстәнә песән өйәбез, астында мал да тора шунда.

**сайғау асты** *тпк.* к.: **пайыт 1.**

**САЙКЫТ** [*удм.*] *глз.* җиләс, салкынча (прохладно). Өйдә сайкыт була җәй көне. Көн бүген сайкыт, өстеңә ки.

**САЙЛ′АМ** [*гар.*] *карс.* сәлам (привет). Ишектән керер үзе, Иңлек сайл′ам бирер үзе (*хал. җыр.*).

**САЙЛАНУ** *перм.* саташу (бредить). – Қәтип балдыз мондамы тей! – Мә! Сайланасың мәлә, мин әйтәм.

**САЙЛАП** *төм.* к.: **түбә 1.**

**САЙПАР** *т.кам.-крш.* к.: **ара-тура 2.** Бу сайпар очрый торған қош. Быйыл бәрәңге бик сайпар тишелгән.

**САЙРА: сайра килү** *себ.* хәлсезләнү (ослабеть).

**САЙРАН** *т.я.-крш.* к.: **сай II**. Җырактан җакын күренәдер, Җирәнчә атның кашкасы; Сагынмак сайран барыр идем, Ай-кай awылларның башкасы (*хал. җыр.*).

**САЙРАНЛЫҚЛАР** *минз.* сайраучы кошлар (певчие птицы).

**САЙРАШУ** *глз.* сөйләшү, аралашу (разговаривать, общаться). Сайрашмага, гөрләшмәгә боломга төштек сабантуйда.

**САЙРИГӨЛ** *әстр.* ахирәтлек дустына эндәшү сүзе (слово-обращение к вечной подруге – на этом и на том свете). Ахирәтлек дусына сайригөл әйтә, атын атамый.

**САЙСА** *бгрс.* чокыр-чакыр (рытвины, ухабы); чаг.: **базлавык**. Сайсаларда да су йуқ бит, җамғыр булмағач.

**САЙ-САЙ** *трх.* сарык куу ымлыгы (междометие, употребляемое при отгоне овец).

**САЙСАН** *туб.-ирт.д.* сазан балыгы (сазан).

**САЙУ I** *туб.-ирт.д.* к.: **сайыру**.

**САЙУ II** *том.д.* чукраклану (оглохнуть). Қолақ сайса, им итәткәннәр иде қортқалар.

**САЙУК** [*рус.* сайка] *срг.* к.: **йомшак**. Зур сайук салып килгән анай.

**САЙЧАК** *срг., чпр.* чәчәк (цветок). Син булмагач, сайчак атмый, Сүwекле гөлләрем дә (*хал. җыр.*). – *срг.* Йугалган сайчагым кебек, Торасың уйларымда (*хал. җыр.*). – *чпр.*

**САЙЫҒУ** *минз.* азаю, сирәкләнү (уменьшиться в количественном отношении, поредеть). Суда балыклар сайыкты хәзер.

**САЙЫР** *злт.* к.: **мечек: мечек сагыз**. Кайын былса, кайын былсын, төбө сайырлы былсын, дигән, ди, берәү.

**САЙЫРУ** *т.я., минз.* саегу (мелеть, обмельчать). Берничә йылдан сезнең Зewәгез сайырыр. – *трх.* Сайырды су хәзер, төбө, дуйыны қата да. – *минз.*

**САҚ I** *лш., нокр.*, **САК** *лмб., кузн., м.-кар., чст., чпр.* усак (осина). Сақ ағач бу. – *нокр.* Сак агачы китергән йагарга. – *лмб.* Сак белән әwәл катыннарны тиңнәгәннәр. – *чст.* Сак агацы буш агац ул, бездә нацар агац санала ул. – *чпр.*

**САҚ II: саққа йөгерү** *минз.* к.: **уйнау: сақлы уйнау**. Йәш чағында саққа йөгерә торган ыйық. Җыйында саққа йөгөрдек.

**сыйыр сақ** *нокр.* көтүче (пастух). Быздә сыйыр сақлар. Сыйыр сақлар исерек дий, сыйырлар беттегесе йералманы басқан.

**САҚ III** *том.д.*, **САК** *миш.д.* юка пальто (тонкое пальто). Сақ дигән кийем булған, пал′ту кебек ул. Сақ ул бер қаттан, озын була, шул сақны кигәннәр киленнәр. – *яүшт.* Сак дип әйткәннәрен белəм әбиләрнең. – *кузн.*

**САК: сак ишетү** *клд.* начар ишетү (плохо слышать). Бабайның кылаклары да сак ишетә.

**САҚА I** *трх.* сарык алкасы (серёжки у овец).

**САҚА II** *себ.* XVIII–XIX йөзләрдә гаскәргә ашау-эчү әйберләрен сатып йөрүче (маркитант).

**САҚАЙУ** *перм.* **1.** өркү, шүрләү (бояться, трусить). Атасыннан сақайа да сикереп тора. Мә, сақайасын инде ата кешедән, әлбиттә. Сақайа, әнә шуңа өйдә көтеп кенә утыра да мине, берқайа да китми; **2.** сагаю (остерегаться, быть настороже). Сақайып тор инде дибез, берәр қурқыныч булдисә.

**САҚАЛ I** *минз., т.кам.-крш.* к.: **муйынҗақа**.

**САҚАЛ II** *тпк.* к.: **қәситә 2**; чаг.: **йага II**. Сақалны төрле мәрҗәннәр белән эшләгәннәр, тәңкәләр тезеп.

**САҚАЛ III** *минз.* балта түтәсенең аскы ягындагы кечкенә чыгынтысы (выступ на нижней стороне обуха топора, бородка топора).

**балта сақалы** *туб.-ирт.д.* к.: **сақал III**.

**САКАЛ 1.** *миш.д.* ияк (подбородок). Йыгылып сакалым бәрдем. – *лмб.* Сакалыма цыбан цыкты. – *чст.* Мының этисенең сакалына суга. – *мәл.*; **2.** *стрл.* к.: **кәситә 2.**

**сакал асты** *миш.д.* ияк асты, тамак асты (нижняя часть подбородка). Сакал астына бәлә йаулыгың. – *срг.* Аның эстенә ике митыр йарым ызынлыгында ак тастар сыргыйлар иде, сакал астына ике рәт әйләндереп салындыралар. – *карс.*

**сакал севәге** *миш.д., м.-кар.* ияк сөяге (подбородочная кость).

**САКАЛАУ** *м.-кар.* тычкан авыруы белән авыру – ат турында (болеть мытом – о лошади).

**САҠАЛДЫРЫҚ** *злт.*, **САҠАЛТАЙ** *минз., трбс.*, **САКАЛТАЙ** *стрл.* к.: **сағалдырық**. Киленнәр төшәргә барғанда әбәзәтелни бөркәнчек, ике жаулыкны теркәп, бит турысында сақалдырықлар, чуқлар была. Сақалтайлы жаулық. – *трбс.* Сакалтай була, шау тәңкә була аңарда. – *стрл.*

**САҠАТАШ** *тпк.* чакматаш (кремень, кресало). Сақаташ күк кипкән. Йомро ғына түгәрәк сақаташлар була.

**САҠАУ** *трх.*, **САҠБАЙ** *минз.*, **САКБАЙ** *стрл.* к.: **қолақай**. Сақау саучим сүләшми ул, қул белән генә, ишарәт белә генә. Камилне қайа қуйғаннар эшкә, ул бит сақбай. – *минз.* Күзе дә күрми, колак та сакбай. – *стрл.*

**САҠЛАУ** *себ.* асрау, тәрбияләү (содержать, держать, воспитывать). Малны күп сақлағаннар. – *тбл.*

**САКМА: сакма йаға** *тмн.* к.: **муйынжақа**.

**САКМАЙ: сакмай изү** *стрл.* укалар һәм ефәк тасмалар белән бизәлгән изү (разрез платья, украшенный позументом и шёлковыми лентами).

**САҠРА** *брб.д.* сәхрә (равнина, поле).

**САКСУН** [*рус.*] *срг., хвл.* к.: **пал′ак**.

**саксун патшасы** *мәл.* ак таракан, таракан патшасы (белый таракан, который иногда встречается среди рыжих; букв.: царь тараканов).

**САҠТАЙАН** *тбл.* сәхтиян (сафьяновая кожа).

**сақчы I** *урт.д., себ.* сакчы (сторож):

**әржә сақчы** *нокр.* туйда кызның бирнәләрен алып килүче (человек, привозящий приданое невесты). Әржә сақчылар ике кешеләр була.

**бәбәй сакчы** *глз.* бала караучы (няня, человек, ухаживающий за ребёнком). Без, оланнар, бәбәй сакчылар булып корга бардык.

**йан сақчы, кийәү сақчы** *нокр.* кияү егете (дружка). Йан сақчы кийәүнең келәткә кереп чыққанын сақлап тора.

**олан сакчы** *глз.* к.: **бәбәй сақчы**.

**САҠЧЫ II** *туб.-урт.д.* өч яньле, өч тармаклы тимер таяк (железная палка с тремя зубами).

**САҠЫ** *себ.* су ташучы, су эчертүче (водонос, поильщик).

**САҠЫР** [*рус.* сахар] *чпр.* шикәр (сахар). Чәй эсәремсен, сакыр бирәм.

**САҠЫРУ: сақыруға йөретү** *к.-уф.* кунакка йөретү (приглашать по очереди в гости). Өй бөрнә сақыруға йөреттеләр утырмаға баргас.

**САЛА** *саз.я.* зал. Сала йахта cowых.

**САЛАБАШ 1.** *перм.* сабаклары белән алынган колмак (хмель, собранный вместе со стеблем); **2.** *минз., трбс., злт., тпк., стрл.* юкә кабыгы (липовая кора). Аның қабыгы салабаш атала, салабаш батырған, диләр. – *злт.*

**салабаш төшөрү** *трбс., тпк.* юкә төшерү (драть лыко). Урманға барып салабаш төшөрәләр ийе. Салабаш төшөрәбез, күлгә батырабыз, бер айдан чыгарабыз, киптерәбез, көлтәгә бәйлибез. – *трбс.* Күршеләр салабаш төшөрергә бардылар. – *тпк.*

**САЛАК** *хвл.* шапшак, жыйнаксыз (неаккуратный, неряшливый, неопрятный).

**САЛАКАЙ** *клд.* к.: **йыбытқы 1**.

**САЛАКЛЫК** *хвл.* шапшаклык, жыйнаксызлык (неаккуратность, неряшливость, неопрятность).

**САЛАМ I** [*рус.* солома] *срг.* к.: **айак III**. Картубыңның саламы нецкә, утлы булгангамы?

**САЛАМ II** [*гар.*] *тара.* сәлам (привет).

**кейәү салам** *тара.* кияү сәламе, кияүнең кыз әти-әнисе белән күрешүе (приветствие жениха родителей невесты). Кейәү салам тип кейәү қайын-қайна белән күрешәте.

**САЛАМАЙАҚ** *перм.* параличланган (парализованный). Саламайақ у(л) бичә, параличланған.

**САЛАМАҚ** *брб.д.* сынау, сынап карау, тәжрибә (проба, опыт).

**САЛАМАТ I 1.** *т.я.-крш., чпр., тмн.* к.: **жүрмә**. Кермәгә жаряймы дип, капкага саламат белән суга. – *т.я.-крш.* Саламатлар үрәләр пәзидән, красивый була, кайыштан гына тегел. – *тмн.*; **2.** *чст.* казлар куу өчен кулланыла торган озын таяк, гадәттә аның бер очына чүпрәк бәйләнгән була (длинная палка с тряпочкой на одном конце, которой гоняют гусей).

**САЛАМАТ II** *глз., нокр., к.-уф.* боламык (болтушка, мучная каша). Саламат былгаталармы сезди? – *нокр.*

**болом саламат** *нокр.* печән өстендә болынга алып бару өчен пешерелгән боламык (мучная каша, сваренная для угощения в дни сенокоса). Болом саламатны қыз әнисе пешереп боломға илтә.

**САЛАМАТ III** *мәл.* кыш өчен саламнан ясалган тәрәзә каплawычы (соломенные маты для окон, используемые зимой для тепла).

**САЛАМЛАШУ** [*гар.* + *афф.*-лашу] *тара.* исәнләшү, күрешү (приветствие). Кейәү саламлашып керәте қыс өйенә.

**САЛАМНЫҚ** *перм.* к.: **абзар: абзар алды**. Саламныкта салам салыб ашатасың қыш көне.

**САЛАСА** *тпк.* к.: **сөйрәтмә**. Ике қайынны ботақлы көйөнә кисеп атқа йигәләр дә, саласа була анысы.

**САЛАСКА** [*рус.*] *шрл.* к.: **сәләскә**. Шуннан саласкага утырган да шуган.

**САЛАШ** *стрл.* к.: **кuwыш I**.

**САЛБУЛТАҚ** *туб.-урт.д.* салынкы, салынып төшкән тире (отвислая кожа).

**САЛБЫҚ** *туб.-урт.д.* сүрән, сүлпән (вялый, хмурый, медлительный – о человеке).

**САЛҒЫЗУ** *мам.* салдыру (заставить положить). Салғызыйық бу бүлмәгә.

**САЛҒЫМ** *туб.-урт.д.* салкын (холодно; холодный).

**кицке салғым** *туб.-урт.д.* кичке салкын hава (вечерняя прохлада).

**САЛДАН** *перм.* иннек (румяна). Кершәннәр йағынып, қызыл салданнар сөртеп, сөрмәләр тартып, теш қаралары...

**САЛДАТ** [*рус.*] *срг., чпр., мәл., трх.* көлтәләрдән өелгән чүмәлә (копна, сложенная из снопов).

**салдат йасау** *срг., чпр., мәл., трх.* көлтә киптерү ысулы: сигез-унике көлтәдән чүмәлә өю (способ сушки снопов: складывание стога из восьми-двенадцати снопов); чаг.: **маржа: маржа башы**. Келтә белән салдат йасый идек, бер келтә-

не туздыра идек тә башагы белән аска каратып йасый идек. – *мәл.*

**салдат турысы** *чст.* солдат хезмәте (солдатская служба). Әле йәш әле, салдат турысына да бармаган. Ул салдат турысыннан да качып йерде.

**салдатқа утырту** *трх.* к.: **салдат йасау.**

**САЛДАТЧЫР** *перм.* вак балыклар (мелкие рыбёшки).

**САЛДАУ** *трбс.* судан балык чәнчеп ала торган сөңге (пика, острие которой вонзают в плавающую в воде рыбу).

**САЛДЫБАЙ** *злт.* алпан-тилпән йөри торган кеше (человек, который ходит раскачиваясь).

**САЛИТАЛЫ** [*гар.*] *срг.* сәләтле (способный). Салиталы кеше ул Ариф.

**САЛКЫТМА** *м.-кар.* к.: **киштә II, 3.**

**САЛКЫТУ 1.** *м.-кар.* к.: **бәwетү; 2.** *срг.* к.: **сырқыту.**

**САЛЛАУ** *трх.* олауга күп итеп йөк төяү (нагрузить большое количество чего-либо на подводу). Ай-һай саллаган бу печәнне.

**сал саллау** *минз.* к.: **қуғын I: қуғын қуу.** Хөкүмәт сал саллады бедһең җанбызда.

**САЛМА I 1.** *тмн., кузн., хвл., карс., нокр., злт.* өйдә ясалган токмач (домашняя лапша). Салманы кисеп куйдыңмы? Салма да пешерәбез. – *хвл.* Салма булса да ашый симийа белән. – *кузн.* Салма саласыңмыни? – *нокр.* Қамырын йәйәбез, wақ қына итеп кисәбез, шул салма была. – *злт.*; **2.** *лмб., мәл., срг., т.я.-крш.* ракушка формасында ясалган өй токмачы (лапша в форме ракушки домашнего приготовления). Салма ашадык, куй ите. Ләкшәне пыцак белән кисәбез, салманы бармак белән йасыйбыз, цумарны картыпсыз йасыйбыз, бал кашыгы белән салалар. – *срг.* Йантыктан салма салганыңны карилар, ничек, салма сала беләме. Битне ачкач инде бу салманы саласың. – *т.я.-крш.*

**алпама салма** *әстр.* эре итеп киселгән токмач (крупно нарезанная лапша). Баштанарда қызлар алпама салма пешерәделәр. Қул ылақша қамырын қыйықлап кисеп шулпада пешерәләр дә итнең шулпасын қойоп бирәләр, алпама салма була.

**әби-бабай салмасы** *кас.* бөтеркә салма (рожки).

**җана килен салмасы** *т.я.-крш.* туй көннәрендә яшь килен пешергән чумар (клёцки невесты). Җана килен салмасын санап җасилар, парлы булсын.

**җәш килен салмасы** *кас.*, **йәш килен салмасы** *миш.д.* Туйдан соң беренче көнне яшь килен тарафыннан җәелеп киселгән токмач; аны табынга биргәндә, яшь киленгә бүләк салалар (лапша, нарезанная невестой в первый день после переезда в дом жениха; когда её подавали на стол, молодую одаривали подарками). Йәймә йәйә килен кеше, салма кисә, раунымы була, карап тыралар, килен уңганмы, йукмы, тизме йәйәр ул йәймәне, закмы. Йәш килен салмасын ашарга йәшәләр тирә-кырукны, китерәләр бүләкләр, кас'ы анда чолка, кас'ы басма. – *лмб.*

**кәлин салмасы** *нокр.* к.: **йәш килен салмасы.** Кәлингә салма бастыралар. Кәлин салманы басып бетерә, бер сабый баладан йырттыралар. Кәлин селге бирергә тийеш.

**квашн'а салмасы** *кузн.* ипи камырыннан пешерелгән чумар (клёцки из теста, приготовленного для выпечки хлеба). Килен квашн'а баса, әпәй йаба, квашн'а салмасы пешерә.

**кылак салмасы** *срг.* колак яфрагы, колак йомшагы (мочка уха).

**салма ашама алу** *баст.* ярәшелгән кызны туй алдыннан иптәш қызлары белән бергәләп мәҗлескә йөртү (гостевание невесты перед свадьбой). Мин бер ай җарашылып тордом. Қардәшләр салма ашама алалар. Җарашылған қыз үзе белән қызлар җөрөтә, ағары тийеш шулай чақырма. Икешәр-өчәр өстәл қызлар җыйа, туйға қадәр инде бу. Анда салмасы да бар, бар да бар. Салма ашама әйтәләр. Җарашылған қызны минем радн'ам барып ала салма ашамаға. Ул биш-алты қыз ала бара. Икенчеләй башқа қызларны ала, шулай җөриләр.

**салма ашама чакыру** *хвл.* токмач ашарга чакыру (пригласить на девичье угощение). «Салма тапа да, кызларны салма ашама чакыр», – дигәннәр. Чакырмый калдырсаң, үпкәләш була, нигә мине калдырдын?

**салма басу** *нокр.* токмач камыры басу (приготовить тесто для лапши). Туйның икенче кенде салма бастырдылар. Бер бәбәйне китерделәр дә ул салманы қармалаттырдылар, аңа мин йанйаулық бирдем.

**салма вакыты** *срг.* к.: **күлем: кичке күлем** Кичкә табан сәгат' дүртләрдә салма вакыты була.

**салма йәйү** *нокр.* токмач җәю (готовить тесто для домашней лапши). Давай салма йәй, диләр. Салманы йәйәм, йезгеләп ташлайлар. Йаман келешәләр үзләре. Дағын басамин, дағын йәйәмин, дағын йезгеләйләр дә ташлайлар. Келешмә йабыштылар. Йанйаулықлар бирдем аларға, йәйеп бетердем.

**салма кисү** *тмн.* токмач кисү: туйда яшь киленне сынау йоласы (резать домашнюю лапшу: свадебный обычай). Йәймә йәйә килен кеше, салма кисә ывак кына.

**салма салу** *тмн.* ашка токмач салу (класть в суп домашнюю лапшу: свадебный обычай). Йантыктан салма салганыңны карилар, ничек, салма сала беләме. Битне ачкач инде бу салма саласың.

**салма тапау** *кузн.* к.: **салма йәйү.** Багалар инде, йәш килен салма тапи беләме? Камырны кыйты басса, йәймәне туры йәймәсә, йырткалый иделәр, салма тапый белми килен, дип. Килен ул кешегә култасмал бирә.

**ывыз салмасы** *кузн.* угыз сөтенә пешерелгән чумар (клёцки из теста, замешанного на молозиве). Ывыз салмасы ашаган wахытта кашык белән маңгайга сугалар, хатем укилар, салма салалар. Камыр басалар, салма йасилар, ывызны да кискәләп салалар, катык каталар. Ывыз салмасы була.

**САЛМА II** *туб.-ирт.д.* **1.** ишеккә аркылы салына торган тимер (железный засов для запирания дверей); **2.** кое сиртмәсе (журавль у колодца).

**САЛМАҚЛАНУ** *туб.-ирт.д.* икеләнү (колебаться).

**САЛМАКЛАУ** *кузн.* **1.** чамалап, тикшереп карау (прикинуть: определить приблизительно вес, сделать приблизительный расчёт); **2.** төрле яклап уйлап карау (обдумать всесторонне). Эшләүдән элке салмакларга кирәк;

**САЛМАҠЛАУ** *брб.д.* авырлыкны үлчәү (определить вес, взвесить).

**САЛМАКЛЫ** *кузн.* **1.** саллы, авыр үлчәүле (тяжёлый, увесистый). Кургашын бик салмаклы була; **2.** һәрьяктан уйлап эшләүче (всесторонне обдумывающий). Ул бик салмаклы кеше, ухты-барахты эшләмәс.

**САЛМАН** *чст.* саман, балчыкка тирес катнаштырып сугылган кирпеч (саман).

**САЛ'НИК** [*рус.* сальник] *тмн., лмб.* терлекнең эч мае белән мичтә пешерелгән тары боткасы (пшённая каша, сваренная на нутряном сале в печи).

**САЛПАК** *чст.* к.: **қонсоз.**

**САЛТАНАТ** *минз.* к.: **алапа.** Бик салтанат бала икән бу.

**САЛУ I 1.** *глз., нокр., туб.-ирт.д.* кую (класть, ставить). Тағарақны әллә қайа салғаннар ич, табалмыйм. Пыйала салғандыр аңа (тәрәзәгә). Мин алсам, әллә қайа салмамдыр, салсам, ышкапқа салыпмын. Ипи пычақны әллә қаа салыпмын ич. Әй бу чебеннәргә қағаз салырмын дигән идем ич. – *нокр.*; **2.** *глз., нокр.* кию, тагу (надеть, повесить). Нәстә салдың қылағыңа, нинди сырға ул? Бырушкалар саласы булған. – *нокр.* Уникегә эстинага сала торган бар икән кибеттә. – *глз.*; **3.** *глз., нокр.* билгеләү; сайлап кую (назначать, определять; выбирать). Секретар′ итеп кемне салабыз? Аны тырактырдан алып санитаркаға салдылар. – *нокр.* Урманға утын чапмаға салдылар қызымны, анда бара. – *глз.*; **4.** *срг.* урнаштыру (устроить). Техникумга, аннан институтка салды Хавас апаны; **5.** *глз., нокр.* кую (ставить). Клубта пйысалар салабыз – *глз.*; **6.** *глз., нокр.* бирү, тапшыру (передавать). Радийудан кансирт салалар; **7.** *глз., нокр.* к.: **бөтәү 1.** Радийоны салып кара әле, Казан йырламыймы; **8.** *нокр.* к.: **ат II: ат кыцкырту.** Бу улын Ринат салдылар. Андри салма келәделәр атын; **9.** *мәл.* кисү (рубить); чаг.: **чабу I, 1.** Урман салуны бетерделәр инде; **10.** *тмн., лмб., срг., хвл.* к.: **быргыту.** Катнын салган кеше инде ул, эценцегә үләнде. – *срг.* Үләнеп салган. Салган катны тырмыш эзләргә килгән. – *лмб.* Катныңны сал, ку, Наймәне алабыс. – *хвл.*; **11.** *хвл., чст.* төшерү – бала турында (произвести выкидыш, сделать аборт). Мин берне салдым. – *хвл.*; **12.** *м.-кар., чст.* судка бирү (подавать в суд). Судка да салдылар инде. Имеш, алай булсаң, салам судка. – *чст.* Тытам да сутка салам, дим, ишмейләр дә. – *м.-кар.*; **13.** *чст.* сугу – кирпеч турында (формовать – о кирпиче); **14.** *шрл.* кушу (велеть). Кич белән боларны идән йуwарга салам; **15.** *байк.* тапшыру (сдать, сдавать). Целләдә сөтәм әзәйде, салганым йуг әле; **16.** *мәл.* охшату (принимать за кого-либо). Шыны Адиләгә салдым әле. **17.** *трх.* больницага яту (лечь в больницу). Түшәктә җатып қына булмый, салын, мин әйтәм, балнисқа.

**атап салу** *глз.* к.: **салу 3.**

**исем салу** *глз.* к.: **ат II: ат кыцкырту.** Исем салма карт бабачларны чакыргаладык.

**қул салу** *глз.* к.: **қул III: қул басу.** Шул йазуға қул сал әле, Ғазимҗан абый.

**қызны салып бирү** *перм.* кич утырганда яки аулак өйдә кунак егетне ул теләгән кыз белән сөйләшү өчен аерым урынга утырту (устроить молодому человеку, гостю, встречу с понравившейся ему девушкой в уединённом месте – во время посиделок или на вечеринке).

**машинаға салу** *тпк.* к.: **ағызу.** Сыйыр cawабыd, машинаға салабыd, қорт йасайбыd.

**сау йөрәккә салу** *хвл.* ялт иттерү, шәп итеп ашап кую (хорошо покушать, съесть всё без остатка). Ике шawа ашны сау йөрәккә салдым.

**сүзгә салу** *глз.* к.: **ақлашу.** Сүзгә салғач, нигә димен мине кетмәден?

**тора салу** *эчк.* торып китү, яши башлау (начать жить). Ул хатыны белән тора салмады.

**САЛУ II** *кузн.* бизәк (узор). Ай-хай башымдагы тастарым, Ике очонда да бер салу (*хал. җыр.*).

**САЛУЛЫҚ** *кмшл., минз.* к.: **қағылма.** Мына шул салулыкны узса зыйан йуғ аннан. – *кмшл.*

**САЛУСКАН** *срг.* к.: **с′аваскан.**

**САЛФИТ** [*рус.*] *чст.* к.: **битйаулық.** Бит себерегә бүтән салфит йукмы?

**тәлил салфиты** *чст.* тәһлил тастымалы, ягъни кеше үлгәч өләшенергә тиешле тастымаллар (маленькие полотенца, приготовленные для раздачи во время похорон). Менә тәлил салфиты үлгәч әләшергә йыртта бабайларға. Унике тәлил салфитым бар.

**САЛФИТКА** [*рус.*] **1.** *т.я., минз., злт., бөрг., стрл., байк.* тастымал (салфетка). Қызны ашқа йертәләр, анда тағын әйбер саласын, салфитка саласын. Хәрендәшләренә сөлгә биреп қалдыра, салфиткалар биреп қалдыра. – *трх.*; **2.** *злт., минз., стрл.* к.: **алсузма.** Озон салфитка кеше алдына йәйеп қуйа. Салфитка қунақ алдына йәйәргә, түрдән посмаққа хәтле. – *злт.* Салфитка ике ыстан йарым була, бер ыстан – дүрт аршын. – *минз.* Ашаганда алныга йәйә торган салфиткалар суктык. – *стрл.*; **3.** *байк.* к.: **битйаулық.** Салфитка – бит себерә торган, ике митырлы.

**САЛФИТКӘ** [*рус.*] **1.** *перм.* к.: **алсузма.** Өстәлне чүрәли салына салфиткә әлеге кәртәләп суғыла инде, бөтөн қунаққа җитә; **2.** *карс.* к.: **йаулық.** Йермә, йегет, су буйында, Салфиткәңне дымайтып (*хал. җыр.*).

**САЛЫ'-СОЛО'** *кас.* к.: **алғай-салғай.** Салы'-соло' җерий.

**САЛЫМ I** *себ.* калым (калым, выкуп за невесту). Туйтан алта йегет салым бирәте. – *төм.*

**САЛЫМ II: салым чәй** *тмн.* бер салырлык чәй (на одну заварку – о чае). Ике салым чәй бирде.

**САЛЫНМАЛЫ: салынмалы чыганак** *м.-кар.* к.: **бад′йа: бад′йалы кыйы.**

**САЛЫНУ I** *м.-кар.* чишенү, киемне салу (раздеваться, снимать одежду).

**САЛЫНУ II** *туб.-ирт.д.* камыр әвәләү, икмәк пешерү (стряпать).

**САЛЫШТЫРУ** *брб.д.* чагыштыру (сравнить, сопоставить).

**САМАWЫР: самаwыр миләше** *дөб.* к.: **байбай.**

**САМАЙ I** *бөрг.* үсеп җиткән, балигъ булган кеше (человек, достигнувший совершеннолетия). Йуқ инде, ул малай түгел хәзер, самай.

**САМАЙ II 1.** *туб.-ирт.д., том.д.* чигә (висок).

Самай цацыңнан йолғырым. – *тбл.*; **2.** *тбл.* чигә чәче (волосы на висках).

**САМАР** *нокр., глз.*, **САМАРАУ** [*рус.* самовар] *т.кам.-крш., срг., глз.* самовар. Самарау қуй, кызым! – *срг.* Самар су алай уқ. Самар морйа. – *нокр.* Әбей самарау йуwa, дип йазырсин. – *глз.*

**САМАРҒАУ** *себ.* уйлау, үлчәү, чамалау (обдумывать, взвешивать, рассчитывать). Самарғап әйткән сүс алтын.

**САМАУ** *дөб.* иркен (свободный, незагруженный). Эшең самау wақытта утын җарып бир әле.

**самау итү** *лш.* к.: **йан I: йан тарту 1.** Самау итеп алам бала йоқлағанда ғына.

**САМАУЛАНУ** *лш.* к.: **айаз: айаз булу.** Әзерәк самауланған чағында җерим мин кисәк-кисәк.

**САМБУСА** *шрл., кргл., минз.* к.: **бирук.** Самбусаның эченә ит, эремчек куйып пешерелә. – *шрл.*

**САМҚА** *перм.* к.: **белексез 2.** Өмөреңә самқа булдың инде, эшләмәгә белмисең. Элек кеше самқарақ булған.

**САМРАУ** *глз.* к.: **самар.**

**САМСА 1.** *шрл.* эченә ит яки эремчек салып пешерелгән өчпочмак (кулинарное изделие: треугольник с творогом или с мясом); чаг.: **мун′ик; 2.** *срг.* к.: **бирук.** Пичтә кимак та, белен дә, самса да пешә ызба кытлатканда; **3.** *том.д.* урама (хворост). Самсаны қалаққа урыйсың да май қызғач пешереп аласың. Өстенә қойоп торасың әйләндереп. Ул қабарып пешә. Камыр басасың, йәйеп кисәсең, ачы қамырдан пешерәсен. Мин чөчөне йаратмыйм. – *клм.*

**САМСЫРАУ** *каз.ар., нгб.-крш., срг.* хәлсезләнү, ару (обессилеть, устать). Җүгерә-җүгерә самсырап бетәм. Самсырап қайттым утын кисеп. – *нгб.-крш.* Ул әби самсыраган инде. – *срг.*

**САМУСА** *кргл.* к.: **бирук.** Самусасын пешердем қарлығаннан.

**САМЫWАР: самыwар ағартқыч** *т.я.*, **САМЫВАР: самывар ачқыч** *лмб.* к.: **байбай.** Самыwар агартқыч җимеше белән самыwар ағарталар. – *к.т.*

**САМЫЙЛАНУ** *минз.* акылсызлану, юләрләнү (сойти с ума, потерять рассудок). Самыйланып чыгып та китәр ийе.

**САМЫН** *том.д.* сабын (мыло).

**САМЫРАУ** [*рус.* самовар] *каз.ар.-крш.* к.: **самар.** Самырауны эчеп бетерәм инде.

**САН** *дөб., т.кам.-крш., т.я.-крш.* к.: **йәүдә 1.** Шунда барып кайтканга, машина белән барсаң да санны wата. Тундырганда бөтен сан белән өшисен. – *т.я.-крш.* Бөтен саныңны күтәреп җәри айақ. – *т.кам.-крш.* Бөтен саным дерелди. Бер дә салларым күтәрә алмадым. – *дөб.* Мыйтумарны санга кийәдерийек. – *т.кам.-крш.*

**сана** *к.-уф., злт.* чана (сани):

**сана бала** *к.-уф.* к.: **сәләскә.** Сана бала тартып килдем.

**САНАРА** *перм.* к.: **сарана.**

**САНАУ** *том.д.* тарткы (смычок).

**САНАШ** *туб.-ирт.д.* саналмыш – балалар уены (считалочка – детская игра).

**САНАШУ** *нокр.* эштән чыгу, расчёт алу (брать расчёт, рассчитываться). Алып кетәм дий, эшендән санаша тыр. Ышкуладан санашып китте.

**САНДАЙ** *лмб.* к.: **кемәйем.** Сандай, кил, күлмәгемне кара, матурмы булган?

**САНДАЛ** *злт.* иннек (губная помада).

**САНДРАҚЛАУ** *себ.* саташу (бредить – в горячке).

**САНДУҒАС** *злт.* к.: **дусай.** Сандугаслар иде бит безнең инәйләр.

**САНДУҒАЧ I** *әстр.* к.: **абызастай.** Қәйен сеңелләренә ат қуша, сандуғач, ди.

**САНДУҒАЧ II: сандугач тәпийе** *блт., каз.ар.-крш.*, **сандуғач теле** *мам., блт.* к.: **күгәрчен: күгәрчен тәпийе.**

**сандуғач чәчәк** *мам.* к.: **күгәрчен: күгәрчен сөте.**

**САНДУГАЧ I** *м.-кар.* яз көне кошлар килә торган вакытта пешерелә торган прәннек (пряники, которые пекли ко времени весеннего перелёта птиц). Камырдан сандугач җасисын, аны балаларга бирәсен. Кунаклый барасын. Ул сына бирә, мин аңа бирәм. Шул кул алмашлап бирәсен.

**САНДУГАЧ II: сандугач геле** *чст.*, **сандуғач түше** *минз.*, **сандугач түше** *байк.* к.: **бақа: бақа гөле.**

**САНДУҚ** *к.-уф.* сандык (сундук). Сандуқта әйбер-қарасы күп була: күмәсләр, баллар, майлар.

**күмәс сандуқ** *к.-уф.* туй күчтәнәчләре сандыгы (сундук со свадебными гостинцами). Бешереп тутыралар күмәс сандуқны. Ике затқысның икәwендә дә белекирәк күмәс сандуқ була.

**сандуқ малай** *к.-уф.* туйда кызның сандыгына утырып килгән малай (мальчик, сопровождающий сундук невесты). Қызнықы йагыннан бара сандуқ малай булып. Төшми утыра сандуқ малай сандуғында. Сандуқны сандуқ малайға ақса түләп керетәләр.

**сандуқ үрнәк** *к.-уф.* чигү үрнәге (название узора вышивки). Менә моносон сандуқ үрнәк дип әйтәбез.

**САНДЫҒАЦ** *себ.* сандугач (соловей). Кинтер қалым тигән сywы бар астаната, сандығацлар сайрый, кәwекләр қыцқыра торган.

**САНДЫЙ** *бөре., мам., минз.* к.: **ат′акыш 1.**

**сандық** (сундук):

**бирнә сандық** *к.-уф.* кызның кулдан эшләнгән әйберләре салынган сандык (сундук с рукодельными вещами невесты). Бирнә сандықта қызнықы тастымаллары, өстәл йабулары, бүкән йабулары була.

**килен сандығы** *әстр., каз.ар.-крш.* яшь киленнең бирнәләре һәм киемнәре салынган сандык, аны һәрвакыт каенана кабул итеп ала (сундук с приданым невесты). Баласы қыз алып килгәндә, килен сандығына сикереп менде қайынана: «Сандығыңа қунайым, қайынанаң булайым», – дип, киленнең сандығына утырып әйтәде. – *әстр.*

**мәһәр сандығы** *бәр.* егет ягыннан кызга бирелгән сандык (сундук, подаренный невесте со стороны жениха). Мәһәр сандығым бу.

**сандығ арбасы** *трбс.* к.: **аш II: аш арбасы.** Ашам-әчем алып киләләр туйға сандыққа салып, чәкчәк, қаз, сандығ арбасы дип ишеткәнең җуқмыни?

**сандық әйбере** *к.-уф.* кыз бирнәләре (приданое невесты). Кейәү акча түләп ала сандық әйберен.

**сандық сакчы** *нокр.* к.: **сакчы II: әрҗә сакчы.** Кызны алма киләләр, кыз артыннан сандық салалар, аның өстенә утыралар йәш йегетләр, сандық сакчы, диләр, дүрт йегет була, сандыкны бирмиләр акча бирмийенче.

**сип сандық** *том.д.* к.: **килен сандығы.** Сип сандыклар зур булған, йөктөп-йөктөп әйбер булған байларның. Мамамнан калған сип сандық бар әле.

**САНДЫКСЫ** *к.-уф.* к.: **сандук: сандук малай.** Сандық өстенә кызныкы бер туғаны сандыксы булып утырып килә. Ул сандыксы йәбешә, сандыкны бирмим, ди.

**сандыксы малай** *к.-уф.* к.: **сандук: сандук малай.** Сандыксы малай булып кемнең белеки малайы бар, шул утырып килә.

**САНДЫРАТУ** *перм.* аптырату, башны әйләндерү (надоедать, докучать, донимать). Сантый нимәне сандыратамсыз ни?

**САНДЫРАУ** *перм.* **1.** юк-барны сөйләү (говорить чушь, ерунду). Исерек көйенә сандыраб җийма ни!; **2.** аңгыралану, миңгерәүләнү (отупеть, стать бестолковым). Мин сандырап беткәнмен инде.

**САНИК** *нокр.* сәнәк (вилы).

**САНЛАЙАК** *чст.* к.: **күчтәркә 2.** Тәбәне санлайакта пешердем.

**САНЛЫ** *кузн.* хөрмәт итүчән, илтифатлы (учтивый, уважительный).

**САННЫ 1.** *мәл.* к.: **асыл 1.** Ну Уфа санны йырлый да; **2.** *срг.* к.: **латлы.**

**САНСА** *туб.-урт.д.* вак бавырсак (мелкие баурсаки).

**САН-САБАҚ I** *минз.* сан, хөрмәт (уважение, почёт). Үзе бик фәкир кешенең баласы ийе, сансабак булмады аңа.

**САН-САБАҚ II** *минз.* буыннар (суставы). Хәзер инде сан-сабак катқан, бөгелеп булмый.

**САН-САҒЫШ 1.** *бәр.* буй-сын (фигура); чаг.: **йәүдә 1.** Аның сан-сағышы бик матур, шуңа, кисә кийем килешә; **2.** *мам.* исәп, сан (учёт, численность). Андагы халықның сан-сағышын белергә дә кирәк.

**САН-СИРӘК** *перм., злт., минз.* к.: **ара-тура 1.** Сан-сирәк булалар қайчақта. Җөзгә җиткән кеше бик сан-сирәк кенә. – *перм.* Киндер орлыгы сансирәк кенә бақчада әле дә чыга. – *минз.* Бездә бәрәңгесез кеше сан-сирәк былды. – *злт.*

**САНСЫЗ** *дөб.* к.: **салак.** Кит, сансыз, айағыңны қызурақ атла. Бу қадәр сансыз булырсың икән, шул ишегалдын да жыйыштырмагансың.

**САНСЫНУ** *нгб.-крш.* санлау (считаться, почитать, уважать). Мине бөтенләй сансынмый ул.

**САНТАЛА** *сазл., төм.* к.: **бүкән I, 1.** Сантала алф хилф утыр өстәл йанға. – *сазл.*

**САНТРАҚ** *тара.* сантый (шальной, шалый).

**САНТУҒАЦ** *туб.-урт.д.* к.: **бийауса.** Сантуғац, сантуғац, сантығың ац, малың күрәйек.

**САНТЫЙ 1.** *нгб.-крш.* акылга жиңел (слабоумный, придурковатый). Сантыйрақ ул қыз, төскә сылу булса да. Теге қызлары да сантый бугай; **2.** *бөре., перм., каз.ар., кмшл., нгб.-крш.* к.: **ат'акыш 1.** Сантый булғачыннан бернәрсәгә дә қатнашмасқа кирәг ийе. – *каз.ар.-крш.*

**с а н т ы к I** *себ.* сандык (сундук):

**сантық ацу** *себ.* яшь киленнең сандыгын ачып әйберләрен күрсәтү (свадебный обряд: открывать сундук невесты). Сантыкны йеңәлек ацайты күргәскәле, менә бы қадәр байлығы бар қысыбысныңқы, ти. – *клм.*

**САНТЫҚ II** *туб.-урт.д., брб.д.* хайванның ашаганнан соң калган салам-печән калдыклары (оставшиеся от скота объедки корма).

**САНТЫРАТУ** *к.-уф.* к.: **сандырату.** Китап қайда дип сантырата мине.

**САНЧАК** *кузн.* брошка (брошка, брошь); чаг.: **булавка.** Алтын сыргаларым да, алтын санчакларым да бар иде алынга кади торган, гарух чәре сәлендермәләре дә бар иде.

**САҢ** *тара.* гадәт, әхлак кагыйдәләре, йола (обычай, обряд, нормы поведения). Әwәлдән килгән саң: туй йасаған кешегә ақчамы, малмы, онмы апарасың аңа туй алдында. Саңы шулай: қысға сөт эцереп цыгаратлар өйеннән цығар цакта.

**САҢАҚ 1.** *минз.* к.: **сақал III; 2.** *к.т.* к.: **бәлчә 2.** Саңақлары белән жыйдыңмыни қарлыганны?; **3.** *злт.* ботак (ветка). Вис саңақларын сындырып төшөргән алмағасның. Саңағын айырыб алған.

**САҢҚАЙ** *минз.* к.: **қолақай.** Ишетми, саңқайрақ ул.

**САҢРАУЛАНУ** *себ.* саңгыраулану (глохнуть).

**САП I** *каз.ар.* к.: **айақ III.** Сабы да болай ғына буладырыйы бәрәңгенең элгәре. Бездә дә бәрәңге сабы урасы бар әле. – *лш.* Бәрәңге сабын урыға чыга алмассымма көз көне? – *дөб.*

**САП II** *срг., чпр.* к.: **сабак I.** Валник сабы. Чолка сабы. Ызба башында тырып итек сабын күwә тишкән. Саплы калушка балцык керә дир, кин саплы итекләр бар лаукада, алырга инде. – *чпр.*

**САП III: иртә саптан** *глз.* к.: **иртәгәч.** Иртә саптан икене эчеп чық.

**САПИНКА** [*рус.*] *туб.-урт.д.* төймә (пуговица).

**САПҚАЙ** *минз.* к.: **сантый 1.**

**САПҚЫ** *тпк.* к.: **кәтмәк I.** Сапқы белән сабабыз бәрәңкене, аннан тагын күмәсе була әле.

**САПЛАЙАК** *кузн., карс.* к.: **дустыған 1.** Нинди, ди, зыйан итепсез, ди, алтын саплайак, ди, алып китепсез, ди. – *кузн.*

**САПЛАЙАҚ** *тбл., тара.* жамаяк, касә (миска, пиала, чашка).

**САПЛАШТЫРУ** *тара.* бутау, саташтыру (путать, сбивать с толку). Мин кәпләгәнтә саплаштырма.

**САПЛЫҚАЙ 1.** *нгб.-крш.* к.: **қалач: саплы қалач 2.** Саплыкайның уртасында тишек була; **2.** *минз.* к.: **ачыкый.**

**САПМА I** *мәл., срг., чст.* к.: **артча.** Элгәре бит бездә сапма, изүчә, хаситә кыз-катыннар тагып йөри иде ике килограмнан артык. – *чст.* Сапмасы булмаган карты-йәше чулпы тага иде. – *мәл.*

**изү сапма** *чст.* к.: **алынча.**

**САПМА II** *эчк., брб.д.* күннән тегелгән үкчәсез итек (сапоги без каблуков, сшитые из кожи).

**САПМА III: селге сапмасы** *чст.* сөлгенең кызыл башлы өлеше (красная узорчатая часть домотканого полотенца). Селгене цүпләп сугалар, селге сапмасы кызыл, цүпләгән.

**САПОН** *туб.-ирт.д.*, **САППУН** [*рус.*] *саз.я.* к.: **ал җапма**.

**САПСАҚ** *злт., к.-уф.* кисмәк (деревянная или жестяная кадка). Агас сапсақ та была, тимер сапсақ та была. – *злт.*

**сыу сапсақ** *к.-уф., злт.* су кисмәге (кадка для воды). Сыу сапсақны тутырдым. – *к.-уф.*

**САПТАР** *злт.* аксыл-сары ат (каурая лошадь).

**САПУК** [*рус.*] *карс.* **1.** к.: **галуш 1**; **2.** *хвл.* к.: **пима 1**. Сапук бастырып кидек.

**САПУН** [*рус.*] *туб.-ирт.д.* к.: **алҗапма**.

**САПЫЙА'** *кас.* к.: **дустыған 1**.

**САРАБАН** [*фарс.*] *туб.-ирт.д.* сарафан. Мин үзем дә чакыртуға бардым йәшел сарабан кийеп.

**САРАWАЦ, САРАWЫЦ 1.** *төм.* яшь киленнәрнең баш киеме (головной убор молодухи). Сараwыц уқа белән цийылып цыққан, түбәсе йуқ. Сараwыц башында, питен бөргәп йөргән бер йылғаца, ойалған. Кийәүгә цыққац пәйләгәле бирә торғаннар ите сараwац. Сараwац бәйләмәдем, цацым зур; **2.** *туб.-ирт.д.* карчыклар кия торган укалы баш киеме (головной убор старух, вышитый позументом). Сараwыцым қалған, қарт пашлық пулып уйнасалар, алып китәтеләр; **3.** *себ.* маңгай бәйләвече (налобник).

**сараwыц қатау** *туб.-ирт.д.* башка *сарашыц* бәйләү (одевать на голову *сарауц*). Сараwыцны қартайғансын қататган.

**сараwыц сәбәмен** *туб.-ирт.д.* башыма *сарашыц* бәйлим (повязываю на голову *сарауц*).

**САРАЗБАН** *кргл.* к.: **мурта 2**.

**САРАЙ 1.** *каз.ар., минз., м.-кар., туб.-ирт.д.* к.: **абзар 1**. Қыш көне малларны сарайға җабалар. – *лш.* Выгрыт сарайға, ди, бернәстәсе йук. – *м.-кар.* Қыш көне малларны сарайға җабабыd, җәйлектә абзарда ғына торалар. Бабайлардан қалған сарайны ике тапқыр сипләттем инде. Мал йаба торған сарай өчәү. – *минз.*; **2.** *нокр., глз.* к.: **ишегалды**. Бызау сарайға кергән дә чапчақны түнтәргән. Сарай эшекләрен ачып салдық. Сарайдан исме кери? – *нокр.* Теге калган лысларны, кеше кермәсен инде дип, сарайның ишек башына, азбарның ишек башына тыккалыйлар әнейләр инде аны. – *глз.*; **3.** *перм.* келәт (клеть, амбар); **4.** *минз., тмн.* лапас (лабаз); **5.** *кузн.* к.: **абзар 3**; **6.** *минз.* к.: **чиннек I, 1**. Утынны сарайға қуйабыd. Ydалдына сарайы булмағач, лапас буйына өй (утынны); **7.** *тбл., к.-уф.* чардуган (изгородь вокруг могилы).

**алды сарай** *нокр.* к.: **ишегалды**. Алды сарайны чығып себер.

**мунча сарай** *глз.* мунча өйалды (предбанник). Мунчада эссе, мунча сарайда йуwынгаладык.

**сарай ал** *нокр., глз.* к.: **ишегалды**. Сарай алды йуwыштым. Сарай алны себердем.

**сарай асты** *кузн.* к.: **абзар 3**.

**сарай кәбән** *туб.-ирт.д.* к.: **сарут II**.

**сарай киртү** *туб.-ирт.д.* чардуган кору (соорудить ограду, огораживать могилу).

**САРАЙАҚ** *т.кам.-крш.*, **САРАЙАК** *кузн.* к.: **балайак**. Иләр ал сезгә, ал сезгә, Сарайаклар белән бал сезгә. Сарайакай балыгыз ич бетмәсен, Башыгыздан дәүләт китмәсен (*хал. җыр.*). – *кузн.*

**САРАНА** *перм., минз.* сарана лалә (лилия саранка).

**сарана күкәйе** *к.-уф.* сарана бүлбесе (бульба сараны). Сарана күкәйе дей торған ыйық, аның төптә сыуғаны була қый, қазып алып киләйек, қоймақ итеп тә пешерәйек аны.

**САРАПАН** *бөре.* алъяпкычның бер төре (вид фартука).

**САРАПИНКА** *т.я.-крш.* к.: **сәрәпин**.

**САРАС: баш сарас** *т.я.-крш.* баш сару, ягъни туйда кыз кеше кия торған баш киемен хатыннар баш киеме белән алмаштыру (замена девичьего головного убора на женский во время свадьбы). Тастарлар әзерләп куйылган әнде, баш сарас, диделәр, җылатас, диделәр.

**САРАТАН: саратан башы** *минз.* июнь башы (начало июня).

**САРБИНКА** *м.-кар.* к.: **сәрәпин**.

**САРҒАЙ** *том.д.* сарана (жёлтая сарана, саранка). Сарғай күп үсә, төбөндә күкәй хәдәр була ашый торған нәрсә.

**САРҒУТ** *туб.-ирт.д., брб.д.* кешедән калган аш (остаток пищи, объедки – обычно после знатных людей). Үндәү килде: қайтсын! тип, ир саргутын ичсен! тип, иргә салам бирсен! тип. – *тбл.*

**САРҒЫЧ: айақ сарғычы** *трх., минз.* аяк чолгавы (портянки). Айақ саргычы киндердән, аның башын чигәдерийек төрле-төрле җеп белән. – *трх.*

**САРЙАУ** *нокр.* җырлау (петь). Сарйап йаталардыр ысла эчеп.

**САРҚАМЫШ** *к.-уф.* камышлы җир (место, где растут камыши). Сарқамышта сыу безнең, йәшенне йаwын булды. Сарқамышта йыланнар күп.

**САРҚЫЗ** *т.я.-крш.* к.: **печкәчи**. Саркыз, тау сана, дидем.

**САРҚЫМ** *трх.* эремчек суы (густая сыворотка, остающаяся при прессовании творога). Сарқымын қамыр басқанда салып җибәрегез, қамырны үзле итә.

**САРҚЫТ 1.** *бгрс., кргл.* кунаклардан калган ашамлык (остатки угощения). Сарқытқа айақ – чыларымны чақырдым. – *кргл.*; **2.** *себ., әстр.* хөрмәтле олы кешеләрдән, картлардан калган ашамлык, аны серле, тылсымлы көчкә ия дип исәпләр (остатки пищи, объедки – обычно после стариков). «Бабаңның сарқыты, эцеп қуйың цайын. Аның йәшен пирсен сиңа та»,– тиделәр. – *клм.* Йақын кешегә туйга килә, қартларның сарқытын бир, ди. – *әстр.*

**туй сарқыты** *әстр.* туйдан соң калган ашамлык (остатки еды после свадьбы). Туйға күп итеп пылау пешерәделәр. Киткәндә балаларға, нан өстенә пылау салып, туй сарқыты дип биреп җибәрәде.

**үлем саркыт** *тмн., лмб., кузн., хвл.*, **үлем сарқыты** *бгрс.*, **үлем саркыты** *стрл.* **1.** к.: **бер: бер йаңыс**. Йке үлем саркыт иделәр: бер кызы, бер

оло. Алты кыз арасында үлем саркыт бер малай. – *кузн.* Үлем саркыт күлмәген йырткан. Үлем саркыт кынам иде, тук сукты. – *хвл.* Үлем саркыт кызым бар. – *лмб.* Үлем сарқыты гына бала булғач иркәләде, эшләтмәде. – *бгрс.* Әй, үлем саркыт ла, диләр, берләч бала булса. – *хвл.*; **2.** *тмн.* бик кирәкле, сирәк була торган әйбер (очень нужная, редкая вещь). Берәр кеше сораса, әй, үземә дә үлем саркыты гына дисең, берәр кирәкле генә әйберне сыраса.

**САРҚЫТУ I** *каз.ар.-крш.* чемченү (привередничать, есть неохотно, разборчиво). Аша, сарқытып қына утырма.

**САРҚЫТУ II** *кмшл.*, *т.я.*, **САРКЫТУ** *хвл.* к.: **кәкшетү**. Айаз булгач, айак астын хәзер саркыта. – *хвл.* Быраз сарқытсын инде, аннан китәрсез. – *кмшл.*

**САРЛАМА** *кас.* сары авыруы (желтуха). Абыйым сарлама булып үлде.

**САРМАҚ** *трбс.* к.: **ләкелдек**. Бигрәк сармақ қартны күреп қайтқансыз.

**САРМАҚЛАУ** *тпк.* такмаклап елау (плакать причитая). Инәсенең сармақлаwы, ди, улы үлгәч.

**САРМЫЗАН** *туб.-ирт.д.* туп (пушка).

**САРНАУ** *себ.* бию көен көйләү, җырлау (напевать танцевальную мелодию, петь). Син сарна, мин уйнайым.

**САРПАТЛЫ** [*гар.* + *афф.* -лы] **1.** *т.я.* әдәпле, тәрбияле (этичный, скромный, воспитанный); чаг.: **йосуқ**. Қызлар сарпатлы булырға тийеш. – *к.т.*; **2.** *злт.* җыйнак (аккуратный, собранный). Синең сарпатлымы, сарпатсызмы икәнне тикшерәләр.

**САРПАТСЫЗ** [*гар.* + *афф.* -сыз] **1.** *кмшл.*, *т.я.*, *чст.* тәртипсез, әдәпсез (невоспитанный; невоспитанно). Сарпатсыз утырма табын җанында. – *к.т.* Бу қәдәр сарпатсыз булырсың икән. – *кмшл.*; **2.** *т.я.*, *злт.* кадерсез, саксыз, җыйнаксыз (небрежно, неаккуратно, безалаберно). Кийемне бик сарпатсыз кийә лә ул. – *к.т.* Сарпатсыз кеше ике кийүдә кәстүмен қарайтыр ыйы. – *злт.*

**САРСЫЛУ, САРСЫНУ** *каз.ар.* күңел эзләнү, берәр нәрсәне ашыйсы килү (захотеть поесть чего-либо особенного); чаг.: **аш II: аш сайлау**. Шушы йаз көне кеше сарсыла, әллә ниләр ашыйсы килә. Сарсынып җибәргәндә қаwып җибәрегез (балыкны). – *дөб.*

**САРТЫН 1.** *миш.д.*, *нокр.*, *глз.* өчен (за). Эшләпә сартын акча түлиләр. – *кузн.* Олым сартын акча алам. – *глз.* Хади сартын акча алып тырды Хайрук абзый. – *тмн.*; **2.** *миш.д.* к.: **атына 5**. Синең сартын гына килгән идем. – *тмн.* Үз кешем сартын җанымны сатам. – *хвл.*; **3.** *миш.д.*, *кас.* өчен, турында, хакында (насчёт, о, про, за, для). Шуны сартын орыштык, диләр. – *м.-кар.* Әллә шул Рузиләләр сартын килдегезме дип тырам. – *шрл.* Мондагы йомош сартынмы килдең? – *кузн.* Агарут сартын ирти тороп су 'итирдим. – *кас.*; **4.** *глз.*, *каз.ар.-крш.*, *кузн.*, *к.т.* турында, хакында (о, про). Элгәреге сартын шөйләшеп утырдық. – *каз.ар.-крш.* Элгәрегеләр сартын мин белмим инде. – *глз.* Аның сартын бер сүз ишеттем. – *кузн.* Ат сартын сийләштек. – *нокр.*

**САРТЫНДА** *миш.д.* к.: **сартын 4**. Аның сартында күп йаздылар. – *хвл.*

**САРТЫННАН** *чпр.* к.: **сартын 3**. Ахыры ул персидәтелләр сартыннан килә микән.

**САРУ I** *блт.* к.: **базлавык**. Чана саруға төшеп қапланды.

**с а р у II** (окутывать):

**баш сару** *т.я.-крш.* к.: **сарас: баш сарас**. Киленгә итәкле күлмәкләр энде, баш сарган энде, тастар.

**тастар сару** *лмб.* к.: **сарас: баш сарас**. Чәчне кешегә күргәзергә йарамый, диләр ийе әлеке, чәчне күрмәсеннәр эчен тастар саралар инде, йылы да була башка, бун'н'ар эшеми.

**цабата сару** *чпр.*, **чабата сару** *т.я.-крш.* чабата кию (обувать лапти). Элек бит чабата сарган. – *т.я.-крш.* Цабата сарсаң цабарсың. – *чпр.*

**САРУКА** *кузн.* сары ука (жёлтый позумент). Бормада гына борма сарука, Турай ат кына гынайым делбига (*хал. җыр.*).

**САРУЛ** *т.я.-крш.* к.: **йанаға(й)**. Сарул Мекетә атлы минн, атлар карауда.

**САРУЛАУ** *блт.* к.: **кагылу**. Чана сарулап киткән дә җыгылып төшкән.

**САРУТ I 1.** *минз.* ак тамыр (пырей); **2.** *т.я.*, *чст.* к.: **айраwык IV: айраwык печән**; **3.** *минз.* сусән, арышбаш (тимофеевка); **4.** *мам.* к.: **ут II: тары уты**.

**САРУТ II** *тбл.* эскерт (скирд).

**САРФАТСЫЗ** [*гар.* + *афф.* -сыз] *каз.ар.*, *минз.* ваемсыз (беспечный, беззаботный); чаг.: **сарпатсыз 1**. Сарфатсыз хатын инде ул Саимә, баласы турында исенә дә кертми. – *минз.*

**САРФИНКЫ** [*рус.* салфетка] *бөре.* к.: **алсузма**. Сарфинкы итеп суққан, кеше алдына сузарға.

**САРФИТКӘ** [*рус.* салфетка] **1.** *бөре.* к.: **дастымал**; **2.** *минз.* к.: **алсузма**. Безнең дәwердә безгә инәйләр суғып бирделәр сарфиткәне.

**САРШИН** *мам.* к.: **тымабалавыз**.

**САРЫ I** *м.-кар.* сандугач (соловей).

**САРЫ II** *минз.*, *стрл.* таба (послелог к ..., по направлению к ...). Быйыл қыш килде, йазга сары килгән ийе. – *минз.*

**САРЫ III** *мам.* сарылучан, якын итүчән (льнущий, любящий). Бишәү булсалар да, үземә сары, қорорақ та инде мин үзем, өзөләп торалар миңа. Болар үземә сары, нәнәм дип өзөлеп китәләр.

**с а р ы IV** (жёлтый):

**сары мәтрүшкә** *блт.*, **сары нәркәмәс** *тмн.*, *лмб.*, *кузн.* к.: **албидрә**.

**сары печин** *перм.* сары чәчәк (пупавка красильная).

**сары суган** *перм.* к.: **сарана**.

**сары тал** *перм.* кузаклы төлке куагы (карагана кустарниковая, дереза, чилига).

**сары тәтәй** *блт.* к.: **печин: сары печин**.

**сары тырма** *перм.* к.: **сәбес**.

**сары черки** *перм.* к.: **сырхуwат**.

**сары шәңгә** *перм.* к.: **печин: сары печин**.

**САРЫҒЫЧ** *минз.* к.: **сарғыч: айақ сарғычы**.

**САРЫҚ I** *злт.*, *тбл.* к.: **чарық 2**.

**САРЫҚ II** (овца):

**киртә баш сарық** *трх.* к.: **киртәбаш**.

**сарық бала** *нокр.* к.: **сасун 2.**

**сарық шырланы** *мам.* к.: **йабышқақ.**

**САРЫҚ III** *себ.* сары авыруы (желтуха – болезнь). Сарық булса, пәтер эшләгәннәр тоссыс, түрт өлөшнең перен аңа ашатқаннар. – *тбл.*

**САРЫҚ-СОРЫҚ** *каз.ар.-крш.* сарык-кәҗәләр (овцы и козы, мелкий скот). Сарық-сорық та суйасын.

**САРЫЛАҢҚАН: сарылаңқан май** *тбл.* сары май (топлёное масло).

**САРЫМСАҚ** *перм.* к.: **сарана.**

**САРЫН** *себ.* җыр, такмак (песня, частушки). Сарын сарнайтылар үсләре цығарып.

**сарын сарнау** *себ.* җырлау, такмаклау (петь песни, частушки). Перәүләр сарын сарнап торған, перәүләр бийегән. Сарын сарный тоғаннар ыйы туйларда.

**САРЫПЛАП** [*гар.* + *афф.* -лап]: **сарыплап тормау** *мәл., трх.* талымлап, тартынып тормау (не привередничать, не стесняться). Өстәлгә ни куйдыгыз, бер дә сарыплап тормый, барысын да бөгә. – *мәл.* Ул бик сарыплап тормый, ашый бирә. – *трх.*

**САРЫПЛАУ I** [*гар.* + *афф.* -лау] **1.** *трх.* к.: **мөһөрләү.** Ул йегет эшен сарыплап эшли; **2.** *т.я., хвл.* к.: **қорлану.** Сарыпламыйча ашый. – *хвл.*; **3.** *кмшл.* киләп сару (мотать моток). Йен сарыплау; йеп сарыплау.

**САРЫПЛАУ II** [*гар.* + *афф.* -лау]: **йырға сарыплау** *кргл., бгрс.* көйгә салу (перекладывать на музыку). Мин сүзне дә йырға сарыплап апкитәм. – *кргл.*

**САРЫПЛЫ** [*гар.* + *афф.* -лы] **1.** *трх.* талымлы, талымчан (привередливый, разборчивый в еде); **2.** *кузн., мәл., трх., чст.* сайлануучан, таләпчән (разборчивый, привередливый). Малайлар сарыпсыз булалар алар, кызлар сарыплылар, күлмәкнең матурын кийәргә йараталар. – *мәл.*

**с а с** *туб.-ирт.д.* саз (болото):

**сас цийә** *себ.* к.: **торнакүз.**

**САСРАУ: сасрап тору** *дөб.* яшьләнеп тору (слезиться). Күзләрем сасрап тора.

**САСТӨП** *том.д.* көрәк (лопата). Хөсәйен, син састөп китер әле. – *яушт.*

**САСУ: кырсакка сасу** *лмб.* аш теләү (привередничать во время беременности). Кырсакка сасыганда чече ашаган.

**САСУН** [*рус.* сосун] **1.** *кузн., мәл., чст., срг.* к.: **қолқай.** Ул бийәнең сасуны бар, авырга йикмибез аны. – *мәл.* Байталның астында сасун тай. – *кузн.*; **2.** *чст.* имә торган сарык бәрәне (сосун – о ягнёнке). Сасунның йоны йахшы; **3.** *нокр.* яшь бозау ите (телятина). Сасун йаман тәмле була.

**САСЫҚ** *туб.-ирт.д.* к.: **ислекәй 1.** Сасық қыйнайты, йоқлап пулмайты.

**САСЫҚАЙ** *минз.*, **САСЫКАЙ** *байк., мәл.* к.: **йылан: йылан көпшәсе 1.**

**САСЫХ** *саз.я.* к.: **ислекәй 1.**

**САТ** [*рус.* сад] **1.** *кузн., лмб., хвл., шрл., чст., карс., минз., т.кам.-крш.* к.: **сад-бакча.** Падишаның сарайы каршында була бик матур сат, мының катыны чыгыб йөри сатка (*әкият.*). Сат караргa кайчан барасыз? Ул мында тырмый, үзе алма сатлары утыртып йөри. Мында карлыган саты бар иде, йаңадан күләб җибәрәм әле. – *чст.* Сандуғачлар булып сайрар идем, Өй артында җәшел сат булса (*хал. җыр.*). – *т.кам.-крш.* Ашарлық җиләк хәдер бардыр сатта. – *минз.* Катыны белән ире ашаб утыралар икән сат эчендә. – *шрл.* Сатыгыз дамы бар? – *хвл.* Әтийемнең алма саты, Алмалары кызарадыр (*бәет*). Сатыбыз бар, ну мурталар җугиде әл дә. – *карс.*; **2.** *глз., срг., чст.* куак, бер төп агач (куст, дерево). Сатлы ызба безнеке. Ызба йагасында бер сат бар. Орманда алманың сатын күрдем. Бездә бер агачка сат диләр. – *срг.* Сат йапырякларны йаңгыр йаwып кыйып төшерә. – *глз.* Вата чийә сатлары. – *чст.*

**сат тебе** *чст.* агач төбе (пень). Әдәгез шул сат тебенә утырыйг әле.

**САТА** *туб.-ирт.д.* **1.** аңсыз, аңгыра (бестолковый, непонятливый); **2.** тиз ышануучан, беркатлы (легковерный).

**САТАҒА** [*гар.*] *туб.-ирт.д.* к.: **сагада.**

**САТАГАРУТ** [*рус.* сад + огород] *чст.* бакча, яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчасы (сад, где выращивают овощи и фрукты). Ике йары сатагарутлары.

**САТАЙ** *каз. ар.* тиле, юләр (дурак, сумасшедший, безумный). Сатай әйткәндәй, кеше сигез чеби дә үстермәгәндә, сигез бала үстердем. – *мам.* Қалық бит элек уқымаған, бик сатай булған. – *блт.*

**САТАЙЛАНУ** *мам.* тилерү, акылдан язу (сойти с ума, помешаться). Қоса-қоса awыртты да сатайлана башлады.

**САТАЙ-МАТАЙ** *блт.* аңгы-миңге, аңгыра (бестолковый, тупой). Сатай-матай инде мин, күпне күрдем.

**САТАЛЫ** *злт.* к.: **йәпмәлө.** Ике саталы сәнәк была. Көлтә әйләнеп тора, ике саталы сәнәк әйләнергә бирми.

**САТАНДЫРУ** *минз.* к.: **сандырату.** Көн буйы сатандырасың-сатандырасың да киләсең кич белән безгә.

**САТАНУ** *минз.* к.: **сандырау 1.** Син сатаныб утырасың да утырасың шунда.

**САТАШУ: чиргә саташу** *нгб.-крш.* чиргә сабышу (заболеть). Чиргә саташып үлде бабайым.

**САТӘ** *твр.* гади, беркатлы (простой). Антай сатәмен мин.

**САТБАКЦА, САТБАКЧА** *чст.* өйтүр бакча, түрбакча (палисадник). Безнең сатбакчада сирин кuwагы үсә. Күгәрченнәр гөлдери сатбакчада ийада.

**САТБАҚЧА** *т.я., каз.ар.* к.: **сад-бакча.** Иске тактalар череп йата сатбақчада. – *трх.* Кругум сатбақчада утыра өйләре. – *каз.ар.-крш.*

**САТ-ЗАТ** *чст.* нәсел-нәсәп (род, родословная). Сат-зат ул кешенең нәселе икән, нәселен тикшергәннәр.

**САТМАШТЫРЫП** *злт.* чалыштырып (крестнакрест). Сабата кәркешен сатмаштырып, солғау өстеннән урап қуйам.

**САТУЛАШУ** *глз.* сату итү (торговать). Элек нукратлар сатулашып йергәннәр.

**түшәк-җастық сатулашу** *нгб.-крш.* туйда шаярып яшь киленнең урын-җир әйберләрен «са-

тып» алу (свадебный шуточный обычай: купля-продажа постельных принадлежностей невесты). Туй қаршылау беткәч, кийәү җегете түшәкҗастық сатулаша. Қунақлар, туй қарарға килгән кешеләр шунда җыйылалар. Түшәкчеләр кийәү җегетеннән ақча сорыйлар түшәк өчен. – *нгб.-крш.*

**САТУРЛАНУ** [*рус.* + *афф.* -лану] *туб.-ирт.д.* кызып китү (разгорячиться).

**САТЫЙ I** *каз.ар.-крш.* к.: **ат'акыш 1.** Нинди сатый кешеләр икән бу, карчық белә күкәйгә барганнар.

**САТЫЙ II** *крш.* кеше исеме, аны ырымлап кушканнар (заговорное имя человека).

**САТЫНЫП-СУҒЫНЫП** *перм.* сатып; таратып (распродав; раздав). Сатынып-суғынып чығып киттек өйдән.

**САУҚА** *тпк.* каенлык (березняк); чаг.: **саwыл.** Todlo сыw апқайтып, сауқаға барып қайната торған ыйық.

**САУЛАШУ 1.** *лмб.* исәнләшү, күрешү (поздороваться, приветствовать). Саулаша бардым урамнан. Мин саулашам, күп кеше саулаша; **2.** *м.-кар.* саубуллашу (прощаться). Кристийаннар саулаша моно бели.

**САУЛЫҚ** *сазл.* тана бозау; сарык бәрәне (тёлка, ягнёнок-самка).

**САУЛЫКЛАНУ** *чст.* савыгу, терелү, сәламәтләнү (выздоравливать, поправляться). Үлми, үлгесе келәми, саулыклана.

**САУЛЫКЛАШУ** *хвл.* саубуллашу, хушлашу (прощаться). Бик озак саулыклашасыз инде.

**САУЛЫКЛЫ** *чпр.* к.: **кандаwый.** Элгәреләр саулыклы шул карцыклар, эшләп йөриләр.

**САУМАР** *глз., нокр.* к.: **самар.** Эндәшәме саумарың? – *глз.* Саумарым қайнамый дип торам. Бер саумарны бетереббез. – *нокр.*

**САУРЫ** *себ.* арт сан, савыр (задняя часть лошади).

**САУЦЫ** *туб.-ирт.д.* к.: **башқода 1.** Сиңа перәү күңеле төшәтиген, сауцы йебәрәте. Сауцы килә-те, қысыңқы ата-аналары киңәшәтләр. Қалыстан исемне сеңнемә сауцы килте. Сауцы килте тә Қалыстан әйтте: «Мин пармайын», – тиде.

**САУЦЫЛАУ** *туб.-ирт.д.* яучылау (сватать). «Үсем парайын сауцылағалы», – тип әйтте әкәм.

**САУЧЫ** *себ.* к.: **башқода 1.** Йегетнең ата-анасы саучы йөргәсгәннәр, бирергәме, бирмәскәме. Саучы уң айақныгы балагын чығарып, сәлам биреп, исәнлек-саулық сорашып кергән. – *төм.*

**САХЛАУ** *сазл.* асрау (держать – о корове). Сыйыр сахлайм, посawы wар wерәү.

**САЧИНКӘ** [*рус.* чёсанки] *минз.*, **САЧУҢКӘ** *бәр.* галош белән киелә торган юка киез итек (чёсанки). Сачуңкә кийәдер ийе бер кеше безнең awылда.

**СӘӘТ** [*гар.*] *тмн., чст., карс.* к.: **сәйәт.** Дүртенче сәәт инде. – *тмн.* Апа, ничә сәәттә китәсез? – *чст.*

**СӘБА** *хвл.* к.: **кәҗи.**

**СӘБӘЛӘҮДӘЙ** *кас.* килешсез озын күлмәк кийеп йөрүче хатын-кыз турында (о женщине, носящей неуклюжее длинное платье). Җәри сәбәләүдәй булып.

**СӘБӘР: сәбәр ай** *төм.* к.: **сабыр: сабыр ай.** Сәбәр айларында тудым, Шуңа бәгытсес пултым тип йырлайтылар. Сәбәр айны туйны йасағалы йарамай, бәгытсес тормыш була, тиделәр.

**СӘБЕКӘЙ: сәбекәй итү** *злт.* к.: **чәбекәй: чәбекәй итү.** Сабан туйында көрәшеп йеңсә, сәбекәй итәләр.

**СӘБЕРСЕК** *злт.* к.: **кәмәцә 1.** Сәберсек килми боз китми (*мәкаль*).

**СӘБЕРЧЕК** *дөб.* к.: **себерчек: себерчек җомырқа 1.**

**СӘБЕС** *чст.* кишер (морковь).

**СӘБҮ** *злт.* **1.** барып чыгу, килеп чыгу (оказаться). Қулын ысқындыра, бер йарға барып сәбә; **2.** әләгү, әләктерү (доставаться). Кызыл алма бирмәделәрмени, сәпмәдемени сиңа?

**СӘWӘНӘЙ** *тпк., стрл.* ямьсез кыяфәтле кеше, карачкы шикелле (человек, у которого не красивый вид, человек как пугало). Сәwәнәй който гына нәрсә ул. – *стрл.*

**сәwәнәй сынны** *стрл.* карачкы кебек, ямьсез киенеп (как пугало, как чучело огородное). Сәwәнәй сынны йөрмә.

**сәwәнәйле уйнау** *стрл.* кием алмаштырып, көлке ясап йөрү (рядиться, делать маскарад, смешно переодеваясь).

**СӘWEM** *злт., трх., байк.* киләптәге дүрт бөртек җеп (четыре нитки в мотке). Йөз йегерме бөртеге бер басма была, дүртәр бөртөге бер сәwем была. – *злт.* Йепне эрләп бауга тутырасың, сәwемдә дүрт йеп була. Сәwемне дүрт йептән булса, йуwарга awыр, ди иде ини. – *байк.*

**СӘWЕРӘ** [*удм.*] *нокр., глз.* каен тузыннан ясалган савыт (посудина, коробка из бересты, бурачок, туесок); чаг.: **күнәк.** Чәйне сәwерәдән эчәләр икән. Менә сәwерәдә бырага дий. – *глз.*

**СӘWЕСКӘН** *тмн.* к.: **с'аваскан.**

**СӘВИТЫМ** [*рус.* + *афф.* -ым] *кас.* к.: **дусай I.**

**СӘҒӘТ** [*гар.*] *минз.* к.: **сәгат суққан көн.** Сәгәткә қунақлар чақырған ыйым.

**беләк сәгәте** *бәр.* кул сәгате (ручные часы).

**сәгат суққан көн** *минз.* көн озынлыгы унҗиде сәгатькә җиткән көн, бу көнне төрле уеннар уздырганнар, дару үләннәре җыйганнар (время года, когда долгота дня достигает семнадцати часов; в этот день проводились различные молодёжные игры, собирались лекарственные травы и т.д.). Элгәре қортқалар сәгат суққан көнне үләннәр, чәчәкләр җыйалар ыйы.

**сәгат туқмағы** *минз.* сәгать гере (гиря часов). Күтәр сәгат туқмағын.

**түш сәгәте** *перм.* кесә сәгате (карманные часы). Түш сәгәте тора хушбуй өстәлдә.

**унҗиде сәгат суққанда** *минз.*, **унҗиде сәгат сукканда** *стрл.* к.: **сәгат суққан көн.** Унҗиде сәгат суққанда, ураза тотып әрдәнә ташыдық. – *минз.*

**СӘҒӘТЛӘМӘ** [*гар.*] *нгб.-крш.* сәгать (часы). Әйт әле, сәгәтләмә ничә?

**сәгәтләмә печин** *перм.* күкчәчәк (василёк посевной). Сәгәтләмә печин зәңгәр чичкә ата, арыш төптә була, wақ чичкә була, сәгәтнең эстрилкә кебек чичкәсе әйләнеп бара қойаш артыннан.

**СӘҒӘТТӘ** [*гар.*] *нгб.-крш., минз.* к.: **бер: бер шәптә**. Сәгәттә килеп җитәр, бик тиз җәри ул. – *нгб.-крш.* Сәгәттә қайный самоwар. Сәгәттә барып қайтам. – *минз.*

**СӘГЕНҮ** *т.я.-крш.* атыну (качаться). Таган салалар иде, йугарыда сәгенәләр. Төрле урыннарда агачка күләнгән таганда сәгенәләр парлап-парлап.

**СӘДӘП** *мам.* таблетка. Бер сәдәбен генә әчәм дә, башым awыртқаны басыла.

**сәдәп үләп** *к.-уф., злт., глз.* к.: **бырцак: бырцак үләне**. Сәдәп үлән йапырағына буйағаннар күкәйне. – *к.-уф.*

**сәдәп чәчәк** *мам.* к.: **албидрә**.

**сәдәпле дару** *мам.* таблеткалы дару (лекарство в таблетках).

**сәй** *злт., тпк.* чәй (чай):

**сәй апкерү** *тпк.* к.: **бәбәй: бәбәй үстерү**. Сәй апкерергә кирәк ийе, Әлфийә қайтқан, бәбәй апқайтқан.

**СӘЙӘТ** [*гар.*] *мәл., кас.* сәгать (часы). Бу, бырат, сәйәт инде. – *мәл.* Дүрт сәйәттә эш'и 'иттем. – *кас.*

**СӘЙҒАУ** 1. *кргл.* сайгак (половица); 2. *трбс.* к.: **пайыт 1**.

**сәйгау асты** *трбс.* к.: **пайыт 1**. Сәйгау астына җәйеп суганны киптердем.

**сәйгау җәйү** *кргл.* сайгак җәю (настилать пол). Сәйгау җәйдерде, түбә йаптырды.

**СӘЙГҮН** *тпк.* к.: **гал'ник**. Сәйгүнемне йандырдым, сywы беткән дә.

**СӘЙЕЛ** 1. *себ.* аяз (безоблачный, солнечный). Көн сәйел; 2. матур, ачык җир (красивый, открытый – о местности); 3. урман күле (лесное озеро); 4. *тара.* рәхәт (радость, удовольствие). Улым – көн күрмешем, қысым – сәйелем; 5. *себ.* күңел ачу (прогулка, пикник).

**сәйел йаңқыр** *себ.* кояшлы яңгыр (дождь в солнечную погоду).

**СӘЙЕЛҒАНӘ** *туб.-ирт.д.* балкон.

**СӘЙЕЛЛӘП: сәйелләп йөрү** *туб.-ирт.д.* күңел ачып йөрү (гулять).

**сәйелләп пару** *туб.-ирт.д.* кунакка бару (ездить, ходить в гости).

**СӘЙЕЛЛӘҮ** *себ.* к.: **сәйелләп: сәйелләп йөрү**. Атам мына инәмә барайық, сәйелләйек. – *тара.*

**СӘЙЕР** *минз., к.т., перм.* к.: **мәсқәрә**. Кичә бик сәйер булды. – *минз.*

**СӘЙЕРГӘ** *перм.* кызык итеп (для забавы). Сәйергә дә эчмәдек инде рақы.

**СӘЙЕРСЕНЕП** *каз.ар.-крш.* кызык итеп, кызык өчен (для смеха, ради потехи). Сәйерсенеп ашқа кийеп барайым қәситәләрне, түшлекләрне.

**СӘЙЕСКӘН** *минз.* к.: **с'аваскан**.

**СӘЙЛАМ** [*гар.*] *карс.* к.: **сайл'ам**. Ызак тырмабыз, тиздән кат'ырбыз, Әтийеңә сәйлам әтербез (*бәет.*).

**СӘЙЛӘП** *себ.* к.: **цәйләп**.

**СӘЙХУР** *злт.* чәй эчәргә яратучы (любитель пить чай).

**СӘК** *т.кам.-крш.* ян, яны белән (бок, боком).

**СӘҚА** *себ.* су эчертүче, балдан ясаган кайнар эчемлек сатучы (поильщик, сбитенщик).

**СӘКАСТЫ** *нрл.* к.: **сике II**. Сәкастында киндер дә суғадырыйық, алача да суғадырыйық.

**СӘКӘЙҮ** *туб.-ирт.д.* гаҗәпләнү (удивляться).

**СӘКӘЛҮК** [*рус.*] *том.д.* к.: **уклawык**. Камырны сәкәлүк белән җәйә дә пешерә. – *клм.*

**СӘКӘНЛӘҮ** *туб.-ирт.д.* бер аякта сикерү (скакать на одной ноге).

**СӘКЕ** *минз.* үлчәү берәмлеге: бер сәке тактасына җәеп киптерелгән җиләк-җимеш кагы күләме (единица измерения: количество фруктовой пастилы размером с одну доску нар). Миңа бер йарты ғына сәке қақ сат әле.

**сәкасты ачу (суғу)** *мам.* киндер сугу станы кору (устанавливать ткацкий стан). Әлек бит сәкасты сугу барыйы.

**СӘКИ** *кузн., әстр.* имеш, янәсе (как будто, якобы, дескать, мол). Әлек заманда караңгылык булган, укымасын, сәки, йегеткә хат йазмасын. Сәки, башы авырта. Сәки, син дә барыпсың. Фатима белән кемнеке, сәки, йахшы, ди. Икенчесе армәдән килер дә үләндеребез, сәки. Сәки, кан'ушн'ага, ди, йабарбыз. Кайа, сәки, үмер иткең кели. Укий, сәки, картайганда ат врачына. – *кузн.*

**СӘКТӘ** *туб.-ирт.д.* көтелмәгән, уйланмаган (непредвиденный). Сәктә үлем. – *тбл.*

**СӘЛ: кеше айағы сәл булу** *т.кам.-крш.* к.: **сил: кеше айағы сил булу**. Кеше айағы сәл булғачтын, су алып қайтасын ошом тотқан кешегә сибергә.

**сәл бирү** *каз.ар.-крш.* сәламәтләндерү, хәл кертү (исцелять, оздоровлять). Дару кешеләргә сәл бирә.

**сәл итү** *лш.* ял итү (отдыхать). Әйдә, сәл итеп алыйғ әле.

**СӘЛӘМ** *нгб.-крш.* к.: **бетеғ**. Сәләмең килгәнче пасылка килсә, җақшы булырыйы. Сәләм йаздығызмы өйөгезгә?

**сәләм бирүчеләр** *дөб.* печән чапканнан соң чабылмыйча калган үләннәр (трава, оставшаяся нескошенной после косьбы). Энем, қарап чап, артыңда сәләм бирүчеләр қалып бармасын.

**СӘЛӘМӘ** *чст.* 1. картаеп, корып беткән – кәкре агач турында (старый, засохший, плохо растущий – о деревьях). Бу агачлар сәләмә; 2. к.: **който**. Аларның бер-берсе белән атнашинийлары сәләмә булган. Ник бик сәләмә торасың йоқоңнан?; 3. начар, бозык (плохой, испорченный). Алмасы сәләмә, йартысы калсын, цыгарма пугрәптән.

**сәләмә кеше** *чпр.* к.: **пырдымсыз 1**.

**СӘЛӘСКӘ** [*рус.* салазки] *злт., чпр.* кечкенә чана (салазки). Балалар үстергәндә, сәләскә тартып йөрдем. – *злт.* Икебезгә бер сәләскә урман цыгардык. – *чпр.*

**СӘЛӘҮ** *кас.* тастарның астына куеп калдырыла торган тасма (лента, которая подкладывается под тастар).

**СӘЛБӘГӘЙ** *бәр.* нечкә сабаклы, начар (с тонким стеблем, плохой). Гөлләрне қуйы чәчкән ийем, сәлбәгәй булып үстеләр.

**СӘЛБӘЛТӘК** *туб.-ирт.д.* селкенеп тора торган (качающийся).

**СӘЛБЕ** *кузн.* к.: **бер: бер саба' җеп**. Бер сәлбе генә йеп биреп торчы.

**СӘЛБЕРӘҮ** *злт.* салыну (свисать). Мынawы эскәтер фис сәлберәгән. Сәлберәп тора қулы.

**СӘЛГЕ I** *мәл.* сәләмә (лохмотья; рваный); чаг.: **алама-шалама**. Күлмәгенең сәлгеләре асылынган.

**СӘЛГЕ II: бер сәлге** *минз., стрл.* бер уч, әп-әз (горстка, немножко). Тезем өшәмәсен дип чана төбенә салған бер сәлге печән бит ул. – *минз.* Бер сәлге печән йук. – *стрл.*

**сәлге дә** *кмшл.* к.: **җоғоро(сы) 1.** Сәлге дә печәнебез йуқ быйыл.

**СӘЛДЕРӘП: сәлдерәп тору** *перм.* шалтырап тору (звенеть, бренчать).

**СӘЛДЕРӘҮ 1.** *перм.* к.: **сәлберәү.** Айақны идәнгә сәлдерәтмә булмый. Туңкайды исә, баулары сәлдерәп тора бабайның; **2.** *мәл.* к.: **дөлкөлдәгән.** Сәлдерәгән қарчық йөри әле.

**СӘЛЕЙ** *перм.* бишек (люлька).

**СӘЛЕМЧӘК** *чпр.* к.: **даған 2.** Сәлемчәк куwar астында эшләнгән ыланнар эчен.

**СӘЛЕНГЕЦ** *срг.*, **СӘЛЕНГЕЧ** *перм.* к.: **атын.** Ана сәленгецләр. – *срг.*

**СӘЛЕНМӘ** *трх.* к.: **қолға 1.** Ышкул җанда сәленмәле қойо бар.

**СӘЛЕН-СӨЛЕН** *мәл.* авыр атлау, авыр кыймылдау (тяжело шагать, медленно двигаться).

**СӘЛЕНЧЕК 1.** *перм.* к.: **сәлей.** Бығысы сәленчеккә сала торған мендәр була; **2.** *кргл.* к.: **атын.**

**сәленчек итү** *кргл.* к.: **сәгенү.** Сәленчек итәбез қачаннан бирле.

**СӘЛЕНҮ 1.** *кузн., хвл., перм.* таган атыну (качаться на качелях); **2.** *чст.* салыну (висеть, свеситься). Өзеңнеке көренми дә, үзеңнеке сәленми лә (*әйтем*); **3.** *себ.* асылыну, салыну (повиснуть, висеть). Алмалары сәленеп тораты – *төм.*; **4.** *срг.* тирбәнү (качаться). Сәленгец бишектә балаларны сәлендерә.

**СӘЛЕҢГЕЧ** *перм.* к.: **атын.** Йәсле ишегалдында бар сәлеңгеч, балалар утырып сәленәләр.

**СӘЛИ I** *нгб.-крш.* к.: **матур 1.** Ул бик сәли бәйеткә дә.

**СӘЛИ II** *перм., брб.д.* к.: **сәлей.** Сәлийен тегәләр киндер белән, пуржинаға асалар. Уланны сәлигә салып тирбәт. – *перм.*

**сәли ағач** *перм., к.-уф.* агач сиртмә (деревянный шест, журавль, с помощью которого подвешивают люльку); чаг.: **силә 1.** Сәли ағачқа асылындым да шушылай қарап торам. Сәли ағачны қара шыршыдан йасыйлар. Сәли ағач қайындан да була, талдан да, мелиштән дә була. – *перм.* Сәли ағачны қайындан йасама, қайын қайғылы була. – *к.-уф.*

**сәли сәнчек** *к.-уф.* к.: **сәли ағач.** Сәли сәнчек бишек элә торған кәртә була.

**СӘЛИЙАТ** [*гар.*] *чпр.* сәләт, булганлык (способность, одарённость); чаг.: **сол.** Бетен малайларның да сәлийатлары бар, өй салалар. Йыраққа ычсалар, умарталарның сәлийатлары кими төшә.

**СӘЛИЙӘТЛЕ** [*гар.*] *лмб.* к.: **салиталы.** Кечкенәсе бик сәлийәтле, тегә дә, бәли дә.

**СӘЛЛӘ** [*фарс.*] *злт.* чалма (чалма, тюрбан). Сәлләне муллалар урай торған ыйы.

**сәллә йаулығы** *тпк.* к.: **сәллә.** Қайныма сәллә йаулығы қайыдым намадға барыға.

**СӘЛЛИ** *перм., бөре., минз.* к.: **сәли II: сәли ағач.** Элек сәлли ийе ағастан, хәзер генә пыржина. – *перм.* Сәллине миләштән қуйа торғаннар ыйы, хәзер пружина, сәлли түгел. – *бөре.*

**СӘЛМӘ** *трх.* к.: **атын.**

**сәлмә сәленү** *трх.* к.: **сәгенү.** Ат-ат уйныйдырыйық, сәлмә сәленәдер ийек.

**СӘЛПӘҢНӘҮ** *тпк.* сүлпәнләнү, салмаклану (становиться вялым, медлительным). Сәлпәңнәп тотона тибед дақ қудғалган кешене. Сәлпәңнәмә!

**СӘЛПӘҮ** *тпк.* сүлпән (вялый, медлительный).

**СӘЛПЕ** *т.я., чпр., мәл.* к.: **билтәк 1.** Әҗелдә (*ав. ис.*) бар бер апам, телендә сәлпе. – *трх.* Берәз сәлперәк аның теле. – *чпр.*

**СӘЛТӨП** *туб.-ирт.д.* к.: **сәлей.**

**СӘМӘЙМИ'И** *кас.* к.: **семәйү.** Ни' сәмәйеп 'ена утырасың?

**СӘМӘК** *туб.-ирт.д.* чәйнек борыны (носик чайника).

**СӘМӘКЛӘНГӘН: сәмәкләнгән буз** *себ.* боз сөңгесе (ледяная сосулька).

**СӘМБҮСӘ** *минз., тпк., стрл.* эчәктән яки ит һ.б. пешерелгән сумса, бөккән (пирожки из ливера). Сәмбүсә пешерәбез, мал суйсақ. – *минз.* Иттән төйөп тутырып, майлап пешергәнне сәмбүсә дибез. – *тпк.* Эчәкнекен сәмбүсә пешерәләр. – *стрл.*

**СӘМЕК** *туб.-ирт.д.* мылтык тәтесе (спусковой крючок).

**СӘМЕРҮ** *брб.д.* симерү (тучнеть, разжиреть). Ады сәмерде.

**СӘМНӘНЕП** *тпк.* үч итеп (назло). Мин сәмнәнеп бардым аңа, йөри тиб әйттеләр дә.

**СӘМСӘ** *тпк.* бизәк (узор, рисунок ткани). Қалфақ энйе генә була, қайу қайыған күwек ситек сәмсәсе төшөрәбед дә.

**СӘМСӘҮР** *туб.-ирт.д.* кылыч (сабля, меч). Паланың қырық қылыц, қырық сәмсәуре пар ите.

**СӘМСЕЛ** *тпк.* узышучан, ярышучан (старающийся обогнать, опередить кого-либо, любящий соперничать). Шулхәтле тырыш ыйы, сәмсел ийе.

**СӘМҮЛСӘ** *минз., тпк., стрл.* к.: **сәмбүсә.**

**СӘНӘЗКӘ** [*рус.* салазка] *стрл.* к.: **сәләскә.**

**СӘНӘЙЦЕК** *туб.-ирт.д.* кечкенә эт (порода мелких собак).

**СӘНӘК** *нокр.* ядәч (дужка).

**СӘНӘКЛЕК** *каз.ар., минз.* к.: **қыра III.** Печәннe сәнәклеккә салып бетермәдек, йаңғыр сибәләргә дә тотонды. – *блт.*

**СӘНӘСКӘ** [*рус.* салазка] *каз.ар.-крш., минз., кргл., трбс., злт., стрл., байк.* к.: **сәләскә.** Ике қарт сәнәскә сөйрәп килә. – *кргл.* Икенчелей инде, қаршыларында тау, шуwам сәнәскә белән, Ибый дәдәй қарап тора икән. – *каз.ар.-крш.* Уникe сәнәскә сығып китте курмаға. – *злт.* Кицтән сәнәскә уйнап йерде. – *байк.*

**СӘНӘШКӘ** [*рус.* салазки] *каз.ар.-крш.* чана (сани). Сәнәшкәгә салып утын ташыдық, күрмәгән бер дә қалмады.

**СӘНБҮСӘ** *минз., тпк., стрл.* к.: **сәмбүсә.**

**СӘНДЕ'ӘС** *кас.* сандугач (соловей).

**СӘНДЕРӘ** *бөре., минз., чпр.*, **СӘНДРӘ** *каз.ар.* к.: **бастырма.** Сәндерәсенә печән өйгәч, җылырақ булды. – *минз.* Печәннәрне сәндрәгә аттым әле. Лапаста безнең бик йақшы сәндрә бар, шунда бәрәм бу печәннәрне. – *мам.*

**сәндерә қаш** *перм.*, **сәндерә қашағасы** *минз.* сәндерәнең ал ягы, йөзлеге (передняя сторона,

наличник полатей). Сәндерә қашта эленеп тора литни пәлтәсе. – *перм.*

**СӘНЕЧКӘ** *блт.* ике япьле сәнәк (вилы с двумя развилинами).

**СӘНСӘК** *злт.* к.: **киштә II, 2**. Бишеккә кәрәк былгас, килен белән икәү ағастан сәнсәк йасап куйған ыйық. Қайын сәнсәк көллөбезгә дә йетте. Ағас сәнсәк ийе әлгәре.

**СӘНСИЙӘ** *к.-уф.* исле үлән (душистая трава). Сәнсийә дигән үлән бар, бик тәмле исле булайы ул сәнсийә.

**СӘНТӘ** *туб.-ирт.д.* авыр (тяжёлый).

**СӘНТӘП** [*рус.*] *кузн., срг.* к.: **синтәп**. Сәнтәб айына тагы чакырган. – *кузн.* Картупны сәнтәп кергәц эзә башладык. – *срг.*

**СӘҢ I** *туб.-ирт.д.* тәмәке төтене (табачный дым).

**СӘҢ II** *туб.-ирт.д.* к.: **қый III**.

**СӘҢ III** *туб.-ирт.д.* күгәрек (плесень).

**СӘҢ IV** *трх.* хуплау, җөпләү кисәкчәсе (частица, служащая для выражения одобрения, утверждения). Хәзер бит җагада инде халық – сәң, сәң! Сәң, өрәнмәгән.

**СӘҢӘТ** *туб.-ирт.д.* к.: **сәйәт**.

**СӘҢГЕЛТӘК** *тпк.* **1.** к.: **чәңгелдек 2**. Сәңгелтәк кинтертән пула ыйы инте; **2.** к.: **сикертмә I, 2**.

**СӘҢГЕРӘЙТҮ** *перм.* к.: **исәңгерәү 2**. Сәңгерәйтмә мине. Булмаган эш икә эшегез, башығызны wата торган, башығызны сәңгерәйтә, үләрсез аның белә.

**СӘҢГЕСӘК** *туб.-ирт.д.* к.: **сәлей**.

**СӘҢЛӘНҮ** *туб.-ирт.д.* тутыгу (ржаветь).

**СӘҢЛӘҮ** *туб.-ирт.д.* күгәрү (заплесневеть). Сәңләп мөг үсеп қалаты.

**СӘПӘМӘ** *злт.* к.: **бал′ук**. Қызлар сәпәмәне күтәреп тә сыгалар. Ана безнең йақта бәрәңге сәпәмә кебек үскән.

**СӘПӘР: сәпәр йолтос** *туб.-ирт.д.* Сәфәр йолдызы (Венера). Күктә бертөрле йолтос, Сәпәр йолтос, ул йолтосқа қаршы барғалы йарамайты туй атларынта.

**СӘПКӘЙ: сәпкәй итү** *тпк.* к.: **чәбекәй: чәбекәй итү**.

**СӘПЛӘЧКЕ** *брб.д.* ямаулык (заплатка).

**СӘПҮН** [*рус.* запонка] *перм.* к.: **элдек**.

**СӘР** *туб.-ирт.д.* агу (яд).

**СӘРӘН** *т.я.-крш.* к.: **сай II**. Зиналар ырымга киттеләр, китмә дигән сәрән.

**СӘРӘНӘ** [*рус.*] *злт.* сарана (саранка).

**СӘРӘПИН** *глз.* тукыма атамасы (название ткани). Алай димә, болай димә, Сарлы сәрәпин кимә. Сарлы сәрәпиннәр кийеп, Минем өчен бик кимә (*хал. җыр.*).

**СӘРӘТӘ** *бөре.* к.: **зәрдә**.

**СӘРБӘГӘЙ** *бәр.* юка – печән турында (жидко, редко – о сене). Сәрбәгәй булып үскән болон печәне, қалын булмаган.

**СӘРБИ: сәрби куwагы** *чст.* к.: **қузақ: қузақ ағачы**.

**СӘРWӘ** *глз.* гөбе (пахталка, ручная маслобойка). Кайын тузыннан сәрwә йасадылар, аның белән май да сугалар.

**СӘРWӘРИ** *минз., т.кам.-крш.* к.: **кузақ: қузақ ағачы**.

**СӘРWИ: сәрwи ағачы** *дөб.*, **сәрwи талы** *бәр.* тополь.

**СӘРДӘК** *эчк.* к.: **сәбес**.

**СӘРЕН** *лмб., кузн., хвл., әстр.* **1.** к.: **йарау**. Чирәмдә утырғайдең, сәрен бит. Кыйаш калыкмаганда әле сәрен була. Кен беген сәрен, жар тегел, былытлы. – *кузн.*; **2.** к.: **күләткә 1**. Сәрендә жар тегел. – *лмб.* Анда кыйаш пешерә, бире кил, мында сәрен. – *кузн.* Ызбада сиңа беләсең йакшы сәрендә. Сәрендә вата утырабыз. – *хвл.*

**сәрен җир** *әстр.* к.: **күләткә 1**. Сәрен җирдә киптереп салам даруға дигән үләнне.

**СӘРИНДИ** *туб.-ирт.д.* буйлы киҗе-мамык тукыма (полосатая, хлопчатобумажная материя).

**СӘРКӘШ** *злт.* к.: **кирлемур**. Тегесе дә Ғөмәрдән қалышмый, сәркәш инде. Хатыны да насар туры килде, дөнйа көтәрлек түгел, сәркәш.

**СӘРЛЕК** *трбс.* мунчала телү өчен түшәмгә элеп куелган колга (перекладина, подвешенная на потолке для разрезания мочалки). Сәрлектә эленеп торыр ыйы мунчала, кибеп торор ыйы.

**СӘРМӘКЛӘҮ** *трбс.* к.: **бүкәйләү**. Сәрмәкләп себерәм иденнәрне.

**СӘРМӘНҮ** *минз., стрл.* к.: **қабалау**. Белмим, ни арада сәрмәнеп алғандыр. – *минз.*

**СӘРМӘҮ** *минз., тпк., стрл.* к.: **қабалау**. Кергән уңайына сәрмәп кергән, син шуны сәрмисеңмени? – *минз.* Берәү батинканы сәрмәде дә чанага атты. – *стрл.*

**СӘРМҮСӘ** *стрл.* к.: **сәмбүсә**. Сәрмүсә иттән була, мал суйсак, шуны йасыйбыз бawырларыннан, эчәкләреннән.

**СӘРПИН** *хвл.* к.: **сәрәпин**.

**СӘРСӘК: сәрсәк қылану** *кргл.* к.: **абдырау 1**. Сәрсәк қылана бик.

**СӘРСӘН 1.** *минз.* к.: **қорамыш II, 1**. Минем малай алай сәрсән түгел; **2.** *минз., каз.ар.* саксыз, тәртипсез – кием кию турында (небрежно, неаккуратно). Безнең Әлфийә сәрсән кийә ул әйберне, берсен сала, берсен кийә шунда, барын да бертөсле итеп бетерә. – *минз.* Бигрәкләр дә сәрсән кийәсең инде күлмәгеңне, бу төшләрен қара, бөгәрләнеп беткән. Сәрсән кисәң, кийем тиз туза ул, йәмсез булып туза. – *мам.*

**СӘРСӘҢНӘҮ** *кргл.* кабалану, ашыгу (суетиться, торопиться). Сәрсәңнәп килеп керде бу безгә.

**сәрсәңнәгән кеше** *кргл.* к.: **қабаланчык**.

**СӘРТӘ** *туб.-ирт.д.* **1.** кыздырып аш өстенә салган май (поджаренный жир, которым заправлен суп); **2.** к.: **быт′ык**.

**СӘРТӘК** *себ.*, **СӘРТӘХ** [*фарс.*] *саз.я.* к.: **сәбес**. Сәртәк турап пылау бешереп туйларны атқардылар. – *тара.*

**СӘСБАУ** *тпк.* чәчүргеч (лента, заплетаемая в косу). Қартинәй даманында сәсбау суқлы-суқлы була торған ийе, эшлийә суғы кебек.

**СӘТ** [*гар.*] *мәл.* к.: **сәйәт**. Сәт сайын.

**СӘТӘҒӘМ** *туб.-ирт.д.* бик ерак, җәһәннәмдә (очень далеко, у чёрта на куличках). Ул сәтәгәмгә цыгып киткән, барып йетә алмас.

**СӘТӘП** *туб.-ирт.д.* сәдәп (пуговица).

**сәтәп үлән** *туб.-ирт.д.* к.: **бырцак: бырцак үләне**.

**СӘТӘШ** *злт.* к.: **гәтәч**. Таwық сәтәше. Сәтәш айыраң, берсе онота, мынсы ота, сәтәш дип қысқыра.

**СӘТЛӘWЕК** *злт.* к.: **чепчәги**.

**СӘТЛӘМӘСЕЗ** *дөб.* тиз көндә (в ближайшее время). Сәтләмәсез үлсәйе дип қаргады. Қайсы кеше сәтләмәсез үлә.

**сәтләмәсез итү** *дөб.* юкка чыгару, бетереп ташлау, эзен дә калдырмау (уничтожить, превратить в ничто, и следа не оставить). Сәтләмәсез итәрмен, қулыма тешсәң.

**СӘТЛӘМКӘЙ** [*гар.*] *срг.* к.: **сәгәтләмә**. Актай ак ызбаның эцләренә Сәтләмкәй элсәм, йәме бар (*хал. жыр.*).

**СӘТЛЕК** [*гар.* + *афф.* -лек] *чпр.* шунда ук, хәзер үк (тотчас же, сейчас же). Сәтлек әзәл тисен үзенә.

**сәтлек әҗәл тигере** *мәл., шрл., хвл., чст.*, **сәтлек эзелгере** *мәл.* сәгате белән үлгере – каргау сүзе (ругательное слово: подохнуть бы тебе сейчас).

**СӘТЛЕКСЕЗ** [*гар.* + *афф.* -лексез] *каз.ар.-крш.* к.: **сәтлек**. Сәтлексез Данила җанына җәшәқарты, бөтен awыл җыйылған.

**сәтлексез булу** *каз.ар.-крш.* тынсыз калу (замереть, замолкнуть).

**сәтлексез итү** *каз.ар.-крш.* тынсыз итү (сделать бездыханным).

**СӘТСЕЗ** [*гар.* + *афф.* -сез]: **сәтсез булу** *каз.ар.-крш.* юкка чыгу (исчезать, запропаститься). Сәтсез булды тамақсам.

**СӘТТӘ** [*гар.* + *афф.* -тә] *нгб.-крш., чст.-крш.* к.: **заман 1.** Җыр сәттә генә искә төшәмени ул? Ул сәттә китте бездән. Сәттә пешеп чыға ул. – *нгб.-крш.* Сәттә җырлап бирә икән, әйтеп күрсәтә икән радиудан. – *чст.-крш.*

**СӘҮЛЕМ** *эстр.* киленнең каенсеңлесенә эндәшү сүзе (слово-обращение снохи к золовке). Сәүлем, әйдә кизәккә барабыз.

**СӘҮР'АК** *кузн.* матур яшь ат (хорошая молодая лошадь).

**СӘҮРӘ** [*удм.*] *нокр.* каен тузыннан ясалган һәм катык, әйрән салып йөртә торган кечкенә чиләк (маленькое ведёрко из бересты для квашеного молока); чаг.: **сәwерә**. Бер сәүрә қатық йасадым.

**СӘҮРӘWЕК** *минз.* яңа шытып чыккан юкә (молодой росток липы).

**СӘҮРЕ** *глз.* к.: **сәүрә**. Әрйенне сәүрегә салып илтәсин кор тепкә, берсе кулыбызга сәүре тыта идек.

**СӘҮРЕК** *туб.-ирт.д.* яшүсмер кеше һәм хайван (подросток – о человеке и животных). Сәүреклəр дә керәләр туйда.

**СӘҮРИ** *минз.* к.: **қузақ: қузақ ағачы**.

**СӘФӘР** [*гар.*] *тмн.* к.: **кирмән**. Сәфәрдә торадыр бер улым, сәфәрдә үсте ундүрт йәшенә тике.

**СӘХИТӘ** [*гар.*] *трбс.* к.: **буйдымар**. Түшләрендә сәхитә, чәчендә чулпылар, камзул киделəр.

**СӘЧӘРӘ** *туб.-ирт.д.* шәҗәрә (родословная). Пуннан пунгаца сәчәрәне белəтегән ите. – *тара.*

**СЕБЕРӘК I** [*рус.*] *себ.* себер кешесе, Себердә яшәүче (сибиряк; человек, живущий в Сибири). Пес, себерәкләр, пилмин пешерәпес туйға.

**СЕБЕРӘК II** *чпр.* тастымал, сөлге (полотенце, салфетка).

**айак себерәге** *чпр.* к.: **себергец: айак себергец**.

**бит себерәге** *чпр.* к.: **битйаулық**.

**кул себерәге** *чпр.* кул сөрткеч тастымал (салфетка для вытирания рук). Кул себерәкләре дә ап-ак йуган була.

**чашкы себерәге** *чпр.* к.: **бистәр: чәй бистәре**. Айак себерегә – айак себерәге, бит себерегә – бит себерәге, чашкы себерегә – чашкы себерәге, селге-эскәтер булды өшәнцектә.

**СЕБЕРГЕН** *туб.-ирт.д.* җәяүле буран, җирдән себерә торган җил (позёмка).

**СЕБЕРГЕЦ** *чст.* к.: **себерәк II**.

**айак себергец** *чст.* аяк сөрткеч тастымал (маленькое полотенце для вытирания ног). Айак себергец, намазлык бирәләр кан'атага.

**СЕБЕРГЕЧ** *карс.* к.: **битйаулық**. Себергеч ван'е чүгә таккан.

**чынайак себергече** *шрл.* к.: **бистәр: чәй бистәре**.

**СЕБЕРКЕ** *миш.д., кмшл., перм., т.я.*, **СЕБЕР'Е** *кас.* тырма (борона). Себеркеләре, сукалары була. – *хвл.* Тимер себерке ағач себеркедән йахшырақ эшли, қантар қалдырмый. – *перм.* Безнең калхуччылар себеркегә киттеләр. – *к.т.* Агач себерке ийе. – *м.-кар.* Килен ат белән йер себерә тырган себеркене иткән дә мунчаның ишек тебендә калдырып кат'кан. Тимер себерке белән себердегийе бу җирне. – *чст.* Җирне ағач себерке белән себерәләр иде, хәзер тимер себерке белән. Себерке булмағач, чачақлы ағачны өстәрәтеп җәргәннәр тамыры белән. – *трх.* Себерке – ағач себерке, хәзерге себеркеләрдән зур, җегерме биш теш анарда була. – *нрл.* Себерделəр себер'елир белин, тимири ди була, а'ачы да. – *кас.*

**себерке себерү** *чпр.* к.: **себерү 1**. Мине себерке себерергә алып бара иде атай кырга.

**себерке тарысы** *эстр.* ашарга яраклы үлән орлыгы (зерно съедобного растения). Себерке тарысын қорытып, төйеп ашадық теге йылларда, ашарға йарақлы.

**СЕБЕРТКӘЙ: себертқәй күкәй** *перм.* к.: **йонно: йонно бәрәңге**.

**СЕБЕРТКЕ 1.** *минз., перм., бөре., трбс., тпк.* к.: **митла**; **2.** *м.-кар., себ.* к.: **себерке**. Себертке белән себерәләр, плуг белән сукалыйлар. Себертке белән себерәләр сукалагач. – *м.-кар.*; **3.** *тпк.* к.: **сүрәтмә**. Себертке тағып, оло агасны атқа тағып, себертеп сыққаннар, күмелгәне күмелгән, күмелмәгәне қарғаларға қалған.

**себертке себертқәле** *төм.* к.: **себерү 1**. Себертке себертқәле цығапыс, себертке белән йер себертәбес.

**СЕБЕРТКЕШ** *том.д.* к.: **себерке**.

**СЕБЕРТҮ** *минз., тпк., перм.* к.: **себерү 1**. Тырма артына чыбық тагалар, ансы тары себертер өчен. – *минз.* Бер генә қат себертке белән себерттек. Игенне сәскәс, элек себертқәннәр, хәдер кәтүкләйләр, оло ағасны тағып себертеп сыққаннар. – *тпк.* Җир себертә торған малай. – *перм.*

**СЕБЕРҮ 1.** *миш.д., перм., т.я., кас., себ.* җир тырмалау (бороновать). Җирне калхузныкын тырактыр себерә, бер утыз-қырыкны тага торғандыр, шәт, ә? – *трх.* Себергән артыннан да көп алма чыга әле. Сәнәк белә себерке себерү, керәк белә

йир басу, үгез белә диләңкә ташу – берсе дә калмады бит сугыш wакытында. – *чст.* Себерәләр 'ор себер'есе белин. – *кас.*; **2.** *миш.д., трх., кас., чпр.* сөртү (вытирать, стирать). Бит себерегә тастымал кайа? – *чпр.* Әней, цабуwыңа себермә, йаулыгың кайа? – *срг.* Бит себерегә салфит кирәг иде. Битегезне менә бу сөлгегә себерегез. Качан гына кат'ып салфитымны зилкәмә салып, битемне себерә-себерә чәй эчәрмен икән! – *чст.* Аның йыглауларын күргәч, йәшем себерәм бүркем белән. Ул да йәшләрен себерә үзенең йиңнәре берлән (*бор. жыр.*). – *тмн.* Чүпрәк бирегез әле тирләремне себерегә. – *шрл.* Йезлек китер битне себерегә. – *лмб.* Awызынны себер дә утыр. – *кас.*; **3.** *лмб.* сарган кортны җыеп алу (собирать привившийся рой пчёл).

**СЕБЕРЧЕК** *дөб.* чәберчек (тухлый, протухший).

**себерчек җомырқа** *дөб.* **1.** чәберчек йомырка (тухлое яйцо); **2.** к.: **ару 1: ару йоморқа**.

**СЕВӘЗ** [*рус.* связь] *тмн.* уртада коридор калдырып салынган алты почмаклы өй (шестистенный дом с коридором посередине).

**СЕВӘК** *миш.д.* сөяк (кость).

**думбырау севәге** *кузн.* умрау сөяге (ключица).

**үле севәк** *хвл.* к.: **сөйәк I: үле сөйәк**. Әткән сүземне тыңнамасаң, кыйнап үле севәгеңне сузармын. Икенче кен абид суны Үле севәгемне ызаттылар (*бәет.*).

**СЕВӘК-САЙАК** *м.-кар.* сөяк-саңак (кости, мослы). Севәгем-сайагым awырмый, баш awырта минем.

**СЕВӘЛБИ: севәлби сынны** *хвл.* тик кенә, эшсез (без никакого дела, ничего не делая). Севәлби сынны тыра.

**СЕВӘР** *хвл.* яраткан (любимый). Севәр сүзе аның шул.

**СЕWӘТӘ** *тпк.* к.: **куймалақ**. Бер сеwәтә қатық эсермәгән шул кеше.

**малирауный сеwәтә** *тпк.* кечкенә эмаль савыт (маленькая эмалированная мисочка).

**СЕWЕРТХЕ** *сазл.* себерке (веник).

**СЕВУ** *миш.д.* ярату, сөю (любить, предпочитать). Ул картүк севә бик. Фатиха атлы кызымны бик севә иде атасы. – *карс.* Мин лакша севә тешәм. Мин урман севүче. Севәләр дә, кайа да сүзем үтә. – *клд.* Үпмәк белә сөт ашарга севәмен. – *срг.* Атлар севә иде малайы. – *тмн.*

**СЕДИЛКА** [*рус.* седёлка] *тмн., лмб., кузн., чст.* к.: **сигелцә**.

**СЕЗГЕ** *нокр.* ияк (подбородок).

**СЕКӘРИ** [*рус.* сухари] *чст.-крш.* к.: **кәтермәс**. Пичкә йагып, секәри киптерә.

**СЕКЕРЕ** [*удм.*] *нокр., глз.* түгәрәк, бөтен – ипи турында (круглый, целый – о хлебе). Кейем белән баручылар қыз йақтан чепчеги алып баралар, қыз анасы гөбәдийә, таwық тутырып, бер секере быдай экмәк алып бара. – *нокр.* Бер секере ипине ашый ул бер утырғанда. – *глз.*

**секере икмәк** *глз.* түгәрәк икмәк (круглый хлеб). Йегет анасы бер секере икмәк белән бара, секере икмәкне кызның анасына бирә.

**СЕЛ** *тпк.* к.: **чел**. Wақ қына қош ул сел, убуркы беткәннән соң тары йаланнарына да төшәләр.

**СЕЛ'АГУЙ** *кузн.* сулагай (левша).

**СЕЛӘВЕС** *кас.* к.: **сылаwыщ**.

**СЕЛӘУ I** *лш.* **1.** җебегән, селәгәй (мямля, слюнтяй); чаг.: **пестелчек 2.** Мич астында беләү, аны белмәгән селәү (*табышмак*); **2.** к.: **алгай-салгай**; **3.** к.: **чели: чели күз**.

**СЕЛӘУ II** *тпк., каз.ар.*, **СЕЛӘҮКӘЙ** *злт.* **1.** суалчан (червь). Қайа, селәүкәй бир әле, балық тотам. – *злт.*; **2.** суалчан (глиста; глистный). Селәүләр йәри микән дим, чуқыр-чуқыр ийе эче. – *блт.*

**СЕЛӘҮЛӘНҮ** *дөб.* текәлеп, чекерәеп карау (впиваться глазами). Нәрсә селәүләнеп тырасын?

**СЕЛӘҮСӘН** *злт.*, **СЕЛӘҮЧӘН** *бөре., минз., кмшл.*, **СЕЛӘҮЧЕН** *бөре.* к.: **селәү II, 1.** Бәрәңге бақчасында селәүчән күп була. – *бөре.*

**селге** *нокр., чст.* сөлге (полотенце):

**селге алмаға келү** *нокр.* к.: **ақ III: аққа салу**. Селгалмаға йегет, йегет анасы тағы бер йақыны белән келәләр. Ул инде алып келә бер сум ақча парлы итеп. Қыз йағыннан қызыл башлы селге бирәләр.

**селге зийу** *чст.* сабан туе алдыннан сөлге җыю (обычай собирать полотенца для сабантуя). Кицкә хатлек зийалар селгеләр, күлйаулыклар зийалар ыйы әлеке. Йәш киленнәрдән селге зидылар.

**селге курасы** *чст.* сабан туенда сөлгеләрне бәйләп күтәреп йөрү өчен эзерләнгән таяк, колга (палка, жердь, куда привязывают собранные для сабантуя полотенца). Селге курасына бәйләп зийалар селгене.

**селге кытлату** *чст.* сабан туена сөлгеләрне җыеп бетергәннән соң, җыелган сөлгеләрне өй саен күрсәтеп йөрү (обычай ходить по всей деревне, показывая собранные для сабантуя полотенца). Селгеләрне кытлатып йөриләр күрсәтеп, күкәй бирәбез, акца бирәбез, күлйаулык бирәбез.

**селге палкасы** *чст.* к.: **селге курасы**. Таза кеше кирәк селге палкасын күтәреп йерүце, селгеләр күп зийыла.

**селге салу** *глз.* сөлге бүләк итү (подарить полотенце). Сабанту булдисә, йәш киленнәр үз нәселтамырларына селге салгаладылар, селге салма дип, чәй эчмә дип килгәләделәр.

**селге тайагы** *чст.* к.: **селге курасы**.

**селгегә кадау** *чст.* туйга алып барылган бүләкләрне сөлгегә кадап кую (прикалывание к полотенцу подарков, принесённых на свадьбу). Мин үзем генә дә йез күлмәк кадаганмын инде.

**СЕЛГЕБАШ** *глз.* к.: **битйаулық**. Зыбун кийеп, асалы селгебашлар белән беллерин бәйләп йөриләр.

**СЕЛДӘҮ** *миш.д.* **1.** к.: **быргыту**. Вата ыланнарны селдәп китәләсенме? Өч ай селдәгәнемә. – *хвл.* Берне селди, эчне ала. Катнын селдәгән. Выт мулла катнын селдәп йыртка кергән. – *чпр.* Биж йыл инде селдәгәнемә. – *срг.*; **2.** бик каты ачулану, орышу, кирәген бирү (сильно отругать); чаг.: **азарлау**. Селдәп ташлау. – *хвл.*

**СЕЛДЕРӘГӘН** *кргл.* к.: **ачыган**. Минем кебек селдерәгән қарт булған инде.

**СЕЛДЕРМӘКЛЕ: селдермәкле беләзек** *злт.* вак тәңкәләр тезеп эшләнгән беләзек (браслет с

подвесками из мелких монет). Селдермәкле белəзекляр была.

**СЕЛЕК I** *тпк.* к.: **шелек 1.** Селек сары сəскə ата, оло, эре булып үсмəй ул. Селекнең эрерəклярен сирем себерергə бəйлəйбез.

**СЕЛЕК II** *күрш., баст.*, **СЕЛЕ'** *кас.* к.: **битйаулык.** Мəген селек, себерегез. Селек алыр идем, белмəдем, инешкə тəке киляcен. – *күрш.* Селе' алып бирийем үзенə. – *кас.* Эчəр йезгə чике селекляр суқтық. – *баст.*

**селе' бирү** *кас.* к.: **сөлге: сөлге бирү.** Йараш'анда селе' бирилир 'оз йа'тан, алар инде 'итири 'үли'ме, ни дə булса 'итири.

**СЕЛЕКБИКƏ** *чст.* мифологиягə караган сүз: су анасына эндəшү (слово, относящееся к мифологии: обращение к водяной). Су анасы Селекбикə...

**СЕЛЕКҮ** *перм.* 1. к.: **селкү.** Самыwар селектегезме?; 2. к.: **азарлау.** Тəүпиқланып қайтсын дип, кеше балаларын селекмəсен дип сурыйм. Мə! Кеше балаларын селекмəсен, үз балаларын селексен.

**СЕЛЕН** *кас.* сеңел (младшая сестра).

**СЕЛКƏWEЦ** *байк.*, **СЕЛКEWEC** *тпк.* к.: **йулпуч.** Элек баланы селкewecтə асырағаннар хаттə, қəйнə қортқа сөйлəй торган ийе.

**СЕЛКЕНГЕЧ** *шрл.* к.: **атын.** Рəйсə белəн селкенгечтə селкенгəннəр дə, баш əлəнə, ди. Абыйсы алып киткəн ийе, селкенгечтə селкетəляр, дип.

**СЕЛКЕНЧƏК** *каз.ар.-крш.* сиртмəле җиңел арба (один из видов телеги). Селкенчəккə салғачтын, Акбүз атны җиктеляр (*хал. җыр.*).

**СЕЛКЕНЧЕК** *кузн.* к.: **йақлы.** Селкенчек, кылына выт.

**СЕЛКҮ** *перм., хвл.* кагу (трясти, вытряхивать). Күтəрмə башта самаwыр селкеп тора йкə. – *перм.*

**СЕЛПЕ** *к.т.* к.: **пəйеж.** Ашның селпесен җыйып ал.

**СЕЛТƏҮ** *миш.д.* к.: **быргыту.** Үне селтəп китəр хал' йук, мал-тywар булгач. Чыгып киткəн бит əле син симйа селтəп. – *мəл.* Энемне селтəдем дə килдем сезнең катка. Усадлар селтəп кайа китəсен. – *срг.*

**СЕЛ'ЫК** *лмб.* сөлек (пиявка).

**сел'ык йебəртү** *лмб.* сөлек салдыру (ставить пиявки). Сел'ык йебəрттем Хатимəдəн бун'ыма.

**СЕМƏЙТҮ** *злт.* кызык итү (поставить в смешное положение). Йəори белмəгəн йегетляpне семəйтəляр.

**СЕМƏЙҮ** *бөре., бгрс.* моңаю, боегу (унывать, печалиться); чаг.: **какайу.** Семəйешеп кире қайттылар. – *бгрс.*

**СЕМƏК I** *туб.-ирт.д.* кендек, чəй (стержень, клин, шкворень).

**СЕМƏК II** *туб.-ирт.д.* к.: **сəмək.** Цайны семəгеннəн ағыс. – *тбл.*

**СЕМƏН** *минз., мəл.* боз вату коралы, ломның бер төре (лом для скалывания льда).

**СЕМЕ I** *туб.-ирт.д.* тиреслек, тирес өеме (навозная куча).

**СЕМЕ II** *туб.-ирт.д.* саз белəн уратылган яки күл тирəсендəге коры җирляр (небольшие участки суши среди болота или около озера). Семетə алацык йасаптылар. – *тбл.* Пес алтта цығайық, оллы күл семетəн атлайық. – *төм.*

**СЕМЕЛЕК** *эчк.* к.: **сазамақ.** Ул күлгə кереп булмый, семелек.

**СЕМЕРҮ** *том.д.* сөзү (процеживать).

**СЕМКЕРЕК** *туб.-ирт.д.* маңка (сопли).

**СЕМКЕРҮ** *туб.-ирт.д.* сеңгерү (сморкаться).

**СЕН: сен қату** *т.я., каз.ар.* 1. сын кату, сулыш ала алмаслык булу (остолбенеть). Баласы сене қатқанча жылаган. Жəш баланың хəзер сене қата анын. – *к.т.*; 2. эч күбү (вздуться – о животе). Қарбозны күп ашадым – сенем қатты, сулыш та ала алмыйм. Соло кесəле бик тиз сенне қатыра. – *к.т.*; 3. к.: **бағана I: тоз бағана булып қату.** Сенең қатса да, сереңне бирмə (*мəкаль*). – *лш.* Ул хəбəрне ишетеп сенем қатты инде. Күрсəң, сенең қатар. – *дөб.*

**СЕҢДЕР'ЕС** *кас.* к.: **қортқоч.**

**СЕННЕ** *туб.-ирт.д.* шикелле (как – послелог). Син сенне сылу бер қатынга йабышып цыққан.

**СЕҢ: сең түү** *перм.* к.: **сеңер II: сеңер түү.** Эй балақайым, сең теүгəн бит сийə.

**СЕҢƏЛ I** *лмб., кузн., хвл., срг., чпр., карс., мəл., клд.* сыек (жидкий; жидко). Сете сеңəл, диляр. – *карс.* Картуп сеңəл, тəмне тегел. Сетляшең сеңəл булган. Сеңəл йасама, куйы йаса. Сеңəлдерəк эцəм цəйне. – *срг.* Камырың бик сеңəл булган. – *хвл.* Йаса сеңəл генəне анарга (чəй турында). – *кузн.* Сеңəл булмаганмы аш? – *лмб.*

**СЕҢƏЛ II** *лмб.* сирəк – тукыма турында (редкий – о ткани). Үлемнеккə сеңəл генə суга булганнар.

**СЕҢƏЛЛƏНҮ** *лмб., хвл., кузн.* сыегаю, сыекланy (разжижаться). Пешə-пешүк сеңəлляняедер кесəл. – *лмб.*

**СЕҢƏЛҮ: баш сеңəлү** *срг.* зиһен таралу (стать рассеянным – о человеке). Синең башың сеңəлгəн инде күп укып.

**СЕҢƏРТҮ** *чпр.* тарату, таркату (разогнать, рассеивать). Сузыңкы былыт бу, сеңəртеп йебəрсə генə.

**СЕҢГƏК** *эчк.*, **СЕҢГƏКЛЕК** *чст.* к.: **баткылык.**

**СЕҢГƏЛƏК I** *злт.* к.: **баткылык.** Сеңгəлəкнең төбе быламы? Сеңгəлəк былды микəн, тирəн былды микəн?

**СЕҢГƏЛƏК II** *туб.-ирт.д.* инə карагы (стрекоза).

**СЕҢГƏЛЦЕК** *срг.*, **СЕҢГƏЛЧЕК** *чет., шрл.* к.: **баткылык.**

**СЕҢГЕЛДƏК** *срг.* к.: **җиңгеле.**

**СЕҢГЕР 1.** *минз., т.я.* к.: **будырма.** Тота микəн моның сеңгере? – *нрл.* Сүтəргə дə сеңгер тағарға кирəк. Йəшляр хəзер сеңгер генə кийəляр. – *минз.*; 2. *минз.* к.: **җуйғыч.** Əни, магазинга сеңгер қайтқан, алыйқ эле.

**СЕҢГЕРТКƏ** *тпк.* к.: **чигеркə.**

**СЕҢЕЛ** *лмб.* к.: **сеңəл I.** Аш сеңел тегелме? Йаңы бал сеңел була. Аш сеңел булган.

**СЕҢЕЛЦƏК** *том.д.* таган (качели).

**СЕҢЕЛҢЕК** *срг.* к.: **баткылык.**

**СЕҢЕР I 1.** *мəл., срг., чст., байк., перм., бөре.* к.:

**будырма**. Ыйык сеңерләрем бушаган, тытмыйлар. Харап иттем сеңерен, кисәм дип ойык балтырын кистем. – *мәл.* Сеңерләрен эзләмәдеме, эзләсә, цылкалары белән куйдым. – *срг.* Сеңер начар, тар сеңер генә, айакны кыса шулкадәре. – *чст.*; **2.** *чст.* метрлы тар резинка (метровая узкая резинка). Ылавкадан сеңер сатыб алдым күлмәк билдәмәсенә куйарга; **3.** *перм., клд.* резин (резиновый). Машинаның сеңер тәгәрмәчен йаққаннар. Туп хәзерге кебек сеңер туп түгел ийе. – *перм.* Сеңер итек кийеп барабыз, йылан күп. – *клд.*; **4.** *чст.* к.: **җуйғыч**. Йаңылыш йазыб йебәрдем, бетерегә сеңер кирәг иде; **5.** *перм.* нечкә резина көпшә (тонкая резиновая трубка). Сеңер йотқанда ишшу awыртыр (ашказаны).

**сеңер итек** *мәл.* резина итек (резиновые сапоги).

**сеңер II** (сухожилие):

**колак сеңере** *м.-кар.* колак пәрдәсе (барабанная перепонка). Колак сеңере эзелгәндер.

**сеңер түү** *перм.* кан төшү (припухать, затекать от непривычной физической нагрузки – о мускулах ). Урағ урғанда қулға түwә торған ийе сеңер, шәб эшләудән. Сеңер түүгә бернәмә дә кәрәкми, ywарға да ywарға ти аны. Күп җөрсәң, айаққа түwә сеңер.

**СЕҢЕРДӘҮ** *перм.* катылану (делаться твёрдым, жёстким). Қайнасын әле, картуп сеңердәп китә тоз салгас, тоз қатырып китә. Пешә башлағас салсаң тозно, сеңердәми. Идән аста сеңердәп йатқан картуп.

**СЕҢЕРҮ I** *чпр.* к.: **сеңәлләнү**. Синең кан сеңерә башлады бугай.

**СЕҢЕРҮ II** *т.кам.-крш.* куу (гонять, отгонять). Берсен-берсе сеңерә инде чабата белән, төннөкләр алып мучадан сеңерәләр, қырау қуwалар.

**СЕПЕЛДЕК: сепелдек башмак** *чст.* артсыз башмак (шлёпанцы). Сепелдек башмакны йалан айакка кийеп урамга чыккан.

**СЕПЕРҮ** *перм.* к.: **сыптыру 5**.

**СЕПЛӘҮ** *брб.д.* ямау, тегү (латать, шить). Қапларны сепләтеп алу гәрәк.

**СЕПТЕ** *саз.я.* керле, пычрак (грязно; грязный). Ник күсеңне уасың септе қулын пән.

**СЕПТЕК I** *злт.* сидек (моча).

**СЕПТЕК II** *туб.-ирт.д.* к.: **қый III**.

**СЕПТЕХ** *саз.я.* пычрак (грязь). Септех йер.

**СЕРӘЙҮ 1.** *перм.* калку, чыгу, барлыкка килү (появиться, вскочить). – Арпа ул чыға серәйеп кенә. – Серәйеп? – Мә! Астыннан чыгып килә қый шешеп; **2.** *кргл., туб.-ирт.д.* тырпаю, калкып тору (торчать). Чап, чап, бер серәйеп торған үлән дә қалмасын. – *кргл.* Қоры ағаң серәйеп утыра. – *тбл.*; **3.** *бгрс.* япа-ялгыз калу (остаться совсем одиноким). Серәйдем дә йалғыз үзем қайттым, кетү йуқ бит инде.

**күс серәйү** *туб.-ирт.д.* күз акаю (таращиться – о глазах). Әнә күсе серәйеп утыра, сураң, ник алай қыланат. – *төм.*

**СЕРӘК** [*удм.*] *глз., нокр.* к.: **чатлық 2**. Без белдектә бу серәктә экей бар иде. Бер серәккә боролсаң, қаршыга алар. – *нокр.*

**СЕРӘҢКЕ** [*рус.*] *себ.* к.: **сызғыч**.

**серәңке қап** *себ.* шырпы кабы (спичечная коробка).

**серәңке қумты** *тара.* к.: **серәңке қап**.

**СЕРГӘ I** *себ.* серкә (гнида).

**СЕРГӘ II** *себ.* аш серкәсе (уксус).

**СЕРГӘЛӘҮ** *кргл.* сыткылау (покрываться прыщами, угрями). Арқаларым сергәләп беткән эсседән.

**СЕРГӘТӘЙ** *туб.-ирт.д.* үпкәчән (обидчивый).

**СЕРГЕЛТӘҮ** *тбл.* тетрәү, калтырау (дрожать, трепетать). Йөрәк сергелтәйте.

**СЕРДЕ** *байк.* к.: **меле**.

**СЕРЕ** *перм.* **1.** к.: **арқыры 2**. Ул сүзеннән чыкмый, сере ул. Шундый сере, киссәң дә қаны чыкмый; **2.** к.: **зыт**. Сере кешенең awызыннан сүз алып булмый.

**СЕРЕК** *глз., нокр.* к.: **қурдақ**. Ат майын эреткәч, сереге қала. – *нокр.*

**СЕРЕМ I** *кас.* ис (угар). Серем тимисен. – *кас.*

**СЕРЕМ II: сереме кыйылу** *шрл.* сөмсере коелу (стать мрачным, помрачнеть; хмуриться). Сереме кыйылып кайтып керде малый.

**СЕРЕН** *глз.* к.: **серем I**. Серен чыкты ийгә самраудан. Серен тиде мичада, усал awырткалады башым.

**СЕРЕНҖЕГӘН** *бөре.* әлсерәгән, мәлҗерәгән (измотанный, дряхлый). Шул серенҗегән қартны өстерәп йөртмә инде.

**СЕРКӘ I** *әстр.* печтерелгән кәҗә тәкәсе (кастрированный козёл).

**серкә II** (пыльца):

**серкәле балцық** *эчк.* к.: **мәте I, 2**. Серкәле балцық дан, диләр, мәтел балцық йарыла ул.

**СЕРКӘЙ** *к.-уф.* к.: **йомоқ**. Җәйгедә серкәйләр исәңгерәтә, кичкедә күп чыға серкәйләр.

**СЕРКӘЛӘҢУ** *чст.-крш., перм.* эчемлекнең озак торудан айнып, өстенә ак бөрчекләр чыгып бозылуы турында (выдохнуться, испортиться – о напитке). И ал, диләр, ал, диләр, Безнең кодаларны да бай, диләр; Сәке астында сигез мичкә Серкәләнгән баллары бар, диләр (*хал. җыр.*). – *чст.-крш.*

**СЕРКӘТАРАҚ** *перм.* к.: **көйәләк**.

**СЕРЛӘWЕХ** *туб.-ирт.д.* тетрәү (дрожь).

**СЕРЛӘҮ** *туб.-ирт.д.* к.: **сергелтәү**. Қуллар, йөрәкләр моныңқы серләп китәте ачуына түсмәй.

**СЕРМИ-СЕРМИ** *срг.* к.: **бармак I: урта тийәк**.

**СЕРТЕК-БЕРТЕК** *дөб.* к.: **ара-тура 2**. Бик сертек-бертек быйыл алма. Ашлық сертек-бертек.

**СЕРТЛӘWЕК** *тпк.* к.: **чеки**.

**СЕРТҮ 1.** *тмн.* майлау (мазать). Сөртмәгән арба кебек шыгырдый; **2.** *клд.* к.: **сырлау I, 1**. Кыраска серттек тә, куба башлады.

**СЕРҮ** *глз.* к.: **кәперән**. Тышы да йанган, серүсе дә йанган мындарның.

**СЕРХЕЛТӘҮ** *саз.я.* тиз кызып китү (вспылить). Ицмә әйтхәле йарамайт, серхелтәйт тә хитәт.

**СЕРЧЕК** *дөб.* к.: **черчек I**.

**СЕТӘКЛЕ** *т.я.-крш.* **1.** к.: **зимне**. Үдә басқан тоқмач сетәкле була; **2.** туклыклы (сытный, питательный). Сетәкле у, бүксәләре тулган, кайа ашасын у.

**СЕТЕСТЕСЕ** *глз.* каймак (сметана). Сетестесе белән чәй эчмә киләләр кайбан чыгарган көнне.

**СЕТКЕЛЕК** *кузн., хвл.* к.: **баткылык**. Сеткелеккә атлар баталар. – *хвл.*

**СЕТЛӘЧ** *лмб.*, **СЕТЛӘШ** *срг.* тары, дөге һ.б. төрле ярмадан сөткә пешерелгән өйрә (молочный крупяной суп). Сетләч пешереп куйалар йоморкалыны шунда. – *лмб.*

**СЕТЛҮК** *чст.* к.: **сөтлут**.

**СЕҮЛЕК** *перм.* к.: **сел'ык**.

**сеүлек утыру** *перм.* сөлек кадалу (впиваться – о пиявке). Сеүлек әле ул утырмый да йаматай қанға.

**СИБАЙ** [*рус.* сивый]: **сибай ат** *лмб.* күк төстәге ат (сивая лошадь). Әтийемнең сибай аты, Баскан сайын кистенә (*хал. җыр.*).

**СИБӘРЛЕК** *әстр.* туйда сибеләсе тәңкәле акчалар (монеты, которые должны быть рассыпаны во время свадьбы). «Бу синең сибәрлегең» дип, туйға өндәүчеләргә дә акчалар бирәләр.

**СИБЕЛЕШҮ** *срг.* к.: **тетелү 1**. Туй беткәч, сибелешәләр кунаклар.

**СИБЕЛҮ** *кузн.* к.: **тетелү 1**. Сибелегез ашарга пешерегә.

**СИБҮ** *тмн., чпр., кузн.* тарату (растаскать, рассеять). Атасыннан калган йыртны сипкәнгә үкенер әле. – *тмн.* Аларны терле awылга сиптеләр. Безне кырга сибәләр. – *чпр.*

**СИГӘРСИН** *к.-уф.* карагай (лиственница). Сигәрсин ағас – қаты ағас.

**СИГЕЗАЙАҚ** *каз.ар.*, **СИГЕЗАЙАК** *чст., хвл.* к.: **җүwешмән**. Сигезайақ дымлы урында җарала. Сигезайақ диләр аны, айағы ишлегә күрә. – *дөб.* Хазер бит, бәбкәм, сигезайак бетте. – *чст.*

**СИГЕЗЛИН** *перм.* к.: **селәү 1**.

**СИГЕЛЦӘ** [*рус.* седёлка], **СИГЕЛЧӘ** *чст., чпр.* к.: **иңелчәк**. Ат акцасына дилбегә, сигелцә алып кат'ам. – *чст.* Аты бар, сигелцә ат аранында тыра, дир. – *чпр.*

**СИДЕЛ'ЧА** *чст.*, **СИДЕЛЧӘ** [*рус.* седёлка] *мәл., хвл.* к.: **иңелчәк**.

**СИД(Е)РӘҮ** *чст., хвл.* сизерәү, тузу (изнашиваться, износиться).

**СИДЕРҮ** *перм.* к.: **каклау**. Беләкләремне сидереп җыйды кечерткин, җана инде беләкләр.

**СИДИЛЧА** *мәл., хвл.* к.: **иңелчәк**.

**СИДУЛКА** [*рус.* седёлка] *срг.* к.: **сигелцә**.

**СИЗИК** *туб.-ирт.д.* яшь бозау тиресеннән ясалган күн (опоек: кожа из шкуры молодого телёнка).

**СИЙАУ** *чст., лмб., чпр.* шөшле (кочедык). Лашманда бит шөшлене сийау диләр. – *чст.* Сийау мынан туги чабатаны, әрәләр, кас'ын биштән. – *лмб.* Йукагацтан сийау был'ан тугилар цабатаны, кәркеш был'ан бәләп куйалар. – *чпр.*

**СИЙӘК** *минз.* к.: **айақ III**. Җитен сийәген ашадылар ачлық йылларны.

**СИЙӘК-САНДРАҚ** *кмшл.* к.: **матамал**. Бетен сийәк-сандрақны үзеңә җыйасың да үзең бәлә эзлисең.

**СИЙЕРЕЛҮ 1.** *перм.* сүрелү (затухать). Ут сийерелсен әле азырақ. Ут сийерелгәч қарыйбыз... абышқасы йуқ; **2.** *т.я.-крш.* таралу (расходиться). Теннек кырыйын җабыгыз, Ишек кырыйын ачыгыз; Кара халык, сийерелегез, Мина ирек бирегез (*хал. җыр.*).

**СИЙЕРТЛЕ** *перм., трх.* к.: **бирук**.

**СИЙЕРТМӘ** *каз.ар.-крш.* к.: **силә 1**. Сийертмәне миләш ағачыннан җасыйлар.

**СИЙПАЛАНУ** *перм.*, **СИЙПАНУ** *байк.* к.: **кабалану**. Сийпаланып тордом да айақ очлый бастым. Иликтыр сүнеп китә дә сийпанып йөрергә қала, төнне ут булмаса, сийпанып йөрисең.

**СИЙРУ** *срг.* сыдыру, сую (поцарапать, ссадить). Матасикылдан йыгылып, йөзен ап-ару сийрган Муса.

**СИЙҮ** *брб.д.* к.: **каклау**.

**СИКАС: сикас сугу** *мам.* к.: **сике II: сике арасы суғу**. Сикас суғу ди торған ыйық, киндер күлмәк кидек үзебез суғып.

**СИКӘ** *перм.* чаршын, бал корты икмәге (хлебина). Сикәле кәрәзләр була, ашарга тәмсез, ну файдалы тиләр. Моноң сикәләре файдалы, сапсары, бала туйдыралар шуның беле.

**СИКӘНҮ** *злт.* к.: **ирәнү**. Сикәнә қайбер кеше, шуңа қулымны тықмый торам.

**СИКӘРТМӘ** *трбс.* сикәлтә (ухаб, выбоина, яма). Нинди сикәртмәләрдән үткән.

**СИКЕ I** *блт., мам., минз., бөре.* сәке (нары).

**буй сике** *бөре.* стена буена түшәлгән тар сәке (скамья, узкие нары вдоль стены).

**СИКЕ II** *мам.* киндер сугу станы, киндер урыны (ткацкий стан).

**сике арасы суғу** *мам.* киндер сугу (ткать холст). Элек сике ийе, өй кечкенә ийе бит, шуңа, сике арасы суғабыз дип, сике арасына қороп суғалар ыйы.

**сике асты озату** *мам.* киләп сару (сновать).

**сике асты суғу** *мам.* к.: **сике арасы суғу**. Сике асты суғучылар күб иде бездә.

**СИКЕЗ** *кузн., тмн.* сигез (восемь). Без йидесикез йыл укыган инде. – *кузн.*

**СИКЕРЕК** *туб.-ирт.д.* тиктормас, кыбырсык (попрыгун, егоза, непоседливый). Минем палам сикерек пулатығын.

**СИКЕРТЕН** [*рус.* секретно] *к.-уф.* яшертен, серле рәвештә (тайно, секретно). Алар бигрәк сикертен эшлиләр эшне.

**СИКЕРТКӘ** *т.кам.-крш., каз.ар.* к.: **чигеркә**. Сезгә күрсәтергә дип сикерткә тотып қайтқан басудан. – *мам.*

**СИКЕРТМӘ I 1.** *т.я., минз.* к.: **силә 1**. Әүwәл мәләш ағачыннан йасыйлар ыйы сикертмәне. – *трх.* Түбә тақтағамы, матчағамы алқа таққаннар, шул алқаға нәзек сәленә торған сикертмә таққаннар. Озон ағачтан сикертмә киртләп бишек асалар. – *нрл.* Сикертмә белән селкеткән бишекне, миләш куйалар күбрәк, озын була, сыгылып тора миләш агачы. – *т.я.-крш.* Ағач сикертмә йасап қуйалар бәллүгә. – *минз.*; **2.** *чпр.* бишек пружинасы (пружина детской люльки). Бишекнең сикертмәсе өзелгән.

**СИКЕРТМӘ II** *каз.ар., туб.-ирт.д.* сикәлтә (ухаб). Қақлықма йул циттә булаты, сикертмә йул өстөтә. – *тбл.* Сикертмәдә мәтәлеп қалдым. – *блт.*

**СИКЕРТМӘ III** *туб.-ирт.д.* сикерү басмасы (трамплин).

**СИКЕРТМӘЛЕ** *т.кам.-крш.* кулдан сугылган киндер (домотканый холст). Киндер сүсеннән си-

кертмәле суғадыр ыйық. Үзем суққан сикертмәле бар.

**СИКЕРТҮ: шобаға сикертү** *каз.ар.* шобага салу (метать жребий). Печәнне шобаға сикертеп бүләләр ийе. – *лш.* Шобаға сикертәбезме, кемгә чыға, шуңа була. – *мам.*

**СИКЕРТХЕ** *саз.я.*, **СИКЕРТЧӘ** *мам.* к.: **чигеркә**. Сикертчә чер-чер килә.

**СИКСӘНҮ** *брб.д.* сискәнү (вздрогнуть от испуга).

**СИЛ: кеше айағы сил булу** *каз.ар., кргл.* аяк тавышы тыну, хәрәкәт тукталу, тыныч лык урнашу (затихнуть – о шагах, о прекращении ходьбы). Кеше айағы сил булғач, кеше җирүдән туқтағач, им итәсе кеше үзе барасы урынға барып қайта. – *блт.* Кеше айағы сил былғач, һәммә кеше йоқлап бетә бит сәғәт өчләрдә. – *кргл.*

**СИЛАНУ** *лмб.* к.: **аулагаш**. Әни, майым, силанырга барабыз, йибәрә күр, дийр.

**СИЛӘ 1.** *каз.ар., минз.* бишек элә торган агач колга яки тимер пружина (деревянный шест, журавль или пружина, с помощью которых подвешивают люльку к потолку); чаг.: **дайа; сикертмә**. Хәзер агач силә әлмиләр инде. – *мам.* Элек агач силәләр була иде, хәдер пыружиналы силәләр. – *минз.*; **2.** *минз.* арбаның арт күчәрен күкрәге белән тоташтыра торган агач (тонкое бревно, которым соединяют заднюю ось телеги с подушкой передней оси).

**СИЛӘЗӘН** [*рус.* селезень] *злт., срг.* ата үрдәк (селезень).

**силәзән йөрү** *срг.* туйда махсус җырларны җырлап йөрү (петь на свадьбе специальные обрядовые песни). Күпме йөрдем үмеремдә силәзән, йырлары онытыла. Кем йахшы йырли, шул йөри силәзән.

**СИЛӘК** *злт., тпк.* **1.** к.: **чиләк I, 1**. Ағас силәк була, суға да, сийыр да сауғаннар. – *тпк.*; **2.** к.: **ләнгәц**. Әпәй идә торған күнәкне дә силәк тип әйтәләр. – *тпк.*

**СИЛӘҮ** *туб.-ирт.д.* сирәгәю (редеть).

**СИЛВӘРӘ** *срг.* хатын-кызлар кия торган озын балаклы ыштан (длинные женские шаровары). Тиңгекәйләр бертөрле силвәрә кийәләр иде.

**СИЛГӘҮ** *туб.-ирт.д.* **1.** сүрән булу (быть плохо пропечённым – о хлебе); **2.** суыну (остывать). Мич силгәп китте.

**СИЛДЕРҮ** *эчк.* сизерәү (протереться, напр., о платье). Күләгем силдерәгән инде.

**СИЛЕНЦӘ** [*рус.* сеяльница] *эчк.* к.: **илгәк**.

**СИЛ'ЛЫК** [*рус.* сенник] *шрл.* к.: **чиннек I, 1**. Сил'лык аталар тизәк куйа тырган җиргә бездә.

**СИЛНЕК** [*рус.* сенник] **1.** *срг.* тегермәндә капчыклар куя торган урын (место для хранения мешков на мельнице); **2.** *хвл.* к.: **чиннек I, 1**.

**СИЛ'НИК** [*рус.* сенник] *стрл.* к.: **чиннек I, 1**. Сил'никтә арбалар, чаналар, атлар тора, такта капкалы. Сил'ник такта капкалы була, анда буралар йасыйлар ыйы.

**СИЛНИЦӘ** [*рус.* сеяльница] *туб.-ирт.д.* к.: **йулпуч**.

**СИЛНИЧӘ** [*рус.*] *туб.-ирт.д.* зур чүлмәк (корчага).

**СИЛ'НЫК** [*рус.* сенник] *хвл.* к.: **чиннек I, 1**.

**СИЛТЕР** *туб.-ирт.д.* иләк шикелле сирәк әйбер (редкий, как сито – вещь, ткань, снег и др.).

**СИЛФЕРҮ** *бәр.* к.: **икеләнү**. Силфергән ул хәзер, үзем дә силфермәгәйем дип қурқам.

**СИЛ'ЫНЧА** [*рус.* сенница] *кузн.* ындырда башак һәм кибәк сала торган урын, әрбәлек (закрытое место на гумне для хранения мякины). Сил'ынчабызга тийәгән винекләре.

**СИМАЛАНУ** *том.д.* кармалау (ощупывать, общаривать).

**СИМӘ I** [*рус.* семянка] *глз.* **к.: чемечки 1**. Симә бирегез ылыннарга, симә ашасыннар.

**СИМӘ II: симә қабырға** *туб.-ирт.д.* кыска кабыргалар (ложные рёбра).

**СИМӘЛӘК** *туб.-ирт.д.* **1.** бик кечкенә эт (порода мелких собак). Симәләк шигелле өрәте, иц әш цығара алмайты; **2.** овчарка (эт).

**СИМӘЛӘХ** *саз.я.* бүлмә эте (болонка).

**СИМӘН** *минз., мәл.* к.: **семән**.

**СИМӘНӘ** [*рус.* семена]: **симәнә алды** *дөб.* яз көне уздырыла торган яшьләр уены (весенние игрища молодёжи). Май сисласында йегетләр, қызлар урманга бардылар, түгәрәк әйләнделәр. Чәмәч урманы астында киң болын, шунда уйнашалар ыйы кисләрен дә, көндез дә. Шымырт сәчәг атқан wақытта була ул симәнә алды.

**СИМӘНКЕ** [*рус.* семянка] *каз.ар., т.я.*, **СИМӘҢКЕ** *т.я.* к.: **айбагар**. Симәнке чәчәг атқан. – *дөб.* Симәңке май бармы? – *трх.*

**симез** (жирный):

**симез гөл** *мәл.* к.: **бақа: бақа гөле**.

**СИМЕЗӘЙҮ** *м.-кар.* симерү (ожиреть).

**СИМЕК** [*рус.* семик] *крш.* **1.** керәшен татарларының җәйге бәйрәме (летний праздник у крещёных татар). Паскыдан сун җиде атна қала ул симек, зиратқа менәләр җыйылып. Иртәгесен симек болынына киләләр, симек болынында җырлыйлар. Симек тройсыннан бер атна алдан була, симек көнне қайын башын төйнәргә барадырыйық. – *каз.ар.-крш.* Симек көнне җегетләр белән ун'идырыйык әйләнеп, қайын башын бәйлидерийек, тасмалар, асылырак җаулыклар инде. – *чст.-крш.*; **2.** *т.кам.-крш.* христиан дине йоласы буенча үлгән кешеләрне искә алу көне (семик, день поминовения усопших). Симек ул – зиратка бара торган көн, тыруйсын паминкасы ул симек. Симектә зиратка барабыз.

**СИМЕРҮ** *брб.д.* суыру, суырып алу (всасывать).

**СИМЕЧКЕ** *минз., стрл.*, **СИМЕШКА** *байк.*, **СИМЕШКЕ, СИМИЧКЕ** *минз., стрл.*, **СИМЫЧКА** [*рус.* семечки] *карс.* к.: **айбагар**.

**СИНӘК I** *туб.-ирт.д.* сәнәк (вилы).

**синәк пот** *туб.-ирт.д.* сәнәк чаты (развилина). Синәк пот айырылып цықты ғуй.

**СИНӘК II** [*рус.*] *том.д.* өйалды (сени). Үзем синәк йасап қуйдым өйгә.

**СИНӘП** *карс.* сентябрь. Аугыс бетә, синәптә барып чыгаралар (мунчаланы).

**СИНӘХ** *саз.я.* к.: **синәк I**. Өц тешле синәх.

**СИНДЕК** [*рус.* сенник] *злт., тпк., мәл., чст.* [*рус.* сенник] к.: **чиннек I, 1**. Буш синдеккә салдык печәнне. – *чст.*

**СИНДЕКЛӘНҮ** *дөб.* к.: **киберләнү**. Җаратмыйм да инде шулай синдекләнгән кешене.

**СИНЕ** (*-м, -ң, -зе*) *том.д.* хатынның яки ирнең сеңлесе (младшая сестра мужа или жены).

**СИНЕЛ** *минз.* к.: **албуй: албуй саты 1**. Синел ағачын әйтәсезме сез? Синел ағачы дәп-дәңгәр чәчәк ата.

**СИНИЛ'** [*рус.* сирень] *минз., стрл.* к.: **кәләмпер.**

**СИННӘТЛӘҮ** *төм.* зиннәтләү, бизәү (нарядить, украсить). «Синнәтләргә тейеш»,– тип әйтәте. Муйын түмәләре, алҡалар ала икән кейәү, хуш күрү була икән.

**СИННЕК** [*рус.* сенник] *каз.ар., тпк., чст.* к.: **пайыт 1**. Монда синнекләр ийе, хәзер сүтеп алдылар. – *лш.*

**СИНТЕКЛӘНҮ** *дөб.* к.: **ирәйү 1**. Синтекләнү генә инде ул, рәхәткә чыдый алмый.

**СИНТӘП** *мәл.* сентябрь. Быйыл синтәптә була ураза. – *мәл.*

**СИНҮ 1**. *туб.-ирт.д.* шиңү, кибү (вянуть, сохнуть). Име синеп петер. – *твр.*; **2**. *брб.д.* кимү (уменьшаться).

**СИҢГИР** *туб.-ирт.д.* сеңер (сухожилие).

**СИҢЕР 1**. *саз.я.* борын (мыс). Сауысҡан сиңер. Ҡосыҡ сиңер; **2**. *туб.-ирт.д.* тау итәге, үр (предгорье, холм).

**СИҢНЕ** *брб.д.* сеңел (младшая сестра). Пир сиңнең пар, аны моңа пәрәрмезең?

**СИП I** *перм.* шифа, файда (сила исцеления, целительное свойство). Телнең сибе бетә, имеш, дарым өшкереп йөрсәң.

**СИП II** *туб.-ирт.д.* бирнә (приданое). Ҡыс йаҡтан кейәү йаҡҡа кешегә килгән нәрсә сип пулаты. Ул ҡыс бай икән, сибе күп икән. Сипкә өләшәтләр йаулыҡлар. – *төм.*

**СИПЕЙ** *к.-уф.* чеби (цыплёнок). Сипейне ҡарға алған.

**СИПЛЕ I** *перм.* шифалы, файдалы (целительный, приносящий пользу). Уҡымышлы кеше өшкеренсә, файдасы килсә, теле сипле, диләр.

**СИПЛЕ II** *кас.* к.: **атына 5**. Синең сипле 'ени бардым. Синең сипле 'ени ҙырладым.

**СИПЛЕКЛЕ** *каз.ар.* к.: **сипле I**. Өшкергән сиплекле булды. – *дөб.*

**СИПУН** [*рус.*] *срг.* чөелдерек (супонь). Элек алашалар белән алып баралар кызны, кыз алашасын тикшерәләр, сипунмы йебәрелә, тугарыламы, йә алаша туктаса, айырыла.

**СИРА** *срг.* к.: **арый**. Мәскәүгә быйыл дүрт сира бардым. Йке сира керде йәшәргә. Эҫ сира бал каптыра. Йылға бер-йке сира барабыз, итергә кирәк бит. Йке сира барып дустыган белә су эҫтем. Эҫ сира эҫ салган. Бер сира малай белән тутырабыз казы.

**СИРАТ: сират күпер** *саз.я.* к.: **дуға: күк дугасы**.

**СИРӘ I** *срг.* к.: **арый**. Йке сирә килделәр инештән ҡазлар.

**СИРӘ II** *туб.-ирт.д.* к.: **аҡбаш**.

**СИРӘЙҮ** *трбс.* к.: **сирелү I**. Ҡортлар бик күб ийе, әле әҙәйде, сирәйде.

**СИРӘК** [*удм.*] *глз.* **1**. к.: **чатлық 2**. Аларның ийләре сирәктә. Монау сирәктә бер әнем тыра; **2**. к.: **мийеш**. Ий сирәккә йабыша иде инде йангын, сүндерделәр. Мин сирәктә генә утырдым; **3**. як, кырый (сторона, край). Зиратның бу йаҡ сирәгендә ҡәберләре бар.

**СИРӘКЛӘП** *трбс., бөре.*, **СИРӘК-ПЫРАК** *клд.*, **СИРӘК-САЙАҠ** *трбс.*, **СИРӘК-СОРАҠ** *т.я.* к.: **ара-тура 1**. Сирәкләп ҡайталар инде алар. – *бөре.* Әле дә сирәк-пырак калада күргәлим. – *клд.* Сирәк-сайаҡ үтеп баручы бар. Сирәк-сайаҡ әйтәләр дуwадаҡ тип. – *трбс.* Сирәк-сораҡ ҡына чәчәләр ийе арпаны. – *к.т.*

**СИРӘЛӘЙ** *злт.* тирәли, түгәрәкләп (около, вокруг). Аймаҡ кеше өстәлгә сирәләй утыра.

**СИРӘМ** *тпк.* к.: **йорт 1**. Сирәмендә аның йәйнең көнендә аш-су бешерә торган өйе. Ындырларны, сирәмнәрне себерергә себертке әдерлиләр. Арба, сана йәй сирәмдә тора инде, ҡыш арбаны абdар эсенә кертәсең.

**СИРӘНҮ** *брб.д.* курку, туктау (испугаться, остановиться).

**СИРӘҢКЕ** *том.д.* к.: **сызгыч**. Сирәңке чийып йийады мич йаҡҡанда.

**СИРӘТҮ** *туб.-ирт.д.* к.: **сирәү**. Йамғыр сирәтте.

**СИРӘҮ** *туб.-ирт.д.* к.: **сирелү I**. – Тawыҡларығыз саламы? – Сирәде.

**СИРӘХ** *саз.я.* тырыш, эшчән (трудолюбивый).

**СИРГӘК** *мәл.* тере (живой). Күзләре бик сиргәк, хале awыр булмаска тийеш.

**күңеле сиргәк** *мәл.* күңеле күтәренке (приподнятое настроение у кого-нибудь).

**сиргәк йоҡлау** *каз.ар.-крш.* йокыга сак булу (чутко спать). Сиргәк йоҡлыйм мин.

**СИРГӘҮДЗҮК** *брб.д.* кечкенә кошчык (маленькая птичка).

**СИРЕК I** *тпк.* ике бөтен уннан биш метр озынлыктагы үлчәү берәмлеге (мера длины, равная двум с половиной метрам). Йке митыр йарым булса, пер сирек була, дүрт сирекне пер ҡара тиләр.

**СИРЕК II** [*удм.*] *глз., нокр.* к.: **чатлық 2**. Олча сиректе безненкесе бақча. – *нокр.*

**СИРЕК III** *том.д.* к.: **озонайаҡ**.

**СИРЕЛҮ I** *трбс.* сирәкләнү (редеть, становиться редким, уменьшаться в количественном отношении). Сиреледеләр быйыл йалманнар.

**СИРЕЛҮ II 1**. *т.я.-крш.* чигенү, артка китү (пятиться, отступать). Мына сирелмиләр бит, безгә күренми; **2**. *к.-уф.* к.: **сайығу**. Халыҡ сирелгәч кенә килерсез.

**СИРЕМ** *тпк.* к.: **йорт 1**. Селекнең әрерәкләрен сирем себерергә бәйләйбез.

**СИРИ'-САЙА'** *кас.* к.: **ара-тура 1**. Сири'-сайа' 'илип 'итилир.

**СИРИЛҮ** *туб.-ирт.д.* сөртелү, кырылу, бетү (стираться, сходить, исчезать).

**СИРКӘЙ** *туб.-ирт.д.* к.: **чәркәй**.

**СИРКӘРӘҮ** *брб.д.* яла ягу (клеветать).

**СИРКӘТЛӘНҮ** *эчк.* к.: **сайығу**. Цебеннәр сиркәтләнеп ҡалды.

**СИРКӘЦ** *брб.д.* яла ягучы (клеветник).

**СИРКҮ** *лш.* к.: **кәкшү**. Әзрәк ҡойаш чыҡса, кипшенә, хәзер сирки айаҡ асты. Айаг асты сиркегән.

**СИРМӘЛӘНҮ** *туб.-ирт.д.* иренү, ялкаулану (лениться). Аман йатасың сирмәләнеп, мынта ашағы килеп ҡуйған.

**СИРТЛӘWЕК** *тпк.* к.: **чеки**.

**пүлмәле сиртлəwек** *тпк.* к.: **чикләwек: салам чикләwеге**.

**әре сиртлəwек** *тпк.* к.: **йаңак II**.

**СИРТМӘ 1.** *мам.* к.: **друга 2**. Арба wатык булгач, сиртмә белән йөри; **2.** *бәр., дөб.* к.: **сәлей**. Баланы сиртмәгә сал. – *бәр.*

**СИРҮК** *том.д.* чәгә (стерлядь).

**СИРЧАЛЫ** [*рус.* сердце + *афф.* -лы] *минз.* кызу канлы (горячий, вспыльчивый). Мин бик тыныч кеше бит, сирчалы түгел.

**СИРЫМТА** *т.я.* аз ашаучан (тот, кто мало ест). Ашарға бик сирымта бу кунак, озак торса да курқыч жук. – *к.т.*

**СИСӘК** *к.-уф.* к.: **сичак**. Сисәкләр күп тау сыртта.

**СИТӘ** [*рус.* соты] *тпк.* кәрәз (сот, соты). Пал қорто талның көтийеннән ин тәүдә ситә йийа. Йийып, ситәне қайнатып, tadасын ғына хөкөмәткә ыddawайт итәләр, балawыd була ул. Ситәле бал алып қайттым.

**СИТЛЫ** *карс.* к.: **басма I, 2**. Ситлы тастар бирәм дийеп, Кыдагыйым алдады (*хал. жыр.*).

**СИФАНА** *кас.* тыйнак, әдәпле (скромный); чаг.: **сарәгатлы**. Сифана 'ына 'оз үзе.

**СИФАТ** *туб.-ирт.д.* к.: **кип II**.

**СИХИРЛИК** *туб.-ирт.д.* хәйлә, хәйләкәрлек (хитрость).

**СИЧАК** *тмн.* чәчәк (цветок). Йәш wакытта алларыма Сичаклар кадамадым (*хал. жыр.*).

**СКӘМБИЙӘ** [*рус.* скамья] *минз.* урындык (стул).

**СНАЧ** [*рус.* снасть] *перм., минз.* корал, прибор (инструмент, прибор).

**СОБОК** [*рус.*] *бәр.* соскыч (совок). Оно улақтан ағып тора, собоғы да шунда тора.

**СОБХАН** [*гар.*]: **собхан әтү** *лмб.* азан әйтү (призывать к молитве). Элгәре собхан әтәләр иде мәчеттә.

**СОГАНАК** *чст.* к.: **алйот 2**.

**СОГАНЫП: соганып эшләү** *клд.* чын күңелдән, бөтен көчен биреп эшләү (работать старательно, усердно). Соганып эшли инде, әтәләр бик тырышып эшләгәнне.

**СОҒОНДОРУ** *минз., кргл.*, **СОГОНДЫРУ** *стрл.* сыйлау (угощать). Мәҗелес булса, бөйәтне соғондорышалар тәгәрмәч-тәгәрмәч йасап. – *минз.* Үткән берсен соғондора икән ит белән, қазы белән. – *кргл.*

**СОҒОНУ I** *минз.* ярышып ашау (кушать соревнуясь).

**СОҒОНУ II** *саз.я.* **1.** ашарга теләү, нәфесләнү (иметь желание, хотеть съесть чего-нибудь.); **2.** ашап кую (съесть). Соғонып та қуйтыңма қунаққа тигән ашны?

**СОҒОНУ III** *себ.* к.: **согону II**. Қоңорчақларға соғонып торғаннар барабалар. И Аллам, үзенә соғонып тywа қылам. – *брб.д.*

**СОГОНУ I** *стрл.* к.: **соғону I**. Әwәле бит кулча-кулча казылыкларны соғонганнар.

**СОГОНУ II** *күрш.* баш ию, буйсыну (подчиняться, покоряться). Агары согонып торасын иргә.

**СОҒЫМНЫҚ** *брб.д.* сугымлык (скот для забоя).

**СОҒЫР** *брб.д.* сукыр (слепой).

**СОЗҒАҚ** *злт.*, **СОЗҒО** *перм.* к.: **күмерилəк**. Ул созғақ белән ут китереп утыртқан.

**СОЗҒЫ** *к.-уф.* соскыч (совок).

**созғы сызу** *к.-уф.* соскычка кисәү агачы белән сугып көй чыгару (наигрывать мелодию, ударяя совком по кочерге). Созғы белән тәртешкәне сызып көй чыгаралар.

**СОЗУ** *перм.* **1.** сосу, бушату (черпать, вычерпывать что-либо жидкое). Бөкмә қашық белән созалар бәрәңгене. Қашық белән созабыз қазандан. Аш пешкәндер инде, созоп алмаға кәрәк. Бештисә, созам да ашайым мин; **2.** к.: **себерү 3**. Қортно созоп тутырдылар инде тубалға.

**СОЙҒАҚ** *нрл.* бәрәңге бакчасын әйләндереп алган киртә (загородка вокруг картофельного огорода).

**СОЙЫР** *брб.д.* суер (глухарь).

**СОҚ** *себ.* карак (крадущий, вор).

**СОКЛАНУ** *срг., лмб.* к.: **қызу I**. Берсе байлыкка сокланып йетмеш йәшлек картка унзиде йәшлек кызны биргән. – *срг.* Йәш wакытта йегетләр сокланган үзенә. – *лмб.*

**СОКЛАНЫШУ** *тмн.* яратышу, сөешү, мәхәббәт тотышу (любить друг друга). Сокланышып бардылар болар.

**СОКЛЫ** *срг.* яхшы, әйбәт (хорошо, прекрасно). Wәт ишегалдында йокларга соклы.

**СОКМА** *срг.* елга ярындагы биек урын (возвышенный берег реки).

**сокмадагы урам** *срг.* биек елга яры өстендәге урам (улица на пологом, возвышенном берегу реки).

**СОҚМА** *том.д., брб.д.* к.: **awан III**.

**соқма балтасы** *том.д.* к.: **келисап**.

**СОКНАУ** *хвл.* сулкылдау (свербеть, дёргать). Тешем сокнап тора.

**СОҚОР** *злт.* к.: **җомор**. Сәй соқоры белән икене эскән Сағыйдә.

**СОҚУ** *злт.* к.: **басу I**. Рәсүл дигән қарт таш соқоған.

**СОЛ** [*гар.*] *хвл., мәл.* сәләт (способность, талант). Аның балта эшенә соло бар. – *хвл.* Малайы бик солло күренә. Кит, солсоз, бер эшкә қулың бармый. – *мәл.*

**СОЛАН** *злт.* к.: **ишегал**. Соланның утын қабызған ыйым. Соланның ишеген йабып йебәр, таwықлар кермәсен.

**СОЛАН-КЕЛӘТ** *злт.* к.: **кәзәнкә 2**.

**СОЛАҢҒЫР** *брб.д.* к.: **дуга: күк дугасы**.

**СОЛАУ** *брб.д.* **1.** бик, элгеч (затвор, крючок); **2.** к.: **солаулау**.

**СОЛАУЛАУ** *брб.д.* бикләү (запереть затвором).

**СОЛОҚ** *злт.* к.: **күмерилəк**.

**СОЛСЫЗ** *хвл., чпр.* к.: **пырдымсыз 1**. Эй, солсоз! – *хвл.*

**СОЛЫЧА** *тмн.* болын солычасы (овсяница луговая).

**СОМ** *трбс., к.-уф.* култык астына, бот төбенә чыга торган зур шеш, кайрак (опухоль под мышкой, на внутренней стороне бедра).

**сом имнәү** *к.-уф.* кайракны имләү (лечить знахарским способом опухоль). Сомны қайрақ белән имни торганнар ыйы.

**сом ташы** *трбс.* им-том итә торган таш (камень для лечения знахарскими действиями).

**сӧм** *клм.* **1.** борыс, кисәк (брус, кусок); **2.** бөтен, тоташ, зур (цельный, массивный).

**сӧм алтын** *твр.* саф алтын (чистое золото).

**сӧм йүрәк** *клм.* таза, ныкмускуллы йөрәк (крепкое мускулистое сердце). Сӧлқылдама, сӧм йүрәк!

**СОМНЫҚ** *брб.д.* чәч тәңкәсе (накосная монета). Чәчләренә сомнык таққаннар, көмөштән суққан.

**СОНГРА** *глз.* к.: **азақ**. Анда сонгра шүре агач диләр, даруга йыйалар коп-козол. Ыл′ык сорап йырайлар, сонгра туй йасыйлар.

**сондок** *миш.д.* сандык (сундук):

**аш сондок** *кузн.* туй күчтәнәчләре салынган сандык (сундук со свадебными угощениями). Туй ашлары туй алныда килә, аш сондокта, ике катын китерә. Оликмәк куйган, уннымы, уникенеме катлама, йезәңге китерә бер сондок. Туйдан алныда аш сондок килә.

**сондок йийу** *күрш.* бирнә әзерләү (готовить приданое). Сондок йийа килен, йаулыгын, күлмәген, адийалын.

**сондок кертү** *срг.* туйда махсус йола буенча бирнә сандыгын кертү (внести сундук с вещами невесты, соблюдая определённые правила). Сондок, сондок өстенә куйа мендәрен, адийалын, шыны сүтмицә, цыбылтмица кертеп утырталар.

**сондок кертүчеләр** *срг.* яшь килен сандыгын өйгә кертү өчен билгеләп куелган кешеләр (люди, назначенные для внесения сундука невесты). Сондок кертүчеләр бер генә никахлы, тигез, йахшы тора торган ир булсын, ике никахлы булмасын.

**СОНТОН** *кас.* соңыннан (потом, затем).

**СОНУ 1.** *перм., эчк., туб.-ирт.д.* сузу (протянуть, вытянуть). Айағыңны соноп утыр. – *эчк.* Ашаудан қалдыранам инде, айақны соноп үләргә генә қала. Мал да үлсә, айағын сона шул. Телен соноп йаттийе (бозау), башын соноп. – *перм.* Теле мән әйтәте, айақны соналмайты. – *төм.*; **2.** *т.кам.-крш.* өләшү, тәкъдим итү (раздавать, предлагать). Ире арақыны сона тора ит тураганда. Бөтен сawымнарны соноп бетергәч, пашол бутқасы утырталар.

**қул сону** *туб.-ирт.д.* кул сузу (тянуть руку).

**чәй сону** *минз.* чәй ясау (разливать чай). Чәйне кем сона, мин сонмайым бит. Мин чәй сонған булырмын.

**СОНУЧЫ** *т.кам.-крш.* мәҗлестә аш-су, эчемлек өләшүче (тот, кто разливает гостям напитки или чай, угощает их на званом обеде). Килгәннәрдән бирле қәстәрлисең, Сонучыға берәү тимәсме (*туй жыр.*)? Аннан сонучының қатынына жырлыйлар.

**СОҢ** *тмн.* к.: **анар**. Аша, соң чәй эчәрбез. Пирвый ат мынан, соң машина мынан килдек.

**СОҢАДАН** *минз., стрл.* к.: **азақ**.

**СОҢҒА** *перм.* бурычка (в долг). Әнә соңга ақча сурап килгән ийе қый.

**СОҢОДАН** *минз.*, **СОҢЫНТЫН** *бөре., чпр.* к.: **анар**. Соңынтын ғына булды. – *бөре*.

**СОҢЫРА** *чст.* соң, соңыннан (после). Сәлам соңыра үзебез исән-сау, сезнең дә дөнйада рәхат, шат йәшәwегезне теләп калам.

**СОПО** [*гар.*] *т.кам.-крш.* к.: **нәзәркә**. Безнең ашны ашамады, сопо булып чықты бу. Бик сопо бу малай, исләнгән ди балыкны.

**СОР I** *перм.* соры (серый). Сор була у, ақсыл.

**СОР II** [*гар.*] *кас., хвл.* к.: **сыр II**. Алтын беләзек бик нәзек, Кимә кулыңа, сынар ул. Сораганга сор сүләмә, Сынар өчен сорар ул (*жыр*). – *хвл.*

**СОР III** *брб.д.* зур (большой).

**СОР IV** *брб.д.* кыен, авыр (трудно, тяжело).

**СОРАМЧАҚ** *нгб.-крш.* сорануучан (попрошайка). Безнең күршеләр бик сорамчақ.

**СОРАНЦЫ** *срг.*, **СОРАНЧЫ** *перм.* к.: **келәнче**. Бу соранцыны куwыгыз, дир бай. – *срг.* Соранчылар бетте хәзер. – *перм.*

**СОРЗЫНУ** *брб.д.* моңарчы күрмәгән әйбергә гажәпләнү (удивляться предмету, который до сих пор не видел).

**СОРҚА** *минз.* сөркә (сурок). Сорқа таwында сорқалар күп, сызғырып утыралар.

**СОР'А** *кас.* к.: **сырға I, 1**. Сор'ан 'ола'онда жу'мы?

**СОРЛЫҚ** *брб.д.* җәбер, көчлек (гнёт, притеснение, обида).

**СОРНАЙЦЫ** *себ.* сорнайчы (трубач).

**СОРОҚ** *глз.* к.: **пыды**. Чәй сороқны қайа салдың?

**СОРОКА** *м.-кар.* мордва-каратай хатын-кызлары кия торган ак киндер тукымадан тегелгән баш киеме (старинный головной убор у женщин мордвы-каратаев, сшитый из белого холста). Башка сорока кийеп жөргәнләр.

**СОРЫҚ** *туб.-ирт.д.* **1.** дүрт ишкәкле көймә (четырёхвесельная лодка); **2.** ике ишкәкле зур көймә (большая лодка с парными вёслами).

**СОРЫНДЫ** *м.-кар.* көрт (сугроб).

**СОРЫХ** *туб.-ирт.д.* к.: **сорық 2**.

**СОС I** *перм.* хәйләкәр (хитрый).

**СОС II** *туб.-ирт.д.* кәефсез, күңелсез (унылый, грустный, печальный).

**СОСАН** [*рус.* сосун]: **сосанға йебәрү** *перм.* бозауны симертеп сую өчен тугач та анасы янында калдыру (оставить новорождённого телёнка около матери для откармливания).

**сосар** (куница):

**урал сосары** *перм.* кеш (соболь).

**СОСАУ** *лш.* к.: **күзәү II, 1**. Қуйанға мылтыкны сосадым да атып та жибәрдем.

**СОСҒАҚ 1.** *себ.* соскыч (совок); **2.** к.: **дустыған 1**.

**СОСҚАҒАЦ** *туб.-ирт.д.* соскыч, кечкенә чүмеч (совок или маленький ковш). Сосқагацқа қурғаш салатлар.

**СОСҚАЙАҚ** *перм.* к.: **дустыған 2**.

**СОСҚАҚ I** *минз., эчк.* к.: **дустыған 1**.

**СОСҚАҚ II** *туб.-ирт.д.* к.: **кәпкер II**. Пелмәнне сосқақ белән сосып алатылар шурбадан.

**СОСҠО** *минз.*, **СОСКО** *стрл.* к.: **күмерилəк**.

**СОСҠЫС, СОСҠЫЧ** *каз.ар.* к.: **багырча**. Əүвəлге қарчықлар қуштан қашық дигəннəр, хəзер сосқыс, аш чүмесе диляр. – *дəб.*

**СОСЛОК** *глз.* к.: **имгеч 1**. Шикəр, ипи салып сослоклар имезə идек марл'ага салып балага.

**СОСМА 1.** *каз.ар.* к.: **багырча**. Бир сосманы, аш салам. – *мам.*; **2.** *срг.* к.: **күмерилəк**. Сосма белəн ал күмерне. Сосмам ywалды.

**СОСОН** [*рус.* сосун]: **сосон ит** *перм.* яшь бозау ите (телятина, мясо телёнка-сосунка).

**СОСУН** [*рус.* суслон] *блт.* көлтə чүмəлəсе (суслон). Сосуннары түнеп йаталар.

**СОСХАХ** *сазя.* чүп соскычы (совок для мусора).

**СОСХЫ** *сазя.* судан балык сосып ала торган соскыч (совок для ловли рыбы).

**СОСЫМ** [*рус.* сосун] *мам.* сөт имгəн чордагы яшь бозау, колын, бəрəн (сосун).

**СОСЫН** [*рус.* сосун] *мам.* к.: **сасун 3**.

**сосын итү** *мам.* яшь бозауны сугымга симертү (отжормить на убой – о телёнке). Мин бodауны сосын иттем.

**СОХ** *сазя.* комагай, туймас күз (обжора, ненасытный). Сох симермəс, ууры байымас (*əйтем*).

**СӨГОЗЛИН** *перм.* к.: **селəү II, 1**. Жawыннан сун чыга wы сөгөзлин.

**СӨЗƏК** *клд.* к.: **ашақ I**. Сөзəк булса, тагын бер йастык куйыгыз.

**СӨЗƏҮ** *т.кам.-крш.* к.: **күзəү II, 1**. Тəрəзəдəн сөзəгəн дə атқан инде.

**СӨЗГƏК** *перм.* к.: **сөзгө 1**. Сөт сөзгəк, чипаратныкы.

**СӨЗГӨ 1.** *перм., кузн.* сөт сөзгеч (цедилка, фильтр); **2.** *эстр.* к.: **кəпкер II**. Қул ылакса пешерə бишбармаққа, сөзгө белəн сөзə шорпадан, ит белəн табаққа қуйып бирəт.

**СӨЗӨК** *злт.* к.: **чыр I**. Аш бик сөзөкле булған. Симез ит былса, сөзөк күп была инде.

**СӨЗӨЛЕП: сөзөлеп тору** *т.кам.-крш.* башны аска иеп, түбəн карап тору (стоять, низко опустив голову). Жəш киленнəр келəү иткəн жирдə сөзөлеп кенə торалар.

**СӨЗҮ** *перм.* к.: **созу 1**. Ашны күбəтəгə сөз.

**СӨDӨК** *тпк.* **1.** ашның куесы (густая часть супа). Майлы аш йарамый, сөдөген генə салығыd; **2.** сөтне кайнатканда өстенə утыра торган яры яки каймак (плёнка или сливки, образующиеся при кипячении молока); **3.** чəй h.б. сыекчалар өстенə чыккан элпə (плёнка, появляющаяся на поверхности чая и т.п.). Сап-сары майлы була cywы, сөдөкле (сырганак согы).

**СӨDӨКЛƏНҮ** *тпк.* элпə, яры белəн каплану – сөт, чəй h.б. турында (покрыться плёнкой – о молоке, чае и т.п.). Кичəге бит ул, сөдөкləнгəн бит, йаңыны қайнатайық.

**СӨЙ** *сазя.* сыер куу ымлыгы (слово-междометие, которым погоняют коров).

**СӨЙƏГƏЦ** *себ.* сөякчек (косточка, маленькая кость).

**сөйəк I** (кость):

**чалма сөйəге, чалым сөйəге** *нрл.*, **чалыр сөйəге** *минз., стрл.* чалу сөяге (шейный позвонок в месте резания – во время убоя животного).

**шаталақ сөйəге** *минз.* к.: **ашық II, 2**.

**үле сөйəк** *дəб.* үле гəүдə (мёртвое тело, труп).

**СӨЙƏК II 1.** *лш.* к.: **айақ III**. Киндернең сөйəкляре бик жywан була торғаныйы; **2.** *глз.* төш (косточка). Эчендə сөйəге бар бу йемешнең. Шомырт сөйəге.

**СӨЙƏКТƏШ** *туб.-ирт.д.* яшьтəш (одногодок, одного возраста).

**СӨЙƏМ** *каз.ар.* кайрысы салдырылган юкə агачы (липовое бревно, с которого снята кора). Безнең йақта сөйəмнəн өй эшлəмилəр. – *мам.* Көрəкляргə йарақлы сөйəмнəр бармы? – *блт.*

**СӨЙƏН I** *каз.ар., минз., т.кам.-крш.* к.: **сөйəм**. Сөйəннəн генə буралары. – *мам.* Сөйəн диляр қабағын қубарған жүкəне. – *т.кам.-крш.*

**сөйəн чапчақ** *бөре.* ашлык салу өчен агачтан чокып ясалган тирəн кисмəк (выдолбленная из дерева кадушка для зерна).

**СӨЙƏН II** *т.я., т.кам.-крш.* сөял (мозоль). Қаты сөйəн була, аңгар ляпес сөртə торғаннар ыйы. – *нрл.* Менə минем барнақта сөйəн бар, кисеп тə қарыйым, бетми ул, менə шушы сөйəнне қарчыклар бетерəляр. – *т.кам.-крш.*

**СӨЙƏНХЕЦЛЕ: сөйəнхецле урнтых** *сазя.* артлы урындык (стул со спинкой). Қунақларға сөйəнхецле урнтых пирең.

**СӨЙЕНЦЕЛƏҮ** *туб.-ирт.д.* сөенче алу, шатлыклы хəбəр китерү (сообщить радостную весть).

**СӨЙЛƏШҮ** *мам.* сөйлəү (говорить, рассказывать). Үлəляр инде сезне сөйлəшеп диляр тегермəндə.

**СӨЙЛЕГƏН** *лш.* к.: **мəмəч**.

**СӨЙЛЕГҮ** *злт.* кыегаю, бер якка янтаю, авышу, бер башы күтəрелү – мəс., өстəл, эскəмия турында (покоситься, приподняться одним боком или концом – напр., о столе, стуле). Уртағарақ утыр, эскəмийəң сөйлекмəсен.

**СӨЙНƏКЛЕ** *злт.* сөйкемле (симпатичный, миловидный, привлекательный). Иң сөйнəклесе шул артис инде.

**СӨЙӨНЦЕ** *себ.* **1.** тынычлык хəбəрчесе (возвеститель мира); **2.** сөенче (сообщение о радостной вести).

**сөйөнче** *урт.д.* сөенче (радостное сообщение):

**қолақ сөйөнче** *мам.* к.: **ақ III,1**. Қолақ сөйөнчесенə сөлге, кийəүгə айақ сөрткеч бирəляр.

**сөйөнче қабу** *нокр.* сөенче алу (получить подарок за радостную весть). Сөйөнче қабарға килгəн, бабай туғач.

**СӨЙРƏ I** *каз.ар.-крш.* к.: **озонайақ**. Сөйрə чыққан, тешлий.

**СӨЙРƏ II: сөйрə шалған** *себ.* гəрəнкə (брюква).

**СӨЙРƏКЛƏҮ** *минз., крғл., стрл.* сөйрəү (тащить за собой, волочить что-либо). Икесе ике қулымнан тотоп сөйрəкли. – *крғл.* Сөйрəкляп керттеляр дə йебəрделəр. – *стрл.*

**СӨЙРƏТМƏ** *тпк.* кибəн салганда печəн тарттыра торган жайланма, сүрə (приспособление, применяемое при перетаскивании волоком сена, волокуша). Сөйрəтмə белəн йыйалар песəнне, dyp кəбəнгə салалар. Ике қайынны odон итеп кисеп

алалар да атҡа йигәләр, сөйрәтмәгә күтәрәмнәрне төйәйләр.

**СӨЙРЕ** *туб.-ирт.д.* очлы (острый).

**СӨЙРЕК** *туб.-ирт.д.* чөгә (стерлядь).

**СӨЙСӨН** *к.-уф.* туйда кияү өеннән кыз ягына китерелгән эчемлек (свадебный напиток, принесённый из дома жениха в дом невесты). Сөйсөнне ҡодағый ыспай ғына итеп тотоп бара, өс литырлы шешәгә тутырып. «Сөйсөн китердек, сөйсөн сыгарабыз», – диләр шунда. Малай йағы утырта сөйсөнне. Бөтә кеше awыз тейәргә тейеш, сөйсөн, йаратсын дигән сүз.

**сөйсөн мәжлесе** *к.-уф.* кияү ягыннан килгән эчемлек белән сыйлану мәжлесе (свадебное застолье, угощение с напитками, принесёнными из дома жениха). Сөйсөн мәжлесе дип дан итеп сөйлиләр. Сөйсөн мәжлесенә бардым дип ҡыwанышалар. Сөйсөн эчми ҡалған кешеләр үпкәлиләр, сөйсөн мәжлесенә чақырмадың дип.

**сөлге** (полотенце):

**көлле сөлге** *себ.* чәчәкле сөлге (цветастое полотенце). Көлле сөлгеләр белән аш оцлап апцыҡҡаннар.

**сөлге бирү** *нокр.* к.: **билге I**. Бармаймин, утҡа салсағыз да бармаймин, қайтмаймин, қайтмаймин да өйгә, ди абыстам. Әби әйтте, син, ди, сөлгене бир, ди, барыр, ди, бармай чарасы булмас, ди. Дағы қызданмы сорармин, үзем бирермин сөлге, ди әнийем. Йаучы сөлгене селкетеп китә, қызны бирделәр, дип.

**үпле сөлге** *чпр.* чүпләмле сөлге (полотенце, вытканное браным способом). Ызбага элеп тутырған үпле сөлгеләрне.

**чөй сөлгесе** *дөб.* стенага элеп кую өчен махсус әзерләнгән сөлге (полотенце, специально приготовленное для развешивания на стене – для украшения дома). Чөй сөлгесе дип бик матур қызыл башлы сөлгеләр әләрләр ийе әwәле.

**СӨЛДӘР** *т.кам.-крш., кргл.* к.: **дүстер**. Сөлдәре генә қалған инде, йаратып кигән ийем күлмәгемне. – *кргл.* Өстөнә жүнне күлмәк тисә, сөлдәргә қалғинчы кийә инде ул аны. – *т.кам.-крш.*

**СӨЛДӘРЛӘНҮ** *т.кам.-крш.* к.: **амалану**. Күлмәкләр, жыш жусаң, сөлдәрләнәләр.

**СӨМӘЙҮ** *перм.* к.: **семәйү**. Бер тастымал, ике тастымал белән сөмәйеп қайтайы, бер нимәсез қайтайы wы сабантуйдан.

**СӨМӘНДИ** *мәл.* к.: **ажғырыйн**.

**СӨМБӘ** *туб.-ирт.д.* шомпол – мылтыкта (шомпол).

**СӨМБӘЛӘ** *минз.* сентябрь.

**СӨМЛӘҮ** *нрл.* сиземләү, чамалау (ощущать, чувствовать, полагать). Суқырайгач, үзенең күргән wахытындағыны сөмләп йөри үзе сөме буйынча.

**СӨММӘҮ** *кмшл.* комсызланмау (не жадничать). Сөммә инде, зинһар, диләр. Сөммә диб әйтәләр бит сиңа.

**СӨМНӘҮ** *нрл.* к.: **сөмләү**. Мин бераз сөмним, ул жаққа барған бар.

**СӨМСЕРӘҮ** *мам.* к.: **самсырау**.

**СӨНБӘЛӘ** *минз.* к.: **сөмбәлә**. Элек сөнбәләдә урақ ура торған ыйық.

**СӨНДӨКЛӘНҮ** *дөб.* к.: **итенү 1**. Әй, сөндөкләнеп утырма әле өстәл йанында, матур ғына утыр.

**СӨНТОЙМАС** *т.я.* к.: **озонтоймас**. Ул ник қартайсын соң, ул бит ғомер буйы сөнтоймас. Ул сөнтоймасқа әйттең ни, әйтмәдең ни, үзенекен қыла. – *к.т.*

**СӨНТОЙМАСЛАНҮ** *т. я.* к.: **сырымнау**. Аның исе китми, сөнтоймасланып тик жөри. – *к.т.*

**СӨҢГЕ** *чст.* к.: **қайау**.

**СӨҢГӨТ** *саз.я.* күлдән балык аулау коралы (приспособление для лова рыбы из озера). Сөңгөтне тегәтеләр күлтә, асқарны йылғата.

**СӨҢКӘ** *злт.* к.: **айақ I, 2**. Бер сөңкә сәй белән утырма. Сөтлө сөңкә туры килгән. Мин бер сөңкә сөтөмне йәлләмим қуй.

**СӨҢКӘҮ** *тпк.* чүгәләү (садиться на корточки). Сөңкәйеп утырып сawасың инде сыйырны.

**СӨПӘТ** *шрл.* к.: **сәwәнәй**. Әнинең пәлтәсен кисәм, сөпәт булам.

**СӨР: сөр ит** *әстр.* тозланған ит (солёное мясо). Сөр ит тиде, қыштан қалған итне пешерәде әмилдә.

**СӨРӘ I: аңы сөрә** *саз.я.* шуңа күрә, шуның өчен (поэтому). Йақшы эшләйте, аңы сөрә бушатып тораға йебәрептеләр.

**СӨРӘ II: сөрә қарау** *злт.* караңғы чырайлы булу, маңгай астыннан карау (быть неприветливым, смотреть исподлобья). Кеше килгәндә сөрә қарап утырып булмый инде. Фәрит сөрә қараб утырды. Сөрә қарады да сүләшми сығып китте.

**СӨРӘЙҮ** *перм.* к.: **серәйү 2**. Озон-озон сөрәйеп утырайы кидрә ағачы.

**СӨРӘН I 1.** *мам.* сабан туе алдыннан ат белән бүләк жыю (сбор подарков накануне сабантуя). Малайлар күкәй жыйып қайтқач, сөрән чыгар ыйы ат белән; **2.** *трх.* ат чабышы (конные скачки). Сөрән килә, бу сөрән малайы; **3.** *лш.* солдатка озату мәжлесе (званый обед в честь проводов в армию). Сөрәндә йәшләр күп булган, күңелле дә утырғаннар.

**атлы сөрән** *минз.* к.: **сөрән I, 1**. Сөрән атлы сөрән була инде, иртәгә сабан туйы дигән көнне жоқламисың да, иртән торасың да, атлы сөрән қарап торасың.

**газиз сөрән** *чст.*, **ғәзиз сөрән** *т.я.* сабан туе (сабантуй). Ғәзиз сөрән – мақтаулы, бер йыл тәүлеге көтөп торалар була. – *трх.*

**сөрән агач** *к.-уф.* к.: **селге: селге қурасы**. Сөрән ағачны жарып қуйалар чыршы ағачтан, аны урам буйы күтәреп жөриләр, сөлге-тастымалларны элдереп жийалар.

**сөрән көне** *мам.* сабан туе алдыннан бүләк жыю көне (день сбора подарков накануне сабантуя). Сөрән көнне өй боронча жөрдөләр бит күкәй, тастымал жыйып.

**сөрән суғу 1.** *т.кам.-крш., бгрс.* к.: **сөрән I, 1**. Оло көннән өченче көнне сөрән суғу була, шул чағында жәшләр атқа атланып чығалар. – *т.кам.-крш.* Сөрән суғалар ыйы атқа атланып, awылны әйләнеп бүләк жыйалар. – *бгрс.*; **2.** *кргл.* эшсез, тик йөрү (шататься без дела). Сөрән сугып йөри, диләр, эшләмичә йөргәч.

**сөрәнгә чығу** *мам.* сабан туе алдыннан йорт саен әйбер җыярга чыгу (о выходе с целью сбора подарков накануне сабантуя). Сөрәнгә чыққанар инде, монда да килеп җитәрләр. Тау башында ут җағарлар ыйы, сабан туйы билгесе шул булыр ыйы, андары сөрәнгә чығарлар ыйы атқа атланып.

**СӨРӘН II** *туб.-ирт.д.* хамелеон.

**СӨРӘНЙЕГӘН** *злт.* к.: **дөлкөлдәгән.**

**СӨРГӘБӘТ** *саз.я.* кыш көне күктә күренә торган ут (свечение неба в зимнее время).

**сөргәбәткә суғылған** *саз.я.* ревматизмлы (ревматический больной).

**СӨРГӘК** *трх.* к.: **илдәтнә.** Сөргәк мин, йөрергә бик йаратам.

**СӨРГӨНЧЕ** *перм.* к.: **қасырғы.** Урамда сөргөнче уйный, машина килә маса. Сөргөнче килә урап-урап, тузаннар җомарланып awaға күтәрелә.

**СӨРГӨЧ** *перм.* агач кабыгын ярып җибәрә, куптара торган корал (орудие для распиливания, обдирания древесной коры). Агач сөргөч белән сөрөп чыгарасын қабығын.

**СӨРЕМ: сөрем қойылу** *т.я.* сөмсере коелу (быть не в духе, хмуриться).

**СӨРИЙЕК** *кргл.* к.: **сузан 2.** Кит аннан, сөрийек.

**СӨРЛӘҢКӘ** *стрл.* вак балыклар (мелкие рыбёшки).

**СӨРМӘ** *минз.* карандаш үзәгендәге графит (карандашный графит). Нәзир автакарандашын сөрмә қуйарға қалдырып киткән.

**СӨРМИ I 1.** *кузн., тмн.* шәмәхә төс (фиолетовый цвет); **2.** *мәл.* к.: **қақ II: қақ төсле.**

**СӨРМИ II: сөрми термәк** *чст.* к.: **бармак I: бәбли бәпчек.**

**СӨРМИЛЕ** *трх.* кан йөгергән – ит турында (с кровоподтёком – о мясе). Күг атның ите сөрмиле була, начар була, қан җөгөргән була.

**СӨРӨЛҮ: сөрөлеп қарау** *перм.* акаеп карау (смотреть выпучив, вытаращив глаза). Сөрөлеп қарап тора ди қайнатасы, тизерәк кереп киткән инде килене.

**СӨРӨМ I** *злт.* к.: **серем I.**

**сөрөм тийү** *злт.* ис тию (угорать; отравление угарным газом). Исәңгерәп торам, әллә сөрөм тиде.

**СӨРӨМ II: сөрөм осу** *злт.* сөмсере коелу (быть не в духе, хмуриться, быть мрачным, угрюмым). Нийә сөрөмең осты, әллә шул сүз йарамадымы?

**СӨРӨМДӨК, СӨРӨМНЕК** *перм.* мунча төнлеге (отдушина в бане). Кичә мин йапмадым сөрөмдөкне, эссе шәп төшкәнгә.

**СӨРӨНТЕ** *минз., трбс., стрл.* сөрелә торган җир (пашня). Биш-алты диктары сөрөнте йе. – *минз.* Сөрөнте җир бер дисәтинә биргәннәр. – *трбс.*

**СӨРӨНТЕК** *перм.* к.: **сөрөмдөк.** Төтөн сөрөнтектән чықмый, тишегеннән чықмый.

**СӨРӨНҮ** *саз.я.* сөртенү (спотыкаться). Сөрөнөф йығылты.

**СӨРӨШЛӨК** *себ.* каушап калу, аптырау (замешательство).

**СӨРСҮ 1.** *себ.* каушау (растеряться); **2.** *туб.-ирт.д.* сасу, исләнү (протухнуть).

**СӨРТКЕЧ** *нокр.* к.: **дастымал.**

**сир имчәк сөрткеч** *нокр.* сыер имчәге сөртү өчен әзерләнгән тастымал (маленькое полотенце, приготовленное для вытирания сосков коровы). Сир имчәк сөрткеч әзерли қыз кийәүгә барғанда.

**тирән сөрткеч** *нокр.* к.: **бистәр: чәй бистәре.** Тирән сөрткечләрен илтә қыз терлек дип.

**СӨРТКӨЧ 1.** *кузн.* к.: **битйаулық; 2.** *к.т.* таба сөртү өчен тотыла торган чүпрәк (тряпка для смазывания сковороды).

**СӨРТӨНГЕЦ** *брб.д.* к.: **дастымал.**

**СӨРТҮ** *к.-уф., перм.* к.: **битйаулық.** Тәрзә араға сөртүләр әләләр. – *к.-уф.* Сөртүләрне алып мучаға китә. Барса, муча йагылмаған була. – *перм.*

**бит сөртү** *'перм., к.-уф.* к.: **битйаулық.** Бит сөртүwем қайда қалды суң? – *перм.*

**қул сөртү** *к.-уф., перм.* к.: **дастымал.** Қул сөртүләр үзем суғып җыйдым. – *к.-уф.*

**чыныйақ сөртү** *перм., к.-уф.* к.: **бистәр: чәй бистәре.** Қыз йақтан қул сөртүләре, чыныйақ сөртүләре, күлмәкләр бирнә була. – *к.-уф.* Чыныйақ сөртү қайда икән, өстәлне җыйар ыйым. – *перм.*

**СӨРҮ I** *перм.* җөй (шов).

**СӨРҮ II** *себ.* арттан куу (гнать, гнаться). Тоттырма, арттан сөрсәләр тә.

**СӨСӘК** *туб.-ирт.д.* **1.** озакка сузылган авыру (продолжительная болезнь); **2.** акрын, ашыкмыйча (медленно, не спеша).

**СӨСМӘ** *туб.-ирт.д.* к.: **чыр I.**

**СӨСӨК** *туб.-ирт.д.* сыек (жидкий). Қаймақ сөсөк икән.

**сөт** (молоко):

**күгәрчен сөте** *минз.* испәрәк, зәңгәр чәчәк (живокость полевая, шпорник).

**сөт дәржин** *перм.* к.: **сөтлут.**

**сөт қаулақ** *туб.-ирт.д.* сөтлегән (молочай).

**сөт қаулау** *туб.-ирт.д.* к.: **сөт қаулақ.**

**сөт печин** *перм.* к.: **сөтлут.**

**сөт су** *перм.* к.: **сарқым.** Сөт су белән йуwабыз башны.

**сөт үләне** *том.д.* билчән (осот).

**сөт шурба** *туб.-ирт.д.* сөтле аш (молочный суп).

**СӨТЛӘШ 1.** *срг., кузн.* сөттә пешерелгән ботка (молочная каша). Йарма түwә идем сөтләшкә. – *срг.* Туйда килен төшкәч, киленгә сөтләш бирә, пичтакта өстенә куйып, кан'ишенә ийәләшсен дип. Сөтләш пешереп, шулай пичтакта өстенә куйып бер йенгә инде бирә киленгә. – *кузн.*; **2.** *срг.* сөтле тары өйрәсе (молочный пшённый суп). Сөтләш куйыртып алдым.

**СӨТЛӨГӘН** *туб.-ирт.д.* тукранбаш (клевер).

**СӨТЛӨК** *тпк.* к.: **күкрәкчә.**

**СӨТЛУТ** *т.кам.-крш., эчк., чст.* сөтле билчән (осот полевой).

**СӨТЛҮЛӘН** *трх.* тузганак яфрагы (листья одуванчика). Әй, сөтлүләнне чебешләр җаратып ашыйлар инде, тезелешеп ашыйлар.

**СӨТЧҮ** *хвл.* агып торган суга авызны куеп эчү (пить, приложившись ртом к воде).

**су** (вода):

**әйрән су** *учл.* к.: **кебар'ане.**

**әче су** *блт.* к.: **сарқым**. Әче су белән чәч җусаң, чәч үсә, йалтырап тора.

**балан сувы** *стрл.* балан компоты (компот из калины).

**баллы су** *минз., стрл.*, **җимеш сувы** *к.-уф.* компот. Җимеш сувы дип өмөже салып пешергән шәрбәтле су биргәннәр. Җимеш сувын бер табақ белә утырттылар. Кажный кеше қалақ белән эчте җимеш сувын.

**йумал** [*удм.*] **су** *нокр.* баллы, төче су, ширбәт (сладкая вода). Чәйнүктә ширбәт, йумал су. Йумал суны қаптыра эч мәртәбә. Йумал суның қалдығын йәшләргә бирә. Кийәүгә дә, қызға да йумал су эчерәләр.

**қара су** *кргл.* акмый торган су (стоячая вода); чаг.: **күлләwек 2**. Әwәл монда қара сулар, күлләр булған.

**қолмақ сувы** *минз.*, **қомалақ су** *к.-уф.* колмакны салып кайнаткан су (вода, кипячённая с хмелем). Қолмақны су салып қайнатасың, қолмағын сөзеп аласың. Қолмақ қайнатып, шуның сувы белән ачытып саладырыйық ипине. – *минз.* Қомалақ су қайнатып алалар ике бидерәме, өч бидерәме. Шуны чапчаққа салалар ый. Қүwәтле булайы уw бал қомалақ белә эшләгәч. – *к.-уф.*

**қот сувы** *брб.д.* куркудан авырган кешене имләү өчен әзерләнгән су (заговорённая вода от испуга). Қорқоп аурадым. Йөрәгемне күргәздем бер әбигә: «Қот сувы эчергәле кәрәк сийа, – тиде, – йақшы булмас инде». Башымға йаулық салып, чаңнауны (чүмечне) баш түбәгә утыртып, су өстенә қурғашны қойады. Бер қойдо, ике қойдо, қот сувын эчерделәр.

**нардуған сувы** *крш.* нардуганда күрәзәлек итү өчен алып кайтылган су (вода, принесённая в дни святок для гаданий с кольцами). Нардуған сувын алып қайтқанда, балта белән суны сызықлап алабыз.

**никах сувы** *хвл.* к.: **йумал су**. Никах укыган wакытта чәйнүктә су куйалар, никах суы, ширбәт. Эстенә йеслек йабалар.

**өрек су** *к.-уф.* өрек компоты (компот с урюком). Өрек су қайнаттылар никахта, бәлеш пешерделәр.

**сары су** *әстр.* к.: **сарқым**. Сыйыры туса инде сөт була, сөтне қатық итә, қатықтан эремчек була, сары сувын эчә, эремчеген ашый.

**су алғыч** *перм.* к.: **кичү I, 2**. Берәү қарчық бар, монда су алғычта ғына тора безнеке.

**су алу** *себ.* су басу (затоплять водой).

**су байы** *глз.* су иясе (водяная). Су байы тота.

**су бите** *эчк.* су буе (около речки); чаг.: **йаға I, 2**. Бала су битенә төшкән.

**су геле** *лмб., тмн.* к.: **қына I: қазан қынасы**.

**су җулы ачтыру** *т.я.-крш.* яшь киленгә су юлы күрсәтү (свадебный обряд: показывать невесте дорогу к роднику). Су җулы ачтырабыз, диләр, мине ачтырдылар. «И Наталины су җулы ачтырыга алып китәбез». Элек җиңги чыккан, күwәндә асып барам. «Жә, җана килен, сәләмеңне бир әле миңа»,– ди. Өч мәртәбә баш ордым, карт кешегә сәләм бирдем. Картлар чыгыб уқ торалар ыйы су җулы ачкан кешегә. Бар да итәкләр тотып торалар. Туганнары да бара сәләм алырга. Шанда барган кызлар баш ырып тыралар, сәләм алып. «Су нинди чичта, шун кебек тырмыш матур булсын, ызын гумер булсын. Чәй утыртыгыз, су кебек тулы булма кушсын», – диләр.

**су иғезәк булу** *глз.* бала туганда алдан су китеп бетү (схождение воды до рождения ребёнка). Беренче балам су игезәк булды, корога калды, үле туды.

**су йулы** *минз.* су агып төшү өчен түбә такталарының ике ягына буйдан-буйга ясалган улак (колоды на краях крыши для стока воды).

**су йүзү** *себ.* су өсте (поверхность воды). Күс болғанда, суларның йүзү туңар.

**су қарамығы** *туб.-ирт.д.* к.: **алабата**.

**су қойу** *перм.* к.: **қойу II, 2**. Суны күп қойсаң, бик шәб үсә ул қыйар.

**су қыйағы** *бәр.* к.: **асака**.

**су мылтығы** *к.т.* к.: **йылан: йылан көпшәсе 1**.

**су печәне** *бәр.* к.: **қазыйақ 1**.

**су салу** *перм.* к.: **қойу II, 2**. Эш бетте, сыйыр саудым, су салдым. Су салалар – сүнми, болайғына итә дә тағы қаба. Җитмеш алты төп қыйарға су салынды.

**су тору** *срг., мәл.* су җыелу (скапливание воды). Орамда су беген, сулар торган йаңгыр йаугач. – *срг.*

**су утрawы** *минз.* к.: **сувалма**.

**су цабу** *туб.-ирт.д.* боз өстенә су чыгу (появление воды на поверхности льда).

**су цуму** *туб.-ирт.д.* су коену, су керү (купаться в реке).

**су эчеп чыққан** *бөре.* к.: **қышлаған**. Су эчеп чыққан бозау инде бу.

**сума су (булу)** *туб.-ирт.д.* манма су булу (промокнуть насквозь).

**талқан су** *нокр.* куас (квас). Талқан сувы илткәләдек боломға. «Кәлин, талқан су китер», – дилир.

**таң сувы 1.** *каз.ар., бәр., перм., т.я., нгб.-крш.* авырган кешене им-томлау өчен таң вакытында чишмә яки инештән китерелгән су (вода, принесённая на заре из родника или речки для знахарского лечения больного человека). Хәмденисәттә таң сувына дип чиләк қалдырған ыйы. – *мам.* Әзерәк йарый ул шунда, хәл кереп китә таң сувы белән қойонсаң. – *бәр.* Таң сувы алған, чәшке чоқоро белән киткән сыуға, бистәрләр тотқан, белгән әбигә илтеп бирәсең, ул күмер сала, ипи сала, өшкөрөп бирә инде. Өшкөргән суны балаға эчерә. Таң беленгенче алып қайтасын суны. – *нгб.-крш.*; **2.** *т.я.* күз тиеп авыручыны им-томлау өчен, таң вакытында қыйблага таба агып торган чишмә яки инештән китерелгән су (вода, принесённая на заре из родника или речки, текущей на юг, для лечения человека, подвергнувшегося сглазу – у знахарей).

**таң сувы алу** *блт., мам., лш., т.я.* элек: күз тиеп авырган кешене им-том итү өчен таң атканда төшеп су алу (набирать на заре воду из родника или речки для заговаривания человека, подвергнувшегося сглазу). Таң сувы алалар, өч мәртәбә алып йувындыралар кемгә күз тийә, ана шул awыртқан кешене. – *мам.*

**чөгендер сувы** *минз.* чөгендер турап кайна-

тылган су (свекольный компот). Аш, бәлеш, ит чыгаралар, аш артыннан кыдыл чөгендер сувы чыгаралар. Чөгендерне олы чүлмәкләрдә пешереп, шуның сувын куйу ыйы. Чәй эчертү дә җуқ ыйы әвәле. «Чәй куймадым инде»,– дийәрләр ийе. – *минз.*

**чөче су** *хвл.*, **шәрбәт су** *к.-уф., себ.*, **ширбәт суы** *хвл.* к.: **йумал су**. Қалақ белә шәрбәт су эчереп чыгалар бар кешегә дә. Қайнә қаптыра, малайның инәсе никахта қаптыра: «Киленем тәмле телле булсын, ақыллы булсын», – дип. – *к.-уф.* Қатымга пирбай кергәндә шәрбәт су куйалар, шуны авыс итәләр, қашықлап эцеп алалар. «Үлеккә шунтай су насип итсен», – тип эцертәләр. – *төм.* Киленне дә, йегетне дә сандык эстенә тешерәләр дә икесенә дә чөче су эчерәләр, ширбәт. Өсләренә дә ширбәт сувы сибәләр. – *хвл.*

**СУБАҒАЙЛАНУ** *лш.* физик яктан формалашу – кыз кеше турында (достичь физической зрелости – о девушке).

**СУБАГАЧ** [*рус.* цеп + агач] *лмб., карс.* к.: **чип I**.

**СУБУҚ** *каз.ар., бәр.*, **СУБЫҚ** [*рус.* совок] *бәр.*, к.: **күмерилә́к**. Субуғы бар әле аның көл алырға. – *дөб.* Мичтән күмер алабыз күмер субуғы белән, он субуғы да була, он ала торған. – *бәр.*

**СУВАҒАЧ** *әстр.* көянтә (коромысло). Сувағачны сырлап йасады эти қызларға.

**СУВАҚ** *том.д.* суык (холодно; холодный).

**СУВАЛДЫ: сувалды сыгыр** *себ.* савымсыз сыер (недойная корова).

**СУВАЛҖЕН** *чст.* к.: **селәү II, 1**.

**СУВАЛҚА** *лш.* язгы ташудан җыелып калган су (озеро, оставшееся после весеннего половодья).

**СУВАЛМА** *лш.* язын су баса торган болын (заливной луг). Қырларда сувалмалар бар ыйы, хәзер бетте инде, Иделне буғач.

**СУВАЛУ I.** *саз.я.* күз начарлану (ухудшаться – о зрении). Күсем сувалған цақ, күрмәйем.

**СУВАЛУ II** *себ.* **1.** сыерның сөте азаю (уменьшаться – о молоке коровы). Сыйырыбыс сувалған, сөт йуқ. – *тбл.*; **2.** сыерның сөте бетү (перестать давать молоко – о корове). Сыйырым суалты, сөте цыкмайты. – *клм.*

**СУВАН** *срг.* к.: **сувана́ш**. Итсез кем ашасын, кырда суван пешермиләр инде.

**СУВАНАШ** *мәл., срг., хвл.* итсез аш (постный суп). Беген сувана́ш кына пешереп ашадык. Иртә белән сувана́ш ашадым, төшкә итлесе пешә. – *хвл.*

**СУВАРУ** *туб.-ирт.д.* сугару, эчертү (поить животных). Қуйларны сувар ғалы әпкилгәннәр.

**СУВАТУ** *брб.д.* суыту (охладить).

**СУВАШЫ** *мәл.* к.: **сувана́ш**.

**СУВӘСИ** *глз.* су иясе (водяная). Сувәси тарткан, дилир.

**СУВУ** *т.я., перм.* суыну (остывать). Аша, ашаң, эсселәй ашаң, ул мә йазу! Сувый қый. Чәйе сувып торсон, ашлары пешкәнче. – *перм.* Чыгыгыз тизрәк, аш сувый. Чәйем сувыған, бер генә чынайақ эчтем. Аш сувып бетте, әйдә керим, аш сувымасын. – *трх.*

**с у w ы қ** суык (холод; холодный):

**зықы сувык** *нгб.-крш.* к.: **сыкы сувык**.

**сувык алу** *хвл.* к.: **сувык суғу**.

**сувык қул** *т.я.* к.: **йончу III**. Сувык қуллы кешеләр диләр аларны. – *к.т.*

**сувык суғу** *перм., минз., саз.я.* салкын тию (простудиться). Сувык суққанда қура җиләк варен'йысы белән чәй эчү йахшы була. – *минз.* Сувык суқтырдым да мин көтү көткән кен. – *перм.*

**сувык тоту** *перм., т.я.-крш.* к.: **шом I: шом тоту**. Сувык тоту, бизгәк тоту икесе бер чир, бервақытны абзый сувык тотоп зарланып җатты. – *перм.*

**сувык төшү** *дөб.* салкын тию (простудиться). Кәҗәнең эченә сувык төшкән.

**сувык чир** *бөре., перм., т.я.*, **сувык чире** *перм.* к.: **шом I: шом тоту**. Сувык чир белән озақ чирләде. – *нрл.* Йазға чықсам, мине сувык чир тота башлый. – *бөре.* Сувык чире белән қалтырап җатқанда берәр бидерә қойо сувы сибеп җибәрәсен. – *перм.*

**сыкы сувык** *мәл.* агачларга бәс төшерә торган суык (мороз, при котором деревья покрываются инеем, изморозью).

**чытырдаған сувык** *мам.* чатлама суык (трескучий мороз). Чытырдаған сувыкта келәттә қуна ыйы, бичуралы диләр ийе аны.

**СУВЫКЛЫ** *срг.* суыграк (холоднее). Ызба тыштан күп сувыклы.

**СУВЫҚСУ** *перм., т.кам.-крш.* к.: **сувык: сувык суғу**. Мин қаттым, сувықсыдым беркөннe. – *перм.* Сувықсығансың диделәр бырачлар. – *т.кам.-крш.*

**СУВЫҚСЫРАУ** *себ.* суык тиюне тою (чувствовать простуду).

**СУВЫҚСЫУ I** *саз.я.* туңыбрак тору, өшү (зябнуть).

**СУВЫҚСЫУ II** *саз.я.* чырай сыту (хмуриться). Пер көләте, пер сувықсыйты.

**СУВЫНТЫН** *минз.* к.: **анар**. Сувынтын аны җаздым инде.

**СУВЫРЛЫ** *крғл.* к.: **йаңгыз**. Көтү көтәргә чығып китәм сувырлы башым.

**СУВЫРТҚЫЧ 1.** *лш.* имезлек (соска, жвачка). Сувыртқыч сувыртадырыйық балаға. Сувыртқыч диләр ийе элек бәбигә ипи белән шикәр чәйнәп салған марлыға, җә манный ботқасы пешереп, марлыға салып сувыртқыч бирә бәбигә. Қарны ачса, шул сувыртқычны сувыртқан анасы эштә чағында; **2.** *минз.* к.: **қортқоч**. Қара тамды, тид генә сувыртқыч бир әле.

**СУВЫРТҚЫЧ** *чст.* к.: **қортқоч**. Сувырткыч дәфтәр арасында.

**СУВЫРТМА** *перм.* тегермәндә солының кабыгын салдыру өчен махсус җайланма (специальная установка на мельнице для очистки овса от шелухи).

**СУВЫРУ** *т.я., каз.ар., хвл.* җилгәрү (веять). Көне буйы сувыруда эшләдек, бодай сувырттық. – *т.я.*

**СУВЫТ** *туб.-ирт.д.* кыяк үләне, күрән (осока).

**сувыт пецән** *тбл.-ирт.д.* саз печәне (скошенное на болоте сено, состоящее в основном из осоки).

**СУҒА** [*рус.* соха] *себ.* сука (плуг).

**суға сөрөү** *туб.-ирт.д.* сабан сөрү, җир сөрү (пахать).

**СУҒАБАШ** *туб.-ирт.д.* сука тимере (сошник).

**суған** (лук):

**ата суған** *лш.* к.: **бәбәк II**. Ата суған ул, салқын тигәннән шулай булып үсә.

**қыр суғаны** *лш.* юа (дикий луг).

**қырықма суған** *трх.* орлыктан чәчеп үстерелә торган вак кыяклы күпьеллык суган (лук-шнитт). Қырықма суган белән қатыштырып тозлағач әйбәт була (кәбестә).

**суған бабайы** *лш.* к.: **бәбәк II**. Суған бабайларын өзеп чыққаныйым инде бер.

**төп суған** *нрл.* башлы суган (репчатый лук). Төп суган йуқ, қыйақ қына.

**СУҒАНАСТЫ** *т.я.*, **СУҒАНАСЫ** *лш.* к.: **сүwәсе**. Суганасты алған диләр ийе, кеше суға төшеп үлсә. – *нрл.*

**СУГЕРМӘК** *злт., трбс.* су жыелып тора торган уйсу жир (низменность, где накапливается вода). Сугермәктә йыл да сулар йыйылып утыра. – *злт.* Өйләре қырында сугермәк, қазлар йөзеп йөри. – *трбс.*

**СУҒУ I 1.** *тпк., трбс.* к.: **койу I, 1**. Йаңақларны үзе суға торған ыйы. – *тпк.*; **2.** *тпк.* агачтан әйберләр ясау (делать изделия из дерева). Күнәк суғу. Тәгәрмәч суғу; **3.** *перм.* туры килү (приходиться, прийтись). Боларға бер көн дә арқа тырнатмаға суқмады.

**туры суғу** *перм.* к.: **суғу I, 3**. Кемнәр генә туры суқмый дисең. Бернәрсә дә әйтми туры суқмый субранийада.

**суғу II** сугу (ткать):

**алача суғу** *чст.* төрле төстәге жепләрдән сугу (ткать разноцветными нитками). Бездә алача сугу бар, алача чаршаулар булды.

**буйлап суғу** *перм.* буй-буй итеп сугу (ткать полосками, в полоску). Киндер жасыйбыз житеннән кәртәләп, жә буйлап суғабыз.

**йезекләп сугу** *чст.* киндер сугуның борынгы төре (древний вид тканья). Йезекләп сугу булган элекерәк. Ул сугу хазер онотылган.

**күтәреп суғу** *каз.ар., перм.* үзеннән бизәк чыгарып сугу (способ браного тканья холста, при котором получаются ажурные узоры, белое браньё). Күтәреп суғасы булса, тақта күтәреп тордо, тәтә. Бүртмәчле-бүртмәчле була сөлге башлары, күтәреп суққач. Кижеле башлы чүпләмле булса ақ сөлгө, күтәреп суққан була. – *мам.* Күтәреп суққан тастымалларым сандықта күп, суғып жыйдым. Қуйан, күбәләк төшереп суққан. – *перм.*

**кырык шырпылы суғу** *чст.* бизәкләп сугу (тканьё с узорами). Алмалы бизәкләр төшә, кырык шырпылы сугу дибез.

**сөрмәләп суғу** *минз.* к.: **буйлап суғу**. Мин үdем сөрмәләп суқтым, бизәк төшереп суқмадым. Менә сөрмәләп суққан паласларым эстинәдә.

**тақта күтәреп суғу** *минз.* бизәкләп сугу (ткать с узорами). Тақта күтәреп көрө белән суқтым битжаулықларымны.

**тешкә берле итеп суғу** *минз., тпк.* кылыч тешләре арасыннан бер генә жеп уздырып, юка итеп, сирәк итеп сугу (тканьё редкого холста). Тешкә берле анысы иң йиңел суғу инде, менә себерегә нитәргә инде. Мин үзем қыз wахытта сарфитлар суғып килгән идем, қыз wахытта суга идем, пәзине эрләп тешкә берле итеп суға идем. – *тпк.*

**тешкә икеле итеп сугу** *чст.* кылыч тешләре арасыннан ике жеп уздырып, тыгыз итеп сугу (тканьё холста толстым и крепким). Кан'анам биг оста иде, ул тешкә икеле итеп суга иде, анысы тыгызрак була иде. Тешкә икеленең кылычы да озон, киң була. Пицкә келгә салып йомшарта идек пәзине.

**чәкәннәп суғу** *минз.* бизәкләп сугу (тканьё с узорами). Чәкәннәгән булса, бизәк төшереп суққан була. Чәкәннәп суқмадым, сөрмәләп кенә суқтым.

**СУҒУ III** *тпк.* кыйнау (бить, избивать). Элгәре бик суққаннар қатыннарын.

**йөрәк суғу** *тпк.* йөрәк кагу (ёкать, биться – о сердце). Йөрәк суға, мунсадан қайтам.

**салқын суғу** *тпк.* салкын тию (простудиться). Awырдым, салқын суққан.

**СУҒУ I** *миш.д.* **1.** рәсемгә төшерү (фотографировать, снимать). Картычкага суга. Син аны сугып алгиден. – *срг.* Картычкага сукканнар. Сүрәтеңне сугып алыр идем үмере күз алдында тытарга. – *лмб.* Карточкага сугамы әллә бу? – *хвл.* Йәштә сугылганнарыңнымы күрсәтәсең? – *кузн.*; **2.** рәсемен төшерү, бастыру (напечатать, напр., в газете). Йетмеш йәшлек картны гәзиткә суктылар. – *срг.* Гаҗитәгә сукканнар диме? Әллә газиткә сугып аласызмы? – *мәл.*

**кыйма сугу** *чст.* к.: **қойу I: қойма қойу**. Мин үзем плутник, кара, кыйма суктым.

**СУҒУ II** *срг.* к.: **ағызу**. Сепаратта сөт сугабыз.

**СУҒУ III** *глз.* к.: **кагу 1**. Күкәй сындырып, дыружилар салып, быдай оно был'ан сугып табагый була инды, табага салып пышыралар.

**камыр суғу** *глз.* камыр басу (месить тесто). Камыр сугып тәбәгый пешерәбез.

**май суғу** *карс., клд.* май чыгару (выжимать масло из семян). Киндераштан май сугалар иде. – *карс.* Элән майы була иде, суктыралар иде. – *клд.*

**СУҒУ IV** *клд.* төшү (падать). Тенне ай шәүләсе сугамы ызбага?

**СУҒУ V** *карс.* к.: **қойу I: қойма қойу**.

**СУҒЫДАН** *перм.* к.: **анар**.

**СУҒЫЛУ** *карс.* имгәнү (ушибаться, калечиться). Атасы матасикыл ман сугылды, бездә күп инде аны ман сугылдылар.

**СУҒЫЛУ** *кмшл.* капкынга төшү (попасть в капкан). Қапқанға суғылған бер кыриса.

**бидгәк суғылу** *минз.*, **бизгәк сугылу** *стрл.* бизгәк белән авыру (болеть малярией). Бәләкәй чақта бидгәк суғылды миға. – *минз.*

**СУҒЫМ** *т.я.*, **СУГЫМ** *лмб., мәл., карс., чпр., клд.* **1.** суярга симертелгән ат (лошадь, откормленная на убой). Уҗым әйбәт була торған ыйы, ат алып суғым симертә қайсы берсе. Суғым дип атны барып алалар ыйы атына базардан. – *трх.* Чембер айгыры сугымга чала. – *лмб.* Сугым ите дә бик биздерде. – *карс.* Жыл да сугым ала идек, быйыл да сугым алдык. – *чпр.* Ай-һай илдегез, илдегез, Илләр аша килдегез. Үз кемлегегезне белдегез, Сугымнар йеген килдегез (*хал. жыр.*). – *лмб.*; **2.** *лмб.* ат ите (конина). Сугым бар, аласызмы? Кичә генә чалдылар.

**сугым бар′амы** *лмб.* ат суйганда ясалган мәҗлес (застолье, устраиваемое после забоя коня). Сугымнар чалынгач, сугым бар′амы буладыр, сугым чалырга чакыралар берничә кеше, чалалар, эчен алалар, тиз генә бирәләр пичинын, йөрәген, аннан грудинкасын wак кына турап йералма белән пешерәләр, күршеләрен чакыралар.

**сугым ите** *чпр.* к.: **суғым 2**.

**СУГЫНУ** *м.-кар.* сузылу (протянуться, протягиваться). Дилбегәме алырга сугындым.

**СУҒЫНУЦЫ** *төм.* киндер сугучы (ткачиха). Монда суғынуцы йуқ элек-электән, Төмәннән алған.

**СУҒЫР** *туб.-ирт.д.* сукыр (слепой).

**СУҒЫШАҚ** *эчк.* к.: **бәтрәк 2**.

**СУҒЫШҚАҚ** *злт., трбс.* сугыш чукмары (любящий драться, драчун). Сугышқақ малай ул. – *трбс.*

**СУДАЧУК** *хвл., кузн.* авылның елга аръягындагы өлеше, урамы (часть деревни, улица, расположенная за рекой).

**СУДЛАНУ** *лш.* үзлеләнү (стать вязким). Киндер орлоғы төйгән сайын судлана, судлы балчық шикелле қамыр була бу чиҗтый.

**СУДУК** *лш.* судак балығы (рыба судак).

**СУДЫ** [*рус.* судорога]: **суды тарту** *нгб.-крш.* к.: **йезән: йезән тарту**. Айағымны суды тартты.

**СУЗАН 1.** *т.кам.-крш.* озын (длинный). Сузан Әләкси сузан буйы белә килә. Аның доклады сузан булыр инде. **2.** *дөб.* озын буйлы нечкә кешегә карата әйтелә (говорится о высоком худом человеке).

**СУЗМА 1.** *минз.* к.: **будырма**; **2.** *чст.* аска җәя торган киез (подстилка из войлока); чаг.: **черге**; **3.** *трх.* кулдан сугылган тар палас, идән паласы (половик, дорожка домашней работы). Су буйында сузмалары да қала идәнгә җәйә торған. Идәнгә җәйәргә сузмалар суқтым; **4.** *мам.* язгы йон – сарык йоны турында (овечья шерсть весенней стрижки). Сузмасы жақшы шешкән айаққа бәйләп қуйарға, аннан йомшақ була инде ул; **5.** *лш.* к.: **қулазақ**.

**озын сузма** *дөб.* к.: **ад′ур 2**.

**СУЙБАҚ** *том.д.* сөзәк (покатый).

**СУЙҚАҚ** *минз.* сөзәк (пологий, отлогий).

**СУЙЛАҚ** *бәр., дөб., кмшл., т.кам.-крш., к.т.* к.: **азымтық**. Суйлақ бусаң, бағытыңнан қоро қалырсың. Суйлаққа сут та қурқыныч түгел. – *т.кам.-крш.* Сәгат ун булмаған, йықларға йатқан суйлақ шайтан. – *кмшл.*

**СУЙЛАҚЛАНУ** *кмшл., т.я.* ялкаулану (лениться). Нәрсә син суйлақланып йатасың, анда эш қайнап йата. – *кмшл.*

**СУЙЛАҚЛАП** *мам.* к.: **чайрап**. Мәче ничек суйлақлап жатқан.

**СУЙУ 1.** *тмн., лмб., кузн., чст., шрл., карс.* әрчү (чистить). Алманы суйыпмы бешерим? Хазер үзем суйам картушканы. – *тмн.* Картук суйарга чыгам әлдә. Мә, кызым, картук суй. – *лмб.* Бәрәңге суйганмы? – *шрл.* Без картукны суйабыз, үзгә төшкә тawыкны суйалар. – *кузн.* Ашак келәсә, хәзер картук суйып пешерәбез; **2.** *тмн.* сүтү (распороть); чаг.: **қутару 3**. Адийалларның өсләрен суйдым йыварга; **3.** *перм., чст.* к.: **суйыру 1**. Тал қабығын суйып сатасың. – *перм.* Йука агачны кисеп, кабыгын суйып. – *чст.*

**СУЙЫЛ** *злт., себ.* колга, озын күсәк (жердь, длинная дубина). Суйыл белән башына суққаннар. – *злт.*

**СУЙЫНДЫ** *чст.* к.: **сөйәм**.

**СУЙЫПТАШ** *минз., кмшл., мәл.* к.: **ногый**.

**СУЙЫРУ 1.** *минз., стрл., мәл.* каезлау, төшерү (сиять, сдирать кору с дерева); **2.** *минз., стрл.* сыдыру, тырнату – тире турында (содрать, ободрать – о коже). Аркасын ныкъ суйырган бит әнә йулга йыгып. – *стрл.*

**СУК** [*рус.* сок] *лш.* киптереп төелгән киндер орлыгын су белән сыек кына итеп изеп иләккә салып саркытканнан соң барлыкка килгән сөт сыман сыекча (особым способом приготовленный сок из конопляных семян). Төбөн қазанга салып эретәсең, су белән дә иләктән сөзәсең, сук була.

**СУҚ** *туб.-ирт.д.* алдакчы, хәйләкәр (вороватый).

**СУҚА I** *перм.* шул көе (в таком виде, в таком состоянии). Идәне, пытылугы бар ий, суқа йатқан ийе, суқа торған.

**с у қ а II** сука (соха):

**суқа боты** *перм.*, **сука боты** *тмн.* сука башы (рукоятка сохи).

**сука кашыгы** *чст.* к.: **қарлау**.

**сука пычагы** *чст.* сука тимере (сошник).

**сука сыздыру** *срг.* к.: **йару I**.

**сука чәчәге** *мәл.* к.: **арыш II: арыш чәчәге**.

**СУҚАРДАҚ** *перм.* кыр үрдәгенең бер төре (вид дикой утки).

**СУҚАТ** [*рус.* сохатый] *перм.* к.: **моши**. Инә суқат мүгезле булмый қый, ата суқат мүгезле.

**СУҚҚА** *перм.* к.: **суқа I**. Кимисең дә, шулый суққа йата иләсәң.

**СУҚҚЫ** *перм.* к.: **аламалық 1**. Намуслы булганның белә суққы күрмәдем. Менә мин монда бер суққы күрдем, чүкеч белән бирдийе бер кеше.

**СУҚҚЫР** *саз.я.* сугучан, сугарга оста (умеющий ударять).

**СУҚҚЫЦ** *туб.-ирт.д.* к.: **келисап**.

**СУҚЛАНУ** *туб.-ирт.д.* теләү, ярату (желать, любить).

**СУҚЛАУ** *туб.-ирт.д.* соклану, кызыгу, мавыгып китү, теләү, көнләшү (прельститься, пристраститься, желать, завидовать).

**СУҚЛЫ** *срг.* к.: **йарау**. Жарау кен беген, суқлы. Ызбагыз суқлы икән. Идәнне йусаң, ызба суқлы булды.

**СУҚЛЫҒУ** *перм.* к.: **ишелү**. Хәзер генә машина тawыш суқлыга әнә, сезгә дә суқлығамы?

**СУҚМА** *том.д.* к.: **awан III**. Бодайларны суқмада суғып йарма итәтгән идек, суғотғон идек. Қырдан башақ жыйып алып килеп суқмада суғотғон идек.

**СУКМАН** *глз.* чикмән (чекмень). Сукман кигән бабам, пәтеридә утыра. Сукманны йапканнар эстесенә әнинең.

**СУ′НАЙЫМ** *кас.* к.: **анар**.

**СУҚРАУ** *туб.-ирт.д.* ачулану, зарлану, мыгырдау (негодовать, жаловаться, ворчать).

**СУҚТА I** *каз.ар., бәр., нокр.* әчәгегә итне ярма белән аралаштырып тутырып, шулпада пешерелгән тутырма (домашняя колбаса, начинённая крупой, мясом). **Җәйгә бераз суқта хәзерләп куйыйк.** – *дөб.* Калбаса дисәң калбаса түгел, суқта диләр, суған да саласың, йарма тутырасың ит белән, қайсы кеше бер-ике бәрәңге дә қуша. – *бәр.* Қаз суйғач та суқта йасап ашата, бawыры, йөрәге бар ич, ичиккә салып пешерәләр. – *нокр.*

**СУҚТА II** 1. *туб.-ирт.д.* кәҗә мамыгы (козий пух); 2. *саз.я.* яшь үрдәктә яңа чыгып килә торган йон (пух, только что появившийся у маленьких утят).

**СУҚТА III** *әстр.* иренең өченче ир туганы (третий брат мужа – для жены).

**суқта кинҗәм** *әстр.* к.: **суқта III.**

**СУҚТАҒАЧ: суқтағач кебек** *кмшл.* уклау йоткан кебек (как оглоблю проглотил). Эш эшли белми, суқтағач кебек йөри иде.

**СУҚТАМ** *әстр.* иренең иң кече энесенә эндәшү сүзе (слово-обращение к самому младшему брату мужа).

**СУҚТЫРУ I** *срг.* 1. к.: **ағызу.** Үдә сипаратта суқтырдым (сөтне); 2. май чыгару (выжимать масло из семян). Элән орлыгыннан май суқтыра идек.

**СУҚТЫРУ II** *глз.* сындыру (сломать). Йыгылып кулын суқтырды мескен.

**СУҚТЫРУ I** *саз.я.* 1. керү, тоттыру (заходить, ловиться). Инце күлгә опты суқтырылмайты;

**СУҚТЫРУ II** *саз.я.* тыпырдап бию (выбивать дробь в пляске). Суқтырып уйнасын.

**СУҚТЫРУ III: кийез итек суқтыру** *бәр., дөб.* киез итек бастыру (валять валенки).

**СУ'ТЫРЫЛУ** *кас.* суқтырылу (быть побитым).

**су'тырылып чы'у** *кас.* бик ябыгу, суырылу (сильно похудеть); чаг.: **қойтылану.** Җабы''ан, су'тырылып чы''ан.

**СУҚЫ** *саз.я.* к.: **awан III.**

**с у қ ы р** (слепой):

**суқыр кесерткән** *срг.*, **суқыр кечеркән** *тмн., лмб.* к.: **айу I: айу табаны 1.**

**суқыр кузлут** *мам.* к.: **кузлут 3.**

**суқыр қычытқан** *дөб.* к.: **печин: гүзәлдәшле печин.**

**суқыр нәркәмәс** *лмб.* к.: **нәркәмәс: кара нәркәмәс.**

**суқыр тары** *т.кам.-крш.* к.: **ут II: тары уты.**

**суқыр ут** *чст.* к.: **пысқыш.** Суқыр ут булды элеке. Уникеләргә хатлек шыл суқыр ут белән киц утыра тырган ыйык.

**суқыр чықан** *т.кам.-крш.*, **суқыр чытқан** *дөб.* к.: **айу I: айу табаны 1.**

**СУЛА: сула қату** 1. *дөб.* эч кату (запор); 2. *минз.* к.: **сулу: сулу қабу.** Сула қатуwына dawa шул, җон белән онны қайнар су белән тугылап сула қатуwына җапқаннар, шуннан қатулары таралып киткән (иске йола).

**СУЛАҒАЙ** *трбс.* сул (левый). Сулағай йақ бото да сызлый.

**СУЛАҚАЙ** 1. *бөре., перм., злт.* к.: **сулағай.** Мондан төшкән җирдә сулақай җақта. – *перм.* Аларның өйләре сулақай йақта. – *злт.*; 2. *перм.* к.: **култырак.**

**СУЛАМА** *каз.ар., бәр.* сумала (смола, вар). Сулама эретеп йатадырыйық. – *блт.* Ат арқасына сулама қойганнар шүрәләләр қупмасын дип. – *мам.* Суламаға йабышқан. – *бәр.* Шүрәләгә сулама җабыштырып бағыйқ дигәннәр. – *дөб.*

**СУЛАМАЙ** *туб.-ирт.д.* к.: **сулахман.**

**СУЛАМЫҚ** *эчк.*, **СУЛАМЫК** *чст.-крш.* дымлы, сулы (влажный, водянистый, пропитанный водой). Әй суламык, суламык, суламыкта була суганнык. Сезләр чакырдыгыз, безләр килдек, Менә шушылай була туганнык (*хал. җыр.*). – *чст.-крш.*

**суламық җир** *эчк.*, **суламык җир** *шрл.* дымлы җир (влажная земля). Кайда суламык җир чыккан, анда чәчмиләр. – *шрл.*

**СУЛАНУ** *лш.* дымлану (сыреть, становиться влажным). Безнең өй сулана, көн сайын җақтык.

**СУЛАНЧА** [*рус.* солонка] *лмб.* к.: **борок.** Кабак башында дранча, Эстәл эстендә суланча (*бор. җыр.*).

**СУЛАУ I** *туб.-ирт.д.* 1. су сибү (поливать). Сулап йебәрәйен қawыннарны. – *тара.*; 2. сулы, елгалы җир (место, богатое водой, где течёт несколько рек); 3. су эчә торган урын (водопой).

**СУЛАУ II** *брб.д.* бик, элгеч (затвор, крючок). Сулауны кәпләп қуй.

**СУЛАУ III** *перм.* к.: **йебетү.** Күбәдә генә қалдийе печинем, йаңгыр сулап китте қый.

**СУЛАХМАН** *хвл.* сулагай (левша).

**СУЛБЫҚ** *туб.-ирт.д.* озынча йомры (овально-продольный).

**СУЛ'ҠА** [*рус.* золка] *срг.* к.: **күмериләк.**

**СУЛЛЫҚ** *минз.* салам түбәле йортларда салам төшмәсен өчен түбәнең кырыена куелган аркылы агач (поперечная перекладина для удержания соломенной крыши). Салам түбәләргә суллык қуйалар салам тешмәсенгә.

**СУЛЛЫК** *чпр.* киртәлек (жердь, пригодная для изгороди). Муни суллыкка йарый тырган, моны аударыгыз.

**СУЛТЫЙ** *эчк.*, **СУЛТЫҚ** *перм.* к.: **сулахман.**

**СУЛТЫҚЛАУ** *кузн.* йөрәкнең көчле тибүе (сильное биение сердца).

**с у л у** (дыхание):

**сулу қаплану** *нгб.-крш.* тын бетү (задыхаться). Йөгергән ийем, сулуwым қапланды.

**СУЛЫҒУ** *лш.* сулу (вянуть); чаг.: **пожу.** Үтәсең дә, ғүмрем, ай үтәсең, Сахралардан искән җил кебек; Сулыгасың да, йөзем, сарғайасың, Өзөлеп төшкән гөл кебек (*хал. җыр.*).

**СУЛЫҚ I** *перм.* бизәкләрне аерып тора торган юл, полоса (полоска, которая разделяет узоры). Тегесен сулыклап суқмадым, менә монсонда да сулык йук, чәчкә генә. Паласның айырылган җире сулык, айырып тора.

**СУЛЫҚ II** *туб.-ирт.д.* авызлык, йөгән авызлыгы (удила). Атның сулыгын ал, су эцерәйек.

**СУЛЫҚ III** *әстр.* 1. к.: **битйаулык.** Сулыгы уннан да ким булмаган, сандыгына салып алып килгән сулыкларын. Ақлыққа килгәндә, мата алып килә қайсы, қайсы сулык әкиләде; 2. сөлге

сыман яулык (полотенцеобразный платок). Кинчәкнең сулыгы башында булаты, сулыктың чите узырлап чиккән.

**СУЛЫКЛАУ** *кузн.* к.: **султыклау**.

**СУМ I** *туб.-ирт.д.* көймә койрыгы (корма).

**СУМ II** *туб.-ирт.д.* калып (форма).

**СУМҒА I** *туб.-ирт.д.* чүл, ялан, дала (степь, пустыня, равнина).

**СУМҒА II** *туб.-ирт.д.* хәҗрә, монах бүлмәсе (келья).

**СУМИЙӘ** *перм., эчк.* к.: **сүwәсе**. Ул кызны сумийә упкынга алып кереп киткән. – *перм.*

**СУМЛАҒАН: сумлаған кеше** *туб.-ирт.д.* к.: **сумцы**. Сумлаған кеше ишәте, сумта утыраты.

**СУМЛАУ** *туб.-ирт.д.* эшкәртү, форма бирү (обделывать, дать форму).

**СУМНЫЙ** *нгб.-крш.*, **СУМНЫҚ** *перм.* бөтен тәнкә, бер тәнкәлек көмеш акча (целковый). Чәчбауга сумныйлар тагалар. Чәчкә сумныҡ тагалар.

**СУМСА** *хвл.* бөккән (пирожки). Кодачалар тевенендә була унмы, уникеме катлама, сумсалар.

**СУМЦЫ** *туб.-ирт.д.* койрыкчы, койрыкта ишүче (сидящий на корме, рулевой).

**СУНА: суна үрдәк** *перм.* зур кыр үрдәге (большая дикая утка).

**СУНАРЛАУ** *туб.-ирт.д.* сунарчылык итү, аулау (охотиться).

**СУНАРЧЫ** *минз.* к.: **илдәтнә**.

**СУНУҒУ** *тбл.* ямансылау, кәефсезләнү (грустить).

**СУҢАҚЛАУ** *себ.* су ерып йөрү (бродить в воде).

**СУҢНАШ-СУҢНАШ** *туб.-ирт.д.* бер-бер артлы (гуськом). Қаслар суҢнаш-суҢнаш китеп параты. – *төм.*

**СУҢЫДАН** *перм.* к.: **анар**.

**СУПАН** [*рус.* супонь] *нокр.* чөелдерек (супонь).

**СУПАТ** *срг.* к.: **азымтыҡ**. Вот супат кеше дә инде, селкенүwенә бакчы.

**СУПИН** [*рус.* супонь] *чст., чпр., мәл.* к.: **супан**. Әтәм, ат туктады, супины тишелгән икән. Супинга йахшы бу кайыш. – *чст.*

**СУПҚАҚ** *туб.-ирт.д.* ябышкак балчык (липкая, вязкая глина).

**СУПЛЫҚ** *туб.-ирт.д.* җәенке, сай (плоский).

**СУР I** *туб.-ирт.д.* соры-зәңгәр (серо-синий).

**СУР II** *туб.-ирт.д.* 1. кыен, авыр (трудно, тяжело); 2. бәхетсезлек (несчастье).

**СУР III** *брб.д.* тыш (наружный, внешний).

**СУРА** *каз.ар., минз., кргл.* ефәк тукыманың бер төре (сорт шёлковой ткани). Сура эчлекле кәлләләр тектек. Сура күлмәкләр әле дә бардыр ул. – *дөб.* Қалынга сура күлмәк китерәләр. – *минз.* Элек қатын-қыз сура қуйалар ыйы күкрәккә, тасма сура. – *кргл.*

**СУРАЙУ** *брб.д.* кырын тору (косо стоять).

**СУРАЙЫП** 1. *кргл.* чыгып, зураеп (увеличившись, высунувшись). Шулхәдәре йабыққан, ике күзе генә сурайып қалған; 2. *каз.ар., т.я.* озынаеп, сузылып (вытянувшись). Сурайып чыгып килә. – *блт.* Сурайып утыра гөлләре тәрәзә төбендә. – *дөб.* Сурайып килеп керде ишектән. Җәри шунда сурайып йуқ эш артыннан. Озын булып, сурайып үсеп килә малайы – гел атасы. – *к.т.*

**СУРАМСАҚ** *туб.-ирт.д.* соранырга яратучы (любитель попрошайничать).

**СУРАС** *брб.д.* к.: **тума II**. Инәмнең абасыныкы қысы сурас китерде, әбилек чақырып алтык.

**СУРАТҚАЛЫ** *төм.* соратып, яучылап (сватать). Минең сеңлемә саучы суратқалы килте.

**СУРӘБӘТ** *чст.* к.: **кукамай**.

**СУРҚУ** *каз.ар., минз.* к.: **кәкшү**. Мондый җауғанда тәгәрмәчкә пычрак ийәрми, ул сурқый башлағач бик нык ийәрә. – *минз.*

**СУРЛЫҚЛАУ** *саз.я.* олылау (почитать, уважать). Сурлыҡлап әйтәтхән пулырлар.

**СУРУКА** [*мари.*] *м.-кар.* к.: **сорока**. Башка сурука белән йөриләр икән.

**СУСИК** [*рус.* сусек] *лмб., хвл., шрл.* к.: **бүлмә 3**. Келәт сусигында бодай күп әле. – *хвл.* Сусик кына сусик ару быдайым. Агайлар килер тийәргә ғенә. Сусикларда сигзән пыдаука булыр быдай. – *лмб.* Хазер сусик йасамыйлар инде. – *шрл.*

**СУСЛАН** *саз.я.*, **СУСЛУН** *глз.*, **СУСЛЫН** *нокр.* к.: **сосун**.

**СУСУ** *т.я.* сусыл (водянистый). Ашы сусу булған. – *к.т.*

**СУСУН** [ *рус.* сосун] *чст., мәл.* к.: **қолқай**.

**сусун тай** *т.я., чст.* к.: **қолқай**. Йәш тайны, ике йәшлек тайны сусун тай дибез инде. – *трх.*

**СУСЫҒЫРЫ** *себ.* эш үгезе (буйвол).

**СУСЫМ** [*рус.* сосун] *мам.*, **СУСЫН** *минз., эчк.* к.: **сасун 3**. Сусын йәш бозау ите була. Сусын ите қаз ите күк була. – *минз.*

**сусым итү** *мам.* к.: **сосын: сосын итү**. Бызавыбызыны без һәр җылны сусым итәбез.

**с у с ы н** (жажда):

**сусын калу** *кузн.*, **сусыны қану** *себ.*, **сусынға тийү** *минз.*, **сусынга тийү** *стрл.* сусаганны басу, эчәсе килү басылу, кайту (утолить жажду). Бик эчкем келәгән иде, ике чашка эчтем, сусыным калды. – *кузн.* Қарыны туйып китте, сусыны қанды. – *себ.* Аны китерсәң бигерәк әйбәт, сусыныма тийәр, дигән. – *минз.* Сусынга тими торгандыр инде, күп итеп чәй эчәр ийең су эчкәнче. – *стрл.*

**СУТАШ** *брб.д.*, **СУТӘШ** *кас., брб.д.* күлмәк бизәү өчен кулланыла торган тар тасма (зигзагообразная тесьма для отделки платья).

**СУТҚАҚ** *минз.* к.: **йепсәк**. Сутқак урында тупыл бик үсә.

**СУТУҢҒА** *саз.я.* юан бүрәнә (толстое бревно). Сутуңға телтерәтеләр.

**СУУ** *туб.-ирт.д.* суыну (остывать, охлаждаться, стать холодным). Көн сувып китте.

**СУУҒУ** *брб.д.* юешләнү (сделаться мокрым).

**СУУҚТЫРУ** *брб.д.* чылату (намочить, промочить).

**СУЧЫНКЫ** *чст.*, **СУЧЫҢКЫ** *т.я.* [*рус.* чёсанки] к.: **сачинкә**. Сучынкы бастырттым, балтыры да тар тегел, кистек урынына да кийәргә была. – *чст.*

**СУШИЛ** [*рус.* сушило] *т.я.*, **СУШИЛА** *чст.* к.: **бастырма**. Печәнне сушилға үдек, бәк күгән. – *трх.* Сушиласында печән тора, йугары йағында, астында утыннар тора. – *чст.*

**СҮБӘК** *злт.* чүбек (очёски, вычески, очёс).

Үзәген буйға, сүбәген артқырысына эрлиләр. Сүбәген дә эрлиләр ийе.

**СҮБӘТ** [*гар.*] *нокр., глз.* к.: **бишек: бишек туйы**. Бәбәй туғач, сүбәт уздырасы булыр. Бер қатын йеде айлық бала тапты, алай да сүбәтен уздырма булалар. – *нокр.*

**бабай сүбәт** *глз.* к.: **бишек: бишек туйы**. Бабай сүбәт йасапсыз икән. Бабай сүбәт йасайлар зур итеп, бабай туғач. – *нокр.* Сүбәт йасайлар зур итеп, бабай сүбәт, икенче, эченче балаларга тәбәгый, белен китерә әбисе. – *глз.*

**өй сүбәт** *глз.* өй котлау мәҗлесе (новоселье). Өй сүбәткә нәселе-йәwере ийылып килгәләде.

**СҮБҮК** [*рус.* совок] *дөб.* соскыч (совок). Сүбүкләрең, себеркеләрең бу төштә торсон.

**СҮWӘК: орчоқ сүwәге** *минз.*, **орчоқ сүwәк** *перм.* к.: **ашық II, 2**.

**отош сүwәге** *перм.* к.: **сәнәк**.

**СҮWӘМ I** *трх.* сөям (пядь, четверть аршина).

**бер сүwәм төн** *трх.* кып-кыска төн (очень, совсем короткая ночь). Бер сүwәм төннө дә жамау жамап утырадырыйың.

**СҮWӘМ II** *перм.* к.: **сөйәм**. Йүкә сүwәмне чыраққа ғына тотабыз.

**СҮWӘРБИ** *шрл.* к.: **ахық**.

**СҮWӘРМӘТ** *перм.* эш рәтен белмәүче (не знающий дела).

**СҮWӘСЕ** *чст.* су иясе, су анасы (водяная). Пидуч карчык балаларны сүwәсе булып куркыткан.

**СҮWӘТӘ** *тпк.* к.: **қуймалақ**. Сүwәтәгә аш салып бирийемме? Бер сүwәтә аш эсте.

**СҮWЕНЕКЛЕ** *трх.* шәфкатьле, изге (милосердный, милостивый, святой). Әдәмнәргә сүwенекле қош – күгәрчен.

**сүwенец** *срг.* сөенеч (радость):

**кылак сүwенеце** *срг.* ярәшелгән кыз өчен бирелә торган мәһәрнең яртысын алдан биреп кую йоласы (старинный свадебный обряд: внесение женихом половины выкупа после помолвки).

**СҮГӘН I** *тмн.* к.: **тудық 3**.

**СҮГӘН II** *туб.-ирт.д.* балык тоту коралы (морда – рыболовная снасть).

**сүгән өңү** *туб.-ирт.д. сүгән*нең тышкы капкачы (наружный колпак).

**сүгән үзәне** *туб.-ирт.д. сүгән*гә керү урыны (вход в морду).

**СҮГЕШҮ** *туб.-ирт.д.* сүгенү (выражаться).

**сүз** (слово):

**йакшы сүз бирү** *кузн.* к.: **сүз бирү**. Башкода бер-ике көн шулай йөрөгәч, йакшы сүз бирәләр. Йакшы сүз бирү инде ызначит ризалык бирәләр кызның эти-әниләренә, башкыдага бирә, әпәй-тоз, үзләре йаба инде, әпәй-тоз, йакшы сүз бирдек дип сүлиләр.

**сүз алышыну** *карс.* куелган вәгъдәне үзгәртү (изменить своему слову, обещанию). Башкыданың кулына тыттыралар инде сүз алышынмасын эчен бер платинса – йезлек.

**сүз бетерү** *кузн., лмб., тмн.* кызны бирергә килешкәч, туй һәм аның кирәк яраклары (мәһәр, бирнә һ.б.) турында сөйләшеп хәл итү (последние окончательные переговоры, договорённость о свадьбе и свадебных расходах, о приданом и др.). Ата-анасына йараса, биргән инде кызны, давай бирәбез инде, сүз бетерәбез, диләр. – *кузн.* Сүз бетерергә килгәндә, падарка китерәләр, син кийәү йагына кулйаулыгымы, баж йаулыгымы, йезлекме биреп йибәрәсең. – *лмб.* Алай булса, кызым, бу башкода сине сорый килгән бер байга, Сине бирмәк булдым, сүз бетердем, Awыл байы Мәхмүт агайга (*бәет.*). – *тмн.*

**сүз бирү** *кузн.* кызны бирергә ризалык бирү, вәгъдә бирү (дать слово, согласие выдать дочь).

**сүз йасау** *нокр.*, **сүз килмеше** *кузн.* к.: **ақлашу**. Йаучы килеп қызны сырый инде. Селге бирәләр қыз йақтан, ә теге йақтан селге, ақча бирәләр. Бу була инде сүз йасау. – *нокр.*

**сүзгә кермәү** *кузн.* сүзгә күнмәү, киреләнү (упрямиться).

**сүз(гә) куйу** *кузн.*, **сүзгә салу** *нокр.* к.: **ақлашу**. Сүзгә куйарга киләләр. Берәр йыл узгач, бу кызны сүзгә куйалар. Башкыда сүзгә куйганда паднус китерә, кызга күлмәк китерәләр, кызның башына китерәләр. Ике атнагамы куйа, эч атнагамы куйа сүзне. – *кузн.* Сүзгә салғачын, селге биргәчен қызаш дип ашқа йергәләде, үзенең дустымнары, қәрдәш-қәбиләләре чақыра. – *нокр.*

**сүзгә чыгару** *лмб.* гайбәтен сөйләү, яманатын сату (ославить, распространять дурную славу, сплетничать о ком-либо). Сүзгә чыгарыр эчен йабалар иде кызны.

**СҮЗӘНӘК** *том.д.* сөзә торган (бодливый).

**СҮЗЛӘШҮ** *нокр.* сүз куешу (договориться между собой). Сүзләшкәннәр йегет белән қыз.

**СҮЗМӘКӘР** *злт.* сүзчән, сөйләшергә ярата торган (словоохотливый, разговорчивый). Аның сүзе, әй сүзмәкәр хатын ул, белмәгәне йуқ.

**СҮЗҮК** *брб.д.* үтә күренмәле, чиста (прозрачный, чистый).

**СҮЗҮЛҮ** *брб.д.* арыганлыктан күз йомылу (закрываться от усталости – о глазах).

**СҮИТЛҮ** *туб.-ирт.д.* сөекле (любимый).

**СҮЙӘМ** *туб.-ирт.д.* сөям (четверть).

**СҮЙӘМЛӘҮ** *туб.-ирт.д.* чирекләп үлчәү (мерить четвертями).

**СҮЙМӘН** *туб.-ирт.д.* боз вата торган корал (пешня).

**СҮЙРҮ** *туб.-ирт.д.* **1.** очлы (заострённый); **2.** чөгә (стерлядь).

**сүйрү шалган** *туб.-ирт.д.* гәрәнкә (брюква).

**СҮК** [*рус.* сок] **1.** *каз.ар.* к.: **сук**. Сүкне кесәл белән ашыйлар ыйы, сөт булмағанда. – *лш.* Орлоқны уwасың да қул белән майын сыгып аласың, қалған түбен жылымса суда изәсең, иләк аша сөзәсең, иләк астында аппақ сүге қала. – *блт.*; **2.** *каз.ар.-крш.* к.: **әнәчә 1**; **3.** *брб.д.* солы ярмасыннан пешерелгән ботка (каша из овсяной крупы). Қасанга су қойоп соло салып қайнатып алаты кибәге мән. Аны йәйеп қоротады. Қалай ман аны пицкә қуйып қоротып алғаннан сун, агацтан эшләнгән ашлау, киле мән төйөп, кибәген қойаты, ашлауты кибәген оцораты. Солосын қул тирмәне мән тартады. Йармасын сүк итеп ашайты. Сүк тиләр, соло қайнатып аш салатлар. Өстенә май қойоп ашайтылар.

**СҮКӘЛҮ** *бөре., минз., хвл.* кагылып китү, орынып китү (дотронуться, прикоснуться). Сүкәлмә миңа. Песи бер дә алай сөткә сүкәлмәй иде. – *бөре.* Кочок сүкәлеп киткән. – *хвл.* Моңар сүкәлмәгез дә тийе. – *минз.*

**СҮКӘҮ 1.** *лмб., тмн.* тирәли әйләнү (обходить кругом). Кочок ни сүки бала йагалый. – *тмн.* Сүкәп тийенгән урнына ташладык. – *лмб.*; **2.** *карс.* тидереп алу, төртеп алу – имнәгәндә (касаться, тыкать – при заговаривании ячменя). Чәршәмбе көн йапкан әпәйнең күшәмен сүкиләр дә... (арпа имнәгәндә).

**СҮКЕ** *туб.-ирт.д.* төрбә (гробница).

**СҮКЕЛӘҮ** *туб.-ирт.д., брб.д.* сүгү, орышу (бранить, ругать, хулить). Инте сүкеләтеләр собранйәтә. – *тбл.*

**СҮККЕ I** *саз.я.* к.: **киртмә III, 3.**

**СҮККЕ II** *перм.* сүгенү сүзе (ругань, сквернословие). Бер генә сүкке әйтсен – суға дип чыга да йөгөрә.

**СҮККЕЛӘНҮ** *перм.* сүгенү (ругаться, сквернословить). Көлмәгә йәбештеләр, сүккеләнмәгә биг остайкән диләр.

**СҮККЕЛӘҮ** *әчк.* ачулану, тиргәү; гаепләү (ругать; осуждать). Сүккеләп китмәгез инде безне.

**СҮКМӘН 1.** *саз.я., тбл.* чикмән (чекмень). Элек сүкмән кийәтегән итек. – *тбл.*; **2.** *тара.* калын сукнодан тегелгән кафтан (сермяга). Йигет ак сүкмән киде, шалбыр киде.

**СҮЛ** *туб.-ирт.д.* итне кыздырганда чыккан сыекча (сок, выделяемый при жарении мяса).

**СҮЛӘГЕР** *себ.* сөйләргә яратучы (разговорчивый, любящий поговорить). Туғыста (*ав. ис.*) пер қарт пар, сүләгер әшкәрә.

**СҮЛӘМӘҮ** *чст.* сөйләшмәү, тел яшерү (обычай не разговаривать со свёкром и со старшими братьями мужа). Сүләмәдем әтиләр белә, бер дә сүләмәдем, биш йыл тырдым.

**СҮЛӘНЧӘК** *баст.* к.: **сүләгер.** Минем кебек сүләнчәк бысы.

**СҮЛЕК** *перм.* к.: **сел'ык.**

**СҮЛИ: сүли торған** *т.я.-крш.* к.: **цилбәй.** Сүли торган җегетләр күбийе, барсын да қалдырып моңа цыктым.

**СҮЛПӘН** *т.я., кмшл., мәл.* йомшак, сыек – җеп кату турында (слабо – о сучении нитки). Җонно бик сүлпән қатма, чираң қат, сүлпән қатылған җон таза булмый. – *т.я.* Йенеңне бик сүлпән қатқансың. – *кмшл.*

**СҮЛТӘКӘ** *стрл.* тәбәнәк һәм бөкре – кеше турында (низкорослый и горбатый – о человеке). Сүлтәкә булса да, эшләмәгән эше йук, җитмәгән җире йук.

**СҮНБЕЛӘ** *туб.-ирт.д.* Кыз йолдызлыгы, август (созвездие Девы, август).

**СҮНДӘРӘ** *каз.ар.* к.: **сүндерә.** Сүндәрәңне сүтәм дип әйтте, сүндәрәгә менеп җатасың дибәйтте. – *каз.ар.-крш.*

**СҮНДЕРӘ** *каз.ар.*, **СҮНДЕРИ** *кас.* сәндерә (полати). Бабай мемми анда сүндерәгә, тым бетә, ди. – *каз.ар.-крш.*

**сүндерә қашағасы** *нгб.-крш.* к.: **сәндерә: сәндерә қаш.** Сүндерә қашағасына ғына элеп қуй қупайқаңны.

**сүндерү** (гасить, потушить):

**күмер сүндерү** *перм.* утлы күмерне сүндереп җыеп бару (копить потушенный уголь). Күмер сүндермиләр дә сорап йөрөйләр. Мин күмер сүндерәм дә аларға бирәм.

**СҮҢКҮ** *себ.* сөңге (копьё). Қылыцын қырлап, сүңкүсүн сүрәтеп алтанды.

**СҮНҮ** *минз.* йоклап китү (заснуть). Быраз ғына сүнсен әле, аннан ашарбыз.

**СҮРӘ** *перм., к.-уф.* **1.** печән өемен машина яки ат белән эскерткә тарттыру өчен үсеп утырган яшьрәк каен агачын кисеп ясалган җайланма (приспособление из срубленных молодых берёз и т.д., применяемое при перетаскивании волоком сена; волокуша). Сүрәгә төйәп чыгарабыз. – *к.-уф.*; **2.** шушы җайланмага салынган печән өеме (копна, куча сена на волокуше).

**СҮРӘКӘ** *крш.* маңгай һәм чигә турыларына ука тасмалар беркетелеп, тасмаларның очлары баш артына китереп бәйләнә торган баш киеме: баш такыя кигән сыман тора (один из видов головного убора у крещёных татарок). Қарчық булғач та сүрәкәне чишмәдем. Сүрәкә ике мөгезле, удмуртлардағы кебек башқа кийә торған инде. – *каз. ар.-крш.*

**СҮРӘКЛӘҮ** *перм.* өстерәү (таскать, волочить по земле). Сүрәкләп алып китте утынны. Мичкә дә бәргәннәр, сүрәкләп тә йөргәннәр қапчыкны.

**СҮРӘТ** [*гар.*] **1.** *шрл.* фоторәсем (фотокарточка). Сүрәт тешерергә бик ыстайы. Ул wахытта сүрәт былмаган; **2.** *дөб.* ямьсез (некрасивый, невзрачный); чаг.: **кукамай.** Баласы бик сүрәт икән.

**СҮРӘТКЕ** *перм., злт., байк.* к.: **сүрә 1.** Күбә йасап җийалар, мендәр зурлығы ғына итеп күбәлиләр дә сүрәтке белән җийалар. – *перм.* Сүрәткегә төйәп пецәнне сүрәтке белән тарттырабыз. – *байк.*

**СҮРӘТМӘ** *минз., стрл.* чәчкән ашлыкны күмдерү өчен тырма артына тагылган ботаклы агач (ветвистое дерево, которое прикрепляется к граблям для закапывания засеянного зерна). Артына чыбық тағалар, ансы тары себертер өчен, аны сүрәтмә диләр. – *минз.*

**СҮРГҮЦ** *том.д.* кар көри торган көрәк (лопата для разгребания снега).

**СҮРЕГҮ** *мәл.* к.: **кәкшү.** Карале, айбагарларының эстен бутап йебәр әле, эсте сүреккәндер аның.

**СҮРЕК** *себ.* укборын (севрюга).

**СҮРЕЛҮ** *шрл.* к.: **сирелү.** Кунаклар әле сүрелделәр, йырт сайын иде.

**СҮРКЕТҮ** *кузн., хвл., чст.* к.: **кәкшетү.** Беген койаш бага төшә, җирне берсәк сүркетер. – *кузн.*

**СҮРКҮ 1.** *кузн.* сарку (просачиваться). Марлы үтәли сөзәсең, сүркә көн буйы (катык); **2.** *чст., мәл.* кибү, кипшенү (подсыхать). Йаргалап кертергә булыр әле, тенката сүркер ул. – *мәл.*

**СҮРСҮ** *кузн.* к.: **қабығу 2.** Бу салам ометына су үткәнгә сүрсеп беткән.

**СҮРҮ I** *блт.* сүрелдерү (перестать горячиться,

заставить остыть). Бик қызғаныйым, тағы үземне-үзем сүрдем.

**СҮРҮ II** *себ.* көтү (стадо).

**СҮС** *нокр., бөре.* к.: **мошко I, 1**. Сүс чәчәдерийек, аны талқыйдырыйық. – *бөре*.

**буй сүс** *бәр.* җитен сүсенең иң яхшысы (лучший сорт кудели). Буй сүстән әзерләп йақшы киндер суқтық.

**СҮСӘН 1.** *каз.ар.-крш.* кыяк үлән (осока). Сүсән қулын кискән, бармағы қаный; **2.** *мам., каз.ар.-крш.* ак кырчыл (полевица белая; полевица обыкновенная).

**сүсән печән 1.** *бәр.* к.: **сүсән 2**; **2.** *минз.* к.: **солыча**.

**сүсән уты** *дөб.* кылчыксыз сүсән (костёр безостый).

**СҮСӘНУТ 1.** *блт.* к.: **сүсән 1**. Сүсәнут қаты қыйақлы була, нәзек, чawып та булмый; **2.** *әчк.* к.: **зибәләй: зибәләй үлән**.

**СҮСКӘР** *әстр.* күп сөйләшүчән (болтун).

**СҮСМӘГЕР** *туб.-ирт.д.* сүзчән (говорливый, разговорчивый).

**СҮСМӘКӘР** *туб.-ирт.д., том.д.* к.: **сүсмәгер**.

**СҮТЕК** *минз.* җыйнаксыз, таркау (неряшливый, неаккуратный). Үзе сүтек кенә, ә ашы тәмне була аның.

**СҮЦҮК** *туб.-ирт.д.* җиләк-җимеш суы (сок).

**СЫБА** *злт.* ак киндердән тегелгән өске кием, элек хатын-кызлар кигән (женская верхняя одежда из белого домотканого полотна). Пәлтә йуғ ыйы элек, сыба кидек. Сыба булса, зур байлық әле ул.

**СЫБАГАЧ** [*рус.* цеп + агач] *лмб.* к.: **чип I**.

**сыбагач кебәк** *лмб.* чабагач сабы (цеповище).

**СЫБАЙ** *перм., әчк., к.-уф., минз., злт., кргл., стрл.*, **СЫБАЙЛЫ** *тпк.* к.: **ждагат**. Ул йақта ат белән сыбай килә. – *әчк*. Сыбай көтәләр хәзер сыйырны. – *перм*. Быригадир сыбай йөри. – *к.-уф*. Кәwәлирләр килә, бар да сыбай. Мында сыбай йөриләр awыл қырыйында. – *минз*. Безнең awылдан уннап сыбай килә. – *злт*. Ул йегет минем йанға сыбай килә. – *кргл*. Пычыракта сыбай барадырыйык атның койрогын төйнәп. Сыбай бардыңмы? – *стрл*. Сыбайлы кеше китеп бара. Сыбайлы барасың, ат менеп ийәрләп тороп. – *тпк*.

**СЫБАР** *трбс., злт., тпк.* чуар (пёстрый). Сыбарырақ күлмәк ки. – *злт*.

**СЫБАШУ** *сазя.* ябышу, чәерләнү (склеиваться). Цац, йақшы йуылмаса, сыбашып тора.

**СЫБРА** *туб.-ирт.д.* тиредән ясалган куна (доска для стряпни, сделанная из кожи).

**сыбызгы** (свисток, дудка):

**сыбызгы кывагы** *лмб.* к.: **қузақ: қузақ ағачы**.

**СЫБАЛ′, СЫВАЛ′ЧАН** *кузн., мәл.* к.: **селәү II, 1**.

**сывалчан үләне** *лмб.* к.: **албидрә**.

**СЫВАН** *мәл., хвл.* к.: **сywанаш**. Сыван салма пешердем. – *мәл*. Ит йук чакта катыклы аш пешерәсен, май сызгырып та пешерәбез. Салма саласын. Сыван аш була. – *хвл*.

**СЫWУ** *злт.* суыну (остывать). Сәй көйләп қуйсам, сыwыр. Ақ мынса тиз сыwый. Қыз, сәйең сыwый.

**сывык** *миш.д.* суык (холод; холодный):

**су сывыгы тыту (алу)** *лмб.* к.: **шом I: шом тоту**. Су сывыгы ала. Су сывыгы тытсын үзеңне.

**сывык алу** *лмб.*, **сыwык сугу** *тмн.* к.: **сywық: сywық суғу**.

**сыwық тоту** *к.-уф.* к.: **шом I: шом тоту**. Элек күп кеше сыwық тоту белән awырыййы, хәзер бетте.

**сыwық чир** *к.-уф.* к.: **шом I: шом тоту**. Йәшлектә сыwық чир белән awырдым.

**СЫВЫКЙАК** *кузн., хвл.* төньяк (север).

**СЫWЫҚСУ** *нгб.-крш.* к.: **сywық: сywық суғу**. Ирем сыwықсып үлде.

**СЫВЫР** [*рус.* сор] *кузн., лмб.* чүп (сор). Үлене алып киткәч, бармы сывыры, йукмы сывыры, ишек төптән түргә чәре идәнне себерәләр, бөтен нәрсәне йывалар. – *кузн*.

**бер сыwыр шырпы** *кргл., бгрс.* бер шырпы (спичка). Хәзер қыз бер сыwыр шырпы ала да бабайға бирә. Менә шул шырпыны патшаға бир, ди (*әкият.*). – *кргл*.

**СЫВЫРЛАУ** [*рус.* сор + *афф.* -лау] *кузн.* чүпләү (сорить). Нәстәгә монда тагы сывырладыгыз инде?

**СЫВЫРЛЫ** [*рус.* сор + *афф.* -лы] *тмн.* чүпле (сорный, засоренный). Әткәй, абзарың сывырлы, Метла гына алып себерче (*бор. җыр.*).

**СЫВЫРЛЫК** [*рус.* сор + *афф.* -лык] *кузн.* тиреслек, чүплек, чүплек башы (место свалки навоза, навозная куча, свалка).

**СЫВЫРУ** *кузн.* к.: **сywыру**. Ике керәк белән тенне сывырдык.

**СЫВЫРЫЛУ 1.** *тмн.* аерылу (расстаться). Сывырылып китә алмадым; **2.** *мәл.* суыну (остудиться, охлаждаться). Ызбам берчи сывырылды.

**СЫГАНУ** *кузн., мәл.* сызгану (засучить). Пирут җиңеңне сыган, аннары йыварсың. – *мәл*.

**СЫҒУ** *сазя.* кысу, кысып тоту (сжать, сжимать). Пеләгемне сығып қуйты. Сығып үлтермә. Кигертәгеңне сығарым.

**СЫГЫЗ** *чпр.* сызык (шкварки). Бер кашык кына цыкты сыгыз.

**СЫҒЫЛМАЛЫ** *тя.* пружиналы (пружинный). Сығылмалы карawат алган безнеке ишене. – *к.т.*

**СЫГЫМ** *м.-кар.* к.: **астыр**. Сыгымрак ул анда, анда сушыны чәсәргә кирәгә.

**СЫҒЫНУ** *трбс.* ялыну (умолять). Сығынып әйтәм инде үзеңә хәзер.

**СЫҒЫҢҚЫ** *трх.* к.: **астыр**.

**СЫҒЫР** *злт.* к.: **чығыр I, 1**. Сығыр белән җеп эрләгәнне йазарға килгән.

**СЫҒЫРТҚЫЦ** *туб.-ирт.д.* сыбызгы (свисток).

**СЫҒЫРУ I** *сазя.* карын ачу, ачыгу (проголодаться). Қәйер, сығыртыгысма?

**СЫҒЫРУ II** *туб.-ирт.д.* сызгыру (свистеть).

**СЫҒЫТ** *туб.-ирт.д.* елау (плач). Пер ай пулаты сығытын қуйғанга. – *тбл*.

**СЫДЫРТУ** *перм., минз.* ышкыту (обтереть). Кийемеңне стенаға сыдыртып буйама. – *минз*.

**СЫДЫРУ** *перм.* **1.** к.: **быргыту**. Төшәп йарка (утын агачы) сыдырып йеппәр ий шуларға (тавыкларга), иренәм; **2.** оекның кунычын чабата киндерәсе өстенә төшереп кую (опускать паголенок чулка поверх оборок лаптей).

**СЫЗА** *т.кам.-крш., каз. ар.* ызан (межа). Ҡәзер ҙирләр арасында сыза ҡалдырмыйлар инде. – *т. кам.-крш.*

**СЫДАТЛАП** *тпк.* к.: **сугу II: буйлап суғу.** Ашаулыҡны ҙоҡа ғына итеп суғалар ыйы, ҡыдылға дәнкәрне сыдатлап суҡтылар.

**СЫЗҒЫ 1.** *перм.* к.: **ҙәмкә; 2.** *злт.* к.: **күмериләк.** Сызғы белән күмер алырға китә торған ыйыҡ.

**СЫЗҒЫРТМА** *блт., мам.* сыбызғы (свисток). Менә сызғыртма йасадым ҡузаҡтан. – *блт.*

**СЫЗҒЫРУ** *перм.* суелган хайванның маен эретү (вытапливание сала). Сыйырның майын сызғырасың, майын аласың, сызыҡ ҡала.

**СЫЗҒЫРЧЫҠ** *хвл.* к.: **сызғыртма.**

**СЫЗҒЫЧ** *глз., нокр., бөре.* шырпы (спичка). Сызғыч кетермә ынытыпмын ич лафкадан. – *нокр.*

**СЫЗДЫРУ** *клд.* к.: **йару I, 1.** Бер-ике көннән сыздырым инде, картофым үскән.

**СЫЗЛЫҠ** *туб.-ирт.д.* мүкләү өчен ҙайланма (конопатка: орудие труда, которым конопатят).

**СЫЗМА** *т.кам.-крш.* ефәк тасмадан күлмәк итәгенә яки калфакка аркылы салына торган бизәк (узор из шёлковой ленты, тесьмы на платье или на колпаке). Бәби итәк ҙасыйлар ыйы, сызма ҡуйалар ыйы матурлыҡ өчөн, ҙефәк тасма.

**СЫЗМАЛЫ** *т.кам.-крш.* бер рәт бизәк чыгарылган (с узором в один ряд, в одну полоску). Әзәй буйларыннан әз киткән, Ак калпакай кигән кыз киткән. Ак калпакайы сызмалы, Без Йакты Күл (*ав. ис.*) кызлары (*хал. җыр.*).

**СЫЗУ 1.** *т.я., каз.ар., тмн., чпр.* к.: **йару I, 1.** Ҡул белән күтәрәбез, суҡа белән дә сызалар. – *каз. ар.-крш.* Сызғач ашамыйлар ҡазлар бәрәңгене. Бездә суҡа белән сызалар бәрәңге бақчасын. – *лш.* Икенче ҡатын утағач, суҡа белән сыздыҡ бәрәңгене. – *к.т.* Китте йаңғыр, ат белән дә сыза алмыйлар. – *чпр.*; **2.** *трх.* сую (резать). Хәмәтшәриф сызды микән үгезләрен?

**СЫЙ 1.** *кузн.* кызның әти-әнисен кияү ягына өч көн рәттән кунакка алу йоласы (один из свадебных обрядов: угощение, устраиваемое родственниками жениха в честь родителей невесты); **2.** *клд.* кызны килешкәч, егет ягында була торган мәжлес (угощение на стороне жениха после сговора). Кыда-кыдагый сүләшә сый йасарга. Сый йегет йагында.

**кеце сый** *срг.* зур туйдан соң якын туганнарны чакырып кунак итү (угощение близких родственников, устраиваемое после свадьбы). Кеце сый кыз йагында да, йегет йагында да була.

**сый кайтару** *кузн.* егет ягындагы туйдан соң кыз ягында үткәрелә торган мәжлес (угощение в доме невесты, устраиваемое на следующий день после свадебного застолья на стороне жениха); чаг.: **ҡайтарма: кийәү ҡайтармасы.** Иртәсен инде кыз эвенә сыйга алалар, сый кайтару дип әтелә. Анда инде үз симийәсе, үз кардәше, ата-ана, быраты-катнысы сыйга килә.

**сый эндәргә килү** *карс.* яшь кияү белән кәләшне кунакка чакырып килү (приходить с приглашением в гости жениха и невесты). Ике кайынсеңнем килде сый эндәргә, аларга күлмәк, берсенә йабына торган шәл салдым.

**сыйыр сыйы** *каз.ар.-крш., чст.-крш.* к.: **ақ I.** Аннан ары сыйыр сыйлары була торған ыйы туйда, сөзмәләр сөзә торғаннар ыйы, тугаруклар, ҡаймаҡлар ҡайната торғаннарыйы. – *каз.ар.-крш.* Шилыкка чыкканда да сыйыр сыйлары әзерләп алып баралар. – *чст.-крш.*

**уртак сый** *кузн.* кыз һәм егет өендә бер үк көндә үткәрелә торган мәжлес (угощение в доме жениха и невесты в один и тот же день). Чебелдек теккәннән соң уртак сый буладыр, кыз эвендә дә кунаклар йыйалар, шул көнне кийәү эвендә кийәү йегетләрне сыйлыйлар.

**СЫЙА I** [*фарс.*] *кас., себ., әстр.* язу карасы (чернила). Сыйалары кипкән. – *әстр.*

**СЫЙА II** *себ.* балык агы, балык сөте (молоки).

**СЫЙА III** *минз., стрл.* яңғырдан соң җыелып торган су, күлләвек (лужа, возникшая после дождя).

**сыйа булып төшү** *бгрс.* к.: **гөренте.** Шәп йаңғыр йәwа, ҡойаш ҡыздыра, ҡары-нийе белән су кинәт төшә, шуны сыйа булып төшә дибез.

**СЫЙАУ** *кузн., мәл., хвл., чпр., чст., кас.* к.: **сийау.** Сыйаулар калмады. Иске каберләрдә сыйаулар цыга иде. – *чпр.* Сыйау – чабата тугый торган. – *мәл.* Әнекәйем, тырнаклары сыйау кебек. – *чст.*

**СЫЙБАҒАС** [*рус.* цеп + агач] *злт.* к.: **чип I.**

**СЫЙҒЫЛЫҠ** *төм.* мәҗлес (угощение, сборище для проведения обеда). Тәсторған түшәп сыйғылық йасайты.

**СЫЙҒЫРЦЫ** *туб.-ирт.д.* сихерче (колдун, волшебник).

**СЫЙҒЫС, СЫЙҒЫЧ** *к.-уф.* к.: **сызғыч.** Сыйғыс бир әле ут йағарға. Сыйғыс мунчаның йүшкәсендә ҡалған.

**СЫЙЛАУ 1.** *әстр.* хөрмәтләү (оказывать почтение, уважение). Үлене сыйлап бағырсақ пешерәләр, үле коранына пешерәләр. «Үлене сыйлаған кешенең тересе дә ач булмас», – дигәннәр әзилдә; **2.** *брб.д.* бүләк итү (подарить). Нурғали абыйсы тәптәр сыйлап салты.

**СЫЙЛЫ** *себ., әстр.* хөрмәтле (почётный). Атамыз бик сыйлы кеше булыпты. – *әстр.*

**СЫЙЛЫҠ** *әстр.* кунаклар өчен, туй мәҗлесе өчен әзерләнгән ашамлыклар (еда, угощение, приготовленное для свадьбы).

**сыйлық ҡуйу** *әстр.* сарыкның башын пешереп дәрәҗәле өлкән кеше алдына кую (обычай ставить перед почётными гостями печёную голову овца). Ҡуй суйалар, зур кешегә баш ҡуйарға кирәк, ул сыйлық ҡуйу булады.

**сыйлық күрсәтү** *әстр.* туй ашамлыкларын кунаклар алдына кую (преподнести свадебные угощения гостям). «Менә безнең сыйлығыбыз, күрегез»,– дип кисеп-кисеп, турап-турап дастарханға сала иде. Бу – сыйлық иде, сыйлық күрсәтү иде. «Хәйерле булсын ашығыз»,– ди, туйга килгән халыҡлар әйтә.

**сыйлық күрү** *әстр.* хөрмәт күрү, сыйлану (быть уважаемым, почитаемым). Ҡода балаларға да бирә

баш итен (сарык башының итен). «Менә минем кебек карт булығыз, сез дә шулай сыйлык күрегез», – дип бирәде.

**сыйлык өләшү** *әстр.* туйдан соң туйга әзерләнгән ашамлыкларны туганнарына һәм күршеләренә өләшеп ашату (раздать остатки свадебного угощения соседям и родным). Икенче көнне қодағый чәй қайнатып чәйгә чақыра иде қардәшләрен. «Менә маға тартқан аштан awыз итегез», – ди. Ул сыйлықны, килгән ашны туған-тохомына кисәк-кисәк бүлеп салып өләшәләр. Ул ашны бирмәсәң – үпкәли. Өлеш бирсәләр – санға санау була. Ул сыйлықны, ашны биргәндә әйтәләр: «Синең малайыңа да җуш булсын, синең қызыңа да җуш булсын», – дип.

**СЫЙЛЫККА** *хвл.* к.: **аруга I**. Шоноң бийеклеге балаклы вал'ник иде, берсе сыйлыкка гына, берсе прастуйга – ничәшәр кийем.

**СЫЙЛЫҚЛЫ** *әстр.* кунакчыл (гостеприимный). Сыйлықлы бездә халық.

**СЫЙМАЛАУ** *том.д.* сыйпау, сыйпалау (гладить).

**СЫЙПЫҢҚЫ** [*рус.* сыпать] *трх.* ашлык салганда кулланыла торган цилиндр формасындагы бер тоткычлы савыт (посуда в форме цилиндра с одной ручкой, употребляемая при засыпке зерна).

**СЫЙРА** *мәл., чст.* к.: **қайтара 2**. Нүwешкә ике сыйра нүwек түдем инде. Эц сыйра цабына дийен. – *чст.*

**СЫЙРЫМТА** *т.я.* к.: **сырымта**.

**СЫЙСУ** *сазл.* сыйдыру, тыгызлап кертү (вмещать, плотно набить).

**СЫЙСЫЛУ** *туб.-ирт.д.* кысылу, кысылып керү (втискиваться, втиснуться).

**СЫЙУ** *мәл.* **1.** туры килү, әләгү (попасть, попадать). Анда ул сакрашчинийага сыйды; **2.** керү, мөнәсәбәттә булу (относиться). Алай сез мишәргә сыймыйсыз.

**СЫЙЫЛ** *туб.-ирт.д.* **1.** шырпы (заноза). Қулыма сыйыл гаталты; **2.** балыкның сыртындагы вак кылчыклары (мелкие кости на спинной части рыбы).

**СЫЙЫНДА** *кргл.* хәлендә, хәлле (в силах). Йә, сыйындамы? Ул әле сыйында.

**с ы й ы р** сыер (корова):

**қыдай әби сыйыр** *глз.* к.: **бийауса**.

**қыр сыйыр** *перм.* к.: **болан: болан сийыры 1**.

**мугла сыйыр** *глз.* к.: **туқал**. Мугла сыйырым кайтты.

**сыйыр койрык** *глз.* тар яфраклы ат кузгалагы (щавель узколистный).

**сыйыр куригы** *чст.* соры кыркырый (икотник серо-зелёный).

**сыйыр теле I 1.** *хвл.* эремчек сумсасы (пирожки с творогом); **2.** *туб.-ирт.д.* коймак (оладьи); **3.** *т.кам.-крш.* озынча юка булка (длинная продолговатая булка). Әпәй пешердем дә қалган қамырдан сыйыр теле пешердем.

**сыйыр теле II** *бөре.* **1.** буяу ясау өчен кулланыла торган үлән (растение, используемое для изготовления краски жёлтого цвета). Сыйыр теле, дидер ийек. Танып буйыннан җыйып, сарыға манадырыйық. Сыйыр теле сазда, әрәмәләрдә була, ат қузғалағы сыман ақ җапрақлы; **2.** к.: **қазайақ II**.

**СЫЙЫРУ 1.** *мам., кмшл.* сыдыру, тырнату – тире турында (содрать, ободрать – о коже). Айағын сыйырып бетергән чәбедән төшкәндә. – *кмшл.*; **2.** *дөб.* сыдыру (сдирать что-либо). Көндөз қазларны җыйылып җолқалар қызлар, кисен, ботқасын пешереп, қаурый сыйырып кис утыралар инде; **3.** *т.я.* кайтару, сызгану (засучить). Җиңнәрен сыйырған, балақларын сыйырып қуйган.

**СЫЙЫРЧЫК** *чст.* **1.** куырган киндер орлыгы (жареное конопляное семя). Киндерашны, киндер орлыгын казанда курып аши идек. Ул майлы була, йарма-йарма, бөртек-бөртек тора. Сыйырчык дип атала. Сыйырчык курып ашадык әле, диләр; **2.** камыр ашы: юка гына итеп җәелгән төче камыр шакмак-шакмак итеп киселә, аларның уртасында повидло яки төелгән шомырт ягылып ике яктан гына тоташтырыла (мучное блюдо: тонко раскатанное пресное тесто нарезается на квадраты, на них кладётся толчёная черёмуха или повидло, и затем две противоположные стороны этих кусочков теста соединяются на середине).

**СЫЙЫРЧЫҚ** *баст.* киндер орлыгы кушып пешерелгән күмәч (хлебцы с конопляными семенами). Сыйырчық йасыйлар киндераштан, түгәрәк итәләр, үпмәк белән қатыштыралар.

**СЫЙЫШУ** *чст.* сыю (умещаться). Йылы сеwәк сыйыша.

**СЫКЛАНУ** *чпр.* к.: **қызу I**. Кизләүгә тешсәм, суны сыкланып эцәм.

**СЫКЛАНЫЧ** *лмб.* соклангыч, кызык, күңелле (восхитительный). Туйлар сыкланыч була бездә.

**СЫКЛАНЫШУ** *лмб.* к.: **сокланышу**. Сыкланышып үләнделәр.

**СЫҚРА** *перм.* к.: **мыжым**. Сыкра нимәләр чамасыз.

**СЫҚТАҚ** *перм., себ.* елак (плакса). Сыктамады үзе, сыктак түгел алый. – *перм.*

**СЫҚТАУ** *перм., нгб.-крш., әчк., бөре., себ.*, **СЫКТАУ** *кузн., глз.* елау (плакать); чаг.: **вернәү**. Бала сыктап йата. – *әчк.* Хәзер уқып җиппәрәм, сыктап җиппәресез. Ул сыктый, мин сыктыйм, ул кайткан чағында. Сыктый у, аннан кире сыктағас, аны суқмаға кәрәк. Сыктамаға кереште. – *перм.* Бүген мин дә сыктап алдым. – *кузн.* Җырладым-җырладым да сыктаб алдым әле. – *бөре.* Дагы сыктап китәмен кат йук дип. – *глз.* Қайту гәрәк, малай сыктар анта. – *тбл.*

**СЫҚЫ** *перм.* юылмаган, керле – йон җебе турында (грязная, немытая – о шерстяной нити). Җебе сықы, шумый, тығыз, җумағач.

**СЫЛ I 1.** *хвл.* камыр изү өчен махсус әзерләнгән сыекча: яңа гына кайнап чыккан колмак суына он болгатып, томалап куялар; бераз вакыттан соң, төче ис килә башлагач, чүпрә салып камыр изәләр (специально приготовленная жидкость для заварного хлеба). Йомшак куйарга сыл чөчөтәм; **2.** *эчк.* көрпәне суга салып ачыту юлы

белән ясалган чүпрә (дрожжи, приготовленные путём квашения высевок в воде).

**СЫЛ II** *чст.* ылыс (хвоя).

**СЫЛ III** [*гар.*] *мәл.* сер, рәт, җай (секрет, порядок, лад); таг.: **ғыйллә 2.** Сылын белмисең бит кеше мататсиклының.

**СЫЛА** *минз., бөре., трбс.* судак.

**СЫЛАWЫЩ** *срг.*, **СЫЛАВЫЧ** *кузн., тмн., хвл., лмб., әстр.* к.: **арт III.** Чәчең майлы, сылавыч ки. – *тмн.* Сылавыч ука белән йасалган була иде. Сылавычлары кәпәч кебек. – *кузн.* Сылавычны чәчкә кийәләр, чәч эремнәрен шанда тыгалар, әле манитлар тагалар бырынгыларны. – *лмб.* Тастар, сылавыч эчендә чачы торган, чачларын күрсәтми, битен күрсәтми. – *әстр.*

**СЫЛАМА I** *дөб., чст.* дегет (дёготь).

**СЫЛАМА II** *мам., кргл., мәл., кмшл.* савытның кырые белән тигез (полный до краёв). Чиләгем сылама булды җиләк белән. Сылама ғына йасап қайттым чиләгемне. – *кмшл.* Сылама машина печән китерделәр. – *кргл.* Мин бер чиләк сылама он алган идем. – *мәл.*

**сылама итү** *т.я.* савытның кырые белән тигез итеп тутыру (наполнить посудину до краёв).

**СЫЛАПЦЫ** *туб.-ирт.д.* бәләкәй таз (тазик).

**СЫЛАУ I** *срг.* ябыштыру (прилепить, прилеплять). Бар, шул обйавлинийене сылап кил. Кино турында обйавлинийе сылаганнар.

**СЫЛАУ II** *шрл.* су буенда җәй көне сыерлар сава торган урын, туплавык (место около водоёма, где летом доят коров). Сылау йакын, үләгә cawарга барабыз сийырларны.

**СЫЛАУ III** *злт.* тауга менә яки елгага төшә торган сукмак (тропинка). Қызылбай қарт аңа сылау қазырға қуша.

**СЫЛАУГЫЧ** *стрл.* к.: **арт III.** Сылаугычны кан′анага бирәләр киленнәр. Ват килен алган, сылаугычы бар, изүчәсе бар.

**СЫЛҒА** *туб.-ирт.д.* аз ашаучан (тот, кто мало ест).

**СЫЛҚЫЛАНУ** *дөб.* сыену (прильнуть). Мин бик йаратам ул қызымны, шуңа күрә кереп миңа сылқылана.

**СЫЛЛЫ** [*гар.*] *чст., чпр., мәл.* к.: **йегәрле 1.** Эшкә сыллы күренә. – *чст.*

**СЫЛТЫҚЛАУ** *лш., нрл.*, **СЫЛТЫКЛАУ** *мәл.* аксау (хромать). Әз генә сылтықлар инде. – *нрл.* Мыни хазер әзрәк сылтыклыйм, дип әтә, ди. – *мәл.*

**СЫЛЫЗЫ** [*рус.* салазки] *злт.* бүрәнә ташыганда кулланыла торган чана (сани, приспособленные для перевозки брёвен). Сылызы бәләкәй генә, тәмәш кенә эшләнгән сана, бүрәнә төшерү өсөн, алтышар метрдан йегермешәр бүрәнә салаң.

**СЫЛЫУ** *туб.-ирт.д.* итне сөягеннән сыдырып алу (отделять мясо от костей).

**СЫМАРАУ** [*рус.* самовар] *мәл.* к.: **самар.**

**СЫМРАҚ** *туб.-ирт.д., брб.д.* имезлек (соска).

**СЫМРЫЙ** *саз.я.* кечкенә алабуга (маленький окунь). Ауға сымрый wаллардан пашха иймә хермән.

**СЫМЫЗҒЫ** *туб.-ирт.д.* сыбызгы, курай (свисток, дудка, свирель).

**СЫМЫЛЫП: сымылап йату** *лмб.* бөгәрләнеп яту (лечь съежившись, сжавшись в комочек.

**СЫМЫРАҚ** *эчк.* к.: **мәте I, 2.** Балалар сымырақ белән уйнайлар.

**СЫН I 1.** *лмб., кузн., чст., чпр.* к.: **йәүдә 1.** Сын авыр, сынны күтәрә алмый. Аның сыны бик килешле, әмен койып куйган. – *кузн.* Сыны бик килешсез. – *лмб.* Сыны матур диләр бездә тагы. – *чст.*; **2.** *т.я., кмшл., хвл., чпр.* төс, кыяфәт, рәвеш (внешний вид, облик). Кеше сыны қалмаған инде аның. – *т.я.* Кеше сыны булса ийе үзендә. – *кмшл.*; **3.** *тмн.* к.: **буй.** Күлмәк сыны; **4.** *минз., т.я., кмшл., кузн., хвл., чст.* к.: **күләткә 3.** Сын төшерергә бик оста икәнсең син. – *хвл.* Сынга сугылдык. – *кузн.*; **5.** *минз., стрл.* сынау, юрау (толкование, примета). Шул қарт утырыр ыйы җиргә, тәненә җылы килсә, чәчәбез, ди. Wәт шул булған сыны аның. – *минз.* Акчаны қалдыралар матча астында бертөрле сын өчен инде. – *стрл.*

**СЫН II** *саз.я.* кебек, шикелле (как, словно). Қасанның сәгәте Москваның сын.

**СЫНАМЫШЛЫ** *т.кам.-крш.* сынала торган, мәгънәле (со значением, с намёком). Җырлар сынамышлы алар, Үринә әбигә монау җыр чықты, чирләп китте, җыгылды да.

**СЫНДАМ** [*фарс.*] *туб.-ирт.д.* зиндан (тюрьма). Бу кешене алып сындамға ташлаң. – *төм.*

**сындык** сандык (сундук):

**сындык аузы** *мәл.* туйда килен сандыгын ачкан кешегә бирелә торган бүләк (подарки, предназначенные тому, кто открывает сундук невесты). Сындыг аузы бирә кыз йагы кайнанага, йеслек йә күкерәк бирә.

**СЫНДЫКЧЫ** *карс.* к.: **wақ: wақ сатучы.** Сындыкчылар йериләр иде элек, шул сындыкчылар китерә иде китап.

**СЫНДЫРҒАН I** *т.я., каз.ар.* көн җылыта төшкән (стало теплее). Бүген быраз сындырған, кичәге кебек үк салқын түгел. – *к.т.*

**СЫНДЫРҒАН II** *әстр.* ярәшелгән (сосватанная, просватанная). Ике қодағый шикәрне сындырып қабалар, қызны, малайны килешәләр, сындырған дигән сүз шул була.

**СЫНДЫРУ I** *чст.* ваклау – акча турында (разменять – о деньгах). Уннықны сындырыга акчагыз йукмы, кызлар?

**СЫНДЫРУ II** *глз.* сыту – йомырка турында (разбить яйцо). Алты кукай сындырып камыр суктым, чыпчаги пышырам. Кукай сындырып, быдай оны белән камыр сугабыз.

**СЫНЛЫ I** *мәл., чст.* матур, сөйкемле (красивый, миловидный, симпатичный); таг.: **йәмле 2.**

**СЫНЛЫ II** *тмн., кузн.*, к.: **сынны II.** Сәйет сынлы бу көзге. Кодагый сынлы мин дә йаңгыз торам. – *тмн.* Дегет сынлы эчәм чәйне. Сезнең awыл сынлы awыл йук, диләр. – *кузн.*

**СЫННЫ I 1.** *лмб., срг.* билле (в талию). Сынны йеңсез бишмәт минем әле дә бар. – *срг.*; **2.** *чст.* төз буйлы (стройный). Сынны гына кеше ул, күрерсез.

**эч сынны** *лмб.*, **өч сынны** *срг.* өч билле (с тремя фалдами). Эч сынны бишмәт кийә идек. – *лмб.*

**СЫННЫ II** *лмб., кузн., шрл., хвл., стрл., мәл., себ.*

кебек, шикелле, төсле (как, подобно). Минеке дә үдәге сынны тегелдер дә, йалан йарый. Ак шәкәр сынны. Үзе кеше сыннымы, ди. – *кузн.* Урман сынны иде бу тешләр. – *тмн.* Айу сынны кеше иде. Багалма прусты сырга сынны тыра. Равил сынны бер малайы бардыр. – *лмб.* Үзем сынны азгын, үзем сынны йеремтәк сыйырым. – *шрл.* Безнең сынны икәү калырсыз. Бер әби әткән, бу халык кайа йөри икән, мин хут кызыма барам, атә икән, шуның сынны. – *стрл.* Кеше сынны әтсәң йарамыймы, нәстә тырataш сынны торасың. – *мәл.* Санийәнең цацы пеләк сынны ите. – *тбл.*

**шан сынны** *карс.* шуның шикелле (подобно тому).

**СЫНСЫЗ** *перм.* к.: **қонсоз**. Бу кеше бигрәк сынсыз қый.

**СЫНТЫҚ** *минз.* аксак (хромой).

**СЫНТЫҚЛАУ** *минз.* к.: **сылтықлау**. Сынтықлап йөрү. Айағы да әд генә сынтықлап китә, ди.

**СЫНЦЫ** *туб.-ирт.д.* алдан әйтүче, күрәзәче (предсказатель, вещун). Палам үләте тителәр сынцылар.

**СЫНЦЫЛ** *туб.-ирт.д.* кызыксынучан (любопытный).

**СЫНЧЫ** *хвл.* шымчы (сыщик). Сынчылар йибәргән. Шындый сынчыларны йаратмыймын.

**СЫНЧЫЛЫК: сынчылык итү** *т.я.-крш.* шымчылык итү (шпионить).

**СЫҢ** 1. *тмн.* к.: **анар**. Башта йыладым, сыҥ риза булдым; 2. *трх.* әйе, шулай (да, так).

**сыңарлап** (по одному):

**сыңарлап қалу** *бөре.* тол калу, ялгыз калу (остаться одиноким: вдовой или вдовцом). Парлы-парлы җәшәсәң, рәхәт җәшисең, сыңарлап қалсаң, қыйын.

**СЫҢҒЫДАН** *стрл.* к.: **азақ**.

**СЫҢРА** *нокр.* к.: **соңыра**. Сабантуйдан сыңра булған дий. Сыңра қыз туғаннары ғына қалды. Дағын барып қайтырмын сыңра.

**СЫҢЫНТЫН** *чст.* к.: **анар**. Сыңынтын укып чыктым бу китапны.

**СЫПАТ** [*гар.*] *карс.* кыяфәт, рәвеш, төс (вид). Вис сыпатларын ала кычкырып куркытып.

**СЫПҚА** *минз., т.кам.-крш.* 1. пычрак, пычрак тап (грязь, грязное пятно). Сөрт сыпқаларыңны. – *т.кам.-крш.*; 2. пычрак, шапшак (грязный). Сыпқа су. – *минз.*

**СЫПҚАЛЫ** *минз., т.кам.-крш.* к.: **салак**. Гайепләп китмәгез инде бу апа сыпқалы, герәзле дип. – *т.кам.-крш.*

**СЫПҚЫ** *т.кам.-крш.* к.: **булата**. Менә җаңғыр җауды да сыпқы, маллар артыннан җөрийем. Без дә ничawa җөрибез сыпқы булса да, гел алай алама түгел.

**СЫПҚЫЛЫ** *т.кам.-крш.* пычрак (грязный). Айақ асты бик сыпқылы икән.

**СЫПЛАП** *кргл.* сипләп (обновив, починив, отремонтировав). Әнә шулай сыплап йасаған ишек.

**СЫП-СЫРҒАҚ** *трх.* сырып алган күк, бик күп (очень много, как облепленный). Безнең қарлыған сып-сырғақ.

**СЫПРА** *саз.я.* ындыр табагы (ток – на гумне). Сыпра тасартқалы цығың.

**СЫПТАУ** *тпк.* бау белән урап бәйләү (обматывать, обвязывать верёвкой). Арқан белән сыптай-сыптай теге әрдәнәне алып китте бадарга.

**СЫПТЫҒАЙ** *перм.* бизәксез читек (ичиги без украшений, без отделки).

**СЫПТЫРУ** 1. *т.я.* җиңелчә генә сөртү (слегка протереть); чаг.: **себерү** 1. Тиз генә идән-сәкеләрне сыптырып алдым; 2. *т.я.* сыйпау, сыйпалау (гладить, погладить рукой). Башыннан, битләреннән сыптыра-сыптыра сөйде баласын; 3. *т.я., мәл., кузн., чст., чпр., кмшл.* сугу, бәрү (ударить). Биткә агач сыптырды. Аны җил сыптырып тешерде. – *чст.* Сыптырырмын малай берне мин сиңа. – *кмшл.* Күwәндә белән сыптырып башым тиште. – *трх.* Бу сыптырып йыкты, ди, вит хурлык. – *мәл.*; 4. *кузн.* к.: **абжурлану**; 5. *хвл., чст., кмшл.* урлау (красть). Пирчәткамны сыптырган. – *хвл.* Бәрәңгене сыптыргаладылар да, бернәрсә чыкмады. – *чст.* Мындагы алманы сыптырып бетергәннәр. – *кмшл.*; 6. *кас.* к.: **бырғыту**. Тепли сыптыралар 'аба' аша, 'айсы җа''а 'ити, шул җа''а 'ийеү'и 'итисин, диләр.

**СЫПТЫРЫЛУ** *срг.* бәрелү (ударяться, удариться). Сырхау йатам, сес киләсе кенне агацка сыптырылдым иде.

**СЫПТЫРЫҢҚЫ** *т.кам.-крш.* к.: **сифана**. Буй җиткән җегет инде, әзерәк сыптырыңқырақ булырға тийеш. Шушы Микулай сыптырыңқы да инде, күзен күтәреп бер қарамас сиңа. Сыптырыңқы булсаң, башыңа менеп утырырлар безнең awылда, қыйурақ булырға кирәк. Бик сыптырыңқы безнең бу қыз. Кешедән ойалсалар, әзерәк сыптырыңқы җөрерләр ийе алар.

**СЫПЫ** *нгб.-крш.*, **СЫПЫЙ** *каз.ар.-крш.* к.: **сирымта**. Пәрит, син сыпы икәнсең. Бер ашасам, бернәрсә ашыйсы килми, бигрәк сыпый мин.

**СЫПЫЙЫМЛАНУ** *т.кам.-крш.* артык дәрәҗәдә чисталыкны ярату (быть слишком чистоплотным, чистюлей). Чиләкне пычыратмыйм дип сыпыйымланып қына җөрисең. Сыпыйымланмыйм, нишләп сыпыйымланыйм.

**СЫПЫРАМА** *т.кам.-крш., минз.* к.: **сылама II**. Сыпырама итеп алып қайтқан, суны түкмәгән. – *минз.* Бер машина сыпырама ашлық. Сөтен сыпырама итеп салма, түгелер. – *т.кам.-крш.*

**СЫПЫРУ** 1. *перм.* себерү (подметать). Идәнне сыпырыб алыйм әле қанат белә генә. Рафисе әйтә, әллә идән сыпырған йафрақ белә (мунча) индег инде, ди. Балчығын сыпырмый тороп, кәҗүнкәләрне җыйштырып булмый әле. Үкәртәдән аламаларны сыпырабыз себертке белә. Үкәртәләр тулған әле, сыпырылмаған безең; 2. *кузн.* к.: **сыптыру** 5. Сыпырып качкан.

**СЫР I** 1. *миш.д., кас., эчк., перм., к.-уф., себ.* к.: **буйак** 1. Сырга буйалып беттек. Сыры да алган иде ул чакта, шулай калды да калды. Күбесенчә сырга китә киндераш майы. – *кузн.* Ййләрен сырлап 'уй'аннар. – *кас.* Ылаукада зәңгәр сыр бар. Ызбаны сылап, сыр сөртәп ырамнарына, котолор идем. Кодагиның кабагын, ди, Төрлә сырга сырлагыз. Кодагиның көңлен күреп, Бер-ике йыр йырлагыз (*туй җыр.*). Сырлы да кашык сырлы

икән, Сыры гына китәр көн икән (*хал. җыр.*). – *тмн.* Кабаклары сары сырга буйаган иде. – *срг.* Быйыл гына куйган йаңы ызбам Нинди сырлар менән сырларлар (*хал. җыр.*). – *лмб.* Қанатларына сыр булайым. – *эчк.* Алачаны җирек қабық, шомырт қабық қайнатып тыгасың да, төрлө-төрлө сыр була, үзең сырлап кийәсең. Сырны қазанга саласың, җепләрне шунда тыгасың. Бер пакет сыр иде, әнигә күлмәк буйадым. – *перм.* Идәннең сыры беткән, сырларга кәрәк әле. – *к.-уф.*; **2.** *кузн.* к.: **сыйа I**.

**cow сыр** *сазл.* ак буяу (белила). Cow сыр мейец сылагалы қаты шәф, ап-ах пулат.

**СЫР II** *тмн., лмб., кузн., стрл., карс., нокр., глз.* сер (тайна, секрет). Кешегә сырыңны сүләмә. Сырымны сүләдем шул кардәшемә, ул сүләми инде, сеңеп кала. Алар бит безнең тиңнәр тегел, сырлары сыймас. Син анарга сырыңны сүләмә, ышанычсыз ул. – *кузн.* Сиңа бетен сырын сили. Сырлы иде күзләре. Сырларыңны бергә сүлисең, сүтәсен сырларыңны козларга. – *глз.* Кешегә сырын бирми. – *лмб.* Белгезмимен эс сырны. – *карс.*

**сыр салу** *тмн., кузн.* тәкъдим ясау (делать предложение). Хазрәтнең буй кызына сыр салмыйнча мин йередем. – *тмн.* Ил мулласының кызы белән сыр салмыйнчы мин йередем. – *кузн.*

**СЫР III 1.** *минз., тпк., стрл.* киемдәге складка (складка на одежде). Күлмәк тектердем, озонрак булды да, ике мәртәбә сыр чыгардым. – *минз.* Итәген сырлатадырыйык, әл дә салам мин, мона бит сырлар. – *тпк.*; **2.** *минз., т.я., стрл.* бәйләү бизәге (узоры вязки). Печәткә бәйләсәләр, арқасын сырлыйлар ыйы. Ойоқның қунычына сырлыйлар. – *минз.*; **3.** *минз.* к.: **албуй I, 1**. Сыр күлмәккә тар итеп икенче төрле материядән тотыла, дийәктән дә тотқаннар. Сырлы күлмәкләр булды, бәбәйтәкләр тоталар ийе сырлап. Өстемдәге күлмәккә Сыр саласым қалмаган, Үз башыма хәсрәт итеп, Йар сөйәсем қалмаган. Өстөмдәге күлмәгемә нинди сырлар тотайым, Җөрәгемнең җанганына нинди сулар жотайым (*хал. җыр.*).

**СЫР IV: сыр күбек** *перм.* к.: **сып-сыргақ**. Жиме сыр күбек, хәттин ашқан.

**СЫР V** *дөб.* кызыл төстәге он шикелле әйбер, элек хатын-кызлар имгә ашаганнар (порошок красного цвета, употреблявшийся женщинами в старину для лечения). Дawa сыры ис ул, awыруларга ашаталар.

**СЫР VI: сыр қатыру** *минз.* туп-турыга катыру (сделать неподвижным). Қымшатмый ул, менә сыр қатыра инде кешене көдән чире.

**СЫРАҚ** *злт.* чыра (лучина). Сырақ йандырдық.

**СЫРАЛУ I 1.** *хвл.* рөхсәт сорау, рөхсәт алу (просить или получить разрешение). Ышкулдан сыралып киттем; **2.** *карс.* к.: **сыгыну**. Шултике сыралалар, жалкы. Хазер дә сыралалар, кайа инде тегү.

**СЫРАЛУ II** *брб.д.* ябышу, сылану (прилипать).

**СЫРАУ** *туб.-ирт.д.* **1.** кар өеме, көрт (снежный сугроб). Сырауға баттым; **2.** кар сыру, кар басу (замести, облепить, завалить снегом). Өй түрне қар сырапты.

**СЫРАУЦ** *туб.-ирт.д.* к.: **сәсбау**.

**СЫРҒА I 1.** *каз.ар., т.кам.-крш., нокр., глз., перм., нгб.-крш., злт., трбс., эчк., себ.*, **СЫР'А** *кас.*, **СЫРГА** *миш.д., м.-кар.* алка (серьги). Мәкәржә сырғасын қолагына кигезәң. – *каз.ар.-крш.* Жиңгә қолақ сырга таққан. – *перм.* Сырғаңны кимәпсең ич әле. – *нокр.* Бер сырғам төшеп қалган. – *эчк.* Сырғаға өчәр тәңкә таға торган идек. – *нгб.-крш.* Чылтыр-чылтыр қамышқа, Сырғам төште йар-йар (*йола җыр.*). – *брб.д.* Картрак булса да, сырга белән йөри бусы. – *кузн.* Колагымда колак сырғам, Сикеретни бикләнә, Бардыр синең башка йарың, Никтер күңлем шикләнә (*хал. җыр.*). Кашлы сырга шул көне белән йугалды. – *срг.* Сырға тагайық қолаққа. Хәзер дә таққан кеше сырга тага. – *злт.* Йәш wақытта сырғалар бар ыйы, сулпылар бар ыйы. – *трбс.*; **2.** *минз.* к.: **қаптырма 1**; **3.** *минз., злт., кргл., трбс., байк.* к.: **йага II, 2**. Сырға тегелми ул, тәңкәдән йасалган була. – *минз.* Тәңкә тезелгән сырга была, шуны кийәбез. – *злт.*; **4.** *перм.* к.: **бәлчә 1**. Шомыртны сыдырып-сыдырып қына аласың сырғасыннан.

**алка сырга** *лмб.* божра кебек алка (серьги круглой формы). Алка сырғалар да бар, кашлы сырғалар да бар.

**асма сырға** *себ.* к.: **оло сырға**. Асма сырғаларым бар, өннәмнән калған. – *төм.*

**җапырақай сырға** *т.кам.-крш.* яфрак формалы алка (серьги в форме листьев). Җапырақай сырға киңнәр дә сырға, Китәм жанықайым киң қырға (*хал. җыр.*).

**муйын сырғасы** *минз.* к.: **йага II, 2**.

**оло сырға** *т.кам.-крш.* тәңкәләр тагып челтәрләп эшләнгән алка (серьги с подвесками). Оло сырға тәңкәле, челтәрле, җепәк тасма сырганың билендә.

**сырға бawы** *каз.ар.-крш.* бер як алкадан икенчесенә сузылган тасма (лента, которая тянется от одной серёжки к другой). Сырға ди бауларың билдәндер, Кийемчеләр печеп лә биргәндер; Бу қашларың белән айлар күзеңне Бер Қодайым сөйеп лә биргәндер (*хал. җыр.*).

**сырға кебек** *тпк.* к.: **сып-сырғақ**. Сырга кебек ийе ул, бәк күп була аның алмасы.

**тага сырга** *кузн.* алканың бер төре (вид серьги).

**шабала сырға** *туб.-ирт.д.* кашык рәвешле алка (серьги в форме ложки).

**СЫРҒА II** *т.я.* **1.** йогырт (подмаренник цепкий); **2.** к.: **йабышқақ II**; **3.** к.: **wақ: wақ шырлан**.

**сырга геле** *тмн., кузн., лмб.*, **сырға гөл** *эчк.* к.: **гөл I: тамчы гөле**.

**СЫРГАБАУ** *стрл.* к.: **йага II, 2**.

**СЫРҒAWЫЛ** *минз.*, **СЫРГAWЫЛ'** *стрл.* к.: **жywылгы**. Сырғawыл белә жарып қywалар ыйы бала-чаганы. – *минз.*

**СЫРҒАҚ** *мам.*, **СЫРҒАНАҚ** *бәр.* к.: **йабышқақ II**.

**СЫРҒАТАШ** *туб.-ирт.д.* тамчылы гөл (бурачок – растение).

**СЫРҒАТЛЫҚ** *туб.-ирт.д.* сәламәтлек (здоровье). Сырғатлыгым йуқ, қартайдым. – *төм.*

**СЫРҒАУ I** *туб.-ирт.д.* сырхау, авыру (больной).

**СЫРҒАУ II** *брб.д.* атып бәрү, ырғыту (швырнуть, забросить).

**СЫРҒЫ** *лш.* к.: **йабышқақ II**.

**СЫРҒЫЙ** *себ.* колга, киртә (жердь).

**цитән сырғый** *саз.я.* читән казыгы (жердь для плетени). Цитәннең сырғыйларын қағып пирсәгез, йахшы пулыр ите.

**СЫРҒЫРАУ** *себ.* таралу, барып җитү – тавыш турында (распространяться, достигать – о звуке).

**СЫРКАЙ** *чст.* **1.** мамык белән сырган җиңсез өс киеме (стёганая безрукавка); **2.** к.: **кийез 1.** Астыгызга сыркай салып йатыгыз.

**СЫРҚАУ** [*гар.*] *перм.* к.: **awырту**. Қызыбыз сырқый башлады да, шун ашарға қуштылар.

**СЫРҚУ** *перм.* к.: **сырқыту**. Қатыкны ойотабыз да шуның сырқыб алабыз сuwын, сөзмә йасыйбыз.

**СЫРҚЫТУ** *перм., к.-уф.* сөзү (цедить, процеживать). Сөтне сырқыттыңмы? – *перм.* Қатыкны мәрлегә салып сырқытырға қуйдым. – *к.-уф.*

**СЫРЛАҚ** *себ.* җилле салкын hава (холодная, ветреная погода).

**СЫРЛАМА'А** *кас.* к.: **сырлау I, 1.**

**СЫРЛАН 1.** *тмн.* к.: **кырмалау: дуңгыз кырмалавы**; **2.** *лмб.* к.: **сырға I, 1.**

**СЫРЛАНУ I 1.** *кузн., срг., лмб.* буяну, бизәнү (краситься); чаг.: **айфарлану**. Йә инде, бик ызак сырланасың, сине вет көтәләр. – *кузн.* Сырлы гына сындык эстендә Сырланасыңмы, йеңгакай (*хал. җыр.*). – *лмб.*

**СЫРЛАНУ II** *нгб.-крш.* к.: **пәтәрләнү**. Күлмәгем сырланған, үтүклим.

**СЫРЛАР** *кас.* төсле карандашлар (цветные карандаши).

**СЫРЛАУ I 1.** *миш.д., перм., к.-уф., т.кам.-крш., кас., себ.* буяу (красить). Циләк сырларга иттем. Маләр сырлап йөри. Идәнне мин сырлаган идем. Кас'акларны кацан сырлыйсыз? – *срг.* Крыйшасы йәшелгә сырлаган. – *лмб.* Бер тамызмыйнчы сырладым. Әтийемнең йил милчасын йашыл белән сырлыйлар. Сырлагыйнчык әле ике атна үтәр. Идәннәреме инде майга тике сырламыйм. Натурал'нига сырладым, бер сутка кибә. Тенә генә сырладым идәнне. Безнең awылда идәнне сырламыйлар. – *кузн.* Җаңа өйләремнең шүрлекләрен Нинди сырлар белән сырлыйым (*хал. җыр.*). – *т.кам.-крш.* Фатыйма идәнен сырламаганмы, сырламаган бугай ул. Теге ызбаны сырлыйлар, сыр исе монда килә. – *перм.* Түби сырлыйлар. – *кас.*; **2.** *т.я.* күлмәк итәгенә икенче төстәге материядән тасма салып чыгу (нашивать к подолу платья узкую полоску из другой материи). Күлмәкне пар атлас белән сырлыйлар ыйы. Итәкне сырлый торганнар ыйы икешәр кат линте тотоп. – *трх.*; **3.** *минз., байк., стрл.* бизәкләп бәйләү (вязать узорами). Пирчәткә сырлап бәйләй торган ыйык. – *минз.*; **4.** *байк.* җыеру (собирать в складки). Сырлап кийәбез ий тула йокно.

**СЫРЛАУ II: аш сырлау** *кузн., мәл.* аш сайлау (приверединчать, быть разборчивым в пище). Хайат бу арада аш сырлый башлаган. – *кузн.* Аш сырлый иде, касталана иде дә. – *мәл.*

**СЫРЛАУ III** *минз.* к.: **қырлау I**. Керне сырласы бар.

**СЫРЛЫ I 1.** *кузн.* буяулы, буяган (крашеное, окрашенное). Идәннәре, кас'аклары сырлы, имеш; **2.** *кузн.* төсле (цветной). Сырлы чапан астында; **3.** *чст.* буй-буйлы (полосатый). Калада кийеп йериләр бит сырлы күлмәк шындый.

**бер сырлы** *лмб.* бертөсле (одинаковый). Адәм бер сырлы булмыйдыр.

**СЫРЛЫ II** *злт.* к.: **кукыр**. Ул сырлыга күлмәк тегеп йаратып булмый.

**СЫРЛЫГАН** *лмб.* мактанчык, кыланчык (хвастливый, кичливый); чаг.: **йақлы**.

**сырма** (стёганый матрац):

**буй сырма** *блт.* сырылган тар озын киез (длинная стёганая подстилка, тюфяк). Буй сырмалар булыр ыйы, аларны сәкегә җәйәр ийек. Буй сырмалары бер иңнән сырыла, җанга да җәйәсең, түргә дә җәйәсең, уртада табақлык.

**СЫРМАҚ 1.** *перм.* сырып, биллән тегелган бишмәт (стёганый бешмет, сшитый в талию); **2.** *туб.-ирт.д.* сырма, бишмәт (стёганое пальто).

**СЫРМЫҚ** *перм.* **1.** к.: **сыпқылы**. Тирәзәләрне алганым җуқ, сырмық; **2.** к.: **зәләмә 2**. Сырмық ызбалар гына ийе, элег awыл белеки генә ийе, хәзер байықтылар инде; **3.** бозык, яраксыз (испорченный, негодный). Безнең сырмық-сармық сүзләрне йазыб алып җийасыз инде.

**СЫРМЫШ** *трх., кргл.* сырма (стёганка, телогрейка).

**СЫРПАЛАНУ** *т.я.* к.: **қанчықлау**. Начал'никлар тирәсендә бик сырпалана торган кеше ул.

**СЫРПАНЧАҚ** *нрл.* к.: **сарыплы 1**. Ашауга сырпанчақ мин үзем, қаты-қаты ашый алмыйм.

**СЫРСАУ** *брб.д.* к.: **сырлау II: аш сырлау** (быть разборчивым в пище).

**СЫРТ 1.** *кргл., мәл., кас.* берәр нәрсәнең арты, арт ягы (задняя сторона чего-либо). Магазинны узып китеп, сырттарақ. – *кргл.* Бездә йәшләр зийаратка кереш йук, сыртта гына кала. – *мәл.* Безнең ба'ча сыртта. Җиралманы сыртта да, 'орда да чәчте. – *кас.*; **2.** *миш.д., кас.* өй арты (участок за домом). Сандугачлар сайрашалар Сыртыбызда усакта. – *лмб.* (*хал. җыр.*)

**сырт бирү** *мәл.* арты белән борылу (повернуться спиной). Бер эш кушсаң, ул сыртын гына бирә.

**сырт йақ** *саз.я.* арт як, чит (задняя сторона, край). Awыл сыртта тораты ул.

**сырт сөйәге** *бөре., т.я.* умырткалык (позвоночник).

**сыртны җиргә тидермәү** (*мәкаль*) *мәл.* сынатмау (не подкачать; не подавать виду).

**үз сыртыннан** *клд.* үз исәбеннән (за свой счёт). Мин үз сыртымнан бирә алмыйм. Бозау керсә, ыстурыжга үз сыртыңнан түләтерсең.

**СЫРТАҚ** *перм.* ак сыртлы сыйыр (корова с белой полоской на спине). Сыртақ сыйыр.

**СЫРТЛЫҚ 1.** *минз.* ыңгырчак астына куя торган йомшак әйбер, ыңгырчак киезе (потник). Сыртлыкларны җитәрлек хәзерләргә кирәк; **2.** *к.-уф., себ.* аркалык (чересседельник). Атыңның сыртлыгын күтәргәнсең, бераз бушата төш. – *к.-уф.*

**СЫРУ** *брб.д.* авызда тоту (держать во рту).

**СЫРХАБАТ** *кас.* авыру (болезнь). Сырхабат, адәм баласының алтмыш тамырында җөрөрмен, ди'ин.

**СЫРХАWAT** *тпк.* экзема. Салқын тигән сырхаwатқа, диде. Сырхаwат үденнән-үде булған нәстә, бодоқ.

**СЫРХАУ** *баст., минз.* чирле, чирләү (больной; болеть). Қызым да сырхау булды. – *баст.* Умбиш көн сырхады песәйебез. – *минз.*

**озын сырхау** *лмб.* туберкулёз.

**сырхауға сабу** *мәл.* авыруга дучар булу (подвергаться болезням). Сырхауга саба – казлы теләк укыта.

**СЫРХАУЛАУ** *кас.* чирләү, авырып китү (болеть, заболеть). Сырхаумын бик, 'атны белин ун 'эн булдылар, анан сырхаулады.

**СЫРХУWАЛАНУ** *т.я.-крш.* к.: **давырсу: кеңел давырсу**.

**СЫРХУWAT** *глз.* к.: сары мәтрүшкә (зверобой).

**СЫРЫҒУ** *эчк.* сыру, сырып алу (облепить). Монда сырықмағандыр әле ул қандала.

**СЫРЫҒЫУ** *злт.* сыену (прибегать к покровительству кого-либо, обращаться за покровительством). Өйне саттым да балаларга сырығырға булдым.

**СЫРЫЖҒАҚ** *туб.-ирт.д.* бөдрә (кудрявый).

**СЫРЫҚ** *глз.* **1.** к.: **құрдақ**; **2.** к.: **пыды**.

**сырық кебек** *каз.ар., т.я., злт.* к.: **ажғырыйн**. Сырық кебек ирләр үлде суғышта. – *трх.* Сырық кебек инде малайлары. – *мам.*

**СЫРЫҚТАЙ** *минз., каз.ар.* таза, матур (здоровый, красивый).

**СЫРЫҚТЫРЫП** *перм.* якын китереп, янәшәсенә китереп, терәтеп (сблизив вплотную). Салны ташқа сырықтырып туқтаталар.

**СЫРЫМНАМАУ** *нокр.* әһәмият итмәү, колакка да элмәү (не обращать внимания, не принимать во внимание). Хот'бы сырымнамай да, борылып та қарамай.

**СЫРЫНДЫҚ** *к.-уф.* к.: **сырау 1**. Қар сырындығына кереп батқаннар.

**СЫРЫНУ** *сазя.* оялу, тартыну (стесняться).

**СЫРЫСХАН** *туб.-ирт.д.* к.: **тыйрақ II**.

**СЫС** *туб.-ирт.д.* авырту, сызлау (боль). Эсемнең сысы пөтөпте.

**СЫСҒЫРҒАН: сысғырған май** *тбл.* сары май (топлёное масло).

**СЫСҒЫРУ** *туб.-ирт.д., брб.д.* эретү (топить, растапливать, плавить).

**май сысғыру** *туб.-ирт.д.* к.: **ачлау**.

**СЫСҚЫ** *туб.-ирт.д.* бура бураганда билгеләп сыза торган металл инструмент (металлический инструмент с двумя острыми, загнутыми концами для черчения – при изготовлении сруба).

**СЫСҚЫЧ** *дөб.* к.: **багырча**. Балаларға аш сысқычын тотарға йарамый. Ашны сысқыч белән бүләләр.

**СЫСЛА** *перм.* йорт сырасы (домашнее пиво).

**СЫСУ I** *мәл.* су алу (черпать, вычерпывать). Үзе дә сысар әле. Күлдән терлеккә сысабыз, кыйыдан чәйгә. Суны койдан сысабыз.

**СЫСУ II** *сазя., тбл.* **1.** ябыгу, йончу (похудеть). Пағыр, сысып қалыпты. – *сазя.*; **2.** авыру (болезнь). Перәй сысуы бар мигән, йонцыб утыраты. – *тбл.*

**СЫСЫНТЫҚ** *бәр.* әрәмтамак – этләрғә, мәчеләргә карата әйтелә (бездельник, дармоед – говорится о кошках, собаках).

**СЫТҚЫЙ** *мам.* к.: **мечек: мечек сағыз**. Сытқыйы әллә қайан беленеп тора қара шыршының.

**СЫТҚЫЧЛАУ** *т.кам.-крш.* бетчәләү (покрываться угрями, прыщами). Айырмачық белмийем, бит байтақ жәрдә әле шулай сытқычлап.

**СЫТЫҚ 1.** *каз.ар., минз., туб.-ирт.д.*, **СЫТЫК** *мәл.* к.: **сықтақ**. Кискән шикелле жылый, бигрәк сытық. – *мам.*; **2.** *мәл., туб.-ирт.д.* еларга гына торучы (плаксивый). Бигрәк сытык бу бала, хазер йыларга гына тора. – *мәл.*

**СЫТЫРУ** *брб.д.* чистарту, сыдыру (чистить, сдирать). Палық сытыру.

**с ы у** *себ.* су (вода):

**сыуға гитү** *төм.* суга бату (утонуть). Аталары сыуға гитеп үлте.

**СЫУ-БАЛ: сыу-бал қарау** *туб.-ирт.д.* күрәзәлек итү (гадать, ворожить).

**СЫУЛАМЫҚ** *каз.ар.-крш.* к.: **суламык**.

**СЫУЛАУ** *каз.ар.-крш.* к.: **кыйу II, 1**. Памидурлар сыуладым.

**СЫУЛЫҚ 1.** *минз.* юкә кабыгы белән ябылган йортларда түбәне тотып тору өчен аның аскы ягына тоташтырылган улак сыман аркылы агач (поперечная перекладина для удержания крыши, покрытой липовой корой); чаг.: **суллык**. Өй түбәләре қазақ белә булмаған, сыулық белән булған; **2.** *каз.ар.-крш., перм.* өй түбәсенең ике як читендә су агу өчен эшләнгән улак (водосток на крыше дома). И жаусайы жаңғырлар, и жаусайы, Сыулықлардан тамчылар тамсайы (*хал. жыр.*); **3.** *перм.* дранча түбәне тотып тору өчен түбәнең аскы ягына урнаштырылган улак сыман аркылы агач (поперечная перекладина для удержания крыши из дранки); чаг.: **суллық**; **4.** *туб.-ирт.д.* авызлык (удила).

**СЫФАТ** [*гар.*] *клд.* к.: **сыпат**. Хазер сыфатым нинди, мәтәм, апа, әле сез сары, ди.

**СЫФАТСЫЗ** [*гар.*] *хвл.* ямьсез, килбәтсез (некрасивый, неуклюжий).

**СЫФЫ** *кузн.* нәзберек, талымчан (привередливый, разборчивый). Зур малайы ашка бик сыфы.

**СЫЧКАН** *хвл., мәл.* к.: **кийек I, 3**.

**СЫХТАУ** *сазя.* елау (плакать).

**СЫХТАХ** *сазя.* к.: **сықтақ**.

# Т

**ТААМЫНУ** *тбл.* татып карау, авыз итү (отведать пищу).

**ТААН** *том.д., тбл.* чәүкә (галка).

**ТАБА** *мәл.* патефон тәлинкәсе, пластинка (патефонная пластинка). Апа, безгә бер уннап таба йебәрегез әле! Их, «Койаш гомере телим сиңа» табасы матур да инде, дамы?

**патифун таба** *нокр., глз.* к.: **таба**.

**таба әпәйе** *злт.* к.: **тәбийә 1.**

**таба бәлеш** *тмн.* төче камырдан эченә ит һәм бәрәңге салып пешерелгән зур бәлеш (большой пирог с мясом и картофелем). Камырны сөткә басалар, төпкә ит, аның өстенә йералма салалар, каплилар йәймә белән, анарга, таба бәлешкә шурбаны сала баралар.

**таба булу** *перм.* күңелдә авыр әз калдыру – сүз турында (оставить неприятный осадок – о слове).

**таба җасау** *дөб.* оятлы итү, хур итү (заставить покраснеть, поставить в неудобное положение). Миңа таба җасадын, битемә қара жақтын.

**таба исе чығару** *каз.ар.* дини бәйрәмнәрдә табада ризык пешерү йоласы (обряд: на религиозных праздниках печь на сковороде мучное блюдо).

**таба күмәц** *срг.*, **таба күмәч** *мәл.*, *тмн.* к.: **тәбийә 1.** Ацыган камырны кул белән ләпелдәтәләр дә таба күмәц пешерәләр. – *срг.* Әни пешергән таба күмәчне генә йаратам мин. – *тмн.*

**таба қысқыц** *тара.* к.: **табақычқыч.**

**таба тишеге** *каз.ар.* к.: **пич I: суқыр пич.** Таба тишеге ақтарып, табаларны төшөрмә тағы. – *дөб.*

**таба тотқа** *тара.*, **таба тотқыч** *перм.* к.: **табақычқыч.** Әтнәкич, бәйрәм кич, әләктергеч-тарттырғыч, чаш-пыш, дип әйткән була, имеш, таба тотқычын. Әнәй эзләп китте таба тотқычқа тайанып. – *перм.*

**цынайақ таба** *төм.* к.: **җәйләү.**

**чоқор таба** *перм.* берничә чокырлы таба (сковорода с углублениями). Элек чоқор табада қамыр салып пешерәләр ийе.

**ТАБАҒАЧ** *твр.* к.: **тәбеч.**

**ТАБАДЫН** *клм.* таба (сковорода).

**табадын тотқасы** *клм.* к.: **табақычқыч.**

**ТАБАЙКМӘК** *перм.* эченә җиләк-җимеш салып, ачы камырдан пешерелгән бәлеш (большой круглый пирог из кислого теста с начинкой из ягод или фруктов); чаг.: **ләwәш 1.**

**ТАБАҚ** *перм.* **1.** к.: **җәйләү.** Әби, табағыңы бир әле; **2.** к.: **таба.** Табақлар йуғ әле, алдыртмадық.

**алпама табағы** *кргл.* к.: **ашлау I, 2.**

**ипи табағы** *мам.* мичкә тыгар алдыннан ипи салып кабарта торган агач табак (деревянная чаша, в которую кладут увалянный хлеб); чаг.: **чара 2.** Пичкә тығар алдыннан ипи қабарта торган ипи табағы була.

**қақ төш табағы** *каз.ар.-крш.* кыз ягыннан ризалык билгесе итеп егет ягына китерелгән чәкчәккә җыелган мәҗлес (угощение чакчаком, присланным со стороны невесты стороне жениха в знак согласия на помолвку). Баллы төшкә җийып (егет) сый уздыра, аңа ақча салалар, аны қақ төш табағы, диләр.

**қом табақ** *бөре.* балчықтан яндырып ясалган табак (чаша, миска из обожжённой глины).

**қунау табақ** *тара.* кыз ягыннан килгән кунакларны махсус кундырып калдырып сыйлау өчен әзерләнгән ризык (еда для угощения гостей со стороны невесты, специально оставленных ночевать).

**күмәч табағы** *к.т., нрл.* к.: **ипи табағы.** Басқач қабара, аннары сун тутырасың күмәч табақларына, элек саламнан үргән була торған ийе. – *нрл.*

**лакавый** [*рус.* лаковый] **табақ** *бөре.* к.: **таба.**

**оло табақ** *каз.ар.-крш.* зур табак белән (үлгән кешене искә алу мәҗлесенә) алып килгән аш-су (еда, съестное, принесённое на поминки). Оло табақны өч табаққа бүләләр, ололарга, уртада – үлгән кешегә, өченче табақ килгән-киткәнгә қуйыла.

**патифун табақ** *перм., нокр.* к.: **таба.** Патифун табақлар җибәрең әле безгә. – *перм.*

**пеләшкә табақ** *т.кам.-крш.* һәртөрле кечерәк табак (мисочка из любого материала); чаг.: **бад′йан I, 1.** Аны пичкә утыртырга чыдый, тәбә утырталар, пеләшкә табақ чыдамлы була.

**салам табақ** *трх., к.т.* ипине мичкә тыкканчы салып тора торган, салам белән камышны аралаштырып үреп эшләнгән савыт, форма (форма для увалянного хлеба, плетённая из камыша в перемежку с соломой); чаг.: **ипи табағы.** Салам табақ буладыр ыйы, ипи әwәләгәч пичкә салғанчы қуйып тора торган. – *к.т.*

**табақ җасау** *нгб.-крш.* үлгән кешене искә алу мәҗлесенә алып килгән ризыклардан өлешләр алып аерым табакка җыю йоласы (обряд: из блюд, принесённых на поминки, собирают определённую часть в отдельную посуду для покойника). Менә атап тәберсен иткәндә үлгән кешегә табақ жасыйбыз. Зур итеп кажныйның нәрсәсе бар, шуны салып бер зыур табақ жасыйбыз.

**таш табақ** *минз., перм.*, **таш табак** *әжә.* аш тәлинкәсе (глубокая тарелка). Шуның хәдәр генә салып китерәләр таш табаққа. – *перм.* Таш табаклар була иде. – *әжә.*

**чаған табақ** *минз.*, **чара табақ** *каз.ар.-крш., т. кам.крш., лш., к.т., перм., тара.* к.: **ашлау I, 2.** Ағач чара табақ белән бәрәңге пешереп утыртқан. – *каз.ар.-крш.* Оло чара табақ белән китереп утыртқан бәрәңгене. – *т.кам.-крш.* Зур чара табақ белән аш сосоп қуйған. – *к.т.* Бер чара табақ аш. – *перм.* Бер чара табақ ашны ашаса да күңне булмый аның. Чара табағын инде ун җылдан бирле җөртәдер ийем, озаққа чыдаған ыйы, менә бөген Микайлабыз жардәле. – *т.кам.-крш.*

**чәй табақ** *нокр.*, **чинайақ табағы, чинәк табағы** *нрл.* чынаяк тәлинкәсе (чайное блюдце). Чинәк табағы белән чеки китереп утыртты wатып ашарға. – *нрл.* Чәй табақларны аласы. – *нокр.*

**ТАБАҚ** *мәл.* эмаль табак (эмалированная миска, чаша). Капчыгың кипкәч, мин дә берәр табак ын бирермен.

**салма табагы** *срг.* к.: **ашлау I, 2.** Ашны барың бергә салма табагыннан ашый иден.

**ТАБАҚЛЫҚ** *мам., блт., нокр.*, **ТАБАКЛЫК** *глз.* **1.** табын әзерләнгән өстәл (накрытый стол, стол с угощениями). Табақлық йанына қул йумыйча утырмыйлар. – *мам.* Иремнең абыйсы табақлықта утыра, сөйләшмибез, уртада табақлық. – *блт.*; **2.** *злт.* кухняда савыт-саба кую өчен стена буенда ясалган озынча өстәл (длинный и узкий стол для посуды вдоль стены на кухне); **3.** *кмшл.* кухняда савыт-саба кую өчен стенага ясалган кечкенә шүрлек (маленькая полка для посуды на кухне). Табақлыққа қуй шунда тәрлекәләрне.

**ТАБАКҮМӘЦ** *срг.*, **ТАБАКҮМӘЧ** *хвл.* **1.** ачы камырны җәеп, өстенә изелгән бәрәңге, орлык һ.б. ягып пешерелгән ашамлык (мучное блюдо – подо-

бие шаньги, ватрушки и т.д.); **2.** *хвл.* ипи камырыннан таба зурлыгында итеп жәеп пешерелгән камыр ашы (большие лепёшки из кислого теста); чаг.: **тәбийә 1**. Табакүмәч түгәрәк кенә таба зурлыгында, әпәй камырыннан, берәз пешереп алгач каймак сөртәсен, пичен өлгерсә, мичтә, өлгермәсә, майда пешерәбез.

**ТАБАҚЦА** *тара.*, **ТАБАҚЧА** *брб.д.*, *твр.*, **ТАБАКЧА** *байк.* к.: **жәйләү**.

**ТАБАҚЫЧҚЫЧ** *төм.* табагач (сковородник).

**ТАБАЛАМА** *перм.* к.: **йунгы**.

**ТАБАЛАУ** *минз.*, *тбл.* ачулану, орышу (ругать, бранить).

**ТАБАН I** *миш.д.* **1.** кеше аягының үкчәсе (пятка). Әллә табаның awыртамы, цатанныйсың. – *чст.* Ташка басып табанымны awырттырдым. – *хвл.* Табаннарың асфальт шикелле йалтырый. – *срг.* Айакның табаны йезелде вайнада. – *лмб.* Менә мынысына табан ат'абыз. Табан артымны кырды туфли. – *мәл.*; **2.** аяк киеменең үкчәсе (каблук обуви; пятка чулка); чаг.: **келә**. Ойыкны башта куныч, аннан табан, аннан башын бәлисең. Бийек табанны туфли кигән. – *хвл.* Бийек табанны туфле белә йери ул. – *чст.* Бийек табанны баритка кийә иде. – *срг.* Ыйыгының табаны йук. – *шрл.*; **3.** аяк киеменең арты (задник обуви). Исай, сандалийыннын табанына басып бетерәсен. – *кузн.*

**табан қywышы** *перм.* табан астының биллән торган урыны (плюсна).

**табан төп** *перм.* табан асты (стопа). Идәнгә кынупкы төште, табан төпкә қадалмасын.

**табанынан тузған** *перм.* тәбәнәк буйлы карт кешегә карата әйтелә (говорится о старом человеке низкого роста).

**ТАБАН II: миц табаны** *тмн.* мич төбе (под печи). Пумала белән себерәбес, мицнең табанына салып пешерәбес.

**ТАБАН III** *перм.* тәлгәш (кисть, гроздь). Милишнең табаны қысқа. Паланның табаны аз булған. Табанын ғына кисеп аласың да палан табанны бергә мунчала қушып бәйлисең.

**ТАБАН IV** *стрл.* буын (поколение). Өченче табанға китсә, тудықай әйтешәләр иде.

**өч табан тайган** *хвл.* дүртенче буын туган (четвероюродный). Өч табан тайган кардәшем бар иде, йыраграк кардәшем, өченче табанга киткән – ике туган, туганнан туган.

**табан тайган** *хвл.*...нче буынга киткән (...-ое поколение).

**ТАБАН V** *клм.* к.: **табадын**.

**ТАБАНДЫРЫК** *кузн., тмн.* тәбәлдерек, туку станогының аяк баса торган урыны – педаль (подножки – у ручного ткацкого станка).

**ТАБАННАУ I** *яушт.* төпләү (подшивать). Табанный идек пиманы.

**ТАБАННАУ II** *нокр.* китү, үкчә күтәрү (удрать, убраться, показать пятки). Әйдә, табанныйбыз, диде дә китте.

**ТАБАНТЫННАН** *мам.* к.: **табатын**. Әнә тегеләй табантыннан берәү килә.

**ТАБАНЧА** *т.кам.-крш.* тимераяк (коньки). Балалар табанча шуwалар ыйы.

**ТАБАТАН** *яушт.* к.: **табадын**. Бәдерне оннан бешерәбез, пиц өстендә табатанда.

**табатан тотқағы** *яушт.* к.: **табақычқыч**.

**ТАБАТЫН** *бәр., минз., чст.* таба (по направлению к ... или от ...). Без барабыз коммунизмга табатын. – *минз.* Менә моннан табатын киләйе ул. – *бәр.* Кем килә инде бездән табатын? – *чст.*

**ТАБАЦ** *төм., тбл., брб.д.* к.: **табач**.

**ТАБАЦА 1.** *туб.-ирт.д.* кечкенә савыт (маленькое блюдце); **2.** *төм.* к.: **жәйләү**.

**ТАБАЦТАУ** *том.д., тбл.* учлау, учлап алу (взять горстью).

**ТАБАЧ** *брб.д., клм.* уч (ладонь). Табач қычыса ақча килә. Йеләк пер табач ашаты. Табач чапқалы пес парып отырапыс кансирт килсә. – *брб.д.*

**бер табач** *клм.* бер уч, аз гына (немного). Пер табач қалық қалды мында қәзер.

**табач қағу** *клм.* к.: **чәбекәй: чәбекәй итү**. Ақча бәрәләр, табачты қағалар.

**ТАБЕРСЕ: таберсе көн** *чпр.* берсекөнгә (послезавтра).

**ТАБИКМӘК 1.** *т.я., каз.ар., тбл.* к.: **тәбийә 1**; **2.** *мам., трх.* өстенә бәрәңге яки эремчек ягып ачы камырдан пешерелгән пәрәмәч, шәнгә (шаньга). Табикмәкне кечкенә итсәң дә була, таба қәтле дә була, ипи қамырыннан бәрәңге жағып пешерәсең. Ипиләрне пичкә тыққанчыға хәтле табикмәкне қызартып аласың. – *мам.* Табикмәкне болай қамыр өстенә қоймак қамыры йағып та пешерәсең, бодай бик хәдерле булған ул элек. – *к.т.*; **3.** *блт., тбл.* коймак камырыннан юкарак итеп табада пешерелгән ашамлык (один из видов блинов). Табикмәкне қоймақ апарасыннан пешерәләр ул. – *блт.*; **4.** *перм.* эченә жиләк-жимеш салып, эче камырдан пешерелгән бәлеш (большой круглый пирог из кислого теста с начинкой из ягод или фруктов); **5.** *м.-кар.* бодай кабартмасы (пышка, лепёшка из пшеничного теста на дрожжах).

**бәрәңге табикмәге** *т.я., каз.ар.* пешкән табикмәкнең өстенә бәрәңге измәсе ягып, яңадан ут каршында өсте қызарганчы пешерелә торган азык (вид шаньги: на готовую лепёшку намазывается картофельное пюре и жарится на огне до покраснения); чаг.: **дурочмақ**.

**ТАБИПИ** *твр.* төче камырдан пешерелгән кабартма (пышка на пресном тесте).

**ТАБИС: табис чығару** *баст.*, **ТАБИСЕ: табисе чығару** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* үлгән кешене искә алу көнендә табада ризык пешерү йоласы (обряд: на поминках приготовить на сковороде блюдо); чаг.: **таба: таба исе чығару**. Табисе чығарып хәйер бирәләр. – *каз.ар.-крш.* Қырқысында шул табисе чығарыб атап бер мал суйа инде, анда бәрәнме, қазмы. – *т.кам.-крш.* Табис чыгаралар. Ул әбигә бер ней табис чығарған кеше булмады. Әниләрдән уқымаға әрәндем дуwалықлар, табис чығармаға кәрәк. – *баст.*

**ТАБУ** *кас.* күрү (видеть, увидеть). Әwәл тешен таба, 'үли' алып бири, башынамы.

**ТАБУН** *трх., тмн., кузн.* көтү (табун, стадо). Табун үткән борчақ жирләредер, хәзер шуны суқалыйлар. – *трх.* Табун килә. – *тмн.* Арслан куwагында табун көтә идек. – *кузн.*

**табун сакчысы** *тмн.* көтүче (пастух). Табун сакчылары күргән.

**ТАБУН-ТАБУН** *чст.* төркем-төркем (группами). Табун-табун зегетләр.

**ТАБЫДАН** *клм.* к.: **табадын**.

**ТАБЫЛУ I** *нокр., глз.* тапталу (быть задавленным, попасть под транспорт). Атасы машинага табылған, үлгән инде. Бәбәй сакълама дип барды да пуйызға табылды. – *нокр.*

**ТАБЫЛУ II** *нокр., глз.* **1.** очрау, туры килү, тап булу, юлыгу, әләгү (попасть, прийтись, встретиться). Бәлагә табылу. Йаңғырға табылса, бу да сулы була (каен җиләге). Анда барсалар, табылмайлар да иде ич әле бызға да. – *глз.* Қаладан қайтқанда, йаңғырға табылдым. Без бер пыласкартқа табылдық. Ризық әйтсен бай кешегә табылдым дип, йатасы кечти генә. – *нокр.*; **2.** кушылу, катышу, берләшү (сливаться, смешиваться, объединяться). Awылдар бер калхузға табылды хәзер бездә; **3.** килү, килеп чыгу (приходить, появляться). Қайан табылдығыз сез былай, Глазданмы, Қазанданмы? Мин мында қаан табылдым диме? – *нокр.*; **4.** алыну (быть призванным в армию). Быйыл олом салдатка табылды. Ул табылды Мәскәүгә, йыл ыслужит итте. – *глз.*

**табын I** (накрытый стол; стол с угощением): **табын әйләнәсе** *лш., чст.*, **табын әйләнмәсе** *к.т.* к.: **алсузма**.

**табын җәймәсе** *минз., трх.* к.: **ашаулық**.

**табын тастымалы** *минз., стрл.* к.: **алсузма**.

**ТАБЫН II** *перм., эчк., тмн., твр.* төркем (группа). Пер табын қыслар үтеп парады. – *твр.*

**ТАБЫН III** *перм., эчк., тмн.* к.: **табун**. Бу табарақ қу да китер табыны белә (сарыкларны). Әле монда мә бозау бик шәп қый табында. – *перм.* Бер табын көтү йөрәй. – *эчк.* Үрдәкләр инештә бер табын йөриләр. – *тмн.*

**ТАБЫР 1.** *минз.* ындыр табагы (ток); **2.** *трх., кмшл., чст., мәл.* көннең эссе вакытында су буенда көтү туктап ял итә торган урын, туплавык (лежбище, место отдыха и водопоя для скота). Сийыр көтүwe табырга төште. – *чст.* Табырдан барып таптым кат'маган куйымы. Сыйрлар табырга төшкән, диләр. – *хвл.* Кетү табырға тешкән, теш йеткән инде. – *кмшл.*; **3.** *кмшл.* тапталып беткән урын – идән, җиләклек h.б. турында (говорится о чём-либо затоптанном: ягоднике, грязном поле и т.д.). Табыр йасағаннар бит, җиләкнең эзе дә йуқ.

**ТАБЫСҚА** *злт.* к.: **йунгы**. Күзенә табысқа сәсрәп суқыр қалған. Табысқаны балта белән сабып сығаралар.

**ТАБЫШ I** *срг.* өстәмә акча (дополнительные деньги). Индиски цәй китерде туғзан алты тингә, табыш та алмады.

**ТАБЫШ II** *тмн.* киңәш (совет). Атинәсеннән сураты, туган-карынташка табыш кылайык, тиделәр.

**табышмак** (загадка): **табышмак таныту** *м.-кар.* табышмак таптыру (заставить разгадать загадку).

**ТАБЫШТАН** *глз.* зинадан (вне брака). Табыштан дүрт бала китерде. Әле бала табыштан табалар.

**ТАWАП** [*гар.*] *тбл.* гыйбадәт йоласы буларак түгәрәк ясап йөрү (хождение кругом как молитвенный обряд).

**ТАWАШ** *каз.ар.* тавыш (шум, крик, возглас). Төне-көне бер tawaш туқтамый. Бер tawaш бар. Tawашлы кеше. – *дөб.* Машина tawашы килә. – *лш.*

**tawық** *урт.д.*, **tawык**, **тавык** *миш.д.* тавык (курица):

**қортый tawық** *дөб., бөре.* чебеш анасы (наседка). Бер қортый tawық сатам, бер tawық қортлап йөри. – *дөб.*

**қунаштырмый торған tawық** *трх.* әтәчне якын китерми торган тавык (курица, которая не подпускает к себе петуха). Әтәчем қунаштырмый торған tawыкны талый.

**күке tawық** *бәр., дөб.* акка кара тимгел төшкән tawык (белая курица с чёрными пятнами). Күке tawық чуwар tawық була. – *бәр.* Күке tawық киндер орлоғы төслө тимгелле tawық. – *дөб.*

**tawық башы** *карс.* к.: **тузғақбаш**.

**tawык каравы** *мәл.*, **tawык карawы** *чпр.*, **tawык карawылы** *срг.* тавык күзе (куриная слепота). Күзем tawык карawылы, ни дә күрмим, дийр. – *срг.*

**тавык күз** *хвл., кузн.*, **tawык күзе** *карс* **1.** кызыл бөрлегән (костяника); **2.** *срг.* к.: **байбай**.

**тавык кыравы** *тмн.* к.: **чәчәк I: ағулы чәчәк I, 2**.

**tawық суқыры** *кмшл.* к.: **tawык каравы**. Әллә tawық суқыры булды инде күземә, бернәрсә күрми.

**tawык тапайы** *чпр.* үлән исеме (название травы). Tawык тапайы йылга буйында үсә.

**tawык тарысы** *срг.* к.: **ут: тары уты**.

**tawык тәпәйе, tawык тәпийе** *чпр.* к.: **tawык тапайы**. Tawык тәпәйен ашамыйлар, ул дару өцен генә, ап-ак цәцәк ата, ул йылгалык йанында була, түгәрәкләнеп кенә wак кына цәцәг ата.

**tawық үләте** *нрл.* к.: **чәчәк I: ағулы чәчәк I, 2**.

**tawык эләге** *срг.* к.: **байбай**.

**ТАWЫС** *лмб.*, **ТАВЫЧ** *мам., лмб., кузн., м.-кар.*, **ТАWЫЧ** *нокр., глз., мам.* **1.** к.: **тәбеч**. Мә тавыч картукка. – *лмб.* Tawыцны tawычқа салайыммы? – *нокр.* Менә бу tawыч белән ал сыуны. – *мам.*; **2.** *м.-кар.* к.: **ашлау I, 2**. Татар кеше, табак, ди, ә без, tawыс, дибез.

**ТАWЫШЛЫ-ТЫННЫ** *блт.* ызгышучан (бранчливый, скандальный, вздорный). Tawышлы-тынны қатын түгел.

**ТАWЫШ-ТАЛГЫН: tawыш-талгын тору** *байк.* ызгыш-талаш белән тору, тавышланышып тору (жить в ссоре). Тыныч тордык, tawыш-талгын тормадык.

**ТАҒА** *миш.д.*, **ТАҒА** *төм.* дага (подкова).

**ТАҒАЙА** *клм., яүшт.* бүрек (шапка).

**ТАҒАЛЫҚ** *клм.* догалык (молитвенник). Тағалығы бунда, ол кежене көркөм көрсөтө ти.

**ТАҒАМ** *эстр.* ашамлык (съестное).

**ТАҒАН 1.** *трх., перм.* шеш (шест в середине стога, стожар). Таған – кибән аумастан. Кичәге җил, таған булмаса, кибәнне ала да китә. – *трх.*; **2.** *бөре.* бәпкә, кайчы (стропило).

**таған асты** 1. *мам.* элек: җыен вакытында көндезге уенга чыгу урыны (раньше: место проведения игр во время *джйын* – весенних сельских празднеств, устраиваемых группой сёл). Таған астына төшә торган ыйык чишмә башына. Җыйын вакытында таған астына төшә торган ыйык; 2. *лш.* сабан туенда уеннар үткәрелә торган мәйдан (площадь, где во время сабантуя устраиваются бега, различные игры). Таған асты анау болонда безен ат җөгөртәләр, көрәшәләр; 3. *нгб.-крш.* кичен яшьләр уены була торган урын (место проведения вечером молодёжных игр). Инде җегетләргә әйтәләр, кичкелеккә таған астына барабыз, таған астында ат алмаштырып җөртәбез.

**ТАҒАРАҚ** *нрл., трх.* к.: **йулпуч**. Элек тағарақларда он иләгәннәр. – *нрл.* Тағарақ – озынча ағач савыт, анда он илибез. – *трх.*

**ТАГУ** 1. *карс., стрл.* элү (вешать). Ничек karawat башларына тактым, шулай ук калган йаулыгым. Элгегә таккан зәләмә йубка. Ылампа таккан пиз баштан мерҗә йагалый. – *карс.* Сез сөлгеләрегезне монда тагыгыз. – *стрл.*; 2. *карс.* асу, күтәрү (взвалить, поднимать, вешать). Ике чимаданны ике кулга, вишшевый капчыкны аркама тагам да китәм.

**ТАҒЫДАҚ** *мам.*, **ТАГЫДАК** *мәл.* тагын да (ещё). Тағыдақ әйләнеп қайтам әле мин. – *мам.* Тагыдак та мының туганнары бар, ди. – *мәл.*

**ТАҒЫЛУ** *тбл.* абыну (запнуться, споткнуться). Айағым тагылып йығылдым.

**ТАГЫЛЫНУ** *карс.* асылыну (повеситься). Элек берәү шунда тагылынган иде урманда. Тагылынган кешегә пам′атник куйалармы?

**ТАҒЫМ** *себ.* тез асты (сгиб под коленом). Тағымым серләйте. – *тбл.* Цацым тағым астан ит. – *тара.*

**ТАҒЫН** *перм.* к.: **даған 2**.

**ТАҒЫНДАҚ** *мам., кмшл.* к.: **тағыдақ**. Тағындақ ике йөз қырық сум ақча күчерелгән. – *мам.*

**ТАҒЫНУ** *перм.* (таган) атыну (качаться на качелях). Башны әйләндерәсең, тағынма.

**ТАҒЫРМАҚ** *тара.* тырпаеп тора торган куе ботаклы агач, чатыр (густой кустарник с торчащими ветками, хворост).

**ТАҒЫРЦАҚ** *брб.д.* кыска чәч белән яки кыска чирәм белән капланган (покрытый короткими волосами или короткой травой).

**ТАЗА** 1. *нокр., перм., клд.* куәтле, көчле, нык, шактый нык (сильно, крепко, значительно). Бик тиз сүндердең андый таза утны. Утырыгыз, утыр, төшсәгез ки чабармын таза (атта). Бик таза йарата. Бик таза сақланасы дий (уттан). Теге көнне и таза кеткәннәр икән. Бик таза йаумады. – *нокр.* Йаңгыр бик таза йауды, нawызга чыга алырбыз микән. – *клд.*; 2. *нокр., перм., срг., хвл., мәл.* яхшы, әйбәт, шәп (хорошенько, много). Ашагыз таза гына. – *хвл.* Ашасым да келәми, әнәйләрдә бик таза чәй эчтек. Син, кызым, таза аша. – *мәл.*; 3. *хвл.* каты, нык (сильно, крепко). Таза кын′аганнар; 4. *минз., нокр., перм., стрл.* яхшы (хорошо). Ручча таза белә ул. – *стрл.* Берәүнеке малайы әрмийәдән килгәч, урычча бик таза беләм инде, ди икә, арта үзе хелипне дә белмәгән. Ул бик таза шәп йырлай ич, хәтеремдә таза қалды. Миндә тордылар ике йыл, алар бик таза беләләр мине. – *перм.* Бу таза укыта, институтта да эшләре йахшы бара. – *срг.*

**tada күкәй** *мам.* чебешсез, яралгысыз йомырка (яйцо без зародыша). Күкәйләре tada булды, чығармады күркәм.

**ТАЗАЙАҚ** *мам., эчк.* таз, түгәрәк ләгән (таз). Әнә тазайақ, йомочқа апкерергә. Қазларға утыртқан тазайаққа сал. – *мам.* Әнә тазайақ йуwыша торған. – *эчк.*

**ТАЗАРТУ** *бәр., чст.* төзәтү, ясау (чинить, ремонтировать). Арбаның пилеткәсен тимерче тазартмаған әле. – *бәр.* Кат′мадылар инде быйыл, үләрен тазарталар. – *чст.*

**ТАЗҒАРА** *минз.*, **ТАЗГАРА** *стрл.* ак башлы зур ерткыч кош (гриф). Башы ак була тазгараның, таз кешенеке шикелле. – *стрл.*

**ТАЗЗИТ** *дөб.* тәкәрлек (чибис, пигалица). Болында таззитлар килгәлләр, иртәдән кичкә қәдәр қычқыралар.

**ТАЗРАЦ** *брб.д.* шакылдаткалау (постукивать).

**ТАЗ-ТАРАУ** *каз.ар.-крш.* таркау, таралган (разбросанный). Балалар таз-тарау.

**ТАЗЫ** *тбл., тара.* ау эте (охотничья собака – гончая).

**ТАИКМӘК** *тбл.* җәймә (лепёшка).

**ТАИН** [*гар.*] *төм.* тәгаен (наверняка, наверное). Таин ул шул йаққа гитте.

**ТАЙ I** *каз.ар.-крш., лш., трх., миш.д.* к.: **қолқай**. Җәш тайы бар, җаз туған. – *трх.* Бер йәш үсте бит инде тай, қырықма була, йалларын қырқасың. Тайлы бийә җиктем дә. – *стрл.*

**тай боты** *трх.* ипи камырыннан мич алдында табада пешерелгән озынча формадагы камыр ашы (мучное блюдо из хлебного теста в продолговатой форме, испечённое в сковородке у горящей печи).

**ТАЙ II** *перм.* тутай, апа (форма обращения к женщинам старше себя). Кифайа тайларга быйыл да килә икә ул. Фәнийә тай үдә йуқмы?

**ТАЙА** *перм.* печән, салам ташый торган арба (тележка, приспособленная для перевозки сена, соломы).

**т а й а қ** таяк (палка):

**башландырық тайақ** *перм.* киндерне тукый башлаганда, буй җепнең очларын бәйләп чыга торган агач (палочка, на которую привязывают концы основных нитей при тканье холста). Башландырық тайақны бер йарты митер суққас алып қуйабыз.

**бура тайақ** *к.т.* юан таяк (толстая палка). Бура тайақ белән терлек қумыйлар, суқсаң имгәтерсең. Бура тайақ белән қыйнаган атны.

**көлтә тайағы** *мам.* көлтәләр төяп кибән янына ташый торган пар колгалар (пара шестов, на которую поперечно кладут снопы и несут их к стогу). Көлтә тайағы белә көлтә ташый-ташый қулбашларым қалмады.

**лишут тайағы** *дөб.* кәшәкә (клюшка).

**салам тайағы** *бәр.* к.: **көлтә тайағы**. Салам тайағы белә көлтә ташып кибән қуйдық.

**тыйғыча тайақ** *перм.* боргычны ныгытып куя торган таяк (притужильник – часть ткацкого станка).

**ТАЙАҚАЙ** *кргл.* тайгак (скользкий; скользко). Тайақай суқмақтан йөрмә, йығылырсың.

**ТАЙАҚЛАНУ** *перм.* таякка таяну (опираться на палку). Тайақланып қайттым, тубықланып керләр йудым.

**ТАЙАН-МАЙАН** *брб.д.* бераз вакыт (некоторое время).

**ТАЙАНСЫҚ 1.** *злт., тпк.* киленне кияү йортына алып кайткач, арбадан яки чанадан төшкәндә бүләк ителә торган аяклы мал (домашнее животное, чаще овца, передаваемое невесте со стороны жениха). Тайансық сарық китерәләр, тайанып төшә килен. – *злт.* Әлеге тайансығы бары қырғарақ төшереп киленне, тайансыққа тайандырып та әпкиләләр. – *тпк.*; **2.** *тпк.* таяныч, ышаныч (опора, надежда). Мона минең тайансығым шушы инде, исән-имин үссә.

**ТАЙАНУ** *перм.* сөялү (опираться). Бүкәндә утырам шулай арт җағына тайанып.

**ТАЙАНЦЫҚ** *эчк.*, **ТАЙАНЦЫК** *байк.*, **ТАЙАНЧЫҚ** *минз., перм., кргл., глз.*, **ТАЙАНЧЫК** *стрл., чст., т.я.-крш.* к.: **тайансық 1.** Сарык сыйпаталар, тайанцык тотып торалар. – *байк.* Пawазкадан төшкәндә киленгә тайанцық кирәк. – *эчк.* Байрақ кешеләр сарықмы, бызаумы тайанчык тыттыралар, аңа бер селге бирәсе була. – *глз.* Тайанчык килен төшкән wақытта бирелгән мал, килен шуңа тайанып төшә дә сөлгө бирә. – *минз.* Киленгә тайанчык тоттыралар ыйы, минем үземә дә тоттырганнар ыйы. – *кргл.* Ишек тебендә тайанчыкка тай китерделәр. – *стрл.* Төшкән йереңгә сарык, тайанчык, диләр, ул сиңа була. – *чст.* Капкадан кергичтән азбардан кырыкмыш тай җитәкләп чыгалар, тайанчык дип, кыз кулына тезген тыттыралар, халат чабуwы белән тытыб ала. – *т.я.-крш.*

**ТАЙАР** [*фарс.*]: **тайар тырып** *дөб.* игътибар белән (внимательно). Бик тайар тырып уқырға кирәк.

**ТАЙАРЛЫ** *клм.* хәстәрле (запасливый, предусмотрительный). Аққаға тайарлы түгел ул бичә.

**ТАЙАУ I 1.** *минз., бөре.* арткы күчәрне арба күкрәгенә беркетә торган тимерләр (железные детали для соединения осей телеги); **2.** *минз.* таган (верёвочные качели).

**ТАЙАУ II** *тбл.* терәү, якын китерү (поставить вплотную, приблизить). Күсеңә тайап күрсәттем қуй.

**ТАЙАШУ** *тбл.* азаплану, тырышу (мучиться, стараться). Көн күргәле тайаша.

**ТАЙБАҚЛАУ** *тбл.* сүздә тормау (не сдержать слова).

**ТАЙҒА** *яүшт.* саз (болото).

**ТАЙҒАЙАҚ** *тара.* бозлавык (гололедица).

**ТАЙҒАЛЫҚ** *клм.* урманлык (лесистое место, тайга). Беснеңке пабалар Тум арйағында болганнар, соу басқычын, тайғалық тип, бу йаққа чыққаннар.

**ТАЙҒЫЛАУ** *тбл.* агачка кирт салу (делать насечки на дерево).

**ТАЙҒЫЛЫЧ** *перм.* к.: **тайақай.**

**ТАЙҒЫЧ** *лш., минз.*, **ТАЙГЫЧ** *стрл.* к.: **тайақай.** Айақ асты бик тайғыч. – *лш.* Бик тайгыч ийе, пычыраг ийе. – *стрл.*

**ТАЙДАҚЛАП** *тара.* нәрсәгәдер сыярлык зурлыкта алып (взяв в достаточной величине). Бер табаға тайдақлап йәйәсең қурны, табаға салып майда пешерәсең.

**ТАЙКА** *лмб.* элек кызлар кигән тәңкәле баш киеме (старинный девичий головной убор, украшенный монетами). Тайкалы чакны йакшы атаана эвендә тырырга, тастарлы булгач авыр (*әйтем*).

**ТАЙҚАН** *тбл.* ау эте (борзая собака).

**ТАЙЛАҚ** *брб.д.* улак (жёлоб, желобок). Чишмәдә тайлақ белә сыу ағып тора.

**ТАЙЛАУ** *лш., каз.ар.-крш., нрл., к.т., трх., миш.д.* к.: **коннау.** Тайлый торган атны байтал дибез. – *лш.* Байталлары һәр җылны тайлый бит, атлар күп. – *трх.*

**ТАЙЛЫҒУ** *перм.*, **ТАЙПУ** *минз.* таю, качу (удрать, убегать). Шуннан мин инде икенче иргә тайлықмақчы да булам. Абзыйсы икенче иргә тайпыған.

**ТАЙПЫНУ** *трх.* тартыну, оялу (стесняться). Қунақ башта тайпынып торды, аннан иләште.

**ТАЙРАҢНАШУ** *брб.д.* тай кебек булу (стать подобным жеребёнку).

**ТАЙСАҚ** *брб.д.* сай (мелкий, неглубокий). Тайсақ анта су.

**ТАЙТАК** *срг.* аңгыра, булдыксыз (бездарный, глупый, бестолковый).

**ТАЙУ 1.** *срг., шрл.* берәр нәрсәдән язу, югалту (потерять, лишиться чего-либо). Саулыктан тайганчы гына. Һуштан тайу. – *срг.*; **2.** *брб.д.* көчсезләнү, хәлсезләнү (обессилеть, терять силы). Йәшисе килде, йөрәк тайғандыр, диде.

**ТАЙХА** *кузн.* **1.** тәңкә яки мәрҗән тезеп, ука тотып ясалган изү (женское нагрудное украшение); чаг.: **алынча**; **2.** хатын-кызлар киеменең бер компоненты, күлмәк астыннан күкрәккә киеп калдырыла торган чигүле материя, күкрәкчә (вышитый нагрудник, надеваемый женщинами под платье).

**ТАЙЧАНУ 1.** *лш.* уңайсызлану (чувствовать неловкость). Матурлыгы белә тайчансаң да, ай ақыллыйы; **2.** *тара.* ял итеп алу (немного отдохнуть). Тайчанабыс, урман цийә йийабыс та.

**ТАЙЧУ'** *кас.*, **ТАЙЧЫҚ** *клм.*, **ТАЙЧЫК** *карс.* к.: **қолқай.** Аты да бар, тайчығы да бар иде. – *клм.*

**ТАЙЧЫН-ТОЙЧЫН** *перм.* алпан-тилпән (вперевалку). Әби җәри шунда тайчын-тойчын.

**ТАЙЫ** *брб.д.* ачык җир (открытая местность).

**ТАЙЫЛУ** *т.я.-крш.* кыйшаю, янтаю (скособочиться, накрениться на один бок). Тайылып кына барып карады, сине күрмәде булыр.

**ТАЙЫЛЧЫК** *чпр., мәл.* к.: **тайақай.** Йул бик тайылчык, атка йерергә хутсыз. – *мәл.*

**ТАЙЫМ I** *т.кам.-крш.* таба (ближе к ...). Җәйгә тайым ғына, уйдық-уйдық қына җиләк.

**ТАЙЫМ II 1.** *трх., хвл., чпр., чст., баст.* иркәләп, яратып эндәшү сүзе (форма ласкового обращения). Кирәкми, тайым, майың, дир. – *чпр.* Лисапит

белән барыга иде, барыга иде, тайым. – *хвл.* Тайым, сабағыңны уқыдыңмы? – *трх.* Мин җырлый да белмим, тайым. – *баст.*; **2.** *шрл.* үзеннән кечерәкләргә иркәләп эндәшү сүзе (форма обращения по отношению к младшим себя). Ризидә, салыйм, тайым, аш.

**ТАЙЫН 1.** *кргл.* к.: **тике**; **2.** *твр.* ахыры (кажется).

**ТАЙЫНЧА** *брб.д.*, *тара.* **1.** тана (телёнок). Тайынчалар белән гелән көтәләр, сawын сыйырлар белән. – *тара.*; **2.** ана колын (жеребёнок-самка). Атыбысныңқы баласы бар, тайынча. – *брб.д.*

**ТАЙЫР** *баст.* әзер (готовый). Ыстақан тайыр булды чәй эчмә.

**ТАЙЫС** *яүшт.* сай (мелкий, неглубокий).

**ТАЙЫШҚАЙАҚ** *тара.* к.: **тайақай.**

**ТА'** *кас.* балалар уенчыгы – агач коляска (детская игрушечная коляска).

**так I** (нечётный):

**таққа салу** *әстр.* егет белән кызны кавыштыру (организовать встречу жениха с невестой).

**таққа торош** *төм.* к.: **уйнау: сақлы уйнау.** Таққа торош уйнағанта арттагы икәү йөгөрә, перәү тотқалы китә.

**такны ташлау** *хвл.* китеп югалу (пропадать, исчезать). Нәстә такны ташлап йөрисең?

**ТАҚ II** *әстр.* кыз бирнәсе (приданое со стороны невесты). Бүген тақ киләде икән инде дип торалар.

**ТАҚAWЫЧ** *перм.* к.: **атawыч.**

**ТАҚАН I** *брб.д.* стакан.

**ТАҚАН II** *кргл.* к.: **тике.** Суға тақан ур йасағаннар қызны сақлар өчөн.

**ТАКИ** *трх.* һаман, бертуктаусыз, өзлексез (постоянно, беспрестанно). Ире белән баралар ыйы таки йалға.

**ТАКИЙА 1.** *т.я.-крш.* яшь киленнең мәрҗәннәр белән чигелгән конус формасындагы баш киеме (головной убор конусообразной формы у молодухи, вышитый кораллами). Такийага мәрҗәннәр тезгән әнде, нукыратлар тезгән, кылбулар; **2.** *әстр.* дүрт клинлы ирләр түбәтәе (четырёхклинная мужская тюбетейка).

**ТАҚИЙА** *баст.*, **ТАҚИЙӘ** *брб.д.*, **ТА'ИЙӘ** *кас.* к.: **кәртәши.** Тү'әрик та'ийәлир башларына 'иилир ийе. Кәпәч кебек башларына кийәләр иде тақийәне.

**ТАҚЙА** *тбл.* бүрек (шапка). Пайларта қама тақйалар пулатите.

**ТАҚҚАН** *төм.* калын чуен савыт (толстый чугун). Уцақныңқы алтына таққанны қайнатқаннар, қалын чуйыннан.

**ТАҚҚАРAWЫЛ** *дөб.* яшьләр уены: егетләр һәм кызлар кара-каршы тезелеп басалар; тезем башында берәү так кала һәм ул, бер җыр җырлангач, үзенә пар алып әйләнә (молодёжная игра, сопровождающаяся с песней и пляской; ручеёк).

**ТАККЫЧ** *хвл.* кием элгече (вешалка на одежде). Пал'тywыңның таккычын йөзгәнсең.

**ТАҚЛАУ** *брб.д.* тигезләү, таптап тигезләү (выравнивать, сделать гладким, затоптать).

**ТАКМАК** *лмб.* куплет. Бер такмагы бар бит бу йырның.

**ТАҚРАУ: тақрау җегерү** *дөб.* к.: **уйнау: сақлы уйнау.**

**ТАҚСАҚ** *перм.* каралтыда терлек азыгы, сбруйлар һ.б. шундый нәрсәләр куя торган урын (помещение, куда складывают корм для скота, сбрую и т.д.); чаг.: **чиннек I, 1.** Миңке тақсақ түбәгә орасы печин бар да.

**ТАҚСУ** *тбл.* бетеп китү, юкка чыгу (пропасть, исчезнуть).

**ТАҚСЫР** *төм.* җитәр-җитмәс, кысынкы (недостаточно). Шәлләр тақсыр ите, йөннән бәйләб алтық үсепес. Әwәл мал тақсыр булған, ситса сирәк булған.

**ТАКТА** *әҗе.* куна тактасы (доска для раскатывания теста). Тәскирә алган иде тактамны, әле үзем мында кисәм.

**айак такта** *т.я.-крш.* күтәртмә (деревянный каблук, деревянная подставка, прикрепляемая в весеннее время к лаптям).

**ал тақта** *мам.* киемнең алгы өлеше (передняя часть одежды).

**арт тақта** *мам.* киемнең арткы өлеше, арка ягы (спинка одежды). Бишмәтнең гәүдәсе ике ал тақтадан, бер арт тақтадан тора.

**аш тақтасы** *яүшт.* к.: **такта.**

**җиназа тақта** *нокр.* к.: **тәбүт 1.**

**қазан тақтасы** *бәр.*, *злт.* казан өстенә яба торган такта капкач (крышка из досок для котла).

**қамыр тақта** *нокр.*, **қунақ тақта** *тара.* к.: **такта.**

**такта асты** *клд.* к.: **гелбәч.** Такта астына тешә кыз, аннан да ырлап китәләр.

**такта башы** *клд.*, *байк.* тактадан ясалган киштә (деревянная полка, полочка); чаг.: **табақлық 2.** Чыланым бар ишегалнында, анда такта башы, wаринйамы бар, шында тыра. – *клд.*

**тақта башы** *тбл.* тышкы өй алды (наружные сени).

**түбә тақта** *бгрс.*, *кргл.*, *эчк.*, *к.-уф.*, **түбә такта** *чст.*, *мәл.* к.: **түбә 1.** Түбә тақталарны буйадым быйыл. – *эчк.* Түбә тақтам да бик беткән инде, малайым қайтқач буйатам! Буйалған түбә тақтасы йywарға җиңгел. – *бгрс.* Түбә тақта матур булмады безнеке. – *к.-уф.* Түбә такта йарыкларына кагыз куйдым бетен. – *мәл.*

**чус** [*рус.* тёс] **тақта** *трх.*, *нрл.* юка, юнылган, шомартылган такта (тёсаная доска). Абрашуткы чус тақтасыннан йасала. – *трх.*

**ТАҚТАБАШ 1.** *эчк.* өсте ябылмаган өй алды (некрытые сени); **2.** *тбл.* болдыр (крыльцо).

**ТАҚТАЛАНУ** *дөб.* керешү, киезләнү – дебет турында (сваляться, сбиться – о козьем пухе). Ул шәл тақталанған инде, йатқан.

**ТАҚТАЛАУ 1.** *кргл.* юып киптергән керне кул белән шомарту, тигезләү (разглаживать, разравнивать отстиранное вручную и высушенное бельё). Тақталап салганмын әйберләремне, чиста; **2.** *тбл.* такта кадаклау, такта белән тышлау (прибивать доски, обшивать досками).

**ТАҚТАМБИТ** *әстр.* к.: **түр 1.**

**ТАҚТАСТЫ** *брб.д.*, **ТАКТАСТЫ** *лмб.*, *кузн.*, *карс.* к.: **гелбәч.** Тактастына куйам майны. – *лмб.*

**ТАҚЫ** *к.т.* начар – ашамлык турында (неваж-

но, плохо, всухомятку – о еде); чаг.: **қыры-қары**. Жулда алай-болай читеннек күрмәдек, ашау җаҗы ғына тақы булды.

**ТАҚЫЙ** [*рус.* так и] *каз.ар.-крш.* шулай да, барыбер (так и, всё равно). Ачмадыңмы тақый?

**ТАҚЫЙА 1.** *мам.* бәрхеттән түбәтәй формасында тегелгән, алгы ягы чигүле хатын-кыз баш киеме (женский головной убор из бархата, напоминающий тюбетейку, но с овальным дном и вышитый спереди); чаг.: **кәртәши**. Тақыйасы мескен бүрек шикеллерәк, түбәкәй шикелле буладыр ыйы, чигешле, җә җаулык өстеннән кийәләр ийе; **2.** *минз., кргл., тпк., әстр.* к.: **кәпәч 1**. Қазан тақыйасын кидек инде, йаратып кидек. Тақыйа белән суға. – *минз.* Бабайлар тақыйа кийә, қарамы шунда, чиккәнме. Бер тақыйа тары чәч, менә сиңа уражай. – *кргл.* Тақыйа пит ул пабайларның түбәтәйе. Тақыйаны пүрек эченнән кийәләр. – *тпк.*; **3.** *туб.-ирт.д., брб.д.* бүрек (шапка). Тақыйаны қуйан ататқаннар ите тә тегәткәннәр ите. – *твр.* Йуша тақыйа кийеп килепте, тақыйаны нуркалардан кийәтеләр. – *тбл.*

**ТАҚЫЛ I** *перм.* бер көе, ярыйсы, уртача (ничего; средне, удовлетворительно). Чәй эчкәч, тақыл булды әле. Бүген эшем тақыл булды. Мин әле былтыр ғына да нишшан тақыл ийем, хәзер идән себерүwе дә көч.

**ақылға тақыл** *перм.* алты-биш, акылга җиңел (полоумный, слабоумный). Бу кеше ақылға тақылрақ.

**ТАҚЫЛ II 1.** *перм.* ышкы (струг); **2.** *мам.* түбә такталарын тигез сызу өчен ясалган туры такта (прямая доска для равного подрезания краёв крыши).

**ТАҚЫЛАЙУ** *перм.* **1.** уңайлану, сәламәтләнү (поправляться). Тор әле, ашап қара, тақылайып китмәссең микән; **2.** әйбәтләнү, рәтләнү – тормыш турында (наладиться, улучшиться); чаг.: **арулану**. Хәзер тормышлар тақылайды. Хәзер тақылайды, элек салам түбәйе бөтен җирдә.

**ТАҚЫЛЛАНУ** *перм.* к.: **тақылайу 1**. Хәйреттин чирләгән иде, тақылланған шикелле.

**ТАҚЫЛЛАУ** *перм.* ышкылап тактаның йөзен шомарту, тигезләү (строгать, выстрогать). Ағачларын тақыллаб эшлиләр. Тақыллаған инде – ике йақлы тақта йасатасың.

**ТАҚЫТ** [*гар.*] *брб.д.* тәхет (трон).

**ТАҚЫ-ТОҚ** *тбл.* таяк белән качыш уены (игра в прятки с палочкой).

**ТАҚЫ-ТЫҚЫ** *мәл., лмб.* к.: **тақы**. Тақы-тыкы мачы быты (*әйтем*). – *лмб.*

**ТАЛ I 1.** *трх., хвл.* агач (дерево, деревце). Безнең бақчада таллар күп. – *трх.* Алма талы утыртык. – *хвл.*

**сары тал** *перм.* шелек (карагана кустарниковая, дереза, чилига).

**тал уты** *лмб.*, **тал үләме** *т.кам.-крш., чст.*, **тал үләне** *к.т., мам.* карабодайчалар семьялыгыннан булган бер үлән (гречишник шероховатый).

**ТАЛ II** *тара.* төк, бөртек (волосок, шерстинка, пушок – на теле). Цацыңның бер талын да қалдырман, барын да йолғып пөтөрәрем.

**ТАЛА** *тара.* урман (лес). Талата пулып, кән йиләк йийып.

**ТАЛАWАЙ** *твр.* каты, тупас (грубый). Песнең тел талаwайрақ.

**ТАЛАЙ 1.** *нгб.-крш.* берникадәр, бераз (некоторое количество). Ни талай бәрәңге алдық; **2.** *тара.* күп (много). Талай эшләнте, көцөм петте.

**бер талайга** *хвл.* бераз вакытқа (на некоторое время). Бер талайга хатле чыгармыйча тырабыз.

**ТАЛАЙ-ТАЛАЙ** *кргл.* кат-кат, берничә тапкыр (не раз, неоднократно). Белсәм дә онотып йебәргәнмендер, талай-талай үлеп терелдем.

**ТАЛАҚЛАУ: ачқа талақлау** *мам.* ачтан үлү (умереть с голоду).

**ТАЛАҚСА** *каз.ар.-крш.* күкрәккә ябыла торган кечкенә алъяпкыч (небольшой передник).

**ТАЛАН** *кас., хвл., мәл.* бәхет (счастье). Йаланйалан ни талан (*әйтем*). Таланы китте. – *хвл.*

**ТАЛАУ 1.** *стрл.* к.: **қадау II**. Этне корт талаган, йата; **2.** *брб.д., клм., тара.* к.: **тетү 3**. Өйөн таладылар аның. – *тара.* Йорт талағаннар та, алтыны чыққан. – *брб.д.* Өйне талағанда матча башларында тәңкә чыққаны бар. – *клм.*

**ТАЛАУЛАУ 1.** *мам., блт.* бик каты авыртудан газап чигү (мучиться от очень сильной боли). Эч, диде дә, талаулады да үлде. – *мам.* Ашқазаны белән талаулыйм суған ашыйм да. – *блт.*; **2.** *мам., т. я., бәр.* борчылу, тынычсызлану, үз-үзеңне кая куярга белмәү (не находить себе места, сильно беспокоиться). Йоқлый алмыйча төне буйы талаулап чықтым. – *мам.* Эссе чақта бик талаулыйм мин. – *бәр.*

**ТАЛАШМАҚМАН: талашмақман сөйләшү** *тара.* бер-берсеннән уздырып сөйләшергә тырышу (говорить наперебой). Талашмақман сөйләшәте, басар булып китәте.

**ТАЛАШУ 1.** *нокр.* ачулану, орышу (ругать, бранить). Ул мине талашты; **2.** *перм.* сугышу (драться); чаг.: **орышу 1**. Күршенеке талаша аныкы әтәче, өскә қуна.

**ТАЛАШЫНУ** *перм.* к.: **узышу**. Қатын-қотон қайсыбыз күберәк ура тип талашынып җөри торған ийек.

**ТАЛӘ** [*гар.*] *хвл.* Тәгалә (Всевышний).

**ТАЛБАҢНАУ** *брб.д.* селкенү (качаться, шататься).

**ТАЛБРАҚ** *том.д., тбл.* иске-москы, ертык-портык, сәләмә (старьё, лохмотья, обноски).

**ТАЛБЫЙА I** *тара.* к.: **талбраң**.

**ТАЛБЫЙА II** *тбл.* балыкның суын саркыту өчен көймә өстендә ясалган улак (жёлоб, лоток на лодке для рыбы).

**ТАЛБЫҚ** *том.д., тбл.* озын колаклы (длинноухий).

**ТАЛБЫР** *том.д., тбл.* йонлы, йонлач (мохнатый, шерстистый).

**ТАЛҒА** *брб.д.* корбан (жертва).

**ТАЛҒАҚ** *брб.д.* к.: **зийандаш**.

**талғақ пулу** *тбл., твр.* балага узу (забеременеть). Балаға талғақ пулып йөри.

**ТАЛҒЫНУ** *том.д., тбл.* талу, ару (уставать).

**ТАЛДА** [?] **1.** *т.я., мәл., чст.* файда (польза). Һәркем үзенә талда эзли бит. – *чст.* Духтыр дару биргән иде, талдасы йахшы булды. – *мәл.* Бу дару бик талдалы, баш awыртуwың замат туқтала. –

*нрл.*; **2.** *к.т.* тынычлык (покой, спокойствие). Шул хәбәрдән талда таптым.

**ТАЛДАНУ** *том.д., тбл.* вакчыллану (привередничать).

**ТАЛДАР** *брб.д.* сазда яши торган кечкенә кош (небольшая болотная птица).

**ТАЛДАРУ** *брб.д.* эзләү (искать).

**ТАЛДЫБЫЙ** *к.т.* **1.** талгын, җылымса (тепловатый, чуть тёплый). Қамырны талдыбый ғына суға изәргә кирәк; **2.** талгын, акрын (медленно). Талдыбый ғына қайнасын ашың.

**ТАЛДЫБЫЙЛАНУ 1.** *к.т.* җебү, йомшау (размякнуть). Итне инде watарға була, талдыбыйланды ул; **2.** *т.я., минз.* к.: **моңғолану**.

**ТАЛКАН** *чст.* к.: **йүгә: йүгә бете**.

**ТАЛҚУ 1.** *дөб.* тинтерәтү, кат-кат сорап йөдәтү (докучать, беспокоить, спрашивать одно и то же много раз). Ник син аны талқыйсың, аптыратасың; **2.** *т.я., кмшл.* борчу, еш-еш имеп борчып тору (беспокоить, напр., беспрестанным сосаньем). Ике бәрәне гел талқып торғанға, бу сарық бигрәк җадау. – *т.я.*

**ТАЛҚУРА** *әстр.* талдан үрелгән читән (плетень из ивовых прутьев).

**ТАЛҚЫНУ** *мам., бәр.* күп көч түгү, авырлыклар кичерү, газап чигү (потратить много сил; перенести много трудностей); чаг.: **гүрләнү**. Әсма балаларын үстергәндә бик талқынды инде. – *бәр.* Ул ачлық йылны бик талқынды халық. – *мам.*

**ТАЛҚЫУ** *злт.* к.: **талқу 1**. Сез аны талқыйсыз, шуңа йақшы беләсез.

**ТАЛЛЫҚ** *тпк.* чалгыны сапка ныгытканда куела торган өстәмә чөй (дополнительный клин, шпонка при закреплении косы к косовищу). Салғы сабы йанынта таллық була, сөйө уртада.

**ТАЛМА** *тара.* йөрәк авыруы (сердечная болезнь, болезнь сердца).

**ТАЛНИКСАР** *кузн.* тал чыбыгы (ивовый прут, лоза). Талниксардан үргән кашлик тыра күркле генә.

**ТАЛПА** [*рус.* толпа] *срг.* көтү, өер (стадо, табун). Кәзәләр талпасы белән китәләр бер йакка.

**ТАЛТАЙА: талтайа басу** *злт.* уңайсызлык сизмичә, иркенләп басып тору (стоять свободно, не чувствуя себя стеснённым). Нишләп тораң талтайа басып? Муйсаласын тотқан да талтайа басқан да, тора бу. Талтайа басқан да ашап тора.

**ТАЛТАЙУ** *сазя.* алпан-тилпән йөрү (ходить вперевалку).

**ТАЛТЫРУ** *сазя.* камырны баскач бераз вакытка куеп тору (после замеса тесто оставить на время). Онны талтырырға қуйасың, эцен әсерләйен.

**ТАЛУ I** *миш.д., каз.ар.-крш.* җылымса хәлгә килү – салкын сыекчаның берникадәр җылынуы, кайнар сыекчаның берникадәр суынуы турында (несколько остыть, остудиться – о горячей жидкости; подогреть, подогреться – о холодной жидкости). Сывы бераз талсын да геллəр қыйарсың. – *лмб.* Азрак тала төшкән бу чәй, кан′арлат әле. – *тмн.* Менә әче сыw, пичалдына кертеп қуйып торыйм, әзрәк талсын. – *каз.ар.-крш.* Тенәге су бу талган, талсын дип кыйдан сyw алып куйам. – *срг.*

**ТАЛУ II** *брб.д.* һушсыз булу (терять сознание). Талғақ полса талып йығыла кеше.

**талып төшү** *тара.* һушын югалтып егылу (падать в обморок). Талып төштә миңке керәстәйне күргәцен.

**ТАЛУ III** *тбл.* иң авырта торган җир (больное место). Терсәгемнең талу йерен төйтем.

**ТАЛЫҒУ I** *блт., мам., минз., т.кам.-крш.*, **ТАЛЫГУ** *чпр.* к.: **талу I**. Ғадилә, су талыққан, әйбәт хәдер җywынырға. Талыққан су белән бодау қарап булмый. – *минз.* Қойашқа қуй сywыңы, әдрәк талықсын. – *мам.* Кирасинкы қайнағач, талығып киткән бу өй. – *блт.*

**ТАЛЫҒУ II** *каз.ар.-крш., перм.* ару, талу (устать, утомиться). Қайтып йөрсәң, атлар талыға. – *перм.* Үземне дә күрәсем килми, бөтөн тәнем талыгып тора. – *каз.ар.-крш.*

**ТАЛЫҚ** *мам.* к.: **җиләмә**. Сywың талықмы, эссе булмасын.

**ТАЛЫҢҚЫ** *дөб.* уңмаган, җәелеп пешкән – ипи турында (неудавшийся – о хлебе). Пируклары талыңқы була торған ыйы, бу бик күпергән.

**ТАМАҚ** *нгб.-крш., кргл., әстр.* ашамлык, азык (еда). Тамақ қәстәрлик, қорсаг ачты. – *нгб.-крш.* Тегеңәргә тамақ алып килгән, ашарға кирәк бит инде. – *кргл.* Тамағын пешер. – *әстр.*

**тамақ қату** *тбл.* эчәсе килү (захотеть пить).

**тамақ туйымныгы** *мам.* туклыклы, тамак туярлык (сытный). Тамақ туйымныгы түгел инде ул, күңеллелек өчен генә (варенье).

**т а м а к** (горло):

**тамагы буу** *м.-кар.* дифтерия белән авыру (болеть дифтерией).

**ТАМАКАЙ** *шрл.* к.: **тамақсау 1**. Бик тамакай кеше ул, ашарга йарата.

**ТАМАҚЛАНУ** *нгб.-крш., эчк.* ашау (есть, питаться). Тамақланырға барасыңмы? – *нгб.-крш.* Тамақланып килгәнсез икән. – *эчк.*

**ТАМАҚСА** *минз., каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* тар гына тукыма кисәгенә мәржән һәм бөтен тәңкәләр тезеп ясалган, муенга арттан кысып бәйләп куела торган бизәнү әйбере (старинное женское украшение из монет и бус, нашитых на узкую материю, плотно надевавшееся на шею); чаг.: **йақа**. Әwәле тамақса бәйләгәннәр, дәwәт кигәннәр. – *т.кам.-крш.* Тамақса бәйли қызлар. – *каз.ар.-крш.* Муйынына тамақса таққан. Тамақса элек булған. – *минз.* Әwәле тамақсайы, хәситәдән қалган бәләкәй әйбер инде ул тамақса, тәңкәсе ничә рәт булса да була, килешә ул үзе. Бер қат вақ тәңкәне тезеп җыйнақ қына, бәләкәй генә, бәйләп җәриләр ийе муйынға. – *минз.*

**ТАМАҚСАУ 1.** *крш., к.т., тара.* ашамчак, күп ашарга яратучы (любящий поесть); чаг.: **йот**. Баласы бик тамақсау икән. – *т.кам.-крш.* Син тамақсау түгелсең икән. Мин күп ашыйм, мин тамақсау. – *нгб.-крш.* Тамақсау булмый ул, ашамый. Өстәл өстендә утырған кеше тамақсау булмый ул. – *каз.ар.-крш.*; **2.** *нрл.* к.: **қатымыш**.

**ТАМАКСАУ** *кузн., чст., чпр., мәл.* к.: **тамақсау 1**. Ул бик тамаксау, ни тапканың ашап бетерә. – *кузн.*

**ТАМАҚЧА** *т.кам.-крш.* к.: **тамақса**. Дәwәт белән тамакча бергә генә кийелгән.

**ТАМАКЧА** *хвл.* сагалдырык (подбородок уздечки).

**ТАМАН 1.** *бәр.* уртача, акрынрак (средне; потише, послабее). Безнең чишмә шәп ағадырыйы, хәзер таман аға башлады; **2.** *глз.* вакытлыча, аз вакытка (временно, ненадолго). Алар безнең awылға таман гына килделәр, бер-ике көннән китәләр дә.

**ТАМАНРАҚ** *мам.* уртача, бертөрле (средний, среднего качества). Таманрак итләр иде базарда.

**ТАМАНСУ** *минз.* к.: **тамақсау 1**. Ул тамансу кеше, нинди аш булса да ашый.

**ТАМАНЫСЫ** [*гар.* + *афф.* -ысы] *мам.* тәмам (полностью, совсем). Таманысы үзәкләремә үтте.

**ТАМАРСЫҚ** *брб.д.* табышмак (загадка).

**ТАМАША** [*гар.*] **1.** *перм.* бик күп, искиткеч күп (очень много, удивительно много). Тамаша булай бу Тунтур буйларда монда. Тамаша зур булыр ийе, күтәреб апкайта алмассыз ийе; **2.** *бәр.* бик (очень); чаг.: **бида; қаты**. Тамаша әйбәт арпа бик. Тамаша матур ыйы зәңгәр күкшилем.

**тамаша булу** *кузн., мәл.* көлкегә калу, хур булу (оскандалиться, опозориться). Саҗидәбез йер артыннан чыккан, тамаша булдык. – *кузн.*

**тамаша калу** *кузн.* таңга калу, гаҗәпләнү, ис китү (восхищаться). Вис халык тамаша калды.

**ТАМЗЫҚ** *т.кам.-крш.* к.: **тамызлық**.

**ТАМПАҚ** *тпк.* никель йөгертелгән (никелированный). Тампак самоварлар, сәй эстек тә киттек клупка.

**тамук** *миш.д.* тәмуг (ад):

**тамук пирахлаты** [*гар.* + *рус.*] *хвл.*, **тамуг терәүләре** [*гар.* + *тат.*] *кмшл.* орышу сүзе (бранное слово).

**ТАМЧУ** *тара.* тамчылап тамызу (капать капельками). Қырық қоймак пешерәләр, бер табаға тамчып-тамчып қот салмасы тейиләр, қурыкса пешерәләр.

**ТАМЫ: тамы та** *тара.* бөртеге дә, тамчысы да (ни крошки, ни капли). Тамы та йоқ.

**ТАМЫЗЛЫҚ** *лш., каз.ар.-крш., дөб.* ут кабызгыч чыра, йомычка яки башка әйбер (щепки, лучина или что-нибудь другое для разжигания огня). Менә сарайыбызда тамызлық тора, мич йаққанда тамызлық кирәк бит. – *дөб.*

**ТАМЫЗУ** *нгб.-крш.* кабызу (зажигать, включать – свет). Ут тамызып қуйа қырқына чақлы, түшәген җәйеп қуйа.

**лампа тамызу, лампы тамызу** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* к.: **лампы: лампы эрү**. Лампы тамызып җибәрергә була. – *каз.ар.-крш.* Лампыны тамыз әле, қараңғы төште. – *т.кам.-крш.*

**ут тамызу** *каз.ар.*, **ут тамыdy** *минз.* к.: **лампы: лампы эрү**. Лампаға ут тамыз әле. – *дөб.* Ут тамыз, қараңғы бит. – *нгб.-крш.* Ут тамызғач килсен, чақырып қайтығыз. – *т.кам.-крш.* Теге йаққа да ут тамызырбыз, қызым! – *мам.* Лампыдқа ут тамыd. – *минз.*

**ТАМЫР 1.** *минз.* к.: **нәсел-асап**. Балаларым да күп, туганнарым да күп, тамырым бик күп минем; **2.** *кргл.* әшнә, дус (близкие, знакомые; приятель, приятельница); чаг.: **әхи 2**. Барсақ, тамырлары қунаққа чақырганнар.

**ТАМЫРАС** *лмб.* тез асты (место сгиба в колене). Тезләрнен тамыраслары эшенделәр.

**тамырлану** (пустить корни):

**тамырланып тору** *каз.ар.-крш.* к.: **томрау 1**. Быйақтан тағын җawарға тамырланып тора әле.

**тана** (двухгодовалая тёлка):

**қонадин тана** *минз.* ике-өч яшьлек тана (тёлка двух-трёхлетняя).

**қонажын тана** *минз.* ике тапкыр бозаулаган яшь сыер (корова после двух отелов).

**ТАНАУ 1.** *минз., кмшл., бгрс., нгб.-крш., злт., кргл., тпк., дөб., тбл., миш.д.* борын (нос). Ыланның танавын сөртөп ал әле. Безнең кебек булса танавын күтәрер иде. Күwәз эшеми, калтырый, танау асты йалтырый. – *мәл.* Танауларын җыйырып қына көлгән була. Минем танауларым қанады. – *бгрс.* Җырлағанда танау тартмағыз. – *нгб.-крш.* Зәриға бигрәк тиз сизгән, барысының да танаулары йуғары бит. Танawыңы серт. – *кмшл.* Танаулар бик dур ийе. Танawың қычытқандыр, кил әйдә, чәй эч күчтәнәчләр белән. – *минз.* Борыныңнан кан килә, танawыңны сөрт. – *лмб.* Қарап сикер, җыгылып борын танawыңны җимерә күрмә. – *дөб.* Танawыннан су аға. – *злт.* Танау қысытадыр ийе, синең балықларны ашарга булған икән. – *тпк.*; **2.** *баст., тбл.* борын тишеге (ноздря). Ике танawыннан да шарлап қан китте. – *баст.*

**қарсыға танау** *злт.* аска караган кәкрерәк борын (турецкий нос).

**ТАНҒАННАНУ** *брб.д.* мактану (хвастаться).

**ТАНДА'А** *кас.* **1.** иртәгә (завтра). Ма'а танда'а базар'а барма'а 'ири'; **2.** иртән, иртә белән (утром).

**танда'а арты** *кас.* берсекөнгә (послезавтра).

**ТАНСЫҚЛАУ** *баст.* аш талымлау – авырлы вакытта (привередничать, быть разборчивым в еде – при беременности). Awыр қалдым да, тансықладым, қаң'иш қаты.

**ТАНСЫКЛАУ** *байк.* үзең теләп, үз теләгең белән (по своему желанию, добровольно). Акца биреп тансыклап аңынны йугаткан, таза башыңны каста итеп.

**ТАНТАМАША** *кас.* искиткеч, искитәрлек, кызык (замечательно, интересно). Тантамаша булды.

**ТАНТЫР** *тара.* учак (очаг).

**ТАНУСЫЗЛАР** *перм.* таныш булмаган кешеләр (незнакомцы).

**ТАНЫЙЕННИ** *кас.* искитәрлек икән (оказывается чудесно, удивительно).

**ТАНЫҚЛЫ** *бәр., трх.* атаклы, билгеле, күренекле (знаменитый, известный). Танықлы ич мин, балам, бар(ы)да беләләр мине. – *бәр.*

**ТАНЫҚСЫЗ** *перм.* танымаслык (неузнаваемый). Хәзер инде танықсыз рәwештә тормош үзгәрде.

**таң I** (заря):

**әче таң белән** *каз.ар.* бик иртә, иртә таң белән (чуть свет, очень рано). Иртәгә әче таң белән үк китәрсез. – *мам.*

**таң килү** *нрл.* таң ату (рассветать). Таң килә башлаган, тегеләрне алып киткәннәр.

**таң кучат әтү** *тмн., кузн.* элек кыз елату йоласы: иртәгә туй буласы көннең кичендә ярәшелгән кыз өенә дус кызлары чыбылдык тегәргә җыелалар. Чәйләр эчкәч, төн урталарында тәрәзәләрне ачып куеп, бөтен авылга шаулатып җыр җырлыйлар. Шуны «таң кучат әтү» диләр (накануне свадьбы собираются девушки в дом невесты для шитья полога. Окончив чаепитие, в полночь они раскрывают настежь окна и громко поют песни, что и называется «таң кучат әтү»); чаг.: **йаслату**. Йәшел кечеркәннәр эчендә Йәшеренеп кычкыра йәш кучат; Торыгыз, тиңнәрем, торыгыз, Әтегез миңа таң кучат (*бор. җыр.*). Ат'кен-ат'кен генә син аңа таңкучатларны. Кычкыр әле таңкучат, син йәтле. – *тмн.*

**таң тебеннән** *карс.* таң тишегеннән, иртүк (ни свет ни заря, очень рано). Таң тебеннән китәргә үзеңә.

**ТАҢ II: таң итү** *кргл.* к.: **таңнану**. Читтән килгәннәр мунча керсәләр, таң итәләр ушы суның йомшаклыгына.

**ТАҢ III: таң төшү** *блт., перм.* күз тию (подвергнуться сглазу, заболеть от сглаза). Әле таң да төшә шунда. – *блт.* Әллә таң да төштәме дип, таң сулары белән дә имнәп карадым. – *перм.*

**ТАҢАТАР** *төм.* су буенда яшьләр уйный торган мәйдан (площадка около воды для молодёжных игр).

**ТАҢҒАЙ** *нгб.-крш., кргл., яүшт.* к.: **қамақаш**. Таңғайым awыртып тора. – *нгб.-крш.* Таңғай сай булса да, тормой куйган теш. – *кргл.*

**ТАҢГИРТӘДӘН** *бәр.* к.: **таң I: әче таң белән**. Қунақлар таңгиртәдән бирле китәләр инде.

**ТАҢДА** *глз., нокр., м.-кар.* иртәгә (завтра). Таңда кеч қызны элтәсе кенне қызлар ийылып йырлаганнар. Ну қыз йылағалаган нәкәс. Таңда уникедә қунақ чақырышам. Таңда безгә килерсенмә? Таңдагы кеннән печән чапмаға чыгабыз. – *нокр.*

**ТАҢЛАЙ** *әстр.* к.: **қамақаш**.

**ТАҢНА** *брб.д.* к.: **таңда**. Таңна пескә керең.

**ТАҢНАЙ** *тара.* к.: **қамақаш**.

**ТАҢНАНУ** *минз., т.я., т.кам.-крш., мәл.* таңга калу, таң калу, гажәпләнү, ис китү (восхищаться). Матур дип таңнаналар бу қызга, аннан күзегә. – *к.т.* Жарамый бит алай таңнанырга. – *т.кам.-крш.*

**ТАҢНАУ** *тбл.* соклану (восхищаться, восторгаться). Кем таңнаса, күсе тейсә, сыктайды кецкенә малау.

**ТАҢУ** *лш.* танымау, икърар итү (не признавать). Теге таңа, жук дей. Таңу шул – эшләмәдем диб әйтә инде.

**ТАҢЫЛЧАҚ** *твр.* к.: **ураучык**. Ишектән кераделәр, әwәл таңылчак, эчендә ашамлык.

**ТАҢЫРҒАҚ** *брб.д.* гажәпләнүчән (легко удивляющийся).

**ТАН I** *тпк., саз.я., яүшт., төм.* к.: **йунгы**. Ағасының табы пит, турағанта төшкән. – *тпк.* Тап цүпләф цай қайнатawc. – *саз.я.* Таплар йийыштырыб апкер әле пицкә йағарға. – *яүшт.* Йорт төзи башлаган, таплары очқан йылғаға. Тап китер. – *төм.*

**ТАП II 1.** *нгб.-крш.* нәкъ (точно, словно, будто). Сез Қазанның тап үзендәме?; **2.** *карс.* коеп куйган (точь-в-точь, вылитый). Тап кырым татары инде йезе.

**ТАПАWЫЧ** *к.-уф.* чалгыны чүкеп үткенләү өчен махсус корал, сандал (бабка, на которой отбивают косу).

**ТАПАЛАУ** *перм., эчк.* таптау, таптатып үтерү (задавить). Ат тапалагач шундый начарланды ул қарт. – *перм.* Мине тапалап китә йазды. – *эчк.*

**ТАПАЛУ** *бөре., перм., к.-уф.* тапталу (быть задавленным, попасть под транспорт). Мотоциклға тапалырбыз. – *бөре.* Кеше машинаға тапалыб үлә. – *перм.*

**ТАПАМА** *тмн., лмб., чст.* бәрәңге, ит, кәбестә чаба торган тигәнә (корыто для рубки картофеля, мяса, капусты). Тапамада тевәбез итне. – *лмб.* Бар, тапамада кис итне. – *тмн.*

**ТАПАС** [*рус.* топаз] *т.я.* муенса (бусы, ожерелье); чаг.: **буйынса**. Муйынына ақ тапас таққан. Тапас белән нишлисең, қызым, үскәч тагарсың. Мәрҗән wақ була, тапас эрерәк була. Гәрәбәләре дә була, чын тапас диләр аны, оло ул, ул пайдалы зублы кешеләргә. – *к.т.*

**муйын тапасы** *блт.* к.: **тапас**. Муйын тапасы асарлар ыйы бауға тезеп.

**тапас қолағалқа** *трх.* асылташ яки хрусталь кашлы колак алкасы (серьги с камнями). Тапас қолағалқа қыйбатрақ була.

**тапас түмә** *трх.* ак төстәге пыяла муенса (бусы, ожерелье из белого стекла).

**ТАПАУ I 1.** *бөре., к.-уф., злт., тпк., стрл.* таптау (топтать, мять). Йөрмә анда бақча тапап. Чиннектәге печәннәрне тапап җөрмә кереп. – *бөре.* Алма сабагын тапаган сыйр. – *лмб.* Игенне сыйырлар тапаган. – *к.-уф.* Сабынны тапап қайа барасыd. Тапап-тапап монау хәтлек кенә ағачны күмдек. – *тпк.* Кәпестәне тапаган сийыр. – *стрл.*; **2.** *перм., нгб.-крш.* таптау, пычрату (топтать, грязнить). Су түгәм дә тапыйм үзем, җебегән қарчық. – *перм.* Идәнне тапыйм бит. – *нгб.-крш.*; **3.** *лмб., нгб.-крш., злт., тпк., стрл.* к.: **тапалау**. Тawыкны машина тапап киткән. – *нгб.-крш.* Машина тапагыры үзен. – *лмб.* Машина тапамай микән палаңы. – *тпк.* Чебешләрне тапыйсың. – *стрл.*; **4.** *хвл., чст.* ваклау – утын турында (мелко нарубить – о дровах). Кешеләр алып киләләр дә утынны тапаталар. – *хвл.* Утынны тапарга инде мин үләмгә китмәсәм. – *чст.*; **5.** *лмб., чст., чпр., мәл.* кисү (разрезать, раскрошить, разорвать). Салма тапим. – *лмб.* Wаклап тапап тормим инде кәкәшне. Алай тапамый әле. – *чст.* Вич тапаган ди документны. – *мәл.*; **6.** *чпр.* турау (нарезать). Казларга алма тапарга кирәк выт, мин утырдым да утырдым; **7.** *тмн.* сугу – боз турында (побить градом). Арышны чирахман тапаган; **8.** *мәл., чпр.* кисү (точить – о моли). Күwә тапап бетерә инде пәлтәмне. – *мәл.* Күwә дә тапый тунны. – *чпр.*; **9.** *чпр.* ашау, кабыкка калдыру (грызть, оставить

кожурки – о грызунах). Сылыны тыцкан тапаса, эштән цыгып бетә инде.

**арқаны тапау** *кргл.* аркадан кагу, сөю (похлопывать по спине в знак одобрения). Дисәтникләр килә дә теге қызның арқасын тапыйлар.

**салғы тапау** *злт.*, **чалғы тапау** *перм., к.-уф.* чалғыны чүкеп үткенләү, чалғы таптау (отбивать косу). Күрше, чалғыны тапап аласы иде, тапawычың белән түштимереңне бирең тор әле. – *к.-уф.*

**ТАПАУ II** *хвл.* уенда җиңеп чыгу (выиграть, победить кого-либо). Шахматтан икесен дә тападым.

**ТАПАУ III** *срг.* тукып тору (твердить одно и то же). Йалан үзенекен тапый, әдә безгә, кыш цыгарсын, дир.

**ТАПЕ** *кас.*, **Т'АПЕ** [*рус.*] *чпр.* чапкы (тяпка).

**ТАПКА** [*рус.* тапка] *тмн.* чүәк (тапочки, чувяки). Чиккән тапкалар Казандан китерәләр.

**Т'АПКА I** *хвл.* чулпы (женское накосное украшение).

**Т'АПКА II** [*рус.* тяпка] *шрл.* к.: **тапе**. Т'апканы кертеп куй.

**ТАПҚЫР** *злт., тпк., кргл.*, **ТАПКЫР** *чст., стрл.* туры (напротив). Мәстүрәләр тапқырында көйәнтәм белән йығылдым. – *злт.* Тирән уй тапқырынта awып йөрөмәле ташлар бар. – *тпк.* Куйкы тапқырына чыбылдық элеләр. – *кргл.* Тапкырысына булса да мен. – *чст.* Кайсы тапкырдадыр инде. Машина тапкырында гына ызбасы. – *стрл.*

**ТАПЛАНУ** *эчк.* к.: **табылу I**. Йезнәм машинаға тапланды.

**ТАПСЫҚ** *злт.* к.: **йунғы**. Тапсық йыйам қазан асқа йағарға.

**ТАПТАМА** *төм.* **1.** кул белән баскалап җәелгән камыр (тесто-лепёшка, полученное способом надавливания рукой); **2.** пешереп алган гөлҗимешне изеп, кул белән камырны баскалап ясалган җәймә (лепёшка из варёного шиповника, полученная путём надавливания рукой). Көлйемешне цөгин белән мицкә эткән, төйөп таптама йасаган, сынтырып-сынтырып чай эцкән.

**ТАПТАТУ** *минз.* к.: **бастыру**. Ат белә таптату ийе бит ашлыкны.

**ТАПТАУ I 1.** *т.я.-крш., трх., к.т.* камырны басу (месить, размесить тесто). Без бит ипине изәбез дәген куwашнадан алып таптыйбыз. – *т.я.-крш.* Қамырны таптадым да қабартма пешердем. – *трх.* Қамырны таптыйсың да пич алдында пешереб аласың. – *к.т.*; **2.** *минз.* җәю (раскатать, раскатывать – о тесте). Ачы булса, көлчә итеп таптайсың да бәрәңге җағасың. – *минз.*

**ТАПТАУ II: арқадан таптау** *тара.* к.: **тапау I: арқаны тапау**. Маладис тейте, арқамнан таптайды беригатир.

**ТАПТЫРЫҚЛАУ** *тбл.* тик кенә басып тора алмау – кеше турында (быть не в состоянии стоять спокойно, постоянно перебирать ногами). Исерег игән, аның өцөн таптырықлайты.

**ТАПУ: тапу печине** *перм.* к.: **бақа I: бақа қабығы**.

**ТАПЧЫҚ** *перм., бөре., к.-уф., твр.* к.: **йунғы**. Тапчық – табаламасы инде балтадан түгелгән, шул алама ағып пара икән түбәнгә. – *перм.* Тапчықларны җыйып ут йағып җибәр. – *к.-уф.*

**ТАПШУ** *брб.д.* шудыру, кузгату (сдвинуть).

**ТАПЫЙ** *трх.* балалар кәләпүше (детская тюбетейка).

**ТАПЫРЛАУ** *к.т.* к.: **тапау I, 2**. Идәнеме тапырлама.

**ТАПЫРЫН** *мам.* ашыгыч (спешный, срочный; спешно, срочно).

**ТАПЫ-ТАПЫ** *хвл.* төер-төер (комками). Йонны теткәндә арасыннан тапы-тапы затлар килеп чыга.

**ТАРАЙУ** *лш., т.я.* тартыну, оялу (стесняться). Бер дә тараймыйча ашағыз. – *лш.* Тарайма, җаным, балы белән эч. – *т.я.*

**тарақ** тарак (гребень, гребёнка):

**дебет тарағы** *кргл.* кәҗә өстеннән мамык тарап алу өчен махсус эшләнгән тарак (специальный гребень для счёсывания пуха с козы).

**тарақ печәне** *блт.* торнабаш (аистник, грабельник).

**тәрәш тарағы** *лш., кмшл.*, **тимер тарақ** *перм.* тәрәшле тарагы (гребень, чесалка). Тимер тараққа тартып, чүбәктән үзәк йасала.

**шайтан тарағы** *карс.* абага (папоротник).

**ТАРАҚАН** *брб.д.* к.: **җүwешмән**.

**айры тарақан** *минз.* к.: **қайчығойроқ**. Айры тарақан күбәйгән.

**ак таракан** *лмб.*, **йеwеш таракан** *карс.*, **йүwеш тарақан** *минз., нрл.*, **йүwеш таракан** *мәл., т.я.-крш., стрл.*, **қарт тарақан** *лш.*, **қаты тарақан** *минз.*, **күк тарақан** *кргл.* к.: **җүwешмән**. Безнең йүwеш тараканыбыз кайан булсын, ай. – *мәл.* Йүwеш тарақан элгәре булды инде. – *минз.* Йүwеш тараканнан да шакшы, усал әйбир йуктыр. – *стрл.*

**койрықлы таракан** *глз.* к.: **қайчығойроқ**. Йүwеш җиргә чыга койрыклы таракан.

**мәчет тарақаны** *кмшл.* к.: **пат'аткай 1**.

**очқалақ тарақан** *мам.* к.: **пал'ак**. Қырғайақ түгел бу, очқалақ тарақан.

**су тараканы** *лмб.* к.: **җүwешмән**.

**чабата тарақан** *каз.ар.*, **чабата тарақаны** *кмшл.* кара таракан (чёрный таракан). Чабата тарақаны бетерегә пич астына дегет лагуны қуйганнар. – *каз.ар.-крш.* Хәзер күргән дә йуғ инде чабата тарақанны. – *мам.*

**чабата тарақаны булу** *кмшл.* артык булу, кара таракан булу (оказаться третьим лишним).

**черек тарақан** *трх.*, **чи таракан** *чст., мәл.* к.: **җүwешмән**. Чи таракан, күргем дә келәми шындый кешене. Чи таракан йук бездә. Йаратмаган кешегә дә, кит әле моннан, чи таракан, диләр. – *мәл.*

**ТАРАҚЛЫ** *трх.* тармаклы (с отводами, разветвлённый). Дүрт тарақлы чулпым бар ийе.

**ТАРАМЫЦ** *брб.д.* к.: **тарамыш 1**.

**ТАРАМЫШ 1.** *эчк., злт., төм., тбл.* сеңер (сухожилие). Қулның тарамышы тартылған. – *эчк.* Итнең тарамышын йемә. – *тбл.*; **2.** *төм.* оекбаш кунычындагы сыр (резинка – у носков). Наскы қуныцы тарамышлы; **3.** *төм., тбл.* к.: **будырма**. Ойоқ кийәм қуй, тарамыш қысып китәде әүwәлге

йалбақ тарамыш. – *төм.* Йышымыңа тарамыш тақ. – *тбл.*

**ТАРАНТАС** [*рус.*] *бәр.* бака яфрагы чәчәгенең сабагы (цветоножка подорожника).

**ТАРАНУ** *т.я.* к.: **тиберценү**.

**ТАРАС** [*перс.*] *брб.д., тара.* үлчәү (весы). Ирнең күңле йибәкте, бир түгүлсә чичелмәс, тарасҡа салсаң, тиңәлмәс, мысҡалга салсаң, ким имәс. – *тара.*

**ТАРАТҠЫ** *блт.* чөгендерле катык (катык со свёклой). Без кечкенә wақытта әни йасаган тараткыны бик йаратадырыйық, чөгөндере баллы булғач, тәмне була ул.

**ТАРАУ I** *т.я.* к.: **тиберценү**. Қыйар түтәлләремне tawық тарап бетергән.

**ТАРАУ II 1.** *каз.ар., кмшл.* таралып урнашу, таркау (разбросанно, беспорядочно). Бәк тарау утырған awыл ул. – *мам.* Awыл зур, тик тарау. Кисеп тутырырға кирәк, тарау җата чыбыҡлар. – *лш.*; **2.** *минз.* к.: **йөтәweч 2**. Минем кебек тарау кешенең өйөндә дә рәт булмас.

**ТАРАУНИК** [*рус.*] *төм.* утын сарае (дровяник).

**ТАРАЧОК** *клм.* кәтүк җебе (катушечные нитки). Мамық йебенә қушарға тарачок йарамайты.

**ТАРАШҠЫ** *перм.* к.: **чирахман I**.

**ТАРБАҒАЙ** *тбл., тара.* җәенке, киң (плоский, широкий).

**ТАРБАННАП** *злт.* тармакларын тырпайтып, җәелеп (разветвившись, растопырив ветви). Тарбаннап үсә ғөлйемеш. Әрем тарбаннап тора.

**тарбаннап басу** *злт.* баланың тәпи йөри башлаганда егылмас өчен, аякларын бер-берсеннән ераграк куеп, кулларын җәеп басып торуы (стоять, расставив ножки и растянув ручки – о ребёнке, начинающем ходить); чаг.: **қақай: қақай басу**. Баласына сигез ай, тарбаннап басып тора.

**ТАРБАНУ: тарбанып тору** *дөб.* акрын кыймылдау, маташу (быть медлительным, нерасторопным). Нигә тарбанып торасың, эшеңә сыңа қаласың бит. Нәрсә тарбанып торасың, эшеңдә бул.

**ТАРБАСА** *төм.* зур капка (ворота).

**ТАРҒАУ** *тара.* к.: **тетелү 1**. Иптәшем үлмәстә үк тарғап киттеләр арбуwыннар.

**ТАРИЛКА** [*рус.* тарелка] *әҗе.* к.: **табак**. Тарилкаға илисең, илəмәгән он он түгел.

**ТАРҠАЛУ** *мәл.* к.: **тетелү 1**. Балаларым таркалгачтын сагынып йырлыйм инде.

**ТАРҠАП: тарқап бетү** *трх.* к.: **тетелү 1**. Малайлары тарқап бетте.

**ТАРҠАУЧАН** *тбл.* үтемле (ходовой, легко расходящийся – о товаре).

**ТАРЛАУ** *минз.* көтүлек (пастбище); чаг.: **чөрөш**. Май бетә инде, әле тарлауда үлән мал ашарлық йуқ.

**ТАРМА 1.** *перм., минз., злт., к.-уф., стрл., твр., брб.д.* к.: **мошко I, 1**. Тарма бар ийе, ороп җыйғаным. Тарма эре була. – *перм.* Тарманың иртә йолқый торғаны баса була. – *минз.* Тарманы арқан бау ишәргә алалар. Тармадан дилбегә, мишәк ишәләр, ныҡ была. – *злт.* Тарманы эскәб (йолкып) алалар, көлтәне бәйлисең. – *твр.* Тармасы йуwанрақ була, басасы нәзегрәк. – *стрл.* Тарма бик үстердек элек. – *к.-уф.*

**қысыр тарма** *минз.* к.: **мошко I: кыр мошкосы**.

**тарма бау** *перм.* киндер сүсеннән ишелгән бау (верёвка, свитая из пеньки).

**тарма орлоғо 1.** *тпк.* к.: **мошко I: кыр мошкосы**. Тарма орлого үсә йыwан булып, анысының сүсе эре була, аны төйүwе дә қыйын, тегендә-монда үсә ул, аны йыймыйлар да; **2.** *минз., злт.* к.: **киндераш 2**.

**тарма орлоқ** *перм.*, **тарма орлығы** *стрл.* к.: **киндераш 2**. Тарма орлогыннан кәкере пешерәләр. – *злт.* Тарма орлоқ була. – *перм.*

**ТАРМАҚ I** *перм.* тамыр, нәсел-ыру (весь род, вся родня).

**ТАРМАҚ II** *брб.д., яүшт.* уылдык (икра рыбная).

**ТАРМАҚЧА** *хвл.* арба тәгәрмәченең тормозы (тормоз у телеги).

**ТАРМАН** [*фарс.*] *кузн.* көч, хәл, чара (сила, средство); чаг.: **дарман**. Тарман җуқ, әни, бир бер сыйырыңы.

**ТАРМАРЛОҚ** *перм.* к.: **киндераш 2**. Тармарлоқны төwәсең дә пирукка саласың.

**ТАРМАТ** *сазя.* төнге ау (ночная охота). Мылтықны қалай көсләгәле пелмәй, тарматқа төшәм тей. Тарматха төшхәле йыйына.

**ТАРНАЙ** *минз.* к.: **гөбө**. Элекке шикелле тарнай йуғ инде он сала торған. Тарнай odon була ул, бучкы сымақ қына түгел, бийек.

**ТАРПАЙТУ** *брб.д.* ярпайту, яхшылату (сделать важным, хорошим). Йақшы әр тарпайта, йаман әр қартайта.

**ТАРСЫМАЛ** *төм.* үтүк (утюг).

**ТАРСЫХ** *сазя.* акай күзле (пучеглазый, лупоглазый). Өгөнең күзләре тарсых.

**ТАРТАЙ 1.** *минз., перм., злт.* тартар (дергач, коростель). Тартай теленнән таба (*әйтем*). – *перм.*; **2.** *злт., минз., тпк.* к.: **йадау**. Усаллығы белән тартай да ул. – *злт.* Қара ғына, тартай ғына. – *тпк.*

**ТАРТҚУ** *брб.д.* струк (струг – инструмент для строгания).

**ТАРТКЫ** *чст.* түшлек, бавыргалык (подбрюшник).

**ТАРТҚЫЙ** *тбл.* үлән үрү (плести траву).

**ТАРТМА I 1.** *чст., перм., злт.* зур ящик (большой ящик). Кертимме бер тартма? – *злт.* **2.** *перм.* к.: **ачылма**; **3.** *сргн.* моржаның тартып ачыла һәм этеп ябыла торган тимере (задвижка в печной трубе для прекращения тяги воздуха; вьюшка). Тартманы ацтым самарау исе цыкмаска.

**ТАРТМА II** *мам.* **1.** к.: **бау I: кылак бawы**; **2.** чабатаның киндерәне юкә белән чолгап алган кырые (обушник, кайма лаптей). Awызы урынына киндерә қуйып, җүкә белән ике тапқыр чолғаталар, шул чабата тартмасы була.

**тартма йүшкә** *лш.* к.: **тартма I, 3**.

**ТАРТМАҒАЧ** *клм.* к.: **кабатеп**.

**ТАРТМАЧЫ: қырық тартмачы** *нгб.-крш.* искемоскы, чүпрәк-чапрак, ташландык әйберләр җыючы, утиль җыючы (сборщик утильсырья, утильщик). Қырықтартмачыға чүпрәк бирең, балалар шар алалар.

**ТАРТТЫРУ** *карс.* кертү, куйдыру (установить). Эвенең эченә кырук батарейлар тарттырды.

**ТАРТУ I 1.** *лмб., мәл., срг.* к.: **күтәрү I, 1.** Картулары тартмаган, чәчәктәләр. – *лмб.* Бәрәңге ачымастан ғына тебенә әзерәк тарттык. – *мәл.* Цәцәккә түмәләнгәцтән тебенә тартабыз матика белән. – *срг.*; **2.** *блт., лмб., мәл., кмшл.* ярату, якын күрү, якын итү (любить, считать близким). Безнең Мәрҗәмне қайнешләре бик тарталар үзе. – *блт.* Тартмаган кеше белән бер көн дә тыргы келәми. – *мәл.* Ыру харендәш тартмады, Әткай шолай каплады (*бор. җыр.*). – *лмб.*; **3.** *мәл., хвл., срг.* үзенә алу (брать на себя). Ул һәр сүзне үзенә тарта. – *хвл.* Син дәме үз башыңа тарттың? – *срг.* **3.** *клм.* тоту (поймать). Су ийәсе тарта, мин қурқыймын.

**йылым тарту** *сазл.* җылым белән балык тоту (ловить рыбу неводом). Йылым тартхалы төшф хитте.

**көзән тарту** *перм., злт.* көзән җыеру (сводить судорогами, корчить). Көзән тарта икә тиб әйтә, ти, герип белә чирләп, айақлары тартышайы шул. – *перм.*

**сипарат тарту** *тмн., кас.*, **сөт тарту** *кргл., чпр.* сөт аерту (сепарировать). Хазер сипарат тартам сезгә. – *тмн.* Сипарат тарта, 'әймә'не сата банкасын эч тән'әдин. – *кас.* Қыш көнә тартырлық сөт йуқ, қайнатып қуйабыз. – *кргл.* Сөт тартмадыгызмы, Заидә? – *чпр.*

**су тарту** *м.-кар., кузн., кмшл.* коедан су чыгару (достать, вытащить воду из колодца). Тартыйм әле су. – *м.-кар.* Қойодан су тарта. – *кузн.* Су тарта тырығыз бидрәләргә. – *кмшл.*

**тартып сызу** *нрл.* утырткан бәрәңгене кул белән суканы тартып йөреп күмү (окучивать картофель с помощью сохи); чаг.: **йару I, 1.**

**тартып чәчү** *трх.* сука белән утырту (сажать картофель с помощью сохи). Кул белә тартып та чәчтек.

**ут тарту** *срг., твр.* чүп утау (полоть). Утлар тарттым. – *срг.*

**чәй тарту** *баст., әстр.* чәй эчү (пить чай). Ат қушма җыйалар, чәйенне тарталар, чәй қуйасын. – *баст.*

**әлән тарту** *лмб.* җитен йолку (теребить лён).

**ТАРТУ II 1.** *каз.ар., минз., бөре., перм., стрл.* туй чыгымнары өчен егет ягыннан қызның әти-әнисенә бирелә торган акча (деньги, даваемые родителям невесты со стороны жениха на свадебные расходы). Менә тартуwын да шул көйе дигән дә қодағыйына ақчасын да чыгарып биргән, қызын да алып қайтып киткән. – *мам.* Тарту ақчасы дигән булып, ақча да китерәләрийе. Тарту ақчасына қыз сawыт-сабалар, самыwар, чиләк алып барған, үзенә камзул, читек-кәwеш йасый. – *лш.* Ничә тәңкә тарту биргәннәрдер миңа, хәдер инде белмим. Тарту wул – қалым малы түгел, ақча, туй йасау өчен бирелгән қыз ата-анасына. – *блт.* Қыз бирнә белә килә, йегет йағы тарту ақчасын пулныcты бирмәдисә, бирмиләр қызны. – *перм.*; **2.** *кргл.* к.: **тайансық 1.** Сарық китереп бирде бирнә биргәч тартуға. Аның йанына сыйырын бирә тартуға, атын; **3.** *брб.д.* гернең авырлығы (вес гири).

**тарту көче** *минз.* к.: **тарту II, 1.** Тарту көчө күпме бирәсең, бер пот бирәсеңме балны, мәһәрне күпме бирәсең.

**ТАРТУ III** *тпк.* мичнең самовар моржасын тыга торган махсус тишеге (специальный дымоход у печи для самоварной трубы).

**ТАРТУЛАП** *минз.* тарту түләп, тарту акчасы биреп (с внесением денег со стороны жениха родителям невесты на свадебные расходы). Қызларны, балам, тартулап килешкән булдылар инде.

**ТАРТУЧЫ** *кузн.* к.: **башқода 1.** Кызны тартучыга күлмәк бирәләр.

**ТАРТЫҚ** *клм., тара., тбл., том.д.* тотлыга торган (заика). Тартық паласы бар, тартышып сөйләшә. – *тара.* Тартық икән бу кижи. – *клм.* Тартық пулған, қурқыцтан та булаты ол. – *тбл.*

**ТАРТЫҚЛАНУ** *тара.* тотлыга башлау (стать заикой).

**ТАРТЫЛУ I** *яүшт.* тотлыгу (заикаться). Бәләкәй цағында әт талады да, сөйләшә алмады, тартылайды.

**ТАРТЫЛУ II** *лмб., хвл.* батып керү, эчкә бату, суырылу (похудеть, осунуться). Җәйәкләре тартылган. – *лмб.*

**ТАРТЫМНЫ** *глз.* к.: **йанйоломны.**

**ТАРТЫМНЫҚ** *трх.* тәмәке (курево, табак).

**ТАРТЫМЫНА: тартымына йетмәү** *тбл.* туймый калу (не наесться, не насытиться). Пырас тартымына йетмәпте.

**ТАРТЫШҚАҚ** *тара.* **1.** к.: **тарамыш 2.** Тартышқақ ул, пер уңқа, пер сулға пәйләйсең. Тартышқақ наски, тартышқақ ойоқ була; **2.** ыштан бавы, резинка (резинка для чулков, для штанов). Тартышқақ қатабыс хәсер, элек пау пулган ыштанда.

**ТАРУ I 1.** *карс.* ирешү, насыйп булу (выпадать на долю, доставаться друг другу). Бик каты севешкәннәр, ну тарый алмаганнар. Бик матур булсаң да быйыгырсын, Тарый алмагач сүгән йарыңа (*хал. җыр.*). Кем тарый инде йулыңда; **2.** *м.-кар.* очрау, туры килү (встретиться, попадать). Кем тарий кәзер, татармы, чуwашмы. Машина сирәк тарий.

**ТАРУ II** *туб.-ирт.д., брб.д.* тараю (суживаться). Күз каналы тарый, көрмәс бола. – *брб.д.* Йылға қорып тарып қалыпты. – *тбл.*

**ТАРУ-ТАРМАН** *тара.* дару-фәлән (лекарства и им подобные).

**тархан** (тархан, приволье):

**тархан йату, тархан җату** *минз.* тик яту, эшләмичә яту, буш яту (бездельничать, лежать без дела).

**тархан китү** *злт.* җәелеп, иркенләп утыру (сидеть развалившись). Тархан китеб утыра бер абзый. Пөтеннәй тархан киткәнсең дә, кешегә дә урын бир.

**тарханға җибәрү** *минз.* үз иркенә җибәрү – терлек турында (отпустить на волю – о скоте). Терлек-туwарларын тарханға җибәргән.

**тарханға чыгу** *минз.* авыл арасында йөрергә чыгу, иреккә чыгу (выйти на волю, погулять). Ирем өйдә йуқ, тарханға чыгып киткән.

**ТАРХАНЛАУ** *тара.* иркенләү, эшләмичә тик яту (чувствовать себя свободно, бездельничать).

**ТАРЦЫМАЛ** *тбл.*, **ТАРЧЫМАЛ** *тара.* к.: **тарсымал.**

**ТАРШАЙУ** *тбл.* масаю (кичиться, зазнаваться).

**тары** (просо):

**корым тары** *кузн.* песи тарысы орлыгы (семена амаранта).

**тары уты** *лмб.*, **тары үләне** *минз.* (ежовник, петушье просо).

**ТАРЫҒУ 1.** *блт., минз.* тарсыну, тар күңеллеләнү (не жаловать, тяготиться, проявить эгоизм). Кешедән тарыққан кешегә Ходай Тәғәлә бирмим дигән. – *блт.*; **2.** *тбл.* к.: **тару II**.

**җан тарығу** *минз.*, **җан тарыгу** *стрл.* тарсыну (считать для себя тесным). Алҗапқычны буwасым килми, җаным тарыға минең. – *минз.*

**хәтер тарығу** *злт.* зиһен таралу (стать рассеянным). Хәтер дә тарыққан.

**ТАРЫГУ 1.** *стрл.* к.: **тарығу 1**. Кайтма, кайтма, мин сиңа тарыкмыймын; **2.** *чпр.* мохтаҗ булу, кирәксенү (нуждаться). Чүперәгә тарыккан энде без; **3.** *чпр.* зарлану (жаловаться, сетовать, роптать). Кат'ып, тарыгып-тарыгып сүләгән безнең әбигә; **4.** *чст.* кысылу (сжиматься). Йаның тарыкмыймы, эчең пышмыймы, уңайсызланмыйсыңмы?

**ТАРЫҚ I** *тара.* тары (просо). Тарық, солоно та беләсез инте. Тарық та булмаған. Тарыклар төйөп туй ашы йасатық, анан күцереп китерде.

**ТАРЫҚ II** *брб.д.* турта (отстой, вытопки – после вытапливания масла). Асқа утыра май тарыгы.

**ТАСА 1.** *сазл.* бөтенләй (совсем). Таса көцөм пөттө; **2.** *тбл.* яхшы, әйбәт, нык (хорошо, крепко). Мин аны таса пеләм. Үткән йыл ағачларны таса көйтөрөп китте.

**ТАСАЙАҚ** *том.д.*, **ТАСАЙАХ** *сазл.* к.: **тазайақ**. Тасайаққа бау элеп қуйатлар, шулай цацыпты ашны.

**ТАСАЛАУ, ТАСАЛЫХЛАУ** *сазл.* мәетне юу (обмывать покойника – ритуал). Мәйетне тасалыхлағаннан соң питен ацтырмайтлар.

**ТАСҚАҒАС** *перм.* лапас, гадәттә бер стенасы урынына бер-ике киртә генә куела (навес для скота). Шунда тасқағасқа керәләр. Тасқағасқа йаптым сыйырны.

**ТАСҚАҚ 1.** *перм., к.-уф., злт.* к.: **чиннек I, 1**. Шифыр белән җawып җыйған мунчаларын, тасқақларын. – *перм.* Тасқаққа ике рәт әрдәнә утын өйеп қуйдым. – *к.-уф.* Тасқаққа қуйабыз утынын да, башқасын да. Башы йабылған тасқак, утын, арба, қыш килсә, кешенең атын шунда қуйабыз. – *перм.*; **2.** *минз.* печән, утын куяр өчен кыек лапаска терәп, өстен ябып эшләнгән урын (пристроенное к навесу крытое помещение, куда складываются дрова, сено). Қыйықлы лапасның алдында тасқак була печән өйә торған; **3.** *минз.* йорт төзегәндә яки кое казыганда басып эшләү өчен стена буенча баганалардан күтәртелгән яки бауларга асып ясалган тезмә, басма (леса, помост на строительстве или при раскопке колодца). Тасқақ өй эшләгәндә, тәрәзә наличниклары қуйғанда басып эшләү өчен қуйыла. Қойо қadыған чағында қуйабыd тасқақны балчық ырғытырға; **4.** *минз., злт., тпк.* күтәрәмгә калган ат яки сыерны бау белән өрлеккә күтәртү өчен кулланыла торган агач җайланма (деревянное приспособление, которое служит для поднятия к перекладине с помощью верёвки обезножевших от слабости корову или лошадь). Бер ат тасқақта тора. Тасқақтағы атлар айаққа басты. – *злт.* Awырған атларны тасқаққа қуйалар, йирдә йатса лутсы түгел микәнни? Пасалмый айағына, йонсу, бау белән тасқаққа қуйалар күтәреп. – *тпк.*; **5.** *минз.* көтүчеләргә малларны күзәтү өчен күтәренке итеп тақта түшәп ясалган мәйданчык (высокий деревянный помост, служащий пастухам как наблюдательный пункт). Тасқаққа көтүчеләр менеп йата малны қарау өчен; **6.** *тбл.* агачның югары ботаклары арасына ясалган алачык, шалаш (укрытие, устраиваемое на дереве во время охоты).

**ТАСҚАЛАНМА'А** [*рус.* таскаться] *кас.* ару (устать). 'эн буйы тасқаланып петим.

**ТАСҚУ 1.** *дөб.* камырны яки балчыкны каты итеп басып үзләндерү (хорошо замесить тесто; размять глину и т.д.). Бурны қамыр кебек итеп тасқыдым да, шуның белә сыладым җарықларын; **2.** *тпк.* сыер маен кул белән баскалап, йомарлап ясап кую (сделать комок масла путём надавливания руками); чаг.: **тачқу**. Қаймақны басалар да тасқып қуйалар. Майны тасқып тора, ырғытып тора, теге йақта үлсәп тора; **3.** *дөб.* урын өстен аунату, изү (мять – о постели).

**ТАСЛАП** *т.я.* әйбәтләп, тәртибе белән (хорошенько, по порядку). Қапчықлар сарайда, әйбәтләп таслап қара! Чәчәкләр җыйып қайтты да әйбәтләп таслап баңкыға утыртты. – *трх.*

**таслап сөйләшү** *трх.* ипләп сөйләшү, җайлап сөйләшү (разговаривать вежливо, говорить дипломатично). Малайы килеп таслап сөйләште дә, мине бирделәр инде.

**ТАСЛАП-ТАСЛАП** *кмшл.* шомартып, тигезләп, рәтләп, тәртибе белән (разгладив, выровнив, по порядку).

**ТАСЛАУ** *минз., кмшл., к.т., мәл.* тәртипкә салу (упорядочить). Җыйған чәчәкләрне таслап букет йасадым. – *к.т.*

**ТАСМАЛ** [*фарс.*] **1.** *тпк., стрл.* к.: **битйаулық**. Ап-ақ итеп тасмал суғабыd. – *тпк.* Кыдага килүчегә бер билге биреп җибәрәсең, тасмалмы шунда. – *стрл.*; **2.** *кузн., тмн.* яулык (платок). Кардәшләренә тасмал, насук китерә кыз. Атлар тотучы(лар) катыннар күлмәге кийәләр иде, башына тасмал бәлиләр иде. Ак тасмалны йәйдем кывакка, Иртә берләп төшкән бывакка (*хал. җыр.*). – *кузн.* Тасмал бәлә башыңа. – *тмн.*

**ТАСПАШ** *тбл.* ташбаш (пескарь).

**ТАСТАР** [*фарс.*] **1.** *т.я.-крш., перм.* чиккән башлы озын сөлге (длинное полотенце); **2.** *мәл., чст.* тастымал (салфетка, маленькое полотенце). Тастар, диде, сөлге алып чыгып бара. Тастар каа безнең? – *чст.*; **3.** *мәл.* к.: **алсузма**. Кызны килешкәннән соң башкодага тастар бирәләр, итәк тастары; **4.** *злт.* бәбине биләгәч урап куяр өчен ситсыны яки марляны берничә кат итеп теген ясалган бау (марлевая или ситцевая верёвка, сделанная для наматывания запелёнутого младенца); **5.** *каз.ар.* мәетне юганда корыла торган япма (покрывало, используемое для покрытия покойника при его омовении); **6.** *әстр.* башка урала торган шарф формасындагы баш яулыгы (старинное головное покрывало в форме шарфа, *тастар*).

**итәк тастары** *мәл.* к.: **алсузма.**

**тастар башы тоту** *каз.ар.* к.: **дастар: дастар башын дыту.** Тастар башы тотқан кешеләргә дә билгеләп қуйдым әйбер, тастарны дүрт почмақта дүрт кеше тота. – *блт.* Тастар башларын тотып торучыларға берәр тастымал бирәләр. – *лш.*

**тастар сакалы** *срг.* ияк астында салындырып калдырыла торган тастар башы (концы *тастара* – старинного головного платка, *тастара*, завязывающиеся под подбородком).

**тастар сапмасы** *срг.* тастар астыннан киелә торган *башкигецкә* беркетелеп, аркага салындырыла торган башы чигешле тукыма, гадәттә ул тастар белән бер очтан була (кусок материи с расшитым концом, спускающимся из-под тастара на спину).

**ТАСТАРАУ, ТАСТАРУ** *нгб.-крш.* җыйнаксыз, тәртипсез (разбросанный в беспорядке; беспорядочно). Бөтен әйберләр дә тастарау булған. Әйберләрең тастарау йата. Өстәлләр тастарау. Әйберләрегезне җыйығыз, тастару йатмасын.

**ТАСТАРХАН** [*фарс.*] *әстр.* к.: **ашаулық.**

**Қор'ән тастархан** *әстр.* мәет ашы үткәргәндә кулланыла торган 80 см озынлыктагы тукыма кисәге (кусок ткани длиной в 80 см, используемый при проведении поминок).

**ТАС-ТАС: тасы-тасы белән** *трх.* оеш-оеш, катлы-катлы (слоистый). Баздан тасы-тасы белән йәм-йәшел килеп чыға синаж үләне.

**ТАСТИМАЛ** [*фарс.*] *перм.* к.: **тастар 1.**

**ТАСТМАЛ** [*фарс.*] *сазл.* к.: **тастар 2.**

**өстәл тастмал** *сазл.* өстәл сөрткеч (тряпка для вытирания стола).

**ТАСТЫМАЛ** [*фарс.*] **1.** *злт., тпк., мәл., байк., стрл., брб.д.* к.: **битйаулық.** Килен кешенең тастымалы былған, патмусы, бидерә, шаршаwы. – *злт.* Хәзер дә сирәк кенә тастымаллар чигәләр. – *бгрс.* Әдмени ул бедда тастымал, ана әлүле торалар. – *тпк.* Битемне тастымал белән себерәм. – *байк.*; **2.** *мәл., срг., кузн., хвл.* баш яулыгы (платок). Йабынырдый тастымал йебәр, дим. – *срг.* Илле тастымалым чалмага, киселгән йеслекләр чалмалык бар. Барсы да буйлата тастымал йабынганнар. Башыннан тастымалын сыдырып алды. – *хвл.* Салкын иде, бер кат тастымалдан гына утырдым. – *мәл.*; **3.** *дөб., перм., минз., бөре., чпр., к.-уф.* к.: **тастар 1.** Байырақ кеше қырыг-илле тастымал белә барды (кияүгә). Тастымал бирегез. – *перм.* Тастымаллар йыwып қуйдым. Бит сөртергә тастымал қайда? – *к.-уф.*; **4.** *брб.д.* к.: **алсузма.** Утыр, утыр тастымалға, тастымалны ташларға йарамый; **5.** *брб.д.* к.: **ашаулық.** Сөртөңгеч тә эшләгән китәннән, тастымал да, ашағанта йәйәсең. Тастымал йәйеп чәй эчә теген; **6.** *кузн., хвл., мәл.* кулъяулык (носовой платок). Тастымалым бик карамы? – *хвл.*; **7.** *твр.* идән юа торган чүпрәк (швабра); **8.** *тара., тбл.* мунчала (мочалка).

**йүгә тастымал** *туб.-ирт.д.* к.: **тастымал 8.**

**қасан тастымал** *туб.-ирт.д.* савыт-саба юа торган чүпрәк, мунчала (тряпка или мочалка для мытья посуды).

**кишле тастымал** *перм.* асалы сөлге (полотенце, концы которого сотканы закладным способом). Күбәләк тастымал күберелеп тора, ә кишлесе шома була. Кишле тастымаллар әпкиләләр ийе элек, имәнеч чичкәле була wы, барыбер чүпләп суғасын аны.

**кул тастымалы** *клд.* к.: **тастымал 6.**

**күбәләк тастымал** *перм.* баш-башлары янәшә торган ромблар рәвешендә сугылган сөлге (полотенце, концы которого вытканы ромбиками). Қайсы тастымал бирә күбәләкләп суққан.

**муйца тастымал** *төм.* к.: **тастымал 8.**

**озын тастымал** *мам.* к.: **алсузма.**

**пас тастымал** *том.д.* к.: **тастымал 2.**

**тоташ тастымал** *лш.* к.: **алсузма.**

**тастымал арасы** *минз., стрл.* чигүле башлы сөлгенең уртасы, чигелмәгән өлеше (невышитая часть, середина вышитого полотенца). Тастымал арасы айырым да сугыла, башын айырым сугып йалгап куйганнар. – *стрл.*

**тастымал баш** *перм.*, **тастымал башы** *минз., байк., стрл.* аерым эшләнә һәм сөлгенең уртасына ялганып кына куела торган сөлге башы (расшитые концы полотенца). Мона тастымал башы, такта күтәреп тугылган. – *байк.*

**тастымал бөксә** *перм.*, **тастымал сабағы** *минз.*, **тастымал сабагы** *стрл.* к.: **тастымал арасы.**

**хатем тастымалы** *брб.д.* к.: **алсузма.** Хатем тастымалын та аны сестән кем сораты.

**ТАСТЫМАН** [*фарс.*] *блт.* к.: **тастар 2.** Тастыманға сөрт ыстаканнарны.

**ТАСТЫРҚАН** [*фарс.*] *клм.* к.: **ашаулық.**

**ТАСТЫРТУ** *хвл.* куркып качу (удрать, пуститься наутёк). Тастырта, артына да әләнеп бакмый.

**ТАСТЫРХАН** [*фарс.*] *эчк.* к.: **ашаулық.**

**ТАСХАХ** *сазл.* **1.** ишегалдында кирәк-ярак әйберләрне кую өчен тактадан ясалган озын өстәл (длинный стол во дворе, на котором хранят всякие вещи); **2.** сазлык урында ял итү яки төнлә йоклау өчен дүрт аяклы итеп ясалган сәке (нары на четырёх ножках на болотистом месте для отдыха или ночлега).

**ТАСЫЛ 1.** *перм.* җай, уңай, җайлы, уңайлы (удобный, сподручный; удобно, сподручно). Тасылын тапқан кешегә awылда тороға була қый; **2.** *стрл.* осталык, җаен, рәтен белү (умение, мастерство; знать толк); чаг.: **сол.** Минем тасылым җук. Көч кирәкми аңа, тасыл кирәк.

**тасыл белән** *стрл.* җаен белеп, рәтен белеп (с толком, умело). Һәр эшне тасыл белән эшләү кирәк.

**ТАСЫП** *тбл.* толып (тулып).

**ТАСЫРАЙУ** *том.д.* күз акаю (вытаращить глаза).

**ТАСЫРДАП** *дөб., трх.* бик тиз, чабып, дөбершатыр (очень быстро, живо). Тасырдап машинасы белән қайтып та җитте. – *трх.* Кибет йанында тасырдап йөри башладылар инде, пинсийә биргәннәрдер. – *дөб.*

**тасырдап тору** *бгрс., кмшл.* җилкенеп тору (рваться, стремиться к чему-либо). Тасырдап торам, йарты нурмы (чөгендер) булса да алып эшләр ийем дип. – *бгрс.*

**ТАСЫРДАТУ** *чпр., кмшл.* ачулану, орышу (ругать, бранить). Кайбычка барып тасырдатып кайтам әле үзләрен. – *чпр.* Тасырдатып чыгардым үзләрен. – *кмшл.*

**ТАСЫРДАУ** *дөб., т.я., нгб.-крш., кмшл.* ашыгу (торопиться, спешить). Нигә тасырдыйсың, әллә бер дә курыкмыйсыңмы? – *нгб.-крш.*

**ТАСЫРДЫК** *дөб.* кабалануучан, уйламыйча эшләүчән (горячий, суетливый, неосторожный). Кайа ул хәтле тасырдыйсың, тасырдык, җана мәллә?

**ТАТ I** *саз.я., тбл.* тап (пятно). Көләйеңә әллә ни тат тейхән. – *сазя.* Тат төшермә өстеңә. – *тбл.*

**ТАТ II: тат бут'асы** *кас.* тары боткасы (пшённая каша).

**ТАТ III** *брб.д.* әләк, гаепләү (донос, обвинение).

**ТАТАБИ** *хвл.* күп сөйләшә торган кеше, такылдык (болтун, трещотка).

**ТАТАБЫЙ** *к.т.* абыйларның өлкәнрәге (более старший брат). Оло булғач, татабый диб әйткәннәр.

**ТАТАҚАУ** *эчк.* бабай, әтисе яки әнисенең әтисе һәм аңа эндәшү сүзе (дедушка, отец отца или матери и форма обращения к нему). Аның сиксән йәшәр татакайы бар. Татакау, цәй эцеп ал.

**ТАТАҢҚЫРАУ** *туб.-ирт.д.* аңгыраю (стать несообразительным, непонятливым; глупеть, поглупеть). Татаңқырап йатабыз.

**ТАТАР 1.** *т.я., тмн., лмб., кузн., хвл., срг.* к.: **абышқа 2.** (Килен) китергенчек татар булган инде. – *кузн.* Татар инде ул, катнын салды. – *лмб.* И-и, ул хәзер татар бит инде қызлар артыннан йөрергә. – *трх.*; **2.** *срг.* ир кеше (мужчина). Биш татар күтәрәлмәгәнне күтәреп азаплана инде. Әйбәт татар түгел бу. Үлгән татарның кызы була, ул да бәхет били алмыйдыр.

**ТАТАРЫМ** *срг.* иптәшем, ирем (мой муж). Татарым да йәж иде. Минем татарым өземнән он йәш зор. «Әй» дә, «татарым» да диләр (үз иреңә).

**ТАТЛЫ** *кузн.* тәмле, ләззәтле, яхшы (приятный). Иң татлы папирус ул. Безнең мунча бик татлы була.

**татлы тамак** *кузн.* тәмле ашларны гына яратучы (гурман); чаг.: **сарыплы 1.**

**ТАТСЫЗ** *т.я.* **1.** тәмсез, ләззәтсез (невкусный); **2.** олы гәүдәле, килешсез, ямьсез, котсыз (неприглядный, некрасивый на вид). Әй, татсыз, сөйләгән буласың инде шунда.

**ТАТУWЫМ** *том.д., тбл.* җаныкаем (душенька моя).

**ТАТЫҚ** *тбл.* алдакчы (обманщик). Ул татық, тыңламаң аны.

**ТАТЫМАЛ I** *дөб.* калын (толстый). Җуқанын қамырын татымалырағ итәләр, бик җуқа булса, тотышлы булмый ул. Бу татымал әйбер инде, қалын.

**ТАТЫМАЛ II** *тбл.* **1.** олы яшьтәге тәҗрибәле кеше (пожилой, опытный человек); **2.** бик яхшы кеше (замечательный человек).

**ТАТЫМЛЫ** *тпк.* ачы исле (с острым запахом). Әрем татымлы ул.

**ТАТЫР I** *кргл.* тәм (вкус). Сум ите бар, аның татыры йуқ.

**ТАТЫР II** *минз., стрл.* каты, тозлы – су турында (жёсткий, солёный – о воде). Қойолар бик татыр, эчеп булмай. – *минз.*

**ТАТЫРЛЫ** *бгрс., минз., стрл.* к.: **татыр II.** Шарда (*ав. ис.*) татырлы инде су. Кинәле сувы татырлы.

**т а у I** (гора):

**тау тыйу** *минз.* таудан акрын төшү (медленно спускаться с горы). Атқа эшләйә қуйсаң, тау тыйарға йардәм итә.

**тауға менү** *минз.*, **тауга менү** *стрл.* уенга чыгу – гадәттә җомга көнне (ходить на молодёжные игры – обычно в пятницу). Тауға менәдер ийек атна сайын, сабан чорларында.

**ТАУ II: квас тавы** *кузн.* туйда квас эчү йоласы (обычай пить квас на свадьбе).

**сиңа тау** *к.т.* сиңа да йоксын (пусть будет взаимным). Қотло булсын күлмәгең! Сиңа да тау булсын!

**тау ат'у** *лмб.* рәхмәт әйтү (сказать спасибо, благодарить). Йорт уртасында кийыгыз, Тартатарта беләгем талдырдым. Күб эшегезне эшләдем, Тау ат'ырга ишмәдем (*хал. җыр.*).

**тау итү 1.** *т.я.* васыять итү (завещать, оставить завещание). Кеше үлгәч, кемгә тау итеп қалдырдикән дип тә әйтәләр. – *нрл.* Сиңа тау итәм. Әй, абыйым, тау сиңа: Ике стакан бал сиңа. Берсе күңелең ачарға, Берсе йөрәгең басарға (*хал. җыр.*). – *к.т.*; **2.** *лш., лмб.* хөрмәтләп каршы алу, күтәреп алу (принять с почётом и уважением). Барып керүгә тау итеп алдылар инде. – *лш.* Тау итәргә квас бирәләр – *лмб.*; **3.** *мам., лш., дөб., каз.-ар.-крш., нгб.-крш.* рәхмәтле булу, рәхмәт әйтү (быть благодарным, благодарить). Менә сиңа бер камфит, awыз ит тә тау ит. – *мам.* Бу өйләрнең сыйы күп булыр, тау итийек тә без китийек. – *каз.ар.-крш.* Ашадық, эчтек инде, тау иттек. – *нгб.-крш.* Баш җаулығы булса, абау зур күчтәнәч апкилгән дип тау итәсең инде. – *дөб.*

**таулар бирешү** *кузн.* туйда бер-берсенә квас бирешү (обычай угощения квасом друг друга на свадьбе).

**ТАУЛАҚ** *брб.д.* **1.** йонсыз – сарык тиресе турында (без шерсти – об овчине); **2.** тиредән тегелгән чалбар (брюки из овчины); **3.** шәрә, такыр (голый, безволосый).

**ТАУМАШҚА 1.** *брб.д., яүшт.* к.: **пангы; 2.** *брб.д.* к.: **гембә: зана гөмбәсе.**

**шайтан таумашқасы** *брб.д.* к.: **май I: җир майы.**

**ТАУСАУ** *твр.* басылу, тыну, туктау (успокаиваться, утихать). Мушат пашымның awырywы таусар.

**ТАФ** *саз.я.* к.: **йунгы.**

**ТАФИҚСЫЗ** [*гар.* + *афф.* -сыз] *карс.* киребеткән, үзсүзле (упрямый, не поддающийся уговорам).

**ТАХАТ** [*гар.*] *чпр.* түземлек, чыдамлык (терпение). Тахатым корыды инде бу бала белән.

**ТАХТАМБИТ** *эстр.* к.: **түр 1.** Тахтамбиткә тастырхан җәйә.

**ТАХЫ** *нгб.-крш.* тагы (ещё). Тахы да шулай бу җақтагы күк қодаға җыйылалар.

**ТАЧ I 1.** *т.я., мам., бәр., бөре., перм., нгб.-крш., чст.* нәкъ, бөтенләй (точно, точь-в-точь, совсем). Тач үзе инде. Тач инәсе инде бу бала. Күзгә қарап

тач йуқны сүли. Тач исәр икә у қыз, мә? – *перм.* Тач безнең малай күк син. Тач синең кебек инде. – *нгб.-крш.*; **2.** *блт., мам., перм., нокр.* гел, фәкать, шыр..., гына (совершенно, совсем, весь; лишь, лишь только, исключительно). Тач орлоқ қына ул гөлҗимеш. – *блт.* Тач май. – *бәр.* Тач май ғына аш. – *нокр.*; **3.** *перм.* бик (очень); чаг.: **дуwамал 2.** Тач дөрес булмаса да, шулайырақ булыр инде. Тач қарт түгел, җәш. Тач қыйын тормошта йәшәмәдек; **4.** *перм.* рәттән, тулысынча (сплошь). Тач қорт баса.

**ТАЧ II** [*рус.* таз] *минз., стрл.* тас, кечкенә ләгән (тазик).

**ТАЧҚА I** [*рус.* тачка] *нрл.* бала караваты (детская кровать). Бабыйы тачқа җасап бирде, әрәшәткәләп.

**ТАЧҚА II** *трх.* сусыл – бәрәңге турында (водянистый – о картофеле). Йылғаға йақын төштә бәрәңге тачқа була.

**тачқа булу** *нокр.* к.: **тачқалану.** Бодай онынан тачқа була тәбәғый.

**ТАЧҚАЛАНУ** *к.т.* лычкылдап тору (быть сырым, недопечённым – о хлебе).

**ТАЧҚУ** *дөб., бәр.*, **ТАЧЛАУ** *дөб.* к.: **тасқу 1.** Қамырны қатырақ тачқысаң, тоқмач тәмле була, ди торған ыйы безнең әни. – *дөб.* Қамырны қунада тачқыйлар кыругум. Төчө қамырдан тачқып пешерәләр кәтермәчне. – *бәр.* Тачла әле әйбәт итеп, тоқмачы тәмле булыр.

**ТАЧОК** *клм.* кичке уен (вечерние игры). Йәйен тау башында тачок була, танцеват′ кыла идек, булавкалар да уйный идек. Йәйен тачок була торған, былафкы уйный идек.

**ТАЧРАННАП: тачраннап йөрү** *кмшл.* нечкә һәм озын ботлы кешенең йөрүенә карата көлеп әйтелә (говорится о походке человека с длинными и тонкими ногами). Тачраннап йөри шунда.

**ТАШ 1.** *әстр.* кирпеч (кирпич); **2.** *мам., т.кам.-крш.* к.: **қолташ.** Таш ул тегермән ташы кебек була. Әз генә йарма булғанда таштан чығарабыз. Орлоқны таштан чығарып төшен генә алалар да балға қатыралар. – *мам.* Таштан җарма җасап ашатадыр ыйық төннә, балалар ачтан үлмәсен дип, үлмисең әзерәк җалманғач. – *т.кам.-крш.*; **3.** *брб.д., тара.* алка яки йөзек кашы (драгоценный камень, вставляемый в серьгу или перстень). Ташлы сырғалар булған йылқултақ, минең аг ите ташы. – *брб.д.* Сырғаның ташы йуғалыпты. – *тара.*; **4.** *твр., төм.* к.: **чирахман 1.**

**атқа таш** *перм.* к.: **ноғый.** Әйдәң, малайлар, атқа таш белә уйнамаға барабыз.

**бөйер таш, бүwер таш** *перм.* зур шома таш (крупный гладкий камень).

**җәкер ташы** *минз.* вак қаты таш, мунча ташы (мелкие камни, которые применяются для каменки банной печи).

**йемеш ташы** *тмн.* җимеш төше (косточка фруктов и ягод). Хан′ук йемеш ташларын ватыб ашый.

**қойаш ташы** *минз.* эре чуерташ (крупная галька). Йулға қойаш ташы түшиләр.

**мәнүwәр таш** *эчк.* мәрмәр таш (мрамор). Әй мәнүwәр таш, Чын мәрзенкәйләр белән аралаш. Бармаққайым қамыш, бәгрем қойаш, Ақылларым камил, башым йәш (*хал. җыр.*).

**орлоқ ташы** *мам.* к.: **қолташ.** Орлоқ ташы була ике таш, тегермән ташы кебекнең кечкенәсе, шуны орчоқ белән әйләндерәдер ийек тә орлоқның төшен аладырыйық.

**тақта таш** *перм.* тақта шикелле акташ; гадәттә кабер ташына куела (белый, плоский камень, который обычно ставится и на могилу). Өй астына салырға алалар тақта ташны. Тақта ташы таптыңмы, утырттыңмы?

**таш ағы** *минз.* акбур (мел).

**таш әрем** *перм.* к.: **җабалдаш: җабалдаш әрем.**

**таш йиләге** *тпк.* каен җиләге (земляника). Таш йиләге тауда була. Хәдер таш йиләге пешә башлай инде.

**таш қамашы** *бөре.* к.: **қамақаш.**

**таш қатығы** *мам.*, **таш сuwы** *блт., мам., лш.* акбур яки ак балчык суы (раствор мела, белой глины или извести). Таш сuwы йасап моржа ағарттым. – *мам.*

**таш өй** *каз.ар., бәр., тпк., карс.* кирпеч өй (кирпичный дом). Дәү таш өй бар, шуның теге йағы. – *лш.* Чатта таш өйдә тора. Хәзер таш өй үзе йарты чир. – *бәр.*

**таш тазасы** *лмб.* типсә тимер өзәрлек (здоровый, сильный). Таш тазасы, сигезән эстендә, мәйетләр йыwып йери.

**таш тарилка** *хвл.* фарфор тәлинкә (фарфоровая тарелка).

**таш тарту** *тмн.* тәсбих тарту (перебирать чётки). Таш тартырга, төнәтергә баралар мәйет булған ызбага.

**таш тәникә** *бәр.* к.: **таш тарилка.** Элек awылда таш тәникәләр йугыйы, аш уздырасы булса, бездән әпкитәләр ийе дужинасы белә.

**таш тәрлинкә** [*рус.* тарелка] *бөре.* к.: **җәйләү.**

**таш тешәу** *мәл.* тегермән ташын тешәү (зазубрить жёрнов). Таш тешәгән арты салганга, он чытырдый.

**таш чүлмәк** *глз.* балчык чүлмәк (глиняный горшок).

**төп таш** *перм.* тегермәндә иң аста әйләнә торған таш, тегермән ташының аскысы (нижний камень мельницы).

**ТАШАЙАҚ** *минз.* чынаяк, кечкенә касә (маленькая полоскательница).

**ТАШАЛДЫР** *перм.* к.: **дустыган 2.**

**ТАШАЛДЫРЫҚ** *перм.* касә (чаша большая, полоскательница).

**ТАШБИЛГЕ** *каз.ар.-крш.* кичен яшьләр уены була торған урын (место проведения молодёжных игр). Тушында оло урамда инде ташбилге, диләр әлекеләр, шунда уйныйлар хәзер дә.

**ТАШБОРЧАҚ** *мам.* пешмәгән җиләк (ягода неспелая). Ташборчағын-нийен рәттән җыйып барған бу бала. Ташборчағын ашама, эчең awыртыр. Ташборчақ җыйып алып қайтадырыйық, җәм-җәшел инде, балан қаты булгач, пешмәгәч, ташборчақ әйткән инде.

**ТАШИЙАҚ** *бәр.* к.: **дустыган 2.**

**ТАШҚА: ташқа тамға үлчим** *лш.* ташка үлчим, Ходай, шулай булырга язмасын – имеш, шушы

сүзне әйтмәсәң, авыру үзеңә күчәргә мөмкин (Боже упаси, не дай Бог; слова, произносимые для того, чтобы эта болезнь не перешла на говорящего). Ташқа тамға үлчим, бөтен җире зәңгелә қуwырған кебек.

**ТАШЛАWЫЧ** *т.я.* ташландык (заброшенный). Урам буйынча төшсәң, ташлаwыч җорт жук.

**ТАШЛАМА** *туб.-ирт.д.* дүрт почмаклы итеп киселгән токмач (вид лапши, нарезанной квадратиками).

**ТАШЛАМАЙАҚ** *перм.* зур савыт (большая миска).

**ТАШЛАНДЫРЫҚ** *перм.* к.: **ташлаwыч**. Бетекий генә ташландырык чүлмәк китеге йатамы.

**ТАШЛАНУ** *төм.* кибән кую (метать стог, стоговать). Алар ташлантылар, пес моғоллантык. Йаңқыр йауса та ташланаларmы?

**ТАШЛАҢҚЫ** *минз.* к.: **ташлаwыч**. Ташлаңқы җортно тазартып керәбез. Шул ташлаңқы өйдән тапқаннар арақы.

**ТАШЛАУ** *байк.* таракан катыру өчен кыш көне мичне якмыйча вакытлыча башка өйгә китү (уходить временно из дома зимой с целью вымораживания тараканов). Элек күршегә цыгып өцәр көн йөрибез ийе ташлап пал'ак цыкса. Күршедә пал'ак, пал'ак кыш та ташлыйлар, һиц бетерәлмиләр.

**арпасы баш ташлау** *лш.* картлык җитү (состариться). Кешене дә әйтәләр, арпасы баш ташламаған әле, диләр, картлык wакыты җитмәсә.

**бозау ташлау** *перм.* бозау салу (самопроизвольный выкидыш – у коровы). Сыйырыбыз бозау ташлады көзгедә.

**ТАШЛЫ** *тмн., кузн., кас.* төшле – җиләк-җимеш турында (косточковый, с косточками – о фруктах). Ташлы әләк була чирумка. – *тмн.* Ташлы дҗимеш бели чәй эч'ин. – *кас.*

**ТАШПАК** *стрл.* никел йөгертелгән (никелированный). Биш литерлегә ташпак самаwырым бар.

**ТАШТАБАҚ 1.** *перм., төм.* аш тәлинкәсе (глубокая тарелка); **2.** *каз.ар.-крш.* балчыктан ясалган табак (глиняное блюдце).

**ТАШТАБАК** *кузн.* к.: **таштабақ 1.** Таштабагыңа саласын эштийеңе.

**ТАШТАБАН 1.** *бөре., перм.* күтәрмә (деревянная подставка, прикрепляемая к лаптям); **2.** *перм.* тимераяк (коньки). Таштабан шумаға барабыз бүген.

**ТАШТӘКИ** *каз.ар.* балалар уйный торган чәчәкле фарфор ватыклары (осколки, черепки цветной фарфоровой посуды, с которыми играют дети). Таштәки дийер ийек, шуны тезеп-тезеп уйнарыйык. – *лш.*

**ТАШТИН** *кмшл.* шаян, шук (шаловливый, шалун, озорник). Икәүләр, таштиннар. Усалырақ, шуғырақ балаға таштин, диләр.

**ТАШТИ-ТУКТИ** *кузн.* таштай, таш кебек (как камень). Ташти-тукти булсын.

**ТАШТЫРУ** *срг., хвл.* ташыту (дать перелиться через край, убежать – о жидкости). Сөтне таштырма, әй таштырыпсың, диләр чыгып киткәндә. – *срг.*

**т а ш у** (разлив, половодье, наводнение, потоп): **ташу җийыны** *мам.* күрше-тирә авыллардан ташу күрер өчен җыелу йоласы (обряд собираться из окрестных деревень, чтобы посмотреть на половодье). Ташу җийыны ташу күрегә килгәннәр, Илмәтләр (*ав. ис.*) килгәннәр, Җурашлар (*ав. ис.*) килгәннәр. Элек сулар киткәч, болонға су җәйелә торган булған, айақларын җуwып, чирләрен ағызып җибәрәләр җәнәгесе.

**ТАШ-ШАЛЕ** *глз.* к.: **таш: таш ағы**. Пичне ташшале белән ағартабыз.

**ТАШЫЙ** *әстр.* кирпеч өй (кирпичный дом). Казан өй, ташый, земл'анка өй.

**ТАШЫЙАҚ 1.** *дөб., мам., бәр.* к.: **дустыған 2.** Бер кечкенә генә ташыйағым бар. Чәйне ташыйаққа ғына йаса, анда чәй тиз cуwынмый. – *дөб.* Ташыйақ белә эчә чәйне үзбәкләр. – *мам.*; **2.** *бәр.* балчыктан яндырып ясалган табак (чаша, миска из обожжённой глины). Элек балчыктан йасалған ташыйақлар; **3.** *мам.* к.: **таштәки**. Ташыйақлар җыйып өйлә уйныйдырыйык.

**ТӘБӘ I 1.** *минз.* тары оныннан пешерелгән белен (блины, испечённые из пшённой муки); **2.** *каз. ар.-крш.* бодай яки борчак оныннан күкәйгә туглап пешерелгән белен (блины из пшеничной или гороховой муки). Бодай тәбәсе, борчақ тәбәсе.

**қалын тәбә** *каз.ар.-крш.* сөткә туглап пешерелгән йомырка куырмасы (омлет). Қалын тәбә салғанда, җаратқан ыйың, қодағый; Қызыңны алып киткәндә, Үпкәләдең, қодағый (*хал. җыр.*).

**қан тәбәсе** *т.кам.-крш.* яңа суйган хайван каныннан пешерелгән тәбә (лепёшка из свежей крови скотины). Қан тәбәсен пичтә пешерәбез. Қан тәбәсен мин бик йаратам.

**ТӘБӘ II** *брб.д.* түбә (крыша). Қалай тәбәле йорт. Тишек тәбәгә тә қамыштан эчерге.

**ТӘБӘҒЫЙ** *нокр., глз.* сөткә, йомыркага һәм майга туглап, мичтә томалап табада пешерелә торган кунак ашы – зур кекс (большой кекс, выпеченный на сковороде). Қунақлар кәлгәч, тәбәғый бешердем. Тәбәғый белә чәй эчерәләр, сыңра, күwәнтә салып иңгә, суға китәсин. – *нокр.* Тәбәғыйны пичкә салалар да инде, тәбәғый қабарғанмы, диләр. – *глз.*

**ТӘБӘЙ** *брб.д.*, **ТӘБӘКӘЙ** *каз.ар.-крш.* к.: **ашақ I.**

**ТӘБӘЛАЙАК** *хвл.* карта уенында черви (черви в игральных картах). Тәбәлайак валеты белән йап.

**ТӘБӘЛӘҮ** *лш.* йомыркадан тәбә пешерү (приготовить омлет). Күкәй тәбәлимме?

**ТӘБӘЛДЕРЕК 1.** *минз.* арбаның басып менә һәм төшә торган басмасы, җайланмасы (подножка – у телеги); **2.** *перм.* бастырык башын бәйләп куя торган аркан (толстая верёвка, аркан для закрепления гнёта).

**ТӘБӘЛДЕРЕКЛЕ** *дөб.* мәшәкатьле, расходлы (расходный). Туйға бару буш түгел бит, тәбәлдерекле. Туй ул бик тәбәлдерекле була бит.

**ТӘБӘЛҮ** *брб.д.* мөһерле йөзек (печатка). Пелә-лекләр, қатмышлар полған тәбәлү-тәбәлү.

**ТӘБӘНЧӘ** *каз.ар.-крш.* к.: **бәйсәкә**. Тәбәнчәрәк кенә, матур ғына бер қатын киләдерийе.

**ТӘБӘРЛЕК** *дөб.* тәбәлдерек – туку станогының аяк баса торган урыны (педаль – у ручного ткацкого станка). Тәбәрлеккә әйбәт бас, җебе күтәрелеп җитсен.

**тәбәрлек асты** *брб.д.* к.: **латас**.

**ТӘБӘТӘЙ** *чст., мәл., кмшл., брб.д.* к.: **кәпәч 1**. Тәбәтәйне татар кийә инде аны. Казанда бит тәбәтәй күп, диләр. – *чст.* Тәбәтәйемне йугаттым, Казански тәбәтәй. – *мәл.* Тәбәтәйеңнең түбәсен төп-түгәрәк итеп кем уйган. – *брб.д.*

**ТӘБӘТЕР** *тара.* к.: **табикмәк 5**.

**ТӘБӘЧЕК** *яүшт.* лапас (лабаз).

**ТӘБӘШ** *минз., стрл.* **1.** к.: **ашақ I**. Мин аны әйтмәгәнмен, чақ қына тәбәш булсын дип. – *минз.* Тәбәшрәк булган, ди, йарар, карт, мин әйтәм, минем баш тимәсә. – *стрл.*; **2.** к.: **бәйсәкә**. Киленем әйбәт, тәбәш кенә. – *стрл.*

**ТӘБӘШӘК 1.** *т.кам.-крш., перм., кмшл., бгрс., кргл., минз., злт., трбс., нгб.-крш., эчк., к.-уф., шрл., твр.* к.: **ашақ I**. Безнең ни, тәбәшәк кенә өйгә йарый инде. Урының тәбәшәк буган. – *нгб.-крш.* Аларның өйләре тәбәшәк. – *эчк.* Син ничек йатасың, балакай, андый тәбәшәктә? Йазыр эчен тәбәшәк инде ул әстәл, иркәм. Тәбәшәк дип сәкегә күләмәгән идем чәйне. – *шрл.* Тәбәшәк өстәл ywалған. – *к.-уф.* Өйөм йылы була, тәбәшәк бит. – *минз.* Баш астыгыз тәбәшәк түгелме? – *злт.* Сике тәбәшәк бит инде. – *трбс.*; **2.** *минз., бгрс., трбс., т.кам.-крш., нгб.-крш.* к.: **бәйсәкә**. Бер қатын тәбәшәгерәк кенә килеп керде, ул инәй икән. – *бгрс.* Тәбәшәк, җәш кенә кеше. – *т.кам.-крш.* Ул қыз оло, тәбәшәгерәк кенә. – *трбс.*

**ТӘБЕКМӘК** *нокр.* янып торган мич каршында пешерелә торган ачы коймак (блины).

**ТӘБЕР I** *т.я.-крш.* тагын, тагы бер (ещё раз, ещё один раз). Озата килүчеләрне озатканда қыз тәбер җырлай. Тәбер қызы бар аныкы.

**ТӘБЕР II** [*рус.* табор] *минз., стрл.* ерак кырларда эшләгәндә колхозчылар урнашкан урын, кыр станы (полевой стан); чаг.: **балаган**. Тырактыр тәберенә алып барып биргәннәр. – *стрл.*

**ТӘБЕРЕ** *брб.д.* кинәт (внезапно, вдруг). Кешегә тәбере пербер нәмә көркәскәннәр пискәк полса.

**ТӘБЕРСЕН** *т.кам.-крш.* үлгән кешене искә алып аш уздыру йоласы (поминки). Лидканы күрмәдем, тәберсенгә барып қалдым. Тәберсеннән қайттым ғына әле.

**тәберсен итү** *нгб.-крш.* авыз итү (попробовать, отведать). Пилмәнемнән тәберсен итеп кит.

**ТӘБЕТ** [*гар.*] *кузн.* мәетне салып зиратка илтә торган җайланма (специальные носилки из лубка, на которых несут покойника на кладбище); чаг.: **арата: арата ағачы**.

**ТӘБЕЧ** *нокр., глз.* кечкенә эмаль савыт (маленькое эмалированное блюдце). Кечтик тәбеч белә аш салып қалдырыр ыйы. Тәбеч тотып ике кәҗәне саудым. Беккәнне мискәләрдә пешерәбез дә тәбечләргә тутырабыз. – *нокр.*

**ТӘБЕШӘК** *перм., злт., төм., клм.* к.: **ашақ I**. Ағаслар мында бийек түгел, тәбешәк. – *злт.* Тәбешәк өйнә сатыб алган. – *төм.*

**ТӘБИЙӘ 1.** *минз., стрл., чст.* ачыга изгән арыш яки бодай камырыннан кул белән юкарак итеп җәеп, ут каршында табада пешереп алган ризык (лепёшки из кислого теста). Без беген тәбийә пешердек. – *чст.*; **2.** *минз., стрл.* тары яки борчак онынан пешерелгән коймак (оладьи, маленькие блины из пшённой или гороховой муки). Борчақ тәбийәсе, тары тәбийәсе. – *минз.*; **3.** *карс.* бодай онынан сөт-каймак, йомыркага гына басып, таба зурлыгында юка итеп җәелгән һәм мич каршында пешерелгән камыр ашы (национальное мучное блюдо); **4.** *тпк.* тары, карабодай, борчак онынан пешерелгән күмәч (лепёшка из пшеничной, гречишной и гороховой муки). Көнтөдгә тары тәбийәсе сала торган ийем; **5.** *лш.* йомырка тәбәсе (яичница). Тәбийә қуwырып аппардым, дәүрәкләре ашаған.

**ТӘБИК** *глз.*, **ТӘБИКМӘК 1.** *т.кам.-крш., нокр., к.т., дөб.* к.: **тәбийә 1**. Эки карчык пич каршында тәбик пешергәннәр. Анда дәү итеп тәбикмәк пешерәләр икән. – *дөб.* Әни тәбикмәк пешерде. – *к.т.* Қорбан бәйрәмендә тәбикмәк тә, тәбәғый дә пешерәбез. Тәбикмәк пич қаршында пешерәбез, ачытып табада майга пешерәбез. – *нокр.* Тәбикмәкләр пешерәләр пич қаршында әчегә. – *т.кам.-крш.*; **2.** *т.кам.-крш.* к.: **кәлҗемә I, 2**. Китәр ийек черек бәрәңге эзләргә, аны төйөп, тәбикмәк, дибез, пешереб ашыйдыр ыйық.

**ТӘБИЧ** *глз.* к.: **тәбеч**.

**ТӘБҮТ** [*гар.*] *тмн.* **1.** колаша, мәет юа торган җайланма, гадәттә ул тактalардан ясала, баш турысында су агызу өчен тишеге дә була (устройство из досок для омовения покойника); **2.** мәетне салып зиратка илтә торган, бер ягы ачылмалы, сай ящик сыман җайланма (приспособление из досок для переноса покойника на кладбище); чаг.: **тәбет**.

**ТӘБШӘК** *минз., стрл.* к.: **ашақ I**. Башыгызга тәбшәк булдымы әллә? – *стрл.*

**ТӘWӘ** *мам., трх., чст., хвл.* к.: **дәwә**. Шушы таштан тәwә чықсын, дигән. Шул таш ыңғыраша башлаган, шуннан тәwә чыққан (*легенда*). – *мам.* Тәwәләр белән йөргәннәр. Биш тәwәләре бар аларның. – *чст.* Өч йәшәрлек тәwә. – *трх.* Тәwәләр йигеп китерәләр кызны. – *хвл.*

**мар тәвәсе** *хвл.* озын гәүдәле, килбәтсез кеше (неуклюжий, высокий человек).

**ТӘWӘККӘЛ** *тбл.* булыр-булмас (эш), билгесезлек (неопределённость). Тәwәккәлгә утыру йаман, йә китү түгел, йә тору түгел.

**ТӘWӘТ** [*гар.*] *төм.* кара савыты (чернильница); чаг.: **дәвәт II**. Тәwәт тигәннәр қара сawытны, қалтықчыққа бәйләп йөрткәннәр.

**ТӘВӘТОЙАК** *хвл.* к.: **тәбәлайак**.

**ТӘWӘЧ** *нрл.* к.: **тәбеч**. Бар, тәwәчтә аш бар, ашағыз.

**ТӘWЕЛГӘН** *твр.* к.: **кагау**.

**ТӘWЕР: эсе тәwерентә** *туб.-ирт.д.* кызуында, тиз генә, сузмыйча (быстро, в тот же момент, по горячим следам).

**ТӘWЕРМӘН** *брб.д.* к.: **тирмән**. Айланған тәwермән, шуңа қысылады.

**йәл тәwермән** *брб.д.* җил тегермәне (ветряная мельница).

**қул тәwермәне** *брб.д.* к.: **қолташ.** Тарыны қул тәwермәненә үүреп ләпәшкә пешерәте.

**ТӘWҮ** *брб.д.* кыерсыту (обижать). Малайы тәwепте Байансылуны.

**ТӘҒАЖ** [*гар.*] *перм.* к.: **тийәғәз.**

**ТӘГӘЙ** *твр., тара.* к.: **тәғәрми.** Тәгәйне күчәргә кигезәләр. Тәгәйне үзләре эшләгән. – *тара.*

**ТӘГӘЙМӘТ** *яушт.* киез келәм (войлочный ковёр).

**ТӘГӘЛДӘШ** *дөб.* к.: **бәлчә 1.** Тәгәлдәшле булғастын шомортно, миләшне, бер-ике тәгәлдәш ашыйм әле, дисең.

**ТӘҒӘНӘ** [*гар.*]: **әдәм тәғәнәсе** *минз.* адәм көлкесе (посмешище, позор). Ир башы белән мучасының ташы җук, әдәм тәғәнәсе!

**ТӘГӘНӘК** *эчк.* к.: **гөләф.**

**ТӘГӘРЛӘҮ** *нгб.-крш., минз.* тәгәрәү (катиться). Қапчыкны тәгәрләп кертик. – *нгб.-крш.* Дус сипкән ийем, қортлар тәгәрләп җиргә төшкәннәр. – *минз.*

**тәгәрмәч** (колесо):

**тәгәрмәч қоршawы** *бөре.* тәгәрмәч бүкәне эченә куела торган тимер көпшә (втулка).

**тәгәрмәч тимере** *бөре.* тәгәрмәч шины (шина колеса).

**ТӘГӘРМИ** *нгб.-крш.*, **ТӘГӘРМӘЙ** *перм.* тәгәрмәч (колесо). Сигез тәгәрмәйле машина. – *перм.*

**ТӘГӘРНӘҮ** *эчк.* к.: **тәгәрләү.** Тәгәрнәп йыладым баламны қалдырып киткәц.

**ТӘГӘРСӘК** *злт.*, **ТӘГӘРЦӘК** *эчк.*, **ТӘГӘРЧӘК** *әстр., брб.д.* к.: **тәгәрми.** Тәгәрсәктәге сыулар апақ былып туңған ыйы. Арбаның дүрт тәгәрсәге была. – *злт.* Дүрт тәгәрчәкле арба. – *әстр.*

**ТӘГӘЦ** *эчк.* **1.** к.: **тәбеч.** Тәгәце дә безнеке; **2.** к.: **җомор.**

**ТӘГӘЧ** *бгрс.* к.: **тәбеч. 1.** Бер тәгәч тутырып қызыма биреп чығардым қатық.

**ТӘҖӘЛ** [*гар.*] *каз.ар., минз., трх., нрл., чст., т.я.-крш., т.кам.-крш., мәл., чпр.* ашығыч рәвештә, тиз (срочно, спешно). Бик тәҗәл генә кирәк иде. – *чст.* Қайта да тизрәк тәҗәл-тәҗәл ашый да чығып китә суға. – *каз.ар.-крш.* Тәҗәл генә су алып қайттым. Әйдә чығып кериг әле, тәҗәлрәк бул. – *мам.* Қайчағында тәҗәл генә бик кирәкле қунағың килеп керә. – *блт.* Нинди тәҗәл эше булсын, әйберне урынына қуймыйча китмәс ийе. – *дөб.* Бик тәҗәл кирәгең чықса, барып та чығарсың. – *нрл.* Миңа тәҗәл. – *т.я.-крш.* Тәҗәлләренә генә сызып куйалар, барысына да тегел. – *чпр.*

**ТӘҖӘЛЛӘНҮ, ТӘҖӘЛЛӘҮ** *каз.ар.-крш.* ашыгу (торопиться). Эштән қайталар дип тәҗәлләп бәрәңге пешердем. Тартырға җуқ, шуңа барам тәҗәлләп кибеткә. Тәҗәлләп чәй җасарға килде.

**ТӘҖӘЛ-ТӨҖӨЛ** [*гар.*] *т.я.-крш.* ашык-пошык (торопливо, наспех, кое-как). Тәҗәл-тәҗәл кийенде дә чыгып китте.

**ТӘЙӘН** *төм.* **1.** гел, барысы да (всегда, все). Пиш йегет үскерте, тәйән йегетләр, пер дә қысы йуқ; **2.** *төм., злт.* к.: **гелән.** Үс қөцләре белән йәшәйте, сатылатығаннарны тәйән алып үскерәте. – *төм.* Тәйән-тәйән awылларда йөрисезме? Тәйән уқысаң белер ийең. Тәйән генә майлы бутқа былмый. Синең қызларыңа қызып йөрмәм мин тәйән. – *злт.* Тәйән-тәйән әйтәсең тә торасың. – *төм.*; **3.** *перм., к.-уф.* бертоташтан, берреттән (подряд). Күпкә чыдамый батарей тәйән эшләгәч. Берәү тотқылый да суң қайчақта, тәйән тоталмый (нинидер җәнлекне). – *перм.*; **4.** *перм., к.-уф.* бөтенләй (совсем). Тәйән безнеңчә сүләшә. – *к.-уф.*

**ТӘЙЕ** *клм.* теге (те). Тәйе сәдәфләрне бирче.

**ТӘЙЕКМӘК** *дөб.* **1.** к.: **тәбийә 1.** Ипи тәйекмәге. Тәйекмәк пешергәннәр; **2.** карабодай күмәче (лепёшка из гречишной муки). Тәйекмәге тәмне була қарабодайның.

**ТӘЙЕН-ТӘЙЕН** *эчк.* һаман, һаман саен, һәрвакыт (всегда, постоянно); чаг.: **берче 1.** Тәйен-тәйен безгә килеп торма. Тәйен-тәйен ит ашы пешермәйләр.

**ТӘЙКМӘК 1.** *т.кам.-крш.* таба зурлығында итеп мич каршында табада пешерелә торган камыр ашы (мучное блюдо – блин в размере сковороды). Тәйкмәк пешерәләр бер табаға бер тәйкмәк, әлеке бодай оно иде, ағ он йуқ иде, пич йанғанда пич қаршында пешерәләр; **2.** *блт., дөб.* к.: **табикмәк 1.** Тәйкмәкне әле дә пешерәм таба белән мич алдында, ипи салам. – *блт.*; **3.** *мам., бәр.* ачы сыек камырдан юка гына итеп табада пешерелгән коймак, белен (блин). Иртә белән кийәү белән қызға муча йағалар, мучадан чығышқа тәйкмәк пешерәләр, тәйкмәк табаның иңге белән салынған қыймағ инде. Сыйық қамырны табаға салып пешерәләр дә тәйкмәк була. Бодай ононнан да була, соло ононнан да була ул тәйкмәк. – *бәр.* Қоймақның сыйығы тәйкмәк була, ул таба зурлығында инде. – *мам.*; **4.** *бөре., минз.* тары ярмасы онын бодай оны белән туглап, ачытып, аннан соң он белән басып пешерелгән зур коймак (блины, испечённые из пшеничной и пшённой муки на дрожжах); чаг.: **тәбийә 4.**

**ипи тәйкмәге** *бәр.* к.: **табикмәк 1.** Ипи тәйкмәге пешереб алдым мич қаршысында.

**тышлы тәйкмәк** *бәр.* табада пешерелгән күзикмәк өстенә катыкка туглаган йомшак камырны сылап, мич каршында пешерелгән ризык (мучное блюдо, приготовленное путём намазывания на испечённую тонкую лепёшку жидкого теста на катыке). Иң ал күзикмәген пешерәләр, андары чи қатыққа туглаган йомошақ қамырны қашық белә генә җәйеп җибәрәләр, менә була тышлы тәйкмәк, мич қаршысында пешерәсең.

**ТӘК** *күзн., тмн.* к.: **тике.** Шының тәк қырсағына бер ыстакан чәй. – *күзн.*

**ТӘҚА** *кргл.* бик (очень). Тәқа нық беткән иде ул бабай, ничек исән қалғандыр?! Бик матурны без тәқа матур дибез.

**ТӘКӘ** *мам., минз.* бөккән (пирог). Эремчек тәкәсе пешерәм. – *мам.* Тәкә-тәкә булса инде суған турыйсың, бороч сибәсең бәрәңгегә, бәрәңге тәкәсе пешерәсең. Беднең тәкәне бөкри диләр Йутадыда *(ав. ис.)*. – *минз.*

**тәкә ағач** *перм., минз.* утын кискәндә яки тақта ярганда бүрәнә кую өчен җайланма, кузла (козлы для распилки дров или досок).

**ТӘКӘ-МӨКӘ** *бөре.*, **ТӘКӘ-МУКӘ** *минз.* әкәмтәкәм (улитка).

**ТӘКӘРЛЕК I** *минз.* сипкелле (веснушчатый).

**ТӘКӘРЛЕК II: тәкәрлеккә бару** *т.кам.-крш.* үлгән кешене искә алып аш уздыру йоласы (поминки). Пыкырау алдыннан тәкәрлеккә бара, эшен бетереп, бәрәңгесен алып бетереп.

**ТӘКӘ-ТӨКӘ** *минз.* к.: **тәкә**.

**ТӘКӘЧӘ** *сазл.* к.: **дустыган 2**. Тәкәчәтә цай тис cowыйт.

**ТӘКЕ** *тмн., хвл., срг., кузн., мәл., карс., стрл., шрл.* к.: **тикә**. Качанга тәке булырсын. Эч айга тәке карасы бара. Төшкә тәке китермәсләр әлдә. Күзләре чиләк тәкешәр, ди. – *кузн.* Уникегә тәке тешәрмен әлдә. – *срг.* Иртәдән кичке тәке эшлиләр. – *хвл.* Туйыңа тәке тезәлер әле (*әйтем*). Шын тәке эшләдек, кырда кундык. – *тмн.* Шоның тәке генә шиша бирде. – *шрл.* Dawлинийам мының тәке купканы йук иде. – *карс.* Анасы умарта кортының барыбер корт тәке генә wet, күреп булмый аны. – *стрл.*

**шан тәке** *карс.* шуның хәтле (величиной с это). Күкерәк чиктек иргә барганда шан тәке, шан тәке.

**ТӘКЕМЛӘП: тәкемләп әйтү** *эчк.* аермачык итеп әйтү (говорить чётко, ясно). Тәкемләп әйт, аңламай қый.

**ТӘКЕН** *срг.* к.: **тикә**. Сугышка тәкен анда торды.

**ТӘКЕНҮ** *т.я.-крш., трх.* абыну, сөртенү (спотыкаться, отступаться). Тәкенеп җыгыла бит бу. Мин тәкенеп тешкинчек чабам. – *т.я.-крш.* Мин тәкенеп йыгылырлык озон күлмәкне йараттым. – *трх.*

**ТӘКЕРЛӘТҮ** *минз.* тәгәрәтү (катать). Тәкерләтеп менгезәләр.

**ТӘКЕРМӘЧ** *мам., блт., минз.* к.: **тәгәрми**. Тәкермәч чөйең төшкән. – *блт.* Кибән өстенә көлтәне ырғытыйм дип тәкермәчкә басып йыгылып төштем. – *минз.*

**ТӘКЕРМӘЧЛӘП** *блт.* түгәрәкләп кисеп (разрезать кружочками). Тәкермәчләп бәрәңге салдым.

**ТӘКЕРНӘҮ** *минз.* к.: **тәгәрләү**. Тәкерни-тәкерни җоқладык.

**ТӘКИ** *срг., стрл.* к.: **тикә**. Шибык йериләр, тиха йересәләр бу тәки тузан купмас иде. Бөгөлмәдә укыган кызым бәләкәй генә тордо-тордо да, әле, күрәсең, өрлөк тәки. – *стрл.*

**ТӘКИ-ТӘКИ** *дөб.* к.: **гелән**. Тәки-тәки мин төшәм, тәки-тәки мин төшәм, аның чыққаны да йуқ.

**ТӘККӘ** [*рус.* так + *афф.* -кә] *перм.* болай гына (так, просто так). Мин тәккә сүлим аны, йазмаа кәрәкмәс.

**ТӘКЛӘМ** *кузн.* хәтле, тикле (до). Қорғочларның түбәнгеләре бүз иде, йарты тәкләм генә.

**ТӘКЛӘП** *перм.* к.: **таслап**. Йуған әйберләрен тәкләп салып җыйдым.

**ТӘКЛЕ** *кузн., чпр., чст., каз.ар.-крш., т.я.-крш.* к.: **тикә**. Сугышка тәкле бардык. – *чст.* Абитка тәкле. – *кузн.* Элекеләрне белгән тәкле сүлим энде. Беренә тәкле тытты тawыкларны. – *т.я.-крш.*

**ТӘКМӘКЛӘНҮ** *дөб.* кыегаю, бер якка янтаю, авышу, бер башы күтәрелү, мәс., өстәл, эскәмия турында (покоситься, приподняться одним боком или концом – о столе, стуле). Әйдә утыр, тәкмәкләнеп китмәсен.

**ТӘКМӘН** *трх., төм.* к.: **кәтмәк I**. Тәкмән сабын сындырдым. – *трх.*

**ТӘКМӘРЛӘТҮ** *минз.* тәгәрәтү (катать, катить); чаг.: **каталату**. Өстәлгә үзем саладырыйым, тәкмәрләтеп җywадырыйым.

**ТӘКМӘС: тәкмәс ату** *тпк.* мәтәлчек атыну (кувыркаться). Баштүбән әйләнеп барып төшә исә, тәкмәс ату була инде.

**тәкмәс ташлау** *тпк.* мүкәләү (ходить на четвереньках). Артыбыздан тәкмәс ташлап башақларны тикшереп йөрделәр.

**ТӘКМӘСЛӘҮ** *тпк.* к.: **тәкмәчләү**. Иртә белә торсаң, урам туп-тулы була торған ийе тәкмәсләп йатқан кеше аслықта.

**ТӘҚМӘТ** *тара.* **1.** билбау, пута (пояс). Тәкмәт пилдә була; **2.** хлястик.

**ТӘКМӘЧ: тәкмәч ату** *шрл.* к.: **тәкмәс: тәкмәс ату**.

**ТӘКМӘЧЛӘҮ** *перм.* егылу, әйләнеп төшү, мәтәлү (упасть, свалиться; перекувыркнуться). Тау төшкәндә кинәт Җәмил тәкмәчләп барып төште.

**ТӘКУ: тәку саз** *әстр.* кызны кияү йортына озатканда җырлана торган җыр (песня, которая поётся во время проводов невесты в дом жениха).

**ТӘКЦӘК, ТӘКЧӘК** *брб.д.* өй почмагы, урам почмагы (угол дома, угол улицы). Төр тәкчәгенә песмеләләп ақча салады, ишек башқа тywалық салып ишек торысына арқалық астына. Әwәлге қатны ана у тәкчәктә торады.

**ТӘКШЕ** *брб.д.* тигез (ровный).

**ТӘҚЫЙА** *минз.* к.: **кәпәч 1**. Әнкәсенә күлмәк, атасына күлмәк белән тәқыйа бирә килен.

**ТӘЛ** *тара., твр.* к.: **тач I, 1**. Тәл урнына килгәнсез ул телнең.

**ТӘЛӘ** *брб.д.* к.: **табан I, 1**.

**ТӘЛӘЙ** [*гар.*] *т.я.-крш., чст., чпр.* к.: **талан**. Ыланнарның тәләйләре булса инде. Көн кыскара, бабай тәләйе. – *т.я.-крш.* Шулай итеп миңа тәләй йawып кына тыра. – *чст.* Тәләйе ницек туры килер. – *чпр.*

**ТӘЛӘКӘ I** *минз.* **1.** кечкенә уклау (валёк); **2.** суйган терлекне тунаганда аса торган агач (приспособление для подвешивания при обдирании туши); **3.** эшермә, капка биге (засов – у ворот). Җалқау кешеләрнең қапқасы тәләкәле була; **4.** *минз., бөре.* көлтә бавы, көлтә бәйли торган боргыч, гомумән, боргычка да әйтелә (закрутка, притужальник).

**қапқа тәләкәсе** *минз.* ялкау, эшләмичә тик ятучы (лентяй, лодырь; ленивый). Хөрәсән кешене қапқа тәләкәсе, диләр.

**ТӘЛӘКӘ II** *мам.* к.: **бәйсәкә**. Кеше буйга үскән чақта, Қайда калдың, тәләкә (*хал. җыр.*)?

**ТӘЛӘКӘ III** *лмб.* әләк (ябеда). Анасының тәләкәсе мән бәләнде миңа.

**ТӘЛГӘ** *тпк.*, **ТӘЛГЕ** *перм.* к.: **бәлчә 1**. Муйылы йә өсәү була, йә дүртәү бер тәлгәдә, эре генә. – *тпк.* Моноң баланы бер тәлге, ике тәлге бар қый әле. – *перм.*

**ТӘЛДӘҮ** *брб.д.* таган (качели). Тәлдәү атқалы.

**ТӘЛЕК** *нокр.* к.: **тикә**. Умбиш йәшкә тәлек йердек.

**ТӘЛИЛ** [*гар.*] *чпр.* тәсбих (чётки). Тәлил тарту. Карцыклар тенката тәлил тарта үле эстенә баргацтан.

**ТӘЛИНКӘ** [*рус.* тарелка] *перм.* фарфор яки эмаль табак (фарфоровое или эмалированное блюдо). Хәзер тәлинкә бар зур, аш соза торган.

**шүшкә тәлинкә** *нокр.* аш тәлинкәсе (глубокая тарелка).

**ТӘЛПӘК 1.** *мәл., чст., клд.* к.: **кәпәч 1.** Шында тәлпәк бар эстәл астында. – *мәл.* Тәлпәктән, казакидан. – *клд.*; **2.** *кргл.* йон эшләпә (войлочная шляпа). Тәлпәк кигән бер ир йерде бит.; **3.** *кмшл., брб.д.* самовар томалагычы, самовар түбәтәе (заглушка самовара).

**ТӘЛПИ** *стрл.* күп сөйләшә торган кеше, такылдык (болтун, трещотка).

**ТӘМ I 1.** *минз., стрл., бгрс.* тәм-том әйберләре (сладости); чаг.: **капкыч.** Чәй тәме алып кил әле. Чәй тәмен китер. – *стрл.* Сөтсез генә, тәм тутырып қына эчегез. – *минз.* Миңа чәй эчәргә тәм дигәнем йуқ. – *бгрс.*; **2.** *нгб.-крш.* ит (мясо). Ашқа тәм салмаган әле.

**ТӘМ II** *тара.* тын (дыхание). Тәмеңне өрмәце.

**ТӘМӘ** *төм.* өмет (надежда). Тәмәң таңқан игән қуй.

**ТӘМӘӘ** *тара.* тәмәке (табак).

**ТӘМӘЙ** *брб.д.* буш, эчтәлексез, файдасыз (пустой, без содержания, напрасный).

**ТӘМӘЙТҮ** [*гар.* + *афф.* -әйтү] *эчк., злт.* тәм бирү, тәм кертү (дать привкус, испортить вкус). Гөрәздәй тәмле түгел, сawыт тәмәйткән. – *эчк.*

**тәмәке** (табак):

**тәмәке ғунта** *брб.д.* тәмәке тартмасы (портсигар).

**ТӘМӘКЕШ** *тара.* тәмәке тартырга яратучы (заядлый курильщик).

**ТӘМӘН** *сазя.* чамасы (приблизительно, около).

**ТӘМӘРТҮ** *стрл.* тәмлеләндерү (делать вкусным).

**ТӘМӘТҮ** *хвл.* к.: **тәмәйтү.**

**ТӘМӘШ, ТӘМӘШӘК** *стрл.* к.: **ашақ I.** Диваннан утырса, тәмәш бит. Ызбасы тәмәшәк булган.

**ТӘМДӘК** *яүшт.* тамга (знак, ставящийся вместо печати).

**ТӘМНӘНҮ** *брб.д.* барырга әзерләнү (готовиться идти).

**ТӘМНӘРҮ** *стрл.* тәмлеләнү (становиться вкусным). Җылкының ите, майы сuwынган сайын тәмнәрә.

**ТӘМНӘТҮ** *тара., твр.* авыз иттерү (давать попробовать, отведать). Былтыр атты да (кошны) безгә тәмнәтте. – *тара.*

**ТӘМС** *сазя.* тәмсез (невкусный). Тәмс соу.

**ТӘМШӘК** *перм.* к.: **бәйсәкә.** Қара, ат берсе тәмшәк, берсе бийегерәк.

**ТӘН: тән йышхыц** *сазя.* мунчала (мочалка).

**тән куну** *срг.* тазару (поправиться, пополнеть); чаг.: **йалпайу I, 1.** Анарга тән кунмас умер буйына да.

**ТӘНӘ** *чст., срг.* әнә (указательное местоимение: вон). Тәнә тегендә күл казыттылар. – *чст.* Әни йәшләрцә кийенә тәнә. Тәнә-тәнә былытлар. Тәнә зур ызба. – *срг.*

**ТӘНӘЙ** *тбл.* каене һәм аңа эндәшү сүзе (шурин, форма обращения к младшему брату мужа). Әнийемнеңке тәнәйенең қысы бы.

**ТӘНӘЛДЕРҮ** *дөб.* тондыру (давать устояться). Өч көн тәнәлдерәсең шул суны.

**ТӘН-БАШ** *нокр.* бөтен гәүдә, бөтен әгъзалар (всё тело, весь организм). Тән-башым йаман awырта.

**ТӘНДҮ** *яүшт.* каңгырып йөрү (скитаться, шататься).

**ТӘНЕМ** *блт.* гадәттә хатын-кызларның яшьләргә, балаларга иркәләп эндәшү сүзе (ласковое обращение – обычно женщин к молодым и детям). Тәнем, ни хәлләр?

**ТӘНКӘ: тәнкә қорыту** *каз.ар.-крш.* теңкә корыту (надоедать). Тәнкәне қорытып сорап җөрде Үрнә түшлекләрне, тамақсаларны.

**ТӘНКӘЛ** [*чув.*] *дөб., т.я.-крш., чпр.* артсыз урындык (стул, табурет). Дүрт нүwешле була тәнкәл. – *чпр.*

**ТӘНТӘРӘК** *чст.* иркә (неженка; любимец); чаг.: **буйка 1.**

**ТӘНТЕРӘҮ** *перм.* алпан-тилпән килү, чайкалу (вихляться, ходить вперевалку, шататься). Баш әйләнгән кеше тәнтерәп җөри. Исергән, тәнтерәп җыгылып җөри.

**ТӘНТЕРЕКЛӘҮ** *төм.* к.: **таптырықлау.**

**ТӘНҮ** *брб.д.* селкенеп йөрү, эшсез йөрү, адашып китү (слоняться, бродить, заблудиться).

**ТӘНҮШКӘ** *баст.* помадка. Тәнүшкә пешерәләр, сөт, писук, берсәк ысливычный май салалар да қайнаталар.

**ТӘҢӘЛ** *минз., стрл.* к.: **тәңгәл I, 2.**

**ТӘҢӘЛДӘН** *минз., стрл.* турында, хакында (о, насчёт). Бернәрсә белми ул тәңәлдән. – *стрл.*

**ТӘҢӘҮ** *брб.д.* бәйләү (связать, завязать). Тәңәб өйгәннәр үлмәк кеше дип.

**ТӘҢГӘЛ I 1.** *минз., злт., кргл.* урын, тирә (место). Кис белән утынны менә шул тәңгәлгә аударған да киткән. – *злт.* Шушы тәңгәлгә қыйар чәчтек. Мынawы тәңгәлне Бүләк йәңкесе диб әйтә торғаннар ыйы. – *кргл.*; **2.** *перм., минз., стрл.* туры (напротив). Безнең тәңгәлдән генә чығып кер. – *перм.* Мулла тәңгәленә йеткәндә гармунны туқтатасың. – *минз.* Тайып бабай безнең тәңгәлдәйе. Кылуп тәңгәлендә генә тора. – *стрл.*; **3.** *перм., эчк., к.-уф.* туры (прямо). Бу йул бу йаққа тәңгәл китә. – *эчк.* Машина безгә тәңгәл бара. – *к.-уф.* Ана унда тәңгәл генә машина тора. – *перм.*; **4.** *перм.* нәкъ (точно, точь-в-точь).

**ТӘҢГӘЛ II** [*чув.*] *чпр., трбс.* к.: **тәнкәл.** Тәңгәл бир әле. – *чпр.* Син икенче тәңгәлгә утыр. – *трбс.*

**ТӘҢГӘРҮ** *нгб.-крш.* к.: **тәгәрләү.** Әбәү, тәңгәреп киткән.

**ТӘҢЗӘЛТҮ** *брб.д.* тирбәтү, чайкалдыру, атындыру (качать).

**ТӘҢЗӘЛҮ** *брб.д.* арт аякларга басу – ат турында (встать на дыбы – о лошади).

**ТӘҢИШ** *брб.д.* тиеш (должно).

**ТӘҢКӘ 1.** *стрл.* бауга бер рәт тәңкәләр тезеп ясалган, муенга киелә торган бизәнү әйбере (старинное женское украшение, сделанное из монет, надеваемое на шею); **2.** *клд.* чәчкап (женское украшение для волос). Тәңкәне тепкә бәлиләр иде, икедән үрү иде чәчне.

**маржа тәңкәсе** *чст.* Әби патша рәсеме төше-

релгән тәңкә (монета с портретом Екатерины II). Кашбауга маржа тәңкәсе тезгәннәр, йалтырawыклы ул.

**мыйын тәңкәсе** *т.я.-крш.* бер, ике яки өч рәт тәңкә тезелгән, муенга таға торган бизәнү әйбере (женское нагрудное украшение, состоящее из одного, двух или трёх рядов монет).

**тәңкә печән** *бөре.* шылдыравык (погремок).

**тәңкә чийршык салу** *мам.* йөзек салыш уены (молодёжная игры дотрагивается ладонями до всех сидящих – делает вид, что кладёт кольцо). Тәңкә чийршык салып уйный торған ийек, қулға шырпы тоталар да шушылай салып җөриләр, тәңкә чийршык кемдә, дип сорыйлар, кем дөрес әйтми, йаза бирәләр.

**чәч тәңкәсе** *мам., клд.* буйдан-буйга тәңкәләр тезеп, очына таба эрерәк тәңкәләр арасына асылташ куелган бизәнү әйбере, чәчкап (один из видов женского накосного украшения). Чәч тәңкәсе бар ийе, ун митр ситса апқайттым шул чәч тәңкәсен биреп. – *мам.*

**ТӘҢКӘЛ I** *тпк.* **1.** вакыт (время). Ydләре дөнйа көтсә тәңкәлендә, пулты; **2.** туры (напротив). Монтараг әле алар, машина тәңкәлентә түгел; **3.** урын, тирә (место). Сабатаның қолағы урта тәңкәлентә.

**ТӘҢКӘЛ II** [*чув.*] *дөб., т.я.-крш.* к.: **тәнкәл.** Сыйфарат тәңкәлемне чыланға кертеп қуй. Бер тәңкәлгә бассаң, түшәмен җуwарға була. – *дөб.* Син кайа тушы тәңкәлеңнән утырырсыңмы? – *т.я.-крш.*

**ТӘП** *лш.* чиртеш уенында: чәчеп җибәргәндә берсе өстенә берсе төшкән шакмаклар (положение кубиков во время игры).

**ТӘПӘ I: қаз тәпәсе** *трх.* бәбкә үләне (птичья гречиха, травка-муравка).

**ТӘПӘ II** *чпр.* көчек, эт баласы (щенок). Бер сәләмә тәпә инде.

**ТӘПӘ III** *брб.д.* калкулык (холм).

**ТӘПӘЙ** *тпк., злт.* аяк (нога). Калхуз эшенә тәпәй басмаған кешегә... – *тпк.*

**тәпәй өстө** *тпк.*, **тәпәй үрә** *злт.* аяк өсте, аягүрә (стоя, на ногах). Тәпәй өстө cawam, пот арасына қыстырам пидерәмне. – *тпк.* Утырып аша, тәпәй үрә ашарға йарамый. – *злт.*

**ТӘПӘН I 1.** *хвл., чст.* кисмәк (кадушка); чаг.: **қушма I; 2.** *минз., каз.ар.-крш.* су багы (бак для воды). Бәй, жуқмыни, улым, тәпәндә су. – *минз.* Тәпәнгә бер чиләк су сыйа. Қуwыш җүкә ағачын қуwышлаб алып тәпән йасый. Тәпән қуwышлаб эшлиләр, тишеге була су аға торған. Қырға су алып барғаннар тәпән белән. – *каз.ар.-крш.*; **3.** *кргл.* к.: **ләнгәц.**

**ТӘПӘН II** *злт.* к.: **бәйсәкә.** Тәпән генә, йуwан хатын.

**ТӘПӘННӘП** *бөре., трх.*, **ТӘПӘННӘП-ТӘПӘННӘП** *к.т.* аяк очларына гына басып (на цыпочках, встав на цыпочки). Тәпәннәп менәдер ийем эшемдә, ди. Тәпәннәп тә җитеп булмый. Тәпәннәп қарыйым әле, күренмәс микән?! – *бөре.* Тәпәннәптәпәннәп сузылып қарый, иту буйы җитми. – *к.т.*

**ТӘПӘРЛӘНУ 1.** *минз., злт., карс., байк., стрл., чст., хвл., срг.* бөрешү, бөгәрләну, таушалу (мяться, измяться). Күлмәк тәпәрләнә. Пәлтәңнең сабуwы тәпәрләнгән. – *злт.* Калын була бубрик (тукыма төре), тәпәрләнми торган. – *чст.* Сез бит тәпәрләнүдән йуwасыз, сезнең бит ару. – *срг.* Тәпәрләнгән, сывык ут′ук белә ут′укладым выт. *хвл.*; **2.** *злт.* киезләну, оешу (сваляться, сбиться, скомкаться); чаг.: **керү.** Мамық көйгә йатқызырға йарамый, тәпәрләнә.

**ТӘПӘРЛЕ** *байк.* бөтәрләнгән, таушалган (мятый, измятый). Бу йупка тәпәрле шул, тәпәрле.

**ТӘПӘЧ** *нгб.-крш., нрл.* чабагач (цеп). Тәпәч белән суғадырыйық. – *нгб.-крш.*

**тәпәч айақ** *кмшл.* бик зур аяк (говорится об очень большой ноге).

**тәпәч баш** *нрл.* чабагач тәпәче (било – у цепа).

**ТӘПӘШ** *минз., стрл., злт., тпк.* к.: **ашақ I.** Безнең өй тәпәш бит. – *минз.* Бу утырғыс тәпәш шикелле. Тәпәш түгелме урының, қара. Өстәл берсе бийек, берсе тәпәш. – *злт.* Өйләре тәпәш кенә, башы салам. – *тпк.* Элекесе чак кына тәпәшерәг ийе. – *стрл.*

**ТӘПЕ** [*рус.* тяпец] *злт., тпк.* кечкенә капкын, тәбе (капканчик для мышей). Тәпегә бер тысқан эләккән. – *злт.*

**ТӘПЕРӘНУ** *брб.д.* арлы-бирле йөрү, селкенү (двигаться туда-сюда, качаться).

**ТӘПИ 1.** *бәр.* аяк (нога). Мәрфуғаның тәпийенә басқан. Тәпи басқан көйө тегеп торам; **2.** *блт.* мебель аягы (ножка мебели). Өстәл тәпийен сындырғансың бит инде; **3.** *бөре.* ат дагалау станында атның аягын күтәреп бәйләп куя торган җайланма (часть станка для ковки лошади).

**тәпи башы** *бәр.* кечкенә чолгау (маленькая портянка). Тәпи башлары булыр ийе, ансы ақ қынайы. Чолғауның башына тирәк чығарған була, тәпи башы ақ қына була.

**тәпи табу** *перм.* тәпи йөрү (ходить – о ребёнке). Йаңа тәпи тапқан чақта йығылды ул.

**тәпи үрә** *минз., стрл.* к.: **тәпәй: тәпәй өстө.** Тәпи үрә басып тороп үткәрдем инде төннө. – *минз.*

**ТӘПИЙӘ** [*рус.* тафья] *дөб.* кечкенә буйлы, йомры гәүдәле – әбиләр турында (полный и маленького роста – относительно женщин преклонного возраста).

**ТӘПКӘ** [*рус.* тапка] *кас.* чүәк (чувяки).

**ТӘПКӘЛӘУ** [*рус.* тяпка + *афф.* -ләу] *мам., т.я.* к.: **кәтмәкләу.** Бәрәңгене бер көндә тәпкәләп бетерде бу қыз. – *мам.*

**ТӘПКЕ** [*рус.* тяпка] *перм.* к.: **кәтмәк I.**

**ТӘПКЕЛӘУ** [*рус.* тяпка + *афф.* -ләу] *мам., т.я.* к.: **кәтмәкләу.**

**ТӘПНИШ** *брб.д.* таптау – ат турында (топтание ногами, удар ногой – о коне).

**ТӘПРӘ** *т.я.-крш.* күсәк (дубина). Тәпрәне алған да куwып киткән этне.

**ТӘПСӘУ** *брб.д.* **1.** кызны килешү турында сөйләшү өчен ике якның да якын туганнарын чакырып үткәрелә торган мәҗлес (обед с участием самых близких родственников жениха и невесты). Цай, май бәргәннәр қыс өцөн, тәпсәүтән суң бәргәннәр, тойдан алда; **2.** никахтан соң, туйга хәтле булған җырлы-биюле мәҗлес (застолье с песнями и пляской, проводимое после помолвки). Қыс тос-

лары белән утыра, нәкәне төш wахытында уқыйлар, тәпсәүгә хәтле оғып қуйалар, уқып пөтөргән сен йыйылалар, тәпсиләр. Кәримә киленнеке қысы гийәүгә цыгып, аның тәпсәwе wақытында от цығып кәтте. Мән олулар тәпсәwентә бәк болмадым да; **3.** жырлы-биюле мәжлес уздыру (проведение пиршества с песнями и плясками).

**тәпсәү эчү** *брб.д.* туйдан соң қыз әти-әниләренең кодаларны сыйлау гадәте (обряд: после свадьбы родители невесты угощают родителей жениха). Өч көн тойлыйлар, қыслар айыры, эрләр айыры, аннан қысны алып китәләр, ата-инәләре тәпсәү эчәләр йырлап-пийеп, қоталарны сыйлыйпыс.

**Т'ӘПТӘ I** *нокр.* к.: **кәлҗемә I, 2.** Т'әптә йералмадан була, қырдан йералма апқат'асын да крахмалындан пешерәбез, ул шығыр-шығыр тора.

**ТӘПТӘ II** *хвл.* бабай (дед, дедушка). Мансур тәптәң кайа китте?

**ТӘПТӘК I** *стрл.* к.: **бәйсәкә.** Тәптәк кенә буйлы бер кеше ийе.

**ТӘПТӘК II** *тбл.* буш, бик вак, әһәмиятсез (пустой, ничтожный, незначительный).

**тәптәк әйтү** *тбл.* яла ягу (оклеветать).

**тәптәк иш** *тбл.* бик вак эш (ничтожное дело).

**ТӘП-ТӘКШЕ** *брб.д.* бик яхшы (очень хорошо). Пархыт тәп-тәкше булты.

**ТӘПТӘП** *нокр.* к.: **кәлҗемә I, 2.** Чәй алынга пешереб алам тәптәп. Тәптәп тә йасап ашадылар черегән бәрәңгедән. Сөткә басалар, әчегән сөткә дә басалар, жәйәләр, табада пешерәләр тәптәпне.

**ТӘПҮЧ** [*рус.*] *клд.* сөт белән кайнатылган шикәр (помадка, сделанная из сахара и молока); чаг.: **тәнүшкә.** Тәпүч белән эч, дип чәй китерде.

**ТӘПЦҮ** *брб.д.* булавка кадап кую, тегеп кую (прикалывать, пришить).

**ТӘППШЕ** *брб.д.* тагарак, ялгаш (корыто).

**ТӘРАЛ(ДЫ)** *каз.ар.-крш.* тәренең як-ягына корган пәрдәләр (занавески, повешанные по сторонам креста). Тәралдыларны килен килгәндә алып килә. Тәралларны чиккән булған.

**ТӘРӘ** *брб.д.* тире (кожа). Кәчә тәрәсен эшләwе awыр.

**тәрә тамга** *м.-кар.* миң (родинка).

**ТӘРӘБАҒАЧ** *перм.* тәрәш тарагы (чесалка для льна). Талқығас тәрәбағач тотоп тәрәплибез житенне.

**ТӘРӘБАС** *перм.* талкыш (костра, кострика). Ыспайы қала, жаматайы қойола, тәрәбас была. Тәрәплибез ий тәрәпәч белә, аның сүwәге қойола, жаматайы, ағысы тәрәбас была.

**ТӘРӘWЕЧ** *лш.* тегү теккәндә тукыманы кадау өчен энә, таявыч (подпора, подпорка – при шитье).

**ТӘРӘГӘН** *том.* к.: **пал'ак.**

**т ә р ә з** *тмн., срг., лмб., эчк., стрл.* тәрәзә (окно):

**тәрәз бүлмәсе** *срг.* тәрәзә күзе, тәрәзә өлгесе (звено – у окна).

**тәрәз буйында йөрү** *стрл.* кыз күзләп йөрү (высматривать девушку, выбирать невесту).

**тәрәз жәйәге** *лмб.* тәрәзә яңагы (боковой брус оконной рамы, косяк).

**тәрәз каршы** *лмб.* өй арты, өйнең урам ягы (передняя сторона дома, фасад).

**тәрәз кырыклары** *лмб.* тәрәзә әлгече (оконные петли).

**тәрәз қысасы** *эчк.*, **тәрәз ырам** *лмб.* тәрәзә рамы (оконная рама). Тәрәз қысасы тузған. – *эчк.*

**тәрәз эленгеләре** *лмб.* к.: **коргоч.**

**т ә р ә з ә** (окно):

**казан тәрәзәсе** *каз.ар., т.я.* өйнең арттагы стенасына ясалган кечкенә тәрәзә (маленькое окошечко в стене около котла). Қазан тәрәзәсен қалдырмасағыз да жарый. – *дөб.*

**тәрәзә арасы** *кмшл.* ике тәрәзә арасына эленә торган киҗеләп суккан киң сөлге (широкое хлопчатобумажное, домотканое полотенце, которое вешается на стене между двумя окнами).

**тәрәзә буйында йөрү** *стрл.* к.: **тәрәз: тәрәз буйында йөрү.**

**тәрәзә геләнҗәсе** [*рус.* глянец] *т.я.-крш.* тәрәзә пыяласы (оконное стекло).

**тәрәзә йөрү, тәрәзәгә йөрү** *стрл.* к.: **тәрәз: тәрәз буйында йөрү.**

**тәрәзә кәсәге** *нгб.-крш.* к.: **тәрәз: тәрәз жәйәге.** Бүген тәрәзә кәсәген буйадым.

**тәрәзә царшаwы** *байк.* к.: **коргоч.**

**ТӘРӘКӘН** *саз.я.* к.: **пал'ак.**

**ТӘРӘН** *т.я.-крш.* к.: **тике.** Питырауга тәрән чыккан уйынга, урыс атнас кенне жатка киткән.

**ТӘРӘҢ** *брб.д.* тирән (глубокий). Тәрәң әйре, ағып йата.

**ТӘРӘПӘЧ** *перм.* к.: **тәрәбағач.** Талқып чыгарғас, тәрәплибез ий тәрәпәч белә, аның сүwәге қойола.

**ТӘРӘПЛӘҮ** *перм.* **1.** к.: **тәрәтләү 2.** Талқығач, тәрәб ағач тотоп тәрәплибез житенне; **2.** к.: **тәрәтләү 1.** Ә әбийе жон тәрәпли, аңа ақча эләкми.

**ТӘРӘС** *себ.* к.: **тәрәз.**

**тәрәс инә** *тбл.* тәрәзә башы (верхняя часть оконного косяка).

**тәрәс рәйбәк** *тбл.* пәрдә, чыбылдык (штора, занавеска).

**тәрәс тупса** *туб.-ирт.д.* к.: **қучагыс.**

**тәрәс шешә** *төм.* тәрәзә пыяласы (оконное стекло).

**ТӘРӘТ** [*гар.*]: **тәрәт жаулық** *әстр.*, **тәрәт йаулық** *тара.*, *тбл.* к.: **битйаулық.** Қыз тәрәт жаулық әзерлиде. – *әстр.*

**ТӘРӘТҚАНА** *нокр.* бәдрәф (туалет, уборная).

**ТӘРӘТЛӘҮ** *перм.* **1.** тарау, йон тетү (бить, трепать шерсть). Оло сарықныкын ғына тәрәтлә, бәрән жәнө тәрәтләмәгә кәрәкми; **2.** житенне талкып тәрәшләү (мять, трепать лён).

**ТӘРӘТҮ** *перм.* к.: **тәрәтләү 1.** У, Гөлпи қарчық жөн тәрәтеп жыйған. Жөн тәрәттем.

**ТӘРБИЙӘ** *т.кам.-крш.* бизәнү әйберләре (предметы украшения). Чигәчәсе, сүрәкәсе, оло сырғалар жәш килен тәрбийәсе инде мона.

**өй тәрбийәсе** *минз., стрл.* к.: **элү I.** Арчыйлар өй тәрбийәсен әләләр. – *стрл.*

**ТӘРБИР** *брб.д.* чара (средство, лекарство). Әчәлгә тәре йуқ, тәкдиргә тәрбир йуқ (*әйтем*).

**ТӘРГЕ** *перм.* к.: **бәлчә 1.**

**ТӘРГИ-ТӘРГИ** *срг.* тирги-тирги (ругая).

**ТӘРЕ I** *брб.д., саз.я., тара., тбл., төр., төм.* дару (лекарство). Йасмыштан қачмыш йуқ, әчәлгә тәре

йуқ. – *брб.д.* Үләңнәр тәре қый, питамин. – *тара.* Тәремне эцеп қуйам. – *тбл.* Бүлнистә тәреләр пар ғый. – *төм.*

**ТӘРЕ II: ут тәре** *туб.-ирт.д.* дары (порох).

**ТӘРЕ III** *нгб.-крш., м.-кар.* к.: **тике.** Қайда тәре барабыз? – *нгб.-крш.* Быйыл тәре калхузда эшләдем. Быйыл тәре калхузда эшләде ийе, кәзер йук. Кошка тәре эшлим. Санап алдым умбишкә тәре, тагы дөртне куйдым, исәпсез күп булды. Чушында тәре килсәм дә житми әле. – *м.-кар.*

**тәре IV** (крест, икона):

**тәре алды** *каз.ар.-крш.* к.: **тәрал(ды).**

**ТӘРЕ-ТӘРМӘН 1.** *тбл.* дәва (лечение). Тәре-тәрмәнкә пал гәрәк қуй; **2.** *төм.* дару-фәлән (лекарство и прочее). Тәре-тәрмән пулмайты.

**ТӘРЗӘ** [*фарс.*] *перм., злт.* к.: **тәрәз.**

**тәрзәwыз** [*фарс.* + *тат.*], **тәрзә табақ** *перм.* к.: **қучағыс.** Гөл тәрзәw(ы)зында утыра.

**ТӘРИЛКӘ** [*рус.* тарелка] **1.** *әҗе., баст.* табак (блюдо). Тәрилкәләрдә атлыйбыз да май була, ар'аны була. – *әҗе.*; **2.** *перм.* зуррак эмаль табак (большая эмалированная посуда). Тәрилкәсе белән апчығыймму қаймақны?

**ТӘРИНКӘ** *нокр.*, **ТӘРИҢКӘ** [*рус.*] *шрл.* тәлинкә (тарелка). Кирикә тәлинкә таш тәринкә санала. – *нокр.*

**ТӘРИЦӘ** *срг.* к.: **алабата 2.**

**ТӘРМӘЗ** *чпр.* к.: **бәлчә 1.** Ул анда була ул винаграт тәрмәзе белән.

**ТӘРМӘН** *сазя.* к.: **тәмән.** Тәрмән пиш кила цыға йасты.

**ТӘРМӘЦЛЕ** *срг.* япьле (развилистый, с развилками, ветвистый). Өц тәрмәцле агацны шишага утырталар.

**ТӘРМӘЧ** *кмшл., хвл., мәл., тмн.* к.: **бәлчә 1.** Тәрмәчләр анарда киткән, шарт. – *тмн.* Йөзем тәрмәче, малан тәрмәче, мәләш тәрмәче. – *хвл.* Бөрлегән тәрмәч-тәрмәч (булып) йата, қызыл ашаулық кебек. Берлегән тәрмәче генәдер. – *кмшл.*

**ТӘРМӘЧЛӘНҮ** *хвл., мәл.* тармаклану, тәлгәшләнү (ветвиться, разветвляться).

**ТӘРНИКӘ** *минз.* к.: **тәринкә.** Мынаwы бәләкәй тәрникә белән ике тәрникә жыйған ыйым жиләк.

**тәрникә чәчәк** *чст.* к.: **чәчәк I: айлы чәчәк 2.**

**ТӘРСӘНӘ** *тбл.* сугыш кораллары склады (арсенал).

**ТӘРТ** *тара.* авыру, чир (болезнь). Рәхмәт, палам, айақ-қулыңа Алла тәрт пирмәсен.

**ТӘРТӘ 1.** *трх., тбл.* к.: **йәпләшкә.** Қунартты инде суғыш wақытында безне тәртәләр. – *трх.* Тәртә белән утын алып киләбес. – *тбл.*; **2.** *төм., тбл.* к.: **сәләскә.**

**ТӘРТЕШКӘ 1.** *перм., эчк., к.-уф., минз., злт., чст., м.-кар., стрл., чпр.* к.: **қустартқыч.** Тәртешкә шунда торайкән. Күмер алғалы тәртешкә дә йуқ. – *эчк.* Тәртешкә белән суға йаздым үзенә. Тәртешкә белән мичнең қузын таратып жибәр әле, қызым. – *к.-уф.* Тәртешкәне әббир әле, Зөлфийа, пичтән күмер тартам. – *чст.* Мичтәге күмерне тәртешкә белән тартырга кирәк. – *перм.* Терәп қуйған тәртешкә белән. Тәртешкә белән бастым да мискә йақтым. Әбиләр тәрәзә йанында утыра тәртешкәсен тотоп. – *злт.* Шәкәрне тартып тешерәм дә тәртешкә белән, куйа алмыйм. – *чпр.*; **2.** *дөб.* терсәк (локоть). Тәртешкәләреңне жәйеп утырма; **3.** *дөб.* дүртпочмаклы тактаны уртасыннан сапка беркетеп, түтәл тигезләү өчен ясалган жайланма (приспособление, орудие для разравнивания грядки, сделанное путём прикрепления к концу черенка четырёхугольной доски).

**ТӘРТЕШКЕ** *дөб.* ашлык сукканда ашлыкны өю, тарату яки бер урыннан икенче урынга күчерү өчен кулланыла торган көрәк сыман корал (деревянное орудие наподобие лопаты для сгребания и т.п. зерна на току).

**ТӘРТЕШКИ** *нокр., глз.*, **ТӘРТЕШ'И** *кас.* к.: **қустартқыч.**

**ТӘРТЛӘНҮ** *төм.* моңлану, моңаю (печалиться, унывать).

**ТОП: чапҡы топ** *перм.* эченә төш куеп сыер йонынан әвәләп ясалган туп (мяч из шерстиниьки). Чапҡы топ уйнадыҡ у чаҡта.

**чийыҡ топ** *перм.* уен исеме: түгәрәкләп тезелеп йөриләр, уртадагы кеше туп белән бер кешегә бәрә һәм йөгерә (молодёжная игра). Чийыҡ топ уйныйбыз, кругум чийасын да, ҡөрөйләр дә, топ белә берсенә бәрәсен дә, ҡөгөрөшәләр.

**чоҡор топ** *перм.* уен: ҡиргә кечкенә чокырлар ясап, аңа пыяла, таш кисәкләре салып чыгалар. Һәр чокыр янында хуҡасы тора. Тупны чокырлар буйлап тәгәрәтәләр: кемнең чокырына төшә, шул кеше тупны алып кемгә дә булса бәреп тидереррә тиеш (молодёжная игра). Ҡиргә үкчә белән чоҡор ҡазып тезелеп китәсең дә штуклап нимә саласың, тәгәрәтеп ике кеше чапҡытып ҡибәрә, йөгөрәләр, кемнең чоҡорына топ төшсә, у алып кемне дә булса ормаға тийеш, тидермәгә тийеш.

**ТОПЛИ** *әҙе.* к.: **пима 1**.

**ТОПОРЧАЛАП** *дөб.* труба рәвешендә (в форме трубы). Элгәре ҡүкәне тотош салдырып, топорчалап, тәгәрәтеп ҡуйалар ыйы.

**ТОПРАҠ** *каз.ар.-крш.* тузан (пыль). Болотлап тора, ҡаумый, ҡауса, топраҡ басылыр иде.

**ТОПСА** *перм., тпк.* бусага (порог). Нишләп торасың топсада? – *перм.*

**топса төбө** *минз.* к.: **йорт 1**. Топса төбөнә дә чыгармыйлар бу ҡортлар.

**ТОПСАУ** *брб.д.* талымламау (быть нетребовательным к еде).

**ТОП-ТОЙОҠ** *тара.* ябык, томаланган (закрытый). Топ-тойоҡ, аҡлы ғына пеләсек. Менә пы йаҡта топ-тойоҡ полот.

**ТОПЦОҠ** *туб.-ирт.д.* плавки.

**ТОПШАУ** *злт.* к.: **ҡырлау**. Тақта ҡуйып топшыйң сәпәмә белән.

**ТОПЫРЧА** *перм.* әвернә (моталка, мотовило).

**ТОРА I** *тбл., тара., клм., саз.я.* шәһәр (город). Тораға паргалы кәрәк. – *тбл.* Торадан ҡайтмаған. – *тара.*

**ТОРА II** *брб.д.* һаман (постоянно). Тора айағым сыслады дейде.

**тора салып 1.** *бгрс., кргл., минз., стрл.* к.: **кискәнәттән**. Бер йал көнендә тора салып ҡына машина белән алып кил әле ҡодағыйны, ди. – *кргл.*; **2.** *минз., стрл., төм.* гаепсезгә, бер дә юкка (без вины, ни за что). Кинада кәчтүр йанындагы халыкны тора салып аттылар. – *стрл.* Тора салып миңа йәбеште. – *төм.*

**ТОРАЙАТ** *кузн.* бишенче буын вәкилләре, чыбык очы кардәшләр (представители пятого поколения, дальние родственники).

**ТОРАҠ: озон торақ** *злт.* озын сыйраклы (голенастый, длинноногий).

**ТОРАТАН** *саз.я.* ян, туры (около, рядом).

**ТОРА-ТОРЫП** *дөб.* к.: **тикмә**. Тора-торып бер күзем суҡырайды, аwыртмады да.

**ТОРАЦЫҠ** *төм.* курган.

**ТОРАЧИ** *кузн., тмн., стрл.* дүртенче буын туганнар (родные четвёртого поколения).

**ТОРАШ** *стрл.* к.: **дөңгориш**.

**ТОРБАҠ** *брб.д.*, **ТӨРБАҠ** *том.д.*, **ТОРБОҠ** *клм.* тана (тёлка).

**ТОРБОС** *тбл.* к.: **торнакүз**.

**ТОРБОЧА I** *перм.* тәгәрмәч бүкәне (ступица – у колеса).

**ТОРБОЧА II** *минз.* к.: **торбоша**. Ике торбоча ҡорганнар.

**ТОРБОЧА III** *минз.* к.: **катлама 1**. Торбоча бидерә дәүмәлег инде бийеклеге.

**ТОРБОША** *минз.* иген ташыганда арбага ҡәелә торган зур киндер ҡәймә, торпыша (полоғ, вытканный из грубого холста). Бодайны арбаға торбошасыз салма. Бер ҡылны умбер торбоша суҡтым. Торбошаны ҡөк өсләренә ҡawып ҡуйалар, хәдер бериҡин инде ул.

**ТӨРҒА** *брб.д.* кыйммәтле ефәкнең бер төре (дорогой сорт шёлка). Моойныңа салған төрға орамалны тижен.

**ТОРҒАНЫ 1.** *блт.* к.: **берче 5**. Ҡаты печән гел торғаны чәчәк; **2.** *минз., злт., тпк.* нәкъ (точно, словно, будто); **3.** *перм., мам.* к.: **гелән**. Мин торғаны чаҡырдым ҡайт дип. Торғаны, бүтән нәрсә кирәкми, китап кирәк. – *перм.* Бәрәңгене ҡул белән утырталар бездә торғаны. – *мам.*

**ТОРГАНЫ 1.** *мәл.* к.: **берче 5**. Торганы йаңгал сүзенең; **2.** *стрл.* к.: **торғаны 2**. Торганы шуның кебег инде. Менаwы Уфадагы кызым торганы иптәшем инде.

**ТОРГАНЫСЫ** *кузн.* к.: **берче 5**. Аларның торганысы шулай.

**ТОРҠЫШ** *к.-уф.* к.: **батҡаҡ**. Үлисәләре бигрәк торҡыш. Кер сайҡарлыҡ та түгел бу йаға, бик торҡыш.

**ТОРЛАҠ** *перм.* торак (место обитания). Торлағы – тора торған ҡорто шунда булған.

**ТОРЛАП: торлап ҡалу** *твр.* торып калу (остаться навсегда). Йебәргәннәр дә (шунда), торлап ҡалғаннар, ҡир төпләп, ҡойаш та чыҡмаған, урман булған.

**ТОРЛАУ: торлаған торлау** *твр.* к.: **торлаҡ**. Торлаған торлаwына китсен (күз тигәннән имнәү сүзләре).

**т о р м а** (редька):

**аҡ торма** *перм.* ачы торма (редька).

**ҡызыл торма** *перм.* к.: **ләпләбә**.

**сары торма** *перм.* к.: **сәртәк**.

**ТОРМОШЛАНУ** *хвл.* кияүгә чыгу, тормышка чыгу (выйти замуж, вступить в брак).

**ТОРМЫШЧЫ** *тмн.* торучы, яшәүче (житель). Пешлидән (*ав. ис.*) дә бар тормышчылар Ҡазанда.

**т о р н а** (журавль):

**торна ҡузағы** *лш.* торна борчагы (сочевичник). Торна ҡузағы нәзек кенә, ҡузаҡлары, чәчәге була. Тар йылғада туҡранбаш үсә, торна ҡузағы.

**торна т′ит′и** *перм.* к.: **күк II: күк цәцәк**.

**ТОРНАКҮЗ** *брб.д., тара.*, **ТОРНАКҮС** *твр., тара., тбл.* мүк җиләге (клюква). Торнакүс сас цийәсе ул. – *тара.*

**ТОРОWЧЫ** *кас.* квартирда торучы, фатирчы (квартирант).

**ТОРОҒА: тороға башлау** *перм.* ачып туктау – ачыткан бал турында (прекратиться – о броже-

нии медовой браги). Ачып басыла да тороға башлый, арта зимниләр.

**ТОРОЖО** [*рус.*] *клм.* чүпрә (дрожжи).

**ТОРОҚЛЫ: қысқа тороқлы** *перм.* к.: **бәйсәкә**. Қысқа тороқлы гына малай ийе. Берсе белекий-ерәк кенә, қысқа тороқлы ғына, малай үлде бүwер чир белән.

**озон тороқлы** *т.я.* озын буйлы (рослый, высокого роста). Озон тороқлы буласы атасы кебек.

**ТОРОМ I** *күрш.* к.: **тереклек**. И бәхетем булмады, тором булмады, вайна булды.

**ТОРОМ II** *перм., минз., стрл.* корымбаш, кисәү авыруы, ашлык гөмбәсе (головня – грибок на злаковых; ржавчина). Тором бодай арада була, қара җим була. – *перм.*

**ТОРОМ III: торомнан торомға** *мам., каз.ар.-крш., минз.* 1. вакыт-вакыт (временами, время от времени). Торомнан торомга ала ди cow (кешене). – *каз.ар.-крш.* Торомнан торомға шул сөтне қawып қына тордом. – *минз.*; 2. ара калдырып, бераз ара калдыра барып (через определённый промежуток пространства, дороги и т.п.). Торомнан торомға қазық қағып чыққан. Тезелешеп басып торалар торомнан торомға. – *мам.*

**ТОРОМБАШ** *злт., тпк., эчк., к.-уф.*, **ТОРОН** *тбл., саз.я.* к.: **йосомбаш**. Торомбашы йанып петсен әле. Торомбаш сүнми қалған. – *злт.* Эсендә торомбаш икән. – *тпк.* Мистә торомбаш йанып қалмасын. – *к.-уф.* Мейецнең тороны пәтцә пихләгәле кәрәх. – *саз.я.*

**ТОРОШ** *перм.* к.: **тереклек**. Торошы начар булмаған Мәнди қартнықы. Торош йахшы өчөн ул аурулар онотылды. Торош итәбез. Торошы алға бара. Мона мин дә торош итеп торам, җиңгә дә үзе генә торош итеп тора.

**ТОРОШЛЫ** *мәл.* мул тормышлы, иркен тормышлы (состоятельный). Торошлы кеше бура тешерә пүгрәпкә.

**ТОРПА** [*фарс.*] *мам., каз.ар.-крш.* дорфа, тупас (грубый); чаг.: **лапалай**. Ана кешегә алай торпа булырға җарамас. – *мам.* Анасына торпарақ ыйы. – *каз.ар.-крш.*

**ТОРПАЛАНУ** *блт.* дорфалану (вести себя грубо). Килен торпалана, малай йаратмый, ә үзе тел белән әйтми.

**ТОРПОЧА** *бөре.* 1. к.: **топырча**; 2. к.: **катлама 1**.

**торпоча awыз** *хвл.* турсайган авыз (надутые губы – об обиженном человеке).

**ТОРТЫН: тортын шәл** *срг.* зур, эре чәчәкле калын шәл (большая, с крупными узорами толстая шаль). Тортын шәл зур була, цәцәкле дә, калын да, өстән йабынып йөриләр иде адийал кебек.

**ТОРЫМ: торым булмау** *т.я.* яшәргә, тормыш итәргә мөмкинлек булмау (невозможность жить, существовать). Мәчегә дә торым булмады. Жақшыға торым жүк, начарға үлем жүк (*әйтем*). – *к.т.*

**ТОРЫПЦА** *чпр.*, **ТОРЫПЧА I** *т.я.* к.: **торбоша**. Қапчықлар өстенә торыпчаны жап, жаңғыр үтмәсен. – *к.т.*

**ТОРЫПЧА II** *т.я.* к.: **топырча**. Ашлағач жазып киптерәләр дә торыпчаға чорныйсың (җепне).

**ТОСҚАУ** *перм.* төсмерләү (припоминать, узнавать по внешности). Тосқап торам әле мин бу қызны.

**ТӨСҚЫР** *брб.д.* тузан (пыль).

**ТОСЛЫХЛАУ** *саз.я.* тозлау (солить, засолить).

**ТОСНАҚ** *злт.* тоткын (невольник). Нисег инде аңарға барып тоснақ булып торыйм.

**ТОТА** *клм.* тотка, сап (ручка чего-либо). Чәкчәк кисүчегә бычақ тотасына ақча бәйләп қуйа. Бычақ тотасы. Чалғы тотасы. Ишек тотасы.

**ТОТА-ҚАБА** *лш.* к.: **қаба-тота**. Тота-қаба әле килеп керде ич.

**ТОТАҚЛАШУ** *перм.* култыклашу (взяться под руки). Безнең awылға чақ киләләр тотақлашып, җырлыйлар сузып.

**ТОТАНАҚ I** *мам.* к.: **тотнақ**. Қулымның тотанағы йуқ, нәрсә тотам, шул төшөп китә.

**ТОТАНАҚ II** *твр.* 1. үзчир тоту (эпилепсия, припадок); 2. тотлыгып сөйләүче (заика).

**ТОТАНАҚЛЫ** *к.-уф.* тыйнак, әдәпле (скромный).

**ТОТАНАҚСЫЗ** *злт.* тотнаксыз, әдәпсез (невыдержанный, нетактичный).

**ТОТҚА** *брб.д., клм.* к.: **табақычқыч**.

**табадан тотқасы** *клм.* к.: **табақычқыч**.

**ТОТҚАҚ** *яүшт.* к.: **тота**. Ике тотқақлы да була.

**ТОТҚАУ: тотқау итү** *к.-уф.* тоткарлау (задерживать). Без синең эшеңне тотқау итәбез қый.

**ТОТҚОР** *перм.* тоткарлый торган, тотып тора торган (задерживающий). Пучта бик шәп тотқор йер, берқайа китмәгә булмый, беркем қалып тормый.

**тотқон** *себ.* тоткын (пленник, узник, невольник):

**тотқонға ләгү** *тбл.* кулга алыну (быть арестованным). Минең пер пала тотқонға ләгеп қуйган.

**ТОТҚЫЧ** *клм.* ая, кәҗә мамыгын аялый торган бер пар тарак (пара гребёнок для расчёсывания козьего пуха путём их пришлёпывания одну о другую). Аның өсөнеңке тотқычы бар, мамықны эшлисең аны белән.

**ТОТЛАШУ** *мам.* тоташу (соединиться). Инеш ағып Бөр җылғасына төшә, Изелгә төшөп тотлаша инде.

**ТОТЛОҒУ** *мам., т.я., минз.*, **ТОТЛОГУ** *хвл., мәл., чпр.* тотылу – кояш һәм ай турында (затмение луны, солнца). Әле өчөнчекөн генә тотлоқты ай. – *мам.* Ай тотлоққанны күрдем мин. – *минз.* Ай тотлокса, караңгы була. – *мәл.*

**йозақ тотлоғу** *лш.* йозакның ачкыч белән бикләнми торуы (не запереться, не щёлкнуть – о замке). Йозақ тотлоға, майлап қуйам.

**ТОТНАҚ** *т.кам.-крш.* тотрык, ныклык (устойчивость, крепость, твёрдость). Тотнақ йуқ, қартайғач тотнақ булмый икән.

**ТОТОЛЫП: тотолып тору** *төм.* тотлыгу (заикаться, запинаться). Тотолып тора минем телем, хуш килепсез, димәдем.

**ТОТОП 1.** *кузн., хвл.* к.: **берче 2**. Тотоп вын шонон шикелле. Читлавыкныкы тотоп кыйаклар йапраклары. Тотоп тайга булган. – *кузн.* Тотоп шондый таба. – *хвл.*; 2. *кузн.* бөтенләй, нәкъ (совсем, точь-в-точь). Вот тотоп Майрә инде бөтөн булганы.

**ТОТОШ** *минз., стрл.* к.: **аруга II, 4.** Тотош кайтам дип торайы. Тотош кайтырмы, кабат килерме? Чиләбедә торалар ийе, йазга тотош кайталар. – *стрл.* Атбускаға ғына қайтқанмы, тотош қайтқанмы? – *минз.*

**ТОТОШЛАЙ** *тпк.* бөтенләе белән, тулысынча (полностью). Икәусе дә йегет сөйләйләр, өй йыwарға тотошлай мийә қала бит инде.

**ТОТОШУ** *каз.ар.-крш.* тотынышу (взяться за руки). Уйында анда тотошып түгәрәк уйын уйныйлар ыйы, қызлар барысы бергә тотоша.

**ТОТТОРМА** *лш.* к.: **уйнау: сақлы уйнау.** Тотторма уйныйдырыйық шушы тықырықта.

**ТОТУ 1.** *нокр.* әзерләү, пешерү (готовить, варить, печь). Пилмән тоту. Чақырышқанда зур бәлеш тотабыз; **2.** *клм.* бөрү (делать, сделать сборки, складки). Пәрәмәч йурағынға (төчегә), аузын тотасын.

**ТОТЫҚ I: тотыққа ләгү** *глз.* к.: **тотқон: тотқонға ләгү.** Мәскәүгә китте, йазмай, тотыққа ләктеме инде.

**ТОТЫҚ II** *глз.* зәхмәт (болезнь, хворь). Читкә кереп симәгез, ул тотық дийә иде, анда ташланган әйберләр була, йулның уртасында бер нә дә йуқ.

**ТОТЫНУ** *перм.* тоту (расходовать, затрачивать). Ақчаны алалар да, тотынып беттек, ти башлыйлар артаба.

**ТОТЫР** [*рус.*] *минз.* зур йөк машинасы (грузовая машина). Ағач алам, тотыр белән килсәң, дигән. Тотыр бер өйлекне төйи ул.

**ТОУУ** *себ.* **1.** к.: **асрау 2; 2.** *том.д.* к.: **туу I, 2.** Сыйыр йаңы тоуды, сөтөбөс йоуқ. – *клм.*

**ТОУМЫЛЫҚ** *брб.д.* к.: **томалақ.** Тоумылық ул wақ, қаты тешли.

**ТОФЫН** [*гар.*] *клд.* сүлпән, әкрен (вялый, медлительный). Ул үзе тофынырак кеше, үзе дә нинди-дер лыбырдаган.

**ТОХТАМБИТ** *әстр.* к.: **түр 1.**

**ТОЧ: точ булу** *минз., стрл.* саллы, тыгыз (увесистый, плотный); чаг.: **тачқалану.** Әпәй уңмый, шулхәтле точ була. – *минз.* Әwен арышының оны кыйбатрак җәри, ул точ була. – *стрл.*

**ТӨБӘ** *минз.* к.: **түбә 1.** Төбә бийау зерә алама әш икән ул.

**төбә сайғағы** *минз.* түшәм тактасы, түшәм итеп тезелә торган такта (доска, тёс для потолка). Төбә сайғақлары сөйән. Хәзер нараттан бетерәләр, менә безнең күршенең төбә сайғағы нарат, идән сайғағы нарат.

**ТӨБӘЙ** *твр.* к.: **ашақ I.**

**ТӨБӘК I 1.** *перм., бөре.* к.: **курмыйш.** Безнең төбәктә торалар. – *бөре.* Төбәктән тағы берәр кеше кирәк. Ғаптулла абзыйлар төбәктә торамы? – *перм.*; **2.** *минз.* к.: **йага I, 4.**

**ТӨБӘК II** *себ.* зур кәтүк (большая катушка). Пер төбәк йеп алтым.

**ТӨБӘКӘЙ** *минз., бгрс., кргл.* к.: **кәпәч 1.** Қазан қызлары хәзер төбәкәй чигәргә утырдылар, ди торған ыйы – *бгрс.*

**ТӨБӘНИЙ** *лш.* к.: **гелбәч 1.**

**ТӨБӘ-ТҮШӘМ** *стрл.* к.: **түбә 1.** Балчыгы калды да, теге өйнең төбә-түшәмен дә сыладылар.

**ТӨБЕ** *төм., тара.* яны (возле, около – послелог). Өй төбентә торып торчы. – *төм.* Бойыста қайтқанта төбөмтә ике қатын утырып параты. – *тара.*

**ТӨБЕНДӘ** *кузн.* буенда (около, рядом). Су төбендә кирпеч суктык.

**ТӨБӨ 1.** *клм.* к.: **түбә 1; 2.** *брб.д.* түбә, оч, баш (вершина, верхушка, верхняя часть); **3.** *брб.д.* к.: **түң; 4.** *брб.д.* балта түтәсе (обух топора); **5.** *брб.д.* өем (куча).

**ТӨБӨ-ҖИРЕ** *перм.* к.: **төп I, 1.** Уймыжның төбө-җире Имайкиннар.

**ТӨБӨР** *кргл.* мамыкны аялаганнан соң ая төбендә калган калдык-постыгы (остаток, отход пуха, оставшийся после расчёсывания).

**ТӨБӨРҮ I** *тара.* төтөнне кире кайтару (дымить – о печке). Уцак әшкәрә төбөрәте.

**ТӨБӨРҮ II** *тбл.* куу (гнать, догнать). Төбөрөп йеттеләрме сескә?

**ТӨБӨТ** *тара.* к.: **тебет 1.**

**ТӨWӘРӘХ** *сазл.* тирә, тирә-як (окрестность). Awыл төwәрәхтә қайwаннарға йөрхәле йер йух.

**ТӨWӨР** *трх.* ипи валчыгы (крошки хлеба). Ипинең бер төwөрен төшөрмиләр инде, турап бирәләр.

**ТӨWҮ** *твр.* төйнәү (завязывать узлом). Әр быwынға үлчәп пәйләде, төwөп чықты йепне.

**ТӨГӘЛЛЕК** *төм.* исәнлек-саулык (здоровье). Балаларыма төгәллеккә сатаға пиртем.

**ТӨГӘНӘК** *туб.-ирт.д.* к.: **гөләф.**

**ТӨГӘНҮ 1.** *срг.* бетеренү, ябыгу (истощиться, похудеть). Төгәнгән инде мескен; **2.** *к.т.* бетү, төгәлләнү (заканчиваться, завершаться). Фәмөрләр төгәнгән булса, иман белән үтәргә йазсын.

**ТӨГӘҮ** *тбл., тара.* бетерү (кончать).

**ТӨГЕМ: төгем генә** *клм.* болай гына (так себе).

**ТӨГӨЙ** *трх.* туку станында шүрегә җеп чорнау җайланмасы (приспособление для наматывания нитки на шпульку в ткацком стане).

**ТӨГӨРИК** *перм.* к.: **түбәрәк.** Күмәч төгөрик була.

**ТӨГҮЧКЕРЕ, ТӨГҮЧСЕН** *хвл.* ачуланып әйтелә торган сүз, каргау сүзе (выражение проклятия).

**ТӨДҮРҮ** *төм., тбл.* кире, киригә (обратно).

**төз** (прямо; прямой):

**төзөнә қатып қалу** *перм.* турыга катып калу (остаться прямым, несгибающимся). Бармағын әт чәйнәп, урта бармақ төзөнә қатып қалды.

**ТӨЗӘМ** *к.т.* төз, туры (прямой; прямо).

**төзәм агач** *т.я.* төз агач (стройное дерево).

**төзәм җир** *бөре., т.я.* тигез җир (ровная земля, равнина).

**ТӨЗӘТҮ** *перм.* к.: **ибаз: ибазға бирү.** Тегене төзәттем қапқаны бикләп қуйып.

**ТӨЗЕЛҮ** *тмн.*, **ТӨЗЕНҮ** *срг., баст.* йорт-җир кору (строиться). Алар быйыл төзеләләр. – *тмн.* Төзенәләр әле, ызба куйалар. – *срг.* Төзендек алтмыш беренче җылны. – *баст.*

**ТӨЗҮ** *нгб.-крш.* әлек солдатка алынасы егетнең киеме өчен кассага түләнә торган акча (в старину: деньги, которые вносились в кассу рекрутом за одежду). Минем төзү җөз умбиш сумға төште.

**ТӨЙӘ** *әстр.* к.: **дәwә.**

**ТӨЙӘК I** *тпк.* к.: **йатқылық 2.** Мал төйәге инде ул урманда да була.

**ТӨЙӘК II: төйәк пастыру** *тара.* игенне ат ярдәмендә сугу (молотить хлеб с помощью лошади).

**т ө й ә л ү** (набиться, погрузиться):

**төйәләп йату** *минз.* тулып яту, күп булу (быть полным-полно; много). Чәй үзебездә төйәләп йата.

**ТӨЙГӨ** *тбл.* к.: **awan III**.

**ТӨЙГӨС** *тпк.* чапкы (тяпка, сечка). Мәсәрупкадан да тартасың, төйгөс белән дә төйәсең.

**ТӨЙДӘК** *кргл.* к.: **төйләк**.

**ТӨЙЛӘГӘ** *төм.* гадәттә бәрәнләмәгән бер яшьлек сарык яки кәҗә (обычно неягнившаяся, годовалая овца или коза).

**ТӨЙЛӘК** *кргл.* бер тапкыр куеп эрләрлек күләмдәге кәҗә мамыгы, көнҗәлә (пучок взбитого пуха, свиток пуха). Дебетне манып айалаганнан соң төйләк төрелә.

**ТӨЙЛӘКЛӘҮ** *кргл.* аяланган мамыктан көнҗәләр ясау (делать свитки пуха для пряжи). Айалыйсың да төйләкләп артилгә тапшырасың.

**ТӨЙЛӘМӘ** *лш.* к.: **бүре: бүре борочо**. Төйләмә йафрағын шешкә йабалар.

**ТӨЙЛЕГӘН** *мам.*, **ТӨЙЛӨГӘН** *тбл.* к.: **кагау**. Төйлегән ала күрмәсен чебешләрне.

**ТӨЙМӘ 1.** *минз., бөре., бгрс., чст., чст.-крш., стрл., брб.д., твр.* к.: **гылбу 1**. Без аны төймәгә төзәбез (гөлҗимешне). – *минз.* Анасының төймәсен тагып чыккан. – *бгрс.*; **2.** *минз., трбс.* эре гәрәбә (крупные янтарные бусы). Төймә гәрәбә инде. – *минз.* Муйын төймәсе. – *брб.д.*; **3.** *брб.д.* каш (драгоценный камень). Төймәлесе булса, сырға тиеләр, алга пулса. – *тбл.*

**төймә бәрәңге** *мам.* вак бәрәңге, бәрәңгенең җирдә кала торган бик ваклары (мелкий картофель, мелочь картофеля). Кеше бакчасында калган шушының кебек төймә бәрәңгеләрне чүпләп кайтабыз.

**төймә печин** *каз.ар.-крш.* к.: **алма I: алма геле**.

**төймәле баш** *бгрс.* к.: **мөрбаш: мөрбаш печән**.

**ТӨЙМӘБЕРГӘ** *минз.* тик торганда, сәбәпсез (ни с того ни с сего, без всякой причины). Төймәбергә кычыта айак.

**ТӨЙМӘЛӘҢҮ** *минз.* җитеннең орлыгы өлгерү (поспевание семян конопли). Җитенне төймәләнгәчтән җолокасың.

**ТӨЙНӘК 1.** *кргл.* кавында яңа барлыкка килгән җимеш (завязь, плод у дыни). Беренче төйнәк шулай иде кәwында; **2.** *брб.д.* к.: **ураучык**. Төйнәкләрен әзерләп кайтқалы тип торганда.

**ТӨЙӨЛҮ I 1.** *злт., кргл.* чәчәү, чәчәп китү (поперхнуться). Йатсаң төйөлдерә. – *злт.*; **2.** *тбл.* бәрелү (удариться). Айағыгыс төйөлте.

**ТӨЙӨЛҮ II** *брб.д.* бөреләнү (набухание почек). Чәчкәгә төйөләб утыра.

**ТӨЙӨН** *брб.д.* сөял (мозоль).

**ТӨЙ(Ө)РЕМ I** *т.я., злт.* **1.** калын эрләнгән (о толстой пряже из шерсти). Җонно төйөрем эрләгән. Җебе төйөрем эрләгән. Җебе төйөремрәк, мондый нечкә әйберне тегәргә нечкә җеп кирәк. – *к.т.*; **2.** тигезсез, юанлы-нечкәле (неровная; местами толстая, местами тонкая – о пряже). Җон җепләрең төй(ө)рем булган, тигез эрләмәгәнсең. – *к.т.*

**ТӨЙӨРЕМ II** *к.-уф.* кирәкле, тиешле (нужный, необходимый, должный). Дөрес, бу да бик төйөрем сүз.

**ТӨЙӨРӨЛЕП** *төм.* бөтерелеп (закрутившись, завертевшись). Уғалы камсулларны кейеп төйөрөлеп уйнайтығайты.

**ТӨЙӨРҮ** *минз., злт., стрл., яүшт.* арчу, чистарту – тәлгәшле җиләк-җимеш турында (чистить – о ягодах с кистью и гроздью). Муйылны төйөреп җый. Башта сындырдық та аннан утырып төйөрдек. – *минз.* Маланны төйөреп куйдым. Шомортно ағацы белән китерделәр дә, төйөрөб алдым. – *яүшт.* Тәлгәшле йеләкләрне төйөреп куйалар, шомыртны, мәләшне, маланны. – *злт.*

**ТӨЙӨС** *злт., тара.*, **ТӨЙӨСКЕ** *твр.* кечкенә тырыс (туесок). Тозны төйөскә салдым. – *злт.* Катыкны төйөскә койоп... – *тара.* Төйөске басуга катык йөртөргә шәп. – *твр.*

**ТӨЙРӘWЕЦ 1.** *төм.* брошка (брошь); **2.** *тара., тбл.* к.: **түрәгец**.

**ТӨЙРӘҮ** *тбл., төм.* кадау (прикалывать, накалывать).

**ТӨЙТЕ: палта төйте** *туб.-ирт.д.* балта түтәсе (обух топора).

**ТӨЙТЕРҮ** *брб.д.* аздыру, котырту (развращать, подстрекать).

**ТӨЙТИ-ТӨЙТИ-ТӨЙТИ** *к.т.* к.: **тити-тити**.

**ТӨЙҮ 1.** *тпк.* тапау (рубить). Пешкән итне төйәсең тә, май, суган кушып, камыр эсенә тыгасың; **2.** *тбл., твр.* сугу (ударить). Пашыңны төйөб алырым. – *твр.*; **3.** *тбл., төм.* төйнәү, төрү (завернуть, завернуть в узелок). Лымчык-ламчыкларны төйтөм, йүкә пән пәйләтем. – *тбл.*

**пиц төйү** *байк.* мичне балчыктан төеп чыгару (класть печь путём утрамбования глины). Пиц төйәргә өмә йасыйбыз ийе.

**тула төйү** *каз.ар.-крш., лш., чст.-крш.* к.: **пат′ник: пат′ник басу**. Бу инде өйдә төйгән тула. – *каз.ар.-крш.* Тула диләр, аны төйдөрөб апкайталар ийе күрше awылда. – *лш.*

**ТӨЙШӘМБЕ** *тара.* к.: **башкен**.

**ТӨК: ана төгө** *бөре.* корт анасы урнашкан күзәнәк (маточная ячейка в сотах, где сидит матка). Ана төгөн кисеб алып бу эрәтәгә йәбештерәсең.

**ТӨКӘЙҮ** *твр., саз.я.* бөкрәю, иелү (сгибаться, сгорбиться). Ул да төкәйеп китеп параты, чисти үрмәкүч. – *твр.*

**ТӨКӘЛҮ** *кргл.* мөгез белән килеп терәлү – үгез турында (упереться рогами – о быке). Үгез миңа да килеп төкәлде.

**ТӨКӘНӘКӘЙ** *минз.* эш рәте белмәгән, юньсез (бестолковый, безалаберный). Төкәнәкәй тип эш рәте белмәгән кешегә әйтәләр беддә. Кортқа кеше төкәнәкәй була инде.

**ТӨКӘТМӘ** *минз., стрл.* к.: **кушма II**. Төкәтмәсен актәбердә салып кердек. – *минз.*

**ТӨКӘШТЕРҮ** *кргл.* беркетү, тоташтыру (прикрепить, соединить). Каплawычның очын итәккә төкәштергән җирен күнчек диләр, күзгә арпа чыкса, шуның белән имниләр.

**ТӨКЛӨ: төклө йеләк** *брб.д.* җир җиләге (клубника).

**ТӨКЛӨТАРА** *трх.* к.: **дөңгөриш**.

**ТӨКМӨЛДЕРИК: төкмөлдериг ату** *перм.* к.: **мәтәкләү**. Фәрзийә төкмөлдериг атты да барды да төште сыуға.

**ТӨКМӨЦ** *төм.* бүкән (пень, обрубок).

**ТӨКӨМӘ** *тпк.* к.: **кушма II**. Төкөмә эшләйсең, алты мөйөшле йорт була. Бу төкөмәне кутарып, оло йағын қалтырып эшләмәксе булалар.

**ТӨКӨМ-ТӨКӨМ** *перм.* к.: **бермекләп**. Төкөм-төкөм, бәйнә-бәйнә йатладым.

**ТӨКӨТМӘ** *минз., стрл.* к.: **қушма II**.

**ТӨКӨТУ** *минз., стрл.* ике озын әйберне яки бер әйбернең ике башын бер-берсенә тоташтыру (подпирать или стыковать друг к другу концы двух вещей или два конца одной вещи). Туғымның ике башын қара-қаршы китереп төкөтеп йасыйлар. – *минз.*

**ТӨКСӘ** *минз.* к.: **борнай 2**.

**ТӨКСӘРУ I 1.** *тэ., срг.* күңелсезләну, чырайны караңгыландыру (хмуриться, мрачнеть). Нәк төксәргән бу? – *срг.*; **2.** *тэ.* ачулану, ачуланып тору, ачуны йөзгә чыгару (злиться, гневаться, сердиться). Нигә шулай төксәреп йөри бу кеше? – *трх.*

**ТӨКСӘРУ II** *трх.* бала йоны чыгу (покрыться мурашками – о коже). Чыгығыз, мин этәм (судан), төксәргәнсез.

**ТӨКСЕЗ** *хвл.* хайванга ачуланып әйтелә торган сүз (сердитый возглас на животное).

**ТӨКТУWАР** *яүшт.* к.: **дөңгөриш**.

**ТӨКШӨК: төкшөк паш** *тбл.* пумала баш, тузган баш (косматый).

**ТӨКҮ** *бгрс., кргл.* сөзү (бодать). Сawарга қуркам сыйырны, йә төкер. – *бгрс.*

**ТӨЛӘУ** *төм., тара.* ябага кою (линять – о животных).

**ТӨЛДӨРӨП: төлдөрөп алу** *нрл.* черем итеп алу (подремать, вздремнуть). Төлдөрөп алсаң, бик йақшы була баш awыртқанда.

**төлкө** *урт.д.* төлке (лиса):

**төлкө қойрого** *к.т.* **1.** гади күрән (вейник наземный); **2.** чәчбай, тутык үләне (вейник тростниковидный).

**ТӨМӘ I** *кузн., хвл., чст.* к.: **гылбу 1**.

**ТӨМӘ II** *перм.* к.: **башала 1**. Төмә надан кеше wы, бернимә дә белмәс. Мин сийә, төмә җат кеше ти.

**төмәгә утыру, төмәләнә башлау** *хвл.* ярала башлау, яралгысы барлыкка килү (появиться – о завязях). Пымидурлар төмәләнә башлаган.

**ТӨМӘН-ТӨРЛЕ** *хвл., твр., тара.* күптөрле, төрле-төрле (разный, разнообразный). Төмән-төрле бүләкләр китерәләр. – *хвл.* Цәкәйтмә төмән-төрле йенцеле булған. – *твр.*

**ТӨМҒЫЙЫҚ** *эчк.* төнбоек (водяная лилия, кувшинка).

**ТӨМПӘ** *төм., тара.* агачны чокып ясалган көймә (лодка-долблёнка). Төмпә пер ағацтан йасалаты. – *төм.*

**ТӨМСӘ** *чист.* к.: **темсә**.

**ТӨМСӨНУ** *саз.я.* к.: **темсенү**. Өйтән өйхә төмсөнөф йөрит.

**ТӨМЧӨХ** *саз.я.* кыска буйлы кеше (человек низкого роста).

**төн** (ночь):

**төн гөлө** *тэ., т.кам.-крш., хвл.*, **төнгө гөл** *нгб.-крш.* бүлмә гөле (ночная красавица).

**төн озайған, төн озайу** *перм.* к.: **нажағай**. Төн озайу йәшен йәшнәгәндә суқмый ул, күкрәми. Төн озайғанда йәшен йәшни. Төн озайғандыр, шуны күргәнсездер.

**ТӨНӘ** *трх., миш.д., м.-кар.* к.: **кенәген**. Төнә кина булған икән. Суқаладылар, себерделәр төнә. – *трх.* Ире төнә шунда йөри иде, бөгөн күргәнем йук. Төнә сезнең сыйыр ике кызның җөрәген җарды бит. – *чст.* Мин төнә җидедә китә идем вет. Төнә әләкшә пешергән идем, ашамадылар. – *хвл.* Төнә йуган идән, кырыб йуды нарасыйда гынам. Икзамин ыздават итеп төнә генә килде. – *кузн.* Бик төнә уйладым иде дә куркытырга... Кичә дитмиләр инде бездә, төнә дитләр. Төнә дә барган кибеткә. Төнә суйдылар бозу. – *м.-кар.* Әле төнә генә сарык баллады. – *мәл.* Ана төнә биргән идек бит, мондагы книжка кайа икән? – *срг.*

**ТӨНӘWЕЦ** *тбл.* йокысыз бала (ребёнок, который мало спит).

**ТӨНӘГЕН** *блт., мам., дөб., минз., трх., каз.ар.-крш., перм., чст., бәр.* к.: **кенәген**. Қорт күче киткән төнәген генә. – *блт.* Ник син төнәген қайтмадың? – *каз.ар.-крш.* Төнәген бик қаты урған ийем. Төнәген қызларым машина белән қайттылар. – *мам.* Элгәрге нәмәрсәне түгел, төнәгенгене дә белмим. – *трх.* Төнәген қайттым Йошкардан. – *бәр.* Төнәген шундый рәхәт булды. – *минз.* Төнәген генә қайтқан әле бу қызлар. – *дөб.* Бөген дә таммаган, төнәген дә таммаган. – *чст.*

**ТӨНӘЙТУ** *тмн.* к.: **тенәтү II**. Мәйетне төнәйтәбез, йәшләр дә йөри, картлар гына төгел.

**ТӨНӘК 1.** *злт.* куначa (насест). Төнәккә менгәннәр инде таwықлар; **2.** *трбс.* торыр урын, яшәр урын, йоклар урын (место жительства, место ночлега). Төнәге булмаған кешегә қызымны бирмәм, дигән.

**ТӨНӘКЛӘУ** *байк.* кунаклау, төн куну (устроиться на ночь в гнезде или на дереве – о птицах). Таwыклар төнәкләргә ызба башына менәләр.

**ТӨНӘП: төнәп алу** *тбл.* к.: **төлдөрөп: төлдөрөп алу**. Аш пешкәнце төнәп алайым.

**ТӨНӘРТУ** *дөб.* к.: **тенәртү**. Әчтерхән чикләweген сулы шешәгә салып төнәртеп эчте. Қызыл борычны суға салып төнәртеб эчәләр.

**ТӨНӘТУ I 1.** *мам., минз., перм., злт.* алдау, оту, кәкре каенга терәтү (обмануть, объегорить, оставить в дураках). Төнәтмәсеннәр болар сине, қара, йоқлап торма. – *мам.* Уйау кеше уйау былмаганы төнәтә инде. – *злт.*; **2.** *стрл.* ачулану, тиргәү (сердиться, ругать). Төнәтмәдем дә үзен, күп сүләмә дип.

**ТӨНӘТУ II** *тмн., хвл., мәл., байк., нгб.-крш.* к.: **тенәтү**. Үлек йанында төнәтеп утырабыз. Төнәтеп чықтым бүген. – *нгб.-крш.* Йакын әхирәтем үлде, төнәтеп өч көн тордок. – *хвл.*

**ТӨНӘУ I 1.** *дөб.* к.: **төлдөрөп: төлдөрөп алу**. Бераз гына төнәп алыйм әле, бик йоқым килә; **2.** *перм.* куну, кунып китү, төн куну (переночевать). Төнәде дә китте қый; **3.** *перм., саз.я., тбл., төм.* к.: **төнәкләү**. Қазлар утырып төниләр алар, раудаға менмиләр. Төнәгәннәрмени, йарар, йоқласыннар айса (бәбкәләр кунаклагач). – *перм.*

**ТӨНӘУ II** *перм., злт., клм.* к.: **қунақса**. Қазлар төнәүгә менмиләр, җирдә генә жоқлыйлар. Қышқылықта төнәүдә йоқлады күркә. – *перм.* Лапас

астында төнәү бар, ағаслар қуйылған, шунда тawық менеп төни. – *злт.*

**ТӨНГӘК** *перм.* төенчек, төргәк (узелок, завёртка). Аҡчаны төнгәге бели алған да бәргән. Төнгәген қайда? Тyweннән қуйғач төнгәк була.

**ТӨНГЕЛЕК: төнгелеккә чыгу** *бөре.* к.: **куну: кунарга бару**. Атларны төнгелеккә алып чығалар.

**ТӨНГӨШ: төнгөш печән** *минз., бөре.* к.: **айу I: айу табаны 1**.

**ТӨНДӘК** *яүшт.* урындык (стул).

**ТӨНДЕК** *срг.* төнлек (вентиляционное отверстие, отдушина в курных избах и чёрных банях). Йугары була төндек, карызбы йакканда төндекне ачалар иде.

**ТӨНДӨК 1.** *хвл.* к.: **төндек**. Төндөк мунчаның эстәнасында путалаг белән тигез, үләрдә ишегалнысына таба, кара ызбалар беткәч който hава чыксын өчен; **2.** *злт.* к.: **сөрөмдөк**. Төндөген йапмыйса ғына йыwыш, башыңа ис тийәр.

**ТӨНДӨР** *клм.* к.: **қолақай**. Қолағы төндөр аныкы.

**ТӨНЕЙ** [*угор.*] *перм.* мамык белән сырып тегелгән аяк киеме (обувь, стёганная на вате). Төнейфәлән тектергәндер айагына. Тездән дә сыралар төнейне, мамык белә сырып тектерәләр, қунычлы.

**ТӨНИ** [*угор.*] *перм.* к.: **пима 1**.

**ТӨНЙАКӘР** [*гар.* + *афф.* -кәр] *тбл., төм.* уңган, житез (дельный, проворный).

**ТӨНКӨ** *төм.* төнлә атлар көтү (пасти лошадей ночью). Әйтәң, песнең төнкөгә барың, йомақны кән эшетәрсес.

**ТӨНЛӘҮ** *тара., тбл.* куну (ночевать). Сестә төнләп цыққалы пуламы? – *тара.*

**ТӨНЛӘЦЕ** *төм.* к.: **бабалаш**.

**ТӨНЛЕК** *твр.* өске катка баскыч чыгару өчен түшәмдә ясалган тишек (проём в потолке для лестницы, ведущей на второй этаж).

**ТӨННЕК** *к.т.* к.: **төндек**.

**төннек бәйрәме** *лш., дөб.* уразага керер алдыннан башкарылган иске йола (старинный обряд, связанный с религиозным праздником). Төннек бәйрәмендә кеше йоқламасын өчен аның төннеген, төннек тишегенә тыққан чүпрәген урлап йөргәннәр. Қапқаларны, арба-чаналарын алып китеп суға сала торған булғаннар. – *лш.* Төннек бәйрәмендә кешеләр төнлә бер-берсенең қапқаларын күчерәләр, моржаларын сүтәләр. – *дөб.*

**ТӨННӨК** *тара.* к.: **уйма 1**.

**ТӨНӨЛҮ** *злт.* сүрелү, дәртләнгән эштән кире кайту (охладеть, передумать, отступить от намерения). Бу да төнөлде инде тора-бара.

**ТӨНТӘЙҮ** *лш.* төмсәләнү (стать нахмуренным, помрачнеть, насупиться).

**ТӨНТЕК** *блт.*, **ТӨНТӨК** *перм.* к.: **борнай 2**. Сөйләшергә әwәс түгел кешегә төнтек диләр. Төнтөк төнтәйеп тик йөри инде. – Нурғали бабай бар, ул сүләр. – И ул бер нәмә белми ул, төнтөк.

**ТӨҢ I** *кргл.* к.: **башала 1**. Әби төң берүзе тора.

**ТӨҢ II: төң йер** *брб.д.* к.: **түң**. Төң йерләрнең бечәне қоро. Ике қас уртаснан төң йер кереп киткән.

**ТӨҢӘК** *брб.д.* түмгәк (кочка, пень).

**ТӨҢӘЛҮ** *тпк.* өмет өзү (терять надежду, утратить надежду). Пер барып төңәлсә, шунда тыныс йатыр ыйы.

**ТӨҢГӨЛ** *төм.* суккан келәмдә бизәк исеме (название узора на тканом ковре).

**ТӨҢГӨТҮ** *тбл.* ныгыту, нык итеп беркетү (накрепко соединить, укрепить). Ике қыртан апкиләтеләр тә төңгөтәтеләр икәwен бергә.

**ТӨҢКӘЙҮ** *минз.* к.: **мәтәкләү**. Башым әйләнә дә, барып төңкәйәм.

**ТӨҢКӘЛӘҮ** *төм.* к.: **күтәрү 1**.

**ТӨҢКӘЛӘХ** *сазя.* к.: **түңгәләк**.

**ТӨҢКӘЛҮ 1.** *төм.* азаплану, җәфалану (мучиться, измучиться). Иге йыл төңкәлтем. Ақшамта солоно қыwырып ашайтым, төңкәлеп эшләтем; **2.** *трх.* к.: **мәтәкләү**. Теге малай төңкәлеп китте.

**ТӨҢКӘХ** *сазя.* к.: **тумрам**. Төңкәх ташыйwс.

**төңкәх waш** *сазя.* к.: **төңкәх**. Утын йару өцөн төңкәх waш йасаф қуйды.

**ТӨҢКӨ** *злт.* к.: **төрмәк**. Ул төңкөсе белән алған. Төңкө-төңкө hәркемгә бирәләр икән, шуннан кем күпме күлмәк сыгара.

**ТӨҢКӨРТӘҮ: күк төңкөртәү** *төм.* күк күкрәү (гром греметь).

**ТӨҢКӨШ** *твр.* к.: **дәшмәки**.

**ТӨҢКҮ** *тбл.* ою (онеметь). Қулым төңкөп китте ишә-ишә.

**ТӨҢЛӨК** *твр.* к.: **гелбәч**. Төңлөккә картупка қуйатық.

**ТӨҢНӨК** *брб.д.* к.: **түннүк**. Төңнөк йемерелде, су аға.

**ТӨҢӨЛҮ** *тбл.* бизү, күңел суыну (разочароваться, охладеть). Күрү белән төңөлтөм.

**ТӨҢПӘ** *төм.* каек (лодка).

**ТӨҢРӨТ** *тбл.* самовар торбасын куя торган тишек (отверстие в печке для трубы самовара). Төңрөтөңне тык.

**ТӨҢТӘ: палта төңтә** *сазя.* к.: **төбө 4**.

**ТӨҢТӘРҮ** *сазя.* к.: **түнтәрү**.

**ТӨҢЧӨК** *брб.д.* к.: **гөмбек**. Ортасы төнчөк, ике йағы көймәләйен ойдоқ полып тора.

**ТӨӨР** *төм.* к.: **түр 1**.

**ТӨП I 1.** *блт., дөб., кргл., перм., мәл.* чығыш (происхождение). Мәңгәрнеке (*ав. ис.*) атасы, төбө, Кенәрдә (*ав. ис.*) йәшәде ул. – *дөб.* Мында төрлө йақтан жыйылған, безнең төбөбез Қазаннан. – *кргл.* Түбән Сөп (*ав. ис.*), Барсай (*ав. ис.*) йақтан килде ул, төбө Барсай (*ав. ис.*). Миңке төбөм Йалан Оч (*ав. ис.*), төпләре awылныкы. – *перм.*; **2.** *мәл., чст., чпр., перм.* к.: **йәwер I**. Алар инде бер төптән азганнар. Безнең төбебез чywаш булган. – *мәл.* **3.** *каз.ар.-крш., бгрс., кргл., чпр., мәл., төм.* к.: **диңгез 3**. Г.Кандалыйның туып үсән төбө менә шушы урында. – *мәл.* Тегесе төптә қалам дип жөрий. – *каз.ар.-крш.* Төп безнең Иске Йақупта (*ав. ис.*). – *бгрс.*

**ТӨП II 1.** *кузн., тпк.* азак, ахыр (конец). Мин баштан тотындым, төпкә чике. – *кузн.* Асырадың, әнекай, үстердең, Кадерен белмәгән йат өчөн (*кыз елату жыр.*). Бу инде «Таң кучат»ның төбе. Төбенә тәке белмим инде бу йырны. – *тмн.* Ике генә жегет печән чаба, Жепәк әзәрләрен талгы элеп. Төбе ничек, Супы тай? – *чст.-крш.*; **2.** *мәл.* берәр нәрсәнең чите, яны, буе (рядом, вдоль чего-либо). Правли-

нийе төбендә машина тыра. Магазин төбенә салалар йаңы ажидал′не; **3.** *кузн.* ас, түбән (вниз). Волга белән төпкә таба төшәсең; **4.** *хвл.* к.: **тач 1.** Төп үзе инде кызы.

**йорт төбе** *глз.* өй нигезе (фундамент дома). Йорт төбе салабыз элек агачтан, хәзер таштан, кирпечтән.

**мич төбе** *перм.* к.: **қазнақ.** Мичнең төбөн йасап қуйа башта.

**өй төбө** *төм.* к.: **йорт төбе.** Өй төбөн тишкеләп пөткәннәр керисләр.

**төб йебәрү** *хвл.* к.: **китү II.**

**төб өй** *төм., тбл., тара.* к.: **төп йақ.**

**төбе-җире** *перм.* к.: **нәсел-асаб.** Әни аның төбө-җирен дә белә инде, Таныпнықы булғач.

**төбө китү** *хвл.*, **төп бикләтү** *блт.*, **төп бикләү** *дөб.* к.: **китү II.** Утыртқаныйым төп бикләрмә, җуқма дип, төп бикләде тагын. Бу гөлнең ботағын түгел, төп бикләткәнен бирәм мин сийа. – *дөб.* Төп бикләтергә ботағын ботағаннар. – *блт.*

**төп йақ** *саз.я.* өйнең төп өлеше (основной четырёхстенник дома, обычно гостевая часть). Инәй төп йақтан цықты, пес қуқната цай эцәфс.

**төп күләү, төп салу** *перм.* өй нигезен әзерләү (закладывать фундамент).

**ТӨПӘ-ТӨЗ** *лш.* төп-төз (абсолютно прямой). Төпә-төз җир булған ул атау урманнары.

**ТӨПКӨ** *минз., стрл.* төп (основной, главный).

**бүрекнең төпкө йағы** *трх.* бүрекнең эче (подкладка шапки). Бүрекнең төпкө йағы соро төстә.

**төпкө бүрәнә, төпкө нигез** *минз., стрл.* к.: **төплөк.**

**төпкө өй** *кргл.* түр өй, зур өй (основной большой дом). Бүген қызлар төпкө өйдә өчәү йоқлойлар инде.

**төпкө хуҗа** *тпк.* төп кода (главный сват). Төпкө хужада ашыйлар да одаталар туй қунақларын.

**ТӨПКӨЛ** *злт.* сазламық җир (болотистая местность). Төпкөл – сазамық йер, пөтөн мал шунда.

**ТӨПКҮТӘРӘ 1.** *срг., мәл., кмшл., кргл., злт., хвл.* тулаем, бөтенләй, тулысынча (целиком и полностью, совсем; оптом); чаг.: **башала 1.** Бер самаwар суны төпкүтәрә эчеп бетердек. – *кмшл.* Бер чүмәлә печәнне төпкүтәрә ашаган да бетергән бу сыйыр. – *мәл.*; **2.** *каз.ар.-крш., к.-уф.* к.: **дихай 1.** Төпкүтәрә ақча күтәреп җөрибез бит. – *каз.ар.-крш.* Төпкүтәрә миңа бәйләнә башлады бу кеше. – *к.-уф.*

**ТӨПЛӘНҮ 1.** *перм.* төпченү (тщательно разобраться, детализировать); **2.** *минз.* суганның башы формалашу, суганлануы (формирование головки лука). Суганым төпләнмәй, нишләргә инде.

**ТӨПЛӘҮ I** *глз.* бикләү (запереть). Өйне төпләп киткән дип әйтерләр дип қайттым. Анда-монда чыққан арада да төпләп чыгасы була.

**ТӨПЛӘҮ II** *минз., стрл.* к.: **күтәрү I, 1.** Әле бәрәңге төпләделәр дә, җауса йарар ыйы дигән ийек. – *минз.*

**ТӨПЛЕ I** *глз., нокр.* бикле, йозаклы (запертый). Төпле ий, ачқычы миндә. – *нокр.*

**ТӨПЛЕ II** *тбл., тара.* **1.** хәтта (даже); **2.** бөтенләй (совсем).

**ТӨПЛЕК** *мәл., чпр.* олтан, табанлык (подошва обуви). Итек төплеге алдым әле, итек тектерәм. – *мәл.*

**ТӨПЛЕКӘЙ 1.** *минз.* к.: **дурочмақ; 2.** *бөре.* төче камырдан юка гына итеп җәеп пешерелгән ашамлык (мучное блюдо, приготовленное из тонко раскатанного пресного теста).

**ТӨПЛИТЕК** *срг.* астына олтан салынган киез итек (подшитые валенки).

**ТӨПЛӨК** *төм.* бураның беренче ниргәсе (первый ряд сруба, первый венец).

**ТӨПЛӨКИ** *трх.* к.: **қуйан: қуйан тобоғы.** Төпләки урманда күп була, қақылар кебек, бармақ қалынлық, тәмне була, wақ қына ақ чәчәг ата, өлгөргәч, төбөндә бәрәңге була, tawық йомырқасының сарысы хәтле.

**ТӨПСӘ 1.** *минз.* тәмәке төпчеге (окурок); **2.** *минз.* к.: **туй(ы)ра 7.** Элек төпсә бик шәбийе; **3.** *тпк.* теш тамыры (корень зуба). Ике төпсә тороп қалған самый күd тамырына тоташқан тешләрнеке; **4.** *тпк.* кабер урыны (место могилы).

**ТӨПЦӨК I** *төм., тара., тбл.* **1.** к.: **ашақ I; 2.** к.: **қалдық 2.**

**ТӨПЦӨК II** *туб.-ирт.д.*, **ТӨПЦӨХ** *саз.я.* хатынкызның коену костюмы (купальник дамский).

**ТӨПЧЕЛӘҮ** *трх.* к.: **төпләнү 1.** Син бит төпчелисең, миннән сорасаң.

**ТӨР 1.** *әстр.* җирдә эшләнгән ятак (земляная лежанка); **2.** *клм.* к.: **түр 1.**

**ТӨР** *төм.* к.: **түр 1.**

**төрән** (лемех у плуга, сошник у сохи):

**төрән айақ** *кмшл., кргл.* к.: **тәпәч: тәпәч айақ.** Төрән айақ безнең Вил, үзе бәләкәй булса да. – *кргл.*

**ТӨРӘҮ** *тара.* төртү, этү (толкать). Пы самахут түгел, арттан катер төрәп параты.

**ТӨРБИЧӘ** [*рус.*] *перм.* к.: **торбоча I.**

**ТӨРГЕ** *чпр.* өтерге (долото).

**ТӨРГЕҢ I** *тбл.* мәртәбә (раз). Бер-ике төрген урап қуйты.

**ТӨРГЕН II** *брб.д.* к.: **түрген 1.**

**төрген ашы** *брб.д.* туйдан соң бераз вакыт узгач, яшьләрнең кыз эти-әниләренә кунакка бару йоласы (обряд, согласно которому родители невесты через некоторое время после свадьбы приглашали молодых в гости). Элек ашлар бешереп перницә көннән соңмы, пер айдан соңмы қысныңқы өйөнә алып паралар йақыннары, абыйсымы, ышанычлы кеше былырға тейеш кейәү йақтан, төрген ашы тип цақыралар қыс йақлары, пөләк пирә, тағын кейәү йаққа йебәрәде, алар та цақыралар.

**ТӨРГӨ** *хвл.*, **ТӨРГӨН** *тбл.* төркем, өер, көтү (группа, куча). Палықлыр төргөн йөрителәр үлән арата, сыуның эцентә. – *тбл.*

**ТӨРДӨРҮ** *минз.* тышлау (обшивать). Ағач өйнө қызыл кирпеч белән төрдөрик.

**ТӨРЕМБАШ** *к.-уф.* к.: **йосомбаш.** Мунчаны йахшылап қарап бетер, төрембашы қалмасын, башқа ис тийәр.

**ТӨРЕТНӘ** [*рус.*] *стрл.* хезмәт көне (трудодень).

**ТӨРЛӘМӘҮ** *срг.* төрләндермәү (не разнообразить). Бездә монда бит Қазан йағына қарағанда аш төрләмиләр.

**төрләнү** (изменяться, разнообразиться):

**төрләнеп җөрү** *каз.ар.-крш.* к.: **бабай I: бабай булып җөрү.** Туйда болар берсе ир, берсе қатын булып сандық сатулашалар, шулай төрләнеп тә чығалар. Төрләнү чоры була, қыш була ул, ураза була да awыз ачқач, аннан төрләнеп җөрибез.

**ТӨРЛӘҮ** *байк.* **1.** өстен бизәү, матурлау (укра-

шать верх чего-либо). Майаш пешерсәң, төрләп куйасын битаминнар, фал′аннар белән; **2.** киндерне төрле җепләр белән бизәкләү (украшать холст узорами, ткать холст с орнаментом). Төрләп суккан киндер, әй төрләгән, бийаган киндерне.

**ТӨРЛӨГӘН** *перм.* к.: **кагау**. Каз баланы ала торган төрлөгән.

**ТӨРМӘ 1.** *бөре.* киндер орлыгы һәм эремчек белән пешерелгән бөккән (пирог с начинкой из творога и конопляного семени); чаг.: **кукыл′**; **2.** *минз.* к.: **кукыл′**. Қабақ төрмәсе пешерәләр ийе, орлоқтан да пешерәләр, пируг инде, төрмә тибед. Төрмә дары, дөгө йармасыннан да була, алмадыр, шоморттыр.

**ТӨРМӘК** *лш.* төргәк, рулон (рулон). Ун төрмәк түл алған ийем. Төрмәге-төрмәге белән саталар. Сиссы төрмәге шикелле төрәсең.

**ТӨРМӘЛӘП: төрмәләп қуйу** *минз.* төреп кую (завернуть).

**ТӨРМӨЖНИК** [*рус.* тюремщик] *хвл.* төрмәдә утырып чыккан кеше (бывший заключённый).

**ТӨРӨК** [*рус.* вдруг] *тбл.* бергә, берьюлы (вместе, сразу, одновременно). Пөтөнөгөс төрөк кәпләмән; **2.** *төм., тбл.* тиз (быстро). Төрөк кенә алырпыс та қуйарпыс. – *төм.*

**ТӨРӨМ I** *трх.* төрмә (тюрьма). Ике йылға төрөмгә киткән.

**ТӨРӨМ II: төрөм башы** *минз., стрл.* к.: **йосомбаш**. Төрөм башын чи печәнгә урый торган ийек тә, фурманга тагып аппара торган ийек, бидерәгә салып. – *стрл.*

**ТӨРӨМБАШ** *к.-уф., перм.* к.: **йосомбаш**.

**ТӨРӨП-ЧАРЫП** *нрл.* төреп-урап (завёртывая, укутывая). Балаларны төрөп-чарып мунчаға йөргәннәр.

**ТӨРСӘЙҮ** *перм.* тырпаю (взъерошиться, топорщиться). Төрсәйеп тороргә тийеш ул чәч, ул қәдәр сүрәкләп йөртүгә.

**ТӨРТӘННӘП** *злт.* абына-сөртенә (спотыкаясь). Төртәннәп йөри айаг астында. Ул қарсық бер дә өйдә генә утырмый, төртәннәп тик йөри.

**төртәннәб утыру** *злт.* ныкбирелеп, текәлеп утыру (сидеть уткнувшись, не отрываясь). Бер тотонғас, төртәннәб тиг утырақ инде. Китабы белән иртәдән бирле төртәннәб утыра.

**ТӨРТЕЛГӘН** *мәл.* к.: **кирәмәт 2**.

**ТӨРТЕШҮ** *чпр.* этәрешү, этешү (помогать толкать). Төртешеп бара арбаны.

**ТӨРТМӘ I** *минз.* к.: **арқыры 2**. Бик төртмә аларның киленнәре, сүләшә дә белми кеше белән җүнләп.

**ТӨРТМӘ II** *төм.* **1.** к.: **қушма II**; **2.** алтыпочмаклы өй (шестистенный дом).

**ТӨРТМЕШ** *мәл., чпр., срг.* к.: **кирәмәт 2**. Төртмеш дип үз киресен эшләп торган кешегә әйтәләр. – *срг.*

**ТӨРТӨКИ** *трх.* к.: **пысқыш**.

**ТӨРТӨШҮ** *перм.* сөзешү (бодаться). Сыйыр төртөшә. Bozawы төртөшә, сыйыры төртөшмийе микән сун? Ғаптула ыздawат′ иткән теге төртөшә торған сыйырын.

**ТӨРТҮ** *перм.* манчу (макать, обмакнуть). Майларга төртөб ашасағыз. Ашаң, төртеб ашаң, қоролай ашамаға.

**пүрәнә төртү** *тпк.* туйдан соңгы табын вакытында хуҗаның өй бүрәнәләрен тышкы яктан төртеп йөрү йоласы (обряд ходить и тыкать на брёвна дома с наружной стороны во время последнего застолья на свадьбе). Әхсән abdый пүрәнә төртә, өйне йемерә пит пу, ти қайным.

**ТӨРҮ I 1.** *минз.* урау, чорнау (мотать, наматывать, обматывать). Тәкермәчне төргән шиңе диләр; **2.** *минз.* урап алу, урау (обступать, окружать). Төрөб алдылар йәшләр; **3.** *минз.* әйләндереп алу (огородить). Бирлин кирпес белән төрөб алынған; **4.** *минз.* к.: **төрдөрү**. Тақта белә төрөлгән өй булыр, шуны үткәч...; **5.** *тбл.* этәрү (отодвинуть). Үпне циткә төрөп қуйу гәрәк.

**төрөп йапқан** *минз.* дүрт кыеклы, чатыр формасында япкан, шатрун япкан (крытый шатром). Мин cedгә күрсәтәйем әле, төрөп йапқан өйнө күрәсedме, дүрт почмақлап йапқан түбәсе.

**ТӨРҮ II** *перм.* таптыру, бастырып сорау (заставить найти, потребовать). Ничек кердең дип сурыйм моңан, төрәм генә.

**ТӨРҮК** [*рус.*] *тбл.* кинәт, көтмәгәндә (вдруг, неожиданно). Төрүг әрмийәгә китеп қалп ике энем.

**ТӨС I 1.** *мам., каз.ар.-крш.* сурәт, рәсем (рисунок, картинка). Төскә төшкән ийем. – *мам.* Жикмешкә җитеп төскә төшкәнем жүқ. – *каз.ар.-крш*; **2.** *тара.* бит (лицо). Төсөмә қарасам, төсөм тә итсес қалыпты, күсләрем төпкә төшөпте.

**төсең бармы** *кузн., хвл.* к.: **тес: тесең бармы**.

**төс бирмәү** *мам., блт., кмшл.* килешмәү (быть не ко двору). Безгә қызыл сыйыр төс бирми. – *блт.*

**төс төшөрү** *каз.ар.-крш.* к.: **сугу I, 1**. Әллә сез төс төшөрәсезме? Төскә дә төшөрәләр мәллә?

**ТӨС II** *себ.* урман, дала, кыр (лес, степь, равнина, поле). Кицә мин төстә йөреп, пер сыңар аш йуг ийән, исем китте. Цуқ йөрөң төстә, аташырсыс. – *брб.д.* Төстә цийә йәйеп йататқаннар әwәле. – *тбл.*

**төс қас** *тбл.* кыр казы (дикий гусь).

**төс кәчә, төс кәчәсе** *тбл.* тау кәҗәсе, кыр кәҗәсе (серна, косуля). Төс кәчәсе бар, алар бүредән қагылған.

**төс махлух** *саз.я.* к.: **кыйык I**.

**төс мешәх** *саз.я.* селәүсен (рысь).

**төс үртәк** *туб.-ирт.д.* кыр үрдәге (дикая утка).

**ТӨСӘҮ 1.** *к.т., тпк.* төсләү (знахарскими приёмами окуривать от испуга или сглаза). Күз тигән дип ағач гөмбәләре жандырып төсәде. – *к.т.* Имән мәшкәге белә төсәйләр. – *тпк.*; **2.** *к.т.* төзәү (целить). Төсәп ату.

**ТӨСБӘТ** *бәр.* шыксыз, кыяфәтсез (безобразный, неуклюжий); чаг.: **қошбәтсез**. Төсбәтеңне арттырма.

**ТӨСЛӨГӘН** *минз.* агач кабыгы астындагы сыекча, су (сок под древесной корой). Ағачның төслөгәне қата башлаған, жүкәсе қупмый.

**ТӨСНӘҮ I** *глз., дөб.* к.: **төсәү 1**. Артыш агач белән төснийләр бала көйсөзләнсә. – *глз.*

**ТӨСНӘҮ II** *блт.* тондыру, кундыру (ударить, дать тумака). Арқасына бер төснәде.

**ТӨСӨ-ҚОНӨ: төсө-қоно бетү** *мам.* бик ныкқуркып, агарып калу (стать бледным от сильного испуга). Төсө-қоно бетеп, төн уртасында килеп керде, бүре дип.

**ТӨСӨЛӘҮ** *дөб.* к.: **төсәү 1.** Күз тисә, төсөлиләр баланы, менә куптығызның бик кирәк җирен генә алып...

**ТӨС-ТӨГӘЛ** *төм.* сау-сәламәт, исән-имин (здоровый, невредимый). Суғыштан төс-төгәл килептә энем. Уғысыннар исән-сау, төс-төгәл генә. Исән-сау төс-төгәл йоқлаң.

**ТӨТӘКЛӘҮ** *каз.ар.-крш.* к.: **тәтәләү.**

**ТӨТӘТҮ** *трх.* к.: **төткәзү.** Шулай төтәтеп барсаң җарый инде.

**төтен** (дым):

**төтен булу** *лмб.* миңгерәүләнү (отупеть, становиться тупым, бестолковым). Аңғы-миңгеләндек, төтен булдық, киләбез.

**төтен салу** *бәр.* үсемлекләрне кыраудан саклау өчен ут ягу (разводить огонь для того, чтобы уберечь растения от заморозков).

**ТӨТЕННЕК** *минз.* умарта караганда кулланыла торган төтен җибәргеч, төтәткеч (дымарь).

**ТӨТКӘЗҮ** *мам., чпр.* җиткерү, төткәрү (напастись). Булса да, китап төткәзә алмыйлар. – *чпр.* Аққаны төткәзеп булмый, ту зайом, ту налук суғыштан суң. – *мам.*

**ТӨТӨН** *тпк.* тополь мамыгы (пух тополя). Тирәк төтен осора.

**ТӨТӨННӘҮ** *минз.* серкә очыру – киндер турында (опыление). Төтөнни башлағанда җыйыб алабыз басаны.

**ТӨТСЕНҮ** *кргл.* сизү, тою (чувствовать, ощущать). Укыл қадады врач, төтсенми дә бызawым, шулхәдәрле awыртywы көчле.

**ТӨТТӨРҮ** *хвл.* к.: **төткәзү.** Монда барына да акча төттөреп булмас.

**ТӨТҮ** *кузн.* к.: **тетү 2.** Аны төттеләр шул.

**ТӨҮРӘҮ** *брб.д.* к.: **төйрәү.** Кейгән кийememгә төүрәп қойамын.

**ТӨХТӘ** [*фарс.*] *трх.* пөхтә, җыйнак (аккуратный, собранный). Җиз самawыр төхтә кешедә бардыр инде.

**ТӨЧӨГӘН 1.** *бәр.* төчлегән (заболонь, неотвердевшие слои древесины под корой). Нарат төчөгәнен бездә ашыйлар да; **2.** *дөб., минз.* к.: **төсләгән.** Җүкәгә җафрақ җара башлаганда төчөгән инә, питраудан сун ул қатықланып ағачқа әйләнә. – *дөб.*

**төчөгән атнасы** *бәр.* июньнең унбиш-егерме бишләрендә үткәрелә торган җыен атамасы (название сельского праздника, проводимого в пятнадцатых-двадцать пятых числах июня).

**ТӨЧӨҚАТ** *минз.* **1.** төче күмәч (булочка из пресного теста); **2.** уган бәрәңгегә яки чөгендергә он кушып пешерелгән ашамлык (кушанье, приготовленное из протёртой свёклы или картофеля и муки).

**ТӨЧҮЛӘН** *каз.ар.* канлы үлән; гади сөял үләне (чистотел; бородавник).

**ТӨШ I** *кас.* теш (зуб).

**ТӨШ II 1.** *дөб., мам., т.кам.-крш., минз., к.т., чст.* к.: **чепчәги.** Күзикмәкләр, төшләр пешерәләр. – *минз.* Төш тә пешердек, күкәйгә писүк, суды, уксус, тос салып туғыйсын. Шуны он белән йомшақ қына басам, тоқмач қамыры шикелле җәйәм, бер ун минут тотам қуна өстендә, ул қабарып китә, аннары тоқмач кебек кисәм, йә тәгәрәтеп кисәм, майда пешерәм. Оло табаққа төшне салам да бал салам, қалақ белән болғатам, табаққа өйөп қуйам. Кем туйға қатнаша, бар да бер чумадан алыб бара пешереп, булкилар, пирушкилар, төшләр. – *т.кам.-крш.*; **2.** *каз.ар.-крш.* к.: **қатый.** Төш пешергәндә қамырны төчөгә күкәйгә генә басабыз, җуқа ғына итеп җәйәбез, тар ғына итеп кисәбез паласа итеп, аны тағын кисәбез, арқылы да майда пешерәбез; **3.** *лш.* бавырсак (баурсак). Төш пешердем, ирерәк булды.

**баллы төш** *лш.* к.: **чепчәги.** Бер тәникәгә баллы төш төйөнчеккә төйнәп җегеткә аппара.

**қодағый төшө** *бәр.* қыз анасы туйга алып килгән чәкчәк (чакчак, приносимый матерью невесты на свадьбу). Қодағый төшөн қодагый алып бара туйға.

**төш баллау** *мам.* киндер орлыгын кибәгеннән арчып бал белән болгату (смешать с мёдом конопляное семя, очищенное от шелухи). Киндер орлыгының төшөн баллый торған ыйық. Киндер орлогын таштан чығарып төшөн генә алалар да, кибәген очортоп, шуны матур итеп қатыралар ийе бал белән.

**төш кисү** *бәр.* туй мәҗлесеннән бер-ике көн алдан чәкчәк кисү йоласы уздыру (один из свадебных обрядов). Туй йасар алдыннан бер-ике көн алдан төш кисәләр. Төш кисәргә қайынсеңелләрен чақыралар.

**төш өсте** *т.кам.-крш.* җәелгән камыр өстенә сыек камыр җәеп пешерелгән ашамлык (лепёшка из двух слоёв теста).

**төш өстө 1.** *лш., минз.* юка гына итеп җәелгән камырны майлап, өстенә киндер орлыгы сибеп, аны катлы-катлы итеп шакмаклап төргәч, кискәләп мичтә пешерелә торган азык (слойка с начинкой из конопляных семян). Төш өстөнең көлчәсе ачы қамырдан була аның, шуңа тарма йағып пешерәсең дә ақ май белән ашыйсың. – *минз.*; **2.** *лш.* өстенә бәрәңге яки эремчек ягып ачы камырдан пешерелгән пәрәмәч, шәнгә (шаньга); чаг.: **дурочмақ.** Төш өстөн ипи салганда да пешерәсең, мин башта қамырын аерым пешереб алам, сразы пешерсәм, қамыры чи калған кебек.

**чикләwек төше** *лш.* к.: **чепчәги.** Қамырны сөткә йомырқа салып басалар да wақ-wақ итеп кисеп майға салып пешерәләр – шул чикләwек төше була.

**төш III** (полдень):

**төш бырылгач** *чст.* өйләдән соң, төштән соң (после обеда). Төш бырылгач кат′тылар.

**төш көне, төш туры** *минз.* төш вакыты (полдень, время обеда). Төш көне қайтқан ийе. Төш турына бәрәңге пешерәбез.

**төштән кич** *перм.* к.: **төш бырылгач.** Бер күлем төштән кич кенә чықтым печин җиймаға.

**ТӨШӘНИ** *кас.* к.: **ана I: теш анасы.**

**ТӨШӘНЦЕК 1.** *тара.* киез (войлок); **2.** *тбл.* ияр киезе (потник); **3.** *тбл.* кечкенә матрас (маленький матрас).

**ТӨШӘНЧЕК** *брб.д.* к.: **төшәнцек 1.**

**ТӨШӘТИ** *кас.* яшь балага теш чыга башлаганны беренче булып күргән ир кешегә бала тарафыннан әйтелә (форма обращения ребёнка к муж-

чине, который первым увидел прорезавшийся у него зуб).

**ТӨШӘҮ** *себ.* төш күрү (видеть сон). Ол көннө абзийны көрөп төшәдем. – *брб.д.* Көн тә төшөмтә төшәйем қуй мин аны. – *төм.*

**ТӨШЕЛДЕРИК** *перм.* күкрәкчә (лифчик; нагрудник женский).

**ТӨШКӨ** *төм.* төшке аш (обед). Төшкөгә қайтайың!

**ТӨШЛӘНҮ** *брб.д., төм.* төшке ашны ашау (обедать). Сес төшлəнтегесмә? – *брб.д.* Төшлəнкəле килсəм, өйтə йуқ. – *төм.*

**ТӨШӨНДӘ** *перм.* эчендә, арасында (в течение, за). Сәфчим қыстылар ий әле аны бер-ике йыл төшөндә.

**ТӨШТӘТӘ'** *кас.* яшь балага теш чыга башлаганны беренче булып күргән кыз кешегә бала тарафыннан әйтелә (форма обращения к девушке, которая первой увидела прорезавший у него зуб).

**ТӨШТӨК** *клм.* к.: **төшелдерик**.

**ТӨШҮ I 1.** *срг.* коелу (выпадать, вылезать – о волосах). Цəцем төшə нəктер; **2.** *нрл.* бару (ехать, идти). Қазанға төшеп китте. Қарт әйтә, төшкәләп мен, ди, Қазанға, мин һаман wақыт җитми төшәргә. Қазанға төшəм малай қатына, бәрәңге аптөшəм; **3.** *чст.* тукталу (остановиться). Мин Миннеғали бабайларга төштем; **4.** *тбл.* туры килү (соответствовать). Пəзе сүсляр килеп төшəте сеснеңкенə.

**җәйгә төшү** *перм.* җәйгә чыгу (наступление лета). Җәйгә төшкәч, утын кисәргә бардық. Җәйгә төшсəң, қайда қарама, тузан инде. Җәйгә төшсəм, қумалақ җийам, аны сатам көзгедə.

**йазға төшү** *перм.* язга чыгу (наступление весны). Йазға төшкәч, үзебез утырттық кәртүк.

**қолаққа төшү** *перм.* колакка чалыну, ишетелү (послышать, быть услышанным краем уха). Миңке қолагыма төшкəне йуқ, буча белмим.

**қuwартирға төшү** *злт.* фатирга керү (снимать квартиру). Фағыйләттәй, төшөрəңме кuwартирға, ике қыз килгəн.

**күл төшү** *эчк.* су керү (купаться). Туған илем күлендə күл дə төшəлмəдем инде.

**мәктəпкə төшү** *злт.* мəктəпкə укырга керү (поступить учиться в школу). Киләсе йылға төшəме мəктəпкə?

**мунча төшү** *мəл., тара., төм., твр.* мунча керү (мыться в бане). Алар мунча төшəләр. – *мəл.* Эсү мунча төшү кирəк. – *твр.* Мунча төшеп килделəр. – *тара.* Иртə белəн төшеп цыгу кирəк мунцаны. – *төм.*

**су төшү** *минз., стрл.*, **сыw төшү** *злт.*, **сыwға төшү** *перм.* к.: **күл төшү**. Сыw төшəргə была. Қайтыр сақта ғына сыw төштə. Кəкүк қычқырғач, суға төшəләр, бер умбиш көннəн тотлоға. – *минз.*

**тансыға төшү** *злт.* бии башлау (включиться в танцы).

**түрдəн төшү** *минз.* элек: əгəр егет ягыннан кода кеше аклашкан чагында билгеләнгəн тартуны һəм калымны никахка килгəндə тулысы белəн китермəсə яки җиренə җиткереп алып килмəсə, қыз ягыннан булған кода бирнə биргəн вакытта «Сиңа, қода, түрдəн төшəргə туры килер, синең шушы əйберең җитми» дип əйтү йоласы (один из свадебных обрядов).

**уқырға төшү** *минз.*, **укырга төшү** *стрл.* к.: **мəктəпкə төшү**. Йəреңгə укырга төшə инде. – *стрл.*

**ТӨШҮ II** *тпк.* басу (ограбить). Кемнең амбарына төшкəн мин?

**ТӨШҮ III** *лш.* кору (занавешивать). Мунчаға да фəрдə төшкəн, сарайға да фəрдə төшкəн хəзер.

**ТӨШҮ IV** *перм.* отыш чыгу (выпасть – о выигрыше). Төшми озур əрбирләр, берəр тəнкə төшкəләдийе, хəзер алғаным җуқ латарей. Бер тəңкə ақча төштийе латарейға.

**ТПРУWALИ** *нрл.* сыерчык чакыру ымлыгы (возглас, которым скликают скворцов).

**ТПРУWAX-ТПРУWAX** *тара.* атны чакыру ымлыгы (возглас, которым скликают лошадей).

**ТПРУГА-ТПРУГА** *трх.* к.: **пкон'-пкон'**.

**ТРАНТАЧ** [*рус.*] *мам.* к.: **крандас**. Кəчим айғыры бит, трантачы да безнеке бит, диләр.

**ТРАПА** [*рус.* тропа]: **кəжə трапасы йебəрү** *хвл.* чəчне бармак белəн каты итеп басып ышку, «кəжə мае чыгару» (тереть волосы, крепко нажимая пальцами).

**ТРАПКАЛУШ** [*рус.*] *дөб.* балтырлы галош (глубокие резиновые галоши). Трапкалушымны җuwып қуйдым.

**ТРАТАЙКА** *чпр.* ике тəгəрмəчле кул арбасы (двухколёсная ручная тележка); чаг.: **ухалла**, **йəпләшкə**. Кышлыгын сəләскə, җəйлеген тратайка тартып Ул'анга (*шəһ. ис.*) бара; ике куласалы арба ул, кул арбасы.

**ТР'А-ТР'А** *хвл., чпр.* к.: **сай-сай**.

**ТРАХМАЛ** [*рус.* крахмал] *т.кам.-крш.* к.: **өшемкə**. Трахмал җийабыз, черегән бəрəңге, шуны таптап күмəч пешерəбез.

**ТРӘЧӘЙ** *кас.* к.: **тумачи 1**.

**ТРЖӘ-ТРЖӘ** *төм.* к.: **вəс-вəс**.

**ТРОШ** [*рус.*] *төм.*, **ТРОШШАЙ** [*рус.*] *саз.я.* к.: **друж**. Трошлы көлчə. – *төм.* Пер килалых трошшайлар килхəн мəгəсингə. – *саз.я.*

**ТРУЙСЫ** [*рус.* Троица] *т.я.-крш.* Троица бəйрəме (Троица). Труйсы җиткинчи үлəм җылкырга да, агач сындырырга да җарамый.

**ТУ 1.** *минз., злт., стрл.* токымсыз, нəселсез (бесплодный, неспособный иметь потомство). Бəй, бер дə бəрəннəмəсə, ту сарық була инде, қаз бер дə күкəй салмаса, ту була. Ту сарық. – *минз.* Ту бийə. – *злт*; **2.** *минз., тпк., стрл.* чəчелмəгəн җирдə үсеп чыккан ашлык, яшелчə (злаки, овощи, выросшие на незасеянном поле или на залежной земле). Фəлəн җирдə ту тары үсə икəн чəчмичə, дип сүлиләр. Ту ғомбағыш. Ту киндераш. Ту тары. Ту бəрəңге күп сыққан, былтыр алып бетми қалғамбыd. Ту суғаны күп. Ыраз тороп қалған былтырғы, ту була инте ул. – *тпк.*

**ту бийə** *минз., стрл.* эш аты (рабочая лошадь). Калхузның ту бийəсе булдым, чалғы қулдан төшмəде. – *минз.* Ту бийə күк җери диләр эшләмичə җөргəн кешегə, җə симез, көр кешегə. – *стрл.*

**ту қаз** *минз.*, **ту қad** *тпк.* **1.** к.: **ту 1**. Күкəй дə салмады, бала да чығармады, ту қаз булды. –

*минз.*; **2.** к.: **дуwадақ 1.** Дүртәү җөриләр әле ту қаd урамда. – *тпк.*

**ТУБ: туб инү** *тбл.* тәүбәгә килү (раскаяться, прийти к раскаянию).

**ТУБА I: ала туба** *минз.* кыр күгәрчене (вяхирь).

**ТУБА II: туба ғылу** *тбл.*, **туба туу** *стрл.* тәүбә итү (покаяться, раскаяться). Мин песәй балалары ыргытып туба тудым, йөзөп йөрделәр, нирмыма тиде. – *стрл.*

**ТУБАЛ 1.** *срг.* кыз яки егет ягыннан табакка куеп туйга китерелә торган төрле камыр ашлары (мучные блюда, приносимые на свадьбу со стороны жениха или невесты). Икенче көнне туй, тубал була: йәшшиккә куйалар ике йомшак, бодай йомшагы, ике катлама, ике бөкмә, бәлеш. Никах көннә дә бер тубал, туй көнне кыз тубалы. Кыз үwенә тубал киләдер, акца китерә, шәкәр; **2.** *тбл.* түгәрәк футляр (круглый футляр).

**қаз тубал** *нокр., перм.* каз оясы (глубокая круглая корзина из ивовых прутьев, где гусыня высиживает яйца). Қаз тубал мында утырды пычмақта. – *нокр.* Қаз тубалны ышықлап қуй, қызым, сике қазнасына палас әл, қаз кешене җаратмый. – *перм.*

**каз тубал** *чпр., хвл.* түгәрәк, тирән кәрзин (круглая корзинка).

**төпсез тубал** *перм.* төпченүчән кеше (человек, который любит тщательно разбираться во всём). Әйсә сез шундый төпсез тубаллар икә инде. Төпсез тубал сезнең кебек төпләнеб утырған нимәләр.

**тубал бәйләү** *перм.* кунакка чакырышу (делать друг другу визиты, ходить в гости). Тубал бәйләдег әле, қунаққа бардық кичә. Менә без Рифкә қунаққа бардық, хәзер инде аларны чақырмаға кәрәк, шул тубал бәйләү була.

**ТУБАЛАҚ I** *трх.* к.: **кәләмпер.** Анан тубалақ буладыр ийе awызны тәмнәргә. Тубалақ буладырыйы тубалчыларда.

**ТУБАЛАҚ II** *туб.-ирт.д.* туйдан соң туйда ярдәм итүчеләр һәм туйга чакырылмаган авылдашлар өчен уздырылган мәҗлес (вечеринка после свадьбы для тех, кто работал на свадьбе, а также для односельчан, которые остались неприглашёнными на свадьбу).

**ТУБАЛАУ** *чпр.* шикләнү (бояться, страшиться). Мин аның белән җилгә цыгарга тубалыйм.

**ТУБАЛБАШ** *лмб.* к.: **баллықай.**

**ТУБАЛЧЫ** *карс.* к.: **wақ: wақ сатучы.** Тубалчылар сата иде китапларны, әнә, түмә, җеп. Элеке китаплар да сатып җөриләр ийе тубалчылар.

**ТУБАН** *тбл., төм., тара.* кибәк (мякина).

**ТУБЫҚ** *бөре., минз., злт., перм., крғл., трбс., к.уф., тара., тбл., төм.*, **ТУБЫ'** *кас.*, **ТУБЫК** *стрл.* тез (колено). Менә шулай қайрылып чыққан тубықтан. – *перм.* Тубығымны бәрдем қый. – *әчк.* Тубыгым сызлый минеке. Бозға йығылып тубығымны awырттырдым. – *к.-уф.* Пысрақ тубық тиңентен. Тубық awырта, тубық белән тайанған ыйым пипи ашатқанда. Йетенне тубыққа қуйып туқмап тәпәрлиләр. – *злт.* Әдәмнең тубығыннан була иде үлән. – *крғл.*

**нәзек тубық** *лш.*, **тубык төбе** *лмб.* к.: **бәкәл 1.** Чабата киндерәсе нәзек тубықтан гына була ул. – *лш.*

**тубық цәнцү** *тбл.* к.: **тезәнү.** Тубықны цәнцеп торып цәй эцәтләр.

**тубық чәнчеп** *перм.* тез чәнчеп (прижав колено к себе). Тубыгын чәнчеп кенә утырған, ди, су аста.

**шайтан тубығы** *каз.ар.-крш., минз.*, **шайтан тубыгы** *стрл.*, **шайтан тубық** *крғл.* к.: **ашық II, 2.** Шайтан тубыгыннан сыдырды. – *каз.ар.-крш.* Шайтан тубыгыннан awырта. – *стрл.*

**ТУБЫҚАЙ** *твр.* к.: **бәйсәкә.** Синең бицәң шигелле тубықай түгелмен.

**ТУБЫҚБАШ** *перм.* к.: **тез: тез күзе.**

**ТУБЫҚЛАНУ** *минз., злт., перм., к.-уф.*, **ТУБЫКЛАНУ** *стрл.*, **ТУБЫҚЛАУ** *тбл.* к.: **тезәнү.** Ийелеп тубықланырга хәлемнән килми. – *злт.* Тубықланып утыра сикедә. – *минз.*

**ТУБЫҚПАШ** *тбл.* тез башы, тез капкачы (коленная чашечка).

**ТУБЫЛ** [*рус.*] *перм.*, **ТУБЫЛҒАН** *нгб.-крш.* тирәк, тополь (тополь). Тубыл ағачлар бар. – *перм.*

**ТУБЫЛГЫ: тубылгы агачы** *стрл.* тәртәгә яраклы төз агач (стройная древесина, годная для оғлоблей). Бер бай кайтартадыр ийе тубылгы агачлары дип, тәртәгә йараклы, нәрсәкәй агачыдыр шунда.

**ТУБЫРЛАУ: айақ тубырлау** *трбс.* аякның йөри алмас хәлгә килүе (лишиться способности ходить). Айағы тубырлап беткән бер урында утырып, йәш йарымнық бала.

**ТУБЫРСЫҚ** *төм.*, **ТУБЫРЦЫҚ, ТУБЫРЦЫН** *тбл.* нарат, чыршы күркәсе (шишка сосны, ели). Тубырцық тергетә тә булаты, пайланта (ак чыршы) та, урманта (чыршыда). – *тбл.*

**ТУБЫРЧЫҚ 1.** *тя.* тыгыз, тулы тәнле, хәрәкәтчел яшь балага карата әйтелә (говорится о здоровом, полном, подвижном ребёнке); чаг.: **балбан; 2.** *твр.* к.: **ашық II, 2.**

**ТУWА** *брб.д., тара.* к.: **дива I.** Туwа йастырып қуйғайным қураға. – *тара.* Палазы көп кешегә туwа қылтыраты. – *брб.д.*

**ТУWАЛЫҚ I** *тбл.* саз түмгәге (болотная кочка).

**ТУWАЛЫҚ II** *твр., брб.д., тара.* догалык (молитвенник). Туwалықлар сала йастығ астына. – *твр.*

**ТУWАН** *себ.* к.: **бума I.** Туwан пуwатлар. – *брб.д.* Йылғаны туwатылар. – *төм.* Қышқы йағын туwан қылып, Вағайны туwып ийәделәр. – *тбл.*

**ТУWАНА** *том.д.* к.: **қамыраш 2.**

**ТУWАР** *каз.ар., бәр., тбл., төм., кузн., срг., глз., лмб.* терлек, мал-туар (скот, скотина). Иген иктек, туwар асырадық. – *дөб.* Әле ире булыша туwарларын қарарга да. Урмаллы җирдә туwар асрамаға бик йақшы. – *бәр.* Кеше туwары цен цәцмәгән бит картуш. – *срг.* Алаша багабыз, туwарлар багабыз элек. – *кузн.* Туwар бик күп, туwарны бытырма кыл'амим. – *глз.* Туwарларны кас'ын сүмәгәннәрне калудага да сала, сыйыр туwарны да тен ката кывып йери, пакуй бирми йырт анасы. – *лмб.* Калхузныңқы туwарларын қарап... Туwар күп қуй. – *төм.*

**кара тywар** *кузн.* кәҗә-сарык (овцы-козы).

**ТЎWАРА** *перм.* бәрәңге алмасы (картофельное яблоко).

**ТЎWАР-ҚАРА** *каз.ар.* мал-туар (скот). Тywар-қара күп булгач, өйне ташлап китеп булмый. Чат тywар-қара асырап җаталар. – *дөб.*

**ТЎWАРЛЫҚ** *төм.* малчылык эше (животноводство). Пинсийәгә чыктым тywарлыктан.

**ТЎWАР-МАЛ** *глз.* к.: **тywар**. Тywар-мал белән бергә безне картычкага снимайт итәсе.

**ТЎWАРУҚ** [*рус.* творог] *шрл.* корт (курт, красный творог).

**ТУҒАДАҚ** *эчк.*, **ТУГАДАК** *стрл.* к.: **дywадак 1.**

**ТУҒАЙ** *каз.ар.-крш.* тирән (глубокий). Туғай җирендә төшөб үлгән кешеләр була. Сыw туғайы.

**ТУҒАЙЛАП: туғайлап җасаған** *дөб.* ярым түгәрәк итеп ясалган (сделанный полукругом). Қатын-қызға зиратқа аппарганда туғайлап җасаған чаршау қоралар.

**ТУГАЙУ** *карс., мәл., чст., хвл.* тую, туйганчы ашау, ашап тую, туклану (наесться, насытиться). Ашагыз, туғайыгыз. – *карс.*

**ТУҒАЛАҚ** *клм., яүшт.* к.: **җомор**.

**ТУГАН** *срг., лмб., кузн.* үзеннән кече ир туганы (младший брат). Әнинең Насруг исемне дә туганы бар иде. – *срг.* Тукыз кыз тапкан, ике ол тапкан, ике туганым булган. – *лмб.*

**туған апа, туған апақ** *дөб.* иренең абыйсының хатынына эндәшү формасы (форма обращения к жене старшего брата).

**туған бала** *баст.* яшь бала (младенец).

**туган балалары** *шрл.* к.: **тудыка(й) 1.**

**туған кечкә** *твр.* к.: **туған**.

**туган тутасы** *чст.* җиңги, абыйсының хатыны (невестка, жена старшего брата). Туган туталары йегерме биш киламитер тыра, шунда да барганнары йук. – *чст.*

**туғаннан тywышқан** *мам., крш.* к.: **тудыка(й) 1.** Нәгимә ул минем ыру, туғаннан тywышқан хатны. Аның анасы белән мин туғаннан тywышқан. – *мам.* Марҗи белән без туғаннан тywышқан: әтиләребез бертуған. Туғаннан тywышқан без аның белә. – *каз.ар.-крш.* Матрунә ул минем туғаннан тywышқан абыстай. Пawел белән Марҗа туғаннан тywышқан, аларның икесенен дә әтиләре бертуған. Безнең бөтөн awыл берберсенә туған, менә бу да туғаннан тywышқан. – *т.кам.-крш.*

**ТУҒАНАЙ 1.** *нгб.-крш.* бертуган (единоутробный). Болар бер туғанайлар дисеннәр; **2.** *нгб.-крш.* бертуганына эндәшү формасы (форма обращения к родному брату или сестре). Туғанай, энекәйең бит мин синең. Бөгөнгө көндә туғанайың түгел мин синең; **3.** *минз., кмшл.* туганкай, дускай (форма вежливого обращения к постороннему человеку). Әле бит кешегә кереп утыра тырған wахыт түгел, туғанай. – *кмшл.* Әйдә, туганай, өйгә керик, чәй эчәрбез. – *минз.*

**ТУҒАНИ** *трх.* к.: **абызастай.**

**ТУҒАН-ИГӘЧ** *каз.ар.-крш.* к.: **нәсел-асаб**. Туған-игәчләре йөртә инде қызларны ашқа.

**ТУҒАН-ҚАРЫНТАШ** *тбл.* к.: **нәсел-асаб.** Туған-қарынташларыма теләк теләйем.

**ТУҒАНКӨН** *перм.* к.: **башкен.**

**ТУҒАН-ТОХОМ** *әстр.*, **ТУҒАН-ТУWАЧА** *мам.*, **ТУҒАН-ТУМЫШ** *трбс.* к.: **нәсел-асаб**. Туғантохомын җыйа, аш-су әзерли башлый. – *әстр.* Туған-тywача булмағач, бармыйсың инде. – *мам.*

**ТУҒАНЫЙ** *к.т.* килен белән каенсеңлесе яшьтәш булганда бер-берсенә эндәшү сүзе (форма взаимного обращения невестки с золовкой, являющихся ровесницами).

**туғаный абый** *нрл.* әтинең энесе (младший брат отца).

**туғаный апа** *к.т., трх.* к.: **аппақ; туған аппақ**. Туғаный апаң қайтмый. – *трх.*

**ТУҒАНЫМ 1.** *нокр.* әти яки әнисенең апасына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре отца или матери); **2.** *кузн., хвл.* үзеннән яшьрәкләргә иркәләп эндәшү сүзе (ласковое обращение к лицам младше себя); **3.** *чст.-крш.* к.: **абыстумачи**; **4.** *стрл.* I, II, III зат кушымчалары белән: эне яки сеңел һәм аларга эндәшү сүзе (младшие брат или сестра и форма обращения к ним).

**туғаным абыстай** *нокр.* килен иренең апаларыннан иң кечкенәсенә шулай эндәшә (форма обращения невестки к самой младшей из старших сестёр мужа).

**туғаным апа** *дөб.* бертуган апа (родная старшая сестра).

**туғаным астай, чибәр астай** *чст.* к.: **балдыз 2.**

**ТУҒАҢКӨН** *перм.* к.: **башкен.**

**ТУҒАР** *нокр.* к.: **тywар**. Әй бик йуқ туғарны асрағанчы... (үрдәк турында).

**ТУҒАРЛАНУ** *том.д.* тәгәрәү (катиться).

**ТУҒАРУҚ** [*рус.* творог] *каз.ар.-крш., дөб.*, **ТУГАРУК** *блт., дөб.* эремчек (творог). Ашасағыз, туғаруқ бирәм. Чәчне тугаруқ сywы белән җywабыз. Әнәй, миңа туғаруқ тық бүген ашарга. Туғаруқ җасыйм ачышқан сөттән. – *каз.ар.-крш.* Болгатыгыз туғаруқны салып. – *дөб.* Тугарук сywы эчә безнең қыз ашқазанынннан. Кипкән тугарук ашатыр ыйым қайтқан балаларга. – *блт.*

**ТУҒАЦ 1.** *себ.* кабартма, төче күмәч (булочка, пышка). Туғац тип қуйабыс булычканы. Туғацлар пешерәтләр. – *тара.*; **2.** *тбл.* сушка, клиндер (сушка, баранка); **3.** *сазл.* уртасына тишек ясалган күмәч (булка с дырочкой в середине). Тугацны қахқа (төчегә) wасылган оннан пешерсәң, тың тәмле wулат.

**ТУҒАЧ 1.** *брб.д., тара., твр., клм.* к.: **туғац 1.** Бәйрәмдә пешеренәбез тугач, самза, бawырсақ, пирашкилар. – *клм.*; **2.** *әстр.* к.: **туғац 2.** Туғач белән чәй эчмәгә чақырдылар.

**ләчипкәле туғач** *клм.* эчле кабартма, сумса (булочка с начинкой, пирожок). Ләчинкәле туғач быжырабыс. Ләчинкәле туғач йарадам.

**ТУҒАШ** *әстр.* к.: **туғац 2.**

**ТУҒЛАНУ** *каз.ар.-крш.* әйләнү, тулгану (крутиться, вертеться). Тизрәк қайт инде, тугланма. Туғланалар әле бер урында.

**ТУҒОЛОҚ** *клм.* к.: **җомор**.

**ТУГУ 1.** *миш.д.* туку (ткать). Сөлге тугу. Чигү чигә, йөслек тугый, тасмал чигәләр. Башыңа төшкәч, башмак тугырсың. – *хвл.*; **2.** *тмн., срг.*

қату, бөтерү – җеп турында (сучить – о нитках). Йеп тугам әле. – *срг.*

**ТУҒУ I 1.** *баст.* бәйләү (вязать). Җөннән наски туғыйлар инәләр белән. Пухawуй вәлләр туғыйлар иде; **2.** *баст.* үрү (плести). Тал'никтан кашулкалар да туғыйлар. Чабат кигәннәр җүкәдән туғыганны.

**ТУҒУ II** *кргл.* май язу (паҳтать масло). Қаймақ туғықай машинам да бар.

**ТУГУН** *м.-кар.* тугым (ободок колеса).

**туғыз I** *урт.д.* тугыз (девять):

**туғыз буwын 1.** *т.кам.-крш.* кырлач (горец узловатый); **2.** *чст., байк.* к.: **ут II: тал уты.**

**ТУҒЫЗ II** *әстр.* егет ягыннан кызга бирелә торган әйберләр, кием-салым (одежда и вещи, предназначенные для невесты со стороны жениха).

**туғыз табақ** *әстр.* к.: **туғыз II.** Туғыз табақ килә кийәү биттән қыз битхә.

**ТУГ(Ы)ЗАН** *кузн., хвл.* туксан (девяносто). Тугызан тугызынчы йылны тувыпмын. – *кузн.*

**ТУҒЫЛЫҚ** *клм.* к.: **җомор.**

**ТУҒЫМ** *минз.* к.: **ашық II, 2.**

**ТУҒЫРТМА** *туб.-ирт.д.* к.: **тумырқа.**

**ТУҒЫШ** *тбл., саз.я.* бер яшьлек поши баласы (ғодовалый лосёнок).

**ТУДИ, ТУДЫЙ 1.** *кузн.* ике яшьтәш яки адаш килендәшләрнең бер-берсенә эндәшү сүзе (форма взаимного обращения сношенниц, являющихся ровесницами или тёзками); **2.** *стрл.* к.: **тудыка(й) 1; 3.** *срг.* к.: **дусай I.**

**ТУДЫҚ 1.** *дөб.* к.: **туди 1; 2.** *трх.* к.: **дусай I.** Җақын дуслар әйтәләр ийе тудық дип; **3.** *трх.* килендәшләрнең бер-берсенә эндәшү сүзе (форма обращения сношенниц друг к другу). Килендәшләр қушылып әйтәләр ийе тудық дип.

**абыз тудық** *лш.* олы кыз туганына якын итеп, зурлап эндәшә торган сүз (уважительная форма обращения к родственнице старше себя).

**бал тудық** *дөб.* к.: **тудық 3.**

**тудығ астай** *дөб.* эти яки әнисенең абыйларының хатынына эндәшү сүзе (жена старшего брата отца или матери и форма обращения к ней).

**тудық җиңи** *дөб.* к.: **тудық 3.**

**ТУДЫК 1.** *тмн.* к.: **тудыка(й) 1; 2.** *чпр.* к.: **дусай I; 3.** *чст.* к.: **туганый.**

**тудык апа 1.** *хвл.* к.: **тудыка(й) 1; 2.** *чст.* каенсеңлесе җиңгәсеннән олырак булган очракта җиңгәсенә мөрәҗәгать итү сүзе (форма обращения золовки к жене старшего брата, если последняя старше её).

**ТУДЫКА** *тмн., стрл.* к.: **тудыка(й) 1.** Wот симйасы ман килгән кийәүнең тудыкасы. – *тмн.* Бер инәдән ике туган була бит, аларның балалары тудыка бит. Туганнан туган малай булса да, кыз булса да тудыка була. – *стрл.*

**ТУДЫ'А** *кас.* к.: **тудыка(й) 1.**

**ТУДЫҚАЙ** *эчк.* **1.** к.: **тудыка(й) 1; 2.** к.: **дусай I.**

**тудықай туған** *эчк.* к.: **тудыка(й) 1.** Йаңа awылда тудықай туғаннарыбыз бар.

**ТУДЫКА(Й) 1.** *тмн., кузн., хвл., чст., мәл., срг.* туганнан туган (двоюродный). Тудыкайы палкалар селди. – *тмн.* Ике бертума ыланнары тудыкайлар булалар. Тудыкайларым бар. Вата байа килде бер абзыйым, бер тудыкайым Сызранда. – *хвл.* Беген тудыкайларга барырым кунарга, Фәһимәгә ибдәш бар. – *мәл.* Тудыкам йанга барам. – *чст.* Аның кан'атасы белән минем ирем ике тудыкай – ике бырат ыланнары. Гөлҗиан минен тудыкайым. – *кузн.*; **2.** *чст.* к.: **туди.** Тудыкайым, цәй куй инде, wакытым йук; **3.** *карс., шрл.* туганнан туганнарның бер-берсенә эндәшү формасы (форма обращения двоюродных братьев и сестёр друг к другу). Ике туган баласы тудыкай ат'ышалар бер-берсенә. – *шрл.*; **4.** *карс.* к.: **тудық 3.** Ике бырат хатыны тудыкай атешәләр; **5.** *срг.* к.: **дусай I; 6.** *тмн., карс.* үзеннән олы кыз туганы һәм аңа эндәшү сүзе (сестра старше себя и форма обращения к ней). Кызның үз тудыкайы үрә инде цәцен туйда. – *тмн.*; **7.** *мәл.* иренең апасына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре мужа); **8.** *карс.* эти яки әнисенең сеңлесенә эндәшү сүзе (форма обращения к младшей сестре отца или матери). Ул бырыннарда ателгән тудыкай, атасының сеңлесенәме, анасының сеңлесенәме; **9.** *карс.* каенанасының хатын-кыз кардәшенә эндәшү сүзе (форма обращения к родственницам свекрови). Wат йырагырак ыру или кан'нын кардәше, тудыкай ат'алар иде.

**ТУДЫК-ТУДЫКА** *тмн.* к.: **нәсел-асаб.** Тудык-тудыкаларым бар. Ирләрдән дә бар тудык-тудыка.

**ТУЖ** *нокр.* кырлыган (лабазник, таволга вязолистая). Туж – чәчәкле, сазлыкларда үсә.

**ТУЗ I** *т.я.* саңгырау гөмбә (дождевик). Туздырма тузны, қолағың чуқрақланыр. – *нрл.*

**туз ғөмбә** *к.т.* к.: **туз I.**

**туз II** (берёста, кора):

**туз май** *твр.* сумала (смола, вар). Туз май белән дә қарайталар чарыкны.

**тузан** (пыль):

**тузан иләтү** *срг.* тузан кундыру, тузан өрү (запылить; надуть пыль). Тышкы йактан ницек тузан иләткән, цыгып себерергә кирәк (тәрәзәне).

**ТУЗБАШ** *нрл.* к.: **тузғақбаш.**

**ТУЗҒАҚ** *минз.* тузгыган, җыештырмаган (разбросанный, неубранный). Бөтен нәрсәләре дә тузғақ.

**ТУЗҒАҚБАШ** *мам.*, **ТУЗҒАНА** *т.кам.-крш.* тузганак (одуванчик).

**ТУЗГЫКЛАТУ** *глз.* туздыру, тирғәү (устроить разнос, отругать). Тузгыклатасыйы азырак, эшләсеннәр азырак.

**ТУЗҒЫЛДАУ** *дөб.* таралу, тузгу (разбросаться, растопыриться). Себерке җақшы булған тағы, тузгылдап тора.

**ТУЗДЫРАТУ** *перм.* **1.** тузгыту, тарату (рассеивать, распускать). Йастыкны туздыратты; **2.** куып тарату (разгонять). Бақчаға кергән малайларны тузанын да қалдырмый туздыратты.

**ТУЗДЫРУ 1.** *чст.* тарату, таратып бетерү (распространить, раскидать); чаг.: **тетү 1.** Мин аларны шулай туздырып бетердем инде; **2.** *мәл.* тарату (раздать, разложить). Туздыр, кызым, тарилкаларны; **3.** *нрл.* сүтү, тарату (распарывать, разобрать). Туздырыйыммы дибанны? Сәгәт туздырып қарадым төзәтергә.

**ТУЗМА I** *нрл.* к.: **икралы**. Тузма бәрәңге, сакълап торам, изелә дә китә, таралып китә. Итле памидур тузма була. Пудыш алмасы тузып тора, тузма була. Китайка алмасы қаптың, эреп кенә китә үзеннән-үзе, тузып қына тора, тузма.

**ТУЗМА II** *нрл., трх.* к.: **тузғақбаш**.

**ТУЗУ 1.** *чпр., мәл., трх., м.-кар., брб.д.* к.: **тетелү 1.** Ызын тәнәфескә туздылар. – *чпр.* Сәгат′ икедә туздылар инде. Тузарлар инде. – *мәл.* Җарар, китик, тузарға wахыттыр. – *трх.* Қазақлар торғаннар, тузғаннар анан соң. – *брб.д.*; **2.** *трх.* таралып сибелү (рассыпаться). Дегет бучкәсе қыза, шартлый да вич туза; **3.** *трх.* ачылу (раскрываться). Йафрақ тузғынча «бөдөрләнгән» дибез.

**тузып төшү** *төм.* һуштан язу (потерять сознание). Шаларны күреп тузып төшә йаздым.

**ТУЗЫЙАҚ: тузыйақ күнәк** *брб.д.* туздан эшләнгән цилиндр формасындагы савыт (посудина цилиндрической формы, сделанная из берёсты).

**ТУЗЫЛУ: баш тузылу** *клд.* к.: **тетелү: баш тетелү**. Кырыс кан′иш кулында Тузылды инде башларым (*хал. җыр.*).

**ТУЗЫМТЫҚ: тузымтығы йаматай** *перм.* әйбернең – тузгач, кешенең картайгач ямьсез булып калуы турында (о потере качеств в результате износа, старения). Моңқы тузымтығы йаматай булыр диб әйтәйе бабай иске чеприктән суққан материйәне. Йәш күб өчен дә тузымтығым әшәке.

**тузымтығы бетү** *перм.* **1.** тузып бетү – әйбер турында (износиться до предела – о вещах); **2.** картаеп бетү, ямьсезләнү (предельно состариться).

**т у й** (свадьба):

**билге туй** *әстр.* кызны килешеп, ризалык билгесе итеп егет ягына бүләк биргәч, кыз өендә үткәрелә торган мәҗлес (застолье в доме невесты, которое проводится в день передачи подарка в знак согласия на брак). Билге туйында җаулык бирәләр, ул җаулык кийәүнең анасына була.

**боз туйы** *твр.* яз көне боз киткән вакытта су буенда үткәрелә торган яшьләр уеннары (молодёжные игры, проводимые у реки во время половодья). Боз киткентә барыб ашанабыс, уйный идек боз туйлары йасағанда.

**икөн туй** *әстр.* кыз егет өенә килгәч үткәрелә торган туй мәҗлесе (свадебное застолье, проводимое в доме жениха в день переезда невесты).

**йараш туй** *тмн., күрш., шрл.* кызны килешү турында сөйләшү өчен ике якның да якын туганнарын чакырып кыз ягында үткәрелә торган мәҗлес (званый обед, пиршество с участием самых близких родственников жениха и невесты после сговора). Алгы йараш туй зур булайды, санкыларда киләйдәр, сун китәйдәр жинихка. – *күрш.* Р′уза чыксын да йараш туйны эшлибез. – *тмн.*

**калдык туйы** *срг.* үлгән кешенең өчесе, җидесе, кырыгы, илле бер көнлеге һәм бер ел үткәч туганнарны, күршеләрне мәҗлескә чакырып искә алу йоласы (поминки); чаг.: **атау 1.** Өчен, бишен узгаралар, җидесен зур итеп узгаралар калдык туйы дип.

**кечкенә туй, кечки туй** *әстр.* кыз өендә үткәрелә торган никахлашу мәҗлесе (свадебное застолье, проводимое в доме невесты в честь обручания).

**қода төсәр туй** *әстр.* ризалык биргәннән соң, кыз өендә егетнең һәм кызның әти-әниләре белән үткәрелә торган мәҗлес (свадебное застолье в доме невесты с участием родителей жениха и невесты). Йаулық алмаға килгәннән сун қода төсәр туй булады. Қода төсәргә бер мал суйады.

**ник′ах туйы** *минз.* никах мәҗлесе (свадебное застолье в день бракосочетания молодых по мусульманскому обряду). Кызга дигән кийемне ник′ах туйына алып киләләр.

**өлкән туй** *әстр.* кияү йортында үткәрелә торган туй (свадьба на стороне жениха).

**сыйырчық туйы** *твр.* сыерчык килгән вакытта үткәрелә торган мәҗлес (застолье в честь прилёта скворцов). Әнийем безгә потқалар пешереп, қоймақлар қойоп, қырта башына менеп ашый идек, сыйырчық туйы йасап.

**тақ туй, тақка салу** *әстр.* куенга керү уңае белән үткәрелгән мәҗлес (свадебные торжества в честь первой брачной ночи). Йегет йағында тақ туй була, қызны ничек кийәү йанына йатқызу, беренче кичләр, тақка салу диләр.

**тенге туй** *нокр.* иртәгесе көнне никах укылачак кичне кыз өендә егетләр-кызлар җыелышып уеннар оештыру йоласы (один из свадебных обрядов: игры, организуемые в доме невесты накануне бракосочетания).

**туғыз туй** *әстр.* егет ягыннан туй алды бүләкләрен китергәннән соң кыз өендә үткәрелә торган мәҗлес (свадебное угощение, которое проводится в доме невесты после доставки предсвадебных подарков со стороны жениха). Туғыз туйда йегет әнисеннән қызға кийетләр, қодағыйга да бүләкләр килә, кийет бирелә. Чатыр эчендәге бөтен халыққа кийет бирелеп чыға.

**туй аш** *каз.ар.-крш.* туй мәҗлесе (свадебное застолье). Ақ җаулық була ул, аны туй ашта ғына бәйлиләр оло кешеләр генә, киленнәр түгел, җәшләр түгел.

**туй ашы** *минз., байк., стрл.* кияү яки кыз ягыннан туйга алып килгән ашамлыклар (гостинцы, кушанья, приносимые на свадьбу сторонами жениха и невесты).

**туй ийәсе** *әстр.* туйны алып баручы, тамада (тамада); чаг.: **аргош**.

**туй куйу** *кузн.* туй ясау, туй үткәрү (сыграть свадьбу).

**туй күтәрү 1.** *чст., лмб.* к.: **туй куйу**; **2.** *әстр.* туйны үткәрергә булышу (помочь провести свадьбу). Йегетнең туйын күтәрәләр.

**туй малы** *әстр.* туйда егет ягыннан бирелә торган хайван (живность, даримая молодым со стороны жениха).

**туй ун′ау** *чст., лмб.*, **туй эчү** *т.кам.-крш.* к.: **билге туй**. Без туйны шушы апада ун′адық инде. – *чст.* Туйлары ун′амаган әле дә. – *лмб.* Туй эчәләр, нәсел-ырuwын җыйа да. – *т.кам.-крш.*

**ТУЙАС** *тара.* тырыс (коробок из берёсты). Туйазга сөтләр, эремчекләр салып қүйабыс. Бидрә мән битон шикелле туйас.

**ТУЙҒАЙУ** *төм.* алдан сизү, сизенү (предчувствовать).

**ТУЙРА** *минз., стрл.* к.: **туйыра 2**.

**ТУЙСИ** *т.я.-крш.* туйга әзерләнә торган ашамлыклар (угощение, приготовляемое на свадьбу). Элке туйсилар былай былган: бырай калачы, бәрәңге пәрәмәче пешергән.

**ТУЙТАҚ-ТУЙТАҚ: туйтақ-туйтақ йөрү** *перм.* к.: **сылтықлау**. Аwыртқач басып булмый, туйтақ-туйтақ йөрисең шунда.

**ТУЙУҚЛАУ** *брб.д.* бикләү, буа буу (запереть, запрудить).

**ТУЙЧЫ** *нгб.-крш.* туйда егет яки кыз ягыннан катнашкан кеше, ул туй мәҗлесен үзләренә чакырырга тиеш (человек со стороны жениха или невесты, участвующий на свадьбе, который должен пригласить участников свадьбы к себе в гости). Моноң туйын қайчанрақ җасарбыз икән, безгә бит туйчы эзләргә кирәк булыр ике жаққа, дип сөйләшәләр инде болар.

**ТУЙЫЗ** *перм., трбс.* каен тузы (берёста). Қайыннан туйыз төшөрәләр, – *перм.*

**ТУЙЫМ: туймыга туймымны** *перм.* к.: **зимне 1**. Базар туқмач туймыга да туймымны ул.

**ТУЙЫМЛЫ** *кас.* к.: **зимне 1**. Туймымлы аш те'ел акрушкы.

**ТУЙЫНУ 1.** *лш.* аптырау, теңкә кору (надоесть, докучать). Тәкә қайтмый җөри башлаған ийе, туйынған ийем, шуңар күрә суйдым; **2.** *перм.* ашау (есть, кушать). Туйыныб утырай әле. Йегет тороп туйынган.

**ТУЙ(Ы)РА 1.** *лш., т.я., м.-кар.* имән (дуб). Туйра утыны жылы була жағарга. – *к.т.* Туйра йағу өчен ғәйрәтле. – *лш.* Алар имән тайак ди, без туйра тайак дибез. Кайыны кабыгы ак була, туйраны кабыклары кара була. – *м.-кар.*; **2.** *лш., трх., нрл., минз., стрл.* яшь имән (молодой дуб). Пасаткыда бер рәт туйыра, бер рәт әрбет утыртқан. Җәш имән генә туйыра, менә болый булғасын имән диләр. – *нрл.*; **3.** *кузн.* куаклар, һәртөрле куак (кустарник); **4.** *мам., блт., дөб., кмшл., кузн., хвл.* к.: **қуwақ I, 3**. Аслық йылны асы булса да туйыра ашадық. – *злт.* Ағачны кисәләр дәген қырыйыннан үренделәр килеп чыға, шул туйыра була. Қурасын кискән ийек, тагын йәш туйыралар үскән. – *мам.* Йүкә туйралары кистем сарықларға. Мондағы имәнне былтыр кискән ийек, хәзер туйрасы шундый қуйы булып үскән. Әнә wақ туйыраны ботыйбыз жафраққа. Безнен инешнен буйында Туйыра таллар бар икән (*хал. жыр.*). Тал туйырасы да, имән туйырасы бар жыйганы. – *блт.* Қура жиләге быйыл жиләк бирсә қорой, быйыл чыққан туйыралар киләсе жылға жиләк бирәләр. – *дөб.* Пинуктан үскән йәш потақлар: бер генә булса туйра әтелми. – *кузн.*; **5.** *блт.* юкә кайрысы (кора липы); чаг.: **қуры**; **6.** *минз., злт., стрл.* агач кайрысы (кора дерева); **7.** *дөб., злт.* к.: **дуңгәк 2**. Ағас кисеб алғас, туйырасы қала. – *злт.* Туйыра жардым әле жағарга. – *дөб.*; **8.** *дөб.* к.: **гембә: зана гембәсе**. Ағач чирләсә, аңа туйыра чыға; **9.** *перм., злт.* имән чикләвеге (жёлудь). Имән туйырасын қайнатып қорталар. – *перм.*; **10.** *стрл., минз.* к.: **бәрән: бәрән миннеге**. Туйыра йасыйбыз. Туйыраны элек йәш имәннән йасыйдырыйық, хәзер қазыққа йарақлысын да тутыра йөк тулсын өчен. Туйыраға бөтөн ағачның йафрақлары керә, виткурмы әзерлиләр хәзер. – *минз.*; **11.** *мам.* гөл ботагы (цветочная ветвь). Ике жаққа ике туйыра чығарған бу гөлем.

**ТУЙРАЛЫҚ 1.** *т.я.* имәнлек (дубняк); **2.** *блт., минз.* вак юкәлек (мелкий липняк).

**ТУЙЫРАЛЫК** *мәл.* к.: **қуwақ I, 3**. Туйыралык калган, уратыб алганнар.

**ТУЙЫРУ I** *нгб.-крш.* туйдыру (кормить, накормить). Мине ашатып туйырып жибәрде.

**ТУЙЫРУ II** *минз., стрл.* **1.** сыдыру, кабыгын салдыру (сдирать кору); **2.** к.: **бөрчү 2**.

**ТУЙЫРЫЛУ** *тара.* кайтарылу (затупиться). Пычақның безе туйырылған.

**ТУК** [*рус.* ток] **1.** *миш.д., кмшл.* ындыр табагы (ток). Тук короб йөрибез әле. – *чст.*; **2.** *чст.* ябык ындыр табагы (крытый ток). Бу ибдәшләр камбайыннан журна ташырга тийешләр тукка.

**Т'УКА I** [*рус.* тётка] *чпр.* к.: **абыстай 1**.

**Т'УКА II** *кузн.* к.: **кети**.

**ТУҚАЛ** *эчк., злт.* мүкләк (комолая, безрогая). Туқал сыйыр. Туқал кәзә. Туқал сыйыр сирәк была. Минең апаның сыйыры туқал ыйы. – *злт.*

**ТУҚАННАУ** *перм.* к.: **бүкәйләү**. Бала да туқаннаб йөри айағыннан басалмағач. Туқаннап балчықта йөргән. Аларны кигәч, туқаннаб йөриләрмени балчықта.

**ТУҚАР** *перм.* к.: **бәйсәкә**.

**ТУҚАЦ** *тара., төм.*, **ТУҚАЧ** *тара,, твр.* күмәч (булка). Пичинйә әлек туқач кебек пула, Тарада (*ав. ис.*) туқач дип сүли, хәзер булычка диләр. Туқацлар пешерәләр бездә. – *тара.*

**туқац таба** *төм.* дүртпочмаклы калай таба (противень).

**шикәрле туқац** *тара.* өстенә шикәр сибеп пешерелгән күмәч (плюшки).

**ТУ'ЛАНМА'А** *кас.* к.: **туғайу**.

**ТУҚЛЫ** *тбл.* әле бәрәнләмәгән сарык (овца, которая ещё не ягнилась).

**ТУКЛЫ 1.** *чпр.* гадәттә бәрәнләмәгән бер яшьлек сарык яки кәжә (годовалая овца или коза, обычно не ягнившаяся). Былтыргы туклы инде сарык; **2.** *чст.* бер яшьлек (годовалый). Туклы дуңгыз баласы килеп керде.

**ТУҚМА** [*удм.*] *нокр.* **1.** юк-бар нәрсә (сүз), юк нәрсә (чепуха, ерунда, вздор); чаг.: **л'агу**. Лишаклар, азбар әбиләре дип сийләсәм, туқмалар сийли башлады дип келә. Туқма сүз шай ул; **2.** к.: **ару II: ару йукка 1**. Туқма ғына йатып үлде. Туқма үзем келдем, аны йебәрәсейде.

**ТУҚМАҚ I 1.** *дөб., тбл.* ат муенындагы ярага камыт тимәсен өчен камытка бәйләп куела торган киез (войлок, который кладут под хомут, если холка коня натёрта). Атынға қамыт тийергәнсең, туқмақ қуйып жик. – *дөб.*; **2.** *трх.* гер (гиря); **3.** *төм.* чабагач (цеп). Порын саманта ашны йыйып асапланып туқмақ пелән суққан.

**туқмақ йейү** *том.д.* кыйналу (быть побитым).

**туқмақ тирәзә** *бөре.* ян тәрәзә, казан янындагы кечкенә тәрәзә (небольшое боковое окошко на кухне).

**ТУҚМАҚ II** *тбл.* к.: **йар I: йар йафрағы**.

**туқмақ йеләк** *себ.* жир жиләге (клубника). Туқмақ йеләк урманда үсә. – *төм.*

**ТУҚМАҚ III** *перм., тара.* к.: **туқал**. Туқмақ сыйыр. – *тара.*

**ТУҚМАҚ IV: туқмақ йул** *нокр.* сукмак юл (тропинка).

**ТУКМАК** *тмн., хвл.* чәкән, кукуруз чәкәне (початок кукурузы). Быйыл кукуруз тукмаклары бик зур булдылар. – *хвл.*

**сәгат′ тукмагы** *чст.* сәгать гәре (гиря – у часов).

**ТУ'МА'** *кас.* тукмак (колотушка).

**ката ту'ма'ы** *кас.* к.: **бәл′ук**.

**ТУҚМАҚБАШ 1.** *перм.* карчыганың бер төре (один из видов ястреба); **2.** *мам.* чукмарбаш (головастик); **3.** *минз.* к.: **тупыйбаш 1**.

**ТУКМАКБАШ** *чст.* к.: **песи: песи балалары**.

**ТУҚМАҚЫЛ** *нокр.* к.: **туқма 1**.

**туқмач** *урт.д.*, **тукмач** *миш.д.*, токмач (лапша):

**кәкре туқмач** *мам.* токмачның бер төре (рожки). Кәкре туқмач қайтқан кибеткә, қыйбатлы микән?

**кул тукмачы** *стрл.* өйдә киселгән токмач (домашняя лапша). Кул тукмачы кистем.

**ТУКМЫЙР: тукмыйр башлы** *хвл.* чукмар башлы, йомры башлы (с тупым концом). Арысланның кор′ыгы тукмыйр башлы.

**ТУКРАМАУ** *мәл.* тормау (не держаться). Кыл да сыймый, кисап та тукрамый.

**ТУКРАУ 1.** *байк.* озак тору, озак тукталып тору (останавливаться надолго, задерживаться). Алар безгә тукрамыйлар, апасы бар кийәүнең; **2.** *мәл.* тукталу, урнашу, эләгеп калу (останавливаться, устраиваться, зацепляться). Сәмәркан йагына барып тукрадылар. Анда тукрый алмадык.

**ТУҚСЫРАУ 1.** *каз.ар.-крш.* тую (наедаться). Тәмам туқсырыйм инде; **2.** *блт.* тую, бизү (надоесть кто-либо, что-либо); чаг.: **җиләү**. Тәмам туқсырыйм инде үзләреннән (балалардан).

**ТУҚСЫРТУ** *мам.* биздерү, туйдыру (надоесть что-либо). Бәрәңгене көн дә ашасаң да туқсыртмый ул.

**туктату** (остановить):

**кар туктату** *срг.* кар тоту (снегозадержание). Кыш вата кар туктаттык.

**ТУҚУ** *бөре., перм.* к.: **ачлау**. Май чапчағы була шуның бийеклеге, туқып йазабыз майны, әйрән майы була. Иләмтекне чебечкә туқыйбыз, малга. Қайттым да қамыр туқып қуйдым. Қызым, майны туқыштырыб утыр, үзебез йазмағач, кем йазып бирер ни? – *перм.* Онны суга туқайлар да, апра була. – *бөре.*

**әпәй туқу** *перм.* камыр изү, камыр басу (замесить тесто).

**ТУҚУWЫЧ 1.** *перм.* камыр изә торган дүрт кырлы таякчык (мутовка). Әпәй туқуwыч; **2.** *перм.* к.: **атаwыч**.

**ТУКШЫРУ** *хвл.* туку (говорить, долбить, твердить). Тукшырып йебәрдем вет.

**ТУҚЫЗ** *тмн., кузн.* тугыз (девять).

**ТУҚЫМ** *каз.ар.-крш.* туган, кардәш (родственник, родня). Безгә туқым кеше ул.

**ТУҚЫМЫШ** *минз.* к.: **болгама 2**.

**ТУКЫНДЫРУ** *м.-кар.* чукындыру (крестить, перекрестить). Без пирвай татар булып, аннан тукындырганлар, имеш.

**ТУҚЫННАТУ, ТУҚЫННАУ** *перм.* к.: **бүкәйләү**. Иртән тороп басам, басарға минең айак җуқ, туқыннатып китәм. Айагың басалмагач, туқыннап китәм дисең.

**ТУҚЫРАУ** *злт.* к.: **тукрау 1**. Анда йыйлып петкәс, туқырап тормаң.

**ТУКЫРКАН** *тмн., лмб., чст.*, **ТУҚЫРТМА** *эчк., тбл.* к.: **тумырқа**. Тукырканча тукый-тукый да йаза. – *чст.* Туқыртманы күргәнең бармы? – *эчк.*

**ТУҚЫШ** *перм.* к.: **болгама 2**. Байна туқышны күтәрмәгә менгезеп қуйдым и чебечләрнекә. Қазларға ак туқыш қуйдым. Қайда кемнең туқыш, шуны эзләб ашый (сыер).

**ТУЛА: тула йаwын** *брб.д.* кинәттән, кызу гына явып китә торган яңгыр (неожиданный, быстро проходящий дождь).

**ТУЛАЙ** *тбл., тара., саз.я.* **1.** барысы, бөтенесе, барлык, бөтен (всё). Тулайыгыс бергә йөрөң. Төгөләре циттә тулайы. Тулай нимә әсер қысныңқы. – *тбл.* Тулай геше йыйылышхан ит. – *саз.я.*; **2.** хәвефле чакта үз якыннарын чакыру ымлыгы (восклицание, которым созывают своих в случае опасности).

**ТУЛАК** *т.я.-крш.* тула (домотканое сукно). Тулак басканда йырлиләр энде: Сездә тулак басалармы, Бездә тулак басалар. Басик тулакны, җырлик җыруны (*хал. җыр.*).

**тулак чапан** *т.я.-крш.* туладан теккән чикмән (зипун из домотканого сукна).

**тулак чука** *т.я.-крш.* к.: **ойок: туры ойок**.

**ТУЛАНА** *төм., тбл.* к.: **қамыраш 2**.

**ТУЛАСЛАУ** *тпк.* түгәрәкләү, тәмамлау (закруглить, закончить). Эшләрне туласлағас, пахутқа йөрөй башлайым.

**ТУЛҒА** *брб.д.* өч аяклы таган (треножник, таганок); чаг.: **даган 1**.

**ТУЛҒАМА** *трх.* әремнең бер төре (один из видов полыни зелёного цвета). Тулғамадан себеркә дә йасыйлар әле.

**ТУЛГАУ** *тбл.* сазның аяк астында селкенүе, тирбәлүе (качаться, колебаться под ногами – о болоте).

**ТУЛКА** [*рус.*] *бөре., минз., перм., трх., карс.* тәгәрмәч бүкәне эченә куела торган тимер көпшә (втулка).

**ТУЛҚАННАУ 1.** *минз.* тулып ашу (быть переполненным, быть в избытке). Синең өрөле ашларың өстәлдә тулқаннаб утыра; **2.** *кргл.* өрелү, кабару – кием турында (надуваться, вздуваться – об одежде). Тун кийә байлар, ул wақытта тунның биле тулқаннап тора.

**ТУЛКАУ** *м.-кар.* үзара сугышу, кара-каршы сугышу (драка).

**ТУЛҚЫН** *каз.ар.-крш., перм.* дулкын (волна). Су киткәс, сөйәкләр чыққан, тулқын чыгарган аны. – *перм.*

**ТУЛЛАМА'А** *кас.* тутыру (наполнить). Туба туллама'а.

**ТУЛЛАУ** *кас.* тутыру (наполнить). Эси' белин 'азы туллайлар алаша итендин 'ени.

**ТУЛОЙОҚ** *минз.* к.: **ойык 2**.

**ТУЛУҚ** *каз.ар.-крш., кмшл., к.-уф., төм.* тутырып (с верхом). Тәлиңкә тулуқ пирмән салдық. –

*каз.ар.-крш.* Бидрә тулуқ чықты. – *кмшл.* Бақчадан бер бидрә тулуқ итеп кәртүк қазып алып кердем. – *к.-уф.*

**ТУЛФАҚ** *злт.* алюминийдан эшләнгән балдак (кольцо, колечко, сделанное из алюминия). Тулфақ көмөш түгел, ал'уминнан эшләнгән балдақ.

**ТУЛЫҚ 1.** *каз.ар.* тулы, тулы ук (полный, доверху). Өй тулық кеше булды. Бақча тулық қазлар ийе. Чиләк тулық су. – *блт.* Ындыр табагы тулық халық була торған ыйы. – *дөб.* Өй тулық қунақлар. – *каз.ар.-крш.*; **2.** *бәр.* туп-тулы (совершенно полный, переполненный). Әле кийем-салым шифанирда тулық, сандоқта тулық.

**ТУЛЫҚЛЫ** [*рус.* толк + *афф.* -лы] *блт.* төпле, аңлы, акыллы (толковый). Дәү абыйлары да тулықлы түгел.

**ТУЛЫШУ** *перм.* шеш тулу турында (налиться, созреть – о нарыве). Туры килгән булгандырмы инде, тулышқас тишелми име. Жан баштагысы әтнә сайын тулышып аға.

**ТУМ** *клд.* причёска төре (вид причёски).

**ТУМА I 1.** *хвл., твр.* к.: **бертума**. Тума тәтәмнең өч оло. Тума булгачтан ошарлар инде. Арчи (булып) өж-дүрт иш тума агалары, биргән игәчләре бара, йакыннары булмаса, читләр бара. – *хвл.* Минем тума абыйым. – *твр.*; **2.** *бгрс.* к.: **тудыка(й) 1**. Аның атасы белән минем инәй бертуган, тума булабыз; **3.** *бгрс., бәр.* туган (родня, родственник). Мужыт тума булып чыққандыр. Читтә бер тумабыз бар, шуның малайы. Тума кирәк тырмыш итәргә. – *бгрс.*; **4.** *каз.ар.* (фәлән авылда, шәһәрдә h.б.) туган (уроженец такого-то села, города и т.д.). Безнең awыл тумасы үзе, бүрек шикелле күперткән чәсне. – *дөб.* Тума қайсы йақныкы? Мин үзем Алан (*ав. ис.*) тумасы. – *каз.ар.-крш.* Нөнәгәр (*ав. ис.*) тумасы бит бу, бусы монда килгәч туды. – *блт.*

**йорт тумасы он** *минз., стрл.* гади тегермәндә тартылган он, түбән сортлы, карарак он (мука, молотая на обычной мельнице, т.е. не сеянка и не крупчатка).

**тума тудыкай** *хвл.* бертуган апа яки сеңел (родная сестра).

**ТУМА II** *стрл.* зинадан туган (незаконнорождённый).

**ТУМА III** *төм.* бөтенләй (совершенно, совсем). Муллашта тел тума пашқасу, Интрәйнең (*ав. ис.*) песнең пелән пер.

**ТУМАК I** *кузн., лмб.* к.: **тума II**. Тумак тапканга. – *кузн.*

**тумактан бала табу** *тмн., лмб.* к.: **дус: дустан табу**.

**ТУМАК II** *лмб.* к.: **ту 2**. Тумак картукмы бу?

**ТУМАЛАҚ I** *тбл.* киселгән утын (распиленные дрова); чаг.: **тумрам**.

**ТУМАЛАҚ II** *брб.д., тбл.* күз бәйләш уены (игра в жмурки).

**ТУМАЛАҚ III** *брб.д.* к.: **йомоқ**.

**ТУМАЛЫП** *дөб.* учарланып, тармакланып (разветвляясь). Ул шулай тумалыб утыра қуwақ кебек. Бу гөл шулхәдәр матур булып тумалыб үсә. Йалғыз ағачлар шулай тумалыб үсәләр, күп ботақлар чыгарып.

**ТУМАМА'А** *кас.* коендыру (искупать, окатить). Мунчада cow белин тумадылар, сал'он тийде.

**ТУМАННАУ** *перм.* к.: **бүкәйләү**. Барып туманнаған шулай. Тезе белин туманнаған. Баланы да туманнап жәри башлады инде дибез.

**ТУМАР 1.** *перм., злт.* к.: **тумрам**. Йарылмады исә, тумар була инде ул, йомро булды исә. – *перм.* Сыгып бер-ике тумар утын йарып керең. – *злт.*; **2.** *тбл., саз.я.* саз түмгәге (болотная кочка). Анта тумарлы йер, пецән цапқалы пулмайты. Пецән пулмады тумар цабып. – *тбл.* Тумарлы йертә пецән цawawc. – *саз.я.*

**тумар waш йеләх** *саз.я.* түмгәкләр өстендә үсә торган жир жиләге (клубника, которая растёт на кочках).

**цәцле тумар** *эчк.* сазлы жирдә өстенә кыяк үскән түмгәк (кочка на болоте, обросшая осокой). Жалан ғына йердә цәцле тумар, Йанып қына йата парланып (*жыр*).

**ТУМАРЫҚЛАУ** *брб.д.* к.: **томрау 1**.

**ТУМА-ТУWЫШҚАН** *кргл.* к.: **нәсел-асаб**. Халық алысқа, тума-тувышқаннарына жибәрә шәлне.

**ТУМАЦА** *чст.*, **ТУМАЦИ** *чст., эчк.* к.: **тумачи 1**. Зәйтүнә әптәйләр дә тумацимы? – *эчк.*

**ТУМАЧА 1.** *чст.* к.: **тумачи 1**; **2.** *блт.* к.: **тудыка(й) 1**. Әти жағы тумачалар ғына бар инде, дәwәти қызлары.

**ТУМАЧАЙ** *кас.* к.: **тумачи 1**.

**ТУМАЧӘНИ** *к.т.* әтисе яки әнисенең апасына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре отца или матери).

**ТУМАЧИ 1.** *тмн., чст., стрл.* өченче буын туганнар (троюродные). Әле чәче агарып бетсә дә, тумачины ынытмаган. – *стрл.*; **2.** *мәл.* к.: **туганый**. Минем абыйның хатыны белән мин бер яшь булсак, тумачи дийешәбез. Килен килеп төште хәзер, кас'ына тумачи ди, кас'ына тудыка ди; **3.** *чст.* иң кече каенсеңел (самая младшая сестра мужа); чаг.: **балдыз 2**. Тумачи кат'мадымы әле, тудык?; **4.** *трх.* әтисенең апасы (старшая сестра отца). Тумачиларға барып қайтам әле; **5.** *трх.* олы яшьтәге кардәш хатын-кыз һәм аңа эндәшү сүзе (старшая родственница и форма обращения к ней). Тумачи шулай общи исем инде ул, жақын кеше инде. Адаш әпти белә инде тумачины, минем балалар анарға тумачи диләр.

**ТУМАЧЫЙ** *лш., дөб., к.т.* туган тиешле ике хатын-кыз арасында эндәшү сүзе (форма обращения между двумя женщинами-родственницами). Тумачый апа. – *лш.*

**ТУМАШҚА** *лш.* бөке (бутылочная пробка).

**ТУМАШЫЙТУ** [*гар.* + *тат.*] *глз.* борчу, тынычсызлау (беспокоить, тревожить). Ул килдисә, тумашыйтә мине.

**ТУМБАЛАҚ** *тбл.* к.: **тумрам**. Нигескә тумбалақларны тесеп цыққаннар тотош, эц йақтан күмәләр.

**ТУМИЛ** *кас.* калкулык жир (бугристое место).

**ТУМНАУ** *клд.* причёска ясау (сделать причёску). Чәче кудра, тумнаган.

**ТУМПАЛАҚ** *тбл.* к.: **тумрам**.

**ТУМРАМ** *тара., тбл.* бүкән (пень, чурбан, обрубок). Пер тумрам утын кистек. – *тара.*

**ТУМРАУ** *твр.* нык (крепко). Асрағанта қул көсле, күкрәк тумрау ите.

**ТУМСЫЗ** [*рус.* дума + *афф.* -сыз] *сргː* беркатлы, саф (простодушный, добродушный, доверчивый). Бигрәк тумсыз инде бу кеше.

**ТУМЫРАУ** *сргː* к.: **томрау 1**. Кругум тумырый әллә ни, йаумас микән?

**ТУМЫРҚА** *злт.*, **ТУМЫР'А** *кас.*, **ТУМЫРКА** *лмб., кузн., хвл.*, **ТУМЫРТҚА** *перм., тпк., тбл.* тукран (дятел). Тук-тук тумырка агачтан кырт казый. – *хвл.* Тумырка дигән асыл кыш Туңган агачларны тукыйдыр (*хал. җыр.*). – *лмб.* Әлмәгә тумыртқа дигән қош чоқоп ойа йасый. – *перм.* Тумырқа йәй буйы өзелми, серек қойма былса, туқылдатып утыра. – *злт.* Тумыртқа бар, ағастағы қортно сүпләй. – *тпк.*

**ТУМЫРУ** *лш., злт.* әре итеп, тупас итеп кисү (рубить грубо, сделать топорно). Тумырған да сөйәгән, балта-пычақ тимәгән (*мәкаль*). – *лш.* Элгәре пысқы йуғ ыйы, балта белән тумырып кертеп йаға торған ыйық. – *злт.*

**ТУН I** *тара.* өске кием (верхняя одежда). Әкмәл, туннар алып килце.

**бикеш тун** *т.кам.-крш.* киң итәкле, арты ерыклы, өзек билле тун (шуба с широким подолом, сзади с вырезом и отрезной талией). Бикеш тунның арт итәге җырықлы, билле, итәге киң булған аның күлмәк сымақ, биле өзөклө, қатын-қызнықы – бөрмәле.

**боцқақ тун** *себ.* эчке ягы җәнлекнең аяк тиреләреннән тегелгән тун (шуба, подкладка которой сшита из шкуры ног зверя). Сипкә эце боцқақ тун пирәтеләр – *төм.* Ул боцқақ тунны минтәй әбиләр башқа бөргәнеп тә йөрителәр, эце боцқақ, тышы тышлы була тун. – *тара.*

**дубит** [*рус.*] **тун** *мәл.*, **дуп** [*рус.* дублёный] **туи** *трх., кмшл., минз.*, **дуплы тун** *чпр.* к.: **қабық тун**. Дуплы тун, шалаwар кигән. – *чпр.* Хәзер дуп тун бит инде. – *минз.*

**йыwан тун** *тара.* к.: **тулуп тун**. Йыwан олло туннар кийепләр, оссон пулады.

**қабық тун** *блт.* кайры тун (дублёная шуба). Қабық тунны кийеп чыққан идем.

**кыштыр тун** *кузн.* кыска тун (полушубок).

**олло тун** *тара.* к.: **тулуп тун**. Иге олло туны пар ите, перәwе бүренеке.

**тире тун 1.** *сргː* к.: **қабық тун**; **2.** *тара.* тун (шуба). Осоно да булады, қысқасы да булады тире туннықы.

**тулуп тун** *перм.* толып (тулуп). Безнең өйдә этинең йамаулы, катып беткән тулуп тун бар иде, әнинең берәү лыстыр паласы.

**тун цатыр** *тара.* чыбылдык (занавеска).

**тыш тун** *тбл.* к.: **тулуп тун**.

**хәнәwез тун** *шрл.* тышы атлас яки ефәктән, эченә ак бәрән тиресе куеп тегелгән тун (шуба с атласным или шёлковым верхом на белой мерлушковой подкладке).

**эцке тун** *тара.* костюм. Эцке тун, камсул – ул уқ.

**ТУН II: тун йабу** *перм.* к.: **бикәц; бикәцкә керү**. Мин суқа сөрәм, эти қызлар йәрәшмә китте, килгәч, чәчү беткәч, тун йабуға тиб әйтәйек, тун йабуға йебәрделәр.

**ТУНДУРУК** *чст.* к.: **гөпшә**.

**ТУНЛЫҚ** *тбл.*, **ТУННЫҚ** *төм., тбл.* кәфен (саван). Туннық теккән энәне кемнәр тегәде, шуңа бирәде. – *төм.* Үлгән кешегә туннық тегү гәрәк. Тунныққа мал гәрәк қуй. – *тбл.*

**ТУН-ПРАҚ** *тара., тбл., төм.* кием-салым (одежда вообще).

**ТУҢ I 1.** *перм., бгрс.* пешеп җитмәгән – җиләк турында (неспелый, зелёный – о ягоде); чаг.: **пукран**. Туң күwенә җыйалар, пешмәгән күwенә. – *перм.* Мында җиләкне туң көйөнә ашап бетерәләр. – *бгрс.*; **2.** *твр.* киселгән, ләкин эшкәртелмәгән агач (спиленное, но не обработанное дерево). Туң қайынны киртләп пиртеләр.

**туң бөре** *злт.* к.: **пукран I**. Саwылдан туң бөрө йыйып қайта бала-саға.

**туң кучан** *хвл.* өлгермәгән, күбрәк алма турында (неспелый – в основном, о яблоках).

**ТУҢ II 1.** *тара.* калку җир (высокое место, холмик); чаг.: **тумил**. Йаңаwыл оцы-башы йуқ-йуwан аwыл ите, туң-туң йерләр ғалты; **2.** *себ.* сазлык эчендә калку җир, кечкенә утрау (высокое место, островок среди болота).

**ТУҢ III: туң аwырuwы** *трх.* к.: **шом I**.

**ТУҢАЙАҚ I** *перм.* чакырылмаган кунак (незваный гость). Қунақлар җыйылған өйгә туңайақ килеп керсә, «туңайаққа бер айақ» дип, бер ыстакан эчемлек бирәләр (кешесенә карап).

**ТУҢАҚЛАУ** *нокр.* кырау сугу (побить морозом). Туңақлый қайсы җылны җиләк чәчәге.

**ТУҢБАШ** *тбл.* аңгыра (бестолковый).

**ТУҢДЫРУ** *нрл., трх.* к.: **шом I**.

**ТУҢҚАЛАҚ I** *тбл.* туңучан (мёрзнущий).

**ТУҢҚАЛАҚ II: туңқалақ өй** *төм.* дүрт почмаклы өй (четырёхстенный дом).

**ТУҢҚАННАУ** *перм.* к.: **бүкәйләү**. Туңқаннап китә идән бетереп.

**ТУҢУ** *чст., кузн.* **1.** өшү – кеше турында (озябнуть – о человеке). Мин бик өшедем, туңа йаздым. – *кузн.*; **2.** өшү – бәрәңге, яшелчә турында (замёрзнуть – о картофеле, об овощах). Баздагы бәрәңгебез туңган. – *чст.*

**ТУҢЫРУ** *себ.* туңдыру (замораживать). Маразилникта туңырам балықны. – *тара.* Пәлмәннәрне йасап туңырып қуйабыс. – *төм.*

**ТУП: тупқа салу** *туб.-ирт.д., брб.д.* киптерелгән тал кабыгы – тире иләү өчен кулланыла (сушёная кора тальника – употребляется при дублении кожи). Аш ацытаты этийем арыш оннан, тупқа сала торған итек тирне. – *тбл.*

**ТУПА** [*рус.* тупой] *т.я., хвл.* үтмәс (тупой). Тупа пычак. – *хвл.*

**тупа тел** *сргː* тупас сөйләм (грубая речь). Безнең йак тупа тел белә сүли.

**ТУПАҚ** *злт.* тупа, җәенке, тупыйк (с тупым носом). Тупақ башлы туфли.

**тупақ сүләү** *злт.* мәгънәсез сөйләү (говорить бестолково). Тупағрақ сүли ул.

**ТУПАЛАҚ: тупалақ суғу** *злт.* туп сугу (играть в мяч).

**ТУПАРУ** [*рус.* тупой + *афф.* -ару] *т.я., хвл.* үтмәсләнү, тупаслану (притупиться). Пычак-

ны чарларга иде, тупарган, бернәстә кисми. – *хвл.*

**ТУПАУ** *мам.* кыйнау, тукмау (бить, колотить). Қарawылчы кәзәне бақчадан тотоп ару ғына тупады да қуwып җибәрде.

**ТУПИ I** 1. *нокр.* тупый (туфья). Тупины апалар, қызлар да кигән, мона хәзер дә күрсәтәләр ич, йаулығ астында ул, ул зур булмый; 2. *чст.* колакчын бүрек (малахай, ушанка). Тупийеңне кырын кигәнсең.

**ТУПИ II: тупины туздыру** *дөб.* пыр туздыру (разнести в пух и прах). Ризwан тупийыбызны туздырыр, без сөйләгәнне ишетсә, дибез.

**ТУПИН** [*рус.* тупой] *мәл.* дорфа, тупас (грубый); чаг.: **лапалай**. Ире бит тупинрак.

**ТУПИЧА I** [*рус.* тупица] *кас., кузн., хвл.* үтмәс, тупас (тупой, неострый). Тупича балта белән йуныр булмый. – *кузн.*

**ТУПИЧА II** [*рус.* ступица] *лмб.* таза, тере (здоровый, живой, подвижный). Тупичалар балалары, үсәләр.

**ТУПҚЫТЫП: тупқытып ашау** *т.кам.-крш.* гарык булганчы ашау (есть до отвала); чаг.: **ыңқылғанчы**. Мин ул хәтле тупқытып ашағаным да җуқ, симерәм.

**ТУПЛАП** *мам.* җыеп (скопив). Көтүне туплап тоталар қашта.

**ТУПЛИ** [*рус.*] *әҗе.* к.: **пима 1**. Тупли ташлий кабак башыннан, иргә кайа барасы дип.

**ТУПЛЫҚ** *к.т.* к.: **табыр 2**. Көтү туплыққа төшкәч, барып cawам сыйырны төшкесен. Туплық awыл йанында ғына.

**ТУПРАС** *т.я.-крш.* к.: **қатнар**.

**ТУПСА I** 1. *блт., минз., боре., перм., нокр., глз., кмшл., бгрс., кргл., злт., шрл., стрл.* бусага (порог). Ишек тупсасына утырырға йарата бу. Тупсаның бу йағына кереп сөйләш. – *блт.* Тышқа чығып киткән, тышқа чығып тупсаны ғына атлаған, җығылған. – *минз.* Ишек тупсасына басарға йарамый, атлап қына керергә (кирәк). – *кмшл.* Тупсаға барыб утырған да җылай бит. – *минз.* Тупсаға салып тапый үләнне. Тупсага утырган да йоқлаған. – *злт.* Өйгә кермәдегез, тупса аша гына булды. – *стрл.*; 2. *хвл.* ишек тоткасы, ишек бавы (дверная ручка); 3. *м.-кар.* к.: **диңгез 2**. Җир эвәләр, тупса салу кирәк, диләр, сuwык җитә.

**тупса йырту** *төм.* килен төшкәндә, бусагага җиткәч ситсы ерту йоласы (один из свадебных обрядов: при входе невесты в дом жениха у порога две девушки разрывают ситец пополам). Ишек тупсаға йеткән цақта, тупса йыртқаннар. Тупса йырттырган була тыганнар, ут атлатып киленцәкне.

**тупса төбө** 1. *минз.* баскыч алды (крыльцо). Әнә тупса төбөндәге итегегезне алып қайтығыз. Тупса төбө тулы эризиңкә; 2. *злт.* ишек төбе (преддверие).

**тупса төп** *перм.* к.: **тупса төбө 2**.

**ТУПСА II: тупсаға утыру** *минз., трх.*, **тупсага утыру** *чст.* к.: **буазлану**.

**ТУПСАЛАНУ** *минз.* к.: **буазлану**.

**ТУПСАЛЫ** *мам.* каптырмалы (с застёжкой); чаг.: **теркәгечле**.

**тупсалы беләзек** *мам.* каптырмалы беләзек (браслет с застёжкой).

**ТУПСУ** *злт.* чигеп тутыру (вышивать плотно – о вышивке гладью). Нәрсәгә тупсығансыңдыр инде ул хәтле.

**ТУПЦЫҚ** *төм.* к.: **бәйсәкә**.

**ТУПЧУ** 1. *дөб.* аннан-моннан сылау, ямау (залатать, слегка починить). Җарыгын сылап қына торам, тупчып қына; 2. *мәл.* тоташтыру, ялгау (соединять, присоединять). Ай дустыган, дустыган, Сапларындыйн тупчыган (*хал. җыр.*).

**канат тупчу** *мәл.* май канаты ясау (сделать помазок из перьев).

**ТУПЧЫҚ** *тара.* бит алмасы (щека).

**ТУПЧЫЛАУ** *минз.* җыю, җыеп кую (убрать, собрать, спрятать в определённое место). Бер җиргә тупчылап тыққансың инде.

**ТУПЫ** *кузн.* киндер орлыгы белән бәрәңгене изеп пешерелгән пилмән (пельмени с конопляным семенем и картофельным пюре).

**ТУПЫЙ I** [*рус.* тупой] 1. *мам., блт.* тирәсенә мех тотылган түгәрәк сай бүрек (шапка с меховой оторочкой). Элгәре қарчықлар тупый кийәрләр ийе. – *мам.*; 2. *чст.* колакчын бүрек (малахай, ушанка). Үгә кергәч тупыйыңны салып куй, улым! Тупыйымны кун′ыма кыстырдым да цаптым; 3. *перм.* элек хатын-кызлар кигән тәңкәле баш киеме (старинный женский головной убор, украшенный монетами); 4. *трх.* бәйләгән башлык (вязаная шапка). Башына тупыйлар җасадым; 5. *лш., к.т.* ситсыдан тегелгән балалар кәләпүше (детский головной убор из ситца).

**тупый тәтәй, тупый чәчәк** *мам., блт.* к.: **тупыйбаш 1, 2**.

**ТУПЫЙ II** [*рус.*] *минз., чст.* дорфа, тупас (грубый). Настайашчий тупый халык. – *чст.*

**ТУПЫЙБАШ** *мам., блт.* 1. тау бөҗәк чәчәге (букашник горный); 2. кыргый кашкарый (короставник полевой); 3. к.: **бадийан: бадийан чәчәк**.

**ТУПЫРАК** *карс.* нигез, йорт (дом, земля, место, где родился или где живёт). Минем туган тупырагым шал үй, бу – тешкән тупырагым.

**ТУПЫРАС** *нрл.* к.: **қатнар**. Кер киптерә қайсыбер кеше җаңғыр wақытларында тупыраста. Қарт үләсе җылны бәк күп бирделәр игенне, бурсый, тупырасқа таратабыз.

**ТУПЫРСЫ** *мам.* к.: **тубырчык 1**. Тупырсы кебек бик җитез бала.

**ТУПЫРСЫҚ** 1. *мам.* тупас, юан (толстый, с некрасивой фигурой). Һай, бик тупырсық ла ул, қыз кешегә алай тупырсық булу әйбәт түгел; 2. *злт.* к.: **тубырчык 1**. Қызлары бик матур, тупырсық кебек.

**ТУПЫРЦЫЙ** *эчк.* к.: **тумачи 1**.

**ТУПЫРЧЫҚ** *мам.* к.: **тубырчык 1**. Тупырчық кебек бала.

**ТУР** *мам., кмшл.* вакыт (время); чаг.: **ара**. Хәзер самый төш туры, төш турында аш пешерербез инде. – *мам.* Мин барган турга син дә бар. – *кмшл.*

**ни тур белән** *каз.ар.* нинди йомыш белән, нинди эш белән (с какой целью, с каким делом). Ни тур белән килдегез? – *лш.*

**ул туры** *каз.ар.* ул ягы (с этой стороны). Ул туры йарый. – *дөб.*

**Т'УРА** [*рус.* тюря] *кузн., хвл.* суга бер кашык көнбагыш мае, тоз салып, бер телем икмәк турап ясалган ашамлык (окрошка из хлеба, соли, подсолнечного масла, воды). Суға тоз салабыз, май, әпәй турыйбыз, суган турыйбыз да ашыйбыз, шул т'ура була инде. – *хвл.*

**ТУРА I 1.** *каз.ар., чст.* корт, кызыл эремчек (особо приготовленный красный творог). Тәмне сөтләрдән ғенә тура қайнаттым. Туралы май да бар, қайсын җаратсаң, ансын аша. Тура итеп қайнатырмын дигән ийем, төчө сөтөмне қушып, туралы май. – *мам.* Гөбе сөтен тураға салалар аны. Туғаруқ йасыйлар да сап-сары булғанчы қайналар тураны. – *лш.*; **2.** *чпр.* эремчектән ясалган вак кына күмәч (мелкие лепёшки из творога). Бик күп тура җасап бардым; **3.** *бгрс.* җиләк кагы (пастила из клубники). Бездә бит җиләкне тура йасайлар.

**қорт турасы** *нрл.* корттан ясап, майда пешерелгән сумса (пирожок с красным творогом).

**ТУРА II** *тара.* шәһәр (город). Тураға китеп үлте.

**ТУРА III: тура биими'и** *кас.* кара-каршы бию (плясать вдвоём, друг напротив друга).

**тура 'эйе** *кас.* бию көе (плясовая музыка).

**ТУРАЖА** [*рус.* дрожжи] *яүшт.* к.: **друж.**

**ТУРАЙТЫН** *мәл.* турыдан (прямо, напрямик). Безнең апа, күрәсең, турайтын йебәргән.

**ТУРАМСЕЛЕК, ТУРАМЧЕЛЕК** *трх.* төз лапас (прямой навес). Йаңғыр чақта терлекләрне турамселеккә йабалар.

**ТУРАМША** *әстр.* ит һәм камыр кисәкләре белән пешерелгән ризык, бишбармак (национальное кушанье – бишбармак).

**ТУРАНТИЙ** [*рус.* дуранда] *нрл.* түп (дуранда, жмых); чаг.: **кулып**. Мамық турантийы була. Чимәңкеләрнең, киндер орлоқларының қаты төбө була, шул турантий була.

**ТУРАП 1.** *төм., тара.* киндер (холст). Әwwәл саман турап көйләк, турап ыштан кийгәннәр. Тураптан көйләк тә теккәннәр. Турап суқтық, йетенне үскерәсең, аны ийерәйсең, эрләйсең. – *төм.*; **2.** *тбл.* өйдә тукылган палас (домотканый половик).

**тураб урын** *төм., тбл., твр.* киндер урыны (ткацкий стан). Тураб урын пулаты суғатыған. Тураб урын бөтөрә торайы, мәктәпкә пирәрем тиб уйлайым. – *төм.*

**ТУРАПЦЫ** *тбл.* киндер сугучы (ткачиха). Мин менә тигән турапцы бултым.

**ТУРАУ** *трх., чст.* **1.** ваклау – утын турында (мелко нарубить – о дровах). Утын турыйлар алар. – *трх.*; **2.** кисү (разрезать, раскрошить).

**ТУРӘWЕСЛЕК** *нрл.* к.: **турамселек.**

**ТУРБАҚ** *клм.* **1.** тана бозау (телёнок); **2.** бер яшьлек тана, башмак тана (годовалая тёлка). Тумаған (бозауламаған) булса, турбақ була. Турбақ йылны тумый, тумаса, қысыр була.

**ТУРБИЧӘ** [*рус.*] *перм.* тәгәрмәч бүкәне (ступица – у колеса).

**ТУРҒАЙ** *перм., тпк., эчк., әстр., себ.*, **ТУРГАЙ** *стрл.* чыпчык (воробей). Турғайлар йабырылып йаталар. – *перм.* Қарағат йуқ, әллә турғай алған. – *тпк.* Песәй турғай тотқан қый. – *эчк.* Қарлығач турғайдан зур, қара ул. – *төм.*

**қар турғайы** *кргл.* кызыл түш, карабүрек (снегирь).

**қара турғай** *әстр.* к.: **пақцар.**

**тал турғайы** *тара.* сандугач (соловей). Тал турғайы инте матур итеп сайрайты.

**тумалақ турғай** *кргл.* көрән төстәге чыпчык (воробей коричневого цвета).

**тургай тарысы** *стрл.* к.: **сүсәнут**. Печән тургай тарысы ғынайы, тычқан кисебетте.

**турғай үләң, турғай әләге** *эчк.* давыл үләне (спаржа).

**урман турғайы** *тара.* урман чыпчыгы (лесной воробей). Урман турғайлары башында қалфағы бар.

**ТУРҒАЛЫ** *брб.д.* тасма тоткан (отороченный лентой). Турғалы шәлләре бар ите.

**ТУРИС** [*рус.*] *мам.* йорт куяны (кролик). Кем турисы бу, бер турис урамда.

**ТУРКА** *әстр.* к.: **коргыч 1.**

**ТУРҚА** [*рус.* тёрка] *баст.* кыргыч (тёрка).

**ТУРҚАН: қойроқлы турқан** *нокр.* к.: **қайчығойроқ.**

**сары турқан** *нокр.* к.: **пал'ак.**

**чабата турқан** *нокр.* кара таракан (чёрный таракан). Қара турқанны чабата турқан дибез.

**ТУРЛАШУ** *яүшт.* аталану (оплодотворяться). Турлашса, күкәйләре буш булмый. Эй, турлашмаған, ахыры, күкәйләре буш.

**ТУРЛИКӘ** *тара.* к.: **тәринкә.**

**ТУРЛУШКА** *әстр.* камыштан, саманнан төзелгән өй (дом, построенный из камыша или самана).

**ТУРЛЫЙ** *срг.* аркада (из-за, по, благодаря). Синең турлый миңа да йәшмиме?

**ТУРЛЫҚ** *әстр.* камыштан сугылған палас (палас, сотканный из камыша).

**ТУРМАН** *төм.* к.: **тилвәрән.** Күгән теш кебек инде турман да.

**ТУРПИН** *срг.* пәрәмәч (национальное блюдо).

**ТУРПЫША** *злт., байк.* к.: **торбоша.** Уналтышар турпыша суқтық. Турпыша йәйәбез дә ашлықны қоротабыз. – *злт.* Турпышасын да эшләп бирәләр калхузга киндердән. – *байк.*

**ТУРСАЙУ** *кузн.* к.: **томсару.** Биредә туже йаз, ну көннәр турсайып торалар.

**ТУРСҚЫЛТАҚ** *тбл.* балыкның шартлавыгы (рыбий пузырь).

**ТУРСЫЛТАҚ: турсылтақ үләң** *тбл.* шартлавык – үсемлек (хлопушка – растение).

**ТУРТА 1.** *минз., злт.* к.: **пәйеж.** Туртасын гел алып ташламағанмын. – *злт.*; **2.** *лш.* к.: **тура I, 1.** Байағы қатын турта керткән иде, алып китәрсең, иләрсең дә қамыр эченә тығарсың; **3.** *тбл.* к.: **кебар'ане.**

**ТУРТТА** *тара.* турта (вытопки, отстой, садящийся на дно горшка при топлении масла).

**ТУРТЫЙ** *т.кам.-крш.* тиле (дурак). Туртыйдан туры хәбәр (*әйтем*).

**ТУРУWЫН** *брб.д.* турылыклы (прямой, честный).

**ТУРУН** *тбл.* к.: **йосомбаш**. Капкада керүләренә мылтык ататылар, кысның айак асқа утлы турун ташлап атлаталар, аша басып цыксын.

**ТУРЫ 1.** *кмшл., злт., мәл., хвл., срг., чпр.* дөрес, төгәл (правильно, точно). Бу сәгат туры микән? – *кмшл.* Синең сәгатең туры тегелме? – *мәл.* Саат туры йери. – *срг.* Сәгат турымы? – *злт.* Сәгәтең турымы? – *чпр*; **2.** *тмн.* ғел, бары (полностью, сплошь). Туры кабырға да севәк, йымшағы йук.

**ТУРЫЛАҒАН** *әстр.* чигелгән (вышитый). Энҗе белән турылаган.

**ТУРЫЛАУ** *минз., кмшл., злт., бөре., чпр., стрл.* дөресләү – сәгать турында (выверять – о часах). Аны (сәгатьне) турылаган кеше дә йуғ инде. Шуны да турыларға булмады бу арада. – *минз.* Сәгәтне турыладыңмы, сиңайтәм? – *кмшл.* Турылап қуй әле, бәбәйем, сәгәтне. – *бөре.* Сәгат тә турылап булмый хәзер, радыйа сүләмәгәс. – *злт.* Сәгәтен турылама кели. – *чпр.*; **2.** *клд.* атау, багышлау (посвящать). Кемгә турылап чығардыгыз бу йырны.

**ТУРЫМ** *чпр.* калын (толстый). Малайга турымырак кирәк насук, бу нәзек, кызга булыр.

**ТУРЫМАЙУ** *срг.* тугаю, тулу, өлгерү (созреть, поспеть). Арышлар турымайган инде.

**ТУРЫТЫН** *мәл.* к.: **турайтын**. Турытын кат'ырга киләгәннәрдер дә батканнардыр.

**ТУС: тус күнәк** *брб.д., тара.* к.: **тусайак**.

**ТУСА** *тпк.* к.: **туча**.

**ТУСАЙАҚ** *тбл.* тырыс (коробок из берёсты). Тусайакта цай эцкәннәр, аш та эцкәннәр.

**қасан тусайак** *тбл.* туздан ясалған зур савыт (большая посудина из берёсты).

**ТУСҚАЙЫС** *тбл.* к.: **тусайак**.

**ТУСҚАҚ** *төм.* вак, сибәләп торган (моросящий).

**ТУСКӘ** *тара.* туздан ясалган тоз савыты (солонка из берёсты). Талаға қунау йөргәнтә тускә пелән тос йөртәбес.

**ТУСМАЙ** *төм., төр., тбл.* дегет (дёготь).

**ТУСРАЙУ** *бгрс.* турсаю (дуться, надуться). Тусрайып қына қайтып килә.

**ТУСТАҒАН 1.** *мам., блт., минз., бөре., бәр.* к.: **тустак 1**; **2.** *перм.* к.: **ашлау I, 2**. Бездән тустаған сорап керә. Тустаған ағачтан чуқып йасаған сawыт була ул. Аш та созабыз ый тустағанға; **3.** *минз., перм.* к.: **тәбеч**. Тустаған белекий була, сөт сawыты ғына була. – *перм.* Бер тустаған белән дә туйам мин. – *минз.*; **4.** *блт.* бал, май салу өчен балчык савыт (глиняная посуда для мёда, масла); чаг.: **бадйан I, 1**; **5.** *блт.* касәдән зуррак агач савыт (деревянная чаша); **6.** *нгб.-крш.* к.: **тустыған 3**. Тустаған белән эчә торған ийе; **7.** *каз.ар.-крш.* стакан; **8.** *минз., бгрс.* кечкенә агач савыт (маленькая деревянная чашечка, мисочка).

**тустаған җәйпече, тустаған тәрлинкәсе** *бөре.* к.: **җәйләү**.

**чара тустаған** *перм.* к.: **ашлау I, 2**. Чара тустаған зур булайы.

**чәй тустаганы** *минз.* к.: **тустак 1**.

**ТУСТАГАН 1.** *т.я.-крш.* к.: **тустак 1**. Әй җиңгәйем, җиңгәйем, тулы тустаган бирәсең, Әчәсем килми, нишләйем (*бор. җыр.*); **2.** *стрл.* зур касә (пиала большого размера).

**ТУСТАҚ 1.** *перм., злт.*, **ТУСТАК** *стрл.* чынаяк (чашка чайная). Эчең бодай икмәге белән бер тустак. – *перм.* Бер тустак сәй эсәң. Сәй эсәсем килә, дисез, ике тустак сәй эсәсез. Бер-ике тустак сәй эсеп алың. – *злт.*; **2.** *минз., тпк., трбс., стрл.* к.: **ашайак**. Ағач тустақлар була торганыйы тамырдан чоқолған. Элек ағач тустақ була торган ыйы аш салып эсә торган. – *минз.*; **3.** *минз., трбс., стрл.* к.: **дустыган 2**. Кичкелеккә чәй қуйдым, аны тустақлар белән эчердем. – *минз.*; **4.** *перм.* к.: **тустаган 7**; **5.** *тпк.* фермада: автоэчергечнең чүмече (ковшик автопоилки на ферме). Хәдер фирмәдә әрәхәт, сыwы эргәсендә, ике сыйырға пер тустақ.

**тәтәй тустақ** *трбс.* к.: **тустақ 1**.

**тустак эчү** *стрл.* к.: **дустыган: дустыған эчү**. Алар тустак эчеп куйган булганнар, әниләре берсе кыз, берсе малай асрагач.

**ТУСТАҚАЙ** *кргл.* **1.** к.: **тустақ 1**. Тустақай тытып йери сет сырап; **2.** к.: **тустаган 8**.

**ТУСТАКАЙ** *әстр.* **1.** к.: **дустыган 2**. Тустакай белән шорпа бирә; **2.** к.: **тустаган 7**; **3.** соскыч, озын саплы чүмеч (черпак).

**ТУСТАКАН** *стрл.* к.: **тустаган 7**.

**ТУСТЫҒАН 1.** *мам., блт., бәр., т.я., бөре., минз., нгб.-крш.* к.: **тустақ 1**. Тустыған китер әле. – *нгб.-крш.* Барыгыз, кереп бер-ике тустыған эчеп чығығыз. Тушы тустыған чәйне эчәм дә барам. – *бәр.* Аннан-моннан бер тустыған чәй эчте дә җөгөрде. – *мам.* Өчәр тустыған чәй эчәбез. – *бөре.*; **2.** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш., нгб.-крш.* к.: **тустаган 7**. Тустыған белә эчәсезме? – *каз.ар.-крш.* Тустыганны төбөндәге ақчасына була бушатып шаршау қорғанда, чәй кағабыз, диләр. – *т.кам.-крш.*; **3.** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш., нгб.-крш.* аракы эчә торган кечкенә стакан, рюмка (стопка); чаг.: **чәрке**. И ал сийа, ал сийа, Тустыганнар белә бал сийа (*хал. жыр*). Ирләр йағыннан шушылай соноп киләләр, берәр тустыған арақы эчәләр, ипидән тәберсен итәләр. – *т.кам.-крш.*; **4.** *к.т., төм.* к.: **дустыган 1**. Чишмәгә барсаң, тустыған ал тутырырға. – *к.т.*; **5.** *брб.д.* тирән табак (глубокая миска).

**тустыған эчү** *минз.*, **тустыган эчү** *стрл.* к.: **дустыган: дустыган эчү**.

**ТУСТЫГАН 1.** *чст., чпр., м.-кар.* к.: **дустыган 1**. Тустыган белән генә салыйм әле. – *чст.* Тустыганны алып бирче, этра. – *м.-кар.*; **2.** *чст.-крш.* к.: **тустаган 7**. Тот тустыганнарың кулыңа, Тустыган төбөн сырлыймын (*хал. җыр.*).

**ТУСУ** *тбл.* к.: **тетелү 3**. Тусаты цацларым.

**ТУСЫМ: йән тусым, мулла тусым** *тбл.* каенегә эндәшү формалары (формы обращения к младшему брату мужа).

**ТУТ** *минз.* суык (мороз). Киндерне манчып сүwыққа әләләр ийе, сүwыкны тут тиләр ийе.

**тут ашау 1.** *кмшл.* к.: **айаз: айаз ашау**. Қара керләрне тышқа элмә, тут ашый аларны; **2.** *кмшл., злт.* кыш көне суыктан агару (стать белым от мороза). Фәрдәләремне тышта қалдырған ыйым, тут ашаған, сүwыктан аппақ былғаннар. – *злт.*

**тут исе** *перм., злт.* кыш көне урамда кипкән кердә була торган специфик ис, хуш ис (специ-

фический приятный запах белья, высушенного зимой на улице). Қышқыда булса төн қунган кердән тут исе килә. – *перм.*

**тутқа элү** *перм., минз.* кыш көне ак керне агартыр өчен тышка элү (вешать бельё зимой на улицу с целью отбеливания). Керне тутқа эләсең, дип тиргәште. – *перм.* Киндерне фивралда тутқа эләләр ийе. Сувыққа маналар да эләләр, маналар да эләләр (киндерне), тее тутта ағара. – *минз.*

**ТУТА 1.** *мам., т.я., крш., минз., злт., кргл., кузн., карс., хвл., мәл., чпр.* апа (старшая сестра). И балалар, тутагыз җырақ шул, дигән. Сеңнесе түгел, тутасы. – *мам.* Бертуған тутасы беднең бабайга да қайтқалый. – *минз.* Аның тутайын алган ыйым тәүдә, мының әнийенең сеңелесен. – *злт.* Тутаң қайтқач, барысыз. – *каз.ар.-крш.* Күршедә туталы-сеңеллеләр барыйы. – *лш.* Минем тутам кийәүгә китте. – *нгб.-крш.* Тутаң китте калага, ат'ыр идең анарга, китер дир идең. – *кузн.* Вана тутаң ызбада утыра. – *хвл.* Безнең бер тутабыз бар иде, шул, ад'а бекмәләр пешердем, диде. – *карс.*; **2.** *дөб.* әтисенең сеңлесе (младшая сестра отца); **3.** *лмб.* үги ана (мачеха).

**туган тута** *мәл., стрл.* к.: **игәч**. Минем туган тутам бар. – *стрл.* Арйакта туган тутам бар. – *мәл.*

**ТУТАЙ I 1.** *каз.ар.-крш., перм., к.-уф.* үзеннән олы кыз туганына эндәшү сүзе (форма обращения к сестре старше себя). Бу минең җизнә, тутай үлде дә җизнәгә бардым тагы. Сәвәдә (*ав. ис.*) оло тутайым бар, ул йәрәшеп барды. – *перм.* Тутасы белән икәү генә торалар. Аннуштай, тутай килде. Тутайга да алып қайтты балық. – *каз.ар.-крш.* Тутайым қунаққа килде иптәше белән. – *к.-уф.*; **2.** *чст.* к.: **абзәни 3**. Бәйрәм кенне тутай кайта дип кеткән идек, кайтмады. Минем тутайның эч кайынсеңелесе бар иде. Минем тутайлар гына бар анда; **3.** *әҗе.* нәселдәге карт әби (родственница пожилого возраста); **4.** *кузн.* олы яштәге хатын-кыз (любая женщина пожилого возраста). Күрше әбисе булсын, тутай этәбез.

**җырак тутай** *чст.* к.: **абзәни 3**. Җырак тутай да бала каз сорады.

**туры тутай** *хвл.* туры әйтүчән хатын-кызга карата (говорится о женщине, прямой, недипломатичной).

**ТУТАЙ II** *нокр.* к.: **т'ит'и II**.

**бал тутай** *нокр.* тукранбаш (клевер).

**ТУТАК** *срг.* туташ (барышня, девушка). Тутаклар кайа бара?

**ТУТАКАЙ 1.** *тмн.* әтисе яки әнисенең иң олы агасының хатынына эндәшү сүзе (форма обращения к жене самого старшего брата отца или матери); **2.** *кузн., карс., стрл.* к.: **абыстай 1**. Ак та канат кынам тутакайым, Син дә шул үләргә димнәдең (*бор. җыр.*). – *кузн.* Тутакайым Уфада хәзер. – *стрл.*; **3.** *срг.* к.: **қаймбикә**. Казандағы тутакай килә; **4.** *срг.* әтисенең апасы (старшая сестра отца).

**абыз тутакай** *срг.*, **абыс тутакай** *тмн.* иренең өлкәнрәк кыз туганы (более старшая сестра мужа).

**ТУТАҚАЙ** *баст.* к.: **қаймбикә**. Әтисе яки әнисенең апасына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре отца или матери).

**ТУТАМЛАУ** *тбл.* дүрт бармак киңлеге белән үлчәү (мерить шириной четырёх пальцев).

**ТУТАШ** *срг.* өлкән хатын-кызга эндәшү формасы (форма обращения к женщине старшего возраста).

**абыс туташ, күркле туташ, сандуғач туташ** *баст.*, **чибәр туташ** *стрл.* к.: **абызастай**.

**ТУТӘППЕЛ** *дөб.* юан, таза, калын (здоровый, плотный, упитанный); чаг.: **балбан**. Мының күк тутәппел түгел ул, чәпелдек.

**ТУТИ** *тара.* чеби, чебеш (цыплёнок).

**ТУТЛАУ I** *кмшл., злт.* к.: **тут: тут ашау 2**. Бозга салып тырып сәпибез, шуннан алып қайтып әләбез кәртәгә, ул тутлый, тутлағас, йомшақ қына была. – *злт.* Ақ керләрне тышқа әләбез тутларға. – *кмшл.*

**ТУТЛАУ II** *әчк.* күгәрү (ржаветь). Карawат тутлай безнең.

**ТУТЛЫ 1.** *тара.* сары (жёлтый). Тутлы су ага; **2.** *брб.д.* күгәргән (заплесневелый).

**ТУТЛЫҒУ** *дөб.* к.: **тутлау II**. Чиләк дымлы җирдә тырып тутлыққан.

**Т'УТ'У** *глз.* бәбкә (гусёнок). Каз т'ут'у, үрдәк т'ут'у. Т'ут'улары кычкырганга анилары кырмасын (кермәсен) инде. Бишнең икесеннән т'ут'у чыкты. Каз т'ут'у саклаб утырабыз.

**ТУТЫҒУ** *перм.* карлыгу (хрипнуть). Таwыш тутыққан, җырлап булмый.

**аwыз тутыгу** *срг.* авызның тәме булмау (отсутствие аппетита). Р'уза да картуш белән, кийар белә тыттым, аwызым тутыга.

**ТУТЫРЛЫ** *миш.д.* кара тутлы (смуглый). Сары тутырлы. Кара тутырлы бу кыз, атасына охшаган. – *тмн.* Кара тутырлы синең кебек, карамсыл күзле – *лмб.*

**ТУТЫРМЫШ** *т.я.-крш.* малның эчәгенә ярма, суган, канны болгатып тутырган, казанга салып пешерелә торган ашамлык (ливерная колбаса, начинённая крупой, луком и кровью). Тутырмыш диләр, канга җарма, суган салалар, кишкага тутыралар.

**ТУТЫРТМА I** *т.кам.-крш.* кабыктан ясалган чиләк (ведро, сделанное из коры). Тутыртманы қабықтан йасағаннар. Қайын тузындан эшләнә тутыртма.

**ТУТЫРТМА II 1.** *т.кам.-крш.* фаршка бүрттерелгән дөге кушып, әвәләп суда пешерелә торган ризык (фарш, смешанный с отмоченным рисом и обвалянный в муке, который варится в воде). Тутыртмаға итне чабасың да әwәләп қуйасың, рисне бүрттерәбез дә, ит белән бергә әwәлибез дә суга салып пешерәбез; **2.** *дөб.* эре малның юан эчәгенә тапаган итне ярма белән болгатып тутырган, казанга салып пешерелә торган ашамлык (колбаса с мясом и крупой). Туган апа, тутыртма салып аш пешерәм, қайтма бүген, ди.

**ТУТЫРУ** *бөре., минз.* тәмамлау, бетерү (завершить, окончить). Биш классны тутырдым инде мин. – *минз.*

**йәш тутыру** *блт.* туган көн үткәрү (отмечать день рождения). Кукмараға йәш тутырыға барған дусына.

**ТУТЫРУҚ** *мам.*, *кмшл.*, **ТУТЫРЫҚ** *мам., минз.* **1.** к.: **тулық 1**. Қайтсам, ишегалды тутыруқ кеше.

Чиләкнең сувы тутыруқ. Өй тутырық хатын-кыз, өйдә су йуқ. Сувы бөтенләй тутырық түгел ийе аның савытта. – *мам.* Әнәй, мин қайтсам, идәнегез тутырық бала булыр. — *минз.*; **2.** тулысынча, шар (полностью, настежь). Ишекләр тутырыҕ ачық. – *минз.*

**ТУТЫШ** *кузн.* пешкән иттән пешерелгән пәрәмәч (перемяч с начинкой из варёного мяса).

**ТУТ'ЫШ** *лмб.* каенанасының җиңгәсе (сноха свекрови). Тут'ыш, мәтәм, сырый алмадым. Тут'ыш кан'анамның агасының катны буладыр.

**Т'УТ'ЫШ** *шрл.* әти яки әнисенең апасына һәм сеңлесенә эндәшү сүзе (форма обращения детей к старшим и младшим сёстрам отца или матери).

**ТУУ I 1.** *чст., мәл., кузн., хвл., әҗе., карс., бгрс., кргл., кмшл., баст., себ.* к.: **асрау 2.** Мин умбер бала тудым. Әни тувa алмады, йәшлий үлде. – *чст.* Габдулланы туганнан бирле, кыйынганым йук минем. – *мәл.* Күп тудым баланы, йәшләтә тудым, шул awыру белән awырғаны булмады. – *бгрс.* Ике бишек, килне дә туган, кан'анасы да туган. – *әҗе.* Сигез ыл тудым, бишем үлде элкегеләре. – *карс.* Җиде бала туды инәй. – *кмшл.* Икене тудым, ике үсте. – *баст.* Қәсер бала асырамайдылар, мин онике тудым. – *брб.д.* Атаң йуқ, мин ницек пала тувыйн? – *твр.*; **2.** *клм.* бозаулау (отелиться). Сыйыр тумаса, қысыр була; **3.** *клм.* бәрәннәү (ягниться). Көз тоуды, берсе қочқар, берсе теше; **4.** *клм.* йомырка салу (нести яйца). Қазым тумады. Қас чиртә тәрәзәне, тувaрға керә. Қас тәрәзәне чиртә иде күкәй салырға, тувaрға керә, утыра, тувa, аннан чығарам.

**қойаш туу** *перм.* кояш чыгу (взойти – о солнце). Қойаш тувып килә маса? Қойаш туганчы тороп китәбез ий эшкә.

**таң туу** *клд.* к.: **зәрә I: зәрә беленү.** Таң тугач та эшкә китә.

**ТУУ II** *тбл., тара., твр.* елларча җәйләп, җигелми яки савылмый йөргән симез хайван (незапрягавшаяся или недоившаяся, откормленная скотина). Йа, мырза, син туганда туу бийәләр сө идырдым. – *твр.*

**ТУУ III** *тбл.* буу (прудить, запрудить). Вагайны тувып ийәделәр.

**ТУФАН** [*гар.*] *мәл., срг.* ком бураны, өермә (песчаная буря, вихрь). Аййай урамда туфан. – *срг.*

**ТУФИН** [?] *мәл.* к.: **азымтық.** Ул туфиннән эш көтеп булмый.

**ТУФЫЙН** [?] *хвл.* **1.** к.: **торпа.** Туфыйн гына татар бар иде; **2.** аңгыра, миңгерәү, белексез (глупый, невежда); чаг.: **ат'акыш 1.** Элгәре шондый туфыйн халк булган.

**ТУЦ** *брб.д.* бронза.

**ТУЧ: туч балдақ** *бөре.* элек: сары металлдан ясалган балдак (раньше: кольцо, сделанное из жёлтого металла). Элек туч балдақ була торган ийе, җиз дә түгел, бақыр түгел, туч диләр ийе, борынғы.

**ТУЧА** *минз., стрл.* беренче кат бозаулый торган өченче яшьтәге сыер (корова третьего года, впервые отелившаяся). Тешәү җылны туча була сыйыр, сарықны шешәк диләр. – *минз.* Тана бозаулап тучага әйләнә, аннан олога әйләнә. Беренче бозауны бозауларга тийешле йылда бозаулamыйча калса, аннан соңгы йылда бозауласа, тучага чыгып бозаулады, диләр. – *стрл.*

**туча сыйыр** *минз.* ике тапкыр бозаулаган сыер (дважды отелившаяся корова).

**ТУША** [*рус.*] *хвл.* **1.** түшкә (туша); **2.** гәүдә – кимсетеп, көлеп – ешрак юан кеше турында (туша – чаще о толстом человеке).

**ТУШАWИК** [*рус.* душегрейка] *төм.* к.: **сырмыш.** Тушawикны Рауза төрәп йепәрде.

**ТУШНА I** [*рус.*] *миш.д.* бөркү (душно). Беранча йан алырга авыр жар, шандый тушна. – *лмб.* Тегендә бик тушнамы? Ату мында тушна. – *чст.*

**ТУШНА II** *м.-кар.* сагыш (тоска, грусть, печаль).

**ТУШНАЛАНУ** [*рус.* душно + *афф.* -лану] *лмб., кузн., хвл.* **1.** һава җитешмәү (стать кому-то душно). Ызбада тушналанам әтә. – *лмб.* Тушналанган жарга, тышка чыгарга чакыра. – *кузн.*; **2.** бөркүләнү (стать душным). Үнең һавасы тушналанды. – *хвл.*

**ТУШНИК** [*рус.*] *клм.* күмер чүлмәге (посудина для угля). Тушникта күмер көп, самувар шулаб утыра.

**ТУШЫ** *дөб., каз.ар.-крш., м.-кар.*, **Т'УШЫ** *м.-кар.* к.: **ошо.** Уйнасаң-келсәң тушы чак. Менә тушы мынча артыннан киткәч. Мин җаратам т'ушы сил'анканы (солянканы). Аннары әле Чулна районында да күп әле алар, тушы безне кебек сүлиләр иде. – *м.-кар.* Тушы көнне дә күргәч, бик шат инде без. – *дөб.*

**ТУШЫҚ** *туб.-ирт.д.* к.: **бәйсәкә.**

**ТУШЫЛАЙ** *каз.ар.-крш.*, **Т'УШЫЛАЙ** *м.-кар.* к.: **алай II.** Кийемнәре, сүләшүләре т'ушылай. Чәнчү аланы белмим, т'ушылай күрсәттем, ди. Тушылай тушы түгәрәк җаулыкларны аппардым да тегендә, бийағамнарда, тушылай матур иттереп кийендем дә камзул кидем.

**ТҮ** *баст., күрш., әҗе.* тары (пшено). Түнекен, пылауныкын, қарабодай бытқасы қуйалар, кемдә ни бар. – *баст.* Бер кило тү бирделәр. – *әҗе.*

**тү белене** *хвл., күрш.* төеп ясалган тары ярмасы оныннан пешерелгән белен (блины из пшённой муки, полученной путём толчения в ступке). Тү беленнәре пешерәйде әнийем. – *күрш.*

**тү буткасы** *кузн.* киледә төеп ясалган тары ярмасыннан пешерелгән ботка (каша из пшена, приготовленного путём толчения проса в ступке). Киндерашны тевәләр, йакшы гына илисен, пешерәсен тү буткасы, аны әз генә он мынан бутыйсын да пилмин йасыйсын.

**тү йарма** *тмн.* к.: **йарма I: сары йарма.**

**тү йармасы** *кузн.* килегә салып төелгән тары яки карабодай ярмасы (пшённая или гречневая крупа, полученная путём толчения в ступке).

**тү коймагы 1.** *хвл.* тары ярмасын төеп ясалган оннан пешерелгән төче коймак (оладьи из пшённой муки, приготовленной путём толчения в ступке); **2.** *тмн.* тары онынnан пешерелгән белен (блины из пшённой муки).

**тү оны** *кузн.*, **тү ыны** *тмн.* тары ярмасын төеп ясаган он (пшённая мука, приготовленная из пшена путём толчения в ступке). Тү ыныннан да пешерәм бәлеш.

**ТҮБӘ 1.** *туб.-арт.д., брб.д.* түшәм (потолок). Бишекне бау ман әләләр түбәгә. – *твр.* Тәбәнәк түбәсе, йылы қышлықта. – *тара.*; **2.** *эчк.* тау башы, тау түбәсе (вершина горы). Түбәдә малайлар йеләк йыйалар. Түбә йергә йыйылалар қызлар, йәш хатыннар; **3.** *к.т.* к.: **қатнар**. Түбәдә ике самаwарыбыз йата.

**ағач түбәсе** *минз.* агач башы (вершина дерева). Ағач түбәсеннән генә җөрде, шайтан булды. Ағач түбәсеннән жығылып төшкән.

**айақ түбә** *баст.* аяк йөзе (подъём ноги).

**қатнар түбә** *перм.* к.: **қатнар**. Қатнар түбәнең жуғары жағы – мөржә, өй эченнән чығып китисә, мөржә, диләр.

**мейец түбәсе** *төм.* мич башы (лежанка). Мейец түбәсентә йоқлайты мешәге.

**өй түбә 1.** *минз.* к.: **қатнар**. Өй түбәдә чәй эчә торған ыйық; **2.** *эчк.* к.: **түбә 1**.

**өй түбәсе** *минз.* к.: **қатнар**. Шул аш өйөнең моржасын өй түбәсенә менеб ачадыр ийек. Ийоққа тула кирәк бит, өй түбәсендә тулайоғома хәтле бар.

**тоқон түбә** *перм.* к.: **чиннек I, 1**. Безнең печин бер тоқон түбә булайе.

**түбә тақта** *чст., мәл.* к.: **түбә 1**. Түбә тақта нарат.

**түбә тақта** *әстр., том.д., туб.-арт.д., нрл.*, **түбә тақтасы** *к.т., бгрс., крғл., эчк., к.-уф.* к.: **түбә 1**. Түбә тақта қуйғаннан соң қачы батырмалары қуйыла. – *нрл.* Түбә тақтаға цебен қунған. – *тбл.* Түбә тақтасына гәжит жабыштырдым, тузан қойоладырыйы. – *к.т.* Буйалған түбә тақтасы йуwарға жиңгел. Түбә тақтам да бик беткән инде, малайым қайтқач буйатам. – *бгрс.* Түбә тақталарны буйадым быйыл. – *эчк.* Түбә тақталық алдым. Түбә тақта матур булмады безнеке. – *к.-уф.*

**ТҮБӘКӘЙ** *бгрс.* к.: **кәпәч 1**. Бабай башына түбәкәй кигән.

**ТҮБӘЛӘҮ** *мам.* түбә ябу (крыть крышу).

**ТҮБӘЛЕК 1.** *стрл.* тирә-ягы ачык туры лапас (прямой открытый навес); **2.** *тбл.* өсте ябылган болдыр (крытое крыльцо); **3.** *туб.-арт.д.* лапас (лабаз, навес).

**түбәлег асты** *төм.* к.: **бастырма**. Түбәлег астына ташлап қуйғайным.

**ТҮБӘН I 1.** *лш., мам., минз., нгб.-крш., т.кам.-крш., стрл.* к.: **кире**. Аннан түбән хутырда тордом, аннан түбән монда килдем. – *лш.* Инде моннан түбән үзең килерсең. Моннан түбән бер дә бармыйм дип қайтқан. Моннан түбән қабатланмасын бу эш. – *мам.* Иртәдән түбән қазан астына жағарга итәм. Бүгеннән түбән чақырмыйым да аны. Аннан түбән ике малай булғач, кумнат бирмиләр моңа. – *нгб.-крш.* Моннан түбән нәстә булыр, Қодай белә. – *т.кам.-крш.* Моннан түбән бирсен зиһен. Моннан түбән нишләрләр инде. – *минз.* Моннан түбән балаларның балалары күрмәсен. Моннан түбән йазгандыр. – *стрл.*; **2.** *хвл.* яшьрәк (моложе). Катным унике йәш түбән.

**түбән II** (низкий):

**түбән awыз** *минз.* жумба, шамбы (налим).

**ТҮБӘНИЙ** *лш., мам.* к.: **гелбәч**.

**ТҮБӘНЧЕК** *минз., стрл.*, **ТҮБӘНЧЕЛЕК** *минз.* к.: **астыр**. Түбәнчеккә генә төшкәннәр дә суғаннар үскәннәр. Беднең awыл, әйтергә була, бик нық түбәнчелектә, садда утырған. – *минз.*

**ТҮБӘРӘК** *злт., к.-уф.* түгәрәк (круглый). Аның йапрағы түбәрәк була. – *к.-уф.*

**түбәтәй** (тюбетейка):

**самаwыр түбәтәйе** *мам.* к.: **тәлпәк 3**. Самаwырның түбәтәйе, ис чықмасқа йаба торған.

**ТҮБӘЧӘ** *минз.* к.: **тәлпәк 3**. Көләбез тегенәрдән, самаwырның нинди түбәчәсе булсын дип.

**ТҮБЕР** *каз.ар.-крш., т.я.* түп (выжимки, жмых). Орлоқ түбере. Симәңке түбере. Житен түбере. – *каз.ар.-крш.*

**чәй түбере** *каз.ар.-крш., т.я.* к.: **пыды**.

**ТҮБИЛИШМИ'Й** *кас.* к.: **орошу 1**. Әний, Илдар түбилишми'и тели.

**ТҮWАШ** *төм.* тары ярмасыннан пешерелгән өйрә (суп из пшённой крупы). Түwаш йарамый миңа.

**ТҮWӘ** *төм.* к.: **дәwә**. Ул патшаның қоралы пер түwә йаңағы пулған.

**ТҮWЕНБЕШ** *трх.* кыланчык (кривляка, любитель покривляться). Қыймматне түwенбешрәк кеше әйтә.

**ТҮWЕРТ** *тара.* дүрт (четыре).

**ТҮWЕЧ** *м.-кар.* кәбестә турагыч, тәпке (шинковка). Түwеч түwә торған, кәбестә түwәсен. Кәбестә түwә торганы зур түwеч.

**ТҮWЕШЛӘНҮ** *минз., стрл.* түш белән шуышу (ползти по-пластунски). Мақсут awылына төшкән түwешләнеп. – *минз.*

**ТҮГӘРӘК I** *эчк.* к.: **ләнгәц**. Тирмәннән онны тарталар, түгәрәккә салып ацыталар.

**ТҮГӘРӘК II 1.** *минз., стрл.* төбәк, тирә (окрестность, местность, регион). Бу түгәрәктә башқортлар күб инде. – *минз.* Бодай игелмәгән шушы түгәрәктә. – *стрл.*; **2.** *тара., тбл.* тирә, тирә-як (окружность). Қасан түгәрәкнең сесләр? Awылның пөтөн түгәрәгендә күл. – *тара.* Түгәрәкләрен цитәннәгән. – *тбл.*; **3.** *тара., тбл.* әйләнә (окружность, вокруг). Мунцақ қадай тығаннар түшелтерекнең түгәрәгенә, песләртә алай. – *тара.* Итәк түгәрәг өскә манит тесеп китә теген итек. – *тбл.*

**ТҮГӘРӘК III** *төм.* к.: **диңгез 2**. Көскөсөн өйнең түгәрәген күмеп чығалар, йасқысын ацқаннар.

**ТҮГӘРӘҮ** *к.т.* к.: **аунау 1**. Түгәрәп жан биргере! Тауға түбән түгәрәде. Пичкәне түгәрәтеп уйныйлар (балалар).

**ТҮГӘРУК** [*рус.* творог] *лш.* к.: **тура I, 1**.

**ТҮГЕЛҮ 1.** *перм.* к.: **түгү 4**. Қызылайақ (кына гөле) қартайып түгелә башлад инде; **2.** *себ.* чәчелү (рассыпаться).

**ТҮГЕМ** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* дини бәйрәмнәрдә зиратқа ризыклар алып барып үлеләрне искә алу (ежегодные общие поминки, совершаемые перед Пасхой, накануне ссемика, в Покров день и т.д., при котором приносят еду на кладбище). Паскада, пыкрауда түгемгә барабыз зиратқа. – *каз.ар.-крш.* Безнең тағын пыкрау түгеме була, пыкырауға қаршы көнне пирук пешерәләр инде жармаданмы, нәстән бар инде. – *т.кам.-крш.* Түгем пыкыраудан бер атна алдан була, төрлө-төрлө пируклар, әтәч суйып. Түгем көне укт'абернең сигезендә, анда әтәчләр суйалар үлеләр өчөн. – *т.кам.-крш.*

**ТҮГЕН** *төм., тбл.* ялган (ложь). Эшәнмәң, түгенне кәпләйте ул. – *төм.* Түген генә кәпләп қуйтың қуй. – *тбл.*

**ТҮГЕНЦЕ** *туб.-рт.д.* ялганчы (лжец, обманщик).

**ТҮГҮ 1.** *глз., нокр.* су сибү (поливать). Гөлләргә су түкмәдеңме, әни? Гөлләргә су түгәйем. – *нокр.* Гелләремә бүген су да түкми калдым, су сырап утыралар. Бақча ашауларға су түгә идем. – *глз.*; **2.** *тпк., төм.* бушату, аудару (выгрузить). Утын апқайтып түгеп китәбез. – *тпк.* Сәғыйрәләргә утын түккәннәр, өц тилишка утын түккәннәр. – *төм.*; **3.** *карс.* бушату (опорожнить, вылить). Әчәү суга барабыз, су тейибез, ул суны түгәбез азбарга, икенче су китерәбез; **4.** *минз.* яфрак кою (сбрасывать – листья). Тиздән гөлләр йафрақ түгә башларлар инде; **5.** *перм.* төшерү (ронять). Идәнгә түкмәң аламағызны.

**ТҮЗ** *перм.* **1.** агач төбе (пень). Түздән йасыйлар аны күберәк (умартаны); **2.** нәрсәнең дә булса төбе (под, низ чего-либо). Уланны көлтә түзгә салып қуйалар; **3.** елга тамагы (устье реки). Башапның (*елг. ис.*) түзендә утырawы, Башап түз (*ав. ис.*) диләр. Без ике жылғаның самай түзендә утырабыз. Cawap (*елг. ис.*) түзендә утыралар, шуңа Уст Cawap диләр.

**борон түз** *перм.* борынның ике күз арасындағы өлеше (переносица). Борон түзгә шешеп чыға, арпа чыққан диб әйтәләр.

**жилкә түз** *перм.* к.: **йөннөк.**

**кәбестә түз** *перм.* күчән (кочан).

**суған түз** *перм.* суган башы (луковица).

**тырнақ түзе** *перм.* тырнак асты (под ногтём). Тырнақ түзендә-фәләндә кер булса, шапа тиб әйтәләр.

**ТҮЗЛЕК 1.** *перм., бөре.* төп, агач төбе (пень, пенёк); **2.** *трбс.* чыра агачы (полено для лучин). Әңкәй түзлекне ала да суға.

**түзлег умарта** *перм.* к.: **умарта: буй умарта.** Элек күбесенчә шундый умарта булған. Ул wақытта түзлег умартадан өчәр пот алайек.

**ТҮЗНҮ** *перм.* мунчада коену (окачиваться, окатиться в бане).

**ТҮЙҮК** *том.д., тбл.* бөтен, бөтенләе белән, тоташтан (весь, целиком, сплошь).

**ТҮЙҮС** *яшт., тбл.* к.: **қайас.**

**ТҮК** *лш., дөб.* к.: **түбер.** Орлоқның түге генә қала ич, алай қысқач. Жйтен орлоғо түген мал да ашамый. – *лш.* Орлоқ түкләре дә ашадық суғыш wақытында. Бу киндер түге, жйтен түге awыр ыйы ашарға. Майын чығарыб алалар, түген қайтаралар малларға. – *дөб.*

**ТҮКӘН** *перм., кмшл.* к.: **бәйсәкә.** Бәләкәй кешене түкән кеше тиләр. – *перм.*

**ТҮКЕЧ: күмер түкече** *лш.* к.: **күмериләк.**

**ТҮКМӘК** *төм., брб.д.* тумгәк (кочка, пень). Түкмәккә тә утысқан йоқ моноң эwе.

**ТҮКМӘКӘ** *төм.* к.: **тумрам.** Суғымцылар түкмәкәгә салып цапқаннар.

**ТҮКМӘСТЕРҮ** *тпк.* төрлеләндерү (изменить, разнообразить). Туғыдға түкмәстерәсең инде кинтерне.

**ТҮКМӘЧ** *клм.* к.: **тумрам.** Түкмәч кewек утырам менә, урын түкмәче кewек.

**ТҮКМЕЛДЕРИГ: түкмелдериг ату** *перм.* к.: **мәтәкләү.** Түкмелдериг атабыз.

**ТҮКТӘРЛӘНҮ** *перм.* к.: **тәпәрләнү 1.** Керләрем түктәрләнеп беткән.

**ТҮЛӘГӘ 1.** *твр., брб.д., тара., төм.* к.: **бикәч II**; **2.** *төм., тбл.* бәрән (ягнёнок).

**түләгә бала** *тара.* к.: **шешәк.**

**ТҮЛӘҮ** *лмб., кузн., хвл.* к.: **асрау 2.** Эч бала түләдем. Киленем кыз түләде. Кыз бала түләде. – *лмб.* Элгәре бала түләми йөрде. Бересенеке бала түләми. Әнкәй бәни түләгән дә Ак йаулыкка йүләгән, Йүләүләрен дә йүләгән, Бәхыт сырый белмәгән (*хал. жыр.*). Чүлмәк салдыра булганнар, шоннан соң, имеш, түли булган. – *хвл.*

**ТҮЛГӘН** *трх., нрл., бгрс., чст., туб.-рт.д.* к.: **қагау.** Өч бәбекәмне дә шул түлгән алды. – *трх.*

**ТҮЛЕ** *дөб., т.я.* түл (зачаточные яйца, образуемые в утробе птиц). Қаз, түле жиғач, жомырқа сала башлый. – *к.т.*

**ТҮЛКЕННӘЙ: түлкеннәй килү** *тпк.* туйға зур бүләкләр белән килү (приходить на свадьбу с большими подарками). Түлкеннәй килгән тиләр, бай килгән тиләр, түлкеннәй килү пай килү була. Қода булған кеше түлкеннәй килгән, йылқы қадылықлары апкилгән.

**ТҮЛЛӘНҮ** *кргл.* төймәләнү, жиләкләнү (завязаться – о плоде). Жиләк түлләнә башлаған.

**ТҮЛЛЕГӘН** *минз.* к.: **кагау.** Чебине түллегән алып китте.

**ТҮЛЛЕК** *әстр.* к.: **төндек.**

**ТҮМӘ 1.** *трх., злт., чпр., әжә.* к.: **гылбу 1.** – Бу чын түмәме? – Йук, чын түмә йалтырап тырмый ул. – *чпр.*; **2.** *тбл.* сәдәп (пуговица).

**ақ түмә** *нокр.* сәйләп (мелкий бисер).

**йандар түмә** *срг.* гәрәбә муенса (янтарные бусы).

**мәржәм түмә** *нокр.* к.: **гылбу 1.**

**ТҮМӘЛӘНҮ** *минз., стрл.* чәчәккә бөреләнү (появление, образование цветочных бутонов). Агач йафракка түмәләнгән. – *стрл.*

**ТҮМӘН** *тбл., төм.* түбән, тәбәнәк (низко, низкий). Аларның эше түмән тәрәчәтә барат. – *тбл.* Түмән кеше. – *төм.*

**ТҮМӘР** *минз.* **1.** юан агач (толстое дерево). Урманыбызда түшәм тақтасына жарырға жарақлы түмәрләр үсә; **2.** юан бүрәнә (толстое бревно). Түмәр – кискән ағач, жарылмаған ағач инде. Қарасам, су өстендә түмәр йөдөп йөри, су сеңгән.

**ТҮМӘРКӘ** *блт., каз.ар.-крш.* к.: **бүскә 1.** Ике түмәркә утынны жаралмыйбыз. – *блт.* Бер түмәркә йарты митыр була. – *каз.ар.-крш.*

**ТҮМӘЧӘЙ** *кас.* к.: **тумачи 1.**

**ТҮМГӘКЛЕК** *чст.* баткаклык, сазлык (болотистая местность, болото, трясина).

**ТҮМГӘКСӘР** *т.я.-крш.* түмгәклек (кочковатое место). Түмгәксәргә печән чапма бармалы.

**ТҮМГӘЛӘК** *минз., стрл.* к.: **қулса.** Түмгәләккә сиртмәне тығалар да, шуның башына бәллүне асып... – *минз.* Чылбырга түмгәләкләр тагасың да, шул мунчак инде. – *стрл.*

**ТҮМРӘЙ** *нгб.-крш.* к.: **лагун 1.** Қырға түмрәйне алабызмы?

**ТҮН** *срг.* к.: **ураучық.** Кыз түн түнәп куйа.

**ТҮНӘҮ** *тбл.* чыгымчылау, тибенү – ат турында (упрямиться – о лошади).

**ТҮНДӘК 1.** *лмб., мәл., чст., кузн.* к.: **гөмбек.** Кырмыска түндәге. Түндәкләрдә куча-куча була кымырыска. – *лмб.* Элгәр ул сал урнында түндәкләр генә булган. – *мәл.* Аның әле түндәкләрен без белә-без. – *чст.*; **2.** *срг.* к.: **бүкән 1.** Түндәккә утыр, йаң(ы) урдыкта келәмәсең. Үзеңнең түндәгең бит, каа да бармыйсың. Түндәкне түндәккә куйган да йыгылып төшкән цийә йыйганда; **3.** *кузн.* к.: **мурта 1.** Ничә түндәк муртасы?; **4.** *чпр., лмб., карс.* тәгәрмәч бүкәне (ступица). Кал'уса түндәге. – *лмб.* Машинада түндәк цәйкәлә хазер; **5.** *кузн.* юан бүрәнә (толстое бревно). Мурталар түндәкләрдә булган; **6.** *чст.* к.: **бәйсәкә.**

**түндәг алыш** *срг.* уен исеме (игра – третий лишний).

**ТҮНДЕР** *брб.д.* к.: **қолақай.**

**ТҮНДЕРБАШ** *мам.* тукранбаш (клевер). Минем әле түндербаш җыйарға барасым бар.

**ТҮНДЕРҮ** *т.я.-крш.* к.: **түнтәрү.** Зина, түндердек қыйманы.

**ТҮНДИ'** *кас.* **1.** к.: тумрам; **2.** к.: **мурта 1.** Түнди' та'талардан эшләнә.

**бал түнди'и, мурта түнди'и** *кас.* к.: **мурта 1.**

**ТҮНДИКӨН** *т.я.-крш.* к.: **башкен.**

**ТҮНЕ'** *кас.* сәке (нары). Түне' әле'е бәрендә дә бар иде, та'тадан 'уйалар, астына ни дә булса 'уйа.

**ТҮНЕШ** *к.т.* к.: **қойғорош.**

**ТҮНИ I** [*угор.*] *перм., к.-уф., злт.* к.: **пима 1.** Айағың өшегән, түни ки. – *перм.* Айағыңа түни кийеп утыр. Қыш айақ түни белән дә туңа. – *к.-уф.* Түнине эшкә кими торған ыйық. Түни басусылар килә, алар да, Қазандан без, тиләр. – *злт.*; **2.** *төм.* к.: **сачинкә.**

**ТҮНИ II** *тбл.* тәмам (совсем, совершенно). Түни көцөм петте.

**ТҮННҮК** *төм., тбл.* төтен юлы (дымоход).

**ТҮНСӘЛӘНҮ** *дөб.* тигезләнү (разравниваться). Безнең урам түнсәләнми, түнсәләнергә әле монда күпме чоқор, балчығы үз урынына сыйа алмый қалған.

**ТҮНТӘРӘМӘ** *чпр.* к.: **тулық 1.**

**ТҮНТӘРМӘ** *нрл.* бәрәңге һәм киндер орлыгыннан пешерелгән рулет (рулет, испечённый из картофеля и семян конопли).

**ТҮНТӘРҮ** *дөб., бәр., нокр.* аудару (повалить, опрокинуть). Бу ағачны ничек түнтәрәсе дип тора йем, җил түнтәреп бирде тағы. Бозау чиләкне түнтәргән. – *дөб.* Гөл чүлмәкләрне түнтәрмә, йәме! – *нокр.*

**җуққа түнтәрү** *дөб.* юкка чыгару, хурлау, яманлау (превратить в ничто). Алай уқ җуққа түнтәрмәгез әле.

**ТҮНҮ 1.** *каз.ар., блт., бгрс.* өйрәнү, күнегү (привыкать). Ашамасқа түнәрсез икән. – *блт.* Аларны урыс қызлары дип белгәннәр инде, безгә түнгәннәр дә. – *бгрс.*; **2.** *к.т.* к.: **итенү 1.** Нәрсә дип шулқадәр түнәдер бу түнеш. Түнмә инде, җүләрләнмә!; **3.** *дөб., бәр.* аву, егылу (упасть, валиться, падать). Қызы түнгән, анасын күргәч. Чәйнек-мазар тота күрмә, түнәрсен дә пешәрсен. Әйтсәләр – күнгәнмен, төртсәләр – түнгәнмен. – *дөб.* Икесе түнгән қарлығанның. Чулпы күрсәтсән хәзер йәшләргә, түнеп китәләр. – *бәр.*; **4.** *бәр.* к.: **төлдөрөп: төлдөрөп алу.** Бер йарты сәғәт түнеб ала торған ыйым абитқа қайтқач; **5.** *карс.* кебек булу, ошау (стать как ..., походить). Ике битем әләккә түнде, қызардым; **6.** *кргл.* үкенү (жалеть, сожалеть). Бабақайым, ник анда барғаныма түндем.

**әфтәләмгә түнү** *хвл.* аяктан егылу дәрәҗәсенә җитү, хәлдән таю (выбиться из сил, сильно устать).

**ТҮҢ** *тара., брб.д.* калку җир (высокое место, холмик). Сират түңен көрдегесмә, аул анда булған. – *брб.д.*

**ТҮҢӘРЦӘК** *төм.* к.: **тәгәрми.** Афтawысныңқы түңәрцәге цығып китепте, қалықлар пер биткә йатыпты.

**ТҮҢГӘЛӘК** *том.д., тбл.* бөҗра (кольцо).

**ТҮҢГӘРЦӘК** *төм.* **1.** к.: **тәгәрми.** Тимер түңгәрцәк булған; **2.** к.: **түңгәләк.** Түбә тақтада түңгәрцәк пула.

**ТҮҢКӘЙҮ** *дөб.* үлү (умереть).

**ТҮҢКӘК: қырмысқа түңкәге** *тпк.* кырмыска оясы (муравейник). Қырмысқа түңкәге мона улай булып тора.

**ТҮҢКӘЛӘК** *тпк., төм.* к.: **дүмгәләк 1.** Салғы түңкәләге пыла пит. – *тпк.* Түңкәләг алға кейепте. – *төм.*

**ТҮҢКӘРҮ** *злт.* бирү, тарату (давать, раздавать). Барын аларға түңкәрдем дә хәзер үземә қалмады.

**ТҮҢКӘРЦӘК** *төм.* к.: **тәгәрми.**

**ТҮҢКӘҮ** *төр.* қыйнау (бить). Түңкәүче булматы ғартым, әйбәт үтте үмерем.

**ТҮҢКҮ: эшкә түңкү** *дөб.* эшләтү, эшләргә мәҗбүр итү (вынуждать, заставить работать). Йампаслый-йампаслый эшкә түңкегәннәр қызны, бик усаллар, ди.

**ТҮҢНҮК** *брб.д.* тирмәнең төтен чыга торган тишеге (отверстие в юрте для выхода дыма); чаг.: **төндөк.**

**ТҮҢТӘРҮ** *тбл.* к.: **түнтәрү.** Пәтрәңне түңтәреп қуй.

**ТҮП** *клм.* к.: **туртта.**

**ТҮПЕРӘ: ақбур түперәсе** *кргл.* акбурның төбе, куесы (осадок, сгусток извести); чаг.: **будыра 4.**

**ТҮПИЙ** *нокр.* к.: **қалпақ 1.** Йәшләр түпий қуйа маңғайға, тегеп салғанда бәрхәттән, түмәләр чигәләр.

**ТҮПЛӘНКӘ** [*рус.*] *тара.* к.: **тун I: қабық тун.** Тиредән түпләнкә тегәләр.

**ТҮПЛИ** [*рус.* туфли] *кас.* к.: **галуш 1.**

**ТҮР I** *лмб., хвл., срг., том.д.* сәке, түр сәке (нары в избе). Түргә ыстинадан ыстинаға тире җәйгәннәр. – *клм*;

**түр асты** *клм.* к.: **гелбәч.**

**тур урдык** *кузн.* к.: **тур I.**

**ТҮР II** *әстр.* к.: **гуринча 1.**

**түр әйләнмәсе** *минз., стрл.* к.: **каршага.**

**түр буйы** *кмшл.* өйне бизәү өчен матча буена, тәрәзә өсләренә һәм түшәм кырыеннан стеналарга әленә торган ярты метр киңлегендәге бизәкле яки чигелгән тукыма, кашага (бордюр шириной

полметра вдоль матицы, под потолком и у верхней части окон).

**түр җаулыгы** *минз.*, **түр итәге** *стрл.* к.: **каршага**. Алты почмаклы өй, менә болай түр итәге элгән.

**түр йурганы** *кмшл.* өй түренә, идәнгә җәю өчен тар гына итеп сырылган корама юрган (узкое лоскутное стёганое одеяло, которое расстилается в передней части комнаты).

**түр күрсәтү** *перм.* әлек егет белән кызның әтиләре килешкәч, егет ягында кызның якын туганнарын гына мәҗлескә чакыру йоласы (обычай устраивать званый обед в доме жениха с приглашением близких невесты, после сговора между родителями жениха и невесты). Ризалык алгач бер атнамы, күпме торгач, түр күрсәтәләр, җегет йаккa чакыралар.

**түр сөлгөсе** *минз.* к.: **каршага**.

**түр чите** *к.т.*, **түр ызба** *хвл.* к.: **гуринча 1**.

**ТҮР III** *чпр.* түл (зачаточное яйцо в утробе птиц). Түре бетсә утырыр иде тawык, кез кене түре бетә.

**ТҮРӘ: түрә баба** *тбл.* к.: **түрә ғуца 1**.

**түрә ғуца** *тбл.* **1.** иренең абыйсы (старший брат мужа); **2.** укыган, хөрмәтле кешене олылап атау (обращение к уважаемому, почтенному человеку).

**ТҮРӘWЕСЛЕК** *трх.* к.: **турамселек**.

**ТҮРӘГЕЦ** *туб.-ирт.д.* булавка.

**ТҮРӘЛӘП: түрәләп кийәүгә бару (бирү)** *минз.* соратып, туйлап кияүгә бару (выходить замуж со свадьбой). Минем түтәй түрәләп кийәүгә барды. Қыdларымы түрәләп кийәүгә бирдем.

**түрәләп килгән қыз** *минз.* соратып, туйлап кияүгә чыккан кыз (девушка, выходившая замуж со свадьбой). Түрәләп килгән қыз ул, туй белән.

**түрәләп китерү** *минз.* баланы үз вакытында табу; вакыты җитеп табу һәм кендек әби күзәтүендә тәрбияләнү (родить ребёнка доносив; донашивать ребёнка и находиться под присмотром повивальной бабки). Мин түрәләп туғыd бала китердем.

**түрәләп қунаққа килү** *минз.* зурлап, затлырак күчтәнәчләр белән кунакка килү (приходить в гости с большими подарками); чаг.: **түрәле: түрәле қунақ**. Dурлап күчтәнәч белән килгән, түрәләп.

**түрәләп табу** *минз.* к.: **түрәләп китерү**. Мин унны таптым, унысын да түрәләп таптым. Биш баланы түрәләп таптым. Безнең заманда ғынайы түрәләп табу, хәзерге замандамы суң түрәләп бала табу.

**ТҮРӘЛЕ: түрәле қунақ** *перм.* күчтәнәч белән килгән кунак (гость, пришедший с гостинцами). Түрәле қунақ тип, сый белән килгән кешене әйтәләр қый.

**ТҮРӘ-ТЕРПЕ** *нгб.-крш.* түрәләр (начальник и др.). Түрә-терпене генә кертә wy.

**ТҮРӘТКӘ** *тбл., төм.* иренең зур абыйсы (старший брат мужа).

**ТҮРӘУ I** *тмн., лмб., кузн., срг., күрш.* к.: **асрау 2**. Дүртне түрәдем, икесе үсте. Ике бала түрәдем, икесе дә үлде. Адәм дөнйага килгән бала түрәргә, бала асрарга. Кәләшем бала түрәми. Бала түрәгәндә йәштерде кызым. – *срг.* Әни ике кыз, ике малай түрәгән, әчебез исән. – *лмб.* Иртүг бардык, бу төнне түрәгән. Унны түрәдем. Анасына килде, анда түрәде дә. – *кузн.* Мин унны түрәдем олан. – *күрш.* Катны түри алмый. – *тмн.*

**ТҮРӘУ II** *брб.д.* кадау (прикалывать). Көңнәгемгә түрәп қуйадым.

**ТҮРГЕН** *тара.* **1.** туйдан соң кызның әти-әниләренең кунакка килүе (посещение, приход в гости родителей невесты после свадьбы). Күүтән соң қысныңқы инәләре қысқа түрген мән киләтеләр. Утау түшәк булгач, түрген була. Түргенгә барган җирендән әтисе белән әнисе (кызны) алып қайтып киткән. Түргенгә қыснықы аталарын кийәү йаққа чақыралар. Түрген игенце көнне була, туған-тумацалар, қота-қодагыйлары булганнан соң була; **2.** туй булганнан соң, кыз ягы егет ягын һәм егет ягы кыз ягын кунакка чакырып, бүләкләр бирешү йоласы (обряд: после свадьбы родители жениха и невесты приглашают друг-друга в гости и взаимно дарят друг-другу подарки). Туй булганнан сен түрген диләр, қыс йаққа цақырыб ала аларны, анан йегет йақ цақырышып бүләк бирешәләр.

**түргеннәй алу** *төм.* туйдан соң кызның әти-әниләрен кунакка чакырып алу (после свадьбы приглашение родителей невесты в гости). Ул цақта түргеннәй ала тыгын ите қысның атинәсе, туганнарны алаты, пергә атинәгә қунаққа парасың.

**ТҮРГҮН** *тара.* кияүгә барган кызның әтисе йортына беренче мәртәбә кунакка кайтуы (первое посещение родительского дома дочерью, вышедшей замуж).

**ТҮРЕМ 1.** *чст., срг., тмн., кузн., мәл., шрл.* калын (толстый). Түрем ыйык. Эстемә түрем күлмәк кидем. Түрем итеп зәймә зәймәңне, нәзек итеп зәй. – *срг.* Бу ситса түремрәк йаулык эчен. – *тмн.*; **2.** *шрл., срг., чст.* калын, юан – энә, җеп турында (толстый, грубый; грубо – о нитке и иголке). Мамык түрем эрләнгән, шәле калын чыгар. – *шрл.* Түрем энә. Энәләрегез түремме әллә? Түрем эрлисең дә бит. – *срг.*

**түрем энә** *стрл.* к.: **инә II: чирмеш инәсе**.

**ТҮРЕМАЙУ** *срг.* юанаю, калынаю (толстеть, полнеть). Бу кыз түремайа бара бит.

**ТҮРИК** *перм.* **1.** кәтүк (катушка, шпулька). Түрик җебегез бармы?; **2.** юкә кабыгының йомшак җиреннән ишелгән бау (бечёвка). Арқан ишәм түриктән, делбигә ишәм. Түрик бау нык була.

**ТҮРИМИ'И** *кас.* к.: **асрау 2**. Түри'ин дип җазмай.

**ТҮРКЕН** *брб.д.* к.: **түрген 1**.

**түркен йағы** *әстр.* кияүгә чыккан кызның туган йорты, туганнары (родной дом невесты, родственники).

**түркеннәп бару** *әстр.* к.: **түлкеннәй: түлкеннәй килү**. Ничә қардәше бар, атасының биш кардәше бармы, бара да түркеннәп чақыра да, кажный қардәшенә түркеннәп барып, бер ай торамы атасының өйөндә, йарты аймы. Қызны қайтарып җибәргәндә өйенә, түркеннәре бар да қуй атағаннар.

**ТҮРКЕННӘЙ: түркеннәй килү** *тпк.* к.: **түлкеннәй: түлкеннәй килү**. Түркеннәй килә хәллесе, мал алып китә, қыd атасы-инәсе бирә.

**ТҮРКӨРПӘ** *дөб.* к.: **түр II: түр йурғаны**. Кистән түркөрпәләрне жыйып қуйа тырған булғаннар.

**ТҮРКҮН** *твр.* хатын-кызның туганнары (родственники жены). Түркүнчели ни йаман? Түркүнү йооқ қыс йаман (*әйтем*).

**ТҮРЛӘМӘ** *лш., минз.* к.: **түр II: түр буйы**. Түрләмәбез ақ булса да, матча қашағасын ақ жасамадық. – *лш.* Қулжаулығы да, ачйаулық та, түрләмәләр дә чигәдер ийем. Түргә йасыйдырийек чигеп түрләмә. – *минз.*

**ТҮРЛӘҮ** *срг.* к.: **асрау 2**. Биш-алты бала түрләгән катын.

**ТҮРТТАҒАННАП: түрттағаннап йөрү** *төм.* к.: **бүкәйләү**.

**ТҮРЦӨӨ** *брб.д.* хәзер үк, тиздән, ... диярлек (тотчас, скоро, почти).

**ТҮС** *брб.д.* ау (охота).

**ТҮСЛӘҮ** *брб.д.* далада йөрү, аулау (ходить по равнине, охотиться).

**ТҮСТӘЙ** *байк.* к.: **абзәни 3**.

**ТҮСТЕП: түстеп бейү** *кас.* бик яхшы бию (отлично танцевать).

**ТҮТӘ I 1.** *срг.* карандашның очламаган башы (незаточенный конец карандаша); **2.** *кузн.* көлтәнең төп ягы (нижняя сторона снопа). Тугыз келтәне севисең, бер келтәнең түтәсен өскә куйасың.

**ТҮТӘ II** *дөб.* башка, аерым (иной, другой, отдельный). Илдән түтә бәлә бирмәсен.

**ТҮТӘ III** *твр.* апа (старшая сестра). Бу түтә минеке башка әтәйдән, уналты йәшкә олорақ.

**ТҮТӘЙ 1.** *минз., бөре., перм., кмшл., т.кам.-крш., т.я., нгб.-крш., бгрс., трбс., тпк., байк., чст.* бертуган апа һәм аңа эндәшү сүзе (родная сестра старше себя и форма обращения к ней). Мин түтәй малайына бардым. Түтәй минем бийемем була. – *минз.* Беркен түтәйләрдә қунып чирләп қайттым әле мин, бер тун ғына салған да асқа. – *кмшл.* Бездә апаның нәстә икәнен дә белгән кеше йуқ иде әле моңыйнчы, түтәй генәйе. – *т.кам.-крш.* Түтәйнең бер қызы, минем бер улым ғына бар. – *бгрс.* Сәмсеқәмәр түтәй йоқлап киткән дә ... – *трбс.* Элек түтәй ийе, хәзер апа диләр. Туған түтәйем үлгән. – *тпк.* Түтәй алтмышта үлде. – *байк.*; **2.** *чст., нгб.-крш.* ерак туганга һәм олы яшьтәге хатын-кызга карата әйтелә (по отношению к дальней родственнице и любой посторонней пожилой женщине); чаг.: **абыз 2**. Әлинә түтәй сүләсен. – *чет.* Ул мийа түтәй тийешле. – *нгб.-крш.*; **3.** *перм.* эти яки әнисенең апасына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре отца или матери); **4.** *бгрс.* олы яшьтәге кардәш хатын-кыз һәм аңа эндәшү сүзе (старшая родственница и форма обращения к ней); **5.** *бгрс.* өлкән хатын-кызга хөрмәтләп эндәшү сүзе (форма почтительного обращения к пожилой женщине); **6.** *минз., бөре.* иренең апасы (старшая сестра мужа). Түтәйне күрәсем киләдерийе. – *минз.*; **7.** *минз.* иренең абыйсының хатыны (жена старшего брата мужа); чаг.: **абсын**. Түтәй гел тик тормый, бәйли.

**ақ түтәй 1.** *бөре.* к.: **апақ**. Ақ түтәй дибез, инәйнең сеңлесе булған; **2.** *минз.* берничә апа булганда аерып эндәшү сүзе (форма обращения к одной из старших сестёр). Ақ түтәй, самаwыр қуй, бергәләп күчтәнәчләр белән чәй эчәрбеd.

**жырақ түтәй** *минз.* әнисенең апасы (сестра матери).

**мулла түтәй** *минз.* әтисенең олы кыз туганнарының берсенә аерып эндәшү сүзе (форма обращения к одной из старших сестёр отца).

**түгәрәк түтәй** *чст.* апа – яратып әйтү сүзе (тётя – ласкательное слово). Әй, түгәрәк түтәйләрдән кайтам.

**чибәр түтәй** *минз.* к.: **ақ түтәй 2**. Шул чибәр түтәй әйтә, ди, әни, үдең мөржә буйына йат, ди икән.

**ТҮТӘЛ** *төм.* к.: **киштә I, 1**. Түтәл йыйылған, йул кебек тора.

**түтәлдә йөрү** *стрл.* яшелчә бакчасында эшләү (работать в огороде). Түтәлдә йөредем биж йыл су кыйып, утап.

**ТҮТӘРӘМ** *бөре.* кисәк (кусок).

**ТҮТЕЙ** *т.кам.-крш., каз.ар.-крш.* үзеннән олы кыз туганына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре).

**ақ түтей, алма түтей, бал түтей** *т.кам.-крш., каз.ар.-крш.* берничә апасы булганда аерып эндәшү сүзләре (формы обращения к старшим сёстрам).

**жырақ түтей** *т.кам.-крш.* әнисенең апасы яки сеңлесе (старшая или младшая сестра матери). Жырақ түтей, жаз, жаз, жәме. Бик күптән-күп сәләм әйтәм бабай белән әбигә, Әрнәштәге қодаларга, Аудый жырақ түтейгә.

**чибәр түтей 1.** *т.кам.-крш. борындык* әнинең балалары яшь киленгә шулай эндәшә (так обращаются дети посажёной матери к невестке); **2.** *каз.ар.-крш.* берничә апасы булганда, кечерәгенә эндәшү сүзе (форма обращения к младшей из старших сестёр).

**ТҮТЕК** *к.т.* к.: **пысқыш**.

**ТҮТЕШ 1.** *карс., стрл., шрл.* к.: **абай: зур абай**. Безнең дәдәй бар ыйы түтеш белән, ул күп белә иде. – *стрл.* Уфада безнең түтеш бар. – *шрл.*; **2.** *стрл., шрл.* туганнан туган апага эндәшү сүзе (форма обращения к двоюродной сестре, старшей по возрасту). Аның әнкәсе Бәдри түтеш белән без ике туган баласы. – *шрл.*; **3.** *күрш.* к.: **түтәй 1**. Түтешкә шәлләр китердем. Түтешкә бирдем; **4.** *кузн.* ерак кардәш хатын-кыз (дальняя родственница).

**мулла түтеш** *стрл.* к.: **абызтүти 2**.

**ТҮТИ I 1.** *тмн., кмшл., т.кам.-крш., чст.* к.: **абыз 1**; **2.** *минз.* ерак хатын-кыз кардәш (дальняя родственница); **3.** *минз., шрл.* к.: **түтәй 1**. Сеңнем қура жиләгеннән варинийы қайнатқан да, түти, аша әле, аша, ди. – *минз.* Түти исән чағында мин район газетасы аладыр идем. – *т.кам.-крш.* Мәтүк түти өйдә жүқ. – *нгб.-крш.*; **4.** *кргл., шрл.* өлкән хатын-кызга хөрмәтләп эндәшү сүзе (форма почтительного обращения к пожилой жен-

щине). Түти, азрақ борыч бир. – *кргл.* Түти, печән алмыйсыңмы? – *шрл.*

**адаш түти** *тмн.* бер исемдәге хатын-кызларга балалары тарафыннан әйтелә торган сүз (форма обращения к тёзке матери).

**аң түти** 1. *нгб.-крш.* олы яшьтәге кардәш хатын-кызга эндәшү сүзе (форма обращения к старшей родственнице). Аң түти, қайчан килдең?; 2. *т.кам.-крш.* к.: **абыстакам**. Сәwәләйдән аң түти киләсейе туйға.

**дәү түти** *каз.ар.-крш.* иренең апасына эндәшү формасы (форма обращения к старшей сестре мужа).

**жырақ түти** *мам., т.кам.-крш.* әнисенең апасына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре матери).

**кечти түти, май түти** *каз.ар.-крш.* иренең апаларына аерып эндәшү формалары (формы обращения к старшим сёстрам мужа). Кийәwенең тәтәләренә қайсына май түти ди, қайсына дәү түти, кечти түти ди.

**ТҮТИ II** 1. *тара.* тавык чебие (цыплёнок). Йемен түтиләргә бирсәң; 2. *хвл.* тутый кош (попугай). Былбыл микән, түти микән.

**ТҮТКӘЙ** *минз.* к.: **абыстакам**.

**зур түткәй, дур түткәй** *минз.* әтисенең апасына эндәшү формасы (форма обращения к старшей сестре отца).

**ТҮТҮ I: түтү әби** *кас.* к.: **кендекәй**. Түтү әби бул'ан, шул таптыра бул'ан, аты түтү бул'ан.

**ТҮТҮ II** *глз.* к.: **бала I, 2**. Каз түтү. Үрдәк түтү.

**ТҮТҮК** *трх.* к.: **пысқыш**.

**ТҮТҮТ** 1. *бәр.* үңәч (пищевод). Қайсы төшәм awыртадыр, буғазда бардырмы, түтүттәме; 2. *дәб.* к.: **ғолдордық**.

**ТҮҮ** 1. *перм.* к.: **тапау I, 7**. Пичминдә боз түгән ди әле икмәкне; 2. *срг., твр.* к.: **тewү**. Кызның түне (төене) түгән, анда күлмәк тә, сөлгө дә. – *срг.* Түйенчек түтем. – *твр.*

**ТҮФӘК** *әстр.* түшәк (тюфяк). Түфәк түши.

**ТҮШ I** *дәб.* к.: **йәүдә 1**.

**түш уқа** *бөре.* к.: **изү I: сакмай изү**.

**ТҮШ II** *чст.* түшкә (туша мясная). Бер каз түшем бар.

**ТҮШ III** 1. *злт.* к.: **тапawыч**; 2. *перм.* тимерче сандалы (кузнечная наковальня). Тимерне қыздыргач, түшкә қуйып мылтоқ беле суғабыз.

**ТҮШ IV** *дәб.* туш, боз өстенә чыккан су (полынья). Көн сywыққадыр, боз өстенә түш чыққан.

**түшәк I** (перина, тюфяк):

**йул түшәк** *тара.* вак чүпрәкләрдән жыелып, озынча сырылган түшәк – идәнгә утырганда түргә жәелә (длинный, узкий тюфяк, собранный из лоскутков – стелется в передней части комнаты, когда садятся на пол). Йул түшәк күбетем.

**түшәк awырywы** *твр.* үлем авыруы (смертельная болезнь).

**түшәк сақлау** *нгб.-крш.* к.: **тенәтү**. Чатаг әбейнең түшәген сақларға бардым.

**түшәк сикермәгә** *перм.* кияү булып керергә (проводить первую брачную ночь). Эшмитче (*ав. ис.*) кийәү билбywлар бәйләп килде түшәк сикермәгә.

**утау түшәк** *тара.* яңа өйләнешкән кыз белән егет өчен егет ягында әзерләп куелган түшәк урыны (постель, приготовленная для новобрачных в доме жениха). Кийәү йаққа килгәц утау түшәк була. Утау түшәк қырық көн булған, йеңгәсе абслуживат′ итә, башқа кеше керми алар йанына. Кийәү белән килен қырық көн айырым йәшәгәннәр, аны утау түшәк дигәннәр, урынны жәйеп қуйғаннар. Утау түшәк була кийәүдә.

**ТҮШӘК II** *срг.* бака ефәге (водоросль).

**ТҮШӘЛҮ** *минз., стрл.* тезелеп яту (ложиться, выстроившись в ряд). Түшәлделәр беразы, йоклыйлар. – *стрл.*

**ТҮШӘМ** *минз., стрл.* 1. туры лапасның өсте, әвеслек өсте (верх навеса). Жәй булса, кышкы ызбыруйны мендерә түшәмгә. – *стрл.*; 2. к.: **турамселек**. Түшәм дигән жир әл дә бар, ул қыйықсыз ғына, өстенә йафрақ, печән өйәбез, астында мал йөри. – *минз.*; 3. к.: **бастырма**. Түшәмдә эссе булды, печән өйдек. – *стрл.*

**түшәм асты** *минз., стрл.* к.: **турамселек**.

**ТҮШӘМӘ I** 1. *төм.* урын-жир, мендәр, ястык, түшәк (постельные принадлежности). Түшәмәләрне сантығ өстөгө өйеп қуйған; 2. *төм.* жәйгән урын (постель). Түшәмәдә аунап йатсаң пулама?; 3. *тбл.* идәнгә жәелә торган келәм (половик); 4. *әстр., тбл.* палас, киез (половик, войлок). Қыз түшәмә алып килә. – *әстр.*; 5. *тара.* корама белән сырган киез (войлок, стёганный из лоскутков).

**ТҮШӘМӘ II** *злт., стрл.* к.: **бастырма**. Түшәмәгә менеп йаттым. – *злт.*

**ТҮШӘНТЕК** *тара.* к.: **түшәк I: йул түшәк**.

**ТҮШӘНЦЕК** *тара.* киез матрас (войлочный матрац). Түшәнцек кеше йата торған. Түшәнцек була эценә пақты салып.

**ТҮШӘНЧЕК** *брб.д.* палас (половик). Поронғы wақыт, өсләренә түшәнчекләр суққаннар, итәнгә йәйәр өчен.

**ТҮШӘРЕЛЕП** *бгрс., кргл.* сузылып (вытянувшись). Йоқлағыз, түшәрелеп йатыгыз да. – *кргл.*

**ТҮШӘҮ I** 1. *т.кам.-крш.* к.: **түбә 1**. Жаңа өйләремнең түшәwе, Бер дә бер-береннән кин түгел (*хал. жыр.*). Түшәү белән идән буйамаган бит; 2. *тбл.* намазлык (коврик для молитвы); 3. *тбл., төм.* келәм (ковёр, покрывало).

**ТҮШӘҮ II** *карс., тбл.* урын жәю (стелить постель). Апаңнарга теге ызбага түшә, сез чыланында йатырсыз. – *карс.*

**ТҮШБАУ** *к.-уф.* к.: **зипун I**. Малайым ат жигә белә инде, түшбawын ғына тарта алмый, көче житми.

**ТҮШЕ** *тбл.* к.: **тапawыч**.

**ТҮШЕЛДЕРЕК** 1. *перм., злт., тпк., тмн.* к.: **күкрәк**. Элек түшелдерек кигәннәр. Әбиләр түшелдерек кигәннәр түш күренмәскә. Су жулы күрсәтә қыз бала, аныңа түшелдерек бирә. Йылы булырга эчтән түшелдерек кидем. – *перм.* Түшелдерек кимәдең исә, аш пешерергә дөрес түгел. Түшелдерек өләшә торғаннар ийе қәйнесеңнеләренә. – *тпк.* Түшелдерек бирә килен кан′насына. – *тмн.*; 2. *перм.* бавыргалык (подбрюшник).

**түшелдерекле күлмәк** *минз.* к.: **изү I: изүле күлмәк**. Түшелдерекле күлмәк күлмәкнең күкрәгенә генә тасмалар тотып, тәңкәләр тағып тегелә.

**ТҮШЕЛТЕРЕК** *тара., твр., төм.* к.: **изү I: сакмай изү**. Түшелтерек қатқаннар, малға көмөшләр теккәннәр, астына күсләре пар, иң суңқы wақ циберләр теккән. Түшелтерекне, мунцақны ницек қатасың, шулай қатып сәдәп белән түмәләнеп қуйган. Түшелтерек көмөшне түгәрәкләп тесеп қуйғаннар матурлыққа, қунаққа барсалар. Түшелтерек тигән песнең чалтун. Кийәүнең сур бүләге түшелтерек пулған. – *төм.* Түшелтерекнеке тамағы уйылган пылады, йелткәдән төймәле, алтта ағыйық, мунцақ қадай тығаннар түгәрәгенә. – *тара.* Порыңқыларның түшелтерек пулатыған ите. – *твр.*

**ТҮШЕНДЕРЕК** *әҗе., баст.* к.: **күкрәк I, 1**. Түшендерек кесәсенә ақча да, қасиданы да қуйа. – *баст.*

**ТҮШЛЕК 1.** *минз., мам., твр., брб.д.* к.: **изү I: сакмай изү**. Түшлек ул тәңкә тезгән, җалық-җолоғ итеп тора. – *минз.* Нугадан тегеп йағасын, йақшы матирийа алта, йағаға манит тақпайлар, түшлек йағаға йалғаған бит. Күңнәге иске булса да, түшлеге йаңадан пола. – *брб.д.*; **2.** *минз.* к.: **чылбыр 1**; **3.** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш., перм.* к.: **алынча**. Түтидә бар әле түшлек. Базарларға бардым, тәнкә алдым, Қәсиләгә түгел, түшлеккә (*хал. жыр.*). – *каз.ар.-крш.*; **4.** *твр.* к.: **күкрәк I, 1**. Түшлек көйләг әчендән кейеп қуйасың; **5.** *т.кам.-крш.* кечкенә балаларда алъяпкыч (передник – у детей); **6.** *к.-уф.* к.: **зипун I**.

**ТҮШТИ** *бөре.* к.: **күкрәк I, 1**.

**ТҮШТИМЕР** *к.-уф.* к.: **тапawыч**.

**ТЫБА** *лмб., чст.* к.: **тоба 1**. Тыбага батсаң әле. Тирән-тирән тыбалар, анда балық күп иде без килгәндә. – *чст.*

**ТЫБЫНДЫРЫК** *м.-кар.* к.: **томашка**. Без бутылка тыгынчыгы дибез, алар тыбындырык диләр.

**ТЫБЫРЧА** *дөб.* к.: **топырча**.

**ТЫWА** *тбл.* к.: **дива I**.

**ТЫWАЛЫҚ** *төм.* бөти (амулет, талисман).

**ТЫWАН** *төм.* к.: **бума I**. Пыwатлар қуй, тыwан пулыпты.

**ТЫWАР** *тбл.* к.: **тywар**. Песнең awылта тыwар кән пулаты.

**ТЫВАР** *тмн., кузн., күрш., карс., кас., тбл.* к.: **тywар**. Зур висаны әле йасадылар т(ы)варлар үлчәргә. Тывар чегендере тегел, шәкәр чегендере. Тывар бик йери әле, йәм-йәшел үлән иде. Моннан т(ы)варлар гына эчә, анда ару су. Тыварларны суйасын, инде ит күп була. Тывар йөргән өчен түлиләр иде. – *кузн.* Тывар карап тырам. Артта тыварлар кыва йөрдек. Тывар ийәсен таба (*әйтем*). – *тмн.* Тывар азбарда, ызба зылы. Тывар тытсаң, тиг утырма йук. – *күрш.* Тывар йабарга инде латасты дип ат'абыз. – *карс.* Тыwар сақлаған кеше ацықмайты. Тыwарға пүтпүлгә қуйам кәртепкәне. – *тбл.*

**ТЫВАР-КАРА** *лмб.* к.: **тywар-қара**. Сездә дәме тывар-кара асрилар?

**ТЫВАРУ** *хвл.* тугару (распрягать).

**ТЫWУ** *тара.* к.: **асрау 2**. Қәсер йөргәнемце, қәсер тыwып қуйам.

**ТЫWЦА** *әчк.* беренче тапкыр бозаулаячак тана (тёлка перед первым отёлом). Хәлле кеше қызына тыwца бәйләп йебәрә.

**ТЫWЫҚ** *тбл.* к.: **тубык**.

**ТЫWЫРУ** *твр.* әбилек итү (принимать роды). Үсе тыwырды баланы, инәлек ул.

**ТЫWЫШ** *төм.* к.: **кизләү 1**. Ағымны йылға төгөл, йир астындан цыққан тыwыш ул.

**ТЫҒУ I** *трх.* кию (одевать, одеть на себя). Өстөмә тықмаған куфтыларым бар. – *трх.*

**ТЫҒУ II: пич тығу** *трх.* мичтә сыра пешерү (варить пиво дома, в печи). Пич тығалар ыйы, сыра йасый инде, пичтә пешергәнне әйтәләр инде. Элек шулый әйтәләр ийе пич тығабыз, сыра асытабыз дип.

**ТЫҒУ III** *әстр., туб.-ирт.д.* мал-туарны каралтыга кертү (загнать скотину в хлев). Малны тықканма? Сыйыр тыға тығын йер йуқ. – *төм.* Киц йағын тыгабыз, иртәгесен бушатабыс, малны қарау кәрәк. Қайwан тығатқан йертә тawық торама? – *тбл.*

**ТЫГУ** *срг.* **1.** кию (обувать). Айакларыгызга тыккыз; **2.** кидерү (надевать). Апаңа күлмәк тыга иде анаң.

**ТЫҒЫЗ 1.** *нрл.* куе (густой). Урман безнең тығыз ийе ул wахытларда; **2.** *лш.* к.: **қатымыш**. Бик тығызлар алар, ақчаға байыдылар чистый. Бик тығыз булған ул, өчлөк ақча керсә, тотмаған, wақ ақча булса ғына тотқан.

**ТЫГЫЗЛАУ** *миш.д.* комачаулау (мешать). Тыгызлап йөрмә монда. Эш эшләргә тыгызлыйсың, бар кит мыннан. – *хвл.*

**ТЫҒЫЛҒАН: алтынға тығылған** *твр.* алтынга манылган (позолоченный).

**ТЫҒЫМ I.** *клм.* түшәм такталары (потолочные доски).

**ТЫҒЫМ II** *клм.* йомырка (яйцо).

**ТЫҒЫН** *клм.* елгада боз тыгылу (затор льда на реке).

**ТЫҒЫНЧЫҚ** *т.я.* томалагыч чүпрәк (тряпичная затычка для дымохода). Кече моржа тығынчығына икенче чүпрәк қуй әле, бусы бик қорымны. – *к.т.* Тыгыз (тыгын) йергә тығынчық (*әйтем*). – *кмшл.*

**ТЫГЫНЧЫК 1.** *хвл., мәл.* к.: **томашка**. Шишаның тыгынчыгы эчкә төшкән. – *хвл.* Шишага тыгынчык йаса. Чәпчәкнең тыгынчыгы төшкән дә сывы агып беткән. – *мәл.*; **2.** *карс.* к.: **төндек**.

**ТЫҒЫНЧЫҚЛАУ** *т.я.* hава чыкмаслык итеп тыгызлап томалау (заткнуть наглухо). Шышадагы чүпрәңне тығынчықлап қуй, айнымасын. – *к.т.*

**ТЫҒЫРЛЫҚ** *төм., тбл.* к.: **икара**. Тығырлықта күртем пәшкәгесне. Тыгырлықны усып игенце йорт. – *төм.*

**ТЫЗҒЫТУ** *злт.* котырту, коткы салу (подстрекать, подговаривать, портить отношения между кем-либо). Кеше тызғытып йөрмәсәң. Мыны Зиләгә дә, теге хатынға да әйтеп тызғытып булмый.

**ТЫЗЛӘҢГӘЧ** *м.-кар.* тоз савыты (солонка).

**ТЫЗЫҚ: тызық тығу** *злт.* к.: **тызғыту**. Тызық тықма инде, әйбәт кенә йәшәсеннәр.

**ТЫЙ** *минз.* туй (свадьба).

**ТЫЙА'** *кас.* **1.** тояк (копыто); **2.** к.: **табан I, 2**.

**ТЫЙАҚ** *кмшл., чст.* к.: **тыйа' 1**.

**дәwә тыйагы, кәҗә тыйагы, сыйыр тыйағы**

*чст.* төрле формада пешерелгән камыр ашы (булочка, плюшка).

**ТЫЙАНА** *кмшл.* 1. бөтенләй юкка, юк өчен, сәбәпсез (зря, совершенно зря, без причины); 2. к.: **тикмә**. Әлфийә ул тыйана ғына кергән кебек керде, аның ғырамытасы бар инде үзе.

**Т'ЫЙАНА: бер т'ыйана** *шрл.* бик аз, кечкенә (немножко; малюсенький).

**ТЫЙБАҚЛАУ** *тара.* котыртып читкә китү (раззадорить и уйти в сторону). Сүс қалыңға китсә, тыйбақлайсың.

**ТЫЙҒАЛУ** *брб.д.* сөялү (прислониться, прижаться).

**ТЫЙҒЫС** *тпк.* өйнең тышкы нигез такталары (доски, которыми обшита завалинка). Тыйғыс бу, туфрақ салабыз қышқа нигезгә.

**ТЫЙДАУСЫЗ** *к.т.* к.: **баштақ**.

**ТЫЙЛЫҒУ** *дөб., мам., к.т.* к.: **тилығу 2**. Борно қанады, салқын сыу белән тыйлықты қаны. Бу арада тыйлығып тора иде (сызлау), йылан дарувы белән уған идем. Бармағым кистем, и ақты қан, ақты қан, жудылар (йод) сөрткәч кенә тыйлықты. – *к.т.*

**ТЫЙЛЫҚТЫРУ** *дөб.* туктату, әкренәйтү, хәрәкәттән калдыру (останавливать, замедлить).

**ТЫЙРАҚ I** *тбл.* 1. житез, пөхтә (проворный, аккуратный); чаг.: **чирақ**; 2. нык, таза (здоровый, крепкий).

**ТЫЙРАҚ II** *дөб.* сыйрак (голень). Кич белән көтүче хатынның тыйрағы ташый.

**ТЫЙТАҚ-ТЫЙТАҚ** *лш.* титаклау (ходить прихрамывая на одну ногу). Ул да тыйтақ-тыйтақ әле, айағы ақсап жөри.

**ТЫЙУ** 1. *нрл.* ябу (закрыть). Төтен чыға, әллә кечкенә морҗаны тыйдыңмы; 2. *перм.* туктау – яңгыр турында (прекратиться – о дожде). Иртәнге жawын көн буйы жawар дисең мәллә, тыйа да ул. Әнә қый, тыйды да инде жawын.

**ТЫЙУСЫС** *тбл.* тотнаксыз (невыдержанный).

**ТЫЙЫЛЦАМ** *тбл.* иркенләп (спокойно). Тыйылцам утырып кәпләшеп алайық.

**ТЫЙЫН** *кас.* тиен (белка).

**ТЫЙЫНУ** *минз.* тап булу, әләгү, юлыгу (попасть, прийтись, встретиться). Инәй сөткә тыйынды.

**ТЫЙЫС** *тара.* к.: **туйас**.

**ТЫҚҚЫЧ** *т.кам.-крш.* тыгыз (тесно).

**ТЫҚҚЫЧЛАНУ** *т.кам.-крш.* тыгызлану (тесниться, потесниться). Монда бик тыққычланған ыйы, тыққыч ыйы, өч қужалығ ыйы.

**ТЫКМА** *м.-кар.* к.: **бүсә**. Тавык, үрдәк, каз тыкмасы.

**ТЫКМАСА: тыкмаса сукыр** *чпр.* к.: **дөмә-дөм 1**. Моның апасы бар ыйы тыкмаса сукыр.

**тықмач** *кмшл.* токмач (лапша):

**шүре тыкмач** *дөб.* к.: **токмач: шүре токмач**. Син шүре тыкмач та алғансың икән, мин алмадым.

**ТЫКМАЧ** *карс.* дүртпочмаклы итеп киселгән токмач (лапша, нарезанная квадратиками).

**дүрткел тыкмач, карга тыкмачы** *шрл.* к.: **тыкмач**.

**ТЫҚТЫМАЛ** *төм.* тиктомалга (ни с того ни с сего).

**ТЫКТЫМАТ** *чпр.* бөтенләй (окончательно). Йаңгыр бер йауса, тыктымат үткәрерлек итеп йawa иде.

**ТЫҚШЫНДЫРУ** *мам.* сыендыру (дать место около себя). Без базарда торғанда ничектер кешене тыкшындырабыз.

**ТЫҚЫ** *кргл.* к.: **тике**.

**ТЫҚЫWЫЧ** *перм.* к.: **атawыч**.

**итмәк тыкыwыч** *перм.* ипи калагы (тестомесилка).

**май тыкыwыч** *перм.* к.: **атawыч**.

**ТЫКЫЛДАУ** *карс.* шакылдату (стучать, стучаться). Тук-тук ишектә бер кеше тыкылдый.

**ТЫҚЫРЫҚ I** *лш.* өйнең арт ягыннан керү өчен ясалган капка һәм өй ишеге (воротца сзади дома). Ашны теге тыкырыкта ғына ашарбыз, анда жарау хәзер.

**ТЫҚЫРЫҚ II** *бәр.* к.: **уйнау: сақлы уйнау**.

**ТЫЛАЖҢЫН** *к.т.* к.: **лятчә II**. Ы-ы, тылажын маржа, қай арада ишеткән дә кибеткә әйбер қайтқанны, қай арада килеп тә житкән.

**ТЫЛАҚЫЙ** 1. *блт.* жилбәзәк (непостоянный, легкомысленный); 2. *т.кам.-крш.* лыкылдык, авызында сүз тормый торган, күп сөйләүчән (болтун). Бәчүк қатны тылақый да инде шул, аңар берәр нәстә сөйләгәнче урамға чығып қычқыруын артық.

**ТЫЛҚЫУ** *злт.* 1. имчәкне тарта-тарта сөт имү – бозау турында (при сосании дёргать вымя – о телёнке). Йылый-йылый тылқый бала, инәсенең сөтө йуқ; 2. к.: **талқу 1**. Тамам тылқыдылар инде, малайдан белергә тырышалар.

**ТЫЛҚЫШУ** *т.кам.-крш.* катнашу (вмешиваться). Ул да сүзгә тылқышқан була бит.

**ТЫЛДАҚ** *тбл.* 1. телчән, күп сөйли торган (говорливый, ловкий на язык); 2. такылдык (болтун).

**ТЫЛТЫҚ I** *төм.* бүдәнә, бытбылдык (перепёл, перепёлка).

**ТЫЛТЫҚ II** 1. *тбл., брб.д.* сакау (картавый, косноязычный); 2. *тбл.* биртәк (заика).

**ТЫЛЫҚ** *төм.* к.: **маман 1**. Бер апа қыцқырады, ул тылық ишетмәйте.

**ТЫЛЫМ** 1. *к.т.* учма, тотам (пучок, клок). Тылымы белән ағарған чәчем, бармақ қалынлық тылымы жолқонған чәчнең; 2. *лмб., кузн.* к.: **тезмә I**. Артка тылым тегәләр баштан кийеп, ыскывоз чәчләрен тыгалар да шал тылымнар ман, кашпаулар ман ураг урганнар. – *кузн.*

**ТЫМ I** *чст.* аңгыра, миңгерәү, белексез (глупый; невежда); чаг.: **ат'акыш 1**. Элек халық тым иде.

**ТЫМ II: тым ак** *чпр.* бик ак, ап-ак (белый-пребелый, очень белый).

**тым сукыр** *мәл.* к.: **дөмә-дөм 1**.

**ТЫМАБАЛАВЫЗ** *хвл.* умарта корты жилеме (прополис).

**ТЫМАЙ** *тпк.* к.: **қолақай**.

**Т'ЫМАЙ-Т'ЫМАЙ** *шрл.* тәпи-тәпи (ножками – о детях). Кызым т'ымай-т'ымай килә вет.

**ТЫМАР** *тара.* догалык (амулет, талисман). Әбәм таға тыған тымарны.

**ТЫМАТ** 1. *чпр.* күп (много). Тымат йазды бу беген; 2. *мәл.* нык итеп, ныгытып (плотно). Ишекне тымат йап.

**ТЫМАЧИ 1.** *стрл.* к.: **тумачи 1.** Ике туганны тудыка диләр, әченчегә әләнсә, тымачи; **2.** *стрл.* к.: **йакындаш.** Нинди туган булсын, тымачига әйләнгән инде; **3.** *глз.* бергә үскән иптәш кызларның бер-берсенә эндәшү сүзе (форма обращения друг к другу девушек, которые росли вместе).

**ТЫММАУ** *перм.* эндәшмәү (молчать, не разговаривать). Бу тыммады шулай тигәч тә.

**ТЫМПИ** *том.д., тбл.* к.: **дәшмәки.**

**ТЫМРАУ** *шрл., кузн.* к.: **томрау 1.** Тагы тымрый башлады энде, йаңгыр булыр. – *кузн.*

**тымрап йаwу** *кузн.* күк йөзенең төмсәләнеп явуы (идти дождь обвалакивая тучами, хмуро).

**тымрап қарап тыру** *кмшл.* тутырып карап тору (смотреть пристально с особым выражением). Мескен эт тымрап қарап тыра.

**ТЫМТЫКЛАУ** *чст.* күбрәк үзенә алырга тырышу (стараться побольше взять себе). Йегет йагын тымтыклыйлар мында.

**ТЫМЫWЫН** *төм.* сиздермичә (исподтишка, втихомолку). Қәтемгә тымыwын йөргәннәр, ураса ошлаганнар.

**ТЫМЫЗУ** *кргл.* тынычландыру (успокоить). Бақырды хатта сыйыр қапқадан чыққач, ничек тымызырга белмим.

**ТЫМЫЗЫҚ** *кмшл.* к.: **дәшмәки.**

**тымызық тығу** *дөб.* к.: **тызғыту.**

**ТЫМЫЗЫҚ 1.** *мәл., чпр.* тыныч, сабыр (спокойный, выдержанный). Бабай безнең бик тымызык кеше, йукка-барга кызмый. – *мәл.* Әнәсе бик тымызык кына кеше, кешегә белгертми. – *чпр.*; **2.** *лмб.* караңгы чырайлы (хмурый, мрачный, неприветливый). Кәҗәләре килсә, ул ачык, кәҗәләре килмәсә, тымызык ул катын; **3.** *м.-кар.* томанлы (туманный; туманно); чаг.: **болаңгыр 1.** Тымызык күренә күзләргә (күзлексез); **4.** *мәл., кузн.* коры суык, чатнама суык (трескучий мороз). Беген тымызык сывык, чыдап булмый. – *кузн.*

**ТЫМЫҚ** *лш., эчк., төм., тбл.* җилсез, тыныч hава (тихая, безветренная погода). Бүген балық әләгер, көн тымық. – *эчк.* Бер генә дә тымық кен җук, гел dawыл, гел dawыл инде. – *лш.* Йел пулса, йаумайтхын, тымықтан килсә, йаwайтхын. – *төм.*

**ТЫМЫҚСЫН** *клм.* акрын, тыныч (тихоня). Ул бик тымықсын булған.

**ТЫМЫЛЫП** *стрл.* тынычланып (успокоившись). Тымылып йоклап киткән.

**ТЫМЫРАТЫП: тымыратып қарап тору** *дөб.* к.: **тымрау: тымрап қарап тыру.** Фәни тымыратып қарап тора, баш селектем.

**ТЫМЫРСЫҚ I 1.** *кргл., эчк., төм.* к.: **бөркәү 1.** Бигрәк тымырсық өйләре. – *эчк.* Торасым килмәде, өйләре тымырсық. Тын алыйг әле әзерәк, тымырсық өйдә, ишекне ач. – *кргл.*; **2.** *минз.* җилсез, давылсыз, тыныч hава (тихая погода). Бүген тымырсық, салқын.

**ТЫМЫРСЫҚ II** *төм.* к.: **дәшмәки.**

**ТЫМЫРУ** *дөб.* ыргыту, ташлау (бросить, выбросить, выкинуть). Тымырыйың бақчаға син аны (чүпне).

**ТЫМЫТУ 1.** *төм.* туктату (остановить); **2.** *тбл.* әйттермәү (заставить молчать).

**ТЫМЫШ** *тбл.* аз сүзле (молчаливый, неразговорчивый); чаг.: **дәшмәки.**

**тын I** (дыхание):

**тын ычу** *глз.* к.: **тыну 1.** Сабантуй wакытында кырга чыктылар, утырып ашатырлар ыйы, сайрашырлар ыйы сыра ычып, тын ычып йерерләр ийе.

**тынға утыру** *чст.-крш.* бәке янына утырып, елның ничек киләсен юрау йоласы (один из способов предсказания судьбы: сесть около проруби и угадать характер предстоящего года). Су буйына тешкәч, бәке җанына тынга утыралар, дөнжа тынын тыңныйлар, җыл ничек килә дип җурыйлар, чана – җакшы җыл, эт өргәнне җаратмыйлар, тавыш ишетүгә сикереп тыралар.

**тын да алминца** *чст.* бер сүз дә әйтмичә (не сказав ни слова). Бертуган ази мине килешкән, үзе тын да алминца базарга китте.

**тын җебәк** *м.-кар.* нечкә ефәк (тонкий шёлк). Башы бөркәүле тын җебәк була.

**тын тартмау** *минз.* гаҗәпләнмәү (не удивляться). Тын да тартмады ул.

**тыны чыгу** *нокр.* искерү, кибү – ипи турында (засохнуть – о хлебе); чаг.: **кизәрү.** Кәсмәгез искерә, тыны чыға.

**ТЫН II** *мам.* к.: **тына 2.** Бер тын әзрәк җаумый торды.

**ТЫН III** *төм.* якын (близкий). Майра минең инәм, ул миңа тын.

**ТЫНА 1.** *чпр., чст., чст.-крш., т.я.-крш., трх., минз., злт., стрл., м.-кар.* мәртәбә, тапкыр (раз); чаг.: **пайма.** Ике тына Ул'анга барган иде. – *чпр.* Ике тына ашап бетерде. Ике тына шылай. – *мәл.* Бер тына шылай гармун уйный, йыладым да инде. Бер әткәч, игенче тына кеше үзе дә белә. Үләннәр күтәрелми шул, былтыр ике тына чаптык. – *чст.* Аза энде бу дуңгыз бер тына, әрәтеп бетерәсез аны. – *т.я.-крш.* Ничә тына бал'ниска кереп җатты. – *чст.-крш.* Чөгөндерне өч тына матиклыйлар. Ике тына җауған йақшылап җаңгыр. Ике тына, өч тына пешерәләр. Ике тына бүлеп салырмын үзем. – *трх.* Сафыйа әби игез бәбәй таба торганыйы, өс тына икешәрне тапты. – *злт.* Бер тына да уқымаган. – *минз.* Бер-ике тына барган ийем. – *стрл.* Ике тына барып кат'тем. – *м.-кар.*; **2.** *трх.* вакыт (время). Бер тына тынып тырган ийе дә.

**ТЫНАҚ** *тбл.* буйсындырылган, ияләштерелгән (укрощённый, дрессированный).

**ТЫНАНУ** *яүшт., твр.* к.: **тыну 1.** Йатыб алыгыз, тынанығыз. – *яүшт.*

**ТЫНАП** *миш.д., кас.* к.: **тына 1.** Ике тынап 'ереп чы'тым үзени. – *кас.* Икенче тынап йырта инде вын! Биш чакрым, өч тынап бара. – *кузн.* Мең тынап йерергә вакытым йуктыр. Ике тынап бардым Мескүгә. Беренче тынап саварга бардым. – *лмб.* Апа, ничә тынап йаңылышкан. – *мәл.*

**ТЫНАРСУ** *брб.д.* еш сулау, тиз-тиз сулау (дышать часто, быстро).

**ТЫНАУ** *кузн.* томау (насморк).

**тынау алу** *кузн.* к.: **томау: томау алу.** Ул каста, борынын тынау алган, бик йүткерә.

**ТЫНҒЫЛЫ** *злт.* тыныч (спокойный). Безнең бу Шәрип дигән awыл – тынғылы awыл, Мийәшәгәр тынғысызрақ awыл былыр, дигән.

**ТЫНДЫҚЛАНУ** *перм.* тынычлану (успокоиться, получить покой).

**ТЫНДЫҚСЫЗ 1.** *перм.* тынгысыз, борчылучан (беспокойный). Өскә бер эш йөкләнсә, шуны эшләп бетергәнче тындыксыз буласын; **2.** *злт.* тынычсыз (неспокойный).

**ТЫНДЫ'СЫЗ** *кас.* к.: **тындыксыз 2.**

**ТЫНДЫҚСЫЗЛАУ** *злт.* тынычсызлау (беспокоить, тревожить). Тындыксызлыйң нийә кешене?

**ТЫНДЫҚСЫЗЛЫҚ** *злт.* тынычсызлык, борчу (беспокойство). Һәр кешенең тындыксызлыгы была.

**ТЫНДЫР** *әстр.* ипи пешерү өчен ачык учак (открытый очаг для хлебопечения).

**ТЫНДЫРУ 1.** *каз.ар.-крш., нрл., кмшл.* ял бирү, ял иттерү (дать возможность отдохнуть, дать отдых). Мине тындырамыни суң ул. – *каз.ар.-крш.* Атларны тындыра-тындыра җир суқалыйбыз. – *нрл.*; **2.** *күрш.* киметү, сүрелдерү – ут турында (убавить, уменьшить – об огне). Варинйа ташты, тындыра тешәр иден.

**ТЫНМАУ** *перм.* к.: **тыммау**. Теге бер дә тынмый, җawап бирми. Үләрен сизеп тынмый йөри икә, эче йанып.

**ТЫННАКЛЫ** *глз.* тыңлаулы (послушный). Биг ыланнарым тыннаклылар иде.

**ТЫННЫ** *м.-кар.* к.: **тике**. Шуның тынны кар басты.

**ТЫНУ 1.** *миш.д., т.я.-крш., мам., нокр., тара.* ял итү (отдыхать). Тынарга кирәк инде йул арты. – *кузн.* Бер-ике сотка йөри, бер-ике сотка тына. Утырыгыз, тынығыз. – *хвл.* Йатып тырыгыз, тынарсыз. Тына төшәр идегез. – *лмб.* Тынам быраз, бик шипка килдем. – *тмн.* Тынып алик әле. – *т.я.-крш.* Қышын бара тынарга бабай Кавказ йағына. – *нокр.*; **2.** *т.я., хвл., мәл.* тынычлану (успокоиться, получить покой). Китсә, әнисе тынар инде. – *хвл.*; **3.** *тбл.* тын алу, сулау (дышать).

**тыну кене** *тмн.* ял көне (день отдыха). Атнарас кен китәләр Питергә, тыну кене.

**ТЫНЦУ** *тара.* бизү, тую (надоедать). Тынцып киткәнгә алып ташлайым сырғаны.

**ТЫНЦЫҚ** *тара., тбл.* тынчу, бөркү (затхлый, спёртый). Ишек ацық торсынцы, тынцық пулып китте. – *тара.* Тынцық көн. – *тбл.*

**ТЫНЧЫЛ** *шрл.* күндәм (послушный).

**ТЫНШАЙУ** *әстр.* к.: **тыну 1.**

**ТЫНЫҒУ 1.** *перм., к.-уф., брб.д.* к.: **тыну 1.** Элек җыллар буйына тыныгайы. Тыныгың инде бераз, җатыб алың. Йегет тынычырға диб йатқан. Җатып тыныгыб алың арығач та. – *перм.* Тыныгыб алыйық әле. Җитәр, озақ тынықтық, эшкә тотынырға wақыт. – *к.-уф.*; **2.** *тара.* тынып тору (притихнуть, успокоиться). Ат тыныққан wақытта ул та тыныға, йәме.

**ТЫНЫҚ** *минз.* к.: **тымық**. Иртән тынық, кичен тынық, Бик шәфқәтле айларың (*хал. җыр.*).

**ТЫНЫҚТЫРУ 1.** *к.т.* к.: **дымайту**. Җаңгыр әз җауса да, җирне тынықтырды быраз; **2.** *к.-уф.* ял иттерү – атларны (дать отдохнуть – о лошадях). Атларны бераз тынықтырып алыйқ әле, арғаннар.

**ТЫНЫЧ** *кас.* тын, сулыш (дыхание, вздох); чаг.: **йаналыш 1.** Тынычым 'осола.

**ТЫНЫЧЛАУ** *перм.* к.: **тыну 2.** Ғабдулланың, бу сүзләрне ишеткәч, күңеле тынычлый.

**ТЫНЫШ 1.** *хвл., әстр.* к.: **тыныч**. Тыныш алалмыйм, күкрәгем кыса. – *хвл.*; **2.** *лмб.* кушымта (припев). Тынышы ничек бу йырның, йәдләмисеңме?

**ТЫҢ I: тәрәз тыңга бару** *срг.*, **тың тыңнау** *перм.* берәр эшне фаллау өчен кичен тәрәзә артына барып, өйдәгеләрнең ни сөйләгәннәрен тыңлап йөрү, тынга йөрү (с целью гадания ходить вечером к окну подслушивать, о чём говорят дома). Тың тыңный торғаннар ыйы. Тәрәз тыңга барасын, если йахшы хабар сүләсәләр, киңәнеп китәсен.

**ТЫҢ II 1.** *себ.* каты, коры (твёрдый; сухой). Сас арата тың йерләре тә пар; **2.** *себ.* таза, ныk (здоровый, крепкий). Пабай тыңрақ wахытта ыстыроит' иткән ийе. – *брб.д.* Әле алар тың ите, әйбәт. Ағацны ай башынта йыгу кәрәк, тың пулады. – *төм.* Әwәлге халық тың булған. – *твр.*; **3.** *тара.* хәлле (состоятельный, зажиточный). Тыңрақ халық тың йәшәгән; **4.** *себ.* бик (очень). Оло ғасаннар пулган, тың тәмне пулайте шантай пылаулар. – *төм.* Тың тирән күлебес. Тың тәмне. Тың эшләй. Ике қысымны кийәүгә пиреп, тың уңтылар. Аңчы булган кеше килгән дә Нирда буйына, тың палықлы йылға икән, тигән. – *төм.*; **5.** *твр., төм.* күп (много). Awырчылықлар тың булты суғыш wахытта. – *төм.*

**тың ацу** *төм.* шар ачу (открывать настежь). Ишекне тың ацып қуйыпсың.

**ТЫҢҒЫЧ** *бәр.* тыныч (спокойный). Тушыңғар чықсаң, тыңғыч булыр дип димләп җибәрделәр. Бик тыңғыч җиргә кергәнсез.

**ТЫҢҚАУ** *блт.* тыңкыш (гнусавый). Борын белән сийләшкән кешене тыңқау диләр.

**ТЫҢНAWЫК, ТЫҢНAWЫКЛЫ** *срг.* тыңлаучан, күндәм (уступчивый, послушный). Безнең Халим тыңнawык кеше ул. Болар бик тыңнawыклар икән. Ул вит бик тыңнawыклы. Аннан Искәндәргә аттем дә, китте, тыңнawыклы ул. Ул бик тыңнawыклы иде ылан wакытта.

**ТЫҢНАКЛЫ** *лмб.* к.: **тыңнawык**. Бик тыңнаклы иде кызы.

**ТЫҢНАП: тыңнап тору** *мам., каз.ар.-крш., хвл., срг.* бireп тору (одолжить). Бер җегерме сум тыңнап тор әле, Гришкә дус. Мамық шәлеңне бер генә көнгә тыңнап тормассыңмы? Мунча тыңнап тору. – *мам.* Кыдага барамын, тыңнап тыр каст'умыңны. – *срг.*

**ТЫҢНАШМА** *тбл.* к.: **дәшмәки**.

**ТЫҢСАЛУ** *тбл.* чайкалу, тибрәнү (качаться, колебаться).

**ТЫҢСУ** *төм.* ныграк (прочнее). Тыңсу булсын тибес наскиға.

**ТЫҢСЫЗ** *карс.* тыңламаучан, буйсынмаучан, итагатьсез (непослушный, непокорный).

**ТЫҢ-ТУЛЫ** *дәб.* шыгрым, туп-тулы (битком, полным-полно). Кибете тың-тулы әйбер.

**ТЫҢУ 1.** *твр.* ныгу, рәтләнү (поправляться, выздоравливать). Тыңып киттем, тасарып эшлим; **2.** *тбл.* кату (затвердеть). Йер тыңып бара.

**ТЫҢЧЫ** *кузн.* к.: **тыңнawык**.

**ТЫҢЫТУ** 1. *тбл., төм.* ныгыту (укреплять). Ишекне тыңытып куйаты. – *тбл.*

**ТЫПМА-ТЫК** *стрл.* к.: **дихай 1**. Тыпма-тык кешенең чәчен кисәргә, димен.

**ТЫПСЫҚЛАУ** *тара.* к.: **тызғыту**.

**ТЫПТОМАЛҒА** *т.я.* к.: **тикмә**. Тыптомалға сүгеп ташлады. – *к.т.*

**ТЫПТОМАЛГА** 1. *чпр.* к.: **тикмә**; 2. *хвл.* к.: **дуwамал 1**. Тыптомалга барып чыктым бүре эстенә.

**ТЫП-ТЫЙЫҚ** *тара.* шыплап ябылган (наглухо закрытый). Тып-тыйык, узорлы, түгәрәклерәкле була.

**ТЫП-ТЫМА** *глз.* япа-ялгыз (один-одинёшенек). Тып-тыма үдә берүзем утырам.

**ТЫПТЫМАТ** *чпр.* к.: **дихай 1**. Каан килеп цыккан тыптымат кына.

**ТЫПЧУ** *стрл.* типчү (метать, намётывать, шить мелкими стёжками). Тыпчып булса да бир дим, тулкы күлмәг итеп кидер.

**ТЫПЫН-ТЫПЫН** *минз.* әкренләп, әкрен генә (осторожно, тихонько). Ул тыпын-тыпын әйләнеп қайтқанчы, бу баздан бал апчығып кийәwе белән чәй эчә.

**ТЫПЫРИН** *стрл.* к.: **йыбытқы**. Безнең кебек тыпырин хатын түгел, бик уңган, йылан айагы кискән.

**ТЫРА: тыра салып** *шрл.* к.: **дихай 1**. Мәңлескә бармагач, тыра салып кына йырлап булмый.

**Т(Ы)РАЙ I** [*рус.*] *хвл.* к.: **йәпләшкә**.

**ТЫРАЙ II: озон тырай** *дөб.* к.: **торақ: озон торақ**.

**ТЫРАЙАТ** *минз.* к.: **торайат**.

**ТЫРАЙ-ТЫРАЙ** *лш.* яшьләр уены: кәс тибеп уйнау (один из видов молодёжных игр).

**ТЫРАЙУ** *тара., тбл.* катып калу, үлү (околеть). Башына суқтым ите, тырайып китте. – *тара.*

**ТЫРАК** *миш.д., хвл.* олтырак (стелька). Чабатыңа тырак кирәк. – *тмн.* Цабатага тырак куйалар. Тулкы тырагы бик әллә ничек тора. – *срг.* Биштән үргән цабата, ни булса тырак куйа. – *әҗе.*

**ТЫРАҚМАЛ** *тбл.* к.: **өшөмкә**. Тырақмалны қасып ашаган йас пашы, көскөлөк қалаты қуй.

**ТЫРАКМАН** [*рус.* крахмал] *глз.* к.: **өшөмкә**. Мына йералма казисын ич, ул череп кала инде туфырак эчени, аны арчисын, аның тырақманы қала, ул бик тәмне (сугыш вакытында).

**тыракман т′апен′а** *глз.* к.: **кәлҗемә 2**. Тыракман т′апен′а йасап ашагаладык.

**ТЫРАҚ-ТЫРАҚ: тырақ-тырақ уйнау** *дөб.* сызыкташ уены (игра в классики). Тырақ-тырақ уйный торган идек.

**ТЫРАН-БЫРАН** *каз.ар.-крш.* пыран-заран (в пух и прах). Улы белән киленнең тормышларын тыран-быран китерде шул әби.

**ТЫРАНТАС: канатлы тырантас** *чст.* үрәчәле арба (тележка с отводами). Без канатлы тырантаска утырып килдек килен булып тешкән чакта.

**Т(Ы)РАПАЧ** [*рус.* драпач] *минз., стрл.* к.: **дырапач**. Агач тырмалар, агач трапачлар белән җир бик начар эшләнелде. – *стрл.*

**Т(Ы)РАТАЙКА** *трх., хвл., чпр.* к.: **йәпләшкә**. Тыратайка ике тәртәлийе, ике көпчәклийе, чыбыққа барадыр ийек. – *трх.*

**ТЫРАТАШ I** *тмн.* к.: **торайат**.

**ТЫРАТАШ II** *чст.* балбал (таш һәйкәл). Тыраташ тыра тырган таш ул, пытилары бар аныкы, кыз бала булган ул, цәце бар.

**ТЫРАХ** [*рус.*] *злт.* олы юл (тракт). Бик йырақ түгел, тырах белән китең.

**ТЫРАХМАН** [*рус.* крахмал] *трбс.* к.: **өшөмкә**.

**ТЫРАЧӘЙ** *кас.* бик ерак туган (очень дальний родственник); чаг.: **тыраташ I**. Тырачәй пырашшай була.

**ТЫРАЧИ** *тмн.* к.: **торачи**.

**ТЫРБА I** [*рус.*] *клм.* моржа (труба).

**ТЫРБА II** *перм.* ачы торма (редька).

**ТЫРБАЙУ** *лш.* тәкәбберләнү (возгордиться, высокомерничать). Үзен-үзе әллә кемгә қуйып җәри тырбайып. Нигә тырбайасың, кирәгеңне бирермен.

**ТЫРБАЙЧЫҚ** *мам.* к.: **тырбық**.

**ТЫРБЫҚ** *лш.* һавалы, тәкәббер (высокомерный, гордый). Дөн′йа күргән кеше тырбық булмый кешегә, кече күңелле була. Прастуй кешеләр икәнсегез, бер дә тырбық түгел икәнсез. Алар тырбығырақ, кертмәсләр қызларны.

**ТЫР-БЫР** *лш.* сирәк, анда-санда (редко, там и сям). Тыр-быр тишелгән чәчкән қарабодайы.

**ТЫРҒАНЫ: бар тырғаны** *кмшл.* бар белгәне; һәрвакыт, гел (постоянно, беспрестанно). Бар тырғаны сырау да зарлану, бер дә бире(р)гә түгел.

**ТЫРДЫБАЙ** *кмшл.* килделе-киттеле, уйламыйча эшләүче (взбалмошный, несерьёзный). Малайым ақыллы, тырдыбай түгел, төптән уйлый.

**ТЫРҖЫҚ** *злт.* киң һәм җәенке – борын турында (приплюснутый нос).

**ТЫРҚАННАУ** *кргл.* бер аякта сикерү (прыгать на одной ноге). Тытынды тырқаннарга.

**ТЫРҚУ** *перм.* к.: **арусызлау**. Тимә, тырқыйсың чүмичне.

**ТЫРҚЫЛДАУ** *перм.* тыкылдау (тараторить); чаг.: **лайгу 2**. Тырқылдамаң әле, тыңнап қына торығыз.

**ТЫРҚЫННАУ** *к.т.* аксаклау (хромать). Тырқыннап җәри әле. Тырқыннаған көйө җәйәү қайтқан.

**ТЫР'ЫНСЫЗ** *кас.* к.: **қошбәтсез**.

**ТЫРҚЫШ** *перм., к.-уф.* пычрак, шапшак (грязный). Қулыңны жумый ашама, қулың тырқыш синең. – *перм.* Эчмә, тырқыш су ул. – *к.-уф.*

**ТЫРҚЫШЛАУ** *к.-уф.* пычрату (пачкать, запачкать).

**ТЫРЛАК: мал тырлагы** *стрл.* к.: **аран 1**. Атка азбар булган анарга, мал тырлагы үзенә башка.

**ТЫРЛАУ** *т.кам.-крш.* бүлеп алынган җир, участок (земельный участок). Быйыл тырлауга киндер чәчтек.

**ТЫРМА I** *минз.* туку станында озаткыч озынлыгындагы җеп үлчәү берәмлеге (единица измерения нитки, соответствующей длине сновальной рамы в ткацком деле). Бу палас өч тырмалы. Бер тырмаға басма йарым җеп кирәк. Кәтүк белән җеп җөрөтәләр, шул ағачтан ничә тырма сала инде.

**сыйфат тырмасы** *минз.* җирдә калган башакны җыя торган тырма (грабли для сбора оставшихся на земле колосьев).

**тырмаға зату** *т.кам.-крш.* җепне озаткычка сару (сновать пряжу на сновальную раму).

**тырма тартучы** *мам.* өченче яшькә кергән ат (лошадь, которую можно впрячь в борону).

**тырма II** *перм.* торма (редька):

**сары тырма** *перм.* кишер (морковь).

**тырма үләне** *т.кам.-крш.* к.: **тырнawык.**

**ТЫРМАWЫЧ** *чст., чпр., клм.* к.: **грәплә.** Халисә, мин сиңа тырмawыч алып килергә куштым. Тырмawыч кирәк печән җыйарга. – *чст.* Бәрәңгене чәчкәч эч атнадан сың тырмawыч белән себерәбез. – *чпр.*

**ТЫРМАТУ** *перм., кмшл., минз., злт., стрл.* к.: **себерү 1.** Ағач тырма булган элке, җирне тырматқаннар. Суқа белә сөрә дә, тырмата да, қул белән чәчә. Чәчкәч ат белән тырматалар (элек). – *перм.*

**ТЫРМАУ** *перм.* тырнау (царапать).

**тырмыш** *кмшл.* тормыш (жизнь):

**тырмыш алу** *лмб.* аерылып китү (развестись). Тырмыш ала да әнисенә китте киленем.

**тырмыш җыйу** *лмб.* башка чыгу (отделиться, начать жить отдельно). Бер ылым үләнеп тырмыш җыйды, үзенә үү куйды.

**тырмыш эзләү** *лмб.* к.: **тырмыш алу.** Салган катны тырмыш эзләргә килгән.

**ТЫРНAWЫҚ** *бөре.* торнабаш (аистник, грабельник).

**ТЫРНAWЫС** *кас., злт.*, **ТЫРНAWЫЦ** *туб.-ирт.д., яүшт.*, **ТЫРНAWЫЧ** *трх., перм., бөре., нрл., т.я.-крш., төм., твр., брб.д.*, **ТЫРНAWЫШ** *әстр.* к.: **грәплә.** Тырнawыч белән җийабыз. – *перм.* Элке тимер тырнawыч белән дә тырнадық бақчаны. – *трх.* Тырнawыч алып барып тырнап йөрисең. – *бөре.* Тырнawычлар йасап шунда китәдер ийек. – *нрл.* Нawызларны таратырға нawыз тырнawыч кирәк. – *т.я.-крш.* Тырнawыц белән тырнайбыс. – *төм.*

**ТЫРНАГҮС** *туб.-ирт.д.* к.: **торнакүз.** Көс йетсә, тырнагүс цүпләйпес. – *тбл.*

**ТЫРНАҚ** *минз.* **1.** чананың табаны белән үрәчәсен тоташтыра торган теш (зубья в полозьях саней); **2.** к.: **бармак II.**

**тийен тырнағы** *блт.* шайтан тырнагы, эт тырнагы (заусеница).

**ТЫРНАҚ** *хвл.* к.: **бармак II.**

**тырнак гөле** *чст.*, **пәйгәмбәр тырнағы** *т.кам.-крш., минз.* тырнак гөл (ноготки).

**ТЫРНАКҮЗ** *твр.* к.: **торнакүз.**

**ТЫРНАУ 1.** *злт., перм., себ.* кашу (чесать, почёсывать). Қолағыңны тырнама син. Башын тырнап утыра. – *злт.* Боларға бер көн дә арқа тырнатмаға суқмады. – *перм.*; **2.** *перм.* бәрәңге төбен өю (окучивать картофель). Шул купка белә тырнап-тырнап өүwеп җийалар балчықны; **3.** *перм., хвл., себ.* печән җыю (сгребать сено); **4.** *перм.* майны, балны, вареньены һ.б. ризыкны әзләп-әзләп алу (скрести, т.е. брать понемногу – о продуктах). Әйдә тырнаштыр йемешләрең. Балны тырнап қара, қызларның күмәче қый. Тустағанны утыталар да идәнгә, аш сосоп шуныңан барың да тырныйсың.

**ТЫРНАУНИК** [*рус.*] *к.-уф.* к.: **бөгән.**

**ТЫРП: тырп итеп** *брб.д.* тырпаеп (торчком). Урамда тырп итеп басып торалар, ди.

**ТЫРПА** [*фарс.*] *т.кам.-крш.* к.: **торпа.** Бер берегезгә тырпа тормагыз, дидем.

**ТЫРПАЦАЙ** [*рус.*] *эчк.* трактор тырмасы (борона).

**ТЫРПЫ** *дөб.* тырпаеп тора торган (торчащий). Минем чәсем бик тырпы, күтәрелеп тора.

**ТЫРПЫЧА** *чст.* к.: **белөзек 1.** Ул тырпычаны аш күләүче йасый инде. Тырпыча пешерәләр казанда, сыра куйалар иде.

**ТЫРТАЙУ** *лш., кмшл.* холыксызлану, көйсезләнү, үпкәләү (капризничать, обидеться). Бер алай, бер болай тик тыртайып җөри. – *лш.*

**ТЫРТУ** *кмшл.* тоту (держать). Икешәр-эчәр күчкән кешеләргә дип тырттылар да.

**Т(Ы)РУБА** [*рус.*]: **т(ы)руба башыннан** *лмб., карс.* һәр хуҗалыктан (с каждого хозяйства). Труба башыннан унар йымырка йыйдылар корманга. – *лмб.* Тыруба башыннан акча җийалар иде. – *карс.*

**ТЫРЦАЙУ** *тбл.* кирәкмәгән җиргә тыгылып йөрү (вмешиваться не в своё дело). Үс эшен қарамайты, әшгәрә тырцайып йөрөйте, бақ.

**ТЫРЦЫҚ** *туб.-ирт.д.* сугыш чукмары (зазиристый, забияка).

**ТЫРШАУ** *лмб.* тышау, ат тышавы (путы).

**ТЫРЫМ-ТЫРАҒАЙ** *минз.* аерым-аерым (врозь, порознь). Нигә тырым-тырағай җөрисез?

**ТЫРЫН** *клм.* к.: **тырба II.**

**ТЫРЫС** *мам.* каен тузыннан ясалган цилиндр формасындагы капкачлы савыт (берестяная посудина цилиндрической формы и с крышкой). Үмәк җәрминкәсеннән тырыслар алып қайта торғаннар ыйы, туздан ул, чиләк сымақ, қапқачы да бар, сүwы тәмне була.

**ТЫРЫШ** *м.-кар.* к.: **тереклек.** Безнең вет тырышыбыз да начар булды.

**ТЫРЫШМА** *стрл.*, **ТЫРЫШЧАН** *мәл.* тырыш, эшчән (старательный, работящий). Кызымның кызы бик тырышма, шул кыз белән кискән ийек утынны. Ул үземә охшаган, мин бик тырышчан идем.

**ТЫСКАН** *м.-кар.* к.: **кесеркән.** Тыскан җый.

**ТЫСҚАН** *злт.*, **ТЫС'ҚАН** *хвл.*, **ТЫС'АН** *кас.* тычкан (мышь).

**җир тыс'аны** *кас.* сукыр тычкан (крот, землеройка). Җир тыс'аны җирне 'азып-'азып йөрөй.

**тыскан борсағы** *злт.* к.: **борчақ.** Тыскан борсағы үскән өйгә қыйалаш тора аларның өйө.

**тыскан күdенә сибәрлек** *тпк.* бик аз, бөтенләй аз (очень мало, совсем мало). Тыскан күdенә сибәрлек тә оннары булмаган.

**тыскан сыбығы** *злт.* к.: **шелек 1.** Тыскан сыбығы қашлақларда үсә. Митла бәйлибез тыскан сыбығыннан.

**ТЫСЫРДАТУ** *мәл.* к.: **азарлау.** Кулыннан тотты да тысырдатып алып китте.

**ТЫТ** *клм.* к.: **тет ағац.**

**тыт ағачы** *клм.* к.: **тет ағац.** Элек тыт салганнар, тыт ағачы.

**ТЫТУЦЫ** *срг.* басу каравылчысы (полевой сторож). Ул тытуцы иде, кырларны багып җери.

**ТЫТЫҚ** *клм.* ертык (рваный). Тытық күләк кийәмен, матур күләк кийәргә йазық дийә иде.

**ТЫТЫКЛАНУ** *лмб.* тотлыгу (заикаться). Сүләгәндә тытыклана.

**ТЫТЫМСЫЗ: күз тытымсыз** *глз.* түземсез (нетерпеливый). Күз тытымсыз син, казыр баранги пышар, ашарсын. Күз тытымсыз бәндә баранги ашама кели.

**ТЫТЫНЫП** *клд.* җитәкләшеп (взявшись за руку). Шул килде бергә тытынып мында.

**ТЫТЫП** *лмб.* к.: **бетереп**. Ыланнары инде тытып үз балаларым.

**ТЫУ** *злт.* к.: **ту 1**. Үзенең ғумеренә қолоннамаған бийә тыу бийә была. Өс йыл бозауламады исә, тыу сыйыр была, тыу қалған.

**ТЫУҒАН-ИГӘЧ** *каз.ар.-крш., к.т.* к.: **нәсел-асаб**. Мына қызлар кийәүгә киткән чақта тыуған-игәчләре ашқа җертәләр ийе қызларны. – *каз. ар.-крш.* Кийәү иттереп ике көнгә қунақ булып баралар, тыуган-игәчләр аларны ашқа җөртәләр ийе, чәйгә алалар ийе. – *к.т.*

**ТЫУДЫҒЫЙ: тыудығый заманда** *перм.* туган вакытта (во времена рождения). Пиғәмбәребез тыудығый заманда... (*мөнәҗәт.*).

**ТЫУСА** *тпк.* к.: **туча**. Пашмақ йылны подауламаса, тыусаға сығып подаулады, тиләр.

**ТЫҢҚАННАР** *срг.* беләк мускуллары (мускулы рук).

**ТЫЧҚАНЛАУ** *глз.* тычкан тоту (ловить мышей). Зурысын тотып китергән печәй кумакның, ит ашатмыймын, тычканламый ату.

**ТЫЧҚАН** *каз.ар.-крш.*, **ТЫЧКАН** *м.-кар.* к.: **кесеркән**. Минем дә тычқан әпкилеп чабасы бар әле. – *каз.ар.-крш.* Тычкан ашадық, алабута, җыва, кузганак. – *м.-кар.*

**тычқан қузағы** *каз.ар.-крш.* к.: **борма: борма үләи**.

**тычкан тигәнәге 1.** *мам.* к.: **сырга II, 1**; **2.** *минз.* к.: **дуңгыз I: дуңгыз кырмалавы**.

**ТЫШ I** *минз., байк., нокр., глз.* төш, урын (место). Бер тышта ғына чабабыз. – *нокр.* Бу тышлары бигрәк қызгаңгыч. – *минз.*

**ТЫШ II 1.** *минз.* төш (семя, ядрышко, зёрнышко). Чикләвекнең тышы бетә шул, нажағай күп булса; **2.** *минз., бөре., перм., лмб.* к.: **чепчәги**. Әбекайлар пешерә иде тыш раштыwa wакытында, пичтә шанын чикешәрне. – *лмб.* Күчтәнәчкә баллар, итләр, қазлар парны, тышлар – барсын да алып килә инде. – *бөре.* Қақ, тыш апкилә (туйга). Тышны dур итеп пешереб утыралар. – *минз.*

**тыш өстә** *минз.* к.: **қатлама 1**.

**ТЫШ III** *перм.* күкрәкчәнең җирлеге (основа нагрудника).

**т ы ш а у** (путы):

**тышау кисү** *тмн., брб.д.* озак тәпи йөрмәгән баланың аягын салам тышау белән бәйләп, шуны кисеп җибәрү, яисә көтү кайтканда урамга чыгарып утыртып, шул бауны кисү ырымы (обряд знахарского лечения, согласно которому ребёнка, долго не начинавшего ходить связывали ноги соломенной верёвкой и делали, будто режут туты, либо сажали на дорогу перед приходом стада). Бездә ылан йөри алмаса, тышawын кисәләр, саламнан тышау йасыйлар, «кызымның тышawын кисәм» дип кисәбез, әwәле тышау саламныкы булган. Тышawын кискәле тейләр, паланы пасқырып перәү кейскән шәгелле ишарәтен итәләр икән, ишарәт итсә, йөреп китәде. – *брб.д.*

**ТЫШҚАРЫ 1.** *каз.ар.-крш.* тыш, башка (кроме). Әйбер апқайтқаннан тышқары да ақча бирде (малайы); **2.** *тара.* тышка, тыш якка (наружу). Таш үйнү бысып тышқары цықтылар.

**ТЫШЛАП** *байк.* буйлап, ...дан (по). Басу тышлап кит, диләр, капка төбенә карawыл куйганнар.

**ТЫШЛАУ** *перм.* к.: **қақтыру**. Арпа тышлау. Тары тышлау.

**ТЫШМАҚ** *себ.* тыш бияләй, өстән кия торган бияләй (верхние рукавицы).

**ТЫШМАҚЛАУ** *тара., төм.* тыш бияләй кию (надевать верхние рукавицы). Бийәләй кигәннәр тышмақлап тороп қышқыта.

**ТЫШЫ** *минз.* теше (самка). Тышы бозау.

**ТЫШЫГУ** *лмб.* к.: **табылу II, 1**. Андыйга балаң тышыкмасын. Усалга тышыкма, тышыккач, пышыкма (*әйтем*).

**ТЫШЫНДА** *минз., кмшл., перм.* эчендә, тирәсендә, чамасында (в течение, около, примерно). Әле ике-эч кен тышында ғына килеп киткән ийе. – *кмшл.* Җиде көн тышында йәшен суқты җиде сарықны. – *минз.* Әле өч-дүрт көннең тышында ғына таптымый. Қарабодай ик(е)-өч йыл тышында йуғ әле, чәчмиләр. – *перм.* Йалагай ике-өч көн тышында гына уйнады әле монау йакта. Әле дүрт йыл тышында бийә саудым. – *стрл.*

## У

**У** *к.т., перм., саз.я., төм.* ул (он, она, оно). У заманда бер өй, ашарга йуқ, он хәдер генә ул бүлмәләр тулы. – *к.т.* Сезне чақырып килгән у. – *перм.* У шийелле қыйланма. У йултан усартайма? – *саз.я.* Мин у йақтан цықтым қуй. – *төм.*

**у көннә** *перм.* шушы арада, шушы көннәрдә (совсем недавно, на днях). Әни апкилдийе у көннә генә.

**УБА 1.** *минз., бгрс., кргл., стрл., брб.д., тбл., твр.* калкулык өсте, биек җир (вершина холма, возвышенность, возвышенное место). Уба – кибән сыман қалку урын. Ул қәбер чыққан йер уба булып торадыр ийе, какырас Минач абзыйның ындырыйы. – *минз.* Шул уба артында йатқан инде Пугач ғәскәре. – *бгрс.* Оло уба бар анда. – *кргл.* Убаға утырған цөн песнеңке ауылны Убawыл тиләр. – *брб.д.* Уба бар, қыслар убасы, анда әүлийә, гыслар фыронт тотқан, йыван ағачларны өйөрәп атсалар, пер салтат қалмый игән, Ус Ишендән (*ав. ис.*) күренеп торады. – *твр.*; **2.** *кмшл., нгб.-крш.* кечкенә калкулык (небольшая возвышенность); чаг.: **қаш**. Убага да менеп қарадым, күрмәдем. – *нгб.-крш.*; **3.** *минз., бгрс.* җиргә казып ясалган чокыр, җәнлек оясы һ.б. Урманда бүре убасы таптық. Бөтен кешегә йақын була менә шунда убаға китереп төшерсә суны. – *бгрс.*

**УБАҠ** *тбл.* пычрак (грязь; грязно).

**УБАҠ-СУБАҠ** *дөб* к.: **пырдымсыз 1.** шундый бер убак-субак кына нәрсә инде.

**УБАТҠА** *нокр.* каен гөмбәсе (подберёзовик).

**УБЖУР** [*рус.* обжора] *блт., кмшл.* к.: **алйот 2.** Убжур булды инде.

**УБИН** [*рус.*] *тбл.* әвен (овин). Ашны көлтә белән убинта киптергәннәр, эценә мейец йагатыганнар.

**УБУ** *төм.* суырып алу (втянуть в себя, втянуться). Айагым саста убып калыпты.

**УБУЙ** [*удм.*] *глз.* түп, җитен түбе (жмыхи, выжимки льна); чаг.: **түбер**. Ачлык йылларны ашадылар да убуйны.

**УБЫ** *төм.* к.: **уба 1.**

**УБЫЗ** *перм.* к.: **ывыз**. Убыз бүкмә пешерәбез, сыйыр бозаулагас. Шәңгә дә салалар убыз эректән.

**УБЫЙА: убыйа порцак** *тбл.* ногыт борчагы (боб).

**УБЫЙДА** *кмшл.* җебегән, акрын кыймылдаучан (медлительный, нерасторопный). Утырган бит убыйда. Убыйда шикелле утырма инде, кузгал әзрәк.

**УБЫЛУ** *кмшл.* күп бетү, күп тотылу (много расходоваться, тратиться). Әй шикәр убыла да инде wәринйәгә.

**УБЫНУ** *клд.* бик тырышып эшләү, казгану (работать очень старательно, работать много, усердно). Кырдан киләсең убынып. Ызнай убына.

**у б ы р** (оборотень, вампир, упырь):

**убыр күзе кагылу** *бәр.* к.: **зийандаш: зийандаш кагылу**. Убыр күзе кагылган, диде бер әби, убыр кешегә карап китсә, шул кеше awырта.

**убыр табагачы, убыр тайагы** *хвл.* к.: **убыр уты**.

**убыр тырнак** *брб.д.* атсыз бармак (безымянный палец).

**убыр уты** *лмб., срг.* шайтан таягы (чертополох курчавый).

**УБЫРҠАРСАҠ** *лмб.* к.: **бармак: гөлчәчәк бармак**.

**УБЫТ I** *карс.* к.: **ашык II, 2.**

**УБЫТ II** [*рус.* обод] *мәл.* тугым (обод).

**УWА** *минз., стрл.* бөкре (горб). Җылкы майы аруга йарый, аркага уwа чыга, шуны тийерәләр. Уwалы кешене нәрсә диләр сездә, бөкреме? – *минз.*

**УWАЛ** [*рус.* вал] *стрл.* к.: **чәбен**.

**УWАЛМА** *мам.* **1.** төче камырдан пешерелгән вак күмәч (лепёшки из пресного теста). Соло уwалмасы пешердем иртәңге чәйгә; **2.** к.: **икралы: Уwалма бәрәнге**.

**УWАЛУ 1.** *срг., мәл., перм., мам., к.-уф., нгб.-крш.* к.: **валу**. Безнең калхузның бар иде дә (машинасы), уwалды. Йырлаганда йаман шулай уwалып китә (патифун). Халадилнигым уwалды, ашларым әрәм булды. – *срг.* Қай тышы уwалган (трактор-ның), шул тышны эшләй торганнар ыйы алачыкта. – *мам.* Машиналары уwалган. – *нгб.-крш.*; **2.** *стрл., мәл.* ватылу (разбиться). Бәргәч уwала бит тарилка. – *стрл.* Ул урманга барып күзлеге уwалган булган, бал'ничада йатып чыккан. – *мәл.*; **3.** *перм.* бәрелү (удариться). Башы уwалды.

**УWАЛЫ** *тбл.* үткен акыллы, алдан күрүчән (прозорливый).

**УWАЛЫП-СЫНЫП** *срг.* боргаланып-сыргаланып (кокетничая, жеманничая). Кукырайып, уwалып-сынып йөри.

**УWАНИХАЙ** *тара.* чуалыш (путаница).

**УWАРМАҠ: уwармак килү** *т.кам.-крш.* шаяру, шау-гөр килү, ыгы-зыгы килү (расшуметься, устроить шум-гам). Балачагасы айак астында уwармак килеп ята.

**УWАУ** *тара.* изү, әвәләү (месить, мять, раскатывать).

**УWАФЫР** *тбл.* мул, күп (много, обильно).

**УWАЧАҠ** *брб.д.* **1.** вак бавырсак, төш (мелкий баурсак). Уwачак wак-wак, ул йарылып-йарылып бешә; **2.** чәкчәк (чакчак – национальное блюдо).

**УWЫЗ** *трх., злт., баст., клм.* к.: **ывыз**. Кайсы кеше уwызын пешерә чүлмәк белән. – *трх.* Уwыз сап-сары, күйы була, пешерәләр ийе, күкәй шикелле була, хәзер ашамыйлар. – *клм.* Уwыз пешерәләр иде пирwый сауганыннан, пичкә куйалар әтдилне, әтдилне җыйа сөтен, тозлый, пичкә куйа пешмә, сәситкәләргә бирә, алар бозауның саулыгына үкмәк бирә. – *баст.*

**уwыз сөте** *трх.* к.: **ывыз**. Уwыз сөте сап-сары каймак кына була.

**УWЫЛДЫҠ I** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш., минз., трх.*, **УWЫЛДЫК** *чпр.* к.: **айак II: айак корсагы**. Уwылдыклар шеште, итекне салып булмый. Уwылдыгын тешләп алган эт. Уwылдыктан сыймый итек кунычы. – *каз.ар.-крш.* Уwылдыкларым эши. – *чпр.*

**УWЫЛДЫҠ II** *баст.* умач (затируха). Уган уwылдыкларны гына саласын, онны саласын.

**УWЫС** [*рус.* овёс] *баст.* солы (овёс). Ишекне ачып уwыс сибәләр дә чыгып китәләр.

**УҒАЛУ** *перм.* к.: **уwалу 2.** Тирәзәнең бер өлгесе угалды.

**УҒАТА** *перм., минз., к.-уф., кргл., брб.д.* к.: **әләк 2.** Җонойык кисәң, угата җылы була. – *минз.* Угата кылыксыз, өстәлгә утырганчы түзмиләр, ти (балалар). Угата да матур инде. – *перм.* Угата күп сүләшәсең. Угата матур инде шушы бала, бигүк йаратам үзен. – *к.-уф.* Күңелем угата шартланып тыра син йылмырап тырсаң, мин угата дәртләнеп тырам. – *кргл.* Угата йаман болоп китте тормышлар. – *брб.д.*

**УҒРАТ** [*рус.* ограда] *перм.* **1.** к.: **йорт 1.** Себерке генә төшөб алдым уграт себерегә; **2.** к.: **бакча**. Монда уратта корт.

**уграт эч** *перм.* к.: **йорт 1.** Коршалыб алынгач, уграт эч тисең.

**УҒУ I** *тара.* оешу (сваливаться, сваляться – о шерсти). Йоном угып калган.

**УҒУ II** *брб.д.* ишетү (слышать). Пабладарны (*шәһәр ис.*) уктыңысму? Колагы та укмас полоб йөрөдө.

**УГЫЛ** [*рус.* угол] **1.** *кузн., хвл., карс.* к.: **мийеш**. Йортнон бер угылына куйган бер олона ызба. Идәнгә йыгылмадым, ызба угылы мине тотоп калды. Пыс та тыр угылында. Кан'ана бәли инде дүрт угылга дүрт акча. – *кузн.*; **2.** *стрл.* к.: **бөгөл 2.** Угылдан санап дүртенче йырт. Менә бу угылда тора ул.

**УГЫЛЛАП** [*рус.* угол + *афф.* -лап] *хвл.* почмаклап (углами; углом). Угыллап бәли идек.

**УГЫЛНИК** [*рус.* угольник] *карс.* к.: **абзар: абзар алды.**

**УҒЫМАЧАҚ, УҒЫМАШАҚ** *твр.* к.: **убыр: убыр тырнақ.**

**УҒЫР** *кргл.* к.: **бур I.** Балалы өйдә уғыр йатмас.

**УҒЫРА: уғырасы қотору** *тара.* сыерның качу чоры (период обгуливания коровы). Уғырасы қотырты тиләр, сыйыр йөгерекләсә.

**УДИГҮРӘ** [*рус.* уйди + горе]: **удигүрә былу** *злт.* әйбәт булу, бик яхшы булу (быть хорошим, быть прекрасным). Бу матур пәлтә йанына итек тә алып йебәрсәң, удигүрә была инде. Аҡбур салырға қапсыҡны өйдән алып килгән былсам, удигүрә былайы.

**УДРАЧ** *клм.* утрау (остров).

**УЖАУ 1.** *злт.* к.: **багырча.** Бер ужау аш ашап бетермәскә инде; **2.** *эчк.* агачтан ясалган аш чүмече, татар кашыгы (деревянный половник); чаг.: **багырча.**

**УЖУ** [*рус.* ужо] *дөб.* вакыт (время). Ужуwым жуқ әле анда барырға.

**УЖАҚ I** *брб.д.* вак (мелкий, маленький).

**УЖАҚ II** *брб.д.* к.: **ошақ.**

**УЖАУ** *минз., бгрс., трбс., стрл., шрл.* к.: **багырча.** Ужауның нәрсә икәнен ат′теңме? – *шрл.* Элгәре ағач уҗаулар була торған ыйы. – *бгрс.* Уҗау белән сала фурмыға әпәйне. – *трбс.*

**УЖИ: уҗи кәрәм әтү** *кузн.* к.: **айникар′ам.**

**УЖЫ** *нокр.* каенсеңел (золовка, младшая сестра мужа). Уҗыларым бар иде, бер генә уҗым бар иде, без аның белә күп тырмадық.

**УЖЫМ** [*рус.* озимь] **1.** *т.я., нокр., глз.* к.: **көзлөк 1, 2; 2.** *каз.ар.-крш., блт., мам.* к.: **кәлшә 1.** Памидур уҗымы алып утырттым. – *каз.ар.-крш.* Ағач уҗымы ғына анда, чабарға да жуқ. Чөгөндерләре жаңарып килә, беркөннәре генә уҗым утыртқаннар ыйы. – *мам.*

**уҗым чәчәге** *лмб.* күкбаш, күкчәчәк (василёк посевной).

**УЗ** *әҗе.* к.: **ывыз.** Башта сете узлы була, зиде cawымыннан сун сет эцәргә йарый.

**УЗАЛ** *тара.* усал (злой). Йаман пицә, узал.

**УЗАУН** *брб.д.* өченчекөн (позавчера). Узаун парып килдег иде.

**УЗАРЫШТАН** *дөб.* ярышып, узышып (соревнуясь, вперегонки). Узарыштан бәйлийек шәлне Мәдинә белән.

**УЗҒАРУ 1.** *нгб.-крш., перм.* үткәрү, уздыру (проводить – о времени). Сүләп узғардым бит. Сездә гумер узғарып утырдым. – *нгб.-крш.*; **2.** *нгб.-крш.* уздыру (пропускать, разрешать пройти). Тықырықтан узғармыйлар машинаны; **3.** *перм.* билгеләп үтү (отметить). Шуwи узғардылар ышколанықы йубилины.

**УЗҒЫРУ** *т.кам.-крш.* к.: **узғару 1, 3.** Тройсында жәшләр түгәрәк уйын жасыйлар, жәш киленнәр сүрәкә бәйли мәләчлек қуйып жепәк жаулық, чачақлар, шулай бәк жәмне узғыралар ыйы.

**УЗУ** *тмн., кас.* к.: **йару I, 1.** Алманы утап бетердем, инде сука мынан узасы гына бар. – *тмн.* Джиралма узаймын. – *кас.*

**мунча узу** *перм.*, **муйса узу** *злт.* мунча әзер булу (баня готова). Мунча узды, керергә бармыйсызмы? – *перм.*

**УЗУН: узун аш** *яүшт.* токмач (лапша).

**УЗ′ЫМ** [*рус.*] *кузн.* уҗым (озимь). Апкай, ад′а, сый′ыр киткән уз′ымга. Уз′ымнар да бойыл йакшы.

**УЗЫРӘТИ** *перм.* к.: **қартатай 1.**

**УЗЫРНӘЙ** *перм.* к.: **қартинә(й) 1.**

**УЗЫШТАН** *блт.* к.: **узарыштан.** Берсеннәнберсе узыштан қарыйлар дуңғызларны.

**УЗЫШУ** *мәл., дөб.* сүз көрәштерү, бәхәсләшү (спорить). Узышма минем белән, сүзең дөрес тегел барыбер. – *мәл.*

**УЙ I 1.** *минз., тмн., лмб., кузн., срг., мәл., чст., твр., тбл., тмн.* к.: **астыр.** Уй үde, түбән җирдә аның сuwы да була. – *минз.* Директыр уйның теге йагында. – *кузн.* Аларның уйда иде ызбалары. – *срг.* Уйдан барасыз да уңга бырыласыз. – *чст.* Уйларта ғына печән. – *твр.* Уйта утыс моң, қырта қырық моң йылғысы пулган ийен (икән). – *тбл.*; **2.** *тмн.* казылган җир, тишек (выемка, выбоина). Шывып-шывып бийергә, Идәнегезнең уйы бар, Чыгарыгыз киленегезне, Ничә кар′е буйы бар (*хал. җыр.*); **3.** *мәл., чпр., карс., тпк.* чокыр (овраг, углубление). Тыгрыктан бырылгач уй бардыр, карап йере. – *мәл.* Шуwаш уй дигән уй бар. – *тпк.* Уг аттым, уйга деште, Ул уйдин кышлар ыс′т′ы (*хал. җыр.*). – *карс.*

**уй йир** *трх.* к.: **астыр.**

**УЙ II** *срг.* түр (почётное место, красный угол). Әчәт менгән ындырга, Кур′игын салган кыңырга; Әткәй, майым, булырмы сын Трантаслар уйында (*хал. җыр.*).

**УЙ III** *перм., саз.я.* к.: **ис III, 1.** Уй җуқ, қайа қуйганым белмийем, уй беткән. – *перм.* Уйны пөтөрте. – *саз.я.*

**УЙА** *стрл.* к.: **уй I, 3.** Араның бу йагында уйа бар.

**УЙАЗ** *перм., кргл.* к.: **астыр.** Уйаз инде анда җир. – *кргл.*

**уйаз җир** *перм., нгб.-крш.*, **уйаз йер** *эчк.* к.: **астыр.** Уйаз йергә сыу йыйыла. – *эчк.* Уйаз җирләрдә бардыр пычырағы, күл буйларда. – *перм.* Уйассыман җир. Уйаз җирдә җөри бозау. – *нгб.-крш.*

**УЙАН I** *твр.* к.: **йорт 1.**

**УЙАН II** *глз.* уяу (бодрствующий, неспящий, пробудившийся).

**уйан йату** *глз.* уяу яту (не спать). Бүген иртә торганым булды, сагат дүрттән уйан йаттым.

**УЙАС** *төм.* к.: **астыр.** Уйас-уйас йерләр пар.

**уйас йер** *төм.* к.: **астыр.**

**УЙАТ-УЙАТ** *трбс.* урыны-урыны белән (местами). Уйат-уйат қына алан.

**УЙАУ I** *минз.* к.: **багырча.**

**УЙАУ II** *чст.-крш.* җырлап уйнау (игра с песнями). Симектә уйаулар башлана чувашларда.

**УЙБАС** *тара.*, **УЙБАТ** *тпк.* к.: **астыр.** Уйбас йерләргә су салған. Уйбат йердә утыра беднең awыл.

**УЙҒАРУ: эс уйғару** *брб.д.* аңга килү (прийти в сознание, очнуться). Әртәнгәче йатқан, эсен уйғарған.

**УЙҒАШ** *минз.*, **УЙГАШ** *стрл.* төзек, шома, рифмалы – шигырь турында (складный, гладкий, рифмованный – о стихах). Бар шиғыр, күб ул, ну алар Туқайнықы кебек уйғаш түгел.

**уйғаш китерү** *минз.* буйлы, бизәкле әйберләрне бер-берсенә туры китереп ялгау (подгонять, соединять по рисунку). Сырлы, буйлы-буйлы әйберләрнең паласасын бер-берсенә туры китерү уйғаш-уйғаш китерү була.

**УЙҒАШТЫРУ** *төм.* шомарту, рифмалау – такмак турында (сделать складным, рифмовать – о частушках). Тақмағын уйғаштырырсыз.

**УЙҒУЗУЛ** *брб.д.* йоқы капчығы (соня; сонуля).

**УЙҒЫ** *төм.* усак көймә (лодка из осины).

**УЙДА** *яүшт.* югарыга, өскә (вверх). Түбән ташлама, уйдарақ ырғыт.

**уйда йату** *тара.*, *брб.д.* чалкан яту (лежать на спине).

**УЙДУР** [*рус.* одёр] *чст.* к.: **ад'ур 2**.

**УЙДЫҚ 1.** *кмшл.* берәр нәрсә күп булган җир (место скопления чего-либо); чаг.: **аймак 1**. Уйдық тапсаң, безгә қычқыр. Мин уйдығын белəм җиләкнең; **2.** *тбл.* к.: **уй I, 3**.

**УЙДЫҚ-УЙДЫҚ** *тя.*, *кмшл.*, *перм.* урыны-урыны белән (местами, полосой). Җиләк бит уйдығы-уйдығы белән генә. – *кмшл.* Қунаққа барғанда да күреп киттек, уйдық-уйдық қына урман. – *перм.*

**УЙДЫМ 1.** *злт.* җиләкнең күпләп, күп булып үскән урыны (место, где много ягод). Бер уйдым таптым да йарты бидыра қара йеләк йыйып алдым; **2.** *м.-кар.* к.: **астыр**. Ике җүн уйдым була, уртада сыр кала. Уйдымда су кала анда.

**УЙДЫМЛЫ** *м.-кар.* уелмалы-уелмалы (с углублениями, выемками; неровный).

**УЙДЫМ-УЙДЫМ** *злт.*, *дөб.* к.: **уйат-уйат**. Уйдым-уйдым боз йауған. Уйдым-уйдым сыққан кишере. Уйдым-уйдым сабылмый қалған песән. – *злт.* Мүк җиләге оло урманда, уйдым-уйдым саз була, шунда үсə. – *дөб.*

**УЙДЫРТМА** *минз.* мунчала (мочало, мочалка для мытья). Уйдыртмаңны бирче.

**УЙЛЫ-ЧУТЛЫ** *перм.* к.: **исле I, 2**. Элекке кебек уйлы-чутлы булсам, белерем и қый.

**УЙМА 1.** *тмн.*, *лмб.*, *карс.* идән астына төшеп йөрү өчен ясалган ятма ишек, алынмалы идән (голбец, сборная дверца в подполье); **2.** *карс.* к.: **гелбəч**. Этийесе килде пагун, кызны салганнар уймага; **3.** *хвл.* к.: **уй I, 3**. Сикереб уздым урамның уймасын.

**УЙМАЛЫҚ** *трх.* к.: **астыр**.

**УЙМАРЛАУ** *дөб.* чоку, ую (долбить, делать углубление). Тушының җуанлығы агач, шуны уймарлаған була.

**УЙМАТ** *төм.* к.: **астыр**. Уймат йерләртə су китми утыра қый.

**УЙНАТУ 1.** *перм.* көчләү (обесчестить); **2.** *перм.*, *эчк.* берәр нәрсə белəн яки берәр нәрсəдə уйнау (играть с чем-либо или на чём-либо). Йоморқаны уйнатыр сийə, чыбыта да ашый у. – *перм.* Гармун уйнатып үрəнгəн. – *эчк.*; **3.** *минз.*, *стрл.* комиссиядəн үткəрү (пропускать через комиссию). Малайның малайлары бар инде, берсе унсигездə, берсе унтуғызда, икесен дə уйнаттылар. – *минз.*; **4.** *минз.*, *стрл.* сборга алу (призывать в сборы). Əрмийəгə китəсе йегетлəрне бер ай, ике ай уйнаталар. – *стрл.*

**УЙНАУ 1.** *чст.-крш.*, *минз.* егет белəн кызның дус булып йөрүе (дружить – о парне с девушкой). Ана Зинаның уйнаган җегете. – *чст.-крш.* Əле аның армийəдə дə уйнаган йегете барыйы. Қайтқач бер қыd белəн уйнаған да шуңа үртəлгəн, күрəсең. – *минз.*; **2.** *төм.*, *тбл.* бию (танцевать). Син сарна, мин айағуйын уйнаб алайын. – *төм.*

**җыр суқтырыб уйнау** *лш.* кара-каршы җыр əйтешеп уйнау (игра со взаимоответным пением). Җыр суқтырыб уйнағанда қызлар гел минем белəн буласы киләдер ийе; мин булғанда җазаға ләкмидер ийек.

**қала-қала уйнау** *каз.ар.-крш.* Масленица бəйрəмендə яшьләрнең кардан төрле корылмалар ясап уйнаулары (игры молодёжи в снежную крепость во время праздника Масленицы). Масленитсада қызлар, йəшләр қала-қала уйныйлар ийе қар өйəп.

**сақлы уйнау** *минз.* парлашып бер-бер артлы тезелеп басалар, тезем башында берəү так кала, арттагы бер пар аерылып алға таба йөгереп китə, так калган кеше аларның берсен куып тотарга тиеш, əгəр тотса, так калган кеше тезем алдына барып баса (молодёжная игра: попарно встают друг за другом, один встаёт впереди пар, последняя пара разбегается, а впереди стоящий должен поймать одного из них, кто остаётся один, встаёт впереди пар). Җыйында сақлы уйнадық.

**туй ун'ау** *карс.* туй үткəрү (сыграть свадьбу, справить свадьбу). Туйны йазга калдырганнар, қыш ун'амыйлар.

**туплы уйнау** *каз.ар.-крш.* туп уйнау (игры с мячом). Кич туплы уйнарға чыққачыннан төшəрсез.

**УЙНАШТЫРУ** *минз.* сөрлегү (полечь – о хлебах). Арышларны җил уйнаштырған.

**УЙПАТ** *кргл.* к.: **астыр**. Чоқорлырақ, түбəнрəк җир уйпат була.

**УЙРАУ** *тмн.* **1.** иңү (оседать). Хəсəн абзыйның кабере уйраган, бар'əмдə төзəтергə кирəк; **2.** ишелү, коелу (сыпаться, рассыпаться). Пəсук уйрый ул.

**УЙТЫҚ** *тбл.* батынкы (вогнутый). Уйтық йергə утырыпсыс.

**УЙУҚ** *яүшт.* корбан аты (жертвенная лошадь).

**УЙУЛЫ** *яүшт.*, *тара.* каюлы читек (узорчатый – о женских сапогах). Ату булган уйулы. – *тара.*

**УЙУУ** *брб.д.* **1.** сыру (стёгание); **2.** каю, чигү (вышивка).

**УЙЫ** *сазл.* к.: **астыр**.

**УЙЫҚ** *тбл.*, *тара.* к.: **астыр**.

**УЙЫҚЛЫ** *яүшт.*, *клм.* каюлы (вышитый). Уйықлы пималарын алып цығып киткəннəр өй башыннан. – *яүшт.* Ату (читек) йомшақ куныч-лы, қайсы уйықлы, Казан йақлар читек əйтə. – *клм.*

**УЙЫҚЛЫ-ЧИЙЫҚЛЫ** *клм.* к.: **уйықлы**. Уйықлы-чийықлы қулчы (куныч) адунықы.

**УЙЫЛДЫҚ** *кргл.* к.: **уйдым 1**. Йақын килмəгез, дисең, уйылдық тапсаң.

**УЙЫЛУ** *бəр.* өзгəлəнү (терзаться, убиваться). Уйылдым, уйылдым, уйылсам да бара алмадым.

**УЙЫМТЫҚ** *баст.* яка уемы (вырез, пройма на одежде).

**у й ы н** (игра):

**айағ уйын** *себ.* бию (пляски, танцы).

**ашық уйын** *клм.* бишташ уены (игра с пятью камнями). Ашық уйын уйный идек су буйыннан таш йийып.

**гүрелдәшле уйыны** *шрл.* качышлы уен (игра в прятки).

**қулдан сығу уйыны** *злт.* пар-пар булып, кулга-кул тотынышып тезелеп басалар, көй астында арттағы пар куллар астыннан чыгып алга барып баса (молодёжная игра: попарно встают друг за другом, последняя пара из-под рук выходит под музыку на передний ряд).

**қыз җөгөртөшү уйыны** *перм.* к.: **уйнау: сақлы уйнау.**

**таққарawыл уйыны** *дөб.* к.: **чупләмле.**

**татар уйыны** *яүшт.* түгәрәк уен (игра в круг). Татар уйыннары әйбәт буладоған, кыруг уйный идек.

**тегүче уйыны** *хвл.* балалар уены (детская игра). Әлһам да Вәли, йасын да Вәли, Кашың кармалый, күзең сөрмәли, Абыстайлар, тун тегәргә йукмы әли? дип, икәү кочаклашып «керәләр» – болар «тегүчеләр» булалар. Кереп утыралар да «абыстай, бераз катыгың йукмы?» ди. Син китәсең пугар'аптан катык чыгарам дип, болар кызыңны орлый да китә. Син аны kowa башлисын.

**тоттырма уйыны** *мам.* к.: **уйнау: сақлы уйнау.**

**УЙЫНЦЫ** *тбл.* **1.** гармунчы (гармонист). Йырцы ите бу, анта уйынцы та пар ите; **2.** биюче (танцор).

**айағ уйынцы** *төм.* к.: **уйынцы 2.**

**УЙЫНЧЫ** *тмн.* **1.** скрипка; **2.** скрипкачы (скрипач). Уйынчы ун'ады бабам үлгәнче, бабам биг уйынчы иде.

**у й ы н ч ы к** (игрушка):

**уйынчыққа алу** *нгб.-крш.* уенга алу (принять в шутку). Алар минем сүзне уйынчыққа алалар.

**УЙЫРҒАҚ** *тбл., тара.* уйсу җирдәге болын (луг).

**УЙЫРЫЛУ** *хвл.* ишелү (рушиться, рухнуть). Бәлчек уйырылып болар өстенә төшкән.

**УҚ** *әстр.* ике бөтен уннан биш метр озынлыгында юнылган таяк, киртә (жердь длиной два с половиной метра).

**күз угы** *тмн.* күзнең катылыгы (острие взгляда). Күз сийрның мәмәсен дә корота, кешене дә корота, күзнең угы бар әл дә, шул корота.

**УҚАЧАЧАҚ** *каз.ар.-крш.*, **УКАЧӘЧӘК** *лмб., хвл., күзн.* маңгай турысына тастар астыннан бәйләп калдырыла торган укалы чук (женское надлобное украшение). Уқачачақ, қалпақ чачақны да қызлар кигән. – *каз.ар.-крш.* Укачәчәкне маңгайга бәлиләр иде. Укачәчәк тужы анайларның апайларында гына булган, сарука булган, агука булган. Укачәчәкне кызлар бәли, йәш килен йылны бәли. – *хвл.* Укачәчәк маңгайга кийелә иде, кызлар да бәли иде. – *күзн.*

**УҚ-ЙАҒЫ** *брб.д.* ук белән җәя (лук со стрелой). Уклегә тигән ахутник уқ-йағыны өсө йасаған.

**УКЛАWЫК** *глз.* уклау (скалка). Уклawык бу.

**УҚЛАМАУ** *брб.д.* ишетмәү (не слышать). Уқламыйм та, ти.

**УҚ-САНАЙ** *тбл.* җәя (лук). Уқ-санай белән алар атышқан.

**УҚСЫН 1.** *минз., нгб.-крш.* кыргый сарымсак (дикий чеснок). Уқсынны бақчаға утыртып қарадық әле. – *нгб.-крш.*; **2.** *мам.* кыргый суган (дикий лук). Җуwa тәмнерәк, уқсын сасырақ. Уқсын – кыргый суған, қыйағы түгәрәк, җуwаның қыйағы җәйенке була, җуwасы тәмнерәк, уқсын әчерәк; **3.** *перм.* сарымсак (чеснок).

**уқсын кебек** *минз.* таза, сәламәт (здоровый). Бигрәк әрәм була инде, уқсын кебекләр бит.

**УКСЫН** *стрл.* к.: **уқсын 1.**

**УКСУ** *нгб.-крш.*, **УҚЦУ** *тбл.* укшу, косасы килү (тошнить). Шом тотто берwахыт, уқсыйм инде. – *нгб.-крш.*

**УКТӘП** [*рус.*] *срг.* октябрь.

**УКУБА** [*рус.*] *перм.* окоп. Қалатауда суғышқаннар, укубалары бар анда өч митыр тирәнлектә, өч митыр киңлектә, ыштубы ат чыға алмасын.

**УКУС** [*рус.* окос] *стрл.* к.: **алсын 1.**

**УКШАУ** *стрл.* ошау (нравиться). Безнең awыл укшадымы?

**УҚШАУ** *тбл.* үкерү, ырылдау (реветь, рычать).

**УҚШЫНУ** *яүшт.* үбү (поцеловать).

**УҚЫМЫШ** *перм.*, **УКЫМЫШ** *срг.* укымышлы (образованный). Безнең awылда бер уқымыш кеше бар иде. Уқымыш булмагас, белеп пулмый. – *перм.* Ул бит укымыш. Миркай да укымыш. – *срг.*

**УКЫМЫШЛЫК** *тмн.* белем (образование). Укымышлык йук, сабан артыннан йөрөдек, йилкә белән йемердек.

**УЛ I** *тара* **1.** бертуганның улы (племянник); **2.** к.: **нук 1.**

**сары ул** *т.я.-крш.* **1.** к.: **йанаға(й); 2.** каенеләрнең берсенә эндәшү формасы (форма обращения к одному из младших братьев мужа).

**ул балам** *перм.* к.: **йанаға(й).**

**чибәр ул** *т.я.-крш.* к.: **йанаға(й).**

**УЛ II** *мам., каз.ар.-крш.* бал корты күкәе (пчелиное яйцо). Улны күп салалар, бал җыймыйлар нишләптер. Ул салу. Ул сибү. – *мам.* Әй улсайде, улсайде, ул сипмәгән баллар булсайде. – *каз.ар.-крш.*

**УЛАҒУ** *брб.д.* адашу (заблудиться).

**УЛАҚ I 1.** *брб.д.* ул (сын). – Бу әл Гөлбәстанның улағымы? – Йоқ, унуғы. Рәйсә килен қайтты улағы белә; **2.** *яүшт.* бала (ребёнок, дитя). Минем улақтар әтиләрен үбеп-үбеп қалдылар.

**УЛАҚ II** *к. т.* к.: **кизләү 1.** Җәй булса, улаққа барыла суға. Киндерләрне улаққа барадыр ыйық чиқарға. Ул Ылғыма җылғасы монда зурайа, төрле улақлардан чығып килә. Қара қuwағыбыз бар, тужы улақ, изгеләр улағы диләр ийе мин қыз wахытта.

**УЛАМ** *брб.д.* еш (часто).

**УЛАННАР** *перм.* к.: **олан.** Биш уланнары бар. Ик(е) уланнар белә килгәннәр алар. Җит(е) уланнар белә қалдым. Алт(ы) уланнарны урыс ти.

**улан бүкән** *перм.* к.: **бүкән III: бала бүкәне.** Улан бүкәннәрен төзәтмиләр дә, әчләре awыртучан була.

**уланнарырақ чақ** *перм.* балачак, кечкенә чак (детство, младенчество). Ул чақта мин йәшерәг ийем, уланнарырағ ийем мин.

**УЛАНШАҚ** *перм.* к.: **бала-бақра.**

**УЛАУ I 1.** *лмб.* к.: **каклау**. Айакны кечеркән улады; **2.** *тмн.* чактыру – кычыткан турында (жалить крапивой). Кечеркән мән улыйм үзеңне. Тытам, вычы кечеркәнгә улыйм.

**УЛАУ II** *хвл., мәл., чпр.* күп, мул булу (много, обильно). Быйыл игеннәр улады. – *мәл.* Симийаң уламаган әле. – *хвл.*

**улап тору** *срг.* гөрләп үсеп утыру (бурно расти). Усатыбыз улап тора.

**УЛҒА** *твр.* к.: **сырға I, 1.**

**УЛДЫҚ** *твр.* к.: **айақ II: айақ қорсағы.**

**УЛЖА** *кргл.* булачак сөенечкә билге, сөенеч – юрау, ырым белән бәйле рәвештә кулланыла (радость – говорится при толковании, предсказывании). Улжа төшкән қызымның чәйенә, кийәүгә барыр йә күчтәнәч килер. Тырнаққа ақ төшсә дә улжа киләкәй.

**УЛЖАЛ** *минз.* к.: **божал**. Дилене durайа, улжалы тула инде. Сыйырның улжалы умбишендә тула. Кешенең дә инде туғыd айы тулса, улжалы тула, диләр.

**УЛИЧА** [*рус.* улица] *тмн.* к.: **awыл**. Бу уличада су бар, күрештә.

**УЛТРАУ** *тбл.* көчсез булу (быть слабым).

**УЛЦА** *тбл., тара.* файда, табыш (прибыль). Йулдан улцаланып қайтқан.

**УЛЦАЛАНУ** *тбл., тара.* табышлы булу, файда күрү (получить прибыль, иметь пользу).

**УМА** *срг.* к.: **қыра III.**

**УМАЗА** *т.кам.-крш.* к.: **алйот 2.**

**УМАЙ** *тмн., глз.* уңай (удобный). Умей тегел. – *тмн.* Былай ди умай. – *глз.*

**УМАЙУ** *төм.* кылану (представляться, кривляться). Умайып йатма.

**УМАК 1.** *срг.* ачыга изгән бодай камырыннан вак-вак итеп ясап пешерелгән кабартма (пончики, испечённые из пшеничной муки на дрожжах); чаг.: **пипи II, 1.** Май эчендә умақ пешерәләр; **2.** *хвл.* йомарлам (комок). Умак-умак йасап куйалар майны; **3.** *карс.* баса яки киндер вак көлтәсе (небольшой сноп поскони или конопли). Пажийын алалар әлгәрләк, аны умакка куйалар.

**УМАКЛАУ** *хвл.* к.: **умарлау**. Майны кысып-кысып умаклап куйалар да саталар.

**УМАЛЫ** *срг.* умач (затируха).

**УМАЛЫП** *мам.* ябалдашланып, җәелеп, тармакланып – үсү турында (развесисто). Қарға күзе болай умалып үсә.

**УМАРЛАНУ** *хвл.* бөрешү, бөтәрләнү, бөгәрләнү (мяться, измяться). Күлмәгең умарланган.

**көңөл умарлану** *кузн.* күңел нечкәрү (растрогаться). Синең көңләң умарланган былай да.

**УМАРЛАП** *хвл.* учлап (горстями). Шунда умарлап-умарлап сала ашлыкны, йә ыстакан белән.

**УМАРЛАУ** *кузн., хвл.* йомарлау (скомкать).

**УМАРТА** *дөб., шрл., стрл., нгб.-крш.* к.: **мурта 2.** Умарта чақты мине. – *нгб.-крш.* Умартачы кешеләрне сарыб алган умартасы, күзе генә күренә. – *стрл.*

**буй умарта** *перм.* багана умарта (борть, дословно: продольный улей). Ызур шыршы қуwышлыйлар да буй умарта күлиләр.

**бүрәнә умарта** *перм.* к.: **буй умарта**. Бүрәнә умарта, уртасы қуwыш.

**тумар умарта** *каз.ар.-крш.* к.: **буй умарта**. Тумар умарталар булған элек эчен қыwыш ағачтан йасаған.

**умарта күтәрү** *перм.* аерылып киткән корт иле кунып ояласын өчен урманда агач башына махсус умарта ясап кую (устроить борть в лесу на дереве для пчелиного роя).

**умарта менү** *минз., стрл.* умартадан бал суырту (откачивать мёд; медосбор). Умарта менгәннәр дә чақырып җибәргәннәр ийе. Қодалар бүген умарта менәләр, дигән ийе, бал ашап қайта инде. Қызым, тор, инәкийең җәймә пешергән, мин умарта мендем. – *минз.*

**УМАРУ** *дөб.* **1.** умыру (вырвать, оторвать кусок). Қулымның тиреләрен умарып төшерде эт; **2.** йөрәкне телү (терзать душу). Балалар умарып-умарып ала җөрәкләрне.

**УМИР: умирга алу** *стрл.* элек: җәй көне эшләп түләр өчен кыш көне бурычка әйбер алу (раньше: взять вещь, обычно хлеб, в долг с тем, чтобы отработать следующим летом). Умирга алып ашый байлардан.

**УМИТ** [*рус.* омёт] *каз.ар.-крш., к.т., нрл.* к.: **аймут**. Эшләдек, умитын да қуйдық, зурат та қуйдық. – *к.т.* Ире калхузға умитлар қуйа печән, саламныкын. – *нрл.*

**УММА** *төм.* бөтенләй (совершенно, совсем). Аның улы кәпләшмәйте ите умма.

**УМРАУ** *тара.* **1.** түш (грудинка животных); **2.** түш, күкрәк (грудь человека). Умрawың ацық икән, cywық тимәсен.

**УМУТУЛУ** *твр.* онытылу (забываться, быть забытым). Чықма, бабам, ултыр, бир дywабыс умутулуп қалды.

**УМЫРЫЛУ** *лмб.* ишелү (обвалиться). Пугар′-абем бар иде, умырылды.

**УМЫРЫЦҚА** *төм.* тычкан борчагы (мышиный горошек). Умырыцқаны бик йарата сарық, йабрақлары йалбық, қамылы салам шигелле қаты. Умырыцқа уралыб үсә, қабу awыр аны.

**УМЫТ I** *кас.* җәфа (мука, страдание).

**УМЫТ II** *кас., перм.* к.: **қазан.**

**УН** *блт.* к.: **уң I.**

**УНА** *мам., срг.* к.: **ван′а**. Уна безнең dират оло бик. – *мам.* Мында түгел, уна кайа ашат. Уна йылы су бар бит, йусан. – *срг.*

**УНАҒАЙ** *дөб.* уң кул белән язучы, эшләүче, сулагайның киресе (пишущий, делающий правой рукой, антоним слова левша). Сеңлем өйрәнде унағай йазарға.

**УНАЛУ** *нокр., глз.* уңайлану, төзәлү (поправиться, вылечиться). Уналдымы инде кулың, йук каз артыннан йереп кулын сындырды. – *глз.*

**УНАРТЫ** *лмб.* ятак янындагы стенага кора торган әйбер, палас (коврик на стене возле кровати). Унартына йарар бу кызыл читча.

**УНАУ 1.** *карс.* үкереп елау, каты елау (реветь). Анасы биг унады инде; **2.** *тбл.* уйлау (думать, полагать).

**УНДЫЙ** *тара.* унты.

**УННЫ-ТӘРЕСЛЕ** *баст.* к.: **уңны-тиресле**. Унны-тәресле сүзләрне йазып барасыз.

**УННИП-УННИП** *кас.* төптән уйлап (основательно обдумав, тщательно взвесив). Уннип-уннип сүли ул сүзне.

**УНТЫЙ** *эчк.* к.: **унагай**.

**УНУГӘЧ** *твр.* кечкенә онык (маленький внук, внучек). Минеке унугәчем бар. Минең инәмне унугәчем картинә тиде.

**УНУК** [*рус.* внук] *стрл.* к.: **нук**. Унукның унугы инде, шулай өч буwынга киткән.

**УНЧА** *перм.* аерым, үзенә аерым (отдельно). Өстәлне тезеп җийалар, қатын-қызлар унча утыра ти. Унча ғына утыра бер дум.

**УНЫ** *срг.* к.: **ван'а**. Алар уны кузыны тытып тыралар.

**УҢ I** *блт.* элек: берничә аерым хуҗалыкның җире яки болыны (раньше: объединённые участки земли или луга, принадлежавшие нескольким хозяевам). Уңны чыққач та утырып көтәләр ашсу китергәнне.

**УҢ II** *тбл.* уңай, җай (удобный момент). Иц қайтан кәпләр уңын тапмый утырам.

**УҢАЙ** *глз.* чак, әйбәт, җитәрлек (нормальный; нормально). Уңаймы тозы ашның?

**УҢАЙЛАП** *нокр.* яхшылап, әйбәтләп (тщательно, старательно). Ул оланны да уңайлап қарамыйсың ич.

**УҢАЙЛАУ: чәй уңайлау** *нокр.* әзерләү (готовить, накрыть стол). Чәй уңайламайбызмы? Өстәл йийыштыралар да чәй уңайлыйлар.

**УҢАРУ** *глз.* уңайлану, уңалу (поправляться, выздоравливать). Бик озак йаттым awыртып, инде уңардым.

**УҢАШУ** *чст.* аңлашу, киңәшү (советоваться, обмениваться мнениями). Мена шылай җыйылабыз да сүләшәбез, уңашабыз.

**УҢҒАЙ** *минз.* як, тараф (чья-либо сторона). Бу уңғай кешесе күк тимисез.

**УҢГАЙТЛАНУ** *чст.* к.: **уңару**. Әз генә уңгайтланган иде, малайларын көтәләр.

**УҢҒАРУ** *лш.* уңдыру (сделать качественным, вкусным – о тесте). Чүпрә булмаса, бодай әйберсен уңғарып булмый.

**УҢҒАТСЫЗ** *нгб.-крш.* уңмаган ипи турында (неудачный, некачественный – о хлебе). Ипийем уңгатсыз булып пешкән.

**УҢДАРУ** *минз.* к.: **уңғару**. Ниләр уңдарып йөрисез. Биг уңдара торғанийем ипине, бик тәмне була торған ийе.

**УҢДАШ** *блт.* элек: җирләрен, болыннарын бергәләшеп эшкәртүчеләр (раньше: участники коллективной обработки земли или косьбы сена). Әхмәтгәрәй абыйлар белән бер уңдаш ийек. Уңдашта җә алты, җә сигез кеше чаба. Уңдашқа әбәт төшөрер ийек, бәлешләр.

**УҢЛЫ** *тбл.* уңайлы (удобный). Йул уңлы түгел.

**УҢНЫ** *тара.* уңган, булдыклы (дельный, деловитый, способный). Инәм уңны, пес инәмә уқшаған, минең қыслар уңны қый. Атасы да уңныйы, эшмәгәр булты, пөтөн эшне эшли ийе. Ирем әйбәт, уңны кешийе.

**УҢНЫ-ТИРЕСЛЕ** *срг.* килделе-киттеле (несуразно, нелепо); чаг.: **тирес 4**. Уңны-тиресле итеп сүли дә кан'иш. Уңны-тиресле итеп сүли.

**УҢСЫСЛАНУ** *тбл.* уңайсызлану (стесняться). Сестән ойалып уңсысланып утыраты.

**УҢУ** *нокр.* к.: **уңару**. Әти awырта, һаман уңа алмый.

**УҢЦА** *төм.* к.: **унча**.

**УҢЫШМАУ** *мам.* килешмәү, уртак тел тапмау (не сойтись характерами, не ладить друг с другом). Қызым белән кийәwем уңышмадылар.

**УҢЫШУ** *лш.* уңу, килешү, уртак тел табу (ладить, найти общий язык, найти взаимное согласие). Разийалар бик матур торалар, уңыштылар.

**УПҚАҚ** *тбл., тара.* саз (болото).

**УПЛЫҒУ** *к.-уф.* утлыгу (запасть, ввалиться – о боках животных). Малқайларымның көн буйы ач торып, эчләре уплыгып беткән.

**УПМӘК** *срг.* к.: **үпмәк**. Аш сал'аганда карупмәк тә, агупмәк тә ашами. Карупмәк бар. Ашарга упмәген бар, торырга булсын йакшы.

**УПТЫ** *блт.* опты, бәртәс балыгының иң зурысы (крупный язь).

**УПТЫМ** [*рус.* оптом] **1.** *трх.* барын, барысын (всё). Уптым кан'ушна башында йатасызмы? Уптым йыйылдылармы?; **2.** *тмн.* бөтен, барлык (все, весь, полностью). Уптым awылларда да буласызмы?

**УПУТ** [*рус.* путь] *хвл.* рейс, юл (рейс). Бер упутта гына китерәлмәдем, ике сыйра бардым.

**УПШЫР** [*рус.*] *төм., тбл.* комагай, туймас күз (обжора; ненасытный).

**УПЫWЫТ: бер упыwыт** *злт.* к.: **бер: бер тын**. Бер упыwыт эшләсәк, бетә.

**УР I 1.** *т.кам.-крш.* текә ярлы сусыз коры елга (засохшая река с крутыми берегами). Ағачлар, йарлар күп, урлар болонда; **2.** *злт., бгрс., крғл.* тирән канау (глубокая канава). Тирә йағында тирән канау, ур. Ур қазығаннар өй тирәсендә. – *злт.* Ышкул йанында булдығызмы, шунда элек ур қазығаннар. – *крғл.*

**УР II** *тбл.* к.: **бур I**. Уртан ур ғәләл, имеш (*әйтем*).

**УРА** *брб.д.* к.: **уй I, 3**. Урасы йанында қайыннары булған, чөпрәкләр элеп, йаңа кийем алса, кисәген элеп қалдыра торған булғаннар. Ура болган, шуннан күл барлыққа килгән.

**УРАWЫЧ** *кмшл., минз., стрл.* к.: **сарғыч: айақ сарғычы**. Эчтән урawыч урыйлар ыйы чәлтергә, шома булсын өчен. – *кмшл.* Урawыч урап, соңғо wахытта ийоқ була башлады. – *минз.*

**УРАҒАЙ** *минз.* к.: **җаңғалчы**. Урағай, сөйләшмә инде.

**УР'АГАЙА** *хвл.* **1.** к.: **айағочта**. Ур'ағайа йаза; **2.** көлтәләрне киптерү ысулы: биш көлтәдән торган өем (один из способов сушки снопов).

**УРАҒАН** [*рус.* ураган] *төм.* бик каты җил (сильный ветер). Ураған тың қаты йел.

**УРАҒЫЧ** *нгб.-крш.* к.: **сарғыч: айақ сарғычы**.

**УРАҚ** *яүшт., тбл.* каклаган балык (вяленая рыба).

**УРАҚЛАУ** *твр.* сукмак салу; эз калдыру (протоптать дорожку, оставить след). Қуйан урақлап киткән.

**УРАЛМА** *минз., бгрс.* юка гына итеп җәелгән камырны майлап, өстенә киндер орлыгы, варенье яки шикәр комы җәеп, аны катлы-катлы итеп төреп мичтә пешерелә торган камыр ашы (рулет, слойка с начинкой из конопляных семян, варенья или песка); чаг.: **катлама 2.**

**УРАМ** *к.-уф.* к.: **йорт 1.** Малларны урамға йабып куйдым.

**урам арасы** *минз.* к.: **awыл.** Чыгып китте урам арасына.

**урам йөзендә** *кузн.* урамда (на улице). Бар безнең урам йөзендә дә койылар.

**урамнан йөрү** *м.-кар.* кичке уенга чыгу (выходить на хоровод). Урамнан йөремәде, үләнгән.

**УРАМА 1.** *к.т., тбл., брб.д.* юка гына итеп җәелгән камырны буй-буй кисеп, аларны урап, кызган майда пешерелгән камыр ашы (кушанье в виде свёрнутых в трубки полос тонко раскатанного сдобного теста, жаренное в масле). Тоқмач қамыры шикеллене озон итеп кисәләр дә тәгәрәкләп төрәп майда пешерәләр, шул урама була. – *к.т.* Урама ғылып пешерәбес, урап-урап қасанга ташлайсың. – *тбл.* Йомарлаты та, йәйте тә орап-орап майға салып пешерте. – *брб.д.*; **2.** *дөб.* к.: **катлама: шырпылы катлама 1; 3.** *тара.* әт эчәгесе (вьюнок полевой).

**УРАМАЛ** *брб.д., яүшт.* к.: **тасмал 2.**

**УРАНЛАУ** *брб.д.* кычкыру (кричать).

**УРАПЫЙ** *дөб.* җыйнаксыз (неаккуратный, неряшливый, несобранный). Өйөнә керсәң дә урапый, үзе дә урапый инде ул.

**УРАТА** *дөб.* **1.** арбаның арткы күчәре өстендәге агач (толстый брус на задней оси телеги); **2.** бүрәнә ташыганда чанага аркылы куела торган уелмалы агач (приспособление, подкладываемое под брёвна при перевозке их на санях).

**УРАТМА I** *кузн.* киләп агачы (сновалка).

**УРАТМА II** *минз., стрл.* юка гына итеп җәелгән камыр өстенә бәрәңге боткасын сылап, аны төреп, вак-вак кисәкләргә кисеп табада пешерелгән рулет (рулет с начинкой картофельного пюре).

**уратмалы күмәч** *тпк.* катламлы камырдан пешерелгән күмәч (слойка).

**УРАТЫМНЫ** *минз.* уратырлык (длиной обмотки). Өч уратымны, менә шулай муйынга таға торған төймәм бар иде.

**УРАУ I** *карс.* уру (жать). Йазны килен кырдан да килми, ураг урый. Урак белән урый идең.

**УРАУ II** *твр.* куплет. Йырла пер-ике урау.

**УРАУГЫЦ: балтыр ураугыц** *чст.* к.: **сарғыч: айақ сарғычы.**

**УРАУЛ'АҢ** *тбл.* мунчала оек – итек эченнән киелә (чулки под болотные сапоги, сделанные из мочала).

**УРАУЧЫҚ** *твр.* төенчек (узел). Наски кийәүгә, инәсенә йышым (оек), атасына наски, қулйаулық, қалач урама ураучыг эчендә.

**УРАЧА** *глз.* үрәчә (грядки телеги). Арбасына сикереп утырдым, ат артка чигенде, арба капланып, урача белән эчтинага китереп кыстырды.

**УРҒЫЧ** *клм.* урак (серп). Урғыч белән ашлық урғаннар, көлтә бәйләгәннәр.

**УРДЫК 1.** *миш.д.* урындык (стул, табуретка). Йаңы урдыклар алырга кирәк. – *лмб.* Артлы урдык. – *срг.*; **2.** *т.я.-крш., кузн., срг., хвл., чст., чпр., әҗе., шрл.* к.: **түр 1.** Урдык аста, зур козауда, бер ана каз утырган; Хаз'ыр, җиңи, аңгардыңмы, Кем чеметте ботоңнан (*хал. җыр.*). Бәйнем сөйәр урны гынам, Чоландагы урдыкта, Бәйнем әтийем бик хвалный, Көңлө йөри зурлыкта (*хал. җыр.*). Мин урдыкта йыкладым. – *чст.* Идән-урдыкка гына инде бу су. Урдыкта йыкларсын микән син? Агач урдык, бар сәләмәңне дҗәйгән дә менеп йаткан. – *чпр.* Урдык түрдә, митр киңлеге, картлар шонда йаталар. – *хвл.* Урдыкка түшәлеп йаталар да, әмән үлеп йоклыйлар. – *кузн.* Ул урдыкта тора церге, этәнәгә тоташтырган, такталар җәйгән, анда куна идек, зата идек йоклама. Тәрәзә өстендә була иде урдык түрдә. – *әҗе.* Элгәре урдык була иде үтүрендә. – *шрл.*; **3.** *тмн., срг., кузн.* эскәмия (скамья). Циләкләр урдыкта. Катны идәнне, урдык асларын йуwырга тотынгач, йыланны күреп бик куркынган. – *срг.*; **4.** *карс.* карават (кровать). Тартып тешерәләр, дир, урдыктан.

**кыцы урдык** *тмн.* мич каршына беркетелгән эскәмия (скамья, прикреплённая напротив печи). Кыцы урдык пиц каршында була.

**тар урдык** *лмб.*, **түр урдык** *срг.* к.: **урдык 3.** Шылай түр урдыгына килеп утырды. – *срг.*

**тезмә урдык** *чпр.* к.: **түр 1.**

**УРҖУ** *перм.* к.: **пожу.** Эче урҗып бетә, ашар җире қалмый бәрәңгенең, шытқач.

**УРИН** *перм.* к.: **мыштым.** Қычқырма, уриң ңына уқы.

**УРИНА: урина кебек кийенү** *злт.* уралу, калын киенү (одеваться очень тепло, укутываться). Сuwық былғас, хатыннар урина кебек кийенеп баралар. Баласын урина кебек кийендергән, атлый да алмый.

**УРЛАҚЦЫ** *тара.* к.: **бур I.**

**УРЛАП-ТУРЛАП** *төм.* урлаштырып (понемногу воруя). Урлап-турлап қына утын йаға.

**УРЛЫҚ 1.** *твр.* караклык (воровство); **2.** *төм.* урланган әйбер, хайван (украденная вещь, скотина). Урлыкны төннә суйа, қәләл малыңны төннә суйғалы түгел.

**УРМАЛЧЫҚ: урмалчық печин** *перм.* к.: **бермәкәй.**

**УРМАЛЫ-УРМАЛЫ** *минз.* спираль сыман (спиральный, спиралеобразный). Тимер (сиртмә) урмалы-урмалы була.

**УРМАН 1.** *срг.* куак, бер төп агач (куст, дерево). Тәнә анда урманны ызба безнең атайларныкы. Бер агач та урман, урман да урман бездә. Имән урманын ызба салганда ызба астына куйалар; **2.** *төм., тбл., сазл., тара.* чыршы (ель). Қарағай, урман цытамнырағ өйгә. Урман тубырцыгы. – *тбл.* Пестә йәй тә йәшел, қыш та йәшел, урман тигән пер ағац үсәте. Нарат пестә ас, күберәге урман, қарағайлар пестә йуқ. Урманныкы қулға қаты энәсе. – *төм.*; **3.** *тара.* ылыслы агачлар (хвойные деревья).

**кызыл урман** *карс.* к.: **ағач: қызыл ағач.**

**төн урманы** *перм.* кара урман (дремучий лес, дебри).

**урман анасы** *срг.* к.: **йарымтық.**

**урман әбей** *глз.* мифик образ – урман иясе (мифический образ – главный лесной дух).

**урман бабам** *нокр.* к.: **йарымтык**. Кешене урман бабам қытықлап үтерә икән дигәннәр борыңғылар.

**урман йасмығы** *мам.* к.: **чыпчык: чыпчык борчағы**.

**урман қырлығы** *мам.* к.: **үлән: қырлығ үлән**.

**урман талы** *мам.* вак тал, кәҗә талы (бредина, ива козья).

**урман тәмәкесе** *минз.* к.: **қырлыған 1**.

**УРМАННЫҚ** *тбл.* урман (лес).

**УРМАНЧЫ** *перм.* к.: **аңцы 1**. Җаланға йөргәндә мылтық белә генә җәрим ийе, үзем урманчы.

**УРМАУ** *перм.* урау (намотать, обмотать). Қысқа нимә белән урмап куйған идем, қысқа нимә җиңдән чыгып қачқан.

**УРНАЛУ** *нокр.* урнашу (устраиваться). Барып урналғач, хат йазармын дигән.

**УРНАРТЫ** *кузн.* карават турысына стенаға әленгән келәм (ковёр, навешенный около кровати). Үне кийендерәләр, урнарты вата кавир ала, пыл′ут ала.

**УРНАСТЫ** *сазл.* к.: **ғелбәч**. Кәртфх′әне урнастыға қойawc. Урнастыта утын, кирәк′мәс әйwерләр сахлайwc.

**УРНАТУ** *нөкр., брб.д.* урнаштыру (помещать, поместить). Бик Қазан йаққа урнатасы килә балаларны. – *нокр.*

**УРНАУ 1.** *перм.* урнашу (помещаться, поместиться). Чумадандағы әрбир белә булмый, бер җиргә урнамаға кәрәк; **2.** *тбл.* урын алу (занимать место).

**УРНАШ 1.** *злт., кргл., бгрс.* к.: **аулағаш**; **2.** *минз., бгрс., кргл., стрл.* аулак өйдә пешерелә торган ризык (блюдо, приготовляемое на посиделках). Инәкәй өйдә йуқ, әйдә бүген урнаш пешерәйек. – *минз.* Ике күкәй алып барасың, он алып барасың бер қоштабақ, урнаш пешерәсең шунда. – *бгрс.* Бәйрәм булса йегетләр теңкәгә тийәләр ийе, әйдә урнаш пешерик дип. – *кргл.* Кыз wакытта урнаш пешерәдер ийек. – *стрл.*; **3.** *хвл.* к.: **ботка: йаңгор боткасы**. Әwәл йаңгор йаумаганда, урнаш пешерәләр иде. Тоталар да су буйына казаннар төшөрөп урнаш пешерәләр – кем нәрсә китерә: ике йоморка, каймак. Карчыклар, оланнар җийыла. Катыннар пешерә. Ашагач, су бәрешәләр.

**УРНЫ 1.** *кузн.* урын (место). Эшләминче вет йарамый, урныга керер; **2.** *нокр., кузн.* к.: **урныйир**. Урны чыгарганда әтеки әтәләр иде. – *кузн.* Урныға йат. – *нокр.*

**УРНЫҒУ** *перм.* урнашу (устроиться). Тулкы күтәренмә ти, бик шәп урныққан ти сүwәген (сынгач). Улан абай урныкмаса, бик шәб awырта эч улан тапқач.

**УРНЫ-ЙИР** *тмн., кузн.* урын-җир (постельные принадлежности). Урны-йирсез калды, йандылар. – *тмн.* Чыгаралар урны-йирен, шонда инде әтеки әтәләр иде, йегетләр әтә иде. – *кузн.*

**УРНЫЛАУ** *карс., лмб.* **1.** урнаштыру, ябу (закрыть, поместить). Аларға туры килгән куйларны урныларга азбарға. – *карс.*; **2.** урнаштыру (устраивать, устроить). Ирем үлде, йәш ылан мынан калдым, аларны урныладым. – *лмб.*

**УРСАЙ** *каз.ар.-крш.* к.: **урсәний**.

**УРСАНАЙ: карт урсанай** *чст.-крш.* эти-әнисен чукындырган хатын-кызга эндәшү сүзе (слово обращения к крёстной матери родителей).

**УРСАТАЙ: карт урсатай** *чст.-крш.* эти-әнисен чукындырган ир кешегә эндәшү сүзе (слово обращения к крёстному отцу родителей).

**УРСАТНА** *тмн., кузн., лмб.*, **УРЫСАТНАС(Ы) КӨН** *блт., мам., лш., минз., бөре., нгб.-крш., стрл., т.я.-крш., м.-кар.* якшәмбе (воскресенье). Урсатна көн йалмы сездә дә? – *тмн.* – Качан, Һава, кунакка чакырасын мине? – Урсатнаны. – *кузн.* Китәктә (*ав. ис.*) базар урсатнас(ы) көн була торған ийе. – *блт.*

**УРСӘНИЙ** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* баланы чукындырган хатын-кыз (крёстная мать). Урсәнийнең қәле ничек тий? – *каз.ар.-крш.*

**УРСӘТИЙ** *каз.ар.-крш., чст.-крш.* баланы чукындырган ир кеше (крёстный отец).

**УРСИЙ** *каз.ар.-крш.* к.: **урсәний**. Урсийда бит әле ул.

**УРТ 1.** *тара.* к.: **қамақаш**; **2.** *тара., тбл.* битнең эчке ягы (внутренняя сторона щёк); **3.** *төм.* авыз куышлыгы (полость рта). Уртын тутырып ашай. У мәцкәй уртын тутырып ашай, цәйнәмәй йийама? **4.** *брб.д.* теш казнасы (десна).

**УРТА** *минз.* уртанчы (средний). Машинаны урта малайға бирдем.

**УРТАҒЫМ** *каз.ар.-крш.* нардуган вакытында маскарад киеме киенеп өйдән өйгә йөрүчеләрнең өй хуҗасына эндәшү сүзе (форма обращения к хозяйке во время святок, когда наряженные ходят по домам). Тәрәзәгә килә дә инде өйгә кереп җиткәнче, уртағым, кередеме, кередеме, дип тақмақлап керә инде. Менә берәү килә инде, Дарийа уртағым, безне кертеп чыгарыгыз әле, дип.

**УРТАГЫМ** *чст.-крш.* якын таныш (приятель, близкий знакомый); чаг.: **тамыр**. Уртагым киләм дигән ийе, шуны көтәм.

**УРТАҒЫШ** *каз.ар.-крш.* **1.** урта, урталык (середина). Уртағыштайы кантур; **2.** урталай (пополам, на две части). Моно уртагыш бүләсез.

**УРТАҒЫШЛАЙ** *минз.*, **УРТАҒЫШЛЫЙ** *кмшл.*, **УРТАГЫШЛЫЙ** *чст.-крш.* к.: **уртағыш 2**. Уртағышлай инде ул чағында. Мин уртагышлый китердем хәзер (тукыманы). Каҗыр шушы катламаны кисәләр уртагышлый.

**УРТАК 1.** *чст.-крш.* бергә эшли торган кешегә эндәшү сүзе (форма обращения к работающему вместе человеку). Уртак, әйдә утыр ашарга; **2.** *т.кам.-крш.* кызның әнисе һәм *кыямәтлек*нең бер-берсенә эндәшү сүзе (форма обращения матери невесты и *кыйаматлык* друг к другу). Уртақлар бит без, қызымны боларға қачырды Бит′а кийәү. Қыз анасы, қызның қыйаматлығы икесе уртақ булалар.

**УРТАҚШЫЛ** *яүшт., брб.д.* перпендикуляр (перпендикулярный).

**УРТАЛА** *лш.* к.: **уртағыш 2**. Уртала бүлгән бүлмәне сүтеп ышкул йасағаннар.

**УРТАЛАУ** *тбл.* урталай бүлү, арадашчы итеп алу (делить пополам, принимать в посредники).

**УРТАМ** *том.д., тбл.* йотым (глоток).

**УРТАН I: уртан җилек** *минз., стрл.* ботның юан сөяге (толстая бедренная кость).

**УРТАН II** *тара.* уртанчы (средний). Бу уртан қысым.

**УРТАРА 1.** *нокр., глз., лмб., перм.* к.: **уртағыш 2.** Чап уртара бу утынны. – *лмб.* Башыңны уртара йарма керәк ич синенкесен дий. – *нокр.* Қалақларны, сawытларны уртара бүлеп алып чыгып китте, мал уртара, кәртүк уртара. – *перм.* Уртара кисә чөгөндерле ипине. – *глз.*; **2.** *трх.* к.: **уртағыш 1.** Уртадан кизләү ага.

**УРТАШ** *лмб.* үлгән кешене алты айдан соң искә алып үткәрелгән аш (поминки, проводимые через полгода после смерти кого-либо). Урташын үткәрдем кан'амның.

**УРТЛАТУ** *кузн.* егет белән кызга баллы су каптыру йоласы (свадебный обряд: дать глотнуть сладкую воду жениху и невесте с пожеланиями жить в ладу). Кыз белән йегет кушыламы, чөчө су йасыйлар да, кыз белән йегеттән уртлаталар, килен йакшы булсын, тату торсыннар.

**УРТЛАУ** *әстр., тбл.* кабу (брать в рот). Сөт уртлай. – *әстр.* Awызымны уртлаб алайын. – *тбл.*

**УРТЫН 1.** *т.я.-крш., чпр.* астыртын, яшерен (скрытно, исподтишка, тайком). Уртын гына тикшерергә килделәр. – *чпр.* Уртын барып эчәбез, алар күрмәсен дип. – *т.я.-крш.*; **2.** *дөб.* акрынлап, азлап (постепенно, медленно). Оно сuwығрақ булса, қамыр уртын ғына күтәрелә.

**УРУ I** *яүшт., брб.д.* сарык йонын кырку (снимать шерсть с овец).

**басып уру** *минз.* урганда узып китү (опережать – при жатве серпом). Күп кешеләрне басып ура торған идем.

**УРУ II** *тбл.* шеш (опухоль).

**УРУҚ** *төм.* нәсел (род, родня). Песнең уруқ, қәртнәбес тә Талмы (*ав. ис.*) сийәраткә йатты.

**УРЦУ** *сазя.* үрчү (плодоносить). Урцыйтхан кәртфх'ә.

**УРЦЫҚ** *брб.д.* орчык (веретено).

**УРЦЫКПАШ: урцыкпаш сөйәк** *тбл.* к.: **ашық II, 2.**

**УРЧА** [?] *т.я.-крш.* к.: **абышқа 2.** Урчага китү.

**УРЧЫҚ** *брб.д.*, **УРЧЫХ** *сазя.* к.: **урцық.**

**УРЫ** *сазя.* к.: **бур I.** Син уры тиф қыцхырат.

**УРЫЙН** *к.-уф.* тавыш-тынсыз, акрын (тихо, бесшумно). Урыйн ғына артларыннан нәрсә сүләшкәннәрен тыңлап бардым.

**УРЫН I 1.** *минз.* к.: **аслата.** Урын мич бәрәңгесе дә ашап булмый инде (киленгә). Кийәү йегетләр урын ғына эчәләр ийе (чәйне).

**урын-җир** *минз.*, **урын-йер** *глз.* аулак җир (укромное место). Қайда урын-җир бар, барадыр ыйым да кисәдер ийем ағачны. Йер йетмәгән, урын-йергә утырганнар.

**УРЫН II 1.** *төм., тбл., сазя.* к.: **түр I.** Урыннар йасап қуйганнар тақтадан. Хәсерге шигелле диваннар булмаган, урыннар булган. Түртә урын пулган, өстәл тә пулмапты әwәле. – *төм.* Урын өстенә сантых қуйабыз. – *сазя.*; **2.** *к.-уф.* к.: **урындық.** Идәнне сырлаганда урынны күчереп қуй.

**мишәр урын** *трх.* к.: **урынтык.**

**сыйыр урыны** *яүшт.* сыер абзары (коровник).

**урын алу** *т.кам.-крш.* туй йоласы: кодалар туйға килгәч җыр җырлап урын алалар (свадебный обряд: приехавшие на свадьбу сватья занимают места лишь после того, как споют песню). Урын алырға киләләр қызның аналары, туганнары, җырламийнчы урын бирмиләр. Нидийен генә җырлайм микән: Бийек тауларның башында Пыйала мәчетнең урны бар, Өстәл башларына утырырға Оло қодаларның урны бар.

**урын асты** *тбл., тара., төм., сазя.* к.: **гелбәч.** Бәрәңгене урын астына қойабыз. – *сазя.*

**урын килмәү** *лмб.* җайсыз булу – урын турында (быть неудобным – о месте). Урын килмәдеме әллә, кыйты йыкладың?

**урын өстәл** *төм.* сәке өстенә куела торган кыска аяклы өстәл (столик на коротких ножках, который ставится на нары).

**урыннан бул** *т.кам.-крш.* утыр (садись).

**урыс урыны** *нрл.* к.: **урынтык.** Урыс урыныңың кылычы, көрөсе, сосасы, шүресе була.

**УРЫНАЙЛАНА** *глз.* к.: **урын-чабулар.** Урынайлана бик ару тора, ыстирал'ный машина бар.

**УРЫНБАШ** *твр.* к.: **инсә.**

**УРЫНДЫҚ** *нрл.* эскәмия (скамья).

**УРЫНҖОБАН** *бөре.* к.: **аслата.** Урынҗобан була кеше, эрмәй тешнәй торған.

**УРЫНТЫ** *тара.* камыл (стерня; жнивьё).

**УРЫНТЫҚ 1.** *тбл., төм., тара.* к.: **түр I.** Урынтык йоқ қәсер. Порон заманта пулған урынтык кыруғум. – *тбл.*; **2.** *тара.* к.: **бүкән I, 1.**

**урынтығ асты, урынтық асты** *тара.* к.: **гелбәч.** Пы урынты ғасты, картуп қуйа торған. Урынтық астына кәртүк қуйасың. Урынтық асты салқын песнең.

**УРЫНТЫҚ** *т.я.-крш.* киндер сугу станы, киндер урыны (ткацкий станок). Түгән кисап белән тәрәшле тарак күбек, пичкә салып пешергән, озатқан, урынтыгы бар энде аныкы.

**УРЫНТЫН 1.** *мам.* җирле (местный). Урынтын сүзләр килеп чыққалый; **2.** *нокр., глз.* к.: **аслата.** Әтәй-әнәйдән урынтын чығалар (кияүгә). – *нокр.* Кызым урынтын китте. Әтәй-әнәйдән урынтын чыктым. – *глз.*

**УРЫНЧА** *каз.ар.-крш.* урын җиткән кадәр (по возможности, сколько хватает место). Утыр урынча, сөйләшербез урысча (*әйтем*).

**УРЫН-ЧАБУЛАР** *т.я.-крш.* урын-җир (постельные принадлежности). Урын-чабулар сугабыз ыйы, ыланнарга күлмәк, кызлар утырма килә йат awыллардан.

**УРЫСӘТНӘ** *перм.* к.: **урсатна.**

**УРЫСБАШ** [*рус.* + *тат.*] *перм.* к.: **қарағай: қарағай үләне.** Урысбашны җаңы үскән чағында турап пирук пешерәбез.

**УСАWЫН** *яүшт.* өченчекөн (позавчера).

**УСАҒА** *злт.* к.: **гарнич.**

**УСАД'БА** *нгб.-крш., лмб.*, **УСАДБЫ** [*рус.* усадьба] *лш., каз.ар.-крш., минз.* к.: **паз'ма.** Иске җорт, усад'басы да кечкенә. Узған җыл безнең усадбы утыз туғызыйы. – *минз.*

**УСАДБА** [*рус.* усадьба] **1.** *карс., стрл.* к.: **паз'ма.** Башка чыкканда усадба кирәк инде. –

*стрл.*; **2.** *лмб.* к.: **алмалык**. Усадбаны тырактыр сукалый.

**УСАҚ 1.** *брб.д.* озак (долго); **2.** *төм., тбл.* ерак (далёкий).

**УСАЛ 1.** *лмб., кузн., срг., карс., нокр., кас., т.кам.-крш., нрл.* начар, әйбәт түгел (плохой, дрянной); чаг.: **йаматай**. Ул жа'ларда жуллар би' усал. – *кас.* Тупрақ усал безнен, йералма булмай. Бусы усал да булды, илле тәңкәгә алдым (шәл). – *нокр.* Ацы катык, усал кашык малайым белән киленемә (*әйтем*). Ыштапел бик усал йүләргә. Урын усал тегелме? – *срг.* Усал тырмадык каниш белән, йахшы тырдык. Кылакларым усалрак. – *лмб.* Бездә урман йагынан усалрак. Ул кыйының cywы бик усал. – *чст.* Пиж башында йаттым, күлмәгем усал. Йыры усал тегел вет. Усал тырганнар киткесе кели инде. Пирбуй килгәндә усал гына кийенә башкыда. – *кузн.* Кыкумәт awызыңа салып тора, иту да усал бездә. – *нрл.* Ийем усал хазер. – *глз.* Мындый герәздә йул усал, беләмесен. Усалын да, йакшысын да күрдег инде. Йазу эше вет усал, тенне, кенне, бакчы. Манарасын кистеләр теге усал йылларны. – *карс.*; **2.** *кас., нокр.* авыр (тяжёлый; тяжело). Усал тормышта үсмиди' без. – *кас.* Қәйwан acpawы бик усал. – *нокр.*; **3.** *минз., чпр.* үткен, җитез, оста, булдыклы (бойкий, проворный, умелый; умело); чаг.: **чирақ**. Усал ура торған идем урақны. Бу қызым тағы да усал: бакчаны бер көндә бетерә утап. Эшкә усаллар алар. Усал уқытты ул безне. – *минз.*; **4.** *глз.* нык, көчле, каты (сильный, крепкий). Кош коно биг усал cywык була ий; **5.** *байк.* кыю, үткен акыллы (смелый, бойкий). Усал кеше капшап та йөрөй икән сарыкны, сез беләсездер әле, усал сез; **6.** *кас., нокр.* ачы (едкий, жгучий). Усал җил. – *кас.*; **7.** *бөре.* әйбәт, күп (хорошо, много, обильно). Хәзер кыругым бирелә бит бирнә, әле дә усал, әлеке ул тикле бирелмәй торған ийе.

**алама усал** *злт.* явыз (злой, зловредный).

**усал йозак** *байк.* ватык йозак (неисправный замок). Үзең шунда йортта тороп, усал йозак белән бикләгән.

**УСАЛЛАУ** *кузн.* начар итеп күрсәтү (показать с плохой стороны). Бик усалламагыз да, мактамагыз да. Үлгән кеше үлгән инде, аны хазыр тагы да усаллаганнар.

**УСАЛЛЫҚ** *нокр.* начарлык (дрянь; скверность). Денйаның йақшысындин усаллығын күп күрдем.

**УСАЛТЫНА** *саз.я.* белә торып, махсус (специально, зная). Усалтына кицхәсен үцехтерәт.

**УСАТ** [*рус.* усадьба] **1.** *срг., карс., клд.* к.: **алмалык**. Усатка цыгарга кирәк. Усат күтәрәм. Иртәгә усатымны утарсын да, әләкле генә тешкә итәрмен үзегезне. Усатыбыз бик зур, картуп күтәргәндә билләрем калмый. – *срг.* Усатыбыз йакшы, бәрәңге күп була. Йегерме биш сутый усат бирделәр. – *карс.*; **2.** *клд.* кырдагы бәрәңге бакчасы (картофельный огород в поле). Артта безнеке агарут бар, усат та чәчәм. Усатым бик гордалы, кышын салам ташыганнар. Бездә усатлар тигез түгел, кемнең ун сутый, без пинсианир, ун сутый; **3.** *карс.* к.: **паз'ма**. Усатка инде бар да керә.

**УСАТБА** [*рус.* усадьба] **1.** *мәл.* йорт-җир, хуҗалык (личное хозяйство). Бер кадак какмады усатбага; **2.** *стрл.* к.: **йорт 1**. Казларны кертмәскәйе, ату усатбаны чүплиләр.

**УСАТБЫ** [*рус.* усадьба] **1.** *чст., перм., минз., трбс.*, **УСАТПЫ** *перм., минз.* к.: **паз'ма**. Усатбыдан йәш алма алып керим булмаса. Усатбыга казлар кергән, үләт кыргылары. – *чст.* Бу этиләрнең усатпылары. Өй сала торған җирләрне, бакча утырта торган җирләрнең барын да усатпы диб атыйбыз. Без теге усатпыда ийек. – *минз.* Мынaw қыр күрше дә бар иде, усатбысы ғына қалды. – *трбс.*; **2.** *трбс.* к.: **алмалык**. Тормаған өйнең усатбысына бәрәңге чәчәбез.

**УСҚЫРМА** *төм.* нигез туфрагы (завалинка).

**УСТАН** *тбл.* к.: **қазнақ 1**.

**УСТУҒАН** *тбл.* мәетләр куела торган сарай йорт (сарай, дом, где ставятся трупы).

**УСТЫ** *тара., тбл.*, **УСТЫЛЫҚ** *тбл.* к.: **қазнақ 1**. Усты да кирбецтән. Усты ағацтан, уртасына қом тутыратлар, аннан кирбец төзәтләр. – *тара.*

**УСТЫҒА** *төм.* мич алды (шесток).

**УТ I** *тбл.* учак (очаг).

**сайысқан уты** *перм.* тычкан уты (гнилушка). Сайысқан уты черек усағачта була.

**ут башы** *нрл.* к.: **йосомбаш**. Ут башын учаққа тартасың кисәү белән.

**ут қайсы** *клм.*, **ут қайчысы** *яүшт.* к.: **кустартқыч**.

**ут қыстыру** *саз.я.* ут кабызу (зажечь огонь). Их'мәх' күwхәнце мейец қыстырыф йеwәрәм.

**УТ II** *миш.д.* чүп үләне (сорняк, сорная трава). Минем бакчаны да утадыгызмы, утлар калмадымы? – *чст.* Аларның басуwында ут та йук. – *чпр.* Картуп утадым, уты күп. Матига белән утларны кистерәбез. – *срг.* Алманы ут баскан, утарга кирәк. – *лмб.* Ат йигеп ындырны себерәбез герәблә белән, ут чыкса, аны тырныйбыз. Цегендере дә бигрәк утлинде. – *мәл.* Ут баскан бакчаны бик. – *тмн.* Арышны ут баскан. – *м.-кар.*

**кандала уты 1.** *срг.* себерке үләне (клоповник, венечник); **2.** *кузн.* к.: **үләм: кандала үләме**.

**кәккүк уты** *тпк., стрл.* күкебаш (медуница, хохлатка).

**кишер уты** *лмб., тмн.* төтәч (дымянка лекарственная).

**тал уты** *лмб.* карабодайчалар семьялыгыннан (гречишник шероховатый).

**тары уты** *лмб.* (ежовник, петушье просо).

**убыр уты** *лмб., срг.* шайтан таягы (чертополох курчавый).

**ут чәчәге 1.** *минз.* саз бишьяфрагы, саз ут чәчәге (сабельник болотный); **2.** *каз.ар.-крш.* ала миләүшә (фиалка трёхцветная)

**ут чәчәк** *бгрс., кргл.* к.: **убыр уты**.

**утка цыгу** *чст.* чүп утарга чыгу (идти полоть). Үзе утка цыга, әнисен цәй эцерә.

**чәнчү уты** *трх.* чәнчү үләне (синеголовник плосколистный). Чәнчү уты күл буйларында үсә, киртләч йафрақлы, чәнчү чыққанда эчә торған үләп.

**УТАБА** [*рус.*] *брб.д.* к.: **алсын 1**.

**УТАWА** [*рус.* отава] *эчк.* к.: **алсын 1**. Утawаға цыққан сыйырлар.

**УТАWЫЩ** *саз.я.* к.: **йара II: йара йапрақ**.

**УТАЙЛАУ** *хвл.* уру, сыпыру (уплетать, поедать). Мат′амал казлары болгамамны утайлаганнар.

**УТАР 1.** *минз., т.кам.-крш., крғл., стрл.* аерым кешеләрнең йортында терлек ябу өчен киртә яки читән белән тотып алынып, өсте ачык яки ябык булган урын (открытый или закрытый загон для скота во дворе; карда). Абзарларына, утарға кереп салам алып чыгалар икән. Утарның йартысы түшәмне була торганыйы, салам тутырырға. – *минз.* Мин тептә берүзем, Хәйерттин утарына барып җиттем. – *крғл.* Утарлары урынына монча салганнар. – *т.кам.-крш.*; **2.** *мам., минз., нгб.-крш.* колхозның фермалары янында вакытлыча терлек ябып тоту өчен киртәләр белән әйләндереп алынган ачык яки ябык урын, ферма каралтылары (открытый или закрытый загон для скота на колхозной ферме). Утарларны җылда тазарталар ыйы, быйыл җуғ әле. – *мам.* Калхузның утары йабық булмый. Сыйырларны фермы йанында cawалар да утарға җибәрәләр. – *минз.*; **3.** *минз.* иген чәчү өчен уратып алынган җир (загороженное место для посева); **4.** *чпр.* к.: **мурталык.**

**утар абзар** *стрл.* к.: **абзар: абзар алды.**

**УТАРУ** *дөб.* майны атлаганнан соң, суга салып йомарлау (делать комочек, придавать круглую форму – о масле). Атлағач майны суға салып утарасың инде.

**УТАРЦА** *тбл., төм.* к.: **йара II: йара йапрақ.**

**УТАУ I 1.** *твр., том.д.* алачык (куыш, шалаш). Утаута қуналар игән. – *твр.*; **2.** *тара., твр.* яңа өйләнешкән кыз белән егетнең түшәк урыны (ложе новобрачных). Туйдан соң утау була. Утау түшәк булгач, кийәү белән кәләш түрғенгә баралар. – *тара.*

**утау түшәк** *тара.* к.: **утау 2.** Қыс көйәү йаққа килгәч, боларға утау түшәк тигәннәр, қырық көн булған ул, йеңгәсе аш-су әсерләп йөргән.

**УТАУ II** [*рус.* отава] *мам.* к.: **алсын 1.** Утawын чawып та боғол қуйалар қай җылны.

**УТАУЛАУ** *тара.* кияүләп йөрү (ходить, ездить к невесте). Перәүләр пер йете, пайлар айғаца утаулап йатқаннар.

**УТАУЛЫ** *перм.* к.: **утлы.**

**УТАУЦЫ: утауцы йапрақ** *тбл.* к.: **йара II: йара йапрақ.**

**УТБАСАР** *әстр.* туй алдыннан кыз өенә җибәрелә торган кием-салым һәм ашамлыклар – калым (выкуп, уплачиваемый женихом родителям невесты).

**УТЕШ** *хвл., мәл.* к.: **утыч-утыч.**

**УТИНӘ** *тбл.* к.: **бийауса.**

**УТҚУУ** *яүшт.* кая булса да барасы килү (желать непременно идти куда-нибудь).

**УТКҮЗ** *чст.* нәдербаш, күркә борыны, кузлут чәчәге (чистец забытый).

**УТЛАНУ** *тмн., чст., кузн.* чүп үлән басу (зарасти сорной травой). Ул чөгендерем утланган. – *тмн.* Бакчабыз утланган, утарга иде әле. Бакчага күз салганым йук бу көннәрдә, утланган йаңыдан. – *чст.* Суганнар йәп-йәшел утланган. – *кузн.*

**УТЛАРИКӨН** *тя.-крш.* к.: **бушкен.**

**УТЛАУ I** *лмб., күрш.* к.: **уклawык.** Утлау бән йәйәсен камырны. Утлауга чормап йәймә йәйәбез. – *күрш.*

**УТЛАУ II** *минз.* ашау (есть, кушать). Ғәлимнәр күп җоқламас, харам ридық утламас (*мөнәҗәт.*).

**УТЛИW** *перм.* утлык (ясли, кормушка для скота). Утлифкә саласын да печинне ашатасын.

**УТЛЫ** *лмб., тмн.* чүпле, чүп үләнле (сорный). Тары мынан тривужны, тары бик утлы. – *лмб.* Бакча бик утлы. – *тмн.*

**утлы күз 1.** *глз.* к.: **баллы: баллы қuwәт 2.**

**УТЛЫҒУ** *төм.* к.: **самсырау.** Awырған кеше утлыға, йонцый. Утлығып қалған.

**УТЛЫГУ** *срг.* хәлсезләнү, ару (обессилеть, устать). Йулдан утлыгып килгәч, эцелә ул цәй.

**УТЛЫҚ I** *нокр.* к.: **сызғыч.**

**УТЛЫҚ II** *әстр.* утлавык (пастбище).

**УТРАК** *хвл.* арт сан (ягодица).

**утрау** (остров):

**су утрawы** *минз.* язын су баса торган болын (заливной луг).

**УТРАЧ** *яүшт.* утрау (остров). Әстәған утрачта та бар.

**УТРЫБ, УТРЫП** [*рус.* отруби] *срг., хвл., кузн.* **1.** к.: **эре**; **2.** көнбагыш түбе (выжимки, жмыхи, дуранда). Ике мишук утрып эцергән бызawына. – *срг.* Кулып утрыбы да ашадык сугыш wакытында. – *хвл.*

**УТ′У** *глз.* к.: **утлык II.** Ут′уга илтте ашасы сыйырны, чилеме ашарга.

**УТУРЛАШУ** *тбл.* каршы килү, каршы төшү (противоречить, противиться).

**УТ′-УТ′-УТ′** *кузн., мәл.* үрдәк чакыру ымлыгы (возглас, которым подзывают уток).

**ҮШӘН** *каз.ар., т.я., минз., бөре., перм.* к.: **азымтык**. Бу қадәр үшән булырсың икән, йатқан урыныңны да жыйыштырмыйсың. – *минз.* Күпме суқсаң да бармай, бу ат бик үшән икән. – *бөре.* Безнең атқа қарағанда Ғилмиләр аты үшәнрәк йөри. – *перм.*

**ҮШЕЛДЕРЕК** *м.-кар.* к.: **зипун**.

**ҮШКӘ** *тбл.* кечкенә борау (буравчик).

**ҮШИ'** *кас.* к.: **йәләк**.

**ҮШИ'ЧЕ** *кас.* гайбәтче (сплетник, сплетница); чаг.: **үширге**.

**ҮШИРГЕ** *перм.* арттырып сөйләүче, гайбәтче хатын-кыз (сплетница). Арттырып сүли, йалғанны сүли, ир кешеләр түгел, қатын-қыз үширге була.

# Ф

**ФАЙ** *тмн.* тукыма төре (один из видов ткани). Мин фай күлмәктән, фай камзулданештем.

**ФАКЫР** [*гар.*] *срг., чст., чпр., кузн., карс., хвл., кас.* к.: **бахыр**; чаг.: **па'арча'**. Әй, шуны да белмисең, факырым. – *чпр.* Ишек алның ком-такыр, Йаңгыз йатасын, факыр (*хал. жыр.*). – *кузн.* Нурийәнең, факырнын, хале йук, ылан тужы кесерәк. Сыwык, фырашкасы да йук факырныкы. – *карс.* Факыр гынам, ник соң алай эшләдең инде? – *мәл.* Факыр, 'айан элип 'ил'ин. – *кас.*

**ФАНТАМА: фантамаға қалу** *дөб.* аптырау (оставаться в безвыходном положении; озадачиваться). Әле сөт жыйарға кеше йук дип, фантамаға қалғаннар, ди.

**ФАРТАWЫЙ** [*рус.* франт] *трх.* к.: **қуқыр**. Бик фартawый қарчық иде.

**ФАРТАЛ** [*рус.* квартал] *байк.* билгеле зурлықта бүленгән жир участогы (определённый участок при разделе земли). Зимнәмир килде дә фартал тезеп чыкты. Багана утыртып, фартал йырып чыга, урман туры килсә, короп баралар.

**ФАРТУК** *баст.*, **ФАРТЫК** [*рус.* фартук] *тмн., кузн., срг., карс., кас., тара., әстр.* к.: **алжапма**. Фартык – бун′нан тыга торган(ы). – *кузн.* Әй, ниләдем, ниләдем, Билимдин фартыгым тишмәдем (*бор. жыр.*). – *кас.* Фартык бун′га бywa тырган ул, бу запун. – *карс.* Йабық фартык. – *әстр.*

**алынны фартук** *баст.* к.: **алжапма**. Пич йаққанда эсте буйалмасын дип алынны фартук кийәләр иде.

**култыклы фартык** *кузн.* сарафан формасында тегелгән алъяпкыч (фартук сарафанного типа).

**сербийанкы фартык** *кузн.* күкрәге каплаулы алъяпкыч (фартук с нагрудником).

**ФАТИЙӘ** [*гар.*] *карс.* к.: **кәбен I, 1**. Фатийә ұкыгач, күwәү белән ү беренә кунакка йеретәләр. Йәрәшәләр, килә инде туй, фатийә укилар.

**ФАТЫЙМА** [*гар.*] *лш.* к.: **бийауса**.

**ФӘЙСУНКА** *тмн.* к.: **күбек II**. Фәйсункадан, калфактан йөрегәннәр.

**ФӘЙТУН** [*рус.*] *карс.* сиртмәле кечкенә арба (небольшая лёгкая коляска; фаэтон); чаг.: **мәдәк 3**. Йакшы атларда, йефәк фәйтунда Аның белә кунак йерерсен (*бәет.*).

**ФӘЙШҮНКӘ** *тмн.* к.: **күбек II**. Фәйшүнкәләр бар иде.

**ФӘЛФӘЙЕЗЛӘҮ** *бәр.* үзен генә карау, үзен генә көйләү (следить только за собой, присматривать за собой, прихорашиваться). Ул үзен-үзе генә фәлфәйезли.

**ФӘН** *сазя.* к.: **ман**.

**ФӘНЕСҚЫЙЫҚ** [*рус.* + *тат.*] *дөб.* к.: **бишинәйык**. Қышқа бер фәнесқыйық бәйләми булмас – айаққа жылы була.

**ФӘНЧЕК** [*рус.* фант] *мәл.* уенның бер төре: шешә тәгәрәтү уены, шешәнең авызы кем турысында туктаса, шул кеше жәза үтәргә тиеш, ягъни жырларга яки биергә h.б. (один из видов молодёжной игры: игра в бутылку, против кого останавливается бутылка, тот должен петь или сплясать). Ул шиша кемгә карый, шынардан фәнчек алалар. Фәнчекләр күп жыйылгачтан кычкырталар, бу фәнчекне нишләтәбез, дип.

**ФӘРWӘЙСЕD** [*фарс.* + *афф.* -сез] *минз.* юньсез (бестолковый, безалаберный). Ydемнең фәрwәйсedлегемнәндер, аққча житкерә алмыйм.

**ФӘРДӘ** *яүшт.* битлек (маска, сетка на лице). Фәрдәле бала бәхетле була, фәрдәсен бирсәм кемгә булса да, йулы уңа иде.

**матча фәрдәсе** *минз., стрл.* матча кашагасы (узкая длинная занавеска вдоль матицы); чаг.: **каршага, мажит 1**.

**ФӘРДЕ** *перм.* к.: **пәрде**.

**ФӘРТӘ** [*гар.*]: **фәртә шәл** *твр.* челтәр шәл (паутинка, вуаль). Фәртә шәл салып қуйғаннар қалфақ өсөннән. Ақ фәртә шәл алып қайтқан ыйым, пәйләп пөтөртөм.

**ФЕЛГӘ: фелгә дә алмау** *шрл.* ис китмәү (в ус не дуть). Рифкат, үтереп мактый, Фәрит үтереп хурлый, Флүрә фелгә дә алмый.

**ФЕРӘН** *стрл.* киже (хлопчатобумажная пряжа).

**ФИБЕК** *нокр.* бибек, тәкәрлек (чибис). Фибек күлләр өстендә, болоннарда қычқырып йөри фибек-фибек дип.

**ФИҒЫЛ′СЕЗ** *дөб.* тупас, холыксыз кеше (грубый, неуравновешенный, дурной по характеру).

**ФИЛИМ** [*рус.* филин] *нокр.* к.: **бабалаш**. Ур-

манда ух-ух дип қычқыра, қаршыңа килеп бәрелә филим, аны қотортма йарамый.

**ФИРЕНҖЕ** [*фарс.*] *минз.* хатын-кызлар күлмәген бизәү өчен уртасы тишек, ялтыравык вак тәңкә (мелкая с отверстием посередине блестящая монета блёстка, применяемая для украшения женского платья). Фиренҗе тотарлар ийе.

**ф и р е ш т ә** *чст.* фәрештә (пророк):

**фирештә куwагы, фирештә тайагы** *чст.*, **фирештә үләме** *мам.* к.: **қандала: қандала печәне**.

**ФИРТА** *тмн.* к.: **пирта**.

**ФИТРА** [*гар.*]: **фитра садақасы, ФИТЫР** [*гар.*]: **фитыр сәдәқәсе** *трх.* фытыр (подаяние в день праздника после мусульманского поста уразы). Ураза бәйрәмендә фитра садақасы бирәләр иде. Фитыр сәдәқәсе бир, өч кила бер көн өчен, утыз көн өчен туқсан кила бодай кирәк, дигән, имеш.

**ФЛАНТ** [*рус.* план] *бөре.* к.: **паз′ма**.

**ФОР** [*рус.* фура] *клд.* к.: **ад′ур 1**. Бер фор салам китерделәр.

**ФОРСАСЫЗ** [*гар.*] *трх.* бик каты (сильно, очень сильно). Форсасыз awырды инде.

**ФУР** [*рус.* фура] *трх., мәл.* к.: **ад′ур 1**. Фур қырыйына тезелеп, алҗапқычлар тағып печән җыйарға китәдер ийек. Элгәре фур диләр ийе печән ташый торған арбаны. – *трх.* Печәнгә фур җигеп барганнар. – *мәл.*

**ФУРАЙ** [*рус.* фуражка] *хвл.* фуражка.

**ФУРМАН** [*рус.* фура] *минз., кмшл., кргл., бгрс., стрл.* к.: **ад′ур 1**.

**ФУТАЛ** [*рус.* поталь] *минз., стрл.* **1.** алтын йөгертелгән (позолоченный). Аш тарилкаларының өстенә йөгертелгәне дә футал. – *минз.*; **2.** төрле төстәге бизәнү әйбере, пудра, кершән өстеннән сөртелә (косметика разного цвета, обычно мажут после пудры).

**ФЫЛ′** *кузн.* тукыма төре (один из видов ткани). Фыл′ дийә идек, йебәк фыл′ ат′ә идек.

**ФЫЛАН** *трх.*, **ФЫЛАНТ** [*рус.* план] *бөре., чпр.* к.: **паз′ма**. Бу фыланда төгәл инде, теге фыланда үстем. Һәркемнең үзенә фыланты была. Фылант сорап ғариза бирәсең. – *бөре.* Бер фылантта торабыз малайлар белән. – *чпр.*

**ФЫРАК** [*рус.*] *тмн.* итәккә ике якка өстәп янга тегеп куела торган өстәмә итәк (дополнительная оборка, пришитая к подолу). Йага да куйалар иде, изүләре ачык, фыраклар куйа идек.

**ФЫРТЫК** *хвл.* к.: **ирен I: дөйә ирен**.

# Х

**х а б а р** [*гар.*] *миш.д.* хәбәр (известие, весть, сообщение):

**хабар әтә килү** *срг.* кунакка чакыра килү (прийти, чтобы пригласить в гости). Хабар әтә килдем, абыстакай.

**хабар бирү** *кузн.* кунакка чакыру (пригласить в гости); чаг.: **димнәү**. Хабар бирегә килгән.

**ХАВАЛ** *әстр.* кыңгыраулы барабан (бубен).

**ХАВИЛ** [*рус.*] *клд.* кылган (ковыль). Бу хавил үләме, парализованный кешеләргә йакшы.

**ХАWЫПСЫТУ** [*гар.* хәвеф + *афф.* -сыту] *төм.* куркыту (устрашать).

**ХАWЫПСЫУ** [*гар.* хәвеф + *афф.* -сыу] *төм., тбл., твр.* хәвефләнү, курку (опасаться, бояться).

**ХАДУК** [*рус.* ходок] *твр.* тарантас. Хадук белән күцтем (килен булып төштем), қыңғыраулар тағып.

**ХАҖ** [*гар.*]: **хаҗ қынасы** *бөре., кмшл.* бохар кынасы (бальзамин).

**ХАҖАТ** [*гар.*] *тара.* кирәклек (необходимость).

**ХАҖӘЙ** [хъаҗәй; *фарс.*] *блт.* хуҗалык (хозяйство). Айырым хаҗәй чақта җиргә дә сала торганыйығ ич ул тамғаны.

**ХАЗА** [*гар.*] *чпр.* бәла-каза, афәт, зур бәхетсезлек (бедствие, злоключение). Хаза күрә икән бу awыл.

**ХАЗАЙЫН** [*фарс.*] *кас., тмн.* к.: **абышқа 1**. Минем хазайыным үлде. – *кас.* Миннән хазайыным картыраг иде унбер йәшкә. – *тмн.*

**ХАЙКӘ** [*фарс.*] *байк.* к.: **путемар**.

**ХАЙЛӘ** [*гар.* хаил – чыбылдык ?]: **хайлә әйтү** *күрш.* кыз елату; туй алдыннан яки кызның әтиәнисе өеннән чыгып китәр алдыннан җырлар җырлау (исполнение плача невесты перед свадьбой или перед тем, как невеста покидает отчий дом). Ул хайлә әйтү була, кызны йырлап йобаталар.

**ХАЙРУС** [*рус.*] *злт.* бәрде (хариус).

**ХАЙЫҢНЫҚ** *брб.д.* каенлык (березняк). Хайыңныкта сәйел, көрәп киләйенмә?

**ХАЙЫР** [*гар.*] *срг.* тиен акчалар (медяк). Нәнәй берцәк хайырлары йукмы ат′а.

**х а к** [*гар.*] плата, оплата, вознаграждение:

**хак алып кайту** *стрл.* җир саткач алып кайткан акча һәм әйберләр (деньги и вещи в виде дополнительного вознаграждения за проданную землю). Җир сатарга барган җирдән хак алып кайталар ийе, булешәләр аны.

**ХАҚЛАУ** [*гар.* + *афф.* -лау] *перм.* бәяләү (определить цену, оценить). Ызбаны унике меңгә хаҡлағаннар.

**ХАЛ** *брб.д.*, **ХАЛ′** [*гар.*] *миш.д.* хәл, көч (положение, сила, состояние).

**хале йук** *срг.* авыру (больной). Анасы йанына бара, анасынын хале йук, дир.

**ХАЛАЙАК** *чпр., кузн., шрл., карс.*, **ХАЛАЙЫК** [*гар.*] *тмн., карс.* халык, кешеләр (народ, люди). Зиба буйыңы күрәлмидер дышман халайак. – *чпр.* Аталатма күзеңне, Барча халайыклар куркадыр (*бор. җыр.*). – *тмн.* Аурадым мин, халайак! – *шрл.*

**ХАЛ′АК** [*гар.*] *стрл.* к.: **нал′ак**. Көйә күп, ха′лак инде.

**ХАЛАТ** [*гар.*] *лмб.* җилән (джилян). Ак чалмалы, йәшел халатлы мулла барадыр.

**халат қаптал** *әстр.* халат.

**ХАЛБА** [*гар.*] *әстр.* әлбә (сладкое мучное изделие).

**ХАЛИ** *тбл.* бушлык, ялгызлык (скука, пустота, уединение, уныние).

**ХАЛ′ЛӘНУ** [*гар.* + *афф.* -ләнү] *лмб., тмн., карс.*,

*кузн., чст.* к.: **йан I: йан тарту 2.** Хал′ләнәләрме чебешләрең, Нәймә?! – *лмб.* Эрәбийә, хал′ләндеңме, иртән урманга барыйык сың? – *карс.* Кат′кач-тан йаттым, хал′ләндем берче. – *кузн.* Аз гына хал′ләним дип бик күп эшләмим. – *чст.*

**ХАЛСЕЗ, ХАЛ′СЕЗ** [*гар.* + *афф.* -сез] **1.** *тмн., карс.* чирле, авыру (больной). Алла анай үлем саркыт кына баласы, ул да хал′сез. Бервакыт урныда идем, хал′сез идем, кергән. – *карс.* Хал′сез ыланнарны эвенә барыб укытабыз. – *тмн.*; **2.** *кузн.* аяк өсте авырып йөргән кеше (человек, который переносит болезнь на ногах). Касталанмаган, халсез генә. Халсез йери, каста йатадыр.

**халсез булу** *тмн., стрл.* чирләп китү, чирләп яту (заболеть, болеть). Унсигезгә йиткәч халсез булды. – *стрл.* Бар йангызак әбиләр, күрешең дә керми халсез булса. – *тмн.*

**ХАЛСЕЗӘЙҮ** [*гар.* + *афф.* -сезәйү] *кузн.* аяк өсте авырып йөрү (переносить болезнь на ногах). Халсезәймәдек тә, касталанмадык та.

**ХАЛСЕЗЛӘНҮ** [*гар.* + *афф.* -сезләнү] *тмн.*, **ХАЛ′СЕЗЛӘУ** [*гар.* + *афф.* -сезләү] *стрл.* чирләү, авыру (болеть). Анасы кетүдә, чагасы халсезләнгән иде. – *тмн.* Хал′сезләп тыра күптәннән бирле ахыр′ысе. Кан′атам хал′сезләп китте, винеклек китерде дә. – *стрл.*

**ХАЛЫК** [*гар.*] *лмб.* нәсел, кавем, семья (род, потомок); чаг.: **йәwер.** Мыхай халкы, мачы халкы, шаркүз халкы дип атәләр awыл халкын.

**ХАМЫТ** *кузн.* к.: **путемар.**

**ХАН: хан чәйе** *кмшл.* кырлыган (иван-чай).

**ХАНЖА** [*гар.*] *чпр.* к.: **аңкала.** Ханжа агызган элекке эңәргә. Туйга ханжа кан′атайыг инде.

**ханжа ызбасы** *чпр.* самогон куа торган йорт (помещение, где варят самогон). Ханжызбасы бу.

**ХАНТАМА** [? + *гар.*] *минз.* ихлас, теләк, күңел (увлечение, желание, усердие). Аның бар хантамасы ашауда.

**хантамасын салу** *злт.* **1.** кызыгу, зур теләк, алырга тырышу, нәфесне сузу (иметь сильное желание, иметь желание приобрести, желать овладеть чем-то). Тәмәм хантамаңны салдың шул күлмәккә; **2.** ихлас күңел белән, тырышып, бар көчне биреп (усердно, не жалея сил). Шулхәтле хантамаларын салалар инде, тырышып-тырышып йазалар да йазалар баш күтәрми.

**ХАНУЗ** *кмшл.*, **ХАНЫЗ** [*фарс.*] *минз.* к.: **һануз.** Хануз аңардан туйып китәбез дә үзебез салабыз әпәйне. – *кмшл.* Тегеләр йуғ әле ханыз. – *минз.*

**ХАНЫШ** *тбл., тара.* хан хатыны (ханша).

**ХАП** *хвл.* к.: **касидә.** Путемар – бу йилкәсеннән тага да култыг астыннан чыгара, арттан каптыра; монда, вата култыг астында, хап дийәләр иде, Кор′ан айәте тыккан иде.

**ХАПЫТНИК** [*рус.* хапать] *злт.* к.: **қомкүз.**

**ХАРАБА** [*гар.*] *минз.* авыр, кыен, начар (трудный, тяжёлый). Шундый хараба хәл булды бит суғыш чоронда.

**ХАРАWAT** [*гар.*] *тбл.* **1.** бөлү (разорение); **2.** харәбәләр (развалины).

**харawat үй** *тбл.* трактир, кабак.

**ХАРАЖ** [*гар.*] *тбл.* ясак, җир өчен салым (подать; дань, поземельная повинность).

**түтүн харажы** *тбл.* моржа башыннан түләү (подымный налог).

**ХАРАМТАЛЫҚ** [*гар.* + *афф.* -лык] *минз.* хәрәмләшү, законсызлык белән эшләү (сделать что-либо незаконным путём, плутовать). Харамталығ итеп айыртты.

**ХАРАП** [*гар.*] *минз., стрл.* бик нык, бик (очень, очень хорошо). Мунчам берүземә җәйгелеккә харап йарый, малайлар кайтса гына карсак диләр. – *стрл.*

**ХАРЕНДӘШ 1.** *шрл., чпр., чст., мәл.*, **ХАРЫНДАШ** *срг.* к.: **йәwер I.** Мының кийәwе тегенең харендәше булган. – *шрл.* Ул безгә харендәш. – *чст.* Безнең дә Казанда харендәшләр бар. Харендәшләреме сез аларның, болай гына килдегезме? – *мәл.* Харындашларыма хат йебәрдем. – *срг.*; **2.** *лмб.* сеңел (младшая сестра). Үзеннән кечкенә харендәше ман быраты бар.

**ХАРЫЖ** [*гар.*] *перм.*, **ХАРЫЧ** [*гар.*] *кузн., шрл.* акча (деньги). Харыч кирәк инде анда барырга. – *шрл.* Қырылған җирләр бик күп, харыж булмағач, төзәтмәгә булмый. – *перм.*

**ХАС** [*гар.*] *бөре., кргл., минз., стрл., тпк.* нәкъ (точь-в-точь, вылитый, точный). Айу камыры хас та мәләш инде ул. – *стрл.* Бөтөннәй әңкәсенә охшап тора, хас шул иде. – *тпк.* Хас үзе инде қызы, қойоп қуйғанмыни. – *бөре.* Хас менә шуның кебек бәйлиләр иде. – *кргл.*

**ХАСИДА** [*гар.*] **1.** *карс., клд.* к.: **путемар.** Акча кадаган хасида әләләр иде мун′нарына. – *клд.*; **2.** *кузн.* к.: **тезмә I.** Хасида чәчкә үрә торган, бай кешедә генә була, үремне айырым үрә дә шынарга бәли, үрем шының астында.

**ХАСИДӘ** [*гар.*] *кузн.* к.: **касидә.** Хасидәгә хыт догалар да тыгарга була, акча да.

**ХАСИТА** [*гар.*] *карс.* к.: **путемар.**

**ХАСИТӘ** [*гар.*] **1.** *чпр.* к.: **путемар.** Агиделдән агып килә Алтын баулы хаситә, Гайшик хале бигерәк йаман, Таза башны хаста итә (*хал. җыр.*); **2.** *тмн.* к.: **касидә.**

**ХАСЛАНУ** [*гар.* + *афф.* -лану] **1.** *минз., стрл.* каныгу, үчегү (пристать, придраться, привязываться). Безнең әтәйгә хасландылар да безнең маллар қырылып китте. – *стрл.*; **2.** *хвл.* үзсүзләнеп берәр нәрсәгә омтылу (настойчиво, упрямо стремиться сделать что-либо); **3.** *перм.* үчегү (затаить злобу, озлобляться против кого-то). Берсе энесен төрмәгә утытқач, икенче энесе хаслана қый моңа.

**ХАСЛАП** [*гар.* + *афф.* -лап] *хвл.* к.: **атына 1.** Хаслап алган идем.

**ХАСЛАУ** [хъаслау; *гар.* + *афф.* -лау] **1.** *перм.* омтылу, теләү, өмет итү (стремиться, намереваться, желать); чаг.: **келәү 2.** Хаслый ул умартаға керергә, бик хаслый – аны кертмиләр. Ул бүләкне хаслый шу, кийәүдән бүләкне җолқа ул (кунакка чакыручы); **2.** *тбл.* билгеләү, хәл итү, карар чыгару (определить, решить, постановить).

**ХАССЫНУ** [*гар.* + *афф.* -сыну] **1.** *минз.* үч алырга йөрү (затаив обиду, стремиться отомстить); **2.** *чст.* көнләшү, кызыгу (завидовать). Гүмергә хассынган кеше дә йакшы төгөл.

**ХАСТ** [хъаст; *гар.*]: **хастын күрү** *перм.* хәстәрен күрү, алдан чарасын күрү (заблаговременно забо-

титься, предпринять меры). Хастын күрсәң, астын күрерсең (*мәкаль*).

**ХАСТА** [*гар.*] *кузн.* урында ятып авырган авыру (больной, который лежит в постели). Хаста – йатадыр пастил тартып, халсез йери.

**хаста йату** *лмб.* авырып яту, чирләп яту (болеть, лежать в постели). Ылы биг awыр хаста йата.

**ХАСТАЛАНУ** [*гар.* + *афф.* -лану] **1.** *лмб.* авыру, чирләү (болеть). Бuwым да ике лан мынан калды, ире хасталаныб үлде; **2.** *кузн.* к.: **хаста: хаста йату**. Хасталанды ике ай, сың үлде.

**ХАСТӘ** [*гар.*] *мәл., чст., стрл., минз.* к.: **путемар**. Хастә төрлө кашлар, тәңкәләр, түмәләр тезеп йасала, шоно кигач кийәләр. – *мәл.* Хастә булай, камыт күбег итеп кийәйек, бу йагына эре тәңкә тезәйек, уртасына wакны. – *стрл.* Хастәм дә бар иде, камыт кебек кийәләр ийе күлмәг эстеннән. – *чст.* Хастәсе дә бар, хасилтә дип тә әйтәләр ийе ансын. – *минз.*

**ХАСТӘ-ДӘҮҒАТ** *чст.* хәситә (перевязь).

**ХАС-ХАС** *трх.* сыер куу ымлыгы (возглас, которым отгоняют коров).

**ХАСЫ** *төм.* казы (копчёная колбаса).

**ХАСЫЙДА** [*гар.*] *хвл.* к.: **касидә**. Путымар йанында бетү кебеге бар – хасыйда.

**ХАТ** [*гар.*] *мәл., чст.* **1.** чаклы, хәтле (с..., величиной с...). Tawык йымыркасы хат бәрәңгесе бар. – *мәл.*; **2.** к.: **тике**. Мында хат килдеңме? – *чст.*

**ХАТАҚ** [*рус.* ходок] *тара.* к.: **хадук**. Хатакта сөйөнеп ултыратлар, аны талдан үргәннәр.

**ХАТАРЛЫ** [*гар.* + *афф.* -лы] *кузн.* к.: **қурқычлы**.

**ХАТ'ЕМ, ХАТЕМ** [*гар.*] *лмб., карс., чст., клд., тара., тбл., төм., брб.д.* дога (молитва). Хат'ем укыйлар да (кыз белән егетне) култыктыралар. – *карс.* Хатем тулы Кор'ән санала, утыз парәле Кор'әнне укып багышлау дигән сүз. – *чст.* Йаңа йорт салты, икмәк-тос тотоп керәсең, өй хатем оуқытабыс, пүләге булаты хәленә күрә. – *тара.* Пәйшәмпе гөн хатем уғыта тоған көн. – *тбл.* Хатембәләнгә цақыратлар. – *төм.* Хатемгә барасыс болыр. – *брб.д.*

**хатем ашы** *брб.д.* к.: **қатем**. Хатем ашына аш (токмач) кисәләр, озончалай кисәделәр.

**хатем иттерү** *баст.*, **хатем укыту** *лмб., кузн., карс., срг.*, **хатем уқыту** *твр.* Коръән укытып аш уздыру (провести званый обед, где читают Коран). Хатем иттерәсен, қартлар әйтелгән, аш пешерелгән, тыwарларым саулығына дип. – *баст.* Хатем укыттым кан'анама. – *лмб.* Улүwенә ун йыл, хатемен укыттым. – *кузн.* Хатемнәр укыттым ире килгәц. – *срг.*

**ХАТЛАШУ** [хъатлашу] *перм.*, **ХАТЛАШУ** [хатлашу; *гар.* + *афф.* -лашу] *тмн., карс., срг.* хат алышу (переписываться). Мыны белән хатлаша идек. – *срг.* Аның ул қызы белән мин армийәдә хатлашайым. – *перм.* Хатлашырга кирәк бит безгә. Сүләшмә, хатлашма дип, йазу өрәтмәделәр. – *тмн.* Анын вет хатлашкан кызы ул. – *карс.*

**ХАТЛЕМ** [*гар.* + *афф.* -лем] *чст.* к.: **тике**. Сез килгәнгә хатлем мин йазып утырдым.

**ХАТОК** [*рус.* ходок] *тара.* к.: **хадук**.

**х а т ы н** (жена; женщина):

**кече хатын** *мам., бәр.* яшь хатын (молодая, следующая жена). Фәғыйләттә кече хатын булып килгән бит ул жиде бала өстенә. – *мам.* Кече хатыны да үлгән. Мин кече хатын булып килдем. – *бәр.*

**ХАТЫНЧАҚ** [хъатынчақ] *минз.* к.: **қатыншақ**.

**ХАША** [*гар.*? *калм.*?] *әстр.* **1.** койма (забор). Хашадын буйында вес' виноград; **2.** шалаш.

**ХАШАП** [*гар.*] *минз.* юкә башмак (башмак из лыка). Хашап шап-шоп кийеп жөриләр ийе қартлар, аста ағач бит аның.

**ХАШӘП** [*гар.*] *стрл.* к.: **хәшәп: чабата хәшәп**. Жүкәдән үргән, табан астына калутка йасаган да. Шушы галуш фурмалы, хашәп диләр.

**ХАШРАТ** [*гар.*] *тбл.* хәшәрәт, бөжәк (гады, насекомые).

**ХАШШАҚ** [*гар.*] *кргл.* ачулануны, жирәнүне, яратмауны белдерә торган ымлык (междометие, выражающее отрицание, отвращение, гнев). Кит, хашшақ! Әй, хашшақ, үләргә йөрим.

**хәбәр** [хъәбәр; *гар.*] (весть, сообщение; слух, молва):

**хәбәр сату** *тпк.* имеш-мимеш сөйләү (говорить, рассказывать слухи). Аны хәбәр саталар инте, имеш, Ырыс тигән қарт килеб утырған тип.

**хәбәр ташлау** *нокр.* хәбәр итү (сообщать, извещать). Абыстайға ничек хәбәр ташламаға инде.

**хәбәргә бару** *перм.* к.: **божал: божалға бару**. Инәсе дә өйдә булмаған хәбәргә бармаға (егет өйләнгәндә).

**ХӘБӘРЛӘҮ** [*гар.* + *афф.* -ләү] *твр.* сөенче алу (сообщать радостную весть). Бәбәйләгәч хәбәрләделәр дә йаулық биртем.

**ХӘБӘРЛӘШМӘҮ** [хъәбәрләшмәү; *гар.* + *афф.* -ләшмәү] *блт.* искә төшермәү, искә дә алмау (и не думать, и не вспоминать). Ақча ала да, түләү өчен хәбәрләшми дә. Хәбәрләшми дә аналарын (кечкенә бала турында).

**х ә б е р** [хъәбер; *гар., фарс.*] кабер (могила):

**хәбер өс** *перм.* зират (кладбище). Хәбер өстә йе қый, хәбер өскә фирмә салмыйлар.

**ХӘДЕ** [?] *әстр.* бүләк (подарок, дар). Жиңгәләр хәде сораған кийәүдән.

**ХӘЗЕР** [*гар.*] **1.** *брб.д.* кадер (уважение, почёт). Хәзер-хөрмәт күрмәгән кеше; **2.** *тара.* кадер (достоинство). Минең хәзеремне белгән ите, бәхыр.

**ХӘЗЕРӘТ** [*гар.*] *брб.д.* хәсрәт, кайгы (горе, печаль). Кән хәзерәт көрдем, чеwәм (бәбкәм).

**ХӘЙЕБИРӘН** [*гар.* + ирән] *твр.* абзардагы терлекләр – дога кылганда кулланыла (домашние животные – употребляется в молитвах). Қара күсле қайваннарға та доға уқый, хәйебирәннәргә тә, сыйырларны хәйебирән диләр.

**ХӘЙКӘ** [хъәйкә] *бөре., перм., байк.* к.: **путемар**. Хәйкәнең бик күп буладырыйы тәңкәсе. – *бөре.* Хәйкәләрне без кимәдег аны. Хәйкә тәңкә тезелеп қыйгацлап эшләнә. – *байк.* Хәйкә тәңкә тезеп жийған була, әбиләр кийәләр ийе. – *перм.*

**х ә й л ә** [хъәйлә; *гар.*] (хитрость, уловка):

**хәйлә салу** *минз., стрл.* хәйләләү (хитрить). Сез тартмыйсыз арбаны, хәйлә саласыз. – *минз.*

**ХӘЙЛӘ-ХӨЙЛӘ** [хъәйлә-хъөйлә; *гар.*] *мам.* төрле хәйлә, алдау-йолдау (разные хитрости, обман). Хәйлә-хөйлә белән алып қалдым анасыннан (баланы).

**ХӘЙНӘ** *твр.* каенана (свекровь, тёща). Хәйнә жәнәшә, күрешә, йаулыкмы бирә киленчәккә.

**х ә л** (сила, мощь; сила, состояние):

**бу хәлдә** *каз.ар.*, **шушы хәлдә** *каз.ар., минз.* бу арада, бу көннәрдә (в эти дни, на днях); чаг.: **қайкөн**. Бу хәлдә киметтек әле сөтне. – *мам.* Әле бу хәлдә генә қайтқан ул. Әле шушы хәлдә генә қайтты ул читтән. – *блт.*

**хәл итү** *нокр.* к.: **йан I: йан тарту 1**. Хәл итегез мәтик. Күп эшләдегез, хәл итегез инде.

**хәл хәтәре** *тара.* хәленә күрә, булдыра алган хәтле, хәле җиткәнчә (на сколько хватит возможности, по возможности). Хәл хәтәре бирәде, пиш тинмә, оутыс тинмә.

**хәл эчендә булу** *каз.ар., т.я.* үлем хәлендә булу (быть при смерти). Бабаң начар дый, хәл эчендә генә дий. – *мам.*

**ХӘЛӘЙҮ** [хъәләйү; *гар.* + *афф.* -әйү] *перм.* к.: **йан I: йан тарту 2**. Беренчедә уқыған малай аз уғ үлмәде, хәләйә башлаған ти инде.

**ХӘЛӘК** [хъәләк; *гар.*] **1.** *злт., эчк., байк.* бик, искиткеч (очень, слишком). Қағыты хәләк тәмне. Қайтқанда хәләк тиз қайттық. Бер улы бар, хәләк матур инде. – *злт.* Хәләк кыйланып сүләнә. – *байк.*; **2.** *эчк.* шәп (замечательно). Хақы да хәләк икән бу канфитның.

**ХӘЛӘМБЕР** [*гар.*] *брб.д.* канәфер (гвоздика). Хәләмбер әче, фадийан төчө, Бақчаларда үсә, су салмай, Үткән ғөмрөмне уйлап тороп, Қычқырып җырлап җибәрәм, түсәлмай (*хал. җыр.*).

**ХӘЛӘМФЕР** *трх.*, **ХӘНӘФЕР** [хъәләмфер; *гар.*] *трх., блт.* канәфер агачы, сирень (сирень).

**ХӘЛӘНФҮР** [*гар.*] *тбл.* канәфер (гвоздика).

**ХӘЛБӘ** [*гар.*] *яүшт., клм.* чәкчәк (чакчак: татарское национальное мучное блюдо).

**ХӘЛWӘ** [*гар.*] **1.** *әстр.* к.: **халба**; **2.** *төм.* к.: **хәлбә**.

**ХӘЛСЕРӘТҮ** [хъәлсерәтү; *гар.* + *афф.* -серәтү] *эчк.* к.: **йончу 2**. Эт төлкене хәлсерәтеп бетергән.

**ХӘНЧЕР** [*фарс.*] *тбл., төм.* хәнҗәр (кинжал).

**ХӘРӘПЛӘҮ** [хъәрәпләү; *гар.* + *афф.* -ләү] *нөкр.* харап итү (погубить, привести в негодное состояние). Гөлләрне хәрәпләгән ич печәй, при-парә булган ич.

**ХӘРЕҖЛӘҮ** [хъәреҗләү; *гар.* + *афф.* -ләү] *әстр.* тоту – акча турында (расходовать – о деньгах). Рөстәм синең ош манит ақшаңны хәреҗләгән.

**ХӘРЕНДӘШ** [хъәрендәш] **I 1.** *т.я., минз., бөре., дөб.* к.: **йәwер I**. Ара өзәк булса, хәрендәшлек йақын була (*әйтем*). – *т.я.* Хәрендәш хәрендәшкә җафа қылмас (*әйтем*). – *дөб.*; **2.** *злт.* қыз туган (родственница). Рәйфәнең хәрендәшенә ошаттым сезне; **3.** *злт., эчк., тпк., трбс., кргл.* сеңел (сестрёнка, младшая сестра). Дөрөс сүләйсең, хәрендәш, тиб әйтә ти. – *трбс.* Бер энем бар, ике хәрендәшем бар. – *злт.* Минең хәрендәш йаман матур. – *эчк.*

**ХӘРЕНДӘШ** [хъәрендәш] **II** *перм., блт.* к.: **қәләм**. Қарағыз, қайсығызның хәрендәшен алып чыққан. – *блт.*

**ХӘРЕНДӘШ-ЙӘWЕР** *глз.* туган–тумача (родные, родственники, родня, родичи).

**ХӘРЕНТӘШ** (хъәрентәш) *тпк.* үзеннән яшь хатын-кызга мөрәҗәгать итү сүзе (форма обращения к женщине моложе себя). Йиде мәртәбә бардым, хәрентәш. Хәрентәш, син қайан килтең?

**ХӘРЕС** [хъәрес; *гар.*] *байк.* байлык (богатство, состояние). Туй йасарга хәрес булмады, хәл булмады. Байлыгың булдисә хәресе бар, диләр.

**ХӘС** [хъәс; *гар.*] *злт.* к.: **хас**. Хәс қатығ әйрәне кебек қымыз. Хәс минең әйбергә охшаған.

**хәс тә** *эчк., к.-уф.* к.: **хас**. Ул хәс тә син инде. – *эчк.* Хәс тә инәсе инде. – *злт.* Қызы хәс тә үзенә охшаған. – *к.-уф.*

**ХӘСЕЛ** [хъәсел; *гар.*]: **хәселен күрү, хәселенә керү** *минз.* к.: **хаст: хастын күрү**. Алмағачның хәселен күрмичә үсми ул.

**ХӘСИЙӘТЛӘҮ** [хъәсийәтләү; *гар.* + *афф.* -ләү] *к.т., каз.ар.* бөтен шартларын туры китереп, җиренә җиткереп эшләү (делать что-либо по всем правилам); чаг.: **қәстәрләү 2**. Бик хәсийәтләп аш пешердем. Шулай хәсийәтләп торма, тиз-тиз сөрт тә ал (идәнне). – *к.т.* Хәсийәтләп төрөп сандыққа тутырган әйберләрен. Бигрәк тә хәсийәтләп утырасың, тиз-тиз чүплә. – *мам.*

**ХӘСИЙӘТЛЕ** [хъәсийәтле; *гар.* + *афф.* -ле] *т.я.* барлык шартлары да туры китереп эшләнгән – аш-су турында (приготовленный по всем правилам – о пище). Өй тоқмачы тәмне булмыйча, ул бит хәсийәтле: җоморқа сытқан, басуwын китергән. – *к.т.*

**ХӘСИЛӘ** [хъәсилә; *гар.*] *мам., лш.* к.: **путемар**. Хәсиләне қыйқач кийәр ийег инде. – *лш.* Хәсиләләр, чәчтәңкәләр тагарыйық әwәл. Хәсиләләр, чәчтәңкәләр байырақ қызларда булған. Хәсиләләр йуғ инде, күптән кимиләр. – *мам.*

**хәсилә бawы** *мам.* к.: **путемар**. Хәсилә бawы асадыр ыйы хатын-қыз.

**ХӘСИЛТӘ** [хъәсилтә; *гар.*] **1.** *блт., эчк.* к.: **путемар**. Қарчықлар хәсилтә кийә торганыйы. – *блт.* Инәйнең хәсилтәсе бар ыйы. – *эчк.*; **2.** *мам.* яңа туган бәрән яки бозауның муенына тагыла торган чуклы бау (ошейник с кистями, надеваемый на шею ягнёнка или телёнка). Муйнына хәсилтә бәйләргә кирәк бу бозауның, күз тийүwе бар.

**ХӘСИС** [хъәсис; *гар.*] *минз.* юньсез (дурной, безобразный, возмутительный).

**ХӘСИТӘ** [хъәситә; *гар.*] **1.** *мам., бәр.* яшь балага, күз тимәсен өчен, қыйгачлап күкрәгенә киелә торган, төрле ситсы кисәкләре, төймәләр белән бизәлгән тар тасма (неширокая полоска материи с нашитыми лоскутками, пуговицами, надеваемая маленьким детям наискосок через левое плечо, чтобы сберечь их от сглаза). Хәситә тегеп кийертәбез балаларға биләш тағып. – *мам.* Балаларға хәситәне қыйғачлап кийертәләр. – *бәр.*; **2.** *мам., бәр.* к.: **хәсилтә 2**. Йәш бозауға да хәситә кийертәбез. – *бәр.*; **3.** *бөре., минз.* хәситә кебек киелә торган дүртпочмаклы зур бөти (амулет, обычно в форме четырёхугольного карманчика, пришиваемый к широкой тесьме и надеваемый через левое плечо); чаг.: **хәсилә**. Хәситәдә йақшы сүзләр була инде. – *минз.*; **4.** *стрл.* хәситәнең аскы кырыена тагыла торган бөти (амулет, пришиваемый к пере-

вязи с правой стороны). Йазулы хәситәме карыйм, чиргә-чорга кийә торган; **5.** *тпк.* к.: **бетек**. Хәситәм бар ыйы, төшмәсен әле монауда; **6.** *глз.* тукымага тәңкәләр, асылташлар тезеп ясалган, муенга бау белән бәйләп, күкрәккә киелә торган бизәнү әйбере (старинное женское нагрудное украшение из монет, нашитых на материю). Алйапқыч күкрәге кебек теккән дә бар иде хәситәнең, болай қыйық та, муторлық өчен тәңкәләр, ахықлар таққан.

**хәситә бawы** *лш.* к.: **путемар**. Хәситә бawы бар ийе бай кешедә, тәңкә, ахақлар тезгән, йат нәстәләр тезгән. Хәситә бawына бөти тағалар ийе.

**ХӘСТӘ** [хъәстә; *гар.*] **1.** *стрл.* к.: **путемар**; **2.** *бәр.* к.: **хәситә 1**. Хәстә балаларға кийертеп қуйарлар ыйы.

**ХӘСТӘРЛЕ** [хъәстәрле; *гар.*] *мам.* **1.** җыйнак, пөхтә, чиста (аккуратный, опрятный, чистый); чаг.: **сарпатлы**. Кийемнәрне бик хәстәрле кийә ул үзе; **2.** тәрбиягә мохтаж, тәрбияне яратучан (нуждающийся в уходе). Күркә баласы бик хәстәрле ул.

**ХӘСТӘРЛӘНҮ** [хъәстәрләнү; *гар.*] *мам.* үзеңне карау, тәрбияләү, дәвалану (заботиться о себе, лечиться). Җәрәгем бик борчола, бер нәстә белән дә хәстәрләнгәнем дә җук.

**ХӘСТӘРЛӘҮ** [хъәстәрләү; *гар.*] *мам., нокр.* к.: **ардақлау I**. Бер генә баласы булды, хәстәрләп кенә үстерде. Ничек сиң баланы хәстәрлә, шуның хәдәр awырыйлар. Җәш көйө алғач, бик хәстәрләп кенә тора инде қатнын. – *мам.* Хәстәрләп кимәгә қуштылар. Оланнарны хәстәрләп асырайбыз да, кийәүгә китәләр. – *нокр.*

**ХӘС-ХӘС-ХӘС 1.** *нрл.* к.: **хас-хас**; **2.** *мам.* сарык куу ымлыгы (возглас, которым отгоняют овец).

**ХӘТ** [хъәт; *гар.*] *мәл., чст.* к.: **хат**. Мында хәт килдеңме? – *чст.* Awылга хәт барадырмы автawызлары, белмим. – *мәл.*

**ХӘТӘР I** [*гар.*] *тара.* кадәр (до).

**ХӘТӘР II** [хъәтәр; *гар.*] *перм.* шәп, әйбәт, яхшы, булдыклы (хорошо, замечательно, здорово). Үзем генә утыттым картупны, хәтәр булдым мин. Хәтәр йоқлап булам мин.

**ХӘТБӘ** [хъәтбә; *гар.*] *трбс.* к.: **қатыба**. Нәнәй, хәтбә җәйгәнсез икән ти. Хәтбә җәйгәнсез бит җиргә, йәм-йәшел ти.

**ХӘТЕР I** [*гар.*]: **хәтер калу** *брб.д.* ошатып җиткермәү, кабул итмәү (не воспринимать, недолюбливать, не понравиться).

**ХӘТЕР II** [*гар.*] *к.т.* кадер (достоинство, почёт, уважение). Ипиләрнең хәтерен белмиләр. Печти генә кийәләр дә ташлыйлар кийемне, хәтерен белмиләр әйберләрнең.

**ХӘТЕРЛӘҮ I** [хъәтерләү; *гар.* + *афф.* -ләү] *к.т.* кадерләү (оказывать почёт, уважение); чаг.: **ардақлау 1**. Хөкүмәт хәтерли қатыннарны қәзер.

**ХӘТЕРЛӘҮ II** [хъәтерләү] *минз.* **1.** күзәтү, карау (наблюдать, смотреть). Ул хәтерләп җөргәндер инде ничек бәйләгәнеңне (көлтә турында). Син хәтерли тор әле, җәме, баңқыларны, мин суға барып қайтыйм. Мин әйтәм, бер хәтерләп чығыйм әле, пичкә йақтылар микән дип; **2.** карау, тәрбияләү (ухаживать, воспитывать). Җиңгәй ике баланы хәтерләй инде.

**ХӘТЕРЛЕ** [*гар.* + *афф.* -ле] *төм.* кадерле (дорогой). Хәтерлерәк тоуғаннарны гына цақырады.

**ХӘТИМ** [*гар.*] *төм.* борынгы (древний, стародавний). Мақтым тигән сылу қыс пулған хәтим саманта.

**ХӘТИСӘ** [хъәтисә; *гар.*] *бәр.* **1.** к.: **хәситә 1**. Хәтисәне кечкенә балаларға тағалар күз тимәскә; **2.** к.: **хәсилтә 2**. Ат муйнына хәтисә йасаған ыйы күз тимәскә.

**ХӘТЛӘНҮ** [хъәтләнү; *гар.* + *афф.* -ләнү] *каз. ар.-крш.* к.: **бетү I, 1**. Бура күк сыйырыбыз хәтләнде былтыр.

**ХӘТЛЕК** [хъәтлек; *гар.*] *мам., кмшл.* к.: **тике**. Минем хәтлек булған инде қызы. – *мам.*

**ХӘТМӘЛЛӘЙ** *лш.* бик тиз, бик тиз арада (очень быстро, вмиг). Күзикмәк түгел ул, йуқа ғына, хәтмәлләй генә пешереб алғаныйым. Хәтмәлләй қайсы ғына башқа килсен.

**ХӘТНАШҚАН** [хъәтнашқан; *гар.* + *афф.* -тин) + ашқан] *перм.* к.: **хәттин: хәттин ашқан**. Алар хәтнашқан йорт салып торалар.

**ХӘТСЕЗДӘН** [хъәтсездән; *гар.* + *афф.* -сез + дән] *мам.* күптән, байтактан, күптәннән (порядочно, давно, издавна); чаг.: **кан′-качан**. Қазаннан алған ыйық хәтсездән (сәгатьне). Мин cedнең хатығыdны хәтсездән алған ыйым. Хәтсездән бирле эшли бит инде ул, өч кенә җыл түгелдер.

**ХӘТТӘКИЙЕН** [хъәттәкийен; *гар.*] *тпк.* хәтта (даже). Йал алмайынсы эшләп торған ийем хәттәкийен.

**ХӘТТИ, ХӘТТИЙ** [хъәтти, хъәттий; *гар.*] *перм.* шактый (достаточно много, далеко и т.д.). Тегеләр хәттий үк йырақ киткәннәр. Чоба монда бар хәттий үк кешеләрдә.

**ХӘТТИЙУҚ** [*гар.* + уқ] *перм.* байтак (достаточно, немало, изрядно). Утыныгыз хәттийуқ былған қый, икәү генә кистегезме?

**ХӘТТИН** [хъәттин; *гар.* + *афф.* -тин]: **хәттин ашқан** *перм.* бик шәп, чиктән ашкан, чиктән тыш әйбәт (исключительно хороший, замечательный); чаг.: **асыл 1**. Ат җиккәннәр хәттин ашқанны. Нықый шул хатынны алдыйы, хәттин ашқан (бик әйбәт хатын).

**ХӘТФӘ: хәтфә чәчәк** *дөб.* күкбаш, күк чәчәк (василёк посевной).

**ХӘҮЛЕ** [хъәүле; ?] *кргл.* челән (цапля).

**ХӘШӘП** [хъәшәп; *гар.*] *минз., кмшл., кргл., бгрс.* **1.** өсте юкәдән йә киндер җептән үреп ясалган агач табанлы башмак (башмак на деревянной подошве с верхом, плетёным из лыка или холщовой нити). Җүкәдән үргән, табан астына калутка йасаған да шушы галуш фурмылы тарткан, хәшәп диләр. – *стрл.* Чабата хәшәп, астына ағач қағалар ийе, киндерәсе җуғ ийе аның. – *минз.* Күн хәшәпләр, чүбек хәшәпләр кийеп үткән инде ғумеркәйләр. Чабата, ойоқ, хәшәп кебек әйберләрне кристийаннар үз қуллары белән җитештергәннәр. – *бгрс.*; **2.** иске, начар аяқ киеме (старая, плохая обувь). Сал шул хәшәбеңне. – *кмшл.*

**чабата хәшәп** *минз.* юкәдән үрелгән башмак

(башмаки, плетёные из лыка). Чабата хәшәпнең астына күтәрмә куйалар, анысының киндерәсе җук.

**ХЕWӘТ** [*гар.*] *к.т.* көчле, каты (сильно, бурно, быстро). Бик хеwәт ағадыр ыйе Изел.

**ХЕЗМӘТ** [*гар., фарс.*] *әстр.* эш (труд, работа). Утырырга wакыт йук, хезмәт эшлибез.

**ХЕРӘСӘН** [хъерәсән; *гар.*] *дөб., кмшл.* к.: **азымтык**. Бигрәк херәсән кеше булып чыкты ул Сәләх. – *дөб.* Тыр, херәсән, теш йитә бит инде. – *кмшл.*

**ХЕРӘСӘННӘНҮ** [хъерәсәннәнү; *гар.* + *афф.* -нәнү] *кмшл.* к.: **суйлакланy**. Тыр, малай, херәсәннәнеп йатасың.

**ХЕРТӘ, ХЕРТИ** [*фарс.*] *шрл.* к.: **көрти 2**. Хертийеңне дә кидерәм.

**ХИЛWӘТ** [*гар.*] *төм.* ерагаю, читләшү (отдаление, уединение).

**ХИРЕШТЕРМӘҮ** *дөб.* соңга калмау, вакытны уздырмау (не задерживаться, не терять времени). Бер генә минутны да хирештермим.

**ХИСАП** [хъисап; *гар.*]: **хисап итү** *эчк.* хисаплашу, санашу, санга сугу (почитать, уважать, считаться). Безнең аш-сыwны йаратмай, хисап итмәй диләр.

**ХИТЛАНУ** [хъитлану; *гар.* + *афф.* -лан] **1.** *злт., тпк.* к.: **хыйтланy**. Мал эзләп үзем хитланам. Хитланып йөрисе килми. – *злт.* Мин кеше кеwек хитланып йөрөмәдем. – *тпк.*; **2.** *блт.* маташу (возиться). Нишләп хитланасың инде, җат. Җитәр инде, хитланма, ашарға утыр.

**ХИТЛЫК** *минз.*, **ХИТЛЫК** [хъитлык; *гар.* + *афф.* -лык] *стрл.* кыенлык, читенлек (трудность, тягостность; тяжёлый). Элгәре шау хитлык белә булган инде тормыш. – *стрл.*

**ХЛАПИ** [*рус.*] *лмб.* себерке үләне (венечник).

**ХОБОТЫЙ** [?] *мәл.* иләмсез, иске, зур (безобразный, неприглядный). Шул хоботый чүнийең белән идәнемне баскалап бетердең.

**холок** *урт.д.* холык (нрав, натура, характер):

**тар холоклы** *т.я.* тар күңелле, көнче (завистливый). Бик көннәшәләр алар бер-берсеннән, холоклоры тар аларның. – *к.т.*

**ХОРНАУ** *тмн.* гырылдау (храпеть). Бик хорный выд, йоклап булмыйдыр.

**ХӨББӘРСЕЗ** [хъөббәрсез; *гар.*?]: **хөббәрсез йөрү** *кмшл.* аумый-түнми, төп-төз йөрү (ходить прямо, не качаясь).

**ХӨҖӨРЛӘНЕП** [хъөҗөрләнеп; *гар.* + *афф.* -ләнеп] **1.** *мам.* дәртләнеп, бирелеп (от всей души, с радостью). Хөҗөрләнеп эшли ул бер тотонса; **2.** *лш., блт.* артык хискә бирелеп, көчле хис белән (сильно возбудившись, с сильной эмоцией). Хөҗөрләнеп килеп йабышты. – *лш.* Кит әле, хөҗөрләнмә. – *блт.*

**ХӨЗМӘТЛӘҮ** [*гар.* + *афф.* -ләү] *хвл.* хезмәт итү, хезмәт күрсәтү (работать, трудиться; обслуживать).

**ХӨНҖҮ** [хъөнҗү; *гар.*] *минз., стрл.* ыгы-зыгы килү (суетиться). Малай өйләнде, шуның белән хөнҗөб алдығ әле. – *минз.*

**ХӨРӘН** [*гар.*] *брб.д.* Коръән (Коран). Хөрән оқытқалы кәрәк.

**ХӨРӘНУ** [хъөрәнү; *гар.* + *афф.* -әнү] *минз., стрл.* к.: **хөрү**. Миннән хөрәнә ул, мин выжлатыбырак җибәрәм эчкән өчөн. – *стрл.*

**ХӨРӘСӘН** [хъөрәсән; *гар.*] *минз., бөре., перм.* ялкау, күп йоклый торган (лентяй, любящий много спать).

**хөрәсән йалқау** *перм.* ата ялкау (в высшей степени лентяй).

**ХӨРТ** [хъөрт; *гар.*] *минз., тпк., стрл.* начар (плохой, дрянной). Хәзер хөрт сөйләшә ул, ушы йуқ. Хөрт өйләр күб ийе. Самаwыр хөрт қайный, алама. Бабайларда боларға хөрт булыр микән. – *минз.* Ул wахытларда агач тырма, игеннең үсешләре бик хөрт. Тормошлар хөрт ийе әлгәре. Бик хөртләре ире кат'кинча он җийып бурычка. – *стрл.* Бик бәләкәй булган awыл, хөрт. Өйләре хөрт инде бик. – *тпк.*

**ХӨРТӘЙҮ** [хъөртәйү; *гар.* + *афф.* -әйү] **1.** *минз., тпк., стрл.* начарлану (стать плохим, ухудшиться, стать дрянным). Минем күзләр хөртәйде инде. – *минз.* Мунчабыз бик хөртәйгән әле, йагып та кертер ийек, йаратмассыз. – *стрл.* Күd дә хөртәйде. Дөнйаларның хөртәйгән wахытлары да булты. Қартайғас ашау да қысыла, хөртәйәсең. – *тпк.*; **2.** *кргл.* үпкәләү (обидеться). Хөртәйүwем бар, күп йазасыз дип.

**ХӨРТӘМШӘ** [хъөртәмшә; *гар.*] *тпк.* к.: **хөрт**. Хөртәмшә шикелле умарталары, йәш кенә пер кеше эшләй.

**ХӨРТИ** [*фарс.*] *бгрс.* к.: **кесәбикә I, 1**. Рәсимәгә хөртигә дигән плүш бар әле.

**ХӨРҮ** [хъөрү; *гар.*] *минз.* өркү, шүрләү (бояться, трусить). Килергә ул хөри миннән.

**ХӨС-ХӨС!** *блт.* к.: **чәбә 2**. Хөс-хөс! Абзарға!

**ХӨШӨР** [*гар.*] *твр.* савап (божье вознаграждение за богоугодное деяние). Хөшөр булсын, астыған (кура җиләге) керттем, утыралмый, йил суқты микән әллә.

**ХРИСТИЧ** [*рус.* крестец] *кузн., тмн., лмб., шрл.* к.: **кристич**. Биш христич сугарга келисен. – *кузн.* Христич куйа келтәдән. – *лмб.*

**ХУWАТ** [*гар.*] *срг.* **1.** к.: **х(ы)ват 5**. Бик хуwат эшли сәәтләрне. Тукай хуwат булган, бичара. Тартар кыцкырган йылны ашлык хуwат була, бүдәнә кыцкырган йылны нацар була дийр; **2.** к.: **дибә**. Минем бруке хуwат йакшы, тузан да кунмый дийр; **3.** шәп (чудный). Хуwат булган сайкысы; **4.** җиткән (достаточно). Намазның фарызын укысаң да бик хуwат.

**ХУWӘТ** [*гар.*] *к.т.* к.: **хеwәт**. Таулардан төшә, ташу була, хуwәт була бик.

**ХУДАЙЦЫЛЫҚ** [*гар.* + *афф.* -цылық] *тбл.* диндарлык (набожность).

**ХУҖА** [*фарс.*] *лмб., кузн., тмн., чст., кас., минз., брб.д.* к.: **абышқа 1**. Хуҗам дүөрт йыл эндә улевенә. – *тмн.* Хуҗаң бармы? Хуҗам сугыштан килмәде. – *лмб.* Ул минем анам тугел, хуҗамның анасы. Хуҗам минеке йәш, ул унберенче йылгы гына. – *кузн.* Сез хуҗалылармы? – *кас.* Хуҗаң бар арқылы ник җафа чигеб утырасың, ди. Ху-

җамнан да қалдым, өйдәш җөрөдөм. – *минз.* Хуҗаның чикмәне бар иде. – *чст.* Хуҗаларығыз парма, эшләймә? Хуҗам әрмийдән қайтты согыш пөтеп. – *брб.д.*

**ХУЛИ-ХӘЛИ** [*гар.*] *дөб.* **1.** көчкә-көчкә, чак-чак (еле-еле, чуть-чуть, насилу). Атлawы да хулихәли генә, қартайган; **2.** көчкә генә эләгеп тора торган (предмет или строение, которое еле-еле держится). Йортлары хули-хәли генә тора.

**ХУПТЫРТУ** *бәр.* купайту, арттыру (преувеличить, приукрасить). Ул хуптыртып та җибәрә, дөресен генә сөйләми, арттыра ул.

**ХУР** [*фарс.*]: **хур йасау** *клд.* хур итү, түбәнчелеккә төшерү (позорить, унижать). Ыланнарны хур йасагың келәми, тырышасың.

**ХУРЛАУ** [*фарс.* + *афф.* -лау] *кузн., хвл., срг., мәл.* ачулану, орышу (ругать, бранить). Килнем, мәтәм, хурлар, китим инде. Әни хурлый мине, петерә, ишә хазер. – *срг.* Әни мине бик каты хурлады бармаган өчен. Мине дә вит шолай хурлый әти. – *хвл.*

**ХУРЛАШУ** [*фарс.* + *афф.* -лашу] *кузн., хвл., срг., мәл.* оршышу, талашу (ссориться). Хурлаштан кын′аш йакшы. – *мәл.* Бары белән хурлаша. Хурлашыпмы өлгөрдең Эрумия белән? – *хвл.*

**х у р′м а** *тмн.* хөрмә (финик):

**хур′ма ташы** *тмн.* хөрмә төше (косточка финика).

**ХУР′МӘТЛӘНУ** *хвл.* сыйлану (угощаться). Әw сайын ашап йериләр хур′мәтләнеп, без аларны беләбездер.

**ХУТ I** [*рус.* ход] **1.** *карс.* тимер күчәрле, тимер арба (телега, оси у которой железные). Шинawуй кал′уса, жилизный хут Сәүдәгәр йегетнен арбасы (*хал. җыр.*); **2.** *мам., минз., кмшл., стрл.* тарантас. Миңнехәйер абзый берүзе бер хут булыб утырадыр ийе. – *кмшл.* Без awылда булғач, пawузкалар белә килмәдег инде, хут белә килдек. – *минз.* Йакшы хутлар җиккән. – *стрл.*

**ХУТ II** [*рус.* ход] **1.** *чст., мәл., кузн.* к.: **лат 3.** Хуты булса, сезгә дә килеп китәрбез. Агач хутына матыйк белән кыралар. Аты барның хуты бар (*әйтем*). Бер дә бызылырга хуты йук, шылай кайнаштыра идем дә йерий иде (сәгать турында). – *чст.* Аның йортына тыглырга хут йук. – *кузн.*; **2.** *дөб., мам., мәл.* к.: **лат 1.** Хуты булса, җайын табар. – *мам.* Хуты йуқ килеп китәргә. – *дөб.* Бармый хуты йук. – *мәл.*; **3.** *чпр.* барлык (достаток, богатство). Кайберәүләр күп йагалар тупкыны, хуты барлар.

**бу хутка** *мәл., чст.* болай, бу көйгә (так, в таком виде). Бу хутка ыспырафкысы йаңгал булып чыга. – *мәл.*

**шул хутта** *хвл., мәл.*, **шыл хутта** *чст.* шул көе, шул рәвешле; шул формада, шул рәвештә (таким образом, в такой форме). Шул хутта, малай, эшләрсен инде. Моны Мәфтухага ошата, ахыры, шул хутта көлүwе дә. – *хвл.* Наҗийә апай бер картаймый, һаман шыл хутта. – *чст.*

**ХУТ III** [хъут; *гар.*] *минз.* февраль.

**хут сuwыгы** *дөб., мам.* егерме бишенче гыйнвардан алтынчы мартка кадәр була торган салкыннар (холода в период с двадцать пятого января до шестого марта); чаг.: **қырлач: кече қырлач.** Хут сuwыгы ғыйнварның алтысы қала керә, мартның алтысы қала чыға. Хут сuwыгы қырык бер көн була. – *дөб.* Ай сuwык, хут сuwыклары килгән. – *мам.*

**хут чығу** *дөб.* март аенда көн белән төн тигезләнүе турында (о наступлении весеннего равноденствия).

**ХУТЛАНУ** [*рус.* ход + *афф.* -лану] *трх., мәл.* әзерләнү (приготовиться). Ул ызба хутланған ийе дириктырға. – *трх.* Син хутлан, барасың бит. Ул туйга хутлана, кызын бирде. – *мәл.*

**ХУТЛАУ** [*рус.* ход + *афф.* -лау] **1.** *чст., чпр., мәл.* әзерләү (приготовить). Малайы тақта ташый, этисе хутлап тора. Теге ызбаға хутлыйбызмы чәйне? – *трх.* Цәйеңе хутла, кунакларны цәй эцер. – *мәл.*; **2.** *трх., чст., чпр., мәл., хвл.* көйләү, җайлау, рәтләү (налаживать, приспособить, улаживать). Бабаң чалғыны хутлап бирәдер ийе, чawып күрсәтәдер ийе. Мататсикыл хутлыйлар да чығып китәләр. Киндер суққанны күрсәтер идем дә, хутлап қуймаған. – *трх.* Кыйыны хутла әле, карт, су алып булмый бит. Әйберләреңне хутлый тор. Сипаратны хутлап куйабыз. – *мәл.* Аңа бикәче хутлар әле барын да. – *чст.*

**ХУТЛЫ** [*рус.* ход + *афф.* -лы] **1.** *чпр., мәл.* җайлы, уңайлы (удобно; удобный); **2.** *чпр., шрл.* хәлле; рәтле, нормаль (нормальный – о состоянии). Мин үзем чәй белән генә хутлы. – *шрл.*

**ХУТСЫЗ** [*рус.* ход + *афф.* -сыз] *чст., мәл.* уңайсыз, җайсыз (неудобно; неудобный). Тытарга бик хутсыз бу агач. – *мәл.* Алай бит әле хутсыздыр йазарга. – *чст.*

**ХУХАЛ′** [*рус.* куколь] *кузн.* к.: **кукал′**. Йебегәннең катламасы, Сылы-хухал′ ынныннан... (*хал. җыр.*).

**ХУШAWAЗ** [*гар.* + *фарс.*] *әстр.* туй җырлары (свадебные песни). Туйда хушawаз әйтәләр қартлар.

**ХУWӘТ** [*гар.*] *к.т.* шәп (хорошо, замечательно). Алма бақчабыз хүwәт. Убуркылар хүwәт ийе, йаңгыр булмады, урақлар бетте.

**ХЫВАТ** [*гар.*] **1.** *мәл., кузн., хвл.* көч, куәт (сила, мощь). Хыват бирсен эшләргә. – *мәл.* Хыват белән тартты да йезде. – *хвл.*; **2.** *кузн., хвл.* көчле, куәтле (сильный; сильно); чаг.: **ару I, 12**. Чәчәгендә исе бик хыват выт. Былай хыват йаугач, йылгалар китә. Сuwы хыватрак ага. Биг инде аның раны хыват булган. – *кузн.* Зур тишмә иде, хыват ага иде. – *хвл.*; **3.** *кузн., мәл.* тиз (быстро). Ад′а, хыват кына эшләп бетерик. – *мәл.* Элгереп тә булмый, шындый хыват баралар. – *кузн.*; **4.** *срг., тмн., кузн.* күп (много); чаг.: **каты I, 2**. Бик хыват ташлар анда. – *тмн.* Чийәм де, шымыртым ды бик хыват чәчәк атты. – *кузн.*; **5.** *тмн., лмб., срг., кузн., влгг.* яхшы, әйбәт (хорошо; хороший). Бик хыват китаб иде, йанды. Эц абуркалы да була, бик хыват була иде ул күлмәк. – *срг.* Казан кызлар бик хыват инде. – *тмн.* Алар минекеннән хыват ызба куйдылар. – *лмб.* Казанга караганда бездә хыва-

тырак. – *кузн.* Йәш бозау ите жаркуга хыват, севәген дә ашыйсың. – *влгг.*; **6.** *кузн.* к.: **салиталы**. Безнен асыл нәсел бәк, укырга хыватлар.

**ХЫWAT** [*гар.*] *срг.* **1.** к.: **хыват 4**. Бакцасында бик хыwat сетле ут. – *срг.*; **2.** к.: **хыват 5**. Бик хыwat иде бабайым, шәм шырагацы кебек.

**ХЫЙЛЫ** [*гар.*]: **бер хыйлы** *әстр.* берникадәр, шактый, бераз (немного, несколько). Бер хыйлы көннәр үтә.

**ХЫЙТ** [*гар.*]: **хыйт китерү** *трх.* җәфалау, аптыратып бетерү (замучить, измучить). Тегеләрне хыйт китерә гипнуз йасап.

**ХЫЙТЛАНУ** [*гар.* + *афф.* -лан] *нрл., трх., минз., бгрс., злт., стрл.* интегү, газаплану (мучиться, замучиться). Без хыйтланған инде, күрдек инде күрмәгәнне. – *трх.* Бик хыйтландық йулда, ди. – *бгрс.* Йәшлек хыйтланыб үтте. – *злт.* Безнең бабайлар хыйтланып йәшәгән инде. – *стрл.* Су белән әле дә мин хыйтланам әле, калунка торбасы wатылған. – *нрл.*

**ХЫЙТЫ** *кргл.* к.: **җаматай**. Бик хыйты ғына awыл аларның тырған җире.

**ХЫЛАТ** [*рус.* клад] *лмб., кузн.* кибән (стог). Тен катага китә идек хылатлар куйарга. – *лмб.* Эшләминче бер минут тырмады, хылат тәке тейәгән арбага нарат пытагы. – *кузн.*

**ХЫЛЫЙН** [?] *мәл.* үткен, хәйләкәр һәм явыз – кеше турында (злой обманщик; злобный, злонамеренный). Аларның зур малайлары бер хылыйн инде.

**ХЫНҖАЛ** *мәл.* хәнҗәр, кинжал (кинжал).

**ХЫРДЫЙ-БЫРДЫЙ** [хъырдый-бырдый] *т.я.* вак-төяк, коры-сары азык (сухомятка); чаг.: **қыры-қары**. Әй мондый хырдый-бырдыйлар белән тамақ туйамыни соң?! – *к.т.*

**ХЫРМЫРЛАУ** *мәл.* хәрәмләү, алдашу (мошенничать, плутовать).

# Һ

**ҺАЙЛАК** [*гар.*] *минз., стрл.* к.: **һал′ак**. Уфа буйында һайлак, ди, колмак. – *стрл.*

**ҺАЛ′АК** [*гар.*] *минз., тпк., стрл.* бик күп, бик яхшы, харап (очень много, очень хорошо; чудо, прелесть). Баштан әллә нәрсәкәйләр үтте инде, һал′ак. Чийә чыбыклары аппак, чәчкәсе һал′аг ийе. – *минз.*

**ҺАЛӘК** [*гар.*] *тпк.* к.: **һал′ак**. Утын өскә өйөләп тора, ир-атың булса, һаләк инде.

**ҺАЛ-ҖӘМӘТ** [*гар.*] *кас.* җәмәгать, халык – эндәшү сүзе (люди, народ – форма обращения).

**ҺАМАНДАҚТА** [*фарс.*] *минз.* һаман, һаман да (постоянно, всё время). Һамандақта шулай булған инде тормош, эшләмичә бирмиләр бит.

**ҺАНУD** [*фарс.*] *тпк.* һаман (всегда, постоянно). Һануd йawамы?

**ҺАССЫНУ** [*гар.*] *стрл.* к.: **хассыну**. Ул һассынып йөри моны үтерергә.

**ҺӘЛАК** [*гар.*] *минз., стрл.*, **ҺӘЛӘК** [*гар.*] *минз., байк., стрл., тпк.* к.: **һал′ак**. Чебешләргә дә бик күп кирәк, һаләк. – *минз.* Казан хазер һаләк үзгәргәндер инде. – *стрл.* Йаңқырдан суң һаләк инде һawа. – *тпк.* Бәрәңгеләр һаләк әйбәт. – *трбс.*

**ҺӘНҮЗ** [*фарс.*] *минз.* ничничек (никак). Һәнүз кеше тапмадылар.

**ҺӘНYD** [*фарс.*] *тпк.* **1.** к.: **һанyd**; **2.** шулай булса да (несмотря на, всё-таки). Пинсийәдә, һәнyd йәрдәмгә йөрдәм, кәбән қойдоқ.

**ҺӘС-ҺӘС-ҺӘС** *мам., лш., блт.* к.: **чәбә 2**. Һәс-һәс-һәс! Безнеке түгелсез, қу шул сарықларны! – *блт.* Һәс-һәс, рәхмәт җауғырлары, бу сарық қуғанны һич белмәс. – *мам.*

**ҺӘТ: «һәт» тигәнсе** *тпк.* «ә» дигәнче, бик тиз (быстро, сразу). «Һәт» тигәнсе алып та қайтты.

**ҺӘҮЛӘТЕП** *тпк.* менә дигән итеп (отлично, превосходно). Һәүләтеп гөмөр иттек.

**ҺЕМЕ** *к.-уф.* әйе бит, әйеме (да ведь, так ведь); чаг.: **әйтә**.

**ҺОППАЙЛАУ** *мәл.* авыр әйберне ыргытыр алдыннан билгеле бер ритмда селтәнү (покачивание тяжёлого груза перед тем как кинуть).

**ҺӨНӘРМӘН** [*фарс.*] *минз., трбс., стрл.* һөнәрле, эш белә торган (мастер на все руки). Һөнәрмән җегет ул, мақталып қына тора. Безнең күрше һөнәрмән җегет ийе. – *трбс.* Бәк һөнәрмән кеше ийе, йәшләй үлде шул. – *минз.* Һөнәрмәннән һөнәрмән тywар инде. – *стрл.*

**ҺҮПЛӘШҮ** [*гар.*] *бәр.* узышу, көнләшү (состязаться, соперничать). Берсеннән-берсе һүпләшеп матурдан матурны утырталар гөлнең.

# Ц

**ЦАБАҚЛАУ** *тбл.* **1.** итне кисәкләргә (буйга) кисү (разрезать мясо (вдоль) на длинные куски); **2.** ит тозлау (солить мясо).

**ЦАБАЛ** *брб.д.* тал чыбыгы (ивовый прут).

**ЦАБАЛАҚ** *брб.д.* нечкә тал чыбыгы (тонкий ивовый прутик).

**ЦАБАН** *тбл., тара.* **1.** әкрен, әкрен хәрәкәтле (медлительный). Синең түwәң арық иде, симес болыпты, цабан иде, йылдам болыпты. – *тбл.*; **2.** үшән (ленивый, вялый). Цабан ат. – *тара.*

**ЦАБАТ** *срг.* к.: **чабат**. Казанда музида булдым, әби пиц арасында, кабага ураган йеб эрли, бабай йеб ишә, цабатлардан бабай. Кунакка барганда цабатның башын себерәләр.

**ЦАБУ I** **1.** *чпр.* итәк (подол, пола, фалда). Цабу астында эшләнә тырган эш түгел. Бишмәтенең цабуларын йил күтәрә; **2.** *брб.д.* кештәк (ластовица, подмышник).

**ЦАБУ II** *брб.д.* уру (жать). Аш цабу (ашлык уру). Шатка (жатка) менән аш цаптым, қол менән цаптықлар.

**ЦАБУЛ** *туб.-урт.д.* почта яки эш кәгазьләре йөртүче (почтальон, курьер).

**ЦАБЫН 1.** *эчк.* к.: **чабын 1**. Цабыннан қайтып киләләр; **2.** *төм.* к.: **чабын 3**.

**ЦАБЫННЫҚ** *төм.* печәнлек (луга – под сенокос).

**ЦАБЫНТЫ 1.** *тбл.* к.: **чабын 3**; **2.** *төм.* чал-

гы алымы киңлегендә чабылган җир, пакус (прокос; прокошенная полоса в ширину взмаха косы).

**ЦАБЫНТЫҚ** *тбл.* чабылган печән (скошенное сено).

**ЦАБЫНУ: мунца цабыну** *срг.* мунча керү (мыться в бане). Без мунца цабындык, сез барыгыз.

**ЦАWАН** *тбл., тара.* ялкау – ат турында (ленивый – о лошади); чаг.: **цабан.**

**ЦАWАП** [*гар.*] *брб.д., тбл.* җавап (ответ).

**ЦАWАПЛАШУ** [*гар.* + *афф.* -лашу] *тбл.* әңгәмә алып бару (вести разговор, беседовать).

**ЦАWАХ** *саз.я.* чабак (плотва).

**ЦАWУ** *саз.я.* чабып җибәрү, битенә сугып җибәрү (ударить, шлёпнуть по лицу). Куймасаң, цаптырырам. Питнә цаптым.

**ЦАWЫЛ 1.** *эчк., себ.* яшь каен (молодая берёза); чаг.: **чаwыл 1; 2.** *эчк., тара.* чи каен утыны (дрова из сырой берёзы). Мицкә цаwыл йагыпты. – *эчк.*

**ЦАWЫЛАҒАЦ** *тбл.* каен (берёза).

**ЦАWЫЛЛЫҚ** *тбл.* каенлык (березняк).

**ЦАWЫЛЛЫХ** *саз.я.* чабынлык (покос, место косьбы).

**ЦАWЫЛТҚАЙЫН** *төм.* к.: **чаwылағац.** Пестә цаwылтқайын, сестә тәме шалай?

**ЦАWЫНТЫ** *саз.я.* к.: **чабынтық.** Өц хөннөх цаwынтыwс (чабынтыбыз) йатат.

**ЦАWЫШУ** *саз.я.* к.: **бүкәйләү.** Ул йетте (җиде) айынта цаwыша пашлаган.

**ЦАГА** *чст.* к.: **чага II.**

**ЦАҒАWЫН** *эчк.* к.: **мурта 2.** Цағawын цақты баланы. Цағawынның файдасы күп тий анын.

**ЦАҒАНАҒАЦ** *тбл., төм.* к.: **чаган.** Сестә нәмә титләр, пестәге цағанағацны? – *төм.*

**ЦАҒУ I** *төм., тбл.* ук, чаккыч (жало).

**ЦАҒУ II** *тара.* гаепләү (обвинять). Олло әккәсе барып цаққанты ийән.

**ЦАҒУ III** *тбл., тара., брб.д.* чагу, кабызу (высекать, зажигать кресалом огонь). Ташы полопты, аны цагады, палықны пежерәде. – *тбл.*

**ЦАҒУWАН** *эчк.* к.: **мурта 2.** Цағуwан цақты.

**ЦАҒУWЫН** *төм., тбл., саз.я.* **1.** к.: **кормош; 2.** чага торган бөҗәкләр (жалящие насекомые). Цағуwын парысы бер. – *төм.*

**йецкәбил цағуwын** *тбл.* к.: **кормош.** Йецкәбил цағуwын сәрле (зәһәр) у.

**пал цағуwын** *туб.-арт.д.* к.: **мурта 2.**

**ЦАҒУН** *төм.* к.: **мурта 2.** Цағышаты у цағун.

**ЦАҒЫЛУ** *тбл.* ару, хәлдән таю (устать, выбиться из сил). Киймә пелән йул алыс (ерак), awыр, парсағыс цағылып килерсес.

**ЦАҒЫН** *тбл., тара.* кечерәк (маловатый). Пы (бу) көйләк аңа цағын игән, йыртып куйар.

**ЦАҒЫРТУ** *тбл.* чакыру (вызов, приглашение). Салтатқа алгалы цағырту килепте.

**ЦӨЙЛӨХҮ** *саз.я.* к.: **цөйлөгү.** Машина цөйлөхкән кицкә пала қултан төшф хитә йасты.

**ЦӨЙМӘШКӘ** *тбл.* туп (мяч).

**ЦӨЙӨР: цөйөр йелән** *туб.-ирт.д.* җир җиләге (клубника лесная).

**ЦӨЙҮ** *тбл., саз.я.* чөю (подбрасывать вверх). Паланы цөйәте. – *тбл.* Тулғын киймәне цөйәт. – *саз.я.*

**ЦӨЙҮЛҮ** *брб.д.* сузылу, киңәю (растягиваться, расширяться).

**ЦӨКӘҮ, ЦӨКӨҮ** *саз.я.* зурларның бер-берсенә яратып эндәшү сүзе (форма ласкового обращения взрослых друг к другу).

**ЦӨЛЦӘЙҮ** *саз.я.* җемелдәү (мерцать – о лампе).

**ЦӨЛЦӨК: цөлцөк ламбы** *тбл.* к.: **пысқыш.**

**ЦӨЛЦӨХ** *саз. я.* лампа яктысы, лампа уты (свет от лампы). Лампа цөлцөхентә тәрес әсерләгәннәр.

**цөлцөх лампа** *саз.я.* к.: **пысқыш.**

**ЦӨМӘЛДЕ** *брб.д.* кырмыска (муравей).

**ЦӨМБӘЙҮ** *тара.* тырпаеп тору, чыгып тору, калкып тору (торчать). Пақцы, нимәте цөмбәйеп тора?

**ЦӨМЦӘЙҮ** *саз.я.* турсаю, үпкәләгән булып кылану (дуться, обижаться).

**ЦӨМЦӨМ** *себ.* к.: **цемцем 1, 2.**

**ЦӨПЛӘҮ** *брб.д.* пычрату (запачкать, замарать).

**ЦӨПРӘЙҮ** *тбл., брб.д.* к.: **цөбөрәйү.** Көйләкләре цөпрәйгәнте. – *тбл.* Цөпрәйгән итәктән палас қыла. – *брб.д.*

**ЦӨРӘГӘЙ** *төм., тбл., саз.я.* чүрәкәй үрдәк (чирок – порода уток).

**цөрәгәй тawық** *тбл.* үрдәкнең бер төре (один из видов дикой утки). Цөрәгәй тawық мамықсысты, йөн кенә.

**ЦӨРӘКӘЙ** *саз.я.* к.: **цөрәгәй.**

**ЦӨРӨШ** *тбл.* җыерчык (морщина).

**ЦӨРӨШҮ** *туб.-ирт.д., брб.д.* җыерчыклану (морщиниться). Пер қартайғац, питләр тә цөрөшәте инте. – *тбл.*

**ЦӨЦБӘРА, ЦӨЦБӘРӘ** *тара.*, **ЦӨЦБҮРӘ** *тбл.* **1.** к.: **шөшпәрә**; **2.** эремчек пилмәне (вареники). Цөцбәрә бәребер пилмин шикелле (ахры). – *тара.*

**ЦӨЦЕК** *себ.* к.: **цөцөк 1.**

**ЦӨЦКӨРҮ** *себ.* төчкерү (чихать).

**ЦӨЦМӘРӘ** *брб.д.* к.: **шөшпәрә.**

**ЦӨЦӨ** *туб.-ирт.д.* **1.** төче (пресный); **2.** баллы, татлы (сладкий; сладкое). Ацы-бацы, цөцө-бөцөне генә йаратам. – *төм.*; **3.** имчәк – балалар телендә (сосок – на детском языке); **4.** конфет (конфета).

**цөцө ауру** *тбл.* төче авыруы (золотуха). Цөцө ауру цөцөне кән (күп) ашағантан пулаты.

**цөцө төшү** *төм.* сифилис белән авырып китү (заболеть сифилисом). Цөцө төшөп порно та өсөлгән.

**ЦӨЦӨК 1.** *эчк.* каенның кайрысы белән үзагачы арасында була торган юка лайлалы катлам (заболонь – у берёзы); чаг.: **төчөгән.** Бала цақта цөцөк ашый торғаныйық; **2.** *тбл.* каен суы (берёзовый сок); **3.** *тбл.* тукранбаш (клевер). Цөцөк пы, сыwырыб аласың та, имсән цөцөк, цөцөк тибес пес.

**цөцөк ут** *тбл.* татлы тамыр (солодковый корень).

**ЦӨЦӨЛӘР** *тбл.* конфет, шикәр һ.б. чәй тәмләткечләр (конфеты, сахар и др. сладости для чая). Цайға цөцөләр петепте.

**ЦӨЦӨХ** *саз.я.* к.: **цөцөк 1.**

**ЦӨЦХӨРҮ** *саз.я.* к.: **цөцкөрү.**

**ЦУБАЛТМА: цубалтма йебәрү** *себ.* мичәүләп җигү (запрягать цугом).

**ЦУБАЛТУ** *тбл.* көннән-көн кичектерү, сузу (отсрочивать день ото дня, оттягивать).

**ЦУБАТА** *тбл.* чабата (лапти). Цубатаны қаты йүгәтән йасайтығаннар ите, цитеннән пау үткәсеп (ясыйлар).

**ЦУБАУ** *брб.д.* озаю (удлиняться, становиться длинным).

**ЦУБАЦАҚ** *яүшт.* **1.** хатын (жена); **2.** карчык (старуха).

**ЦУБУР** *тбл.* ахмак (дурак, глупый).

**ЦУБЫР** *тбл.* шадра (рябой). (Кейәү) цубыррақ питлы, Сибердә қушылыптылар.

**ЦУWAЛ 1.** *себ.* алды ачык мич (печь, открытая спереди наподобие камина). Суқыр лампыға қәдәр цuwal йаққаннар, пиц алтына wақлап қына цырақ йаққаннар. – *төм.* Цuwal йақтысынта ийергәннәр, пәйләнкәннәр. – *тбл.* Порнағы өйләртә қасаннық пулмаған, цuwal булған. – *твр.*; **2.** *эчк.* өйнең стенасына терәп чыгарыла торган кечкенә мич (маленькая печка); **3.** *эчк., себ.* аш-су әзерләү өчен ишегалдында махсус ясалган мич (маленькая печка во дворе для приготовления пищи).

**ЦУWAЛАРҒА** *тбл.* бозау асрау өчен киртәләп алынган мич арты (отгороженное место за печкой, где держат новорожденных телят).

**ЦУWAЛАРТ** *тара.* мич арты (место за печкой).

**ЦУWAЛБАШ** *тара.* моржа (труба печная).

**ЦУWAРАТ, ЦУWAРЛАТ** *туб.-ирт.д.* к.: **цuwaларт.**

**ЦУWЫР** *том.д.* олау (воз). Пецән цuwыр.

**ЦУҒУ** *саз.я.* **1.** к.: **цуқцу** (клевать); **2.** шаку (стучать). Ишехкә цуғы!

**ЦУҒУЛ** *брб.д.* балалар тавышы, шау-шуы (детский шум, крик).

**ЦУҒЫНТЫ** *төм.* чукындырылган (крещёный).

**ЦУҒЫРМАҚ** *эчк.* карт каен кайрысы (кора старой берёзы).

**ЦУЗУҚ** *брб.д.* колбаса.

**ЦУҚ 1.** *тбл., тара., брб.д.* күп (много). Цуқ пулса, шәлләмәс идем. – *тара.*; **2.** *брб.д.* куе (густой).

**цуқ йөрү** *тбл., тара.* җыелышып йөрү, күмәкләшеп йөрү (ходить вместе, гурьбой). Цуқ йөрөң төстә (урманда), аташырыс. – *тбл.*

**цуқ қайын** *тбл.*, **цуқ цawыл** *тара.* зират (кладбище).

**цуқ цыбық** *тбл.* куаклык (кустарник).

**ЦУҚЛАНУ** *чст.* (чабата) тузып-сүсәреп юкәнең очлары чыгып тору (появление усиков у лаптей от изношенности). Цабата тузгац цуқлана.

**ц у к л ы** *чст.* чуклы (с кисточкой, с бахромой): **цуклы цабата** *чст.* юкә очлары чыгып сүсәреп тора торган, тузган чабата (изношенный, измочаленный лапоть).

**ЦУҚЛАУ 1.** *тара.* берләштереп эреләндерү (укрупнять объединив). Қалғусларны цуқлағаннар; **2.** *брб.д.* кысу (стеснять).

**ЦУҚМАР** *тбл.* гер (гиря).

**ЦУКРАК** *чст.* к.: **батқақ**. Былтыр кез бәрәңгене цукракта казыган идек.

**ЦУКРАКЛАНУ** *чст.* пычраклану, пычракка әверелү (превратиться в грязь); чаг.: **апаралану**. Йаңгыр йawa да зир цукраклана.

**ЦУҚЦУ** *сазл., том.д., брб.д.* чуку (клевать). Қарға қарғаның күсен цуқцымас. – *яүшт.*

**ЦУҚЫШ** *туб.-ирт.д.* кәгазь конфет (конфеты в бумажной обёртке).

**ЦУЛАК** *срг., тмн.* к.: **чулак**. Малайым бик тырыштыр да бит, катны цулак, уңмады. И цулак катын!

**ата цулак** *срг.* бер дә эш рәте белми торган, кулы бер эшкә дә бармый торган (слишком неумелый, ни на что не способный; слишком неумеха). Бу бит ата цулак! Минем ише уңган тегел.

**ЦУЛАҚ 1.** *тбл.* аңлаешсыз (непонятный); **2.** к.: **чулак**.

**күстән цулақ** *тбл.* к.: **қашақ 2**.

**ЦУЛБАН** *тбл.* бер рәт көмеш тәңкә тезеп эшләнгән бизәнү әйбере (монисто из нанизанных в один ряд серебряных монет). Цулбан осон қына пер сап қына, аны та муйынқа қатып қуйатыған ите.

**ЦУЛБЫ 1.** *төм., тбл.* чулпы (накосник). Цулбы төрлө-төрлө күслеләре. – *тбл.*; **2.** *төм.* элек: күкрәккә тагыла торган көмеш бизәнү әйбере (в старину: нагрудное серебряное украшение). Цулбы күкерәктә қатулы булыпты, инәманың көмөш цулбысы бар ите.

**айақлы цулбы** *төм., тбл.* аскы ягында кашлар, тәңкәләр салынып тора торган чулпы (накосник с подвесками). Айақлы цулбы осон қына цулбытан игенце нәрсә қатылып қуйулы астынта булған, перәй күслерәк йалтырawық таққан былыр. – *төм.* Айақлы-айақлы цулбылар, қалпақлар кейеплəр. – *тбл.*

**өц айақлы цулбы** *төм.* аскы ягына өчәр көмеш тәңкә тагылган чулпы (накосник с тремя серебряными монетами-подвесками). Өц айақлы цулбылар тага тыганнар цәцкә.

**тақталы цулбы** *тбл.* читенә тәңкәләр тагылган, уртасында кашы булган көмеш калайдан торган чулпы (накосник в виде лопастного листа с камнем в середине и монетами по краям). Ике тақталы цулбы булаты, оцларынта манитлар.

**ЦУЛҒАҚ** *брб.д.* лалә төреннән булган кыр үсемлеге (потничная трава, сарана – разновидность полевых лилий).

**ЦУЛКА** *тмн., әҗе.* к.: **чолка**. Цулкалар китергән. – *тмн.*

**зым цулкасы** *әҗе.* к.: **бишинәйык**.

**ЦУЛКАУ** *тара.* к.: **саргыч: айақ саргычы**. Айағыпысқа цулкау урап қуйа тыгампыс.

**ЦУЛПЫ** *срг.* к.: **чулпы II, 1**.

**такта цулпы** *чст.* уртасы кашлы юка көмеш тактачыкларны тоташтырып эшләнгән, читләре челтәрле-тәңкәле зур чулпы (накосник, состоящий из ряда лопастных листов с камнем в середине и объединённых в один накосник с кружевами и монетами по краям). Такта цулпы булган әнинеке, тугыз такта. Такта цулпы ул целтәрле такта, такта уртасында ахыклардан кашы була.

**ЦУЛЦАН** *тбл.* **1.** суалчан (глиста); **2.** к.: **селәү II, 1**.

**ЦУМАР 1.** *срг., чст., чпр., әҗе.* чумар (клёцки). Сез тудыгыз, цумар пешермә кирәк, цумар пешереп итәләр туган хатынга. – *чпр.*; **2.** *брб.д.* вак шакмак итеп тураган салма (клёцки в форме квадрата).

**каккан цумар** *срг.* к.: **чумар: қашық чумар**. Каккан цумар борцак онынна була.

**цумар зийу** *әҗе.* кунак җыеп мәҗлес уздыру, Коръән укыту (провести званый обед, угощение). Сун цумар зийалар, киленгә башына китерәләр падаркалар, башына әтәләр, әтийем, кем акца, кем цепрәк.

**ЦУМАРТ** *туб.-ирт.д.* юмарт (щедрый).

**ЦУМАРЦАК** *срг.* металл бизәнү әйберләрендәге деталь: пыяладан яки көмештән күпкырлы шар рәвешендә эшләнгән һәм чумар шикелле асылынып тора (висячий элемент металлических украшений в виде многогранного шарика из стекла или металла).

**ЦУМҒА 1.** *сазл.* ала чумгалак (гоголь – вид дикой утки). Пашы цумғаныңқы қара, икке цихәсентә икке ах wулат; **2.** *тбл., сазл.* чүрәкәй үрдәкнең бер төре (нырок).

**ЦУМҒЫ** *сазл.*, **ЦУМҚА, ЦУМҚЫ** *туб.-ирт.д.* к.: **цумға 1**.

**ЦУМУ** *тара.* коену (купаться). Йәйен цумалар Пәтәледә дә (*елг. ис.*).

**ЦУМЫНУ** *себ.* чуму (нырять).

**ЦУМЫРУ** *чпр.* чумдыру, тондыру, төшерү – суга (бросать, кинуть швырнуть – в воду). Суга цумырыр кабан дуңгызы, караклап тыр дигән.

**ЦУНИ** *тара.* к.: **чуни**. Калуш шигелле цуниләр пулады.

**ЦУНТЫҚ** *тара.* **1.** чулак (криворукий); **2.** сакау (косноязычный).

**ЦУПЫЛДЫҚ** *төм.* такылдык (болтун).

**ЦУРАҒАЙ** *эчк.* чуртан (щука). Цурағай тотқан безнең малай.

**ЦУРБА** *том.д.*, **ЦУРҒА** *тара.* к.: **сәмәк**.

**ЦУРҒАҚ** *тара.* булдыксыз (неспособный, беспомощный).

**ЦУТЫР** *срг., чпр.* к.: **чутыр: қара чутыр**.

**ЦУЦАЙУ** *тара.* чүгәләү (сесть на корточки). Цуцайғаннан айлан (әйләнеп) китте.

**ЦУЦАҚЛАП** *төм.* кыланып (кривляясь, рисуясь). Қортқайақ тың игән әле, цуцақлап йөрөйте.

**ЦУЦАҚЛАУ** *төм.* су ерып бару (идти вброд). Сасны цуцақлап киләпес. У йаққа барсақ та цуцақлап, пу йаққа барсақ та цуцақлап.

**ЦУЦҚА** *себ.* дуңгыз (свинья).

**цуцқа қағы** *том.д.* к.: **қазайақ II**.

**цуцқа эләге** *эчк.* к.: **бырцак: бырцак үләне**.

**ЦУЦҚУН** *том.д.* он соскычы (совок для муки).

**ЦУЦҚЫ** *себ.* к.: **цуцқа**.

**цуцқы йафрагы** *яүшт.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы**.

**ЦУЦХА** *саз.я.* к.: **цуцқа**.

**ЦУЦЫҚ** *туб.-ирт.д.* өлкәннәр арасында үзен тота белми торган бала (ребёнок, не умеющий вести себя среди взрослых соответствующим образом).

**ЦУЦЫЛТАҚ** *тбл., брб.д.* тыкшынучан, әрсез (пройдошный, пронырливый).

**ЦУЦЫЛТАУ** *тбл.* тыкшыну (вмешиваться).

**ЦУЧАҚЛАУ** *төм.* к.: **цуцақлау**. Сыутан йөрисең нә цучақлап.

**ЦҮБӘК 1.** *тбл., том.д.* чүбек, сүс (пакля). Йақшы цүбәктән ийерсән (эрләсәң), пақта (мамык) шикелле тораты йеп. Йетеннән тә, цүбәктән тә ийрәбес. – *тбл.* Тилагрейканыққы эценә цүбәк салганнар, тышы турап пулған. – *яүшт.*; **2.** *тбл.* чүпрәк-чапрак (тряпьё).

**ЦҮГӘЛӘҮ** *тбл.* к.: **йегенү**.

**ЦҮГӘРӘЙ** *эчк.* к.: **чүрәч**.

**ЦҮГӘТ** *төм.* кечкенә күл (маленькое озеро).

**ЦҮГӘЦӘЙ** *яүшт.* табак, касә (чаша, плошка, пиала).

**ЦҮГҮ I** *тмн.* чүкү (отбивать – косу). Цалгы цүгәргә илтәсенме?

**ЦҮГҮ II 1.** *төм.* чүгәләү (присесть на корточки); **2.** *тара.* тезләнү (встать на колени). Түwәнең цүккән йирен күрдү.

**ЦҮЙҮ** *том.д.* тарту, сузу (тянуть, растянуть).

**ЦҮКӘ** *тара.* бүкән (пень, обрубок).

**ЦҮКМӘН** *төм.* чикмән (чекмень). Минең әтийем қәлле булғац, цүкмән кенә кимәгән, қуй тиртән туннар тектерәте, қараға буйатып. Цүкмәннең исүwентә циккән күк йон пуйаулы. Минең әтийем-әнийем цүкмән тә суқтырған, пуйына йақшы йетеннән ийерәсең, аргаwына йон, күрше awылда суқтырған.

**ЦҮК-ЦҮК-ЦҮК** *күзн.* песи чакыру сүзе (слово, которым подзывают кошку).

**ЦҮЛЕГҮ** *чпр.* к.: **чәүмәлү 2**. Цирәм йылкыганда цүлегеп-цүлегеп китә каз балалары.

**ЦҮЛЕКМӘЛЕ** *чпр.* к.: **чүлекмәле**. Цүлекмәле кый бар ул урамда.

**ЦҮЛМӘК** *тбл.* чуен (чугунок).

**ЦҮМЛӘК** *тбл.* чүлмәк (горшок).

**ЦҮМӘК** *тара.* к.: **цүбәк 1**.

**ЦҮМӘН** *саз.я.* сөймән (пешня). Цүмән пийен (белән) қыйу (бәке) тиштем.

**ЦҮНИ** *төм., тара.* зур юка галош (большие, тонкие галоши, надеваемые поверх обуви). Цүни ул – калуш, қысым. – *төм.* Пурки өстеннән цүни кидем, цүни магасинта бар қуй (бит). Пиманың өстеннән цүни кийеп қуйатлар. – *тара.*

**ЦҮҢКЕР** *тбл., саз.я.* көймә койрыгы (корма).

**ЦҮП** *тбл.* соңгылык (послед). Кентеген йақшы йептән пыwыб ийәтләр икән, цүбен күмәтләр.

**цүп тә** *тмн.* к.: **чүп: чүп тә**. Цүп тә авырүwын тапмыйлар кызынын.

**ЦҮПЛӘМӘ 1.** *срг.* к.: **мошко I: кара мошко; 2.** *тара.* аннан-моннан чүпләп кенә җыйган җиләк (ягоды, собранные по штучке, собранные то тут, то там, а не на одном месте). Пы (бу) цүпләмә, қәсер йоқ йеләк, аннан-моннан цүпләп.

**ЦҮР** *тбл.* шүре (шпулька).

**ЦҮРӘ** *срг., әҗе.*, **ЦҮРӘЙАК** *чст.* к.: **кискәржақ**. Халатыннын цүрәсен кийепсен. – *әҗе.* Цүрә бишмәт кидең, шатланырсың, мин әвәле цүрә бишмәт кийә идем дә шатлана идем, цүрә булгац тәрс йагы. – *срг.* Күлмәгеңне цүрәйагы белә кигәнсең. – *чст.*

**ЦҮРГӘМЕШ** *тбл.* тигәнәк (репейник). Цүргәмеш қола булаты, цүргәмеш қawағы бы.

**цүргәмеш қawақ** *тбл.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы**.

**ЦҮРЕК** *тара.* **1.** үрдәкнең бер төре (вид утки). Цүрек оцло боронны, wақ қына; **2.** үрдәк (утка). Wақ қына цүрекләр, аларныңқы ите дә йуқ.

**ЦҮРИ** *тара.* каз бәбкәсе (гусёнок). Өц цүрине үтертеп қуйдым.

**цүри үләп** *тара.* каз үләне (гусиная лапка).

**ЦҮТҮ** *тбл.* очырту (заставить летать, дать лететь).

**ЦҮҮ** *тбл.* очу (лететь).

**ЦҮҮРҮ** *брб.д.* әйләнү (вертеться кругом).

**ЦҮФ** *саз.я.* кылчык, вак сөякләр – балык турында (косточки – о рыбе).

**палых цүф** *саз.я.* к.: **цүф**. Палых цүф қадалыф уртына.

**ЦЫБАЛ** *брб.д.* **1.** тал чыбыгы (ивовый прут); **2.** үсенте (росток); **3.** яшь (молодой). Цыбал ат мүнү ойнарлар иде.

**ЦЫБАН** *срг.* ыспай, җыйнак (аккуратный, опрятный).

**ЦЫБАР** *чпр., әҗе., төм.* к.: **чобар**.

**шийырцык цыбар** *әҗе.* сипкелле (веснушчатый).

**ЦЫБАРАЙУ** *брб.д.* чуарлану (пестреть). Күсемкә (күзем) цыбарайып китте.

**ЦЫБЫ** *том.д.* чыршы (ель).

**ЦЫБЫҒЫМЦЫҚ, ЦЫБЫҒЫНЦЫҚ** *төм.* тәңкә салыш, йөзек салыш – уен исеме (игра в колечко). Цыбыгынцық уйын пар ите, қулға йомтороп китә, аны эстәйсең.

**цыбык** *чст.* чыбык (прутик):

**цыбык ыцында** *чст.* ерак туган, чыбык очы туган (дальний родственник). Кыда була кан'атаның туганнары, кан'ананың туганнары, цыбық ыцында булса да кыда инде.

**ЦЫБЫҚАЙ** *эчк.* кыр үрдәгенең бер төре (порода диких уток).

**ЦЫБЫҚЛАНУ** *төм.* агачлык белән каплану (зарасти лесом).

**ЦЫБЫН** *брб.д.* к.: **озонайақ**. Цыбын цыңнап оцоп йөрәде йицкә генә.

**ЦЫБЫНДЫҚ** *брб.д.* к.: **чымылдық 2**. Киленне цыбындыққа керетәләр, йырлар мин пелер wахыттан полгон йоқ ол, элек йырлар полгон.

**ЦЫБЫР** *төм.* к.: **чобар**.

**ЦЫБЫРЦҚЫ** *туб.-ирт.д.* к.: **жүрмә**.

**ЦЫБЫРЦЫҚ** *тбл.* кош теленең бер төре (хворост: тонкие полоски пресного теста, изогнутые во время кипячения в масле).

**ЦЫWAЛ** *тбл.* к.: **цywал 2.** Ғарип пабаның асты өйөнтә цыwал ул.

**ЦЫWЫ** *тара.* күчәр (ось, стержень).

**ЦЫWЫМ** *брб.д.* чөй (клин). Мыш иткәле цыwым ғағаты.

**ЦЫҒАНАҚ 1.** *төм.* буын (сустав). Әрбер пywыннар цыганақ қуй; **2.** *туб.-ирт.д., брб.д., яүшт.* терсәк (локоть); **3.** *төм., тбл.* к.: **бармақ: гөлчәчәк бармақ**; **4.** *тбл., төм., сазл., брб.д.* тупса (шарнир, дверная петля). Ишектә дә цыганақ. – *төм.*

**ЦЫҒАНАХ** *сазл.* к.: **цыганақ 4.** Ишех цыганахны майлаф паққалыма әллә?

**ЦЫҒАРУ 1.** *себ.* кертү (впускать кого-либо жить). Монта үсебес торабыс, өскө өйгә кеше цыгарабыс. – *төм.*; **2.** *төм.* өйләнү (жениться). Паласы йаңқыс, цыгармаған қуй.

**бицә цыгару** *төм.* өйләнү (жениться). Ике бицә цыгарған минән алтта.

**ЦЫГАРУ** *срг., әҗе.* чыгу (выступать, выступить; прививаться, привиться). Кызамык цыгара, цицәк цыгара ыланнар. – *әҗе.*

**ЦЫҒУ 1.** *себ.* менү (подниматься, взбираться). Өй түбәгә цықтым. – *тбл.*; **2.** *тбл.* бизү (охладеть, приестся). Палықтан цықтым; **3.** *тара.* тулу, үтү – вакыт турында (исполниться, выйти срок).

**қырығы цығу** *тара.* кырык көн тулу (исполниться сорок дней). Кентег әби белән тапқан, суңқылыгын төшөрәте, кентек төшсә, исем қушқан, қырығын цыққан, цацын алғаннар, кентеген, цацын йәйеп (җыеп) қуйғаннар.

**цыгарып алу** *срг.* кызның эти-әнисенең рөхсәтеннән башка өйләнү (пожениться тайком, без разрешения родителей девушки). Кызны цыгарып алды Али.

**цығып килү** *срг.* к.: **ир II: ир артыннан китү.** Ул килене цыгып килде аның. Цыгып килсә дә моннан артык булыр иде, дир.

**ЦЫГЫР** *срг.* машинаны кабызу өчен кул белән әйләндерә торган тимер, (заводная ручка, рукоятка от машины).

**ЦЫҒЫРУ** *брб.д.* борып-борып кую – бауны (прикрутить – о верёвке).

**ЦЫҒЫРТАУ** *тбл.* **1.** шыңшу (хныкать); **2.** шыңшый торган (хныкающий). Цыгыртау пала.

**ЦЫГЫТ** *чпр.* эремчекне йомырка белән туғлап табада пешерелгән ашамлык (блюдо из творога, смешанного с яйцом, испечённое в печи на сковороде). Эремцекне йымырка белән ywып мицтә табада пешерәләр.

**ЦЫҒЫТ** *тара.* **1.** кызның төп үскән йорттан кияүгә чыкканда алып киткән әйберләре (все вещи, которые невеста привезла из отцовского дома). Оунике цана цығыты цыққан картинәнеке. Қиленцәкнең өйөнән цыққан цығыт пы, таслары, көйәнтәләре; **2.** бирнә (приданое).

**цығыт кейем** *тара.* кызның төп йорттан бирнә белән алып килгән, эти-әниләре тарафыннан бирелгән кием-салымнары (предметы одежды, которые невеста привезла с собой и которые приготовлены были её родителями). Цығыт кейемне инә бирәте, қыс йаңнықын. Пылар цығыт кейемнәр, пы палитә дә, пы пыймы та.

**ЦЫҒЫШУ** *тара.* аерылышу – ир белән хатын турында (развестись – о супругах).

**ЦЫДАМАЛ** *брб.д.* чыдам (выносливый, терпеливый).

**ЦЫДАУ** *брб.д.* **1.** чыдау (терпеть); **2.** чыдам (выносливый).

**ЦЫДЫР** *том.д.* куе агачлык (густой лес, чащоба).

**ЦЫЙ** *брб.д.* сызык (черта, линия). Пер қыс цый цыйып утыраты.

**ЦЫЙҒАН** *туб.-ирт.д.* сызлавык, чуан (фурункул, чирей). Арқама цыйған цыққан, үлекле. – *төм.* Цыйған цыға тыған ите йәш цақта. – *тбл.* Цыйған сур цықты потыма. Цыйған тиделәр шешек цыкса, төпле була, сур. – *тара.*

**ЦЫЙҒАНАҚ** *яүшт.* **1.** к.: **цыганақ 1.** Цыйғанақлар инде менә бywыннар; **2.** к.: **цыганақ 4.** Ишекнеңмә, қапқаныңма цыйғанағына май қойам.

**ЦЫЙҒЫ** *тбл.* сызгыч (линейка).

**ЦЫЙЛАУ** *төм.* шыгырдау (скрипеть, поскрипывать).

**ЦЫЙРАҚ I 1.** *тбл.* чирак (туго скрученный – о нитке). Цыйрақ цыйратылған йеп тың пулаты, йулбән цыйратылған тис тусаты; **2.** *төм.* орчык (веретено). Пер цыйрақ йеп өйөртем.

**ЦЫЙРАҚ II** *твр.* к.: **чырақ 1.**

**цыйрақ цыйрату** *твр.* чыра телү (щепать лучину).

**ЦЫЙРАҚ III** *том.д.* чыдам (выносливый, терпеливый).

**ЦЫЙРАТУ** *туб.-ирт.д.* кату (скручивать, ссучить – нитки). Йөннө ийергән урцық пелән, цыйратып қуйған қатма белән, ийереп беткәц иге ғатлайбыс, анан цыйратабыс қатма белән. – *төм.* Цыйратылған йеп тың (нык) пулаты. – *тбл.*

**ЦЫЙРАТУЛЫ** *туб.-ирт.д.* катылган (скрученный, ссученный). Йеп ике ғабат пулса цыйратулы тиб аталады.

**ЦЫЙУ 1.** *туб.-ирт.д.* сызу (чертить, линовать); **2.** *туб.-ирт.д.* сызу –шырпы турында (чиркать – о спичках). Көн пуйға пер қап сирәңкә цыйып пөтөрәм. – *тбл.* Сирәңкә цыйтың – цай әсер. – *төм.*; **3.** *төм.* аякны сөйрәү (волочить ноги).

**ЦЫЙУЛЫ** *сазл.* каюлы (вышитый – об ичигах). Песнең инәмнеңке пар ите цыйулы атулар.

**ЦЫЙЫҚ** *туб.-ирт.д., брб.д.* сызык (черта, линия).

**ЦЫЙЫЛУ** *эчк.* суелу, сыдырылу (сдираться – о коже). Қулым цыйылды ағацқа.

**ЦЫҚМЫР** *тбл., төм.* **1.** аралашучан (общительный); **2.** к.: **қатымыш.**

**ЦЫЛ** *брб.д.* к.: **цел I.**

**ЦЫЛАМЫРТУ** *тбл.* аз-маз гына хәтерләү, искә төшерү (смутно помнить, припоминать). Инәмне пырас қына цыламыртам.

**ЦЫЛАН** *м.-кар.* к.: **бүлмәч 2.**

**ЦЫЛБАТУ** *тмн.* чуалту (спутать, взлохматить). Цылбата цәцен йырт анасы, сүмәгән тыварны.

**ЦЫЛБЫР 1.** *чст.* көмештән, буын-буын итеп, буыны саен каш утыртып, бер яки ике рәтле итеп эшләнгән бизәнү әйбере (нашейное нагрудное украшение в виде цепочки в один или два ряда, на каждом звене глазки из драгоценных камней); **2.** *брб.д.* тезген (повод).

**ЦЫЛҒЫЙ** *төм., тбл.* һаман, һаман саен (всё время, постоянно).

**цылғый су булу** *том.д.* к.: **лач: лач булу 1.**

**ЦЫЛКА** *срг.* к.: **чолка**. Майлагач цылка да йытыла дийр (*мәкаль*).

**бишнә цылкасы** *срг.* к.: **бишинәйык**. Бишнә цылкасы кийә идек сыкна цылкасы эценнән.

**сыкна цылка** *срг.* к.: **ойык 2**. Сыкна цылка кийәләр иде. Сыкна цылкаларга кара тыта иделәр.

**ЦЫЛ-ЦУ** *брб.д.* чыр-чу, балалар тавышы, шаушуы (детский крик, шум-гам, крик).

**ЦЫМ I** *тбл.* кәс (дёрн).

**ЦЫМ II** *төм., тбл.* җәй башында үләләрне искә алу: гаилә белән яисә авыл халкы җыелышып зиратка бару, каберләрне карау, шунда ашау-эчү, балаларга күчтәнәчләр тарату, хәер бирү (поминание умерших в начале лета: собравшись приходят на кладбище, убирают, устраивают угощение, детей угощают сладостями). Цым майның иң матур көнендә булат, сийаратқа барадылар, туғаннарын искә төшөрәтләр, палларға канфитлар өләшәтләр, цай эцәтләр. – *тбл.*

**цым салырға бару** *тбл.* зиратка үләләрне искә алырга бару (идти на кладбище поминать умерших). Цым салырға барып килтек Йаңawыл (*ав. ис.*) сийәрәтенә.

**ЦЫМАЙТУП** *төм.* к.: **цөймәшкә**.

**ЦЫМҒУ** *том.д.* җөй (шов).

**ЦЫМРАҚ** *туб.-арт.д.* имезлек (соска). Цымраққа сөт салғаннар, awыслантырғаннар, аннан имцәк имәргә йәбешә. – *тбл.*

**ЦЫМСАЛЫР** *төм., тбл.* к.: **цым II**. Цымсалыр үтмәгенцәк, қомға тигәле йарамайты, паған төпләр қасарга йарамайты. – *төм.* Цымсалыр туғысына қатәр пулат тиләр, цымсалыр устырмыйца қом алырға пойормайды. Цымсалыр тип майның унынта (зиратка) барып, тасартып, tywa ғылып, тәкбирләр әйтеп қайтасың. – *тбл.*

**ЦЫМЦА** *тбл.* к.: **цым II**. Қар бөтсә, парабыс анта, сийәрәттә мулла қатем уғыйты та ирне (җирне) эшләргә йарайты тейте, цымца пөттө тейте.

**ЦЫМЦУ** *брб.д.* чеметү (щипать).

**ЦЫМЦЫҒЫШУ** *төм.* ызгышу, кычкырышу (ссориться, браниться). Цымцығышып йататлар паллары белән.

**ЦЫМЦЫРЫҚ** *эчк., туб.-арт.д., том.д.* тыныч, тын (тихо, спокойно). Бала булмағац, цымцырық булып тора өйләре. – *эчк.* Цымцырық йөриләр. – *тбл.* Цымцырық отуруб отурлар (утыралар). – *клм.*

**ЦЫМЦЫРЫХ** *саз.я.* тынычрак, әкренрәк (потише, поспокойнее). Цымцырых wулыңцы, ицмә эштелмәйт.

**ЦЫМЫЛДЫҚ** *төм.* к.: **чымылдык 2**. Киленцәк цымылдық эцендә утырат.

**ЦЫМЫЛТЫҚ** *туб.-арт.д.* **1.** к.: **чымылдык 2**; **2.** өйнең чаршау белән бүлеп куелган өлеше, яшь килен төшкәч тә шунда кияү һәм бер яшь кыз белән әрбет чикләвеге ашый-ашый утырып торалар, аннан соң яшьләрне мәҗлес каршына чакыралар һәм киленнең битен ачу йоласы үткәрелә (отгороженное специальным пологом место в доме, где молодые сидят после переезда невесты и щёлкают кедровые орехи; затем их выводят к столу и происходит обряд открывания лица невесты). Цымылтықта утыраты киленцәк, питентә әцемлек. – *тара.* Ғыс цымылтыг эцтә, ғосоқ циртәсен, шәл пөргәнеп утырады цымылтық түртә. – *төм.* Цымылтықта утырган йуқ, туйта утыртым, иге цыбық ман ацатылар киленцәкнеңке әцемлеген. – *тбл.* Цымылтық эцтә йататы кейәу белән киленцәк. – *твр.*

**ЦЫМЫЛТЫХ** *саз.я.* к.: **чымылдык 2**. Элек цымылтыхқа йаңа килгән киленне уцханнар (утыртканнар).

**ЦЫМЫРЫҚ** *тбл.* к.: **цымрақ**.

**ЦЫНАЙАҚ** *себ.* к.: **айақ I, 2**.

**цынайақ таба** *тбл.*, **цынайақ tawақ** *саз.я., төм.* к.: **җәйләү**.

**ЦЫНАЙАХ** *саз.я.* к.: **айақ I, 2**.

**ЦЫННЫҚЛАП** *твр.* чынлап (действительно, всерьёз). Аңа уйнап әйтеп киткән, ул миңа цыннықлап сөйләмәсмә?

**ЦЫНТЫР, ЦЫНЦЫР** *төм.* к.: **җынҗыр**.

**ЦЫНЫ** *тара., том.д.* к.: **айақ I, 2**. Соусатым, тейте, пер генә цыны цай эцте. – *клм.*

**ЦЫНЫРҒАП** *тбл., саз.я.* к.: **цыннықлап**.

**ЦЫҢҒЫЛЛЫҚ** *тбл.* күгән куаклыгы (терновник).

**ЦЫҢҒЫЛТАУ** *тбл.* гыжылдау, карлыгу (сипеть).

**ЦЫҢҚА I** *твр., тбл., саз.я.* йозак элә торган божра (кольцо для вдевания замка); чаг.: **чыңға**. Ишек цыңқаға йосақ сал.

**ЦЫҢҚА II** *тара., тбл.*, **ЦЫҢҚЫ** [*рус.* цинга] *тара.* зәңгелә – авыру исеме (цинга). Цыңқа ман аурапты қый Сибертә. – *тара.*

**ЦЫҢҚЫЛТАУ** *твр., том.д.* к.: **цыңқыру 2**. Нәсек tawыш мән цыңқылтап сөйләште. – *твр.*

**ЦЫҢҚЫРУ 1.** *тбл.* шыңшу (скулить). Эт цыңқырайты; **2.** *тбл., том.д.* нечкә тавыш белән кычкыру (визжать, кричать резким, зычным голосом); **3.** *саз.я.* кычкыру (кричать). Цыңқырма, tawышың йаман.

**ЦЫҢҚЫРЫҚ** *тбл., саз.я.* нечкә итеп кычкырган тавыш (визг; писк; крик).

**ЦЫҢЛАУ 1.** *тбл.* безелдәү (жужжать). Арбуwынлар цыңлаб оцатылар; **2.** *саз.я.* чинау (визжать, пищать). Эт цыңлайт.

**ЦЫҢНАУ** *брб.д.* безелдәү, чеңнәү (жужжать, звенеть). Цыңнап оцоп йөрәде, энәсен төзгән wахытта ғына сизәсең цыбынны.

**ЦЫҢЦАЛЫҚ** *том.д.* к.: **бармақ: гөлчәчәк бармақ**.

**ЦЫПЛЫЙ 1.** *туб.-арт.д., брб.д.* кыргый үрдәкләрнең бер төре (одна из пород диких уток); **2.** *саз.я.* кечкенә гагара (гагара маленькая).

**ЦЫПУР** *срг.* к.: **пал′ак**.

**ЦЫПЦЫҚ** *срг.* к.: **турғай**.

**сука цыпцыгы** *срг.* к.: **бистурғай**. Сука цыпцыгы оцып йери тырган кыш, йәмне.

**ЦЫПЦЫҢАЛЦЫҚ** *брб.д.* к.: **бармақ: гөлчәчәк бармақ**.

**ЦЫР** *туб.-ирт.д.* оят (стыд). Питенең цыры бар мигәнни! – *тбл.*

**ЦЫРАЙ I** *туб.-ирт.д., том.д.* бит, чырай, төс (лицо). Йуwышмайс ицқацан, цырайларығыс қаралып қалған. – *сазл.*

**ЦЫРАЙ II** *туб.-ирт.д.* шикелле, төсле, ахры (подобно, кажется, как будто). Иген урынына қайын, аусақ үскән, иген пулған цырай, параса (буразна) йерләр күренеп тораты. – *тбл.*

**ЦЫРАЙЛЫ 1.** *сазл.* к.: **цырай II**; **2.** *брб.д.* матур (красивый). Киленцәкләре цырайлы. Қасанта болпмын, тын цырайлы ғой (бик).

**ЦЫРАЙСЫС** *тара.* ямьсез (некрасивый). Цырайсыс қортқайақлар ман кәпләшәсмә (сөйләшәсезме)?

**ЦЫП-ЦЫРАЙСЫС** *тара.* япь-ямьсез (очень некрасивый, самый некрасивый). Мин цып-цырайсыс пулсам та, сөйләште минең пелән.

**ЦЫРАҚ I** [*фарс.*] *туб.-ирт.д., том.д.* **1.** к.: **чырақ 1**. Цырақны мин оцлап (тотып) тора тыған итем, алар ашана тыған ит урасаға. – *төм.*; **2.** к.: **чырақ 2**; **3.** *тара., тбл.* шәм, якгылык (свечка, свет). Ал цырағымнан айырмасын тиб әйтәсең. – *тара.*

**ЦЫРАҚ II: цырақ кәмпит** *туб.-ирт.д.* карамель.

**ЦЫРАҚЛАНУ** *төм.* ярылу (растрескаться, расщепляться). Ошо ыстакан цырақланып китте.

**ЦЫРАҚЛАУ** *туб.-ирт.д.* яру (расщеплять). Қарағай утынын wақ қына цырақлап көртөп қуйадылар, йепләр әрләгәннәр. – *твр.* Тешемне цырақлап цүпләде шал бырач. – *төм.*

**ЦЫРАХ** *сазл.* к.: **чырақ 1**. Цырах ут қыстырғалы (кабызырга) шәф.

**ЦЫРБЫ** *төм., тара.* казык юанлыгындагы боталмаган агач (тонкое, неочищенное от веток дерево, используемое для кольев).

**цырбы басу** *тара.* ботаклы чыбыктан читән ясау (ставить плетень из не очищенных прутьев).

**ЦЫРWЫ** *сазл.* колга (шест, жердь).

**ЦЫРҒАУ** *тара., брб.д.* ыргыту, атып бәрү (забросить, швырнуть). Ашайтығын кәртепкәсен цырғады. – *брб.д.*

**ЦЫРГАУ** *срг.* урау, төрү, чорнау (заворачивать, закутывать, обвёртывать). Газит белән айакларын цыргый.

**ЦЫРҒЫЙ** *тара., твр.* **1.** к.: **цырwы**. Цырғыйларға йаулықлар, қашықлар пәйләб атыб алғаннар пейектән. – *твр.*; **2.** нечкә бүрәнә (тонкое бревно). Ағацлыққа цырғыйға цығарып йебәргәле. Цырғыйтан кийертләгән (бураган) өй бар ите. – *тара.*; **3.** койма аратасы (поперечина, перекладина). Цитәннеңке цыргыйларын қуйтым. – *твр.*

**ЦЫРМАWЫҚ** *төм.* к.: **бөрмәкәй II**. Цырмаwық матур үсә, пер йиргә цырмалып үсә. Цырмаwық үсәте, цәцәге тә ататы.

**ЦЫРМАУ 1.** *твр.* чорнау (мотать, наматывать); **2.** *брб.д.* чуалту (запутать).

**ЦЫРНАЙ** *тара.* ябык (худой). Түрт йәшенәцә иместем, пер йомалақ сөт алматым кешетән, үсем цырнай булып қалтым.

**ЦЫРНАУ** *чст.* к.: **сарғыч: айақ сарғычы**.

**ЦЫРТАҚ** *тбл.* нык утыртылмаган, селкенә торган (некрепко всаженный, шатающийся).

**ЦЫРТЫТУ** *төм.* чиртү – кылны (тренькать, бренчать). Қылны цыртытып йебәрсәң, ат үсе килер.

**ЦЫРУ** *брб.д.* черү (гнить).

**ЦЫРЦЫК** *срг.* к.: **пақцар**.

**ЦЫРЫЙ: цырый таwыш** *төм.* к.: **цыцқырық**. Паланың цырый таwышы цығып китте.

**ЦЫРЫҚ** *брб.д.* черек (гнилой).

**ЦЫРЫЛДАУ** *срг.* шалтырау – телефон (звенеть – о телефоне). Цырылдап беткәнен көтеп тор, нәнәй, алма тилифунны.

**ЦЫРЫЛДЫК** *срг.* **1.** гөрләвек (ручеёк). Балалар цырылдыклар йасап ун′иләр йаңгыр йаугац; **2.** к.: **жышқы 2**. Аранга су керә, цырылдык йасамасаң.

**ЦЫРЫШҚАҚ** *тбл.* бөдрә (кудрявый).

**ЦЫРЫШТЫРУ** *тбл.* бөдрәләтү (завивать). Цацын цырыштырып қуйған.

**ЦЫРЫШУ** *твр.* к.: **цөрөшү**.

**ЦЫТ** *төм.* читән (плетень).

**ЦЫТА** *сазл.* юка гына катлау (тонкий, очень тонкий слой).

**ц ы т а у** *тбл.* чыдау (терпеть):

**эцтәи цытамау** *тбл.* эче авырту (страдать болезнью живота). Эцтән цытаматы, үлеп китте.

**ЦЫЦАЛАҚ** *тара.* к.: **бармақ: гөлчәчәк бармақ**.

**ЦЫЦҚАН** *себ.* к.: **кийек I, 3**.

**йер цыцқан** *туб.-ирт.д.* к.: **әндәк**.

**күмәк цыцқан** *туб.-ирт.д.* к.: **ирлән**.

**ЦЫЦХАН** *сазл.* к.: **кийек I, 3**.

# Ч

**ЧА!** *лш.* хайван куу ымлыгы (возглас, которым отгоняют животных). Кит аннан, ча! (эткә карата).

**ЧАБ: аты-чабы** *т.я.* к.: **атак II, 1**.

**ЧАБА I 1.** *мәл.* кәжә куу ымлыгы (возглас, которым отгоняют коз). Чаба! Чаба! Сәтлек тигере, ындырга кергән бит бу кәжә; **2.** *нрл.* сарык куу ымлыгы (возглас, которым отгоняют овец). Чаба! Чаба! Көтүдән қачмақчы буласыңмы!

**ЧАБА II: чаба чүбе** *дөб., блт.* к.: **қырмыза**.

**ЧАБАДИ** *срг.* к.: **чабат**. Бусы сыйау, чабади тугый торган.

**ЧАБАЙ** *тбл.* к.: **ашық II, 3**.

**ЧАБАҚ I** *т.кам.-крш.* вак-төяк балык (мелкая рыбёшка, мелочь). Чабақ қына монда, инеш бит.

**даран чабақ** *минз.* яшь корбан балыгы (молодой лещ).

**йомор чабақ** *перм.* к.: **қомпалық**.

**чабақ таш** *перм.* җәенке, яссы таш (плоский камень).

**ЧАБАҚ II** *тбл.* яшь баланың баш киеме (чепчик для грудного ребёнка).

**чабақ қолақчын** *перм.* к.: **чапқы II**. Зәәр җибәрәйте чабақ қолақчынны уқытқан wақытта.

**чабақ қолақчын кийертү** *перм.* к.: **чапқыту**. Берәр нимә тип сүли башладисә, чабақ қолақчын ғына кийертә.

**ЧАБАЛА** *нгб.-крш.* тишекле күмер соскычы (железный дырчатый совок); чаг.: **созғо**. Чабала белән алғанда көлө қойола, күмере генә қала.

**ЧАБАЛАНУ 1.** *перм.* хәрәкәтләнү, кыймылдау (шевелиться, двигаться). Бик awыр чабалана тип хәбәр килде; **2.** *минз.* к.: **абдырау 1**. Киленнәрнең атбускасы җитте дип чабаланды китәргә.

**ЧАБАН** *лш.* к.: **чаман**. Чабан ат.

**ЧАБАРУ** *каз.ар.-крш.* чабыру (выступить, высыпать – о сыпи, волдырях). Қычытқан өткән ийе қулымны, и қычыта: чабара башлаған икән.

**ЧАБАТ** *тмн., срг.* чабата (лапти). Чабаттан йериләр иде выта эшкә. – *тмн.*

**ЧАБАТА 1.** *брб.д.* тиредән тегелгән аяк киеме (обувь из сыромятной кожи; поршни). Чабатаны мал айағынын сойған тәреснән тегә деген, пөрөп пәйләй деген. Чабатаны тегә деген сыйр тәреснән, көн йәүсә, болай болоп китәде, көн қойашласа, қатып, кечү қалады; **2.** *саз.я.* бала оекбашы (пинетка). Элеке чәбәхләр (башлыклар), ыштан кисәкләр тегеп, пиләүләр кергесхәннәр, чабата айахқа кергесхәннәр. Чабатаны пәйләгәннәр тә йептән, қалынырах малтан та теккәннәр.

**бетле башлы чабата** *нрл.* башын төрлечә бизәп суккан чабата (лапоть, головка которого отделана, по-разному украшена). Бетле башлы чабата буладырыйы, башы wақ-wақ қынайтеп суққан буладырыйы.

**биш қабырғалы чабата** *трх.* к.: **урыс чабата 1**.

**бушымны чабата** *перм.* аяк йөзен капларлык итеп киндер тегелгән чабата (лапти, сверху обшитые грубым полотном). Бушымны чабата кийеп китәбез ий йаланға.

**җиде қабырғалы чабата** *трх.* к.: **эш чабатасы 1**.

**иске чабата** *бөре.* к.: **шом I**. Қасыймға иске чабата йәбешкән, awыртып йата.

**қунақ чабатасы** *мам., блт.* тугыз юкәдән үрелгән чабата (лапти, сплетённые из девяти лык). Тугыз җүкәлесе қунаққа җөри торған ыспай чабата. – *блт.* Җыйынға дип қунақ чабаталары йасыйдырыйық. – *мам.*

**мөгөзле чабата** *каз.ар.-крш.* башында ике якка мөгез сыман чығып тора торган, хатын-кыз өчен ясалган көяз чабата (нарядные, женские лапти, плетёные с рожками на головке). Мөгөзле чабатаны бөтөрөп, бороп қуйасың хатын-қызныкын.

**мукшы чабатасы** *срг.* к.: **урыс чабата 1**. Бусы мукшы чабатасы, сукалаганда кийә торган.

**пошоклаған чабата** *глз.* к.: **бушымны чабата**.

**серкә башлы чабата** *брб.д.* к.: **бетле башлы чабата**. Менә серкә башлы чабата туғып пирте әтәй тип, ыспайы инте, башы цимәйле, цимәйләре булған сын йецкә йүгәләрне қыстырып туғыған.

**суқма чабата** *перм.* юкә башмак (башмаки из лыка); чаг.: **хәшәп 1**. Әнә шул суқма чабатаны кийеп чық. Суқма чабата була, тузмасқа табанына тақта қуйалар.

**татар чабата** *нокр., глз.*, **татар чабатасы** *блт.* тар юкәдән кечкенә башлы итеп үрелгән чабата (лапти, сплетённые из узких лык, с маленькой головкой). Татар чабатам йанды. – *глз.*

**ташлаған чабата** *минз.* к.: **шом I**.

**туғыз җүкәле чабата** *блт.*, **уникеле чабата** *т.я.-крш.* к.: **қунақ чабатасы**. Туғыз җүкәлесе чабатаның матур була торғаныйы. Уникеле чабата йасап бирде ирем, уникe йыл чисқа ғына сарып җөргән инде аны.

**урыс чабата 1.** *нокр., глз.*, **урыс чабатасы** *блт., мам.* киң юкәдән зур башлы итеп үрелгән чабата (лапти, сплетённые из широких лык, с глубокой головкой). Урыс чабатасы икенче төрле, башы қарлығач ойасы шикелле дәү башлы, киң җүкәдән була. – *блт.* Минем әл дә урыс чабатам бар. – *нокр.*; **2.** *м.-кар.* уникe юкәдән үрелә торган зур башлы чабата (лапти с большой головкой, сплетённые из двенадцати лык). Урыс чабатасын уникедән үрәтләр.

**чабата басымы** *бәр.* **1.** чабата эзе (след лаптя); **2.** чабата эзе хәтле ара, озынлык (расстояние, длина, равная следу лаптя). Awылда бер чабата басымы да эшләмәгән кешеләр дә пинсийә ала.

**чабата бау** *перм., глз., нокр.* к.: **кәркеш 2**. Чабатаны кийенмәгә белмиләр, бawын алға бәйлиләр. – *перм.*

**чабата қайтарып җату** *минз.* тик яту, тик йөрү (ничего не делать, лодырничать). Тор, чабата қайтарып җатма, қунақлар бар, дим. Чабата қайтарып җөри шунда, кеше эшкә җөри.

**чабата мыйығы** *мам.* тузган, сүсәргән чабатаның тырпаеп торган җепселләре (растопыренные волокна у износившегося, измочалившегося лаптя). Чабатаның мыйықлары чыққан, су җырып қайтып кердек, айақлар туңып.

**чабата сару** *т.я.-крш.* кию – чабата турында (обувать – о лаптях).

**чабата тарақан** *мам.* кара таракан (чёрный таракан). Хәзер күргән дә йуг инде чабата тарақанны.

**чабата тарақаны булу** *кмшл.* артык булу, кара таракан булу (оказаться третьим лишним).

**чабата тезү** *мам., блт.* чабата ясау (плести лапти). Онотқаным тезгәнеме, чабата тездермәкче булды миннән. – *блт.*

**чабата тугу** *м.-кар.* чабата ясау (плести лапти). Чабата туғый җүкәдән.

**черек чабата** *минз.* к.: **шом I**. Одақ йатқан черек чабата белән.

**черек чабата қағылу** *минз.* бизгәк тоту (лихорадить). Ydем үскәндә бер күршем үлде, шул черек чабата қағылып. Черек чабата қагыла башлады миңа.

**чирмеш чабата** *нокр., глз.* таррак юкәдән, кечкенә башлы итеп, башының ике ягына да мөгез чыгарып үрелгән чабата (лапти, сплетённые из узких лык, с рожками); чаг.: **татар чабатасы**. Чирмеш чабата тар битле, урыс чабата кәкерерәк, уңга, сулға йасай, ә бусын кут′ қай йаққа қуй. – *глз.*

**шақмақлы чабата** *минз.*, **шакмаклы чабата**

*стрл.* күтәртмәле чабата (лапти на деревянных подставках). Йаз башында, көзән шакмаклы чабата кийәләр ийе. – *стрл.*

**эш чабатасы** 1. *блт.* җиде юкәдән үрелгән чабата (лапти, сплетённые из семи лык). Җиде җүкәдән эш чабатасы була торған ыйы; 2. *срг.* астын каеш, сүс, бау яки башка берәр әйбер белән нығыткан чабата (лапти, подошва которых подковырнута ремнём, паклей, проволокой и т.п.). Бусы эш чабатасы, төбөнә кайыш җүләгән, пралука белән.

**ЧАБАТАБАШ** *перм.* 1. маймыч (малёк); 2. күшбаш (голавль).

**ЧАБА-ЧАБА-ЧАБА** *нрл.* к.: **сай-сай**.

**ЧАБУ I** 1. *нокр., глз., тмн.* кисү (рубить). Урманга утын чапмаға йерделәр. – *нокр.* Милек чаба калхузга. – *глз.* Ике балтадан имәннәр чаптык. – *тмн.*; 2. *перм.* бурау (рубить сруб). Җал көн бура чаптырдылар. Азбарлар, мынчалар чапты. Чабып мича китереп утытып қуйды; 3. *нокр., глз.* к.: **борнау 2**. Унтугыз (йомырка) салганда иде дә, умбиш чапкан. – *глз.*

**шахты чабу** *блт.* шахтада эшләү, күмер чабу (работать в шахте). Аның ике малайы шахты чаба.

**ЧАБУ II** *минз., стрл., тпк.* йомшарту (рыхлить землю). Киндераш чаптық. – *тпк.* Чөгөндөр чабарға барабыз. – *минз.* Ике рәт чабасың әле чөгөндерне, аның эше күп. – *стрл.*

**ЧАБУ III: айада чабу** *кргл.* кәҗә мамыгын махсус тараста аялау (расчёсывание козьего пуха на специальном гребне). Күбрәк айада чапқан сайын *дебет* йылтыраучан була, күперүчән була.

**ч а б у IV** (скакать, мчаться, нестись, бежать):

**җуwa чабу** *трх.* *Җуwa* җыенында атка утырып йөрү (кататься на лошадях во время татарского народного праздника – джиена «*Җуwa*»).

**йәмшик чабу** *перм.* кучер булып йөрү (быть кучером, работать кучером). Безне эти йәмшик чапқан.

**ЧАБУ V** 1. *трх., перм., нокр., к.-уф.* к.: **чабын 1**. Уналты ат җибәрделәр чабуға. – *трх.* Чабуларны қарап қайттық. – *к.-уф.* Байның җире дә күп булды, чабуwы да күп булды. Әле мин белгәндә дә Йаңawыллар (*ав. ис.*) килеп чабуларын чабып йөриләр ийе. – *перм.*; 2. *нокр., глз.* к.: **чабын 2**. Чабуын да чаптық, урағын да урдық. – *нокр.*

**ЧАБУ VI** *лш.* сабу (приставить). Бер кийем ойоқ бирәләр ийе, балтырға баш чабар өчөн бирәләр ийе (туланы киленнәргә).

**ЧАБУ VII** *әстр.* сылау (первая обмазка).

**ЧАБУ VIII** *брб.д.* кештәк (ластовица, подмышник). Чабу йоқ, қәзер уйып тегәдек.

**қыйық йасаған чабу** *т.кам.-крш.* кыек итәк, клёш итәк (юбка с раструбом).

**чабу асты** *лмб.* итәк асты (под подолом). Чабу астында асырый үзләрен оланнарын, күздән саклый, диләр.

**ЧАБУЛАУ** 1. *мам.* к.: **абдырау 1**. Чабулыйм көтү китә дип; 2. *кргл.* чабып йөрү, анда-монда чабу (бегать туда-сюда, провести время в беготне). Күп чабуласа, Лидийәгә дә Фәтикә дибез. – *кргл.*

**чабулап җөрү** *нгб.-крш.* чабып йөрү (бегать, скакать). Кәзә қайда җөри чабулап, шунда шалтырый да төшөп қала мөгөзө.

**ЧАБЫЛДЫҚ** *дөб.* к.: **чабын 1**. Әби сөйлидер ийе, бу җирләр элек чабылдық булған дип.

**ЧАБЫЛШЫ** *блт.* к.: **пәйеж**. Ашның чабылшысы шикелле өскә чыға (вареньеның).

**ЧАБЫМ** *кргл.* бер тапкыр аяга куеп аяларлық күләмдә кәҗә мамыгы (козий пух в количестве на одну чёску). Айалаганнан соң чабым була, бер чабымны икенче чабым өстенә қуйып төйләклиләр.

**ЧАБЫН** 1. *лш., минз., стрл.* чабынлык (покос, место косьбы). Элек чабын ийе, печәнен чабалар ийе. – *стрл.*; 2. *лш., минз.* болын, печәнлек (луг). Әле чабында печән чабабыз. – *лш.* Ағиделнең буйында, Атлар җөрәй чабында (*хал. җыр.*). – *минз.*; 3. *минз.* печәне чабып алынган җир (скошенный луг).

**ЧАБЫНДЫ** 1. *мам., каз.ар.-крш.* к.: **чабын 2**. Чабынды җирдә, болоннок җирдә була дару үләне. – *мам.* Безен awылнын чабындылары күп. Чикмәнче дигән чабынды барыйы аннарысы. – *каз. ар.-крш.*; 2. *брб.д.* к.: **чабын 3**. Йалан айақ та йөрөдөк чабындыларда, тәләләр (үкчә) қанап, табан қалынайа икән.

**ЧАБЫНДЫҚ** *мам., бөре.* урман уртасында печәнлек, печән чаба торган ачык җир (поляна, открытое место в лесу, где можно косить сено); чаг.: **айаз 1**. Анда бер бәләкәй чабындық, монда бер бәләкәй чабындық, шуңа да шөкерана қылабыз. – *мам.*

**ЧАБЫР** *к.т.* Татарстанда Тау ягында бер төркем авылларның һәр елны беренче июльдән өченче июльгә кадәр үткәрелә торған бәйрәме; ярминкәсе Бәки авылы янында була торган булган (празднества, устраивавшиеся группой сёл Нагорной стороны Татарстана ежегодно с первого по третье июля. Ярмарка была на определённом месте у деревни Бекеево); чаг.: **җыйын 3**. Чабыр чағында әмме җортта қунақлар була. Чабырдан соң икатна үткәч ураққа төшәләр.

**чабырга чыгу** *т.я.-крш.* биләмгә йөрү (праздно шататься по чужим домам). Чабырга чыгып киткән, шалай үдә тормай ул Марийа.

**Чабыр таwы** *к.т. Чабыр* ярминкәсе урыны (место, где устраивалась ярмарка). Чабыр таwы изгеләре дип сүлиләр ийе.

**ЧАБЫРМА** *мам.* к.: **пәйеж**. Чабырманы таралғанчы җыйарға кирәк.

**ЧАБЫШУ** *карс.* йөгерү, чабу (бегать). Иртәрәг элгермәсә кичен чабыша тиз генә. Мин бер айагыма кийәм бат′инка, вал′ник бер айагымда, китәм чабыша. Чабыша чыктыг инде. Баллун пылашлыны күрә дә чабыша бара, баллун пылашлыны күрә дә чабыша бара.

**ЧАWАФ** [*гар.*] *сазл.* җавап (ответ).

**ЧАВКА** *кузн.* к.: **ақсырдақ**.

**ЧАWЫЛ** *перм.* 1. к.: **цawылағац**. Бик йәмне йердә чawыл арада булдыйы сабантуй; 2. кибән яки эскерт төбенә янәшә салып калдырыла торган ботаклы һәм яфраклы ике каен агачы (подмостки под стог, состоящие из пары берёз, срубленных с ветками и листьями). Қышын алып

қайтқанда шул чаwыл башыннан ғына әләктереп өстөрәтеп алып қайталар (кибәнне); **3.** сугылган ашлыкны яки ашлык өстеннән чүпләрне себереп ала торган йомшак каен себеркесе (берёзовая метла для сгребания обмолоченного зерна или сметания с груды зерна мусора); **4.** *минз., стрл.* нечкә озын киртә яки озын юан чыбык (длинный толстый прут или тонкая жердь).

**ЧАWЫЛЛЫҚ** *минз.*, **ЧАWЫЛЛЫК** *стрл.* каенлык, каен урманы (березняк, берёзовая роща).

**ЧАWЫМ** *кргл.* к.: **чабым**.

**ЧАWЫННЫҚ** *перм.* к.: **чаwыллык**. Чаwынныкта бийыл шартлама, ти, хәттин ашқан. – *перм.*

**ЧАГА I** *тмн., лмб., кузн., хвл., мәл., карс., влгг., клд.* **1.** к.: **бәкәй I**. Кәҗә чагасы каадыр йугалган. Чагасы менән үк кәзә алдым. Кечкенә генә кара куй чагасы күрмәдеңме? – *кузн.* Куй чагасы *какра*га кергән. – *тмн.* Чагалары бардыр, кәбәм, куйның. – *карс.*; **2.** эт, мәче, дуңгыз, куян кебек вак хайваннарның баласына карата әйтелә торган сүз (детёныш мелких домашних животных и зверей). Мачы чагасы. Эт чагасы. – *лмб.* Бүре чагалары тытканнар. – *тмн.*; **3.** колорадо коңгызының балалары (колорадские жучки). Иртән чыксам әмән чәчкәләр, куңгыз тагын чагаларын салып киткән. – *клд.*; **4.** кешегә кимсетеп әйтелә торган сүз (уничижительное слово по отношению к человеку). Безне керәшен чагасы дийрләр иде. – *лмб.*

**чага винеге** *стрл.*, **чага винек** *мәл.*, **чага виник** *хвл.*, **чага вин'ыгы** *стрл.* к.: **бәрән: бәрән минеге**. Чага вин'ыгы бәләргә бардык атай белә.

**чага салу** *стрл.* бал кортының күкәй салуы, ук салуы (кладка яиц – о пчеле). Бал корты чага сала. Күп чага салса кисеп тә ташлыйлар.

**чага ызбасы** *хвл.* кышын бәрәннәр тота торган өй (тёплое помещение для содержания зимой ягнят); чаг.: **алачык 1; қарий**. Касы берсендә бар иде чагалар ызбасы.

**ЧАГА II** *чст.* к.: **қайау**. Чагасын алдыңмы соң?

**ЧАҒАЙТУ** *т.я.* чак итү, таман итү (сделать так, чтобы было впору, как раз). Ашқа тозно чағайтып сал үзең. – *к.т.*

**ЧАҒАЙУ 1.** *дөб.* начарлану, бозылу, ямьсезләнү (испортиться, ухудшиться – о качестве); чаг.: **койтылану**. Мончада да салмыйм, бер чағаймый бу мәрҗән. Қартайғач кеше чағайа инде ул. Өйалдына чығарып қуйарбыз, монда торса чағайа (май); **2.** *т.я.* таман булу, чак булу (стать как раз, впору).

**ЧАГАЙУ** *мәл.* к.: **чағайу 2**. Алганда батиннарым кечкенә иде, йөри-йөри чагайдылар.

**ЧАГАК** *чст.-крш.* к.: **ақсырдақ**. Чагаклар төшкән, кычкыралар шыкы-шыкы.

**ЧАҒАҚ** *том.д.* к.: **дөңгөриш**.

**ЧАҒАЛА** *әстр.*, **ЧАГАЛА** *влгг.* к.: **ақсырдақ**.

**ЧАГАЛАУ** *миш.д.* **1.** к.: **бәкәйләү**. Кәҗә эчне дә, дүртне дә чагалый. – *карс.* Кәҗәм икене чагалады. – *мәл.* Куй чагалады да үлде, балалары калды. – *хвл.* Нигәдер бойол, вет, көтү тулган: өчәрне, икешәрне чагалаганнар. – *кузн.* Сарык икене чагалаган: берсе йарка, берсе тәкә. – *шрл.*; **2.** балалау – эт, мәче, куян, дуңгыз һ.б. турында (ощениться, окотиться, опороситься и т. д.). Идән астында мачы чагалаган. – *карс.* Бу бит андагы маччагалады. – *кузн.* Мачы чагалаган, алты чагасы бар. – *тмн.* Дуңгыз вет күп чагалый. – *клд.*; **3.** *клд.* кондызларның күкәй салуы (кладка яиц жуками). Чыгасың агарудка, кып-кызыл, әмән мәләш, шул жук чагалап киткән була; **4.** *лмб.* азу, тармаклар җибәрү (запускаться, разрастаться, разветвляться – о грыже). Гыриж чагалаган була, апиратсийа файда итмидер дә үләдер; **5.** кешегә карата кимсетеп әйтелә (рожать унизительно о женщине). Атна сайын чагалыйлар. – *кузн.*

**ЧАҒАН** *кмшл., бөре., минз., перм.* өрәңге (клён). Чағаннан чана табаны йасыйлар. Чаган имән кебек қатағач була ул. – *минз.* Чаған үсә бездә, Қазан йақлар аны өрәңге диләр икә. – *перм.*

**татар чағаны** *бгрс.* кара өрәңге (черноклён, клён татарский).

**ЧАГАНКА** *әстр.* камыш түбә (камышовая крыша).

**ЧАГАРЛАУ** *лмб., срг.* **1.** чигенү, артка тартылу (попятиться, отступать назад); чаг.: **сирелү 1**. Йитийем дигәндә, малай артка чагарлый. – *лмб.*; **2.** артка сөйрәү, артка тарту (тянуть назад). Сөт сату планын безнең awыл йылдан-йыл артка таба чагарлый. – *срг.*

**ЧАҒWAН** *твр.* к.: **мурта 2**.

**ЧАҒУ I** *бгрс., кргл.* тел тидерү, битәрләү, әрләү, кимчелек табу (упрекать, обижать словами, корить, бранить). Чақмағыз, қызыбызның пыридаңы йуқ дип. – *бгрс.* Син чағасың аларны, ди, шуңа күрә җабықлар, ди. – *кргл.*

**начағай чағу** *твр., тара.* ажаган уйнау (вспыхивать – о зарнице). Арышны йеткерә, начағай чаға тип сөйләйләр. – *твр.*

**ЧАҒУ II 1.** *мам., минз.* калку җир, калкулык (холм, возвышенная местность); чаг.: **қаш I 1**. Чағуларда үләннәр көйөп беткән инде бу эсседә. – *мам.*; **2.** *мам.* кояш нурлары туры төшкән җир, кояшка каршы як (местность, куда падают прямые лучи солнца, солнцепёк); чаг.: **айаз 2**. Бигрәк чагуға утыргансың. Чағу йақ. Бақча қойаш чағуwына қаршы булса, җиләк пешә инде. – *минз.* Эссе суқмасын, ник чағуда утырасың? – *мам.*

**чағулап қарау** *каз.ар.-крш.* кулны күз өстенә куеп (кояшка каршы) карау (смотреть, приложив руку козырьком – обычно напротив солнца). Теге кешегә қарыйм чағулап, җырақ, танымыйм.

**ЧАҒУWЫН 1.** *төм.* к.: **кормош**. Чағуwын пал йийа тыган қуй (бит); **2.** *твр., тара.* к.: **мурта 2**. Чағуwын керепте, қурқам. – *тара.*

**ЧАҒЫWАН** *твр.* к.: **кормош**. Чағыwан қырта ир (җир) астынта бал сала.

**ЧАГЫЗ** [*гар.*] *чст.* к.: **қийәғәз**. Wатмыйсың, чагызга этерәсең дә wатылмый ул (йомырка).

**ЧАҒЫЛ I** *минз.* к.: **чағу II, 1**. Күркә асыраргa җай йуқ менә бednең: таулар да, чағыл да йуқ.

**ЧАҒЫЛ II** *перм.* к.: **чиқылдаган 1**. Бик чағыл кийем кигән.

**ЧАГЫЛДЫРУ** *чст.* тешкә тию (вызывать внезапную острую боль в зубах). Карлыган тешне чагылдыра.

**ЧАҒЫЛМАҚ** *том.д.* к.: **нажағай**.

**ЧАҒЫЛУ I 1.** *трх.* бетү, булмый башлау (перестать уродиться). Бер чағылса булмый бит қаз, бер булса ғына була; **2.** *блт.* бетеренү, ябыгу (худеть, захиреть). Көрәйеп киткән ийе, әле бу арада чағылып тора.

**ЧАҒЫЛУ II** *нокр.* чәчелү, чәчрәү (разметаться, рассыпаться – об искре, огне). Awызыннан утлар чағыла инде.

**ЧАГЫЛУ** *чст.* кинәт авыртып китү – тешләр турында (почувствовать внезапную острую боль – о зубах). Канфит тешкә йарами, чагыла.

**ЧАГЫР I** *кузн.* ике яньле агачның башына үткен тимер, күбесенчә сука тимере беркетеп ясалган корал; кабер казу өчен кулланалар (орудие для копания могилы).

**ЧАГЫР II** *срг., чпр., мәл.* кылый (косой, кривой). Чагыр күз. – *чпр.* Күзләре чагыр. Чагыр бәбәкле балалар күп. – *срг.*

**ЧАГЫР III** *кузн.* к.: **чобар**.

**ЧАГЫР IV** *влгг.* шәраб (вино).

**ЧАҒЫРТ I** *брб.д.* к.: **чобар**.

**ЧАҒЫРТ II** *брб.д.* аксыл зәңгәр – күз һ.б. турында (светло-голубой – о глазах и др.). Чағырт күсле қысы бар. Чағырт шәлем бар ите.

**ЧАҒЫРУ** *брб.д.* өмә (помощь). Чағыруға кәттек қас йолқорға тип, кичен қанат, айағын тотоп киләделәр.

**ЧАҒЫТ** *твр.* төрле сулар җыелып ясалган күлчек (маленькое озеро, возникшее после дождя, накопления талых вод и т.д.).

**ЧАҒЫШУ** *дөб., мам., минз., трх., нгб.-крш.* туры килү (соответствовать, совпадать); чаг.: **кәри: кәри килү 2**. Нишләп бу җawабы белән чағышмый. – *минз.* Аның сүләwе моноқына чағышмый шул. – *трх.* Ул сүз сез әйткәнгә чағыша. Безнен мисаллар чағышамы, тикшереп қарыйқ. – *дөб.* Икесенең әйткәне чағышмағач, қайсына ышанырға да белгән җуқ. – *мам.*

**ЧАД(Ы)РЫҚ** *клм.* **1.** к.: **чардак 1**; **2.** киртә (ограда). Чадрық қуйғаннар игезенә дә.

**ЧАДРЫҚЛАУ** *клм.* чардуган кую (ставить ограду на могиле). Ағач белән чадрықлайбыс.

**ЧАЖ: чаж үләне** *минз.* к.: **чаш: чаш печәне**.

**ЧАИЛ** [*гар.*] *тара., брб.д.* ачулы, явыз (злой, злобный). Әшкәрә чаил кеше болпто. – *брб.д.*

**ч а й I** *твр., тбл., брб.д.* чәй (чай):

**чай ашау** *тбл.* чәй эчү (пить чай).

**ЧАЙ II** [*рус.*] *карс., лмб.* ахрысы, бугай, булса кирәк (должно быть, кажется, видимо). Чай, байа да үзен Пинзага итә, картук салган ике капчык. Чай, үзеңнән генә келәләр вет. – *карс.*Ниг аны йураб итәргә, чай, кетә, гарип, кен дә. – *лмб.*

**ЧАЙА** *тбл., брб.д.* усал, кире, үҗәт (злой, упрямый). Ул чайа кеше, аны ман сөйләшеп пулмайты. – *брб.д.*

**ЧАЙАН** *влгг.* кысла (рак).

**ЧАЙҒАҚ** *яүшт.* к.: **қотан 1**.

**ЧАЙҒАЛУ** *яүшт.* **1.** к.: **қупайу**; **2.** юк-барны сөйләү (болтать вздор, нести чепуху).

**ЧАЙҚАУ** *нрл.* болгау (махать – рукой). Қул чайқый-чайқый айырылыштылар. Җозороқ чайқап тора икән.

**ЧАЙПЫРЫШ** *бөре.* кыйгач (наискось, наискосок). Мәктәпкә чайпырыш қына йәшәй ул.

**ЧАЙРАП** *т.я., лш., мам.* таралып, җәелеп (раскинувшись). Саф hawада чайрап җоқлый рәхәтләнеп. – *к.т.* Чүмәлә күләгәсенә салдым да, чайрап җоқлап китте баласы. – *мам.* Чайрап, изерәп җықыға китте балам. – *дөб.*

**ЧАЙРЫ** *мам.* **1.** к.: **чайыр 2**. Нарат чайрысы; **2.** нарат бүрәнәсе (сосновое бревно). Чайрыдан бура эшләгәннәр.

**чайры ағач** *мам.* **1.** сагызлы агач (смолистое дерево); **2.** тиз кабынып китүчән, кызу – кеше турында (горячий, вспыльчивый). Чайры ағач булма инде, диләр тиз қабынып китә торган кешегә.

**ЧАЙРЫЛАНУ** *мам.* сагызлану (пропитаться смолой). Нарат чайрыланса, нық була, өй дә тиз череми.

**ЧАЙЫЛЛЫҚ** [*гар.* + *афф.* -лык] *твр.* әшәкелек (мерзость). Чайыллығын адәм әйтеп тамам қылмас.

**ЧАЙЫР 1.** *к.т., мам., лш.* агач кайрысы астында була торган куе җилем сыман матдә (клейкообразная масса под корой у деревьев). Чийә чайыры. – *к.т.* Җүкәдә дә була бит чайыр. – *мам.*; **2.** *трх., к.т., дөб., лш., мам.* сагыз (сера, смола, камедь – у хвойных деревьев). Чайырын алған нарат ағачы ул. – *трх.* Нарат чайыры. Чайырын алған нарат тиз эчери икән. – *к.т.* Нарат чайырын май белән қайнатып үзебез сағыз җасыйдырыйық. – *дөб.*; **3.** *к.т., дөб., лш.* сагыз (жевательная сера). Чат-чат чайыр чәйни. – *к.т.* Мин чайыр чәйнәргә йаратмыйдырыйым. – *дөб.*

**ЧАҚ I** *каз.ар., бәр., каз.ар.-крш., трбс.* **1.** к.: **който**. Хәзер бик җабыг инде, чақ малайы хәсерәтендән. Кийәwем ару, қызым чақ. Шулай чақ қына қарчық булсам да әйбәт малайлар үстергәнем. – *каз.ар.-крш.* Нәселләре белән чақ бит алар. – *мам.* Үз анаң бергwақытта да чақ булмый ул. – *бәр.* Хай, чақ сүз әйттеме инде? Чақнын чағы wул. Йазуwы бик чақ шул. – *дөб.* Чақ сөйләй, аңғарып булмай. – *трбс.*; **2.** кечкенә, ябык, чандыр (маленький, худой, хилый, тощий); чаг.: **йадау**. Балалары бик чақ, бик кечкенә. Бәк чақ ул, фуртычкыдан сыйа. – *мам.* Кечкенә генә, чақ қына бер қатын ул. Чақ чебеш син. – *каз.ар.-крш.*

**чақ қуллы** *дөб.* к.: **йончу III**. Бездә чақ қуллы кешеләр йуқ.

**ЧАҚ II** *минз., перм.* к.: **тике**. Дүртенче қыласқа чақ монда бар. – *перм.* Ашқа чақ чәй китердем, син чәй әчәсе килде дигәч. – *минз.*

**ЧАҚ III** *перм.*, **ЧАК** *влгг.* **1.** нәкъ (ровно, точь-в-точь). Без чақ беркөннө утыртқан идек аның белән; **2.** *перм.* әле генә (только что). Без чаг ашадық әле. Әйдән, утырың, эчең йасап-йасап, без чағ эчкән ийег әле.

**ЧАҚ IV** *брб.д.* имән бармак (указательный палец).

**ЧАКА** [*рус.* чека] **1.** *тмн., кузн., карс., стрл., әстр.* тәгәрмәч төшмәсен өчен арба күчәренә куела торган чәй (чекушка у телеги). Чакалары төшөп калган да күләсәләре изелгән. – *стрл.* Тәгәрмәч чыкмас өчөн кигертә чақа. – *әстр.*;

**2.** *мәл.* к.: **чашка II**. Чака белә куйдым самаwырны.

**ЧАҠАЛ** *әстр.* камыш чыпта (рогожа из камышей).

**ЧАҠАН** *төр.* тиз, тиз-тиз (быстро, быстро-быстро). Чақан тарата өләшне. Чақан саwаты сийрны.

**ЧАКАН'А** *м.-кар.* чөгендер яфрагыннан әзерләнгән ашамлык (еда, приготовленная из листьев свёклы). Чөгендер җапрагын пешерәтләр, кысыб алатлар, тевә дә жарит итә, чакан'а дитләр.

**ЧАҠҚЫЧ** *нокр.* бөгәлчән (слепень).

**ЧАККЫЧ** *хвл.* к.: **қайау**.

**ЧАҠЛАНУ** *лш.* начарлану (стать плохим). Күзе чақланды, сиксәндәге кеше бит инде.

**ЧАҠЛАУ** *т.я., т.я.-крш., төм., том.д.*, **ЧАКЛАУ** *чст., влгг., мәл.* чамалау, кирәгенчә итү, ярарлык итеп, чамасын белеп эшләү (соразмерять, сделать что-либо в меру, в пределах нормы). Ашқа суны чақлап сал. Баланы қойондырырға су чақлап бир әле: қайнар да, салқынрақ та булмасын. – *к.т.* Сиңа чақлап пешердек җымырқаны. – *т.я.-крш.* Тозны чаклап үзең саласын. – *влгг.* Суны чақлап торучыларға ситсы бирәсең. – *төм.*

**ЧАҠЛЫ** *к.т., трх., мам.*, **ЧАКЛЫ** *чст.* **1.** чамалы, уртача, бик үк әйбәт түгел (неважно, посредственно). У чағында тормош чақлы ғына бара торған, өч тәңкәлек күлмәк өстөндә. – *к.т.* Тазалыгым чақлы. – *мам.*; **2.** чак, ярарлык, әйбәт (в меру, как раз, в самый раз). Ашның тозо чақлымы? – *к.т.* Су чаклы ғына, зур су тегел инде. – *чст.*

**ЧАҠЛЫҚ** *дөб., бәр.* начарлык (дрянь; всё плохое, отрицательное); чаг.: **кәйлек**. Иркәлек, чақлық белән бозолған алар. – *дөб.*

**ЧАКМА** *хвл., мәл., кузн., влгг.* келә (щеколда). Ишекнең чакмасын тешер. – *хвл.* Теннә шылай ишекнең чакмасына бәрә. – *кузн.* Ишекнең чакмасы йаман. – *влгг.*

**ЧАКМАЛЫ: чакмалы йул** *срг.* иген басуы арасындагы юл (тропинка, дорога в хлебном поле).

**ЧАКУ** [*рус.* чека] **1.** *тмн.* эшермә, эшермә бик (задвижка). Кийәү келәтенә кергәндә Келәт чакуwысын элмәде (*бор. жыр.*); **2.** *мәл.* к.: **чака 1**. Күләсәсенең чакуwымы тешкән.

**ЧАКУЛ** [*рус.* щеколда] *кузн.* к.: **чакма**.

**ЧАКУШ** *чст.*, **ЧАКУШКА** [*рус.* чекушка] *хвл., чпр., мәл.* к.: **чака 1**. – Кузничкә барыпсынмы? – Чакушка йасаткы келим. – *мәл.*

**ЧАКЧУР** *хвл., карс., влгг., клд., мәл.* кәвеш (кожаные башмаки). Чакчур иде, пырастуй кужыдан, чабата башмакка ышаганырак. – *клд.* Безнең анайнын чакчуры булган. – *хвл.*

**ЧАҚЫ I** *әстр.* камыш сабагы (стебель камыша).

**ЧАҚЫ II** *минз.* чаклы, хәтле (до). Моноң чақы, моноң чақы бәрәңгеләр чыға.

**ЧАҚЫН** *әстр.*, **ЧАКЫН** *влгг.* камыш.

**ЧАҚЫРАТУ** *әстр.* ярәшелгән кызны кунакка чакырып сөйләшү (поговорить со сговорённой девушкой, пригласив её в гости к родственникам жениха).

**ЧАҚЫРАУ: чақырауға бару** *минз., трбс.* кызның ир туганы кияү ягына туй вакытын хәбәр итәргә бару йоласы (обычай, согласно которому один из родственников невесты едет к жениху сообщить о сроке свадьбы). Минем қарт чақырауға күп йөрөде. – *минз.*

**ЧАҚЫРТУ** *яүшт.* кунак чакыру (приглашать в гости).

**чақыртуға йөрү** *яүшт.* кунакка йөрү (ходить в гости, ходить на званые обеды).

**ЧАҚЫРУ 1.** *минз.* кыз ягыннан кияү ягына туйга чакырып баручы кеше (мужчина, обычно родственник невесты, едущий к жениху сообщить о сроке свадьбы); чаг.: **чақырау: чақырауға бару**. Чақыру булып та үзем бардым мин йәтим қатын былғач; **2.** *төр., брб.д.* аш, аш мәҗлесе (званый обед). Чақыруға алып парырым. – *брб.д.*; **3.** *брб.д.* ашка җыю (устраивать званый обед). Ынугына ике йәш толды, чақырып чай эчерделәр; **4.** *перм., нокр., глз.* кычкыру (петь – о птицах). Әтәч чақырғанчи тора, үкәртәдә бернимә қалмый, ботуғысын эшләп бетә. Чақырма кәкүк қаршымда, Чақыр ағач башында (*хал. жыр.*). – *перм.*

**чақыруға бару 1.** *минз.* к.: **чақырау: чақырауға бару**; **2.** *брб.д., төр.* ашка бару (идти на званый обед).

**ЧАҚЫРУ 1.** *стрл.* к.: **чақыру 1**. Чакыру җибәргән былалар қыз йагыннан, ни көнне туйга барырга тәгайеннәп; **2.** *глз.* к.: **чақыру 4**. Әтәс чакыра.

**ЧАЛ I** *перм.* **1.** күк, коба, җирән һ.б. төсләр катнашмасындагы ак йон (белая шерсть с примесью серой, рыжей или какой-либо другой; чалый). Чал ат; **2.** к.: **чобар**. Чалы була кийез итекнең, ақ белә қараны қушқаны.

**чал чығу** *нокр.* агару (седеть). Чәченә чал чыққан.

**ЧАЛ II** *брб.д.* терлекнең корсак асты өлеше (брюшина). Қазылыкны қорсақ чалыннан эшлиләр.

**ЧАЛА 1.** *төр., том.д.* аз гына, чак кына (едва, чуть-чуть). Аны мин чала күреп қалған. – *төр.* Өн салып йылады, чала шатлансын, чала қowонсон тәп. – *клм.*; **2.** *яүшт.* начар (плохо). Түбәсен чаларақ йапқансың, рәтләбрәк йапсаң, су үтмәс иде.

**ЧАЛА-БОЛА** *төр.* зәгыйфь, булыр-булмас (изувеченный, хилый, с недостатком). Қәйнәм чала-бола кеше иде.

**ЧАЛАЙ 1.** *м.-кар.* к.: **чал I, 1**; **2.** *тмн., лмб., кузн.* чал – чәч турында (седой). Чәче чалай инде, карт. – *лмб.* Чәчең чалай синеке, биг ак синеке чәчең. – *кузн.*

**ЧАЛАҚ** *брб.д.* бот, юан бот (бедро, ляжка). Чалағы аураб утырады.

**ЧАЛА-МОЛА** *яүшт.* аннан-моннан, эштер-өштер (тяп-ляп, кое-как). Чала-мола йапқансың шул сарай түбәсен.

**ЧАЛА-ЧОЛА** *брб.д.* **1.** аз гына (еле-еле, чуть-чуть). Чала-чола пер көрдем; **2.** барлы-юклы, азмаз гына (очень плохой, совершенно недостаточный, неполноценный). Чала-чола ашасақ та, «третий лишний»не уйнайбыс.

**ЧАЛҒАЙ** *клм.* к.: **кесеркән**. Чалғайға тотонмаң, чаға ғуй.

**ЧАЛҒАЙУ** *яүшт.* лыгырдау (болтать, трепать языком).

**ЧАЛҒАН** *твр.* к.: **селәй II, 1.**

**чалғы** (коса):

**гурбуша чалғы** *перм.* кыска, кәкре чалгы (короткая кривая коса).

**қадақ чалгы** *глз.* гадәти чалгы (коса обычная). Гурбушкалар белән чаба идек бүгелеп, ирләр айақтан қадақ чалғы белән чабалар иде.

**чалгы алға китү** *дөб.* таррак алып, азрак кизәнеп чабу (косить с меньшим размахом). Чалғы алға китсә, пакусны кечкенә ала.

**чалғы җану** *дөб.* янау, җиңелчә генә кайрап алу (править, точить косу). Җануч қалағынны бир әле, чалғыны җанып алыйм.

**чалгы қулы** *мам., лш., дөб.* к.: **бөгәлҗә I, 2.** Чалғының қулы бушады да, Шәрипҗан абзый йанына киттем, шуны нығытып бир әле дип. – *мам.* Чалғы қулы қақшаған, шуны бәйлим. – *дөб.*

**чалғы қырғыч** *дөб., лш.* к.: **йанүwыц.** Чалғы қырғычым өйдә қалған, биреп тор әле. – *лш.*

**чалгы оноғо** *дөб.* к.: **дүмгәләк 1.**

**чалгы суғу** *кузн., хвл.* чалгы таптау (отбивать косу). Чалгы суга, печән чаба. – *кузн.*

**ЧАЛҒЫЙ** *минз.* каз канаты, коелган каз йоны (перо – у птиц). Җийын җитә, чалғый җийабыз, ди торғаннар ийе, аны сыдырып саталар ийе.

**ЧАЛГЫР** *хвл.* к.: **чагыр I.** Ике айырлы агачның бер башына шашник куйалар – чалгыр ул була.

**ЧАЛҚА** *бәр.* к.: **чалқай I.** Башларын чалқа китә торған бийек җортлар бар.

**ЧАЛКА** *чст.* аксыл күк (светло-синий; сивочалый). Чалка ат.

**ЧАЛҚАЙ I** *дөб., блт., лш., перм.* чалкан (навзничь, на спину). Итәгеңне җыйып тормасаң, хәзер чалқай төшөрәләр. – *блт.* Җегермике көн чалқай йаттым. – *лш.* Чалқай җатқан да үлгән, ди. – *дөб.* Чалқай йатқан. – *перм.*

**ЧАЛҚАЙ II** *клм.* к.: **кесеркән.** Билгә чақтырайты чалқай белән.

**ЧАЛКУДРӘ** *стрл.* к.: **чалқай I.**

**ЧАЛҚУЛЫҚ** *мам., минз.*, **ЧАЛҚЫЙ** *минз.* к.: **чағу II, 1.** Чалқулықта тора бит ул Арча. – *мам.* Чалқый җир. Чалқый җирдә үлән үсми. – *минз.*

**ЧАЛЛАНУ** *блт.* чарлану, усаллану (стать бойким, опытным, бывалым; злым). Чалланып беткән халық монда, усал.

**чалма I** (мужской головной убор – у мусульман):

**чалма җаулығы** *лш.* чалма төрә торган чүпрәк, яулык (кусок материи или платочек для завёртывания чалмы). Чалма җаулығы, диләр, эшләгән, аны икене җибәрә.

**чалма чалу** *хвл.* килеп туктаган пароходны пристаньга бәйләп кую (чалить, прикреплять чалкой).

**ЧАЛМА II** *бәр.* катыкка салып ашала торган төрле үлән яки яшелчә (приправы – обычно лук, щавель и т.п., употребляемые для заправки катыка). Чалма туғып ашыйсын, әйбер салып, ат қузғалағы турап ашыйдырыйық, қайсы кеше суған туғып ашый йә соло оно туғып ашыйлар. Сыйыр сөтөн қайнатып, қатығ итеп ойотасын, шуны ашыйсын, чалма туғып ашыйсын инде әйбер салып.

**ЧАЛМА III** *т.кам.-крш.* чалыштырылган атлама (скрещённый хлястик у передника). Алҗапқычының түше бар, арт җағында чалмасы тора.

**чалма салу** *т.кам.-крш.* атламаны чалыштырып тегү (шить со скрещённым хлястиком).

**ЧАЛМА IV: чалма геле** *кузн.* яран гөле (герань).

**ЧАЛМАБАШ** *байк.* акчәчәк, ромашка (ромашка пахучая).

**ЧАЛМАЛЫ** *т.кам.-крш.* чалыштырылган атламалы (со скрещённым хлястиком). Чалмалы алҗапқычны да музейга биреп қалдырдым. Алҗапмасы бар чалмалы.

**ЧАЛМАП: чалмап куйу** *чст.-крш.* чәнчеп кую (сделать один стежок). Бер-ике мәртәбә чалмап куйасың, изүwең ачыграк булса.

**ЧАЛНИК** [*рус.* чайник] *шрл.* к.: **гал′ник.**

**ЧАЛПАЙУ** *трх.* чалышаю (перекоситься); чаг.: **awышайу.** Арбаның көпшәге чалпайған.

**ЧАЛПУ: чалпу салу** *дөб.* иске ырым: егылган урынны ырымлау, дога язып күмү (старинный обряд: заговаривать то место, где человек упал и ушибся). Чалпу салырға кирәк җығылған урынға.

**ЧАЛПЫ** *дөб.* зәхмәт (болезнь, хворь).

**чалпы булған 1.** *мам.* арпа чыккан кешене ырымнаганда әйтелә торган сүз (слово, произносимое во время заговаривания человека, страдающего от ячменя). Күрше әби килеп керде дә, бу кешегә чалпы булған дип, йаңағыма суғып та җибәрде, арпа чыққан күземнән утлар күренде; **2.** *дөб. чалпы салу* ырымында языла торган сүз (слово, которое пишется в заговорном письме во время заговаривания больного места человека). Ни булған, чалпы булған, кемне имнисең, Факийаға чалпы булған, шуны имним, бер-берлексез булсын, ике, өч – очсон китсен, дүрт, биш – бизсен китсен, алты, җиде – җилгә-қузга, туғыз – туфыраққа, ун – берлексез булсын тфу, тфу, минем телем түгел, Әйшә Патман теле.

**чалпы салу** *дөб., лш.*, **чалпы тәгәрәтү** *дөб.* иске ырым: зәхмәт кагылган кешене яки кешенең берәр авырткан урынын ырымлап, шул ырым язылган язуны җиргә күмү (старинный обряд: заговаривать больное место или орган человека, подвергнувшегося заболеваниям, путём захоронения на определённом месте заговорного письма).

**ЧАЛТ** *перм.* к.: **нажагай.** Чалт уйный.

**чалт итеп** *мам.* махсус, аермачык, ачык итеп, ныгытып (чётко, точно, особо, чётко и ясно). Аны чалт иттереп сорашқаным булмады.

**ЧАЛТАБАН: чалтабан 'илми'и** *кас.* бик ныкачулану, ачуланып кычкырыну, чыгырдан чыгу (сильно раскричаться, выйти из себя); чаг.: **чаугу 2**; 'ер'ин ди, 'урлаша, гәреп, чалтабан 'илде.

**ЧАЛТО** *яүшт.* к.: **йүгә: йүгә бете.**

**ЧАЛУ I 1.** *миш.д., т.я., лш., әстр.* к.: **чабын 2.** Бу йер чалу иде, хазер аны сукалыйлар. – *тмн.* Wата биредә чалуда гына эшли. – *карс.* Мында чалу, кетү йебәрмиләр. – *м.-кар.* Ақлар тауда, без аста чалуда. – *нрл.* Қойаш байышына насып қазыған, чалуны бозоп. – *трх.* Әничләр чалуда үсәләр ийе. – *лш.* Чалуларны тутырды, су арта тора. –

*әстр.*; **2.** *к.т.* топонимик атамалар составында (в составе топонимических названий). Халиқ чалуында печән чаптық. Қәнә баба чалуы; **3.** *кузн., чпр.* печән чабу (сенокос, косьба). Кай тешкә чалуга йерисез? Чалулар беткәч барабыз. – *кузн.* Җиде-сигез җәшендә чагында чалуга чыгалар ыйы. – *чпр.*

**чалу чалу** *тмн., кузн.* печән чабу (косить сено). Чалу чалу айы хазер, ийүл. – *тмн.*

**ЧАЛУ II 1.** *кмшл.* ботаклы-тармаклы агачтан ясала торган ишегалды себеркесе (особая метла, сделанная из ветвистого дерева); чаг.: **чawыл 3.** Чалу себеркегә караганда күбрәк урын алып себерә, сабы да үзеннән, ызын, бытақлы ағач. Мәйтәм, чалу йасар ийең, алай иткәнче дим; **2.** *кргл.* ишегалды себеркесе (метла). Ишегалды себерегә чалуwығызны бирең тороғыз әле.

**чалу ағачы** *дөб.* сугылган ашлык арасындагы эре чүпләрне себерү өчен ясалган тармаклы агач (тонкое, развилистое на одном конце дерево для очистки зерна от мякины и колосьев при молотьбе); чаг.: **чawыл 3.** Әwәл чалу ағачы булыр ыйы, хәзер себерке белән дә чалалар инде.

**ЧАЛУ III** *мам., дөб., лш., минз.* ашлык сукканда яки җилгәргәндә сугылган ашлык өстенә төшкән башакларны һәм очыкларны себереп тору (во время молотьбы очищать зерно метлой от мякины и колосьев). Син, Асма түти, син чалып торосоң. – *мам.* Себерке белән кибәк-сабакны чалып торалар, чалып торорга бик оста кеше кирәк. – *дөб.*

**башақ чалу** *мам.* к.: **чалу III.**

**чалу себеркесе** *мам.* к.: **чалыр.** Ындырға чалу себеркеләре әзерләргә кирәк. – *мам.* Қулбашлары қалмыйдырыйы, көнә буйы чалу себеркесе белән чалып тороп. – *лш.*

**ЧАЛУ IV** *твр.* әйләнеп карап йөрү (кружить, высматривать). Алар чалып йүрдүләр, ойда ой кийеген атады, қырда қыр кийеген атады.

**чалып алу** *мам., минз.* тирәсен тотып алу (окружить, огородить); чаг.: **қоршау 1.** Басуны өчкә чалып алғаннар, болон қапқасы барыйы, басу қапқасы әллә ничә. – *мам.* Теләсә, һәркем үd тирәсен чалыб ала рәшәткә белән. Йәшелчә бакчасы әнә анда қойма белән чалыб алған. – *минз.*

**ЧАЛУ V 1.** *мам., лш., т.кам.-крш.* җептән бау үрү ысулы (способ плетения шнура из ниток). Ыштан бawын чалалар ийе җептән, чаршау бawын да чаладыр ыйық. Чала белмәгән кешеләр үрәләр, үргән матур булмый ул. Өчтән дә чалалар ийе, җомро була ул, биштән чалғаны шақмақлы матур була. – *лш.* Ыштан баулы булған, ул бауны җептән чалалар ийе, чалған барыбер суққан шикелле тора ул, берәр кеше қағып тора, берәү биш бармаққа элеп чала инде, тулкы дөрес қағарға кирәк, ул бик матур, җомро тора, әни чаладырыйы, балалар қағып торадырыйы. – *т.кам.-крш.*; **2.** *твр.* урау (наматывать). Ичәгәсен биленә чалгалы итте, андан соң агачқа чалды.

**ЧАЛУ VI 1.** *к.т.* кушу, катыштыру, салып болгату (смешать, приправлять, прибавить к еде чего-либо). Эшчигә дә әз генә он да чалдым, сыйық булмасын дип; **2.** *твр.* изү, туглау (мешать, замешивать, взбивать). Қоймақ чаламын ағач шабала ман (калак белән); **3.** *твр.* ишү – ишкәк белән (грести веслом).

**ЧАЛУ VII** *тмн.* буу, бугазлау (задушить, убить). Бүре чалган куйны.

**чалма сөйәге, чалым сөйәге** *нрл.*, **чалыр сөйәге** *минз., стрл.* чалу сөяге (шейный позвонок животного в том месте, где режут).

**ЧАЛУЛАУ I** *лш., бгрс.* салулау (раскатываться, съезжать на ухабах зимней дороги). Чалулый машина. – *бгрс.* Чишмә таwын төшкәндә атым чалулады. – *лш.*

**ЧАЛУЛАУ II** *бәр.* к.: **чалу III.** Башақлары төшә икән, чалулап алырлар ыйы.

**ЧАЛУЧЫ** *тмн.* печәнче, печән чабучы (косарь). Чалучылар килер йаңгыр булгач.

**ЧАЛЧА** *том.д.* к.: **йүгә: йүгә бете.**

**ЧАЛЧОҚ** *яүшт.* элмәк (крючок).

**ЧАЛЧЫҚ** *кмшл.* туш (вода, выступающая на льду рек и озёр). Чалчық су.

**ЧАЛЫЙ-ЧОЛЫЙ** *минз.* чалыш-чолыш (перекошенный, искривлённый, кривой). Муқшылар чабатаның киндерәсен тезгә тикле урыйлар чалый-чолый, чалый-чолый, шақмақлы-шақмақлы булып тора.

**ЧАЛЫҚ** *твр.* қызу, елдам – ат турында (быстрый, резвый – о коне). Чалық ат. Аттан чалықмын.

**ЧАЛЫМ** *т. я., мам., лш., кмшл.* уртак билгеләр, охшашлык (черты сходства, похожесть). Әтисенең чалымы бар бу қызда. – *к.т.* Чалымы белән генә, охшатып қына таныдым тәтәне, шулхәтле қартайған, бетеренгән. – *мам.* Йуқ, йуқ, инәсенең чалымы да йуқ. – *кмшл.*

**чалымға килмәгән** *кмшл., кргл., бгрс.* гадәттәгечә булмаган, гадәттәгегә охшамаган (необычный – о поступке). Чалымға килмәгәнне эшләмәсәң йарамас ийе. – *кмшл.*

**чалымға китерү** *минз.* күз алдына китерү (представить, вообразить). Хәзер чалымға да китермиләр бороңғы тормошны, бәбекәйем, сүләмә дип кенә торалар.

**ЧАЛЫМЛАШУ** *бгрс.* ызгышу (ссориться). Чалымлашалар бит ирле-хатынны.

**ЧАЛЫМНАУ** *т.я., каз.ар.* охшату, төсмерләү (узнавать по общим чертам сходства). Хәзерге йәшләрне биг үк танымыйм да, шул атасына қарап чалымнасаң ғына. – *к.т.* Шулай да атаналарына чалымнап танып була әле йәшләрне. – *мам.*

**ЧАЛЫМСЫТУ** *лш.* аз ғына төсмерләү, берәр кешегә аз ғына охшату (находить некоторые общие черты с кем-то).

**ЧАЛЫНУ** *карс.* суелу, үзен-үзе сую (зарезаться). Зелхабирәне дә атасы пупка иткән, кайсы чалыныб үлгән (*бор. риваять.*).

**ЧАЛЫР** *минз., мәл., стрл.* сугылган ашлык өстендәге башакларны себерә торган йомшак һәм озын итеп эшләнгән махсус себерке (специально приготовленная, мягкая и длинная метла для очистки зерна от мякины и колосьев при молотьбе). Чалыр белә башакларын тиберә идек тә... – *мәл.* Ансы аның чалыр бит, болай-болай итеп ашлык чалырлыйсың. – *стрл.*

**чалыр себеркесе** *минз.* к.: **чалыр.**

**ЧАЛЫРЛАУ** *трх., стрл.* к.: **чалу III**. – Ашлык чалырлый торганын себерке диләрме? – Түгел, ансы аның чалыр, ашлык чалырлый торган. – *стрл.*

**ЧАЛЫШЛЫҚ** *минз.* кирелек, үҗәтлек (упрямство). Һаман чалышлыгын итә.

**ЧАМА** *кузн.* к.: **пыды**.

**ЧАМАЛЫ** *минз., стрл., хвл.* аз, чикле, сирәк (ограниченно, мало, редко). Хәзер чамалы инде ул тәгәрмәчләр. Сәләмәтлеге чамалы. – *минз.* Карагат бийел чамалы. Элек үлән күб ийе, хәзер генә бит ул чамалы. – *стрл.* Килгән кеше бездә бик чамалы. – *хвл.*

**ЧАМАН** *т.я., нокр., глз., чст.* ялкау, үшән атка карата әйтелә (ленивый – о лошади); чаг.: **найан; суйлақ**. Тайның нинди ат буласын – тирақмы, чаманмы – тойағына басып қараб уқ белгәннәр. – *к.т.* Чаман атлар ақырын йөри. Чаман булса да атны үрәтмә була. – *нокр.* Чаман ат – йалкау ат, бармый ул, тыннашмый. – *глз.*

**ЧАМБАР** *яүшт., клм.* чалбар (брюки).

**ЧАМБЫР** *мәл., хвл., кузн., чст.* чабыр үләне (богородская травка).

**ЧАМЛАНУ** *твр.* гарьләнү (оскорбляться, оскорбиться).

**ЧАМНАНУ** *твр.* азу (запускаться, быть запущенным). Қарамықтан (чәчәк кутырыннан) чамнанса шатыра булады.

**ЧАН** [*гар.*] *себ.* җан (душа).

**рух чаны** *твр.* җан (душа). Рух чанын пәйшәмбе көнөн өйгә гилеп йөри титләр.

**ч а н а** (сани):

**бака чана** *шрл.* печән ташу өчен көйләнгән киң чана (сани широкие, приспособленные для перевозки сена).

**бала чана** *перм., к.-уф.* к.: **сәләскә**.

**қанатлы чана** *минз., бгрс.* үрәчәле чана (сани с отводами).

**каплы чана** *чст.*, **катлы чана** *т.я.-крш.* артлы чана (кошёвка). Катлы чанага утырып баралар энде туйга. – *т.я.-крш.*

**кермәле чана** *нрл., трх.*, **көрмәле чана** *т.я.* к.: **каплы чана**. Кермәле чаналар җигеп қаз җуwарға барабыз. – *трх.* Кермәле чана белән баралар қыз алырга. Кермәле чана белән йөрделәр қыш буйына. – *нрл.*

**крисалы чана** *дөб.* киң кырыйлы печән чанасы (сани с широкими развозами для перевозки сена).

**крыйслалы чана** *минз.* к.: **каплы чана**.

**кузырлы** [*рус.* козырь + *афф.* -лы] **чана** *карс.* җиңел чананың бер төре (один из видов лёгких санок, маленькие одиночные санки с крутыми полозьями, козырёчки).

**ләҗүнкә чана** [*рус.* лежанка] *перм.* к.: **қанатлы чана**.

**сондоқ чанасы** *перм.* кызны кияү йортына озатканда сандык h.б. әйберләрен куеп бара торган чана (повозка-сани, на которой везут вещи невесты в дом жениха).

**терәкле чана** *мам.* к.: **каплы чана**. Терәкле чаналарыбыз бар ыйы, қараға буйатқан.

**тирәчи чана** *чст.*, **тирәчле чана** *минз.* к.: **қанатлы чана**.

**түрәле чана** *мам.* к.: **каплы чана**.

**утын чана** *бөре.* утын ташый торган үрәчәсез чана (сани-дровни).

**хутлы чана** *минз.* к.: **каплы чана**. Җәй көнө трантаста, қыш көнө хутлы чанада йөрөр ийе.

**чана айағы** *тара.* чана табанына беркетелгән тешләр (зубья, прикреплённые к полозьям саней).

**чана бала** *перм.* к.: **сәләскә**.

**чана бетү** *перм.* чана юлы бетү (весеннее бездорожье). Йазғыда чана бетү белән башқа чығардық малайны.

**чегән чанасы** *дөб.* к.: **йара II: йара йапрақ**.

**чыпта чана** *бөре.*, **чыпталы чана** *дөб., бәр., кмшл.* к.: **каплы чана**. Қодалар апқайтырга булғач, чыпталы чана җигәрсен. – *дөб.*

**ЧАНАҒАЧ** *брб.д.* кечкенә чана (маленькие сани). Чанағач пелән оутынны сүрәп қайтадыған.

**ЧАНАҚ** *брб.д., том.д.* чана (сани). Чанақ белә йөргән, йақшы қунаққа йөргәне кошопкада туйларға. Чанақ мынан ötын ташқан. – *брб.д.*

**бәләкәй чанақ, қычу чанақ** *клм.* к.: **сәләскә**. Қыш wақытны қычу чанақ белә китеп қала иде отонға.

**ЧАНАРЫШ** *лмб.* чана тәртәсе, тәртә (оглобли саней).

**ЧАНАСКА** [*рус.*] *кузн.* чана (сани). Чанаска белән орлок таши идек.

**ЧАНАТЕРӘК** *перм.* чананың арты (спинка кошёвки).

**ЧАНДЫР 1.** *минз., перм., стрл.* хайван тиресенең бот төпләрендә йон үсми торган ялангач җире (голые, непокрытые шерстью места на шкуре животных у основании их ног с внутренней стороны); **2.** *клд.* хайванның тез тирәсендәге итсез, сөякле җире (голень – у животных); **3.** *минз., стрл.* бот төбенең эчке ягы (внутренняя сторона основания ног скота). Малның чандыры була, йамбашының йомшақ җире, чандыр, диләр. – *минз.* Чандыр майын карале, симерә микән? – *стрл.*; **4.** *лмб.* ит ярысы, иттә була торган яры (плёнка на мясе); **5.** *тмн., баст.* сеңгер (сухожилие). Арық иттә чандыр гына була. – *баст.*; **6.** *тмн., баст.* ябык, ярылы ит (худое мясо, мясо с сухожилиями). Йымшаклардан тутырсаң, казы йымшак чыга, чандырыннан – каты була. – *тмн.* Чандырларны қазыға қуймыйлар, җымшақ ит кенә қуйалар. – *баст.*

**чандыр сүwәк** *перм.* оча сөяге (тазовая кость).

**ЧАНДЫРЛЫ** *тмн.* ярылы, сеңгерле – ит турында (с плёнкой, с сухожилиями – о мясе). Син чандырлысын алган, әтәм, аны чәнәп булмый.

**ЧАҢ: чаң күтәрә** *м.-кар.* к.: **киралкан**. Ул, вед′, чаң күтәрә җыгылды.

**ч а ң ғ ы** *урт.д.* чаңгы (лыжи):

**қама чаңғы** *бөре.* тауга менгәндә киргә таба шумасын өчен астына мех тоткан чаңгы (лыжи, обитые шкуркой).

**ЧАҢҒЫЛДАУ** *карс.* чыңнау, шалтырау (издавать звон, греметь, звякать). Калай кашык чаңгылдый, йаратмийым.

**ЧАҢҒЫРАWЫҚ** *трх.* калай кыңгырау (жестяной колокольчик); чаг.: **бутал**. Атларга чаңғырawықлар тағып киләләр ийе.

**ЧАҢҒЫРДАУ** *трх.* яңгырау (звучать, звенеть, раздаваться – о звуке). Йегетләр килсен дип чаңғырдатып суға идек киндер туқмақлағанда.

**ЧАҢҒЫТУ** *перм.* **1.** чаң кагу, чыңнату (звонить, издавать звон). Пажар чыгып киттисә, тимер әләләр дә шуны сугып чаңғыталар; **2.** к.: **чапқыту**. Чаңғытмасын йанақ төбөңә.

**ЧАПАҚ 1.** *кргл., бгрс.* сәләтле, оста, зирәк (смышлёный, способный); чаг.: **қырқындық; матай II; салиталы**. Уқырға бик чапақ идем. – *кргл.*; **2.** *минз., кргл., бгрс.* оста – телгә оста (мастер на язык, хорошо подвешенный язык). Мәхмүт абзый телгә бик чапақ кеше. Аларның телләре сезгә тартым, бик чапақ. – *минз.* Безең алай грамытный, чапақ силәүче йуқ урысча. – *кргл.* Шулай сүзгә чапақ булмағач, минекен алмыйсың, ди. – *бгрс.*

**ЧАПАҚ** *стрл.* к.: **чапақ 2**. Сүзгә бик чапаг алар.

**ЧАПАЛАҚ** *каз.ар.* резинка яки каеш кисәген таяк башына беркетеп ясалган чебен үтергеч (мухобойка). Чапалагым бар чебен үтерергә, берәү өйдә, берәү тышта. – *дөб.* Бабай, мин әйтәм, чапалақ җасап бир әле, чебеннәр күбәйде. – *мам.*

**ЧАПАЛАНУ** *минз.* **1.** бәргәләнү, селкенү (метаться, биться, трястись). Әдрәк җатқач чапалана башлады. Алты йыл бума белән бувылып чирләде: гыр-ғыр чапаланып йата да тынып қала; **2.** борчылу, тынычсызлану (беспокоиться, психовать); чаг.: **борсалану**. Илла сабырлығым инде, бер чапаланмадым. Чапаланмыйм мин, тыныч, ачувым килмий, кеше жу итеп күтәрелеп китә бит.

**ЧАПАН** *лмб., т.я.-крш.* туладан теккән чикмән (зипун). Тулактан чапан кигән, озон итәкле, эче йук. – *т.я.-крш.*

**ЧАПАП** *лмб.* чәбәкләп (хлопая). Кан'ана туйда, итәкләрен җийып, чапап-чапап бии, күрсәтәләр: килен кизе ыштан бирде.

**ЧАПАУ 1.** *карс.* басу, төшерү – бизәк турында (печатать, тиснуть). Чапаган чәчәкле чаршау. Такыйа була, аның маңгайында шулай мәрҗән чапаган була иде; **2.** *хвл.* бәләк белән суккалау, бәләкләү (колотить вальком). Керләрне чапый-чапый чәйкәдем.

**ЧАПАЧАК** *тмн.* тип-тигез, бертигез (ровно). Кемнәргә бирешәбез падарка, кодалар, кодачалар, алар уникe кеше, бездән дә уникe булдык, самый гына, чапачак эшләдек.

**ЧАПКАЙ: чапкай итү** *хвл., кузн., карс., мәл.* к.: **чәбекәй: чәбекәй итү**. Чапкай итеп бииләр. Чапкай итәләр хуп-хуп. – *карс.* Йырлагач үзенә бик каты чапкай иттеләр. – *мәл.*

**ЧАПҚАЛАҚ** *глз.* чалгы таптый торган махсус чүкеч (специальный молоток для отбивания косы). Чапқалақ белән үткенәйтәләр чалғыны, суғучысы була иде усубый.

**ЧАПҚЫ I** *каз.ар.-крш.* бот төбенә чыга торган каты шеш (твёрдое уплотнение в промежности); чаг.: **қайрақ**. Чапқы буған, чапқы имним, диләр, бот төбөндә була.

**ЧАПҚЫ II** *перм.* чабып җибәрү, яңакка сугу (пощёчина). Тагы чапқы кәрәкме? Йырақ төгөл, хәзер қундырыб алам мин арқырайып торсаң.

**чапқы туп** *перм.* туп (мяч); чаг.: **чүкәтә; чүке**.

**ЧАПҚЫ III: ит чапқы** *нокр.* ит чаба, яшелчә һ.б. турый торган кечкенә тагарак (маленький желобок для рубки мяса, капусты и т.п.). Ит чапқы була қайындан, таслайлар аны, қайын агачыннан да чабалар.

**ЧАПҚЫЙ** *т.кам.-крш.* күзнең кызарып торуы (появление красноты в глазах). Чапқый, диләр, күз қызара, қызарып тора, тоймастан чawып бирсәң, бетә торган ийе.

**ЧАПҚЫН I** *минз.* йомышка йөрүче, курьер, дежур (рассыльный, курьер, дежурный). Чапқынга кергәч кенә белдем ул awылны.

**ЧАПҚЫН II: чапқын булу** *т.я.* к.: **чапқый**. Күзгә чапқын булғанда искәрмәстән җаңаққа чawып җибәрәләр, шуннан аннары бетә, ди. – *к.т.*

**ЧАПҚЫН I** *кузн.* чабыш аты (бегун, скакун – о лошади).

**ЧАПҚЫН II** *лмб.* азгын, йөрүчән, типтерүчән кеше (распутный, гулящий, безнравственный человек); чаг.: **азман II**. Алар шандый чапкыннар.

**ЧАПҚЫТУ** *перм.* яңакка сугып җибәрү, чабып җибәрү (дать пощёчину, ударить по щеке). Қәзер чапқытқан булалар қый сары булса, бер кеше керә дә чапқытып қуйа да чығып китә сүләшми генә.

**ЧАПҚЫЧ I** *перм.* к.: **кәтмәк 1**. Күмәбез картупны чапқыч белә.

**ЧАПҚЫЧ II** *твр.* тозак (западня, силок). Төлкөне, қуйанны чапқыч ман тотасың.

**ЧАПЛЕ** *т.я.-крш.*, **ЧАПЛЫ** *нрл.* яхшы, әйбәт (хорошо; хороший); чаг.: **ару I, 9**. Әллә ниләр кийенеп чыгабыз ыйы, матур, чапле кийенәбез ийе. – *т.я.-крш.* Бездә бақча бик чаплыйы бит. – *нрл.*

**ЧАПРАШ** *әстр.* баскыч (лестница). Чапраш менеп қарачы, қуйлар күренмиме?

**ЧАПРУ** *лш.* к.: **очору**.

**ЧАПРЫШ I 1.** *к.т.* чалыш, кыек, аяк башларын як-якка каратып (косолапый). Чапрыш атлап йөрисең икән син, ә? Әй, чапрыш айақ!; **2.** *бөре., мам.* к.: **чапырыш 1**; чаг.: **ачамай 2**. Ғалийәләрнең өйө безгә урам аша чапрыш қына тора. – *бөре.*

**ЧАПРЫШ II** *бөре.* сулагай (левша).

**ЧАПТАРЛЫ** *мам., минз.* чуптарлы (с узорчатым тканьём). Чаптарлы күлмәкләре бар әнинең. Әнинең қалынға салған күлмәге чаптарлы булған. – *мам.* Чаптарлы алйапқыч. – *минз.*

**ЧАПТЫРМА** *чст.* юл-юл, буй сызыктан торган бизәк – тукымада, сөлгедә һ.б. (полоска, узор в виде полос по краям ткани, полотенца и др.). Минем селге кара-кызыл чаптырма.

**ЧАПТЫРМАЛЫ** *чст.* юл-юллы, буй сызыклы (с полосками). Чаптырмалы селге апкилде күстәнәцкә. Чаптырмалы итеп тә тугыганнар киндерне.

**ЧАПТЫРЫП** *мәл., мам.* ашыгып, тиз-тиз (торопливо, быстро-быстро); чаг.: **қабалан-қабалан**. Чаптырып җырлама, аңлашылмый. – *мәл.* Чаптырып сөйләде шиғырен. – *мам.*

**ЧАПУГ** *стрл.* к.: **путемар**.

**ЧАПУК I 1.** *тмн., лмб., кузн., стрл., шрл.* к.: **путемар**. Чапук байларда була иде вет, кемнекe әтисе бай. – *кузн.* Чылбырлыкай чапук, буй бетү; Буй гына үстердем, элмәдем (*бор. җыр.*). – *тмн.*

Чачкап тага идек, килен булгач инде шынардан чапук йасыйлар. Чапукның астарын элек эшлисең дә аннары тәңкә тагасың. – *стрл.* Чапук кыйыклап тагыла, урталыгына чил тәңкәләр, читенә иллешәр тиннек, ун тиннек. – *шрл.*; **2.** *хвл., карс.* к.: **бака I.** Чапукны эремнәренә тагып йериләр иде. – *карс.*; **3.** *тмн.* тәңкәләр тезеп эшләнгән, муенга бәйләп куела торган хатын-кыз бизәнү әйбере (нашейное украшение из монет, подвешиваемое на шею). Чапуклар була иде, тәнкә чапукларны мун′галәләр иде; **4.** *кузн.* уртасына каш куеп, тирә-якларына акчалар тезеп ясалган һәм күкрәккә кадап куела торган бизәнү әйбере (один из видов женского нагрудного украшения); **5.** *кузн.* камзул каптырмасына тагылган чылбырлар (цепочки, прикрепляемые к застёжке камзола); **6.** *кузн.* сәгать чылбыры (цепочка часов); чаг.: **җынҗыр.**

**куш чапук** *тмн.* к.: **касник: куш касник.** Кемеш кенә манит, куш чапук, Кыз буйым үстердем, элмәдем (*бор. җыр.*).

**ЧАПУК II** *карс.* нинди дә булса сигнал бирү өчен асып куелган металл кисәге, тимер әйбер (кусок металла, подвешенный для подачи сигнала, напр., о пожаре). Үзе бара чапукны селкетергә, тимерне. Теге китте чапук сугарга, пожар.

**ЧАПУР** *әстр., влгг.* челән (цапля).

**ЧАПЧАК 1.** *т.я., каз.ар., минз., әстр., нокр., перм., бөре., трбс., клм.* зур агач яки металл кисмәк, су кисмәге (большая деревянная, либо металлическая кадушка для воды). Чапчак чоланда, шуннан алығыз суны. Әле чыгып чапчактан салкын су эчә ул. – *к.т.* Чапчак белән су утыртқан мин капка төбенә. – *нрл.* Чапчаққа су салып кил әле, кызым! – *мам.* Кеше чапчакларга тутырып куйа суны. – *лш.* Мичада чапчак тулы кайнар су. – *нокр.* Чапчаққа сал суларыңны. – *перм.* Анасы чапчак белән бер, җуwан. – *дөб.* Чапчак булган өстә йабулы, монаwы хәдәр awызлары. – *трбс.*; **2.** *т.я., дөб., нокр., минз., бөре., трбс.* он, тоз, бал h.б. ашамлыклар салып куя торган агач кисмәк (деревянная кадка для хранения продуктов); чаг.: **әләңгәз.** Он чапчагына тычкан кергән. – *к.т.* Су чапчагы, бал чапчагы йасагалаганда әүwәлгеләр. – *нокр.* Чапчак белән он утыра кәзәнкәдә. – *трбс.*; **3.** *перм., нокр.* яшелчә тозлый торган агач кисмәк (деревянная кадка для засола овощей); чаг.: **кадушка 1.** Ике чапчак кыйар тозладым. – *перм.* Чапчаққа тозла. – *нокр.*; **4.** *дөб.* дүрт почмаклы калай савыт (четырёхугольная жестяная посудина). Чапчак утыртқан почмаққа, ашлык белән тутырык.

**әйрән чапчак** *перм.* к.: **батман II, 2.** Элек әйрән чапчаққа салып йазабыз ий.

**әпәй чапчак** *перм.* к.: **ләнгәц.** Әпәй чапчактагы камырны катырдым, пичкә йактым.

**бал чапчак** *нокр.* тәпән, бал тәпәне (кадушка для мёда).

**каймак чапчак** *перм.* к.: **батман II, 2.** Икешәр каймак чапчак берҗулы йазып төшөрә торган ийе.

**күмер чапчак** *перм.* күмер савыты (посуда для хранения угля).

**май чапчак** *перм.* к.: **батман II, 2.**

**ЧАПЧАК 1.** *стрл.* к.: **чапчак 1.** Она минең чапчагым коргаксып утыра; **2.** *чст., чст.-крш.* к.: **чапчак 3.** Чапчакай-чапчакай кәбестә, Әчи генә микән ул нәстә (*хал. җыр.*). – *чст.-крш.*

**ЧАПЧАҚЫЙ** *мам.* өйдә киеп йөри торган аяк киеме (мягкая домашняя обувь); чаг.: **пәпеш.** Чапчакыйлар бар ийе, нигә бирмәдең, әни?

**ЧАПЧУР** *кргл., бгрс.* өйдә иләнгән тиредән, гадәттә сыер тиресеннән тегелгән чүәк (чувяки, сшитые из кожи домашней обработки); чаг.: **чакчур.**

**ЧАПЫЙ** *трх., нрл.* сидек (моча). Чапый йулына апиратсийа йасыйлар. – *трх.*

**ЧАПЫРЫ** *перм.* **1.** к.: **арҡыры 2.** Ул кеше чапыры, сүзгә каршы килә; **2.** кыек, кәкре (кривой, косой). Чапырырак калды айак сынып йалганғас.

**чапыры карау** *перм.* кыек карау (смотреть косо, коситься). Үзе чапыры карап йөри.

**ЧАПЫРЫШ 1.** *трх., минз., мәл.* кыйгач (наискось, наискосок). Хаситәне чапырыш тагалар ыйы җанға. Берсе мында чапырыш кына, айырым тора. Чапырыш кына әртил бар икән. Тәкыйаларга чапырыш кына тора. – *трх.* Беднең өй силсәwиткә чапырыш тора. – *минз.* Шыңа чапырыш, тыгырык буйы (өйләре). – *мәл.*; **2.** *мәл.* туры килмәү, каршылык (противоречие, несоответствие). Мына зур эш эшләгәндә үз симйаң белән дә туры килә чапырыш.

**ЧАРА 1.** *блт., дөб., лш., бәр., кргл.* әвәләнгән ипиләрне мичкә тыкканчы салып тору өчен хезмәт итә торган, агачтан эшләнгән табак яки салам, чыбык, мунчала h.б.дан үрелгән савыт (небольшая деревянная чаша или круглая посудина, сплетённая из прутьев, соломы, мочала и т.д., куда кладут увалянный хлеб). Улым, чараларны әпкереп бир әле, ипи әwәли башламакчыйым. Ипи чарасы. – *блт.* Безнең әткәй саламнан чара үрә торган ыйы. Ипине чараға саладырыйык, чарадан көрәккә, көрәктән мичкә тыгадырыйык. – *дөб.*; **2.** *кас.* кер юа торган тагарак (корыто); **3.** *кргл.* дүрт тоткалы зур савыт (большая посудина с четырьмя ручками). Чара ди торганнарыйы элек, шул чараның дүрт тытқасы былган, астына ит салганнар, эстенә казы, каз салып дүрт ир аны чак күтәреп керткән; **4.** *кас., баст.* камыр баса торган, тирән җилпуч рәвешендәге агач савыт (деревянная посуда в виде глубокой ночвы для замесивания теста). Чара 'амыр баса тор'ан, уртасы овал′ный. – *кас.* Чараларда куллар белән басалар үкмәкне. Чара сузык була, агач карита күүк. – *баст.*; **5.** *м.-кар., яүшт.* җилпуч (ночва). Чарам да бар минем ағачтан. – *яүшт.* Чара белән тушылай җилписен карабодай, солы, мусырлары очып китә. – *м.-кар.*; **6.** *клм.* ит тапый торган тагарак (корыта для рубки мяса). Чарада қош (ит) чапқан чапқыч мынан.

**қамыр чарасы** *баст.* к.: **чара 4.**

**кер чарасы** *баст., кас.* к.: **чара 2.**

**он чарасы** *баст.* к.: **йулпуч.**

**үкмәк чарасы** *баст.* к.: **чара 4.**

**ЧАРАЧА** *минз., бөре.* мунча алды, мунча өйалдысы (предбанник). Муча чарачасында тора миллек. – *бөре.* Суны салқынга чарачаға қуйдым. – *минз.*

**ЧАРWA** [*фарс.*] *кргл.* эш, мәшәкать (работа, заботы). Чарwада йөрөгәч, алар дайым тыңламый ырадийуны.

**ЧАРДАК 1.** *тмн., лмб., күрш., кузн.* чардуган (решётка, изгородь – на могиле). Чардаклар бармы зиратта. Шул бабама чардак салдырганнар зиратта. – *күрш.* Безнең зыйәрәттә чардаклар күп. – *тмн.* Бабаң каберенә чардаклар эшләт, дим. – *лмб.*; **2.** *тмн.* к.: **қатнар.**

**ЧАРДАҚЛАУ** [*фарс.* + *афф.* -лау] *клм.* чардуган тоту (ставить ограду на могиле). Бес ағыч белән чардақлайбыс.

**ЧАРҚА 1.** *минз.* к.: **тыйрақ II**; **2.** *брб.д.* к.: **чабата 1.** Чарқа боопты, йәш тәрене (эшләнмәгән тирене) пөрөп, көн йәүсә, шәлбәйеп китәде, эзү (эссе) болса, қороп қатып китәде.

**ЧАРҚА** *хвл.* агач савыт (деревянная чаша). Агачтан чарка казыган, буйаклаган, анарга салма да сала идек, күберәге йарыла иде озагырак торгачтын.

**ЧАРКАП** *минз.* к.: **тезмә I.**

**ЧАРЛАҚ I 1.** *трх.* к.: **чардак 1.** Қабер өстенә Чарлақ қуйығыз *(мөнәҗәт.)*; **2.** *бөре., брб.д.* балкон. Бийек чарлақ, қуш тәрәзә, Тәфтиләү байларның өйләре. – *брб.д.*

**ЧАРЛАҚ II** *брб.д.* к.: **ақсырдақ.**

**ЧАРЛАУ** *т.кам.-крш.* суккалау, кыйнау (бить, ударять). Тегендә тал чыбыгы белән, бәрмәнчек белән чарлап алып чыгып китәләр.

**ЧАРЛАШУ** *брб.д.* талашу, ызгышу (ссориться, браниться, ругаться). Чарлашқан кешене узал тип әйтәләр.

**ЧАРЛОВАН** *срг.* к.: **чардак 1.**

**ЧАРПУ 1.** *мәл.* тимгел (сыпь). Битләрен чарпу баскан; **2.** *минз., нокр.* чабырттыру (вызвать сыпь, волдыри, обжечь – о растении). Қулға чарпый кәзәкәй (үсемлек). – *нокр.*

**чарпу салу** *әстр. чарпу* булган кешене имләү (лечить знахарским способом сыпь).

**чарпу ташлаучы әби** *әстр.* имче карчык (знахарка).

**чарпу-чарпу килү (булу)** *хвл.* к.: **йарпалану.** Кулларым чарпу-чарпу килгән, әрневенә түзәр халем йук.

**ЧАРПУЛАНУ** *хвл., мәл.* **1.** тимгел тибү, чабырттыру (выступить, высыпать – о сыпи). Авыз-борын чарпуланып беткән. – *мәл.*; **2.** к.: **йарпалану.**

**ЧАРПЫ** [*фарс.*] *трх.* бүкән, утын бүкәне (обрубок, пенёк); чаг.: **бүскә 1.** Ну ботоғоздан тотоп чарпыға бәрәсе генә қалды инде.

**ЧАРПЫНУ 1.** *чст., к.т.* зәхмәт кагылу, чир ияру (подвергнуться болезни). Чарпынгансың, арусыз тешкә утыргансың. – *чст.*; **2.** *әстр.* шикләнү (опасаться).

**ЧАРПЫ-ЧЫРПЫ** *карс.* вак-төяк утын, чыбык-чабык (хворост). Вана чарпы-чырпы кистеләр, утынмы инде ул, анакайым.

**ЧАРТЛАУ 1.** *каз.ар.-крш.* к.: **көйрәү 1.** Җоқодан чартлап уйандым инде; **2.** *кас.* шартлау (лопнуть, взорваться).

**ЧАРУ I** *чст.-крш.* бәйләгән әйберләрдә: киткән күзне әләктереп тегү (пришивание, зашивание распустившейся петли – у вязаных изделий); чаг.: **чалмап: чалмап куйу.** Чармый, бер күзе киткән сайын чарып барса, наскийы озакка чыдар ийе. Чарым дигән ийем, күзем күрми.

**ЧАРУ II: чару тору** *т.я., каз.ар.* бик нык каршы тору, риза булмау (сильно сопротивляться). Бармыйм, дип чару тора. – *к.т.*

**ЧАРЧАУ** *брб.д.* ару (уставать).

**ЧАРЧЫҒА** *брб.д.* к.: **сикертмә II.**

**ЧАРШАМПЫ** [*фарс.*] *сазл.* чәршәмбе (среда).

**ЧАРШАУ** *к.т., стрл.* пәрдә (занавес).

**тәрәзә чаршawы** *бөре., стрл.*, **тәрзә чаршawы** *стрл.*, **тәрзә чаршау** *перм.* к.: **коргоч.** Тәрәзә чаршawы эләләр. – *стрл.*

**чаршау өстө** *мам.* чаршау кашагасы (бордюр, короткий занавес над пологом); чаг.: **фәрдә: матча фәрдәсе.**

**ЧАРЫЗ** *мәл.* к.: **чарыс 1.** Безнекеләр (балалар) чарыз, тыттырмыйлар.

**ЧАРЫҚ** [*фарс.*] **I 1.** *каз.ар.-крш.* күн башмак, кәвеш (кожаные башмаки). Җегетләр бәйрәмгә чарық кийеп киләләр ийе; **2.** *твр., тара.* күн аяк киеме (кожаная обувь из самодельной кожи типа ботинок). Чарыққа бау ишәткәннәр ите қысылны, күкне, қараны. Чарық күнтән тегәткәннәр ите. Чабата йуқ, чарық ман маташтылар. – *твр.* Чарық тегәргә күн эшләгәннәр. – *тара.*; **3.** *тара., твр.* чи тиредән тегелгән аяк киеме (обувь из сыромятной кожи). Чарық поролоп тора, ат тирчәгеннән, қуй тирчәгеннән айақ йөзөнәчә, қара быwақ (бау) йасап йетен йебеннән. – *тара.*

**ЧАРЫҚ II 1.** *минз.* палас сукканда асалап ясала торган бизәк исеме (название узора при закладном тканье); **2.** *кргл.* киндер күлмәк итәгендәге сугып ясалган бизәк (узор, рисунок на подоле холщового платья). Җиде чарық чүпләп қуйып итәгенә, ике қат өстө итәк салып кийә идек (күлмәкне).

**ЧАРЫК 1.** *тмн.* тупас күннән тегелгән кәвеш (башмаки, изготовленные из грубой кожи); чаг.: **чакчур, чапчур.** Айакларына читекләр, кәwешләр, чарыклар кигәннәр, чарыг энде күннән теккән генә; **2.** *стрл.* к.: **чарық II, 1.** Чарык төшкән палас алдым.

**ЧАРЫК-ЧАРЫК: чарык-чарык кинау** *мәл.* чарт-чарт кыйнау (бить с треском). Шулай чарык-чарык кинап биртек йасар.

**ЧАРЫС** *трх., мәл.* **1.** оялчан, кыргый – кеше турында (стеснительный; дикарь – о человеке). Мындый чарыс кеше булмый да инде. – *мәл.*; **2.** кулга килми торган, өркәк – хайван турында (нелюдимый, пугливый – о скотине). Бу чарыс сарыкны тытып та булмас әле. – *мәл.* Чарыс та инде бу тawық, һич йанына барып булмый, қачарға ғына тора. – *трх.*; **3.** *мам., мәл.* уткен, чая (смелый, бойкий, живой); чаг.: **айаз 6.** Чарыс түгел ул қыз, бик йомшақ. – *мам.*

**ЧАРЫШ** *боре.* бал корты икмәге, кәрәз күзәнәкләрендәге чәчәк серкәсе (пыльца в медовой ячейке сота, залитая нектаром и мёдом). Чарышлы кәрәз. Чарышлы булғанын уртаға қуйабыз.

**ЧАС** *перм.* к.: **мәс.** Бүген иртән час төшкән.

**ЧАСАРУ 1.** *минз.* к.: **мәсәрү**; **2.** *дөб.* томанлану, томан каплау (затумариваться). Мынысы часарып қына тыра күзем.

**ЧАСИНКА** [*рус.* чёсанки] *срг., бөре.* к.: **сачинкә. йон часинкасы** *срг.* к.: **сачинкә.**

**ЧАСЛЫ** *мам.* бәсле (заиндевелый). Бик әшәке часлы көн ийе.

**ЧАСТАКУЛ** [*рус.* частокол] **1.** *стрл.* к.: **қайырма I; 2.** *хвл.* өй янындагы кечкенә бакча, түр бакча (полисадник).

**частакул азбар** *стрл.* утыртма читәнне сылап әшләгән абзар (хлев, стены которого из частокола, замазанного глиной).

**ЧАТ I 1.** *к.т., трх., блт., стрл.* к.: **мийеш.** Шул көзгө чатқа қуйылган ыйы. Әйбәт қулҗаулықлар, чатына чигешле. Ишегалдының бер чаты тәртипләнде. Дүрт чаттан җанғыр җawып тора. – *трх.* Түр чатына утырып тор. Чатқа кереп посқан. Өйөбезнең чатлары тузған. – *к.т.* Бер чығам бер чатқа, бер чығам икенче чатқа балаларны қарарға. – *блт.* Өр-йаңыдан өч чат бурады. – *стрл.*; **2.** *каз.ар.-крш.* к.: **awыл.** Чат әйләнәләр җырлап; **3.** *клм.* тау астындагы тигезлек (ровное место под горой). Пашта чатта йәшәгәннәр тау астыда, анаң мондо көчкөннөр.

**чат көйө** *каз. ар.-крш.* түгәрәк уен көе (хоровод).

**ЧАТ II** *мам., кргл., шрл.* тармак (ветвь). Артка тагалар иде тагы чулпы, берәр чатлы, өчәр чатлы була. – *шрл.* Awылның бер чаты тауга төртөлә безнең. Суқыр эчәк эчәкнең бер чаты икән ул. – *мам.*

**ЧАТ III 1.** *каз.ар., нрл.* к.: **берче 1.** Чат чәйни суды белә чәйким инде. Чат өйдә утырып булмас, тышқа да чығарга кирәк. Печән wақытында чат шуннан эчтем. Үзән түре болонында агач арасында чат ут йаныш тора. – *дөб.* Чат көтү көтте ул, йүлләп әрәхәт тә күрмәде. – *бәр.*; **2.** *каз.ар.* гел, фәкать (только, лишь только). Чат ашамыйчы ғына йабыға инде ул. – *мам.*; **3.** *каз.ар.* к.: **ару II, 5.** Чат күкәйгә генә басасын инде (камырны). – *мам.*; **4.** *каз.ар., нрл.* нәкъ, төгәл (точно, ровно). Чат унтуғыз ай җөрдөк. – *дөб.* И озақ тордолар, чат биштә киттеләр ийе. – *нрл.*; **5.** *каз.ар.* к.: **гөл II.** Чат ағачлық қынайы монда. – *лш.* Су буйлары чат ташлық қына. – *мам.* Чат тәңкә тезгән була торған ыйы (хәситә). – *дөб.*; **6.** *каз.ар.* тоташтан, туктаусыз (беспрестанно, беспрерывно, сплошь). Бүген чат җауды, чат җауды. – *дөб.* Чат сызлап тордо башым, сөләк қуйдырғач қына әзрәк җиңеләйеп киттем. – *мам.*; **7.** *т.я., каз.ар.* төп (коренной). Син үзең чат Қазаннықымы? – *каз.ар.-крш.* Йәрминкә чат үзебез awылда булмады ул. – *нрл.*

**чат җату** *трх.* таман булу (быть как раз); чаг.: **л'акыт.** Бу эрҗинкә айағыма чат җата.

**ЧАТАЙ** *стрл.* чая (бойкий, отчаянный, лихой). Хатыны бик чатай кеше ийе.

**ЧАТАҚАЛМАҚ, ЧАТАҚАМА** *перм.*, **ЧАТАҚАРМАН** *минз.* чытырдатып, бик нык, бик каты (очень сильно, крепко). Чатақарман йабыша эшкә. Улан, җығылам тип, чатақалмақ йәбеште. Чатақама йәбешкән дә айырып алыр да хәл йуқ.

**ЧАТАЛАУ** *дөб.* чатанлану, аксау (стать хромым). Чаталап беткәнсең бит инде сарық асрыйм дип.

**ЧАТАН 1.** *перм., нгб.-крш., клд., мәл.* кәкре аяклы (кривоногий). Чатан-чотан йери кеше, пытларын айырыбырак, шынарга чатан диләр. – *клд.*; **2.** *дөб., хвл.* к.: **чапрыш I, 1.**

**ЧАТАШТЫРУ** *трх.* аркылы-торкылы итү, чалыштыру (сделать крест-накрест). Кәрәз мөрүwe белән мөргәндә, җепләрне чаташтырып тарттыралар.

**ЧАТҚЫТЫП: чатқытып йому** *перм.* чытырдатып йому – күз турында (сильно зажмурить – о глазах). Күзне чатқытып җомдомий, қабыргасына чапқаным (бүкәннең).

**ЧАТЛАТУ** *дөб.* к.: **көйрәтү.** Чатлата ис ул тызлы балық.

**ЧАТЛЫ-БЫТЛЫ** *кмшл.* ямьсез, ничек төшсә шулай – язу турында (некрасиво, как попало – о почерке).

**ЧАТЛЫҚ 1.** *т.я.-крш.* к.: **мийеш.** Өйнең чатлықлары җүwешләнә. – *к.т.* Кәнүшни чатлықларында өши башлаған ыйы бәрәңге, қурқа башлаған ыйы. – *нрл.*; **2.** *мам., каз.ар.-крш.* урам чаты (место пересечения двух улиц, угол). Чатлықта өченчөй алар. – *каз.ар.-крш.* **Көтү** башта чатлықта җыйыла бит, шуннан көтүчеләр алып китә. Чатлықтан борылу белән қуwып җитте ул мине. – *мам.*

**ЧАТЛЫҚ** *т.я.-крш.* к.: **чатлық 2.** Бер awыл әйләнгистән, шул чатлықта кызларны тешереп калдыра.

**ЧАТМА: чатма суwық** *дөб.* чатлама суwык (трескучий мороз). Чатма суwық кендә қайтты.

**ЧАТМАШТЫРУ** *злт.* к.: **чаташтыру.**

**ЧАТНАУ** *лш., мам.* к.: **көйрәү 1.** Чәй қуйарбыз, қызлар чатнап қайтырлар. Чәйгә чатнадығызмы? Чатнасам чатнармын, мин балық ашыйм әле. Хәзер була (чәй), менә бозау чатнаган әле монда, бозау әчерәм. – *лш.* Чатнап қайтып керәдерийе урақтан, әңкәй, чәй бармы, дип. Қазлар чатнағаннар, әлсерәгәннәр гүпчи. – *мам.*

**ЧАТРА** *нгб.-крш.* к.: **йәпләшкә.**

**ЧАТУ** *тара., брб.д.* **1.** к.: **белемче 2; 2.** к.: **белемче 1.**

**ЧАТ-ЧАТ: чат-чат итеп тору** *мам.* теле телгә йокмау, җавапка аптырап тормау (быть бойким на язык, отвечать без запинки). Чат-чат итеп тора қызы, бар икән осталық.

**ЧАТЧЫРАУ** *т.кам.-крш.* шыгырдау (скрипеть – о санях). Ай-һай суwық бөгөн, чаналар чатчыралар. Чатчыратып қына барып қайтығыз әле райунға.

**ЧАТЫР I 1.** *туб.-ирт.д.* кашага, чаршау (занавески, бордюр). Мич чатыры. – *тара.* Ыстина чатыры көллө, ыспайы. Ишек чатырлары була. – *твр.* Ишек чатырлары алтлар, әшкәрә (бик) қәсерләнтләр. Чатыр шигелле сур шәлләр бар ите. – *тбл.*; **2.** *туб.-ирт.д.* өйнең әле генә өйләнешкән яшьләр өчен зур чаршау белән бүлеп алынган өлеше (часть дома, загороженная большим пологом для молодожёнов). Киленчәк чатыр эчендә утыра. – *твр.* Чатырны уникe митердән йасағаннар. Куйкаларға чатыр қоралар борон саманта уникешәр митер. – *тбл.*; **3.** *нрл., трх.* к.: **кимәлек.** Чатырны чыназа ағачына бәйләп қуйалар очоп төшмәсен өчөн. – *нрл.*

**ЧАТЫР II: чатыр итәк** *каз.ар.-крш.* **1.** тукыманы (аеруча шакмаклы), киндерне кыекка ки-

сеп теккән итәк (подол платья, сшитый из ткани или холста, выкроенного по диагонали). Элеке чатыр итәк кийәрләр ийе, бороп-бороп чатыр итәк куйарлар ийе күлмәккә; **2.** шулай ук киселгән тукымадан тоткан киң бала итәк (широкий волан на подоле платья из ткани, выкроенной вкосую). Элеке бит киндер күлмәг ийе, чатыр итәк, өстеннән тасма салырлар ийе. Қайыш алжапқычқа дағын чатыр итәк куйарлар ийе.

**ЧАТЫРАЙЫП: чатырайып тору** *мам.* курыкмыйча, каушамыйча тору (не бояться, держаться смело, не смущаться). Бернәрсәдән дә курыкма, чатырайып тор, қызым!

**ЧАТЫРМА** *дөб.* чатлама (трескучий – о холоде). Жиләмәрәк су, бик салқын да түгел чатырма.

**ЧАТЫРЫҚ** [*фарс.*] *клм.* **1.** койма (забор). Урамта чатырық қырынта йоқлап йатқан; **2.** к.: **чардак 1.**

**ЧАУҒАН** *тара.* к.: **мурта 2.** Чауғаннар йаңқурта чыға алмый.

**ЧАУҒУ 1.** *перм.* к.: **абалау I.** Эт чаугып өрмәгә йәбеште бақчаға қарап; **2.** кычкырып талашу, тавыш-гауга күтәрү (поднимать шум, скандалить). Чауғып йөрөр кеше йуғ әле бүген, Аллаға шөкер.

**ЧАУҚА 1.** *нгб.-крш.* к.: **чawыл 1.** Әнә чауқа үсеп утыра; **2.** *нгб.-крш.* яшь каен урманы (молодой березняк); **3.** *минз.* к.: **чawыллық; 4.** *минз., трбс.* куаклык, вак агачлык (кустарник, полесье). Печән биргәндер берәр чауқадан. Чауқада жиләк былған бийыл. – *минз.* Уйынға чығабыз, чауқа буйы шаулап тора. – *трбс.*; **5.** *минз., мам.* туйра, агач төбеннән үсеп чыккан яшь үсентеләр (молодая поросль вокруг дерева). Тездән су жырып чабата белә, имәннең чауқасын жыйабыз, йүкә чауқасын жыйабыз. – *мам.*; **6.** *минз., кргл., бгрс.* к.: **сүрә 1.**

**ЧАУКА I** *миш.д.* чәүкә (галка – птица). Чаука китми бит ул, әллә эшеми шунда? – *чст.*

**ЧАУКА II** *стрл.* **1.** к.: **чауқа 4.** Әдәм бийеклеге булса агач, чаука була; **2.** к.: **сүрә 1.** Печәнне чаука белән ташый тырахтыр. Чаука жигәләр дә атка, тарттыралар инде шуның белә.

**ЧАУКАБАШ** *миш.д.* тукранбаш (клевер, кашка). Чаукабаш, анай, сыйырлар вет севә, анай, сет тә бирә. – *лмб.*

**ЧАУҚАЛЫҚ 1.** *нгб.-крш.* к.: **чawыллық.** Чауқалыққа бардығызмыни?; **2.** *минз.* к.: **киләклек; 3.** *минз.* куак (кустарниковое растение, кустарник). Әрәмәлектә чыға wул чауқалық куч-куч булып.

**ч а ч** *брб.д.* чәч (волосы):

**чач айыру** *брб.д.* кияүгә китәсе кызның чәчен ике толымга аерып үрү (заплести волосы сговорённой девушки в две косы). Қысларның чачын айырып туйлағаннар, олу йеңкәләре чачын айырады йар-йар әйтеп қысцықтарты, өрәтеген болған икегә айырып, қыз wақтында перәү генә ишү болпты, кийәүгә барған суң ғына икегә айырып...

**чач қабы** *брб.д.* к.: **арт III.** Чач қаптары бестеңке заманға болмады, манитлар белән кийепләр порнағыда.

**ЧАЧАҒ-ЫРУ** *каз.ар.-крш.* к.: **нәсел-асап.** Чачаг-ырулары инде, қызлар урамнардан жырлаб узалар инде.

**ЧАЧАҚ 1.** *брб.д.* жеп (нитка). Зор үнә таптым, чачағы та йуқ; **2.** *минз., т.кам.-крш., твр.* чук (кисть, кисточка, бахрома). Сүрәкәләр кидек, жепәк жаулықлар бәйләдек, чачақлары барнақ кewек. – *т.кам.-крш.* Шәлнеңке чачағы осон ите. – *твр.*; **3.** *минз., т.кам.-крш.* чуклы яки чачаклы калфак (калфак с бахромой). Чачақ асылынып торған уқалы, жылық-жылық итеп торадырыйы. Чигәчә, сүрәкә, жепәк жаулық, аның өстеннән чачақ бәйлиләр. – *т.кам.-крш.*; **4.** *мам., глз.* к.: **чабата: чабата мыйығы.** Чабатасының чачақлары чыққан. – *глз.*

**тәгәрчекле чачақ** *брб.д.* к.: **чачық.** Тәгәрчекле чачақ алтым магасинтан. Тәгәрчекле чачақтан челтәр бәйли дегән.

**чачақ очо** *лш., мам.* ерак туган, ботак очы (дальний родственник).

**ЧАЧАК** *стрл.* к.: **чачақ 1.**

**чачагы чалынмаган** *чст.-крш.* бер дә аралашмаган, бер дә алыш-бireш итмәгән (никогда не общавшийся). Чачагы чалынмаган кешеләргә барабыз бит, артилләр ташланды казер, без элек әртил жеридер ийек бәйрәм житсә, шуларга ғына барадырыйык йомышка да.

**ЧАЧАҚЛАУ** *минз.* чуклау (делать кисточку, бахрому). Йаулықларны чачақлап суғадыр ыйық, киндер булса да.

**ЧАЧАҚЛУ** *твр., брб.д.*, **ЧАЧАҚЛЫ** *минз., твр.* чуклы (с кисточкой, с бахромой). Чачақлу шәл инәмнеңке, йыwан (зур), чатыр чикелле ите. – *твр.* Йефәк шәл, чачақлы, сабан туйларына бөркәнеп чығадыр ыйым. – *минз.*

**ЧАЧАЛАНУ** *дөб.* **1.** тармаклану, кечкенә тармакларга аерылу – елга турында (разветвляться – о реке). Ул йылға чачаланып аға; **2.** телгәләнү, чачаклану (излохматиться). Күлмәкне итәкләре чачаланып беткәнче кидек.

**ЧАЧАЛАУ** *дөб.* **1.** бераз ғына кузгату, тузгыту – печән турында (чуть-чуть растрепать, взлохматить – о сене). Печәнне бераз чачалап жибәр, тизерәк кипсен; **2.** көлтәнең башларын бераз тузгытып, таратыбрак жибәрү (взъерошить головку снопа). Көлтәне утыртасың да башын чачалап жибәреп қуйасын, кибеп тора ул.

**ЧАЧИНКӘ** *бөре.*, **ЧАЧИНКЫ** [*рус.* чёсанки] *т.кам.-крш.* к.: **сачинкә.** Чачинкыны басалар йуқа итеп, кәлүш кийертеп кийәсең.

**ЧАЧМАУ** *клм.* ука-чачак (девичий головной убор с позументом и кисточками).

**ЧАЧЫҚ** *брб.д.* кәтүк жебе (нитка в катушках, в шпульках). Мәгәләй үрәргә чачық алдым.

**ЧАЧЫТУ** *брб.д.* куркыту (пугать). Пискәк полса, кешене чачытқаннар.

**ЧАЧЫШУ** *брб.д.* сибешү (брызгать водой, окроплять водой). Паллыр сыу чачышаты.

**ЧАШ: чаш печәне** *блт., дөб.* күрән, саз кыягы (осока).

**ЧАШКА I** [*рус.* чашка] **1.** *чст., кузн.* к.: **жомор.** Бер чашка эчепсең вет инде. – *кузн.*; **2.** *стрл.* кечкенә (агач) савыт (маленькая (деревянная) чаша); **3.** *әжә.* кечкенә эмаль савыт (маленькая эмалированная чаша); **4.** *баст.* табак (большая чаша). Чашкалар белән чығарып қуйалар аш.

**ЧАШКА II** [*рус.* шашка] *тмн.* самоварга ягар өчен ясалган шакмак (шашки для самовара).

**ЧАШМАНЛАНДЫРУ** *нрл.* к.: **борсалану**. Бик чашманландыра үзеңне.

**ЧАШТЫЙ** *дөб.* гади яки йон җебеннән бәйләнгән чүәк (тапки, вязанные из простой или шерстяной нитки). Чаштыйны айаққа кийәләр ыйық қатмасқа.

**ЧАШУ** *мам., к.т.* шашу (обезуметь, сойти с ума). Чаша инде сайрый-сайрый сандуғач гөлҗимеш чәчәк атқанда. – *мам.* Ақылыннан чаша инде бу уқый-уқый. – *к.т.*

**ЧӘ!** *лш.* к.: **че!** Чә, су беткән дә (самоварның)!

**ЧӘӘТЛЕ** [*гар.* + *афф.* -ле] *төм.* булдыклы, ни эшләсә дә кулыннан килә торган (дельный, проворный). Қысларым чәәтле бултылар.

**ЧӘБӘ 1.** *мәл., хвл.* к.: **чаба I, 1; 2.** *нгб.-крш.* сарык куу ымлыгы (возглас, которым отгоняют овец).

**ЧӘБӘЙ** *минз., бөре., стрл.* к.: **ашық II, 2.** Менә бу чәбәйнең үзендә бар аскулкы. – *минз.*

**ЧӘБӘК** [*рус.* чеп, чепчик] *сазл.* бала башлыгы (чепчик). Чәбәкләре әлт тә тораты қысцағымныңқы.

**ЧӘБӘКЛӘҮ** *трх.* сыйпау, сөю – кул белән (похлопать, гладить рукой). Камилне искә төшерегез әле, дидем дә инде, үземне чәбәкләделәр. Чәбәкләп йоқлатыр ийем, үбеп уйатыр ыйым. Баланы чәбәкләп йоқлатасың.

**ЧӘБӘКӘЙ: чәбәкәй итү** *бөре.* **1.** к.: **чәбекәй: чәбекәй итү; 2.** к.: **чәбәкләү.**

**ЧӘБӘЛӘНДЕРҮ** *хвл.* к.: **чиләндерү II.**

**ЧӘБӘЛӘНҮ 1.** *мәл.* чуалу (запутаться – о нитке). Йебе чәбәләнгән; **2.** *трх.* буталу, әрләшү (ссориться, поссориться). Чүт чәбәләнеп китмәдек бабаң белән.

**ЧӘБӘЛӘТҮ** *хвл., шрл.* к.: **чиләндерү II.** Йепләрне чәбәләтеп бетермә, аннан ычын да таба алмассың. – *хвл.*

**ЧӘБӘЛӘШҮ** *трх.* к.: **чәбәләнү 2.** Чәбәләшкәннәр дә қызлары қайтқан.

**ЧӘБӘЛИ 1.** *к.т.* киндерәсез чабата (лапти без оборок); **2.** *дөб.* к.: **чәпәш.**

**ЧӘБӘХ** [*рус.*] *сазл.* к.: **чәбәк.** Элеке чәбәхләр, ыштан кисәхләр кергесхәннәр баласы булғац.

**ЧӘБӘЧ** *трх.*, **ЧӘБӘШ** *нрл., мәл.* к.: **йарка I, 2.** Минем чәбәш кенә әле сарық. – *нрл.*

**ЧӘБЕ** *мам., минз., бөре., байк.* читән (плетень). Чәбе тотарга бардық қырға сыйырлар җабарға. Кругум чәбеләрне ныгытасы бар әле маллар кермәскә. Бувасы җуқ быйыл, йазғы су чәбеләрен үк аптәшәп китте. – *мам.* Элек гел чәбе йе. – *минз.* Чәбе тотып алды ихатасына. – *бөре.*

**чәбе чыбығы** *трх.* сугу станында көрегә килә торган җеп чуалмасын өчен куелган нечкә таяк (деталь, снасть ткацкого станка в виде тонкой палочки, вставляемая между нитками, чтобы они не запутывались во время тканья).

**ЧӘБЕГҮ** *трх.* к.: **чәбәләнү 1.**

**ЧӘБЕКӘЙ: чәбекәй итү** *бөре., стрл.* кул чабу (рукоплескать). Безнең туганыбыз гирой була дип чәбекәй итеп йөриләр. – *стрл.*

**ЧӘБЕН** *трх., стрл.* күбә (ворох сена, который можно поднять вилами в один приём). Печәнне кипкәч чәбенгә җыйалар да чүмәләгә ташыйлар, чүмәләдән клат қуйалар озонча. – *трх.* Чәбен кечкенә, бер сәнәклек була ул. – *стрл.*

**ЧӘБЕРЧЕК** *нокр.* **1.** карлыгач (ласточка). Чәберчек чиннеккә ойа йасыййы. Чәберчекнең бик қанаты ызын: сарық өстенә утырып йөри чәберчек, балчықтан ойа йасый; **2.** яр карлыгачы (береговая ласточка). Чәберчек қарлыгач ул, аның зарары йуқ.

**ЧӘБЕРЧЕКЛӘНҮ** *к.т.* к.: **чилләнү.** Нигә җуққа чәберчекләнәсең?

**ЧӘWҮ** *твр.* кайгыру (грустить, переживать, печалиться). Сән чәwәрсен, мән чәwәрмен, Өмөрләр үтәр сайаға (*хал. җыр.*).

**ЧӘГӘРТҮ** *карс.* чиктерү (дать назад, заставить пятиться). Машинаны кечкә генә кире чәгәртеп этәреп киттек, дир.

**ЧӘГЕ** *глз.* эчәге (кишка).

**тар чәге** *глз.* нечкә эчәк (тонкая кишка). Хайwанның тар чәгесе.

**ЧӘГҮ** *брб.д.* чагу (жалить – о пчеле, о крапиве). Кечерткән бик сәәр, қолно чәгә тоған, бусы әре ғawақлысы алай уқ тешнәми.

**ч ә й I** (чай):

**бәбәй чәйе** *лмб.*, **бәби чәйе** *трх.* бала туу уңае белән уздырыла торган мәҗлес (застолье в честь новорождённого); чаг.: **ботқа: бәби боткасы.** Бәбәй чәйе йасак келәмәде, син аурарсын, диде әрем. Бәби чәйенә күп килделәр қунақлар, зағутырдық.

**буш чәй** *дөб.* коры чәй, тәмләткечләр салмаган чәй (чай, куда ничего не положено, ни с чем не смешанный; неподслащенный чай). Буш чәй эчәм эсседә.

**қалмық чәй** *эстр.* эре сабаклы чәй (чай крупноствольный).

**қара чәй** *эстр.* такта чәй (плиточный чай).

**нәнә чәй** *твр.* к.: **ботқа: бәби боткасы.** Баланы алып қайтты, нәнә чәй йасадық, муллинәне (абыстайны) китереп исем қуштық.

**татлы чәй** *кас.* баллы чәй (сладкий чай). Татлы чәйне бик севә инде, өстәл йаныннан кыwып та китмәс.

**үлән чәй** *тара.* кырлыган (Иван-чай).

**чәй ашы 1.** *бәр.* май һәм йомырканы күбрәк салып, ачыга пешерелгән кабартма (небольшие сдобные булочки из кислого теста). Чәй ашлары пешерер ийек эчегә, май салып, күкәй туғлап; **2.** *бәр.* яхшы камырдан пешерелгән камыр ашлары: кош теле һ.б. (всякие мучные изделия из пресного сдобного теста, жаренные в масле). Төрлө эризық була инде чәй ашында, қош теле, бawырсақ; **3.** *мам.* к.: **чәлпәк 1.** Қоймақ та пешергән, чәй ашы да пешергән; **4.** *дөб.* катлы-катлы итеп ясалган вак күмәч (слойка).

**чәй җаңарту** *каз.ар., каз.ар.-крш., т.я.* чәй кую, самовар кую (поставить чай, самовар). Қарт чәй җаңартмаға қушса, сөт қалдырыйм дигән ийем. – *каз.ар.-крш.*

**чәй җиткерү** *блт., мам.* чәй өлгертү, чәй кайнатып кую (вскипятить чай, приготовить чай). Сез қайтқанчы, чәй җиткерем мин. – *блт.*

**чәй кадагы** *мәл.* к.: **пыды.** Чәй кадагы төшсә нәстә диләр сездә?

**чәй кашык** *лмб.* к.: **қалақ 2.** Чәй кашыкларны йумапсын вет, ынытыпсын.

**чәй кимагы** *тмн., лмб., чст.* төче коймак (оладьи).

**чәй қомғаны** *минз.* к.: **ғал′ник.** Қырда чәй қомғанында чәй қайнатып җибәрсәң, шәп була шул.

**чәй табагы** *лмб.*, **чәй табак** *хвл.* к.: **җәйләү.** Чәй табакларымны tawык watты тенәген. – *лмб.*

**чәй тәме** *блт.* к.: **чече 3.** Чәй тәмнәре күп қайтты әле бу арада кибеткә.

**чәй тезү** *мәл.* чәй табыны әзерләү (накрывать стол к чаю). Чәй тезимме?

**чәй тоқмачы** *блт.* к.: **қатый.** Туйға чәй тоқмачы пешерттем бер биш-алты күкәйгә.

**чәй үләме** *каз. ар.-крш.* сары мәтрүшкә (зверобой). Чәй үләмен чәй итеп эчәләр; паминни чәйләрең бер җақта торсын бу чәй булғанда.

**чәй чашкасы** *лмб.* к.: **җомор.**

**чәй үләне 1.** *кмшл.* к.: **үлән чәй; 2.** *т.кам.-крш., кргл., бгрс.* сөтле билчән (осот полевой).

**чын чәй** *бәр.* бөртек чәй (байховый чай). Чын чәй сал ыйы, тақта чәй чүб ул. Чын чәй белә тақта чәйне қушып сал.

**ЧӘЙ II** [*рус.* чай] *мәл.* кереш сүз: -дыр бит, -дыр әле, -дыр, ахры (по-видимому, вероятно, чай). Чәй, мине үзең беләсең.

**ЧӘЙӘ** *яүшт.* үткен, чая (проворный, смелый). Қызы бик усал, чәйә.

**ЧӘЙГЕН** [*рус.* чайник] *мам., минз., тара., твр.*, **ЧӘЙГҮН** *минз., бөре., перм., кмшл., кргл., бгрс., трбс., стрл., брб.д.* к.: **гал′ник.** Чәйгендә чәй бар, эчәсең килсә. Чәйген белән қуй чәйне. – *мам.* Чәйген ташымасын, сеңнем. – *твр.* Эчәсең килсә, улым, чәйгүн белән дә қуйған ийем. Чәйгүн белән су аппарабыз. – *кмшл.* Чәйгүннең сабы watылды. Эчләрем күбеп бетте минем чәйгүннәреннән эчеп. – *минз.* Чәйгүнгә су салың. Чәйгүн беле айран алып киттек җаланға. – *перм.* Чәйгүнеңе утка утырт, чәй эчәрбез. – *стрл.* Чәйгүн қапқағы кәтле иге картуп бәрде (бирде). – *брб.д.*

**ЧӘЙЕР** *дөб.* **1.** сагыз (сера, живица); **2.** к.: **мечик.**

**кара чәйер** *чст.* к.: **сулама.** Кистек төбенә салганда йепне ышкыйлар кара чәйер белә.

**чәйер чумарасы булу** *мәл.* сагыз булу (пристать как банный лист).

**ЧӘЙЕРЛӘНҮ 1.** *трх.* каз йонының көйрәп оешуы (превращение пера в смолообразную массу после сгорания). Күпчек бәг җанмый икән, чәйерләнә генә; **2.** *дөб.* эремчекнең кайнатканда сузыла торган массага әверелүе (превращение творога в тягучее вещество при кипячении). Чәйерләнә шул эчегән сөтнең эремчеге, чәйерләнеп сузылып тора.

**ЧӘЙИЛКЕ** [*рус.*] *трх.* чәчкеч (сеялка). Чәйилкедә дә эшләдек, чәчү чәчтек.

**ЧӘЙКӘНДЕК** *стрл.* ашлы су, юынтык (помойный). Бидерәне керт, шунда гына чәйкәндек бидерәсе.

**ЧӘЙКЕ** [*рус.* сеянка] *кмшл., трх.* югары сортлы ак он (мука высшего качества, сеянка-мука). Ике йаташлыйы тирмән, өскө йаташта чәйке тарта, аққа. Бөтенесен дә чәйкегә йасаттым, аққа. Арыштан чәйке йасый торған тирмән бар иде. – *трх.* Pawил кез кене дүрт қапчық чәйке йасатып китерде. – *кмшл.*

**ЧӘЙЛӘМӘҮ** [*рус.* чаять + *афф.* -ләмәү] *кузн.* ышанмау, өмет итмәү (не верить, не надеяться). Чәйләми йан гынам тынарга (*хал. җыр.*).

**ЧӘЙНӘК** *перм.* бер кабып чәйнәрлек аш, сыныk (пища на один кус, глоток); чаг.: **қабас.** Бер қабам чәйнәге қала ди усал кешенеке (*әйтем*).

**ЧӘЙНӘМ: бер чәйнәм** *минз.* бер чәйнәрлек (на один откус, порция жвачки на один раз). Сағызны берәр чәйнәмнән сатабыз.

**ЧӘЙНӘМЕШ** *клм.* к.: **пизел.** Аныкы йемен буйныға тағарга тезәләр, чәйнәмеш ачы ул, тәмсез.

**ЧӘЙНӘҮ 1.** *минз., перм., чст., стрл., твр.* тешләү – эт, песи, кандала, черки h.б. турында (кусать – о собаке, кошке, клопах, комарах и т.д.). Песәй бармагымны чәйнәде. – *стрл.* Бездә алай чәйни торган эт йуктыр. – *чст.* Эт чәйни. Песи чәйни. Қандала чәйни. Қәзер урманда чебен чәйни. – *перм.* Айағы менә болый өйөлдө, чебен (озынборын) чәйнәгән. – *твр.*; **2.** *перм.* к.: **йару I, 2.** Сувыдан чәйнәрсен гөмбағышынны; **3.** *минз.* ачулану (ругать). Инәкәй awырып йатса да чәйнәмә; **4.** *минз.* hаман бер сүзне әйтеп тору, туку (твердить одно и то же). Чәйнәмә инде, әйттең бит инде бер.

**терсәк чәйнәү** *перм.* терсәкне тешләү, үкенү (каяться, сожалеть). Утырығыз, терсәгегезне чәйнәрдәй булып.

**ЧӘЙТАБАҚ** *нокр., перм.*, **ЧӘЙТАБАК** *байк., хвл., кузн., карс.* к.: **җәйләү.** Чәйтабақ шикелле итеп, wағырақ итеп пешерәсең күмәчне. – *перм.* Мин үземә чәйтабакка гына салган идем. – *хвл.*

**ЧӘК I** *минз.* к.: **който.** Баласы да бик чәк.

**ЧӘК II** *брб.д.* **1.** чит, чит ил (другая сторона, чужая сторона; край). Қызы чәктә, Омскида. Чәккә йөргән йуқwыс; **2.** кырый, чит (край чего-нибудь). Арба чәгенә утыр.

**ЧӘКӘН I 1.** *кргл.* мамык шәлдәге бизәк (узор на ажурном, пуховом платке). Бер қызны сайуз йебәрде паутинка өйрәнергә, төрле чәкәннәр бәйләргә; **2.** *минз.* өйдә суккан киндердәге, паласгы бизәк (узор в браном тканье холста, палосов). Чүпләп суғадыр ыйық тақта күтәреп, чәкән төшөрөп. Моноң чәкәне чүпләп суққанныкы; **3.** *трх.* сыр, бизәк – агач әйберләрдә (резьба украшения, узоры на деревянных предметах, мебели и др.). Иренмичә ничек шақмақ қуйып утырғаннардыр, шул чәкән инде; **4.** *тара.* тәрәзә йөзлегендә: бизәк, сыр (резьба на наличниках). Тирәс пашыныққы чәкәне матур; **5.** *тара.* читек куныcындагы каелган бизәк (узоры на голенищах ичигов). Атоу қуныцынта чәкән пулады.

**ЧӘКӘН II: чәкән сөйәге** *минз., бөре.* к.: **ашық II, 2.**

**ЧӘКӘННӘҮ 1.** *трх.* агач әйберләрне бизәкләү, сырлау, (резать узоры на дереве, т.е. на деревянных предметах). Ағач karawat, чәкәннәп-чәкәннәп йасаған. **2.** *кргл.* паштетның өстен камыр белән бизәү (делать на паштете узоры из теста). Паштитның өстөн қамыр белән чәкәннисең; **3.** *минз., кмшл., чст.* асалап бизәкләр ясау (делать узоры закладным способом). Чаршауны чәкәннидер ийек биш тийен ақча шикелле чәкән төшөрөп, түгәрәк-

түгәрәк булып тора. Чәкәннәп паласлар да суқтым әле мин. – *минз.* Чаршауны чәкәннәп суғалар ийе. – *кмшл.*

**ЧӘКӘННЕ** *к.т.* бизәкле (с узорами). Элкеге сөлгөләрне күрсәң, чәкәнне сөлгөләр дә бар ийе.

**ЧӘКӘШҮ** *минз., стрл.* бәрелешү (столкнуться). Машиналар чәкәшеп, шунда үлгән. – *минз.*

**ЧӘКЕ I** *тмн., кузн., хвл., срг., стрл., мәл., шрл.* к.: **тике**. Ун йәшемә чәке сабакка йердем. Әрәзе шул чәке хасрәт. – *тмн.* Балына чәке китерәләр иде туйга. Шунда чәке ойокны бәли идек. – *стрл.* Выт миңа шул чәке йәш. Машина бире чәкемени китерде? Көзгә чәке. Ашка чәке. Ул кичкә чәке дә торор алай. Безнең awылның йартысы чәке булыр. – *кузн.*

**ЧӘКЕ II** *мәл.* сөт продукты: куе сөттән оеткан катыкка яки аның сөзмәсенә каймак, шикәр комы салып эшләнә (особый вид молочного продукта: катык или сюзьма из катыка, смешанный со сметаной и сахарным песком). Чәке әче була, писүк салгач кына ашап була.

**ЧӘКЕЛДӘГӘН** *каз.ар.-крш.* таш кебек каты – җир, юл h.б. турында (твёрдый как камень – о земле, дороге и т.п.). Арбадан чәкелдәгән җулның уртасына (егылып) төштөм, бернәрсә дә булмады миңа.

**ЧӘКЕЛДЕК** *кргл.* йомранның бер төре (один из видов суслика).

**ЧӘКИ** *мам.* к.: **батырақ**. Әбәттә бер чәки сөт эчеп җибәрсәң, хәл кереп китә.

**ЧӘКЛЕ** *т.кам.-крш., кргл., бгрс., чст.-крш.* к.: **тике**. Ызбага чәкле җүгердем. – *чст.-крш.* Анда чәкле бар ийе. – *т.кам.-крш.*

**ЧӘКНӘТҮ** *брб.д.* чигендерү – атны (осаживать – лошадь).

**ЧӘКРӘ** *перм.* үсемлек начар үсә торган ташлы текә тау бите (крутой каменистый склон горы); чаг.: **чағу II, 1**. Менә шушы чәкрәләрне ат сөрәйе. Берwахыт анда тауда, чәкрәдә дә булды сабантуй.

**ЧӘКРӘННӘП** *минз.* зур булып, чыгарга җитешеп (выпучившись, вылупившись). Чәкрәннәп тора инде күдләре, қурчақ баласы күwек. Китапны да уқып булмый, күзләр чәкрәннәп чыгарға җитә.

**ЧӘКУШКА** [*рус.* чекушка] *карс.*, **ЧӘКҮШ** *трх.*, **ЧӘКҮШКЕ** *нрл., каз.ар.* к.: **чака 1**. Кал′усалар ваны кигезмәгән, аның чәкушкасы йуг ахыр′ы. – *карс.* Чәкүшкесен алып қуйғаннар шайарып. – *нрл.*

**ЧӘКЧӘГИ** *блт., мам., кргл.* к.: **чепчәги**. Чәкчәгиләре бик уңган, awызда эреп тора. Чәкчәгиләре бик дәү дәген, бик матур дағын, тәмне дәген. – *блт.*

**ч ә к ч ә к** (татарское национальное блюдо, чакчак):

**баллы чәкчәк** *перм.* к.: **чепчәги**. Қодаларның баллы чәкчәге була.

**орлоқ чәкчәге** *минз.* киндер орлыгын төеп, әвәләп ясаган йомры ашамлык (блюдо из толчёных семян конопли в виде шариков).

**шоморт чәкчәге** *минз.* төйгән шомыртны әвәләп ясаган вак шарчык рәвешле ашамлык (блюдо в виде шариков из толчёных ягод черёмухи). Орлоқ чәкчәге, шоморт чәкчәге буладыр ийе.

**ЧӘКЧӘКИ** *хвл., чст., клд., мәл.* к.: **чепчәги**. Кыз йагыннан зур патнус белән чәкчәки китерәләр. – *клд.* Чәкчәкине тарилкаларга саласын, кан′аган пәс′укны койабыз, йезем эләкне тезеп чыгабыз, аны туйларга куйабыз, бездә бал белән тегел чәкчәки. – *хвл.*

**ЧӘКЧУР 1.** *кргл.* тиредән тегелгән сай аяк киеме (мягкая неглубокая обувь из овчины и др.); **2.** *перм.* к.: **чакчур**.

**ЧӘЛӘҢ** *твр.* к.: **селәү II, 1**. Кәү wақыт қулын тиермәиенчә чәләңен атадылар игән, кәү wақытта қармагының йибен үзә атарлар игән.

**ЧӘЛБӘК** *тбл.* черек бәрәңгедән пешерелгән төче күмәч (лепёшка из сгнившей за зиму картошки). Өшөк кәртүшкәне tewen, он қушып, липүшкә шигелле пешерәсен, чәлбәк пула.

**ЧӘЛБЕН: чәлбен су** *твр.* пычрак су, җыелган су (грязная вода, лужа). Чәлбен суда чумқалы кәрәкмәй.

**ЧӘЛДЕР** *минз., стрл.*, **ЧӘЛДЕРКӘЙ** *минз.* балтыр (икры ног). Синең чәлдеркәйең өшөмәсә йарар ийе, қызым. – *минз.*

**ЧӘЛДЕРТЕК** *минз.* к.: **чолдор I**.

**ЧӘЛИ I** *мәл.* тагы (ещё); чаг.: **тәбер**. Казанда чәли туганыбыз бардыр.

**ЧӘЛИ II: чәли бәләү** *хвл.* к.: **бәйләү: тартмалы бәйләү**.

**ЧӘЛКӘМӘРӘ** *дөб.* шау-гөр килеп, шаулашып (с шумом, с шумом-гамом); чаг.: **илаулашып**. Денйа тутырып, чәлкәмәрә менеп китәләр (яшьләр).

**ЧӘЛМӘШТЕРҮ 1.** *мәл.* аннан-моннан гына эләктереп, ямагандай итеп кую (зашить кое-как, заштопать кое-как); **2.** *трх.* аркылы-торкылы кую (ставить крест-накрест). Киндерәсен чәлмәштереп кийәләр иде чабатаны.

**ЧӘЛПӘК** [*фарс.*] **1.** *мам., трх., минз., стрл., тпк., кргл.* бодай онынан, сөт-каймак, йомыркага гына басып, таба зурлыгында юка итеп җәелгән һәм мич каршында майда пешерелгән камыр ашы (национальное мучное блюдо); чаг.: **күзикмәк I, 1**. Туйға күмәч пешерәләр, чәлпәк пешерәләр, күзикмәк тышы кебек пешерәләр майда. – *мам.* Чәлпәкләр пешереп алып чыгалар (сабан туенда). – *трх.* Чәкчәк камырын йука итеп җәйәләр дә майда пешерәләр, тау тике булып тора ул. – *стрл.* Сигез қадақ майга чәлпәк пешердек. – *кргл.*; **2.** *трх.* қыстыбый тышы (верх или обложка қыстыбый). Чәлпәккә бәрәңге қыстырып пешерәләр қыстыбый. Чәлпәген йасый барасын, пешерә барасын. Чәлпәк пешереп қыстымбый пешеремен, дидем ийе бәрәңге қыстырып әңкәң қайтуға; **3.** *мам.* к.: **қатый**; чаг.: **катлама 1; 4.** *перм.* к.: **йуwача 2**.

**ЧӘЛПӘН** *тара., твр.* кара булып торган җир (лысина). У йауды да, чәлпәннәр чығып қалды. – *тара.* Йарты ийүлгә қәтлем йауды, чәлпән чығып қала йерләр. – *твр.*

**ЧӘЛПҮШ** *минз., стрл.* самовар томалагыч, капкач (заглушка – у самовара). Чәлпүшең қайа, ташый бит самwарың. – *минз.*

**ЧӘЛТ: чәлт эрзиңкәсе** *стрл.* к.: **будырма**. Рагаткы йасап бич бетергән чәлт эрзиңкәсен.

**ч ә л т е р** *мәл., чст., минз., стрл., бгрс., твр., брб.д.* балтыр, сыйрак (голень):

**чәлтер севәге** *чст., мәл.* балтыр сөяге (берцовая кость). Чәлтер севәкләрем арды җәйәү йерүдән. – *мәл.* Чәлтер севәген генә үлчәп биргән, ахры (итнең). – *чст.*

**ЧӘЛЧЕ** *глз.* көлтә өеп киптерү өчен кулланыла торган ботаклы агач (ветвистое дерево, употребляемое для обкладывания и сушки снопов). Чәлче дибез, мына былай бытаклы була ул, былай йерге утыртасин, дүрт-биш келте мына былай йабасин, йелләй.

**ЧӘМ 1.** *минз., стрл., бгрс.* гарьлек (обида, огорчение; стыд, позор, срам). Ирем ташлап чыгып китте дә, чәм белә эшләдем. – *стрл.* Кеше арасында чәме миңа, гәрләндерәләр. – *минз.*; **2.** *кргл., бгрс.* дәрт (душевный подъём, охота, желание). Бу қызым тырышып уқый, чәм белән, тегеләре кебек түгел. – *бгрс.*; **3.** *кргл., бгрс., шрл.* кызулык, гарьләнүчәнлек (горячность; обида от чувства несправедливости). Сабыр итмәсәң, чәм кемдә дә бар ул. Чәменнән асылынып үлде. – *бгрс.*

**чәм килү** *минз., стрл.* ачу килү, гарьләнү (обижаться, чувствовать себя обиженным, униженным). Қайчағында чәмем дә килә, бер эшләмәгән кеше қырық биш сум ала. – *минз.* Минем дә бик чәмем киләдер ийе, нигә йәшләрне мактый дип. – *стрл.*

**ЧӘМӘЛЕ** *хвл.* к.: **чамалы**. Миннән карт әбиләр бик чәмәле инде.

**ЧӘМБӘР** *твр.* **1.** коршау (обруч); **2.** итәккә тасмадан, шнурдан аркылы салынган кайма (ленточная, шнурковая кайма на подоле платья). Чәмбәр тиләр, линте салып қуйған.

**ЧӘМБӘРЛӘҮ** *твр.* кайма салу (пришивать кайму). Чәмбәрләгән гөйләкләр әлке болған қуй (бит), қәсертә дә тегәтләр.

**ЧӘМБӘРЛҮ** *твр.* каймалы – күлмәк итәге турында (с каймой – о подоле платья). Чәмбәрлү көйләкләрем пар.

**ЧӘМНӘҢҮ 1.** *минз., стрл., бгрс.* гарьләнү, хурлану, кеше белән узышып эшләү (обижаться, оскорбиться, соперничать, стыдиться, испытывать чувство стыда, стараться держать первенство всегда за собой). Әйтер хәл йуқ, бу чәмнәнгән дә қайтқан. – *минз.* Ашап бетер, чәмнәнеп тотонган идең бит. Ашамый, эчми, чәмнәнеп эшли торган ийе инде, әз генә артта була башласа. – *стрл.*; **2.** *кргл., бгрс.* дәртләнү, гайрәтләнү; гарьләнү (горячиться, разгадориться; обидеться от чувства несправедливости). Бер эшне эшли алмыйсың дисә, чәмнәнеп китә дә тырышып эшли. – *кргл.*

**ЧӘМНЕ** *минз., стрл., бгрс.* гарьләнүчән, хурланучан, гарьчел (обидчивый, чувствующий себя униженным, опозоренным). Бик чәмне, бер дә кешедән калырга тегел. – *стрл.* Нәфсем зур булды, чәмне булдым, ирләр эшен эшләдем. – *бгрс.*

**ЧӘМЧЕЛ** *кргл., минз., бгрс.* кирәкмәс урында сүз көрәштерүчән, бәхәсләшүчән кеше (человек, необоснованно настаивающий на своём).

**ЧӘНӘҮ** *клд., карс.* **1.** к.: **кабу I, 3**. Усал кучат, чәнәде. – *карс.*; **2.** тешләү – хайваннар турында (кусать – о животных). Бәлә алашны, чәнәтәсең. – *клд.*

**ЧӘНӘЧКӘ** *блт., нгб.-крш.*, **ЧӘНӘШКӘ** [*рус.* саночки] *каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* к.: **сәләскә**. Умбер қазны аптәшәп киттем чәнәчкәгә салып. – *блт.* Бийек тау башыннан шуwадырыйық чәнәшкә белән. Ул чәнәшкәнең киндерәләре өзәләп бетте. – *каз.ар.-крш.* Безнең туғанайның әйберләре Чәнәшкәләп түгел, чаналап (*бор. жыр.*). Бер чәнәшкә утын төшерәсен ышкулға. Чәнәшкә тартып симәнә дә ташыдық. – *т.кам.-крш.*

**ЧӘНДЕР I** *бөре., байк., минз., стрл.* к.: **тыйрақ II**. Чәндереңне кечерткән чаға бит. – *минз.*

**ЧӘНДЕР II** *мәл.* ябык – бала турында (худой, тощий – о детях).

**ЧӘНДЕРКӘ** *т.кам.-крш.* бик ябык (очень худой). Чәндеркә нәзек кеше була.

**ЧӘНЕТҮ** *кузн.* к.: **қадау II**. Селкенмә, кузгалмасаң, мурта чәнетми.

**ЧӘНЕЧКӘ** [*рус.* саночки] *чст., нгб.-крш.* к.: **сәләскә**. Кыш кыны ырчык кырам, чәнечкәләр йасыйм. – *чст.*

**ЧӘНЕЧКӘК** *тбл.* к.: **кормош**. Чәнечкәк тешни ул.

**ЧӘНЕЧКЕ I** *минз.* к.: **саник**. Өч чатлы чәнечкене бир әле.

**чәнечке печән** *блт.* торнабаш (аистник, грабельник).

**чәнечкеле күзлут** *мам.* тимгелле сукыр кычыткан (яснотка пятнистая).

**ЧӘНЕЧКЕ II** *тбл.* к.: **мурта 2**. Чәнечкеләре бар, чәнчемәсеннәр.

**ЧӘНЕЧҮ 1.** *к.т., нрл., перм.* к.: **қадау II**. Марта чәнечте, саңа бара алмадым. – *нрл.* Дөңгәж бу, чәнечми, балқорт қына чәнечә. Қорт чәнечте, диләр, аймақлап йабышса, талады, диләр. – *перм.* Марта чәнечтейе, жаңағым ничек эшете. – *к.т.*; **2.** *перм.* кагу, утырту (поставить, вбить – о столбе, коле). Бағана чәнечәләр дә уртаға, өчнө таған утырталар, шунда кәбән салалар. Қазық чәнечәсең дә печинне үwәсең.

**ЧӘНЕШҮ** *трх.* к.: **қадау II**. Марта чәнешсә, шешә, қарарлық булмый.

**ЧӘНИСӘ** [*рус.* сани] *кас.* к.: **сәләскә**.

**ЧӘННӘМ** [*гар.*] *брб.д.* җәһәннәм (ад, преисподняя). Чәннәм қазабы!

**ЧӘНТЕР** *стрл.* к.: **тыйрақ II**. Чәнтерегезгә кийегез, чебен бик усал безнең.

**ЧӘНТӘ: чәнтә пер** *тбл.* сирәк, әллә нигә бер (редко, изредка).

**ЧӘНЧӘWЕК** *кргл., бгрс., шрл.* чәнчү уты, зәңгәрбаш (синеголовник плосколистный).

**ЧӘНЧӘЙ** *брб.д.* к.: **бармақ: гөлчәчәк бармақ**.

**ЧӘНЧӘКЛЕ** *минз.* чәнечкеле (колючий). Гөлҗимеш чәнчәкле.

**ЧӘНЧӘҮ** *трх.* кадау (колоть – укол). Укул чәнчәгәннәр.

**ЧӘНЧЕК** *перм.* к.: **силә 1**. Тындықлы булырға, бала йоқларга миләштән қуйалар чәнчекне.

**чәнчек арба** *перм., к.-уф.* к.: **крандас**.

**ЧӘНЧЕКӘЙ** *брб.д.* к.: **бармақ: гөлчәчәк бармақ**.

**ЧӘНЧЕМ** *минз., стрл.* к.: **чәбен**. Килендәшем чәнчемгә жийып жөри. Wахыт булмаганда чәнчем көйө төйәп жибәрәбез фурманға, кәбән қойар өчөн. – *минз.* Тырма белән жыйып салып китәсең, бер чәнчем инде. – *стрл.*

**ЧӘНЧИ: чәнчи ағач** *перм.* к.: **силә 1**.

**ЧӘНЧҮ 1.** *трх.* к.: **қадау II**. Марталар бәч чәнчеделәр, моный, моный; **2.** *брб.д.* к.: **қақлау II, 1**. Кечерткән чәнчә ғуй у, ачыттыра; **3.** *перм.* тезү (нанизать, выстраивать в ряд). Баллы чәкчәккә канфитлар чәнчеп җийалар. Көлтәне чәнчеп барасың иртәңге йақта чық булса, анан сосланға әwәсең.

**чәнчү әкәләсе** *бәр.* шайтан таягының чәчәк төймәсе (бутон чертополоха).

**чәнчү печәне** *каз.ар.-крш., бәр.* шайтан таягы (чертополох). Чәнчү печәне чәнечкеле ул, шайтан кермәсен дип ишек башына қуйалар. – *каз. ар.-крш.*

**чәнчү уты** *к.т.* к.: **чәнчәwек**. Қаты чәнчү белән awырғанда чәнчү утын парлап эчертәләр.

**чәнчү үләне 1.** *чст.* к.: **чәнчәwек; 2.** *дөб.* кыр яраны (герань луговая).

**ЧӘНЧҮWEЧ** *чст.* чәнечке (вилка). Чәнчүwеч тә биргән идем, аша.

**ЧӘҢГЕЛДӘҮ** *бәр., кмшл., мәл.* талашу (ругаться). Миңға чәңгелдәргә шул җитә. – *бәр.* Чәңгелдәмәгәйе, аларның бөтен эше чәңгелдәү. – *кмшл.* Зәрә бәбәгеннән нәстә чәңгелдисең. – *мәл.*

**ЧӘҢГЕЛДЕК 1.** *перм.* к.: **чолдор I; 2.** *стрл.* төбе киндердән, читләре агачтан эшләнгән бишек (люлька, низ которой сделан из холста). Бишек кабыктан йасыйлар, бөгәлҗә куйабыз кабык бишеккә, ә чәңгелдек киндердән була.

**ЧӘҢГЕЛЧӘК 1.** *минз.* к.: **сәлей**. Чәңгелчәктә балам йатмый, барысына да барам; **2.** *тбл.* тарантас, читән арба (тарантас). Чәңгелчәкнеңке карзинасын үреп қуйалар.

**ЧӘҢКЕЛТӘК** *минз.* к.: **чәңгелдек 2**. Безнең инәй туғыз бала үстерде шул бер чәңкелтәктә.

**ЧӘҢҚҮ** *перм.* күшегү (зябнуть, мёрзнуть); чаг.: **чирайу**. Әллә бармақ чәңкеде шуны эшләгәнче дә, җемерҗеп тора, қатты.

**ЧӘП** [*рус.* цепь] *лш.* к.: **чип I**. Чәп белән суғалар ийе, дүрт чәп, биш чәп белән суғалар ийе, үзенең көйә бар ийе.

**ЧӘПӘК** *хвл., чст.* к.: **бал′ук**. Керләрне чәпәк белә чәпәп-чәпәп йудым. – *чст.*

**ЧӘПӘЛӘЙ** *дөб., блт.* йон җебеннән бәйләнгән чүәк (тапки, вязанные из шерстяной нитки). Мә, чәпәләй ки айағыңа. Чәпәләй кийеп қарыйм. Шушындыймы чәпәләйе? – *блт.* Чәпәләйенне кем бәйләп бирде? – *дөб.*

**ЧӘПӘЛӘК 1.** *бөре.* к.: **бал′ук; 2.** *дөб.* зур булмаган таякка резина кагып ясалган чебен үтергеч (мухобойка). Чәпәләк белән үтер чебенне; **3.** *дөб.* к.: **ләпләмә**. Элек айа йы, хәзер чәпәләк. Чәпәләк белән айалағанда мамық күбрәк чыға, җайлы да.

**ЧӘПӘЛЕК** *мәл.* ямаулык (заплата). Сезнең чәпәлек йукмы, күлмәк йыртылган мында?

**ЧӘПӘЛҮ** *минз.* бәрелү, сылану (шлёпнуться, влепиться). Күлмәкнең җиңе күдгә килеп чәпәлде.

**ЧӘПӘМӘ** *стрл.* к.: **бал′ук**. Чәпәмә белән шомартадыйык ул киндерләрне шап-шап сугып.

**ЧӘПӘҮ I** *стрл., минз.* бәрү, сугу (шлёпнуть, стукнуть, ударить). Теге ташны чәпәп җибәрде туп чәпәгән шикелле. – *стрл.*

**ЧӘПӘҮ II** *мәл.* чәпелдәтү (чавкать).

**ЧӘПӘШ** *дөб.* чүпрәктән тегелгән чүәк (тапки, сшитые из тряпки); чаг.: **чаштый**. Балаларға чәпәшләр тегеп кийерер ийем.

**ЧӘПЕ 1.** *кузн.* чүпрәк (тряпка). Бер чәпе ала да астына куйа; **2.** *шрл.* идән мунчаласы (мочалка, швабра).

**ЧӘПЕ-ЧОПЫ** *срг.* к.: **цәпе-цепе**. Чәпе-чопыларны алып бетергән.

**ЧӘПЛӘ** [*рус.* цапля] *хвл., мәл.* к.: **сузан 2**. Чәплә кеше. Бик чәплә дә инде. – *хвл.*

**ЧӘППӘР** *перм.* карыш (пядь). Дүрт чәппәр – бер аршын, алты чәппәр бер митыр була.

**ЧӘПҮ 1.** *минз.* к.: **чәпәү I**. Өйгә алып кереп чәпедем балчыңны; **2.** *мәл.* ягу (мазать, намазывать). Камырга бәрәңге чәписең.

**ЧӘПЧӘК I 1.** *лмб., кузн., мәл., чст., хвл., кас., м.-кар., карс., влгг.* к.: **чапчақ 1, 2**. Ит тозлаган бер чәпчәк. – *влгг.* Бер чәпчәк суны йаңлыш түккән. Чәпчәк тә генә чәпчәк сары май, Кенгә генә каршы эреттем (*хал. җыр.*). – *кузн.* Чәпчәккә тутыр арышны. – *лмб.* Бер чәпчәк ит тозладык. – *мәл.*; **2.** *лмб.* мичкә (бочка). Вата чәпчәккә сал кывасын. – *чст.* Чәпчәк борыннан бар. Кырга су ташыйлар чәпчәк белән. – *хвл.* Чәпчәктә кәбестә тозлый. Сил′уткы чәпчәге. – *м.-кар.*

**ЧӘПЧӘК II** *дөб.* төелгән киндер орлыгына бал кушып пешергән түгәрәк шарчыклар (еда в виде мелких шариков, испечённых из толчёной конопли с мёдом). Бүсерле кешегә чәпчәк йасатып ашаталар ийе, орлоғ онона бал тугып пешерәләр ийе. Бүсере қузғалды әле қартның, чәпчәк йасыйм әле, киндер орлоғы эзләп җәридерийем.

**ЧӘПЧӘ'** *кас.* к.: **чапчақ 1, 2**.

**ЧӘПЧӘНДҮК** *шрл.* таган (качели). Чәпчәндүктә атыныр килгән дә awылда, мында килгәч чәпчәндүк таптыра икән.

**ЧӘПЧЕК** *глз.* к.: **турғай**.

**ЧӘПЧЕР: чәпчер итми'и** *кас.* чәчрәтү (разбрызгивать).

**ЧӘПЧҮ** *хвл., мәл.* чәчрәү, чәчрәп түгелү (расплескаться, выплёскиваться). Сывың чәпчи, тихарак баргайдең. – *мәл.* Сывың чәпчи, әкренрәк бар. – *хвл.*

**ЧӘПЧҮР 1.** *минз.* итек кебек итеп тегелгән кыска һәм тар кунычлы аяк киеме (кожаная обувь с коротким и узким голенищем); чаг.: **қата I, 1**. Yde қунычлы ул чәпчүр, моннан сеңерле, сыйраққа җабышып торор ыйы; **2.** *шрл.* к.: **чаштый**; **3.** *брб.д.* эшкәртелмәгән, иләмәгән тиредән теккән аяк киеме (поршни). Чәпчүр кийә идек аш цацқанта, тәрене кәсеп тегәделәр, бөрәделәр, қойашта йөрсәң қатып қалаты.

**ЧӘРӘПИНКӘ** *тмн., лмб., кузн.* к.: **чирәп I, 1**.

**чәрәпинкә бүрек** *тмн.* түгәрәк очлы бүрек (папаха).

**ЧӘРГӘЙ** *брб.д.* к.: **чәркәй**. Тәрәзләр ачық, чәргәй толуқ.

**ЧӘРДӘКЛӘҮ** *т.я., каз.ар.* вак-вак итеп тишкәләп бетерү – көя турында (сильно изъесть – о моли). Кизитекләргә көйә төшкән, wич җырмачлап, чәрдәкләп бетергән. – *к.т.*

**ЧӘРЕ** *кузн., каз.ар.-крш.* к.: **тике**. Үгә чәре киттем. Безнен кабак эскә чәре барганнар. Йы-

мырка чәре шеште вет. Крыват чәре сындык китергән. Абидга чәре. Йахшы тегел ары чәре барырга. Туганнан үскәненә чәре. – *кузн.* Өчкә чәре саный. – *каз.ар.-крш.*

**ЧӘРЕК** *чст.-крш.* к.: **чарык I, 1.**

**ЧӘРЕКСЕЗ 1.** *мам., дөб.* чыдамсыз, түземсез (неустойчивый, невынословый); чаг.: **хәстәрле 2.** Дуңғыз бит чәрексез, қарамасаң хәзер үлә; **2.** *мам., минз.* тотрыксыз, тиз сынучан яки уалучан – агач, үлән турында (некрепкий, неустойчивый, ломкий, хрупкий – о дереве, о сене). Чәрексез агач, сына да тора. Йәш нарат чәрексез була, төзелешкә йарамый, сағызланмас борон. Бик чәрексез ул (үлән), бөтеннәй қойолоб бетәр. – *мам.* Нарат ағачы чәйерләнергә тиеш, чәйерләнмәсә чәрексез була ул. – *минз.*; **3.** *минз.* чыдамсыз, таза түгел, нык түгел – кеше турында (невынословый, некрепкий – о человеке).

**ЧӘРЕКСЕD** *минз.* к.: **чәрексез 2, 3.** Чәрексed ул тупыл. Чәрексed дә түгел үdem.

**ЧӘРЕП: чәреп басмау** *т.я.-крш.* к.: **айақ II: айақ салмау.** Ышкулга чәреп басмаган иде, ди, үзе укып өрәнгән. Чегендер булмаса, катыны чәреп басмый эшкә.

**ЧӘРИК 1.** *чст.-крш.* к.: **чарык I, 1.** Ишәле урамын җери-җери Чуклы чәригеме туздырдым. Чуклы чәригеме туздырмадым, Җәшлек дәwереме уздырдым (*хал. җыр.*); **2.** *м.-кар.* чүәк (тапочка); чаг.: **чаштый.** Безне картлар чәрикләр белән куйдырмыйлар (мәетне).

**ЧӘРКӘ I** *миш.д., минз.* к.: **тыйрак II.** Чәркә севәге. Чәркәңне капмасын эт. Чәркәсеннән тытып выргыткан, ди, алашаны. – *лмб.* Чәркәләреннән сүрәп кертермен. Чәркәләре шонон тике. – *кузн.* Катыннын айаклары шешкән иде, чәркәләре. – *хвл.* Ике чәркә дә шулай, менә wы төз бегелергә бирми. Этләре бар шул, әллә ни чәркәңе фәлән тешләр. – *мәл.* Кас'ынарда кала аслажнинйы вана, күзләре шешеп чыга, чәркәләре. – *шрл.* Чәркәмне бәрдем. – *тмн.* Йаланайақ йөриләр бит, чәркәләрен күрсәтеп. – *минз.*

**чәркә йомшагы** *тмн.* к.: **айақ II: айақ қорсағы.**

**ЧӘРКӘ II** [*рус.* чарка] **1.** *каз.ар.-крш., мам., минз., лш., чст.-крш., мәл.* к.: **чәрке 1.** Тустаған қәтле бар бу чәркә. – *каз.ар.-крш.* Р'умка да йарый, чәркә дә йарый пилмән кисәргә. – *чст.-крш.*; **2.** *каз.ар.-крш.* стакан кебек эшләнгән йөз граммлы рюмка (стограммовая рюмка); **3.** *мам., лш., минз., мәл.* кечкенә агач табак (маленькая деревянная чаша); чаг.: **айак I, 1; кәнди I, 2.** Бер чәркә аш эчми. – *мам.* Сәкегә сыра мичкә қуйалар терәтеп, чәркә белә эчерәләр, ағачтан була ул. – *лш.* Бәбәкләре чәркә хатле. – *мәл.*; **4.** *крш.* стакан; **5.** *нгб.-крш.* аяклы рюмка (рюмка с ножкой). Биллесен чәркә, диләр. Чәркәне алып бир әле; **6.** *минз.* тарелка.

**ЧӘРКӘЙ** *брб.д.* чебен (муха). Йәйкетә чәркәй кән қый. Әнә тоупса (тәрәзә төбе) толған чәркәй менән (белән).

**ЧӘРКЕ** [*рус.* чарка] **1.** *перм., чст.-крш.* йөз граммлы рюмка (рюмка стограммовая, стопка). Бер чәрке арақы эчеп төрөнөп йаттым да тирләтте әле. Қунақларға қуйды, үзенә чәрке қуймады. – *перм.* Питырның мәниннигендә wатылды теге чәрке. Пилмән камырын чәрке белән кисәм мин. – *чст.-крш.*; **2.** *лш.* кечкенә стакан (маленький стакан).

**ЧӘРКЕМӘ: чәркемә килү** *дөб.* ду килү, пыр тузыну, сугышу-кыйнашу (поднять шум, устроить драку); чаг.: **чауғу 2.** Чәркемә килеп суғышып йаталар. Тегеләр тағын чәркемә килгәннәр.

**ЧӘРКЕМӘЛӘ** *дөб.* к.: **чәлкәмәрә.** Чәркемәлә суғышалар икән.

**ЧӘРКИ 1.** *глз.* кунычлы күн ботинка (ботинок с голенищем по щиколотку). Кунычлы батинка инде у чәрки. Кунычлы бәтинкә кебек була иде, чәрки дип әйтерлер ийе тәтәйләр; **2.** *яүшт.* күн аяк киеме (кожаная обувь типа ботинок). Чәркине күннән тегәсең, эрзиңке итекләр йуғ иде. Чәрки қунычлы да була, қунычсыз да була.

**ЧӘРЛӘҮ** *минз.* чәрелдәү (визжать). Тик кенә тор, чәрләмә!

**ЧӘРМӘТӨП** *перм.* к.: **намазҗәй.** Чәрмәтөпне килен аппара, җегетнең атасына бирә.

**ЧӘРНӘЙ, ЧӘРНИ** [*рус.* ?] *трбс.* һәртәрле ашый торган үләннәр (всякие съедобные травы). Чәрни җыйарға киттек.

**ЧӘРПӘК** [*рус.* черпак] *дөб.* к.: **кәпкер II, 1.**

**ЧӘРТАЛ** *брб.д.* таллык (тальник).

**ЧӘРЧӘ** [*фарс.*] *дөб.* тәрәзә яңагы утырту өчен чабыла торган киртек (зарубка, куда вставляется оконный косяк).

**чәрчә чабу** *дөб.* киртек ясау (делать зарубку). Чәрчәне чаба тор, чәрчә чawып беткәч йаңғақларын қуйарбыз.

**ЧӘРЧӘКЛӘҮ** *блт., кргл., бгрс.* чәрдәкләү (раздробить, разломать, расщепить на мелкие кусочки). Бер ағачны йәшен суғып китте, чәрчәкләп петерде. – *блт.*

**ЧӘРЧӘКЛЕ** *лш.* четерекле, саклык кирәк булган (щепетильный, требующий внимания, осторожного обращения); чаг.: **чәрчекле.** Соло бик чәрчәкле ул, чүт җил булдымы – қойола.

**ЧӘРЧЕКЛЕ** *минз.* четерекле (щепетильный). Қайнанасы бик чәрчекле кеше.

**ЧӘРЧЕҢҮ** *мәл.* үзалдына мыгырдану, ачулану (недовольно бормотать про себя, сердиться, раздражаться). Нәстә чәрченеп утырасың?

**ЧӘРШӘННЕ** [*фарс.*] *срг.* к.: **қанкөн.**

**ЧӘРШЕ** *бөре.* печән киптерү өчен колгалардан шалаш сыман итеп ясалган җайланма (конусовидной формы приспособление из жердей для просушки сена). Чәршегә қуйалар, черетми печәнне халық.

**ч ә с** *әҗе.* чәч (волосы):

**чәс анасы** *әҗе.* балага бер яшь булгач, аның чәчен алучы хатын-кыз (женщина, стригущая волосы ребёнка, когда ему исполняется год). Зәш тулгач, атасымы, анасымы цәцен ала, цәцен алган катын чәс анасы була.

**ЧӘСӘТИЙ** *кас.* яшь баланың беренче чәчен алучы ир кеше (мужчина, который состриг первые волосы младенца).

**ЧӘСТӘРҮШКӘ** *туб.-урт.д.* тарак (расчёска).

**ЧӘСТӘТӘ'** *кас.* к.: **чәс: чәс анасы.**

**ЧӘТ: чәт итә алмау** *шрл.* ышанып җитмәү, кыючылык итмәү (не решаться; не надеяться, что у тебя получится). Базарда кырып китермәгәннәр

картаны, үзем чистартырыма чәт итә алмагач, алмадым.

**ЧӘТӘ** *стрл.* к.: **маман 1**. Нуми Нәгыймә үлгән, бер чәтә хатын ийе.

**ЧӘТӘБИ** *минз.* к.: **чәтердек**.

**ЧӘТӘН** *мам.* к.: **тыйрақ II**. Шәрә чәтән дип беркем әйтми сине (кара булгач). Нечкә чәтәнле кеше.

**ЧӘТЕРДЕК** *т.я.* артык күп сөйләүче (говорунья, болтунья); чаг.: **телазар**. Әй ул чәтердектә тел генә бит, қулыннан ни килә! – *к.т.*

**ЧӘТЕРМӘН I** *т.кам.-крш.* сазлы болын (болотистый луг); чаг.: **сувалма**. Бүген без чәтермәндә печән чабабыз.

**ЧӘТЕРМӘН II** *к.т.*, **ЧӘТЕРТӘК** *минз.*, **ЧӘТЕРТӘН** *т.кам.-крш., минз.* үткен, телгә-жавапка оста (бойкий, острый на язык); чаг.: **чарыс 3**. Ул бик чәтермән қатын. – *к.т.* Чәтертән бу бала бик. – *т.кам.-крш.*

**чәтермән кебек** *к.т.* к.: **чәтермән II**. Қызлары чәтермән кебек, телгә-тешкә биг оста.

**ЧӘТЕРТЕК** *минз.* к.: **чәтердек**. Бу қатын чәтертек.

**ЧӘТИ I** *перм.* к.: **чәтердек**. Белеп сүлиме, белми сүлиме, теләсә ничек сүләгән кешене ай чәти дип қуйалар.

**ЧӘТИ II** *минз.* кечкенә балага орышып әйтү сүзе (форма сердитого обращения или упрёка к маленьким). И чәти!

**ЧӘТЛӘWЕК** *перм., к.-уф.* к.: **чики 1**.

**қысық чәтләwек** *перм.* к.: **қосоқ 1**. Қысық чәтләwек бийек шыршыда үсә.

**ЧӘТНӘБИ** *кмшл., минз.* к.: **чәтермән II**. Айһай, бигрәк чәтнәби қатыны.

**чәтнәби кебек** *минз., кмшл.* к.: **чәтермән II**. Аның қызы чәтнәби кебек. – *кмшл.* Аларның чәтнәби күwек бер қызы бар. – *минз.*

**ЧӘТНӘТКЕЧ** *хвл.* к.: **ләпәмә I**.

**ЧӘТТӘ** *трбс.* к.: **маман 1**.

**ЧӘҮКӘ** *каз.ар.-крш.* к.: **чәбен**. Кипкәч печәнне чәүкәгә қуйабыз, чәүкә-чәүкә қуйабыз.

**ЧӘҮКӘБАШ** *тара.* тукранбаш (клевер). Печән ташлатық, чәүкәбашның йысы тәмнү.

**ЧӘҮМӘЛДӘРЕК-ТАҚТАЛДЫРЫҚ** *к.т.* балаларга тирбәлеп уйнар өчен җайланма: озын тактаны бүрәнәгә аркылы куеп, ике башына ике кеше утырып тирбәлә (один из видов детской качалки, состоящей из длинной доски, устроенной поперёк бревна).

**ЧӘҮМӘЛҮ** *к.т., блт.* **1.** кыегаю, бер якка янтаю, авышу, бер башы күтәрелү, мәс., эскәмия, такта турында (покоситься, приподняться одним боком или концом); чаг.: **awышайу**. Қарап кер, басма тактаң чәүмәлмәсен. Қара, мин торам, эскәмийәң чәүмәлмәсен. – *к.т.* Идән чәүмәлә, бер башын булса да қадақлап қуйасы бар. – *блт.*; **2.** аву, егылу, мәтәлеп егылып төшү (упасть). Син тағы суға чәүмәлмә. Сәндрәдән чәүмәлеп төшә йаздым. – *к.т.*

**ЧӘҮМӘЛЧЕК** *блт.* к.: **ботқа: йаңгор боткасы**.

**ЧӘҮЧӘК** *мам.* тиктормас, хәрәкәтчән (непоседа, неспокойный – о ребёнке). Безнең қыз бик чәүчәг ул, тиктормас.

**ЧӘҮЧӘЛӘК** *мам., минз., кргл., кмшл., бгрс., стрл.* көянәк, юкка-барга борчылучан кеше (беспокойный, беспокоящийся по пустякам). Үзе дә чәүчәләк, ақыра, килене дә чәүчәләк. – *кмшл.* Берсе бик чәүчәләк, берсе бик сабыр инде. Мин тырышсам да симерә алмыйм, чөнки мин сабыр түгел, чәүчәләк. – *стрл.* Үтә чәүчәләк мин, шуңа күрә йабық. – *мам.* Инәсе чәүчәләк, атасы сабыр гына аның. – *кргл.*

**ЧӘҮЧӘЛӘКЛӘНҮ** *мам., минз., стрл.* көяләнү, борчылу (беспокоиться по пустякам, раздражаться, болезненно реагировать на всё); чаг.: **чапалану 2**. Жуққа-барға чәүчәләкләммәгән теге, йәпйәш көйә йәри. – *минз.*

**ЧӘҮЧӘЛӘКЛЕК** *мам.* көянәклек; көючән, борчылучан булу (раздражительность, болезненное реагирование на всё). Артық чәүчәләклек белән дә берни эшләп булмый.

**ч ә ч I** (волос):

**чәҗ башы** *м.-кар.* толым очы (кончик косы). Чәҗ башына тәңкә тагып Жөрөр идем кыз булсам (*хал. җыр.*).

**чәч қабы** *мам.*, **чәч капчыгы** *лмб.* к.: **сылawыщ**. Чәч қабына тәңкәне турыга ғына тезәләр ийе.

**чәч тә баш** *мам., каз.ар.-крш., к.т.* тарау, тузылган (разбросанный, беспорядочный). Балалар әрәхәтләнгән уйнап, урын-җирләр бар да чәч тә баш. – *мам.* Әйберсе чәч тә баш. – *каз.ар.-крш.* Җый бу кәгәзләреңне, чәч тә баш йата. – *к.т.*

**чәч тәңкәсе** *мам.*, **чәч тезмәсе** *мам., лш.* к.: **сылawыщ**. Чәч тәңкәсе бар ийе. Ун митыр ситса апқайттым чәч тәңкәсенә. – *мам.* Чәч тезмәсе бар ийе, тәңкә тезгән, артқа салалар ийе. – *лш.*

**ЧӘЧ II** [*рус.* часть] *каз.ар.-крш.* к.: **бай II**.

**чәчкә керү** *каз.ар.-крш.* өлешкә керү, катнашу (принять участие в чём-либо, внести свою долю). Келәү җасағанда кем нәрсә бирә алса, шуның белә чәчкә керә.

**ЧӘЧАВЫЗ** *тмн.* к.: **чәс: чәс анасы**. Кем выт пирвыйгы чәчен кырккан, чәчавыз ат'абез, үзенеке йакыныннан кыс-катыннан кырыктыра.

**ЧӘЧАПА** *тмн.* баланың иң беренче чәчен алучы кыз кеше (девушка, которая состригла первые волосы младенца).

**ЧӘЧӘ** *тмн.* тәти (игрушка, побрякушка). Чәчәләр бирәм кызыма.

**ЧӘЧӘБИЧӘ** [*рус.*] *срг.* ясмык (чечевица). Каташлыкка арыштан гайре сабан ашлыгы бары да керә: соло, арпа, бодай, чәчәбичә.

**ЧӘЧӘК I** *т.я.-крш.* яфрак (лист дерева). Урман җакта карама, Ничек чәчәк йара ла, Матур кызлар билен бугис, Ничек атлап бара ла (*хал. җыр*).

**ағулы чәчәк** *блт.* **1.** зәһәр казаяк (лютик едкий); **2.** агулы казаяк (лютик ядовитый).

**айлы чәчәк** *чст.* **1.** к.: **ағулы чәчәк 1, 2**; **2.** акчәчәк, ромашка (ромашка непахучая).

**әпипә чәчәге** *клм.* тузганак (одуванчик).

**бжан чәчәге** *мам.* карабаш (черноголовка).

**бүwын чәчәк** *мам.*, **бүwынтықлы чәчәк** *дөб.* к.: **бишбарнақ**.

**бүрәнкә чәчәк** *мам.* кыңгырау чәчәк (колокольчик).

**дawыл чәчәге** *дөб., каз.ар.* к.: **ағулы чәчәк 1, 2**.

**җитен чәчәк** *блт.* көтүче сумкасы (пастушья сумка).

**қамыш чәчәге** *кргл., бөре.* к.: **ағулы чәчәк 1, 2.**

**мең дә бер чәчәк** *лш.* меңьяфрак, ярмабаш (тысячелистник).

**сағызлы чәчәк** *минз.* дегет чәчәге (смолка липкая).

**төкле тура чәчәге** *мам.* к.: **бжан чәчәге.**

**чалғы чәчәге** *к.т.* кыр яраны (герань луговая).

**чәчәк утлап** *лш.* кайгы-хәсрәт күрмичә, авырлык күрмичә (не зная забот, не зная нужд). Дөнйада чәчәк утлап йәшисез сез хәзер, дим балаларға. Чәчәк утлап йөри диләр нужа қумағанны, әрәхәтләнеп матур җөргән кешене.

**чәчәк чыгару** *клд.* чәчәккә бөреләнү (набухание бутонов). Чәчәк чыгарган дамыни?

**чәчәккә бару** *брб.д.* көннең иң озын чагында үләннәр җыярга чыгу (ходить собирать лечебные травы летом в то время, когда дни бывают самые длинные); чаг.: **сәгәт: сәгәт суққан көн.** Қайчан чәҗәккә барабыс тип йөриделәр пашлықлар, унйите сәат соуқсо өлөңнөр, чәҗәкләр йийадылар.

**ЧӘЧӘК II 1.** *хвл., тмн., лмб., баст.* к.: **чачақ 2.** Очона сылawычның йалгаган чәчәк, көргәзергә бар иде сылawыч. – *тмн.* Әнийемнен бар әле озын чәчәкле шәле. – *баст.* Бик зур йылы шәлләр йабыналар иде, бармак калыннык чәчәкләре була иде. Шәл чәчәге. – *лмб.* Ылан тегел вит, эскәтер чәчәкләре белән ун'аб утырасын! Шәл чәчәге. – *хвл.*; **2.** *минз., стрл.* чуклы-чачаклы калфак (калфак с бахромой).

**ЧӘЧӘК III** *каз.ар.-крш.* к.: **қатый.** Менә без бәйрәмнәрдә чәчәк пешерә торған ыйық, май белә күкәйгә генә пешерәбез, машинасы бар кисә тоғон, майға салып пешерәбез.

**чәчәк IV** (оспа):

**алла чәчәге** *к.-уф.* чәчәк авыруы (оспа).

**әҗәл чәчәге** *лмб.* яман шеш (рак). Әҗәл чәчәге чықты да кулына, үлде.

**бишек чәчәге** *каз.ар.-крш.* су чәчәге, җил чәчәге (ветрянка).

**чәчәк анасы қалу** *каз.ар.* чәчәк авыруыннан өзлегү (получить осложнение от оспы). Чәчәк анасы қалып суқырайды қызы. – *дөб.*

**чәчәк йулы** *дөб.* чәчәк авыруын имләү ысулы: авыруның буе озынлыгында кисеп балага бирелгән кызыл тасма (один из знахарских способов лечения оспы). Чәчәк йуллары дип үзе буйы қызыл линте үлчәп бирәләр ийе чәчәк белән awырса.

**чәчәк кисү** *стрл.* чәчәк салу (прививать оспу).

**ЧӘЧӘК-ҚАЛПАҚ** *каз.ар.-крш.* әлек қызлар кия торган баш киеме: чигүле, чуклы зур калфак; башка кигәч чуклы түбәсе аркага салындырып куела (в старину: девичий головной убор у крещёных татарок). Кичке уйынға балитәкле күлмәкләр кийеп, алйапқычлар, тамақсалар бәйләп чығалар, чәчәк-қалпақлар кийеп.

**ЧӘЧӘКЛЕ** *срг., хвл., лмб.* чуклы (с кистьями, с кисточками). Дзебәг эрфәкләр бар иде ызын чәчәкле. – *лмб.* Чәчәкле шәл. Чәчәкле эскәтер. – *хвл.*

**ЧӘЧӘЛӘК** *минз.* бәйләнчек, гаугачыл кеше (придирчивый, скандальный человек); чаг.: **чечеркле.**

**ЧӘЧӘЛӘНҮ** *каз.ар.-крш., трх.* к.: **чилләнү.** Әй чәчәләнергә тотона бер сүз әйтсәң. – *каз.ар.-крш.* Теге қыз чәчәләнеп атты инде, әни чақырды бит дип. – *трх.*

**ЧӘЧӘЛИ** [*рус.* чечевица] *лмб.* к.: **чәчәбичә.** Чәчәли чәчә идек элек, эшти күмәч пешерә идек.

**ЧӘЧӘНИ** *тмн., кузн.* к.: **чәс: чәс анасы**; чаг.: **чәчапа.** Йегетнең сеңлесеннән, атасының радн'асыннан кыркыталар, анарга бүләк бирергә кирәк, йезег үтә генә кисәләр чәчне, анарга чәчәни этәләр. – *кузн.*

**ЧӘЧӘҢКЕ** *перм.* кырку – аш турында (кислосолёный – о супе). Чәчәңке булып пешә ул тоз салсаң. Борчақлы аш та чәчәңке була қый.

**ЧӘЧӘТҮ** *перм.* томалау, тончыктыру – үсемлек турында (заглушить, погубить – о растениях). Җawын чәчәтмәсме шалқанны?

**ЧӘЧӘҮЧӘ** [*рус.* чечевица] *кузн.* кыр тайтоягы, ярут (ярутка полевая).

**ЧӘЧБҮЙ** *минз.* к.: **арт III.**

**ЧӘЧБҮ** *каз.ар.-крш.* к.: **сәсбау.** Чәчбү белән чәч үрәләр.

**ЧӘЧЕ 1.** *минз., перм., каз.ар.-крш.* көлтә, урылган карабодай, борчак, ясмык h.б. киптерер өчен, колгалардан шалаш сыман итеп ясалган җайланма (конусовидной формы приспособление, сооружение из жердей для просушки снопов, скошенного гороха и т.п.). Чәчегә қуйалар җawымны җылларны борчақны. – *минз.* Қарабодай апқайту белән чәчегә қуйаң, астын бушрақ иттерәң, киптерергә. – *каз. ар.-крш.*; **2.** *чст., стрл.* к.: **чәрше.** Чәчегә куйалар инде йә печән, йә салам үwәләр. Чәчегә үгеннәр икән астыннан дзил йөреп торыга. – *чст.* Йаңгырлы булса, чәчегә куйалар көлтәне, печәнне дә шулай киптереп булашалар. – *стрл.*

**ЧӘЧЕЛДЕРҮ** *перм.* очыртып җибәрү; тәгәрәтү, тәгәрәтеп җибәрү (отбросить, отшвырнуть). Күтәрмәдән тибеп чәчелдерәм дә торам, ди, әпкилеп кенә қарасын, ди.

**ЧӘЧЕЛМӘ** *лш.* тармаклы (ветвистый, разветвлённый). Чәчелмә қайын төбөндә, Чәчен тарый бер матур (*хал. җыр.*).

**ЧӘЧЕЛМӘЧЕР** *кргл.* таралып, киртәләнмичә (открытый, незагороженный). Татар зираты бар, чәчелмәчер тора.

**ЧӘЧЕЛҮ** *перм.* **1.** егылу, барып төшү, тәгәрәп китү (упасть, свалиться); чаг.: **тәгәрәү.** Тубығыма төрткән генәйе кәзәтәкә, чәчелдем дә төштөм. Исән көйгә генә чәчелеп китеб үлү сирәк була бит; **2.** к.: **чәпчү.** Чуwашларның қапқачлы була май чапчақ, қаймақ чәчелми.

**ЧӘЧЕШҮ** *перм., клм.* сибешү (брызгаться, брызгать друг в друга). Җылға буйда сыу чәчешеп уйныйбыз ий. – *перм.* Йамқыр йуқта ол тау башқа кәттәк, тawық пежердек, соу чәчештек. – *клм.*

**ЧӘЧИ I: чәчи кечерткән** *лмб.* к.: **кесеркән.**

**ЧӘЧИ II** *хвл.* к.: **бармақ: гөлчәчәк бармақ.**

**ЧӘЧҚАП** *минз., бөре.*, **ЧӘЧКАП** *кузн., хвл.* к.: **арт III.** Элек қызны қодаларға барғач, «Чәчқабы, дәwәте бармы?» дип сорағаннар. Чәчқап чәч толомо белән бергә йөртөлә; тар итеп материйәдән

сырыла, өстөнә өч рәт тәңкә тезелә, очонда йә бөтөнлек, йә чулпы була, бау белә башқа бәйләп қуйыла. Мескен Маһирәттәй ұлгәнчәк шалтор-шолтор чәчқап тағып йөрде. – *минз.*

**чәчкә** *минз., бөре.* чәчәк (цветок):

**ипи чәчкәсе** *минз.* к.: **баллықай**.

**ЧӘЧКЕЧ** *карс.* ук (жало – у пчёлы, у крапивы); чаг.: **қайау**. Кечерткәннең вет чәчкечләре чагып ала.

**ЧӘЧЛИБАШ** *хвл.* тузгак чәчле (с лохматыми волосами, лохматый). Төпчегем чәчлибаш иде, сылу иде, үмере генә булмады.

**ЧӘЧМӘ** *клм.* к.: **чардак 1**. Үлеккә генә чәчмә йасыйлар.

**ЧӘЧРӘМӘ** *блт.* сабырсыз, кызу канлы (горячий, вспыльчивый, нетерпеливый). Болай салмақ қына хатын ийе, чәчрәмә дә түгел.

**ЧӘЧРӘТКӘ** *кузн.* чәчкапның бер төре: чәч үремнәре өстенә куела торган тасманың яки тукыма кисәгенең уртасына тугыз эре тәңкә тезелә, ян якларына сабаклаган ун тиенлек тәңкәләр тезеп чыгыла (один из видов накосного украшения).

**ЧӘЧРӘҮ** *минз., стрл.* дөмегү, олагу (сдохнуть, подохнуть, провалиться). У, чәчрәгере малай. – *минз.*

**ЧӘЧТАСМА** *перм.* к.: **сәсбау**.

**ЧӘЧТӘҢКӘ** *мам., лш., нрл., кргл.* к.: **манит 2**. Минем әнинең чәчтәңкәләре бар ыйы, көмөш ийе. – *мам.* Әби патшалы чәчтәңкәме жуғалттым, чын көмөш ди торғаннар ыйы аны. – *лш.*

**ЧӘЧТЕЗМӘ** *мам., нокр.* к.: **арт III**. Чәчтезмә артта чәчтә, алда ачқычбау, бетүләр белән булған. – *нокр.*

**ЧӘЧТЕРҮ** *лмб.* чактыру (ужалить). Кыртлардан чәчтердем.

**ЧӘЧҮ I 1.** *лмб., карс.* к.: **қадау II**. Марталар чәчмиләр үземне, аны чәчәләр. – *лмб.*; **2.** *лмб., карс., брб.д.* чәнчү (колоть, уколоть). Башын чәчкәннәр, ыршышкан да. Мыны чәчкәлиләр дә выргыталар. – *лмб.* Пестән йырақ түгел перәү изереп перәүне чәчкән. – *брб.д.*; **3.** *карс.* к.: **қақлау II, 1**. Анда бытыңны кечеркән чәчә; **4.** *т.я.-крш.* тегү (шить). Ире чәчкән моның зурлык, жүли белмәгәненә; **5.** *т.я.-крш.* к.: **чәнчү 3**. Кашбуга кылбу да чәчәләр; **6.** *т.я.-крш.* сую – дуңгыз турында (колоть – свинью). Бозау суйган, дуңгыз да чәчкән; **7.** *брб.д.* к.: **чәнчәү**. Укул чәчеп кенә торды; **8.** *брб.д.* кадау (воткнуть). Тайағын чәчкән, анта аш бешереб утырған.

**ЧӘЧҮ II** *трх., минз., кмшл., лмб., хвл., чст., карс., мәл., стрл.* утырту – яшелчә һәм бәрәңге турында (сажать, посадить – об овощах и картофеле). Бәрәңге чәчәләр суқа белән. Бәрәңге чәчәргә ат йуқ. – *трх.* Бәрәңге чәчкәндә бозаулаған ийе сийырыбыз. Сездә кәбестә чәчәләрме? – *минз.* Бәрәңге чәчәргә йөрдем. Суган да чәчмиләр, кәбестә дә чәчмиләр хәзер. – *стрл.* Бәрәңге чәчәбез, айағында вал'ник. – *карс.* Алмалар чәчмәгән иде әлдә, мин килдем. – *лмб.*

**ЧӘЧҮ III** *перм., брб.д.* сибү, сибеп жибәрү, түгү – сыек әйберләр турында (расплескать, разбрызгать, пролить – о жидкостях); чаг.: **чәпчер: чәпчер итми'и**. Йақшы ғына утырайы, Мансур бал чәчте. Су чәчелгән. Бидрәнеңке сыwын чәчми генә китерә йәш килен. – *перм.* Өйлек (үлек, мәет) сыwы чәчкәннәр ишегалныгызға. – *брб.д.*

**нуғыт чәчү** *т.кам.-крш.* нугыт белән күрәзәлек итү (гадать на фасолях). Мин дә нугыт чәчә белә-дер ийем, қырық бергә хәтле саныйлар аны.

**ЧӘЧҮ IV** *минз.* к.: **чилләнү**. Бик нык чәчедем, хәйерле булсын.

**ЧӘЧҮ V** *әстр.* үлгән кешене искә алу мәжлесендә өләшенгән акча (деньги, раздаваемые участникам поминок).

**чәчү чәчү** *әстр. чәчү* (V) өләшү (раздавать деньги участникам поминок).

**ЧӘЧҮРЕМ** *каз.ар.-крш.* к.: **тезмә 1**. Чәчүремнең очона ике-өч бүwынны чулпы тагыла.

**ЧӘЧҮРМӘ** *чст., мәл.* к.: **сәсбау**. Чәчүрмә куйалар, шының әстенә сикереп тешә килен. – *чст.*

**ЧӘЧХАП** *кузн.* к.: **арт III**. Чәчхап: ике әрәт манит, очка табан ыwаклана бара; ике йакта элмәкләр, анда чәчне куйа иде.

**ЧӘШЕ** *минз., стрл.* к.: **чәрше**. Чалаш фурмылы йасыйлар да өстенә йаwымны йылларда печән таратып киптерәләр. – *минз.*

**ЧӘШКАСЫ** *трх.* к.: **җәйләү**.

**ЧӘШКӘ** [*рус.* чашка] **1.** *трх.* к.: **айақ I, 2**. Чәшкәләрне үwеп қуй. Тарил'ка, чәшкә тутырылған; **2.** *тбл.* икмәк савыты (хлебница).

**чәшкә асты, чәшкә табағы** *трх.* к.: **җәйләү**. Чәшкә асты ғына кирәк, чәшкәсе бар.

**ЧӘШКЕ** [*рус.* чашка] *чст., чпр., хвл., стрл.* **1.** к.: **айақ I, 2**. Йезнәңне чәшкеләр алырга калдырганнар. – *чпр.* Бер-ике чәшке генә чәй эчәрсез инде. Берәр чәшке чәй эчәйек, кунаклар килә. – *хвл.* **2.** к.: **җомор**. Бер-ике чәшке генә җиләк җыйган көн буена. – *стрл.*

**чәшке өсте** *стрл.* к.: **җомор**. Бидрада да сет бар, чәшке өсте белә чыгыб ал.

**чәшке табагы** *чпр., байк.* к.: **җәйләү**. Әз генә итеп чәшке табагына ашны салдым. – *байк.*

**ЧӘШНӘК** [*рус.* чеснок] *тара.* суган (лук). Чәшнәк туткаға китеп йатады.

**ЧӘШХӘ** [*рус.* чашка] *саз.я.* икмәк пешерә торган калай форма (металлическая форма для выпечки хлеба).

**чәшхә итмәх** *саз.я.* калай формада пешерелгән икмәк (хлеб, испёченный в форме).

**ЧЕ!** *минз.* гаҗәпләнүне белдерә торган ымлык сүз (слово-междометие, служащее для выражения удивления). Че! Ақчалғач байыққан, күрмәй дә бара.

**ЧЕБӘЛҮ** *карс.* **1.** ара бозылу (рассориться, разладиться). Аралары чебәлеп, начар торды кыз, килде йыл тулгач. Аннан сың инде чебәлә башлыйлар, туйалар бер-берсеннән; **2.** чуалу (путаться). Кеше ирләре белән чебәлмәсен.

**ЧЕБЕК** *кргл.* нечкә, нәзек (тонкий). Инде бәләкәй, инде чебек бу қыз.

**ЧЕБЕКИ: чебеки чығу** *лш.* к.: **кәшәләү II, 2**.

**ЧЕБЕЛДЕК** *миш.д.* чыбылдык (полог). Чебелдегемне кырдыгыз, Чәчәге сайын тырдыгыз... Чебелдек кенәм чып-чывар, Чебеннәр кунса, кем кывар (*бор. жыр.*). – *лмб.*

**чебелдек бечү** *күрш.* әлек: кызны килешкәч,

туйдан берничә көн элек кыз ягында кызлар ашы уздыру (старинный свадебный обычай проводить у помолвленной девушки вечеринку за несколько дней до свадьбы). Син – кыдаги, улыңа аласын минем кызымны, кыдачалар йибәрәсен, шунда бер кич кызлар утыра, чебелдек бечү әтелә инде, гастиничлар куйасын эстәлгә.

**ЧЕБЕН** 1. *мәл.* к.: **озонайак**. Карлыганга барган идем урманга, йаман да чебен талады; 2. *лмб.* к.: **йомоқ I**.

**wак чебен** *хвл.*, **қаз чебен** *бөре* к.: **йомоқ I**.

**кара чебен** *мәл.* чебен (муха). Жар чагында ызбада йаман да кара чебен күбәйде.

**сурый чебен булу** *мәл.* әрсезләнү (проявлять беззастенчивость, быть пронырой).

**ЧЕБЕРДЕК** *лш., к.т.* вак-вак, бик вак, кечкенә (очень мелкий; мелко-мелко; маленький); чаг.: **бетеки 1**. Өй тулы бала-чага, бар да чебердек. Чебердек кенә итеп йазған, танып та булмый. – *к.т.*

**ЧЕБЕЧ** *перм.* тавык (курица). – Күкәйең йуқмы, апа? – ди. – Чебечләрем аз ғына, сатмыйм мин, – дим. Көртлек чебеч.

**ЧЕБЕШ** 1. *лмб., хвл., кузн., чпр., т.я.-крш.* к.: **бала I, 2**. Үзе вет бер чебешен йугат′мый, бер чебешен үтерми (каз турында). – *кузн.*; 2. *нокр.* к.: **әнәч 1**. Чебеш буласы йиде, әтәчләре күбрәк.

**пар чебеше** *минз.* инкубаторда чыгарылган чебеш (цыплёнок, выведенный в инкубаторе).

**ЧЕБЕШКЕ I** *минз.* каен агачы кабыгындагы қутыр, кытыршылык (шершавость коры берёзы). Йәш қайынның чебешкесе күп.

**ЧЕБЕШКЕ II** *кмшл., кргл.* кечкенә агач яки металл савыт (металлическая или деревянная миска, небольшая мисочка).

**ЧЕБЕШКИ** 1. *кмшл.* к.: **чебешке II**; 2. *стрл.* чокып ясалган, буялган, капкачсыз агач савыт (маленькая, разукрашенная деревянная мисочка).

**ЧЕБИ** 1. *мам., блт.* к.: **әнәч 1**. Бер оядан бер генә чеби дә булмады, бар да әтәз. Ул ақлар икесе дә чеби – ике ақ тawығым буласы. – *мам.*; 2. *минз., кузн.* к.: **бала I, 2**. Үрдәк чебиләре кебек минем дә ақ (каз бәбкәләре турында). Қаз чебиләренә була җилдә утырдым. – *минз.* Казыбызның чебиләре чыкты, йиде. – *кузн.*

**ЧЕГЕРДӘҮ** *перм.* сайрау – чикерткә турында (петь – о стрекозе, сверчке). Чегерткә чегердәгәндә чегерт-чегерт итеп тора.

**ЧЕБРИК** *мам.* пәрәмәч (перемяч).

**ЧЕБРҮК** *клм.* 1. чүпрәк (тряпка); 2. тастымал (ручное полотенце, салфетка).

**ЧЕГӘН: чегән арбасы** *дөб.* к.: **йара II: йара йапрақ**.

**ЧЕГӘШ** *дөб.* к.: **кирәмәт 2**.

**ЧЕГЕЛДЕК** *срг.* бодай онынан пешерелгән вак күмәч (лепёшки из пшеничной муки).

**ЧЕГЕРТКӘН, ЧЕГЕРТКИН** *перм.* к.: **кесеркән**.

**чегерткин печин** *перм.* ак баллут; сукыр кычыткан (яснотка белая; глухая крапива).

**ЧЕКАЙ** *чст.-крш.* фарфор. Чекай тәликә куйдым эстәлгә.

**ЧЕКӘ** *кас.* нечкә (тонкий); чаг.: **нәзек I**.

**ЧЕКЕРӘЙҮ** *перм.* к.: **йырчыклану**.

**ЧЕКЕРЕШ** *перм.* к.: **йырчык**. Бик шәп эшләгәнгә чекереш күп минеке.

**ЧЕКЕРТКӘН** *брб.д.* к.: **кесеркән**.

**ЧЕКЕРТҮ** *лш.* күз төшү (приглянуться, влюбиться); чаг.: **күзәүләү**. Матур қызға чекерткән.

**ЧЕКЕРҮ** *чпр.* эч китү (расстройство желудка, понос). Ылан чекерә башлады.

**ЧЕКИ** *нрл.* к.: **чики 1**. Мының қадәр буладыр ийе кишәнкесе эрбет чекийенең.

**ЧЕКРӘН** *нгб.-крш.* 1. сеңер (сухожилие). Чекрәне сузылған; 2. к.: **тыйрақ II**.

**ЧЕКРИ** *дөб., мам., блт.* тыйнаксыз, әрсез (беззастенчивый, нахальный); чаг.: **битсез, қырчын**. Қызлары бик чекри. – *блт.* Балалары бигрәк чекри, күзеңгә керәм дип торалар. – *мам.* Чекри түгел баласы, бик инсафлы. – *дөб.*

**ЧЕКҮ** *лмб.* кагу, чиртү (слегка постучать пальцами). Тәрәзәне чеки.

**ЧЕЛ** *брб.д.* боҗыр (рябчик).

**ЧЕЛӘН** *мам.* к.: **селәү II, 1**. Балық тотабыз, қармаққа челән кидерәбез дә.

**ЧЕЛӘНИ** *нокр.* к.: **рәшмән**.

**ЧЕЛӘҮЧӘН** *мам., блт.* к.: **селәү II, 1**. Челәүчәнем бетте дә мин қайтып киттем, әй қабадырыйы балық. – *мам.*

**ЧЕЛБӘЙ** *срг.* к.: **цилбәй**. Челбәйе үдә йук Алийәнен, армийәдә.

**ЧЕЛБӘНҮ** *хвл.* к.: **чебәлү**. Атның йаллары челбәнгән кебек була, йырт анасы үргән, диләр.

**ЧЕЛГӘН** *чст.* к.: **пысқыш**. Кичкырын челгән белә утыра тырган идек.

**ЧЕЛГИ** 1. *хвл., кузн., стрл., мәл., влгг.* сөял (бородавка). Шул челгигә кырк түwен бәлиләр и белəккə бәлиләр, йеп йугалганча йөриләр. – *кузн.*; 2. *лмб.* бетчә, сыткы (прыщь, угорь). Битемә зур гына челги чыккан.

**ЧЕЛДЕБИ** *минз.*, **ЧЕЛДЕМБИ** *мам., дөб.* кечкенә дә, ябык та булган кеше (человек одновременно и худой, и маленького роста); чаг.: **челчемби**. Син дә зур гәүдәле түгел инде, челдемби генә. – *дөб.* Челдемби генә қатыны бар шуның. – *мам.*

**ЧЕЛДЕР** *срг.* к.: **арт III**.

**ЧЕЛДЕРӘҮ** *перм.* еш тибү – йөрәк турында (учащённо биться – о сердце); чаг.: **султыклау**. Йөрәкләрем челдери.

**ЧЕЛДЕРДӘҮ** *лмб.* чылтырау (звенеть). Сәәт челдердәде.

**ЧЕЛДЕР-ЧАЛДЫР** *перм.* к.: **қылқа I**. Челдер-чалдыр жемпер-фәлән йуқмы?

**ЧЕЛЕГҮ** *каз.ар.-крш.* 1. шытырдап кибү, бик артык кибү (пересохнуть); 2. к.: **көйрәү 1**; 3. бик ныk ашыйсы килү, берәр нәрсәне ашарга тилмерү (сильно желать есть, иметь сильное желание поесть что-либо). Аш ашарға челеккәннәр икән бу трактарислар.

**челегеп кибү** *каз.ар.-крш.* к.: **челегү 1**.

**ЧЕЛЕКТЕРҮ** *каз.ар.-крш.* шытырдатып киптерү, бик артык киптерү (пересушить). Печәннәрне челектереп бетермә.

**ЧЕЛЕМ** *тбл.* челем (курительная трубка).

**челем чәчәк** *т.кам.-крш.* баллы чәчәк (льнянка).

**ЧЕЛИ: чели күз** *к.т.* чекерәеп караучы, күз-

ләре белән тишәрлек итеп караучы (о человеке со сверлящим взглядом).

**ЧЕЛИЙҮ** *каз.ар.-крш.* ябыгу, ябыгудан яңаклар бату (похудеть, осунуться); чаг.: **йадаулану**. Кипкән инде, челийеп кенә қалған.

**ЧЕЛКӘ** *чст.* аклы-каралы, чуар (белый с чёрным, пёстрый). Челкә сарык.

**ЧЕЛКӘWEЧ** *к.-уф., перм.* к.: **йулпуч**. Челкәwечкә он илиләр, қамырны ипи чиләгенә изәләр бездә. – *перм.*

**ЧЕЛКӘР** *кмшл., каз.ар.-крш.* к.: **кыкычыбар**.

**ЧЕЛКӘР-ЧЕЛКӘР** *каз.ар.-крш.* сипкел (веснушки).

**ЧЕЛКИ** *хвл.* к.: **йомоқ I**.

**ЧЕЛЛӘ 1.** *тмн., мәл.* нәкъ үзәге (самый центр). Самый челлә тешендә торабыз каланың. – *тмн.*; **2.** *хвл.* түбәнең иң очы, иң өсте (самая макушка, самая верхушка). Тауның челләсенә менеп йиттек тә; **3.** *лмб., хвл., кузн.* нәкъ (точно, как раз). Мин килдем челлә шал чакта. Челлә убуркы вакыты. – *лмб.* Азбарның кабагы челлә йул өстендә, йулның урталыгында тора икән. – *кузн.* Йулның челлә уртасына җәйәләр. – *хвл.*; **4.** *кузн.* к.: **дибә**. Барган иде, челлә иртүк китте.

**ЧЕЛЛӘЛЕК** *влгг.* чикерткә (стрекоза).

**ЧЕЛЛИ I** *чст.-крш.* челлә, җәйге челлә (пора самой сильной жары). Челли айы җәй кене эссе багытта инде.

**ЧЕЛЛИ II** *мам.* к.: **селәү II, 1**. Челли җыйа, балыққа барам дип җәри.

**ЧЕЛТЕМБИ** *мәл.*, **ЧЕЛЧЕК: челчек ламба** *тбл.*, **ЧЕЛ-ЧЕЛ** *чпр., чст.* к.: **пысқыш**. Чел-чел лампы белән кырачин бетә иде дә, май йандыра идек. – *чст.*

**ЧЕЛЧЕМБИ** *дөб.* к.: **челдеби**. Эй бигерәк челчемби дәйнде бу Фазыл абый.

**ЧЕМ I** *каз.ар., каз.ар.-крш., т.кам.-крш., чст.-крш.* **1.** к.: **бәлчә 2.** Алма чеме. Шоморт чеме. Чеменнән өзмәгез алманы. Безнең урам озон урам, Баш-башында алтын бағана; Қарағыз ла безнең қодаларға, Чемнәрендә үскән бағалма (*хал. җыр.*). – *каз.ар.-крш.* Чийә чемнәрендә булсаң, Алыр ийем йәшереп (*хал. җыр.*). – *мам.* Бер чемендә унар тугызарый чикләwек. – *т.кам.-крш.*; **2.** касә яфрагы (чашелистик). Җиләкне чемнәре белән җыйғаның. – *мам.*; **3.** гөлҗимеш борынчыгы (усик – у ягод шиповника). Чемен чистарттыралар ийе гөлҗимешнең, хәзер өздермиләр дә. – *т.кам.-крш.*

**ЧЕМ II** *дөб.* чын (настоящий, натуральный, истинный). Чем гәрәбәләр булайы, чем мәрҗәннәр булайы.

**ЧЕМӘК 1.** *чст.* тупса кендеге (стержень дверной петли); **2.** *трх.* сумка яки кошелёк бикләвеченең шар формалы башы (шаровидная головка защёлки сумки или кошелька). Сумканың кечкенә генә чемәге бар, шуны басқач, ачыла да китә; **3.** *мам.* к.: **бәбәк II**. Суған чемәге; **4.** *к.т., мәл., м.-кар.* агач бөке, тыккыч – мичкә, сыра чүлмәге кебек әйберләрдә (деревянная затычка, пробка – напр., у бочки и т.д.). Күрчәгәнең чемәген сылыйлар қамыр белән, пичкә қуйалар. – *к.т.*

**ЧЕМӘЛТЕ** *брб.д.* к.: **қымрысқа**.

**ЧЕМЕК I** [*рус.* семик] *перм.* к.: **мәйдан**. Матурны бирәләр қый чемеккә тастымалны.

**ЧЕМЕК II** *твр., тара.* к.: **тутыртма II, 2**. Эчәкбаwырны турап чемек йасайлар. – *твр.*

**ыwыс чемеге** *твр., тара.* угыз тутырмасы (домашняя колбаса из молозива).

**ЧЕМЕКИ** *чпр., трх., чст.* к.: **пысқыш**. Чемеки лампы төтеннән утыра, пузырʹы да булмый. – *трх.* Чемеки лампы белән таң атканчы борының тетен белән тула. – *чст.* Чемеки лампа. – *чпр.*

**ЧЕМЕЛДЕК** *яүшт.* сызык (шкварки). Хәзер тугымнык, чемелдекне ашамыйлар.

**ЧЕМЕЛ-ЧЕМЕЛ: чемел-чемел көлү** *т.я.-крш.* чырык-чырык көлү (хихикать, смеяться). Уйын-уйын, дидегез, Уйын эчен үлдегез. Без уйынга чыккистан, Чемел-чемел көлдегез (*хал. җыр.*).

**ЧЕМЕТЕК** *дөб.* кечкенә, чеметем (маленький; мало). Бер чеметек тиритурийәгә қайсы бозау китерә.

**ЧЕМЕТЕП** *мам., глз.* бөреп (делая сборы). Күлми'ләрне чеметеп теккәндә. – *глз.* Билен чеметеп тексең, матур ғына була инде бу күлмәк. – *мам.*

**ЧЕМЕТКӘН** *мам., т.кам.-крш.* бераз бөргән (с редким сбором). Күлмәгемнең қултығаслары киң, өститәге чеметкән. – *т.кам.-крш.* Чеметкән итәкле күлмәгемнең итәгенә тасма да тотқан ийе. – *мам.*

**ЧЕМЕТҮ** *мам., лш., төм.* камырны: бөгү, тоташтыру (защепить тесто). Қапшырма осоррақ, цөцөгә, ошнан чеметеп-чеметеп қуйасың. – *төм.* Аның бөккән чеметкәнен карап торасым килә, бигрәк тә матур йасый инде. – *мам.*

**ЧЕМЕЧКӘ** [*рус.* семечко] *минз., стрл.* к.: **чемечки 1**. Чемечкә майы алдым. – *минз.*

**ЧЕМЕЧКЕ** *твр., тбл.* бетчә (прыщик). Чемечке қутырлаған. – *твр.*

**ЧЕМЕЧКИ** [*рус.* семечки] *минз., стрл.* **1.** көнбагыш төше (семечки). Чемечки ашый төш. – *стрл.* Чемечки майын йаратмайым. – *минз.*; **2.** к.: **айбағар**. Чемечки кисәргә барабыз, чемечкинең кар өстендә башы шулай ғына. – *стрл.*

**ЧЕМКӘ** *т.кам.-крш.* к.: **бәлчә 1**. Чемкәсендә ике-өч кенә қалған қарлыган.

**ЧЕМКЕТҮ** *перм.* к.: **кабу I, 2**. Җә чемкетерләр җат кешеләрне теге чәйни торған нимәләр.

**ЧЕМНӘҮ** *дөб., мам., лш., блт., бәр.* чистарту, арчу – җиләк-җимешне, яшелчәне (очистить – о ягодах, овощах). Систалап йуғанда чемнәмәсәң дә йарый. – *дөб.* Шомортны җыйа бардық, чемни бардық. – *мам.* Кил, җиләк чемнәшергә кеше кирәк. – *бәр.* Урман аwызына чыққач, утырып чемнәдек. – *лш.* Чикләwек чемнәгәндә қуллар әчетеп бетәдер ийе. Чемнә чәйеңә җиләкләрне. – *мам.*

**чемнәп җыйу 1.** *лш.* сабагы белән, касә яфрагы белән җыю (собирать вместе с чашелистиком, с ножками). Җиләкләрне чемнәп җыйабыз, қура җиләген гел чемнәп җыймыйбыз, аны тартып-тартып қына аласың; **2.** *мам.* чистартып җыю – җиләк-җимешне (собирать очищая – о ягодах и т.п.). Чемнәп бер чиләк җиләк җыйғаннар.

**ЧЕМТЕКЛӘҮ** *кузн.* чеметү (щипать, щипнуть). Йорт анасы чемтекли, диләр.

**ЧЕМТИ** *чст.* к.: **пысқыш**. Чемти лампа.

**ЧЕМЧЕК** [*рус.*] *минз.* вак суган (сеянец, се-

вок). Орлоғон чемчек итеп чәчәбез, чемчеген киләсе җылға чәчәбез.

**ЧЕМЧЕКЛӘҮ 1.** *мам.* чемченү, аз-маз гына, сайлап-сайлап кына ашау (есть выбирая, понемногу); чаг.: **қорлану**. Үрдәк булса, хәзер сосоп бетерә, болар (казлар) бик чемчекләп кенә ашый; **2.** *лш.* к.: **хәсийәтләү**. Җәүликмәкне җоморҡалар сытып чемчекләп пешерәләр, қыстыбый тышын алай чемчекләп тормыйлар инде; **3.** *кргл., бгрс.* астыртын талау, җанга тию (терзать, мучить исподтишка). Шулай дип мине чемчекли. – *бгрс.*

**ЧЕМЧЕМ** *твр.* чеметем (щепотка). Ике чемчем тыражи саласың та күбәте.

**ЧЕМ-ЧЕЧЕ** *перм., тмн.* төп-төче (пресный). Учакта тыра иде тү үрәсе, ул чем-чече була иде, шуны квашн'ага сала. – *тмн.* Маланны пичкә утыталар арыш он беле, чем-чече була қый у. – *перм.*

**ЧЕНАЗА** [*гар.*] *лмб., карс.* җеназа (треба, отпевание). Ченаза намазы укибыз. – *карс.*

**ЧЕНЕ** *тара.* к.: **җомор**. Пер чене соу эчте.

**чене йаулық** *тара.* чынаяклар өстенә ябып куя торган кечкенә җәймә (маленькая салфетка для чайных чашечек на столе).

**ЧЕҢ: чең кийе** *чст.-крш.* туйда кызга карата махсус көй белән җырлана торган җырлар (один из старинных свадебных обрядов – песни, посвящённые невесте). Кыз беркәнчег астында җата, кыз җаны кызлар чең кийен җырлыйлар инде.

**ЧЕҢГЕРТКӘ** *тпк.* к.: **чигеркә**.

**ЧЕҢГЕРҮ** *клд.* ат эчерү (поить лошадь). Сыw бармы, бажай, барып чеңгерергә кәрәк.

**ЧЕҢНӘҮ 1.** *каз.ар.-крш.* чыңнау, җырлатып елатудан гыйбарәт булган кыз елату йоласы (один из старинных свадебных обрядов – плач невесты, состоявший в том, что невеста в определённый момент пела песни о своей несчастной доле и плакала; иногда вместе с ней пели и подруги или же приглашались специальные плакальщицы); **2.** *т.кам.-крш.* туйда киленнең елап җырлау йоласы (обряд причитания девушки во время свадьбы). Қызлар туй җыры җырлый, ә килен чеңней инде уртада, менә болай-болай селкенеп болганып утыра ул.

**ЧЕП I 1.** *перм.* катылган йон җебе (ссученная шерстяная нитка); **2.** *к.-уф.* йон җебе (шерстяная нитка). Чеп ирләп қуйам наскиға.

**ЧЕП II** [*рус.* цеп] *тмн.* к.: **чип I**.

**ЧЕПА: чепа-йаланғач** *перм.* к.: **ана-тума**. Арта чепа-йаланғач киттем.

**ЧЕПЕЛДЕК 1.** *дөб.* к.: **чақ I, 2**. Мының күк түтәппел түгел, ул – чепелдек; **2.** *к.т.* тәмлетамак, тәмле ашарга-эчәргә яратучы (лакомка, любитель полакомиться). Чепелдек, чәй җаныннан бер китми тәмне әйбер булса.

**ЧЕПЕЛЧИ** *хвл., мәл.* чи, пешеп җитмәгән (недопечённый, непропечённый, сырой – о хлебных изделиях); чаг.: **ләчкелдәгән**. Әпәйләре чепелчи булган. – *мәл.* Әпәйләрем чепелчи булган. – *хвл.*

**ЧЕПЕР** *срг.* к.: **пал'ак**.

**ЧЕПЕРИК** *перм.* **1.** чүпрәк, чүпрәк кисәге (тряпка). Чепериктән теwеннәгән туп; **2.** чынаяк япкычы (салфетка, которой накрываются чашки и пр.). Әнә анда җаба торған чепериге; **3.** к.: **бистәр: чәй бистәре**. Өстәл чеперик. Чынийақ чеперик. Қул чеперик.

**ЧЕПЕШ** [*рус.* щипцы] *минз.* к.: **җәмкә**.

**ЧЕПИ I** *глз.* чуртан (щука).

**ЧЕПИ II: чепи күз 1.** *мам., хвл.* кысык күз (узкие глаза; узкоглазый). Чепи күзле генә, бәләкәй генә қыз ийе. – *мам.*; **2.** *блт.* начар күрә торган күз (о глазах, которые плохо видят).

**ЧЕПИЙӘК** *бөре.* к.: **озонайақ**.

**ЧЕПКИН** *перм.* к.: **чипкән**.

**ЧЕПЧӘГИ** *нокр., глз.* чәкчәк (татарское национальное кушанье, чакчак). Кийем алып баручылар қыз йақтан чепчәги алып баралар (туйда). – *нокр.*

**ЧЕПЧӘРӘ** *клм.* к.: **шөшпәрә**. Бесгә чепчәрә йасап ашатты.

**ЧЕП-ЧЕБҮРИНКЕ** *т.кам.-крш.* эремчек белән онны кушып, йомыркага басып, вак кисәкләргә бүлеп майда пешерелгән камыр ашы (мучное блюдо, жаренное в масле; в тесто кладут яйцо и творог). Чеп-чебүринке пешерәбез: барукны күкәй белән туглыйбыз, җемышақ қына итеп аг оннан қамыр басабыз да, шар итеп йасыйбыз да майға салабыз, күпереп пешкәч, пилмән чүмече белән алабыз сөзеп.

**ЧЕПЧИНӘ** *чст.-крш.* кыр эшләре беткәч яшьләрнең өйдән өйгә кереп җырлап-биеп күңел ачып йөрүләре (один из видов молодёжного гуляния после завершения полевых работ: молодёжь ходила из дома в дом, пела песни, плясала и т.д.). Җалтаннар (*ав. ис.*) чепчинә, диләр, без, кызлар, эчкесе, дибез, ул кызлар эчкесен инде кызы булса да, булмаса да кертәдер ийек.

**ЧЕРӘЙСЕС** *кас.* ямьсез (некрасивый); чаг.: **қонарсыз; сурәбәт**.

**ЧЕРӘПСӘ'** *кас.* к.: **қыйсар**.

**ЧЕРӘШЕП** *т.я., каз.ар.* артык көч куеп, көчәнеп (с большими усилиями, с большим напряжением, изо всех сил). Ат черәшеп тарта. Черәшеп йабышқан. – *лш.* Бик артығын черәшмә, йарый ла қәдереңне белсәләр. – *мам.*

**черәшеп утыру** *к.т., лш., мам.* к.: **қағайу: қағайып утыру 1.** Көнө буйы бүген тегү белән черәшеп утырдым. Утырма инде черәшеп, hаман йазу белән, күзләрең бетәр. – *к.т.*

**байлыққа черәшеп бетү** *мам.* бик нык баю (сильно разбогатеть); чаг.: **байығу**.

**ЧЕРГӘЙ** *твр., брб.д.* к.: **чәркәй**. Чергәйләр толпты. – *брб.д.*

**зор чергәй** *брб.д.* зур яшькелт чебен, кунак чебене (большая зеленоватая муха). Зор чергәй тә бар қой (бит).

**ЧЕРГЕ 1.** *кузн.* сарык йоныннан басылган киез (кошма, войлок). Идәненә черге йәйгән; **2.** *брб.д.* камыш чыпта (маты из камышей). Қамыштан черге согадыған, алайға йәй(еп) қойадыған.

**ЧЕР'И** *кас.* к.: **черге 1**. Идинди дүрт илили' чер'илир буладыр ийе.

**ЧЕРГИЙӘК: чергийәк чебен** *клм.* к.: **йомоқ I**.

**ЧЕРДЕ** *к.-уф.* вак балык төре (вид мелкой рыбы).

**ЧЕРЕК** *м.-кар.* тишек, тузган (дырявый, ста-

рый). Башта черек җаулык, пич суткәндә. Черек җаулык бәйләдек, җебәк җаулыгы байларда гына булды.

**баба череге** *лш.* черек көле, агач череге (древесная труха).

**ЧЕРЕКЕЙ** *кас.*, **ЧЕРЕКИЙ** *бөре.* к.: **озонайақ.** Безди черекейлир би' 'үп. – *кас.* Черекий тешнәде танавымны. – *бөре.*

**ЧЕРЕКЛЕК: бер череклек** *хвл.* өч литр (три литра). Бер череклек сете булды, әнийем сауды йылап-йылап.

**ЧЕРЕМӘ: черемә күкәйе** *т.кам.-крш.* игеннәр уңсын өчен дип, басуга күмелә торган йомырка (ритуальные яйца, собранные и закапываемые в поле для того, чтобы хорошо уродился урожай).

**черемә җыйу** *т.кам.-крш.* пасха бәйрәме үткәч, басуга алып чыгып күмү өчен йомырка җыю (сбор яиц перед началом посева для закапывания в борозду); чаг.: **чирмә.** Аннары берсе черемә җыйа, бөтен кеше аңар күкәй бирә, ул черемә күкәйен басуга итеп күмәләр, игеннәр уңсын дип.

**ЧЕРЕТҮ** *перм.* бөтерү, әйләндерү – орчык турында (крутить, вертеть – о веретене). Җеб ирлибез орчоқлар беле черетеп. Черетмәсәң, җебе үрелми, үрелеп тора wы череттең исә.

**ЧЕРКӘМ 1.** *дөб., блт., минз., стрл.* эшкә әрсез, нык, чыдам (неприхотливый, крепкий, стойкий). Эшкә черкәм қызлар булып чықтыгыз сез. – *минз.* Бик черкәм ул, нинди эшкә тотонса, шуны эшли. – *блт.* Черкәм тырышлыгым белән генә барам. – *стрл.*; **2.** *минз., дөб.* к.: **чарыс 3.**

**ЧЕРКӘМӘРӘ: черкәмәрә килү** *дөб.* ватылып бетү (совершенно сломаться, совсем поломаться). Черкәмәрә килеп беткән тешем бар.

**ЧЕРКЕН** *твр., тара., том.д.*, **ЧЕРКИН** *тара.* шапшак, пычрак (грязный, гадкий). Черкен халық тора икән анта, йыбышуны белмиләр, ти икән. – *твр.*

**ЧЕРЛӘҮ** *мам., каз.ар.-крш., минз.* к.: **қортлау II.** Бер тawығым черләп утыра икән ойада. – *мам.* Барыбер салмый инде ул, черли башлый аннары. Тawықларым бик черләде, утыртмадым гына. – *каз.ар.-крш.* Черләмәй бит ул тawық кирәк wақытта. – *минз.*

**ЧЕРНӘЙ 1.** *мәл.* елак (плакса). Чернәй бака пистакта, аны чышканнар тарта; **2.** *кмшл., хвл.* к.: **чақ 1, 2.** Бер чернәй генә кыз бит, нинди авыр күтәргән! – *хвл.*

**ЧЕРНӘКИ: чернәки кебек** *мәл.* ябык, чандыр (худой, тощий). Чернәки кебег идем, әлтәмәм йуг иде.

**ЧЕРНӘҮ** *мәл.* елау, чер итү, юк-барга да еларга тору (ни с того ни с сего плакать, пищать).

**ЧЕРТЛӘМӘ** *минз.*, **ЧЕРТЛИ** *мам., блт.* күлмәктәге яки сумкадагы кнопка-бикләвеч, кнопка-каптырма (застёжка-кнопка – у одежды или сумки). Чертлийе тотмый, ачыла да китә, ачыла да китә халатым. Зур чертли қуйғаннар сумкасына. – *мам.*

**ЧЕРТМӘ I** *брб.д.* берничә ел чәчелмичә тотылган җир (залежь).

**ЧЕРТМӘ II** *дөб.* черемә (перегной, компост). Чертмә алып китегез.

**ЧЕРҮ: қырым черүwe чақлы (хәтле)** *к.т.* бик күп, күпсанлы (о большом количестве чего-либо); чаг.: **айап 1.** Қырым черүwe чақлы бала-чағасы.

**ЧЕРЧЕК I** [*рус.* сверчок] *дөб., шрл.* өй чикерткәсе (сверчок). Черчек керсә, йықы бирми ул. – *дөб.*

**ЧЕРЧЕК II** *перм.*, **ЧЕРЧЕ'** *кас.* к.: **чақ I, 2.** (Баласы) бетеки генә, черчек. – *перм.* Черче' чебеш. – *кас.*

**ЧЕРЧЕКЛӘНҮ** *лш.* **1.** җентекләп карау, тикшерү (проверить тщательно, досконально); чаг.: **чемчекләү 1; 2.** ваклану (мелочиться). Черчекләнеп эзләб утыра.

**ЧЕРЧЕКЛӘҮ** *м.-кар.* ваклану (быть мелочным, разборчивым). Энде черчекләмитләр, ничек тә бара.

**ЧЕРЧЕКЛЕ** *лш.* вак, җентекле (скрупулёзный, тщательный, требующий подробностей). Син бик черчекле эшкә чыққан икәнсең.

**ЧЕРЧЕТ** *трбс.* бәйләнчек, үҗәт – кеше турында (навязчивый, назойливый – о человеке).

**ЧЕҮГЕЦ** *яүшт.* сөзгеч (цедилка).

**ЧЕЧБӘРӘ** *твр.* к.: **шөшпәрә.**

**ЧЕЧЕ 1.** *карс.* баллы – бал, шикәр кебек татлы әйберләр турында (сладкий). Чече чәй. Бик чече эчә, вич шәкәрне тейи чәйенә; **2.** *карс.* төче, әчетелмәгән (пресный). Чече камырны шылай әwәлисен дә; **3.** *лмб., чст.* чәй эчә торган һәртөрле тәмле әйберләр, шикәр-конфет һ.б. (сладости к чаю: сахар, конфеты и пр.). Лаукага чече килгән. – *лмб.* Кызыкам чечеләрне йебәреп тыра. – *чст.*; **4.** *чст.* тозы җиңел, тозы аз (недосолёный). Чече булса, тыз салыгыз түwен белән.

**ЧЕЧЕК** *перм.* к.: **мәмәч.** Тузны чечек wахытында төшөрөп қалырға кәрәк, печәннән элек.

**қайын чечек** *перм.* к.: **цөцөк.** Қырыб ашыйлар қый, қайынны қабығын суйғач, шул қайын чечек була.

**ЧЕЧЕЛИ** *тмн.* төче (пресный, в пресном виде). Була чечели катлама, ачытминча чечелидән бешерәсең, ул инде кетер-кетер итә.

**чечели бәлиш** *брб.д.* җиләк-җимештән әзерләнгән татлы бәлеш (сладкий пирог с начинкой из ягод и фруктов). Чечели бәлиш йасайын бырусниктан, бик санлы, бик ыспай була, чөчө булады ашарга.

**ЧЕЧЕРЕКЛЕ** *мәл.* бәйләнчек (назойливый, навязчивый); чаг.: **бәтрәк.** Кычык кебек, чечерекле нәстә.

**ЧЕЧЕТКЕЛИЙ** *карс.* төчегә, төче көе (пресно, в пресном виде). Бәлеш тә бар, бар да бар, ачытқылыймы йук, чечеткелийме йук.

**ЧЕЧЕТҮ** *карс., чст.* төчетү, баллы итү (сделать сладким). Шәкәр йуктыр, пәсүк мән чечетегез чәйегезне. – *карс.*

**ЧЕЧИКАЙ** *чст.-крш.* к.: **чекай.** Чечикай тәликәне тешереп wаттым куркудан.

**ЧЕЧКА** *глз.* чәчәк (цветок).

**сагат чечка** *глз.* к.: **күгәрчен: күгәрчен тәпийе.**

**ЧИ** *нрл.* юеш (мокрый, влажный). Җүwешмән чи ызбада була. Тотоп қарамадым, қулым чи.

**чи йат** *карс.* бөтенләй ят, чит (совершенно чужой). Иртә тырып син китәсен Чи йатлар арасына (*хал. җыр.*).

**чи май** *карс., влгг.* ак май (сливочное масло, нетоплёное масло). Чи майлата сатыла иде. – *карс.*

**чи сөт** *минз., стрл., тпк.* кайнамаган сөт (молоко некипячёное). Чиләтә сатыб алганда, сөтнең банкысы кырык тин. – *стрл.*

**чи таш** *әстр., влгг.* саман кирпече (саманный кирпич).

**ЧИБА** *м.-кар.* хатын-кызлар кия торган чигүле киндер җилән (женская вышитая лёгкая одежда из холста); чаг.: **чоба.**

**ЧИБАЙАК** *хвл.* нечкә аяклы кеше (тонконогий человек).

**ЧИБӘ** *кас.* чеби (цыплёнок).

**ЧИБӘР 1.** *кмшл., чст.* әйбәт, яхшы характерлы (славный, с хорошим характером). Малай белгән кеше инде, әтисе-әнисе чибәр кешеләр. – *кмшл.* Хазайкам бик чибәр иде. – *чст.*; **2.** *каз.ар., т.я.* к.: **ару I, 8.** Быйыл игеннәр чибәр күренә. – *к.т.* Кайбер бакчаларда бәрәңгеләр чибәр. – *дөб.*

**чибәр җиңги** *мам., каз.ар.-крш.* иренең абыйсының хатынына эндәшү сүзе (форма уважительного обращения к жене старшего брата мужа).

**чибәр тутай** *чст.-крш.*, **чибәр түти** *т.кам.-крш.* әнисенең *кыямәтлегенә* эндәшү сүзе (посажёная мать своей мамы и форма обращения к ней). Чибәр түти дип әнинең әңкийен әйтәләр, әңкий булгач, ир җәгыннан җәкын туганы ул, әңкий кеше оло кеше булған ул, үзенең анасыннан тары бөртеге хәтле генә айырыла ул.

**ЧИБӘРӘЙҮ** *мәл.* к.: **арулану.** Хазыр чибәрәйдек инде, байыды тырмышыбыз.

**ЧИБӘРТТӘЙ** *брб.д.* әтисенең олы кыз туганына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей родственнице отца).

**ЧИБЕР** *перм.* чибәр (красивый).

**чибер күшә** *перм.* к.: **чиберкәй.**

**ЧИБЕРКӘЙ** *перм.* бәрәңге күшәсе (бутень клубненосный).

**ЧИБЕШ** *нокр.* к.: **чак I, 2.**

**ЧИБҮРӨК** *клм.* чүпрәк (тряпка). Чибүрөкнө алсаң, аныңкы астында кыргайак була.

**ЧИВ** *лмб.* көяз (франт, щёголь). Кан′ам бар иде, кечкенә генә иде, чив кешиде йәж вакытында.

**ЧИҒАН** *минз., перм.*, **ЧИГАН** *стрл., мәл., кузн.* чегән (цыган). Чиғаннар аман да шулай күченеп җөрөрләр микән? – *минз.* Кызы чиган булып кийенгән иде. – *кузн.*

**чиган мәдәге** *мәл.* чегәннәрнең өсте ябулы арбасы (кибитка цыган).

**чиган мәдәгеннән йыгылып төшкән** *мәл.* аңгыра, ямьсез (тупой, неприглядный).

**ЧИГӘ 1.** *минз.* к.: **кас′ак I.** Ә чигәгә булса инде, қара чыршыдан қуйабыз; **2.** *әҗе.* кырый, чик (грань, граница). Зийарәтнен чигәсен куралап йередек; **3.** *влгг.* к.: **гуз′.**

**арба чигәсе** *минз.* к.: **чака 1.**

**чигә җебе** *минз.* тәртә бавы (тяга).

**ЧИГӘЛӘ: чигәлә бәйләү** *перм.* к.: **бәйләү: тартмалы бәйләү.** Чигәлә бәйләгәнсең, элмәкле булса, берсе йагы бүкләнеп торор ийе.

**ЧИГӘЛӘШҮ** *перм.* к.: **иргәләшү.** Қолаққа керәйе, чигәләшәләр ийе бер дә харап.

**ЧИГӘЛИ: чигәли бәйләү** *кузн.*, **чигәли бәләү** *карс.* к.: **бәйләү: тартмалы бәйләү**; чаг.: **бау: ир bawы.**

**ЧИГӘНДӘК** *чст.* к.: **йywача 2.**

**ЧИГӘЧӘ** *т.кам.-крш., чст.-крш.* чигә турысына тәңкәләр тезгән хатын-кыз баш киеме (женский головной убор из монет, надеваемый на висок). Элгәре бетен тәңкәләр, чигәчәләр кемештән генә булган. – *чст.-крш.*

**ЧИГЕ** *глз.* карындык (перепонка, сделанная из желудка животных). Қазны ат чигесене тереп қуйар ыйы әбилер.

**ЧИГЕЛДӘК 1.** *миш.д.* к.: **йywача 2.** Туйда чигелдәк сибәләр. – *кузн.* Туйга чигелдәкләр пешерәләр. – *лмб.* Чигелдәк белә чәй эчерермен дигән идем. – *чст.* Рыштывада йөзгәләп-йөзгәләп чигелдәк пешерәләр. – *кузн.* Йедесенә (кеше үлгәч) чигелдәк пешерәләр бездә. – *срг.* Ураза тытучылар чигелдәк тарата. – *тмн.* Хазер инде заман йакшы булды, магазин ашлары, чигелдәк куйалар... – *карс.* Туй вакытында чигелдәк әзерлиләр. – *чст.*; **2.** *лмб.* төче яки ачы камырдан, ромб формасында кисеп, мичтә томалап пешерелә торган азык (печенье домашнего приготовления); **3.** *трх.* к.: **чигелдек.** Чигелдәкне раштыwa кеннe пешерәләр, сарық күп булсын, диләр, анарға май да салмыйлар. Миннән майсыз пешертәдер ийе җywачаны чигелдәк кебек; **4.** *карс.* эченә йөзем җимеше салып пешерелгән бавырсак (баурсак с начинкой из изюма).

**рыштыwa чигелдәге** *лмб.* к.: **чигелдек.** Рыштыwa чигелдәге була, камыр басалар да, вәлиләр дә йымры-йымры, пешерәләр, ыланнарны ашаталар.

**чигелдәк бәйрәме** *чст.* Раштуа бәйрәме (Рождество).

**ЧИГЕЛДЕК** *трх.* йола ашы: Раштуага каршы кичтә, сарыклар күп булсын дип, арыш оныннан, ачыга мич төбендә пешерелә торган әре төш (ритуальное блюдо: крупные ржаные шарики из кислого теста, печённые в печи накануне Рождества, чтобы овцы были плодовитыми). Раштуwa көнне чигелдек пешерәләр арыш оныннан, имеш, бәрән күп булсын.

**ЧИГЕЛДЕРҮ** *срг.* читкә, артка этәрү (отстранить, оттолкнуть). Иптәшен чигелдерде дә аның урынына үзе менеп утырды.

**ЧИГЕНДӘК** *чст.* к.: **йywача 2.**

**ЧИГЕНДЕР** *лмб.* чөгендер (свёкла). Чигендерләр тишелмәде, дир, казларны ашаган.

**ЧИГЕРКӘ** *чст., кузн., хвл., карс., мәл.* чикерткә (кузнечик).

**ЧИГЕРТКӘ** *влгг.* к.: **кисеркә I.**

**ЧИГЕРТКИН** *перм.* к.: **кесеркән.** Чигерткин арада утыралар чебечләр, эссе қый.

**ЧИГЕРТЛЕК** *клм.* чөелдерек (супонь).

**ЧИГЕРТҮ I** *лмб.* яру – көнбагыш турында (лущить семечки). Келәнгеч чигертә идек ywыннан пирут.

**ЧИГЕРТҮ II** *лмб.* к.: **чекү.** Тәрәзне чигертә.

**чигеү** *т.кам.-крш.* чигү (вышивать; вышивание, вышивка):

**урыс чигеwе** *т.кам.-крш.* к.: **чигеш: урычча**

**чигеш**. Урыс чигеwен җаратадырыйым, битҗаулыҡлар чиктем.

**ЧИГЕШ** *чст.* чигү (вышивка, вышивание). Чигеш тә чикми хазер халык.

**ишмә чигеш** *минз.* тамбурлы чигү (вышивать тамбуром). Ишмә чигешне бәк күп чиктем мин.

**йомошаҡ чигеш** *минз.* тоташ чигү (гладь). Атлатып-атлатып, күпертеп чигәдер ийек, йомошаҡ чигеш анысы.

**татар чигеше, татарча чигеш** *минз.* к.: **ишмә чигеш**. Татарча чигеш булса, энә төбеннән алып-алып атлатып-атлатып чигәдер ийек.

**урычча чигеш** *минз.* тапкырлап чигү (вышивать крестом).

**чигешле читек** *трх.* к.: **читек: чәмчәле читек**.

**чигү I** (вышивать, расшивать):

**җылан чигүwе** *т.кам.-крш.* к.: **чигеш: ишмә чигеш**. Җылан чигүwе белән чиккән эскәтерем бар ийе.

**йомошаҡ чигү** *минз.* к.: **чигеш: йомошаҡ чигеш**.

**камба** [*рус.* канва] **чигү** *т.кам.-крш.* канва белән чигү (вышивать на канве). Камба чигү дә чиктем, җәш чақта бик чиктем мин.

**керәшен чигүwе, керәшенчә чигү** *т.кам.-крш.* к.: **чигеш: урычча чигеш**. Басмага кырислап, керәшенчә чигәләр ийе.

**күпертмә чигү** *т.кам.-крш.* к.: **чигеш: йомошаҡ чигеш**. Күпертмә чигү, ди торған ыйыҡ, қабарып тора торган ыйы, эскәтерләрем бар ыйы күпертмә чигүле.

**нимесчә чигү** *минз.* җебен чыгарып калдыра-калдыра чигү (вышивать, делая завитки). Җепне күпертеп-күпертеп, сузып чыгарып нимесчә дә чиктек.

**татарча чигү** *минз., т.кам.-крш.* к.: **чигеш: йомошаҡ чигеш**. Татарча чигәдер ийек кийерге белән.

**үреп чигү** *чст.* к.: **чигеш: ишмә чигеш**. Үреп чигәргә бик тырышлык кирәк.

**чирәм чигү** *трх.* тоташтан чигү (вышивать гладью). Чирәм чигү шул була, бизәк төшөрелә, шул бизәгеннән қарап чигә, ниндийенә нинди җеп кирәк. Чирәм чигү белән җәймәләр чигелә.

**чылбырлы чигү** *чст.* к.: **чигеш: ишмә чигеш**.

**шома чигү** *т.кам.-крш.* к.: **чигеш: йомошаҡ чигеш**. Ә теге шома чигү татарныҡы.

**ЧИГҮ II: рай чигү** *мәл.* к.: **гөлмән: гөлмәндә йәшәү**.

**ЧИГҮ III** *мәл.* юмалап, матур итеп сөйләп алдау, төп башына утырту (обмануть льстивыми словами, притворно хвалить, льстя, оставить в дураках). – Йакшы сүлиме? – Һу, чигә ул.

**ЧИГҮ IV** *тмн., кузн., лмб., влгг., әстр.*, **ЧИ'Ү** *кас.* тарту – тәмәке турында (курить). Сигарит чигү. Тәмәке чигәм мин. – *әстр.* Чигәргә алдырмыйм мин. – *влгг.* Эчми, чикми, малый бик шәп. Чигәргә гәзит биргән азига. Тәмәке чигәргә йарамый биредә. – *тмн.* Папирус чигәм. – *лмб.* Бер карупка папирусны чи'еп петерде. Эсми иде, чи'ми иде, атабыз би' йа'шы иде. – *кас.*

**ЧИГҮ V** *каз.ар.-крш.* элекке сәләтен югалту, начарлану (потерять прежнюю способность, стать плохим). Минем күзләрем бик җаҡшы күрәләр ийе, қәзер қартайгач чигә башладылар инде.

**ЧИГҮ VI** *әстр.* үлчәү (взвесить, взвешивать). Әтийем кукуруз чигә.

**ЧИДУН** [*рус.* седун] *нокр.* үсми калган кеше, тәпи йөрми торган бала (человек или ребёнок, который не может ходить, сидячий). Аз ашасан, чидун булып қаласын, ашаб бетер.

**ЧИЙ I** *каз.ар.-крш.* к.: **пәйеҗ**. Тәҗелләнеп ашның чийесен җыйып алмағаммын.

**ЧИЙ II: чийен чығару 1.** *минз.* чи җепне кайнату (обработать сырую нитку); **2.** *к.т.* киемне сакламыйча кию (носить одежду или обувь небрежно). Бер кигәндә чийен чығара инде ул кийемнең; **3.** *мам.* нәрсәне дә булса бик ныҡ эшләү, кирәген бирү (делать что-то в избытке, как следует). Чийен чығардық бийеп, аулағәй бик күңелле булды. Чийен чығардым мин аны ашап.

**ЧИЙАКАН** *мәл.* кан эчендә, канга баткан (в крови, весь в крови). Бите-башы чийакан.

**ЧИЙАН** [*гар.*] *твр.* җиһан, дөнья (мир). Уқыған кеше чийан кисәте.

**ЧИЙАНАҚ** *твр.*, **ЧИЙАНАК** *мәл* к.: **айақ I, 2**.

**ЧИЙӘ I: чийә бәйләү** *мам.* к.: **бәйләү: тартмалы бәйләү**. Чийә бәйләңгән, шишеп пулмый.

**ЧИЙӘ II: чийә җат** *каз.ар.-крш.* бөтенләй ят, бөтенләй чит (совсем чужой, совершенно чужой). Чийә җат кеше килеп керде.

**чийә кан эчендә** *кузн.* бөтенләй кан эчендә, канга батып (в крови, весь в крови). Чийә кан эчендә йата, тәрәзәдән тыгылдым да кычкырдым.

**ЧИЙӘ III 1.** *тара., төм., брб.д.* нарат җиләге (брусника); **2.** *брб.д.* мүк җиләге.

**қыр чийә** *төм.* к.: **чийә III, 1**.

**шыган чийәсе** *м.-кар.* к.: **гөләф**. Шыган чийәсе дә җийдык, аны тewәбез күмәчкә.

**ЧИЙӘК: чийәк йабалақ** *мам.* ябалакның бер төре (один из видов совы). Чийәк йабалақ – хәбәр бирә торган йабалақ бит ул, тынычсыз җылларда қычқыра ул.

**ЧИЙӘЛӘЙ: чийәләй бәйләү** *мам.* к.: **бәйләү: тартмалы бәйләү**.

**чийәләндерү I** *урт.д.* чияләндерү (запутать): **чийәләндереп бәйләү** *к.т.* к.: **бәйләү: тартмалы бәйләү**. Батинкы ышнурыңны чийәләндереп бәйләгәнсең, һичничек шишалмыйм.

**ЧИЙӘЛӘНДЕРҮ II** *к.т., лш.* чиләндерү (натирать до крови). Қашый-қашый чийәләндереп бетергән. – *к.т.*

**ЧИЙӘЛӘҮ** *лш.* к.: **хыйтлану**. Дүрт нәни бала белән қалдым, алар белә дә чийәләдем. Газ да йуқ, нишәп чийәләнгәнмен мин алар белән.

**ЧИЙБЕК** *брб.д.* чеби (цыплёнок).

**ЧИЙЕНЧЕ** *мам., лш.* сөенче (радостное сообщение).

**қолақ чийенчесе** *мам., лш.* элек: ярәшкәч, кыз ягыннан егет ягына ризалык билгесе итеп бирелә торган бүләк (старинный свадебный обычай дарить подарок в знак согласия родственникам жениха со стороны невесты после сговора). Қолақ чийенчесен әйтмәдем әле, җаучыға биреп җибәрәләр, wәғәдә бүләге, диләр. – *лш.* Қолақ чийенчесе дип бер йаулық, бер бийәләй алып қайтып тотторған җаучысы. – *мам.*

**ЧИЙЕП** *хвл.* тегәрҗеп (суровая нитка).

**ЧИЙЕРТ** *блт.* к.: **ақбаш**. Чийерт ақ чәчәг ата, аны ашыйлар.

**ЧИЙЛЕК** *чст.* к.: **чөйлөк**.

**ЧИЙУ** *перм.* **1.** сызу – шырпы турында (черкнуть, зажечь – о спичке); **2.** чагу – чакма турында (высекать, высечь – об огне). Ала да чакма таш белә чийа; **3.** сызу, сызып ташлау (вычёркивать). Управлайушшиға китердем ий йазып, чийды да куйды; **4.** тырнау (царапать); чаг.: **йышу 2**. Чийыбырағ алсаң, қаны чыға. Битен чийған; **5.** *трбс., перм.* сызу (чертить); **6.** *трбс.* сызу, таю (удирать, убегать). Машина алалар да чийалар awылдан.

**йазу-чийу** *перм.* язу-сызу (писанина; букв. писать и чертить). Болый йазу-чийуға барсаң да йазып пирә, тыңный.

**ЧИЙҮ** *перм., трбс., брб.д.* сызу (чертить, нарисовать). Көнө буйы цабабыс, пер балка (палка) чийеп қуйады. – *брб.д.*

**ЧИЙҮЧҮРМӘК** *клм.* атсыз бармак (безымянный палец).

**ЧИЙЫЛУ** *минз., кргл., трбс., стрл.* сыдырылу (поцарапаться, потереться). Мона бит чийылған. – *минз.* Бу йерем чийылғанмы сың. – *кргл.* Чийылып киткәннәр, ранный булғаннар. Ағачны чийып узған пул'ылары. – *трбс.*

**ЧИЙЫРЧЫҚ** *глз.* к.: **чигеркә**. Чийырчық сайрай инде.

**мунча чийырчығы** *каз.ар.* к.: **царыцқы**.

**ЧИК I** *стрл.* хәтле, кадәр (до). Йаңгырға чик кайтып элгердегезме сың?

**ЧИК II** *клд.* вакыт, срок, көн (срок, установленный день). Ашка алалар туй чиген койгач.

**ЧИК III** *әстр.* к.: **қатем**.

**ЧИКАЙ** *мәл.* к.: **чики 1**.

**ЧИҚАН I** *т.кам.-крш.* к.: **кийек I, 3**.

**ЧИҚАН II** *тпк.*, **ЧИКАН** *стрл.* чуан (чирей).

**ЧИҚАН III** *т.кам.-крш.* к.: **кесеркән**. Чиқан пешерәбез дуңгызларға.

**ЧИКӘЧ** *т.я.-крш.* к.: **дегәч**. Чикәч белән майлап, кара камырдан кабартуларны ашаган.

**ЧИКӘЧИЙ** [*рус.* чека + **чөй**] *минз.* к.: **чака 1**.

**ЧИКЕ I** *брб.д.* дымлы (влажный).

**ЧИКЕ II** *хвл., кузн., карс., стрл., мәл.* к.: **тике**. Зур вет аларнын, анарга ник сыймасын, эстәл чике. – *карс.* Йегерем биш йәшкә чике байда эшләдем. – *стрл.* Ни чике эттем вет инде. – *мәл.* Школга чике бар да борол. Очтан тотонам да күпергә чике. – *хвл.* Аның чике булганы йуг иде качан да. Әл дә шул чике азабына сау кат'ты. Каа бу чике, болай да инде күп эчтем. Төнгә чике торган, ылан баккан. Кышка чике калыр. – *кузн.*

**ЧИКЕЙ** *лш.* к.: **чики 1**.

**ЧИКЕЛДӘК** *чст.* к.: **йуwача 2**.

**ЧИКЕРТАШ** *әстр.* яндырылмаган кирпеч (сырой кирпич).

**чикерткә** (кузнечик; сверчок; стрекоза):

**бирән чикерткә** *мәл., кмшл.* зур чикерткә (кузнечик больших размеров). Бирән чикерткә кешене тешли, зур чикерткә.

**ЧИ'ЕРТ'И** *кас.* к.: **кисеркә I**.

**ЧИКЕРТҮ** *төм.* яру (лущить). Паллар симечкә чикертәделәр.

**ЧИКИ 1.** *мам., каз.ар.-крш., трх., нрл.* чикләвек (орех). Урманда шоморт, чики җыйдык куб итеп. Ғомбағыш була торғаныйы чики шикелле (эре). – *мам.* Чики күп була безнең урманда. – *трх.* Ымсын булды, чикигә қызықтым да. – *каз.ар.-крш.*; **2.** *лш.* к.: **қосоқ 1**; **3.** *лш.* әчтерхан чикләвеге (грецкий орех).

**имән чикийе** *мам.* к.: **әкәлә 1**. Имән чикийе җыйабыз малларға ашатыр өчөн.

**ЧИКЛАWЫҚ** *чст., чпр.* **1.** чикләвек агачы (орешник); **2.** к.: **чики 1**.

**таракан чиклаwығы** *чпр.* к.: **қосоқ 1**.

**чиклаwык йәшене** *карс.* к.: **нажағай**.

**чикләвек** (орех):

**болотский чикләwек** *дөб.* фундук.

**дун чикләвеге** *тмн.* к.: **чики 3**. Чигелдәк пешерәләр, дун чикләвеге хатле итеп.

**қаз буғы чикләwек** *дөб.* к.: **салам чикләwеге**. Алар Қабақта (*җыен ис.*) қаз буғы чикләwек, қызыл билле перәллекләр саталар.

**қузы чикләwеге** *дөб.* к.: **қосоқ 1**.

**салам чикләwеге** *трх.* арахис, җир чикләвеге (арахис). Салам чикләwеге бармақ озонноғы, төчө генә, қабығы йуқа, ақ, сырлы-сырлы.

**чебер чикләwеге** *трх.* к.: **қосоқ 1**. Чебер чикләwеге wақ кына борчақ кебек, қара борчақ.

**чикләвек йәшене** *кузн.* к.: **нажағай**.

**чикләwек төше** *минз.* к.: **йуwача 2**.

**ЧИКЛӘМҮШ** *каз.ар.-крш.* бишташ уены (вид детской игры). Чикләмүш уйнағанда қул арқасына тотқанда, пеште-пеште, диләр.

**ЧИКЛЕ** *т. я., бөре., перм., кргл., т.кам.-крш., лш., минз., трбс., бгрс., чст., стрл.*, **ЧИКЛЕГЕ** *минз., стрл.* к.: **тике**. Бергадир булып эшләдем суғышқа чикле. Көзгә чикле awыртты. – *лш.* Шушы гумеремә чикле йөргәнемә қуwанам инде. – *трбс.* Сез чыгып киткән ыңгайга тулды кунак, кичкә чикле кунак булды. – *чст.* Бөтенесендә булғы, шул чиклеге байлар. – *стрл.* Ике қат төңкәне тезәләр дә монда чикле төшөрәләр. – *бөре.* Күпергә чиклеге төштөм мин. – *к.т.* Кичен без уқу йортонда сәғәт унға-умбергә чикле утырабыз. Әлегә чикле лафка тулы әйбер булды. – *минз.* Төшкә чикле керталмадым. – *т.кам.-крш.* Сыйыр көтүwенә чикле үк қайтып җиттек, ди эти. – *бгрс.* Ул гөл бер җылны утыртсаң, ун җылға чикле үсә. – *перм.*

**ЧИКМӘК** *глз.* к.: **калат**. Йакшылардан үрнәк алсагыз, Йәшел чикмәк кийәрсез (*хал. жыр.*).

**ЧИКМӘР** *төм., твр.* капчык (мешок). Пер чикмәр он китерте кийәwебес. – *төм.* Чикмәрчикмәр картуп төйәп йебәрә машина ман. – *твр.*

**ЧИКНӘҮ** *м.-кар.* к.: **авырту**. Бүген што-то чикнәдем, тыра алмадым. Малай чирканган, шунан чикнәде, салкын алган.

**ЧИКПӘН** *глз.* к.: **чипкән**.

**ЧИКТАН** *глз.* шөшле (кочедык). Чиктан кәрәк чабата йасама.

**ЧИКУШКА** [*рус.* чекушка] *бөре.* к.: **чака 1**.

**ЧИКЧӘГИ** *мам.* к.: **чепчәги**. Туйда чикчәгиләр апчығып биргәлибез малайларға. Туй булса, қапқа төбөнә бала-чаға җийыла бит инде, чикчәгиләр әле дә алып чығып бирәбез.

**ЧИҚЫЛДАҒАН** *к.т.* **1.** бик ачык – төс турын-

да (очень яркий – о цвете). Чиқылдаған қызыл; **2.** бик эссе (очень жаркий, знойный – о солнцепёке). Чиқылдаған қойашқа чығарып утыртқан баланы; **3.** чеп-чи, күзгә ташланып тора торган (явный, бросающийся в глаза). Төсе-бите белән чиқылдаған татар.

**ЧИҚЫЛДАУ** *перм.* кычкыру – саескан турында (кричать, трещать – о сороке). Қунақ килер булса, сайысқан чиқылдый.

**ЧИЛ I** [*рус.* целый] *миш.д.* **1.** к.: **беткел.** Чил авыл килгән иде. – *кузн.* Чил урам кубып килә, ыланнар артыннан килә. Чил пул тутыра су белән. – *лмб.*; **2.** бөтен, бербөтен, бөтене белән (целый, целиком). Без кыш буйы чил ат ашыйбыз. – *шрл.* Рәшиткә чил билит. – *кузн.* Чил силутканы ашаб бетерә. Чил агач күтәргән. – *лмб.* Чил каз куйасын, итең әз булса, бер тавык суйасын. – *хвл.*; **3.** тулы (полный). Чил банка китергән идем, бетергәннәр. – *лмб.*; **4.** бөтен, исән (целый, невредимый). Азыгың чилмы? Үрдәкләреңә чилмы? Бүресе дә тук булсын, куйы да чил булсын (*мәкаль*). – *кузн.*; **5.** җеназа агачы, җеназа тагарагы – гадәттә ул бөтен кабыктан ясалган була (похоронные дроги; носилки, на которых выносят покойника); чаг.: **тәбүт 2.** Чилга салабыз да мәйетне йывып, халайыг илтә шуны җеназага. – *тмн.*

**ЧИЛ II** *әстр., влгг.* к.: **герәдә.**

**ЧИЛӘК I 1.** *минз., тпк., стрл.* цилиндр формалы, агачтан чокып эшләнгән, ачык авызлы төрле савыт (ведро или небольшая кадушка, выдолбленная из цельного дерева); чаг.: **күшма I.** Чиләк кувыш агачтан йасалган була, аңа бал да салалар, әпәй дә салалар. – *стрл.*; **2.** *минз., бөре., стрл.* к.: **ләнгәц.** Уңдырмайлар, мин өчәр чиләк пешереп пирәм әпәйне. – *минз.*

**әбәт чиләге** *мам., дөб., лш.*, **әбәт силәге** *дөб.* кырга әйрән, катык һ.б. алып бару өчен махсус эшләнгән капкачлы агач чиләк (деревянная, цилиндрическая посуда с крышкой для того, чтобы везти в поле айран или другой напиток). Әбәт чиләген күләгәгә қуй, қатық җылынмасын. – *лш.* Кәбестәне әбәт чиләгенә тозлап түбәнийгә төшөрсәң, әйбәт кенә тора wыл. – *мам.* Әүwәл әбәт силәге дигәлләр, тушыңа әйрән салып песәллеккә алып барғаллар. – *дөб.*

**әпәй чиләге** *минз., стрл.*, **итмәк чиләк** *твр.*, **қuwac чиләге** *бәр.* к.: **ләнгәц.** Қuwac чиләкләре дип җәри торған ыйық ипи басарға. Қuwac чиләгенә төшөп мендем, қuwac чиләгенә ипи издем.

**пот чиләге** *минз., стрл.* бер пот ашлык сыешлы савыт (посудина, вмещающая пуд зерна; пудовка).

**татар чиләге** *трх.* камыр изә торган агач савыт (деревянная посуда, кадушка для замешивания теста); чаг.: **қушма I.**

**туз чиләк** *мам.* каен тузыннан ясалган чиләк (берестяной сосуд, берестяное ведро). Туз чиләк қайын тузыннан эшләнә, анысы күберәк басуға су алып бару өчен кирәк, аның тәме чыкмый.

**ЧИЛӘК II** *брб.д.* җиләк (ягода).

**ЧИЛӘМ** *нокр., глз.* чирәм, үлән (трава, мурава). Ашуға йарамай бу чиләм. – *глз.* Ишегалдым йәшел чиләм, Ашамайлар атларым (*хал. җыр.*). – *нокр.*

**ЧИЛӘНДЕРҮ** *хвл.* чияләндерү (сильно спутать; спутать так, что невозможно распутать, напр., нитки). Йепне чиләндереп бетердең.

**ЧИЛӘҢКИ** *глз.* тәбә (яичница). Йомролаймы, чиләңки пешеримме йоморка?

**ЧИЛБӘЙ** *срг.* к.: **цилбәй.**

**ЧИЛЕГҮ** *минз.* селкенү (шататься, качаться, трястись – о столе). Өстәлемнең бер айагы қысқарақмы шунда, әйбер қыстырмасаң, чилегә.

**ЧИЛЕЗИН** [*рус.* селезень] *карс.* к.: **чилиҗин.** Чилезины утыра вет ойада, үрдәге күлдә ваны.

**ЧИЛЕК** *бөре.* кискән агач төбеннән чыккан вак үсентеләр (молодая поросль, отростки молодого дерева). Чилек басқан җиләклекне.

**ЧИЛЕМ** *бөре.* тәмәке (табак, курево). Чилем тарту.

**ЧИЛЕМЕ** *глз.* к.: **чиләм.** Чилеме йыйдым қаз т′ут′уларға ашамага.

**ЧИЛЕНЧӘ** [*рус.* сеяльница] *твр., тара.* к.: **йулпуч.**

**ЧИЛИ: чили бәйләү** *хвл.* к.: **бәйләү: тартмалы бәйләү.** Мәшуг awзын чили бәләмә, ату шишә алмабыз анда.

**ЧИЛИҖИН** [*рус.* селезень] *карс.* ата үрдәк (селезень).

**ЧИЛКӘ** *перм.* к.: **чолка.**

**ЧИЛКӘWЕЧ** *перм.* к.: **йулпуч.** Чилкәwечләрне күрәсең килсә, музыйға бару кәрәгә, анда қуйганнар қарарға.

**ЧИЛЛАТА** [*рус.* цел + афф. *-лата*] *тмн., лмб., хвл., кузн.* бөтен көе, бөтенләтә (в целом виде, целиком). Чиллата бешерәм алманы. – *тмн.* Чиллатамы йундың картушны? – *лмб.* Бабай беркачан чиллата ашамый йоморканы. – *хвл.* Чиллата суда пешерәсен. – *кузн.*

**ЧИЛЛӘНҮ** *мәл., т.я.* җенләнү, тузыну, ачулану (взбеситься, злиться); чаг.: **йерәкләнү.** Әйткәч җарамады, чилләнергә тотонды. – *к.т.*

**ЧИЛНЕК** [*рус.* сенник] **1.** *карс.* каралтыда терлек азыгы куя торган урын (помещение, куда складывают корм для скота). Чилнекне чыбыктан йасыйлар, шуның эченә курмыны тейиләр иде; **2.** *чст., кргл., бгрс., шрл.* к.: **чиннек I, 1.**

**ЧИЛНИК** [*рус.* пчельник] **1.** *т.кам.-крш.* к.: **мурталык; 2.** *минз.* к.: **киртә I, 4.**

**ЧИЛПӘК** [*фарс.*] *әстр.* к.: **күзикмәк I, 1.**

**ЧИЛТӘК** *твр.* челтәр, челтәрләп бәйләгән (кружево; кружевной, ажурный). Чилтәк пәли тегән итем.

**ЧИЛТЕР** *твр.* рәшәткә, текмә (решётка, частокол).

**ЧИЛУМ** [*рус.* силой] *бөре.* к.: **awаннап.** Чилум алып киткәннәр.

**ЧИЛЧӘ** [*рус.* силья, сило] *м.-кар.* к.: **қанатқы.**

**ЧИМА I** *перм.* к.: **сызғыч.** Чима бир әле, қаранғы. Мин дә йөртә торган ыйым чима, тәмәке тартмасам да.

**чима тишек** *перм.* мич алды ягында шырпыфәлән кую өчен ясалган кечкенә куышлык (маленькая печурка для хранения спичек); чаг.: **қучқар 2.**

**ЧИМА II** *глз.*, **ЧИМӘ** [*рус.* семя] *нокр., глз., к.-уф.* к.: **чемечки.** Аби, чима киракмы? – *глз.* Чимә бир әле, йарыйқ. – *нокр.*

**ЧИМӘЙЛӘҮ** *твр.* бизәкләү, бизәү (делать узоры, украшать). Уңа ман чимәйләп, әнцеләр тесеп кийәтеннәр қалбақны.

**ЧИМӘКЛӘНҮ** *дөб.* к.: **чәүмәлү 2.** Чимәкләнеп китә йаздым тағы.

**ЧИМӘҢКЕ** [*рус.* семянка] *нрл.* **1.** к.: **чемечки 1.** Чимәңке кәтиг әле; **2.** к.: **айбағар.** Қырда чимәңке уралар силусқа.

**ЧИМБӘР** *әстр.* юка бөркәнчек (лёгкое покрывало).

**ЧИМГЕРҮ** *брб.д.* сеңгерү (сморкаться).

**ЧИМЕК I** [*рус.* семик] *нрл.* чуашларның җәйге календарь бәйрәмнәреннән берсе (один из летних календарных праздников у чуваш).

**ЧИМЕК II** *твр.* тапаган эчәге, бавыр, сызык h.б. кушып, табада кыздырып әзерләнгән ашамлык (кушанье, приготовленное на сковороде из нарубленных кишков, печени и шкварок). Қәсер чимек тә йасамайтлар, шикалат та микалат.

**ЧИМЕЧКЕ, ЧИМЕЧКИ** [*рус.* семечки] *бөре., минз., стрл.* к.: **чемечки 1.** Без элек гомбагыш дийәйек, әл инде чимечке, диләр. – *стрл.* Утырыгыз урындықтан, Чимечки ашатайым, Былбыл дисәм, йуқ қанатың, Кемнәргә ошатайым (*хал. җыр.*). – *минз.*

**ЧИМСЕНҮ** *тбл.* җирәнү (брезговать).

**чин I** [*рус.* чин]:

**чин қору** *кргл., бгрс.* дәрәҗә төшү (потерять авторитет). Чиның қоромас, китер инде шул баланы монда, дигән. – *бгрс.*

**ЧИН II** [*гар.*] *брб.д.* җен (бес, чёрт).

**ЧИНАЙАҚ** *мам., нокр.* к.: **айақ I, 2.** Чинайақларны төшөрөп watma тағы. – *мам.*

**чинайақ табақ** *нокр.* к.: **җәйләү.**

**чинайақ тирән** *нокр.* к.: **җомор.**

**ЧИНАҚ** *твр.* к.: **җомор.**

**ЧИНӘВЕК** *мәл., хвл.* елак, чыелдык, чәрелдек (пискля, пискун). Баласы бер чинәвек иде, бик тафиклы булып үскән. – *мәл.*

**ЧИНӘҮ 1.** *карс.* чыелдау, талашу (визжать, скандалить). Былдырга җитте, тытынды чинәргә; **2.** чәрелдәү, елау (пищать, визжать, плакать).

**ЧИНДЕК** [*рус.* сенник] *минз., стрл.* к.: **киртә I, 4.**

**ЧИНИЙАҚ** *т.я., мам.* к.: **айақ I, 2.** Чәй булды, чинийақларны хәзерли тор. – *к.т.* Бер чинийақ чәйне эчеп бетермәдем қайтып, бергадир алмаға килеп җиткән. – *мам.*

**чинийағ өстө** *т.я., мам.* чынаяклар, гомумән, өстәлдәге савыт-сабалар өстенә ябып куела торган җәймә яки челтәрләп бәйләгән япма (салфетка или кружевное маленькое покрывало, специально приготовленное для накрытия посуды на столе). Қызлар сөлге-скәтер, чолғау, чинийаг өстө кебек әйберләрне кийәүгә киткәнчүк хәзерли. – *к.т.* Бусы қыз wақытта үзем чиккән чинийаг өстө. Челтәр дә бәйләдем, чинийаг өсләре дә, karawat челтәре дә. – *мам.*

**ЧИНИЕК I** [*рус.* сенник] **1.** *т.я., кмшл., кргл., минз., бгрс., чст., стрл.* хуҗалыкта арба, чана, сбруйлар h.б. куя торган яхшырак каралты (помещение, чаще всего добротное, для хранения телег, саней, сбрую и т.д.). Безнең таш чиннек бар ийе. – *стрл.* Чиннеге арбалар-madарлар сақларға, келәттә ашлық сақлыйсың. – *минз.* Чиннектәге печәнне ашатмый тор, сайғақтан ғына сал сыйырга. Көрәк-сәнәкләреңне чиннеккә кертеп қуй. – *к.т.* Басқыч шунда, чиннектә генә бит. – *кмшл.*; **2.** *минз., лш.* келәт, амбар (клеть, амбар). Чиннектә ларда арышы күп булған. – *лш.*; **3.** *трх.* түбә астында буш урын, өстенә печән өелә, асты тышкы абзар хезмәтен үти (свободное место под навесом, служащее зимой для кормления скота); чаг.: **абзар: абзар алды; 4.** *минз., стрл.* абзар (хлев). Чиннектә мал тора беднең. – *минз.*

**ЧИННЕК II** [*рус.* пчельник] *дөб.* к.: **мурталык.** Бик зур чиннек бар бездә.

**ЧИННЕК III** *лш.* к.: **тике.** Элгәре бәрәңгесенә чиннек үсмәде.

**ЧИННИК** [*рус.* пчельник] *стрл.* к.: **мурталык.** Чинникләре ул awылның шунда җылга буйда ғына икән, йәмне җирдә.

**ЧИН-СӘХМӘТ** [*гар.*] *брб.д.* к.: **чин II.** Чин-сәхмәт йақын килмәсен тип, қарағай қуйадылар қыстырып өскә.

**ЧИНТӘП** [*рус.* сентябрь] *карс.* сентябрь. Аннан кезен чүплиләр чинтәптә.

**ЧИНУКА** [*рус.* циновка] *хвл., кузн., мәл.* к.: **йабу II, 2.** Төнката чинука тугыганнар. – *мәл.* Әткәй байыдың, мине дә бактың, Бешмет алдыма чинука йаптың (*бор. җыр.*). – *кузн.*

**ЧИҢГА** *кргл.* кильки.

**ЧИҢГЕЛДЕК, ЧИҢГЕЛТЕК** *стрл.* к.: **чәңгелдек 2.** Безгә чиңгелдекләр әләкмәде, кабык бишектә үстек. Дүрт агачны тотошторалар да киндер тарталар, мона сиңа чиңгелтек.

**ЧИҢЕ** *м.-кар.* к.: **тике.** Менә тушында чиңе салына иде ул бик күп.

**ЧИҢКЕН** *перм.* чирак (туго скрученный). Берсе сәлпе булса, берсе чиңкен була (җепнең). Қаты боролоп торса, чиңкен була (җеп).

**ЧИҢНЕ** *м.-кар., к.т., каз.ар.-крш.* к.: **тике.** Иртәгә чиңне эш бетте. – *м.-кар.* Төшкә чиңне җоқлағанмын. – *к.т.* Без сәгәт умбергә чиңне утырабыз. – *каз.ар.-крш.*

**ЧИП I** [*рус.* цеп] *тмн., хвл., мәл., кузн.* чабагач (цеп). Йындырларда чиплар мынан каға идек, мына озон тайак, аны очона тагып кыска тайак бәләгән, ике йаклап дүртәр кеше каға иде. – *тмн.*

**ЧИП II** [*рус.* цепь] **1.** *лмб., влгг., дөб.* к.: **җыңҗыр.** Чипны аласың эстеннән уратып, астына бер күсәк тығасың. – *дөб.* Чиптан қытылган (әт) кебек (*әйтем*). – *лмб.*; **2.** *лмб.* чылбыр рәвешендәге бизәнү әйбере (цепочка – об украшении). Чипләр иде кемешнекеләр; **3.** *карс.* муенса (бусы).

**чипле манит** *лмб.* үзара чылбыр белән тоташкан тәңкәләрдән торган бизәнү әйбере (украшение из монет, соединённых цепочками). Чипле манит, чипка сабаклап манит тезгән иде.

**ЧИПАН** *перм.* **1.** сыткы (прыщ). Чипан биткә чыға; **2.** к.: **чобан.** Чипан чыққан битенә, сuwық суққан мыса?

**ЧИПКӘН** *т.кам.-крш., перм.* чикмән (чекмень); чаг.: **зыбын.** Тула чипкән кидек үзебез тегеп, озон чипкән. – *т.кам.-крш.* Татарлар ақ чипкән киде, марилар қараны. – *перм.*

**ЧИПКИТ** *том.д.* к.: **қомпалық**.

**ЧИПУР** *срг.* к.: **пал′ак**.

**ЧИПУШКА** [*рус.* цепочка] *кас., мәл., лмб.* к.: **чапук I, 4**.

**чипушкалы чип** *лмб.* кашлы челтәр түгәрәкләр тезеп ясалган бизәнү әйбере (украшение: цепочка из ажурных блях с камнями). Чипушкалы чиплар тактым әл дә тәтәйнекен, уртада каш кебек.

**ЧИПЧИ′** *кас.* к.: **чапчақ 1**.

**ч и р** (болезнь, хвороба, хворь):

**ийәле чир** *т.я.* озакка сузылган чир, төзәлми торган авыру (затянувшаяся или неизлечимая болезнь).

**йөрү чире** *минз.* венерик авыру (венерическая болезнь). Йөрү чире белән балниста йатқан.

**сөйәк чире** *минз., стрл.* сөяк туберкулезы (костный туберкулёз). Ничә йыл сөйәк чире белән йатты. – *стрл.*

**сuwық чир** *бөре.* к.: **шом I**. Сuwық чирне әллә ничек қурқытсаң да бетми.

**тир чире** *нгб.-крш.* к.: **қаста: эссе қаста 2**. Ирем тир чире белән awырды.

**чиргә awышу** *минз.* авырып китү (заболеть). Қайтқачтын тағын awыл сәwите персидәтеле булыб эшләдем, аннан суң чиргә awыштым.

**чиргә уралу** *минз., трбс.* авырып китү, чиргә сабышу (заболеть, лишиться здоровья). Қызым бәг әйбәт ийе дә чиргә уралды. – *минз.* Әбийең чиргә уралды. – *трбс.*

**чирдән қачыру** *перм.* озакка сузылган авыруны имләү, ырымлау: авыру кеше, беркемгә дә әйтми-нитми, үз өеннән чыгып китә һәм авылның елга аръягындагы очына барып, берәр кеше өенә кереп ята. Шулай иткәндә, имеш, чир адашып кала (знахарский способ лечения затянувшейся болезни). Чирдән қачырдылар элек, бу чуқта awыртынса, теге чуққа барып қачып йаттылар.

**ЧИРАЙУ** *бәр.* туңу, өшү (зябнуть); чаг.: **қалчайу**. Чираймыйсығызма өйалдында, бик җил бит?

**ЧИРАҚ** *т.я., каз.ар., бәр., себ.*, **ЧИРАК** *лмб., кузн., хвл., чст.* җитез, өлгер, булдыклы, уңган, иренмәүчән (проворный, расторопный, дельный); чаг.: **җитек**. Чирақ қатын ул, эшкә иренми, иртүк тора. – *к.т.* Цицатасы тың чирақ пулты. – *төм.* Үсем чирақ полтым, келән тайаштым. – *тбл.* Баласы йылак булса, анасы чирак була (*әйтем*). – *чст.* Бик катны чирак, уңган. – *хвл.* Кан′анам бар иде, ул бик чирак иде, эшен бетерә дә битен йыwа, йыкларга күлмәк башканы, эшкә башканы кийә. – *лмб.*

**ЧИРАКА: чирака йапрагы** *кузн.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы**.

**ЧИРАҚЛАНУ** *т.я.* җитезләнү, иренмәүчән булып китү (сделаться расторопным, проворным). Бу арада бик чирақланып киттең әле син, иртүк тороп чәй сuwына да барасың, урманга да менәсең. Көтүче қатыны кич чирақлана, ди (*әйтем*). – *к.т.*

**ЧИРАПИНКӘ** [*рус.* черепинка] *лмб.* тирән эчле балчык савыт (глубокая глиняная миска).

**ч и р а т** [*рус.* очередь]:

**чират awырту** *блт.* кизү (эпидемия). Чират awырту ул, үтәр.

**чиратқа чығу** *мам.* кеше кулында яки кеше өстендә чираттан йөреп яшәү (жить поочерёдно на иждивении посторонних людей). Мулла булған бер, чиратқа чығып үлгән, бер кешесе дә қалмағач.

**ЧИРАТУ I** *мам.* к.: **кәкшетү**. Әзрәк чиратасы бар айбағырны.

**ЧИРАТУ II** *кргл., бгрс.* кату, бөтерү – җеп турында (ссучить, скрутить – о нитке). Ушы дебетне чиратып бетерәсе бар. – *бгрс.*

**ЧИРАУ I 1.** *дөб., мам., блт.* к.: **чирайу**. Арқам чирәды. Аз ғына чирап китәм хәзер дә, нәрсәседер қалды бизгәкнең. – *блт.* Мунчадан чығышлый чебиләр қuwып җөрдәм дә чирап киттем. Чиратып җибәрде, җил чықтымы. – *мам.*; **2.** *мам.* бераз туңу, аз ғына ката башлау (чуть-чуть замерзать). Җирнең өсте чирап киткән, әле бәрәңгегә үтми ул. Су өсләре чираған. Йаз бирешми әле, иртә белән чиратып қуйа.

**ЧИРАУ II** *минз., стрл.* орлыкның ката башлавы (начать затвердевать – о зерне в период созревания). Хәзер чирый башлаған, ура башларга waқыт. – *минз.*

**ЧИРАХМАН I** *тмн., лмб., кузн., влгг.* боз (град). Чирахман мынан каты йаңгыр төште. – *влгг.* Хыт чиләк йый, шындый чирахман йауды. – *тмн.* Чирахман теткән арышны. Чирахман теште, бытаклы кебек мытырлы-мытырлы. – *лмб.* Аксыл болот, чирахманлымыдыр? – *кузн.*

**чирахман кинау** *тмн.* боз сугу (побить градом). Тегендә, кырда, кинаган чирахман.

**ЧИРАХМАН II** *шрл.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы**.

**чирахман йапрагы** *тмн., лмб., кузн.*, **чирахман йафрагы** *тмн., кузн.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы**.

**ЧИРӘ** *перм.* нигез (завалинка). Өйнең чирәсен күмдем әле.

**ЧИРӘКӘЙ** *чст.* чүрәкәй (чирок).

**ЧИРӘМ 1.** *т.я., каз.ар.* бәбкә үләне (птичья гречиха, травка-муравка). Қазлар рәхәтләнеп чирәмдә йөрделәр. – *мам.* Чирәм йәм-йәшел, җалан айақ шунда уйнап үстек. – *лш.*; **2.** *мам.* казаяк, каз үләне (гусиная лапка); **3.** *карс.* к.: **йорт 1**.

**дуңгыз чирәме** *м.-кар.* к.: **чирәм 1**. Дуңгыз чирәмен ашийлар, тиз картайа түлке.

**ЧИРӘП I 1.** *хвл., карс., мәл.* киң авызлы чүлмәк (горшок с широким горлышком). Гел чирәбе. Сет чирәбем бар. – *карс.*; **2.** *срг., хвл.* тирән балчык табак (глубокая глиняная чаша). Чирәп белән казларга бирәбез. – *срг.*; **3.** *клд.* балчыктан ясалган (глиняный). Чирәп табаклары да була, агач табаклары да була. – *клд.* Чирәп кукшины бызылды, сабы бер тештә йата. – *мәл.* Чирәп чүлмәкләр бар иде катыкка, чирәп савытлар иде, чирәп чашкылар. – *хвл.*; **4.** *м.-кар.* чүлмәк китеге (черепушка, черепок). Бик каты кирпечләр, чирәпләр чықты.

**чирәп чите** *мәл.* чүлмәк ватыгы (осколок горшка).

**ЧИРӘП II** [*рус.* череп] *лмб.* баш капкачы (череп, скальп).

**баш чирәбе** *лмб.* **1.** к.: **чирәп II**. Чирәпне кайырыб алган бунбы тешеп; **2.** баш сөяге рәсеме (рисунок черепной коробки). Ишегенә баш чирәбе тешкән.

**ЧИРӘПИНКӘ** [*рус.* черепинка] *мәл., тмн., хвл., чст.* к.: **чирапинкә**. Чирәпинкәм уватылды. – *тмн.* Чирәпинкә каймак җыйа торган, бәлчектән ул. – *хвл.* Чирәпинкә белән куйдым инде бәрәңгене, awылча булсын дип. – *чст.*

**чирәпинкә лампы** *чст.* к.: **пысқыш**.

**ЧИРБЕК** [*рус.* черевик, чирики]: **чирбек батиңка** *бөре.* биек үкчәле, озын кунычлы күн аяк киеме (кожаные ботинки с высоким голенищем, на высоких каблуках). Чирбек батиңка, wақ қына төймә була анарда, үкчәле була, монда қәдәре була қунычлары.

**ЧИРБИК** [*рус.* чирики] *клд.* кунычлы аяк киеме, итек (обувь типа сапожка). Чирбик бар иде шылай тытып кийә тырган, ваты балдак шылай гына, кансиртта орос кызлары кийәләр, эризинка куйа булганнар тытып кийә торган йиренә.

**ЧИРБИТ** [*рус.* черевик, черевички] *бәр.* к.: **чирбек: чирбек батиңка**. Элек чирбит киделәр, бийек үкчәле, андары артқылы баулы батиңкә, андары чықты сандал.

**ЧИРЕК I** *глз.* почмак (угол). Эч чирекле шал. Бетүне эч чирекле итеп салалар, қуйныға салалар.

**ЧИРЕК II** *мәл., чст., кмшл.* егет туганнарының беренче мәртәбә кыз ягына күрешергә килү йоласы (свадебный обряд: первое посещение родственниками жениха дома невесты). Беген кич чирег әле, йегет йагы килә. – *мәл.* Иртәгә чиреккә киләселәр. – *кмшл.*

**ЧИРЕКЛӘНҮ** *кмшл.* **1.** к.: **көшкөләнү 1**. Чирекләнә генә ул, чирләми, чирле кеше алай қыланмый да; **2.** уйнау, қылану (кокетничать, заигрывать). Йегет қызның кийәнтәсеннән тытты да и чирекләнә инде.

**ЧИРЕМ: чирем итек** *чст.-крш.* чи тиредән теккән аяк киеме (обувь из сыромятины). Чирем итек тә кийәләр, эшләмәгән тиредән теккән була ул.

**ЧИРЕҮ** *каз.ар.-крш.* гаскәр (войско). Дошман чиреүләрен атлары белән диңгезгә батырған.

**ЧИРҚАН** *себ.* ас аулау җайланмасы (приспособление для ловли горностаев).

**ЧИРҚАНЧЫҚ** *кмшл.* чирканыч (омерзительный, гнусный).

**ЧИРКАУ** [*рус.*] *карс.* чиркәү (церковь).

**ЧИРКӘ** *глз.* к.: **чигеркә**.

**ЧИРКӘЙ** *перм.* к.: **йомоқ I**. Чиркәй қазый тужы, малныкы җөн араға утыра.

**чиркәй печин** *перм.* к.: **йылыwыт**.

**ЧИРКӘМ** *бәр.* нык, таза (прочный, крепкий).

**ЧИРКӘНҮ** *твр., тара.* җирәнү (брезговать). Нawыс түгәтеләр, аннан чиркәнәм.

**ЧИРКИ** *минз.* к.: **озонайақ**. Чиркиләрнең безелдәwен йаратмайым.

**ЧИРЛӘҮ** *к.т., лш.* к.: **йончу I, 1**. Әллә нишләп бибекәләрем чирләп китте, бер дә үсмиләр. Җаңғыр булмағач, арышлар чирләде, күтәрелә алмадылар. – *к.т.*

**ЧИРЛӘШ** *перм.* к.: **чирле-чорло**. Йәштән чирләш булды қый.

**ЧИРЛЕ** *к.т., лш.* к.: **чақ I, 2**. Үзе чирле генә булса да бик тере, үткен бу бала: менмәгән җире җүқ. – *лш.* Бер бибекәсе нишләптер үсми, чирле, кечкенә булып қалды. – *к.т.*

**ЧИРЛЕ-ЧОРЛО** *мам., блт.* чирле, чирләшкә (болезненный). Минем кебек чирле-чорло кешегә йарамый икән әче. – *блт.* Чирле-чорло кешегә йүқ-барны ашарға йарамый бит ул, сақланып қына торасы. – *мам.*

**ЧИРМӘ 1.** *минз.* сабан туе өчен җыелган йомырка һ.б. әйберләр (яички и др. вещи, собранные для сабантуя); чаг.: **черемә: черемә күкәйе**. Шунда уқ чирмә өчөн күкәй җыйалар. Алдан бер җитез атлы үткер йегет чирмәне алып сөрәнчеләр арасыннан чығып қача; **2.** *мам.* сабан туе алдыннан йорт саен әйбер җыеп йөрү (обряд сбора подарков с каждого двора накануне праздника сабантуй).

**ЧИРМӘНЧЕК** *блт.* к.: **ботка: йаңгор боткасы**.

**ЧИРМӘЧЕ** *мам., минз.* сабан туе алдыннан йорт саен кереп бүләк җыючы, сөрән сугучы (собиратель подарков для сабантуя). Чирмәче йегетләр чыққандыр инде, без нәстә бирәбез, әней? – *мам.* Чирмәчеләр килә, қапқаның зурысын ач, улым. – *минз.*

**ЧИРПАК** [*рус.* черпак] *карс.* к.: **багырча**.

**ЧИРТ I** *трх.* шакмак уены – чәчеп җибәргәндә бертөсле ягы белән төшкән агач шакмакларны бер-берсенә чиртеп уйнала торган уен (вид игры в шашки). Малайлары белә чирт уйнадыг ийе. Син бит чирт уйнаучы әби, ди, мине күрде дә.

**ЧИРТ II** *чст.* кирт, киртек, ырмау (зарубки, нарезка). Кисмәк тебенең чирте.

**ЧИРТӘЙ** [*рус.* четверть] *срг.* чирек литр (четверть литра). Бер чиртәйлек тә акца йук кесәдә.

**ЧИРТЕШ 1.** *мам., лш.* к.: **чирт I; 2.** *лш.* шул уен өчен юан булмаган таяктан өч-биш см озынлыгында кисеп һәм аларны урталай ярып әзерләнгән ярым цилиндр шакмаклар (шашки полуцилиндрической формы, используемые в игре *чирт* I); **3.** *мам.* шушы ук уен өчен ясалган, бер ягы буялган зур булмаган яссы шакмаклар (шашки квадратные, покрашенные с одной стороны и используемые в этой же игре). Без чиртеш уйныйдырыйық энем белән, ул гел отадырыйы. Әби, чиртешләр йасап бир әле, дип аптыраталар ийе балачаға.

**ЧИРТКЕЧ** *перм.* к.: **қанатқы**.

**ЧИРТЛӘWЕК** *крғл., бгрс.* к.: **чики 1**. Чиртләwек күп булды, қапчық-қапчық җыйдық. – *бгрс.*

**ЧИРТМАҚ** *трх.* к.: **қанатқы**.

**ЧИРТМӘ I** *нгб.-крш.* икенче елда сөрелгән чирәм җир (целина, вспаханная через год). Чиртмә булса, бодайлар уңар инде.

**ЧИРТМӘ II** *лш.* агач сиртмә (деревянный шест, журавль, с помощью которого подвешивают люльку); чаг.: **силә 1**. Қайын чиртмәләрдә үстем, Шуңа қайғылы башым (*хал. җыр.*).

**ЧИРТМЕШ** *к.т.* **1.** к.: **чирт I; 2.** к.: **чиртеш 2**. Чиртмешләрне җүкә ағачыннан җасыйдыр ыйық. Қайда чиртмешләрең, әйдә уйныйбыз.

**ЧИРТҮ 1.** *чпр.* к.: **борнау 2; 2.** *твр., тара.* яру (щёлкать орехи). Қосоқ чирттем. – *твр.*

**ЧИРУТ** [*рус.* очередь] *карс., стрл., минз.* к.: **бай II, 2**. Чирут инде санала бер сыйыр, эч куй. Ике куй, эҗ гәҗә чирутка санала бездә. – *карс.* Чирут башына туғызар тәңкә ақча көтүчегә. – *минз.*

**чирут чиртү** *мәл.* авыл көтүен көтәргә алынган көтүчеләрнең өй борынча эш хакын җыеп йөрүләре (сбор деревенскими пастухами вещей, полагающихся им по весеннему договору за пастьбу). Көтүче чирут чиртеп йөри.

**ЧИРҮ: эт чирүwe** *лш.* к.: **черү: қырым черүwe чақлы.**

**ЧИРЧЫҚ** *глз.* к.: **пақцар.**

**ЧИСЕЛ** *чст.* өлгереп җитмәгән сыман (не совсем спелый). Игеннәрне урасың әз генә чисел wакытта.

**ЧИСЛАЛЫҚ** [*рус.* число + *афф.* -лык] *т.я., каз. ар.*, **ЧИСЛАЛЫК** *чст.* календарь (календарь, численник). Хәзер аның числалыгын карасаң да гел гыйлем. – *чст.* Числалыкны үзе җыртып бара ул, бабай бер кешегә шаммый. – *мам.*

**ЧИСЛАУ** [*рус.* честь + *афф.* -лау] *т.я.-крш.* карау, чистартып тору – мәс., киемне (ухаживать, заботиться, чистить – напр., одежду). Моно числамаган, әрмәк бу, күwә дә төшкәндер.

**ЧИСЛЫ** [*рус.* честь + *афф.* -лы] *бөре.* к.: **ару I, 8.** Числы кийем. Числы итеп кийә белми кийемне.

**ЧИСЛЫҚЛЫ** [*рус.* честь + *афф.* -лыҚлы] *мам., дөб., блт.* абруйлы, авторитетлы, дәрәҗәле (престижный, авторитетный). Бу пылач числыҚлырақ. – *мам.* Бик числыҚлы ғына апа инде сезнең хуҗагыз. – *блт.* ЧислыҚлы кешегә генә бирәм җабынырга, қыйты кешеләргә бирмим җурганны. ЧислыҚлы җаулык. – *дөб.*

**ЧИСНАЙ** [*рус.* честный] *мам.* к.: **числыҚлы.** Чиснайырақ бусы, бусын алам, төймәләре дә килешеп тора, шәп тә тора.

**ЧИСТАРТУ** [*рус.* чисто + *афф.* -рту] *төм.* яшь киленне, егет йортына кергәч, әрем белән кагу, имеш, шуннан соң аның янындагы явыз көчләр юкка чыгалар (очищение молодой невестки от злых духов с помощью полыни). Мүмәтәктән (өсте ябулы арбадан) төшкән цақта киленчәкне йүшән (әрем) белән қағатлар, чистартатлар, туганнары булыр йә муллалар қагатлар, уғынып қағатлар, пашыңнан ашыу айағыңа цақлы қағатлар.

**ЧИСТЫЙ** [*рус.*] *мам., блт.* шулхәтле, бөтенләй (до того, до такой степени, совсем). Чистый арып беттем. Чистый башымы қатырдың инде шул тақылтаwың белән. – *мам.*

**ЧИТ I 1.** *к.т., лш., әстр., чст., мәл., клд.* к.: **мийеш.** Ызба чите. Үwебез алты читле, икәү тырабыз. – *чст.* Өй чите черә башлаган. – *лш.* Читтә басып тырырга йарамый, йәшен атыр. – *мәл.* Машинасы белән бәрелеп ызба читен җимергән. – *к.т.* Салдатлар бетү йасап йазалар хатны, әч читле була. – *клд.*; **2.** *мәл.* як (сторона). Безнең бу читтә булмады чуwашка катнашу.

**ЧИТ II** [*рус.* сеть] *лш.* к.: **мәрәтә.**

**ЧИТ III** *минз.* к.: **кайма.** Қара җеннә суға ақ чит қуйып; җаулыққа да чит қуйып суғалар.

**ЧИТА 1.** *нокр.* к.: **чара 2.** Читаға салабыз эпейне. Таба күбек талдан үргән була чита, йыш була ул, қамыр сыйық түгел бит ул, төшми, көрәккә қаплайлар да пичкә тыгалар, пич путына; **2.** *злт.* киртә (ограда). Бақчаның анаwы почмагыннан читаны гына алганнар да кергәннәр.

**ЧИТАЛАУ** *злт.* киртәләү (оградить). Читалanмаган зират.

**ЧИТӘН 1.** *байк., чст., минз.* утыртма читән (частокол); **2.** *минз., перм.* рәшәткә (решётка). Әнә йаңа читәнне (өй). – *минз.*; **3.** *бөре.* койма (забор); **4.** *минз., к.т., чпр.* кәрзин (корзина). Тирес читәненә төйәп, Әлмәт базарына әпкиләләр ийе. – *минз.* Қарақлықта тотолса, тирес түгә торган читән булган, шуның белә урам җөрткәннәр. – *к.т.*

**бастырма читән** *чст.* к.: **читән 1.**

**дуңғыз читән** *дөб.* к.: **чәбе.**

**йаткырма читән** *чст.* үрмә читән (плетень).

**читек** (старинная национальная обувь: ичиги):

**бизәкле читек** *чст.* каюлы читек (с узорами – об ичигах).

**қолақлы читек** *каз.ар.* тамагы турысында ике якка бизәк куеп тегелгән хатын-кыз читеге (женские ичиги с узором на обе стороны подъёма).

**падбурлы (пудбурлы) читек** *каз.ар.* үкчәсенә юка гына набойка сугылган читек (ичиги с набойкой).

**саwырлы читек** *каз.ар., перм.*, **сауры читек, саурый читек** *каз.ар.* үкчә артына яшел төстәге күн тегелгән ирләр читеге (мужские ичиги, к задникам которых пришита кожа зелёного цвета). Саwырлы дийәнен ирләр кийә ийе. – *перм.*

**турлы читек** *хвл.* к.: **чәкәнле читек.** Турлы читек кәлүшләре белән булсын, шылай туй йери башлыйлар.

**тыбықлы читек** *баст.* үкчәле читек (ичиги на каблуках). Тыбықлы читек, җымшақны сөйләшәләр иде, калуша белән генә кийә тырган.

**чәкәнне читек** *перм.* төрле төстәге күннәрдән бизәкле итеп каелган хатын-кыз читеге (женские ичиги с узорами из разноцветных кусков кож). Чәкәнне читек кийәләр ий.

**читек ғөл** *бөре.* карабодай гөле (бегония).

**ЧИТЕК-ҚАТА** *минз.*, **ЧИТЕК-КАТА** *стрл.* читек-кәвеш (ичиги – собир.). Читек-қата киделәр инде байлар. Сәлим бабайларда читек-ката калгандыр әле.

**ЧИТИ** *блт., дөб.* литрның дүрттән бер өлеше, чирек литрлы шешә (четверть литра, четвертинка); чаг.: **чиртәй.** Бер чити сөт эчәм көнөнә. – *блт.* Бер чити сөт салып аппарыр ыйым урақка. – *дөб.*

**ЧИТКӘ** [*рус.* сетка] *перм.* челтәр тасма (кружево, кружевная тесьма).

**ЧИТКӘ-ЧОТҚА** *дөб.* читкә, кырыйга (в сторону). Бер дә читкә-чотқа китмиләр, туп-туры баралар.

**ЧИТКЕ** *минз., стрл.* читтәге, кырыйдагы (боковой, крайний). Минем қаз пипийенең уң айағының читке йәтмәсе йарған. – *минз.* Казның читке йәтмәсенә кадак кадалган булган. – *стрл.*

**ЧИТЛАWЫК** *тмн., кузн., мәл., чст., стрл.* к.: **чики 1.** Читлаwык йук буйыл, йәшен алган. – *стрл.* Читлаwык агацы. – *тмн.* Читлаwык сың элгерә әле. – *чст.*

**читлавык йәшене** *тмн., кузн.* к.: **нажағай.**

**ЧИТЛӘWЕК** *трбс.* к.: **чики 1.** Бездә хәзер читләwек бар.

**читләwек ағачы** *бөре.* чикләвек куагы (орешник).

**ЧИТЛӘП** *минз.* 1. к.: **читләтә**. Ак җаулыкларны читләп кенә бәйлиләр, бүкләп җуг ыйы ул элек; 2. каймалап (делая кайму). Читләп-читләп суғадыр ыйык киндер җаулыкларны.

**ЧИТЛӘТӘ** *перм.* бөкләмичә, дүрт почмаклы килеш – яулыкны бөркәнү турында (не сложив, четырёхугольником – о платке). Сары шәл йабынған читләтә. Без, татарлар, җаулыкны читләтә йабынабыз қый.

**ЧИТЛӘҮ I** *минз., стрл.* кагу, чит итү (притеснять, обижать, отвергать). Тегеләрне читли, сине бик йарата. – *минз.* Үгәй инәй безне бик читләде. – *стрл.*

**ЧИТЛӘҮ II** *перм.* 1. чатнау (трескаться, надтреснуть). Сүwәкне читләтеп қуйғаннар, сүwәге wатылған. Айақның читләгән җирләре awырта; 2. к.: **борнау 2**. Берсе читли башлаған ийе, үлде шу күwе (чебинең).

**ЧИТЛӘҮ III** *дөб.* тактаның кырыен тигез итеп юну (ровно обтесать по краям, обработать края – о доске). Тақталарны читли торағоз. Бу тақталар бар да читләнде инде.

**ЧИТЛӘШ** *чпр.* янәшә (рядом). Идарә белән читләш кенә тора.

**ЧИТЛӘШӘ** *срг.* к.: **ачамай 2**.

**ЧИТНӘ** [*рус.* сидня] *баст.* баланың тәпи йөрмәве (сидеть, не ходить – о ребёнке); чаг.: **чидун**. Читнә була, җеремәгән бала ул, кетү килгән wахытта ыланны тшаулыйлар да урамға чығарып утырталар им эчен.

**ЧИТНӘҮ** 1. *лш., мәл.* авырый башлау (заболеть, начинать болеть). Сыйырыбыз читнәде. – *лш.* Кәримә әби читнәгән. – *мәл.*; 2. *м.-кар., твр.* авыру, чирләү (болеть, хворать). Читнәде дә үлде, сигездә иде кызым. – *м.-кар.* Пашы читнәде, ат күтәреб атты та. – *твр.*; 3. *к.т., лш.* авырып үлеп китү (заболеть и умереть). Аның аты читнәгән, бернәстә булмаған көйө атың харап булсын әле. Бәрәңге сабын ашап сыйырыбыз читнәде былтыр. – *лш.* Аларның сыйырлары читнәдейе. – *к.т.*

**ЧИТСЕ** [*рус.*] *минз., тпк., стрл.* ситсы (ситец). Читсе килгән лафкаға. – *минз.* Читсе йаулық, читсе күлмәк пулты. – *тпк.* Читседән үзгәне кийәсе келәми минең. – *стрл.*

**ЧИФ** *лмб.* к.: **чив**. Чиф кеше иде йәж wахытта минең бабакам.

**ЧИХАЙ** *чст.* к.: **нокыр**.

**ЧИЧ** [*рус.* шест] *твр.* чәй (вешалка). Чичта такыйа булып, шаны алған та гейгән.

**ЧИЧАР** *влгг.* к.: **пал′ак**.

**ЧИЧӘК** *тмн.* к.: **абызастай**. Гөләм чичәк, ал′ем чичәк, көркле чичәк ат′асын иреңнән кечеләргә.

**ЧИЧӘКЛЕ** *баст.* чуклы (с бахромой, бахромчатый). Иргә барғанда сөйләшәләр, тун, қалын шәл қыш кененә, күләк, чичәкле шәл, йефәк була.

**ЧИЧӘН** *тмн.* уенчык (игрушка). Чичәннәрне йийасынмы, олым.

**ЧИЧҒАШАҚ** *твр., тара.* песнәк (синица). Чичғашақ сары түшле. – *тара.*

**ЧИЧЕКЕЙ** *каз.ар.-крш.* к.: **айақ I, 2**.

**ЧИЧИ I** *перм., кузн.* тәтиләр, матур әйбер, уенчык – балалар телендә (игрушки – в детской речи); чаг.: **т′ит′и I**.

**чичи кул** *кузн.* уң кул, тәти кул – балалар телендә (правая рука – в детской речи).

**ЧИЧИ II: дегет чичийы** *каз.ар.-крш.* дегет чәчәге (смолка липкая). Дегет чичийы болонда үсә, қызыл, ал чәчәк ата. Дегет чичийы дегетлерәк була, чәчәге бик матур, аллы-гөллө.

**сары чичи** *каз.ар.-крш.* к.: **ахық**. Җаз көне сары чичидән тотона торған ийек ашарга.

**ЧИЧИ III** *күрш.* 1. бертуган апага эндәшү сүзе (форма обращения к старшей сестре); 2. үзеннән олы қыз туганына эндәшү сүзе (форма обращения к старшей родственнице).

**ЧИЧИ'** *кас.* гөл (комнатный цветок). Чичи' савыты.

**ЧИЧИКАЙ I** *мәл.* 1. уенчык (игрушка); 2. чынаяк китеге, чынаяк қыйпылчыгы (осколок фарфорового блюдца); 3. телеграмм баганасындагы фарфор ролик, изолятор (изолятор на телеграфном столбу).

**ЧИЧИКАЙ II** *кузн.* чәчәк, чәчкә (цветок – в детской речи); чаг.: **т′ит′и II**. Чичикайлар болар.

**ЧИЧИКЕЙ** *каз.ар.-крш.* к.: **айақ I, 2**. Менә шушы чәшкеләрне әйтәләр чичикей дип.

**ЧИЧИН I** 1. *дөб.* затлы, чиста, яхшы (хороший, красивый, хорошего качества); чаг.: **асыл 1**. Эсбаш бик чичин, әйбәтне кийәсез бит инде; 2. *мәл.* к.: **қуқырт**. Бу йегет бик чичин икән.

**чичин бай** *чст.* ак, культуралы бай, укымышлы бай (образованный богач, просвещённый богач). Чиртушта (*ав. ис.*) элек бер чичин бай булган.

**ЧИЧИН II** 1. *хвл., кузн., мәл.* чыбыктан үреп, чана өчен ясалган әржә (плетёнка для саней); 2. *хвл., кузн.* ящигы чыбыктан үрелгән чана (сани с плетёным коробом). Чичин үрәләр иде чанаға куйарга, дүрт читле була, асты түгәрәк була. – *хвл.*; 3. *мәл.* тал чыбыгыннан үрелгән зур тубал (большой плетёный короб).

**чичин арба** *мәл.* к.: **крандас**. Чичин арбага тийәлеп киттеләр.

**ЧИЧИ-ПАЛ′АЙ** [*рус.* чистоплюй]: **чичи-пал′-айы пычырану** *мәл.* кара эш яратмау, эштән җирәнү (брезговать чёрной работой). Чичи-пал′-айым пычырана дип куркамысың әллә, сawыт-саба да йумыйсың.

**ЧИ-ЧИ-ЧИ** *м.-кар.* к.: **тити-тити-тити**. Чи-чичи дип чакыратлар (тавыкны).

**ЧИЧКӘ** *перм.* чәчәк (цветок).

**көймә чичкә** *перм.* к.: **йара II: йара йапрақ**.

**ЧИЧТИ, ЧИЧТЫЙ** [*рус.*] *каз.ар.* к.: **чистый**. Чичти аптырадым бу сийыр белән, саудырмый. – *лш.* Чичти башым қатты бу чалғы белән, қулы чыға да чыға. Чичтый үзәгемә үтте бу кәҗә. – *мам.*

**ЧИЧЫКАЙ** *чст.* савыт-саба ватыклары – балалар телендә (осколки посуды – в детской речи).

**ЧИШӘРӘ** *т.кам.-крш.* к.: **йуwача 2**. Элгәре оло көн бәйрәмнәренә пешерәләр ийе чишәрә.

**ЧИШЛИК** *м.-кар.* элек: мордва-каратай хатын-кызлары кигән баш киеме (женский головной убор у мордвы-каратаев в старину); чаг.: **мәләнчек**.

**ЧИШМӘ** *минз.* инеш (речка, ручей). Ике қойо бергә җыйыла да чишмә була. Монда чишмә бар, Қыңгыр сувы дибез.

**чиләк чишмә** *стрл.* чыга торган жиренә цилиндр рәвешле савыт куелган чишмә (ключ, на истоке, глазке которого помещена цилиндрическая посуда).

**чишмә башы** *минз., стрл.* чишмә (ключ). Тәмне сувыбыd бар бит бednең чишмә башында. – *минз.* Ана шул чишмә башының сувын китерсеннәр ийе awылга. – *стрл.*

**ЧИШМӘКҮЗ** [*фарс.* + *тат.*] *глз.* к.: **чишмә: чишмә башы**; чаг.: **күзләү I**. Чишмәкүзләр тау аста күп. Чишмәкүзләр күп бездә.

**ЧИШНӘК** [*рус.* чеснок] *тбл., твр.* суган (лук). Сөт мән чишнәкне қайнатам. – *твр.*

**ЧОБА** *минз., перм., бөре.* киҗеләп суккан алачадан астарсыз, озын итеп тегелгән өс киеме (длинная верхняя лёгкая одежда без подкладки из домотканого белого или полосатого полотна). Чоба тегәләр ийе бөрмәләп. – *бөре.* Чобаны киҗеләр белән қатыштырып суғаларыйы; қызқатыннықы қара буй-буй булайы чоба; сабан туйында да кийәре җуғы чоба кийеп җөрий ийе. – *перм.*

**ЧОБАЛДЫРУ** *хвл.*, **ЧОБАЛТУ** *хвл., перм., трбс., мәл.* чуалту (спутать – о нитках).

**ЧОБАН** *хвл., кузн., трх., мәл., кргл., минз., бгрс.* чуан (чирей); чаг.: **челги 2**. Улымның шушы төшендә өч чобаны бар ийе. – *трх.* Чобан чыққан, салқын тидергәнме? – *минз.*

**ЧОБАР** *минз., хвл., кузн., стрл., перм., бгрс., кргл., мәл., трх.* чуар (пёстрый); чаг.: **челкәр 2**. Уғата чобар пиманы базардан апқайталар ийе. – *минз.* Синең сынны чобар ийе ул да. – *стрл.* Чобар тawыгы минеке инде. – *трх.* Чебелдеккайым чопчобар, Чебен кунса, кем кывар (*бор. җыр.*). – *кузн.* Чобар итекләр булайы. – *перм.*

**чобар бит** *лмб.* шадра (рябой).

**чобар гөл** *кмшл.* бака гөле, юкә гөле, карабодай гөле (бегония).

**ЧОБАРАЙ: чобарай чаука** *шрл.* к.: **кыкычыбар**.

**ЧОБАРКА** *мәл.* сипкел (веснушки). Битенә чобарка тешкән, сүкемле кешегә төшә икән ул.

**ЧОБАРЛАУ** *трх., минз., перм., бгрс., кргл., хвл., кузн., мәл., стрл.* чуарлау, чуар итү (делать пёстрым, сделать пёстрым). Бик чобарлап суқмағаннар инде киндерне. – *минз.* Чобарлап суққан паласны асалап суққан дип тә әйтәләр. – *перм.* Мыны үзегез чыбарлапсыз? – *кузн.* Рәсемнәр белән чобарлап бетергән кагызын. – *трх.*

**ЧОБОР** *тара.* к.: **чобар**. Чобор итекнеңке пашын кисеб алты.

**ЧОБОЧОҚ** *клм.* карчык (старушка).

**ЧОҒАЛ** *брб.д.* чокыр (ямка на шее). Тамақ астының чоғалтарын көргәскәле йарамай.

**ЧОҒОН** *нокр.* чыгымчы – ат турында (уросливый, норовистый). Чоғон атны үрәтмәгә awыр, ул арқылана, қаршылана.

**ЧОҒОНДЫРЫҚ** *твр.* умрау сөяге (ключица).

**ЧОҒОНЧЫ** *нокр.* к.: **чоғон**.

**ЧОҒОР I** *к.т., трх., нрл.* к.: **җомор**. Бер чогор сөт эчте. – *к.т.* Йарты чоғор җыйалмаған җыллар була җиләкне. – *нрл.*

**татар чоғоры** *нрл.* агач чүмеч (деревянный ковш). Татар чоғоры белән эчеп қуйалар ыйы да қuwасны, сүләшеп утыралар ыйы әткәйләр.

**ЧОҒОР II** *к.т.*, **ЧОГОР** *т.я.-крш., стрл.* чокыр (овраг). Чогор җасаган кизләүдә, тустыган белә алас. – *т.я.-крш.* Безнен awыл чогорда булган. – *стрл.* Җаз көнә тулы була бу чоғорларда су. Чилче чоғоронда да су озақ тордо быйыл җазлый. – *к.т.*

**җаңғал чоғоро** *к.т.* җилкә чокыры (ямочка на затылке). Җаңғалчы кешенең җаңғал чоғоро тирән була дий (*әйтем*).

**ЧОҒОРТ** *минз.* к.: **тура I, 1**. Чоғорт йасадым.

**ЧОҒЫР** *брб.д.* иңбаш, җилкә (плечо).

**өз чоғырыңа алу** *брб.д.* үз өстеңә алу (брать на себя).

**ЧОЖ** *минз.* мә сиңа (ымлык) (междометие – на тебе). Миннибайлар (*ав. ис.*) чож тотсоннар, эләктердем инде аларның җегетләрен. Күлмәк алам дип барсам, чож, күлмәкләрне сатып бетергәннәр.

**ЧОҚОР** *мам., блт.* бәрәңге базы (яма для хранения картофеля). Бер чоқор бәрәңгене бер дә қузғалтмадық. – *блт.* Бер чоқор бәрәңгийе, ашаб бетерәләр инде маллар. – *мам.*

**җаңғалчы чоқоро** *мам.*, **җен чоқоры** *минз.*, **йалған чоқоро** *лш.* к.: **чоғор II: җаңғал чоғоро**. Қайале, қарыйг әле җаңғалчы чоқорон, беләбез хәзер, җаңғаллыймы, җуқмы.

**ми чоқоры** *т.кам.-крш.* лепкә (темя).

**ЧОҚОРЧА** *бөре.* чокырлы табага салып пешерелгән күмәч (булка, испечённая на сковородке с углублениями).

**ЧОКОРЧА** *шрл.* ачы камырдан мич төбендә пешерелгән пәрәмәч (ватрушка из кислого теста, испечённая на поду печи).

**ЧОҚУ** *нрл., минз., трбс.* казу (копать, рыть, выкопать, изрыть). Ул бадайымнарны без чоқодоқ. Төннә чоқодом нәүрәпне, ул чақ эш қаты ийе. – *нрл.* Чоқор чоқоп қуйғаннар тегеләр. Көрәк белән җир чоқый. – *трбс.* Аның бийатасы Calawat, шул чоқоған ул қойоны. Бақча чоқоп җөрисең чирле көйөңә. – *минз.*

**ЧОКУ 1.** *стрл.* к.: **басу I**. Соло йерләрен чокоп чәчтек көрәк белә; **2.** *чпр.* шаку (стучать). Килә, кабак чоки.

**ЧОҚЫНУ** *трбс.* кызыксыну, чокчыну (доискиваться, допытываться). Ул турда чоқынмадылар болар.

**ч о қ ы р** *урт.д.* чокыр (яма):

**алдақ чоқыры** *глз.* к.: **чоғор II: җаңғал чоғоро**.

**ЧОЛАН 1.** *т.я., минз., перм., к.-уф., стрл., брб.д.* к.: **ишегалды**. Чолан ишеген җawып җөрөгөз, чебешләр керә ату өйгә. Чоланда кәзәңкәбез бар, шунда җоқларсыз, анда бик тыныч. – *к.т.* Сарықларны чоланга йаптық, ишек эчкә таба йабыла торған ыйы. – *нрл.* Ике ызба аллы-артлы, уртада чолан. – *трх.* Қуш җорт булса, арасында чолан була. – *минз.* Чоланда су бар, керт әле. – *к.-уф.* Бидрәләр чоланда мыса, кәрәк була йе. – *перм.* Чоланны биранда кебек итеп эшләде. – *стрл.* Су чоланда. – *брб.д.*; **2.** *каз.ар., чст., мәл.*,

*чпр., хвл., т.я.-крш.* к.: **кәзәнкә 2.** Чоланға қуй чиләкне. – *каз.ар.-крш.* (Өйалдына) чолан кирәкми безгә, өйалдында торабыз ғына, әйберләр қуйарға келәт бар. – *лш.*; **3.** *блт.* баскыч алды корылмасы (навес над крыльцом). Чолан башына басты да өй түбәсенә менеп китте. Чолан түбәсенә қалай җабарға, дий. Басқыч алды қапламмаған булғач, чолан булмый, қапланса ғына чолан була; **4.** *хвл., кузн., м.-кар., стрл.* к.: **бүлмәч 2.** Чолан вана арткызбаның пич алды. – *хвл.* Чоланда күп была бит кычаугачтыр, таба тоткочтыр. – *стрл.* Чоланда тора йаңа киленнәр, түргә чыкмый. – *м.-кар.*; **5.** *кузн.* түр якта яки өйнең ак ягында ясалган бүлмә, йокы бүлмәсе (спальня в чистой половине избы). Чоланны йаратмыйм мән, кайчан мәҗлес була, чаршауны алай да итеп була, былай да, чоланны хот′ ват; **6.** *дөб.* зиратта мәет озату өчен булган кирәк-яракларны саклый торган кечкенә каралты (маленький сарайчик на краю кладбища для хранения принадлежностей, необходимых для проводов покойника). Чолан бар зиратта, дәү түгел, җywa тырған қабық бар анда; **7.** *клм.* абзар (хлев).

**ақ чолан** *к.т.* өй алдының ак ягы, кунак-төшем каршы алыр өчен ясалган ягы (парадный ход, парадные сени). Қунақлар булғач ақ чоланны ғына ачтым әле. Җәйгә чыққач ақ чоланда ғына җоқлыйбыз.

**йылы чолан** *клм.* җылы абзар (утеплённый хлев для скота). Йылы чоланнар әзерлисең қайwаннарға.

**чолан тақтасы** *блт.* к.: **бүлем 1.**

**ЧОЛБАНУ** *тмн., стрл., минз.* чуалу (путаться, спутываться). Җепләрне ишә иде чолбанмасын өчен. – *тмн.*

**ЧОЛҒAWЫЧ** *нрл.* к.: **сарғыч: айақ сарғычы.** Чолғawычларны да чиккән қыз, булачақ кийәү өчен.

**айақ чолғawыч** *нрл.* к.: **сарғыч: айақ сарғычы.** Әни биреп төшәргән ийе бер сөлгө, айақ чолғawычлары.

**ЧОЛҒАЙ** *лш.* үткен, тере (бойкий, резвый, проворный, расторопный); чаг.: **чылғый.** Үзем чолғай булғанға ғына чыдағанмын.

**ЧОЛҒАҚ** *клм.* к.: **сарғыч: айақ сарғычы.** Үтекне чолгақ урап кийәләр. Чолғақ урап кийәләр кемнең йоны йуқ.

**ЧОЛҒАУ** *блт.* чорнау (мотать, наматывать). Тубырчаға чолғыйсың җепне, озатасың.

**ЧОЛГЫЙ** *стрл.* каурый (перо). Тавис чолгый койрыклы, чолгыйлары озын.

**ЧОЛДОР I** *минз.* кечкенә қыңгырау (колокольчик); чаг.: **қутаз; җиңгеле.** Қыңгырау қалын, зурырақ була, туй атына тағалар, чолдорны малға тағалар, бәләкәйрәк (була).

**ЧОЛДОР II** *перм.* **1.** иске (старый, изношенный – об одежде); чаг.: **қылқа.** Чолдор ғына бер күлмәк. Қайда чолдор бар, шуны кийеп кенә йәшәгән; **2.** иске, тузган – йорт-җир h.б. турында (старый, ветхий – о жилище и т.п.); **3.** ялангач, киемгә мохтаж (голый, нуждающийся в одежде). Өстенә кийәренә булмадисә, чолдор диб әйтәсең инде. Оланнар ач булмасыннар, чолдор булмасыннар тип тырыштық; **4.** чүп-чар, иске-москы (мусор, старьё). Мичкә чолдор, wақ-түwәк өстәдем дә озағ утыра.

**ЧОЛКА** *тмн., кузн., хвл., карс., мәл., әстр.* оек (чулки). Айагында wal′ник, чолкасы йук. – *карс.* Бак, чолкаларым йыртылган. Чолкаң йебенер, ки айагыңа. – *кузн.* Нәзек чолкадан басам идәнгә дә, салкын. – *хвл.* Айақтан чолка чишелми. – *әстр.*

**йеп чолка, мамык чолка, нәзек чолка** *кузн.* к.: **ойоқ I: базар ойоғы.**

**ЧОЛКАБАШ** *хвл., мәл.* базар оекбашы (носки). Мәзәкчеләр чепрәк тә җийа, чолкабаш та сата иде. – *хвл.*

**чолоқ I** *перм.* чолык (борть):

**чолоқ йасау** *перм.* агач куышын зурайтып, умарта кортлары кереп яшәрлек итү (увеличить и устроить дупло дерева для пчелиного роя). Анда қарагайда бар, чолоқ йасалган.

**чолоқ күтәрү** *перм.* аерылып киткән корт иле кунып ояласын өчен, урманда агач башына махсус умарта ясап кую (устроить борть в лесу на дереве для пчелиного роя). Қайсы монда чолоқ күтәргән?

**ЧОЛОҚ II** *клм.* к.: **чолка.**

**ЧӨЛПЫ** *брб.д.* ат ялы (грива).

**ЧОМАК** [*гар.*] *м.-кар.* к.: **очтомақ.**

**ЧОМОҚ** *перм.* сапсыз чүмеч яки чүмеч урынына йөртелә торган савыт (ковшик без ручки или какая-нибудь посуда, используемая вместо черпака). Чомоқ бар қый анда, кыwac қына алып бирим?

**ЧОҢҒОЛ** *минз.* к.: **базлавык.** Йулның менә бу төшөндә чоңғоллар күп.

**ЧОҢГЫЛ** *кузн.* кыңгырау (колокольчик). Чоңгыл тагалар алашларга, кызның кибиткасы бар.

**ЧОҢҚЫР** *влгг.* чокыр (овраг, яма).

**ЧОР I** *мам., минз.* ара, вакыт (время). Қайттық инде шушы чорларда. – *мам.* Сабан туйы чорында қунақлар күп булды. – *лш.* Мин чирләгән чорда бәрәңге утырту чоройы. – *минз.*

**ЧОР II** *перм.* к.: **маймуч.**

**ЧОРАҒАЙ** *твр., тара.* чуртан баласы (щурёнок). Пер чорагай та қәтерле болып соуғыш wахытта. – *твр.*

**ЧОРГАЛУ** *хвл.* чорналу (наматываться, намотаться).

**ЧОРҒАУ I** *лш.* чорнау (окружить). Awылны чорғап алпут алып бетергән.

**ЧОРҒАУ II** *брб.д.*, **ЧОРҒУ** *перм.* к.: **быргыту 1.** Мәргән кеше болған, Баарчын аны йаратмаған, йамыға чорғаған. Қатны оқый дадыр чоргаб ийәдер. Пуйыстан чоргодолор. Чорға, кәрәкмәс тәгәҗ у. Чоргадым мин у нимәгезне.

**ЧОРДЫ** *перм.* к.: **черде.**

**ЧОРКА** [*рус.* чурка] *стрл.* **1.** к.: **чашка II.** Самawырны чорка белән кайнатадырыйык; **2.** ут кабызырга яраклы йомычка яки телеп куйган чыра (щепка, годная для разжигания огня, или лучина). Монawы күк чорка тоткан да уйнаб утыра.

**ЧОРЛАУ** *саз.я.* акрын гына агып тору, аз гына агып тору (течь слабо, понемногу). Кранныңқы соу чорлайт, төсәтхәле кәрәх.

**ЧОРЛЫ** *т.кам.-крш.* әйбәт, яхшы, ярыйсы (хорошо, прилично, в пределах нормы); чаг.: **ару I, 9.** Башта бик начар торалар иде, ә хәзер чорлы торалар.

**ЧОРМА** *минз.* к.: **картус.**

**чорма башы** *трх.* к.: **қатнар.**

**ЧОРМАWЫҚ** *лш.* тычкан борчагы (мышиный горошек).

**ЧОРМАЛЧЫҚ: чормалчық печән** *перм.* йогырт (подмаренник цепкий).

**ЧОРМАУ** *перм.* **1.** төрү, урау (окутывать, закутывать, завёртывать, обвёртывать). Әнийең чормап қуйған булдийе, җоқлап китәр дигән булып (баланы); **2.** бәйләү (перевязать, бинтовать). – Айаққа пычақ төштө. – Қанадымы? Чормадыңмы?

**ЧОРНАWЫЧ** *лш.*, **ЧОРНАУ** *мам.* к.: **сарғыч: айақ сарғычы.** Айаққа тулайоқ, чорнаwычлар: мондый чорнаwыч, чиккән чорнаwычлар йасыййық. Башы эшләгән чорнау була кийәүгә.

**ЧОРОК** *хвл., кузн., мәл., тмн.* **1.** янбаш (бок, бедренная часть тела); чаг.: **йантык: йантык сәвәге.** Чорогын тешләгән. – *тмн.* Чорокларым чиләнде, бер чиләкле самуwар. – *кузн.* Йата-йата чорокларым тишелә йазды. – *хвл.*; **2.** бот сөягенең таз сөягенә тоташкан урыны (место соединения тазобедренных костей). Чорогы сынган. Айагы чороктан каймыккан. Чорогы wатыг иде шыннан, кисәргә бирмәде. – *хвл.*

**чорок сәвәге** *лмб.* к.: **чорок 2.**

**ЧОРОШУ** *саз.я.* бөрешү, җыерчыклану (сморщиться).

**ЧОРСОЗ** *каз.ар., т.я., хвл.* тәртипсез, тыйнаксыз, әдәпсез, хәрәкәтендә яки кыланышын да чик белмәүче (о человеке, не знающем меры в поведении и поступках); чаг.: **алакай.** Балалары бик чорсоз. Оло қызы бик чорсоз аның. Малайы чорсоз, бер сүз тыннамый. – *блт.* Чорсозрақ ыйы аның ул малайы үскәндә үк. – *нрл.*

**ЧОРТМА** *перм.* балкон. Чортмасы бар, уң йақта икенче дум.

**ЧОС 1.** *минз., стрл.* әвәс (пристрастный, охочий до чего-либо). Ул зерә чос шундыйларға. – *минз.* Тозлы кыйарга чос ийе. – *стрл.*; **2.** *минз.* үткен, булдыклы (способный, дельный; ловкий, проворный). Қара, улым, син бик чос икәнсең эшкә; **3.** *минз.* (ымлык сүз) күкиш сиңа (на тебе кукиш). Безгә чос қалды бәлешләр, җегетләр тәрәзәдән алып чығып сызғаннар.

**ЧОСЛОҚ** *минз.* тырышлык (старательность). Чослоқ кирәк күрергә бу рәхәтләрне.

**ЧОЧҚО** *клм.* дуңгыз (свинья).

**ЧӨЧЫТУ** *брб.д.* куркыту (испугать, пугать).

**ЧӨШҚОЛТАУ** *минз.* пыш-пыш сөйләшү (говорить шёпотом; шептаться, шушукаться). Бик чошқолтыйсыз, балалар.

**ЧӨБӘК** *перм.* сүс (кудель). Җитенне талқыйлар да, шул чөбәк була.

**ЧӨБӨГӨ** *яүшт.* без (шило).

**ЧОБОР** *брб.д.* иске, тузган (обветшалый, старый – дом). Пер гейә (генә) әбийәк, чөбөр гейә өйө.

**ЧӨБҮ** *брб.д.* үбү (целовать). Чөпип алу.

**ЧОWӨР** *саз.я.* иске-москы кием (старая, изношенная одежда).

**ЧОГӘН** *т.кам.-крш., бәр.* агач кабыгы астындагы сыекча, су (сок под древесной корой). Ағачның чөгәне қата башлаған. – *бәр.*

**ЧӨГӘЧӨЙ** *нгб.-крш.* к.: **чака I.** Арбаның чөгәчөйө чыққан.

**ЧӨГИН** *перм.* **1.** к.: **чуйын: чуйын чүлмәк; 2.** к.: **чуйын.**

**ЧӨГӨЛДЕРЕК** *блт.* к.: **чөйлөк.** Қамытның чөгөлдереген шишкәндә, ат башы белән бәреп йықты кигәwен тешләгәнгә.

**ЧӨГӨРМӘК 1.** *минз., стрл.* кайнап чыгып тора торган су (источник, бьющийся вверх из-под земли); **2.** *минз., стрл.* кар һәм яңгыр сулары җыела торган уйсу җир (впадина, углубление, наполняющееся водой весной и во время сильных дождей). Чөгөрмәктән су ташып, қар базына төшкән. – *минз.*; **3.** *кргл., бгрс.* к.: **қазан.** Менә шулай аска киткән чөгөрмәк бар, менә шунда бик тирән. – *кргл.* Чөгөрмәк суwыра инде. – *бгрс.*; **3.** *минз., стрл.* һаман ишелә барып зурая бара торган чокыр (котлован, возникший в результате обвала и всё время увеличивающийся). Чөгөрмәк урамы, дибез, чөгөрмәк бар анда. – *стрл.*

**ЧӨЙГӘЧӨЙ** *к.т.* к.: **чака I.** Бу арбага тимер чөйгәчөй кирәк.

**ЧӨЙГЕЛЕ** *т.кам.-крш.* майсыз, ябык – ит турында (без жира, тощий – о мясе). Мин итнең чөйгелерәген җараттам.

**ЧӨЙГЕМАШ** *т.кам.-крш.* к.: **сүwанаш.** Чөйгемаш сирәк булғанға тәмне була.

**ЧОЙҚӘЛҮ** *лш.* янтаю, авышу (покоситься, наклоняться). Ике-өч көннән биртен йөрәгем начар, әз генә чөйкәлеп-чөйкәлебрәк китәм.

**ЧӨЙКЕЛЕП: чөйкелеп бәйләү** *әстр.* чөеп бәйләү – яулык турында (способ повязывания платка: повязать платок, сделав на голове маленькие рожки с двух сторон).

**ЧӨЙЛӨК** *т.я., мам., лш., бәр., чст.* чөелдерек (супонь). Тартма шулхәтле, чөйлөгән өзәсең бит. – *лш.*

**чөйлөк бағы** *бәр., бөре.* к.: **чөйлөк.** Чөйлөк бағын да мунчаладан иштеләр әле. – *бәр.*

**ЧӨЙМӘЛҮ** *минз., кргл.* к.: **чәүмәлү 2.** Чөймәлмәсен өчөн генә қыстырырға дигән идем. – *кргл.* Самаwар чөймәлмәсен өстәлгә. – *минз.*

**ЧӨЙМӨК** *тара., твр.* **1.** малның эчке әгъзаларын турап, табада қыздырып әзерләнгән ашамлық (еда, приготовленная из внутренностей животных, жаренная на сковороде). Чөймөк йасыйлар, эчәгене, йөрәген, үпкәсен, паwырын турайлар да қыстып ашайлар. – *твр.*; **2.** сызык (шкварки). Майы эреп петә дә чөймөге қала. – *тара.*

**ЧӨЙӨРӘ** *мам.* ат арбасының югарырак күтәрелеп тора торган башы, арба башы (облучок телеги).

**ЧӨЙӨРТҮ** *к.т., мам., лш.* к.: **чекү.** Маңғайына чөйөртә. Бармақ белә чөйөртмәде дә ул миңа. Иртә дә кил, кич тә кил, Тәрәзәңне чөйөртә кил; Чөйөртүwеңнән танырмын да Қаршы чығып алырмын (*хал. җыр.*). – *к.т.*

**ч ө й ү** *урт.д.* чөю (метать, кидать):

**җаулық чөйү** *минз., стрл.* яулыкны артка бәйләү (повязать платок назад); чаг.: **чөйкелеп: чөйкелеп бәйләү.** Кулым гарипләнде, җаулык чөйәргә дә бармый. – *стрл.* Бийатай, бийағай җанында җаулық чөйү җуғ инде. – *минз.*

**ЧӨКӘЛТӘ** *минз.* к.: **пысқыш**.

**ЧӨКӘЛҮ** *лш.* мәтәлеп китү (кувыркнуться, упасть вверх тормашками). Мәтәләләр, чөкәләләр. Чөкәлә-чөкәлә кереп китте.

**ЧӨКӘН** *т.кам.-крш.* к.: **мәмәч**. Җүкәне чөкән бағытында төшөрөп қалсаң, әйбәт була инде аны.

**ЧӨКЕ** *чст.* к.: **кәшә**.

**ЧӨКӨРМӘК** *кмшл.* җир аска убылып ясалган чокыр (котлован, возникший в результате проваливания земли). Бер чөкөрмәк бар Йаңа Йәрмәк (*ав. ис.*) йулында, сулы мәмержә, Залатуй узиро дигәннәр аны.

**ЧӨКӨ-ЧӨКӨ** *бөре.* чөкердәшеп (воркуя, щебеча). Эй, чөкө-чөкө самавырдан эчәләр, ди, балны.

**ЧӨКЧӨР** *төм.* кечкенә дә, ябык та – кеше турында (и худой, и тощий – о человеке).

**ЧӨЛ** *минз.* к.: **батырақ**. Ced чөл алығыd, чөл йанына берәр телем әпәй алығыd.

**ЧӨЛБӘЙ** *срг.* к.: **цилбәй**. Чөлбәйемне карап багыйм, Күзләре кара микән (*хал. җыр.*)?

**ЧӨЛДИ** 1. *чст.* к.: **чити**; 2. *к.т.* ябык, кечкенә балага карата әйтелә (говорится о маленьком, худом ребёнке); чаг.: **чақ I, 2**.

**ЧӨЛКӘ** 1. *минз., перм., крш., әстр.* к.: **чолка**. Тула чөлкә кигәннәр айақ қатмасқа. – *перм.* Тула чөлкә киндерә белән кийенәләр. – *каз.ар.-крш.* Ақ чабата белән ақ чөлкәне Сыйпый ғына сыйпый кийәмен (*хал. җыр.*). Бәйрәм көннәрендә айакка ак чабата, ак чөлкә кийәдерийек. – *т.кам.-крш.* Айакка кигәннәр чөлкә, сарык җыныннан. – *чст.-крш.*; 2. *минз.* к.: **башай**.

**җеп чөлкә** *минз.*, **җөн чөлкә** *т.кам.-крш.* к.: **бишинәйык**. Җеп чөлкә бәйләп кийәдер ийек җөннө эрләп. – *минз.* Қәзер җөн чөлкәләрне әллә неди матур җепләр белә чәчәкләп бетерәләр. – *т.кам.-крш.*

**мамық чөлкә** *каз.ар.-крш.*, **мамык чөлкә** *чст.-крш.* к.: **ойоқ I: базар ойоғы**. Мамық чөлкәләр апқайтқан барыбызға да. – *каз.ар.-крш.* Бер чумадан мамык чөлкәләр таратты. – *чст.-крш.*

**паныскый чөлкә** *т.кам.-крш.* к.: **бишинәйык**. Сарық җононнан озон чөлкә кийәләр ийе, паныскый чөлкә диләр ийе, наскилар бәйлибез.

**тула чөлкә** *т.кам.-крш., чст.-крш.* тула оек (чулки из сукна домашнего приготовления). Тула чөлкә суқтық элгәре, ашйаулыгын, бистәрен, чаршаулар да алача булды. – *т.кам.-крш.*

**чөлкә башы** *т.кам.-крш.* к.: **чолкабаш**. Қызым, чөлкә башы беткән, чөлкә башы алырға кирәк.

**ЧӨЛКӘБАШ** *каз.ар.-крш., перм.* к.: **башай**. Аппақ чөлкәбашлар, җырларыйық, бийерийек. – *каз.ар.-крш.*

**кийез чөлкәбаш** *перм.* йоннан басылган оекбаш (носки, валяные из шерсти). Кийез чөлкәбаш кийәм, айақлар қата. Кийез чөлкәбашны ywалыйлар гына, җомшақ қына итеп.

**ЧӨЛКӘWEЧ** *перм.* к.: **йулпуч**. Чөлкәwечтән оннарын җыйдық. Чөлкәwечме он или торған нимә?

**ЧӨЛКӘР** 1. *хвл.* күк төс (сизый, сивый); чаг.: **чалка**. Чөлкәр кәзә; 2. *кмшл., мәл.* к.: **кыкычыбар**.

**ЧӨЛЛИ** *минз.* к.: **чити**. Чөлли белән җиләк җыйаларmыни? Чөлли шешә.

**ЧӨЛМӘЙҮ** *брб.д.* к.: **лач: лач булу 1**.

**ЧӨМӘ** *твр., тара.* чүмәлә (копна). Көлтәне чөмәгә утызалар, чөмәне кибәнгә. – *тара.*

**ЧӨМӘК** *нрл.* чалгы тупсасы (пятка косы). Чалгы сынды чөмәгеннән.

**ЧӨМӘКӘЙ: чөмәкәй итү** *мам., лш.* өеп тутыру, очлы итеп өеп (наполнить с верхом, полным-полно). Җиләкне чөмәкәй-чөмәкәй итеп салып чығарган ийем. – *лш.* Cawытларны чөмәкәй итеп қайын җиләгә җыйып алып қайтты. – *мам.*

**ЧӨМӘКӘЙЛӘП** *мам.* өеп, очлы итеп өеп, өеп тутырып (наполнив доверху). Бер банкыны чөмәкәйләп алып килде (җиләк).

**ЧӨМӘКЛӘНҮ I** *мам.* чәчәк сабагы җибәрү – суган турында (пускать стрелу – о луке). Суған инде чөмәкләнгәч қартайа, ашарға тәмне булмый.

**ЧӨМӘКЛӘНҮ II** *дөб.* к.: **чәүмәлү I**. Эскәмийәнең чөмәкләнеп китүwе бар.

**ЧӨМӘЛ** *твр.* кибән (стог). Йегермә-йегермә пиш моғол пер чөмәл пулады.

**ЧӨМӘЛДЕЛЕК** *брб.д.* к.: **қымрысқа**.

**ЧӨМӘЛЧЕК** *мам.* к.: **ботка: йаңгор боткасы**.

**ЧӨМӨКИЙ** *блт.* туп-тулы, өеп (полным-полно, верхом); чаг.: **күздәй**. Ун җеп ире булқы алдық, оло сандыққа тутырдық: чөмөкий булды.

**ЧӨМӨШ** *клм.* чүмеч (ковш).

**ЧӨНӘКӘ** *кас.* к.: **бармақ: гөлчәчәк бармақ**.

**ЧӨНГӨРҮ** *мам.* к.: **борнау I**.

**ЧӨНҖЫЛАУ** [*удм.* + *афф.* -лау] *нокр.* к.: **макшу**. Йералма чөнҗылаған. Чигендер, кишер, йералма чөнҗылай.

**ЧӨНКӘ** *блт., бәр.* мари хатын-кызларының яулык астында маңгай турысына киеп калдыра торган чигүле һәм тәңкәләр тезелгән баш киеме (часть головного убора – у марийских женщин). Ике әнкә, бер чөнкә, әләбез дә чөйәбез (*мәкаль*). – *блт.*

**ЧӨҢГЕР: чөңгер табақ** *яүшт.* тирән табак (глубокая чаша).

**ЧӨҢГЕРҮ** *мам., минз.* яшь баланы көлдерү өчен иреннәр белән төрле тавышлар чыгару (издавать различные звуки губами, чтобы позабавить ребёнка). Атасы чөңгергәнгә рәхәтләнеп awызын йырып йата (яшь бала). Қайәле, бер чөңгерим әле үзеңә! – *минз.* Мин чөңгерсәм, көлеп җибәрә, йат кешене таный, қарап қына тора. – *мам.*

**ЧӨҢГӨЛ** *минз.* болыннарда, елга буйларында язгы ташу вакытында су кереп калган чокырлар, кечкенә күлләр (маленькие озёрца, оставшиеся после весеннего половодья); чаг.: **cywалқа; чөгөрмәк I**. – Быйыл чөңгөлләргә су кердеме? – Керәшен чөңгөленә керде, анда балық күп булырға тийеш.

**ЧӨҢКӘ** *минз., стрл.* балчык савыт (глиняная мисочка). Чөңкә белән чийәле май қуйасың, алдан әзерлисең аны малай өйләндерергә булғач. – *минз.*

**ЧӨПИ: чөпи орлоғо** *каз.ар.-крш.* төтәч – үсемлек (дымянка).

**ЧӨПРӘК** *клм.* тастымал, кул тастымалы (маленькое полотенце, салфетка для рук).

**ЧӨПЧӘРӘ** *яүшт., клм.* к.: **шөшпәрә**. Мән дүрт читкел йасыйм чөпчәрәне. – *клм.*

**ЧӨРКӘНТӘЙ** *перм.* к.: **дыраңғыш**. Бигрәк чөркәнтәй қый Бақый.

**ЧӨРӨШ I** *минз.* терлек йөри торган җир, көтүлек (пастбище).

**ЧӨРӨШ II** *төм., яүшт.* җыерчык (морщина). Питемтә чөрөшләрем пулса, қаймақ сөртәмен. – *төм.* Битләрендә бер дә чөрөш йуғ иде. – *яүшт.*

**ЧӨРӨШҮ** *перм.* бөрешү (мяться, измяться). Ал әле күлмәкне, чөрөшөп җийа.

**ЧӨРТЛӘҮ** *бөре.* к.: **қортлау II**. Чөртләгән тawық. Миндә бар чөртләгән тawық, кирәк булса, алып басарға сал үзеңә.

**ЧӨРЧӘ** *брб.д.* **1.** ләтчә (ласка). Чөрчә пасқырығ аснан чығады, цыцқан тотады; **2.** тычкан (мышь).

**ЧӨТИ** *бөре.* к.: **мақау 2**; чаг.: **ат′акыш 1**.

**ЧӨҮ** *твр.* чыршы (ель). Пестә тет, қарағай, чөү, пайлан, қайын, аусақ ағачлары үсәте.

**ЧӨЧБӘРӘ** *тара.*, **ЧӨЧБҮРӘ** *тбл.* к.: **шөшпәрә**. Чөчбәрәләре йоwан-йоwан булып, абзыма сыймайты. Чөчбүрәне гән (күп) қылыпты, цайға килегес.

**ЧӨЧГЕЛ** *твр.* төче (пресный). Ирга чөчгел пулаты, аңа күрә йаратамын.

**ЧӨЧКЕЛТ** *тмн.* төчкелт (сладковатый, слегка сладкий). Тү йармасыннан бешерә иде кимаклар, ул чөчкелт бик инде, тәмне була иде.

**ЧӨЧМӘРӘ** *брб.д.* к.: **шөшпәрә**. Йаңы йылта чөчмәрә йасайбыс. Чөчмәрәләре әре-әре, гөштне (итне) кән қуйыпты.

**ЧӨЧӨ 1.** *миш.д., перм.* баллы – бал, шикәр кебек баллы әйберләр турында (сладкий). Чөчө чәй. Бәлешкә чөчө салып та кабартырмын. – *күзн.* Чөчө генә эч, канфиты белән. – *хвл.* Ачымы-чөчөме, Без эчмәгән кешеме? (*хал. җыр.*). – *перм.*; **2.** *миш.д.* к.: **чече 3**; **3.** *миш.д., перм., бөре.* төче, әчетелмәгән (пресный). Чөчө кыймак. – *тмн.* Чөчө камырдан күмәч. – *күзн.* Әпәй чөчө булған. – *бөре.* Бер қат җимеш салғаннар да, бер қат чөчө қамыр салғаннар. – *перм.*; **4.** *перм.* тозы аз (недостаточно солёный); чаг.: **йумал 2**. Чөм-чөчө йе аш; **5.** *к.-уф.* яңа тотылган, тозламаган балык турында (свежий – о рыбе). Чөчө балық ашап қына эшкә китте.

**чөчө җибәрү** *перм.* к.: **зимнәү I**.

**чөчө нәркәмәс** *лмб.* кара әрем (чернобыльник).

**ЧӨЧӨК I** *перм.* сөт касмагы (поскрёбки, осадок молока на дне посуды после кипячения); чаг.: **пәйеч 2**.

**ЧӨЧӨК II** *перм., к.-уф.* **1.** каен суы (берёзовый сок); чаг.: **мәмәч**; **2.** к.: **төчөгән 1**; **3.** баллы, татлы (сладкий). Поларға чөчөк су кәрәк.

**ЧӨЧӨКЛӨ** *брб.д.* сөтле – үләннәр турында (с млечным соком – о травах). Пер чөчөклө үләң үсә, урысца осот тейте.

**ЧӨЧӨЛӘНДЕРҮ** *перм.* шикәр, он яки салат белән болгатылган баланны мичтә томалап төчетү (приготовить сладкую пищу из калины). Чөчөләндермәгә утыртам паланны.

**ЧӨЧӨ-МӨЧӨ** *перм., мәл.* чәй янына куела торган татлы ашамлыклар (всякие сладости к чаю). Чөчө-мөчө белин өстәл тулған да. – *перм.*

**ЧӨЧӨТКЕ** *хвл.* к.: **сыл I, 2**.

**ЧӨЧӨТМӘ** *мәл.* камыр изү өчен махсус әзерләнгән сыекча, чүпрә: яңа гына кайнап чыккан колмак суына он болгатып, томалап куялар; бераз вакыттан соң, төче ис килә башлагач, чүпрә салып камыр изәләр (специально приготовленная из хмеля жидкость, закваска для заварного хлеба).

**ЧӨЧӨТҮ 1.** *миш.д.* төчетү, баллы итү (сделать сладким); **2.** *чст., хвл.* ипи яки күмәч изәр алдыннан кайнар колмак суына он болгатып һәм аны томалап куеп махсус әзерләгән төче сыекча – сыл ясау (замесить тесто на специально приготовленной жидкости из горячего раствора хмеля с мукой). Әпәйләрнен камырын чөчөтөп куйган идем, шонарга бик уңдылар. – *хвл.* Әпәй чөчөтергә куйдым. – *чст.*

**ЧӨШЛӨ** *минз.* шөшле (кочедык).

**ЧҮ** *мәл.* чү, тукта (чу, стоп, тихо). Чү, әлдә, көтеп тор.

**әлдә чү** *мәл.* к.: **чү**.

**ЧҮБАҚ** *твр.* чокыр (яма).

**ЧҮБА-ЧҮБА-ЧҮБА** *нрл.* к.: **чаба-чаба-чаба**.

**ЧҮБЫНУ** *каз.ар.-крш.* к.: **чумыну**. Су чубыналар. Су чубынырға барма, ату әпкитәләр (баланы кисәтү).

**ЧҮWА** *каз.ар.-крш.* элек: хатын-кызлар кигән ак киндер күлмәк (женская одежда из белого домотканого полотна в старину); чаг.: **чоба**. Без җәш бағытта чуwа кийәрләр ийе, қәсилә тагарлар, түгәрәк җаулық җабарлар ыйы.

**ЧҮWАҚ I** *бөре., брб.д.* аяз (ведренный, ясный). Көннәр чуwақ булганда йул йөрергә әйбәт. – *бөре.*

**қортқалар чуwағы** *бөре.* әбиләр чувагы (бабье лето).

**ЧҮWАҚ II** *твр.* чокыр (яма).

**ЧҮWАЛ 1.** *әстр.* җәен аш-су пешерү өчен ишегалдындагы учак (летний очаг на дворе); **2.** *әстр.* торба, морҗаның түбәдән чыгып торган өлеше (печная труба на крыше); **3.** *төм.* алгы ягы ачык булган мич (печь, передняя сторона которой открыта). Чуwал йаққаннар, палық пешергәннәр.

**ЧҮWАЛЧАН** *к.т., трх., лш.*, **ЧҮWАЛЫЙ** *трх.* к.: **селәү II, 1**. Чуwалчанға балық шәп қаба шул. – *трх.* Чуwалчан қазырға киттеләр, балық тотарға барабыз. Әчендә чуwалчан бардыр, дим, бүлнискә аппарасым килә (баласын). – *к.т.* Әнә-әнә, ашағыз чуwалый (чебиләргә). – *трх.*

**ЧҮWАН** *срг.* куштан (услужливый, льстивый); чаг.: **йаштакай**. Чуwан кеше.

**чуwар** *урт.д.* чуар (пёстрый):

**тәңкә чуwар** *лш.* алмачуар (серый в яблоках – масть лошади).

**ЧҮWАРИ: чуwари таш** *мам.* к.: **ногый**. Чуwари ташлар бар тау башында.

**ЧҮWАРКАЙ** *т.кам.-крш.* түндербаш (болиголов).

**чуwарлану** *урт.д.* чуарлану (пестреть):

**җөрәк чуwарлану** *дөб., мам.* борчылу, бозылу (беспокоиться, нервничать); чаг.: **көйдерү**. Ишегалдына қаз керсә дә җөрәгем чуwарлана. – *дөб.* Қыланмышларына җөрәгем чуwарланып қайттым әле. – *мам.*

**ЧҮWАРЧАН** *дөб.* к.: **селәү II, 1**. Ул балаларнын бармақлары чуwарчан кебег ийе.

**ЧҮВАШ 1.** *срг.* таза, зур гәүдәле кеше (чело-

век высокого роста, здоровенный). Зур таза кешеләрне чуваш диләр; **2.** *брб.д.* бараба татарларының бер төркеме (некоторые из барабинцев, называющиеся этим именем). Пестә татар чувашы булған, урыс чуwашы булған. Ажбаковлар татар чувашы булған.

**ЧУWЫШ** *брб.д.* бәйләү энәләре, бишинә (спицы). Йышымны (оекны) чуwыш белә пәйләгән.

**ЧУҒАЛТУ** *блт.* к.: **чобалдыру**. Эрәтен чуғалтмыйм.

**ЧУҒАЛУ 1.** *блт.* чуалу, маташу (возиться); чаг.: **кан'ау**. Ул да өй белән чуғала бит инде; **2.** *лш.* чуалу, бозылу (запутаться, портиться – об отношениях); чаг.: **чебәлү 1**. Тормошо чуғала.

**ЧУҒУР** *брб.д.* иңбаш, җилкә (плечо). Чуғурына салып парадыған оутынны.

**ЧУГЫР** *мәл.* тәмәке төпчеге (окурок).

**ЧУДА: чуда булу** *тбл.* к.: **чута: чута булу**.

**ЧУДУН** [?] *глз.* ябык (худой). Қызыбыз энечкә, чудун.

**ЧУЙ: чуй булу** *лш.* таш булу (стать камнем). Қайа барған, шунда чуй булсын, айырылып-сайырылып җөрөргә зазмасын. Барған җирендә чуй булсын (кияүгә киткән кызларга карата әйтелә).

**ЧУЙЫН** *перм., к.-уф.* казан (котёл). Чуйын қызған, су салып җибәр. – *к.-уф.*

**чуйын чүлмәк** *бөре., минз., перм.* чуен (чугун). Чуйын чүлмәг эчләрендә Пешә салдат ашлары (*бор. җыр.*). – *бөре*. Монда чуйын чүлмәк бар, апай, сал әле шунда (суны). – *минз.*

**ЧУЙЫРТ** *мам., трх.* к.: **ақбаш**. Чуйырт ашадым, диләр, әнис йафырағына әйтәләр. – *трх.* Қартаймаса, чуйырт бәк тәмне ул. – *мам.*

**песи чуйырты** *мам.* сары чәчәкле, яфрагы формасы белән миләш яфрагына охшаган тәбәнәк үлән (трава с жёлтыми цветками, с листьями, похожими на листья рябины).

**эт чуйырты** *мам.* меңьяфрак, ярмабаш (тысячелистник).

**ЧУК I** *мәл., кузн., хвл., лмб.* тукыма кисәге (кусок, лоскут материи); чаг.: **цәпе I, 1**. Ыланнар чук белән ун'и. – *мәл.* Күкрәкчә, шында баскан чуклар, пыт'ины кем дә күрмәсен. – *лмб.*

**ЧУК II: чук кына** *кузн.* к.: **безрәк**. Каны, чук кына.

**ЧУҚ 1.** *перм.* к.: **курмыйш**. Түбән чуқ. Урта чуқ. Безнең чуқта күршедә генә икәү суға қапны; **2.** *туб.-ирт.д.* күп (много). Қызыл тамыр чуқ монта. – *тара.*

**ЧУКА I** [*рус.* чека] *мәл.* к.: **чака 1**.

**ЧУКА II** [*рус.* чурка] *мәл.* к.: **чашка II**.

**ЧУКА III** [*мар.*?] *срг.* калкулыкның очы, түбәсе (вершина возвышенности). Казыдым чукадан, тебенә йетә алмадым.

**ЧУКА IV** *т.я.-крш.* к.: **чолка**.

**чука башы** *т.я.-крш.* к.: **чолкабаш**.

**ЧУҚАЙУ** *перм.* бөрешеп, бөкрәеп чүгәләү (сесть на корточках сгорбившись, сжавшись). Артаба төннә утырам йоқлап, чуқайып.

**ЧУҚЛАНЫШУ** *тара., брб.д.* җыелышу (собираться вместе).

**ЧУКЛЫ** *кузн., хвл.* к.: **бөтүле**. Чуклы йурган. – *кузн.*

**ЧУҚЛЫҚ** *перм.* җиләк-җимеш, үсемлек күп булып үскән урын (местность, где много ягод, фруктов и т.д.). Этпорон чуқлық. Өмәжә чуқлық.

**ЧУҚМАР** *т.кам.-крш.* чумар (клёцки). Ашны пешеп җиткәндә онно сыйықлыйсын, тоз саласын, туғылыйсын, йомшақ қамыр була бит инде изгәндәге кебек, қалақ белән *өзәбер* wақлап саласын ашқа, чуқмар була.

**ЧУКМЫЙР** *мәл.* чукмар (булава, палица, кистень).

**ЧУҚРАҚ 1.** *крғл., бғрс.* к.: **батқақ; 2.** *крғл., бғрс.* к.: **салак**. Бик чуқрақ булды, диләр, ана, өсләренә қарасаң да нинди. – *крғл.*; **3.** *т.кам.-крш.* аңгыра, мәнсез (тупой, бестолковый).

**чуқрақ бөйә** *мам.* акмый торган буа (тихий, стоячий, непроточный пруд). Чуқрақ бөйәнең сuwы чичта булмый.

**ЧУКРАК 1.** *чст., байк., шрл.* к.: **батқақ**. Чукракка теште сикереп. Ана, җиңенә буйалган чукрак. Бетен ийне чукракка батырып бетерә. – *чст.*; **2.** *клд.* баткак (топь, грязь, жижа). Зер (пычрак) йийыла, йийыла да калынайып чукракка әләнә. Сазларда үләмлек була, чукракта үләм йук, ул чукрак кына.

**ЧУ'РА'** *кас.* к.: **кизләү 1**.

**ЧУКУЛ** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш. сүрәкә* яки *мәләнчек*нең арткы өлешенә беркетелгән яулык сыман ефәк тукыма кисәге (шёлковая материя в виде платка, пришитая сзади к головным уборам крещёных татарок). Чукул, диләр, мәләчлек артында асылынып тора. – *каз.ар.-крш.* Мәләнчек кийәбез иң башта, аннары қолаққа чигәчә диләр тәңкәле, аны бәйлисең, аннары чукулны бәйлисең.

**ЧУКЫРДАУ** *мәл.* чупырдау, суда уйнап юешләнү (плескаться, намокнуть).

**ЧУКЫР-ЧУКЫР** *мәл.* чупыр-чупыр (звукоподражание плеску воды).

**чукыр-чукыр ун'ау** *мәл.* чупыр-чупыр уйнау (плескаться). Су белән чукыр-чукыр ун'илар.

**ЧУЛАҚ** *перм., к.-уф.* сулагай (левша).

**ЧУЛАК** *тмн., м.-кар.* булдыксыз, кулыннан эш килми торган кеше (неумелый, неспособный; неумеха); чаг.: **гидай**. Чулак катын, итәк-йиңен йимас ул. – *тмн.* Адасы-тәтәсе йахшы кеше, ник ул былай чулак булган, кемгә охшаган? Чулак була бездә әшли белмәгән кеше. – *м.-кар.*

**ЧУЛАПАЙ** *крғл.* к.: **чулақ**.

**ЧУЛӘН** *твр.* к.: **селәү II, 1**. Чуләнэстәп йөрәте ғуй палық аулағалы.

**ЧУЛБАНУ** *тмн.* чуалу (запутываться – о нитках). Килеп-килеп чулбанадыр да, йүләргә йук.

**ЧУЛҚА** *баст.*, **ЧУЛКА** *т.я.-крш., чст.* к.: **чолка**. Кәсим җүкнекеләр чулқаны да йоқ, диләр. – *баст.* Кан'атаң алдында йаланайак йөрмә, айагыңа чулка ки. – *т.я.-крш.*

**тулак чулка** *т.я.-крш.* тула оек (длинные суконные чулки). Кийәүгә алмаллы кызларны тулак чулкасы бар микән дип сураганнар.

**чулка башы** *т.я.-крш.* к.: **чолкабаш**.

**ЧУЛҚИБАШ** *бөре.* к.: **чолкабаш**.

**ЧУЛНА** *м.-кар.* Чаллы – Кама елгасы буендагы авыл исеме (Челны – название населённого пункта на Каме). Аннары әле Чулна райунында

да күб әле алар (ягъни мордва-каратайлар), тушы безне кебек сүлиләр иде.

**ЧУЛПЫ I** *т.кам.-крш.* тәңкә (серебряная монета). Чигәчәләрне кигәндә чулпы да асқаннар.

**айақлы чулпы** *нокр.* астына тагын бер рәт тәңкәләр таккан чулпы (накосник, на низ которого подвешивается ещё один ряд монет); чаг.: **цулбы: айақлы цулбы**. Кемеш тәңкә, қайсы чулпы таға иде, айақлы чулпы алай: уртасында чулпы, сырға аста тәңкәләр тезгәндә, айақ, диләр, өч айақлы була.

**бөтөннән борған чулпы** *минз.* бөтен тәңкәләрне тезеп эшләнгән чулпы (накосник, состоящий из целковых монет). Бөтөннән борған чулпы бәк матур буладыр ыйы.

**бүwынны чулпы** *лш., чст.* чәчүргечкә махсус боҗра ярдәмендә тагыла торган чулпы (накосник, подвешиваемый к косам посредством специального кольца).

**гөрәбәнкәле** [*рус.* гривенник + *афф.* -ле] **чулпы** *лш.* очына бөтен тәңкә таккан чулпы (накосник, на конце которого подвешена старинная целковая монета). Гөрәбәнкәле чулпы була торган ийе, мин үзем дә тақтым әле.

**дүрт тақталы чулпы** *лш.* к.: **тақталы чулпы**.

**ике бүwынны чулпы** *лш.* үзара аслы-өсле тоташкан ике чулпыдан тора торган чулпы (накосник, состоящий из двух узлов, соединённых вертикально).

**қанатлы чулпы** *трх.*, **көйәндә чулпы** *т.я.*, **көйәнтәле чулпы** *каз.ар.-крш.*, **крамыйсла чулпы** *хвл.*, **күwәндәле чулпы** *чст.* ике аерлы чулпы (накосник, состоящий из двух параллельных блях с монетами, соединённых на одном орнаментированном кусочке металла). Әнинең көйәнтәле чулпылары, кәбен қойған балдақлары бар әле. – *каз.ар.-крш.*

**оло чулпы** *минз.* берничә чулпыдан тора торган зур чулпы (большой накосник, состоящий из нескольких обычных накосников). Оло чулпыны үремгә түгел, чәчқап башына тағалар ыйы, awыр бит ул.

**сабақлы чулпы** *бәр.* к.: **бүwынны чулпы**.

**тақта чулпы** 1. *т.я.* төрле яклап тәңкәләр тагылган, челтәрле һәм уртасы кашлы зур чулпы (накосник в виде лопастного листа с камнем в середине и монетами по краям). Чәч толомо өстенә қуйыла торган тәңкәле тезмә буладыр ыйы, тезмә очларына тақта чулпылар тағылған була. – *к.т.*; 2. *минз.* к.: **тақталы чулпы**. Тақта чулпы аппақ, қашы йуғ ыйы, қайсы қашлы да була, йанында да тәңкә, очында да тәңкә.

**тақталы чулпы** *мам.* уртада аслы-өсле итеп ике чулпы, ике читкә тагын ике чулпы тоташтырып эшләнгән зур чулпы (накосник, состоящий из четырёх узлов, соединённых в форме ромба). Дүрт чулпыны бер итерләр ийе, өстәгесе, астағысы зуррақ, қырыйдағылары бәләкәйрәк, аны тақталы чулпы дийерләр ийе.

**тасма чулпы** *минз.* ике яки өч тәңкәне тасмага бер-бер артлы беркетеп ясалган чулпы (накосник из двух или трёх целковых монет в один ряд). Ике иллелектән ясалған тасма чулпым бар ыйы, бер сыңарын жуғаттым. Ике оло ақчаны сабақлап чәчүргеч очона берсенә берсен тағып қуйалар да шушыны тасма чулпы дип тағалар ийе.

**ЧУЛПЫ II** *кас., т.я., блт., минз., кузн., стрл., влгг.* 1. казаннан бәрәңге, ит, пилмән һ.б. әйберләрне сөзеп алу өчен камыштан, юкәдән яки тал чыбыгыннан үреп ясалган чүмеч (ковшик, плетёный из камыша, лыка, лозы и т.д.; шумовка); 2. *минз.* к.: **кәпкер**. Қаданда бәрәңге пешерәбед дә, қашық белән алуwы қыйын, чулпы белән алабыd.

**ЧУЛУҚ** *яүшт.* к.: **чолка**.

**ЧУЛУН** [?] *глз.* утлык (ясли, кормушка для скота). Чулун абзар бычмакта була, печин салма эчен.

**ЧУЛЧАН** *брб.д.* к.: **селәү II, 1**.

**ЧУЛЫ** *нгб.-крш.* он савыты (посуда для хранения муки). Чулыдан он алып умач удым.

**ЧУЛЫҒУ** 1. *крғл.* ябыгу (худеть, похудеть). Нық чулыққан ыйы бабай; 2. *каз.ар.-крш., лш., мам.* ачлыктан эч тартылып керү, эч эчкә ябышу (подтянуться – о животе голодного животного). Дуңғыз да чулыққан, ашарға бир. – *каз.ар.-крш.* Маллар эчләре чулығып қайтып керәләр көтүдән. – *лш.* Берәр җирдә җабылуда җатқандыр бу, эчләре чулыққан. – *мам.*

**ЧУМ** *минз.* кастрюль. Ике чум (сөт өсте) җыйдым, әле һаман йадмыйм майны.

**ЧУМАЙЛАУ** [*рус.* чумазый + *афф.* -лау] *мәл.* су кереп чыккан кешенең тәнен көл, балчык яки ком сибеп пычрату (пачкать землей, золой или песком тело только что искупавшегося человека).

**ЧУМАҚАЙ** *крғл.* чумгалак, чүрәкәй (нырок).

**ЧУМАЛАҚ: паш чумалақ** *саз.я.* баш сөяге (череп человека). Пы паш чумалақ қуй, күмеп сақламасаң, төшкә керәте қуй.

**ЧУМАН I** 1. *кмшл., трх., минз., крғл., нгб.-крш., т.кам.-крш.* чанага куеп тирес, чүп, кибәк һ.б. ташыр өчен тал чыбыгыннан үрелгән зур кәрзин (большая корзина, плетёнка, которая ставится на салазки и применяется для перевозки зимой навоза, мякины и т.д.); чаг.: **мөргө**. Чуманға салған да теге қызны китә икән урманға. – *минз.* Түктем өч чуман чүп бозау абзарыннан. – *крғл.* Тирес чуманына утыртқан да. – *т.кам.-крш.* Чуман үрә Әләкси ағачай. – *нгб.-крш.*; 2. *т.кам.-крш.* тал чыбыгыннан үрелгән кәрзин (корзина, сплетённая из ивовых прутьев); 3. *к.т., хвл.* астына боз катырып ясалган кечкенә такта чана яки кәрзин (ящик или корзинка с дном, покрытым слоем льда); 4. *кузн.* кабык әржә (лубяной ящик). Чуманга утырып тау шуwалар; 5. *шрл.* утырып шуар өчен боз кисәген чокып ясалган җайланма (приспособление из куска льда для катания на горке). Быздан чуман қазый, утырып шуwый торган.

**қаз чуманы** *т.кам.-крш.* тал чыбыгыннан үрелгән каз оясы (большой короб из ивовых прутьев для гусей, чтобы высиживать гусят). Қаз чуманы була, безнең ике қаз чуманы бар иде. Йаз җитә башласа, бабай қаз чуманы үрәдер ийе, тал чыбықлары жыйып апқайтадырыйы да.

**ЧУМАН II** 1. *т.я.* к.: **чаман**. Аты чуман, чуман булса да бара, жулы жаман (*мәкаль*); 2. *чпр.* таза, зур гәүдәле (крупный, здоровый); чаг.: **алапа**.

**чумар** (клёцки):

**қашық чумар** *бөре.*, **қашық чумары** *т.я., минз.* төче камырны куерак итеп туглаганнан соң кашык белән кайнап торган шулпага салып пешерелә торган чумар (клёцки, которые кладут в суп ложкой). Борчаҕ ононнан ире-ире итеп қашық чумары салған. – *к.т.*

**қашықлы чумар** *бәр.* сыек солы оны камырын кайнап торган шулпага кашык белән салып пешерелә торган чумар (клёцки из овсяной муки, которые кладут в суп ложкой). Соло қамырыннан қашықлы чумар пешерәбез.

**қул чумары** *к.т.* кул белән ясала торган чумар: йомшак кына итеп басылган камырны кискәлиләр һәм аз гына җәяләр, аннан кайнап торған шулпага кул белән вак-вак итеп өзгәләп салалар (клёцки, которые отрывают рукой и кладут в суп). Бодай оны булҕач, хәсийәтлерәк булыр дип, қул чумары ғына йасадым, қатық қатып, мөтлөк сызғыртқач, бик җаратып ашадылар.

**ЧУМАРА 1.** *лмб., мәл., хвл., кузн.* чумар (клёцки). Әбисе чумара пешерә дийр иртә менән ашарга. – *лмб.* Чумара пешергәннәр. Йезеп тә пешерәләр, кисеп тә пешерәләр чумараны. – *хвл.* Бездә чумара пешерәләр йезеп-йезеп. – *кузн.*; **2.** *м.-кар.* к.: **шөшпәрә.**

**кашык чумарасы** *хвл.* к.: **чумар: қашық чумар.**

**чумараны чыгару** *кузн.* юк итү, бетерү (уничтожить). Сукса, чумараңны чыгарыр, шының тәке пеләчәләр, тулган битләре.

**ЧУМҒАҚ** *лш.* чумгалак (нырок – одна из разновидностей диких уток); чаг.: **цыбыкай; цүгәрәй.**

**ЧУМҒЫЛ** *перм.* к.: **қазан.** Аның (елганың) зур чумғыллары бар, әлек бит үлгән анда кеше төшөп.

**ЧУМГЫЧ** *чст.* к.: **чумғақ.**

**ЧУМНАУ** *каз.ар.-крш., лш.* чуму (окунуться, нырять). Абый буйдан-буйға чумнап бер баштан икенче башқа чыға ийе. – *лш.*

**ЧУМУ** *төм.д.* коену (купаться). Челлә керсә су чумырға йарый. Челлә кермичә җәй булмас, җәй булмыйча чумып пулмас. – *яүшт.* Су чумарға керәсең, йылу су. – *клм.*

**ЧУМЫЛҒАН** *каз.ар.-крш.*, **ЧУМЫЛГАН** *чст.-крш.* чукынган (крещёный). Чапый Бәчкәсен белəм мин, башларына чалма чалалар ыйы, пуп үгетлидер ийе, сез чумылган кешеләр, сез былай җермәскә, дидер ийе. – *чст.-крш.* Безнең Нусла (*ав. ис.*) татардан чумылған кешеләрдән тора. – *каз.ар.-крш.*

**ЧУМЫЛДЫРУ** *каз.ар.-крш.* к.: **ал'андерү.** Бездә баланы чумылдырғаннар бит, урсатасы була.

**чумылдырған аиасы** *каз.ар.-крш.* чукындырган анасы (крёстная мать). Минем иптәшемнең чумылдырған анасы булған ул, зур анай, дидер ийек.

**ЧУМЫНУ** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш., чст.-крш.* коену, су керү (купаться). Кем суға чумына, барын җаза. – *каз.ар.-крш.* Суға сикереп төштө дә чумынды. – *т.кам.-крш.* Анда бywa бар, тирән ийе, чумынадырыйык. – *чст.-крш.*

**ЧУМЫРУ** *твр.* коендыру (купать). Малайны чумыртым әле.

**уйга чумыру** *карс.* уйга чуму (погружаться в думы).

**ЧУНИ** *төм., тара.* юка резин галош (тонкие резиновые галоши). Чуни калуш ул йоға ғына. – *төм.* Чунисыс қышын йәшәп пулмайты, пыйманың өстөнә кийелә, калуштан йоқарақ. – *тара.*

**ЧУҢГЫЛТ** *мәл.* чумуны, батуны белдергән аваз иәртеме (звукоподражание, обозначающее погружение в воду, в жидкую грязь). Йакшы ғына барганда баткылчыкка чуңгылт!

**ЧУҢКАЙГАН** *мәл.* чалшайган (искривившийся). Чуңкайган авыз.

**ЧУҢҚАЙЫП** *дөб., лш., кргл.* җәелеп – утыру яки яту (развалившись – сидеть или лежать); чаг.: **лақайып: лақайып утыру.** Чуңқайып утырған. – *дөб.* Утырма чуңқайып. – *лш.* Балалар арасында чуңқайып йықлап йатасың, ди. – *кргл.*; **2.** *дөб., мам.* канатларын төшереп һәм җәелеп – каз турында (распластавшись – о гусях). Қазлар чуңқайып утыралар да үләләр. – *дөб.* Бақча буйында утырған чуңқайып, күтәреп апқайттым қазны, тормас инде. – *мам.*

**ЧУПАЙ 1.** *блт.* имезлек (соска, пища для грудных младенцев, завёрнутая в тряпку, марлю); **2.** *мәл., кузн.* һәрвакыт бармагын имеп торучы бала (ребёнок, имеющий привычку сосать палец).

**ЧУПАЙЫП: чупайып утыру** *перм.* к.: **чуңқайып.** Урам уртада шулай итеп чупайып тик утыра, ти, қарап, ти.

**ЧУПАН** *перм.* к.: **чобан.**

**ЧУПТАРЛАП** *лш.* үзеннән бизәк чыгарып – киндер сугу турында (делая браный узор – о тканье холста). Ақ киндерне чуптарлап-чуптарлап бизәкләр чығарып сөлгө суққаннар, үзеннән бизәк чығарып.

**ЧУПТАРЛЫ** *минз., бөре.* чүпләмле – сөлге яки чаршау (с браным узором – о полотенце или пологе из холста). Инәйнең үde қулы белән суққан чуптарлы шаршау бу. – *минз.* Чуптарлағаны чичкәләп суғу инде. – *бөре.*

**ЧУПЫР** *хвл.* шадра (рябой).

**ЧУР 1.** *кузн., хвл., мәл.* к.: **ара II.** Кай чур кибә! Кай чур ал'анеп тә кат'тың. Әдә уз ашарга, самый чурына туры килдең әле. Шул чурга элəксə идек, кем дə ачуланмый. – *хвл.*; **2.** *мәл.* чик, чама (мера, грань). Үгез дунаса, чуры йук (*әйтем*).

**чур басу** *мәл.* тиз бетерү (молниеносно сделать что-нибудь). Лавкыга эпәй килгән, чур басканнар, барсам.

**чур чугындыру** *мәл.* эштән чыгару (вывести из строя, привести в негодное состояние); чаг.: **чий: чийен чыгару 2.**

**чуры йук** *хвл.* к.: **чорсоз.** Кемгә бәләнсə, чуры йук. Бəйләнсəң, чурың йук.

**ЧУРА** *карс.* ефәк тукыманың бер төре (сорт шёлковой ткани). Чура күлмәк кийәү китергән.

**ЧУРАҒАЙ** *кргл.* чүрәкәй (чирок).

**ЧУРАҚ** *брб.д.* уңган, булдыклы (ловкий, проворный). Қәртнәм бағыр әйтедегән, чурақ қатыннарның түңнөгөннән, йалқау қатыннарның ашқағыннан танырым. Түңнеге апычық болса – чурақ қатын.

**ЧУРАПАН** [*рус.* шарпан?] *минз.* килбәтсез, ямьсез (безобразный, уродливый, несуразный). Монда чурапан кебек барып булмас.

**ЧУРБАК** [*рус.*] *блт., мәл.* к.: **муклака**. Йул уртасында чурбак торган, шуны алып қуйғансың, гөнаһың кимегән дигән. – *блт.*

**ЧУРКА** [*рус.* тёрка] *м.-кар., чст.-крш., перм.* угыч (тёрка). Улсы бәрәңге ywa торган чурка. – *м.-кар.* Чурка беле ыwасын кәртүкне, оң қушып қатырасын (басасың) ачытқач. – *перм.*

**ЧУРЛАУ** *кмшл.* бик нык ашыйсы килү (проголодаться); чаг.: **челегү 3; чулығу**. Чурлағансыңдыр үзең дә. Чурлаганбыз, утын кисеп кергәнмени, кинәндек ашап.

**ЧУРНАЙ** *перм.* чәй кайната торган чәйнек (чайник, в котором кипятят воду для чая).

**ЧУРСЫЗ** *хвл.* к.: **чорсыз**. Бу хат′лы чурсыз кыланма.

**чуртан** (щука):

**чуртан малай** *глз.* бала чуртан (щурёнок, щурок).

**ЧУРЧЫҚ** *нокр.* **1.** к.: **чиғеркә; 2.** к.: **черчек I**.

**ЧУРЫШ** *к.-уф.* шыртлака (ёрш). Чурышны арчywы қыйын, үзе лайлалы, үзе чәнечкеле.

**ЧУС** [*рус.* тёс] *клм.* юка такта (доска, тёс). Келәт, сарай башы чус белен йабылған.

**ЧУСАЙ** *срг.*, **ЧУСАНКЫ** *кмшл.*, **ЧУСЫНКИ** [*рус.* чёсанки] *мәл.* к.: **сачинкә**. Чусайны калуш белән кийәләр.

**ЧУТ** *дөб.* к.: **кәтмәк I**.

**ЧУТА: чута булу** *тбл.* акча түгү, чыгым ясау (сделать расход, израсходоваться, издержаться). Чута болтым, туй үтте, қунақлар кән килтләр.

**ЧУТЛАУ** *дөб.* к.: **кәтмәкләү**.

**ЧУТУ** *твр.* чабу (рубить). Сыйырларын балта белән чутқаннар.

**ЧУТЫЙК** [*рус.* чуть] *мәл.* аз, бераз, чак кына (чуть-чуть, чуть). Чутыйк кына йышкын.

**ЧУТЫР** *перм.* к.: **чупыр**. Аз булса да, май йақшы, чутыр булса да, қыз йақшы (*мәкаль*).

**қара чутыр** *тя., каз.ар., кмшл.* кара тутлы кеше (смуглый). Мин қара булғач, әй қара чутыр, эчегән арбасыннан төшеп қалған нәрсә, дип қоторталар ыйы мине кечкенә чақта. – *к.т.* Бу Зәйтүнә бигрәк қара чутыр, кемгә охшағандыр. – *лш.* Бер қара чутыр ғына қыз белән җөри дип ишеттек. – *мам.*

**ЧУТЫ-ЧУМАНЫ** *т.кам.-крш.* исәбе-хисабы (нет счёту, тьма-тьмущая). Анда инде килгән кешенең чуты-чуманы җуқ.

**ЧУЧАҚ** *мам.* түземсез, сабырсыз, тынгысыз (нетерпеливый, беспокойный, неугомонный). Үзләре дә қайта бит инде сарықлар, әй чучақ, чучақланып йөри бит. Шундый ашығыч кешене чучақ диләр, тынғысыз.

**ЧУЧАҚЛАНУ** *мам.* түземсезләнү, сабырсызлану, борчылу (беспокоиться, не угомониться, проявлять нетерпеливость); чаг.: **тәүчәләкләнү**.

**ЧУЧАЛА** [*рус.* чучело] *төм.* карачкы (пугало). Чучалаға охшап йөрисең.

**ЧУЧИҢКЫ** [*рус.* чёсанки] *к.т.* к.: **сачинкә**. Кизитекне қарадан, чучиңкыны ақтан бастырдық.

**ЧУЧҚА I** *мам., перм.* дуңгыз (свинья, хрюшка).

**қыр чучқа** *перм.* кабан, кабан дуңгызы (кабан, вепрь). Қыр чучқалар бездә тужы йуқ. Қыр чучқа биг усал қый ул, кешегә ташлана тиләр.

**чучқа йапрақ, чучқа қабақ** *клм.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы**. Чучқа қабағ арада ийән тawық палабыс.

**чучқа тигәнәге** *минз.* дару кырмавыгы (чернокорень лекарственный).

**ЧУЧҚА II** *минз.* к.: **дуңгыз II**. Ут башта чучқаға бәрелә. Чучқа белән чыгарганмы (мичне)?

**ЧУЧЫ** *мәл.* чү, чү әле (чу, чу-ка, стоп, тихо).

**ЧУЧЫНКА** [*рус.* чёсанки] *мәл.* к.: **сачинкә**.

**ЧУЧЫНУ** *брб.д.* сискәнү, курку (вздрагивать, испугаться).

**ЧУШКАЙ** [*рус.* чушка] *мәл.* кимсетеп, яратмыйча әйтү сүзе (слово, выражающее пренебрежительное, уничижительное отношение).

**ЧУБАҒАЧ** [*рус.* цеп + агач] *нокр.* к.: **чип I**. Чубағач белән эшләдек элек.

**ЧҮБӘК** *перм., минз., стрл.* к.: **чөбәк**. Чүбәкне сатыб алабыз ий, ирлибез ий. – *перм.* Чүбәкне йерли торган ийек төннәр буйы утырып чыра йақтысында. – *минз.*

**ЧҮБӘТӘ** *бгрс.* агач савыт (деревянная мисочка). Бер чүбәтә қатық салып алдым.

**ЧҮБЕКЧЕ** *т.кам.-крш.* к.: **wақсу I, 1**. Чүбекченең кесәсе тулы чүп булыр, ди (*мәкаль*).

**ЧҮБЕРЕКИ** *каз.ар.-крш.* төче камырдан пешерелгән ит пәрәмәче (перемячи из пресного теста). Чүберекиләр пешерәбез, төчө қамырны җәйеп, эченә ит салып йабып қуйабыз да табада әйләндереп-әйләндереп пешерәбез.

**ЧҮWӘ I** *брб.д.* сеңел яки эне (младшие: брат или сестра).

**ЧҮWӘ II: чүwә байлау** *брб.д.* к.: **бәйләү: тартмалы бәйләү**.

**ЧҮWӘКӘЙ** *перм.* чүәк (чувяки); чаг.: **чәрик**.

**ЧҮВӘТӘ** *стрл.*, **ЧҮWӘТӘ** *минз., стрл.* к.: **чүбәтә**. Бер чүвәтә аш та ашарга келәми. – *стрл.* Чүwәтәләрне тезгән өстәлгә. Элег ийе чүwәтә, хәзер тәрлекә тотабыз бит инде. – *минз.*

**ЧҮWЕН** *нокр.* к.: **чүгүн**.

**ЧҮWҮ** *чст., кузн.* **1.** к.: **быргыту 1**. Мыны йылкыпмы чүwәрмен? – *чст.*; **2.** салу (положить). Казанга май эченә чүwәсен. – *кузн.*

**ЧҮГӘРМӘК 1.** *кргл.* уйсу, түбән җир (низина, лощина); **2.** *трбс.* җыелып торган су, сазлыклы урын (болотистое место, впадина, углубление, наполняющееся водой весной или во время сильных дождей).

**ЧҮГӘТ** *брб.д.* камышлык эчендәге кечкенә күл (маленькое озеро в камышовых зарослях).

**ЧҮГӘТӘ** *кргл., бгрс.* к.: **чәркә II, 3**. Сез бит әкерен ашыйсыз, мин ике чүгәтәне бәреп йықтым. – *бгрс.*

**ЧҮГЕН** *саз.я.* к.: **чүгүн**. Чүгенне тимер мицхә қуйawc та аш пешерәwc.

**ЧҮГЕНУ** *тмн.* тез чүгү (становиться на колени). Әвәл килен мынан кийәү чүгенеп торган йанаша.

**ЧҮГЕЦ** *яушт.* тукмак (колотушка).

**ЧҮГҮН** *глз.* чуен (чугун).

**ЧҮК I** *каз.ар.-крш.* җыен исеме (название праздника, джиена, празднуемого в определённое время в определённой группе деревень). Чүктә сабан туйы була Питровский йағында, Тәмтедә. Җугары Әрнәштә чүк була, безнең awылда, Бладимырда – тырайсын.

**чүк итү** *т.кам.-крш.* к.: **ботка: йаңгор боткасы**. Аннары қорман артыннан чүк итәләр, боламық, он, күкәй, сөт, чиләге белә аптәшәсең, шунда пешереб ашилар.

**ЧҮК II** [*рус.* сок] *каз.ар.-крш.* к.: **сүк I**. Соло кесәле белән ашыйлар чүкне.

**ЧҮКӘТӘ** *каз.ар.-крш.*, **ЧҮКЕ** *т.кам.-крш.* резин туп (резиновый мяч). Җанғыш миңа килеп бәрелде чүкәтә. Тыкырыкта әйбәт, чүкәтә уйныйлар җәшләр.

**ЧҮКЕР** *влгг.* к.: **йымычка**.

**ЧҮКЕШ** *каз.ар.-крш.* чүкеч (молоток). Кийәү йегете чәй қага ақча белән, чүкеш белән, кийәү йегетенә эш күп туйда.

**ЧҮКЕШКӘ** [*рус.* чекушка] *перм.* к.: **батырақ**. Чүкешкә шешәдә бирәп кайтаралар ыйы шул майны.

**ЧҮКЛӘЙ** *влгг.* җилембалык, ач чабак (уклейка).

**ЧҮКЛӘНҮ** *кузн.* тезләнү (стать на колени).

**тез чүкләнү** *кузн.* к.: **чүкләнү**. Тез чүкләнеп картуп йидым.

**ЧҮЛ I** *минз., стрл.* к.: **батырақ**. Бер чүл сөт белә эшләдек без.

**ЧҮЛ II** [*рус.* тюль] *чст.* челтәр (тюль). Безнең мишәр каты сүлибез: агына пәрдә дибез, мынсына чүл дибез.

**ЧҮЛ III: чүл йуwа** *брб.д.* кыр суганы (лук полевой).

**ЧҮЛӘ** *әстр.* ботка (каша, икра). Баклажаннан чүлә йасадым.

**ЧҮЛӘН** *твр.* к.: **селәү II, 1**.

**ЧҮЛДӘҮ** *влгг.* к.: **көйрәү 1**. Ну, чүлдәдегезме жарда йәреп. Чүлдәдегезме инде, койашта озак булдыгыз.

**ЧҮЛДИ** *минз., стрл.* к.: **батырақ**. Җартыларны, чүлдиләрне бирәсез бит кешегә қарата. – *минз.* Сөт алып барабыз да бер чүлди, таратабыз һәрберсенә. – *стрл.*

**ЧҮЛЕГҮ** *минз.* зәгыйфьләнү, чирләшкәгә әйләнү (стать хилым). Анан чүлеген қала мал, җабыгып.

**ЧҮЛЕК 1.** *трх., чст., т.я.-крш.* к.: **чөйлөк**. Чүлек белән қамытны бәйлиләр. Чүлек қамытны қысып хутлый торган. – *трх.* Атның чүлеге тишелгән. – *чст.*; **2.** *байк.* камыт бавы (гуж).

**ЧҮЛЕКМӘ** *чпр.* сиртмә – коеныкы (колодезный журавль). Чүлекмә белән батырып ала суны кийыдан.

**ЧҮЛЕКМӘЛЕ** *мәл., чпр.* сиртмәле (имеющий коромысло, с журавлем – о колодце). Чүлекмәле кый бар. Чүлекмәле кийы бире генә. – *чпр.* Чүлекмәле кый бар иде йыртларында. – *мәл.*

**ЧҮЛКЕНҮ** *минз.* аву (свалиться, опрокинуться). Утырған җирдән чүлкенеп китте.

**ЧҮЛКӘҮ** *т.я.-крш.* **1.** чорнау (обвивать). Элек бит тастар сарган башны чүлкәп; **2.** төрү – баланы (кутать, закутать). Ыланны чүлкәп куйалар.

**ЧҮЛЛЕК** *перм.* һәрвакыт дымлы һәм мүк белән капланган җир (влажная, покрытая мхом местность): чаг.: **йепсәк**. Чүллеге зур түгел күк җиләкнең.

**чүлмәк** (горшок):

**йил чүлмәге салдыру** *тмн.*, **чүлмәк салдыру** *мам.* эче төшкән кешене әбиләрчә дәвалау (знахарский метод лечения при опущении живота). Йил чүлмәге салдыручы әби бар иды эчләре төшкәч. Чүлмәк салдырыға барам, эчләрем awыртып тора, ашый да алмыйм.

**чүлмәк чәчәк** *лмб.* бакра (куколь).

**ЧҮЛМӘНЧЕК 1.** *каз.ар.-крш., блт.* к.: **ботка: йаңгор боткасы**. Әле бер җылны ғына малайлар чүлмәнчек җасадылар; чүлмәнчеккә дип күкәйләр җыйалар, узған-барғанны қойондыралар. – *блт.* Җыйын қарчыкларҗыйыла, сыйыр майы, күкәй җыйып, мал суйып чүлмәнчек җасыйлар. – *каз.-ар.-крш.*

**ЧҮЛМӘНЧЕКИ** *каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* к.: **йангор: йаңгор боткасы**. Чүлмәнчеки дип быламық пешерәләр, хәбәр бирәләр чүлмәнчеки була беген дип, қайсы майын алып төшә, сөтен алып төшә, күкәйен алып төшә, оннан ғына пешерәләр быламық, балаларның исәннегенә, йорт-җирнең исәннегенә дип ақча бирәләр бер әбигә, пешеп җиткәчен оло табақларға салалар, аннары китәләр келәү итәргә, урын бар безнең, анда тал ағачы үсә, зур, йуwан, Алладан җаңыр сорыйлар, аннан борылып қайталар пешергән җиргә, ашаулық җәйәләр, табақларны тезәләр, келәү итәләр дә сыw сибешә башлыйлар, быламықларны өйгә алып қайталар, урамда да сыw сибешәләр, башта татар әбиләр килеп сыу сибешеп җөриләр, алар килми бу боламыкны пешерергә җарамый безгә. – *т.кам.-крш.*

**чүлмәнчеки быламық** *каз.ар.-крш. чүлмәнчеки*дә пешкән боламык (каша, сваренная во время моления о дожде). Чүлмәнчеки быламық пешерәләр, кеше сайын йөрмиләр җыйып, хәбәр генә бирәләр, чүлмәнчеки быламық бүген дип, кешеләр үзләре алып төшә он, ағон, күрпәчәткә, су қырына қазан қуйалар.

**ЧҮЛНИК** [*рус.* пчельник] *т.кам.-крш., чст., мам.* к.: **мурталык**. Чүлник җанында ғына җөрдөк, и уңған быйыл қура җиләге. – *мам.*

**ЧҮМӘКӘЙ** *мам., дөб., минз.* к.: **чөмөкий**. Орлоқлық суған бирдем ыстаканны чүмәкәй итеп. – *дөб.* Чүмәкәй ийе, ул ашады җиләкне. – *минз.* Бер оло тәникә чүмәкәй алып қайттым қарлыған. – *мам.*

**ЧҮМӘКӘЙЛӘҮ** *мам., блт.* туп-тулы итеп өеп тутыру (наполнять с верхом, полным-полно). Әржәгә тамға салып киткән балчык өйөп чүмәкәйләп. – *блт.* Чикләwекне ыстаканны чүмәкәйләп сата ул. – *мам.*

**ЧҮМӘКӘЙЛӘТҮ** *бөре.* к.: **бүкәйләү**. Күтәрмәдән чүмәкәйләтеп кенә менә идем.

**ЧҮМӘКЛӘНҮ I** *дөб.* к.: **чәүмәлү 2**. Чүмәкләммә тағы син.

**ЧҮМӘКЛӘНҮ II** *дөб.* күпереп шешеп чыгу (опухать).

**ЧҮМӘЛӘ** *глз.* бер тапкыр кабага элеп эрләрлек киндер сүсе, көнҗәлә (свиток кудели для прядения). Талқып, шыртлап, орчоқ чүмәлә дийә идек, анын утыра торғаны да бар. Йонны чүмәләгә бәйлисең, қабасына чүмәләне саласың.

**ЧҮМӘЛҮ I** *кргл., бгрс.* к.: **чәүмәлү I**. Чүмәлмәсен өчөн генә қыстырырға дигән ийем. – *кргл.*

**ЧҮМӘЛҮ II** *дөб.* к.: **чүмәкләнү II**.

**ЧҮМӘЧЛЕКИ** *мам.* к.: **ботка: йаңгор боткасы**. Элек чүмәчлеки йасағаннар йаңгыр йаумый торса. Әле күрше awылда да су сибешеп йөриләр ийе чүмәчлеки дип.

**ЧҮМӘШҮ** *т.я., дөб., мам., мәл., чпр.* чүгәләү (сесть на корточки); чаг.: **чуқайу**. Тагын йуwарга чүмәштем мин. – *чпр.* Идән жуғанда гел чүмәшеп жуwам, ийелеп бер дә жуwалмыйм. – *к.т.*

**ЧҮМГӘЛ** *минз.* зур тирән чокыр (овраг, большая глубокая яма). Су җыйыла торған дур ғына чоқорно чүмгәл диләр. Бер Ғәйнеттин дигән кеше чүмгәл тawып урман эчендә, шул чүмгәл йанында тора башлаған. Чүмгәлләрнең исеме бар ийе.

**ЧҮМГЕРҮ** *мам.* бәрәңгенең күзе шыта башлау (начинать прорастать – о глазке картофеля). Бәрәңге чүмгереп кенә килә, үрмәгән әле.

**ЧҮМЕР I** *тмн., күрш.* изү, изү уемы (ворот, разрез); чаг.: **күнчек 3.** Әтекайым, күлмәгең Чуклы ғына чүwар чүмере, Әтекайым бирген бахиллек, Тыныч үтсен үмерем. – *күрш.* Әтекәй, өстеңдәге күлмәгең, Зурлак уйган аның чүмерен (*бор. җыр.*). – *тмн.*

**ЧҮМЕР II** *перм.* к.: **цумар.**

**ЧҮМЕЧ** *хвл.* к.: **кәпкер II, 1.** Чүмеч белән генә алабыз пилмәнне.

**алдыр чүмеч** *т.кам.-крш.* к.: **багырча.** Бәчели дәдәй, ригегә барганда алдыр чүмечне алып килергә онотма, җуғыйсә анда төшкашны бүлергә әйбер җук.

**күмер чүмече** *т.кам.-крш.* к.: **күмериләк.** Күмер чүмече дә челтәрле тегел, келе белән тутырабыз.

**пилмән чүмече** *каз.ар.-крш.*, **тишек чүмеч** *брб. д.*, **төш чүмече** *бөре.* к.: **кәпкер II, 1.** Тишек чүмеч белән сособ аласың пилмәнне. – *брб.д.*

**ЧҮМЕЧКҮТ** *кргл.* к.: **майқарақ.**

**ЧҮМКӘ** *блт., бәр.* к.: **чөнкә.**

**ЧҮМКЕ** *перм.* үтмәс, үтми торган, тупас йөзле (тупой, с тупым лезвием). Чүмке пычақ.

**ЧҮМКЕЛӘНҮ** *перм.* үтмәсләнү (притупиться, сделаться тупым). Балта чүмкеләнгән.

**ЧҮМКЕЛӘҮ** *перм.* үтмәсләндерү, кыршу (притупить, сделать тупым). Пычақны чүмкелисез тимер кисеп. Кисәм-кисәм дә, қайчыны чүмкелим хәзер.

**ЧҮМПИЧ** [*тат.* + *рус.*] *глз.* тимер мич (железная печь). Чүмпичне йагыб алырбыз кичке, йыкламага йылы булыр өчен.

**ЧҮМПЫЙМА** [*угор.*] *төм.* к.: **сачинкә.** Чүмпыйма эрәкәт, үсе йеңел, үсе йоға.

**ЧҮМРӘЙҮ** *т.кам.-крш.* турсаю (дуться, сердиться). Чүмрәйгән awыз. Awызың чүмрәйтеп утырасың шунда.

**ЧҮН** *глз.* к.: **чүгүн.** Чүнгә түк барангы cywын.

**ЧҮНӘКӘЙ** *кас.* к.: **бармақ: гөлчәчәк бармақ.**

**ЧҮНӘРИ** *нокр., глз.* к.: **рәшмән.** Чүнәри тештеме суға? – *глз.* Чүнәри ойа. – *нокр.*

**чүнәри бау** *нокр., глз.* пәрәвез жебе (паутинная нить). Чүнәринең бawы була. – *нокр.*

**ЧҮНИ 1.** *мәл., т.кам.-крш., төм., тбл.* зур галош, гадәттә киез итеккә киертелә (большие калоши, надеваемые на валенки). Олы чүнийе белә суқты, мамық шәлемне җабындым да чығып барам. – *т.кам.-крш.* Чүниле быйма. Саста йөргәле чүни гейәтеләр пыйма өстән. – *төм.* Пыймаға чүни гейеп қарга таптайбыс, утын кейсәпес. – *тбл.*; **2.** *м.-кар.* к.: **хашәп; 3.** *глз.* юкә баудан үргән башмак (башмак, сплетённый из бечёвки).

**ЧҮННЕК** [*рус.* пчельник] **1.** *каз.ар.-крш., лш., блт.* к.: **мурталык.** Калхуз чүннегендә эшләдем. – *лш.* Чүннеккә менегез сез, чүннектә умарталар күп. – *каз.ар.-крш.* Әтекий чүннектә йөрөр ийе, умартабыз чүннектәйе. – *блт.*; **2.** *мам.* авылдан читтә (кырда яки урманда) урнашкан умарталык (пчельник, расположенный вдалеке от села, в лесу или на поле). Элек чүннектә күб ийе йылан. Безнең чүннек менә монда ғынайы, өйдә умарта тота алмадық. Чүннек чишмәсе. Чүннек җулы.

**ЧҮННЕКЧЕ** *каз.ар.-крш., лш.* к.: **қортчо.** Минем қарт чүннекчейе. – *каз.ар.-крш.*

**ЧҮННИК** [*рус.* пчельник] *мам., каз.ар.-крш., минз.* к.: **мурталык.** Чүнник йағында печән чабалар. Ғыйлмулла апый чүнниктә торғанда бүре атқан ыйы. – *мам.* Анда чүнник бар калхузнықы. Чүнник сақлый безен әтей. – *каз.ар.-крш.* Чүнниктә қарawылда торам. – *минз.*

**ЧҮҢКӘЙ** *лш.* майлы табада бөтен көе кыздырылган бәрәңге (картофель, жаренный в целом виде на сковороде). Чүңкәй қуйам табаға, ашарсыз қайтқач.

**ЧҮҢКЕ** *перм.* к.: **чүмке.** Чүңке пычақ қул кисәр (*мәкаль*).

**ЧҮҢКЕР** *әстр., влгг.* к.: **йымычка.** Қулға чүңкер керде.

**ЧҮП 1.** *мам.* мехтан әйбер теккәндә калган кисентеләр, кисәк-косаклар (мелкие обрезки, получившиеся во время выкройки меха). Чүптән тегәбез бүреg эче, дүрт өлгө итеп тегәбез дә аны теркибез; **2.** *минз.* чүбек (очёс). Чүбегеннән чүб ойоқ бәйлидер ийек җәй көнө кийәргә; **3.** *влгг.* печән (сено). Чүп аз, кыш асырауга җитмәс; **4.** *мам.* к.: **ислекәй 1.** Чүп булмаса, жоқлап була; **5.** *туб.-ирт.д.* к.: **йымычка.** Чүп керте, паш пармағымта. – *төм.*

**пила чүбе** *мам., дөб., блт., каз.ар.-крш.* к.: **йарма I: ағач йармасы.** Түшәмгә пила чүбе салам. – *дөб.* Пила чүбе дым тарта бит. – *мам.*

**чүп тә** *тмн., лмб., кузн., карс., чст.* **1.** берни (дә), бернәрсә (дә) (ничего). Чүп тә әйтмәдеме нәнәйең? Чүп тә йук. Чүп тәме ишмәдең, Харис үлгән тик тырыштан. – *лмб.* Чүп тә булмас, кайтыр. – *тмн.* Маңа чүп тә мәлүм тегел иде. Ире бер чүп тә белми иде. Чүп тә алмады. Утыра теш, чүп тә булмас. – *кузн.* Алар сабыйлар, чүп тә белми. – *чст.* Әбәй, син чүп тә сүләмә. Чүп тә күрми; чүп тә белми. Чүбе дә йуг анықы. – *карс.* **2.** бернинди (дә) (никакой). Чүп тә эшем йук. – *кузн.*

**чүп тә жүк (түгел)** *дөб.*, **чүп тә йук (тегел)** *тмн., кузн., дөб., шрл.* берни дә йук, берни түгел, зарарсыз (ничего не стоит, ничего). Йуктыр чүп тә, ашапсын инде. Чүп тә йук безнең өчен биш минут. – *кузн.* – Гафу итегез, мин сезнең айакка бастым! – Чүп тә йук! – *тмн.* Жуққа қайғырма, чүп тә жүқ, хәзер тазара. – *дөб.*

**чүп ти** *кас.* к.: **чүп тә.** Чүп ти булмас. Чүп ти йу'.

**ЧҮП-ҖАР** *бәр.* чүп-чар (мусор, хлам, отбросы). Аның сийә чүбен-җарын кертмиләр, өрдөргән күк буладырыйы суққан арышларыбыз.

**ЧҮПКӘ: чүпкә қыйу** *т.кам.-крш.* к.: **ботка: йаңгор боткасы.** Менә элеке шулай жаңғыр жаумый торса, қоро булдисә, чүпкә дип чүпкә қыйарға чығалар ыйы. Җәшләр беркемне қалдырмыйынчы сыw сибәләр ийе.

**ЧҮПЛӘМ: ақ чүпләм** *бөре.*, **борчақ чүпләме** *каз. ар.-крш.* тукыла торган ак җепнең үзен махсус ысул белән чүпләп сугылган киндер (белый холст,

узоры которого сотканы из его же основы). Бийау булмағач, чүпләп суғабыз, ақ чүпләм дибез инде аны. – *бөре*. Борчақ чүпләмле бийөстөр. – *каз. ар.-крш.*

**уймақ чүпләм** *каз.ар.-крш.* чүпләп сугуның бер төре (один из видов браного тканья).

**ЧҮПЛӘМӘ I 1.** *трх., клд., стрл.* к.: **мошко I: кара мошко**. Чүпләмә ул, кара пәҗи дибез аның пәҗийен. – *клд.* Аныкы чүпләмәсе была торган иде, алдан йолкыб алалар иде. – *стрл.*; **2.** *клд.* бакчадагы чүп үләне (сорная трава, сорняк). Wat чүплисең агарутта wак кына чүпләрне, чүпләмә әтәләр.

**ЧҮПЛӘМӘ II 1.** *лш.* чуптарлап, чүпләмләп сугылган киндер (полотно, вытканное с узорами); **2.** *нрл., трх.* кәрәз сыман сырлы сөлге (вафельное полотенце).

**ЧҮПЛӘМЕШ** *каз.ар.-крш.* бишташ уены (вид детской игры).

**ЧҮПЛӘМЛЕ** *мам.* яшьләр уены: егетләр һәм кызлар кара-каршы тезелеп басалар; тезем башында берәү так кала һәм, бер җыр җырлангач, ул үзенә пар алып әйләнә (молодёжная игра, сопровождающаяся с песней и пляской; ручеёк).

**ЧҮПЛӘҮ** [*рус.* цеп + *афф.* -ләү] *глз.*, **ЧҮПЛӘШҮ** [*рус.* цеп + *афф.* -ләшү] *нокр., глз.* ашлык сугу (молотить). Арышны чүпләмәйче келтәләү инде, аны қош көнө чүпләйсин инде, чубағач бели чүпләйсин. Ашлық чүпли торған машина була иде. Ашлық чүпләгәндә, келти бирең тырайы. – *глз.* Арыш чүпләшмә йердек бүген. – *нокр.*

**чүпләшмә бемә** *нокр.* элек: ындыр сугу өмәсе (в старину: коллективная помочь при молотьбе).

**ЧҮПЛЕК-ЧАПЛЫҚ** *к.т.* сидек куыгы ялкынсыныу (цистит). Чүплек-чаплық тиләр нәзек җиргә сuwық тисә, минем җәш чақта булды чүплек-чаплық, себеркегә си, утырып тор, аннар себеркене баш арқылы абзар қыйығына ырғыт тиб өрәткәннәр ийе.

**ЧҮПРӘ** *мам., лмб.* өйдә ясаган сыраның яки квасның төбенә утырган куесы (осадок, образовавшийся на дне домашнего пива или кваса).

**чүпрәк** (тряпка):

**балтыр чүпрәк** *каз.ар.-крш.* к.: **сарғыч: айақ сарғычы**. Бистәр биргәннәр, балтыр чүпрәк биргәннәр җегеткә ағ алышқанда.

**ЧҮПЧИ** *брб.д.* яшь бала башлыгы (чепчик). Чүпчийенә пер ағыйқ тегеп қуйаты күс тимәстән.

**ЧҮПЧҮ** *глз.* чүп утау (полоть). Бакча чүпчегәндә айакларга йабыша бу (үлән).

**ЧҮР: чүргә керү** *т.я.* гөнаһлы булу (грешить). Син алай димә, чүргә керәсең. – *к.т.*

**ЧҮРӘ I** *срг., әҗе.* сул як, тискәре як – кием турында (изнаночная сторона – об одежде).

**ЧҮРӘ II** *перм., брб.д.* тирә, тирәсе, әйләнә-тирәсе (вокруг, около, кругом); чаг.: **йаға I, 1**. Чүрәсенә туңган ти. Көз көн балалар картуб өтөп қыйышалар бақча чүрәдә. – *перм.* Чолбы чүрәсендә пиш тинлек манитлар. Ибраһим баба белгән әнийемне, алар бер чүрәнең булғандыр. – *брб.д.*

**чуйын чүрә** *перм.* казан яны, казан тирәсе (место у котла).

**ЧҮРӘЙАК** *чст.* к.: **кискәржақ**.

**ЧҮРӘ-ЙАҚ** *перм., брб.д.* к.: **мәрә 2**. Җир-су әйбәт булған, шуңа күрә чүрә-йақтан килгәннәр дә килгәннәр. – *перм.* Чүрә-йақтан апкилеп торатылар көңнәкне. – *брб.д.*

**ЧҮРӘК 1.** *кргл.* ипи камырыннан пешерелгән вак күмәч (булочка или мелкие хлебцы, испечённые из хлебного теста). Кәстрүлдә чүрәк бар, алып чығ әле; **2.** *шрл.* май, йомырка белән изеп, яхшы камырдан пешерелгән күмәч (сдобная булочка, лепёшка). Туйда аш-су күп была: май ашлары, чүрәк, катламалар.

**чүрәк күмәч** *минз.* к.: **чүрәк 1**. Чүрәк күмәчләр пешердем күкәй сөртөп өстенә.

**ЧҮРӘКӘ** *перм.* агач шар (деревянный шар).

**чүрәкә умарта** *перм.* багана умарта (борть). Чүрәкә умарта қалын була йы.

**ЧҮРӘКӘЙ** [*рус.* чирок, чурок] *каз.ар.* **1.** уен исеме: агач шарга яки кечкенә таякка сугып уйныйлар (название игры «в чижики»). Чүрәкәйләр, бишташлар уйный торған ыйық. – *блт.* Әйдә, чүрәкәй уйнарға. – *дөб.*; **2.** агач шар яки ике башы бераз очлайтылган кечкенә таякчык; чүрәкәй уенында кулланыла (деревянный шар или чурка, заострённая с концов накось, употребляемые в игре «в чижики»). Чүрәкәй йасала, шул чүрәкәйгә суғасың да, ул очоп китә. – *блт.* Чүрәкәйен дә йасыйдырыйық, берәү шуңа суғып җибәрәдер ийе. – *дөб.*

**чүрәкәй қалағы** *блт., дөб.* уен вакытында *чүрәкәйгә* суга торган калак (деревянная дощечка, которой бьют по чижику во время игры «в чижики»).

**чүрәкәй тайағы** *блт.* к.: **чүрәкәй 2**.

**ЧҮРӘЛИ** *перм.* **1.** тирә-якта, тирә-яктан (вокруг, со всех сторон). Чүрәли күммә кәрәк (өйнең нигезен). Безнең монда чүрәли калхуз; **2.** тирәли (вокруг, кругом). Менә шулай ызба чүрәли йөриләр, икмәк ашап (казлар турында).

**ЧҮРӘ-ТИРӘ** *перм.* к.: **мәрә 2**. Сирәк-мирәк, әзерәк чүрә-тирәдән тартыштырыб алған булалар.

**ЧҮРӘЧ** *лш.* чүрәкәй (нырок – разновидность дикой утки).

**ЧҮРӘ-ЧҮРӘ** *чст.* әйләнеп-әйләнеп (кружась). Чүрә-чүрә килсен иде.

**ЧҮРГӘНЧЕ** *перм.* к.: **қасырғы**. Чүргәнчегә әләксән, алып менә дә китә.

**ЧҮРКӘ I** [*рус.* чурка] *перм.* чолык, багана умарта (улей, выдолбленный в чурбане; борть).

**ЧҮРКӘ II** [*рус.* тёрка] *перм.* к.: **чурка**. Чүркә белә кырахмалына бәлә қыра торған ийек бәрәңгене.

**ЧҮРКӘЛӘҮ** *тбл.* турау, кисү – агачны (пилить на дрова). Кискеләп чүркәләп қуйабыс утынны.

**ЧҮРКИ** [*рус.* чурка] *мам.* шакмак (чурка); чаг.: **чашка II**. Әwәл чүрки белән эшләгән парawуз да.

**ЧҮРМӘ** *каз.ар.-крш., чст.-крш.* төрмә (тюрьма). Чүрмәгә җибәрергә чыққаныйы аңа. – *каз.-ар.-крш.*

**ЧҮРМӘНЧЕК** *каз.ар.-крш.* к.: **ботка: йаңгор боткасы**.

**ЧҮРҮ** *чпр.* кыйнау (бить, отлупить). Мин тытып чүрим сезне!

**ЧҮСИНКЕ, ЧҮСҮНКЕ** [*рус.* чёсанки] *дөб.* к.: **сачинкә**.

**ЧҮТЕ** *перм.* туку станында: күшә (хвост основы, скрученный в виде жгута и ряда петель).

**чүте тайағы** *перм.* күшә баганасы (палочка, при помощи которой закрепляется хвост основы, чтобы не распустились петли).

**ЧҮТЕЛӘҮ** *перм.* күшәләү (сплетение основы петлями). Бау җуқмы чүтеләп күрсәтмәгә. Җепне чүтелиләр.

**ЧҮҮ** *твр.* к.: **чәwү**.

**ЧҮЧЕНКӘ** [*рус.* чёсанки] *бөре.* к.: **сачинкә**. Қара чүченкәләр кийертеп җибәрдем.

**ЧҮЧИН** *тбл.* төче күмәч (пресная лепёшка).

**ЧҮЧИҢКӘ** *төм.*, **ЧҮЧИҢКЕ** *дөб.* к.: **сачинкә**. Чүчиңкә пыйма шигелле, түлке йоға була. Минем чүчиңкегә тумақ башлы эрҗиңкә кирәк.

**ЧҮЧИТКӘ** [*рус.*] *глз.* корчаңгы (чесотка). Баланы чүчиткә, бытчалаган диләр, ипи пешергән пичкә салдылар да, аннан чыгарып гүлбәчкә салдылар.

**ЧҮШИЛӘ** [*рус.* сушило] *трх., нрл.* печәнлек (сеновал).

**ЧҮШКӘ** [*рус.*] *твр.* тураган утын (дрова, готовые к применению). Чүшкәгә кисәләр дә китерәләр, пичкә йағарлыг итеп.

**ЧЫ!** *лш., минз.* к.: **че**! Чы! Рәмзийә, кер инде балаларны қарап тороpға. – *лш.* Чы, ләфкәгә tawарлар килгән. – *минз.*

**ЧЫБА 1.** *м.-кар.* к.: **чywа**. Ак күлмәк, чыба кийә. Чыбасын сары, җәшел җеп белә тегәләр иде; **2.** *перм., к.-уф., минз.* к.: **чоба**.

**чыбағач** *к.т.* чабагач (цеп, молотило):

**җул чыбағачы** *к.т.* кистән (кистень). **Җул** чыбагачы җәрткәннәр элгәре, башы чуқмарлы булған.

**ЧЫБАЛ** *брб.д.* агачлык, урман (лес).

**кендек чыбалы** *брб.д.* баланың кискән кендеген күмә торган урын (специальное место, где закапывают отрезанную пуповину младенца). Кендек чыбалына йуған сулар ташлағалы қушмайтылар пестә.

**ЧЫБАЛА** *т.я.-крш.* к.: **багырча**. Чыбала белән берне ашап бетерде, ди.

**ЧЫБАЛАНУ** *т.я., кмшл.* к.: **билтәләну**. Орчоқланып чыбаланған чәчләре. – *к.т.*

**ЧЫБАЛДЫРУ, ЧЫБАЛТУ** *кмшл.* к.: **чобалдыру**. Чыбалдырып бетердең бит инде (җепне). Чыбалта күрмә инде, зинһар эчен.

**ЧЫБАН** *кузн., шрл.* к.: **чобан**. Чыбанга йаба тырган гөл. – *шрл.*

**чыбан йапрагы** *лмб.* к.: **йар I: йар йафрағы**.

**ЧЫБАР 1.** *перм., хвл., мәл., кузн., т.я.-крш.* к.: **чобар**. Чыбар tawык. Чып-чыбар күлмәк кигән. – *хвл.* Чыбар күлмәгем бар әле. – *перм.*; **2.** *шрл.* к.: **кыкычыбар**; **3.** *лмб.* шадра (рябой). Чәчәктән чыбар, сыткы урнылары биз-биз тыра; **4.** *төм.* соры, алмачуар, ала (серый, серый в яблоках, крапчатый – о масти лошади); **5.** *перм.* начар – күрү сәләте турында (плохо – о зрении). Менә минем күзем чып-чыбар хәзер.

**чыбар йаулык** *т.я.-крш.* тастар өстеннән бөркәнелә торган яулык (специальный платок, который накрывается поверх национальноғо головного убора – *тастара*).

**ЧЫБАРКА** *стрл.* сипкелле (веснушчатый). Синең кебек чыбаркайы минең килен.

**чыбарка төшү** *стрл.* сипкел төшү (высыпать – о веснушках). Фаилга чыбарка төшкән.

**ЧЫБАРЛАНУ** *перм.* начар күрү, тонық күрү (видеть плохо, туманно); чаг.: **күз VI: күз қайту**. Балаларны қайгырам тигән булып җылап-җылап күзләрем чыбарланды.

**ЧЫБА-ЧЫБА** *мәл.* кәҗә куу ымлыгы (употребляется при отгоне коз).

**ЧЫБУ-ЧЫБУ** *мәл.* тавык чакыру ымлыгы (употребляется для скликания кур).

**чыбық** *урт.д.* чыбык (прут, прутик):

**башландырғыч чыбық** *перм.* киндер тукый башлаганда буй җепнең очларын бәйләп чыга торган таякчык, чыбык (палочка, на которую привязывают концы основных нитей при тканье холста в начале ткацкой работы на стане). Башландырғыч чыбығым җуқ қый, тартып алдым ий, җепләрен бәйләп қуйдым.

**ЧЫБЫК I: бараңгы чыбык** *глз.* бәрәңге сабагы (стебель картофеля). Бараңгы чыбык бели чай кайнаталар.

**ЧЫБЫҚ II** *мәл.* җир үлчәү берәмлеге; алтмыш алты сотый? (единица измерения площади земли; шестьдесят шесть сотых?) Халим бабай үлгәчтән бер чыбык арыш биргәннәр иде.

**ЧЫБЫҚ-ЧАТЫР** *лш.* чыбык-чабык (хворост). Аның чыбық-чатырын ике җыл җақтыг әле.

**ЧЫБЫЛДАУ** *перм.* қыймылдап тору (шевелиться). Нәсиб абзый ул мә, чыбылдый да чыбылдый.

**ЧЫБЫЛДЫҚ** *минз.* к.: **торбоша**.

**ЧЫБЫЛЖУ** *перм.* к.: **мылғу**. Көтү чыбылжып тора, арасыннан tawыб алырлық түгел тәкәне.

**ЧЫБЫЛУ** *перм., к.-уф.* сүтелү – чәч, бау, елан h.б. турында (расплетаться, размотаться – о косе, верёвке, змее и т.п.). Чawыл төпкә утырған, астыннан чыбылып чығып килә икән җылан. – *перм.* Чәчеңне нық итеп бәйлә, чыбылмасын. – *к.-уф.*

**ЧЫБЫН** *брб.д.* к.: **озонайақ**. Чыбын кәчен кән полп кәтте.

**ЧЫБЫРТАҚ** *брб.д.* тал чыбыгы (ивовый прутик). Чыбыртақтәү сипа (тал чыбыгыдай зифа).

**ЧЫБЫРТҚЫ** *минз., перм.* к.: **җүрмә**.

**ЧЫБЫТУ** *перм., к.-уф.* **1.** сүтү – теккән һәм бәйләгән әйберне (распороть, распустить – о сшитых и вязаных вещах). Порзимутны камзулдан чыбытыб алғач уқа диб әйтәбез. – *перм.*; **2.** чорналган әйберне сүтү (размотать намотанное). Көрәскә түрик (кәтүк) чыбытыб озаттым. – *перм.*; **3.** ишкәнне сүтү (развить свитое, закрученное). Ишкән чепләрне чыбыталар. – *перм.* Бау йywан булған, чыбытып йаңыдан иштем. – *к.-уф.*; **4.** төргән әйберне сүтү, ачу (развернуть, раскрыть). Йаңыш чыбытқаным, мин ашый торған камфит түгел икән; **5.** өзү, ычкындыру – радио, электр h.б. (выключать, разъединять). Моно чыбыттыңмы? (электр пробкасы турында). – *перм.*

**ЧЫБЫТЫЛУ** *перм.* **1.** яңадан әйләнеп кайту – күч турында (возвращаться в прежнюю семью – об отделившемся рое). Қорт сарый да йаңыдан урнына қайта, чыбытылды, диләр; **2.** ватылу, җимерелү – боз турында (откалываться, разрушаться – о льдине). Тегенән тын боз чыбы-

тылганчи қаплап тора, боз да китә, бу да китә ағып.

**ЧЫWAЛ: чыwал түңе** *брб.д.* ял, ат ялы (грива).

**ЧЫГАНАК** *м.-кар.* к.: **чыганақ I, 1.** Монда чыганак сywыма?

**ЧЫҒАНАҚ I 1.** *трх., әстр.* к.: **кизләү 1; 2.** *лш., брб. д.* чишмә күзе, чишмәнең кайнап тора торган җире (фонтанирующая точка родника). Чишмәнең чыганагы булган, хәзер йуғалган. – *лш.* Чыганак тип чишмә сywы чыккан йерне дәйтәделәр бестә. – *брб.д.*

**ЧЫҒАНАҚ II 1.** *тара., твр., брб.д.* терсәк (локоть). Чачларны, чыганакларны қайныга күрсәтмәссең. – *твр.*; **2.** *брб.д.* ишек тупсасы (шарнир, дверная петля). Чыганаклар алтық ишеккә қуйарға кәрәк; **3.** *клм.* кул беләзеге (запястье).

**ЧЫҒАРУ 1.** *перм.* фатирға кертү, өйдәш кертү (пустить на квартиру). Йә, берәрне уқучы чыгарым әле; **2.** *лш.* аерту (сепарировать). Чыгарасыйық сөтнө, қороп қараған ийек сипаратны.

**бәрәңге чыгару** *бәр.* бәрәңге алу (выкопать картофель, уборка картофеля). Җиләккә қайтмасағыз, бәрәңге чыгарырға қайтығыз. Қызым чыгарыша бәрәңгене.

**ЧЫГАРУ** *лмб., кузн., хвл.* нәрсә белән булса да авыру (болеть чем-нибудь). Анай йәшләтә үлде, сары мынан әспе чыгарды. Кызамык чыгаралар иде, сукырайучылар бар иде әспе чыгарып. – *лмб.* Сары чыгару, кызамык чыгару булып торган элке. – *кузн.*

**ЧЫҒУ 1.** *перм.* керү (заходить). Күршеләрегез чықтылармы сезгә?; **2.** *лш., перм.* китү (уезжать). Сеңелнең малайы әрмийәгә чыга, шуны заталар. – *лш.* Қызымы читкә чыгардым ий, сағынам. – *перм.*; **3.** *брб.д.* тулу (исполниться – о сроке). Қырығы чыққынчы сәлгенчеккә (бишеккә) қайчыма-нимәмә саладыр, паланы йалғызға қалтырғалы йарамайды.

**йортқа чыгу** *нокр.* к.: **йегерү II.** Балалар тапмады, йортқа чықмады.

**йөгөрөп чыгу** *глз., блт.*, **қачып чыгу** *перм., бөре.* к.: **ир II: ир артыннан китү.** Йөгөрөп чықтылар қызларым. – *глз.* Йөгөрөп чықтым мин, димнән биргәнне көтмәдем. – *блт.* Киленнәрем қачып чыққан иде. – *бөре.*

**чыгып бару** *минз.* к.: **ир II: ир артыннан китү.** Чыгып баруны җаратмады әwәлге кеше.

**чыгып төшү** *т.я.* бик нык тузу (сильно износиться – об одежде); чаг.: **амалану, қылқалану.** Өс-башы бөтөннәй чыгып төшкән аның. – *к.т.*

**чыгу** (выходить):

**сүзгә чыгу** *лмб.* телгә менү, кеше теленә керү (иметь дурную репутацию). Сүзгә чыкмийнчы, азмыйнчы тырдым.

**чыгып бару** *хвл.*, **чыгып китү** *кузн.* ябышып чыгу (выходить замуж убегом). Каумын-нисен йарашса, шынарга бирә, чыгып баручылар да булған. – *хвл.* Чыгып китте тырмышка, кан′аналыкиленле тырабыз. – *кузн.*

**ЧЫГЫЛ** *т.я.-крш.* к.: **пысқыш.**

**ЧЫҒЫМ I** *дөб.* к.: **чоғон.** Туры ат бар ыйы бик матур, бик қуwәтлейе, үзе чыгым ийе. Чыгым дигәне тыңнамый атның.

**ЧЫҒЫМ II: чыгымға чыгару** *блт.* юкка чыгару, юк дип исәпләү, исәптән чыгару (списать). Чыгымға чыгарғаннар да бетергәннәр wатылғач.

**ЧЫГЫМ** *кузн.* күл, елга төбеннән бәреп чыга торган чишмә (родник на дне озера, реки); чаг.: **кизләү 1.** Күлнең чыгымы бар. (Бу күлнең) чыгымы бармыдыр, йукмыдыр, белмим.

**ЧЫҒЫН** *перм.* к.: **чоғон.**

**ЧЫҒЫННАНУ** *дөб.* чыгымчылау (упрямиться – о лошади). Менә шундый wахытта чыгыннана ат.

**ЧЫҒЫР I** *минз.* **1.** җеп эрли яки бау ишә торган җайланма (приспособление для прядения). Чыгыр әйләндереп төннәр буйы, аның уты нәрсәкәй; **2.** кош теле пешергәндә җәелгән камырны сырлы-сырлы итеп кисәр өчен сәгать механизмындагы шестернядан ясалган җайланма, кискәндә тәгәрәп бара (приспособление из шестерни часового механизма для разрезания теста). Қош телен тоқмач шикелле җәйәләр дә чыгыр белән қыйықлап кисәләр, сырлы-сырлы булып пешә.

**чыгыр җебе, чыгырлы йен** *кргл.* к.: **йеп I: күләсә йеп.**

**ЧЫҒЫР II** *блт., лш.*, **ЧЫҒЫРДЫЙ** *минз.* к.: **жылawық.** Минем үземнең хатын да чыгырын чыгарды бер малайның, қара булып төртөп торадырыйы кәчеркәсе. – *блт.* Чыгырдыйын чыгарғаннар әле, ваннада тирләтеп баланы, ими сөтө белән арқасын ywып, бүген тыныч жоқлаған әле. – *минз.*

**ЧЫҒЫТ 1.** *минз.* к.: **тура I, 1.** Бүген чыгыт қайнатқаныйым; **2.** *глз.* махсус эшкәртеп ясалган эремчек (творог специальной обработки); **3.** *глз.* сыр (сыр – молочное изделие). Бу чыгытқа тоз да микән салалар?

**ЧЫГЫТ 1.** *тмн., чпр.* к.: **мешке I; 2.** *т.я.-крш.* сыер сөтеннән эшләнгән сыр (сыр домашнего приготовления). Сийыр сетеннән жасаган чыгыт, ыйыган сетне капчыкка салган, ул кирәк булган туйларга, аны мазар эстенә алып киткәннәр. Чыгытны куна белә куйасын сүрән пичкә жаулык белә чөлкәп, тузгымасын өчен; **3.** *т.я.-крш.* эремчектән мичтә пешерелгән ашамлык (запеканка из творога). Эремчекне басасын, йомырка саласын, тоз саласын, писук салгачтын, чыгыт балагырак була, пичкә куйабыз, у анда пешә. Чыгытны сыразы ашарга кирәк. Камырны изәләр дә чыгыт салып пәрәмәч пешерәләр. Эремчектән йасайлар чыгытны, пичкә утырталар, пешерәләр.

**ЧЫҒЫТЛАУ** *перм., к.-уф.* к.: **кикнату.** Абийыңы (читкә) чыгардым исә, чыгытлата, сағына, ахыры.

**ЧЫҒЫШ I** *лш.* к.: **кицмә.** Жаңғыр жауғач, чыгышлар тулды, атлар белән дә чыгып пулмады.

**ЧЫҒЫШ II** *к.т., лш., тара.* к.: **кизләү I.** Чыгыш сywы ғына тотам чәйгә. Чыгышқа суға китте. Чыгышлар бик күб ийе. – *к.т.* Чыгышқа чишмә сywына барады. – *тара.*

**ЧЫҒЫШ III: чыгыш итү** *к.т.* чыдау, түзү (терпеть, выдержать). Қызулыққа чыгыш итеп пулмый. Майына чыгыш италмый.

**ЧЫҒЫШ IV** *әстр.* чуан (фурункул).

**ЧЫГЫШ I** *м.-кар.* к.: **кизләү 1.** Суны тегенән чыгыштан алабыз.

**ЧЫГЫШ II** *клд.* сызлавык (болячка, нарыв). Пытларына чыгышлар чыккан.

**зур чыгыш** *клд.* чуан (фурункул).

**ЧЫГЫШ III** *влгг.* көнчыгыш (восток).

**ЧЫҒЫШЛАНУ** *минз.* расҳодлану, чыгым ясау (сделать расход, израсходоваться, издержаться).

**ЧЫГЫШЛЫ** *кузн.* булдыклы (деловитый, способный); чаг.: **матур 1.** Кызым бик чыгышлы, бик атчайынный.

**ЧЫҒЫШУ** *тара.* килешү, сүз куешу (договориться).

**ЧЫГЫШУ 1.** *кузн., шрл.* булдыру (суметь сделать что-то, справиться). Сылап бетер чыгышсаң. – *шрл.* Зөфәр ул кайа барса да чыгыша. – *кузн.*; **2.** *шрл.* ерып чыгу (выкрутиться). Үзенә дип бәйләгән иде шал′не, энде чыгышалмыйлар, ү салдылар, сата энде.

**ЧЫДАҚЛЫ** *минз.*, **ЧЫДАКЛЫ** *стрл.* чыдам (ноский, добротный). Чыдаҡлы ул, ике ай кидем мин аны.

**ЧЫДАМАУ** *м.-кар.* ямансулау, күңелсезләнү (грустить, тосковать, скучать). Чыдамыйтлар, кат′атлар да киләтләр.

**ЧЫДАМЛЫ** *м.-кар.* күңелле (весело, приятно). Җәмәгат белән чыдамлы ул ашау.

**ЧЫЖЫМ 1.** *минз., т.кам.-крш.* телефон чыбыгы (провод, проволока). Чыжымнарга бөгөн төннә беләк җуwанның бәс җабышҡан. – *т.кам.-крш.*; **2.** *мам.* үрмәле үсемлекләрдә: мыек (усики – у растений). Қара җиләк чыжымы. Биктурый утыртҡаныйым, оторо җиргә җатып, оторо чыжым җибәреп үсә икән.

**чыжым баганасы** *минз., т.кам.-крш.* телеграмм баганасы (телеграфный столб). Сай чоқордағы чыжым бағаналарын алыштырасы бар, чергәннәр. – *т.кам.-крш.*

**ЧЫЖЫМ** *мам.* к.: **чыжым 1, 2.**

**ЧЫЙҚАН** *әстр.* к.: **чығыш IV.**

**ЧЫЙҚЫТЫП** *перм.* каты итеп, кетердәп торырлык итеп (очень сильно, досуха). Тутырма йарма белән йасыйлар, киптерәләр чыйқытып.

**ЧЫЙРАТУ** *каз.ар.-крш.* к.: **кәкшетү.**

**ЧЫЙУ** *перм.* к.: **чийу 1, 2.**

**ЧЫЙЫРЧЫҚ** *мам.* к.: **черчек 1.** Пич арасында чыйырчық сайрый. Муча чыйырчыгы.

**ЧЫҚАН I, ЧЫКАН** *т.кам.-крш.* к.: **кийек I, 3.** Қапчыҡның моносон чыҡан ашаған мәллә? Күрәсең килер, шулай йөзеңне чыканнар тишеп бетерсә.

**ЧЫҚАН II** *т.кам.-крш.* к.: **кесеркән.** Чыҡан өтә.

**тимер чыҡан** *т.кам.-крш.* вак яфраклы кычыткан (крапива с мелкими листьями).

**ЧЫҚАН III** *кргл., бгрс.* к.: **ныҗы.** Әби, чыҡанга нинди дару бар? – *бгрс.*

**ЧЫККЫСЫЗ** *тмн.* чиксез, бик күп (много, очень много). Читлawык чыккысыз була иде.

**ЧЫҚЛАУ** *баст.* йоклау (спать). Бабай әтә идек, әнийемне быраты, чыҡлый, җәшләр киләләр, шум, чыҡлый да чыҡлый.

**ЧЫКЛАУ** *влгг.* вак яңгыр яву (идти – о мелком дожде; моросить). Йаңгыр чыклый.

**ЧЫҚМЫР** *твр.* к.: **қатымыш.** Анынқы әтәсе чыҡмыр полыпты, ақча пирмәпте.

**ЧЫКМЫШ** *кузн.* чыгыш (происхождение, выход); чаг.: **тума 2.** Бабайларнын чыкмышлары Төмәннән.

**ЧЫҚ-СУ** *перм.* к.: **чықы.**

**ЧЫКУ** *мәл.* күп итеп, туйганчы ашау, рәхәтләнеп ашау (наесться досыта, наесться с удовольствием). Ну, шонда малинаны чыкыдык.

**ЧЫҚЫ** *нгб.-крш.* чык (роса). Бүген чықы төшкән.

**ЧЫҚЫҚЛАУ** *перм., твр.* к.: **кикнату.** Бала чыҡыҡлама йәбеште қый сuwыққа. – *перм.* Уйантым та чыҡыҡлап киттем. – *твр.*

**ЧЫҚЫЛДАҒАН** *мам.* к.: **чиқылдаған 3.** Суқа суқалап, печән чawып үстем, чыҡылдаған керәстийән мин.

**ЧЫКЫЛМА: чыкылма йевеш (су) булу** *хвл., мәл.* к.: **лач: лач булу 1.** Йаңгыр астында калып, чыкылма су булдым. Итег эчләре чыкылма йевеш, айакларым сызлый, ди тагын. – *хвл.* Чыкылма су булып кат′тык. – *мәл.*

**ЧЫҚЫЛТАШУ** *минз.* әрепләшү (ссориться). Бер дә чыҡылташмайым. Чыҡылташып тормадық, унике җыл тордоқ. Балаларга суқса ғына чыҡылташып китәдер ийек килен белән, бу балалар өчән үләм мин.

**ЧЫКЫНАК** *м.-кар.* рәхим итегез (пожалуйста).

**ЧЫКЫР: чыкыр су булу** *мәл.* к.: **лач: лач булу 1.**

**ЧЫКЫР: чыкыр(ын) чыгару** *мәл.* бик ныk эшләтеп хәлдән тайдыру (заставить работать до изнеможения, до упаду).

**ЧЫҚЫРДАТЫП: чықырдатып җому** *к.т.* к.: **чатқытып: чатқытып йому.** Чыҡырдатып җомған күзләрен.

**ЧЫКЫРЧА** *шрл.* өсте ачык булган ит пәрәмәче (перемяч).

**ЧЫЛАЙ** *т.я.-крш.* к.: **айап 1.** Оныткан мин аны, чылай җыллар беттәнде, картайган. Тәрбит (*ав. ис.*) белән безен арада чылай айырма бар.

**ЧЫЛАН 1.** *чст., м.-кар., мәл., карс.* к.: **ишегалды.** Мин бүген чыланда йыкладым. – *чст.* Чыланны бикләб алган. – *карс.*; **2.** *лмб., карс., мәл., м.-кар.* к.: **бүлмәч 2; 3.** *кузн., мәл.* к.: **кәзәнкә 2.**

**каршы чылан** *мәл.* к.: **кәзәнкә 2.**

**тыш чыланы, тышкы чылан** *карс.* к.: **ишегалды.**

**ызба чыланы, эчке чылан** *карс.* к.: **кәзәнкә 2.**

**ЧЫЛАНУ** *каз.ар.* к.: **сулану.** Чылана безнең өй қош көнө. Мичебез килешмәде, өйөбөз чылана. – *блт.* Пич килешмәсә, почмақлар бич чыланып тора. – *мам.*

**ЧЫЛАТУ** *нокр.* **1.** манчу (макать, помакать). Сөткә чылатып ашай; **2.** изү, изеп кую – камыр турында (замесить тесто). Иртән килеп чылата да соңра баса.

**ЧЫЛБЫР 1.** *минз.* тәңкәләрдән ясалган дүртбиш чылбырлы бизәнү әйбере (женское украшение с четырьмя-пятью подвесками, сделанными из монет); чаг.: **каптырма 1.** Алты чатлы чыл-

быр буладыр ийе, артында тәңкә буладыр ийе бөтөн, чулпы сымаг итеп. Чылбырны көмөшчеләр йасайлар ийе, озон-озон чатлы итеп; **2.** *кргл.* элек: тар гына тукыма кисәгенә тәңкәләр тезеп ясалган һәм муенга бәйләп куела торган бизәнү әйбере (старинное женское нашейное украшение из монет, надеваемое на шею); **3.** *перм.* к.: **йага III**. Чылбыр булайы көмөштән, қаптырып; **4.** *минз., кмшл.* тәңкәләрне кашлы-челтәрле буыннар белән аралаш тезеп, бер, ике яки өч рәтле муенса кебек итеп эшләнгән бизәнү әйбере (старинное нашейное украшение в один, два или три ряда из монет, соединённых между собой ажурными или лопастными звеньями, имеющими камни в середине). Чылбырны арасына тәңкә қуйып, аннары тимер-чыбық сыман әйбер, челтәрләп йасыйлар ийе, бер рәтле дә була, ике рәтлесе дә була. Өдөлдинде, өдөлдинде, Муйнымдағы чылбырым; Алмыйсың син, алдыйсың син, Сандуғачым, былбылым (*хал. җыр.*). Чылбыр қаш белә, тәңкә белә беткән нәрсә йенде, өчәр рәт тә, икешәр рәт тә була, арттан бәйлисең. – *минз.* Чылбыр боҗра-боҗра тора, қыйғайтеп бәйләп җөриләр. Чылбыр да тағалар ый, тәңкә тезгән әллә ничә рәт. Безнең үзебездә чылбыр бар ыйы, бер әрәте сарырақ қашлы, бер әрәте ағрақ, җемелдәп тора, бер әрәте wағрақ, сабақлы буладыр ийе, җуғарырақ тора ул. – *кмшл.*

**ботлы чылбыр** *нокр.*, **чылбыр йаға** *перм.* к.: **қаптырма 1**.

**ЧЫЛБЫТУ** *тмн.* чылату (мочить, смочить). Чылбыталар гәҗит-журналларны бу оланчыклар.

**ЧЫЛҒЫЙ I** *мам., лш., минз.* к.: **қawыр**. Әwәлдә без чылғый җыйнап итеп бирәйек тә, чикләwекләр алайек. – *мам.*

**ЧЫЛҒЫЙ II 1.** *каз.ар.* эшкә әрсез, булдыклы, тырыш (способный, усердный, выносливый); чаг.: **чирақ, чыгышлы**. Һәммә эшкә дә булган кеше була чылғый кеше. – *лш.*; **2.** *бәр.* чыдам, түзем (выносливый). Чыдам кешене чылғый диләр; **3.** *бәр.* дымык, дымлы, уалып тормый – печән турында (гибкий, влажный, неломающийся – о сене); чаг.: **мижанны, мижаннану**. Печән бик кипми әле, бик чылғый.

**ЧЫЛДЫР I** *хвл.* к.: **бака I**. Чылдыр чәчнең очона куйыла, акчадан йә ахыктан йасап.

**ЧЫЛДЫР II** *перм., к.-уф.* **1.** к.: **чолдор II, 2**. Инәдән бер генә малай, чылдыр ызбаға чықтинде. – *перм.* **2.** начар, вак (плохой, мелкий); чаг.: **който; чебердек**. – Эре булдымы бәрәңгесе? – Әйбәт, чылдыр түгел.

**ЧЫЛДЫРДАУ** *шрл.* чылтырау (звенеть – о будильнике). Сәгат чылдырдады.

**ЧЫЛДЫР-ЧАЛДЫР** *перм.* к.: **алама-шалама**. Эчмәкне теләсә нинди нимәдән сырып җийасын инде, чылдыр-чалдырдан.

**ЧЫЛКА** *лмб., кузн.* к.: **чолка**. Утырминча чылка бәләнми. Чылкалар ки, йермә былай. – *лмб.* Чылка да бәләп бирәм. – *кузн.*

**ЧЫЛПЫ** *минз.* чулпы (накосник). Чылпым awыр, тақмайым; Эчемдәге серләремне Кем белә уртақлайым (*хал. җыр.*).

**ЧЫЛТ: чылт-қара** *брб.д.* кап-кара (чёрный-пречёрный). Чылт-қара посawы, көскөтә тоуған қой.

**ЧЫЛЫҒУ: күзгә чылығу** *блт.* күзгә чалыну (попасть на глаза).

**ЧЫЛЫҚ I** *клм.* к.: **чолка**.

**ЧЫЛЫҚ II: бал чылық** *глз.* умарта (улей). Бал чылықлар күп урман эчтә.

**чылыққа чығу** *кргл.* кырга күңел ачарга чыгу (отправиться на пикник).

**ЧЫЛЫМ** *брб.д.* кабык (чешуя).

**ЧЫЛЫМЛАШУ** *минз.* сүзгә килешү, килешмәү (поссориться). Аның белән чылымлаштык та, ул мине awыр эшкә қуйды.

**ЧЫМА** *перм.* к.: **сызғыч**. Чымаңны чый әле.

**ЧЫМАЛАУ** *глз.* йому (закрывать глаза). Күзен чымалай.

**ЧЫМЧЫРЫҚ** *твр.* тып-тын, шыпырт (тихонько, без шума, молча). Бабасын керткән, соратыб утыра, аққам, пирмимен, тиде, мин чымчырық қына йөрим.

**ЧЫМЫЛДЫҚ 1.** *бөре., к.-уф.* к.: **торбоша**; **2.** *перм., әстр.* чыбылдык (полог, балдахин). Җите қат түшәк түшиләр, чүрәли чаршаулар, чымылдықлар. – *перм.*; **3.** *перм.* к.: **коргоч**. Нашатырныйны чәчкәле әйберләргә салма, йарамый, бары тәрзә қашағаларға, тәрзә чымылдықларға шунда.

**ЧЫМЫЛДЫҚ** *байк.* к.: **торбоша**.

**ЧЫМЫЛТЫҚ** *тбл.* бишек (люлька, колыбель).

**ЧЫМЫН** *клм.* чебен (муха). Чымынны толтрып қойодолор эжикни ачып.

**ЧЫМЫРЫ** *стрл., тпк.* булган, тырыш, йөрәкле (ловкий, способный, хваткий). Дайарка булыб эшли, алар эшкә бик чымыры. – *стрл.*

**ЧЫМЫТҚЫ** *трх.* сосла (сусло). Әтәйләр чымытқыга су өстәп квас йасыйлар ийе.

**ЧЫН: чын гына** *кузн.* гел, һаман, бары (только, всё время). Гумерем буйы чын ғына эшләдем.

**чын чәй** *бәр.* бөртек чәй (фамильный чай, байховый чай). Чын чәй сал ыйы, тақта чәй чүб ул. Чын чәй белә тақта чәйне қушып сал.

**ЧЫНА** *брб.д.* к.: **җәйләү**.

**чына йазу** *брб.д.* чынаяк тәлинкәсе читенә дога язып, авыруга эчертеп, аны дәвалау, имтом итү (один из знахарских способов лечения больного). Чына йазалар, tywa (дога) йазып эчерә иде аурасам.

**ЧЫНАЗА** [*гар.*] *трх.* к.: **ченаза**.

**чынайак** (чашка):

**чынайак аслыгы** *шрл.*, **чынайак асты** *чст.* к.: **җәйләү**.

**чынайақ йапқычы** *мам., блт.* к.: **чинийақ: чинийаг өстө**.

**чынайақ өстө** *тпк.* к.: **җомор**.

**чынайақ табагы** *бөре.* к.: **җәйләү**.

**чынайак эслеге** *шрл.* к.: **чинийақ: чинийаг өстө**.

**ЧЫНА'ИМ: чына'им 'адәр** *кас.* чәнчә бармак калынлыгы (толщиной с мизинец). Чына'им 'адәр майы бар.

**ЧЫНГЫ** [*рус.*] *тмн.* зәңгелә авыруы (цинга).

**чынгы үләне** *тмн.* су борычы (водяной перец). Зәңгелә авыруын чынгы үләне белән дәвалыйлар.

**ЧЫНДЫР I** *дөб.* к.: **җынҗыр**. Чындыр белән тотоп җөриләр ийе айуны.

**ЧЫНДЫР II** *чст.* к.: **араччык**. Кийәү белән кыз арасында чындыр идем.

**ЧЫНДЫР III** *тбл.* кәс, чирәм (дёрн). Өйне чындыр ман йабатаган порноғолар.

**ЧЫНҖЫР** [*фарс.*] *минз., дөб., м.-кар., стрл.* к.: **җынҗыр**. Сәғәтем җөридер ийе, чынҗырын алган балалары. – *минз.* Сары чынҗыр белә йапайакты итеп тагатлар иде җиз тараклар. – *м.-кар.* Чынҗырны төшөрәләр дий суға, җуқ тий; алмаштилмәш чумышқа ғына тапқаннар (баткан кешене). – *дөб.*

**ЧЫНИКАЙ** *кузн.* к.: **чынлықлап**. Бик чыникай сау тегел иде кан′анам.

**ЧЫНИТ** *кузн.* к.: **ахық**. Чын чынит аший идек, айбагар чәчә идек көрәк белән.

**ЧЫНҚЫЙ 1.** *каз.ар.-крш.* чын (истинный, настоящий). Өстәл өсләрендә эскәтер, Эскәтер өсләрендә чынайақ; Чынайақ тигәнебез чынқый көмөш, Чынқый қодаларыбыз сез, имеш (*хал. җыр.*); **2.** *каз.ар.-крш.* төгәл, дөрес (точный, верный). Бу сәғәт чынқыйрақ; **3.** *т.кам.-крш., трх.* чынлап, чын-чынлап, чыннан да (всерьёз, по-настоящему). Чынқый тотонсаң була икән. – *т.кам.-крш.*

**ЧЫНЛЫҚЛАП** *мам.* чынлап (по правде, всерьёз, взаправду). Йуқ, чынлықлап йазганнар.

**ЧЫНСЫЗ** *чст., мәл.* чамадан тыш, чиксез (чрезмерно). Элеке бик күп тегел ийе сатлар, әле хазер бик чынсызга әләнде. – *чст.* Йиләк бийыл чынсыз булган анда. – *мәл.*

**ЧЫНЧА** *клм.* к.: **бармақ: гөлчәчәк бармақ**.

**ЧЫНЫ I** *чст.* кешелек йөзе, кешелек сыйфаты (человечность, человеческое достоинство, порядочность). Чынысы чыккан кеше. Чынысы йугалган бит бу кешенең. Чынысы йук.

**ЧЫНЫ II** [*рус.* челнок] *чст.* соса (челнок).

**ЧЫНЫ III** *брб.д.* к.: **җомор**. Чәй эчкәле чыны йоқ. Мөсөлман кеше пер чыны чай эчмәстән чықса, ол нимә болады?

**ЧЫНЫҒУ** *дөб.* күнегү, өйрәнү (привыкать). Чыныға ийе инде анаң да, дим, қайтмасан да йарый ийы, дим.

**ЧЫНЫСЫЗ** *чст.* кешелек йөзен югалткан, кешелексез (потерявший человеческий облик, непорядочный).

**ЧЫҢ** *кмшл.* к.: **awaз-қауға**. Чыңсыз чақта чың чығарып йериләр бит.

**ЧЫҢАРАКЛАР** *лмб.* чыр-чулы (шумный – о детях). Малайларым бар, чыңараклар үтә.

**ЧЫҢҒА** *твр.* келә, бикләвеч (щеколда). Чыңға салулымы? Тирәснеңке чыңғасы төшкән.

**ЧЫҢГЫ** *хвл.* **1.** кыңгырау (звонок); **2.** эт исеме (кличка собаки).

**ЧЫҢҚЫ** *каз.ар.-крш.* усал, явыз (злой); чаг.: **дәллә 2; матур 2; зәңки**. Чыңқы кеше.

**ЧЫҢҚЫЙ** *т.кам.-крш., трх.* к.: **чынкый 3**. Чыңқый, кирәк тә бит, нишләр дә хәл җуқ. Алар чыңқый белеп җырлыйлар. – *трх.*

**ЧЫҢҚЫРУ** *твр.* **1.** кычкыру (кричать). Пы нәрәситә ичкемгә чыңқырмас ата тип; **2.** кешнәү (ржать). Атның инәсе алты ай чыңқырган.

**ЧЫҢНАТУ** *каз.ар.-крш.* к.: **йаслату**. – Қыс чыңнатқан чақта ничек җырлыйсың? – дий. – Үземне чыңнатмағач, белмим!

**ЧЫҢРАК** *хвл.* «юләр», «тиле» тибындагы ымлык сүз (междометие типа «глупый», «дурень»). Кит, чыңрак, килә дә чулт-чулт үбә кызлар кебек, тартмий, аракыны белми дә.

**чыңрак үтә кит(кере)** *хвл., мәл., тмн.* каргау сүзе (выражение проклятия). Чыңрак үтә кит, кадал! – *мәл.* Чыңрак үтә кит, башкаданмы тапмамын. – *тмн.*

**ЧЫПРА-ЧЫПРА** *тмн.* шабыр-шыбыр (о звуке, производимом дождевыми каплями). Чыпра гына чыпра йаңгыр йава, Укалы түбәтәй башымда (*бор. җыр.*).

**ЧЫПЧАҒИ** *нокр.* к.: **чепчәғи**. Чыпчағи бал белин ничек булса йасайлар шай.

**чыпчык I** (воробей):

**җиләк чыпчык** *перм.* кычыткан чыпчығы (крапивник).

**йардан чыпчыгы** *тмн.* ярда оялый торган чыпчык (воробей, гнездящийся по крутым берегам).

**йәшел чыпчык** *хвл., мәл.* к.: **майқарақ**.

**сабан чыпчық** *перм.*, **сука чыпчығы** *тмн., кузн., хвл., клд.* к.: **бистургай**. Сука чыпчығы кырда ычып йери, чывар-чывар. – *хвл.*

**чыпчық айағы** *нрл.* бәбкә үләне (птичья гречиха, травка-муравка).

**чыпчык башы** *чст.* тукранбаш (клевер).

**чыпчық борчағы** *минз., мам.* кырмыска борчагы (горошек заборный).

**чыпчық борчақ** *перм.* акация (жёлтая акация).

**чыпчық дарысы** *минз.* песи тарысы (амарант, щирица).

**чыпчық йафрағы** *блт.* к.: **йара II: йара йапрақ**.

**чыпчық қузғалағы** *мам.* к.: **кәрешкә**.

**чыпчық күзе 1.** *кргл., бгрс., минз.* күгәрчен күз (незабудка); **2.** *чст.* тмин.

**чыпчық миләше** *бәр., блт.* к.: **байбай**.

**чыпчық орлоғо** *мам.* төтәч (дымянка лекарственная).

**чыпчық сабыны** *минз.*, **чыпчык сандалы** *тмн.* канәфер чәчәк (гвоздика цветная).

**чыпчық талы** *шрл.* мурт тал (ракита, ива хрупкая).

**чыпчық тигәнәге** *мам.* сырлан (липучка).

**чыпчык үләне** *бөре.* канәфер чәчәк (гвоздика – травянка).

**чыпчық чәчәге** *дөб.* ала миләүшә (фиалка трёхцветная).

**чыпчык ырлыгы** *чст.* шепкән (рыжик яровой).

**ЧЫПЧЫҚ II** *лш., минз.* ачы камырдан ишеп пешерелгән камыр ашы, слойка (слоёная булочка из кислого теста). Базарлардан апқайталар ийе чыпчықлар, қызылга буйаган, башы чыпчық башы шикелле. – *лш.*

**ЧЫПЧЫҚ** *чст.-крш.* чирек литр (четверть литра). Бер чыпчык ийе, ыстаканга сыйарга тегел лабаса.

**ЧЫП-ЧЫН** *глз., нокр.* дөрестән дә, чыннан да (на самом деле, действительно); чаг.: **чынқый 3**. Алма йабыштық та қап-қайнар су, чып-чын. – *глз.* Чып-чын малайым икән, Хәдичә күргән сучөн

төшүче. Чып-чын да син матур силисең. Булмай йырлама, чып-чын. – *нокр.*

**ЧЫПЧЫРҒЫ** *перм.* к.: **йеп.**

**ЧЫПЫЙ** *нгб.-крш.* к.: **турғай.**

**ЧЫПЫЛТАУ** *кузн.* лычкылдау, лычма су булу (стать совсем мокрым). Йаратмаган алашаны кадулага сала, сийрның касы йаратмаган, йеп-йевеш була эсе чыпылтаган.

**ЧЫР I** *каз.ар., кргл., хвл., лмб.* аш өстенә чыккан май (навар). Чыры да чыкмаған итнең шурпага. – *кргл.* Чырлары бар эштинең. – *лмб.* Миңа чырсызрагын сал. – *хвл.* Бу ашның чыры йуқ. – *дөб.* Бер чыры да чыкмады ул итнең. – *блт.* Ник бер чыры булсын ашның, йәш бозау ите бигрәк арық. – *мам.*

**ЧЫР II** *перм.* вак балык (вид мелкой рыбы). Агын җирдә йата торған чыр ул.

**ЧЫРА** [*фарс.*] **1.** *карс., себ.* к.: **йымычка.** Чыра керде кулга. – *карс.* Чыра қадалды баса, алыңцы. – *тбл.*; **2.** *нокр.* чыра кыстыра торган өч яньле тимер, шәмдәл (железо с вилкой для вложения лучины; подсвечник).

**ЧЫРАҒАЧ** [*фарс.* + ағач] *мам.* чыра агачы (полено для лучины). Чырағачны тапмадым дағын пич утынын телеп маташам.

**ЧЫРАЙ** *минз.* **1.** йөз (лицо). Чырайларыбыз җәм-җәшел булып бетте, үлән ашый-ашый; **2.** чабата йөзе (верх головки лаптя). Чабатаның чырайын җywадыр ыйық та сабантуйға китәдер ийек. Чырайы бер фурмы чығарып йасала, муқшы чабатасы диләр ансын; **3.** көрәк йөзе (лезвие лопаты). Көрәк чырайы җалтырап тора.

**пәтер чырай** *твр.* табак бит (широкое лицо). Пейек пуйлы, пәтер чырайлы пер әтәм ите.

**салқын чырай** *нрл.* караңгы чырай (угрюмое лицо). Чырайы бик салқын аның.

**чырайдан калу** *тмн.* ямьсезләнү (стать некрасивым, потерять лицо). Аны мынан йатқан кеше үлде, хуҗам да който булды хазер, чырайдан калды.

**чырайы чырт иткән** *хвл.* таза, чиртсәң, каны чыгарга тора торган (здоровый, кровь с молоком).

**ЧЫРАЙСЫЗ** *клд.* караңгы чырайлы (угрюмый, хмурый). Ату вет инде касы кешегә баралмыйлар, чырайсыз.

**ЧЫРАҚ** [*фарс.*] **1.** *перм., к.-уф., төм., твр.* чыра (лучина). Чыраққа диб әпкердем и, тағы табарым әле чыраққа (агач). – *перм.* Чырақ йандырған заманнар узды инде. – *к.-уф.*; **2.** *тара., твр.* йомычка (щепка). Йәшен ағачны чырақларға айлантырты. – *тара.*; **3.** *себ.* к.: **йымычка.**

**чырақ йарқа** *перм.* к.: **чырағач.** Әни, чырақ йарқа йуқмыни?

**ЧЫРАҚЛАУ** *тара., твр.* йомычкага әйләндерү, телү (превращать в щепки, щепать). Көймәне чырақлап ташлады. – *твр.*

**ЧЫРАҚЛЫҚ** [*фарс.* + *афф.* -лық] *перм.* өй эчендә бер башы белән сәндерәгә, икенче башы белән түр стенага беркетеп куела торган озын такта, киштә (полка, устроенная в передней части избы: один конец её прикрепляется к полатям, другой – к передней стене).

**чырақлық түз** *перм. чыраклык*ның түр стенага беркетелгән башы (тот конец *чырақлық*, который прикреплён к передней стене). Безгә дә гнә дигән нә тастималлар, Чырақлық түзләргә салыңңан (из обрядовой песни, исполняемой во время сбора у населения подарков для сабантуя).

**ЧЫРАЛЫҚ** *трх.*, **ЧЫРАЛЫК** [*фарс.* + *афф.* -лык] *мәл., чст.* мич буенда югарыда чыралык агачлар яки чыралар кую өчен эшләнгән ике янәшә колга яки киштә (полочка или жерди, устроенные наверху около печи для сушения полена для лучины или лучин). Пич алнында эч чыралык. – *мәл.*

**ЧЫРАМСЫТУ** *мам., лш., каз.ар.-крш.* охшату (принимать за кого-либо, за что-либо). Чырамсыттыңмы? – *лш.* Кемгәдер чырамсытам бу қызны. – *мам.*

**ЧЫРАПИҢКА** [*рус.* черепинка] *минз., стрл.* балчык савыт (глиняная посуда); чаг.: **чирапинкә.** Бәләкәй сawытлар буладырыйы, чырапиңка диләр ийе. – *стрл.*

**ЧЫРАХМАН** *лмб.* к.: **чирахман I.** Чырахман йауды, алма сабакларын тетте.

**ЧЫРГАЛГЫЧ** *лмб.* йогырт (подмаренник цепкий).

**ЧЫРГАУ I** *кузн., хвл., мәл.* к.: **сарғыч: айақ сарғычы.** Чыргауларны чигәләр иде кийәүгә. – *кузн.*

**ЧЫРГАУ II 1.** *карс., кузн., мәл., лмб.* чорнау, төрү, урау (окутывать, закутывать, завёртывать, обвёртывать). Йылы шәлгә чыргалырга кушкан. – *карс.* Мужик кийәр карыш йарым чабата, Кәркешләрен чыргый-чыргый таң ата. – *мәл.* Баштан алган баш тастарым, Баш кыдага йарасын, Минем йаным тынмаса, Йан йулдашын чыргасын, Йан йулдашы аз булса, Ылын-кызын чыргасын (*кыз елату җыры*). Айагында чабата булган, кәркешләрен йугары гына чыргый булганнар, кыз кун′ына бара булган. – *лмб.* Пешкәннәрен мишугына чырга. – *кузн.*; **2.** *хвл., мәл., кузн.* тәмәке төрү (завернуть, обернуть табак). Тәмәке чыргаганнар. – *мәл.* Бир тәмәкеңне, берне чыргыйм. – *кузн.*

**ЧЫРҒЫТУ** *перм.* к.: **быргыту 1.** Башларына кийеп карыйлар да тагы чырғыталар.

**ЧЫРЛИ-БЕРЛИ** *лмб.* к.: **бистурғай.**

**ЧЫРМАУ** *карс.* к.: **чыргау II, 1, 2.**

**ЧЫРМАШЫП** *мам.* тырышып-тырышып (усердно, очень старательно). Шулай чырмашып гөмөр иткәннәр инде бабайлар.

**ЧЫРНАWЫҚ** *баст.*, **ЧЫРНАВЫ'** *кас.* эт эчәге(се) (вьюнок).

**ЧЫРНАWЫЧ** *мәл., чст.* к.: **сарғыч: айақ сарғычы.** Бәләгән эч кийем ыйык, айак чырнawычы. – *мәл.*

**ЧЫРНАУ** *мәл.* к.: **сарғыч: айақ сарғычы.** Чырнаулар чүпли идек, селгеләр чүпли идек, палас суга идек.

**ЧЫРПЫ** [*фарс.*] *лмб.* нечкә агачлар, чыбык-чабык (хворост, прут). Чырпылардан эшләгән йыртлар бәлчек сылап.

**ЧЫРСЫЗ** *перм.* к.: **черәйсес.**

**ЧЫРТАН** *тбл.* учак (костёр).

**ЧЫРТЛЫ** *тмн.* к.: **чылғый II, 2.** Чыртлы, бик ару иде теге катны.

**ЧЫРТСЫЗ** *шрл.* усал (злой). Хазерге кан′аналар вет чыртсыз.

**ЧЫРЧАГЫШ** *влгг.* сагыз (сера). Әнийем кызлардан чырчагыш китерде.

**ЧЫРЧЫК** *кузн.* к.: **йырчык**. Битеңә чырчык була.

**ЧЫРЧЫҚ** *нокр.* **1.** к.: **чигеркә**; **2.** к.: **черчек I**.

**ЧЫРЧЫКАЙ** *мәл.* к.: **нәзек 3**. Чырчыкай выт бу ылан.

**ЧЫРЧЫННЫ** *яүшт.* **1.** чыршы (ель); **2.** ак чыршы (пихта).

**ЧЫРШЫ I** *влгг.* к.: **қомпалық**.

**ЧЫРШЫ II** *влгг.* к.: **йымычка**.

**чыршы гөлө** *минз.* аспарагус.

**чыршы печәне** *бөре., блт.*, **чыршы печин** *перм.*, **чыршы тәтәй** *перм.*, **чыршы уты** *тмн.*, **чыршы үләне** *дөб., мам., бөре.* к.: **қарағай: қарағай үләне**.

**ЧЫРЫ** *мәл.* к.: **чыр I**. Ашка чырысы чыккан.

**ЧЫРЫЖ** *карс.* чыршы (ель). Чырыжмы үсә, кайынмы.

**ЧЫРЫК** *лмб., кузн., хвл., м.-кар., шрл.* к.: **чорок 1**. Чырык севәгем авыртты урнысында. Чырыклырым авыртты вычы катыда йатып. Чырык севәге тишелде йата-йата. Лапаларым, чырыкларым мынан ук awырта. – *лмб.* Чырыгым авырта. – *м.-кар.* Чырыгым авыртып тыра, йыгылган идем. – *шрл.*

**ЧЫРЫЛДАҚ** *срг.* к.: **цырылдык 1**. Чырылдаклар төшмичә, инеш сywы кузгалмый.

**ЧЫРЫМТА 1.** *мәл.* юкә кайрысын суда җебетү юлы белән ясала торган мунчала (мочало); **2.** *мам.* чабата ясар өчен юкә әзерләгәндә чыккан вактәяк юкәләр (мелкие остатки, получаемые при заготовке лыка для плетения лаптей). Киндерә ишә торган wақ җүкәләрне чырымта дидер ийек; **3.** *лш., к.т., влгг.* чүп, вак-төяк калдык; чытыр (мусор, мелкие остатки чего-либо; хворостина). **Җүкә чырымтасы.** Агач чырымтасы. – *к.т.*; **4.** *мам.* агачның чәрдәкләнеп вакланган урыны (раздробленное, размозжённое место дерева). Чырымталы ағач. Чыршы сынганда да чырымталы була; **5.** *нокр.* чыпта (рогожа). Чырымта белән күмдек, қатыннар хәбер қазыдылар; **6.** *влгг.* чыра (лучина). Самawырга wаклап чырымта салыйым.

**ЧЫРЫМТАЛЫ** *мам.* җепселле – ит турында (волокнистый – о мясе). Үгез ите чырымталы була.

**ЧЫРЫШ I** *м.-кар.* к.: **чырыж**. Арчыган чырыш, шуңа Чыршалан (*ав. ис.*) кушканнар.

**ЧЫРЫШ II** *перм., минз.* тырыш (старательный, усердный); чаг.: **чылғый II**. Чырыш та хатын ыйым. Иллә чырыш та инде ул. – *минз.*

**ЧЫРЫШУ** *минз., стрл.* ябыгу, кору, кибү (худеть, иссохнуть). Киленнәрнең кайсы чырыша, кайсы тулыша. – *стрл.*

**ЧЫРЫШХАХ** *саз.я.* бөдрә (кудрявый). Қылғойроқ пywыны оссон, чырышхах йоно бар. Чырышхах цац.

**ЧЫС: чыс кына** *срг.* тиз генә (быстренько). Урамда чыс кына ут йагалар.

**ЧЫСУ** *мәл.* язып ташлау – хат h.б. язу-сызулар турында (быстро написать – письмо или другую какую-либо писанину).

**ЧЫТАЙУ 1.** *дөб.* чиркану, җирәнү (брезгать, чувствовать отвращение); **2.** *дөб.* чирканып китү, туңу, суыксып китү (зябнуть, почувствовать холод). Әзрәк чытайасыңмы әллә? Җилкәм туңадыр дип уйладым чытайғач. Арқам чытайды дисең, бик қаты туңдырмый ич; **3.** *дөб., к.т.* оялу, уңайсызлану (чувствовать себя неловко, стесняться). Мәйеткә қарарға җарамый, имеш, мәйет чытайыр дий. – *к.т.*

**ЧЫТАЛАНУ** *влгг.* кырау алгач бөрешү – үсемлекләр турында (морщиться, сморщиться после заморозков – о растениях). Чыталанган памадурлар, картуп сабакларын да кырау суккан.

**ЧЫТҚАН** *дөб., каз.ар.-крш.* к.: **кесеркән**. Чытқанны апараға қушсаң, дуңгыз бик ашый. Чытқан чақмыймы? – *каз.ар.-крш.* Чытқан чаға. – *дөб.*

**ЧЫТКЫС** *м.-кар.* хатын-кызлар буа торган чуклы билбау (женский пояс с кистями на концах). Кызыл чыткыс, зур чуклы чыткыс иде.

**ЧЫТЛАНУ** *нрл.* шуклану, тик тора алмау, тиктормас булу (не усидеть, быть шаловливым, егозой). Чытланып тора, басқан урынында түзә алмый.

**ЧЫТЛЫ I** *кмшл., нрл., минз.* шук, тиктормас (непоседливый; егоза; озорной); чаг.: **қорамыш 1**. Эй чытлы да инде. – *нрл.* Чытлы малай. – *минз.* Бу хәдәр чытлы булырсың икән. – *кмшл.*

**ЧЫТЛЫ II** *дөб., т.кам.-крш.* тамчы, бөртек (капля, крупинка). Awылны чыққан ыйым, чытлы йаңгыр йуқ. – *дөб.* Җөрәктә бер чытлы май да қалмаган, диделәр бырачлар. – *т.кам.-крш.*

**ЧЫТЛЫҚ I** *мам.* **1.** к.: **чылғый II, 1**. Безнең қодағый чытлығрақ кешул, иренмий эшкә; **2.** тегендә-монда тыгыла торган, кызыксына торган (интересующийся всем; человек, который везде сует нос). Балалары чытлық та инде, кермәгән тишекләре, қағылмаган әйберләре җуқ.

**ЧЫТЛЫҚ II** *минз.* көяз, матур киенергә әвәс (щегольской, форсистый, любитель красиво одеваться). Алар бик чытлық булган, түшләрендә дә бар ыйы тәңкәдән тезелгән (бизәнү әйбере), итәгенә дә тәңкә тегәләр ийе.

**ЧЫТНЫЙ** *мам.* чын, бик (совершенно, очень); чаг.: **чиқылдаған 1**. Yde бидәкле, үde чытный ақлы икән бу читсы.

**ЧЫТНЫМ** *мам.* к.: **чытлы II**. Атна буйы бер чытным да йоқламадым. Бер чытным да су йуқ.

**ЧЫТЫ I** *минз.* к.: **мөргө**.

**ЧЫТЫ II: чыты ақ** *мам.* бик ак, ап-ак (белый-пребелый). Чыты ақ алйапқычым тора әле.

**ЧЫТЫР I 1.** *бгрс., т.кам.-крш.* куаклык, вак агачлык (кустарник); чаг.: **чawыл; чаука**. Мында җир-су йахшы булған, чытырлар күб ийе, безне күмәрлек. – *бгрс.*; **2.** *шрл.* чыбык-чабык (хворост). Утын бездә бик сирәк, виршинадыр, чытырдыр йагасын тизәк йанында; **3.** *перм.* ыбыр-чыбыр (малый, маленький – о детях). Барың, барың, чытыр кәмер. Чытыр булып җөрисең дип уланнарға әйтәләр, урмандағы чытырларға ушатып; **4.** *бөре.* коры чыршы ботагы (сухие ветки ели).

**чытыр арба** *минз.* чыбыктан үргән әрҗәле арба – печән ташу өчен (телега с плетёным коробом – для сена и т.п.). Чытыр арбаға төйәп илтеп саттым йасаган чабаталарын.

**чытыр утын** *минз., стрл.* к.: **чытыр-чыбык**. Мескен бала, чытыр утын күтәреп қайта. – *минз.*

**ЧЫТЫР II: чытыр ак** *бәр.* к.: **чыты II: чыты ак**. Чытыр ағы көмөш шикелле булыр ыйы белә-зекнен, сарысы алтын җүгертелгәнмә.

**чытыр йаңгал** *клд.* чеп-чи ялган (совершенная ложь). Чытыр йаңгалны сүләргә.

**чытыр надан** *клд.* чеп-чи надан (настоящий невежда). Чытыр надан иде, уки белми иде.

**ЧЫТЫР III** *брб.д.* бер дә, аз гына да, кечкенә генә дә (нисколько). Чытыр қәлем йоқ.

**ЧЫТЫРАЙУ 1.** *дөб.* к.: **чирайу**. Чытырайа башласағыз, ишекне йабырсыз, эсселәнә башласағыз, ачырсыз; **2.** *перм.* көйсезләну, кәефсезләну (капризничать, быть не в духе); чаг.: **ныңғылдау**. Чытырайып торайым әле йықлаб алғач. Бала-чаға җылый бит чытырайып, оло кеше инде эчсә чытырайа.

**ЧЫТЫРЛЫҚ** *т.кам.-крш.* к.: **чытыр I, 1**. Чытырлық чикләwеге буладыр ыйы.

**ЧЫТЫРМА** *хвл.* кап-караңғы (темным-темно). Чытырма иде, утлары йанмаган.

**ЧЫТЫРМАҚЛЫ** *перм.* кытыршы (шершавый). Римин чытырмақлы була.

**ЧЫТЫРМАН: чытырман салқын** *трх.* бик көчле салкын, нык салкын, кышкы челлә (сильный мороз, пора самых сильных зимних морозов). Йарты қышта булса чытырман салқын. Чытырман салқында җигеп чыгып китәбез бит ул сыйырны.

**ЧЫТЫРМАНЛЫ'** *кас.* куаклык (кустарник).

**ЧЫТЫРТ: чытырт иткән** *хвл.* өр-яңа, шәп, яшь, таза (свежий, хорошо сохранившийся).

**ЧЫТЫР-ЧЫБЫҚ** *мам.* чыбык-чабык (хворост). Сикердем дә чытыр-чыбық арасына барып йығылдым.

**ЧЫТЫУ** *кузн.* куркыну, курку (трусить, робеть). Мин чытыйм тотынсам. Машинка белән ул аман да булса чытый.

**ЧЫХЫМ** *чпр.* казан татарына, *ч*-лаштырып сөйләүче кешегә карата әйтелә торган сүз (слово, употребляемое мишарями по отношению к казанским татарам). Кызым, ничек тә өрәнеп кат′ чыхымца сүләргә, димен. Чыхым Алиме катны чылаштырып сүли, шуннан балаларына чыхым кушаматы биргәннәр.

**ЧЫХЫМЛАНЫП** *трх.* *ч*-лаштырып, «ч» авазы белән – сөйләү турында (чокая, говорить, употребляя звук «ч», напр., вместо мишарского «ц»). Монда берәзрик кенә чыхымланып сүлиләр, шырланып сүлиләр.

**ЧЫЧАЛАҚ** *твр., брб.д.*, **ЧЫЧАЛЧЫҚ** *брб.д.* к.: **бармақ: гөлчәчәк бармақ**. Чычалақ пармағым сынты. – *твр.* Чычалчық пармақ қайсына төшә, ансы сиңа, тийән. – *брб.д.*

**ЧЫЧЫЛАУ** *карс.* чәрелдәү (визжать). Кызы бер затсыз, йери шалай чычылап урамда пажарда.

**ЧЫШКАН** *мәл.* к.: **кийек I, 3**. Айу, бүре, чабата, пич астында тик йата, аны чышканнар тарта (*әйтем*).

**ЧЫШНАУ** *тмн.* чыжлау (шипеть). Муча ташы чышный, су сиптем.

# Ш

**ША** *туб.-ирт.д.* теге (тот, та, то).

**ша йақта** *туб.-ирт.д.* тегендә (там).

**ШАБАҒАЧ** [*рус.* цеп + агач] *бөре., блт.* к.: **чип I**.

**ШАБАҚ** *әстр.* корбан балык (лещ).

**ШАБАЛА I** [*рус.* шабала] **1.** *нгб.-крш., эчк.* к.: **чабала**. Шабаланы бир күмер салғалы. – *эчк.* Шабала күмер алырға уңай ул, көле аста қала, күмере генә өстә була. – *нгб.-крш.*; **2.** *минз.* к.: **қарлау**.

**ШАБАЛА II** *себ.* кашык (ложка). Кинчәк кергәндә шабала сугып торатылар. – *тбл.*

**шабала борын** *себ.* үрдәкнең бер төре (уткасоксун).

**ШАБАЛА-ҚЫРМАЙАҚ** *төм.* савыт-саба (всякая посуда). Килен шабала-қырмайақ йуwаты, қоймақ қойаты.

**ШАБАЛКА** [*рус.*] *нокр., глз.* к.: **багырча**. Қызалдычыларны кейәү шабалка белән касага (ысла) сала-сала сыйлап йөрей. Метик кени, бер шабалка ғына сал. Шабалканы алып бир әле. – *нокр.* Шабалка белен аш айыра талиркага. – *глз.*

**ШАБОРТ: шаборт су булу** *мам.* к.: **шәбәрү**. Күлмәкләре шаборт су булган.

**ШАБРА** [*рус.* шабура] *злт.* күрше (сосед). Тегеләре (малайлары) шабра инде, күршедә тыра.

**ШАБЫР I** *туб.-ирт.д.* чикмән (кафтан). Аның өстентә пула турап шабыр, турап чалбар.

**ШАБЫР II** *том.д.* юк-бар сүз сөйләүче (болтун, говорящий нелепости).

**ШАБЫРДАWЫҚ** *дөб.* шарлавык (перекат на реке). Шабырдawықта без қыйынмыйбыз инде, малайлар гына қыйыналар, без қурқабыз.

**ШАБЫРУ I** *том.д.* мактану (хвастаться).

**ШАБЫРУ II** *туб.-ирт.д.* кашык белән болгату (помешивать ложкой). Цайың қайнар пулса, шабырып сuwыт.

**ШАБЫРШЫ** *блт.* к.: **пәйеж**. Ашның шабыршысын җыйып алдым.

**ШАБЫРЫНУ** *туб.-ирт.д.* актарыну (рыться, копаться, ворошить).

**ШАБЫШЛЫ** *блт.* к.: **пәйеж**.

**ШАWА 1.** *минз., тмн., лмб., мәл., карс., хвл., стрл.* зур агач табак (большая деревянная чаша). Awылга шawалар китерәләр йармынкада. Борон бер шawа аш ашаган. – *тмн.* Шawа була иде зур симийәләрдә. Йукагачтан шawалар казыганнар. Минем бабай каандыр барыб алган иде бер шawа. Бер шawадан ашилар иде күбесе. – *лмб.*; **2.** *шрл., чст.* зур аш табагы (большая чаша для супа). Бер шawа кура әләге йыйып керттем. – *чст.*

**ШАВА I** *кузн., хвл.* к.: **табақ: чара табақ**. Кулларында шавалар, шаки баралар. Әнкай, ашың пешкән булса, Чыгарып куй шавага (*бор. җыр.*). – *кузн.* Бер шава аш ашап бетердем. – *хвл.*

**ШАВА II** *минз.* к.: **салак**.

**ШАWАЙ** [*рус.* шавить?] *злт.* к.: **чатай**. Ул шawай былды, аптырап тормады.

**ШАWАЛА** *саз.я.* к.: **шабала II**.

**көчхәнә шawала** *саз.я.* бал кашыгы (чайная ложка).

**олло шawала** *саз.я.* зур кашык, аш кашыгы (ложка для супа).

**ШАWЫЛДАУ** *хвл., каз.ар., м.-кар.*, **ШАВЫЛДАУ** *срг.* шаулау (шуметь). Урман шawылдый. – *хвл.* Шawылдатып кыңгырау белән киләтеләр. – *м.-кар.* Қамыш шawылдый. – *лш.*

**ШАГА 1.** *кузн.* сага (бита, боёк – в игре в бабки); чаг.: **пан; 2.** *лмб.* к.: **чашка II**. Шага ман куй самаварны. Ут йебәрергә шагалар кирәк.

**ШАҒАРАҚЛАУ** *твр.* шаркылдау, көлү (громко смеяться, хохотать). Мин әйтсәм, шағарақлап торып көләләр.

**ШАҒЫР I** *туб.-ирт.д., эчк.* өлгермәгән, пешеп җитмәгән (недозрелый, неспелый). Цейә шагыр игән. – *тбл.* Әле җиләк шағыр қый. Шоморт шағыр әле. – *эчк.*

**ШАҒЫР II** *туб.-ирт.д.* буяу (краска). Шагырым бар, пер-ике генә кила йетмәйте.

**шағыр күз** *туб.-ирт.д.* чагыр күз, зәңгәр күз (пёстроглазый, голубоглазый).

**шағыр күк** *туб.-ирт.д.* ачык зәңгәр (светло-голубой).

**ШАҒЫРЫЙ: шағырый туңу** *том.д.* шакырдап кату, туңу (крепко замёрзнуть).

**ШАДА-ПОДА** *брб.д.* төерле (бугорчатый).

**ШАДРА** *перм., каз.ар.-крш.* сөлгегә киселә торган шадралы ак материя (вафельная ткань для полотенец). Бер митырлы шадра бирдем. – *перм.* Ум митыр шадра апқайтқан, маңа бир, дим, бистәрләрең күп бит, дим. Җегерме митыр шадра апқайтты бистәрлек. – *каз.ар.-крш.*

**ШАДРАЙУ** [*фарс.* + *афф.* -айу] *тмн.*, **ШАД(Ы)-РАЙУ** *кузн., баст.* шатлану (радоваться). Шадрайганнармы тапканга? – *тмн.* Шад(ы)райып уйнап-келеп жерибез ийе кен буйына. – *баст.*

**ШАДЫР** [*фарс.*] *миш.д., кас., глз.* шат, шат күңелле; кәефле (весёлый, жизнерадостный, в хорошем настроении). Шадыр кеше ул, гел көлдерә. – *хвл.* Йаңгырлар күп булды, халык шадыр. Бик алар йывашлар иде, бик шадырлар. – *кузн.* Мин шадыр кеше, хмури тегел. Бик шадыр карчык. – *чст.* Күңел шадыр булу белән кинуга барам. – *глз.* Анда шадыр халы' би'. – *кас.*

**шадыр эчен** *глз.* күңеллелек өчен (для веселья). Туйда шадыр эчен буза куйабыз кодаларга.

**ШАДЫРЛАНУ 1.** *кузн.* к.: **шадрайу**. Куwашнасын баскан чакта, Қулы камырланадыр. Кыз кун'ына кергән чакта, Йегет шадырланадыр (*хал. жыр.*); **2.** *т.кам.-крш.* тартыну, оялу (стесняться, смущаться). Әле монда шадырланып қына жырлау, сақланып қына.

**ШАЖҒЫРУ** *минз.*, **ШАЖГЫРУ** *стрл.* ажгыру (быть в состоянии крайней ярости, неистово набрасываться). Берүземә йылан шажгырып килә.

**ШАЖИН** [*рус.* сажень]: **шажин кисү** *кузн.* к.: **лашман: лашман тарту**. Урманда шажин кистек. Шажин кисеп кат'алар.

**ШАЙ I** [*рус.* чай] *нокр., глз., мам., минз., перм., к.-уф., злт.* ахыры, бугай, булса кирәк (должно быть, кажется, видимо). Қараңгы булды, дағы йаума кели, шай. – *нокр.* Ипигә йәшник иттеләр шай. – Быйыл жиләк күпме? – Бар шай, ахыры. – *глз.* Алар шунда менеп киткәннәр шай тағы. – *мам.* Син йоқлыйсың шай. – *минз.* Қарағай мәшкә, терке биләнкә икесе бер шай алар. – *перм.* Аңа утыз йәш шай. Анда шыршылық шай. – *к.-уф.* Сезнең йақта hаман шулай шай әле. Син «Туған йагым»ны белән шай. – *злт.*

**ШАЙ II 1.** *туб.-ирт.д.* кием-салым, бизәүбизәнү әйберләре (одежда, украшения, предметы косметики); **2.** *саз.я.* өй жиhазлары (обстановка, мебель); **3.** *тбл.* сбруй, дирбия (сбруя); **4.** *брб.д.* кирәк-ярак, корал (снаряжение, инструмент, орудие).

**ШАЙ III** *тара.* таман (впору). Күләшең шайма айагыңа?

**ШАЙ IV: шай жир** *м.-кар.* тигезлек, дала (равнина, степь).

**ШАЙ V** *күрш.* шулай (так). Айакларын шай сузган, утыра сыу анасы.

**ШАЙЛАНУ** *саз.я.* бизәнү, матур киенү, көязләнү (прихорашиваться). Киц wулса, шайланып пичуркаға китү.

**ШАЙЛАУ 1.** *брб.д.* бизәү (украшать). Атларны шайлайтылар; **2.** *төм., саз.я.* әзерләү (готовить). Қысның атасы шайлайты шай: шабаласын, цинийағын – пөтөрөсен; **3.** *себ.* төзәтү (исправлять).

**ШАЙЛАНЦЫҚ** *тбл.* көяз (щёголь, франт).

**ШАЙЛЫ 1.** *туб.-ирт.д.* матур киенгән (нарядный). Әттә-тә-тә, айақлары шайлы, пашлары шайлы; **2.** *тбл.* кулай, уңай (подходящий, удобный).

**шайлы ғылу** *твр.* харап итү (губить). Уй, шайлы гылғаннар игән!

**ш а й т а н** (чёрт):

**шайтан агач** *глз.* шайтан таягы (чертополох). Шайтан агачны олан бишегенә салабыз.

**шайтан ашық** *к.-уф.*, **шайтан бәкәйе, шайтан бәкмә**, *эчк.* к.: **ашық II, 2**. Шайтан ашығым awыртты. – *к.-уф.*

**шайтан булып йөрү** *срг.* к.: **бабай I: бабай булып жөрү**. Раштywада шайтан булып йөриләр, кас'ы рагалар куйа, кас'ы линталар куйа цәцәк кебек.

**шайтан дилбегәсе** *срг.* көзге пәрәвез, тожым (нити паутины, летающие осенью в воздухе).

**шайтан қарағат** *том.д.* мүк жиләге (клюква).

**шайтан қолақ** *әстр.* гөмбә (несъедобные грибы). Шайтан қолақ ашамыйбыз.

**шайтан қурқытқан** *тара.* чәнчү үләне (синеголовник).

**шайтан күпшә** *к.-уф.* ашарга ярамый торган үлән, көпшә (несъедобное растение). Сөрелмәгән жир күп, шайтан күпшә үсә йаланда.

**шайтан сийәге** *каз.ар.*, **шайтан сөйәге** *бәр.* к.: **ашық: II, 2**. Шайтан сийәгенә балта түтәсе тийеп киткәнийе, айаққа басып булмый.

**шайтан тубық** *эчк.* к.: **ашық: II, 2.**

**ШАЙТЫ** *төм.* шаять, ахрысы (вероятно, возможно).

**ШАЙЫ** *каз.ар., минз., тпк.* к.: **тике**. Ат шайы кеше. Тушы җылга шайы сакладым. Син кайчанга шайы эшлисең? Аның шайы кеше булама суң денйада, шының кәдәр йawыз. Аларын анда шайы менгерәселәре дә килми. Ойалмыйча кайтып та килгәлләр, кичкә шайы эшләргә җарамаганмы? Ырматиз дигән булалар, быйылга шайы ничек булмагандыр ул? – *дөб.* Шалканнарга шайы чәчәр ийек. Безнең белә берләшкәч, безнең шайы булдылар. – *минз.* Өстенә шайы сыгарып май салган. – *тпк.*

**ШАЙЫК 1.** *злт., туб.-ирт.д.* селәгәй, авыздан килгән күбек (слюна, пена изо рта). Шайыкларына хәтле йата ди айуның, кырмыска ойасын ашаганнан соң. – *злт.* Пер ала сыйыр которган, шайыкларын цоборып килеп утыраты. – *тара.*; **2.** *себ.* лайла (слизь).

**ШАЙЫКЛАУ** *тара.* кечкенә балаларның күкрәк япкычы (нагрудник для маленьких детей).

**ШАҚ I** *перм.* к.: **туқмақ I, 1**.

**ШАҚ II: шақ тишек** *перм.* мәгарә, тау тишеге (пещера).

**ШАҚ III** *перм.* к.: **бәзәр**. Паласларны шакълап суктым әле. Бер шақ суктым бүген, теге көннәрне унар шақ суктымый.

**ШАҚ IV** *тбл.* тагарак (корыто).

**ШАҚ V** *төм.* юынтык су (помои).

**ШАҚ VI: шақ қалац** *туб.-ирт.д.* келиндер (бублик).

**ШАҚА: айақ шақасы** *минз., бгрс.* к.: **ашық II, 2**.

**ШАҚАЙ I** *минз.* к.: **ашық II, 2**. Шақайыңа бәремен.

**шақай сөйәге** *минз.* мал аягының тез башы (коленная чашечка – у скотины).

**ШАҚАЙ II** *дөб.* телсез (немой). Аның атасы шақай булган, шақай Минзифасы, диләр.

**шақай булу** *дөб.* шаккату, гажәпләну (поражаться, изумляться). Көтмәгәндә кайтып кергәч, шақай булдым.

**ШАКАЙЛАНУ** *глз.* акылдан язу (потерять рассудок). Урманда йапа-йаңгызы йөрде дә шакайланды бер карчык.

**ШАҚАЙ-МАҚАЙ** *блт.* мәгънәсез, рәтсез (бестолковый, непутёвый). Шақай-мақай түгел алар үзләре, әйбәтләр. Күзләре дә шақай-мақай, курқыныч кеше.

**ШАКАЙУ** *мәл.* бик каты туңу, өшү (сильно мёрзнуть).

**ШАҚАРМА** *тпк.* к.: **қайырма I**. Шақарма башына килеп кенә карап торор ыйым.

**ШАҚАРУ** *минз., тпк.*, **ШАКАРУ** *стрл.* каеру (вывернуть, скрутить). Сыбыкны шақарып тороп йасыйсың шақарманы. – *тпк.*

**ШАҚЛЫ: шақлы тастымал** *перм.* асалап, аркау җепләрен төрледән куеп сугылган сөлге (полотенце, тканное закладным способом из разноцветных уточных ниток).

**ШАКМАЙ** *мәл.* к.: **қолақай**.

**ШАҚМАҚ I** *т.я.*, **ШАКМАК I** *чст.* кәтүк (катушка, шпулька). Ничәле шакмаклар бар икән? – *чст.* Ақ шақмақ бармы? Қара шақмақ бармы? Зәкийә апа, унны шақмақ җебе йуқ. – *к.т.*

**ШАҚМАҚ II** *нрл.*, **ШАКМАК II** *чст.* шакмаклап сугылган кечкенә тастымал (холщовая салфетка). Сawытларны шакмак белә себерәбез.

**ШАКМАК III** *мәл.* к.: **қолақай**.

**ШАҚМАРА** *мам.* к.: **чашка II**.

**ШАҚРАННАУ** *мам.* бозланып кату (оледенеть). Бишмәте шакраннаган.

**ШАҚТАЙ** *нгб.-крш.* тәртипле (аккуратный, в порядке). Синең өйөңдә бар җирең шақтай.

**ШАҚТАЙАҚ** *к.-уф.* уен исеме (название игры). Малайлар шақтайақ уйнарга чыгалар.

**ШАКУ** *лмб.* самоварга ягар өчен шакмак ясау (приготовить шашки для самовара). Урманнан китерә идек, вак кына шаки идек тә самuwар куйа идек.

**ШАКУЛ** *кузн.* к.: **чашка II**.

**ШАКШАКИ** *мәл.* балалар уены исеме (название детской игры).

**ШАҚШЫ** *каз.ар.* начар (плохой, скверный). Шақшы нәрсә ул арақы. – *блт.* Шақшы булды буйawыбыз, шарт-шырт җабыша. Ул көзән җыйыруны бик шақшы нәрсә диләр. – *лш.*

**ШАҚЫРАЙУ** *перм.* к.: **селәүләнү**.

**ШАҚЫРЫНУ** *перм.* карану, эзләнү (осматриваться вокруг себя, водить глазами).

**ШАЛ I** *нрл., т.я.-крш., карс., себ.* шул (тот).

**ШАЛ II: тәрәзә шалы** *бөре.* тәрәзә наличнигы (оконный наличник). Тәрәзә шалы йуг әле.

**ШАЛ III** *саз.я.* паралич. Шал тарыгыр! (Паралич суккыры!)

**ШАЛАWA** [*рус.* шалава] *лш.*, **ШАЛАВАЙ** *блт.* эчкерсез, гади (простой, доброжелательный). И ул ачык, шалawa кеше бик рәхәт бит. – *лш.* Нәгыймә шалawай гына хатын инде сөйләшергә. – *блт.*

**ШАЛАWAН** [*рус.* шалава] **1.** *каз.ар., минз.* к.: **шалawa**. Оло киленебез тагын шалawан шулай әтисе кебек. – *мам.* Бөтенөсе җараталар инде, шалawан бит ул бик. – *минз.*; **2.** *кмшл.* уенчак кеше (шутливый человек).

**ШАЛАВАР** *т.я.-крш., чпр.* чалбар (брюки).

**ШАЛАЙУ** *себ.* юләрләну (сходить с ума).

**ШАЛАМА 1.** *т.я.* к.: **алама-шалама**. Шалама кийем(ле) қәйерчеләр йуг инде. Шалама кийезне үзем җыйалмый қалам. – *к.т.*; **2.** *к.т.* к.: **сәлге 1**. Кит, шаламаларыңны селкемә монда; **3.** *т.я., чпр.* к.: **цәпе-цепе**. Бер шалама тawып сөрт шунда тәрәзәне. – *к.т.*; **4.** *дөб.* к.: **чырымта 1**.

**ШАЛАМАЛАНУ** *к.т.* к.: **амалану**. Өсте-башы wич шаламаланып беткән.

**ШАЛБАЙУ** *злт., саз.я.* **1.** к.: **самсырау**. Мин дә, карт та шалбайган инде. – *злт.*; **2.** *злт.* җыерылу (морщиться). Ойоқ шалбайган; **3.** *саз.я.* салыну, кыйшаю (обвиснуть, скривиться). Awысы шалбайып төшкән; **4.** *тара.* булдыксыз булу (быть беспомощным, растяпой).

**ШАЛБАР** *перм., т.кам.-крш., мам.* к.: **шалавар**. Дүрт шалбар алды. – *т.кам.-крш.*

**ШАЛБЫҚ** *том.д.* салынган (отвислый).

**шалбық awыс** *туб.-ирт.д.* кыйшык авыз (криворотый).

**ШАЛҒАМ 1.** *төм.* шалкан (репа); **2.** *брб.д.* гәрәнкә (брюква).

**қысыл шалғам** *төм.* чөгендер (свёкла).

**ШАЛГАМА I** *хвл.* коймада такталар кагылган

буй агач, арата колга (поперечина). Урагыңны ван′а шалгамага кыстыр.

**ШАЛГАМА II** *срг.* 1. к.: **уша I**. Шалгамаға басып мен пиц башына; 2. чыра (лучина, лучинка). Элек шалгама йандырып кызлар киц утыралар иде.

**ШАЛҒАН** *себ.* шалкан (репа). Йуwан қасан ман итне пешерәтеләр. Ит пешсә, шалған турап салатлар. – *тара.*

**ШАЛДЫР** *минз.*, **ШАЛДЫРАWЫК** *чст.* к.: **чолдыр I**. Қайсы шалдыр таққан атына. – *минз.*

**шалдырawық үлән** *эчк.* к.: **печин I: ақча печин 2**.

**ШАЛДЫРАВЫК** *лмб.* кыңгырау (колокольчик). Адларга шалдыравыклар куйганнар, йеслекләр белән.

**ШАЛҚА** *бәр., дөб.* 1. к.: **сыпқа 2**. Бу су шалқа бит, эчәрлек түгел. – *бәр.* 2. к.: **салак**. Шалқа булып җөрмә, чичта җөрө, дим мин аңғар. – *дөб.*

**шалқан** *урт.д.* шалкан (репа):

**сыйыр шалқан** *перм.* турнепс.

**шалқан бичин** *к.-уф.* пичтә томалап пешерелгән шалкан (печёная репа). Шалқан бичин ашап үстек.

**ШАЛМИР** [*рус.* шарнир] *шрл.* күгән (дверная петля).

**ШАЛТАЙУ** *себ.* кату (становиться жёстким, твердеть).

**ШАЛТАЙЫП: шалтайып тору** *эчк.* тик тору, эшсез тору (стоять без дела). Безнең кебек шалтайып басып тормас инде.

**ШАЛТЫР** *злт.* к.: **телазар**. Ул бисә сүзгә бик шалтыр инде.

**ШАЛТЫРAWЫК** *чпр.*, **ШАЛТЫРAWЫҚ** *минз.* к.: **чолдор I**.

**ШАЛТЫРАҚ** *брб.д.* колга (жердь).

**ШАЛТЫРАТЫП: айақ шалтыратып** *перм.* яланаяк, оексыз (на босу ногу, без чулок). Хатын-қызлар да җоқа чөлкә киде, айақ шалтыратып җөрмәде.

**ШАЛТЫРМАҚ** *перм.* шакылдавык (колотушка, трещотка).

**ШАЛТЫРМАТУ** *перм.* шакылдату (стучать, колотить). Сөрән суққанда, урам қарawыллағанда шалтырмақ шалтырматалар.

**ШАМ** *төм.* шәм (свеча). Ақ шам тип қысның ишегенә тиңентен апкилеп қуйатлар кейәүне.

**ШАМА** *минз., тпк., бгрс., әстр., эчк., мәл., тара., том.д.* чәй чүбе (остатки заваренного чая; чаинки). Чәй шамасымы, чебенме? – *минз.* Шамалы булды әле сиңа сәй. – *тпк.* Чәй шамасымы ул өскә чыққан, шуны алып қалсаң, бәхет өскә чыға, диләр. – *бгрс.* Чәйнең шамасы ғына қалған. – *эчк.* Чәйнең шамасы торды: кунак килер. – *мәл.*

**ШАМАҚАЙ** *т.кам.-крш.* к.: **сөрми 1**. Шамақай белән қызыл суққан күлмәгем бар ыйы.

**ШАМАҚЫ** *кмшл.* к.: **сөрми 1**. Шамақы қарағыз йуқмы, ә?

**ШАМАТУ** *брб.д.* кисәтү (предупредить). Шаматты әрен: анда парзаң, ицпәгел арағы!

**ШАМБА** *лш.*, **ШАМБЫ** *перм.* к.: **цурағай**.

**ШАМҒАНУ** *әстр.* сүгенү, ачулану (ругаться, злиться). Албасты киләйәк булса шамганмаға, ачуланмаға кәрәк, диде, шуннан ул айырылып қалмаға тийеш икән.

**ШАМКАЙ: шамкай башмак** *чст.* юкә башмак (лыковые башмаки). Су карауга шамкай башмак кийеп бардым бер йылны.

**ШАМТА** *перм.* к.: **чырымта 1**. Сез шамта белә ышқынамсыз?

**ШАМЫҚАЙ** *трх.* к.: **қурқылық**. Шамықай йасап қуйдым, тегеннән қазлар тешә.

**ШАНГИ** [*рус.*] *нокр., глз.* шәңгә (шаньга).

**йумал** [*удм.*] **шанги** *нокр.* төче камырдан пешерелгән шәңгә (шаньга из пресного теста). Ачытминча пешергән қамырдан йумал шанги була.

**курайләк шанги** *глз.* кура җиләге белән пешерелгән шәңгә (шаньга с малиной).

**т′ап-т′ап шанги** *глз.* ачы камырдан пешерелгән шәңгә (шаньга из кислого теста). Т′ап-т′ап шанги пешерәсин, камыр басасын, әwәлисин. Кабарып менгәчин, бәрәңге түwеп, сөттә изеп, йоморка сытып камыр өстенә саласин.

**шоморт шан′ги** *глз.* шомырт белән пешерелгән шәңгә (шаньга с черёмухой). Ачытминча пешергән қамырдан йумал шоморт шан′ги була.

**ШАНДЫҚ** *перм.* ышаныч (доверие, вера). Пастайанны ачық булмағас, лафкаға шандық йуқ.

**ШАНДЫРАҚ** *том.д.* кыңгырау (колокольчик). Киленне йақшы атлар, шандырақлар белән күчерделәр. Шандырақлары күп була атларда. – *клм.*

**ШАНҚЫЙ** *нрл.* к.: **шақай II**.

**ШАНЧАК** *т.я.-крш.* шулчак, шул чакта (тогда, в то время). Шанчак дәдәсе зур капканы ачып җибәрә, килен утырган алаша урам йакка чыгып китә.

**ШАНЫЛТАУ** *брб.д.* ялап эчү (лакать). Төннә йоқлап йатса, лаплап шанылтатып итләр қасантағы сөтни ичкәнгә ойанып китәте.

**ШАҢҒЫРAWЫҚ** *том.д.*, **ШАҢҒЫРАҚ** *туб.-урт.д.* кыңгырау (колокольчик). Шаңғырawықлары бар иде адларда. – *яүшт.*

**ШАҢҒЫРАУ** *каз.ар.*, **ШАҢГЫРАУ** *стрл.* яңгырау (звучать, звенеть). Тимер қазан қуйалар, шаңғырап тора торған, шуңа суғалар, сәгәт шул булған әwәле. – *дөб.* Пар кыңгырау әллә кайа шаңгырап тора инде. – *стрл.*

**ШАҢГЫРТУ** *чст.-крш.* шыгырдату (скрипеть, производить скрип). Майларны да чапсаң син каты чап, Чана үрәчәләрен шаңгыртып (*хал. җыр.*).

**ШАҢКАЙ** *чст.* түбән сортлы ялтыравыксыз резин галош (галоши, сделанные из резины низкого сорта). Эшкә барганда шаңкай кисәң дә йарар.

**ШАҢҚЫРТАҚ** *туб.-урт.д.* шалтыравык (побрякушка).

**ШАҢҚЫРТАУ** *туб.-урт.д.* шалтырау (бренчать).

**ШАҢЛАУ** *сазл.* колак чыңлау (звенеть в ушах).

**ШАҢНАУ** *минз.* тибү (пнуть). Берәрне шаңнап җибәремен. Ат қуш айақлап шаңнаган ыйы, тәртәне сындырды.

**ШАҢРАУ** *брб.д.* к.: **шаңғырау**.

**ШАПА I** *перм.* к.: **салак**. Шапа торганға қазаннары ашлы күгә була, қашайағы шул күгә утыра. Элек шапа булды қый халық.

**ШАПА II: шапа awызлы** *шрл.* зур авызлы (большеротый). Безнең кодагыйларның балалары бары да шапа awызлы.

**ШАПАЙ: шапай шабу** *тара.* к.: **чәбекәй: чәбекәй итү**. Шапай шабатлар питкүремтә.

**ШАПАЛА** *перм.* к.: **қарлау 1.**

**ШАПАЛАҚ** *мәл.* алдын-артын уйламыйча сөйләүче кеше (человек, говорящий необдуманно).

**ШАПАЛАҚ 1.** *трх.* к.: **ләпәмә 1.** Шапалақны Илһам сындырып чығып китте; **2.** *минз.* к.: **чолдор II, 1.**

**шапалақ бирү** *т.я.*, **шапалак бирү** *чпр.* кыйнау, сугу (бить, ударить). Әһе, әнийең шапалақ бирдеме? – *к.т.*

**ШАПАЛАҚЛАНУ** *перм.* пычрану, шапшаклану (загрязниться, испачкаться). Қулыңны жуwып исең китереп йөр, шапалақланып йөрмә.

**ШАПАЛАҚЛАТУ** *бгрс.* кәҗә мамыгын махсус таракларда тарау, аялау (расчёсывание козьего пуха на специальных гребёнках). Шапалақлатқач, дебет әйбәт эрләнә, wатылмый, озон була.

**ШАПАЛДАК** *срг.* к.: **йунгы.**

**ШАПАМА** *шрл.* киемдәге кнопка (кнопка на одежде).

**ШАПАПАЙ: шапанай қагу** *әстр.* к.: **чәбекәй: чәбекәй итү**. Җиңгәләр туйда йастық талаш йасайлар (шаярып), без җиңдек, дип шапанай қағалар.

**ШАПАТЛАУ** *тара.* яңакка сугу (дать пощёчину).

**ШАПИ** *кузн.* өй эчендә кия торган туфлиләр (домашние туфли). Вас'муй мартка сеңелем бирде шапилар.

**ШАПКА** [*рус.* шапка] *карс., бөре.* к.: **бәбкә I, 1.** Шапкаларга куйа идек ун көлтәне. – *карс.* Арыш көлтәсеннән шапка дип туғыз көлтәне утыртасың да өстенә берне қаплыйсың. – *бөре.*

**ШАПКАЙ** *т.я.-крш.* к.: **маман 1.** Минен ирем шапкай.

**ШАПКЫ** [*рус.* шапка] *бөре.* к.: **бәбкә I, 1.**

**ШАПҚЫТУ** *перм.* **1.** шап иттерү (шлёпнуть, хлопнуть). Төшсә, айағың бар, басарсың шапқытып; **2.** чөмерү, күп эчү (пить много, хлестать). Теге дә чәйне бик йарата, шапқытып қына тора wыл, муча-палан кереп чыкса.

**ШАПТАЛАК** *шрл.* к.: **чәпәләк 2.** Әле чыкты шапталак, шап-шап-шап иттереп сугасын.

**ШАПТЫРМАҚ** *злт.* ерганак (промоина, рытвина). Киң соқор бар, шыңардан шаптырмақ аға йаз көне.

**ШАП-ШАҚАЛ** *минз.*, **ШАП-ШАКАЛ** *стрл.* сабырсыз, түземсез (нетерпеливый, несдержанный); чаг.: **чучак**. Шап-шақал кебек сикереп тормый үзе, басыңқы ғына. – *минз.*

**ШАП-ШАҚТЫЙ** *минз.*, **ШАП-ШАКТЫЙ** *стрл., хвл.* к.: **латлы 2.** Әнисен апкайтканнар бал'ныстан, шап-шактый гына утыра. – *стрл.*

**ШАПЫҚ** *тбл.* шапшак (неряшливый).

**ШАПЫР** *срг.* к.: **митла**. Шапыр белән себерәбез азбарны.

**ШАПЫРТМАҚ** *минз.*, **ШАПЫРТМАК** *стрл.* к.: **қауға I**. Үзе шапыртмак та инде бу кеше. – *стрл.*

**ШАПЫРУ** *т.я.* к.: **очору**. Госманныкылар шапырғаннар, күпме генә чыға, ди. Киндер орлығын шапырмыйча ғына апқайталар. Бабай тирмәнгә бара, ахры, арыш шапыра. Җил бик қуwәт түгел, арыш шапырырға әйбәт.

**ШАПЫРЫШЛАП** *минз.* к.: **қыйалап 1.** Күdикмәкне басасың, тоқмач кебек шапырышлап кисәсең.

**ШАР I** *лмб.* к.: **шақмақ I**. Кара шар йебе кирәг иде, синдә йукмы?

**ШАР II 1.** *эчк.* урман (лес); **2.** *тбл., твр.* кечкенә таллык (ивняк, ивовая рощица); **3.** *минз.* к.: **горда**. Пирwый тырмадық, шарын wаттык.

**ШАР III** *злт.* к.: **суламык**. Йеләклеккә кергәнсе шар үтәсе бар, сусылырақ йер. Шар қайыны, шар талы.

**ШАРА I** *әстр.* чара табак (большое блюдо). Шара-шара бүрәк пешерә бездә туйға.

**ШАРА II: шара тайақ** *мам., дөб.* к.: **кәшә.**

**шара уйыны** *мам.* шар сугу уены (игра в мяч, шары).

**ШАРАВАР** *лмб.* к.: **шалавар**. Сырган шаравар.

**ШАРАҚ I: шарақ ағаң** *эчк.* шома, ботаксыз агач (гладкое, без ветвей дерево).

**ШАРАҚ II** *тбл., тара.* тиз ярылучан (ломкий, хрупкий).

**ШАРАҚА** *нокр.* к.: **йаңақ II**. Шарақа ашап утырып, син қоймақ ашамапсин.

**ШАРАЛАНУ: күз шаралану** *лш.* шар булу, зур итеп ачылу – күзләр турында (широко открываться – о глазах). Бүген тағы күз шараланған, тәки жоқо жук.

**ШАРАЛЫҚ** *әстр.* күчтәнәч (гостинец). Шаралық алып килгән.

**ШАРАМТА** *перм.* к.: **чырымта 1.**

**ШАРАШКА** *каз.ар.-крш.* чыбык-чабык (хворост). Нихадәре шарашка бар чәй қуйарға, шақмақ итеп чабаң да.

**ШАРҒЫ** *брб.д.* усал, әшәке (злой, дурной).

**ШАРҒЫЛТЫҚ** *тара.* мактанчык (хвастун).

**ШАРЛАУ** *тбл.* акшарлау, агарту (белить). Иртәгә пәйрәм гөн қуй, мейецне шарлап алайын.

**ШАРЛАWЫҚ** *тара.* гөрләвек (ручей).

**ШАР-МАР** *злт.* ачык күңелле, беркатлы (радушный, простодушный). Роза апа шар-мар инде ул, ис уйламый бернәрсә дә. Аның бер дошманы да йуқ, шар да мар.

**ШАРПАТСЫЗ** *перм.* чамадан тыш (чересчур, слишком). Шарпатсыз зур бүрек кийеп йөри.

**ШАРПУ** *әстр.* имләп ташлана торган әйбер (вещь, которую заговаривают и бросают). Менә йомырқа, тоз, чәй, көл, күмер, қадақ алалар да шарпу дип, башыңнан-күзеңнән, билеңнән әйләндереп, чәршәмбе көнне ташлыйлар.

**шарпу ташлаучы** *әстр.* имче (знахарь). Шарпу ташлаучы әби була.

**ШАРПУЛАУ** *әстр.* имнәү (лечить знахарским способом). Қайсы кеше озақ awырый. Ул кешене шарпулап, өстендәге күлмәген чишеп, бер аулақ жиргә күмәләр.

**ШАРТ 1.** *т.кам.-крш.* к.: **шадыр**. Үзе шарт

инде, қыстау гына җитмәгән; **2.** *мам.* к.: **алчак**. Шарт кеше ул, сөйләп көлеп кенә тора. Шарт күңелле кешеләр.

**ШАРТАЙАҚ** *трх.*, **ШАРТАЙАК** *чст., мәл.* к.: **кәшә**.

**ШАРТЛАВЫК** *чст.* к.: **печин I: акча печин 2**.

**ШАРТЛАМА** *перм., злт., к.-уф.* җир җиләге (клубника). Үткән җыл тугыз кила кароттым шартламаны. Әрләп шартлам(а) ашап утыра иде. Көннәр матурланса, шартламалар пешә башлар. – *перм.* Шартлама күп была безнең урманда, көн дә бер бидерә йыйа торган ыйык. – *злт.* Шартлама пешеп килә. – *к.-уф.*

**шартлама йабалак** *перм.* к.: **керфек I, 2**. Йабалакълы була кый шартлама, арчыйбыз да кайнатабыз.

**шартлама печин** *перм.* шапылдавык (хлопушка).

**ШАРТЛАМЫҚ** *лш.* к.: **шартлама: шартлама печин**.

**ШАРТЛЫҚ** *каз.ар.-крш.* шатлык (радость). Бу синең шартлығыңмы, ди.

**ШАРУК** *кузн.* кечкенә агач шар (маленький деревянный шарик). Бак, ничек шаругым әләнә.

**шаршау** *урт.д.* чаршау (занавес):

**тәрәзә шаршаwы** *бөре.* к.: **корма 1**. Тәрәзә шаршаwын теккән.

**ШАРЫЛДАВЫК** *срг., чпр.* к.: **шабырдаwык**.

**ШАТАЛАҚ I 1.** *каз. ар., перм., злт., минз., бөре.*, **ШАТАЛАК** *стрл., мәл.* кыю, чая (бойкий, отчаянный). Шаталақ қатын теләсә нишләп утыра диген. – *дөб.* Шаталақ күк икәү қызлар килгәннәр. – *перм.* Сәйдә апаның қызы бик үткен, шулқәдәр шаталақ қыз инде. Бер шаталақ әбейдә сәй эсеп сықтым. – *злт.* Уйынчак булды кирәкмәгән, шаталак булды кирәкмәгән. – *стрл.* Шаталақ кеше қартаймый. – *бөре.* Бу катын бик шаталак. – *мәл.*; **2.** *минз.* өстән уйлаучан (несерьёзный, легкомысленный). Бу бигрәк шаталақ инде, йәш шул әле, йәшлек белән берни дә уйламый.

**ШАТАЛАҚ II** *минз.* кыңгырау (колокол); чаг.: **бутала**.

**ШАТАЛАУ** [*рус.* + *афф.* -лау] *нокр., кргл.* кыекмыек атлау (шагать вкривь и вкось, идти пошатываясь). Шаталап-шаталап кетте. – *нокр.* Шаталаған теге, урамға төшеп барайы. – *кргл.*

**ШАТИБӘТ** *брб.д.* Нәүрүз бәйрәмендә әйтелә торган сүз (слово, произносимое в дни празднования Навруза). Шатибәт, шатибәт, Нәүрүз мөбарәкбад.

**ШАТИРӘТ** [*гар.*] *т.я.-крш.* ахирәт дус (задушевная, близкая подруга). Анан ун′ибыз ый урамга чыккистан: шатирәт, кем кирәк, Анна матур кыз кирәк, ди.

**ШАТҚУ, ШАТҚЫТУ 1.** *перм.* к.: **шалтырмату**. Бабушка әйтә, син, ти, мәсә шатқыйсың тей. Артаба бидрә шатқытым да китте бүре; **2.** *туб.-ирт.д.* шартлату (производить треск).

**ШАТЛАНКӘ** [*рус.* шотландка] *әстр.* шакмаклы тукыма (ткань в клетку – шотландка). Әзилдә қодағыйларға шатланкә бирәйделәр, ә болай халыққа ыштапел бирәделәр.

**ШАТНАТҚЫЧ** *лмб.* шапылдавык (хлопушка).

**ШАТРАҚ** *тара.* күңелле, шатлыклы (радостный, весёлый). Шатрақ көн күреп торам.

**ШАТРУН: шатрун йапқан** *трх.* дүрт кыеклы итеп япкан (покрытый шатровой крышей). Өйләре дә өйләре, Шатрун йапқан түбәле (*хал. җыр.*).

**ШАТУН** [*рус.*] *злт.* шук, шаян (шалун, озорной).

**ШАТЫР** *сазя.* эре бөртекле (крупнозернистый).

**ШАУ I** *чст.* к.: **сийау**.

**ШАУ II** *каз.ар., т.я., кргл.* тышау (путы). Айақлар шауда бит әле үрдәкләр чыққач. – *мам.* Бусы шау, атның айағын бәйли торған. – *трх.* Шау белән атны шаулыйбыз. – *кргл.*

**шау кисү** *дөб., т.кам.-крш.* озак тәпи йөрмәгән баланы юкә бау белән бәйләп, шуны кисеп җибәрү (знахарский метод лечения ребёнка, долго не начинающего ходить). Баланың айағын йүкә бау белән бәйлиләр дә арттан килеп пысақ белән кисәләр: «Шау-шау-шау, баланың шаwын кисәм, шаwын кисәм», – дип, айаг арасыннан кисәләр. «Ишшәдрук» дип әйтәләр, шаwын кискәндә. Әнә-әнә атлый дип қарап торадырыйық инде. – *дөб.* Шау кисү диләр, бала беренче атлап китә бит. Шул атлап киткәндә, шау кисәм дип, пычақ белән сызарга қушқаннар айақ баwын. – *т.кам.-крш.*

**ШАУ III** *кмшл., каз.ар.* к.: **ару II, 5**. Мамық алып килгән, шау қыл, сигез сум. – *кмшл.*

**шау кайнар су** *мәл., хвл.*, **шау қайнар су** *т.я.* кап-кайнар су (кипяток, очень горячая вода). Шау кайнар су белән йу кашык-айакларны. – *хвл.*

**ШАУ IV: шау җару** *блт.* шау-гөр килү (шуметь; быть в приподнятом настроении). Биг ачыг ыйы, шау җарып җөри ийе.

**ШАУКА** [*рус.* шавка] *шрл.* кечкенә эт, мүчкәй (маленькая собачка, моська).

**ШАУКЫМ** *кузн.*, **ШАУКЫН** *чпр.* паралич. Хәсәнне шаукым суккан. Кырсаклы багытта әнәйне шаукын суга.

**ШАУЛАУ** *т.я., бгрс., төм.* тышаулау (надеть путы). Атны шаулап җибәрәләр. – *трх.* Күп тә уйламадым, байагы атны шауладым. – *бгрс.* Шаулаган атны күреп қала. – *төм.*

**ШАУШАҚ** *тара.* боз кисәге (льдина).

**ШАУШАҚЛАНУ I** *трх.* к.: **қуқыртлану**.

**ШАУШАҚЛАНУ II** *т.я.* суның өсте ката башлау (замерзание поверхности воды в реке). Зөйә йылғасы шаушақланған, тиздән арқылы чығып булыр. – *к.т.*

**ШАУШАУ 1.** *сазя.* какшау (расшатываться). Өстәл шаушап китте; **2.** *себ.* таркалу, җимерелү (распадаться, разрушаться).

**ШАУШЫР: шаушыр таша** *төм.* шаулый (шумит). Қарурманда қамыш башы, шаушыр таша, шаушыр таша.

**ШАФХА** [*рус.* шапка] *сазя.* бүрек (шапка).

**ШАШ** *әстр.* чәч (волосы). Җиңгәләре кийендергән, шашын үргән, тастарын кигән.

**ШАШБАУ** *әстр.* чәчүргеч (лента, тесьма для плетения волос). Шашбау салған қызлар шашның очона. Шаш төбөндә төплекле шашбау булған.

**ШӘБӘЙҮ** *перм., каз.ар.* к.: **киберләнү**. Кәлимулланы председатель′ итеп сайлағач шәбәйде шәй. – *перм.* Персидәтел бик шәбәйеп киткән әле. – *дөб.*

**ШӘБӘЛӘ** *себ.* кашык (ложка).

**ШӘБӘЛӘЙ** *дөб.* к.: **шапи**. Шәбәләй генә ки дә йөгер, көтү қайта.

**ШӘБӘН** *чст.* к.: **шәбен**. Фәйрүзә, шәбәнеңне җийып куй.

**ШӘБӘРҮ** *мам., минз., кмшл., чст.-крш., т.кам.-крш.* манма су булу, бик нык чылану (измокнуть насквозь); чаг.: **йебенү**. Йаңғырда шәбәреп қайтты. – *минз.* Тawықлар, мескеннәр, йаңғыр астында қалып шәбәргәннәр. – *кмшл.* Көнөзон килә-без, шәбәрдек, айакта чабата булган ул чакта. – *чст.-крш.* Бөтөн awыл тулып су сибешәбез шәбәргәнче, қорман чалған көнне ашағачын су сибешә-без, шәбәреп қайтабыз. – *т.кам.-крш.*

**ШӘБЕН** *каз.ар., бәр., т.я., минз., чст., мәл.* күбә (ворох скошенного сена и т.п.). Шәбен итеп қуйабыз башта, шәбеннән чүмәләгә өйәләр, ат белән тарттыралар эскерткә. – *дөб.* Қабартқач, шәбенгә җыйабыз. – *бәр.* Борчақ, җәшел көйө чапсаң да, шәбеннәрдә кибә, кибәнгә салырлық була ул аннары. – *к.т.* Ике пакусны җыйғач шәбен була. – *трх.* Шәбеннәрегез тигез булсын. Бырцак шәбенен атка тийәп киттек. Кецкенә шәбен йасап үwеп куйабыз. – *чст.* Пакусны шәбен йасап әләнә. – *мәл.*

**ШӘБЕНЛӘҮ** *каз.ар., бәр.* к.: **күтәрәмнәү**. Печәнне пакуска чабалар, кипкәч шәбенлиләр, чүмәлә итеп өйәләр. – *дөб.* Печән кипкәч шәбенлиләр. – *бәр.*

**ШӘБЕРЕҢҮ** *кргл.* чылану (мокнуть, вымачиваться). Йаңғыр астында қалғаннар, шәберенеп қайтқаннар.

**ШӘБЕРЛЕК** *мам., минз.* к.: **пейеж**.

**ШӘБЕРШЕК** *мам.* к.: **пәйеж**.

**ШӘБЕН** *каз.ар., перм.* к.: **шәбен**.

**ШӘГЕЛ** *төм., брб.д.* кыяфәт (внешность). Шәгелләре тә әйтеп тора параба тип. – *брб.д.*

**ШӘЙ I** *крш.* иш, тиң (пара, ровня). Кит монан, безнең шәй булмадың син.

**ШӘЙ II** *минз., злт.* к.: **шай**. Былтыр бу қыз түгел ийе шәй. Арқа сугышны йазмадық шәй әле.

**ШӘЙГӘ** *тбл., том.д.* кечкенә кисмәк (кадушка).

**ШӘЙГӘН** *срг.* к.: **пәйеч 2**.

**ШӘЙЕН** *кргл.* к.: **тике**. Алтмыш йәшемә шәйен утында эшләдем.

**ШӘЙКӘ 1.** *т.я.* лакан (лохань). Шәйкә белән терлек эчерәләр ийе. – *трх.*; **2.** *мәл.* кечкенә табак, савыт (маленький таз, тазик); **3.** *перм.* чиләк (ведро). Йә суга китәр ийем, шәйкәне чығарып қуйарлар ийе дә. Шәйкәнең кәшбәйткән йерләрен төзәттем.

**ШӘЙКЕ** *каз.ар., бәр.* к.: **шәйкә 1**. Шәйкеләр була торған ыйы, сыйырларға башақ бирә торған ыйық, аның қолағы да була. – *мам.* Ағачтан йасаған шәйке ике қолақлы, түгәрәк була. – *бәр.*

**ШӘЙЛӘНҮ** *эчк.* к.: **айфарлану**. Ғалимә апа, шәйләнеп, клубқа цығып китте.

**ШӘЙЛӘҮ I** *төм.* бизәү (украсить).

**өй шәйләү** *төм.* өй бизәү (украсить дом). Чигүле бәрдәләр, урын-төшәкләр мән өй шәйләйтеләр әwәле.

**ШӘЙЛӘҮ II 1.** *хвл., чст., чпр.* аз-маз күрү (немного видеть). Бабайның күзләре аз-маз шәйлиләр әле. – *мәл.* Караңғыда йактыны шәйлим. – *чст.*; **2.** *минз.* аз-маз хәтерләү (немного помнить); **3.** *нокр., эчк.* әзерләү (готовить). Шәйлә инде, шәйлә әйбереңне. – *нокр.* Қыз бүләкләр шәйләй кийәүгә. Башқа өй шәйләгез, миннән китегез. – *эчк.*; **4.** *минз., бөре., перм.* игътибар итү (обращать внимание). Сәхиптә қомақ бар, шәйләле, дидем, дару очраса. – *минз.* Тасқағаста бар минем күләсә, шәйләң. – *перм.* Әтәй, қара аны, килеп җитмәсәм, шәйлә. – *бөре.*

**ШӘЙМЕК** *перм.* к.: **гөмбек**. Шәймек атлам сайын, чawып булмый. Шәймек баштан җиләк җыйдым.

**ШӘЙТАН: шәйтан ашығы** *бөре., минз.* к.: **ашық II, 2.**

**шәйтан табагачы** *хвл.* к.: **ут II: убыр уты**.

**шәйтан туйы** *срг., т.я., чпр.* тузан өермәсе (пыльный вихрь).

**ШӘЙҮ** *кузн., хвл., срг.* к.: **қомшу**. Шәйи мәтәм. – *кузн.* Сөтөм шәйеде дир. – *срг.*

**ШӘК** *брб.д.* шик (сомнение).

**ШӘК: шәк суғу** *злт.* к.: **кәртләки: кәртләки қалақ уйнау**.

**ШӘКӘЛМӘ** [*рус.* щиколотка] *стрл.* к.: **ашық II, 2.**

**ШӘКӘНӘ** *перм.* к.: **қанатқы**.

**ШӘКӘР** *әстр., кузн.* шикәр (сахар). Монда шәкәрең, балың қайнап тора, шул лақша өстөнә аударасың. Кан'на чәй йаси, шәкәреңне дә, закускаңны да қуйа өстәл читенә. Чаршау эчендә утырып чәй эчәсең. – *кузн.*

**бер пукыл'** [*морд.*] **шәкәр** *чпр.* бер шакмак шикәр (кусок сахара). Бер пукыл' шәкәр белән цәй эцтем.

**ШӘКӘР-ЧҮРӘК** *әстр.* өйдә пешерелгән печенье (домашнее печенье). Шәкәр-чүрәк пешергәндә йарты кила майға йарты кила шикәр, өчәүмедүртәүме йомырқа салына, ул күпертелә. Он салып бутыйлар, фурмыға салып пешерәләр. Ул шәкәр-чүрәк әйтелә, кийәү сыйға да пешердем шәкәр-чүрәк. Әнә килен пешерә бирә, әйдә шуны пешериг әле дип.

**ШӘКӘЦӘ** *туб.-ирт.д.* касә (пиала).

**ШӘКӘШӘ** *тара.* зур касә (большая пиала). Порыңқы төмән-төрле шәкәшәләрне йарып қақшатты.

**ШӘКЕ** *шрл.* к.: **тике**. Син шул шәке гаризалар да йаздың.

**ШӘКЕЛМӘ** *клд.* киндер сугу станында тәбәлдерек (педаль ручного ткацкого станка). Көрөнең тайагын шәкелмәгә тыгасың.

**ш ә л** (шаль, платок):

**алдырлы шәл** *лш.* бизәкле калын шәл (толстая шаль с узорами). Алдырлы шәл диләр ийе, ансысы йәшел төшәдер ийе суқнаға, қыйбатлы инде.

**бала шәл** *чст.* кечкенә шәл, яулык (маленкая шаль, платок). Матур киммәтле бала шәлгә акца түлиләр.

**барашкawый** [*рус.* барашковый] **шәл** *срг.* чуклы йон шәл, бер генә төс яки буй-буй төрле төсләрдән сарык йоны кыстырып тукылган шәл (шерстяной платок с кистью, буклированный шерстью одного цвета или разных цветов в по-

лоску). Барашкаwый шәл сүлиләр әwәле кызга, бәйәле шәл, кара төстә дә була.

**бубрик** [*рус.* бобрик] **шәл** *бәр.* к.: **тула шәл.** Бубрик бик йакшы шәл ул, пустау йанында торған бубриг инде, аның бөтөркәсе булыр ыйы, пустаwы шома.

**гөлле шәл** *тмн.* к.: **күбек шәл.**

**жуwан шәл** *трх.* шакмаклы калын шәл (клетчатая толстая шаль). Жуwан шәл китерделәр миңа, жуwан шәл қыш бәйли торған, чуқлары да бар.

**йебәк шәл** *срг., төм.* ефәк шәл (шёлковая шаль). Калпак кийәләр туйда, йә йебәк шәл йәмне. – *срг.* Кинчәк ак йебәк шәл бөргәнеп утыра. – *төм.*

**йыwан шәл** *тара.* калын шәл (большая суконная шаль). Йыwан шәл йабалар кинцәкнең өстөнә.

**казлаwый шәл 1.** *лмб.* зур постау шәл (большая суконная шаль); **2.** *мәл.* к.: **пинзе шәл.**

**қалын шәл** *т.я.* к.: **казлаwый шәл.**

**камчат шәл** *трх.* бизәге күпертеп чигелгән калын шәл (толстая шаль с выпуклой вышивкой).

**карталы йефәк шәл** *чпр.* күпертмәле ефәк шәл (шёлковая шаль с выпуклыми узорами). Карталы йефәк шәл цуклы, шыны бәләдек.

**кәзә шәле** *чст.* к.: **ангур: пыхавуй ангур.**

**кәмил шәл** *тмн.* к.: **күбек шәл.** Кәмил шәл бар кан'сеңелемдә, синең дәме бар кәмил шәлең?

**куwыклы шәл** *мәл.* к.: **күбек шәл.** Ак куwыклы йебәк шәлләр бәйли идек, мудыдан чыктылар алар.

**күбек шәл** *срг.* бүртмәле, озын чачаклы ак ефәк шәл (белая шёлковая шаль с длинной бахромой и выпуклыми узорами).

**күпертмәле шәл** *хвл.* к.: **күбек шәл.**

**оло шәл** *каз.ар.-крш.* кыш көне юл йөргәндә чанада бөркәнеп утыра торган зур калын шәл (большая шерстяная шаль, которой накрываются зимой во время езды на санях). Оло шәл мин дә алдым, кеше ала дип. Диванға қуйып бетердек.

**пинзе шәл** *дөб.* мамык шәл (пуховая шаль). Пинзе шәле барма, дип сораганнар қыз биргәндә, қалын әйберсенә пинзе шәл, читек-кәwеш китергәннәр.

**постау шәл** *мәл.* к.: **тула шәл.**

**сип шәл** *том.д.* кызга кияү ягыннан туйга бүләк ителгән шәл (шаль, подаренная женихом невесте перед свадьбой). Сип шәл мамамныкы сандыкта әле дә бар.

**тақта пухаwай шәл** *кмшл.* фабрикада бәйләнгән ярым йон шәл (фабричная полушерстяная шаль). Тақта пухаwай шәлем генә барийе дә, аның йылысы йуқ.

**тақта шәл** *кмшл.* юка йон шәл (тонкая шерстяная шаль).

**тула шәл** *байк.*, **туртын шәл** *срг.* зур калын шәл (большая толстая шаль). Тула шәл кебек зур шәл ийе ул. Тула шәленне биреп тор әле.

**чана шәле** *перм.* к.: **казлавый шәл 1.** Берне зур чана шәлен қуйған Жәмигага.

**чатырақ шәл** *әстр.* күпертмәле ефәк шәл (шёлковый бугорчатый платок). Қодагыйым матур икән, чатырақ шәле башында.

**шәл бала** *мәл., чст.*, **шәл баласы** *т.я.-крш., чпр.* зур йон яки кашемир яулык (большой шерстяной или кашемировый платок); чаг.: **бала 1: бала шәл.** Матур шәл баласы бар лавкада. – *т.я.-крш.* Саумы, дип күрешәсең дә бер шәл баласы бирәсең кан'анаңа. – *чпр.*

**шәл йабу** *к.-уф.* кода күчтәнәчләрен шәл белән котлау (поздравляя сватов, пришедших с гостинцами, накрывать на их гостинцы шаль или платок). Қода күмәчләренең өстенә шәл йабалар, акча салалар. Шулай шәл йабып жыйалар күмәчләр өстенә.

**шәл китерү** *срг.* кыз ягында туй алдыннан үткәрелә торган мәҗлес: гадәттә, анда егет ягы кызга бүләк итеп шәл китерә, кыз ягы да бүләкләр бирә (предсвадебное угощение на стороне невесты, где обычно сторона жениха дарит невесте шаль, а сторона невесты также одаривает их подарками). Туй алдыннан шәл китерү була. Йегет йагыннан зур шәл китерәләр, өстенә көмеш тәңкәләр тезгән. Шунда китерәләр аны йегетнең йакын радителләре, аларга кыз йагыннан падаркылар бирәләр.

**ыштоп** [*рус.* штоф] **шәл** *брб.д.* чуптарлап эшләнгән калын шәл (платок с узорами). Ыштоп шәл, чуқлары қара, чичәкләре күкчин (сирень төсле), шәле ғара.

**эрфәк шәл** *срг.* төрле төстәге бизәкләр төшерелгән юка шәл (тонкая шаль с разноцветными узорами).

**ШӘЛӘМӘ** *мәл.* к.: **алама-шалама.** Бу бишмәтеңне ки, анысы шәләмә.

**ШӘЛӘП** *трх.* к.: **йәт I.** Кибеткә чәй қайтты ийе, дуһым шәләп алдылар.

**ШӘЛӘУ** *тбл.* уңмаган (неумелый, неудачный).

**ШӘЛБӘЙУ** *тара.* шиңү, пәжү (вянуть). Көл шәлбәйеп қалған.

**ШӘЛБЕК** *саз.я.* шапшак (неряшливый).

**ШӘЛБЕРӘЙУ** *минз.* к.: **пожу.** Бүген қырау төшкәнгә үләннәр шәлберәйгән.

**ШӘЛГӘМӘ** *т.я.-крш.* күкрәккә кию өчен тәңкәләр тезеп эшләнгән бизәнү әйбере (нагрудное украшение). Шәлгәмәгә нухратны куйа йугары башына, тәңкән аз булгас.

**ШӘЛДЕРМӘС** *м.-кар.* шалтыравык, балалар уенчыгы (погремушка).

**ШӘЛЕМ** *туб.-урт.д.* пәрәвез (паутина).

**ШӘЛЛӘУ** *м.-кар.* кыздыру (жарить). Бәрәңгене шәлләп тыктым иде бичкә. Иске мохшы да шәлләгән бәрәңге, бәрәңге шәллим, диләр.

**ШӘЛТӘУ: шәлтәү тайақ** *перм.* туку станогының бер детале (деталь ткацкого станка). Шәлтәү тайақ башына төшә, қызықай, қайа җәрдөң?

**ШӘЛТӘWE: шәлтәwe төшү** *минз.* к.: **семәйу.** Қызның бөтенләй шәлтәwe төштө дә китте, шул сүзләрне ишеттерә башлағачтын.

**ШӘЛТЕП** *төм.* бишек (колыбель). Шәлтепкә салып ырғаған баланы. Шәлтепне қыраға алып барған, қайынға бәйләп элгән, урақ урған.

**ШӘЛТҮ** *төм.* тирбәтү (качать).

**ШӘЛҮНКӘ** [*рус.* шаленка] *баст.* шәл (шаль). Қайнанам бутқа пешерде, бирнәгә шәлүнкә бирдем ағары.

**ШӘЛШЕ** *лш.* к.: **чәрше**. Җawымны йылларда шәлше йасыйлар.

**ШӘМ I** *тбл.* лампа.

**шәм қалбақ** *төм.* абажур.

**ШӘМ II** *байк.* чыра кыстыру өчен эшләнгән өч япьле тимер (железное приспособление для закрепления лучинки). Шәмгә цыра кыстыралар, аска цыраның күмере койолып тора.

**суқыр шәм** *тпк.* к.: **пысқыш**.

**ШӘМӘЙ** *минз.* к.: **шага 1**. Их, йәш чақта суғадырыйық шәмәйне.

**ШӘМБӘ** *мәл.* елга балыгының бер төре, вак балык (разновидность мелкой речной рыбы).

**ШӘМГӘДӘН** *трх.* к.: **шәм II**. Шәмгәдәнгә чыра қыстыраларыйы да җеб эрләп киндер суғалар ыйы кич.

**ШӘМДӘР** *каз.ар.-крш.* к.: **шәм II**. Шәмдәрдә чыра җандырғаннар.

**ШӘМДЕ'** *кас.*, **ШӘМДЕК** *блт., срг., мәл.* к.: **шәм II**. Шәмдекне өч тармақлы итеп тимерчедән йасата торғаннарыйы, шуңа қыстырып қуйасың чыраны. – *блт.* Шәмдекләргә цыра йандырғаннар. – *срг.* Шәмдегебез йәшәсен диб әйтәбез, ди. – *мәл.*

**ШӘМИР** [*рус.* кашемир] *чст.-крш.* кашемир (кашемир; кашемировый). Шәмир ийе сүрәкә канатым, кызыл шәмир ийе.

**ШӘМКӘ I: шәмкә чийе төшү** *кмшл.* к.: **семәйү**. Нишләп әле мының шәмкә чийе төшкән?

**ШӘМКӘ II, ШӘМКӘЛЕК** *минз.* яшь наратлык (молодой сосняк); чаг.: **пумиллек**. Шәмкәдән барсағыз, өч киламитыр. Күренеп кенә тора бит шәмкәлек башында.

**ШӘМКӘЧИ: шәмкәчийе төшү** *минз., стрл.* к.: **семәйү**. Қыз бала дигәч, шәмкәчийе төшә тегенең. – *минз.* Шәмкәчийе төшкән әле моның, күңелсез йөри. – *стрл.*

**ШӘМКИ: шәмки төшү** *минз.* к.: **семәйү**. Инәләре өйдә чақта балалары шат җөриләр, тик инәләре эшкә китсә генә шәмкиләре төшә. Шәмкийең төштеме?

**ШӘМЛЕК** *бәр.* к.: **шәм II**. Қайын чырасы әзерләп, бер кеше шуны қарап қына утырды, шәмлеккә шуны қуйып-қуйып йандыралар.

**ШӘМНЕК I** *минз., стрл.* к.: **шәм II**. Шәмнек буладырыйы шушылай өч тармаклы, чырасын бер бәләкәйрәк бала сындыргалап тора. – *стрл.*

**ШӘМНЕК II** *трбс.* бәпкә, кайчы (стропило).

**ШӘМПЕ** *тара.* шимбә (суббота). Шәмпегә мул'цаға ғына қайтатылар.

**ШӘМ-ШЫРА** *әчк.* элек: шәм урынына кулланыла торган чыра (в старину: лучинка, употреблявшаяся вместо свечи). Шәм-шырақайның йанганындыйн йанмағаны йахшырақ (*бор. җыр.*).

**ШӘНГӘРӘЙ** *кузн.* к.: **пысқыш**.

**ШӘНДЕК** *перм.* ышаныч (доверие). Аныңа шәндек булмағач.

**ШӘНКӘЙ** *срг.* к.: **қолқай**.

**ШӘНКӘЙЛӘҮ** *срг.* к.: **коннау**. Алаша шәнкәйләде.

**ШӘНЧЕК I** *м.-кар., т.я.-крш.* юкә агачыннан ясалган әржә (короб, сундучок, сделанный из липы). Кәзер сындык дибез, элек шәнчек дигәннәр. – *м.-кар.* Шәнчек элеке сандык урынында җөртөлгән, капкачы кабыктан була. – *т.я.-крш.*

**ШӘНЧЕК II** *брб.д.* төенчек, төргәк (узелок, свёрток).

**ШӘҢГӘ** *перм., к.-уф., нокр., глз.* ачы камырның өстенә нинди дә булса әйберләр ягып пешерелгән ашамлык (шаньга).

**балтырған шәңгә** *к.-уф.* җәй көне балтырган үләне өлгергәч пешерелә торган шәңгә (шаньга с борщевиком). Балтырған шәңгә дә пешерәбез. Башта балтырғанны пешерәсең дә аныңа йомырқасын қушасың пешереп, азырақ қына борыч та салам хуш исле булырға. Май салам, қаймақ йағам өстенә.

**җиләк шәңгә** *к.-уф.* нинди дә булса җиләк белән пешерелгән шәңгә (шаньга с ягодами). Җиләк шәңгәне күп пешерделәр инәйләр. Бала чақта күп җыйайық қый җиләкне, йаланнар күп қый, таулар да күп.

**қалын шәңгә** *к.-уф.* ачы камыр өстенә талкан оны сибеп пешерелә (шаньга с толокном). Қалын шәңгә диләр ийе. Табаға йасыйлар әпәйне, шуның өстенә май җәйә, талқан җәйә, писук сибә өстенә. Қунақ чақырганда телемләп-телемләп кенә кисеп қуйалар қалын шәңгәне.

**кәртүк шәңгә** *к.-уф.* камыр өстенә бәрәңге боламыгы ягып пешерелгән шәңгә (шаньга с картошкой). Қунақ килә башласа, иң элеке кәртүк шәңгә бешерәбез. Қамырны күптерә дә, күпкән қамырның өстенә тәмне генә итеп, сары май салып туқыған кәртүкне йағып, арта пешереп алаң. Безнең Уралда шуw инде, ыспай ғына итеп кәртүк шәңгә бешерәбез.

**күкәй шәңгә** *к.-уф.* камыр өстенә каймак белән тугылган йомырка ягып пешерелгән шәңгә (шаньга с яйцом). Қаймаққа күкәй салаң, азырақ он болғыйың, туқыйың шуны да шәңгә итеп қабартма өстенә йағаң. Қызғылт-сары шундый тәмне була wы күкәй шәңгә. Қамырын мискә тығып әзерәк кенә өстөн қатырағ инде аны. Сыразы салсаң, аға да китә қый суwық қамырдан. Йылы қамырны алаң, күкәйне сылайың да тағын мискә тыгаң инде. Күкәйне сылағач қына өстенә писук сибәң. Шундый тәмне булайы күкәй шәңгә.

**мәшкә шәңгә** *к.-уф.* камыр өстенә пешкән гөмбә ягып пешерелгән шәңгә (шаньга с грибами). Мәшкә шәңгә бик тәмне була, қарта шикелле. Мәшкәне пешерәләр дә ит тартқычтан чығаралар. Қаймақ, май салалар да шәңгә итеп пешереп алалар.

**өмөже шәңгә** *к.-уф.* кура җиләге белән пешерелгән шәңгә (шаньга с малиной). Өмөже wақытында өмөже шәңгә бешерәбез шулай. Өмөже күп була қый җәйгедә.

**сары торма шәңгә** *к.-уф.* кишер шәңгәсе (шаньга с морковью). Сары торма шәңгәне көзгедә, пумичқа кешеләр чақырғанда пешерәбез. Сары торма күп була қый. Өстәлдә кәртүк шәңгә дә, сары торма шәңгә дә була.

**таба шәңгә** *к.-уф.* табага салып пешерелгән

шәңгә (шаньга, испечённая на сковородке). Таба шәңгә пешерәбез табада. Мис алдында қызуда пешереп алабыз тиз генә. Тегеләй мис төбөнә салып пешерәсең инде.

**талқан шәңгә** *к.-уф.* к.: **калын шәңгә**. Талқан шәңгә бешерәләр ийе. Солоны мичкә тығып бешерәләр чүлмәк белә. Бешергәч солоны қоротолар, тарттыралар. Тарттырғач сөткә туқыйсың да шәңгәнең уртасына чоқыр йасап саласың талқанны. Тәмне шәңгә wы.

**шартлама шәңгә** *к.-уф.* җир җиләге белән пешерелгән шәңгә (шаньга с клубникой). Шартламадан шәңгә салдылар, бируғы да була. Қоротып қуйабыз аны. Йебетәң дә салаң. Йә тартабыз аны ит тартқычтан. Әл дә бешерәбез аны шартлама шәңгәне. Қабарған қамыр өстөнә сылыйың да шәкәр сибәбез.

**шәңгә тәтәй** *к.-уф., перм.*, **шәңгә чичкә** *перм.* к.: **чәчәк I: айлы чәчәк**.

**шоморт шәңгә** *к.-уф.* шомырт оны ягып пешерелгән шәңгә (шаньга с черёмухой). Кипкән шомортны тирмәннән тартып шоморт оны йасыйлар. Хәзер ит тартқычтан ғына чығарабыз қый. Шуны ачы қамыр өстенә йағаң, шоморт шәңгә була.

**ыwыз шәңгә** *к.-уф.* уғыз сөте эремчеге белән пешерелгән шәңгә (шаньга с молозивом). Ыwыздан пешерделәр элек шәңгәләр. Элек сақырыша торған ыйық, ыwыз шәңгә ашарға барабыз дип. Хәзер йуқ қый андый. Сыйыр бозауласа, шәңгә ашарға йөрдек, ыwыз шәңгә ашарға. Ыwыз шәңгә ашарға барабыз дип дан итеп сөйли торғаннар ыйы аны. Рәхмәт әйтәң сақырған өсөн. Әби-бабайлар айәт уқыйлар ыwыз шәңгәсенә. Ыwыз шәңгәне шулай кеше сақырып ашатабыз.

**эрек шәңгәсе** *перм.* эремчек шәңгәсе (шаньга с творогом). Эрек шәңгәсе йасап ашатасың сыйыр бозаулагач. Сawаплы.

**эремек шәңгә** *к.-уф.* к.: **эрек шәңгәсе**. Эремек шәңгә бешерәбез сөт күп булғанда, сыйырлар күп сөт биргәндә. Сөттән эремек йасап қуйаң қый күб итеп. Менә шул эремек шәңгә бешергәндә эремек йағып қуйарға кәрәк була.

**ШӘҢГӘ-ШӨҢГӘ** *к.-уф.* һәртөрле шәңгәләр (всякие шаньги). Аш пешерә дә, шәңгә-шөңгәсен пешерә дә, шул була сый өмәдә.

**ШӘҢКӘ** *төм.* шәңгә, бәрәңге пәрәмәче (шаньга). Күрше-ғаралар шәңкә салып, қоймақ қойоп апкерәте бала асыраған бичәгә.

**ШӘҢКИ** *минз.* к.: **бирук**.

**ШӘП I 1.** *бөре., минз.* күп (много). Анда кеше бик шәп иде. – *бөре.*; **2.** *бөре., минз., кмшл.* көчле (сильно). Қыр йағында боз бик шәп йауған, ти. – *бөре.* Дәүләткол қырында йаңғыр бик шәп йауған, бездә бик әз булды. – *кмшл.*

**бер шәп** *к.-уф.* бераз (немножко). Бер шәп қызларга бүләк әлә башлыйсың.

**бер шәпкә** *перм., к.-уф.* беразга (на некоторое время). Қара пирчәткә, Сау бул бер шәпкә (*жыр.*). – *перм.*

**ШӘП II** [*рус.* цеп] *перм., бөре.* к.: **чип I**. Шәп белән сукканнар. – *перм.* Шәп белән ашлық суғабыз. – *бөре.*

**ШӘПКӘ** [*рус.* шапка] **1.** *тпк., стрл.* әшләпә (шляпа). Ирләр йон шәпкә кийәләр. – *стрл.*; **2.** *төм.* бүрек (шапка). Чачны йиғалы, шәпкә сынлы кийеп қуйғалы сарawыцны.

**ШӘПКИР** *тбл.* ерактан начар күрүче (близорукий).

**ШӘПЛЕ** *перм., минз.* көчле, таза (сильный, здоровый). Безне ашлық сугарға ғына җәртә торғаннар ийе шәпле булғанға. – *перм.* Сезнең кебек җөргән кеше шәпле була ул. Шәпле райуннар Иделнең теге йағында. Теге тана шәплеме? – *минз.*

**ШӘПТӘКӘ** *чст.* к.: **салак**.

**ШӘПТҮКӘ** [*рус.* шептунки] *к.-уф., перм.* идән паласы (половик). Шәптүкә суғып идәнгә җәйдек. – *к.-уф.*

**ШӘПШАҚТАЙ** *минз.* к.: **латлы 2**. Әткәйнең хәле ничек, шәпшақтаймы?

**ШӘПШӘК** *мәл.* тиз авыручан, чирләшкә (болезненный, быстро поддающийся болезням).

**ШӘР I 1.** *бөре., перм., злт., шрл.* қышын боз өстенә чыккан су (вода, наледь, выступившая на льду). Боз өстенә шәр сығадыр инде, бүтән бара алмас. – *злт.* Боз өстенә шәр чыккан икән, пималарым манма су булды. – *шрл.*; **2.** *мам.* дым (сырость). Бөтен эстина шәр була қыш көне.

**ШӘР II** *төм.* шәһәр (город).

**ШӘР III** *брб.д.* князь, биләүче (князь, владелец).

**ШӘР IV: шәр қawын** *төм.* кавын (дыня). Шәр қawыннар сатуцы килепте.

**ШӘРӘ 1.** *лмб., кузн., кмшл.* к.: **әкәлә 1**. Шәрәли имән ауды (*әйтем*). – *кузн.* Булатларға мәктәптән имән шәрәсе җыйарға қушқаннар. – *кмшл.*; **2.** *тмн.* к.: **әкәлә 2**. Нарат шәрәсе белән куй самыварны; **3.** *кузн.* төер (желвак). Куйнын йилнесенен щәрәләре беленә.

**ШӘРӘБӘ** *туб.-урт.д.* **1.** жирәбә (жребий); **2.** ядрә (картечь).

**ШӘРӘКӘ 1.** *каз.ар.-крш.* к.: **шақмақ I**. Җон аның арқawы, буйы шәрәкә җебе; **2.** *мам.* к.: **чашка II**. Самawыр шәрәкәсе беткән икән безнең, қарт.

**шәрәкә күк булу** *блт.* йомры булу, түгәрәк булу (быть круглым, шарообразным). Әбийем чәчемне қысып-қысып үреп қуйадырыйы да, шәрәкә күк булды, дип әйтеп қуйар ыйы.

**ШӘРӘЛӘҮ** *минз., стрл.* тозлаган кыярның бозылуы, черүе (порча, гниение огурцов при неправильном солении). Шәрәли тулкы, қышқа қуйып булмый. – *минз.*

**ШӘРӘҮ 1.** *чст., чпр., хвл.* чәберчекләнү (тухнуть, протухать). Тawық утырткан идем, ун йымыркадан эцесе шәрәгән. – *чст.*; **2.** *чпр.* черү (гнить). Алма шәрәгәндер инде, астан да йүwеш, өстән дә йүwеш.

**ШӘРБӘТ** [*гар.*] *перм.* ширбәт (сладость). Сағызағ ул шәрбәткә үч бәк. Шәрбәт салсаң, майын қушсаң, қатлама тәмне була.

**ШӘРБӘТЛӘНҮ** *к.-уф.* баллану (становиться сладким). Арыш оны шәрбәтләнә.

**ШӘРБӘТЛЕ** [*гар.*] *перм.* ширбәтле (сладкий). Күл сuwы шәрбәтле.

**ШӘРКЕ** *минз., т.кам.-крш.* к.: **сыпқылы**. Күлмәге шәрке. – *т.кам.-крш.*

**ШӘРКЕЛЕК** *т.кам.-крш.* к.: **салаклык**. Ул шәркелектән килмәй бит, җазға таба түшәм башлары парлана, шуннан кырыйак чыга.

**ШӘРЛӘҮ** *минз., стрл.* боз өстенә су чыгу (выступление воды на поверхности льда). Җылга шәрләде. – *минз.*

**ШӘРШӘКЛӘНҮ** *дөб.* ярылу (трескаться, растрескаться); чаг.: **кизәрү 1**. Бу ом белән пешергән кабартма шәршәкләнә.

**ШӘРҮ I** *злт., срг.* к.: **шәрәү 1**. Йоморкә шәрегән. – *злт.*

**ШӘРҮ II** *срг.* уеннан чыгу, исәптән төшеп калу (выйти из игры). Аны тирсән йаулык салып ун'аганда, ул шәри, крукның уртасында утыра, ун'амый багып тыра.

**ШӘТ** [*гар.*] *хвл., кузн., мәл., чст., чпр., кмшл., бгрс.* шаять, бәлки, мөгаен (может быть, возможно, наверное). Шәт, сырттан төшеп китәрбез. Мин кунакка килгәч, шәт, син алдырттың. Шәт, икенче авылдан килдегез? – *кузн.* Күптән инде ул, мин әле, шәт, йегермедә дә булмаганмын. Шәт, катык та ашагың келидер. – *хвл.* Шәт, син дә килерсең? – *чст.* Шәт, ыныттың шул эшне, бергә идек. Шәт, кибәннәре дә шунда булган? – *бгрс.*

**ШӘТЧЕ** *байк.* печән кибәне уртасына куеп калдырыла торган агач, колга (жердь, которая вставляется в середину стога сена). Шәтче йасарга агач булмадисә, нәрсә саласың?

**ШӘШКӘ** [*рус.* чашка] *минз., стрл.* к.: **айак I, 2. шәшкә асты** *минз., стрл.* к.: **җәйләү**. **шәшкә өсте** *минз., стрл.* к.: **җомор**.

**ШӘШТӘКҮЛ** *туб.-ирт.д.* казык читән (частокол).

**ШӘШӘРӘ: шәшәрә җүле** *м.-кар.* буй-буй лента тотылган – күлмәк турында (о платье, к подолу которого пришиты ленты в виде поперечных полос).

**ШӘШҮРӘ** *чст.* к.: **кукамай**.

**ШӘҮКӘЛ** [*гар.*] *каз.ар.* начар, ямьсез (плохой, некрасивый); чаг.: **қошбәтсез**. Итегем шәүкәл ийе, итек бастырып пирде. – *каз.ар.-крш.* Шәүкәл өсбаш белән бармый ич инде кеше. Бигерәк шәүкәл өсте-башы. – *дөб.*

**ШӘҮЛӘҮ** *туб.-ирт.д.* сызлау (ныть). Айакларым шәүләп утыраты.

**ШӘҮШӘЛӘК** *чст.* к.: **сыктак**.

**ШЕБӘ I** *эчк.* к.: **чекә**.

**ШЕБӘ II** *туб.-ирт.д.* тегәрҗеп (суровая сучёная нить).

**ШЕБЕШ** *злт.* тавык (курица). Өс ойадан дүрт бәпкә сыкты, аның да өсөсе әтәс, берсе генә шебеш. Иртән шебешегезне ашап бетердек. Иң йаратканым шебеш шулпасы.

**ШЕЙЛЕ** *туб.-ирт.д.* шикелле (как). Нимә шейле? – *саз.я.*

**ШЕЛДЕРӘҮ** *мәл.* к.: **самсырау**. Шелдерәгән карчыклар тыта, ди, уразаны.

**ШЕЛДЕРМӘ** *чпр., хвл.* арканны муенчакка беркетә торган тимер җайланма (приспособление для прикрепления аркана к ошейнику).

**ШЕЛЕК 1.** *стрл.* акация төсләрәк тәбәнәк куак, тау битләрендә үсә (чилига); **2.** *минз., нгб.-крш.* к.: **гөләф**. Элек шелек тий торган ыйы халык, хәдер гөлҗимеш инде. – *минз.* Шелек арасыннан бозawыма печән җыйып кайтып киләм. – *нгб.-крш.*; **3.** *минз., кмшл.* к.: **сары: сары тал**. Шелекне хужалыкта ишегалды себеркесе ясау өчен кулланалар. – *минз.*; **4.** *кмшл.* тәбәнәк бадәм (миндальник низкий, бобовник).

**ШЕЛЕП** [*удм.*] *нокр., глз.* к.: **йунысқы**. Айагына шелеп чәчерәгән. – *нокр.*

**ШЕЛКЕНЧӘК** *нгб.-крш.* к.: **чолдор I**. Туйдагы атларга шелкенчек тагалар.

**ШЕНҖҮ** *дөб.* сизү (чувствовать). Мин аны шенҗеп утырам.

**ШЕНҮ** *лмб.* шешенү (опухать, отекать). Бармаклары шенде, күзе шенгән, бер айагы шенә иде.

**ШЕҢКӘН** *туб.-ирт.д.* сыек (жидкий – о чае). Цай шеңкән.

**ШЕПШИ** [*рус.* щипцы] *срг., каз.ар.* к.: **җәмки**. Мистән wак күмерне шепши белән алып самawырга сал. – *дөб.*

**ШЕР** *туб.-ирт.д.* акылга җиңел (слабоумный). Кецкенә паласы иргәлектән шер пулган.

**ШЕРБҮРӘК** *срг.* к.: **пәрәпәч 1**.

**ШЕРЕШ** *туб.-ирт.д.* арыш оныннан ясалган клейстер (клейстер из ржаной муки).

**ШЕРЕШЛӘҮ** *тара.* ябыштыру (клеить). Тирәс шерешләп куйтым.

**ШЕШ I** *т.я.* кечкенә кадак (гвоздик); чаг.: **гуз′**.

**ШЕШ II: шеш йөгерү** *т.я.* шеш барлыкка килү, шешү (распухнуть). Кулыма шеш йөгөрде.

**ШЕШ III** *кргл.* туйның соңгы көнендә пешерелгән бәлешкә камырдан ясап куелган фигуралар: ул туй мәҗлесенең беткәнлеген аңлата (фигуры, сделанные из теста на свадебном пироге, обозначающие завершение свадебного пиршества). Бәлеш сала, бәлешләргә шешләр йасап кадый. Бу инде шеш, йәнәсе, кодаларга кайтып китәргә wакыт йетте. Шешләрне алып көлеп-көлеп ашыйлар.

**ШЕШ IV 1.** *төм., тбл.* чәнечке (вилка); **2.** *туб.-ирт.д.* бозау иммәсен өчен борынына киертелә торган агач кисәге (деревяшка, которую одевают на морду телёнку, чтобы он больше не сосал). Посау имәйем тисә тә, имәлмайты, шеш бөйәп куйаты.

**кый шеш** *саз.я.* тирес сәнәге (навозные вилы).

**шеш гөлө** *к.т.* к.: **алый**.

**шеш йарагы** *мам.* к.: **бакa: бакa кабыгы**.

**шеш палык** *туб.-ирт.д.* ысланган балык (копчёная рыба).

**ШЕШӘ** *перм., к.-уф., эчк., себ.* пыяла (стекло). Безнең кебек йарлы кешеләр шешә урынына карындык куйабыз иде (тәрәзәгә). Болаңгыр шешәдән лутчырак кararга. Шешәле аптабус. – *перм.* Тәрәзә шешәсен йыwасы бар икән. – *к.-уф.* Шешә табак. – *тара.*

**ШЕШӘЛӘҮ** *туб.-ирт.д.* пыяла кую (застеклить).

**ШЕШӘЦЕК** *туб.-ирт.д.* кечкенә шешә (пузырёк, флакон).

**ШЕШБӘРӘ** *нрл., кргл., шрл., себ.*, **ШЕШБҮРӘ** *эчк.* к.: **шөшпәрә**. Шешбәрә йасап куйабыз. – *кргл.*

**ШЕШЕК I** *перм.* **1.** шеш (опухоль, нарыв). Нагыш йафырагын шешеккә йабыштырсаң, тартыб ала; **2.** к.: **кырыбытак**.

**төп шешек** *перм.* к.: **қырыбытақ**. Теге озорон төп шешек тибез, сувық тигәндән чығавы.

**ШЕШЕК II** *каз.ар.-крш.* к.: **қыслаңқы 3**.

**ШЕШКӘН** *эчк.* к.: **қырыбытақ**. Қулыма шешкән чыққан.

**ШЕШКЕ** *минз., стрл.* шеш (нарыв, опухоль). Су кергән дә, җаңағына шешке чыққан. – *минз.*

**ШЕШЛӘҮ** *төм., тара.* кыздыру (жарить).

**ШЕШМӘКЛӘНҮ** *бәр.* шешү (опухать, распухать). Йығылганыйым, қулым шешмәкләнеп китте.

**ШЕШМӘРӘ** *крғл.* к.: **шөшпәрә**. Суғым суйғач, шешмәрә пешерә башлыйбыз инде.

**ШИБАН** *тбл., тара.* чығымчы – ат турында (норовистый – о лошади).

**ШИБЕТ** *туб.-ирт.д.* бик кечкенә чуртан (маленькая щука).

**ШИБИРҮ** *туб.-ирт.д.* урап әләктереп алу (охватить, схватить).

**ШИБЫГАЙТУ** [*рус.* шибко + *афф.* -айту] *срг.* тизләтү (ускорить, убыстрить). Апа да шибыгайтты.

**ШИБЫК** [*рус.* шибко] *срг.* к.: **йәт I**. Шибыграк ашагыз. Су бик шибык ага. Нүгезен бәләгез, айагын бәләгез, шибык кына сawып алыгыз.

**ШИБЫЛ: шибыл суғу** *крғл.* к.: **кагылу**.

**ШИБЫЛЛАУ** *шрл.* к.: **кагылу**. Чана шувып йантыкка китсә, шибыллады, йаки шибыл сукты ат'алар.

**ШИГӘЙҮ** *мам.* шикләнү (сомневаться, подозревать). Шигәйә булыр әле.

**ШИГЕЛ** *төм.* кыяфәт (внешность). Минең йегетләр ничawамы шигелгә?

**ШИГҮ** *туб.-ирт.д.* шикләнү (сомневаться, подозревать). Қарт шикте, тойты поларның қачқанын.

**ШИД** *кузн.* кадак (гвоздь). Кечерәк кенә шид шыл йирдә.

**ШИЖИК** *брб.д.* симерә башлаган ике яшьлек бәрән (двухлетний баран, начинающий набирать вес).

**ШИЙЫРУ** *минз., стрл.* к.: **ызгу**. Қартлар безне чыгып шийыралар ыйы. – *минз.* Монау инәй лапылтый да лапылтый дип шийыра инде. – *стрл.*

**ШИЙҮ** *том.д.* бүлү, салу (разливать, раскладывать). Аш шийгәле.

**ШИКАЙ** *тпк., стрл.* кирәкмәгән мәгънәсез сүзләр сөйләүче (говорящий ненужные, бессмысленные слова). Дурак шикай шикелле сөйли ул. – *стрл.*

**ШИКАЛАЙ** *тпк.* к.: **тықыwыч: итмәк тықыwыч**.

**ШИКАР** [*фарс.*] *т.я., мәл.* шикәр (сахар). Шакмаклы шикар гына бар. – *мәл.* Санийа апа шикар wата, Wақ-wақ итеп шақмағын (*хал. җыр.*). – *к.т.*

**ш и к ә р** (сахар):

**башлы шикәр** *әстр.* кибән формасында итеп койдырылган шикәр (сахар конусообразной формы). Башлы шикәр булыр ыйы әwәле, менә шушылай очлайып килгән шикәр. Күк алашаға да башлы шикәр қаптырып қарадық без сабан туйында. Башлы шикәр чүмәлә кебек итеп йасаган булыр ыйы, байларда булыр ыйы күберәк.

**зур шикәре** *әстр.* кияү өеннән кыз өенә туй көненә дип җибәрелә торган күчтәнәч: шикәр-конфет h.б. (свадебные гостинцы-сладости жениха, преподнесённые в день свадьбы). Зур шикәрендә инде паднус белән зур итеп шикәр-канфит китерә. Зур шикәрендә қодағыйларға кийет бирәләр, мата бирәләр, ақча чәчәләр.

**кечкенә шикәре** *әстр.* кызны ярәшү көненә кияү ягыннан кыз өенә китерелә торган шикәр-конфетлар (гостинцы-сладости, преподнесённые из дома жениха перед свадьбой). Йаучы булып килгәндә камфит-шикәрне апкилә торганыйы. Туған-қардәшләрен чақыра торганнар ыйы, шикәр-камфитны бүлешә торганнар ыйы. Йырақта торган туганнарына җибәрә торган ыйы беткәнчә, аны инде кечкенә шикәре дип тә әйтә торганнарыйы. Йегет биттән қызға йаучы килгәндә кечкенә шикәрен китерә, шулай итеп башын бәйләр өчен инде. Анда канфит, шикәр инде.

**өлкән шикәре** *әстр.* к.: **зур шикәре**. Өлкән шикәрендә зур паднуслар белән канфит-шикәр килә. Ул паднуста канфитлар ғына түгел, шикалатлар, шикәр була, кийетләр була. Өлкән шикәрендә зур паднус белән тутырып әкилә йаучы, шикәр-җимешләр килә.

**шикәр сындыру** *әстр.* кызны бирергә ризалык белдерү (дать согласие на свадьбу). Бу көнне кияү ягыннан бирелгән шикәрне ватып ваклап куялар. Килешәдләр, йома көнне шикәр сындыра торган булганнар. Туй йасилар. Шикәр әкиләде. Монда озын башлы баш шикәр булган. Шуны әкитеп бара доган булган. Кийәүнең әтисенеңме хәрендәше, әнисенеңме хәрендәше шикәр әкитеп бара-ды. Шикәрне сындырып wатып қуйалар. Әйдә, малайыбызға шикәр сындырайық, диләр. Анда шикәр сындырыға алтаумы, җидәүме қодағыйлар килә инде паднусны күтәреп. Канфитмы, шикәрме сындырады ике қодағый. Берawыз булып йәшәйек, берawыз булып торайық, дип. Бер-берсенә тәтле булсыннар, дип. Кәнфит йә шикәрне сындырып икесенә бүлеп ашыйлар ике қодағый. Шикәр сындырған дигән сүз шул инде.

**ШИКЕЛ** [*гар.*] *бәр.* кыяфәт, кыланыш (вид, выходка). Күр әле шикелләрен моның, ни эшләрен белми.

**шикеленнән чығу** *дөб.* кылану, кыяфәтләнү (кривляться, ломаться). Шикеленнән чыгып утырма инде.

**ШИКЕЛСЕЗ** [*гар.* + *афф.* -сез] *каз.ар., бәр.* **1.** к.: **қошбәтсез**. И, шикелсез бит ул, йәмсез. – *блт.* Эндәшмичә қарайып тора бит, үпрәм була, шикелсез диләр. – *бәр.*; **2.** тышкы яктан ямьсез, матур булмаган, начар (плохой, некрасивый, неприятный). Бусысы әйбәт әле, беркөннәре бигрәк тә эшәкесе, шикелсезе қайтқан ыйы халваның. – *блт.*

**ШИКЕЛСЕЗЛӘНҮ** [*гар.* + *афф.* -сезләнү] *мам.* килешсез кыяфәткә керү, кыяфәтсез булу (стать безобразным, терять вид). Йөрмә шикелсезләнеп, ки йахшы күлмәгеңе.

**ШИКЕЛТ, ШИКЕРТ** *перм.* кызык, мәзәк, әкәмәт (потеха, забава, чудо). Кеше күп булса, шикелт чығып тора. Анда йазыб алың әле безнең шикелтләрне, ғәләмәтләрне. Шундый шикерткә

тарыганым бар, Хәтип белә. Монда шикертләр күб у авылда. Шикерт! Шунда сулмаш өскә бардым исә адашам.

**шикерт чыгару** *перм.* гаҗәпкә калдыру (удивлять, поражать). Көн буйына син, ничек печән җиймага кәрәк, карт кеше, шикертеме чыгарасын. Җуқны сүләсә, шикерт чыгарма қый, диләр.

**ШИКЛӘНЧӘК** *т.я.* шөбһәләнүчән, шикләнүчән (мнительный, сомневающийся). Безнең Тәлгат′ тә шикләнчәк. – *трх.* Мин үзем бик шикләнчәк, җаңғыз өйдә дә қунмыйм. – *к.т.*

**ШИКМӘ** *нрл.* басма (мостик). Шикмә салсаңыз да, чыгалмыйм мин (судан).

**ШИКМӘТСЕЗ** *злт., кргл.* к.: **шикелсез**. Йуwан шикмәтсез кеше килә. – *кргл.*

**ШИҚТЫЛАУ** *нокр.* тәкъдим итү (предлагать). Сарыг ите кем дә шиқтылап йермәсме?

**ШИКШЕНҮ** *туб.-урт.д.* шикләнү (сомневаться, подозревать).

**ШИЛ: шил булу** *кмшл.* к.: **сил: кеше айағы сил булу**. Кеше айағы шил булғач килерсез.

**ШИЛӘ 1.** *нөкр., глз., каз.ар., т.я., перм., чст., чпр.* к.: **берче 1**. Шилә җаңғырлар җуқ бит әле. – *мам.* Мансур белми ул, читтә җерде шилә. – *т.я.* Шилә шыны саклыйм. – *чпр.* Ул безгә шилә киләйе, Мыгина әби сүли иде шилә. – *чст.*; **2.** *нөкр., глз., мам., перм., мәл.* әллә (не то, или, ибо). Шилә ун стакан айбағар ашағанмын? – *глз.* Китәргә булса, китәрбез Ташкент йуллары белән, Шилә айырылырбыз микән Дошман сүзләре белән (*хал. җыр.*)? – *мәл.*; **3.** *нокр., глз., мам., перм., кргл., мәл., чст., чпр.* к.: **башала 1**. Мин дә салғалыйм да, қортқа белән татулық шилә бетә, қортқа мине бик ачулана. – *кргл.* Ну қызық та булды шул әтәч, күпме қусам да җибәралмыйым, шилә килми хәзер. – *трх.* Шилә касталандым. – *мәл.* Шилә безне рәткә тыкмыйлар. – *чст.*; **4.** *кмшл., бгрс., перм.* шулай да (всё-таки). Шилә чәчен үрмәде, безгә күрсәтмәде. – *бгрс.* Шилә идәнгә төшердең қый. Шилә мине бергадир апчыгып китте. Мин ниқадәр азапландым, қапқан салдым артаба, шилә икесе қалдәле. – *перм.*; **5.** *бгрс., шрл.* шактый, ярыйсы гына (достаточно, порядочно). Ул бүген шилә йоқлады. Пешә башлаған, тәм кергән шилә. – *кргл.*; **6.** *кмшл., мәл.* чыннан да (в самом деле, действительно). Шилә алыр, бирсәң. Нәрсә йаңғаллыйсың, шилә кешене ышандырыр бит. – *кмшл.* Шилә Тупли (*ав. ис.*) матур икән, ди, сат эчендә, ди. – *мәл.*; **7.** *минз.* к.: **бәләкәй I, 2**. Бәйрәкәтамақ матур awыл шилә; **8.** *мәл.* ачыктан-ачык (явно, определённо). Шилә белә тырып ыланнар атасын тартып алды; **9.** *трбс.* к.: **бер: бер буйдан**. Шилә атлап килдегезме қойаш тотолғанда тимен, йуқ, ди, ағач йанында тордоқ, ти; **10.** *стрл.* барыбер (всё равно). Чатан-чатан булсам да, шилә эшләдем. Шилә кыйынлык бит ул тегермәннәрдә, чират; **11.** *кргл., шрл.* бик (очень). Шилә йаратам, инәй, шуны, қаймақ салынса. – *кргл.* Шилә матур уйный да бит. Шилә ардым әле. – *шрл.*

**ШИЛӘ-БИЛӘ** *мәл.* менә шулай, күз дә йоммыйча (вот так вот, и глазом не моргнув). Шилә-билә йаңалап утыра бит карт башы белән.

**ШИЛКӘТЛӘНҮ** *эчк.* **1.** к.: **сайыгу**. Цебеннәр шилкәтләнде; **2.** акрынаю, басылу (затихнуть). Йаңғыр шилкәтләнә, туқтар.

**ШИЛЛЕК** *трбс.* к.: **шелек 1**. Миллек бәйләтәләр, митла бәйләтәләр шиллектән.

**ШИЛҮ 1.** *кузн., хвл., срг., чст., чпр., злт., кмшл.* кимү, кими төшү (уменьшаться, убавляться, спадать). Қара нихәдәр шилгән бу. – *кмшл.* Симийә күп иде, әле бераз шилде. – *срг.* Әле инде шилә башлагандыр инде. Көннәр жар булғанга йылгада су шилде. – *кузн.* Чиләктәге су шилгән, кемдер салыб алган, ахрысы. Он шилгән. Сөтнең күбеге шилде. – *хвл.* Кешене ашатам, бер пайда, бернәрсә шилми. – *чпр.* Қорсағым шилде. Қорсағым шиләр, әзерәк эшләсәм. Бидрада йеләк тә шилә. – *злт.*; **2.** *мәл.* ябыгу (худеть). Үгезләребез дә шилеп бетә инде, йадау; **3.** *минз., стрл.* к.: **сил: кеше айағы сил булу**.

**ШИЛЫҚ** *тпк.*, **ШИЛЫК** *хвл.* к.: **ботқа: йаңғор боткасы**. Элек йаңғыр йаумайрақ торса, шилық йасайбыd, сыу сибешәләр ийе урам арасынта бидерә белә, awылта мал суйып алып парып пешергәннәр, болонқа төшөп теләгәннәр. – *тпк.* Шилык булган кенне кызлар-йегетләр су сибешәләр, гайепләш тә йук. – *хвл.*

**ШИМ** *тбл.* юләр, ахмак (дурень, дуралей, дурак).

**ШИМӘКЦЕМ** *туб.-урт.д.* ғайбәтче (сплетник, сплетница). Шимәкцем – ошақ йөртәтегән пицә пулаты.

**ШИМЕШКӘ** *злт.*, **ШИМЕШКЕ** *минз.* к.: **чемечки 1**. Бер уч шимешке биреп күңелемне ачты. Шимешкә ашыйсыгыз килсә, йал иткәндә менеб алың.

**ШИМШЕТҮ** *саз.я.* тилертү (одурачить, сводить с ума). Қара эшләпә кийеп, бөтөн қалықны шимшетәтхән.

**ШИМШҮ** *туб.-урт.д.* акылсызлану, юләрләнү (глупеть, сходить с ума). Мин шимшегән карт ғуй.

**ШИНА: ипи шинасы** *дөб.* рахит авыруы (рахит). Ипи шинасы булған дип керәккә бәйләп мискә тыгып алалар баланы.

**ШИНӘ: шинә булу** *дөб., лш.* к.: **шина: ипи шинасы**. Бик йылаған балага шинә була.

**шинә қуwыру** *каз.ар.* рахит авырулы баланы имләү (знахарский метод лечения ребёнка, больного рахитом). Баланың айағы көйлә булмый, шинәне қуwыралар. Қайын тузын қырық бер кисәк итеп имлисең дә шул қайын тузын қуйасың бер табаға. Баланы көрәккә бәйләп, пичкә шул таба турысына, қайын тузы парысына тотасың. Шул тузны алып баланың муйнысына тагасың. «Нәстә имлисең? Фәлән балага шинә булған, шуны қуwырам», – ди. Бала айақланып җөри дә башлый. – *дөб.*

**ШИННЕК** *минз.* к.: **чиннек I, 1**.

**ШИҢГЕЛ** [*удм.*] *глз.* ялгыш (ошибочно). Шиңгел китә бездә телләр.

**ШИП** [*рус.* шип] **1.** *тмн., срг., чпр., клд.* кадак (гвоздь). Анда шиплар бардыр, эл пал′тоң. – *тмн.* Шип белән кагып куй иде шунда үзен. – *чпр.* Шипка бастың айагың белән, галиш, сикергән шикелле. – *срг.*; **2.** *карс.* к.: **агач 1**; **3.** *тмн.* шифер. Шип менән йапкан ызба.

**ШИПА** *стрл.*, **ШИПАЙ** [*рус.* шип] *карс.* к.: **гөләф**. Урманда бәк матур булып шипа үсә йәй көне. – *стрл.*

**ШИПАҚ** *каз.ар.-крш.* уен вакытында откан кеше әйтә торган сүз (слово, которое произносится во время игры человеком, который выиграл). Җәшләр-қызлар урамда уйный торған ыйы, күкәй уйныйбыз, дип. Шипақ дип қуйа отқаны, бер күкәйне отқач, шипақ дип қуйа тайақны.

**ШИПАН** *дөб.* к.: **гөләф**.

**ШИПАР** *лш.* к.: **гөләф**.

**ШИПКА** [*рус.* шибко] *карс., мәл.* к.: **куwат**. Бик шипка киләсен, әкертерәк бар, дийер. – *карс.* Шипка тешми. – *мәл.*

**ШИПЛАУ** *срг.* кадаклау (заколотить гвоздями). Шиплап киттем сарайны.

**ШИР** *тара.* ит шулпасы өстендәге май (жир на мясном бульоне). Итнең өстөндә май булаты, шире. Аны йийып алатылар.

**ШИРАС** *мам.* к.: **йалау 2**. Ул халатына җиде ширас таққан.

**ШИРӘ 1.** *саз.я.* ачыткы, камыр башы (закваска); **2.** *тара.* җиләк суы (ягодный сок). Йеләктән йе, ширәсеннән эц.

**ш и р б ә т** (шербет, сладкий напиток):

**ширбәт каптыру** *кузн.* туйда яшь киленне кияү йортында каршы алганда баллы су яки чәй каптыру йоласы (свадебный обычай: при встрече невесты в доме жениха дают попробовать сладкую воду или чай); чаг.: **авызландыру: кыз авызландыру**. Йегетнең әнийе – кан'ана ширбәт каптыра. Йегет эч кат ыртли, кыз эч кат ыртли, ул инде чече су, эмере буйы йакшы гына чече генә торсоннар эчен, балди, майди гына булыгыз, ди. Аннан сибә өсләренә дә. Шуннан ширбәтне каптыргач, кыдаги фартугыннан алып wак акча сибә.

**ширбәт сону** *крш.* яшь килен алып кайткан суны стаканнарга салып туйда кунакларга бируу (раздача воды, принесённой молодухой и налитой в стаканы, гостям на свадьбе). Җәш киленне печкәчәме суға алып бара, су җулы күрсәтә. Суны алып қайтып өйгә кергәчен, ширбәт дип, ыстаканнарга салып қунақларга ширбәт соналар инде. Җәш килен апқайтқан суны қыйаматлық белән кийәу җегете «ширбәт сонабыз» дип қодаларға, қунақларга эчертеп җөри. Эчкән сawытқа, паднусқа ақча салалар. – *каз.ар.-крш.*

**ширбәткә салу** *дөб.* туй мәҗлесендә кияу белән киленгә бүләк салу (преподнести жениху и невесте свадебные подарки во время свадебного застолья). Туйда ширбәткә салу була: бар да бүләк алып килә. Килгән бер қода сала күлмәклек, чаршаулық, җефәк шәлләр. Шул ширбәткә салу була, киленгә бүләк була.

**ШИРБӘТЛӘНУ** *нгб.-крш.* баллану (сделаться сладким). Бәрәңге ширбәтләнгәндер инде.

**ШИРЕП 1.** *мәл.* яңа (свежий). Күптән чапкан эчен печәннәр ширеп түгел; **2.** *т.я.* майлары сыгылып чыгарга торган – эретелмәгән туң май турында (сало). Көрәйwе җиткән сарықның, эч майлары бик ширеп.

**ШИРЕХ** *саз.я.* уртак эш (совместный труд). Ширехкә аңтынгалы төшөф китте.

**ШИРЛӘУ** *твр.* тиргәу, битәрләу (бранить, ругать).

**ШИРТ I** *перм.* зәхмәтле урын (место, где человек заболевает – поверье).

**ширт булу** *перм.* зәхмәт кагылу (заболеть, захворать). Ширт була анда, җығылырға җарамый.

**ширт салу** *перм.* аяк авыртканда ырымлау (лечить знахарским способом). Айақ awырттисә, чебеч үтереп итен күмәләр, шул ширт салу була, урыны ширт була.

**ШИРТ II** *тбл.* кыл (щетина).

**ШИРТЛӘНУ** *тбл.* **1.** сырт йонын кабарту (ощетиниться); **2.** чәчләр үрә тору (встать дыбом – о волосах).

**ШИТАЙ** *минз.* **1.** к.: **ашық II, 2**; **2.** сөяк (кость). Әй Ходайым, гел сеңгер, қоро шитай ғына.

**ШИТЕМ** [*рус.* шутем] *злт.* сөрелмәгән җирдә үскән үлән (трава, растущая на невспаханной земле). Йақшы шитемнәрне сабалар ат белән.

**ШИТЕМНЕК** [*рус.* шутем + *афф.* -нек] *злт.* сөрелмәгән җир (невспаханная земля). Бездә бар мәтрүшкә шитемнек йердә, йырақ ана тыра.

**ШИФАН** [*рус.* шифон] *трх.* сирень. Шифан чәчәгенең исе бик әйбәт була.

**шифан ағачы** *минз.* к.: **байбай**.

**ШИФИН** [*рус.* шифон] *чст.* к.: **қуқырт**.

**ШИФОН** [*рус.* шифон] *перм.* к.: **кибер**. Шифон йегет, үзен зурға қуйып йөри.

**ШИФРАН** *минз.* ялагай, төче телле (подхалим).

**ШИФРАНЛАНУ** *минз.* ялагайлану, төче телләнү (подхалимничать). Шифранланып йөрмә.

**ШИХ** [*гар.*] *миш.д.* шәех; дин эшләрен башкаручы, дин башлыгы (шейх, духовный наставник). Ших тапмый, шик таба сырхауны (*мәкаль*).

**ШИХАН** [*рус.* шихан] *хвл.* биегрәк калкулык (возвышенность, холм); чаг.: **қаш**.

**ШИША 1.** *трх.* к.: **пийала 2**; **2.** *кргл.* к.: **пузыр**. Безнең әниләр сөйли торган ыйы, лампының шишасына төкергән дә, wатылып киткән дип.

**ШИШАРА I 1.** *каз.ар., байк.* к.: **төш I, 3**. Бәлештән қалған қамырны шишара итеп пешерде. – *лш.* Шишара майаш ононнан пешерәсең. – *байк.*; **2.** *трх.* к.: **чигелдек**. Шишараны күбрәк пешерсәң, терлек үрчи, ди; **3.** *минз.* төче камыр (пресное тесто). Шишарадан күмәч тәмле була; **4.** *т.кам.-крш., кмшл., нгб.-крш.* к.: **йуwача 2**. Шишара күкәйгә генә басасын да майга қайнатып пешерәсен. – *нгб.-крш.* Бәйрәмгә шишара пешереп қуйдым. – *т.кам.-крш.*; **5.** *кмшл., чст.* камырны вак-вак кисеп, эченә повидло салып пешерелгән камыр ашы (мучное блюдо с повидлом внутри). Йаса үзеңә шишаралар. – *кмшл.*

**ШИШАРА II** *чст.* бозлы яңгыр (дождь с градом).

**ШИШАРАТ** *стрл.* к.: **төш II, 3**.

**ШИШӘРӘ 1.** *трх., мам., лш., байк.* к.: **төш II, 3**; **2.** *чст.* токмачның бер төре (вид лапши).

**ШИШИРИ** *кас.* к.: **төш II, 3**.

**'ийеү шиширисе** *кас.* к.: **төш II, 3**. 'оз артындан баралар туй'а, карзинкада 'или шишири, 'ийеү шиширисе.

**ШОБАГА** *кузн.* язмыш (судьба). Һәркас'ының

шобагасы үзенә инде, мин әнинең иң беренчесе идем.

**ШОҒАЙ** *к.т.* саз наратбашы (хвощ иловатый). Шоғай белән җусаң, ағара идән.

**ШОҒАН** *лш.*, **ШОГАН** *глз.* к.: **гөләф**.

**ШОЛАҚАЙ** *туб.-ирт.д.* паралич.

**ШОМ I** *чст.-крш., срг.* бизгәк (лихорадка). Казер шом белә awырмыйлар инде. – *чст.-крш.*

**шом тоту** *каз.ар., т.кам.-крш.* бизгәк тоту (лихорадить). Мине шулай шом тотты да Панаукаға (*ав. ис.*) бүлнискә аппардылар. – *каз.ар.-крш.*

**ШОМ II** *чст.* к.: **салак**.

**ШОМ III** *трх.* к.: **сынчы**. Шул шомнар ғалып, awыл төзегәннәр.

**ШОМ IV** *туб.-ирт.д.* начар, яман (плохой). Йегетне күрү йуқ, шоммы, ысбаймы, көйәүгә пирәтәгән тә қуйатаган. – *төм.*

**ш о м а** (гладкий):

**шома йафрақ** *дөб.* к.: **бақа: бақа қабығы**. Шома йафрақны – шешкә йабу, чәчәген эч киткәндә эчертү өчен файдаланалар.

**ШОМАЛАУ** *минз.* к.: **қарлау**.

**ШОМАН: шоман озату** *т.кам.-крш., каз.ар.-крш.* Масленица бәйрәмендә үткәрелә торган уеннар (игры, которые проводятся в дни Масленицы). Май дибез инде, шуның умбиш көне тулганда шоман озату була. – *т.кам.-крш.*

**ШОМАРЧУК** *чст.* гөмбәнең бер төре (вид гриба: сморчок).

**ШОМНОҚ** *трбс.* к.: **имәнеч 2**. Шомноқ инде, җawып килә җаңғыр.

**ШОМРАН** *мәл.* йомран (суслик). Шомран ойалары күп быйыл басуда.

**ШОМРОТ** *брб.д.* шомырт (черёмуха).

**ШОМСЫНУ** *тара.* ямансулау (грустить, тосковать).

**ШОМТАМАҚ** *тара.* нәзберек (привередливый к еде).

**ШОМШОНУ** *тара.* к.: **шомсыну**. Маа нәрсә булсын, тик үсем шомшынам.

**ШОННОҚ** *нгб.-крш., каз.ар.-крш.* гаҗәп, искитәрлек (удивительно, очень). Шонноқ зур өйләр. Тawышы шонноқ әйбәт. – *нгб.-крш.* Шонноқ бит бу, димен, мине иҗекләп сөйли, димен. – *каз.ар.-крш.*

**ШОННОҚЛЫ** *хвл.* **1.** к.: **йаслawык**; **2.** орышу, тиргәү сүзе (бранное слово).

**ШОҢҚАР** *тбл.* лачын (сокол).

**ШОРМА I** *карс.* к.: **ғ(е)рәплә**.

**ШОРМА II** *том.д.* шулпа (суп).

**ШОРОҚ** [*рус.* швырок] *злт.* бер әрдәнә утын (ряд дров). Теге йортта бер шороқ утын қалды.

**ШОТОРМА** [*рус.* шторм] *хвл.* җил-давыл (вьюга); чаг.: **бур'а**. Әлгәр сабантуйы йуг иде: шоторма куба, диләр.

**ШӨГӨРНӘ** [*гар.*] *брб.д.* яңгыр теләп, корбан чалу (обряд вызывания дождя с жертвоприношением). Шөгөрнә суйады йаңғыр йаумағанда, намаз уғып, итне өч ғазанда бешердек.

**ШӨЙЛӘ 1.** *нрл.* бөтенләй (совсем). Шөйлә сапсары күкәйе, бозылып та қарамаган; **2.** *минз., стрл.* барыбер, шулай да (всё-таки, всё же). Табам бит шөйлә, тырыша торғач. Шөйлә әрәхәт бер кеше белән мыдырдап қалу, ату бер кеше хыйаллandыра бит, әйеме? – *минз.*

**ШӨЙТЕ** *туб.-ирт.д.* шаять, ахрысы (вероятно, возможно). Элекке йылларта булатаан ите цебен, үткән йыл булматы, шөйте. – *тара.*

**ШӨЙТЕМ** [*рус.*] *злт.* к.: **шитем**. Сөрелгән йердә үскәне шөйтем былмый.

**ШӨКӘ** *чпр.* сөкә (морда). Шөкә салганнар анда.

**ШӨКӘТСЕЗ** *минз., кргл.* к.: **шәүкәл**. Кит әле, Ханә апа, шөкәтсезен биргәнсең шуткының. – *кргл.*

**ШӨКЕТСЕЗЛӘНҮ** *мам.* к.: **шикелсезләнү**. Қартайа килә шөкетсезләнәсең икән.

**ШОКИ** *нрл.* агач күбәләге корты (древесница). Шөки ашый бүрәнәне, һаман он чығара шуннан.

**ШӨҚМИТ** *перм.* к.: **қырmawық**.

**шөқмит түз** *перм.* әрекмән төбе (часть лопуха, оставшаяся после порубки).

**шөқмит җапрақ** *перм.* к.: **йафрақ: абдрахман йафрагы**.

**ШӨКРАНА** [*гар.*] *төм.* яңгыр теләп, корбан чалу (обряд вызывания дождя с жертвоприношением). Йаңғыр йаумағанға, қорқақлық булып киткәнгә шөкрана суйғаннар, оллы хайwан. Қуйлар суйып шөкрана йасағаннар.

**ШӨҚТИЛ** *перм.* люпин.

**ШӨЛӘҢҮ** *перм.* чоку (выдалбливать). Шөләңөп алу.

**ШӨЛДЕРМӘ** *минз., чпр.* ыргак (крюк, крючок). Чиләгебез қойыга төште, әләктереп чығарырға шөлдермә кирәк иде. – *минз.*

**ШӨЛДӨР: шөлдөр чәчәге** *мам.* к.: **чәчәк I: бүрәнкә чәчәк**.

**ШӨЛЛӘП** *перм.* ипләп (осторожно). Йүкәғачны шөлләп кенә суйып алабыз, тасма кебек, тасма кебек итеп.

**ШӨЛЛӘҮ** *каз.ар., минз., стрл., т.кам.-крш.* к.: **сақайу 1**. Үзем генә қунарга да бик шөлләдем. – *блт.* Берүзем төннә шөлләп-шөлләп қайттым. Бер селтәнгән ийем, шөлләде дә қалды, бигрәк өркәк икән бу эт. – *минз.* Шөлләп кенә суккалады. – *стрл.* Татый әбидән шөллим мин, қарт булса да усал. – *т.кам.-крш.*

**ШӨМЧЕНҮ** *т.кам.-крш., минз.* к.: **чемчекләү 1**. Ашамый ул шөмченеп.

**ШӨМШЕК** *тара.* кешедән берәр әйбер алырга өмет итеп йөрүче (тот, кто пытается поживиться за чужой счёт).

**ШӨТИМ** [*рус.* шутем] *перм., злт.* сөрелмәгән җир (невспаханная земля). Шөтим йерләр элек күб ийе, қайсы сөрми торган ыйы, аты былмаганы. – *злт.*

**ШӨХБӘТСЕЗ** *кмшл.* к.: **шәүкәл**. Чәч шөхбәтсез тузылған шулхәдәре.

**ШӨХШӨР** *сазл.* сазанак (багульник).

**ШӨШ: шөш йафрағы** *мам.* к.: **бақа: бақа қабығы**.

**ШӨШКҮ** *перм.* к.: **хөрү**. Азырақ шөшкөп қалғандыр. Шөшкетәләрме? Һа, шөшкөттең инде.

**ШӨШЛӘЙ** *перм.* кечкенә чуртан балыгы (маленькая щука). Шөшләй өч килаға таба үстисә, чуртан була.

**ШӨШЛЫ: шөшлы балык** *перм.* шамбы балыгы (налим).

**ШӨШПӘРӘ, ШӨШПҮРӘ** *туб.-ирт.д.* пилмән (пельмени).

**ШУ 1.** *перм., к.-уф.* шул (этот, тот). Шу йердә генә утырып тор, мин хәзер киләм. Минем шу чакта йәш чыкты. – *к.-уф.*; **2.** *перм.* шул (же). Кайтма тийем шу.

**ШУБИКНА** [*рус.* шубёнка] *перм.* эче-тышы мех биялә (меховые варежки); чаг.: **ыркача 1.**

**ШУБИНКА** [*рус.* шубёнка] *перм.* мамыктан сырган оек (чулки на вате).

**ШУWAЛ** *әстр.* моржа, төтен юлы (труба, дымоход). Туйга чакырганда шуwал сайын чакыр дип әйтәделәр.

**ШУWЫТУ** *мәл.* к.: **кауғалау.** Шәт, без шуwытабыз.

**ШУГЫРДА** *күрш.* шунда (там, в нём). Кесәл пешерәм шугырда, шул кәстрүлдә.

**ШУҒУЙМА** *том.д., тбл.* алдакчы, карак (мошенник).

**ШУҒЫРЫК** *туб.-ирт.д.* тишекле чүмеч (шумовка).

**ШУДЫР** *минз.* к.: **чолдор I.**

**ШУЖЫ** [*удм.*] *глз.* к.: **ывыз.** Шужыга камыр чылатып тәбәгый ашамага димлей.

**ШУЙӘК** *дөб.* шаян (шутник). Ул бик шуйәк кеше.

**ШУЙӘКЛӘНҮ** *дөб.* шаярту (шутить). Син шуйәкләнеп утырма.


**ЫРТЫН I** *чпр., м.-кар.* **1.** астыртын, яшерен (скрытно, исподтишка, тайком). Ыртын эшләүчеләр бармы әллә? – *чпр.* Ол ыртын гына җылый, ди. Катыннан ыртын гына эс сум акча алды. – *м.-кар.*; **2.** к.: **акыр: акыр гына**. Ыртын гына кан′ап тора икән бу (су). – *чпр.*

**ЫРТЫН II** *себ.* к.: **латан**.

**ЫРТЫШ: ыртыш ағачы** *дөб.* артыш (можжевельник).

**ЫРУ I** *чпр., кузн., тмн., т.кам.-крш., каз.ар.-крш.* туган, туган тиешле (родные, родственники, родня); чаг.: **йәwер 1.** Миколскида безнең ырywыбыз бар. Саумы, сау килдеңме, саулармы андагы ырулар, кар′д′ашлар берчесе. Бакуда ырулары бар иде. Шолай сүли-сүли ыру да чыгыб ала (ягъни ыру да булып чыгасың). – *кузн.* Ырулары ашқа җөртәләр ийе җәш қызны. – *каз.ар.-крш.* Ул ырywыбыз буладыр. – *лмб.* Митралда ыруларым бар иде, кан′сеңелләрем бар иде. – *тмн.*

**ЫРУ II** *тара.* аяк чалу (ставить подножку). Айақ ырып йықты.

**ЫРУГ** [*рус.* рог]: **ыруг чыгару** *тмн.* яулыкның бер почмагын төенләп, кырыйга калдырып бәйләү (завязывать платок, оставив на одном боку головы рог – кику); чаг.: **кукыйш: кукыйш бәләү**. Кызлар йаулык йабына, ыруг чыгара, эшәл бәли, әле дә шәл бәләмим. Безнен әбиләр камзул кийәләр иде, башларына эшәл бәлиләр иде, башларына йантыкка бер ыруг та чыгаралар иде.

**ЫРУҒА** *каз.ар.-крш.* чиркәүдә никахлашкан өчен салына торган салым (налог, взимаемый за венчание). Кәбен башыннан бер пот арыш, бер пот соло җыл сайын ыруга дип (биргәннәр).

**ЫРУДА** [?] *перм.* өй эчендә әйберләр элеп кую өчен бер стенадан икенчесенә беркетелгән агач (перекладина внутри дома под потолком, на которую развешивают носильные вещи и т.д.); чаг.: **арқылагач**.

**ЫРУЗА** *срг.* к.: **руза**. Ыруза тоталар алар.

**ЫРУ-РАДНӘ** [*тат.* + *рус.*] *лмб.* к.: **нәсел-асаб**. Үзеңнең ыру-раднәләреңдә керә казлар йолкырга.

**ЫРУ-ТАМЫР** *лмб., т.кам.-крш.*, **ЫРУ-ТАРУ** *срг., кузн.* к.: **нәсел-асаб**. Ырывым–тамырым тегел. – *лмб.* Кем кызы да кем кызы – тегермәнче Әндри кызы, диләр, ыру-тамыр әйтә инде. – *т.кам.-крш.* Ыру-тарywым тегел. – *срг.* Ыру-тарywын кергезә. Ыру-тарывыңы күрер идең. – *кузн.*

**ЫРУХСАТ** [*гар.*] *срг.* рөхсәт (разрешение). Ырухсатсыз кылакул бәләгәннәр.

**ЫРЦАЙТУ** *брб.д.* теш ыржайту, авыз еру (скалить зубы, смеяться).

**ЫРЧЫҚБАШ** *глз., нокр.* к.: **ашық II, 2.**

**ЫРШАЙУ** *саз.я.* ыржаю (щериться, ощериваться).

**ЫРШЫК** *чпр.* к.: **дастуй 1.**

**ЫРЫ** *лш.* нарат, чыршы күркәсе (сосновая или еловая шишка). Нараттан ыры қойоладырыйы, шул ырыны җақтық.

**ЫРЫЙ** *перм.* к.: **ат′акыш 1.** Хатын кеше ырый қый, мәгә кәрәк ни ир, эшләб ашағач үзең. Җуқны сөйләп торма эле ырый.

**ЫРЫЙЛАНУ** *перм.* юләрләнү (дурить, дурачиться). Мәйтәм, ыруланып торма, кит-кит моннан.

**ЫРЫҚ** *тпк.* ирек (воля). Ырық бирмәделәр. Бедгә дөнйа көтәргә ырық йуқ монда дип чыгып киткән.

**ЫРЫҚУ** *төм.* сикерү, ыргу (прыгать). Қайын йыгылулы йатқан, айу моноқы өскә ырыққан.

**ЫРЫМАУ** *чпр.* ачуланмау (не ругать). Кан′ам да ырымады, кан′атам да ырымады.

**ЫРЫС** *брб.д.* бәхет, муллык (счастье, благосостояние).

**ЫРЫСЛЫ** *әстр.* кадерле (дорогой, ценный). Ырыслы қунақ.

**ЫРЫСЛАУ** *тбл.* атап кую (предназначать). Сиңа тиб ырыслап қуйтым пу қаңзаны (трубканы).

**ыс I** (чад, дым):

**ыс салу** *твр.* төтен җибәрү, ыслау (дымить, окуривать).

**ЫС II: ыс былу** *злт.* көлке хәлгә калу, төп башына утыру (оставаться в дураках, оставаться в смешном положении). Без килгәнсе лафканы йапса, ыс былабыз инде. Азақ үзе дә ыс былды. Ыс былғаннар теге қызлар, көтөп-көтөп қайтып киткәннәр.

**ыс итү** *злт.* кызык итү, төп башына утырту (оставить в дураках). Ыс итәм дип уйлаган инде ул. Ыс иттек тегеләрне.

**ЫСАК** *лмб.* к.: **осак I.**

**ЫСБАЙЫ** *төм., тбл.* әйбәт, яхшы, вакытында (опрятно, аккуратно). Пинсемне ысбайы алам. – *тбл.* Төгәрмәй утыр, ысбайы эцең. – *төм.*

**ЫСКУТ** [*рус.* свод] **1.** *бөре.* мич сыры (выступ на печи); **2.** *бәр.* мичнең төтен йөри торган юллары (дымоход печи). Ыскутны ике йылға бер әрчибез.

**ыскут башы** *кмшл.* к.: **қашага I, 1.**

**ЫСЛА** *нокр.* к.: **буза I.** Кейәүгә қаса белән ысла берәләр. Ул эчә дә қасаға бүләк йә йөзек, йә ақча сала. Ул қасаны аннан сыңра чыгаралар қызға, қыз қалган ысланы метик эчә дә этәге белән, қыры қул белән дегел, ала. Кешеләр ысла эчкәндә, без чәй эчәйек. Қайтышларына ысла қуйам.

**ЫСЛАН** *төм., тбл., твр.* к.: **бума I.**

**ыслан салу** *тбл., твр.* буа буу (ставить запруду, прудить). Ысланға патып үлте.

**ЫСЛЫҚ** *перм.* корым (сажа). Тартуныңы бериты (зарары) күберәг анықы, утыра бит ул ыслық, чихутқаға әйләнәләр шуннан.

**ЫСМУЛЛА** [*рус.*] *тбл., саз.я.* сумала (смола).

**ЫСНАС** [*рус.*] *тбл.* балык тоту кораллары (снасти). Палық аңтығалы ысначым йуқ.

**ЫСНАЧ I** [*рус.*] **1.** *минз., перм., к.-уф.* теге яки бу эшне эшләү, үтәү өчен кулланыла торган кораллар (орудия труда, инструменты, приборы). Балта останың ысначлары бездә қалған. – *к.-уф.*; **2.** *трх., минз.* к.: **мәрәтә**. Ысначлары хәзер дә күп. – *трх.*

**ЫСНАЧ II** *лмб.* гәүдә (туловище). Минең әнинең ысначы зур иде, тәртә арасына керә иде алаша булып.

**ЫСПАЙЛАП** *тбл.* матурлап, бизәп (украсив, нарядив). Монта төрлө нимәләр тегәтеләр, ыспайлап йылтырақ нимәләр тегәтеләр, уга белән тегеп цығатлар.

**ЫСПАЙЫ** 1. *перм., төм., тбл.* матур, күркәм (красивый, прелестный, изящный). Күлмәгегез ыспайы. Чәкәнне читек ыспайы. – *перм.* Йәптертәкле гөйләкләр, бақ, ыспайы. – *төм.* Антайны қортқайақлар кийә тегәннәр, ыспайы. – *тбл.*; 2. *перм.* яхшы (хороший, добротный). Ыспайы үзәкләрне алып ирлибез ий. Ыспайы қала, җаматайы қойола, тәрәб ас була. Малайға ыспайы булсын, зур булсын дип салдым; 3. *перм., тбл.* әйбәт, яхшы, ипле (хорошо, вежливо). Ыспайы ғына сүләшә, чынны сүләшкән кебек. – *перм.* Пес ыспайы йәшәп киттек. Элек саманта туй ыспайы үткән, арақа эцмәгәннәр, ыспайы үткән уйын-йыр белән. – *тбл.*

**ЫСПУТ** [*рус.* свод] *перм.* к.: **гарнич.** Ыспут хәзер қуймыйлар, шоп-шома ғына шалқанны уйып ыспутқа утыртып қуйабыз, аны май салып чеприккә ут төртәбез ий элек.

**ЫСПУТНА** [*рус.* ступня] *злт.* к.: **галуш: чабата галуш.**

**ЫСТАНУК** [*рус.* станок]: **ыстанук сугу** *күрш.* к.: **сике: сике арасы суғу.** Элән цәцәләр, ыстанук сугалар, киндер була, шуны аклилар и күлмәкләр тегәләр.

**ЫСТАWЫЧ** [*рус.* ставец] *каз.ар.-крш.* кечкенә табак (маленькое блюдце). Ағач ыстаwыч була торған ыйы элгәре, кечкенә табақ. Бәләкәй ыстаwыч.

**ЫСТАЙА** [*рус.*] *к.т.* к.: **йага I, 4.** Әнә шул ыстайаға утыр.

**ыстайа җақ** *к.т.* уңай як, җайлы як (удобное направление, удобная сторона; удобный момент).

**ыстайасы килү** *к.т.* җае килү (при удобном случае, моменте). Ыстайасы килгән, кердем.

**ыстайасын табу** *к.т.* җаен табу (улучить момент, изловчиться). Ыстайасын табалмыйм, ыстайасы килсә ачыла (йозак).

**ЫСТАЙКА** [*рус.* стойка] *яүшт.* 1. каралтылар (надворные постройки); 2. к.: **абзар 1.**

**ЫСТАН** *тбл.* к.: **ырдын.**

**ЫСТАУ I** *кузн.* к.: **йага I, 4.** Йир чәчә идек шул ыстауда, без дүрт бырат идек.

**ЫСТАУ II** [рус. став] *стрл.* к.: **каплама 1.**

**ЫСТИНАЛАП** [*рус.* стан + *афф.* -лап]: **ыстиналап тегү** *трх.* билле итеп тегү (шить приталенным и расклёшенным книзу). Күлмәкне боропборопыстиналап тегә идек.

**ЫСТРАМ** [*рус.* срам] *миш.д., злт.* оят (стыд).

**ыстрам сату** *кузн., хвл.* хур итү, оятлы итү (позорить). Ник син болай ыстрам сатасын? – *кузн.*

**ЫСТУЙКА I** [*рус.* стойка] *эчк., минз.* өй күтәргәндә, нигезенең дүрт почмагына чокыр казып утыртып калдырылган юан агач (стойка). Без ыстуйка салабыз, таш йуқ монда. – *минз.*

**ЫСТУЙКА II** [*рус.* стойка] 1. *дөб., срг.* к.: **лагун.** Ыстуйка awызыннан эчәрийе ничә кеше булса да. – *дөб.* Ыстуйкага бер циләк су китерми. – *срг.*; 2. *кузн.* яшелчә тозлый торган агач кисмәк (деревянная кадка для засола овощей).

**ЫСТУПАЙ** [*рус.* ступа]: **ыступай бәлеш** *перм.* к.: **қайтыраш.** Ыступай бәлешләр пешә өч кич қунғач, қайталар була.

**ЫСТУПН'Ы** [*рус.* ступня] *баст.* юкә башмак (башмаки из липы).

**ЫСТУТИН** [*рус.* студень] *тара.* койка, дереллдек (холодец). Сыйырнын айақларыннан ыстутин пешерәбес.

**ЫСТЫЙКА** [*рус.*] *хвл.* к.: **ыстуйка II, 2.** Ыстыйкага тутыралар иде капыстаны, банкыга.

**ЫТЫК-СЫТЫК** *стрл.* иске-москы (лохмотья, старьё, обноски). Бизгәк бизсен дийеп, ары-бире тагалар ийы ытык-сытык.

**ЫТЫРҒАУ** 1. *дөб., минз.* чиркану, җирәнү (брезговать, испытывать неприятное ощущение). Керергә ытырғап торасың, былчырақ кылуп, шуны йуwып чыгарырға кирәк. – *дөб.* Ытырғап торорсың аның өйөнә керергә. – *минз.* 2. *минз.* жәлләү, кызгану, саклау (оберегать, жалеть). Ытырғаған баланың бәхете булмас, ди. Менә мин ғөмөр буйына Шәһитемне ытырғадым, эшкә җибәрмәдем, бәхетләре йуқ; 3. *к.т.* тән чымырдау (передёрнуться всем телом; забегать – о мурашках). Синең шул сүзеңне ишеткәч, бөтен тәнем ытырғап китте; 4. *лш., к.т.* рәнжү, күңел әрнү (сильно обижаться). Ытырғыйм да инде синең шул сүзләреңә. – *к.т.* Җөрәкләрем ытырғады. – *лш.*

**ЫТЫРҒУ** *тпк.* к.: **ытырғау 2.** Шуны ытырғыб аптырадың.

**ЫТЫРҒЫ** *том.д.* өтерге (долото).

**ЫТЫРЫ** *дөб.* к.: **оторо 5.** Җәйнең көне эризиңке кисәң, ытыры сызлый айақ.

**ЫУҒЫСУ** *твр.* борчылу (беспокоиться). Миңниса килен ыуғысып тормасын.

**ЫХ: ых йақ** *саз.я.* төньяк (северная сторона). Ых йақтан киләтләр.

**ЫХТЫМАТ: ыхтымат йату** *минз., стрл.* шып яту, шып итеп кереп утыру, төгәл кереп урнашу (быть впору, точь-в-точь). Уйып алабыз бүрәнәне, икенче бүрәнәгә ыхтымат йатсын өчен. – *минз.*

**ЫЧҚАНУ** 1. *твр., тбл., том.д.* көчәнү (кряхтеть, тужиться). Күб ычқанмаң. – *твр.*; 2. *брб.д.* уфылдау, ыңғырашу (охать, стонать).

**ЫЧКЫРОЧ** [*рус.* сквозь] *чст.* үтәдән-үтә (насквозь). Нигезне тишеп ычкыроч йөри ул кыриса.

**ЫЧҚЫРЫҚ** *т.я.* очкылык (икота).

**ычқырық тоту** *т.я.* к.: **кикнату.** Байадан бирле ычқырық тота, үләм инде, су эчкәч тә басылмый. – *нрл.*

**ЫЧЛЫЙ-ЫЧЛЫЙ** *срг.* бер-бер артлы (один за другим). Безгә бит хасрәт ычлый-ычлый туры килде.

**ЫЧЛЫҚ** *кузн.* аяк киемнәре тегәр өчен ясалган сумалалы җеп, җеп очы (дратва).

**ЫЧНАЧ** [*рус.* снасти] *перм.* киндер станы (ручной ткацкий станок). Киндернеке мә! Ычначы була суға торган.

**ЫЧТАWЫЧ** [*рус.*] *каз.ар.-крш.* к.: **ыстаwыч.**

**ЫЧТИНАЛЫ: ычтиналы итеп тегү** *к.т.* к.: **ыстиналап: ыстиналап тегү.** Ычтиналы итеп тегәдер ийек күлмәкне, моннан бөрөп-бөрөп, киң итеп.

**ЫЧТЫҚ** *чпр.* мактанчык (хвастливый; хвастун). Ычтык бит ул, ышанма син.

**ЫЧЫКЛАУ** *эстр.* имләү, ырымлау (ворожить, заговаривать – болезнь; наговаривать, заклинать). Бер йиңгә килә дә ычықлый киленне.

**ЫШ: ыш салу** *брб.д., твр.* к.: **ыс I: ыс салу.**

**ЫШАНДЫҚ** *перм., к.-уф.* ышаныч (доверие).

Ирләргә ышандық йуқ қый. – *перм.* Бу кешегә ышандық йуқ, әллә нәрсә эшләп ташлар. – *к.-уф.*

**ЫШАНДЫҚЛЫ** *бөре., перм., к.-уф.* ышанычлы (надёжный, верный, достоверный). Миләш булған йылны ышандықлы була, иген була, имеш. Ул болай бик ышандықлы буғай. – *к.-уф.*

**ы ш а н д ы р у** (обещать):

**ышандыра бару** *хвл., срг.* кунакка алдан чакырып кую (заранее пригласить в гости). Үлә чығышына ышандыра барасын. – *хвл.* Абстакайны ышандырырга бардым (кунакка). – *срг.*

**ЫШҒЫРЫҚ** *тбл.* селәгәй (слюна, слюни). Ышғырығын цацып гәпләйте.

**ЫШҚУ** *перм.*, **ЫШКУ** *срг.* идәнне юу (мыть пол). Идән ышкыма келим. Идәнне дә ышкымадым бөген.

**ЫШКУWЫЧ** *мәл.* мунчала (мочало, мочалка для мытья); чаг.: **йуғыч**. Миннән келәләр, ышкуwыч сырадым да.

**ЫШКЫГЫЦ** *мәл.* идән юа торган мунчала (мочалка для мытья пола). Ышкыгыц вата пиц артында.

**ЫШҚЫНДЫРУ** *том.д., тбл.* узындыру (потакать, баловать – о ребёнке).

**ЫШЛАПЫР** [*рус.* шлифор] *блт., мам., бәр., кмшл.*, **ЫШЛАФЫР** *минз.* күлмәкнең якасына, күкрәк турысына тегеп куела торган тар бала итәк (воланчик, пришиваемый к воротнику или на грудь платья). Бу күлмәкнең ышлапыр йақасы. Түгәрәк ышлапыр да була, бу йарты ғына ышлапыр. – *блт.* Ышлапырлы итеп алйапқычлар тегәр ийек. Бала итәкле дә була күлмәк, ышлапырлы да була, ике рәт итеп тоталар ыйы. – *мам.* Ышлапырны кыругум қуйалар ыйы. – *бәр.* Ашқа йөри торған күлмәк, жақа урынына ышлафыр йасыйлар бөрөп челтәрдән, аннан ике қатлап қуйалар ыйы читсадан тағын ышлафыр йасый. – *минз.*

**ЫШЛАУ** *брб.д.* к.: **ыс I: ыс салу**.

**ЫШНА** *лш., мам.* урман эчендә чәчүлек өчен яки печән чабып алу өчен аерым хуҗалыкларга бүлеп бирелгән алан (лесная поляна, разделённая под посев или под сенокос отдельным хозяйствам). Печән күп, ышнасы барлар чабалар. Урманда бүлеп бирәләр дә, бүлемне ышна диләр. – *лш.* Айырым хуҗалықта ышналарның исемнәре бар ыйы. – *мам.*

**ЫШТАҒЫ** [*фарс.*] *тбл.* аждаһа (дракон).

**ЫШТАПЕЛ** *әстр.* тукыма (полотно). Болай халыққа ыштапел бирәләр.

**ЫШТОП** [*рус.* штоф]: **ыштоп шәл** *брб.д.* чуптарлап эшләнгән калын шәл (платок с узорами). Ыштоп шәл чуқлары қара, чичәкләре күкчин (сирень төсле), шәле ғара.

**ЫШТОФ** [*рус.* штоф] **1.** *минз., стрл.* затлы тығыз ефәк тукыма (ценная плотная шёлковая ткань). Зөлхәбирә күлмәк тектергән, Итәгенә ыштоф тотторған (*бор. бәет.*). – *минз.* Ыштоф бер кыйммәтле нәрсә инде, бәрхеттән дә кыйммәтле. – *стрл.*; **2.** *тпк.* чуптарлап эшләнгән калын материал (толстая ткань с узорами). Ыштоф камдул киделәр.

**ЫШТУФ** [*рус.*] *карс.* к.: **ыштоф 2**. Ыштуф камзул алып бирер идем, Нинди күлмәк белән кийәрсен (*хал. җыр.*).

**ЫШТЫР** *перм.* **1.** к.: **гәрәбайақ**; **2.** к.: **йубалгы 1**. Ыштырырақ булд(ы) исә – шапарақ кеше була. Ыштырырағ анда күбесе кеше.

**ЫШЫҚ** *тбл.* яшерен (тайный, скрытый).

**ЫШЫҚЛАП-ЫШЫҚЛАП** *әстр.* имли-имли (заговаривая, заклиная). Ышықлап-ышықлап өйгә кертте.

**ЫШЫМ** *чст., чст.-крш.* к.: **шом I**.

**ышым тоту** *чст.*, **ышым тыту** *чст.-крш.* к.: **шом I: шом тоту**. Ышым тытты мине, бер җәй имән кайрысы эчтем. – *чст.-крш.*

**ЫШЫРУ** **1.** *м.-кар.* этү, күчерү (передвинуть). Самавырны тегендәрәк ышыр; **2.** *тпк.* ышкып алу (потереть). Анаwы себеркегә бәйләп кенә ышырмадың бит буйаулы идәнеңне; **3.** *минз., стрл.* кирәген бирү (давать по заслугам, наказывать, взгревать). Қайсы йере кечи тегенең, ышырдым ғына. – *минз.*

**ЫШЫРЫЛЫП, ЫШЫРЫП** *минз., стрл.* дәррәү (разом, гурьбой). Ышырып керткән туталарын бич. – *минз.* Жиде кеше микән мондалар ийе, ышырылып чыктылар бар да йортка. – *стрл.*

# Э

**ЭВ** *миш.д.* к.: **ызба**. Эвгә килерсен, цәй генә куйармын, прәмәц кенә пешерем. – *күрш.* Бар, эвеңә кит. – *мәл.*

**утыру эве** *миш.д.* аулак өй; яшьләрнең күңел ачу өчен җыелып утыру өе (дом, где собирается молодёжь для посиделок). Утыру эвендә йегетләр сүлиләр, йөзек салыгыз, диләр.

**ЭВЕНДӘ-ИЛЕНДӘ** *карс.* яшәгән, торган җирендә (на месте, где жил). Ну барыбер чарасы тиде анарга, эвендә-илендә йакшылык-изгелек күрмәде.

**ЭВЕРҮ: эвереп бәләү** *кузн.* к.: **негез: негез чыгарып бәләү**.

**ЭWЕРҮ** *брб.д.* **1.** эрләү (прясть); **2.** әйләндерү (вращать).

**ЭWЕРЦЕК** *брб.д.* орчык (веретено).

**ЭВНӘ** *м.-кар.* к.: **игнә**.

**эwнә кадаучысы** *м.-кар.* к.: **энәлек I, 2**.

**эwнә карак** *м.-кар.* к.: **энәлек II**.

**ЭҖНӘ** *м.-кар.* к.: **эзнә**. Ойык бәйлиләр, тоже эҗнә. Чыршы эҗнәсе.

**ЭЗӘР** *каз.ар., нгб.-крш., т.я.* к.: **зәр**. Элек заманда җегетләр қызыл эзәр бuwып йөриләр ийе. – *лш.* Элек эзәрсез беркем дә йөрмәде. – *нгб.-крш.*

**эзәр бawын тишү** *чст.* туй йоласы: кияү кергәч, кыз аның билбавын чишә (свадебный обычай). Йегетнең эзәр bawын тишә кыз.

**ЭЗЕЛДЕК** *чст.* бер саплам җеп (один конец нитки; нитка, достаточная, чтобы один раз вдеть в иголку). Энә йепне адаштырырга кели, йеп эзелдекне – «энә, йеп, эзелдек» уены.

**ЭЗЕЛҮ** *кузн.* уен вакытында ике кеше җитәкләшеп барганда ике якка аерылып йөгереп китү (во время игры, когда два человека, идущие дер-

жась за руки, вдруг разбегаются в разные стороны). Икәү эзеләсең дә чабасың.

**ЭЗЛЕК** *минз., стрл.* эзләүче, эзләп килүче (разыскивающий). Сезнең артыгыздан эзлек килер. – *минз.* Ни булса йугалтканнар да шунарга эзлек чыга инде. – *стрл.*

**ЭЗМӘКӘЙ** *минз., стрл.* шәл чите бизәге исеме (название узора края шали).

**ЭЗНӘ** *м.-кар.* энә (игла; спица). Бәйли тырган эзнә була.

**ЭЙАРА** *минз.* к.: **йорт 1.**

**ЭЙӘЛӘМӘ** *кмшл.* мөлдерәмә (доверху, до краёв). Эйәләмә тутырганнар чиләкне (җиләк белән).

**ЭЙЕК** *туб.-ирт.д.* ияк (подбородок).

**ЭЙЕРҮ** *туб.-ирт.д.* чирату, кату, ишү (скручивать, ссучивать).

**ЭЙНИ** *кас.* к.: **эзнә.**

**ЭЙНУ** *т.я.-крш.* к.: **анай 1.** Эйну чуваш булган, Карамалдан (*ав. ис.*) килгән.

**ЭЙТ** *кас.* к.: **кочок.**

**ЭЙЧОУ** *т.я.-крш.* к.: **тәтә 2.** Эйчоу, мин мында дип кычкыра мина.

**ЭЙҮ I** *т.кам.-крш.* к.: **ийү 1.** Дуга эйә. Җегетләр дә кебек йегет кеше Элмәләрдән дуга эймәсме (*хал. җыр.*)?

**ЭЙҮ II** *туб.-ирт.д.* **1.** җибәрү (отпускать, посылать). Атамга қағас килте қайтуға, ә инә эймәйте песне. – *твр.*; **2.** ярдәмче фигыль (вспомогательный глагол). Қана, битеңне йуыб эйәйен. Палама пүген түрт тултыр, пишкә пасыб эйте. Цай қойып эйсә!

**ЭЛӘ** *т.я.* өйнең почмагына ясап куелган аркылы киштә (перекладина для вещей, устроенная в углу или около печи). Тастымалны ишектән кергәч тә элеп қуйасың әләгә, аны нәзек кенә ағачтан йасыйлар ыйы. Элә булмаса, қулларына бирәсең инде. – *трх.*

**ЭЛӘГЕТ** *перм.* ләгънәт (проклятье). Угата элә-гет инде шушы малай.

**ЭЛӘГЕТЛӘҮ** *перм.* әләгешү, бәйләнешү (ссориться). Мин аның белән әләгетләмийем, ди.

**ЭЛӘЙ I** *эчк.* кечкенә эскәмия (маленькая скамейка). Әләй өстенә қуйғанмын қашықны.

**ЭЛӘЙ II** *туб.-ирт.д.* мич казнасы (основание печи). Әләй ғырға утыр. – *тмн.*

**әләй тақта 1.** *тбл.* эскәмия (лавка, сиденье); **2.** *тара.* к.: **набулат 1**; **3.** *тбл.* сәке (нары).

**ЭЛӘК I** *миш.д.* җиләк (ягода). Кайын әләге. – *лмб.* Сәйет йөзөб бетерә әләкләрне. – *кузн.* Сузылып алдым әләкне кайыннан, Мин саргайдым синең кайгыңнан (*хал. җыр.*). – *хвл.* Урманга барабыз әләккә. Тагы әләккә керә кеше булмагац. – *срг.* Әләккә барса, әләк йыйар иде бер чашка. Элекке әләккә барыга йарамый ийе, куwалар ийе. – *чст.* Кызлар, әләккә барабыз. – *чпр.*

**йөзем әләк** *хвл.* йөзем җимеше (виноград). Йөзем әләк белән бутка пешерәләр.

**күк әләк** *клд.* к.: **бөрлегән II: кара бөрлегән.** Күг әләк күзгә бик фәйдәле икән.

**нугай әләге** *карс.* к.: **гөләф.**

**ЭЛӘК II** *нокр.* к.: **илгәк.** Әләк белән он әләйбез.

**ЭЛӘКЦЕН** *тбл.* әләктергеч (зацепка).

**ЭЛӘКШӘ** [*рус.* лапша] *миш.д.* к.: **салма 1.** Әләкшәне кисеп калдырдым да, салып ашарсыз. Әләкшәне беген пешермим ди бит әле. – *чст.*

**ЭЛӘМӘ** *дөб.* к.: **дүстер.**

**ЭЛӘН** [*рус.* лён] *миш.д.* җитен (лён). Этекәй, элән чәчмәдең, Чәчрәп чәчәк атмады (*бор. җыр.*). – *лмб.* Быйыл бездә элән уңды. Элән орлок вак була. Элән дә чәчәләр урыс халкы. Элеке бик чәчәләр иде әләнне. – *хвл.* Элгәре элән тугый идек. – *чст.* Элән ырлыгын ашарга йарамый. – *шрл.*

**элән тарту** *лмб.* җитен йолку (убрать лён). Кызны итәләр урманга элән тартырга.

**ЭЛӘНГӘЦ 1.** *чпр.* к.: **чиләк I: әбәт чиләге**; **2.** *кргл.* агачтан ясалган катык савыты (деревянная посуда для квашеного молока, катыка).

**ЭЛӘНГӘЧ** *чст.* к.: **чиләк I: әбәт чиләге.**

**ЭЛӘНКӘЙ** [*рус.* лён + *афф.* -кәй] *тмн.* к.: **элән.** Аг элән кәй царшау комац бау, Кор дисәгез дә кормамын (*хал. җыр.*).

**ЭЛӘҢГӘЗ** *т.я.* агачтан чокып ясалган кечерәк кисмәк, тәпән, гадәттә ул бодай камыры ачыту өчен, бал, тоз кебек әйберләр салып кую өчен кулланыла (небольшая кадка, изготовленная из полого ствола дерева); чаг.: **кыwашҥа 2.** Күмәченне пичкә тыққач уқ элаңгәзеңне җуwып қуй, ату икенче җулы изгәндә қамырың әче булыр. Тоз элаңгәзе келәттә. Элаңгәз-элаңгәз баллары җыл әйләнәсенә җитә. Бер элаңгәз тутырып қамыр изгән: қабартма пешергән, күмәч салған. – *к.т.*

**ЭЛӘҢКЕТ** *злт.* хәлсез, әлсерәгән (обессилевший, измотанный). Асмын, әлсерәгәнмен, элаңкет кебек. И, элаңкет дип әлсерәгән эткә әйтәләр.

**ЭЛӘТАНАҚ: эләтанағы қалмаған** *блт.* к.: **энәталақсыз.**

**ЭЛӘТАНАҚСЫЗ** *каз.ар.* к.: **энәталақсыз.** Өстебашы эләтанақсыз, қылқа. – *лш.*

**эләтанақсыз итү** *лш.* **1.** к.: **энәталақсыз: энәталақсыз итү**; **2.** к.: **селдәү 2.**

**ЭЛБӘДА** [*рус.*] *тмн.* к.: **алабата.**

**ЭЛГӘК** *перм.* ырғаклы элгеч (крюк, крючок, зацепка). Элгәк қый ул, сәли ағач тығарға.

**ЭЛГӘН-ТАҚҚАН** *перм.* өйне матурлау өчен эленгән пәрдә, чаршау, сөлге һ.б. (полотенца, занавески и т.п.). Элгән-таққаннарны йуwыйм тийем.

**ЭЛГӘР** *хвл.* элек (раньше). Элгәр келәтләр ызба алдында буладыр иде.

**ЭЛГӘРЕ I** *т.я., злт., т.я.-крш., миш.д.* элек (раньше, прежде).

**көн элгәре** *т.я.-крш.* бер көн алдан (на день раньше). Сезнен белән бергә утырулар Көн элгәре керде төшемә (*хал. җыр.*).

**элгәре йыл** *злт.* өченче ел (позапрошлый год). Элгәре йыл килгән шуфирлар Мәскәүдән килгәннәр ийе.

**элгәре көн** *злт.* өченчекөн (позавчера). Элгәре көн былды.

**ЭЛГӘРЕ II** *перм.* **1.** к.: **бүлмәч 2.** Мин элгәредә әйтеп қуйдыми қолағына ғына; **2.** түр (передний угол, противоположная сторона от двери). Бетеки үнең элгәресе дә бер, ишек төбе дә бер. Ызбаның элгәренә узмаға кәрәк қый. Ишек мөгөштә дә, элгәре мөгөштә дә эш.

**ЭЛГӘРТЕ, ЭЛГӘРТЕН** *к.-уф.* к.: **бүлмәч 2.** Аш пешерә торған җирне элгәрте диләр бездә. Сандыкны элгәртенгә утыртып куйалар ыйы.

**ЭЛГӘШҮ** *каз.ар., т.я., минз., стрл.* җитешү, өлгерү (успевать). Тутаң қайтып элгәште микән инде, қызым? – *лш.* Син элгәшмидер ийеңме теге машинаға? – *каз.ар.-крш.* Бик соң киттеләр, пойызға элгәшсәләр йарар иде. – *к.т.* Көчкә мунчаға кереп элгәштем бит, йawa башлады. – *минз.* Җиләкләр килеп чыга, ашаб элгәшеп булмый, алжапкычка җыйдым. – *стрл.*

**рәхәткә элгәшү** *т.я.* рәхәткә тиенү (достичь благоденствия).

**ЭЛГЕ I** *лмб.* гыйбрәт (поучительный пример). Миннән дуслар элге алыгыз, Йибәрмә айучы кунарга (*бор. җыр.*).

**ЭЛГЕ II** *карс.* элгеч (вешалка).

**ЭЛГЕК, ЭЛГЕТ** *туб.-ирт.д.*, **ЭЛГЕЦ** *тмн.* киемдәге төймә өчен элмәк (петля для пуговиц на одежде).

**ЭЛГЕЦӘ** *төм.* элгеч (вешалка).

**ЭЛДЕК** *перм.* каптырма (застёжка).

**элдек бау** *злт.* к.: **ыңқыр: ыңқыр бawы.** Кийәү йортта wақ малайларға әлдек бау тарата.

**ЭЛДЕРӘ** *әстр.* савыт-саба шүрлеге (полка для посуды). Менә тустақайларны элдерәгә қуйам.

**ЭЛДЕРГЕЧ: ишек элдергеч** *перм.* ишек элгече (дверной крюк).

**ЭЛДЕРЕК** *әстр.* к.: **кәпкер.** Пешкән қабақны элдерек белән алып, табаққа пуднусқа салып, суытып ашыйбыз, шуны чәй белән әчәбез.

**ЭЛДЕРМЕЧ** *перм.* **1.** к.: **элгец**; **2.** элмәк (вешалка – у одежды); **3.** к.: **элдергеч: ишек элдергеч.**

**ЭЛДЕРҮ** *перм.* **1.** элү (повесить). Чобаны сабантуйларында гына кийәсең дә қайтқач элдереп қуйасың. Мә, пинжагыңны элдереп қуй, Илнур; **2.** каптыру, төймәләү (застёгивать). Элдер үңгереңе, диләр, ычқынса, үңгереңе ач, тиләр.

**учақ элдерү** *т.я.* учак кабызу (разжечь огонь в очаге). Учақ элдерсәләр дә крачинға маналар. Утыны чи, учақ элдереп булмый. – *нрл.*

**ЭЛЕК I** *лмб., кузн., хвл., мәл., чпр.* җелек (костный мозг). Севәк элеге. – *лмб.* Элгәре байлар йарлы кешенең элеген сывралар иде. – *хвл.* Аның бит сүwәгенең элегенә үткән инде. – *мәл.* Сүwәг эцендә элекләре булмый икән кышларның, аларга ыцарга йеңел икән. – *чпр.*

**арка элеге** *срг.* арка мие (спинной мозг).

**ЭЛЕК II** *нокр., глз.* к.: **илгәк.** Элек сарайда, ни илемеге буласы. – *глз.*

**ЭЛЕК III** *перм.* иртә (рано). Мә ашыгасың, әле элек қый. Утырырға элегерәк әле, йәш тулмаған (бала турында). Элек өлгөргән шул бу, моңа суны күп салсаң, элек өлгөрә ти ул.

**кичәдән элек** *перм.* өченчекөн (позавчера, третьего дня).

**элек кицтән** *чпр.*, **элек кичтән** *хвл.* кич була башлагач (с раннего вечера). Элек кичтән үк йатып йоклый да төнне уйанам дип зарлана.

**ЭЛЕ'Е** *кас.* к.: **элгәр.** Эле'е шулай эшлий ийе.

**элеке көн** *перм.* к.: **элек III: кичәдән элек.**

**ЭЛЕККЕ** *мам., хвл.* беренче (первый). Минем дә ул элекке ирем, мин дә аның элекке хатыны, тигез йәшибез әле. – *мам.*

**элекке йыл** *перм.* к.: **элгәре I: элгәре йыл.** Үткән йыл мыса, элекке йыл мыса килделәр ийе. Элекке йылны җийып қуйдым ыйы.

**ЭЛЕМ-ҚОРОМ** *бөре.* өйгә элү әйберләре (занавески). Элем-қором әйберләре: шаршаулар, чымылдықлар була.

**ЭЛЕМ-ТАЛЫМ** *саз.я., тара.* эленке-салынкы (неряшливый).

**ЭЛЕМТӘСЕЗ** *блт.* түземсез, чыдамсыз, тотрыксыз (неустойчивый, невыносливый). Бернәрсәгә йарамый менә бу ситсы, элемтәсез.

**ЭЛЕМ-ЧАЛЫМ** *трх.* аз-маз (очень немного); чаг.: **безрәк.** Элем-чалым ғына җауды җаңғыр.

**ЭЛЕНГЕ** *лмб., чпр.* к.: **коргоч.** Кыз үwеннән чаршау инде, тәрәз эленгеләре, йастык тышлары илтәләр. – *лмб.*

**ЭЛЕНДЕРҮ** *хвл.* тегү, тегеп кую (пришить). Йантыгында кесә элендергән.

**ЭЛЕНМӘҮ** *лмб.* бик тиз бетү (очень быстро кончаться). Бер кадак сабын эленмидер дә.

**ЭЛЕНҮ I 1.** *кузн., хвл., срг.* эләгү, туры килү (попасть). Ул ничектер безнең Узинга (*ав. ис.*) эленә. – *кузн.* Бу кеше бер сира эленде инде төрмәгә. Минем кулыма эленде бер китап. – *срг.*; **2.** *срг., тмн.* к.: **элгәшү.** Туй багарга элендегез инде. – *тмн.* Без бераз элендек. – *кузн.* Икатна эшләргә генә эленгән. – *срг.*

**ЭЛЕНҮ II** *себ.* эләгү (зацепиться). Ул арада айағымды эленеп йығылдым.

**тел элену** *тмн.* тотлыгу (заикаться).

**ЭЛЕҢГЕ** *лмб., чпр.* пәрдә (занавеска). Кыз үwеннән тәрәз элеңгеләре илтәләр. – *лмб.* Тәрәзә элеңгеләрем дә бар, элмәгән әле. – *чпр.*

**ЭЛЕП** *лмб., т.я.* алып, башлап (начиная с ..., с, от). Иртәдән элеп көтәбез Әхмәтне. – *лмб.* Көздән элеп аурый. Моннан элеп қой җанына хәтле җөгөрдем. – *к.т.*

**ЭЛЕШ** *лмб.* өлеш (доля).

**атна кич элеше** *лмб.* ярәшкәннән соң кыз янына китерелгән күчтәнәч – күмәч (обычай: принесённые после сговора в дом невесты гостинцы, обычно – белый хлеб). Йәрәшкәннән сың инде күмәч китерәләр акча салудан элек, атнакич элеше илтү була.

**ЭЛҖИН** [*рус.* Ильин] *крш.* керәшен татарлары үткәрә торган җәйге бәйрәм (христианский праздник – Ильин день, который празднуют крещёные татары).

**ЭЛИН** *кас.* к.: **элән.** Элин үстермәйләр безди.

**ЭЛИП** *кас.* к.: **элеп.** Питердин элип 'ил'ин.

**ЭЛКЕ** *кузн., хвл., тмн., трх.* элек (раньше, прежде). Аннан элке скулкы булгандыр әле. Элке булган вет барски налук, коллар шикелле; байлар тоткан инде үзләрен, теләсә нәстә эшләткән. – *кузн.* Мазарлы халкы бездән элкерәк килгән, матри. Элке абзарга чыгарга курка идең төнне (кызлар турында). Тамбур белән чиккәннәр элке.

Элке кийәүгә, аннан инде кийәү йегетләргә йырлыйлар. Балык сөзәрбез элке, аннан син кереп тынарсын. – *хвл.* Элке безнең эти ақча күрмәгән, бабай қулында булған. – *трх.*

**ЭЛКЕ-СЕЛКЕ** *перм.* к.: **алғай-салғай**. Әнә шулай элке-селке эшләб үрәнделәр.

**ЭЛКЕН-СЕЛКЕН** *чпр.* эленке-салынкы (вяло, неряшливо, медленно). Элкен-селкен эшлиләр кызлары.

**ЭЛКҮК** *шрл.* элек үк (ещё раньше). Аны элкүк белә идем.

**ЭЛМӘ I: элмә чәчәге калмау** *хвл., мәл.* сәләмәләнеп бетү, тузып бетү, ерткаланып бетү (сильно истрепаться, изорваться, стать обветшалым); чаг.: **чачалану 2**. Элмә чәчәген дә калдырмаганнар йаулыгымның. – *мәл.*

**ЭЛМӘ II** *туб.-ирт.д.* элгеч (вешалка).

**ЭЛМӘ III** *минз.* өйгә элү өчен әзерләнгән килен әйберләре (вещи невесты, приготовленные для развешивания дома). Зәңгәр белән озатқан, қара белән читләгән элмәләр булалар ыйы. Ару кеше шулай элмәләр алып бара.

**түр элмәсе** *минз.* кашага (бордюр). Түр элмәләрен дә чигәләр ийе.

**ЭЛМӘ IV** *перм.* өрәңге (клён).

**ЭЛМӘК I 1.** *лмб., срг.* к.: **элгеч**. Нәк элмәге булмасын (пальтоның). – *срг.*; **2.** *тмн.* төймә (пуговица).

**ЭЛМӘК II** *туб.-ирт.д.* келә (щеколда, затвор).

**ЭЛПӘ I** *блт.* к.: **элпе II: қаты элпеле сыйыр**. Қаты элпәле бу сыйыр, сawарға озақ.

**ЭЛПӘ II** *бөре., кмшл.* яры, юка пәрдә (плёнка, перепонка). Қолақ элпәсе. – *кмшл.*

**ЭЛПЕ I** *нгб.-крш.* зелпе (жимолость). Арйақлардан берәү килә, Элпе тайақ тайанған (*хал. җыр.*).

**ЭЛПЕ II: қаты элпеле сыйыр** *мам.* авыр савыла торган сыер (корова с тугими сосками).

**ЭЛПЕЛДӘТҮ** *стрл.* **1.** к.: **элперәтү**; **2.** җилтерәтү (стремительно привести и увести). Элпелдәтеп ике кеше киленне апкереп китә.

**ЭЛПЕР: элпер канат** *м.-кар.* йөнтәс, йонлач канат (мохнатое крыло). Ай, элпер генә канат шул, элпер канат, Аққайын башындагы кукыда (*хал. җыр.*).

**элпер-элпер итү** *м.-кар.* җилфер-җилфер итү (развеваться, колыхаться). Керләр элгән читәнгә, Элпер-элпер итәргә (*хал. җыр.*).

**ЭЛПЕРӘТҮ** *кмшл.* коймакны бик юка итеп пешерү (испечь очень тонкие оладьи).

**ЭЛПЕРӘҮ** *кмшл.* кия-кия юкарып бетү – кием турында (износиться, стать тонким – об одежде). Элперәгән бит күлмәген.

**ЭЛТӘМӘ: элтәмә калмау** *мәл.* к.: **элмә II: элмә чәчәге калмау**. Эштән кат'т'ым, элтәмәм калмаган.

**ЭЛТЕК** *том.д.* амбар.

**ЭЛҮ I** *блт., мам., кргл., т.кам.-крш., злт.* кызның сөлге, тастымал, ашъяулык кебек әйберләре (в старину: часть приданого невесты – полотенца, салфетки, скатерти и т.п.). Элү элеп керәсең инде кергәндә төшкән җиреңә, бийем-бийатага күлмәк. – *блт.* Қодалар бер қат ашағач-эчкәч, элүләрне элеп бетергәчен, бөркәнчек ача торганнар ыйы җәш киленнекен. – *т.кам.-крш.* Элү элеп керә килен, сөлге, намазлыклар, күлмәк. – *кргл.* Иң элгәре элү итеп элә бик матур тастымалны, ул қәйнәнәсенә була, аннан инде үзенә была торган әйберләрне элә, матса қашағасы диләр, бик матур итеп эшләгән була. – *злт.* Қәйнеш йортона кергәндә қыз элү элеп керә. – *мам.*

**әйбер элү** *минз., каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* к.: **тезү III: ызба тезү**. Килен төшкәчтен чәй эчәләр дә әйбер әләргә тотоналар: матча қашағалары, өй әйләндермәләре, фәрдәләр, чаршаулар қороп бетерә, чыбылдықлар қороп бетерә. – *минз.* Бадийаннар салдым миннәр батмасқа, Қәләмперләр салдым ақмасқа; Бу да әйберләрне без әлеп қуйдық, Берсесе дә әйләнеп қайтмасқа (*хал. җыр.*). – *т.кам.-крш.*

**ЭЛҮ II 1.** *срг.* тагу, тагып йөрү (носить на себе). Кызык та безнең Нәймә, бөтү элми, сырга элми, әллә нинди ахуталы кеше түгел; **2.** *мам.* кабу, әләгү (попадать, попасть). Моноң-моноң буй бәртәс элеп җата; **3.** *кузн., карс.* әләктерү, әләктереп алу (хватать, поймать, ловить в ловушку, в капкан). Эл кәбәм, ни булса белән. Йангор әлдеме үзегезне. – *кузн.* Элдегез инде мине капкынга. – *карс.*

**салкын элү** *мәл.* к.: **сүwық: сүwық суғу**.

**тутқа элү** *перм.* кыш көне керне агарсын өчен тышта киптерү (вешать бельё на улице зимой для отбеливания).

**ЭЛҮ III** *туб.-ирт.д.* **1.** җитү (быть достаточным). Йурған әләр мийән өц кешегә?; **2.** җитү (достигать). Күңел қай wақыт әләте, шанта параты.

**ЭМБЕР: эмбер үләне** *минз.* сафия; бүрек сынырчыгы (дескурения).

**ЭМЕР** [*гар.*] *тя.-крш.* к.: **өмер**. Кыз эмере бер эмер, Нәк булмаган эч эмер.

**ЭМЕЧЕКЛЕ** *перм.* сусыл (сочный). Йәш қайынның йапырағы эмечекле була.

**ЭН** *лмб.* өн (голос).

**эн бетү** *лмб.* тын бетү, сулыш кысылу (задыхаться). Тау менгәндә энем бетә.

**э н ә** (игла):

**әкәй энәсе** *байк.*, **сарық энәсе** *злт.* к.: **инә II: чирмеш инәсе**. Сарық энәсе пима йамый торган.

**чәнчү энә** *перм.* к.: **энәлек I, 1**.

**энә карағы үләне** *чст., срг.* к.: **тырнawық**.

**энә мыры** *злт.* энә карагы (стрекоза). Өйгә энә мыры кергән.

**энәдән йепкә түнгенчә** *чст.* барысын, бар булганын, бөтенесен (до последнего, всё без остатка). Энәдән йепкә түнгенчә кызыма биреп бардым.

**энәдән чеметү** *лмб.* бөрү (делать сборки). Энәдән чеметкән була абуркалар.

**ЭНӘК 1.** *туб.-ирт.д.* ана поши (лосиха); **2.** *брб.д.* ана хайван (самка – у животных). Энәк қуй тоғым пулаты.

**ЭНӘЛЕК I 1.** *перм.* булавка. Миңке энәлек тә йуқ; **2.** *перм.* энә мендәре (игольник); **3.** *трх.* тырманың тешләр куела торган агачы (часть граблей, куда вставляются зубья). Себеркенең энәлеге имәндән қуйыла; **4.** *чпр.* сәке такталары кую өчен

аркылы агач (деревянный поперечник, на который кладутся доски нар в избе). Әнәлек куйа да буйы белә такталар тезеп цыга, тезмә урдык була.

**ӘНӘЛЕК II** *төм., тара., эчк.* әнә карагы (стрекоза).

**ӘНӘТАЛАҠ: әнәталағы қалмаған** *к.т.* к.: **әнәталақсыз**. Кийеменең әнәталағы қалмаған, җаным.

**ӘНӘТАЛАҠСЫЗ** *к.т.* сәләмәләнеп беткән, тузып беткән, ерткаланып беткән (сильно истрёпанный, изорванный, обветшалый); чаг.: **қылқа**. Өстенә кигән күлмәге әнәталақсыз.

**әнәталақсыз итү** *к.т.* бик нык туздыру, сәләмәләндерү (сильно износить, истрепать – одежду). Бер ай кимәде, әнәталақсыз итте кәчтүмен.

**ӘНӘХ** *саз.я.* к.: **әнәк 1**.

**ӘНДӘҮЛӘҮ** *блт.* махсус әзерләнеп чакыру (приглашение со специальным приготовлением). Эндәүләп ал, узганда-барғанда гына чақырма.

**ӘНЕКӘ** *саз.я.* әнә (вот, вон). Энекә йатат ғуй.

**ӘНЕР I** *миш.д.* әңгер-меңгер (сумерки). Энер йитә, кетү кат'а. – *лмб.*

**ӘНЕР II: энер бау** *нгб.-крш.* күлмәкнең изүенә төймә урынына тагылган бау (тесёмка, завязка, пришитая к вороту рубашки). Энер бawы элек кенә була торган ыйы.

**ӘНЕЦ** *байк., чпр.* к.: **әнеч**. Арка әнеце. Күлбаш әнеце. – *байк.*

**ӘНЕЧ** *лмб., кузн., хвл.* эчлек, инеч (подкладка). Энечкә салдым фартыгымны. – *лмб.* Пал'томның әнече тузган. Ситчадан нечкә әнеч була, ну тотрокло була ул кийәргә дә, йowарга да. – *хвл.*

**ӘНЕЧКӘ** *м.-кар.* к.: **чекә**. Кашыңны кемнән алдырдың, Кылдан әнечкә калдырдың (*хал. җыр.*)?

**ӘНЕҖИ** [*угор.*] *лмб.* к.: **курл'ак**.

**ӘНҖЕ** *бөре.* вак ак төймәләр (мелкие белые пуговицы).

**әнҗе чәчәк** *кмшл.* ландыш.

**ӘНҖЕНҮ** *т.я.* эчке күңел белән, йөрәк белән кабул итеп бетермәү (не совсем воспринимать). Әнҗенә-әнҗенә бик күп сүзләрне төшереп қалдырдым. – *трх.*

**ӘНЗЕ** *чст.* әнҗе (жемчуг). Әнзе кебек үтә күренмәле аның сuwы.

**ӘНЦЕ** *туб.-ирт.д.* сәйләп (бисерина).

**ӘНЧЕК I** *чст.* кечкенә эт (собачка).

**ӘНЧЕК II** *карс.* күлмәк изүе (ворот рубахи, разрез рубашки, платья). Энчегеңә текер дә бас, дийәләр иде, кыйаш байыгачтанмы (егылгач).

**ӘҢГЕР** *каз.ар.-крш., мам.* к.: **энер I**. Әңгер була, ут алырға кирәк. Әңгердә қайтам қарawылдан. – *каз.ар.-крш.* Почмақларға әңгер кергән инде. – *мам.*

**ӘҢГЕЧ** *перм.* к.: **әпчи: әпчи қарчық**.

**ӘҢЕЛҮ** *кргл.* тынычлану (успокоиться). Тегеләр әңелделәр дә аш эчәргә тытындылар.

**ӘҢЕР I** *нгб.-крш.* к.: **энер I**. Қазақ китә, озатайық, Қомайаққа җиткенче. Қойаш байып әңер қабар, Без айырылып киткенче (*хал. җыр.*). – *нгб.-крш.* Тенә әңер wакытында килде, әңер wакытында мунца кермиләр. – *срг.*

**ӘҢЕР II** *т.кам.-крш.* изү (ворот, разрез рубашки).

**әңер бау** *т.кам.-крш.* к.: **энер II: энер бау**. Әңер баулы булган ирләр күлмәге, төйнәшле булған ул, сәдәп булмаған ул.

**ӘҢЕРЕ: әңере бау** *нгб.-крш.* к.: **энер II: энер бау**.

**ӘҢЕРТ** *себ.* к.: **энер I**.

**ӘҢКӘЛ** *хвл.* эре итеп киселгән токмач (крупно нарезанная лапша). Җәймәне җәйәбез дә кыйыкча кебек кисәбез, шурпада пешерәбез, әңкәл була.

**ӘҢКИ** *бгрс.* к.: **беткелгесе**. Әңки менә шуның кебек йәшләр.

**ӘҢРӘҮ** *себ.* ыңгырашу (стонать).

**ӘПИ** *бөре., минз.* к.: **әпәй**. Эпи кисеп бир әле. – *бөре.*

**ӘПИКӘЙЛӘР** *бөре.* иген, ашлык (хлеба в поле). Эпикәйләр әйбәт быйыл.

**ӘПИКҮР** [*удм.*] *глз.* к.: **икралы**.

**ӘРӘ** [*рус.* разве] *чст., мәл.* к.: **разе**. Ата битенә әрә текерәләр? Әрә шулай әтәләр? – *чст.* Әрә бу нигезне йугалтырга кирәк? Әрә йаланбаш йерергә йарый, никах ыча, йә бүрек, йә эшләпә кийәргә. – *мәл.*

**ӘРӘГӘҢ** [*рус.* рычаг] *саз.я.* к.: **әрәцәк**.

**ӘРӘЖӘ** *стрл.* к.: **нажағай**. Әрәжә ул былытлы булмаганда уйный, сезнең кебек йәшләр курка да аннан.

**ӘРӘЙ** [*рус.* разве] *мәл., срг.* к.: **разе**. Сиксән эч йәш әрәй йәш? – *мәл.* Йылы көн булса, әрәй эшләмиләр чөгендердә? – *срг.*

**ӘРӘЙБӘК** *төм.* яшь килен бөркәнчеге (головное покрывало молодухи). Килен әрәйбәктә утырған аны қортқайақ ацаты йелбеп.

**ӘРӘЙЕШ: әрәйешен китерү** *перм.* яхшы итеп, җаен китереп эшләү (делать как следует, по порядку). Теләсә кемгә дәбирәйт итеп былмый қый, әрәйешен китерегә кәрәг аның. Әрәйешен китереп эшлә.

**әрәйешенә төшү** *тпк.* җаена төшү (приспособиться, подладиться). Мин аның әрәйешенә төшмим, туйны тибәләр дә тибәләр тиб утырам.

**ӘРӘЙЕШКӘ** *каз.ар., к.т.* к.: **аруга I**. Алача киндер ийе, бер-ике кийем әрәйешкә генә булайы сиссы күлмәк. – *мам.* Кизитекләр әрәйешкәйе. – *лш.*

**ӘРӘЙЕШЛЕ** *дөб.* рәтле, тәртипле (порядочный). Әзерәк әрәйешлерәк кирәк, килде-киттеле түгел.

**ӘРӘЙҮ** *тпк.* зураю (увеличиться). Қортларыбыз әрәйделәр. Селек бик әрәйми, тәбәнәгрәк була.

**ӘРӘЛЕК** *минз.* к.: **бастырма**.

**ӘРӘМЗӘЛЕ** *минз.* юкка-барга тавыш чыгаручан, ызгышучан, гаугачыл (скандальный); чаг.: **қыдрач**. Әрәмзәле түгел алай бер дә.

**ӘРӘНҖҮ I 1.** *каз.ар., т.кам.-крш., минз., бгрс., кргл., глз.* к.: **қасталану**. Син мәңгелеккә килгәнсең, әрәнҗемисең, диләр. – *минз.* Бәпкәгез әрәнҗимени? Awырта башым, туңам, әрәнҗим, ахры, дим. – *мам.* Дуңғызым әрәнҗеп тора, кенәген берни ашамады. Қызым әрәнҗи, бизгәкли. Бәпкәләрем әрәнҗи әле. – *каз.ар.-крш.* Бу эшкә бар-

мый әле, эрәнҗештереп җәри. – *т.кам.-крш.* Биг эрәнҗеп үстеләр каз т'ут'уларым. – *глз.*; **2.** *глз.* аптырау, кирәксенү (нуждаться в чём-либо). Утынга биг эрәнҗеп торганнар бабалар.

**ЭРӘНҖҮ II** *минз., мам., шрл.* авыру (болезнь; больной). Бик начар эрәнҗү ул бизгәк. – *минз.* Сау булсаң, җоқосы да тәмне, эрәнҗүнең җоқосы да җуқ. – *мам.* Минем ирем эрәнҗү чагында кәҗә сөте эчәргә куштылар. – *шрл.*

**ЭРӘСӘСЕ** *трх., дөб.* асылы, мәгънәсе (значение, смысл, суть). Эрәсәсен сорамадым шул. – *трх.* Эрәсәсен мин дә белмим инде аның, белеп сөйләмим мин аны. – *дөб.*

**ЭРӘТ 1.** *тмн.* тәртип, закон (порядок, закон, обычай). Эрәтләр алышына бара хәзер awылда; **2.** *тпк.* бик, чиксез (очень много). Сөгендер дә күп, эрәте йуқ. Эрәхәтлекнең эрәте дә йуқ, балалар қәдерен белмиләр.

**эрәт керү** *т.кам.-крш.* көз көне чираттан үткәрелә торган мәҗлескә кунакларның җыелып керүе (обычай заходить всей группой в дом, где проводится очередное осеннее застолье). Эрәт керергә қазанда аш пешә, пичтә чуйында ашлар пешә.

**эрәт җөрү** *т.кам.-крш.* көз көне авылда берберсенә кунакка йөрү (поочерёдное взаимное хождение в гости осенью). Awылның бер башыннан икенче башына эрәт җөридерийек, ул гармун, ул җырлау.

**эрәт җырулары** *т.кам.-крш.* мәҗлес җырлары (застольные песни). Эрәт җыруларын барыбыз да беләбез.

**ЭРӘТӘ: эрәтә қапқа** *бөре.* к.: **қапқа: кәртә қапқа.**

**ЭРӘТСЕЗ** *минз., стрл.* к.: **айаусыз 2.** Сарыкны эрәтсез симертә инде. – *стрл.*

**ЭРӘТСЕЗ-САНСЫЗ** *тпк.* к.: **белеп: белеп тә түгел.** Эрәтсез-сансыз була ул алма.

**ЭРӘФ: эрәфе очу** *мәл.* чырае качу (побледнеть). Сәлимә алмакайның битеннән эрәфе очкан, каста, күрәмсең.

**ЭРӘФЛЕ** *мәл.* матур, сөйкемле (миловидный).

**ЭРӘЦӘК** [*рус.* рычаг] *тара.* күсәк, озын таяк (дубина, жердь).

**ЭРӘШЕЛ** *трх.* к.: **чүмәлә.** Түгәч эрәшел йасап сүсне эрлисең.

**ЭРӘШМӘН** *трбс.* к.: **рәшмән.** Ызбаны тазартып тормасаң, хәзер ойа йасый эрәшмән. Эрәшмән тозағы қорған бу хәйләдән.

**ЭРӘШМЕКИ** *лш.* к.: **болотлы.** Эрәшмеки ул, қашын-қабагын җимерә дә төнтәйеп тик тора.

**ЭРГӘ I 1.** *миш.д., эчк., перм.* к.: **диңгез 2.** Тыскан тишеп эргәләрне бетерә. – *мәл.* Идән астыныме, мының бит эргәсе йук, ди. – *чст.*; **2.** *кузн., хвл.* өйнең тышкы ягына алтмыш-җитмеш см чамасы биеклектә такталар кагып яки читәннән үреп, җылылык өчен арасына туфрак һ.б. салып ясалган нигез (завалинка, сколоченная из досок или сплетённая из прутьев и для утепления дома засыпанная землёй). Бәлчек белән без эргәне сылыйбыз. – *хвл.* Ад'агыз, эргәгә чыгып утырабыз. Менә шул эргәдә бала карап утырам инде мин. – *шрл.*

**эргә күмү** *перм.* к.: **эргә салу.** Эргә күмәләр сuwық кермәскә. Сuwық булмасқа кругум тирәли салып чығалар балчық, аны эчтән дә салып чығалар, эргә күмү диләр.

**эргә кыйу** *чст.* к.: **эргә салу.** Кезен без эргә кыйабыз, йаз башына кире сүтәбез.

**эргә салу** *кргл., лмб., хвл.*, **эргә үү** *чст.* нигез салу (обвалить завалинку). Эргә салдым. – *лмб.* Эргә салгач, ызба йылы булды. – *хвл.* Ызба алнына эргә үwәргә кирәк. – *чст.*

**ЭРГӘ II 1.** *туб.-ирт.д.* буй, озынлык (длина). Крawат эргә. – *тбл.*; **2.** *туб-ирт.д.* ян, янында, буй, буенда (около, вдоль). Йылга эргәсентә. Агацлық эргәтән пар. – *тбл.*; **3.** *себ.* нигез (основа, фундамент дома).

**ЭРГӘДӘ** *кргл.* янәшә (рядом). Чийә җыйа, синең эргәндә генә.

**ЭРГӘРЕ** *себ.* ерак, ары (далеко; дальний).

**ЭРГЕТ** *туб.-ирт.д.* әчегән сөт (простокваша).

**ЭРЕ** *кузн., срг., чпр., чст., хвл., карс., мәл., перм., злт.* көрпә (отруби, высевка муки). Тawыкларга эре ашаттым. Иләдем, эресе күп цыкты. – *срг.* Эреләрне болгыйбыз да тawыкларга бирәбез ашарга. – *кузн.* Бодай эресе. – *хвл.* Ынның эресен алма белә тawыкларга бутап бирәбез. – *чст.* Эресе былса, бик шәп была да тawықларға бутарға. – *злт.*

**ЭРЕЗНӘҮ** *м.-кар.* эренләү (гноиться, нагноиться). Кул чушыннан эрезни.

**ЭРЕК** *к.-уф., перм.* эремчек (творог). Элек қулдан үзләре эшләделәр сауған сөттән эрекне дә, сөзмәне дә. – *к.-уф.* Элеке көн мин бөкмә җасап җыйдым эректән. – *перм.*

**уwыз эрек** *перм.* к.: **ывыз.**

**эрек печин, эрек тити (т'ит'и)** *перм.* к.: **ақ IV: ақ мәтрүшкә.**

**ЭРЕЛҮ 1.** *карс.* күбенү (набухать, разбухать); **2.** *тмн.* кабару (раздуваться, подниматься). Май эченә саласын катламаны, кан'аган майга, шуның чәкле эрелеп китә.

**ЭРЕМ I** *карс., м.-кар.* чәч үреме, толым (женская коса). Арттан эрем эрәләр иде. – *карс.* Катыннар эсткә эремнәрен аркылы бәйләп йөриләр иде. Кызлар эремнәрен сузып лента бәйләп йөриләр иде. – *м.-кар.*

**ЭРЕМ II** *клм.* эрен (гной).

**ЭРЕМЕК** *злт., тпк., к.-уф.*, **ЭРЕМЕТ** *перм.* к.: **эрек.** Қызыма эремек ашарға қушалар. Бездә эремектән қазан кәкересе пешерәләр. – *злт.* Эремек бәрәмәсе бешерәмен. – *тпк.* Ойоған сөтне эремек итеп эшлисен. Эремектән шәңгә бешерәм, әжекәй қайнатам. – *к.-уф.*

**ЭРЕМЗЕМЗЕМ** *мәл.* балалар уены исеме (название детской игры).

**эремцек** *чпр.* эремчек (творог):

**эремцек кәлҗемәсе** *чпр.* эремчек пилмәне (вареники из творога). Эремцек кәлҗемәсе шурпада пешерелә.

**ЭРЕМЧЕК** *мам.* к.: **тура I, 1.** Эремчек қайнаттым.

**қызыл эремчек** *минз.* к.: **тура I, 1.**

**ЭРЕНҮ** *туб.-ирт.д.* иренү, ялкаулану (лениться).

**ЭРЕСЕМӘК** *перм.* к.: **кибер**.

**ЭРЕТКЕ** *злт.* к.: **эрек**. Сыйырлы кеше эреткедән дә пешерә шәңгәне.

**ЭРЕТНЕК** [*рус.*] *төм.* к.: **эртнек**.

**ЭРЕШКЕ** *перм.* чебен (муха). Эрешке дә булмый, чипарат булмағач. Эрешке күбәйде, эрешке тәгаж йуқ бырачта.

**ЭРЕШҮ** *хвл.* эрү – сөт турында (свернуться – о молоке). Сөтем эреште.

**ЭРЕҮ** *злт.* җепшек (слякоть; мокрый). Бөген эреү, пима лаштыр-лаштыр килә.

**ЭРЗИҢКӘ** *каз.ар.* к.: **калуша 1**. Айағына эрзиңкә белән ақ наски кийеп башқawылдан килгән. – *блт.*

**ЭРИДУWАН** [*рус.* рыдван] *чст.* к.: **ад'ур 1**.

**ЭРИК** *тбл.* слива, караҗимеш (слива, чернослив).

**ЭРИН, ЭРН** *саз.я.* ирләрнең бер-берсенә эндәшү формасы (форма обращения мужчин друг к другу).

**ЭРКЕЛДӘП: эркелдәп тору** *бәр.* йомшак булып, эреп тору (быть мягким, таять во рту). Бер қат қаз баш-айагы, бер қат йарма, шулай тутырып пешерәсен бәлешне, эркелдәп тора, чәйнисе дә йуқ.

**ЭРКЕТ 1.** *кргл.* к.: **тура I, 1**. Элек эркет кайнатулар бар иде; **2.** *тпк.* к.: **эрек**.

**эркет қadaны** *тпк.* зур казан (большой котёл). Эркет қadaны нинтәйен dур пит әле, йегерме пиш пидрә сыйа.

**эркет сywы** *тпк.* эремчек суы (сыворотка). Эркет сywы белән йыwам сәсемне.

**эркет сүмесе** *тпк.* зур чүмеч (большой ковш). Эркет сүмесе белән май алып килгән.

**э р л ә ү** (прясть):

**орчог эрләү** *каз.ар.-крш.* җеп эрләү (прясть пряжу). Орчоғ эрли керәләр нардуганда, аның орчоғ эрләүнең тужы үзенең җыры бар.

**ЭРЛЕК 1.** *лмб.* к.: **арқылағач**; **2.** *тмн.* к.: **диңгез 2**. Кыш эчен эрлек куйабыз да йылы була ызбабыз.

**ЭРЛИҒАНДАЙ** *кмшл.* к.: **алапа**. Эрлиғандай ирләр шундый қызу эш эстендә ийдә йата.

**ЭРМӘК** *перм.* к.: **мешке I**.

**ЭРМӘК-ЭРМӘК** *хвл.* таралып торучан (рассыпчатый).

**ЭРМӘКЛӘНҮ** *хвл.* ярмалану, ярмаланып тору (быть зернистым, рассыпчатым). Ком бәрәңгесе, ах'р'ы, эрмәкләнеп тора.

**ЭРМӘКЛЕ** *хвл.* к.: **эрмәк-эрмәк**. Комныкта үскән бәрәңге эрмәкле була.

**ЭРМЕК** *туб.-ирт.д.* тыгыз түгел (неплотный).

**ЭРМЕКЛЕ** *трх.* к.: **икралы**. Бәрәңгенең бүген пешкәне эрмекле икән.

**ЭРНҮ** *глз.* эрү (таять, раствориться). Казның майы эрнеп бетә.

**ЭРПӘК 1.** *срг.* к.: **ангур**. Пухуй эрпәк йапканы йәш килен; **2.** *дөб., мәл.* бөркәнчек (фата). Башларына чалма күк итеп эрпәк салып җәриләр ийе. Әwәлге кеше ул күренмәгән кешегә, эрпәк салып җәргән. – *дөб.* Эрпәкләре чыланып бетә тырган булган йылый-йылый (кызларның). – *мәл.*

**ЭРПЕ I** *кузн.* к.: **эре**. Эрпе йуқ, ак ыннан чүп тә калмый.

**ЭРПЕ II** *лш.* к.: **элпе II: қаты элпеле сыйыр. қаты эрпеле сыйыр** *трх.* к.: **элпе II: қаты элпеле сыйыр**. Қаты эрпеле сыйырыбыз, тартып-тартып cawарға кирәк.

**ЭРПЕК I** *минз.* әрбет (кедр). Эрпек чикләwеге.

**ЭРПЕК II** *перм.* эре, юан (крупный, толстый). Эре бөртөкле икә чәчең, эрпек. Эрпек чәчнең күдрәсе буламы?

**ЭРРӘ** *туб.-ирт.д.* пычкы (пила).

**ЭРТИПИЙЕ** *глз.* иртәнге аш белән төшке аш арасындагы ашау (еда между завтраком и обедом). Эртипийе ашайлар боломда.

**ЭРТНЕК** *том.д.*, **ЭРТНИХ** [*рус.*] *саз.я.* балык пирогы (рыбный пирог). Балыкны қурға төреп, пыйас турап эртнек пулаты. Эртних салмахцыма?

**ЭРҮ I** *карс.* үрү (заплетать косы). Кызнын ике тылым чәчен әрәләр мунчада.

**ЭРҮ II** *кузн., лмб., срг., карс.* к.: **тамызу**. Ут та эрмибез, йатабыз. – *лмб.* Эримме лампаны, караңгы вит. – *лмб.* Ут эрегә инде кирәк. – *кузн.* Сез теге ызбага керегез, ут эрәм ары. – *срг.*

**ЭРҮСӘ** [*гар.*] *төм.* ураза (мусульманский пост). Ике әйет арасынта, эрүсәтә никах уқымасқа қушқан.

**ЭРЧӘК** [*рус.* рычаг] *перм.* юанрак таяк, агач кисәге (палка, часть дерева). Эрчәк сындырып алған, ул черек булған, кәртә инде wы.

**э с** *миш.д.* өс (верх, верхняя часть):

**эсте алмаган** *мәл.* әрчемәгән (неочищенный). Эсте алмаган бәрәңге бик тә тәмне була да, пешермибез шул.

**ЭСЕМӘЛДӘН, ЭСЕМӘЛЕНДӘ** *злт.* кызуында, тиз генә, сузмыйча (быстро, в тот же момент, пока горячо). Эсемәлендә алуны қарыйбыз аны. Эсемәлдән миңа да шалтыратқан да, Риммаға да шалтыратып өлгергән.

**ЭСЕРТҮ** *минз., стрл.* к.: **қыздыру 1**. Чәйне эсертеп алдым. – *минз.*

**ЭСЕРҮ I** *стрл.* к.: **жарайу**. Кызу йаксаң, эсереп тә китә әле ул кыш кыны.

**ЭСЕРҮ II: эрәхат эсерү** *карс.* к.: **гөлмән: гөлмәндә йәшәү**. Иң сewекле малайым иде, үмерендә эрәхатен син эсер, дигән.

**ЭСКӘЙМӘ** *клд.*, **ЭСКӘМБИЙӘ** [*рус.* скамья] *минз.* эскәмия (скамейка). Одон эскәмбийәгә теделеп утырабыd. – *минз.*

**ЭСКӘМГӘ** [*рус.* скамья] **1.** *срг.* к.: **эскәймә**. Нәнәй, утыр, эскәмгә китердем; **2.** *клд.* тау шуу өчен кечкенә эскәмиянең астына такта тотып, боз катырып эшләнгән җайланма (приспособление для катания с горы в виде скамейки). Кызлар ләдән, малайлар эскәмгә белән инде шыwалар.

**ЭСКӘМИ** *чпр.* артлы урындык (стул, кресло). Лаукада эскәмиләр бар, дир, алып кат'ырга инде.

**ЭСКӘМИЙӘ I** [*рус.* скамья] *лш., чпр.* урындык (стул). Җимерек эскәмийә ул, аңарга утыра алмыйсың. Сезгә эскәмийә алып қалдым. – *лш.*

**ЭСКӘМИЙӘ II** *хвл.* көлтә киптерү ысулы: көлтәләр ике-өч рәт итеп озынча формада тезеп утыртыла (один из способов сушения снопов).

**ЭСКЕ I** *туб.-арт.д.* эскәк (щипчики, пинцет).

**ЭСКЕ II** *злт.* к.: **эчемтек**. Ул wақытта эске йуқ.

**ЭСҚЫР** *злт.* нечкә бау, ычкыр (тонкая верёвка; очкур, шнур, вдетый в шаровары). Резинкы өстөннән эсқыр белән бәйләргә кирәк.

**ЭСМИЛИНМИ'И** *кас.* к.: **билтәләнү**. Чәслирим эсмилин'ин.

**ЭССЕ** *тбл.* аш (суп). Эссе пешерәсесмә?

**ЭССЕ-ЙЫЛЛЫ** *сазл.* кайнар аш (горячая еда). Килүләренә эссе-йыллы пешерәм.

**ЭССЕЛӘҮ** *перм.* к.: **аш II: аш сайлау**. Бәрәңгегә эсселәдем. Балыққа эсселәдем. Мин бик шәп эсселәп йөрдем печин чақта.

**ЭССЕНҮ** *тбл.* **1.** җылыну (греться); **2.** эсселәнү (изнывать от жары). Эссенеб ултырабыс.

**ЭССЕРТҮ** *минз., тпк., стрл.* к.: **қыздыру 1**. Әзерәк эссертә бирдем дә шикәр салдым балға. – *тпк.*

**ЭССЕРҮ** *нгб.-крш.* к.: **жар: жар алу 1**. Эссергән бит су. Көннәр эссерде.

**ЭССЕСЕРӘҮ** *тбл.* җылыту (подогревать).

**ЭССЕТҮ** *тбл.* к.: **қыздыру 1**.

**ЭССҮ** *туб.-арт.д.* **1.** эсселәнү, кайнарлану (стать горячим); **2.** эссе (горячий).

**ЭСТ** *м.-кар.* к.: **кочок**. Аларны эстләре йук.

**ЭСТӘКЕР** [*рус.* скатерть] *карс., лмб., кузн.* к.: **ашаулық**.

**ЭСТӘЛ** [*рус.* стол] *лмб.* табын (застольная компания). Ике эстәл кунаклар җиган.

**эстәл җапмасы, эстәл йапмасы** *чст.* к.: **ашаулық**.

**эстәл кыру** *лмб.* табын, аш әзерләү (накрыть на стол). Хазер эстәл кырабыз, чәй эчәрсез.

**ЭСТӘРЛӘНҮ** [*гар.*] *т.кам.-крш.* әзерләнү, хәстәрләнү (готовиться, собираться).

**ЭСТӘҮ 1.** *срг.* теләү (хотеть, желать). Күпме йаның эсти, шулай тага иден тәңкәләрне; **2.** *лмб., каз. ар., минз., себ.* эзләү (искать). Шандый сүзләрне эстәп йөрүчеләр алар. – *лмб.* Қайсылар усаллық эсти. – *минз.* Питйаулық эстәтем. – *тбл.*; **3.** *лмб., каз.ар.* юллау, артыннан йөрү (хлопотать). Өстеннән эстәүче кеше булмады, эстәсәләр, табыладырыйы жүгисә. – *дөб.* Эстәмәсәң, булмас ул. – *мам.*

**ЭСТЕ I** *лмб.* **1.** төбе (у, около). Ишег эсте; **2.** ...-да (в, на). Авыл эстендә идем. Дөнйа эстендә андый хал'ләр була.

**ЭСТЕ II** *мам.* к.: **жар**. Эстегә күрә эчми торғандыр инде.

**ЭСТЕ III** *кузн.* вакыты, өсте (время).

**картуг эсте** *кузн.* бәрәңге алу вакыты (время уборки картофеля). Картуг эсте иде, эш күб иде.

**сугыш эсте** *глз.* сугыш вакыты (военное время). Сугыш эстендә awыр булды.

**уйын эсте** *чст.-крш.* җәйге уеннар вакыты (время летних хороводов, игр). Жиде атна җымырка ун'ибыз, уйын эсте дибез.

**ЭСТЕНӘ** *лмб.* артык, югары (больше). Йөз эстенә труддин эшләде.

**эстенә куйган** *хвл.* бик охшаган, суйган да каплаган (вылитый, очень похожий). Малайы атасының эстенә куйган.

**ЭСТЕНДӘ** *карс.* к.: **гоманда**. Эстендә бар иде шыл апаныкы. Хатынысының баласы калды эстендә сигез айлык.

**ЭСТЕРНӘЧ** [*морд.*] *м.-кар.* к.: **балдыз 2**. Мине катыным мине сеңелемә эстернәч ди. Эстернәч дип мине сеңелемә катыным әйтә.

**ЭСТИЙКӘ** [*рус.* стойка] *блт.* к.: **утыртма**. Эстийкә ағач тақтадан йасала, ул қыйық, тишекле, су салып аппарабыз басуға; аның awызы қаплаған була, ике тишеге була, берсе эчә торған, берсе вуздых бирә торган, шул булмаса, су чықмый.

